ТАТАР

ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР М.Х. ХӘСӘНОВ

2

Г–Й

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ
2010

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ҖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

Баш гыйльми мөхәрририят

М.Х.Хәсәнов (рәис), Р.К.Абдуллин, С.С.Айдаров, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, Р.М.Вәлиев, З.Р.Вәлиева, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, А.Х.Гыйльметдинов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Ә.М.Мазһаров, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, Г.С.Сабирҗанов (рәис урынбасары), К.М.Салихов, М.Х.Сәлахов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.


© «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2010.
«Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында»гы РФ Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

ISBN 978-5-902375-06-7

# Г

**ГАБӘ́Ш** (псевд., чын исем-фамилиясе Гобәйдулла бине Кәлимулла әл-Әлдермеш әл-Болгари) (1785, Казан өязе Әлдермеш а. — 1874 тән соң), дин эшлеклесе, шагыйрь, хаттат. Йомышлы татар гаиләсеннән. Х.*Габәшинең* бабасы. Башлангыч дини белемне Олы Кавал авылы мәдрәсәсендә мөдәррис Габдеш хәзрәттән ала. 1812 елда Бохарага укырга китә. Уку елларында язылып, хатыны Бибифатыйма бинте Сәйфелмөлек исеме б-н аталган «Фатыйманамә» шигъри җыентыгы сакланган (Бохара, 1813, кулъязма рәвешендә). 19 йөз башына караган аз санлы шигъри әсәрләрдән саналган бу китапта (135 бәйт, 270 юл) авторның гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызның тоткан урыны турында карашлары һәм фикерләре урын алган.

Бохарадан кайтканнан соң, 1822 дә, Г. Казан өязе Кече Солабаш авылы мәчетенең имам-хатибы була. Тиздән ул үзен югары белемле исламият галиме, Шәрекъ әдәбияты әсәрләрен күчерүче хаттат һәм кабер ташларына язулар уючы оста буларак таныта. 1864 тә Казан тюркологы Е.Малов: «Гобәйдулла күчермәләренең кайберләре Казан ун-тында саклана», — дип яза; И.Ф.Готвальдның «Казан Император университеты китапханәсе карамагындагы гарәп кулъязмалары тасвирламасы» («Описания арабских рукописей, принадлежавших библиотеке Императорского Казанского университета», 1855) китабында Г.нең берничә кулъязмасы күрсәтелә. Алар арасында Шәрәфетдин бине Хисаметдиннең «*Тәварихы Болгарийә*»се (1832 елгы күчермә); Насретдин Рабгузиның «*Кыйссас әл-әнбия*»се («Пәйгамбәрләр тарихы»), Хисаметдин Әбелхәер бине Мөсләхетдин Мостафа Ташкөпрезадәнең (1495–1560) «Шакаик әл-ногъмания фи зикр голәмә әд-дәүлә Госмания»се («Госманлы дәүләте галимнәре һәм шәехләренең тормыш бәяны») һ.б. бар.



Шәрәфетдин бине Хисаметдиннең «Тәварихы Болгарийә» әсәре битләре. Нәсех язуы. 1832 елгы күчермә.

Г. ишан Нигъмәтулла әл-Әлмәтинең Казанга һәм аның тирәсендә сәяхәт кылуы хакында «Хөласа әл-бәян» («Бәян ителгәннәрнең асылы») (1889 да басыла) исемле шигъри әсәр авторы. Ул 19 йөзнең 40 нчы елларында язылган дип фаразлана. Әлеге китапта һәм «Фатыйманамә»дә автор тарафыннан күп гарәп-фарсы алынмалары кулланылса да, стильне гадиләштерү, 19 йөзнең 1 яртысында татар әдәбиятында традициягә кергән шигырьне бизәкләр б-н артык чуарлаудан котылу омтылышы чагыла.

Г. — гарәп галиме Габделкаһир бине Габдрахман Җирҗәнинең «Китап әл-гавамил әл-мийа» (1078) — «Йөз кисәкчә китабы»на һәм гарәп теле грамматикасына (*Мөхәммәд Нәҗип Түнтәри* китапханәсеннән) фарсы телендә шәрехнамәләр яза. Алар Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә саклана.

Г.ның уллары әтиләренең хаттатчылык һөнәрен дәвам иттерәләр. Өлкән улы Әхмәт Казанның Яңа татар бистәсендә яши. Казан ун-ты китапханәсендә аның 1844 елгы кулъязмасы саклана. Кече улы Мөхәммәд 1850 дә Кече Солабаш авылының икенче мулласы (әтисе б-н бергә) итеп билгеләнә. Ул шулай ук китап күчерүче һәм кабер ташларына язу төшерүче буларак мәгълүм. Г. хезмәтләре бүтән каллиграфлар тарафыннан күчереп алынган.

*Әд.:* Кулъязмалар тасвирламасы. VII чыг. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары / Төз. А.Фәтхи. К., 1969; М а л о в Е. Миссионерство среди магометан и крещёных татар. К., 1892; Султан Габяши: Материалы и исследования. К., 2000; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 2001.

*М.В.Гайнетдинов, Р.И.Шәмсутов.*

**ГАБӘ́ШЕВ** Рөстәм Солтан улы (10.5.1941, Уфа ш. — 2.1.2010, Казан), археолог, тарих фән. канд. (1978), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). С.Х.*Габәшинең* улы. Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1974 елдан СССР ФА Казан филиалының, 1992 дән РФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1993 тән ТР ФАнең Тарих ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. ТР Дәүләт бүләге *Татарстан Республикасының археологик картасын* төзүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәтләре Идел буе һәм Урал төбәкләренең таш һәм бакыр гасырлар археологиясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Второе Татарско-Азибейское поселение // Древности Икско-Бельского междуречья. К., 1978; Тенишевский («Сорокин бугор») энеолитический могильник // Новые памятники археологии Волго-Камья. Йошкар-Ола, 1984 (автордаш); Нижнее Прикамье в эпоху неолита // Очерки по археологии Татарстана. К., 2001; Население Нижнего Прикамья в V–III тысячелетиях до нашей эры. К., 2005

**ГАБӘШИ́** Солтан Хәсән улы (Солтанәхмәт Хәсәнгата улы) (1.5.1891, Казан губ., Казан өязе Кече Солабаш а. — 8.1.1942, БАССР,



С.Х.Габәши.

Борай р-ны Чалкак а.), композитор, музыка белгече, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе. Х.*Габәшинең* улы. Кече Солабаш мәдрәсәсендә, Уфада «Госмания» һәм «Галия», Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый (1899–1911); 1911 елда Уфада Оренбург Диния нәзарәтендә имам-хатиб һәм мөдәррис булып эшләү өчен имтихан тапшыра. 1912–15 тә Уфа реаль уч-щесендә, 1915–17 дә Казан ун-тының юридик ф-тында укый. 1918–22 дә Казан уку йортларында, ш.и. Шәрекъ консерваториясендә (1920–22) эшли. 1922–32 дә Шәрекъ музыка техникумында музыка теориясе һәм хор фәннәрен укыта, мөдир урынбасары, бер үк вакытта Казан уку йортлары һәм мәдәни-агарту оешмалары каршында хорлар оештыра. 1930 еллар башында аның иҗаты һәм җәмәгать эшчәнлеге вульгар социологизм карашларының чыгып кискен тәнкыйтьләнә. Шул сәбәпле 1932 дә Казаннан Уфага күченеп китәргә мәҗбүр була. 1932–36 да Башкорт Милли мәдәният фәнни-тикшеренү ин-тында сәнгать белеме бүлеге фәнни хезмәткәре, бер үк вакытта Башкорт сәнгать техникумында музыка теориясен укыта һәм хор җитәкчесе булып эшли. 1936–41 дә БАССР ХКСның Сәнгать эшләре идарәсе каршындагы муз. фольклор кабинеты фәнни хезмәткәре һәм мөдире. 1941–42 дә Чалкак урта мәктәбендә музыка укытучысы. Г. иҗат эшчәнлеген 1909 дан пианист һәм аккомпаниатор буларак башлый. Аннан соң Уфада, Казанда әдәби-муз. кичәләр, лекция-концертлар, вокаль ансамбль һәм хорлар оештыру б-н шөгыльләнә. Татар хор музыкасын үстерүгә мөһим өлеш кертә. Г.нең композиторлык иҗатында милли сәхнә музыкасы әсәрләре зур урын алып тора. 1917–28 дә милли театрның Г.Исхакый, Ф.Бурнаш, К.Рәхим һ.б. пьесалары буенча куелган 10 нан артык спектаклендә музыка иҗат итә. Г. беренче татар опера коллективын оештыруда катнаша, беренче татар опералары «*Сания*» (1925) һәм «Эшче»не (1930, Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов б-н бергәләп) иҗат итүчеләрнең берсе була. Бу опералар Татарстанда композиторлык иҗаты һәм муз. башкару сәнгате үсешендә зур роль уйный. Г. хор өчен, ш.у. вокаль һәм инструменталь әсәрләр иҗат итә, татар һәм башкорт җырларын эшкәртә. Иҗатында милли фольклор (бәетләр, озын көйләр) элементларын куллануга омтыла, Шәрекъ халыклары музыкасы б-н кызыксына.



Х.Габәши.



С.Ф.Габбасов.

Шул ук вакытта халык музыкасы традицияләрен Европа классик музыкасы тәҗрибәсе б-н баету юлларын эзли.

Г., беренче татар музыкасы белгече һәм фольклорчы-этнограф буларак, фольклор экспедицияләре вакытында 200 дән артык татар, 100 ләп башкорт көйләрен җыя һәм туплый, музыка иҗаты турында лекцияләр укый, татар һәм башкорт телләрендә музыка буенча әсбаплар, дәреслекләр төзи, татар һәм башкорт музыка мәдәниятенә кагылышлы актуаль проблемаларны яктырткан мәкаләләр яза. Аның иң мөһим язмаларының берсе — «*Яңалиф*» ж-лында татар музыкасы турында басылган (1931, № 3–6) анкета сорауларына җаваплары. Анда татар музыкасы үсешенең киләчәктәге тулаем фәнни-тарихи юлын анализлауга беренче омтылыш ясала. Г.нең күпкырлы иҗат эшчәнлеге энциклопедик характерга ия булып тора, хәзерге татар һәм башкорт музыкасы мәдәниятенең төп юнәлешен билгеләүгә хезмәт итә.

Төп әсәрләре: «Сания» (1925), «Эшче» (1930) опералары (Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов б-н берлектә); «Зөләйха» (Г.Исхакый), «Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Бүз егет» (К.Рәхим), «Фәтхулла хәзрәт» (Ф.Әмирхан), «Йосыф белән Зөләйха» (К.Әмири), «Җир уллары» (Һ.Такташ) һ.б. спектакльләргә музыка; «Кәккүк», «Оркыя», «Эшче кызы», «Ике заман», «Курай» җырлары; хор өчен татар һәм башкорт җырлары эшкәртмәләре; вокаль һәм камера-инструменталь әсәрләр, ш.и. фортепиано өчен «Пикник», «Кайгы», «Кайгыдан соң шатлык», «Яшьлек» исемле пьесалар; симф. оркестр өчен «Яңалиф маршы» (Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградов б-н берлектә) һ.б.

Х е з м.: Уфада музыка мәсьәләсе // Вакыт. 1910. 12 гыйнв.; Музыканың эшләнеше // Безнең юл. 1925. № 7–8; Татар сәхнәсендә музыка // Татар театры (1906–26). К., 1926; Татарстанда курайчылар һәм гармунчылар // Атака. 1932. № 1; Программа по музыке для начальной школы. Уфа, 1933.

*Әд.:* Н и г ъ м ә т җ а н о в М. Солтан Габәши турында биографик белешмә: Яңа документлар // Казан утлары. 1967. № 7; С ә й д ә ш е в а З. Солтан Габәшинең тууына 90 ел // Казан утлары. 1981. № 5; Х а й р у л л и н а З., Г и р ш м а н Я. Султан Габяши // Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; Н и г м е д з я н о в М.Н. Султан Габяши // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; С а л и т о в а Ф. Габяши Султан Хасанович: 100 лет со дня рождения // Ежегодник памятных музыкальных дат и событий. М., 1991; Газиз Альмухаметов и Султан Габяши в Казани: Материалы и док. Уфа, 1995; Султан Габяши: Материалы и исслед.: В 2 ч. К., 1994–2000.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГАБӘШИ́** Хәсәнгата (11.1.1863, Казан губ., Казан өязе Кече Солабаш а. — 7.8.1936, шунда ук), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог. Башлангыч белемне бабасыннан һәм атасыннан ала. 1874–86 елларда Казандагы Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсендә укый һәм соңрак шунда мөгаллимлек итә. 1889 да Казан эшмәкәрләре бертуган Юнысовларның мөселман балалары ятимханәсендә укыта һәм анда, шәһәрдә беренчеләрдән булып, җәдитчә укыту ысулларын кертә. 1890 да Кече Солабаш авылы мәчете имам-хатибы. 1894 тән — *ахун.* 1895–99 да Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә *казый*, бер үк вакытта «Галия» һәм «Госмания» мәдрәсәләрендә укыта, төрле химаячелек җәмгыятьләренең әгъзасы булып тора. 1899 да, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Кече Солабашка кайта һәм сәүдәгәр Г.Хөсәеновның матди ярдәме б-н җәдитчә белем бирә торган мәктәп ача, анда традицион дәресләр б-н беррәттән тарих, география, Шәрекъ халыклары мәдәнияте укытыла. 1905–15 тә яңадан Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә казый. 1915 тә Кече Солабаш авылы мәдрәсәсенә кайта. 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә катнаша (президиумга сайлана). 1917 дән Казан өязенең идарәсе Кече Солабаш авылында урнашкан 2 нче мөхтәсибәтендә *мөхтәсиб* вазифаларын башкара, бер үк вакытта фәнни һәм пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Окт. рев-циясеннән соң Арча кантоны пед. курсларында укыта. ТАССР Үзәк музееның татар-мөселман коллекциясен туплауда зур роль уйный. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтендә Голәмалар шурасы әгъзасы (1923). 1932 нең гыйнварында кулга алына, хөкем ителеп, Архангельск өлкәсенә төзәтү эшләренә сөрелә. 1936 ел башында, сәламәтлеге какшау сәбәпле, ирекккә чыгарыла. Фәлсәфә, педагогика, тарих мәсьәләләренә кагылышлы хезмәтләр авторы. «Ефим Маловка рәддия» (1886), «Тәрбияле бала» (1889), «Саулык» (1889), «Басыйрәт» (1889) мәкаләләрендә Г. фәлсәфә, пед. һәм мәгариф реформасы мәсьәләләрен күтәрә, кадими мәдрәсәләрдәге укыту процессын тәнкыйтьли һәм татар яшьләренә белем бирү өчен төзелеше ягыннан рус гимназияләре программасына охшаш дөньяви программа кертергә тәкъдим итә. 1890 да бабасы Габәшинең «Хөласа әл-бәян» («Бәян ителгәннәрнең асылы») дип исемләнгән шигырьләр җыентыгын, ш.у. шәригать тарихына караган «Ысуле фикъһ тарихы» («Фикъһ ысуллары тарихы») хезмәтен бастырып чыгара. Г. татар тарих гыйлемендә беренче булып туран (сары) расасы барлыгын икърарлый, һәм ул бу расага уртак ватан — «Олуг Төркстан» халыкларын — малайялы, кытай, япон, фин һәм төркиләрне кертә. Г. һун, скиф, гиперборияле, сармат, авар, аланнарны төркиләр дип атый, угор-венгр, башкорт, болгар-хәзәр һәм мажар-мишәрләрне угор-болгар төркеменә берләштерә. «Татар» этнонимын ул Себер һәм Ерак Көнчыгыш халыклары б-н бәйләп аңлата. Г. татар милләтенә «Россия төрекләре» дип билгеләмә бирә. Аның фикеренчә, болгарлар — төрекләр б-н *сәкълаблар* кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән халык һәм шунлыктан болгарларның ханы сәкълаб хакиме дә булып тора. Г. Болгар дәүләтенең мөселман динендә булуын, аның күрше халыкларга ислам динен таратудагы ролен ассызыклый, төрки халыклардагы идарә итү ысулларын, дин, мәдәният, мәгариф, фән, хуҗалык тәртибе, хәрби сәнгать мәсьәләләрен анализлый.

Х е з м.: Төрк ыруглары. К., 1897; Мөхтасар тарих кауме төрк. К., 1899; Мөфассал тарих кауме төрк. К., 1909.

*Әд.:* Ислам в Среднем Поволжье: История и современность. К., 2001; С а л и х о в Р. Габаши Хасан-Гата // Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1999. Вып. 2.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**ГАББА́СОВ** Айдар Минсабир улы (25.3.1959, Арча р-ны Штерә а.), галим-агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1981), Арча р-нында эшли: «Заветы Ильича» к-зында баш агроном (1982 дән), Вахитов исем. к-з рәисе урынбасары (1987 дән), «Ракета» к-зы рәисе (1989 дан), «Арча сөт комбинаты» АҖ ген. директоры (1998 дән), авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, бер үк вакытта район хакимият башлыгының 1 нче урынбасары (2001 дән). Дәүләт бүләге «Рапс җитештерү, эшкәртү һәм файдалануның фәнни дәлилләнгән икътисади нигезләрен гамәлдә киң куллану» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГАББА́СОВ** Назыйм Салих улы (29.1.1958, Мамадыш р-ны Дусай а.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1980 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол. ин-тының (хәзер Казан технол. ун-ты) Түбән Кама ф-лында, 1990 нан Чаллы пед. ин-тында матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре Фредгольм тигезләмәләре тибындагы сызыкча интеграль тигезләмәләрне чишү ысулларына карый. 3 нче һәм 1 нче төр интеграль тигезләмәләрне чишүгә яраклаштырып, төп һәм гомумиләштерелгән функцияләр фәзаларында якынаю теориясен төзи. Бирелгән тигезләмәләрне гомумиләштерелгән функцияләр фәзасында классик туры проекция ысуллары б-н чишүгә нигезләнеп, исәпләү алгоритмнарын төзи һәм нигезли.

Х е з м.: Оптимальный метод решения интегральных уравнений 3-го рода. // Докл. РАН. 1998. Т. 362. № 1; Теория разрешимости одного класса интегро-дифференциальных уравнений в пространстве обобщенных функций // Дифференциальные уравнения. 1999. Т. 35, № 9.

**ГАББА́СОВ** Сәет Фәйзерахман улы (8.9.1925, Тәтеш р-ны Үтәмеш а. — 17.3.2007, шунда ук), механизатор, Соц. Хезмәт Герое (1973). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда Тәтеш р-ны Монастырский авыл һөнәри-техник уч-щесен тәмамлый. 1941–85 тә шул ук районның «Алга» к-зында: колхозчы, тракторчы, трактор бригадасы бригадиры (1963 тән). Г. җитәкчелегендә бригада системалы рәвештә фән һәм алдынгы техника ка-

занышларын гамәлгә кертә, игенчелекнең югары культуралылыгына ирешә, 1973 корылык елында да бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 33,5 *ц* уңыш алына. Герой исеме бөртеклеләрдән югары уңыш алган өчен бирелә. КПССның 25 нче съезды делегаты (1976). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Зыятдинов Ф.С. Сын полей. К., 1975; Мягков Г. Габбасов Саит Файзрахманович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАБДЕЛБАРИ́** (19 йөзнең 2 нче — 20 йөзнең 1 нче яртысы) (кайбер мәгълүматларда — Мөэминов Габделбари), ташка уеп язучы, хаттат, *кятиб*, дин эшлеклесе. Казанның Дары з-ды бистәсе мәчете имам-хатибы. Ул эшләгән кабер ташларының берсе Биектау р-нындагы Өлә Казагы (хәзер Казаклар) авылы зиратында саклана. Ак известьташтан плитә рәвешендә эшләнгән ядкәр (үлчәме 107×34×18 *см*) 1890 елда Әхмәтҗан бине Халид каберенә куелган. Аның турыпочмаклы өлеше дугасына: «Би хөкем Аллаһу Тәгалә» («Аллаһ хөкеме алдында торучы») дигән гыйбарә уелган ярымтүгәрәк рәвешендә төгәлләнә. Истәлек язуының ташның алгы ягындагы 6 юлы гарәп язуының нәстәгъликъ стилендә башкарылган һәм турыпочмаклы кыса эченә алынган. Ташның ян-якларына Коръәннән кыска аятьләр һәм останың имзасы — «Кятиб Габделбари» дип уелган. Язма тирән уеп кисү техникасы б-н башкарылган. Бизәкләр кулланылмаган. Язу стиле һәм башкару техникасыннан чыгып фикер йөрткәндә, 1880–1920 елларда Казан һәм аның тирәсендәге авылларның зиратларында кызыл мәрмәрдән куелган кабер ташлары ш.у. Г. тарафыннан эшләнгән. 2006 да эпиграфик экспедиция вакытында Г.ның тагын бер имзалы эше Пенза өлкәсе, Кузнецк р-ны Пәндәлгә авылы зиратында ачыкланды. Әлеге истәлек пирамида формасында кызгылт мәрмәрдән эшләнгән. Анда уеп «сөлес» стилендә гарәп телендә текст язылган. Аста бер урында «Кятиб Габделбари әл Баруди, әл Газани» дигән имзасы бар. Язмада 1906 ның 14 февралендә 86 яшьтә вафат булган Яхъя бине Габденнасыйр Дибердиев җирләнгәнлеге бәян ителә.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕЛВАҺА́Б бине МОСТАФА́** (18 йөз), татар шагыйре. Оренбург губернасының Минзәлә өязе Дәвек авылында укыган елларында «Ике сукыр» (1780 ел тирәсе) балладасын яза. Кулъязмасы ТР Дәүләт музеенда саклана. Әсәрләренең төп темасы — мохтаҗларны кызгану, бозыклыкны тәнкыйтьләү. Балладаның чәчмә варианты Таҗетдин *Ялчыголның* «Рисалә-и Газизә» (1795) китабында урын алган һәм татарлар арасында киң таралган.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕЛГАНИ́ЕВА** Гүзәл Габдерәүф кызы (13.1.1958, Казан), китап белгече, филол. фән. д-ры (2007), проф. (2007). 1981 елда Казан мәдәният ин-тын (хәзер Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1983 тән китапханә мөдире. 1986 да китапханәчелек белеме кафедрасында, 1995 тән документларны өйрәнү кафедрасында (1998–2002 елларда каф. мөдире). Хезмәтләре Казанда китап бастыру һәм китап сәүдәсе тарихына карый.

Хезм.: Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005; Издательская и типографская деятельность Казанского университета во второй половине XIX века. М., 2005; Книжная торговля в Казанской губернии. Вторая половина XVIII века — 1917 г. К., 2006.

**ГАБДЕЛҖАББА́Р бине ГАБДЕРАХМА́Н әл-ОРНАШБАШЫ́** (? — 1829), дин эшлеклесе. *Юныс Иванайның* оныгы. Казан губернасы Орнашбаш авылы мәчете имамы. 1823 елда Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәте казые итеп сайлана. Мөхәмммәтҗан Хөсәеновның вафатыннан соң (1824), Габдессәлам Габдрәхимов билгеләнгәнчегә кадәр (1826 ның феврале) мөфти вазифаларын башкара. 1826 дан Казандагы «Барудия» мәчете имамы.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ГАБДЕЛКӘРИ́М ХАН** (? — 1520 еллар), Әстерхан ханы (1490 еллардан). Әхмәд ханның оныгы. 1490 еллар башында Олы Урда гаскәре ярдәмендә *Касыйм ханны* тәхеттән төшерә, хакимиятне үз кулына ала. Олы Урда ханнары б-н якын бәйләнештә тора, аларның Кырым ханлыгы һәм Мәскәү кенәзлегенә каршы оештырылган яуларында катнаша. 1491 елда Г.х., Олы Урда ханы Мортазага (Әхмәд хан улы) ярдәмгә килеп, Кырымга һөҗүм итүдә катнаша, ләкин Кырым ханының союздашлары булган Казан һәм Мәскәү гаскәрләре тарафыннан җиңелүгә дучар ителә. Олы Урда ханлыгының көчсезләнә баруы Г.х.да мөстәкыйль идарә итү омтылышы тудыра, ул үз хакимиятен ныгыту сәясәтен үткәрүгә керешә. 1498 дә Олы Урда ханы Сәедмөхәммәд (Әхмәд хан улы) гаскәренең ханлыкка һөҗүмен кире кайтара. Миңлегәрәй хан тарафыннан Олы Урда тар-мар ителгәннән соң (1502), Г.х. тышкы сәясәттә Кырым ханлыгы б-н Нугай Урдасына йөз тота башлый.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Заметки об Астраханском ханстве // Сб. статей преподавателей Мордовского гос. пед. ун-та. Саранск, 1952; Османская империя и страны Центральной, Восточной и Юго-Восточной Европы в XV–XVI вв. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**ГАБДЕЛКӘРИ́МОВ** Ногман (3.1.1840, Казан губ., Царёвококшай өязе Олы Көек а. — 1918), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, 1895 елдан тукымалар б-н сәүдә итүче ширкәт хуҗасы. 1911 нең гыйнварында Казанда 30 мең сумлык сәүдә капиталы булган «Н.Габделкәримов сәүдә йорты» ширкәтен нигезли. Казан һәм Царёвококшай өязләрендә аның матди ярдәмендә 10 нан артык мәчет төзелә.

**ГАБДЕЛЛАТЫ́ЙФ** (1475 тирәсе, Казан — 19.11.1517, Кашира ш.), Казан ханы (1496–1502). *Ибраһим* хан б-н *Нурсолтан* ханбикәнең улы, *Мөхәммәдәминнең* энесе. 1485 елда Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыгуы сәбәпле (Мөхәммәдәмин Казан тәхетеннән икенче тапкыр бәреп төшерелгәч), энисе Г.ны үзе белән Кырымга алып китә, ул Бакчасарайда тәрбияләнә. 1490 еллар башында Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III кә хезмәткә җибәрелә, бөек кенәз аңа уделга Звенигород шәһәрен бирә. *Мамык* хан үтерелгәч, Казан аксөякләренең үтенече буенча, Иван III аны Казан тәхетенә утырта. Баштарак Г. тышкы сәясәттә Мәскәүгә карап эш йөртә. 1499 да Себер ханлыгына йөз тоткан Казан аксөякләре Урак бәк җитәкчелегендә фетнә оештыргач, аны бастыра. 1500 еллар башында Мәскәүдән бәйсез сәясәт үткәрергә омтыла, ләкин Мәскәүгә йөз тоткан, башында карачыбәк *Колмөхәммәд* торган Казан аксөякләренең каршылыгына очрый. Г. тәхеттән төшерелә һәм Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Белоозеро шәһәренә сөрелә. 1510 ның җәендә Нурсолтанның Мәскәүгә уңышлы сәфәреннән соң Мәскәү кенәзлеге б-н Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләр яхшыргач, Г. сөргеннән Мәскәүгә кайтарыла. Ләкин Миңлегәрәй вафат булгач (1515), Мәскәү б-н Бакчасарай арасындагы үзара мөнәсәбәтләр бозыла башлый. 1517 елда (башка мәгълүматларга караганда, 1518 нең ноябрендә) Кашира шәһәрендә Г. билгесез шартларда һәлак була.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Казан ханнары. К., 1995; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ГАБДЕЛМӘҖИ́Д** (14 йөзнең 2 нче яртысы — 15 йөз башы), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. Кайбер мәгълүматларга караганда, 1410 елларда Кырымда яшәгән. Бүгенге көнгә Сәйф Сараи тарафыннан назыйрә язылган «Күңел» исемле газәлләренең берсе генә килеп җиткән һәм «Китабе Гөлестан бит-төрки» китабында сакланып калган. Йосыф-Зөләйха сюжетына нигезләнеп язылган поэма (сакланмаган) авторы.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

**ГАБДЕЛМӘҖИ́ТОВ** Рафил Гыйният улы (29.3.1947, БАССРның Октябрьск ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), техник фән. канд. (1983), ТРның атказ. уйлап табучысы (1996). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), ТатНИПИнефтьтә сектор, лаб., бүлек мөдире, 2000 елдан директор урынбасары. Нефть чыганакларын үзләштерү ысуллары буенча 50 гә якын ачышы бар. Дәүләт бүләге «Авыр чыгарыла торган нефть запасларын эшкәртүнең югары нәтиҗәле комплекслы системасы» дигән хезмәте өчен бирелә.

Хезм.: Геология и разработка крупнейших и уникальных нефтяных и нефтегазовых месторождений России. М., 1996 (автордаш).

**ГАБДЕЛМӘ́Н** Сабир (1879, Самара губ., Богырыслан өязе Котлымбәт а. — 22.12.1917, хәзерге Кыргызстан Респ-касы, Җидесу өлкәсе Тукмак ш. ), татар шагыйре. 1902 елдан «Икъбалия» мәдрәсәсендә укыта (хәзерге Кыргызстан Респ-касы Карагол ш.). 1910 да Төркия, Мисыр, Согуд Гарәбстанына сәяхәт кыла. 1914 тә Россия армиясенә алына, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Яралана, авыру сәбәпле демобилизацияләнә. Ши-

гырь, хикәя, публицистик мәкаләләре «Шура» ж-лында, «Кояш» г-тасында һ.б.да басыла. Пржевальск шәһәрендәге Татар-кыргыз җәмгыяте әгъзасы булып тора. Җәмгыять хисабына үзенең социаль һәм антиколониаль яңгырашлы «Фөръядлар» («Аһ-зарлар», Казан, 1908) исемле лирик шигырьләр җыентыгын чыгара. Китап, чыгу б-н үк, хакимият органнары тарафыннан җыеп алына, авторы төрмәгә ябыла. 1909 да балалар өчен язылган «Нәтиҗәи әхлак. Хикмәтле сүзләр вә хикәяләр» китабын бастыра. Китапта авторның үз шигырьләре һәм үгет-нәсыйхәт рәвешендәге мәкальләр урнаштырылган.

Ә с ә р.: «Әүлия ата»дагы иске әсәрләр турында // Шура. 1915. № 8; Милләтнең юлбашчылары // Шура. 1915. № 20; Мөхәммәт әфәнде // Шура. 1916. № 14/15.

*Әд.:* Сабир әфәнде Габделмәновның вафаты // Олугъ Төркестан. 1918. 24 гыйнв.; Ә х м ә т җ а н о в М. Татар әдәбияты тарихына яңа исемнәр // Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. К., 1987; М у р а д ы м о в Н. Ценная находка из Казани // Вечерняя Казань. 1990. 26 марта.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕЛРАХМА́Н ХАН** (? — 1545 тән соң), Әстерхан ханы (1533–37, 1539–45). 1533 елда нугайлар гаскәре ярдәмендә Ак Күбәк ханны төшереп тәхеткә утыра. Нугай Урдасына бәйле сәясәт алып бара. 1537 дә нугайлар Әстерхан тәхетенә Дәрвиш Галине утырталар. 1539 да Г.х. кабат Әстерхан тәхетен яулап ала. 1545 тә тәхетне нугай морзалары көчләренә таянган Ак Күбәк били. Г.х.ның шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Заметки об Астраханском ханстве // Сб. статей преподавателей Мордовского гос. пед. ун-та. Саранск, 1952; Османская империя и страны Центральной, Восточной и Юго-Восточной Европы в XV — XVI вв. М., 1984.

**ГАБДЕЛХА́КОВ** Валерьян Фәрит улы (1.1.1957, Чиләбе өлкәсенең Златоуст ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1992), проф. (1993), РСФСРның халык мәгарифе отличнигы (1991), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1995). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1978 елда Оренбург пед. ин-тын тәмамлый. 1978–80 дә Оренбург шәһәре урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы. 1980 нән Казанда: СССР ПФАнең Һөнәри-техник педагогика фәнни-тикшеренү ин-тында (1980–85), 1985 тән ТР Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-тында (хәзер Мәгарифне үстерү ин-ты) рус теле һәм әдәбияты каф. мөдире, проректор (2003–2007). 2007 дән Татар гуманитар пед. ун-тының рус теле, әдәбияты һәм методикасы каф. мөдире. Хезмәтләре рус-татар икетеллелек шартларында укучылар сөйләме үсешенең лингводидактик системасына карый.

Х е з м.: Развитие связной русской речи учащихся в татарской школе. К., 1989; Современная языковая коммуникация и технологии развития речевой деятельности в условиях билингвизма. К., 1999; Русский язык, речь и риторика. К., 2000.

*Әд.:* Ш а к и р о в а Л.З. Новаторские исследования профессора В.Ф. Габделхакова // Науч. Татарстан. 1998. № 4.

**ГАБДЕЛХАЛИ́К бине ӘГЪЗА́М эт-ТЕНӘКИ́** (? — 1801 яисә 1802), дин эшлеклесе. Мамадыш өязенең Тенәки авылы мәчете имамы. 1797 елдан Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәте *казые*.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Асар. Оренбург. 1901. 2 җөзья.

**ГАБДЕЛХӘ́ЕВ** Билсур Габделхәй улы (29.10.1936, Чиләбе өлкәсенең Курган р-ны Чистопрудное а. — 19.3.2008, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1986), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1987 дән проф., 1988 дән функцияләр һәм якынчалылык теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре сингуляр интеграль тигезләмәләрне аппроксимацияләү һәм санча анализлау теориясенә карый. Төрле класс сингуляр интеграль һәм интеграль-дифференциаль тигезләмәләрне чишүнең туры һәм проекция ысулларын, ш.у. Гёльдер, Никольский һәм Соболев фәзаларында функцияләргә полином һәм сплайн аша якынчалау нигезләрен эшли. Операторлы тигезләмәләрнең чишелешен чикләнгән санда оптималь апроксимацияләү проблемасын чишә һәм шуның нигезендә хисаплау ысулларын оптимальләштерү, чикле үлчәмле һәм күп үлчәмле сингуляр интеграллар өчен квадратлы һәм кублы формулалар чыгаруның төп мәсьәләсен, ш.у. дөрес куелмаган мәсьәләләрне оптималь җайлаштыру проблемасын хәл итә.

Х е з м.: Оптимальные аппроксимации решений линейных задач. К., 1980; Оптимизация квадратурных методов решения интегральных уравнений // Докл. АН СССР. 1983. Т. 271, № 1; Прямые методы решения сингулярных интегральных уравнений 1-го рода. К., 1994; Численный анализ сингулярных интегральных уравнений. К., 1995.

**ГАБДЕННАСЫ́ЙР бине РАХМАНКОЛЫ́Й эл-ҖӘБӘЛИ́** (? — 1835, Казан), дин эшлеклесе. Атасында укый, соңрак Каргалы бистәсе мәдрәсәсендә Габдеррахман бине Шәриф әл-Кирмәнидә белем ала. Казанга кайтып, 4 нче җамигъ мәчет имамы була, ахун дәрәҗәсе ала. 1823 елда үз мәхәлләсендә мәдрәсә ача, 1825 тә мәхәллә байлары акчасына аны яңартып төзи һәм 10 ел дәвамында шунда мөдәррис булып тора.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ГАБДЕННАСЫ́ЙР бине САБИ́Т бине СӘФӘРГАЛИ́ эл-ӘЧКЕНИ́** (1746, хәзерге Курган өлкәсе Әлмән а. — 1841, шунда ук), хаттат, китап күчерүче. Остазларының берсе Яугилде авылыннан (хәзерге Башкортстан Респ-касы Бөре р-ны) Габденнасыйр булуы мәгълүм. 1770 еллар башыннан бирле 223 кульъязма китап күчерә. Хаттат үзенең чыра яктысында язуын, шәм сатып алырга акчасы булмавын теркәп калдырган. Ул башкарган күчермәләр арасында 13 йөз исламият галиме Габдулла Байдавинең «Әнвәр әт-тәнзил» («Илһам чыганаклары») хезмәте — Коръәннең 2 томдагы тәфсире бар.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Асар. Оренбург, 1904. 1 т., 8 җөзья; Ә х м ә т җ а н о в М. Татар кульъязма китабы. К., 2000.

*Р.И.Шәмсутов.*

**ГАБДЕРӘХИ́М бине ГАБДЕРАХМА́Н** (18 йөз уртасы), ташка уеп язучы, хаттат, *кятиб*. Мөфти Г.*Габдрәхимовның* атасы. Г. бине Г. тарафыннан эшләнгән кабер ташы 1753 елда Әлмәт р-нының Габдрахман авылы зиратында атасы — «таш уючы Габдрахман Бикмөхәммәд улы» каберенә куелган. Истәлек язуы (6–7 юлы сакланмаган) известьташ плитәдә гарәп язуының *тәгъликъ* стилендә уеп кисү техникасы б-н башкарылган. Останың исеме — «Кятиб Габдерәхим» — аска, сул якка язылган. Бизәкләр кулланылмаган.



Г а б д е р ә х и м б и н е Г а б д е р а х м а н. Габдрахман авылы (хәзерге Әлмәт р-ны) зиратындагы кабер ташы. Известьташ. Уеп бизәкләү. 1753.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕРӘХИ́МОВ ГАБДЕССӘЛА́М** (1765 — 1840, Уфа ш.), дин эшлеклесе. Оренбург өязенең Каргалы бистәсе мәдрәсәсендә белем ала. 1799–1802, 1805–23 елларда Оренбург җамигъ мәчетенең имам-хатибы, 1805 тән ахун. Г. Казакъстанда һәм Урта Азиядә Россия хөкүмәтенең дипломатик йомышларын үти. 1825 тә император Александр I Фәрманы б-н Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнә, ул эшләгән елларда Нәзарәт эшчәнлеге тотрыклы төс ала, штатлар арттырыла. Г. тырышлыгы б-н Беренче җамигъ мәчет, вакыф йорты, Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтенең идарә бинасы төзелә. Башкорт һәм типтәрләргә Казан ун-тына укырга керергә булышлык итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Габдессәлам мөфти. К., 2002.

**ГАБДЕСАТТА́Р бине СӘГЫЙТЬ эш-ШЫРДАНИ́** (? — 1831, Түбән Новгород), дин эшлеклесе, Габделгариф бине Сәгыйть эш-Шырданиның бертуганы. Башлангыч белемне татар исламият галимнәре Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Мәчкәрәвидән һәм Салих бине Сәгыйть әл-Калидән ала, соңрак Бохарада укый, анда булачак әмир Миркәҗән б-н якыннан аралаша. 1814 елга кадәр Бохара янындагы Нәсеф шәһәрендә мөхтәсиб, мәхкәмә башкаручысы һәм нотариус вазифаларын башкара. 1829 дә Казанга кайта һәм 5 нче мәчеттә атасына ярдәмче булып эшли. Бер үк вакытта 1821 дән өлкән ахун вәкаләтләренә ия була. 1824 тә Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтенә мөфти булып сайла-

ныргa омтылыш ясый, ләкин уңышка ирешә алмый.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ГАБДЕССӘЛА́М бине УРАЙ́** (тулы исеме Габдессәлам бине Уразмөхәммәт бине Колмөхәммәд бине Колчура; псевдонимы Габдүш) (1700, Казан өязе Мәңгәр а., хәзерге Әтнә р-ны Олы Мәңгәр а. — 1767 дән соң), шагыйрь, дин эшлеклесе. Шагыйрь Ә.*Каргалыйның* бабасы. 1725 елдан Казан өязенең Ташкичү авылында яши һәм мөгаллимлек итә, 1742–46 да имам-хатиб һәм мөдәррис. 1746 да Каргалы бистәсенә (хәзерге Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы а.) күчеп китә, андагы мәдрәсәнең попечителе һәм *ахун* була. 1755–56 дагы татар-башкорт күтәрелеше җитәкчеләренең берсе *Батырша* б-н якын элемтәдә тора, аның патшага юллаган хатында телгә алына. Г. — 40 ка якын шигырь авторы. Аеруча киң танылган әсәре — 1757 елгы рус-прусс сугышында һәлак булган татар сугышчысы турындагы «Меллагол бәете». Г. ның әдәби мирасында мәхәббәт лирикасы зур урын алып тора; тарихи-иҗтимагый мәсьәләләр чагылыш таба. Әсәрләрендә хөкүмәткә каршы күтәрелешләрдә катнашучыларга теләктәшлек белдерелә. Г. шигърияте халык авыз иҗаты б-н тыгыз бәйләнгән. Аның әсәрләренең күчермәләре киң таралыш алган. Г.ның кайбер шигырьләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелгән (т. 1–2, 1992).

*Әд.:* Әхмәтҗанов М.И. Татар кульязма китабы. К., 2000; Ахметзянов М.И. Габдуссалям // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДИ́** (Мескен Габди, Мелла Габди, Галим Габди) (псевд., чын исеме билгеле түгел) (1679 — 18 йөзнең 1 нче чиреге), татар шагыйре. Казанда яшәгән һәм иҗат иткән дип фаразлана. 1927 елда шигырьләренең бер өлеше, авторның исеме күрсәтелмичә, «Безнең юл» ж-лында басыла. Автор 1709 да *нәсер* жанрында язылган, кульязма рәвешендә сакланган «Габди шигырьләре» исемле җыентыгы 1975 тә табылганнан соң гына таныла. Җыентыкта суфичылык рухында язылган 60 ка якын шигырь тупланган. Г. шигырьләрендә рухи мәсьәләләрдән тыш бик күп тормыш проблемалары да күтәрелә, җәмгыятькә карата тәнкыйть сүзләре урын ала. Габди халыкка якынлыгын белдерә, аның хәленә керә, түземлек тели, хакимнәрне гадел булырга өнди. Татар халкының имин киләчәген иҗади хезмәттә, үзара ярдәмләшүдә күрә. Г. кульязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты мирасханәсендә һәм Казан ун-ты фәнни китапханәсенең сирәк очрый торган китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана.

Әсәр.: Габди шигырьләреннән үрнәкләр // Казан утлары. 1978. № 10.

*Әд.:* Абилов Ш.Ш. XVIII йөз башы татар шагыйре Габди әсәрләре // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 кит.; шул ук. Поэзиябез тарихына яңа исем // Казан утлары. 1978. № 10; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 т.; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ГАБДРАХМА́Н** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2008 елда 1597 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Дәвалау амбулаториясе. Мәчет. 1747 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр, асаба башкортлар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Мәчет турында беренче тапкыр 1749 да телгә алына. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3678 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе — Әлмәт, 1918 дән Каратай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт р-нында. Халык саны: 1762 дә — 73, 1782 дә — 103, 1795 тә — 180 ир-ат; 1859 да — 817, 1889 да — 1311, 1897 дә — 1422, 1910 да — 1851, 1920 дә — 2009, 1926 да — 1838, 1938 дә — 1826, 1949 да — 1432, 1958 дә — 1656, 1970 тә — 1560, 1979 да — 1547, 1989 да — 1300, 2002 дә — 1504 кеше. Г. да «Татнефть» АҖнең ген. директоры Ш.Ф.*Тәхәветдинов*, Оренбург Мөселман Диния нәзарәте мөфтие Г.*Габдерәхимов* туган.

*Әд.:* Баһманов С. Гасырлар аша (Габдрахман авылы тарихы). Әлмәт, 1999.

**ГАБДРАХМА́Н** посёлогы, Сарман р-нында, 1991 елдан шәһәр тибындагы Җәлил посёлогы составында, Сарман авылыннан 27 *км* көньяктарак, Урсалы елгасының югары агымы буенда. 1924–25 тә нигез салына. ТАССРның Чаллы кантоны Кармалы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 34, 1938 дә — 101, 1949 да — 83, 1958 дә — 51, 1970 тә — 41, 1979 да — 27, 1989 да — 5 кеше (татарлар).

**ГАБДРАХМА́Н бине ГАБДЕЛХӘЛИ́М** (19 йөзнең соңгы чиреге — 20 йөз башы), ташка уеп язучы, хаттат, дин эшлеклесе. Аның тарафыннан эшләнгән кабер ташлары Әлмәт р-нының Әлмәт (хәзерге Әлмәт ш.),



Габдрахман бине Габделхәлим. Колшәриф авылы (хәзерге Әлмәт р-ны) зиратындагы кабер ташы. Известьташ. Уеп язу. 1908.



Б.Г. Габдрахманов.

Аксу авыллары зиратларында сакланган. Турыпочмаклы формадагы, гадәттә, 60×39×17 *см* үлчәмле известьташ өске яктан ярымтүгәрәк рәвешендә төгәлләнә. Гарәп язуының тәгъликъ стилендә башкарылган истәлек язуы ташның алгы ягында 6–7 юлда урнаштырылган. Баштагы 3–4 юлда гарәп телендә Коръән гыйбарәләре, калган юлларында татар телендәге язу урын алган. Даталар миладиел исәбендә гарәп шрифты б-н бирелгән. Оста үзенең имзасын ташның ян-якларына яисә төп язу алдыннан иң өскә уеп язган. Гадәттә, төп язу уйма кыса эченә алынган.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДРАХМА́Н бине МӨХӘММӘ́Д әл-КИРМӘНИ́** (1743–1826), дин эшлеклесе, педагог. Оренбург янындагы Каргалы бистәсендә Базар мәчетенең имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ГАБДРАХМА́НОВ** Әлтаф Әфләтун улы (25.10.1954, Арча р-ны Шекә а.), механизатор, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Арча авыл хуҗалыгы һөнәри техник уч-щесен тәмамлаганнан соң (1972), Арча р-нының «Северный» күмәк пр-тиесендә тракторчы булып эшли. Дәүләт бүләге фән һәм техника казанышларын производствога кертү нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алганы өчен бирелә.


**ГАБДРАХМА́НОВ** Бари Габдрахман улы (25.5.1912, Казан губ., Чистай өязе Кармыш а. — 23.1.1944, Украина ССРның Кировоград ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944, үлгәннән соң), гв. кече сержанты. Донбасс, Мәскәү, Пермьдә эшли (1928–41). 1941 елның сентябреннән Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 233 нче гв. артиллерия полкының (5 нче гв. армиясенең 95 нче гв. укчы дивизиясе) орудие төзәүчесе. Сталинград, Дон, Воронеж, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск сугышларында, Днепрны кичүдә һәм Полтаваны азат итүдә (барысы да — 1943), Кировоград операциясендә (1944) катнаша. 1944 нең 15 гыйнварында Грузский авылы (Кировоград өлкәсе) янындагы бәрелештә батырлык күрсәтә: дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда аның танкын шартлата, 2 орудиесен һәм 2 пулемётын юк итә. Яу кырында һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Кировоградта бер урам Г. исемен йөртә.




Р.Ф. Габдрахманов.



С.З. Габдрахманова.



Г.Г. Габдрәхимов.



Ф.Г. Габдрәшитов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАБДРАХМА́НОВ** Равил Фәтхерахман улы (21.11.1954, Казан), балет артисты, ТРның халык артисты (1992). Ташкент хореография уч-щесен тәмамлый (1972) һәм ТАССР Җыр һәм бию ансамбленә эшкә килә. «Аулак өй», «Ялда», «Сарман яшьләре», «Бишле бию», «Мәдрәсәдә булган хәл», «Казан кунаклары» хореография композицияләрендә, «Идел буе халыклары биюләре» сюитасында төп партияләрне башкара. Ансамбль б-н



Р.Ф. Габдрахманов «Каз өмәсе» биюендә (ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле).

Тунис (1977), Италия (1978), Нигерия, Бенин, Сенегал (1979), Чехословакия (1981), Германия (1980, 1989), Япония (1987), Польша, Йәмән (1988), Финляндия (1989), Югославия (1990), Төркия (1991), Англия (1992) һ.б. илләрдә гастрольләрдә була. Бию осталыгы, төгәл хореографик дикциясе һәм виртуоз башкару техникасы б-н аерылып тора. 2000 елдан Казан музыка уч-щесендә бию укыта.

*В.Н.Горшков.*

**ГАБДРАХМА́НОВ** Равил Шакир улы (20.8.1930, Оренбург ш. — 23.6.1994, Самара ш.), физиолог, биол. фән. д-ры (1976), проф. (1977). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Самарада: 1953–61 елларда пед. уч-щесендә, 1961–71 дә мед., 1971–78 дә политехника, 1978–94 тә пед. (кеше һәм хайваннар физиологиясе һәм анатомиясе каф. мөдире) ин-тларында. Хезмәтләре сулыш алу үзәгенең морфофункциональ төзелешенә һәм аның башка системалар б-н бәйләнешенә карый. Сулыш алу үзәге медиаль зонасының ритмогенездагы әһәмиятен күрсәтә, сулыш алу нейроннары эшчәнлегендә адренореактив системаларны ачыклый, сулыш алу һәм йөрәк-кан тамырлары системаларының, сулыш алу үзәгенең проприорецепторлар б-н үзара бәйләнешләре механизмнарын аңлата.

Х е з м.: Дыхательный центр. М., 1975 (автордаш); Структурная и функциональная организация дыхательного центра. Новосиб., 1993 (автордаш).

**ГАБДРАХМА́НОВА** Ләйлә Әсхәт кызы (2.7.1966, Казан), микробиолог, биотехнолог, биол. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1989), шунда ук эшли: өлкән фәнни хезмәткәр, бүлек мөдире (2007 гә кадәр), Казан ун-тының уку-укыту методик идарәсе башлыгы (2007 дән). Хезмәтләре микроорганизм ферментларының күзәнәктән тыш биосинтезын көйләүдә күзәнәкнең сигнал системаларының ролен ачыклауга карый. Адаптация системаларының стресс шартларында микроорганизмнардагы күп кенә гидролитик ферментлар биосинтезын көйләвен билгели.

Х е з м.: Выделение и характеристика сериновой протеиназы 2 Bacillus intermedius 3–19 // Биохимия. 2004. Т. 69, № 4 (автордаш); Получение суперпродуцентов внеклеточных низкомолекулярных рибонуклеаз бацилл для нужд биотехнологии // Микробная биотехнология. К., 2007 (автордаш); Продукция Glu, Asp-специфичной протеиназы Bacillus cereus на разных этапах роста культуры // Журн. экологии и промышленной безопасности. 2008. Т. 1, № 36.

**ГАБДРАХМА́НОВА** Стелла Зәки кызы (17.11.1933, Казан) педагог, Соц. Хезмәт Герое (1978). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1955–89 да Арча р-нының Яңа Кенәр урта мәктәбендә татар һәм рус телләре һәм әдәбияты укытучысы. Герой исеме мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Педагогик эшчәнлегендә укучыларны әхлакый тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Бөтенсоюз укытучылар съездында катнаша (1977). Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б а д ы г о в Р. Габдрахманова Стелла Закиевна // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2.

**ГАБДРӘХИ́МОВ** Газиз Габдрәхим улы (16.4.1906, Вятка губ., Малмыж өязе Комаров Заводы а. — 18.7.1994, Пермь өлкәсе Үзәк Каспаш пос.), шахтёр, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1920 елларда Донбасс шахталарында эшли. 1936–57 дә Кизель бассейнының (Көнбатыш Урал) «Комсомолец» һәм 30нчы номерлы шахталарында тау токымын тишү машинисты. Текә төшә торган катламнарда беренче булып тау токымын тишү машинасын куллануны кертә, анда бәреп вата торган штанганы уңышлы куллана, соңыннан бу деталь тау токымнарын уеп, өемнәргә өю машинасының нигезен тәшкил итә. Герой исеме югары хезмәт уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Шахтёр Газиз Габдрахимов // Пермяки — Герои Социалистического Труда. Пермь, 1959; Б е р е з и н С. На крупных пластах // Герои Труда. Пермь, 1970.

**ГАБДРӘХИ́МОВ** Фәрит Ибраһим улы (8.1.1933, БАССРның Бүздәк р-ны Арслан а.), шагыйрь, БАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Башкорт ун-тын тәмамлый (1963). 1965–69 елларда «Ленин юлы» г-тасы (Туймазы ш.) редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1969–94 тә «Кызыл таң» г-тасында (Уфа ш.) әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. Шигырьләрендә якташларының образлары, туган төбәге табигате гәүдәләнә. «Йөрәк уты» (1971), «Ерҙәге йондоҙҙар» (1975), «Алтын туй» (1982), «Күңел күҙе» (1985), «Кичер мине!» (1995), «Син дә мин» (2000) җыентыкларына тупланган шигырьләре татар халкының гыйбрәтле язмышы турында уйланулар б-н тулы. Г.ның күп кенә шигырьләре рус, чуаш, украин телләренә тәрҗемә ителгән. Уфада яши.

*Әд.:* Х ө с ә е н М. Табигатьтә бары да табигый // Ватаным Татарстан. 1993. 15 гыйнв.; М ө л е к о в М. Керәм давыл уртасына // Тулпар. 1996. № 6.

**ГАБДРӘШИ́ТОВ** Фәйзулла Габдулла улы (25.10.1903, хәзерге БРның Туймазы р-ны Иске Кандыр а. — 5.4.1975, шунда ук, Бүздәк пос.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), гв. рядовое. Туймазы кулланучылар җәмгыятенең әзерләүләр конторасында эшли. 1941 елның декабреннән Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 60 нчы гв. кавалерия полкында (16 нчы кавалерия дивизиясе, 61нче армиянең 7 нче кавалерия корпусы) станлы пулемёт төзәүчесе. Көньяк-Көнбатыш, Брянск, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия, 1 нче һәм 3 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Мәскәүне саклауда (1941–42), Белёвтан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак барган сугышларда (1942–43), Чернигов–Припять, Гомель–Речица (икесе дә — 1943), Калинковичи-Мозырь, Белоруссия, Рига (барысы да — 1944), Варшава–Познань, Көнчыгыш Померанье һәм Берлин (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 тә Нивки авылы янында (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагин р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: полкта беренче булып елганы кичә; полк подразделениеләренә елганы кичүне тәэмин итә. Сугыштан соң Бүздәк р-ны кулланучылар җәмгыятенең әзерләүләр конторасында эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2. Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАБДРИ́ЕВ** Рөстәм Вагыйз улы (1.4.1946, Казан), психолог, психол. фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый (1969). Казан пед. ин-тында (1970–75), Казан ун-тында (1975–82) укыта. 1982 дән Казан технол. ун-тында, 1986 дан инженерлык психол. һәм пед. каф. мөдире. Бер үк вакытта 2003 тән психология һәм эшлекле идарә итү ф-ты деканы. Хезмәтләре инженер кадрларның һөнәри эшчәнлеге һәм һөнәри әзерлеге психологиясенә карый. Инженерлык эшчәнлеген, белгечләрнең мөһим һөнәри сыйфатлары һәм аларның эшчәнлеге объектының үзенә генә хас үзенчәлекләрен чагыштыру юлы б-н тикшерә.

Х е з м.: Моделирование в познавательной деятельности студентов. К., 1983; Теория, методология, психологические резервы инженерной подготовки. М., 2001.

**ГАБДРИ́ЕВА** Наталия Викторовна (8.2.1961, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2006), РФ югары мәктәбенең мактаулы хезмәткәре (2007). Казан дәүләт ун-тын тәмамлый (1983). 1986 елдан Казан а.х. ин-тында, 1996 дан Казан техник ун-тында (2002 дән рус һәм татар телләре каф. мөдире). Хезмәтләре стилистика, рус һәм француз телләре лексикасына, тәрҗемә мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары өчен рус теле укыту ярдәмлекләре авторы.

Хезм.: Лексика французского происхождения в русском языке. Ижевск, 2001; Теория и практика изучения французских заимствований. К., 2001; Стилистика русского языка и основы литературного редактирования. К., 2007 (автордаш).

**ГАБДУЛЛА́ ХАН**, Болгар шәһәренең легендар хөкемдары. Аның турындагы мәгълүматлар халык риваятьләрендә сакланган, алар 1236 елдагы монгол яулары вакытында үтерелгән соңгы болгар идарәчесе б-н бәйле. 17–18 йөзләр татар тарихи чыганакларында Г.х. 1391 дә Урта Азия хөкемдары *Аксак Тимер* гаскәренең шәһәргә һөҗүме вакытында һәлак булган соңгы хан дип тасвирлана.

*Әд.:* У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; М ә р ж а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*И.Л.Измайлов.*

**ГАБДУЛЛА́ бине БАШТУ́** (9 йөз ахыры — 10 йөзнең 1 нче яртысы), болгар бәге. *Ибне Фазлан* мәгълүматларына караганда, Г. бине Б. — сәяси сәбәпләр аркасында Хәзәр каганлыгыннан качарга мәҗбүр булган мөселман. 921 елда ул *Бохарага һәм Багдадка Алмыш илтәбәр илчелеген* җитәкли. Шул елның язында Г. бине Б. Багдад хәлифәсе әл-Моктадир сараена Алмыш илтәбәрнең хатларын китереп җиткерә. Хатларның берсе хәлифәнең үзенә, икенчесе сарайны саклаучылар башлыгы Нәзир әл-Хәрамигә юлланган була. Вәзир Хәмид ибне әл-Аббаска язылган өченче хат та булгандыр дигән фараз бар. Г. бине Б. хәлифә тарафыннан кабул ителә. Алмышның хәлифәдән «дингә күндерерлек кеше җибәрүен», Болгарда мәчетләр төзергә һәм ислам кануннарын урнаштырырга булышуын, хәлифә исеменнән хөтбә укырга рөхсәт бирүен, үзенә дошман хакимнәр һөҗүменнән саклану өчен кальга төзергә ярдәм итүен үтенгән хатын тапшыра. Г. бине Б.ның эше уңышлы тәмамлана — 922 дә Идел буе Болгарында болгар дәүләтчелеге һәм рухи мәдәнияте тарихында мөһим роль уйнаган әл-Моктадир илчелеге булып китә (к. *Болгарга әл-Моктадир илчелеге (921–23)*).

*Әд.:* К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Хар., 1956.

**ГАБДУЛЛА́ бине ГАБДУЛЛА́** (Габдулла Болгари) (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), язучы, публицист. Татар һәм гарәп телләрендә язган. Бәхәс характерындагы ике китап авторы. «Гаҗәлә мәрзыйа фи бәян әл-Әшгари» («Әл-Әшгарине аңлатуда кабаланып ашыгу») (1905) китабында Р.Фәхретдинне һәм аның «Асар» китабын ортодоксаль ислам тәгълиматы ноктасыннан чыгып, урта гасыр гарәп дин белгече Әбүл-Хәсән Гали әл-Әшгаригә (936 елда үлә) ишарә итеп тәнкыйтьли. Китап ахырына Г. бине Г. үзенең шигырьләрен дә урнаштыра. Аның икенче китабы — «Изһар әт-тәәсүф» («Кызганыч») (1907) хатын-кыз эмансипациясенә, татарлар арасында сәнгатьнең үсүенә каршы юнәлтелгән, анда ш.у. җәдитчелек идеологы булган Г.Барудига һәм бу юнәлешне яклаган Ә.Н.Максудига карата тәнкыйди фикерләр урын алган.

*А.М.Ахунов.*

**ГАБДУЛЛА́ бине ИБРАҺИ́М әл-КАЗАНИ́** (? — 1793/94), дин эшлеклесе. *Мәрҗани мәчете* имамы. Уфа Мөселманнар Диния нәзарәтенең беренче казыйларыннан.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

**ГАБДУ́ЛЛИН** Габделхан Габдулла улы (5.7.1936, Мамадыш р-ны Сәртек а.) педагог, пед. фән. д-ры (1991), проф. (1991), РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1958–67 елларда комсомол һәм партия эшендә, КПССның Әгерҗе райкомы секретаре (1964 тән). 1967 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1967–70 тә Әгерҗе урта мәктәбендә: тарих укытучысы, директор. 1970–79 да Әгерҗе р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1979–84 тә ТАССР мәгариф министры урынбасары. 1984 тән Казан пед. ун-тында пед. каф. мөдире (1988 дән), бер үк вакытта проректор (1990–95). Хезмәтләре мәктәп, мәгариф системасындагы идарә итү, укытудагы социаль проблемаларга карый. ТРның Мактау грамотасы, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Перестройка школы: проблемы управления. К., 1990; Педагогика школы. К., 1993; Школоведение. К., 1997; Воспитательный потенциал педагогических дисциплин в формировании личности будущего учителя. К., 2003 (автордаш).

**ГАБДУ́ЛЛИН** Рәфәгат Габделвәли улы (20.9.1938, Азнакай р-ны Югары Әстәрле а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2003), РФнең атказ. уйлап табучысы (2007). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), «Азнакайнефть» НГДУында эшли, җитештерү бүлеге башлыгы (1970 елдан). 1978 дән катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау буенча Азнакай үзәк инж.-техник хезмәте идарәсе башлыгы. 1980 нән ТатНИПИнефтьтә: сектор, лаб-я мөдире (1986 дан), баш фәнни хезмәткәр (2007 дән). Хезмәтләре скважиналарның сулану сәбәпләрен, нефтьле-сулы катламнардагы күчеш зоналарының үзлекләрен тикшерүгә карый. Судан изоляцияли торган эшләрнең яңа юлларын, катламнарны тишкәләмичә икенчел ачу өчен, скважиналарны сулanудан саклаучы югары нәтиҗәле алымнар һәм конструкцияләр тәкъдим итә. Скважиналарны эксплуатацияләү һәм ремонтлау өчен җиһазлар һәм реагентлар комплексы эшли. Г. хезмәтләре «Татнефть» АҖнең, ш.у. Башкортстан, Удмуртия, Көнбатыш Себер, Үзбәкстан һ.б.ның нефть-газ чыгару пр-тиеләрендә киң кулланыла. Уйлап табуга 170 тән артык авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Ограничение притока пластовых вод в нефтяные скважины. М., 1976 (автордаш); Новые способы вторичного вскрытия пластов и конструкций забоев скважин. Тюмень, 1998 (автордаш); Сохранение продуктивности пластов при строительстве и эксплуатации скважин. Бугульма, 2003.

**ГАБДУ́ЛЛИН** Салих Галимҗан улы (10.4.1933, хәзерге Яңа Чишмә р-ны Акбүре а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, партия хезмәткәре, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре (1993). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1957). 1957–59 елларда Ямаш авыл хуҗалыгын механикалаштыру уч-щесендә укытучы, 1959–64 тә Яңа Чишмә р-ны «Красный Октябрь» с-зы баш инженеры. 1964–69 да Чистай р-ны «Сельхозтехника» берләшмәсенең баш инженеры, аннан соң башлыгы. 1969–70 тә КПССның Чистай шәһәр ком-ты 2 нче секретаре, 1970–79 да КПССның Алабуга, 1980–83 тә Яшел Үзән шәһәрләре ком-тларының 1 нче секретаре. 1979–80 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты а.х. бүлеге мөдире. 1983–85 тә «Элитасемеnоводхоз» тресты (Казан), 1985–94 тә Мәскәү сыек ашламалар фәнни-тикшеренү ин-ты махсус КБсының Идел буе ф-лы директоры. 1971–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАБДУ́ЛЛИН** Тимерхәтмулла Габдулла улы (19.12.1937, Мөслим р-ны Бүләк а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1998), БАССР һәм РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1976, 1979). 1957 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, 13 номерлы пр-тиедә (Загорск ш., Мәскәү өлкәсе) эшли. 1959 дан Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында (Бөгелмә ш.), сектор, лаб. мөдире. 1971 дән Уфа шәһәрендәге Бөтенсоюз нефть сәнәгате-геофизика фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб-я мөдире. 1993 тән Әлмәт нефть ин-тында автоматлаштыру һәм мәгълүмат технологияләре каф. мөдире. Хезмәтләре нефть сәнәгатендә контроль-үлчәү приборларын конструкцияләүгә карый. Эшли торган скважиналарны тирәндәге приборлар комплексы (чыгым һәм дебит үлчәгечләр, дебит һәм дым үлчәгечләр, термометр һәм манометрлар) б-н

термодинамик тикшеренүләр өчен станцияләр әзерли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге бирелә (1968).

Х е з м.: Применение глубинной дистанционной аппаратуры в нефтедобывающей промышленности Татарии. К., 1968 (автордаш); Оперативное исследование скважин. М., 1981; Основы контроля за разработкой нефтяных месторождений. К., 2001 (автордаш).

**ГАБДҮ́Ш**, псевд. к. *Габдессәлам бине Ураи.*

**ГАБДҮ́Ш** Хөсәен Рәхимҗан улы (5.1.1901, Троицк ш. — 14.4.1944, Харбин ш., Кытай), язучы, журналист. Реаль уч-щедә укый (Петропавловск ш., Казакъстан). 1917 елдан соң Маньчжуриягә (Кытай) күчеп китә. «Милли байрак» г-тасында, «Ерак Шәрекъ», «Яңа милли юл», «Белдереш» (Хельсинки), «Казан» ж-лларында языша. Г.Камал, М.Фәйзи, Г.Исхакый пьесалары буенча спектакльләр куя, үзе аларда баш рольләрне башкара, татар мөһаҗирләре өчен әдәби кичәләр оештыра. Берничә пьеса, ш.и. «Татар телендә беренче телеграф» пьесасы, хикәяләр һәм шигырьләр авторы. «Дүрт хикәя» (Токио, 1931) җыентыгына кергән кайбер хикәяләре туган илне сагыну хисе б-н сугарылган.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Урал егете // Мирас. 1992. № 9; ш у л  у к. Чит илләрдәге татар әдәбияты. К., 2007.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ГАБЕ́ЛКО** Олег Леонидович (1.4.1968, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1993). 1996–99 елларда РФАнең Гомуми тарих ин-тында (Мәскәү) эшли. 1999 дан Казан ун-тында борынгы дөнья һәм урта гасырлар тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Кече Азиядәге эллинистик дәүләтләрнең дәүләтчелек проблемаларына, династия елъязмалары системаларына, эллинизмның теоретик мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: История Вифинского царства. СПб., 2005.

**ГАБЕТДИ́НОВ** Малик Салих улы (1.1.1939, Яңа Чишмә р-ны Зирекле а. — 31.8.2007, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1996), проф. (1999), ТАССРның атказ. химигы (1983), СССРның мактаулы химигы (1990). ТРның атказ. уйлап табучысы (1993). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1961), Оборона сәнәгате министрлыгы пр-тиеләрендә эшли (Рубежное ш., Украина ССР). 1965 елдан «Казаноргсинтез» АҖдә (цех җитәкчесе, баш технолог, директор урынбасары, 1982 дән баш инженер, 1994 тән техник директор, 1999–2004 елларда фәнни-техник үзәк директоры), бер үк вакытта Казан технол. ун-тының органик һәм нефтехимик синтез технологиясе каф. проф. (1996 дан). Хезмәтләре яңа каталитик системалар булдыруга, югары селектив процессларны эшләүгә, аларны гамәлдәге технологияләр һәм җиһазларны камилләштерүдә куллануга карый. Этилен оксидын трегерлы көмеш катализаторда җитештерүнең проектын эшләүдә һәм төзүдә катнаша (1976, СССР МС бүләге). Г. җитәкчелегендә этиленның бутен-1 гә (яңа буын полиэтилен алу өчен сомономер) каталитик әверелеш процессының фәнни нигезләре эшләнә, үзләштерелә һәм илдә беренче тапкыр бу материалдан газлаштыру һәм социаль-көнкүреш биналары төзелеше өчен торбалар җитештерү файдалануга кертелә (1987, СССР МС бүләге); бөҗралы йөрткечтә, этиленны этиленоксидка оксидлаштыру өчен, модификацияләнгән югары селектив көмеш катализатор эшләнә, ул «Түбәнкаманефтехим», «Салаватнефтеоргсинтез», «Казаноргсинтез» пр-тиеләрендә җитештерүгә кертелә; полимерлаштыручы бифункциональ катализаторлар кулланып урта тыгызлыктагы полиэтилен табу технологиясе эшләнә. Г. тарафыннан сәнәгый ташландык суларны органик матдәләрдән чистартуның биохимик ысулы, газ яндыру ысулы һәм җайланмасы тәкъдим ителә. Уйлап табуга 85 тән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1997). ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1988), катализ өлкәсендәге фәнни-тикшеренү хезмәтләренең нәтиҗәләрен җитештерүгә керткәне өчен РФнең Фән һәм технологияләр министрлыгы дипломы (1997), медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Альфа-охтанол-промышленный процесс получения бутен-1 полимеризационный чистоты // Пластические массы. 1991. № 10 (автордаш); Полимеризация диенов на титан-магниевых катализаторах // Высокомолекулярные соединения. 1996. Т. 38, № 33 (автордаш); Научные и тривиальные названия органических соединений. К., 1999 (автордаш).

**ГАБЕТДИ́НОВА** Алла Максимилиановна (12.10.1941, Украина ССР, Ворошиловград өлкәсе Артёмовск ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССР, РФнең (1989, 1996) атказ. икътисадчысы. Харьков икътисад-инженерлар ин-тын тәмамлый (1963). 1966–82 елларда Казанның «Полимерфото» з-дында, 1981 дән партия ком-ты секретаре. 1983–85 тә КПССның Казан шәһәре Мәскәү райкомы секретаре. 1985–89 да Татарстан Статистика идарәсе башлыгы урынбасары. 1989–91 дә ТССР Дәүләт планы комиссиясе бүлеге башлыгы. 1991–92 дә ТР Дәүләт милкәте белән идарә итү дәүләт ком-ты рәисе урынбасары, 1992–95 тә ТРның Статистика дәүләт ком-ты рәисе, 1995–96 да ТР Икътисад һәм фаразлау дәүләт ком-ты рәисе. Бер үк вакытта 1995–97 дә ТР премьер-министры урынбасары. 2000 нән ТР Статистика дәүләт ком-ты каршындагы Халык санын исәпкә алу республика үзәге рәисе. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Инициатива рабочего. К., 1983; Республика Татарстан: Экон. карта. К., 1997 (автордаш).

**ГАБИ́Д** (Габидуллин) Гиз-әл (Гыйздулла) Лотфи улы (7.1.1918, хәзерге Оренбург өлкәсенең Свердлов р-ны Хөсәен (Саиновка) а. — 1955), шагыйрь. Богырыслан пед. техникумын тәмамлаганнан соң (1937), Оренбург өлкәсенең Зианчура р-нында укытучы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронт газеталарында хәбәрче була. Армиядән демобилизацияләнгәч (1946), Үзбәкстан шәһәрләрендә балалар укыта. Г.ның сугыш елларында язылган шигырьләре «Алар сафта» (1961), «Беренче карлыгачлар» (1968) исемле күмәк җыентыкларга кертелгән.

*Әд.:* Ә п с ә л ә м о в Г. Г.Габид турында // Социалистик Татарстан. 1968. 18 февр.; М ә җ и т о в З. Һәр шагыйрьнең үз тавышы // Сугышчан поэзия. К., 1975; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Библиогр. белешмә. К., 1986.

**ГАБИДИ́** (Габидуллин) Әзһәр Сәмигулла улы (26.9.1926, Сарман р-ны Чукмарлы а. — 22.8. 2001, Сарман р-ны Сарман а.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Минзәлә пед. уч-щесен тәмамлый (1950). 1950–80 елларда авыл мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Әдәби иҗат б-н 1942 елдан бирле шөгыльләнә. Республикада чыга торган газета һәм журналларда, күмәк җыентыкларда әсәрләре басылып килә. Балаларга багышланган «Без — яз дуслары» (1965), «Тапкырҗан табышмаклары» (1966), «Кошчыгым» (1981), «Калган эшкә кар ява» (1993) исемле шигырь җыентыклары авторы. Лирик шигырьләре «Таң сәгате» (1989), «Болыннарым» (1997) җыентыкларына тупланган. Г. ның шигырьләренә ихласлык, самимилек хас. Г. ш.у. публицистика һәм әдәби-тәнкыйть өлкәсендә дә эшли.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а л и к о в Р. Чишмәләр дә бик тиз бәреп чыкмый // Заман. 1999. 6 сент.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГАБИДУ́ЛЛИН** Мәхмүт Гариф улы (15.1.1949, Пермь өлкәсе Кизел ш.), төзелеш материаллары технол. өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007). 1973 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлый, 1981 дән шунда ук эшли, төзелеш материаллары каф. профессоры (2008 дән). 1973–81 дә тимер-бетон конструкцияләр җитештерү пр-тиесендә (Казан), баш технолог (1978 дән). Г. төрле кулланылыштагы үтә җиңел ныклы керамзит-керамик бетон катнашмалар, Казан метрополитены туннельләрен эшкәртүдә кулланылган тимер-бетон блоклар өчен су үткәрмәүчән бетон катнашмалар (РФдә беренче тапкыр гамәлгә кертелә) эшли. Төзелеш материалларының физик-механик үзлекләрен аларга зыян тидермичә тикшерү һәм бетонның су үткәрмәүчәнлеген билгеләү җайланмалары уйлап таба; күзәнәкле керамик материалларны тикшерүнең, аларның физик-җылылык үзлекләрен исәпләү һәм фаразлауның методикаларын һәм программаларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 23 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. ТРның «Елдагы иң яхшы уйлап табу» конкурсы лауреаты (2004) һәм җиңүчесе (2006).

Х е з м.: Методология определения и представления структуры черепка с пористой керамикой в системе поры-стеклофаза-кристаллические новообразования // Огнеупоры и техническая керамика. 2005. № 9; Моделирование поведения пористой керамики в условиях эксплуатационной влажности // Огнеупоры и техническая керамика. 2006. № 6; Разработка научных и технологических основ производства высокопористых блочных керамзитокерамических изделий // Строительные материалы, оборудование, технологии 21 века. 2007. № 3.

**ГАБИДУ́ЛЛИН** Хаҗи Заһидулла улы (1897, Уфа губ., Бүздәк өязе Сивада Баш а. — 12.8.1940), дәүләт эшлеклесе, тарих фән. канд. (1933), проф. (1934). Көнгер тимер юллар уч-щесен (1911), Кызыл профессорлар ин-тын (1933) тәмамлый. 1916 елдан Россия армиясендә. 1917 дә РСДРП(б) сафларына керә. Түбән губернасында 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша, 1917–18 дә мөселман эшләре буенча комиссар. 1919 да 11 нче Петроград дивизиясенең кавалерия полкы, аннары бригадасы хәрби комиссары, 1920 дә Казан кавалерия курслары комиссары. 1920–24 тә ТАССР Милиция баш идарәсе җитәкчесе, 1924–27 дә ТАССР ХКС рәисе. 1927–30 да РСФСРның Кече ХКС әгъзасы. 1930 дан Мәскәүдә: 1933–37 дә РСФСР Университетлары һәм фәнни-тикшеренү оешмалары баш идарәсе җитәкчесе, бер үк вакытта Мәскәү ун-тында колониаль һәм бәйле илләр тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Россиядәге пантюркизм һәм панисламизм тарихына, төрек буржуаз рев-циясе вакыйгаларына карый. Репрессияләр чоры корбаны (к. «Идел-Урал оешмасы» эше, *«Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы» эше*).

Х е з м.: Татарстан за семь лет (1920–1927). К., 1927; Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931 (автордаш); Младотурецкая революция. М., 1936.

*Әд.:* Б е л я л о в У. Габидуллин Хаджи Загидуллович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ГАБИ́ТОВ** Илдар Равил улы (3.10.1950, Красноярск ш.), физик, физ.-матем. фән. канд-ты (1984), проф (1994). 1974 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң, Технология фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Ленинград өлкәсе, Сосновый Бор ш.). 1975–87 дә СССР ФАнең Кыргызстан физика һәм математика ин-тында. 1987–90 да СССР ФАнең Су проблемалары ин-тында (Мәскәү). 1990 нан Л.Д.Ландау исем. теоретик физика ин-тында (Мәскәү), бер үк вакытта 1998 дән Лос-Аламосс милли лаб-ясендә (АКШ) оптик-җепселле элементәне матем. модельләштерү һәм анализлау төркеме җитәкчесе, 2002 дән Аризона ун-ты (АКШ, Тусон ш.) матем. ф-тында информатика һәм фотоника өлкәсендә матем. алымнар һәм модельләштерү төркеме җитәкчесе. Хезмәтләре математика, теоретик физика, нәсызыкча оптикага карый. «Journal of Physics. D» (АКШ) ж-лы мөхәррире.

**ГАБИ́ТОВ** Исмәгыйль Билалетдин улы (Исмәгыйль Габди) (1890/91, Казан губ. Тәтеш өязе — ?), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстиян катлавыннан. Айтуган мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (1910), Төркиядә белем ала. Мәккәдә һәм Мәдинәдә була. 1913–17 елларда Бишбалта бистәсендәге җамигъ мәчеттә мулла, имам-хатиб (Казан). 1917 дән Сугыш афәтеннән качкан мөселманнарга ярдәм итү ком-ты әгъзасы, Төркестан мөселманнарына матди ярдәм оештыруда катнаша, *«Шураи ислам»* г-тасы редакциясе сәркәтибе. Бөтенроссия мөселман руханилары корылтаенда (1917, Казан) катнаша; «әл-Гыйма» җәмгыятенең сәркәтибе. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18), «төркичеләр» фракциясе әгъзасы. *«Иттифакъ»* г-тасы хезмәткәре (1918). Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Д.М.Госманова.*

**ГАБИ́ТОВ** Нурулла Кәлимулла улы (2.10.1924, Буа кантоны Иске Тинчәле а. — 8.1.2001, Казан), нәшрият хезмәткәре, тәрҗемәче, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1969, 1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан укытучылар ин-тын (1951), Казан пед. ин-тын (1954) тәмамлый. 1940–42, 1946–52 елларда Әлки һәм Буа р-ны мәктәпләрендә укыта (1950–52 дә Буа р-ны Әлши җидееллык мәктәбе директоры). 1955–59 да КПССның Буа райкомында партия эшендә. 1954–55 һәм 1959–87 дә Татарстан китап нәшриятында: мөхәррир, өлкән мөхәррир (1959–63, 1984–87), тарихи һәм сәяси әдәбият редакциясе мөдире, баш мөхәррир урынбасары (1972–84). Г. ның аналитик мәкаләләре һәм очерклары күп кенә респ-ка басмаларында дөнья күрә. Партия, совет сәяси эшлеклеләренең, совет һәм чит илләрнең фәнни-популяр һәм матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Х.Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1980). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Р.Заманова.*

**ГАБИ́ТОВ** Сафиулла (1872, Тәтеш өязе Иске Әнәлә а. — ?), әкиятче. Урман кисүдә, Кострома шәһәрендә туку ф-касында, Ташкентта тимер юлда эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Фронттан кайткач Кострома шәһәрендә, 1923 елдан туган авылында яши. Гомере буе халык авыз иҗаты б-н кызыксына, башкалардан ишеткәнне туплый бара, үзе дә сөйли. 1947 дә фольклорчылар Х.Х.Ярми һәм Х.Х.Гатина аңардан 10 әкият язып алалар, бу әкиятләр күптомлы «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» (т.1–3, 1977–81) китабына кертелә.

*Әд.:* Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. К., 1994.

**ГАБИ́ТОВ** Фаризан Рәкыйп улы (10.7.1951, Казан), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (2000), проф. (2003). 1974 елда Казан хим.-технол. ин-тын тәмамлый. 1974–76 да Казан компрессорлар з-дында, 1976–78 дә Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1978 дән Казан технол. ун-тында гидравлика (1978–88), инженерлык графикасы (1988–92), җылылык техникасының теоретик нигезләре (1992 дән) кафедраларында. Хезмәтләре энергетикадагы мөһим җылыйөрткечләрнең термофизик үзенчәлекләренә һәм энергия саклаучы яңа химик технологияләргә карый. Гадәти һәм авыр су парларының 30 *МПа* гә кадәр басымда һәм 1000 К га кадәр темп-рада молекуляр темп-ра үткәрүчәнлеген үлчәү ысулын эшли. Органик кушылмаларның 10 классына караган 30 дан артык матдәнең термофизик үзлекләрен өйрәнә. Үтә югары сыеклык экстракциясен кулланып, энергия саклаучы экологик хәвефсез күп кенә химик технологияләрнең теоретик нигезләрен дә-



Х.З. Габидуллин.

лилли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Применение метода импульсного нагрева для измерения теплофизических свойств жидкостей в потоке // Вестн. Казан. технол. ун-та. 1999. № 1; Температуропроводность различных органических жидкостей при высоких температурах // Журн. прикладной химии. 1999. Т. 72, вып. 2 (автордаш); Концентрирование глицерина в смеси с жирными кислотами и водой методом сверхкритической флюидной экстракции // Теорет. основы хим. технологии. 2001. Т. 35, № 3 (автордаш); On Estimation of the Radiant Component at measurement of Liquid Thermal Conductivities at High Temperatures // High Temperatures — High Pressures. 1993. V. 25 (автордаш).

**ГАБИ́ТОВЛАР**, җәмәгать эшлеклеләре; 1) **Шәрәфетдин Габитов** (19 йөз), Кытайның Синьцзянь провинциясендә Россия консуллыгы хезмәткәре; 2) аның балалары: **Исмәгыйль** (? — 1937), «Тәрәкъкый» г-тасы нашире (1906, Сәмәрканд ш.); **Зәйнәп** (? — ?) һәм **Рәбига** (? — 1954), Казанда үз өйләрендә «Шимбә» әдәби түгәрәген оештыручылар (к. *«Шимбәчеләр»*). Җир тетрәүдән зыян күргән Җидесу казакъларына (Казакъстан) ярдәм оештыруда катнашалар.

**ГА́БИШЕВ** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 25 *км* көньяктарак, Кавал күленнән 1,5 *км* ераклыкта. 2008 елда 2555 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 58%, руслар — 36%) яши. Кошчылык ф-касы. Урта мәктәп. Мәдәният йорты, китапханә. 1970 елларда нигез салына, торак пункт буларак 1986 да теркәлә. Халык саны: 1989 да — 1636, 2002 дә — 2488 кеше.

**ГА́БИШЕВ** Иван Яковлевич (1888, Казан губ., Лаеш өязе Паново а. — 20.9.1918), сәясәт эшлеклесе. 1914 елга кадәр Казанда яши. Бертуган Крестовниковлар з-дында эшли, шунда ук 1912 дә РСДРП төркеменә керә. 1914 тә гаиләсе б-н Бакуга күчеп китә. Красноводск, Ашхабад шәһәрләрендә, Челекен утравы нефть промыселларында эшчеләр арасында революцион эш алып бара. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Россия армиясендә — Ашхабадта хәрби фельдшер. 1917–18 дә Бакуда: Кызыл гвардиянең Үзәк штабы рәисе, Кавказ Кызыл Армиясенең хәрби-революцион ком-ты әгъзасы, бригада комиссары. Бер үк вакытта Бакуның Порт р-ны Эшче һәм солдат депутатлары советы рәисе; Эшче һәм солдат депутатларының Баку Советына сайлана. 1918 нең сентябрендә Баку комиссарларын Әстерхан шәһәренә эвакуацияләгәндә кулга алына һәм Красноводск төрмәсенә ябыла. 20 сентябрьдә 26 Баку комиссары арасында Каспий аръягы тимер юлының



А.А.Гаврилов.

207 нче чакрымында, Перевал һәм Ахча-Куйма станцияләре арасында атып үтерелә.

*Әд.:* М у л ю к о в М. Габишев Иван Яковлевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ГАВРИ́ИЛ** (Кременецкий Григорий Федорович) (1708, Киев губ. Носов ш. — 8.8.1783, Киев ш.), дин эшлеклесе. Киев һәм Мәскәү руханилар академияләрен тәмамлый. 1736 елдан Петербург руханилар семинариясендә укыта, 1740 тан — шунда ректор (1739 дан монахлыкта). 1748 дән архимандрит һәм Изге Синодта вәкил. 1749 дан Коломенск, 1755 тән — Казан һәм Зөя епискобы, 1762 дән Петербург архиепискобы, 1767 дән Киев митрополиты. Аның чорында Казанда элегрәк епископ булган Лука (Конашевич) тарафыннан алып барылган мөселманнарны аяусыз изү сәясәте туктатыла, консистория хезмәткәрләре һәм благочинныйларның вәкаләтләре чикләнә.

*Е.В.Липаков.*

**ГАВРИ́ИЛ** (Зырянов Гавриил Михайлович) (14.3.1844, Пермь губ., Эрбет өязе Бобровки а. — 24.9.1915, Казан), дин эшлеклесе. 1864–74 елларда Калуга губернасындагы Оптина пустынендa укый, Амвросийның һәм Оптинадагы башка остазларның шәкерте. 1874 тән Мәскәүнең Высоко-Петровский монастырендa (1875 тән, Тихон исеме алып, монахлыкта). 1882 дән Раифа Богородица монастырендa, 1888–1908 дә Седмиозёр пустынендa (1892 дән Гавриил исеме ала), 1902–08 дә схиархимандрит, монастырь наместнигы. Седмиозёр пустынендa Зәбурны тоташ уку өчен махсус гыйбадәтханә төзетүе, абруйлы дин эшлеклеләрен һәм җитәкчеләрне тәнкыйтьләве кебек гамәлләре өчен вазифасыннан читләштерелә. 1908–15 тә Псков янындагы Спас-Елиазаров пустынендa. 1915 тә, Седмиозёр пустынена кайтып барганда, авырып китә һәм Казанда үлә. 1890 еллар урталарында Г. Россиядә иң абруйлы дин әһелләренең берсе була, аңа йөзләгән кеше килә. Аны олылаучылар арасында Казан архиепископлары Арсений (Брянцев), Дмитрий (Самбикин), бөек княгиня Елизавета Фёдоровна бар. 1990 елларга кадәр Казан епархиясе терр-ясендә Г.ны олылау рәсми булмаган рәвештә дәвам итә. Г. 1996 да изгеләштерелә. Искә алу көне — 24 сент. (7 окт.). 2000 дә Г.ның җәсәде яңадан торгызылган Седмиозёр монастырена күчерелә.

Х е з м.: Поучения и слова иеромонаха Гавриила. К., 1900; Построение и освящение храма в Седмиозерной пустыни для поминовения усопших и непрестанного чтения Псалтири. К. 1901.

*Әд.:* Старец схиархимандрит Гавриил (Зырянов) и Седмиозёрная Казанская Богородичная пустынь. М., 1991; Житие преподобного Гавриила, старца Седмиозёрной пустыни. М., 1997.

*Е.В.Липаков.*

**ГАВРИ́ИЛ** (Воскресенский Василий Николаевич) (1795–1868), философ, дин белгече. Елантау-Успение (1829–32) һәм Спас-Преображение (1832–40) монастырьлары башлыгы. Бер үк вакытта 1835–40 елларда Казан ун-ты профессоры. Россиядә фәлсәфә тарихы өлкәсендә беренче тикшеренүләр («Философия тарихы», 1–6 кисәк; 1837–40) авторы. Хезмәтләре ш.у. дин хокукы, Казан тарихына карый.

**ГАВРИ́ЛОВ** Аким Андреевич (22.9.1904, Казан губ., Зөя өязе Олы Мәми а. — 22.1.1982, Алабуга ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), гв. кече лейтенанты. Казан танк уч-щесен тәмамлый (1943). 1921–26 елларда Донбасста шахтада, 1926–33 тә туган авылында колхозда, Разумов исем. с-зда (соңрак «Мамадыш» с-зы) профсоюз эшендә эшли (1936), Әгерҗе шәһәрендә «Кызыл Шәрекъ» з-ды базасы б-н идарә итә (1938–39), 1940–42 дә Алабуга шәһәренең «Ударник» артелендә эшли. 1942 нең июленнән Кызыл Армиядә. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 136 нчы гв. укчы полкының (40 нчы армиянең 42 нче гв. укчы дивизиясе) взвод командиры. 1943 тә Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск һәм Полтава сугышларында, Сумы өлкәсен азат итүдә катнаша. Черкассы өлкәсенең Маньков р-ны Антоновка авылы янындагы Таулы Тикич елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: взводны үз артыннан әйдәп, беренче булып бозлы суга ташлана; суны кичеп, взвод плацдармда нығып кала, аны кулда тоту һәм киңәйтү өчен сугыш алып бара. Г. авыр яралана. 1944–45 тә Алабуга р-ны Разживино авыл советы рәисе. 1946–57 дә райбашкарма ком-тының социаль тәэминат бүлеге мөдире, ТАССР Әзерләүләр министрлыгы вәкиле, Алабуга шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Геройның исеме Югары Ослан р-нының Түбән Күл бистәсе урта мәктәбенә бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАВРИ́ЛОВ** Анатолий Михайлович (15.9.1937, Владимир өлкәсе Вязники ш.), спорт судьясы (гандбол), халыкара категорияле судья (1976). 1964 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук укыта, радио б-н идарә итү каф. доценты (1999 дан). СССР (1966–91), Россия (1991 дән) чемпионатларында, СССР халыклары спартакиадасында (1971, 1975, 1979, 1983, 1986), Европа кубогына ярышларда (1978–87), дөнья чемпионатында (1975), Олимпия уеннарында (1980) судьялык итүдә катнаша. Греция (1981), Бразилия (1996) халыкара судьялык курсларында җитәкче. 1975–87 дә Халыкара судьялар федерациясенең иң яхшы 10 судьясы исемлегендә.

**ГАВРИ́ЛОВ** Андрей Петрович (17.10.1942, Казан — 28.9.1991, шунда ук), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1970). 1960–61, 1963–70 елларда Казан вертолёт з-дында, 1962 дә ВЛКСМның Киров райкомында эшли. 1970 тән күптиражлы «Знамя труда» г-тасы (Казан) хәбәрчесе. 1973–75 тә КПССның Киров райкомы инструкторы, гомуми бүлек мөдире, КПССның Казан шәһәр ком-тында пропаганда бүлеге мөдире урынбасары. 1979 дан Татарстанда беренче шәһәр г-тасы «*Вечерняя Казань*»ны чыгаруны башлап йөрүче, оештыручы һәм аның беренче мөхәррире. СССР ЮС депутаты (1989–91).

*Әд.:* М о р о з о в А.В. Персоны. К., 1998; Тематическая подборка, посвящ. 60-летию А.П.Гаврилова // Вечерняя Казань. 2002. 16 окт.; Он был редактором от бога. К., 2002.

*Г.Р.Заманова.*

**ГАВРИ́ЛОВ** Владимир Иванович (8.8.1942, Йошкар-Ола ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Казан финанс-икътисад ин-тында эшли. 1967 елдан Казан технол. ун-тында, төп органик һәм нефть химиясе синтезы технологиясе каф. мөдире (1990 елдан). Хезмәтләре мышьякорганик кушылмаларның химиясе һәм технологиясе, органик һәм нефть химиясе синтезына карый. Г. мышьякорганик кушылмаларның реакциягә сәләтләрен һәм структурасын, Меншуткин, Мейер һәм икетөшле ароматик системаларны арсенлау реакцияләрендә мышьяк-углерод бәйләнешенең барлыкка килүе һәм өзелүе закончалыкларын тикшерә. Мышьяк кушылмаларын материалларны һәм эшләнмәләрне биологик таркалу һәм биологик зарарланудан саклау өчен практик куллану мөмкинлеген өйрәнә. Мышьяклы химик матдәләрне (люизит, адамсит) утильләштерү технологияләрен эшли. Адамсит нигезендә диңгез суднолары өчен капланып үсми торган эмальләрнең югары нәтиҗәле биоцид компонентларын эшли.

Х е з м.: Влияние заместителей на реакционную способность мышьякорганических соединений // Строение и реакционная способность органических соединений. М., 1978 (автордаш); Ликвидация запасов люизита // Проблемы уничтожения химического оружия. Ижевск, 1995; Мышьякорганические биоциды // Вестн. Казан. технол. ун-та. 1997. № 1 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАВРИ́ЛОВ** Пётр Михайлович (17.6.1900, Казан губ., Лаеш өязе Әлбәдән а. — 26.1.1979, Брест ш.), татар милләтеннән. Сов. Союзы Герое (30.1.1957), майор. Мәскәүдә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1939). Гражданнар һәм совет-фин сугышларында катнаша. 1941 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 44 нче укчы полк (13 нче армиянең 42 нче укчы дивизиясе) командиры. 1941 нең 22 июненнән 23 июленә кадәр Брест крепостеның Көнчыгыш фортын саклау б-н җитәкчелек итә. Әсирлеккә эләгә. Брест концлагеренда була. 1945 нең маенда совет гаскәр-

ләре тарафыннан азат ителә. 1946 га кадәр армиядә хезмәт итә. Репрессияләнә; 1957 дә аклана. Брест крепосте оборонасы б-н җитәкчелек итүдәге батырлыгы өчен Сов. Союзы Герое исеменә лаек була. СССР ЮС депутаты (1958–62). Туган җирендә, соңрак Краснодарда яши. П.Гаврилов К.Молчановка «Брест крепосте» операсын иҗат иткәндә киңәшче була, «Чик буе» кинофильмын төшерүдә катнаша. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Брест шәһәренең мактаулы гражданы, Г. исеме Казан, Краснодар һәм Питрәч авылы урамнарына бирелә. Питрәч р-нының Күн авылында Геройның бюсты куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Смирнов С.С. Брестская крепостә. М., 1964; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАВРИ́ЛОВ** Фёдор Павлович (16.2.1890, Пенза губ., Түбән Ломов өязе Плёсс а. — 1926, Казан), архитектор, педагог, рәссам. 1913 елда Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый һәм эшләр башкарырга хокуклы техник дәрәҗәсе ала. 1913–15 тә Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе өчен бина төзелешендә арх. В.А.Трифоновның ярдәмчесе була. 1915–16 да Казан дары з-дында (хәзер В.И.Ленин исем. фәнни-җитештерү пр-тиесе) район прорабы булып эшли. 1918–19 да — Казан шәһәр идарәсендә шәһәр техникы, шул ук вакытта Казан югары ирекле сәнгать остаханәләрен тәмамлый (1920). 1920–21 дә шул остаханәләр эшләре буенча вәкаләтле вәкил. 1922 дән Казан архит-ра-техника ин-ты (соңрак — Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре) ректоры, бер үк вакытта Татарстан дәүләт биналары



Ф.П. Гаврилов. Зобнин йорты. 1914.

ком-тында проектлаштыру бюросы мөдире, ш.у. 1924–26 да ТАССР инженерлык-төзелеш идарәсе архитекторы булып эшли. ТатЛЕФ әгъзасы (1925). Зобнин йорты (1914), совет хакимияте елларында Казан шәһәрен үстерү буенча төзелгән беренче схемалар (1924–26), М.Вахитов (1921) һәм Халыклар дуслыгы һәйкәлләре (1924–26, сакланмаганнар) авторы.

*Т.Р.Закирова.*

**ГАВРИ́ЛУШКИН** Александр Никитич (28.8.1897, Тула губ., Алексеев өязе Подмоклово а. — 10.8.1975, Мәскәү), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Мәскәү текстиль ин-тын тәмамлый (1932). Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнаша. 1921–29 елларда Серпухов шәһәре (Мәскәү өлкәсе) пр-тиеләрендә эшче. 1932–36 да Горький киез итек басу ф-касы баш инженеры, 1936–37 дә Омск, 1941–42 дә Казан киез итек басу ф-калары директоры. 1942–46 да ТАССР җиңел сәнәгать халык комиссары. Бөек Ватан сугышы елларында аның инициативасы белән ТАССРда берничә яңа пр-тие, ш.и. Казан балалар аяк киеме ф-касы, Алабуга киез итек-дирбия җитештерү комб-ты оештырыла. 1946–53 тә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1953–54 тә ТАССР МС каршындагы Юл һәм транспорт хуҗалыгы идарәсе, 1954–57 дә Автомобиль транспорты һәм шоссе юллары идарәсе башлыгы. 1947–55 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ГАГА́ЕВ** Борис Михайлович (20.7.1897, Казан — 1.8.1975, шунда ук), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1936), проф. (1933), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1954, 1966). 1923 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1934–74 елларда матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре матем. анализ өлкәсенә, ортогональ функцияләр системалары һәм интегродифференциаль тигезләмәләр теориясенә карый. Г. тригонометрик функцияләр системасының дифференциаллау һәм интеграллау (даими тапкырлаучыларга кадәр төгәллек б-н) нәтиҗәсендә шул ук функцияләр системасына китерелә торган бердәнбер ортогональ функцияләр системасы булуын исбатлый. Полигармоник функцияләр, интеграль һәм интегродифференциаль тигезләмәләр теориясен төзи һәм үстерә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Интегральные уравнения. К., 1931; О сходимости в банаховских пространствах // Успехи матем. наук. 1948. Т. 3, № 5; Единственность одной задачи сопряжения функций, удовлетворяющих эллиптическому уравнению // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116., № 1; Ортогональные системы функций, производные которых также ортогональны. // Успехи матем. наук. 1957. Т. 121, вып. 2.

**ГАГА́РАЛАР** (Gavia), гагаралар семьялыгыннан су кошлары ыругы. 4 төре билгеле, Европада, Азия һәм Төньяк Америкада очрый. ТРда 2 төре — кызыл бүксәле гагара (G. stellata) һәм кара бүксәле гагара (G. arctica) бар. Кара бүксәле Г. Көләгәш сазлыгында һәм Мишә елгасы тамагында оялаган (1932 һәм 1947), хәзер исә көзге һәм язгы күчеш вакытларында очрый. Түбән Кама сусаклагычында, Агыйдел елгасы тамагы тирәсендә 1000 ләп гагара төркем булып җыела. Гәүдәсе 100 *см*, канат җәеме 150 *см* га кадәр. Муены озын, сыгылмалы. Башы кечкенә, томшыгы озын, туры, хәнҗәрсыман. Каурыйлары тыгыз, куе. Коры җирдә, бәкәл сөягенә таянып, шуышып кына йөри ала. Төп азыгы — балык, эре су умырткасызлары. Кызыл бүксәле гагара Татарстан терр-ясендә юкка чыккан хайваннарның «кара исемлеге»нә, кара бүксәлесе ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГАДЕ́Л** (псевд., фамилиясе Гаязов) Әхмәт Һади улы (2.2.1942, Мамадыш р-ны Акчишмә а.), шагыйрь, кинодраматург. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1977, Мәскәү) тәмамлый. 1966–82 елларда Түбән Кама район газетасы хәбәрчесе, Балык Бистәсе р-ны Шомырбаш мәктәбендә укытучы, ТАССР МС Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында тәрҗемәче, Республика халык иҗаты йортында һәм Мәдәният министрлыгында методист булып эшли. 1983–84 тә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. 1992–97 дә ТР Кинематография дәүләт комитетында, 1997–99 да ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары.

Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. Армия тормышыннан алып язылган шигырьләре рус телендә «Поиск» исеме белән аерым җыентыкта дөнья күрә. Заманча эчтәлекле, жылы бер аһәң б-н өртелгән лирик шигырьләре «Күгәрченнәр» (1971), «Чам» (Кырым татарлары телендә, Ташкент, 1978), «Көмеш кылган җыры» (1982), «Яшьлегем былбыллары» (1985), «Дәрт» (1992) җыентыкларына тупланган. Аның сценарийлары буенча һәм автордашлыгында 50 дән артык документаль фильмнар һәм балалар өчен мультфильмнар төшерелгән. Ашхабад һәм Мәскәүдә үткәрелгән бөтенсоюз кинофестивальләре лауреаты (1984; 1987).

*Әд.:* Ахунов Г. Шагыйрь дөньясы // Социалистик Татарстан. 1992. 1 февр.; Хисматулла Р. Бердәнбер // Ватаным Татарстан. 1997. 14 март; Әхмәтҗанов М. Әнкәйләрдән килгән бу мәхәббәт // Мәдәни җомга. 1997. 14 март.



П.М. Гаврилов.



Б.М. Гагаев.

**ГАДЕ́ЛЕВ** Нәүфәл Исмәгыйль улы (4.12.1932, Казан — 1.12.2004, шунда ук), сынчы, ТРның халык рәссамы (1993), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1983). Казан сәнгать уч-щесендә С.С.Ахун җитәкчелегендә укый (1947–51), Пенза сәнгать уч-щесенең скульптура бүлеген А.А.Фомин җитәкчелегендә тәмамлый (1957). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Портретлы, сюжетлы, анималистик скульптура һәм монументаль бизәлеш скульптурасы жанрларында бронза, мәрмәр, чуен һәм гипс кебек материаллар б-н эшли. Агачтан композицияләр ую остасы, фактураларының байлыгы (агачның текстур сыйфатлары һәм төс үзенчәлекләре, аны эшкәртү һәм буяуның төрле алымнары) б-н аерылып торучы зәвыклы пластик әсәрләр авторы. Аеруча танылган әсәрләре — «Советлар Союзы Герое патриот-шагыйрь Муса Җәлил» (мәрмәр, 1963), «Г.Тукай» (гипс, 1967), «Математик Якушев» (агач, 1969), «Актёр Г.Шамуков» (гипс, 1960 еллар) һ.б. Г.нең иң әһәмиятле әсәрләреннән берсе «Батыр» (агач,



Н.И. Гаделев.



Х.Г. Гаделшин.

1967) Сов. Союзы Герое Газинур Гафиятуллин образын гәүдәләндерә. Рәссам тарихи жанрга («Пугачёв», агач, 1966; «Үткәннәрдән», агач, 1967), композицион скульптурага мөрәҗәгать итә. Соңгысында нечкә зәвыклы, лирик хисләр б-н өртелгән хатын-кыз образлары өстенлек итә: «Кояш чыгышы», «Яшьлек», «Картлык», «Ана» (агач, 1972), «Ромашка» аллегорик фигуралар сериясе (агач, 1979). Гипстан һәм агачтан вак формалы әсәрләр иҗат итә («Үрдәкләр очышта», «Кыш», «Сакчылар», 1980 еллар). Г. хезмәтләренә хисләр байлыгы, декоративлык, образны гомумиләштереп бирү хас. Монументаль бизәлеш һәм мемориаль скульптура үсешенә



Н.И. Г а д е л е в. «Актёр Г.Шамуков». Гипс. 1960 еллар.

өлеш кертә, Юдино бистәсендәге Я.А.Юдин кабере ташы (мәрмәр, гранит, 1964), Җәлил посёлогындагы Муса Җәлил һәйкәле (чуен, 1967), элеккеге Казан сәнгать мәктәбе диварында Н.И.Фешин һәм Б.И.Урманче истәлегенә куелган мемориаль такталар (1952) авторы. Бөтенроссия («Совет Россиясе», 1967 елдан), төбәкара («Зур Идел», 1964 тән) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда 1966 да (Т.А.Зуева һәм Е.В.Зуев б-н берлектә), 1982 дә (В.К.Фёдоров б-н берлектә), 1998 дә уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1970. Т. 1; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАДЕ́ЛШИН** Альберт Сөнгат улы (18.4.1939, Зәй р-ны Бигеш а.), цирк режиссёры, эстрада артисты, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). 1964 елда, Ульянов шәһәр филармониясенең эстрада артисты буларак, иллюзион номер б-н чыгыш ясый, шул ук елда Казандагы М.Горький исем. клубта иллюзионистлар түгәрәге оештыра. 1965–68, 1970, 1973 елларда Татар филармониясендә иллюзион эстрада артисты. 1978 дә Мәскәүдә Югары режиссёрлар курсларын тәмамлаганнан соң, Ярославль шәһәре циркында баш режиссёр (1979) була. 1981–96 да Казан циркында: баш режиссёр (1992 гә кадәр), 1992 дән директор урынбасары. 1990 да «Кара иллюзия театры» («Чёрный театр иллюзии») дип аталган эстрада-цирк программасын оештыра, анда ул, гипноз чаралары кулланып, фокус трюклары күрсәтә. Театр 3 ел чамасы эшли. Г. шактый цирк тамашалары һәм фантастик әкиятләр сюжетына корылган пьесалар, күп сценарийлар авторы. Алар арасында 1998 елда Казан яшь тамашачылар театрында куелган «Кырлай кызы Айсылу» («Айслу из деревни Кырлай»), 2000 дә Казан татар яшьләр театрында куелган «Хикмәт бабай хикмәтләре» пьесалары бар.

*Ю.А.Благов.*

**ГАДЕ́ЛШИН** Рөстәм Рәшит улы (14.4.1955, Уфа ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1999), Башкортстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (2006). 1977 елда Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Уфа гыйльми үзәгенең Математика ин-тында эшли, 1995 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1997 дән Башкорт пед. ин-тының алгебра һәм геометрия, 2003 тән матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре матем. физиканың сингуляр тайпылышлы, чик шартларына кечкенә параметрлар кергән кырый мәсьәләләрен чишүгә карый.

Х е з м.: Существование и асимптотики полюсов с малой мнимой частью для резонатора Гельмгольца // Успехи мат. наук. 1997. Т. 52, вып. 1; О спектре дифференционального оператора на оси с быстро осциллирующими коэффициентами // Мат. сборник. 2007. Т. 198, № 8 (автордаш): Спектр периодического оператора с малым локализированным возмущением // Докл. РАН. 2007. Т. 413, № 4 (автордаш).

**ГАДЕ́ЛШИН** Хәмит Габдулла улы (10.7.1923, БАССРның Бишбүләк р-ны Ает а. — 10.1.2000, Кыргызстан Респ-касы Бишкәк ш.), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), полковник. Радиотелеграфчылар курсын (1941), сугыштан соң Ленинград хәрби уч-щесен һәм Ленинградтагы Сов. Союзы Маршалы С.М.Будённый исем. Хәрби элемтә академиясен тәмамлый. 1941 елның августыннан Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1449 нчы аерым элемтә ротасының (46 нчы армиянең 31 нче укчы дивизиясе) өлкән радиотелеграфчысы. Кавказ арты, Төньяк Кавказ, Дала, 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында СССР б-н Төркия арасындагы дәүләт чикләрен һәм Кара Диңгез ярларын саклауда (1941–42), Зур Кавказ сыртының үзәк өлеше өчен барган бәрелешләрдә (1942), Кавказ һәм Днепр өчен барган сугышларда (1943), Уңъяк яр Украина, Румыния, Болгарияне азат итүдә (1944), Яссы-Кишинёв операциясендә, Дебрецен (икесе дә — 1944), Будапешт (1944–45), Вена һәм Прага (1945) һөҗүм оперцияләрендә катнаша. 1943 нең 27 сентябрендә Сошиновка авылы янында (Днепропетровск өлкәсе Югары Днепр р-ны) Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара (1969 га кадәр). Фрунзе (Бишкәк) шәһәрендә Фрунзе исем. һөнәр уч-щесендә хәрби җитәкче булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**«ГАДИ́ АНТО́НОВКА»**, алманың кышкы сорты, халык селекциясе. Үзәк Россиядә һәм Урта Идел буенда киң таралган. ТРда йорт яны һәм җәмәгать бакчаларында үстерелә. Бакчачылык хуҗалыклары өчен төп сәнәгать сорты булып санала. Алмалары эре, хуш исле, яхшы сакланаучан, югары уңышлы (бер алмагачтан 300 *кг* га кадәр һәм аннан да күбрәк) булуы һәм кутыр авыруына чыдамлылыгы б-н югары бәяләнә. Кышка чыдамлылыгы уртача. Алмагачы биек, ябалдашы нык, яшь алмагачныкы кысынкы, пирамида сыман, җимеш бирү чорында — куе яфраклы, түгәрәк була. Яшь ботаклары буынлы, коңгырт төстә, яфраклары озынча-түгәрәк — эллиптик формада, зәңгәр төсмерле куе яшел төстә, төпчек яфраклары озын, ланцет сыман. «Г.а.» озын вегетацияле сортларга керә. 6–7 елдан соң, тулысынча 15 елдан алма бирә башлый, Алмалары уртачадан зуррак һәм эре (100–150 *г*), түгәрәк яки конус сыман. Алманың кабыгы ялтырап тора, җыеп алганда саргылт-яшел, тулысынча өлгергәч ачык-сары төстә була. Җимеш сабы кыска, уртача юанлыкта. Җимеш сабы урнашкан чокыр тирән һәм киң, бу сортка гына хас булганча коңгырт төстә. Алманың йомшагы ак, бераз саргылт төстә, ярмалы, әчкелтем-баллы, хуш исле, саклаганда үзенә генә хас булган үзенчәлекле тәм керә. ТР шартларында октябрь башларында, җәй эссе елларда сентябрь ахырында өлгерә.

**ГАДИ́ СӨЙЛӘ́М**, әдәби телнең орфоэпик һәм грамматик нормаларыннан читләшкән, әмма шул ук вакытта әлеге телдә сөйләшүчеләр өчен аңлаешлы сүзләр, гыйбарәләр, сөйләм әйләнмәләре, сүз ясалышы һәм үзгәреше формалары, сөйләү үзенчәлекләре. Татар Г.с.ендә тел белеме бүлекләренең барлык берәмлекләре урын ала. Г.с. үзенчәлеге әдәби тел элементларының башка мәгънәдә кулланылуында (яулык урынына — ябынча, канәгатьсез урынына — комагай), гомуми сүзлек фондындагы (канәгатьләнү урынына — кану, көлке урынына — көленеч) һәм рус теленнән алынган сүзләрнең фонетик һәм грамматик яктан үзгәртелүендә (газета урынына — гәҗит, пальто урынына — пәлтә, кастрюля урынына — кәстрүл) аеруча ачык чагыла. Г.с. сүзләре эш-хәрәкәтләрнең охшаш булуыннан да барлыкка килә ала: сөйләшү урынына — сүз чәкештерү һ.б.

Г.с.гә әдәби телдә нейтраль синонимнары булган, экспрессив яктан «түбәнәйтелгән», әрсезлектән дорфалыкка кадәр төсмерле бәяләү сүзләре хас: дөмбәсләргә — кыйнарга; дөмек — югал; тулы түгел — юләр һ.б.

Г.с.нең составы һәм чикләре тарихи яктан үзгәрүчән. Кайбер гади сөйләм сүзләре һәм формалары вакыт үтү б-н гомум кулланылыштагы сүзләр рәтенә күчәләр: хөрти; шылу; шыңшу һ.б. Әдәби әсәрләрдә Г.с. предмет, күренеш, вакыйгаларны сүз б-н тасвирлау , билгеле бер төсмер (колорит) бирү өчен кулланыла.


*Әд.:* Хәзерге татар әдәби теле. К., 1965; Сәгыйтов М.Ә. Гади сөйләм проблемасын өйрәнүгә карата // Вопр. тюркского языкознания. К., 1976; Вып. 162. Хаков В.Х. Татар әдәби теле: Стилистика. К., 1999.

*А.М.Сәгыйтова.*

**ГАДИ́ ТИЕ́Н** (Sciurus vulgaris), тиенсыманнар семьялыгыннан имезүче җәнлек. 40 лап астөре бар, бер-берсеннән төсләре б-н аерыла. Евразиядә һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТР терр-ясендә күбесенчә Кама алдында очрый. Ылыслы, киң яфраклы һәм катнаш урманнарда яши. Еш кына кешегә якынрак, шәһәр паркларында урнаша. Гәүдәсенең озынлыгы 30 *см* га кадәр, койрыгыныкы — 15 тән алып 20 *см* га кадәр, 270–330 *г* авырлыкта. Колаклары озын, очлары чуклы. Арткы аяклары алдагыларына караганда озынрак. Төсе үзгәрүчән: ачык җирәннән (җәен) алып соры-зәңгәргә (кышын) кадәр. Йон капламы озын, йомшак, кышын йөнтәс, җәен беркадәр каты, кыска һәм ялтыравыклы. Язын һәм көзен төсен алмаштыра. Әләктерүчән һәм үткен тырнаклары булу сәбәпле, күсә һәм ботакларга иркен менә, агачтан агачка җиңел сикерә. Ылыслы агачлар орлыгы, имән чикләвеге, чикләвек, җиләк, гөмбәләр б-н туклана. Кышка азык әзерли. Уңдырышсыз елларда азык эзләп массакүләм күчәргә мөмкиннәр. Оясын агачларда лишайниклардан, мүкләрдән, кайрыдан һәм ботакчыклардан ясый яки куышларда урнаша. Бер елга 2 оя бала тудыра (һәрберсендә биш-җиде). 10 елга кадәр яши. ТРда Г.т. саны 3,57 меңнән (1991) 6,14 меңгә (2000) кадәр арта. Кәсәбәчелек объекты. 1950 елларда бер сезонга 3–6 мең баш ауланган, 1990 елларда бу сан ун тапкыр кимегән. Иң эре гәүдәлесе, Г.т.нең кыйммәтле астөре зур тиен — телеутка Алтайның нарат урманнарында яши. 1949–53 елларда Тукай һәм Лаеш р-ннары терр-ясендәге урманнарга, ш.и. Идел-Кама саклаулыгының Саралан мәйданына җибәрелә.

*Әд.:* Природные ресурсы Волжско-Камского края. К., 1968. Т. 2.

**ГАДИ́ ТУЗБА́Ш** (Natrix natrix), еланнар отрядының тузбаш елансыманнар семьялыгыннан сөйрәлүчеләр төре. ТР терр-ясендә барлык р-ннарда да таралган. Күбрәк елга һәм күл буендагы куе куаклыкларда яки куаклар үскән сазлыкларда, дымлы туфраклы урманнарда очрый. Озынлыгы 80–110 *см*. Гәүдәсенең өске ягында куе көрән яки куе соры төстәге, ачык булмаган рәсемнәр күрергә мөмкин. Башының як-ягы сары яки кызгылт сары таплы. Арка һәм ян тәңкәләренең ачык кабырчалары бар. Коры җирдә тиз шуыша, әйбәт йөзә һәм чума, агачларга җиңел менә. Кояшлы сөзәклекләрдә, аланнарда һәм кисенделәрдә апрель ахыры — май башында парлашалар. Ул вакытта тузбаш еланнарны төркемләп, ягъни 50–150 ләп очратырга мөмкин. Июль аенда ана Г.т. йомшак калын кабыклы тышчага 10 нан алып 28 гә кадәр йомырка сала. Инкубация чоры 40–60 көн дәвам итә. Августта 12–14 *см* озынлыктагы тузбашлар туа. Г.т. көндез аулый, төнлә ышык урыннарга — агачларның тамыры һәм төбендәге бушлыкларга, кимерүчеләрнең өннәренә кача. Сентябрь ахырында кышкы йокыга тала. Кышны имезүчеләрнең өннәрендә, агач төпләрендә һәм тирес өемнәре астында үткәрә. Нигездә, бакалар, вак балыклар, кәлтәләр, тычканнар һәм кыр тычканнары, вак кошлар б-н туклана. Г.т. — кеше өчен зарарсыз һәм куркынычсыз. Клоаналь бизләреннән бик тәмсез исле сары-көрән сыекча сиптереп дошманнарыннан саклана. Бу ис төлкеләргә, чәшкеләргә һ.б. ерткычларга тузбаш еланнарны ашарга комачауламый.



Гади тузбаш.

**ГАЕ́Д** (гарәп. عيد — бәйрәм) ислам динендәге төрки халыкларда иң олы ике дини бәйрәм — *Ураза бәйрәме* һәм *Корбан бәйрәменең* исеме.

**«ГАЗҺӘМ ЭЛЕ́КТР»**, Казанда бельгиялеләр тарафыннан оештырылган акционерлык җәмгыяте (1897–1914). Концессион килешү нигезендә эл. станциясеннән һәм газ з-дыннан файдалана. Шәһәрдәге 5044 йортның 309 ын эл. б-н тәэмин итә (1899). 1914 елдан җәмгыятьнең пр-тиеләре Казан шәһәр идарәсе карамагына күчерелә. 1918 дә милкен Совет хакимияте үзенә ала.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*В.А.Шагалов.*

**әл-ГАЗАЛИ́** (ألغزالى) әбү Хәмид Мөхәммәд (1058 яки 1059, Иран, Тус ш. — 1111, шунда ук), исламият галиме. Нишапур шәһәрендә белем ала. 1085 елда сәлҗүкләр вәзире Низам әл-Мөлек тарафыннан «Низамия» мәдрәсәсенә (Багдад) ислам хокук гыйлеме *фикъһ* мөгаллиме итеп билгеләнә. Вәзир үтерелгәннән соң (1095), күңел тетрәнүе нәтиҗәсендә Г. *дәрвишлеккә* китә. 1106 да, Низам әл-Мөлекнең улы Фәхр әл-Мөлек чакыруы б-н, яңадан «Низамия» мәдрәсәсендә укыта. Вафаты алдыннан туган шәһәре Туска кайта. Г. антик философия традицияләрен инкарь итү, ислам кануннарын рациональ күзлектән чыгып шәрехләү — *калям*, суфичылык тәгълиматын рәсми ислам кысаларына кертү тарафдары. Төп хезмәте «Ихйа голүм әд-дин» («Дин гыйлемнәренең яңаруы») китабында Г. гыйбадәт гамәлләрен шәрехли, дин гыйлемен дөньяви максатларга ирешү чарасына әверелдергән дин әһелләрен тәнкыйть итә. Аның фикеренчә, мөселманнан, остазыннан белем алганнан соң, иман һәм иҗат берлегенең хаклыгын аңлау өчен фәкать шәхси тырышлык кына таләп ителә. Хәзерге ислам дөньясында да Г. нең югары абруе саклана.

Хезм.: Воскрешение наук о вере: Избр. главы / Пер. с араб. М. 1980; Наставление верующим. М., 2002; «Наставление правителям» и другие сочинения. М., 2004; Права человека в исламе. М., 2006; Весы деяний и другие сочинения. М., 2007; Письмо к ученику. М.-Спб., 2007; Правильные весы (Ал-Кустас аль-Мустаким). М., 2007.

*Әд.:* Хисматуллин А.А. Классическое суфийское сочинение «Кимийа-йи саадат» («Эликсир счастья») Абу Хамида Мухаммада ал-Газали ат-Туси (1058–1111). СПб., 2001; Bousquet G.H. Jh'ya oulum aol-din ou Vivifcation des Seiences de la Foi. P., 1950.

**ГАЗӘ́Л** (гарәп. غزل — гыйшык-мәхәббәт), Урта һәм Якын Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Идел буе һәм Урал яны төрки телле халыкларның лирик поэзиясендәге шигъри жанр. Гадәттә, һәрберсе тәмамланган фикергә һәм мөстәкыйль мәгънәгә ия булган 7–15 бәйттән (икеюллыктан) тора. 1 нче бәйттә 2 юл да рифмалаша, башкалары **ба**, **ва**, **га**, **да**... тәртибендә бирелә. Соңгы бәйттә, кагыйдә буларак, автор исеме яисә псевдонимы искә алына. Г. жанрындагы иң камил әсәрләр безгә Рудаки, Сәгъди, Хафиз, Физули, Нәвои, Лотфи иҗатлары аша билгеле. Татар әдәбиятында урта гасыр шагыйрьләреннән Сәйф Сараи, Өмми Камал, Колшәриф; 19 һәм 20 йөзләрдә Ш.Зәки, Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Бабич һәм соңрак Н.Арсланов, Р.Гаташ, М.Мирзаның Г. жанрында иҗат иткән әсәрләре бар. Г. жанрына ш.у. Европа һәм рус шагыйрьләре дә (Гёте, А.Платен, А.Фет, В.Брюсов һ.б.) мөрәҗәгать иткән.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Квятковский А. Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Поэтический словарь. М., 1966.

**ГАЗЕНБУ́Ш** Конрад Конрадович (5.3.1874, Уфа губ., Уфа өязе Зубовка а. — 1918), революцион хәрәкәт эшлеклесе. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1898). 1897–98 елларда РСДРП-ның Казан төркемен оештыручыларның берсе, аның җитәкчесе (к. *Газенбуш төркеме*). Социал-демократик пропаганда алып бара, студентлар һәм Алафузов пр-тиеләре эшчеләре арасында тыелган әдәбият тарата. Казанда беренче маёвка үткәрүдә катнаша, анда чыгыш ясый (1898). 1898 нең декабрендә кулга алына. 1899 да азат ителә, Уфада яши, 1900 дән — Самарада. 1903 тән Көнчыгыш Себердә, С.-Петербургта, Екатеринбургта революцион эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Окт. рев-циясеннән соң партия эшендә. 1918 нең көзендә фронтка алына, шунда Әстерхан шәһәре янында тифтан үлә.

*Әд.:* Деятели революционного движения в России. От предшественников декабристов до падения царизма: Библиогр. словарь. М., 1933. Т. 5, вып. 2; Будрин А. Газенбуш Конрад Конрадович // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ГАЗЕНБУ́Ш ТӨРКЕМЕ́**, Казан губернасында марксизмны таратучы беренче с.-д. оешмаларның берсе. 1897 елның көзендә Казанда К.К.Газенбуш тарафыннан оештырыла. 2 түгәрәкне — Казан ун-ты һәм вет. ин-ты студентларын һәм Алафузов пр-тиеләре эш-

челәрен (барысы 30 лап кеше, ш.и. А.П.Беликов, В.В.Владимирский, Н.И.Гусев, П.Н.Зимин, И.Е.Крутиков, С.И.Потёхин, А.А.Рейпольский, А.И.Шибков) берләштерә. Г.т. Алафузов пр-тиеләрендә, дары з-дында, шәһәр типографияләрендә агитация һәм пропаганда эше алып бара; хастаханә кассалары, яшерен китапханәләр, үз белемеңне күтәрү түгәрәкләре оештыра; студентлар һәм эшчеләр арасында листовкалар һәм прокламацияләр тарата; П.Г.Кузнецов һәм П.А.Смелов булышлыгында Перов типографиясе хәреф җыючылары стачкасын (1898 нең феврале), 1898 нең маенда К.К.Газенбуш, Н.И.Гусев һәм И.Е.Крутиков җитәкчелегендә Идел буенда эшчеләр маёвкасын оештыра. Г.т. Г.В.Плехановның «Хезмәтне азат итү» («Освобождение труда») төркеме һәм С.-Петербург, Мәскәү, Вятка, Киев, Кострома, Түбән Новгород, Пермь, Саратов, Сембер с. -д. оешмалары белән элемтәгә керә. 1898 нең ноябрендә полиция тарафыннан ачыла һәм куып таратыла, 1899 елның җәендә яңа составта торгызыла.

*Әд.:* Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1973; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии 1883–1985. К., 1985. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*




**ГАЗЕ́ТА**, вакытлы матбугат басмасы; массакүләм мәгълүмат чараларының берсе. Казанда беренче газета — «Казанские известия» — 1811 елның 19 апрелендә чыга башлый. Казанда вакытлы матбугат үсешенә «*Казанский вестник*» (1821–33) ж-лы көчле йогынты ясый. Н.И.Лобачевскийның актив катнашында бу журналга кушымта итеп чыгарылган «Прибавление к «Казанскому вестнику» г-тасы Россиядәге либераль басмалар арасында мөһим урын алып тора. «Казанские губернские ведомости» г-тасы 1838–1917 дә губерна идарәләре тарафыннан рәсми газета буларак чыгарыла һәм 19 йөзнең 2 яртысына кадәр Казан губернасында бердәнбер вакытлы матбугат басмасы була. 19 йөзнең икенче яртысында Г.лар саны арта бара: 1861–70 та 3 газета чыкса, 1870–79 да — 4, 1880–89 да — 10, 1890–99 да 12 газета нәшер ителә. Казан губернасында икътисади-сәяси үсеш темпы көчәю нәтиҗәсендә Казанда сәнәгатьчеләргә, банкир һәм сәүдәгәрләргә хезмәт күрсәтүче махсус хосусый Г. лар барлыкка килә. Бу елларда цензура игътибарыннан читтәрәк торган «Листок объявлений» дип аталган газеталар чыгарыла. Аларда белешмә характерындагы төрле кыска хәбәрләр басыла. «Справочный листок города Казани», «Казанский биржевой листок», «Камско-Волжская газета», «Городской листок», «Казанские новости», «Волжско-Камское слово», «Камско-Волжский край» кебек Казан һәм Идел-Кама төбәгенең иҗтимагый-сәяси тормышы мәсьәләләрен яктыртучы Г.лар зур популярлык казана. 1880 еллардан белешмә-реклама характерындагы Г.ларның универсаль юнәлештәге иҗтимагый-сәяси басмаларга әверелү тенденциясе күзәтелә. Мәс., «Камско-Волжский корреспондент для деловых людей» — «Листок объявлений покупки, продажи имений, земель, заводов во всей России» г-тасыннан, «Казанские вести» — «Справочный листок»тан, «Листок объявлений торгово-промышленности и техники» — «Листок объявлений» г-тасыннан башлангыч ала. 1890 еллар башына Казанда көчле вакытлы матбугат, бигрәк тә хосусый матбугат системасы барлыкка килә. Губерна мәдәни тормышында «Волжский вестник» г-тасы мөһим урын тота. Материалларының тирән иҗтимагый әһәмияткә ия булуы, Идел-Кама төбәгенең күренекле либераль-демократик интеллигенциясе вәкилләре б-н хезмәттәшлек итүе нәтиҗәсендә ул 19 йөз ахырында Россиядәге провинциаль Г.лар арасында иң популяр басмаларның берсенә әверелә. 1905 тә наширлек хокукын алу тәртибен гадиләштергән «Вакытлы матбугат басмалары турында вакытлы кагыйдәләр» («Временные правила о повременных изданиях») кабул ителгәннән соң, Казанда вакытлы матбугат үсеше тамырдан үзгәрә. Цензураның бетерелүе Г. битләрендә илдәге иҗтимагый-сәяси тормышның актуаль мәсьәләләрен яктырту мөмкинлеге бирә. Г.ларның төрле сәяси партия һәм оешмаларга йөз тотуы буенча бүленеше барлыкка килә. Монархистик һәм карагруһчы партияләр «Казанский телеграф», «Газета «Правых», «Сошники», «Черносотенец», «Русь православная» г-таларын чыгара. Кадетларның карашлары «Вечернее эхо», «Казанский вечер», «Волжско-Камская речь», «Камско-Волжская речь» кебек Г.ларда чагылыш таба. Үтә сул партияләр — социал-демократлар һәм социал-революционерлар үз идеяләрен пропагандалау өчен «Волжский листок», «Волжский курьер» һәм «Дневник Казани» Г. ларын файдаланалар. Еш кына Г.ларның кайбер саннары һәм тиражлары конфискацияләнә, ә мөхәррирләре мәхкәмә эзәрлекләвенә дучар була. Казан матбугат эшләре вакытлы комитеты мәгълүматларына караганда, 1906 да 70 ләп Г. конфискациягә дучар була. Большевиклар газетасы «Рабочий» яшерен рәвештә нәшер ителә. Казан губернасы земство оешмаларының да үз басма органнары була («Вестник Казанской международной выставки», «Земская неделя», «Трудовой путь»).

1917 елгы Февр. рев-циясе вакытында Россиядә монархистик матбугат юкка чыгарыла. Вакытлы хөкүмәт тарафыннан игълан ителгән сәяси азатлык Казан губернасында эсерларның («За землю и волю», «Социалист-революционер») һәм большевикларның («Рабочее дело», «Рабочий»), ш.у. сайлап куелган яңа хакимият органнарының легаль Г.ларын нәшер итү өчен шартлар тудыра.

19 йөз башында ук Россиядә татар телендә Г. чыгарырга омтылышлар була, ләкин алар уңышка ирешә алмый. Татар телендә Г. барлыкка килү 1905 елгы рев-ция вакыйгалары б-н бәйле. Аңарчы гектографта басылган яшерен Г.лар гына чыгарыла: «Иттифакъ» (1902–05), «Хөррият» (1905). Беренче татар г-тасы «Нур» 1905 елның 2 сентябрендә С.-Петербургта нәшер ителә. Шул елның 7 октябрендә Казан шәһәр думасы гласные С.Алкин, рус һәм татар телләрендә бастыру шарты б-н, «Казан мөхбире» г-тасын чыгарырга рөхсәт ала. 1905 нең 27 ноябрендә Җаек (Уральск) шәһәрендә «Фикер» г-тасы, 1906 ның гыйнвар уртасыннан Казанда икенче татар г-тасы — «Йолдыз», ә 1 февральдән өченчесе — «Азат» нәшер ителә башлый. Г.лар Оренбург, Әстерхан, Мәскәү, Ташкент, Троицк, Семипалатинск һ.б. шәһәрләрдә дә барлыкка килә.

Рев-циягә кадәр иң абруйлы, озак вакыт чыккан татар Г.лары: «Вакыт» (Оренбург, 1906–18), «Йолдыз» (Казан, 1906–18), «Бәянелхак» (Казан, 1906–14), «Идел» (Әстерхан, 1907–14), «Кояш» (Казан, 1912–18), «Тормыш» (Уфа, 1913–18), «Ил» (С.-Петербург, Мәскәү, 1913–18). Аз гына вакытта чыгып алган басмалар арасында аеруча билгелеләре: «Азат» (Казан, 1906), «Таң йолдызы» (Казан, 1906), «Ислах» (Әстерхан, 1905–06), «Дума» (Петербург, 1907), «Безнең тавыш» (Казан, 1917–18), «Олуг Төркестан» (Ташкент, 1917–18), «Корылтай» (Казан, 1917–18), «Урал» (Оренбург, 1907). 1917 гә кадәр Россиядә татар телендә барлыгы 62 Г. нәшер ителә. Барлыкка килүләреннән үк Г.лар татарларның иҗтимагый-сәяси тормышында мөһим урын алалар. Аларда татар милли хәрәкәтенең өч төп юнәлеше — буржу-

аз-либераль, революцион-демократик һәм консерватив юнәлешләр арасындагы каршылыклар чагылыш таба. Революцион-демократик басмаларның нигезен «Таң йолдызы», «Тавыш» (Казан, 1907), «Азат», «Азат халык» (Казан, 1906), «Дума», «Урал» (Оренбург, 1907) г-талары тәшкил итә. «Фикер» (Җаек, 1905–07), «Яңа тормыш» (Җаек, 1907–08), «әл-Ислах» (Әстерхан, 1907) г-талары урта позицияләрдә торалар. «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Вакыт», «Әхбәр» (Казан, 1907–08), «Борһане тәрәккъый» (Әстерхан, 1906–11) г-талары буржуаз-либераль юнәлеш тоталар. Консерватив һәм клерикаль-монархистик лагерьга «Нур», «Өлфәт» (Петербург, 1905–07), «Бәянелхак», «әл-Галәме әл-Ислами» (Уфа, 1906–07) г-талары керә. 1905–07 еллар рев-циясеннән соң матбугат өлкәсендәге активлык сүлпәнәя (бигрәк тә революцион-демократик лагерьда) һәм ул Г. басмаларында да чагылыш таба. Г.ларда күбрәк урталыктагы юнәлешле материаллар урын ала. Вакытлы матбугатның нигезен буржуаз-либераль юнәлештәге басмалар тәшкил итә, алар арасында яңа Г.лар «Мизан» (Әстерхан, 1908–09), «Хак» (Әстерхан, 1911), «Игълянәт» (Казан, 1909–10), «Сибирия» (Томск, Уфа, 1912–13), «Тормыш» (Уфа, 1913–18), «Кояш» (Казан, 1912–18), «Милләт» (Петроград, 1913–15) һ.б. бар. Сәяси һәм милли проблемаларны кискенрәк яктырту омтылышлары самодержавие б-н каршылыкка керә. Бу яктан «Ил» г-тасы тарихы гыйбрәтле: Г.Исхакый тарафыннан нәшер ителгән әлеге Г. га хакимиятнең эзәрлекләүләре аркасында исемен берничә тапкыр үзгәртергә туры килә.

1917 елгы Февр. рев-циясен татар вакытлы матбугаты зур күтәренкелек б-н каршылый: әйдәп баручы татар Г.лары «Йолдыз», «Вакыт», «Кояш», «Тормыш» инкыйлабны азатлык һәм демократия тантанасы башлангычы буларак бәялиләр. Яңа милли оешмаларның басмалары «Азат халык» (Әстерхан мөселманнар бюросы органы), «Җөмһүрият» (Сембер мөселман милли шурасы органы) һ.б. барлыкка килә. Алар татарларның милли һәм мәдәни үзидарәсен яклыйлар. Кайбер милли хәрби оешмалар да татар телендә Г.лар чыгара башлый: «Безнең тавыш» (Бөтенроссия мөселманнар хәрби шурасы органы), «Солдат теләге» (Уфа мөселман гаскәриләре советы органы), «Солдат ялкыны» (Мөселманнар комитетының Әстерхан оешмасы органы) һ.б. Февр. рев-циясеннән соң революцион-демократик юнәлештәге татар вакытлы матбугаты яңадан аякка баса: «Аваз» (Казан), «Авыл халкы» (Уфа), «Алга» (Уфа), «Игенче» (Казан), «Ирек» (Уфа), «Кызыл байрак» (Казан) һ.б.

Совет хакимияте урнашкач, вакытлы матбугат системасы шактый үзгәреш кичерә, партия-совет матбугаты органнары барлыкка килә. 1917 нең 29 октябрендә Казанда «Знамя революции» г-тасының (Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан советы каршындагы Казан эшчеләр советы органы) беренче саны нәшер ителә. 1918 нең 12 мартында Казанда татар телендә беренче совет Г.сы «Эш» (Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан советы каршындагы Мөселман комис-ты органы) басыла. Татар телендә чыккан беренче совет һәм большевиклар яклы Г.лар рәтенә «Кызыл байрак», «Безнең юл», «Кызыл армия» һ.б. керә. Окт. рев-циясеннән соң партия-совет Г.лары Казан губернасының барлык өязләрендә диярлек чыга башлый, ш.у. чуаш («Канаш», «Хёрле ялав»), мари («Йошкар кэчэ», «Тор», «Ужара»), удмурт («Гудыри») телләрендә дә Г.лар басыла. 1918–20 дә Казанда крәстияннәр өчен махсус «Бедняк», «Деревенские думы», яшьләр өчен «Клич юного коммунара», «Кызыл яшьләр» г-талары нәшер ителә. 1917 нең 27 октябрендә Матбугат турында декрет кабул ителгәннән соң, җирле хакимият тарафыннан большевистик булмаган Г.лар ябыла башлый: 1917 нең декабрендә «Камско-Волжская речь», «Крестьянская газета Казанского губернского земства», 1918 нең гыйнварында «Вакыт», «Чыңгыз баласы», 1918 нең февралендә «Безнең тавыш», «Известия Всероссийского мусульманского военного шуро», 1918 нең май–июлендә меньшевиклар һәм эсерларның «Рабочее дело», «За землю и волю», «Игенче» һ.б. Г.ларны бастыру туктатыла. Гражданнар сугышы вакытында Казан губернасы терр-ясендә каршы торып сугышучы якларның күп кенә Г.лары басыла. Большевистик булмаган Г.лар аклар армиясе контрольдә тоткан районнарда гына чыга. Әйтик, Казан, Самара, Уфа, Бәләбәй, Чиләбе, Оренбург, Петропавел, Омск, Томск шәһәрләрендә «Безнең фикер», «Корылтай», «Маяк», «Том сүзе», «Уфа хәбәрләре» һ.б. Г. лар Кызыл Армия җиңгәч чыгудан туктый.

ТАССР совет вакытлы матбугаты 1920 елда респ-ка оештырылганнан соң формалаша башлый. Аның нигезен, үзәк һәм респ-ка органнарыннан тыш, өяз һәм кантон Г.лары, ә 1930 еллардан башлап *шәһәр, район-шәһәр, район газеталары*, ш.у. *күптиражлы газеталар* тәшкил итә. Рәсми басмалар б-н беррәттән армия, крәстиян, яшьләр, балалар Г.лары чыгарыла. 1920 елларда формалашкан татар телендәге вакытлы матбугат системасына үзәк («Эшче», «Игенчеләр»), губ. һәм өлкә («Азат Себер», «Коммунист», «Ялкын» һ.б.), өяз («Урал», «Ярлылар тавышы») һәм кантон Г.лары керә. Юнәлешләре б-н алар эшче, крәстиян, хәрби, яшьләр, балалар өчен; типлары ягыннан иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис, сатирик Г.ларга бүленә. Татар телендәге Г.лар татарлар күпләп яши торган төбәкләрнең барысында да диярлек чыгарыла. Ләкин 1930 еллар уртасына аларның саны күпкә кыскартыла.

Окт. рев-циясеннән соң чит илләрдә мөһаҗирләр вакытлы матбугаты үсеш ала: Германиядә — «Татар иле», «Идел-Урал», «Төрек берлеге», «Очар яфраклар», «Урал авазы», «Азат Ватан», «Яңа тормыш» һ.б., Финляндиядә — «Ак юл», «Мәгърифәт», «Тавыш», «Туфан» һ.б., Польшада — «Пшегленд исламски», Кытайда — «Аксу», «Безнең Ватан», «Ерак Шәрекъ», «Мең ел», «Милли байрак», «Чаткы», «Йолдыз» һ.б., Япониядә «Игъляне хакыйкать» Г. лары басыла.

Бөек Ватан сугышы елларында ТАССРда Г.ларның саны кими һәм форматлары кечерәя, *фронт газеталары*, ш.и. татар телендә дә оештырыла (16 Г.). Сугыштан соңгы елларда төп матбугат органнары буларак респ-ка Г.лары «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», яшьләр өчен «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Татарии», балалар өчен «Яшь ленинчы» Г. сы чыгарыла. 1980 еллар уртасы — 1990 еллар башында илнең иҗтимагый-сәяси тормышындагы кискен үзгәрешләр вакытлы матбугат системасында да (структура һәм эчтәлегендә) үзгәрешләр китереп чыгара. Иҗтимагый-сәяси оешмалар Г.лары («Алтын Урда», «Независимость» — «Бәйсезлек», «Республика», «Слово коммуниста», «Суверенитет» һ.б.) һәм хосусый басмалар барлыкка килә. Г.ларның тематикасы шактый киңәя: эшмәкәрләр даирәсе өчен дә Г.лар чыга башлый («Время и деньги»), матбугатка реклама үтеп керә («Казанская ярмарка», «Из рук в руки», «Ва-банкъ» һ.б.), дини эчтәлектәге басмалар пәйда була («Вера», «Иман») һ.б. Хәзерге вакытта ТРда әйдәп баручы Г.лар арасында — «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Время и деньги», «Вечерняя Казань», «Известия Татарстана», «Татар иле — Татарские края», «Казанские ведомости», «Молодёжь Татарстана», «Сабантуй», «Сувар», «Татарстан яшьләре» г-талары. 1990 елларда ТРның эре шәһәрләре — Әлмәттә, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Камада басмалар саны арта. Күп кенә район Г.ларының исемнәре һәм эчтәлекләренең сыйфаты үзгәрә. 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында ТРдан читтәге төбәкләрдәге татар җәмгыятьләре туган телләрендә Г.лар чыгару мөмкинлеге ала; РФнең 30 лап төбәгендә милли Г.лар чыгарыла башлый. 2010 елның 1 гыйнварына ТРда 593 Г. теркәлә, шуларның 112се татар телендә.

Чыг.: Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт: Татар басма сүзенең сәхифәләреннән. К., 1979; Әмирхан Р. Октябрьгәчә чыккан татар вакытлы матбугаты // Татарстан. 1995. № 3–8; Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7; Нуруллина Р.М. Татарча вакытлы матбугат тарихыннан (1905–1907 елларда демократик газеталар). К., 2002; Пономарёв П.А. Казанская периодическая пресса: Библиогр. заметки // Казанский литературный сборник. К., 1878; Иванович Е. За сто лет (Юбилейная историческая справка) // Камско-Волжская речь. 1911. 19 апр.; Петровский Н.М. По поводу столетия Казанской периодической печати // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1911. Т. 17, вып. 3; Туринский М. Газеты в провинции // Исторический вестн. 1912. апр.; Ильинский Л.К. Список повременных изданий за 1917 год. П., 1919. Ч. 1; Из истории местной периодической печати. К., 1960. Вып. 1; Нуруллина Р.М. Татарская революционно-демократическая печать в период подготовки Октябрьской революции. К., 1974; шул ук. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; шул ук. Газеты и журна-



И.И. Газетдинова.



И. Гази.

лы на татарском языке (1905–1985). К., 1989; Шул ук. Голос времени. Газеты и журналы на татарском языке 1905–1990 гг. К., 1992; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Из истории казанской прессы. К., 1977; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979; Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика. К., 1983; Ершов А.Н. Молодёжная пресса Татарии (1917–1921). К., 1983; Айнутдинов А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984; Агзамов Ф.И. Тукай-журналист. К., 1986; Мусульманская печать России в 1910 г. Оксфорд, 1987; Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать (1905–1907). М., 1988; Каримуллин А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999; Насыров Т.М. Репрессии против небольшевистской татарской прессы в 1917–1918 годах // Отеч. история. 2000. № 4; Беляева Л.М., Зиновьева М.К., Никифоров М.М. Библиография периодических изданий России. 1901–1916: В 4 т. М., 1958–61; Русская периодическая печать (1702–1894): Справ. М., 1959; Казанская периодическая печать XIX — начала XX века: Библиогр. указ. К., 1991; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX века: Библиогр. указ. К., 2000; Мәдәнейәт фырунтында X йыл: Материалдар йыйынтыгы. Өфө, 1929; Башкортостан милли матбуғат альбомы // Ватандаш. 2000. № 2–5.

*Р.А.Айнетдинов, Г.Р.Заманова.*

**«ГАЗЕ́ТА «ПРА́ВЫХ»** («Уңнар» газетасы»), атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1906 елның 22 июленнән 1908 нең 9 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 69 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Н.О.Прокофьев. Төрле псевдонимнар астында «Русское собрание», «Союз русского народа» җәмгыятьләренең Казан бүлеге, «Царско-народное русское общество в г. Казани», «Общество церковных старост и приходских попечителей в г. Казани» җәмгыятьләре әгъзалары П.Ф.Будылин, В.Ф.Залесский, А.Н.Поливанов, А.Т.Соловьев һ.б.ның мәкаләләре һәм кыска язмалары басыла. Материалларның күпчелеген Россиядә чыга торган монархистик һәм карагруһчыл юнәлештәге «Вече», «Голос русского», «День», «Русское знамя», «Чёрный сокол» һ.б. басмалардан күчерелгән язмалар тәшкил итә. Газета «Рус газетасы — рус кешеләре өчен» («Русская газета для русских людей»), «Самодержавие һәм халык» («Самодержавие и народность») шигарьләре б-н чыга, Россиянең бердәмлеге һәм бүленмәслеге, дәүләт нигезләрен саклау, бөек державачылык шовинизмы һәм антисемитизм кебек уң монархистик партияләргә хас төп принципларны алга сөрә. Газета материалларында карагруһчыларның кораллы отрядлары тактикасын идеаллаштыру тенденциясе күзәтелә, ул килмешәкләргә яки басып алынган вак милләт вәкилләренә каршы чыга. Сайлау алды кампанияләренә һәм Дәүләт думасы эшенә зур игътибар бирә, монархистик партияләр идеологлары һәм депутатларының чыгышларын бастыра. Россиядәге күп партияләрнең эшчәнлеген тартынмыйча тәнкыйтьли: октябристлар — «дәүләт җинаятьчеләре», «җәзага лаеклылар», кадетлар — «кадюклар», тыныч рәвештә яңарту партиясе — «Ватанның һәм Патшаның дошманнары». Үтә сул партияләрнең сәяси карашларына каршы чыгып, газета аларны «фетнә һәм котку таратучылар» дип атый, алар тоткан индивидуаль террор тактикасын кискен гаепли, аның җәмгыять өчен куркыныч икәнлеген исбатлый. 1905 нең маеннан 1906 ның маена кадәр террорчылар тарафыннан үтерелгәннәрнең саннарын китерә. Ш.у. газета юнәлешенә туры килердәй фельетоннар, шигырьләр бастыра. Нашире, өйдә балалар укытып, күп акча эшли алмаса да, аның зур өлешен газета чыгару өчен тота. Матди кыенлыклар туу сәбәпле газетаны ябарга туры килә.

*Г.Р.Заманова.*

**ГАЗЕТДИ́НОВ** Миршәриф Хәсән улы (1.3.1958, Калинин, хәзерге Мөслим р-ны Яңа Уразмәт а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2004), проф. (2005). ТРның атказ. икътисадчысы (2002), РФ югары проф. белем бирү мәктәбенең мактаулы хезмәткәре (2008). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1980), Хисаплау техникасын халык хуҗалыгына кертү буенча фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында фәнни хезмәткәр (1980–1983) булып эшли. 1987 елдан Казан аграр ун-тында: өлкән укытучы, доцент, икътисад ф-ты деканы урынбасары (1992–2001), икътисади кибернетика каф. мөдире (2001 дән). Фәнни тикшеренүләре күп укладлы икътисад шартларында агросәнәгать комплексын үстерүнең оештыру-икътисади механизмын булдыру мәсьәләләренә карый. Үзгәреп торучан мохит шартларында а.х. пр-тиеләрен үстерү стратегиясен эшли.

Хезм.: Прогнозирование и планирование развития сельскохозяйственного производства в условиях изменяющейся окружающей среды. К., 2003; Стратегия устойчивого развития сельских территорий в условиях рыночной экономики. К., 2007.

*Әд.:* Баһаветдинов Ф.Н. Без Мөслим балалары. К., 2006.

*Ф.С.Зыятдинов*

**ГАЗЕТДИ́НОВА** Илсөяр Ибраһим кызы (3.5.1951, БАССРның Дүртөйле р-ны Исмәгыйль а.), драма актрисасы, БАССРның һәм ТРның халык артисты (1990, 1997). Уфа сәнгать уч-щесен (1972), Уфа ун-тының филол. ф-тын (1980) тәмамлый. 1972 дән Башкорт акад. драма театры актрисасы. Җәмилә («Кыз урлау», М.Кәрим), Сандугач («Ялкынлы яшьлек», И.Абдуллин), Галия («Тапшырылмаган хатлар», Г.Кутуй повесте буенча) кебек рольләрне башкарып, актриса тормыш тантанасын, киң күңеллелек, рухи байлыкны раслый; ул башкарган Галиябану (М.Фәйзинең шул исемдәге пьесасы), Галимә («Кара йөзләр», М.Гафури әсәре буенча В.Галимов, М.Әмири), Маша («Тере мәет», Л.Толстой) образлары эчке дөньяларының матурлыгы, хатын-кызларга хас фидакарьлекләре б-н тамашачыны таң калдыра. Лирик-драматик һәм үткен характерлы рольләрне дә актриса бер үк дәрәҗәдә ышандырырлык, үзенә генә хас темперамент б-н башкара; Тутай («Шартлап китсен дөньясы», Колдәүләт), Зәбирә («Законлы никах белән», Ә.Атнабаев), Октябрина («Бер яшьлектә, бер картлыкта», Н.Гаетбай) образларын уйнаганда аларның рухи фәкыйрьлеген фаш итә. Зөлхәбирә («Айгөл иле», М.Кәрим) ролендә «Г.» эпик күләмле образ тудыра.

*Әд.:* Саитов С. Мир образов Ильсияр Газетдиновой: Буклет. Уфа, 2001.

*И.Илялова.*

**ГАЗИ́** (Мингазиев) Ибраһим Зариф улы (7.2.1907, Тәтеш өязе Иске Карамалы а. — 21.2.1971, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1924–26 елларда Казанда өлкә партия мәктәбендә укый. 1931 елга кадәр комсомол эшендә, бер үк вакытта «Кызыл яшьләр» г-тасы һәм «Колхоз яшьләре» ж-лы мөхәррире. 1932 дән Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир. Бөек Ватан сугышы елларында фронт газеталарында әдәби хезмәткәр. Сугыштан соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында, «Азат хатын» һәм «Казан утлары» ж-ллары редакцияләрендә эшли. Аның беренче «Көлмә, Идел!», «Соңгы чаң» лирик парчалары матбугатта 1929 да басылып чыга. «Кич алтыда» (1929), «Байраговның көндәлек дәфтәреннән» (1930), «Көмеш сулы Нурминкә» (1930), «Бригадир кыз» (1931), «Катя Сорокина» (1938) хикәяләрендә шәһәрдә һәм авылда барган социаль үзгәртеп корулар бәян итәлә. Сугыш елларында язылган «Әхмәт бабай» (1943), «Малай белән эт» (1943) хикәяләренең һәм «Алар өчәү иде» (1944; рус теленә тәрҗемәсе «Их было трое», 1947), «Без әле очрашырбыз» (1947) повестьларының үзәк темасы — үткән вакыйгаларга карата кешенең җаваплылыгы һәм аларда патриотизм хисе тәрбияләү. Г. иҗатының иң югары ноктасы — аның сугыштан соң язган әсәрләре. Г.ның «Тургай картаямы икән?» (1966) хикәясе, «Алмагачлар чәчәк ата» (1950) повесте, «Онытылмас еллар» (1949–66; рус теленә тәрҗемәсе «Хлеб, винтовка и любовь», 1950–75) трилогиясе, «Гади кешеләр» романы (1955; рус теленә тәрҗемәсе «За городом, за Казанью»,М., 1957) татар прозасының иң гүзәл үрнәкләреннән санала. Язучының 1933 тә үк языла башлаган «Онытылмас еллар» трилогиясе бигрәк тә уңыш казана. Авыл малаеның үсмер чагын хикәяләүдән башланган бу әсәр, Идел буенда барган тарихи вакыйгаларны эченә алып, Совет власте урнашу һәм социаль җирлектә яңа тормыш коруны тасвирлауга багышланган киң планлы тарихи-революцион эпопея булып үсә. 1969 да трилогия Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була. Г. ш.у. публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре б-н дә чыгыш ясый. А.П.Чехов, М.Горький, М.Е.Салтыков-Щедрин , Г.Мопассан, Э.Золя хикәяләрен татар те-

ленә тәрҗемә итә. 1968–71 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе. 1970–71 дә СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы һәм ике «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Онытылмас еллар. 2 кит. К., 1970; Әсәрләр: 3 томда. К., 1987–88.

*Әд.:* А х у н о в Г. Гомер буе үзе булып калган кеше // Казан утлары. 1972. № 1; М у с т а ф и н Р. Живые традиции // Образ времени. К., 1981; С а ф у а н о в С. Ибраһим Гази. К., 1968.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГАЗИ́ЕВ** Идрис Мөдәррис улы (21.4.1960, БАССРның Авыргазы р-ны Корманай а.), җырчы, БРның һәм ТРның халык артисты (1993, 2002), РФнең атказ. артисты (1998). Ялгыз җыр классы буенча Уфа сәнгать ин-тын (1986, М.Мортазинада), «музыкаль театр режиссёры» белгечлеге буенча Россия мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләрен яңадан әзерләү ин-тын (1996) тәмамлый. 1986 елдан Башкорт филармониясе солисты. Репертуарында төрле стильдәге, жанрдагы һәм юнәлештәге татар, башкорт, рус халык көйләре, дөнья халыклары җырлары, Россия композиторлары, рус һәм чит ил классиклары әсәрләре бар. Алар арасында башкорт («Эскадрон», «Урал», «Зөлхиҗә», «Азамат») һәм татар («Әллүки», «Тәфтиләү», «Кара урман», «Хәмдия») халык җырлары; башкорт һәм татар композиторларының вокаль әсәрләре; Г.Ф.Гендель, Д.Каччини, А.Страделла, Ф.Шуберт, М.Глинка, С.Рахманинов, Р.Шуманның камера-вокаль әсәрләре. Киң масштаблы вокаль-симфоник әсәрләрдә («Тукай ритмында», А.Монасыйпов муз., М.Әхмәтовның 3 нче һәм 4 нче симфониясе), Р.Абязовның «Җырга әверелгән...» (С.Сәйдәшевнең 100 еллыгына багышланган) вокаль триптихында һ.б. соло партияләрен башкара; Уфа рәссамнары төркеме б-н берлектә «Чыңгыз хан» һәм «Мирас» галереясының муз.-сәнгать проектларын әзерли. Г. радио һәм телевидениедән «Могҗиза», «Ак чишмә» һ.б. соло программалары б-н чыгышлар ясый, башкорт һәм татар эстрада йолдызларының концерт программаларын сәхнәгә куя, актив гастроль эшчәнлеге (Германия, Нидерланд, Италия, Финляндия, Швеция, Төркия) алып бара. Башкортстан Респ-касының С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге (1998), халыкара һәм бөтенроссия, ш.и. совет җырларын башкаручыларның «Сочи-84», «Татар җыры-89» бөтенсоюз (1нче бүләк), вокалистларның Швециядәге халыкара конкурслары (1998), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2005) лауреаты.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*


**ГАЗИ́ЕВ** Мансур Хәмит улы (20.5.1953, Төмән өлкәсенең Түбән Тавда р-ны Киндерле а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1990), проф. (2001). 1975 елда Төмән индустриаль ин-тының инженерлык-икътисад ф-тын тәмамлый. 1975–80 дә СССР ФА Себер бүлегенең Икътисад ин-тында эшли. 1983–92 дә РФ Госпланы каршындагы Бөтенроссия ягулык-энергетика проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1988 дән — ягулык чыгару һәм җитештерүнең нәтиҗәлелеген икътисади бәяләү лаб-ясе, 1991 дән икътисади һәм экологик тикшеренүләр бүлеге мөдире. 1993 тән «Россия энергетикасы үсеше» ассоциациясе (Мәскәү) ген. директоры. Бер үк вакытта 1992 дән РФнең ягулык һәм энергетика министры киңәшчесе, 1993 тән РФ Дәүләт Думасында киңәшче. Фәнни тикшеренүләре базар шартларында Россиянең ягулык-энергетика комплексы икътисадына карый.

Х е з м.: Теоретические и методологические проблемы формирования рыночных отношений в отраслях топливно-энергетического комплекса. М., 1992; Развитие нефтяного комплекса России и его роль в расширенном воспроизводстве. М., 2002; Проблемы и основные направления активизации энергосбережения в свете энергопотребления. Труды Тюменского нефтегазового ун-та. Тюмень, 2003.

**ГАЗИ́ЕВ** Наил Хәмит улы (2.9.1947, Төмән өлкәсенең Түбән Тавда р-ны Киндерле а.), геофизик, икътисад фән. д-ры (2006), проф. (2006). ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1997), ТРның атказ. экологы (2008). Төмән индустрия ин-тын тәмамлый (1970). 1970 елдан Төмән өлкәсенең дәүләт идарә органнарында, Көнбатыш Себернең нефть һәм газ разведкалау фәнни-тикшеренү оешмаларында. 1991 дән Татарстанда: ТР Икътисад дәүләт комитетының Җитештерүче көчләрнең терр. урнашуы һәм табигатьтән файдалану идарәсендә бүлек башлыгы, башлык, 1996 дан ТР МК аппаратында, 2001–2007 дә табигатьтән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча ТР премьер-министры киңәшчесе. 2007 дән ТРның экология һәм табигый байлыклар министры киңәшчесе.

Х е з м.: Анализ и основные направления развития и размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996 (автордаш); Формирование экономического механизма природопользования в Республики Татарстан. М., 1997 (автордаш); Проблемы гео- и социоэкологии Республики Татарстан. К., 1998 (автордаш). Атлас Республики Татарстан. М., 2005 (автордаш).

**ГАЗИ́ЕВ** Рәшит Хәмис улы (10.2.1954, Казан), театр рәссамы, нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). ТРның халык рәссамы (2009). Казан сәнгать уч-щесен (1974), Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын (1980) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991). 1980 елдан Казан, Йошкар-Ола (Шкетан исем. Мари милли театры), Чабаксар (Рус драма театры), Әлмәт театрларында эшли. Татар акад. театрында (1985–88 дә баш рәссам) 1980–90 елларда төп репертуарга кергән «Алмазбулат» (Ю.Сафиуллин; 1981), «Һаваларда йолдыз» (М.Горький; 1983), «Бирнәсез кыз» (А.Н.Островский; 1983), «Әниләр һәм бәбиләр», «Без китәбез, сез каласыз» (Т.Миңнуллин; 1984, 1986), «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев; 1987), «Галиябану» (М.Фәйзи; 1991), «Шәҗәрә» (Т.Миңнуллин; 1998), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов; 1999), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин; 2000) спектакльләренә сәхнә бизәлеше эшли. Аның бу өлкәдәге иҗатына театр сәнгатенең сурәтләү чараларын даими рәвештә камилләштерү, драма әсәренең эчтәлеген органик рәвештә кабул итү, үзләштерү һәм чагылдыру, хәзерге заманга карата үз мөнәсәбәтен белдерү хас. Г. тарафыннан башкарылган сәхнә бизәлеше бизәкләрнең катлаулы ритмикасы, төсләр тәэсирлелеге, нечкә зәвыклы яктылык чаралары б-н аерылып тора.



Р.Х.Газиев.

1992 дән Г. пейзаж һәм натюрморт жанрларындагы әсәрләр иҗат итә. Матди форманы хисләр аша чагылдыручы картиналары — «Божра» мәйданы» (1995–96), «Төнге кар» (1997), «Карлы шәһәр» (1998), «Казан Кремлендә Колшәриф җамигъ мәчете төзелеше», «Китаплар китабы» сериясе (2000) лирик рухы б-н җәлеп итә.

Республика (1980 нән), төбәкара «Зур Идел» (1980, 1985) күргәзмәләрендә, театр, кино һәм телевидение рәссамнарының Бөтенроссия (1985) һәм Бөтенсоюз (1987) күргәзмәләрендә, 16 автономияле республика күргәзмәсендә (Мәскәү, 1989), «Россия — 9» Бөтенроссия күргәзмәсендә (Мәскәү, 1999), Төркиядә Татарстан декадасы күргәзмәсендә (Истанбул, 2001) катнаша.


Рәссамның әсәрләре Г.Камал исем. Татар акад. театры музеенда, ТР Дәүләт сынлы сән-



Р.Х. Г а з и е в. Х.Вахитның «Туй алдыннан» пьесасы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. 1983. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Р.Х. Г а з и е в. «Казан Кремлендә Колшәриф җамигъ мәчете төзелеше». 2000.



М.Ш. Газизов.

гать музеенда, А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда саклана.

*Әд.:* Современная сценография Татарстана: Каталог выставки. К., 2002; Султанова Р. О том, что дорого и близко // Аргамак. 1996. № 9; шул ук. Вечная «Голубая шаль» // Казань. 2002. № 5; шул ук. Күңелдәге якты сагыш // Идел. 1997. № 1.

*М.Е.Ильина.*

**ГАЗИ́З ШӘЁХ ХАН** (? — 1367 тирәсе), Алтын Урда ханы (1364/65 елдан). Җучи хан нәселеннән; Шәйбан нәселеннән булган Төмән Тимер улы дип фаразлана. Күк Урда ханы Чимтай ярдәмендә Булат Хаҗины төшереп, Алтын Урда тәхетенә утыра. Үзәк хакимиятне ныгыту сәясәтен үткәрә, дәүләтнең көнбатыш олысы ханы Абдуллаһ (аны тәхеткә Мамай утырта) б-н көрәшә. Сарай әл-Җәдид аксөякләре Г.Ш.х.ны өнәп бетермиләр. Аксөякләр фетнәсе вакытында үтерелә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Куликовская битва. М., 1980; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983.

**ГАЗИ́ЗОВ** Алмаз Шакир улы (25.5.1931, Бөгелмә р-ны Кече Бөгелмә а.), нефтьче, техник фән. д-ры (1989), проф. (1998), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1955). 1955–67 елларда «Татбурнефть» трестында (1959 елдан инженер-диспетчерлык һәм җитештерү-техника хезмәте башлыгы). 1967–79 да ТатНИПИнефтьтә (1969 дан скважиналардагы суларны селектив изоляцияләү лаб-ясе мөдире). 1979 дан Нефтепромхим фәнни-тикшеренү ин-тында, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыруның физ.-химик ысулларын эшләү технологиясе бүлеге мөдире (1986 дан). 2005 тән «ИДЖАТ» АҖнең ген. директоры. Бер үк вакытта Удмурт ун-тында һәм Уфа нефть ун-тында укыта. Нефтьле коллекторга, химик реагентлар кулланып, суландырылган зоналарда сарку каршылыгын арттыруга нигезләнгән тәэсир итү моделен эшли. Әлеге модель нигезендә файдалануның соңгы стадиясендә сулы ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыра торган күп кенә технологияләр эшләнә, алар Урал-Идел буе һәм Көнбатыш Себердәге нефть һәм газ чыгару пр-тиеләрендә киң кулланыла. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

Хезм.: Ограничение притока пластовых вод в нефтяные скважины. М., 1976 (автордаш); Влияние полимердисперсных систем на выработку продуктивных пластов // Нефтяное хоз-во. 1991. № 4 (автордаш).

**ГАЗИ́ЗОВ** Гәрәй Хәсән улы (15.10.1932, БАССРның Бөрҗән р-ны Монасыйп а. — 11.11.2004, Казан), инженер-механик, ТАССРның атказ. нефтьчесе (1990). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Урыссу газ бүлү станциясе башлыгы булып эшли. 1958–59 елларда Казан магистраль газүткәргечләр идарәсендә баш диспетчер. 1959–71 дә Миңлебай газүткәргечләр идарәсендә баш инженер, башлык. 1971–74 тә «Татгаз» җитештерү идарәсе башлыгы, 1974–93 тә «Таттрансгаз» җитештерү берләшмәсендә ген. директор. Республика газ хуҗалыгы үсешенә зур өлеш кертә (Миңлебай–Казан, Миңлебай–Түбәнкул, Миңлебай–Ижевск, Оренбург–Зәй газүткәргечләрен төзү һәм файдалануга тапшыру). Г. җитәкчелегендә продуктүткәргечләрне эшләтеп җибәрү технологиясе, ремонт-яңадан торгызу эшләрен алып бару алымнары эшләнелә, сыекландырылган газ һәм сыек углеводородларны ерак араларга күчерү үзләштерелә. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Солнце греет и ночью: Летопись Таттрансгаза. К., 2000. Ч. 1.

**ГАЗИ́ЗОВ** Мәхмүт Минәхмәт улы (8.2.1940, Шөгер, хәзерге Лениногорск р-ны Туктар Урдаласы а.), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Лениногорск р-ны мәктәпләрендә укытучы, укыту бүлеге мөдире, директор булып эшли. 1970 елдан Чаллы шәһәрендә. «Миләш сиртмә» исемле беренче җыентыгы 1969 да басыла. «Тәгәри китте йомгагым» (1976), «Мәйдан» (1990), «Гаҗәп көн» (Чаллы, 1995) шигъри җыентыкларындагы төп тема — хезмәт кешесенең тормышы. Балалар өчен язылган «Бер, ике, өч...» (1972), «Ике куян койрыгы» (2001) исемле кыска шигырьләр китаплары авторы. Матбугатта публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре б-н чыгыш ясый.

**ГАЗИ́ЗОВ** Мостафа Шакир улы (12.10.1923, БАССРның, Кырмыскалы р-ны Иске Муса а.), Дан орденының тулы кавалеры (10.2.1944, 8.5.1944, 23.9.1944), өлкән лейтенант (1959). Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның мартыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 69 нчы гв. танк полкының разведка отделениесе командиры, автоматчылар взводы командиры ярдәмчесе (1 нче гв. танк армиясенең 8 нче гв. механикалаштырылган корпусы 21 нче гв. механикалаштырылган бригадасы). Воронеж, 1 нче Украина, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украина, Польшаны азат итүдә, Берлин һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1943 нең 24 декабреннән 1944 нең 1 гыйнварына кадәр Казатин шәһәре (Украина ССРның Винница өлкәсе) янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә: яралы взвод командирын алмаштыра һәм сугышчан бурыч үтәлгәнче взвод б-н җитәкчелек итә; 1944 нең 23 мартында Копыгинцы шәһәреннән (хәзерге Украина Респ-касының Тернополь өлкәсе Гусятино р-ны) көньяк-көнбатыштарак барган бәрелешләрдә дошманның 2 эре калибрлы пулемётын граната б-н шартлата, 10 солдатын әсир итә, трофей сыйфатында миномёт һәм 3 эре калибрлы пулемёт кулга төшерә; 1944 нең 21 июнендә Олешице шәһәре (Польша) өчен барган сугышларда батырлык һәм тапкырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам иттерә. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1950). 1959 дан запаста. Уфа шәһәрендә слесарь-сантехник булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ерошин А.Е. Слава солдатская. Уфа, 1967; шул ук. Не ради славы. М., 1969; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 5; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ГАЗИ́ЗОВ** Мөкаддис Барый улы (8.10.1939, Ютазы р-ны Кәрәкәшле а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1985), проф. (1988), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1999), РФнең атказ. проф. белем бирү эшлеклесе (2007). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1986 дан органик химия каф. проф. Хезмәтләре органик кушылмалар электрохимиясенә, элементорганик кушылмалар химиясенә, органик химиягә, химик кушылмалар номенклатурасына карый. Г. өч валентлы фосфор хлоридларының О,О-гемдиалшынган органик кушылмалар б-н реакцияләрен тикшерә; өч валентлы фосфорның яңа кушылмаларда альдегидлар б-н реакциясе механизмнарын ачыклый. Сулы булмаган тирәлектә гем-полигалогенидлардан карбониллы кушылмалар алу ысулын эшли. Югары дәрәҗәдә бактерицид һәм вирусларга актив каршылыклы фосфорорганик кушылмалар синтезлый.

Хезм.: Реакция хлоридов трёхкоординированного фосфора с кислородосодержащими органическими реагентами / ВИНИТИ // Итоги науки и техники. Сер. Органическая химия. 1990. Т. 15 (автордаш); Реакции Р(III) с карбонильными соединениями // Успехи химии. 1990. Т. 59, вып. 3 (автордаш); Номенклатуры химических соединений. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000); Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАЗИ́ЗОВ** Нәгыйм Вәли улы (9.11.1954, Саба р-ны Ике Басу Арташ а), икътисадчы, ТРның атказ. урманчысы (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). 1985 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1977 дән Саба урман хуҗалыгында: агач эшкәртү цехы мастеры, 1979 дан Курса һәм 1983 тән Сабабаш урман хуҗалыкларында урманчы. Дәүләт бүләге «Урман кискәндә урман байлыгын саклап калуны, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агач материалларын эшкәрткәндә алдынгы ысуллар куллануны оештыру. Саба урман хуҗалыгында чыршы үстерү стадияләрен тизләтүне гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГАЗИ́ЗОВ** Рафаил Шәкүр улы (26.4.1947, Мамадыш р-ны Кече Кирмән а.), язучы, укытучы, ТРның атказ. укытучысы (1994), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2006). Казан ун-тын һәм Казан пед. ин-тын тәмамлый (1972; 1986). 1972 елдан Кече Кирмән урта мәктәбе директоры. Язмалары 1960 еллар-

дан «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» г-таларында, «Ялкын», «Чаян» ж-лларында басыла башлый. «Бөре керфекләре» (1985), «Җиләкле алан» (1988), «Чөгендер хикмәтләре» (1990), «Бүләгем» (2003; Г.Х.Андерсен исем. халыкара Мактаулы диплом, 2006), «Яшен ташы» (Ижевск, 2007) исемле шигырь җыентыкларында автор табигать матурлыгына, туган җирдәге тыныч хезмәткә дан җырлый. «Хат» (1993) җыентыгында, башлыча, тарихка мөрәҗәгать итә. «Кичер, кичерә алсаң» (1998), «Түбән оч малайлары» (1998), «Ак болыт» (Чаллы, 2003) китапларында тупланган хикәяләрендә яшүсмерләрне тәрбияләүдә әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Г. иҗатына образлар байлыгы, кеше психологиясен тирәнтен анализлау хас. «Мамадышым-язмышым» (1 кит. 2005, 2 кит. 2007) китапларының авторы һәм баш мөхәррире.

*Әд.:* З ө л к а р н ә е в Ф. Бөрене тамыр уята // Казан утлары. 1987. № 7; Ш а б а е в М. Төшсез чикләвекләр // Казан утлары. 1988. № 2:

**ГАЗИ́ЗОВ** Ризаэтдин Сәләхетдин улы (28.8.1894, Алабуга өязе Турай а. — 4.7.1981, Казан), тел галиме. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1917), Шәрекъ пед. ин-тында укый. Турай мәктәбендә (1918–19), Казан мәктәпләрендә (1922 елдан), Татар-башкорт хәрби мәктәбендә (1925–32), Алабуга пед. техникумында (1934–35), Зөя а.х. техникумында (1936–37), Биектау р-ны Мүлмә урта мәктәбендә (1938–39) укытучы. 1944–61 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, бер үк вакытта Казан ун-тында һәм Казан пед. ин-тында укыта. М.Х.Корбангалиев б-н берлектә татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүне башлап җибәрүчеләрдән, икетелле сүзлекләр төзү принципларын эшләүче. Хезмәтләре лексикография, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасына карый. Татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзүдә катнаша. Мәктәпләр өчен уку ярдәмлекләре авторы. К.Насыйриның «Әнмүзәҗ» китабын рус теленә тәрҗемә итә (1975). Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша.

Х е з м.: Русча-татарча сүзлек: Башлангыч мәктәпләр өчен. К., 1948; Учебник татарского языка для русских школ. К., 1926; Сравнительная грамматика русского и татарского языков. К., 1940; Фонетика и морфология русского языка в таблицах. К., 1968; Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. К., 1977.

Әд.: С а б и р о в К.С. Галим-ветеран // Совет мәктәбе. 1974. № 9; М ө х ә м м ә д и е в М. Мәгърифәт юлында // Татарстан хәбәрләре. 1994. 22 окт.

**ГАЗИ́ЗОВ** Таһир Хәсән улы (12.9.1935, БАССР Иске Монасыйп а. — 28.11.2010, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1986). Казан ун-тын тәмамлагач (1962), РФА КГҮнең Органик һәм физ. химия ин-тында, 1986 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1992 елдан ТР ФАнең фәнни-оештыру бүлеге җитәкчесе, 2000–02 дә баш белгеч. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Г. Арбузов реакциясенең классик һәм классик булмаган төрләре механизмын тикшерә. Реакциянең азаккы продуктын фаразларга һәм аны үткәрүнең оптималь шартларын сайларга мөмкинлек бирүче гомуми схема тәкъдим итә. Өчле- һәм дүртле координацияләнгән фосфорның катнаш эфирлы кушылмаларын табу өчен спиртлар, феноллар, меркаптаннар һәм аминнарны селектив фосфорлау методын эшли. Үсемлекләрне саклау чараларына караган, югары биологик активлыкка ия 100 гә якын яңа фосфорорганик кушылмалар таба. Процесслар агышының тизлеген, юнәлешен үзгәртергә һәм аларны йомшак темп-ралы, энергия саклаучан, экологик чиста шартларда кыйммәтле катализаторлардан башка үткәрергә мөмкинлек бирә торган химик реакцияләрне стимуллаштыруның традицион булмаган ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: О механизме реакций фениловых эфиров кислот трёхвалентного фосфора с хлорангидридами карбоновых кислот // Журн. общей химии. 1980. Т. 50, № 8 (автордаш); Реакция Арбузова. К., 1991. Ч. 1.; Reactions of phosphorus acids with carbonyl compounds activated by electronegative groups // Phosphorus and Sulfur. 1976. V1 (автордаш).

**ГАЗИ́ЗОВ** Фәрид Фәйзи улы (13.9.1935, Казакъстан АССРның Петропавловск ш. — 23.5.2005, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. канд. (1985), ТРның атказ. машина төзүчесе (1995). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), «Енисей» химия комб-тында эшли (Красноярск ш.): мастер, механик, производство башлыгы (1963 тән), техник бүлек башлыгы (1968–69). 1969–78 дә В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсендә баш инженер урынбасары, баш инженер. 1978–86 да Рошаль химия комб-тында (Мәскәү өлкәсе): директор (1985 кә кадәр), Үзәк лаб-я башлыгы (1985 тән). 1986–92 дә Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында директорның беренче урынбасары, 1992–94 һәм 1997–2001 дә директор. 1994–97 дә В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесендә ген. директор. Г. катнашында һәм җитәкчелегендә дарының яңа төрләре, шартлаткыч матдәләр һәм ракета-артиллерия зарядларын җитештерү технологиясе һәм җитештерү калдыкларын файдалану (утильләштерү) технологиясе эшләнә һәм производствога кертелә.

Пр-тиедә 7 исемдә яңа төр продукция үзләштерелә (1996), ш.и. аучы патроннары өчен дары, техник һәм азык спирты, катодлы саклау өчен ферросиллидлы электродлар һ.б. РФнең хөкүмәт бүләге (2002), Октябрь Революциясе ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Пороховая промышленность: Краткий ист.-биогр. справ. М., 1995; К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998.

**ГАЗИ́ЗОВ** Флюс Мирзасалих улы (25.6.1937, Мөслим р-ны Симәк а. — 4.2.2008, Эстәрлетамак ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1993), проф. (1995), БРның һәм РФнең атказ. химигы (1992, 1993), БР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1995). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Эстәрлетамак шәһәренең оборона пр-тиесендә эшли. 1966 елдан Эстәрлетамакта «Авангард» ҖБдә: техник контроль бүлеге җитәкчесе, баш инженер урынбасары (1966 дан), директор урынбасары (1988 дән), ген. директор урынбасары (1991 дән). Хезмәтләре полимерлар, ракеталар өчен каты ягулыклар химиясе һәм технологиясе, дары җитештерү экологиясе буенча. Нитроэфирлар җитештерү процессында барлыкка килүче азот оксидыннан, күкертле кушылмалардан, сульфат кислотасы томаныннан газларны чистартуның комплекслы ысулларын эшли. Искергән баллистит (төтенсез) дарылар нигезендә яңа сәнәгый шартлаткыч матдәләр (ш.и. эластик кумулятив корылмалар) эшләүнең рецептурасын һәм технологиясен тәкъдим итә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Махсус технология буенча фәнни хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 42 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Пороховой исполин // Вестн. АН Респ. Башкортстан. 2003, Т. 3.

*Әд.:* Ш и к В.Н. Флюс Мирзасалихович Газизов — первый доктор наук на заводе «Авангард» // Из истории отечественной пороховой промышленности. М., 2003.

**ГАЗИ́ЗОВА** Лилия Рифкат кызы (6.6.1967, Казан), шагыйрә. Казан мед. ин-тын (1990), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1996, Мәскәү) тәмамлый. Рус телендә яза. 1990–96 елларда «Казанский» санаториенда эшли. Г. шигырьләренә төгәллек, метафорага байлык, эчкерсез кичерешләр хас. Шигърияте рус поэзиясенең классик юнәлешенә тартым. Иҗаты: «Кара энҗе» («Чёрный жемчуг», 1995) «Лирик проза» («Лирическая проза», 2001), «Кышкы арабескалар» («Зимние арабески», 2002). Г.Державин исем. бүләк лауреаты. Татарстан Язучылар берлегенең рус әдәбияты һәм тәрҗемә бүлеге җитәкчесе.

*Әд.:* Б а л а ш о в Ю. Поэтическая Вселенная Лилии Газизовой // Казань. 2001, № 5.

**ГАЗИ́ЗОВА** Фәтхия Мөхәммәт кызы (25.5.1928, Бөгелмә кантоны Бәйрәкәтамак а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1976), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1951–2000 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты). Хезмәтләре лексикографиягә, тәрҗемә белеменә, татар прозасы (Г.Ибраһимов, Ф.Хөсни, Г.Ахунов һ.б.) теленә һәм стиленә карый. Г. «Русча-татарча икътисад терминнары сүзлеге»н (1999) төзүче, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (1–3 *т.*, 1977–81), татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр төзүчеләрнең берсе.

**ГАЗИ́ЗОВА** Хәлимә Хисаметдин кызы (26.1.1933, Әгерҗе р-ны Барҗы а.), ташчы, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1976, 1981, 1986). Мәктәпне тәмамлаганнан соң (1947), Әгерҗе р-нының С.Разин исем. к-зында эшли. 1954 елда ташчылар курсын тәмамлый. 1954 тән «Әлмәтнефтьтөзелеше» трестында, 1961–63 тә 6 нчы трестның 42 нче төзелеш-монтаж идарәсендә, 1963–88 дә 8 нче трестның 41 нче төзелеш-монтаж идарәсендә (Әлмәт ш.). Хезмәт Даны орденнары 9, 10, 11 бишьеллыкта ирешкән югары күрсәткеч-


ләре өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медаль, КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКнең Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданы, Геройлар аллеясында бюсты куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные Кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Әхмәдулла Һади улы (20.3.1931, Тәкәнеш р-ны Түбән Арбаш а.), урманчылык белгече, туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТАССР һәм РФнең атказ. урманчысы (1968, 1997). 1955 елда Идел буе урман-техника ин-тын (Йошкар-Ола ш.) тәмамлаганнан соң, Лубян урман техникумында укыта. 1956 дан Татарстан урман хуҗалыгы идарәсе системасында: 1959–62 дә Кама урман сәнәгате хуҗалыгының Кама урман хуҗалыгында баш урманчы, 1965–73 тә Татарстан урман туфрагы химиясе лаб-ясе мөдире. 1973 тән Мари техника ун-тында: 1979–87 дә урман туфрагы белеме һәм туфракларны мелиорацияләү, 1997–99 да экология, туфрак белеме һәм табигатьтән файдалану каф. мөдире. 2000 нән Казан а.х. академиясе (2006 дан Казан аграр ун-ты) урман белеме каф. мөдире. Хезмәтләре урманны, аның туфрагын һәм культураларын өйрәнүгә, урманнан файдалану ысулларына карый. База питомникларында утырту материалларын үстерү агротехникасына, Урта Идел буе урманнарыннан өзлексез файдалануга һәм урманнарны яңартып торуга караган 40 тан артык ысул эшли һәм куллануга кертә. «Туфрак белеме. Туфрак турында гомуми тәгълимат» («Почвоведение. Общее учение о почве». М., 2007) уку ярдәмлеге авторы. «Урман кисүдә урман байлыгын саклап калуны, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агач материалларын эшкәрткәндә алдынгы ысуллар кертүне оештыру, Саба урман хуҗалыгында чыршы үстерү стадияләрен тизләтүне гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (2003).

Х е з м.: Бурозёмообразование и псевдооподзоливание в почвах Среднего Поволжья и Предуралья. Йошкар-Ола, 1997; Почвенно-экологические условия произрастания темнохвойных фитоценозов Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 2001 (автордаш); Ведение комплексного многоцелевого лесного хозяйства в малолесных регионах. К., 2003 (автордаш); Почвенно-экологические условия формирования лесов Среднего Поволжья. Т. 1. Почвы лесов Среднего Поволжья, их генезис, систематика и лесорастительные свойства. К., 2005; Почвообразование, почвы и лес. К., 2006.

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Ибраһим Галим улы (3.6.1919, Чиләбе ш. — 30.5.1944, Яссы ш. янында), Сов. Союзы Герое (1.7.1944, үлгәннән соң), гв. өлкән лейтенанты. Пермь хәрби авиация очучылары мәктәбен тәмамлый (1940). 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең 1 гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 667 нче штурм авиациясе полкының эскадрилья командиры урынбасары (1 нче штурм авиациясе дивизиясе, 1 нче штурм авиациясе корпусы). Төньяк Кавказ, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Кавказ өчен барган сугышларда (1943), Кубаньдагы һава сугышларында (1943), Белгород-Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Днепр өчен барган сугышларда (1943), Кировоград, Корсунь-Шевченковский, Умань-Ботошани һәм Яссы-Кишинёв (1944) операцияләрендә катнаша. Г. 90 сугышчан очыш ясый, төркем б-н 16 һава сугышында дошманның 7 самолётын бәреп төшерә. Сугышчан бурычын үтәгәндә батырлык күрсәтә. Сугыш барган урында җирләнә. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Г. исеме Чиләбедәге бер урамга бирелә.



И.Г. Газизуллин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; К и с л и ц и н А.С. За землю родную. Челябинск, 1967; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Исмәгыйль Корбан улы (17.8.1946, БАССРның Ишембай ш.), нәкышьче, график. П.П.Беньков исем. Ташкент сәнгать уч-щесен тәмамлый (1972). Ишембай шәһәрендә яши. Балалар сәнгать мәктәбендә укыта (1973–78), бизәүче рәссам булып эшли (1978–90). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). Г.ның нәкышь әсәрләрендә «классик» авангард сәнгате, аерым алганда, Д.Бурлюк, А.Тюлькин иҗатының йогынтысы сизелә. Гади сюжетларга корылган картиналарында гомумкешелек идеяләре чагылыш таба. Г. үз иҗатында татар халык традицияләренә таяна, фольклор әсәрләре образларына һәм көнкүреш сюжетларына мөрәҗәгать итә. Әсәрләрендәге төсләр җыелмасы татар халык палитрасына, авыл йортлары бизәлешендә кулланылучы төсләр гаммасына кергән күк, ак, сары, яшел, кызгылт-көрән тоннардан гыйбарәт. Күренекле офорт остасы Г. графика әсәрләрендә социаль яктан калку образларның галереясын тудыра. Аларның капма-каршы перспективалы һәм яссы фонлы бай композициясе, сурәтләрнең катлаулы мозаикасы стильләштерүгә, форманың хисси символикасына нигезләнә, кешенең тереклек мохитен чалыш көзгедәге кебек чагылдыра. Төп әсәрләре: нәкышь — «Кое янында» (1986), «Бабай һәм бала» (1986), «Онык» (1987), «Язгы күренеш» (1988), «Укучы кыз», «Тау юлы» (1989), «Капка төбендәге әби» (1991), «Картлач», «Гариф бабайның җирләү» һәм «Чәй табыны» (1990 еллар); графика — «Кунакка бару», «Туу», «Агач янында» (барысы да — 1986), «Ахшам намазы», «Әт һәм кош», «Өйгә кайту», «Җирләү» (барысы да — 1998) офортлары; акварель — «Кыш», «Яз» (1988) «Печәннән кайту» (1997) һ.б.

1982 елдан — республика, 1987 дән төбәкара, бөтенроссия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә, «Инзер» (Уфа, 1989, 1993; Мәскәү, 1992) һәм «Сары бия» (Мәскәү, 1991; Йошкар-Ола, 1991; Новосибирск, 1993) иҗат төркемнәре составында, «Татарт» бөтентатар төбәкара күргәзмәсендә (С.-Петербург-Казан, 1991), Урал станлы басма графика триенналесында (Уфа, 1995 — Көмеш медаль; 1998); «Лесковас — 1997» халыкара басма графика бьенналесында (Югославия) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1988 дә һәм 1996 да Уфада уза.

Әсәрләре «Шәрекъ» фонды» АҖнең традицион һәм заманча сәнгать галереясында һәм «Урал» хәзерге заман сәнгате галереясында (Уфа), «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда һ.б. саклана.

*Әд.:* Г а р б у з А. Заметки о современной живописи Башкирии // Искусство авангарда: язык мирового общения. Уфа, 1993; Галерея традиционного и современного искусства фонда «Восток»: Каталог. Уфа, 1997.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Наил Фәйзелхак улы (17.10.1951, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1976 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1980–89 елларда Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында, Казан төзүче-инженерлар ин-тында укыта. 1994–96 да С.-Петербург профсоюзларның гуманитар ун-тында икътисад һәм идарә итү каф. профессоры, 1996 дан С.-Петербург инженерлык-икътисад академиясенең дәүләт һәм муниципаль идарә итү каф. профессоры һәм Европа эксперт-



1



2

И.К. Г а з и з у л л и н. 1. «Укучы кыз». 1989; 2. «Өйгә кайту». Офорт. 1998.

лар ин-тында каф. мөдире. Евразия регионара фәнни-аналитик «Проблемы современной экономики» ж-лының баш мөхәррире (2002 елдан). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре — экологик-икътисади тигезләнеш һәм социаль-икътисади системаларның тотрыклы үсеше проблемалары, гомуми реформалар теориясенең экологик-икътисади аспектлары.

Х е з м.: Экологический вектор экономической деятельности. М., 1992; Эколого-экономическое равновесие общества. М., 1992; О философских основах предмета и метода экологической науки. СПб., 2008.

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Равил Гобәй улы (27.9.1935, Кукмара р-ны Манзарас а.), нефтьче, техник фән. д-ры (1986), проф. (1988). Свердловск тау ин-тын тәмамлый (1958). 1958–61 елларда Көнбатыш Себер геол. идарәләрендә эшли (Алтай крае Змеиногорск ш.), 1959–61 дә Корбалиха шахтасы башлыгы, 1961–67 дә Кузнецк ташкүмер фәнни-тикшеренү ин-тында (Кемерово өлкәсе Прокопьевск ш.), 1964 тән төркем җитәкчесе. 1967–87 дә Казан химия-технол. ин-тында. 1987–93 тә Курск политехник ин-тында каф. мөдире. 1993 тән Казан архит-ра-төзелеш академиясендә: төзелеш материаллары, конструкцияләр һәм эшләнмәләр технологиясе каф. профессоры (1996 га кадәр), сызма геометрия һәм графика каф. мөдире (1996 дан). Хезмәтләре күмер һәм табигый битум чыганакларын өйрәнүгә карый. Кузнецк күмер бассейнының юка һәм текә күмер катламнарын табу технологиясен гамәлгә кертә һәм нигезли; Шөгер чыганагы сәнәгый шартларында битумлы токымнардан табигый битумнар табу һәм чыгару технологиясен, тау-эшкәртү комплексын проектлаштыру өчен технологик регламентлар эшли. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Технологические основы открытой разработки месторождений природных битумов. Тула, 1991.

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Фәйзелхак Газиз улы (25.3.1925, Мамадыш кантоны Песәк а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1987). 1950 елда Казан юридик ин-тын, 1953 тә Казан ун-тының иҗтимагый фәннәр укытучыларын әзерләү курсларын (сәяси икътисад бүлеге) тәмамлый. 1953–63 елларда Казан авиация ин-тында сәяси икътисад каф. укытучысы. 1963–2000 дә Казан пед. ун-тында эшли (1964 тән сәяси икътисад, 1991–2000 дә икътисад теориясе каф. мөдире). 2000 нән Казан техник ун-тының икътисад теориясе каф. профессоры. Төп хезмәтләре 20 йөз башларында татар халкында, фәннең аерым бүлеге буларак, социаль-икътисади фикер формалашу тарихына һәм проблемаларына карый. Г. — икътисади интеграциягә, югары уку йортларында икътисад теориясен укытуның фәнни методологиясенә багышланган хезмәтләр авторы. 1945 тә Мәскәүнең Кызыл мәйданында Җиңү парадында катнаша. 1997 елдан Татар энциклопедиясенең икътисад бүлеге фәнни мөхәрририяте рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Файзханов и формирование системы экономических взглядов в татарской литературе // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1975. Вып. 141; Дорогой к правде. К., 1979; Социально-экономическая мысль татарского народа как феномен его духовной культуры. К., 1999; Формирование и развитие социально-экон. мысли татарского народа. СПб., 2004; Историческая преемственность в развитии теории воспроизводства общественного продукта // Проблемы современной экономики. 2007. № 1.

*Әд.:* А б д у л л и н Я., Н у г а е в Р. Очерки истории экономической мысли татарского народа // Коммунист Татарии. 1979. № 8.

**ГАЗИЗУ́ЛЛИН** Фәрит Рәфыйк улы (20.9.1946, Яшел Үзән ш.), хакимият-хуҗалык, дәүләт эшлеклесе, социология фән. д-ры (1994). Горький су транспорты инженерлары ин-тын тәмамлый (1973). 1969–73 елларда ВЛКСМның Яшел Үзән, 1973–75 тә Чаллы шәһәр ком-тларының 1 нче секретаре, 1975–80 дә Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1980–84 тә КПССның Чаллы шәһәре Комсомол райкомы 2 нче секретаре. 1984–87 дә халык депутатларының Брежнев шәһәре Комсомол район советы башкарма ком-ты рәисе. 1987–89 да ТАССР МС да комплекслы икътисади һәм социаль үсеш бүлеге мөдире. 1989–91 дә ТАССР Дәүләт план ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1991–95 тә ТР премьер-министры урынбасары, 1995–96 да 1 нче урынбасары — ТР Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт ком-ты рәисе (1995 тән ТР Сәнәгать сәясәте һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт ком-ты рәисе). 1996–97 дә РФ Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары, 1997–98 дә рәисе, бер үк вакытта 1997–98 дә РФ Хөкүмәте рәисе урынбасары. 1998 дән РФ дәүләт мөлкәте министры, 2000–04 тә РФнең мөлкәти мөнәсәбәтләр министры, 2004 елдан «Газпром» АҖ директорлар советы әгъзасы. Мәкаләләре фәлсәфә, социология, ш.у. җитештерү коллективларында хезмәт эшчәнлеге шартларын камилләштерү мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ГАЗЛАШТЫРУ́**, халык хуҗалыгы тармакларын һәм көнкүреш өлкәсен гадәти ягулык урынына яна торган газ куллануга күчерү. Г. өчен табигый һәм ясалма янучан газлар файдаланыла. Г. үзәкләштерелгән һәм җирле системаларга бүленә, үзәкләштерелгән системада газны кулланучыларга җибәрү өчен шәһәр газ челтәре, җирле системада урындагы җайланмалар яки сыек газ тутырылган цистерна, баллоннар кулланыла. Республикада беренче мәртәбә иярчен газ, ягулык буларак, 1949 елда известь яндыру мичләрендә файдаланыла һәм Миңлебай нефть чыганагы мәйданындагы бораулау җайланмасы котельныена җибәрелә. 1954 тә 8ГК тибындагы газмотокомпрессорлары җирлегендә беренче промысел газ компрессоры станциясе файдалануга тапшырыла. Әлмәт р-нында 25 йортка беренче мәртәбә газ кертелә, икмәк з-ды, шәһәр мунчасы газ ягуга күчерелә. Баулы шәһәрендә Баулы–Түбәнкүл газүткәргеч станциясен эшләтә башлау б-н иярчен газ куллану чикләре Башкортстанга кадәр киңәя. 1954 тә Миңлебай–Казан магистраль газүткәргече (СССР да өченче), 1956 да Миңлебай–Түбәнкүл газүткәргече файдалануга тапшырыла. Магистраль газүткәргеч б-н бер үк вакытта газ бүлү станцияләре һәм газүткәргеч тармаклар салына. 1955 тә Казанда беренче 82 фатирга газ кертелә, сәнәгать пр-тиеләреннән В.И.Ленин исем. химия з-дында беренче мәртәбә газ кулланыла. Шул ук елда газүткәргеч тармаклар Урыссу посёлогына һәм Бөгелмә шәһәренә, 1957 дә Әлмәт, Лениногорск, соңрак Чистай шәһәрләренә кадәр җиткерелә. 1957 дә Казан–Горький магистраль газүткәргече, 1959 да Миңлебай–Түбәнкүл газүткәргеченең 2 нче линиясе салына. 1960 та магистраль газүткәргечләрнең озынлыгы 854 *км* тәшкил итә. 1955–60 та кулланучыларга 2,7 млрд. *м*³ газ җибәрелә. 1962 дә Миңлебай–Ижевск газүткәргеченең Зәй шәһәренә кадәрге участогы төзелә, шәһәр халкы шул ук елда газ куллануга ирешә. 1963 тә Миңлебай–Казан газ үткәргече төзелеп бетү нәтиҗәсендә республика башкаласын газ б-н тәэмин итү күпкә яхшыра. Шул ук елда бу газүткәргечне сыек газ продуктлары үткәргече итеп үзгәртеп кору башлана һәм ул 1964 елда файдалануга тапшырыла, 1965 тә республика газүткәрүчеләре тарафыннан илебездә беренче мәртәбә сыек газны торба үткәргечләр буенча ерак араларга җибәрү үзләштерелә. Төзелә башлаган Казан оргсинтез з-дының файдалануга бирелгән беренче җитештерү куәтләрен углеводород чималы б-н тотрыклы тәэмин итү мәсьәләсе дә хәл ителә. 1964 тә республика кулланучыларына, 1955 ел б-н чагыштырганда, 37 тапкыр артыграк күләмдә — 1 млрд. 464 млн. *м*³ газ җибәрелә. Казан–Йошкар-Ола газүткәргечен файдалануга тапшыру (1965) Яшел Үзән шәһәренә газ җибәрү мөмкинлеге бирә. Миңлебай–Түбән Кама продуктүткәргече гамәлгә кертелү (1960) б-н, Түбән Кама нефть химиясе комб-тына углеводород чималы җибәрелә башлый. 1960–70 елларда Түбән Кама, Чаллы, Алабуга, Миңлебай шәһәрләрендә, Алексеев посёлогында газүткәргеч тармаклар һәм газ бүлү станцияләре файдалануга тапшырыла, авыл районнарын Г. башлана. Шул ук елларда республика кулланучыларына 11,4 млрд. *м*³ газ озатыла. 1970 тә магистраль үткәргечләрнең озынлыгы 1978 *км* тәшкил итә. 1971 дә Оренбург–Зәй газ үткәргече сафка басу Оренбург табигый газын Зәй ГРЭСына даими җибәреп торуны тәэмин итә. Миңлебай–Казан этанүткәргечен файдалануга тапшырганнан соң (1972), Миңлебай газ эшкәртү з-дыннан этан фракциясен «Органик синтез» җитештерү берләшмәсенә җибәрү җайга салына. 1976 да Казанга кадәр китереп җиткерелгән Түбән Тура–Пермь–Казан–Горький–Үзәк магистраль газүткәргечләренең эшли башлавы нәтиҗәсендә газ б-н тәэмин ителешнең ышанычлылыгы арта. Республиканың күп кенә район үзәкләре Төмән өлкәсеннән килә торган табигый газдан файдалану мөмкинлеге ала. 1982 дә Оренбург–Казан этанүткәргече б-н Апак авылында (Әлмәт р-ны) регазификацияләү пункты файдалануга кертелә — илебездә беренче мәртәбә магистраль торба

буенча этан фракциясен аеруча хәтәр 100 *кгс/см²* режимда кудыру процессы үзләштерелә. 1983 тә газүткәргеч тармагын Түбән Кама сәнәгать төйнәлешенә кертү б-н, Түбән Камадагы ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2 гә, «КамАЗ» җитештерү берләшмәсендәге ТЭЦка табигый газ килә башлый. 1990 еллардан газлаштыру республика халык хуҗалыгының иң мөһим юнәлешләренең берсенә әверелә. 1995 тә район, шәһәр, авылларны Г. буенча Президент программасы кабул ителә, ул 2003 тә үтәлә. 2003 нең 1 гыйнварына ТРда магистраль газүткәргечләрнең озынлыгы 5145 *км* га җитә, 34 мең *км* чамасы газ бүлү үткәргечләре төзелә, 20 шәһәр, шәһәр тибындагы 17 посёлок, барлык район үзәкләре, 3000 ләп авыл, 585 тән артык сәнәгать пр-тиесе, 290 а.х., 6340 коммуналь-көнкүреш объекты, 1221110 фатир газлаштырыла. Республикада Г. 98,5% (шәһәрләрдә — 99,5 % һәм авылларда — 95,8%) тәшкил итә. «Востокмонтажгаз», «Татнефтепроводстрой», «Татспецстрой», «Татгазстрой», «Востокстройтрансгаз», «Таттрансгаз» трестлары Г.ны гамәлгә ашыра. 1955–2000 дә республикага 369,4 млрд. *м³*, 2008дә 1,85 млрд. *м³* чамасы газ бирелә. 2009 елга 22 шәһәр, шәһәр тибындагы 17 посёлок, 3000нән артык авыл газлаштырыла. Ш.у. к. «*Таттрансгаз*».

*Әд.:* Абрамов В.П., Кладиев Н.Х., Шагимухаметов Ф.Г. Наш край Татарстан. К., 1979; Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2; Наш Альметьевск. Наб. Челны, 1993; Нефть Татарстана: Дела и люди. К., 1993; Солнце греет и ночью: Летопись Таттрансгаза, К., 2000. Ч. 1.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.Л.Лобанов.*

**ГАЗРАЙ́Л** (гарәп.عزرائيل — Коръән персонажы, үлем фәрештәсе), Аллаһка иң якын торган дүрт фәрештәнең берсе. Каршылык күрсәтүче Җирдән көч һәм кырыслык б-н Адәмне яралту өчен кирәкле балчыкны алуга ирешкән фәрештәләрнең берсе дип исәпләнә. Шуның өчен Г. баш үлем фәрештәсе итеп билгеләнә. Кеше гомеренең соңгы көннәре якынлашкач, Аллаһ тәхете янындагы агачтан аның исеме язылган яфрак өзелеп төшә, шуннан соңгы 40 көн эчендә бу кешенең җаны тәненнән аерылырга тиеш. Г. исеме һәм аның сыйфатларының тасвирламасы Библиядә һәм аннан соңгы мифологиядә дә очрый.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГАЗЫ́ЙМОВ** Мидхәт Гариф улы (2.1.1942, Яңа Чишмә р-ны Зирекле а.), педагог, төбәк тарихчысы, халык гамәли бизәлеш сәнгате һәм шигъри фольклор (бәет, мөнәҗәт, шигырьләр һ.б.) әсәрләрен җыючы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Яңа Чишмә р-ның Зирекле авылында халык иҗаты һәм көнкүреше музеена нигез сала (1992 елның декабрендә ТР Милли музее ф-лы буларак ачыла) һәм 1993 тән аның директоры. Зирекле һәм күрше-тирә авылларның осталары тарафыннан 19 йөз — 20 йөзнең 1 нче яртысында эшләнгән гамәли бизәлеш әсәрләренең уникаль коллекциясен туплый. Алар арасында бизәкләп туку (сөлгеләр, ашъяулыклар, матча кашагалары һ.б.), элмәләп чигү (намазлыклар, туй сөлгеләре, аяк чолгаулары, хатын-кыз күкрәкчәләре, баш киемнәре һ.б.) үрнәкләре, милли киемнәр, зәркән бизәмәләре, металлдан, агачтан, талчыбыгыннан, каен тузыннан эшләнгән көнкүреш кирәк-яраклары, уенчыклар, нумизматика үрнәкләре, сәнгати эшләнмәләр җитештерү өчен кирәкле традицион кораллар һәм җайланмалар (туку станнары, кабалар, киергеләр һ.б.) бар. Музейда барлыгы 1037 экспонат саклана (2002 нең 1 гыйнварына). 1998 дә Казанда музей коллекцияләре күргәзмәсе уза. Г. Зирекле авылының һәм элек шул исемдә булган вилаять тарихын, этнографиясен өйрәнә, музей архивы туплый, халык иҗаты әсәрләренең һәм көнкүреш әйберләренең каталогын төзи.



Яңа Чишмә р-ны Зирекле авылындагы Халык иҗаты һәм көнкүреше музее. Экспозициядән бер күренеш. Алгы планда М.Г.Газыймов.

Хезм.: Хәтер тамчылары: Бәетләр. Түбән Кама, 2001; Музей как центр духовной жизни села // Музей российской глубинки. Екатеринбург, 1998.

Әд.: Нуруллин В. Музейларыбыз // Татарстан. 1997. № 12; Газымов М.Г. // Кто есть кто в науке об искусстве: Справ. К., 1998; Завьялова М. Мастерицы села Зирекле // Ежегодник — 98. Государственный объединенный музей Республики Татарстан. К., 1999; Семья Газымовых // Сто семей Татарстана. К., 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАЗЫ́ЙМОВ** Минвәли Мингали улы (29.10.1930, Яңа Чишмә р-ны Зирекле а.), хирург, уролог, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1991), Чуаш Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1995). Н.П.*Медведев* шәкерте. Чистай фельдшер-акушерлык мәктәбен (1951) һәм Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Татарстан һәм Чуаш Респ-касы мед. учреждениеләрендә эшли. 1976 елдан Чуаш мед. ун-тында, 1991 дән ф-т хирургиясе курслары мөдире. Хезмәтләре балалар урологиясенә карый. Аның тарафыннан бөер тамырлары аномалияләренә, ш.и. тумыштан булганнарына диагноз кую һәм дәвалауның яңа ысуллары, авыруларны амбулатория хирургик дәвалау алымнары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. 1968–73 тә Лениногорск шәһәр советы депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Активное выявление, лечение и диспансеризация детей с аномалиями мочеполовых органов. Чебоксары, 1992 (автордаш); Амбулаторная урология. Чебоксары, 2000.

**ГАЗЫ́ЙМОВА** Диләрә Минвәли кызы (26.7.1957, Казан), уролог, балалар хирургы, мед. фән. д-ры (2000). Чуаш ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли. Хезмәтләре балалар урологиясенә карый. Г. тарафыннан сидек-җенес системасы авыруларын амбулаториядә хирургик дәвалауның яңа ысуллары эшләнә һәм тәкъдим ителә.

Хезм.: Аномалия почек. Чебоксары, 2000 (автордаш).

**ГАИ́Б ИРӘННӘ́Р** (күзгә күренми торган әүлияләр), төрки-татар мифологиясендә тау куышлыкларында яки йортларда яшәүче 366 изге рух (бүтән чыганакларда — 40), эпик каһарманнарга, соңгы күзаллауларга караганда, гомумән, кешеләргә ярдәм итүчеләр. Гадәттә, алар ак сакаллы, һәркайсының үз исеме булган зирәк картлар рәвешендә күзаллана. Аларга табынганнар һәм корбан китергәннәр. Соңрак алар ислам мифологиясе б-н бәйләнә, аларга фәрештәләрнең кайбер сыйфатлары бирелә. Шулай ук Г.и. образлары татар фольклоры әсәрләрендә («Идегәй», «Кисекбаш китабы») һәм төрки-татар язма әдәбиятында да (Котбның «Хөсрәү вә Ширин», З.Халидинең «Җиһанша хәзрәт» әсәрләрендә) очрый.

*Әд.:* Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. К., 1977. Т. 1; Борынгы төрки-татар әдәбиятының чыганаклары. К., 1981; Алеева Ә.Х. Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе // Уйланулар, эзләнүләр, табышлар. К., 1987; Рамазанова Д. Татар мифологиясендә гаиб-ирәннәр // Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар. К., 1991; Сараи С. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999; Сибгатуллина Ә. Илаһи гашыйклар юлыннан (Суфичылык турында очерклар). К., 1999.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГАИЛӘ́** (гарәп. عائلة — өй җәмгате), кешеләрнең, *никахка* яки кан кардәшлегенә нигезләнеп, тормыш итү уртаклыгы һәм үзара әхлакый җаваплылык б-н берләшүе. Г. аша нәсел дәвам иттерелә, балалар тәрбияләнә, кешеләр буыны алышына, картайган һәм эшкә яраксыз әгъзаларына кайгыртучанлык күрсәтелә. Г. ш.у. социаль сәясәтнең төп объекты булып тора. Г. турында төп чыганак булып *халык санын исәпкә алу* хезмәт итә. 2002 елгы халык санын исәпкә алуда (ш.у. 1994 тәге микроисәпкә алуда да) Г. түгел, ә «йорт хуҗалыгы» (й.х.) категориясе кулланыла. Г.дән аермалы буларак, й.х. әгъзалары туганнар гына түгел, ә башка кешеләр дә (мәс., яллланган эшчеләр) була ала; аннан тыш, мөстәкыйль яшәүче бер генә кешедән дә торырга мөмкин. Й.х. барлыкка китерүче билгеләр: әгъзаларның бюджеты уртак (тулысы б-н яки өлешчә) булу, аларның бергә яшәве һәм тукланувы.

Татарстанда 1979 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча, 852,5 мең Г. (Й.х.нда 2 һәм аннан да күбрәк кеше булганда) исәпләнә. 1979–89 да Г.ләр саны 116,4 меңгә арта (1989 да 968,9 мең Г.). Шул ук вакытта, Г. саны халык санына караганда тизрәк үсә, бу яшь Г.нең аерым яшәүгә омтылышында һәм Г.дә әгъзалар саны кимүдә күренә. 1979 да 2, 3, 4 әгъзалы гаиләләрнең өлеше 78,7% булса, 1989 да ул 84,3% ка кадәр үсә, ә Г.нең уртача зурлыгы 4 тән 3,7 кешегә кими. 2002 елгы халык санын исәпкә алу нәтиҗәсе буенча, ТРда 1305,4 мең шәхси й.х. (970,5 мең шәһәр җирлегендә, 334,8 мең авыл

җирлегендә) теркәлгән; 4 һәм аннан аз кешесе булган й.х. өлеше 88,7% (тиңдәш рәвештә 90,4 һәм 83,7%), й.х.ның уртача зурлыгы 2,9 кеше (тиңдәш рәвештә 2,8 һәм 2,9 кеше). Хәзерге Г.гә хас үзенчәлек — балалар санының азаюы. 2002 дә 18 яшьтән яшьрәк балалары булган шәхси й.х. өлеше 45,3% күләмендә теркәлә (1989 да Г. 61,4%), шундый бер й.х.на уртача 1,49 бала туры килә. Шул ук вакытта бер балалы й.х.ның өлеше — 59,2%, ике балалыларныкы — 34,7%, өч һәм аннан да күбрәк балалы й.х.ның өлеше нибары 6,1% тәшкил итә. Г.дә балалар саны кимү *туымның* кискен төшүе б-н аңлатыла. Ихтыяҗларның үсүе, бала үстерүче эшләүче аналарның үтә мәшгульлеге кайбер Г.не, теләсәләр дә, аз бала б-н чикләнергә мәҗбүр итә. Хәзерге Г.нең формалашуы чагыштырмача иртә яшьтә башлана. Өлкән һәм кече буынның аерым яшәүгә омтылышын чагылдыра торган — ата-ана һәм балалардан торучы гадәти гаиләләр киң таралыш ала. Г.нең мондый үсеш каршылыклары сәбәбе — яшьләрнең никахлашуга һәм гаилә тормышына җитәрлек әзер булмавы, Г.нең тотрыксызлыгы.

«Яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» (1999) ТР Законы нигезендә яшь гаиләләргә 15 елга кадәр ваклап түләү шарты б-н торак сатып алуда, төзүдә яки үзгәртеп коруда ярдәм күрсәтелә. 2002–10 елларга «Торак» максатчан федераль программа составына керүче «Яшь гаиләләрне торак б-н тәэмин итү» кече программасы кысаларында яшь гаиләләрнең торак мәсьәләсен хәл итү максатында дәүләт ярдәме исәбеннән торак сатып алуга, ш.и. торак сатып алу яисә шәхси йорт төзү өчен торак-ипотека кредиты яки займ алганда беренче взносны түләү өчен субсидияләр бирелә. 2007 дән «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» дип аталган федераль закон гамәлдә, аның нигезендә баласы икенче булып яки аннан соң туган гаиләгә ана (гаилә) капиталын алу хокукы бирелә.

2009 елда Татарстан Республикасының Гаилә кодексы гамәлгә кертелә (13.1.2009 да ТР Президенты М.Ш.Шәймиев тарафыннан имзалана). Аерым алганда, федераль законга караучы РФ субъектлары карамагындагы гаилә мөнәсәбәтләре, ш.и. 16 яшькә җиткәнче никахлашу тәртибе һәм шартлары, ир б-н хатынның фамилия сайлау, балага исем һәм фамилия бирүдә үзенчәлекләр, опекунга (попечительгә) бала тәрбияләгән өчен акчалата түләүнең тәртибе һәм күләме, тәрбиягә бала алган ата-анага түләү күләме, тәрбиягә бала алган гаилә турында килешүләр рәсмиләштерелә.

*Әд.:* Народонаселение. Энцикл. словарь. М., 1994.

*Ф.Г.Борһанов.*

**ГАИЛӘ́, АНА́ ҺӘМ БАЛАЛА́Р СӘЛАМӘТЛЕГЕ́Н САКЛА́У**, яралгыны антенаталь саклау, балада авыруларны булдырмау, аның физик һәм акыл ягыннан камил үсешен тәэмин итү, авыруларны кисәтү һәм дәвалау, хатын-кызның сәламәтлеген ныгыту буенча дәүләт, иҗтимагый-профилактика һәм дәвалау чаралары системасы. Бала һәм ана хокуклары ТР Конституциясенең 38, 39, 40, 41 маддәләрендә теркәлгән.

Казан губ-насында 19 йөз уртасында ана һәм бала сәламәтлеген саклау дәүләт дәрәҗәсендә башкарыла. Җәмәгать тәрбиясе приказы карамагына ятимнәр йорты, балалар приютлары, ярлылар һәм өлкәннәр өчен гариппләр йорты керә. Сабыйлар үлеме 100 балага 40 очрак тәшкил итә. Казанда беренче мөселман балалары приюты (1844), «Җәмәгать банкы» кереме хисабына гариппләр йорты, Лихачев бала тудыру йорты (1874), Александр-Чемесов, соңрак Чистай (1886) приютлары ачыла. Авыл земство медицинасы мед. һәм аның профилактик юнәлеше үсешенә зур йогынты ясый, халык арасында авырулар таралу дәрәҗәсен ачыклау буенча сан.-стат. тикшеренүләр алып барыла (П.Н.Песков, 1874). 1900 еллар башында 75 табиблек участогы була, авылларда дәвалау пунктлары төзүгә игътибар арта, Казан ун-тының мед. ф-ты клиникалары (ш.и. балалар клиникасы, соңрак В.К.Меньшиков исем., В.С.Груздев исем. акушерлык-гинекология клиникасы) ачыла. Кызыл хач җәмгыятенең Казандагы шәфкать туташлары оешмасы лазареты нигезендә Казан клиника ин-тының акушерлык һәм хатын-кыз авырулары каф. ачыла (беренче мөдире А.И.Тимофеев). 1920 елларда ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында аналарны һәм балаларны саклау бүлеге оештырыла; авылларда сәламәтлек саклау пунктлары, соңрак бала тудыру йортлары төзелә. 1922 елдан йөкле хатыннар өчен махсус ташламалар–өстенлекләр булдырыла, аларга йөкле чорда һәм бала тудырудан соң дәүләт социаль иминияте шартлары нигезендә түләүле ял бирелә.

РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-ты карары б-н Казанда (1920) 2 нче балалар шифаханәсе (соңрак Лепский исем. клиника) җирлегендә Казан клиника ин-тының педиатрия каф. ачыла, аның каршында имчәк балалар палаталары, вакытыннан алда туган балалар бүлекләре, балалар кухнясы була, «аналар мәктәбе» эшли. Клиника һәм кафедраның фәнни хезмәткәрләренең «Рахит һәм аның белән авыручыларның туклануы» («Рахит и питание рахитиков», 1945), «Балаларны ничек ашатырга» («Как кормить детей», 1947) һ.б. хезмәтләре нәшер ителә. 1940 та һәр 1000 туган балага 26,4 үлем очрагы туры килә.

1970 елларга кадәр Татарстанда педиатрия хезмәтенең бердәм үзәге булмый. 1977 дә күп профильле комплекс — *Республика балалар клиник хастаханәсе* (ДРКБ) ачыла; андагы стационарда — 104, поликлиникада 26 мед. белгечлеге буенча хезмәт күрсәтелә. Стационарда бер үк вакытта 750 бала дәвалана. Елга 20 мең балага дәвалау үткәрелә. Хастаханәдә балаларга кечектергесез мед. ярдәме күрсәтү оештырыла; нәселдән килгән авыруларны булдырмау максатында мед.-генетик консультация үткәрелә.

1970 тә Казан ГИДУВы нигезендә илдә беренче аллергология каф. оештырыла (балалар аллергологиясе каф. мөдире А.М.Потёмкина). Казанда балаларга хирургия, урология, стоматология ярдәме күрсәтү хезмәтләре булдырыла; махсус мед. үзәкләре эшли.

1992 дә «Гаилә, аналарны һәм балаларны саклау» республика үзәге төзелә (мөдире проф. С.В.Мальцев), 2000 нән үзәк ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика мед.-социаль тикшеренүләр икътисади үзәге составында эшли. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: хәзерге гаиләнең мед.-социаль мәсьәләләрен, ТРның шәһәр һәм авыл р-нnarында яшүсмерләр сәламәтлегенең торышын, хатын-кызларда һәм балаларда төрле патологияләр вакытында интенсив экологик фактор буларак микроэлементлар алмашын өйрәнү; гаиләдә бала булмау сәбәпләрен ачыклау һәм дәвалау; хатын-кызларда, яңа туган һәм кече яшьтәге балаларда сексуаль трансмиссив йогышлы авыруларга диагноз кую; реабилитация комплекслары булдыру. Үзәк эшчәнлегендәге өстенлекле юнәлешләр: булачак аналар сәламәтлеген саклау, фето-инфантиль (яралгы — кече яшьтәгеләр) һәм бала тудыру сәләтендәге югалтуларны булдырмау, перинаталь ярдәм, махсус ярдәм күрсәтүне үстерү, вакциналы профилактика, яшүсмерләр һәм мәктәп балалары сәламәтлеген саклау, тышкы сәбәпләргә бәйле балалар үлемен булдырмау, гаиләгә психологик ярдәм, шәхесне бозучы холык-фигыльдән арындыру эшләре. 2000 елларда ТРда социаль тәэминат авыруларга, хезмәткә яраксызларга, өлкәннәргә, күп балалы гаиләләргә һәм балаларга ярдәм күрсәтүне үз эченә ала. ТРда балалы гаиләләргә түбәндәге ярдәм чаралары күрсәтелә: яшәү минимумыннан түбән керемле 16 яшькә кадәрге балага (108354 кеше); хезмәттә булмаган бала караучыларга (15890 кеше), гаскәри хезмәткә чакырылган хәрбинең баласына (164 кеше) һ.б. акчалата түләүләр. 2007 дән башлап, икенче һәм аннан соң туган бала исәбенә «ана капиталы» түләнә.

2008 дә ТРда 18 респ-ка реабилитация үзәге (4 се өлкәннәр өчен), 4 психоневрология интернаты, 2 балалар йорты (акылга зәгыйфь балалар өчен), картлар һәм инвалидлар өчен 31 интернат йорты, 2003 тән «Татарстан балалары» респ-ка программасы эшли. ТР балалар сан.-курорт учреждениеләрендә (11 санаторий) ел саен 8 мең бала сәламәтлеген ныгыта; җәйге айларда шәһәр читендәге балалар лагерьларында ял оештырыла. Ш.у. к. *Балалар санаторийлары.*

2008 дә респ-када 16 балалар хастаханәсе, ш.и. фәнни үзәкләре булган Республика балалар клиник хастаханәсе, 29 балалар поликлиникасы, 9 бала тудыру йорты, 3 сабыйлар йорты эшли.

*Әд.:* Макаров Ю.В., Макарова Г.А., Еникеева Р.И. К истории становления педиатрической службы в Казани // Казан. мед. журн. 1967. № 5; Мальцев С.В. Охрана здоровья матери и ребёнка в республике Татарстан // Казан. мед. журн. 2003. № 1.

*Д.Р.Нуретдинова, Р.Г.Исхакова.*

**ГАИЛӘ́ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ́**, аерым затлар арасында кардәшлеккә, никахка яки уллыкка (кызлыкка) алуга нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Татарларның Г.м. үсешенә милли гореф-гадәтләр һәм мөселман тәртипләре (к. *Гореф-гадәт*) йогынты ясаган. Ислам тарафын-

нан урнаштырылган хокук кагыйдәләре (к. *Шәригать*), керәшен татарларның яшәү рәвешен билгеләгән христиан кануннары кебек үк, үлгән кешене искә алу йоласы (к. *Мәет күмү һәм мәрхүмне искә алу йолалары*) һәм *бала тууга бәйле йолалар* б-н беррәттән, никах бәйләнешләренә кагыла. Татарларда гаилә борынгы заманнардан ук тотрыклы хуҗалык итүнең бердәнбер мөмкин төре (к. *Җыен*, *Җәмәгать*), җитеш картлыкның терәге булып торган, ә никахлашу исә табигый зарурлык булып саналган (1897 елгы халык исәбен алу буенча, Казан губернасында яшәүче халык арасында 50 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ирләрнең — 1,7, хатын-кызларның 3,6% гына бер тапкыр да никахлашмаган). Ата-ана һәм бала-чагасы гына булган кечкенә (19 йөз ахырында андый гаиләнең уртача составы 5,4 кешегә җиткән) яисә 3–4 буын якын туганнарны берләштергән ишле татар гаиләләре гомумгаилә милегендә оеша.

Кәләш яки кияү сайлау мәсьәләсен, кагыйдә буларак, гаилә башлыклары (әби, бабай, ата) хәл итә. Татарларда киленне, гадәттә, башка авылдан эзләгәннәр. Рев-циягә кадәрге Россиядә барлык халыклар өчен никахлашу турында бердәм канун булмый, шуңа күрә төрле дин тотучы затлар үз диннәренә бәйле төрле кагыйдәләр йогынтысына буйсынганнар. Кагыйдә буларак, татарлар үз милләте һәм дине вәкилләре б-н никахлашканнар (Коръән мөселман ирнең башка диндәге хатын-кыз б-н никахын тыймый, әмма гамәлдә мондый никахлар татар җәмәгатьчелегендә гаепләнгән, ә кайчакта эзәрлекләнгән). Гадәттә, тигез мөлкәтле кешеләр кодалау аша никахлашканнар, кәләш өчен чагыштырмача зур булмаган *калым* түләгәннәр, булачак килен исә үз чиратында ире яшәгән гаиләгә *бирнә* алып килгән (к. *Туй йолалары*). Сирәк кенә *левират* — баласыз тол хатынның үз каенесенә кияүгә чыгу очраклары булгалаган.

Яңа өйләнешүчеләрнең төп нигездә, ягъни кияүнең әти-әнисе йортында яшәүләре гадәти хәл итеп кабул ителгән, кияүнең килен әти-әнисе йортына килү очрагы бик сирәк булган. Гадәт буенча, гаиләле өлкән уллар вакытлар узу б-н ата-ана йортыннан аерылып чыккан (к. *Башка чыгару*), ата кеше хуҗалыгы төпчек улга мирас ителгән. 20 йөз башына кадәр мишәрләрдә, Чыпча татарларында ишле гаиләләр (әти-әниләре б-н бергә яшәүче берничә өйләнгән уллары — 3–4 никахлы пар) сакланып калган. Казан татарлары арасында ике никахлы пардан торган гаиләләр (ата һәм ана, ул һәм килен) шактый киң таралган. Гаилә кору төрле туй йолалары б-н башкарылган, аларның үзәгендә дини йолалар торган: мөселманнар өчен *никах* укылган, ә керәшеннәрдә христиан гадәте буенча чиркәүдә кәбен койдырылган. Асылда, татарлар арасында, башлыча, моногамик гаиләләр өстенлек иткән. Шәригать полигамиягә (күп хатынлылыкка) рөхсәт бирсә дә, андый никахлар киң таралыш алмый (мәс., 1844 елгы мәгълүматлар буенча, Казандагы 2112 ир-атның нибары 55е генә (2,6%) — 2; 6сы (0,2%) — 3; 2 се (0,09%) — 4 хатын б-н яшәгән).

Татарларда гаиләләр тотрыклы булулары б-н аерылып торган, гәрчә мөселманнарда иргә гаилә килешүен берьяклы гына өзәргә хокукый өстенлек бирелсә дә, аерылышулар бик сирәк күзәтелгән. Аерылышу өчен ирнең өч тапкыр «талак» дип әйтүе дә җиткән.

Социаль составы буенча гаиләләр гомоген (бертөрле) булган: балалар әтиләренең эшен дәвам иткән, хатын-кызның гаиләдәге урыны иренең тормышта тоткан дәрәҗәсе б-н билгеләнгән. Татарларда хезмәт җенси принцип буенча бүленгән: ир-атлар хуҗалыкта авыр эшләрне башкарганнар, хатын-кызлар өйдә эшләгәннәр (крәстиян гаиләсендә алар хуҗалык тормышында ирләр б-н беррәттән катнашып, зур мөстәкыйльлеккә һәм иреккә ия булганнар). Җенесләрнең тигезсезлеге җәмгыятьтә һәм гаилә тормышында гадәти хәл исәпләнгән, башлыча, хатын-кызның икътисади яктан бәйле һәм юридик хокуктан мәхрүм булуында чагылган. Шәһәр татарларының иркен тормышлы катламының гаилә көнкүрешендә хатын-кызның ирекен чикләүче тәртипләр (мәс., кеше б-н аралашу) тагын да катгыйрак булган. Татар хатыны иренең рөхсәтеннән башка өенә кунаклар чакырырга һәм хәтта үзенең әти-әниләре йортына барып килергә җөрьәт итмәгән.

Татарларда традицион гаилә этикетының төп принциплары балаларның — әти-әниләрне, кечкенәләрнең өлкәннәрне берсүзсез хөрмәт итүгә һәм олылауга корылган. Ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрдә билгеле бер хисси басынкылык сакланган (балаларны артык узындырырга тырышмаганнар). Балалар кече яшьтән үк хезмәткә өйрәнгәннәр (7–8 яшьтә малайлар кыр эшләрендә катнашканнар, ә кызлар йорт хуҗалыгында булышканнар). Кече яшьтән ата-анага булышу эшкә тизрәк һәм җиңелрәк өйрәнү дип каралган. Татарлар балаларын укый-язарга өйрәтүне (малайларны да, кызларны да) даими игътибар үзәгендә тотканнар.

20 йөздәге социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси үзгәртеп корулар татар җәмгыятендәге Г.м.-нең патриархаль нигезләрен какшата, татар гаиләсендәге дини гореф-гадәтләргә җитди үзгәрешләр кертә. 1917 елның декабрендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы «Гражданлык хәле актларын теркәү бүлекләрендә язылышып өйләнешү, балалар һәм актлар хәле китабын кертү турында» һәм «Аерылышу турында» дигән 2 декрет кабул итә. Әлеге документлар өйләнешү һәм гаилә, ир б-н хатынның үзара мөнәсәбәтләре, ата-аналар һәм балалар турында яңа кагыйдәләрдән торалар. Дәүләт гражданлык хәле актлары теркәү бүлекләрендә (ЗАГС) теркәлгән никахларны гына таный, ә дини никахларны ир б-н хатынның шәхси эше дип игълан итә. Баланың әти-әниләре саналырга тиешле затлар әлеге хакта гариза язарга тиеш була, аталыкны суд тәртибендә раслау канунлаштырыла, ир б-н хатынның — икесенең яки берсенең теләге буенча — ирекле аерылышуы кертелә (икесенең дә теләге булган очракта — судсыз гына ЗАГСта хәл ителә). Балигъ булмаган балаларның кем б-н калуларын, аларны тәрбияләү һәм карау буенча ир б-н хатынның бурычларын ачыклауны суд хәл итә. 1930–40 еллардан башлап, ирекле никахлашу нормага керә (ш.и. терр. принцип буенча), милләтара никахлар ят күренеш булудан туктый (1999 да Татарстанда мондый никахларның күрсәткече 25,7% ка җитә). Совет власте елларында татарларда хатын-кызның хәле, гаиләдәге урыны турындагы караш тамырдан үзгәрә. Хәзерге татар хатыны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә актив катнаша. Яшь егет б-н кызның әти-әниләренең социаль, матди хәле яшь гаиләне аеручы яки бергә кушучы билге булудан туктый. Татарларда яшь парларга никах беркетү өчен беренчел дәрәҗә шарт булып шәхси сыйфатлар (хезмәтне ярату, хуҗалык итү һ.б.), белем һәм хезмәткә әзерлек дәрәҗәсе санала. Теркәлмәгән никахлашулар («гражданлык никахлары») саны сизелерлек арта. 1990 еллардан башлап гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрнең демократияләшә баруы б-н бергә, дини традицияләрнең, этник-конфессиональ гадәтләрнең, никах б-н бәйле йолаларның, гаилә көнкүреше һәм хуҗалыгының яңару омтылышлары сизелә башлый. 1996 елның 8 декабрендә РФнең Дәүләт Думасы гаиләне ныгытуга, гаилә мөнәсәбәтләрен үзара ярату, хөрмәт итү һәм җаваплылык хисләрендә төзүгә нигезләнгән, гаилә эшенә кемнәрнеңдер башбаштакларча тыкшынуына юл куймауны һ.б. чараларны эченә алган Гаилә кодексын кабул итте. РФ Президенты В.В.Путинның 2007 нең 14 июнендә чыгарылган Указы нигезендә 2008 ел Гаилә елы дип игълан ителде. ТРда аңа хәзерләнү һәм уздыру вазифалары ТР Президенты М.Ш.Шәймиев җитәкләгән Хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча респ-ка советына йөкләнде. Гаилә елы кысаларында ТРда социологик тикшеренүләр, конкурслар, фестивальләр, ярышлар, конференцияләр, хәйрия акцияләре һ.б. үткәрелде, аларда төп игътибар гаиләләрне (ш.и. ишле гаиләләрне) социаль яклауга, Г.м.-нең абруен, гаиләнең нигезендә яткан кыйммәтләрне ныгытуга юнәлтелде.

*Әд.:* Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Столярова Г.Р. Этнодемографические процессы в Казанском Поволжье. К., 1991; Мусина Р.Н. Семья и семейный быт // Татары. М., 2001; Столярова Г.Р. Феномен межэтнического взаимодействия: опыт постсоветского Татарстана. К., 2004.

**ГАЙТОВ** Марс Җамали улы (14.10.1935, Ворошилов, хәзерге Тукай р-ны Иске Абдул а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1977), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2009), ТРның атказ. икътисадчысы (1993). 1958 елда Казан а. х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Яңа Юл сортлар сынау участогында агроном-мөдир булып эшли. 1960–63 елларда Минзәлә р-нында а. х. инспекциясендә, В.Воровский исем. с-зда баш агроном; 1963–66 да Татарстан респ-ка а. х. тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр, 1966 дан «Татмелиоводстрой» трестында план-икътисад бүлеге башлыгы. 1971–97 дә Казан а. х. ин-ты-



Р.Х.Г а и т о в. 1. «Хужа Насретдин сәяхәте». 1990; 2. «Мисырга һиҗрәт». 1990; 3. «Чак-дала». 1993; 4. «Чәчәкле натюрморт». 1991. «Шәрекъ» фонды АҖнең традицион һәм хәзерге сәнгать галереясы (Уфа).

ның а. х. икътисады кафедрасында өлкән укытучы, доцент. 1997–2004 тә Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү ин-тында икътисад һәм менеджмент каф. мөдире, 2004 тән ТР ФА нең Татар энциклопедиясе ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. Дәүләт бүләге «Җир ресурсларыннан файдалану нәтиҗәлелеген күтәрүнең оештыру-икътисади механизмнары» дигән хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реформирование внутрихозяйственных экономических отношений на основе микрорынка. К., 2002 (автордаш); Экономический механизм земельных отношений в сельском хозяйстве. К., 2004 (автордаш).

**ГАЙТОВ** Рәис Хәмидулла улы (6.1.1956, БАССРның Октябрьский ш.), нәкышьче, график. Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1986). Уфа сервис технол. ин-тының сәнгатьчә проектлау кафедрасында укыта (1995–2000). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991). Г. әсәрләре стилистик яктан модернизм принципларына һәм Шәрекъ мөселман сәнгатенә, аның шартлы сурәтләү хасиятенә таяна. Әсәрләре бизәкләр байлыгы һәм төсләр композициясенең полихромлыгы ягыннан татар халык иҗаты әсәрләре б-н охшаш. Аларның тематикасы рәссамның милли хиссиятен, татар мәдәниятенең борынгы тамырлары һәм аның ислам мәдәнияте эстетик мохитендә токкан урыны турында уйлануларын чагылдыра. Г. иҗатында үзәк урында гает намазына баскан Мөселман образы («Намаз укучы мөселман», 1992) һәм татар халкының бабалары — борынгы төркиләр, болгарлар заманнарыннан ук килгән, урта гасырлар башында кыяга уеп ясалган болгар җайдаклары сурәте стилендә эшләнгән Җайдак образы тора («Чак-дала», 1993). Г. әсәрләре композициясендә космологик символлар, гарәп хаттат язуы, җан ияләренең, ш.и. кешенең шартлы сурәтләре, ш.у. модерн сәнгате сурәтләү системасына хас абстракт формалар һәм ритмика мөһим роль уйный. Төп әсәрләре: нәкышь — «Мисырга һиҗрәт» (1990; шул ук — литографиядә, 1997), «Беренче кар» (1996), «Сириус» (1997), «Дәвамчанлык» (1997), «Чирәмдә бәйрәм», «Композиция. Очыш» (икесе дә — 1998), «Рок-н-ролл», «Иске фрескалар», «Шәһәр. Натюрморт», «Ике юл» (барысы да — 1999); графика — уникаль офорт һәм литография: «Будда кендеге» (1997), «Үткәннәр күләгәсе», «Далада эңгер», «Эчке Монголия», «Аркаим төннәре» серияләре (барысы да — 2001–02) һ.б.

Республика, төбәк, бөтенроссия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә (1980 елдан), «Татарт» бөтентатар төбәкара күргәзмәсендә (С.-Петербург-Казан, 1991), «Инзер» иҗат төркеме составында Уфада (1989, 1993), Мәскәүдә (1992) узган күргәзмәләрдә, Урал станлы басма графика триенналесында, татар рәссамнарының «Башкортстан Республикасының хәзерге заман рәссамнары» күргәзмәсендә (С.-Петербург, 2000), төрле төркемнәр составында Израильдә (Хайфа ш., 1990), Австриядә (Зальцбург, Вена ш., 1992–93), халыкара «Туран» фонды тарафыннан Төркиядә уздырылган (Истанбул ш., 1994) күргәзмәдә, АКШта узган «Уралдагы хәзерге заман басма графикасы» (Фресно, Калифорния ш., 2000), Испаниядә үткән халыкара басма һәм кече басма графика (Барселона ш., 2002), Польшада уздырылган экслибрис (Краков ш., 2001) күргәзмәләрендә һ.б.да катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфада 1988, 1989, 1991, 1993, 1994, 1997, 1999, 2001 елларда уза.

Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Сәнгать музеенда (Уфа), «Шәрекъ» фонды АҖнең Традицион һәм заманча сәнгать галереясында (Уфа), «Урал» хәзерге заман сәнгате галереясында (Уфа), «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Екатеринбург шәһәрендәге һәм Төмән өлкәсенең Яңа Уренгой посёлогындагы хәзерге заман сәнгате музейларында, Чиләбе шәһәренең Дизайн үзәгендә, чит илләрдәге (АКШ, Германия, Англия, Франция, Голландия, Италия, Австрия һ.б.) шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Г а р б у з А. Восток и Запад в живописном пространстве Урала // Востокозапад. Живопись. Уфа., 1994; Галерея традиционного и современного искусства фонда «Восток»: Каталог. Уфа, 1997; Современные художники Республики Башкортстан. Живопись, графика: Каталог выставки. СПб., 2000; Гаитов Раис Хамидуллович // Сияние лун. Уфа, 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАЙ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көнчыгышында урнашкан. 1960 елның 4 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 3540 *км²*. Үзәге — Гай шәһәре (Оренбургтан 330 *км* көньяктарак). Халкы — 12188 кеше, ш.и. татарлар — 804 кеше (2002). Алар, башлыча, Гайнулла һәм Өзембай авылларында яши. 1917 гә кадәр бу авылларда мәчетләр була. 1932 дән Гайнулла авылында татар теле фән буларак өйрәнелә. 1917–66 да Өзембай авылында татар мәктәбе эшли, 1966 да ул рус мәктәбе итеп үзгәртелә, һәм 1968 дән татар теле фән буларак өйрәнелә. 2001 дә Өзембайда мәчет ачыла.

**ГАЙЗАТУ́ЛЛИН** Радик Рәүф улы (20.7.1964, Буа р-ны Яңа Тинчәле а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (1996). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1985). 1986–88 елларда — Лаеш р-ның «Маяк» к-зы, 1988–99 да Биектау р-ның «Бөреле» агрофирмасы баш бухгалтеры. 1999 дан ТР Финанс министрлыгында: бүлек башлыгы, 2000 нән министр урынбасары, 2001 дән министрның 1 нче урынбасары, 2002 дән ТР финанс министры.

**ГАЙНА́НОВ** Габделхәбир Гайнан улы (8.5.1930, хәзерге Яшел Үзән р-ны Түбән Урысбага а.), «Яшел Үзән икмәк комбинаты» АҖ ген. директоры (1997–2003), ТАССР һәм РСФСРның атказ. азык-төлек индустриясе хезмәткәре (1986, 1991). 1963 елда Яшел Үзән суднолар төзү техникумын тәмамлый. 1947–82 дә өзеклекләр б-н Горький исем. Яшел Үзән суднолар төзү з-дында эшли (1949–61 дә 12 нче һөнәр уч-щесендә мастер, 1967–74 тә Яшел Үзән ашханәләр һәм ресторраннар тресты директоры). 1982–97 дә

Яшел Үзән икмәк комб. директоры. Г. җитәкчелегендә пр-тиене яңартып төзү эшләре, технол. җиһазларны модернизацияләү үткәрелә; яңа цехлар төзелә, продукциянең ассортименты киңәйтелә һәм сыйфаты яхшыртыла (халыкара һәм Россия конкурсларында призларга ия була), шәһәрдә үз сәүдә челтәре (15 кибет) оештырыла һ.б. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә, РФ Хөкүмәте рәисе В.В.Путинның Рәхмәт хатына лаек була. Яшел Үзән шәһәре һәм р-нының мактаулы гражданы (2004).

*Әд.:* Г а ф ф а р А. Цена людской благодарности // Деловой Татарстан. 1998. № 2; Татарстан — мой второй дом. Зеленодольск, 1999; С у б б о т к и н А., Ш а м с у т д и н о в а Р., Г а л а н и н С. Зеленодольский хлеб. К., 2000; Хлеб Татарстана. К., 2001.

*М.Я.Гаитов.*

**ГАЙНА́НОВ** Рашат Рәшит улы (27.10.1925, БАССРның Салават р-ны Нәсибаш а. — 6.10.1990, Казан), әдәбият галиме, текстолог, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1952–65 елларда «Совет Татарстаны», «Яшь ленинчы» г-таларында, «Азат хатын», «Татарстан коммунисты» ж-лы редакцияләрендә эшли, 1965–86 да СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1986–90 да Казан ун-тының татар халкы тарихы кафедрасы каршындагы Археография фәнни-тикшеренү лаб-ясендә эшли. Н.Думави (1960), Г.Тукай (т.1–4, 1975–77; т. 1–5, 1985–86), Г.Ибраһимов (т.1–8, 1974–86) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша (шәрехнамәләр, искәрмәләр яза). Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Газиз, Ф.Кәрим, Н.Исәнбәт, З.Байчурина, М.Җәлил, Һ.Такташ, Г.Кутуй иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. Татар мәдәнияте тарихына (1900–17) караган 752 шәхес исеменнән торган белешмә өчен сүзлекчә төзи (кульязма рәвешендә). Татар теленә В.А.Осееваның «Васёк Трубачёв һәм аның иптәшләре» («Васёк Трубачёв и его товарищи», 1953), М.Твенның «Принц һәм теләнче» («Принц и нищий», 1954) повестьларын, М.Шагинянның «Ульяновлар гаиләсе» («Семья Ульяновых», 1962) роман-хроникасын тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар вакытлы матбугаты (1905–1924). К., 1999 (автордаш); Татарская периодическая печать начала XX века: Библиогр. указ. К., 2000.

*Әд.:* У р м а н ч е е в Ф. Кадерлерәк була бара // Казан утлары. 1987. № 4.

**ГАЙНА́НОВ** Хаҗип Сабир улы (29.1.1931, Лениногорск р-ны Урдалы а., хәзерге Туктар Урдалысы а.), инженер-механик, а.х. производствосында технологик процессларны механикалаштыру белгече, техник фән. кандидаты (1965), проф. (1991), РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1990), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991), ТАССРның атказ. механизаторы (1981). Саратов а.х. механикалаштыру ин-тын тәмамлый (1960). Хезмәт эшчәнлеген 1948 елда Урал вагон төзү з-дында электрик булып башлый (Түбән Тагил ш.). 1960–62 елларда Саратов өлкәсенең Балтай р-ны «Царёвщинский» с-зында инженер. 1965 тән Казан а.х. академиясендә, а.х. машиналары каф. мөдире (1981–97).

Хезмәтләре а.х. машиналары узелларын камилләштерүгә карый. Г. тарафыннан беренче тапкыр игенчелекне механикалаштыру өлкәсендә функциональ анализ методологиясенең төп кагыйдәсе эшләнә, үсемлек һәм орлыкларның фенологик үсеш фазасында биологик ихтыяҗын тулы канәгатьләндерү хисабына эшкәртелә торган җиргә тагын да югары технологик нәтиҗәлелек б-н тәэсир итүгә сәләтле яңа эшләү җайланмалары һәм машиналар булдыруның методик нигезләре тәкъдим ителә.

Г. тарафыннан бөртекле һәм техник культураларны, бәрәңге, азык чөгендере, орлыклык люцернаны үстерү һәм уңышын җыю өчен яңа оригиналь техник чаралар һәм технол. ысуллар эшләнә. Уйлап табуга 70 кә якын авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге туфракның өске катламын эшкәртү өчен модульле а.х. кораллары комплексын эшләп файдалануга кертүдә катнашканы өчен бирелә. СССР ВДНХсының ике көмеш медале, «СССР уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Совместные операции в земледелии. М., 1991; Регулировка и настройка машин к полевым работам. К., 1997; Повышение эффективности и использования уборочной техники. К., 1998. Урып-җыю машиналары (Зерноуборочные машины). К., 2003; Машины для очистки и сушки семян. Йошкар-Ола, 2007.

**ГАЙНА́НОВА** Фәния Гариф кызы (15.11.1929, Әтнә р-ны Олы Әтнә а. — 4.5.2007, Казан), тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1951). 1952–86 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә, 1999–2003 тә ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тында эшли. Татар теленә В.А.Осееваның «Тылсымлы сүз» («Волшебное слово», 1953) хикәяләр китабын, Ж.Вернның «Капитан Грант балалары» («Дети капитана Гранта», 1974), «Серле утрау» («Таинственный остров», 1981) романнарын, И.С.Тургеневның «Язгы сулар» («Весенние воды», 1975) повестен, И.А.Гончаровның «Гыйбрәтле язмыш» («Обыкновенная история», 1979) романын, гарәп һәм әзәрбайҗан авторларының «Мисыр хикәяләре» (1958), «Әзәрбайҗан хикәяләре» (1963) җыентыкларын, ш.у. Л.Голосницкийның балаларга багышланган «Үткән заманга сәяхәт» («Путешествие в прошлое», 1960), А.М.Макушаның «Егет булыйм дисәң» («Мужчинам до 16 лет», 1969), ш.у. «Мәктәптән галәмгә» («Из школы во вселенную», 1973) фәнни-популяр китапларын тәрҗемә итә.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; М и ң л е б а е в К. Урының түрдә, Фәния // Мәдәни җомга. 1999. 19 нояб.

**ГАЙНЕТДИ́Н** Равил (Гайнетдинов Равил Исмәгыйль улы) (25.8.1959, Питрәч р-ны Шәле а.), дин эшлеклесе. Бохарадагы «Мир-Араб» мәдрәсәсендә белем ала (1979). 1985 елдан СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәтендә җаваплы сәркәтип (Уфа ш.). 1987 дән Мәскәү җамигъ мәчетенең имам-хатыйбы. 1991 дән Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе Ислам үзәге президенты, 1994 тән мөфти, Россиянең Үзәк Европа төбәкләре мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, бер үк вакытта 1996 дан Россия мөфтиләре шурасы рәисе. Г. дәүләти-конфессиональ мөнәсәбәтләрдә актив катнаша: Россиянең Диннәрара советы (1998 дән), РФ Президенты каршындагы Дини берләшмәләр б-н үзара бәйләнешләр советы (2004 тән), РФнең Иҗтимагый палатасы (2006 дан) әгъзасы, «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивале президенты. Ислам йолалары һәм догматикасы мәсьәләләренә караган китаплар авторы. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Халыклар дуслыгы, Почёт орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ислам: вера, милосердие, терпимость. М., 1997; Как усилить роль религиозных организаций мусульман в духовном возрождении России. М., 1999; Ислам в современной России. М., 2004.

*Әд.:* Таныш булыгыз: мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин. К., 2002; Современная политическая история России (1995–1998). М., 1999. Т. 2.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Альфред Ризван улы (29.6.1960, Казан), невропатолог, рефлексотерапевт, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1988 елдан ГИДУВта. Г.А.*Иваничев* шәкерте. Төп фәнни тикшеренүләре сулыш системасының нейромотор тайпылышларына диагноз куюга һәм дарулар кулланмыйча дәвалауның мөһим мәсьәләләренә карый. Ул хроник обструктив үпкә авырулары (хозл) вакытында вентиляция аппаратының мускул-буын эшчәнлеге бозылу урынын, ешлыгын һәм күренешен тикшерә, күкрәк читлеге сыгылмалылыгы кимүнең тын кысылуга китерү үзенчәлеген ачыклый; вентиляция бозылуның төрле этапларында нейромотор сулыш системасының периферик һәм үзәк буыннары торышын өйрәнә. Хроник обструктив үпкә авырулары (хозл) б-н авыручыларда көйләнешнең нейромотор контурындагы үзәк һәм периферик буыннар эшчәнлеге бозылуның этаплап баруын беренче булып ачыклый (1999), тышкы сулыш алу функцияләре бозылганда мануаль һәм акупунктур дәвалау ысулларын эшли һәм гамәлгә кертә. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2006).

Х е з м.: Физиология нейромоторного контура системы дыхания // Казан. мед. журн. 1996. № 1 (автордаш); Нейрофизиологические предпосылки сочетания мануальной терапии и акупунктуры в лечении болевых мышечных синдромов // Сенсорное и рефлекторное взаимодействие в механизмах акупунктуры. К. 1999.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Владимир Григорьевич (28.6.1956, Удмуртия АССРның Кизнер р-ны Кибья а.), самолётлар төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1964), проф. (2001). 1979 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: югары математика каф. профессоры (1994–96), очкыч аппаратларны конструкцияләү һәм проектлаштыру каф. мөдире (1996 дан). Хезмәтләре сыгылмалы конструкцияләрнең геометрик нәсызыкча механикасына карый. Г. җитәкчелегендә күпмаксатлы үтә җиңел КАИ-81 самолёты төзелә.

Х е з м.: Расчёт самолёта на прочность. К., 1989 (автордаш); Математические модели авиационных конструкций при конечных перемещениях. К., 1998; Расчётная модель составной тонкостенной конструкции // Изв. вузов. Авиац. техника. 2003. № 2.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Вячеслав Кәрибулла улы (6.11.1947, Приморье крае Иман ш., хәзерге Дальнереченск ш. — 17.8.1980, Әфганстан Респ-касы), хәрби очучы, Сов. Союзы Герое (1980, үлгәннән соң), майор. Югары хәрби авиация уч-щесен тәмамлый (1970). 1966 елдан Совет Армиясендә. Әфганстан Респ-касындагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бу республикага булышлык иткәндә батырлык күрсәтә. Ленин ордены, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1; З а й ц е в А.Д., Р о щ и н И.И., С о л о в ь ё в В.Н. Зачислен навечно. М., 1990. Кн 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Илгизәр Гыйльметдин улы (8.1.1966, Балык Бистәсе р-ны Ямаш а.), икътисадчы, а.х. фән. канд. (1993), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан а.х. ин-тын тәмамлагач (1988), шунда ук игенчелек кафедрасында укытучы, 1992 елдан а.-х. продукциясе җитештерүне оештыру кафедрасында, 1999 дан доцент. 1997 дән бер үк вакытта Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү ин-тының икътисад һәм социаль-гуманитар фәннәр кафедрасында, 2000 нән мөдир. Татарстан Дәүләт бүләге «Җир ресурсларыннан файдалану нәтиҗәлелеген күтәрүнең оештыру-икътисади механизмнары» исемле хезмәте өчен бирелә.

Хезм.: Реформирование внутрихозяйственных экономических отношений на основе микрорынка. К., 2002 (автордаш); Экономический механизм земельных отношений в сельском хозяйстве. К., 2004 (автордаш).

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Илдус Сәлах улы (28.3.1938, Казан), физик, техник фән. д-ры (1999), проф. (2004), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998), СССР Оборона сәнәгате министрлыгының атказ. уйлап табучысы (1980). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Федераль фәни-җитештерү берләшмәсе дәүләт унитар пр-тиесенең «ГИПО» гамәли оптика ин-тында эшли: оптик капламнар бүлегендә сектор (1966 дан), лаб. (1969 дан), бүлек (1986 дан) башлыгы. Бер үк вакытта ГИПО Оптик капламнар фәнни җитештерү пр-тиесенең 1994–2003 тә директоры, 2003 тән фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре оптик приборлар төзүгә, оптик капламнарга карый. Махсус техника өчен вакуумда юка оптик капламнар әзерләү технологиясен эшли, ул Украина, Белоруссия, Чехословакия һәм Һиндстанның төрле пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. СССР МС бүләге лауреаты (1990). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Высокоотражающие лазерные зеркала с малыми потерями для лазерных гироскопов // Оптический журн. 1994. № 2; Разработка и создание оптических интерференционных покрытий различного назначения с прогнозируемыми свойствами: Дис. ...СПб., 1998; Просветление оптических элементов в области 2,5–3,5 мкм // Оптический журнал. 2008. № 1 (автордаш); Оптические материалы и технологии. К., 2008 (автордаш).

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Илдус Хаҗимулла улы (5.8.1957, Арча р-ны Яңасала а.), гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, дизайнер. Мәскәү җиңел сәнәгать технол. ин-тының күн эшләнмәләр конструкцияләү бүлеген тәмамлый (1983). 1978 елдан Арча милли аяк киемнәре ф-касында модельер, баш рәссам (1983–86), баш инженер (1986–87) һәм Арча милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе ген. директоры булып эшли (1987–99); 1999 дан Биектау р-нының Дөбъяз авылында урнашкан халык сәнгати кәсепчелеге пр-тиесе статусындагы, күннән традицион технол. б-н кулдан эшләнмәләр җитештерүче «Экоскин» ЖЧҖ директоры. Күнне сәнгатьле эшкәртү өлкәсендә тәүге проф. рәссамнарның берсе, аяк киемнәре һәм күн әйберләр буенча конструктор-технолог. Каюлы күннән хатын-кыз һәм ир-ат читекләре, туфлиләр, диван мендәрчекләре, йорт җиһазы тышлыклары, дивар паннолары, бүләк җыелмалары (читек, букча, янчык һәм портмоне) үрнәкләрен эшли. Әлек күнне тишү өчен кулланылган кылларны машина инәсе б-н алыштырып, кулдан чигү технологиясен камилләштерүче авторларның берсе. Аяк киеме үрнәкләрен эшләгәндә Г. каюлы күннең татар халкында 18 йөз–19 йөз уртасында аеруча үсеш алган традицияләренә мөрәҗәгать итә, төсләрне һәм табигый буяуларны гармоник рәвештә яраклаштырып, аларның классик гаммасын киңәйтә, ш.у. җөйсез читекләр эшләү технологиясен үстерә. Каюлы бизәкләрне стильләштереп, Г. бизәк композициясен яңа декоратив детальләр һәм алтынсу, аксыл-көрән, чия-көрән, зөбәрҗәт-яшел, күксел-зәңгәр һ.б. төсләр б-н баета (к. *Каюлы күн*).



В.К. Гайнетдинов.




И.Г. Гайнетдинов.

Казанда узган 1 нче республика гамәли бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә (1983), Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган татар гамәли бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә (Казан, 1986), «Зур Идел» (1985, 1991) төбәк күргәзмәләрендә, С.Кузьминых һәм С.Гарбузова б-н уртак күргәзмәдә (Ленинград, 1990), халык сәнгати һөнәрләре һәм гамәли бизәлеш сәнгате эшләнмәләренең респ-ка күргәзмә-конкурсларында (Казан, 2001–02, 2002 дә — 2 нче бүләк) катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, «Туран» фондында саклана.


*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х гг.). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*


**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Исмәгыйль Гали улы (10.2.1908, Казан губ., Казан өязе Олы Мәңгәр а. — 21.10.1977, Мәскәү, Казанда җирләнгән), тәүге татар проф. архитекторларының берсе, рәссам, педагог, проф. (1967), ТАССРның (1945), Төньяк Осетия АССРның (1955) һәм БАССРның (1967) атказ. сәнгать эшлеклесе. 1931 елда Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый һәм шунда укыта, бер үк вакытта Казандагы төзелешләрдә прораб булып эшли. 1934 тән Казан шәһәр башкарма ком-тының проектлау остаханәсендә архитектор, 1933–36 да СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлегендә җаваплы сәркәтип була, 1936 дан СССР Архит-ра академиясе аспирантурасында укый, 1939 дан СССР Архит-ра академиясенең Шәһәр төзелеше ин-тында фәнни хезмәткәр, 1949 дан — Мәскәү архит-ра ин-ты укытучысы. Г. — Казан химия-технол. ун-тының «А» уку корпусы (1936, Г.С.Гурьев-Гуревич б-н бергәләп), Татар академия опера һәм балет театры (1933–56, Н.А.Скворцов б-н бергәләп), Мәскәүдә Бөтенсоюз а.-х. күргәзмәсенең ТАССР павильоны (1939, А.П.Ершов б-н бергәләп), Н.И.Столяров (1950, сынчы В.И.Мухина), Орджоникидзе шәһәрендә К.Хетагуров (1956, сынчы С.Д.Тавасиев), Уфада С.Юлаев (1967, сынчы С.Д.Тавасиев) һәйкәлләре, Казан елга вокзалы (1962, М.Константинов б-н бергәләп) һ.б.ның проектлары авторы. Г.ның «Кы-







И.Х. Г а й н е т д и н о в. Каюлы күн. 1. Дивар панносы; 2. Диван мендәрләре; 3. Хатын-кыз читекләре.



М.Г. Гайнетдинов.

рым» (1938), «Урта Азия» (1941–45), «Европа тирәли» (1959) дигән тематик серияләргә кергән акварель һәм графика әсәрләре күргәзмәсе СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлекчәсендә күрсәтелә (1972, Казан). Г. Казан төзелеш инженерлары ин-тында 1966 елда архит-ра ф-тын оештыруга һәм Татарстанның үз архитекторларын әзерләү эшенә зур өлеш кертә. Хезмәтләре татар халык төзелеш сәнгатенә карый.





И.Г. Гайнетдинов. 1. Татар опера һәм балет театры. 1933–56 (Н.А.Скворцов б-н бергәләп); 2. Казан технол. ун-тының «А» уку корпусы. 1936 (Г.С.Гурьев-Гуревич б-н бергәләп).

Хезм.: Национальные черты жилища казанских татар // Архитектурное наследство. 1975. № 23; Народные традиции в планировке селений казанских татар // Архитектурное наследство. 1978. № 26.

*Т.Р.Закирова.*

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Марат Лотфулла улы (13.12.1939, Чүпрәле р-ны Иске Шәйморза а.), педагог, пед. фән. канд. (1998), РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1988). 1963 елда Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1968 гә кадәр Питрәч р-нының Шәле урта мәктәбендә: укытучы, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары. 1968–82 дә ТАССР Мәгариф министрлыгында: инспектор, мәктәпләр бүлеге башлыгы. 1982 дән Казан пед. көллияте директоры, бер үк вакытта ТР Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-ты доценты (2001). Тикшеренүләре укучыларның укуын оештыру өлкәсенә карый. Дидактика һәм Татарстанда һөнәри белем бирү турында методик хезмәтләр, ш.у. яңача укыту стандартлары эшкәртмәләре, РФ һәм ТР махсус урта пед. уку йортлары өчен укыту планнары, программалар авторы. ТР махсус урта пед. уку йортлары директорлары советы рәисе (1989). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2000).

Хезм.: Курс лекций по педагогике. К., 1996; Нравственные корни народной педагогики. К., 2000.

*Әд.:* Нурмухамедов Ф. Верный традициям татарского просветительства // Татарстан. 2001. № 11.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Марат Хәмит улы (1.11.1947, Ташкент), биохимик, биол. фән. д-ры (1983), проф. (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1974–84 елларда Биохимия ин-тында эшли, 1985–93 тә Үзбәкстан Респ-касы ФАнең Физиология һәм биофизика ин-тында (Ташкент ш.) лаб. мөдире. 1994 тән ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-тында эксперименталь экология бүлеге мөдире. Хезмәтләре экологик физиологиягә, биол. системалар б-н идарә итү механизмнарына карый. Инсулинның бавыр күзәнәкләре метаболизмына тәэсиренең күзәнәк эчендәге арадашчысы булып торучы цитоплазматик гликопептид булуын ача. Суда яшәүче умырткасызларның темп-ра стрессы шартларында һәлакәтен феромоннар һәм әйләнә-тирә мохиттәге башка химик сигналлар б-н көйләнүче процесс икәнлеген эксперименталь исбатлый. «Митохондрияләрнең энергетик реакцияләрен физиологик җайга салу» («Физиологическая регуляция энергетических реакций митохондрий», Таш., 1980) дигән монографиясе өчен Үзбәкстан ССРның фән һәм техника өлкәсендәге Бируни исем. Дәүләт бүләге бирелә (1984).

Хезм.: Циклические нуклеотиды и гормональная регуляция метаболизма. Таш., 1986.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Махметин (Дмитрий) Галентин улы (17.8.1921, Свердловск өлкәсе Григорьевка а. — 7.5.1993, Төмән ш.). Сов. Союзы Герое (30.10.1943), старшина. Харьков хәрби-сәяси уч-щесен (1945), Мәскәүдәге В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академиянең ике курсын (1950), Харьков ун-тын (1958) тәмамлый. 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 43 нче укчы полкның (65 нче армиянең 106 нчы укчы дивизиясе) элемтә ротасында взвод командиры. Дон, Үзәк, Белоруссия, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск (1943) сугышларында, Чернигов–Припять, Гомель–Речица, Калинковичи–Мозырь, Белоруссия, Млавск–Эльбинг, Көнчыгыш Пруссия, Көнчыгыш Померания һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (1944–45) катнаша. 1943 нең 15 октябрендә Лоев торак пункты янында (Гомель өлкәсе, Белоруссия ССР) Днепрны кичкәндә батырлык күрсәтә: дошман уты астында елга аркылы телефон кабеле сузып, полк штабы б-н роталар арасында элемтә урнаштыра. 1953 елга кадәр Совет Армиясендә, соңрак Краснотурбинск, Качканар (Свердловск өлкәсе) һәм Төмән шәһәрләрендә эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Золотые Звёзды свердловчан. Свердловск, 1970; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Мәсгуд Вәлиәхмәт улы (25.5.1929, хәзерге Ульянов өлкәсенең Яңа Малыклы р-ны Лабит а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2000). Мәләкәс шәһәрендә Укытучылар ин-тын тәмамлый (1950). 1968 елга кадәр Үзбәкстан ССРның Яңа Юл р-ны урта мәктәпләрендә укыта. 1968 дән СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1996–2003 тә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. К.Насыйринең сайланма әсәрләрен (1957), Г.Ибраһимов әсәрләрен (Т. 1–8, 1974–87), Х.Туфан сайланма әсәрләрен (Т. 1–2, 1974–75) текстологик яктан әзерләүдә, «Татар поэзиясе антологиясе»н (Т. 1–2, 1992) төзүдә катнаша, Х.Туфан иҗатын тирәнтен өйрәнә. Хезмәтләре 19–20 йөз татар әдәбияты тарихына, совет чоры поэзиясенә, татар әдәбияты текстологиясенә карый.

Хезм.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2 (автордаш); Давылларда-җилләрдә. К., 1989; Хакыйкать юлыннан. К., 2001.

*Әд.:* Исламов Р. Бәрәкәтле хәрәкәт // Мәдәни җомга. 1999. 21 май.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Мисбах Фәхри улы (8.5.1925, БАССРның Чишмә р-ны Бишказы а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1980), проф. (1981). 1953 елда Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый. 1957–64 тә Свердловск һәм Рязань а.х. ин-тларында эшли, 1965–71 дә а.х.н матди-техник тәэмин итү буенча Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире. 1972–95 тә Рязань а.х. белгечләренең квалификациясен күтәрү ин-тында базар мөнәсәбәтләре каф. мөдире. Хезмәтләре а.х.нда азык сәнәгате калдыкларын файдалануга, агросәнәгать комплексын матди-техник тәэмин итүне оештыруга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Рафаил Шакир улы (1.12.1929, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1978), проф. (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Пермь шәһәрендә Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1959 елдан Казан технол. ун-тында (бүленеп, 1966–73 тә Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, сектор җитәкчесе, лаб. мөдире), 1979–94 тә химик процесслар физикасы һәм механикасы каф. мөдире. Хезмәтләре күпшәле һәм ракета системаларының эчке баллистикасына, яну һәм шартлау физикасына, җылы үткәрүчәнлек теориясе һәм югары энергетикалы системаларның куркынычсызлыгы технологиясенә карый. Г. эчке камера процессларын тикшерә, эчке баллистиканың төп мәсьәләсенә яңа тео-

ретик чишелеш таба. Аның шартлаткычлар җитештерүнең куркынычсызлыгы технологиясе, яну һәм шартлау физикасы буенча тикшеренү нәтиҗәләре җитештерүгә кертелә. 250 дән артык хезмәт авторы, уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Энергетические и баллистические свойства порохов и твёрдых ракетных топлив. К., 1995 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Ренат Хәмит улы (7.3.1950, Ташкент), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1998). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1995 тән оптика һәм спектроскопия каф. профессоры. Хезмәтләре квант системалары теориясенә карый. Квант теориясендә вакыт эчендә локаль тәэсир итешмәгән квант системаларының вакыт буенча эволюциясен тасвирлау очраклары өчен квант динамикасын гомумиләштерү ысулын үстерә. Шул ысул кысаларында спектр сызыкларын табигый киңәйтү теориясен төзи. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2006). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Естественное уширение спектральных линий многозарядных ионов и проблема поверхностных расходимостей // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1995. Т. 108; The decay and energy distributiun of unstable bound states // Journal of Physics. A: Math. Gen. 1989. V. 22. № 2; Nonlocal interactions and quantum dynamics // Journal of Physics. A: Math. Gen. 1999. V. 32; Current Topics in Quantum Field Theory Research. N. V. 2008 (автордаш).

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Рифгат Сәлах улы (5.11.1933, Казан), нефтьче, Ленин премиясе лауреаты (1976), техник фән. канд. (1987). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1957). 1957–60 елларда компрессорлар проектлаштыру буенча махсус КБда (Казан) эшли. 1960–66 да «Татнефтегазразведка» трестында баш механик, 1966–93 тә ТатНИИнефтемашта бүлек мөдире. Аның турыдан-туры катнашуы б-н промысел шартларына җайлаштырылган газ, ш.у. нефть табу һәм әзерләү өчен 35 ләп төрдәге технологик җиһазлар эшкәртелә һәм серияле җитештерүгә кертелә. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Ленин премиясе нефть чыгару сәнәгатен яңа фәнни-техник чаралар һәм комплекслы автоматлаштыру нигезендә җиһазлаганы өчен бирелә.

Х е з м.: Интенсификация теплообмена применительно к аппаратам нефтегазосбора и подготовки нефти. М., 1981; Воздействие колебаний на теплообмен в аппаратах нефтегазосбора и подготовки нефти. М., 1982.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Усман (Госман) Гайнетдин улы (29.4.1917, хәзерге Чистай р-ны Татар Талкышы а.), хәрби фән. д-ры (1965), проф. (1969), 1 нче ранг капитан. Югары хәрби диңгез уч-щесен (1940, Ленинград), К.Е.Ворошилов исем. Хәрби диңгез академиясен (1953, Ленинград) тәмамлый. 1936 елдан СССР Хәрби диңгез флотында. Бөек Ватан сугышында су асты көймәсе штурманы, командиры. 1955–93 тә Н.Г.Кузнецов исем. Хәрби диңгез академиясендә укыта, су асты көймәләре тактикасы каф. башлыгы урынбасары, проф. (Ленинград). Хезмәтләре һәм дәреслекләре СССР Хәрби диңгез флоты су асты көймәләре тактикасы, флотта оператив осталык мәсьәләләренә карый. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Тактика подводных лодок: Учеб. Л., 1960; Тактика подводных лодок с крылатыми ракетами. М., 1965; Курс тактики подводных лодок. Л. 1971.

**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Хәйдәр Гайфетдин улы (27.11.1952, Зәй р-ны Дүрт Мунча а. — 23.7.2000, Казан, Дүрт Мунча авылында җирләнә), язучы. Казан ун-тын (1976) һәм Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1989). 1976–87 елларда «Ялкын» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, өлкән мөхәррир, бүлек мөхәррире, җаваплы сәркәтип булып эшли. 1989–91 дә «Яшь ленинчы» (1990 нан — «Сабантуй») г-тасында бүлек мөдире. 1991 дән «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә өлкән мөхәррир, тапшырулар алып баручы. Әсәрләре 1970 елларда басыла башлый. Шигырьләре һәм поэмалары «Ут теле» (1982), «Солдат абый» (1988) җыентыкларында тупланган. «Яшел алма» (1987), «Су кызы» (1990) повестьларында заман кешесенең әхлакый йөзе чагылыш таба. Публицистик мәкаләләр авторы.

*Әд.:* К а м а л о в Б. Имтихан тапшырганда // Татарстан яшьләре. 1982. 2 окт.; М и н г а л и м Р. Көтелгән кешеләр килә // Социалистик Татарстан. 1982. 11 июль.


**ГАЙНЕТДИ́НОВ** Хәлил Латыйп улы (1.6.1947, Томск өлкәсе, Зырянов р-ны Тукай а.), биофизик, биол. фән. д-ры (1994), проф. (2006). 1971 елда Новосибирск ун-тын тәмамлаганнан соң, Новосибирск мед. ин-тында, 1974–89 да СССР ФАнең Себер бүлеге Автоматика һәм электрометрия ин-тында (Новосибирск ш.) эшли. 1989 дан РФА КҮНең Физика-техника ин-тында: әйдәп баручы фәнни хезмәткәр һәм гыйльми секретарь (1995–2000), биофизика лаб-ясе мөдире (2001 дән). Бер үк вакытта Казан пед. ун-тының анатомия, физиология һәм кеше сәламәтлеген саклау каф. профессоры. Хезмәтләре укыту һәм хәтер механизмнарын өйрәнүгә һәм нейроиммунологиягә карый. Озак вакытка исәпләнгән модификацияләрдә, аерым алганда, шартлы саклану рефлекслары барлыкка килгәндә, хайваннарның үз-үзләрен тотышында нейрон челтәрендәге команда элементлары мембранасының электрик сыйфатламалары үзгәрешенең әһәмиятен күрсәтә. М.Б.Штарк һәм В.И.Хиченко б-н берлектә, трансмембрана потенциалы б-н нерв күзәнәге өслегеннән үтә торган антиген-антитәнчекнең үзара тәэсир итешү реакциясен җайга салу закончалыгын ача. Макромолекулалар биофизикасы (1999) һәм биологик системалар эшчәнлегенең молекуляр нигезләре (2002) буенча югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Исследование эффектов антител к белку S-100 на ионные каналы входящего и выходящего токов идентифицированных нейронов улитки Helix lucorm // Журн. эволюционной биохимии и физиологии. 2006. Т. 42, № 3 (автордаш); Электрофизиологические исследования эффектов хронического введения кофеина на формирование условного оборонительного рефлекса у виноградной улитки // Журн. высшей нервной деятельности. 2008. Т. 58, № 2 (автордаш); Reconsolidation of a context long-term memory in the terrestrial snail reguires protein synthesis // Learning and Memory. 2005. V. 12, № 6 (автордаш).

**ГАЙНУЛЛА́ ХӘЙРУЛЛА́** угылы (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче яртысы), ташка уеп язучы, хаттат. Аның тарафыннан турыпочмаклы известьташка уеп эшләнгән кабер ташлары Әлмәт р-ны Гөлбакча авылы зиратында сакланган. Алар үлчәмнәренең зур булмавы б-н аерылып тора (55×21×14 *см*), өске өлешләре традицион кабер ташларына хас рәвештә түгәрәкләнмәгән. Истәлек язуы ташның алгы ягына гарәп язуының тәгъликъ» стилендә тирән уеп кисү техникасында башкарылган. Текстта традицион Коръән гыйбарәләре бар; даталарны күрсәткәндә рим һәм гарәп цифрлары кулланылган. Язулар бизәкләр б-н нәкышьләнмәгән. Ташларда оста үз имзасын «Язучы — Хәйрулла угылы Гайнулла» дип уеп язган.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*



К.Г. Гайнуллин.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Камил Гайфулла улы (19.3.1946, Казан), балет артисты, ТАССРның халык артисты (1978), РСФСРның атказ. артисты (1982). Ленинград хореография уч-щесен (1965), Казан ун-тының юридик ф-тын (1973) тәмамлый. 1965–87 елларда Татар опера һәм балет театры солисты, 1987–88 дә Казан музыка уч-щесе хореография бүлеге мөдире, ТР Музыка җәмгыяте рәисе урынбасары (1988–97), рәисе (1997–98). Хореографик партияләре арасында Альберт («Жизель, »А.Адан), Базиль, Солор («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Зигфрид, Дезире, Принц («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Щелкунчик», П.Чайковский), Ромео, Принц («Ромео һәм Джульетта», «Золушка», С.Прокофьев), Габдрахман («Раймонда», А.Глазунов), Хозе («Кармен-сюита», Ж.Бизе-Р.Щедрин), Байтимер («Әсәл», В.Власов), Штраус («Вена урманы әкиятләре», И.Штраус) һ.б. бар. Ачык чагылышлы актёрлык сәләте, ялгыз бию буенча көчле техникасы һәм парлы бию остасы булуы б-н аерылып тора.


*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*В.Н.Горшков.*

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Мидхәт Фазлый улы (13.11.1925, БРның Бүздәк р-ны Кече Үсту-



Н.С.Гайнуллин.



Р.Х.Гайнуллин.

бә а. — 15.3.2001, Мәскәү, Уфада җирләнгән), әдәбият галиме, публицист, филол. фән. д-ры (1975), проф. (1977), БАССРның, РСФСРның атказ. фән. эшлексесе (1977, 1985). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1954 елдан СССР ФА Башкортстан филиалының Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында, 1958 дән КПССның Башкорстан өлкә комитетында фән, мәдәният һәм мәктәпләр бүлеге мөдире, 1961 дән Башкорт ун-тында (1961–89 да уку-укыту буенча проректор, 1989–93 тә журналистика каф. мөдире). Хезмәтләре башкорт һәм татар драматургиясе тарихына, С.Мифтахов, М.Гафури, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, А.Таһиров, М.Сөндекле, М.Җәлил, Н.Әсәнбаев, Ә.Атнабаев h.б. язучылар иҗатларына карый. Рус телендә «Писатели Советской Башкирии» (1967), башкорт телендә «Совет Башҡортстаны языусылары» (1969) биобиблиографик сүзлекләрен (Г.Хөсәенов б-н автордаш), «Башҡорт драматургияһы антологияһы»н (1984, И.Бүләков б-н автордаш) төзүче. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ысынбарлык. Конфликт. Характер. Өфө, 1974; Башҡорт совет драматургияһының үҫеш юлдары. Өфө, 1985.

*Әд.:* Ғ ә й н у л л и н М., Х ө с ә й е н е в Г. Совет Башҡортстаны языусылары: Биобиблиогр. белешмә. Өфө, 1988; Мидхат Гайнуллин: Библиогр. указ. Уфа, 1985.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Мөхәммәт Хәйрулла улы (18.8.1903, Тәтеш өязе Коллар а., хәзерге Апас р-ны Кызыл Тау а. — 24.5.1985, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1958), проф. (1967), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1963, 1973). Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук эшли. 1943–44 елларда Татарстан дәүләт нәшрияты управляющие, 1944 тән СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1944–53, 1959–61 дә директор). Г.Тукай, К.Насыйри, Ш.Камал иҗатларына багышланган беренче мәкаләләре 1930 елларда басыла. 1950–60 еллардагы хезмәтләрендә З.Һади, З.Бигиев, М.Акъегетзадә, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Мөхәммәдев иҗатларын анализлый. 20 йөз башы татар публицистикасын өйрәнә. Г. — беренче татар хатын-кыз язучыларының (Г.Сәмитова, Маһруй Мозаффария, З.Сәгыйдә, Гыйффәт Туташ, М.Акчурина) әсәрләрен туплаган «Өмет йолдызлары» (1988) исемле җыентыкны төзүче һәм кереш сүз авторы. Төп хезмәтләре 19 йөз — 20 йөз башы татар әдәбияты тарихына, иҗтимагый фикер һәм матбугат тарихына карый. Урта мәктәпләр, югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы.

Х е з м.: Татар әдәбияты. XX йөз.: 2 кис. К., 1947; Татар әдипләре. К., 1978; Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1985 (автордаш); Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1966; Татарская литература XIX века. К., 1975.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Мөхәммәт Гайнуллин (1903–1985) // Казан утлары. 1993. № 8; Мөхәммәт Гайнуллин — олуг галим һәм язучы. К., 2003.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Мөхәммәтвафа (1862, Казан губ., Казан өязе Битаман-Ювас а. — 1917 дән соң), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Казан сәүдәгәрлегенә 1897 елда языла. Мануфактура һәм тимер-томыр б-н сату итә, Печән базарында өч кибет тота (еллык акча әйләнеше 1 млн. сум тәшкил иткән). Казан шәһәр думасы гласные булып сайлана. 1907–12 дә *«Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте»*нең идарә әгъзасы, 1 нче шәһәр рус-татар уч-щесенең тышкы идарәчесе. Казан өязе Суыксу авылы мәчете төзелешенә акчалата ярдәм күрсәтә (1906).

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Нәҗип Сәмигулла улы (2.5.1912, Оренбург губ., Троицк ш. — 14.7.1969, Казан), драма актёры, ТАССРның халык (1950), РСФСРның атказ. артисты (1957). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1936). 1936 елдан Татар акад. театрында актёр, 1957–63 тә директор һәм сәнгать җитәкчесе. Үзен киң иҗат диапазонлы зур талант иясе буларак таныта, психологик пландагы рольләрне дә, ш.у. ачык гротесклы (көлкеле) рольләрне дә бертигез дәрәҗәдә уңышлы иҗат итә. Камал («Тукай», Ә.Фәйзи), Насыйри (шул исемдәге пьеса, М.Гали һәм Х.Уразиков), Уразмәтов («Хәерле юл», Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романы буенча), Шмага («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Хәйрүш («Шамил Усманов», А.Гыйләҗев, А.Яхин) образларын тормышчан, ышандырырлык итеп башкара. Н.Ф.Погодинның «Мылтыклы кеше» спектаклендә Ленин образын тудырганда, ул аеруча зур җаваплылык хисе тоеп эшли. Комик, сатирик образлар өстендә эшләгәндә исә (Городничий — «Ревизор», Н.В.Гоголь; Җиһанша — «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин; Җиһангир — «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт; Хәмзә — «Беренче театр», Г.Камал) фарс алымнарын киң куллана, ш.у. вакытта ышандырырлык һәм табигый булып кала. Г.ның сәнгать җитәкчесе сыйфатындагы эшчәнлеге театрда Х.Вахит, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Ю.Әминев кебек драматургларның әсәрләре куелуы б-н бәйле. 1952–62 елларда Г. Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеген җитәкли.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И. Артисты театра им. Г.Камала. К., 1996.

*И.И.Илялова.*

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Рифгат Хәйрулла улы (11.1.1924, Алабуга кантоны Баржы Умга а.), Дан орденының тулы кавалеры (14.3.1944, 12.8.1944, 10.11.1970). Сугышка кадәр туган авылында элемтә бүлеге мөдире булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 60 нчы армиянең разведка бүлеге разведка ротасы укчы-разведчигы. Үзәк, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украина, Польша, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1943 нең ноябрь-декабрендә Коростышево һәм Радомышль торак пунктлары (Украина ССРның Житомир өлкәсе) янында барган бәрелешләрдә дошманның яшерен мәгълүматын кулга төшерә; 1944 нең 1–16 июлендә Дембица тимер юл үзәге (Краков шәһәреннән 140 *км* көнчыгыштарак, Польша) янында һәм 1945 нең 20 февралендә Ротбор шәһәре (Рацибуж, Польша) янында барган бәрелешләрдә батырлык күрсәтә. 1947 дән запаста. Алабуга пед. ин-тында өлкән укытучы булып эшли. 1989 дан Түбән Кама шәһәрендә яши. «Татарстан геройлары» җәмәгать оешмасы әгъзасы. Мәскәүдә Җиңү Парадларында (1985, 1990, 1995) катнаша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Хасият Зәйнулла улы (1890, Казан губ., Зөя өязе Танай а. — 1953), сәясәт эшлеклесе, журналист. Казан югары партия мәктәбендә укый (1921–22). 1907–17 елларда бертуган Кәримовларның Казандагы сәүдә фирмасында йомышчы, хисапчы. «Аваз» г-тасын оештыручыларның берсе. Казанда 1917 елгы Окт. коралллы күтәрелешендә катнаша. 1917 дә Мөселман социалистлары ком-ты әгъзасы, Татар-Башкорт Совет Соц. Респ-касы проектын эшләүдә катнаша. 1919 да Төньяк өлкә милләтләр эшләре комис-тының мөселман бүлеге мөдире, «Кызыл Шималь», «Коммунизм байрагы» г-талары мөхәррире. 1920–21 дә ТАССР ҮБК Президиумында, 1928–38 дә Революция көрәшчеләренә халыкара ярдәм оешмасының Татарстан бүлекчәсендә 1 нче секретарь. Күмәкләштерү елларында ТАССРда артельләр оештыруда катнаша. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М у л ю к о в М., Ш а ф и г у л л и н З. Гайнуллин Хасият Зайнуллович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ГАЙНУ́ЛЛИН** Хәлим Габдулла улы (1.1.1951, Апас р-ны Кызыл Тау а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Казан ун-тын (1973) һәм Ленинград югары партия мәктәбен (1984) тәмамлый. 1975–82 елларда «Социалистик Татарстан» г-тасы редакциясендә эшли, 1985–90 да «Татарстан яшьләре» г-тасының баш мөхәррире. «Шәһри Казан» г-тасының беренче баш мөхәррире (1990–96). 1996 дан ТР мәгълүмат һәм матбугат министры урынбасары. 2000 нән «Мәгариф» нәшрияты директоры урынбасары, 2002 дән «Хокук һәм хәят» — «Пра-

во и жизнь» ж-лы баш мөхәррире. Мәкаләләре «Мәдәни җомга» г-тасында, «Казан утлары» ж-лында һ.б. басмаларда чыга. Язмалары ТРда социаль-икътисади һәм сәяси реформаларның барышы, татар тарихы, милли мәдәнинят үсеше проблемаларына карый. Төп жанрлары — мәкаләләр, документаль очерклар, интервьюлар. Татарстан Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1986). 1985 тән ТАССР Журналистлар берлеге президиумы әгъзасы.

Ә с ә р.: Күңелдән китми батырлар. К., 1975 (автордаш); Ачык дәрес. К., 1980; Кешеләргә барам. К., 1998; Апасым — гомер бишегем. К., 2000; Гомер чакрымнары. К., 2003; Язмыш тукталышы. К., 2004.

*Г.Р.Заманова.*

**ГАЙНУ́ЛЛИНА** Алсу Әскар кызы (24.2.1954, Чүпрәле р-ны Иске Чүпрәле а.), драма актрисасы, ТАССР һәм РФнең халык артисты (1986, 1996). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1974, М.Х.Сәлимҗанов остаханәсе), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Киң иҗат диапазонлы, драматик, үткен характерлы рольләрне дә, ш.у. көлкеле, сатирик рольләрне дә бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкара; эшли башлавының беренче елларыннан ук Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов, 1978) һәм Сәрби («Качаклар», Н.Исәнбәт, 1980) кебек бер-беренә охшамаган, капма-каршы характердагы зур образлар тудырып, театрда әйдәп баручы актрисалар рәтенә баса. Сөйләм интонацияләренең байлыгы, төсмерләр төрлелеге, уйнавының психол. нечкәлеге актрисага көләч, шаян, хәйләкәр Мөршидә («Казан сөлгесе», К.Тинчурин, 1981) һәм юаш, якты күңелле, газаплануның бөтен тирәнлеген кичергән Сәрвәр («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин, 1982) образларын зур осталык б-н башкару мөмкинлеге бирә. А.Н.Островскийның «Бирнәсез кыз» (1983) пьесасы буенча куелган спектакльдәге Лариса образы Татарстан театр сәнгатендә зур вакыйга буларак кабул ителә. Героиня б-н социаль тирәлек арасындагы драматик конф-



А.Ә.Г а й н у л л и н а Шәфәкъ ролендә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим).

ликтны актриса үз эченә бикләнү, тормыштан тую, читләшү аркылы чагылдыра. Азатлыкка омтылуы, обывательләр һәм икейөзлеләрнең тынчу, черек дөньясыннан котылырга тәвәккәлләве образның лейтмотивы булып тора. Шәмсегаян образында («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев, 1987) үз героинясының бәхетле, яшь, гашыйк авыл кызыннан вакытсыз картайган, авылын, туганнарын сагынудан саргаеп үлеп баручы хатынга әверелү юлын эзлекле рәвештә үстерә барып, туган җиренә хыянәт иткән кешенең үз гаебен тану фаҗигасен актриса ышандырырлык итеп ачып бирә. Г. башкаруында Зөләйха образы («Яра», А.Гыйләҗев) тирән психологизм б-н бирелгән. Гайни («Бәхетсез егет», Г.Камал), Валентина, Нина («Бишек җыры», «Илгизәр + Вера», Т.Миңнуллин), Җаникәй («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Ренева («Җимерелгән бәхет», А.Н.Островский) образлары социаль-психол. үзенчәлекләрнең кискенлеге б-н аерылып торалар. Тышкы буяуларның саранлыгына, тыйнаклыгына карамастан, актрисаның уены темпераменты, дәрте б-н җәлеп итә, бу сыйфат классик репертуардан Катарина, Клеопатра («Тискәрегә авызлык», 1986; «Антоний һәм Клеопатра», 1989, У.Шекспир) образларында бигрәк тә ачык чагыла. Э. де Филиппоның «Гауғалы гаилә» пьесасы буенча спектакльдәге (2000) Роза образы актрисаның күпкырлы сәләтен тулысынча үзенә җыйган характерның асылын ачып салуы б-н әһәмиятле; Г.Хугаев пьесасы буенча эшләнгән «Кара чикмән» мюзиклында пластик тәэсирле Буретта образын тудыра; аның бу образда персонажның лирик, драматик һәм комик якларын виртуоз рәвештә һәм ышандырырлык итеп күрсәтә белүе игътибарга лаек. Тирән тормыш дөреслегенә һәм ачык сәхнә формасына ия буларак, Г. татар театр культурасы үсешенә зур өлеш кертә. РСФСРның К.С.Станиславский исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Медаль б-н бүләкләнә.



А.А.Гайнуллина.

*Әд.:* И л я л о в а И. Артисты театра им. Г.Камала. К., 1996.

*И.И.Илялова.*

**ГАЙНУ́ЛЛИНА** Мөнирә Кәбир кызы (1.7.1965, Казахстан ССРның Чимкент ш.), а.х. терлекләрен тукландыру буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (2007), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). 1988 елда Казан вет. ин-тының (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) зооинженерлар ф-тын тәмамлый. 1988–2000 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: терлек азыгы җитештерү һәм аны файдалану лаб-ясендә зоотехник, фәнни хезмәткәр, өлкән фәнни хезмәткәр. 2000–2007 дә Фәнни җитештерү вет. лаб-ясендә фәнни-тикшеренү һәм эшкәртмә-тикшеренүләрне гамәлгә кертү лаб-ясе мөдире. 2007 дән Казан вет. медицинасы академиясендә продукция җитештерү һәм яңадан эшкәртү каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре табигый минераль сорбентлар кулланып, терлекчелектә экологик чиста продукцияне ресурс саклау технологияләр буенча җитештерүгә карый. 2 патенты, 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында агроминераль чимал файдалану юлы белән ресурслар саклаучы технологияләрне Буа районы авыл хуҗалыгы производствосына кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Корма Республики Татарстан: состав, питательность и использование: справ. К., 1999 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002 (автордаш). Перспективы использования природных сорбентов РТ в животноводстве // Агроэкологические проблемы с. х. производства в условиях техногенного загрязнения агроэкосистем: Сб. докладов Всерос. науч.-практич. конф., посв. 10-летию АН РТ. К., 2002. Ч. 2.

*Әд.:* Я к и м о в А.В. Научно-исследовательский центр кормовых добавок: вчера, сегодня, завтра // Элита животноводства. 2005. № 6.

**ГАЙНУ́ЛЛИНА** Фәридә Исмәгыйль кызы (28.3.1947, Казан), профсоюз эшлеклесе, сәясәт фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1970). 1970–83 елларда Казан электрон хисаплау машиналары з-дында эшли. 1983–86 да КПССның Казан шәһәре Совет райкомы секретаре. 1986 дан Профсоюзларның Татарстан респ-ка советы секретаре, 1990 нан рәисе, 1995–2000 дә ТРның Профсоюзлар фе-





А.Ә.Г а й н у л л и н а: Лариса («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский); Ренева («Җимерелгән бәхет», А.Н.Островский) рольләрендә.

дерациясе рәисе. 2000 нән РФ Дәүләт Думасы депутаты, Дәүләт Думасының Хезмәт һәм социаль сәясәт буенча ком-ты рәисе урынбасары. Хезмәтләре профсоюзларның дәүләт хакимияте органнары б-н хезмәттәшлек итүенә, ТРда социаль партнёрлык системасы барлыкка килү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Профсоюзы и государство в эпоху общественных перемен.К., 1996; Парламентская и внепарламентская деятельность профсоюзов. М., 1997; Становление системы социального партнёрства в РТ. М., 1998; Политические аспекты социального партнёрства. М., 2000.

**«ГАЙРӘ́Т»** нәшрияты, Әстерхан шәһәрендә. 1905–07 елгы рев-циядән соң ачыла. 1910 елларга кадәр эшли. Татар мәдәнияте эшлеклеләре һәм әзәрбайҗан мәгърифәтчеләре тарафыннан оештырыла. «Г.». басмалары татар, әзәрбайҗан, казакъ һ.б. төрки телле халыклар арасында мәгърифәтчелек эшен камилләштерүгә булышлык итә. Шулай ук Көнчыгыш мөселман илләре наширләренең заказларын үти. «Г.» нәшрияты китаплары *Гомәров Г.И. басмаханәсендә* басыла.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**ГАЙСА́РОВ** Әхмәт Җиһанша улы (20.11.1906, Казан губ., Зөя өязе Олы Кайбыч а. — ?), Бөек Ватан сугышы чорында Белоруссиядә (Барановичи өлкәсе) партизаннар хәрәкәте җитәкчеләренең берсе. Казан коммунистлар ун-тын тәмамлый (1932). 1939–40 елларда совет-фин сугышында, 1941 дә Белосток шәһәрен немец гаскәрләре һөҗүменнән саклауда катнаша. 1943 нең мартыннан партизаннар сафында: рядовой, взвод командиры, отряд комиссары. 1943 нең октябреннән 1944 нең июленә кадәр Г.К.Жуков исем. партизаннар бригадасы комиссары, бер үк вакытта 1943 нең декабреннән Белоруссия Коммунистлар партиясенең Столбцов ашерен район ком-ты 2 нче секретаре. 1944–77 дә Белоруссия ССРның Барановичи һәм Гродно өлкәләрендә партия һәм хакимият-хуҗалык эшендә.

*Әд.:* Белорусская ССР. Краткая энцикл. Минск, 1982. Т. 5.

**ГАЙСӘ́**, Коръән персонажы, Мөхәммәд пәйгамбәрдән алдарак килгән һәм исламда аеруча хөрмәт ителә торган пәйгамбәр; христианнарда — Иисус Христос. Коръәндә ул мессия, Мәрьям Ананың улы, Алла колы, аның рәсүле (илчесе) буларак телгә алына. Г.гә *Инҗил* иңдерелә. Коръәндә Г. образы аерым урын алып тора. Ул Аллаһка якын торучылар рәтенә кертелгән, бу исә Г. табигатенең ярты-лаш илаһи булуы хакында фикер йөртергә урын бирә. Христиан дин гыйлемендә Иисус Христос хачка кадакланган килеш үлгән дип икърарланса, Коръән аның үлемен инкарь итә, ул күккә ашкан һәм Хисап көнендә Аллаһ каршында динсезләргә каршы шаһитлек итәчәк, дип раслый. Г. Аллаһ тарафыннан яратылуы б-н Адәмгә охшаш, аның Мөхәммәд пәйгамбәр б-н үзенчәлекле бәйләнеше бар: ул аның киләчәген алдан белдерә. Г. гә, соңрак Мөхәммәд пәйгамбәргә дә, гадәттә, *Җәбраил* б-н ассоциацияләшүче Изге Рух булышлык итә. Шуның б-н бергә Коръәндә Г. нең Аллаһ улы булмавы, аның Илаһ түгеллеге басым ясап әйтелә, исламда Өчлек — (Троица) идеясенең кире кагылуы очраклы түгел. Коръәндә Г. нең туу могҗизасы, аның пәйгамбәрлек вазифасы, үлеләрне терелтүе, авыруларны савыктыруы турында җентекләп сөйләнә. Аның яңадан кайтуы Хисап көненең якынлашып килүен аңлатачак, һәм Коръәннән соңгы фаразларга караганда, шушы көн алдыннан *Дәҗҗал* үзен Г. дип игълан итәчәк. Коръәндә Г. гә башка пәйгамбәрләргә караганда күбрәк игътибар бирелә, бу исә 7 йөздә Гарәбстанда христианлыкның төрле секта агымнары, апокрифик Инҗилләр б-н бәйле христиан легендаларының киң таралган булуын дәлилли. Г. кайбер мөселман агымнары вәкилләре өчен табыну объекты булып тора (мәс., Әхмәдийә тарафдарлары Г. Кәшмирдә үлгән һәм үз җәмгыятен оештыручы сыйфатында терелгән дип исәплиләр).

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГАЙСӘ́ бинѐ ГЫЙЗЗӘТУЛЛА́** (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы, Әлмәт а., хәзерге Әлмәт ш.), ташка уеп язучы, хаттат. Иҗатыннан кабер ташлары эшли. Аның иҗаты Әлмәт авылында (хәзерге Әлмәт шәһәре) башланган. «Кятиб Гайсә» дигән имзасы уелган 44×30×19 *см* үлчәмле бер кабер ташы 1997 елгы эпиграфик экспедиция әзләнүләре вакытында Әлмәтнең 2 нче зиратында табыла (кятибнең имзасы б-н, 1889 да вафат булган Мөхәммәтгариф хатыны Биби истәлегенә куелган). Әлеге таш останың исеме сакланган булуы б-н әһәмиятле. Язуы уеп кисү техникасы б-н тәгъликъ ысулында башкарылган, төп урынны Коръән гыйбарәләре алып тора. Даталар гарәп цифрлары б-н һиҗри һәм миладиел исәбендә күрсәтелгән. Бизәкләр кулланылмаган. 2006 да Гайсә останың берьюлы имзалы ике хезмәте табыла. Аларның берсендә оста атасының исемен дә атаган — «Кятибе Гайсә бине Гыйззәтулла», дип куйган. Ташъязмадагы текст сөлес стилендә, калкытып, сүзләрне, хәрефләрне оста урнаштырып, бизәкләр кулланып язылган. Ташның бер кырында үлем хакында хикмәтле әйтем һәм автограф имзасы теркәлгән. Останың Чистай зиратында мәрхүмә Бибизөһрә бине Садыйк каберенә, вафат тарихын күрсәтеп, 1911 нең 28 июлендә куелган, тәгъликъ стилендә язылган эпитафик тексты да сакланган.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«ГАЙСӘ́ УГЛЫ́ ӘМӘ́Т»**, татар тарихи дастаны. 14 йөз ахыры — 15 йөз башында иҗат ителгән дип фаразлана. Берничә тапкыр күчереп язылган булуы ихтимал; 17 йөздә *«Дәфтәре Чыңгызнамә»*гә кертелә. Төп геройлары — чын тарихи шәхесләр: Казан (Алтын Урда) ханы Җанибәк, аның хатыны Тайдула һәм аларның туганнары. Яуга чыгар алдыннан хан үзенең йөкле хатынына, малай туса, сөенче б-н хәбәрче җибәрергә, кыз туса — аны үтерергә, дип әйтеп калдыра. Тайдула Җанибәкне тыңламый: яңа туган кызын ханның олы улы *Бирдебәк* биләмәсенә яшерә. Моны белеп, хан, кызын үтертер өчен, кеше җибәрә. Тайдула да Бирдебәккә, аңа янаган куркыныч турында хәбәр итәр өчен, үзенең хәбәрчесен юллый. Хан халык алдында Бирдебәкне алып килүчегә кызын кияүгә бирергә вәгъдә итә. Бу эшкә Гайсә улы Әмәт алына. Ләкин хыянәтчел ханның кызны Менгел бай малаена да вәгъдә иткәне ачыклангач, Әмәт хан кызын урлап китә һәм Зөя тамагындагы далаларга кача. Берничә елдан аларның уллары туа. Җанибәк качакларны эзәрлекләвен дәвам итә һәм аларга каршы 300 сугышчыдан торган гаскәр җибәрә. Әмәт аларга каршы сугыша башлый. Малаен ул бишеге б-н агач ботагына элеп калдырырга мәҗбүр була. Әмәт җиңә, ләкин улы югала. Җанибәк хан үлгәннән соң, Әмәт хан варисы Бирдебәк б-н бергә дәүләт башлыгы була (ханлыкның яртысы б-н идарә итә). Әмәтнең улын сал агызучылар таба, һәм аңа Салчы исеме кушалар. Аны Алтын Урданың баласы булмаган ханы Тимер Котлыгъ уллыкка ала.

Дастанда тискәре Җанибәк хан уңай персонаж — Бирдебәк ханга каршы тора, ләкин бу тарихи дөреслеккә туры килми. Дастан мотивлары (ханның тугыз малае, яңа туган кыз баланы үтерергә боеруы, агачта бишеге б-н эленеп калган сабый бала) халык авыз иҗатының күп кенә әсәрләренә хас («Җик Мәргән» дастанының татар һәм башкорт версияләре, Алтай халыкларының «Маадай-Кара» дастаны, үзбәк халкының «Орзигөл» дастаны, хорватларның «Солтания» балладасы һ.б.). Дастан беренче тапкыр И.И.Хәлфин тарафыннан «Чыңгызхан һәм Аксак Тимер тормышыннан төрле вакыйгаларны чагылдырган, алфавит тәртибендә төзелгән төрле өзекләр» («Жизнь Чингиз-хана и Аксак-Тимура с присовокуплением разных отрывков, до истории касающихся, коих все слова для обучающихся расположены по алфавиту», 1822) китабында басыла. 2000 елда дастанның хәзерге татар теленә салынган версиясе басылып чыга.

*Әд.:* Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Дәфтәре Чыңгызнамә. К., 2000; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; У р м а н ч е е в Ф.И. Дастан об Амате // Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГА́ЙСИН** Азат Фивзәт улы (4.5.1975, Казан), физик, техник фән. д-ры (2008). 1998 елда Казан техник ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2009 дан техник физика каф. профессоры. Хезмәтләре плазма физикасына карый. Беренче тапкыр сыек анодлы күп каналлы бушануны тикшерә. Металлар һәм аларның эретмәләрен чистарту һәм шомарту, аларны производствода эшкәртү җайланмаларын эшли. Металларны тузан бөртегенә әйләндерү һәм порошок алу алымын тәкъдим итә. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Струйный многоканальный разряд с электролитическими электродами в процессах обработки твёрдых тел. К., 2006 (автордаш); Нестационарный многоканальный разряд между струёй электролита и металлическим электродом при атмосферном давлении // Теплофизика высоких температур. 2006. Т. 44, № 5.

**ГА́ЙСИН** Әхмәтсафа Гайсә улы (1918, хәзерге Мари Респ-касы, Бәрәңге р-ны Портчара а. — 27.11.1943, Запорожье өлкәсе, Вольнянский р-ны Капустяный а.), Сов. Союзы

Герое (22.2.1944, вафатыннан соң), гв. кече лейтенанты. Колхозда эшли. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1943). 1938 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 185 нче гв. укчы полкның (12 нче армиянең 60 нчы гв. укчы дивизия) укчы взвод командиры. Көньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре составында Донбасс һәм Запорожье һөҗүм операцияләрендә катнаша (1943). 1943 нең 26 октябрендә Запорожье шәһәре янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: дошман траншеясына беренче булып бәреп керә, сугышта рота командирын алыштыра, дошманның 13 контрһөҗүмен кире кайтара. Шуннан соңгы сугышларның берсендә һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Ә.Г. Гайсин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 3; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГА́ЙСИН** Бәхти (Бәхтегани) Миңнияр улы (24.1.1930, БАССРның Авыргазы р-ны Кешәнне а. — 5.10.1991, Уфа), баянчы, БАССРның халык артисты (1962), РСФСРның атказ. артисты (1986). Уфа музыка уч-щесенең халык уен кораллары бүлеген тәмамлый (1953). 1953–61 елларда Башкорт драма театры концертмейстеры, 1961–90 да Башкортстан филармониясе солисты һәм концертмейстеры. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Солист буларак зур репертуар б-н чыгышлар ясый, ш.у. күренекле җырчы Ф.Кудашеваның эстрада төркеме җитәкчесе була. Популяр җырлар — «Кичегеп килгән мәхәббәт» (Г.Зәйнашева), «Ике аккош» (Ә.Баян), «Әйтсеннәр» (Ә.Атнабаев), инструменталь пьесалар, халык көйләренә эшкәртмәләр авторы.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГА́ЙСИН** Илгизәр Тимергали улы (15.7.1952, Чаллы р-ны Казаклар а.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), проф. (2001), РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1999). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), проф.-техник һәм гомуми белем бирү системасында. 1995 елдан Мәскәү коммерция ун-тының Казан ин-тында уку-укыту һәм фәнни эшләр буенча проректор. 1999 дан Казан пед. ун-тында икътисади география һәм аны укыту методикасы каф. мөдире, 2002–2008 дә география ф-ты деканы. Хезмәтләре экологик белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләренә, икътисади география фәнен укыту алымнарына карый.

Х е з м.: Эколого-нравственное воспитание учащихся. К., 1996; Преемственность экологического воспитания. К., 1999; Непрерывное экологическое образование. К., 2002; Экономико-географическая характеристика городов Республики Татарстан. К., 2006.

**ГА́ЙСИН** Илшат Әхәт улы (12.10.1939, Зәй р-ны Бигеш а.), галим-агроном, агрохимик, а.х. фән. д-ры (1989), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1966). 1969–71 елларда Казан зона агрохимия лаб-ясендә өлкән агрохимик. 1971 дән Казан а.х. академиясендә: агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире (1983 тән), агрономия ф-ты деканы (1988–93), проректор (1997–2004), агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире (2005 тән). Г. сабан бодае һәм уҗым арышы чәчүлекләрендә мочевина куллануның нәтиҗәле ысулларын эшли, микроэлементларны интенсив куллануның а.х. культураларының продуктлылыгына һәм туфракның уңдырышлылыгына тәэсирен өйрәнә, интенсив игенчелектә үсемлекләр һәм а.х. культуралары уңышының элементлар составын көйләү механизмнарын ачыклый. Республика игенчелегендә микро- һәм макроэлементларның баланс торышына бәя бирә. Бу тикшеренүләрнең нәтиҗәләре микро- һәм макроэлементлар куллану практикасын һәм теориясен комплекслы өйрәнүнең нигезендә ята һәм «Интенсив игенчелектә микро- һәм макроашламалар» («Микро- и макроудобрения в интенсивном земледелии», 1989) дигән монографиядә һәм докторлык диссертациясендә гомумиләштереп бирелә. Г. республика а.х. да киң кулланыла торган, экологик яктан нәтиҗәле микроэлементлы яңа ашламалар составын эшли һәм тәкъдим итә. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм 5 патенты бар. РФ ФАнең акад. Д.Н.Прянишников исем. (1992) һәм ТР Дәүләт бүләкләре (2000) лауреаты. Дәүләт бүләге полифункциональ, хелат микроашламаларны эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, көмеш, бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эффективность минеральных удобрений на нечернозёмных почвах Татарской АССР // Агрохимия. 1972. № 6; Удобрения и элементный состав сельскохозяйственной продукции // Актуальные проблемы развития прикладных исслед. и пути повышения их эффективности в с.-х. пр-ве. К., 2001. Агроэкологическая характеристика и приёмы рекультивации нефтезагрязнённых чернозёмов Республики Татарстан. К., 2003 (автордаш); Полифункциональные хелатные микроудобрения. К., 2007 (автордаш).

**ГА́ЙСИН** Наил Кивам улы (8.1.1935, Куйбышев өлкәсенең Шонталы р-ны Татар Әбдекие а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1996), 1958 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1961–73 тә шунда ук эшли, 1972 дән физика каф. мөдире. 1974 тән Казан технол. ун-тында, 1996 дан физика каф. профессоры. Хезмәтләре сыеклык һәм кристалларда төшнең магнит релаксациясенә карый. Иодидлар һәм литий тозларының спирттагы эремәләрендә беренчел сольватация саннарын билгели, органик сыеклыкта молекулаларның яңача юнәлеш алу һәм аларның йөреш хәрәкәте үзлекләрен билгели, гадәти спирт молекулаларының водород бәйләнешләре аша берләшү модельләрен өйрәнә, $^{13}C$ тә спин-рәшәткә релаксациясендә төрле магнитлы тәэсирләшүләрнең кросс-корреляция



Б.М. Гайсин



Р.Х. Гайсин.

эффектын ача, органик кристалларда күрше молекулаларның юнәлешләре үзара ярашып үзгәрүе дәрәҗәсен билгели, органик матдәләрнең каты катнашмаларында башлангыч эрү механизмын өйрәнә.

Х е з м.: Электрофизические процессы в разрядах с твёрдыми и жидкими электродами. Свердловск, 1989 (автордаш); Возникновение и развитие объемного разряда между твёрдым и жидким электродами // Химия плазмы. 1990. Т. 16 (автордаш); Объемный разряд в парогазовой среде между твёрдыми и жидкими электродами. М., 1990 (автордаш); Спин-решёточная релаксация $^{13}C$ и молекулярное движение в жидком толуоле // Химическая физика. 2000. Т. 19, № 9 (автордаш).

**ГА́ЙСИН** Нур (Нурулла) Әхияр улы (2.11.1914, хәзерге Башкортстан Респ-касының Чакмагыш р-ны Әхмәт а. — 1.12.1995, Казан), шагыйрь. 1936–40 елларда Казан пед. ин-тында укый. 1941 гә кадәр Ютазы р-ны мәктәпләрендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән кайткач, «Кызыл таң» (Уфа ш.) г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1946–52 дә Казан татар театр уч-щесендә директор урынбасары вазифаларын башкара. «Ватаным өчен» дип аталган беренче шигъри җыентыгы 1937 дә дөнья күрә. Башлыча яшьләргә багышланган «Тайгада очрашу» (1956), «Айлы кичтә» (1958), «Өмет тулы хыялым» (1983), «Таныш моң» (1984) исемле җыентыклар авторы.

Мәсәлләрендә һәм сатирик шигырьләрендә икейөзлелек, ялагайлык, комсызлык кебек кимчелекләр фаш ителә. 1981 елда Г. автобиографик характердагы «Кызыл ыштанлы малай» повестен бастыра. Аның әсәрләре лиризм һәм нечкә юмор б-н сугарылган. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Мәктәптә яз: Сайланма әсәрләр. К., 1974.

*Әд.:* З ә л к а р н ә е в Ф. Балачак иленнән килгән шагыйрь // Ялкын. 1984. № 11; Г а т а ш Р. Нур Гайсинга 80 яшь // Казан утлары. 1994. № 11; Г а л и е в Ш. Ике тапкыр ветеран // Ватаным Татарстан. 1994. 2 нояб.

**ГА́ЙСИН** Рәмзис Хәниф улы (11.5.1944, Шөгер, хәзерге Лениногорск р-ны Яңа Иштирәк а. — 2.5.1995, Казан), флейтачы, педагог, ТССРның халык артисты (1991). Казан консерваториясен флейта буенча (А.Геронтьев классы) тәмамлый (1968). 1966 елдан ТАССР Дәүләт оркестры артисты (1975 тән флейталар төркеме концертмейстеры), бер үк вакытта 1975 тән Казан музыка уч-щесе укытучысы. Концерт эшчәнлеге алып бара. Көнбатыш Европа флейта репертуарына (итальян һәм немец бароккосыннан алып Француз «Алтылыгы» композиторлары әсәрләренә

кадәр) кергән әсәрләрдән соло программалары б-н чыгышлар ясый. Г. аеруча татар композиторлары (Н.Җиһанов, Р.Яхин, Ф.Әхмәтов, А.Монасыйпов, Р.Еникиев, Ш.Шәрифуллин һ.б.) әсәрләрен пропагандалауга игътибар бирә. Музыкантның югары проф. дәрәҗәдә, тирән эчтәлекле һәм образлы башкару осталыгы тыңлаучыларда якты тәэсир калдыра.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ГА́ЙСИН** Фивзәт Миңлебай улы (27.4.1946, Буа р-ны Иске Суыксу а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1994). ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000). 1970 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1995 тән техник физика каф. мөдире. Хезмәтләре плазма физикасына, плазма техникасы һәм технологиясенә карый. Гадәти булмаган электродларда (электролитлар) тотрыклы һәм тотрыксыз пар-газ бушануыннан туган түбән темп-ралы плазма физикасының фәнни нигезләрен төзи. Атмосфера басымында яңа төр электр бушануын — күпканаллы бушануны беренче булып билгели (1988). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электрофизические процессы в разрядах с твёрдым и жидкими электродами. Свердловск, 1989 (автордаш); Возникновение и развитие объёмного разряда между твёрдым и жидкими электродами // Химия плазмы. 1990. Т. 16 (автордаш); Объёмный разряд в парогазовой среде между твёрдыми и жидкими электродами. М., 1990 (автордаш); Струйный многоканальный разряд с электролитическими электродами в процессе обработки твёрдых тел. К., 2006 (автордаш).

**ГАЙФУЛЛА́ бине МОЗАФФА́Р** (19 йөз уртасы — 20 йөз башы), хаттат. Казанда эшли. Казан император ун-ты типографиясендә басылган «Мәккә һәм Кәгъбә мәчете сурәте» (1890), «Мөхәммәд с. г.в. пәйгамбәрнең бөеклеге» (1898), «Кодрәтле сүз» (1900) исемле аклы-каралы төстәге литографик шәмаилләр авторы. Г. әсәрләренең график композицияләре образларның күп планлы булуы, текcттагы Коръәни эчтәлек һәм сурәтләү алымнарының тәңгәллеге, исламның төп атрибутларын һәм символларын, билге һәм бизәк өлешләрен, литографик шәмаилләрнең бизәлешенә хас капма-каршы чишелешләр кулланылуы б-н аерылып тора. Г.ның осталыгы матур итеп яза белүендә, язманы кәгазь битенә бердәй зурлыкта һәм тигез үлчәмдә урнаштыра алуында ачыла. Тормышның авыр хәлләрен Коръән аятьләре аша аңлатканда, җәһәннәм һәм җәннәт күренешләрен тасвирлаганда, Мөхәммәд с. г.в. пәйгамбәрнеке булып саналган әйберләрнең тәэсир итү көче турында мәгълүмат биргәндә, Г.ның дини белемнәрне гаять тирәнтен аңлавы сизелеп тора. Аның җитди мәсьәләләр турында образлы фикер йөртүендә дөньяга халыкчан караштa тору үзенчәлекләре күп. Г.ның әсәрләре ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003; А б з а л и н а Р. Шамаили из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец 19 — начала 20 вв.). Собрания профессоров И.М.Покровского и Н.Ф.Катанова. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАЙФУ́ЛЛИН** Васил Габдулла улы (23.3.1937, Мөслим р-ны Югары Табын а.), педагог, пед. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000), РФнең атказ. укытучысы (2004). 1961 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1961–71 дә урта мәктәптә физика укытучысы, 1971 дән Мөслим р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1974–94 тә Казан пед. ин-тында физ.-матем. ф-ты деканы. 1990–97 дә ТР мәгариф министры. 1997–2005 тә Татар гуманитар ин-ты ректоры, 2006 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тының физика ф-ты деканы. Физика укыту методикасы һәм теориясе буенча хезмәтләр һәм урта мәктәп өчен дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Язмыш борылышлары. К., 2007; Проблемные ситуации на уроках физики. К., 1980; Профориентационная работа на уроках физики. К., 1988; Активизация учения школьников. К., 1992; Национально-региональный компонент стандарта образования. Татарстанский вариант. К., 1999.

**ГАЙФУ́ЛЛИНА** Әсфирә Гали кызы (1.8.1929, Лаеш р-ны Татар Кабаны а.), спортчы (байдаркада ишү, чаңгыда узышу, йөгерү), СССРның спорт остасы (1962). Казан механика-технол. техникумын тәмамлый (1967). 1948 елдан Казан ясалма күн з-дында эшли. 60 яшьтән өлкәннәр арасындагы чаңгы ярышларында (3, 5, 10, 20 *км* лы дистанциядә) СССР (1990), БДБ илләре (1992), Россия (1994,1996), дөнья (1993, 1994, 1996) чемпионы; 65 яшьтән өлкәннәр арасында җиңел атлетика буенча (800, 1500, 3000 *м* га) Россия чемпионы (1996–97, абсолют чемпион — 2000); 70 яшьтән өлкәннәр арасында байдаркада ишү буенча (200, 1000, 2000 *м* га) Бөтенроссия ярышларында берничә тапкыр җиңүче.

**ГАЙШӘ́-БАТМА́Н, ГАЙШӘ́-ФАТЫЙМА́,** төрки-татар мифологиясендә әүлияләр, мөселман хатын-кызларының яклаучылары; Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатыны Гайшә һәм аның беренче хатыны Хәдичәдән туган кызы Фатыйма б-н тиңләштерелә; кайбер чыганакларда алар икесе бер шәхес буларак күзаллана. Алар шифалы кулларга ия булган дип фаразлана. Бу караш түбәндәге сихерләү-әйтемдә чагылган: «Минем кулым түгел, Гайшә-Батман кулы».

Күп кенә ислам илләренең халык авыз иҗатында Г.-Б., Г.-Ф. ислам нуры таратучылар булып саналалар.

Чуаш фольклорында алар капма-каршы образга — явыз рухлар башлыгы Ашапатманга, алтын тәхеттә утыручы, алтын йөзле, бер күзле, бер тешле һәм башында бер бөртек кенә чәче булган карчыкка әверелгән.

*Әд.:* Н а д и р о в И. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Е г о р о в Н.И. Чувашская мифология // Культура Чувашского края. Чебоксары, 1995.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГАКЕ́ЛИЯ** (Hackelia), кыярчалар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. ТРда бер төре — иенке Г. (H. deflexa) Идел-Кама саклаулыгының Саралан бүлемтегендә очрый. Күләгәле сөзәклекләрдә, текә яр битләрендә үсә. Биеклеге 15–45 *см*. Сабагы ботаклы, кытыршы. Яфраклары озынча — ланцетсыман. Чәчәкләре озын чәчәк сабында. Май-июнь айларында чәчәк ата. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГАКСТГА́УЗЕН** (Haxthausen) Август (3.2.1792, Бёкендорф ш. — 31.12.1866, Ганновер ш.), барон, икътисадчы, Пруссия дәүләте чиновнигы. 1843 елның апреле-октябрендә Россия хөкүмәтенең матди булышлыгы б-н рус авыл җәмәгатьләрен өйрәнү максатында Үзәк Россия, Украина, Идел буе һәм Кавказ буйлап сәяхәт итә. 1847–52 дә немец телендә «Россиядә халык тормышының эчке мөнәсәбәтләрен, аеруча авылдагы оешмалар эшен тикшерү» («Исследования внутренних отношений народной жизни и в особенности сельских учреждений России» — рус теленә тәрҗемәсе — М., 1870) дигән хезмәте дөнья күрә. Китапка Казан губернасында тупланган материаллар да кертелгән, ул төбәк тарихын өйрәнүчеләр өчен мөһим чыганак булып тора.

Х е з м.: Studien über die inneren Zustände, das Volksleben und insbesondere die ländlichen Einrichtungen Russlands. Hannover — B. 1847–52. Bd. 1–3.

*Әд.:* С е м е н о в с к и й В.И. Крестьянский вопрос в России в XVIII и в 1-ой пол. XIX в. СПб., 1888. Т. 2.

**ГАКЫЙДӘ́** (гарәп. عقيدة — инану, караш), ислам дини әдәбиятының аерым бер төре; тулы бер дин белеме мәктәбенең яисә аерым бер авторның догматика һәм хокукның төп мәсьәләләренә карата ачык һәм төгәл итеп билгеләнгән карашы. 8 йөздә барлыкка килә, исламның төп догматик мәктәпләре оешып җиткән 9–10 йөзләрдә аеруча үсеш ала. Бу чорда *Әбу Хәнифә ән-Ногман бине Сабитка* нисбәтле «Әл-Фикъһ әл-әкбар» («Бөек гыйлем») һәм «Китап әл-васыйә» («Васыять китабы»), «Гакыйдә әт-Тәһави» («Тәһави гакыйдасе»), ш.у. күренекле мөтәзилиләрнең (к. *Мөтәзилиләр*) Г. өлкәсендәге мәшһүр әсәрләре дөнья күрә. 10 йөздән Г. эволюциясе мөселман догматикасы һәм хокук гыйлеме үсешенә бәйле һәм бу хәл төп догматик күзаллаулар, хокук, йола, этиканың норма һәм кагыйдәләре тәфсирләнгән һәм нигезләнгән күләмле җыентыклар барлыкка килүгә сәбәп була. Шундый хезмәтләрнең аеруча билгелеләре әл-Ашари (10 йөз), әл-Газали (11 йөз), әш-Шәһристани (12 йөз), ән-Нәсәфи (14 йөз), Ибн Таймиягә (14 йөз) һ.б. авторларга карый.

Г. догматика, идеяләр, күзаллауларның үзенчәлекле җыелмасы буларак, традицион мөселман мәгарифенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Татар дини уку йортларында Г. төп дәресләрнең берсе булып тора.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Ф ә х р е т д и н Р. Гакаид. Оренбург, 1909; М а к с у д и Ә.-Һ. Гыйбадәте Исламия. К., 1989; А д ы г а м о в Р. Акыда (Исламское вероубеждение). К., 2007.

**ГАЛА́КТИКА** (грек. galaktikós — сөтле, сөттәй), йөзләрчә млрд. йолдызның, ш.и. Кояшның да, тузан һәм газ болытларының гравитациягә (бөтендөнья тартылу законына) бәйле халәттә тупланган системасы. Г.ның магнит кырлары бар, аны гаять зур энергия кисәкчекләре агымы — космик нурлар кисеп

үтә. Г. йолдызлары фәзада катлаулы һәм шактый төзек фигура хасил итеп, аның үзәге шарсыман калынаеп торган яссы диск рәвешендә күренә.

Г.ның диаметры 100 меңгә якын яктылык елын тәшкил итә (1 яктылык елы — яктылык 1 елда узган ара). Диск йолдызларның сферик ассистемасы (гало) б-н әйләндереп алынган, аның радиусы 70 мең яктылык елы чамасы. Үзәк өлкәдән диск читләренә таба гаять зур спираль тармаклар сузылган. Г. ның аеруча якты йолдызлары күбрәк шуларда тупланган. Кояш системасы Г. дискының симметрия яссылыгында диярлек, үзәктән радиусның өчтән ике өлеше чамасы ераклыкта урнашкан. Җирдән күзәтүче дискны «кабыргага» юнәлешендә караса, йолдызларның тоташ тасма булып яктырып торуын, бөтен күкне колачлап алган Киек Каз Юлы (Г.ның икенче исеме) хасил итүен күрә. Г.ның массасы бик зур, чама б-н $3 \cdot 10^{41}$ *кг*. Кояш Г. үзәге тирәли 220 млн. ел эчендә әйләнеп чыга. Г. ның йолдызлар составы гаять күптөрле. Йолдызларның аерым төркемнәре яше, химик составы, торышы һәм Г. үзәге тирәсендә әйләнү рәвеше б-н бер-берсеннән бик нык аерыла. Шул сыйфатламага карап, Г. дагы йолдызлар гало, юка диск, калын диск кебек өч ассистемага бүленә. Гало ассистемасын 13–15 млрд. яшьтәге иң карт йолдызлар тәшкил итә. Аларда авыр элементлар Кояшныкына караганда бер ярым — өч мәртәбә азрак һәм алар сузынкы орбита буенча хәрәкәт итәләр. Гало үз эченә дистә меңнәрчә йолдызны эченә алган гравитацион бәйләнештәге системаларны — шарсыман йолдыз тупланышларын ала. Кояш юка диск (аның калынлыгының яртысы 1 мең яктылык елыннан артмый) ассистемасына керә. Бу ассистемадагы йолдызлар 9 млрд. яшьтән дә карт түгел, алар арасында бөтенләй яшь, берничә млн. яшьтәге йолдызлар да очрый. Бу хәл Г. да йолдызлар ясалу дәвам итүен раслый. Юка диск ассистемасындагы йолдызларның химик составы Кояшныкы кебегрәк, алар Г. үзәге тирәли түгәрәккә якын орбиталар буенча хәрәкәт итәләр. Бу ассистемага йөзләрчә, меңнәрчә йолдызларны, кайнар йолдызларны, пульсарларны, рентген һәм гамма нурлары чыганакларын, йолдызара газ һәм тузан болытларын эченә алган таркау йолдыз тупланмалары керә. Калын дисктагы йолдызлар төркеме (диск калынлыгының яртысы 6 мең яктылык елы чамасы) фәзадагы торышы буенча



Спираль галактикаларның берсе.

уртада, әмма яше (12–13 млрд. ел) б-н ул юка диск йолдызларына караганда галога якынрак.

Г.ның төзелешен хәзергечә күзаллау 20 йөзнең 20–30 нчы елларында Америка астрономнары Х.Шепли һәм Р.Трюмплер тикшеренүләре нәтиҗәсендә формалаша башлый. Спираль тармаклар булуын 1951 елда Америка галимнәре У.Морган, С.Шарплесс һәм Д.Остерброк исбатлый. Г.ның үзәк өлкәсенең беренче сурәтләрен 1948 дә совет галимнәре В.Б.Никонов, А.А.Калиняк һәм В.И.Красовский инфракызыл нурларда төшереп алалар. 20 йөзнең 40 нчы елларында немец астрономы В.Г.Бааде, совет галимнәре Б.В.Кукаркин һәм П.П.Паренаго Г. да төрле йолдыз төркемнәре булу концепциясен үстерәләр. Казан ун-тында Г. ны өйрәнү эшләре 19 йөзнең 50 нче елларында башлана. 1859 елда М.А.Ковальский Г.ның әйләнеше турындагы идеяне беренче булып әйтә һәм фәзада Кояш хәрәкәтен билгеләү ысулын тәкъдим итә. Аңарга бәйсез рәвештә Америка астрономы Д.Б.Эри да шул ук ысулны тәкъдим итә (Ковальский-Эри ысулы). 20 йөзнең 20 нче елларында гына күзәтүләр нәтиҗәсендә Г.ның әйләнеше раслана, 1927 дә Нидерланд (Голландия) астрономы Я.Оарт Г.ның әйләнешен тулысынча исбатлый. Казан галиме Ш.Т.Хәбибуллин (1948, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе) Г. да йолдызлар таралу тыгызлыгын берничә юнәлештә тикшерә. Шуннан соң 1950–80 елларда Г.дагы спираль тармакларның торышын һәм рәвешен ачыклау буенча тикшеренүләр циклы башлана. 2000 елда Казан шәһәр астрономия обсерваториясе тарафыннан калын дисктагы йолдызлар төркеменең, гало төркемендәге йолдызлар кебек үк, карт булуын раслаган күзәтү мәгълүматлары алына.

*Әд.:* Морочник Л.С., Сучков А.А. Галактика. М., 1984; Физика космоса: Маленькая энцикл. М., 1986.

*Л.И.Машонкина.*

**ГАЛАКТИО́НОВ** Алексей Петрович (1886 — 5.6.1922, Казан), партия эшлеклесе. 1905 елдан Ташкент, Чиләбе, Самара шәһәрләрендә революцион эшчәнлек алып бара. 1906 дан РСДРП әгъзасы. 1916 да революцион пропаганда алып баруы өчен Себергә сөрелә. 1917 дә Самарага кайта; РСДРП(б)ның губерна ком-ты секретаре, соңыннан губерна башкарма ком-ты рәисе булып эшли. Гражданнар сугышы чорында 1918 дә Самара, соңрак Чапаев исем. 25 нче дивизиянең сәяси комиссары була. Самараны азат итүдә катнаша (1918, окт.). 1919–20 дә Кубаньда һәм Ростов-Дон шәһәрендә партия эшендә. 1921 дә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан шәһәр Советы башкарма ком-ты рәисе, бер үк вакытта ТАССР ХКС рәисе урынбасары. 1922 дән РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. Авиация һәлакәтендә вафат була.

*Әд.:* Саркин В. Галактионов Алексей Петрович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ГАЛАКТИО́НОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́ СОВХО́З** посёлогы, к. *Александровка авылы* (Чистай р-ны).



А.П. Галактионов.

**ГАЛАКТИО́НОВА** Лидия Алексеевна (25.3.1955, Казан), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1976–78 елларда ТатНИПИнефтьнең Казан филиалында. 1978 дән «НИИнефтепромхим» АҖдә эшли. 2008 дән «ИҖАТ» АҖнең техник директоры. ТРның Дәүләт бүләге «Татарстанда авыр чыгарыла торган нефть ятмаларының нефть бирүчәнлеген күтәрүнең нәтиҗәле технологияләр комплексын эшләү һәм сәнәгатьтә киң куллануга кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГАЛАКТИО́НОВО** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 11 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2008 елда 93 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Жукотино, Никольский, Савино Городище, Савин Городок исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Николай Чудотворец чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1028,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. Халык саны: 1782 дә — 383 ир-ат; 1859 да — 583, 1897 дә — 781, 1908 дә — 1074, 1920 дә — 1192, 1926 да — 1284, 1938 дә — 1052, 1949 да — 614, 1958 дә — 410, 1970 тә — 219, 1979 да — 87, 1989 да — 80, 2002 дә — 113 кеше.

**ГАЛАНЗА́** Пётр Николаевич (26.9.1893, Кишинёв — 24.8.1982, Мәскәү), юрист, юридик фән. д-ры (1961), проф. (1947). Мәскәү ун-тын (1917), Кызыл профессорлар ин-тын (1927, Мәскәү) тәмамлый. 1918–19 елларда Тверь губернасында өяз халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1919–23 тә Кызыл Армиянең Көнбатыш фронт Сәяси идарәсендә. 1923–27 дә Смоленск, Мәскәү югары уку йортларында укыта. 1927–29 да Татарстан коммунистик ун-ты (Казан) профессоры. Бер үк вакытта 1928–29 да Казан ун-ты ректоры. Ун-тның физ.-матем. ф-тын ябуны туктатуга ирешә. Бондюг химия з-дының яңадан эшли башлавына булышлык итә. 1929–39 да Белоруссия ун-тында, 1939–41 дә, 1946–49 да Бөтенсоюз юридик читтән торып уку ин-тында (Мәскәү) дәүләт тарихы һәм теориясе, хокук каф. мөдире. 1949 дан Мәскәү ун-тында, дәүләт тарихы һәм хокук каф. мөдире (1954 кә кадәр). Чит илләрнең дәүләт һәм

хокук тарихы һәм теориясе буенча дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Психологическая школа права и марксизм. К., 1929; Государство и право в странах Древнего Востока. М., 1940; Государство и право Древней Греции. М., 1940; Всеобщая история государства и права: В 2 вып. М., 1947–48; Государство и право Древнего Рима. М., 1963; Феодальное государство и право Германии. М., 1963; Феодальное государство и право Франции. М., 1963.

*Е.Б.Долгов.*

**ГАЛА́НИН** Иван Дементьевич (15.10.1939, Курган өлкәсенең Шатрово а.), архитектор, ТАССРның (1985) һәм РФнең (1992) атказ. архитекторы. 1968–77 елларда «Татгражданпроект» ин-тында архитектор, 1977 дән «Казгражданпроект» ин-тында баш архитектор. 2001 дән бүлек мөдире. 1988–91 дә РСФСР Архитекторлар берлегенең Татарстан оешмасы рәисе. Г. проектлары б-н Казанда ДОСААФ бинасы (1979), «Новинка» сәүдә һәм күргәзмәләр комплексы (1985, И.Г.Нургалиев б-н бергәләп), Казан мед. ун-тының уку корпусы (1990), «Сувар» АЖнең офис бинасы (1994) төзелә; КазХимНИИ ин-ты (ТР Милли архивы итеп үзгәртелә, 1997), ТР Министрлар Кабинеты (1998) биналары, ш.у. ВИКОның (хәзер «Казан ярминкәсе») үзәк павильоны (2000, А.Ф.Хисамов б-н бергәләп), ТРның Финанс министрлыгы бинасы (2000–01) реконструкцияләнә.





И.Д.Г а л а н и н. 1. Казан мед. ун-тының уку корпусы. 1990; 2. ТР Финанс министрлыгы бинасы. Реконструкция. 2000–2001.

**ГАЛӘВЕТДИ́НОВ** Мансур Фәләхетдин улы (1.1.1940, хәзерге Удмуртия Респ-сы Воткинск ш.), физик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1988), СССРның уйлап табучысы (1980), физ.-матем. фән. канд. (1983). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан оптика-механика з-дында эшли. 1972 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре ярымүткәргечләрне импульс ярдәмендә үзгәртү — *лазер нурында чыныктыруга*, ярымүткәргечләрнең нәсызыкча оптикасына, динамик голография һәм спектроскопиягә карый. Өслеккә якын катламнарда структура-фаза күчешләре динамикасын нәсызыкча оптик өйрәнүнең яңа методикасын эшли (бергәләп). Лазер нурланышы һәм югары басым биргә тәэсир иткәндә фаза күчешләрен тикшерүнең яңа методикасын тәкъдим итә. Дәүләт бүләге «Каты җисемнәрне юнәлтелгән импульс ярдәмендә кристаллаштыру (лазер нурында чыныктыру) күренешен ачу» («Открытие явления импульсной ориентированной кристаллизации твёрдых тел (лазерный отжиг»)) дигән фәнни хезмәтләр циклы (автордаш) өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ионно-легированный слой — новый материал для записи голограмм // Оптика и спектроскопия. 1975. Т. 38 (автордаш); О коэффициенте использования внедрённой примеси при лазерном отжиге ионно-легированных слоёв на кремнии // Физика и техника полупроводников. 1977. Т. 11 (автордаш); А.С.504435 (СССР). Способ легирования полупроводников. Опубл. в Бюл. изобрет. и открытий. 1982. № 42 (автордаш); Исследование динамики неравновесных решёток индуцированных фемтосекундными лазерными импульсами в плёнках кремния // Физика и техника полупроводников. 2001. Т. 30, вып. 12 (автордаш).

**ГАЛӘВИ́ЕВ** Шамил Шәйхи улы (24.2.1954, Теләче р-нының Югары Кибәхуҗа а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), техник фән. канд. (2002). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: мастер-механик, механик, цех башлыгы (1986 дан), этилен з-дында баш механик (1998 дән), АҖдә баш механик (1999 дан). Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге түбән олефин, бутадиен һәм бензолны нәтиҗәле җитештерүдә егәрлекне үстерү буенча комплекслы эшләрнең фәнни һәм практик нигезен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**«әл-ГАЛӘМЕ́ әл-ИСЛАМИ́»** («العالم الإسلامى» — «Ислам дөньясы»), атналык газета. 1906 елның 30 маеннан 1907 нең гыйнварына кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 42 саны чыга. Рәсми мөхәррире һәм нашире Ш.Абызгилдин, аннан соң нашире Г.Мостафин, мөхәррире Б.Максуди (29 нчы саннан). Асылда мөхәррирләре З.*Камали*, М.Хәсәни. Төп максатларының берсе — төбәк, Россия, бөтен дөнья мөселманнары тормышын яктырту. Газета битләрендә дини-фәлсәфи фикерләр, ислам мәсьәләләре урын ала, дөньяви, иҗтимагый-сәяси темаларга багышланган материаллар басыла, ш.у. шигъри әсәрләргә, мөнәҗәтләргә һ.б.га урын бирелә.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты: (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Р ә м и е в И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«ГАЛӘМЕ́ НИСВА́Н»** («عالم نسوان» — «Хатын-кызлар дөньясы»), әдәби-мәгърифәтчелек юнәлешендәге рәсемле журнал. 1906–10 елларда Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төрки-татар телендә нәшер ителә, барлыгы 51 саны чыга. Наширләре һәм мөхәррирләре И.*Гаспринский*, Ш.*Гаспринская* (1907 дән). «*Тәрҗеман*» г-тасына кушымта булып чыга. «Г.н.»га кадәр И.Гаспринский 1887 дә хатын-кызлар өчен «Тәрбия» һәм 1891 дә «Къадын» г-талары чыгару өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә, ләкин уңышка ирешә алмый. Журнал чыгару өчен 1905 нең 3 ноябрендә рөхсәт алына, 1906 ның 3 мартыннан чыга башлый. «Г.н.» — төрки-мөселман дөньясында хатын-кызлар өчен чыгарылган беренче журнал. Анда Ш.Гаспринская, Нәҗип Йосыфбәйле, Абдулла Сур әсәрләре еш басыла. Төп темалары: Россиядә мөселман хатын-кызларның хокуклары, дөньяның төрле илләрендә яшәүче хатын-кызларның хәле, күренекле хатын-кызлар эшчәнлеге, йорт эшләрен алып бару һәм балалар тәрбияләү; кул эшләре турында һ.б. киңәшләр. Журнал битләрендә әдәбият белеме, тарих һ.б. фәннәргә кагылышлы мәсьәләләргә зур урын бирелә. «Г.н.» проза һәм поэзия әсәрләрен бастыра, укучылар б-н хатлар алыша. Әбунәчеләре Россиядә, Төркестанда, Мисырда, Һиндстанда, Японииядә була.

*Әд.:* К е р и м о в И.А. «Живая» история Гаспринского: По материалам газеты «Терджиман» 1883–1914 гг. Симферополь, 1999; H a b l e m i t o ğ l u S., H a b l e m i t o ğ l u N. Şefika Gaspıralı ve Rusyada Türk Kadın Hareketi (1893–1920). Ankara, 1998.

*А.М.Ахунов.*

**«ГАЛӘМЕ́ СЫЙБЪЯ́Н»** («عالم صد بيان» — «Балалар дөньясы»), к. «*Тәрҗеман*».

**ГАЛӘМЕТДИ́НОВ** Юрий Геннадьевич (24.5.1948, Амур өлкәсенең Возжаевка ст.), физик-химик, химия фән. д-ры (1997), проф. (1999). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлап, шунда эшли. 1980 нән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, 1998 дән баш фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта 1997 дән Казан технол. ун-тында, 2005 тән физик һәм коллоид химия каф. мөдире. Хезмәтләре сыек кристаллар химиясенә һәм физикасына карый. Г. металлары булган (бакыр, тимер, ванадий, лантанидлар) смектик һәм нематик парамагнитик сыек кристалларны синтезлау стратегиясен эшли һәм дөньяда беренче булып (хезмәткәрләр б-н берлектә) аларны таба. Парамагнит сыек кристалларны ЭПР ысулы б-н матдәнең сыек кристаллик халәтен тикшерү өчен кулланырга тәкъдим итә. Полимер сыек кристаллар өлкәсендәге берничә (немец галиме В. Хаазе б-н берлектә) эше пироэлектрик сенсорлы элементлар табуга китерә. Электрохимик җитештерү калдыкларында авыр металларның бик кечкенә кушылмаларын билгеләү өчен сыек кристаллик тапшыргычлар (автордаш) эшли. Сыгылмалы дисплейлар, оптик көчәйткечләр, электрон газета йөрткечләре һ.б.ш. ясау өчен нәтиҗәле люминофорлар һәм рекордлы магнитик анизотропияле лантанидлы кушылмалар таба. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001).

Х е з м.: Жидкокристаллические комплексы оснований Шиффа с медью // Докл. АН СССР. 1984. Т. 276, № 1 (автордаш); Metallomesogens and Metallopolymers-recent Result on Magnetic Properties // Molecular Materials. 1993. V.3 (автордаш);

Influence of the Lanthanide Contraction on the Transition Temperatures of Rare-Earth Containing Metallomesogens with Schiff Base Ligands // Chemistry Physics Letters. 1999. V.300 (автордаш).

**ГАЛӘ́Ү** (Мәрҗани) Мәхмүт Галәветдин улы (сент. 1886, Казан губ., Казан өязе Ташкичү а. — 12.11.1938), язучы, журналист, тәрҗемәче. 1897–1903 елларда Казанда мәдрәсәдә укый. 1903–07 дә Әстерхан шәһәрендә укытучы булып эшли. Шул елларда беренче язмалары «Шәркый рус» (Баку ш.) һәм «Борһане тәрәкъкый» г-таларында күренә башлый. «*Туп*» ж-лын оештыручыларның берсе һәм аның чынлыкта мөхәррире була. 1907 дә Оренбург шәһәренә күчеп килә һәм анда 1914 кә кадәр «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе басмаханәсе» ширкәтендә эшли. 1914 тә үзенең 1918 гә кадәр эшләп килгән «Белек» исемле нәшриятын ача һәм анда «*Кармак*» ж-лын, фәнни-популяр брошюралар, уку-укыту әсбаплары һәм дәреслекләр («Төрки сарыфы», 1910) редакцияли һәм бастыра. «Төрки уку» (1911) хрестоматиясен төзи. Шул ук елларда татар теленә А.С.Пушкинның «Буран» («Метель») повестен, Л.Н.Толстойның «Хаҗи Морат» («Хаджи-Мурат») һәм «Крейцер сонатасы» («Крейцерова соната») әсәрләрен тәрҗемә итә. К.Н.Батюшков, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов шигырьләренең аның тарафыннан эшләнгән тәрҗемәләре үз шигырьләре б-н беррәттән Оренбургта басылган «Ник язылганнар?» (1912) җыентыгына кертелә. 1919 да Башкортстан АССР Мәгариф халык комис-тының кантон бүлегендә, 1920 дә Оренбург, Мәскәү шәһәрләрендә мәгариф системасында һәм нәшриятларда эшли. 1921 дә Оренбургта әзерләүләр артеле оештыра, ләкин властьлар тарафыннан ул 1923 тә ябыла. 1925–26 да Мәскәүдә Үзәк нәшриятта эшли.

Актив иҗат чоры 1920 елларга туры килә. Яңаның иске б-н көрәше, авыл-шәһәр мөнәсәбәтләре, яңа кеше тәрбияләү темаларына багышланган очерклары һәм хикәяләре б-н матбугатта еш чыгышлар ясый. 1920 елларга хас булган яңа кыйммәтләрне мактау, искелек билгеләрен инкарь итү күренешләре «Каяу» (1927), «Төеннәр» (1928), «Күпнең берсе» (1931) исемле җыентыкларга кергән хикәяләрендә чагылыш таба. Мәсәлән, 1934 тә Мәскәүдә рус теленә тәрҗемә ителеп басылган «Кабулсай» романында мөселман татарларның күмәкләшү чорындагы психологиясен үзгәртү идеясе — татар авылларында дуңгыз фермалары төзү, яңа кеше формалашу Туктамыш картның диннән ваз кичүе аша күрсәтелә. Г. үзен драматургиядә дә сынап карый: «Салам-торханнар» (1926), «Пугач явы» (1926) пьесаларын яза.

1920 еллар ахырында Г. дүрт китаптан торырга тиешле «Канлы тамгалар» исемле эпопея өстендә эшли башлый. Анда 1877–1917 еллар вакыйгаларын, татар крәстиәненең милли һәм социаль азатлыкка таба үткән катлаулы юлын тасвирлау күздә тотыла. Сюжеты конкрет тарихи вакыйгаларга нигезләнә. «Ил тыныч чакта» исемле беренче китап авылдагы социаль каршылыкларның кискенләшүенә китергән 1877 дәге ачлыкны сурәтләүгә багышлана. «Ил өреккәндә» исемле икенче китабында язучы 1897 дә үткәрелгән халык санын алу вакыйгаларын һәм татар крәстиәннәренең 1894 тә массакүләм рәвештә Төркиягә күчеп китүен яктыртырга, «Сабак» дип аталачак өченче китап рус-япон сугышын һәм 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларын, «Өермәләр» дип исемләнгән дүртенче китап Окт. рев-циясен чагылдырырга тиеш була. Ләкин бу ниятен язучы өлешчә генә тормышка ашыра ала: ике китап язылып бетеп, басылып чыга; алар татар әдәбиятында күренекле вакыйга буларак кабул ителә, яңа реалистик тарихи роман жанрына нигез салалар. «Болганчык еллар» («Ил тыныч чакта») романында заманына хас булган идеологик карашлар кысаларында Г. үз игътибарын социаль каршылыкларны сыйнфыйлык б-н аңлатуга юнәлтә. Сафа, Таҗи, Саҗидә кебек төп уңай геройлар мисалында автор аларның сыйнфый үзаңнары барлыкка килүенең һәм үсешенең сәбәбе итеп авыр тормышны һәм гаделсезлекне күрсәтә. «Мөһаҗирләр» («Ил өреккәндә») романында Г. «Болганчык еллар» романы геройларының язмышларын яңа тарихи вазгыятьтә тасвирлый: татар крәстияннәре Төркиягә күчә, революцион идеяләр татар авылларына үтеп керү сәбәпле, аларда сыйнфый үзаң уяна һәм үсеш кичерә. Бу әсәрләр Мәскәүдә 1930 да һәм 1934 тә, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Муть» һәм «Мухаджиры» исемнәре б-н басылалар, ләкин татар телендә дөнья күрмиләр. 1960 елларда гына романнар татар теленә (Р.Даутов һәм Я.Халитов тарафыннан) тәрҗемә ителәләр һәм Казанда «Болганчык еллар» (1976) һәм «Мөһаҗирләр» (1977) исемнәре б-н нәшер ителәләр. Г. 1937 дә милләтчелектә гаепләнеп кулга алына; романнарның кульязмалары конфискацияләнә һәм соңыннан югала. 1938 дә Г. атып үтерелә; соңыннан аклана.

*Әд.:* Д а у т о в Р. Әдипнең фаҗигасы // Казан утлары. 1966. № 9.

*Ф.М.Мусин.*


**ГАЛИ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 84 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ары-Казы елгасы буенда. 2008 елда 77 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәр Кече Кадыбаш, Гали Пүчинкәсе исемнәре б-н дә билгеле. 19 йөздә халкы дәүләт крәстияннәре, асабалар, типтәрләр катлауларына бүленә; игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. дә мәчет эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1890 да — 207, 1926 да — 232, 1938 дә — 288, 1949 да — 220, 1958 дә -219, 1970 тә — 257, 1989 да — 101, 2002 дә — 87 кеше.

**ГАЛИ́ АРСЛА́Н**, к. *Арслан хан.*

**ГАЛИ́ ӘКРА́М** (16 йөз), нугай морзасы. Олы Нугай Урдасы идарәчесе *Йосыф бәкнең* улы. Тарихи әдәбиятта Казан җирлегендә рус яулап алучыларына каршы оешкан халык күтәрелешендә (1552–56) катнашучы буларак тасвирлана (М.Г.Худяков, С.Х.Алишев һ.б.). *Мамышбирде* аңа, имеш, Казан тәхетен вәгъдә иткән булган. Рус елъязмаларында: «Мамышбирде хан тәхетенә Ахполбей угланны чакыра, шул кеше 100 кешелек нугай гаскәре б-н ханлыкның Болын ягына килә», «булачак патшаның (ханның) ярдәме булмау сәбәпле..., Мамышбирде аны һәм аның нугайларын үтерә», — дип хәбәр ителә.



М. Галәү.



Г.Б. Гали.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

**ГАЛИ́** (Галиев) Габдулла Гали улы (20.6.1920, Лаеш өязе Шәдке а. — сент. 1941), шагыйрь. 1935 елда Казан. пед. ин-ты рабфагына укырга керә. «Яшел бөреләр» (1939), «Үсәбез» (1940) исемле җыентыклар чыгара, аерым шигырьләре «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкка керә. Бөек Ватан сугышында катнаша, Украинадагы Каменец-Подольск шәһәре өчен барган сугышта һәлак була.

**ГАЛИ́** (Галиев) Гомәр Билал улы (16.6.1900, Сембер губ., Буа өязе Иске Тинчәле а. — 6.7.1954), язучы, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе. Гражданнар сугышында катнаша. 1919 елдан революцион пафос б-н сугарылган публицистик мәкаләләр һәм очерклар, әдәби рецензияләр б-н матбугатта актив рәвештә чыгышлар ясый башлый (соңыннан алар «Пролетариат әдәбияты өчен көрәшкәндә» (1931) җыентыгына керә). 1921 дән — Казанда. 1925 тә Татар коммунистлар ун-тын тәмамлый. 1923–24 тә Һ.Такташ һәм К.Нәҗми б-н берлектә татар совет язучыларының «Октябрь» исемле беренче әдәби оешмасын төзи. 1925–36 да (бүленеп) — «Безнең юл» ж-лының баш мөхәррире. 1931 дән Татарстан китап нәшриятының әдәби секторын, Татар пролетар язучылары ассоциациясен (ТАПП) җитәкли, Татарстан совет язучылары берлеген оештыру комитеты рәисстәшләренең берсе була. 1929–34 тә — Казан мед. ин-тында татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 1925 тә Парижга гамәли-кулланма сәнгать күргәзмәсенә җибәрелә. Анда алган тәэсирләре «Чит илләрдә» (1926) исемле китабында чагылыш таба. Башлап дөнья күргән «Биктимер ничек эшче булды?» (1921), «Ат саклаганда» (1922), «Кубань буйларында» (1922), «Беренче мәхәббәт» (1924) хикәяләре б-н үк Г. укучылар һәм әдәби тәнкыйть

игътибарын җәлеп итә. Ләкин ул, 1920–30 елларда актив язып, татар әдәби процессына юнәлеш биреп торучы тәнкыйтьче буларак аеруча киң таныла. Иҗатында вульгар социалогизмның көчле тәэсире сизелә. Шуңа да карамастан, Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, Һ.Такташ, Х.Туфан, М.Крыймов иҗатларына багышланган мәкаләләре тирән фикер йөртү, төгәл бәя бирү б-н игътибарны җәлеп итә. 1937 дә советларга каршы юнәлтелгән милләтчелектә һәм троцкизмда гаепләнеп кулга алына. 1947 дә азат ителә, ләкин 1949 да кабат кулга алына, сөргенгә җибәрелә һәм анда 1954 тә фаҗигале рәвештә һәлак була. 1955 тә аклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1958.

*Әд.:* А х у н о в Г. Нигез ташларын салганда (Гомәр Гали иҗаты) // Әдәби язмышлар. К., 1970; Г а т а ш Р. Гомәр Галинең тууына 100 ел // Казан утлары. 2000. № 6; М у с и н М. Гомәр Гали турында истәлекләр. К., 2002.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ГАЛИ́ ДӘРВИ́Ш**, к. *Дәрвиш хан.*

**ГАЛИ́** (Галиев) Закир Халит улы (1902, Тәтеш өязе Ямбакты а. — 1941), әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче. 1923–25, 1928–34 елларда «Кызыл Татарстан» г-тасы редакциясендә эшли (1928–32 дә җаваплы сәркәтип, 1932–34 тә баш мөхәррир урынбасары), 1932 дә «Атака» ж-лының, 1934–36 да «Кызылармияче» г-тасының баш мөхәррире, Татар пролетар язучылары ассоциациясенең (ТАПП) идарә әгъзасы, Татарстан совет язучылары берлеген оештыру ком-ты рәисе урынбасары була. 1920–30 елларда барган әдәби процесска багышланган (ш.и. Сирин, Г.Газиз иҗатлары турында) мәкаләләр авторы. К.Горбунов, И.В.Сталин хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итә. Репрессияләнә (1937); үлгәннән соң аклана (1958).

*Т.Ш.Гыйләҗев.*

**ГАЛИ́** (Галиев) Мөхәммәт Вәли улы (24.3.1893, Лаеш өязе Олы Елга а. — 16.5.1952, Казан), язучы, журналист, әдәбият галиме. «Касыймия» (1910–12), «Хөсәения» (1912–14) мәдрәсәләрендә укый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1917–19 елларда туган авылында укыта. 1919 дан Казанда. «Кызыл армия», «Эш», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» г-таларында, «Игенче» ж-лында эшли, Идел буе хәрби округының цензоры булып тора. 1922–24 тә «Безнең байрак», 1924–29 да «Крестьян газеты», 1929–31 дә «Кызыл Татарстан» г-таларында җаваплы сәркәтип. 1933 тә Казан ун-тын тәмамлый һәм 1939 га кадәр Казан пед.ин-тында, Казан берләштерелгән пед. техникумында, КПСС өлкә комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм ин-тында укыта. Бөек Ватан сугышы елларында СССР Әдәби фондының Татарстан буенча вәкиле була, ш.у. Дәүләт музееның әдәбият бүлегендә эшли. 1946 дан СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Әсәрләре 1914 тән башлап «Йолдыз» г-тасында, «Аң» ж-лында басыла башлый. «Сабан туенда» (1921), «Балалык көннәремдә» (1925), «Кала кешеләре булдык» (1928), «М.Гали әсәрләре» (1929–31) китапларына кергән хикәя һәм очеркларында авылда рев-циягә кадәр һәм 1920–30 да барган социаль үзгәрешләрне тасвирлый. «Теләнчеләр, яки бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939), «Каюм Насыйри» (1945, Х.Уразиков б-н берлектә языла һәм Татар акад. театрында куела) пьесалары, Каюм Насыйри турында язылып бетми калган роман авторы. Х е з м ә т л ә р е н д ә 19–20 йөз башы татар әдәбияты тарихы, Г.Каргалый, Г.Утыз Имәни, Г.Курсави, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Камал, С.Рәмиев, Ш.Камал, М.Гафуриның тормыш юллары һәм иҗатлары яктыртыла. «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге» (1928), «Русско-татарский словарь» (1941) төзүче. Татар теленә И.С.Тургеневның «Аучы язмалары» («Записки охотника», 1936), Ж.Верннның «Су астында 80000 километр» («20000 лье под водой», 1938) әсәрләрен, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов хикәяләрен тәрҗемә итә.



М.В.Гали.

Ә с ә р.: Тормыш юллары. К., 1940; Г.Камал. К., 1941; Сайланма хикәяләр. К., 1952; Шагыйрь баскан эзләрдән. К., 1957; Сайланма әсәрләр. К., 1964.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Мөхәммәт Гали // Татар әдипләре (Иҗат портретлары). К., 1978; Ә м и р х а н Р. Тыйнак талант // Татарстан. 1993. № 3; Р ә м и е в З. Талантлы язучы, күренекле галим // Казан утлары. 1993. № 3.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ГАЛИ́ ХАН**, к. *Илһам хан.*

**ГАЛИӘКБӘ́РОВ** Әнвәр Гомәр улы (13.7.1939, Буа р-ны Бәбки а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (1998), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2000), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1989). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1965). 1966–69 елларда Казакъстан ССРның Красноводопадск селекция-тәҗрибә станциясенең орлыкчылык бүлеге мөдире, 1969–75 тә фән буенча директор урынбасары. 1975 тән Ульянов а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында шикәр чөгендерен эшкәртү технологиясе лаб. мөдире, 1984 тән а.х. культураларын үстерүнең интенсив технологияләр бүлеге мөдире, 1987 дән технологик үзәк җитәкчесе, инновацион технологияләрне гамәлгә кертү буенча директор урынбасары, бер үк вакытта ТР ФАнең Ульянов региональ бүлегенең а.х. фәннәре секторы мөдире (2000 нән). Хезмәтләре а.х. культураларын үстерү һәм терлек азыгы җитештерү технологияләре мәсьәләләренә карый. Ул «Ульянов өлкәсе хуҗалыкларында терлек азыгы җитештерү һәм терлек азыгы культураларын үстерү технологияләрен оптимальләштерү» («Оптимизация технологии возделывания кормовых культур и кормопроизводства в хозяйствах Ульяновской области», Ульяновск, 1996) дәреслеген һәм «Урта Идел урман-дала зонасында терлек азыгы җитештерүнең актуаль мәсьәләләре» («Актуальные вопросы кормопроизводства в лесостепи Среднего Поволжья», Ульяновск, 1997) монографиясен бастыра. Г. тарафыннан Урта Иделнең урман-дала зонасы шартларына җайлаштырылган, азрак күләмдә хезмәт, акча һәм энергия чыгымнары тотып, шикәр чөгендере, көнчыгыш кәҗә сакалы, кукуруз игүдә югары уңышны тәэмин итә торган экологик зарарсыз технологияләр эшләнә. Г. җитәкчелегендә терлекчелектә планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итәрлек терлек азыгы культуралары чәчүлекләренең оптималь структурасын билгеләү өчен компьютер программасы булдырыла, бу программа Ульянов өлкәсе хуҗалыкларында нәтиҗәле кулланыла.

Х е з м.: Селекция озимой, яровой пшеницы, зернобобовых и кормовых культур в условиях богарного земледелия Чимкентской области. А.-А., 1975; Справочник свекловода России. М., 1986; Типовой организационно-технологический проект возделывания сахарной свёклы на индустриальной основе. Ульяновск, 1987; Основные направления стабилизации земледелия в Ульяновской области в условиях ограниченного ресурсного обеспечения. Ульяновск, 1999; Концепция развития кормопроизводства и пути её реализации в хозяйствах Ульяновской области. Ульяновск, 2002.

**ГАЛИӘКБӘ́РОВ** Ромэн Рәхимулла улы (23.2.1936, Свердловск ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1976), проф. (1977), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Свердловск юридик ин-тын тәмамлый (1961). 1955–61 елларда СССР МС каршындагы Дәүләт иминлеге ком-тының Свердловск өлкәсе буенча хезмәткәре. 1964–79 да Свердловск юридик ин-тында, 1974–78 дә тикшерү-криминалистика ф-ты деканы. 1979–85 тә СССР Эчке эшләр министрлыгының Омск, 1986–87 дә Хабаровск югары мәктәпләре башлыгы урынбасары. 1985–86 да СССР Эчке эшләр министрлыгының Горький югары мәктәбендә җинаятькә каршы хокук каф. мөдире. 1987–94 дә Саратов хокук академиясендә, 1988 дән җинаятькә каршы хокук һәм хезмәт б-н тәэзәтү хокукы каф. мөдире. 1994–97 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Саратов югары мәктәбендә җинаятькә каршы хокук каф. профессоры. 1997 дән Кубань агрономия ун-тында (Краснодар ш.) җинаятькә каршы хокук каф. мөдире. Хезмәтләре җинаятькә каршы хокукка, җинаятьләрнең төрлелеге, аларда катнашу мәсьәләләренә, тоталитар дини секталарның законсыз эшчәнлегенә каршы җинаяти-хокукый көрәш оештыруга карый. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Групповое преступление: Постоянные и переменные признаки. Свердловск, 1973; Квалификация групповых преступлений. М., 1980; Совершение преступления группой лиц. Омск, 1980; Уголовная ответственность за посягательства на личность и права граждан под видом исполнения религиозных обрядов. Омск, 1981; Квалификация многосубъектных преступлений без признаков соучастия. Хабаровск, 1987.

**ГАЛИӘКБӘ́РОВ** Фәрит Закир улы (25.3.1913, хәзерге Казакъстан Респ-касының Акмола өлкәсе Петропавловск. ш. — 15.6.1984, Мәскәү), генерал-майор (1967). Ленинград танк техник уч-щесен тәмамлый (1942). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940 еллар ахырыннан отставкага чыкканчы (1973), Совет Армиясе сафларында югары командирлык вазифаларын башкара. 1 нче

һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГАЛИӘСКӘ́РОВ** Әкрам Зиннәт улы (15.3.1950, Казан — 16.5.2005, Биектау р-ны Әлдермеш а.), очучы, СССРның атказ. сынаучы-очучысы (1990). Армавир һава һөҗүменнән саклану югары хәрби очучылар уч-щесен (1971) һәм Горький ун-тын (1987) тәмамлый. 1971–78 елларда авиация полкының эскадрилья командиры урынбасары. 1978–96 да РФнең Хәрби-һава коралы көчләре идарәсенең өлкән сынаучы-очучысы. Һавада Л-29, Су-27, Миг-31, Ту-22, Ту-214, Ил-62М, Ил-76 самолётларын сыный. Очышлары вакытының гомуми күрсәткече 5,5 мең сәгать тәшкил итә. 1996–98 дә Россия Федераль авиация хезмәтенең Татарстан региональ идарәсе башлыгы. 1998–99 да Урал оптика-механика з-дының Казан ф-лы директоры. 1999–2001 дә «Илбартабак» ф-касы (Казан) директоры. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

**ГАЛИӘСКӘ́РОВ** Мәхмүт Сабир улы (9.11.1936, Әтнә р-ны Исләйтар (Ары) а.), шахтёр, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). Воркута шәһәре (Коми Респ-касы) шахталарында чистарту забоенда тау эшчесе, аннан соң механикалаштырылган комплексλы бригада җитәкчесе. Аның бригадасы «Донбасс» комплексында күмер чыгару буенча специальләшә һәм тәүлегенә 1000 *т* күмер чыгаруга ирешә. Дәүләт бүләге хезмәттә ирешкән уңышлары һәм күмер чыгаруны арттыруга керткән зур шәхси өлеше өчен бирелә.

**ГАЛИӘХМӘ́ТОВ** Габделхәй Халик улы (30.9.1934, Әтнә р-ны Яңа Җөлби а.), Соц. Хезмәт Герое (1984). 1952–96 елларда Казан моторлар төзү ҖБдә шомартып ялтыратучы слесарь, җыючы-чүкеп беркетүче, механик җыю эшләре слесаре. Герой исеме яңа авиация техникасын җитештерү буенча 11 нче бишьеллык йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне, хезмәт нәтиҗәлелеген күтәрүгә зур өлеш кертkәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Фролова Л. Казанскому моторостроительному — 70 лет. К., 2001. С. 117, 168; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАЛИӘХМӘ́ТОВ** Равил Әлми улы (17.1.1924, Арча р-ны Күпербаш а. — 9.10.1991, Казан), халык мәгарифе эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1966). Арча пед. уч-щесен (1941), Казан пед. ин-тын 1953 тәмамлый. 1941 елдан Арча р-ны балалар йортында эшли, 1942 дән Совет армиясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша, 1946 дан Арча шәһәр тибындагы эшчеләр поселогында 2 нче мәктәптә укыта. 1949 дан Арча р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1959–85 тә ТАССР Мәгариф министрлыгында, өлкән инспектор, министрның 1 нче урынбасары (1960 тан). Гомуми белем мәктәпләре эшенә җитәкчелек итә, ТР Мәгариф министрлыгының халык мәгарифе музеен (Казан) оештыручы һәм беренче директоры (1986–91). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИӘХМӘ́ТОВ** Таһир Әхмәт улы (11.8.1921, хәзерге Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Урта Шөн а. — 24.5.2000, шунда ук), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1971), РСФСРның атказ. агрономы (1979). Савальск а.х. техникумын тәмамлый (1966). 1937–87 елларда Вятка Аланы р-нының 22 нче партсъезд исем. к-зында (1961 кадәр Сталин исем.) бухгалтер (1942 дән), рәис (1950 дән). Г. җитәкчелегендә хуҗалык югары уңыш алу, терлекчелектәге җитештерүчәнлек, икътисади нәтиҗәлелек буенча Россиядә һәм Киров өлкәсендә алдынгылар рәтенә керә. 100 *га* файдалану җирләренә җитештерелгән продукциянең күләме: бөртекле ашлык — 229 *т*, сөт — 56,5 *т*, ит — 9,7 *т* (1986) тәшкил итә, колхозчыларның тормыш дәрәҗәсе шактый күтәрелә. Герой исеме дәүләткә игенчелек һәм терлекчелек продуктларын сатуда бишьеллык планны (1966–70) үтәүдә һәм а.х. производствосын үстерүдә ирешелгән алдынгы уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Хезмәт иялəре депутатларының Киров өлкә советы депутаты (1950–54), КПССның 22 нче съезды делегаты (1961). Вятка Аланы р-нының мактаулы гражданы (1999). Урта Шөн авылының бер урамына Г. исеме бирелгән.

*Әд.:* Сибат Р. Көзге сабантуй = Осенний сабантуй. К., 2005.

**ГАЛИ́ЕВ** Айвенго Һади улы (2.12.1937, Апас р-ны Апас а.), җылылык энергетикасы һәм двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1990), проф. (1992). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Химия машиналары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1994 тән лаб. башлыгы, бер үк вакытта Мәскәү авиация ин-тында (1982 дән) һәм Мәскәү индустрия ин-тының Сергиев Посад шәһәре ф-лында (2002 дән) эшли. Г. тавыш тизлегеннән югары агымда җылылык алмашу һәм җылылык саклаучы материалларның бозылуы процессларын тикшерә. Космик аппаратларның, сыек ягулыклы ракета двигательләренең һәм кайнау темп-расы югары, ш.у. криоген компонентлы ягулык б-н эшли торган двигатель җайланмалары элементларын җирдә сынау өчен стендлар, сынау алымнарын, ягулык компонентларын кертү системаларында җылылык алмашуны кабызып җибәрү һәм интенсивлаштыру алымнарын эшли. Аның җитәкчелегендә «Энергия» транспорт космик ракеталар системасы һ.б. өчен аерым блоклар эшләп тикшерелә. 5 уку ярдәмлеге авторы. Уйлап табуга 42 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге (1982) лауреаты. Медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең К.Э.Циолковский һәм Н.А.Пилюгин исем. медальләре б-н бүләкләнә.



Г.Х. Галиәхмәтов.



Т.Ә. Галиәхмәтов.

Х е з м.: Эксплуатация испытательных комплексов ракетно-космических систем. М., 2007 (автордаш); Эксплуатация стартовых комплексов ракетно-космических систем. М., 2007 (автордаш).

**ГАЛИ́ЕВ** Әнәс Закир улы (1.5.1932, Лениногорск р-ны Сугышлы а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1982), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1980). Лениногорск шәһәренең мактаулы гражданы (1990). Лениногорск нефть техникумын тәмамлый (1976). 1950–52 елларда Уфа тимер юл идарәсенең Бөгелмә станциясендә паровоз мичењә ягучы, паровоз депосының күмер күтәрү краны машинисты. 1955–90 да «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең «Лениногорскнефть» НГДУында: оператор ярдәмчесе, оператор, нефть һәм газ чыгару мастеры (1977–90). Дәүләт бүләге хезмәттә ирешкән казанышлары, нефть һәм газ чыгаруны арттыруга керткән зур шәхси өлеше өчен бирелә. «Дары һәм нефть исе» («Запах пороха и нефти» (1995), «Ромашкалар үскән җирдә» («Там, где растут ромашки»), (1–2 кис., 1993–98) китапларын төзүчеләрнең берсе. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Әнәс Касыйм улы (3.4.1920, Казан. губ., Казан өязе Кушлавыч а. — 26.7.1996, Казан), язучы. Казан финанс-икътисад техникумын тәмамлаганнан соң (1939), Юдино һәм Дөбъяз р-ннарында, Казанда салым инспекторы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942 елның сентябрендә Майкоп шәһәре янында барган бәрелешләрдә каты яраланып, әсирлеккә эләгә. Фашист концлагерьларындагы (Польша, Германия) авырлыкларны үз җилкәсендә кичерә. 1945 нең мартында Америка гаскәрләре тоткынлыктан азат иткәннән соң, совет эвакогоспиталенә озатыла. 1945 нең октябрендә Казанга әйләнеп кайта. 1946–70 елларда (бүленеп) ТАССР Финанс министрлыгы оешмаларында эшли. Беренче шигырьләре 1937 дә басыла. Г. — «Сөю» (1940), «Кыен юл» (1958), «Тормыш бакчасында» (1960) исемле шигъри җыентыклар авторы. 1960 еллардан, нигездә, проза өлкәсендә иҗат итә. Фашист тоткынлыгының газаплары автобиографик характердагы «Йолдызлар шаһит» (1968), «Һәр солдатның үз язмышы» (1991) повестьларында чагылыш таба. Финанс оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә багышланган «Намус кушканча» (1982) , «Җәза озак көттермәде» (1994) повестьлары да әдипнең тормыш тәҗрибәсеннән алынган. «Авылдашлар»

(1995) романында фәлсәфи-психол. анализ аша кешенең эчке дөньясы ачып бирелә.

*Әд.:* Р а с и х А. Язучы турында берничә сүз // Социалистик Татарстан. 1970. 5 апр.; Г ы й л ә - җ е в А. Борма юллар үтеп // Социалистик Татарстан. 1990. 1 апр.; Г а л и м у л л и н Ф. Авылдашлар кемнәр алар? // Шәһри Казан. 1993. 3 апр.
*Г.М.Габделхакова.*

**ГАЛИ́ЕВ** Әсрар Әбрар улы (16.10.1938, Әлки р-ны Түбән Биктимер а. — 13.8.1998, Лениногорск ш.), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1971). Укытучы, шахтёр булып эшли, республика һәм район газета-журнал редакцияләре б-н хезмәттәшлек итә. «Төнге җыр» (1980) дип аталган хикәяләр җыентыгында татар халкының милли гореф-гадәтләре үзенчәлекләре турында сүз бара. «Асыл кошым минем» (1987) повесте, «Көн яктысы» (1993) романы шахтёрлар тормышыннан алып язылган. 1996–97 дә аның «Гали батыр» (1–2 кит., 1–4 *т.*) исемле автобиографик повесте дөнья күрә. Г. әсәрләренең геройлары — тормыш кадерен белгән, гадел, максатларына ирешүчән шәхесләр.

*Әд.:* М а н н а п о в Ш. Гали батыр оныгы // Казан утлары. 1998. № 11.

**ГАЛИ́ЕВ** Әхмәт Мөхетдин улы (10.8.1931, Арча р-ны Сеҗе а.), машина төзүче, «Казан компрессор машиналары төзү заводы» АҖ директоры, ген. директоры (1973–96), техник фән. д-ры (1994), ТАССРның атказ. машина төзүчесе (1991). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1958). 1951–58 елларда 16 нчы з-дта (хәзер Казан моторлар төзү ҖБ) мастер, инженер-конструктор булып эшли. 1958–65 тә КПССның Татарстан өлкә комитетында инструктор, оборона сәнәгате бүлеге мөдире. 1965–72 дә компрессорлар төзү махсус КБның баш инженеры, 1972–73 тә Казан компрессорлар з-ды баш инженеры. Г. җитәкчелегендә з-дта 100 дән артык төрдәге компрессор җайланмалары һәм суыткыч машиналар җитештерү гамәлгә кертелә. Хезмәтләре компрессорларның шуу подшипникларын тикшерү һәм ясау, компрессорлар һәм суыткыч машиналар җитештерүне оештыру мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге бирелә (1981). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт двустороннего конического подшипника скольжения // Тр. Казан. хим.-технол. ин-та.

**ГАЛИ́ЕВ** Әхмәтсәлим Сабир улы (18.3.1955, Норлат ш.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2000). 1977 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, 2000 елга кадәр Уфа нефть техник ун-тының Октябрьский ф-лында эшли. 2001 дән Әлмәт нефть ин-тында нефть-газ җиһазлары каф. профессоры. Хезмәтләре нефть скважиналарындагы бораулау һәм суырту җиһазларының эш динамикасына карый. Авыш һәм горизонталь скважиналардагы бораулау кәүсәсе буйлап тирбәнеш таралу процессын тикшерә. Гидравлик вибратор, бораулау агрегатларын үзкләтү өчен җайланмалар комплекты һәм насосларның гидравлик файдалы эш коэффициентын термодинамик ысул б-н үлчәү өчен микропроцессорлы прибор эшли һәм җитештерүгә кертә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Вибродиагностика насосных агрегатов. Уфа, 1990 (автордаш); Техника управления динамикой бурильного инструмента при проводке глубоких скважин. М., 1997 (автордаш); Эффективность работы насосных агрегатов. Уфа, 2004 (автордаш).

**ГАЛИ́ЕВ** Булат Мәхмүт улы (2.10.1940, Ташкент ш. — 5.1.2009, Казан), философ, хәзерге заман эксперименталь сәнгате теориясе һәм практикасы белгече, филос. фән. д-ры (1987), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). 1962 елда Казан пед. ин-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый. 1963 тән Казан авиация ин-тында укыта, 1966 дан ин-тның «Прометей» махсус КБ җитәкчесе, 1994 тән ТР ФА һәм Казан техник ун-тының «Прометей» уртак фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, бер үк вакытта Казан консерваториясендә проф. (1991), ТР ФАнең табигыять фәннәре гыйльми советы рәисе (1992). Хезмәтләре сәнгать төрләренең үзара кушылуы, хисси танып белүне системалы өйрәнү, сәнгатьтәге синестезиянең табигате һәм функцияләре, *төсле музыканың* генезисы, *яктылык архитектурасы* үзенчәлекләре, абстракт кино, тиреләк музыкасы һәм сәнгатьнең лазер, компьютер техникасын кулланучы башка формалары мәсьәләләренә карый. Эксперименталь композицияләр, яктылык концертлары, спектакльләр һәм фильмнар (башлыча, И.Л.Ванечкина б-н бергәләп, фәнни-тикшеренү ин-тының «Прометей» техник төркеме катнашында), ш.и. СССРда беренчеләрдән булып ачык һавада актёр катнашыннан башка куелган яктылык һәм тавыш спектакле (Бөтенроссия театр фестивале дипломы, 1970), Г.Свиридов музыкасына «Кечкенә триптих» («Маленький триптих») төсле музыка фильмы (Прагада узган халыкара кино фестивале дипломы, 1975) режиссёры; Казанда Салих Сәйдәшев музеен төсле музыка б-н театральләштерү, «Совет Фаусты» («Советский Фауст») кинофильмы сценарие («Зеркало-98» бөтенроссия конкурсы дипломы) авторы . Г. «Яктылык һәм музыка» бөтенсоюз фестивалендә (Казан, 1987), «Яңа сәнгать» республика күргәзмәсендә (Казан, 1993), «Электра-83» (Париж ш., Франция), «Ars electronica-89» (Линц ш., Австрия), «WRO-89» (Вроцлав ш., Польша), «Images du Futur-91» (Монреаль ш., Канада), «Impakt-91» (Утрех ш., Нидерланд), «Video-art-91» (Локарно ш., Швейцария), «Academia of light-91» (Гаага ш., Нидерланд), «Ostranenie-93 (-95, -97)» (Дессау ш., Германия), «Videofenster-98» (Базель ш., Швейцария), «Oberhausen-2000» (Оберхаузен ш., Германия) халыкара фестивальләрендә һәм күргәзмәләрендә, ш.у. Голландия, Ирландия, Франция, Австриядә узган халыкара симпозиумнарда катнаша. Каралы-аклы тасмага төшергәндә күп төсле абстракт фильмнар иҗат итү ысуллары, лазер нурының парга әверелүче матдә аша үтүе нәтиҗәсендә «очраклы фазалы модульләү юлы» б-н хәрәкәттәге яктылыкның интерференцион сурәтен китереп чыгару ысуллары кебек ачышларга авторлык таныклыгы бар. РФ Кинематографистлар берлеге (1991; 1979 дан СССР Кинематографистлар берлеге), СССР Дизайнерлар берлеге (1991), Россия Язучылар берлеге (2001), халыкара «Сәнгать-фән-техника» җәмгыяте һәм аның «Leonardo» ж-лы редколлегиясе (1987) әгъзасы.



«Прометей (Скрябин+Кандинский)» концерт куелышыннан күренеш. Казан. 1996.

Х е з м.: Светомузыка: становление и сущность нового искусства. К., 1976; Поющая радуга. К., 1980; Поэма огня. К., 1981 (автордаш); Человек-искусство-техника. К., 1987; Искусство космического века. К., 2002.

*Әд.:* Х а р и с Р. Булат Галиев турында бер-ике сүз // Идел. 1970. Чыг.1; Б а л а ш о в Ю. Самый большой прикол // Казань. 2000. № 10; Музыканты мира: Биогр. словарь. М., 2001; А л е к с е - е в П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002; А б д у л л и н Р. Периодическая система искусств Булата Галеева // Респ. Татарстан. 2003. 24 июня.

**ГАЛИ́ЕВ** Вил Зәйнулла улы (25.2.1938, Алма-Ата ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1983). Казакъ ун-тын тәмамлый (1960). Төркестан пед. уч-щесендә (Чимкент өлкәсе), Чимкент һәм Караганда пед. ин-тларында эшли. 1968–90 елларда Казакъ хатын-кызлар пед. ин-ты укытучысы. 1990–95 тә Казакъстан Респ-касы ФАнең Тарих, археология һәм этнография ин-тында Казакъстанның яңа заман тарихы бүлеге мөдире, соңрак Казакъстан Респ-касы Милли китапханәсендә баш фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта баш китапханәче. Хезмәтләре Россиядәге революцион-демократик хәрәкәтнең 19 йөздә Казакъстанның иҗтимагый-сәяси тормышына йогынтысын өйрәнүгә карый. Китапханәчелек буенча хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Татар тылмач-сәяхәтчеләр // Казан утлары. 1968; Ссыльные революционеры в Казахстане (вторая половина XIX в). А.-А., 1978; Медицинская деятельность ссыльных революционеров в Казахстане (вторая половина 19 в.). А.-А., 1982; Декабристы и Казахстан. А.-А., 1990; Библиотечное дело в Казахстане (вторая половина XIX — начало XX веков). Алматы, 1998; Тюркская библиотека в Верном. Алматы, 1998.

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

**ГАЛИ́ЕВ** Габделхак Гали улы (2.8.1916, Мамадыш өязе, хәзерге Теләче р-ны Олы Нырсы а. — 23.7.1991, шунда ук), Соц. Хезмәт Герое (1966), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Хезмәт

юлын 1934 елда Теләче р-нының «Кремль» к-зында колхозчы булып башлый, 1936 дан шул ук колхозда хисапчы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942 дән Теләче р-ны башкарма ком-тында җир эшләре бүлеге мөдире, а.х. идарәсе һәм әзерләүләр бүлеге башлыгы (1953 кә кадәр), 1954–56 да рәис урынбасары. 1956–61 дә Кызыл Йолдыз һәм Балык Бистәсе р-ннарында РТС һәм МТС директоры. 1961–77 дә Теләче р-нының *Ленин исем. Тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы* директоры. Аның җитәкчелегендә хуҗалык а.х. культураларының уңышы, бөртекле культуралар, күпьеллык үләннәр һәм бәрәңгенең элиталы орлыкларын җитештерү, игенчелек һәм терлекчелектә интенсив технологияләр кертү буенча республикада алдынгы хуҗалыкка әверелә. Хуҗалыкта югары артымлы эре-ак токымлы дуңгыз, уртача еллык савымы 4000 *кг* нан артык булган кара-чуар токымлы сыер көтүләре булдырыла. Г. сугарулы культуралы болыннар булдыру энтузиастларның берсе. 1963–67 дә ТАССРның ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а т в е е в а Е. Галеев Габделхак Галеевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980.

**ГАЛИ́ЕВ** Габдулла, к. *Батырша*.

**ГАЛИ́ЕВ** Гайфетдин Сәләхетдин улы ( Гай Саевич) (18.11.1911, Сембер губ., Буа өязе Янгелде а. — 7.2.1996, Краснодар краеның Кавказ р-ны Ботаника пос.), агроном, селекция белгече, а.х. фән. д-ры (1962), ВАСХНИЛ академигы (1973), Соц. Хезмәт Герое (1971). Краснодар селекция һәм орлыкчылык ин-тын тәмамлый (1934). 1934–36 елларда «Таловский» с-зында агроном, 1936 дан Каменно-Степь селекция станциясендә (Воронеж өлкәсе), 1940 тан Мордва АССРның республика колхозчы кадрлар мәктәбендә эшли. 1946–96 да Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тының Кубань тәҗрибә станциясендә фәнни хезмәткәр, бүлек мөдире, директор урынбасары. Хезмәтләре кукуруз селекциясе һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. Күренекле галим — селекция белгече. Кукурузның уннарча сортларын һәм гибридларын чыгара (уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы бар). Чехословакия, Болгария, Югославия, ГДР һ.б. илләрнең фәнни-тикшеренү учреждениеләре б-н бергәләп кукуруз гибридларын районлаштыра. Селекция белгечләренең «Север» иҗат берлеге (1972 дән), сорго һәм кукуруз буенча Эукарпия секциясе Көньяк комитеты (1977–79) әгъзасы. Халык депутатларының Краснодар крае советы депутаты (1971–83). Ленин премиясе (1963) һәм СССР Дәүләт бүләге (1986) бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының 8 медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Результат изучения и селекционного использования цитоплазматической мужской стерильности кукурузы на Кубанской опытной станции ВИР // Цитоплазматическая мужская стерильность в селекции и семеноводстве кукурузы. Киев, 1962; Гетерозис и повышение продуктивности кукурузы // Гетерозис служит человеку. М., 1968; Селекция высоколизиновой кукурузы на Кубанской опытной станции ВИР // Вестн. с.-х. науки. 1971. № 12; Сравнительное изучение продуктивности гибридов кукурузы на разных типах ЦМС // Сельскохозяйственная биология. 1986. № 8; Селекция кукурузы с повышенным содержанием белка в зерне и улучшенным его качеством // Науч.-техн. бюл. ВИР. 1989. Т. 189.

*Әд.:* С и д о р о в Ф.Ф. Селекционеры — новаторы // Вестн. с.-х. науки. 1962. № 7; Х а д ж и н о в М.И. К 60-летию члена-корреспондента ВАСХНИЛ Г.С.Галеева // Вестн. с.-х. науки. 1971. № 11; П л о с к о в Ф.Н. Зёрна жизни. Краснодар, 1978; Б р е ж н е в Д.Д., Ш м а р ё в Г.Е. К 70-летию академика ВАСХНИЛ Г.С.Галеева // Вестн. с.-х. науки. 1981. № 12; Ш м а р ё в Г.Е. Славный юбилей выдающегося селекционера // Бюл. ВИР. 1981. Вып. 115; С о т ч е н к о В.С. Юбилей селекционера // Кукуруза и сорго. 1991. № 6. *Ф.С.Зыятдинов.*

**ГАЛИ́ЕВ** Гариф Закир улы (10.5.1903, Самара губ., Бөгелмә өязе Урманай а. — 22.3.1985, Казан), язучы. 1918 елга кадәр «Гобәйдия» мәдрәсәсендә, соңыннан Бөгелмә укытучылар семинариясендә укый. 1928–41 елларда «Сабанчы», «Колхоз газеты» г-талары, «Советлар канаты», «Колхоз бригадиры» ж-ллары редакцияләрендә җаваплы сәркәтип булып эшли. 1941–46 да — «Кызыл сугышчы», «Кызыл Армия» фронт г-таларында хәрби хәбәрче, җаваплы сәркәтип. Сугыштан соңгы елларда «Кызыл Татарстан» г-тасы, «Сельское хозяйство Татарстана» ж-лы редакциясендә. «Вәли ничек кызылармеец булды» дигән беренче хикәясе 1925 тә «Эшче» г-тасында басыла. 1927 дә «Кызыл Армия хикәяләре» дип аталган беренче җыентыгы дөнья күрә. Иҗатында чагылыш тапкан төп тема — татар авылының үткәне һәм бүгенгесе («Еллар һәм кешеләр», 1951; «Мин авылны яратам», 1960; «Старый дуб», 1976; «Җир турында җыр», 1980; «Без авылныкылар», 1982; «Истә, һаман истә», 1986). Балаларга багышланган «Борчаклар сөенәләр» (1962), «Чәчәкле малайлары» (1965), «Хикәяләр» (1970) җыентыклары, авыл театрлары өчен язылган бер пәрдәлек пьесалар авторы. Г. аеруча 1949 да Мәскәүдә — рус телендә, 1956 да Дрезденда немец телендә басылган «Хаттан башланды» комедиясе б-н таныла. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1961.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Яңа авыл җырчысы // Казан утлары. 1983. № 5; А б с а л я м о в А. Самобытный талант // Советская Татария. 1973. 12 мая.

**ГАЛИ́ЕВ** Данил Юныс улы (10.8.1948, Биектау р-нының Татар Әйшәсе а. — 23.3.1993, Түбән Кама ш.), спортчы, татарча көрәш буенча РСФСРның спорт остасы (1972), классик көрәш буенча СССРның спорт остасы (1976). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1983). «Урожай» спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Чистай ш., 1967 дән тренеры *М.М.Сәхәбетдинов*). 1971 дән Түбән Камада яши. Татарча көрәш буенча РСФСР (1971–76, 1979–80), ТАССР (1971–83) чемпионы, ТАССРның баш батыры (1979, 1983). 1995 тән ел саен Түбән Кама шәһәрендә Д.Ю.Галиев истәлегенә республика турниры үткәрелә.

*Әд.:* «Без көрәшле халык». Чабаксар, 2003.



Габделхак Г. Галиев.



Г.С. Галиев.

**ГАЛИ́ЕВ** Илгиз Гакыйф улы (12.4.1965, Түбән Кама р-ны «Прикамский» с-зы), авыл-хуҗалыгын механикалаштыру гыйлеме белгече, техн. фән. д-ры (2004), проф. (2005). 1987 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлый, шунда ук энергия-ресурс саклау кафедрасында эшли. Хезмәтләре а.х. техникасыннан нәтиҗәле файдалануга карый. Агрегатларның техник эксплуатацияләү дәрәҗәсен һәм торышын бәяләү алымнарын эшли; тракторларның эшләү шартларыннан чыгып, оптималь ремонтлау һәм эшләтү срокларын нигезли.

Х е з м.: Повышение эффективности использования тракторов с учётом условий их функционирования. К., 2002; Рабочий проект по управлению работоспособностью тракторов с учётом их состояния и условий функционирования. К., 2002.

**ГАЛИ́ЕВ** Илгиз Гатуф улы (26.4.1957, Ахалцихе ш., Грузия ССР), физик, физика-матем. фән. д-ры (1996). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан техник ун-тында эшли, 1996 дан гомуми физика каф. профессоры. Хезмәтләре үтә тигезләшмәгән түбән темп-ралы газ бушану плазмасын фәнни тикшерүгә карый. Газны төрлечә кудыру шартларында газдагы бушанудан хасил булган түбән темп-ралы плазманың санча һәм аналитик модельләрен эшли. Криоген темп-ралардагы газны тавыштан югары тизлектә бик кечкенә сопло аша кудырганда барлыкка килгән пыскулы бушануны фәнни тикшерә. Лазер өчен югары нәтиҗәле бушану камерасы эшли.

Х е з м.: Модель положительного столба тлеющего разряда в потоке смеси газов // Теплофизика высоких температур. 1992. Т. 30 (автордаш); Генерация низкотемпературной плазмы и плазменные технологии: проблемы и перспективы // Низкотемпературная плазма. Новосиб., 2004. Т. 20 (автордаш).

**ГАЛИ́ЕВ** Илдус Хәмит улы (31.10.1934, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1964). 1963–64 елларда КПССның Казан шәһәре Идел буе райкомы инструкторы, 1964–67 дә бүлек мөдире, 1973–80 дә 1 нче секретаре. 1967–70 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1970–73 тә Казан төгәл машиналар төзү з-ды парткомы секретаре. 1980–87 дә ТАССР Дәүләт иминлеге ком-ты рәисе. 1988–89 да Гамәли оптика ин-ты директоры урынбасары. 1989–94 тә ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе. 1994–2001 дә «Тал-связь» (Казан) уртак пр-тиесенең директорлар советы рәисе. 1975–90 да ТАССР

ЮС депутаты. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Илсур Илдар улы (21.5.1959, Казан), җылылык энергетикасы инженеры. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлагач (1982), «Энергоспецмонтаж» җитештерү берләшмәсендә (Мәскәү) мастер, көйләүче инженер; В.И.Ленин исем. Казан химия з-дының казаннар цехында өлкән мастер булып эшли. 1984 елдан «Татэнерго» АҖнең ТЭЦ-3 ф-лында: турбиналы казан цехының блоклы системасы б-н идарә итү машинисты, сәнәгый ташландык суларны термик эшкәртү цехында өлкән мастер, турбиналы казан цехы башлыгы урынбасары, ТЭЦ-3 тә баш инженер (1999 дан). Аның җитәкчелегендә Казандагы ТЭЦ-3 тә термик ысул б-н дистиллят комплексын эшләтү гамәлгә ашырыла, казаннар, турбиналар, аркылы салынган пар үткәргечләре алыштырыла. Т-120–130 һ.б. җылылык үткәрү турбиналары реконструкцияләнә. Дәүләт бүләге «Югары басымлы казаннар өчен термик су әзерләүнең югары нәтиҗәле һәм экологик камил технологиясен эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. РФ Энергетика министрлыгының мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Максуд Салих улы (10.11.1951, Саба р-ны Урман хуҗалыгы пос.), урман хуҗалыгы инженеры, ТАССРның атказ. урманчысы (1991), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Мари политехник ин-тын тәмамлый (1988). 1972 елдан Саба урман хуҗалыгында: 1975 тән Сабабаш урманчылыгында урманчы ярдәмчесе, 1982 дән Шәмәрдән урманчылыгында урманчы, 1998 дән урман хуҗалыгы бүлеге башлыгы, 1999 дан баш урманчы. ТРның Дәүләт бүләге «Урман кискәндә урман байлыгын саклап калуны, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агачларны нык эшкәртүдә алдынгы ысуллар кертүне оештыру, Саба урман хуҗалыгында чыршылар үстерүнең стадияләрен тизләтүне гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә (2003).

**ГАЛИ́ЕВ** Марсель Баян улы (8.10.1946, Азнакай р-ны Балтач а.), шагыйрь, прозаик, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995). Казан ун-тын (1974) һәм Әдәбият ин-ты каршында югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1985) тәмамлый. Беренче шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1972) исемле күмәк җыентыкта басыла. «Еллар чалымы» (1979), «Апрель кызы» (1985), «Су буеннан әнкәй кайтып килә» (1992), «Гомер бизмәне» (2004) дигән шигырь җыентыклары авторы. Шигырьләренә нечкә психологизм, үзенчәлекле стиль хас. Лирикасы көчле гражданлык хисе б-н сугарылган, актив социаль яңгырашлы. Г.нең 1980 дә «Ул чакта» дип исемләнгән беренче проза китабы басыла. Дөньяның катлаулы якларын, һәртөрле тормыш вакыйгаларын үзенчә сурәтләргә омтылу, үзенчәлекле алымнар табу, психологик тирәнлек, сурәтле әдәби тел осталыгына ирешү Г. әсәрләренең нигезен тәшкил итә. «Ерак урман авазы» романында (1981), «Нигез» (1984), «Алтын тотка» (1988) повестьларында һәм күпләгән хикәяләрендә Г. үткән гасыр азагының катлаулы сынауларын узган замандашлары образларын тудыра. Очерклар, юлъязмалар, татар язучылары һәм сәнгатькярләренең әдәби портретларын үз эченә алган, әдәбият-сәнгать мохитенең шул дәвердәге



М. Галиев.

елъязмасын хәтерләткән «Догалы еллар» (1998), чор, заман, милли тарихыбыз турында фәлсәфи уйланулары тупланган «Рух» (2005) китаплары укучыларга яхшы билгеле. Г. ш.у. юмористик хикәяләр дә иҗат итә, публицистик мәкаләләр б-н матбугатта еш чыгыш ясый. Аның әсәрләре рус, төрек, поляк, украин, үзбәк, казакъ, чуаш һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. Кайбер шигырьләре көйгә салынган һәм халкыбызның яраткан җырларына әверелгән. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә, Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2006).

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1998–99.

*Әд.:* Ф ә й з у л л и н Р. Марсель Галиев // Казан утлары. 1980. № 8; Х ө с н и Ф. Яшьлек яшел генә димә // Карурманга керсәң. К., 1984; Т и м е р г а л и н А. Марсельезалы сәхифәләр // Мәдәни җомга. 2006. 29 сент.

**ГАЛИ́ЕВ** Мәнсаф Нури улы (22.12.1925, БРның хәзерге Чакмагыш р-ны Яңа Калмаш а.), генерал-майор (1977). Тыл һәм транспорт хәрби академиясен тәмамлый (1959, Ленинград). 1942 елда 2 нче Әстерхан хәрби пехота уч-щесенә җибәрелә. 1944 тән фронтта, укчы взвод командиры. 3 нче Украина фронты гаскәрләре составында Яссы-Кишинёв һөҗүм операциясендә (1944), Венгрия, Австрия терр-яләрендә барган сугышларда катнаша. 1946 дан Венада Совет зонасы хәрби коменданты идарәсендә хезмәт итә. 1951–56 да Карпат яны хәрби округында рота командиры, полк мәктәбе башлыгы урынбасары, укчы батальон штабы башлыгы. 1959–83 тә Германиядә Совет гаскәрләре төркемендә, соңрак Белоруссия хәрби округында полк, дивизия командирлары урынбасары, штаб башлыгы һәм берләшмәнең тыл хезмәте идарәсе башлыгы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Генералы Башкортостана. Уфа., 1995.

**ГАЛИ́ЕВ** Мәхмүт Әхмәтвәли улы (16.9.1928, Оренбург ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1968), проф. (1968), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976), РФнең атказ. табибе (2002). Оренбург мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Казакъстан ССРның Актүбә өлкәсе мед. учреждениеләрендә эшли. 1958 елдан Башкорт мед. ин-тында, 1968 дән балалар хирургиясе, 1970 тән гомуми хирургия, 1979 дан ф-т хирургиясе, 1985 тән хирургия авырулары, 1988–93 тә урология һәм эндокринология курслары б-н хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре бавыр, үт юллары, ашказаны асты бизе хирургиясенә, төрле урыннардагы ялкынсынулы авыруларны дәвалау һәм аларга диагноз куюга карый. Г. үт ташлары ясалу сәбәпләрен, үт ташлары барлыкка килүдә микроэлементлар (марганец, тимер, никель һ.б.) җитмәү ролен өйрәнә. Г. гемотогенлы остеомиелитка радиоизотоп диагноз куюны, панкреат эчәк анастомозы техникасының яңа ысулын гамәлгә кертә (1959), эренле-ялкынсынулы авыруларны дәвалауда лазер хирургиясен куллануны тәкъдим итә (1998). Г. Башкортстанда беренчеләрдән булып үт юллары хирургиясе мәсьәләләрен тикшерүче, Г.Г.Куватов исем. клиник хастаханә каршында (БР) Республика үт юллары һәм бавыр хирургиясе үзәген оештыручы. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оперативное лечение рака поджелудочной железы. М., 1959; Желчно-каменная болезнь. Уфа, 1975; Остеомиелит. Уфа, 1978.

**ГАЛИ́ЕВ МӘЧЕТЕ́,** (Казандагы 5 нче җамигъ мәчет, Баруди мәчете) Казанда 18 йөз ахыры — 19 йөз башына караган татар дини архит-расы истәлеге. Печән базары мәчете, Муса бай мәчете дип тә аталган. 1798–1801 елларда сәүдәгәр Муса Мәмәш иганәсенә Печән базары янында башлангыч классицизм формаларында төзелә.

Күп тапкырлар үзгәртеп корулардан соң, хәзер төньягына янкорма өстәлгән, көньяк өлешенең почмаклары китекләндерелгән, озынча һәм турыпочмаклы, түбәсендә манарасы булган ике заллы мәчетләр төренә керә. Башта ике гыйбадәт залы һәм вестибюле булган үзәк өлеше салына. Залларны бүлеп торган калын дивардан сигез кырлы, өч катлы, чатырланып төгәлләнүче мәчет манарасы күтәрелә.

Фронтоннар б-н төгәлләнгән ризалит чыгынтылары фасадларны симметрияле итә. 1882 дә мәчетнең көньягында сәүдәгәр И.С.Уразаев акчасына янкорма салына (арх. П.И.Романов). 1897 дә сәүдәгәрләр М.И.Галиев һәм И.Г.Иманколов иганәсенә бина көньяк һәм төньяктан киңәйтелә. Бер үк вакытта түбәсе күп кыеклы итеп ябыла, ул беркадәр үзгәртелгән өч катлы манара һәм көньяк янкорма өстендәге чатыр б-н төгәлләнә. Төньягындагы ишектән тыш, көньяктан да ишек уела. Янкормаларның фасадлары бизәлеше мәчетнең үзәк өлеше диварлары б-н бер үк стильдә. 1931 дә гыйбадәтханә ябыла. 1930 елларда манарасы җимертелә, эчке катларының саны үзгәртелә, 1 нче катта һәм михраб чыгынтысында ишекләр уела. Интерьерлары



Галиев мәчете. Казан. 1798–1801 елларда төзелә. 20 йөз башы фотосурәте.

сакланмаган. 1882–1917 дә күренекле исламият галиме, ислахчы педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Оренбург мөселманнар Диния нәзарәте мөфтие Г.М.*Баруди* (Галиев) мәчеттә имам-хатиб булып тора. Атасы — сәүдәгәр М.И.*Галиев* б-н бергәләп ул мәчет каршында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ача. 1992 дән Г.м. кабат үз вазифаларын башкара.

*Әд.:* Х а л и т о в Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1982; Мечети Татарстана / Сост. Надырова Х.Г., Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. К., 2000.

*Н.Х.Халитов.*

**ГАЛИ́ЕВ** Миңгол Вагыйз улы (27.8.1941, Мамадыш р-ны Иске Комазан а.), җырчы (тенор), педагог, муз.-җәмәгать эшлеклесе, ТРның халык артисты (1992). Казан консерваториясен (М.Кольцов классы) тәмамлый (1970). 1969–74 елларда ТАССРның 10 еллыгы исем. Мәдәният сарае каршында татар хоры коллективы җитәкчесе, 1974–79 да ТАССРның Хор җәмгыяте җаваплы сәркәтибе, 1979–87 дә СССР Музыка фондының Татарстан бүлеге директоры. 1978 дән Казан пед. ун-тында укыта (1998–2001 дә вокаль әзерлек каф. мөдире). Камера концерты җырчысы буларак, еш чыгыш ясый. Г. репертуарының нигезен татар халык җырлары һәм Татарстан композиторлары әсәрләре тәшкил итә. Җырчы күбрәк татар халык музыка иҗатының классик үрнәкләрен, аеруча *мөнәҗәтләр*не башкаруга игътибар бирә. 1987–91 дә Казанда «Татар җырлары антологиясе» дигән тематик соло концертлары циклы үткәрә. Муз. агарту эшчәнлеге алып бара. Концертлар б-н Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә (Болгария, Япония, Төркия һ.б.) гастрольләрдә була. Татар вокаль музыкасы культурасына караган язмалар авторы. Радиодан (фондта 100 гә якын язмасы саклана), телевидениедән чыгышлар ясый. Шәкертләре арасында эстрада-вокал башкаручылары — БРның атказ., ТРның халык артисты А.Галимов, ТРның атказ. артисты Р.Закиров һ.б. бар.

*Ф.Ш.Салитова.*


**ГАЛИ́ЕВ** Мөхәммәтҗан Ибнеәмин улы (4.9.1832, Казан — 1908 яки 1909, шунда ук), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, сәнәгатьче, җәмәгать эшлеклесе. Г.*Барудиның* әтисе. 100 гә якын модельдә милли аяк һәм баш киемнәре җитештергән ф-ка хуҗасы. 1893 елда Чикаго шәһәрендә (АКШ) уздырылган халыкара күргәзмәдә күннән затлы әйберләр җитештерүе өчен бүләкләнә, 1898 дә Түбән Новгородта узган Бөтенроссия күргәзмә-ярминкәсендә аңа көмеш медаль бирелә. 1904 тә «М.И.Галиев һәм уллары» дип аталган сәүдә йорты оештыра. Аның Уфа, Эрбет, Троицк шәһәрләрендә милли аяк киемнәре сату буенча бүлекчәләре булдырыла (устав капиталы — 25 мең сум). 1875–1905 тә Казан шәһәр думасы гласные, шәһәр управасы әгъзасы (1875–80), Казан шәһәре җәмәгать банкының исәп-хисап ком-ты әгъзасы (1880–83 һәм 1887–98). Мөселман зираты идарәчеләренең берсе (1876 дан). «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе төзелешенә, *Галиев мәчетен* яңартуга, Б.И.Үтәмешеваның Казандагы җәдит мәктәбенә (1890) акчалата иганә кыла. «*Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте*»н оештыруга ярдәм итә (1898). Дүрт улы (Галимҗан, Газизҗан, Салихҗан һәм Габдерахман) арасыннан Газизҗан гына (1859 — ?) аның эшчәнлеген дәвам итә, калганнары дин эшлеклеләре була.



М.В.Галиев.



Н.М.Галиев.



Р.Г.Галиев.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 1; Д е в я т ы х Л.И. Из истории Казанского купечества. К., 2002.

*Р.Р.Салихов.*

**ГАЛИ́ЕВ** Наил Әхмәт улы (8.3.1930, БАССРның Дәүләкән р-ны Тугай а. — 14.11.1997, Уфа ш.), галим-агроном, яшелчәчелек белгече, а.х. фән. д-ры (1988), проф. (1990). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1956). 1960–62 елларда Балашов а.х. тәҗрибә станциясендә үсемлекчелек һәм игенчелек лаб-ясе мөдире (Саратов өлкәсе). 1962 дән Казан пед. ин-тында, ботаника каф. мөдире (1964–66). 1966 дан Башкортстан а.х. ун-тында физиология һәм биохимия каф. мөдире, 1988 дән үсемлекләр селекциясе һәм физиологиясе каф. профессоры. Башкортстанның таулы-урманлы зонасында игенчелек системасын, яшелчә культуралары чәчүлекләрендә чүп үләннәр б-н көрәшү ысулларын һәм сызма культураларны үстерү технологиясен эшли, бу ысуллар Урта Идел һәм Уралдагы хуҗалыкларда киң кулланыла. 1970 елларда яшелчә культураларын үстерүнең интенсив технологияләрен эшләү һәм биологияне комплекслы өйрәнү буенча Г. җитәкчелегендә фәнни юнәлеш барлыкка килә.

Х е з м.: О системе земледелия в горно-лесной зоне Башкирии // Сельское хоз-во Башкирии. 1957. № 1; Занятые пары. Саратов, 1962; Химическая борьба с сорняками. К., 1964; Промышленное выращивание моркови. Уфа, 1985; Программирование урожая овощных культур. Уфа, 1989; Овощи, малораспространённые в Башкортостане. Уфа, 1996.

**ГАЛИ́ЕВ** Нургали Мөхәммәтгали улы (25.5.1914, Оренбург өлкәсенең хәзерге Шарлык р-ны Сарманай а. — 28.4.1977, Төркмәнстан ССР, Ашхабад ш.), Сов. Союзы Герое (26.10.1943), гв. рядовое. Сугышка кадәр ташчы булып эшли. 1941 елның октябреннән Кызыл Армиядә. 1943 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 387 нче аерым сапёр батальоны (7 нче гв. армиясенең 213 нче укчы дивизиясе) сапёры. Воронеж, Дала, 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында катнаша (1943). 1943 нең 27 октябрендә Переволочна янында (Полтава өлкәсе, Кобеляк р-ны Светлогорский а.) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Кировоград, Умань-Ботошани, Яссы-Кишинёв, Дебрецен, Будапешт, Братислава-Брно һәм Прага һөҗүм операцияләрендә катнаша (1943–45). Сугыштан соң Мары һәм Ашхабад шәһәрләрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЛИ́ЕВ** Равил Сәет улы (16.6.1947, Казан — 18.7.2006, шунда ук), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли. 1970–75 елларда Ульянов политехник ин-тында, 1975 тән Казан ун-тының Математика һәм механика фәнни-тикшерену ин-тында. Хезмәтләре газ динамикасына һәм аэрозольләр механикасына карый. Г. Лаваль соплоларында һәм лазер генераторы зонасында (оптик резонаторда) актив тирәлек (тутырып кабартылган зонада тирбәнүле газның) агышын исәпләү буенча берничә мәсьәләне чишә. Резонатор эчендә лазер нурланышы таралуны исәпләүнең оригиналь юлларын тәкъдим итә. Стационар һәм стационар булмаган пыскулы бушануларны исәпләүнең эффектив санлы ысулларын үстерә, аркылыга һәм буйлыга бушана торган газ бушанулы лазерларның матем. модельләрен һәм исәпләү алымнарын эшли, ике үлчәнештә пыскулы бушану турындагы мәсьәләнең яңа куелышларын тәкъдим итә. Аэрозольләр агышын модельләү өлкәсендә тикшеренүләр үткәрә.

Х е з м.: Приближённый метод расчёта неустойчивых телескопических резонаторов // Квантовая электроника. 1982. Т. 9, № 6; Моделирование быстропроточного $CO_2$-лазера с продольным разрядом в трубе переменного сечения // Теплофизика высоких температур. 1996. Т. 34, № 1; Teoretical investigation of ozone producing in high pressure axial flow de glow discharge in air // 12th International Conference on Gas Discharges Their Applications. Greifswald, 1997. V.2.

**ГАЛИ́ЕВ** Ринат Гали улы (12.1.1947, Ютазы р-ны Кәрәкәшле а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), техник фән. канд. (1997). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1969). 1971–72 елларда «Татнефть» АҖнең «Сөләйнефть» НГДУында нефтьне комплекслы әзерләү җайланмасы башлыгы. 1972–94, 1997–99 да «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: нефть химиясе з-ды цехында башлык урынбасары, башлык, этилен з-дында баш инженер урынбасары, өстәмә продукты пропилен оксиды булган стирол җитештерү тәҗрибә-сәнәгать з-ды баш инженеры, директоры, АҖнең ген. директор урынбасары (1985–94), ген. директоры



Ф.Г. Галиев.



Шакир Г. Галиев.

(1997 дән). 1994–96 да «Полифом» фирмасы ген. директор урынбасары (Түбән Кама ш.). 1996–97 дә нефть химиясе комплексы ген. директоры урынбасары, бер үк вакытта «Татарстан-Америка инвестицияләре һәм финанслары» АҖнең (Казан) Түбән Камадагы вәкиллеге директоры. 1999 дан Мәскәүдә эшли һәм яши. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы, 17 патенты бар. Дәүләт бүләге «Түбәнкаманефтехим» АҖдә бутилкаучук, пропилен оксиды һәм стирол җитештерү химик технологиясенең теоретик нигезләрен эшләү һәм камилләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Ринат Гыймаделислам улы (13.1.1939, Әлмәт р-ны Шарлама а. — 23.10.2007, Әлмәт ш.), нефтьче, «Татнефть» АҖнең ген. директоры (1990–99), техник фән. канд-ты (1995), ТАССРның, БРның атказ. нефтьчесе (1982, 1998), РФ нефть һәм газ сәнәгатенең атказ. хезмәткәре (1993). Оклахома штатының (АКШ, 1990), Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт р-ның (1993) мактаулы гражданы. Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1967). 1967–99 елларда «Татнефть» АҖдә эшли: мастер, нефть чыгару буенча участок башлыгы, нефть промыселында өлкән инженер, «Җәлилнефть» НГДУында инженерлык-технол. хезмәт күрсәтү үзәге башлыгы, берләшмәнең ген. директор урынбасары (1974–77), «Әлмәтнефть» НГДУ башлыгы (1977–83). 1970–72 дә «Җәлилнефть» НГДУында партком секретаре, 1972–74 тә КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты 2 нче секретаре, 1983–90 да 1 нче секретаре. ТРның нефть чыгарган районнарының социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертә. Г. җитәкчелегендә «Татнефть»тә нефть чыганакларын разведкалау, аның кыен чыгарыла торган запасларын эшкәртү буенча отышлы технологияләр эшләнә һәм үзләштерелә; респ-када нефть чыгаруның күләме кимү туктатыла һәм тотрыклылана; нефть беренче мәртәбә турыдан-туры экспортка озатыла башлый. Пр-тие, нефть чыгару б-н бергә, аны эшкәртү һәм нефть продуктларын сату б-н шөгыльләнүче, вертикаль интеграцияләнгән холдинг компаниясенә әверелә; берләшмә акционерлаша, һәм Россия, нефть компанияләре арасында беренчеләрдән булып, дөньяның фонд базарларына чыга. Табигатьне саклауга юнәлдерелгән мөһим программалар (атмосфераның пычрануын киметү, чишмәләрне төзекләндерү, сулыкларга килгән зыянны бетерү, а.х. җирләрен рекультивацияләү һ.б.) гамәлгә ашырыла, кадрларны әзерләү һәм аларның белгечлеген күтәрү системасы оештырыла. Татарстан, Көнбатыш Себер, Башкортстан, Оренбург өлкәләренең нефть чыганакларын үзләштерүне оештыруда катнаша. Уйлап табуга 17 патенты бар. СССР ФАнең И.М.Губкин исем. (1981), СССРның Нефть һәм газ сәнәгате министрлыгы (1991), Кол Гали исем. халыкара (1993), ТР Дәүләт (1994) бүләкләре лауреаты. 1985–90 да ТАССР ЮС, 1990–91 дә РФ ЮС, 1995–99 да ТРның халык депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, РСФСР, ТР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. *Әлмәт мөселман дини-мәгърифәтчелек үзәгенә* аның исеме бирелә (1998).

*Әд.:* 100 лидеров Российского бизнеса. М., 1996; Кто есть кто в нефтяном комплексе России. СПб., 1997; З а р и п о в М. Черное сокровище. М., 1998; Ринат Галеев: Время, события, люди. К., 1999.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ГАЛИ́ЕВ** Ринат Харис улы (19.10.1946, Әлмәт р-ны Яңа Нәдер а.), уролог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996); ТРның атказ табибе (2005), ТРда урология буенча иң танылган белгечләрнең берсе. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Йошкар-Ола һәм Казан шәһәрләре хастаханәләрендә уролог булып эшли. 1980 елдан Казан ГИДУВында, 1996 дан урология каф. мөдире, бер үк вакытта 1980–83 тә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш урологы, Респ-ка гемодиализ һәм бөер күчереп утырту үзәген оештыручы һәм аның җитәкчесе (1992 дән). Хезмәтләре сидек куыгындагы рак авыруын хирургик алымнар б-н дәвалауны камилләштерүгә, анастомоздагы кимчелекләрнең сәбәпләрен ачыклауга, операция ясау техникасының яңа ысулларын эшләүгә (эчәк сегментыннан файдаланып, сидек куыгын формалаштыру — Браунча күчереп утырту ысулы) карый. 1988 дән бөер күчереп утырту операцияләрен башкара, республика гемодиализ үзәгендә Г. сидек куыгы пластикасы буенча 200 дән артык операция ясый. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы, 3 патенты бар.

Х е з м.: Цистоэктомия и илеоцистопластика у больных раком мочевого пузыря. М., 1993; Нефрогенная артериальная гипертензия. К., 1996; Органозамещающие и реконструктивные операции на органах мочевой системы. К., 2008.

**ГАЛИ́ЕВ** Сирин Әхәт улы (4.10.1949. Ютазы р-ны Бәйрәкә а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1993, 1996). Бөгелмә индустриаль-пед. техникумын тәмамлаганнан соң (1972), *«Бәйрәкә»* к-зында инженер булып эшли. 1984 елдан «Бәйрәкә» АҖн җитәкли. Г. җитәкчелек иткән елларда ул республикада алдынгы а.х. пр-тиесенә әверелә: материаль-техник база ныгый, а.х. культураларыннан тотрыклы югары уңыш үстерелә, терлекчелекнең югары продуктлылыгы тәэмин ителә, халыкның социаль-көнкүреш шартлары тамырдан үзгәрә. 2000–2005 тә Ютазы р-ны хакимияте башлыгы, «Нур-Агро» ААҖ ген. директоры (2005 тән). Медаль б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Фәйзрахман Әхмәт улы (2.7.1925, Арча кантонының Түбән Шашы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986), ТАССРның атказ. агрономы (1965). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944–93 елларда Әтнә р-ның «Искра» к-зы рәисе. Аның җитәкчелегендә колхоз республикада алдынгы хуҗалыкка әверелә. 1993 елга колхозда бөртекле культураларның уңышы 1 гектардан — 29 *ц*, бәрәңгенең 139 *ц* тәшкил итә, 1 сыердан уртача еллык савым 3900 *кг* га җитә. А.х. җирләренең 100 *га* исәбенә — 504 *ц* сөт, 73 *ц* ит җитештерелә. 1979–83 тә СССР ЮС, 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Фәнәвил Әхми улы, к. 214 бит.

**ГАЛИ́ЕВ** Фәнил Ислам улы (27.7.1939, Үзбәкстан ССРның Бохара өлкәсе Каракүл ш.), язучы, хокук белгече, ТРның атказ. юристы (1992). Рус телендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1963–66 елларда БАССРның Хәйбулла р-ны прокуратурасында тикшерүче булып эшли. 1966–75 тә Азнакай р-нында тикшерүче һәм прокурор ярдәмчесе, 1975–81 дә Кукмара р-ны, ә 1981–85 тә Казан шәһәре Идел буе р-ны прокуроры, 1985–92 дә ТР прокуратурасының тикшерү идарәсендә, ә 1992–94 тә Теләче р-нында өлкән прокурор вазифаларын башкара. 1994 тән Саба р-ны юридик консультациясе адвокаты. Г.ның әсәрләре детектив жанрда язылган, аларның нигезендә авторның проф. эшчәнлегенә бәйле вакыйгалар ята. «Эзләр кала» («Следы остаются») дип исемләнгән беренче җыентыгы 1983 тә басылып чыга. «Өрәк эзеннән» («По следам призрака», 1986), «Урмандагы йорт сере» («Тайна лесного дома», 1989), «Тикшерүче Сомов хикәяләре» («Рассказы следователя Сомова», 1991), «Үтерүче якында гына» (1994), «Үтерүчене табарга» («Искать убийцу», 1994) җыентыкларына тупланган хикәя һәм повестьларына психологизм хас, аларда кискен рәвештә этик проблемалар күтәрелә.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГАЛИ́ЕВ** Фәхразый Гали улы (12.2.1912, Уфа губ., Минзәлә өязе Җәмәк а. — 13.5.1997, Минзәлә р-ны Җәмәк а.), Сов. Союзы Герое (19.3.1944), кече сержант. Йөкче, тракторчы булып эшли. Казан респ-ка партия мәктәбен тәмамлый (1952). 1934–36 елларда һәм 1942 дән Кызыл Армиядә. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1248 нче танкка каршы артиллерия полкында (12 нче армия) орудие командиры урынбасары. Көньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре составында Донбасс һәм Запорожье һөҗүм операцияләрендә катнаша (1943). 1943 тә Губенский авылы янында (Запорожье өлкәсе Вольнянский р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: кичү вакытында туп һәм расчётларны коткара; сугышчылар төркеме б-н дошманның 22 һөҗүмен кире кайтара. Кара диңгез буе далаларында (1944) һәм Днестр елгасы буенда (1944) барган су-

гышларда катнаша. Авыр яралангannan соң (1944) демобилизацияләнә, туган авылында яши һәм эшли: КПССның зональ партия оешмасы секретаре, 1957–60 та МТС директоры. 1946–50 дә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЛИ́ЕВ** Һади Гали улы (12.7.1908, Казан губ., Тәтеш өязе Өченче Чирмешән а., хәзерге Апас р-ны Багыш а. — 4.6.1989, Казан), партия, хакимият хезмәткәре. Тәтеш пед. техникумын тәмамлый (1930). 1930–31 елларда Апас р-ны Ясаклы Бураш, Апас авыллары мәктәпләрендә укытучы, 1931–32 дә Апас р-н халык мәгарифе бүлегендә инспектор һәм мөдир, 1932–34 тә хезмәт ияләре депутатларының Апас р-н советы башкарма ком-ты секретаре; 1934–41 дә Дәвеш авылы мәктәбе директоры, 1941–42 дә Апас р-н халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1943–47 дә Мөслим райбашкарма ком-ты рәисе. КПССның Баулы (1947–52), Зәй (1952–55) райкомнарының 1 нче секретаре. 1955–67 дә ТАССР ЮС Президиумы секретаре. 1947–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** Шакир Гали улы (2.6.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Сугышлы а. — 1.1.1988, Әлмәт ш.), машинист, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1935 елдан Чиләбе өлкәсе Ярославль шәһәре сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1947 дән Татарстан нефть промыселларында. 1959 дан Миңлебай газ эшкәртү з-дының компрессорлар цехында машинистлар бригадиры. Герой исеме бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Гайтанникова Л. Галиев Шакир Галиевич // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАЛИ́ЕВ** Шамил Госман улы (18.4.1942, Казан), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1979), проф. (1991). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1972 дән Украина ССР ФАнең ныклык проблемалары ин-тында (Киев), 1995 тән Окленд ун-тында (Яңа Зеландия). Хезмәтләре сыеклык салынган конструкцияләрнең динамик ныклылыгы теориясенә, үткәргеч торбалардагы газ һәм сыеклык мохитенең нәсызыкча тирбәнешенә карый. Деформацияләнүче җисемнәрнең сыеклык б-н тотрыксыз нәсызыкча тәэсирләшү теориясен һәм куәтле нурланыш импульслары тәэсир иткән деформацияләнүче җисемнәрнең ныклылыгын исәпләү теориясен төзи. Украина ССР ФАнең акад. А.Н.Дынник исем. бүләге лауреаты (1985).

Хезм.: Динамика взаимодействия элементов конструкций с волной давления в жидкости. Киев, 1977; Динамика гидроупругопластических систем. Киев, 1981; Нелинейные волны в ограниченных сплошных средах. Киев, 1988.

**ГАЛИ́ЕВ** Шамил Ибраһим улы (10.9.1939, Кемерово ш.), гамәли матем. гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1991). 1967 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук 1972 гә кадәр югары матем., 1978 гә кадәр кибернетика, 1978 дән гамәли матем. кафедраларында эшли. Хезмәтләре экстремаль мәсьәләләр һәм иярчен системаларына карый. Интегралль-аермалы тигезләмәләрнең үзенчәлекле очракларын тикшерә. Чикле-үлчәмле евклидча фәзалардагы сфераларны төрү һәм каплау мәсьәләләрен һәм максимум-минимум мәсьәләләрен санча чишүнең кайбер ысулларын эшли. Бу ысуллар төрле кулланылыштагы иярчен системаларын проектлаштырганда гамәлгә кертелә. Иярчен системалары структураларын матем. модельләштерү һәм оптимальләштерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Космонавтика федерациясе дипломы б-н бүләкләнә (1995). 1997–2001 елларда Санта-Мария шәһәрендәге Федераль ун-т профессоры (Бразилия).

Хезм.: Нахождение приближённого решения максимина со связанными переменными и кратного максимина // Вычисл. математика и мат. физика. 1986. Т. 26, № 10; Системы из минимаксного числа спутников для многократного обзора Земли // Исследования Земли из космоса. 1990. № 5; Модели спутниковых систем глобальной связи и методы анализа и синтеза их структур // Исследования Земли из космоса. 1993. № 5; Нахождение приближённых решений минимаксных задач // Вычисл. математика и мат. физика. 1997. Т. 37, № 12.

**ГАЛИ́ЕВ** Шамил Хәсән улы (3.6.1926, Мәскәү өлкәсенең Подольск ш. — 14.2.2008, Казан), физик тәрбия һәм спортны оештыручыларның берсе. РСФСРның атказ. физик культура хезмәткәре (1976). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1957). Казан пед. ин-тының физик тәрбия каф. укытучысы (1957–60), физик тәрбия ф-ты деканы (1960–75). Профсоюзларның Татарстан өлкә советы физик культура һәм спорт бүлеге мөдире (1975–87), 1987–90 да Р.Г.Нәҗметдинов исем. шахмат һәм шашка сарае директоры, 1990–93 тә Профсоюзлар физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан республика советында, 1994 тән — ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының үзәк спорт клубында әйдәп баручы белгеч. «Казан чаңгы марафоны» (1968 дән), җиңел атлетика буенча «Казан тынычлык марафоны» (1981 дән), авыр атлетика буенча А.П.Курынов (1978 дән), шахмат буенча Р.Г.Нәҗметдинов (1979 дан), гер спорты буенча Н.Г.Жеребцов (1994 тән Дөнья Кубогы) бәйгеләрен оештыручыларның берсе. Гер спорты буенча халыкара федерациянең вице-президенты (1994 тән). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́ЕВ** (Һидиятуллин) Шәүкәт Гали улы (20.11.1928, хәзерге Апас р-ны Олы Бакырчы а.), шагыйрь, ТРның халык шагыйре (1995). Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1961). 1949–53 елларда Кайбыч р-ның «Колхоз бригадасы» г-тасы редакциясендә җаваплы сәркәтип, җаваплы мөхәррир, 1953–59 да «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. 1971–84 тә Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире. Аның шигырьләре республика газета-журналларында 1948 дә басыла башлый. 1954 тә — «Яңа көйләр» исемле беренче җыентыгы, 1956 да «Кичке утлар» китабы дөнья күрә. Г.ның поэзиясенә нечкә лиризм хас. Ул «Сөенечләрем, көенечләрем» (1961), «Күңел күзе» (1963), «Чынлык» (1972), «Тамчылар тамар чаклар» (1975), «Чаң турында баллада» («Баллада о колоколе», М., 1976), «Мәхәббәт тулы җаным» (2002), «Серләрем бар» (2002), «Сиңа әйтер сүзем бар» (2008) дип аталган шигъри җыентыклар иҗат итә. Шагыйрь замандашларының уй-фикерләрен эчкерсез бер җылылык б-н чагылдыра. Аның шигырьләрендә авыл тормышы, халыкның гореф-гадәтләре, яшьлекләре сугыш чорына туры килгән буын вәкилләренең кичерешләре, туган якның сугыштан соңгы яңарышы тасвирлана. Г.нең табигать һәм мәхәббәт турындагы шигырьләренең образлы яңгырашы, композицион камиллеге татар композиторлары игътибарыннан да читтә калмый. Аның шигырьләренә язылган «Раушаниям, бәгърем» (В.Хәбисламов музыкасы), «Утыр әле яннарыма» (И.Хисамов музыкасы) һ.б. популяр җырларга әверелә. Г.нең иҗаты җылы, тормышчан юмор б-н сугарылган. Лирик шигъри интонация органик рәвештә ирония б-н үрелә, шагыйрь тормыштагы хәлләрне җиңелчә көлеп сурәтли («Уены-чыны бергә», 1966; «Фикердәшкә», 1969; «Шалт, Мөхәммәтҗан!», 1970 һ.б. җыентыклар). «Шәвәли» (1965), «Котбетдин мәргән» (1971), «Заяц на зарядке» (1980; Г.Х.Андерсен исем. халыкара Мактаулы диплом, 1982), «Исәнме, дус!»(1985), «Кто играет на курае?» (М., 1985) җыентыкларында тупланган шаян шигырьләре балаларга хас тапкырлык, шуклык, фантазия б-н тулы; җор, йөгерек телдә язылган. Г.нең «Минем беренче гомерем» (1997) автобиографик повесте, «Илһамым-мәхәббәтем» (2006) исемле лирик язмалары дөнья күрә. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1972). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Шәүкәт Г. Галиев.

Әсәр.: Шигырьләр, поэмалар: Лирика, юмор, балаларга. К., 1978; Сайланма әсәрләр. Балалар өчен шигырьләр. К., 1987; Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2002.

*Әд.:* Хәким С. Юмор — шагыйрьнең табигатендә // Үз тавышың белән. К., 1969; Туфан Х. Киләчәккә барырлык иҗат // Социалистик Татарстан. 1972. 19 апр.; Юзиев Н. Әйтер сүзе бар // Шигърият дөньясы. К., 1981; Ахунов Г. Шагыйрь ачкан дөнья // Казан утлары. 1998. № 11; Корбан Р. Бер язучы — биш әдип // Галиев Ш. «Сиңа әйтер сүзем бар» җыентыгына кереш мәкалә. К., 2008; Галиуллин Т. «Коль сын зем-

ли — будь добр к её судьбе...» // Здравствуй, поэзия! М., 1987.

**ГАЛИ́ЕВА** Асия Әмир кызы (25.4.1929, Казан), драма актрисасы, педагог, ТАССРның халык артисты (1982). 1944–49 елларда Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС, Мәскәү) Татар студиясендә О.И.Пыжова һәм Б.В.Бибиков остаханәсендә укый, 1954 тә шул ук ин-тның актёрлар ф-тында И.М.Раевский курсын тәмамлый. 1949–50 дә Казан яшь тамашачылар театрының татар труппасы составында эшли. Баян сылу («Козы көрпеш белән Баянсылу», Г.Мөсрәпов), Клариче («Болан патша», К.Гоцци), Людмила («Васса Железнова», М.Горький), Булат, Сөмбел («Бишек җыры», «Илдус», Д.Аппакова), Зөһрә («Үги кыз», А.Әхмәт) рольләрен башкара. 1950 дән Татар акад. театры сәхнәсендә. Беренче рольләреннән үк (Илсөяр — «Маякчы кызы», Г.Гобәй повесте буенча; Әсмагөл — «Ачык алан шаулый», С.Кальметов; Вера — «Соңгылар», М.Горький) үзен МХАТ мәктәбенең лаеклы вәкиле итеп таныта. Актриса иҗатында образның тирән психологизмы һәм эчке дөньясының әзлекле рәвештә ачылуы башкаруда милли традицияләр үзенчәлекләре б-н оста итеп үрелеп бара. Г.ның Гайни («Бәхетсез егет», Г.Камал, 1955), Негина («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», А.Н.Островский, 1956), Корделия («Король Лир», У.Шекспир), Айсылу («Ташкыннар», Т.Гыйззәт, 1976) рольләрен башкаруы Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә образны ачуга яңалык кертү дип билгеләнә. Актрисаның бу рольләре үзәк матбугатта уңай бәяләнә. Н.Исәнбәтнең «Гөлҗамал» спектаклендә Гөлҗамал ролен башкаруы (1963) Казан театр тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Героиняның прототибы — күренекле татар актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская — спектакльнең премьерасында була һәм актрисаның эшенә югары бәя бирә. Бу рольдә бәхеткә, теләгенә ирешүдә үз ихтыяры б-н эш итү хокукын яклардай алдынгы, көчле хатын-кызларның җыелма образы гәүдәләнә. Актрисаның бу образны тудырганда ирешкән лирик дулкынлануы һәм тирән драматизмы, эчке һәм тышкы ышандыру көче аны татар театр сәнгатенең зур осталары рәтенә чыгара. Тормыш дөреслегенә турылыклылыгы, гәүдәләндерә торган персонажның һәр кыланышын нигезли белүе аңа комик һәм үткен сатирик пландагы рольләрдә дә бертигез дәрәҗәдә ышандырылык итеп уйнарга ярдәм итә (Зөбәрҗәт — «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт; Дилбәр — «Американ», К.Тинчурин; Полина — «Бер төн», Б.Л.Горбатов; Дорина — «Суган суфые», Ж.Б.Мольер; Беатриче — «Хатыннар гайбәте», К. Гольдони).



А.Ә.Галиева Гөлҗамал (Н.Исәнбәтнең шул исемдәге әсәре) ролендә.



А.Ә.Галиева.

1990 нан Г. Татар акад. театры каршындагы «Инсаният» труппасында эшли, анда Людмила («Сагыш», А.Галин), Луиза («Уллабым», Р.Җиһаншина) рольләрен башкара. 1971 дән Казан консерваториясендә, Казан театр уч-щесендә (1971–89), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (1971–2007) укыта. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986; Даутова Р. Асия Галеева: «Для меня все время горит свет» // Татарстан. 2009. № 4.

*Ю.А.Благов.*

**ГАЛИ́ЕВА** Нәгыймә Хәмидулла кызы (9.9.1949, Ленинград), җырчы (меццо-сопрано), Белоруссия Респ-касының атказ. артисты (1994). 1980 елда Ленинград консерваториясен (И.П.Алексеев классы) тәмамлый. 1979 дан Белоруссия опера һәм балет театры солисткасы. Төп партияләре: Азучена, Амнерис («Трубадур», «Аида», Дж. Верди), Кармен (шул исем. оп., Дж. Бизе), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Графиня («Пики дамасы», П.Чайковский). 1989 да Киев опера һәм балет театры б-н чит илләрдә гастрольләрдә катнаша. Франция, Швейцариядә М.Мусоргскийның «Хованщина» (Марфа), «Борис Годунов» (Марина Мнишек) операларында төп партияләрне һәм Дж.Вердинең «Реквием»ендә соло партиясен башкара. Белоруссия опера һәм балет театры труппасы б-н ил буйлап, чит илләрдә (Испания, Германия, Швейцария) гастрольләрдә була. Репертуарында барокко стилендәге музыкадан алып борынгы рус романсларына кадәр әсәрләр булган концерт программалары б-н чыгышлар ясый. Вокалистларның М.Глинка исем. бөтенсоюз конкурсы дипломанты (1979).

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГАЛИ́ЕВА** Эльмира Рәкыйп кызы (3.2.1954, Биектау р-ны Каракүл а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2003), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1979 елдан Казан. пед. ун-тында укыта, 1991 дән татар әдәбияты каф. мөдире, 1995–96 да татар филологиясе ф-ты деканы. Хезмәтләре татар әдәбияты, әдәби тәнкыйть һәм әдәби-эстетик фикер тарихына, 1920–30 елларда татар әдәбият белеменең барлыкка килүенә һәм аның кысаларында мәдәни-тарих мәктәбенең формалашуы һәм үсешенә карый.

Хезм.: Татар әдәбияты тарихы К., 1989. Т. 4 (автордаш); Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002.

**ГАЛИКӘ́ЕВЛӘР**, Казан сәүдәгәрләре: 1) **Мөхәммәтсафа** (1822, Казан губ., Казан өязе Мәмсә а. — 1890), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, мануфактура һәм үзенең сабын кайнату з-ды продукциясе б-н сату итә. Казан шәһәр җәмәгать банкының исәп-хисап ком-ты әгъзасы (1879–84). 1870–80 елларда Казанның 1 нче җамигъ мәчете имамы Ш. Мәрҗанигә «Мәрҗания» мәдрәсәсен төзүдә ярдәм күрсәтә. Әтиләренең эшен ике улы дәвам иттерә; 2) **Мөхәммәтсадыйк** Мөхәммәтсафа улы (20.1.1847, Казан — 1919, шунда ук), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, Ш.Мәрҗани шәкерте. Мануфактура б-н сату итә. «Гостиный двор»да кибет (еллык акча әйләнешенең күләме 1 млн. сумнан артып китә), Печән базарында һәм Екатерининский урамында тире, йон складлары һәм кибетләр тота. Замандашлары аны «мануфактура короле» дип атый. 1897–1917 дә Казан шәһәр думасы гласные. Казан шәһәр җәмәгать банкының исәп-хисап ком-ты, Россия Дәүләт банкы Казан бүлекчәсенең хисап-ссуда ком-ты әгъзасы (1903–17). Соңгысында озак еллар дәвамында эшләгәне өчен алтын медаль б-н бүләкләнә. «Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте»нең шәрәфле әгъзасы, 8 нче рус-татар уч-щесенең попечителе. 10 нан артык мәчет (ш.и. Казандагы Кызыл мәчет) һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең яңа бинасы төзелешенә, мәдрәсәне тотуга акчалата иганә кыла. Халык мәгарифендә реформа үткәрүнең актив тарафдары була, Г. *Баруди* идеяләрен яклый; 3) **Габдерахман** Мөхәммәтсафа улы (1854–1926, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Мираска сабын кайнату з-дын ала (сабынның 10 лап сортын чыгара). 20 йөз башында үз заводының продукциясен сату буенча фирма ача, ул иң эре 10 пр-тиенең берсе санала.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков). К., 1995; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р., Хайрутдинова Л.Ф. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ГАЛИКӘ́Й** Нарыйк улы (? — окт. 1552, Казан), Казан ханлыгының *карачыбәге*, Чура бәкнең бертуганы. 1552 елның март башында Зөя кальгасендә Мәскәү хөкүмәтенең башында Иван IV нең «тиз һәм яшерен эшләре өчен» мөһерен саклаучы А.Ф.Адашев торган вәкилләре б-н Ходайкол углан җитәкләгән Казан аксөякләре төркеме арасында булган сөйләшүләрдә катнаша. Анда патшаның Казандагы наместнигы итеп С.М.Микулинский билгеләнә; Казанның аксөякләре аңа тугрылыклы булырга ант итәләр. 9 мартта Микулинский Зөядә булган барлык рус гаскәрләре б-н бергә Казанга юл тота. Шулкадәр

чирүне күргәч, Г. карачыбәк Ислам һәм Кибәк бәк б-н Микулинский яраннарыннан аерылып китәләр һәм ашыгыч рәвештә шәһәргә киләләр; аларның өндәве буенча шәһәр капкалары бикләнә, һәм халык үз ханлыгын сакларга кораллы бәрелешкә күтәрелә. Шуннан соң Мәскәү гаскәрләре б-н башланган сугышта Г. һәлак була.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ГАЛИМӘРДӘ́НОВ** Марсель Мәгафур улы (3.10.1951, Актаныш р-ны Яңа Балтач а.), генерал-майор (1996). СССР Дәүләт иминлеге ком-тының чик буе хәрби-сәяси югары уч-щесен (1974, Мәскәү), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1983, Мәскәү) тәмамлый. 1974 елдан Төньяк-Көнбатыш чик буе округында: чик буе заставасы башлыгы урынбасары (1976 га кадәр), 1976–79 да чик буе комендатурасы коменданты урынбасары, 1979–80 дә чик буе отряды сәяси бүлеге өлкән инструкторы. 1983 тән Кавказ аръягы чик буе округында: 1984–85 тә агитация һәм пропаганда бүлеге башлыгы, 1985–89 да сәяси бүлек башлыгы, 1989–91 дә башлык урынбасары. 1991 дән Мәскәүдә: Шәхси состав б-н эшләү идарәсе башлыгы урынбасары — РФнең Чик буе гаскәрләре командованиесе аппаратында бүлек башлыгы (1994 кә кадәр), 1994–96 да РФ Федераль чик буе хезмәтенең Тәрбия эшләре идарәсе башлыгы урынбасары, 1996–2000 дә 1 нче урынбасары, 2000 нән РФнең ТРдагы баш федераль инспекторы.

**ГАЛИМБӘ́К**, легендар болгар бәге. Аның турындагы мәгълүматлар халык риваятьләрендә сакланган. 17–18 йөзләр татар тарихи әдәбиятында Г. Болгарның соңгы идарәчесе *Габдулла ханның* улы дип белдерелә. Урта Азия хакиме Аксак Тимер гаскәрләре шәһәрне штурмлаганда атасы һәлак булгач, Г. бертуганы Алтынбәк б-н әсирлеккә эләгә; соңрак ярлыканып, аның азат ителүе хакында әйтелә. Шуннан соң, бер төрле мәгълүматлар буенча, Г. Казан төбәгенә килеп чыга һәм анда шәһәргә нигез сала, башка мәгълүматлар буенча, Чирмешән елгасы буенда Бүләмәр (Балымер) дигән шәһәр кора.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972.

*И.Л.Измайлов.*

**ГАЛИМҖА́НОВ** Әсгат Галимҗан улы (2.3.1936, Апас р-ны Болын Балыкчы а.), меценат, эшмәкәр. Автомобиль йөртүчеләр курсларын тәмамлаганнан соң (1964), М.Вахитов исем. химия комб-тында (1978 елга кадәр), Казанның 110 нчы кибетендә (1990 га кадәр) эшли. 1980 еллар башыннан эшмәкәрлек б-н дә шөгыльләнә — үзенең шәхси ярдәмче хуҗалыгында дуңгызлар һәм сыерлар асрый. Ит һ.б. азык-төлек сатудан кергән акчаның зур өлешен хәйрия максатларына тота: 30 елдан артык Казанның 1 нче балалар йортына ярдәм итә, 2003 тә аңа бүләк итеп «Газель» микроавтобусын тапшыра; балалар бакчаларына, приютларга ул бүләк иткән автобуслар саны 70 кә якын (2006). Ул үз акчасының зур өлешен Иваново шәһәрендәге Стасова исем. интернациональ мәктәпкә, Әрмәнстанда (1988) һәм Чилида җир тетрәүләрдән, Чернобыль АЭСндагы авариядән зыян күрүчеләргә (1986), туган авылы Болын-Балыкчыда мәчет төзелешенә һ.б.га иганә кыла. Бөтенроссия балалар фондының шәрәфле әгъзасы (1988 дән), 1999 дан бу фондның Татарстан Респ-касы бүлеге идарәсе рәисе. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, хәйрия эшчәнлеге өчен Л.Н.Толстой исем. халыкара алтын медаль (1990), ТРның Мактау грамотасы (2001) б-н бүләкләнә.

*Ю.М.Ханҗин.*

**ГАЛИМҖА́НОВ** Илсур Габделхак улы, к. 214 бит.

**ГАЛИМҖА́НОВ** Сәлимҗан Галимҗан улы (25.9.1915, хәзерге БРның Аскын р-ны Төлгезбаш а. — 12.7.2005, Екатеринбург ш.), Сов. Союзы Герое (26.10.1943), гв. кече сержанты. Сугышка кадәр колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 225 нче гв. укчы полкы (7 нче гв. армиясенең 78 нче гв. укчы дивизиясе) укчысы. Сталинград, Дон, Воронеж, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Белгород шәһәре тирәсендә Северский Донец елгасы янындагы оборона сугышларында (1943), Курск өчен һәм Днепр елгасы янында барган сугышларда (икесе дә — 1943) катнаша. 1943 нең 25 сентябрендә Домоткань авылы янында (Днепропетровск өлкәсе, Верхнеднепровский р-ны) батырлык күрсәтә, дошман һөҗүмен кире кайтара һәм яралы командирны коткара. Кировоград, Умань-Ботошани, Яссы-Кишинёв, Дебрецен, Будапешт, Братислава-Брно һәм Прага һөҗүм операцияләрендә катнаша (1944–45). Сугыштан соң туган авылында «Дружба» к-зында төзүче булып эшли. 1998 дән Екатеринбург шәһәрендә яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЛИМҖА́НОВ** Фоат Гыйният улы (26.6.1929, БАССРның Аскын р-ны Көбъяз а. — 30.8.2000, Уфа ш.), гамәли гидродинамика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1989). 1952 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Машиналар төзү з-дында (Артемовск ш, Свердловск өлкәсе) эшли, 1954 тән з-дның махсус КБнда, 1960 тан аның тикшеренүләр секторы башлыгы, 1964–67 дә яңа техника буенча баш инженер урынбасары. 1967 дән Уфа авиация ин-тының авиация теориясе һәм ракета двигательләре кафедрасында. Хезмәтләре турбомашиналар теориясенә һәм исәпләүләренә, ш.у. стеналар тирәли турбулентлы хәрәкәткә карый. Файдалы эш коэффициенты югары булган яңа аэродинамик вентиляторлар схемасын эшли. Гидравлик шома һәм кытыршы үткәргеч торбада сыеклыкларның стеналар янында уртача турбулентлы хәрәкәтләнү теориясен төзи. Стеналар янында турбулентлы җылылык һәм массаалмашу хәрәкәте теориясен үстерә. Хәрәкәтнең йомык тигезләмәләрен, кинематик һәм динамик параметрларын тасвирлый. Медальләр, ш.и. Россия Космонавтика федерациясенең акад. А.Д.Надирадзе исем. медале б-н бүләкләнә.



С.Г. Галимҗанов.

Хезм.: Вентиляторы: Атлас конструкций. М., 1968; Пристенное турбулентное движение. Уфа, 1979; Теория турбулентного движения в элементах летательных аппаратов. Уфа, 1989; Теория внутреннего турбулентного движения. Уфа, 1999.

**ГАЛИМҖА́НОВ** Хәлил Мингали улы (3.11.1950, Әстерхан ш.), йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1998). РМФА академигы В.И.Покровский шәкерте. Әстерхан мед. ин-тын тәмамлый (1973). 1974 елдан Үзәк эпидемиология фәнни-тикшеренү ин-тының Әстерхан ф-лында. 1984 тән Әстерхан мед. академиясендә, 1989 дан йогышлы авырулар каф. мөдире. Тикшеренүләре йогышлы авыруларның этиопатогенезына, клиникасына, диагноз кую һәм дәвалауга карый. Г. беренче булып Әстерхан риккетсиоз бизгәге клиникасын, Идел-Каспий сусаклагычында таралган табигый чыганаклы гельминтоз — псевдамфистомозны тасвирлый, аңа диагноз кую һәм дәвалау ысулларын эшли (1999), арбовирус йогышлы авырулар төркемнәренең (Көнбатыш Нил бизгәге, Кырым-Конго геморрагик бизгәге, Инко бизгәге һ.б.). төрле аспектларын өйрәнә. Г. тарафыннан йогышлы авыруларны иммунитетны көйләү б-н дәвалау, ш.у. түбән дәрәҗәдәге лазер нурланышы кулланып, иммунитетны элекке хәленә кайтару мәсьәләләрен хәл итү юллары эшләнә. Әстерхан татар милли мәдәни «Дуслык» җәмгыяте рәисе.

Хезм.: Эпонимы в инфектологии. Астрахань, 1998; Астраханская риккетсиозная лихорадка. Астрахань, 1999.

**ГАЛИМНӘ́Р ЙОРТЫ́**, ТР ФАнең мәдәни-мәгърифәт йорты. 1925 елның ноябрендә Казанда А.Е.Арбузов, А.В.Вишневский һ.б. галимнәрнең тырышлыгы б-н ачыла. 1935 тән (Инженерлар йорты б-н берләшкәннән соң) — Фән һәм техника хезмәткәрләре йорты, 1941–48 елларда эшләми. 1965 тән — Галимнәр һәм студентлар йорты, 1977 дән — Галимнәр йорты, 1990 нан — Фән һәм халык мәгарифе хезмәткәрләре профсоюзының ял һәм мәдәният үзәге, 1993 тән хәзерге исемдә. 1935 тән элеккеге Александра исем. балалар ятимханәсе бинасында урнашкан, 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге (арх. Л.К.Хрщонович,



А.Г.Галимов.



Вахит Г.Галимов.

1889). Төп эшчәнлеге: фәнни конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр, мәдәни чаралар уздыру, фән өлкәсендәге хезмәткәрләрнең ял вакытларын оештыру. Төрле еллардагы идарә рәисләре: галимнәр — Г.Х.Камай, Н.А.Васнецов, Б.Л.Крылов, А.Х.Халиков, М.М.Гыймадиев, 2001 дән — А.В.Ильясов.

*Әд.:* Казанский Дом учёных — страницы истории. К 75-летию со дня открытия. К., 2000.

*И.С.Донская.*

**ГАЛИ́МОВ** Айдар Гани улы (23.2.1967, Казакъстан ССР, Целиноград өлкәсе «Мәдәният» с-зы), эстрада җырчысы (тенор), БРның атказ. (1995) һәм ТРның халык артисты (2008). Башкорт ун-тын (1993), Казан пед. ун-тының муз.-пед. ф-тын тәмамлый (2001). 1989 елдан үзешчән вокаль-инструменталь ансамбль солисты. Проф. музыка эшчәнлеген 1993 тә башлый, соңрак үзе җитәкләгән «Айдар» театр-студиясен оештыра. Репертуарында (башлыча, яшь татар, башкорт композиторлары әсәрләре) татар, башкорт, рус, төрек телләрендә 400 дән артык җыр бар. Татарстан, Башкортстан Респ-каларында, РФнең башка төбәкләрендә гастрольләрдә йөри; чит илләрдәге гастрольләре Казакъстанда, Үзбәкстан, Латвия, Эстония, АКШ, Төркия, Финляндиядә булып уза. «Татар җыры» конкурсы лауреаты (1990).

**ГАЛИ́МОВ** Әкрам Миңнегали улы (14.11.1892, хәзерге Казакъстан Респ-касы, Тургай өлкәсе Кустанай ш., башка мәгълүматлар буенча, Акмулла өлкәсе Акмулла ш. — 7.8.1913, Оренбург губ. Троицк ш.), шагыйрь, журналист. Татар һәм казакъ телләрендә язган. «Рәсүлия» мәдрәсәсендә (Троицк) белем ала. 1911–13 елларда беренче казакъ ж-лы «Айкап»та (1911–16 да Троицк шәһәрендә нәшер ителә) җаваплы сәркәтип, төрле оештыру эшләрен алып баручы. «Шура», «Айкап», «Кармак» ж-лларында, «Идел» г-тасында «Чала татары», «Кара туры егет» псевдонимнары б-н чыгышлар ясый. Мәкалә һәм фельетоннарында казакъ халкының артта калганлыгы турында яза, аны укыту-агарту зарурлыгын яклап чыга. Казакъ телендә чыккан «Яшьлек җимешләре» («Жастық жимістері», 1912) исемле шигъри җыентык авторы. Руханиларга каршы юнәлтелгән, татар телендә язылган «Май мәсьәләсе, яхуд Аңгыра мулла» (Троицк, 1913) пьесасы башта Кустанай шәһәренең һәвәскәр театры сәхнәсендә, соңыннан һәвәскәр труппалар тарафыннан Уфа, Троицк шәһәрләрендә уйнала. Г.Тукай, Абай шигырьләренә *назыйрә* яза. Татар, рус һәм Европа язучылары әсәрләрен (мәс., Тукайның «Сөткә төшкән тычкан» мәсәлен, Байронның «Шильон мәхбүсе» поэмасын) казакъ теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г а ф и ф и С. Шагыйрь Әкрәм Галимовның вафаты // Шура. 1913. № 17; Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун // Акмулла. 1913. № 28; М ә х м ү т о в Һ., И л я л о в а И., Г ы й з з ә т Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Р ә м и И.Г., Д а у т о в Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001; И с м а и л о в Е.К. К вопросу казахско-татарских литературных связей // В поисках нового. А.-А., 1967; И с к а к о в Б. Этапы развития казахско-татарских литературных связей // Казахская литература и её интернациональные связи. А.-А., 1973.

*А.М.Ахунов.*

**ГАЛИ́МОВ** Вахит Газиз улы (1921, БРның хәзерге Чакмагыш р-ны Иске Балак а. — 28.9.1943, Украина ССР, Днепровский а.) Сов. Союзы Герое (22.2.1944, үлгәннән соң), гв. өлкән сержанты. Колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 100 нче гв. укчы полк (6 нчы армиянең 35 нче гв. укчы дивизиясе) снайперы. Көньяк, Көньяк-Көнбатыш, Воронеж һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Донбасс (1941), Барвенково–Лозовая, Воронеж–Ворошиловград, Урта Дон һәм Донбасс (барысы да — 1942) операцияләрендә катнаша. 1943 нең 28 сентябрендә Звонец авылы янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: сугышта сафтан чыккан офицерларны алыштыра, ротаны 3 мәртәбә һөҗүмгә күтәрә. Яуда һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Уфа шәһәрендә туган якны өйрәнү музеенда Г.ка багышланган стенд бар. Иске Балак авылындагы һәм Чакмагыш р-ны үзәгендәге урамнарга, ш.у. туган авылындагы колхозга аның исеме бирелә. Иске Балак авылындагы паркта геройның бюсты куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАЛИ́МОВ** Вәлиәхмәт Гыйрфанетдин улы (12.6.1908, Казан губ., Зөя өязе Сатмыш а. — 15.2.1994, Уфа ш.), драма актёры, режиссёр, драматург, педагог, БАССРның халык артисты (1944), РСФСРның атказ. артисты (1949). Башкортстан сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (В.Г.*Мортазин-Иманский*, М.Ә.*Мәһдиев*, Х.Г.*Бухарский* классы, 1930, 1 нче чыгарылыш). 1930–31 елларда Уфа эшче яшьләр театрын җитәкли, 1931 дән Башкорт акад. драма театрында актёр; 1942–48, 1956–71 дә сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссёр. 1971–82 дә Казан кинохроника студиясенең Уфа бүлегендә фильмнарны башкорт теленә тәрҗемә итү (дубляж ясау) режиссёры. Бер үк вакытта 1935 тән Уфа сәнгать техникумында укыта. Беренче тапкыр проф. сәхнәдә Базаргол ролендә уйный («Башкорт туе», М.Бурангол). Иң яхшы рольләре арасында — Әхмәт («Сакмар» — «Һакмар», С.Мифтахов), Тукай (шул исем. пьеса, Ә.Фәйзи), Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Яго («Отелло», У.Шекспир), Фердинанд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) һ.б. образлар. Киң иҗат диапазонлы, әсәрнең жанрын нечкә тоя белүче актёр образларны тамашачыны ышандырырлык, геройлары язмышы турында уйландырырлык итеп башкара. Режиссёр һәм театрның сәнгать җитәкчесе буларак, куйган спектакльләре б-н башкорт сәхнәсе эстетикасын, башкорт театры үсешенең программ юнәлешен билгели. Г.ның иң яхшы постановкалары авторның төп идеясе төгәллеген саклаган һәм күптөрле чаралар кулланган хәлдә дә академизмы һәм эчке бөтенлекләре б-н аерылып торалар: «Кара йөзләр» (М.Гафури повесте буенча үз инсценировкасы), «Идүкәй һәм Мурадым» (М.Бурангол), «Салават Юлаев» (Б.Бикбай), «Кыз урлау», «Айгөл иле» (М.Кәрим), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Тукай» (Ә.Фәйзи), «Караңгылык хакимлеге» («Власть тьмы», Л.Н.Толстой), «Өченче патетик» («Третья патетическая», Н.Ф.Погодин), «Ябырылу» («Нашествие», Л.М.Леонов). Күп кенә пьеса һәм инсценировкалар авторы. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Башкирский академический театр драмы: Альбом. Уфа., 1969; М ә һ ә ҙ и е в М. Театр тураһында. Өфө, 1962.

*И.И.Илялова.*

**ГАЛИ́МОВ** Искәндәр Галимҗан улы (6.6.1950, Казан), генерал-полковник (2009). СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен тәмамлый (1980, Мәскәү). 1973–76 елларда Казанның Мәскәү, 1976–77 дә Бауман р-ннарының эчке эшләр бүлеге инспекторы. 1977–82 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсендә. 1982–84 тә халык депутатларының Чаллы шәһәр советы башкарма ком-ты Эчке эшләр идарәсе башлыгы урынбасары, 1984–88 дә башлыгы, 1988–93 тә Казан шәһәре башкарма ком-ты Эчке эшләр идарәсе башлыгы. 1993–98 тә ТР эчке эшләр министры. 1998–2002 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Икътисади җинаятьләр б-н көрәш баш идарәсе башлыгы, 2002 дән РФ Эчке эшләр министрлыгының Баш мәгълүмат үзәге, 2006 елдан Җинаятьчеләрне эзләү департаменты җитәкчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́МОВ** Корбан Закир улы (31.12.1909, хәзерге Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Сасмак а. — 16.4.1986, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1958), проф. (1959), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1979, 1984). 1935 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 1985 кә кадәр шунда ук эшли, бер үк вакытта 1946–60 елларда СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре пластиклык, нәсызыкча сыгылмалылык, сүрүләрнең нәсызыкча теорияләренә карый. Г. иреклe күчешләр ясаучы җисемнең көчәнеш-деформация халәтен анализлауның гомуми алымнарын тәкъдим итә, деформацияләрнең өзлексезлеге тигезләмәләрен чыгара, теләсә нинди күчешләр һәм деформацияләр булганда дефформация һәм көчәнеш тензорлары компонентлары арасында физик нис-

бәтләрне билгели, җисем статикасының төп тигезләмәләрен чыгара, аларны көчәнешнең симметрик тензор компонентларына туры китереп үзгәртә һәм мәсьәләләр чишүнең вариатив ысулларын үстерә. Деформацияле һәм деформациясез халәткә китерелгән нәсызыкча сүрүләр теориясенә караган төп тигезләмәләрне чишә, чик деформацияләр алганда статик чик шартларын тәгъбирли. Аерым көчешне исәпкә алып, сүрүләр теориясенә төгәллек кертә, геометрик һәм физик нәсызыкча мәсьәләләр чишүнең вариатив ысулларын эшли, бүселгән өслекләрнең изометриклыгы турындагы карашка нигезләнеп, сүрүнең тотрыклылыгы мәсьәләләрен чишүгә ирешә. Сүрүләрнең нәсызыкча механикасы буенча фәнни юнәлешкә нигез салучыларның берсе. «Пластиналар һәм сүрүләр теориясенә караган тикшеренүләр» («Исследования по теории пластин и оболочек», 1961) дигән тематик җыентыкка нигез сала. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нелинейная теория упругих оболочек. К., 1957 (автордаш); Основы линейных теорий тонких оболочек. К., 1975; Теория оболочек с учётом поперечного сдвига. К., 1977; Теория оболочек сложной геометрии. К., 1985 (автордаш).

**ГАЛИ́МОВ** Мансур Ибраһим улы (15.3.1926, Чистай р-ны Яуширмә а. — 9.9.2000, Казан), икътисадчы, РСФСРның атказ. икътисадчысы (1989). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1957). 1943 елдан Бөек Ватан сугышында катнаша, 2 нче Ерак Көнчыгыш фронтының 363 нче Уссурийск укчы дивизия гаскәрләре составында Япониягә каршы сугыша. Кызыл Армиядән 1950 дә демобилизацияләнә. 1956–58 дә ВЛКСМның Молотов р-н ком-тында эшли, 1958–59, 1962–69 да КПССның Совет р-н ком-ты, Казан шәһәр ком-ты, Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1959–62 дә Казан финанс-икътисад ин-тында. 1969–76 да СССР Дәүләт банкы Татарстан респ-ка конторасының управляющий урынбасары, 1976–93 тә ТР Милли банкы рәисе. Г. катнашында ТРда банк системасын үзгәртеп кору һәм коммерция банкларын оештыру башлана. Банк операцияләрен автоматлаштыруга зур өлеш кертә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Əд.:* Банк на все времена. Берлин, 1997.

**ГАЛИ́МОВ** Марс Зәйнулла улы (1.5.1933, Октябрь р-ны Түбән Чаллы а. — 27.10.2001, Казан), инженер-механик, СССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1976), техник фән. канд. (1970). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (1958–79, 1981–96 елларда лаб., бүлек башлыгы; 1984 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр). 1979–81 дә һәм 1997 дән Казан технол. ун-тында. Дәүләт бүләге махсус җитештерү технологияләрен, җиһазларын эшләгән өчен бирелә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Əд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАЛИ́МОВ** Рәзиф Хиразетдин улы (7.11.1951, Мөслим р-ны Симәк а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), «Татнефть» АҖнең «Лениногорск» НГДУында эшли, 1985–88 елларда үзәк инженерлык-технол. хезмәте башлыгы, 1988 дән баш инженер — идарә башлыгы урынбасары. ТРның Дәүләт бүләге «Аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрү буенча яңа термоимплозион һәм перфорацион-имплозион экспресс технологияләр эшләү һәм киң куллануга кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГАЛИ́МОВ** Рәфкать Габделәхәт улы (8.1.1953, Казан), химик, химия фән. д-ры (1998), проф. (2003). Казан химия-технол. ин-тын (1975) тәмамлаганнан соң шунда ук эшли. 1986–87 дә Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, 1987–2004 тә РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 2004 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре нефтьне эшкәртү технологиясенә карый. Н-алканнарны синтетик май кислоталарына кадәр сыек фазада оксидлаштыруның өчкомпонентлы катализаторын эшли. Нефтьләрдә һәм нефть компонентларында порфириннар концентрациясен билгеләү ысуллары комплексын тәкъдим итә. Ванадий һәм никель кушылмаларының нефть компонентлары составында бүленеш закончалыкларын ача. Нефть асфальтеннарында ирекле стабиль радикалларның күләме ванадил комплекслары күләменә кире характерда бәйле булуын билгели. Литий кушылмаларын, нефть һәм табигый битумнарның углеводородсыз компонентларын кулланып майлау композицияләренең рецептураларын эшли. Нефть асфальтеннарының өч мөстәкыйль төркемгә бүленүен раслый (аларда күкерт, кислород булуына һәм конденсатлашу дәрәҗәсенә бәйле рәвештә).

Х е з м.: Определение содержания никельпорфиринов в нефтях // Геохимия. 1990. № 10 (автордаш); Расщепление асфальтеновых частиц // Журн. общей химии. 1993. Т. 63, № 11 (автордаш); Парафиновые углеводороды — сырьё нефтехимии. К., 2008 (автордаш).

**ГАЛИ́МОВ** Рөстәм Ибраһим улы (23.3.1938, Әстерхан өлкәсенең Ленин р-ны Энгельс пос.), контр-адмирал (1989). Хәрби диңгез сәяси уч-щесен (1959, Ленинград), В.И.Ленин исем. хәрби-сәяси академияне (1967, Мәскәү) тәмамлый. 1976–82 елларда Приморье флотилиясенең хәрби кораблар берләшмәсе командиры урынбасары, сәяси бүлек башлыгы урынбасары. 1982–84 тә Тын океан флотының сәяси бүлеге башлыгы — тыл башлыгы урынбасары. 1984–90 елларда Приморье флотилиясендә сәяси бүлек башлыгы. 1990 нан РФ Хәрби диңгез флоты фәнни-тикшеренү ин-ты җитәкчесе урынбасары. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Нахимов, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Əд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГАЛИ́МОВ** Фәрит Мисбах улы (8.1.1962, Азнакай р-ны Мачаклыбаш а.), радиофизик, техник фән. д-ры (2001). 1987 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан моторлар төзү берләшмәсендә эшли. 1989 дан «Востокстройтрансгаз» (Казан) АҖдә, 1994 тән ген. директор урынбасары. 1997 дән Казан технол. ун-тында. 2002 дән Казан техник ун-тының стандартлаштыру, сертификация һәм технол. менеджмент каф. профессоры, 2007 дән мөдире. Хезмәтләре сыек, газсыман һәм суспензияле ягулыкларның яну сыйфатларына һәм файдалану күрсәткечләренә, җылылык физикасына һәм термодинамик үзенчәлекләренә карый. Фаза әверелеше шартларында җылы бирүчәнлек коэффициентының басымга, җылылык ташкыны һәм реактив ягулыкларның маркасы үзгәрүгә бәйлеләген хисаплап чыгара. Углеводород ягулыкларын җылытканда утырым булдырмау һәм аны бетерү буенча тәкъдимнәр эшли, бу исә энергия җайланмаларының ресурсын 10 тапкыр арттырырга мөмкинлек бирә. Углеводородлы ягулыкларның физик-химик һәм файдалану үзлекләрен исәпләүнең инженерлык ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Экология лёгких моторных топлив. К., 1997 (автордаш); Авиационные криогенные углеводородные топлива. К., 1998 (автордаш); Коксоотложения в авиационных и ракетных двигателях. К., 1999 (автордаш); Основы авиационной химмотологии. М., 2005 (автордаш).

**ГАЛИ́МОВ** Энгель Рәфыйк улы (2.7.1950, Буа ш.), материаллар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1997), проф. (1999). 1972 елда Казан хим.-технол. ин-тының нефть ф-тын тәмамлый, 1978 гә кадәр Казан төзүче-инженерлар ин-тында, 1980 гә кадәр Татарстан нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1980 нән Казан техник ун-тында, 1998 дән материаллар белеме һәм материаллар технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре күптонналы полимерларны төрле өстәмәләр, ш.и. сәнәгать калдыклары б-н эшкәртүнең нәтиҗәлелегенә карый. Полимерларның технол. һәм файдалану үзенчәлекләрен үзгәртү закончалыкларын ачыклый. Поливинилхлорид нигезле композит материалларның составын һәм үзенчәлекләрен оптимальләштерү ысулын, сәнәгать калдыкларыннан файдаланып, яңа композит материаллар җитештерүнең ресурслар саклый торган югары нәтиҗәле технологияләрен эшли. Композит материаллар һәм саклагыч капламнар җитештергәндә ресурсларны саклаучы экологик чиста технологияләрне гамәлгә кертә. ТР ФАнең Г.Камай исем. бүләге лауреаты (1994), СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние дисперсности гидролизного лигнина на реологические свойства ПВХ // Пластические массы. 1991. № 3; Композиционные материалы на основе поливинилхлорида и промышленных отходов. К., 1995; Использование принципов синергетики для описания физико-химических аспектов разработки дисперсно-наполненных композиционных материалов // Вест. Казан. техн. ун-та. 1996. № 1.

**ГАЛИ́МОВ** Энгель Сабир улы (17.10.1934, Мөслим р-ны Мөслим а.), а.х. пр-тиесе җитәк-



Э.М. Галимов.



Ә.Ә. Галимова.



Д.Һ.Галимова.



Р.Л. Галимова.

чесе, ТАССРның атказ. агрономы (1975). 1962 елда Сәмәрканд а.х. ин-тын тәмамлый (Үзбәкстан). 1965–77 елларда Мөслим р-ның Киров исем. к-зында баш агроном, 1977–97 дә колхоз рәисе. Ул җитәкләгән елларда хуҗалыкның бөтен тармакларында матди-техник база ныгытыла: 800 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән комплекс, симертүдәге терлекләр өчен бина, 500 баш сыйдырышлы дуңгыз фермасы, механика паркы, ашлык чистарту-киптерү комплексы, 70 фатир, мәдәният-көнкүреш объектлары төзелә, газ кертү гамәлгә ашырыла. Бөртекле культураларның 1 гектарыннан алынган уңыш 40 *ц* га җитә, а.х. җирләренең 100 *га* исәбенә 370 *ц* сөт җитештерелә (1996). КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМның Кызыл байрагы хуҗалыкта мәңгегә калдырыла. Г. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ГАЛИ́МОВ** Эрик Михайлович (29.7.1936, Владивосток ш.), геохимик, геол.-минерал. фән. д-ры (1970), РФАнең хакыйкый әгъзасы (1994; 1991 елдан мөхбир әгъза), проф. (1982). 1959 да Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1959–73). 1959–65 тә «Спецгеофизика» трестында. 1973 тән В.И.Вернадский исем. Геохимия һәм аналитик химия ин-тында (Мәскәү) лаб. мөдире, проф. (1982), 1994 тән ин-тның директоры. РФАнең хакыйкый әгъзасы Ренат З. Сәгъдиев б-н берлектә төш-изотроп эффектын ача. Биокушылмаларда, нефть һәм газларда углеродның изотоплы составы буенча уникаль тикшеренүләр, океаник утырма токымнарның модельдәге киселешен өйрәнүләр үткәрә. Нефть ясаучы токымнарны ачыклауның изотоплы-фракцион алымын эшли; тиз агучан магмадагы кавитацион процесслар вакытында алмазлар хасил булуын фаразлый; углеводородларның төрле фракцияләрендә изотоплар бүленешенең төп закончалыкларын ача, Җир матдәсенең барлыкка килүендә үк ике углерод чыганагы булу турында фараз әйтә. Хезмәтләре тотрыклы изотоплар химиясенә һәм геохимиясенә, нефтьнең органик геохимиясенә, Җирнең һәм Айның килеп чыгышына карый. РФАнең Геохимия фәнни советы рәисе (1993 тән), Халыкара геохимия һәм космохимия ассоциациясенең вице-президенты (1993 тән). РФАнең Космос буенча советы бюросы әгъзасы (1994 тән), Айны өйрәнү буенча халыкара эшче төркемнең рәисе (1996 дан), РФАнең Геология, геофизика, геохимия, тау токымнары бүлегенең академик секретаре урынбасары (1996 дан), РФА Президиумы әгъзасы (2003 тән). СССР ФАнең В.И.Вернадский исем. бүләге иясе (1984). Ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геохимия стабильных изотопов углерода. М., 1968; Природа биологического функционирования изотопов. М., 1984; Феномен жизни. М., 2001.

**ГАЛИ́МОВА** Әлфия Әхмәт (Габделәхәт) кызы (30.5.1922, Казан), җырчы (сопрано), ТАССРның халык артисты (1985). Мәскәү консерваториясен (проф. Д.Б.Беляевская классы) тәмамлый (1950). 1950–61 дә Татар опера һәм балет театры солисткасы, 1961–63, 1966–76 да Татар филармониясендә. Төп партияләре: Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», Ш.Гуно), Антонида («Иван Сусанин», М.Глинка), Кар кызы (шул исем. оп., Н.Римский-Корсаков), Сәрвәр («Башмагым», Ж.Фәйзи), Алтынчәч (шул исем. оп., Н.Җиһанов).



Ә.Ә. Г а л и м о в а Сәрвәр (Ж. Фәйзинең «Башмагым» муз. комедиясе; Җиһан — М.Г. Рахманкулова, Галимҗан — Ф.Х. Насретдинов) ролендә.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ГАЛИ́МОВА** Дания Һадиҗан кызы (3.6.1932, Арча р-ны Миржәм а.), дуңгыз караучы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Арча р-ны «Кызыл Таң» к-зында (1948–57), «Северный» (1957–67), «Ватан» (1967–87) с-зларында эшли. Герой исеме а.х. производствосында ирешкән уңышлары һәм терлекчелек продуктларын дәүләткә сатуның бишьеллык планын үтәгәне өчен бирелә. 1975–80 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а г и т о в Т. Галимова Дания Хадизяновна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАЛИ́МОВА** Резеда Локман кызы (26.10.1966, Түбән Кама ш.), җырчы (лирик колоратуралы сопрано), ТРның атказ. һәм халык артисты (2001, 2009). 1996 елда Гнесиннар исем. Россия музыка академиясен (Мәскәү) тәмамлый. 1986–97 дә Түбән Кама шәһәренең 3 нче номерлы балалар музыка мәктәбе укытучысы, 1997 дән Татар филармониясе солисткасы. ТРның әйдәп баручы музыка коллективлары (ТР Дәүләт халык уен кораллары оркестры, ТР Дәүләт симф. оркестры, «La Primavera» камера оркестры) б-н, ш.у. телевидение һәм радиодан чыгышлар ясый. Җырчы репертуарында чит илләр, рус, татар композиторларының әсәрләре бар. Россия шәһәрләре буйлап һәм Австрия, АКШ, Германия, Финляндия, Һиндстанда һ.б. илләрдә гастрольләрдә була. Яшь вокалистлар (1992, Уфа), Халыкара Дельфы уеннары (2000, Мәскәү), Ibla Grand price (2003, Италия) һ.б. халыкара, бөтенроссия, төбәк конкурслары лауреаты һәм дипломанты.

*Әд.:* А й м ә т Р. Мин һәрвакыт хәрәкәттә // Сөембикә. 2003. № 3; М ө с л и м о в а Ф. Җыр илчесе — Резеда // Ялкын. 2003. № 1.

**ГАЛИМУ́ЛЛИН** Фоат Галимулла улы (21.3.1941, Кукмара р-ны Арпаяз а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1995, 2006), РФның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1974). 1957–60 елларда Арпаяз авыл клубы мөдире, 1960–62 дә Кукмара р-ны мәдәният сарае каршындагы татар театры җитәкчесе, 1965–67 дә КПССның Кукмара райкомы инструкторы, 1967–74 тә ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радио ком-ты дикторы. 1974 тән Казан пед. ун-тында: татар әдәбияты каф. укытучысы, тарих-филол. ф-ты деканы (1986–91), татар әдәбияты каф. мөдире (1995–2000, 2005 тән). Бер үк вакытта 1975 тән респ-ка радиосында «Тел күрке — сүз» тапшыруын алып бара. 1999–2005 тә ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбияты үсешенең закончалыкларына, 1920–30 еллар татар әдәбиятын өйрәнүдә эстетик һәм социологик категорияләрнең үзара мөнәсәбәтләренә, татар әдәбиятын урта һәм югары мәктәптә укыту методикасына карый. Урта мәктәп өчен мәктәптә сәнгатьле уку теориясе һәм практикасына багышланган хезмәтләр, татар әдәбияты дәреслекләре авторы. ТР Дәүләт Советы депутаты (1999–2009).

Х е з м.: Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү. К., 1988; Эстетика һәм социологизм. К., 1998; Әле без туганчы... 1920–30 еллар әдәби хәрәкәтенә бер караш. К., 2001; Эзләнү вакыты: XX–XXI гасырлар чигендәге әдәби мохит хакында. К., 2005.

*Әд.:* Хатипов Ф. Иплe галим, төплe тәнкыйтьче // Казан утлары. 2001, № 3; Сибат Р. Еллар сыйган мизгелләр // Көлдән күтәрелгән гөлләр. К., 2002.

**ГАЛИМУ́ЛЛИН** Харис Галимулла улы (10.3.1932, Балтач р-ны Иске Салавыч а. — 11.3.2006, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1982). 1971 елда Савальск совхоз-техникумын тәмамлый (Киров өлкәсе). Хезмәт юлын 1944 тә колхозчы булып башлый, 1948–51 елларда Балтач МТСында комбайнчы, 1954–64 тә бригадир, 1966–71 дә Балтач р-ның «Алга» к-зы, 1971–96 да «Татарстан» к-зы рәисе. Ул җитәкләгән елларда «Татарстан» к-зы республикада алдынгы, икътисади яктан көчле хуҗалыкка әверелә. 1984–89 да СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**ГАЛИМУ́ЛЛИНА** Рәисә Гали кызы (7.5.1931, Кыргызстан АССРның Каракүл, хәзерге Пржевальск ш. — 6.9.2000, Уфа), җырчы (лирик колоратуралы сопрано), педагог, БАССРның халык артисты (1974), РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1998), проф. (1995). 1954–57 елларда Башкорт опера һәм балет театры, 1957–80 дә Башкорт филармониясе солисты. Бер үк вакытта 1971 дән Уфа сәнгать ин-тында укыта, операга әзерлек (1983 тән), ялгыз җырлау (1994 тән) кафедралары мөдире. Опера партияләре: Марфа, Кар кызы («Патша кәләше», шул исем. оп., Н.Римский-Корсаков) һ.б. Концерт репертуарына чит ил, рус, башкорт композиторларының камера-вокаль әсәрләре, традицион башкорт халык җырлары керә. Башкорт вокаль башкару сәнгате тарихы буенча хезмәтләр авторы. Шәкертләре арасында Башкортстан Респ-касы халык артистлары Р.Азнакаева, Л.Гәрәева, халыкара, бөтенроссия, региональ конкурслар лауреатлары һәм дипломантлары (С.Аргинбаева, Д.Некрытов, Р.Идрисова һ.б.) бар.

*Әд.:* Уфимскому государственному институту искусств 25 лет. Уфа. 1993.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГА́ЛИН** Фәннур Зөфәр улы (1.11.1947, БАССРның Нуриман р-ны Красная Горка а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1993). проф. (1999), БРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1970 елда Башкортстан ун-тын тәмамлый. 1972–86 елларда СССР ФА Башкортстан ф-лы Химия ин-тында. 1986 елдан РФА Уфа Гыйльми үзәгенең Органик химия ин-тында, лаб. мөдире (1993–2008), баш фәнни хезмәткәр (2008 дән), бер үк вакытта Башкорт ун-тында органик химия каф. мөдире (2006 дан). Хезмәтләре органик синтез мәсьәләләренә карый. Г. табигый түбәнмолекуляр биорегуляторлар аналогларын, ш.и. югары нәтиҗәле пиретроидларны синтезлауда катлаулы төзелешле күкерт илидларын куллануны өйрәнә. Индолизидиндион һәм пирролизидиндион рәтләре алкалоидларын синтезлауның яңа ысулын, фазаара катализ шартларында алынган күкерт илидлары реакцияләренең яңа юнәлешләрен эшли. Табигый биорегуляторлар һәм аларның структур аналогларының энантиоспецифик синтезы өчен (+)-3-карен һәм аның кушылмаларының озонолитик оксидлашуын кулланырга мөмкин булуын күрсәтә. Экологик яктан куркынычсыз, югары нәтиҗәле инсектицид препаратлар (анометрин, баверсан) ясый, умартачылык өчен вет. препаратлар (аскоцин, апилат) булдыруда катнаша. Аның тикшеренүләренең нәтиҗәләре Волгоград «Химпром» ҖБдә, Чабаксар «Химпром» ҖБдә кулланыла. Ленин комсомолы бүләге лауреаты (1987). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Синтез пиретроидов с использованием сульфониевых илидов // Агрохимия. 1998. № 11 (автордаш); Новые достижения в синтезе комптотецина и его структурных аналогов // Панорама современной России. Природные и синтетические биологически активные вещества. М., 2008 (автордаш); The Synthesis Active Pyrethroids from (+)-3-Carene. Haifa, 1994.

*Әд.:* Исмагилов Р.С. Очерки по истории Нуримановского района Башкортостана. Уфа, 1998.

**ГАЛИНЗО́ГА** (Galinsoga), оешма чәчәкләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 дан артык төре билгеле, бөтен җир шары буйлап таралган. ТР терр-ясендә бер төре — вак чәчәкле Г. (G. parviflora) төньяк р-ннарда очрый. Чәчүлек мәйданнарында, җимеш һәм яшелчә бакчаларында үсә. 20–50 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Сабагы төптән үк ботаклы, кыска, төкләр сырып алган. Яфраклары йомыркасыман. Чәчәкләре вак, ак яки алсу төстә, озын чәчәк сабындагы кәрзиндә урнашкан. Җимеше — орлык. Июль-август айларында чәчәк ата. Әрсез чүп үлән. Дару үләне. Халык медицинасында аппетит ачу һәм ашкайнатуны яхшырту өчен файдаланыла.

**ГАЛИ́Т** (грек. háls — тоз), таштоз, аш тозы; хлоридлар классындагы минерал, NaCl. Составына Br, Cu, J һ.б. элементларның кушылмалары керә. Куб яисә октаэдр формалы кристаллар хасил итә. Бөртексыман-кристаллы агрегатлар, куныклар, кабырчыклар һ.б. рәвешендә очрый. Төссез һәм үтә күренмәле, еш кына соргылт-ак, зәңгәр яисә соры төстә була. Пыяласыман ялтырый. Катылыгы 2–2,5, тыгызлыгы 2,2 *г/см³*, уалучан, суда җиңел эри. Г.ның төп массалары корылыклы климат зоналарының тозлы сулы бассейннарында, сирәк очракларда вулканнар эшчәнлеге һәм хлорлы минераллар ашалу нәтиҗәсендә барлыкка килә. ТР терр-ясендә, нигездә, 90 нан алып 600 *м* га кадәр тирәнлектәге түбән Пермь утырмаларында катламнар һәм линзалар (калынлыклары 6 *м* га җитә), кабырчыклар рәвешендә очрый. Аш тозы алуда, туку, химия, фармацевтика, урман химиясе сәнәгатендә һ.б. максатларда кулланыла.

**ГАЛИУЛЛА́** (Галиуллин) Габдулла Сафа улы (2.9.1954, Казан), дин эшлеклесе. Бохарадагы «Мир-Араб» мәдрәсәсен (1983) һәм Әл-Бохари исем. Ташкент ислам ин-тын (1987) тәмамлый. 1987–90 елларда Мәрҗани мәчетендә, 1990 нан Нурулла мәчетендә имам-хатиб. 1992–98 дә мөфти, *Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте* рәисе, бер үк вакытта 1993–96 да Россия мөселманнарының югары координацион үзәге рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы рәистәше (1996–98), 1996–99 да «Өмет» иҗтимагый-сәяси хәрәкәте рәисе.

*Әд.:* Современная политическая история России. М., 1999. Т. 2.



Ә.К.Галиуллин.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Альберт Камил улы (22.1.1954, Әлки р-ны Чуаш Кичүе а.), вет. микробиологы, вет. фән. д-ры (1997). 1979 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1979–80 дә Әлки р-ны «Ярыш» с-зының баш вет. табибе. 1981–86 да Казан вет. ин-тында эшли. 1986 дан Бөтенроссия вет. ин-тында, 1998 дән терлекләрдә аеруча куркыныч авырулар китереп чыгаручы штаммнар саклау лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре терлекләрдә аеруча куркыныч авырулар китереп чыгаручыларга диагноз кую һәм индикацияләүнең яңа ысулларын эшләүгә, гамәлдәгеләрен камилләштерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Әгъзам Кәрим улы (30.1.1925, Казан — 31.1.1976, Әлмәт ш.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1971). Сәхнә эшчәнлеген 1947 елда Мамадыш колхоз-совхоз театрында башлап җибәрә. Проф. сәхнәгә Яшел Үзән шәһәренең үзешчән театр коллективы тарафыннан куелган «Чаткылар» (Т.Гыйззәт) спектаклендә староста Дәүли ролен уңышлы башкарганнан соң чакырыла. Табигый талант, үткен күзәтүчәнлек, импровизация сәләте, сыгылмалылык һәм музыкальлеге аңа проф. сәхнәдә күп кенә күренекле образлар тудырырга ярдәм итә. Г. 1949–64 елларда һәм 1968 дән — Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә. Ул башкарган Вәли («Аршин мал алан», Г.Гаҗибәков), Сәйфулла («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Чыңгызов («Бишбүләк», Т.Гыйззәт), Галәви («Тальян гармун» Г.Әхмәтшин), Әнәс («Гөлмәрфуга», И.Абдуллин) рольләре актёрның яңача гәүдәләндерүгә күчү осталыгы, образны ачканда тышкы чагылдыру детальләрен төгәл һәм нечкә файдалануы, иң соңгы чиккә җиткән катлаулы хәлләрдә дә самими, табигый булып кала белүе б-н аерылып тора. Эмоциональ тәэсир итү көченә ия булуы, тамашачыны импровизация стихиясенә җәлеп итә һәм шул минутта гына табылган сәхнә детальләрен тота белүе актёр иҗатына чын халыкчанлык төсмере бирә. Г. башкарган Хафиз («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Казбек («Хатынымның ире», Г.Хугаев), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал) образлары комик алымнардан чын виртуозларча файдалануы б-н сокландыралар. Характерның хәл-кыланышларын комик алымнар аша бирүе б-н актёр образының социаль асылын үткен сатирик буяулар ярдәмен-



Ә.С. Галиуллин.

дә дә оста гәүдәләндерә. Окаёмов («Машенька», А.Н.Афиногенов), Максуд («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Нурислам («Мәхәббәтең чын булса», Х.Вахит), Галилей («Бөек еретик», Н.Персонов, Г.Добржинский) рольләрендә Г. чын драматизмга, психологик ышандыруга, тормышчанлыкка ирешә. Ул башкарган Салих бай («Бай һәм батрак», Х.Хәмзә) һәм Карабай («Козы көрпеш һәм Баянсылу», Г.Мөсрәпов) рольләре оригиналь чишелешләре, үзенчәлекле булулары б-н сокландыралар. Ачык, үзенчәлекле талант иясе Г. Әлмәт татар драма театры тарихында зур эз калдырды.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Әнәс Сәгыйдулла улы (14.12.1940, Алексеев р-ны Чуаш Брод а.), драма актёры, ТРның халык артисты (2008). 1962 елда Республика күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исем. драма һәм комедия театры) труппасына кабул ителә, бер үк вакытта Казан театр уч-щесендә, 1971–76 да Казан культура ин-тында укый һәм Республика халык иҗаты фәнни-методик үзәгендә методист булып эшли. 1977 дән яңадан Күчмә театр труппасында, 1979–89 да театрның сәхнәгә кую бүлеге мөдире, 1982–92 дә директор урынбасары. Күп кенә җитди рольләрдә уйный, шулар арасында Йолдыз («Әниемнең чал чәчләре», А.Мирзаһитов), Антонио («Терезаның туган көне», Г.Д.Мдивани), Миша («Тынгысыз йөрәк», С.Н.Алёшинның «Палата» әсәре буенча) рольләре бар. Эпизодик рольләр остасы буларак, Г. теге яки бу сәхнә персонажының үз-үзен тотышы өстендә күп эшли, аның рухи дөньясын, психол. халәтен тиешле дәрәҗәгә җиткереп, төгәл, нигезле, ышандырырлык итеп чагылдыра. Аеруча истә калырлык рольләре: Симеон («Богауланган мәхәббәт», Ю.О'Нил), Шишкин («Мещаннар», М.Горький), Маклер («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Тикшерүче («Сакла сөюне — таплама берүк!», Х.Төхфәтуллов). «Американ» (К.Тинчурин) спектаклендә Шәехмирза ролен башкарып, Г. бар уңышсызлыкларының гаебен кешедән күрүче булдыксыз галимнең үзенчәлекле образын тудыра. Шулай ук Кәрим («Урман егете», Т.Закиров), Хәлил («Нигез ташлары», Т.Миңнуллин), Леонидика («Минем бичара Маратым», Р.Мингалимов) рольләрен дә уңышлы башкара.

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Әфгат Нәбиулла улы (20.9.1944, Октябрь р-ны Кычытканлы а.), җәмәгать-көнкүреш гигиенасы белгече, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. табибе (1995). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Татарстан һәм Удмурт АССР мед. учреждениеләрендә эшли. 1974 елдан КПССның Татарстан өлкә ком-тында адм. бүлек инструкторы. 1984 тән Казан мед. ун-тының социаль мед. һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире. Хезмәтләре балаларның физик үсешен билгеләүгә, аллергик авыруларның мед.-социаль профилактикасына, социаль мед. үсешенә, ТРда аналар һәм балалар сәламәтлеген саклауга карый.

Х е з м.: Медико-социальная профилактика аллергических заболеваний у взрослых. К., 1997; Медицина Волжской Булгарии и Казанского ханства. К., 1997.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Габделхак Сафиулла улы (26.11.1919, Казан — 17.4.1999, Мәскәү), математик һәм механик, техник фән. д-ры (1958), проф. (1959), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1999), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1974). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1947–60 елларда Казан авиация ин-тында эшли. 1961 дән П.Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-тында (Мәскәү), 1988 гә кадәр теоретик механика каф. мөдире, 1996 дан шәрәфле проф. Хезмәтләре аналитик динамикага һәм идарә итү системалары төзүгә карый. Г. программа буенча хәрәкәт итүче системаларны аналитик төзү нигезләрен эшли, дифференциаль тигезләмәләр теориясенең кире мәсьәләләрен чишә, Намбу һәм Гельмгольцның гомумиләштерелгән материаль системаларында динамиканың классик ысулларын куллана, аналитик динамиканы геометрик-дифференциаль һәм алгебраик юл б-н тасвирлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Построение систем программного движения. М., 1971 (автордаш); Методы решения обратных задач динамики. М., 1986; Аналитическая динамика. М., 1989; Системы Гельмгольца. М., 1995.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Заһидулла Талип улы (26.12.1929, БАССРның Бакалы р-ны Яңа Урсай а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1970), проф. (1974), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), газ сәнәгатенең шәрәфле хезмәткәре (1977), СССРның уйлап табучысы (1974). 1956 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлый, 1958 гә кадәр Башкортстан нефть эшкәртү фәнни-тикшеренү ин-тында. 1962 гә кадәр акад. И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында эшли. 1962 елдан Россия «Газпром» АҖнең Бөтенсоюз табигый газ һәм газ технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тында: газ транспортлау башлыгы (1966–77, 2002–04), директорның беренче урынбасары (1977–94), «Газ транспорты» бүлеге директоры (1994–2002), баш фәнни хезмәткәр (2004 тән). Хезмәтләре торбаларда газ агымнарының термогидрогаз динамикасына, газны кудырганда ресурсларны саклауга һәм үткәргеч торбаларның оптималь параметрларын билгеләүгә карый. Магистраль газ үткәргечләрне проектлаштыру һәм файдалануның (ш.и. Төньяк р-ннарында) фәнни нигезләрен эшли, зур газ агымын кудырганда техник чараларның параметрларын нигезли. 1978 елдан «Союз», 1987 дән «Уренгой–Помары–Ужгород», 1990 нан «Прогресс» газ экспортлау үткәргечләренең куәтләрен проектлаштыру һәм үзләштерүдә, Бохара–Урал, Урта Азия–Үзәк, Игрим–Серов, Ухта–Торжок, Оренбург–СССР Дәүләт чиге магистраль газ үткәргечләренең, ш.у. Медвежье, Уренгой, Вынгапур, Ямбург чыганакларының куәтләрен проектлаштыру һәм үзләштерүнең төп параметрларын нигезләүдә катнаша. Уйлап табуга 39 авторлык таныклыгы һәм 6 патенты бар. РФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге бирелә (1992). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, СССР ВДНХсының алтын медальләре һ.б. б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые методы проектирования газонефтепроводов. М., 1964 (автордаш); Методика расчёта количества газа, измеряемого диафрагменными расходомерами (для газотранспортных систем). М., 1978 (автордаш); Измерение и учёт расхода газа. М., 1979 (автордаш); Газовое оборудование, приборы и арматура. М., 1985 (автордаш); Интенсификация магистрального транспорта газа. М., 1989 (автордаш); Внутренние покрытия труб на магистральных газопроводах. М., 2006.

*Әд.:* Кто есть кто в газовой промышленности. СПб., 2001; Кто есть кто в татарской диаспоре в Москве. М., 2001.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Илдус Һади улы (5.1.1934, Арча р-ны Орнашбаш а. — 30.5.2009, Уфа ш.), кинооператор, кинорежиссёр, БАССРның атказ. мәдәният эшлеклесе (1984). 1957 елда Уфа авиация ин-тын, 1969 да Бөтенсоюз кинематографистлар ин-тын тәмамлый, 1960 ка кадәр комсомол эшендә, 1960 та С.Орджоникидзе исем. мәдәният сарае каршында киностудия булдыра. 1966–89 да БАССРның Телевидение һәм радиотапшырулар буенча дәүләт ком-ты операторы, бер үк вакытта Үзәк телевидение үзхәбәрчесе. 1990–2003 елларда «Башкортостан» киностудиясе операторы. 50 дән артык документаль фильм, ш.и. «Курай» (1967), «Мостай Кәрим» (1986), «Акмулла» (1990), «Корылтай» (1995) фильмнарын, «Өмет» («Надежда», 1972) нәфис фильмын төшерә. Бакудагы Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивале лауреаты (1979), РФнең мактаулы кинематографисты (2000).

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Ильяс Габделхак улы (26.3.1951, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (2002), проф (2002). 1973 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү авиация ин-тының теоретик механика кафедрасында эшли. Хезмәтләре каты җисем динамикасына, аналитик механикага, тотрыклылык теориясенә карый. Г. реономик механиканың геометрик нигезләрен билгеле, көчләрнең Ньютонча үзәк кырында каты җисемнең регуляр прецессиясе тотрыклылыгы мәсьәләсен чишә, потенциаль кырлардагы беркетелгән ноктасы булган каты җисемнең барлык регуляр прецессияләрен тасвирлый. Нептун планетасының прецессиясе регуляр якынаюда тотрыклы булуын, төзек системалар күплекләрендәге Ляпунов кӱр-

сәткечләренең өзлексезлек нокталары булуы турындагы теореманы исбатлый.

Х е з м.: Регулярные прецессии твердого тела с одной закрепленной точкой // Изв. АН СССР. Механика твёрдого тела. 1987. № 5; Построение динамических систем на многообразиях // Дифференциальные уравнения. 1991. Т. 27, № 12; К характеристике точек непрерывности показателей Ляпунова правильных систем // Дифференциальные уравнения. 1998. Т. 34, № 11; Бэровские классы показателей Ляпунова механических систем, содержащих параметры // Изв. вузов. Математика. 2001. № 10.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Камил Рәхим улы (13.7.1951, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2001), ТРның атказ. укытучысы (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1973) һәм шунда (1977 елдан) эксперименталь фонетика лаб-ясе мөдире, проректор (2000–02), теоретик һәм гамәли лингвистика каф. мөдире, бер үк вакытта филол. ф-ты деканы (2002 дән) булып эшли. Хезмәтләре төрки-рус тел бәйләнешләренә, рус һәм татар лингвографиясенә, гамәли һәм компьютер лингвистикасына карый. Г. рус теле лексикасындагы төрки катламның барлыкка килүен хронологик тәртиптә тикшерә, рус һәм татар лингвографиясенең теоретик һәм гамәли аспектларын, 16–17 йөзләргә мөнәсәбәтле Казан төбәге рус язма истәлекләренең сүзлек составын өйрәнә, рус һәм татар телләренең компьютер сүзлекләрен төзи.

Х е з м.: Компьютерная лингвография. К., 1995 (автордаш); Казанский край: Словарь памятников XVI века. К., 2000 (автордаш); Казанский край: словарь языка памятников первой четверти XVII века. К., 2008.

*Әд.:* Кто есть кто в лингвистике XX века. Сыктывкар, 1999. Т. 1.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Равил Вагыйз улы (1.1.1940, Тула өлкәсенең Ефремов р-ны Турдай ст.), матем. кристаллография гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1980). 1968 елда Мәскәү ун-тының геол. ф-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Кристаллография ин-тында (хәзерге РФАнең Кристаллография ин-ты) эшли, 1984 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре дискрет геометриягә, каты җисем физикасына, космологиягә карый. Идеаль кристаллның локаль теориясен төзи, бирелгән химик формуласы буенча компьютерда кристаллның төзелешен билгеләү ысулын эшли (1994), Галәмнең кристаллга охшаш моделен (1995), Җир төшендәге каты өлешнең дендрит алмаз кристаллы булarak фракталь теориясен (1999) төзи. Нәевклид кристаллографиягә нигез салучыларның берсе. РФАнең Е.С.Фёдоров исем. бүләге иясе (1997).

Х е з м.: Локальный критерий правильности системы точек // Докл. АН СССР. 1976. Т. 227, № 1 (автордаш); Кристаллографическая геометрия. М., 1984; Аксиоматика формирования месторождений кристаллических полезных ископаемых // Геологическое изучение и использование недр. М., 1998.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Рәшит Фатих улы (3.2.1938, Кострома өлкәсе Кологрив ш. — 4.6.1999, Яшел Үзән ш.), график, педагог, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1950, П.Т.Сперанский шәкерте) һәм И.Яковлев исем. Чуаш пед. ин-тын (1970) тәмамлый. Яшел Үзән шәһәрендә балалар сынлы сәнгать мәктәбен оештыручыларның берсе, шунда укыта (1954–97), бер үк вакытта директор булып эшли (1958–88). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). 1950–90 елларда Яшел Үзәндә сынлы сәнгать үсешенә, рәссам-педагоглар коллективын туплауга зур өлеш кертә. Шәкертләре арасында В.Новиков, А.Крымов, Е.Миронов, А.Лопаткин, Д.Барышева бар. Үз иҗатында үзенчәлекле һәм басма графикага — карандаш б-н язу, гуашь, офорт, акватинт, коры энәгә мөрәҗәгать итә, пейзаж һәм натюрморт жанрларында эшли. Г. әсәрләренә ихласлык һәм күпторле чалымнарны, детальләрне чагылдыру аркылы чынбарлыкны яңа яктан күрсәтү хас. «Соңгы букет» (гуашь, 1968) әсәре, «Беренче кар», «Зур су» (икесе дә — 1989), «Февраль кары. Кызылтүшләр» (1990) офортлары һ.б. шундый сыйфатларга ия. Республика (1958 дән), төбәкара «Зур Идел» (1980, 1985, 1991) күргәзмәләрендә, Мәскәүдә (1980) һәм Башкортстанда (1988) уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре күргәзмәләрендә, Мәскәүдә 15 автономияле республика сәнгате күргәзмәсендә (1990) катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Яшел Үзән һәм Лениногорск картиналар галереяларында саклана.

*М.Е.Ильина.*



Р.Ф. Г а л и у л л и н. 1. «Иске Переяславль-Залесский». Тушь, каләм; 2. «Көзге ишек алды». Темпера, пастель. 1955; 3. «Тавыклар белән пейзаж». Акварель, темпера. 1984; 4. «Март. Язгы чыр-чу». Офорт, акватинта. 1986. Барысы да ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Тәлгат Нәбиулла улы (22.7.1938, хәзерге Нурлат р-ны Кычыткалы а.), әдәбият галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1981), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1962 елдан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1965–86 да Алабуга пед. ин-тында (1967–71 дә проректор, 1971–1985 тә ректор, 1983 тән проф.). 1986 дан Казан пед. ин-тында, 1988 дән Казан ун-тында (1989–2008 дә татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. мөдире, бер үк вакытта 1989–2000 дә татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре ф-ты деканы). Хезмәтләре 20 йөз татар поэзиясенә, Г.Тукай, Х.Туфан, Һ.Такташ, С.Хәким, М.Мәһдиев, Г.Бәширов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин һ.б. иҗатларына карый. «Замана балалары» (1993) документаль повесте, «Дәгъва» (1995) хикәяләр һәм публицистик мәкаләләр җыентыгы, «Тәүбә» (1996), «Элмәк» (1998) һәм «Төнге юллар» (2002) романнары авторы. «Почёт билгесе» һәм Дуслык орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Шагыйрьләр һәм шигырьләр. К., 1985; Дәвамлылык. К., 1987; Шигърият баскычлары. К., 2005; Әдәбият — хәтер хәзинәсе. К., 2008; Здравствуй, поэзия! М., 1987.

*Әд.:* Илһам чишмәләре / Юзиев Н. Сүз башы. Иҗат серләрен эзләүче галим. К., 1988; З а һ и д у л л и н а Д. Ил йөрәгенә яза ул // Казан утлары. 2008. № 7.

**ГАЛИУ́ЛЛИН** Шәүкәт Рәхмәтулла улы (27.4.1935, Баулы р-ны Татар Кандызы а.), авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005), ТРның атказ. а.х. механизаторы (2000). Башкорт а.х. ин-тын (1961) һәм Чиләбе политехник (1964) ин-тын тәмамлый. 1949 елдан Баулы р-ны Попово МТСында хисапчы, комбайнчы-механик булып эшли. 1961–81 елларда ТАССР-

ның Авыл хуҗалыгы техникасы дәүләт ком-ты системасында. 1981–83 тә «Татарское» җитештерү-транспорт берләшмәсе ген. директоры, 1983–90 да СПТУ укытучысы. 1990 нан Казан аграр. ун-тының механизмнар һәм машиналар теориясе кафедрасында, проф. (2005 тән). Бәрәңге алу машиналарының нәтиҗәлелеген күтәрү ысуллары, орлыкны шомарту, инкрустацияләү, киптерү өчен агымлы эшләү җиһазы, туфрак эрозиясенә каршы культиваторлар, тырмалар, туфрак эшкәртү һәм чәчү өчен катнаш агрегат эшли (РФ пр-тиеләрендә һәм хуҗалыкларында производствога кертелгән). Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технология и технические средства для промышленной подработки семян сахарной свёклы и подготовки их к севу. К., 2005.

**ГАЛИУ́ЛЛИНА** Бибинур Дәмин кызы (1907, Казан губ., Лаеш өязе Олы Солтан а. — 2.8.1984, Казан), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисты (1954). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1928). 1928–33 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театры труппасында эшли, 1933–62 дә Республика күчмә театры актрисасы. Бу театрга нигез салучыларның берсе, аның тарихында күренекле эз калдыра, коллективның этик һәм иҗади традицияләренә турылыклы актриса буларак зур абруй казана. Киң диапазонлы актриса, төрле пландагы рольләрдә уйный, көчле эчке темпераменты б-н һәр образның колоритлылыгына, рольнең масштаблылыгын арттыруга ирешә. Мәскәү татар эшче театры сәхнәсендә башкарган беренче рольләрендә үк — Елена («Давыллар арасында», Д.И.Курдин), Татьяна («Разлом», Б.А.Лавренёв), Фәхрия («Козгыннар оясында», Ш.Камал) — халык аңында бара торган тирән үзгәрешләрнең катлаулы процессларын күрсәтүче иҗтимагый рухны чагылдыра. Г. иҗатына хас ачык, якты чагылышлы күркәм форма актрисага образның чын социаль-психологик асылын ачарга комачауламый. Г.ның аеруча күренекле рольләре арасында — Сәрби («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Шәмсекамәр (шул исем. пьеса, М.Әблиев), Фатыйма («Тормыш җыры», М.Әмир), Караубикә («Карагол», Д.Юлтый), Җәннәт («Каенана», М.Шамхалов), Хәмидә («Кара йөзләр», М.Гафури), Шаһсәнәм («Тугыз гашыйк», З.Шаһиморатов), Анна, Лебёдкина («Бай кәләш», «Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский), Параска («Украина далаларында», А.Е.Корнейчук) һ.б. Г., асылы б-н халыкчан башкару осталыгына ия артист буларак, хатын-кыз характерының иң үрнәк милли сыйфатларын чагылдыра.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГА́ЛИЦКИЙ** (Хлюпин) Михаил Олегович (23.1.1953, Иваново өлкәсе Вичуга ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (2005). Ярославль югары театр уч-щесен (Ф.Е.Шишигин һәм В.С.Нельский классы) тәмамлый (1987). 1980–85 елларда Саранск, 1985–92 дә Йошкар-Ола рус драма театрларында эшли. 1992 дән Казан Зур драма театрында. Саранск театры сәхнәсендә Луиджи («Луиджи йөрәге», И.Буковчан), «Человек-Бой» («Кәлтә», А.М.Володин) кебек рольләрне ачык, темпераментлы итеп башкара. Йошкар-Ола театрында уйнаган иң зур рольләренең берсе — А.К.Толстойның «Иван Грозныйның үлеме» пьесасы буенча куелган спектакльдә Иван патша роле. Биредә актёр үз өстенә алган бурычларның чиктән тыш авырлыгыннан сыгылган, сынган характерның трагик куәтен ачып бирә. Казан Зур драма театры сәхнәсендә төрле пландагы 20 ләп рольдә уйный, башкару мөмкинлекләренең киң диапазоныннан, чагылдыру чараларыннан оста файдаланып, көлкеле рольләрдә дә, драматик рольләрдә дә бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп уйный белүен күрсәтә. Җырлау сәләтенә ия булуы, теге яки бу образны берьюлы һәм муз., һәм драматик яктан сурәтли белү осталыгы аңа драма сәхнәсе өчен катлаулы саналган мюзикл жанрында киң колачлы, бай эчтәлекле, психологик Тевье («Түбәдәге скрипкачы», Д.Стайн, Д.Бок), Пичем («Өч тиенлек опера», Б.Брехт, К.Вайль) образларын тудырырга мөмкинлек бирә. ТРның Г.Тукай исем. дәүләт бүләге лауреаты (2000).

Башка рольләре: Ракитин («Авылда бер ай», И.С.Тургенев), фон Кальб («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Митька («Тавык күзе», Н.В.Коляда), Анчугин («Провинция анекдотлары», А.В.Вампилов), Мамаев («Һәр акыл иясендә гадилек җиңәр», А.Н.Островский).

**ГАЛИ́Ч (ГӘРЕ́Ч) ДАРУГАСЫ́,** Казан ханлыгында, 16 йөз уртасы — 18 йөз башында Казан өязендә адм.-терр. бүленеш төбәге. Аңа Казаннан төньяк-көнбатыштагы, *Алат даругасыннан* көньяк-көнбатыштагы җирләр: Казансуның сулъяк ярлары, Илләт һәм Кокшага елгалары бассейннарындагы (Сумка, Кавал, Мәмдәл, Комаровка елгалары) җирләр кергән. Г.д. терр-ясенең чикләре төгәл билгеләнмәгән, хәтта Алат даругасы җиреннән аерымланмаган.

16 йөз ахыры — 18 йөздә барган адм.-терр. үзгәртеп бүлүләр нәтиҗәсендә Г.д.ның марилар күпләп яшәгән волостьлары Казан, Чабаксар, Царевококшай, Царевосанчурин, Уржум һәм Козьмодемьян өязләренә керә. Г.д.сында шәхси, сарай милкендәге биләмәләр, монастырь һәм ясак җирләре була. 19 йөздә Г.д.нда Каравай, Кадыш авыллары аша Казаннан Себергә бара торган транспорт-сәүдә магистрале трансформацияләнә, Алат яки Уржум магистрале б-н кушыла һәм Вятка губернасы чигенә кадәр дәвам итә.

*Әд.:* Списки населённых мест Российской империи: Казанская губерния. СПб., 1866. Вып. 14; Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов. К., 1978; Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов. М., 2001.

*Д.Г.Мостафина.*

**ГАЛИ́ШНИКОВА** Елена Михайловна (22.4.1951, Казан ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2000). 1974 тә Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1980 нән Казан финанс-икътисад ин-тының чит телләр кафедрасында, 1993 тән каф. мөдире. Хезмәтләре эстетик тәрбия бирүнең теориясе, практикасы һәм тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: История и теория эстетического воспитания (XX век). К., 2003; Развитие эстетической мысли и практики в педагогике XVIII–XIX веков. К., 2003.

**«ГАЛИЯ́»** («Мәдрәсәи Галия диния»), Уфа шәһәрендәге мәдрәсә, 20 йөз башында татарлар һәм башка төрки мөселманнарның иң эре мәгърифәт учакларының берсе. 1906 елның октябрь аенда ачыла. «Г.» мәдрәсәсен нигезләүче һәм алыштыргысыз җитәкчесе 20 йөз башы татар интеллигенциясенең иң белемле вәкилләреннән берсе *Зыя Камали* була. 1907 дән «Г.» Уфа алпавыт хатыны Суфиябикә Җантурина һәм сәүдәгәр Сәдхи Назиров иганәсенә махсус төзелгән өч катлы бинага урнаша. «Г.» гә иң зур матди ярдәмне С.С.*Җантурин* күрсәтә. Мәдрәсәдә уку түләүле була; ул дин әһелләре әзерләү юнәлешендә эшли, уку-укыту курсы якынча 30 фәннән тора: *тәфсир* (Коръән текстларын шәрехләү һәм аңлатма бирү), *хәдис* (Мөхәммәд пәйгамбәрнең хикмәтле сүзләре), башка дини фәннәр, гарәп, татар, рус телләре, фәлсәфә, риторика, география, тарих, арифметика, химия, физика, физиология һ.б. 1914 тән «Г.»дә музыка укытыла башлый (укытучы Вильгельм Клименц — Беренче бөтендөнья сугышы башланганчы Варшава консерваториясе профессоры). Мәдрәсәдә Идел буе, Урал һәм Көнчыгыш Себердән генә түгел, Урта Азия, Кырым, Кавказдан да шәкертләр укый. «Г.» нең танылуына биредә төрле елларда укытучы (мөдәррис) булып З.*Кадыйри*, Ә.*Вәлиди*, Х.*Бәдигый*, Х.Зәйни, Г.*Терегулов*, Г.*Ибраһимов* һ.б. эшләве дә сәбәп була. Аларның күбесе Мисыр, Сүрия, Төркиядә белем алган югары белемле кешеләр. 1906 да С.Петербургка җибәрелгән жандарм белдермәсендә «...укытучы Камалетдинов (Зыя Камали) «Галия» мәдрәсәсендә фәкать фәнни темаларга гына лекцияләр укый... Бу лекцияләргә бәйрәм көннәрендә мәдрәсәдә укымаганнар йөри» диелгән. Педагогика курсын Ф.А.Дәүләткильдиева алып бара, ул мондый төрдәге уку йортларында хатын-кызлардан беренче укытучы була. «Г.» дә шәкертләр түгәрәкләре эшли, аларның кульязма журналлары дөнья күрә. 1913 тә Ш.Бабич редакциясендә «Парлак» фәнни-популяр һәм әдәби ж-лы, казакъ һәм черкәс шәкертләре журналлары чыга. Уку-укыту программасына дөньяви фәннәрне керткән өчен 1908–11 елларда Уфада жандарм идарәсе мәдрәсәдә берничә тапкыр тикшерү, тентүләр уздыра, З.Камалидан сорау ала.

Октябрь рев-циясеннән соң, 1919 да, мәдрәсә ир балалар өчен икенче баскыч гомуми белем мәктәбе итеп үзгәртелә, 1920 елда ябыла. Эшләү елларында «Г.»дә якынча 1400 шәкерт белем ала. Алар арасында татар һәм башкорт мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре — Г.Алпаров, Ш.Бабич, С.Габәши, Х.Габидов, М.Гафури, Г.Ибраһимов, С.Кудаш, Ш.Сүнчәләй, Х.Туфан, К.Хәкимов; үзбәк язучысы Мирмөхсин Ширмөхәммәтов, казакъ шагыйрьләре Баембәт Майлин, Мәгъҗан Җомабаев һ.б. була. Мәдрәсә бинасы тарихи һәм архит. истәлегенә әверелә. Аның диварында Ш.Бабичка, М.Гафурига һәм Г.Ибраһимовка багышланган истәлек такталары бар.

*Әд.:* Р ә х и м о в С. «Галия» мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан. К., 1992; Ф а р х ш а т о в М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период в 60–90-е годы XIX в. М., 1994; Я л а л о в Ф.Г. Национальное гимназическое образование: история, теория, практика. К., 2000.

*Г.С.Сабирҗанов, З.М.Маһиярова.*

**«ГАЛИЯБАНУ́»**, Галиябану исемле кызның фаҗигале мәхәббәте турында татар халык җыры. Текстта борынгы шәрекъ шигъриятенә хас алымнар файдаланыла (мәхәббәт газаплары кичерүче егет һ.б.). Ул халык көенә җырлана, җырның исеме башта «Сәгадәтбану» була. Аңа нигезләнеп, М.Фәйзи шул исемдә драма яза, ул 1917 елда Оренбург шәһәрендә куела. Пьесаны сәхнәгә куючы В.Мортазин-Иманский тәкъдиме б-н «Сәгадәтбану» исеме «Галиябану» дип үзгәртелә. С.Сәйдәшев һәм А.Ключарёв спектакльгә оригиналь музыка язганнан соң, «Г.» беренче татар муз. драмасы булып китә. «Г.» җыры аның үзәк муз. номеры булып тора. Ул тиз арада зур популярлык казана һәм, муз. драма чикләреннән чыгып, халыкның яраткан җырларының берсенә әверелә.

*Әд.:* К л ю ч а р ё в А. Татар халык көйләре. К., 1955; Ф ә й з и Җ. Халык җәүһәрләре. К., 1971; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988. *Ф.И.Урманчеев.*

**«ГАЛИЯБАНУ́»**, М.Фәйзинең 4 пәрдәле муз. драмасы. Иң популяр әсәрләрнең берсе. 1916–17 елларда языла, 1922 дә беренче мәртәбә нәшер ителә. Проф. һәм һәвәскәр татар театр труппалары тәүге спектакльләрен автор кулъязмаларына нигезләнеп куялар. Авылдагы матур кыз Галиябану һәм соңрак көндәше Исмәгыйль бай тарафыннан үтерелгән ярлы егет Хәлилнең көчле мәхәббәтендә социаль гаделсезлек, золым-җәбергә, дини хорафатларга каршы протест белдерелә. Драматургның вакыйгалар барышына татар халык җырларын күпләп кертүе нәтиҗәсендә пьеса *музыкаль драмага* әверелә, һәм татар драматургиясендә яңа жанр барлыкка килә. Әсәр беренче тапкыр 1917 елның 19 мартында — Оренбург шәһәрендә «*Ширкәт*», 1918 дә Казанда «*Сәйяр*» труппалары тарафыннан куела; рольләрне: Галиябану — Ә.Синяева, Хәлил — С.Айдаров, Бәдри — Г.Кариев, Исмәгыйль — Х.Колмәмәт һ.б. башкара. Ш.у. «Аң» труппасында, Троицк, Оренбург, Чиләбе, Әстерхан татар театрларында һәм Казанда Кызыл Октябрь исем. Беренче татар дәүләт театрында (1920–21) куела. Татар акад. театрында «Г.» 1929 (реж. Г.Девишев, рәссамы П.Т.Сперанский), 1937 (реж. Г.Исмәгыйлев, рәссамы М.Абдуллин), 1948, 1952 (реж. К.Тумашева), 1972 (реж. М.Сәлимҗанов, рәссамы М.Сутюшев), 1991 (реж. П.Исәнбәт) елларда сәхнәләштерелә. Әлмәт, Минзәлә, Чаллы, Республика күчмә театры репертуарларына кертелә. Рольләрне башкаручылар арасында: С.Байкина, Г.Кайбицкая, Р.Кушловская, М.Миңлебаева, Р.Хәйретдинова, М.Хәйруллина, И.Төхфәтуллина, Н.Ирсаева, Л.Низамиева (Галиябану); Камал III, З.Закиров, Г.Уральский, Г.Сәгыйтов, Д.Ильясов, Р.Әбүлмәмбәтов, Р.Төхфәтуллин, Ф.Гафаров, И.Әскәров (Хәлил); Б.Тарханов, Камал I, Ш.Шамильский, Х.Сәлимҗанов, Һ.Солтанов, Ә.Камалиев, Г.Каюмов, И.Камалиев (Исмәгыйль).





«Галиябану» спектакльләреннән күренешләр: 1. Татар акад. театры. 1952. Режиссёры К.Тумашева; 2. Татар акад. театры. 1991. Режиссёры П.Исәнбәт. Төп рольләрдә И. һәм Р.Төхфәтуллиннар.

*Әд.:* Г и з з а т Б. Татарская драматургия начала XX века // Пьесы татарских драматургов-классиков. К., 1958; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986. *И.Илялова.*

**ГА́ЛКИН** Владимир Иванович (30.6.1954, Курган өлкәсенең Шадринск ш.), химик, химия фән. д-ры (1992), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2004), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1991 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, проф. (1998). 1998–2003 тә химия ф-ты деканы, 2004 тән А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты директоры. ТФА нең химия һәм химик технол. бүлеге акад.-сәркәтибе (2007 дән). Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә, химик кинетикага, реакция механизмнарына карый. Г. теләсә нинди реакцион үзәкләрдәге стерик һәм индуктив константаларны, атомнар һәм төркемнәрнең төркемчә тискәре электрлылыгы зурлыгын дөрес микъдари исәпләргә мөмкинлек бирә торган алмашларның стерик һәм индуктив эффектларының яңа теоретик модельләрен эшли. Молекуляр геометрияне оптимальләштерү активлашкан комплексның структурасын бәяләү, молекулаларның реакциягә керү сәләтенең мөһим индексларын (парциаль корылмалар, локаль һәм глобаль катылык һәм йомшаклык) микъдари билгеләүнең квантхимик булмаган оригиналь ысулларын тәкъдим итә. Үстерелүче ысуллар нигезендә Арбузов, Пудовик, Вильямсон, Кабачник-Филдс һ.б. реакцияләренең кинетикасын һәм механизмын өйрәнә. Полифункциональ органик субстрактларны селектив фосфорлау ысулларын эшли.

Х е з м.: Стерический эффект: проблема количественной оценки и проявление в реакционной способности элементоорганических соединений // Успехи химии. 1991. Т. 60, вып. 8 (автордаш); Индуктивный эффект заместителей в корреляционном анализе // Успехи химии. 1998. Т. 65, вып. 8; Реакция Кабачника-Филдса: синтетический потенциал и проблема механизма // Успехи химии. 1998. Т. 67, вып. 10; The main regularities in synthesis structure and reactivity of carboxylate phosphabetaines and their derivatives // Heteroatom Chemistry. 2006. V. 17, № 7 (автордаш).

**ГА́ЛКИН** Николай Алексеевич (1773 — 15.12.1859 Спас өязенең Полянка а.), табиб, С.-Петербург мед.-хирургия академиясенең мөхбир әгъзасы (1822). 1814 елда Мед.-хирургия академиясен тәмамлый. Кронштадт госпиталендә лекарь һәм 1818 дән штаб-лекарь булып эшли. Казан ун-ты проф. И.М.Симонов б-н бергә Ф.Ф.Беллинсгаузен һәм М.П.Лазарев җитәкчелегендәге Көньяк полюс экспедициясендә (1819–21) катнаша. Экспедициядән соң Казанга күчә. 1822 дән Казан табиблек идарәсе операторы. Проф. И.М.Симонов тәкъдиме б-н Пенза губ. уч-щеләре директоры (1823–25), соңрак (1826–51) Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе директоры булып эшли. Уч-щенең яңа штаты проектын төзи, аның тәкъдиме б-н беренче тапкыр айлык уку табельләре бирелә, славян теле укытыла башлый һәм Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан Россиянең башка гимназияләрендә дә бу телне укыту гамәлгә кертелә. Карантин режимын төгәл үтәү һәм Г.ның табиблек тәҗрибәсе нәтиҗәсендә 1830 елгы холера эпидемиясе вакытында гимназиядә балалар үлеме очрагы булмый кала. Шуның өчен аңа имп. Николай I нең хөрмәте белдерелә. Г. эшләгәндә тәртип бозучыларга башкалар алдында җәза бирү бетерелә, дәрескә йөрмәүчеләр өчен гимназиядән чыгару чарасы кулланыла башлый (1826 елда 25 кеше чыгарыла). Гимназиягә эшкә Казан ун-ты профессорларын һәм укытучыларын тарта (А.К.Казимбәк, К.К.Фойгт, М.С.Рыбушкин һ.б.). Проф. Н.П.Вагнер, доктор А.А.Ильинский, гимназия укытучылары А.Е.Лазарев һәм К.К.Фойгт истәлекләренә караганда, Г. эшлекле һәм булдыклы җитәкче була, укытучылар һәм укучылар арасында ихтирам казана. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 4 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* В л а д и м и р о в В. Историческая записка о 1-ой Казанской гимназии: в 3 т. К., 1867–68; Казанское дворянство 1875–1917 г.г.: Генеалогич. словарь. К., 2001.


*И.А.Новицкая.*

**ГА́ЛКИНО** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 13 *км* көньяктарак, Томбарлы елгасы буенда. 2008 елда 46 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Баулы р-нына керә, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-ннарында. Халык саны: 1938 дә — 127, 1949 да — 97, 1958 дә — 198, 1970 тә — 108, 1979 да — 25, 1989 да — 25, 2002 дә — 64 кеше.

**ГАЛЛӘ́МОВ** Альберт Барый улы (4.4.1940, Мөслим р-ны Мөслим а.), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1998). Казан



А.М. Галләмова.



Н.Н. Галочкина

мед. ин-тын (хәзерге Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли, 1990 елда гомуми гигиена каф. мөдире, бер үк вакытта 1994 тән мед.-профилактика ф-ты деканы. Хезмәтләре балаларның сәламәтлеге торышына һәм экологиягә карый. Г., зарарлылыгын исәпкә алып, беренчел пычратучы матдәләрнең (индикатор) күп таралуын ачыклый, шәһәрләрдәге атмосфера һавасының күп компонентлы химик элементлар б-н пычрануына комплекслы гигиеник бәя бирү ысулын, Казан һавасын яхшырту чараларын тәкъдим итә. Тикшеренү нәтиҗәләре әйләнә-тирә мохитне саклау, Казанда табигый байлыклардан тиешенчә файдалану, экологик яктан киеренке терр-яләрдә төзелешне чикләүне нигезләү өчен комплекслы программалар эшләүдә файдаланыла.

Х е з м.: Геронтогигиенические аспекты донозологической диагностики водителей автотранспорта. К., 1998.

*Әд.:* Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**ГАЛЛӘ́МОВ** Әбүзәр Кәрам улы (20.6.1939, БАССРның Бакалы р-ны Иске Корыч а.), мәгълүмат технологияләре гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1974), проф. (1976), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1972), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1982). 1962 елда Уфа нефть ин-тын (хәзерге Уфа нефть техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1974 елдан югары матем. каф. мөдире. Хезмәтләре нефть үткәргечендәге технол. процессларны матем. модельләштерүгә карый. Нефть чыгарудагы механик объектларның торышын һәм алардан файдалануны оптимальләштерүне диагнозлау ысулларын эшли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидродинамика трубопроводного транспорта нефти и нефтепроводов. М., 1984; Трубопроводный транспорт в сложных условиях эксплуатации. М., 1990; Экономика математических моделей при планировании капитального ремонта магистральных нефтепроводов. Уфа, 2001.

**ГАЛЛӘ́МОВ** Рушан Рәхимҗан улы (27.10.1962, Уфа ш.) социолог, социология фән. д-ры (1997), проф. (2000). Башкорт ун-тын тәмамлый (1985). 1985–86 елларда Уфада урта мәктәптә укыта. Башкорт а.-х. ун-тының социол. лаб-ясе фәнни хезмәткәре. 1988–94 тә Уфа авиация техник ун-тында. 1997–98 дә РФАнең Уфа фәнни үзәгендә. 1998 дән Башкорт ун-тының филос. һәм социол. каф. профессоры. 2003 елдан Башкорт аграр ун-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре этносоциологиягә, этнополитологиягә карый.

Х е з м.: Многонациональный город: этносоциологические очерки. Уфа. 1996; Ресурсы мобилизованной этничности. М., 1997 (автордаш); Патернализм и этническая мобилизация народов России. М., 1998 (автордаш); Элита Башкортостана: политическое и конфессиональное измерение. К., 2006.

**ГАЛЛӘ́МОВ** Филүс Гатиф улы (2.9.1956, БАССРның Илеш р-ны Исәмәт а.), тел белгече, филол. фән. д-ры (2007), проф. (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982 елдан Алабуга пед. ин-тында, 2001 дән татар теле каф. мөдире, 2009 дан профессоры. Татар теле синтаксисыннан хезмәтләр, югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр авторы.

Х е з м.: Сайланма хезмәтләр: 2 кис. Алабуга. 2007; Повторы в современном татарском языке. К., 2003; Синтаксис осложнённого простого предложения в татарском языке. К., 2006.

**ГАЛЛӘ́МОВА** Алисә Михайловна (18.1.1972, Казан), шахматчы, халыкара гроссмейстер (1989). Шахмат б-н 1981 елда «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыяте тренеры И.И.Ильясовта шөгыльләнә башлый. СССР беренчелегендә көмеш (1987, 16 яшькә кадәрге кызлар арасында), СССР чемпионатында бронза (1991, хатын-кызлар арасында) медальләр ала. Дөнья беренчелекләрендә 1987–88 елларда (16 яшькә кадәрге кызлар арасында), 1988 дә (20 яшькә кадәрге кызлар арасында) җиңүче, 1989 да (20 яшькә кадәрге кызлар арасында) бронза медаль ала. Бөтендөнья шахмат олимпиадаларында: СССР җыелма командасы б-н 1–2 урыннар (1990, 1992), Украина җыелма командасы б-н 2 урын (1992), РФ җыелма командасы б-н 2–3 урыннар (1996). Европа (Украина җыелма командасында, 1993), РФ (1997, 2009, 2010) чемпионы. Хатын-кызлар арасында дөнья беренчелеген дәгъвалаучылар турнирында җиңүче (1997). Дөнья чемпионы исеменә (1999), «Татарстан-Европа», Россиянең 5 нче кубогы финалы (ТР җыелма командасы б-н, 2001) бәйгеләрендә катнаша. Халыкара шахмат «Оскар»ы иясе (1997).

**ГАЛЛӘ́МОВА** Мәрьям Шакир кызы (4.2.1902, Минзәлә өязе Саклаубаш а. — 5.5.1995, Казан), педагог-методист. Башлангыч белемне Мортышбаш авылы мәдрәсәсендә ала. 1917 елда Наратлы Кичү авылында мәктәп оештыра, укытучы булып эшли. 1929 дан Казан пед. ин-тында укыта. 1939 дан Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында методист, «Совет мәктәбе» ж-лында редколлегия әгъзасы. Пед. уч-щеләр һәм гомуми урта белем бирү мәктәпләре өчен методик ярдәмлекләр һәм дәреслекләр авторы һәм мөхәррире.

Х е з м.: Башлангыч мәктәптә сөйләм культурасын үстерү методикасы: Педучилищеләр өчен дәреслек һәм башлангыч мәктәп укытучылары өчен кулланма. К., 1944; Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы: Педучилищеләр өчен дәреслек. К., 1945; Туган тел: 1 класс өчен уку китабы. К., 1946; 1 классның дәреслекләре белән ничек эшләргә. К., 1970 (автордаш).

**ГА́ЛОЧКИН** Владимир Иванович (13.9.1939, Мордва АССРның Саранск ш.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991). Казан мед. ин-тын (хәзерге Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1962), шунда ук эшли, 1966–86, 1988–92 елларда оториноларингология каф. мөдире. 1986–88 дә Казан ГИДУВының шул исем. каф. мөдире. 1992–97 дә һәм 2001 дән Ульянов ун-тының дипломнан соң әзерлек каф. мөдире. Тикшеренүләре төрле формадагы саңгыраулыкка диагноз куюга, аны консерватив һәм хирургик дәвалауга карый. Г. отосклероз процессының активлыгын операциягә кадәр үк диагнозлау, урта отитка аудиологик һәм рентгенологик диагноз кую, хроник урта колак авырулары вакытында тимпанопластиканың төрле төрләренә чагыштырма бәя бирү һәм отосклерозны дәвалау ысулларын тәкъдим итә. Уйлап табуга караган авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Консервативная терапия отосклероза с целью предупреждения прогрессирования тугоухости. К., 1989.

**ГА́ЛОЧКИНА** Надежда Николаевна (4.9.1935, Питрәч р-ны Аркатау а. — 25.5.2009, Ленино-Кокушкино а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Питрәч р-нының «Путь к коммунизму» (1947–65), В.И.Осипов исем. (1966–79) к-зларында, «Осиповский» (1979–90) с-зында эшли. Сыерларны ашату һәм савуны оста үзләштереп, 1965 елда һәр сыердан 4045 *кг* сөт савып алуга ирешә. Герой исеме терлекчелектә ирешкән зур уңышлары өчен бирелә. 1966–70 елларда СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б е л о к о п ы т о в С. Галочкина Надежда Николаевна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАЛЬГА́Ф** (псевд., чын исем-фамилиясе Галиев Нургали Гали улы) (1902–40), язучы, әдәби тәнкыйтьче. Беренче тәнкыйть мәкаләләре матбугатта 1920 елларда басыла башлый. «Буталчык көннәрдә» пьесасы (1925), «Авылыма хат» шигырьләр җыентыгы (1927), «Манёврдан соң» хикәяләр җыентыгы (1927) авторы. Татар теленә А.Неверовның «Ташкент — икмәкле шәһәр» («Ташкент — город хлебный», 1929) повестен тәрҗемә итә. Нахакка репрессияләнә (к. *«Солтангалиевчеләрнең Мәскәү үзәге» эше*); үлгәннән соң аклана.

**ГАЛЯ́ВИЧ** Альберт Сәрвәр улы (1.1.1954, Баулы р-ны Уруссу пос.), кардиолог, мед. фән. д-ры (1998), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2004), ТРның атказ. табибе (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), 7 нче шәһәр (Казан) хастаханәсендә табиб булып эшли. 1984 елдан Казан мед. ин-тында (хәзерге Казан мед. ун-ты), 2000 нән ф-т терапиясе каф. мөдире. Хезмәтләре йөрәк ишемиясенә, йөрәк зәгыйфьлеге авыруларына карый. 2001 дә аның мөхәррирлегендә Мәскәүдә ике томлык «Эчке авырулар» («Внутренние болезни») дигән хезмәт нәшер ителә.

Х е з м.: Диагностика и лечение артериальных гипертоний. М., 2000.

**ГАМА́З ТАЛПАННА́Р** (Gamasoidea), паразит формалылар отрядыннан талпаннар өссемьялыгы. 20 дән артык семьялыкны берләштерә. Дөнья фаунасында 5000 ләп төре исәпләнә. Татарстанда вак имезүчеләр һәм кошлардагы Г.т. шактый тулы өйрәнелгән. Бу төркем 114 төрне үз эченә ала, ш.и. кошларда — 28, вак имезүчеләрдә 111 төре табыла. Гәүдәсенең формасы озынча түгәрәк яки түгәрәк. 0,2–2 *мм* зурлыкта, аксыл саргылт, кызгылт-көрән төстә. Гәүдәсе аерым-аерым калканнар б-н капланган, алар арасындагы бушлыкка параллель җыерчыкларга җыелган һәм киңәя ала торган ярылы кутикула урнашкан. Авыз аппараты төзелеше туклану ысулына бәйле рәвештә үзгәрә. 4 пар аягы бар, аларның беренчесе сизү ролен үти. Г.т.ның үсеш циклы: күкәй — личинка — курчак — бөҗәк стадияләреннән гыйбарәт. Г.т.ның күбесе ерткычлар һәм полифаглар. Туклыклы туфракта, умырткалы хайван өннәрендә һәм ояларында яшиләр. Семьялыктагы күпчелек төрләр яки барлык төрләре дә сөйрәлүчеләр, кошлар һәм имезүчеләр хисабына тереклек итәләр (тышкы әгъзаларда һәм эчке әгъза куышлыкларында яшиләр). Паразит төрләрнең личинкалары тукланмый. Кайбер төрләренең генә үрчемлелеге һәм яшәү чоры төгәл билгеле. Мәсәлән, күсе талпаны (Bdellonyssus bacoti). Кан эчкән саен, аны үзләштерү дәрәҗәсенә карап, ана талпан 1–20 күкәй сала. Ана талпан 5–6 ай яши, шул вакыт эчендә ул 6–7 тапкыр кан б-н туенып һәм күкәй салып өлгерә. Кан суыручы Г.т. табигый чыганакларда талпан энцефалиты, Сан-Луи энцефалиты, лимфоцитар хориоменингит вируслары, туляремия, Ку-риккетсиоз, күсе тимгелле тифы һ.б. авыруларның таралуына китерә. Кимерүчеләр һәм кошларда тереклек итүче Г.т.ның кешегә дә куркыныч тудыруы мөмкин, мәс., күсе талпаны, тавык талпаны (Dermanyssus gallinae). Г.т.ның күп кенә ерткыч төрләрен теплицаларда үсемлекләрне кимерүче талпаннарга каршы биологик көрәш чарасы итеп тә файдаланалар.

*Әд.:* Клещи грызунов фауны СССР. М.–Л., 1955; Эктопаразиты птиц в Среднем Поволжье. Ч. 1. Клещи. К., 1991.

*В.А.Бойко.*

**ГАМАЮ́РОВА** Валентина Семёновна (8.12.1939, Куйбышев, хәзерге Самара өлкәсенең Новодевичье р-ны Биринск пос.), химик, химия фән. д-ры (1983), проф. (1985), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1962), 1965–69 елларда Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1969 дан Казан технол. ун-тында, 1992 дән сәнәгать биотехнологиясе, 2004 тән азык-төлек биотехнологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре мышьякорганик кушылмалар химиясе һәм экологиясенә карый. Г. ретроарбузов реакциясе закончалыкларын, биш валентлы мышьяк кислотасының кислородлы кушылмаларының нигезлелеген һәм нуклеофиль реакциягә керү сәләтен өйрәнә. Дүртле координацияләнгән мышьякның алифатик кушылмалары өчен ретроарбузов реакциясенең универсаль булуын ача. Мышьяк атомына яки алкокситөркемгә электротискәре алыштыргычлар кертүнең реакциягә булышлык итүен күрсәтә. Дүртле координацияләнгән мышьякның кислородлы кушылмаларының ретроарбузов реакциясенә карата термототрыклылыгы һәм омтылучанлыгы рәтен төзи. Микроэлектроника, хроматография, медицина, ветеринариядә кулланырга яраклы мышьяк кушылмаларын синтезлый. Г. җитәкчелегендә биотехнология өлкәсендә биополимерларны — гөмбә хитинын һәм хитозанын — өйрәнү буенча эшләр алып барыла, аларны химик модификацияләү үткәрелә, сорбентлар һәм иммуномодуляторлар сыйфатында куллану мөмкинлеге күрсәтелә. Ферментларның (липазалар) сусыз тирәлектә биокатализы һәм фермент активаторлары өйрәнелә. Үсемлекләр өчен биологик саклау чаралары булдырыла. ТР ФАнең Г.Камай исем. бүләге лауреаты (2001).

Х е з м.: Нуклеофильность и основность арсенильных соединений // Успехи химии. 1981. Т. 50, вып. 9; Мышьяк в экологии и биологии. М., 1993; Пищевая химия: Лабораторный практикум. СПб., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000); Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАМӘЛИ́ БИЗӘЛЕ́Ш СӘНГАТЕ́**, *бизәлеш сәнгатенең* бер төре, кеше яшәгән тирәлектә әйбер-көнкүреш мохитен формалаштыручы утилитар максаттагы нәфис эшләнмәләр җитештерү һәм табигый яисә ясалма материаллардан (агач, кызыл балчык, металл, тукыма, пыяла, пластмасса һ.б.) әзерләнгән әйберләрне нәфис эшкәртү (кою, уеп бизәкләү, уеп язу, чүкеп бизәкләү, *чигү*, туку һ.б.). Г.б.с. халык (традицион яки үзешчән) һәм профессиональ иҗат төрләренә аерыла. Татар халкында Г.б.с.нең традицион төрләре булып чигү, *укалап чигү, хаттатчылык, келәмчелек, каюлы күн, металлны нәфис эшкәртү*, агачка уеп бизәк төшерү һәм язу, ташка уеп бизәк төшерү, *сәнгати туку*, *зәргәрчелек сәнгате* һ.б. исәпләнә, алар нәфис һөнәрчелек, *халык нәфис кәсепчелеге* рәвешендә, ә 20 йөз башларыннан профессиональ һәм һәвәскәр рәссамнар иҗатында үсеш ала.

Татар халкының, аның борынгы бабаларының Г.б.с. Азия (Монголиядәге Ноин-Ула, Алтайдагы Пазырык курганнары сәнгате ядкәрләре), Арал алдындагы «саз шәһәрлекләре», Таштык (Урта Енисей) һ.б. археол. культуралар һәм б.э.к. 1 меңьеллык — б.э. 4 йөздәге Көнчыгыш Европа дала күчмә кабиләләре (скифлар, сарматлар, һуннар), урта гасырлар башларындагы Төрки (6–7 йөзләр), Хәзәр (7–10 йөзләр) каганлыклары һәм Бөек Болгар (7 йөз) кебек дәүләтләрнең мәдәниятеннән башлангыч ала. Көнчыгыш Европа терр-ясендә күпчелек очракта табылган кызыл төстәге пыяла кашлы бизәмәләр, сугыш коралларының аерым өлешләре, ат дирбиясе әйберләре — һун-болгар (4–5 йөзләр) Г.б.с. үрнәкләре. Болгар аксөякләре хәзинәләрендә һун-болгар төсле каш стилендәге, алтыннан һәм көмештән эшләнгән, җепкыр һәм бөртек б-н бизәлгән асылташ һәм пыяла кашлы бизәмәләр, савыт-саба, сугыш кораллары табылды (Перещепино, Сент-Миклош хәзинәләре һ.б.). Археол. казылмалардан күренгәнчә, Татарстан терр-ясендә Г.б.с. тарихы борынгы община дәвереннән үк башлана. Буралы, Абашево, Казан яны дип исемләнгән һ.б. археол. культуралардагы керәч һәм металл бизәмәләр үрнәкләре бакыр һәм бронза дәверләренә карый. Ананьино кабиләләре культурасында (б.э.к. 8–3 йөзләр) Г.б.с.нең югары формалары — вак пластикалы геометрик фигуралар һәм зооморф бизәкләр, «җәнлек стиле» мотивлары (поши, болан, ат, аю, кабан, бөркет сурәтләре һ.б.) б-н бизәкләнгән көнкүреш кирәк-яраклары, сугыш кораллары, алтын, бронза һәм сөяктән ясалган әйберләр очрый. Табылдыклар арасында балчыктан эшләнгән йола киемендәге хатын-кыз сыннары, кабер ташларына уелган ялгыз сугышчы сурәтләре дә бар. Сармат культурасы (б.э.к. 4–3 йөзләр) ядкәрләренә, нигездә, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендәге каберлекләрдән табылган аерым керәч һәм металл эшләнмәләр карый. Пьянобор кабиләләре сәнгатенә (2–5 йөзләр) эполет рәвешендәге зур кием каптырмалары, тимерчыбык муенсалар, каз һәм үрдәк тәпиләре рәвешендәге чигә асылмалары, төрле формадагы алкалар, шөлдерле асылмалар кебек металл бизәмәләр һәм бигрәк тә җәнлекләр, кошлар һәм кеше чалымнары тупланган фантастик сурәтләр (хайван танаулы кошлар, ш.у. кеше гәүдәсен хәтерләткән, күкрәк турына битлек куелган ике яисә өч башлы кошлар) хас.

Урта гасырлар башы Г.б.с.нә Имәнкискә һәм Турбаслы археол. культураларындагы көнкүреш кирәк-яраклары җыелмасы, һуннарның кайбер табылдык әйберләре карый (бронза казаннар, хәрби дирбия өлешләре). Элгәреге болгар дәвере (8–10 йөзләр) Г.б.с. үрнәкләре металл эшләнмәләр (камәр эленмәләре, ат дирбиясе әйберләре, кием бизәмәләре), зәркән бизәмәләр (муенса, алка, беләзек, йөзекләр һ.б.), әвәләп ясалган һәм яндырылган керәч әйберләр (комган, касә, көнкүрештәге башка төрле савыт-саба), сөяктән уеп эшләнгән тараклар, пычак саплары, орчыклар һ.б. сакланып калган. Болгар «җәнлек стиле» җирле фауна мотивларының өстенлеге, тыныч, салмак хәрәкәтле, күркәм кыяфәтле, яхшы теләкле булып тасвирланулары б-н аерылып тора. Ул 8–12 йөзләр Г.б.с.ндә үсеш ала (к. *Болгар сәнгате*).

10–12 йөзләр Идел буе Болгар дәүләтенең Г.б.с. образлар тудыру рәвеше мәҗүси мифологиянең һәм *Салтау-Маяк культурасы* традицияләренең ислам әхлагы кысаларында урта гасырлар символизмына таба үсеше б-н аерылып тора. Әлеге дәүләтнең авылларында һәм шәһәрләрендә һөнәрчелек (металл эшкәртү, зәркәнчелек, керәч җитештерү һәм күн эшкәртү) югары үсеш ала, җитештерелгән продукция Европа, Үзәк Азия илләренә, Себергә һәм Ерак Көнчыгышка, Төньяк халыкларына җибәрелә. Болгар осталары алтын, көмеш, бакыр, бронза, тимер кебек металларны һәм аларның катнашмаларын нәфис эшкәртү алымнарын камил дәрәҗәдә үзләштерәләр, урта гасырларда Европада зәркән бизәмәләр (к. *Болгар чигә асылмасы*), өс киеме бизәмәләре, ат җигү дирбиясе, хәрби

корал, көнкүреш кирәк-ярагы җитештерүдә үзенчәлекле җепкыр һәм бөртекләү сәнгатен (к. *Җепкыр*) барлыкка китерәләр. Төсле буяулар һәм бизәкләр б-н зиннәтләнгән керәч савыт-саба җитештерелә, күп төрле эшләнмәләр арасында борыннарын һәм токкаларын бизәүдә вак пластика (ат, поши, кыр үгезе, үрдәк, әтәч башлары, тәкә, аю сыннары рәвешендә) кулланылган кувшиннар игътибарга лаек. Геометрик фигуралар һәм үсемлек рәвешендәге бизәкләр б-н кушылган зооморф мотивлар (хайван һәм кошларның еш кына вак пластикада стильләштерелгән сурәтләре б-н) сөяктән ясалган әйберләрне (пычак, камчы, кашык саплары, җәя сырты) бизиләр. 13 йөз башыннан чәчәк-үсемлек орнаменты һәм гарәп язуы рәвешендәге бизәк еш кулланыла (к. *Орнамент*).

Алтын Урда дәверендә Г.б.с. яңа баскычка күтәрелә, ул зәркән сәнгате (алтын һәм көмеш бизәмәләр), металлны нәфис эшкәртү (торевтика), керәч сәнгате өлкәләрендә (ялтыравыклы савытлар, майоликалы һәм мозаикалы плитәләр) югары казанышларга ирешә. Г.б.с.нең Казан ханлыгы дәвереннән сакланып калган азсанлы үрнәкләре арасында татар зәркәнчеләренең сирәк очраучы югары зәвык б-н эшләнгән әсәрләре (алтын җепкырлы каптырмалар, аксөякләр өс киеменең бизәк сәдәфләре, Коръән тартмачыклары һ.б.), ш.у. керәч осталарының (формалары һәм бизәлешләре ягыннан күптөрле савыт-сабаның археол. калдыклары), ташка уеп бизәк төшерүчеләрнең (бизәкле кабер ташлары), күнгә бизәк төшерү һәм тегү осталарының (Казан Кремлендә табылган аяк киеме кисәкләре) эшләнмәләре бар. Башка татар ханлыкларының сәнгате, сакланып калган материалларның җитәрлек булмавы сәбәпле, өйрәнелмәгән диярлек. 16 йөз уртасыннан Татарстан терр-ясенә рус Г.б.с. үтеп керә, ул өйдә җитештерү, шәһәр һәм авыллардагы нәфис һөнәрләр, кәсепләр рәвешендә үсә. 16–17 йөзләрдә Казан һәм Зөя һөнәрчелек үзәкләре булып әверелә; нәфис керәч, зәркән сәнгате әсәрләре эшләнә (к. *Казан көмешчеләре*). Рус булмаган халыкларга тимерчелек б-н шөгыльләнү патша боерыгы тарафыннан тыелу сәбәпле, 17 йөздән металл эшкәртү тулысынча диярлек рус осталары кулына күчә. 18 йөздән керәч сәнгате, агачны, күнне нәфис эшкәртү, бизәкләп туку кебек һөнәрләр Казан губернасы шәһәрләрендә генә түгел авылларында да тарала. Хатын-кыз монастырьларында шәхси заказлар буенча һәм сату өчен чигеп (көнкүреш әйберләре), укалап чигеп (чиркәү тукымалары), тукып (тукылган билбаулар) бизәкләнгән киң кулланылыш әйберләре җитештерелә. *Казан Богородица хатын-кызлар монастырендa* меңгә якын оста эшләгәне мәгълүм.

Традицион Г.б.с.нең безнең көннәргә кадәр сакланып калган төп өлеше 18 йөз — 20 йөз башына карый. Милли классик сәнгать үсеше дәверендә (к. *Бизәлеш сәнгате*) күн каю, укалап чигү, зәркән сәнгате, металлны нәфис эшкәртү, туку, чигү, костюм сәнгате, киез басу (к. *Киез*), ташка уеп бизәк төшерү, агачка уеп бизәк төшерү һәм язу кебек төрләр чәчәк ату чоры кичерәләр. 18 йөз — 20 йөз башы Г.б.с. төрләрен функциональ яктан 2 төркемгә берләштерергә мөмкин. Беренче төркем матди-киңлек мохите, көнкүреш һәм йолалар бизәлеше, өйләрнең тышкы һәм эчке күренеше б-н бәйле. Икенче төркем милли кием-салым җыелмасына бәйләнешле. Чигү, туку кебек төрләр исә йолалар һәм өйләрнең эчке бизәлеше б-н бәйле әйберләрдә дә, киемнәрдә дә кулланыла. Алар өй шартларындагы һөнәрчелек, шәһәр һәм авылларда нәфис һөнәрләр рәвешендә үсеш кичерә. Һөнәрханәләрдә осталар тәрбияләнә һәм, гадәттә, якын туганнардан торган артельләр оеша, аерым заказлар буенча эшләүче осталар да үсеп чыга. Осталык серләре һәм эш кораллары буыннан-буынга сакланып килә һәм атадан улына яисә кызына, мәс., зәркәнчелектә, мирас булып күчә. 19 йөз урталарыннан Казан губернасына кергән шәһәр һәм авылларда татар һәм рус халык нәфис кәсепчелеге барлыкка килә — каелып бизәлгән татар аяк киемнәре һәм укалап чигелгән эшләнмәләр (к. *Күн эшләү һөнәрчелеге*), киезләр һәм тукылган келәмнәр, рус һәм татар халкы традицияләрендә ясалган зәркән эшләнмәләре һәм бизәмәләре (к. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе*), тимерчелек эшләнмәләре (к. *Чабакса һөнәр-сәнгать остаханәсе*), челтәр (к. *Челтәр бәйләү*), керәч әйберләр (к. *Питрәч һөнәр-сәнгать остаханәсе*) җитештерү үсеш ала. Казанда һәм Казан артында милли зәркән бизәмәләрен җитештерү һөнәрчелек үзәкләре барлыкка килә. Аерым яисә кечкенә артельләргә берләшеп эшләүләренә карамастан, көмешче осталар иҗаты югары дәрәҗәдә үсеш кичерә. Сорау буенча, яисә сәүдә өчен әйберләр җитештерүче һөнәрчелек остаханәләре, ш.у. Әстерхан, Касыйм, Оренбург, Троицк, Тубыл, Төмән, Томск, Җаек, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге татар бистәләрендә туплана. Күп кенә авылларда көнкүреш әйберләре җитештерү төп шөгыльгә әверелә. Осталар арасында читкә барып эшләү киң тарала: балта осталары, тегүче, читекче, зәркәнчеләр акча эшләү максатында Идел аръягына, Урал алдына, Себер, Казакъстан һәм Урта Азиягә юнәләләр. Алар ясаган әйберләргә, бигрәк тә ул төбәкләрдәге татарларның гына түгел, башкорт, казакъ, үзбәкләрнең кайбер төркемнәре киеменең бер өлешенә әверелгән зәркән бизәмәләргә һәм каюлы аяк киеменә ихтыяҗ зур була. Татар Г.б.с.ндәге камил образлылык, бизәү, орнамент һәм төсләр б-н эшләү алымы өлкәләрендәге казанышлар күрше халыклар (башкорт, чуаш, мари, удмурт, рус), Урта Азия (казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән) һәм кайбер Кавказ (әзәрбайҗан һ.б.) халыклары сәнгатенә сизелерлек йогынты ясый.


19 йөз ахыры — 20 йөз башында арзанлы фабрика продукциясенең киң таралуы, көнкүреш мәдәниятенең үзгәрешләр кичерүе һәм Европа модасы йогынтысы нәтиҗәсендә Г.б.с.нең күп кенә традицион эшләнмәләре, аерым алганда, милли киемгә кергән борынгы бизәмәләр, баш, өс һәм аяк киемнәренең аерым төрләре, ш.у. кайбер төр тукымалар, киезләр, зәркән сәнгатендә катлаулы, кыйммәтле технологияләр (күпертмә һәм челтәрле җепкыр, бөртекләү, чүкеп бизәк төшерү), нигезле һәм күп көреле тукучылык һ.б. юкка чыга. 20 йөздә традицион халык һәм профессиональ Г.б.с. нәфис мәдәниятнең мөстәкыйль тармаклары буларак үсеш алалар. Профессиональ Г.б.с. өлкәсендә рәссамнарның Казан сәнгать мәктәбе берләштергән интернациональ коллективы оеша. 1920 елларда хезмәт һәм көнкүреш киемнәренең, татар милли киеме төрләренең яңа шартларга яраклаштырылган эскизлары һәм экспериментал модельләре, күн эшләнмәләр, басма бизәкле тукыма, агачка уелган бизәк үрнәкләре эшләнә (Н.И.Коробцова, Д.М.Федоров, И.А.Никитин, П.М.Байбарышев, А.Г.Платунова, Г.И.Сатонина һ.б.). Казан сәнгать мәктәбендә керәч остаханәсе оештырыла, 1927–29 елларда аның укучылары Б.И.Урманче җитәкчелегендә нәфис эшләнмәләрнең үрнәкләрен эшлиләр. Традицион Г.б.с. авыл көнкүреше өчен кирәкле эшләнмәләр җитештерүче халык кәсепчелеге һәм өй һөнәрләре рәвешендә кустарь сәнәгать кысаларында үсә. Гражданнар сугышы һәм аннан соңгы җимерекләкләр зыян китерүгә карамастан, агачны нәфис эшкәртү, чигүле баш киемнәре, каюлы күн аяк киемнәре, зәркән эшләнмәләр, челтәр җитештерү б-н мәшгуль булган һөнәрләр сакланып кала. Халык осталары (кустарьлар) артельләргә берләшәләр. 1920 еллар ахырында Казанда Кустарьлар һәм һөнәрчеләр җәмгыяте оеша, ул үзендә меңгә якын осталны берләштерә, 1920–27 дә Кустарьчылык музее эшли. Халык осталарының эшләнмәләре (каюлы күннән тегелгән аяк киемнәре, диван мендәрчекләре, зәркән бизәмәләр) чит илләргә чыгарыла, алар Мәскәүдә узган Бөтенсоюз кустарь сәнәгать күргәзмәсендә (1923) һәм «СССР халыклары сәнгате» күргәзмәсендә (1927), Парижда (1925), Монце-Миланода (1927), Лейпцигта (1928) һ.б. чит ил шәһәрләрендә үткәрелгән бизәлеш сәнгате күргәзмәләрендә уңыш казаналар. Шулай да Г.б.с.нең күп кенә төрләре акрынлап юкка чыга бара. Илдә бу продукцияне сатып алуга ихтыяҗ кимү бу күренешнең бер сәбәбе булып тора; 1930 елларның 2 нче яртысында илдән читкә чыгару туктатыла, бу да кәсепчелекнең икътисади хәлен нык кыенлаштыра. Бөек Ватан сугышы елларында Балык Бистәсендәге зәргәрчелек һәм челтәр бәйләү һөнәр-сәнгать остаханәләре ябыла. 1950 елларда халык осталары һәм үзешчән рәссамнар Казандагы Халык иҗаты йорты тирәсенә берләшә, анда чигү, туку, керәч, зәркән эшләренә өйрәтү студияләре эшли. 1960 еллардан башлап Казан сәнгать фонды каршында Г.б.с. профессиональ рәссамнары төркеме оеша (Э.В.Волков, Г.А.Зяблицев, В.В.Киселёв, С.Д.Кузьминых, В.О.Ковалевский, А.А.Сысоев, Б.А.Шубин, С.В.Шәкүрова һ.б.). 1981 дә Рәссамнар берлегенең Г.б.с. секциясе ачыла. Проф. рәссамнар иҗаты халык Г.б.с.нең сүнүе, юкка чыга баруы, сәнәгать пр-тиеләре, һөнәр-сәнгать остаханәләре продукциясенең сәнгати дәрәҗәсе түбәнәю шартларында үсә. Иң соңгы артельләр фабрика һәм комбинатлар итеп үзгәртелә, 1965 тә ТАССР Җирле сәнәгать министрлыгы кара-










































**Гамәли бизәлеш сәнгате.** 1. Бизәкле сугыш балтасы. Бронза. Кою. Ананьино культурасы. Б.э.к. 6–4 йөзләр; 2. Чүмеч. Көмеш. Уемлау, алтын йөгертү. Перещепино хәзинәсе (Кубрат хан хәзинәсе). 582–602. Дәүләт Эрмитажы; 3. Муенса. Көмеш. Җепкыр. Идел буе Болгар дәүләте. 10–12 йөзләр. ТРның Милли музее; 4. Кувшин. Әвәләп ясалган керамика. 10–12 йөзләр. ТРның Милли музее; 5. Тастымал. Киҗе-мамык тукыма, ефәк җепләр. Әлмәләп чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Милли музее; 6. Сөлге башы. Фрагмент. Асалап сугу. 19 йөз. ТРның Милли музее; 7. Яка чылбыры. Көмеш, алтын йөгертү, фирәзә, аметист, төрле төстәге асылташлар. Җепкыр. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. «Ай-йолдыз» бизәкле калфак. Бәрхет, алтын җепләр, укалап чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. Ирләр түбәтәе. Бәрхет. Алтын җепләр, ука, ялтыравыклар, трунцал. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Милли музее; 10. Бизәкле читекләр. Каюлы күн. 19 йөз уртасы. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Калфак маңгайлыклары. Фрагментлар. Бәрхет. Энҗе белән чигү. 19 йөз ахыры. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. Бизәкле тастымал. Ефәк, тукыма. Тырнак алмалау. «Туран» фонды. 2000; 13. Ваза кую өчен аслык. Металл. Чүкү. Чабакса тимерчелек промыселы. 20 йөз башы; 14. Кокошник. Укалап чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Милли музее; 15. Челтәр. Балык Бистәсе челтәр промыселы. 1920–30 еллар. ТРның Милли музее; 16. Әйрән өчен савытлар. Балчык, төсле ялтыравык. Кабарынкы бизәк. Рәссам Б.А. Шубин. 1975. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

магына кертелә (Казан нәфис эшләнмәләр ф-касы, нәфис кәсепчелекнең өйдә эшләүче осталары комб-ты, Казан сувенирлар ф-касы, Арча милли аяк киемнәре ф-касы һ.б.). Продукцияне күпләп җитештерүгә күчү кул хезмәтеннән баш тартуга китерә, нәфис кәсепчелек сәнәгый җитештерүнең бер төренә әверелә; аларның күбесе бөлгенлеккә төшә һәм ябыла. 1990 елларда татар халкының Г.б.с. традицияләрендә нәфис эшләнмәләр җитештерүче яңа үзәкләр — «Актүбә уенчыгы», «Азнакай итекләре», «Туран» фонды пр-тиеләре, укалап чигү («Традиция» фонды), каюлы күн («Экосин», «Болгари» ҖЧҖ, «Презент» ЯАЖ) остаханәләре һ.б. барлыкка килә. Башлыча, татар һәм рус авылларында халык Г.б.с.нең агачны уеп бизәкләү, өйләрне төрле төсләр б-н бизәү, бизәкләп тукуның гадирәк төрләре, чигү, келәмчелек кебек юнәлешләре сакланып килә. Хөкүмәтнең Халык нәфис кәсепчелеген, гамәли бизәлеш сәнгатен саклау, яңарту һәм үстерү программасына (2000–06) нигезләнеп, 2000 дә ТР МК каршында халык нәфис кәсепчелеге советы, 2003 тә Халык нәфис кәсепчелеген һәм һөнәрчелекне үстерү үзәге (җитәкчесе Н.Ә.Мустафаев) һәм ТРның Һөнәрчелек палатасы оештырыла. Профессиональ рәссамнар иҗатында Г.б.с.нең уникаль нәфис туку һәм гобелен (Г.И.Анютина, А.Н.Егоров, А.Р.Ильясова, М.С.Килдебәкова, Х.М.Шәрипов һ.б.), укалап тегү һәм чигү (И.А.Галант, А.В.Липина, О.Н.Марсова, Л.Ф.Фәсхетдинова һ.б.), күн эшкәртү (И.Х.Гайнетдинов, С.Ю.Гарбузова, Н.Х.Кумысникова һ.б.), керәч һәм фарфор (Р.К.Закирова, Н.В.Кузьминых, И.Х.Сәлахова, Л.Н.Сафина, Ф.М.Сәхәбетдинова, Б.А.Шубин һ.б.), нәфис металл (И.Н.Башмаков, Г.В.Богородская һ.б.) һәм зәркән сәнгате (И.А.Васильева, И.Г.Фазылҗанов һ.б.), кием модельләү (Е.М.Борисова, Р.И.Исхаков, Р.А.Камалова, З.Н.Сафина, Л.С.Чубукова һ.б.), агачка, сөяккә уеп бизәк төшерү һәм язу (В.Г.Ибраһимов, Х.Н.Латыйпов, Н.Г.Мокрецова, А.Н.Мокшин, С.А.Федотов һ.б.) кебек төрләре үсеш ала. Һәвәскәр осталар (Ф.А.Калмурзина, А.П.Обрезкова, М.М.Фәйзрахманов, И.Х.Хәлимуллин, О.А.Черкасова һ.б.) күбесенчә сәйләнләр, мәрҗән б-н чигү һәм тегү, челтәр бәйләү, аппликация, агачны уеп бизәү, тал чыбыгыннан, саламнан үрелгән әйберләр ясау һ.б. өлкәләрдә эшлиләр. Рәссамнар үз иҗатларында халык нәфис кәсепчелеге традицияләренә таяналар, Г.б.с.нең борынгы технологияләрен, образлы чагылдыруның нәфис чараларын, бизәк системасын яңарталар.

*Әд.:* В о р о б ь ё в Н.И., Б у с ы г и н Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Б у с ы г и н Е.П. Русское население Среднего Поволжья. К., 1966; В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — 1990-е гг.). К., 1995; Российские промыслы: Спец. выпуск. 2001. Окт.-нояб.; Изделия народных художественных промыслов и декоративно-прикладного искусства Республики Татарстан: Каталог. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАМӘЛИ́ О́ПТИКА ИНСТИТУТЫ́**, Р Ф И к ъ т и с а д м и н и с т р л ы г ы н ы ң д ә ү л ә т и н с т и т у т ы, фәнни-җитештерү берләшмәсе, гадәти кораллар җитештерү буенча Россия агентлыгының федераль унитар пр-тиесе (ФГУП «НПО «ГИПО»). 1957 елда С.И.Вавилов исем. Ленинград оптика ин-тының Казан ф-лы буларак оештырыла, 1966 дан Гамәли оптика ин-ты (ГИПО) итеп үзгәртелә. 1991 дән ГИПО фәнни-җитештерү берләшмәсе, 1997 дән ГИПО федераль фәнни-җитештерү үзәге, 2001 дән хәзерге исемдә. Космос, авиация һәм коры җир өчен махсус оптик-электрон аппаратура һәм көнкүреш оптик приборлары төзү өчен оештырыла. Ин-т оешкан көннән аның эшчәнлеге фундаменталь эзләнүләр алып бару һәм гамәли мәсьәләләр чишү, хәрби сәнәгать һәм халык хуҗалыгы өчен конкрет технол. процесслар, җиһазлар, приборлар эшләү б-н бәйләп алып барыла. 1950–60 елларда оптика фәненең куәтле үсеше оптикада яңа элементлар базасын эшләүгә, яңа фәнни-техник юнәлешләр барлыкка килүгә ярдәм итә. Асферик оптик элементларны серияләп җитештерү өчен ГИПОда беренче мәртәбә пыяланы суык килеш эшкәртү өлкәсендәге технол. процесслар эшләнә. Оптик каплам салганда оптик материалны термик парга әйләндерү электрон нурланыш б-н алыштырыла. Лазерлар эшләнү ГИПОда голография һәм голограмма техникасы үсүенә китерә. Өметле ярымүткәргеч материаллар — индий антимониды һәм өчләтә кушылмалар, ш.и. заманча фотоалгыч җайланмалар өчен кадмий-терекөмеш-теллур алу эшләре башлана. Халык хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен яңа технологияләр, ш.и. оптик детальләрне тирән оптик контакт ысулы б-н ялгау, аэродинамик торбалар, илнең аэробаллистик трассалары өчен электрографик приборлар, голографик интерферометрлар, заманча спектрографлар һәм спектрометрлар эшләнә. Корал һәм хәрби техника чаралары өчен оптик-электрон приборлар төзүнең яңа юнәлешләре — авиация һәм космос өчен тепловизорлар, дистанцион оптик шартлаткычлар, җылылык пеленгаторлары төзү үсеш ала. Бер үк вакытта фонны максатчан өйрәнү һәм атмосфера оптикасы өлкәсендә зур тикшеренүләр җәелдерелә, аларны башкару өчен ГИПОда спектрорадиометрик аппаратура эшләнә. 1957–82 елларда оптик механика сәнәгате пр-тиеләрендә ГИПО проекты буенча 20 ләп оптик һәм оптик-электрон прибор серияләп чыгарыла. Тармак пр-тиеләрендә 100 дән артык яңа технол. процесслар гамәлгә кертелә, 30 мең данәгә якын спектраль интерференцион оптик фильтр һәм көзге (ш.и. лазер техникасы өчен дә) эшләнә, әзерләнә һәм заказчыларга җибәрелә. Йомык цикл буенча дифракцион рәшәткәләр җитештерү өчен 1976 да махсус корпус төзелеп беткәннән соң, дифракцион рәшәткәләр һәм аларның копияләре серияләп чыгарыла башлый. 1982 гә ГИПО СССРның дифракцион рәшәткәләргә булган ихтыяҗын тулысынча тәэмин итә, ә 1984 тән башлап дифракцион оптик эшләнмәләр чит илләргә дә җибәрелә. 1981–96 да 130 мең данәгә якын төрле типтагы дифракцион рәшәткә илебезнең халык хуҗалыгына, 8 меңнән артыграгы экспортка озатыла. СССРда яңа ракета комплекслары төзелү уңае б-н 1960 еллар азагында инфракызыл нурланыш алгычлар әзерләү һәм серияләп җитештерү ихтыяҗы килеп туа. Андый комплексларны җиһазлау өчен 1970–80 дә заказ бирүчеләргә 225 меңнән артык алгыч эшләнә һәм җибәрелә.



Гамәли оптика институтының административ бинасы.



Интерференцион фильтрлар, көзгеләр, яктылык бүлүче һәм яктыртучы каплау материаллары үрнәкләре.

1968–80 дә ГИПОда ракета комплексларының төбәү (төзәгеч) системаларын метрологик тәэмин итү юнәлеше үсеш ала һәм төп фәнни юнәлешләрнең берсенә әверелә, бу исә астрономик нурланыш чыганаклары параметрларын тикшерү һәм үлчәү, аларның физик модельләрен төзү өчен күп кенә фотометрик приборлар эшләү ихтыяҗына китерә. 0,4–16 *мкм* спектры диапазонында үлчәү приборлары комплексын һәм уникаль сынау аппаратурасын эшләү өчен шул җирлектә оптик-электрон приборлар төзү буенча тармак метрология хезмәте оештырыла.

1968–98 дә ГИПО уникаль приборлар эшләүдә һәм төзүдә катнаша. Алар арасында: «Салют-М» орбиталь станциясе өчен «Волга» һәм «Янтарь» приборлары; «Космос» сериясенә кергән космик корабльләр өчен югары сизгерлекле термовизион аппаратура; космик корабльләрне «Мир» станциясенә төшерү өчен борттагы йолдыз глобуслары һәм радиометрик приборлар; «Метеор-3М» метеоиярчене өчен радиометрик аппаратура; Россия һәм Украинаның уртак «Океан-О» иярчене өчен күп спектрлы уникаль аппаратура; Марс һәм Венера планеталарын тикшерү өчен спектраль һәм фотометрик аппаратура бар.

1980 елларда ГИПОда, СССРда беренче булып, танкларга каршы ата торган ракета комплекслары өчен термовизион төбәгечләр эшләнә, СССР Оборона министрлыгы заказлары буенча аларның 1 мең данәдән артыгы экспортка ясала. 1987–2001 дә 11 төрле типтагы термовизион приборлар һәм системалар эшләнә. 1990–2000 дә ин-тның зур казанышлары: оптик-электрон аппаратураның киләчәк үрнәкләренә оптик комачау тәэсирен компьютерда модельләштерү технологияләрен эшләү һәм аларның төрле фон, һава һәм климат шартларында кулланылу нәтиҗәлелеген бәяләү; төрле корал комплекслары һәм төрле гаскәрләрнең хәрби техникасы өчен сызыкча, субматрицалы һәм матрицалы фотоалгыч җайланмаларда термовизион каналларның бердәм база модульләрен эшләү; киләчәк авиация комплекслары өчен модульле термовизион канал төзү; ГИПОның тәҗрибә з-дында термовизион төбәгечләр ясау һәм аларны сериялап җитештерүне үзләштерү; радиоэлектрон каршылык күрсәтү өчен авиация комплекслары бортларына урнаштырыла торган комачаудан сакланган ультрамиләүшә пеленгация каналы эшләү; термовизион приборларны сынау өчен метрологик аппаратура комплексын ясау һәм җитештерүне үзләштерү; спектрның инфракызыл өлкәсе өчен югары нәтиҗәле саклагыч, ачыклаткыч һәм кайтаргыч капламнар алу, лазер нурланышын югары дәрәҗәдә бастыручы тар өлкәдәге интерференцион һәм голограммалы фильтрлар, югары төгәл асферик һәм дифракцион оптика технологияләрен эшләү.

1957 елдан ГИПО армия, авиация һәм флотны коралландыруга кертелгән 60 ка якын комплекс эшләүдә катнаша; аның тарафыннан төрле максатлар өчен билгеләнгән 1 меңнән артык исемдәге оптик-электрон приборларның эксперименталь һәм тәҗрибә үрнәкләре эшләнә.

ГИПО күп кенә фәнни-техник юнәлешләр буенча баш пр-тие булып санала һәм коры җир гаскәрләрен, авиацияне, хәрби диңгез флотын коралландыру комплекслары өчен термовизион техника җитештерү өлкәсендә әйдәп баручы булып тора.



Танкка каршы ракета комплекслары өчен термовизион төзәгеч.

Ин-т галимнәре Россия һәм БДБ илләрендә мәгълүм фәнни юнәлешләр билгеләде: молекуляр спектроскопия һәм атмосфера оптикасы (С.О.Мирумянц, Н.И.Москаленко, В.Л.Филиппов, А.С.Макаров, В.П.Иванов, В.К.Козлов, И.А.Непогодин һ.б.); ярымүткәргеч материаллар белеме (Н.С.Барышев, И.М.Несмелова һ.б.); оптик интерференцион капламнар технологиясе (И.С.Гайнетдинов, Е.А.Несмелов һ.б.); голография һәм голограмма техникасы (К.С.Мостафин, А.В.Лукин һ.б.); инфракызыл оптик-электрон приборлар төзү (Н.Л.Пантелеев, Р.Д.Мөхәммәдьяров, В.П.Иванов, С.О.Мирумянц, И.А.Непогодин, В.Л.Филиппов һ.б.).

ГИПОның фәнни-техник потенциалын үстерүгә инженер-техник хезмәткәрләрдән Е.Ф.Дедюхин, Д.Ш.Галиәкбәров, В.А.Дорофеев, А.Т.Шепталин, С.Г.Давыдов, О.Г.Карлин, А.В.Васильев, Р.М.Шәймәрданов, В.С.Елистратов, Г.Н.Петров, Ю.Г.Кожевников, Б.Н.Бардин, Е.Г.Москвич, В.А.Кормаков, В.Д.Филипков, Г.А.Краснов һ.б. зур өлеш кертә.

ГИПОның фәнни бүлекләрендә түбәндәге юнәлешләр буенча тикшеренүләр үткәрелә: атмосфера һәм молекуляр спектроскопия; атмосфера оптикасы; фонны максатчан тикшерү; вакуумда оптик капламнар эшләү технологиясе; дифракцион, голографик, интеграль, җепселле һәм асферик оптика; ультрамиләүшә, күренмә һәм инфракызыл өлкәләр өчен оптик системалар һәм махсус объективлар хисаплау. Ин-тка спектраль, фотометрик, радиометрик, йөртелә, күчерелә, ташыла торган термовизион приборлар, үлчәгеч оптик приборлар, коры җир гаскәрләре, авиация, хәрби диңгез флоты, космос өчен махсус оптик-электрон приборлар төзү һәм эшләү буенча махсус бүлекләр, ш.у. конструкторлык-технол. бүлекләре, оптик һәм оптик-электрон приборлар җитештерү тәҗрибә з-ды керә.

ГИПОның тематик юнәлеше, конструкторлык-технол. мөмкинлекләре һәм җитештерү куәтләре, персоналның югары квалификациясе тикшеренүләрнең тулы циклын уздырырга, мөһим ведомствоара һәм максатчан программалар буенча хәрбиләр һәм тормыш-көнкүреш өчен билгеләнгән оптик һәм оптик-электрон приборларның өр-яңа төрләре буенча тулы цикллы тикшеренүләр алып барырга һәм сәнәгый җитештерергә мөмкинлек бирә.

ГИПО илебезнең 200 дән артык пр-тиесе, фәнни-тикшеренү ин-тлары, югары уку йортлары һ.б. учреждениеләр, ш.и. Казан ун-ты, Казанның техник, технол., энергетика ун-тлары, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-ты, «КОМЗ» АҖ, «Фотон» Үзәк КБ б-н фәнни-техник бәйләнеш тота. ГИПО хезмәткәрләре фәнни журналларда 4 меңнән артык мәкалә бастырган, 40 лап монография нәшер иткән, 1,5 меңнән артык уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патентлы алган (2004). Ин-тның 9 хезмәткәре Дәүләт, СССР МС һәм ТР бүләкләренә лаек була, 10 кешегә РФ һәм ТРның мактаулы исемнәре бирелә, 135 кеше орден һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ин-т директорлары — Е.Н.Кожевников (1957–63), С.О.Мирумянц (1963–86), Ю.М.Беляков (1986–87), А.С.Макаров (1987–98), В.П.Иванов (1998 дән).

*Әд.:* Макаров А.С. НПО ГИПО — лидер российского тепловедения // Военный парад. 1996. № 6; Комплекс измерительных и метрологических средств в тепловидении // Военный парад. 1999. № 4; Научно-производственное объединение «Государственный институт прикладной оптики» 1957–1977 гг.: В 2 ч. К., 1997; НПО ГИПО — 40 лет // Оптический вестн. 1997. № 3–4; Белозёров А.Ф. Тепловидение в НПО ГИПО // Оптический вестн. 1997. № 5–6; Макаров А.С., Белозёров А.Ф., Мирумянц С.О. Исследуя тайны оптических явлений // Научный Татарстан. 1997. № 1.


*С.О.Мирумянц, Р.Г.Усманов.*

**ГАМБӘ́Р** (Гамбәров) Наис Гыймран улы (25.8.1947, Мөслим р-ны Бүләк а. — 5.5.2005, Казан) язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1974–92 елларда (бүленеп) Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 1992 дә «Татарстан», 1993–97 дә «Казан утлары» ж-лларында җаваплы сәркәтип. Х.Туфан, Р.Фәйзуллин, Р.Гатауллин, Гәрәй Рәхим, М.Әгъләмов, Зөлфәт, М. Хәбибуллин, Т.Галиуллин һ.б. иҗатлары турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре авторы. Лирик шигырьләре тупланган «Баш очымда — Кояш» (1991), «Күзләрем яфрак коя» (2001) җыентыклары, әдәби эсселар авторы.

*Әд.:* Сафин Ф. Күңелемнең ачык тәрәзәләре // Мәдәни җомга. 1998. 17 апр.; Кутуй Р. Мир своих детей не прячет // Казань. 1984. № 7/8.

**ГАМБӘ́Р ҮЛӘНЕ́** (Polygala), гамбәр үләнчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәгрәк берьеллык үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 600 ләп төре билгеле. Җир шарының уртача, субтропик һәм тропик поясларында киң таралган. ТРда 5 төре үсә: гади Г.ү. (P. vulgaris), йөнтәс Г.ү. (P. comosa), әчкелтем Г.ү. (P.amarella), гибрид Г.ү. (P. hybrida), Себер Г.ү. (P. sibirica). Известьле сөзәклекләрдә куак араларында, дала, болыннарда үсә. 5–45 *см* биеклектәге үсемлекләр. Яфраклары эллиптик-ланцетсыман, чиратлашып урнашкан. Чәчәкләре вак, шәмәхә-зәңгәрсу, кайчакта алсу-сары төстә. Җимеше — ике оялы тартмачык. Май-август айларында чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Җир асты өлешләрендә сапониннар, дуплау матдәләре, җир өстендәгеләрендә алкалоидлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе сулыш юллары авырулары вакытында кулланыла. Яфраклары һәм яшь бәбәкләре кулинариядә тәмләткеч буларак файдаланыла. Декоратив, баллы үсемлекләр. Себер Г.ү. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГАМБӘ́Р ЧӘЧӘГЕ́**, (Adoxa), гамбәрчәчәкчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. ТРда бер төре — исле Г.ч. (A.moschatellina) Идел һәм Каманың түбән агымындагы яфраклы урманнарда, бай туфраклы әрәмәлекләрдә очрый. Иртә яздан, агачлар яфрак ярганчы тамырчадан үсеп чыга. Тамырчалары итләч тәңкәләр б-н капланган. Биеклеге 5–10 *см*. Аскы түшәлмә яфраклары итләч, өске яфраклары өчәр бүлемтекле, каршыдаш урнашкан. Чәчәкләре вак, сар-



А.Г. Ганиев.

гылт яшел төстә, мускус исле. Өске чәчәкләре 4 әгъзалы, яндагылары 5 әгъзалы. Сабак очындагы чәчәк төркеме башчада урнашкан. Җимеше — хуш исле әчкелтем тәме булган каты кабыклы төшчә. Дару үләне, антисептик. Тамырчаларыннан ясалган препаратлар яра төзәтүдә кулланыла. Орлыклары — кошларга азык. *Ф.З.Вәлиев.*

**ГАМБӘ́Р-АНА́**, Идел буе татарлары мифологиясе һәм фольклорында кошларны яклаучы, Урта Азия халыкларында һәм Урал яны татарларында — уңыш алиһәсе һәм бала табучы хатыннарга ярдәм итүче, мөселман риваятьләрендә — Урта Азия шагыйре С.*Бакыргани* хатыны, ул үлгәч, *Зәнки бабай* хатыны.

Бу риваятьләр нигезендә «Хикәйә-и Хәким-ата» (1846) язылган. Г.-а., Бакыргани һәм аның улы Хөбби Хуҗа — *Кол Шәрифнең* «Кыйсса-и Хөбби Хуҗа» поэмасы геройлары.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Табышмаклар. К., 1977; Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр... К., 1997; Я х и н Ф. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. К., 2000; С н е с а р е в Г.П. Реликты домусульманских верований и обрядов у узбеков Хорезма. М., 1969.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГАММАРБИ́ ҮЛӘНЕ́** (Hammarbya), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. ТРда бер төре — саз Г.ү. (H. paludosa). Сирәк очрый торган төр, Идел-Кама саклаулыгының Раифа бүлемтегендә очрый. Торфлы сазлыкларда үсә. 30–80 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы 5 кырлы, эллиптик яки йомыркасыман 3–4 яфрагы бар. Чәчәкләре саргылт-яшел төстә, вак. Июньнән август башларына кадәр чәчәк ата. Яфрак читендә урнашкан җенессез бөреләреннән үрчи. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГА́ММЕР-ПУ́РГШТАЛЬ** (Хаммер Пургшталь) (Hammer-Purgstall) Йозеф фон (9.6.1774, Грецe ш., хәзерге Грац ш., Австрия — 23.11.1856), Австрия шәркыятьчесе һәм дипломаты, Петербург ФАнең шәрәфле читт ил әгъзасы (1823). 1796 елдан Россия Тышкы эшләр министрлыгында хәрби департамент секретаре. 1799–1807 елларда Төркиядә Австрия илчелеге хезмәткәре. 1801 дә Мисырда була, анда бай археографик материаллар коллекциясе туплый. 1847–49 да Вена ФА президенты. Хезмәтләре Госманлылар империясе, Алтын Урда, Шәрекънең мөселман халыклары әдәбияты тарихына карый. Галимнең гыйльми мирасында күпсанлы төрек чыганакларын һәм Австрия архивлары материалларын файдаланып язылган 10 томлы «Госманлылар империясе тарихы» («История Османской империи», Пешт, 1827–35) аерым урын алып тора.

Х е з м.: Des osmanischen Reiches Staatsverfassung und Staatsverwaltung. W., 1815. Bd.1–2; Geschichte des osmanischen Reiches. Pest, 1827–35. Bd. 1–10; Geschichte der Goldenen Horde in Kiptschak. Bdpst., 1840; Geschichte der Chane der Krim unter osmanischer Herrschaft. W., 1856.

*Әд.:* S c h l o t t m a n n K. Joseph von Hammer-Purgstalle. W., 1858.

**ГАНДБО́Л** (ингл. hand — кул һәм ball — туп), тупны каршы капкага кертү максатында куллар б-н ыргытуга корылган командалы спорт уены. Г. буенча беренче командалар (ирләр һәм хатын-кызлар)1959 елда Казандагы «Радиоприбор» физик культура коллективы каршында (оештыручысы һәм тренеры Р.М.*Яушев*) булдырыла. 1961 дә ТАССР Г. федерациясе оештырыла, 1966 дан 1980 еллар ахырына кадәр шәһәр һәм республика беренчелегенә ярышлар уздырыла. Казан физик культура коллективларының (Воровский исем. СК, «Электрон», «Луч», «Ракета» СК), Казан пед., авиация, химия-технол. ин-тлары, югары хәрби инженерлар уч-щеләре командалары — ТАССР, РСФСР, «Труд», «Зенит», «Урожай», «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятьләренең үзәк советлары беренчелегендә катнашалар. ТРның иң көчле командалары: «Заря» (1969 дан «Электрон») — «Труд» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советы беренчелекләрендә катнаша, 3 нче урын ала (1960, 1965, хатын-кызлар), 1964–87 дә (хатын-кызлар) РСФСР беренчелегендә «А» классында уйный; Воровский исем. СК (ирләр, 1971 дән «Б» классында, 1972 дән «А» классында) — РСФСР беренчелегендә көмеш медаль ала (1982), «Зенит» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы беренчелегендә җиңүче (1982, яшүсмерләр); «*КАИ-ТАЦИТ*». ТР җыелма командасы РСФСР халыклары спартакиадасында катнаша (1967 дән, ирләр һәм хатын-кызлар), РСФСР чемпионы (1969, кызлар). 1974 тә Казандагы комплекслы 6 нчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе каршында Г. бүлеге ачыла. 1983 тә Г. буенча 13 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе булдырыла (беренче директоры В.Н.Обрядин). 1997 дән олимпия резервы мәктәбе статусын ала, бу мәктәптә тәрбияләнүчеләр РФнең югары һәм супер лигаларында уйныйлар. Иң яхшы уенчылар — Р.Г.Газимов, М.Е.Жуков, Н.О.Осетинская, В.Селезнёва, В.Уткин, Т.Харитонова, Л.Е.*Шубина*. Танылган тренерлар: В.Д.Былкин, В.И.Кремлёв, В.Н.Обрядин, М.Ю.Феоктистов, Р.М.Яушев. Халыкара категорияле судья А.М.*Гаврилов*.

**ГАНИ́ЕВ** (Мөхәммәтганиев) Азат Вәли улы (1.5.1942, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль а.), язучы. Лениногорск сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1966). Заводта токарь, урта мәктәптә рәсем укытучысы булып эшли. Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. «Тагын күченәбез» исемле хикәяләр җыентыгы (1969), «Сүзсез җыр» (1972), «Габделхак» (1984), «Адашкан җаннар» (1993) повестьлары авторы. Әсәрләренә фәлсәфилек хас, әхлак мәсьәләләре кискен куела.

*Әд.:* В ә л и е в М. Учагың сүрелмиме? // Учагың сүнмәсен. К., 1988.

**ГАНИ́ЕВ** Азат Минһаҗ улы (5.5.1945, Апас р-ны Апас а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1976), проф. (1997). Татарстан ССРның атказ. икътисадчысы (1991). 1969 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1963–64 елларда «Спартак» күн аяк киемнәре комб-тында эшли. 1969–73 тә һәм 1976 дан Казан финанс-икътисад ин-тында: ассистент, өлкән укытучы, тармаклар икътисады каф. доценты, сәнәгатьне планлаштыру ф-ты деканы (1982–86), уку-укыту эшләре буенча проректор (1986 дан), ин-тның беренче проректоры (1990–2007). Фәнни тикшеренүләре пр-тие, хезмәт б-н идарә итү һәм конфликтлылык проблемаларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Управление персоналом — основы развития бизнеса // Уч. зап. Казан. фин.-эконом. ин-та. 1996. Вып. 15; Конфликтология. Формирование установок толерантного сознания и поведения. К., 2002.

*Әд.:* Земля предков — колыбыль моя. К., 2000.

**ГАНИ́ЕВ** Али Гани улы (1897, Казан губ., Казан өязе Түбән Аты а. — 9.5.1938), дәүләт эшлеклесе. 1911–15 елларда Дагстандагы шәхси пр-тиеләрдә приказчик булып эшли. 1916–17 дә Россия армиясе сафларында хезмәт итә. Казанда 1917 елгы Окт. коралды күтәрелешендә катнаша. Гражданнар сугышы чорында 1918–21 дә Көнчыгыш, Көнбатыш һәм Көньяк фронтларда Кызыл Армиянең сәяси хезмәткәре. Идел буе һәм Урал яны шәһәрләрен, ш.и. Казанны һәм Ижевскины акгвардиячеләрдән азат итүдә катнаша. 1919 да 7 нче укчы дивизиянең полк комиссары, генерал А.И. Деникин армиясенә каршы сугыша. 1921–22 дә БҮБК каршында һәм РСФСР Милләтләр эше халык комис-тында ТАССРның вәкаләтле вәкиле, 1922–25 тә ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы, рәис урынбасары. 1925–27 дә Казанда хакимият-хуҗалык эшендә: Дәүләт банкының һәм Бөтенроссия коммерция банкының Татарстан конторасы җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе, Татарстан Кәсепчелек промыселлары берлеге рәисе. 1928–29 да ТАССР ХХС рәисе. 1929–34 тә җылылык эл. станциясе төзелеше җитәкчесе, соңрак 1 нче Җылылык эл. станциясе директоры. 1934–36 да ТАССРның җиңел сәнәгать, 1936–37 дә җирле сәнәгать халык комиссары. Татарстанның Соц. Төзелеш Батыры (1932). Репрессияләр чоры корбаны (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше; «*Уң троцкийчы милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы оешмасы*» эше); вафатыннан соң аклана.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б. Ганеев Али Ганеевич // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

**ГАНИ́ЕВ** Вил Хәлил улы (10.7.1934, Норлат, хәзерге Яшел Үзән р-ны Норлат а. — 7.4.2005, Мәскәү), әдәбият белгече, тәрҗемәче, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), «Казан утлары» ж-лы редакциясендә эшли. 1959 елдан Мәскәүдә яши. 1964–67 елларда «Советский писатель» нәшриятында, 1967–91 дә СССР Язучылар берлеге идарәсендә, бер үк

вакытта 1986–94 тә Әдәбият ин-тында эшли. 1997 дән РФАнең Дөнья әдәбияты ин-тында. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбиятына (Г.Тукай, Г.Исхакый, З.Вәлиди, С.Максуди, М.Гафури) карый. «XX йөз татар әдәбияты» очеркы (2001) авторы. Рус теленә татар шагыйрьләре Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Гафури, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Х.Туфан, Г.Кутуй, Ә.Ерикәй, С.Хәким, Г.Афзал, З.Нури, төрки телле шагыйрьләр Н.Хикмәт, Мәхтүмкули, Җамбул, М.Кәрим шигырьләрен, Г.Әпсәләмовның «Ак төннәр» повестен (1959) тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г а ф ф а р Ә. Игелекле эш кешесе // Казан утлары. 1984. № 3; М у с т а ф и н Р. Поэтическая интонация переводчика // Образ времени. К., 1981.

**ГАНИ́ЕВ** Гали Газиз улы (1.10.1947, Баулы р-ны Яңа Шалты а.), нефтьче, «Татнефть» АҖнең «Баулынефть» НГДУы башлыгы (1984 тән), техник фән. канд. (2001), РФ нефть һәм газ сәнәгатенең атказ. хезмәткәре (1993), РФ Җылылык энергетикасы министрлыгының атказ. хезмәткәре (1996), ТРның атказ. нефтьчесе (1997). Казан химия-технол. ин-тын (1971) һәм Уфа нефть ин-тын (1976) тәмамлый. 1972–81 елларда «Баулынефть»нең 4 нче НГДУында катламнардагы басымны нормада тоту җайланмасы бүлеге, хезмәтне фәнни оештыру, техник нормалаштыру һәм хезмәт хакы түләү бүлеге, нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы. 1981–84 тә «Татнефть» АҖнең «Елховнефть» НГДУы башлыгы. Уйлап табуга 11 патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). 1999–2004 елларда ТР халык депутаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГАНИ́ЕВ** Гыйләҗ Камалетдин улы (16.11.1906, Уфа губ. Уфа өязе, хәзерге Кушнаренко р-ны Казарма а. — 18.11.1967, Казан), партия-хуҗалык эшлеклесе. Уфа шәһәрендә Югары коммунистик а.х. мәктәбен (1934), ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1939). 1927–28 елларда Кушнаренко р-нының Үгез авыл советы секретаре, 1928–29 да рәисе. 1929–39 да БАССРның Кушнаренко, Дүртөйле, Кырмыскалы, Мишкә, Миякә р-нnарында партия эшендә, 1939–40 та Казакъстан КП(б) ҮКның кадрлар бүлеге мөдире урынбасары, 1940–42 дә Казакъстан игенчелек һәм терлекчелек совхозлары халык комиссары урынбасары, 1942–44 тә Казакъстан ССР буенча ВКП(б) ҮК каршындагы партия контроле ком-ты (КПК) вәкиле урынбасары, 1944–47 дә ТАССР буенча ВКП(б) ҮК каршындагы партия контроле ком-ты (КПК) вәкиле урынбасары. 1947–48 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тының кадрлар бүлеге мөдире урынбасары, 1948–52, 1953–57 дә ТАССР авыл хуҗалыгы министры, 1952–53 тә ВКП(б)ның Казан өлкә комитетының 1 нче секретаре, 1957–59 да ТАССРның җиңел сәнәгать министры. Г. а.х. министры булып эшләгән елларда респ-када а.х.ның матди-техник базасы ныгый, мөгезле эре терлекләрнең баш саны 11% ка, дуңгызларныкы 161% ка, сарыкларныкы 64% ка, ит җитештерү 52% ка, сөт җитештерү 35% ка арта. 1947–51, 1951–55, 1955–59 елларда ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ГАНИ́ЕВ** Илшат Газыйм улы (3.1.1954, Баулы р-ны Яңа Шалты а.), а.х. фән. канд. (2000), ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1994, 2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1976). Хезмәт юлын Яшел Үзән р-нының «Майский» с-зында башлый: агроном (1976–78), үсемлекләрне саклау буенча өлкән агроном (1978–79), цех башлыгы (1979–80), баш агроном урынбасары (1980–82), баш агроном (1982–86). 1986–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-тының а.х. һәм эшкәртү сәнәгате бүлеге инструкторы. 1989 дан «Майский» агрокомбинаты дәүләт унитар пр-тиесе, 2003 тән «Майский» теплица комбинаты» ААҖ директоры. Дәүләт бүләге экологик яктан куркынычсыз һәм сезоннан тыш яшелчә продукциясе үстерүдә җитештерү ресурсларын саклый торган технологияләр булдырганы һәм аларны производствога керткәне өчен бирелә. ТР халык депутаты (1995–99, 1999 дан). Медальләр б-н, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ГАНИ́ЕВ** Ирек Гыйләҗетдин улы (22.7.1933, Уфа ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1973). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), Казакъстанда Үзәк Казакъстан экспедициясендә эшли. 1960 елдан Мәскәүдә: Электрон сәнәгать министрлыгы системасында (1962–70), Бөтенсоюз минераль чималлар ин-тында эксперименталь минерал. лаб-ясе мөдире (1970–76). 1976 дан РФАнең Литосфера ин-тында: бүлек мөдире, директор урынбасары (1976–81), баш фәнни хезмәткәр (1994 тән). Бер үк вакытта гыйльми секретарь (1976–77), СССР ФА президиумының Җир турындагы фәннәр секциясе рәисе урынбасары (1984–89). 1991–93 елларда РФ Президенты каршындагы Эксперт советының җаваплы секретаре. 1994–97 дә ТР Президенты киңәшчесе. Хезмәтләре эксперименталь минералогиягә һәм геохимиягә карый. Файдалы казылма чыганаклары барлыкка килүнең физ.-химик модельләрен, юкка чыгу моделен, кварц һәм корунд мисалында минераль матдәләрнең миграция һәм кристаллашу формаларын өйрәнә. Минералогиядә яңа юнәлешне — литосфераның анизотроп җылылык кырларында минераллар барлыкка килүне эксперименталь өйрәнүне башлап җибәрүче. Бу юнәлеш төрле шартларда гидротермаль минераллар барлыкка килү закончалыкларын һәм матдәнең элегрәк билгесез булган фәзада химик дифференциациясе күренешен беренче тапкыр өйрәнергә һәм билгеләргә мөмкинлек бирә. Аның тикшеренүләре нәтиҗәсендә фосфат, карбонат һәм сульфатларның аларның эчке структуралары б-н генетик бәйләнеше закончалыклары билгеләнә.

Х е з м.: Рудные ресурсы и их размещение по геоэпохам. Редкие литофильные металлы (олово, сурьма, висмут). М., 1994 (автордаш); Рудные ресурсы и их размещение по геоэпохам. Благородные металлы (платина, золото, серебро). М., 1995 (автордаш); Composition and Properties of Hydrotermal solutions and form Migration Mineral Matter // International Geological Review. 1978. V.20, № 12.

**ГАНИ́ЕВ** Марат Сәет улы (6.12.1964, Куйбышев ш.), спортчы (велосипед спорты — тректа узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1987). СССР (1985–89), дөнья (1987) чемпионы, СССР халыкара спартакиадасында җиңүче (1986), СССР кубогына бәйгедә (1987), Олимпия уеннарында бронза медаль (1988) алучы. Дөнья рекордчысы (1985). Самара шәһәрендә яши.

**ГАНИ́ЕВ** Мәҗит Сәет улы (12.2.1917, Таврия губ., хәзерге Украинаның Кырым өлкәсе Коп-Утуз а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974), Үзбәкстан ССРның атказ. механизаторы (1967). 1942 елда Ташкент а.х.н ясалма сугару һәм механикалаштыру инженерлары ин-тын тәмамлый. Урта Азия а.х. механикалаштыру һәм электрлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Ташкент) эшли, бүлек мөдире (1957), директор урынбасары (1960–64), директор (1974 кә кадәр); Ташкент а.х. ин-тында а.х. машиналары (1983 кә кадәр) һәм Ташкент а.х. ясалма сугару һәм механикалаштыру инженерлары ин-тында а.х. машиналары кафедралары мөдире (1989 га кадәр). Хезмәтләре мамык игүне механикалаштыру һәм мамык җыю аппаратларын камилләштерүгә карый. Мамык уңышы калдыкларын һәм мамык сабакларын җыю өчен машина төзи һәм гамәлгә кертә. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологические основы и обоснование параметров рабочих органов машин для уборки хлопчатника. Таш., 1977.

**ГАНИ́ЕВ** Мулла Гани улы (25.2.1921, Мамадыш кантоны Иске Завод а. — 25.11.1992, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Урал урман-техник ин-тын тәмамлый (Свердловск ш., 1954). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–50 елларда Мамадыш урман сәнәгате хуҗалыгы директоры урынбасары, 1950–51 дә баш инженеры. 1954–57 дә Кама урман сәнәгате хуҗалыгы баш инженеры, 1957–62 дә директоры. 1962–63 тә ТАССР җирле сәнәгать министры урынбасары. 1963–65 тә ТАССР Азык-төлек товарлары сәнәгате министрлыгында идарә башлыгы, 1965–66 да ТАССР МСның Җирле һәм ягулык сәнәгате идарәсендә бүлек башлыгы. 1966–83 тә ТАССР ягулык сәнәгате министры. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАНИ́ЕВ** Мулланур Фәхразый улы (21.12.1951, Алабуга ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), проф. (1995). 1975 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1964 тә эшче булып башлый. 1975–79 да Чаллы шәһәрендә хокук саклау, 1982–84 тә икътисад эшендә. 1984 тән Алабуга һәм Чаллы пед. ин-тларында укыта, 1987 дән иҗтимагый фәннәр каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре хезмәтне активлаштыруның икътисади механизмнарын формалаштыруга багышлана. РФ Дәүләт Думасы депутаты (1995–99).



Р.Ф. Ганиев.

Х е з м.: Механизм активизации труда. К., 1993; Экономические законы и формирование механизма активизации труда. М., 1993.

**ГАНИ́ЕВ** Наил Сәетгәрәй улы (8.3.1929, БАССРның Ярмәкәй р-ны Исламбахты а. — 10.12.2007, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1974), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1953 тән Казан химия-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты), 1973–98 елларда теоретик механика каф. мөдире, бер үк вакытта энергомашиналар төзелеше һәм җиһазлар технологиясе каф. мөдире (1975–77), шул ук каф. профессоры (1998–99). Хезмәтләре әйләнмә анизотроп сүрүләрнең тотрыклылыгы теориясенә, сүрүләрнең нәсызыкча теориясендәге туры һәм кире мәсьәләләрне чишүгә карый. Юка конструкцияләрне хисаплау өчен юка пластиналар һәм төрле рәвешле сүрүләрнең бөгелеше, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре теориясен төзи. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Разностный метод решения задач устойчивости ортотропных оболочек вращения // Исследования по теории пластин и оболочек. 1984. К., Вып. 17, ч. 2; Свободные колебания ортотропных оболочек вращения // Расчет пластин и оболочек в химическом машиностроении. К., 1994 (автордаш).

**ГАНИ́ЕВ** Ривнер Фазыл улы (1.4.1937, БАССРның Илеш р-ны Таҗи а.), машиналар белеме һәм гамәли механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1969), РФА академигы (1994; мөхбир әгъза 1987). 1959 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлый. 1964–78 елларда Украина ССР ФАнең Механика ин-тында эшли, 1969 дан профессор, тирбәнешләр теориясе бүлеге мөдире. 1978 дән СССР ФАнең Машиналар белеме ин-тында (Мәскәү) вибротехника бүлеге мөдире. 1987 дән РФАнең Нәсызыкча дулкыннар механикасы һәм технологиясе фәнни үзәге директоры (Мәскәү), бер үк вакытта 1997 дән Мәскәү авиация ин-тының гамәли физика каф. мөдире. Хезмәтләре машиналар һәм аппаратлар динамикасына, күп фазалы системаларның нәсызыкча тирбәнешләре теориясенә, тирбәнешләрнең гамәли теориясенә, дулкынлы һәм вибрацияле технол. процесслар нигезләренә карый. Каты һәм деформацияләнүче җисемнәрнең нәсызыкча тирбәнешләре вакытында резонанс күренешләре теориясен төзи. Машина һәм аппаратларның фәзаи хәрәкәте тотрыксызлыгының механизмнарын билгели. Газ-сыеклык структураларының турбулентлы хәрәкәте б-н идарә итү һәм дулкын б-н тотрыкландыру эффектын билгели. Нәсызыкча механика һәм космик технологияләрдә идарә ителүле вибрация процесслары өлкәсендә фәнни-техник юнәлешне башлап җибәрә. Г. җитәкчелегендә космик корабльдә технол. тәҗрибәләр уздырыла. Сыеклыклы конструкцияләрнең тавышсызлыгы һәм вибрациягә ышанычлыгы буенча яңа принципларны, үткәргеч торбалардагы тирбәнешләрне тотрыкландыру системаларын тасвирлый. Йөкләнеш режимнары сикерешле үзгәргәндә дулкын процесслары б-н идарә итүче стабилизаторларга конструктив вариантлар тәкъдим итә. Уйлап табуга 100 дән артык авторлык таныклыгы бар. Почёт ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Динамика частиц при воздействии вибраций. Киев, 1975; Проблемы механики в космической технологии. М., 1979; Волновая технология в упрочнении материалов. М., 1989; Стабилизация колебаний давления в трубопроводных системах энергетических установок. М., 1993.

**ГАНИ́ЕВ** Фуат Әшраф улы (1.8.1930, БАССРның Салават р-ны Нәсибаш а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1978), проф. (1985), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1989, 1996). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1954–56 елларда БАССРның Салават р-ны мәктәпләрендә эшли. 1957–59 да Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 1962 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты), 1991–2004 тә лексикология һәм лексикография бүлеге мөдире. Бер үк вакытта Казан ун-тында, Казан һәм Чаллы пед. ин-тларында укыта. Хезмәтләре төрки телләр типологиясенә, татар теле грамматикасы, сүз ясалышы һәм лексикографиясенә карый. Г. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (1–3 т., 1977–81; 2005), татарча-төрекчә, төрекчә-татарча, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрне, икътисад һәм мәдәният хезмәткәрләре өчен егермедән артык сүзлекчәне төзүчеләрнең, «Татар грамматикасы» (1–3 т., 1992–93; ТРның Дәүләт бүләге, 1994) авторларының һәм фәнни мөхәррирләренең берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Татар теленең орфография сүзлеге. К., 2002; Суффиксальное словообразование в современном татарском литературном языке. К., 1974; Образование сложных слов в татарском языке. М., 1982; Конверсия в современном татарском литературном языке. К., 1985; Способы действия глаголов в татарском языке. К., 2003; Функциональное словообразование в современном татарском языке. Чебоксары, 2009.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Фәнгә багышланган гомер // Мирас. 2000. № 9; Член-корреспондент Фуат Ашрафович Ганиев. К., 2005; Professor Fuat Ashrafovich Ganiev // Living science. England, 2003.

**ГАНИ́ЕВ** Хәбиб Габдрахман улы (17.11.1909, хәзерге Башкортстан Респ-касының Салават р-ны Малаяз а. — 10.11.1970, Ереван), генерал-майор (1944). Казан хәрби пехота уч-щесен (1934), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1938, Ленинград) тәмамлый. 1938 елдан Киев махсус хәрби округының 99 нчы укчы дивизиясендә сәяси бүлек җитәкчесе, өлкән батальон комиссары. Бөек Ватан сугышында 169 нчы укчы дивизия командиры урынбасары, полк комиссары, 1942 нең августыннан — 41 нче, 1943 нең маеннан — 65 нче армиянең сәяси бүлек башлыгы. Курск (1943), Днепр буендагы бәрелешләрдә, Белоруссия, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. Сугыштан соңгы елларда Кавказ арты хәрби округында корпус сәяси бүлеге җитәкчесе, Хәрби совет әгъзасы. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Генералы Башкортостана. Уфа, 1995.

**ГАНИ́ЕВ** Хәбибрахман Гани улы (12.2.1910, Казан губ. Мамадыш өязе, хәзерге Саба р-ны Тенеки а. — 6.9.2006, шунда ук), зәркәнчеләр нәселеннән, көмешче, күбесенчә каралту (к. *Каралту*) техникасы б-н эшли. Гаилә артелендә җепкыр, уеп ясау, чүкеп ясау һәм кою юлы б-н заказ буенча көмеш бизәмәләр (чулпы, беләзек, алка, йөзекләр, *Корьән тартмачыклары* һ.б.) ясаучы бертуган абыйсы Габдрахман Ганиев һәм кардәше Габдулла Латыйповтан 8 яшендә зәркәнчелек эшенә өйрәнә башлый. Узган гасырларда Тенеки авылы һәм күрше-тирәдәге Йосыф-Алан, Юлбат, Байлар Сабасы авыллары һ.б. зәркәнчелек һөнәре үзәкләре булып танылa, аларда бизәмәләр, көнкүреш кирәк-яраклары (комган, савыт-саба, ләгәннәр һ.б.) ясаучы көмешчеләр һәм *бакырчылар* эшли. Бертуган Ганиевләр башка зәркәнчеләр б-н бергә Башкортстанга, Оренбург һәм Әстерхан өлкәләренә, Казакъстанга һәм кыргыз далаларына йөреп эшлиләр; фаразланганча, көмеш каралту алымын элеккеге Уфа губернасы Кырмыскалы авылында үзләштерәләр, һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Тенеки 20 йөз башында Казан артында каралту һөнәрчелеге үзәге булып әверелә. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында кустарь зәркәнчеләр кулаклар сыйныфына кертелә, Г. колхозда тракторчы булып эшли башлый. 1941–44 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, яраланып, туган авылына кайта. 25 ел дәвамында тимерче булып эшли. 1970 еллар



Х.Г. Г а н и е в. 1. Беләзек. Көмеш. Уемлау, каралту. 1970 еллар; 2. Беләзекләр. Көмеш. Гравирлау, каралту. 1980 еллар.

башында Саба р-ның Шәмәрдән эшчеләр посёлогында оештырылган зәркәнчелек цехына остаз итеп чакырыла. Цех озак эшләми, көмеш куллану тыелганлыктан, ул ябыла. Шәхси заказлар кабул итеп, 1998 гә кадәр Г. мөстәкыйль рәвештә эшли. Хатыны Мөкәррәмә Ганиева ш.у. каралту эшен үзләштерә, ул нәфисрәк, катлаулырак бизәкләрне уя. Г. 1 нче республика гамәли бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә (1983), Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәдә (1986), төбәкара «Зур Идел» күргәзмәсендә (Чабаксар, 1985) һ.б. да катнаша. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, шәхси коллекцияләрдә саклана. Г. ның эш кораллары Саба р-ны музеена тапшырылган.

*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов), К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГАНИ́ЕВА** Венера Әхәт кызы (24.3.1955, Казан), җырчы (колоратуралы сопрано), ТР һәм РФнең халык артисты (1992, 1995), проф. (2001). Казан консерваториясен (В.Лазько классы) тәмамлый (1983). 1983 елдан Татар опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Виолетта, Джильда («Травиата», «Риголетто», Дж.Верди), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Кар кызы, Марфа (шул исем. оп., «Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Адель («Ярканат», И.Штраус), Алтынчәч (шул исем. оп., Н.Җиһанов), Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи), Зөбәрҗәт («Наёмщик», С.Сәйдәшев), Зәйтүнә («Шагыйрь мәхәббәте», Р.Ахиярова). Аның концерт репертуарында татар, рус, чит ил композиторлары җырлары бар. Г. Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә төп опера партияләрен башкаручы һәм концертлар бирүче җырчы буларак иҗади эшчәнлек алып бара. Г. югары проф. башкару сәләте, вокал техникасының камиллеге, матур, моңлы тембрлы тавышка ия булуы, ачык дикциясе, сәхнәдә үзен иркен тотуы б-н аерылып тора. Россия һәм БДБ илләрендә, чит илләрдә (АКШ, Германия, Төркия, Чехия, Голландия, Дания, Франция, Венгрия, Англия һ.б.) гастрольләрдә чыгышлар ясый. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта, 2000 елдан ялгыз җырлау каф. мөдире. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1997). «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.





В.Ә. Г а н и е в а: 1. Розина («Севилья чәчтарашы», Дж. Россини); 2. Виолетта («Травиата», Дж.Верди) рольләрендә.



В.Ә. Ганиева.

*Әд.:* Венера Ганиева дөньясы // Шәһри Казан. 2003. 23 февр.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ГАНИ́ЕВА** Мөзәянә Сәетгәрәй кызы (30.6.1932, БАССРның Ярмәкәй р-ны Исламбахты а.), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1986), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1957–91 елларда СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, 1986 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 1991–2000 дә РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында юка конструкцияләр механикасы лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре сыгылмалылык һәм сүрүләр теориясенә карый. Темп-ра-көч йөкләмәләре тәэсир иткән юка һәм юка булмаган сүрүләр статикасы һәм тотрыклылыгының нәсызыкча мәсьәләләрен исәпләү өчен теория, ысуллар һәм программа комплекслары төзи.

Х е з м.: Прочность и устойчивость оболочек вращения. М., 1992; Исследования по теории пластин и оболочек в КФТИ — ИММ КНЦ РАН (1946–1955) // Обзоры исследований по механике сплошной среды (К 50-летию КНЦ РАН). К., 1995 (автордаш).

**ГАНИ́ЕВА** Резеда Кадыйр кызы (13.11.1932, Норлат, хәзерге Яшел Үзән р-ны Кече Шырдан а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1951–58 елларда Норлат, Биектау р-ннары һәм Казан мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1958 дә читтән торып Казан ун-тын, 1962 дә Мәскәү ун-тында аспирантура тәмамлый. 1962 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә, Шәрекъ һәм төрки-татар әдәбиятларындагы Ренессанс хәрәкәтенә, иҗат ысуллары мәсьәләләренә, татар әдәбиятының Көнбатыш Европа, рус, украин, гарәп, фарсы-таҗик, төрки әдәбиятлары б-н бәйләнешләренә, Кол Гали, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, С.Рәмиев, Н.Думави, Ш.Бабич, Р.Гаташ иҗатларына карый.

Х е з м.: Думавиның иҗат сәхифәләре. К.,2003; Шагыйрьнең рухи дөньясы. К., 2003; Сатира в творчестве Тукая. К., 1964; Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. К. 1988; Татарская литература: традиции, взаимосвязи. К., 2002.

*Әд.:* Б а к и р о в М.Х. Чын галим һәм педагог // Фәнни Татарстан. 2002. № 3/4; М и ң н е г у л о в Х. «Каюм баба»ның дәвамчысы // Гасырлар өнен тыңлап. К., 2003; З а к и р җ а н о в Ә. Кече Шырданның олуг кызы // Мәдәни җомга. 2007. 13 нояб.; С а я п о в а А. Говорю о своем учителе // Идель. 2002. № 10.

**ГА́НЦЕВ** Шамил Хәнәфи улы (19.4.1951, Уфа ш.), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991), БРның атказ. фән. эшлеклесе (1995). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук эшли. 1976–79 елларда Уфа шәһәренең 6 нчы хастаханәсе хирургы. 1979 дан Башкортстан мед. ун-тында, 1989 дан онкология каф. мөдире, 1990 нан Башкортстан онкологлар ассоциациясе президенты. Тикшеренүләре корсак куышлыгындагы ябышма авыруына диагноз кую, дәвалау һәм аны булдырмау, ш.у. корсак куышлыгы әгъзаларындагы авыруларга һәм яман шеш авырулары профилактикасына карый. Г. тарафыннан корсак куышлыгында ябышма авыруының таралуында карын маеның тәэсире өйрәнелә, онкологик авыруларны дәвалау схемасы тәкъдим ителә, яман шеш авыруына беренчел һәм икенчел профилактика ысуллары гамәлгә кертелә, беренче мәртәбә барлыкка килгән яман шешләргә операцияләр эшләнә, химик терапия вакытында органопротекциянең зарурлыгы исбатлана. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Диагностика и лечение заболеваний большого сальника. Уфа, 1988 (автордаш); Неотложные состояния в онкологии. Уфа, 1992.

**ГАРА́НИН** Валериан Иванович (2.6.1928, Татар Спасы ш.), зоолог, эколог, биол. фән. канд. (1965). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), Казан ун-ты каршындагы Биология ин-тында (бүленеп, 1953–56 елларда комсомол һәм партия эшендә). 1970 тән Казан ун-тында, 1980–86 да табигатьне саклау каф. мөдире, 1986 дан умырткалылар зоологиясе каф. доценты. Хезмәтләре умырткалы хайваннарны (җир-су хайваннары, сөйрәлүчеләр, кошлар, имезүчеләр) өйрәнүгә, гомуми экологиягә, фаунаны саклауга, фән тарихына (зоология һәм экология) карый. ТРның Кызыл китабын төзүчеләрнең һәм Идел-Кама саклаулыгы терр-ясендә фәнни тикшеренүләрне оештыручыларның берсе. Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең мактаулы әгъзасы (1994). А.М.Никольский исем. Халыкара герпетология җәмгыятенең мактаулы ьгъзасы (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Отряд козодоеобразные Caprimulgiformes // Птицы Волжско-Камского края. Неворобьиные. М., 1977; Семейство иволговые Oriolidae // Птицы Волжско-Камского края. Воробьиные. М., 1978; Земноводные и пресмыкающиеся Волжско-Камского края. М., 1983 (автордаш); Волжско-Камский заповедник // Заповедники СССР. Т. 2. Заповедники Европейской части РСФСР. М., 1989 (автордаш); Животный мир Восточного Закамья. Альметьевск, 2000 (автордаш); Жизнь и деятельность Э.А.Эверсманна. К., 2002.

**ГАРА́НИНА** Ирина Петровна (31.12.1925, Казань), физиолог, мед. фән. д-ры (1967), проф. (1969). 1948 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1961–67 дә Казан вет. ин-тында эшли. 1967 дән Әстерхан мед. ин-тында патофизиология каф. мөдире. Хезмәтләре хайваннар организмына энтеротроп йогышлы-агулы агентлар тәэсир иткәндә, сулышның нервлар б-н көйләнешенә һәм югары нерв эшчәнлеге төрләренә бәйле рәвештә аллергик реакцияләрен өйрәнүгә карый. Анатоксин һәм антитоксин сыворотка куллану, ш.у. бруцеллёзга каршы пероральэ иммунлаштыру һәм ион радиациясе шартларында иммунитет механизмын тикшерә.

**ГАРӘБША́Һ ХАН** (1340 тирәсе — 1379/80 тирәсе), Алтын Урда ханы (1377/78 дән). Җүчи нәселеннән, Шәйбан нәселе вәкиле Пулад улы дип фаразлана. Күк Урда гаскәре ярдәмендә 1377 елның язында *Каганбәк ханны* Сарай әл-Җәдидтән куып, тәхеткә утыра. Үз исеменнән акча суктыра (1377/78). Дәүләттә үзара тарткалашу-сугышуларга чик куя алмый. Хакимиятен ныгыту максатыннан 1377 нең җәендә Сура елгасы буйларына яу б-н бара, кайбер рус торак пунктларын басып ала. Аңа каршы чыккан рус гаскәре Пьяна елгасы буенда Мамай җитәкчелегендәге гаскәр һәм мордва кенәзләре чирүе ярдәмендә тар-мар ителә. 1378 дә Г.х.ның Түбән Идел буеннан торып идарә итүе мәгълүм. Туктамыш хан б-н тәхет өчен барган үзара көрәштә һәлак була.

*Әд.:* Г р е к о в Б.А., Я к у б о в с к и й А.Н. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Куликовская битва. М., 1980.

**ГАРӘ́П АЛЫНМАЛАРЫ́**, *гарәп теленнән* алынган сүзләр һәм гыйбарәләр. Татарларның борынгы бабалары телендә, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгәннән соң (10 йөз) тарала башлый. Хәзерге татар әдәби телендә дә киң кулланыла. Татар теленә Г.а. халыкларның үзара аралашуы (гарәп-фарсы әдәбияты һәм фәнни хезмәтләр, хаҗга бару һәм сәүдә итү) нәтиҗәсендә килеп кергәннәр. Бу процесста Коръәнне, дини эчтәлекле Шәрекъ әдәбиятын өйрәнү, дини йолаларны гарәп телендә башкару аеруча зур роль уйный.

Мәктәп һәм мәдрәсәләрдә гарәп теле — төп предмет, ә мәдрәсәләрнең өлкән сыйныфларында укыту теле булган. Нәтиҗәдә Г.а. татар язуында, аннан соң сөйләм телендә дә күпмедер урын алалар. Бу күренеш лексика үсешендә генә түгел, татар халкының мәдәнияте үсешендә дә мөһим роль уйный. Ислам йогынтысында татар мәдәнияте дини фәлсәфәнең, этика һәм эстетиканың, ш.у. фәнни терминологиянең күпчелек өлешен үзләштерә.

Татар телендә Г.а. дини (Аллаһ, җәннәт, иман); абстракт (ихтыяр, мөнәсәбәт); фәнни (табигать, мантыйк, әдәбият); этик (намус, мәхәббәт); педагогик (мөгаллим, мәктәп, белем); сәяси-иҗтимагый (иҗтимагый, дәүләт, җөмһүрият); медицина (табиб, җәрәхәт, хастаханә); хәрби (хәрби, гаскәр); көнкүреш (гаилә, хат, бина); антропонимик (Габдулла, Ләйлә, Зәйнәп) төрләргә бүленәләр.

Күпчелек гарәп сүзләре, татар теленең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләренә буйсынып, татар телендә ныклап урнашалар һәм аның үз сүзләре кебек кабул ителә башлыйлар (китап, сабырлык, илһам, фикер).

Иске татар әдәби телендә (19 йөз ахыры — 20 йөз башына кадәр) лексиканың күпчелек өлеше Г.а.ннан тора. Бу күренеш, үз чиратында, тарихи әсәрләр һәм фәнни хезмәтләр телен аңлауны гаять кыенлаштыра. Кайбер татар галимнәре һәм фикер ияләре (Г.Курсави, Ш.Мәрҗани һ.б.) үз хезмәтләрен гарәп телендә язалар. Нәтиҗәдә фәнни татар телен халык теленә якынлаштыру мәсьәләсе туа. Г.а. татар теленең үз сүзләре б-н алыштыру мәсьәләсе 1930 еллардан башлап, исламга һәм гарәп язуына каршы пропаганда һәм эзәрлекләүләр көчәйгәч, аеруча актуальләшеп китә. Г.а. татар, рус һәм чит телләрдән кергән сүзләр б-н алыштырыла башлый (мөгаллим — укытучы, хакимият — власть, сәясәт — политика). Хәзерге татар әдәби телендә 10 меңнән артык Г. а. бар. Аларның бер өлеше әдәби телдә һәм сөйләм телендә кулланыла, бер өлеше кулланылыштан чыккан һәм бары иске татар телендә язылган әдәбиятта гына очрый. 1980 еллар уртасыннан, татар телен торгызу программасын тормышка ашыруга бәйле рәвештә, онытылган кайбер Г.а. татар теленә кире кайта башлый (сәясәт, даруханә, мөхәррир). Шуның нәтиҗәсендә татар теле лексикасын эчке мөмкинлекләре нигезендә баету, яңа төшенчәләр һәм сүзтезмәләр төзү өчен шартлар туа.

*Әд.:* Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. К., 1965; С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999.

*М.И.Мәхмутов.*

**ГАРӘ́П ТЕЛЕ́**, Азия һәм Африка илләрендә яшәүче гарәпләр теле. Семит-хәмит телләре гаиләсенең семит тармагына керә. Г.т.ндә якынча 200 млн. кеше сөйләшә. Г.т. Мисыр, Судан, Сүрия, Гыйрак, Мавритания, Гарәп ярымутравы илләрендә һ.б. рәсми дәүләт теле булып санала. Ул ш. у. ислам дине киң таралган башка илләрдә дә (Нигерия, Камерун, Нигер) актив кулланылышта йөри. БМОның 6 рәсми эш теленең берсе буларак танылган. Г.т. борынгы, классик һәм хәзерге үсеш дәверләре үтә. Аның борынгы ядкәрләре самуди, лихъяни һәм сафи язмаларыннан гыйбарәт. Әдәби Г.т.нең классик формасы ислам диненә кадәрге (5–6 йөзләр) поэзиядә барлыкка килә. Хәзерге әдәби телдә бернигадәр лексик үзгәрешләр кичергән борынгы морфология саклана.

Г.т. флектив телләр төркеменә керә, анда 34 фонема бар, шуларның алтысы — сузык, егерме сигезе тартык фонема. Сүзнең тамыры гадәттә өч, сирәк кенә дүрт һәм аннан артык тартык авазлардан тора. Тартыклар мәгънәне, тамырның семантикасын, ә сузыклар грамматик категорияләрне белдерәләр һәм сүзнең мәгънәсен аныклыйлар. Хәзерге Г.т.нә түбәндәге төп морфологик билгеләр хас: билгелелек-билгесезлек категориясе, исемнәрне белдерүнең бердәм системасы; исемнәрнең ике яисә өч килештә төрләнүе; исемнәрдә дә, фигыльләрдә дә берлек, икелек һәм күплек саннары, хатын-кыз һәм ир затлары категориясе; сүз ясалышы һәм сүз үзгәреше билгеләрен үзендә берләштергән («15 фигыль бабы» яисә «масдарлар») өч гади һәм өч катлаулы заман бар. Г.т. синтаксисында иясез фигыль һәм атау җөмләләр киң кулланыла. Гарәп сүзлегенең төп өлешен Г.т.нең үз сүзләре, калган өлешен гомумсемит һәм беразын чит телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә. Г.т. Мисыр, Судан, Сүрия, Гыйрак, Гарәбстан, ш.у. хәсәния (Мавритания), шоа (Нигерия, Камерун, Нигер) һ.б. диалектларга бүленә. Һәрбер диалект бик күп сөйләшләрдән тора. Типологик яктан караганда, хәзерге гарәп диалектларының фонетик һәм морфологик төзелеше семит телләренең яңа үсеш баскычына туры килә. 6 йөздән гарәпләр *гарәп язуын* кулланалар. Ислам дине кабул ителгәннән соң (7 йөз) һәм гарәп яулары башлангач, Г.т. Гарәбстан ярымутравыннан читтә дә тарала башлый. Хәзерге вакытта Идел һәм Урал буе, Урта Азия һәм Кавказ арты мөселманнары арасында Г.т. дини йолалар башкару теле буларак киң кулланыла, дини һәм дөньяви уку йортларында өйрәнелә. Ш.у.к. *Гарәп алынмалары.*

*Әд.:* Ш а р б а т о в Г.Ш. Современный арабский язык. М., 1961; Х а л и д о в А.Б. Арабский язык // Очерки истории арабской культуры V–XV вв. М., 1982; Ш а г а л ь В.Э. Язык и языковая ситуация // Государство Кувейт. М., 1990; К о в ы р ш и н а Н.Б. Арабские страны. М., 1999.

*Г.Г.Зәйнуллин.*

**ГАРӘ́П ЯЗУЫ́**, гарәпләрнең, ш.у. Иран, Әфганстан, Һиндстан, Пакъстан, Малайзия, Индонезия, Кытай һәм кайбер башка дәүләтләрдәге мөселман халыкларының язу системасы. Б. э. ның 4 йөзенә кадәр Гарәбстанда арамей язуының набатый варианты нигезендә барлыкка килә. Хәзерге гарәп алфавитында 28 хәреф бар. Г.я., башлыча, тартыклардан тора. Озын сузыклар «әлиф», «уау», «йа» хәрефләре б-н, ә кыска сузыклар юл өсте һәм юл асты билгеләре — хәрәкәләр ярдәмендә белдерелә. Хәрефләрнең сүздәге урыннарына карап ике яки дүрт төрле язылу рәвеше кулланыла: аерым язылыш, сүз башында, сүз уртасында, сүз азагында язылыш. Уңнан сулга таба языла һәм укыла (1 нче табл.). Идел буе һәм Урал алды төрки-татарлары арасында Г.я. Хәзәр каганлыгы дәвереннән, Идел буе Болгар дәүләтендә 10 йөздән, Алтын Урдада 13 йөз ахыры — 14 йөз башыннан кулланылган. Гарәп графикасына нигезләнгән татар язуына реформа 19 йөз ахыры — 20 йөз башында башлана (К.Насыйри, Һ.Максуди, Ш.Таһири, Х.Гали, Г.Нугайбәк, Г.Алпаров һ.б.). Алфавит һәм орфография мәсьәләләренә багышланган беренче конференция 1899 елда Уфада булып уза. 1920 елларга кадәр

кулланылган Г.я. «Иске имля» исеме б-н билгеле (2 нче табл.). ТАССР ХКС декреты нигезендә (19 дек., 1920) Г.я. ннан кайбер хәрефләр һәм билгеләр алына, өстәмә хәрефләр кертелә. Үзгәртелгән Г.я. «Яңа имля» дип атала башлый. 1925 нең ноябрендә ТАССР Мәгариф халык комис-тының Академүзәге, Г.Ибраһимов рәислегендә, гарәп графикасы буенча алфавит һәм орфография мәсьәләләренә кагылышлы карар чыгара. Әлеге карар нигезендә гарәп язуы барлык совет оешмаларында һәм мәктәпләрендә, татар матбугатында мәҗбүри кулланылырга тиеш була. Алга таба сузык авазларны белдерү өчен өстәмә: а — ئا; ә — ئە; и — ئی; у, ү — ئو; о, ө — ئۇ; ы, е — ئ хәрефләре кертелә (3 нче табл.). «Яңа имля» 1927 дә латин графикасы (к. *Яңалиф*) кертелгәнче кулланыла. Ш.у.к. *Гарәп язуы үрнәкләре*.

*Әд.:* Хәсән Г. Язу үрнәкләре. Оренбург, 1912; Ишмөхәммәтов Г. Гарәп графикасы нигезендә татарча әлифба. Уку, язу күнекмәләре. К., 1961; Ногман М.Н. Иске татар язуы үрнәкләре. К., 1975; Зәйнуллин Җ.Г. Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба. К., 1989.

*В.Х.Хаков.*

**ГАРӘ́П ЯЗУЫ́ ҮРНӘКЛӘРЕ́**, гарәп хәрефләрен язу рәвеше һәм төрләре. Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителгәч (10 йөз), татарларның рәсем сәнгатенә бөтен мөселман дөньясының *каллиграфиясен* тәшкил итүче язу культурасының аерым элементы буларак үтеп керәләр. Киң таралган язу төрләре: куфи, нәсех, сөлес, тәгъликъ, дивани, рикъга, рәйхани. Язу үрнәген һәм аның төрләрен сайлау текстның эчтәлегенә, максатына, текст языла торган материалга (кәгазь, тукыма, пыяла, таш һ.б.), күчереп язучының теләгенә бәйле. Монументаль һәм «чәчәкле» куфи архит-рада коеп ясалган тимер әйберләрне бизәгәндә кулланыла; эре сөлес эчке диварларны бизәү өчен, ә вак сөлес китап бүлекләре исемнәрен язу өчен файдаланыла; ачык, аңлаешлы, уку өчен уңайлы нәсех б-н «җитди» текстлар — Коръән, дини китаплар, фәнни хезмәтләр языла; курсив тәгъликъ, рикъга

Гарәп алфавиты

| Исеме | Транскрипция | Язылышы: сүз башында | сүз уртасында | сүз ахырында | аерымлангандa |
|---|---|---|---|---|---|
| ʼалифун | — | ا | ـا | ـا | ا |
| бāʼун | б | بـ | ـبـ | ـب | ب |
| тāʼун | т | تـ | ـتـ | ـت | ت |
| ҫāʼун | ҫ | ثـ | ـثـ | ـث | ث |
| джӣмун | дж | جـ | ـجـ | ـج | ج |
| х̣āʼун | х̣ | حـ | ـحـ | ـح | ح |
| х̱āʼун | х̱ | خـ | ـخـ | ـخ | خ |
| дāлун | д | د | ـد | ـد | د |
| з̱āлун | з̱ | ذ | ـذ | ـذ | ذ |
| рāʼун | р | ر | ـر | ـر | ر |
| зāʼун | з | ز | ـز | ـز | ز |
| сӣнун | с | سـ | ـسـ | ـس | س |
| шӣнун | ш | شـ | ـشـ | ـش | ش |
| ҫāдун | ҫ | صـ | ـصـ | ـص | ص |
| д̣āдун | д̣ | ضـ | ـضـ | ـض | ض |
| т̣āʼун | т̣ | طـ | ـطـ | ـط | ط |
| з̣āʼун | з̣ | ظـ | ـظـ | ـظ | ظ |
| ʽайнун | ʽ | عـ | ـعـ | ـع | ع |
| ғайнун | ғ | غـ | ـغـ | ـغ | غ |
| фāʼун | ф | فـ | ـفـ | ـف | ف |
| қāфун | қ | قـ | ـقـ | ـق | ق |
| кāфун | к | كـ | ـكـ | ـك | ك |
| лāмун | л | لـ | ـلـ | ـل | ل |
| мӣмун | м | مـ | ـمـ | ـم | م |
| нӯнун | н | نـ | ـنـ | ـن | ن |
| хāʼун | х | هـ | ـهـ | ـه | ه |
| ўāўун | ў | و | ـو | ـو | و |
| йāʼун | й | يـ | ـيـ | ـي | ي |

Гарәп алфавиты «Иске имля» («Иске орфография») нигезендә татар алфавиты

| Исеме | Язылышы: сүз башында | сүз уртасында | сүз ахырында | аерымлангандa |
|---|---|---|---|---|
| а (әлиф) | آ | ـا | ـا | آ |
| ә | ا | ـا | ـا | ا |
| б (би) | بـ | ـبـ | ـب | ب |
| п (пи) | پـ | ـپـ | ـپ | پ |
| т (ти) | تـ | ـتـ | ـت | ت |
| с (си) | ثـ | ـثـ | ـث | ث |
| җ (җим) | جـ | ـجـ | ـج | ج |
| ч (чи) | چـ | ـچـ | ـچ | چ |
| х (хи) | حـ | ـحـ | ـح | ح |
| х (хы) | خـ | ـخـ | ـخ | خ |
| д (дәл) | د | ـد | ـد | د |
| з (зәл) | ذ | ـذ | ـذ | ذ |
| р (ра) | ر | ـر | ـر | ر |
| з (зи) | ز | ـز | ـز | ز |
| ж (жә) | ژ | ـژ | ـژ | ژ |
| с (син, сен) | سـ | ـسـ | ـس | س |
| ш (шын) | شـ | ـشـ | ـش | ش |
| с (сад) | صـ | ـصـ | ـص | ص |
| д, з (дад, зъад) | ضـ | ـضـ | ـض | ض |
| т (тый) | طـ | ـطـ | ـط | ط |
| з (зый) | ظـ | ـظـ | ـظ | ظ |
| ғ (гәйн) | عـ | ـعـ | ـع | ع |
| ғ (ғайн) | غـ | ـغـ | ـغ | غ |
| ф (фи) | فـ | ـفـ | ـف | ف |
| қ (қаф) | قـ | ـقـ | ـق | ق |
| к (кяф) | كـ | ـكـ | ـك | ك |
| г (гяф) | گـ | ـگـ | ـگ | گ |
| ң (эң) | ڭـ | ـڭـ | ـڭ | ڭ |
| л (ләм) | لـ | ـلـ | ـل | ل |
| м (мим) | مـ | ـمـ | ـم | م |
| н (нун) | نـ | ـنـ | ـن | ن |
| һ (һа) | هـ | ـهـ | ـه | ه |
| у, ү, о, ө | و | ـو | ـو | و |
| в (вау) | ۋ | ـۋ | ـۋ | ۋ |
| йы, ый, и, е | يـ | ـيـ | ـى | ى |

Гарәп алфавиты «Яңа имля» («Яңа орфография») нигезендә татар алфавиты

| Исеме | Язылышы: сүз башында | сүз уртасында | сүз ахырында | аерымлангандa |
|---|---|---|---|---|
| А | ئا | ـا | ـا | ئا |
| Ә | ئە | ـە | ـە | ئە |
| Б | بـ | ـبـ | ـب | ب |
| Т | تـ | ـتـ | ـت | ت |
| П | پـ | ـپـ | ـپ | پ |
| Җ | جـ | ـجـ | ـج | ج |
| Ч | چـ | ـچـ | ـچ | چ |
| Х | حـ | ـحـ | ـح | ح |
| Д | د | ـد | ـد | د |
| Р | ر | ـر | ـر | ر |
| З | ز | ـز | ـز | ز |
| Ж | ژ | ـژ | ـژ | ژ |
| С | سـ | ـسـ | ـس | س |
| Ш | شـ | ـشـ | ـش | ش |
| Ғ | عـ | ـعـ | ـع | ع |
| Ф | فـ | ـفـ | ـف | ف |
| Қ | قـ | ـقـ | ـق | ق |
| К | كـ | ـكـ | ـك | ك |
| Г | گـ | ـگـ | ـگ | گ |
| Ң | — | ـڭـ | ـڭ | ڭ |
| Л | لـ | ـلـ | ـل | ل |
| М | مـ | ـمـ | ـم | م |
| Н | نـ | ـنـ | ـن | ن |
| W | و | ـو | ـو | و |
| И | ئيـ | ـيـ | ـی | ئی |
| У, Ү | ئو | ـو | ـو | ئو |
| О, Ө | ئۇ | ـۇ | ـۇ | ئۇ |
| Ы, Е | ئـ | ـٸـ | ـٸ | ئ |
| Һ | هـ | ـهـ | ـه | ه |



Гарәп язуы үрнәкләре: 1. Куфи; 2. Нәсех; 3. Тәгъликъ; 4. Сөлес; 5. Нәстәгъликъ; 6. Дивани.

һәм шикәстә документлар төзегәндә һәм хатларда; эре һәм катлаулы сөлес, дивани язу төрләре рәсми актларда файдаланыла.

Алтын Урда чорында (13–14 йөзләр) Г.я.ү. зур үсеш алалар. Исламның фән һәм мәгърифәткә уңай мөнәсәбәте, уку йортлары һәм алар каршында китапханәләрнең күплеге, халыкның белем дәрәҗәсе югары булуы, китапларга туган ихтыяҗ моңа сәбәп булып тора. Укырга уңайлы, ачык һәм аңлаешлы язылган кульязма китапларга ихтыяҗ аеруча зур була.

Казан ханлыгы яулангач (16 йөзнең 2 нче яртысы), каллиграфия бетүгә йөз тота. Архит-рада матур язу бөтенләй кулланылмый диярлек, кульязмаларда нәсех һәм нәстәгъликъ өстенлек иткән гади язу файдаланыла. Каллиграфиянең яңадан чәчәк атуы 19 йөзгә туры килә. Г.я.ү. биналарның тышкы һәм эчке бизәлешендә, кабер ташлары язуларында (сөлес), шәмаилләрдә, китап һәм журналларда, плакатларда, афишаларда һ.б. яңадан кулланыла башлый (рәйхани, куфи, шикәстә, туграи һ.б.). 1920 еллар ахырыннан латин графикасына, соңрак кириллицага күчү сәбәпле, татарларның рәсем сәнгатендә гарәп язуын куллану кими башлый, шәмаилләр иҗат итүче аерым осталар иҗатында гына саклана. 1980 еллар ахырында каллиграфия, ш.и. Г.я.ү. Б.*Урманче*, Н.*Исмәгыйлев*, Р.Мәрдан, Р.Сәләхетдинов һ.б. рәссамнар иҗатында яңадан торгызыла.

*Әд.:* Госманов М. Каурый каләм эзеннән. К., 1984; Катанов Н.Ф. Казанско-татарские, мусульманские литографированные издания с именами лиц Ветхого и Нового заветов. К., 1910; Дульский П.М. Искусство Казанских татар. М., 1925; Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция. М., 1985; Червонная С.М. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагиева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990.

*Н.Ф.Исмәгыйлев, М.Г.Госманов.*

**ГАРӘ́П-ХӘЗӘ́Р СУГЫШЛАРЫ́**, Гарәп хәлифәлеге б-н Хәзәр каганлыгы арасында 653–765 елларда Көнчыгыш һәм Үзәк Кавказ аръягы җирләре өчен барган сугыш хәрәкәтләре. Г.-х.с., гарәп гаскәрләре Әрмәнстан, Грузия һәм Кавказ Албаниясен басып алып, гарәп яубашы Габдрахман ибне Рабига Дәрбәнд шәһәрен яулаганнан һәм Хәзәр каганлыгы терр-ясенә бәреп кергәннән соң (653–54) башлана. Гарәпләр хәзәрләрнең башкаласы Бәләнҗәр шәһәрен камыйлар. Хәзәрләр батырларча сугышалар һәм, өстәмә көчләр килгәч, гарәп гаскәрен җиңәләр. Бу сугыштан соң вакытлыча тынычлык урнаша. 7 йөзнең 60–70 елларында Гарәп хәлифәлеге көчсезләнә. Шуннан файдаланып, хәзәрләр Кавказ аръягына һөҗүм башлыйлар; 684 тә Албаниягә һәм Әрмәнстанга бәреп керәләр, ул өлкәләрне бөлдергәннән соң, алардан ясак түләтәләр. Хәзәрләрнең Кавказ аръягына юлын кисү максатында 692 дә гарәпләр Дәрбәндне алалар, ләкин тиздән аннан кысрыклап чыгарылалар. Озак еллар буе Албания өчен барган сугышларда уңышлар чиратлашып дәвам итә. 713 тә гарәпләрнең яубашы Хәбиб ибне Мәсләмә җитәкчелегендәге гаскәре, өч ай камалышта торганнан соң, Дәрбәндне яулый һәм Дагстанның Каспий буендагы төбәкләренә бәреп керә. Сәмәндәр шәһәре тирәсендә хәзәрләрнең күпсанлы гаскәренә юлыкканнан соң, гарәпләр сугышсыз гына Грузиягә чигенәләр. 720–21 дә хәзәрләр Албаияне һәм Әрмәнстанны басып алалар, андагы гарәп отрядларын тар-мар итәләр. Хәлифәлек Кавказ аръяына әл-Җәррах бине Габдулла әл-Хәкими җитәкчелегендә яңа отрядлар җибәрә. Алар хәзәрләрне Дәрбәнд артына кысрыклап чыгаралар, Сәмәндәр һәм Бәләнҗәр шәһәрләрен алалар. Соңрак гарәпләр Албаниягә чигенәләр, шуннан торып, 722–25 тә Кавказ алдына һөҗүмнәр ясыйлар һәм Аланияне буйсындыралар. 724 тә әл-Җәррах вазифасыннан читләштерелә, Кавказ аръягы наместнигы итеп әл-Мәсләмә билгеләнә. Яңадан кабынган сугыш хәрәкәтләре вакытында аның гаскәрләре җиңелә, ләкин 727 дә ул кабат хәзәрләрне Кавказ алдына кысрыклап чыгара һәм даими рәвештә хәзәр җирләренә бәреп керә башлый. Шулай да уңышсыз тәгәлләнгән берничә бәрелештән соң, гарәпләр Дәрбәндне калдыралар, ә хәзәрләр гаскәре Албанияне басып ала (729). Каган улы Барҗил җитәкчелегендәге хәзәрләр гаскәре Ардебил шәһәре янында гарәпләрне авыр җиңелүгә дучар итә (731/32). Бу сугышта әл-Җәррах һәлак була. Кавказ аръягына Сәед ибне Әмер әл-Хәраши һәм Мәсләмә ибне Габделмалик җитәкчелегендәге гаскәр җибәрелә, ул Барҗил отрядларын тар-мар итә һәм аларны Дәрбәнд артындагы җирләргә куып чыгара (731). Мәрван ибне Мөхәммәт Кавказ аръягы идарәчесе итеп билгеләнгәннән соң, Г.-х.с.нда яңа этап башлана. 732–33 тирәсендә Мәрван Бәләнҗәр шәһәренә яу б-н бара, ләкин уңышка ирешә алмый. 733–36 да, Византия б-н сугыш вакытында, ул Кавказ аръягындагы төрле төбәкләрне буйсындыра. 737 дә, икегә бүленгән гаскәре б-н Дәрбәнд һәм Дәрьял тарлавыгы аша узып, хәзәрләр башкаласын әйләнеп үтә һәм аларның армиясен тар-мар итә. Шуннан соң ул Хәзәр каганлыгының Каспий буендагы өлкәләрен бөлдерә. Каган гарәпләр куйган шартларда (ислам динен кабул итү, ясак түләү һ.б.) солых төзергә ризалаша. Мәрван явыннан соң Хәзәр каганлыгы Кавказ аръягында актив роль уйнаудан тук-

тый. 740 елларда гарәпләр Кавказ арьягын үз хакимиятләренә буйсындыралар. Ләкин Габбасыйлар династиясе хакимияткә килеп (750), аларның хакимлеге көчсезләнү нәтиҗәсендә әлеге төбәкләрдә хәзәрләрнең йогынтысы көчәя. 763–65 тә Раҗтархан җитәкчелегендә хәзәрләр ике мәртәбә Албаниягә һәм Грузиягә яу б-н баралар. Бер үк вакытта алар гарәпләрне берничә тапкыр җиңәләр. Гарәпләр яубашы Йазид әс-Сулами җитәкчелегендәге өстәмә көчләр килгәч кенә хәзәрләрне Дәрбәнд артына кысрыклап чыгаруга ирешәләр. Г.-х.с. нәтиҗәсендә Кавказ арьягы Гарәп хәлифәлегенә буйсындырыла, Хәзәр каганлыгы б-н ике арадагы чик Дәрбәнд р-ныннан уза. Г.-х.с. төрки телле халыклар (хәзәрләр, болгарлар һ.б.) арасында ислам дине таралуга этәргеч бирә. Г.-х.с. елларында болгар кабиләләренең бер өлешенең (*савирлар, бәрәнҗәрләр* һ.б.) Кавказ алдыннан Идел буйларына күченүе ихтимал.

*Әд.:* Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990.

*И.Л.Измайлов.*

**ГАРӘФЕТДИ́НОВ** Рәфыйк Афзал улы (6.4.1936, Кайбыч р-ны Олы Кайбыч а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1984), проф. (1983), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1997), РФнең мактаулы югары һөнәри белем хезмәткәре (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук эшли. 1969 елдан Казан мәдәният институтында (хәзер мәдәният һәм сәнгать ун-ты), иҗтимагый фәннәр каф. (1970 тән), Ватан һәм чит илләр тарихы каф. мөдире (1994 тән), ун-тның шәрәфле проф. (2003). Хезмәтләре КПССның Идел буе һәм Урал алды өлкәләре оешмалары тарихына, 20 йөз башында Татарстандагы иҗтимагый-сәяси фикер үсеше мәсьәләләренә карый. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Кайбыч р-ны үзәгендә бер урам проф. Г. исемен йөртә.

Хезм.: Туган җирем — Кайбычым = Кайбицы — Край мой родной. К., 2007; Гассан. К., 1978 (автордаш); Галимзян Сайфутдинов. К., 1988; В становлении и борьбе против самодержавия. К., 1990 (автордаш); Казанский государственный университет культуры и искусств. 1964–2004 гг. Краткая история. К., 2004.

*Әд.:* Наш современник. К., 2001.

**ГА́РБЕР** Хаим Иосифович (16.1.1903, Вильно ш. — 1937), философ, сәясәт эшлеклесе. 1912 елдан Казанда. Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-тны (1923, Мәскәү), Марксизм-ленинизм ин-тын (1930, Мәскәү) тәмамлый. 1918–1919 елларда Укучы-коммунистлар берлегенең Казан губ-на ком-ты рәисе, 1919–20 дә РКСМның Казан губерна, 1920–21 дә Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. РКСМның 2 нче (1919, 5–8 окт., Мәскәү) һәм 3 нче (1920, 2–10 окт., Мәскәү) бөтенроссия съездлары делегаты. 1924–25 тә Кызыл Армиядә, сәяси хезмәткәр. 1926–30 да К.Либкнехт исем. ин-тта һәм Н.Крупская исем. Коммунистик тәрбия академиясендә укыта (Мәскәү), 1930–32 дә Марксизм-ленинизм ин-ты профессоры (Баку), 1932–34 тә СССР ФАнең Кавказ арты ф-лы президиумы рәисе урынбасары (Баку). 1934 тән СССР ФА Философия ин-тында фәнни эштә (Ленинград). Хезмәтләре марксистик философиягә карый. Репрессияләр корбаны (1937); үлгәннән соң аклана.



Х.И.Гарбер.

Хезм.: Философия марксизма в интерполяции Маркса-Адлера // Против новейшей критики марксизма: Сб. статей. М.–Л., 1929; Современный русский идеализм // Бюл. Ин-та коммунистической профессуры. 1930. № 6.

*Әд.:* Сейфи Н., Цимхес Э. Гарбер Хаим Иосифович // Борцы за счастье народное. К. , 1983. Кн. 2.


*Ф.С.Хәбибуллина.*

**ГАРЗА́ВИНА** Алла (Алевтина) Викторовна (20.11.1936, Казан), төбәк тарихчысы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1958). 1959–69 елларда ТАССР Дәүләт музеенда, 1969–79 да Казан сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросында (1972–79 да директор), 1979–91 дә Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1992 дән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында эшли. Әсәрләре 1959 да басыла башлый. «Минем Казаным» («Моя Казань», 1984, А.И.Новицкий б-н автордаш), «Казанга, профессор К.Ф.Фукска ...» («В Казань, профессору К.Ф.Фуксу ...», 1987), «Күңелебезнең гүзәл ашкынуын Ватаныбызга багышлыйк!» («Отчизне посвятим души прекрасные порывы!», 1990), «Мәшһүр кешеләр Казан һәм Казан төбәге турында» («Знаменитые люди о Казани и Казанском крае» (1999, А.И.Новицкий б-н автордаш) исемле документаль-нәфис китаплар авторы.

*Әд.:* Ефремов А. Почему скучает турист? // Советская культура. 1979. 24 апр.; Аристов В. Вначале был поиск // Советская Татария. 1987. 2 авг.

**ГАРИ́ЕВ** Равил Мансур улы (16.4.1967, Әлмәт ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Әлмәт нефть ин-тын тәмамлый (1994). 1985 елдан «Татнефть» АҖдә эшли: оператор, мастер, нефть һәм газ чыгару цехы (1999 дан), «Әлмәтнефть» НГДУының коррозиядән саклау җиһазлары цехы башлыгы (2000 нән), АҖнең табигатьне саклау һәм коррозиягә каршы көрәш буенча технол. бүлеге башлыгы (2001 дән). Уйлап табуга 9 патенты бар. Г. «2004 ел инженеры» бөтенроссия конкурсының «Әйләнә-тирә мохит мониторингы һәм экологиясе» номинациясендә җиңүче. Дәүләт бүләге ТРның көньяк-көнчыгышында табигатьне саклау чараларын планлаштыру һәм гамәлгә кертү максаты б-н геоинформация системаларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**ГА́РИНО-БОР КУЛЬТУ́РАСЫ** (Турбаслы культурасы) (археол.), энеолит дәверендә (якынча б.э.к. 3 меңьеллык ахыры — 2 меңьеллык уртасы) Чулман елгасының югары һәм урта агымында яшәүчеләргә нисбәтле культура. 1960 елда О.Н.*Бадер* тарафыннан Турбаслы культурасы буларак аерып чыгарыла. Соңрак археологлар Е.Н.Черных һәм С.В.Кузьминых аңа Г.-Б.к. дигән исем бирәләр. Татарстанда Г.-Б.к. истәлекләре 1970–90 елларда Р.С.Габәшев, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Хуҗалык итү һәм мәдәни яктан караганда, Г.-Б.к. *Волосово культурасына* якын тора. Халкы табигать нигъмәтләрен җыю, балык тоту, аучылык б-н көн күргән. Торулыклары күбрәк елга үзәннәрендә урнашкан. Дүртпочмаклы тораклар яртылаш җиргә иңдереп салынган, аларның уртасында учаклар, эчләрендә азык-төлек саклау базлары булган. Таштан эш һәм сугыш кораллары (шомартылган бәлҗәләр, өтерге, балта, ук һәм сөңге очлыклары һ.б.) ясау зур үсеш ала. Г.-Б. к. халкы бакыр койган (бакыр эретү мичләре, металл кою калыплары, бакыр безләр, бизәнү әйберләре һ.б.); бакыр катнаш комташны эретеп металл җитештергән. Савыт-саба әүвәл казан рәвешле, соңрак тигез төпле итеп ясалган, балчыкка вакланган бака кабырчыгы кушылган. Г.-Б.к. фин-пермь кабиләләре тарафыннан калдырылган дип фараз ителә. Татарстанда Г.-Б.к. истәлекләре Мөслим р-нының Мәлләтамак, Рус Шуганы авыллары янында һ.б. урыннарда табыла.



Гарино-Бор культурасына караган керамика.

*Әд.:* Бадер О.Н. Поселения турбинского типа в Среднем Прикамье // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1961. № 199; Габяшев Р.С., Старостин П.Н. Памятники волосовско-турбинского типа в Икско-Бельском междуречье // Лесная полоса Восточной Европы в волосовско-турбинское время. Йошкар-Ола, 1978.

*Р.С.Габәшев.*

**ГАРИ́ПОВ** Әсгат Гариф улы (15.1.1925, Азнакай р-ны Мәлбагыш а. — 30.3.2001, шунда ук), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1971), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1976). 1951–87 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсендә: «Бөгелмәнефть» трестының 2 нче нефть промыселы операторы (1957 гә



Ә.Г. Гарипов.

кадәр), «Азнакайнефть» нефть промыселлары идарәсендә оператор, мастер (1957–65), «Актүбәнефть» нефть промыселлары идарәсендә мастер, оператор, слесарь-ремонтлаучы (1965–70). Республика промыселларында күп скважинага һәм бер сменалы хезмәт күрсәтүгә күчү инициативасы б-н чыгучыларның берсе, шуның аркасында хезмәт җитештерүчәнлеген 4 тапкырдан күбрәккә арттыру, югары икътисади нәтиҗәгә ирешү мөмкинлеге туа. Эчлекле насослы компрессор торбаларын аерым эксплуатацияләү ысулы юлы б-н нефть чыгаруны техник яктан яңача коралландыру һәм интенсивлаштыруда, нефть җыюны герметиклаштыру схемасын һәм торбаларны деэмульсацияләү куллануны кертүдә актив катнаша. Герой исеме бишьеллык план йөкләмәләрен үтәүдәге зур уңышлары, югары техник-икътисади казанышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Румянцев Е. Гарипов Асгат Гарипович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАРИ́ПОВ** Валерий Зәйнулла улы (1.10.1944, Чистай р-ны Каргалы а.), геофизик, техник фән. канд. (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Томск өлкәсе геофизика партияләрендә эшли. 1973 елдан «Нижневартовскнефтегеофизика» (Төмән өлкәсе) тресты өлкән геофизигы, баш геологы, җитәкчесе. 1987 дән Мәскәүдә: СССР Нефть сәнәгате министрлыгының «Главнефтегеофизика» идарәсе башлыгы урынбасары, 1989 дан Россиянең Геология дәүләт комитетында идарә башлыгы, 1993–2001 дә РФнең Ягулык һәм энергетика министрлыгында Баш идарә башлыгы — министрның беренче урынбасары. Хезмәтләре геофизик мәгълүматны, нефть һәм газ чыганакларын разведкалау һәм эшкәртү материалларын ЭВМда санлы теркәү һәм хисаплау алымнарына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАРИ́ПОВ** Кәрам Гариф улы (20.8.1925, Минзәлә кантоны, хәзерге Актаныш р-ны Иске Кормаш а. — 21.6.1986, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, галим-агроном. 1986 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1941 дә гади колхозчы булып башлый, 1947–62 дә Иске Кормаш МТСында һәм РТСта токарь, остаханә мөдире. 1962 дән Актаныш р-ның «Радио», 1969–86 да «Коммунизмга» к-злары рәисе. Аның җитәкчелегендә кырчылык һәм терлекчелекне алып баруда иң алдынгы технологияләр кертелә. 1975 елга ук бөртекле культураларның уңышы гектарыннан 28,1 *ц* тәшкил итә, 1985 тә тамыразыкларның гектарыннан 600 *ц* уңыш алына. Савым һәр сыердан 3000 *кг* га җитә. 1971–75 тә РСФСР ЮС депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гарипов К.Г., Зыятдинов Ф.С. Рентабельлелек чыганаклары. К., 1977.

**ГАРИ́ПОВ** Рәшит Гариф улы (22.3.1933, Балык Бистәсе р-ны Чирмешән а. — 17.6.2006, Казан), журналист, язучы. Татарстанның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978), ТР Язучылар берлеге әгъзасы (1999). Казан пед. ин-тын (1958), КПСС ҮК каршындагы югары партия мәктәбен (1968) тәмамлый. Балык Бистәсе р-ның «Октябрь юлы» г-тасында бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары (1958–62 еллар), Буа р-ның «Байрак» г-тасы мөхәррире (1963–1966), «Социалистик Татарстан» г-тасында бүлек мөдире (1968–78) булып эшли. 1978–83 тә партия өлкә ком-ты инструкторы, 1983–93 тә Татарстан кинопрокат конторасы директоры, 1993–96 да «Заман-Татарстан» г-тасы мөхәррире урынбасары, 1999–2006 да ТР Язучылар берлеге консультанты.

Г.ның беренче шигыре урта мәктәптә укыганда «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») г-тасында басыла. Ул «Кояш чыгар алдыннан» (1997), «Инану» (2000), «Көт мине, Гөлчәчәк» (2003), «Болыннарда дулкын» (2003) дигән җыентыклар, «Болгар халык әкиятләре» (1960), «Украин халык әкиятләре» (1973) дигән тәрҗемә китаплары, хикәяләр, шигырьләр, публицистик мәкаләләр авторы. Аның шигырьләренә Л.Айтуганов, Ф.Әхмәдиев, Ә.Бакиров, З.Хәбибуллин, Ә.Шәрәфиев һ.б. композиторлар көйләр язды.

*Әд.:* Маннапов Ш. Тормыш кырауларына бирешмичә // Мирас. 1996. № 10; Сафиуллин Ә. Кояш чыкты, сүнмәсен, сүрелмәсен // Ватаным Татарстан. 1997. 12 дек.

**ГАРИ́ПОВ** Роберт Зариф улы (10.7.1946, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1993). 1970 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1963–69 елларда Арча р-ны Дәүләт банкы бүлегендә инспектор, 1969–74 тә комсомол һәм партия эшендә. 1976–98 дә район «Сельхозхимия» берләшмәсендә (1983 тән рәис). 1998 дән «Арчанефтепродукт» АҖдә ген. директор. Аның җитәкчелегендә районның а.х. химияләштерүдә матди-техник база булдырыла, җитештерүгә алдынгы агрохимия алымнары кертелә, минераль ашламалар кертү 4 тапкыр арта, туфракны известьләүнең 5 еллык циклы һәм кырларны комплекслы агрохимик культуралаштыру үзләштерелә. Дәүләт бүләге җитештерүдә фән-техника казанышларын киң куллану нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алган өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ГАРИ́ПОВ** Руслан Мирсәет улы (13.3.1956, Азнакай р-ны Түбән Эстәрле а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (2005). 1978 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре композицион полимер һәм олигомер материалларга карый. Г. җылытмыйча каты халәткә китергәндә эпоксиаминлы матрицалар эластиклашуының физик-химик нигезләрен эшли. Катылану процессының Г. тәкъдим иткән матем. моделе барлыкка килүче челтәрле полимерның структурасын тасвирларга мөмкинлек бирә. Модификацияләнгән эпоксиамин композицияләр катыра торган төрле реакцияләр барышының кинетик закончалыкларын эшли. Җылытмыйча ката торган эпоксиамин композицияләр өчен модификаторлар, композицион материаллар өчен кремнийорганик катыргычлар синтезлый. Җәелмә композицияләр, җилем, герметик, коррозиягә каршы саклагыч капламнар сыйфатында кулланыла торган модификацияләнгән композицион эпоксид материаллар тәкъдим итә. Ул эшләгән материаллар производствода гамәлгә кертелгән.

Хезм.: Изучение кинетики отверждения модифицированных эпоксиаминных систем на модельных соединениях // Докл. РАН. 2003. Т. 392. № 5 (автордаш); Обобщённое уравнение для определения величины критической конверсии при трёхмерной поликонденсации // Высокомолек. соединения. 2004. Т. 46А. № 3 (автордаш); Полиоксимитилены. М., 2008 (автордаш).

**ГАРИ́ПОВ** Талмас Мәгъсүм улы (31.7.1928, Мәскәү), тел галиме-тюрколог, филол. фән. д-ры (1974), проф. (1979), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1983, 1992). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1952). 1956 елдан СССР ФАнең Башкорт ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында. 1966 дан Башкорт ун-тының рус һәм чагыштырма тел белеме, 1980 нән Башкорт пед. ин-тының гомуми тел белеме кафедралары мөдире. Хезмәтләре төрки телләр морфонологиясенә, чагыштырма лексикологиягә, башкорт теле грамматикасына, башкорт тел белеме тарихына, Көнчыгышны өйрәнү белеменә, социолингвистикага карый. Г. Урал-Идел буеның кыпчак телләрен өйрәнә. Күптелле сүзлекләр һәм югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Хезм.: Структурно-семантический глоссарий урало-поволжских языков. Уфа, 1979; Семиречие Башкортостана. Уфа, 1998.

*Әд.:* Юдакин А.П. Гарипов Т.М. // Урало-алтайское языкознание. М., 2001.

**ГАРИ́ПОВ** Тәлгат Вәлирахман улы (17.7.1942, Лениногорск р-ны Түбән Иштирәк а.), вет. фармакологы, токсиколог, вет. фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1969 елда Казан вет. ин-тын (хәзерге Казан вет. мед. акад-се) тәмамлый, шунда ук эшли, 1980–85 елларда вет. ф-ты деканы урынбасары, 1988–96 да декан, 1991–97 дә фармакология һәм токсикология каф., 1999 дан терлекләр физиологиясе һәм этиологиясе каф. мөдире, 1998–2000 дә һәм 2003 тән проректор. Хезмәтләре терлекләрдә тире авыруларын дәвалау өчен яңа препаратлар эшләүгә, яңа химик кушылмаларның фармакологик һәм токсикологик үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы, 3 патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ветеринарная токсикология. К., 1991 (автордаш); Взаимодействие и несовместимость лекарственных веществ. К., 1998.

**ГАРИ́ПОВА** Зөлфия Раиф кызы (20.11.1969, Казан), спортчы (самбо, дзюдо көрәшләре), самбо (1995), дзюдо (1996) буенча Россиянең халыкара класслы спорт остасы. ТРның атказ. тренеры Р.Т.Сабиров шәкерте («Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыяте, Казан). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1993). Дөнья (самбо, студентлар арасында, 1994), Европа (1996) чемпионы, дөнья чемпионатларында көмеш медаль ала (1996–97). Дзюдо көрәше буенча РФ (көмеш 1994, бронза 1996), СССР (бронза 1990), БДБ (бронза 1992), Европа (бронза 1996, РФ җыелма командасы б-н) чемпионатларында медальләр иясе. Дөнья чемпионатында (1995) һәм Олимпия уеннарында катнаша (1996, 7 нче урын). 1999 дан тренерлык эшендә.

*Әд.:* И л д а р х а н о в  И. Без көрәшче халык. К., 2009.



Р.М.Гарипова.

**ГАРИ́ПОВА** Раилә Мөхәммәтхан кызы (22.11.1946, Казан), балет артисткасы, балетмейстер, ТАССРның атказ. һәм халык артисты (1982, 1987). Мәскәү мәдәният ин-тының хореография бүлеген тәмамлый (1974). ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең солисты (1967–69), педагог-репетиторы (1974–77), баш балетмейстеры (1977 дән). ТР Җыр һәм бию ансамбле каршында «Юлдаш» балалар хореографик мәктәбен оештыручыларның берсе. «Сабантуй», «Дуслык бәйрәме», «Туган як моңнары», «Шәрекъ клубы», «Корбан бәйрәме», «Шәһәр биюе» һ.б. вокаль-хореографик композицияләрне куюда катнаша. «Кызлар җыены», «Бишле бию», «Казан кызлары биюе», «Гармун, гармун», «Ярмәк вагы» һ.б. бик күп биюләрне куя. Милли бию фольклорын тирәнтен белүче буларак, үзенең хореографик сәхнә композицияләрендә халык биюе мирасын иркен һәм кыю куллана. Укучылары арасында ТРның атказ. артистлары Л. һәм А. Хәмитовлар, Р.Шәйдуллин, М.Фәттахова һ.б. бар.

*В.Н.Горшков.*

**ГАРИ́ПОВА** Фирдәвес Гариф кызы (7.12.1941, Биектау р-ны Кодаш а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995, 2003), Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), Биектау р-ны Ямаширмә урта мәктәбендә укыта. 1966–70 елларда Республика фәнни китапханәсе китапханәчесе. 1974 тән СССР ФАнең Казан филиалы Тел. әдәбият һәм тарих ин-тында (1996 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) эшли, бер үк вакытта (1976 дан) Казан пед. ун-тында укыта. Хезмәтләре татар ономастикасына, этнолингвистика, тарихи лексикология, терминологиягә һәм татар теле һәм халкы тарихына карый. Татар тел белемендә яңа фәнни юнәлешкә — *гидронимикага* нигез сала. «Татарстан гидронимнары сүзлеге»н (1–2 кит., 1984–90) төзүче. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр авторы.

Х е з м.: Борынгы Болгар шәһәрләре. К., 1990; Татарстан микротопонимнар сүзлеге: 2 китапта. К., 1992–93; Авыллар һәм калалар тарихыннан: 2 томда. К., 2001–03; Рухи башкалабыз. Мәшһүр татар авыллары. К., 2006; Әчәр сулар йөртә безне. К., 2006.

*Әд.:* Ә м и р х а н  Р. Чишмәләрдән чылтыраган иҗат // Казан утлары. 2000. № 9; Г а р и ф у л л и н  В.З. По дороге знаний и добра // Татарстан. 2001. № 12.

**ГАРИФҖА́Н БУАВИ́** (чын исеме һәм фамилиясе Гарифҗан Хәсән улы Вәлидов) (1879, Буа ш. — 30.9.1946, шунда ук), ташка уеп язучы, хаттат. Буа мәдрәсәсендә белем ала, шунда һәм Идел буендагы башка мәдрәсәләрдә укыта. Татар матбугатында мәкаләләр бастыра; «Шура» ж-лында Гарифҗан Вәлиди псевдонимы б-н басылган Түбән Идел буендагы (хәзерге Волгоград өлкәсендәге) татар авыллары тарихына багышланган язмалар авторы. 1910 еллардан Буада яши һәм татар мөселман эпиграфик ядкәрләрен эшләү б-н шөгыльләнә, гомеренең соңгы елларында Буадагы татар мәктәбендә укыта. Аның тарафыннан эшләнгән кабер ташларының формалары үзенчәлекле (ярымшар рәвешендә төгәлләнүче, мөселман мәчетләрендәге кебек ярымцилиндр һәм чалмасыман гөмбәзләр



Г а р и ф җ а н  Б у а в и. Буа шәһәре зиратындагы кабер ташы. Известьташ. Уеп бизәкләү. 1910 еллар.

б-н очланучы турыпочмаклы баганалар), үлчәмнәре зур түгел (40–50 *см* биеклектә, киңлеге һәм калынлыгы 15–20 *см*). Язулар гарәп имлясының «тәгъликъ» стилендә ташның алгы һәм арткы якларында башкарылган. Текстларда Коръән гыйбарәләре б-н беррәттән еш кына дөньядан китү авырлыгы турында татар телендәге шигырьләр очрый. Останың «Гамәле Гарифҗан Буави» имзасы, гадәттә, текстның астына уеп язылган. Кайвакыт язу турыпочмаклы бизәк кысасы эченә алынган, тирәнтен уемлау б-н башкарылган. Текстлар бизәкләр б-н нәкышьләнмәгән. Г. тарафыннан эшләнгән кабер ташлары Буа шәһәренең һәм якын-тирә авылларның зиратларында сакланган. 1980 елларда ул эшләгән 50 ләп кабер ташы теркәлә.

Х е з м.: Актүбә буйлары // Шура. 1913. № 4, 5, 7, 9.


*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАРИФҖА́НОВ** Габделбәр Гарифҗан улы (11.10.1930, Балтач р-ны Нөнәгәр а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1977), проф. (1990), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 1953–55 елларда Таҗикстан ССРның Шураб шәһәрендә эшли, 1955–57 дә Балтач р-нының Димитров МТСында. 1957–61 дә оборона сәнәгате пр-тиесендә (Пермь өлкәсе Кизел ш.), 1958 дән баш инженер. 1961 дән Эстәрлетамак «Каустик» химия з-дында, 1974 тән Зима химия з-дында (Иркутск өлкәсе). 1979–90 да Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек башлыгы. 1990–2001 дә «Плазмохим» фирмасы директоры. Дегидрирлау (водород аерып алу) өчен яңа катализаторлар, хлорорганик продуктлар эшләү өчен калдыксыз технология, сәнәгый ташландык суларны чистарту ысулларын, сәнәгый һәм көнкүреш каты калдыкларын бергә эшкәртү технологиясен эшли. Үзле күкертле нефтьләрне, битумлы токымнарны, сыек сәнәгый калдыкларны экологик куркынычсыз эшкәртеп, мотор ягулыклары һәм мономерлар ясау технологиясен булдыра; төрле углеводородлы чималдан ацетилен алу ысулларын камилләштерә. Г. ның хезмәтләре Эстәрлетамак «Каустик» һәм синтетик каучук з-дларында, Зима химия з-дында, илебезнең оборона пр-тиеләрендә кулланылышка кертелә. Махсус технологияләр буенча уйлап табуга 187 авторлык таныклыгы һәм 5 патенты бар. СССР МС бүләге лауреаты (1988). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ГАРИФҖА́НОВ** Надир Нургаяз улы (25.3.1959, Казан), физик, физ.-матем. фән. канд. (1990), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре металл һәм металлоксид кушылмаларны экспериментал тикшерүләргә карый. Дәүләт бүләге үтә үткәргечләрнең наноүлчәмле үзлекләре табигатен магнит резонансы алымнары б-н тикшерүләре өчен бирелә.

Х е з м.: Сдвиг Найта в сверхпроводящем ванадии // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2008. Т. 87, вып. 6 (автордаш).

**ГАРИФҖА́НОВ** Нургаяз Салих улы (15.5.1920, Вятка губ., Малмыж өязе Чутай а. — 14.3.1970, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1966), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1949 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан филиалының Физика-техника ин-тында эшли, 1968 дән ЭПР лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре парамагнит комплексларның эремә һәм пыялаларындагы ЭПРга карый. Тимер



Б.Г. Гарифуллин.



Габдулла Г. Гарифуллин.

$^{57}$Fe төше спинын билгели (1957, бергәләп). Күмер, корым, синтетик каучукларның парамагнитик табигатен ачыклый (1961). Парамагнитлы комплексларны саф килеш тапмыйча да ЭПР ысулы б-н тикшерү алымын үстерә (1970). Бөек Ватан сугышында катнаша, радиовзвод командиры. Украина, Молдавиядә сугыша, Румыния, Венгрия, Болгарияне азат итүдә катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казан урамнарының берсе аның исемен йөртә.

Х е з м.: Электронный парамагнитный резонанс в некоторых сортах природной нефти и её тяжёлых фракциях // Химия и технология топлива и масел. 1961. Т. 8, № 1 (автордаш); О природе спин-решёточного взаимодействия в магнитно-разбавленных свободных радикалах // Докл. АН СССР. 1963. Т. 150, № 3; Ширина линий ЭПР жидких растворов этиленгликолевого комплекса для чётных и нечётных изотопов хрома // Докл. АН СССР. 1968. Т. 178, № 4.

*Әд.:* Б е л о к о п ы т о в В., Ш е в ч е н к о Н. Их именами названы улицы Казани. К., 1977.

*Р.Г.Усманов.*

**ГАРИФҖА́НОВ** Фәрхәт Нургаяз улы (4.6.1954, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1998), проф. (1999). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1979–98 елларда Казан техник ун-тында эшли. 1998 дән Казан аграр ун-тының физ. һәм матем. каф. мөдире. Хезмәтләре аналитик функцияләр өчен кырый мәсьәләләр теориясенә карый. Моментлар теориясендә аермалы тигезләмәләрнең аналитик чишелешен тикшерү һәм биортогональ-иярешле системалар төзү өчен яңа ысул эшли.

Х е з м.: Проблема обращения особого интеграла и разностные уравнения для функций, аналитических вне квадрата // Изв. вузов. Математика. 1953. № 7; Моменты Стильтьеса целых функций экспоненциального типа // Мат. заметки. 2000. Т. 67, № 5; О регуляции одного класса разностных уравнений // Сибирский мат. журн. 2001. Т. 42, № 5.

**ГАРИФҖА́НОВА** Мәрьям Бари кызы (8.3.1960, Казан), невропатолог, рефлексотерапевт, мед. фән. д-ры (1998). Казан мед. ин-тын (хәзерге Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1983), Казан клиникаларында эшли. 1987 елдан ГИДУВта (хәзер Казан мед. академиясе). Хезмәтләре мимик мускулларны электрофизиологик һәм гистохимик тикшеренүләргә, мануаль рефлексотерапиягә карый.

Х е з м.: Контрактура мимических мышц. Смоленск, 1994.

**ГАРИФҖА́НОВА** Роза Бари кызы (17.2.1921, Арча кантоны Чутай а. — 4.6.2008, АКШ, Сиэтл ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1986), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1990). 1941 елда Киров пед. ин-тын тәмамлый. 1942–51 елларда укытучы, мәктәп директоры, Киров өлкә халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1951–74 тә Казан пед. ин-тында. 1974–95 тә РФ Мәгариф министрлыгы Милли проблемалар ин-тының Татарстан ф-лында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Татар мәктәпләрендә рус теле укыту методикасы буенча хезмәтләр, татар гомуми белем мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм ярдәмлекләр авторы. К.Д.Ушинский исем. медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Обучение русской речи учащихся-татар. К., 1966; Современный урок русского языка в татарской школе. К., 1988; Обучение монологической и диалогической речи в татарской школе. К., 1992.

**ГАРИ́ФОВ** Камил Мансур улы (20.4.1950, Чистай ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), ТРның атказ. уйлап табучысы (1998). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), ТатНИПИнефтьтә эшли, сектор (1981 елдан), лаб. (1986 дан) мөдире, скважиналарны эксплуатацияләү һәм төзәтү бүлеге мөдире (2001 дән). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: нефть катламнарына дарылы газлар б-н тәэсир итү механизмы, берничә катламны бер үк вакытта аерым-аерым эксплуатацияләү мәсьәләләре, скважиналарның сафтан чыгуының төп факторларын анализлау. Г. катламга кислоталы тәэсир итү, продуктив көпшәк катламнан файдалану алымнарын тәкъдим итә; скважиналарны герметиклаштыру һәм изоляцияләү юлларын эшли. Катламга имплозион тәэсир ясау, аңа сыеклык кудырту, скважинада ике катламны бер үк вакытта аерым-аерым эшләтү, утыртма колонналарны ремонтлау һәм аларның эчке өслекләрен чистарту өчен җайланмалар һ.б. җиһазлар уйлап таба һәм эшли (РФнең нефть чыгару пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). ТР Дәүләт бүләге «Эксплуатация колонналарын торгызу һәм саклау өчен техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләү һәм киң сәнәгый кулланылышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 63 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт величины давления при термогазохимическом воздействии на призабойную зону пласта // Тр. ТатНИПИнефти. 1977. Вып. 25; Теоретические и экспериментальные исследования воздействия на нефтяные пласты пороховыми газами. К., 2001; Новые методы защиты и герметизации эксплуатационной колонны // Нефт. хоз-во. 2003. № 8 (автордаш); Установка для одновременно-раздельной эксплуатации двух пластов // Сб. науч. трудов ТатНИПИнефти. М., 2006 (автордаш).

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Бари Гарифулла улы (10.5.1907, Казан губ. Зөя өязе, хәзерге Кайбыч р-ны Борындык а. — 21.12.2003, шунда ук), механизатор-комбайнчы, Соц. Хезмәт Герое (1952). 1929–31 елларда Кызыл Армиядә. Тракторчы-механизаторлар курсларын тәмамлаганнан соң (1932), Кайбыч р-ның Мөрәле МТСында (1958 гә кадәр), 1958–62 дә Апас р-ның Куйбышев исем. к-зында эшли. Техниканы камилләштерүгә аеруча игътибар бирә, аннан яхшырак файдалану, урып-җыю агрегатларыннан өзлексез һәм ритмлы файдалану чаралары комплексын эшли, шул сәбәпле уңышны җыеп алу вакытын кыскарту мөмкинлеге туа. Герой исеме бөртекле культураларны урып-җыю, суктыруда ирешкән уңышлары өчен бирелә. Республикада беренче тапкыр 25 көн эчендә 6249 *ц* бөртек җыеп суктыра (1951). 1952–56 елларда ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З а л я л о в А. Гарифуллин Бари Гарифуллович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Васил Заһит улы (1.10.1961, Теләче р-ны Югары Кибәхуҗа а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1986–89 елларда Казан телевидение студиясенең мәгълүмат бүлегендә мөхәррир. 1989 дан Казан ун-тында эшли: 1999 дан татар журналистикасы каф. мөдире, 2001 дән журналистика һәм социология ф-ты деканы. Хезмәтләре журналистикада заманча технологияләргә, вакытлы матбугат теленә карый. Г. газета-журнал текстларын классификацияләүнең фәнни нигезләрен, татар тележурналистикасы жанрларын аеру критерийларын эшли, татар вакытлы матбугаты үсешенең төп юнәлешләренә характеристика бирә. Рус телле укучылар өчен татар теле дәреслекләрен төзүче авторларның берсе. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы.

Х е з м.: Татар теле. К., 1998 (автордаш); Язар сүзең булса... К., 2000; Типы структурной организации журналистского текста. К., 1997; Способы формирования журналистского текста. К., 2002.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Габдулла Гарифулла улы (3.1.1925, Арча кантоны, хәзерге Балтач р-ны Яңгул а. — 1.8.2002, шунда ук), Сов. Союзы Герое (15.5.1946), сержант. ФЗӨ мәктәбен (1940, Донецк ш.), агрономнар курсларын (1952, Казан) тәмамлый. 1941–42 елларда Чиләбе трактор з-дында, Балтач р-ның «Яңа тормыш» к-зында эшли. 1942 елның августыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 20 нче җиңел артиллерия бригадасының 54 нче җиңел артиллерия полкында (5 нче удар армиянең 6 нчы артиллерия корпусы 2 нче артиллерия дивизиясе) орудие командиры. 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Эстония, Латвия, Литва, Көнчыгыш Пруссия һәм Польшаны азат итүдә (1944–45), Берлинны алу операциясендә (1945) катнаша. 1945 нең 23 апрелендә Берлин өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Берлин биналарының берсенә Кызыл флаг элә, ул җитәкчелек иткән расчёт сугышның бер тәүлегендә дошманның 9 станлы пулемётын, орудиесен юк итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945) Балтач р-ны «Сельхозтехника»сында слесарь, Яңгул авыл советы рәисе (1948–49), Балтач р-ны «Большевик» к-зы рәисе (1953–55), «Сельхозтехника»да нормировщик (1956–90) булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Дан ордены, ме-

дальләр б-н бүләкләнә. Г. исемен Яңгул авылындагы бер урам йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Гафият Гарифулла улы (10.2.1924, Мамадыш кантоны, хәзерге Кукмара р-ны Мәмәшир а. — 17.7.1985, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1979), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1948–54 елларда Пермь өлкәсенең күмер сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. 1955–62 дә Кукмара р-ның «Трактор» һәм «Татарстан» к-злары, 1962–83 тә «Восток» к-зы рәисе. Г. үсемлекчелек һәм терлекчелек үсешенә зур өлеш кертә. «Восток» к-зында холмогор токымлы иң яхшы сыер көтүе булдырыла. Ул җитәкләгән елларда савым 1 сыердан 1845 *кг* нан 4200 *кг* га кадәр арта, а.х. җирләренең 100 *га* исәбенә сөт җитештерү 550 *ц* га җитә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Дамир Хәйрулла улы (5.5.1939, Сарман р-ны Яхшыбай а.), шагыйрь, публицист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1962 елдан КПССның Сарман райкомында (1970–91 елларда пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире) эшли. 1991–93 тә «Ватаным Татарстан» г-тасының үз хәбәрчесе. Әсәрләре республика газета-журналларында 1962 дән бирле басылып килә. Балалар өчен «Тылсымлы шакмаклар» (1984), «Кикринур — гаҗәп этәч» (1985), «Ишегалды» (1990) исемле шигырь җыентыклары авторы. Форма ягыннан җыйнак, җиңел истә кала торган шигырьләрендә шагыйрь балаларны кыю, гадел, мәрхәмәтле булырга өнди. Г. борынгы кульъязмаларны, фольклор әсәрләрен җыйнап матбугатта бастыра; татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре турында публицистик мәкаләләр, очерклар авторы.

Ә с ә р.: Мең дә бер робагый. К., 1997.

*Әд.:* А к м а л Н. Энә белән кое казый ул // Мәдәни җомга. 1999. 7 май.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Илгиз Габделсамат улы (2.7.1946, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1990), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1970 елда Мәскәү физика инженерлыгы ин-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, 1983–87 елларда металлар физикасы лаб-ясе мөдире, 1992 елдан баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре гадәти металлардагы һәм үтә үткәргечләрдәге магнит резонансына карый. Икенче төр үтә үткәргечтә ЭПР булуын беренче булып (1972, бергәләп), ш.у. үрнәк үтә үткәргеч халәтенә күчү б-н магнит катнашмалар арасында өстәмә алмашыну тәэсире барлыкка килүен (1977, бергәләп), диэлектрик һәм үтә үткәрүчән өлкәләрдән торган Y-Ba-Cu-O системасының гетероген булуын ачыклый. Купер парларының үтә үткәргеч-ферромагнетик чиге аша узу коэффициентының, ферромагнит катламындагы үткәрүчән зона алмашынып таркалу сәбәпле, чикләнгән булуын күрсәтә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Наблюдение электронного спинового резонанса в сверхпроводнике второго рода // Физика твёрдого тела. 1972. Т. 14 (автордаш); Электронные свойства системы BaCuO // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1998. Т. 48 (автордаш); Сдвиг Найта в сверхпроводящем ванадии // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2008. Т. 87 (автордаш).

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Казим Мөгаллим улы (1.5.1932, БАССРның Туймазы р-ны Егетәк а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТР, РФнең атказ. икътисадчысы (1994, 2002). 1955 елда Ленинград финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1961–67 елларда Пермь ун-тында өлкән укытучы, доцент, 1965 тән исәпләү һәм финанслар каф. мөдире, 1967–72 дә Казан а.х. ин-тында бухгалтерлык исәбе каф. мөдире. 1969–86 да Хисаплау техникасын гамәлгә кертү дәүләт фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында лаб., бүлек мөдире, фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1972 дән Казан финанс-икътисад ин-тында доцент. 1982 дән бухгалтерлык исәбе каф. профессоры, 1995–2000 дә фәнни эшләр буенча проректор, 2005 тән Fujitsu компанияләр төркеме ICL КПО ВСда идарә итүнең автоматлаштырылган системалары буенча эксперт. Фәнни тикшеренүләре сәнәгатьтә, хәзерге заман хисаплау техникасы чаралары кулланып, продукциянең үзкыйммәтен исәпләү, тикшерү һәм анализлауга карый. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Автоматизированная подсистема управления себестоимостью продукции по нормативному методу. М., 1983; Бухгалтерский учёт в промышленности. К., 1993; Бухгалтерский учёт внешнеэкономической деятельности предприятий. К., 1995; Управление затратами. К., 2005.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Мансур Фоат улы (2.2.1955, Мамадыш ш.), самолётлар төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1994), проф. (1996). 1978 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли (бүленеп, 1984–89 елларда Кама политехник ин-тында, Чаллы ш.), 1995–2003 тә очкыч аппаратлар конструкциясе һәм ныклыгы, 2003 тән материаллар каршылыгы кафедралары профессоры. Хезмәтләре очкыч аппаратлар динамикасына һәм юка конструкцияләренең аэросыгылмалылыгына карый. Су асты канатлы судноларның канатлары төзелешен хисаплау ысулларын эшли, аларны хисаплауны программалар б-н тәэмин итә. Экранопланнар аэродинамикасын һәм кояш батареясе элементларын урнаштыру динамикасын тикшерә.

Х е з м.: Динамика и аэроупругость тонкостенных конструкций. К., 2003.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Фәрит Шәрифулла улы (20.12.1928, БАССРның Благовар р-ны Күчәрбай а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (1984), проф. (1985), БАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1976, 1996), БР ФАнең шәрәфле академигы (1995). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1952). 1952–80 елларда СССР ФА Башкортстан ф-лы Биология ин-тында эшли: өлкән фәнни хезмәткәр, үзе оештырган физика һәм туфрак эрозиясе лаб-ясе мөдире (1965 елдан), фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1980 нән Башкортстан аграр ун-тында: туфрак белеме каф. мөдире (1980–83), фәнни эшләр буенча проректор (1983–90), игенчелек һәм туфрак белеме каф. мөдире (1990–94), каф. профессоры (1994 тән). Хезмәтләре туфракның уңдырышлылыгын кабат торгызу һәм культуралы туфрак ясау процесслары мәсьәләләренә карый. Көньяк Урал һәм Урта Идел төбәкләренең туфрак белгечләре, агрохимиклары, игенчеләренең координацион советы рәисе, Россия А.х. ФА (РАХФА) каршындагы туфрак физикасы секциясе әгъзасы. 1986–89 елларда СССРның Югары аттестация комиссиясенең эксперт советы әгъзасы. 1985–90 да БАССР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Чернозёмы Башкирии. Уфа, 1969 (автордаш); Физические свойства почв и их изменение в процессе окультирования. М., 1979; Зонально-экологические особенности почв Республики Башкортостан и адаптация систем земледелия к агроландшафтам. Уфа, 2001. Зонально экологические особенности, оценка воспроизводства плодородия почв лесостепной зоны Республики Башкортостан. Уфа, 2005; Агрофизические свойства чернозёма Приуралья Башкортостана и пути их оптимизации. Уфа, 2008.

*Әд.:* Н е д о р е з к о в В.Д., З и я з е т д и н о в Р.М. Башкирский государственный университет: история и современность. Уфа, 2000.

**ГАРИФУ́ЛЛИН** Фоат Әсәдулла улы (9.12.1936, Буа р-ны Күл Черкене а.), полимерларның химик технологиясе һәм физикасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1980), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1986, 1993), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын, 1972 дә Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый. 1959–62 елларда оборона пр-тиесендә инженер (Түбән Тагил ш.). 1962 дән Казан химия-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты) (бүленеп, 1966–70 тә Казан төзүче-инженерлар ин-тында), 1980 нән конструкцион материаллар технологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта автоматлаштыру һәм комплекслы механикалаштыру ф-ты деканы (1986 га кадәр), проф. (1981). Хезмәтләре җылылык-массаалмашу теориясенә, полимер һәм композит материалларны эшкәртүгә һәм нәньютонча сыеклыкларның гидродинамикасына карый. Бутилкаучук, пропилен оксиды һәм стирол җитештерү буенча химик технологияләрнең теоретик нигезләрен эшли һәм технологияләрен камилләштерә. Мембранлы процесслар гидродинамикасын, тузанлы газларда радиацияле җылы алмашуны тикшерә. Материалларның радиоактив сыйфатламаларын тикшерүнең тәҗрибә ысулларын, нәньютонча сыеклыкларда һәм чик катламнарда турбулентлыкның матем. модельләрен эшли. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Авыр атлетика буенча СССРның спорт остасы (1970), гер спорты (2002) һәм авыр атлетика буенча халыкара категорияле судья (2002). Ф.К.Туишев исем.



М.Т. Гарнизов.

халыкара гармунчылар конкурсларында җиңүче (1994, 1996).

Х е з м.: Материаллар фәне нигезләре. К., 2002; Реология сложных текучих систем. Минск., 1981; Течение неньютоновских жидкостей. Лейпциг, 1985; Основы механики неньютоновских систем. К., 1995.

**ГАРКА́ВИ** Михаил Ильич (22.6.1896, Казан — 19.6.1955, шунда ук), очучы, химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Республикада беренче гражданнар авиациясе очучыларыннан берсе. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1933). 1914 елда, Казан беренче реаль уч-щесен тәмамлаганнан соң, Мәскәү югары техник уч-щесенә укырга керә (Н.Е.Жуковский тарафыннан оештырылган авиация теоретик курсларын тәмамлый). 1916 да Севастополь очучылар мәктәбенә, берничә айдан Петроград диңгез авиациясе мәктәбенә җибәрелә. Гражданнар сугышында катнаша. 1920 дән Көньяк фронтта авиабүлек башлыгының су авиациясе (гидроавиация) буенча ярдәмчесе, 1921 дән 4 нче гидрогарнизонның 8 нче гидроотряды башлыгы). Г. экипажы Егорлык култыгында сугышчан бурычны үтәгәндә дошман тральщигын һәм судносын батыра. Самолёт аэродромга 13 җирдән тишелеп кайта. Шунда күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен Г. Кызыл Байрак ордены һәм исемле сәгать б-н бүләкләнә. 1922–26 елларда Г. — Республика ХКС авиация базасының 1 нче класслы очучысы. 1929–36, 1945–53 тә Казан мех комб-тының үзәк химия лаб-ясендә химик, куян тиресе эшкәртү ф-касы төзелешендә баш инженер, 1945 тән комб-тның баш инженеры. 1936–43 тә Казанда СК-4 з-дында. 1943–45 тә «Росглавхлеб» трестының үзәк лаб-ясе башлыгы. 1953–54 тә Казан мех техникумы укытучысы. Г. чуар бәрән тиресен (илтерне) кара төскә буяуның үзенчәлекле ысулын эшли; мех эшкәртүнең һәм буяуның катнаш ысулын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнаша; нәтиҗәдә мехның сыйфаты яхшыра, аны эшкәртү циклы 36 дан 26 процесска кадәр кыскара, производство мәйданының һәм җиһазлар куллануның өчтән бер өлешен, эшче көчнең 60% ын кыскарту мөмкинлеге туа. СССР Дәүләт бүләге шул эшләре өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә. Татарстанның Соц. Төзелеш Герое (1932).

*Әд.:* И б р а г и м о в Р.А. Крылья Татарстана. К., 1985; П о д о л ь с к а я М. Земля, вода и воздух Михаила Гаркави // Казань. 1999. № 3/4.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ГАРМО́НОВ** Сергей Юрьевич (10.9.1970, Казан), химик-аналитик, химия фән. д-ры (2004), проф. (2005). 1992 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1995 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре органик кушылмаларның аналитик химиясенә карый. Г. биофармакологик тикшеренүләр, производстволар һәм сыйфат күзәтүе өчен аминлы дару матдәләрен анализлауның агымлы алымнарын фәнни нигезли. Кеше организмындагы ферментлы метаболик системаларның биохимик фенотипларын бәяләү өчен, клиника практикасына аналитик алымнар комплексын кертә, төрле патологик халәтләрдә аларны ксимедон дару препаратлары ярдәмендә химик-фармакологик төзәтү мөмкинлеген күрсәтә; фармакотерапиядә һәм экоагулагычлар б-н эшләгәндә хәвефсезлекне тәэмин итү өчен бу алымнарның кулланылышын нигезли. Кеше организмының оксидантларга каршы системасына акустиканың тәэсирен тикшерә, каты тавыштан саклануның фармакологик юлларын тәкъдим итә. Пульсацияле яну җайланмаларында куркынычлы калдыкларны (мед.-биол., сәнәгый, хәрби) зарарсызландыру өчен яңа технологияләрнең экологик системасын эшли. Уйлап табуга 3 патенты бар. Агымлы-инжекцияле анализ алымын үстерүе өчен РФАнең Аналитик химия фәнни советы бүләгенә лаек була (2004).

Х е з м.: Проточно-инжекционный анализ лекарственных веществ // Журн. аналит. химии. 2001. Т. 56, № 4 (автордаш); Перспективные методы оценки генетически детерминированной химической чувствительности организма человека // Хим. и биол. безопасность. 2003. № 11/12 (автордаш); Аналитические методы исследования генетического полиморфизма организма человека // Вопросы мед., биол. и фарм. химии. 2004. № 1 (автордаш).

**ГАРМУ́Н**, төрле конструкцияле һәм көйләнешле телле-клавишлы, пневматик музыка уен коралы. Чыгышы Европадан. Беренче конструкциясен 1822 елда немец остасы К.Ф.Л.Бушман эшли. Г. — татар халкында киң таралган музыка коралларыннан берсе. Барлык Г.нарга тартып уйнау принцибы һәм авазлар чыганагының конструктив үзенчәлекләре уртаклыгы хас. Аваз чыганагы — металл планкаларның махсус ярыклары («тәрәзәләре») өстенә беркетелгүче, иркен дерелдәүче металл телләр. Мехлар кысылганда һәм тартылганда һава агымы тәэсирендә авазлар барлыкка килә. 19 йөздә уйлап табылганнан соң ук Россиядә тарала башлый. Татарлар арасында бер рәтле рус һәм немец көйләнешле Г.нар, соңыннан төрле конструкцияле ике рәтле рус һәм немец көйләнешле «Саратов гармуны», «бараксин» (Вараксин), «тальян гармун» (вятский), «рус гармуны», «концерт гармуны» була. Татарларда «бараксин» һәм тальян гармуннары, гадәттә, до-, ре-, яисә ми-мажорга көйләнелә. Фабрикада һәм һөнәрчелек ысулы б-н эшләнгән Г.нар файдаланыла. Аларда халык җырлары, көйләре һ.б. әсәрләр башкарыла. К. *Казан музыка инструментлары фабрикасы.*



Гармуннар.

*Әд.:* М и р е к А.М. Из истории аккордеона и баяна: Возникновение, производство, усовершенствование и распространение гармоники. М., 1967; ш у л у к. Справочник по гармоникам. М., 1968; В е р т к о в К., Б л а г о д а т о в Г., Я з о в и ц к а я Э. Атлас музыкальных инструментов. М., 1975; Н и г м е д з я н о в М.Н. Татарские народные инструменты // Музыкальная фольклористика. М., 1978. Вып. 2; Я к о в л е в В.И. Традиционные музыкальные инструменты Волго-Уралья. К., 2001.

*Р.Ф.Халитов.*

**әл-ГАРНАТИ́** (الغرناطي) Әбү Хәмид Мөхәммәт ибне Габдеррәхим әл-Андалуси (1080, Гренада — 1169/70, Сүрия), гарәп сәяхәтчесе. Александрия, Каһирә, Багдадта белем ала. Европа, Урта һәм Үзәк Азия илләре буйлап сәяхәт кыла. 20 ел чамасы хәзәрләр шәһәре Саксинда яши, шуннан Идел буе Болгарына (1135–36, 1150 дә), рус кенәзлекләренә һ.б. дәүләтләргә сәфәр чыга. «Мугърибен бәгыд гаҗаиб әл-Мәгъриб» («Мәгърибнең кайбер гаҗәеп хәлләрен бәян итү», кулъязма күчермәсе Мадридта Тарих академиясе китапханәсендә саклана) һәм «Төхфәт әл-әлбаб вә нөхбәт әл-гаҗәб» («Акыл бүләге вә гаҗәеп хәлләр», 26 га якын кулъязма күчермәсе сакланган) хезмәтләре авторы. Аның хезмәтләрендә Көнчыгыш Европа, ш.и. Идел буе Болгары турында мәгълүматлар бар, Болгар шәһәре һәм анда яшәүчеләр хакында тәфсилләп бәян ителә, Идел буе халыкларының легендалары һәм риваятьләре урнаштырылган, *Ягъкуб бине Ногманның* «Болгар иле тарихы» («Хәдис Болгари») әсәреннән (11 йөз) өзекләр китерелә.

Х е з м.: Путешествия Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг). М., 1971.

*Г.М.Дәүләтшин.*

**ГАРНИ́ЗОВ** Михаил Тихонович (1924, Тәтеш кантоны Шигали а. — 28.8.1943, Полтава өлкәсе Пархоменко а.), Сов. Союзы Герое (10.1.1944, үлгәннән соң), гв. сержанты. Куйбышевта 2 нче ФЗӨ мәктәбен тәмамлаганнан соң, Куйбышев шәһәре кондитер ф-касында эшли. 1942 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 200 нче гв. укчы полкы (4 нче гв. армиянең 68 нче гв. укчы дивизиясе) пулемётчысы. Воронеж фронты гаскәрләре составында Белгород-Харьков һөҗүм операциясендә катнаша (1943). 1943 нең 28 августында Михайловка хуторы (Полтава өлкәсе Котелёв р-ны) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: граната б-н авыр танкны шартлата. Яу кырында һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Самара шәһәрендәге 38 нче һөнәри-техник уч-щегә Г. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982.

Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**«ГАРО́» ЗАВОДЫ́** («Гараж һәм авторемонт җиһазлары»), Казанда машиналар төзү заводы. Эшләүчеләр саны 200 кешедән артык (2001). Тарихы 1941 елдан башлана: Калинин өлкәсе Бежецк шәһәреннән «АГО» («Автогараж җиһазлары») з-ды эвакуацияләнә һәм Казан авторемонт остаханәләре биналарына урнаштырыла. 1956 да — «ГАРО» з-ды, 1973 тә — «Автоспецоборудование» тәҗрибә-эксперименталь з-ды, 1993 тә «ГАРО» АҖ итеп үзгәртелә, 2001 дән хәзерге исемдә. Автотранспортның барлык төрләренә диагностика, ремонт үткәрүдә һәм техник хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган оптик стендлар, гидравлик пресслар, слесарь-монтаж инструментлары һ.б. җитештерә. Пр-тиенең төп җитештерү куәтләре 1961–67 елларда сафка баса, 1970 елларда технол. модернизация уздырыла, 1980 елларда эшләнмәләрнең барлык төрләре яңартыла. 1970–80 елларда з-д үз продукциясен дөньяның 40 иленә, ш.и. Көнчыгыш Европа илләренә, Кытайга һәм Кубага чыгара. Аның эшләнмәләре Венгрия, Канада, Англиядә уздырылган халыкара күргәзмә бүләкләренә лаек була, 1981 дә Чехословакиядәге күргәзмәдә кузов төзәтү инструментлары җыелмасы алтын медаль б-н бүләкләнә. Җитештерүнең төп структурасы автоматлар, тимерчелек-штамплау, механика-җыю цехларыннан гыйбарәт (2001). Пр-тиедә эшләнә торган детальләрне газ б-н кыздыру, электрохимик (гальваник) чыныктыру, эшләнмәләрне цинклауның алдынгы технологияләре кулланыла. Продукциянең күп өлеше нык чыдамлы легирланган корычтан эшләнә. 1996 да токарьлар өчен санлы программа б-н идарә ителә торган кыру станоклары куела, нәтиҗәдә хезмәт җитештерүчәнлеге 2 тапкыр арта. 2002 дә банкротлыкка чыгу нәтиҗәсендә з-д ябыла; аның җитештерү мәйданнарын офис-сәүдә үзәге били. Заводның 5 хезмәткәре «ТССРның атказанган машина төзүчесе» дигән исемгә лаек була. Завод җитәкчеләре — С.П.Феденев (1950–71), И.Е.Кузьменков (1972–86), А.А.Трошин (1986–88), В.А.Кулик (1988–90), Я.А.Бәширов (1990–95), В.В.Мунин (1995–99), В.Л.Чернов (1999 дан).

**ГАРТА́ЛОВКА** посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 35 кеше (татарлар, руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Беренче көннән үк Арча р-ны составында, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-ннарында. Халык саны: 1938 дә — 88, 1949 да — 77, 1958 дә — 67, 1970 тә — 49, 1979 да — 28, 1989 да — 18, 2002 дә — 43 кеше.

**ГА́РТНЫЙ** Тишка (Жилунович Дмитрий Фёдорович) (4.11.1887, хәзерге Белоруссия Респ-касының Копыль ш. — 11.4.1937), Белоруссия ССР дәүләт эшлеклесе, язучы, Белоруссия ФАнең хакыйкый әгъзасы (1928). Польша-Литва татарларыннан. 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша. Окт. рев-циясеннән соң Белоруссия милли комис-ты секретаре, «Дзянница» г-тасы мөхәррире. 1919 ның гыйнварыннан Совет Белоруссиясенең Вакытлы революцион хөкүмәтен җитәкли, соңрак 14 нче армиянең һәм Көнбатыш фронт штабының сәяси хезмәткәре. Аннары Белоруссия ССР дәүләт нәшриятына җитәкчелек итә, Мәгариф халык комис-тында һәм Белоруссия ФАнең Тарих ин-тында эшли. Әдәби эшчәнлеге 1909 да башлана; 1913 тә «Җырлар» («Песни») дип аталган җыентыгы басылып чыга. Рев-циягә кадәрге белорус әдәбиятында беренчеләрдән булып эшчеләр сыйныфы тематикасына мөрәҗәгать итә, аларның тормышы турында берничә очерклар җыентыгы бастыра. Әсәрләренең бер өлешендә Окт. рев-циясе вакыйгалары чагылыш таба. «Дулкыннарда йомычкалар» («Щепки на волнах», 1924) һәм «Аллея» (1924) дип аталган хикәяләр җыентыгында, «Перегуды» (1935) романында белорус авылының Совет хакимияте урнашканнан соңгы чорындагы һәм күмәкләштерү елларындагы тормышы бәян ителә. Репрессияләр корбаны.

Ә с ә р.: Coкi цаліны: В 2 т. Минск, 1957–58; Вершы. Минск, 1967; Насустрач сонцу. Минск, 1978.

*Әд.:* К л а ч к о А. Цішка Гартны. Минск, 1961; Белорусская ССР: Краткая энцикл. Минск, 1982. Т. 5.

**ГАРУ́З** (гарәп. عروض), гарәп классик поэзиясендә барлыкка килгән метрик системадагы шигырь төзелеше. Гарәп, фарсы һәм төрки телле поэзияләрдә кулланыла. Гарәп фонетикасы кануннары буенча сүзләрдә озын һәм кыска иҗекләрнең аерым бер тәртиптә чиратлашу үзенчәлегенә нигезләнгән. Теоретик яктан нигезләүчесе — гарәп галиме Хәлил ибне Әхмәд (700–786). Г.ның төп үлчәмнәре бәхер дип атала. Алар барлыгы унтугыз: тавил, мәдид, басыйт, камил, вафир, һәзаҗ, рәҗәз, рәмәл, сәригъ, мөнсәрих, хәфиф, мозаригъ, мокътәзаб, моҗтас, мөтәкәриб, мөтәдарикъ, җәдид, кәриб, мөшакил. Һәр бәхер үзе берничә төрдәге вәзенгә ия. Төрки телле шагыйрьләр Г. системасын үз телләре хасиятләренә буйсындырып кулланалар: аларда сонор тартык (р, л, м, н) һәм чыжылдавык тартык (ч, ж, ш,) авазларга беткән иҗекләрдән кала барлык ябык иҗекләр озын иҗекләр булып санала, ә сузык авазларга беткән иҗекләр, буыннын, ритм калыбының (тәфагыйльнең) кайсы урынында килүенә карап, йә озын, йә кыска иҗекләр булып саналырга хаклы. Татар телендә сузык авазлар озынга-кыскага бүленмиләр, шунлыктан иҗекнең озынлыгы-кыскалыгы сүзнең язылышы б-н түгел, ә чынлыкта яңгырашы, сүзләр тезмәсендәге ритмик әйтелеше б-н аерымлана. Мәс.:

Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.

Беренче юлдагы башлангыч ике сүз телдән кычкырып укыганда баш-лый-га-ле рәвешендә яңгырый, ягъни вәзен калыбының «фагыйләтен» (- U--) схемасына туры килә. Тулаем поэманың (Г.Тукай, «Печән базары ...») вәзене, ритмик төзелеше — рәмәле мөсәддәси мәхзуф калыбына (- U---U---U-) тәңгәл (фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт). Татар шагыйрьләре Г.ның, нигездә, ике бәхер үлчәмен — һәҗәз б-н рәмәл вәзенен кулланалар. Мәс., «Кисекбаш китабы»нда, Утыз Имәни, Г.Тукай һ.б. шагыйрьләрнең иҗатларында бу ике бәхернең тулы яки кыскартылган шәкелдә әлеге ике вәзене ешрак очрый.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. К., 1984; Т а б р з В. Джам-и мухтасар. Трактат о поэтике. М., 1959; Х а м р а е в М.К. Основы тюркского стихосложения. А.-А., 1963; Ф р о л о в Д.В. Классический арабский стих. История и теория аруда. М., 1991.

*Х.Р.Курбатов.*



Т. Гартный.



Ф.Ә. Гаскәров.

**ГАСКӘ́РОВ** Диләүр Вагыйз улы (3.12.1936, БАССРның Баймак ш.), автоматлаштырылган идарә итү системалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), проф. (1985). 1961 елда Ленинград электроника ин-тын тәмамлый. 1963 елга кадәр Ленинград электрофизика аппаратуралары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1983 кә кадәр Ленинград электротехника ин-тында. 1983 тән Ленинград су транспорты ин-тында (хәзерге С.-Петербург су коммуникацияләре ун-ты) каф. мөдире. Хезмәтләре автоматлаштырылган контроль һәм идарә итү системаларына, фаразлар теориясе һәм практикасына, технологик процессларны техник диагнозлауга һәм оптимальләштерүгә карый. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Диагностика судовой автономики методами планирования эксперимента. Л., 1978; Оптимизация технологических процессов в производстве электронных приборов. М., 1987; Интеллектуальные информационные системы. М., 2003.

**ГАСКӘ́РОВ** Фәйзи Әдһәм улы (8.10.1912, Уфа, кайбер чыганакларда — Бөре ш. — 18.6.1984, Уфа), балетмейстер, педагог, БАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944, 1956). Башкорт һәм татар биюләрен сәхнәгә куючы классик. Мәскәү хореография уч-щесен тәмамлый (1932). 1932–34 елларда Башкорт театр техникумында бию укытучысы, бер үк вакытта Рус-башкорт драма театрында (Уфа) артист һәм биюләрне сәхнәгә куючы. 1934–37 дә Ленинград хореография уч-щесендә укый, шул ук елларда Уфада аның инициативасы б-н тупланган Башкорт балет студиясе кураторы була. 1937–38 дә СССР Дәүләт бию ансамбле (Мәскәү) балетмейстеры И.Моисеевның ассистенты һәм бию төркеме артисты. 1938 дә БАССР Дәүләт бию ансамблен оештыра, аның сәнгать җитәкчесе була һәм 1940–42 дә Башкорт опера һәм балет театрында баш балетмейстер. 1942–43 тә Башкорт кавалерия дивизиясендә үзешчән сәнгать җитәкчесе.



И. Гаспринский.



С.Н. Гассар.

1944–50 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамбле балетмейстеры, бер үк вакытта 1947–49 да Татар опера һәм балет театры баш балетмейстеры, сәхнәдә «Зөһрә» (Н.Җиһанов, 1946), «Коппелия» (Л.Делиб, 1948), «Доктор Айболит» (И.Морозов, 1949) балетларын куя. 1950 дән соң Уфа шәһәрендә яши башлый, Казанга махсус килгәләп, ТАССР Җыр һәм бию ансамблендә һәм Г.Камал исем. Татар акад. театрында биюләр куя. Татар опера һәм балет театрында «Шома бас», «Су буенда», «Басмада бию», «Җизнәкәй», «Чалгычылар биюе» һ.б. биюләрне сәхнәләштерә. Фантазиягә искиткеч бай, образларны үтә нык тоемлап, биюләрне югары проф. дәрәҗәдә кую сәләтенә, көчле иҗади интуициягә ия балетмейстер. Татар бию сюжеты жанры үсешенә зур йогынты ясый. БАССРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1967), «Почет билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г о р ш к о в В. Поэт народного танца Файзи Гаскаров // Татарские танцы. К., 2002.

*В.Н.Горшков.*

**ГАСПРИ́НСКАЯ ЙОСЫФБӘЙЛЕ́** (Гаспралы-Йосыфбәйле) Шәфика (21.11.1886, Бакчасарай ш. — 31.8.1975, Истанбул ш.), журналист, педагог. И.*Гаспринский* б-н З.*Акчурина* кызы. 1907 елдан «*Галәме Нисван*» ж-лы мөхәррире. «*Тәрҗеман*» г-тасын нәшер итүдә катнаша. 1917 нең апрелендә Бөтенроссия мөселман хатын-кызлар корылтае депутаты сыйфатында Казанга килә. 1918 дә Акмәчет (Симферополь) шәһәрендә Гаспринский исем. кызлар мәктәбен оештыра. 1919 да Кырым Милли мәҗлесенә депутат итеп сайлана. 1921 елда Төркиягә күчеп китә. «Kırım» («Кырым»), «Emet» («Өмет») һ.б. төрек ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә. Актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара, «Kırım Milli Merkezi» («Кырым Милли мәркәзе»), «Azerbaycan Milli Merkezi» («Әзәрбайҗан Милли мәркәзе») җәмгыятьләре эшендә катнаша.

*Әд.:* Ү т ә б а й - К ә р и м и Р. Шәфика Гаспралы-Йосыфбәйле турында // әд-Дин вә әл-әдәп. 2000. Май; Hablemitoğlu Ş., Hablemitoğlu N. Şefika Gaspıralı ve Rusya'da Türk Kadin Hareketi (1893–1920). Ankara, 1998.

*А.М.Ахунов.*

**ГАСПРИ́НСКИЙ** (Гаспралы) Исмәгыйль Мостафа улы (8.3.1851, Кырым, Хуҗакөй а. — 11.9.1914, Бакчасарай ш.), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог, нашир. Урта хәлле морза-прапорщик гаиләсендә туа. Бакчасарай шәһәре мәдрәсәсендә, Акмәчет (хәзерге Симферополь) гимназиясендә, Воронеж кадетлар корпусында белем ала. 1865–67 елларда Мәскәүдә күренекле славянофил М.Н.Катков гаиләсендә яши. 1867 дән Кырымда Бакчасарайның «*Зынҗырлы*» мәдрәсәсендә рус теле укыта. 1871 дән Парижда Сорбонна ун-тында укый, реклама агентлыгында тәрҗемәче булып эшли, И.С.Тургеневның сәркәтибе була. Француз либераллары б-н якыная, «Европа цивилизациясенә риясыз караш» (Бакчасарай, 1885) дигән хезмәтен яза, анда ул Көнбатышның колониаль бәйлелегеннән Шәрекънең котылу юлларын эзли. 1874–75 тә Истанбулда яши, Петербург, Мәскәү, Одесса газеталарына хәбәрләр җибәреп тора, яшь төрекләр хәрәкәте эшлеклеләре б-н аралаша, ислам ислахы идеологы әл-Әфгани фикерләре йогынтысында була. 1876 да Кырымга кайтып мөгаллимлек итә. 1878 дә Бакчасарай шәһәре башлыгы итеп сайлана. Россия газеталары б-н языша, әдәбият һәм сәясәт мәсьәләләренә кагылышлы мәкаләләр җыентыгы бастыра. «Таврида» г-тасы (Акмәчет), башлыча, Кырым татарлары телендәге башка басмалар б-н хезмәттәшлек итә. 1883 тә Россиядә төрки телдәге беренче газета — «*Тәрҗеман*»ны нәшер итә башлый. Аның сәхифәләрендә Г. «телдә, фикердә вә эштә берлек» нигезендә Россиядәге барлык төрки халыкларны берләштерү идеясен күтәрә. Мәгърифәт — мөселманнарның алгарышы өчен кирәкле беренче шарт, дигән фикерне алга сөрә һәм бөтен көчен яңа, җәдит мәктәпләре һәм мәдрәсәләре оештыруга юнәлтә. 1884 тә үзе ачкан мәдрәсәдә гарәп әлифбасын яңа ысул б-н укыта башлый, уку программасына дөньяви фәннәрне кертә, шунлыктан әлеге программа Россиянең башка җәдит мәктәпләре өчен үрнәк булып тора. Г. ш.у. наширлек эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, Бакчасарайда Коръән бастыру эшен җайга сала. Россия өчен Иран һәм Төркия б-н дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру мөһим, дип саный. 1904 тә Г. Бакчасарайда китап басучыларның Россиядә беренче һөнәри берлеген оештыра. 1905–07 дәге рев-ция елларында Кырым крәстияннәре корылтайларын оештыручыларның берсе. Бөтенроссия мөселманнарының 1, 2, 3 нче корылтайларында катнаша; 2 нче корылтайда «сыйнфый ызгышлар»га каршы чыга, «мөселманнарның мәдәни үсешен тәэмин итү»не яклый, 3 нче корылтайда «*Иттифакъ әл-Мөслимин*» фиркасенең президиумы һәм ҮК әгъзасы итеп сайлана. Фирка фәкать мәдәният һәм дин мәсьәләләре б-н шөгыльләнергә, сәясәткә катнашмаска тиеш, дигән фикердә тора. 1906 да кырымтатар телендә хатын-кызлар өчен «*Галәме нисван*» ж-лын чыгара. 1910 да Парижның «La Revue du Monde Musulman» («Мөселман дөньясы») журналы Г.ны Нобель премиясенә тәкъдим итә.

Х е з м.: Русское мусульманство. Мысли, заметки и наблюдения мусульманина. Симферополь, 1881; Русско-восточное соглашение. Мысли, заметки и пожелания И.Гаспринского. Бахчисарай. 1896; Из наследия. Симферополь, 1991.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Төрки-татар мәгърифәтчелек тарихында Исмәгыйль Гаспралы: бер идеянең тантанасы һәм фаҗигасе // Казан утлары. 2001. № 3; К у р к ч и Л.И. Исмаил-бей Гаспринский // Дружба народов. 1991. № 12; Ч е р в о н н а я С.И. Идея национального согласия в сочинениях Исмаила Гаспринского // Отечественная история. 1992. № 2; Б е н н и г с е н А. Исмаил бей Гаспринский (Гаспралы) и происхождение джадидовского движения в России // Россия и Восток: Русское мусульманство. Русско-восточное соглашение. К., 1993; Г а н к е в и ч В. На службе правде и просвещению. Симферополь. 2000; Yuz Yilda Gaspiralinin Idealleri. Jst. 2001.

**«әл-ГАСРЕЛҖӘДИ́Д»** («العصر الجديد» — «Яңа гасыр»), айлык сәяси һәм әдәби журнал. 1905 елдан Җаек (Уральск) шәһәрендә татар телендә кульязма рәвешендә тарала; 1906 елның 15 гыйнварыннан 1907 нең 20 маена кадәр басма рәвештә нәшер ителә, барлыгы 17 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — К.Мотыйгый, аннан соң М.Гобәйдуллин, В.Хәмидуллин. Журналда Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Р.Фәхретдин, М.Бигиев, Г.Исхакый һ.б. әдипләр языша, әдәби-нәфис әсәрләргә күп урын бирелә, аның битләрендә Г.Тукайның беренче шигырьләре дөнья күрә. «ә-Г.» нең матур әдәбият бүлегендә лирик, драма, проза (күбесенчә хикәяләр) әсәрләре басыла. Редакция иң яхшы сәхнә әсәрләренә конкурслар уздыра, авторларга махсус бүләкләр билгели. Журнал А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, Л.Н.Толстой кебек рус классиклары әсәрләренең тәрҗемәләренә, иҗтимагый-сәяси һәм икътисади характердагы материалларга да урын бирә. 1907 нең февралендә К.Мотыйгый наширлек һәм мөхәррирлек хокукыннан мәхрүм ителә, журнал чыгымын финанслау М.Гобәйдуллинга күчә һәм тиздән ул аны яба.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты: (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX в. К., 1983.

*А.М.Ахунов.*

**ГАСРЫ́Й** Нәҗип (псевд., чын исем-фамилиясе Мәүләмбирдиев Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы) (1886, Әстерхан губ. Казый а. — 1937), әдәбият тәнкыйтьчесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар әдәбияты укыта. «Ил», «Идел», «Йолдыз» ж-лларында басылган, 20 йөз башы татар әдәбияты һәм татар әдәби теле мәсьәләләренә багышланган, Г.Тукай, М.Акъегетзадә, Г.Ибраһимов, Гыйффәт Туташ иҗатларына караган күпсанлы мәкаләләр авторы.

**ГАССА́Р** Сергей Николаевич (5.5.1877, Казан — 1918), революцион хәрәкәттә катнашучы. 1900–04 елларда Казан ун-тында укый. 1903 тә революцион хәрәкәткә тартыла, Алафузов һәм бертуган Крестовниковлар з-длары эшчеләре арасында сәяси эш алып бара. Берничә тапкыр кулга алына. 1906 да Сембер шәһәренә сөрелә. Революцион эшчәнлеген Чистай шәһәрендә һәм Бондюг химия з-дында дәвам иттерә. Уфа губернасы Минзәлә өязендә һәм Чаллы авылында Совет хакимиятен урнаштыру өчен барган көрәшне җитәкләүчеләрнең берсе. Алабуга Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының беренче рәисе (1918), соңрак Казанда төзелеш эшчеләре һөнәри берлеге секретаре булып эшли. 1918 нең августында Казанны Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясе гаскәрләре алганда әсирлеккә төшә һәм атып үтерелә.

*Әд.:* В о л к о в Р., К а ш и н С. Гассар Сергей Николаевич // Борцы за счастье народное. К., 1967. Кн. 2. *Р.К.Вәлиев.*

**ГАСТЕ́РИЯ** (Gasteria), лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Суккулент. 70 ләп төре билгеле. Чыгышы — Көньяк-Көнбатыш Африка. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Аеруча 2 төре киң таралган: сөялле Г. (G. verrucosa) һәм тимгелле Г. (G. makulata). Сабагы кыска. Яфракларының озынлыгы 30 *см* чамасы, итләч, тар өчпочмак рәвешендә, улаксыман, каты, ак таплы яки сөялле, ике рәткә тезелгән, куе таралгыга җыелган. Чәчәкләре тар, көпшәсыман, 1–2 *см* озынлыкта, алсу төстә, тәлгәшләнеп яки себеркәчкә җыелган, озын нечкә сабакта. Г. орлыклардан, вак суганчалардан һәм яфрак сабакчыкларыннан үрчетелә. Яктылык яратучан үсемлек.

**ГАСУ́ЛЬ** Рувим Яковлевич (27.6.1889, Витебск губ. Ружица ш. — 1976, Запорожье ш., Украина), рентгенолог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1932). Берлин ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1921), шунда ук эшли. 1923 елдан Ленинград рентгенология һәм радиология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1927 дән Казан ГИДУВында, 1938 дән Воронеж мед. ин-тында рентгенология каф. мөдире. 1943 тән Киев радиология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1945–71 дә Одесса һәм Запорожье мед. ин-тларында рентгенология каф. мөдире. Казан ГИДУВында рентгенология кафедрасын һәм Казан рентгенологлар һәм радиологлар җәмгыятен оештыручыларның берсе (1927). Хезмәтләре кеше һәм хайваннар үпкәсе туберкулёзын дәвалауда рентген, кояш һәм ультрашәмәхә нурлар тәэсирен ачыклауга карый; беренче булып ротацион рентгенотерапия ысулын тәкъдим итә. Р. беренче совет томографын төзүдә катнаша, шуның өчен аңа атаклы немец микробиологы Роберт Кох исем. халыкара бүләк бирелә (1920). Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Х е з м.: Основы рентгенодиагностики и терапии туберкулёза лучистой энергией. Л., 1925; Ошибки диагностики лёгочного туберкулёза. Л., 1930.

**ГАСЫ́ЙМОВ** Мәхмүт Моталлип улы (27.7.1945, Кемерово өлкәсе Ленинск-Кузнецкий ш.), сынчы. ТРның атказ. сәгать эшлеклесе (2008). Ташкент сынлы сәнгать уч-щесен (1965; 1974–83 елларда шунда сынлы сәнгать фәнен укыта) һәм Ташкент театр-сәнгать ин-тын (1974) тәмамлый. Ф.И.Грищенко, Ю.Н.Киселёв, К.А.Сәлахетдинов шәкерте. 1978–79 да СССР Сәнгать академиясе каршындагы И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тының сынчылык остаханәсендә стажировка уза. «Үзбәкфильм» киностудиясендә рәссам булып эшли (1968–69). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). 1999 дан Казанда яши. Станлы, монументаль, монументаль-декоратив һәм мемориаль пластика жанрларында эшли. Казанда, Үзбәкстанда, Владивосток һәм Чита шәһәрләрендә галимнәргә, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә куелган



М.М.Г а с ы й м о в. «Хуҗа Насретдин». 1993.

һәйкәлләр, бюстлар һәм портретлар, ш.у. истәлек такталары авторы.

Г. — станлы портрет остасы. Аның әсәрләренә сурәтләү чараларының индивидуальлеге, реализм мәктәбе традицияләренә таяну, геройның портрет охшашлыгына ирешүгә, аның рухи-әхлакый йөзен чагылдыруга аерым игътибар бирү хас. Сыннарның бербөтен гомумиләштерелгән формасы портрет герое сурәтенең барлык нечкәлекләрен бирүче детальләр, гипс һәм мәрмәр форманы модельләү б-н бәйле. Агачтан (япон сәрвие) эшләнгән композицияләрдә декоративлыкка ирешү өчен Г. табигый текстура куллана. Сурәтләү чараларын сайлаганда аның иҗат манерасына образны фәкать психологик яктан ачудан алып («Зирәклек. Үзбәк карчыгы портреты», 1976; «Бокс буенча дөнья чемпионы Р.Рискиев», 1979; «Композитор Мохтар Әшрәфи» 1998; «Рафаил Такташ», 1998) шартлы-декоратив, символик чараларга кадәр («Тагын яз килде» 1985; «Мин-минлек монументы», шамоттан ясалган «Шәрекъ мотивлары» сериясе, 1985–86; «Бәхетле бабай», 1985 һ.б.) булган киң колач хас. Г. — монументаль скульптура өлкәсендә: Әкмәл Икъврамов һәйкәле (гранит, 1989) һәм Алай базары мәйданында куелган өч хатын-кыз сыныннан гыйбарәт «Уңдырышлылык» композициясе рәвешендәге фонтан (бронза, 1993; икесе дә Ташкентта), Үзбәкстанның Гиждуван р-ны Соктари посёлогында куелган С.Айни һәйкәле (бетон, 1978), ш.у. Казанда Б.Урманче һәйкәле (бронза, 1997), Салих Сәйдәшев һәйкәле (бронза, 2005) һ.б.; монументаль бизәлеш скульптурасы өлкәсендә: бакырны чүкеп ясау техникасы б-н башкарылган — «Музалар» рельефы (Беговат ш. мәдәният сарае фасадында, 1977), Кисловодск шәһәрендәге «Үзбәкстан» шифаханәсенең сәламәтләндерү комплексы интерьерларындагы рельефлар һ.б. Казанда М.Е.Евсевьев каберенә куелган истәлек (бетон, 2001), Х.Бигичев (1998), С.Сәйдәшев (2000), Н.Җиһанов (2001) истәлегенә куелган мемориаль такталар; бронзадан, таштан, агачтан, шамоттан эшләнгән Н.Исәнбәт (1996), С.Сәйдәшев (1998), Н.Җиһанов (2000), С.Хәкимнең (2001) станлы бюстлары авторы.

1973 елдан республика, төбәк («Урта Азия республикалары һәм Казакъстан скульптуралары күргәзмәсе», Ташкент, 1982 һ.б.), бөтенсоюз («Җир һәм кешеләр», Мәскәү, 1979 һ.б.) күргәзмәләрендә, халыкара (Финляндиядә һәм Швециядә «Үзбәкстан мәдәнияте көннәре», 1970 еллар) һ.б.күргәзмәләрдә катнаша. Әсәрләре Үзбәкстанның Дәүләт сәнгать музеенда (Ташкент ш.), Хәзерге заман сәнгате музеенда (Үргәнеч ш., Үзбәкстан), шәхси коллекцияләрдә (АКШ, Германия һ.б. илләр) саклана.

*Әд.:* Справочник Союза художников СССР. М., 1989. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*





М.М.Г а с ы й м о в.
1. «Рафаил Такташ». Бронза. 1998;
2. «Мәрҗани». Төс бирелгән гипс. 1998.

**«ГАСЫ́Р»**, Казандагы нәширлек һәм сәүдә итү ширкәте. 1907 елда, нәшрият буларак, Ә.*Хәсәни* тарафыннан оештырыла, 1908 дә «Ә.Хәсәни һәм Кº» ширкәте, 1909 да «Гасыр» дип үзгәртелә. Эшчәнлегенең төп юнәлеше — татарларны рус, гарәп, татар әдәбияты үрнәкләре б-н таныштыру. Матур әдәбият, балалар әдәбияты, мед. китаплары, фәнни-популяр әдәбият бастырыла. Матур әдәбият, нигездә, татар язучылары: Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан һ.б.ның чәчмә әсәрләре (27 исемдә), А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.С.Тургенев иҗатыннан тәрҗемәләр, 1917 гә кадәр татар теленә бердәнбер тәрҗемә ителгән әсәр — М.Горькийның «Ике мужик» («Два мужика», С.Рахманкулов тәрж., 1909) хикәясе мисалында тәкъдим ителә. Драма әсәрләреннән А.С.Пушкинның «Борис Годунов»ы, Ф.Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт»е («Коварство и любовь») тәрҗемәдә басылып чыга. Басмаларның күпчелеген татар драматургиясе классиклары Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим, Г.Коләхмәтов һ.б.ның әсәрләре тәш-

кил итә. Медицина әдәбиятыннан рус авторларының педиатрия, гигиена, ашыгыч мед. ярдәме күрсәтүгә караган хезмәтләре тәрҗемә ителеп бастырыла; ш.у. татар табибе Г.Күгешевнең «Рәсемле санитария һәм гигиена дәресләре» («Рәсемле хыйфыз сыйхәт дәресләре») хезмәте дөнья күрә. Фәнни-популяр әдәбият өлкәсеннән В.Лункевичның «Күк һәм йолдызлар» («Небо и звёзды»), «Җир» («Земля»), В.О.Горнның «Тимер юлны кем уйлап чыгарган» («Кто придумал железную дорогу»), Н.Рубакинның «Телләр тарихы» («История языков») хезмәтләре, татар галиме И.Хәмидовның «Терлекчелек гыйлеме хакында» («Гыйлем хайванат») дигән китабы басылып чыга. Мәктәп дәреслекләре һәм ярдәмлекләр дөнья күрә. Г.Ибраһимовның татар теленең морфологиясе, синтаксисы һәм орфографиясе буенча дәреслекләре, мәктәпләр өчен «Системага салынган уку китабы» («Мөнтәзәм кыйраәт китабы») дигән популяр энциклопедия (төз. С.Рахманкулов), Х.Әбүзәровның «Уку китабы», С.Рахманкулов һәм Г.Кәрам төзегән «Рус теленә чит телләрдән кергән сүзләрнең грамматик үзенчәлекләре һәм басымнары күрсәтелгән тулы русча-татарча сүзлек» («Полный русско-татарский словарь с указанием ударений и грамматических свойств слов с включением иностранных слов, вошедших в русский язык»), ш.у. фольклорчы Х.Габделбәдыйговның (Х.Бәдыйгинның) хезмәтләре һ.б. нәшер ителә.

20 йөз башында «Г.» татар нәшриятлары арасында беренче булып татар язучылары һәм артистларының сурәтләре төшерелгән почта открыткалары чыгара. Нәшрият 1921 дә ябыла. Нашир үзе һәм аның даирәсендәге хезмәткәрләр «Яңа китап» кооператив нәшриятын оештыралар (1926). «Г.» үз эшчәнлеге дәверендә уртача 4 меңнән артык данә тираж б-н 153 исемдә барлыгы 437500 данә китап бастырып чыгара. Үз полиграфия базасы булмаганлыктан, нәшрият китапларны, асылда, И.Н.Харитонов басмаханәсендә бастыра. 1913 тә нәшрият каршындагы китап кибетенә куелган 700 гә якын исемдәге китапларның 100 гә якыны «Г.» нәшриятында чыгарылган була.

Китап репертуарының байлыгы, югары полиграфик, сәнгатьлелек, наширлек сыйфаты, авторларга һәм тәрҗемәчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт нәтиҗәсендә «Г.» нәшрияты 20 йөз башында Казандагы татар нәшриятлары арасында әйдәп баручылардан санала. Ә.Хәсәнинең үзенең нашир булуы һәм тәрҗемәчеләр (Г.Ибраһимов, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, Г.Рәхим һ.б.) б-н хезмәттәшлек итүе сәбәпле, нәшрият эшчәнлеге шул чор таләпләренә җавап бирә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Книги и люди. К., 1985.

**«ГАСЫРЛА́Р АВАЗЫ́ – Э́ХО ВЕКО́В»**, тарихи-документаль юнәлештәге рәсемле журнал. «Записки Центрального архива Татарской Сов. Соц. республики» ж-лының дәвамчысы. Оештыручылары — ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе, «Казан Кремле» тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы, ТР Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгы, «Казан» милли мәдәният үзәге. 1995 елның маеннан Казанда рус һәм татар телләрендә нәшер ителә. Баш мөхәррире Д.Р.*Шәрәфетдинов*. Төп эчтәлеген ТР, РФ архивлары документлары, якын һәм ерак чит илләрдән, бигрәк тә Урта Азия һәм Төркиядән алынган материаллар, аларның шәрехләре тәшкил итә. Документлар журналда төп нөсхә телендә басыла. Төп рубрикалары: «Милли-мәдәни яңарыш юлында», «Гасырлар төбеннән», «20 гасыр: тарих сәхифәләре», «Шаһитлыклар. Мемуарлар», «Язмышларда һәм документларда заман», «Шәхси архив», «Фикерләр. Хөкемнәр. Фаразлар», «Яңа басмалар. Бәяләмәләр һәм рецензияләр», «Мәгълүмат. Хроника». Журнал тарих, археология, этнография, сәнгать, әдәбият, фән һәм дин тарихы (беренче чиратта Идел-Урал төбәгендә), ш.у. ТРда архив һәм музейлар эшенә караган мәсьәләләрне яктырта. Татарстанның




дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, дворяннар, сәүдәгәрләр, рев-циягә кадәрге интеллигенция вәкилләре эшчәнлегенә багышланган тарихи-биографик материалларга зур урын бирә. Журнал редакциясе кушымта китаплар да бастыра.

**ГАТА́ЕВ** Валерий Закир улы (16.9.1938, Казан), драма актёры, РСФСРның халык артисты (1986). Казан Зур драма театры каршындагы студияне (1961) һәм МХАТның мәктәп-студиясен Г.А.Георгиевский классы буенча тәмамлый (1966). Ульянов драма (1961–62), Ленин комсомолы исем. Ленинград (1969–70), А.С.Пушкин исем. Мәскәү драма (1970–71), Калинин драма (1962–69, 1971–87) театрларында эшли. 1987 елдан М.Горький исем. МХАТ сәхнәсендә. Паратов, Окаёмов, Беркутов, Мамаев («Бирнәсез кыз», «Чибәр ир кеше», «Бүреләр һәм сарыклар», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Андрей, Чебутыкин, Яша, Лопахин («Өч сеңел», «Чия бакчасы», А.П.Чехов), Ноздрёв («Үле җаннар», Н.В.Гоголь әсәре буенча), Цыганов («Варварлар», М.Горький), Банко, 1 нче кабер казучы («Макбет», «Гамлет», У.Шекспир), Поза, Лестер («Дон Карлос», «Мария Стюарт», Ф.Шиллер), Ричард («Барысы да бакчада», Э.Олби), Агностос («Эзоп», Г.Фигейреду), Прохор Громов («Миллионщик», В.Я.Шишковның «Хәсрәт дәрьясы» романы буенча), Брюханов («Синең исемең», П.Л.Проскурин) кебек шактый күп күренекле рольләрдә уйный. Кинодагы рольләре: Фрол Курганов («Күләгәләр көн үзәгендә югала», 1972), Котовский («Соңгы гайдук», 1973), Георгий Седов (шул исем. фильм, 1975), Шарков («Икебезгә бер шанс», 1999) һ.б. Актёрның сәхнә һәм экраннардагы күпчелек эшләре геройларның психологиясенә тирән үтеп керү, аларның тышкы кыяфәтләрен һәм үз-үзләрен тотышларын чын тормыштагыча бирү, сәхнәдә яшәешләренең табигыйлеге, үзе тудырган образның социаль һәм идея эчтәлегенә төгәл туры килүе б-н аерылып торалар. «Дуслык» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ефремова В. Поиски сути. М., 1982; Чуйков А. Открыть новую звезду // Театр. жизнь. 1982. № 7.

*А.С.Иванов.*

**ГАТА́У** Макс (Гатауллин Гайнетдин Зәйнетдин улы) (1913, хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән р-ны Тозау а. — 20.11.1941), шагыйрь. 1931–34 елларда балалар йорты директоры, 1934–37 дә Чиләбе шәһәрендәге татар мәктәбендә укыту бүлеге мөдире, 1937–40 та директор. Бер үк вакытта Казан. пед. ин-тында читтән торып укый. Беренче шигырьләрен «Социализм юлы», «Урал большевигы», «Коммунист» г-таларында бастыра. 1939 да «Урал мәхәббәте» исемле беренче шигъри җыентыгы чыга. Аерым шигырьләре «Үсү җыры» (1934), «Очкыннар» (1940) исемле күмәк җыентыкларга кергән. Бөек Ватан сугышында катнаша. Калинин өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Алар сафта. К., 1961.

**ГАТАУЛЛА́ БАЙ ЙОРТЫ́**, к. *Даутов йорты.*

**ГАТАУ́ЛЛИН** Әнвәр Җиһангир улы (23.2.1923, Пермь ш. — 26.8.1994, шунда ук), Сов. Союзы Герое (18.8.1945), гв. подполковнигы. Омскидагы хәрби авиация мәктәбен тәмамлый (1942). 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 99 нчы гв. аерым разведка авиациясе полкында (15 нче һава армиясе) звено командиры. Брянск, 2 нче Балтыйк буе һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре составында Орёл, Брянск (икесе дә 1943), Ленинград-Новгород һәм Рига (икесе дә 1944) һөҗүм операцияләрендә, Курляндия ярымутравында дошман төркемен камап алуда (1945) катнаша. 1944 нең 10 октябрендә Добеле, Ауце (Латвия ССР) шәһәрләре янында дошман оборонасының алгы сызыгын фотога төшерүдә батырлык күрсәтә: яна башлаган самолётын дошманның артиллерия позицияләренә юнәлтә. Сугыштан соң 1955 кә кадәр СССР Хәрби һава көчләрендә хезмәтен дәвам иттерә. Туган шәһәрендәге Я.М.Свердлов исем. моторлар төзү з-дында диспетчер булып эшли. Ике Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, ике



Ә.Җ. Гатауллин.



Р.К.Гатауллин.

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Золотые Звёзды Прикамья. Пермь, 1974; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАТАУ́ЛЛИН** Әхияр Мөгыйн улы (22.12.1935, Оренбург өлкәсенең Абдулин р-ны Иске Шалты а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1980), проф. (1982), РАХФАнең мөхбир әгъзасы (1991), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). 1958 елда К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясенең икътисад ф-тын тәмамлый. 1958–61 елларда Бөтенсоюз а.х.икътисады фәнни-тикшеренү ин-тының терәк пункты мөдире. 1962 дән Мәскәү а.х. академиясендә, 1972 дән икътисади кибернетика каф. мөдире. 1997 дән Россиянең Бәйсез фәнни аграр-икътисад җәмгыяте президенты. Хезмәтләре икътисадта матем. ысулларны һәм модельләштерүне куллану мәсьәләләренә, системалар һәм методология теориясенә, системалы анализга, статистик фаразларны тикшерү теориясенә, агросәнәгать комплексында тармакара һәм төбәкара алмашуда бәяләрнең эквивалентлы проблемаларына карый. Фәнни-техник прогресс барышында җанлы хезмәтне матдиләштерәп алыштыру законын тәгъбирли. Информатика һәм матем. ысуллары кулланып, аграр белем бирү системасын төзи. Г. икътисади-матем. ысуллар һәм кибернетиканың техник чараларын кулланып, аграр икътисад фәнендә информатика буенча фәнни юнәлешне үстерә. Югары уку йортлары һәм техникумнар өчен дәреслекләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Себестоимость и совокупные затраты труда в производстве сельскохозяйственной продукции. М., 1965; Издержки производства сельскохозяйственной продукции — методология измерения и резервы снижения. М., 1983; Основы математической статистики. М., 2002.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ГАТАУ́ЛЛИН** Илгиз Габдулла улы (27.3.1953, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1998). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2004). ТРның атказ. табибе (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. акад-се) эшли, 1998 елдан онкология каф. мөдире. Тикшеренүләре онкопроктология, туры һәм юан эчәк клиникасына, шешләрнең беренчел профилактикасы мәсьәләләренә, онкологиянең экологик аспектларына карый. Г. юан һәм туры эчәктәге яман шеш авыруының һава атмосферасында, туфракта пычраткыч матдәләр (кадмий һәм хром) таралуы б-н турыдан-туры бәйләнеше булуын өйрәнә һәм ачыклап бирә.

Х е з м.: Обоснование и применение димефосфона при остром экспериментальном панкреатите. К., 1986.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Наил Гайнат улы (10.8.1928, БАССРның Дәүләкән р-ны Чуенчы а.), хирург, мед. фән. д-ры (1966), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), БАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1976, 1991). Акад. А.А.*Вишневский*, В.И.Бураковский шәкерте. Башкорт мед. ин-тын (хәзер Башкорт мед. ун-ты) тәмамлый (1951). 1955–58 елларда СССР МФАнең А.В.Вишневский исем. Хирургия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1958 дән Башкорт мед. ин-тында, 1966 дан госпиталь хирургиясе каф. мөдире, проф. (1968). Г. — Башкортстан кардиохирургия үзәгенә нигез салучы һәм аның җитәкчесе, Башкортстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш кардиохирургы. Тикшеренүләре йөрәк-кан тамырлары һәм күкрәк, корсак куышлыгы әгъзалары хирургиясенә карый. Г. бик сирәк ясала торган операция — йөкле хатында үпкә артериясе тромбозы вакытында эмболэктомия операциясен башкара. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар. Г. — үзешчән рәссам. 1998 дә «Н.Гатауллинның тормышы һәм иҗаты» дигән картина һәм портретлар репродукциясе тупланган альбомы нәшер ителә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Послеоперационная спаечная болезнь брюшины. Уфа, 1978; Диагностика и лечение заболеваний большого сальника. Уфа, 1998 (автордаш); Хронический панкреатит. Уфа, 1998.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Равил Гыйбат улы (29.6.1947, БАССРның Эстәрлебаш р-ны Карагош а.), филолог, филол. фән. д-ры (1997), проф. (2000). Башкорт ун-тын тәмамлый (1971). 1973 елдан (бүленеп) Башкорт ун-тында: 1983–90 да һәм 1998 дән немец филол. каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре немец телендә сүз ясалышы системасына һәм фразеологиясенә карый.

Х е з м.: Стилистическое словообразование современного немецкого языка. Уфа, 1986; Перевод стилистически окрашенных и окказиональных словообразовательных конструкций. Уфа, 1995; Lexikographie der deutchen Gegenwartssprache. Ufa, 2000; Praktische Phraseologie der deutschen Gegenwartssprache. Ufa, 2002.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Радион Әхсән улы (23.11.1964, Ташкент), спортчы (җиңел атлетика), СССРның атказ. спорт остасы (1989). Ташкент дәүләт мед. ин-тын тәмамлый (1989). Колга б-н биеклеккә сикерү буенча СССР (1986–87, 1989), АКШ (1989), дөнья (1989, 1993), Европа (1990, 1994), чемпионы, Олимпия уеннарында (1988), Игелекле уеннарда (1986) көмеш, дөнья чемпионатында (1987) бронза медальләр ала. Дөнья рекордчысы (1989). 1990 елдан С.-Петербургта яши.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Рәдиф Кәшфулла улы (псевд. Гаташ) (30.3.1941, БАССРның Кушнаренко р-ны Марс а.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан ун-тын (1964) һәм Мәскәүдә Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (1969) тәмамлый. 1966–71 елларда (бүленеп) Татарстан китап нәшриятында, 1973–74 тә «Ялкын» ж-лы, 1975 тән «Казан утлары» ж-лының шигърият бүлеге мөдире. Шигырьләре 1962 дән басыла башлый. «Гөлләр су сорый» исемле беренче шигъри җыентыгы 1966 да дөнья күрә. «Кояшлы утраулар» (1967), «Ирләр булыйк» (1978), «Чакыру» (1980) җыентыкларына кергән шигырьләренә романтик күтәренкелек, ихласлык, метафоралар байлыгы хас. Г. үз иҗатында лирик геройның күңел дөньясын, аның уй-кичерешләрен тулылыгы б-н ачып бирергә омтыла. Ул хатын-кызның матурлыгына, игелеклелеккә, мәхәббәт һәм тугрылыкка дан җырлый. Татар халкының язмышы, буыннан-буыннарга күчкән тарихи үткәне, рухи күңел байлыгы — Г. лирикасының төп темаларыннан. Г. шигъриятендә рус һәм дөнья әдәбиятлары йогынтысы чагыла. Төрле поэтик формаларда иҗат итсә дә, күбрәк ирекле шигырьгә мөрәҗәгать итә. 1990 еллардан Г. иҗатында классик Шәрекъ шигъриятенең йогынтысы көчәя. Бу чордагы мәхәббәт лирикасы, нигездә, газәлләр һәм робагыйлардан тора («Бу — сиңа кылган догам», 1997 һ.б.). Публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре яза. Шигырьләре рус, башкорт, украин, әзәрбайҗан, каракалпак, латыш, литва, төрек, инглиз, поляк телләренә тәрҗемә ителә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

Ә с ә р.: Мәхәббәткә мәрхәмәт. К., 1987; Гөлләр су сорый: Сайланма лирика. К., 1998; Гамь шәрабы. К., 2001; Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 2009.

*Әд.:* Х ә к и м С. Җырның җире // Халык язмышы — шагыйрь язмышы. К., 1979; Г а л и у л л и н Т. Йокы юк шагыйрьгә // Гомер учагы. К., 1991; Гаташнамә. К., 2009.

*Р.Ә.Мостафин, Х.Й.Миңнегулов.*

**ГАТАУ́ЛЛИН** Ринат Фазлетдин улы (14.6.1953, БАССРның Шаран р-ны Түбән Зәет а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2002). 1975 елда Башкорт дәүләт ун-тының география ф-тын тәмамлый. 1975–77 елларда БАССРның Туймазы р-нындагы Константиновка сигезьеллык мәктәбендә директор булып эшли. 1977 дән СССР ФАнең Башкортстан филиалында: стажер-тикшеренүче, өлкән фәнни хезмәткәр. 1989–90 да Башкорт а.х. ин-тында лаб. мөдире, 1990–91 дә БАССР Госпланы рәисе урынбасары, 1995–99 да БР Дәүләт Җыелышының Закон нар чыгару палатасы рәисе, 1999 дан БРның хезмәт һәм халыкны социаль яклау министры урынбасары. Башкортстан икътисадын тотрыклыландыру, муниципаль һәм дәүләт милкен хосусыйлаштыру программасын, ш.у. респ-ка икътисадын структур үзгәртеп кору программасын эшләүдә катнашучыларның берсе. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше — хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм халыкны социаль яклау. 1990–95 елларда БР ЮС һәм 1995–99 да БР Дәүләт



С.С.Гатауллин.



М.Ә.Гатиятуллин.

Җыелышы депутаты. Парламент оппозициясе лидеры.

Х е з м.: Основные направления реформы социальной сферы села. Уфа, 2001; Построение эффективной системы социальной защиты населения. Уфа, 2003; Формирование экономических основ местного самоуправления. Уфа, 2002.

*Әд.:* Ученые-экономисты Башкортостана. Уфа, 2000.

**ГАТАУ́ЛЛИН** Самат Сәмигулла улы (10.7.1929, Бөгелмә кантоны Югары Мактама а.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1981). Хезмәт эшчәнлеген 1945 елда Әлмәт р-нының «Марс» к-зында башлый. 1953–98 елларда «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» нефть промыселлары идарәсендә нефть һәм газ чыгару операторы, скважиналарны капиталь һәм җир асты ремонтлау цехында мастер, өлкән мастер. Г. җитәкчелегендә бригада беренче тапкыр «Азинмаш-37А» югары җитештерүчән күтәртү агрегатларын үзләштерә һәм гамәлгә кертә, насослар җайланмаларының эштән чыгу сәбәбен ачыклаучы яңа система һәм скважиналар эксплуатацияләүне механикалаштырганда контактлы тикшерү ысулы куллана, скважиналардан торбаларны кабель б-н күтәргәндә күп хезмәт таләп итәлә торган процессларны механикалаштыра. Герой исеме җитештерүдәге зур казанышлары, 10 нчы бишьеллык планын һәм соц. йөкләмәләрне вакытыннан алда үтәгәне, хезмәттә батырлык күрсәткәне өчен бирелә. 1974–79 елларда СССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, СССР Халык казанышлары күргәзмәсенең алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәрендәге Геройлар аллеясында бюсты куелган.

*Әд.:* М а н а с ы п о в Ф. Гатауллин Самат Самигуллович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Л а р и ч е в а Э.П. Дороже золота. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГАТИ́ЛОВ** Юрий Фёдорович (28.9.1935, Арзамас өлкәсенең Чернуха р-ны Чернуха а. — 6.3.1988, Түбән Новгород ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1972), проф. (1972). 1959 елда Горький ун-тын тәмамлагач, СССР ФАнең Органик химия ин-тында (Казан) эшли. 1964 тән Казан пед. ин-тында, 1966–73 тә химия каф. мөдире. 1973 тән Горький а.х. ин-тында шул ук исемдәге каф. мөдире. Хезмәтләре мышьяклы органик кушылмалар химиясенә карый. Г. дүртенчел асимметрик арсоний кушылмаларын синтезлый һәм тикшерә. Өченчел арсин сульфидларының карбон кислоталарының галогенангидридлары тәэсирендә тиоарсин кислоталары эфирларына төркемләнү механизмын ача.

Х е з м.: О разделении асимметричных арсониевых соединений на оптически активные антиподы // Докл. АН СССР. 1961. № 137 (автордаш); О механизме перегруппировки диалкиларилсульфидов мышьяка // Журн. общей химии. 1971. № 41; Перегруппировка окисей третичных арсинов // Журн. общей химии. 1972. № 42.

**ГА́ТИН** Фоат Әгъръф улы (10.9.1966, Казан), спортчы (бокс), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1990). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1991). Танылган тренер С.М.Ромодановский шәкерте. СССР (1983, 1990), Россия (1992) чемпионатларында, БДБ-АКШ командалары очрашуында (1992) җиңүче. СССР кубогы иясе (1987). СССР (көмеш, 1984), Европа (көмеш, 1991) чемпионатларында, Игелекле уеннарда (бронза 1990) медальләр ала. Рингта 209 (183 ендә җиңә), ш.и. 32 халыкара (26 сында җиңә) очрашу үткәрә.

**ГА́ТИН** Фуат Фәттах улы (12.6.1959, Чирмешән р-ны Яңа Кади а.), психиатр, мед. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. табибе (2003). 1982 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, ординатурада укый. 1984 тән Яшел Үзән р-ны Васильево шифаханәсендә уролог. 1985 тән Яшел Үзән р-ны үзәк район шифаханәсендә урология бүлеге мөдире. 1987 дән Васильево җирле мед. берләшмәсенең баш табиб урынбасары, 1988 дән баш табиб. 1999 дан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының В.М.Бехтерев исем. Республика клиник психиатрия шифаханәсе баш табибе. Хезмәтләре психатрия өлкәсендә халыкның саулыгын тәэмин итүне оештыруга карый. РФ сәламәтлек саклау отличнигы. РФ сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Здоровье сельского населения. Психическое здоровье. Моделирование и управление. К., 2002 (автордаш); Клинико-статистические особенности развития основных психических и поведенческих растройств в Республике Татарстан. К., 2004; Математическое моделирование в исследовании психических и поведенческих расстройств. К., 2004; Алгоритм диагностики и терапии соматоформных расстройств. К., 2008 (автордаш).

**ГА́ТИНА** Роза Фатих кызы (1.3.1953, Таҗикстан ССР Гармск р-ны), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1994), проф. (1998). 1974 елда Таҗик ун-тын тәмамлый (Дүшәмбе). 1978–96 елларда Таҗикстан Респ-касы ФАнең Химия ин-тында, 1993 тән Эксперименталь з-д директоры. 1996–2000 елларда Көньяк Казакъстан ун-тында (Чимкент ш.), 2000 нән Казандагы Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында баш фәнни хезмәткәр, аналитик лаб. мөдире (2002 дән), аналитик-экологик сынаулар үзәге җитәкчесе (2008 дән), директор (2009 дан). Хезмәтләре гидридлар химиясенә, җитештерү калдыкларын утильләштерүгә карый. Г. селтеле һәм селтеле-җир металлары алюмогидридларын синтезлауның яңа ысулларын эшли; кушылмаларның яңа классларын — селтеле, селтеле-җир һәм сирәк җир металларның полигалоген алюминатларын һәм полигалогенцинкатларын ача. Алюминий гидридын табуның бер стадияле литийлы ысулы «Нәвои-Азот» АҖдә (Үзбәкстан Респ-касы), алюминий җитештерү калдыкларын утильләштерү технологиясе Таҗикстан алюминий з-дында кулланылышка кертелә.

Х е з м.: Изотерма растворимости $Sr(AlH_4)_2 - AlH_3 - Et_2O$ и $Ba(AlH_4)_2 - AlH_3 — Et_2O$ при 25⁰ С // Докл. АН СССР. 1987. Т. 194, № 1; Исследование комплексообразования в системе «бинарный гидрид (галогенид) металла- галогенид алюминия (цинка) — органический растворитель» Алматы, 1998; Исследование водородных связей в системе нитраты целлюлозы — флегматизатор (ингибатор горения) // Бутлеровские сообщения. 2006. Т. 8. № 1 (автордаш).

**ГАТИЯТУ́ЛЛИН** Мансур Әхмәт улы (21.8.1924, Казан — 3.5.2009, шунда ук), балет артисты, ТАССРның халык артисты (1987). Мәскәү хореография уч-щесендә укый. 1946–66 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамблендә бию төркеме солисты, бер үк вакытта педагог-балетмейстер, 1966–95 тә (бүленеп) шунда ук педагог-репетитор. 1987 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында татар



М.Ә. Г а т и я т у л л и н «Егет биюе»ндә. Ә.З. Кәлимуллин куелышы. 1959.

биюләре буенча педагог. 1987–2003 тә Татар филармониясе каршындагы Фольклор музыкасы ансамблендә балетмейстер-репетитор. «Батраклар», «Кияү каршылау», «Чалгычылар биюе», «Кияү», «Башкорт егете биюе», «Дунган биюе», «Кытай биюе», «Су буенда», «Казан кунаклары», «Шаян бию», «Гармуннар белән бию» вокаль-хореографик композицияләрендә һәм биюләрдә солист буларак чыгышлар ясый. Биюче буларак, Г.ның иҗаты көчле энергиясе, югары техникасы, милли хореография теленең бөтен нечкәлекләрен сиземләве б-н аерыла. Ф.Ә.Гаскәровның хореографик мирасын дәвам иттереп, классик милли репертуарны искиткеч башкара. Бөтенсоюз совет яшьләре фестивале лауреаты (Мәскәү, 1957, көмеш медаль). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*В.Н.Горшков.*

**ГАТИЯТУ́ЛЛИН** Нәкыйп Сәлах улы (6.11.1949, Сарман р-ны Шәрләрәмә а.), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1996), ТРның атказ. геологы (1994), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Татнефть» АҖ оешмаларында: 1980–83 елларда Баулы бораулау эшләре идарәсендә геология бүлеге башлыгы, 1983–89 да «Татнефть» берләшмәсендә геология бүлеге башлыгы урынбасары, 1989–91 дә Казан геология экспедициясенең баш геологы, 1991–93 тә башлыгы. Татарстан геол. разведка идарәсен оештыручыларның берсе һәм беренче җитәкчесе (1993 тән). Ромашкино һәм Яңа Елховой нефть чыганакларының югары перспективалы горизонтларын кабат разведкалауда, Коньяк Татар гөмбәзенең коньяк-кончыгыш сөзәклеген разведкалау эшләрендә катнаша. Сабанчы нефть чыганагы данк-лебедян утырмаларындагы нефть ятмаларын беренче ачучы. Төп тикшеренүләре Татарстанның көнчыгыш өлешендәге рифей-венд катламнарының геологик төзелешен, нефть табу һәм перспективасын бәяләү, кембрийгача кристаллик катламнарда тирәнтен нефть эзләү мәсьәләләре б-н бәйле. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефть и газ Республики Татарстан. К., 1993 (автордаш); Тектоника Татарстана. К., 1998 (автордаш); Докембрий Восточно-Европейской платформы: геология и нефтегазоносность. СПб., 2002 (автордаш).

**ГАТИЯТУ́ЛЛИНА** Зәйтүнә Зиннәтулла кызы (2.4.1938, Казан — 2.4.2003, шунда ук), тел галиме, филол. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), шунда ук эшли: 1968–87 елларда инглиз теле каф. мөдире, 1991 дән чагыштырма лингвистика каф. мөдире. Хезмәтләре төрле система телләренең (герман, роман, төрки, скандинав һ.б.) чагыштырма типологиясенә карый. Россия лингвистикасы тарихында беренче тапкыр француз, инглиз, татар телләрен чагыштырып өйрәнү алымнарын эшли. Татарча-русча-төрекчә фразеологик сүзлек (Истанбул, 1997), инглизчә-русча һәм төрекчә-русча фразеологик сүзлекләр (Истанбул, 1999) төзүче. Югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Сравнительная типология лексических систем английского и татарского языков. М., 1982; Словарь словообразовательных элементов современного татарского языка. К., 1984.

*Әд.:* Ә х м ә д у л л а Ш. Тел белгәнне — ил белгән // Замана авазлары. К., 1997.

**ГАТТА́Р** (عطار) Фәридеддин (тулы исеме Фәридеддин Мөхәммәд ибне Ибраһим ән-Нишапури) (1119–1223 тирәсе), фарсы телле суфи шагыйрь. Тумышы б-н Нишапур шәһәреннән (Иран). Зур гыйлем иясе, гамәли тыйб гыйлеме (медицина), фармакология б-н шөгыльләнгән. Урта һәм Якын Көнчыгыш илләрендә (Мисыр, Гыйрак, Һиндстан һ.б.) булган. Күпләгән әдәби һәм гыйльми әсәрләр авторы. Гомуми күләме 202 меңнән артык бәйтне (икеюллык шигырь) үз эченә алган кырыклап шигъри китап язган, шул бәйтләрдән хәзерге көндә 120 меңләбе билгеле. Аеруча популярлык казанган поэмалары: «Хәйдәрнамә», «Пәнднамә» («Үгет-гыйбрәтләр китабы»), «Әсрарнамә» («Серләр китабы»), «Җөмҗөмәнамә», «Шигырьләр диваны», «Тәзкират әл-әүлиа» («Изгеләр тормышы»). Г.ның шигъри иҗаты суфичылык рухы, дөньялыкта Аллаһны эзләү, илаһи мәхәббәт темасы б-н сугарылган. Г. үзенең иҗатында Шәркый халыклар фольклорына еш мөрәҗәгать итә, әсәрләре тукымасына халык арасында туган гыйбрәтле хикәятләрне кертеп җибәрә. Г.ның әдәби мирасы фарсы һәм төрки телле әдәбиятларга көчле йогынты ясый. Мәс., Галишер Нәвои үзенең «Лисан әт-туйур» («Кошлар теле», 1499) исемле әсәрен Г.ның «Мантыйк әт-туйур» («Кошлар әңгәмәсе») дигән әсәренә нәзыйрә итеп яза. Татар әдәбиятында Г.ның шигъри тәэсире Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, бигрәк тә Әбелмәних Каргалый, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов һ.б. суфи шагыйрьләрнең иҗатында көчле күзәтелә. Г.ның «Пәнднамә» поэмасы татарчага тәрҗемә ителеп, Казанда берничә тапкыр (1872, 1880, 1884, 1885) аерым китап булып басылып чыга.

Ә с ә р.: «Пәнднамә», ягъни Шәйх әл-Гаттар тәсныйфе, «Хәмде бихәдд...»нең тәрҗемәсе. К., 1872; Пәнднамәи Гаттар. К., 1885; Китабе хамд-и би-хәдд. К., 1896.

*Әд.:* Б е р т е л ь с Е.Э. Суфизм и суфийская литература. М., 1965; Т а г и р д ж а н о в А.Г. Рукописи поэм Аттара в собрании библиотеки Восточного факультета // Письменные памятники и проблемы истории культуры народов Востока. XVI годичная науч. сессия Ленингр. отд-ния Ин-та востоковедения АН СССР. М., 1982. Ч. II; М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и восточная классика: К., 1993; Islam Ansiklopedisi. Ist., 1942. 2 cilt.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ГА́ТЧИНА** шәһәре, Ленинград өлкәсендәге шәһәр, Санкт-Петербургтан 46 *км* ераклыкта урнашкан. 1499 елдан мәгълүм. Халкы — 88,4 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 893, 1979 да — 990, 1989 да — 1119, 2002 дә — 500 кеше. Татарлар Г.га 1920–30 елларда күпләп күчеп утыра. Күбесе — Түбән Новгород өлкәсенең *Сергач районыннан* күчеп килүчеләр. 1999 дан «Юлдаш» татар-башкорт җәмгыяте эшли. 2001 дә татар телен һәм ислам мәдәниятен өйрәнү якшәмбе мәктәбе ачыла.

**ГАФА́РОВ** Айрат Нури улы (21.9.1936, Алабуга ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1978), проф. (1988), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2000), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1984). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлагач, Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында (Пермь ш.) эшли. 1971–82 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. башлыгы. 1982 дән Казан технол. ун-тында, 1986 га кадәр азотлы органик кушылмалар химиясе һәм технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре энергиягә туендырылган күп азотлы органик кушылмалар, актив өслекле матдәләр, коррозия ингибиторлары химиясе һәм технологиясенә карый. Г. гидразиннар, аминнар, нитраминнарның реакциягә керү сәләтләрен тикшерә. Формальдегид гидразоннарын аминометиллаштыру һәм дегидродимеризацияләү, аминнарны азидометиллаштыру, нитраминнарны хлорметиллаштыру реакцияләрен ача. Нитразополиэфирлар, нитраминлы пластификаторлар, югары алкандиолларның натрий сульфатларын, коррозия ингибиторларын табу технологияләрен эшли. Энергиягә туендырылган составлар пластификаторлары, синтетик юу чаралары өчен актив өслекле матдәләр, нефть чыгару җиһазлары өчен коррозия ингибиторлары җитештерүгә кертелә.

Х е з м.: Дегидродимеризация диалкилгидразонов формальдегида // Журн. органической химии. 1970. Т. 6; Винилнитрамины // Журн. органической химии. 1973. Т. 9 (автордаш); Алифатические нитраминоспирты и их производные // Изв. РАН. Сер. хим. 2009. № 10 (автордаш); Азидоводород в реакции Манниха // шунда ук.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КХТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАФА́РОВ** Наил Анатольевич (27.6.1953, Үзбәкстан ССРның Коканд ш.), нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү галиме, техник фән. д-ры (2000), РФнең мактаулы газ сәнәгате хезмәткәре (1992), РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1998). 1975 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлый һәм «Оренбурггазпром» пр-тиесендә эшли: цех, лаб., бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары (2000 нән). 2003 тән «Газпром» АҖнең газ, газ конденсаты, нефть чыгару департаменты башлыгы урынбасары. Сероводородлы газларны җыю, сәнәгый әзерләү һәм кудыруны табигатьне саклау б-н бергә алып бару технологиясен эшли. Г. җитәкчелегендә табигый газны киптерү һәм күкертле катнашмалардан чистарту, углеводородларны фракцияләргә бүлү җайланмалары эшләнә һәм гамәлгә кертелә; озак вакытлар коррозияле тирәлекләрдә була торган технол. җиһазларның, торба үткәргечләрнең ышанычлы һәм куркынычсыз эшләвен (моннан соңгы эшләү сәләтен фаразлауны да кертеп) тәэмин итү системасы тәкъдим ителә. Газ һәм нефть чыганакларында яңа буын фонтанлы җиһазларны эшләгәне һәм серияләп үзләштергәне өчен Г. РФ хөкүмәте бүләгенә лаек була (1995). Фәнни эшкәртмәләре «Оренбурггазпром» пр-тиесендә һәм Оренбург газ-конденсат чыганагында гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 48 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАның И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1987, 1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Коррозия и защита оборудования сероводородсодержащих нефтегазовых месторождений. М., 1998 (автордаш); Определение надёжности и технического состояния оборудования сероводородсодержащих нефтегазовых месторождений. М., 2001 (автордаш); Ингибиторы коррозии. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* З о р и н Л.З. Достойный представитель клана газовиков // Газовая промышленность. 2003. № 6.

**ГАФА́РОВ** Фидан Сафа улы (12.10.1947, БАССРның Дүртөйле р-ны Яңа Уртай а.), драма актёры, БАССР (1980), РСФСР (1984), ТРның (1994) халык артисты. Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1966, И.Х.Юмагулов курслары), М.Гафури исем.



Ф.С. Гафаров.



Г.Г. Гафиятуллин.

Башкорт акад. драма театрында эшли. Югары дәрәҗәдә лирик-драматик сәләткә ия булган үзенчәлекле актёр. Г. репертуары төрле жанрга караган әсәрләрдән 100 гә якын рольне үз эченә ала. Матур тышкы кыяфәте, музыкаль сәләтле, хискә бай булуы Г.ка истә калырлык образлар тудырырга ярдәм итә: Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Булат («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Искәндәр («Тапшырылмаган хатлар», Г.Кутуй әсәре буенча), Галимҗан («Башмагым», Х.Ибраһимов), Эрот («Ташлама утны, Прометей!», М.Кәрим) һ.б. «Алтын җайдак» («Всадник на золотом коне») нәфис фильмында («Мосфильм», 1980) Алтындуга ролен башкара. Үзенең муз. комедия гастроль театрына нигез сала (1991). БАССРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1981).

*Әд.:* Лауреаты премии имени Салавата Юлаева. Творческие портреты. Уфа, 1987.

**ГАФА́РОВ** Хәйдәр Зәйнулла улы (3.11.1941, БАССРның Фёдоров р-ны Ишбүләк а.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1987), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). ТРның атказ. уйлап табучысы (1993). Башкорт мед. ин-тын (хәзер Башкорт мед. ун-ты) тәмамлый (1971). 1974 елдан ТР ФАнең «Травматология һәм ортопедия савыктыру» фәнни-тикшеренү үзәгендә, 1989 дан директоры, бер үк вакытта Казан мед. акад-сенең травматология һәм ортопедия каф. мөдире, проф. (1993). Фәнни тикшеренүләре балаларның йөрү-хәрәкәтләнү аппараты биомеханикасының мед. аспектларына һәм патологик анатомиясенә карый. Г. — травматология һәм ортопедиядә яңа юнәлеш — торсион патологиягә нигез салучы. Аның тарафыннан тумыштан һәм соңыннан барлыкка килгән ортопедик авырулар вакытында түбән очлыклар сегментларының үсеш механизмы өйрәнелә; йөрү-хәрәкәтләнү системасының ортопедик патологиясе мәсьәләләрен хәл итүдә клиник биомеханиканың яңа аспектлары эшләнә; йөрү-хәрәкәтләнү системасын, тумыштан килгән күкрәк читлеге деформациясен дәвалау ысулы гамәлгә кертелә. Йөрү-хәрәкәтләнү системасын дәвалау өчен 100 дән артык ысул һәм җайланма (автордаш) һәм оча-балтыр буыны эндопротезларының яңа конструкцияләре эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Г. — РФ Сәламәтлек саклау министрлыгында Балалар ортопедиясенең проблемалы комиссиясе һәм яңа техника куллану ком-ты әгъзасы. «Балаларны торсион патологияне исәпкә алып хирургик реабилитацияләүнең яңа системасы» дигән хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (1995). Акад. Г.А.Илизаров фонды бүләгенә лаек була (1997). Уйлап табуга 89 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Лечение деформации стоп у детей. К., 1990; Лечение детей и подростков с ортопедическими заболеваниями нижних конечностей. К., 1995; Лечение врождённых деформаций грудной клетки. К., 1996.

**ГАФИЯТУ́ЛЛИН** Газинур Гафиятулла улы (13.1.1913, Самара губ., Бөгелмә өязе Сугышлы а. — 14.1.1944, Псков өлкәсе, Великие Луки р-ны Овсище а., Мякотино авылында җирләнә), Сов. Союзы Герое (4.6.1944, үлгәннән соң), сержант. Колхозда, урман сәнәгате хуҗалыгында эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 20 нче укчы полкның (22 нче армиянең 37 нче укчы дивизиясе) отделение командиры урынбасары. Көнбатыш, Калинин, Төньяк-Көнбатыш, Балтыйк буе һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Дрисса һәм Витебск чигендә оборона сугышларында (1941), Смоленск сугышында (1941), Калининград (1941) һәм Ржев-Вязьма (1943) оборона операцияләрендә, Холм һәм Великие Луки шәһәрләре янында Ловать елгасы өчен барган бәрелешләрдә катнаша. 1944 нең 14 гыйнварында Овсище авылы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: отделение б-н бергә дошман дзотын юк итә, икенче дзотның амбразурасына ташлана һәм утны күкрәгә б-н каплап һәлак була. Бөгелмә шәһәрендә һәм Овсище авылында Г.га һәйкәл куела. Геройның исеме Казан, Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт урамнарына бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Г.С.Әпсәләмов. Газинур. Роман М., 1954; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГАФИЯТУ́ЛЛИН** Җаббар Бари улы (1.10.1932, Кама Тамагы р-нының Кече Kариле а.), спортчы, тренер (ирекле көрәш, татарча көрәш), СССРның спорт остасы (1962), РСФСРның атказ. тренеры (1976), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1993). Воронеж пед. ин-тын тәмамлый (1957). Р.А.*Азизовның* шәкерте («Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте, Казан). Татарча көрәш буенча РСФСР (1960, 68), ирекле көрәштә Красноярск крае (1958), Бөтенсоюз динамиадасы (1960) чемпионы. 1963–77 елларда тренер, 1977–94 дә «Ракета» СКда (Казан) өлкән тренер. Шәкертләре арасында С.Ф.*Тимофеев*, ш.у. РСФСР, Профсоюзлар ирекле спорт җәмгыятенең бөтенсоюз үзәк советы һ.б. бәйгеләрнең җиңүчеләре һәм призёрлары (20 дән артык СССРның спорт остасы) бар. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И л д а р х а н о в И. Без көрәшче халык. К., 2009.

**ГАФИЯТУ́ЛЛИН** Рафаиз Хажи улы (15.2.1929, БАССРның Туймазы р-ны Чулпан а. — 23.7.2007, Чиләбе ш.), җитештерүне автоматлаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1977), проф. (1982), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1947–55 елларда БАССРның «Октябрьскнефть» НГДУында эшли. 1960 та Көньяк Урал ун-тының приборлар төзү ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1978 дән сәнәгать җайланмаларын автоматлаштыру каф. мөдире (бүленеп, 1966–78 дә Ачык ысул б-н файдалы казылмалар чыгару буенча фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык ин-тында бораулау станокларын автоматлаштыру секторы мөдире, Чиләбе ш.). Хезмәтләре бораулау процессын автоматлаштыру системаларына һәм югары төгәллекле махсус күзәтү системаларына карый. Киңлек һәм ешлык буенча импульслы модуляциясе берләштерелгән системалар, даими электр тогы чылбырларын потенциаль бүлү өчен янәшә цикллары капма-каршы фазада булган әверелдергеч эшли. Нигезләре тирбәлүчән объектларны тотрыкландыру өчен күзәткеч электр тапшыргычын гамәлгә кертә. Вентильле реактив двигатель нигезендә трамвай өчен электр тапшыргычы уйлап таба. Махсус техника б-н идарә итә торган уникаль системалар булдыра. Уйлап табуга 28 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Автоматизация процессов геологоразведочного бурения. М., 1977; Реактивный коммутируемый электродвигатель. М., 1996; Sweep Converter with Voltage — Decoupled DC Chans // Electronics and Radio Engineering. USA. 1997. № 3.

**ГАФИЯТУ́ЛЛИН** Рәшит Вазыйх улы (4.11.1938, Буа р-ны Казма а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1988), проф. (2001). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлагач, Пермь шәһәрендә оборона пр-тиесендә эшли, 1966 дан Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында: 1968 дән лаб. башлыгы, 1981 дән баш инженер. 1990 нан СССР Оборона сәнәгате министрлыгы баш идарәсе башлыгының беренче урынбасары, 1992 дә баш инженер, 1992–96 елларда инвестиция технол. программалары директоры, 1996 дан «Техник химия» АҖнең технол. программалар һәм коммерция эшчәнлеге буенча директоры (Мәскәү). Хезмәтләре ракеталар өчен катнаш каты ягулыклар (СРТТ) химиясенә һәм технологиясенә карый. Г. СРТТ җитештерүнең физик-химик процессларын тикшерү комплексын үти. Нечкә вакланган һәм ультрадисперс порошоксыман оксидлаштыргычлар, басым астында кою ысулы б-н СРТТдан зарядлар эшләү технологияләрен булдыра, төрле формалы һәм габаритлы зарядлар әзерләүнең оптималь параметрларын билгели. Яңа техника үрнәкләрен төзегәнгә өчен СССРның Дәүләт бүләге бирелә (1978). Махсус химия пр-тиеләрендә конверсион җитештерүне, искергән дарылар, каты ракета ягулыкларын һәм аларның зарядларын юк итүнең техник һәм экологик куркынычсыз технологияләрен эшләүне оештыра. Уйлап табуга 34 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологический процесс изготовления изделий из быстрогорящих смесевых твёрдых топлив методом литья под давлением // Вопр. специального машиностроения. Сер. 2. 1976. Вып. 2(45) (автордаш); Основы технологии производства смесевых твёрдых топлив. М., 1981 (автордаш); За-

щита окружающей среды в производстве порохов и твёрдых ракетных топлив. М., 2002 (автордаш); Основы промышленной технологии утилизации крупногабаритных твёрдотопливных зарядов. М., 2004.

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГАФИЯТУ́ЛЛИН** Сөләйман Хәлил улы (1.1.1905, Казан губ. Чистай ш. — 1.5.1983, Алма-Ата), дәүләт эшлеклесе. 1919–22 елларда Чистай пед. техникумында укый. 1943–45 тә ВКП(б) ҮК каршындагы югары партия мәктәбе тыңлаучысы. Район башкарма ком-тлары инструкторлары әзерләү курсларын тәмамлаганнан соң (1928, Казан), Арча кантоны башкарма ком-ты инструкторы. 1929–30 да ТАССР НКВДсы Коммуналь хуҗалык баш идарәсенең өлкән инспекторы. 1932–38 дә 124 нче һәм 27 нче авиация з-дларының (Казан) янгыннан саклау хезмәте башлыгы. ВКП(б)ның Ленин райкомы 1 нче секретаре (1938–39). ТАССР ХКСы рәисе (1940–43). Бөек Ватан сугышы елларында Г. эвакуацияләнгән пр-тиеләрне Казанда каршылау һәм урнаштыру б-н җитәкчелек итә. 1945 тән Казакъстан ССРда: игенчелек һәм терлекчелек с-злары наркомы (1945–46); хезмәт ияләре депутатларының Көнчыгыш Казакъстан (1946–48) һәм Көнбатыш Казакъстан (1948–52) өлкә советлары башкарма ком-ты рәисе; Казакъстан ССР МС каршындагы Авыл һәм колхоз төзелеше эшләре баш идарәсе җитәкчесе (1952–53); Совхозлар министрлыгының «Совхозснаб» матди-техник тәэминат баш идарәсе җитәкчесе (1953–54). 1954 тән Маметова исем. игенчелек с-зы директоры (Акмола өлкәсе). 1947 дә Казакъстан ССР ЮС, 1939–48 дә СССР ЮС, 1948 елда Көнбатыш Казакъстан өлкә советы депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*М.Ш.Бәдретдинова, Г.Х.Галимуллина.*

**ГАФИЯТУ́ЛЛИНА** Галия (чын исеме Хәтимә) Шәриф кызы (24.3.1915, Казан — 13.8.2003, шунда ук), җырчы, ТАССРның атказ. артисты (1957). Проф. сәхнәгә үзешчән сәнгатьтән килә. 1945–70 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамбле солисты. Татар халык җырларыннан тупланган бай репертуар б-н чыгышлар ясый. Чиста дикцияле һәм яңгыравыклы, матур, моңлы тавышка ия. Татар халык җырларын һәм композиторларның әсәрләрен югары сәнгати дәрәҗәдә башкару үзенчәлеге б-н аерылып тора. Репертуарына кергән аеруча танылган җырлары: «Бормалы су» (З.Хәбибуллин муз., Н.Исәнбәт шигыре), «Ямьле Агыйдел буйлары» (татар халык җыры), «Умартачы сөйгәнем» (И.Хисамов муз., М.Галиев шигыре), «Миндәдер күңелләре» (Ә.Хәйретдинов муз., Р.Ишмөхәммәтов шигыре), «Күл буена килсәң иде» (З.Гыйбадуллин муз., Г.Зәйнашева шигыре), «Сиреньнәр хуш ис тарата» (Н.Җиһанов муз., Ә.Ерикәй шигыре), «Эрбет» (татар халык җыры); «Әрәмәлек», «Көймә килә», «Дисәнә», «Бөдрә тал», «Фазыл чишмәсе» (С.Хәким шигыре) һ.б. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГАФУРИ́** (Гафуров) Мәҗит (Габделмәҗит) Нургани улы (20.7.1880, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Җилем-Каран а. — 28.10.1934, Уфа ш.), язучы, публицист, БАССРның халык язучысы (1923). Татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы. Авыл укытучысы гаиләсендә туа. Яшьли ятим кала. Авыл мәдрәсәсендә укый. Уралда (ш.и. Рәмиевләрнең алтын приискаларында) сезонлы эшләр башкара. 1898 елдан «Рәсүлия» мәдрәсәсендә (Троицк ш.) укый. Җәйләрен приискаларда, казакъ җәйләүләрендә көнлекчелектә эшли. 1905 тә Казанга килә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1906 дан Уфада, 1909 га кадәр «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1902 дә дини фанатизмны фаш иткән «Ишан хәзрәтләренә» исемле беренче сатирик шигырен яза. «Себер тимер юлы, яки Әхвале милләт» (1904) шигырендә, «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» (1909) хикәясендә, «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» (1904) повестенда Г. гади халык тормышын тасвирлый. Алга таба иҗатының тәнкыйди юнәлеше көчәя бара. «Яшь гомерем» (1906), «Милләт мәхәббәте» (1907) җыентыклары патша хакимиятләре тарафыннан тыела, чөнки аларда самодержавиене бәреп төшерүгә өндәү сизелә.

Башлангыч чор лирикасы «Гафури шигырьләре» (1909), «Тәэссоратым» (1909), «Моң вә зар» (1911) җыентыкларында тупланган. Шигырьләренә социаль мотивларның төрлелеге һәм лирик кичерешләргә бай булу хас. Алга таба Г. шигъриятендә психологизм көчәя, дидактик агым да сакланып килә.

Татар мәгърифәтчелек әдәбияты традицияләре, Шәрекъ әдәбиятының реалистик элементлары, татар һәм башкорт фольклорының казанышлары Г. иҗатында 20 йөз башындагы революцион идеяләр б-н баетыла. Җәмгыятьне үзгәртү көче итеп Г. мәгърифәтле булуны исәпли («Себер тимер юлы», «Яшь гомерем», 1906). Башлангыч чор иҗатында ук ул үзен реалист язучы итеп таныта.

1905–07 еллар вакыйгалары аның милли азатлык идеяләре б-н кызыксынуын арттыра төшә. Милли мәсьәләләрне Г. халыкларның царизмга каршы көрәше б-н бергә бәйләп карарга тырыша («Алмашыну», 1905; «1906 елдан 1907 елга васыять», 1906 һ.б.). Соңыннан, реакция һөҗүменә җавап итеп, Г. халыкның аяныч хәленә, социаль проблемаларына, кимсетелгәннәрнең хокукларын яклау мәсьәләләренә игътибарын арттыра («Базарга чыктым», 1907; «Бай һәм хезмәтче», 1909; «Хәерче», 1909; «Кызганам!», «Үлгән җан», икесе дә 1910 һ.б.).



М. Гафури.

Шул ук елларда Г., мәсәл жанрына мөрәҗәгать итеп, бер төркем сатирик персонажларның бөтен бер галереясын тудыра. 1907–17 елларда ул 25 мәсәл яза. Аларның кайберләрендә И.А.Крылов йогынтысы сизелә, аерым мәсәлләрдә «*Кәлилә вә Димнә*» китабы сюжетлары кулланыла. «Үгез белән бүре» (1912), «Сарыкны кем ашаган?» (1912), «Эт белән куян» (1912) мәсәлләре социаль юнәлешле булулары б-н аерылып торалар. «Сандугач» (1906), «Кошларның патша сайлаулары» (1909), «Кара җылан белән Бакалар патшасы» (1912) мәсәлләрендә хөкемдар һәм халык мөнәсәбәтләре проблемасын образлы рәвештә аллегориягә нигезләнеп хәл итә.

Мәгърифәтчелек идеяләренең закончалыклы дәвамы буларак, Г.ның антропологизмы берничә әсәрдә, аеруча «Хәмитнең хәяты» (1910) повестенда ачык чагылыш таба. Ямьсез тормыш күренешләре беркадәр күбрәк тасвирланса да, әсәрдә реалистик хакыйкать хөкем сөрә.

Г.ның алга таба әдәби эзләнүләре трагизмнан оптимизмга таба кискен борылыш ясый. Г.ның шигъри дөньясында, гуманизм идеалларының тантанасы һәм акыллы көч урнашуның чагылышы буларак, мәхәббәт романтикасы үзен нык сиздерә башлый. «Мәхәббәт хатлары» (1912) повестенда ш.у. мәхәббәт культы, бәхет идеаллары тантана итә. «Беренче мәхәббәт» (1915), «Янган йөрәк» (1914), «Таң яктысы» (1913) шигырьләре оптимизм б-н сугарылган.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, мәхәббәт һәм дуслык романтикасын хәсрәт, көч куллануны гаепләү алмаштыра. 1915 тә Г. үзенең атаклы «Юктырсың ла, Алла!» һәм «Кем ул?» шигырьләрен яза. Ул аларда сугышка карата халыкның ачы нәфрәтен чагылдыра, аны кешелек алдында иң зур җинаять дип фаш итә. «Сол-



Сулдан уңга: Н. Думави, З.Бәшири, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, М. Гафури. Уфа ш., 1916.


И.Н.Гафуров.

дат хатыны Хәмидә» (1915) хикәясендә дә туган туганын үтерүгә корылган сугышка каршы кискен протест белдерә.

1917 елгы рев-ция вакыйгаларын Г. шатланып каршы ала, аларга «Кызыл байрак» (1917), «Хөррият иртәсе» (1917), «Хисап көне» (1917), «Безнең юл» (1919), «Нур» (1919) шигырьләрен багышлый. М.Вахитов истәлегенә багышланган «Нур» шигырендә Г. революционерларның көрәштә үзләрен корбан итүләренә басым ясый. Г. иҗатының өзлексез темаларыннан берсе — үткәннәрдә калган коллар хезмәтен ирекле хезмәт идеалыннан чыгып күрсәтү. Бу тема аның «Эшче» (1920) поэмасында яңа сыйфатта калка. 1927 дә ул кабат бу поэмага әйләнеп кайта һәм аның драматик вариантын яза. Бу сюжетка композиторлар Г.С.Әлмөхәммәдов, С.Х.Габәши һәм В.И.Виноградов, татар муз. тарихында беренче булып, шул исемдә опера язалар (1930 да Татар акад. театрында куела). «Кызыл йолдыз» пьесасы (1925) Гражданнар сугышына һәм җимерелгән авыл хуҗалыгын торгызуны күрсәтүгә багышлана. 1921–23 еллардагы ачлык «Ачлык тырнагында» (1923) исемле җыентыкка кергән «Сулган гөлләр» (1921), «Ач» (1921), «Җылыйлар» (1922) шигырьләрендә, «Кеше ашаучылар» (1922) поэмасында сурәтләнә.

1927 дә язылган «Кара йөзләр» повесте Г.ны күренекле язучы итеп таныта. Повестьта геройларга төгәл психологик сурәт, социаль күренешләргә тирән анализ бирелә. Сюжет нигезендә 19 йөз ахырында язучының туган авылында булып узган фаҗигале вакыйгалар ята. Повестьнең төп героинясы Галимә иске тормышның караңгылыгы, мәрхәмәтсезлеге б-н каршылыкка очрый һәм ахырда һәлак була. Галимә кичергән фаҗиганең бөтен тирәнлеген күрсәтү өчен, автор антитеза һәм контраст алымнарын оста куллана. Бу повестька нигезләнеп, 1981 дә композитор Б.Г.Мөлеков шул исемдә опера яза (Гәрәй Рәхим либреттосы, 1982 дә Татар опера һәм балет театрында куела). 1917 гә кадәр язылган «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек», «Ярлылар, яки Өйдәш хатын», «Үги балалар» (1908), «Зәйнәп сабыр иткән иде, сабыр итә алмады» (1911), «Онытылган җинаять, яки үткәнне искә төшерү» (1911) хикәя һәм повестьларында Г. татар хатынының фаҗигале язмышына басым ясый. «Кара йөзләр» повестенда социаль гомумиләштерү юлында яңа югарылыкка ирешә.

«Тормыш баскычлары» (1927) повестенда Г. Беренче бөтендөнья сугышы һәм 1917 елгы рев-ция темаларына кабат әйләнеп кайта. Автор повестьның төп герое Вахитның характеры формалашуын, аның хезмәт ияләре хокукы өчен чын көрәшче булып китүен күрсәтә. «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1929) автобиографик повестенда Г. алтын приискасында эшләгән эшчеләрнең авыр тормышларын чагылдырганда әсәр эчтәлеген тирәнәйтеп, зурайтып күрсәтүгә ирешә. Гади халыкның югары әхлакый сыйфатларын чын җылылык б-н тасвирлый.

Г.татар һәм башкорт матбугатында актив языша. Аның «Шәрекъ ярлылары», «Безнең юл» г-таларында, «Яңа юл», «Кызыл юл», «Совет әдәбияты» ж-лларында басылган очеркларында, язмаларында татар һәм башкорт халыкларының язмышлары ачык чагылыш табалар.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1939; Һайланма әсәрҙәр. Өфө, 1950; Әсәрләр: 4 томда. К., 1980–83; Избранное. Уфа, 1955.

*Әд.:* Хисмәтуллин Г. Мәҗит Гафури // Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. К., 1960; Нигъмәтуллин Э. Мәҗит Гафури: Иҗаты турында очерк. К., 1969; Халит Г. Тормыш һәм ирек җырчысы: Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турындагы очерк. К., 1980; Башкуров Р. Маджит Гафури // История татарской советской литературы. М., 1965; Рамазанов Г. Творчество Маджита Гафури. Уфа, 1970; Магдеев М. Маджит Гафури. К., 1980.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГАФУРИ́ РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Респ-касының* үзәк өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 3039 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Красноусол посёлогы (Уфадан 130 *км* көньяктарак). Халкы — 36761 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 13042, 1979 да — 10218, 1989 да — 8448, 2002 дә 6474 кеше. 94 торак пункт, ш.и. 16 татар, 6 татар-рус, 6 татар-башкорт авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары (1999): Ялгыз Каен (1016 кеше), Бурлы (585), Кормантау (517). Иң борынгылары: Кормантау (1737–38 дә нигез салына), Иньелга (1747), Бурлы һәм Татар Сасыккүле (18 йөзнең 2 нче яртысы). 2002/03 уку елында Г.р.ның 5 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла. Җилем-Каран авылында язучы М.Н.*Гафури* туган.

**ГАФУ́РОВ** Барис Аппаулла (Габдерәуф) улы (9.5.1954, Чүпрәле р-ны Иске Ишле а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР һәм РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1995, 2002). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1976). Чүпрәле р-нында эшли: Шыланги (1976–80), Иске Ишле (1980–81) мәктәпләрендә директор, КПСС райкомында инструктор (1981–83), район кино челтәре директоры (1983–84), «Чынлы» ЖЧҖ рәисе урынбасары (1984–89), рәисе (1989). Г. җитәкчелек иткән елларда хуҗалыкта матди-техник база ныгытыла, 300 урынлы мәктәп, 400 урынлы мәдәният сарае һ.б. төзелә, производство объектларын һәм торак йортларны газлаштыру, су кертү, Чынлы урамнарына асфальт салу эшләре башкарыла. 2004 тә хуҗалыкта бөртекле ашлыкның гектарыннан 58 *ц*, шикәр чөгендеренең гектарыннан 466 *ц* уңыш, 1 сыердан елына 6675 *кг* сөт алына. 100 *га* а.х. җирләренә 616 *ц* сөт, 139 *ц* ит җитештерелә. Җитештерүнең табышлылыгы 31,1% тәшкил итә. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

**ГАФУ́РОВ** Ибраһим Насыйр улы (25.12.1910, Казан — 24.4.1972, шунда ук), драма актёры, ТАССРның атказ. һәм халык артисты (1957, 1970). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1934). 1934–37 елларда Татар эшче театры труппасында, 1937 дән Татар акад. театры актёры. Бөек Ватан сугышы елларында Төньяк-Көнбатыш фронтта концерт бригадаларында чыгышлар ясый. Сәхнә эшчәнлегендә агитацион театр алымнарын киң кулланучы Татар эшче театры сәхнәсендә импровизация осталыгына, тамаша залы б-н ике арада иркен элемтә урнаштырырга, образ тудырганда сүрәтләү чараларыннан кыю файдаланырга өйрәнә. Соңыннан аңа бу осталыгы Татар акад. театры сәхнәсендә Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Нургали («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Галим («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Хөсәен («Кушнарат», К.Насыйри), Әхмәди («Серләр», А.Әхмәт), Хәйри («Тормыш җыры», М.Әмир), Хаммат («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт) кебек рольләрне башкарганда ярдәм итә. К.Тинчуринның «Американ», «Йосыф белән Зөләйха», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Беренче чәчәкләр» комедия һәм драмаларындагы Г. тарафыннан иҗат ителгән Сәхибгәрәй, Йосыф, Әптери, Шәкерт, Хәмит образларында актёр төрле пландагы сәләтен, йомшак комизмнан үткен сатирага күчә алу мөмкинлеген күрсәтә. Ә.Фәйзинең «Тукай» пьесасы буенча куелган спектакльдә (1939), Тукай образын беренче булып башкаручы буларак, Г. халык шагыйренең канатлы романтик образын тудыра, аның халык б-н табигый бәйләнешен ачып бирә. У.Шекспирның «Король Лир» трагедиясендәге Шут ролендә «актёр ...явызлык һәм комсызлыкның дошманы булган кешенең дәртле йөрәгендә, кайнар, кыю акылында ачу кабынуын бирә алды», — дип яза 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә «Советская культура» г-тасы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.


И.Н.Гафуров
Тукай (Ә.Фәйзинең шул исемдәге әсәре) ролендә.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГАФУ́РОВ** Илшат Рәфкать улы (1.8.1961, Баулы ш.), икътисадчы, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2008), ТРның атказ. икътисадчысы (2002). Казан ун-тын (1983), Казан финанс-икътисад ин-тын (1997), Әлмәт нефть ин-тын (2004) тәмамлый. 1983–85 һәм 1988–92 елларда Алабуга пед. ин-тында укыта. 1992 дән төбәк хуҗалыкара «Зилант» ассоциациясе ген. директоры, 1995 тән ТР Дәүләт Советының

икътисади үсеш һәм реформалар мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе урынбасары. 1998 дән Алабуга шәһәре һәм р-ны хакимияте башлыгы. 2010 елның апрелендә РФ Хөкүмәте рәисе әмере б-н Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры итеп билгеләнә. Ул Алабуга шәһәре һәм р-ны б-н җитәкчелек иткән елларда анда «Алабуга» аерым икътисади зонасы булдырыла, Г. икътисади кризис елларында шәһәр тормышында уңай роль уйный, шәһәрне төзекләндерү, Алабуганың мемориаль өлешен үзгәртеп кору, *Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгын* үзгәртеп кору буенча нәтиҗәле эш алып барыла, яңа спорт корылмалары төзелә, шәһәр туристлык үзәгенә әверелә.

Г. «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 1995–2004 елларда ТР Дәүләт Советы депутаты.

Х е з м.: Методология разработки стратегических программ социально-экономического развития территории. К., 2003.

**ГАФУ́РОВ** Исхак Мәхмүт улы (25.3.1903, Казан — 20.5.1990, шунда ук), инженер-химик, СССР кино-фото производствосын оештыручыларның берсе. Түбән Новгород ун-тын тәмамлый (1927). 1928–34 елларда Урта Идел май трестында баш инженер (Самара ш.). 1934–63 тә В.В.Куйбышев исем. химия з-дында эшли (соңрак «Тасма» холдинг компаниясе» АҖ), баш инженер (1938–61). Бөек Ватан сугышы елларында, кино-фото производствосы буенча сирәк белгеч буларак, фронттан кайтарыла. Аның җитәкчелегендә яңа производстволар үзләштерелә һәм төзелә, завод эшләп чыгара торган продукциялар ассортименты барлыкка килә; илдә беренче тапкыр үтә сизгер кинонегатив тасма, гидротиплы һәм төсле тасмалар комплектлары, астрономик күзәтүләр өчен тасмалар, төргәкле рентген тасмалары, рентген җайланмалары өчен эре кадрлы тасмалар, металл ябыштыру тасмалары булдырыла; кино-фото җитештерүендә пар-һава катнашмаларын тоту, ферментлы эремәләр ярдәмендә тасма калдыкларының биологик регенерациясе процессы оештырыла; фото эмульсияләр синтезының прогрессив алымнары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ГАФУ́РОВ** Равил Габдрахман улы (18.4.1930, Чистай ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1978), проф. (1982). 1953 елда Казан химия-технол ин-тын, 1990 да Мәскәү авиация ин-тын тәмамлый. 1953–65 елларда Казан химия-технол. ин-тында эшли. 1965–80 дә СССР ФАнең Химик физика ин-тында, 1980 нән РФАнең Физиологик актив матдәләр ин-тында (Мәскәү өлкәсе Черноголовка пос.): директор урынбасары (1986 га кадәр), биоорганик синтез лаб-ясе мөдире (1981–93), баш фәнни хезмәткәр (1994 тән), бер үк вакытта (1993 тән) «Тахиат» инновацион үзәге директоры. Хезмәтләре органик, биоорганик химия һәм физиологик актив кушылмалар химиясенә, химик информатикага карый. Г. аминнарның реакцияләрен һәм үзлекләрен, аларның нитрокушылмаларының һәм азотлы гетероциклларының кайбер типларын тикшерә, амино- һәм нитраминометиллау реакцияләренең закончалыкларын өйрәнә, нитроминометиллау реакциясе теориясен тәкъдим итә. Нитрат кислотасы тәэсирендә нитрозоаминнарның нитраминнарга әверелү механизмын ачыклый. C-, N-, O-нитролаштыру реакцияләрендә фторлы нитрилның югары активлыгын һәм селективлыгын күрсәтә. Тикшеренү нәтиҗәләрен билгеләнгән үзлекле энерготуендырылган матдәләр синтезлау һәм алардан югары эффектив эшләнмәләр ясау өчен файдалана. Химик дизайн һәм молекулада бер-берсен тулыландыручы физиологик активлыклы химик фрагментларны берләштерү юлы кулланып, түбәнмолекуляр биорегуляторларның физиологик активлыгы спектры б-н идарә итү стратегиясен булдыра. Простагландиннар, фитогормоннар, үсемлекләрнең үсешен һәм җитлегүен көйләгечләр синтезлауны һәм химик модификацияләүне тормышка ашыра. Уйлап табуга 50 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Синтезы, реакции, свойства и молекулярные структуры C-нитро и C-фторнитропроизводных аминов, N-нитрозоаминов и N-нитраминов // Журн. органической химии. 1969. Т. 5, № 1 (автордаш); Синтезы и физиологическая активность простагландинов и регуляторов роста и развития растений // Докл. АН СССР. 1984. Т. 227; Химия простагландинов в патентах. М., 1984 (автордаш); Стратегия химического дизайна и свойства фиторегуляторов и стресспротекторов с заданными свойствами // Докл. РАН. 2004. Т. 394 (автордаш).

**ГАФУ́РОВ** Руханил Габделкадыйр улы (10.6.1933, Чүпрәле р-ны Иске Чокалы а.), двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), проф. (1992), ТРның атказ. уйлап табучысы (1991), ТРның, РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997, 2006). 1953 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, 1975 кә кадәр Пермь моторлар төзү з-дында эшли: инженер-конструктор, бригада, КБ, хисаплау-тикшеренү бүлеге башлыгы, баш инженер урынбасары. 1973 тән Казан техник ун-тында махсус двигательләр кафедрасында, бер үк вакытта 1991 дән Диагностика һәм физик-химик процесслар б-н идарә итү фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Хезмәтләре энергетика җайланмаларының камера эчендәге процесслар диагностикасына карый. «Космос», «Протон», «Энергия» серияләренә очкыч аппаратлары двигательләренең ватылу сәбәпләренә диагностика һәм ресурсларны фаразлау системасын эшли. Сыек ягулыклы ракета двигательләренең ышанычлылыгын тәэмин итү методикасын эшли һәм, аны гамәлгә кертеп, кыйммәтле утлы сынауларны уздырмау хисабына аларны җитештерү бәясен киметүгә ирешә. Җитештерү объектларының авариясез эшләү, әйләнә-тирә мохитне савыктыру һәм халыкны экологик зарарсыз а.х. продуктлары б-н тәэмин итү концепцияләрен нигезли. «КАМАЗ» двигательләре нигезендә кечкенә җылылык электр станцияләре төзи. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Диагностика внутрикамерных процессов в энергетических установках. М. 1991; Научно-технические основы и концепция поэтапного оздоровления окружающей среды, безаварийного функционирования установок и производственных объектов и обеспечения населения экологически чистыми продуктами. К., 2007; Прошедшие годы и пройденные пути на Земле, в космосе и вновь на Земле. К., 2007.

**ГАФУ́РОВ** Сибгатулла Садыйк улы (25.10.1888, Саратов губ., Хвалынск өязе Татар Шомалагы а. — май, 1937, Казан), сәясәт эшлеклесе. Авыл башлангыч мәктәбен (1900), Хвалынск өязе Озёрск авылындагы мәхәллә мәктәбен тәмамлый (1902). 1903–14 елларда Бакуда төрле эшләрдә эшли. 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша, 1905 тән Нефть промыселлары эшчеләре берлеге идарәсе әгъзасы, 1913–14 тә РСДРПның Баку ком-ты әгъзасы. Революцион эшчәнлек алып барганы өчен 1914–15 тә Саратов губернасында сөргендә була. 1915 нең ахырыннан Акчуриннарның постау ф-касы конторасында писарь (Сембер губ. Зөябаш а.). 1916–20 дә Россия армиясенең 96 нчы запас полкында хезмәт итә (Сембер ш.). 1917 дә Солдат депутатларының Сембер губерна советы ком-ты әгъзасы. РСДРПның Сембер ком-тын оештыруда катнаша, 1918 дә Сембер губерна башкарма ком-ты әгъзасы; РКП(б)ның Сембер губерна ком-тында милләтләр эше бүлеген һәм мөселман секциясен оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе. Татар-Башкорт ССРны оештыру мәсьәләсенә багышланган киңәшмә эшендә катнаша (1918, Мәскәү). 1918 нең июнь–август айларында партизаннарның Чех-словак корпусына каршы сугыш хәрәкәтләрен җитәкли. 1919 да Сембердә татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү буенча еллык курслар ачылуга булышлык итә. 1920 дән Казанда: социаль тәэминат халык комиссары урынбасары, дәүләт тәэминаты идарәсе мөдире. 1922 дә Мәскәүдә Коминтерн башкарма ком-тының Шәрекъ бүлегендә эшли. 1923 тә РКП(б)ның Татарстан өлкә Контроль комиссиясенең партия коллегиясе тикшерүчесе, 1924 тә ТАССР ҮБК әгъзасы, 1925–29 да РКП(б)ның Татарстан өлкә Контроль комиссиясе партия коллегиясе 2 нче секретаре, аның президиумы әгъзасы (1934 кә кадәр). 1929 дан ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты тарих-партия бүлеге мөдире. Репрессияләр чоры корбаны (к. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» эше), үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Ю с у п о в А. Г а ф у р о в С. К., 1966; Х а б и б у л л и н а Ф. Гафуров Сибгатулла Садыкович // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ГАФУ́РОВ-ЧЫГЪТА́Й** Галиәсгар Мөгыйн улы (16.9.1867, Казан губ., Чистай өязе Яңа Ибрай а. — 20.8.1942, Аксубай р-ны Иске Ибрай а.), язучы, журналист. 1883–91 елларда Чистай мәдрәсәсендә белем ала. 1891–99 да укытучы. 1899 дан Бозаулык шәһәрендә имам булып тора. 1915 елдан Казанда яши, «Кояш»



Ф.Д.Гахов.

г-тасында эшли, 1916 дан — Уфада, «Тормыш» г-тасында. 1924 тән Мәскәүдә яши. СССР халыклары үзәк нәшриятында эшли, 1925–32 дә — «*Фән һәм дин*» ж-лының җаваплы сәркәтибе. 1941 нең язында Иске Ибрай авылына күчеп кайта.

Г.-Ч. — «Тутам» повесте авторы. Аның 1 нче кисәге 1898 дә языла, 1902 дә Ф.Кәриминең матди ярдәме б-н Оренбургта әсәрнең төп герое Галимә псевдонимы б-н басыла. Әсәр Галимәнең ире б-н әңгәмәсенә корылып язылган. Әңгәмәләрдә гаиләдәге патриархаль яшәү рәвеше тәнкыйтьләнә, хатын-кызның җәмгать эшчәнлегендә катнашу хокукы яклана. Повесть татар һәм рус җәмәгатьчелеге тарафыннан уңай бәяләнә (Р.Фәхретдинов, Н.И.Ашмарин). 1906 ның июнендә «әл-Гасрелҗәдид» ж-лында повестьның 2 нче кисәге басыла. 1908 дә Г.Тукай инициативасы б-н әсәрнең ике кисәге дә аерым китап булып чыга. Г.-Ч.ның исламның төп кагыйдәләренә каршы чыккан «Исабәт» исемле публицистик китабы (1909) Коръән һәм шәригатьнең күп кенә кагыйдәләрен шик астына куя. Бу китап өчен автор руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә.

Ә с ә р.: Мин нидән динсезләндем. М., 1924; Дини корбаннар. М., 1927; Дин хорафатлары. М., 1929.

*Әд.:* Р а х м а н к у л о в З. «Исабәт» китабы хакында мөляхәзә // Шура. 1910. № 1; Г а й н у л л и н М. Татарская литература XIX в. К., 1975; ш у л у к. Татарская литература и публицистика начала XX в. К., 1983.

*А.М.Ахунов.*

**ГАФУ́РОВА** Гөлчирә (Гөлчәһрә) Миңнезаһир кызы (15.3.1901, Казан губ., Тәтеш өязе Борнаш а. — 9.6.1967, Казан), журналист. С.С.*Гафуров* хатыны. 1926–37 дә «Азат хатын» ж-лында эшли (әдәби хезмәткәр, 1929 дан җаваплы сәркәтип, 1931 дән җаваплы мөхәррир). 1937 дә ТАССР ХКС каршында техник хезмәткәрләрнең наданлыгын һәм аз белемлелеген бетерү буенча укытучы, Казандагы Яңа татар бистәсе мәктәпләрендә эшли. 1938 дә «Ватанга хыянәт итүче»нең хатыны буларак репрессияләнә. 1946–53 тә Арча р-н китапханәсендә эшли. 1956 елда аклана.

*Әд.:* А х у н о в А., З а м а н о в а Г. Беренчеләр // Сөембикә. 2001. № 8.

*Г.Р.Заманова.*

**ГАФФА́Р** (Гаффаров) Әхәт (Габделәхәт) Габдрахман улы (1.1.1949, Балык Бистәсе р-ны Олы Әшнәк а.), прозаик, драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1971). «Яшь ленинчы» (1971–74), «Социалистик Татарстан» (1974–79) г-таларында, «Казан утлары» ж-лында (1979–82) бүлек мөхәррире вазифасында. 1982–87 елларда ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркәтип. 1987–91 дә Татарстан мәдәният фонды җитәкчесе. 1991–99 «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Казан утлары» редакцияләрендә бүлек мөхәррире булып эшли. Г. иҗатына татар халык авыз иҗатының йогынтысы зур. Әсәрләренә эпик һәм шигъри башлангычларның бергә үрелүе, чынбарлыкның метафора аша чагылдырылуы хас. Ул — «Язлар моңы» (1973), «Гозер» (1975), «Кашан җыры» (1977), «Су астындагы чишмә» (1980), «Бишек» (1980), «Дәрья башы» (1985), «Яшиселәр алда иде әле» (1987) кебек психологик повестьлар авторы. Аларда кешенең даими рәвештә камиллеккә омтылуы, туган җиргә мәхәббәте сурәтләнә. «Әҗәт» (1972; рус теленә тәрҗемәсе «Долг», М., 1983) хикәясендә фронтта һәлак булганнар алдында әхлак бурычы, дуслар һәм туганнар өчен җаваплылык хисе тою турында сүз бара. «Яра» (1973) повесте катлаулы язмышлы геройлар, аларның борчулы уй-кичерешләренең сурәтләнүе б-н аерылып тора. «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» (1983; рус теленә тәрҗемәсе «Зерно и жернова», М., 1991), «Олы юлның тузаны» (1989), «Богау» (1998) романнарында, «Энә күзе» (2002) повесть һәм хикәяләр җыентыгында заманның аеруча четерекле проблемалары күтәрелә: экологик һәм әхлакый һәлакәт, халыкта милли үзаң уяну, авылларның бетү куркынычы, сталинизм китергән бәла-казалар. Г.ның драматургиясе дә үзенчәлекле. «Иртәгә улың булам» (1977 дә сәхнәләштерелә), «Җиләк вакыты бер генә» (1978 дә), «Соңгы ләкләк» (1980 дә), «Бер картлыкта, бер яшьлектә» (1981 дә) пьесалары Татар драма һәм комедия т-рында, Минзәлә, Чаллы, Эстәрлетамак, Оренбург театрларында куела. Замандашлары образларын чагылдырудан тыш, Г.ның күренекле тарихи шәхесләргә багышланган пьесалары да бар: Мулланур Вахитовның тормышыннан «Сызылып таңнар атканда» (1984 тә сәхнәләштерелә), Муса Җәлилгә багышланган «Хөкем» (1981 дә), Габдулла Тукай турында «Соңгы сәгать» (1986) драмалары. Г. ш.у. балалар өчен хикәяләр, татар әдәбияты һәм сәнгате турында публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, татар мәдәниятенең күренекле шәхесләре турында очерклар авторы. Әсәрләре рус, башкорт, эстон, әрмән, инглиз, испан, француз, немец телләренә тәрҗемә ителә.

*Әд.:* И д р и с о в Р. Кече күңелле һәм горур // Ватаным Татарстан. 1999. 22 гыйн.; Н у р у л л и н В. Талантлы әдип // Мирас 2004. № 8; А л е к с е е в а Т. С верой в человека // Лит. газета. 1986. 28 мая.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ГАФФАРИ́** (غفاري) Казый Әхмәд ибне Мөхәммәд әл-Казвини (? — 1567), фарсы тарихчысы. «Асар әл-билад» дигән әсәрендә Алтын Урда тарихы буенча мәгълүматлар һәм ханнарның шәҗәрәләре урнаштырылган.

Чыг.: Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.- Л., 1941. Ч. 2.

**ГАФФА́РОВ** Сөләйман Шәкүр улы (1.9.1909, Сембер губ., Сембер өязе Зур Чынлы а. — 26.11.1982, Казан), партия хезмәткәре. ВКП(б) ҮК каршындагы Партия эшен оештыручылар югары мәктәбен тәмамлый (1945, Мәскәү). 1925–29 елларда ВЛКСМның Арча кантон ком-тында эшләр идарәчесе, инструктор. 1929–31 дә Казанда ВЛКСМның Елга аръягы райкомы агитация бүлеге мөдире, секретаре. 1931–34 тә В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында пропагандист, партком секретаре урынбасары. 1934–35 тә ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты мәдәният һәм пропаганда бүлеге инструкторы. 1936–37 дә В.И.Ленин исем. Казан химия з-дының мәдәният сарае директоры. 1939–40 та ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты инструкторы, 1940–42 дә 3 нче секретаре. 1942–47 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда буенча секретарь (бүленеп). 1948–58 дә Казан пед. ин-тында укытучы. 1958–73 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы сәяси агарту йорты консультанты, мөдире (бүленеп, 1960–63 тә «Коммунист Татарии» ж-лының тарих-партия бүлеге мөдире). 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. Татарстанда партия төзелешенә караган язмалар авторы.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ГАФФА́РОВ** Харис Зариф улы (8.3.1935, Этнә р-ны Олы Этнә а.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1987), проф. (1998), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1994). 1958 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый . 1958–60 елларда Мөслим р-ның Иске Карамалы вет. табиблеге бүлеге мөдире, 1960–62 дә Мөслим р-ның Фрунзе исем. к-зы рәисе, 1963 тән Казан вет. ин-тында. 1987 тән Бөтенроссия вет. ин-тының эпизоотология лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре вирусология, микробиология, эпизоотологиягә, мөгезле эре терлекләрдә хламидия һәм микроплазма этиологияле йогышлы авырулар өйрәнүгә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Микоплазменные инфекции телят и меры борьбы с ними. Новосиб., 1979; Хламидиозы рогатого скота и меры борьбы с ними. К., 1980; Хламидиозы сельскохозяйственных животных. М., 1984.

**ГА́ХОВ** Фёдор Дмитриевич (19.2.1906, Ставрополь крае Черкесск ш. — 30.3.1989, Минск), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1943). проф. (1943). Белоруссия ССР ФА академигы (1966). 1930 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Свердловск (хәзер Екатеринбург) шәһәрендәге уку йортларында эшли. 1937–39, 1947–53 елларда Казан ун-тында, 1947 дән дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире. 1939–47 дә Төньяк Осетия пед. ин-тында матем. анализ каф. мөдире. 1953–61 дә Ростов, 1961–80 дә Белоруссия ун-тларында. Хезмәтләре комплекс үзгәрешле функцияләр теориясендәге кырый мәсьәләләр өлкәсенә карый. Г. Риманның мәгълүм кырый мәсьәләсен тулысынча һәм нәтиҗәле чишә, төрле класслы функцияләрнең чик мәсьәләләре теориясен төзи, шул мәсьәләләрнең механика һәм матем. физиканың сингуляр интеграль тигезләмәләре һәм гамәли мәсьәләләре б-н бәйләнешен тикшерә. Гиль-

берт мәсьәләсе, Риманның матрицалы мәсьәләсе, сызыкча һәм кире кырый мәсьәләләр буенча нигезле нәтиҗәләр ала, соңыннан «Гахов тигезләмәсе» дип аталган чишелүчәнлек шартын чыгара. Г. ның «Кырый мәсьәләләр» («Краевые задачи», М., 1977) монографиясе рус, инглиз һәм испан телләрендә берничә тапкыр нәшер ителә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Краевые задачи аналитических функций и сингулярные интегральные уравнения // Уч. зап. Казан. ун-та. 1949. Т. 109, кн. 4; Об обратных краевых задачах // Докл. АН СССР. 1952. Т. 86, № 4; Уравнения типа свертки. М., 1978 (автордаш).

*Әд.:* Фёдор Дмитриевич Гахов (к 70-летию со дня рождения) // Успехи матем. наук. 1976. Т. 31, вып. 4.

*Л.А.Аксентьев.*

**ГАЦУ́ЛИНА** Анна Фёдоровна (22.9.1910, Царицын ш. — 7.7.2004, Казан), балет артисткасы, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1945). Ставрополь пед. уч-щесен («башлангыч сыйныфлар укытучысы» белгечлеге буенча, 1930), Татар опера һәм балет театры каршындагы балет студиясенең уку-производство төркемен тәмамлый (1940). Казанда Эшче яшьләр театры (1931–33), Г.Камал



А.Ф. Г а ц у л и н а  Сөембикә (Ф.Яруллин. «Шүрәле») рольендә. 1945.

исем. Татар акад. театры (1933–37), Татар филармониясе (1937–39) бию төркемнәре артисты. 1939–62 елларда Татар опера һәм балет театрында балет солисты. 1962–65 тә әлеге театр каршындагы хореография студиясендә производство практикасы буенча педагог, 1965–87 дә Казан театр уч-щесендә бию дәресләре укыта. Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин, 1945) һәм Зөһрә (шул исем. балет, Н.Җиһанов, 1946) рольләрен беренче башкаручы. Хореографик партияләре арасында — Жизель (шул исем. балет, А.Адан), Сванильда («Коппелия», Л.Делиб), Мерседес («Дон-Кихот», Л.Минкус), Эсмеральда (шул исем. балет, Ц.Пуни), Одетта-Одиллия («Аккош күле», П.Чайковский), Тао-Хоа («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Зарема («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Су анасы («Алтын тарак», Ә.Бакиров) һ.б. бар. Г. Татар опера һәм балет театры балериналары арасында беренче булып ТАССРның атказ. артисты исеменә лаек була. Ачык, көчле артистлык таланты, тырышлыгы б-н таныла. Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша (1957). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н а р ы к о в  А. Анна Гацулина. К., 1957.

*В.Н.Горшков.*

**ГА́ШЕК** (Hašek) Ярослав (30.4.1883, Прага — 3.1.1923, Липнице ш., Чехословакия), чех язучысы. Танылган «Егет солдат Швейк» («Похождения бравого солдата Швейка во время мировой войны», 1921–23, язылып бетмәгән) сатирик романы авторы. 1915 елда Австрия-Венгрия гаскәренә алына, тиздән русларга әсирлеккә бирелә. 1918 нең апрелендә Кызыл Армия сафларына баса, Гражданнар сугышында катнаша, күп кенә газеталарда (ш.и. армия газеталарында) язышa. 1919 да Кызыл Армия частьләре б-н хәзерге ТР җирләрендә була, октябрь-декабрьдә Бөгелмә шәһәре хәрби коменданты ярдәмчесе булып тора. Бу вакытта булган вакыйгаларны 1921 дә Прагада басылган «Бөгелмә шәһәре коменданты» («Комендант города Бугульмы»), «Тәре күтәреп йөрү» («Крестный ход»), «Стратегик уңайсызлыклар» («Стратегические затруднения»), «Бөгелмәнең шөһрәтле көннәре» («Славные дни Бугульмы»), «Яңа куркынычлар» («Новые опасности»), «Потёмкин авыллары» («Потёмкинские деревни») исемле сатирик, юмористик хикәяләрендә һәм очеркларында чагылдыра. Рев-ция вакыйгаларын гротеск формасында тасвирлаган бу әсәрләр1960 елларда Татарстан матбугат басмаларында (С.И.Антонов тәрҗемәсендә) дөнья күрә. 1966 дан бирле Бөгелмәдә Г. музее эшләп килә.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 6 т. М., 1983–85.

*Әд.:* А н т о н о в  С.И. Гашек шагает по Поволжью. К., 1964; ш у л  у к. Если бы имел десять жизней. М., 1990.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ГА́ШЕК ЯРОСЛА́В ӘДӘБИ́-МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЕ́**, Бөгелмә шәһәрендә. Бөгелмә шәһәре хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма ком-ты карары б-н 1965 елда нигезләнә, 1966 да Бөгелмә төбәкне өйрәнү музее ф-лы буларак ачыла, 1981 дән ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее (хәзер ТРның Милли музее) ф-лы. 2007 дән муниципаль музей. 19 йөз ахырында кенәз Р.И.Нижерадзе милке булган, 1918 дә Бөгелмә хәрби комендатурасы урнашкан бер катлы агач йортны били. Бинага мемориаль такта куела (1963).



Бөгелмә шәһәрендә Ярослав Гашекның әдәби-мемориаль музее.



А.Ф. Гацулина.



Я. Гашек.

Музейның гомуми мәйданы 190 *м²*, фондларында 1489 саклау берәмлеге исәпләнә. 2 даими экспозиция эшли: мемориаль бүлек — комендант ярдәмчеләре канцеляриясенең интерьеры рәвешендә төп типологик әйберләр җирлегендә торгызыла, әдәби-документаль өлеш язучының тормышы һәм иҗади эшчәнлегенә багышлана. Музейда ш.у. Ярослав Гашекның тууына 120 ел тулуга багышлап ачылган «Ирония музее. Анонс» дигән даими күргәзмә эшли. Музей директорлары — С.И.Антонов (1965–66), Е.С.Плаксина (1967–88), Л.Л.Сергеева, 2001 елдан — О.Б.Шошева.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И.Г. Дом, где в 1918 жил и работал чешский писатель Я.Гашек // Материалы свода памятников истории и культуры РСФСР. М., 1984. Ч. 2; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

**ГАЯ́ЗОВ** Мансур Гаяз улы (5.10.1917, хәзерге Мари Респ-касы, Бәрәңге р-ны Бәрәңге а. — 19.11.1943), шагыйрь. Бәрәңге пед. уч-щесын тәмамлаганнан соң (1932), туган авылында укыта. 1936 елдан матбугат басмаларында патриотизм б-н сугарылган шигырьләре һәм поэмалары күренә башлый («Тормышны сөю», «Испанка»). Аерым шигырьләре «Алмаш» балалар альманахына (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940) күмәк җыентыкларына керә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронт газеталарында язышa. 1959 да «Шигырьләр» исемле җыентыгы дөнья күрә. Витебск өлкәсенең Ускорово авылы өчен барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Д а у т о в  Р.Н., Н у р у л л и н а  Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГАЯ́ЗОВА** Галия Гаяз кызы (13.4.1915, Казан губ. Спас өязе, хәзерге Алексеев р-ны Әшнәк а. — 17.7.2007, Оренбург ш.), журналист. ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты каршындагы Кичке марксизм-ленинизм ун-тын тәмамлый (1950). 1932 елдан Биләр р-нында чыга торган «Штурмга» г-тасында әдәби хезмәткәр һәм җаваплы чыгаручы, 1933–37 елларда тегү трестының күптиражлы «Большевичка» г-тасында (Казан), 1937–41 дә «Яшь сталинчы» г-тасында мәгълүмат бүлеге мөдире, җаваплы сәркәтип. 1941–68 дә ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында хәбәрче, «Соңгы хәбәрләр» бүлеге мөдире, а.х. тапшырулары мөхәррире, сәяси тапшыруларның баш мөхәррире була. Г. ның мәкаләләре, очерклары респ-ка басмаларында дөнья күрә. Радиода ТАССРның



Г.Х.Гаязова.

иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышын яктыртучы репортажлар, интервьюлар, респ-каның авыл хуҗалыгы, сәнәгате мәсьәләләренә караган тапшырулар цикллары б-н чыгышлар ясый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д ә р з а м а н Җ. Хәтер дулкынында // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998.

**ГАЯ́ЗОВА** Гөлсылу Хәлил кызы (13.10.1936, Тәмте р-ны Иске Барыш а. — 15.2.2004, БРның Нефтекамск ш.), буяучы. Соц. Хезмәт Герое (1974). 1953–56 елларда Яңа Уралда, 1956–58 дә Югары Тагилда, 1958–64 тә Белоярскида, 1964–88 дә Карманда (1981 дән штукатур-буяучылар бригадиры) ГРЭС төзелешендә эшли. Герой исеме 1973 елгы соц. йөкләмәләрне, планнарны арттырып үтәгәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. КПССның XXV съезды делегаты (1976), БАССР ЮС депутаты (1975–80).

*Әд.:* Б ә д р е т д и н о в Х. Кaһарманлык биеклегендәге тырышлык // Гүзәл Кама Тамагы — Камское Устье — жемчужина природы. К., 2006; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2007. Т. 2.


**ГАЯ́НОВ** Әбүзәр Гаян улы (6.8.1936, Тәкәнеш р-ны Акман а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, урманчы, ТАССР һәм РФнең атказ. урманчысы (1968, 1999). 1966 елда Идел буе урман-техника ин-тын (Йошкар-Ола) тәмамлый. 1954–55 елларда Чита өлкәсендәге Ингодинск урман хуҗалыгында урманчы ярдәмчесе, урманчы. 1956–75 тә ТАССР урман хуҗалыгы системасында: 1961 дән Минзәлә урман хуҗалыгы баш урманчысы, 1971 дән Татарстан урман хуҗалыгы идарәсе бүлеге башлыгы. 1975–80 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында сәнәгать-транспорт бүлегендә инструктор, 1980–84 тә сәнәгать бүлеге мөдире урынбасары. 1984–2001 дә ТР урман хуҗалыгы министры. 2003 тән Казан аграр ун-тында фәнни-пед. эштә. Хезмәтләре урманчылык эшенә һәм урман хуҗалыгы өлкәсенә карый. Урман хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлек төзүче (1995). 1985–90 елларда ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Упорядочить рубки ухода за лесом // Лесное хоз-во. 1974. № 12; Леса и лесное хозяйство Республики Татарстан. К., 2001.

**ГАЯ́НОВ** Зөфәр Гаян улы (14.5.1941, БАССРның Балтач р-ны Сәйтәк а.), нәкышьче, график, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, БРның атказ. рәссамы (1996). 1905 ел истәлеге исем. Мәскәү өлкә сынлы сәнгать уч-щесенең нәкышь бүлеген (1968) һәм Уфа сәнгать ин-тын (1981) тәмамлый. А.М.Дубинчик, Р.Б.Нурмөхәммәтов, М.М.Булгаков, О.А.Авсиян шәкерте. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1975). 1981–87 елларда Уфада М.В.Нестеров исем. Сынлы сәнгать музее директоры булып эшли. 1997–2000 дә БРның Рәссамнар берлеге рәисе урынбасары (1997–2000) һәм рәисе (2001–04). 1996 дан Уфа сәнгать ин-тының нәкышь каф. укытучысы. Г. — ефәккә язу, акварель һәм пастель остасы, графиканың офорт, линогравюра, гуашь кебек төрләрендә уңышлы эшли. Аның әсәрләренә кеше яшәешенең, әйләнә-тирә дөньяның асылын фәлсәфи кабул итү («Балачагым лампасы белән вакыт буйлап сәяхәт» тематик пастельләр сериясе, 1998–99; ефәккә төшерелгән «Кубаир. Урал батыр» триптихы, 1999) яисә ислам йогынтысында туган рухи ачылуны хисси чагылдыру («Минем ачышларым. Дин турында уйланулар» акварель һәм пастель эшләре сериясе, 1994–97) хас. Бу сыйфат борынгы истәлекләрне («Хәтер пәрәләре», пастель, 1995), дөнья мәдәнияте символларын («Вакыт буйлап сәяхәт» тематик сериясе, ефәк, катнаш техника, 1995–2001), ш.у. Габдулла Тукай («Илһам. Г.Тукай», сериясе, ефәк, 1990–93), Уфада яшәп, дөньядан иртә киткән татар рәссамы Наил Лотфуллин («Наил йолдызлыгы (Н.Лотфуллинга багышлау» триптихы), (ефәк, катнаш техника, 2000–01) кебек күренекле шәхесләрнең образларын сурәтләгәндә дә өстенлек итә. Табигать күренешләрен чагылдыруда Кытайның «го-хуа» нәкышь традицияләре («чәчәкләр, кошлар, үләннәр» нәкыше) һәм форманы муз. ритмлы итеп модельләү, сурәтләрнең контурларын аерымлаудан гыйбарәт татар бизәлеш сәнгате үзенчәлекләре бергә кушыла («Көзне тоемлау», 1983 һәм «Томанлы иртә», 1986 пейзажлары; «Тукай шигъриятенең хиссияте», 1992; «Таулар һәм сулар», 1997–98; «Табигатьне кабатламакчы булып», 1998; «Инзәрдә көзге иртә», 1997, «Карлы симфония», 2000 серияләре). Г. ның акварель пейзажларына хас булган төс һәм тоннар нисбәтенең нәфислеге, ап-ак битнең үтә күренмәле яссылыгы тудырган күк-һава хисе пастель эшләрендәге җете төсләр муллыгы, бизәк композициясенең яссылыкта геометрик җисемнәрне капма-каршы кую юлы б-н төзелгән динамикасы б-н контрастлаша («Балачагым лампасы», «Хөрмә һәм алтын чәчәкләр» натюрмортлары, икесе дә — 1995 һ.б.). Сурәтләү чараларының стилистикасы үзенең тамырлары б-н Ерак һәм Якын Көнчыгыш эстетикасына, аның эчтәлекне шартлы символлар, күп планлы яссылык композициясе тасвирлау хасиятенә тоташа. Г. композицияләрендә кытай иероглифлары һәм гарәп язуы кулланыла. Иҗаты: ефәккә язылган нәкышь әсәрләре — «Күлнең тууы» (1989), «Ибн-Фазлан Агыйдел буенда» (1990), «Кече Инзәр» (1992), «Су анасы» (1992), «Айгир. Ел фасыллары» (1997–2000); акварель — «Кышкы мәшәкатьләр» (1975), «Печән өсте» (1980), «Кинологлар» сериясе (1981), «Үзән» (1987), «Күңелем ачылу. Бабалар» (1998); офортлар — «Беренче тургай», «Урак өсте», «Җылы көн» (барысы да — 1984); пастель — «Саклык» (1994), «Остаханәдә» (1995), шәмаилләр сериясе (1992–93). Гамәли бизәлеш сәнгате өлкәсендә Г. — агачтан, металлдан, күннән ясалган эшләнмәләр (традицион сугыш, ау кораллары һәм кирәк-яраклары), рельефлы паннолар авторы.

Республика (1972 дән), төбәк (1975 тән), бөтенроссия һәм бөтенсоюз (1974 тән) күргәзмәләрендә, ш.и. графика һәм акварель эшләренең махсус күргәзмәләрендә, «Татарт» бөтентатар төбәкара күргәзмәсендә (С.-Петербург-Казан, 1991), «Артыш» иҗат төркеме күргәзмәсендә (Уфа, Магнитогорск, 1996; Казан, Чаллы, 1997), Төркиядә 3 нче «Тюрксой» иҗат лаб-ясендә катнашучыларның халыкара күргәзмәсендә (Анталия ш., 2000) катнаша. Г.Тукайның 110 еллыгына багышланган республика конкурс-күргәзмәсендә (Уфа, 1996) һәм «Сәнгатьтә тарих чагылышы» конкурс-күргәзмәсендә (Уфа, 1999) 3 нче премия б-н бүләкләнә. Шәхси күргәзмәләре 1974, 1995 (И.Гаянов б-н берлектә), 1996, 1997, 1998, 2001 дә Уфада, 2000 дә Иске Балтач авылында уза. Әсәрләре Уфада М.В.Нестеров исем. Сынлы сәнгать музеенда, «Урал» хәзерге заман сәнгате галереясында, «Шәрекъ» фонды» АҖдә; Казанда ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Габдулла Тукайның әдәби музеенда, Кытай, Германия, АКШ, Төркия, Франция һ.б. чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.





З.Г.Г а я н о в.
1. «Әверелеш шаһиты (Мәңгелек җыры)», «Кубаир. Урал батыр» триптихының үзәк өлеше. Ефәк, кытай карасы. 1999, Башкортстанның М.В.Нестеров исем. Сынлы сәнгать музее.
2. «Күңелдә туган сурәтләр», «Наил йолдызлыгы (Н.Лотфуллинга багышлау)» триптихының үзәк өлеше. Ефәк, катнаш техника. 2000–01.

*Әд.:* Галерея традиционного и современного искусства фонда «Восток»: Каталог. Уфа., 1997; Зуфар Гаянов. «Путь познания». Графика, акварель, живопись на шёлке: Каталог. Уфа, 2001; Гаянов Зуфар Гаянович // Сияние лун. Уфа. 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГӘЙТӘ́Н** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасының иске үзәне буенда. 2008 елда 435 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 79%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп. Клуб. Китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәр Габдрахман исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да чиркәү-приход мәктәбе (1893 тә ачыла), 3 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1999 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 235 ир-ат; 1959 да — 582, 1897 дә — 999, 1908 дә — 1118, 1926 да — 980, 1938 дә — 932, 1949 да — 833, 1958 дә — 712, 1970 тә — 862, 1979 да — 735, 1989 да — 456, 2002 дә — 458 кеше.

**ГӘПЛӘШҮ́ МӘХКӘМӘЛӘРӘ́**, мәхкәмә органнары. Сенатның 1754 елның 5 маенда чыккан Фәрманы нигезендә Казан губернасында шәһәр магистратлары һәм ратушалары каршында оештырыла. Сәүдә, ярминкә, вексель эшләрен карау б-н шөгыльләнә; мәхкәмә эшләре, башлыча, дәгъвачы һәм җавапка тартылучы катнашында телдән алып барыла, эшнең эчтәлеге һәм мәхкәмәнең карары махсус китапка языла. Бургомистр һәм сәүдәгәрләрдән сайланган ике утырышчы катнаша. Мәхкәмә карары б-н риза булмаучылар *өяз мәхкәмәләренә* апелляция б-н мөрәҗәгать итә алалар. Сенатның 1869 ның 4 мартында чыгарылган фәрманы б-н бетереләләр. Вазифалары җәмәгать судына тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 7. № 5145; Собр. 2. СПб., 1867. Т. 39. № 41475.

*Е.Б.Долгов.*

**ГӘР** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Көрен елгасы буенда. 2008 елда 298 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1678 дән мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман кисү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Г. дә тегермән була. 1876–97 елларда Ильинка чиркәве (архит-ра истәлеге) салына. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятский волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1191, 1887 дә — 1552, 1926 да — 1954, 1938 дә — 1270, 1949 да — 565, 1958 дә — 386, 1970 тә — 222, 1979 да — 102, 1989 да — 300, 2002 дә — 320 кеше.

**ГӘР** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 41 *км* төньяк-көнбатыштарак, Илләт елгасыннан 2,5 *км* читтәрәк урнашкан. 2008 елда 158 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 77%) яши. Агач эшкәртү цехы. Тулы булмаган урта мәктәп. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында Г.дә земство уч-щесе, тимерчелек, аяк киеме остаханәсе, 4 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 565 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Краснококшай (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязе Күлле Киме волостена керә. 1920 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 320, 1897 дә — 578, 1920 дә — 720, 1926 да — 721, 1938 дә — 780, 1949 да — 614, 1958 дә — 436, 1970 тә — 335, 1989 да — 200, 2002 дә — 117 кеше.

**ГӘР** авылы, Яшел Үзән тимер юл станциясеннән 3 *км* төньяктарак, Яшел Үзән шәһәре составында. 2002 елда 1200 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Машина-трактор станциясе. Тулы булмаган урта мәктәп. Китапханә. Петропавел чиркәве (1890–92 дә салына, архит-ра истәлеге). 1820 еллар тирәсендә Югары Вязовой авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1830 елларда Бишбатман авылыннан да берничә кеше күчеп утыра. Беренче исеме — Зелёный Дол. Гәр топонимы авылның икенче исеме буларак кулланыла һәм, 1930 елларда Зеленодольск шәһәре төзелгәннән соң, авыл Г. исеме б-н кала. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эшләре, Казан һәм Зөя шәһәрләрендә сату өчен утын кисү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. дә чиркәү, иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе (1882 ачыла), 2 ярма яргыч, 5 җил тегермәне, 12 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1730,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл районында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-ннарында, 1991 нең 2 августыннан Яшел Үзән шәһәр советы хакимияте буйсынуында. Халык саны: 1859 да — 589, 1897 дә — 1057, 1908 дә — 1170, 1920 дә — 1835, 1926 да — 1306, 1938 дә — 1399, 1949 да — 1000, 1958 дә — 1523, 1970 тә — 1775, 1979 да — 1643, 1989 да — 1292 кеше.



Гәр авылы. Петропавел чиркәве.

**ГӘР** посёлогы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 11 *км* көньяктарак, Чөкәнеш елгасы буенда. 2008 дә 8 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1929 да нигез салына. ТАССРның Чистай кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-ннарында. Халык саны: 1938 дә — 58, 1958 дә — 230, 1970 тә — 173, 1979 да — 182, 1989 да — 30, 2002 дә — 16 кеше.

**ГӘРӘ́ЕВ** Альберт Мәсгут улы (1940), мәхкәмә медицинасы белгече, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1992). 1965 елдан БАССРның Туймазы шәһәрендә мәхкәмә табибе. 1969 дан Башкорт мед. ин-тында (хәзерге Башкорт мед. ун-ты), 1984 тән мәхкәмә медицинасы каф. мөдире. Хезмәтләре мәхкәмә-мед. практикасында авыруларга диагноз куюга карый.

**ГӘРӘ́ЕВ** Әмирҗан Хөснимәрдән улы (10.2.1940, Сарман р-ны Карашай-Саклау а.), РСФСРның атказ. табибе (1989), медицина хезмәте генерал-майоры (1991). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлый (1962). 1989 елдан Бөтенармия традицион медицина һәм дәвалау үзәге җитәкчесе, 1993 тән Дәвалау-савыктыру үзәге җитәкчесе (Мәскәү). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГӘРӘ́ЕВ** Гегель Әмир улы (17.10.1937, Мөслим р-ны Түреш а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1981), проф. (1990), РСФСРның атказ. химигы (1989). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Бийск шәһәрендә эшли: «Алтай» фәнни-житештерү берләшмәсендә лаб. башлыгы, 1992 дән «Нитрометан» акц. пр-тиесендә фәнни директор. Хезмәтләре нитрокушылмалар, нитро-, нитрато-, нитрамино- һәм азидоспиртларның туендырылган һәм чиксез эфирлары, ш.у. азоллар һәм аларның нитрокушылмалары химиясе һәм технологиясе буенча. Г. җитәкчелегендә күп кенә азол кушылмаларын (тетразоллар, триазоллар, фуразаннар, фуроксаннар) синтезлау ысуллары булдырыла. Нитрометан, нитразапентан, нитротриазол, парадинитрозобензол, метилсульфамин кислотасы, нитратоэтанолның винил эфирын җитештерүнең сәнәгый технологияләрен эшли. 400 дән артык хезмәт авторы. Махсус технологияләр буенча уйлап табуга 165 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Триазолы и тетразолы. М., 1986; Химия нитрометана. Новосиб., 1995 (автордаш).

**ГӘРӘ́ЕВ** Илгиз Гәрәй улы (22.1.1931, Балтач р-ны Карадуган а. — 21.4.1988, Казан) хокук белгече, РСФСРның атказ. юристы (1981). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1952).



М.Ә. Гәрәев.

1952–54 елларда Теләче р-ны прокуратурасы тикшерүчесе, прокурор ярдәмчесе. 1954–57 дә ВЛКСМның Теләче райкомы секретаре. 1957–60 та Теләче, Саба р-ннарының халык судьясы. 1960–65 тә Чистай шәһәре мәхкәмәсе рәисе. 1966–69 да ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы. 1969 дан ТАССР МС каршындагы Дәүләт арбитражы баш арбитры.

**ГӘРӘ́ЕВ** Илдус Вәли (Минневәли) улы (19.3.1938, Әлмәт р-ны Ирекле а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе (1996), ТАССРның атказ. зоотехнигы (1983), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1992). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый (1969). 1956–57 елларда Арча р-ны «Октябрь Масра» к-зында зоотехник, 1958–61 дә Әлмәт р-ны а.х. инспекциясендә өлкән зоотехник, 1961–62 дә Әлмәт р-ны а.х. продуктларын әзерләү дәүләт инспекциясендә инспектор, 1962–1970 тә Әлмәт а.х. идарәсендә баш зоотехник, башлык урынбасары, 1970–71 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-тында а.х. бүлеге мөдире, 1971–72 дә «Красный Маяк» к-зы рәисе, 1972–74 тә Әлмәт р-ны а.х. идарәсе башлыгы, 1974–77 дә хезмәт ияләренең Тәтеш р-н советы башкарма ком-ты рәисе, 1977–83 тә «Скотопром» тресты директоры, «Татарскотопром» берләшмәсе башлыгы, 1983–84 тә а.х. министры урынбасары, КПСС өлкә ком-тының а.х. бүлеге мөдире урынбасары, 1984–88 дә КПССның Зәй шәһәр ком-ты 1 нче секретаре; 1988–89 да ТАССР а.х. сәнәгате дәүләт ком-ты рәисе урынбасары-министр, 1989–91 дә рәисе; 1991–92 дә ТССРның Икътисад дәүләт ком-ты рәисе урынбасары; 1992–98 дә Әлмәт р-ны һәм шәһәре хакимияте башлыгы, 1995 тән халык депутатларының Әлмәт шәһәре һәм р-ны берләштерелгән советы рәисе. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1995–99 елларда ТР халык депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГӘРӘ́ЕВ** Кавәс Гәрәй улы (27.8.1944, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.), идарә итү теориясе гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998). РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004). 1967 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1984 тән махсус матем. каф. мөдире, 2000 нән физик-матем. әзерлек ф-ты деканы. Хезмәтләре идарә итүнең матем. теориясендә теоретик төркемләү ысулларын куллануга карый. Параметрлары таралган һәм тупланган системаларны оптимальләштерү проблемасын чишү өчен теоретик төркемләү ысулын тәкъдим итә. Яссы һәм күчәр симметрияле очракларда җылылык-масса алмашуын оптимальләштерү мәсьәләләрен чишә, чик катламны оптимальләштерү мәсьәләләрендә беренче интегралларны табып булуын исбатлый. ТР ФАнең Х.М.Мөштәри исем. бүләге лауреаты (2006).

Х е з м.: Группы Ли и теория Нетер в проблеме управления с приложениями к оптимальным задачам пограничного слоя. К., 1994; Инвариантные вариационные задачи ламинарного пограничного слоя при различных режимах течения. К., 2003 (автордаш); Теория инвариантных вариационных задач в проблеме оптимального управления. К., 2005.

**ГӘРӘ́ЕВ** Мәгъсүм Гәрәй улы (7.2.1935, Питрәч р-ны Шәле а.), журналист, язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1976). 1958–67 елларда ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тының «Соңгы хәбәрләр» редакциясе хәбәрчесе. 1967–70, 1975–90 да «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, бүлек мөдире. 1970–75 тә ТАССР Журналистлар берлегендә баш консультант. 1991 дән «Татарстан хәбәрләре» г-тасында икътисад бүлеге мөдире. 1995 тән «Шәһри Казан» г-тасында, 1998 дән «Чаян» ж-лында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире, бер үк вакытта 1997 дән Казан ун-тында журналистика һәм социол. ф-тында укыта. Күренекле совет галимнәре, татар әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре, Татарстаннан чыккан Советлар Союзы Геройларына багышланган очерклар циклы, публицистик мәкаләләр, иҗат портретлары авторы. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1995), Татарстан Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм» бүләге лауреаты (1999).

Ә с ә р.: Арча җиренең ачык китабы. К., 1995 (автордаш); Мин Чуен Гәрәй малае... К., 2004; Җаның кыйбатмы, малыңмы? К., 2005; Яшәсен Мин!.. К., 2009.

*Г.Р.Заманова.*

**ГӘРӘ́ЕВ** Мәхмүт Әхмәт улы (23.7.1923, Чиләбе ш.), армия генералы (1989), хәрби фән. (1982) һәм тарих фән. (1992) д-ры, ТР ФА академигы (2001; 1994 тән мөхбир әгъза). Ташкент пехота уч-щесен (1941), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1950, Мәскәү), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (1959, Мәскәү) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында укчы корпус штабының оператив бүлек башлыгы урынбасары. 1945 елдан 5 нче армия штабының оператив бүлегендә. 1950–70 елларда Ерак Көнчыгыш, Урал, Белоруссия хәрби округларында югары командирлык вазифаларын башкара. 1970–71 дә Берләшкән Гарәп Респ-касы Кораллы Көчләрендә Баш хәрби киңәшченең штаб башлыгы. 1971 дән Урал хәрби округы штабы башлыгы. 1974 тән СССР Оборона министрлыгы аппаратында: Хәрби-фәнни идарә башлыгы, Генштабның Баш идарә башлыгы урынбасары, 1984 тән Генштаб башлыгы урынбасары. 1989–90 да Әфганстан Респ-касында баш хәрби киңәшче. 1990–92 дә РФ Оборона министрлыгы Ген. инспекциясе төркемендә. 1994 тән РФ Хәрби фәннәр академиясе президенты. Хезмәтләре хәрби теориягә һәм практикага, сугышлар тарихына карый. М.В.Фрунзе (1987), Г.К.Жуков (1998) исем. бүләкләр лауреаты. Дүрт Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз, «Татарстан Республикасы алдында казанышлар өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Общевойсковые учения. М., 1983; М.В.Фрунзе — военный теоретик. М., 1986; Советская военная наука. М., 1988; Маршал Жуков — величие и уникальность полководческого искусства. М., 1996; Афганская страда. М., 1998; Полководцы Победы и их военное наследие. М., 2003; Сражения на военно-историческом фронте. М., 2008.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГӘРӘ́ЕВ** Равил Мансур улы (16.4.1967, Әлмәт ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). 1994 елда Әлмәт нефть ин-тын тәмамлый. 1985–2001 елларда «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУында: нефть һәм газ чыгару цехы операторы, мастеры, башлыгы (1999 дан), җиһазларны тутыгудан саклау цехы (2000 нән) башлыгы. 2001 дән «Татнефть» АҖнең тутыгуга каршы көрәш һәм табигатьне саклау технологиясе бүлеге башлыгы. Уйлап табуга 9 патенты бар. Дәүләт бүләге «Татарстан Респ-касының көньяк-көнчыгышында табигатьне саклау чараларын геоинформация системасын планлаштыру һәм гамәлгә кертү максатында эшләү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГӘРӘ́ЕВ** Радик Арслан улы (23.3.1956, БАССРның Яңавыл р-ны Яңавыл пос. — 29.10.1996, Уфа ш.), җырчы (баритон), БАССРның һәм РСФСРның халык артисты (1983, 1988). Уфа сәнгать ин-тының вокал бүлеген (М.Г.Мортазина классы) тәмамлый (1983). 1980–87 елларда Башкорт филармониясендә солист, соңрак директор (1987–90); 1980 нән Башкорт опера һәм балет театры солисты, 1990–95 тә директоры. Партияләре: Фигаро («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Жермон («Травиата», Дж.Верди), Евгений Онегин (шул исем. оп., П.Чайковский), Акчәчән («Урал илчеләре», З.Исмәгыйлев), Эдвин («Чардаш королевасы», И.Кальман) һ.б. Төрле концерт программалары б-н чыгышлар ясый. Матур тембрлы, яңгыравыклы тавышка, сәхнә ягымлылыгына ия, башкару үзенчәлеге б-н аерылып тора. Бөтенроссия (1980), бөтенсоюз (1981) конкурслары лауреаты, «Кызыл канәфер» 8 нче халыкара фестивалендә (Сочи, 1983) «Гран-при» яулый.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГӘРӘ́ЕВ** Рамил Суфиәхмәт улы (26.2.1942, Актаныш р-ны Түмерҗә а.), фармаколог, мед. фән. д-ры (1990), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук эшли. Фармацевтика ф-тын оештыруда катнаша, 1989 дан фармакогнозия һәм ботаника курслары, фармакология каф. мөдире, проф. (1992). Хезмәтләре аз дәрәҗәдәге агулы фосфорорганик кушылмалар б-н холинэстераз ингибиторларының үзара тәэсирен өйрәнүгә карый. Г. тарафыннан антихолинэстераз һәм

антихолинэстераз булмаган фосфорорганик кушылмаларның тәэсир итешү механизмы, бу капма-каршылыкның метаболик нигезләре ачыклана. РФА Казан гыйльми үзәгенең Органик һәм физик химия ин-тында синтезлаштырылган күп сандагы фосфорорганик кушылмаларның химик төзелеше б-н фармакологик тәэсиренең үзара бәйләнешен (автордаш), ш.и. препаратларны: димефосфон — нерв системасы функциясен нормальләштерү, глицифон — тиренең яман шеш һәм яман шеш алды авыруларын дәвалау өчен, яңа антидепрессант тетрамезин, безнең илдә җитештерелгән оригиналь, күбекләнеп эрүчән ацетилсалицил к-тасын тикшерә. Г. җитәкчелегендә антисептик һәм ялкынсынуга каршы чара — эфоран клиникага кадәр сынап карала, ноотроп һәм антидепрессив үзлекле фосфорорганик кушылмалар интенсив өйрәнелә. «Демифосфон — нерв системасы функцияләрен нормальләштерүдә оригиналь дару препараты» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1994). Бөтенроссия фармакологлары фәнни җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм 3 патенты бар.

Х е з м.: Антагонизм фосфорорганических гетероциклов с холинэстеразным средством фосфаколом (параоксоном) // Эксперим. и клиническая фармакология. 1997. № 6; Глициновая мазь в лечении первично-множественного базально-клеточного рака кожи // Terra medica nova. 2002. № 4 (автордаш); Влияние пиримидиновых производных на систему регуляции активного транспорта кальция в иммунокомпонентных клетках // Бюл. эксперим. биологии и медицины. 2002. Т. 134, № 9 (автордаш).

**ГӘРӘ́ЕВ** Рауис Гыйният улы (24.4.1949, БАССРның Шаран р-ны Түбән Зәет а. — 3.6.2004, Казан), галим-агроном, икътисадчы, а.х. фән. д-ры (1999), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1972). 1966–72 елларда Шаран р-ның «Ык» к-зында эшли, 1970 тән колхозның баш икътисадчысы. 1972 дән КПССның Баулы, Тәтеш райкомнарында, 1982–85 тә КПССның Тәтеш район ком-ты 2 нче секретаре, 1985–86 да ТАССРның а.х. министры урынбасары. 1986–89 да «Татрапс» фәнни-җитештерү берләшмәсендә ген. директор, 1990–91 дә ТАССР Агросәнәгать ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары, 1991–96 да «Татрапс» АҖ ген. директоры, 1996–2004 тә Татарстан А.х. фәнни-тикшерену ин-тында ген. директор. Хезмәтләре Татарстанда рапс үстерү һәм куллану системасына карый. 1996 да респ-када рапс орлыгы җитештерү 70 мең, рапс мае — 6 мең, рапс түбе — 12 мең *т* га җитә. ТР Дәүләт бүләге рапс җитештерү, эшкәртү һәм кулланууның икътисади нигезен һәм фәнни яктан нигезләнгән технологияләрен эшләгәне һәм киң күләмдә гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Рапс — культура высокого экономического потенциала. К., 1996; Рапс: состояние, тенденция развития, перспективы. К., 1998; Методологические подходы и опыт организации деятельности научно-исследовательского учреждения в современных условиях. К., 2000.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ГӘРӘ́ЕВ** Рафаил Закир улы (15.9.1930, БАССРның Мишкә р-ны Кече Шады а.), төзүче-ташчы, Соц. Хезмәт Герое (1971), БАССР һәм РСФСРның атказ. төзүчесе (1967, 1981). Уфа шәһәрендә ФЗӨ-16 мәктәбен тәмамлый (1949), «Трест № 21» җитештерү берләшмәсендә эшли: ташчы


Р.З.Гәрәев.

(1949–60), ташчылар бригадасы бригадиры (1960–96). Уфа һәм Благовещенск шәһәрләрендә җитештерү комплекслары төзелешендә, Илеш, Уфа, Иглин р-ннарында авыл объектлары төзүдә катнаша. Герой исеме җитештерүдәге зур уңышлары, бишьеллык (1966–70) план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2006. Т. 2.

**ГӘРӘ́ЕВ** Рафаил Рифхәт улы (27.3.1948, Балык Бистәсе р-ны Олы Әшнәк а.), кинооператор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Бөтенсоюз кинематография ин-тын Б.И.Волчек остаханәсендә тәмамлый (1975). Хезмәт эшчәнлеген 1966 елда Казан кинохроника студиясендә кинооператор ассистенты буларак башлап җибәрә. 1975 тә «Юк» дип әйтә бел» («Умей сказать «нет», реж. Х.Нарлиев, «Төрекмәнфильм» студиясе) нәфис фильмы операторы, шул ук елда Казан кинохроника студиясенә кайта, анда 50 дән артык хроникаль-документаль һәм фәнни-популяр фильм төшерә. Аеруча күренекле эшләре арасында «Татарстан» (1976, реж. А.Сырых, фильм 1981 дә Мексикада үткәрелгән халыкара күргәзмәдә СССР Мәдәнияте көннәре программасына кертелә), «КамАЗ — без ул» («КамАЗ — это мы», 1977, реж. Х.Ф.Фәхретдинов), «Җиңеп кайтырга» («Вернуться с победой», 1978, реж. Н.К.Вәлитов), «Деринг оркестры» («Оркестр Деринга», 1990) фильм-концерты, «Илтуган скрипкасы» («Скрипка Ильтугана», 1993, реж. Г.С.Коков), «Заманнар бәйләнеше» («Связь времён», 1995, реж. В.Е.Игнатюк). 1996 дан Казан телевидение студиясендә кинооператор. Реж. Х.Ф.Фәхретдинов тарафыннан төшерелгән «Иман» (1999) һәм «Тамырлар» («Корни», 2000) фильмнарының баш операторы. Г.ның иҗат почеркына кадрда фильмның төп идеясенә, авторның стиленә җавап бирерлек киңлекне, масштаблылыкны оештыра, фильм геройларын характерлаучы чагылдыру чараларын таба белү, кадрлар эченддәге монтажны виртуоз эшләү хас. Г. тарафыннан төшерелгән фильмнар һәм киносюжетлар берничә мәртәбә елның иң яхшы сюжетлары һәм киножурналлары буларак билгеләнә. Шулай ук фотохәбәрче буларак та эшли, аның рәсемнәре халыкара фотокүргәзмәләргә куела.

*Е.П.Алексеева.*

**ГӘРӘ́ЕВ** Рәүф Әхмәт улы (30.11.1941, Алма-Ата), физиолог, биол. фән. д-ры (1990), Казакъстан Респ-касы МФАнең мөхбир әгъзасы (1996). Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлый (1965). 1980 елдан Казакъстан Милли ФАнең Кеше һәм хайваннар физиологиясе ин-тында: 1980 нән лимфа әйләнеше лаб-ясе мөдире, 1990 нан космонавтлар әзерләү фәнни программасының мед. бүлеге җитәкчесе, проф. (1993). Тикшеренүләре кеше физиологиясенә һәм космик медицинага карый. Г. тарафыннан кан-тукыма-лимфа алмашы бозылуы б-н бәйле инсулин заруриятле диабетка, атеросклерозга һ.б.га бәйләнешле эритроцитлар мембранасына сеңдерелгән макромолекулаларның кан-тукыма-лимфа алмашы механизмы өйрәнелә. СССР уйлап табучысы. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Казакъстан татарлары ассоциациясе президиумы әгъзасы.

Х е з м.: Транскапиллярный обмен и лимфообразование. А.-А., 1989 (автордаш); Методики исследования гематолимфатического обмена. А.-А., 1991 (автордаш).

**ГӘРӘ́ЕВ** Роберт Дәүләтша улы (4.5.1940, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1983), проф. (1993), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 2003). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм 1965–73 елларда шунда ук эшли. 1973 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), 1984 тән терлекләрне химик чаралар ярдәмендә саклау бүлеге мөдире. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә, вет. практикасы, вет. токсикологиясе һәм радиобиологиясе өчен яңа химиотерапевтик чаралар синтезы һәм җитештерүгә карый. Г. өч валентлы фосфор кушылмаларының чиксез электрофиль кушылмалар б-н реакциягә керү сәләтен тикшерә. А.х. һәм вет. өчен биологик актив элементорганик кушылмалар — а.х. терлекләрен техноген һәм табигый килеп чыгышлы югары токсинлы агулардан төркемле саклау чараларын — синтезлый; аларны җитештерү технологияләрен эшли. Ветеринария практикасына бипин-люкс (бал кортларында варроатозны дәвалау өчен), аллилбромин майлагычын (а.х. һәм кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең катлаулы инфекцияләнгән яраларын дәвалау өчен), мелапол (кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең мехларын тизрәк өлгертү өчен), тозифен (радиацион зарарланудан дәвалау һәм аның профилактикасы өчен) һ.б. препаратлар кертә; ш.у. ветеринар күзәтү астындагы төрле объектларда техноген һәм табигый килеп чыгышлы югары токсинлы агуларны индикацияләүнең яңа ысулларын эшли. Уйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О взаимодействии замещённых метиленамидофосфитов с альфа-галогенкарбонильными соединениями // Журн. общей химии. 1983, Т. 53, вып 7 (автордаш); Взаимодействие диалкилизоцианатофосфитов с ацетоуксусным эфиром // шунда ук. С. 1478–1483 (автордаш).

**ГӘРӘ́ЕВ** Филүс Фазлыйәхмәт улы (24.10.1941, БАССРның Краснокама р-ны Иске Җаньегет а. — 1.4.1990, Уфа), җырчы (баритон), БАССРның халык артисты (1987).



В.Х.Гәрәева.



Н.Х. Гәрәева.

Уфа сәнгать уч-щесенең вокал бүлеген (Р.Р.Әхмәдиева классы) тәмамлый (1966). 1965–90 елларда Башкорт дәүләт филармониясендә эстрада һәм муз. лекторий солисты. Г. — башкорт, татар халыклары, ш.у. композиторларның җырларын башкаручы һәм пропагандалаучы танылган солистларның берсе. Тавышы йомшак тембрлы, матур, тирән яңгырашлы; башкару алымы эчтәлекле, образлы булуы, шул ук вакытта югары сәхнә культурасы б-н аерылып тора.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГӘРӘ́ЕВ** Хәмит Гәрәй улы (26.9.1935, Балтач р-ны Куныр а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР һәм РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1989, 1995). 1970 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. Хезмәт юлын 1951 елда Балтач р-нының «Якты юл» к-зында колхозчы булып башлый, 1962–69 да агроном, 1969 дан к-з рәисе. Аның җитәкчелегендә хуҗалыкта игенчелек һәм терлекчелеккә алдынгы технологияләр кертелә. А.х. үстерүдәге уңышлары өчен к-з КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байрагы (1985), СССР (1986) һәм ТАССР ВДНХсының дипломнары (1987, 1988) б-н бүләкләнә. Нәселле терлекчелекне үстерү буенча бөтенроссия һәм бөтенсоюз конкурсларында җиңүче була. Г. «Почёт билгесе» ордены (1984), медаль б-н бүләкләнә.

**ГӘРӘ́ЕВА** Венера Хәсән кызы (25.6.1943, Саба р-ны Сүлә а.), хормейстер, педагог, ТАССРның халык артисты (1987). Казан музыка уч-щесен (1968), Казан консерваториясен (1974) тәмамлый. 1961–64 елларда хор артисты, 1972 елдан ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең хор дирижёры, бер үк вакытта 1990 нан Казан музыка уч-щесендә халык музыкасы укытучысы. Ансамбльдә эшләү дәверендә Ә.Абдуллин б-н берлектә «Җомга», «Су буенда», «Әзифә», «Уел» һ.б. композицияләрне иҗат итә. «Чуаш сюитасы», «Хәтердә һәм җырда», «Бер гаилә булып», «Сәйдәшем», «Сабантуй», «Безнең мирас», «Корбан бәйрәме», «Рамазан» һ.б. концерт программаларын әзерләүдә катнаша. Г. — татар музыка фольклоры һәм милли вокаль башкару осталыгы белгече булып таныла. Тәҗрибәле педагог буларак, Г. ансамбль җырчылары б-н индивидуаль эшләүгә аерым игътибар бирә. Укучылары арасында ТРның атказ. артистлары Л.Бичарина, И.Исламов, Ф.Мирзануров һ.б. бар. Җыр һәм бию ансамбльләренең бөтенроссия конкурсы лауреаты (Мәскәү, 1986).

*В.Н.Горшков.*

**ГӘРӘ́ЕВА** Нелли (Наилә) Хәким кызы (18.11.1940, Казан), драма актрисасы, педагог, ТАССРның халык һәм РФнең атказ. артисты (1976, 2010). Казан Зур драма театры каршындагы студиянең татар бүлеген тәмамлый (1961) һәм Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Театр сәхнәсендә беренче ролен (Рәхилә — «Беренче мәхәббәт», Х.Вахит) студиядә укыганда уйный. Беренче уңыштан соң башкарылган Зөбәрҗәт («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Зөбәйдә («Зөбәйдә — адәм баласы», Ш.Хөсәенов) һ.б. рольләре Г. иҗатының төп темасын — яшь кызның шәхес булып җитлегүен, яшь кызлар характерында иң мөһим әхлакый юнәлешләр формалашуын билгели. Бу теманы ачуда Ч.Айтматовның «Кызыл яулыклы гүзәлкәем» повесте буенча эшләнгән «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Әсәл образын иҗат итүе актрисаның аеруча зур уңышы булып таныла (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1967). Кеше табигатенең бөтенлеген, кичерешләренең тирәнлеген, күңеленең нечкә, тиз җәрәхәтләнүчәнлеген, характерының ныклыгын үзенә генә хас нәзакәтлелек һәм дәрт б-н чагылдыра. Драматик рольләр б-н берләштән (Гөлтекин — «Айдын», Д.Җаббарлы; Изабелла — «Чамасына күрә чарасы», У.Шекспир) комик рольләрне дә сокландыргыч итеп, мавыгып уйный. Рәмзия, Банат («Күк капусы ачылса», «Карлыгач канат кага», Х.Вахит), Диләфрүз («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Бибкәйнур («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Сюзанна («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), Марианна («Тартюф», Ж.Мольер) рольләрен башкарганда, пьесаның драматургик материалыннан чыгып, актриса образларның һәркайсына төгәл характеристика, күп сыйдырышлы, ачык чагылышлы детальләр таба. Соңга таба характерлы героинялар рольләренә күчә, шактый зур, күренекле образлар тудыра: Сәмидә («Кичер мине, әнкәй», Р.Батулла), Арзыгол («Ахырзаман», Ч.Айтматов), Күршекәй («Бичура», М.Гыйләҗев) һ.б. Ш.Хөсәеновның «Әни килде» спектаклендәге Ана образын иҗат итеп, Г. хатын-кыз күңеленең яңа, катлаулы якларын ача.



Н.Х.Г ә р ә е в а Әсәл ролендә (Ч.Айтматов әсәре буенча «Гүзәлем Әсәл»).

Күп еллар дәвамында иҗат эшчәнлеген педагоглык хезмәте б-н үреп алып бара: Казан театр уч-щесендә (1989–92), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (1992 дән) актёрлык осталыгыннан дәресләр бирә. «Дуслык» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Т и м б и к о в а К. Мәхәббәт бер генә // Казан утлары. 2000. № 11; Г а б я ш и Р. Девочка с Подлужной // Казань. 2000. № 4.

*Д.Ә.Гыйммранова.*

**ГӘРӘ́ЕВА** Салисә Гәрәй кызы (6.11.1938, Минзәлә р-ны Тулбай а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1968). Алабуга китапханә техникумын тәмамлагач (1956), Минзәлә р-ны Калмия авылы китапханәсе мөдире булып эшли. 1962 елдан Чиләбе шәһәрендә яши. 1963–69 елларда китапханәдә бүлек мөдире, 1969–70 тә — өлкә Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында, 1984–88 дә «Сигнал» сәнәгать берләшмәсенең җирле радиотапшырулар редакциясендә мөхәррир. 1989–91 дә «Дуслык», «Туган як» г-таларында җаваплы сәркәтип, бер үк вакытта өлкә телевидениесендә татарча «Чишмә» тапшыруларының алып баручысы һәм мөхәррире. 1963 елдан Чиләбедә М.Җәлил исем. татар-башкорт әдәби берләшмәсен оештырып, күп еллар аны җитәкли. 1991 дә Казанга кайта. «Татарстан хәбәрләре» г-тасы редакциясендә эшли, 1995–2003 тә «Мәдәни җомга» г-тасында. «Уралым» (1979), «Тау сукмагы» (1988), «Офыклар-Прозрение» (Чиләбе, 1991), «Йолдыз яңгырлары» (2006) исемле шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләрендә Урал табигатенең матурлыгына, аның олы җанлы кешеләренә дан җырлый. Алар нечкә лиризм, тирән фәлсәфи фикерләр, хезмәт һәм мәхәббәт романтикасы һәм зур гражданлык тойгылары б-н өртелгән.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Матурлык җырчысы // Килер бер көн. К., 1998; Ш ә р и ф у л л и н а Э. Энҗе бөртекләреннән тезмә // Казан утлары. 2008. № 4.

**ГӘРӘ́Й** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Морасаның уң кушылдыгы (Кече Чирмешән елгасы бассейны). Озынлыгы 18 *км*, бассейнының мәйданы 156,4 *км²*. Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Яңа Әмзә авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Яңа Әлмәт авылында. Түбән агымда елга тугае сазланган. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 108 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 60%. Г. елгасының 2 дән алып 11,6 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар, алар арасында иң зурысы Көрнәле инеше (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Г. елгасы ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м³/с*. Суы бик каты (язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада күләме 0,9 млн.м³ *га* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ГӘРӘ́Й** (Гәрәев) Әюп Гәрәй улы (22.4.1910, Уфа губ., Минзәлә өязе Иске Дөреш а. — 1967, Пермь ш.), шагыйрь. Алабуга пед. тех-

никумын тәмамлаганнан соң, укыта. «Эшче» (Мәскәү) г-тасы б-н хезмәттәшлек итә, Мәскәү чит телләр пед. ин-тында укый. 1927 елда «Азат хатын» ж-лында «Буранлы таң» исемле беренче хикәясе дөнья күрә. Матбугатта шигырьләре, поэмалары, очерклары басыла. «Межасыз шигырьләр» (1932), «Яз шатлыгы» (1966) исемле шигырь китаплары авторы. Поэзиясенә эмоциональлек, нечкә лиризм хас.

**ГӘРӘ́Й** (Гәрәев) Йосыф Ибраһим улы (20.3.1904, Уфа губ., Бәләбәй өязе Базгыя а. — 2.3.1988, Уфа ш.), язучы. Башкорт, татар, рус телләрендә иҗат итә. 1923 елдан БАССРның Чакмагыш, Шаран, Бакалы һәм Бәләбәй р-ннарында укыта. 1929–30 елларда мәктәпләрдә һәм оешмаларда башкорт телен гамәлгә кертү буенча Бәләбәй кантон комиссиясенең җаваплы сәркәтибе. 1931–36 да БАССРның Мәгариф халык комис-тында читтән торып укыту инспекторы, башкорт телен һәм әдәбиятын укыту инспектор-методисты. 1937–39 да БАССР Язучылар берлеге идарәсе җаваплы сәркәтибе. 1940–58 дә Казакъстан һәм Таҗикстанда төзелешләрдә эшли. 1958 дән кабат Уфада. Шигырьләр, поэма, хикәя, повесть, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, башкорт теле һәм әдәбиятыннан урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы. Беренче китаплары татар телендә басыла («Истәлекләр», М., 1930; «Тимер», К.–М., 1932; «Пионерлар килде», 1932). Балаларга багышланган «Суртан әмере буйынса» (Өфө, 1937), «Өрөргә нисек өйрәнде көсек» (Өфө, 1962), «Зирәк Куян» (Өфө, 1969) кебек җыентыклар, Социалистик Хезмәт Герое Батырова Банат турында язылган «Банат Батырова» (1966) документаль повесте авторы. Г. башкорт теленә А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, А.П.Чехов, С.Я.Маршак, Г.Тукай һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итә. 1940 та репрессияләнә; 1957 дә аклана.

Ә с ә р.: Шиғырҙар. Өфө, 1964; Якташтарга хат: Шиғырҙар, поэмалар, балладалар. Өфө, 1984.

*Әд.:* С а ф у а н о в С. Шағир тураһында һүҙ // Ағиҙел. 1974. № 5; Ә х м ә ҙ и е в В. Тынгыһыҙ ижад // Ағиҙел. 1979. № 3.

**ГӘРӘ́Й** (Гәрәев) Рәшит Гәрәй улы (15.4.1931, Минзәлә р-ны Малтабар а. — 23.6.1999, шунда ук), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1959). 1959–80 елларда «Казан утлары» ж-лында бүлек мөдире, соңрак Татарстан китап нәшриятында балалар-яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир булып эшли. «Беренче хисләр» дип аталган беренче шигырьләре һәм поэмалары тупланган җыентык 1952 дә басыла. Иҗатының башлангыч чорында Г. нең шигырьләрендә яшьлек романтикасы, мәхәббәт, тугрылык, туган як табигате кебек мотивлар өстенлек итә. Соңрак үзәктә авыл кешеләре, аларның хезмәте, гадәт-йолалары; шагыйрь геройларының күңел дөньясын тирәнрәк сурәтләргә омтыла. «Һаваларда йолдыз» (1965), «Төнге учаклар» (1968), «Сиңа тартыла күңел» (1970), «Синдә калам» (1981), «Син бер генә» (1989), «Тургайлы тугайларым» (1991) җыентыклары авторы. Г.нең шигъри теле кыскалыгы һәм ачыклыгы, сәнгатьчә яңгырашы б-н аерылып тора.

*Әд.:* Рәшит Гәрәйгә 60 яшь // Казан утлары. 1991. № 5. *Г.М.Габделхакова.*

**ГӘРӘ́Й** (Гәрәев) Шамил Мөхәммәтгали улы (31.12.1916, Казан — 22.3.1946, Гливице ш., Польша), шагыйрь. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Сигналчы җыры» исемле беренче җыентыгы 1932 елда басыла. Иҗатында төп мотивлар — мәхәббәт, табигать. «Звено җыры» (1934), «Тормыш иртәсе» (1937), «Тормыш чәчәкләре» (1941) шигъри җыентыклары авторы. Татар теленә М.Ю.Лермонтов, А.П.Чехов, А.Л.Барто һ.б. авторларның әсәрләрен тәрҗемә итә.

**ГӘРӘЙЛӘ́Р**, Кырым ханлыгында идарәче династия (1443–1783), *Хаҗигәрәй хан* варислары. Кайбер тарихчылар (М.Г.Госманов), династиянең исеме Үзәк Азиядәге монгол һәм төрки телле халыкларда киң таныл алган Гәрәй (Кирәй) нәселе яки кабиләсе атамасыннан килә, дип фаразлыйлар.

Г. хакимияте эре феодаль ыруглар (Ширин, Барын, Кыпчак, Мангыт, Аргын) йогынтысы нәтиҗәсендә чикләнгән була. 15 йөз ахырыннан, 1478 елда солтан Мәхмүд II Кырым тәхетенә Хаҗигәрәй улы *Миңлегәрәйне* утыртканнан соң, Г. төрек солтанының вассалларына әвереләләр. Рәсми вассаллык мөнәсәбәтләре Исламгәрәй хан (1584–88) заманында беркетелә, шуннан соң *хөтбә* укыганда солтан исеме хан исеме алдыннан атала башлый. Г.нең солтанга бәйлелеген күчәйтү өчен аларның гаилә әгъзаларын Родос утравында яшәтү гадәткә керә. Кайберләрен солтан үзенә кулай булмаган ханнар урынына Кырым хөкемдары итеп билгели. Г. Төркиянең Польшага, Молдавиягә, Рус дәүләтенә каршы алып барган сугышларында катнашалар, рус, поляк-литва һ.б. җирләргә һөҗүмнәр оештыралар. Г. гаиләсе әгъзалары Кырым ханлыгының югары хакимият органы — диван составына керә. Кырым ханлыгын Россиягә кушкач (1783), соңгы хан Шаһибгәрәй тәхеттән ваз кичә. Г.нең бер өлеше Россия дәүләтенә хезмәткә керә, бер өлеше Төркиягә күченеп китә. Г. нәселенең кайбер варислары хәзер дә Англиядә яши.

*И.Л.Измайлов.*

**ГӘҮҺӘРШАДА́Д** (1481 — 1546 дан соң), Казан ханбикәсе, 1531–45 елларда Казан ханлыгындагы иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда актив катнашучы, 1531–33 тә балигъ булмаган Җангали хан заманында дәүләт б-н идарә итә. *Ибраһим хан* б-н *Нурсолтан бикәнең* кызы, *Мөхәммәдәмин* ханның сеңлесе. Мәскәү тарафдарлары *Булат Ширин*, *Нарыйк улы Чура бәк*, Кече Али морза һ.б. б-н берлектә Казан ханлыгының эчке тормышында һәм тышкы сәясәтендә Кырым ханнары йогынтысы көчәюгә каршы көрәшә, Рус дәүләте б-н мөнәсәбәтләрне тыныч юл б-н җайга салуны яклый. 1531 дә *Сафагәрәй ханны* Казан тәхетеннән кууны оештыручыларның берсе. Җангали хан балигъ булганнан соң (1533), аны нугай бәге Йосыф кызы *Сөембикәгә* өйләндерүне хуплый. Казан тәхетенә 1536 да кабат утырган Сафагәрәй яңадан Мәскәү бөек кенәзе хакимиятенә каршы кискен сәясәт үткәрә башлый. 1546 да Казан аксөякләренең кырымлылар идарәсенә каршы чыгуы нәтиҗәсендә Г. җитәкчелегендәге Мәскәүгә йөз тотучы төркем кабат Сафагәрәйне тәхеттән куга ирешә. Ләкин Сафагәрәй тиздән нугайлар ярдәмендә тәхетне үзенә кире кайтара, Г. үз тарафдарлары б-н эзәрлекләүләргә дучар ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

Чыг.: Казанская история. М.- Л., 1954.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Казан ханнары. К., 1995; У р м а н ч е е в Ф.И. Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә. К. 1997; Ә м и р х а н о в М.Ә. Гәүһәршад. К., 2009; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; С а б и р з я н о в Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1999; П о х л ё б к и н В.В. Татары и Русь: Справ. М., 2000.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ГВО́ЗДЕВ** Иван Михайлович (17.2.1827, Мәскәү — 14.11.1896, Казан), мәхкәмә медицинасы белгече, мед. д-ры (1868), Казан ун-тының атказ. профессоры (1889). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1855), шунда ук эшли. 1868–95 елларда Казан ун-тында, 1892–95 тә мед. ф-ты деканы, 1871 дә мәхкәмә мед. кафедрасын оештыручы. Г. үз хезмәтләрендә беренче булып асфиксиягә гыйльми билгеләмә бирә — организмның канда һәм тукымаларда кискен рәвештә кислород җитмәү б-н бәйле үзенчәлекле патологик халәтен, асфиксия механизмнарын ачыклый. Казан мәхкәмә медицинасы эшендә асфиксиянең төрле төрләрен тикшерү шуннан соң әйдәп баручы фәнни юнәлешкә әверелә. Г. җитәкчелегендә каф. каршында музей, фотолаборатория оештырыла, мәхкәмә медицинасы экспертизаларын үткәрү өчен морг ачыла.

Х е з м.: Материалы для изучения асфиксии преимущественно с точки зрения медицинского правоведения. К., 1868; Первичный наружный осмотр мёртвого тела известной личности. К., 1878; Несколько слов о состоянии судебной медицины в настоящее время. К., 1890.

*Әд.:* З а г о с к и н М.П. Биографический словарь профессоров и преподавателей Казанского Императорского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**ГВОЗДЬ** Юрий Константинович (19.9.1949, Берлин), кинооператор, ТР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1993, 2000). Бөтенсоюз кинематография ин-тын В.В.Монахов остаханәсендә тәмамлый (1973), операторлык эшенә А.Д.Головня җитәкчелегендә өйрәнә. 1967 елдан — «Татарстан» Дәүләт телерадиокомпаниясендә. Реж. Р.Г.Кадыйрова б-н берлектә татар муз. культурасы антологиясен булдыра — Илһам Шакиров, Ренат Ибраһимов, Флёра Сөләйманова, Таһир Якупов турында фильмнар төшерә. Реж. В.И.Беспалов һәм кинодраматург Р.А.Рубцова б-н иҗади дуслыкта КамАЗ кешеләре турында «... Плюс йөрәк» («...Плюс сердце», 1982, 10 нчы телефильмнар фестивале лауреаты, Алма-Ата), «Килешү акчадан кыйммәтрәк» («Договор дороже денег», 1984, 11 нче телефильмнар фестивале лауреаты, Киев), «Кем соңгы булып көлә» («Кто смеётся последним», 1986, документаль һәм телефильмнар смотры лауреаты, Орджоникидзе ш.); экология пробле-

малары турында — «Кояш яктырткан наратлар» («Сосны, освещённые солнцем», 1972); пианист Рэм Урасин турында «Бу мәңгелек могҗиза» («Это вечное чудо», 1992, телефильмнар фестивале лауреаты, Ростов-Дон ш.), яшь музыкантлар турында «Зур уен» («Большая игра», 2000) фильмнарын төшерә. Психол. портрет остасы буларак, Г. камера ярдәмендә персонажның күзләре уйнавын, ихтыярсыз эшләнгән кул хәрәкәтләрен күреп ала, фикер йөрешләрен аңлатып бирә. Ул төшергән кадрлар сыгылмалы, хәрәкәтләр күп. Реж. А.А.Карасикның «Камада гигант үсә» («Растёт гигант на Каме», 1977), «Авыл басу капкасыннан башлана» («Село начинается с околицы», 1982) фильмнарында оператор шигъри текстның ритмик формасын кадрның төгәл монтаж фразалары ярдәмендә оста үреп бара. Г. тарафыннан реж. Э.Х.Үтәгәнов б-н берлектә төшерелгән 12 серияле «Мырау Батыр» балалар муз. фильмы (1989), «Азат Мәргән» тарихи драмасы (1991), комп. Сара Садыйкова иҗаты турында «Моңсара» (1996), бөек татар музыканты Салих Сәйдәшев һәм аның заманы фаҗигасен ачкан «Сәйдәш» (2000) фильмнары Татарстан кинематографиясе өлкәсендә зур вакыйга булып танылалар. Композиция төзелешенең төгәллегенә, фикер тирәнлегенә, поэтик хисләрнең үткенлегенә ирешү сәләте Г.га күп кенә фильмнарның бер үк вакытта сценарий авторы да, куючы режиссёры да һәм операторы да булу мөмкинлеге бирә: «Прелюдия» (1974), «Күңел биреп башкарылган очыш» («Душой исполненный полёт», 1975), «Гримсыз» («Без грима», 1991). Татар әкият-балетлары нигезендә иҗат ителгән «Тылсымлы торна» («Волшебный журавль», 1987) фильмы Г.ның авторлык фильмнары арасында аерым урын алып тора. Анда оператор һәм куючы режиссёрның иҗат алымы, сәнгать б-н җанлы табигатьнең бердәмлеге идеясе аеруча ачык чагыла. 1990–95 елларда Россия Кинематографчылары берлеге идарәсе әгъзасы. Медаль б-н бүләкләнә.

*Е.П.Алексеева.*

**ГЕ** Александр Генрихович (26.10.1842, Казан — 11.7.1907, шунда ук), дерматовенеролог, мед. д-ры (1868), проф. (1884), Казан ун-тының атказ. профессоры (1897). 1865 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1866 дан Казан губернасы земство хастаханәсендә, хатын-кызлар сифилис авырулары бүлеге мөдире, 1870 елда чит илгә тире һәм венерик авырулар өйрәнү өчен командировкага җибәрелә (Вена, Вюрцбург ш.). Г. Казан ун-тында тире һәм венерик авырулар кафедрасына һәм клиникасына нигез салучы, 1872–1907 елларда каф. мөдире, 1896 дан Казан ун-тының мед. ф-ты деканы. Г. мед. фәне тарихына күренекле рус дерматологларының берсе буларак керә. Хезмәтләре югары төзелешле хайваннар организмына хининның физиологик тәэсир итүенә: үзәк нерв системасына, йөрәккә, кан тамырларына хинин тәэсирен тәҗрибәдә өйрәнүгә, ш.у. сифилиска һәм фәхишәлеккә каршы көрәш проблемаларына карый. «Венерик авырулар курсы» («Курс венерических болезней») дәреслеге (1880; 8 басма, 1903) авторы. 1 нче дәрәҗә (1901), 2 нче дәрәҗә (1885), 3 нче дәрәҗә (1881) Изге Станислав, 3 нче дәрәҗә Изге Апостолга тиң кенәз Владимир (1898), 2 нче дәрәҗә Изге Анна (1890) орденнары, Император Александр III истәлегенә Александр тасмасындагы көмеш медаль һәм Кызыл Хач билгесе (1879) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Редкий случай глубокого шанкра уретры. СПб., 1884; Сифилис и сельское население. К., 1892.

*Әд.:* Профессор Александр Генрихович Ге — основатель казанской дерматологической школы // Казан. мед. журн. 1968. № 2.

**ГЕЙНС** (Гейнц) Александр Константинович (21.8.1834 — 29.12.1892, Ницца ш., Франция; Казанда җирләнгән), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, географ, этнограф, генерал-лейтенант (1881). Дворян нәселеннән. Дворяннар полкында курс (1853, С.-Петербург), Ген. штабның Николай исем. академиясен (1859) тәмамлый. 1853 елдан хәрби хезмәттә. 1854–55 елларда (Кырым сугышы елларында) Севастополь оборонасында, 1863 тә поляклар күтәрелешен бастыруда катнаша. 1865 тән Ген. штабның «махсус эшләр һәм гыйльми шөгыльләр» Баш идарәсендә хезмәттә. Соңыннан Дала-чүлләрне билгеләү-бүлүне законлаштыру комиссиясе составында Төркестанга җибәрелә. 1867–69 да Төркестан ген.-губернаторы канцеляриясе башлыгы (Ташкент). Коканд ханлыгын һәм Бохара әмирлеген яулауда, Россиянең Урта Азиядәге биләмәләрендә адм. реформалар уздыруда катнаша. 1870–77 дә Юллар министрлыгында; 1871 дән Гомуми эшләр департаменты директоры. Кара диңгез һәм Азов диңгезе ярларында тимер юллар һәм портлар төзү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1877–78 дә Тургай өлкәсендә хәрби губернатор. 1878–80 дә Одесса шәһәре башлыгы. 1880–82 дә Казан губернаторы. Ул идарә иткәндә Казанда музыка мәктәбе ачыла (1881), беренче телефоннар куела. «Волжско-Камское слово» г-тасын чыгаруга булышлык итә (1881–82). Рус География һәм Табигать, антропология, этнографияне сөючеләр җәмгыятьләренең хакыйкый әгъзасы. Н.А.Северцов 1873 тә Азиядәге хайваннарның бер төрен (Ovis Heinsii), В.Ф.Ошанин Зәрәүшан үзәнендә яшәүче ярымкаты канатлы бөҗәкләр төрен (Palethrocoris Heinzii) Г. исеме б-н атыйлар. Хезмәтләре Төркестан географиясенә, Россиянең социаль-икътисади проблемаларына һәм дәүләт төзелешенә карый. Мемуарлар авторы.



А.К.Гейнс (рәссам И.Е.Репин). ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Х е з м.: Собрание литературных трудов: В 3 т. СПб., 1897.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Либерал во главе Казанской губернии: Александр Константинович Гейнс // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 3/4.

*Е.Б.Долгов.*

**ГЕЛИОЦЕНТРИ́ЗМ** (грек. helios — Кояш һәм лат. centrum — үзәк) Кояшның планеталар системасы үзәгендә булуы турындагы тәгълимат. Фәнни яктан поляк галиме Н.Коперник хезмәтләрендә («Күк җисемнәренең әйләнүе турында», 1543) нигезләнә. Аларда Җирнең хәрәкәтсез торуы хакындагы тәгълимат инкарь ителә, Җирнең һәм башка планеталарның шушы планеталар системасы үзәге булган Кояш тирәсендә әйләнүләре дәлилләнә. Н.Коперникның эшен дәвам иттерүчеләрнең берсе — Италия философы Дж. Бруно Галәмнең чиксезлеге һәм анда Кояш системасына охшаш дөньяларның чиксез күп булуы турында нәтиҗә ясый. Төгәл табигыять фәннәренә нигез салучыларның берсе — Италия галиме Галилео Галилей ясаган ачышлар Г.ны физика һәм филос. күзлегеннән дәлилли. Күк җисемнәренең Кояш тирәли хәрәкәте турындагы фикерләр борынгы заманнарда ук, ш.и. төрки-татар фикер ияләре арасында да яшәп килгән. *Сәйф Сараиның* «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасында (14 йөз) Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе шигъри формада белдерелә. Г.ның фәнни нигезләмәләре Ш.*Мәрҗани*, К.*Насыйри*, Ш.*Күлтәси* һ.б. хезмәтләрендә китерелә.

**ГЕЛЬМИНТОЗЛА́Р** к е ш е д ә, с у а л ч а н и н в а з и я л ә р; үсеп җиткән, җенси җитлеккән суалчаннарның (гельминтлар) яисә аларның личинкаларының кеше әгъзаларында һәм организм системаларында корткычлык итүе б-н бәйле авырулар. Г. күп таралган авырулардан санала. Гельминтларның 250 дән артык төре тасвирланган. Алар 3 типка бүленә: биогельминтлар, геогельминтлар, контактлы гельминтлар. 2000 елда ТРда Г. авыруларының 96%ы контактлы гельминтозларга туры килә. Республика терр-ясендә төп 11 Г. теркәлгән: аскаридоз, трихоцефалёз, токсокароз (геогельминтозлар); энтеробиоз, гименолепидоз (контактлы гельминтозлар); дифиллоботриоз, описторхоз, тениаринхоз, тениоз, эхинококкоз, трихинеллёз (биогельминтозлар). 1958 дә Идел-Кама бассейнында описторхоз, 1995 тә псевдамфистомоз табыла. ТРда Г. ны өйрәнүгә 1960 дан Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе галимнәре С.Г.Карпов, В.Х.Фазылов, Р.И.Хәмидуллин, Э.И.Хәйретдинов, Л.В.Усачёв хезмәтләре багышланган.

*Әд.:* Х а м и д у л л и н Р.И. Трематодозы в Татарстане // Мед. паразитология и паразитарные болезни. 1991. № 2; ш у л у к. Описторхоз и псевдамфистомоз в Республике Татарстан // Казан.


мед. журн. 1995. № 2; С е р г и е в В.П., М а л ы ш е в Н.А., Д р ы н о в И.Д. Значение паразитарных болезней в патологии человека // Эпидемиология и инфекционные болезни в патологии человека. 1999. № 4.

*С.Г.Карпов.*

**ГЕЛЬМС** Эрнст Брунович (15.8.1912, Мәскәү — 2.2.1993, Казан), театр рәссамы, график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1956), ТАССРның халык рәссамы (1960), РСФСРның атказ. рәссамы (1974). Мәскәү автомобиль юллары комбинат-техникумында укый (1928–31). Мәскәүдә Үзәк аэродинамика ин-тында (1933–34), Наркомместпромның йорт җиһазлары трестында (1935–36) рәссам булып эшли, бер үк вакытта «Крокодил» ж-лы каршындагы сәнгать студиясендә (1933–34), Изогиз каршындагы студиядә (1934–36) һәм Мәскәү сынлы сәнгать ин-тының бизәлеш бүлегендә белем күтәрү курсларында укый. 1941–42 елларда Аэрофлот эшелоны башлыгы урынбасары вазифасында Иркутск шәһәренә эвакуацияләнә (командировкага җибәрелә), анда бер үк вакытта агитплакат остаханәсендә һәм «Восточно-Сибирская правда» г-тасында рәссам булып эшли. 1942 дән Казанда яши һәм эшли. Бөек Ватан сугышы елларында «Сатира тәрәзәләре» («Окна сатиры») сериясе өчен плакатлар һәм карикатуралар ясый. 1947 дән Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә, 1951 дән — «Чаян» ж-лының даими авторы һәм рәссамы, яшь сатириклар студиясен оештыручы (рәссам Б.А.Старчиков б-н берлектә). Бер үк вакытта 1945 тән — Казан Рус Зур драма театрында куючы-рәссам, 1964–81 дә — баш рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1944). Г. Татарстанда газета, журнал, станлы графика, плакат сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Аның тарафыннан башкарылган «Сатира тәрәзәләре» динамикалы силуэтның тәэсирлеге, рәсемнең экспрессивлыгы б-н аерылып тора («Җәзадан котыла алмаслар» (№ 63), «Немец-фашист илбасарларына — ләгънәт һәм үлем» (№ 67), «Соңгы сәгатьтә» (№ 71), «Койрыкка да, ялга да» (№ 117); барысы да — 1944). Г.ның журнал графикасында дусларча шаржлардагы риясыз юмордан һәм көнкүрешкә бәйле карикатуралардан алып кискен сарказмга, ачы сәяси сатирага кадәр киң колачлылык хас. Рәссамның халыкара темаларга багышланган әсәрләре образлы чишелешенең киң колачлылыгы б-н аерылып тора: «Яңа Цезарь арбасы» (1952), «Салкын сугыш тирәсендә кайнар эш» (1955), «Хөррият һәйкәле» (1962), «Пентагон горилласы» (1977–81) һ.б. «Шушы көннәрдә яңа романым чыкты» (1969), «Шүрәлене урманчы итеп сайлыйк» (1976), «Мин бит кадак сорадым...» (1990) һ.б. кебек көнкүреш карикатураларына социаль үткенлек хас.




Э.Б.Г е л ь м с. «Койрыкка да, ялга да». «Сатира тәрәзәләре» сериясеннән. Тушь, гуашь. 1944. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Э.Б.Гельмс.

Г. сатирик графика әсәрләрендә әдәби ассоциацияләргә, мәкальләр, әйтемнәр, әкияти образларга мөрәҗәгать итә, сынлы гипербола һәм метафора куллана. Рәссам пейзаж графикасы өлкәсендә (гуашь, акварель, тушь, темпера) нәфис лирика б-н сугарылган бай мирас калдыра: «Казан төзелә» (1953), «Львов. Адам Мицкевич һәйкәле» (1954), «Камадагы пристань» (1955), «Новосибирск. Опера театры» (1960), «Краков. Вавели капкасы» (1968), «Будапешт. Күпер» (1970), «Зальцбург. Кальга» (1972), «Берлин. Фридрихштрассе» (1979) һ.б. Казан Зур драма театры, Татар академия театры, Казан Яшь тамашачылар театры, Казан курчак театры, Опера һәм балет театры, ш.у. Свердловск, Магнитогорск, Чиләбе, Воронеж, Краснодар, Новокузнецк һ.б. шәһәрләр театрлары сәхнәсендә 300 ләп татар, рус, чит ил классикасы һәм хәзерге заман драматургиясе спектакльләрен бизи. Казан Зур драма театры сәхнәсендә А.Фадеев романы нигезендәге «Яшь гвардия» (1947), М.Горькийның «Тормыш төбендә» (1549), Ф.Шиллерның «Дон Карлос» (1955), Р.Ишморатның «Үлемсез җыр (Муса Җәлил)» (1956), А.Штейнның «Океан» (1961), А.Островскийның «Яшенле яңгыр» (1963), М.Булгаковның «Качу», В.Маяковскийның «Мунча» (икесе дә — 1967), К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1969), У.Гибсонның «Булыргамы, әллә булмаскамы» (1976, СССРда беренче куелыш), Д.Вәлиевнең «Дәвам»ы (1972) һ.б. әсәрләр буенча спектакльләр Г. бизәлешендә куела. Татар акад. театрында ул «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт, 1948), «Хатыннар хөррияте» (Д.Флетчер, 1957), «Алар дүртәү иде» (Р.Ишморат, 1962), «Гүзәлем Әсәл» (Ч.Айтматов повесте нигезендә, 1966; 1967 дә — ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге) спектакльләре өчен сәхнә бизәлеше эшли. Татар опера һәм балет театрында «Кармен» (Ж.Бизе, 1958), «Ромео һәм Джульетта» (Ш.Гуно, 1959), «Таш чәчәк» (С.Прокофьев, 1961), «Катерина Измайлова» (Д.Шостакович), «Башмагым» (Җ.Фәйзи, 1967) һ.б. спектакльләр Г. тарафыннан бизәлә. Казан Яшь тамашачылар театрының Г. бизәгән иң уңышлы спектакльләре — «Мещаннар» (М.Горький, 1946), «Шайтан тегермәне» (И.Шток, 1954), «Бумбараш» (А.Гайдар әсәре нигезендә, 1975), «Принц һәм теләнче» (А.Яковлев, 1977) һ.б. Г.ның сәхнә бизәлешендәге сурәтләү чаралары спектакльнең логик нигезен тулыландыра, режиссёр максатына яраклы рәвештә пьесаның идеясен, конфликтның драматизмын көчәйтә. Рәссам читләтеп әйтү, шартлы образлар тудыру б-н бердәй дәрәҗәдә тарихи дәвернең детальләрен, конкрет интерьер, пейзажны зур төгәллек б-н чагылды-




Э.Б.Г е л ь м с. «Никола соборы». Кәгазь, фломастер. 1960 еллар.





Э.Б.Г е л ь м с. 1. Этюд. Акварель. 1960 еллар; 2. А.Штейнның «Океан» пьесасы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. Гуашь. 1961. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Я.И. Генералов.

ру осталыгына ия. Сәхнә тирәлеге композициясен төзегәндә ул еш кына үзгәрешне конструкцияләр һәм яктылык палитрасы кулланып ясый.

1942 дән респ-ка, Идел буе төбәкләре (1947 дән), бөтенроссия (1955 дән), бөтенсоюз (1952 дән), халыкара күргәзмәләрдә һәм Совет сәнгатенең чит илләрдә үткәрелгән күргәзмәләрендә («Сатира тынычлык өчен көрәштә», 1969, 1973, 1977, Болгария; «Дөньяны көлү коткара», 1973, Болгария; «Совет театры плакаты», 1976, СССР, Чехословакия) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1948, 1972, 1959, «Дусларча шаржлар — әйдәгез танышыйк», 1963, «Шаяртып та, җитди дә» (Е.А.Старчиков б-н берлектә) 1965, 1972, 1975, 1981, 1983), Мәскәүдә (1958) уза. Г. әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк дәүләт театр музеенда (Мәскәү), Дәүләт тарих музеенда (Мәскәү), ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда (Казан), Әлмәт шәһәре картиналар галереясында, А.Н.Островскийның музей-утарында (Кострома өлкәсе), Сатира һәм юмор музеенда (Болгария, Габрово ш.) саклана. Казанда Горький урамындагы ул яшәгән 6а йортка мемориаль такта куелган.

Хезм.: С точки зрения художника // Театр. 1956. № 10; Блокноты полны зарисовок // Театральная жизнь. 1963. № 24; Если пьеса многокартинная, а сцена небольшая... // Художник и сцена. М., 1964.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Театральная энциклопедия. М., 1961. Т. 1.

*М.Е.Ильина.*

**ГЕЛЬСИНГФО́РС МӨСЕЛМА́Н ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**. 1915 елның июлендә оештырыла. Төп максаты — ярлы-мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү, мөселман мәдәни-агарту оешмалары үсешенә булышлык итү. Гельсингфорс шәһәрендә (хәзерге Хельсинки шәһәре, Финляндия) эшли. Оешма 1917 дән соң эшләүдән туктый.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**ГЕ́ЛЬТЦЕР** Рудольф Робертович (22.7.1890, С.-Петербург — 24.9.1968, Ставрополь ш.), микробиолог, иммунолог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935). Хәрби-мед. академиясен (1914, С.-Петербург) тәмамлый һәм хәрәкәттәге армиягә җибәрелә. 1921 елдан Казан ун-тында, 1932 дән Казан мед. ин-тының микробиология каф. мөдире. 1943 тән Ижевск, 1948–65 тә Ставрополь мед. ин-тларында. 1930 да, СССРда беренче булып, хезмәттәшләре б-н аксыл спирохетаны чиста культура итеп таба, соңрак ул паллид-антиген әзерләүдә файдаланыла: кайтма талпан тифының спирохета культурасын ала, дифтерия, корсак тифы, тимгелле тиф, дизентерия китереп чыгаручыларның культураль һәм биохимик үзенчәлекләрен өйрәнә. Бөек Ватан сугышы елларында аның тарафыннан эшләнелгән кетгутны стерилизацияләү ысулы сан.-оборона әһәмиятенә ия була. Ставрополь эпидемиологлары һәм йогышлы авырулар белгечләре фәнни җәмгыятенә нигез салучы һәм алмашсыз җитәкчесе.

Хезм.: Этиология и бактериологическая диагностика инфекционной желтухи // Казан. мед. журн. 1939. № 11/12; К вопросу о культивировании Sp. pallida на жидких питательных средах // Журн. микробиологии, эпидемиологии и иммунологии. 1969. № 9.

**ГЕМА́НТУС** (Haemanthus), амариллисчалар семьялыгыннан күпьеллык суганчалы үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле. Чыгышы — Көньяк Африка. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Яфраклары кыска, киң, очы түгәрәк (халыктагы «сыер теле» атамасы шуннан алынган), куе яшел төстә, җиргә таба иелгән. Суганчасы эре, яшел төстә, озынча түгәрәк, җирдән бөтенләй диярлек чыгып тора. Чәчәкләре көпшәсыман, аксыл төстә, саргылт озын серкәчле, ачык кызгылт-сары яки кызыл, кыска юан чәчәк сабында (озынлыгы 5–7 *см*) куе чатырсыман чәчәк төркеменә урнашкан. Җимеше — кызгылт-сары төстәге җиләксыман шартлаучан итләч тартмачык. Орлыктан яки ябь суганчадан үрчетелә.

**ГЕНЕРА́ЛОВ** (Николаев) Яков Иванович (22.11.1916, Самара губ. Бөгелмә өязе, хәзерге Лениногорск р-ны Северовка а. — 19.1.1997, Түбән Кама ш.), Дан орденының тулы кавалеры (11.3.1944, 9.2.1945, 29.6.1945), старшина (1945). Туган авылында колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 886 нчы аерым сапёрлар батальоны сапёры (22 нче армия). Көнбатыш, Калинин, Төньяк-Көнбатыш, 2 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Смоленск сугышында (1941), Калининны саклауда (1941), Ржев–Вязьма һөҗүм операциясендә (1943), Ленинград блокадасын өзүдә, Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1944 нең февралендә Рожков күле янында (Ленинград өлкәсе) 113 минаны зарарсызландырып, дошманның мина кырларында 3 чыгу юлы ясый; 1945 нең 25 гыйнварында Дзингелен торак пункты янында (Лудзбарк шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Польша) дошманның 28 минасын зарарсызландыра һәм мина кырларында 2 чыгу юлы ясый; 1945 нең 29 мартында Хайлигенбаль шәһәре (хәзерге Калининград өлкәсенең Мамоново ш.) өчен барган сугышларда дошман траншеясына беренчеләрдән булып бәреп кереп, яралы хәлендә дошманның орудие расчётын юк итә. 1946 елдан запаста. Түбән Камада яши, балта остасы булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ГЕНЕРА́ЛЬ ҖИР БҮЛЕНЕШЕ́**, Россиядә 1765–1861 елларда аерым затларның, крәстиян общиналары, шәһәрләр, чиркәүләрнең биләмәләре чикләрен билгеләү. 1765 нең 19 сентябрендә чыгарылган Манифест һәм Генераль кагыйдәләр (1766) нигезендә үткәрелә. Г.җ.б. ил икътисадының гомуми җанлануы б-н бәйле рәвештә дәүләтнең җир биләмәләрен тәртипкә салу омтылышын чагылдыра. Җир үлчәүчеләр 12 шаһит катнашында биләмәнең мәйданын үлчиләр. Бүлү ун сажинлы чылбыр б-н башкарыла, үлчәү берәмлеге буларак дис. кулланыла. 1765 елдагы бәхәссез җир биләү факты киләчәктә биләмә хуҗасына җирне беркетү өчен нигез була. Г.җ.б. барышында дәүләт җирләрен рөхсәтсез тартып алуларны легальләштерү нәтиҗәсендә дворян җирбиләүчелеге зурая, әлеге җирләрнең бер өлеше алпавытларга бушлай бирелә. Г.җ.б., нигездә, 19 йөз башында тәгәлләнә. 35 губернада 275 млн. дис. дән артык җир бүленә, 200 мең җир биләмәләре планы, алар нигезендә өяз планнары һәм губерна атласлары төзелә. Г.җ.б.нә караган икътисади искәрмәләрдә хуҗалыклар, кешеләр саны, утар һәм чәчүлек җирләр, печәнлек, урман, сулыклар, кош-корт һәм мал-туар исәбе, ашлык уңышының күләме, крәстиян һөнәрләре һәм кәсепләре һ.б. турындагы мәгълүматлар туплана. Казан губернасында җирләр бүленеше 1793–1803 елларда уздырыла. Милек иясәре арасында чыккан бәхәсләрне хәл итү өчен Казан җир бүленеше конторасы оештырыла. Г.җ.б. нәтиҗәсендә авыллар, утар җирләре, чәчүлек җирләр, болыннар, барлык дача җирләренең мәйданы Казан губернасында 5684239 дис. 1669 сажин (елгалар һәм кайбер күлләрнең мәйданын исәпкә алмаганда) тәшкил итә. Бу биләмәләрдән 3083538 дис. (54,29%) — дәүләт крәстияннәре җирләре, 103597 дис. дән артыгы (18,3%) — казнага караган җир һәм урман дачалары, 862001 дис. дән артыгы (15,17%) алпавыт җирләре була. Казан губернасындагы җирләрнең зур өлешен урманнар (53% чамасы) һәм чәчүлекләр (33%) били.

*Әд.:* Иванов П. Опыт исторического исследования о межевании земель в России. М., 1846; Милов Л.В. Исследования об «Экономических примечаниях» к Генеральному межеванию. М., 1965; Хайрутдинов Р.Р. Управление государственной деревней в Казанской губернии (конец XVIII — первая треть XIX в.). К., 2002.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ГЕНЕ́ТИКА** (грек. génesis — барлыкка килү), нәселдәнлек һәм организмнарның үзгәрүчәнлек законнарын һәм шушы үзлекләр б-н идарә итү ысулларын өйрәнә торган фән. Г. организмнарның иң төп, фундаменталь үзлекләрен өйрәнә; гомумтеоретик әһәмияткә ия һәм хәзерге заман биологиясендә әйдәп баручы урынны алып тора. Тикшерену объектына һәм дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, үсемлекләр, хайваннар Г.сы, кеше микроорганизмнар Г.сы, соматик күзәнәкләр Г.сы, молекуляр Г., генетик инженерия, цитогенети-

ка, радиацион Г., эволюцион Г., популяцияләр Г.сы аерып өйрәнелә.

Г.ның фән буларак барлыкка килүе Г.Мендель исеме б-н бәйле, ул билгеләрнең нәселдән күчү закончалыкларын һәм нәселдәнлекне өйрәнү алымын тәкъдим итә (1865). Аның хезмәтләре 35 елдан соң гына танылa. Иң беренче этапта Мендель законының күпьяклы булуы билгеләнә. 1910 елларда Т.Морган һәм аның күпсанлы укучылары тырышлыгы б-н нәселдәнлекнең хромосомалар теориясе формалаша. 1920–30 елларда индуцияләнелгән мутагенез күренеше ачыла, ул геннарның — нәселдәнлек берәмлекләренең төзелешен өйрәнергә һәм төрле нәселдәнлек үзгәрешләре — мутация китереп чыгарырга мөмкинлек бирә. 1940 елларда нәселдәнлек һәм үзгәрүчәнлекнең молекуляр механизмнарын өйрәнү зур үсеш ала, бу исә генетик материалның химик табигатен ачыкларга, генетик информацияне кодлаштыру һәм куллану ысулларын билгеләргә, геннар активлыгын көйләү юлларын эшләргә мөмкинлек бирә. Киңкүләмле халыкара «Кеше геномы» проекты гамәлгә куелу, геннар инженериясе методы эшләнү әлеге фәнни эзләнүләрнең логик нәтиҗәсе булып тора.

СССРда генетик фәнни тикшеренүләр үсеше Н.И.Вавилов, Н.К.Кольцов, А.С.Серебровский, Ю.А.Филипченко, С.С.Четвериков һ.б. галимнәр исеме б-н бәйле. 1930 елларда совет генетиклары мәктәбе, америкалыларныкы б-н беррәттән, бөтендөнья фәнендә әйдәп баручы урынны ала. 1930 еллардагы сәяси хәлләр, 1948 дә В.И.Ленин исем. Бөтенсоюз а. х. фәннәре академиясенең (ВАСХНИЛ) сессиясе 1965 кә кадәр бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләрне туктатып тора. Илдә Г.ның яңадан торгызылуы С.И.Алиханян, Б.Л.Астауров, Д.К.Беляев, С.М.Гершензон, Н.П.Дубинин, М.Е. Лобашёв, И.А.Рапопорт, Н.В.Тимофеев-Ресовский, Р.Б.Хесин, Н.И.Шапиро исемнәре б-н бәйле.

Казанда яшь фән б-н иң беренче булып мед. галимнәре кызыксына башлый. В.С.Груздев кешедә тумыштан килгән аномалияләр турында байтак хезмәтләр бастыра: «Гариплекләр һәм гарипләр» («Уродства и уроды», 1914), «Нәселдәнлек» («Наследственность», 1917), «Гариплекләр һәм аларның килеп чыгышы» («Уродства и их происхождение», 1929). 1930 еллар башында В.Н.Слепков Казан ун-тында генетик фәнни тикшеренүләр оештырырга омтылыш ясый. Әмма озакламый ул кулга алына, генетика лаб-ясе ябыла. 1960 елларда В.М.Сироткин тарафыннан яңадан өйрәнелә башлаган мед. Г.сы Я.Ю.Попелянский, Н.Ү.Әхмәров һәм М.Ф.Исмәгыйлев хезмәтләрендә алга таба үсеш ала. 1970 еллар ахырында Республика клиник хастаханәсе каршында генетика кабинеты эшли башлый. Соңыннан ул яңа туган балалардагы нәселдәнлек аномалияләренә диагноз куюны тормышка ашыручы мед.-генетика консультациясе итеп үзгәртелә. 1976 да Казан ун-тында Г. кафедрасы ачыла, «Г.» белгечлеге буенча студентлар әзерләү башлана. Кафедраның төп юнәлеше репарация, рекомбинация һәм мутагенез процессларының молекуляр механизмнарын тикшерү б-н бәйле: Bacillus subtilis — печән таякчыкларында рекомбинация процессларын контрольдә тотучы яңа геннар табыла һәм клонлаштырыла, бактерияләрдә «адаптив» мутагенез үзенчәлекләре тикшерелә, картаю процессында кремнийның көйләүче роль уйнавы билгеләнә (Б.И.Барабанщиков, С.В.Малков). Микробиология кафедрасында РНКаза структурасын кодлаштыручы генны клонлау һәм өйрәнү (И.Б.Лещинская), ягъни генетик инженерия буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла, целлюлозаны җимерүче ферментлар структурасын кодлаштыручы геннардан рекомбинант клон алу буенча эзләнүләр исә биохимия кафедрасында үткәрелә (В.Г.Винтер). 1990 еллардан Казан ун-тында (О.Н.Ильинская) һәм Казан мед. ун-тында (В.В.Семёнов) экология Г.сы буенча фәнни тикшеренүләр башлана. Г. белгечләрен әзерләү башка оешмаларда да генетик фәнни тикшеренүләр җәелдерү мөмкинлеге бирә. РФА КГҮнең Казан биохимия һәм биофизика ин-тында микоплазмаларның молекуляр Г.сы буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла, алар нигезендә кешедә, хайван һәм үсемлекләрдә микоплазмалы инфекцияләрне ачыклау өчен диагностик препаратлар (ДНК-зондлар) эшләнелгән (В.М.Чернов, О.А.Чернова): феноллы метаболизм геннары буенча модификацияләнгән соя үсемлегенең трансген формалары алына; соматик күзәнәкләрне гибридлаштыру алымы б-н культуралы һәм күпьеллык карабодайның төрара гибридлары табыла (Н.И.Румянцева). Аеручa куркыныч инфекция тудыручыларны аерып алу алымнарын молекуляр-генетик юнәлештә тикшерүләр, бруцеллёз, түләмә, листериоза һ.б. авыруларны кисәтү максатында яңа вакциналар булдыру өчен Бөтенроссия фәнни-тикшерү вет. ин-тында фәнни эзләнүләр җәелдереп җибәрелә (А.М.Алимов, Т.Х.Фәизов, О.А. һәм В.М.Черновлар). Казан вет. академиясендә Г. һәм а.х. хайваннары үрчетү кафедрасы ачыла (1965), мөгезле эре терлекнең продуктлылыгы һәм авыруларга каршы торучанлыгы җәһәтеннән кан төркемнәре тикшерелә башлый (С.Х.Ларцева). Сөт бирүче хайваннарның токымын яхшырту максатында, 1990 елларда, сыерларның сөтле токымнарын камилләштерү ниятеннән сөт аксымы Г.сын фәнни тикшерү эшләре башланып китә (Р.А.Хәйретдинов, Э.С.Гобәйдуллин). Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында а.х. культураларының кирәкле үзлекләре булган сортларын алу өчен гибридлаштыру кулланыла. Бу ысул, иммунитетлы донорлар һәм сыйфатлы орлыклар җәлеп итеп, катлаулы баскычлы һәм төрара серкәләндерүгә нигезләнеп эшләнә. Шулай ук индукцияле мутагенез, гетерозис һәм биотехнология ысуллары кулланыла. Шушы юл б-н көзге арышның (М.Л.Пономарёва, С.Н.Пономарёв), көзге бодай (Э.Ф.Ионов), борчак (А.Н.Фадеева), карабодайның (Ф.З.Кадыйрова), тары (Н.Ш.Хисаметдинов); арпа (В.И.Блохин), сабан бодаеның (Н.Э.Василова), люцерна (М.Ш.Лапина) һәм җиләк-җимеш культураларының (Г.Е.Осипов) югары сыйфатлы сортлары чыгарыла.

Генетик тикшеренүләрнең төп алымы — генетик анализ. Аның ярдәмендә генотипның төзелеше ачыклана, геннарның тәэсир итү механизмы һәм аларның организмнар үсешенә йогынтысы билгеләнә. Микроорганизм һәм вирус штаммнары, соматик күзәнәк культуралары, хайван һәм үсемлекләр өлкәсендә дрозофила, тычкан, күсе, кукуруз, арабидопсис, борчак һ.б.ның махсус оештырылган модельле (югары сыйфатлы) объектлары файдаланыла. Биохимик һәм цитохимик алымнар, спектроскопия, авторадиография, рентген-төзелеш анализы, оптик һәм электрон микроскопия дә кулланыла.

Г. күп кенә гомуми биология фәннәре б-н бәйләнештә. Эволюция теориясен раслауда һәм үстерүдә ул зур роль уйнады. Г. биохимия, цитология һәм эмбриологиянең тыгыз бәйләнеше шартларында организмнарның индивидуаль үсеш процессында генетик аппаратның ролен өйрәнә. Г., биохимия, физиол. һәм мед. арасындагы үзара бәйләнеш күп кенә авыруларның нәселдән күчүен, аларның молекуляр механизмын билгеләргә, кисәтү һәм дәвалау алымнарына керешергә, яман шеш авыруын беренче стадиядә дәваларга, ш.у. вакытыннан алда картаюның генетик сәбәпләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Селекция алымнарын теоретик нигезләүгә дә Г. мөһим өлеш кертә.

Генетик тикшеренүләрне РФнең Г. буенча фәнни советы, Генетиклар һәм селекционерларның Вавилов җәмгыяте (ВОГиС) җайга сала. 5 елга бер тапкыр генетикларның халыкара конгрессы җыела. ВОГиСның съезды үткәрелә. 1976 дан ВОГиСның Казан бүлеге, 1994 тән Медицина генетиклары җәмгыятенең Казан бүлеге эшли.

*Әд.:* Лобашёв М.Е. Генетика. Л., 1967; Классики советской генетики. Л., 1968; Гершензон С.М. Основы современной генетики. Киев, 1983; Айала Ф., Кайгер Дж. Современная генетика: В 3 т. М., 1987; Гайсинович А.Е. Зарождение и развитие генетики. М., 1988; Хрестоматия по генетике. К., 1988; Ермолаев А.И. Тёмные и светлые стороны казанской генетики // Природа. 1996. № 6; Кузнецова Н.Н., Винтер В.Г. Методы генной инженерии. М., 1997; Сингер М., Берг П. Гены и геномы. М., 1998.

*Б.И.Барабанщиков.*

**ГЕ́НИНГ** Владимир Фёдорович (10.5.1924, Алтай крае Подсосново а. — 30.10.1993, Киев), археолог, тарих фән. д-ры (1974), проф. (1975). Хәзерге заман археол. тикшеренүләр теориясе һәм методикасын эшләүчеләрнең берсе. Пермь ун-тын тәмамлый (1952). 1951–54 елларда Пермь өлкә музее археол. экспедициясе башлыгы, 1954 елдан Удмурт археол. экспедициясе җитәкчесе. 1955 тән СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1960–74 тә Урал ин-тында эшли (Свердловск ш.), бер үк вакытта Урал археол. экспедициясе җитәкчесе. 1974–86 да Украина ССР ФАнең Археология ин-ты директоры урынбасары; археол. теориясе һәм методикасы бүлегенә нигез салучыларның, аның җитәкчеләренең берсе. Идел-Урал төбәге һәм Көнбатыш Себер халыкларының килеп чыгышы, борынгы тарихы һәм мәдәни-

ятенә караган тикшеренүләр алып барган күренекле галим. *Азелино культурасын, Имәнкискә культурасын, Ломоватово культурасын, Кушнаренко культурасын* аерып чыгара. Эшчәнлегенең Казан б-н бәйле чорында *Турай каберлегендә*, Лаеш р-ны Рождествено авылы янындагы Имәнкискә культурасы истәлекләрендә һәм *Олы Тархан каберлегендә* археол. казу эшләре алып бара. Хезмәтләре Чулман буе һәм Урал төбәгенең борынгы тарихына, археологиясенә, археол. теориясе һәм методикасына, борынгы дәверләрдә барган этник процессларны тикшерүгә карый.

Х е з м.: Археологические памятники у села Рождествено. К., 1962 (автордаш); Азелинская культура III–V вв. Очерки истории Вятского края в эпоху Великого переселения народов // Вопр. археологии Урала. Свердловск-Ижевск, 1963. Вып. 5; Ранние болгары на Волге. М., 1964 (автордаш); Объект и предмет науки в археологии. Киев, 1983; Этническая история Западного Приуралья на рубеже нашей эры. Пьяноборская эпоха III в. до н. э. — II в. н. э. М., 1988; Древняя керамика: Методы и программы исследования в археологии. Киев, 1992.

*Е.П.Казаков.*

**ГЕ́НКИН** Роний Лазаревич (11.6.1890, Чернигов губ. Кролевец ш. — 1968, Ленинград), актёр, театр эшлеклесе. Сәхнә эшчәнлеген 1905 елда башлый, Беренче бөтендөнья сугышы елларында армиягә алына, яралангач, Казан хәрби госпиталенә җибәрелә. Казанда Окт. рев-циясендә катнаша, кызылгвардияче, Казан гарнизоны солдатлары арасында пропаганда эшләре алып бара. 1919 да шәһәрдә Эшче театрын оештыра, аның эшчәнлегеннән килгән акчалар РСДРП(б)ның Казан ком-тына «Рабочий» г-тасын чыгару өчен тапшырыла. 1920–23 елларда — Запастагы армия сәяси бүлегенең Казан гарнизоны театрында актёр һәм режиссёр. 1923–25 тә — Казан хәзерге заман театрының тәҗрибә остаханәсендә (КЭМСТ) актёр һәм баш администратор, анда берничә зур рольне башкара. 1934–35 тә — «Электро» (Казан) кинотеатры, 1937–38 дә — Бөгелмә драма театры, 1938–47 дә — В.И.Ленин исем. мәдәният сарае директоры. 1948 дән Ленинградта яши.

**ГЕНОДЕРМАТОЗЛА́Р**, к. *Дерматология.*

**ГЕНТИА́НА**, ч ы н т ы я н а (Gentiana) гентианачалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел яки ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 400 ләп төре билгеле, Европа, Азия һәм Америкада киң таралган. ТРда 4 төре бар. Аралаш яфраклы Г. (ачамай) (G. cruciata) һәр районда очрый; үпкә Г. сы (бүрәнкә чәчәк) (G. pneumonanthe), оялы Г. (бабасыр уты) (G. axillaris), телсыман яфраклы Г. (G. lingulata) — сирәк төрләр. Кыска үләнле болыннарда, кисенделәрдә, урман буйларында үсә. 3–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска, шнурсыман тамырлы. Сабагы туры, куыш. Яфраклары бөтен, озынча-ланцетсыман, аскылары — еш кына таралгыда. Чәчәкләре зәңгәр, күк төстә, ялгыз, себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше — вак орлыклы тартмачык. Июнь–сентябрь айларында чәчәк ата. Күбесенчә орлыктан үрчи. Ачамай һәм үпкә Г.сы тамырчасы һәм тамырларында углеводлар, алкалоидлар, эфир мае бар; халык медицинасында хроник ашказаны-эчәк авырулары вакытында һәм сәламәтлекне ныгыту өчен файдаланыла. Барлык төрләре дә — декоратив, баллы. Үпкә Г.сы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГЕ́О**... (грек. gḗ — Җир), Җир турындагы фәннәргә, гомумән, Җир шарына, Җир кабыгына кагылышлы кушма сүзләрнең бер өлеше (мәс., география, геология, геоботаника).

**ГЕОБОТА́НИКА** (*гео*... һәм *ботаника*), Җирнең үсемлек капламын һәм аларның бергәлекләрен төзүчеләрне (фитоценозларны) өйрәнә торган фән. Хәзерге Г. үзара тыгыз бәйләнгән өч зур бүлекне: фитоценология (үсемлек бергәлекләре турындагы фән), ботаник география һәм тарихи Г.ны үз эченә ала. Гомуми Г.га (үсемлек бергәлекләре структурасының гомуми закончалыклары, экологиясе, динамикасы, классификациясе, географиясе) һәм аграр цикл фәннәренең (урманчылык, болынчылык һ.б.) теоретик нигезен тәшкил иткән үсемлек типларын (урман, болын, сазлык, кыр һ.б.ш. бүленеш) өйрәнә торган махсус Г.га бүлеп карау да яши.

Дөнья һәм Россия табигыять-фәнни әдәбиятында Г. элементлары 18 йөз уртасында, мөстәкыйль фән буларак, Г. 19 йөз ахырында барлыкка килә. «Г.» төшенчәсе 1866 елда Россия ботанигы Ф.И.Рупрехт һәм немец ботанигы А.Гризебах тарафыннан бер үк вакытта тәкъдим ителә. 19 йөз ахырында Н.Ф.*Леваковский*, П.Н.*Крылов*, С.И.*Коржинский*, А.Я.*Гордягин* һ.б. хезмәтләре нәтиҗәсендә Казан ун-тында оештырылган Г. фәнни мәктәбе вәкилләре Россия Г.сы үсешенә зур өлеш кертә. Бу чорда Казан губернасының һәм чиктәш терр-яләрнең (Көнбатыш Себергә чаклы) үсемлекләр дөньясы туфрак шартлары б-н тыгыз бәйләнештә өйрәнелә; Г.ның теоретик мәсьәләләре эшләнә, яңа төшенчәләр (үсемлекчелек тармагы, үсемлек формациясе, үсемлек төрләренең исемлеге, беренчел һәм икенчел формацияләр һ.б.) файдаланыла һәм кулланышка кертелә; геоботаник тикшеренүләр методикасы: үсемлекләр дөньясын тасвирлау ысуллары, үсемлекләр дөньясын фәнни тикшерүнең санча ысуллары (А.Я.Гордягин) эшләнә.

1920 еллардан Казан геоботаниклары ТАССРның үсемлекләр дөньясын өйрәнүдә һәм барлауда (А.Я.Гордягин, В.И.Баранов, М.В.Марков, В.С.Порфирьев, Е.Л.Любарский, Р.Г.Иванова һ.б.) актив катнаша, нәтиҗәдә үсемлекләр дөньясына гомуми күзәтүләр ясала (Гордягин, 1922; Марков, 1948) һәм урман, болын, кыр үсемлекләре бәян ителгән мәкаләләр һәм китаплар языла. Югары уку йортлары өчен «Гомуми геоботаника» (Марков М.В. «Общая геоботаника». М., 1962) дәреслеге нәшер ителә. Г.ның бер бүлеге буларак, кыр үсемлекләре бергәлеген өйрәнә торган агрофитоценология формалашуга һәм аны үстерүгә, аның теориясен төзүгә, фәнни нигезләнгән гамәли тәкъдимнәрен, ысулларын эшләүгә һәм үстерүгә мөһим өлеш кертелә. Югары уку йортлары өчен агрофитоценология дәреслеге нәшер ителә (Марков М.В. «Агрофитоценология», 1972). 1950 еллардан вегетатив-хәрәкәтчән үсемлекләрнең экологиясе өйрәнелә: бу төркемгә караган үсемлек төрләре ачыклана, аларның биологик һәм экологик үзенчәлекләре, үсемлекләр дөньясы бергәлекләрендәге әһәмияте һәм үзара бәйләнешләре билгеләнә (Е.Л.Любарский). 1960 еллардан вегетатив-хәрәкәтчән (Е.Л.Любарский, В.И.Полуянова һ.б.), берьеллык, бер- һәм икееллык үсемлекләрдә (С.А.Маркова, А.С.Казанцева, Т.Н.Добрецова, С.Е.Любарский һ.б.) популяцион-экологик тикшеренүләр циклы үткәрелә. Үсемлекләрнең яшь һәм морфоструктур яктан бериш булмаган ценотик популяцияләре, популяцияләрнең фәзаи структурасы һәм үсемлек төрләренең мәйдан буенча таралышы турында яңа мәгълүмат алына.

*Әд.:* К о р ж и н с к и й С.И. Северная граница чернозёмно-степной области восточной полосы Европейской России в ботанико-географическом и почвенном отношении // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1888. Т. 18, вып. 5; 1891. Т. 22, вып. 6; Г о р д я г и н А.Я. Материалы для познания почв и растительности Западной Сибири // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1901. Т. 35, вып. 2; ш у л у к. Растительность Татарской Республики. К., 1922. Ч. 1. Порфирьев В.С. Темнохвойно-широколиственные леса Северо-Востока Татарии // Уч. зап. Казан пед. ин-та. 1947. Т. 9; М а р к о в М.В. Растительность Татарии. К., 1948; Флора и растительность пойм рек Волги и Камы в пределах Татарской АССР // Уч. зап. Казан ун-та. 1955. Т. 115, кн. 1,5; Л ю б а р с к и й Е.Л. Экология вегетативного размножения высших растений. К., 1967; ш у л у к. Ценопопуляция и фитоценоз. К., 1976; Т р а с с Х.Х. Геоботаника: история и современные тенденции развития. Л., 1976; Л ю б а р с к и й Е.Л., П о л у я н о в а В.И. Структура ценопопуляций вегетативно-подвижных растений. К., 1984.

*Е.Л.Любарский.*

**ГЕОГРА́ФИК ЛАНДША́ФТ**, географик тышчаның чагыштырмача бериш участогы, компонентларының (тау токымнары, туфрак, үсемлекләр дөньясы һ.б.) һәм морфологик кисәкләрнең (фация, табигый һзаннар, җирлекләр) закончалыклы кушылулары, ш.у. кушылмаларның үзенчәлекләре һәм тагын да түбәнрәк территориаль берәмлекләргә характерлы бәйләнгән булуы б-н аерыла. Һәрбер Г.л.ның төзелешен матдәләр алмашы һәм энергия процессы билгели. Ритмик һәм кайтма булмаган үзгәрешләргә дучар ителә. ТР терр-ясендә табигый ландшафтның күп өлеше, нигездә, агроландшафтларга әверелгән. Г.л. — ландшафтлы тикшеренүнең төп берәмлеге һәм төп объекты буларак саналучы физик-географик бүленеш категорияләренең берсе.

Киң мәгънәсендә Г.л. теләсә нинди рангтагы *табигый территориаль комплексның* синонимы.

**ГЕОГРА́ФИЯ** (*гео*... һәм ...*графия*), Җирдәге тереклекнең табигый һәм иҗтимагый шартларын өйрәнә торган үзара бәйләнештәге фәннәр комплексы. Өйрәнү объектына карап, үз бүлекчәләре дә булган физик Г.гә һәм иҗтимагый-икътисади Г.гә бүленә. Физик Г. составына *геоморфология*, *климатология*, *гидрология*, туфрак географиясе, *биогеография*, ландшафт белеме; социаль-икътисади Г.гә халык, сәнәгать, авыл хуҗалыгы географиясе бүлекләре керә. Һәр фәннең гомуми һәм ре-

гиональ бүлекләре бар. Шулай ук барлык география фәннәренә хезмәт күрсәтә торган картографияне дә Г.гә кертәләр. Б.э.к. 2–1 нче меңьеллыкларда Борынгы дөньяның зур үсеш алган илләре — Кытай, Һиндстан, Грециядә беренче географик төшенчәләр формалаша. Г. үсешенә Бөек географик ачышлар (15–18 йөзләр) мөһим этәргеч бирә. 19 йөздә теоретик гомумиләштерелгән зур хезмәтләр (А.Гумбольдт, Ч.Дарвин, В.В.Докучаев һ.б.) барлыкка килә, милли географик җәмгыятьләр оештырыла (Рус география җәмгыяте, 1845). Университетларда Г. кафедралары ачыла, белгечләр әзерләү башлана. 1871 елдан халыкара географик конгресслар чакырыла. 20 йөздә Дөнья океаны, Арктика һәм Антарктиданы өйрәнүдә аеруча зур уңышларга ирешелә. Дөнья картасыннан соңгы «ак таплар» бетерелә. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Халыкара география берлеге төзелә, аның күпсанлы комиссияләре Г.нең барлык тармакларында һәм бүлекләрендә нәтиҗәле тикшеренүләр үткәрәләр. 20 йөзнең 2 нче яртысында Г.дә экологик аспектлар көчәя.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казан ун-тында географик тикшеренүләр башлана. Астроном И.М.Симонов Ф.Ф.Беллинсгаузен һәм М.П.Лазаревның Антарктиданы ачкан экспедициясендә (1819–21) катнаша, климатология һәм океанология буенча күп кенә тикшеренүләр үткәрә. Ун-тның беренче ректоры И.Ф.Яковкин студентларга география курсларын укый. Ун-тның шәркыятьче галимнәре (О.М.Ковалевский, В.П.Васильев, И.Н.Березин һ.б.) Үзәк һәм Алгы Азиянең күп кенә юлсыз, таулы өлкәләрен фән өчен ачалар. Э.А.Эверсман Каспий буенда, Урта Азиядә һәм Кавказда ландшафт тикшеренүләре үткәрә. Казан ун-ты галимнәре — геологлар, ботаниклар, зоологлар, шәркыятьчеләр — Көнчыгыш Европа тигезлеге һәм Уралның табигатен һәм халкын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. 1888 дә Казан ун-тында география һәм этнография кафедрасы ачыла, аны 22 ел дәвамында геолог һәм географ П.И.Кротов җитәкли. Ярты гасырдан соң (1938) мөстәкыйль география ф-ты оештырыла. Хәзер география һәм экология ф-ты өч кафедраны үз эченә ала: физик география һәм геоэкология; атмосфера метеорологиясе, климатологиясе һәм геоэкологиясе; икътисади география һәм региональ анализ. Татар гуманитар-пед. ун-тында (Казан) һәм Чаллы пед. ин-тында Г. кафедралары эшли. Г. өлкәсендә тикшеренүләр СССР ФА Казан филиалының гидрология һәм су хуҗалыгы бүлегендә, 1990 еллардан ТР ФАнең Табигать системасы экологиясе ин-тында алып барыла. 1946 да Бөтенсоюз география җәмгыятенең Казан бүлеге оештырыла, ул 1958 дә шул җәмгыятьнең Татарстан ф-лы, 1993 тән Рус география җәмгыятенең Татарстан ф-лы итеп үзгәртелә.

19–20 йөзләрдә гомумтеоретик һәм региональ проблемаларны аеруча уңышлы тикшеренүләр геоморфологиядә (Н.А.Головкинский, П.И.Кротов, В.Н.Сементовский, В.В.Батыр, А.В.Ступишин, А.П.Дедков, Ю.В.Бабанов, А.М.Трофимов, Н.П.Торсуев, Г.П.Бутаков, В.И.Мозжерин, А.Г.Мусин), метеорология һәм климатологиядә (И.И.Запольский, А.Я.Купфер, Ф.К.Броннер, В.А.Ульянин, П.Т.Смоляков, Н.В.Колобов, Ю.П.Переведенцев), гидрологиядә (Г.Н.Петров), туфрак географиясендә (Р.В.Ризположенский, И.В.Тюрин), биогеографиядә (М.П.Богданов, С.И.Коржинский, А.Я.Гордягин, В.И.Баранов, В.А.Попов), физик-географик районлаштыру һәм ландшафт белемендә (А.В.Ступишин, Н.Н.Лаптева), икътисади һәм иҗтимагый географиядә (Н.-Б.З.Векслин, П.В.Абрамов, Н.И.Блажко, Р.Г.Хуҗиев), Идел буе халыклары этнографиясе һәм географиясендә (Б.Ф.Адлер, Н.И.Воробьёв, Е.П.Бусыгин, Н.В.Зорин) алып барыла. ТРның табигате һәм аның аерым компонентлары (рельеф, климат, елгалар һәм күлләр, үсемлек һәм хайваннар дөньясы) турында күп кенә фундаменталь хезмәтләр эшләнә. Татар һәм рус телләрендә Татарстан географиясе дәреслекләре нәшер ителә (Ә.С.Тайсин, Г.П.Бутаков һ.б.).

*Әд.:* Александров И.Н. Проблемы географии в Казанском университете. К., 1964; Дедков А.П., Переведенцев Ю.П. География в Казанском университете // Вестн. Моск. ун-та. Сер. 5. География. 1998. № 5.


*А.П.Дедков.*


**ГЕОДЕ́ЗИЯ** (*гео*... һәм грек. dáiō — бүләм, бүлгәлим), фәннәр системасы, Җирнең формасын, үлчәмнәрен һәм тышкы гравитация кырын билгеләүне, топографик карталарда һәм планнарда Җир өстен чагылдыру һәм инженерлык мәсьәләләрен (эзләнүләр, проектлау, җирдән файдалану, төзелеш) чишү өчен үлчәүләр алу юлларын өйрәнә. Югары Г.гә, топографиягә һәм гамәли (инженерлык) Г.гә бүленә. Югары Г. Җир өстендәге аерым нокталарның бер-берсенә карата билгеле бер төгәллектә (таяныч геодезик челтәрләр) урнашуын билгеләү максатында үлчәү һәм аларны эшкәртү алымнарын, ш.у. Җирнең фигурасын һәм үлчәмнәрен билгеләү теориясен һәм ысулларын өйрәнә. Топографик ысуллар ярдәмендә җир өстендә төшерелгән план, аэрофотосурәт һәм космостан төшерелгән сурәтләрдән чыгып, җир өстендәге төрле урыннар өйрәнелә, топографик планнар һәм карталар төзелә. Гамәли Г. төзелеш мәсьәләләрендә һәм төрле инженерлык корылмаларын эксплуатацияләүдә алып барыла торган геодезия эшләренең ысулларын, техникасын һәм оештыру юлларын үз эченә ала.

Г. бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Б.э.к. 18 йөздә борынгы Мисырда җир участокларының мәйданнарын билгеләү буенча кулланмалар була. Россиядә геодезик эшләр турындагы беренче мәгълүмат 11 йөзгә туры килә, 16 йөздә беренче карта төзелә. 1739 елда Петербург ФА каршында Г. эшләрен алып бару буенча География департаменты оештырыла. 1950–70 елларда СССР терр-ясендә бердәм триангуляция челтәре төзелә, аэрофотосурәтләр нигезендә 1:100000 һәм 1:25000 масштаблы топографик карталар ясала, бердәм яссы турыпочмаклы координатлар системасы кертелә. ТРда теоретик һәм гамәли эзләнүләр Казан ун-тында, Казан архит-ра-төзелеш академиясендә, Казан инженерлык-төзелеш эзләнүләре трестында һ.б. оешмаларда алып барыла. ТРның барлык терр-ясе аерым нокталардан (геодезик пунктлардан) торган һәм Җир өстендә геодезик тамгалар ярдәмендә беркетелгән геодезик челтәр б-н капланган; аларның урнашуын барысы өчен дә уртак булган геодезик координатлар системасы билгели. Бу челтәр геодезик, топографик, геодезик-бүлгәләү һәм геол. разведка маркшейдер эшләре уздыру өчен нигез булып тора. Дәүләт геодезик челтәре 1, 2, 3, 4 нче классларга бүленә, шуларның беренче өч классы — Роскартография ком-ты, ә дүртенче класс ТРның җитештерү оешмалары тарафыннан башкарыла.

**ГЕОЛО́ГИК ТАБИГА́ТЬ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ́**, фәнни, танып-белү, белемнәрне үстерү һ.б. өчен әһәмиятле булган геол. объектлар. Г.т.и.нә тау токымнарының уникаль һәм сирәк очрый торган чыганаклары, классик геол. киселешләр; минераллар һәм аларның ассоциатив тупланмалары; җир астындагы палеонтологик истәлекләр; мәгълүм карст убылмалары һәм мәгарәләр, борынгы эшкәртү калдыклары һ.б. керә. Г.т.и.н., генетик билгеләренә карап, типларга бүләләр (Ф.Р.Штильмарк, 1978; Н.Л.Фомичёва һ.б., 1993). Бер типтагы Г.т.и. — стратиграфик, минералогик, палеонтологик һ.б. истәлекләр. Бердәй әһәмиятле ике яисә аннан артык билгеләре булган очракта, Г.т.и. күп типтагы, ягъни комплекслы объектлар (геол.-тарихи, геоботаник һ.б.) дип атала. Г.т.и. аерып билгеләү һәм өйрәнү эшләре б-н Казан ун-ты (А.В.Ступишин, В.А.Полянин һ.б.), Казан пед. ин-ты (Ә.С.Тайсин), СССР ФА Казан ф-лы Геол. ин-ты галимнәре (Е.Ф.Станкевич, М.С.Кавиев һ.б.) шөгыльләнә. 20 йөз ахырына тикшеренүләр активлаша: халыкара (глобаль), федераль, республика һәм җирле дәрәҗәдәге 65 тән артык Г.т.и. билгеләнә (В.Г.Халымбаджа, Н.Л.Фомичёва, В.В.Силантьев, О.Г.Столова һ.б.). Г.т.и. булган 15 объект халыкара дәрәҗәгә ия. Алар арасында геол. мирасны саклап калу буенча Европа ассоциациясе 1991 дән башлап төзегән Бөтендөнья геол. мирасы исемлегенә кергән Печище авылы (Югары Ослан р-ны) янындагы югары Казан асъярусының стратотипик киселеше (к. *Печище геологик киселеше*) һәм Ишееводагы (Апас р-ны) Пермь тетраподалары (дүртаяклылары) чыганагы бар.

ТРда халыкара, федераль, җирле дәрәҗәдәге башка Г.т.и. бар. Пермь, неоген һәм дүртенчел системаларның стратотипик, парастратотипик һәм төп киселешләреннән гыйбарәт (Татар ярусының парастратотипик киселеше — Монастырь һәм Ильинка сызаларында, Уфа һәм Казан яруслары киселеше — Алабуга шәһәре янында, эоплейстоценның Лаеш свитасы стратотипик киселеше — шәһәр тибындагы Лаеш посёлогы янында һ.б.). Палеонтологик истәлекләрдән — Пермь системасы бөҗәкләренең уникаль табылдыгы Кама буенда Тихие Горы авылы янында, Пермь системасы флорасы чагылышы — «Тарловка» санаторие (Тукай р-ны) янында һ.б.; геодинамик истәлекләрдән — Пермь токымнарының Тәтеш дислокациясе, *Кама Та-*


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ГЕОЛОГИК КАРТАСЫ
Масштаб 1:1 500 000
2004 ел
Балтач
Олы Әтнә
Арск
Байлар Сабасы
Биек Тау
Теләче
Яшел Үзән
Питрәч
Югары Ослан
КАЗАН
Олы Кайбыч
Лаеш
Балык Бистәсе
Алексеев
Кама Тамагы
Апас
Буа
Тәтеш
Болгар
Базарлы Матак
Аксубай
Иске Чүпрәле
Нурлат
Казанка
Мишә
Зөя
Куйбышев сусаклагычы
Кече Чирмешән
Олы Чирмешән
$N_2$
$P_2kz$
$P_2t$
$J_2$
$J_3$
$K_1$
$K_2$
$N_2$ НЕОГЕН СИСТЕМАСЫ: Югары бүлек (плиоцен)
АКБУР СИСТЕМАСЫ:
$K_2$ Югары бүлек
$K_1$ Түбәнге бүлек
ЮРА СИСТЕМАСЫ:
$J_3$ Югары бүлек
$J_2$ Урта бүлек
ПЕРМЬ СИСТЕМАСЫ: Югары бүлек
$P_2t$ Татар ярусы
$P_2kz$ Казан ярусы
$P_2u$ Уфа ярусы
▲ $P_1$ Түбәнге бүлек
Дуртенчел утырмалар картада күрсәтелмәде




*Мөхәррирләре – Б.В.Буров, А.П.Дедков. Картограф – Р.Г.Нурмөхәммәтов .*
*Картаны төзегәндә ТРның 1:200000 масштаблы Геологик картасы (1998) файдаланылды.*

*магы спелеологик системасы* һ.б.; геологик-тарихи истәлекләр — Дусай авылы (Мамадыш р-ны) янында калган бакыр рудалары эшкәртү урыны, Печище авылы янында калган таш вату эзләре һ.б. Г.т.и.н дәүләт тарафыннан күзәтү формасы булып ТРда аеруча саклана торган табигый терр-яләрнең Дәүләт реестры һәм РФ геол. объектлар мирасының Дәүләт җыентыгы тора. Г.т.и.нең хокукый режимы ТРда гамәлдә булган табигатьне саклау законнары һәм закон актлары (Аеруча саклана торган табигать терр-яләре турындагы закон, Җир асты байлыкларын саклау турындагы закон һ.б.) б-н билгеләнә. Г.т.и. җирләрендә табигый объектларны өйрәнү һәм саклауга бәйле булмаган һәм ТР законнарында каралмаган башка эшчәнлек тыела. Ш.у.к. *Асфальтит чыгышы*, *Ташлы ерым*, *Лобач тавы*, *Черёмушки ерымы*.

*Әд.:* Геологические памятники природы России. СПб., 1988; Фомичёва Н.Л., Садикова В.Р., Мутыгуллин Р.Х. Геологические памятники Республики Татарстан и их конструктивное комплексное использование // Особо охраняемые природные территории Республики Татарстан. К., 1995; Государственный реестр особо охраняемых природных территорий в Республике Татарстан. К., 2007.

*Н.Л.Фомичёва.*

**ГЕОЛО́ГИК ТӨЗЕЛЕ́Ш**. Татарстан Көнчыгыш Европа (Рус) архей-протерозой платформасының көнчыгыш өлешендә, Идел-Кама антеклизы чикләрендә ята. Антеклиза, үз чиратында, берничә уңай структур формадан (Татар, Токмов, Башкорт, Кама гөмбәзләре) һәм аларны бер-берсеннән аеручы батынкылыклардан (Мәләкәс, Югары Кама һ.б.) тора. Архей-түбән протерозой этабында континенталь кабыкның формалаша башлавын чагылдыручы калын гранитоидлар массивы хасил була (к. *Кристаллик нигез*). Авлакоген тибындагы бөгелешләрне соңгы протерозойның (рифей һәм венд) утырма токымнары тутырган (к. *Авлакоген*). Регионның палеозой чоры тарихы платформаның Урал алды буенда континенталь кабыкның аерылып (рифт хасил булып), алга таба (кембрий чоры ахырында — ордовик чоры башында) аның киңәюе активлашып, Урал океаны ачылуга бәйле. Палеозойның башлангыч чоры дәверендә платформаның көнчыгыш чите, биек күтәрелгән терр-ядән гыйбарәт булып, интенсив эрозия процессларын кичерә. Девонда континенталь плитаның көнчыгыш чите диңгез сулары б-н тула, диңгез утырмалары туплана башлый һәм бу процесс соңгы Пермь чорларына кадәр өзлексез дәвам итә.

Пермь системасының башлангыч чорындагы үсеш этабына Урал таулары хасил булу һәм диңгезнең акрынлап платформадан чигенүе хас. Пермь системасының соңгы чоры башланганда, Урал буйларыннан диңгез бассейны тәмам кысрыклап чыгарыла һәм Рус платформасының аның б-н янәшә тирәләрендә таулар хасил булу процессы башлана. Аның терр-ясендә бик киң, Уралга параллель булган тотрыклы бөгелеш зонасы — соңгы Пермь чоры утырмалары бассейны хасил була. Ул Урал ягыннан таркалу һәм җимерелү продуктлары б-н тула башлый. Геоморфологик инверсия барлыкка килә — Рус платформасының көнчыгыш өлеше үзенең девон, карбон һәм башлангыч Пермь чорларында көнчыгышка караган өслек авышлыгын көнбатышка үзгәртә (хәзер дә шул хәлендә саклана). Шул вакытта Урал тауларыннан башланып, платформага таба агучы яңа елга системалары хасил була. Бөгелешләрнең иң көчле стадиясендә (Казан чоры) утырмалар бассейнының өслеге Дөнья океаны өсте тигезлегеннән түбәнәя һәм диңгез сулары б-н тула. Татар чоры башына (к. *Пермь системасы* (*чоры*)) диңгез бассейны Уралдан төшкән ватылма токымнар (молас формацияләр) тарафыннан төньяккарак кысрыклана (к. ТРның Геологик картасын, 104–105 битләр). Регионның мезозой-кайнозой чорларындагы геологик тарихы Урта диңгез орогенезы йогынтысы астында була һәм Татарстан терр-ясенең төп өлешен тәшкил итүче Идел-Кама антиклинорие коры җир булып кала бирә. Мезозой утырмалары (юра һәм акбур) туплану өлешчә республиканың көньяк-көнбатыш өлешенә эләгә. Кайнозойда (неоген, плейстоцен) утырмалар туплану, башлыча, бу вакытка формалашып җиткән зур елгалар үзәннәрендә бара. Ш.у.к. *Голоцен*, *Неоген системасы* (*чоры*), *Акбур системасы* (*чоры*), *Юра системасы* (*чоры*), *Ташкүмер системасы* (*чоры*), *Девон системасы* (*чоры*).

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Геология Татарстана: Стратиграфия. Тектоника. К., 2002. Атлас Республики Татарстан. М., 2005.

*Б.В.Буров.*

**ГЕОЛО́ГИЯ** (*гео*... һәм ...*логия*), Җир һәм Җир кабыгының составы, төзелеше, үсеш тарихы, файдалы казылмалар хасил булу һәм аларның урнашуын өйрәнүче фәннәр комплексы. «Г.» термины 1657 елда Норвегия галиме М.П.Эшольт тарафыннан кертелә. Г. нең төп объекты булып Җирнең тышкы таш катламы — литосфера һәм, беренче чиратта, Җир кабыгындагы файдалы казылмаларны өйрәнү һәм чыгару өчен уңайлы горизонтлар тора.

Хәзерге геология үз эченә *стратиграфия*, *тектоника*, региональ Г., *минералогия*, *петрография*, *литология*, *геохимия*, файдалы казылмалар өйрәнү белемен ала. Г. *физик география*, *геофизика*, *кристаллография*, *палеонтология* б-н тыгыз бәйләнештә. Гамәли әһәмияткә ия булган тармаклары — *гидрогеология*, *инженерлык геологиясе* һәм ш.у. яңа юнәлешләр — петрохимия, *петрофизика* һ.б. үзенә бер төркем хасил итәләр.

Г. 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башында табигать белеменең мөстәкыйль тармагына әверелә (Н.Стено катламнарның өзлексезлек суперпозиция принципларын билгели; В.Смит һәм Ж.Кювье киселешне биостратиграфик бүлемнәргә аеру һәм токымнарның чагыштырмача яшен билгеләү ысулын эшлиләр). 1840 еллар башында фанерозойның стратиграфик шкаласы төзелә. Шул ук вакытта, беренчеләрдән булып, 19 йөзнең 1 нче яртысы геологлары өчен парадигма булган «күтәрелеш кратерлары» дигән беренче тектоник концепция барлыкка килә (Л.Бух һәм А.Гумбольдт). Россиядә бу теориянең тарафдарлары булып Д.И.Соколов, Г.Д.Романовский, Н.А.*Головкинский* һ.б. тора. Күп илләрдә геология җәмгыятьләре оеша, алар Г. фәненең яңа казанышлары турында фикер алыша, эзләнүләр турында материаллар бастырып чыгара һәм кайбер эшләрне финанслый. 1805 тә — Мәскәүдә табигатьне тикшерү, 1807 дә — Лондонда геология, 1917 дә Россиядә Минералогия җәмгыятьләре оештырыла. Системалы рәвештә план төшерү һәм эзләнү эшләре үткәрү зарурлыгы соңрак милли Г. хезмәтләре оештырылуга китерә. 1882 дә Россиядә Г. комитеты оештырыла.

Озак еллар буе Казан губ. терр-ясендә геол. эзләнүләр алып баручы оешма Казан ун-ты була. Физика һәм матем. фәннәре бүлеге составына табигать тарихы һәм ботаника кафедрасы керә; 1805 елда минераллар, рудалар һ.б. коллекцияләрне үз эченә алган табигать тарихы кабинеты, 1824 тә — минерал. кабинеты, 1840 та — минерал. һәм геогнозия, 1865 тә — геогнозия һәм палеонтология, 1920 дә минерал. һәм петрография кафедралары ачыла. 1928 дә геол.-биол.-геогр. ф-ты булдырыла; ул 1937 дә геогр. һәм геол.-туфрак ф-тларына бүленә. 1948 дә геол. ф-ты мөстәкыйль ф-тка әйләнә: гомуми, региональ һәм тарихи геол., геофиз., нефть һәм газ, геол. разведка эшләре һәм файдалы казылмалар кафедралары оештырыла. 1940–50 елларда СССР ФАнең Казан филиалы каршында Геол. ин-ты (хәзерге *ЦНИИгеолнеруд*), Татарстан геол.-эзләнүләр тресты, «Татнефтегазразведка» һәм «Татнефтегеофизика» трестлары, ТатНИПИнефть һәм ТРның башка геол. пр-тиеләре төзелә.

1992 дә Файдалы казылмалар запасы буенча комиссия оештырыла; 1997 дә аның вазифасы ТРның Геол. һәм җир асты байлыклары дәүләт ком-тына йөкләнелә, 2001 елдан ул, департамент сыйфатында, ТРның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына карый. Ш.у.к. *Казан геология мәктәбе*, *Нефть һәм газ геологиясе, Файдалы казылмалар геологиясе*.

*Б.В.Буров.*

**ГЕОЛО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты*.

**ГЕОЛО́ГИЯ МУЗЕЕ́**, А.А.Штукенберг исемендә, Казан ун-тының фәнни уку-укыту бүлекчәсе. Геол. ф-ты бинасында урнашкан. Музейның гомуми мәйданы 1100 *м²*. Коллекция фондында дөньяның 65 иленнән китерелгән үрнәкләр һәм 150 меңнән артык саклау берәмлеге тупланган. Г.м. составында: 7 бүлек (динамик геология, минералогик, палеонтологик һәм тарихи геологияләр, нефть геологиясе, файдалы казылмалар, персоналийләр, монографик коллекцияләр), шомарту лаб-ясе, «Казан Кремле» музей саклаулыгында бүлекчә. Тарихы натураль, ягъни табигать тарихы һәм минералогия кабинетлары оештырылганнан башлап — 1804 елдан бирле килә. 1935 тә кабинетлар бердәм геол.-минерал. музеена берләштерелә. 2003 тән хәзерге исемендә.



































**Геология музее мәкаләсенә.** Музей тупланмаларыннан экспонатлар: 1. Флюорит (Англия); 2. Шпинель (Урал); 3. Пирит (Казакъстан); 4. Гипс роза (Сахара); 5. Кальцит (Англия); 6. Кварцтагы турмалин (Урал); 7. Малахит (Урал); 8. Esquel метеориты (АКШ); 9. Чароит (Якутия); 10. Трилобит (казылма буынтыгаяк); 11. Тропик моллюсклар (Казан ун-ты профессоры И.М. Симонов коллекциясе).

Коллекция кенәз Г.А.Потёмкин-Таврическийның 1789 да Казанга китерелгән минераллар җыелмасыннан һәм Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенең «табигый әйберләр» исәбенә кергән төрле характердагы палеонтологик табылдыклардан туплана башлый. Соңыннан музей коллекциясе бүләкләр, чит илләрдән һәм Россиядә сатып алынган әйберләр, Казан ун-ты галимнәре һәм студентларының экспедиция вакытында җыйган материаллары, Урал з-длары һәм ун-т карамагындагы Себер уку йортларының бүләкләре б-н тулылана. Музейны оештыру һәм аны үстерүдә С.Я.Румовский, И.Ф.Яковкин, К.Ф.Фукс, И.М.Симонов, Э.И.Эйхвальд, А.Я.Купфер, Ф.Ф.Розен, Н.И.Лобачевский, М.Н.Мусин-Пушкин, Н.А.Головкинский, А.А.Штукенберг, А.В.Нечаев, А.В.Лаврский, Б.К.Поленов, П.И.Кротов, М.Э.Ноинский, Л.М.Миропольский, М.Г.Солодухо, Т.А.Тефанова, Н.Л.Фомичёва һ.б. катнашалар.

19 йөздә — 20 йөз башында танылган чит ил фирмалары: Англиядәге Р.Дамон, Германиядә Кранц һәм Верт, Швейцариядә Нобель һәм Вендлер һ.б.дан минераллар һәм палеонтология коллекцияләре сатып алына. Г.м. фондында Россиядә җыелган коллекцияләр генә түгел, ә чит илләрдән кайтарылган кыйммәтле тупланмаларның да булуы аны башка төбәкләрнең фәнни-табигать музейларыннан аерып тора. Музей фонды чит ил һәм Россия минералларының системалаштырылган җыелмаларын, руда һәм руда булмаган файдалы казылмалар, магматик, метаморфик һәм утырма тау токымнарын, метеорит һ.б.ны үз эченә ала. Музей минераллары арасында раритетлар да аз түгел: кара шпинельнең (плеонаст) 21,0162 *кг* авырлыктагы, 260×280 *мм* лы уникаль үлчәмле октаэдрик кристаллы (Уралдан китерелгән), Якутия базальтларыннан анальцимның додекаэдрик кристаллы (200×160 *мм*), Бразилия, Германия, Россиядә шомартылган ахаклар һ.б. Г.м.дагы метеорит коллекциясе — РФдәге иң бай коллекцияләрнең берсе, *Каенсаз* метеориты аеруча әһәмияткә ия. 1996–98 дә Г.м. б-н АКШ (Нью-Йорк) һәм Чехия (Прага) музейлары арасында күп тапкырлар метеорит коллекцияләре алмашу була. Яңа алынган экспонатлар арасында сирәк матурлыкка ия булган Esquel һәм Zagami метеоритлары, Америка галимнәре фикеренчә, Марс матдәсе кисәкчекләрен тәшкил итә.

Палеонтологик коллекцияләрдә, протерозой чорыннан тыш, борынгы хайваннарның барлык типлары бирелгән. Геология фәненең дөньякүләм алтын фондына караган һәм дөньяның күп кенә илләрендә мәңге саклanырга тиешле палеонтологик монографик уникаль коллекцияләр тупланган. Музейда казылма фауна һәм флораның яңа төркемнәре саклана: Пермь чоры фораминифералары коллекциясе (В.А.Чердынцев, Н.А.Вәлиева, В.М.Игонин); девон, карбон, Пермь чоры брахиоподы (Б.В.Селивановский, В.П.Прокофьев һ.б.); девон, карбон, Рус платформасының, Казакъстан һәм Кытайның девон, карбон, Пермь чорлары конодонтларының уникаль коллекциясе (В.Г.Халымбаджа); Пермь, неоген чорларының ике кабырчыклы моллюсклары (А.В.Миртова, А.К.Гусев, В.В.Силантьев); Пермь чоры балыклары (Г.Н.Фредерикс, Б.П.Кротов, М.Г.Солодухо, В.В.Силантьев һ.б.); Пермь чоры палеоген һәм неоген үсемлекләре калдыклары (А.В.Миртова, Е.И.Тихвинская, Т.А.Тефанова, А.В.Богов, Н.Л.Фомичёва, Н.К.Есаулова).

Музейда фәнни әһәмияте, саклануы, комплекслылыгы һәм саны буенча сирәк очраучы плейстоценлы палеозологик коллекцияләр дә саклана, алар арасында 19 йөз ахырында Пермь губернасының Козлово авылы янында табылган мамонтның тулы скелеты бар.

20 йөзнең 2 нче яртысында музей фонды тематикасын һәм экспонатлар географиясен киңәйтә. Музей фондын тагын да үстерүдә Казан ун-тының геология ф-тын тәмамлаучыларның роле арта (А.А.Замараев — Якутия минераллары; Г.А.Мирлин — Тын океан төбеннән алынган тимер-марганецлы конкрецияләр).

Музей коллекциясе материаллары, дөньяда беренчеләрдән булып радио һәм оптик спектроскопия ысулларын кулланып, минералларның изоморфизмын өйрәнү методологиясен эшләү мөмкинлеге бирә, бу исә *минераллар физикасы* буенча Казан фәнни мәктәбенең формалашуына китерә (В.М.Винокуров, И.Н.Пеньков, А.И.Бахтин, Г.Р.Булка, Н.М.Низаметдинов һ.б.).

Музей коллекциясе РФАнең Башкортстан ф-лы, РФАнең Коми гыйльми үзәге, ЦНИИгеолнеруд, РФАнең Палеонтология, Геология һәм Зоология ин-тлары хезмәткәрләре һ.б. үткәргән фундаменталь фәнни тикшеренүләрдә кулланыла.

Музейның монографик палеонтология коллекцияләре һәм казылма фаунаның уникаль индивидлары халыкара геологик конгрессларда, киңәшмәләрдә еш файдаланыла.

Г.м. халыкара статуска ия, халыкара һәм Россиянең каталог һәм белешмәлекләренә кертелгән; ул Халыкара музейлар советы, Россия Геол. җәмгыятенең гыйльми советы составларына керә. Халык арасында фәнни-агарту эшләре алып бара, ТР терр-ясендә тау эшләре тарихы, геол. фәне һәм Казан ун-тында белем бирү тарихы буенча материаллар җыя һәм экспозицияләр тәкъдим итә. Татарстан, Мари, Удмурт, Чуаш Респ-калары, Ульянов һәм Киров өлкәләренең урта һәм югары уку йортларына, төбәкне өйрәнү музейларына фәнни-методик ярдәм күрсәтә.

*Әд.:* Штукенберг А.А. Материалы для истории минералогического и геологического кабинетов Императорского Казанского университета. К., 1901; Тефанова Т.А. Геолого-минералогический музей Казанского государственного университета имени В.И.Ульянова-Ленина за 150 лет // Уч. зап. Казан. ун-та. 1954. Т. 114, кн. 9; Фомичёва Н.Л. Краткая характеристика фонда Геолого-минералогического музея Казанского университета и опыт его научной работы // Новые данные о минералах. М., 1989. Вып. 36.

*Н.Л.Фомичёва, Е.С.Шуликов.*

**ГЕОЛО́ГИЯ-МИНЕРАЛО́ГИЯ МУЗЕЕ́**, к. *Геология музее.*

**ГЕОМАГНЕТИ́ЗМ** (*гео*... һәм грек. magnē̃tis — магнит), Җир магнетизмы, Җирнең магнит кыры, аның фәзадагы структурасы, вакыт эчендә үзгәрешләре һәм башка геофизик күренешләр б-н бәйләнеше турындагы фән; *геофизиканың* бер бүлеге. Магнит күренешләре инде борынгы Римда ук билгеле була. Ләкин Җир магнетизмы турындагы фәннең башлангычы Х.Колумбның 1492–93 елларда Европадан Америкага сәяхәте вакытында магнит авышуын, аннан соң инглиз гидрогрофы П.Норманның магнит тайпылышын ачуы (1581) б-н бәйләп аңлатыла. Россиядә магнит күренешләрен күзәтү эшләре беренче буларак 1556–57 дә Печора елгасы тамагында, Яңа Җир һәм Вайгач утрауларында, Холмогоры авылында, 1761 дә Казанда үткәрелә. 1759 да беренче тапкыр М.В.Ломоносов Җир шарының төрлечә магнитлануы турында фикер әйтә һәм Җир өстендә магнит кырының үзгәрүчән булуын аңлата.

Фәзаның теләсә кайсы ноктасында зурлыгы һәм юнәлеше б-н тасвирлана торган геомагнит кыры даими (99%) һәм үзгәрүчән (1%) өлешләрдән тора. Даими кырны — Җирнең эчке көчләре, үзгәрүчән кырны тышкы көчләр — ионосфера һәм магнитосфера көчләре хасил итә. Геомагнит кыры вакыт узу б-н акрынлап үзгәрә. Шул сәбәпле навигация һ.б. өлкәләрдә файдаланылучы дөньяның магнит кыры карталары (бигрәк тә магнит авышуы карталары) периодик рәвештә яңартылып тора. Геомагнит кырының үзгәрүчән өлеше, башлыча, Кояш эшчәнлеге б-н бәйле; ул периодик рәвештә төрле үзгәрүләргә (магнит вариацияләре) һәм магнит кырының ярсынуларына (магнит давыллары) китерә. Тегеләре дә, болары да Кояштан килүче корылган кисәкчекләр агымы — Кояш җиле йогынтысында хасил була. Аның йогынтысы ионосферада һәм магнитосфера чигендә вакытлы электр кырлары, димәк, үзгәрүчән магнит кырлары барлыкка китерә; алар Җир өстенә магнит вариацияләре рәвешендә килеп җитә. Кояш җиленең интенсивлыгы, кисәкчекләренең тизлеге һәм аларның магнитосферага килеп керүе анда көчле ярсынулар китереп чыгара.

Узган заманнарның геомагнит кыры, тарихи яктан караганда (археомагнетизм), матди культура әйберләрендә (борынгы учаклар, яндырылган кирпеч, керамика һ.б.), ә геол. яктан караганда (палеомагнетизм), тау токымнарында сакланып калган магнитлану чагылышыннан чыгып өйрәнелә. Җир магнетизмы Казан ун-ты галимнәре (Н.М.Симонов, А.Я.Купфер) тарафыннан 19 йөз башында өйрәнелә башлый. 1870 елларда И.Н.Смирнов беренче тапкыр планлы рәвештә Россиянең Европа өлеше һәм Кавказның 281 пунктында магнит кырын үлчи. Аңа кадәр Россия империясенең төрле урыннарында магнит кырын күзәтүләр, башлыча, чит ил галимнәре, һәм өлешчә, Петербург ФА галимнәре тарафыннан башкарыла. Смирнов тикшергән нәтиҗәләр А.Тиллога беренче тапкыр 1880 елларда Россиянең Европа өлеше һәм Кавказның магнит кыры карталарын төзергә мөмкинлек бирә. 1874 тә Белгород шәһәре тирә-

сендә (хәзер Курск магнит аномалиясе дип аталган р-н) Смирнов тарафыннан шактый интенсив чагылышлы магнит кырлары күзәтелә һәм ул тирәнтен өйрәнелә. 20 йөз башында В.А.Ульянин эшләре зур игътибарга ия була. 1931–36 да СССРда беренче тапкыр Магнит кырларын ген. төшерү эшләре Европа өлешендә 20–30 *км* саен күзәтү челтәре төзеп башкарыла. Татарстан терр-ясендә мондый эш, башлыча, 1931–33 тә үткәрелә. Нәтиҗәдә СССРның бөтен терр-ясе өчен (Татарстанны да кертеп) беренче тапкыр Җирнең магнит кыры элементларының фәзада таралуын күрсәтүче карталар төзелә; алар Җир магнетизмы проблемаларын чишүдә, илнең гомуми геол. төзелешен өйрәнүдә һ.б. зур роль уйный. 1934 тән башлап Татарстан терр-ясендә геол. тикшеренү мәсьәләләрен хәл итү — кристаллик нигез һәм утырма тышлыкның төзелешен өйрәнү, нефтьле-газлы структураларны, битум һ.б. файдалы казылмалар чыганакларын эзләү максатында магнит кырын планга төшерү эшләре алып барыла. 1955 кә Татарстанның бөтен терр-ясе Җир өстендә магнит кырын планга төшерү мәйданчыклары б-н капланган була. 1957 гә магнит аномалияләре һәм авырлык көче аномалияләренең беренче уртак карталары (масштабы 1:200000) төзелә. Магнит һәм гравитация аномалияләрен геол. яктан ачыклау нәтиҗәсендә Татарстанның кембрийгача чорындагы кристаллик нигезенең эчке төзелеше турында беренче схема төзелә (В.П.Боронин). 20 йөзнең 2 нче яртысында респ-ка терр-ясенең кайбер участокларында — Җир өстендә һәм һавадан югары төгәллектәге планнар төшерелә. 1955–60 та Татарстан терр-ясе магнит кырын очкыч аппараттан (аэропрофильләр арасы 3–5 *км* була) планга төшерү регионына әверелә. 1960–62 дә, аэропрофиль аралары 500 *м* калдырылып, җентекләбрәк эшләнелгән 1:100000 масштаблы карта төзелә. 1972–73 тә респ-каның үзәк һәм көнчыгыш өлешләрендә магнит кыры югары төгәллектә очкыч аппаратлардан төшерелә. 1987 дән Татарстан терр-ясендә магнит кырын планга төшерү очкыч аппаратлар ярдәмендә аэрограмма-спектрометрия ысулы һәм экол. күзәтүләр б-н бәйләлектә планлы рәвештә, җентекләп, югары төгәллектә (аэропрофильләр арасы 250 *м*, очу биеклеге 200 *м*, карта масштабы 1:50000) үткәрелә. Магнит аномалияләренең Җир өстендә һәм һавадан очкычлар ярдәмендә төзелгән карталары башка геол.-физ. материаллар б-н бергә кристаллик нигез һәм утырма тышлыкның төзелешен өйрәнүдә, нефть, битум һ.б. файдалы казылмалар чыганакларының перспективалы участокларын билгеләүдә кулланыла. Татарстанда мондый мәсьәләләрне чишүгә, магнит аномалияләрен геол. яктан аңлатуга геофизиклар В.П.Боронин, М.Я.Боровский, В.И.Богатов, Н.А.Докучаева, Г.Е.Кузнецов, Д.К.Нургалиев, А.Г.Салихов, В.П.Степанов, И.М.Уразаев, Р.К.Хәбибуллов, Б.Г.Червиков, Э.К.Швыдкин һ.б. зур өлеш кертә. 1963 тә Казан ун-тында Нургалиев инициативасы б-н һәм Боронин җитәкчелегендә тау токымнары палеомагнетизмы һәм магнетизмы өлкәсендә эзләнүләр башлана.

Казан ун-тыннан Г. өлкәсендә эшләүче Б.А.Андреев, В.И.Афанасьева, Н.П.Бенькова, Ю.Д.Калинин, А.А.Логачёв, М.К.Фәтхуллин кебек танылган галимнәр чыга. Алар 1940 елда СССР ФАнең Җир магнетизмы ин-ты ачылуда һәм аның үсешендә зур роль уйный. Андреев һәм Логачёв Ленинград геофиз. мәктәбен оештыралар; Андреев региональ структур геол. мәсьәләләрен чишү өчен геофиз., ш.и. магнит ысулын куллану ысулын эшли, Логачёв дөньяда беренче аэромагнитометр һәм магнит кырын планга төшерүнең яңа аэромагнит төрен уйлап таба һәм аның өчен Ленин премиясенә лаек була.

*Әд.:* Я н о в с к и й Б.М. Земной магнетизм. Л., 1978; Б о р о н и н В.П., С т е п а н о в В.П., Г о л ь д ш т е й н Б.Л. Геофизическое изучение кристаллического фундамента Татарии. К., 1982; Б о р о в с к и й М.Я., Г а з е е в Н.Х., Н у р г а л и е в Д.К. Геоэкология Республики Татарстан: геофизические аспекты. К., 1996.

*В.П.Боронин.*

**ГЕОМЕ́ТРИЯ** (*гео...* һәм *...метрия*), математика фәненең бер бүлеге, фәзадагы үзара нисбәтләрне, формаларны һәм гомумиләштерүләрне өйрәнә. Г. математиканың башка бүлекләре б-н тыгыз бәйләнгән, шуңа күрә аның чикләре төгәл билгеләнмәгән.

Г. гә кагылышлы белемнәр бик борынгы заманнан ук (Мисыр, Вавилон) җир кишәрлекләре мәйданын, җисемнәрнең күләмен үлчәү, төзү, сугару һ.б. эшләр, астрономик күзәтүләр ихтыяҗы нәтиҗәсендә тупланып килгән. Борынгы грек галиме Евклидның «Башлангычлар» («Начала») исемле хезмәтендә (б.э.к. 3 йөз) беренче мәртәбә аксиомалар — Г. нең төп законнары тәгъбирләнгән, алар ярдәмендә иң гади фигураларның төрле үзлекләре исбатлап чыгарылган. Архимед (мәйдан һәм күләмнәрне тулыландырып исәпләү ысулы, б.э.к. 3 йөз), Аполлоний (коник кисемнәр турындагы тәгълимат, б.э.к. 3 йөз), Птолемей (сферик Г., б.э.к. 2 йөз) ачышлары да — Г. өлкәсендәге мөһим казанышлар.

17 йөздә Р.Декарт (1637) тарафыннан төзелгән координаталар ысулы Г. мәсьәләләрен саннар теленә күчерергә һәм аларны алгебраик ысуллар б-н чишәргә мөмкинлек бирә һәм яңа ачышларның — дифференциаль һәм интеграль исәпләүләрнең (И.Ньютон һәм Г.В.Лейбниц) нигезен тәшкил итә. 18 йөздә евклидча фәзадагы кәкреләрне һәм өслекләрне өйрәнгәндә анализ ысуллары куллану барышында (бертуган Я. һәм И.Бернуллилар, Г.Монж, Л.Эйлер һ.б. хезмәтләрендә) классик дифференциаль Г.гә нигез салына. 19 йөздә өслекләр теориясендәге иң мөһим нәтиҗәләр немец математигы К.Ф.Гаусс исеме б-н бәйле. Ул өслекнең эчке Г.се дигән, бөгелгәндә дә үзгәрмәүчән эчке үзлекләре җыелмасы төшенчәсен кертә (1827). Евклидча Г.дән бөтенләй аермалы, логик каршылыксыз булган Г. төзеп, Н.И.*Лобачевский* бу фәннең үсешендә принципиаль яңа адым ясый (к. *Лобачевский геометриясе*). 19 йөздә Лобачевский геометриясе барлыкка килү, шуннан соң бүтән нәевклид Г.ләр төзелү математикада аксиомалар ысулын үстерүгә һәм камилләштерүгә этәргеч бирә (Д.Гильберт һ.б.). Немец математигы Ф.Клейнның рәвешүзгәртүләр төркемнәре теориясе нигезендә нәевклид Г.ләр классификациясен төзүе 19 йөздәге зур казанышларның берсе булып санала. 1854 елда немец математигы Б.Риман нәевклид Г.ләр кысаларына сыймаган фәзалар төзи. Риман күптөрлелекләре һәм аларны гомумиләштерү буенча алып барылган тикшеренүләрдә «гомумиләштерелгән фәзалар» дип аталган төшенчә кертелә, ә аларны өйрәнү 20 йөздә киң колач ала. Мәс., А.Эйнштейн, дүрт үлчәмле Риманча фәза-вакыт төшенчәсен кулланып (1916), чагыштырмалылыкның гомуми теориясен төзи.

19–20 йөзләр чигендә математикада абстракт карашларның үсеше Г. не күплекләр теориясе нигезенә күчерүгә китерә. Француз математигы А.Пуанкареның күптөрлелекләрдә интеграль исәпләүләр, француз математигы М.Фреше б-н немец математигы Ф.Хаусдорфның метрик күптөрлелекләр теориясенә караган һәм Мәскәү матем. мәктәбе вәкилләренең (П.С.Александров, П.С.Урысон, А.Н.Колмогоров, Л.С.Понтрягин) тикшеренү нәтиҗәләре Г. нең яңа бүлеге — топология фәне барлыкка килүгә ярдәм итә, ә ул математиканың бүтән өлкәләре үсешенә дә зур йогынты ясый. 20 йөздә дифференциаль Г.дә ике юнәлеш билгеләнә. Беренче юнәлеш, матем. анализ ысулларын файдаланып, бирелгән нокта тирәсендәге геометрик объектларның локаль үзлекләрен өйрәнә һәм ул тикшерелә торган объектларны сызыкчалатырга, сызыкча алгебра ысулларын кулланырга мөмкинлек бирә. Шул юнәлешнең үсүе нәтиҗәсендә К.Риччи, Т.Леви-Чивита, Э.Картан һ.б. хезмәтләрендә тензорлы анализга, бәйләнгәнлек теориясенә һәм ковариант дифференциаллауларга нигез салына. Икенче юнәлеш — дифференциаль топология — 1930 еллар уртасында Х.Уитни һәм Э.Штифель, Л.С.Понтрягин, Ш.Чжень һ.б. хезмәтләрендә нигезләнә. Шома күптөрлелекләрнең топологик инвариантларын, аларны сыйфатлаучы классларның терминнарын өйрәнгәндә гаять зур нәтиҗәләргә ирешелә (В.А.Рохлин, Д.У.Милнор, М.Ф.Атья һ.б.). Гомумән алганда, Г. кәкреләр һәм өслекләрнең төзелешен Евклид һәм нәевклид фәзаларында һәрьяклап, ш.и. аларның шома түгеллеген һәм үзенчәлекле нокталары булуын да исәпкә алып өйрәнә (Н.В.Ефимов, А.Д.Александров, А.В.Погорелов, Н.Кейпер һ.б.).

Казан Г. мәктәбе галимнәре нәевклидча, риманча һәм «гомумиләштерелгән» фәзаларны өйрәнүгә мөһим өлеш кертәләр. П.А.*Широков* тарафыннан алынган (1923–25) нәтиҗәләр бөтен дөньяга таныла, аның риманча күптөрлелекләр структураларына караган идеяләре Казан геометрлары тикшеренүләренең юнәлешен билгели (Б.Л.Лаптев, И.П.Егоров, А.З.Петров, П.И.Петров). Б.Л.*Лаптев* Финслер күптөрлелекләрен тикшергәндә тензорлы ысуллар куллана (1938), аннары теркәк элементлар фәзаларының гомуми теориясен төзи (1954–58). Эйнштейнның гомуми чагыштырмалылык теориясе кысаларында тар-

тылу кырларын тикшерүгә Риман Г.се ысулларын һәм төркемнәр теориясен кулланып, А.З.*Петров* дөньякүләм югары нәтиҗәгә ирешә (1954). Аның шәкертләре (В.Р.Кайгородов, А.В.Әминова һ.б.) тарафыннан төрле класска кергән ирекле структуралы риманча күптөрлелекләрнең үзлекләре өйрәнелә.

А.П.*Норден* нормальләштерү ысулын уйлап таба (1937–38), зур гомумилеккә ия ысулны ул үзе һәм шәкертләре (В.И.Шуликовский, А.П.Широков, В.В.Вишневский, В.В.Шурыгин һ.б.) риманча күптөрлелекләрнең махсус типларын һәм аффин бәйләнешле күптөрлелекләрне, сызыкча һәм конформлы Г.не өйрәнгәндә кулланалар. А.П.Норденның Г.дә комплекслы, икеләтә һәм дуаль саннарны куллану нәтиҗәләре өстендә эшләп, А.Д.Широков алгебралар өстендә күптөрлелекләр теориясен төзи, ул теория Казан ун-ты Г. кафедрасының төп фәнни юнәлешләренең берсенә әверелә. Б.Л.Лаптев шәкерте Б.Н.Шапуков тарафыннан катламнарга бүленгән күптөрлелекләрнең структуралары һәм аларның аналитик механика мәсьәләләрендә кулланылуы өйрәнелә (1970–90). Күптөрле, ш.и. локаль структураларны фәнни тикшерү б-н беррәттән, алгебраик һәм дифференциаль топологиянең гомуми ысуллары да кулланыла (В.Е.Фомин, М.А.Малахальцев, К.Б.Игудесман).

Казанда П.А.Широков нигезләгән геометрик семинар даими эшләп килә, анда Россия һәм чит ил галимнәре докладлар ясый. Россия күләмендә һәм халыкара фәнни конференцияләр үткәрелә. 1992 елдан (5 елга бер мәртәбә) Казан ун-тында математикларның *Н.И.Лобачевский исемендәге медальгә* халыкара конкурсы уздырыла.

*Әд.:* Математика, её содержание, методы и значение: В 3 т. М., 1956; Каган В.Ф. Очерки по геометрии. М., 1963; История математики: В 3 т. М., 1970–72; Розенфельд Б.А. История неевклидовой геометрии. М., 1976; Математика 19 века: Геометрия. М., 1981; Норден А.П., Широков А.П. Наследие Н.И.Лобачевского и деятельность казанских геометров // Успехи матем. наук. 1993. Т. 48, вып. 2 (290); Математический энциклопедический словарь. М., 1988.

*Б.Н.Шапуков.*

**ГЕОМОРФОЛО́ГИЯ** (*гео*..., грек. morphē̂ — форма һәм ...*логия*), Җир өсте рельефының төзелешен, барлыкка килүен һәм үсешен өйрәнүче фән. Аның төп бүлекләре: структур Г. рельефның геол. структурага һәм литосфера хәрәкәтенә бәйлелеген өйрәнә; климатик Г. рельеф формаларын климатка һәм ул билгеләгән ландшафт төзелешенә бәйләп тикшерә; динамик Г. рельеф төзүче процессларның узу механизмнарын өйрәнә; экологик Г. рельефның, рельеф төзүче процессларның һәм кеше эшчәнлегенең үзара бәйләнешен өйрәнә. Җир өсте рельефының барлыкка килүе һәм төзелеше турындагы беренче күзаллаулар Яңарыш чорында үсә башлый (Леонардо да Винчи, Г.Галилей һ.б.) һәм 18–19 йөзләрдә бигрәк нәтиҗәле бара (М.В.Ломоносов, Д.Геттон, Ч.Лайель, Д.Поуэлл, В.В.Докучаев һ.б.). 19–20 йөзләр арасында Г.не мөстәкыйль фәнгә әверелдерү өчен кирәкле булган теоретик һәм методик база формалаша. В.Девис (АКШ) һәм В.Пенк (Германия) хезмәтләре нигезендә җир өсте рельефы ике төркем — эндоген (эчке) һәм экзоген (тышкы) процессларның үзара бәйлелеге нәтиҗәсе буларак, даими үсеш алган. 20 йөзнең икенче яртысында структур Г. (К.К.Марков, И.П.Герасимов, Л.Кинг), климатик Г. (А.Кайе, Ж.Трикар, Ю.Бюдель) һәм динамик Г. (Р.Хортон, А.Страллер, Н.И.Маккавеев) өлкәләрендә мөһим гомуми нәтиҗәләр эшләнә. Соңгы елларда гадәттән тыш экологик процессларны көйләүнең дөрес юлларын эзләү экологик Г.нең интенсив үсешенә китерде.

Казанда Г.нең үсеше 19 йөзнең 60 нчы елларында башлана. Н.А.Головкинский һәм Ф.Ф.Розен Иделнең елга террасалары хасил булу турында альтернатив караш белдерә; шуның б-н рельеф үсешендә төрле факторларның ролен өйрәнү башланып китә. 19 йөз ахыры — 20 йөзнең беренче яртысында Казан ун-ты геологлары һәм географлары (П.И.Кротов, А.В.Нечаев, В.Н.Сементовский, Б.В.Селивановский, А.В.Ступишин, В.В.Батыр) Г.нең мөһим проблемаларын — тектоник хәрәкәтләр һәм рельеф, борынгы бозлану, елга үзәннәре үсеше тарихын, елга террасалары барлыкка килү, экзоген рельеф төзелешен өйрәнәләр. Мондый эзләнүләр барышында *Казан геоморфология мәктәбе* формалаша. Татарстан терр-ясендә экзодинамик процессларны өйрәнүгә СССР ФАнең Геол. ин-ты галимнәре (М.С.Кавиев, Е.Ф.Станкевич) зур өлеш кертә. 1939 һәм 1951 елларда ТАССР Г.се буенча беренче җыелма мәгълүматлар чыга башлый (Сементовский, Батыр, Ступишин). 1962 дә ТАССРның беренче урта масштаблы геоморфологик картасы төзелә (мөхәррирләре А.П.Дедков һәм М.С.Кавиев). Республика геоморфологлары халык хуҗалыгының зур мәсьәләләрен хәл итүдә (Камстрой, Зур Казан, Куйбышев сусаклагычы, төрле файдалы казылмалар эзләү) актив катнаша. 60 ел дәвамында (1936–95) Казан ун-тының геогр. ф-тында Г. белгечләре әзерләү эше алып барыла, 1960 еллардан аспирантура эшләп килә. Соңгы унъеллыкларда эзләнүләр климатик, динамик, экологик Г.гә (денудацион тигезлекләрнең климатик Г.се, глобаль эрозия һәм кителрмәләр агышы, урта пояста химик денудация) карый; карст, перигляциаль Г., ерымнар эрозиясе (А.В.Ступишин, А.П.Дедков, Г.П.Бутаков, В.И.Мозжерин, А.М.Трофимов, Н.П.Торсуев һ.б.) турында эре региональ туплaнмалар эшләнә. 1991 дә Казанда «Геоморфологик процесслар һәм әйләнә-тирә мохит» дигән темага халыкара симпозиум уздырыла.

*Әд.:* Ступишин А.В. Роль Н.А. Головкинского и А.В.Нечаева в развитии отечественной геоморфологии // Природа. 1950. № 5; шул ук. Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. К. 1967; Климатическая геоморфология денудационных равнин. К., 1977; Дедков А.П. Развитие геоморфологии в Казанском университете // Геоморфология. 1980. № 4; шул ук. Геоморфология на пороге 21 века: пройденные этапы и современные тенденции // Геоморфология. 2001. № 1; Дедков А.П., Мозжерин В.И. Эрозия и сток наносов на земле. К., 1984; Бутаков Г.П. Плейстоценовый перигляциал на востоке Русской равнины. К., 1986; Мозжерин В.И., Шарифуллин А.Н. Химическая денудация гумидных равнин умеренного пояса. К., 1988; Овражная эрозия востока Русской равнины. К., 1990.

*А.П.Дедков.*

**ГЕО́РГИ** Иван Иванович (Иоганн Готлиб) (31.12.1729, Померания — 27.10.1802, С.-Петербург), этнограф, рәсем ясаучы, табигатьне өйрәнүче, сәяхәтче, Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1783). 1770 елдан Петербург ФАндә хезмәт итә. 1768–74 елларда Петербург ФАнең П.С.Паллас җитәкчелегендәге экспедицияләрендә катнашып, Идел буе, Урал, Алтай, Байкал, Байкал аръягында була. Г.ның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларны, ш.у. аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын, өс киемнәрен, торак урыннарын, бизәнү әйберләрен, дин тотуларын һәм башка үзенчәлекләрен тасвирлау» («Описание всех в Российском государстве обитающих народов, также их житейских обрядов, обыкновений, одежд, жилищ, украшений, забав, вероисповеданий и других достопамятностей»; СПб, 1–4 кис., 1799) дигән төп хезмәтендә шул заманда Россиядә яшәгән күпчелек халыклар, ш.и. татар халкы турында мәгълүматлар туплап бирелгән. «1773 һәм 1774 елларда Россия дәүләте буйлап сәяхәт вакытындагы күзәтүләр» («Наблюдения во время путешествия по Российскому государству в 1773 и 1774 гг.»; СПб, Т.1–2, 1775) исемле хезмәте әле дә тарихи чыганак буларак әһәмиятле. Анда Казанда һәм якын-тирә авылларда постау мануфактурасы, күн һәм сабын җитештерү хакында бәян ителә. Татар халкы турында Г. болай яза: «Авылда яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреше һәм өс киемнәре шәһәр татарларныкы кебек үк... Тырыш кешеләр буларак, алар басу-кырларын буш тотмыйлар, ә аннан шактый табыш алалар ...». Әлеге хезмәттә китерелгәнчә, «Татар авылларының һәрберсендә диярлек тире иләүче, читекче, тегүче, буяучы, тимерче, балта остасы кебек һөнәр ияләре бар. ...Казан татарлары балаларын тәрбияләүгә зур һәм мактауга лаек игътибар итәләр. Алар балаларына әдәплелек, сакчыллык кебек ата-баба га-



1 2

И.И.Георги. 1. Казан татары. Гравюра. 1768; 2. Казан татар хатын-кызы. Гравюра. 18 йөз уртасы.

дәтләре б-н бергә уку-язу, гарәп теле, дин сабагы өйрәтү өчен дә җан аталар. Өстәвенә балаларга тагын үз тарихларыннан кайбер гыйбрәтле хәлләр дә укытыла». Этнография, физик геогр. өлкәләрендәге хезмәтләре б-н беррәттән, Г. үзенең күпсанлы акварель рәсемнәрендә һәм натурадан ясалган сурәтләрендә төрле халыкларның, ш.и. Идел буе татарларының милли киемнәрен чагылдыра.

*Әд.:* Пыпин А.Н. История русской этнографии. СПб., 1890–92. Т. 1,4; Русский биографический словарь. М., 1914. Т. 4; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1976. Т. 3.

**ГЕОТЕРМИ́Я**, геотермика (*гео*... һәм грек. thérmē — җылылык), *геофизиканың* бер бүлеге; Җирнең җылылык кырының табигате һәм формалашу закончалыклары турындагы фән. Геотермик эзләнүләр файдалы казылмалар, термаль су чыганакларын эзләү һәм эшкәртү вакытында, сәнәгать һәм көнкүреш максатларында тектоника мәсьәләләрен хәл итү өчен үткәрелә. Җирнең термик кыры чыганагы булып эчке һәм тышкы процесслар — кояш радиациясе, U; Th, K ның радиоактив изотоплары таркалу, матдәнең гравитацион дифференциациясе, су күтәрелеше агымнары һ.б. тора. Җирнең эчке җылылыгы, башлыча, җылылык агымы исәбенә югала, аның уртача тыгызлыгы Җир шары буенча 64–75, ТР терр-ясендә — 30–60 *мВт/м²*. Геотермик план төшерү эшләре коры җирдә — 19 йөз ахырыннан, океаннар төбендә 20 йөз уртасыннан системалы рәвештә алып барыла.

Урта Идел буйларында геотермик эзләнүләр турындагы беренче мәгълүматлар 18 йөзнең икенче яртысына туры килә; экспедициядә катнашучылар — П.С.Паллас, И.И.Лепёхин һәм Н.П.Рычков тарафыннан кайбер җир асты куышлыкларының һәм җир асты сулары чыганакларының темп-расы үлчәнелә һәм температур киселешләре төзелә. Казан суүткәргечен төзү алдыннан (19 йөз ахыры), артезиан скважиналарда җир асты суларының темп-расын үлчиләр (А.А.Штукенберг, В.Н.Щербаков, 1893). 1940 елда Сөйке мәгарәләренең темп-ра режимы өйрәнелә (А.В.Ступишин).

1940 елларда Татарстанда нефть ятмалары ачылу скважиналар термометриясен үткәрүне һәм, башлыча, нефть эзләү юнәлешендә геотермик тикшеренүләр уздыруны таләп итә. Төрле елларда бу эш б-н «Татнефть», «Татнефтегеофизика», ТатНИПИнефть, Казан ун-ты, Мәскәү нефть һәм газ сәнәгате ин-тының Лениногорск ф-лы, СССР ФАнең Казан ф-лы һәм Бөтенсоюз нефть һәм газ ин-тының Кама ф-лы (Пермь ш.) бүлекчәләре шөгыльләнә. Артык тирән, структур, тикшеренү-эзләнү һәм эксплуатацион скважиналар киселешенең темп-ралары үлчәнә; геотермик үлчәү аппаратлары эшләнә һәм аларны куллану ысуллары камилләштерелә; токымнарның җылылык үзенчәлекләре өйрәнелә; җылылык агымының вертикаль өлешенең геотермик үсеше, геотермик градиенты һәм тыгызлыгы үзгәрүе ачыклана; нефть ятмаларын эшкәртү һәм скважиналарның техн. халәтен контрольдә тоту тәэмин ителә. Җир эчендәге термодинамик процесслар, чыганакларның җылылык режимнары тикшерелә. Геотермик ысул ярдәмендә коллектор-токымнарны аеру мөмкинлеге күрсәтелә. ТРда һәм элеккеге СССРның кайбер башка төбәкләрендә термоаномалияләр киселешенең структур-тектоник үзенчәлекләре һәм, аерым алганда, температураның чагыштырмача күтәрелүе (30–48 °С ка кадәр) — кристаллик фундаментның җир өстенә чыгуына, ә темп-раның түбәнәюе (20–22 °С ка кадәр) әлеге фундаментның тирәнрәк ятуына бәйле икәнлеге ачыклана. Җир асты суларының, ш.и. девон һәм карбонның нефтьле катламнарының геотермик режимы үзенчәлекләре билгеләнә. «Татнефть» берләшмәсе утырма катлам киселешенең структур-тектоник үзенчәлекләрен өйрәнү һәм нефть ятмаларын эзләү максатыннан аз тирәнлекле геотермик план төшерү эшләрен башкара (1970 еллар). Сугышлы, Мордва Карамалысы һәм Әшәлче ятмаларын өйрәнү югары геотермик градиентларның битумлы комташлары зонасына туры килүен күрсәтә. Геотермик һ.б. геофизик ысуллар, битум ятмаларын эшкәртүне контрольдә тоту максатыннан, пласт эчендә битумны яндырып карау юлы б-н башкарыла. «Нефтепромавтоматика» фәнни-җитештерү берләшмәсе (Казан) битум һәм битумга туенган чыганакларда шундый януның учагы таралуны тикшереп торучы аппаратура эшләнә. Гамәли оптика ин-ты тарафыннан 1980 елларда ТРның аэроҗылылык (инфракызыл) планы төшерелә, геотермик кыры картасы төзелә; бу Җир кабыгындагы төрле катламнарның төзелеше үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк ин-ты, ТРда Мордва Карамалысы чыганагында битумнарның җир астында яну фронты көчешен күзәтү һәм җир асты сулары пычрану учакларын билгеләү максатыннан, җылылык планын төшерү эшен үткәрә. Ленинград һәм Минск белгечләре б-н бергә җир өстендә геотермик план төшерү, каты һәм көпшәк тау токымнарының җылылык үткәрүчәнлеген үлчәү өчен аппаратура эшләнә; җир өстендә геотермик һәм инфракызыл җылылык планын төшерү методикасы эшләнә, ул, Столбище һәм Сокуры суалгычларында сыналып, илебезнең төрле җитештерү оешмаларында гамәлгә кертелә; ТР терр-ясендә Җир кабыгының төрле катламнарында, геотермик градиент һәм җылылык агымнарының эндоген геол. процесслар мониторингына карата үзгәрүе өйрәнелә. Нырты полигонында һәм Нырты-Тәкәнеш бакыр рудасы полосасында үткәрелгән геотермик тикшеренүләр бакыр һәм затлы металлар (платиноидлы һәм алтын-платиноидлы) рудалашуының геотермик критерийларын эшләүне тәэмин итә (1997).

*Әд.:* Герасимов В.Г., Покровский В.А. О термальных водах палеозойских отложений Татарской АССР // Региональная геотермия и распространение термальных вод в СССР. М., 1967; Яковлев Б.А. Решение задач нефтяной геологии методами термометрии. М., 1979; Христофорова Н.Н. Конвективный тепловой поток Волго-Уральской и Предкавказской нефтегазоносных провинций // Геотермические исследования и использование термальных вод в народном хозяйстве. Тб.; 1985; Близеев А.Б., Боронин В.П., Степанов В.П. Выделение пород-коллекторов по данным термических исследований в глубоких скважинах Татарского свода // Геофизические исследования в Татарии и сопредельных областях. К.. 1990; Опыт и перспективы использования геотермического метода при прогнозе и поиске медных руд Приуралья // Тепловое поле Земли и методы его изучения. М., 1997.

*П.В.Вишневский, В.П.Боронин.*

**ГЕОФИ́ЗИКА** (*гео*... һәм *физика*), Җирне планета буларак өйрәнә торган фәннәр комплексы; аның физ. кырларын, сүрүләре төзелешен, матдәсенең халәтен һәм физ. үзенчәлекләрен, анда баручы физ. процессларны өйрәнә. Болар барысы да Җирнең каты (литосфера), сыек (гидросфера) һәм газсыман (атмосфера) сүрүләренә кагыла. Аерым геофизик фәннәрнең барлыкка килүе һәм үсеше, башлыча, соңгы 5 гасыр дәвамында бара. Алар төрле дәрәҗәдә, бигрәк тә башлангыч стадияләрдә, бер-берсеннән аерым хәлдә үсеш ала. Кайбер геофизик фәннәр башка фәннәргә — иң әүвәл геол. һәм геогр. фәннәренә бәйле; күбесе гамәли характерда. Г. үз эченә *геомагнетизм*, *метеорология* һәм *климатология*; океанология, *гидрология* һәм гляциология; Җир физикасы (Җирнең һ.б. планеталарның хасил булуын һәм үсешен, Җирнең эчке төзелешен, тирән яткан матдәсе составын өйрәнә), *геотермия*, сейсмология, *гравиметрия*, неотектоника кебек фәннәрне ала. 19 йөздә Россиядә метеорология, геомагнетизм, гравиметрия һәм сейсмология фәннәре интенсив үсә (яралгылары күп еллар элек барлыкка килә). Советлар Союзында һәм хәзерге Россиядә югарыда күрсәтелгән геофизик фәннәр киң һәм нигезле үсеш ала.

Казанда, Татарстанда, бөтен Идел-Кама төбәгендә, хәтта аның чикләрендә дә геофизик күзәтүләр 19 йөздә башлана; шулар нигезендә Г. фәннәре туа һәм таралыш ала. Алар Казан ун-ты галимнәре эшчәнлеге б-н тыгыз бәйләнештә: А.Я.Купфер, И.М.Симонов — геомагнит күзәтүләр, А.В.Краснов, Д.И.Дубяго, В.А.Баранов — гравиметрик тикшеренүләр, Н.И.Запольский Татарстанда системалы рәвештә һава торышын күзәтү эшләре башкара.

20 йөздә Казан ун-тында геол. һәм Г. кафедрасы (1950, 1954 елдан мөстәкыйль), палеомагнетизм лаб-ясе (1960 еллар), ЦНИИгеолнерудта Г. бүлеге (1950 еллар), «Татнефтегеофизика» тресты (1953), «Геоком» фәнни-техник үзәге оештырыла. Г. фәне үсешенә, Татарстанның җир асты байлыкларын өйрәнүгә В.П.Боронин, Н.Н.Непримеров, Н.И.Христофорова, Р.К.Хәбибуллов, З.М.Слепак, Д.К.Нургалиев һ.б. (Казан ун-ты), Н.С.Евграфов, А.Г.Салихов, И.М.Уразаев, Г.Е.Кузнецов, В.В.Вишневский һ.б. (ЦНИИгеолнеруд), Г.М.Донов, В.П.Степанов, В.А.Трофимов, Э.К.Швыдкин һ.б. («Татнефтегеофизика» фәнни-җитештерү берләшмәсе), Н.Я.Боровский, К.М.Мирзоев һ.б. (Татарстан геолог.-разведка идарәсе), И.Н.Плотникова (ТРның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы) зур өлеш кертә.

*В.П.Боронин.*

**ГЕОХИ́МИЯ** (*гео*... һәм *химия*), Җирнең химик составы, андагы химик элементлар атом-

нары тарихы, аларның хәрәкәт закончалыклары, туплануы һәм таралуы турындагы фән. «Г.» термины немец галиме К.Ф.Шёнбейн тарафыннан кертелә (1838). Г. объектлары булып барлык табигый һәм техноген әйберләрдә һәм аларны хасил итүче барлык процессларда катнашучы химик элементлар тора. Г.дә тикшеренү ысуллары: химик, физ., термодинамик, физ.-химик, геофизик, төш-изотоп һ.б.; табигый объектларның химик һәм фазалы составын, табигый процесслар бару шартларын билгеләү (табигать системаларын эксперименталь һәм матем. модельләүне дә үз эченә ала).

Геохимик тикшеренүләр, нигездә, файдалы казылмалар чыганакларын билгеләү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында кулланыла. Матдәнең характерына тиңдәшле рәвештә, радиометрик, лито-, гидро-, атмо- һәм биохимик тикшеренүләр була. Объектка якыная бару б-н геохимик аномалия хасил итүче характерлы химик элементлар саны зурая бара.

Г. мөстәкыйль фән буларак 20 йөз башында барлыкка килә. Ләкин аңа озак еллар (берничә йөз ел) буена тупланган геохимик фактлар нигез булып тора. Бу чорда М.В.Ломоносов һәм Д.И.Менделеев тикшеренүләре зур әһәмияткә ия. Г.нең мөстәкыйль фән буларак үсешенә В.М.Гольдшмидт, В.И.Вернадский, А.Е.Ферсман, Ф.У.Кларк зур өлеш кертә. Гольдшмидт — Г.нең кристаллохимик, В.И.Вернадский һәм А.Е.Ферсман генетик юнәлешен эшлиләр; алар химик элементларның күчеш теориясен тудыра. Ферсман файдалы казылмалар чыганакларын Г. ысулларын кулланып эзләүне тәкъдим итә. Кларк Җир кабыгындагы химик элементларның ничек таралуын (кларк элементлары) исәпләп чыгара.

Татарстанда геохимик тикшеренүләр 20 йөз башыннан Казан. ун-тында (Б.П.Кротов, Л.М.Миропольский, А.И.Бахтин, В.В.Корчагин, В.А.Полянин, Г.А.Низаметдинов, Р.Р.Хәсәнов, Н.П.Лебедев һ.б. — файдалы казылмалар эзләүнең геохимик ысуллары), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк ин-тында (Е.Ф.Станкевич, У.З.Галиев — җир асты сулары гидрохимиясе; Ю.В.Сементовский, В.А.Тимесков — Пермь утырмалары Г.се; У.Г.Дистанов — кремнезём Г.се; А.А.Озол — бор катнаш рудалар Г.се һәм экология; Б.Ф.Горбачёв — ак балчык (каолин) Г.се; Р.М.Фәйзуллин, А.С.Михайлов, В.Н.Силантьев һәм М.И.Карпова — фосфат чималы Г.се; В.А.Копейкин, В.М.Федотов — элементларның радиогеохимиясе һәм аларның экологиясе; М.С.Кавиев, А.И.Азизов, Е.И.Синявский һ.б. — җир асты сулары Г.се һ.б.), Татарстан геологик эзләнүләр идарәсендә (В.М.Федотов — фтор Г.се, аның минераллары һәм рудасы) һ.б. оешмаларда алып барыла. Тикшеренүләр, башлыча, нефть ятмаларын эзләү эшләрендә үткәрелгән һәм туфрак һавасында, тау токымы үрнәкләрендә (газ ятмасын картага төшерү) яисә бораулау процессында кулланыла торган балчык измәсендә (газ каротажы) углеводородлы газлар күләмен билгеләүгә нигезләнгән. 20 йөз ахырыннан экология-гидрохимия юнәлеше үсә башлый (О.Б.Кузнецов һ.б.).

*Әд.:* Перельман А.И. Геохимия. М., 1989; Справочник по геохимии. М., 1990.

*А.И.Бахтин, В.М.Федотов.*


**ГЕОХРОНОЛО́ГИЯ** (*гео...*, грек. chrónos — вакыт һәм *...логия*), геологик еллар исәбе турындагы тәгълимат. Ике төрле вакыт шкаласыннан тора: хронометрик — дәвамлылыкның абс. астрономик берәмлекләренә — елларга нигезләнә һәм хроностратиграфик — Җирнең яшәешендә табигый вакыт этабы хасил итүче табигать күренешләре эзлеклелеген чагылдыра. Ел исәбе алып баруның ике ысулы да мөһим — алар бер-берсен тулыландыра. Хронометрик шкала нигезендә — изотоплар таркалганда хасил булган радиацияне (уран-кара кургаш, калий-аргон, рубидий-стронций, радиоуглерод һ.б. ысуллар) үлчәү нәтиҗәсендә билгеләнгән вакыт күрсәткечләре. Шкала — периодик һәм хәзерге заманнан санала (шартлыча, 1950 елдан алына), бертөрле озынлыктагы (миллений — $10^6$ ел, гигений — $10^9$ ел һ.б.) бүлемнәрдән тора. Хроностратиграфия катламланулар эзлеклелеге принцибы (Н.Стенон принцибы, 1669) нигезендә төзелә, һәм ул биота эволюциясе (биостратиграфия), утырмалар туплану (литостратиграфия) һәм геомагнит кыры эволюцияләре (магнитостратиграфия) һ.б. күренешләрне билгеләүдән гыйбарәт. Геологик вакыт эоннарга, эраларга, чорларга бүленә; алар саннар б-н түгел, ә бәлки тасвирлама б-н билгеләнә һәм Җир тарихында теге яки бу күренешнең эволюциясен чагылдыра. Хроностратиграфик шкала вакыт эзлеклелегендә аерым этапларны берләштерә, аларның зурлыгын һәм бер-берсенә бәйлелеген чагылдыра. Һәр геохронологик бүлемгә үзенә генә хас эквивалент стратиграфик бүлем туры килә (к. *Стратиграфия*). Ике төр шкаланы да елларга бүленгән стандарт стратиграфик бүлемнәрдән торган бердәм геологик вакыт шкаласы берләштерә. Абс. геохронология күрсәткечләре, 1950 еллардан башлап, Татарстанның архей һәм протерозой чорларындагы утырма, метаморфик һәм магматик токымнарны бер-берсеннән аеру һәм чагыштыру өчен киң кулланыла. Фанерозойның утырма тышлыгын тасвирлау биостратиграфик һәм полеомагнит хроностратиграфик ысулларга нигезләнә. Соңгы унъеллыкларда кайнозой утырмаларының абс. елларын билгеләүдә калий-аргон ысулы әһәмияткә ия була башлады. Казан ун-тында традицион рәвештә биостратиграфия (1865 тән) һәм *палеомагнетизм* (1964 тән) ысуллары эшләнелә.

*Әд.:* Шкала геологического времени. М., 1985.

*Б.В.Буров.*

**ГЕР СПОРТЫ́**, иң борынгы ярыш төрләреннән берсе. Хәзерге вакытта ярышлар 16, 24 һәм 32 *кг* лы герләр күтәрү буенча ике төрдә (ике кул б-н ике герне күкрәктән этеп күтәрү һәм герләрне чиратлап һәр кул б-н кинәт күтәрү), ш.у. ике герне күкрәктән этеп күтәрү һәм һәр күтәрүдән соң герне аска төшерү (озын цикл) буенча уздырыла. Казан губернасында кагыйдәләр буенча ярышлар 1910 еллардан уздырыла башлый. Авырлык (таш, штанга, гер) күтәрү *Сабантуй* бәйрәмендә ярышларның гадәти төре, ш.у. проф. авыр атлетларның цирк аттракционы була. Г.с.н башлап җибәрүчеләр һәм иң яхшы гер күтәрүчеләр — «Бөркет» («Беркут»), «Көч һәм сәламәтлек» («Сила и здоровье») спорт җәмгыятьләре әгъзалары — В.Магницкий, Н.И.*Морящичев*, П.Никифоров, П.Петухов, Н.Руфимский. Г.с. буенча ТР чемпионатлары 1962 елдан оештырыла (1970 кә кадәр өч төр ярыш буенча: салмак күтәрү, этеп күтәрү, кинәт күтәрү). Гер күтәрү буенча район һәм шәһәр сабантуйларында батырлар — РСФСР, СССР чемпионатларында (1960–80 еллар) төрле үлчәү авырлыкларында җиңүче, приз алучы һәм рекордчылар — Р.Бариев, Г.Борһанов, А.Ф.Вагурин, Ф.А.Гарифуллин, Ф.Гобәйдуллин, В.Николаев. 1980 нән «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы Г.с. буенча Н.Г.*Жеребцов* исем. призга ярышлар уздыра (1994 тән Дөнья кубогына халыкара мемориал). Татарстан җыелма командасы — Россия кубогы иясе (1996–98), Дөнья кубогына бәйгедә 2 нче (1999–2003), дөнья чемпионатында берничә тапкыр 2 нче һәм 3 нче урыннарны алучы (2002–08). 1999 дан башлап Казанда һәр елны, Н.Г.Жеребцов мемориалы б-н беррәттән, Г.с. буенча дөнья чемпионаты уздырыла (озын цикл). ТРның иң яхшы спортчылары — Россия һәм Дөнья кубогы ияләре, ТР, Россия, дөнья чемпионатларында җиңүчеләр һәм приз алучылар — И.Г.Стекольников, Ф.М.Сәләхиев, А.И.Смелый, Р.Р.Насыйров, Ф.Ш.Миңнемуллин, Р.В.Дворецкий, Җ.В.Шакиров, И.И.Сапаркин, Ф.Ф.Һадиев, А.Ф.Вагурин. Иң танылган тренерлар — А.П.Горшенин, И.В.Исламов, В.Н.Фёдоров, Р.К.Фәрхетдинов. Халыкара категорияле судьялар — Ш.Х.Галиев, А.П.Горшенин, Р.А.Хәйруллин, Ә.Ш.Шәйхетдинов.

**ГЕРА́ГА** Павел Иосифович (4.9.1892, Красноярск ш. — 8.8.1969, Мәскәү), драма актёры, режиссёр, РСФСРның халык артисты (1947). Сәхнә эшчәнлеген Красноярск шәһәрендә башлый (1909). Иркутск, Ярославль, Самара, Тула шәһәр театрларында эшли. 1928–30 елларда Казан Зур драма театры актёры һәм режиссёры, аның сәхнәсендә Лопахин («Чия бакчасы», А.П.Чехов), 2 нче мужик («Мәгърифәт җимешләре», Л.Н.Толстой), Тетерев («Мещаннар», М.Горький), Вершинин («Бронепоезд 14–69», В.В.Иванов), Василий («Рельслар гөрелдәгәндә»,



П.И.Герага командарм Шторм роленда (З.Чалая, «Амба»).

В.М.Киршон), Мерц («Иң югары чара», Л.В.Никулин), командарм Шторм («Амба», З.Чалая), Глоба («Ярсу», Е.Г.Яновский) һ.б. рольләрен башкара. Г. тарафыннан иҗат ителгән образларның әһәмияте һәм масштаблылыгы ачык чагылышлы социальлектә, психологик кичерешләрнең тирәнлегендә күренә; бу образлар Казан театр тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Казанда Г. режиссура б-н актив шөгыльләнә башлый. А.Ф.Деннеринең «Апалы-сеңелле Жерарлар» («Сестры Жерар»), Н.Я.Шестаковның «Алтай Робинзоннары» («Алтайские Робинзоны»), С.Поливановның «Сигнал», А.Н.Афиногеновның «Сәер кеше» («Чудак») әсәрләрен сәхнәләштерә. Г.ның спектакльләре драматургның төп идеясен тулы ачарга омтылулары, актёрлар ансамбленең бердәмлеге б-н аерылып торалар. 1932 елдан Г. Мәскәүдә Кызыл Армиянең Үзәк, Моссовет исем. театрларда уйный.

*Әд.:* Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*


**ГЕРА́ЛЬДИКА** (соңгы дәвер лат. heraldica, heraldus — «сөрәнче» сүзеннән), гербларны (к. *Гербләр*) өйрәнү б-н шөгыльләнә торган ярдәмче тарихи фән. Гербларның килеп чыгышы, аларны танып белү, төзү, кабул итү һәм файдалану кагыйдәләре, герб эмблемаларын сурәтләү алымнары б-н шөгыльләнүче белемнәр тармагы буларак, Г. га герольдлар («Г» сүзе алардан алына) — сарай церемонияләрен оештыручылар нигез сала. Г., фән буларак, башлыча, Европада үсеш ала, әмма Азиядә дә герб тамгаларын төзү турындагы белемнәр таралган була: алар 10–12 йөзләр төрки язма традициясендә, Алтын Урда ханнарының ярлыкау актларында һәм юлламаларында (к. *Мөһер, Нишан*) кулланыла. Кайбер галимнәр европалылар бу белемнәрне тәре яулары вакытында үзләштергәннәр дип саныйлар. 14 йөздә Европа илләрендә Г.ның теоретик һәм гамәли мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче оешмалар — герольдияләр барлыкка килә. Россиядә Г. 17 йөздә оеша башлый. 1722 елда Герольдмейстерлык конторасы төзелә; соңыннан аның вазифалары Сенатның Герб бүлекчәсенә күчә. 1918 дә Герб бүлекчәсе Петроград тарих архивының Гербләр музее итеп үзгәртелә. Г.ның үсеше тарих фәненең, аерым алганда, ярдәмче тарихи фәннәрнең үсешенә бәйле рәвештә бара. Европада беренче Г. кафедрасы 1706 да Берлинда ачыла. Россиядә Г. кафедрасы 1726 да Петербург ФА каршында оештырыла. Ярдәмче тарихи фән буларак, Г. материаль культураны, мәдәниятне өйрәнгәндә, матди истәлекләрнең нинди даирәгә каравын, чорын, эшләнү урынын һ.б. детальләрне ачыклаганда, ш.у. язма чыганакларны барлаганда зур әһәмияткә ия. Г. *археология, нумизматика, сфрагистика* һ.б. тарихи фәннәр, аеруча генеалогия (к. *Шәҗәрә*) б-н тыгыз бәйләнгән. Хәзерге вакытта Г. б-н шөгыльләнүче махсус җәмгыятьләр, үзәкләр бар. 1994 тә РФ Президенты каршында Дәүләт герольдиясе (1999 дан Геральдика советы) оештырыла, ул хәзерге Россиядәге Г. мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Аның вазифаларына ш.у. РФ субъектлары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан булдырылган рәсми символлар һәм аерымлау билгеләре проектларын тикшерү дә керә. 2002 нең 10 гыйнварында ТР Президенты М.Ш.Шәймиев указы б-н ТР Президенты каршында Геральдика советы оештырыла (рәисе Д.Р.*Шәрәфетдинов*, 2006 дан Р.Р.Хәйретдинов). Казан ун-тында Г. буенча курс булдырыла һәм укыла. Ш.у.к. *Гербләр*.

**ГЕРАСИМЕ́НКО** Виктор Иванович (4.3.1933, Таҗикстан ССР, Пяндж р-ны Түбән Пяндж а. — 8.7.2005, Чаллы ш.), экскаватор машинисты, Соц. Хезмәт Герое (1963). 1949–94 елларда төзелеш оешмаларында эшли: 1950–51 һәм 1955–57 дә «Нижневыгтэсстрой» (Карелия АССР, Сосновец пос.), 1952 дән «Сталинградгидрострой» (Сталинград өлкәсе Волжск ш.), 1957 дән «Ковдагэсстрой» (Мурманск өлкәсе), 1968 дән Шарьинск юл төзү идарәсендә (Ярославль өлкәсе), 1971 дән «Камгэсэнергострой» оешмасында. КамАЗ, Түбән Кама ГЭСы, ТЭЦы төзелешләрендә катнаша. Герой исеме Кола ярымутравында Ковда гидроэлектростанцияләре каскады корылмаларын төзегәндәге зур уңышлары, техника яңалыклары керткәне һәм эл. станцияләрен вакытыннан алда файдалануга тапшырганы өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Г. яшәгән йортка мемориаль такта куелган (2005). Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (1999).

*Әд.:* Иванов К. Незабываемые страницы // Советская Татария. 1973. 10 авг.; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГЕРА́СИМОВ** Александр Викторович (15.9.1963, Казан), җылылык техникасы белгече, техник фән. д-ры (2007). 1985 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, 1988 дән шунда ук эшли (1985–88 дә Гамәли оптика ин-тында), интеллектуаль системалар һәм информацион системалар б-н идарә итү каф. проф. (2007 дән). Хезмәтләре электрофизик һәм җылылык процессларын матем. модельләүгә карый. Г. югары ешлыклы информацион бушануның электрофизик, җылылык һәм газодинамик параметрларын магнит кырының буйлы төзүчесе үлчәмнәре буенча исәпли торган ике үлчәнешле матем. моделен төзи. Югары ешлыклы плазмотрон индукторының кучәре тирәсендә плазманың температур кырларын бүлү өчен ике үлчәнешле куелышта аналитик нисбәтләр ала. Дугалы бушануның үзара килешенгән ике температуралы канал моделе кысаларында дугалы плазмотрон каналында газ һәм электрон температураларын исәпләү юлын тәкъдим итә; электр дугалы плазмотрон каналында җылылык агышларын, уртача температураны һәм температур профильне бәяләүнең алгоритмын эшли.

Хезм.: Поверхность раздела прямого и возвратного течений в высокочастном индукционном заряде // Докл. РАН. 2003. Т. 389, № 2 (автордаш); Электрофизические и тепловые параметры термической плазмы в высокочастотном индукционном заряде // Изв. вузов. Сер. Физика. 2004. № 7; О балансе энергии высокочастотного индукционного разряда атмосферного давления вблизи оси плазменного сгустка // Прикладная физика. 2005. № 1 (автордаш).



В.И.Герасименко.



А.Ф.Герасимов.

**ГЕРА́СИМОВ** Алексей Фёдорович (28.2.1881, хәзерге Липецк өлкәсенең Лебедянь ш. — 7.2.1952, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1937), проф. (1930), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1939). Мәскәү ун-тына укырга керә, 1902 елда студентлар җыенында катнашканы өчен чыгарыла. Укуын Женева ун-тында дәвам итә (Швейцария), аны 1905 елда физика фән. д-ры дәрәҗәсендә тәмамлый. 1905–30 елларда Казан ун-тында, 1919 дан проф., физ. химия каф. мөдире. 1930–52 елларда Казан хим.-технол. ин-тында физ. һәм коллоид химиясе каф. мөдире, бер үк вакытта (1931–41) Казан ун-тының физ. химия каф. мөдире. Г. тарафыннан тотрыклы һәм суда эрүчән коллоид металларны табу ысулы (Герасимов методы) эшләнә һәм аларда коллоид-химик күренешләр тикшерелә. Коллоид көмеш препаратлары (колларгол һәм протаргол) медицинада кулланылыш таба. Аларны эшләүнең Бөтенсоюз химия-фармацевтика ин-тына тапшырылган ысулы сәнәгатькә кертелә. Г. коллоидлар катнашында электрод потенциалларын өйрәнә. Металларны тозларыннан кайтару реакцияләренең кинетикасын тикшергәндә, «концентрация-вакыт» эмпирик тигезләмәсен чыгара. Термодинамика өлкәсендә күпфазалы системаның бәйсез компонентлары санын билгеләү өчен рациональ кагыйдә ача. Бөек Ватан сугышы чорында нитропарафиннарның физ.-химик үзлекләрен өйрәнә, пироксилин һәм дарыларның бөртеген билгеләү ысулларын, дарыларны флегматизатордан башка флегматлау һ.б. алымнарны эшли. Казан металл эшкәртү з-длары өчен кискеч инструментларны яңадан торгызу ысулларын тәкъдим итә. Пихта маеннан камфара таба (ярымзавод күләмендә), дарыларда флегматлашкан катламның калынлыгын билгеләү ысулын булдыра. В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында һ.б. сәнәгать пр-тиеләрендә даими киңәшче була. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Колларгол, его получение и некоторые свойства // Тр. науч.-исслед. хим.-фармацевтического ин-та. 1926. Вып. 16; Кинетика реакции восстановления мышьяка фосфорно-азотистой кислотой из раствора в соляной кислоте мышьяковистого ангидрида // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Ч. хим. 1930. Т. 62, вып. 2; Курс химической термодинамики. К., 1936.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГЕРА́СИМОВ** Василий Герасимович (25.3.1925, Чуаш автономияле өлкәсенең Чабаксар р-ны Ень-Кассы а. — 30.8.1976, Белоруссия ССР, Гомель ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1969), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1966). Казан ун-тын тәмамлый (1951). 1952–54 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты нефть сәнәгате бүлеге инспекторы. 1954 елдан Бөгелмә шәһәрендә: КПССның шәһәр ком-ты 2 нче секретаре, 1956–57 дә ТатНИПИнефтьтә директор урынбасары, 1957–70 тә гидрогеология һәм гидрохимия лаб-ясе мөдире; бер үк вакытта 1969–70 тә Казан төзүче-инженерлар ин-тында профессор. Төп тикшеренүләре Татарстан палеозой утырмаларында җир асты сулары динамикасын һәм ресурсларын өйрәнүгә карый. Татар гөмбәзенең Төньяк күтәрелмәсенә гидрогеологик характеристика бирә. Татарстан җир асты суларының химик анализлары каталогын төзүчеләрнең берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЕРА́СИМОВ** Виталий Викторович (27.4.1941, Әзәрбайҗан ССР Кировобад ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1964 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1968–76 елларда Бөтенсоюз насос машиналары төзү технологиясе ин-тында (Казан) бүлек башлыгы, материаллар һәм капламнар лаб-ясе мөдире. 1976 дан Казан төзүче-инженерлар ин-тында (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты), химия каф. мөдире (1981 дән), 2001 дән Казан энергетика ун-тында. Г. оптик үтә күренмәле материаллар (силикат булмаган пыялалар) хасил итә торган I–III группа элементларының фосфорнәорганик кушылмалары нигезендәге сызыкча һәм тегелмә полимер продуктларны синтезлый, аларның төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнә. «Татнефть» берләшмәсендә пласт басымын даими тоту системаларында насосларның нәтиҗәлелеген һәм озакка чыдамлыгын күтәрү максатыннан насос җиһазларын гидроабразив саклау өчен озак тузмый торган полимер материаллар тәкъдим итә. Нәорганик пыялаларның, кремний һәм фосфорның башка тип кушылмаларының полимер һәм молекуладан зуррак төзелешен тикшерә, полисиликат һәм полифосфатлар нигезендәге материаллар куллануның практик юнәлешләрен тәкъдим итә. Перспектив материаллар: пыяла, эмаль, глазурь, беркеткеч, бәйләгечләр һәм алар нигезендәге композицион материаллар, яндырыла һәм яндырылмый торган керамик һәм утка чыдам плитәләр җитештерү технологияләрен эшләүдә һәм үзләштерүдә катнаша. Кызуга чыдам корычларның җылылык, электр станцияләрендә һәм терможайланмаларда озак вакытлы кулланылыш чорында структур үзгәрешләре, макрозарарлануы, бозылуы һәм ватылуы буенча хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 100 дән артык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Повышение эффективности и долговечности насосов систем поддержания пластового давления объединения «Татнефть». М., 1971; Неорганические полимерные материалы на основе оксидов кремния и фосфора. М., 1993; Структурный износ металла в системах элементов теплоэнергетических установок на объектах «Татэнерго» // Изв. РАН. Сер. Энергетика. 2005. № 1 (автордаш).

**ГЕРА́СИМОВ** Марк Нестерович (1873, Казан губ., Чистай өязе Борнаш а. — ?), җәмәгать эшлеклесе. Крәстияннәрдән. Өйдә белем ала. Беркадәр вакыт авыл писаре булып эшли. 1 нче Дәүләт думасы депутаты (1906), трудовиклар фракциясе әгъзасы. Дума таратылганнан соң, хөкүмәткә каршы эшчәнлек алып баруы өчен тикшерүгә дучар була. Полиция күзәтүе астында яши. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Члены первой Государственной думы. М., 1906; У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ГЕРА́СИМОВ** Михаил Михайлович (2.9.1907, С.-Петербург — 21.7.1970, Мәскәү), антрополог-сынчы, археолог, биол. фән. канд. (1943), тарих фән. д-ры (1956), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1922 елдан Иркутск төбәкне өйрәнү музеенда, 1932 дән Материаль культура тарихы ин-тында (Мәскәү). 1950–70 елларда СССР ФАнең Этнография ин-тында пластик реконструкция лаб-ясе мөдире. Баш сөяге буенча кешенең кыяфәтен торгызуга багышланган эшләре б-н таныла. Үзе эшләгән ысул нигезендә иң борынгы дәверләрдә (питекантроп, синантроп), борынгы заманда (Буралы курган, Ананьино һ.б. археол. культуралар) һәм урта гасырларда (Алтын Урда чоры Болгар ш., Әрмән колониясе) яшәгән кешеләрнең кыяфәтләрен, ш.у. Ярослав Мудрый, Андрей Боголюбский, Аксак Тимер, Олугбәк, Иван IV кебек тарихи шәхесләрнең скульптур портретларын иҗат итә (барлыгы 200 дән артык). Борынгы таш гасырга караган Мальта торулыгын (Иркутск өлкәсе) ача һәм тикшерә. СССРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1950). «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Раскопки палеолитической стоянки в с. Мальте // Палеолит в СССР. М.–Л., 1935; Восстановление лица по черепу. М., 1955; Люди каменного века. М., 1964.

*Әд.:* Г е р а с и м о в а М.М., М е д в е д е в Г.И. Жизнь и деятельность Михаила Михайловича Герасимова // Вестн. антропологии. 1998. Вып. 5.

*И.Р.Газимжанов.*

**ГЕРА́СИМОВ** Николай Павлович (25.10.1898, Казан — 13.3.1952, Пермь ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1946), проф. (1946). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук эшли (1933 кә кадәр). Бер үк вакытта СССР Геол. ком-тының геол. партияләр башлыгы (1929–32). 1933–34 елларда өлкән геолог; «Востокнефть» трестының (Свердловск ш.) Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе башлыгы, 1934–37 дә «Прикамнефть» трестының (Пермь ш.) баш геологы. 1937–38 дә Свердловск, 1938–52 дә Пермь ун-тларында тарихи геол. һәм палеонтология каф. мөдире. Бер үк вакытта СССР ФАнең Урал ф-лында (Свердловск), Пермь, Ижевск һәм Түбән Новгородның геол. оешмаларында эшли. Башкортстанда (Туймазы нефть чыганагы, 1935), Пермь өлкәсендә (Северокамск һәм Краснокамск нефть чыганаклары, 1938) нефть эзләү эшләрендә һәм беренче нефть чыганакларын ачуда катнаша. 1930–40 елларда Татарстанның көньяк-көнчыгыш өлешендә ташкүмер һәм девон катламнары булуын нигезли, бу исә Шөгер һәм Ромашкино нефть чыганакларын ачуга этәргеч була. Гражданнар сугышында катнаша.

Х е з м.: Разрез классического кунгура // Зап. Всерос. минерал. об-ва. Сер. 2. 1934. Т. 63, вып. 2; Уральский отдел пермской системы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1937. Т. 97, кн. 3/4 (автордаш); Геологическое строение Восточной нефтегазоносной области (западный склон Урала и Западное Приуралье). Свердловск, 1940.

**ГЕРА́СИМОВ** Николай Петрович (3.9.1963, Аксубай р-нының Иске Тимошкино а.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1987). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1987). Россиянең атказ. тренеры Ю.Ф.Золотов («Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең Казан авиация ин-ты СК) шәкерте. Студентларның Бөтендөнья кышкы универсиадасында 4×5 *км* лы эстафетада алтын, 15 *км* га узышта көмеш, 30 *км* да бронза (1987) медальләр ала; «Төньяк бәйрәме» («Праздник Севера») халыкара ярышларында (1987); социалистик илләрнең «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятьләре вәкилләре спартакиадасында (СССР җыелма командасы белән, 4×10 *км* лы эстафета, 1988) җиңүче. Яшьләрнең бөтенсоюз ярышларында бронза (15 *км* га узыш, 1984), СССР чемпионатларында көмеш (30 *км* га узыш, 1986), бронза (4×10 *км* лы эстафета, 1986, 1988) медальләр ала.

**ГЕРБЕ́РА** (Gerbera), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 ләп төре билгеле. Чыгышы — Көньяк Африка һәм Азия тропиклары. ТРда декоратив бакча һәм бүлмә гөле буларак үстерелә. Яфраклары тамыр янында, каурыйсыман-телмә яфрак сабында, яфрак таралгысына җыелган. Чәчәк төркеме — кәрзиннәр, эре, ялгыз, бик нәфис, озын читләре кыякчыклы (таҗ яфракчыклы), төрле төстә (алсу, кызыл, сары, кызгылт-сары, ак, аксыл-сары), яфраксыз озын чәчәк сабагында. Куакларны бүлеп, чыбыкча ялгап (аеруча таралган формалар), орлыктан, яфрак, тамырчадан үрчетелә. Бүлмә шартларында гыйнвардан апрель аена кадәр чәчәк ата.

**ГЕ́РБЕРГ** Александр Генрихович (21.8.1848 — 9.10.1918, Казан), гистолог, мед. д-ры (1884). Мед.-хирургия академиясен тәмамлый (1872, С.-Петербург), Казан мед. идарәсендә хезмәт итә. 1888–1918 елларда Казан ун-тында, гистология каф. прозекторы, 1896 дан приват-доцент. Хезмәтләре кошларда күзнең нерв очларын өйрәнүгә карый.

*Әд.:* Библиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ГЕРБЕРШТЕ́ЙН** (Herberstein) Сигизмунд фон (1486, Австрия — 1566), барон (1532),

Австрия дипломаты. Немец дворяннарыннан. Вена ун-тында белем ала. 1506 елдан Габсбурглар династиясендә хезмәттә. 1515 тән дипломатик хезмәттә. 1517, 1526 да Рус дәүләтендә булып китә. Мөһим дәүләт вазифалары башкара: камергер (1527 дән), империянең Югары хәрби советы әгъзасы (1537 дән), Австриянең Түбән палатасы президенты (1539 дан). Шәхси күзәтүләре һәм славян телләрен белүе нәтиҗәсендә язма истәлекләрне (елъязмаларны һ.б.) өйрәнеп язылган «Мәскәү хәлләре турында язмалар» («Записки о московитских делах»; Вена, 1549) авторы. Хезмәттә Россиянең географик урыны, икътисады, көнкүреше, дине бәян ителә. Анда ш.у. илнең борынгы дәверләрдән үк килгән тарихы, татарлар, аларның яшәү рәвеше, йолалары, хөкемдарлары, рус-татар, татар-төрек һәм рус-төрек мөнәсәбәтләре, ш.у. Казан ханлыгы турында мәгълүматлар да теркәлгән.

*Әд.:* З а м ы с л о в с к и й Е. Герберштейн и его историко-географические известия о России. СПб., 1884. *И.Л.Измайлов.*

**ГЕРБИЦИДЛА́Р** (лат. herba — үлән һәм caedo — үтерәм, юкка чыгарам), *пестицидлар* төркеменнән чүп үләннәрне бетерүче химик препаратлар. Бакчалар, кырлар һәм яшелчә чәчүлекләрендә химик утау, ш.у. буш җирләрдә, урман кисенделәрендә, юл буйларында чүп үләннәрне бетерү өчен кулланалар. Тоташ тәэсир итүче Г. барлык төр үсемлекләрне, сайлап тәэсир итүче Г. аерым төр үсемлекләрне генә юкка чыгаралар. Г. ның биохимик сайлап тәэсир итүе, аларның үсемлек күзәнәкләрендә төрлечә үзгәреше б-н аңлатыла: тотрыклы үсемлекләрдә препарат агусыз яисә агулы кушылмаларга таркала, ләкин шуннан соң йогышсызлана. Г., матдәләр алмашын бозып, үсемлекләрне үтерә яисә аларны үтерә торган агулы матдәләр барлыкка китерә. 2,4Д гирбицидының сайлап тәэсир итү сәләте зур, ул барлык ике өлешле үсемлекләрне юкка чыгара, бодай чәчүлекләрендәге кара солыга каршы кулланыла торган карбин шул юнәлештә генә сайлап тәэсир итә. Г., үсемлекләрдә күчә алу сәләтенә карап, тукымаларның өлешчә агулануына һәм үлүенә китерә торган контактлы (динитроортокрезол, пропанид), һәм чүп үләнне тулысынча юкка чыгаручы системалыларга (2,4Д, атразин, симазин) бүленә. Куллану алымына карап, яфрак Г.на (үсемлекләргә сиптереп эшкәртәләр) һәм туфрак (тамыр) Г.на (туфракка кертәләр) аералар. Г.ның микъдары җир кишәрлегенең чүпләнүенә, туфрак үзлекләренә, һава шартларына, культураның үзенчәлекләренә карап билгеләнә. Г.ның күпчелеге кешеләр һәм хайваннар өчен аз агулы, туфракта берничә атна гына саклана, ә атразин, симазин, прометрин берничә ел буе тәэсир итә. Г.ны дөрес кулланмау (күләмен арттыру, эшкәртү вакыты б-н исәпләшмәү) туфрак һәм сулыкларның пычрануына, үсемлек һәм хайваннарның һәлакәтенә, биогеоценоз системасында биологик бозылышка китерә. Татарстанда Г. 1950 елларда кулланыла башлый (бигрәк тә симазин һәм 2,4Д). Хәзерге вакытта ТРда Г. куллану, барлык басу культураларын игү технологиясенең аерылгысыз өлеше булып тора. Г.ның саны шактый күп. Бөртекле культуралар чәчүлекләрендә 2,4Д гербициды урынына ике өлешле чүп үләннәргә каршы нәтиҗәлерәк препаратлар кулланыла: банвел, дикамба, МЦПА. Алар ике өлешле күпьеллык чүп үләннәрне дә юкка чыгара. Ш.у. югары нәтиҗә бирүче дезорман, луварам, ленацил кебек күпьяклап тәэсир итүче Г. да кулланыла, алар җимеш бакчаларында, җиләк плантацияләрендә һәм техник культуралар чәчүлекләрендә ике өлешле берьеллык һәм кыяклы чүп үләннәрне бетерәләр. Г. куллануда кертү вакытын һәм микъдарын (күләмен) төгәл үтәү, аларның эшкәртеләсе җир мәйданына тигез таралышын саклау зур әһәмияткә ия.

*Әд.:* Система земледелия Татарской АССР. К., 1988; З а х а р ч е н к о В.А. Гербициды. М., 1990; Список пестицидов и агрохимикатов, разрешённых к применению на территории Российской Федерации. М., 2001.

**ГЕ́РБЛАР** (поляк. — herb), төгәл кагыйдәләр нигезендә ясалган һәм югары хакимият тарафыннан расланган символик (шартлы) сурәтләр. Г. нәсел һәм җир билгеләренә бүленәләр, дәүләт Г.ы аерым төркемгә керә (к. *Татарстан Республикасы Дәүләт гербы*). Җир яки дәүләт Г.ы, үз чиратында, 2 төркемгә бүленә: кайчандыр патша сараена беркетелгән (уделда булган) шәһәрләрнең Г.ы (аларның сурәтләре өлкә яки шәһәрләрнең мөһерләренә охшатып геральдик формада эшләнә) һәм Герольдия (Герольдмейстерлык конторасы, Герольдия департаменты) тарафыннан ясалган һәм расланган Г. Алардагы сурәт шәһәрнең тарихи әһәмиятенә, анда булып узган күренекле вакыйгаларга, географик һәм икътисади урынына нигезләнеп ясала.

Г. тәре яулары вакытында Көнбатыш Европада аерым әһәмияткә ия булалар: алар рыцарьнең шәхесен һәм нәселен таныклыйлар. Г.ны төзү, уку һәм аңлату б-н герольдлар шөгыльләнгән. Г.га хокук варислык буенча буыннан-буынга тапшырылган. Аларның сурәтләре байракларга, мөһерләргә, королларга төшерелгән, тәңкәләргә сугылган. Россиягә Г.ны куллану тәртибе Көнбатыш Европадан 17 йөзнең 2 нче яртысында керә. 1722 елда дворяннар катлавы эшләре б-н шөгыльләнгән үзәк дәүләт оешмасы — Герольдмейстерлык конторасы (1817 гә кадәр эшли) төзелә, аның вазифаларына дворян нәселләре өчен Г. төзү керә. 1797 дән император раслаган Г. дан «Россия империясе дворян нәселләренең гомуми гербовнигы» төзелә башлый. 1800 дә Герольдмейстерлык конторасына Россия шәһәрләренең гомуми гербовнигын төзү бурычы куела. 1857 нең 10 июнендә Герольдия департаменты каршында Герб бүлекчәсе оештырыла, аңа геральдика кагыйдәләре буенча терр-яләрнең Г.ын һәм шәхси Г.ны төзү йөкләтелә.

Казан төбәгендә Казан эмблемасы иң борынгы билге булып тора. Легендаларның берсе буенча, шәһәр еланнар күп яшәгән җирдә төзелгән. Алар кырып бетерелә, әмма еланнар патшасы качып котыла. Ул соңыннан Елантау («Елан тавы») дип аталган тауга очып китә, шуннан шәһәр халкының котын алып тора. Кодрәтле тылсымчы Хәким сихерләп еланны үтерә. Шушы вакыйга истәлеге буларак Елан (русча язылышы һәм әйтелеше «Зилант») сурәте шәһәр эмблемасына керә. Борынгы төркиләр фольклорында канатлы елан, гадәттә, тискәре образ (*аждаһа*). Шул сәбәпле кайбер галимнәр (Н.Г.Ханзафаров), канатлы елан татар халкының символы була алмый, дип исәплиләр. Елан яки аждаһа сурәтенең эмблема буларак кайбер болгар кабиләләре тарафыннан һәм татар ханлыкларында кулланылуы ихтимал. Алтын Урда ханнарының шәхси мөһерләрендә нәсел тамгасы — өч япьле чәнечке-сөңге сурәтләнә. Аждаһа символы Казан ханлыгы яулангannан соң (1552) урын алган булса кирәк; ул Изге Георгийның аждаһаны җиңүе турындагы легендадан килә. М.Худяков язуынча, бу герб Казан ханлыгы яулангannан соң митрополит Макарий мәктәбе вәкилләре — Мәскәү геральдистлары тарафыннан төзелгән һәм Казан патшалыгы гербындагы аждаһа сурәте дошмани дәүләтне гәүдәләндерергә тиеш булган. Шул ук вакытта татар ханнары эмблемасының тасвирламасы Карлус Алярд әсәрендә сакланган (Амстердам, 1705). Анда «Татария патшасының сары флагында койрыклы кара аждаһа (зур елан) ятып тора, ул башын читкә борган», диелә. Аждаһа рус чыганакларында да искә алына. 16–17 йөзләрдә бу эмблема беркадәр үзгәрешләр б-н төбәк мөһерләрендә очрый. 1730 да Казан гербы рәсми төстә кабул ителә. 1766 елгы Фәрманда: «Казан мөһере, аның таҗында василиск, канатлары — алтын, койрыгының очы — алтын», диелә. 18 йөз ахырында һәм 19 йөз уртасында ул беркадәр үзгәрешләр кичерә. 1781 нең 18 октябрендә чыгарылган Фәрман буенча Казан гербы: «Алтын Казан таҗы кигән кара елан, канатлары кызыл, әйләнә-тирәсе ак төстә»; 1856 ел 8 декабрь Фәрманы буенча: «Көмеш калканда таҗлы кара аждаһа; канатлары һәм койрыгы кызыл, томшыгы һәм тырнаклары алтынланган, теле кызыл төстә. Калкан өстенә император таҗы куелган һәм Андрей тасмасы б-н тоташтырылган алтынланган имән яфраклары б-н уратып алынган».


Казан Г. бер үк вакытта Казан губернасы Г. да булып торган. Казан губернасы өяз шәһәрләренең герблары проектлары Сенатның 1781 ел 18 октябрь фәрманы б-н раслана. Һәр өяз шәһәре (Зөя шәһәреннән башка) гербының югары өлешендә, губерна үзәге — Казан гербы урын алган. Проектлар авторларының идеясе буенча, өяз шәһәрләре Г.ының символлары алар урнашкан җирләрнең үзенчәлекләрен чагылдырырга тиеш була. Зөянең гербы җир-төбәкләр Г.ының беренче төркеменә карый. Анда «зәңгәр кырда Иделдәге кораблар өстенә салынган агач шәһәр, елгада балык сурәтләнгән» (ягъни шәһәр төзелеше тарихы чагылдырылган. Шәһәр өчен башта Угличта буралар әзерләнеп, алар салларда Идел буйлап төшерелә, соңыннан 28 көн эчендә корыла). Төбәк шәһәрләре Г.ында түбәндәгеләр сурәтләнгән: Чабаксар — «алтын төсендәге кырда очып баручы 5 кыргый үрдәк» (шәһәрнең тирә-ягында үрдәкләрнең күп булуын күрсәтүче символ), Цивильск — «ал-

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ ШӘҺӘРЛӘРЕНЕҢ ГЕРБЛАРЫ


Казан губернасы гербы.



Козьмодемьянск ш.


Лаеш ш.


Мамадыш ш.


Зөя ш.


Спас ш.


Тәтеш ш.


Царевококшайск ш.


Цивильск ш.


Чабаксар ш.


Чистай ш.


Ядринск ш.

тынсу төстәге кырда зур тамырлы имән» (урынның имән урманнарына бай булуына ишарә), Ядринск — «кызыл төстәге кырда өчпочмаклы пирамида рәвешендә өелгән ядрәләр» (шәһәр атамасына ишарәләү), Козьмодемьянск — «кызыл төстәге кырда алтын җәя, аның өстендә аркылы-торкылы куелган өч ук» (халкының әлеге коралдан оста атуына ишарә), Царёвококшайск — «күк фонда көмеш поши» (пошины оста аулауга ишарә), Арча — «көмеш фонда имән буралардан корылган өч манаралы кальга» (шәһәр-кальга символы), Мамадыш — «яшел фонда ике көмеш урак, алар арасында алтын бодай көлтәсе» (уңдырышлы җирләр символы), Чистай — «яшел фонда келәймә суга торган дүрт кырлы алтын басма» (зур икмәк ярминкәсе символы), Лаеш — «күк төстәге кырда юлга чыгарга әзер, струг дип аталучы зур кораб» (зур пристань символы), Спас — «алтын төсендәге кырда борынгы кальга манарасы» (шәһәр борынгы болгар каласы янәшәсендә урнашкан), Тәтеш — «кызыл төстәге кырда ике рыцарь сөңгесе һәм ике калкан» (шәһәрдә элек-электән хәрбиләр яшәве символы). Окт. рев-циясеннән соң элеккеге символика бетерелә.

ТАССРда республиканың рәсми Г. кабул ителгән була (к. *Татарстан Республикасы Дәүләт гербы*). 1990 елларда Г. б-н кызыксыну сизелерлек арта: аерым шәһәр һәм районнарның символлары ясала башлый. Ш.у. к. *Геральдика*, *«Польша татарлары гербовниклары»*, *Мөһер*, *Нишан*.

*Әд.:* Винклер П.П. Гербы городов, губерний, областей, посадов Российской империи, внесённые в «Полное собрание законов». СПб., 1900; Соболева Н.А. Российская городская и областная геральдика XVIII–XIX вв. М., 1981; шул ук. Старинные гербы российских городов. М., 1989; Хорошкевич А.Л. Символы русской государственности. М., 1993; Ханзафаров Н.Г. Казанский «Зилант»: миф и действительность // Науч. Татарстан. 1997. № 3/4; Гербы городов России: Альбом-справ. М., 1998.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ГЕ́РКЕН** Евгений Юрьевич (Георгиевич) (17.10.1886, Казан — март 1962, Мәскәү), шагыйрь, драматург, тәрҗемәче. Е.А.Боратынский оныгының улы. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1910). Шигырьләрендә Г.ның төрле йогынтыларга тартылуы, бүтәннәрнең стилистик алымнарын кабатларга һәвәслеге сизелә. Казан шәһәр театрында барган «Бөек Калиостро» («Великий Калиостро», 1908), «Пыяла киртәләр» («Стеклянные перегородки», 1909), «Алар гашыйк иде-

ләр» («Они любили», 1910), «Дәртле хатын» («Страстная женщина», 1912) пьесалары авторы. 1917 елдан соң Петербургта яши, «Бөтендөнья әдәбияты» («Всемирная литература») нәшрияты өчен тәрҗемәләр б-н шөгыльләнә. 1932 дә репрессияләнә; 1954 тә аклана.

Ә с ә р.: Башня. Л., 1926; Лирические стихотворения. К., 1928.

**ГЕ́РКЕН** Николай Александрович (18.12.1863, Чуаш АССРның Мари Посады пос. — 8.3.1933, шунда ук), хирург, мед. д-ры (1892). Казан ун-тын тәмамлый (1888), Казан губернасы Спас өязендә земство табибе булып эшли. 1892 елдан Томск ун-тында. «К вопросу о пролиферирующих кистах челюстей и гайморовой полости» хезмәтен яклаганнан соң, мед. д-ры исеме ала. 1895 тән чит илдә эшли. 1897–1925 елларда Казан ун-тында: оператив хирургия каф. профессоры (оториноларингология, десмургия б-н хирургик патология укытуны оештыра), факультет хирургик клиникасы профессоры. 1925–33 тә Мари Посады посёлогы хастаханәсе консультанты. Хезмәтләре экспериментал һәм клиник хирургиягә, оториноларингологиягә, борын, борын куышлыгы һәм йоткылык өсте хирургик авыруларына, сөяк сынуларын дәвалауга карый. Чуаш АССРда трахомага каршы көрәштә катнаша.

Х е з м.: К вопросу о пролиферирующих кистах челюстей и гайморовой полости: Дис. ...Томск, 1892.

**ГЕ́РМАН** (Полев-Садырин Григорий Фёдорович) (1505 тирәсе, хәзерге Тверь өлкәсенең Старица ш. — 6.11.1567, Мәскәү), дин эшлеклесе. Рюриковичлар (Смоленск кенәзләре) нәселеннән. 1530 ел тирәсендә Успение Волоколамск монастыренда монахлыкка керә. 1551 дән Успение Старицкий монастырендә архимандрит, 1551–53 тә монастырь башлыгы. 1555 тә Волоколамск монастыреннан ук танышы архиепископ Гурий чакыруы б-н Казанга килә. Аңа Тау ягында чиркәү хезмәтен оештыру йөкләнә. Г. Зөядә урнаша һәм 1555 тә *Успение монастырена* нигез сала, анда мәктәп һәм китапханә ача. 1564 тән Казан һәм Зөя архиепискобы. 1566 да Мәскәүгә чакырыла. Иван IV аңа Мәскәү митрополиты урынын тәкъдим итә, ләкин Г. баш тарта, опричнина репрессияләренә каршы чыга, шунлыктан куыла. Кайбер чыганакларда җил чәчәге кизүеннән вафат булуы, икенчеләрендә Иван IV опричниклары тарафыннан үтерелүе турында мәгълүматлар бирелә. 1595 тә митрополит *Гермоген* инициативасы б-н изгеләштерелә. Җәсәде Зөягә күчерелә һәм 1923 кә кадәр үзе нигез салган монастырьда саклана. Хәзерге вакытта җәсәденең бер өлеше Иоанн-Предтеча монастыренда (Казан) саклана. Искә алу көне — 23 май/6 июнь.

*Әд.:* Никонор (Каменский). Житие Святителя Германа, второго архиепископа Казанского, Всея России Чудотворца. К., 1894; Ю д и н П.Л. Новые данные к житию Святителя Германа, второго архиепископа Казанского. Самара, 1901; Священномученик Герман, просветитель Казани. К., 1911.

**«ГЕРМА́НЧА-ТАТА́РЧА БЕЛЕШМӘ́ — DEUTSCH-TATARISCHES NACHRICHTENBLATT»**, айлык иҗтимагый-сәяси журнал. *Татар арадашлыгы* органы. 1943 елның апреленнән Берлинда татар һәм немец телләрендә (латин графикасында) нәшер ителә. 1944 нең июленә кадәр 14 саны чыга. Баш мөхәррире Г.Солтан. Журнал, башлыча, «Идел-Урал» легионы батальоннарына мобилизацияләнгән хәрби әсирләр, Шәрекъ илләре эшчеләре һәм татар мөһаҗирләре арасында таратыла. Тиражы чама б-н 500–600 данә. Журнал барыннан да элек пропаганда максатында эшли, Икенче бөтендөнья сугышы елларында төрки халыкларга Германия б-н хәрби-сәяси өлкәдә хезмәттәшлек итүнең зарурлыгын дәлилләргә тырыша. Шулай ук журнал үзен Шәрекъ халыкларына Европа мәдәнияте кыйммәтләрен аңларга булышлык итәргә тиеш дип саный. Мәкаләләрнең күпчелеге Германиянең тышкы һәм эчке сәясәте мәсьәләләренә, халыкара хәлләргә багышлана. Журнал битләрендә тарихи очерклар, биографик мәкаләләр, фәнни хезмәтләрдән (мәс., Г. фон Менденең «Россия төркиләренең милли көрәше» монографиясеннән) өзекләр басыла. Журналның чыгудан туктаган вакыты төгәл билгеле түгел.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ГЕРМОГЕ́Н** (1530 тирәсе — 17.2.1612, Мәскәү), дин эшлеклесе. 1570 елларда Казандагы Николо-Гостинодвор чиркәвендә хезмәт итә, 1587 елдан Казанның Спас-Преображение монастыре башлыгы. 1589 дан Казан һәм Әстерхан митрополиты. 1606–12 дә Мәскәү һәм бөтен Русь патриархы. 1579 да Казан Мәрьям Ана иконасын табуда катнаша. Казанда дини эшчәнлек алып барган *Гурий* (Руготин), *Варсонофий*, *Герман* аның тырышлыгы б-н изгеләштерелә. Алар турында хезмәтләр авторы. Ул митрополит булган вакытта Казанда миссионерлык эшчәнлеге көчәя, татарларны күпләп көчләп чукындыру үткәрелә.

Х е з м.: Сказание о чудотворной Казанской иконе Пресвятой Богородицы / Предисл. А.И.Соболевского. М., 1912.

*Әд.:* П л а т о н о в С.Ф. Статьи по русской истории. СПб., 1903; К е д р о в С. Жизнеописание Святейшего Гермогена. М., 1912; П о к р о в с к и й И.М. Гермоген — митрополит Казанский и Астраханский... и его заслуги для Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1907. Т. 23.

**«ГЕРО́Й АНА́»**, иң югары аерымлык дәрәҗәсе, СССРда 10 һәм аннан артык бала тудырып тәрбияләп үстергән аналарга бирелә торган мактаулы исем. 1944 елның 13 августында СССР ЮС Президиумы Указы б-н раслана. Исем бирелгән аналарга орден һәм СССР ЮС Президиумы грамотасы тапшырыла. Беренче орден б-н Кремльдә 1944 нең 1 ноябрендә Мамонтовка посёлогында (Мәскәү өлкәсе) яшәүче 12 бала тәрбияләп үстергән Алексахина Анна Савельевна бүләкләнә. Орден күкрәкнең сул ягында йөртелә. Бүләкләнүченең башка орденнары һәм медальләре булган очракта, орден алардан өстәрәк тагыла. 1994 тә бу исем бетерелә. 2000 дә ТР Президенты М.Ш.Шәймиев Указы б-н ТРда *«Ана даны — Материнская слава» медале* булдырыла. ТРда ул күп балалы 957 анага бирелә (2009, 1 сент.).

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГЕ́РПЕС ВИ́РУСЫ**, йогышлы авыру, герпес вируслары (ДНКлары булган Herpesviridae семьялыгы) китереп чыгара; тиредә, авыз, борын, җенси органнарның лайлалы тышчаларында куыксыман шешләр булу б-н характерлы. Авыруга кычыту, авыртулар, температура күтәрелү хас. Г.в. немец галимнәре В.Грютер (1912) һәм А.Левенштейн (1919) тарафыннан ачыла һәм өйрәнелә. Авыруның 80 нән артык төре бар, 8 төре, ш.и. гади герпес вируслары (җенес органнарында һәм алардан тыш Г.в.) кешене зарарлый. Вирус һава-су, җенси юл, көнкүрештә аралашу вакытында, трансфузион, ш.у. трансплацентар (кан алмаштыру) юл б-н күчә. Бер кеше берьюлы авыруның берничә төре б-н зарарлана ала. Организмга бер тапкыр кергәч, вирус нерв төеннәренә урнаша һәм гомерлеккә шунда кала (вирус йөртүчелек), бавыр, бөерләр, ашказаны асты бизе, ашказаны-эчәк юллары, баш миен (шизофрения авыруына сәбәпче), җенес органнарын зарарлый; ирләрдә еш кына простатит авыруын китереп чыгара. Герпес инфекциясенең яңадан кабатлану куркынычы бар, авырудан соң иммунитет эшләми. Иммунопрофилактика эшләнмәгән. 1990 елдан ТРда Г.в. саны арту күзәтелә, бигрәк тә, куркыныч формалары арта. 1970 еллардан ТР галимнәре авыруны актив өйрәнәләр: авыруны «ацикловир» герпес-зостер препараты б-н дәвалау ысулы эшләнә; көчле авыруларны электрон ысуллар б-н дәвалау гамәлгә кертелә.

*Әд.:* К о л о м и е ц А.Г., М а л е в и ч Ю.К., К о л о м и е ц Н.Д. Многолетний герпес. Минск, 1988; И с а к о в В.И., Б о р и с о в а В.В., И с а к о в Д.В. Герпес, патогенез, лабораторная диагностика: Руководство. СПб., 1999; П о к р о в с к и й В.В., Е р м а к Т.Н. ВИЧ-инфекция, клиника, лечение, диагностика. М., 2000.

*В.Х.Фазылов.*

**ГЕ́РЦБЕРГ** Бенедикт Германович (24.1.1893 — 18.9.1948, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1936). 2 нче Ленинград мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук эшли. 1936–48 елларда Казан мед. ин-тының гомуми хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре үңәч хирургиясенә карый; ялган аневрезмны дәвалау юлларын эшли. Г. — хирургик авыруларны тикшерү өлкәсендә биохимик юнәлешне үстерү инициаторы. Хезмәтләре үңәч физиологиясенә, топографик анатомиягә, кардия авыруларга карый.

Х е з м.: К вопросу о ранении лёгочной артерии. М., 1932; Словарь деятелей медицины, преимущественно хирургов и деятелей естествознания. К., 1940 (автордаш).

**ГИГА́НОВ** Иосиф Иванович (? — 7.9.1800, Тобол ш.), тел галиме, педагог. Дин эшлеклесе гаиләсеннән. 18 йөз ахырында Тобол шәһәренең София соборында рухани, бер үк вакытта Тобол баш халык уч-щесендә татар теле укыта. Беренче татар теле грамматикалары авторларының берсе. Анда татар теленең фонетик һәм морфологик төзелеше бирелә, сүз төркемнәре (исем, фигыль, сыйфат фигыль, рәвеш, алмашлык, ш.у. бәйлек, теркәгеч, ымлык) тасвирлана. Хезмәте шәркыятьче галимнәр В.В.Григорьев һәм А.Е.Крымский тарафыннан югары бәяләнә. Г. татар теленең

Казан һәм Себер (Тубыл) шивәләре арасындагы кайбер аермалыкларга игътибар итә; татар телендәге кайбер күренешләрне рус, француз, төрек, кыргыз телләрендәге шундый ук күренешләр б-н чагыштыра. Н.Атнометовның «Татар һәм гарәп язуы әлифбасы» басмасын («Букварь татарского и арабского письма», СПб., 1802) фәнни яктан әзерли. Татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзүче.

Хезм.: Грамматика татарского языка... муллами юртовскими свидетельствованная. СПб., 1801; Слова коренные, нужнейшие к сведению для обучения татарскому языку... юртовскими муллами свидетельствованные. СПб., 1801; Словарь российско-татарский... муллами юртовскими свидетельствованный. СПб., 1804.

*Әд.:* Веселовский Н.И. Сведения об официальном преподавании восточных языков в России. СПб., 1879; Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974.

*В.Х.Хаков.*

**«ГИГА́НТ»**, Тукай р-нындагы ҖЧҖ. 1970 елда бер үк исемдәге колхоз җирлегендә оештырылган «Гигант» с-зын (1995–2006 да «Г.» а.х. кооперативы) 2006 елда үзгәртеп кору юлы б-н төзелә. Хуҗалык терр-ясендә 4 торак пункт, үзәк утары — «Новый» посёлогы. 1,8 мең кеше яши, ш.и. эшләүчеләр саны 163 кеше. А.х. җирләренең мәйданы 4932 *га*, ш.и. сөрү җирләре 4486 *га*. Төп җитештерү юнәлешләре — бөртекле ашлык хуҗалыгы һәм сөт терлекчелеге. 1970 еллар уртасыннан хуҗалык бөртекле культуралардан алынган югары уңыш һәм сөт җитештерүдәге алдынгы күрсәткечләре б-н билгеле. Барлык тармаклар югары дәрәҗәдә механикалаштырылган. Мөгезле эре терлек — 1655 баш, ш.и. сыерлар — 660 баш. Бөртекле культураларның уңышы (1 *га* дан центнерларда): 1970 тә — 18,8, 1980 дә — 45,1, 2001 дә 50,1, 2002 дә — 53, 2003 тә — 63, 2007 дә 70,1 центнер. 2007 дә 1 савым сыердан уртача 5018 *кг* сөт алына, 100 *га* а.х. җирләренә 671 *ц* сөт җитештерелә. Хуҗалыкка җитештерүдәге югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен 7 тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байраклары (1977, 1980–82, 1984–86), СССР (1983) һәм ТАССР (1980, 1985) ВДНХларының дипломнары бирелә. 1973 тән хуҗалык б-н Соц. Хезмәт Герое Н.З.*Зиатдинов*, 2000 елдан Р.Х.Имамов җитәкчелек итә.

**ГИ́ДРАЛАР** (Hydrida) чагучылар яки эчәккуышлылар тибындагы умырткасыз хайваннар отряды. 10 лап төре мәгълүм. Татарстан терр-ясендә өч төре бар; һәр җирдә очрый. Ялгыз тереклек итүчеләр, скелетсыз полиплар, хәрәкәт итә ала торганнар. Ара-тирә вакытлы колонияләр тәшкил итәләр. Гәүдәләре 1–3 *см* озынлыкта, озынча яки капчыксыман. Полипның конуссыман авыз читендә 6–8 куыш кармавычы бар. Кармавычлар саны һәм озынлыгы гәүдә озынлыгына бәйле. Бүленеп тә, җенси юл б-н дә үрчиләр. Гермафродитлар һәм аерым җенеслеләре була. Җенси юл б-н көзен үрчиләр, аталанган күкәйләр нык тышча б-н каплана һәм кышлый. Аталанганнан соң Г. үлә, ә язын күкәйләрдән яңа буын чыга. Дафнияләр, циклоплар, бөҗәкләрнең вак личинкалары, суалчаннар б-н тукланалар. Кармавычлар кагылганда агулы капсулалар (типның үзенчәлекле билгесе) корбанның хәрәкәтләнүен туктата, аннан соң кармавычлар аны авызга таба юнәлтә. Гадәттә, Г. — күл, буа, су үсемлекләре (элодея, мөгезъяфрак, су кәбестәсе) б-н капланган елга буйларында табаннары б-н береге ияшиләр. Гаять киң таралган төре — гади гидра (Hydra vulgaris). Гәүдәсенең арткы өлешендә урнашкан сабакчыгы б-н башкалардан аерылып торган сабаклы гидра (Pelmatohydra oligactis) һәм бер күзәнәкле хлорелла сүүсеме б-н симбиозда яшәүче яшел гидра (Chlorohydra viridissima) төре сирәк очрый. Лаборатор тәҗрибәләр һәм практикумнар объекты. Әйләнә-тирә мохиттә индикатор буларак та кулланылырга мөмкиннәр.



Гади гидра.

*Әд.:* Наумов Д.В. Гидроиды и гидромедузы морских, солоноватоводных и пресноводных бассейнов СССР. Л., 1960; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных России и сопредельных территорий. Т. 1. Низшие беспозвоночные. СПб., 1994.

*Р.М.Сабиров.*

**ГИДРА́НГИЯ**, гортензия (Hydrangea), гидрангиячәләр семьялыгыннан яфрак коючан куаклар, ярымкуаклар ыругы. Сирәк кенә лианалар яки тәбәнәк агачлар. 35 лап төре билгеле. Төньяк Америкада, Үзәк һәм Көнчыгыш Азиядә (еш кына Кытайда һәм Япониядә) киң таралган. ТРда ачык грунтта үстерелә, салкынга чыдамсызларын, чүлмәк гөлләре дип аталган төрләрен декоратив бүлмә гөле буларак үрчетәләр. Аеруча таралган төрләре: япон Г.се (H. japonica), эре яфраклы Г. (H. macrophylla), себеркәчле Г. (H. paniculata). Кара-каршы яфраклы, яфраклары саплы, гадәти, озынча түгәрәк, шактый эре. Ак, зәңгәрсу, алсу, кызгылт төстәге чәчәкләре шарсыман яки яссы чәчәк төркеменә тупланган. Чыбыкча, үренте, орлыктан (селекция максатларында) үрчетелә. Г. дым яратучан, күләгәне әйбәт кичерә, әче туфракта яхшырак үсә.

**ГИ́ДРО**... (грек. hýdōr — су), суга, сулыкларга h.б. ш.га (мәс., гидрология, гидроэнергетика) мөнәсәбәтле кушма сүзләрнең беренче кисәге.

**ГИДРОАЭРОМЕХА́НИКА**, механика фәненең бер бүлеге, сыеклык һәм газларның хәрәкәтен, ш.у. аларның каты җисемнәр б-н үзара тәэсир итешүен өйрәнә. Г. барлыкка килгән көннән аның төп тикшерү объекты — әйләнә-тирә мохит (су, һава) б-н андагы хәрәкәтләнүче яки хәрәкәтсез җисемнең үзара тәэсир итешүе. Архимед (б.э.к. 3 йөз) — гидростатиканың төп законын ачып һәм сыеклыкларның тигезләнеш теориясен төзеп, Г. га мөһим өлеш керткән беренче галим. Г. үсешендәге икенче этап Яңарыш чорына (16–17 йөзләр) туры килә. Леонардо да Винчи сыеклык яки газда җисемнәр хәрәкәтен өйрәнүгә беренче мөһим адым ясый. Б.Паскаль ике элементар сыеклык күләме орынган өслеккә перпендикуляр көчне (басымны) тикшергәндә сыеклыкның шул ноктасында басымның һәр юнәлештә бер үк көч б-н тәэсир итүен исбатлый. Инглиз галиме И.Ньютон каршылык законына беренче теоретик билгеләмә бирә, динамиканың төп законнарын һәм тигезләмәләрен исбатлап, Г.ның сыеклык һәм газларның аерым мәсьәләләрен өйрәнүдән гомуми законнарын тикшеренүгә күчү юлын ача. Теоретик гидродинамикага нигез салучылар Л.Эйлер б-н Д.Бернулли сыеклыклар агымын тикшергәндә механика законнарын кулланалар. Л.Эйлер «идеаль» дип аталган, ягъни үзле булмаган сыеклык хәрәкәтенең төп тигезләмәләрен беренче булып чыгара.

19 йөздә Г.ның төп казанышы — үзле сыеклык хәрәкәтен тикшерүгә күчү, бу ихтыяҗны исә гидравлика, гидротехника һәм машиналар төзелеше үсеше тудыра (машиналарның ышкылучан өлешләрен майлау). Тәҗрибә күрсәткәнчә, җисемнәрнең хәрәкәт тизлеге кечкенә булганда каршылык, башлыча, үзлелеккә бәйле була. Сыеклык торба һәм каналларда хәрәкәт иткәндә дә шулай.

20 йөз башында авиация барлыкка килү Г.дагы гомуми теоретик һәм инженерлык тикшеренүләренең бик тиз якынаюына китерә, ә аның формалашуы техниканың мөһим мәсьәләләрен чишүдән аерылгысыз була бара. 20 йөзнең 1 нче яртысында Г. да ирешелгән нәтиҗәләрнең күп өлеше Н.Е.Жуковский һәм С.А.Чаплыгинның Мәскәү фәнни мәктәбе, Л.Прандтльнең Гёттинген фәнни мәктәбе (Аэродинамик тикшеренү үзәге, Гёттинген ш., Германия) эшчәнлекләре б-н бәйле. Канатның күтәрү көче, канатның һәм винтның тарту көче теорияләре төзелү, очыш динамикасының күп кенә мәсьәләләрен хәл итү Н.Е.Жуковский хезмәтләренә бәйле. Ул Россиядә беренче аэродинамика лаб-яләре оештыра, С.А.Чаплыгин җитәкчелегендә сыеклык һәм газ механикасы өлкәсендә бөтендөнья үзәгенә әверелгән Үзәк аэродинамика ин-ты ачылуның (1918) башында тора. Мәскәү фәнни мәктәбе (П.А.Вальтер, В.В.Голубев, М.В.Келдыш, Н.Е.Кочин, М.А.Лаврентьев h.б.) Г.ның комплекслы үзгәрешленең функцияләре теориясе кулланыла торган яссылыктагы мәсьәләләрен чишүгә мөһим өлеш кертә.

ТРда Г. өлкәсендәге төп фәнни-тикшеренү үзәкләре — Казан ун-ты, Казан техник ун-ты, РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-ты. ТРда Г. өлкәсендәге эре фәнни мәктәпләр: кайтма кырый мәсьәләләр (ККМ) теориясе, җир асты гидромеханикасы, зур тизлекләр гидродинамикасы һәм аэросыгылмалылык. ККМ теориясенә (СССР да

беренче) Г.Г.*Тумашев* (1942) нигез сала. 1947 елда М.Т.*Нужин* аналитик функцияләр өчен ККМне гомуми рәвешкә куя. ККМ ысуллары гидротехника мәсьәләләрендә (буаларны исәпләү) һәм шартлатып чыгару теориясендә кулланыла. Р.Б.Сәлимов канат профилен яхшырту мәсьәләләрен тикшерә. 1980–90 елларда алдан билгеләнгән сыйфатлары буенча профильне компьютерда проектлаштыруның нәтиҗәле ысуллары эшләнә (А.М.Елизаров, Н.В.Ильинский, А.В.Поташев). Нефть сәнәгате ихтыяҗлары өчен 1950 елларда ТР-да җир асты гидромеханикасына кагылышлы тикшеренүләр киң җәелә. Су-нефть контакты хәрәкәте теориясе төзелә (Г.Г.Тумашев, В.Л.Данилов); скважиналарны оптималь урнаштыру мәсьәләләре тикшерелә (В.Д.Чугунов); ике фазалы саркыту һәм полимер кулланып суландыруны санча исәпләүнең нәтиҗәле ысуллары үстерелә (В.Я.Булыгин, А.Н.Чекалин); нәсызыкча һәм релаксацияле саркытуга кагылышлы теоретик һәм эксперименталь тикшеренүләр үткәрелә (Н.Н.Непримеров, Ю.М.Молокович, Э.В.Скворцов); нефть катламнары һәм скважиналардагы җылылык кырлары өйрәнелә (Н.Н.Непримеров, М.А.Пудовкин, А.Н.Саламатин, В.А.Чугунов); катламнарның су үткәрүчәнлеген ачыклау ысуллары эшләнә (В.Я.Булыгин, В.Г.Голубев, М.Х.Хәйруллин, П.Г.Данилов); катламнар деформацияләренең эшкәртү күрсәткечләренә йогынтысы өйрәнелә (Р.Н.Дияшев, А.В.Костерин, Э.В.Скворцов).

Казан ун-ты каршындагы Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында чикләре иректе сыеклыкларны теоретик тикшеренүләр (зур тизлекләр гидродинамикасы) үстерелә (1962 дән). Шул мәктәп кысаларында каршылыкларны кавитацияле ягалап агу схемасы (А.В.Кузнецов, А.Г.Терентьев); агымнарның төрле тулы басымнар б-н тәэсирләшү теориясе төзелә (О.М.Киселёв, Д.В.Маклаков); чикләрнең тотрыклылыгын һәм резонанс күренеше мәсьәләләрен дә исәпкә алып, кавитацияле каршылык тирбәнүләре өйрәнелә (А.В.Кузнецов); сыеклыкның иректе өслегендә нәсызыкча дулкыннар теориясе үстерелә (Д.В.Маклаков); су асты канатының ягалавы, суперкавитирлаучы винтның эше, җисемнең суга куышлык ясап бик тиз керүе тикшерелә.

1970 елларда СССР ФА Казан ф-лының Физ.-техника ин-тында, аннан соң РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында М.Ә.*Илһамов* җитәкчелегендә гидроаэросыгылмалылыкны өйрәнүгә караган фәнни юнәлеш формалаша (А.А.Аганин, Ш.У.Галиев, А.Н.Гыйльманов, Р.Ш.Гыймадиев, Б.В.Гулин, Р.Г.Зарипов, В.А.Иванов, Р.Н.Мифтахов, В.В.Ридель, Җ.М.Сәхәбетдинов, В.Л.Федяев, Р.Г.Якупов). Контакт өслегенең зур көчешләрен исәпкә алып, үткәрүчән һәм үткәрмәүчән тышчаларның сыеклык һәм газ б-н үзара көчле тәэсирләшү теориясе үстерелә. Цилиндрик тышчаның газлы куышлыгында периодик бәрмә дулкыннар барлыкка килүе ачыклана, бу күренешнең теориясе эшләнә. Йомшак сүрүләрнең агымдагы динамик хәле тикшерелә, парашют ачылу процессы модельләштерелә. Дулкынлы йөрткечләрнең һәм перистальтик насосларның сыналма модельләре эшләнә, аларның теориясе төзелә.

Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты) Н.Г.*Четаев* тарафыннан 1932 дә Г. кафедрасы оештырыла. Г.В.Каменков Т.Карман б-н Н.Е.Жуковскийның өермә эз теориясе буенча тикшеренүләрен үстерә. С.Г.Нужин канат профилен газ агымы ягалавын исәпләүнең нәтиҗәле ысулын тәкъдим итә, канатның иң зур җәелүе винт өермәләре теорияләре буенча тикшеренүләр үткәрә. В.Г.Павлов, К.Г.Гәрәев һәм аларның шәкертләре Г. да өзлексез төркемнәр теориясе ысулларын куллананалар: механик күренешләр охшашлыгы теориясен үстерәләр, чик катлам теориясе мәсьәләләрен төркемләп тикшерәләр, кайтма мәсьәләләрнең һәм алгебраик структураларның бәйләнешен билгелиләр. Шул кафедраның аэродинамик торбаларында уздырылган тәҗрибә нәтиҗәләре илебезнең әйдәп баручы авиация техникасы КБларында кулланыла. Канатларның алгы һәм арткы кырыйлары буенча механикалаштырылган модельләре, озынайтылган һәм супертотрыклы профильле канатлар буенча алып барыла торган тикшеренүләр, ш.у. аэродинамик характеристикаларны ярымэмпирик хисаплау ысуллары Ту-204, Ту-334 самолётлары өчен очып күтәрелү һәм җиргә утыруны механикалаштыру чараларын проектлаштыруны яңа сыйфат дәрәҗәсенә күтәрергә, проектлаштыру вакытын һәм икътисади чыганакларны кыскартырга мөмкинлек бирә.

1970 елларның 2 нче яртысыннан Казан ун-тында О.М.Киселёв б-н Л.М.Котляр җитәкчелегендә, үтәли агымлы газодинамик лазерларга (ГДЛ) бәйләп, нурланучы газ һәм плазманың тигезсез агымы тикшерелә. Лаваль соплосы буенча тавыштан күпкә тизрәк аккан газның тигезсез тирбәнешен чик катламны исәпкә алып хисаплау ысулы эшләнә. Чыгучы агымы тигез булган сопло кисемен хисаплауның вариатив ысулы тәкъдим ителә. ГДЛларны хисаплау өчен гамәли программалар пакеты булдырыла, газлы лазерларның башка типлары тикшерелә. Газ бушанулы лазерның якынча моделе тәкъдим ителә һәм аның параметрларын оптимальләштерү мәсьәләләре чишелә. Пыскулы бушануны хисаплауның нәтиҗәле ысулы эшләнә, аның төзелеше өйрәнелә.

Технологиядә җылылык-масса күчеше процессларын тикшергәндә Г. ысуллары зур әһәмияткә ия. Бу юнәлештә Казан технол. ун-тында (С.Г.Дьяконов, Ф.Ә.Гарифуллин, Н.Х.Зиннәтуллин һ.б.) һәм РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында (Д.Ә.Гобәйдуллин, А.Б.Мазо, В.Л.Федяев) мөһим нәтиҗәләр алына. Катлаулы җылылык-масса алмашу процессларының декомпозиция принциплары, күп фазалы агымнарны, ш.у. нәсызыкча үзле һәм үзле-сыгылмалы мохитне хисаплау ысуллары эшләнә; реологик катлаулы системаларда җылылык конвекциясе тикшерелә.

*Әд.:* История механики. М., 1972; Очерки истории НИИ математики и механики имени Н.Г.Чеботарёва. К. 1989; Механико-математический факультет Казанского университета: Очерки истории. К., 2000; БСЭ. 3 изд. М., 1971; Т. 6; Физический энциклопедический словарь. М., 1983.

*А.В.Костерин.*

**ГИДРОГЕОЛО́ГИЯ** (*гидро*... һәм *геология*), *Җир асты сулары* турындагы фән; аларның составын, үзенчәлекләрен, килеп чыгышларын, таралу һәм хәрәкәт закончалыкларын, режимнары үзгәрүне, тау токымнары б-н үзара бәйлелекләрен һәм аларда очрый торган файдалы казылмаларны өйрәнә; геологиянең бер бүлеге. Аның минералогия, *петрография*, *литология*, динамик геология, *геофизика* (гидрогеотермия), *геохимия* (гидрогеохимия), *инженерлык геологиясе* һ.б. тармакларына һәм, ш.у. география (климатология, метеорология, гидрография һ.б.), *гидрология*, *биология*, *экология*, тау эшләре (шахта һәм рудник Г. се) һ.б. фәннәр б-н бәйле. Җир асты сулары турындагы беренче мәгълүматлар борынгы заманнардан ук билгеле: б.э.к. 1700 елда Каһирәдә 100 *м* чамасы тирәнлектә кое казыла, б.э.к. 1200 дә Палестинада су өчен туннель казу эшләрен башлыйлар һ.б. Татарстан терр-ясендә беренче гидротехник корылмалар борынгы Биләрдә төзелгән була, ә Болгарда яндырылган балчыктан ясалган торбалар табыла. 1874 тә Пановка (Биектау р-ны) чишмәләреннән суны Казанга җибәрүче сүүткәргеч ачыла. 20 йөз башында Әки, Царицыно һ.б. авыллар янында су скважиналары бораулана, 1908 дә Иж минераль суларының шифалы булуы ачыклана (П.Л.Драверт). 1912 дә, ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатыннан, Казанга төрле чыганаклардан тәүлегенә 350–400 мең чиләк су бирелә. Революция алдыннан Казан губернасында 17 ел дәверендә Спас, Лаеш һәм Чистай өязләрендә 30 лап су скважинасы, 1920–40 елларда елына 40 лап, 1950 елларда — 140 скважина бораулана. 20 йөз ахырында ТР пр-тиеләренә һәм халыкка бирелгән җир асты һәм җир өсте чыганаклары суларының күләме 600–670 мең $м^3$ тәшкил итә.

ТР терр-ясендә җир асты суларын 1860 нчы еллардан Казан ун-ты галимнәре (Н.А.Головкинский, А.А.Штукенберг, А.В.Нечаев, П.И.Кротов, М.Э.Ноинский һ.б.) өйрәнә. 1920 елларда гидрогеологик мәйданнарны планга төшерү (В.А.Чердынцев, А.Н.Розенов һ.б.), минераль суларны тикшерү (П.Л.Драверт, А.А.Аносов, М.Г.Солодухо һ.б.), Идел һәм Кама елгаларында ГЭСлар проектлауга бәйле булган гидрогеол. эзләнү (В.В.Батыр, А.В.Миртова, С.Г.Каштанов, Е.Ф.Станкевич, М.С.Кавиев, Н.Н.Нелидов, М.Н.Соколов һ.б.) эшләре алып барыла. П.Л.Шатилов тарафыннан Татарстанның гидрогеол. картасы төзелә. В.А.Сулин, А.В.Ронов, А.И.Азизов, Е.И.Синявский, М.Е.Королёв, И.Х.Кавиев, К.Н.Доронкин һ.б. нефть проблемалары б-н шөгыльләнә. 1950 елларда Казан ун-тында, СССР ФАнең Казан филиалы Геология ин-тында, Татарстан нефть ин-тында, «Нефтегазоразведка», «Татколхозпроект», инженерлык-төзү эзләнүләре трестларында махсус гидрогеол. бүлекләр төзелә, «Промбурвод», «Татводоканал» трестлары, Казан гидрогеол. участогы һ.б. оештырыла. Нефть ятмаларыннан файдалану б-н

бәйләнгән күзәтү скважиналары челтәре төзелә, җир асты сулары запасын барлау үткәрелә, аларны пычранудан һәм бетүдән саклау буенча тикшеренүләр алып барыла; нефть һәм битум чыганакларындагы җир асты суларының составы һәм үзгәрүе өйрәнелә; җир асты суларын табу буенча эзләнү эшләре алып барыла; 1989 елдан җир асты суларын мониторинглау оештырыла. ТРның 1:500000 һәм Казанның 1:50000 масштаблы гидрогеол. карталары һәм су кадастры төзелә; Казан ун-ты хезмәткәрләре (С.Г.Каштанов, Н.Н.Нелидов, М.Н.Соколов, О.Н.Малышева һ.б.), «Татарстангеология» (Т.С.Васильев, Н.В.Полякова һ.б.), Татар. геол.-разведка идарәсе (Ю.П.Бубнов, О.В.Кузнецов, В.М.Федотов һ.б.), ТатНИПИнефть (Б.В.Анисимов, В.Г.Герасимов, К.Н.Доронкин, А.С.Пухов һ.б.), ЦНИИгеолнеруд (Е.Ф.Станкевич, Ю.В.Баталин, Б.С.Касыймов һ.б.), «Казводхоз», «Татбурвод», «Татгидропроект», «Таткурорт» һ.б. тарафыннан экол.-гидрогеол. планга төшерү эшләре башкарыла. ЦНИИгеолнеруд галимнәре 1990 елларда Чернобыль АЭСы р-нында махсус гидрогеол. эзләнүләр үткәрә һәм (А.И.Азизов, В.А.Копейкин, В.М.Федотов) дәүләт бүләкләренә лаек була.

*Әд.:* Подземные воды Татарии. К., 1987.

*М.Е.Королёв, В.М.Федотов.*

**ГИДРОГРА́ФИК ЧЕЛТӘ́Р**, нинди дә булса терр-ядә табигый рәвештә барлыкка килгән (*елгалар, күлләр, сазлыклар*) һәм ясалма (*сусаклагычлар, буа,* каналлар) агымсулар, сулыклар җыелмасы. Г.ч. киңрәк мәгънәдә даими су агымы булмаган вакытлы су юлларын да (*сыза, ерым* һ.б.) үз эченә ала. Абсолют күрсәткечләр — елгалар челтәре озынлыгы, күл, сазлык һ.б. су объектларының мәйданы һәм чагыштырмача күрсәткечләр — елга, сыза, ерым һәм, гомумән, су юллары челтәренең тыгызлыгы коэффициенты (терр-я мәйданы берәмлегенә туры килгән челтәр озынлыгы б-н белдерелә, *км/км²*), күлләнү, сазлыклану коэффициенты (бу объектлар мәйданының терр-ягә карата нисбәте, % ларда) б-н билгеләнә. ТРда су юлы челтәренең гомуми озынлыгы якынча 80 мең *км*, ягъни тыгызлык коэффициенты уртача 1,3 *км/км²* тәшкил итә. 3 мең елганы үз эченә алган елгалар челтәренә шуның 1/3 енә якыны (тыгызлык коэффициенты 0,46 *км/км²*) туры килә. Вакытлы Г.ч. Көнбатыш Кама алдында һәм Идел алды терр-яләрендә киң таралган, биредә тыгызлык коэффициенты 1 *км/км²* дан артык. ТРда иң сирәк Г.ч. Көнбатыш Кама арьягының коры һәм тигез урыннарында (тыгызлык коэффициенты уртача 0,99 *км/км²*), иң куе челтәре — нык дымлы Көнчыгыш Кама алды терр-ясендә (1,37 *км/км²*). ТР эчендә сусаклагычларның гомуми мәйданы — 7230 *км²*, буалар — 200 *км²* дан кимрәк, күлләр — 60 *км²*, сазлыклар — 285 *км²*. Күл һәм сазлыкларның төп өлеше Агыйдел, Вятка, Зөя, Ык һ.б. елгаларның үзәннәренә туры килә. Елгаларның су өслегеn (400 *км²* тирәсе) исәпкә алып, ТРда даими су объектларына барлык мәйданның 8% ы, ягъни 5,2 мең *км²* ка якын мәйдан туры килә. Зур сусаклагычлардан (Куйбышев һәм Түбән Кама) кала, даими Г.ч.нең төп өлешен кечкенә су объектлары тәшкил итә: барлык елгаларның уртача озынлыгы 10 *км* тирәсе (транзит елгаларны исәпләмәгәндә 4–5 *км* гына), күлләрнең уртача мәйданы — 1 *га* дан ким, сазлыкларныкы — 4 *га*, буаларныкы — 10 *га* тирәсе.

*Әд.:* Материалы по длинам малых рек Среднего Поволжья // Тр. КФАН СССР. Сер. энергетики и вод. хоз-ва. 1959. Вып. 2; Площади водосборных бассейнов и плотность речной сети малых рек Среднего Поволжья // Тр. КФАН СССР. Сер. энергетики и вод. хоз-ва. 1960. Вып. 5; Петров Г.Н. К вопросу об определении термина «гидрографическая сеть» и изображении её элементов на картах // Изв. КФАН СССР. 1961. Вып. 3а; Ресурсы поверхностных вод СССР. Л., 1971. Т. 12, вып. 1; 1973. Т. 11; Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976; Мингазова Н.М., Котов Ю.С. Казанские озёра (исторический обзор). К., 1989.

*В.И.Мозжерин.*

**ГИДРОЛО́ГИК РЕЖИ́М**, су объектлары халәтенең вакытка бәйле рәвештә закончалыклы үзгәрешләре. Су биеклеге һәм су чыгымының күпьеллык, сезонлы һәм көндәлек үзгәрешләрендә, суның темп-расында, боз халәтендә, суда эрегән, йөзмә һәм иярмә матдәләрнең күләмендә һәм составында, елгалар юлының үзгәрүендә, сусаклагыч ярларының яңадан формалашуында һ.б. күренешләрдә чагыла. Табигый (климат, рельеф, тау токымнары, үсемлекләр, су җыю мәйданнары) һәм ясалма (су җыю һәм агызу, су җыюның ландшафты үзгәрү, мелиорация, суның пычрануы һ.б.) сәбәпләр б-н билгеләнә. Төрле су объектларының Г.р.ы, бер үк факторларга бәйле булуга карамастан, бертөрле түгел, шунлыктан елга, күл, сусаклагыч, буа, сазлык режимнары аерып өйрәнелә. Төрле күрсәткечләр тезмәсеннән чыгып, Г.р. фазаларын билгелиләр. Мәс., ТР терр-ясендәге елгаларның еллык Г.р.ы өчен язгы су ташу, яңгыр сулары, җәйге-көзге һәм кышкы чорда суның кимүе, ә зур сусаклагычларда су биеклегенең язгы күтәрелеше, аның җәйге-көзге һәм кышкы тотрыклылыгы һәм кимүе (суның төшүе) фазалары хас. Г.р.ның һәрбер фазасы дәвамында күрсәткечләрнең төп өлеше үзара ярашып үзгәрә. Елгаларда язгы су биеклегенең күтәрелеше су чыгымнарының үсүе, болганчыклыкның артуы, эрегән матдәләрнең концентрациясе кимү һ.б. б-н бергә бара. ТР терр-ясендә Г.р.га зона өчен хас булган (ландшафтлы климат шартлары) һәм җирле факторлар йогынты ясый. Аерым фазаларның башлану һәм тәмамлану вакыты, су темп-расы, язгы су ташуның көче һ.б. күрсәткечләр гомумән алганда, ТР ландшафтының зональ төзелешен кабатлый, көньяк һәм көньяк-көнбатыштан төньяк һәм төньяк-көнчыгышка таба закончалык нигезендә үзгәрә бара. Әмма мондый зональ күренеш тау токымнары составы, карст үсеше, рельеф үзенчәлекләре, су җыюның хуҗалыклы үзләштерелүе (урманлык, сөрүлек һ.б.) кебек факторлар йогынтысында катлаулана, һәм бу йогынты бигрәк тә кечкенә елгаларда чагыла. Г.р. 1870 еллар уртасыннан эшләп килүче гидрологик постларда һәм станцияләрдә җентекләп өйрәнелә.

*Әд.: Гидрографик челтәр* мәкаләсендә бирелә.

*В.И.Мозжерин.*

**ГИДРОЛО́ГИЯ** (*гидро...* һәм *...логия*), табигатьтәге суларны, аларның үзенчәлекләрен һәм динамикасын өйрәнүче фән. Диңгезләр һәм океаннар (океанология) Г.сенә, коры җир Г.сенә (объектлары — елга, күл, сазлык, сусаклагыч, бозлыклар), ш.у. җир асты суларын өйрәнә торган *гидрогеологиягә* бүленә.

Татарстан терр-ясендәге зур елгаларны беренче мәртәбә гарәп сәяхәтчесе Ибне Фазлан тасвирлаган (10 йөз). 1870 елларда Россия Юллар министрлыгы тарафыннан, суднолар йөртү һәм сал агызуның гамәли мәсьәләләрен хәл итү өчен, Идел, Кама һәм Вяткада даими рәвештә гидрологик күзәтүләр (суның биеклеге, темп-расы, боз режимы һ.б.) оештырыла. РСФСРда Метереологик үзәк оешкач (1921), күзәтүләр программасы киңәя, кечкенә елгаларда да (Зөя, Үләмә, Казансу, Мишә, Чишмә, Кече һәм Олы Чирмешән, Зәй, Ык һ.б.) гидрологик постлар челтәре барлыкка килә. ТР терр-ясендә су объектлары режимына һәрдаим күзәтү эшен ТРның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы идарәсе алып бара, аның составында 2001 гә 31 гидрологик пост эшли, ш.и. 12 се — Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында, 19 ы — кечкенә елгаларда. Гидрологик күзәтүләрнең үсеше халык хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен (күперләр, буалар төзү, су б-н тәэмин итү, сугару һ.б.) елгалар һәм зур сусаклагычлар режимын алдан фаразлау зарурлыгы б-н бәйле. Күзәтү нәтиҗәләре һәрдаим белешмәлекләрдә басыла (еллык гидрометеорологик журналлар, СССР җир өсте сулары ресурслары, Дәүләт су кадастры һ.б.). 1960 еллардан СССР ФА Казан ф-лының Энергетика һәм су хуҗалыгы бүлеге тарафыннан Г.Н.Петров җитәкчелегендә Татарстандагы һәм барлык Урта Идел буендагы елгалар озынлыгын, сөзәклеген, борылмалыгын, бассейннарының мәйданын билгеләү буенча картометрик эшләр, елгаларның саегу чорында агым чикләренә экспедиция тикшеренүләре алып барыла. Әлеге бүлек, Казан ун-ты һәм күп кенә башка оешма хезмәткәрләре тарафыннан елгалар режимын билгели торган табигый һәм антропоген факторлар (Г.Н.Петров, Г.А.Аверьянова, Р.С.Петрова, Р.А.Сафиуллин, В.Г.Бурлаков, Ю.В.Бабанов һ.б.), батиметрия (тирәнлекне үлчәү) һәм күлләрнең хасил булу шартлары, алардагы суларның химик составы һәм үзлекләре (В.Н.Сементовский, В.В.Батыр, Б.В.Селивановский, А.В.Ступишин, Ә.С.Тайсин, Р.С.Петрова, Н.М.Минһаҗева, Ю.С.Котов), Куйбышев сусаклагычы ярларының режимы үзенчәлекләре һәм динамикасы (В.М.Широков, А.В.Ступишин), буаларның ләмләнүе (Г.Д.Кологреев, А.П.Двинских), сазлыклар барлыкка килү һәм таралу закончалыклары (В.И.Баранов, Р.Н.Апкин) өйрәнелә. Елга утырмаларының формалашу шартлары (А.П.Дедков, В.И.Мозжерин) җир өстендәге суларның җир астыннан туенуы һәм химизмы (Б.В.Селивановский, С.Г.Каштанов, В.И.Мозжерин, Ә.Н.Шәрифуллин), кечкенә елгалар һәм күлләрнең саегу һәм кибү үзенчәлекләре, аның сәбәпләре (Г.Н.Петров, С.Г.Корбанова, Ә.С.Тайсин) ачыклана. 1990

еллардан башлап гидрологик тикшеренүләрдә экологик юнәлеш әһәмиятле урын алып тора (ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-ты, Казан ун-ты һ.б.).

*Әд.:* Очерки по географии Татарии. К., 1957; Петров Г.Н. Меженный сток и его изучение. Методика исследований на примере малых рек Среднего Поволжья // Тр. КФАН СССР. Сер. энергетики и вод. хоз-ва. 1957. Вып. 1; Материалы по длинам рек Среднего Поволжья // Тр. КФАН СССР. Сер. энергетики и вод хоз-ва. 1959. Вып. 2; Площади водосборных бассейнов и плотность речной сети малых рек Среднего Поволжья // Изв. КФАН СССР. 1960. Вып. 5; Петрова Р.С. Водные ресурсы Татарии и их использование для орошения. К., 1975; Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976; Мингазова Н.М., Котов Ю.С. Казанские озёра (исторический обзор). К., 1989.

*А.П.Дедков, В.И.Мозжерин.*

**ГИДРОНИ́МИКА** (*гидро*... һәм грек. ὄnyma — исем), атамаларның килеп чыгышын һәм тарихи үзгәрешен өйрәнүче *топонимика* тармагы. Гидронимнар — елгалар, күлләр, сазлыклар, чишмәләр һ.б. сулыклар исемнәре. Гидронимнар системасы озын тарихи дәвер дәвамында формалаша һәм үзендә тел белеме, этнография, тарих, география һ.б. өлкәләргә караган мәгълүматларны (мәс., объектларның табигать һәм хуҗалык б-н бәйле билгеләре, алар янында булган вакыйгалар, объектларның хуҗалары турында һ.б.) туплый. Төзелешләре ягыннан гидронимнарның күпчелеге — ике составлы. Өч, дүрт составлы атамалар да очрый. Татар гидронимнарының күбесе «исем+исем» (Минһаҗ бабай чишмәсе) һәм «сыйфат+исем» (Түгәрәк күл) конструкцияләре б-н ясала. Борынгы һәм тотрыклы лингвистик материал буларак, гидронимнар тарихи тикшеренүләр өчен кыйммәтле чыганак булып торалар.

*Әд.:* Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимнары сүзлеге: 2 кит. К., 1991–92; Саттаров Г.Ф. Елгалар дөньясына сәяхәт. К., 1992; Гарипова Ф.Г. Исследования по гидронимии Татарстана. М., 1991; шул ук. Реки и озёра — отражение души. М., 1992; шул ук. Татарская гидронимия. К., 1998.

*Ф.Г.Гарипова.*

**ГИДРОТЕ́РМИК КОЭФФИЦИЕ́НТ** (ГТК), терр-ядә дымлылыкны билгеләүнең читләтелгән күрсәткече, вегетация чорында үсемлекләрнең дым б-н тәэмин ителешен чагылдыра. Климат белгече Г.Т.Селянинов тарафыннан тәкъдим ителгән. Уртача тәүлеклек темп-ра 10°С тан югары булган вакыттагы явым-төшемнәр суммасы (r, *мм* ларда) белән шул ук вакыттагы темп-ралар суммасының (t) 10 тапкыр кечерәйтелгән нисбәте буларак билгеләнә, ягъни ГТК= r/0,1 t. ГТКның 1 гә тигез булган кыйммәте дым һәм җылылыкның килешенүен аңлата. ТР терр-ясендә май-сентябрь айларында Г.к. 0,4 тән алып (коры елларда) 1,9 га кадәр (дымлы елларда) үзгәрә һәм Көнбатыш Кама аръягында уртача 0,9, төньяк-көнбатыш, көньяк-көнчыгышта 1,1 була. А.х. культураларының дым б-н тәэмин ителеше зоналарын билгеләүдә климатка бәя бирү, уңдырышлылыкны планлаштыруда фәнни исәпләүләр өчен кулланалар.

*Әд.:* Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.

*Э.П.Наумов.*

**ГИДРОТЕ́ХНИК МЕЛИОРА́ЦИЯ**, а.х. җирләренең начар су режимын тамырдан яхшырту чаралары системасы. ТРда Г.м.нең төп төрләре — сугару, киптерү һәм суландыру; алар игенчелекнең табигый шартларын яхшырта һәм туфракның уңдырышлылыгын күтәрә. Г.м., туфракның су режимын көйләп, аның һава, җылылык, тозлылык һәм микробиологик режимына уңай тәэсир ясый, а.х. җитештерүенең тотрыклылыгын тәэмин итә, җир ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалануга мөмкинлек бирә.

Г.м. җирләрне үзләштерү һәм дөрес файдалану (чәчү әйләнеше, а.х. культураларын һәм аларның сортларын рациональ сайлау, аларны үстерүнең интенсив технологиясе) б-н бергә алып барыла. Г.м. табигатьтәге экологик тигезлекне бозарга тиеш түгел. Шуңа күрә, сугару туфракның су балансын, атмосфера явым-төшемнәрен һәм үсемлекләрнең суга ихтыяҗын исәпкә алып, катгый рәвештә фәнни нигездә уздырыла. Артык күп су сибү а.х. җирләренең сазлануына, туфракның физ.-химик характеристикасы һәм структурасы кискен начарлануга, тозлануга яисә, киресенчә, минераль элементлар юылуга китерә. Урман сазлыкларын киптерү туфракның су балансын боза, урман биогеоценозларының су режимын һәм урман су чыганакларын туендыруны начарайта. Урта Идел һәм Кама алдының түбәнге өлешендә зур сусаклагычлар төзелү су басуга, сазлануга, ТР терр-ясендә иң уңдырышлы һәм су баса торган җирләрне а.х. файдалануыннан чыгаруга, суларның механик һәм биологик пычрануына, аларның эчәргә яраклы сыйфатлары начараюга китерә. Сугару өчен табигый су чыганаклары булмаганда, Г.м. кечкенә елгалар һәм ерымнар челтәре җирлегендә ясалма сулыклар (сусаклагычлар) төзүне күздә тота. Шул максатта гидротехник корылмалар: сутоткычлар — буалар, дамбалар; сүүткәргечләр — каналлар, торбаүткәргечләр, улаклар, су алу, су җыю, су ташлау, су төшерү, су чыгару җайланмалары төзелә.

*Әд.:* Ерхов Н.С., Мисенев В.С., Ильин Н.И. Сельскохозяйственная мелиорация и водоснабжение. М., 1983.

*В.А.Наумов.*

**ГИ́ЛЕВ** Сергей Васильевич (1854 — 1933), җырчы (баритон), педагог, муз.-җәмәгать эшлеклесе. Мәскәү консерваториясенең чыгарылыш-диплом спектаклендә Евгений Онегин (шул исем. оп., П.Чайковский) партиясен беренче башкаручы (1879). Төрле опера труппаларында солист буларак чыгыш ясый. Хорлар оештыручы һәм җитәкчесе, җыр капелласы б-н Россия шәһәрләрендә концертлар күрсәтә. 1884 елда Казанда җыр дәресе класслары ача һәм 10 елга якын шунда укыта, муз.-агарту эшчәнлеге алып бара. Г. укучылары көче б-н әзерләгән спектакльләр арасында Ф.И.Шаляпин беренче тапкыр опера партиясен җырлаган «Евгений Онегин» спектакле аеруча игътибарга лаек. 1925 тән Рязань музыка-пед. уч-щесендә укыта. Читтән торып вокалга өйрәнүчеләр өчен «Җыр дәресе укыту тәҗрибәсе һәм тавыш кую» («Опыт заочного преподавания пения и постановки голоса». СПб, 1910) исемле методик кулланма һәм вокаль әсәрләр авторы.

**ГИЛЬДЕ́ЕВО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 18 *км* көнбатыштарак, Нокса елгасы буенда. 2008 елда 58 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. 1646 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, яшелчәчелек, май язу, утын чаналары ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да земство мәктәбе (1890 еллар башында ачыла), 3 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2296 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл районында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 140 ир-ат; 1859 да — 503, 1897 дә — 822, 1926 да — 1040, 1949 да — 405, 1958 дә — 328, 1970 тә — 241, 1979 да — 164, 1989 да — 111, 2002 дә — 67 кеше.

**ГИ́ММЕЛЬ** Иван Михайлович (20.2.1871, Самара губ — ?), гистолог, мед. д-ры (1900), проф. (1916). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук эшли, тире һәм венерик авырулар кафедрасында гистология курсы приват-доценты. Бер үк вакытта Александров хастаханәсе табибе. 1911 елдан Харьков ун-тында тире һәм сифилитик авырулар турындагы системалы һәм клиника тәгълиматы кафедрасында эшли. 1912 дән Дерматовенерологлар җәмгыяте әгъзасы. Хезмәтләре туберкулёзның тире туберкулёзы б-н үзара бәйләнешен өйрәнү мәсьәләләренә, гомуми гонококк йогышлы авыру вакытында паренхиматоз органнар үзгәрешен өйрәнүгә, биология һәм медицинада радийны файдалануга багышланган.

*Әд.:* Харьковский государственный университет за 150 лет. Хар., 1955; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 1.

**ГИММЕЛЬФА́РБ** Аркадий Лейзерович (30.5.1926, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1982), ТРның атказ. уйлап табучысы (1995). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1955). 1944–49 елларда Совет Армиясе сафларында, 1955–60 та Лениногорск, Сталинск (Кемерово өлкәсе) шәһәрләрендәге мед. учреждениеләрендә эшли. 1960 тан ТР ФАнең «Травматология һәм ортопедик савыктыру» фәнни-тикшеренү үзәгендә, 1981–87 дә патент-мәгълүмат бүлеге мөдире, 1987 дән баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре эре буыннар патологиясенә, дегенератив-дистрофик авыруларга карый. Артрозлар деформациясенең авыр стадияләрендә биомеханика мәсьәләләрен тикшерә. Г. тарафыннан бу авырулар патогенезының нейроваскуляр-биохимик теориясе төзелә, организмның табигый хәленә кайту механизмнары ачыклана (1971–88). 1969–84 тә Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү ин-ты һәм мед. инструментлары з-ды галим-

нәре (В.Б.Абраров, Л.М.Баканов) б-н бергәләп күп кенә мед. инструментлары эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табылган әйберләре халыкара күргәзмәләрдә, СССР ВДНХсында (1974, 1979, 1981, 1986) күрсәтелә, эшләнмәләре көмеш, бронза медальләргә лаек була. Уйлап табуга 90 авторлык таныклыгы бар. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, Икътисади ярдәмләшү илләрендә мед. техникасын үстерү буенча Координация үзәгенең Мактау дипломы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт применения конструкций из титановых сплавов в ортопедотравматологической клинике // Медицинская техника. 1979. № 6 (автордаш); Коксартроз, хирургическое лечение ортопедических заболеваний у детей // Тр. Казан. науч-иссл. ин-та травматологии и ортопедии. 1986. Т. 34.

**ГИМНА́ЗИЯ БАСМАХАНӘСЕ́**, к. *Азия басмаханәсе*.

**ГИМНА́ЗИЯЛӘР** (грек. gymnásion), гомуми урта белем бирү уку йортлары; башлыча, Европа илләрендә 16 йөздән киң таралыш ала. Исеме аксөякләр гаиләсеннән чыккан яшүсмерләр өчен борынгы грек уку йортларыннан алына. Г. өчен 15–16 йөзләрдәге латин мәктәпләре үрнәк итеп алына, аларда яшьләрне университетларга керү өчен әзерлиләр. Латин мәктәбе нигезендә оештырылган Г.дә борынгы телләрне (латин һәм грек) өйрәнүгә дә зур игътибар бирелә. Беренче гимназия 1538 елда Швециядә ачыла; 19 йөздә Г. Европа дәүләтләренең күп өлешендә киң тарала. Тулы булмаган курслы уку йортлары (беренче 4 классны Г.) прогимназия исемендә йөри.

Россиядә беренче Г. 18 йөздә ачыла башлый — С.-Петербургта акад. гимназия (1726), Мәскәүдә ун-т гимназиясе (1755), Казан гимназиясе (1758) (к. *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе*) оештырыла. Г. эшчәнлеге «Университетлар ведомствосындагы уку йортлары уставы» (1804, 1828) һәм «Гимназияләр һәм прогимназияләр уставы» (1864, 1871, 1887) нигезендә алып барыла. 1804 елдан Г. барлык губерналарда һәм берничә өяз шәһәрендә ачыла башлый. Европадагы Г. кебек, аларда да укучыларны университетка әзерлиләр. Укыту бердәм укыту планы буенча алып барыла, элиталы, академик һәм гуманитар юнәлештә булуы б-н аерылып тора. Уку фәннәре исемлегенә борынгы һәм яңа телләр, география, мифология элементлары б-н гомуми тарих һәм Ватан тарихы, алгебра, геометрия, статистика, табигый тарих, Илаһи канун, Изге тарих һәм чиркәү тарихы кебек фәннәр кертелгән. Уку вакыты 1804 елдан — 4 ел, 1828 дән — 7, 1871 дән — 8 ел. 1860 еллардан, аерым типтагы урта мәктәп буларак, кыз балалар гимназияләре таралыш ала (к. *Кыз балалар гимназияләре*).

1871 дән Г. белем бирүнең классик системалы уку йортларына әверелә, алардагы төп уку фәннәре — борынгы телләр һәм математика; Г. статусы буенча реаль училищеләрдән югарырак була. 20 йөз башында классик белем бирү системасы бетерелә, 1901 дән латин һәм грек телләрен укыту туктатыла. 1913 елда Россиядә 430 дан артык ир балалар гимназияләре эшли. Казан губернасы терр-ясендә 20 йөз башында 5 гимназия эшли (Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе, Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе (1835), Казандагы Өченче Г. (1871), Чистай гимназиясе (1908), Тәтеш гимназиясе (1912).

1918 елда Г. уку йорты төре буларак бетерелә. 1990 елдан РСФСР Мәгариф министрлыгының «Гимназияләр турындагы карар»ы нигезендә яңадан оештырыла башлыйлар. Г. статусы хәзерге законнарда һәм педагогикада ахыргача билгеләнеп бетмәгән, һәм бу исем б-н аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнә торган гадәти гомуми белем бирү мәктәпләре йөртелә. Алар арасында гуманитар, табигать-матем., икътисади, техник юнәлештәге Г. аерылып тора. Г. укыту, уку-укыту процессын оештыруда төрле вариантлылык б-н дә аерыла: сыйныф-дәрес системасы өлешчә курс эшләре б-н алыштырыла, сайлап өйрәнелә торган фәннәрнең саны арта, индивидуаль һәм башка төр укыту формалары таралыш ала. 2009 елда ТРда 95 гимназия, ш.и. 28 татар, 14 рус-татар гимназиясе эшли.

*Әд.:* А л е ш и н ц е в И.А. История гимназического образования в России (XVIII и XIX вв.). СПб., 1912; Г а н е л и н Ш.И. Очерки истории средней школы в России во 2-ой пол. XIX в. Гимназии и реальные училища с конца XIX в. до Февральской революции 1917. М., 1956; Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001; Я л а л о в Ф.Г. Национальные гимназии России: методологический аспект. М., 2001.

*Р.Р.Исхакова.*

**ГИМНА́СТИКА**, спорт төре, ирләр өчен — иркле күнегүләрне, таянып сикерүне, снарядларда (аркылы борыс, параллель борыслар, бөҗра, ат; хатын-кызлар өчен — төрле биеклектәге борыслар, бүрәнә) күнегүләр ясауны үз эченә ала. Хәзерге гимнастика буенча күп төрле ярышлар программасына мәҗбүри һәм иркле программалар керә. Мәҗбүри программа Халыкара гимнастика федерациясе тарафыннан билгеләнә (1881 дә оештырыла), иркле программа спортчылар тарафыннан аларның авырлыгы һәм композициясенә рәсми таләпләрне исәпкә алып төзелә. Ярыш күнегүләрен башкару 10 баллы система буенча бәяләнә. Татарстанда Г. 1918 елдан «Маккаби», «Сокол» (1 хатын-кызлар, 2 ирләр), «Единение», «Санитас» һ.б. спорт җәмгыятьләрендә үсеш ала, алар аерым гимнастика төрләре буенча күргәзмә массакүләм гимнастик чыгышлар һәм ярышлар оештыралар (иркле күнегүләр, аркылы борыс, борысларда күнегүләр, сикерү һ.б.). Заманча спорт төре буларак 1928 дән Шәрекъ пед., Казан химия һәм Казан мед. ин-тларының физкультура клубларында, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, ш.у. Үзәк физкультура сараенда үсеш кичерә. Иң яхшы гимнастлар — 1920–30 елларда Казан һәм ТАССР чемпионнары — Н.А.Усов, Б.Л.Цвей, Б.Г.Мельников, И. һәм Г.Бродовскийлар, Г.Оранская, Малышева, Закутаев, Белогривова, М.Шангина, А.М.Липатов. Казан Иркле (балалар) спорт мәктәбе (1937 дә нигезләнә) гимнастларының җыелма командасы — РСФСР беренчелеге чемпионы, СССР беренчелегендә бронза приз алучы (1937). Г. «Динамо» физкультура — спорт җәмгыятендә, Казан югары уку йортларында (химия-технол., пед., авиация, мед. ин-тларында), «Буревестник», «Зенит», «Труд», «Спартак» (1940 еллардан) иркле спорт җәмгыятьләрендә үсеш ала. Г. Казан шәһәрендә, Яшел Үзән, Бөгелмә, Чистай, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә киң тарала. Иң яхшы гимнастлар — ТАССР, РСФСР, СССР беренчелекләрендә (ш.и. яшүсмерләр беренчелегендә), РСФСР халыклары, РСФСР Мәгариф министрлыгы спартакиадаларында, Бөтенсоюз һәм Бөтендөнья яшүсмерләр уеннарында, халыкара турнирларда медаль алучылар һәм чемпионнар — В.Т.Анисимов, Н.М.Белоглазова, Ф.В.Вәлиев, С.С.Галиев, Р.Х.Зарипов, О.П.Захаров, К.И.Канеев, А.Ш.Капрельянц, В.Ф.Логинов, Г.Магазова, И.Н.Мирсәлимов, В.Морозова, Л.П.Некраш, Р.Б.Сәгъдиев, Г.И.Сәйфуллина, Э.Сәлахетдинова, М.Р.*Сафин*, В.М.Смолевский, А.Фёдорова (1940–60 елларда); Р.К.Бикмөхәммәтов, К.Ф.Закиров, Л.А.Лопатин, В.Сафронов, К.Спиридонов, С.Шустраков (1970–80 елларда); Л.М.Габдрахманова, Э.Г.Гыйләҗиев, Е.Карасёв, С.Кисмятулова, А.Н.*Колесникова*, И.К.Кучерова, М.В.Лоскутов, М.А.Мещерякова, Р.Г.Нигъмәтҗанов, Р.Р.Низаметдинов, А.Сидоров, О.И.Титов, В.Тураев (1990 еллар). Иң яхшы тренерлар — Т.А.Агалина, А.К.Артамонов, С.С.Галиев, С.И.Исаев, А.П.Кашин, В.И.Коган, Г.И.Козлов, Р.К.Садыйков, М.Р.Сафин, Н.Д.Селезнёв, Э.М.Шаһиәхмәтов, Б.И.*Якубчик*. Халыкара категорияле судьялар — О.П.Захарова, Н.А.Рәимова.

**ГИ́НДИЧ** Василий Иванович (28.4.1915, Волынь губ., Новоград-Волынск өязе, хәзерге Украина Респ-касы Житомир өлкәсенең Мирополь ш. — 9.12.2006, Казан), химик-технолог, ике тапкыр СССР Дәүләт бүләге лауреаты. Киев индустриаль (хәзерге политехника) ин-тын тәмамлый (1941). 1942–47 елларда Пермь оборона пр-тиесендә; 1947 елдан Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында: 1957 дән лаб. башлыгы, 1967 дән баш инженер, 1975–77 дә бүлек башлыгы, 1985–2001 дә баш белгеч. Хезмәтләре пироксилин дарыларны җитештерү технологиясенә һәм аппаратлар б-н җиһазландыруга карый. Г. эре бөртекле дарылар җитештерүнең өзлексез технологиясен эшли, шуның нигезендә бу тармак пр-тиеләре, пироксилин дарылар технологиясен сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәгә күтәреп, тамырдан реконструкцияләнә. Аннан соңгы хезмәтләре вак бөртекле һәм көпшәсыман дарылар җитештерүне механикалаштырырга, җитештерүнең куәтен үстерергә, сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирә. 1951 дә дарылар җитештерү технологиясен тамырдан яхшыртканы өчен һәм 1976 да химия технологияләре өлкәсендәге хезмәте өчен СССР Дәүләт бүләкләре бирелә. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технология и оборудование производства пироксилиновых порохов: В 2 ч. М., 1971–72; Производство нитратов целлюлоз. Технология и оборудование. М., 1984; Производство порохов. К., 1995.

**ГИ́НЗБУРГ** Борис Соломонович (28.3.1895, Ингулец колониясе, Украина — 3.6.1974, Казан), санитария табибе, сәламәтлек саклау эшлеклесе, мед. фән. д-ры (1940), проф. (1940). Херсон земство фельдшерлык мәктәбен (1916), Саратов ун-тын (1921) тәмамлый. 1937 елга кадәр Саратов, Томск шәһәрләренең төрле мед. учреждениеләрендә эшли. 1935–37 елларда Үзәк ГИДУВ (Мәскәү) директоры урынбасары, 1937 дән директоры. 1938–40 та ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары. 1940–41, 1945–52 дә Казан ГИДУВының сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире. 1953–56 да Татарстан мед. учреждениеләрендә. 1956–58 дә Чита мед. ин-тында сәламәтлек саклау курслары мөдире. Хезмәтләре аналар һәм балаларны саклауга, яшь балаларның үлем-китем мәсьәләләренә, халыкка дәвалау-профилактика ярдәмен оештыруга карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Заразные болезни и как с ними бороться. М., 1925; Экспериментальные исследования и клинические наблюдения по вопросу о переходе антирахитического фактора от матери к ребёнку. К., 1940.

**ГИ́НЗБУРГ** Евгения Соломоновна (7.10.1903, Мәскәү — 25.5.1977, шунда ук), язучы, тәрҗемәче. Язучы В.П.*Аксёновның* әнисе. Казанда 1909 елдан яши. Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый (1924), 1925–30 да шунда ук, 1933 кә кадәр М.Вахитов исем. 1 нче номерлы шәм-стеарин, сабын кайнату химия з-ды каршындагы ВТУЗда, 1935 кә кадәр Казан ун-тында (1934–35 елларда ленинизм тарихы каф. мөдире) укыта. 1934–35 тә «Красная Татария» г-тасында языша, 1937 гә кадәр ТАССР Язучылар берлегенең рус бүлеген җитәкли, актив рәвештә әдәби тәнкыйть һәм тәрҗемә белән шөгыльләнә. Рус теленә Г.Тукай, Галим Мөхәммәтшин, Ә.Ерикәй, М.Садри һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итә. 1937 дә репрессияләнә (контрреволюцион троцкийчылар түгәрәгендә катнашуда гаепләнә), 18 ел Колыма лагерьларында һәм сөргендә уздыра. 1955 тә аклана. «Текә юллар» («Крутой маршрут»; 1 кис. 1967; СССРда 1988–90 да басыла) китабында золымга каршы тора алган кеше рухының көче чагыла.

*Әд.:* Б ы к о в В. Предисловие // Гинзбург Е. Крутой маршрут. М., 1990; А к с ё н о в П.В. Последняя вера // Казань. 1993. № 1; 1994. № 5–8; 1995. № 1, 2, 5–10; 1996. № 1–4, 7, 8; 1997. № 1–6, 11, 12.

**ГИ́НЦБУРГ** Александр Григорьевич (4.1.1898, Вильно ш. — 23.10.1918), Гражданнар сугышында катнашучы. Казан ун-ты мед. ф-тының 1 нче курсын тәмамлаганнан соң, юридик ф-тка күчә. 1917 елгы Фев. рев-циясе вакыйгаларында актив катнаша, Эшче, крәстиян һәм солдат депутатларының Казан советына сайлана һәм армияне тәэмин итү буенча эшче секция рәисе урынбасары, бюро рәисе итеп билгеләнә. Окт. рев-циясеннән соң ревком әгъзасы, Казан губернасы хезмәт комиссары урынбасары һәм социаль тәэминат комиссары. Казан җыелма гаскәри отрядында хәрби-сәяси комиссар, 1918 нең маеннан Чех-словак корпусына, атаман А.И.Дутов һәм инглиз генералы Маллесон гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша. 1918 нең 28 августында авыр яралана, әсирлеккә эләгә, соңрак атып үтерелә. Аның исеме Казан җыелма полкына бирелә.


А.Г. Гинцбург.

*Әд.:* Е р а п о л о в К. Гинцбург Александр Григорьевич // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*К.Ф.Ераполов.*

**ГИППЕА́СТРУМ**, а м а р и л л и с (Hippeastrum), амариллисчалар семьялыгыннан суганчалы күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 75 ләп төре билгеле. Чыгышы — Көньяк Америка субтропиклары һәм тропиклары. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Аеруча киң таралган төрләре: буй-буй Г. (H. vittatum), Эванс Г. (H. evansicae), сарай Г. (H. aulicum), челтәрсыман Г. (H. reticulatum). Яфраклары куе яшел төстә, кыяклы, каешсыман, тыгыз, аскы ягы кильсыман булып тора. Чәчәкләре эре, бүрәнкәсыман яки кыңгыраусыман, төрле төстә (тонык алсу төстән алып куе кызылга кадәр), хуш исле, кайвакыт чуар, нечкә сызыклары һәм кечкенә тимгелләре була (1 *м* га кадәр) яфраксыз озын чәчәк сапларында икешәр-алтышарлап чатырга җыелган. Җимеше — җиңел ачыла торган коры тартмачык, орлыклары җиңел, тыгыз. Кечкенә суганча һәм орлыктан (селекция эшләре уздырганда) үрчетелә. Чәчәк атуын 2–3 ел көтәргә кирәк. Срокларны җайга салганда, Г.ны 15–20 ел дәвамында ел әйләнәсе чәчәк аттырырга мөмкин. Суганчасы яхшы үскән Г. елына ике мәртәбә чәчәк ата. Яктылык яратучан үсемлек.

**ГИПС** (грек. gýpsos — акбур, известь), 1) $CaSO_4 \cdot 2H_2O$, сульфатлар классындагы минерал; составында CaO (32,5%), балчык һәм органик матдәләр катнашмасы, вак ком бөртекләре һ.б. бар. Кристаллар (гадәттә, шакмак рәвешендә), кристалл друзалары, юка-кристаллик, бөртексыман (алебастр) һәм җепсел (селенит) агрегатлар рәвешендә очрый. Төсе ак, төссез, соры, көрән һ.б. Пыяласыман ялтырый, перламутрлы, ефәксыман. Катылыгы 1,5–2. Төрле юнәлештә катылыгы үзгәрүчән. Уалучан. Тыгызлыгы 2,3 *г/см³*. Эрү темп-расы 1450 °С. Суда аз эри, NaCl катнаш суда эрүчәнлеге 3,5 тапкыр арта. Төрләре: селенит (ай ташы, үтә күренмәле, параллель җепселле, ефәксыман шома), гипс шпаты (эре кристаллы), алебастр (кар кебек ак, вак бөртекле Г.), «Мария пыяласы» һ.б. Декоратив төрләренең чыганаклары Архангельск өлкәсендә, Уралда һ.б. терр-яләрдә бар. Вак-төяк әйберләр ясауда һәм оптикада (гипс шпаты) кулланыла. 2) Катламлы яисә массив рәвешендәге тау токымы; бөртексыман төзелешле, ак төстә, Г. минералларыннан тора. Кушылмаларына бәйле буларак, төсе дә төрлечә — аксыл-соры, саргылт, кызыл, кара һ.б. Икенче төре — балчык-гипс. Табигатьтә еш кына *ангидрит* б-н бергә очрый; хасил булуы, хим. составы һәм таралу шартлары буенча аңарга охшаш. Тозлак бассейннарда барлыкка килә. Гипсоангидрит токым ятмалары барлык геол. дәверләр утырмаларында да очрый. Дөньяда Г. запаслары (млрд. *т*) — 7, РФдә — 3,3 тән артык, АКШта — 1 чамасы, Канадада — 0,5. Җир йөзендә ел саен — 100–115, РФдә 3,3–9 млн. *т* Г. чыгарыла. ТР терр-ясендә Г. ятмалары киң таралган, ләкин зур тирәнлектә (100–200 *м*); бу Г.ны гамәли куллануны чикли. Запаслары, сәнәгый категория күзлегеннән караганда, 70 млн. *т* чамасы, фаразлау ресурслары — 110 млн. *т*. 20 йөз ахырында еллык табыш 70–420 млн. *т* тәшкил иткән. Г. чыгару 100 елдан артык дәвердә аның җир өстенә чыккан урыннарында алып барыла. ТРда Г.ның шактый зур запаслары бар; республиканың Көнбатыш өлешендә 6 чыганак билгеле: 4 се — Кама Тамагында, 2 се — Лаеш һәм берничәсе Баулы р-нында. Ике чыганак (*Кама Тамагы чыгана-*


1


2


3

1. Бал төсендәге гипс. Кама Тамагы посёлогы; 2-3. Җепселле гипс (селенит). Югары Ослан авылы.

*гы* һәм Сөйкедә 2 нче участок) — федераль һәм республика, өч чыганак (Сөйкедә 1 нче участок, Антоновка, Саескан тавы) — республика, берсе (Әсәй) җирле әһәмияткә ия. Г. Идел буе, Урал һәм РФнең башка цемент з-дларына, төзелеш материаллары комбинатларына һ.б. пр-тиеләргә җибәрелә. Табигый хәлдә — тышлагыч таш буларак һәм эшкәртелгән хәлдә (ешрак) — беркеткеч материаллар эшләү, төзелештә (алебастр), формалар, югары чыдамлыклы әйберләр ясау, гидравлик (эстрих-гипс), бакыр, гипс цементы эшләүдә кулланыла; а.х.нда — туфракны гипслау, ашлама буларак; химия сәнәгатендә — сульфат кислотасы, аммоний сульфаты, инсектицидлар, буяулар, пластмассалар алу өчен; металлургиядә (флюс); кәгазь һәм резинаны тыгызландыру, нәфис-декоратив әйберләр ясауда һ.б. файдаланыла.

*Әд.:* Сементовский Ю.В., Шишкин А.В. Минеральное сырьё. Гипс и ангидрит: Справ. М., 1998; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Минерально-сырьевые ресурсы Татарстана. К., 2006.

*Ю.В.Сементовский.*

**ГИ́РШМАН** Яков Моисеевич (25.9.1913, Чита ш. — 16.11.1990, Казан), музыка белгече, педагог, муз.-җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1984), проф. (1985). Мәскәү консерваториясенең тарих-теория ф-тын тәмамлый (1947). 1931–34 елларда Көнчыгыш Себер эшче яшьләр театрында музыка бүлеге мөдире (Иркутск ш.). 1948 дән Казан консерваториясендә укыта, музыка тарихы (1949–67), музыка тарихы һәм теориясе (1971–76), музыка белеме каф. мөдире (1987–88). Татар музыка культурасына багышланган хезмәтләр авторы. Г.ның фәнни эзләнү эшчәнлегендә Идел буе һәм Урал алды халыклары музыкасы тарихы һәм пентатоника проблемалары төп урынны алып тора. Муз. агарту эшчәнлеге алып бара (лекция-концертлар, радиодан чыгышлар һ.б.).

Хезм.: Салих Сайдашев. К., 1956; Пентатоника и её развитие в татарской музыке. К., 1960; Назиб Жиганов. М., 1975.

**ГИСТОЛО́ГИЯ** (грек. histós — тукыма һәм *...логия*), биол. фәне, күзәнәк биологиясе өлеше, морфология өлкәсе, кеше һәм хайваннар организмы тукымалары үсеше, төзелеше һәм функцияләрен өйрәнә. Г. цитология, физиология, эмбриология, молекуляр биология, биохимия һәм генетика б-н чиктәш фән. Гомуми Г. тукымалар, шәхси Г. (микроскопик анатомия) тукымалар һәм төрле системалар органнары, ш.у. авыру вакытында үзгәрүчән тукымаларның (гистопатология) төзелешен өйрәнә.

Тикшеренүләрнең мөһим ысуллары булып микроскопиянең яктылык һәм махсус типлары (караңгы өслекле, фазалы-контраст, поляризацияле, люминесцент, электрон, үтә күренмәле, кучермәле), биол. объектларны күзәтү (компьютерлы интерференция, конфокаль, рентген, ТМП-интроскопия, позитрон томография), гистохимия һәм иммуногистохимия ысуллары, цитофотометрия, радиоавтография санала.

Медицинада тукымаларны системалы өйрәнү 17 йөз уртасында, инглиз физигы Р.Гук тарафыннан микроскоп камилләштерелгәч (1665) башлана. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан М.Мальпиги, Н.Грю, А.Левенгук һ.б. хезмәтләре нәтиҗәсендә тукымалар структурасының беренче микроскопик тасвирламалары күренә башлый. 18 йөз ахырында хайваннар һәм үсемлекләр организмы тукымалары морфологиясен системалы тикшерү башлана. Г. фән буларак 19 йөздә формалаша. Чех табигыять фәннәре белгече Я.Пуркинье гистологик буяуларны (индиго һәм ачыклагычлар), күзәнәк төзелешенең яңа категорияләрен (төш, цитоплазма) гамәлгә кертә һәм күп кенә структураларны (кечкенә ми тышчасында ганглиоз күзәнәкләр, нейрон дендритлары, миокардта атипик кардиомиоцитлар, җемелдек эпителий) тасвирлый. Немец биологлары Т. Шванн, М.Шлейден күзәнәк теориясен (1838–39) төзиләр. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан тасвирый гистология үсеш ала (немец галимнәре А.Келликер һәм Ф.Лейдиг тукымалар классификациясен тәкъдим итәләр). 19 йөзнең 2 нче яртысында гамәли микроскопиягә сулы һәм майлы иммерсияле объективлар кертелә, микротом, яңа фиксаторлар (формалин, осмий һәм хром к-талары) кулланыла. Италия галиме К.Гольджи көмеш тозлары б-н импрегнация ысулын тәкъдим итә, бу исә нерв системасының барлык өлкәләренең диярлек күзәнәкләрен тасвирларга мөмкинлек бирә, әлеге ысул авторы мед. өлкәсендә Нобель бүләгенә лаек була (1906).

Россиядә Г. үсеше аны ун-тларның анатомия һәм физиология кафедраларында аерым курс итеп укыта башлау б-н бәйле. 1864 елда Мәскәү һәм Петербургта Г. кафедралары оештырыла. Казан ун-тының мед. ф-тында Г. нең фән буларак үсеше 1864 тә Г. курслары кертүдән башлана. Соңрак Г. кафедрасы (мөдире К.З.Кучин), аннары эмбриология, гистология һәм чагыштырма анатомия кафедрасы ачыла. Казан гистологларының тикшеренүләре К.А.*Арнштейн* һәм аның шәкертләре А.Е.Смирнов, А.С.Догель дәверендә зур танылу таба. Казанда немец биохимигы П.Эрлих тарафыннан исән кешенең нерв очларын метилен зәңгәр б-н буяу ысулы уңышлы кулланыла һәм бу ысул ярдәмендә төрле әгъзалар һәм тукымалар иннервациясе тикшерелә. Беренче тапкыр нерв очлыклары аппаратлары төзелеше фундаменталь эшләнелә, чәчтәге, тәм тою рецептор органындагы нерв очлыклары, ш.у. тире бизләре иннервациясе тасвирлана, күзнең мөгез тышчасы тикшерелә (К.А.Арнштейн, 1870–90 еллар). 19 йөзнең 2 нче яртысында миокард иннервациясе буенча эшләр башкарыла (Н.Лавдовский); үңәч һәм ашказаны эпителиенда нерв очлыклары, ашкайнату тракты тамырлары иннервациясе һәм бизләрнең секретор иннервациясе өйрәнелә (К.Гоняев); күзнең төсле катлавы, цилиар тән (А.Г.Геберг, А.Мейер, А.Агабабов һ.б.), күрү органнары иннервациясе һәм төзелеше, күзнең челтәр катлавы (А.П.Тепляшин), ишетү органнары (А.Сизов), сөт һәм простата бизләре (П.Дмитриевский) тасвирлана. Беренче тапкыр капсулалы механорецепторлардагы өстәмә нерв җепселе тасвирлана (Д.А.Тимофеев), сидек юлының өске өлешендә (А.С.Догель), бугазның тоташтыру тукымалары тышчасында (И.Ф.Иванов) һәм тукымалары (А.К.Плошко) нерв тәенләнешләре ачыклана һәм тасвирлана, интрамураль ганглиоз нерв күзәнәкләренең әһәмияте күрсәтелә (А.Н.Миславский). 20 йөздә нерв системасының вегетатив өлешендә һәм ашкайнату юлларында нерв тукымаларын (Б.И.Лаврентьев һ.б., 1920–30 еллар), эчке органнар иннервациясен (Г.И.Забусов һ.б., 1950 еллар), күзнең челтәр катлавы төзелешен (Н.А.Матвеева, 1950 еллар) өйрәнү; рецепторларны морфофункциональ һәм гистохимик тәзү һәм нейроннар реактивлыгы (Д.В.Бурнашева һ.б., 1970–90 еллар), скелет мускуллары иннервациясе һәм сыгылмалылыгы (Н.П.Резвяков һ.б., 1980–90 еллар) буенча эшләр дәвам иттерелә.

*Әд.:* Догель А.С. К вопросу о строении сетчатой оболочки у человека: Дис. ... К., 1883; Арнштейн К.А. Нервные окончания в роговице // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1889. Т. 20; шул ук. Концевые аппараты вкусового нерва // Неврологический вестн. 1893. Т. 1; Дмитриевский П. О нервах молочных желёз: Дис. ... К., 1894.

*Ю.А.Челышев.*

**ГЛАДИ́ЛОВ** Иван Яковлевич (29.8.1894, Казан губ., Зөя өязе Лобыжки а. — март 1920, Казан губ. Чистай өязе), рев-ция хәрәкәтендә катнашучы. Казандагы Алафузов пр-тиесе эшчесе. 1 нче Бөтендөнья сугышында катнаша. 1917 елдан РСДРП(б) әгъзасы, 1917 нең мартында РСДРП(б)ның Казан ком-ты әгъзасы итеп сайлана, апреленнән Казандагы Алафузов пр-тиеләрендә зав.-фаб. ком-тлары җитәкчесе. Елга аръягы Кызыл гвардиясен оештыручыларның берсе. Казанда окт. вакыйгаларында актив катнаша. 1917 нең октябреннән Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы әгъзасы. Паратск з-дында завод-фабрика ком-тын оештыра. 1918 нең җәендә Казанны ак чехлар гаскәреннән саклауны тәэмин итүчеләрнең берсе. 1918–20 елларда шәһәр советы депутаты, Алафузов пр-тиеләренең партия оешмалары җитәкчесе һәм шәһәрдәге иң зур — РКП(б)ның берләштерелгән Бистә райкомының (аңа Ягодный, Дары заводы, Бишбалта һәм Игумен р-ннары оешмалары керә) җаваплы оештыручысы. 1919 да Елга аръягы эшчеләренең ирекле полкы сәяси комиссары. 1920 дә Мамадыш һәм Чистай өязләрендә азык-төлек отряды комиссары вазифаларын башкарганда һәлак була.

*Р.А.Циунчук.*

**ГЛАДИО́ЛУС**, кылыч гөл (Gladiolus), сусынчалар семьялыгыннан күпьеллык эре суганчалы үсемлек ыругы, декоратив үсемлек. Туган ягы — Көньяк Америка. Якынча 180 төре билгеле. Культурада Г.ның гибрид төре (G.hubridus) киң таралган. Яфраклары туры, кылычсыман формада, эре (2–5 *см* киңлектә, 50–80 *см* озынлыкта), чәчәк төркеме зур (5–16 *см* диаметрлы һәм зуррак та), төрле формада һәм төстә, башаксыман 1 *м* озын-

лыкка кадәр җитә. Г.ның чәчәк төсе буенча 43 төс һәм төсмерле классификациясе эшләнгән. Г.ның җимеше — йомыркасыман элпәле тартмачык. Орлыклары түгәрәк яисә озынча түгәрәк, коңгырт төстә, еш кына канатчалы була. Г.ны өлгергән эре һәм яшь суганчалардан үрчетәләр, туфракка апрель, май башларында тиңдәшле рәвештә 8–12 һәм 4–6 *см* тирәнлектә утырталар. Оч бөреләре, сортларның үзенчәлегенә, туфрак темп-расына, утырту тирәнлегенә карап, 10 көннән 20 көнгә кадәр вакыт эчендә шытып чыга. Тамыр системасы тулысынча формалашсын өчен, туфракта иң яхшы темп-ра 10–15 °С. Г. утыртылган урынны торф һәм черемә б-н мүлчәлиләр. Беренче өстәмә тукландыруны, 1 *м²* җиргә 20 *г* мочевина һәм 25–30 *г* сернокислый калий исәбеннән, икенче яфрак ачыла башлаганда уздыралар. Кош тизәге эремәсе (1:20) б-н өстәмә тукландыру яхшы нәтиҗә бирә. Органик һәм минераль тукландыру һәр 10 көн саен уздырыла. Чәчәклекләрнең көчле үсеше башлангач, фосфор б-н калийның микъдары арттырыла: 1 *м²* җиргә 15–20 *г* мочевина, 60–70 *г* суперфосфат һәм 35–40 *г* калий тозы кертелә. Июль-август айларында (яшьләре 2–3 нче елда) чәчәк ата. Августның 2 нче яртысында азотлы ашламалар микъдары киметелә. Сентябрьдә суганчаларны казып алалар һәм, киптергәннән соң, темп-ра 4–5°С, һава дымлылыгы 70–80% булган, яхшы җилләтелә торган коры урында саклыйлар.

Г.да киң таралган гөмбә авырулары — фузариоз, бактериоз һәм септориоз. Суганчалар грунтта, ш.у. саклау урыннарында да зарарланырга мөмкин. Көрәш чаралары: агротехник чаралар; ел саен утырту урынын алыштыру; утырту материалларын фундазол, ТМТД, топсин, каптан (0,02%) эремәләрендә 30 *мин* яисә марганцовка (0,02%) эремәсендә 2 сәгать йогышсызландыру һәм вегетация чорында шушы препаратлар б-н Г. утыртылган участокны сугару; азотлы ашламаларны тиешле микъдарда кертү. Бактериозга каршы суганчаларны кайнар суда (53–55°С) 20 *мин* тотып, термик йогышсызландыру уздыралар, аннан соң салкын суга салына яисә марганцовка (0,05%) эремәсендә (30 *мин*) эшкәртелә.

Септориозга каршы көрәш фузариоз һәм бактериозныкы кебек уздырыла.

ТРда Г. теплица, чәчәк үстерү хуҗалыкларында («Декоратив культуралар» АҖ) һәм бакчачылык ширкәтләрендә үстерелә. Чәчәклекләрне формалаштыру, кирәк булганда кисеп алу һәм кышкы — язгы чорда өстәмә чәчәк аттыру өчен кулланалар.

*Әд.:* Энциклопедия цветовода. СПб., 2000.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ГЛАДКО́В** Сергей Николаевич (1.10.1902, Казан — 29.10.1969, шунда ук), спортчы, Татарстанда физик культура һәм спорт хәрәкәтен оештыручыларның берсе. Хезмәт иляренә физик белем бирү буенча баш хәрби мәктәпне (1923, Мәскәү), Казан пед. ин-тын (1951) тәмамлый. 1 нче кышкы Бөтентатар физик культура бәйрәмендә, 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында (1928) катнаша. 1923 елда Татарстан хәрби комиссариатында спорт һәм армиягәчә хәзерлек буенча өлкән инструктор; 1923–27 елларда Кызыл Армия команда составының Казан, Краснодар, Әзәрбайҗан мәктәпләрендә — физик культура; 1927–34 тә, 1936–41 дә, 1946–62 дә Казан пед. ин-тында физик тәрбия һәм спорт каф. укытучысы, 1931–62 дә каф. мөдире; бер үк вакытта, 1931–33 тә Казан физик культура техникумы директоры. 1934–36 да ТАССР ҮБК каршындагы Физик культура югары советының җаваплы секретаре, 1941–43 тә 17 нче запастагы пехота полкының (Казан) чаңгы буенча әзерлек инструкторы. 1943–44 тә Мәскәү хәрби округы штабы каршында физик әзерлек башлыгы ярдәмчесе. 1944–45 тә Татарстан хәрби комиссариатында гомуми хәрби өйрәтүләр бүлеге инструкторы, бер үк вакытта хәрби каф. башлыгы (1946–48), Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-ты деканы (1949–53, 1957), спорт гимнастикасы, җиңел атлетика, чаңгыда һәм тимераякта узышу спорты, бокс, фехтование, волейбол буенча ТАССР җыелма командалары тренеры, спорт судьяларын, спорт секцияләре җитәкчеләрен, физик культура укытучыларын әзерләү һәм яңадан әзерләү курслары инструкторы. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамоталары (1946, 1962) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Бобырев Н. С.Н.Гладков (хроникально-документальное исследование жизни и деятельности). К., 2002.

**ГЛА́ЗОВ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* төньягында урнашкан. Мәйданы — 2159,1 *км²*. Үзәге — Глазов шәһәре (Ижевскидан 180 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 18792 кеше (2002), ш.и. 432 татар. Башлыча, Кочишево (200 кеше), Татар Парҗысы (142) авылларында яши. Татар Парҗысы авылына 17 йөз ахырында нигез салына. 19 йөз уртасында Кистем авылы (хәзерге Удмурт Респ-касының Балезин р-ны) татарлары Кече Парҗы авылына (1976 елга кадәр яши) нигез сала. Халкы игенчелек һәм сәүдә б-н шөгыльләнә. Татар Парҗысы авылында 1906 дан — мәчет, 1930 еллардан 1970 еллар уртасына кадәр — татар мәктәбе, Кече Парҗы авылында 1905 тән 1968 гә кадәр мәчет эшли. Хәзерге вакытта Кочишево авылы мәктәбендә татар теле укытыла, «Илһам» балалар оешмасы эшли.

**ГЛА́ЗОВО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2008 елда 74 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. 1760 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәр Шешминка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында Г. да земство хастаханәсе, сәүдәгәр О.Е.Юрьинның су тегермәне, локомобиль була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 146 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сходнев волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нnарында. Халык саны: 1859 да — 276, 1889 да — 235, 1897 дә — 340, 1926 да — 543, 1938 дә — 543, 1949 да — 460, 1958 дә — 328, 1970 тә — 379, 1979 да — 265, 1989 да — 125, 2002 дә — 106 кеше.

*Әд.:* Шугур — край сокровищ = Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе. К., 1997.

**ГЛАУКОНИ́Т** (грек. glaukós — зәңгәрсу-яшел), гидрослюдалар төркемендәге минерал, Fe һәм Mg ның сулы алюмосиликаты, MgO — 45%, Fe — 35%, K — 9,5% ка кадәр. Күпшәк кремнийлы яисә балчыксыл карбонатлы токымнарда диаметры 0,1 дән алып берничә *мм* га кадәрле бөртекләр яисә шарчыклар. Төсе караңгы яшелдән яшькелт-карага кадәр. Тонык яки пыяласыман ялтыравыклы. Катылыгы 2–3. Уалучан. Тыгызлыгы 2,2–2,9 *г/см³*. Куертылган хлорид кислотасында таркала. Катион алмашу үзенчәлеге югары. Г. — типик диңгез минералы; коры җирнең түбән урыннарына якын һәм тыныч диңгез зоналарында утырма хасил булу процессының соңгы стадиясе буларак формалаша. Калын (20–30 *м* га кадәр, ТРда 4,3 *м* га кадәр) кварцглауконит комнары, комташлар, алевролитлар һәм фосфоритлар катламы хасил итә. Татарстан терр-ясендә диңгез төбенең утырма токымнарында таралган, мезозой һәм Казан ярусының барлык утырмаларында комташ һәм известьташлар катламында кушылмалар һәм линзалар рәвешендә очрый. Г. чыганаклары ачыкланмаган, шулай да Чүпрәле һәм Буа р-ннары терр-ясендә (өлешчә, *Сөендек фосфоритлар чыганагында* өскаплам токым) юра-акбур утырмаларында 10 лап ятмасы билгеле. Глауконит-кварц комнары һәм алевритларның фаразланган ресурслары 270 млн. *м³* чамасы. Буягыч оксидлар, К ның актив катионнары, катламлы төзелеше аркасында Г. сәнәгать өчен кыйммәтле чимал булып тора. Яшел буяу (фасад өчен җилемле, известьлы-цементлы һәм силикат буяулар) алуда, караңгы төстәге күләмле күзәнәкле бетон эшләүдә, силикат кирпеч (100 нче марка) сугуда, каты суларны йомшартуда, азык һәм туку сәнәгатьләрендә, җылылык электр станцияләрендә, суны һәм туфракны төрле зарарлы матдәләрдән (ш.и. радиоактив) чистарту, майларны ачык төскә кертү, нефть продуктларын чистартканда сорбент буларак, авыл хуҗалыгында үсемлек авыруларын киметү өчен ашлама буларак, бодай, бәрәңге, карабодай, шикәр чөгендере, кукуруз кебек культураларның уңышын арттыру, сулыкларның биопродуктлылыгын күтәрү, җиргә рекультивация ясау өчен кулланыла.

*Әд.:* Нетрадиционные виды нерудного минерального сырья. М., 1990; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Минерально-сырьевые ресурсы Татарстана. К., 2006.

**ГЛЕ́БОВ** Александр Николаевич (16.6.1947, Львов ш.), химик, химия фән. д-ры (1990), проф. (1992). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1975 тән — Чуаш, 1980 нән Казан ун-тларында, 1997 дән Казан техник ун-тында, гомуми химия һәм экология каф. мөдире (1999 дан). Хезмәтләре гетеровалентлы кушылмалар химиясенә, электролитларның су-



М.Н. Глебов.

дагы эремәләре физикохимиясенә, экологиягә карый. Органик лигандлы күчеш металларының гетеровалентлы комплексларын тикшерә, оксидлашу-кайтарылу реакцияләре өчен каталитик системалар эшли. Күчеш металлары комплекслары нигезендә эшләнгән яңа нәорганик гельләр тәкъдим итә. Тикшеренү нәтиҗәләре басма платалар ясау технологияләрендә, пластик массаларны металлаштыруда, нефть чыгару сәнәгатендә катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү өчен кулланыла. Медицина һәм экологиядә кулланыла торган үлчәү ысуллары һәм приборларын — кече габаритлы магнит резонанслы «Миниспинэхо» релаксометрын, кече габаритлы ротацион вискозиметрын (тамчылы), портатив pH-метр — иономерны эшли.

Х е з м.: Полиядерные комплексы в растворах. К., 1989 (автордаш); Химия гетеровалентных комплексов. К., 1989 (автордаш); Структурно-динамические свойства водных растворов электролитов // Соросовский образовательный журн. 1996. № 9; Магнитные наножидкости в энергосберегающих технологиях // Вестн. КГТУ им. А.Н.Туполева. 2008. № 3 (автордаш)..

**ГЛЕ́БОВ** Геннадий Александрович (26.11.1947, Калининград ш.), двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1972 елда Мәскәү югары техник уч-щесен һәм 1981 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1976 елдан Казан техник ун-тында, махсус двигательләр каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре газ динамикасына һәм җылылык физикасына карый. Двигательләрнең һәм энергия җайланмаларының агым юлындагы турбулент һәм агынтылы агымнарны фәнни тикшерә һәм тасвирлый. Уйлап табуга 34 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Халык мәгарифе һәм фән Дәүләт комитетының җылылык-массаалмашу өлкәсендәге бүләге иясе (1988).

Х е з м.: Турбулентные струйные течения в каналах. К., 1988 (автордаш); Термометрические методы исследования отрывных течений. К., 1990 (автордаш).

**ГЛЕ́БОВ** Михаил Никодимович (29.5.1912, хәзерге Воронеж өлкәсе, Верхнехавск р-ны Зур Приваловка а. — 15.8.1986, Казан), Соц. Хезмәт Герое (1971). Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техн. уч-щесен тәмамлый (1938). Хезмәт эшчәнлеген 1930 елда Владимир өлкәсенең Ковров шәһәрендә заводта слесарь булып башлый. 1940–41 елларда Мәскәү авиация з-дында эшли. 1941–73 тә Казан авиация җитештерү берләшмәсендә: мастер, цех башлыгы урынбасары, цех, производство башлыгы, баш механик, контролёр, технолог, баш инженер (1960 тан), директор (1967 дән). Аның җитәкчелегендә предприятие үзгәртеп корыла, техник яктан яңартыла, Ил-62 самолёты модернизацияләнә, Ил-62М проектлана һәм аны серияләп җитештерү үзләштерелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге иясе (1971). 1967–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГЛИ́НСКИЙ** Григорий Николаевич (20.1.1842 — 24.4.1884, Казан), химик-органик, химия д-ры (1877). 1867 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм шунда ук химия лаб-ясе музее саклаучысы, 1869 дан — фармацевтика лаб-ясе лаборанты, проф. (1877 дән). Хезмәтләре органик химиягә карый. Этилен төзелешен ачыклау максатыннан бромлы һәм хлорлы винилның гипохлорит кислотасы б-н реакциясен өйрәнә; бромлы винилга терекөмешнең уксус кислоталы оксиды тәэсирендә альдегид таба. Хлорлы этил һәм хлорлы этиленнарны хлорлау продуктларын үзе уйлап тапкан дефлегматор ярдәмендә чиста килеш аерып ала һәм тикшерә.

Х е з м.: О радикалах в органической химии. К., 1872; Новые исследования о продуктах охлорения хлористого этила и хлористого этилена и новые доказательства существования органических радикалов, у которых парное свободное средство принадлежит одному из углеродных атомов. К., 1876.

**ГЛИ́НСКИЙ** Михаил Васильевич (? — 1559, Мәскәү), кенәз, дәүләт эшлеклесе, полководец, бояр (1541 елга кадәр), конюший (1541–47). Әнисе ягыннан Иван IV нең агасы. 1543–47 елларда абыйсы Юрий б-н бергә чынлыкта Иван IV хөкүмәтен җитәкли. Мәскәүдә 1547 дәге күтәрелеш нәтиҗәсендә әнисе һәм абыйсы үлгәч, Г.ның йогынтысы бик тиз кими. 1552 дә Казанга яу б-н барганда төньяк-көнчыгыш тарафтан Кама буйлап төшүче гаскәрләр б-н идарә итә, Казанны алуда катнаша, шәһәрдән Казансу аръягына бәреп чыккан отрядны эзәрлекләүне җитәкли.


1553–55 тә Казанда 1 нче (баш) воевода. 1553 тән кенәз И.Мстиславский б-н бергә Болын ягындагы күтәрелешне бастыруга җитәкчелек итә; чынлыкта Казан сугышында (1552–56) гаскәрләр башында тора. Җирле аксөякләрне күпләп юк итүне, төп халыкны Казаннан кууны оештыра. 1556 да Ливониягә яу вакытында зур полкның 1 нче воеводасы, 1556–57 дә Новгородта наместник.

*Е.В.Липаков.*

**ГЛИ́ПТИКА** (грек. glýphō — кисәм), асылташларны, ярым асылташларны уеп бизәкләү сәнгате, татар гамәли бизәлеш сәнгатендә иң борынгы иҗат төрләренең берсе. Уеп киселгән асылташлар элек-электән бизәмәләр, бөтиләр ролен уйнаган, мөһер яисә тамга сыйфатында кулланылган. Рәсемне махсус кискеч б-н уйганнар, таш өслеген игәү б-н эшкәрткәннәр, аннары шомартып ялтыратканнар. Зәргәрчелек эшләнмәләрендәге ахак, фирәзә, яшма, гәрәбә, якут, халцедон, мәрҗән кабырчыгы һ.б. ташлы кашларда гарәп язуындагы Коръән гыйбарәләре, изге теләкләр, иясенең исеме, геометрик бизәк, үсемлек һәм җәнлек рәсеме рәвешендәге Г. кулланылган. 18 йөз — 20 йөз башында ясалма ташларда (күбрәк яндырылган балчык төсендә) Г. башкару таралыш ала. Силикатлар катнашмасын һ.б. кушылмаларны эретү юлы б-н алынган мастика, суынып, каты халәткә кергәннән соң тонык төс ала һәм структурасының йомшаклыгы б-н аерылып тора, бу исә рәсемне ачык һәм төгәл башкару мөмкинлеген бирә. Контрастлылыкны көчәйтү өчен татар зәргәрләре еш кына рәсем өстеннән сумалалы матдәләр нигезендә ясалган ак буяу йөгерткәннәр. Кайбер очракларда мастикага бизәк һәм язулар махсус калып ярдәмендә төше-







**Глиптика.** 1. Бизәү тәңкәсе. Көмеш, сердолик. Глиптика, җепкыр, алтын йөгертү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТРның Милли музее; 2. Бизәү тәңкәсе. Көмеш, сердолик, пыяла. Глиптика, җепкыр, алтын йөгертү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. Россия этнография музее (С.-Петербург); 3. Беләзек. Көмеш, фирәзә. Глиптика. 20 йөз башы. Россия этнография музее (С.-Петербург).

релгән. Татар осталары тарафыннан Г. ир-ат һәм хатын-кыз йөзекләренең асылташ кашларын, аеллар, *хаситә, чулпы, яка чылбыры, изү, Коръән тартмачыклары* бизәүдә кулланылган.Ияләренең исеме яисә тамгасы уелган йөзекләр, урта гасырлардан алып, мөһер буларак йөргән. Безнең көннәргә кадәр сакланган Г. үрнәкләренең иң борынгысы — болгар йөзегенең гарәбә кашы яисә асылмалы мөһер — 10–12 йөзләргә карый. Ул А.П.Смирнов тарафыннан Суар шәһәрендә үткәрелгән казу эшләре вакытында табыла. Кисек пирамида формасындагы әлеге каш өслегенә гарәп хәрефләре б-н иясенең исеме — «Арслан» дип язылган. Борынгы йөзекләр татарлар арасында соңрак та, 20 йөз башларына кадәр кулланылышта була. 18 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында саклагыч бөти ролен үтәүче эшләнмәләрдә, бигрәк тә хаситә бизәмәләрендә гарәп язуы рәвешендәге Г. таралыш ала. 1920 елларда традицион зәргәрчелек сәнгатенең бетүгә йөз тотуы һәм дингә каршы пропаганда, гарәп имлясының бетерелүе сәбәпле татар осталары иҗатында Г. кулланылмый.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; шул ук. Народное декоративное искусство казанских татар: его развитие и истоки (по материалам 18 — начала 20 вв.): Дис....М., 1980; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Ювелирное искусство // Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГЛИЦИФО́Н**, тиренең яман шеш һәм яман шеш алды авыруларын дәвалау өчен кулланыла торган дару. Метилфосфон кислотасының диглицидил эфиры. Төссез сыеклык. Су б-н җиңел катнаша. Казан мед. ин-тында (И.А.Студенцова, И.С.Мокринская һ.б., 1990 еллар) һәм Казан «Татхимфармпрепаратлар» химик-фармацевтик җитештерү берләшмәсендә эшләнелә. РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында алына (Н.И.Ризположенский, А.А.Муслинкин һ.б.). РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы әмере б-н 1994 елда куллануга рөхсәт бирелә.

Г.ның тире яман шеше авыруын дәвалауда сайланма тәэсире антимитотик эффектка һәм бластоматоз үзгәреш кичергән күзәнәкләрдә метаболизмны киметү сәләтенә нигезләнгән. Г. ш.у. микробларга каршы активлыкка ия. Урынлы кулланганда глицифон мае сәламәт тирегә зыян китерми һәм тирегә резорбтив агулы тәэсир итми.

Урынлы куллануга күрсәтмәләр: тире яман шеше авыруының яссы күзәнәкләре формасы, базалиомнар, ш.и. хирургик һәм нурлар б-н дәвалаудан соңгы шешләр; Бовен авыруы һәм сениль кератозлар.

Чит тәэсире: югары индивидуаль сизгерлеккә бәйле рәвештә авыртулар, шеш тирәсе тукымаларда гиперемия һәм шешенкелек. Ланолин-вазелин нигезендәге 30% лы глицифон мае «Татхимфармпрепаратлар» берләшмәсендә җитештерелә.

*Әд.:* Фармакология и токсикология фосфорорганических и других биологически активных веществ. К., 1996; Студенцова И.А., Гараев Р.С. Токсичность и некоторые биологические аспекты фосфорорганических эпоксидов // Экспериментальная и клиническая фармакология. 1996. № 6.

*Р.С.Гәрәев.*

**ГЛОБУЛЯ́РИЯ** (Globularia), глобуляриячәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуакчыклар, сирәк кенә куаклар ыругы. 25 ләп төре билгеле, Европада һәм Азиядә, нигездә, Урта диңгез буенда киң таралган. ТР терр-ясендә бер төре — Вилькомм Г. яки тимгелле зәңгәрбаш (G. willkommii) республиканың көньяк-көнчыгышында очрый. Известьле һәм ташлы тау битләрендә үсә. 10–20 *см* биеклектәге, киң тармакланган кыска тамырчалы күпьеллык үләнчел үсемлек. Туры сабаклы. Яфраклары кыска сапта, таралып урнашкан, сизелер-сизелмәс тешле. Чәчәкләре төкчәле, зәңгәр, ялгыз башчага җыелган. Июньдә-июль башында чәчәк ата. Орлыктан һәм куакларын аерып утырту юлы б-н үрчетелә. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГЛО́ВА** Виктор Иванович (10.9.1939, Чечен-Ингуш АССРның Назрань ш.), мәгълүмат технологиясе һәм мәгълүматны саклау гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1964 елда Казан авиация ин-тының радиотехника ф-тын тәмамлаганнан соң, Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1969 дан Казан техник ун-тының компьютер системалары һәм мәгълүмат иминлеге кафедрасында, бер үк вакытта 1999 дан Идел буе һәм мәгълүмат иминлегенең региональ укыту-фәнни үзәге директоры. Хезмәтләре мәгълүмат технологиясенә һәм махсус мәгълүматны саклауга карый. Мәгълүматны саклауның аппарат-программа чараларын эшли. Сәнәгатьтә мәгълүмат иминлеге чараларын гамәлгә кертә. Уйлап табуга 10 нан артык авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Системы защиты информации. К., 1999 (автордаш); Мягкие вычисления и их приложения. К., 2000 (автордаш); Программно-аппаратная защита информации. К., 2003. Ч.1 (автордаш); Method for Recognition of Fuzzy 2D Primitives via Technology of Soft Computing Pattern Recognition and Image Analisis. 2001. V.11, № 1 (автордаш).

**ГЛОКСИ́НИЯ** (Gloxinia), геснериячәләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр һәм куаклар ыругы. 6 дан артык төре билгеле. Чыгышы — тропик Америка. Бакчачылыкта Г. исемендәге геснериячәләрнең башка ыругларына — синнингияләргә (Sinningia) караган төрле сортлар билгеле. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерәләр. Аеруча киң таралган гибрид төре — матур синнингия (S. speciosa). Яфраклары тамыр янында, киң озынча түгәрәк яки эллиптик формада, куе яшел төстә, бәрхетсыман төкчәле, кыска сабакта. Җир астындагы өлеше — бүлбеләр. Чәчәкләре эре, бүрәнкәсыман, төрле төстә (сезонга бер үсемлектә 50 данәгә кадәр). Орлык, бүлбе, чыбыкча һәм яфрактан үрчетелә. Үсемлек туры кояш нурларын, су бөркүне һәм артык дымландыруны яратмый.

**ГЛОССА́РИЙ** (грек. glṓssa — тел, сүз), аңлатмасы бирелгән яисә башка телләргә тәрҗемә ителгән глоссалар — аңлашылмаган, искергән сүзләр һәм гыйбарәләр җыелмасы. Уйгыр, гарәп, латин графикасында угыз, уйгыр, болгар-кыпчак, иске татар Г.лары шактый күләмдә сакланган.

Иң борынгы төрки Г. — 1245 елда Мисырда төзелгән төрки-гарәп сүзлеге (авторы билгесез). Ядкәрнең кульъязмасы беренче тапкыр 1894 тә Голландия галиме М.Хоутсма тарафыннан типография ысулы б-н немец телендә басыла. Г.-сүзлекләргә ш.у. «*Кодекс Куманикус*» («Коман мәҗмугасы», 1303), Әсиретдин Әбү Хәйәннең «Китаб-и әл-идракъ-ли лисан әл-әтрәк» («Төрки телләргә аңлатма китабы», 1312), Җамалетдин Әбү Мөхәммәд Габдулла әт-Төркинең «Китаб әт-төхфәт әз-зәкийә фи-л-ләгати әт-төрки» («Төрки телләр турында зиһен китабы», 14 йөз), «Китаб-е бүлгат әл-мөштакъ фи-л-ләгать әт-төрк вә-л кыпчак» («Төрки һәм кыпчак телләрен белүне канәгатьләндерә торган китап», 1350), Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булатның «Гарәпчә-төркичә сүзлек» (16 йөз) кебек төрки язма истәлекләре һ.б. да керә.

Г.-сүзлекләр төрки халыклар формалашуының борынгы этапларын өйрәнү һәм борынгы, урта гасырлар төрки кабиләләре теленең лексик, өлешчә фонетик һәм грамматик нормаларын ачыклау өчен кыйммәтле чыганак булып торалар.

Төрки-татар Г.ларын А.Зайончковский, Ә.Н.Нәҗип, Н.А.Баскаков, М.Күпрелезадә, С.Моталлибов, А.К.Курышжанов, В.Х.Хаков һ.б. өйрәнә.


*Әд.:* Ногман М. XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульъязма сүзлекләр. К., 1969; Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Курышжанов А.К. Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XVIII в. — «Тюркско-арабского словаря». А.-А., 1970; Наджип Э.Н. Исследования по истории тюркских языков XI–XIV вв. М., 1989.

*В.Х.Хаков.*

**ГЛУ́МОВ** Иван Фоканович (11.9.1929, Пермь өлкәсенең Елово р-ны Среднее а.), нефтьче, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1966), РСФСРның атказ. нефть һәм газ сәнәгате эшлеклесе (1987), СССРның мактаулы нефтьчесе (1981), РФнең атказ. уйлап табучысы (1993). Томск ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), «Татнефть» берләшмәсе системасында эшли, 1954–56 елларда Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә (Бөгелмә ш.) директор урынбасары. 1956 дан ТатНИПИнефтьтә: директор урынбасары (1976–89), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1989 дан). Аның турыдан-туры катнашуы нәтиҗәсендә ТРдагы нефть чыганакларында катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру буенча яңа технологияләр эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Фән һәм техника өлкәсендәге уңышлары өчен РФнең Дәүләт бүләге бирелә (1995). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Повышение нефтеотдачи пластов на месторождениях Татарии. К., 1978.

**ГЛУХИ́Х** Василий Трофимович (28.3.1927, Киров өлкәсенең Медянский р-ны Евсино а. — 10.5.1991, Казан), спортчы, тренер (академик ишү). РСФСРның атказ. тренеры (1971), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1986). Уфа физик культура



В.П. Глушко.



В.А. Глушков.

техникумын тәмамлый (1966). ТАССР, РСФСР, СССР җыелма командалары тренеры: «Спартак» (1960–62, 1963–67), «Зенит» (1962–63) ирекле спорт җәмгыятьләрендә, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (1969–70, 1988–91), республиканың югары спорт осталыгы мәктәбендә (1967–69, 1970–88) эшли. Шәкертләре арасында — РСФСР, СССР, Европа, дөнья чемпионатларында катнашып, төрле дәрәҗәдәге бүләкләр алган спортчылар Г.Т.*Московский*, А.В.*Плюшкин*, В.Ф.*Потапов*, Е.Г.Янковский, тренерлар В.А.*Гоголин*, С.М.*Ульянов*.

**ГЛУ́ХОВ** Максим Степанович (23.11.1937, Кызыл Йолдыз р-ны Үри Чаллысы а. — 27.10.2003, Казан, Питрәч р-нының Талкыш авылында җирләнә), тарихчы, тарих фән. канд. (1974). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1966–94 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррирлек эшендә, 1975–82 дә Казан төзүче инженерлар ин-тында укыта. «Батыр биеклек яулый» («Батыр набирает высоту», 1974), «Күтәрелү» («Восхождение», 1982), «Яңа буралар» («Новые срубы», 1990) һ.б. очерклар китаплары авторы. Аның иҗатында төп темаларның берсе — керәшен татарларның тарихы («Сөембикә гвардиячеләренең язмышы» — «Судьба гвардейцев Сеюмбеки», 1993; «Tatarica. Энциклопедия», 1997; «Казан ретро-лексиконы» — «Казанский ретро-лексикон», 2002).

**ГЛУШКО́** Валентин Петрович (2.9.1908, Одесса ш. — 10.1.1989, Мәскәү), конструктор, ракета двигательләре төзү һәм ракета-космик техника гыйлеме белгече, СССР ФА академигы (1958; мөхбир әгъза 1953), ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1956, 1961). Илебездә сыек ягулыклы ракета двигательләре төзү эшенә нигез салучы. 1929 елда Ленинград ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый, 1933 кә кадәр Газодинамика лаб-ясендә (Ленинград), электроракета, сыек ягулыклы ракета двигательләре (ЖРД) төзү бүлеген оештыра һәм җитәкли. 1934 тә Ракета фәнни-тикшеренү ин-тын оештыра (Мәскәү), анда С.П.Королёв конструкциясендәге канатлы ракетада файдалану өчен ОРМ-65 двигателе төзелә һәм сынала (1936). 1938 елда репрессияләнә, 1939–40 та — 82 нче Тушино авиация моторлар төзү з-ды каршындагы махсус төрмәдә, 1940–41 дә 16 нчы Казан авиация моторлары з-дындагы (хәзер Казан моторлар җитештерү берләшмәсе) 28 нче махсус бүлектә тотыла, соңгысында Г. җитәкчелегендә илнең Хәрби-һава көчләре самолётларына сыек ягулыклы ракета җайланмалары проектлары кабул ителә. 1941–44 елларда самолётлар өчен сыек ягулыклы ракеталар эшләү буенча баш конструктор, 1944–46 да махсус двигательләрнең аерым КБнда баш конструктор, 1945 тә Казан авиация ин-тында ракета двигательләре каф. мөдире. 1946–66 да 456 нчы аерым КБ, хәзерге «Энергомаш»та КБ (Мәскәү өлкәсе, Химки ш.) баш конструктор. 1974 тән «Энергия» фәнни-җитештерү берләшмәсендә (Мәскәү өлкәсе Калининград ш., хәзер Королёв ш.) директор һәм ген. конструктор. Г. ның төп хезмәтләре сыек ягулыклы ракета двигательләре һәм космик аппаратлар төзү һәм үстерүнең мөһим мәсьәләләрен теоретик һәм эксперименталь тикшерүләргә багышланган. Г. дөньяда беренче электротермик ракета двигателе, илебездә беренче сыек ягулыклы двигательләр конструкторы. 1930 елда сыек ягулыклы реактив двигатель өчен ягулык компоненты итеп азот кислотасын, азот кислотасындагы дүрт окисьлы азот эремәсен, тетронитрометанны, водород перекисен, хлор кислотасын, бериллий (водород һәм кислород б-н), дары б-н бериллийны, махсус кисемле соплоны һәм яну камерасын җылынудан саклау өчен цирконий диоксидын куллануга тәкъдим итә. 1931 елда химик кабызу һәм үзлегеннән кабынучы ягулык, ракета очышы б-н идарә итү өчен сыек ягулыклы двигательгә асылма кардан тәкъдим итә. 1932–33 тә сыек ягулыклы двигательгә ягулык бирү өчен пешкәкле, үзәктән кугыч насослар б-н турбонасослы агрегатлар эшли; аның тарафыннан ул вакытта «тәҗрибә ракета моторлары» дип аталган сыек ягулыклы ракета двигательләре сынап карала. Г. җитәкчелегендә илебездәге барлык йөрткеч ракеталарда (ЙР) һәм күп кенә хәрби ракеталарда: «Восток», «Восход», «Молния», «Союз» ЙР өчен РД-100-РД-103 һәм РД-108; «Космос» ЙР өчен РД-119 һәм РД-214; «Протон» ЙР өчен РД-253; «Зенит» ЙР өчен РД-301, РД-120 һәм РД-171; дөньяда иң куәтле сыек ягулыклы «Энергия»-«Буран» ЙР өчен РД-170 файдаланылган куәтле сыек ягулыклы ракета двигательләре төзелә. Аның җитәкчелегендә 1971–85 елларда «Космонавтика» энциклопедиясе һәм матдәләрнең күп классларының термофизик үзлекләренә караган күптомлы энциклопедик белешмәләр нәшер ителә. Ленин премиясе (1957), СССР Дәүләт бүләкләре (1967, 1984) бирелә. Халыкара астронавтика академиясе әгъзасы (1976). 1966–76 елларда СССР ЮС депутаты. Биш Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Кызыл Байрак орденнары, медальләр, ш.и. К.Э.Циолковский исем. медаль б-н (1958) бүләкләнә. Казан, Элиста, Одесса, Калуга шәһәрләренең мактаулы гражданины. Одессада бронза бюсты һәм истәлек такта урнаштырылган; Казанда ш.у. истәлек такта куелган, бер урам аның исеме б-н аталган.

Х е з м.: Ракеты, их устройство и применение. М.–Л., 1935 (автордаш); Жидкое топливо для реактивных двигателей. М., 1936. Ч. 1; Путь в ракетной технике. М., 1977; Развитие ракетостроения и космонавтики в СССР. М., 1987.

*Әд.:* Однажды и навсегда. Книга о Валентине Петровиче Глушко. М., 1998; Космонавтика: Энцикл. М., 1985.

**ГЛУШКО́В** Владимир (Адольф) Алексеевич (3.6.1927, Киров өлкәсенең Глушки а. — 5.5.1993, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1976), РСФСРның атказ. артисты (1987). Киров өлкәсе драма театры каршындагы студияне һәм муз. уч-щесен тәмамлый (1949). 1946–53 елларда — Киров яшь тамашачылар театрында, 1953–54 тә — Тува автономияле өлкәсенең Кызыл шәһәр театрында. 1954 елдан — Казан Яшь тамашачылар театрында, аның сәхнәсендә 100 дән артык роль башкара. Ачык комедия сәләтенә ия актёр, комик гротеск элементларына тартыла, эпизодлар, импровизацияләр остасы. Һәр ролендә социаль һәм психол. портретның тәгәллегенә, тулы ачылышына ирешә, ул тудырган портрет артында аерым образ гына түгел, иҗтимагый тормыш вакыйгалары чагыла. Бу җәһәттән аеруча әһәмиятле рольләре — Простаков («Җитлекмәгән егет», Д.И.Фонвизин), Жевакин («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Узгынчы («Трень-брень», Р.П.Погодин), Золотуев («Июньдә хушлашу», А.В.Вампилов). Г. — рус реалистик мәктәбе тарафдары, аның иҗатында тирән психологизм б-н тышкы кыяфәтенең күркәмлеге бергә кушыла, ул детальләргә, мимика һәм кул хәрәкәтләренә игътибар бирә, үзе тудырган һәр образга аңа гына хас яшәү манерасын таба белә. Чагылдыру чараларының киң диапазонына ия буларак, аның үткен сатирик рольләре дә (Бургомистр — «Аждаһа», Е.Л.Шварц), драматик рольләре дә (Каширин — «Алёша Пешков», И.А.Груздев, О.Д.Форш) бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык була. Характерның көлкеле күренешлә-





В.А.Г л у ш к о в:
1. Блом («Пеппи Озын оек», А.Линдгрен);
2. Бургомистр («Аждаһа», Е.Л.Шварц) рольләрендә.

рендә дә Г. кеше язмышының төрлелеген, кайвакытта драматик халәтен күрә һәм күрсәтә белә: Заморыш («Җәйге төндә күргән төш», Шут («Ялгышлар комедиясе», У.Шекспир). Аның геройлары бер үк вакытта көлкеле дә, үзләренә карата кызгану хисләре тудырып, дулкынландырырлык та булалар; тамашачыга гадәти генә булып күренгән вакыйганың да кире, социаль зарарлы ягын ачык күрергә ярдәм итеп, куркыныч та тоелалар. Татар драматургиясендә Г. тудырган әһәмиятле образлар — Мөхәммәтхан Мәүлетов («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт), Әхмәтша мулла («Умырзаялар», Ю.Әминев), Шәйхулла бай («Тапкыр егет», Д.Аппакова). Күп кенә әкияти спектакльләрдә уйный. Казан Яшь тамашачылар театрының әйдәп баручы актёрларыннан берсе була.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Благов Ю.А. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**ГЛУШКО́В** Пётр Аркадьевич (19.12.1880, Мәләкәс ш., хәзерге Ульянов өлкәсе Димитровград ш. — 5.3.1937, Ленинград), стоматолог, мед. фән. д-ры (1918), проф. (1920). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1904), хәрби-мед. хезмәтендә. 1912 елдан 2 нче Казан теш табибләре мәктәбендә лекцияләр курсы укый. 1920–30 елларда Казан ун-тында, 1921 дән мед. ф-тының одонтология каф. мөдире, профессоры, 1928 дән одонтология, соңрак стоматология клиникасы директоры. 1930 дан Ленинградта эшли. Хезмәтләре балаларда теш чыгуның тоткарлануы клиникасын, аскы казна сөякләре пластикасын өйрәнүгә карый. Г. бозыла башлаган тешләрне дәвалау ысулларын эшли.


*Әд.:* Блинова Н.Ш. Пётр Аркадьевич Глушков — первый казанский профессор-стоматолог // Тр. Казан. мед. ин-та. 1971. Т. 34.

**ГМИ́НА** (поляк. gmina — волость), ислам динендәге Польша-Литва татарларында мәхәллә атамасы. Дин, хакимият-хуҗалык, мәдәни-агарту мәсьәләләрен хәл иткән. Г.да югары хакимият елга бер тапкыр чакырылган гомуми җыелыш карамагында булган, анда идарә сайланган (аның составына руханилар һәм дөньяви затлар, 1936 елдан фәкать руханилар — имамнар гына кергән). Г. идарәсе турыдан-туры Польша-Литва татарлары мөфтиятенә буйсынган. 1936 да мөфтият карары б-н идарәләр бетерелә, аларның вәкаләтләре имамнар кулына күчә. Һәр Г.ның үз фонды була, аның акчалары мәчетләр, мәхәллә йортлары, мәктәпләр төзүгә һәм тәэмин итүгә, зиратларны карап торуга, мәхәлләнең ярлы кешеләренә ярдәм күрсәтүгә тотыла. 1939 га кадәр 19 Г. була, аларның 9 ы — Новогруд, 2 се — Белосток воеводаларында, 1 се Варшавада урнаша.

*Я.Я.Гришин.*

**ГНЕДЕНКО́В** Александр Васильевич (22.3.1921, Спас кантоны Базарлы Матак а. — 4.11.1998, Казан), партия, хакимият-хуҗалык хезмәткәре. Ленинград 2 нче артиллерия уч-щесен (1942, Белорецк ш.), КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы партия мәктәбен (1956), КПСС ҮК каршындагы Читтән торып уку югары партия мәктәбен (1959, Мәскәү) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1939–47 елларда Кызыл Армиядә: 1939–42 дә Көньяк-көнбатыш фронтта 55 нче укчы дивизиянең 107 нче артиллерия полкында туп командиры, 1944–47 дә тавыш-баллистика станциясе башлыгы. 1948–53 тә Әлки р-ны башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1956–61 дә КПССның Аксубай райкомының 1 нче секретаре, 1961–81 дә Татарстан өлкә ком-тының оештыру-партия эше бүлеге мөдире. 1982–86 да профсоюзларның Татарстан өлкә советында хезмәт инспекторы. 1963–85 тә ТАССР ЮС депутаты. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГНЕЙС** (нем. Gneis), метаморфик тау токымы; күләмле, гадәттә, гранитоид составлы, буй-буй кристаллы сланец. Катнашмалары буларак, гранатлар, дистен һ.б. очрый. Магматик (ортогнейслар дип аталучы вулканик) һәм утырма (парагнейслар) токымнарның нык (тирән) метоморфизмы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Тыгызлыгы 2650–2870 *кг/м³*, көпшәклелеге 0,5–3,0 %. Кембрийгача борынгы комплексларда еш очрый. Җир тарихында Г. хасил булу процессы моннан 2,5 млрд. еллар элек булган. Татарстан терр-ясендә кристаллик нигез токымнары



Гранатлы гнейс (20009 нчы скважина, кристаллик фундамент).

арасында күп, моннан 2,7–3,1 млрд. ел элек хасил булган, гранат катнаш эндербит-гнейслар, пироксен-плагиоклаз, амфибол-пироксен-платоклас гнейслар, биотит-амфибол плато-гнейслар очрый. Г.ларга, мәсәлән, селтеләләренә, сирәк очрый торган элементларның (Ta, Nb, Be һ.б.) зур руда чыганаклары туры килә. Г. токымнар, башлыча, вакланган таш, бут ташы алуда һәм тышлау ташы буларак кулланыла.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996.

*Ю.В.Сементовский.*

**ГО**, спорт төре. Өстәл уены буларак 5 мең ел элек Кытайда барлыкка килә («вей-чи» — тактадагы уен), Корея («бадук» — ташлар б-н уйнау), Япония («Го» — иероглифлар «яшәү һәм үлем»не аңлата) һ.б. дәүләтләрдә тарала. Уенның кыскача мәгънәсе: тактадагы сызыклар (19 вертикаль, 19 горизонталь) кисешкән буш нокталарга чиратлап ташлар (181 кара, 180 ак) куя барып, уенчылар зуррак мәйданны әйләндереп алырга тырышалар. Җиңүче булып иң күп очко җыйган уенчы санала (яулап алынган ноктлар һәм әсирлеккә алынган ташлар саны буенча). Татарстанда го 1975 елдан үсештә. 1976 да Р.Г.Нәҗметдинов исем. шахмат һәм шашка сарае каршында Казан го уенчылары клубы оештырыла. Клубның җыелма командасы 1983–84, 1990 елларда Европа чемпионы була. 1978 дән Татарстан (ирләр һәм хатын кызлар) чемпионатлары, яшүсмерләр беренчелекләре (12, 16, 18 яшькә кадәрге), 1993 тән республикада го уенын башлап җибәрүче А.И.Васильев истәлегенә халыкара мемориал уздырыла. 1990 да Казанда Р.Г.Нәҗметдинов исем. балалар-яшүсмерләр олимпия резервы үзәк шахмат мәктәбендә го уены бүлеге ачыла (җитәкчесе — Россиянең атказ. тренеры В.Д.Шикшин). Го Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләрендә үсеш ала. Иң яхшы уенчылар — Россия, Европа, дөнья чемпионнары Р.М.Гатауллин, И.С.Детков, А.Г.Динерштейн, А.А.Кульков, Р.В.Сәйфуллин, В.Д.Соловьёв, С.В.Шикшина (Россия гроссмейстрлары), А.М.Дугин, Т.М.Дугин, И.Немлий, Д.Сөләйманова, И.В.Шикшин. ТР җыелма командасы — 2001 елда Европа чемпионы. ТРның иң яхшы тренерлары — В.Д.Соловьёв, В.Д.Шикшин.

**ГОБӘ́ЕВ** Фәрит Сәет улы (15.7.1951, Казан), фоторәссам, журналист, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), Казан телевидение студиясендә (1970–73), «Калининец» күптиражлы завод г-тасында (1973–75), «Комсомолец Татарии» (1975–76), «Вечерняя Казань» (1978–91) г-таларында эшли. 1991–96 елларда Мәскәүдә, «Россия» г-тасында, «Обозреватель» ж-лында эшли, Россия Журналистлар берлегендә фотокүргәзмәләр бүлеге мөдире була. Казанга кайткач, «Казан» ж-лы, республика г-талары һәм үзәк ж-ллар б-н хезмәттәшлек итә. Россия Журналистлар берлеге (1976), һәм Фоторәссамнар берлеге әгъзасы (1991).

Ф.Гобәев үзенчәлекле стиле һәм образлы фикерләү нәтиҗәсендә Россиядә һәм чит илләрдә тиз танылa. Иҗат эшчәнлеген 1968 елда Казандагы «Волга» фотоклубында башлап җибәрә. 10 ел дәвамында (1970–80) «Тасма» Казан фототөркеме рәисе, республика һәм аның чикләрендә фотокүргәзмәләр оештыра. «Тасма» фотографларының иҗаты Россия рәссамнары тормышында дикъкатькә лаек күренешкә әйләнә, хезмәтләре күп кенә илләрдә популярлык казана, җитди, саллы альбомнарда басылып чыга. Болары — Г.нең башлангыч иҗатына хас булганча, сурәтләрнең чынбарлыктагыча чагылдырылуы, әчтәлекнең драматизмы, образлардагы психологик сыйфатлар б-н аерылып торучы фотолар. Аның фәлсәфи һәм символик эчтәлектәге аклы-каралы һәм төсле фоторәсемнәрендә замандашларыбызның үз мохитенә хас тормыш тасвирлана. Г. — «Сабан туе» сериясеннән ачык һәм үзенчәлекле фоторәсемнәр авторы. Ул әлеге эшенә 1971 елда керешә һәм 30 елдан артык вакыт дәвамында тиңдәшсез фотоелъязма барлыкка китерә. Күренекле әдәбият, сәнгать, фән эшлеклеләреннән: Н.Даутов, Е.Евтушенко, Р.Нуриев, Б.Окуджава, С.Рихтер, А.Сахаров, Б.Урманче, А.Шнитке һ.б. портретлары галереясын;

«Хатын-кызны эзләгез», «Татарстан. Замандаш портретлары» һ.б. фоторәсемнәр сериясен иҗат итә. Г. үзен рәсем сәнгате өлкәсендә дә уңышлы сыный. Ул май, темпера, тушь, пастель б-н башкарылган абстракт сәнгать стилендәге картиналар авторы (1986 да «Казанның хәзерге заман сәнгате» күргәзмәсендә куела). 1980 еллардан соң ул рәссамнар, фотографлар иҗатына багышланган альбомнар, фотокитаплар бильдредакторы һәм төзүчесе, ш.у. нәфис сәнгатьнең көнүзәк темаларын яктырткан мәкаләләр авторы. «Россия. Фоторәсемнәрдә йөзьеллык тарих» исемле (Нью-Йорк, 1994) тиңдәшсез альбом әзерләүдә катнаша, соңрак бу альбом 10 илдә яңадан басылып чыга.



Ф.С. Г о б ә е в. Рудольф Нуриев Казанда. «Йолдызлар Җирдә яши» сериясеннән. 1992.

Респ-ка, бөтенроссия һәм халыкара фотокүргәзмәләрдә катнаша. Аның хезмәтләре Мәскәү, Ленинград, Вильнюс, Рига, Таллин, Париж, Амстердам, Вашингтон, Нью-Йорк шәһәрләрендә күрсәтелә. Казан, Мәскәү, С.-Петербург, Рязань, Кобург (Канада), Нида (Литва) шәһәрләрендә Г. иҗатына багышланган махсус 20 күргәзмә оештырыла. Нәкышь картиналарыннан торган махсус күргәзмәсе 1986 да Казанда, «Фоторәсемнәрдә — иҗади кырык ел» исемле ретроспектив күргәзмәсе 2008 дә Йошкар-Олада, персональ фотокүргәзмәсе 2009 елда Казанда үткәрелә. ТР журналистларының «Бәллүр каләм» бәйгесе лауреаты (2007).



Ф.С. Г о б ә е в. «Сабан туе» сериясеннән. 1986.

Х е з м.: Советский Татарстан. К., 1980; Татарстан — портрет современника. К., 2006. Т. 1; 2007. Т. 2; Татарстан — наш общий дом. К., 2007; Елабуга тысячелетняя: В 2 т. Елабуга, 2007.

*Әд.:* Л е о н т ь е в М. Я вас люблю ... // Советское фото. 1991. № 1; Д о б р ы н к и н А. Не ловлю удачу за хвост // Фотографический вестн. «Ретикуляция». 1996. № 1 (30); Е р г а е в а Г. Сабантуй без компьютерной обработки // Профессия — журналист. 2000. № 6; Ж а р о в Д. Цвет праздника // Националь, 2004. № 8; К л и м о в О. «Иди и смотри...» (о Фарите Губаеве) // Казань. 2009. № 10.

*Г.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГОБӘ́ЕВ** Шамил Шәмси улы (1.6.1954, Удмурт АССРның Воткинск ш. — 5.4.2009, Казан), икътисадчы, юрист, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2001), РФнең атказ. юристы (1994), ТРның атказ. икътисадчысы (2004). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009, вафатыннан соң). 1981 елда Казан ун-тын һәм 1992 дә РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен тәмамлый. 1971–75 елларда Воткинск шәһәре пр-тиеләрендә эшли. 1981–86 да — ТР Прокуратурасы органнарында (Яшел Үзән район һәм шәһәр прокуроры ярдәмчесе урынбасары). 1986–87 дә Казан механика з-дында производство башлыгы. 1987 дән «Элекон» фәнни-җитештерү берләшмәсендә бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары. ТР Сәнәгать департаментын оештыра һәм 1995 тән аның ген. директорының беренче урынбасары, 1997–2009 да «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖнең ген. директоры урынбасары, бер үк вакытта «Әлнас» АҖ директорлар советы рәисе (1997–2000). ТР Икътисад һәм сәнәгать министрлыгының икътисад советы әгъзасы (2000 дән). Базар икътисадына керү шартларында ТРда сәнәгать б-н идарә итү структурасын төзүдә катнаша; аның җитәкчелегендә ТР нефть-газ-химия комплексының 1998–2003 һәм 2003–2008 елларга үсеш программасы эшләнә. Хезмәтләре сәнәгать тармакларының икътисады һәм идарә итү структурасы, ТР ның нефть-газ-химия комплексында стратегик идарә итү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефтехимический комплекс РТ: стратегическое управление, конкуренция, инвестиции. К., 1998; Нефтегазохимический комплекс Татарстана в условиях социально-экономической трансформации. К., 1999; Развитие нефтегазохимического комплекса РТ в условиях трансформации: результаты и перспективы. К., 2001.

**ГОБӘ́Й** посёлогы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Екатериновка елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 24 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 184 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 56, 1897 дә — 78, 1908 дә — 97, 1926 да — 70, 1958 дә — 89, 1970 тә — 65, 1989 да — 32, 2002 дә — 30 кеше.

**ГОБӘ́Й** (Гобәйдуллин) Гариф Шакир улы (26.8.1907, Казан — 27.4.1983, шунда ук), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1936). Студент елларында ук Татар радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире булып эшли. 1936–40 елларда Әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча баш идарә (Главлит) вәкиле, 1940–46 да Татарстан радиокомитеты рәисе. 1950–53 тә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. «Көмеш канат» дигән беренче хикәясе 1934 тә басыла. Балалар өчен дистәләгән повесть һәм хикәя авторы. «Маякчы кызы» (1938; русчага тәрҗемәсе «Дочь бакенщика», 1951) повесте — татар әдәбиятында Гражданнар сугышына багышланган иң уңышлы әсәрләрдән берсе. Г.нең әсәрләрендә сурәтләнгән яшь геройлар һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә биреләләр. Сугыш елларында тылда авыл балаларының катлаулы тормышын сурәтләгән «Замана балалары» (1945), Ленинград блокадасы вакытында балаларның хәле, совет кешеләренең намуслылыгы, фидакарьлекләре турында «Маратның язмышы» (1956; рус теленә тәрҗемәсе «Судьба Марата», 1963) повестьлары шундыйлардан. Сугыштан соңгы яшь буынның җилкәсенә төшкән авырлыкларны тасвирлаган «Ләйсән яңгыр» (1961) повесте да Г. гә уңыш китерә. Революциягә кадәрге Бишбалта бистәсе тормышын чагылдырган «Без үскәндә» (1959; рус теленә тәрҗемәсе «Когда мы росли», М., 1964) повесте тарихи-революцион теманы үз эченә ала. Г. нең атеистик күзлектән чыгып язган «Коръән серләре» (1967; 3 басма, 1977) исемле әдәби-публицистик повесте да билгеле. Г. — әдәби тәрҗемә өлкәсендә күп эшләгән язучы. Ул татар теленә «Тысяча и одна ночь» («Мең дә бер кичә», 1940) җыентыгын, А.Первенцевның «Честь смолоду» («Намуслы яшьлек», 1950) повестен, А.Толстойның «Пётр Первый» («Пётр патша», 1966) романын һ.б.ны тәрҗемә итә. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1968–69.

*Әд.:* Т ә р җ е м а н о в Җ. Балалар дөньясы аксакалы // Ялкын. 1977. № 9; Р а х м а н и Р. Тормыш чынлыгын эзләп // Казан утлары. 1997. № 8; Советские детские писатели: Биобиблиогр. словарь. М., 1961.

**ГОБӘЙДИ́** (Гобәйдуллин) Даут Гобәйдулла улы (1873, Вятка губ., Алабуга өязе Кыдырлы а. — 1919, Тәбәрле а., туган авылында җирләнә), шагыйрь, тәрҗемәче. 1885–97 елларда «Буби» мәдрәсәсендә укый. Соңыннан, туган авылына кайтып, яңача укыта торган мәдрәсә ача. 1905 елдан Иске Кызылъяр авылы (хәзерге Әгерҗе р-ны) имамы булып тора, мәдрәсә оештыра, үзе шунда укыта. Укыту программаларында татар матур әдәбиятын укытуга зур игътибар бирә. 1912 дә «*Бубилар эше*» буенча кулга алына, 4 айга якын зинданда утыра. 1917–19 да Сарсак Умга авылында (хәзерге Әгерҗе р-ны) волость

башкарма ком-ты рәисе урынбасары, бер үк вакытта халык мәгариф бүлеге мөдире булып эшли, укыта. Беренче шигырьләре 20 йөз башында басыла башлый: «Татар кызы» (1904), «Күке» (1905). «Шүрәле каргаган авыл» исемле шигъри җыентык (1913), «Мөгаллим әл-хоруф» («Хәреф укыту») әлифбасы (1909), гигиена мәсьәләләренә багышланган «Хифзы әс-сыйхәт дәресләре» («Сәламәтлек саклау дәресләре») китабы (1907) авторы. «Җәһәннәм» исемле чәчмә романының кулъязмасы югалган. Н.В.Гоголь, А.В.Кольцов, М.Твен әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Н.В.Гогольнең «Өйләнү» («Женитьба») пьесасы Г. тәрҗемәсендә 1919 ның февралендә Казанда куела. Колчакчылар тарафыннан үтерелә.

Ә с ә р.: Шигырьләр. К., 1959.

*Әд.:* И б р а һ и м о в Ф. Иж-Буби шәкерте // Казан утлары. 1991. № 9.

*А.М.Ахунов.*

**«ГОБӘЙДИЯ́»**, Оренбург губ. Бөгелмә өязе (хәзер ТРның Ютазы р-ны) Бәйрәкә авылындагы өченче җәмигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. Идел буендагы иң зур мөселман уку йортларының берсе. 19 йөздән мәгълүм. Махсус төзелгән бинада урнаша (19 йөз ахырыннан). Мәдрәсәне нигезләүче һәм мөдәррисе авылның 3 нче мәхәллә имам-хатибы, дин белгече, шәригать белеме буенча аңлатмалар һәм хезмәтләр авторы Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт (1785–1845) була. Аның Бәйрәкә авылы мәдрәсәсендәге дәресләре күп шәкертләрне үзенә тарта. Гобәйдулла хәзрәт үлгәннән соң, «Г.»дәге традицияләрне, абруйлы мөселман уку йортларындагы кебек, аның улы, күренекле суфи шәех (ишан) Габделвәли дәвам иттерә, аның уннарча мөриде була.

19 йөз ахыры 20 йөз башларында мәдрәсә тарихында яңа этап башлана, бу вакытта җәмәгать имамнары һәм мәхәллә мәдрәсәсенең җитәкчеләре булып Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт нәселеннән бертуган Мөксин (1897 дән) һәм Мәсәгут (1902 дән) Гобәйдуллиннар тора. Алар «Г.»дә реформалар эшчәнлеген киң җәелдерә, уку-укыту программасына география, математика, Россия тарихы, рус һәм татар телләре кебек дөньяви фәннәрне дә кертәләр. Мөдәррисләр арасында Г.Г.Сәгъди, бертуган Ф. һәм К. Туикиннар була. 20 йөз башында мәдрәсә комплексы өч уку бинасыннан һәм берничә хуҗалык эшләре корылмасыннан тора. Ел саен мәдрәсәдә йөзләгән шәкерт белем ала. 1905–22 елларда кыз балалар сыйныфлары эшли. «Г.» дә булачак шагыйрь Сирин, булачак язучы С.Миңлекәй һ.б. белем ала.

1907 дән мәдрәсә *Бәйрәкә мөселман тәрәккыйпәрвәрләр җәмгыяте* карамагында була. Мөксин һәм Мәсәгут Гобәйдуллиннар вакытында һәм 1924 елда ябылганга кадәр мәдрәсә Россиядә иң алдынгы мөселман уку йортларыннан санала. 19 йөз ахырыннан «Г.» ике таш бинадан торган комплекста урнаша, хәзер архит-ра истәлеге.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Айдар Тимергали улы (28.1.1958, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), РФА КГҮнең Органик һәм физ. химия ин-тында эшли, 2008 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре физ.-химик ысуллар ярдәмендә күп компонентлы дисперс полимер системаларның, органик һәм элементорганик кушылмаларның төзелешләрен һәм үзлекләрен өйрәнүгә карый. Г. сегментлашкан полиэфируретаннарның һәм гетероген полимер системаларының дисперс һәм фаза структураларын өйрәнә, термоэластопластик үзлекләр чагылышы б-н аларның төзелеше арасындагы корреляцияне билгели, аларның молекулалардан зуррак структураларын сурәтли. Калисарен катнашкан матдәләрнең кристалларында гидрофил һәм гидрофоб өлкәләр урнашуы күренешен ачыклый. Молекулаларның амфифиль үзлекләре булуга, ш.у. гидрофил һәм гидрофоб өлкәләрнең максималь урнашуы принцибына нигезләнеп, органик һәм элементорганик кушылмалар кристалларын анализлауның һәм молекуляр кристаллар морфологиясен фаразлауның модельле яңа юлларын тәкъдим итә. Күп кенә кушылмаларның: калисареннар, фосфорлы, күкертле һәм азотлы гетероциклик кушылмалар, табигый полициклик һәм карбоциклик кушылмалар, фуллерен чыгарылмалары һәм аларның комплексларының төзелешләрен өйрәнә. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008).


Х е з м.: Полиэфируретаны на основе олигооксипропилендиола. Малоугловое рентгеновское рассеяние и проявления свойств термоэластопластов // Высокомолекулярные соединения. 1992. Т. 33, № 7 (автордаш); Исследование в области химии супрамолекулярных соединений калисаренов // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3–4 (автордаш); Модель кристаллической структуры на основе анализа гидрофобного соотношения в молекулах. Производные стевиола // Журн. структурной химии. 2005. Т. 46 (автордаш).

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Әгъзам (Экзам) Самат улы (15.7.1953, Чүпрәле р-ны Иске Кәкерле а.), дәүләт һәм хакимият-хуҗалык эшлеклесе, а.х. фән. д-ры (1997), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1975). 1976 елдан Яшел Үзән р-нында: «Комсомолец» к-зының баш зоотехнигы (1981 гә кадәр), 1981–86 да «Искра» к-зы рәисе, 1986–91 елларда район агросәнәгать берләшмәсе рәисе, 1991–92 дә халык депутатлары район советының а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы. 1992–95 тә ТР а.х. һәм азык-төлек министрының 1 нче урынбасары. 1995–98 дә Мамадыш р-ны хакимияте башлыгы, бер үк вакытта 1996–98 дә халык депутатларының Мамадыш район советы рәисе. 1998 дән ТР Президенты Аппараты җитәкчесе. 2005 тән РФ Федераль Җыенынның Федерация Советы әгъзасы. 1996–2004 елларда ТР халык депутаты.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Әмир Әнвәр улы (4.8.1947, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, ун-т каршындагы Электрон машиналар б-н идарә итү ин-ты бүлегендә эшли. 1977 дән Уфа авиация ин-тында.



Ә.С. Гобәйдуллин.



Ә.Г. Гобәйдуллин.

1986 дан РФА Себер бүлегендә (Новосибирск ш.): 1986–89 елларда Төньякны үзләштерү проблемалары ин-тында, 1989–98 дә Күп фазалы системалар механикасы ин-тында, директор (1995 тән) һәм бер үк вакытта 1986 дан Төмән ун-тында. 1998 дән РФА Себер бүлеге Теоретик һәм гамәли механика ин-тының Төмән ф-лы директоры. Хезмәтләре күп фазалы системалар динамикасын матем. һәм санча модельләштерүгә, гетероген мохиттә сызыкча һәм нәсызыкча дулкыннар таралуын фәнни тикшерүгә карый. Г. бәрмә дулкыннарның җылылык релаксациясе күренешен ача. Газлы-сыекчалы системаларның бәрмә йөкләмне көчәйтү сәләтен ачыклый һәм бәрмә дулкыннарны куыклы экраннар б-н нәтиҗәле сүрелдерү ысулларын эшли. Туендырылган кузәнәкле һәм ярыклы-кузәнәкле тирәлектә дулкыннарның сызыкча һәм нәсызыкча таралу теориясен төзи.

Х е з м.: Волны в жидкостях с пузырьками // Механика жидкости и газа. 1982. Т. 17; Приложения механики многофазных систем к разведке, добыче и транспорту нефти и газа // Изв. вузов. Нефть и газ. 1999. № 2.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Әнвәр Габдрахман улы (18.10.1922, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1983). Татар акад. театры каршындагы студияне тәмамлаганнан соң (1948), шул театр труппасына кабул ителә. 1991 елдан — Татар акад. театрының «Инсаният» труппасында. Характерлы рольләр актёры, ышандырырлык итеп, үтемле сәнгать чаралары ярдәмендә образның эчке дөньясын ача белә. Күбесенчә кечерәк рольләрдә уйный, ләкин актёрның осталыгы аларга тирән мәгънә бирә, шул сәбәпле бу рольләр әсәрнең үзенчәлекле камертоны кебек кабул ителә (Сиражи — «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин). Г. тудырган образлар кешелекле булулары, характерның асылын тормыштагы вакыйгалар ярдәмендә аңларга һәм ачып бирергә омтылулары б-н аерылып торалар. Төп рольләре: Гарәфи («Банкрот», Г.Камал), Шәрәфи («Акчарлаклар», Ш.Камал), Питрәй, Сәлим («Зәңгәр шәл», «Американ», К.Тинчурин), Исак («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Ахун, Габделвәли («Хуҗа Насретдин», «Гөлҗамал», Н.Исәнбәт), Карт («Язмышың хәл ителгәндә», Д.Вәлиев), Кадыйр («Әнә килә автомобиль», Ф.Яруллин), Тукаш («Кол Гали», Н.Фәттах), Галәветдин («Күрәзәче», З.Хәким), Дәрвиш («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Василий, Ильич («Котырган акчалар», «Яктырта да, җылытмый», А.Н.Островский).

*И.И.Илялова.*



Ә.Ш. Гобәйдуллин.



Газиз С. Гобәйдуллин.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Әхәт Шәрифулла улы (2.11.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Тимәш а. — 1.2.1993, Әлмәт ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1959). 1938–41 елларда Воскресенск химия комб-тында (Мәскәү өлкәсе) слесарь, 1946–61 дә «Татнефтегазразведка» трестында бораулаучы ярдәмчесе, бораулау мастеры, 1961–72 дә «Әлмәтнефть» НГДУында скважиналарны капиталь ремонтлау цехы мастеры, 1972–73 тә «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең Минзәлә бораулау эшләре идарәсендә өлкән мастер, 1973–77 дә Әлмәт бораулау эшләре идарәсе башлыгы. Герой исеме нефть һәм газ сәнәгате үсешендә ирешкән зур уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Б и з я е в Б. Губайдуллин Ахат Шарифуллович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Габделкадыйр Салих улы (1888, Казан — 4.5.1944), этнограф. С.С.*Гобәйдуллинның* улы. «Халидия» мәдрәсәсен (1916), Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-тын тәмамлый (1920, Казан). Шәкертләрнең «әл-Ислах» хәрәкәтендә катнаша. 1921–25 елларда Шәрекъ китаплары музее китапханәчесе, *Шәрекъ академиясе, Шәрекъ педагогия институты* укытучысы. 1925–38 дә Баку, Махачкала шәһәрләрендә пед. һәм музей эшендә. Хезмәтләре Казан татарларының аш-суларын, 10 йөз болгар акчаларын тикшерүгә карый. 1938 дә репрессияләнә (Красноярск краеның төзәтү-хезмәт лагерenda тотыла); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Заметки по поводу одного инструмента // Казан. музейный вестн. 1924. № 1; О некоторых редких и ненайденных монетах волжских булгар X века // Материалы Центр. музея ТАССР. 1927. № 1; Пища казанских татар // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1927. № 6 (автордаш).

*Әд.:* Автобиография Абдул-Кадыра Губайдуллина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 3/4.

*Д.М.Галиуллина.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Газиз (Габделгазиз) Салих улы (Г.Газиз) (15.6.1887, Казан — 13.10.1937, Баку), тарихчы, тарих фән. д-ры (1927), проф. (1927), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Казанда *Шәрекъ академиясен* нигезләүчеләрнең берсе. С.С.*Гобәйдуллинның* улы. «Халидия» мәдрәсәсен (1904), Казан ун-тын (1916) тәмамлый. Шәкертләрнең «әл-Ислах» хәрәкәтендә катнаша. «Шимбә»



Г.Г. Гобәйдуллин.

театр түгәрәгә әгъзасы. Ун-тта укыганда татар студентлары түгәрәген оештыручыларның берсе. Түгәрәккә Н.Хәлфин, Г. һәм Б.Шәрәфләр, Г.Коләхмәтов, Ф.Туктаров, М.Гобәйдуллина керә. 1914 елдан пед. эштә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих фәне укыта. 1916–17 елларда «Вазифа» мөселман мәктәбе (Троицк ш.) мөдире. 1917–18 дә татар милли азатлык хәрәкәтендә актив катнаша; *Милли Шура* башкарма ком-ты әгъзасы, *Милләт Мәҗлесе* депутаты, *Идел-Урал штатын гамәлгә кертү Һәйәте* әгъзасы. 1917 нең җәендә Бөтенроссия мөселман укытучылары съездында катнаша, башкарма ком-т әгъзасы булып сайлана. Язмалары «*Корылтай*», «*Алтай*» г-таларында, «*Укытучы*», «*Аң*» ж-лларында басыла. Шул ук елларда аның тарих буенча беренче уку ярдәмлекләре — «Борынгы заман тарихы», «Диннәр тарихы», «Россия тарихы» дөнья күрә. 1921 дә Н.Ф.Катанов һәм Н.Н.Фирсов җитәкчелегендә Казан ун-ты каршында аспирантура тәмамлаганнан соң, фәнни һәм пед. эштә; 1922–25 тә Шәрекъ пед. ин-ты укытучысы; бер үк вакытта ТАССР Мәгариф халык комис-ты *Гыйльми үзәге, Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте* әгъзасы, ТАССР Үзәк музее хезмәткәре. 1925 тә гаиләсе б-н Бакуга күчеп китә; Әзәрбайҗан ун-тының шәрекъ ф-тын һәм Югары пед. ин-тын оештыручыларның берсе. 1925–33 тә, 1935–37 дә Әзәрбайҗан ун-тында Шәрекъ ф-ты деканы, төрки-татар халыклары тарихы каф. мөдире, 1935 тән Якын Көнчыгыш тарихы каф. мөдире. Бер үк вакытта Үзбәкстан ССР Гыйльми үзәге б-н хезмәттәшлек итә; 1925 нең августында Гыйльми үзәк каршындагы Үзбәкләр тарихын һәм телен өйрәнү ком-ты эшендә катнаша, Үзбәкстан ССР Мәгариф халык комис-ты Гыйльми үзәге каршындагы Үзәк мәгариф бюросы рәисе була. 1928 дә Сәмәрканд югары пед. ин-тының мөселман Шәрегы каф. профессоры итеп сайлана. 1 нче Бөтенсоюз тюркология съездында (1926 ның феврале, Баку) катнаша. 1930–31 дә Мәскәү ун-тында лекцияләр укый. 1931–33 тә Советларның гомумәзәрбайҗан съезды делегаты, Баку шәһәренең Ворошилов р-н советы депутаты, Әзәрбайҗан ҮБК каршындагы фәнни-тикшеренү ин-тының тарих секциясе җитәкчесе. 1934 тә ТАССР Мәгариф халык комис-ты чакыруы буенча Казанга кайта, 1934–35 тә Марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү ин-тында, Казан ун-тында эшли. Татарстан тарихы буенча китап әзерләүдә катнаша. Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* әгъзасы, рәис урынбасары, СССР ҮБКның Коммунистик академиясе каршындагы Тарихчы-марксистлар җәмгыяте әгъзасы (1928 дән). Хезмәтләре татар халкы тарихына, татар әдәбиятына («Татар әдәбияты тарихы», т. 1–3, 1922–25, Г.Рәхим б-н берлектә), Идел буенда һәм Әзәрбайҗанда барган крәстиян сугышлары тарихына карый. Сатирик һәм юмористик хикәяләр остасы. «Җомга көн», «Исерек» (икесе дә 1913 тә), «Чалбар» (1915) сатирик новеллалары, Г.Исхакый, С.Рәмиев иҗатлары, 20 йөз башы татар әдәбиятында романтизм турындагы (1911–13 тә басыла) әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Репрессияләр чоры корбаны (к. *«Идел-Уралчылар оешмасы» эше*); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Татар тарихы. К., 1922; Борынгы болгарлар. К., 1924; Пугачёв явы. К., 1924; Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда. К., 1924; Крестьян сугышлары тарихы. К., 1933; Пугачёвщина и татары. Баку, 1927; Из прошлого татар. Лондон, 1990; История татар. М., 1994.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н С.Г. Безнең әтиебез // Татарстан. 1993. № 10; А л и ш е в С.Х. Газиз Губайдуллин как историк // Исследования по историографии Татарии. К., 1978; Н а с р е т д и н о в а Д. Газиз Губайдуллин. Автобиография // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 1/2; А ш н и н Ф.Д., А л п а т о в В.М. Гибель профессора Губайдуллина // ALTAICA II: Сб. статей и материалов. М., 1998; Ш и г а б д и н о в Р. Узбекский период научной деятельности профессора Газиза Губайдуллина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.

*Д.М.Галиуллина.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Геннадий Гобәйдулла улы (15.6.1914, Казан губ., Цивиль өязе Токаево а. — 15.5.1981, Приморье крае, Кавалерово р-ны Хрустальный штп), Сов. Союзы Герое (24.3.1942), гв. өлкән лейтенанты. Арзамас пулемётчылар уч-щесен тәмамлый (1943). 1932–36 елларда Балахна эл. станциясендә һәм Горький автомобиль з-дында эшли. 1936 дан Кызыл Армиядә. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 24 нче гв. миномёт дивизионының (29 нчы армия) разведчиклар отделениесе командиры. Көнбатыш һәм Калинин фронтлары гаскәрләре составында Смоленск сугышында (1941), Торопец шәһәреннән көньяктарак һәм Иделнең сул ярындагы Ржев-Старица участогында оборона сугышларында (1941), Калининны саклауда (1941), Калинин, Вязьма (1942) һәм Ржев-Сычёв (1942) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1942 нең 7 февралендә Ржев янындагы бәрелештә батырлык күрсәтә. 1943 тән Ленинград фронты гв. миномёт частендә взвод командиры. 1945 нең декабреннән запаска, Горький автомобиль з-дында һәм шәһәр тибындагы Хрустальный посёлогы руднигында эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Г. яшәгән йортка мемориаль такта куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Дамир Әнвәр улы (6.12.1957, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1994), РФАнең мөхбир әгъзасы (2003). 1980 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан пед. ин-тында (1980–89), РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында (1989–91); 1991 дән Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында (бү-

ленеп, 1995–98 елларда Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында механика каф. мөдире), 1998 дән директор, бер үк вакытта 2001 дән РФА КГҮ президиумы рәисе урынбасары. Хезмәтләре дулкын динамикасына һәм күп фазалы мохиттә җылы алмашуга карый. Үткәргеч торбалар өзелгәндә кайнап чыгучы сыеклыкларның тотрыксыз дулкынсыман агу процессын фәнни тикшерә, полидисперс системаларда һәм сыеклык катнашмаларында яссы, сферик һәм цилиндрик дулкыннарның таралу теориясен үстерә. Аэрозольләрдә аномаль эффект — тавыш диссипациясенең тамчылар концентрациясенә монотон булмаган бәйлелеген ача, катнашманың параметрларын билгеләү өчен акустик ысул тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә торбалардагы аэрозольләрнең нәсызыкча тирбәнеше, тамчыларның акустик коагуляциясе фәнни тикшерелә һәм торбадагы аэрозоль нәсызыкча тирбәнгәндә тамчылар коагуляциясенең тәэсир итү ешлыгына бәйлелегенең монотон булмавы ачыклана. Дуслык ордены б-н бүләкләнә. (1999).



Д.Ә. Гобәйдуллин.

Хезм.: Нестационарные истечение сжиженных углеводородов при разрыве трубопроводов // Теплофизика высоких температур. 1986. Т. 24, № 2 (автордаш); Эффект немонотонной зависимости диссипации звука от концентрации капель в акустике газовзвесей // Докл. АН СССР. 1991. Т. 316, № 3 (автордаш); Влияние фазовых превращений в акустике полидисперсных туманов // Докл. РАН. 1996. Т. 337, № 3 (автордаш); Динамика двухфазных парогазокапельных сред. К., 1998; Сферические и цилиндрические волны малой амплитуды в полидисперсных туманах с фазовыми превращениями // Изв. РАН. Механика жидкости и газа. 2003. № 5.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Камил Гобәй улы (9.12.1949, БАССРның Ишембай ш.), график, нәкышьче, БРның атказ. рәссамы (1997). П.П.Беньков исем. Ташкент сәнгать уч-щесенең театр бизәлеше бүлеген тәмамлый (1969). Х.Хәмзә исем. Ташкент акад. драма театрында рәссам (1972–73), Театр-сәнгать ин-тында офорт эшенә өйрәтү остасы (Ташкент, 1973–75) булып эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1979). 1980 елдан БРның Ишембай шәһәрендә яши. Көньяк Башкортстан рәссамнары ассоциациясе рәисе (1996). Офорт һәм литография остасы, Башкортстанда графика сәнгате, бигрәк тә эстамп сәнгате үсешенә зур өлеш кертә: графика әсәрләре серияләре — «Дон Кихот» (1973–75), «Арал диңгезе» (1975, 1988), «Ишембай нефте» (1984–85), «Башкорт готикасы» (1993–96), «Хакимият экологиясе» (1992–99) һ.б.; офортлар — «Буралар» (1981), «Авыл зиратында печәнлек», «Карсыз кыш» һәм «Байгуҗада карга оялары» (барысы да — 1982), «Кое» һәм «Яңгыр астында кайту» (икесе дә — 1985), «Көзге мәшәкатьләр» (1986), «Тегермән ташы» (1988) һ.б.; литографияләр — «Джун каналы» һәм «Тауларда кыш» (икесе дә — 1980), «Диңгезгә илтүче юл» (1981) һ.б.; нәкышь эшләре — «Остаханәдә» (1974), «Иске баркаслар. Арал» (1978), «Таң. Әтәч» (1984), «Автопортрет» (1984), «Тора тау белән хушлашу» (1985–88), «Нефть һәм кылган» (1988), «Тегермән ташлары» (1988), «Күгәрчен һәм ир-ат» (1988–89), «Әүлия» (2001).

Г.ның сурәтләү чараларына стиль төгәллеге хас, офортларындагы композиция төзелешендә станлы нәкышь йогынтысы сизелә. Аның социаль юнәлештәге әсәрләрендә авыр хезмәт, катлаулы рухи кичерешләр, кеше б-н табигать арасындагы каршылыклар, экологик һәм техноген афәтләр б-н тулы кырыс тормышның тирән фәлсәфәсе чагылыш таба.


1971 дән төрле күргәзмәләрдә катнаша; ш.и. Бөтенсоюз яшьләр күргәзмәсе (Мәскәү, 1978), III Бөтенроссия эстамп күргәзмәсе (Уфа, 1984), 1 нче Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия станлы графика күргәзмәләре (Мәскәү, 1986 һәм 1987), 7 нче Бөтенроссия эстамп күргәзмәсе (Мәскәү, 1989, диплом), «Россия эстампы» квадриенналесы (Мәскәү, 1996). Шәхси күргәзмәләре 1979 да (Ташкент), 1982 дә (Уфа), 1984 тә (Ленинград), 1996 да (Уфа) уза. «Сәнгатьтә тарих чагылышы» исемле респ-ка конкурс-күргәзмәсендә 1 нче премия һәм 1 нче дәрәҗә дипломга лаек була (Уфа, 1999).

Әсәрләре А.С.Пушкин исем. дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. сәнгать музеенда (Уфа), ТР, Үзбәкстан (Ташкент), дәүләт сынлы сәнгать музейларында, Чабаксар, Воронеж, Ростов-Дон шәһәрләре картиналар галереяларында, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Россия сәнгать академиясендә (Мәскәү), Франция, Италия, Германия, Голландия, Япония, АКШта шәхси коллекцияләрдә саклана. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1997).

*Әд.:* Губайдуллин Камиль. Живопись, графика. Йошкар-Ола, 1989; Губайдуллин Камиль Губаевич // Сияние лун. Уфа, 2001; Биографический справочник членов Союза художников России в Башкортстане. Уфа, 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*





К.Г.Гобәйдуллин. 1. «Байгуҗада карга оялары». Офорт. 1982. Башкортстанның М.В.Нестеров исем. Дәүләт сәнгать музее (Уфа ш.); 2. «Тегермән ташлары». Офорт. 1988.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Мансур Садыйк улы (29.11.1920, БАССРның Әлшәй р-ны Аксёнов штп), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1978), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елда Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый. 1953–90 елларда СССР ФА Башкортстан гыйльми үзәгенең икътисади тикшеренүләр бүлегендә, 1980 нән сектор мөдире булып эшли. 1990–95 тә Башкортстан терлекчелек һәм терлек азыгы җитештерү фәнни-тикшеренү һәм проект-технол. ин-тында баш фәнни хезмәткәр. Фәнни тикшеренүләре а.х. тармакларын интенсивлаштыру, урнаштыру, агросәнәгать комплексында хуҗалыкара кооперацияләү һәм агросәнәгать интеграциясе барышында икътисади бәйләнешләрне камилләштерү проблемаларын хәл итүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Размещение и специализация сельского хозяйства Башкирии. Уфа, 1966; Интенсификация сельского хозяйства и его основных отраслей. Уфа, 1972; Опыт и проблемы межхозяйственного кооперирования. Уфа, 1979; Технологический прогресс и проблемы развития общественного животноводства в условиях научно-технического прогресса. М., 1979; Животноводство в АПК Башкирии. Уфа, 1984; Формирование крестьянских (фермерских) хозяйств в Башкирии. Уфа, 1992.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Рәфкать Галим улы (16.9.1940, Фрунзе), материаллар белеме гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1963 елда Фрунзе политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Чиләбе политехник ин-тында (хәзер Көньяк Урал ун-ты), төзелеш конструкцияләре һәм инженерлык корылмалары кафедрасында эшли. Хезмәтләре кысылган терәкләрнең оптималь кисемен билгеләүгә һәм үтә нык корычларны төзелештә нәтиҗәле куллануга карый. Диңгездәге стационар платформа конструкцияләренең каршылыгын һәм тузудан җимерелүен хисаплау ысулларын эшли. Континент шельфында нефть һәм газ чыганакларын эзләү һәм тикшерү өчен техник чаралар эшли һәм гамәлгә кертә, диңгездә 300 *м* га кадәр тирәнлек өчен платформа терәкләре һәм Сахалин утравы шельфы өчен бозга чыдам стационар платформалар әзерләүдә катнаша. Диңгездәге стационар платформа конструкцияләренең хәвефлелек дәрәҗәсен бәяләү методикасын тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Оценка усталостной долговечности конструкций морских стационарных платформ //



Рәшит Г.Гобәйдуллин.



Сафиулла С.Гобәйдуллин.

Изв. вузов. Строительство. 1993. № 3/4; Расчёт точности стальных конструкций: Обзор. М., 1993; Метод расчёта статической прочности конструкций морских стационарных платформ с учётом их сопротивления хрупкому разрушению // Изв. вузов. Строительство. 1994. № 3; Деформационный подход к оценке критических температур хрупкости узлов и элементов стальных конструкций // Изв. вузов. Строительство. 1997. № 1/2.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Рәшит Гомәр улы (10.11.1931, Оренбург өлкәсе Танаулык а. — 18.7.2000, Мәскәү), композитор, педагог. Ташкент консерваториясен (Г.Васильевта виолончель классы, 1954), Гнесиннар исем. Музыка-пед. ин-тын (Мәскәү, 1967) тәмамлый. 1970–72 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамбле сәнгать җитәкчесе, 1972–76 да Казан пед. ин-тында музыка теориясе, тарихы һәм музыка уен кораллары каф. мөдире. 1976 дан Мәскәүдә яши, балалар музыка мәктәпләрендә укыта һәм үзешчән музыка коллективларына, студияләргә җитәкчелек итә. Татар муз. театрлары үсешенә зур өлеш кертә. Г.ның театральләшкән муз. әсәрләре арасында «Кисекбаш» балеты (Г.Тукай поэмасы буенча, Ә.Фәйзи либр.) ачык сатирик һәм образлылыгы, динамик сәхнә хәрәкәте, халык жанры элементларының, ш.у. бәет һәм мөнәҗәтләрнең стилистик эпик җанрлар үзенчәлеген тормышка ашыруы б-н аерылып тора. Г.ның «Җиһангир» операсы (Х.Вахит либреттосы) татар лирик-психол. оперalar үсеше традицияләрен дәвам итә. Анда бай мелодик теле б-н аерылып торган халык вәкилләре образлары чагылыш таба. С.Садыйкова б-н берлектә иҗат ителгән «Мәхәббәт җыры» (1971) һәм «Кияүләр» (1972) муз. комедияләре популярлык казана. Г. иҗаты мирасының зур өлешен оркестр өчен язылган һәм камера-инструменталь әсәрләр алып тора, аларда классик музыканың төп формалары һәм жанрлары б-н эшләү осталыгы ачыла. Г.ның иҗатына жанрлар төрлелеге, аның бай сәнгать чаралары б-н иркен эш итә белүе хас. Композиторның күп чыганаклары күп төрле, аның мелодикасы халык көйләре (ш.и. борынгы татар көйләре) традицияләре җирлегендә 20 йөз музыка ритмын һәм гомуммәгънәле интонацияләр демократизмын колачлый. Г. иҗатында татар композиторлык мәктәбенең алдынгы традицияләре үсә һәм дәвам итә.

Төп әсәрләре: «Кисекбаш» (Г.Тукай поэмасы буенча, Ә.Фәйзи либреттосы, 1958), «Чака» (Д.Мамаду либреттосы, 1983) балетлары; «Җиһангир» (Х.Вахит либреттосы, 1976), «Идегәй» (Р.Харис либреттосы, клавирда тәмамлана, 2001) опералары; симфоник әсәрләре: «Яшьләр увертюрасы» (1958), «Бәйрәм увертюрасы» (1970), «Идел буе халыклары темасына сюита» (1982), «Якутлар темасына симфоник вариацияләр» (1983); виолончель (1961), труба (1960), фортепиано өчен (1968) концертлар; кыллы квартет (1963), скрипка, альт һәм виолончель триосы өчен (1978) камера-инструменталь әсәрләр, инстр. ансамбль өчен «Музыкаль күренешләр» әсәре (1972), скрипка һәм фортепиано өчен соната (1967); виолончель һәм фортепиано өчен 10 пьеса (1980), солистлар, хор һәм оркестр өчен «Торналар кайтканда» ораториясе (1969), «Беренче очыш күге» (1977) һәм «Ана йөзе нуры» (1978) вокаль цикллары; спектакльләргә һәм кинофильмнарга музыка, җырлар һ.б.

*Әд.:* Кантор Г.М. Рашид Губайдуллин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Ринат Шәйхулла улы (21.6.1960, Яшел Үзән ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1986). 1986–92 елларда ТР Финанс министрлыгында. 1992–93 тә «Алина» ширкәте директоры урынбасары, директоры. 1993–96 да «Алтын башак» чикле инвестиция фонды идарәчесе, «Татфондбанк» АҖ идарәсе рәисе. 1996–97 дә ТР Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру дәүләт ком-ты рәисе. 1997–98 дә «Ак барс» банкы идарәсе рәисе. 1998–99 да ТР премьер-министры урынбасары — ТР икътисад һәм сәнәгать министры. 1999–2003 тә «Татфондбанк» АҖ идарәсе рәисе. РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутаты (2003 тән).

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Салих Сабит улы (20.7.1862, Казан — 1935, Дагстан АССРның Махачкала ш.), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Аның әтисе Сабит Гобәйдуллин (1821, Казан губ. Югары Пошалым а. — 1870 еллар) 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре була, үз мануфактурасын оештыра. Г. 1 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсәне тәмамлый, Ш.*Мәрҗани* шәкерте. Ул әтисенең пр-тиесен зурайта, мануфактура товарлары эшләп чыгара һәм сәүдә б-н шөгыльләнә. 1910 елда мануфактураны шинель поставы җитештерүгә көйли; армия ихтыяҗлары өчен постау җитештергәне өчен медаль б-н бүләкләнә. Г.ның ш.у. Казанда туку ф-касы һәм керем китерүче күчемсез милке дә була. 1908 дә Хәерби авылында (хәзерге Лаеш р-нына керә) агач мәчет һәм ике катлы кирпеч йорт салу өчен акча бирә. Демократик яшьләр үткәргән чараларга (әдәби-муз. кичәләр уздыруга, «Әлислах» г-тасын чыгаруга), ш.у. Ш.Мәрҗанинең 100 еллык юбилеена багышланган җыентыкны нәшер итүгә акчалата ярдәм күрсәтә. Окт. рев-циясеннән соң Г.ның мөлкәте дәүләт тарафыннан тартып алына. 1927 дән Бакуда һәм Махачкалада яши. Ш.у.к. Газ.С.*Гобәйдуллин*, Габ.С.*Гобәйдуллин*, М.С.*Гобәйдуллина*.

*Әд.:* Гобәйдуллин С. Бабам Салих турында // Идел. 1994. № 1; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Сафиулла Сәлимулла улы (15.8.1929, Буа кантоны Тутай а.), кран машинисты, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1948–52 елларда Кузбасс шахталарында эшли. 1953–96 да Казан «Гидроспецстрой» идарәсендә электромонтёр, төзелеш техникасын ремонтлау слесаре, копёр машинисты, монтаж краны машинисты. Герой исеме капиталь төзелеш буенча бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ларичева Э. Губайдуллин Сафиулла Салимуллович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Фәрит Галим улы (8.5.1937, Фрунзе ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1998), проф (1998). Фрунзе политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Кыргызстан ССРның җитештерү һәм фәнни оешмаларында эшли. 1968 елдан Казакъстан ССР ФАнең Геол. фәннәре ин-тында, 1998 дән руда формацияләре лаб-ясе мөдире (Алма-Ата). Казакъстан терр-ясендә вольфрам һәм комплекслы (вольфрам, аккургаш, молибден, бериллий, висмут) сирәк металлы казылмалар табу перспективасын күрсәтә. Казакъстан терр-ясенең металл формацияләре буенча күп кенә урта һәм вак масштаблы карталарын төзүдә катнаша («Казакъстанның минераль ресурслары. Сирәк металлар» («Минеральные ресурсы Казахстана. Редкие металлы». А.-А., 1992).

Хезм.: Металлогенические провинции и пояса Казахстана. А-А., 1983 (автордаш); Редкометалльное оруднение Казахстана. А-А., 1988 (автордаш).

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Хәсән Хәйрулла улы (28.12.1913, Уфа ш. — 9.7.1992, Казан), театр белгече, сәнгать белеме канд. (1964), ТР-ның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый (1937), мәктәптә укытучы булып эшли. 1940–48 елларда Татар опера һәм балет театрында хор артисты, режиссёр ярдәмчесе, 1948–52 дә Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлегендә фәнни консультант, 1954–59 да музыка мәктәбе директоры, 1959–77 дә Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре татар халкы тарихына, мәдәниятенә һәм сәнгатенә багышлана. Г. — татар театр белеменә нигез салучыларның берсе. Татар театры тарихына караган документ һәм материалларны җыю, системага салу һәм бастырып чыгаруда зур хезмәт башкара: «Казанның тарих һәм мәдәният истәлекләре» («Казань в памятниках истории и культуры», 1982), «РСФСР һәм ТАССРның тарих һәм мәдәният истәлекләре җыелмасы материаллары» («Материалы свода памятников истории и культуры РСФСР и ТАССР», 1984) дигән хезмәтләр, Г.Кариев (1967, 1977), Н.Исәнбәт (1970), С.Гыйззәтуллина-Волжская (1982) турында истәлекләр җыентыкларын чыгаруда катнаша. Театр тәнкыйтьчесе буларак, татар һәм башкорт театрларында барган

спектакльләргә рецензияләр яза; «Театр энциклопедиясе»ндә («Театральная энциклопедия», М., Т. 1–5, 1961–67) татар театр эшлеклеләре турындагы мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1964 (автордаш); Татар совет театры. К., 1975 (автордаш).

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Мара Шәүкәт кызы (1.1.1956, Казакъстан Республикасы, Кентау ш.), сәясәтче, тарихчы, тарих фән. д-ры (2005), проф. (2006). Казакъ ун-тын тәмамлый (1979). 1980 елдан Казакъ ун-тында (хәзерге әл-Фараби исем. Казакъ милли ун-ты): иҗтимагый профессияләр ф-ты методисты, чит телләр каф. укытучысы, Социологик үзәк тикшерүчесе (1980–89); гомуми тарих каф. укытучысы (1992). 1993 тән Казакъстан Респ-касы халыкара мөнәсәбәтләр һәм тышкы сәясәт кафедрасында. Хезмәтләре Европада, Үзәк Азиядәге халыкара мөнәсәбәтләргә, Германиянең, Казакъстанның тышкы сәясәтенә, Европадагы интеграция процессларына, Үзәк Азиядә халыкара оешмалар эшчәнлегенә һ.б. багышлана.

Х е з м.: Внешняя политика Германии. 1871–2004. Алматы, 2004; Австрия — член Европейского союза. Алматы, 2004 (автордаш); НАТО и Центральная Азия: региональная и национальная безопасность и стратегическое партнёрство. Алматы, 2004 (автордаш); Центральная Азия во внешней политике Европейского Союза. Алматы, 2004 (автордаш); Германия в процессе европейской интеграции. Алматы, 2007; Индия и Казахстан в международных отношениях. Алматы-Дели, 2007; Сотрудничество Республики Казахстан с Организацией по безопасности и сотрудничеству в Европе. Алматы, 2007 (автордаш); Германо-Казахстанские отношения в контексте регионального сближения ЕС и Центральной Азии. Алматы-Берлин, 2009.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Мәрьям Салих кызы (1892, Казан — 1933, Баку), этнограф. С.С.*Гобәйдуллинның* кызы. Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-тын тәмамлаганнан соң (1920, Казан), шунда ук Шәрекъ этнографиясе кафедрасында эшли. 1918 елда Шәрекъ халыклары мәдәниятенә багышланган күргәзмә әзерләүдә катнаша. Беренче булып «Казан татарлары этнографиясе» дигән лекцияләр курсы эшли. 1922 дән Шәрекъ пед. ин-тында укыта, төрки-татарлар этнологиясе буенча лекцияләр укый. *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* эшендә актив катнаша. Бер үк вакытта ТАССР Үзәк музеенда эшли. 1925 тән Баку Югары пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре Татарстан, Әзәрбайҗан халыклары этнографиясенә (ш.и. Казан татарлары, Әзәрбайҗан төркиләре ашлары турында этнографик очерклар) карый.

Х е з м.: Пища казанских татар // Вестн. Научн. об-ва татароведения. 1927. № 6 (автордаш); Пища азербайджанских тюрок // Изв. Вост. факультета Азерб. гос. ун-та. Востоковедение. 1928. Т. 3.

*Әд.:* Г у б а й д у л л и н а А. Наша дорогая Мариам апа // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.

*Д.М.Галиуллина.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Рәисә Гобәйдулла кызы (12.2.1912, Казан губ., Чистай өязе Яңа Кади а. — 22.1.1997, Әлмәт ш.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1968). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1934). 1934–37 елларда Татар эшче театрында, 1937–49 да Мамадыш колхоз-совхоз театрында, 1949 дан Әлмәт татар драма театрында эшли. Сәхнә эшчәнлеген техникумда укыган елларында Татар акад. театрында актриса-травести (үсмер малай рольләрен башкаручы) буларак башлап җибәрә. Осталыкка татар сәхнәсе корифейлары М.Мутин, З.Солтанов, Н.Арапова, Г.Болгарскаялардан өйрәнә. Г.Камал (Биби — «Беренче театр»), К.Тинчурин (Гөлҗамал — «Сакла, шартламасын!») комедияләрендәге, Ш.Камал (Зәйнәп — «Ут»), Р.Ишморат (Алсу — «Ватан өчен!», Раушания — «Гөлзада») драмаларында ул уйнаган героинялар шуклык-наянлыклары, халыкчан юморы, оптимистик рухлы булулары б-н аерылып торалар. Р.Ишморатның «Кайту» драмасында үсмер малай Ирбулат образы Г. башкаруында киң иҗтимагый резонанс ала. Әлмәт театры сәхнәсендә Г. истә калырлык күп рольләр башкара: Гөлгөл («Гөлмәрфуга», И.Абдуллин), Саҗидә («Ана бәхете», Ш.Шаһгали), Фатыйма («Бөдрә тал», Г.Минский), Хөзәймә («Балыкчы кызы», Г.Уральский), Гайшә («Рамай», М.Хәсәнов), Хәдичә («Утлар яна учакта», Г.Ахунов). Тышкы бизәкләрне аз кулланып, психологик тирәнлеккә ирешүе, башкаруының тормышчанлыгы һәм җиңеллеге актрисага образларны ышандырырлык итеп чагылдыру мөмкинлеге бирә һәм шуның б-н тамашачыда җанлы кызыксыну уята. Классик драматургия әсәрләрендәге рольләрне башкарганда Г. күп төрле сурәтләү чаралары куллана: Тәлли («Аршин мал алан», Г.Гаҗибәков), Мөршидә, Зөләйха («Ташкыннар», «Бишбүләк», Т.Гыйззәт), Хаҗи-апа («Бай һәм батрак», Х.Хәмзә), Күнәкәй («Козы көрпеш һәм Баян сылу», Г.Мөсрәпов).



Р.Г. Гобәйдуллина.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Р ә х и м о в Ж. Әлмәт татар дәүләт драма театры. Әлмәт, 1994.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** София (Сония) Әсгать кызы (24.10.1931, Чистай ш.), композитор, РСФСР, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989, 2001), Көнбатыш Берлин Сәнгать академиясенең шәрәфле әгъзасы (1988). 1954 елда Казан консерваториясен (Л.Г.Лукомский һәм Г.М.Коганда — фортепиано, А.С.Леманда композиция классында шөгыльләнә), 1959 да Мәскәү консерваториясен (Н.И.Пейконың композиция классы), шунда ук 1963 тә аспирантура (Б.Я.Шебалинның композиция классы) тәмамлый. 1960–70 еллардан тавыш чагылышы өлкәсендә яңа алымнарны тирәнтен өйрәнә. 1969–70 еллар башында Мәскәү экспериментальь электрон музыка студиясендә эшли; 1980 елларда иҗади җәмгатьчелек тарафыннан «Мәскәү өчлеге» әгъзасы буларак бәяләнә (А.Шнитке һәм Э.Денисов б-н берлектә). 1991 дән Германиядә (башта Ворпсвед шәһәрендә, 1992 дән Аппен-Унтерглиндта) яши.

Г.ның музыкасы стилистик һәм авторлык оригинальлеге, уен кораллары составының күп төрлелеге, жанр киңлеге: хәзерге дөньяны миниатюр һәм филигран бизәлештән (мәс., «Дюймовочка») монументаль символик-дини гомумиләштерүгә кадәр чагылдыруы б-н аерылып тора («Иоанн газаплары» — «Страсти по Иоанну»). Г. музыкасына образларны капма-каршы кую хас. Ул үзе: «Кискен каршылык, ике ипостаськә (асылга) аерылу яки бүленү миңа тумыштан бирелгән. Әтием — татар, әнием рус булганга, мин берьюлы ике — Көнчыгыш һәм Көнбатыш җиһанныкы булам», — дип яза. Капма-каршылыкка һәм үзара бәйләнгәнлеккә, реаль-акустик һәм синтезланган яңгырашка корылып язылганга, Г.ның кайбер әсәрләрендә, «Җанлы-җансыз» («Vivente non vivente», 1970) дип аталганнан башлап ук, каршылыклы идеяләр чагыла. Шулар рәтендә: «Тавыш һәм тынлык» («Rumore e silenzio», 1974), «Яктылык һәм караңгылык» («Светлое и тёмное», 1976), «Уңай һәм тискәре» («Pro et contra», 1989), «Җөп һәм так» («Чёт и не́чет», 1991) әсәрләре бар. 1980–90 еллардагы әсәрләрендә саннар символикасы аеруча әһәмияткә ия («Аллилуйя», 4 нче квартет). Партитураны башта ук җентекләп эшләгәнгә күрә, еш кына әсәрләр специфик саннар сюжеты кебек кабул ителә. Г.ның муз. сәнгате дөньясы тамашачыны үзенең нәзакәтлелеге, ихлас чисталыгы, саф һәм серле мөрәҗәгате б-н җәлеп итә. Үзенең иҗат үзенчәлегенең әчке халәтен композитор: «.... чынбарлыкны тоюның вакыт та, киңлек тә булмаган баскычына күтәрелгән саен, кешенең күңеле чистарып һәм үтә күренмәле булып кына калмый, бәлки ул тагын да ачылып, сафланып китә», — дип тасвирлый. Г. 20 йөз музыка сәнгатенә яңа аваз ресурсларын эзләү һәм эшләүгә шактый өлеш кертә. Аның музыкасы колоритлы яңгырашы, хәзерге экстраординар чараларны тәэсирле, үткен куллану һәм үзенә генә хас аваз тембры (сонорлы) эстетикасы, тавышның этнотембрлы яңгырашын файдалану б-н аерыла. Бу уңайдан «Күңел сәгате» («Час души») әсәре ахырында чанганың (үзбәк халык уен коралы) саф, чиста яңгырашы, яисә Кото, бас-кото, шен һәм оркестр өчен язылган концерты япон халык уен кораллары тәэсирендә гадәти булмаган яңгырашы б-н игътибарны җәлеп итә. Г. музыкасында бигрәк тә «Шәрекъ өчен хас булган «яңгырамау», яңгыраучы тынлык идеясенең яңача эстетик һәм сәнгати чагылышы үсеш ала. Композитор үз карашының раслануын мөселман йолаларындагы «сүзсез аралашу»да күрә. Г.ның хәзерге муз. ладлар дөньясын киңәйтү өлкәсендә яңалык кертүе геомәдәни алшартлар барлыкка килү б-н аңлатыла. Микрохроматика ярдәмендә (ярты тоннан кече булган тавыш югарылыгы системасы) аның тарафыннан аерым система булдырыла. Тавышның яңа концепциясе, яңгырашы, аның акустик үзенчәлеге (мәс., «Офферториум»да тавыш драматургиясе)шуннан үсеп чыга. Еш кына Г. үзенең иҗатында татар музыкасының образлылыгы һәм стилистикасы башлангычына, пентатониканың яңа ори-



С.Ә. Гобәйдуллина.

гиналь алымнарына, муз. вакытка, тембр интонациясе трактовкасына мөрәҗәгать итә (думбра һәм фортепиано өчен «Татар фольклоры мотивлары», баян һәм ике контрабас өчен «Татар биюе»). Г. композитор буларак, кинематография сәнгатендә дә оригиналь муз. концепцияләр эшләү сәләтен күрсәтә.

Аның киномузыка өлкәсендәге эшләре арасында: «Вертикаль» (1966), «Маугли» (1971), «Табиб Калинникованың һәр көне» («Каждый день доктора Калинниковой», 1973), «Карачкы» («Чучело», 1983), «Ирек сөючән Песи» («Кошка, которая гуляла сама по себе», 1984) әсәрләре бар. Г.ның музыкасы — дөньядагы концерт тормышыннан аерылгысыз. Аның әсәрләрен дөньяның атаклы музыкантлары Г.Кремер, Г.Рождественский, В.Гергиев, Ю.Башмет, Н.Гутман, М.Пекарский һ.б. үзләренең концерт программаларына кертәләр. Г.ның орган өчен язган әсәрләрен беренче башкаручы Р.Абдуллин була.

РФнең Дәүләт (1992), композиторларның 7 нче халыкара конкурсы (Рим, 1975, 1 нче бүләк), Монако кенәзе Ренье IIIнең (1987), Кусевицкийлар исем. (АКШ, 1990, 1994), Хатын-кыз композиторларның 7 нче халыкара фестивале (Гейдельберг, 1992), «Империале» (Япония, 1998), «Библия һәм Мәдәният» фонды (Германия, 1999), Швеция музыка академиясе «Полар» (2002) бүләкләре лауреаты. «Фән һәм сәнгатьтәге хезмәтләре өчен» ордены б-н бүләкләнә (Германия).

Төп әсәрләре: «Тылсымлы курай» («Волшебная свирель», 1960), «Дулкыннар өстеннән йөгерүче» («Бегущая по волнам», А.Грин романы буенча, 1963) бер актлы балетлары; «Ишетәм ... илаһи тынлыкны ...» («Stimmen ... verstummen ...», 1986), «Вакыт фигурасы» («Фигура времени», 1994) симфонияләре; симф. оркестр өчен «Диңгез» («Море», 1963) симф. картинасы, «Тантана» («Триумф», 1963–64) увертюрасы; «Дөньяга мәдхия» («Landatio pacis», М.Копелент һәм П.-Х.Дитрих б-н берлектә, 1975) ораториясе; «Мемфис төне» («Ночь в Мемфисе», 1968), «Робагый» («Рубайят», 1969) кантаталары; «Җан авазы» («Час души», 1976) бәрмә уен кораллары һәм симф. оркестрга кушылып ялгыз җырлау өчен инструменталь концерт; Ике оркестр өчен концерт (1976), «Jnutroitus», (фортепиано һәм камера оркестры өчен, 1978), «Корбан бирү» («Offertorium», 1980, 1982, 1986) скрипка һәм оркестр өчен, «Чиркәү китабыннан» («Из часослова» виолончель, оркестр һәм ирләр хоры өчен, 1991), Оркестр б-н альт өчен концерт (1996), «Агач астында күләгәдә» («В тени под деревом», 2000) кото, бас-кото, бас, ике хор һәм оркестр өчен; № 1 (1971), № 2 (1987), № 3 (1987), № 4 (магнит тасмасы б-н, 1993) квартетлары; «Фацелия» (югары сопрано һәм симфоник оркестр өчен, 1956) вокаль циклы; «Биш этюд» (арфа, контрабас, бәрмә уен кораллары өчен, 1965) инструменталь ансамбльләре; «Пантомима» (контрабас һәм фортепиано өчен, 1966); «Марк Пикарский коллекциясеннән клавесин һәм бәрмә уен кораллары өчен музыка» (1972), «Quatro» (ике торба һәм ике тромбон өчен, 1974), «Татар фольклоры мотивы буенча» («По мотивам татарского фольклора», думбра һәм фортепиано өчен, 1977); «Әйтелгән сүз» («Detto-i», орган һәм бәрмә уен кораллары өчен, 1978); «Юбиляция» (4 бәрмә уен коралы өчен, 1979), «Jn croce» (виолончель һәм орган өчен, 1979), «Татар җыры», «Бәйрәм», «Сөембикә» (ике торба өчен, 1979), «Эндәшмәү» («Silenzio», баян, скрипка һәм виолончель өчен, 1991); «Татар биюе» («Татарский танец», баян һәм ике контрабас өчен, 1992); «Иртә таңнан уяныр алдыннан» («Рано утром перед пробуждением», 7 кото өчен, 1993); кинофильмнарга музыка һ.б.

*Әд.:* Х о л о п о в а В. Музыка спасёт мир // Советская музыка. 1990. № 9; ш у л у к. Николай Бердяев и София Губайдулина в той же части Вселенной // Советская музыка. 1991. № 10; ш у л у к. Суперсимфония Губайдулиной, Пярта, Сильвестрова, режиссированная Кремером // Музыкальная академия, 1995. № 3; Ц е н о в а В. Числовые тайны музыки Софии Губайдулиной. М., 2000; ш у л у к. София Губайдулина: Путеводитель по произведениям. М., 2001.

*А.Л.Маклыгин.*

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Татьяна Николаевна (15.8.1953, Мәскәү өлкәсенең Коломна ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2001). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1974). 1976–81 һәм 1984–94 елларда Казан авиация ин-тында фәнни һәм укыту эшендә. 1974 елда һәм 1999 дан Казан финанс-икътисад ин-тында, икътисад теориясе каф. профессоры (2001), микроикътисад каф. мөдире (2002 дән). Фәнни хезмәтләре бүгенге шартларда экологик-икътисади система үсеше проблемаларына карый.

Х е з м.: Методологические аспекты развития эколого-экономических отношений в современных условиях. К., 1999; Экономика и экология: равновесное развитие. К., 2000; Устойчивое развитие эколого-экономической системы: вопросы теории и методологии. К., 2000.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Фәйрүзә Насыйх кызы (18.9.1933, Үзбәкстан ССРның Термез ш.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1975), проф. (1976). 1958 елда Сәмәрканд мед. ин-тының дәвалау ф-тын тәмамлагач, Ташкент мед. ин-тында, 1959–62 елларда Наманган өлкә шифаханәсендә, 1962–66 да Волгоград мед. ин-тында, 1966–74 тә Әндиҗан мед. ин-тының акушерлык һәм гинекология кафедрасында, 1975 тән кафедра мөдире, 2002–2007 дә каф. профессоры. Хезмәтләре хатын-кызларның җенси әгъзаларында ялкынсыну авыруларына, балага узмауга диагноз кую һәм дәвалауга карый.

Х е з м.: Лечение больных, страдающих бесплодием на курорте Чартак: Материалы I Респ. конференции по вопросам курортологии. Ташк., 1966; Комплексное лечение хронических воспалительных заболеваний женских половых органов // Мед. журн. Узбекистана. Ташк., 1968. № 8.

**ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА** Эльза Гариф кызы (26.8.1938, Казан — 7.4.1997, шунда ук), радио журналисты, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Язучы Г.*Гобәй* кызы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), «Татарстан» ДТРК дә «Соңгы хәбәрләр» программасы хәбәрчесе, 1963 елдан әдәби-нәфис тапшырулар редакциясе, 1985 тән балалар һәм яшьләр тапшырулары редакциясе мөхәррире. Татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре тормышына һәм иҗат юлына багышланган тапшырулар циклларын алып бара. Ул оештырган «Әңгәмәдәш» («Собеседник»), «Күңелле баскычлар» («Веселые ступеньки») һ.б. программаларның аерым чыгарылышлары Бөтенсоюз радиосыннан да трансляцияләнә. Татарстан радиосының төп фондын тәшкил иткән тематик тапшырулар, композицияләр һәм радиотамашалар авторы («Актёр белән очрашу», «21 йөз интеллекты», «Хәтер» һ.б.).

*Әд.:* Д о р о щ у к Е. След времени быстробегущего // Тыңлагыз, Казан сөйли! — «Слушайте, говорит Казань!» К., 1998.

*Г.Р.Заманова.*


**ГОБЕЛЕ́Н** (фр. gobelin), бизәлеш максатларында кулдан тукылган югары сәнгати кыймәткә ия тукыма; тукылган рәсемнәр, дивар келәмнәре һ.б. Гобелен фамилияле француз буяучылары исеме б-н аталган.

20 йөз сәнгатендә «Г.» төшенчәсе б-н Көнбатыш Европадагы классик Г. традицияләре — шпалерадан башлангыч алган, кулдан тукылган уникаль тематик һәм бизәкле панноларны (келәмнәрне) атыйлар. Г. чималы буларак нигездә йон, кайвакыт мамык һәм җитен кулланылган. Рәссам композицияләрне алдан катыргыга төшерелгән эскиз нигезендә тукый (еш кына рәссам үзе үк башкаручы да).

Татарстанда Г. сәнгатенә М.С.*Килдебәкова* нигез сала. 1964 елда ул республикада беренче булып, келәм туку ысулы б-н «Музыкант» дип исемләнгән сюжетлы Г. эшли.

1974–90 да М.С.Килдебәкова республика Сәнгать фонды каршында А.Н.Егоров, Г.Н.Маликова, Г.Шәрипова катнашында оешкан һөнәр остаханәсен җитәкли. Эшчәнлекләрен алар иҗат бригадасына берләшеп башлыйлар, һәм беренче киң күләмле эшләре Казан көнкүреш йортының үзәк демонстрацияләү залы диварында келәм ысулы б-н тукылган «Татарстан» гобелены була (1975–76, катыргыда эскиз авторы — Р.Ә.Килдебәков). Остаханә рәссамнары иҗатында ике юнәлеш — орнамент б-н бизәлешле Г. (А.Н.Егоров — «Ай яктысы», 1977; «Тау чишмәсе», 1981; М.С.Килдебәкова — «Чәчәкле интерьер», 1980 һ.б.) һәм сюжетлы-тематик (А.Н.Егоров — «Казанны акгвардиячеләрдән азат итү», 1978; «Иске фонтан», 1980; Г.Н.Маликова — «Су анасы», 1987 һ.б.) юнәлешләр билгеләнә.

1970 еллар ахыры — 1980 еллар — Татарстанда Г. сәнгатенең чәчәк ату чоры. Аңа Россия сәнгать югары уку йортларын һәм уч-ще-




**Гобелен мәкаләсенә.** 1. Р.Ә. К и л д е б ә к о в һәм М.С. К и л д е б ә к о в а. «Гөлчәчәк». Йон, тигез туку. 1974. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. А.Н. Е г о р о в. «Тау шарламалары». Йон, тигез туку. 1979; 3. Г.Н. М а л и к о в а. «Ала миләүшә». Йон, катнаш техника. 1981; 4. А.Н. Е г о р о в. «Казанны акгвардиячеләрдән азат итү». Йон, тигез туку. 1978. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Г.Н. М а л и к о в а. «Язгы моң». Йон, кулдан туку. 1983; 6. М.С. К и л д е б ә к о в а. «Чәчәкле интерьер». Йон, кулдан туку. 1980. Казанның вузара ашханәсе; 7. Г.К. Ш ә р и п о в а. «Шәфәкъ». Йон, тигез туку. 1983; 8. М.С. К и л д е б ә к о в а. «Мисырга качу». Йон, кулдан туку. 1990; 9. Г.Н. М а л и к о в а. «Су анасы». Йон, кулдан туку. 1987; 10. А.Н. Е г о р о в. «Мендельсон маршы». Йон, тигез туку. Казандагы Никахлашу сарае. 1982.

ләрен тәмамлаучылар — Г.П.Анютина, А.В.Карпенко, Х.Шәрипов (Чаллы ш.), Ә.Ильясова һ.б. мөрәҗәгать итә. Г. әсәрләре бетон һәм пыяладан төзелгән иҗтимагый биналарның интерьерларына эмоциональ төсмер бирәләр («Сәүдә үзәге» рестораны, 1977; Казанда студентлар ашханәсе, 1980; Әлмәттә Нефтьчеләр мәдәният йорты, 1977 һ.б.). Эре форматлы әсәрләр б-н беррәттән (М.С.Килдебәкова — «Урман», 1980 еллар, Чаллы ш. загсы; А.Н.Егоров — «Мендельсон маршы», 1982, Казанда никахлашу сарае) мини-Г. барлыкка килә. Бу жанрда А.Н.Егоров («Җайдак», 1984), А.В.Карпенко («Көзге сонет», 1984), Г.Н.Маликова («Ретро стилендә», 1983), Г.П.Анютина («Очыш», 1986) һ.б. актив эшли. Г.га татар халык сәнгатенә хас сурәтләү чаралары үтеп керә (орнаментлы бизәлеш, төсләр кушылудагы һәм образлылыктагы милли үзенчәлекләр), бу исә проф. татар Г. мәктәбе барлыкка килүе турында сөйли. Орнаменталь бизәлешле Г. М.С.Килдебәкова, Г.Н.Маликова, Х.Шәрипов, Ә.Ильясова иҗатларында аеруча киң үсеш ала. Биредә татар милли бизәкләре, җылы, якты төсләр палитрасы актив роль уйный. 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында Г.га заказлар азая, сәнгатьнең бу төренә ихтыяҗ кими. 1990 елларның 2 нче яртысында — 2000 еллар башында Чаллыда А.В.Карпенко, Х.Шәрипов, Е.И.Одинцова, С.В.Большакова, Казанда Ә.Ильясова Г. әсәрләре тудыралар. Хәзерге заман Г. сәнгатендә шартлы-символик образлар, фигураларны, пейзажларны, предметларны орнаменталь-бизәлеш юлы б-н стильләштерү өстенлек итә. Х.Шәрипов әсәрләрендә татар фольклоры сюжетлары төп тема булып тора. Ә.Ильясова эшләрендә ислам сәнгате традицияләре чагылыш таба, алар Шәрекъ миниатюрасын хәтерләтә («Дантау тарлавыгында» диптихы, 1990; «Шәрекъ мотивлары», 1991). Чаллы хатын-кыз рәссамнарының мини-Г. әсәрләренә гомумкешелек темалары хас (С.В.Большакова — «Юллар һәм язмышлар», 2000; Е.И.Одинцова — «Агония», «Болыт эчендә», 1999–2000).

ТР рәссамнарының Г. әсәрләре гамәли бизәлеш сәнгатенең халыкара, бөтенсоюз, бөтенроссия, төбәк, респ-ка күргәзмәләрендә күрсәтелә. Алар ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләре картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Валеева-Сулейманова Г.Ф. Гобелен // Декоративное искусство Татарстана (1920–1990-е гг.). К., 1995.

*М.Е.Ильина.*

**ГО́ВОРОВ** Леонид Александрович (22.2.1897, Вятка губ., Яранск өязе Бутырки а. — 19.3.1955, Мәскәү), Сов. Союзы Маршалы (1944), Сов. Союзы Герое (1945). 1909–16 елларда һәм 1917 нең ноябреннән 1918 нең сентябренә кадәр Алабуга шәһәрендә яши. Алабуга реаль уч-щесен (1916), Константинов артиллерия уч-щесен (1917), командирлар составын камилләштерүнең артиллерия курсларын (1926), Югары академия курсларын (1930), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1933, Мәскәү), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (1938) тәмамлый. Гражданнар сугышында артиллерия дивизионы командиры, адмирал А.В.Колчак һәм барон П.Н.Врангель армияләрен тар-мар итүдә катнаша. Совет-фин сугышында (1939–40) 7 нче армиянең артиллерия штабы башлыгы. 1940 тан Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясендә ген. инспектор урынбасары, 1941 дән Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясе башлыгы. Бөек Ватан сугышында Көнбатыш юнәлеш, Резерв һәм Көнбатыш фронтларда артиллерия башлыгы. 1941 нең октябреннән — Мәскәүне саклауда катнашкан 5 нче армия командующие. 1942 нең июненнән — Ленинград фронты, 1945 тән бер үк вакытта 2 нче һәм 3 нче Балтыйк буе фронтлары командующие. 1948–52 дә Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләре командующие, 1954–55 тә баш командующие — СССР оборона министры урынбасары. 1946 дан СССР ЮС депутаты. Биш Ленин ордены, «Җиңү» ордены, өч Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Суворов, Кызыл Йолдыз, өч чит ил орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Г. исеме Хәрби радиотехника инженерлары академиясенә (Харьков ш.), Мәскәү, С.-Петербург, Казан, Алабуга урамнарына бирелә.



Л.А. Говоров.

Әсәр.: В боях за город Ленина. Л., 1945.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Бычевский Б.В. Командующий фронтом. М., 1971; Здравствуй, Елабуга. К., 1980; Гаглов И.П. Творцы победы: от рядового до Маршала. М., 1987.

**ГОВОРУ́ХИН** Дмитрий Андреевич (9.2.1889, Казан — 11.2.1972, шунда ук), композитор, педагог. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1913). 1913–20 елларда Төньяк Кавказ шәһәрләрендә юрист булып эшли. 1920 елларда Кубань музыка ин-тында укый (Краснодар ш.). Краснодар (1923–31), Казан (1931–32), Сталинград (1935–42) театрларында музыка җитәкчесе булып эшли һәм уку йортларында укыта. 1942–55 тә Казан яшь тамашачылар театрында музыка бүлеге мөдире һәм дирижёр, бер үк вакытта Казан консерваториясендә (1945–62) һәм Казан музыка уч-щесендә (1955–64) муз. теориясе фәннәрен укыта. «Карнавал төнендә» («В ночь карнавала», 1926), «Шаян тегүче» («Весёлый портняжка», 1935) балетлары, симфония һәм камера әсәрләре, драма спектакльләренә музыка авторы.

**ГОВОРУ́ХИН** Станислав Сергеевич (29.3.1936, Пермь өлкәсе Березники ш.), кинорежиссёр, сценарист, Украина ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Казан ун-тының геол. ф-тын (1958), Бөтенсоюз кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тын (1966) тәмамлый. 1959–62 елларда Казан телевидение студиясендә мөхәррир. 1966–86 да Одесса нәфис фильмнар студиясендә куючы режиссёр, 1987–93 тә «Мосфильм» киностудиясендә. Ул төшергән нәфис фильмнар — «Вертикаль» (Б.В.Дуров б-н берлектә, 1967), «Туган көн» («День ангела», 1969), «Ак шартлау» («Белый взрыв», 1970), «Робинзон Крузоның тормышы һәм гаҗәеп маҗаралары» («Жизнь и удивительные приключения Робинзона Крузо», 1973), «Контрабанда» (1975), «Өмет җиле» («Ветер надежды» (1978), «Очрашу урынын үзгәртеп булмый» («Место встречи изменить нельзя», 1979), «Том Сойер маҗаралары» («Приключения Тома Сойера», 1981), «Капитан Грант балалары» («Дети капитана Гранта», 1983), «Ворошилов укчысы» («Ворошиловский стрелок», 1999); публицистик фильмнар — «Болай яшәргә ярамый» («Так жить нельзя», 1990), «Без югалткан Россия» («Россия, которую мы потеряли», 1992), «Бөек криминаль революция» («Великая криминальная революция», 1993) һ.б. Күп кенә фильмнарының, ш.и. документаль-публицистик фильмнарының сценарий авторы да була. Г. тудырган фильмнар Россия кино сәнгатенең мөһим өлеше буларак бәяләнә. РФ Дәүләт Думасы депутаты (1993 тән), 1996–99 да — РФ Дәүләт Думасында мәдәният ком-ты рәисе, «Народовластие» группасының рәистәше. «Вертикаль» киностудиясе һәм «Гандвик» бәйсез телевидение студиясе директоры, кинематограф ветераннарын һәм кино мәктәпләре студентларын социаль яклау хәйрия фондын җитәкләи.

Әсәр: Страна воров на дороге в светлое будущее. Нарва, 1994.

*Әд.:* Кино: Энцикл. словарь. М., 1986; Всемирный биографический энциклопедический словарь. М., 2000.

*Е.П.Алексеева.*

**ГОГО́ЛИН** Владимир Александрович (8.4.1953, Казан), спортчы, тренер (академик ишү), СССРның спорт остасы (1971), РСФСРның атказ. тренеры (1986). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын тәмамлый (1977). «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), РСФСР халыкара спартакиадасы чемпионы (1971). 1978–93 тә тренерлык эшендә: «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә (1978–79), республиканың югары спорт осталыгы мәктәбендә (1979–92), ТР Физик культура, спорт һәм туристлык дәүләт комитетының үзәк спорт клубында (1992–93). Шәкертләре арасында СССРның халыкара класслы спорт осталары А.А.Зарубин, И.В.Ковальков, О.В.Лигачев, А.В.*Устинов*.

**ГОГОЛИ́ХА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 60 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 37 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да башлангыч мәктәп (1888 дә ачыла), 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 780 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өя-

зе Мораса волостена керә. 1920 дән ТАССР-ның Спас кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нnарында. Халык саны: 1859 да — 310, 1897 дә — 552, 1908 дә — 569, 1926 да — 644, 1938 дә — 558, 1949 да — 269, 1958 дә — 210, 1970 тә — 197, 1979 да — 106, 1989 да — 60, 2002 дә — 51 кеше.

**ГО́ДНЕВ** Иван Васильевич (25.9.1854, Кострома губ., Галич ш. — 1919, Омск ш.), табиб, мед. д-ры (1886), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, статский советник (1903). Түбән Новгород руханилар семинариясен, Казан ун-тының мед. ф-тын (1878) тәмамлый. 1878 елдан Казан ун-тының шәхси патология һәм терапия кафедрасында эшли, 1886 дан приват-доцент. Бер үк вакытта Мария хатын-кызлар гимназиясендә, Епархия хатын-кызлар уч-щесендә, Ложкин хәйрия оешмасында табиб булып эшли. Иҗтимагый эшчәнлек б-н актив шөгыльләнә. 1891 дән Казан шәһәр думасы гласные, 1892 дән шәрәфле җәмәгать судьясы. 1900–08 дә Казан ятимнәр мәхкәмәсе рәисе. 1901 дән земство һәм шәһәр эшләре буенча Казан губерна җыены гласные, 1905 тән кабат Казан шәһәр думасы гласные булып сайлана. Бер үк вакытта шәһәр кыз балалар башлангыч уч-щесе идарәчесе, Мария хатын-кызлар гимназиясенең идарәчеләр советы әгъзасы. Җирбиләүче буларак, Уфа губернасында 2000 дис. һәм Казан губернасында 10,5 дис. (ш.у. анда 2 йорты була) җир били. 3 нче һәм 4 нче Дәүләт думалары (1907–17) депутаты, октябрист. 3 нче Думада бюджет комиссиясендә секретарь, керемнәр һәм чыгымнар буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү комиссиясе рәисе урынбасары, халык мәгарифе, шәһәр эшләре комиссияләре составына керә. Аның 3 нче Думадагы эшчәнлеге югары бәяләнә, 4 нче Дума ул берьюлы 6 комиссия (аларның өчесендә ул җитәкчелек составында була): дәүләт йөкләмәләрен үтәү (рәис), сәламәтлек саклау (рәис иптәше, ягъни урынбасары), бюджет (секретарь), халык мәгарифе, ун-тларның уставы һәм штатлары турындагы закон проектын карау, гимназияләр һәм әзерлек уч-щеләре турындагы закон проектын карау буенча комиссияләр составына кертелә. Бюджет мәсьәләләре буенча төп докладчыларның берсе. 1913–16 да Казан губернасы земствосы җыены гласные; 1915 нең августыннан ягулык, азык-төлек һәм хәрби йөкләрне күчерү чараларын тикшерү һәм берләштерү киңәшмәсе әгъзасы. 1917 нең 27 февралендә Дәүләт думасының Вакытлы ком-ты әгъзасы итеп сайлана, аның Сенат өстеннән комиссары итеп билгеләнә. 1917 нең 2 мартында дәүләт контролёры вазифасында Вакытлы хөкүмәт составына керә, 1917 нең 21 июлендә отставкага чыга. Казан ун-ты каршындагы Табибләр җәмгыяте әгъзасы. Хезмәтләре эпидемиологиягә һәм терапиягә карый.

Х е з м.: О жёлчном тифонде. СПб., 1880; О холере и её эпидемии в Казани. К., 1885; Гипнотизм и его терапевтическое значение. К., 1886; Об эпидемии инфлюэнцы (гриппа) в Казани. К., 1890.

*Әд.:* М а л ы ш е в а С. Казанец — министр Временного правительства // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 1/2; Г л и н к а Я.В. Одиннадцать лет в Государственной думе. 1906–1917: Дневник и воспоминания. М., 2001; У с м а н о в а Д.М. Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России, 1906–1917. К., 2002; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ГОЗӘ́ЕРОВ** Камил Сабир улы (27.6.1927, Арча кантоны Балтач а. — 3.1.2005, Казан), оптик-механик, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1941–98 елларда Казан оптика-механика з-дында эшли. Герой исеме бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне һәм яңа техника җитештерүне оештырганы өчен бирелә. 1963–67 дә, 1971–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГОЛЕНИ́ЩЕВ-КУТУ́ЗОВ** Александр Вадимович (18.5.1959, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1981 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан энергетика ун-тында эшли, 1995–96 елларда директор урынбасары, 1999 дан сәнәгый электроника каф. мөдире. Хезмәтләре диэлектриклар физикасына һәм үлчәү системаларына карый. Сегнетоэлектрикларда акустик һәм оптик индукцияләнгән доменнар барлыкка килүен ачыклый (1995), периодик домен структурасында акустик дулкыннар генерациясен тикшерә (бергәләп), югары вольтлы диэлектрик элементларның сыйфатын тикшерүнең комплекслы ысулын эшли (2000).

Х е з м.: Фото-и термоиндуцированные акустические эффекты в ниобате лития // Физика твёрдого тела. 1991. Т. 33 (автордаш); Акустически индуцированная структура в ниобате лития // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1995. Т. 61 (автордаш); Распространение акустических волн в сегнето-пьезоэлектриках с периодическим электрическим рельефом // Акустический журн. 1997. Т. 43 (автордаш); Особенности электрического пробоя высоковольтных изоляторов // Известия вузов. Проблемы энергетики. 2006. № 5–6 (автордаш).

**ГОЛЕНИ́ЩЕВ-КУТУ́ЗОВ** Вадим Алексеевич (1.7.1932, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1982), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1964 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, 1968 дән лаб., 1973–93 тә квант акустикасы бүлеге мөдире. Бер үк вакытта 1979 дан Казан энергетика ун-ты профессоры, 1993–98 дә сәнәгый электроника каф. мөдире. Хезмәтләре квант акустикасына, магнит һәм электр сыйфатлары тәртипкә салынган кристаллар физикасына, материалларны бозмыйча тикшерүгә карый. Акустик электрон-төш резонансын (1968, бергәләп), магнон-фонон резонансын һәм акустик импульсларның солитон таралу режимын ачыклый (1975, бергәләп). Акустик ЭПР кулланып кристалларның сыйфатын тикшерү методикасын эшләүдә катнаша (1975, бергәләп). Сегнетоэлектрикларда катнашмалы Ян-Теллер ионнары тирәлегендә доменнар хасил булу моделен һәм шуның нигезендә оптик һәм акустик индукцияләнгән доменнар структурасын төзү методикасын эшли (1998, бергәләп). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Магнитная квантовая акустика. М., 1973 (автордаш); Импульсная оптическая и акустическая когерентная спектроскопия. М., 1988 (автордаш); Индуцированные домены и периодические доменные структуры в электро-и магнитоупорядоченных веществах // Успехи физ. наук. 2000. Т. 170 (автордаш); Высокочастотные ультразвуковые исследования структурных фазовых переходов в манганитах // Физика твёрдого тела. 2007. Т. 49 (автордаш).



К.С. Гозәеров.

**ГОЛҖА́** (Кульджа, Инин), Төньяк-Көнбатыш Кытайда Элә (Или) елгасы яныңдагы, Шөнҗан-Уйгыр автономияле р-ныңдагы шәһәр. 19 йөз уртасында Г. Кытай б-н Россия империясе арасындагы сәүдәдә мөһим роль уйный башлый. Голҗа килешүе нигезендә 1851 елда пошлинасыз сәүдә итү хокукы алган рус гражданнарының мәнфәгатьләрен яклау өчен биредә рус консуллыгы оештырыла; шул вакыттан Г.га Урта Идел, Казакъстан һ.б. җирләрдән татар сәүдәгәрләре үтеп керә башлый. 1900 да имам-хатиб К.Ваһапов Г.да «Нур» мәдрәсәсе ача (1914 тә Габдулла Буби аны яңача укыта торган «Нур» мәктәбе итеп үзгәртә). 1950 еллар уртасына кадәр Г.да татар мәктәбе эшли. Г.дан күренекле хәрбиләр һәм җәмәгать эшлеклеләре Ф.Мөслимов, Р.Сәфәргалиев, Х.Юничев, бертуган М. һәм Ә.Исхаковлар һ.б. чыккан. 1950–60 елларда, Кытайда мәдәният рев-циясе чорында, Г.татарларының шактый өлеше СССРга кайта.


*Әд.:* Г о с м а н о в М. Чәчелгән орлыклар: Голҗа татарлары // Казан утлары. 1992. № 3–4; Татарларның кыскача тарихы. Урумчи, 1988.

*М.Г.Госманов.*

**ГО́ЛИКОВА** Надежда Александровна (10.8.1925, Спас ш.), гистолог, биол. фән. д-ры (1974), проф. (1979). 1949 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1958–62 елларда Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тының морфология лаб-ясе җитәкчесе. 1962 дән Казан вет. ин-тында, 1979–90 да гистология каф. мөдире, 1990–92 дә зоология каф. профессоры. Хезмәтләре тавыкларның калкансыман биз иннервациясе микроморфологиясе һәм эмбриогенезда тире-каурый өслеге үсешенең морфогистохимик закончалыгын өйрәнүгә, ш.у. бал кортларының майлы тән катламына морфофункциональ анализ үткәрүгә карый. 1986–91 дә Татар заказнигында *бал кортларының* тукымын ачыклауны комплекслы өйрәнүне оештыра.

*Әд.:* Кафедра зоологии // Казан. ордена Ленина вет. ин-т им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

*В.И.Белявский.*



Н.А. Головкинский.

**ГОЛИ́ЦЫН** Сергей Дмитриевич (10.6.1696, Мәскәү — 1.7.1739, Казан губ., Казан өязе Салмачы а.), кенәз, дәүләт эшлеклесе, дипломат, камергер (1724), тайный советник (1729). 1711 елдан дәүләт хезмәтендә, Испаниядә (1722–26), Пруссиядә (1729–31), Персиядә (1733–36) илче. 1731–33 елларда Камер-коллегия президенты. 1736 дан Казан губернаторы. 1737–39 да чума эпидемиясе вакытында губерна халкына мед. ярдәме күрсәтүне оештыра. Россия армиясе өчен калмыклардан атлар сатып алу б-н шөгыльләнә, Оренбург экспедициясен финанслый. 1737 дә В.Н.Татищевка Идел буе һәм Себер карталарын төзү өчен мәгълүматлар җыюда ярдәм итә. 1738 дә архиепископ *Лука* (Конашевич) б-н бергә рус булмаган халыкларны христианлаштыру, Казан семинариясендә укытуның сыйфатын яхшырту һәм Казан губернасында уку йортлары ачу планнарын эшли. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение о торговле Российской. [У. һәм е.к.].

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1854. Ч. 1; Г о л и ц ы н Н.Н. Род князей Голицыных. СПб., 1892; Дворянские роды Российской империи. СПб., 1995; Т. 2; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ГОЛОБО́КОВ** Николай Семёнович (6.12.1906, Екатеринослав губ., хәзерге Ростов өлкәсе, Сальский р-ны Егорлык а. — 14.3.1996, Казан), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), Үзбәкстан ССРның «Калининнефть» трестында эшли. 1947–57 елларда «Татнефтегазразведка» трестында идарә башлыгы, 1957–59 да Татарстан ХХС идарәсендә нефть бүлеге башлыгы, 1959–62 дә «Үзбәкнефтегазразведка» трестында идарә башлыгы. Ромашкино (СССР Дәүләт бүләге), Яңа Елховой, Бондюг, Нурлат һәм Татарстандагы башка нефть чыганакларын ачуда катнаша. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

**ГОЛОВА́НОВ** Александр Иванович (28.4.1956, Гюстров ш., Германия — 17.10.2010, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1992 елдан Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2001 дән теоретик механика каф. профессоры, 2004–07 дә проректор (бүленеп, 1981–84 тә Казан химия-технол. ин-тында, 1995–2001 дә С.-Петербург артиллерия ун-тының Казан ф-лы профессоры). Хезмәтләре конструкцияләрне чикләнгән элементлар ысулы б-н нәсызыкча анализлауга һәм геометриясе катлаулы сүрүләр мәсьәләләрен чишүгә карый. Физик һәм геометрик нәсызыкча булуын исәпкә алып, деформацияләнүче каты җисем механикасы мәсьәләләрен чишүнең санлы ысулларын тәгъбирли. Юка һәм урта калынлыктагы сүрүләрнең эффектив югары төгәллектәге кәкрәйгән чикләнгән элементларын исәпли. Төрле материаллар (пыялалы пластик, тимер-бетон һәм композицион материалларны да кертеп) конструкцияләренең зур күчешләрен һәм чикләнгән деформацияләрен тикшерү схемаларын тәкъдим итә. Нәсызыкча физик мәсьәләләр чишүнең итерацион процедураларын эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в метод конечных элементов статики тонких оболочек. К., 1989 (автордаш); Декомпозиция составных конструкций с несопряжёнными сетками на общей грани и алгоритм организации параллельных вычислений // Проблемы прочности и пластичности. Н.Новгород, 2000; Метод конечных элементов в механике деформируемых твёрдых тел. К., 2001 (автордаш); Расчёт больших деформаций неупругих тел в комбинированной Лагранжево-Эйлеровой постановке // Тр. мат. центра им. Н.И.Лобачевского. К., 2002. Т. 15.

**ГОЛОВИ́Н** Фёдор Иванович (1.2.1704, Мәскәү — 26.8.1758, Казан), граф, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-поручик (1755). 1724 елдан хәрби хезмәттә. 1727 дә Казанда була, Себер заводларыннан Мәскәүгә бакыр озату буенча пунктлар оештыру б-н шөгыльләнә. 1755 тән Казан губернаторы. 1754, 1757 елlardагы янгыннардан соң Казанны торгызу б-н җитәкчелек итә. Шәһәрдә офицерлар өчен гарипләр йортын һәм *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен* (1758) ачуга булышлык күрсәтә. Аның вакытында архиепископ *Луканың* (Конашевичның) күп кенә фәрманнары юкка чыгарыла, мөселманнарга каршы юнәлтелгән *Яңа чукындырылганнар конторасы* ябыла. 1756 да татарлар, чукындырылганнарның саны халыкның 1/10 өлешеннән кимрәк булса, авылларда мәчетләр төзүгә һәм мәктәпләр ачуга рөхсәт алалар.

*Әд.:* К а з а н с к и й П.С. Родословная Головиных. М., 1847; Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1856. Ч. 3; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ГОЛОВИ́НСКИЙ** Александр Андреевич (1833, Тверь ш. — 1912, Сембер губ. Буа ш.), хокук белгече, хакыйкый статский советник (1876). Хокук белеме уч-щесен тәмамлый (1859, С.-Петербург). 1852–53 елларда Сенатның III департаментында хезмәт итә. 1854–59 да Казан губернасының җинаять эшләре буенча стряпчие (сәркәтибе). 1859–60 та Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы рәисе урынбасары, 1860–68 дә рәисе. Казан губернасында 1864 елгы мәхкәмә реформасын эшләү һәм үткәрүдә катнаша. 1868–70 тә — Симферополь, 1871–72 дә Сембер округлары мәхкәмәләре прокуроры, 1872–76 да Одесса округы мәхкәмәсе рәисе. 1876–80 дә, 1891–97 дә һәм 1906 дан Буа өязе дворяннары башлыгы. Россиядә реформа чорында мәхкәмә системасын үзгәртеп кору һәм камилләштерү мәсьәләләре турында мәкаләләр авторы.

*Әд.:* Ф р о л о в С.А. Публичные лекции казанских юристов о Судебной реформе 1864 года // Точка зрения. К., 1999.

*С.А.Фролов.*

**ГОЛО́ВКИНСКИЙ** Николай Алексеевич (17.11.1834, Казан губ. Ядрин ш. — 9.6.1897, Таврия губ. Алушта ш.), геолог, гидрогеолог, минералогия һәм геогнозия д-ры (1868), проф. (1869). *Казан геология фәнни мәктәбенә* нигез салучы. А.М.*Бутлеров* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлый (1861), шунда ук минералогия музее хезмәткәре, геол. кабинеты мөдире, геогнозия һәм палеонтология кафедралары профессоры. 1862–64 елларда Алмания, Италия, Франция, Швейцариядә стажировка үтә. 1871 дә, П.Ф.Лесгафтның эштән алынуына протест йөзеннән, Новороссия ун-тына (Одесса ш.) күчә, анда минералогия кафедрасын җитәкли һәм ун-тның ректоры була (1877–81). Россиядә беренчеләрдән булып «фация» терминын куллана һәм фациаль анализның төп законнарын формалаштыра (1868). Үзенең хезмәтләрендә Пермь системасы һәм аның чикләре турындагы бәхәсле фикерләрне ныгыта, беренче мәртәбә Пермь утырмасында өч катлам (хәзерге Уфа, Казан һәм Татар яруслары) булуын күрсәтә, цехштейн диңгез утырмаларының Вятка һәм Пермь губерналарындагы комлы-балчыклы токымнарга күчүен билгели һәм теоретик нигезли, Рус плитәсе тектоникасын өйрәнүгә нигез сала.

Утырма катламнар стратиграфиясен өйрәнү нигезендә Г. геол. горизонт, Җир кабыгының тирбәнү хәрәкәтләре турында ачык төшенчәләр кертә, борынгы диңгезләрнең трансгрессия һәм регрессияләрен бәйли (к. *Головкинский законы*), елга террасалары һәм рельефның хәзерге башка формалары барлыкка килүне алар б-н бәйли (к. *Головкинский кагыйдәләре*). Җир асты суларының барлыкка килүе һәм режимы турында беренчә оригиналь фикер әйтә. Стационар режимлы гидрогеол. станция корылмасы кирәклеген теоретик нигезли. Кырымда, соңыннан Россиядә аның исемен йөртүче беренче артезиан обсерватория оештыра, Кырым сугышында катнаша. Андреев тасмалы истәлекле бронза медаль б-н бүләкләнә. Фән өлкәсендәге дөньякүләм тәкъдир ителерлек хезмәтләре өчен Халыкара геол. конгрессның 7 нче сессиясендә (СПб., 1897) катнашучылар акчасына Г.га һәйкәл куела (1900, Кырымдагы Никита ботаника бакчасы янында). Кырымдагы шарлавык аның исемен йөртә (Алушта шәһәреннән төньяк-көнбатыштарак).

Х е з м.: О кремнекислых соединениях. К., 1861; О послетретичных образованиях по Волге, в её среднем течении // Уч. зап. Казан. ун-та. 1865. Т. 1.

вып. 5/6; О находке в Ядринском уезде полного скелета мамонта // Изв. Казан. ун-та. 1867. Вып. 6; Древние останки человека в Казанской губернии // Тр. 10-го съезда русских естествоиспытателей. СПб., 1868; О пермской формации центральной части Камско-Волжского бассейна. СПб., 1868; Щёлочно-железные воды близ г. Курска // Тр. Об-ва естествоиспытателей природы при Харьковском ун-те. 1871. Т. 25; Мысли о прошедшем и будущем нашей планеты // Зап. Новороссийского ун-та. 1876. Т. 14; Заметки читателя на статью А.М.Бутлерова «Четвёртое измерение и медиумизм» // Рус. вест. 1878. Т. 136; Наблюдения над осадками в почве. Симферополь, 1896.

*Әд.:* Лагорио А.Е. Памяти Н.А. Головкинского // Ежегодник по геологии и минералогии России. СПб., 1897. Т. 2; Пренделъ Р.А. Памяти Н.А.Головкинского // Зап. Крымского горного клуба. 1897. № 12; Сократов Г.Н. Из истории русской геологии второй половины 19 в. // Зап. Ленинградского горного ин-та. 1949. Т. 15–16; Игнатьев В.И. К столетию труда Н.А.Головкинского «О пермской формации центральной части Камско-Волжского бассейна» // Геология Поволжья и Прикамья. К., 1971; Романовский С.И. Н.А.Головкинский. Л., 1979.

*Н.Л.Фомичёва.*

**ГОЛО́ВКИНСКИЙ ЗАКОНЫ́** (фацияләр хәрәкәте һәм катламнар хасил булу законы), Җир кабыгының тектоник хәрәкәтенә яисә диңгез яры сызыгының алга үтүе — чигенүенә утырмаларның тышкы рәвеше һәм матди составы үзгәрүне бәйләп күрсәтә. Диңгез җәелгәндә, фацияләрнең барысы да (сай урыннардагы вакланган тупас төрләреннән алып тирәндә яткан карбонатлы төрләренә кадәр) диңгез яры сызыгы буйлап күчә һәм һәрвакыт сай урында хасил булган утырмалар өстенә тирән җир утырмалары өстәлә; диңгез чигенгәндә — киресенчә. Н.А.*Головкинский* тарафыннан 1868 елда ачыла.

**ГОЛО́ВКИНСКИЙ КАГЫЙДӘЛӘРЕ́**, елга террасалары хасил булуның өч кагыйдәсе; бу процессның Җир кабыгы тирбәнешләре хәрәкәтенә бәйлелеген чагылдыра. 1) Тектоник күтәрелеш вакытында елга юлы ашала һәм тирәнәя, аллювий туплану һәм террасалар хасил булу чираттагы тектоник түбәнәю нәтиҗәсендә бара. 2) Барлык террасалар да сүнә баручы тирбәнешләр вакытында күзәтелә; күтәрелеш көчәю һәм елга юлының яңадан ашалып тирәнәюе элеккеге террасаларны бетерергә мөмкин. 3) Террасаларның синхронлыгы фәкать бер тектоник өлкәдә генә булырга мөмкин; төрле өлкәләрдә алар, һичшиксез, асинхрон була һәм бер-берсе өстендә ятарга мөмкин. Бу кагыйдәләр Казан ун-тында Н.А.*Головкинский* тарафыннан бәян ителә (1865); Урта Идел террасаларын өйрәнеп, ул аны үзенең магистрлык диссертациясендә чагылдыра. Г.к.нә географ Ф.Ф.Розен каршы чыга, ул елга террасалары хасил булу елга суы агымының географик шартлар нәтиҗәсендә үзгәрүенә бәйле дип саный. Шуңа да карамастан, галимнәр бу кагыйдәләрне 100 елга якын куллана, һәм алар геология һәм география фәннәре үсешендә зур әһәмияткә ия була. Бары тик 20 йөзнең 2 нче яртысында гына елга террасалары формалашуда тектоник хәрәкәтләр генә түгел, ә бәлки климатлар алышынуның да роле дәлилләнә.

*Әд.:* Головкинский Н.А. О послетретичных образованиях по Волге, в её среднем течении // Уч. зап. Казан. ун-та. 1865. Т. 1, вып. 5/6.

*А.П.Дедков.*

**«ГО́ЛОС КАЗА́НИ»** («Казан авазы»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм коммерция юнәлешендәге газета. «*Казанский телеграф*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның 12 мартыннан 12 апрелenә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 22 саны чыга. Нашире А.Г.Ильяшенко, мөхәррире шәһәр милициясе башлыгы полковник Ю.С.Геркен. Газетаның характеры һәм эчтәлеге 1917 нең февраль–март вакыйгалары — Февр. рев-циясе, Николай II нең тәхеттән ваз кичүе, Вакытлы хөкүмәт оештырылу йогынтысында формалаша. Аның битләрендә күбесенчә үзәк газеталардан күчермәләр басыла. Петроград телеграф агентлыгы телеграммалары, Баш командующий ставкасыннан алынган ашыгыч белдерүләр, төрле фронтлардан хәбәрләр бирелә, хәрәкәттәге армиядәге хәлләр, Вакытлы хөкүмәт эше яктыртыла. Патша гаиләсе әгъзалары тормышын тискәре яктан чагылдыручы истәлек язмалары урын ала. «Казан хроникасы» рубрикасында Казан гарнизоны гаскәрләре һәм Казан заводларындагы хәлләр яктыртыла, шәһәрдә эшчеләр милициясе оештырылу турында хәбәр ителә. Солдат һәм эшче депутатлары советы башкарма комитеты, шәһәр азык-төлек һәм санитария комиссияләре эшчәнлеге, Казан шәһәр думасы һәм Казан өязе земство идарәсе утырышлары турында мәгълүматлар басыла.

*Г.Р.Заманова.*

**«ГО́ЛОС ТРУДА́»** («Хезмәт авазы»), иҗтимагый-сәяси газета. Социалист-революционерлар (уң эсерлар) партиясенең Казан ком-ты органы. 1917 елның 7 маеннан 20 ноябренә кадәр (чама б-н) Казанда атнага 2 тапкыр рус телендә нәшер ителә, барлыгы 43 саны чыга. Мөхәррирләре — П.Л.*Драверт*, Д.И.Адаев, Ф.П.Рудко. «Хокукыңны көрәштә яуларсың!» шигаре б-н чыга. Күпчелек мәкаләләрнең авторлары эсерлар партиясенең Казан ком-ты әгъзалары: А.Л.Колегаев, И.А.Майоров, В.А.Чернышёв, В.И.Мохов һ.б. «Вестник революции» ж-лы, «Знамя труда», «Земля и воля», «Революционная Россия» г-талары кебек үзәк басмалардан материаллар күчереп бастырыла. Соц.-революционерлар партиясе программасына туры килүче (самодержавиене бетерү, демократик респ-ка төзү, сәяси азатлык, 8 сәгатьлек эш көне һ.б.) мәкаләләргә зур урын бирелә. Эсерларның җирне социальләштерү таләбенең асылын аңлата, җирле үзидарә нигезләрен тамырдан үзгәртү мәсьәләсен күтәрә. Язмаларда баш җир ком-ты, җәмәгать иминлеге, Казан губ. азык-төлек бүлеге эшчәнлекләре анализлана. «Бөтен власть — Учредительләр Җыенына!» шигаре астында газета эсерлар идеяләрен актив пропагандалый. Партия җитәкчеләренең (В.М.Чернов, А.Р.Гоц, Н.Д.Авксентьев һ.б.) сайлау алды чыгышлары, социалист-революционерларның Казан югары ком-тыннан күрсәтелгән кандидатлар (Н.Н.Фирсов, И.Х.Сорокин, В.И.Якобсон, Д.И.Адаев, В.А.Паленин) исемлеген бастыра. Газета эсерлар һәм большевикларның программ күрсәтмәләрен каршы куюю тактикасын куллана, күп кенә мәсьәләләрдә соңгыларын кискен тәнкыйтьли. Эсерлар партиясенең Казан югары ком-ты таркатылу сәбәпле ябыла.

*Г.Р.Заманова.*

**ГОЛОСО́ВКЕР** Самуил Яковлевич (1891, Барановичи губ. Мир ш. — 1961, Ленинград), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1930), проф. (1930). Казан ун-тын тәмамлый (1915), 1918–23 елларда Казан сәламәтлек саклау шәһәр һәм өлкә бүлекләрендә җитәкче урыннарда эшли. 1920 дән Казан ГИДУВында, 1929 дан тире һәм венерик авырулар каф. мөдире, 1931 дән Свердловск мед. ин-тында шул исем. каф. мөдире, 1940–60 та Ленинград педиатрия мед. ин-тында (каф. мөдире). Фәнни хезмәтләре балалар дерматологиясенә, тире-венерик авыруларына, сифилисны пиротерапия ысулы б-н дәвалауга һәм булдырмауга карый. Тиредәге гөмбәсыман микоз авыруларын һәм балтырның кызарып шешүен тасвирлый. Бөек Ватан сугышы елларында Ленинград, Свердловск хәрби госпитальләрендә хәрби консультант. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О половом быте мужчин. К., 1927; Кожные и венерические болезни у детей. Л., 1963.

*Әд.:* Зверькова Ф.А. Профессор Самуил Яковлевич Голосовкер // Казан. мед. журн. 1961. № 5.

**ГОЛОЦЕ́Н** (грек. hólos — барлык, бөтен, тулы, kainós — яңа), дүртенчел периодның хәзерге яки бозлыктан соңгы эпохасы һәм *дүртенчел системаның (чорның)* аңа тиңдәш булган соңгы бүлекләре утырмалары. Г. 10 мең ел чамасы дәвам итә, аның башлангычы булып Европаның, Азиянең һәм Төньяк Американың төньяк өлешләрендәге соңгы материк бозлануы бетү чоры тора. Археологиядә чиге палеолит һәм мезолит чикләре б-н тәңгәл килә. Башлыча, Җирдә климат, туфрак, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы зоналары, коры җир һәм диңгезләрнең хәзерге контурлары формалаша. Моннан элекке, 8–4 мең еллар арасында, урта киңлекләрдә климат хәзерге б-н чагыштырганда бераз җылырак һәм дымлырак була. Г.да Җир йөзендә кеше таралып урнаша башлый, аның культурасы формалаша, терлекчелек һәм җир эшкәртү барлыкка килә.

Татарстан терр-ясендә Г.да урман үсемлекләре өстенлек итә, көньякта ул дала участоклары (Кама аръягы, Буа даласы) б-н аралаша. Елга үзәннәрендә тугай (болын) террасасы (радиоуглерод ысулы күрсәтүенчә, 8 мең ел элек) һәм иң түбәнге беренче тугай өсте террасасы (8–12 мең ел) формалаша. Хәзерге туфрак капламы хасил була, елга юлларында комлы-чуерташлы-вакташлы утырмалар, күлләрдә һәм сазлыкларда — торф, сапропель һ.б. ләмнәр, карбонатлы катламнардан чыгучы чыганаклар янында известьле туфлар барлыкка килә. Соңгы Г.да, урманнар киселеп бетү һәм җирләр сөрелү сәбәпле, елгалар режимы үзгәрә — язгы ташу агымы зурая, саегу чорында күп кенә кече елгалар кибә. Шуңа бәйле буларак, туфрак һәм ерым эрозиясе процесслары активлаша, делювий, пролювий һәм тугай аллювие туп-

лануы көчәя. Г. утырмаларында ком, ком-вакташ катнашмалары, сапропельләр, торф, тимер оксиды пигментлары чыганаклары билгеле. Дүртенчел система составындагы Г.ны өйрәнү буенча Е.И.Тихвинская, В.А.Полянин, А.П.Дедков, Г.Н.Бирюлёв һ.б. шөгыльләнә.

*Әд.:* Тихвинская Е.И. Четвертичные образования // Геология ТАССР и прилегающей территории. 1939. Вып. 31, ч. 2; Полянин В.А. Литологические исследования четвертичных отложений долин Волги и Камы на территории Татарии // Уч. зап. Казан. ун-та. Геология. 1957. Т. 117, кн.4; Полянин В.А., Изотов В.Г., Бирюлёв Г.Н. Формирование песчано-гравийных смесей в долине нижнего течения р. Камы и практика их использования. К., 1974; Геология Татарстана: Стратиграфия. Тектоника. К., 2002.

*А.П.Дедков.*

**ГО́ЛУБЕВ** Анатолий Иванович (4.1.1937, Владимир өлкәсе Ковров ш.), зоолог, биол. фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1968 дән шунда ук эшли, 1977–2008 елларда умырткасызлар зоологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта 1980–2005 тә биология-туфрак ф-ты деканы. В.Л.*Вагин* һәм Н.А.*Ливановлар* шәкерте. Хезмәтләре умырткасыз хайваннарның эволюцион морфологиясе һәм нейробиологиясенә карый. Умырткасызлардагы иң мөһим филогенетик позицияләрне алып торган макро- һәм микродәрәҗәләрдәге нерв аппараты үсеше закончалыкларын бергә бәйләп торучы нерв системасының цитологик эволюциясе концепциясен эшли (1986). Г.ның шуннан соңгы хезмәтләрендә нерв системасының килеп чыгышының морфогенетик нигезе һәм аның күзәнәкләрне тәшкил итүче ультраструктурасы дәрәҗәсендә эволюциянең беренче этаплары турындагы күзаллаулар киңәйтелә. Казан ун-тының атказ. профессоры (2006).

Х е з м.: Электронная микроскопия нервной системы червей. К., 1982; Механизмы структурной пластичности нейронов и филогенез нервной системы. СПб., 1994.

**ГО́ЛУБЕВ** Георгий Викторович (5.7.1932, Мәскәү), гидромеханика һәм җылылык алмашу гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1994). 1955 елда Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1958 дән Казан авиация ин-тында (хәзерге Казан техник ун-ты), теоретик механика кафедрасында. Хезмәтләре бериш булмаган күзәнәкле тирәлектә сыеклыкны гидродинамик фильтрлау теориясенә карый. Катлаулы техник системаларда җылылык алмашу һәм тирбәнешләр теориясен төзи. Җир асты нефть гидрогаз динамикасының кайбер мәсьәләләрен һәм аларны нефть чыганакларын эшкәртү проблемаларына карата куллануны гомумиләштерә. Махсус оптик-механик приборларны производствога кертә.

Х е з м.: Фильтрация несжимаемой жидкости в неоднородной пористой среде. К., 1972 (автордаш); Определение гидропроводности неоднородных нефтяных пластов нелокальными методами. К., 1978 (автордаш).

**ГО́ЛУБЕВ** Лев Германович (24.8.1932, Казан), матем. модельләштерү һәм химик-технол. процессларны оптимальләштерү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1974), проф. (1975), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1975), Казан технол. ун-тының атказ. проф. (2006). 1957 елда Казан авиация ин-тының моторлар төзү ф-тын тәмамлый. 1960 тан Казан хим.-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты) эшли: декан (1966–69), химия з-длары җиһазлары каф. мөдире (1973–90), агач материалларны эшкәртү каф. профессоры (1990 нан). Хезмәтләре киптерү процессларын оптимальләштерү, суспензияләрне сусызландыру һәм киптерү процессларын матем. модельләштерүгә карый. Агач эшкәртү тармагына заманча җиһазлар гамәлгә кертә. Г. җитәкчелегендә регионда беренче агач эшкәртү кафедрасы оештырыла, агач материаллары белеме, мебельне сәнгати конструкцияләү һәм дизайн нигезләре курслары һәм методикасы эшләнә. Уйлап табуга 155 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Сушка в химико-фармацевтической промышленности. М., 1977; Расчёт оборудования отрасли на ЭВМ. М., 1982; Организация ремонта оборудования химических производств. М., 1986; Древесиноведение: В 2-х ч. К., 1997; Основы художественного конструирования. К., 1997; Основные стили при конструкции мебели. К., 1997.

**ГО́ЛУБЕВ** Михаил Михайлович (4.9.1912, Иваново өлкәсенең Лух р-ны Олешево а. — 3.1.1986, Кукмара р-ны Кукмара штп.), техник-технолог, Кукмара киез итек ф-касы директоры (1951–73). Казан киез-фетр техникумын тәмамлый (1932). 1936–44 тә Казан киез-фетр ф-касында цех башлыгы, 1944–46 да директоры. 1946–73 тә Кукмара киез итек ф-касында (1951 гә кадәр баш инженер, 1951 дән директор). Агымлы линияләр, киез итек эшкәртү конвейерлары булдыруга, фабрикада гамәлдәге машина һәм станокларны камилләштерүгә зур өлеш кертә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГО́ЛУБЕВ** Николай Иванович (5.12.1910, Владимир губ. Гороховец ш. — ?), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый (1938). 1931–32 елларда Иваново өлкәсенең Вязники р-ны «Пролетарий» с-зы өлкән агрономы, 1932–33 тә «Спартак» с-зында техник директор. 1938–41 дә ВКП(б) ҮКның (Мәскәү) а.х. бүлеге секторы мөдире ярдәмчесе. 1941–42 дә ВКП(б)ның Пенза өлкә ком-тында махсус сектор мөдире. 1942–44 тә ВКП(б) ҮК каршындагы (Мәскәү) Партия контроле ком-тының җаваплы контролёры. 1944–48 дә Молдавия КП(б) ҮКның а.х. бүлеге мөдире. 1948–49 да ТАССР МС каршындагы Колхозлар эшләре буенча совет рәисе. 1949–58 дә ТАССР МС рәисенең 1 нче урынбасары. 1958–65 тә хезмәт иясе депутатларының Орёл өлкә советы рәисе. 1965–73 тә СССР А.х. министрлыгының Бәрәңге, яшелчә һәм бакча культуралары баш идарәсе башлыгы. 1949–59 да ТАССР һәм 1955–75 тә РСФСР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ГОЛУНКО́В** Юрий Валентинович (17.9.1935, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1960–62, 1972–94 елларда шунда ук эшли, 1989 дан экологик системаларны модельләштерү каф. мөдире. 1962–72 дә Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. башлыгы. 1994 тән Ульянов ун-тының табигатьтән файдалану икътисады һәм экол. системаларны модельләштерү каф. мөдире. Хезмәтләре программа тибындагы функциональ системаларга, алгоритмик алгебралар системаларына һәм экол. системалар модельләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аппроксимационная полнота в алгебрах рекурсивных функций // Кибернетика. 1987. № 6; Степень неразрешимости проблемы и полноты в алгебрах рекурсивных функций // Мат. заметки. 1988. Т. 44, № 5; Полнота по модулю идеала в функциональных системах программного типа // Дискретная математика. 1990. Т. 2, № 4.

**ГОЛШТИ́Н ТОКЫМЛЫ́ МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К**, дөньяда иң күп сөт бирә торган токым. 1852 елда Голландиядән АКШка китерелә һәм сыерлар күп еллар башка төр б-н кушылдырмыйча, сөтлелеге, сөтнең майлылыгы, тере авырлыгы һәм тән төзелеше тибын яхшырту юнәлешендә күп еллар дәвамында алып барылган селекция эше нәтиҗәсендә үрчетелә. Барлык илләрдә дә диярлек таралган. Нәсел сыерларының тереләтә авырлыгы 700 *кг*, нәсел үгезләре 1000–1200 *кг* га җитә. 85–97% сыерларның җилеме ванна һәм чынаяк рәвешле, сөт бирү тизлеге 1,92–2,37 *кг/мин.* АКШта уртача савым — 7865 *кг* (3,7 % майлылыкта), Израильдә — 8366 *кг* (3,1%), Россиядә — 4364 *кг* (3,66 %).

ТР хуҗалыкларында Г.т.м.э.т. 1986 елдан үрчетелә. Германиядән 210, соңрак Венгриядән 5400 баш терлек кертелә. 2005 елның 1 гыйнварына бу токым терлекләр саны 6,8 мең (барлык мөгезле эре терлекнең 1,7%ы) исәпләнә. Холмогор һәм кара-чуар токымнарны яхшыртуда файдаланыла. ТРда уртача 3,62% майлылыклы 4664 *кг* сөт бирә. Төп нәселле терлек үрчетүчеләр: «Казан ветеринария медицинасы академиясенең укыту хуҗалыгы» з-ды (7043 *кг* сөт), «*Бөреле*» агрофирмасы (8429 *кг*), Мамадыш р-нының «Мамадыш» нәсел з-ды (6005 *кг*), Чүпрәле р-ны-



Голштин токымлы чуар кызыл сыер.

ның «Чынлы» (6172 *кг*), Тукай р-нының «Кама» (6009 *кг*) хуҗалыклары (2005).

*Әд.:* Прохоренко П.Н., Логинов Ж.Г. Голштино-фризская порода скота. Л., 1986; Губайдуллин Э.С., Хаертдинов Р.А. Голштинский скот в Татарстане. К., 1995.

*Р.Э.Хәйретдинов.*

**ГО́ЛЬДБЕРГ** Борис Исаевич (1884–1946), хәрби һәм хуҗалык эшлеклесе. 1902 елдан РСДРП әгъзасы, Екатеринослав, Чита, Красноярск, Уфа шәһәрләрендә революцион эшчәнлек алып бара. 1917 нең Фев. рев-ciясеннән соң Томскида гарнизон советы рәисе. Аннары Кызыл Армиядә хезмәт итә, 1919–21 дә Республика (РСФСР) Запас армиясе командиры. Бер үк вакытта 1920 нең гыйнварыннан Мәскәү-Казан тимер юлының Көнчыгыш бүлеге комиссары; ТАССРның дәүләт органнарын оештырганда Вакытлы революцион ком-т әгъзасы, республика игълан ителгәннән соң, аның беренче хөкүмәте составына керә. 1921–22 дә Халык хуҗалыгы югары советының дәүләт корылмалары Баш комиссиясе рәисе урынбасары. 1922–23 тә Республика Хәрби-һава флоты Баш идарәсе башлыгы ярдәмчесе. 1923–24 тә Тышкы сәүдә халык комис-ты каршындагы Республика РСФСР РВСы вәкаләтле вәкиле. 1925 тән Мәскәүдә хуҗалык эшендә.

*А.Л.Литвин.*

**ГО́ЛЬДБЕРГ** Марк Моисеевич (12.6.1920, Украина ССРның Винница өлкәсе Могилёв-Подольский ш. — 1975, Керчь ш.), корабльләр төзүче инженер, Ленин бүләге лауреаты (1965). 1942 елда Николаев корабльләр төзү ин-тын тәмамлый, Үзәк КБ-51 дә (Горький ш.) эшли. 1949 дан Зеленодольск проектлау-конструкторлык бюросында (ПКБ): проект бүлеге башлыгы, корабль проектлау баш конструкторы урынбасары. 1958 дән Керчь шәһәрендә: Зеленодольск ПКБсының Керчь ф-лында баш инженер. Корабльләрнең ныклыгын хисаплау проектларын эшләүдә катнаша. Зур тоннажлы «Циклон», «Смерч» корабльләре модельләрен һәм һава мендәрле корабль модельләрен төзү һәм сынау б-н җитәкчелек итә. «Киль асты» җайланмасына авторлык таныклыгы бар. Махсус машиналар төзелешендәге хезмәте өчен Ленин бүләге бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГОЛЬДГА́ММЕР** Александр Дмитриевич (13.11.1899, Казан — 1.5.1941, Ленинград), физик, проф. (1930). 1922 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1931 дән физ. каф. мөдире. 1932 дән Ленинград физика-техника ин-тында. Хезмәтләре диэлектриклар физикасына карый. Җылытылган яисә ультрамиләүшә, яки рентген нурлары тәэсир иткән саф яки катнашмалы кристалларның ион үткәрүчәнлеген һәм поляршлашу динамикасын тикшерә.

Хезм.: К вопросу об истинной электропроводности кварца // Журн. Рос. физ.-хим. об-ва. Сер. физ. 1927. Т. 59; Экспериментальное исследование начальных токов в диэлектриках // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1932. Т. 2, № 4 (автордаш); Unterschungen uber die Amfangsstrome in Quarz // Phys. Zs. 1928. V. 52.

*Н.С.Альтшулер.*

**ГОЛЬДГА́ММЕР** Дмитрий Александрович (18.10.1860, Мәскәү — 1922, Казан), физик, физика фән. д-ры (1843). Мәшһүр физик А.Г.Столетов шәкерте. 1882 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1888 елдан Казан ун-тында, 1893 тән магнит-метеорол. обсерваториясе профессоры һәм мөдире. Хезмәтләре оптикага, магнетизмга, метеорологиягә карый. Х.А.Лоренц теориясеннән аермалы булган, хәрәкәтләнүчән тирәлекләрдә электромагнит күренешләре теориясен төзеп карый; ферромагнетиклардагы магнит каршылыгын һәм термомагнит күренешен беренче мәртәбә җентекләп өйрәнә; магнитланган матдәләрнең электр үткәрүчәнлеге үзгәрүен тикшерә (Г. эффекты). Аның «Яктылыкның электромагнитик теориясе. Яктылык поляршлашу яссылыгының табигый әйләнеше» («Электромагнитная теория света. Естественное вращение плоскости поляризации света», 1892), «Яктылык нурлары басымы турында» («О давлении световых лучей», 1901) дигән монографияләре мәгълүм. Россиянең көнчыгыш өлешендә 96 метеостанцияне берләштергән метеорология челтәре оештыра. 1895 елдан Г. катнашында ел саен «Көнчыгыш метеорология челтәре хезмәтләре» («Труды Восточной метеорологической сети»), 1897 елдан «Көнчыгыш Россия челтәренең айлык бюллетене» («Ежемесячный бюллетень сети Востока России») нәшер ителә.

Хезм.: Новая теория электромагнитных явлений в движущихся средах // Изв. Физ.-мат. об-ва. Сер. 2. 1915. Т. 21, № 1–3; Die Farbenempfindlichkeit des Anges und die Photometrische Helligkeit der Senchtenten // Ann. Physik. 1905. V. 16, № 4.

*Р.Г.Усманов.*

**ГОЛЬДШТЕ́ЙН** Дмитрий Ефимович (Мовша Хаимович) (21.11.1897, Белосток ш., Польша — 6.3.1967, Казан), рентгенолог, мед. фән. д-ры (1945), проф. (1946), ТАССРның атказ. табибе (1945), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1958). А.В.*Вишневский* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1924), шунда ук эшли. 1928–67 елларда Казан ГИДУВында, 1942–53 тә 1 нче рентгенология каф. мөдире. Илдә беренче радиологик үзәк булып саналган 2 нче рентгенология һәм радиология кафедрасын оештыручы, 1956 дан мөдире. Фәнни хезмәтләре сөяк системасы патологиясе һәм имгәнүләренә, лимфа системасын (яшәү чорындагы лимфография) өйрәнүгә карый. Кашин-Бек авыруы, остеохондропатияләр, гигант күзәнәкле шешләр турындагы хезмәтләре аеруча әһәмияткә ия. Очлыклар гарипләге патогенезында амнионный һәм аның аномалияләре ролен исбатлый. Бөтенсоюз, Бөтенроссия рентгенологлары һәм радиологлары фәнни җәмгыяте идарәсе әгъзасы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Диагностическая ценность и методика фистулографии в клинике военных травм. К., 1947; Материалы к изучению лимфатической системы методом прижизненной лимфографии. К., 1949; Вопросы клинико-рентгенологической диагностики закрытых переломов костей. К., 1965.

*Әд.:* Сухоруков Б.З. Андриановский А.Ф. К 60-летию заслуженного деятеля науки ТАССР, профессора Дмитрия Ефимовича Гольдштейна // Вестн. рентгенологии и радиологии. 1959. № 2.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ГОЛЬДШТЕ́ЙН** Моисей Исаакович (23.12.1894 — 31.8.1974, Казан), рентгенолог, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1954). Казан ун-тын тәмамлый (1919). Р.А.*Лурия* шәкерте. 1920 елдан Казан ГИДУВында. 1936 дан Казан мед. ин-тының рентгенология курслары, 1953 тән рентгенология һәм радиология каф. мөдире. Радиоактив йод һәм фосфор б-н авыруларны дәвалау өчен радиоизотоп клиник лаб-ясен оештыра. Онкологик авырулар клиникасын өйрәнә, рентген нурлары б-н дәвалау ысулын тәкъдим итә. Йөрәк-тамырлар системасы, ашкайнату юллары авырулары патологиясен тикшерә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К изучению заболеваний желудка лучами Рентгена. К., 1939; Рентгенодиагностика коллагеноза лёгких // Проблемы клинической и теоретической медицины. К., 1967.

*Әд.:* Мусин М.Р. Профессор Моисей Исаакович Гольдштейн (Некролог) // Казан. мед. журн. 1975. Т. 56.

**ГО́ЛЬЦМАН** Карл Матвеевич (18.6.1854, Эстониянең Дерпт, хәзерге Тарту ш. — 1922, Казан), вет.-терапевт, проф. (1897). 1876 елда Дерпт вет. ин-тын, 1884 тә Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. Казан вет. терапевтлары мәктәбенә нигез салучы. 1876 дан Казан вет. ин-тында эшли, 1897–1922 елларда эчке йогышлы булмаган авырулар каф. һәм терапия клиникасы мөдире. 1892–96 да Берлин, Дрезден, Вена, Копенгаген шәһәрләрендә хезмәт күнекмәләре ала. Г. Казан вет. ин-тының беренче сайланып куелган ректоры (1905–07, 1910–14). Казанда Ветеринария табибләре җәмгыятен оештыручы (1897–1917). 19 йөз ахырында кеше һәм хайваннар авыруларын тышкы мохит тәэсире һәм нерв системасы тибына бәйле рәвештә килеп чыккан патологик процесс буларак күзәтеп җыелган тәҗрибә материалларын бергә туплый. Г. шәкертләре арасында проф. Н.П.*Рухлядев* бар. 3 нче дәрәҗә Изге Анна һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Краткий курс частной патологии и терапии домашних животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1893. Т. 10, вып. 1; Краткий курс частной патологии и терапии домашних животных. М.–Л., 1930.

*Әд.:* Евсеенко С.С. По поводу книги Гольцмана // Вестн. обществ. ветеринарии. 1912. № 19; Карл Матвеевич Гольцман: Некролог // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1926. Т. 37, вып. 1; Крапивнер Л.М.Карл Матвеевич Гольцман и его время // Ветеринария. 1964. № 6; Гильмутдинова О.М. Роль руководителей Казанского ветеринарного института в развитии вуза и подготовке кадров // Тр. 1-го съезда вет. врачей РТ. К., 1996; Ветеринарная энциклопедия. М., 1969. Т. 2.

*О.М.Гыйльметдинова.*

**ГОМӘ́Р** (Гомәров) Абдулла Закир улы (15.7.1906, Оренбург ш. — 7.7.1974, Казан), тәрҗемәче. 1925–28 елларда Казан ун-тында укый. 1928–42 дә — «Совет әдәбияты» ж-лы редакциясе хезмәткәре, 1959–63 тә — баш мөхәррир, 1942–59 да — Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлеге мөдире. Татар теленә Я.Гашекның «Егет солдат Швейк» («Похождения бравого солдата



Г. Гомәри.

Швейка во время мировой войны», 1932), Д.А.Фурмановның «Фетнә» («Мятеж», 1934), П.А.Павленконың «Баррикадалар» («Баррикады», 1935) романнарын, А.Г.Голубеваның «Уржум малае» («Мальчик из Уржума», 1939) повестен, М.А.Шолоховның «Нәфрәт гыйлеме» («Наука ненависти», 1942) хикәясен һәм «Алар Ватан өчен сугыштылар» («Они сражались за Родину», 1946) романының аерым бүлекләрен, А.А.Фадеевның «Яшь гвардия» («Молодая гвардия», 1950, Г.Әпсәләмов б-н берлектә) романын, А.С.Яковлевның «Конструктор хикәяләре» («Рассказы конструктора», 1952) китабын, Э.Войничның «Кигәвен» («Овод», 1957) романын, А.Н.Толстой, Л.Н.Толстой, Д.Н.Мамин-Сибиряк һ.б. хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1950–60 еллар әдәби процессына караган мәкаләләр авторы.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ГОМӘ́Р** (Гомәров) Гариф Мортаза улы (10.12.1891, Уфа губ., Бәләбәй өязе Кыргыз-Миякә а. — 18.8.1974, Уфа ш.), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1971). Татар һәм башкорт телләрендә яза. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Шәкертләр чуалышларында катнашуы өчен 1909 елда мәдрәсәдән куыла. 1910–15 елларда туган авылында укытучы булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1919–20 дә Кызыл Армия сафларында сәяси хезмәткәр. 1920–24 тә — «Кызыл юл» (Уфа) г-тасында, 1924–33 тә — «Һәнәк» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1934–40 та Башкорстан китап нәшриятында тәрҗемәче, мөхәррир, бүлек мөдире вазифаларын башкара. «Қызыл усмалар» исемле беренче китабы 1925 тә басыла. «Тулҡын өҫтөндәге ҡала» (Уфа, 1954; рус теленә тәрҗемәсе «Городок на волнах», 1955) повесте сал агызучылар тормышына багышланган. «Тупһанан түргә» (Уфа, 1957; рус теленә тәрҗемәсе «От порога в горницу», 1968), «Жаңыл» (Уфа, 1960; рус теленә тәрҗемәсе «Джаныл», 1975) повестьлары авторы. И.Крылов мәсәлләрен, М.Горькийның «В людях» («Ялсылыкта») повестен, Б.Л.Горбатовның «Непокорённые» («Буйһонмаусылар») романын башкорт теленә тәрҗемә итә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Һайланма проза. Өфө, 1961.

**ГОМӘ́Р** Мөхәммәд угылы (19 йөзнең беренче яртысы), шагыйрь. Оренбургта яшәгән. Татар һәм фарсы телләрендә язган. Оренбург Диния нәзарәте мөфтиенә багышланган «Тәзкирә-и мөфти Габдессәлам» поэмасы (1832) авторы. Поэма 2002 дә «Габдессәлам мөфти: Хәтер дәфтәре» исеме б-н кабат басыла. Ул ике телдә язылган: татарча тезмә текст фарсыча чәчмә текст б-н чиратлаша. 1837 дә Оренбургка килгән булачак патша Александр II яраннары составында була. Бу вакыйга уңаеннан «Сәфәрнамә-и шаһзадә Александр» (1837) исемле мәдхия яза. Соңыннан аны Александр II нең үзенә тапшыра. Поэмаларның кульъязмалары РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының С.-Петербург бүлеге һәм Ташкенттагы Бируни исем. Көнчыгышны өйрәнү ин-ты фондларында саклана. 1783 тә Кавказга, Төркиягә һәм Мисырга баруы турында чәчмә сәяхәтнамә язган дип фаразлана.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Рәхимкулова М. Оренбургта беренче мәчет // Яңа вакыт. 1993. № 23/24.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ГОМӘРИ́** Габдрахман (Гомәров Габдрахман Исмәгыйль улы) (16.1.1867, Әстерхан ш. — 1933, Архангельск өлкәсе Кече Карел а.), дин эшлеклесе, исламият галиме, нашир. 1881 елда «Мәрҗания» мәдрәсәсенә укырга керә, Ш.*Мәрҗани* шәкерте һәм аның тарафдары. 1889–92 дә шул ук мәдрәсәдә гарәп теле укыта. 1892 дә Әстерханга кайта һәм «*Низамия*» мәктәбен (соңрак мәдрәсә) оештыра (1893), соңрак бу уку йорты бөтен Түбән Идел буе мөселманнары өчен укыту-тәрбия үзәгенә әверелә. 1906 ның августында Бөтенроссия мөселманнарының 3 нче корылтаенда катнаша. 1907 дә Әстерханда басмаханә ача, «*Мәгариф*» ж-лын, «*Идел*» г-тасын нәшер итә. 1914 нең башында «Идел» хөкүмәткә каршы эшчәнлектә гаепләнеп ябыла. Г. Казанга сөрелә. Биредә ул наширлек эшен дәвам иттерә. 1917 елгы Фев. рев-циясе вакытында Әстерханга кайта, Әстерхан губернасы *мөхтәсибе* һәм җамигъ мәчет имам-хатибы итеп сайлана. Бөтенроссия мөселманнарының 1 һәм 2 нче корылтайларында катнаша (май, 1917, Мәскәү; июль, 1917, Казан). Окт. рев-циясеннән соң мөхтәсиб вазифасын дәвам итә. 1923 тә Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең гыйльми шурасына сайлана. 1926 да СССР мөселманнары делегациясенең сәркәтибе сыйфатында Мәккәдә узган Бөтендөнья ислам конгрессында катнаша. 1920 елларның икенче яртысында исламны өйрәнү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Исламиятка һәм гарәп филологиясенә, Әстерхан нугайлары тарихына караган дәреслекләр һәм хезмәтләр авторы. 1929 ның июлендә кулга алына, репрессияләнә. Вафатыннан соң аклана.

Х е з м.: Мөгаллим сарыф лисан әл-гарәб. К., 1896; Мөгаллим нәхү лисан әл-гарәб. К., 1903; Кыйсас әл-әнбия әл-гыйзам вә тәрҗемә-и әхвалъ дүәли әл-Ислам. Әстерхан, 1912.

*Әд.:* Габдрахман Гомәри: Фәнни-биографик җыентык. К., 2002; Рахимов С. Габдрахман Гумари // Духовная культура и татарская интеллигенция: Исторические портреты. К., 2000.

*С.Т.Рәхимов.*

**әл-ГОМӘРИ́** (العمری) Шиһабетдин Әхмәд ибне Йахйа әд-Димәшкый (1301, Димәшкъ ш. — 1349), гарәп язучысы, энциклопедияче. Димәшкъта һәм Каһирәдә яши, Мисыр дәүләт канцеляриясендә эшли. Алтын Урда тарихы буенча мәгълүматлар булган «Дәүләтләрнең эре үзәкләре буйлап күзәтүләр» (т. 1–32) дигән тарихи-географик хезмәт, «Югары стиль кабул итеп танышу» дигән әсәрләр авторы.

*Г.М.Дәүләтшин.*

**ГОМӘ́РОВ** Әсгат Мөхәммәтҗан улы (27.10.1947, Буа ш.), химик-технолог, техник фән. канд. (1977), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), ТРның атказ. химигы (2005). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзерге Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, фәнни-җитештерү идарәсе башлыгы (1995 тән), химик кибернетика каф. профессоры (2006 дан). 2006 дан ТР ФА президенты урынбасары. Хезмәтләре химик-технол. процессларны матем. модельләштерүгә һәм оптимальләштерүгә карый. Чүпрә генерацияләүнең өр-яңа ресурс саклаулы технологиясен тәкъдим итә (бергәләп). Чүпрә культурасын субстрат б-н туендыруның технол. алымнарын оптимальләштерү максатында спирт чүпрәләре культивирлауның матем. моделен эшли. Г. тәкъдим иткән җайланмалар «Александровский» һәм Буа спирт з-дларында гамәлгә кертелгән. Полимер материаллар җитештерү технологияләрен фәнни яктан тикшерү һәм эшләү өчен полимерлаштыру җайланмасын проектлаштыра һәм төзи («Түбәнкаманефтехим» АҖнең фәнни-техник үзәгенә тапшырыла). ТР Дәүләт бүләге спирт җитештерүенә чүпрә генерацияләүнең аэроб технологиясен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование раскрытия изоцианатных групп, инициируемого полиоксиэтиленгликолятором калия // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 2007. Т. 49 (автордаш); Системный анализ и принятие решений. Математическое моделирование и оптимизация объектов химической технологии. СПб., 2007 (автордаш); Теория и практика статистики. М., 2008.

**ГОМӘ́РОВ Г.И. БАСМАХАНӘСЕ́,** Әстерхан шәһәрендә. 1907 елда Бирге Тияк бистәсендә пай нигезендә оешкан «Г.Гомәров һәм аның компаниясе» ширкәте буларак ачыла. Танылган татар мәдәнияте эшлеклесе Г.И.Гомәров басмаханәсендә «Идел», «Хак», «Мизан» г-таларын, «Мәгариф», «Ислах», «Туп» ж-ларын бастыра. Биредә наширләр Г.Ниязи, З.Насыйбуллин, Ф.Сөләймания, «*Гайрәт*» нәшрияты үз китапларын бастыра. Китаплар татар телендә нәшер ителә. 1908–14 тә 200 мең данә гомуми тираж б-н 80 гә якын исемдә китап дөнья күрә. Басмаларның тематикасы бай: татар шагыйре И.Юманкулның «Сәда-и мәдәният», «Әдәбият» шигырь җыентыклары һ.б.; Я.Морадинның «Тукаев Уральскида» дигән истәлекләр китабы; Л.Н.Толстойның «Тере мәет» («Живой труп») романының татар теленә тәрҗемәсе; «Өч хикәя» дип исемләнгән төрек хикәяләре җыентыгы; гарәп һәм татар телләре буенча уку китаплары; законнар белеме буенча хезмәтләр, ш.и. мөселманнар өчен; дини әдәбият, ш.и. 1000 данә тираж б-н догалык, терлекчелек һәм а.х.на караган брошюралар (туфрак ашлау, йорт хайваннарының токымын яхшырту турында һ.б.). Хөкүмәткә кар-

шы юнәлештәге «Идел» г-тасын бастыргány өчен 1914 тә басмаханә ябыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Рахимов С. Габдрахман Гумари // Духовная культура и татарская интеллигенция: Исторические портреты. К. 2000.

**ГОМӘ́РОВ** Госман (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), график, 1913–16 елларда нәшер ителгән «Ак юл» балалар ж-лындагы рәсемнәр авторы. Гомәровның нәзек сызыклар б-н ясалган рәсемнәре күз алдында табигать күренешләрен (кырлар түрендәге тегермәннең тонык шәүләсе, урман буеннан офыкларга китеп югалган сукмак, юлдагы мосафир һ.б.) яңарта.

**ГОМӘ́РОВ** Илшат Нургали улы (25.4.1957, Алексеев р-ны Юеш Көрнәле а.), галим-агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), ТР-ның атказ. а.х. хезмәткәре (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Алексеев р-нында эшли: «Родина» к-зында агроном, Юеш Көрнәле урта мәктәбендә укытучы (1983 тән), «Флора» а.х. кооперативы рәисе (1987 дән), «Гомәров» крәстиян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе (1991). Дәүләт бүләге ТР-да биологик шартларга нигезләнеп бөртекле ашлык җитештерүдә ресурс саклаулы технологияләрне эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**ГОМӘ́РОВ** Мәсәгут (1746, Казан губ., Казан өязе Пычак а. — ?), Е.И.Пугачёв армиясе полковнигы. 1773 елның ноябре ахырында баш күтәрүчеләр отряды туплый (3 мең кеше; йөзләргә һәм командаларга бүленә). 1773 нең декабре — 1774 нең гыйнварында Казан–Арча–Мамадыш юнәлешендә хәрәкәт итә. Аның отряды Бемыш, Пыжман, Таишев з-дларын кулга төшерә. Г. вәкилләре төбәк халкын Пугачёвка тугрылык сакларга ант иттерәләр. Г. эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казан өязенең төньяк-көнчыгыш өлешен баш күтәрүчеләр яулап ала. 1774 нең гыйнварында аның отряды Камышлы авылында (хәзер Кукмара р-нына керә) урнаша. Г. Казанга яу әзерли, Арчаны алырга ниятли. Пугачёв әмере буенча отрядының бер өлешен (1500 кеше) баш күтәрүчеләр тарафыннан камалган Минзәлә янына җибәрә. Г. үзе Нагайбәк-Эстәрлетамак төбәгендә көрәшне дәвам итә. 1774 нең мартында кулга алына. Камчы б-н суктырыла, тамгалана һәм каторгага сөрелә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Пугачёв полковнигы // Казан утлары. 1967. № 1; Имамов В. Татар яугирләре (Татарлар Пугачёв явында): тарихи очерк. К., 2003; Крестьянская война в России в 1773–1775 годах: Восстание Пугачёва. Л., 1966. Т. 2; Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973.

**ГОМӘ́РОВ** Рәфыйк Хафиз улы (13.7.1954, Казан), сәнәгать-җылылык энергетикасы белгече, ТРның атказ. химигы (2001). Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лын тәмамлагач (1978), «Органик синтез» җитештерү берләшмәсендә өлкән смена мастеры булып эшли. 1979–82 елларда ВЛКСМның Казан шәһәре Мәскәү р-н ком-тында 2 нче, 1 нче секретарь, 1982–87 дә Казан шәһәр ком-тында 2 нче, 1 нче секретарь, 1987–90 да КПСС-ның Казан шәһәре Мәскәү район ком-тында 2 нче секретарь. 1990–93 тә халык депутатларының Казан шәһәр советы рәисе урынбасары, рәисе. 1993–2004 тә «Татхимфармпрепаратлар» берләшмәсендә ген. директор. Г. җитәкчелегендә гамәлдәге производство җиһазларын реконструкцияләү һәм техник җиһазлау уздырыла. Эшләп чыгарылган продукциянең ассортименты 80% ка яңартыла. Уйлап табуга 7 патенты бар.

**ГОМӘ́РОВ** Рөстәм Исхак улы (5.6.1949, Казан), физик, физ.-матем. фән. канд. (1988), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), Казан вет. ин-тында эшли. 1973 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре астрономик тикшеренүләр өчен приборлар эшләп чыгаруга, астрометриягә карый. Дәүләт бүләге Казан ун-тында булдырылган РТТ-150 телескобы һәм аппаратура комплексы ярдәмендә актив галактикаларның төшләре, гамма-сикерешләр, рентген космик чыганаклар, астероидлар һәм йолдызларның нечкә спектроскопияләре буенча эзләнү-тикшеренү эшләре алып барганы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Искусственное свечение ионосферы при кратковременном воздействии мощного радиоизлучения // Изв. вузов. Радиофизика. 1999. Т. XLII, № 6 (автордаш); Results of Joint Project on Linking Optical — Radio Reference Frames // Kinematics and Physics of Celectial Bodies. Suppl. Ser. № 5 (автордаш).

**ГОМӘ́РОВ** Фәрит Мәҗит улы (3.10.1947, Калининград ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1995). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1972–85 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында, 1985–96 да Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1996 елдан Казан энергетика ун-тының физика каф. профессоры. Хезмәтләре химик радиоспектроскопиягә, сыеклык һәм полимерларның молекуляр динамикасына карый. Сулы һәм микрогетероген системаларда парамагнитик ионнарның молекуляр хәрәкәтчәнлеге, электрон релаксациясе механизмнарын тикшерә. Биологик объектларны түбән темп-рада консервацияләү өчен кулланыла торган, металл ионнарның туңдырылган сулы эремәләрен пыялалау үзенчәлекләрен һәм фаза халәтен өйрәнә. Спин зондлары ысулы б-н ясалма һәм табигый полимерларның физик структурасын, аның эшкәрткәндәге үзгәрүчәнлеген, целлюлоза кушылмаларында релаксация механизмнарының табигатен өйрәнә.

Х е з м.: Особенности спектров ЭПР и парамагнитная релаксация ионов Mn(2) в водно-полиэтиленгликолевых растворах // Журн. структурной химии. 1978. Т. 19; Особенности стеклования водных растворов нитрата хрома по данным ЭПР к парамагнитной релаксации // Докл. АН СССР. 1978. Т. 239, № 5 (автордаш); Electron paramagnetic relaxation in aqueous solutions of manganese (2) ions // Molecular Physics. 1975. V.29, № 3 (автордаш).

**ГОМӘ́РОВ** Фәрит Мөхәммәт улы (15.6.1952, Казан), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2001). 1974 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, механика ф-ты деканы (1995–96), җылылык техникасының теоретик нигезләре каф. мөдире (1996 дан), проректор (1996–2001). Хезмәтләре газ-сыеклык халәтләре чигендәге күренешләрнең җылылык физикасына һәм үтә критик технологияләргә карый. Критик ноктаның киң диапозонында нәквант инерт газларның җылылык һәм темп-ра үткәрүчәнлеген фәнни тикшерә. Сәнәгый ташландык суларны начар очучан углеводородлы пычраткычлардан чистартуның һәм гидролиз глицеринын үтә критик экстракция процессында концентрацияләүнең теоретик нигезләрен эшли.

Х е з м.: Рефрактометрический метод прогнозирования тепло- и температуроводности оптических газов и жидкостей // Докл. АН СССР. 1991. Т. 320, № 6 (автордаш); Температуропроводность неквантовых инертных газов в широком диапазоне критической точки // Теплофизика высоких температур. 1993. Т. 31, № 4 (соавт.); Суб-и сверхкритические флюиды в процессах переработки полимеров. К., 2000 (автордаш); The termal diffusivity of argon in the crical region // Intern J. of Thermophysics. 1999. V. 12.

**ГОМӘ́РОВ** Хаммат Гомәр улы (1899, хәзерге БРның Яңавыл р-ны Югары Чат а. — 1934), дипломат. «Галия» мәдрәсәсендә белем ала (Уфа ш.), Шәрекъ телләре ин-тын тәмамлый (1929, Мәскәү). 1922–25 елларда Уфада эшли, «Яшь юксыл» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1925 тән Мәскәүдә, ВКП(б)ның Мәскәү губерна ком-ты татар-башкорт бюросы лекторы, «Фән һәм дин» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1929 дан СССРның Төркиядәге илчесе ярдәмчесе, 1931 дән илчесе.

*Әд.:* Алюков Т. Беренчеләрдән берәү // Кызыл Таң. 1968. 17 нояб.

**ГОМӘ́РОВА** Заһирә Бакир кызы (12.4.1930, Арча р-ны Чөмә-Елга а. — 3.1.2002, Чаллы ш.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1948–50 елларда Саба р-нының Иләбәр башлангыч, 1950–85 тә Эзмә урта мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Балаларга багышланган «Яшьлек таңы» дип исемләнгән беренче шигырьләр китабы 1964 тә басыла. Аның «Чын герой» (1968), «Нәни врач» (1970), «Әниснең алмалары» (1980), «Йөгерек елга» (1991) җыентыкларында тупланган хикәяләрендә балаларны кече яшьтән үк тәвәккәл, бер-берсенә ярдәмчел, туган җирне яратучы кешеләр итеп тәрбияләүнең әһәмияте турында сүз бара. Әсәрләре мавыктыргыч, юмор хисе б-н сугарылган.

*Әд.:* Заһирә Гомәровага — 70 яшь: Кыскача биография // Казан утлары. 2000. № 4.

**ГОМЕ́Р ОЗЫНЛЫГЫ́**, кешенең тууы һәм үлеме арасындагы вакыт аралыгы; *үлемнең* гомумиләштерелгән демографик статистика бәрәмлеге. Г.о.ның аеруча киң кулланыла торган күрсәткече киләчәк гомернең уртача озынлыгы яки көтелгән Г.о. (бу вакытта үлем хәзерге дәрәҗәгә тигез була дип исәпләнә). Көтелгән Г.о. теге яки бу буынның озак вакыт дәвам иткән тормыш шартлары б-н бәйле. 19 һәм 20 йөз чикләрендә Россиядә халыкның көтелгән Г.о. ир-атлар өчен — 31 һәм хатын-кызлар өчен 33 яшь тәшкил итә. Бу күрсәткечнең кискен үсүе 1950 елларда башлана һәм 1960 еллар уртасына кадәр дәвам итә. Моның сәбәбе — бала вакытта йогышлы авырулардан үлү очракларының кимүе. 1970 ел-



К.М.Гонтарь.

ларда ир-атларның көтелгән Г.о. кими, хатын-кызларның якынча бер дәрәҗәдә тирбәлә. 1980 еллар уртасында (алкогольгә каршы кампания үткәрү чорында) үлем-китемнең кыска вакытка кимүе һәм көтелгән Г.о.ның үсүе күзәтелә (1987 дә ир-атларның — 64,9, хатын-кызларның — 74,3 яшь). 1990 да Татарстан халкының көтелгән Г.о. 70,9 яшь тәшкил итә (ир-атларның — 65,1, хатын-кызларның 76 яшь). Аннан соң бу күрсәткеч акрынлап, ә 1993 тән кинәт төшә. 1994–95 тә көтелгән Г.о. 66,7 яшькә кадәр кими (ир-атларның — 60, хатын-кызларның 74 яшьтән аз). Көтелгән Г.о.ның кимүе өлешчә алкогольгә каршы чараларның гамәлдән чыгарылуы б-н аңлатыла. 1996–98 елларда уңай якка кыска вакытлы үзгәреш булып ала һәм 2000 еллар башында ТР халкының көтелгән Г.о. күрсәткече 67,6 яшь тирәсе була. Көтелгән Г.о. 2006 да 69 яшь, ш.и. ир-атларныкы — 62,7, хатын-кызларныкы 75,6 яшь. Иҗтимагый-демографик төркемнәр буенча көтелгән Г.о.нда шактый аерымлыклар бар. Г.о. буенча ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында бик зур аерма күзәтелә. Бу аерма шәһәр халкында 1990 нан 2006 елга кадәр 10,4 яшьтән 12,5 яшькә кадәр арта; авыл халкында тиңдәш рәвештә 12,4 тән 14,1 яшькә кадәр. Шәһәрдә яшәүче ир-атларның Г.о. авылдагыларга караганда зуррак, хатын-кызларның — якынча бертигез.

Көтелгән Г.о. җәмгыятьнең социаль һәм гуманитар үсешендә төп критерийларның берсе буларак карала. Дөньядагы илләр буенча көтелгән Г.о. турында мәгълүмат БМОның еллык Демографик басмасында басыла. Көтелгән Г.о. кешеләр потенциалы үсеше индексын төзү өчен кирәкле 3 критерийның (белем дәрәҗәсе һәм эчке тулай продукт күләме) берсе буларак кулланыла.

*Әд.:* Социальная энциклопедия. М., 2000; Численность, состав и движение населения в Республике Татарстан в 2005 году: Стат. сб. К., 2006.

*Ф.Г.Борһанов.*

**ГОМУМИ́ ГИГИЕ́НА**, *гигиена* бүлеге, кешенең оптималь яшәү шартларын булдыру, авыруларны алдан кисәтү чараларын эшли, гигиена нормативларын өйрәнә.

Халыкның торак урыннарын сәламәтләндерү буенча сан. чаралары борынгы дәверләрдән үк башкарыла. Сәламәтлеккә көнкүреш җитештерүе мохитенең тәэсире турында беренче фәнни хезмәтләр фәкать 17 йөз ахырында күренә башлый (Италия табибе Б.Рамаццини).

Россия галимнәре (М.В.Ломоносов, 1755; С.Г.Зыбелин, М.Я.Мудров, 1800 еллар) тарафыннан ун-тларның мед. ф-тлары программасына җәмәгать сәламәтлегe һәм профилактика чаралары турында лекцияләр кертелә.

Гигиена өлкәсендә беренче тикшеренүләр Казан табибләре тарафыннан 19 йөзнең 1 нче яртысында үткәрелә. К.Ф.Фуксның «Статистик һәм этнографик нисбәттә Казан татарлары» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях», 1844) исем. монографиясе медик-этнографик тикшеренүләр юнәлешенә башлангыч бирә. Г.г. фәнни дисциплинасына нигез салучылар М.Петтенкофер, А.П.Доброславин, Ф.Ф.Эрисман, А.И.Якобий (19 йөзнең 2 нче яртысы).

1836 да Казан ун-тының мед. ф-тында гигиена буенча мөстәкыйль курслар оештырыла. 1869 дан А.И.Якобий барлык ф-т студентларына Г.г. курсларын укый; 1922 дән Г.г. кафедрасын илнең иң зур гигиена белгечләреннән берсе — В.В.*Милославский* җитәкли. Аның хезмәтләре һәм шәкертләренең эндемик зоб мәсьәләләре буенча тикшеренүләре классикага әверелә. 1930 да Казан ГИДУВында Г.г. кафедрасы ачыла (мөдире И.К.Лукьянов).

Казан гигиена галимнәре тарафыннан хромның микроэлемент буларак биол. роле ачыклана (А.Т.Гончаров), эндемик зоб, тимер җитмәү анемиясе, цинк җитмәү этиологиясе һәм патогенезында туклануның хәлиткеч роле исбатлана. 1970–80 елларда газ бүлү сәнәгате продуктларының канцерогенлыгы (этилен, фенол һәм ацетон окисе, органик перекисьлар һ.б.) өйрәнелә, яңа яман шешләр булдырмауның беренчел чаралары эшләнелә (Ф.Ф.Даутов һ.б.). ТРда сәламәтлек саклауны гамәлгә ашыру өчен, сан. шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә авырулар санын фаразлау тәкъдим ителә, республика шәһәрләрендә атмосфера һавасының һәм туфракның пычрану карталары төзелә, икътисади зыян билгеләнә.

*Әд.:* Альбицкий В.Ю., Галлямов А.Б., Хабриев Р.У. Очерки истории казанской медицинской школы. К., 1991; Альбицкий В.Ю., Галлямов А.Б., Иванов А.В. Казанские профессора-гигиенисты: Биогр. словарь. К., 1995; Научные труды сотрудников Казанской государственной медицинской академии за 1997–2002 гг. К., 2002.

*Ф.Ф.Даутов, А.Б.Галләмов.*

**ГОНДЫ́Р** (Аю) авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шушма елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 96 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1770 тә Кече Лызи авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, аучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1882 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 373,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-ннарында. Халык саны: 1834 тә — 135, 1859 да — 140, 1897 дә — 238, 1908 дә — 255, 1920 дә — 274, 1926 да — 245, 1938 дә — 252, 1949 да — 283, 1958 дә — 228, 1970 тә — 159, 1979 да — 155, 1989 да — 96, 2002 дә — 89 кеше.

**ГОНИОЛИМО́Н** (Goniolimon), кургашсымаңнар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 25 ләп төре билгеле, Европада, Азиядә һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТРда 2 төре бар. Биек Г. (G. elatum) республиканың көньяк-көнчыгышында (ареалның төньяк чиге) очрый, татар Г. (G. tataricum) — сирәк очрый торган төр, Әлмәт р-нында билгеләнгән. Даладагы кайбер участокларда, известьле һәм ташлы тау битләрендә үсә. 30–85 *см* биеклектәге үсемлек. Үзәк тамырлы. Яфраклары чиратлашкан, калын кабыклы. Чәчәкләре вак, тыгыз ике рәтле башакта утыра. Башаклары өстәге чәчәк төркеменә җыелган. Җимеше коры, бер орлыклы. Июнь–июль айларында чәчәк ата. Тамырында дуплау матдәләре бар. Декоратив үсемлек. Татар Г. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГОНТА́РЬ** Константин Михайлович (5.3.1921, Краснодар ш. — 22.5.2003, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (2.11.1944), подполковник (1957). Казан пехота уч-щесен тәмамлый (1940). 1938 елдан Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында (1939–40) катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 95 нче укчы полкның (14 нче армиянең 14 нче укчы дивизиясе) батальон командиры. Төньяк һәм Карелия фронтлары гаскәрләре составында Карелия, Норвегияне азат итүдә, Петсамо-Киркенес һөҗүм операциясендә (1944) катнаша. 1944 нең 15 октябрендә Петсамо бистәсе (хәзерге Мурманск өлкәсе Печенга штп) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. 1957 дән запаста, Мәскәүдә яши. Фәнни тикшеренү ин-тында эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Золотые Звёзды Кубани. Краснодар, 1969. Т. 2; Цкитишвили К.В., Чинчилакашвили Т.Г. Герои Советского Союза из Грузии. Тб., 1981; Героям Родины — слава! Петрозаводск, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**ГОНЧАРО́В** Анатолий Титович (28.11.1923, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Усад а. — 19.6.1997, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1982), проф. (1983). В.В.*Милославский* шәкерте. Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли. 1967–90 елларда гомуми гигиена каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре туклануда хром микроэлементы ролен өйрәнүгә карый. Г. кеше организмы өчен хромның биол. әһәмиятен исбатлый, тәүлеккә физиологик максималь микъдарны (гәүдәнең 1 *кг* на 3 *мкг*) билгели, микроэлементларның биол. ролен өйрәнү методикасын тәкъдим итә. Г. медицинада сәбәплелекнең фәлсәфи категорияләрен өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ор-

деннары, медальләр б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Роль хрома в питании. К., 1981.

**ГОНЧАРО́В** Виктор Иванович (29.11.1951, Әзәрбайҗан ССРның Кировабад ш.), тренер (шахмат), Россиянең атказ. тренеры (1992). Кировабад төзелеш техникумын (1969), Дәүләт үзәк физик культура ин-тын (1976, Мәскәү) тәмамлый. 1975–77 дә Чаллы шәһәре хакимияте каршындагы Физик культура идарәсенең шахмат-шашка клубында тренер, 1992 дән директор. 1990 елдан начар ишетүче шахматчыларның халыкара федерациясе (ИКСК версиясе), Россиянең «Шахматны — мәктәпкә» шахмат академиясе (1994 тән) вице-президенты. Съеста-Флорентина (Италия, 1990), Бад-Рагац (Швейцария, 1991), Эдинбург (Бөекбритания, 1992), Зноймо (Чехия, 1992), Роттердам (Нидерланд, 1996) шәһәрләренең мактаулы гражданы. Шахмат уенына өйрәтү буенча фәнни, укыту-методик басмалар авторы. Шәкертләре арасында — халыкара гроссмейстерлар С.А.Салов (ИКСК буенча үткәрелгән ярышларда дөнья чемпионы, 1992, 1996), В.Б.Яндемиров, Т.П.Воронова. М.М.Чигорин исем. һәм Т.В.Петросян исем. медальләр б-н бүләкләнә.

**ГОНЧАРО́В** Иван Александрович (6.6.1812, Сембер ш. — 15.9.1891, С.-Петербург), язучы, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1860). «Гыйбрәтле язмыш» («Обыкновенная история», 1847), «Обломов» (1859), «Текә яр» («Обрыв», 1869) романнары авторы. 1822–62 елларда үтеп барышлый берничә мәртәбә Казанда була. 1834 тә Буада туктап бер көн уздыруы турында «Ватанда» («На родине», 1887) очеркында яза. 1849 да Казанга килгәндә мәчетләрдә була, Кремльне карап йөри. Татарлар һәм Россиянең бүтән халыклары мәдәнияте һәм көнкүреше б-н кызыксына, шул сәбәпле махсус рәвештә татар, чуаш, мари авылларында була. Казан турындагы истәлекләре «Университетта» («В университете», 1887), «Идел буйлап сәяхәт» («Поездка по Волге», 1873–74), «Иске гасыр хезмәтчеләре» («Слуги старого века», 1887), «Көнчыгыш Себер буйлап» («По Восточной Сибири», 1891) очеркларында очрый.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ГОНЧАРУ́К** Наталья Петровна (26.6.1954, Украина ССРның Житомир өлкәсе Радомышль ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2005), проф. (2005). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол. ин-тының (хәзерге Казан технология ун-ты) югары матем. кафедрасында, 2001 дән социаль эшләр, педагогика һәм психология кафедрасында. Хезмәтләре югары мәктәп педагогикасы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Формирование базовых интеллектуальных умений у студентов технических вузов. К., 2002; Теоретические проблемы интеллектуально-развивающего обучения в техническом вузе. К., 2003; Психолого-педагогические проблемы формирования интеллектуальных структур. К., 2006.

**ГО́НЮХ** Валерий Михайлович (13.1.1945, Бийск ш. — 28.8.2002, Казан), химик-технолог, техник фән. канд. (1974), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2003). 1967 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. «Татарстройматериалы» ҖБдә эшли, 1975 елдан баш технолог. 1979 дан Казан химия-технол. ин-тында патент бүлеге башлыгы. 1982 дән Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында, 1996 дан технологик сынау үзәге директоры. Хезмәтләре ТР руда булмаган файдалы казылмаларын (комлы-гравийлы, карбонатлы һәм агрохимия чималы) сәнәгатьтә һәм авыл хуҗалыгында куллану буенча. Дәүләт бүләге «Металл булмаган файдалы казылмаларны нәтиҗәле файдалануның яңа минералогик-технологик чишелешләрен булдыру һәм тормышка ашыру» («Создание и реализация новых минералого-технологических решений эффективного использования неметаллических полезных ископаемых») дип аталган хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Технологическая оценка минерального сырья. Нерудное сырьё: Справ. М., 1994 (автордаш).

**ГОРБАНЁВ** Николай Кузьмич (14.5.1922, Воронеж өлкәсенең Россошь р-ны Поповка а.), генерал-майор (1968), Сов. Союзы Герое (13.9.1944). Пед. уч-щесен (1940, Россошь ш.), Харьков артиллерия уч-щесен (1942), Бронетанклар һәм механикалаштырылган гаскәрләр хәрби академиясен (1951, Мәскәү) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында — танкка каршы атучы батарея командиры. Яссы-Кишинёв һөҗүм операциясендә батырлык күрсәтә (1944). 1951 елдан совет гаскәрләренең Үзәк төркеме штабында өлкән офицер, 1955 тән Белоруссия хәрби округында танк полкы командиры, 1961 дән Германиядәге совет гаскәрләре төркеменең танк дивизиясе штабы башлыгы, 1967 дән Кавказ арты хәрби округының мотоукчы дивизиясе командиры. 1974–84 тә Казан суворовчылар уч-щесе башлыгы. 1985–91 дә Белоруссия ССР Гражданнар оборонасы штабында. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Г р и н ь к о А.И., У л а е в Г.Ф. Богатыри земли Воронежской. Воронеж, 1965; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982; Кн. 1.

**ГОРБА́ТЫЙ-ШУ́ЙСКИЙ** Александр Борисович (? — 4.2.1565, Мәскәү), бояр, воевода. Суздаль кенәзләре нәселеннән. 1546 елда рус гаскәрләренең Зөя тамагына юнәлдерелгән явында катнаша, чуаш һәм Тау ягы мари аксакаллары б-н Россия хакимиятенә күчү турында сөйләшүләр алып бара. 1550 дә Түбән Новгородтан Зөя елгасы буена килгән гаскәр б-н идарә итә, 1551 дә Зөянең Иделгә койган җирендә аның җитәкчелегендә Зөя шәһәр-кальгасы төзелә. 1552 дә Казанга каршы юнәлдерелгән яу җитәкчеләренең берсе, Казан морзасы *Япанчаның* атлы гаскәрен тар-мар итә. 1552 нең октябрендә Казанның наместнигы һәм беренче (баш) воеводасы итеп билгеләнә. 1552–1555 тә Казан ханлыгы җирләрендәге халык күтәрелешен бастыру б-н җитәкчелек итә. Опричнина башлангач, Иван IV кә каршы фетнә оештыруда гаепләнә, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* С к р ы н н и к о в Р.Г. Царство террора. СПб., 1992. *Е.В.Липаков.*



Н.К. Горбанёв.

**ГОРБАЧЁВ** Борис Фёдорович (13.1.1933, Иркутск ш.), геолог, геол.-минералогия фән. канд. (1963), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), шунда ук эшли. 1965 елдан ЦНИИгеолнерудта, 1993 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре геологиягә һәм руда булмаган файдалы казылмалар технологиясенә карый. ТРның Дәүләт бүләге «Металл булмаган файдалы казылмаларны нәтиҗәле файдалануның яңа минералогик-технологик чишелешләрен булдыру һәм тормышка ашыру» дигән хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Месторождения каолинов СССР. М., 1974; Технологическая оценка минерального сырья. Нерудное сырьё: Справ. М., 1994 (автордаш).

**ГОРБАЧЁВ** Иван Георгиевич (29.1.1952, Әстерхан өлкәсе, Каспий р-ны 10 нчы разъезд торак пункты — 29.5.2009, Казан), юридик фән. д-ры (2002), проф. (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1976), шунда ук дәүләт тарихы, теориясе һәм хокук кафедрасында эшли. Хезмәтләре Россия федерализмының институциональ нигезләрен яктыртуга карый.

Х е з м.: Реализация права наций на самоопределение в Советском государстве: проблемы интернационализации. К., 1985; Российский федерализм: принципы построения и конституционно-договорная база разграничения предметов ведения и полномочий. СПб., 2000; Российский федерализм: проблемы сотрудничества и взаимной ответственности федерального центра и субъекта Федерации. СПб., 2001.

**ГОРБАЧУ́К** Валерий Веленович (9.8.1957, Лениногорск ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (2003), проф. (2007). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң шунда ук эшли. Хезмәтләре супрамолекуляр химиягә, биофизик химиягә, химик термодинамикага карый. Органик матдәләрнең парларын аксымнар (рецепторлар) б-н селектив бәйләү механизмын ачыклый, бу процессны тегелгән гидрофиль полимер, ш.у. бета-циклодекстрин ярдәмендә күрсәтеп бирә. Аксымнарның һәм кайбер гидрофиль рецепторларны (хәрәкәтчәнлеге б-н структураларының ныклыгы арасында оптималь баланс булганнарын) дымландыру нәтиҗәсендә, билгеле бер дымлылыктан башлап, рецепторның гидрофоб субстратлар, мәс., ароматик углеводородлар, терпеннар б-н бәйләнешкә керү сәләте артуын күрсәтә. Г. элегрәк бары тик ферментлы процесслар кинетикасына гына билгеле бул-



Д.И.Горбунов.



С.П.Горбунов.

ган бу эффектның термодинамик характеристикаларын ала. Органик матдәне аксым рәвешендәге рецептор сыйфатында файдалану өчен, аның молекуляр төзелешен ачыклый. Супрамолекуляр рецепторларны (каликсареннарны) ис сенсорларында куллану методикасын эшләп, аларның пар рәвешле матдәләр б-н туенуыннан соң регенерацияләүне модельләү мөмкинлеген күрсәтә (тере организмда сулыш чыгару кебек).

Х е з м.: Supramolecular interactions of solid human serum albumin with binary mixtures of solvent vapors // Biophys, Chem. 1999. V. 81, № 2 (автордаш); Hadicher Biomimetic cooperative interations of dried cross-linked poly(N-6-aminohexylacrylamide) with binary mixtures of solventvapors // Biomacromolecules. 2004. V. 5, № 4 (автордаш); Metastable tret-butylcalix[6]arene with unusually lage tunable free volume for non-thershld enclatrathoin of volatiles // Organic and Biomolecular chemistry. 2008. V.6 (автордаш).

**ГОРБУ́ЛИН** Павел Николаевич (5.6.1909, Курск ш. — ?), генерал-майор (1944). Тимер юл мәктәбен (1924, Курск ш.), Я.С.Свердлов исем. Коммунистик ун-тны (1931, Мәскәү) тәмамлый. 1924–28 елларда Курск тимер юл остаханәләрендә: слесарь, пресслаучы, мастер. 1928 елдан Курскта һәм Курск өлкәсендә комсомол эшендә. 1931 дән авиабригада сәяси бүлеге инструкторы, парашют-десант отряды хәрби комиссары. 1933 тән Кызыл Армиянең Хәрби Һава Көчләре фәнни сынаулар ин-тында сәяси бүлек инструкторы һәм истребитель отряды комиссары. 1937 дән НКВД органнарында, 1939 дан СССР НКВДсының партия ком-ты секретаре (Мәскәү). 1943 тән ТАССР НКВД халык комиссары, 1946–48 дә ТАССР эчке эшләр министры. 1954 тән СССР Эчке эшләр министрлыгында. ТАССР ЮС депутаты (1947–51). Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГОРБУНО́В** Дмитрий Иванович (24.10.1924, Буа кантоны Биеш а. — 28.7.1944, Каунас ш., Литва ССР), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), өлкән сержант (1944). Казанда слесарь булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 136 нчы укчы полкның (5 нче армиянең 97 нче укчы дивизиясе) взвод командиры. Көнбатыш һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Ржев-Вязьма, Смоленск (икесе дә — 1943) һөҗүм операцияләрендә, Белоруссияне, Балтыйк буен азат итүдә катнаша. 1944 нең июнь-июль айларында Суходровка, Березина, Ошмянка елгалары (Белоруссия ССР) буендагы плацдарм өчен барган бәрелешләрдә катнаша, Вильнюс шәһәрендә урам сугышларында батырлык күрсәтә. Каунас шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза. М., 1987. Т. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ГОРБУНО́В ИСЕМЕНДӘГЕ́ КОЛХО́З**, Апас р-нында. 1929 елда «Яңа ил» к-зы булараk оештырыла. 1950 дә Жданов исем. к-з б-н берләштерелә, «Авангард» к-зы б-н 1959 да кушылганнан соң, 2004 кә кадәр шушы исемдә. Аның составына Биеш (үзәк утары), Колчык, Дәүләки авыллары, Каратун посёлогы кергән. 2004 тә 245 хуҗалык исәпләнә. Эшләүчеләр саны — 76 кеше. А.х. җирләренең мәйданы — 2993 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 2738 *га*. Мөгезле эре терлек — 1099 баш, ш.и. 300 баш сыер.

А.х.ның төп тармаклары: бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, сөт һәм ит җитештерү. 1980 нән үсемлекчелек һәм терлекчелектә тотрыклы югары күрсәткечләргә ия була:

Колхоз КПСС ҮК, СССР ЮС Президиумы, СССР МС, ВЦСПСның Почёт билгесе, ВЦСПС, СССР МСның Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә. Эшчеләргә дәүләт бүләкләре бирелә, ш.и. 8 кеше — ТРның мактаулы исемнәре; 1 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Кызыл Байрак, 1 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 5 кеше — медальләр, 1 кеше СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

Колхоз җитәкчеләре: Н.С.Сәлимов (1929–34), Г.С.Сибагатуллин (1934–36), Г.С.Сайхунов (1936–50), З.С.Садриев (1950–56), И.Х.Хисамов (1956–63), Ф.Т.Мифтахов (1963–69), Х.Х.Сафин (1969–76), Ә.Я.*Вәлиев* (1976–99), И.Я.Габбазов (1999–2005).

2005 елда колхоз «Горбунов исемендәге «Алтын башак» ААҖ авыл хуҗалыгы предприятиесе»нең «Дәүләки» бүлеге итеп үзгәртелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ГОРБУНО́В** Иван Яковлевич (1891, Уфа губ., Минзәлә өязе Корчажки а. — 1920), Гражданнар сугышында катнашучы. 1918 елда Солдат һәм крәстиян депутатларының Зәй советы секретаре, РКП(б)ның Зәй волость ком-ты рәисе, Уфа губернасының Зәй волосте хәрби комиссары. 1918 нең август — сентябрендә Минзәлә өязендә чех-словак корпусы һәм Комучның Халык армиясе тылында хәрәкәт иткән партизан отрядын җитәкли; соңрак Кызыл Армиядә коммунистик батальон командиры, 28 нче дивизиянең 40 нчы полкы комиссары. Казанны акгвардиячеләрдән азат итүдә катнаша. 1919 дан Көньяк фронтта. Тифтан вафат була.

*Әд.:* П у ц к о в а З.С. Горбунов Иван Яковлевич // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*Е.Б.Долгов.*

**ГОРБУНО́В** Сергей Александрович (2.01.1953, Чабаксар), геолог. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2009), ТРның атказ. геологы (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), «Северостеология» ҖБндә (Магадан өлкәсе) эшли. 1933–95 елларда Казан ун-тының физик география һәм геоэкология кафедрасында. 1996–97 дә ТР МК каршындагы Запаслар буенча территориаль респ-ка ком-тында өлкән белгеч, 1998–2001 дә региональ эшләр, геология һәм җир асты байлыкларын файдалану буенча ТР Дәүләт ком-тының геологик мохит мониторингы бүлеге башлыгы. 2001–08 дә ТР экология һәм табигать байлыклары министрлыгында, Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты җитәкчесе (2005 тән). 2008 дән «Геоцентр РТ» ФҖБдә генераль директор урынбасары. Хезмәтләре ТР терр-ясен геологик өйрәнүгә һәм җир асты байлыкларын файдалануның экологик куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасы көнбатыш өлешенең нефтьлелеге перспективаларын нефть ятмаларын эзләү барышында ысуллар комплексын эшләү б-н бәяләү» хезмәте өчен бирелә.

**ГОРБУНО́В** Сергей Михайлович (17.6.1952, Украина ССРның Чернигов өлкәсе Седнев пос.), фармаколог, мед. фән. д-ры (1992). 1975 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1981 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 1992 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 2005 тән Казан мед. академиясендә. Хезмәтләре физиологик актив матдәләр булдыру, дару препаратлары ясау буенча. Биол. актив кушылмаларның яралану һәм пешү вакытында тиренең репаратив регенерация процессына тәэсирен, кайбер пиримидинлы матдәләрнең куркынычсызлыгын һәм үзенчәлекле активлыгын тикшерә. Пешкән урыннарны һәм төзәлми торган яраларны дәвалау өчен тәкъдим ителгән *ксимедон* препаратын ясауда һәм клиник практикага кертүдә катнаша. Препаратларның фармакологик классын — сайлаучан миорелаксантларны таба (бергәләп). 100 дән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 26 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ГОРБУНО́В** Сергей Петрович (12.7.1902, хәзерге Мәскәү өлкәсенең Зарайск р-ны Журавка а. — 5.9.1933, Мәскәү), инженер-механик, сәнәгать җитештерүен оештыручы. Гражданнар сугышында катнаша. Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен тәмамлый (1926). 1929–30 елларда 22 нче Мәскәү авиация з-дында техник директор, 1930–33 тә директор. Аның җитәкчелегендә АНТ-3, АНТ-4, АНТ-5, АНТ-6, АНТ-7, АНТ-9 самолётларын җитештерү җайга салына. 1933 елның 5 сентябрендә авиаһәлакәттә һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә. 1933 тә заводка Г. исеме бирелә; 1941 дә завод Казанга эвакуацияләнә (хәзерге С.П.Горбунов исем. Казан авиация җитештерү берләшмәсе). Завод терр-ясендә Г. бюсты куелган (1978).

*Әд.:* Г е н к и н И. Окрылённый талант. К., 1985.

**ГОРБУНО́ВКА** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Калмыя елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 25 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 1910 елларда нигез салына. Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-ннарында. Халык саны: 1926 да — 154, 1938 дә — 327, 1949 да — 356, 1958 дә — 338, 1970 тә- 241, 1979 да — 140, 1989 да — 39, 2002 дә — 36 кеше.

**«ГОРД ГЫРЛЫ́»** («Кызыл чаң»), газета. 1918 елда Казан губ. терр-ясендә сугыш хәрәкәтләре барган вакытта Көнчыгыш Фронтның 2 нче армиясе сәяси бүлеге тарафыннан удмурт телендә нәшер ителә. Җаваплы мөхәррире — сәяси бүлек хезмәткәре Н.Г.Гусев. Саннары сакланмаган.

*К.И.Куликов.*

**«ГОРД САЛДА́Т»** («Кызыл солдат»), газета. 1919 елда Казан губ. терр-ясендә сугыш хәрәкәтләре барган вакытта Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе сәяси бүлеге тарафыннан удмурт телендә нәшер ителә. Җаваплы мөхәррире — сәяси бүлек хезмәткәре Н.Г.Гусев. Саннары сакланмаган.

*К.И.Куликов.*

**ГОРДЕ́ЕВ** Александр Павлович (1852 — ?), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән килгән шәрәфле граждан, җәмәгать эшлеклесе. Сәүдәгәрләр гаиләсеннән. Казанда йортлар, Түбән Новгород (Мәкәрҗә) ярминкәсендә сәүдә кибетләре хуҗасы. 1893–1901 елларда Казан шәһәр думасы гласные. 1887–95 тә Александр исем. хастаханәнең, 1897 дән 21 нче Казан шәһәр башлангыч белем бирү уч-щесенең, 1902 дән Печище земство уч-щесенең попечителе. Россия Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе хисап-ссуда ком-ты әгъзасы (1897–1902). Станислав тасмалы көмеш медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в а Л.Ф. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ГОРДЕ́ЕВ** Александр Степанович (23.11.1894, Казан губ., Спас өязе Шмелёвка а. — 1969 дан соң), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан укытучылар семинариясен тәмамлый (1913). Беренче бөтендөнья һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1918 елда Казан казна палатасы комиссары, Казан губ. башкарма ком-тының финанс бүлеге мөдире (1920 гә кадәр). 1920–24 тә ТАССР финанс халык комиссары. Республиканы финанс яктан тотрыклыландыруга һәм аның икътисади үсешенә өлеш кертә. 1924–29 да СССР Финанс халык комис-тының Баш салым идарәсе башлыгы урынбасары. 1929–30 да СССР Тышкы сәүдә халык комис-тының Казакъстан АССРдагы вәкаләтле вәкиле. 1931–41 дә уңдырышлылыкны билгеләү комиссиясе әгъзасы (Украина ССРның Днепропетровск ш.). 1946 дан Мәскәүдә хакимият-хуҗалык эшендә.

*Е.Б.Долгов.*


**ГОРДЕ́ЕВ** Григорий Степанович (6.9.1891, Казан губ., Спас өязе Шмелёвка а. — 1.2.1972, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе, икътисадчы. 1913–17 елларда Киев коммерция ин-ты студенты. 1916 дан РСДРП әгъзасы; ин-тның партия төркеме тарафыннан большевикларның аграр сәясәтен пропагандалау өчен Спас өязенә җибәрелә. 1917 нең май — июлендә Спас өязенең азык-төлек ком-тын җитәкли, 29–30 майда булып узган өяз киңәшмәсендә алпавыт җирләрен һәм эш коралларын кичекмәстән крәстиян ком-тларына тапшыру турында карар кабул ителүенә ирешә. Г. җитәкчелегендә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының өяз советы оештырыла (1917 нең июне). Эшче, крәстиян һәм солдат депутатлары советларының 1918 нең гыйнварында уздырылган 3 нче Бөтенроссия съездында катнаша. 1918 нең февраленнән Казан губерна башкарма ком-ты әгъзасы, апрельдә финанс комиссары урынбасары һәм Дәүләт банкы комиссары, май-августта Спас башкарма ком-ты рәисе. РКП(б)ның Спас өяз ком-тын оештыра. 1918 нең сентябреннән Казан губернасы җир эшләре комиссары, җирне күмәкләшеп эшкәртүнең (совхозлар һәм коммуналар рәвешендә) актив тарафдары. Бер үк вакытта 1919 ның ноябре — 1920 нең июнендә РКП(б)ның Казан губерна ком-ты секретаре. 1920 нең июле-августында халык мәгарифе бүлеге мөдире, ТАССРның югары уку йортлары комиссары. 1921–24 тә Кызыл профессорлар ин-ты тыңлаучысы (Мәскәү). 1925–30 да Тимирязев исем. Авыл хуҗалыгы академиясендә а.х.икътисады каф. мөдире, проф. (1926). Соңрак Бөтенсоюз терлекчелек ин-тында эшли. 1935 тә Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсенең терлекчелек павильоны директоры итеп билгеләнә. 1938–55 тә репрессияләнә. 1955–67 дә Бөтенсоюз а.х. икътисады фәнни-тикшерү ин-тында проф., бүлек мөдире. Хезмәтләре а.х. икътисадына карый.

Х е з м.: Сельское хозяйство России в войне и революции. М., 1925; Обезземеливание американского фермера. М., 1926.

*Әд.:* И о н е н к о И.М. Гордеев Григорий Степанович // Борцы за счастье народное. К., 1967; И о н е н к о И.М. Г.С.Гордеев. К., 1979.

*С.И.Ионенко.*

**ГОРДЛЕ́ВСКИЙ** Владимир Александрович (7.10.1876, Свеаборг ш., Финляндия — 10.9.1956, Мәскәү), шәркыятьче-тюрколог, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1946). Гельсингфорс гимназиясен (1895), Лазаревларның Шәрекъ телләре ин-тын (1896, Мәскәү), Мәскәү ун-тын (1904) тәмамлый. Сорбоннада укый (1906, Франция). 1904–06 елларда Төркиядә була, анда төрек телен өйрәнә, төрек халкының фольклоры, этнологиясе буенча материаллар җыя. 1907 дән Лазаревларның Шәрекъ телләре ин-тында төрек телен һәм төрек әдәбияты тарихын укыта (1916 дан экстраординар проф.), 1918 дән Алгы Азия ин-ты (Мәскәү), 1920–48 дә Мәскәү ун-ты (бүленеп) профессоры. 1950 еллар башыннан СССР ФАнең Шәрекъне өйрәнү ин-тында Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре телләре һәм әдәбиятлары секторына җитәкчелек итә. Хезмәтләре Төркиянең урта гасырлар тарихына, төрек теле, әдәбияты, фольклорына карый. Г. ның фәнни мирасында «XVI гасырның икенче яртысында Төркиянең эчке халәте» («Внутреннее состояние Турции во второй половине XVI века»), «Кече Азиядә Сәлҗуклар дәүләте» («Государство Сельджукидов в Малой Азии») (икесе дә — М., 1941) монографияләре аерым урын алып тора. Татарларның көнкүреше һәм гореф-гадәтләренә багышланган этнографик очерклар авторы.



В.А.Гордлевский.

Х е з м.: Гадания татарок о женихе. М., 1925; Элементы культуры у касимовских татар // Тр. Об-ва исследователей Рязанского края. Рязань, 1927. Вып. 10; Избранные сочинения: В. 3 т. М., 1960–62.

*Әд.:* А р а к и н В.Д. В.А.Гордлевский — исследователь тюркских языков (К столетию со дня рождения) // Советская тюркология. 1976. № 5; Б а з и я н ц А.П. В.А.Гордлевский (К столетию со дня рождения) // Народы Азии и Африки. 1976. № 6.

*М.Г.Госманов.*

**ГО́РДОВ** Василий Николаевич (30.11.1896, Уфа губ., Минзәлә өязе Матвеевка а. — 24.8.1951, Самара ш.), генерал-полковник (1943), Сов. Союзы Герое (6.4.1945). Татар милләтеннән. Өлкән командирлар составы (1925), «Выстрел» (1927) курсларын, Мәскәүдәге М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1932) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында өлкән унтер-офицер. 1917 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышында Көнчыгыш һәм Көнбатыш фронтларда рота, батальон, полк б-н җитәкчелек итә, Н.И.Махноның Крәстияннәр армиясенә, Урта Азиядә баш күтәргән милли частьләргә каршы сугышларда катнаша. 1925–26 елларда — Монголия Халык армиясендә инструктор. 1927 дән укчы полк командиры ярдәмчесе. 1933–39 да Мәскәү хәрби пехота мәктәбе штабы башлыгы, укчы дивизия штабы башлыгы, соңрак — командиры. 1939 дан — Калинин, 1940 тан Идел буе хәрби округлары штаб башлыгы. Бөек Ватан сугышында 21 нче армиянең штаб башлыгы (1941 нең июль —



В.Н.Гордов. Сталинград шәһәре. 1942.

сентябре) һәм командующие (1941 нең августы, 1941 нең октябре – 1942 нең июне), Сталинград фронты командующие (1942 нең 23 июле – 12 августы), 33 нче (1942 нең октябре – 1944 нең марты) һәм 3 нче (1944 нең апреле – 1945 нең мае) гв. армияләре командующие. Көнбатыш һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларда, Сталинград сугышында (1942–43), Ржев-Вязьма, Спас-Демен, Смоленск, Берлин, Прага (1945) операцияләрендә катнаша. 1945–47 дә Идел буе хәрби округы командующие. 1946–50 дә СССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, өч 1 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр һәм чит ил орденнары б-н бүләкләнә. Аның исеме Минзәләдәге бер урамга бирелә. Гаепсезгә репрессияләнә (1947), үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Герои Советского Союза – наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*М.В.Гордова.*

**ГОРДО́Н** Лев Хаймович (8.6.1935, Казан – 27.3.2010, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1984), проф. (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1959). РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, 1968–2007 елларда күзәнәкле оксидлашуны җайга салу лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре үсемлекләрнең әйләнә-тирә мохитнең тискәре факторларына җайлашуы механизмнарын өйрәнүгә карый. Ионнарны транспортлауда һәм кислородның актив формаларын генерацияләүдә катнаша, стресслы шартларда роле арта торган оксидлаштыру-торгызу системасының үсемлек күзәнәкләренең өске күзәнәк мембрасында эшчәнлеге турындагы гипотезаны тәкъдим итә һәм эксперименталь нигезли. Үсемлек күзәнәгенең хайван бавыры күзәнәкләре кебек ксенобиотикларны зарарсызландыру сәләтен һәм үсемлек тукымаларын төрле фармакологик препаратларны детоксикацияләү механизмнарын ачыклау өчен куллану мөмкинлеген беренче булып күрсәтә.

Х е з м.: Дыхание и водно-солевой обмен растительных тканей. М., 1976; Образование супероксида редокс-системой плазмалеммы корневых клеток и её участие в детоксикации ксенобиотиков // Докл. РАН. 1999. Т. 367, № 3; Дыхание корней пшеницы при ингибировании фосфолипазы $A_2$4 – бромфенацилбромидом // Цитология. 2001. Т. 43, № 7.

**ГОРДЯ́ГИН** Андрей Яковлевич (17.10.1865, Пермь ш. – 15.1.1932, Казан), геоботаник, туфрак белгече, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1929). 1914 елдан Казан ун-ты каршындагы Табигать фәннәре белгечләре җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы, 1925 тән рәисе. Казан геоботаника фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлый (1888). Казан (1891–1909, 1914–32) һәм Саратов (1909–14) ун-тларында укыта, 1901 дән профессор. Г.ның фәнни карашлары флораны җирле табигый-тарихи шартлар б-н тыгыз бәйлелектә өйрәнүче Казан геоботаника фәнни мәктәбе барлыкка килүдә зур роль уйнаган П.Н.Крылов, С.И.Коржинскийның классик хезмәтләре йогынтысында формалаша. Төп фәнни хезмәтләре Россиянең Көнчыгыш Европа өлешен, Көнбатыш Себер һәм Төньяк Казакъстанны табигый-географик тасвирлауга багышланган. «Көнбатыш Себернең туфрагын һәм үсемлекләр дөньясын танып белү өчен материаллар» («Материалы для познания почв и растительности Западной Сибири», (вып. 1–2, 1900–01)) дигән хезмәте өчен ботаника д-ры дәрәҗәсе (1901, магистрлыкны үтеп тормыйча) һәм Рус география җәмгыятенең Н.П.Пржевальский исем. көмеш медален (1902) ала. Ул флораны үсемлекләрне зоналарга бүлү һәм аның туфрак капламы б-н тыгыз бәйләнеше принцибына нигезләнеп тикшерә. Г. фикеренчә, туфрак – үзенең озакка сузылган яшәү дәверендә үсемлекләр дөньясы калдырган һәйкәл, шул нигездә үсемлекләрнең элек нинди шартларда яшәве хакында фикер йөртергә була. Көнбатыш Себер тигезлегенең көньяк-көнбатыш чикләрендә төньяктан көньякка таба (62–49° төньяк киңлектә) Г. биш полоса (туфрак-үсемлекләр зонасы) билгели: ылыслы урманнар б-н капланган көлсу ягъни тайга туфрагы; каен урманнары үскән кара туфрак; агач үсемлекләре үскән кара дала туфрагы; үләнчел ассоциацияләре б-н аксыл-коңгырт туфрак; төссез диярлек туфраклы һәм кокпек куаклары үскән чүл-дала туфрагы. Г.ның хезмәтләрендә, аерым алганда, «Татарстан Республикасының үсемлекләр дөньясы» («Растительность Татарской Республики», 1921) хезмәтендә, үсемлекләр дөньясы формацияләре алмашынуын анализлауга, урман һәм дала үсемлекләре дөньясы динамикасына, ш.у. үсемлекләр бергәлегендәге аерым төрләрнең (чыршы һәм нарат, чыршы һәм имән һ.б.) үзара йогынтысына зур әһәмият бирелә. Г. Россиядә беренче булып ботаникада матем. статистика ысулын куллана башлый, үсемлекләрне биометрик тикшерену, геоботаник күзәтүләрне статистик анализлау б-н шөгыльләнә. Гомеренең соңгы елларына кадәр укыта, ТАССР һ.б. чиктәш өлкәләр һәм республикалар терр-яләрендә геоботаник тикшеренүләрне җитәкли, аларны үткәрү программасын һәм методикасын төзи. Аның шәкертләре арасында ул оештырган фәнни мәктәп традицияләрен дәвам иттерүче талантлы галимнәр: Б.А.Келлер, В.И.Талиев, И.И.Спрыгин, Д.Э.Янишевский, А.Я.Пономарёв, М.В.Марков, В.С.Порфирьев һ.б. Г. Саратов ун-тын, Саратов югары а.х. курсларын (соңыннан а.х. ин-ты), Казандагы күп кенә югары уку йортларын: халык мәгарифе ин-тын (хәзер Татар гуманитар-пед. ун-ты), Казан ун-ты каршындагы урман ф-тын, Казан политехник ин-ты каршындагы а.х. ф-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) оештыруда турыдан-туры катнаша. 1908 дән бер үк вакытта Казан вет. ин-тында укыта, Саратов, Пермь фәнни җәмгыятьләре, Рус ботаника җәмгыяте, Рус география җәмгыятенең Көнбатыш Себер бүлеге шәрәфле әгъзасы итеп сайлана. Хезмәт Батыры (1928). Г. хөрмәтенә түбәндәге үсемлек төрләренә аның исеме бирелә: Echinops Gordiagini Keller, Cleome Gordiagini M. Pop., Crambe Gordiagini M. Pop. Казан ун-тында (ботаника кафедрасына керә торган ишек янына) мемориаль такта куелган; 1979 елдан Гордягин укулары үткәрелә.



А.Я.Гордягин.

Х е з м.: Естественноисторическое описание Казанской губернии. Почвы Казанской губернии. К., 1892; Растительность Татарской Республики // Географическое описание Татарской Республики. К., 1922. Ч. 1.

*Әд.:* Б а р а н о в В.И. О жизни и работе А.Я.Гордягина // Уч. зап. Казан. ун-та. 1933. Т. 93, кн. 6, вып. 1; К е л л е р Б.А. Памяти Андрея Яковлевича Гордягина // Советская ботаника. 1933. № 2; К о л о с к о в а А.В. Вклад А.Я.Гордягина в изучение почвенного покрова России // Почвоведение. 1982. № 12; Андрей Яковлевич Гордягин (1865–1932): К 125-летию со дня рождения // Ботанический журн. 1992. Т. 77, № 12.

**ГОРЕ́Ф-ГАДӘ́Т** (гарәп. عرف عادت – ияләнү, гадәт-йола), мөселман халыкларының йолалары, традицияләре. Аларның бер өлеше исламга кадәрге дәвердә үк барлыкка килә. Шәригать б-н беррәттән, мөселманнар тормышының төрле якларын җайга сала. Татарларда Г.-г. асылы б-н «йола» төшенчәсенә якын. Идел буе һәм Урал алды халыклары арасында ислам дине таралу электән яшәп килгән йолаларның кысрыклануына китерә, аларны мөселман йолалары алыштыра, ләкин элекке Г.-г.ләр тулысынча юкка чыкмый. Ш.у. к. *Җыен*, *Нәүрүз*, *Нардуган*, *Мәет күму һәм мәрхүмне искә алу йолалары*, *Сабан туе*, *Изге урыннар*.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГОРИЗО́НТОВ** Борис Иванович (6.8.1886, Казан – 14.11.1973, шунда ук), галим-агроном, агрохимия белгече, педагог, а.х. фән. д-ры (1946), проф. (1918), ТАССР, Чуаш АССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1944, 1944, 1957). Казан ун-ты физ.-матем. ф-тының табигать бүлеген тәмамлаганнан соң (1910), 1922 елга кадәр шунда ук, бер үк вакытта Казан политехник ин-тында укыта (1920–22). 1922 елда Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-тының агрохимия кафедрасын оештыра һәм җитәкли (1930 дан Казан а.х.ин-ты) һәм 50 елдан артык аның алыштыргысыз җитәкчесе була. Педагогик эшчәнлеген җитәкчелек эше б-н бәйләп алып бара, декан урынбасары, декан (1925–29), проректор (1929–34) вазифаларын башкара. Хезмәтләре игенчелектә фосфорлы һәм яңа формалы ашламалар куллануга, җирле фосфоритларны һәм туфракның агрохимик үзенчәлекләренә аларның тәэсирен өйрәнүгә карый. Аның тарафыннан җирле агрорудаңы бәяләү уздырыла, алардан ашламалар алу ысуллары эшләнә һәм җитештерү сынала. Татарстан һәм Чуаш АССР терр-ясендә фосфоритларның ятмалары җентекләп өйрәнелә, фосфорлы ашламалар алу өчен аларны термик һәм химик эшкәртү ысуллары тәкъдим ителә. Нәтиҗәдә Чуаш АССРның Вурнар з-дында фосфорит оны (1930), Казанның фотожелатин з-дында преципитат җитештерү (1963) оештырыла. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу о методах определения окисей железа и алюминия в фосфоритах. К., 1925; Опыты получения суперфосфата преципитата из фосфоритов Чувашской АССР. К., 1935.

*М.З.Гайнетдинов.*

**ГОРИЗО́НТОВ** Николай Иванович (29.4.1879, Новосибирск ш. — 29.4.1949, шунда ук), мед. д-ры (1909), приват-доцент (1912). 1899 елда Юрьев ун-тына укырга керә, 1902 дә Казан ун-тына күчерелә, 1904 тә тәмамлый. Казан акушерлык-гинекология клиникасында эшли. 1914 тә Германиягә командировкага җибәрелә. 1917 дән Томск ун-ты профессоры, акушерлык һәм гинекология каф. мөдире, клиника директоры, бер үк вакытта Физиотерапевтика ин-ты консультанты. 1935–48 елларда Новосибирск табибләр белемен күтәрү ин-тында һәм мед. ин-тында акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. Акушер-гинекологлар җәмгыяте әгъзасы. Хезмәтләре хатын-кыз җенси әгъзаларының икенчел туберкулёзы турындагы тәгълиматка, күкәйлекнең дермоид кисталарының беренчел яман шеш авыруына әйләнүе мәсьәләләренә карый. Новосибирск шәһәр советы депутаты. «Акушерство и гинекология» ж-лы мөхәррире, «Сибирский медицинский журнал»да бүлек мөхәррире. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К 70-летию профессора Н.И.Горизонтова // Акушерство и гинекология. 1949. № 4. Горизонтов — выдающийся акушер-гинеколог Сибири // Сб. науч. работ молодых учёных Томского мед. ун-та. Томск, 1960; Род российский — Горизонтовы // Наука и жизнь. 1968. № 4.

**ГО́РКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 43 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 172 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәр Богоявление Горка бистәсе исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г.да Богоявление чиркәве, земство хастаханәсе, чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), су һәм 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2585 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 700, 1897 дә — 1285, 1908 дә — 1345, 1926 да — 1095; 1938 дә — 743, 1949 да — 475, 1958 дә — 399, 1970 тә — 328, 1979 да — 241, 1989 да — 158, 2002 дә — 196 кеше.

**ГО́РКИНО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәчкәрә елгасы буенда. 2008 елда 15 кеше (руслар) яши. 1820 елларда нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиянnәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, известь һәм алебастр ясау өчен таш вату б-н шөгыльләнә. 1880 дә авыл җәмәгатенең имана җире 1276 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратай волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 228, 1889 да — 398, 1897 дә — 482, 1926 да — 716, 1938 дә — 423, 1949 да — 493, 1958 дә — 401, 1970 тә — 279, 1979 да — 86, 1989 да — 25, 2002 дә — 5 кеше.

*Әд.:* Шугур — край сокровищ = Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе. К., 1997.

**ГО́РЛОВ** Иван Яковлевич (13.4.1813, Рязань губ. — 5.10.1890, С.-Петербург), икътисадчы, статистика белгече, филос. д-ры (1838), тайный советник (1872). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын (1833), Дерпт профессорлар ин-тын (1838) тәмамлый. 1838–40 елларда Казан ун-тының сәяси икътисад һәм статистика кафедрасында экстраординар проф., 1840–47 дә ординар профессор. Бер үк вакытта 1840–42 дә ун-т каршындагы пед. ин-ты директоры. 1839 да Казан уку-укыту округы губерналарында фәнни командировкада була, шуның нәтиҗәсендә Казан губернасының статистик тасвирламасын төзи (1841). 1847–63 тә Петербург ун-ты юридик ф-ты ординар проф., 1863–73 тә атказ. проф., 1859–62 дә һәм 1869–70 тә деканы. Сәяси икътисадның төп мәсьәләләрендә вульгар икътисадчылар карашларына ияргә, аларны Россиядә хуҗалык итү үзенчәлекләренә ярашлы идеяләр белән баета, 1861 елгы Крәстиян реформасын әзерләү чорында алпавытлар проектын яклый, крәстияннәрне крепостной бәйлелектән чыгару илнең икътисадына тискәре тәэсир итү мөмкинлеге турында яза. Хезмәтләре Идел буе һәм Урал статистикасына карый. Күп еллар дәвамында университетлар өчен мәҗбүри булган укыту программалары һәм «Финанслар теориясе» («Теория финансов», 1841), «Россиянең икътисади статистикасы» («Экономическая статистика России», 1849), «Сәяси икътисад башлангычлары» («Начала политической экономии», 1–2 т., 1859–62) дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Движение народонаселения в Казанской губернии. К., 1840; Калмыцкое народонаселение в России. К., 1840; Описание Тагильского горного округа. К., 1840; О доходе с капитала. К., 1841.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ГО́РНИК** Григорий Лазаревич (15.10.1930, Ростов-Дон ш. — 10.1.2008, Казан), тарих фән. д-ры (1987), проф. (1989), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). Мари пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), мәктәптә укыта, соңрак Йошкар-Олада телевидение хезмәткәре булып эшли (1960–65). 1968 елдан Казан архит-ра-төзелеш академиясендә, 1987 дән сәяси тарих каф. мөдире. Хезмәтләре Идел һәм Урал буе республикаларының сәнәгате һәм эшчеләр сыйныфы, ТРның чит илләр б-н мәдәни багланышлары тарихына карый.

Х е з м.: Развитие социальной активности рабочих. К., 1985; Рабочее творчество. К., 1989; Мосты культуры. К., 2000; Международные культурные контакты (из истории культурных связей Татарстана с зарубежными странами). К., 2002.

**ГОРНОЗАВО́ДСК РАЙОНЫ́**, *Пермь өлкәсенең* көнчыгышында урнашкан. Мәйданы 7057,2 *км²*. Үзәге Горнозаводск шәһәре (Пермьнән 192 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы 27885 (2008) мең кеше. 2002 елгы халык исәбе буенча, Г.р.нда 1,4 мең татар исәпләнә.

**«ГО́РОД КАЗА́НЬ»** («Казан шәһәре»), көндәлек иҗтимагый, әдәби һәм икътисади газета. 1910 елның 2 октябреннән 1917 нең мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда наширләре — Л.П.Антонов, М.Н.Аристов, Н.А.Скворцов, Е.В.Щелкунов, Ю.А.Еленев; мөхәррирләре — Л.П.Антонов, М.Н.Аристов, Н.А.Скворцов, А.П.Чехановец, Ю.А.Еленев, В.М.Еленева, В.С.Андреев. 1913 нең 15 декабренә кадәр «Казань» исемендә чыга. К.А.Марьинский, М.Д.Прыгунов һ.б. хезмәттәшлек итә. Россия телеграф


Городъ
Казань
Цѣна 1 копейка
Рыжая
Прославились
ЖИГУЛЕВСКАГО
АПОЛЛО
СВѢТЪ и МРАКЪ
Буффъ
П. И. Чигарина
ПИВО

«Город Казань» газетасы.

агентлыгы телеграммалары, Россиянең иҗтимагый тормышы турында хәбәрләр, хроника басыла. «Казан тормышы» рубрикасында Казан шәһәр үзидарәсе органнары һәм башкарма комиссияләре эшчәнлеге яктыртыла. Публицистик һәм беллетристик эчтәлекле фельетоннарда Казанны төзекләндерү һәм чистартуга багышланган кискен мәсьәләләр күтәрелә. Реклама-белдерүләр, төрле хәлләр, бәхетсезлек очраклары, үтерешләр, янгыннар турында хәбәрләр басыла. Ш.у.к. «*Казанское слово*».

*Г.Р.Заманова.*

**ГОРОДЕ́Ц КУЛЬТУ́РАСЫ** (челтәр сыман бизәк төшкән керамика культурасы) (археол.), тимер гасырда (якынча б.э.к. 7 йөз — б.э. 5 йөзләре) Ука елгасының урман-дала зонасында, Мокша, Цна, Урта Идел, өлешчә Түбән Идел елгалары буенда таралган культура. 1899 елда археолог В.А.Городцов тарафыннан аерып чыгарыла. Атамасы Спасск-Рязанский каласы янындагы Городец авылына бәйле рәвештә бирелә (хәзер Рязань өлкәсе). Г.к. истәлекләрен төрле елларда ар-

хеологлар һәм тарихчылар А.П.Смирнов, Н.В.Трубникова, В.Г.Миронов, В.И.Ледяйкин һ.б. тикшерә. Г.к. формалашуда соңгы бронза гасырда Идел елгасының уңъяк ярларында яшәгән кабиләләр, *Ананьино культурасының* көнбатыш төркеме вәкилләре катнаша. Урта Идел буендагы фин-угор кабиләләренең ерак бабалары калдырган дип фараз ителә. Г.к. халкы терлекчелек, игенчелек, балык тоту, аучылык б-н көн күргән; алар тимер эретү һәм бронза кою б-н да шөгыльләнгән. Г.к. кабиләләре зур булмаган ырыг торулыкларында яшәгән, торулыклар рәт-рәт урлар б-н әйләндереп алынган. Тораклар землянка, ярымземлянка рәвешендә булган, анда корбан чалу урыннары, көнкүреш кирәк-яраклары табыла. Чүлмәк савыт-сабага челтәр сыман бизәк төшерелгән. Табылдыкларга нигезләнеп, Г.к.ның җирле вариантлары да аерып чыгарыла: Рязань, Саратов һ.б. төбәкләр. Кайбер галимнәр (А.П.Смирнов, В.Ф.Генинг, П.Н.Старостин һ.б.) фикеренчә, 3–7 йөзләрдә Иделнең сул ярындагы җирләргә күчкән Г.к. вәкилләре *Азелино культурасы* формалашуда катнаша. Татарстанда Г.к. истәлекләре Югары Ослан р-нының Карамышиха, Апас р-нының Урта Балтай һәм Урта Биябашы авылларында һ.б. урыннарда табыла.

*Әд.:* Смирнов А.П., Трубникова Н.В. Городецкая культура // Свод археологических памятников. М., 1965. Вып. 1–14; Миронов В.Г. Памятники городецкой культуры и проблема её локальных вариантов: Автореф. дис. ... М., 1976.

*П.Н.Старостин.*

**ГОРОДЕ́Ц-МЕЩЕ́РСКИЙ**, к. *Касыйм шәһәре.*

**ГОРОДИ́ЩЕ** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 22 *км* көньяктарак, Олы Яклы елгасы буенда. 2008 елда 840 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1667 елдан мәгълүм. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Г. дә авыл уч-щесе, чиркәү, ярминкә, базар була. 1920 гә кадәр — Сембер губернасының Буа өязе Городище волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 1060, 1910 да — 1438, 1938 дә — 2681, 1949 да — 1947, 1958 дә — 2118, 1970 тә — 2062, 1979 да — 1764, 1989 да — 1162, 2002 дә — 869 кеше.

**ГОРОДИ́ЩЕ** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 72 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 556 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. 1716 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәр Салкын Чишмә (Студёный Ключ) исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Кама з-дларына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. дә су һәм 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2970,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 812, 1897 дә — 1298, 1908 дә — 1347, 1920 дә — 1351, 1926 да — 1248, 1938 дә — 910, 1949 да — 678, 1958 дә — 670, 1970 тә — 735, 1979 да — 552, 1989 да — 375, 2002 дә — 508 кеше.

**ГОРОДИ́ЩЕ РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* көньяк-көнчыгышында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы 2,1 мең *км*². Үзәге Городище шәһәре (Пензадан 48 *км* көнчыгыштарак). Халкы 50,4 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1959 да — 9845, 1970 тә — 12053, 2002 дә — 32000 кеше. Алар, башлыча, Югары Әләзән (963 кеше), Урта Әләзән (7788), Түбән Әләзән (2456) авылларында (17 йөз башында нигез салына) яшиләр. 1917 гә кадәр район терр-ясендә 7 мәчет (3 се — Югары Әләзәндә, 4 се — Урта Әләзәндә) һәм 3 мәдрәсә эшли. 1920–30 да 2 татар мәктәбе ачыла. Хәзерге вакытта Югары Әләзәндә 3 мәчет, Түбән Әләзәндә — 1, Урта Әләзәндә 4 мәчет һәм 1 мәдрәсә эшли. Г.р.ның 4 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Бу районда мед. фән. д-ры, проф. Р.Ә.*Вяселев*, а.х. фән. д-ры Ф.Х.*Бәхтиев* туган.

**ГОРОДНЯ́НСКИЙ** Иван Ефимович (24.7.1930, Воронеж өлкәсенең Кантемир р-ны Рудаевка а. — 13.3.2009, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Мәскәү ит-сөт сәнәгате технологияләре ин-тын тәмамлый (1963). 1951–52 елларда Чаллы кошчылык комб-тында цех мөдире. 1952–60 та Чаллы ит комб-тының техник җитәкчесе, баш инженеры, 1960–64 тә директоры. 1964–65 тә Татарстан ит җитештерү берләшмәсендә (Казан) баш инженер. 1965–73 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1973–85 тә ТАССР азык-төлек сәнәгате министры. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ГОРОДО́К** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 18 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2008 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәр Казиле исеме б-н дә билгеле. 1961 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре (элек дворян Панаевларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г.та чиркәү-приход мәктәбе, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 381 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 19 ир-ат; 1859 да — 298, 1897 дә — 319, 1908 дә — 233, 1926 да — 340, 1938 дә — 281, 1949 да — 193, 1958 дә — 179, 1970 тә — 82, 1979 да — 46, 1989 да — 24, 2002 дә — 5 кеше.

**«ГОРОДСКО́Й И СЕ́ЛЬСКИЙ УЧИ́ТЕЛЬ»** («Шәһәр һәм авыл укытучысы»), пед. журнал. 1894–96 елларда Сембер шәһәрендә — 21, 1897 нең 8 февраленнән 1899 ның декабренә кадәр Казанда рус телендә 18 саны (елына 6–8 сан, соңгы саны 1900 да) нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — А.И.*Анастасиев*. Журналда халык уч-щеләре инспекторлары, укытучылар семинарияләре тәрбиячеләре һәм директорлары, шәһәр уч-щеләре һәм башлангыч мәктәп укытучылары, табибләр, дин кануннарын өйрәтүчеләр һәм руханилар язышa. Журнал авторлары арасында халык мәгарифенең күренекле эшлеклеләре А.Ф.Бажутин, Н.А.Бобровников, А.В.Векшин, Л.Г.Гуревич, М.А.Егоров, В.Г.Зимницкий, Ф.А.Знаменский, В.М.Ключников, В.А.Латышев, В.К.Магницкий, И.П.Мордвинов, А.С.Никольский, И.М.Петяев, К.И.Тихомиров, А.А.Ухтомский, В.И.Фармаковский, А.И.Червяковскийлар бар. Журнал шәһәр һәм земство уч-щеләре укытучыларына атап чыгарыла, гомуми һәм пед. белем, үзлегеңнән белем алу, фикер алышу һәм тәҗрибә уртаклашу ихтыяҗын канәгатьләндерергә омтыла. Халык мәгарифе министрлыгы һәм Изге Синод, округ уку-укыту идарәләре боерыкларын, губ., епархия һәм өяз уч-щеләре советларының карарларын, халык уч-щеләре директорлары, укыту-тәрбия инспекторларының күрсәтмәләрен бастыра. Предметларны укыту методикасына, башлангыч уч-щеләрдә тәрбия һәм укыту мәсьәләләренә зур урын бирелә. Рус булмаган халыкларга белем бирү өлкәсендә редакция *Ильминский системасын* яклый. Пед. хроника бүлегендә укытучыларның көндәлек практикасы яктырыла, Тәнкыйть һәм библиография бүлеге яңа чыккан пед. әдәбият — Россиянең пед. журналлары, өлкәннәр һәм балалар өчен чыккан уку китаплары, дәреслекләр һәм кулланмалар б-н таныштырып бара. Россиянең күренекле педагоглары һәм галимнәре В.А.Богородский, И.Н.Ульянов, К.Д.Ушинский эшчәнлеге һәм иҗаты турында материаллар бастырыла. 1872 нең 31 маенда кабул ителгән шәһәр уч-щеләренә яңа статус бирү турындагы Нигезләмәгә журналда аерым игътибар бирелә. Халык уч-щеләрендә укытыла торган күп предметларга, ш.и. авыл хуҗалыгына нисбәтле язмалар басыла.

*Г.Р.Заманова.*

**«ГОРОДСКО́Й ЛИСТО́К»** («Шәһәр сәхифәсе»), икътисади газета. 1882 елның 1 июненнән 1884 нең 23 июненә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 375 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре һәм наширләре — В.С.Марасанов, Д.А.Соколовский, В.М.Ключников, С.А.Гисси. Газета башта көн саен «Казанский листок для справок и известий» исеме б-н чыга. Анда Казан складларында һәм кибетләрендә булган товарларны рекламалаучы белдерүләр, вакантлы эш урыннары турында мәгълүмат бирелә. Матбугат эшләре баш идарәсе рөхсәте б-н газета «Казанский биржевой листок» г-тасы

нашире һәм мөхәррире Д.А.Соколовский кулына күчә һәм 1882 нең 19 декабреннән «Г.л.» исеме б-н атнага 3 тапкыр чыгарыла башлый. Сәүдә йортларына, дәүләт оешмаларына, контора һәм банкларга бушлай таратыла, урамнарга ябыштырыла. «Казанский биржевой листок»ның әбунәчеләре теләгәндә, китереп биргән өчен 3 сум түләп, «Г.л.»ны да алдыра алалар, чөнки газетага мөстәкыйль язылу булмый. Күчемсез милекне сату һәм сатып алу, аукционнар оештырылу, Казан китап базарларындагы яңа китаплар турында белдерүләр, Төньяк һәм Халыкара телеграф агентлыклары телеграммалары, төрле хәбәрләр басыла. Ш.у.к. «*Казанские новости*».

*Г.Р.Заманова.*

**ГОРОДЧА́НИНОВ** Григорий Николаевич (1772, Түбән Новгород губ. Балахна ш. — 22.12.1852, Казан), әдәбият галиме, шагыйрь, тәрҗемәче. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1797). 1799–1804 елларда С.-Петербургның Баш почта идарәсендә эшли. 1806 елдан Казан ун-тында — рус әдәбияты адъюнкты (өзеклекләр б-н), 1810 нан — (Казанда беренче булып) экстраординар, 1814 тән — ординар проф. Карьерасының чәчәк аткан чоры Л.М.Магницкий эшләгән елларга туры килә: 1816–22 дә Г. — әдәбият бүлеге, 1822–24, 1826–27 дә әхлак-сәясәт бүлеге деканы, 1820–25 тә (бүленеп) проректор вазифаларын башкара. 1811–13 тә «Казанские известия» г-тасында, 1821–29 да «Казанский вестник» ж-лында актив языша, 1832 дә «Заволжский муравей» ж-лы, 1843 тә «Маяк» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. 1806 дан Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте әгъзасы, 1926–46 да рәисе. Г. — 18 йөз архаик шигъри формалар тарафдары, Карамзин мәктәбен кабул итми. Тантаналы вакыйгалар уңае б-н язылган мәдхияләр һәм нотыклар авторы. Рус теленә Г.Рейнальнең «Европалыларның ике Һиндстандагы оешмалары һәм сәүдәсенең фәлсәфи һәм сәяси тарихы»н («Философская и политическая история о заведениях и коммерции европейцев в обеих Индиях», 1805) тәрҗемә итә.

Х е з м.: Опыт краткого руководства к эстетическому разбору по части российской словесности. К., 1813; Сочинения в стихах и прозе. Л., 1816.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. История Императорского Казанского университета (1804–1904): В 4 т. К., 1902–04; Русские писатели. 1800–1917: Биогр . словарь. М., 1989. Т. 1.

*М.М.Сидорова.*

**ГОРО́ХОВ** Василий Михайлович (1.3.1891, Вятка губ., Алабуга өязе Олы Елау а. — 7.10.1960, Казан), педагог, тарихчы, пед. фән.д-ры (1950), проф. (1950). Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен (1907), Казан укытучылар семинариясен (1911), Иркутск ун-тын (1922) тәмамлый. 1922 дән Казанда: Керәшен пед. техникумында укытучы, 1930 дан Казан пед. ин-тында, пед. ф-ты деканы (1934–60), бер үк вакытта пед. һәм психол. каф. мөдире (1952). Халык мәгарифе тарихына, балалар йортларында тәрбия мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1954).

Х е з м.: Мәктәптә тәрбия эшләре. К., 1955; Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. К., 1941; Кураловский детский дом. К., 1946; Школьное образование среди татар в 19 — начале 20 вв.: В 2 т. К., 1947.

*Әд.:* Х а н б и к о в Я.И. Из истории педагогической мысли татарского народа. К., 1967.

**ГОРО́ХОВ** Михаил Семёнович (8.11.1909, Красноярск крае Иланск ш. — 1994, Ижевск ш.), баллистика өлкәсендәге галим, техник фән. д-ры (1955), Артиллерия фәннәре академиясе мөхбир әгъзасы (1948). РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). 1931 елда Томск ун-тын тәмамлый һәм 1967 елга кадәр шунда эшли: Механика һәм математика фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире (1932 дән), баллистика секторы мөдире (1937 дән), директор (1939 дан). Бер үк вакытта Томск ун-тының баллистика каф. мөдире (1937–39 да һәм 1941 дән), Себер физ.-техника ин-тының баллистика секторы мөдире (1941 дән), проф. (1956). 1968–74 елларда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек башлыгы (Казан). 1974–76 да Ижевск механика ин-тының машиналар динамикасы каф. мөдире. Хезмәтләре эчке баллистика буенча. Г. дөньяда беренчеләрдән булып (бергәләп) күпшәле системаларда эчке баллистиканың газодинамик моделен зарядларның әкренләп кабынуын исәпкә алып эшли. Өч монография, 100 дән артык фәнни хезмәт авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнительная оценка различных методов измерения давления в артиллерийской технике // Изв. Акад. артиллерийских наук. 1951. № 19; Обобщение метода Н.Ф.Дроздова в случае применения основных уравнений при четырех параметрах // Изв. Акад. артиллерийских наук. 1952. № 2; Газодинамические основы внутренней баллистики. М., 1957 (автордаш).

**ГОРОХО́ВСКАЯ** Валентина Ивановна (4.7.1924, Казан), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1974), проф. (1976). 1947 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1950–1992 елларда Казан химия-технол. ин-тының (хәзер Казан технол. ун-ты) аналитик химия кафедрасында эшли. Хезмәтләре электроаналитик химия буенча. Г. хроновольтамперометрия ысулы б-н кайбер күкертле органик матдәләрнең электродлы процесслары механизмын тикшерә, адсорбция һәм кинетик факторларның ролен ачыклый, терекөмешле тама торган электродта күкертле матдәләрне билгеләү ысулын эшли. Бакыр индикатор ионнарының азотлы органик матдәләрне билгеләгәндә үз-үзен тотышын өйрәнә (пуриннар һәм пиримидиннар, триазоллар, тетразоллар һ.б.). Индикатор терекөмеш электродын, бакыр һәм кобальт индикатор ионнарын кулланып, азотлы һәм күкертле органик матдәләрне анализлау өчен квадрат-дулкынлы полярография ысулын файдалана. Органик кушылмаларны, нефть продуктларын, табигый һәм катлам суларын анализлау ысулларын, ш.у. баш сөяге эчендә отоген өзлегүләр булган авыруларның арка мие сыеклыгын тикшерү ысулларын эшли.

Х е з м.: Практикум по осциллографической полярографии. М., 1973 (автордаш); Практикум по электрохимическим методам анализа. М., 1983 (автордаш); Аналитическая химия. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГО́РСКИЙ БИ́ТУМНАР ЧЫГАНАГЫ́**, Татарстанда билгеле булган эре чыганакларның берсе. Нурлат р-ны һәм Самара өлкәсе терр-яләрендә. Мәләкәс батынкылыгының көнчыгыш читендә — Олы Чирмешән елгасы бассейнында урнашкан. 1973 елда ачылган. Битумнарның төп ятмасы Казан ярусына туры килә. Битумнарның сизелерлек чагылышы ш.у. Сакмар һәм Ассель ярусларының күпшәк-ярыклы известьташларында һәм доломитларында күзәтелә. Файдалы катламнар 222–318 *м* тирәнлектә; катламнарда битумның гомуми калынлыгы 4–5 тән алып 35–40 *м* га кадәр. Битумнар мальталар һәм асфальтлар классына керә (майлар — 35,6%, сумалалар — 28,1%, асфальтеннар — 36,1%); токымның массасына карата коллекторда битумга туенганлык — 6–11%. Битумнар составында сирәк очрый торган элементлар (V, Ni һ.б.) бар. Гомуми геол. запаслары — 33,139 млн *т*. Термошахта ысулы б-н чыгару күздә тотыла.

*Б.В.Успенский.*

**ГОРТЕ́НЗИЯ**, к. *Гидрангия*.

**ГОРТЫШО́В** Юрий Фёдорович (17.10.1946, Зәй р-ны Поручиково а.), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1986), ТР ФА акад. (2007), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2003). 1970 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1989–95 елларда җылылык техникасының теоретик нигезләре каф. мөдире, проф. (1988), 1995–2007 дә проректоры, 2007 дән ректоры. Хезмәтләре җир өсте, авиация һәм космик транспорт, ш.у. лазер техникасындагы энергетик җайланмаларда җылылык физикасы процессларын суыту һәм термик стабильләштерү системаларын оптималь проектлаштыруга карый. Г. сәнәгый җылылык алмашу җиһазларын проектлаштыру һәм хисаплауның фәнни нигезләрен һәм ысулларын эшли. Конструкцияләр элементларының суыту системаларын оптималь проектлаштыруны тәэмин итә торган математик һәм программа эшләнмәләр тәкъдим итә. Сәнәгатьтәге ташландык газларны, зарарлы газсыман, каты һәм сыек катнашмаларны чистарту, югары темп-ралы газларны суыту өчен өермә типтагы аппаратларның нәтиҗәлелеген арттыра. Югары күзәнәкле структуралардагы җылылык физик процессларны (җылылык-масса күчерү процессларын), җыйнак җылылык алмашу аппаратларындагы гидродинамиканы һәм җылылык алмашуны тикшерә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дуслык ордены, Россия Космонавтика федерациясенең акад. М.К.Янгель исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научно-исследовательские лаборатории теплофизического профиля. К., 1988; Охлаждение и термостабилизация деформируемых элементов конструкций. М., 1992; Теория и техника теплофизическиого эксперимента. М., 1993; Тепло-

обменные аппараты с интенсифицированным теплообменом. К., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость университета / КАИ: Краткий биогр. справ. К., 2002; Д е г т я р е в Г.Л., С а ф а р и е в М.С. Казанский государственный технический университет им. А.Н.Туполева: Люди и вехи истории. К., 2002.

**ГОРЧА́К** (Rhodeus sericeus), карплар семьялыгына керүче балык. Европа һәм Азия елгаларында таралган. ТРда Куйбышев сусаклагычында очрый. Әкрен агымлы һәм агымсыз елгаларның тугайлы, суүсемнәр б-н капланган өлешләрендә яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 10 *см*, ян-яктан кысылып, эре тәңкәләр б-н капланган. Сыртындагы йөзгече 8–10 тармаклы нурлардан тора. Башлыча, суүсемнәр б-н туклана. Яшәвенең икенче елында җенси яктан өлгереп җитә, уылдык чәчү язгы-җәйге айларга туры килә. Шул вакытка ана балыкларның уылдык салгычы үсә (кайчакта гәүдә озынлыгын да узып китә), аның ярдәмендә ике кабырчыклы эре моллюскларның мантия куышлыгына уылдык бөртекләрен сала. Уылдык бөртекләренең 300 гә якыны үрчемле. Кәсепчелек өчен әһәмияте юк, аквариумнарда тотыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГОРШКО́В** Владимир Николаевич (26.9.1949, Куйбышев ш.), балет артисты, театр белгече, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Белоруссия хореография уч-щесен (1969), Театр сәнгате Дәүләт ин-тының театр белеме ф-тын (1979) тәмамлый. 1969–75 елларда Кыргыз акад. опера һәм балет театры, 1975–84 тә Татар опера һәм балет театры балет артисты. 1985 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укытучы, 2000 нән хореография каф. мөдире, 2006 дан профессоры. Татар балет театры мәсьәләләренә караган фәнни һәм публицистик хезмәтләр авторы. «Татарстан» ДТРК каналында «Бию күренешләре» тапшыруының даими авторы һәм алып баручысы.

Х е з м.: Рудольф Нуриев: судьба и танец. К., 1995; Нинель Юлтыева: Сотни жизней в одной. К., 1996; Балетмейстер Гай Тагиров. К., 1997; Солисты татарского балета. К., 2000.

**ГОРШКО́В** Юрий Александрович (27.3.1954, Казан), биолог, эколог, биол. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), РФА КГҮнең Биология ин-тында эшли. 1993 тән ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-тында, 1994 тән ЮНЕСКОның биосфералы терр-я статусын алган (2005) Идел-Кама дәүләт табигый биосфера саклаулыгы директоры. Г. инициативасы б-н саклаулык мәйданы 2 мең *га* га киңәйтелә (2001), Европа кондызын реинтродукцияләү оештырыла, кондызлар экологиясенә багышланган беренче Евро-Америка конгрессы үткәрелә (1999). Хезмәтләре имезүчеләр һәм кошлар экологиясенә, саклаулык эшләренә, табигатьтән файдалануга карый. Россиядә биологик күптөрлелекне саклауга зур өлеш кертүкәне һәм кыргый хайваннарны саклауда күрсәткән шәхси батырлыгы өчен халыкара Эндрю Сейбин бүләгенә (1966) лаек була һәм медальләр, ш.и. «Әйләнә-тирә мохитне саклаудагы казанышлары өчен» медале (2005) б-н бүләкләнә. Биосфера тыюлыгы б-н идарә итү өлкәсендәге казанышлары өчен ЮНЕСКОның М.Батис исем. бүләгенә лаек була (2009).

Х е з м.: Ресурсы водоплавающих птиц Татарии. К., 1989 (автордаш); Экология ондатры в долинах рек с зарегулированным стоком. К., 1992 (автордаш); Перемещения и миграции. Ондатра. М., 1993 (автордаш).

**ГОРШКО́ВА** Татьяна Анатольевна (13.12.1953, Казан), биохимик, биол. фән. д-ры (1997). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1980 елдан РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, 1997 дән баш фәнни хезмәткәр. 2002 дән үсемлек күзәнәкләре үсеше механизмнары лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре үсемлекләрнең күзәнәк тышчаларында полисахаридлар һәм фенол кушылмалары метаболизмына, фотосинтезга, үсемлекләр үсешенә карый. Үсемлекләр метаболизмында үсемлекләрнең күзәнәк тышчаларының күппланлы роле турындагы күзаллауны үстерә, күзәнәк тышчаларындагы үсеш, онтогенез, стресс барышында үзгәрүгә дучар булган компонентларны ачыклый һәм тасвирлый.

Х е з м.: Cell wall polisaccharides of developing flax plants // Plant Physiol. 1996. V.110, № 3 (автордаш); Composition and distribution of cell wall phenolic compounds in flax (Linum usitatissimum L.) stem tissues // Annals of Botany 85. 2000. V.5 (автордаш).

**ГОРШКО́ВО** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 22 *км* төньяктарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 165 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чаллы, Красный Колок исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Авзянопетров з-дларына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да Петропавел чиркәве (1886 да салына; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1957 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир-ат; 1859 да — 414, 1897 дә — 787, 1908 дә — 841, 1920 дә — 1044, 1926 да — 945, 1938 дә — 910, 1949 да — 714, 1958 дә — 563, 1970 тә — 422, 1979 да — 226, 1989 да — 108, 2002 дә — 225 кеше.

**ГО́РЬКИЙ** Максим (псевд., исем-фамилиясе Пешков Алексей Максимович) (16.3.1868, Түбән Новгород ш. — 18.6.1936, Мәскәү), язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Фома Гордеев» (1899), «Ана» («Мать», 1907), «Артамоновлар эше» («Дело Артамоновых», 1925), «Клим Самгинның тормышы» («Жизнь Клима Самгина», 1927–36), романнары, «Балачак» («Детство», 1913–14 ) «Малайлыкта» («В людях», 1916), «Минем университетларым» («Мои университеты», 1923) автобиографик трилогиясе, пьесалар, хикәя, шигырь, истәлек, очерк, памфлет, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Ун-тка керү максаты б-н 1884 елда Казанга килә, ләкин 2 еллык башлангыч белем б-н бу мөмкин булмый. Елга портында йөк ташучы, генерал Корнэ хатынында бакча караучы һәм ишегалды себерүче, кибетче А.С.Деренковның пекарнясендә ярдәмче булып эшләп йөри. 1887 дә күңел төшенкелеге кичерә (Мария Деренкова аның мәхәббәтенә җавап кайтармый, яраткан әбисенең үлгән хәбәре килә) һәм үз-үзенә кул салырга тырышып карый. Соңыннан бу хәлне Г. «кабахәтлек һәм тормышның рәхимсезлеге каршында курку калу» б-н аңлата. 1885 тә ул народниклар түгәрәкләренә йөри, яшерен әдәбият укый башлый. 1888 нең июненнән сентябренә кадәр Иделдәге Красновидово авылында (хәзерге Кама Тамагы р-ны) яши. Казанда узган еллары Г. ның берничә әсәрендә чагыла: «Бервакыт көз көнендә» («Однажды осенью»), «Каптырма мәсьәләсе» («Дело с застёжками»), «Акулина әби» («Бабушка Акулина», барысы да 1895), «Коновалов» (1896), «Элекке кешеләр» («Бывшие люди», 1897), «Егерме алты һәм берәү» («Двадцать шесть и одна», 1899), «Макар тормышыннан бер вакыйга» («Случай из жизни Макара», 1912) «Хуҗа» («Хозяин», 1913), «Җиңел кеше» («Лёгкий человек», 1917), «Минем язарга өйрәнүем» («О том, как я учился писать», 1919) һ.б. Татарларны «аек акыллы, пакьлек яратучы, хезмәт сөючә, максатка ирешү юлында күңел нечкәлеген үҗәтлек б-н берләштерә белүче халык» дип бәяли. Казанда яшәгән елларын соңрак Г. үзенең шәхес буларак формалашу чоры дип танып: «Физик яктан мин Түбән Новгородта, рухи яктан Казанда тудым. Казан — минем иң яраткан «университетларымның» берсе»,– дип яза. 1928 дә Г. кабат Казанга килә һәм шуннан башлап татар язучылары (К.Нәҗми, Г.Кутуй, Г.Минский, Ш.Усманов, Г.Толымбайский һ.б.) б-н ике арада тыгыз дуслык урнаша. М.Н.Елизаровага язган хатында ул болай ди: «Мин чын күңелдән татар поэзиясе һәм прозасының чәчәк атуын телим. Ләкин бу максатка әдәбият мәсьәләләренә таләпчән караганда гына ирешеп була». Г. әсәрләренең күбесе татар теленә тәрҗемә ителгән. Бу эш б-н күренекле язучылар С.Әдһәмова, Г.Камал, Ш.Камал, А.Шамов, И.Гази, М.Әмир, Г.Кутуй шөгыльләнәләр. 1940 тан Казанда А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музее, 1950 дән Красновидово авылындагы музее эшли. Казанда бер урамга, Үзәк мәдәният һәм ял паркына аның исеме бирелә.



М.Горький.

Ә с ә р.: Полн. собр. соч. худож. произведений: В 25 т. М., 1968–76.

*Әд.:* Летопись жизни и творчества А.М.Горького. М., 1958; Музей А.М.Горького в Казани: Путеводитель. К., 1980.

*Ф.Ф.Мирзина.*







Казанда А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музее. 1. Музей бинасы; 2–3. Экспозиция күренешләре: әдипнең язу өстәле һәм урындыгы; «А.С.Деренков пекарнясы».

**ГО́РЬКИЙ А.М. ӘДӘБИ́-МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЕ́,** Казанда. ТАССР ХКСның 1938 ел 21 июль карары б-н нигез салына, 1940 елда ачыла, 1983 тән ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы. 19 йөзнең 2 нче яртысында М.Беляев милке булган йортта урнашкан, анда 1886–87 дә А.М.Пешков (Горький) А.С.Деренков пекарнясында икмәк пешерүче ярдәмчесе булып эшли. Тарихчы Н.Ф.Калинин җитәкчелегендә бинаны музей итеп үзгәртеп кору эшләре башкарыла, экспозициянең фәнни концепциясе авторлары — Н.Ф.Калинин, В.Н.Терновский, Г.Ф.Линсцер. 1963 тә музей үзгәртеп корыла, экспозициянең фәнни концепциясе авторлары — Л.Н.Иокар, Р.Г.Бейслехем (СССР ФАнең М.Горький исем. Дөнья халыклары әдәбияты ин-ты). 1967 дә бина алдында А.М.Горький бюсты (сынчы И.А.Новосёлов) куела. 1988 дә музей бинасы киңәйтелә һәм яңадан үзгәртелә, экспозициянең фәнни концепциясе музей хезмәткәрләре Р.Г.Гарифҗанова, Ф.Ф.Мирзина, В.З.Дәүләтшина, Л.Б.Белова, И.В.Завьялова тарафыннан эшләнә, баш рәссам — Г.Г.Коган (С.-Петербург). Гомуми мәйданы — 2400 *м²*. Музейны оештыруда һәм аның коллекцияләрен тулыландыруда Е.П.Пешкова (язучының тол хатыны), Н.А.Пешкова (аның килене), Д.М. һәм М.М.Пешковалар (оныклары), И.Ф.Шаляпина (артистның кызы), И.Б.Морфей-Шаляпина (аның оныгы), Д.Робертсон-Шаляпина (оныгының кызы) булышалар.

Музей фондларында 60 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. М.Горькийның мемориаль әйберләре коллекциясен күп еллар дәвамында музейга Е.П. һәм Н.А.Пешковалар тапшырып килә, Ф.И.Шаляпинның мемориаль әйберләр коллекциясе И.Ф.Шаляпинадан алына; фондлар «Горький һәм татар язучылары» темасына караган материаллар, сынлы сәнгать әсәрләре, Н.Ф.Калинин, М.Н.Елизарова архивлары һ.б. б-н баетыла. Экспонатлар арасында Горькийның Мәскәү янындагы Горки дачасыннан кайтарылган язу өстәле һәм кәнәфие, 1928 дә язучының Казанга киеп килгән киемнәре, аның китапханәсеннән алынган 298 китап, әдипнең 20 йөз башында С.-Петербургта, Түбән Новгород, Ялта, Сорренто, Финляндия, Каприда алынган фотосурәтләре һ.б. аеруча кыйммәтлеләрдән санала. Ф.И.Шаляпин әйберләре коллекциясенә аңа С.И.Мамонтов бүләк иткән рояль, артистның Мәскәү фатирыннан әйберләр (имән урындыклар, «Ш» вензеле куелган сөлгеләр, Н.А.Римский-Корсаковның Ф.И.Шаляпин тарафыннан эшләнгән барельефы), граммофон һәм җиде пластинка (аларның 4 сенә җырчының тавышы язылган), язу приборы, кофе сервизы, театр реквизитлары һәм артист чыгышлар ясаган костюмнарның детальләре, аның талантын хөрмәтләүчеләр бүләк иткән тасмалар, 1909 да Франциядә, 1917 дә Россиядә булып үткән чыгышларының афишалары, 1904 тә бүләк ителгән көмеш ваза-чүмеч керә.

Музейда М.Горький һәм Ф.Шаляпинга багышланган даими экспозиция (соңгысы 1968 дән) эшли, төп типологик әйберләр җирлегендә пекарня интерьеры булдырыла. М.Горькийга багышланган даими экспозиция вакытлыча җыеп алынган. «Максим Горькийның Казан «университетлары», «Ф.И.Шаляпин тормышында Казан» дигән күргәзмәләр эшли. Музейның «Сукбай эт» («Бродячая собака») әдәби кафесында даими эшләүче «Көмеш гасыр» («Серебряный век») фотодокументаль күргәзмәсе тәкъдим ителә. Музейның күргәзмәләр залында ел саен төрле музей фондлары, шәхси коллекция материаллары буенча 40 ка якын вакытлы күргәзмә оештырыла.

Музей даими рәвештә Мәскәү, С.-Петербург, Түбән Новгород, Самара, Ижевск, Казан галимнәре, музей хезмәткәрләре һәм коллекционерлар катнашында Горький (1942 дән) һәм Шаляпин (1973 тән) укулары үткәрә.

Музей каршында яшь авторларның әдәби берләшмәсе эшли. Ел саен «Февраль кичләре», «Горький чыршылары» программалар циклы, ш.у. «Шигърият бәйрәме», «Музейда төн» һ.б. үткәрелә.

Музей директорлары: З.И.Позанкова (1938–39), А.А.Егоров (1939), А.А.Мөсифуллин (1940), М.Н.Елизарова (1941–78), Л.Г.Алексеева (1978–79), Н.Х.Тур (1980–81), Г.А.Оноприенко (1981–88), Ә.Ә.Тутаева (1988–2000), М.Ә.Мөдәррисова (2000–2007), М.Ф.Гаврилова (2007 дән). Музейның ф-ллары Красновидово авылында (*Горький М. музее*, 1979–83), Казанда (*Боратынский Е.А. музее*, 1981–83) эшләп килде.

Музейның басмалары: Музей А.М.Горького в Казани: Путеводитель. К., 1980; Казань в жизни А.М.Горького и Ф.И.Шаляпина. Прогулки по Казани. К., 1998. Вып.9; Фёдор Иванович Шаляпин и Казань. К., 1999; Шаляпинские чтения в литературно-мемориальном музее А.М.Горького в Казани (1992–2002). К., 2002; Горький и Поволжье. Материалы Горьковских чтений, посвящённых 135-летию со дня рожд. А.М.Горького, состоявшихся в Казани 26 марта 2003 года. К., 2006.

*Әд.:* Казань: Спец. выпуск, посвящённый лит.-мемор. музею А.М.Горького. 1998. № 4; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

**ГО́РЬКИЙ А.М. МУЗЕЕ́,** Кама Тамагы р-нының Красновидово авылында. 1950 елда мәктәп музее буларак ачыла, 1979 елдан Казандагы *Горький А.М. әдәби-мемориаль музее* ф-лы, 1983 тән ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы.

А.М.Пешков (М.Горький) 1888 нең июненнән сентябрь аена кадәр Красновидово авылында яши. Ул анда Казанда тыелган әдәбият китапханәсе хуҗасы А.С.Деренков өендә үткәрелә торган яшерен җыелышларда танышкан революционер-народник М.А.Ромась (Ромасёв) чакыруы буенча килә. Ромась Казанда Н.Г.Чарушин һәм Н.А.Натансон җитәкләгән народниклар түгәрәге акчасына Красновидовода вак-төяк бакалея әйберләре кибете тота. 1888 нең августында кибет яндырылгач, Ромась һәм аннан соң Пешков та авылдан китәләр.

1979 дан музей 1949 да Красновидовода булып киткән А.С.Деренков күрсәтүе буенча билгеләнгән урында элеккеге кибет бинасында урнаша. Бина архитектор һәм төбәкне өйрәнүче В.В.Чумаков проекты б-н үзгәртеп корыла. Йорт, каралтысының бер өлеше, кап-



Красновидово авылында А.М.Горький музее бинасы.





Красновидово авылында А.М.Горький музее.
1–2. Экспозиция күренешләре.

касы торгызыла, таштан янкорма салына. Музей терр-ясендә 1983 тә А.М.Пешков һәйкәле (сынчы И.А.Новосёлов) куела.

Музейның гомуми мәйданы 144 *м²*, экспозиция мәйданы 77 *м²*. Музей фондларында 998 саклау берәмлеге исәпләнә. Ике даими экспозиция — төп типологик предметлар нигезендә яңадан торгызылган кибет һәм торак бүлмә интерьерларыннан мемориаль; язучының тормышына һәм иҗатына багышланган әдәби экспозицияләр эшли. 1993–94 тә музей экспозициясен яңарту эшләре башкарыла (концепция авторы — музейның фәнни хезмәткәре Л.Б.Белова, проект рәссамы — Ф.Ә.Зыязов). 1999 да әдәби экспозиция авыл тарихы материаллары һәм этнографик комплекс б-н тулыландырыла.

Музей мөдирләре — В.И.Кобзова (1978–79), В.Г.Останина (1979–92), Г.А.Калыгина (1992–96), О.А.Артамонова (1996–97), О.Н.Гришукова (1997 дән).

*Әд.:* Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. К., 1993; Б е л о в а Л.Б. Друзья по ссылке В.Г.Короленко и М.А.Ромась // Казань. 1998. № 4; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

**ГО́РЬКИЙ ТИМЕ́Р ЮЛЫНЫ́Ң КАЗА́Н БҮЛЕКЧӘСЕ́**, 1961 елда Казан (1936 да Мәскәү-Казан һәм Свердловск тимер юлларын бүлү нәтиҗәсендә Казан тимер юлы буларак оештырыла) һәм Горький тимер юлларын берләштерү нигезендә барлыкка килә. 2008 дән — Горький тимер юлының Казан бүлекчәсе — «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы. Төп эшчәнлеге — пассажирлар һәм йөк ташу. 4 республика (ТР, Чуаш, Мари һәм Мордва Респ-калары), Киров, Ульянов өлкәләре терр-яләрен били; ТР б-н мөнәсәбәтләрен Горький тимер юлының хезмәттәшлек турында төбәкләр б-н төзелгән килешүләреннән чыгып урнаштыра. Бүлекчә составына 81 станция, 3 сортировка тавы һәм керү юлларының челтәре керә. Юл составына һәм техникага хезмәт күрсәтү, ш.у. ремонт эшләре 2 локомотив депосы, 1 йөк һәм 2 пассажир вагоннары депосы, Юдино электр б-н тәэмин итү, сигнализация һәм элемтә дистанцияләре, Казан төяү-бушату хезмәте дистанциясе, 1 гражданнар корылмалары дистанциясе тарафыннан башкарыла. Тимер юлларны яраклы хәлдә тотуны һәм төзәтүне 5 юл дистанциясе, 2 юл-машина станциясе, урман саклау утыртмалары дистанциясе тәэмин итә. Пассажирлар ташуны һәм шәһәр яны юлларында хәрәкәтне оештыру б-н Пассажирларга ерак юлларда хезмәт күрсәтү дирекциясе һәм Казан локомотив депосы шөгыльләнә. Югары дәрәҗәдә транспорт хезмәте күрсәтү агентлыгы реклама эшен һәм хезмәт күрсәтүне оештыра. Тимер юлның Казан бүлекчәсе чикләре: көнчыгышта — Кизнер станциясе (керү сигналына кадәр) — Горький тимер юлының Ижевск бүлекчәсе б-н чиктәш; көньякта — Красный Узел, Чыныллы станцияләре (керү сигналына кадәр) — Куйбышев тимер юлы б-н чикләнә; көнбатышта — Канаш станциясе — Горький тимер юлының Муром бүлекчәсе б-н чиктәш. Г.т.ю.К.б. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1971). Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц. Хезмәт Геройлары — 4 кеше; РФ, ТР, Мари Респ-касы, Чуаш Респ-касының атказ. транспорт хезмәткәрләре — 108 кеше; РФ, ТРның атказ. энергетиклары — 7 кеше; ТРның атказ. табибләре — 5 кеше; РФнең атказ. укытучылары — 3 кеше; ТРның атказ. мәдәният хезмәткәрләре — 2 кеше; орденнар б-н — 248 кеше, медальләр б-н 207 кеше бүләкләнә. Казан тимер юл башлыклары — Н.А.Пичугин (1928–43), М.С.Сорокин (1944–45), Я.И.Соколинский (1945–47), И.С.Ромашов (1951–52), А.М.Сидоренко (1952–53), Н.С.Ерогов (1953–56), Р.А.Тышков (1956–61); Г.т.ю.К.б.нең башлыклары — А.М.Мальков (1961–63), Р.А.Тышков (1963–70), А.М.Калинин (1970–72), В.В.Синякин (1972–79), А.П.Пищиков (1979–86), Э.Ф.Самохин (1986–93), Г.В.Тулисов (1993–98), И.А.Белов (1998–2008), Р.И.Мистахов (2008 дән). Ш.у.к. *Тимер юл вокзалы, Тимер юл транспорты.*

*Г.Я.Мәүлетова, А.А.Турцева.*

**ГОРЮНО́В** Лев Васильевич (12.6.1937, Яшел Үзән ш.), гидрогазодинамика һәм двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (1996), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1999). 1960 елда авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1991 дән турбиналы машиналар каф. мөдире, 1983–95 елларда очкыч аппарат двигательләре ф-ты деканы. Хезмәтләре космик энергетика станциясенең модельле турбогенераторында гидростатик терәкләрнең эшләү сәләтен өйрәнүгә карый. Гидростатик радиаль подшипниклардагы эш процессларын өйрәнә һәм авиациядәге газ турбиналы двигательләрнең катнаш терәкләрен тикшерә. Г. гидростатик радиаль подшипникларны берләштерү принцибы җирлегендә проектлаштыруның фәнни нигезләрен һәм хисаплау ысулларын эшли. Гидростатик подшипник куышлыкларында сыеклык агу процессын һәм тәгәрәү подшипникларының вибрация сыйфатламаларын фәнни тикшерә. Голографик интерферометрия өчен лазерлы технол. комплекс төзи. Уйлап табуга 16 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проектирование турбомашин двигателей летательных аппаратов. К., 1994 (автордаш); Исследование разрывных течений смазки в элементах радиальных гидростатических подшипников // Авиац. техника. 1997. № 4 (автордаш); Доводка опор роторов авиационных газотурбинных двигателей по надёжности // Вестн. Казан. ун-та. 1998. № 1 (автордаш).

**ГОРЯ́ЕВ** Николай Константинович (12.6.1875, Тобол губ. Төмән ш. — 11.7.1943, Казан), терапевт, мед. д-ры (1910), проф. (1920), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940), Соц. Хезмәт Батыры (1933). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1902). 1911–12 елларда чит илләрдә (Вена, Берлин, Фрейнбург ш.) эшли. 1903–43 тә Казан мед. ин-тында, 1920 дән госпиталь терапиясе каф. мөдире. Г. кан ясалу органнары морфологиясен, физиологиясен, патофизиологиясен өйрәнә, гематологик тикшеренүләрнең методикасын һәм техникасын әзерли. Канны тикшергәндә файдаланыла торган санау камерасы өчен челтәр — *Горяев санау камерасын* (Германиядә эшләнә) тәкъдим итә. Хезмәтләре гематологик тикшеренүләр техникасына, яман анемия, талак авыруларын дәвалауга карый. Г. төрле эчке органнар авырулары буенча 60 тан артык уникаль гематологик рәсемле таблица төзи. Г. Татарстанда кан күчереп саклу хезмәтен оештыруга зур өлеш кертә.

Х е з м.: Материалы к вопросу о движениях и иннервации селезёнки. К., 1910; Материалы к вопросу о кумысолечении при лёгочном туберкулёзе // Казан. мед. журн. 1930. № 5–6.

Әд.: Профессор Н.К.Горяев // Казан. мед. журн. 1933. № 1–2; Б и л и ч И.Л. Николай Константинович Горяев. К., 1971.

**ГОРЯ́ЕВ САНА́У КА́МЕРАСЫ**, кан күзәнәкләре санын исәпләү приборы. Г.с.к. немец галиме Бюркер санау камерасы тибында эшләнгән һәм беренче тапкыр Германиядә (1922) җитештерелгән. Прибор Н.К.*Горяев* (Казан ун-ты, 1920) тарафыннан эшләнелгән махсус челтәр б-н шкалаларга бүленгән. Конструкциясенең гадилеге кандагы эритроцитлар, лейкоцитлар, тромбоцитларны төгәл исәпләргә мөмкинлек бирә. Ысулны лимфоцит һәм гранулоцитларны аерып санаганда да файдаланырга мөмкин. Н.К.Горяев гематологиягә караган хезмәтләрендә гамәлдәге санау камераларына чагыштырмача бәя бирә, зурлыгына, төшенең һәм протоплазмасының төсенә карап, формалы аерым элементларның сыйфатларын билгели; күзәнәкләргә җентекле морфологик характеристика биргәндә канны пыялага ягып тикшерү ысулының өстенлеген ассызыклый; кайбер техник шартларны төгәл үтәү, ш.и. катнаштыргычта канны алдан әзерләү (4–5 *мин.* буе яхшылап болгату), санау камерасын дөрес тотуры һ.б. эшләрдә күп кенә техник таләп-

ләрнең төгәл үтәлергә тиешлегән күрсәтә, Г.с.к. клиник лаб-яләрдә канның формалы элементларын санау өчен киң кулланыла.

*Әд.:* Горяев Н.К. Исследование и симптоматология болезней крови // Основы клинической диагностики для врачей и студентов. М., 1928.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ГОРЯ́ЧЕВ** Алексей Андреевич (17.3.1917, Уфа губ., Минзәлә өязе Фионовка а. — 15.11.1982, Пермь өлкәсе, Кизел ш.), Дан орденының тулы кавалеры (28.8.1944, 3.3.1945. 19.3.1945), старшина (1945). Кизелдә машинист булып эшли. 1938 дән Кызыл Армиядә. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 407 нче аерым разведка ротасының отделение командиры (43 нче армиянең 334 нче укчылар дивизиясе). Көнбатыш, Калинин, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәүне саклауда (1941–42), Смоленск (1943), Белоруссия, Балтыйк буе (икесе дә — 1944), Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша.

1944 нең 16 августында Личунья авылы (Латвия ССРның Баус р-ны) янында батырлык күрсәтә; 1945 нең 30 гыйнварында Шиппенбайль торак пункты (Көнчыгыш Пруссия) янында дошман траншеяларына беренчеләрдән булып бәреп керә; 1945 нең 15 мартында Грюнвальд торак пункты янында Лаутер елгасын (Кёнигсберг шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, хәзерге Калининград ш.) беренче булып кичә һәм каршы ярда ныгып урнаша. 1945 тән запаста, Кизел шәһәрендә шахтада тау эшләре остасы булып эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лобода В.Ф. Солдатская слава. М., 1967, Кн. 2; Слава солдатская. Пермь, 1984; Хостенков А.Г. Славен их путь боевой. Калининград, 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ГОСМА́Н МӘЧЕТЕ́**, к. *Солтан мәчете*.

**ГОСМА́Н** (Госманов) Хатип Госман улы (21.5.1908, Пермь губ., Усы өязе Сулмаш а. — 14.2.1992, Казан), әдәбият галиме, язучы, фил. фән. д-ры (1962), проф. (1964), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1968). 1927–35 елларда туган авылында колхозда, Казан һәм Мәскәүдә г-та редакцияләрендә эшли. 1939 да Казан пед. ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронттан кайтканнан соң Казан пед. ин-тында укыта. 1951–91 дә Казан ун-тында белем бирә (1951–75 тә татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире). Урта гасырлар һәм 20 йөз башы татар әдәбияты тарихы, әдәбият теориясе һәм татар шигырь төзелешенә караган хезмәтләр, урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторы. 1920 еллар татар поэзиясен, татар әдәбиятында соц. реализм ысулы үсешен өйрәнә. Аның тарафыннан беренче тапкыр төрки шигърият генезисы һәм эволюциясе өйрәнелә; төрки-татар шигыренең ритмик төзелеше барлыкка килү концепциясе тәкъдим ителә; борынгы һәм төрки-татар әдәбиятын өйрәнү методикасы эшләнә. Галим урта гасырлар төрки-татар әдәби мирасын халыкка кайтару юлында зур эш башкара; «Җөмҗөмә солтан» поэмасының тәнкыйди текстын басмага әзерли, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын татар әдәби теленә күчерә, Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки» әсәрен, Батырша хатларын текстологик яктан эшкәртә. «Кырлар лирикасы» (1931), «Кан тавышы» (1933) исемле шигырьләр, «Йосыф» (1937), «Ялкынлы йөрәк» (1943), «Ут сызыгында» (1945) исемле проза җыентыклары авторы. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Такташ поэзиясе. К., 1953; Егерменче елларда татар поэзиясе. К., 1964; Татар әдәбияты һәм тарихы материаллары. К., 1967; Шигырь төзелеше. К., 1975; Әдәбият теориясе. Е., 1980; Тюркский стих в средние века. К., 1987.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Татар әдәбияты тарихы. К., 2001. Т. 4.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**«ГОСМАНИЯ́»**, Уфа шәһәрендәге мәдрәсә. 1887 елда беренче җамигъ мәчет каршында Х.Г.*Госманов* тарафыннан нигез салына. Шәһәрдә беренче мәдрәсә. Башта укыту традицион (гадәти) формада алып барыла, 1895 тән яңа алымнар, рус теле курслары кертелә. 19 йөз ахырына регионда дини белем бирүче иң эре үзәкләрнең берсенә әверелә. Уку вакыты 12 ел, шәкертләр саны 500 дән артып китә. Мөгаллимнәре арасында — З.*Камали*, Г.Х.*Терегулов*, С.С.*Җантурин* һ.б. Башка яңа алымлы мәдрәсәләр б-н чагыштырганда «Г.»дә гарәп телен укыту югары дәрәҗәдә куелган була. Мәдрәсә мөгаллиме К.Жданов киң таралыш алган татарча-башкортча әлифба төзи. 1906 дан Уфа губернасының земство идарәсе акчасына һәм мөселманнардан җыелган иганә хисабына махсус төзелгән үз бинасында урнаша.

1918 дә Директория хөкүмәте карары б-н татар милли гимназиясе, 1919 елда урта мәктәп итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Валеева М.Г. Медресе Усмания // Дорога к храму (история религиозных заведений города Уфы). Уфа. 1993.

**«ГОСМАНИЯ́»**, Казан шәһәрендәге мәдрәсә. 1867 елда 8 мәхәлләле мәчет (к. *Солтан мәчете*) б-н бер үк вакытта ачыла. Комплексны төзетүче сәүдәгәр Ж.Б.Госманов исеме б-н атала. Эшләү елларында мәдрәсә б-н «Кышкар» мәдрәсәсен тәмамлаган Салиховлар гаиләсе вәкилләре җитәкчелек итә. Укыту, нигездә, иске алымнар б-н алып барыла. Г.Салихов матбугатта мәгариф өлкәсендәге үзгәртүләргә каршы мәкаләләр б-н чыга, әмма акрынлап мәдрәсәгә укытуның яңа формалары үтеп керә. 1899 дан рус теле өйрәтелә, аны 1917 елга кадәр Т.С.*Соловьев* укыта. Ел саен 100 гә якын шәкерт укый, тәмамлаучылар арасында Г.Г.*Камал* да бар. Ж.Госманов иганәсенә махсус төзелгән биналар комплексында, Тихвинская урамында (хәзерге Тукай урамы) урнашкан, архит-ра истәлеге.


*Әд.:* Хайрутдинов Р.Р., Салихов Р.Р. Памятники истории и культуры татар. народа. К., 1995.

**ГОСМА́НОВ** Искәндәр Йосыф улы (15.10.1950, Уфа ш.) үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1992). Башкорт ун-тын тәмамлый (1973). 1963 елдан РФА Уфа гыйльми үзәгенең Биология ин-тында эшли. 1991 дән Башкорт ун-тында, үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (2004 кә кадәр). Хезмәтләре үсемлекләрнең адаптив потенциалын теоретик һәм экспериментал анализлауга, дару үсемлекләрен өйрәнүгә карый. Дару үсемлекләре нигезендә физиологик актив матдәләр тупланышы экол. регуляциянең берничә законлыгын күрсәтә. Югары уку йортлары өчен «Үсемлекләрнең экологик физиологиясе» («Экологическая физиология растений», М., 2001) дәреслеге авторларының берсе.

Хезм.: Функциональный анализ типов адаптивных стратегий растений. Киев, 1982; Лекарственные растения Башкортостана. Биология и основы органического растениеводства. Уфа, 2002 (автордаш).



А.А.Горячев.



М.Г.Госманов.

**ГОСМА́НОВ** Миркасыйм Габделәхәт улы (31.5.1934, Көнбатыш Кытай, Голҗа ш., хәзерге КХРның Шөнҗан-Уйгыр автономияле р-ны — 11.10.2010, Казан), тарихчы, археограф, ТР ФА академигы (1992), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003), Казан ун-тының атказ. профессоры (2004). Казан ун-тын тәмамлагач (1963), шунда ук СССР тарихы кафедрасында эшли, 1980–89 елларда совет чорына кадәрге СССР тарихы каф. мөдире, проф. (1982). Бер үк вакытта 1985–91 дә Казан ун-ты проректоры. 1989 да аның тырышлыгы б-н Казан ун-тында татар филологиясе, тарихы һәм Шәрекъ телләре ф-ты оештырыла. 1989–2002 дә татар халкы тарихы каф. мөдире. Казан ун-ты археография экспедицияләрен оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе (1963–88), 1988 дән Казан ун-ты каршында үзе оештырган фәнни-тикшеренү археография лаб-ясе җитәкчесе. ТР ФАн оештыручыларның берсе, 2006–07 дә ТР ФА вице-президенты, 2007 дән ТР ФА Президиумы киңәшчесе. ТР Язучылар берлеге әгъзасы (1969 дан). 1997–99 да РФАнең Көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыяте президенты. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы. Татар телен һәм мәдәниятен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча «Җыен» фонды рәисе (1989 дан). Хезмәтләре тарихи чыганакларны, Идел буе һәм Урал алды төрки халыкларының 14–19 йөзләрдәге тарихын, мәдәниятен һәм әдәбиятын өйрәнүгә карый. Идел буеның урта гасырлар тарихына нисбәтле бер төркем язма чыганакларны, ш.и. Таҗетдиннең «Әт-Тирьяк әл-кәбир» («Агулануlardan көчле дәва») дигән әсәрен, текстлары 17–19 йөзләрдә язма рәвештә теркәлгән

борынгы татар фольклор ядкәрләрен ачыклый һәм фәнни әйләнешкә кертә. Кайбер 17–18 йөз төрки-татар тарихи чыганаклар авторларының идея-сәяси концепцияләрен тикшерә (*Кадыйргали бәкнең* «Җамигъ әт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы»), төзүчесе билгесез «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгы, Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»се, Т.Ялчыголның «Тәварихы Болгарийә»се). Г. Җүчи олысы ханнарының 14–16 йөзләргә караган ярлыкларына — Алтын Урданың һәм ул таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларының социаль-сәяси төзелеше турындагы мөһим документларга җентекле анализ ясый. Г. җитәкчелегендә 1773–75 елларга нисбәтле, Е.И.Пугачёв җитәкләгән крәстияннәр сугышы тарихын шактый тулыландыручы татар телендәге документлар тупланмасы төзелә һәм бастырып чыгарыла. Аз мәгълүм чыганаклар нигезендә татар мәгърифәтчеләре Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Р.Фәхретдин эшчәнлекләрен һәм мирасларын өйрәнә һәм яңача яктырта. «Шәхесләребез» дигән фәнни-популяр җыентыклар сериясе җитәкчесе. Г. кайбер уйгыр, казакъ, үзбәк, кыргыз авторларының әсәрләрен, ш.и. Ч.Айтматовның «Җәмилә» повестен татар теленә тәрҗемә итә (1966). «Ислам конференциясе» оешмасының ислам тарихын, сәнгате һәм мәдәниятен өйрәнү буенча тикшеренү үзәгенең «Тикшеренү эшчәнлегендәге күренекле казанышлары өчен» бүләге лауреаты (2008).

Х е з м.: Каурый каләм эзеннән: Археограф язмалары. К., 1984; Серле балбал: Хикәяләр, очерклар. К., 1984; Үткәннән — киләчәккә: Фәнни-публицистик мәкаләләр. К., 1990; Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар. К., 1996; Гасырдан — гасырга. К., 2004; Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингизнаме», «Таварих-и Булгария». К., 1972; Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Заветная мечта Хусаина Фаизханова: Повесть о жизни и деятельности. К., 1980.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999). Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Казанский университет (1804–2004). Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Миркасым Усманов: Библиогр. указатель. К., 2004; Источники и исследования по истории татарского народа. В честь юбилея акад. АН РТ М.А.Усманова. К., 2006.

**ГОСМА́НОВ** Раунс Госман улы (9.9.1940, Актаныш р-ны Уразай а.), вет.- микробиолог, вирусолог, иммунолог, вет. фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1963 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1984–87 елларда Бөтенсоюз вет. ин-тында. 1987 елдан Казан вет. мед. акад-сендә: микробиология һәм вирусология каф. мөдире, бер үк вакытта 1998–99 да проректор. Фәнни-тикшеренүләренең төп юнәлеше — терлекләрдәге йогышлы авыруларга диагноз кую. Ящур, Ауески авыруы, Ку бизгәге б-н көрәш чараларын эшли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ветеринарная микробиология и иммунология. Омск, 1996; Ветеринарная вирусология. Омск, 1999. Практикум по ветеринарной микробиологии и иммунологии. Омск, 2000.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг). К., 2006.

**ГОСМА́НОВ** Рәшит Әскәр улы (4.8.1937, Казан), график, нәкышьче. Казан сәнгать уч-щесендә укый (1952–56), Чабаксар сәнгать уч-щесенә күчә һәм аны 1958 елда тәмамлый. Йошкар-Олада (1958 дән), Куйбышевта (1965 тән), Казанда (1966 дан) яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1976). 1970–80 елларда сынлы сәнгать осталарының иҗат төркемнәре составында СССР буйлап үткәрелгән күп кенә сәяхәтләрдә катнаша (Иделдән Ерак Көнчыгышка кадәр). 1996–97 дә Сан-Франциско шәһәрендә (АКШ) яши. Г. — респ-када әйдәп баручы акварельче рәссамнарның берсе. Аның иҗаты төрле жанрларны һәм темаларны колачлый: лирик характердагы, шәһәр һәм индустриаль мохитне чагылдыручы пейзажлар, героик һәм хәрби-патриотик темага караган композицияләр, натюрмортлар. Әйләнә-тирәдәге төсләрнең катлаулы арадаш төсмерләрен, табигатьнең төрле халәтләрен сурәтләп бирүдә күп төрле техник алымнарны виртуозларча куллана. Рәссамның иҗади фикере берничә ел дәвамында эшләгән әсәрләр циклында ачылып җитә:







Р.Ә.Г о с м а н о в. 1. «Шайтан каласы». Акварель. 1970; 2. «Идел иртәсе». Акварель. 1978; 3. «Печәннән кайту». «Идел буйлап» сериясеннән. Акварель. 1986. Барысы да ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

«Идел буйлап» (1960 елларда), «Алабуга» (1970), «Болгарлар» (1971–74), «Брест герой-крепосте» (1975–76), «Габдулла Тукай истәлегенә» (1975–76), «Кара диңгез» (1977), «Коми крае» (1978).

Бөтенсоюз, бөтенроссия күргәзмәләрендә (1970–80 еллар), «Зур Идел» төбәкара күргәзмәләрендә (1969, 1974, 1980, 1991), халыкара күргәзмәләрдә һәм совет сәнгатенең чит илләрдәге күргәзмәләрендә катнаша (1970–90 еллар). Шәхси күргәзмәләре 1968, 1975, 1993 тә Казанда, 1973, 1978, 1982 дә Мәскәүдә, 1997 дә Сан-Францискода уза.

Г. әсәрләре Мари Респ-касы фәнни-төбәкне өйрәнү музеенда (Йошкар-Ола), ТР Милли музеенда, А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда (Казан), Яңа Кырлай авылындагы Габдулла Тукай музей-комплексында, Болгар тарих-архит-ра саклаулыгында, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында, ш.у. АКШ, Япония, Австрия, Грециядәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Т о в а р о в - К о ш к и н Б., Ч е р в о н н а я С. Художники Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1978; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; В а л е е в а Д. Искусство Татарстана (XX век). К., 1999.

*М.Е.Ильина.*

**ГОСМА́НОВ** Үзбәк Госман улы (13.8.1935, БАССРның Дүртөйле р-ны Байморза а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1988), проф. (1991), Башкортстан Респ-касы ФА академигы (1991), РАХФАнең мөхбир әгъзасы (1997), БАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1984, 1994). 1959 елда Башкорт а.х. ин-тының зоотехника ф-тын тәмамлый. 1959–62 дә БАССРның Дүртөйле р-ны Ленин исем. к-зда баш белгеч, рәис урынбасары. 1965 тән СССР ФАнең Башкортстан филиалы Икътисади тикшеренүләр бүлегендә, 1971–89 да хуҗалык итү механизмы секторы мөдире. 1989–97 дә Башкорт аграр. ун-тында а.х. икътисады каф. мөдире, бер үк вакытта 1991 дән БР ФАнең А.х. фәннәре бүлегендә акад. секретарь. 1998 дән РАХФАнең Башкортстан гыйльми үзәге рәисе, бер үк вакытта Башкорт аграр ун-тында а.х. каф. профессоры. Фәнни тикшеренүләре хезмәтнең соңгы нәтиҗәләре, җир мөнәсәбәтләре, хуҗалык исәбе һәм хезмәткә түләү, җитештерүне һәм хезмәтне оештыру, агросәнәгать комплексын алып бару системасы мәсьәләләренә карый. Аның тарафыннан аренда, хуҗалыклардагы кооперативлар, а.х. пр-тиеләрендәге ярдәмче хуҗалыкларның икътисади механизмы билгеләнә. «Башкортстанда икътисадны стабильләштерү һәм базар мөнәсәбәтләренә күчү программасы»н төзүдә, 2005 елга кадәр БРның агросәнәгать комплексы концепциясен үстерүдә актив катнаша. Г. редакциясендә «Башкортстан Республикасының агросәнәгать производствосын алып бару системасы» (Уфа, 1997) дигән комплекслы хезмәт нәшер ителә. Аграр икътисадчыларның фәнни мәктәбен булдыра. Авыл хуҗалыгы пр-восын оештыру буенча 267 хезмәт, 37 күрсәтмә һәм тәкъдим авторы. Дуслык ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Накопление и потребление в колхозах. М., 1967 (автордаш); Стимулирование конечных результатов труда в сельском хозяйстве. М., 1984; Стимулы повышения качества молока в АПК. Уфа, 1987 (автордаш); Реформа социальной сферы села. М., 2000 (автордаш). Агропромышленный комплекс региона (состояние, проблемы и решения). М., 2006. Т. 1; Экономико-экологическая эффективность производства продукции в молочном коневодстве. Уфа, 2008 (автордаш).

*Әд.:* Российская академия сельскохозяйственных наук. М., 2004; Ведущие учёные аграрной экономической науки. М., 2002; Область исследований — хозяйственный механизм в АПК // Экономика и управление. 2005. № 4.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ГОСМА́НОВ** Хәйрулла Габдрахман улы (1866–1915), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Казанда мәдрәсә тәмамлый. Оренбург губ. Каргалы авылында мулла һәм мөдәррис була. Икенче Дәүләт думасы депутаты (1907), мөселман фракциясе сәркәтибе, «*Иттифак әл-Мөслимин*» партиясе әгъзасы. 1907 елның июнендә Дума таркатылганнан соң, Оренбург губернасы Сәгыйть бистәсендә ахун. 1914 тә *Бөтенроссия мөселманнарының 4 нче съездында* (С.-Петербург) катнаша.

*Әд.:* Т у к т а р о в М.Ф. (Усал). Беренче, Икенче вә Өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены второй Государственной думы. СПб., 1907; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

**ГОСМА́НОВ** Хәйрулла Госман улы (1848, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Ибрай а. — 1907, Уфа), дин эшлеклесе. Вятка губернасы Малмыж өязе Мәчкәрә а. мәдрәсәсен тәмамлый. 1877–88 елларда Эстәрлетамак шәһәрендә имамлык һәм мөдәррислек итә. 1888 дән Уфадагы 1 нче җамигъ мәчеттә имам-хатиб, 1890 нан — ахун. Г. — Уфадагы «*Госмания*» мәдрәсәсенә нигез салучы һәм аның мөдәррисе (1906 елга кадәр), 1895 тән биредә яңача уку ысулын (җәдитчелек) кертә. Җәдиди мәктәпләр өчен татар телендә гарәп теле дәреслеген башлап төзегән авторларның берсе. 1906 елдан Оренбург Мөселманнары Диния нәзарәтендә казый. Г. җәдитчелекнең урталык сәясәтен тотучы агымына кушыла. Исламны яңарту идеяләрен яклый. Дәреслекләр авторы. Мисырда Г.ның (гарәп телендә) «Сөбел әс-сәлам» («Иминлек юллары») исемле китабы чыгуы мәгълүм.

*Әд.:* Ф а р ш а т о в М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период (60–90 годы XIX в.). М., 1994; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1.

**ГОСМА́НОВ** Хәмзә Фатыйх улы (24.4.1923, БАССРның хәзерге Бәләбәй р-ны Тузлыкуш а. — 13.1.2009, Уфа ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1978), БР ФАнең шәрәфле академигы (1998), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1955 елдан РФАнең Уфа гыйльми үзәге Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында (1987 гә кадәр — СССР ФАнең Башкорт ф-лы, 1992 гә кадәр — СССР ФА Урал бүлекчәсенең Башкорт гыйльми үзәге), сектор мөдире (1978–79), директор (1980–88), рев-циягә кадәрге чор тарихы бүлеге мөдире (1988–93), төп фәнни хезмәткәр (1993), проф. (1994). Бер үк вакытта 1962–63 тә Бөре пед. ин-ты проректоры. Хезмәтләре 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөздә Башкортстанның а.х., сәнәгате һәм революцион хәрәкәте тарихы турында. Башкорт халкы тарихына багышланган «Башкортстан АССР тарихы буенча очерклар» («Очерки по истории Башкирской АССР», 1959), «Борынгы заманнардан алып XIX йөзнең 60 нчы елларына кадәр Башкортстан тарихы» («История Башкортстана с древнейших времён до 60-х гг. XIX в.», 1996) дигән гомумиләштерүче хезмәтләр авторларының берсе. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Столыпинская аграрная реформа в Башкирии. Уфа, 1958; Развитие капитализма в сельском хозяйстве Башкирии в пореформенный период. М., 1981.

**ГОСМА́НОВА** Диләрә Миркасыйм кызы (17.9.1965, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлагач (1988), шунда ук хәзерге (чор) ватан тарихы кафедрасында эшли. Хезмәтләре Россия парламентаризмы тарихына, дәүләтнең 20 йөздәге конфессиональ сәясәте, татар вакытлы матбугаты мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной думе России (1906–1917). К., 1999; Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России. 1906–1917. К., 2002; Мусульманские представители в Российском парламенте. 1906–1916. К., 2005; Депутаты Казанской губернии в Государственной думе России: 1906–1917. К., 2006.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004). Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ГОСТИ́НЫЙ ДВОР**, Казанда рус архит-расы истәлекләре комплексы. Урта гасырларда-гы ханнар Казанының сәүдә үзәге (кәрвансарай) урынында төзелгән дип фараз ителә. 1770 елда арх. В.И.Кафтырев проекты б-н төзелеп, 1797 дә янган иске Г.д. урынында 1800–03 елларда арх. М.Е.Емельянов проекты б-н рус классицизмы стилендә салына. Бинаның планы көнбатыштан Преображение Господня чиркәве (чатыр түбәле, баганасыз, кирпеч гыйбадәтханә, 1634, кайбер чыганакларда — 1695) б-н тәмамланучы турыпочмакны хасил итә. Урам якка һәм ишегалдына караган кибет рәтләрен үзара галереялар тоташтыра. Икенче катта урнашкан кибет бүлмәләрендә түшәмнәр — цилиндр рәвешендә, ә галереяларда хач рәвешендә көмбәләнеп тора. Бинаның Воскресенский (хәзер Кремль) урамына караган үзәк өлешен ярымтүгәрәк тәрәзәле зур фронтон б-н төгәлләнгән 18 колонналы портик бизәп тора, диварга калын руст һәм тигез пилястралар салынган. 1815 елдагы янгыннан соң Г.д. арх. А.К.Шмидт җитәкчелегендә төзекләндерелә. 1825 тә Г.д. ның Преображение чиркәве тузу сәбәпле ябыла һәм аны сүтәргә карар кылына. 1842 дәге янгын бинаның фасадларына зыян китерә. 1843 тә реконструкцияләү эше арх. Х.Крамп һәм И.П.Бессоновка тапшырыла, 1847 гә фасадларны үзгәртеп кору тәмамлана. Зур портик, диварлардагы шомартылган ташлар (рустовка) һәм пилястралар юкка чыга. 1870 тә сәүдәгәрләр Ф.Г.Постников һәм Е.С.Савватеев иганәсенә Г.д. чиркәве реконструкцияләнә, аның чатыры сүтелә. Бу елларда чиркәү төп Изге Николай Чудотворец гыйбадәтханәсеннән, Преображение Господня һәм Казан Мәрьям Ана янкормаларыннан тора. 1895 тә комплексның төньяк өлеше И.Н.Колмаков тарафыннан шәһәр музее өчен көйләнә: эчке бүленеше һәм фасадлары үзгәртелә, очына шпиль куелган дүрт кырлы чатыр б-н төгәлләнүче янкорма рәвешендәге керү юлы төзелә. 1933–35 тә М.С.Григорьев проекты б-н төньяк һәм көнчыгыш корпусларга 2 кат өстәп салына. 1959 да комплексның көньяк-көнчыгыш ягындагы җимерелгән өлеше урынында арх. А.Г.Бикчәнтәев проекты б-н торак йорт төзелә. 1987 дәге янгыннан зыян күргән музей өлеше 1990–95 тә арх. С.Ә.Козлова-Мамлиева проекты б-н реконструкцияләнә, өстәп салынган катлары сүтелә һәм 19 йөз ахырындагы тарихи хәленә кайтарыла.





Гостиный двор. Казан. Арх. М.Е. Емельянов. 1800-03. 1. Комплексның көньяк-көнчыгыш өлеше. 20 йөз башы фотосурәте; 2. Хәзерге күренеше.

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; Ф е х н е р М. Великие Булгары, Казань, Свияжск. М., 1978; А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1981.

*С.Г.Персова.*

**ГО́ТВАЛЬД** Иосиф Фёдорович (13.10.1813, Ратибор ш., Германия — 7.8.1897, Казан), шәркыятьче галим. Бреслав ун-тын тәмамлый, филос. фән. д-ры (1836). 1838 елдан Россиядә. 1841–46 да Санкт-Петербургтагы Император җәмәгать китапханәсенең Көнчыгыш бүлегендә китапханәче. 1846 да мөселман кануннары җыентыгын төзү ком-ты эшчәнлегендә катнаша. 1849 дан Казан ун-тында: гарәп һәм фарсы телләре профессоры, 1850 дән китапханәче, бер үк вакытта 1855–75 тә шәркый әсәрләрне тикшерүче Казан бүлеге цензоры, 1857–84 тә басмаханә

башлыгы, бер үк вакытта 1859–62 дә инглиз теле укытучысы. Хезмәтләре Шәрекъ филологиясе һәм тарихына карый. Үзенең китапханәсен һәм үз әсәрләре тупланмасын Казан ун-тына васыять итеп калдыра.

Х е з м.: Описание арабских рукописей, принадлежащих библиотеке Императорского Казанского университета. К., 1855; Опыт арабско-русского словаря на Коран, семь моаллакат и стихотворения Имрулькейта. К., 1863; Разбор сочинения А.Я.Гаркави «Сказания мусульманских писателей о славянах и русских». СПб., 1872; Хикам (изречения) Ходжи Ахмеда Ясави на джагатайском языке. К., 1878.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*В.Х.Хаков.*

**ГО́ТВАЛЬД ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́,** шәркыятьче галим И.Ф.*Готвальдның* шәхси китапханәсе. 2500 дән артык исемдәге китап, шулардан 870 е Көнбатыш Европа телләрендә (басмалар), 268 е кульязма хәлендә. 1855 елда Шәрекъ бүлеге бай китап фонды б-н С.-Петербургка күчерелгәч, ул Казан ун-ты китапханәсе шәрекъ кульязмаларының яңа җыелмасының төп өлешенә әверелә. Г.ш.к.нең иң кыйммәтле һәм иң бай өлеше — гарәп, фарсы, татар, төрек, чыгтай, кыргыз телләрендәге кульязма китаплар. Аларны еллар буе җыю-туплау барышында И.Ф.Готвальд татар мәгърифәтчеләре һәм галим-голәмасы б-н шәхси танышлыкларыннан файдалана, шулар аша Урта Азия голәмасы б-н дә элемтәгә керә. Тупланмада 15–18 йөзләргә нисбәтле кульязмалардан: фарсы әдәбияты классигы Сәгъди Ширазиның «Гөлестан» әсәре, гарәп әдәбияты ядкәре Зәкәрия әл-Казвининың «Гаҗаиб әл-мәхлукат» («Могҗизалы төрек дөнья») әсәренең фарсычага тәрҗемәсе (15 йөз) — гаҗәеп матур миниатюралар б-н бизәлгән язу үрнәге һ.б. бар.

1858 дә И.Ф.Готвальд беренче тапкыр 11–15 йөз Урта Азия төрки шагыйрьләреннән Мирхәйдәрнең (Хәйдәр) чыгтай телендә язылган «Мәхзән әл-әсрар» («Серләр хәзинәсе») поэмасын, 1878–96 да Әхмәд Ясәвинең «Диван-е хикмәт»ен («Хикмәтләр китабы») бастырып чыгара (4 басма).

Тупланмада ш.у. И.Ф.Готвальдның «Кяферләргә каршы сугыш» («Война против неверных») хезмәте кульязмасы, Гобәйдулла бине Мәсгуднең «Мохтасар» дигән уку әсбабының кульязма русча тәрҗемәсе, Акмулла өязенең Аккүл волостенда халыктан язып алынган кыргыз телендәге «Легендалар, җырлар, әкиятләр» кульязмасы, Карл Фуксның «Казан татарлары» («Казанские татары») исемле хезмәтенең 1842 елда цензурага бирелгән кульязма нөсхәсе; басма китаплардан Коръәннең берничә басмасы, ш.и. М.И.Верёвкин тәрҗемәсендәге русча басма (СПб., 1790), шәркыятьче галимнәрдән В.В.Вельяминов-Зернов, А.Я.Гаркави, Б.Дорн, А.Куник, В.В.Радлов, В.Г.Тизенгаузен, И.Н.Березин, В.П.Васильев, В.Ф.Диттель, Г.К.Казимбәк, Х.Д.Френ, Г.С.Саблуковларның гыйльми хезмәтләре; И.Ф.Готвальд үзе басмага әзерләгән «Гарәпчә әдәби ядкәрләргә язган аңлатмалар» («Описание арабских рукописей ...», 1855), «Коръәндәге аерым сүзләргә гарәпчә-русча сүзлек» («Опыт арабско-русского словаря на Коран ...», 1863) һ.б. бар.

Татарча басмалар да зур урын алып тора, ш.и. К.Насыйриның 30 хезмәте: 1879–83, 1885, 1891, 1892, 1894 елларга нисбәтләп чыгарылган календарьлар, «Тулы русча-татарча сүзлек» (1892), «Зөбдәт мин тәварихы әр-рус» («Россиянең кыскача тарихы», 1890), Казан губернасының татар телендәге картасы (1874), «Кабуснамә» (1882); Г.Барудиның «Сәвадхан» («Уку кагыйдәләре», 1895), Ш.Мәрҗанинең гарәп телендәге мәкаләләр җыентыгы (1879). Сирәк очраучы басмалар — А.С.Пушкин һәм М.Ю.Лермонтовның О.С.*Лебедева* тарафыннан беренче тапкыр төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре булуы да мәгълүм.

Китапханәдәге китапларның якынча өчтән берен Казан басмалары тәшкил итә: проф. И.А.Бодуэн-де-Куртенэ, Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов, С.И.Назарианц һ.б.ның басма хезмәтләре; шунда ук Ибраһим Хәлфиннең «Әхвале Чыңгызхан вә Аксак Тимер» (1822) китабы (анда И.Ф.Готвальдның кульязма искәрмәләре теркәлгән); Г.Барудиның гарәп этимологиясе буенча «Хәсн әл-мәшрәб фи сарфы лисан әл-гарәб» (1891) дигән хезмәте; Ф.Әмәшев наширлегендә гарәп телендә басылган «Хотбә-и җомга» («Җомга вәгазе») (1878) һәм басылып чыккач та тыелган сатирик «Мәкәрҗә бәете» (1879) һ.б.

И.Ф.Готвальд сатуга куелмый торган, аз тиражлы яки сәнәгать оешмалары тарафыннан чыгарылган китапларны җыюга да игътибар бирә. «С.Е.Александров һәм И.И.Алафузовларның күн заводлары, җитен эшкәртү, эрләү вә туку мануфактуралары контрасыннан хисап кенәгәсе» («Расчетная книжка от конторы льнопрядильно-ткацкой мануфактуры, кожевенных заводов С.Е.Александрова и И.И.Алафузова», 1872), «Казан шәһәрендә приказчикларның ярдәм җәмгыяте каршында саклык кассасы кагыйдәләре» («Правила сберегательной кассы при вспомогательном обществе приказчиков в г.Казани», 1872) — шундый төр әдәбият мисаллары. Г.ш.к.ннән алынган кайбер Казан басмалары Казан ун-тының фәнни китапханәсендә бердәнбер нөсхә булып теркәлгән: мәс., Н.К.Баженовның «Искиткеч шәп егет» («Прекрасный молодой человек», 1848), В.П.Невельскийның «Казан трактирлары» («Казанские трактиры», 1866) әсәрләре.

Китапханәдә ш.у. А.П.Бородинның «Князь Игорь» операсы либреттосы (СПб., 1890), сирәк басмалардан К.Званцовның «Айра-Альридж»ы (Одесса, 1861), инглиз әдәбияты классиклары У.Шекспир һәм Дж.Байрон әсәрләренең инглизчә һәм русча басмалары, Казан ун-тының инглиз теле лекторы П.Бересфордның вафатыннан соң (1877), аның китапханәсеннән күчкән китаплар, ш.и. И.С.Тургеневның тәрҗемәче Юджин Шуйлер автографы куелган «Аталар һәм балалар» («Отцы и дети») романының инглизчә басмасы (Нью-Йорк, 1867) һ.б. була.

1895 елда И.Ф.Готвальд Казан ун-ты китапханәсенә 111 берәмлек кульязма бүләк итә. Вафатыннан соң (1897), кызы Иозефина И.Крелленберг, әтисенең васыятен үтәп, китапханәдәге калган китапларның һәм кульязмаларның барысын да ун-тка тапшыра. Китапханәче һәм күренекле иганәче И.Ф.Готвальдның портреты китапханә бинасының диварына эленә. Н.Ф.Катанов тарафыннан тупланмадагы китап һәм кульязмаларның каталогы төзелә һәм тулаем ун-т китапханәсе фондына кертелә.

*Әд.:* К а т а н о в Н.Ф. Императорского Казанского университета почётный член, профессор и библиотекарь Иосиф Фёдорович Готвальд. К., 1900; А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. Всё началось с путеводителя. Поиски литературные и исторические. К., 1975.

*И.А.Новицкая.*

**ГО́ТЛИБ** Елена Михайловна (24.3.1949, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1989), проф. (1992). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол., 1977 дән Казан төзүче-инженерлар ин-тларында эшли, 1985–86 елларда РФА КГҮнең Органик һәм физ. химия ин-тында. 1987 дән Казан химия-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты), эластомерлар эшкәртү үзәге тәҗрибә-сәнәгать пр-тиесендә лаб. мөдире (1991 дән) һәм техник директор (1992 дән). Хезмәтләре полимерларны катыландыру, модификацияләү һәм стабильләштерүгә һәм шулар нигезендә композицион материаллар ясауга карый. Г. эпоксиолигомерларның аминофенол катыландыргычларын эшли. Диоксан спиртларының формальләре нигезендә поляр винил полимерлар һәм аларның сулы дисперсияләре, бутадиенакрилонитрил һәм хлоропрен каучуклар һәм аларның латекслары өчен эффектив пластификатор эшли. Пластификацияләнгән поливинилхлорид өчен антиоксидантлар, полимер һәм синтетик каучуклар сулы дисперсияләре һәм латекслары өчен мицелла барлыкка китерүче нәионоген актив өслекле матдәләр сыйфатында 1,3-диеноксан кушылмаларын тәкъдим итә. Эшкәртмәләре Эстәрлетамак нефтехимия з-дында (эпоксид сумалаларны аминофенол катыландыргычлар, резиналарны термостабильләштерүче һәм тузудан саклаучы матдәләр), Уфа «Химпром» АҖдә (универсаль эпоксид җилем), Казан технол. ун-ты каршындагы Эластомерлар ясау үзәгенең тәҗрибә-сәнәгать пр-тиесендә (изопрен җитештерү калдыкларыннан поляр полимерлар өчен аз токсинлы пластификатор) гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Модифицированные эпоксидные клеи и покрытия в строительстве. М., 1990 (автордаш); Новый пластификатор полимерных материалов. М., 1997 (автордаш); Композиционные материалы на основе модифицированных полимеров. М., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Кафедра технологии синтетического каучука. Встреча поколений. К., 2008.

**ГОШЕ́Р** (гарәп. عشر — уннан бер өлеш), мөселманнарда гомуми ихтыяҗлар өчен җыела торган салым; Якын һәм Урта Көнчыгыштагы күп кенә илләрдә урта гасырларда гадәти дәүләт салымы булып әверелә. Г.нең төрләре: 1) яулап алынган, хәлифә яисә имам

тарафыннан бүләк ителгән, ш.у. яңа үзләштерелгән җирләр өчен салым алу. Җир өчен алынган салымнар ш.у. *хәраҗ* дип тә атала. Техник җайланмалар ярдәмендә сугарылган җирләрдән алынган уңышның — 1/20 өлеше, аз керемле җирләрдән 1/10 өлеше түләнгән.; 2) товар бәясенең 1/10 өлеше күләмендәге сәүдә пошлинасы (чынлыкта ул төрле товарларга төрлечә салына, күбрәк яисә азрак булырга мөмкин); 3) гомуми ихтыяҗлар өчен шәригать кагыйдәләрендә билгеләнгән кертемнән — *зәкяттән* тыш булган төрле сәүдә пошлиналары. 1990 еллардан алып ТР Мөселманнары Диния нәзарәте Г.не авыл хуҗалыгы продуктларыннан алына торган салымның бер формасы — җирле мөселман җәмгыятьләрен финанслау чыганагы буларак яңадан гамәлгә кертү мәсьәләсен күтәреп килә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГОЭЛРО́** планы, Совет республикасының халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерүгә юнәлтелгән бердәм дәүләт планы. 1921 елның декабрендә Советларның 9 нчы Бөтенроссия съездында раслана, 10–15 елга исәпләнә. Татарстанда планны эшләү б-н башта ТАССР ХХС каршындагы Фәнни-техник совет шөгыльләнә. Республиканың һәр кантонында электрлаштыру буенча кантон органнары оештырыла. Бөтентатар халык хуҗалыгы хезмәткәрләренең 1 нче съездында алар алдында гамәлдәге эл. сәнәгатен аякка басту, табигать көчләрен, эл. механикасы җиһазларын исәпкә алу бурычлары куела, Татарстан респ-касын электрлаштыру буенча совет төзелә. ГОЭЛРО планы нигезендә Казанда, Тәтеш, Чистай, Зөядә һ.б. шәһәрләрдә гомуми куәтләре 70 мең *кВт* тәшкил иткән 10 электр станциясе төзү күздә тотыла. 1920 дә Алабугада бер фазалы алмаш токлы, 2 мең *кВт* егәрлекле электр станциясе файдалануга тапшырыла. 1921 нең февралендә Зөя кантонының Норлат авылында остаханәләрне һәм крәстиян торак йортларын яктыртучы эл. станциясе эшли башлый. 1921 нең мартында Тәтеш һәм Чистайда аз куәтле станцияләр сафка баса. 1922 дә Минзәлә шәһәрендә, 1925 тә Казанда (ТАССР ның 3 еллыгы исем.), 1927 дә Бөгелмә шәһәрендә электр станцияләре файдалануга тапшырыла. 1928 дә ТАССРның 3 еллыгы исем. электр станциясендә илебездә эшләнгән 3 мең *кВт* егәрлекле турбогенератор урнаштырыла. 1932 дә Казанда 2 терекөмешле РВ-5 турайткычлы 2 нче подстанция эшкә керешә, ул шәһәрдәге трамвай хәрәкәтен электр энергиясе б-н тәэмин итә. 1933 нең гыйнварында Казанда 1 нче ТЭЦ сафка баса (турбогенераторының куәте 10 мең *кВт*). 1 нче ТЭЦның 35 *кВт* көчәнешле беренче электр тапшыру линиясе эшли башлый. Казанда Авыр сәнәгать халык комиссариатының энергия комб-ты оештырыла. 1934 тә 35 *кВт* көчәнешле тапшыру линиясе буйлап Зеленодольск шәһәренә энергия җибәрелә башлый. Бу вакытта Казандагы сәнәгать пр-тиеләрендә автоном рәвештә эшләүче энергия җайланмалары эштән туктый, һәм җылылык станцияләре энергиясе б-н даими тәэмин итү башлана. Ш.у.к. *Электрлаштыру*, *Электр энергетикасы*.

*В.А.Шагалов.*



ТАССРның 3 еллыгы исем. электр станциясе (1923 елда төзелгән).

**ГӨБӘДИЯ́**, татар халкының милли ризыгы. Әче, күп очракта төче камырдан эченә катлы итеп корт, дөге, ваклап туралган йомырка, җимеш (йөзем, өрек, кара җимеш), ә кайчакта тарткан ит салып пешерелгән калын түгәрәк бәлеш. Г. — Казан татарларында бәйрәм табынына куела торган гадәти ризык; табынга аштан соң яки чәй янына куела. Пермь татарларында Г., туй йоласы таләбенчә, кодалар өчен әзерләнә, Г. ничә катламнан торса, аларны шул катламнар санындагы көннәр дәвамында кунак итәргә тиеш булалар.

*Әд.:* Ахметзянов Ю.А. Татарские блюда. К. 1961; Хайрутдинова Т.Х. Названия пищи в татарском языке. К., 1993.

**ГӨБЕНӘ́** елгасы, Идел алды төбәгендә, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 165,1 *км*, ТР чикләрендә — 121 *км*. Бассейнының мәйданы 2480 *км*$^2$. Идел буе калкулыгы буйлап ага. Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, урта агымы — Кайбыч р-ны терр-ясендә, тамагы Яшел Үзән р-нының Өтәк авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Елганың су җыелу мәйданы калкулыклы тигезлек. Югары агымда елга үзәне тар, тамагына таба елганың киңлеге 3–4 *км* га җитә. Югары һәм урта агымда тугай өслеге тигез, түбән агымының кайбер урыннары ерганаклар б-н кискәләнгән, болын һәм куак үсемлекләре б-н капланган, иске күлләр бар. Ярлары текә, кайбер урыннарда ишелгән. Г.нең 50 кушылдыгы бар, ТР терр-ясендә иң зурлары: сул кушылдыклар — Ырым (45,1 *км*), Инеш (13,9 *км*); уң кушылдык — Ышналы (19,5 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Елга режимын күзәтүләр 1946 елдан башлап Кайбыч р-нының Александровка посёлогы һәм Чүти авылы янындагы гидрологик постларда үткәрелә. Чүти авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 3,7 *м* (макс. 4,3 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 92 *мм*, ташу агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елганың җир асты сулары чыга торган урыннары кыш дәвамында боз б-н капланмый. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,5 *м*$^3$*/с*. Иң зур чыгымы 420 *м*$^3$*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), җәен һәм кышын уртача катылыкта (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Су ресурслары сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

*О.Н.Урбанова.*

**ГӨБЕНӘ́** тимер юл станциясе посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2008 елда 12 кеше (татарлар, руслар) яши. 1943 тә нигез салына. Оештырылган көннән — Норлат, 1963 елның 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1958 дә — 119, 1970 тә — 88, 1979 да — 63, 1989 да — 54, 2002 дә — 22 кеше.

**ГӨБЕРЛЕ́ БАКАЛА́Р** (Bufonidae), койрыксыз җир-су хайваннары семьялыгы. 300 дән артык төре билгеле, Антарктидадан тыш, барлык материкларда да тереклек итә. Г.б. бакалардан өске казналыкта тешләре булмавы, кыска аяклары, киң авыр гәүдәсе, күп сөялле мөгезләнгән коры тиресе б-н аерылып тора. Башының төп өлешендә зәһәр исле майлы сыекча бүлеп чыгара торган симметрияле урнашкан бөресыман 2 төер (калак өсте бизләре) бар, бу сыекча башка хайваннар өчен агулы. Агу — Г.б. өчен бердәнбер саклану чарасы, сыекча бизгә баскач кына бүленеп чыга, шунлыктан алар аны үзләрен ерткыч тотып алгач кына куллана. Г.б. әкрен хәрәкәт итә. Бармаклары өлешчә элпә б-н тоташкан арткы аяклары ярдәмендә еш кына җиргә яки урман түшәлмәсенә күмелә. ТРда 2 төре: гади яки соры Г.б. (Bufo bufo) һәм яшел Г.б. (B. viridis) бар.

Яшел Г.б. ТРның бөтен терр-ясендә таралган, ачык урыннарда, елга тугайларында, сирәкләнгән урманнарда, еш кына торак пунктларда очрый. Соры Г.б.дан кечкенәлеге б-н аерыла (озынлыгы 70–75 *мм*, ана Г.б. 140 *мм* га кадәр). Аркасы соры-саргылт яшел төстә (яшелдән коңгырт төскә кадәрге) караңгы таплар б-н капланган, арткы аяк бармакларында парсыз төерләр бар. Тиресе мөгезләнгән, капшап карауга коры. ТР терр-ясендә Г.б. иң җылы яратучы, корылык шартларына чыдам җир-су хайваннары төрләренең берсе. Далаланган р-ннарда иң күп сандагы төп амфибия төрләреннән санала. Гадәттә, төнге һәм эңгер-меңгердә яшәү рәвешен алып бара. Парлашу чорында ата Г.б. яңгыравыклы көйле тавыш чыгара. Уылдык чәчү вакыты апрель ахырыннан май ахырына кадәр дәвам итә. Ана Г.б. 13 меңгә кадәр йомырка сала. Үсеш вакыты (уылдык барлыкка килүдән яшь бакага кадәр) 50–60 көн. Сулыктан коры җиргә бакаларның күпләп чыгуы көндезге яңгырдан соң, дымлы көндә күзәтелә. Нигездә бөҗәкләр б-н туклана.

Соры Г.б. урманнарда, нигездә, Кама алдында очрый. Бу төр бакалар эрерәк (озынлыгы 80 *мм* дан артык, аналары кайвакыт 200 *мм* га кадәр), өске ягы соры-көрән, аскы ягы тонык ак төстә. Барлык җирдә дә диярлек аз санда, урман-дала зонасында сирәк очрый. Көндезен ояларында, ярыкларда, ур-



Соры гөберле бака.

ман түшәлмәсендә яшеренеп, төнге һәм эңгер-меңгердә яшәү рәвеше алып баралар. Апрель ахыры — май башында, су темп-расы 10 °С ка якынлашканнан соң үрчү башлана. Ана Г.б. су үсемлекләренә баусыман ике рәткә урнашкан 1200–6800 йомырка сала. Яшь бакалар коры җиргә июль башында чыгалар. Умырткасыз вак хайваннар — чебеннәр, әре бызылдавыклар һәм май коңгызлары б-н туклана. 15 елдан (табигатьтә) 30 елга кадәр һәм күбрәк тә (террариумда) яши.


ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГӨБЕРЧӘ́К** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 297 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1930 елларга кадәр Кече Муй исеме б-н билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 636,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир-ат; 1859 да — 283, 1897 дә — 501, 1908 дә — 558, 1926 да — 560, 1938 дә — 632, 1949 да — 582, 1958 дә — 495, 1970 тә — 472, 1979 да — 402, 1989 да — 324, 2002 дә — 284 кеше.

Язучы М.С.*Мәһдиев* туган авыл.

**ГӨБЛӘЛӘ́Р** (Aphidinea), тигезканатлылар отрядыннан бөҗәкләр асотряды. Якынча 2,5 мең төре билгеле, башлыча, уртача поясларда яши; Россиядә берничә йөз төре билгеле. Озынлыгы 0,5–0,6 *мм*; корсагы кыска, кабарынкы, күбесенчә балавыз катламы б-н капланган. Үсемлекләрдә колонияләр булып яшиләр. Үрентеләрнең очына тупланып, яшь үсемлекләр сыекчасы б-н тукланалар. Яфракларның бөгәрләнүенә, үренте очларының формасы үзгәрүгә, авыру үсентеләр — галлар (кутырчыклар) үсүгә китерәләр. Күп Г. төрле азык б-н туклана: аерым сезонда бер төр үсемлекләрдә яшиләр, аннан соң икенче төргә күчәләр. Елына берничә буын үрчиләр. Г.нең үсеш циклы катлаулы, җенесле һәм җенессез буыннар чиратлашып үрчи. Аталанган күкәйләр кышлыйлар, яз көне алардан канатсыз, аталанмыйча үрчи торган (партогенетик) ана бөҗәкләр чыга. Җәй көне яңа колонияләр барлыкка китерүче аталанмыйча үрчи торган ана-бөҗәкләр (мигрантлар) барлыкка килә. Г. бүлеп чыгарган баллы сыекчалар б-н (баллы чык) кырмыскалар туклана, умарта кортлары аларны чык балына әйләндерә. Г. бакча һәм паркларга, урманнарга һәм культуралы үсемлекләргә шактый зыян китерәләр. Г. б-н зарарланган үсемлек ботаклары начар үсәләр, күбесенчә үләләр; Г.нең кайбер төрләре йогышлы авырулар таратучылар. Татарстан терр-ясендә иң зарарлылары: яшел алмагач гөбләсе (Aphis pomi), алмагач һ.б. орлыклы җимеш агачларын, бигрәк тә яшь үсентеләрне нык зарарлый; чөгендер гөбләсе (A. fabae), озынлыгы 2 *мм*, кара төстә, шикәр чөгендерен нык зарарлый тамырлы үсемлекләрне башкаларга алыштыру б-н үрчи (балан, ясмин, кабар агачы, үләнчел үсемлекләр); борчак гөбләсе (Acyrthosipphon pisum) — кузаклы культуралар корткычы (люцерна, клевер, борчак, вика һ.б.); кыяклылар гөбләсенең төрле төрләре — а.х. үсемлекләре корткычлары (үсемлекләрнең зарарланган өлеше саргая, бөтерелә һәм үләләр). Г. б-н көрәш чаралары: культурага Г.гә бирешмәүче сортларны кертү, үсемлекләрне инсектицидлар б-н эшкәртү, кузаклыларны иртә чәчү, агротехник чаралар.

**ГӨЛБАДРА́Н** (Tanacetum), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. ТРда өч төре — меңьяфраксыман Г. (T. achilleifolium) һәм меңьяфраклы Г. (T. millefolium) — Кама аръягында, гади Г., ягъни кыргый миләш (T. vulgare) барлык р-ннарда да очрый. Урман читләрендә, үләнле һәм ташлы сөзәклекләрдә, сулыклар янында үсә. Сабаклары туры, 130 *см* га кадәр биеклектә, озын шуышма тамырчалы. Яфраклары чиратлашкан, каурыйсыман теленмә. Чәчәк кәрзиннәре ачык сары төстә, ярымшар рәвешендә, калкансыман чәчәк төркемендә. Җимешләре — озын сырлы орлыкчалар. Июнь–сентябрь айларында чәчәк ата, август–октябрьдә җимеш бирә. Вегетатив юл б-н үрчи. Гади Г.ның чәчәк төркемендә эфир мае, органик к-талар, флавоноидлар, дуплау һәм ачы матдәләр бар. Г.ның чәчәк төркемнәре халык медицинасында ашказаны, баш авыртканда һәм үт кудыру чарасы буларак кулланыла. Инсектицид. Меңьяфраклы Г. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Гөлбадран.

**ГӨЛЕ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тиргәвеш елгасы буенда. 2008 елда 391 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кулюково исеме б-н билгеле. Халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, арба һәм чана ясау б-н шөгыльләнә, Кама пристаньнарында эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Г. тә 2 су тегермәне, 20 йөз башында тимерчелек, 4 вак-төяк, бакалея һәм мануфактура кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4535 дис. тәшкил итә. Г. тә мәчет 18 йөздән билгеле, аның каршында 1854 тән мәдрәсә эшли, 20 йөз башында 2 мәктәп һәм 2 мәчет була. 1929 да «Кызыл Юл» к-зы (соңрак — М.И.Калинин исем. к-з) оештырыла, 1959 да Вахитов исем. к-з составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 391, 1859 да — 1067, 1870 тә — 1073, 1897 дә — 1708, 1906 да — 1915, 1913 тә — 2138, 1926 да — 1339, 1938 дә — 1380, 1949 да — 957, 1958 дә — 850, 1970 тә — 841, 1979 да — 693, 1989 да — 436, 2002 дә — 379 кеше.

**ГӨЛЕ́Ш** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2008 елда 160 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. 1930 елларда нигез салына. Беренче көннән үк Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 212, 1949 да — 191, 1958 дә — 224, 1970 тә — 283, 1979 да — 222, 1989 да — 194, 2002 дә — 159 кеше.

**«ГӨЛҖАМА́Л»**, татар халкының озын көйгә җырлана торган һәм мелизмнарга бай борынгы лирик җыры. Татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә билгеле. Мөстәкыйль әсәр буларак, 1960 елда И.Н.Надиров тарафыннан язып алына, «Татар халык җырлары» (1965) җыентыгында басыла. Җырда татар халкы тормышына хас вакыйга сурәтләнә: кич б-н бер авыл өендә багу өчен җиткән кызлар җыела. Шәмдәлләрдә шәмнәр яна, тирән кичерешләр б-н тулган җыр яңгырый. «Г.» танылган татар һәм башкорт проф. җырчылары репертуарында киң урын ала.

*Әд.*: Н и г м е т з я н о в М.Н. Татарские народные песни. М., 1970.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГӨЛҖИМЕ́Ш**, к. *Роза*.

**ГӨЛНА́Р ХАНЫ́М** (псевд., чын исем-фамилиясе Лебедева Ольга Сергеевна) (1854, Казан — ?), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Император шәркыять җәмгыятен төзүдә актив катнаша (1900), аның мактаулы рәисе була, Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы. Халыкара шәркыятьчеләр конгрессларында катнаша. 12 нче конгресста (Рим, 1899) Казан татарлары тарихы турында ике доклад б-н чы-

гыш ясый, алар соңыннан аерым китап булып басылып чыга. Беренче докладта Казан ханлыгының сәяси тарихына, аның Мәскәү б-н булган мөнәсәбәтләренә күзәтү ясау б-н беррәттән татар халкының мәдәниятен, татар хатын-кызының җәмгыятьтә тоткан урынын тәфсилләп яктырта, мөселман халыкларына карата Россия хөкүмәте тарафыннан алып барылган көчләп чукындыру сәясәтен тәнкыйтьләп чыга. Икенче докладта мөселман хатын-кызларының төрле тарихи чорларда җәмгыятьтә тоткан урыннарын һәм мөселман илләрендә аларның хокукы өчен барган көрәшне яктырта. И.Ф.Готвальд, Н.Ф.Катанов, К.Насыйри, И.Н.Березин, В.В.Бартольд, Н.И.Веселовский, В.В.Радлов, И.Ю.Крачковский б-н хезмәттәшлек итә. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Л.Н.Толстой һ.б.ның әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итә.

Ә с ә р.: Об эмансипации мусульманской женщины. СПб., 1900; Abrégé de l' histoire de Kazan. Offert aux membres du XII congres des orientalistes. Rome, 1899.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. О.С.Лебедева — «Гульнар-ханум» // Народы Азии и Африки. 1977. № 3. *Ә.Г.Кәримуллин.*

**«ГӨЛЧӘЧӘ́К»**, татар халкының тылсымлы мифологик әкияте. Гөлчәчәкнең бүрегә әверелгән явыз сихерче каенанасыннан качып китүе бәян ителә. Юлда Гөлчәчәкне күл, карама һәм каен агачлары коткарып калалар. Бүре агачның тамырларын казый башлагач, Гөлчәчәк сыерчыктан үзенең чәч бөртеген абыйсына илтеп бирүен сорый. Сыерчык чәчне капка ярыгына кыстырып калдыра, абыйсы, аны алып, думбрасына тарттырып куя. Чәч Гөлчәчәк тавышы б-н ул тарыган бәхетсезлек турында сөйли һәм үзен коткаруын үтенә. Абыйсы бүрене үтерә һәм сеңлесен коткара.

Әкият мифологик мотивларга нигезләнгән: анда татар фольклорында еш очрый торган усал каенана һәм бәхетсез килен образлары, убырлылык мотивы бар, ш.у. табигать объектларына, хайваннарга һәм кошларга кеше сыйфатлары хас булу, чәч бөртегендә кешенең көче, җаны саклана дигән күзаллаулар чагылыш таба. Чәчмә текст тезмә өлешләр б-н аралаша (кызның чибәрлеген сурәтләү, чәч бөртегенең ярдәм сорап ялвару җыры, бүре-каенананың янаулары һ.б.).

Беренче тапкыр «Гөлчәчәк» җыентыгында (1918) «Җан Шәриф язмасы» дигән билге б-н басылып чыга.

*Әд.:* Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. К., 1994. *Ф.И.Урманчеев.*

**ГӨМБӘ́ ЧЕБЕННӘРЕ́** (Mycetophilidae), парканатлылар семьялыгыннан озынмыеклылар асотрядындагы бөҗәк. Һәр җирдә киң таралган. 3000 ләп төре бар, ТРда 50 гә якын төре мәгълүм. Озынлыгы 3–7 *мм*. Башы йомрырак, күзләре бөресыман, мыеклары озын, кыска хортумлы. Күкрәк өлешендә корсагыннан аз гына кечерәк озынча канатлары, нәзек озын аякларында типкеләре бар. Г.ч.нең күп төрләре кышлый. Аларны җепшек көннәрне кар өстендә күреп була. Уңайлы шартларда тулы 5 буынга кадәр үсәргә, ел дәвамында, кайбер төрләре хәтта кар астында да күкәй салырга мөмкин. Личинкалары (гөмбә «кортлары») туфрак яки теләсә нинди субстрат 14°С ка кадәр җылынганда гына үсә, нигездә, гөмбә (мицелий б-н дә, үрчү өлеше б-н дә), коелган яфраклар һәм черегән үсемлекләр б-н тукланалар. ТРда Mycetophila (20 гә якын төре), шул исәптән M. fungorum, M. guttata, M. sigillata ның һәр төре еш очрый.

*Әд.:* Х а л и д о в А.Б. Насекомые — разрушители грибов. К., 1984.

*А.Б.Халидов, В.Д.Капитов.*

**ГӨМБӘЛӘ́Р** (Fungi, Mycota), хлорофиллсыз организмнар төркеме. 100 меңнән артыграк төре бар, күпчелек өлеше Европа һәм Төньяк Америкада киң таралган. ТРда Г.нең 6 классы да очрый: *хитридиомицетлар*, оомицетлар, *аскомицетлар*, *базидиомицетлар*, камилләшмәгән гөмбәләр, загомицетлар. Күп кенә Г.нең вегетатив өлеше (мицелий яки гөмбәлек) нечкә тармаклы җепселләр (гифлар) булып урман түшәлмәләрендә, черегән агачта һәм органик субстратта таралган. Күбесе төрле кунык (пәрәвезсыман, ончыл, мамыксыман), тимгел, төртке һ.б. рәвешендә; кайберләрен микроскоптан гына күрергә мөмкин. Мицелийнең төзелеш үзенчәлекләренә, үрчү ысулларына карап, Г.не түбән һәм югары төзелешлеләргә бүләләр. Түбән төзелешле Г.нең мицелие — күзәнәксез, югары төзелешлеләрнең — күзәнәкле. Вегетатив, җенессез һәм җенси юл б-н үрчи. Күбесенең үсеш циклында җил, су, бөҗәкләр б-н таралучы җенессез һәм җенси споралар барлыкка килүнең чиратлашуы күзәтелә. Г. — гетеротроф организмнар (әзер органик матдәләр кулланалар), бигрәк тә сапрофитлар, үсемлек калдыкларында, агачта, туфракта (агарик, ариллофорик, гастеромицетлар һ.б.), ашамлыкларда, туфракта (күгәрекләр, *чупрәләр*), суда (сапролегинсыманнар) була. Күп төрләре үсемлекләрдә (кисәү, тутык, *ончыл чык гөмбәләре* һ.б.), сирәк кенә хайван һәм кеше тәнендә паразит булып яшиләр, төрле авырулар (хайваннарда микозлар, кешеләрдә дерматозлар) китереп чыгаралар. Кайбер Г. сусемнәр б-н *лишайниклар*, югары төзелешле үсемлекләр б-н микориза хасил итәләр. Аерым төрләре (туфрак гифолицетлары) ерткычлар. Авыл һәм урман хуҗалыкларына шактый зур зыян салучы паразит Г.дән киң таралганнары — фузариум, фитофтора, ольпидиум, *арыш анасы*. *Агач гөмбәләре*, *бүрәнә гөмбәләре* аеруча зарарлы. Татарстан урманнарында Г.нең ашарга яраклы 200 дән артык ашләпәле төре (*ак гөмбә*, *усак гөмбәсе*, *каен гөмбәсе*, *майлы гөмбә*, *гөреҗдә*, *ал гөмбә* һ.б.) үсә. Ашләпәлеләр арасында 20 ләп төре (*чебен гөмбәсе*, *кызыл чебен гөмбәсе* һ.б.) агулы, чикләнгән күләмдә ашарга яраклылары да (*җыерчалы* һәм *җөйле гөмбәләр*) бар. Дәвалау һәм биологик актив матдәләре булган кайбер Г. (*кара каен гөмбәсе*, *ак гөмбә*, *җирән гөмбә*, *арыш анасы* һ.б.) халык медицинасында, чүпрә, пеницилл һ.б. халык хуҗалыгында файдаланыла. Г. табигатьтәге матдәләрне үзгәртүдә дә мөһим роль уйный: органик матдәләрне тарката, минераллаштыра, туфрак ясау процессында катнаша. 34 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ГӨРЕҖДӘ́** (Lactarius), ал гөмбәләр семьялыгының сөтчел гөмбәләр ыругыннан җәймәле гөмбә. Евразиядә киң таралган. ТРда чын Г. (L. resimus), сары Г. (L. scrobiculatus), усак Г.се (L. controversus) һ.б. очрый. Күбесенчә каенлыкларда, наратлы каенлыкларда һәм киң яфраклы урманнарда төркем-төркем булып үсә; июльдән алып сентябрьгә кадәр очрый; каен б-н микориза хасил итә. Ашләпәсенең диаметры 5–20 *см*, яшь гөмбәләрнең ашләпә кырыйлары яссы, соңрак — аска таба бөгелгән йонтәс-җепселле, бүрәнкәсыман. Кабыгы бераз лайлалы, сөт кебек ак. Йомшагы тыгыз, уалучан, хуш исле. Сөтчел сыекчасы ачы, ак төстә, һавада саргая. Пластинкасы артучан яки кимеп баручан, башта ачык төстә, акрынлап карала. Сабагы цилиндрсыман, кыска, юан, куыш, кайбер төрләренеке тимгелле. Ашарга, тозларга яраклы. Рәсеме *Гөмбәләр* мәкаләсендә.

**ГӨРЗИ́** (чукмар), 1 метрга кадәр озынлыктагы агач сапка авыр таш яки металл бәргеч беркетелгән борынгы сугыш һәм ау коралы. Таш чукмарлы Г. — неолит чорында, металл чукмарлысы бронза гасырда барлыкка килә. Борынгы Шәрекъ илләрендә урта гасырларда таралган. Болгарларда — 10 йөздә, Көнбатыш Европада һәм Русьта 13 йөздә кулланыла башлый. Шар формасындагы һәм чукмары берничә кырлы Г.ләр булган. Алар б-н хәрби аксөякләр коралланган. Дошманның тимер сугыш киемен зарарлау һәм аны миңгерәйтү өчен кулланылган. Болгар һәм татар әмирләрендә, төрек пашаларында, поляк һәм украин гетманнарында бай итеп бизәлгән Г.ләр хакимият билгесе булып саналган.

*Әд.:* И з м а й л о в И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XII вв. К.–Магадан, 1997.

**ГӨСЛӘ́**, чиртмәле күп кыллы музыка уен коралы. Татарларда аның беренче тапкыр телгә алынуы 1550 елларга туры килә. «Казан елъязмасы»нда, Казан Кремле сакчылары, Иван IV гаскәренең кальгадан чигенүен күреп, гөсләләрдә уйнап шатланыша, күңел ачалар, диелә. Атамасы рус гөсләләренә бәйле. Г.нең борынгы традицион эшләнеше бүгенге көнгә кадәр саклана. Корпусның формасы һәм зурлыгы, эшләнү технологиясе җирле традицияләргә һәм останың үз тәҗрибәсенә бәйле. Г., нигездә, шлем формасында, кайчакта кисек түбәле, агач корпуслы була. Г.нең кыллары (10 нан 21 гә кадәр) элек хайван эчәгеләреннән, сумалаланган кычыткан яки



Гөслә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы.
ТРның Милли музее фондларыннан.




**Гөмбәләр.** 1. Ак гөмбә; 2. Валуй гөмбәсе; 3. Кызыл гөмбә; 4. Гөреҗдә: а) чын, б) кара; 5. Имән гөмбәсе; 6. Гади әтәч гөмбәсе; 7. Гади майлы гөмбә; 8. Яшел мүк гөмбәсе; 9. Көзге баллы гөмбә; 10. Каен гөмбәсе; 11. Кызыл усак гөмбәсе; 12. Җирән гөмбә; 13. Җыерчыклы гөмбә; 14. Җөйле гөмбә; 15. Яшькелт һәм ал эшләпәле гөмбәләр; 16. Гади шампиньон; 17. Томсык гөмбә; 18. Кызыл чебен гөмбәсе; 19. Чуар чебен гөмбәсе; 20. Ялган баллы гөмбә.

киндер сүсеннән эшләнгән булса, хәзерге вакытта металлдан эшләнә. «Глиссандо» (сул кул бармаклары б-н томаланмыйча яңгыраган кыллар) һәм «арпеджато» (легато, ягъни сузып һәм стаккато — сикертеп уйнауны кертеп, төрле-төрле штрихлар файдаланыла) тибындагы уйнау алымнары киң таралган. Г. көйләнеше ангемитоник, астагы ике кылы квартага, калганнары мажорлы (кайвакытта минорлы) пентатоника буйлап көйләнә.

Г.не тезләрдә яссы тотып, башын үзеңә каратып, кайчакта өстәлгә яткырып яки янтайтып уйнарга мөмкин. Уңышлы эшләнгән уен коралы яңгыравыклы матур тавышка һәм яхшы акустик үзлеккә ия. Элек Г. Татарстанның төньяк-көнчыгыш р-ннарында киң таралыш алган. Хәзерге вакытта Арча һәм Балтач р-ны авылларында (керәшен татарларда) очрый. Г.дә ялгыз һ.б. уен кораллары кергән ансамбль составында, җырчыларга һәм биючеләргә кушылып уйнала. Г.дә уйнау тәҗрибәсе буыннан-буынга күчә. Кайбер керәшен татар гаиләләрендә ата-аналар да һәм балалар да уйнаган; кызлар өчен Г.дә уйнарга өйрәнү мәҗбүри саналган. Татар халык авыз иҗатында Г.дә уйнаучыларга мәдхия җырлана:

Уңган кызлар гөслә чиртсә,
Җырлар сибелә генә...

Уйный белмәүчеләрдән исә көлгәннәр:

Унике генә кыллары,
Гөсләгә килми куллары.
Картаеп торып калдылар
Никулай дәдәй кызлары...

Гөсләчеләр репертуарында төп урынны халык көйләре (бигрәк тә «авыл көйләре») һәм халык бию көйләре алып тора.

*Әд.:* Нигмедзянов М.Н. Татарские народные музыкальные инструменты // Музыкальная фольклористика. 1978. № 2; Яковлев В.И. Традиционные музыкальные инструменты Волго-Уралья. К., 2001.

*Р.Ф.Халитов.*

**ГРА́ВЕ** Иван Платонович (13.11.1874, Казан — 3.3.1960, Мәскәү), корал ясау гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1939), проф. (1927), ген.-майор (1942). 1895–97 елларда Батуми кальгасы артиллериясендә хезмәт итә, 1895 елда Михаил артиллерия уч-щесен, Михаил артиллерия академиясен (1900 ел, С.-Петербург) тәмамлаганнан соң, шунда ук хезмәт итә һәм укыта (1904–17). Пироксилинлы төтенсез дары кулланып, реактив снаряд үрнәген — сугыш ракетасын уйлап таба (1916). Эшче-крәстиян Кызыл Армиясенең Артиллерия академиясен оештыруда катнаша һәм укыта: проф., укыту бүлеге башлыгы, каф. башлыгы булып эшли (1917–18, 1922–39, 1940–60). Баллистика фәнни мәктәбенә нигез сала. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1942). Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Айдагы бер кратерга Г. исеме бирелә.

Хезм.: Внутренняя баллистика: В 5 т. Л., 1933–38; Баллистика полузамкнутого пространства. Л., 1940.

**ГРАВЕЛИ́Т**, к. *Вак чуерташ.*


**ГРАВИМЕ́ТРИЯ** (лат. gravis — авыр һәм ...*метрия*), планеталар өстендә һәм эчендә, ш.у. аларның тирә-юнендә гравитация кыры һәм аның элементларының таралуын өйрәнә торган фән. Г. турындагы мәгълүматлар астрономогеодезиядә (планеталарның массасын һәм формасын исәпләү, космоста тикшеренүләр), геологиядә (Җирнең эчке төзелеше, геол. карта төшерү, файдалы казылмалар эзләү), инженерлык геофизикасында, археологиядә, хәрби эшләрдә (ракеталар җибәрү һ.б.) һ.б. тармакларда кулланыла. Гравитация кыры беренче тапкыр Г.Галилей тарафыннан үлчәнелә (1590). СССРда беренче тапкыр 1930 елларда, Җир кабыгының төзелешен өйрәнү максатыннан, маятниклы приборлар ярдәмендә планга төшерү буенча дәүләт эшләре алып барыла. 1950 еллардан башлап, СН-3 тибындагы гравиметрлар эшләп чыгарыла башлагач, әзлекле рәвештә ил буенча гравиметрик төшерү эшләре алып барыла. ТРда гравиметрик эзләнүләр Казан ун-тында (А.Д.Дубяго, В.П.Боронин, Д.К.Нургалиев, З.М.Слепак һ.б.), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк ин-тында (А.Г.Салихов, Н.С.Евграфов, Г.Е.Кузнецов һ.б.), Казан геофизика экспедициясендә (З.М.Слепак, А.В.Андреев, Ю.Б.Антонов, В.П.Степанов, М.Я.Боровский һ.б.) үткәрелә. Төшерелгән план нәтиҗәләре кристаллик нигез сындырмаларының юнәлешен билгеләүдә, нефть эзләү мәсьәләләрен хәл итүдә, геол. карталар төзүдә кулланыла. 1) Гравиразведканың кире мәсьәләсен микъдари дәрәҗәдә хәл итү мөмкинлеген бирүче нефтьле-газлы структуралар эзләүнең; 2) Җир шарының блоклы төзелешен билгеләүнең; 3) региональ профильләр буйлап тирән геол. киселешләрне ачыклауның теоретик һәм гамәли гравитацион модельләре эшләнгән. Инженерлык геофизикасында яңа юнәлеш — архитектура истәлекләренә зарарлы йогынты ясаучы актив геол. процессларны өйрәнүдә югары төгәллектәге гравиметрик күзәтүләрне мониторинг режимында куллану гамәлгә керә. Казан Кремле терр-ясендә авырлык көче үзгәреше буенча Сөембикә манарасы һәм Губернатор сарае фундаментына техноген суларның тискәре йогынтысы ачыклана; аларның күп еллар буена ясаган тәэсире манара авышуга сәбәп була һәм сарай янкормасы ишелүгә китерә; югары төгәллектәге гравиразведканың нәтиҗәлелеге киселешнең өске өлешендә убылмалар хасил булу куркынычына илтүче йомшак токымлы участокларны тикшергәндә һәм культуралы катламда борынгы таш корылмалар калдыгын эзләгәндә чагыла (З.М.Слепак). Беренче тапкыр структур Г. нәтиҗәләрен геол. тирәлекнең сакланышын бәяләүдә кулланырга тәкъдим ителә (М.Я.Боровский, И.Х.Газиев, Д.К.Нургалиев).

*Әд.:* Слепак З.М. Применение высокоточной гравиразведки при поисках нефтеносных структур. М., 1989; Гравиразведка. М., 1990; Боровский М.Я., Газеев И.Х., Нургалиев Д.К. Геоэкология недр РТ: геофизические аспекты. К., 1996; Slepak Z. Complex Geophysical Investigations for Studying the Cultural Layer and Remains of Ancient Buildings in the Territory of Kazan Kremlin // Archeological Prospection. 1997. V. 4.

*З.М.Слепак.*

**ГРАВИРЛА́У**, к. *Уеплау.*

**ГРАВЮ́РА** (фр. gravure), 1) такта өслегендә басма ясау, уеп кисүнең — гравирлауның төрле ысуллары: ксилография (агачта), литография (металлда, ташта), линогравюра (линолеумда) б-н башкарылган сәнгать әсәрләрен үз эченә алучы графика төре; 2) тактадан кәгазьгә яисә башка материалга басу юлы б-н күчерелгән рәсем. Г. станлы әсәр (эстамп), китап рәсеме һәм бизәге, гамәли графика төре буларак яшәп килә. Тиражлау, ягъни бер үк төрле басма нөсхәләрен күп тапкыр алу мөмкинлеге Г. ның үзенчәлеге булып тора. Г. оригиналь (автор тактага үз әсәрен күчергәндә) һәм репродукция (башка автор әсәре кабатлап басылганда) төрләренә бүленә.




**Гөрзи мәкаләсенә.** 1, 2. 10–11 йөзләр; 3–9. 12–13 йөзләр; 10. 14 йөз; 11. 15–17 йөзләр.

Казанда Г. үсешенә 16 йөзнең 2 нче яртысында башланып киткән рус телендә китап басу эше («*Аноним басмаханә*»), ш.у. татар китапларын басу өчен оештырылган беренче басмаханәләр эшчәнлеге (19 йөз башы, к. *Азия басмаханәсе*) башлангыч бирә. Барыннан да бигрәк уку йортларының тарих, нумизматика, археол. өлкәләренә караган хезмәтләрне иллюстрацияләү ихтыяҗларына җавап рәвешендә репродукцияле Г. үсеш ала. 1810 да Казанда гравёр Левен Кальмер эшли һәм ул Х.Френ, К.Фукс нумизматик коллекцияләреннән күчермә таблицалар әзерли, алар Х.Френның «Җүчи олысы ханнары тәңкәләре» («Монеты ханов улуса Джучиева», СПб., 1832) дигән хезмәтендә басылып чыга. П.Ф.Табуре, Л.И.Шевиц, Ткачук, Н.Я.Кафтанников тарафыннан ж-л иллюстрацияләре сыйфатында башкарылган архит-ра-күренеш Г. сы 1830–40 елларда Казан басмалары битләрендә урын ала. 19 йөзнең 2 нче яртысында В.В.Вараксин, А.М.Кокорев, И.Н.Харитоновның Казандагы басмаханәсендә литография ысулы б-н гарәп язуындагы (ешрак куфи стилендә) Коръән сурәләре һәм мөселманнарның төп мәчетләре сурәтләре чагылдырылган эстамп-шәмаилләр бастырыла. Алар А.Абдуллин, М.Сәетов, Г.Мозаффаров, бертуган Әхмәтсадыйковлар һ.б. татар осталары тарафыннан башкарыла. Г. әсәрләре арасында 19 йөз уртасы шәһәр күренешләрен чагылдырган үрнәкләр аеруча игътибарга лаек. Казан күренешләре В.Туринның ике сериясендә: 10 офортта (рулетка, офорт, лавис, 1820 елларның 2 нче яртысы) һәм Мәскәүдә А.С.Ястребилов литографиясендә нәшер ителгән литографияләр альбомында (1834), ш.у. С.-Петербургта Конрад Вингебер басмаханәсендә басылып чыккан тарихи-дини рәсемнәр альбомында чагылыш тапкан. 1830 еллар ахырында Э.Турнерелли Казан күренешләре сериясен иҗат итә, алар Лондонда Лефер һәм Нейман басмаханәсендә литографияләнә.

Г. ның сәнгать төре буларак үсешендә *Казан сынлы сәнгать мәктәбенең* Ю.И.Тиссен җитәкчелек иткән гравёрлык бүлеге (1895–1908) мөһим роль уйный. Биредә Петербург Сынлы сәнгать академиясендә кабул ителгән традицион методика нигезендә классик Г. һәм офорт укытыла. Ю.И.Тиссенның һәм аның шәкертләре А.Г.Лошадкин, Д.Д.Агафоновның Г. эшләрендә «В.В.Матэ мәктәбе»нең тонлы Г. йогынтысы ачык сизелә, Л.Ф.Овсянников һәм П.М.Дульский әсәрләрендә ирекле стильдә иҗат ителгән офорт көчлерәк тоемлана.

1910 елларда оригиналь Г. ның барлык төр техникалары һәм иҗат юнәлешләре чәчәк атуына, башлыча, А.Ф.*Мантельнең* наширлек эшчәнлеге этәргеч бирә, ул нәшер иткән басмаларда «Сәнгать дөньясы» («Мир искусств») берләшмәсенең күренекле графиклары эшләренә зур урын бирелә.

Г. үсешендәге яңа этап 1920 дә Казан дәүләт ирекле остаханәләренең Н.С.Шикалов җитәкчелегендәге графика бүлеге торгызылу б-н бәйле. Биредә Г. ның барлык төрләре укытыла һәм графика эшләре өйрәнелә. Бу бигрәк тә И.Н.Плещинский һәм Н.С.Шикалов җитәкчелегендәге «*Всадник*» берләшмәсе (1920–24) эшчәнлегендә тормышка ашырыла, алар «үз законнары һәм ирекле график стиле булган Г.ны мөстәкыйль сәнгать төре буларак күтәрү»не максат итеп куялар. 1930 елларда «Всадник» рәссамнары иҗатында авторлык Г.сы үз эченә китап сәнгатен, плакат, лубок, афиша, кече басма формаларны берләштерүче, «массалар телендә сөйләүче», типография техникасына якынрак торучы һәм ул чор өчен актуальрәк булган «производство графикасы» б-н алышына. Казанда *А.В.Луначарский исем. полиграфия мәктәбе* (1922) һәм Казан сынлы сәнгать уч-щесендә производствога якынайтылган графика бүлеге ачылу (1928–29) бу өлкәдә эшләүче милли осталар әзерләүгә (Г.В.*Арсланов*, Ф.Ш.Таһиров, Д.Н.*Красильников*, Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов*, Б.Г.Йосыпов һ.б.) этәргеч бирә.

Г. үсешенең сүрелүенә совет сәнгатендәге гомуми тенденцияләр һәм 1930 елларда әйдәп баручы графика осталарының Казаннан китүе сәбәп була. Бөек Ватан сугышы елларында Г. ны кулдан ясалган рәсем һәм плакат алмаштыра. 1950 еллар ахырына кадәр Татарстанда эстамп б-н шөгыльләнүче рәссамнар булмый диярлек (И.Е.*Бобровицкийның* линогравюралар сериясе һәм Чистайда эшләгән И.А.Нестеровның пейзажлы офортларының гайре). Г. ның яңарышы 1950–60 елларда Балтыйк буе, Украина, Ленинград, Мәскәү сынлы сәнгать югары уку йортларында белем алып, Татарстанга милли һәм «башкала» графикасы мәктәпләренең заманча югары проф. культурасын алып кайткан сугыштан соңгы буын осталарына бәйле. Алар — И.Л.*Язынин*, Л.А.Потягунин, И.К.*Колмогорцева*, Т.А.*Зуева*, С.М.*Кульбака*, Ю.Б.*Лысогорский*, Л.М.Кальюранд, А.Р.Туманов, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов*, Э.Я.*Зарипов* һ.б.

Аеруча линогравюра һәм офорт үсеш ала. 1960 еллар сәнгатендә «кырыс стиль»гә якын пластика теле, сәнгатьтә гомумиләштерүнең яңа формасы б-н каралы-аклы линогравюра аерым урын алып тора. 1960–70 тә Татарстан графикларына төрле темаларны чагылдыру өчен ул универсаль тел булып хезмәт итә. Кешелекнең мәңгелек кыйммәтләре — ватан, хәтер, тынычлык, гаилә, мәхәббәт — С.М.Кульбака, Э.Я.Зарипов, Е.В.*Киселёва*, милли-эпик — Э.Г.*Ситдыйков* һәм интим-лирик — Э.Я.Зарипов, И.К.Колмогорцева, индустрия — В.А.*Попов*, И.К.Әхмәдиев, шәһәр пейзажы — Л.Я.Потягунин, Л.П.Иванова, В.А.Попов, В.А.Дайчман, тарихи-әдәби темалар — И.Л.Язынин, Е.В.Киселёва, И.К.Колмогорцева, В.Б.Зелинский, В.А.Дайчман эшләрендә чагылыш таба. Төсле линогравюра үсешендә И.Л.Язынин һәм Л.А.Потягунин иҗаты мөһим урын тота.

1960 елларда М.К.*Мавровская* тырышлыгы б-н ТАССР Рәссамнар берлеге каршында офорт остаханәсе яңадан оештырыла. Т.А.Зуева һәм М.К.Мавровскаяның лирик пейзажлары, Л.М.Кальюрандтның сугыш темасы сериясе офорт өлкәсендә игътибарга лаек вакыйга буларак бәяләнә. В.И.Ильинның офортларында (1970 еллар ахыры — 1980 еллар) күпмедер дәрәҗәдә стильләшкән иске Казан күренешләре яңа чагылыш таба. 1980 елларда Яшел Үзәндә Р.Ф.*Галиуллин* пейзаж һәм натюрморт жанрларында уңышлы эшли.

1970–80 дә рәссам-графикларның яшь буыны иҗатында эстамп үсешенең яңа тенденцияләрен — көчәя баручы психологизм, аналитик һәм романтик нигезләре, техника катлаулылыгы һәм сурәтләү чаралары байлыгы чагылыш таба (Н.У.*Әлмиев*, Ю.М.Каспина (Вургафт), А.Р.Туманов, В.И.Ильин, ш.у. сирәк булса да офортка мөрәҗәгать итүче Р.Т.*Сафиуллин* һәм Е.Г.Голубцов).


Ю.М.Каспина (Вургафт) һәм А.Р.Тумановның станлы китап графикасы индивидуаль-лирик башлангыч б-н классик штрихлы офорт традицияләрен һәм яңа формалар эзләү омтылышын берләштерә. 1980–90 да иллюстрациянең станлы формаларына тартылу Г.Л.Эйдинов, С.Х.Ибраһимова, Ю.Л.Бердников офортларында ачык сиземләнә. Пейзаж жанрында эшләүче И.В.Антонованың офортлары аерылып тора. Бу елларда Чаллыда офорт графика культурасы В.Сынков иҗаты, А.В.Халдиевның үтә стильләштерелгән һәм аллегорик әсәрләре (төсле офорт), Ю.Г.*Свинин* (йомшак лак б-н яраштырылган офорт), Б.Б.Грабенко эшләре аша танылу ала.

Татарстанның хәзерге заман офорты, пластик һәм стилистик чишелешләр диапазонының киңлеге б-н игътибарны җәлеп итә. 1970–80 еллар графикасында М.К.Мавровская, И.К.Колмогорцева, Н.У.Әлмиев, А.Р.Туманов, Ю.М.Каспина (Вургафт) ирешкән казанышлар аңа нигез булып кала бирә. Литография һәм ксилография — Татарстан графиклары иҗатында сирәк кулланылучы техникалар. 1970 елларда Н.Д.*Кузнецов* литографияләрендә индустриаль пейзаж темасы урын ала. Милли тема Р.Ш.*Зиннәтованың* (С.-Петербург) 1980 еллардагы төсле литографияләрендә чагыла, бу юнәлештә Ә.Р.*Ильясова* да актив эшли. Шулай ук М.В.Нигъмәтуллинаның стилистикасы ягыннан натуралы рәсемгә якын торучы монотипияләрендә милли тема үзенчәлекле чишелеш таба. 1920–30 елларда киң таралган ксилографияне хәзерге заман Казан графиклары сирәк куллана. Биредә А.Р.Туманов, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов* аерым урын алып торалар.

Аркылы кисемле ксилография б-н ясалган китап миниатюрасы өлкәсендә иң зур оста булып Туманов кала бирә, ул гравирлауның күптөрле техникалары б-н эш итә, китап бизәлешендә композицион форманың бөтенлегенә һәм җентекләп башкарылуына ирешә.

*Әд.:* Дульский П.М. Книга и её художественная внешность (В связи с казанским книгопечатанием). К., 1921; шул ук. Актуальная графика. К., 1935; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990; Ключевская Е.П. У истоков казанской графики // Художник. 1990. № 6; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. 1960–1990-е годы. К., 2001.

*О.Г.Вербина.*


































**Гравюра**. 1. В.С. Т у р и н. «Казан кальгасы күренеше». Литография. 1834; 2. Н.С. Ш и к а л о в. «Монастырь дивары». Төсле линогравюра. 1919; 3. К.К. Ч е б о т а р ё в. «Ленин үлде, компартия исән!» Линогравюра. 1925; 4. И.Н. П л е щ и н с к и й. «В.С.Плещинская портреты». Ксилография. 1925; 5. Ш.Н. М ө х ә м м ә т җ а н о в. «Кыз портреты». Литография. 1927 (?); 6. Л.А. П о т я г у н и н. «Таллинның балык гаванендә». Төсле линогравюра. 1957; 7. И.Л. Я з ы н и н. С. Злобинның «Степан Разин» китабына шмуцтитул. Төсле линогравюра. 1958; 8. Т.Г. Х а җ и ә х м ә т о в. «Халык әйтсә, хак әйтә». Татар мәкальләренә багышланган сериядән. Агачка читләп ясалган гравюра. 1969; 9. Э.Я. З а р и п о в. «Әткәм портреты». Линогравюра. 1970; 10. Ю.М. К а с п и н а (Вургафт). «Көз». «Ел фасыллары» сериясеннән. Офорт, акварель. 1974; 11. М.К. М а в р о в с к а я. «Көньяк-көнчыгыш манара». «Казан Кремле манаралары» сериясеннән. Офорт, акватинта. 1976–78; 12. А.Р. Т у м а н о в. «Бәллүр күгәрчен». С. Власов китабына иллюстрация. Ксилография. 1974; 13. И.К. К о л м о г о р ц е в а. «Кекин йорты». «Иске Казан» сериясеннән. Төсле офорт, 1979; 14. Н.У. Ә л м и е в. «Йөгереш турында хатирә». Офорт, акватинта. 1982; 15. И.В. А н т о н о в а. «Үле тынлык». «Төньяк җире хикәятләре» сериясеннән. Офорт, акватинта. 1991.

1918–19 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ




**ГРАЖДАННА́Р СУГЫШЫ́ (1917–22),** Россиядә 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң большевиклар җитәкчелегендә хакимиятькә килгән аерым социаль төркемнәр һәм аларга каршы торучылар арасындагы коралллы көрәш. Петроградта Совет хакимияте урнашуның беренче көннәреннән үк башлана; вакыт ягыннан Дүртлек союзы һәм Антанта илләренең Совет Россиясенә интервенциясе б-н туры килүе сәбәпле, кискен һәм озакка сузылган төс ала. Г.с. елларында Казан губернасы терр-ясе ике тапкыр сугыш хәрәкәтләре мәйданына әверелә. 1918 елның җәендә аның зур өлешен КОМУЧның Халык армиясе һәм чех-словак корпусы (к. *Чех-словак корпусы фетнәсе*) басып ала. Чех-словак корпусы (40 мең чамасы кеше) 1917 нең көзендә чех һәм словак хәрби әсирләреннән һәм мөһаҗирләреннән оештырыла. Сов. хөкүмәте б-н килешү буенча ул 1918 дә Владивосток аша Көнбатыш Европага эвакуацияләнергә тиеш була. Антанта аны үз кораллы көчләренең авангарды сыйфатында файдаланырга карар кыла. Чех-словак легионерларын Совет хакимиятенә каршы котырту өчен, алар арасында җирле совет органнарының чех-словакларның Ерак Көнчыгышка хәрәкәт итүенә каршы булуы, Совет хөкүмәтенең аларны Германиягә тапшырырга җыенуы турында имеш-мимешләр таратыла. Корпус җитәкчелеге легионерларны көч кулланып Владивостокка үтеп чыгарга чакыра. Май ахырында коткыга бирелгән шул легионерлардан Идел буе (8–10 мең кеше), Чиләбе (9–12 мең кеше), Себер (10–11 мең кеше) һәм Владивосток төркемнәре оештырыла. Чех-словак корпусына кергән гаскәри берәмлекләр Идел буендагы, Урал, Себер һәм Ерак Көнчыгыштагы шәһәрләрне (Пенза, Сызрань, Самара, Чиләбе, Златоуст, Новониколаевск, Томск, Омск, Красноярск, Владивосток) яулап ала башлыйлар, урыннарда Совет хакимиятен бәреп төшерәләр. 1918 нең 8 июнендә Самара Идел буе төркеме тарафыннан алына; шул ук көнне шәһәрдә Бөтенроссия *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* (КОМУЧ) оештырыла, ул Самарада һәм губернада Совет хакимиятенең бәреп төшерелүе турында игълан итә һәм шәһәр думасын, земство управаларын торгызу турында күрсәтмә чыгара. КОМУЧның Халык армиясе төзелә. Июнь ахырына аның сафларында 20 меңләп кеше туплана. Совет хөкүмәте гадәттән тыш чаралар күрергә мәҗбүр була: Чех-словак фронты оештырыла, Кызыл Армияне ирекле рәвештә формалаштыру тәртибе урынына мобилизацияләү тәртибе кертелә. Кызыл Ар-








1. Казан янына диңгезчеләр отрядын китерү. 1918; 2. Казан операциясе вакытында десант төшерү. 1918;
3. Кызыл Армия частьләре Казанда. 10.9.1918.

миягә алу (мобилизация үткәрү) турында 12, 17, 29 июньдә декретлар кабул ителә. 13 июньдә Чех-словак фронты урынына *Көнчыгыш фронт* оештырыла һәм аның Революцион хәрби советы (РВС) төзелә. Барлык гаскәрләр дүрт армиягә (к. *Беренче армия*, *Икенче армия*, *Өченче армия*, *Дүртенче армия*) туплана, алар Көнчыгыш фронтны хасил итәләр. Июль ахырында *Бишенче армияне* формалаштыру башлана, ул чех-словак легионерлары һәм аквардиячеләр б-н көрәштә хәлиткеч көчкә әверелергә тиеш була. 22 июльдә чех-словакларның Идел буе төркеме һәм аквардиячеләр Семберне ала һәм, 5 нче армияне туплау тәмамланмаудан файдаланып, 1–3 августта авангард көчләре б-н Казанга һөҗүм башлый. Аларның 3 мең штыгы, 300 кылычы, 16 тубы була. Фронттан коры җир көчләре һәм тылдан елга десанты басымы астында Кызыл Армиянең оператив төркеме Кама Тамагындагы позициясеннән чигенә. Бу төркемнең пароходлары, Идел юлын ачык калдырып, Казан яныннан Түбән Новгородка таба чигенәләр. 5 августта чех-словакларның Идел буе төркеменең һәм аквардиячеләрнең хәрби пароходлары Казан пристаньнарына килеп җитә, аларны утка тота һәм десант төшерә. 5 нче Земгаль латыш полкының ике ротасы, Беренче татар-башкорт укчылар батальоны һәм Д.Н.*Авров* җитәкчелегендә эшчеләрнең ополчение отряды штык һөҗүме б-н десантны чигенергә мәҗбүр итәләр, туптан атып, каршы якның бер пароходын батыралар. Калган башкалары Түбән Ослан ягына китә. Югары Ослан авылы янында В.Н.*Скачков* җитәкчелегендә артиллеристлар ак чехларның десанты б-н канкойгыч сугыш алып баралар. Идел ягыннан яңа һөҗүм булу ихтималын искә алып, командование пристаньнар районын яңа көчләр б-н ныгыта, анда өстәмә берничә туп (ике артиллерия батареясы) урнаштыра. 40 латыш укчысы һәм ике туп Югары Осланга ярдәмгә җибәрелә. Казанда эшчеләр отрядлары (барлыгы 3 мең винтовка һәм 100 мең патрон таратыла) һәм коммунистик отряд оештырыла. 6 августта иртән каршы як Зур Отар авылы тирәсендә десант төшерә һәм көнчыгыштан Суконный бистәсенә, көньяктан татар зиратыннан көнчыгыштарак юнәлештә һөҗүм итә. Суконный бистәсенә ярдәмгә 5 нче Земгаль латыш полкы, К.Маркс исем. *Интернациональ батальон* сугышчылары һәм эшчеләр отряды җибәрелә. Татар зиратыннан көнчыгыштарак Мөселман коммунистик отряды, Беренче мөселман социалистик полкы һәм Икенче мөселман социалистик батальонының кызылармиячеләр төркеме оборонага урнаша. Казанда һәм аның тирәсендә камалыш хәле игълан ителә, И.И.Межлаук (к. *Межлауклар*) гадәттән тыш комендант итеп билгеләнә. 6 августта төш вакытында, шәһәрнең көнчыгыш һәм көньяк читләрендә көчле сугышлар барганда, артиллерия һәм пулемет утына ышыкланып, пристаньнар р-нында каршы як яңа десант төшерә, кызылармиячеләрне кысрыклап, Адмиралтейство бистәсен ала. Шәһәр урамнарында (Юнысов мәйданы тирәсе, Екатеринин-



# Приказъ № 5.

## Коменданта г. Казани

### на 1-е августа 1918 года.

§ 1.

Гражданинъ **Сайгуновъ** за храненіе оружія—разстрѣлянъ.

Гражданинъ **И. Морозовъ** за нахожденіе у него большого кухоннаго ножа—оштрафованъ на 1000 рублей.

Гражданинъ **Довровъ** за нахожденіе у него при обыскѣ 2-хъ винтовокъ —разстрѣлянъ.

Гражданинъ **Лавренюкъ** за продажу спирта заключенъ подъ арестъ на одинъ мѣсяцъ, съ замѣной штрафа на 1000 рублей.

§ 2.

Въ виду того, что контръ-революція еще жива и дѣйствуетъ противъ Совѣтской власти и [illegible] въ ночь на 28-е Іюля подготовлялось выступленіе бѣлогвардѣйцевъ, мною была разоружена самоохрана, состоявшая большею частью изъ офицерства. Оружіе сдано не все и по заявленію районныхъ Комитетовъ, число сданныхъ револьверовъ составляетъ только около 3—5%. А по сему мною было взято въ качествѣ заложниковъ 5 человѣкъ.

Приказываю Центральнымъ районамъ снести въ 2-хъ дневный срокъ со дня опубликованія приказа все оружіе, на которое нѣтъ надлежащаго разрѣшенія Чрезвычайно-Слѣдственной Комиссіи. Въ противномъ случаѣ будутъ взяты еще заложники изъ центра города и преданы разстрѣлу. Всѣ лица, у коихъ будетъ найдено послѣ этого оружіе, будутъ немедленно разстрѣляны.

§ 3.

Согласно приказа наркомвоен. Троцкаго.

А.

Военнослужащимъ иностранныхъ государствъ запрещается носить въ предѣлахъ Россійской Совѣтской Федеративной Республики форму своей страны.

*Примѣчаніе:* Не касается военноплѣнныхъ, носящихъ ту одежду, въ которой они взяты въ плѣнъ.

Б.

Носить оружіе военнослужащіе иностранныхъ государствъ имѣютъ право наравнѣ съ русскими гражданами съ разрѣшенія подлежащихъ русскихъ властей и никакими привилегіями въ этомъ отношеніи по сравненію съ гражданами Россійской республики, пользоваться не должны.

§ 4.

Воспрещается бывшимъ офицерскимъ чинамъ ношеніе всякихъ знаковъ отличія, кокардъ и т. п.

§ 5.

Доводится до свѣдѣнія воинскихъ частей, что пропуски для хожденія по улицамъ послѣ 11½ часовъ ночи, выданные на бланкѣ Государственнаго Банка, за моей подписью считать временно до особаго распоряженія дѣйствительными.

§ 6.

Предписываю всѣмъ домовладѣльцамъ, домовымъ комитетамъ, содержателямъ номеровъ и завѣдывающимъ номерами, отъ всѣхъ пріѣзжающихъ требовать документы для прописки и давать точныя свѣдѣнія въ адресный столъ о всѣхъ пріѣзжающихъ и уѣзжающихъ и мѣняющихъ мѣстожительства въ городѣ гражданахъ не позже 24-хъ часовъ, за неисполненіе настоящаго постановленія, виновнымъ будутъ примѣняться самыя строгія мѣры наказанія отъ принудительныхъ работъ вплоть до разстрѣла и конфискаціи всего имущества.

§ 7.

Всѣ воинскія части должны предупреждать въ цѣляхъ спокойствія населенія объ учебной стрѣльбѣ, салютахъ и проч.

За стрѣльбу на улицахъ виновные будутъ преданы разстрѣлу.

**Комендантъ города Казани К[illegible]нъ.**

**Помощникъ Коменданта Сушковъ.**

**Комендантскій Адьютантъ Штейнворцель.**

Казанъ. Губернская [illegible]типографія.

ская, Московская, Сулъяк Болак урамнары) һөҗүм итүче чех-словак легионнары һәм акгвардиячеләр б-н пристаньнардан шәһәргә кайтарылган Беренче татар-башкорт укчылар батальоны сугыш алып бара. Ак чехларның һөҗүме шәһәрдә калган патша армиясе офицерлары өчен Казанны саклаучыларга каршы күтәрелергә сигнал була. Казанны саклаучы гаскәрләрдә ныклы тәртип булмауда Көнчыгыш фронт штабының кайбер хезмәткәрләренең хыянәте дә сәбәп була. Мәскәүдән җибәрелгән ярдәм (11,5 мең кеше, 19 туп, 136 пулемёт, 16 самолёт, 6 бронепоезд һәм 3 броневик) Зөядә тоткарлана. Зур югалтуларга дучар булган Кызыл Армия частьләре 7 августта Казанны калдыралар. Казан алынганнан соң, шәһәрдә террор башлана: партия һәм совет хезмәткәрләре (М.М.*Вахитов*, С.Н.*Гассар*, А.П.*Комлев*, М.И.*Межлаук*, Я.С.*Шейнкман* һ.б.), ш.у. Сов. хакимиятенең күп кенә тарафдарлары кулга алына һәм атыла. *РСФСРның Алтын хәзинәсенең* төп өлеше дошман кулына эләгә, ләкин Казанның алынуы чех-словак легионерларының һәм КОМУЧ Халык армиясенең бу төбәктәге соңгы уңышы була. 2 нче һәм 5 нче армияләр гаскәрләре аларның һөҗүмен туктатуга һәм хәрби көчләрен камап алуга ирешә. Ярдәмгә килгән гаскәр һәм корал б-н җитәрлек күләмдә тәэмин ителгән Көнчыгыш фронт көчләре, *Идел буе хәрби флотилиясе* һәм авиация катнашында, 1918 нең 5 сентябреннән 10 сентябренә кадәр барган сугышлар нәтиҗәсендә Казан азат ителә (к. *Казанны азат итү операциясе*). 5 нче армия һәм 2 нче армиянең Арча төркеме 19 сентябрьгә Буага кадәр Иделнең уңъяк ярын, Лаешка кадәр Чулман тамагын, 2 нче армия 8 октябрьгә Чистайдан Әгерҗегә кадәрге терр-яне, 5 нче армия ноябрь уртасына Бөгелмәне азат итәләр. Ак армия тылында партизаннар хәрәкәте җәелә (БҮБКның экспедицион партизан отряды). 1918 нең ахырына Казан губернасы тулысынча азат ителә. Урта Иделдә зур җиңелүгә дучар булган чех-словак легионерлары үз илләренә кайтаруны таләп итә башлыйлар, 1920 нең сентябрендә алар эвакуацияләнә. 1919 ның язында Казан губернасы терр-ясенең бер өлешен адмирал А.В.Колчак гаскәрләре басып ала. А.В.Колчак Иделгә үтеп чыгарга, анда ген. А.И.Деникин армиясе б-н кушылып, бергәләп Мәскәү юнәлешендә һөҗүм башларга омтыла. 1919 ның 4 мартында 140 мең штык һәм кылычка, 211 тупка һәм 1300 пулемётка ия булган колчакчылар һөҗүмгә күчәләр. Көнчыгыш фронт частьләре адмирал Колчак армиясе басымы астында Алабуга, Минзәлә, Бөгелмә шәһәрләреннән һ.б. торак пунктлардан кысрыклап чыгарыла. 1919 ның апреле уртасында Казан губернасының көнчыгыш өлешен басып алган колчакчылар Казаннан 85 *км* ераклыкта Нократ елгасында туктап калалар. 10 апрельдә Сембердә Республика һәм Көнчыгыш фронт Революцион хәрби советларының берләштерелгән утырышы була. Гаскәрләр б-н идарә итүне камилләштерү максатында Көнчыгыш фронт армияләре М.В.Фрунзе һәм В.И.Шорин җитәкчелегендә Көньяк (1 нче, 4 нче, 5 нче армияләр һәм Төркестан армиясе) һәм Төньяк (2 нче һәм 3 нче армияләр) төркемнәргә берләштерелә; Идел буе һәм Урал хәрби округлары Көнчыгыш фронт командованиесенә буйсындырыла. Иделдә оборона сызыгы кору турында карар кабул ителә. Казанда, Сембер, Самара һәм Саратовта ныгытылган районнар барлыкка килә. Казан ныгытылган районына Казанны һәм Кама Тамагыннан алып Зөягә кадәрге яр буйларын саклау бурычы куела. Чистай-Лаеш-Казан һәм Әгерҗе-Мамадыш-Казан юнәлешләрендә оборона корылмалары төзелә; Кама Тамагы, Зөя, Ослан тирәләре ныгытыла. Казан гарнизонында булган барлык хәрби частьләр һәм подразделениеләр ике бригадалы Казан кальгасы дивизиясенә берләштерелә. Шәһәрдә милли отрядлар оештырыла башлый. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчелегендә (рәисе М.Х.Солтангалиев) *Идел буе татар укчыларының беренче аерым бригадасы*, *Идел буе татар укчыларының икенче аерым бригадасы* оештырыла һәм хәрәкәттәге армияләргә җибәрелә. Әлеге бригадалар һәм Кызыл Армиянең башка татар милли гаскәри берәмлекләре *Татар запас батальоны* тарафыннан тулыландырылып торыла. Командирлар һәм сәяси состав *Икенче мөселман совет укчылары курсларында*, Шәрекъ халыкларының кавалерия курсларында һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе сәяси бүлекчәсе каршындагы Сәяси курсларда әзерләнә. 1919 елның 28 апрелендә Богырыслан р-нында Көнчыгыш фронтның Көньяк төркеме гаскәрләре һөҗүмгә күчә. Каршы якның Көнбатыш армиясенең 6 нчы Урал корпусына һөҗүм ясала, шуның нәтиҗәсендә колчакчылар башка участокларда һөҗүм операцияләрен туктатырга мәҗбүр булалар. Шуннан файдаланып, 1919 ның 1 маенда 2 нче армия һәм Идел буе хәрби флотилиясе Казан губернасы терр-ясендә актив һөҗүм хәрәкәтләренә күчәләр. 4 майда Чистай азат ителә. В.М.Азинның 28 нче дивизиясе сугышчылары 27 майда Тихие Горы, Бондюг, Карман, Макарово, Камайны, 1 июньдә Әгерҗене азат итә. Шулай ук Бөгелмә (13 май), Алабуга (29 май) азат ителә. 1919 ның ахырына колчакчылар губерна күләмендә тулысынча тар-мар ителә. Казан губернасы терр-ясендә Г.с. крәстияннәр күтәрелешен (к. «*Сәнәкчеләр» фетнәсе*) бастыру б-н тәмамлана.



Латыш укчылары төркеме Казан янында. 1918.

Г.с. елларында Казанда 49 пр-тие хәрби ихтыяҗлар өчен эшли. Хәрби уч-щеләр һәм курслар (к. *Тугызынчы Казан совет шәркый халыклар кавалерия курслары*, *Төрки-татарларның үзәк хәрби-сәяси мәктәбе*, *Уналтынчы үрнәк мөселман укчы командирлар курслары*) Кызыл Армия өчен хәрби резервлар әзерли. Казанда *Республика Запас армиясе* урнаша. Кызыл Армия составында Казан губернасында оештырылган батальоннар һәм полклар сугыша. Г.с. фронтларында Кызыл Армия командирлары Н.Еникиев, Һ.Маликов, Х.Мәүлетов, Й.Ибраһимов, М.Крымов, Я.Чанышев һ.б.ның хәрби таланты ачыла.

Чыг.: Директивы Главного командования Красной Армии (1917–1920): Сб. док-тов. М., 1969.

*Әд.:* За власть Советов. К., 1960; М у х а р я м о в М.К. Гражданская война в Татарии. К., 1969; Н е н а р о к о в А.П. Восточный фронт 1918. М., 1969; Л и т в и н А.Л. Гражданская война в Поволжье. 1918–1920. К., 1974; ш у л у к. Казань: время гражданской войны. К., 1991; Гражданская война в СССР: В 2 т. М., 1980–86; История Казани. К., 1991. Т. 1.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**«ГРАЖДА́НСКАЯ ВОЙНА́»** («Гражданнар сугышы»), кызылармиячеләр өчен көндәлек газета. Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе сәяси бүлеге органы. 1918–19 елларда нәшер ителә, беренче саны 1918 нең 27 августында Зөя шәһәрендә чыга. Ак чехлардан азат ителгәннән соң, газета беркадәр вакыт Казанда басыла. Аннары, фронт сызыгы күчеп йөргәндә, Бөгелмә, Уфа, Самара шәһәрләрендә һәм Себердә нәшер ителә. 1919 ның 11 гыйнварында исеме — «Наш путь», 1919 ның апрелендә «Красный стрелок» ка үзгәртелә. Күчмә басмаханәдә басыла, 1919 ның декабрендә Омск шәһәре хакимиятенә тапшырыла. Мөхәррирләре — В.Сорокин, В.Зазубрин, Я.Грунт һ.б. Газетада күренекле партия хезмәткәрләре һәм әдәбиятчылардан С.Гусев, П.Смидович, Л.Рейснер, Д.Бедный язмалары басыла. 1918 нең октябреннән чех язучысы Я.Гашек редколлегия әгъзасы була. Газетада Казанны алу сугышларының барышы һәм шәһәр хәлләре тулы яктыртыла.

1918 нең 29 август саны «Ни генә булмасын, Казан алынырга тиеш!» дигән гомуми баш астында чыга. Анда еш кына каршы як солдатларын Кызыл Армия ягына чыгарга чакырган өндәмәләр басыла. Газетаны листовкалар б-н бергә Казан өстенә һәм Халык армиясе урнашкан урыннарга самолётлардан ташлыйлар.

*Әд.:* Н а с ы й р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Л и т в и н А.Л. Казань: время гражданской войны. К., 1991.

**«ГРАЖДА́НСКАЯ ВОЙНА́»** («Гражданнар сугышы»), армия һәм эшче-крәстияннәр өчен көндәлек газета. ВЦИК нәшриятының хәрби бүлеге органы. 1918 елның 16 июленнән 4 августына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 17 саны чыга. Мөхәррире В.Н.Скачков. Актив авторлары арасында С.Бакинский, С.Борисов, К.Грасис, В.Засыпкина, Д.Зорин, В.Павлова, В.Скачков, Е.Ярославский була. Редакция изүче сыйныф вәкилләре б-н көрәшне көчәйтү фикерен яклый. Газетаның 1 нче саны: «Без бөтен дөньяны чолгап алган Бөек гражданнар сугышында хезмәт ияләренең җиңүе өчен көрәшәбез. Без бу сугышны бердәнбер изге, бердәнбер азатлык сугышы дип саныйбыз һәм барлык хезмәт ияләрен анда катнашырга чакырабыз!» — дигән өндәмә б-н чыга. Шул ук санда «Яшәсен гражданнар сугышы!» дигән мәкалә дә басыла. Рәсми бүлектә 1918 нең июненнән Казанда урнашкан Көнчыгыш фронт җитәкчелегенең эшчәнлеге яктыртыла, Көнчыгыш фронт гаскәрләре башкомандующие И.Вацетис, РВС әгъзалары һәм фронт штабы башлыгы имзалары б-н 40 тан артык боерык басыла. Газета Чех-словак фронтында контрреволюциягә каршы барган көрәштә М.Лацис җитәкчелегендәге Гадәттән тыш комиссиянең Казандагы эшчәнлеген игътибар үзәгендә тота. «Сәяси мәгълүмат» рубрикасында һәр көнне Көнчыгыш фронт армияләренең туплана баруы һәм сугыш хәрәкәтләре турындагы хәбәрләр басыла. «Контрреволюция белән көрәш» рубрикасында акгвардиячеләр тарафыннан алынган урыннардагы хәлләр турында материаллар бирелә. «Совет хакимиятенең эшләре», «Россия буйлап», «Провинция хәбәрләре», «Казан хәбәрләре», «Кызыл армия тормышы», «Эшчеләрнең кызыл лагеренда», «Ачлыкка каршы көрәш», «Чит илләрдә» рубрикаларында илдәге һәм чит илләрдәге иҗтимагый-сәяси тормыш вакыйгалары яктыртыла. Әдәби бүлектә В.Александровский, Б.Авксентьев, И.Григорьев, Ш.Касскин, Л.Рейснер, Г.Цыбулько һ.б. авторларның революцион шигырьләре басыла.

*Т.М.Насыйров.*

**ГРА́ЙФЕР** Валерий Исаакович (20.10.1929, Баку), нефтьче, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. канд. (1968), проф. (1995), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1966), СССРның Мактаулы нефтьчесе (1979). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1952). 1952–57, 1964–72 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсендә эшли. 1957–62 дә ТАССР ХХСның нефть һәм газ табу-эшкәртү бүлеге башлыгы, 1962–64 тә «Татнефтегаз» тресты башлыгы. 1972–92 дә СССР Нефть һәм газ сәнәгате министрлыгында (Баш план-икътисад идарәсе башлыгы, министр урынбасары, фәнни-техник совет рәисе урынбасары). 1992 дән «РИТЭК» (Россия инновацион җылылык-энергетика компаниясе) АҖ ген. директоры, бер үк вакытта, 2000 нән, «ЛУКОЙЛ» АҖнең директорлар советы рәисе. ТАССР ЮС депутаты (1968–72). Нефть чыгару производствосын яңача җиһазландыруы өчен Ленин премиясе бирелә (1976).

**ГРА́ЙФСВАЛЬД КОРЫЛТАЕ́**, 1944 елның 3–5 мартында Грайфсвальд шәһәрендә (Германия) уздырыла. 200 гә якын делегат (Икенче бөтендөнья сугышында фашистлар Германиясе ягында булган легионер татарлар, чуаш, башкорт, мордва, удмурт һәм марилар) һәм Вермахтның хәрби һәм гражданнар оешмаларыннан рәсми вәкилләр (ген. фон Хайкендорф, проф. фон Менде һ.б.) катнаша. Җитәкчеләре — Шәфи Алмаз, Гариф Солтан һ.б. Максаты: 1942 нең ахыры — 1943 нең башыннан яшәп килгән *Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлеген* рәсми рәвештә игълан итү. Конгресста Берлекнең *Милләт Мәҗлесе* варисы булуы танnetwork, татар милли хәрәкәтенең якындагы бурычлары тикшерелә, нигездә, Г.*Исхакыйның* Гражданнар сугышы елларында ук игълан иткән идеяләрен кабатлаган программа кабул ителә. Милли хәрәкәтнең төп максаты итеп бәйсез «Идел-Урал» дәүләтен төзү билгеләнә.

*Әд.:* Г и л я з о в И.А. Курултай в Грайфсвальде... // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ГРАММА́ТИК КАТЕГО́РИЯ**, бертөрле мәгънәдәге грамматик формаларның бер-берсенә каршы куелган системасы. Һәр Г.к.нең ике ягы бар: эчке ягы — грамматик мәгънәсе һәм тышкы ягы — *грамматик формасы*. Бу системада төп билге — гомуми мәгънә белдерү, мәс., заман, зат-сан, юнәлеш һ.б. гомуми мәгънәсе. Ул аерым заман, зат, сан, юнәлеш һ.б. категорияләрнең мәгънәләр һәм аларга туры килә торган формалар системасын берләштерә. Г.к.нең төп билгесе — грамматик мәгънәнең грамматик форма б-н бердәмлегеннән гыйбарәт. Г.к. морфология материалына нигезләнеп өйрәнелә, шуңа күрә аерым грамматикаларда ул «морфологик категория» дип тә бирелә. Татар телендә Г.к.ләр сүзләрне төрләндерәләр, ягъни Г.к. компонентлары бер үк сүзнең, аның парадигмасындагы төрле формалары рәвешендә генә бирелә (алма-алма**ның**-алма**га**; барды-барды**м**-барды**ң**). Г.к.нең бөтен системасы берничә (икедән дә ким булмаган) формадан гыйбарәт (мәс., китап-китап**лар**). Әмма күп очракта ул гомуми (категорик) мәгънә б-н берләштерелгән күп компонентлы парадигмалар рәвешендә дә белдерелә (фигыльдә заман системасы, юнәлеш, зат, сан, килеш категорияләре һ.б.).

*Әд.:* Т у м а ш е в а Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1964; Татар грамматикасы. К., 2000. Т. 2; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

*Ф.М.Хисамова.*

**ГРАММА́ТИК ФО́РМА**, грамматик мәгънәнең телдә белдерелү чарасы. Г.ф. грамматик мәгънә һәм аны белдерүче чаралар бердәмлегеннән гыйбарәт. Грамматик мәгънәләрне белдерә торган чараларны: 1) *аффикслар*, 2) *басым* үзенчәлеге, 3) редупликация (кабатлаулар), 4) *ярдәмлек сүзләр* кебек төрләргә бүлеп карыйлар. Сүз төрләнеше хас телләрдә, ш.и. татар телендә дә, билгеле бер сүз төркеменә караган сүзләрнең даими төрләнеше Г.ф. дип атала. Сүз төрләнеше морфологик мәгънәләр җыелмасына яисә шундый бер мәгънәгә ия була (мәс., исемнең баш килештәге күплек сан формасы, фигыльнең хәзерге заман 1 зат күплек формасы, сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе формасы). Билгеле Г.ф.да килгән конкрет сүз — сүз формасы дип атала.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 2000. Т. 2; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

*Ф.М.Хисамова.*

**ГРАММА́ТИКА** (грек. grammatikḗ grámma — хәреф, язылыш), 1) тел төзелеше, ягъни тел формалары, сүз ясалышы һәм сүз үзгәреше ысуллары системасы; 2) *тел белеменең* тел төзелешен, аның оешуын, категорияләрен һәм аларның үзара мөнәсәбәтен өйрәнә торган тармагы; 3) аерым грамматик категорияләрнең яисә лексик-грамматик төркемнәрнең функцияләре (мәс., исем. Г.сы, фигыль Г.сы һ.б.). Дәреслекләрдәге һәм уку ярдәмлекләрендәге грамматик кагыйдәләр җыелмасы ш.у. грамматика дип атала.

Грамматик төзелешне өйрәнгәндә Г. тел б-н эш итә, телне статик хәлдә анализлый, әмма һәрвакыт сөйләмгә мөрәҗәгать итә, телне динамик хәлдә өйрәнә. Сүзнең мәгънәле кисәкләренә караган гомуми үзенчәлекләрен Г.ның *морфемика* бүлеге өйрәнә. Морфемаларның сөйләмдә кулланылышы (хәрәкәте) вакытында аларның составында бара торган фонологик һәм просодик үзгәрешләрне өйрәнү б-н *морфонология* шөгыльләнә. Яңа сүзләр ясалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүз структурасы системасын *сүз ясалышы* бүлеге анализлый. Сүзнең абстракт грамматик мәгънәсенә һәм төрләренә бәйле барлык күренешләрне *морфология* бүлеге өйрәнә. Җөмлә һәм сөйләм төзелешен *синтаксис* бүлеге тикшерә. Шулай итеп, Г. бер-берсе б-н үзара бәйләнгән биш бүлектән тора: морфемика, морфонология, сүз ясалышы, морфология һәм синтаксис. Аларның һәрберсенең үз өйрәнү объекты, максатлары һәм бурычлары бар. Мәсәлән, морфемика Г.ның башка бүлекләре өчен кереш хезмәтен үти, ул *фонетика* б-н бәйле; сүзнең семантикасын өйрәнгәндә лексикология дә морфемика нәтиҗәләренә таяна. Морфонология фонетика, фонология, морфология, синтаксис арасында тора, морфемика мәгълүматларыннан файдалана. Сүз ясалышы лексикология һәм морфология мәсьәләләрен берләштерә. Морфология ш.у. Г.ның башка бүлекләре һәм лексикология б-н дә тыгыз бәйләнештә тора. Синтаксис башка бүлекләрнең нәтиҗәләрен туплый һәм, аларга нигезләнеп, сөйләмнең төп берәмлеге — җөмлә аша сөйләмнең структур төзелешен өйрәнә. Г. теләсә нинди грамматик күренешне эчтәлек һәм аны белдерүче чара ягыннан өйрәнә, ул һәрвакыт грамматик мәгънә һәм грамматик форма б-н эш итә. Тел-

нең грамматик төзелеше — тарихи категория, ул һәрвакыт хәрәкәттә, үсештә һәм тел үсешенең гомуми законнарына буйсына.

Татар грамматикасы фәне нигезләре гарәп Г.сына караган хезмәтләргә барып тоташа. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан татар Г.сы формалашуга рус теле белеме дә йогынты ясый. Татар теле Г.сының фәнни эшкәртелүе С.*Хәлфиннең* «Әлифба. Татар теле әлифбиенең тәхкыйк язылган хәрефләре һәм иҗекләре» (1778) хезмәте б-н бәйле. Аннан соң И.*Гиганов* (1801), И.*Хәлфин* (1809), А.*Троянский* (1814), А.*Казимбәк* (1839), М.*Иванов* (1842) һ.б. хезмәтләре барлыкка килә. 19 йөз татар Г.сында гарәп һәм рус грамматик традицияләре үзара яраша, бу күренеш сүз төркемнәренә бүленештә, җөмлә кисәкләрен аеруда, килеш б-н төрләнүдә, сүзләр бәйләнешен тасвирлауда күзәтелә. Татар Г.сын камиллләштерүдә М.*Мәхмүдов*, К.*Насыйри*, Г.*Фәезханов*, Һ.*Максуди*, Ш.*Иманаев*, Г.*Ибраһимов*, Г.*Нугайбәк*, Җ.*Вәлиди*, Г.*Алпаров* һ.б. хезмәтләре мөһим роль уйный. Аларда Г. кагыйдәләрен татар теленең үзенчәлекләре б-н бәйләп төзүгә омтылыш ясала. 1920 еллардан башлап барлык татар Г.лары диярлек сүз төркемнәрен, җөмләнең грамматик бүленешен тасвирлаганда рус Г.сында кабул ителгән принципларга таяна. 1930 еллардан татар Г.сы өлкәсендә төп фәнни-тикшеренү юнәлешләрен билгеләгән В.А.Богородицкий, Л.Җәләй, В.Н.Хангилдин, М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов һ.б. хезмәтләре дөнья күрә. Татар Г.сы үсешендәге яңа этап М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, В.Х.Хаков, Х.Р.Курбатов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов, И.Н.Низамов һ.б. хезмәтләре б-н билгеләнә. Соңгы елларда сөйләмнең төп берәмлеге буларак җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше, семантик структурасы, текст синтаксисы һәм стилистикасына караган тикшеренүләр алып барыла. Грамматик тикшеренүләр төрле тасвирлама хезмәтләрдә чагылыш таба. Традицион рәвештә аларны фәнни, тасвирлама һәм норматив төрләргә аералар. Фәнни Г. өлкәсенә тел төзелешен үсештә өйрәнүче, яки аны үткән дәверләрнең аерым баскычларында карый торган тарихи Г. керә. Бу юнәлештә Л.Җәләй, В.Х.Хаков, Ф.С.Фасиев, И.Г.Абдуллин, Ф.М.Хисамова, Ф.С.Хәкимҗанов һ.б. эшли.

Фәнни Г.га ш.у. татар һ.б. телләрдәге, ешрак рус телендәге (К.Насыйри, М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов, Г.С.Әмиров, К.З.Зиннәтуллина, Ә.М.Ахунҗанов, Л.К.Бәйрәмова һ.б. грамматикалары), уртак һәм аермалы якларны тасвирлый торган контрастив Г. да керә. 1992–93 елларда хәзерге татар әдәби теленең фонетик һәм грамматик төзелешен тасвирлаган өч томлык академик «Татар грамматикасы» басмасы (ТР Дәүләт бүләге, 1994) дөнья күрә.

*Әд.:* Иманаев Ш. Татар теленең нәхүе вә сарыфы. К., 1910; Ибраһимов Г. Татар сарыфы. К., 1911; Нугайбәк Г. Төрлек. К., 1911; Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. К., 1919; Алпаров Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы. К., 1925; Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. Морфология һәм синтаксис. К., 1959; Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.Ә. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1972; Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле: Морфология. К., 1978; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 1994; Татар грамматикасы: 3 томда. М.-К., 1998–2002; Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. К., 1934; Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. К., 1963.

**ГРАН Д.М. БАСМАХАНӘСЕ́,** Казанда. Самара мещаны Давид Маркович Гран милке. 1900 елның 21 гыйнварында ачыла, 1916 га кадәр эшли. Штатта 7 кешедән алып (1902) 45 кешегә кадәр (1915) хезмәткәр исәпләнә. Казан губернасы өязләренең земство идарәләре хисаплары (1904), «Казанская газета» (1907, 1908, 1912, 1914), «Земская неделя» ж-лы (1915), Казан телефон челтәре әбунәчеләре исемлеге (1907, 1908, 1912, 1914), «Казан ветеринария институты гыйльми язмалары» ж-лы («Учёные записки Казанского ветеринарного института» 1908, 1909, 1912, 1914), «Казан халыкара күргәзмә күрсәткече» («Указатель Казанской международной выставки» 1909), Таҗетдин Ялчыголның «Рисалә-и Газизә» китабы (1912), «Цивиль земство җыелышлары карарлары» («Постановления цивильских земских собраний» 1913), «Казан яхта клубы уставы» («Устав Казанского яхт-клуба» 1915) һ.б. басыла.

**ГРАН** Моисей Маркович (1.10.1867, Самара ш. — 14.9.1940, Мәскәү), санитария табибе, сәламәтлек саклау эшлеклесе. 1892 елда ун-т тәмамлаганнан соң, Бөгелмә өязендә земство-санитария эшендә һәм земство идарәсендә. 1908 дән Петербург сан.-эпидемиология хезмәтен җитәкли, 1918 дән РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тының сан.-статистика бүлеге җитәкчелегендә Идел буенда ачлыктан интегүчеләргә ярдәм, сугышның санитария нәтиҗәләрен өйрәнү һәм аларны бетерү комиссиясен оештыра. 1925 тән 1 нче Мәскәү ин-тында. 1928–32 дә Казан мед. ин-тында (хәзерге Казан мед. ун-ты) җәмәгать-көнкүреш гигиенасы каф. мөдире. Хезмәтләре земство һәм җәмәгать-көнкүреш медицинасы, санитария статистикасына, ачлык б-н көрәшү, халыкның сәламәтлеге торышын өйрәнүгә карый.

Хезм.: О присасывательной деятельности сердца. К., 1889; Психометрические исследования у здоровых и больных. К., 1892.

**ГРАН-ТА́У**, Чүри-Бураш урман-даласы, Фәйзуллина сөзәклекләре, Апас р-ны терр-ясендәге ландшафтлы табигать истәлеге. 1991 елда билгеләнә. Мәйданы — 162 *га*. Үләмә елгасы үзәнлегенең уң як сөзәклегендәге урман массивын һәм аңа чиктәш болын даласы кишәрлеген били. Аның терр-ясендә сирәк очрый торган үсемлек төрләре: чын башмакчәчәк, киң яфраклы йод үләне, кызыл серкәбаш һ.б. үсә. Сөзәклекләр астыннан чишмәләр агып чыга. Объект С.И.Коржинский (1878), С.Я.Фәйзуллина (1976) тарафыннан өйрәнелә.



Гран-Тау.

*Әд.:* Файзуллина С.Я.К вопросу о происхождении лугов и луговых степей Татарского Предволжья. О сукцессионных сменах растительного покрова Татарского Предволжья // Научные тр. Марийского ун-та. 1976. Вып. 1.

**ГРАНАТЛА́Р** (лат. granatum — гранат, гранат агачы җимешенең төсеннән алынган), силикатлар классындагы минераллар төркеме. Төрле төсләрдә. Катылыгы 6,0–7,5. Пыяласыман ялтырый. Тыгызлыгы 3,5–4,3 *г/см³*. Г. ның борынгы русча атамасы — «вениса»,



Гранат. Көньяк Урал.

Уралның яшел төстәге Г.лары — «Урал зөбәрҗәте», Көньяк Африканың кызыл Г.лары — «Кап рубины» дип атала. Г. үз эченә 15 минералны ала: пироп (алмаз иярчене), альмандин, гроссуляр һ.б. Гадәттә, магматик яисә метаморфик килеп чыгышлы. Татарстан терр-ясендә, башлыча, кристаллик нигез токымнарында ачыкланган (альмандин, спессартин һ.б.). Дүртенчел аллювиаль утырмаларда (ш.и. республиканың көнбатышында) пироп очрый; ул кызыл төстәге кристаллардан тора, катылыгы 7–7,5. Катылыгы югары булу сәбәпле, абразив материал буларак, приборлар төзүдә кулланыла. Үтә күренмәле һәм ярым үтә күренмәле Г. — ярым кыйммәтле ташлар (кызыл пироплар, сары гессонитлар, яшел уваровитлар һ.б.). Таралмалардан һәм төп чыганаклардан алына. Яшел Г.ны ювелир әйберләр эшләү өчен синтетик юл б-н алалар.

*Әд.:* Романович И.Ф. Минеральное сырьё. Абразивы: Справ. М., 1999.

**ГРАНИ́Т** (итал. granito — лат. granum — бөртек), бөтен кристаллы, интрузив яки сирәк очракларда аксыл төстәге ачы метасоматик тау токымы; башлыча, кварцтан (30–40%), кыр шпатыннан (ортоклаз, микроклин, ачы плагиоклаз) (60–70%) һәм төсле минералдан (биотит, мусковит, роговая обманка) тора. Төсе соры, ак, ал, сары, яшел. Уртача хим. составы (% ларда): $SiO_2$ — 69,92, $Al_2O_3$ — 14,78 һ.б. Тыгызлыгы 2,53–2,72 *г/см³*. Г.ның 10 нан артык төре билгеле. Г.ның интрузияләре яше — архейдан алып кайнозойга кадәр. Архей Г.ы метаморфик токымнар б-н бәйләнгән, аерым алганда, Татарстан терр-ясендә кордиерит — гранатлы Г., гнейс-

лар һ.б. токымнар б-н бергә кристаллик нигезне төзи. Эре гранитлы 4 блок билгеле: Бакалы (көнчыгышта), Сула (көньяк-көнчыгышта), Вятка буе (төньякта), Зөя (төньяк-көнбатышта); алар тирәндәге сындырылмалар б-н чикләнә. Блоклар төрле токымнардан төзелгән. Мәсәлән, Бакалы массивында плагиогранит (сыек-соры төстә, уртача бөртекле) һәм микропертит гранит (сыек алсу-соры төстә, эре бөртекле) өстенлек итә. Яше 1990 нан алып 2710 млн. елга кадәр. Г.ларда төрле руда чыганаклары (Pb, W, Mo, Cu һ.б.) очрый. Төзелештә, тышлау материалы буларак һәм, кислотага чыдам булганлыктан, пыяла эретүдә, юка керамика эшләүдә һ.б. тармакларда кулланыла.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996; Горная энциклопедия. М., 1994. Т. 2.

*Ю.В.Сементовский.*

**ГРАНУЛИ́Т** (лат. granulum — бөртекчек), сыек төстәге, вак бөртекле төзелешле һәм гнейс текстуралы матеморфик тау токымы; югары темп-ра (700 °С тан артык) һәм басым (6–10·10⁸ Па) шартларында формалашкан. Ортоклаздан, плагиоклазлар, кварц, гранат (пироп) һ.б. минераллардан тора. Татарстан терр-ясендә фундаментның ныграк метаморфланган участокларын хасил итә; аның чикләрендә 4 гранулит-гнейс блок (көньяк-көнчыгышта) һәм гранулит-яшел ташлы өлкә (Казан буе); алар тирәндәге сындырылмалар б-н чикләнә. Блоклар архей яшендә. Г.лар төзелеш ташы әзерләүдә кулланыла.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996.

**ГРА́СИС** Карл Янович (11.6.1894, Лифляндия губ. Цесис өязе — 1937), революцион хәрәкәт эшлеклесе. Гражданнар сугышында катнаша. Вольмар укытучылар семинариясендә, соңыннан Николай исем. гимназиядә (Рига ш.) укый. 1912 елда А.Л.Шанявскийның халык ун-тына (Мәскәү) укырга керә. 1909 дан Латыш с. -д. эшчеләр партиясе әгъзасы, аның меньшевиклар тоткан юнәлешен яклый; 1917 нең маеннан РСДРП(б) әгъзасы. 1915 тә революцион эшчәнлеге өчен башта Харьковка, аннан соң Казанга, соңрак Чабаксарга сөрелә. 1917 нең Февр. рев-циясеннән соң Эшче һәм солдат депутатларының Чабаксар советы рәисе, өяз милициясе башлыгы, «Чебоксарская правда» г-тасы мөхәррире. 1917 нең июлендә Казанда кулга алына. Азат ителгәннән соң, РСДРП(б)ның Казан ком-тын җитәкли. Казанда 1917 нең Окт. короллы күтәрелеше җитәкчеләренең берсе. 1917 нең октябрь ахыры — ноябрь башында *Казан революцион штабын* җитәкли. 1918 нең җәендә Көнчыгыш фронтның Революцион хәрби советы сәяси бүлегендә: нәшрият мөдире, «Гражданская война» г-тасы мөхәррире. Аннан соң Казан губернасында, Сембер һәм Түбән Новгород губерналары өязләрендә контрреволюция һәм саботаж б-н көрәш буенча гадәттән тыш комиссар итеп билгеләнә. 1918 нең октябрендә Каспий-Кавказ фронтына җибәрелә. 1919 ның апреленнән янәдән Көнчыгыш фронтта. 1919 ның көзендә Республика запас армиясенә күчерелә. Соңыннан Украина ССР, РСФСР Мәгариф халык комис-тларында һәм РСФСР Дәүләт нәшриятында эшли. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: К национальному вопросу: Сб. статей. К., 1918; Неизбежное будущее. Критические заметки. 1917 год. К., 1918; В огне войны и революции. Хар., 1924.

*Әд.:* К и р и л л о в В. Карл Янович Грасис. Чебоксары, 1969.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ГРАСС** Людвиг Иеронимович (12.8.1841, С.-Петербург — 11.6.1896, Казан), хокук белгече, икътисадчы, тайный советник (1896). Дворяннар нәселеннән. Петербург ун-тын тәмамлый (1863). 1863–66 елларда Петербург җинаять эшләре мәхкәмәсе палатасының һәм Петербург өязе 1 нче участогының мәхкәмә тикшерүчесе ярдәмчесе. 1866–68 дә Рыбинск, 1868–69 да Курск округ мәхкәмәләре әгъзасы, 1869–72 дә Таганрог, Симферополь, Владимир, Тула округ мәхкәмәләре прокуроры. 1872–75 тә Петербург мәхкәмә палатасы прокуроры иптәше (урынбасары). 1875–94 тә Казан округ мәхкәмәсенең, 1894 тән Казан мәхкәмә палатасының җинаять эшләре департаменты рәисе. Хезмәтләре икътисадка, криминалистикага, мәхкәмә психиатриясенә карый. «Авыл хуҗалыгы чәчүлекләрен иген уңмаудан иминиятләштерү» («Страхование сельскохозяйственных посевов от неурожая») (1892) хезмәте авторы. Казан ун-ты каршындагы юридик җәмгыять рәисе.

Х е з м.: Психопатическая конституция как самостоятельный повод невменения. К., 1886; Записка об учреждении общества для страхования сельскохозяйственных посевов от неурожаев. К., 1890.


*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Ч. 1; В е н г е р о в С.А. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. П., 1915. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ГРА́ФИКА** (грек. graphikē̃, gráphō сүзеннән — язам), сынлы сәнгатьнең *рәсемне*, *гравюраны* һәм аларның барлык юнәлешләрен үз эченә алган төре. Башта «Г.» төшенчәсе фәкать язу һәм *хаттатчылык* б-н бәйләп кулланыла. Максаты ягыннан Г. түбәндәге төрләргә аерып карала: станлы Г., китап Г.сы, газета-журнал Г.сы, *плакат*, *экслибрис*, гамәли Г. (график дизайн төрләре). Электрон системалар ярдәмендә башкарылып, экранда чагылдырылучы яисә принтерда басылучы компьютер Г.сы аның яңа төре буларак барлыкка килә. Г. жанрлары нәкышьнең төп жанрлары б-н тәңгәл килә; *архитектура графикасы* — үзенчәлекле жанр. Шәрекъ эстетик системаларында әһәмиятле урын тотучы шрифт, хаттатчылык, *эпиграфика* сәнгате Г.ның мөстәкыйль өлешен хасил итә.


Татарстан сәнгатендә Г. гарәп язуы нигезендәге хаттатчылыкның урта гасырлар традицияләренә барып тоташа, Казан ханлыгы чорында югары дәрәҗәдә үсеш кичерә. 16 йөзнең икенче яртысыннан Г. борынгы рус сәнгате традицияләренең төрләре һәм жанрлары (икона язу, лубок, китап ксилографиясе һ.б.) б-н баетыла. 18 йөз уртасыннан дәүләт уку йортларында, һөнәри сәнгать остаханәләрендә, Л.Д.Крюков, В.С.Турин, Ф.П.Травкиннарның шәхси мәктәпләрендә рәсем предмет буларак укытыла (ш.у.к. *Сәнгать белеме*). 19 йөздә китап, журнал, альбом Г.сы, бигрәк тә аның күренеш пейзажы жанры күтәрелеш кичерә (Э.Т.Турнерелли, В.С.Турин, А.Н.Раковичның Казан күренешләре, А.В.Котельников, Н.Н.Кафтанников, П.Т.Табуре, Ф.Ткачук, Л.Калмерның график иллюстрацияләре, Ф.Залесскийның көндәлектәге рәсемнәре). 19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда Коръән *сурәләре* һәм мөселманнарның җәмигъ мәчетләре сурәтләнгән, татар осталары тарафыннан башкарылган график эстамп-шәмаилләр басыла. Беренче татар проф. рәссамы, каллиграфия һәм бизәк төшерү остасы Г.Мәхмүдов була. Г.ның үсеше һәм бу өлкәдәге осталар әзерләү өчен ныклы нигез *Казан сынлы сәнгать мәктәбендә* салына. Казан рәсем мәктәбе барлыкка килүдә Н.И.Фешинның педагоглык һәм иҗади эшчәнлеге хәлиткеч йогынты ясый. Мәктәпнең Ю.И.Тиссен җитәкчелек иткән гравюра бүлегендә классик гравюра һәм офорт укытыла (ш.у.к. *Гравюра*). Архит-ра Г.сы архит-ра бүлегендә укыту программасының бер өлеше булып тора (к. *Архитектура графикасы, Архитектура белеме*). Мәктәп эшчәнлеге нәтиҗәсендә Г. рәссамнарны сәнгатьнең мөстәкыйль төре буларак үзенә җәлеп итә. К.К.*Чеботарёв*, А.Г.*Платунова*, А.М.Родченко, В.Ф.Степанова, И.А.Никитин һ.б. укучыларның башлангыч иҗатында символизм стилендәге рәсемле Г. чагылыш таба. 20 йөз башында рәсемле Г. рус һәм татар телләрендә нәшер ителүче «Жизнь», «Волжские дали», «Аң», «Ак юл» һ.б. ж-ллар битләрендә, беренче милли рәссамнар — графиклар иҗатында (Х.*Акчурин*, Ш.*Таһиров*, М.*Идрисов*, Г.*Камал*, Г.Гомәров һ.б.) киң кулланыла. 1920 елларда Г. сәнгатенең характерын Н.С.*Шикалов*, И.Н.*Плещинский*, Ф.С.*Быков* җитәкчелегендәге Казан архитектура-сәнгать остаханәләренең графика бүлеге һәм график-рәссамнарның «*Всадник*» берләшмәсе эшчәнлеге билгели. Җәмгыятьнең социаль-сәяси ихтыяҗларына җавап рәвешендә сәяси плакат, китап һәм газета-журнал графикасы күтәрелеш ала, аларның стилистикасына Пролеткульт һәм ТатЛЕФ идеологиясе үз эзен сала. «Всадник» рәссамнары эстамп сәнгате, иллюстрацияләнгән аз тиражлы китап, Г.ның кече формалары (экслибрис, נаширлек маркасы һ.б.) үсешенә өлеш кертәләр. Профессиональ графиклардан тыш, башка юнәлештә эшләүче рәссамнар да сәнгатьнең бу төренә еш мөрәҗәгать итә: К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, А.Н.*Коробкова*, В.В.*Кудряшов*, М.В.*Барашов*, Н.М.*Сокольский*, Г.А.*Козлов* һ.б.). Татар профессиональ графиклары Х.Ә.Алмаев, О.В.Арсланов, Ф.Ш.*Таһиров*, Д.Н.*Красильников*, Ш.Н.Мөхәммәтҗанов, Б.Г.Йосыпов, Җ.Г.*Булат* һ.б. иҗатында төп урынны китап һәм журнал Г., гарәп һәм соңрак латин алфавитларының конструктивизм стилендәге тәҗрибәләре алып тора. 1930 елларда Г. үсешенә *А.В.Луначарский исем. полиграфия мәктәбе* һәм П.М.*Дульскийның* сәнгатьле полиграфия өлкәсендәге педагоглык эшчәнлеге мөһим этәргеч бирә. Вакытлы матбугатта («Азат хатын», «Октябрь яшьләре» ж-лларында, «Кызыл

















**Графика**. 1. Э.Т у р н е р е л л и. «Крепостьтагы кафедраль собор». Сепия. 1830 еллар; 2. «Китабе диван Ризаи» китабындагы унван. Кәгазь, алтын, кара. Басма. 1840; 3. Н.И.Ф е ш и н. Тышлык эскизы. Тушь, акварель, сепия. 1910 еллар; 4. И.Н.П л е щ и н с к и й. «Бүлмәдә». Линогравюра. 1922; 5. К.К.Ч е б о т а р ё в. «Бию (татар кешесе)». Фанерадагы гравюра. 1923; 6. Ф.Ш.Т а һ и р о в. «Көннәр йөгергәндә». Г.Кутуй китабы тышлыгының эскизы. Тушь, гуашь. 1924; 7. А.Н.К о р о б к о в а. «Авыл яшьләре» журналы тышлыгының эскизы. Тушь, гуашь. 1926; 8. Х.Г. Я к у п о в. «Әсир немецлар». Карандаш. 1944; 9. Х.Г.Я к у п о в. «Тапкыр егет». Татар әкиятенә иллюстрация. Гуашь. 1959; 10. С.М.К у л ь б а к а. «Очыгыз, күгәрченнәр!». М.Җәлил шигыре мотивлары буенча. Линогравюра. 1961; 11. Б.У р м а н ч е. «Шүрәле». Г.Тукайның шул исемдәге поэмасы буенча. Тушь. 1980; 12. Э.Г.С и т д ы й к о в. «Колхоз ветераннары». Төсле линогравюра. 1965; 13. В.В.К а р а м ы ш е в. «Су анасы». Г.Тукай әкиятенә иллюстрация. Акварель, гуашь. 1990 еллар; 14. Н.И с м ә г ы й л е в (Нәкъкаш). Илдар Ханов туграсы. Тушь. 1997; 15. Г.Л.Э й д и н о в. «Китү». «Маркесны укыганда» сериясеннән. Тушь. 1999.

Татарстан» г-тасында һ.б.), ш.у. китап иллюстрацияләү өлкәсендә Г.Я.*Мусин*, М.З.*Кәримов*, Б.М.*Әлминов*, А.А.Хохряков, Н.М.Сокольский һ.б. актив эшли. Сатирик Г. «*Чаян*» журналы рәссамнары Г.Я.Поляков, П.М.Новичков, И.Е.*Бобровицкий* иҗатында көчле үсеш ала. Бөек Ватан сугышы елларында Г. сәнгатендә натурадан ясалган рәсем һәм сәяси плакат жанры өстенлек итә. Х.Г.*Якупов*, М.Г.*Усманов*, А.М.Родионов, Җ.Г.Булат, Г.Д.Мелентьев, В.А.Попов, М.И.Семёнов, А.Г.Хуторов һ.б. зур әһәмияткә ия булган фронт рәсемнәре серияләре иҗат итәләр. Бу темага ш.у. Казанга эвакуацияләнгән графиклар — Б.А.Дехтерев, В.Б.Корецкий, В.А.Бадюль рәсемнәр ясый. Р.Ф.Сәйфуллин, Б.М.Әлминов, И.Е.Бобровицкий, Э.Б.*Гельмс*, Н.М.Сокольский, А.А.Прытков һ.б. типография һәм трафаретлау юлы б-н башкарылучы плакат жанрында («Окна сатиры») эшлиләр. Сугыштан соңгы елларда Г. сәнгатенә Татарстан китап нәшриятының бизәлеш редакциясе һәм анда графикларның гына түгел, нәкышьче рәссамнарның да эшләве уңай йогынты ясый. Б.М.Әлминов, М.К.*Мавровская*, М.Г.Усманова, Л.Г.*Фәттахов*, И.С.Хантимеров, Х.Г.Якупов, Р.М.Якупова, Н.В.Родионованың акварель, гуашь, тушьлы рәсем техникасы б-н милли фольклор, хәзерге заман татар әдәбияты әсәрләренә иҗат ителгән иллюстрацияләр серияләренә станлы нәкышь трактовкасы хас. Х.Казаков линография юнәлешендә портретлар сериясе тудыра. Эстамп сәнгатенең яңарышы 1960 елларда башлана. Татарстан сәнгать дөньясына илнең төрле югары уку йортларында белем алган рәссамнар буыны килеп кушыла (И.Я.*Язынин*, С.М.*Кульбака*, И.К.*Колмогорцева*, В.В.*Карамышев*, Э.Я.*Зарипов*, Э.Г.*Ситдыйков*, В.А.*Попов*, Р.Ә.Килдебәков, Л.А.Потягунин, Л.М.Кольюранд, Т.А.*Зуева*, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов*, И.К.*Әхмәдиев*, В.Б.Зелинский һ.б.). Алар, жанрлар һәм темалар колачын киңәйтеп, монотипия, пастель, акварель, гуашь, күмер, тушь, фломастер б-н язу техникасында эшләп, агачта, металлда, линолеумда, катыргыда гравюра сәнгатен үстерәләр, аны стиль тенденцияләре һәм иҗат манералары б-н баеталар. Тарихи-революцион, героик-гражданлык, әдәби, фольклор, көнкүреш, портрет, пейзаж темаларына аерым игътибар бирелә, сюжетлы-тематик һәм репортаж рәвешендәге әсәрләр иҗат ителә. 1960–70 елларда Г.ның сурәтләү теленә киң форматлылык, милли бизәкләр һәм этнографик мотивларны киң куллану, әсәргә плакат рәвеше һәм монументальлек төсмере бирүче гомумиләштерелгән формалар хас, бу күренеш яшьләрнең өлкән буын рәссамнары йөз тоткан «натуралы» караш юлына кануни реакциясе буларак бәяләнә. Шундый ук тенденцияләр китап Г.сында өстенлек итә. Бу өлкәдә Э.Я.Зарипов, Б.И.*Урманче*, Т.Г.Хаҗиәхмәтов, И.К.Әхмәдиев һ.б. графика теленең милли формаларын тудыралар. «Чаян» журналы рәссамнары Л.Х.*Насыйров*, С.Я.Насыйров, Ю.А.*Денисов*, Л.Г.Бочков, И.К.Әхмәдиев, В.П.Игнатьев, Э.Н.Дышаев, Э.Б.Гельмс һ.б. иҗатында сатирик Г. активлаша.

ТАССР Рәссамнар берлеге каршында «Агитплакат» остаханәсенең оештырылуы Г. жанры үсешенә этәргеч бирә. И.Л.Язынин, И.К.Колмогорцева, И.К.*Киселёва*, Л.Я.*Елькович*, И.Г.Закиров (Н.Х.Сәлахиев б-н берлектә) һ.б. тарафыннан плакат серияләре эшләнә. 1980–90 елларда Татарстан рәссамнары Г.га сирәк мөрәҗәгать итәләр. Г. әсәрләрендә иҗтимагый тормыш, гражданлык темалары юкка чыга, рәссамнар образлардагы метафорик ишарәләрне, сурәтләү теленең зәвыгын, башкару техникасы осталыгын игътибар үзәгенә алалар (Н.У.*Әлмиев*, Ю.М.Каспина, В.П.*Аршинов*, В.И.Ильин, В.Р.Иванов, М.М.Кузнецов һ.б.). 1980 елларның 2 нче яртысыннан станлы графикага игътибар арта, рәссамнар яңа сәнгать алымнарына, образлы сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәләр, үз иҗатларында жанр композицияләре, пейзажлар, натюрмортлар, төрле стиль юнәлешләрендә, асылда, *постмодернизм* юнәлешендә тематик һәм абстракт композицияләр тудыралар (Ю.Л.Бердников, В.А.Вязников, Р.Х.Гайсин, Л.Е.Евграфова, Е.С.Ермолина, Ә.М.Закиров, Ә.Р.Ильясова, В.А.Нестеренко һ.б.). Т.А.Зуева, М.И.Мавровская, И.К.Колмогорцева һ.б. тарафыннан гравюрада һәм рәсемдә, башлыча, Казан, Алабуга, Болгардагы тарихи истәлекләрнең архитектур пейзажлары тудырыла. Китап Г.сы өлкәсендә Б.А.Гыйльванов, В.Е.Булатов, Р.Г.*Шәмсетдинов*, И.И.Нәфиев, Н.Т.*Хаҗиәхмәтов*, Ф.Ш.*Хәсьянова*, Г.Л.*Әйдинов* һ.б. актив эшли. Рәссам-графикларның көчле коллективлары Чаллыда, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Лениногорск һ.б. шәһәрләрдә оеша (Б.Б.Грабенко, Г.А.Иванов, А.И.Максютин, Б.Ш.Мәрданов, Р.З.Мөхәммәтдинов, М.А.Покалёв, Д.К.Садретдинов, Р.В.*Сәләхетдинов*, Ю.Г.Свинин, В.И.Сынков, А.А.Терентьев, А.В.Тугаринова, А.В.Халдеев, М.Г.*Шәйдуллин* һ.б.). Хаттатчылык һәм шәмаилләр ясау сәнгате Н.Ф.*Исмәгыйлев*, Р.Шәмсутов, Ф.Г.Гыйрфанов, В.Попов, Р.С.Мөхәммәтҗанов һ.б. иҗатында яңа сулыш ала.

*Әд.:* Дульский П.М. Книга и её художественная внешность (В связи с Казанским книгопечатанием). К., 1921; шул ук. Актуальная графика. К., 1935; Елькович Л.Я. Сатирическая графика художников Татарии. М., 1963. Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времен до 1917 года. М., 1987; Ключевская Е.П. У истоков Казанской графики // Художник. 1990. № 6; Валеева Д.К. Искусство Татарстана (XX век). К., 1999; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. 1960–1999-е годы. К., 2001.

*Е.П.Ключевская.*

**ГРА́ФИКА** (лингв.), 1) теге яки бу телнең язу чаралары җыелмасы; 2) тел белеменең графемалар һәм фонемалар арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган бүлеге. Г.ның төп чаралары — хәрефләр һәм тыныш билгеләре (к. *Пунктуация*). Шулай ук Г. чараларына сүз кыскартуның төрле ысуллары, сүзләр арасында, текстны башлау алдыннан буш урын калдыру, юл хәрефләре куллану, сүзләрнең астына сызу һәм төрле шрифтлар б-н аерып чыгару керә. «Г.» төшенчәсен аваз-хәреф язылышына (*алфавит*, Г., *орфография*) карата кулланалар. Хәзерге вакытта дөньяда *кириллицага*, *латин* һәм *гарәп язуына* нигезләнгән милли язу системалары киң таралган. Татарларның борынгы бабалары (8–10 йөзләр) Орхон-Енисей язуына охшаш борынгы язу системасы кулланганнар. Татарстан терр-ясендәге археол. тикшеренүләр вакытында табылган төрле әйберләрдәге (балчык, металл савытлар һ.б.) язулар шуның ачык дәлиле булып тора. Ислам дине кабул ителгәннән соң, Гарәбстан һәм Иран б-н мәдәни-икътисади элемтәләр урнашу (10 йөз) нәтиҗәсендә борынгы төрки алвафит *гарәп язуы* б-н алыштырыла. Алтын Урда чорында гарәп язуы б-н параллель рәвештә беркадәр вакыт уйгыр язуы да кулланыла. 1927 елда латин алфавитына нигезләнгән *яңалиф* кертелә. 1939 да яңалиф ТАССР ЮС Президиум Указы нигезендә татар теленең үзенчәлекле авазларын белдерү өчен 6 хәреф (ә, ө, ү, җ, ң, һ) өстәлгән кириллица б-н алыштырыла. 1999 ның 15 сентябрендә ТР Дәүләт Советы тарафыннан «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Закон кабул ителә; анда 2011 гә кадәр (күчеш дәвере) ике алфавитның да кулланылышта булуы карала. Ләкин 2002 нең 1 декабрендә РФ Законы «Россия Федерациясе халыклары телләре турында»гы РФ Законының 3 нче маддәсенә өстәмә кертә. Анда «Россия Федерациясенең һәм андагы республикаларның дәүләт телләре алфавитлары кириллицага нигезләнеп төзелә. Россия Федерациясе һәм республикаларның дәүләт телләре алфавитларының башка графикага корылган нигезләре федераль законнар б-н билгеләнә алалар» дип күрсәтелә. Ш.у. к. *Китап графикасы*.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 1998. Т. 1; Курбатов Х. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Матусевич М.И. Графика // Введение в общую фонетику. М., 1959; Клосон Дж. Происхождение тюркского рунического алфавита // Зарубежная тюркология. М., 1986.

*Х.Р.Курбатов.*

**...ГРА́ФИЯ** (грек. gráphō) — язам, сызам, рәсем ясыйм), фән исемнәрен, нәрсәнедер күчереп ясау (язу), тасвирлау (күрсәтү) ысулларын белдерүче кушма исемнәрнең бер өлеше (мәс., география, каллиграфия).

**ГРА́ФОВ** Владимир Сергеевич (28.6.1913, Самара губ. Бөгелмә ш. — 9.12.1991, Казан), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), подполковник (1956). Казан югары танк командирлары уч-щесен тәмамлый (1942). Туган авылында МТС директоры булып эшли. 1935–37 елларда һәм 1939 дан Кызыл Армиядә. 1939 да Халхин-Гол елгасы буенда япон милитаристларына каршы сугышта катнаша. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, мотоциклет батальоны (1 нче гв. танк армиясенең 8 нче гв. механикалаштырылган корпусы) командиры. Воронеж, 1 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Украина, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1945 нең 19 апрелендә Марксдорф торак пункты янында (Зелов шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнбатыштарак,



В.С.Графов.

Германия) барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам иттерә. 1956 дан запаста, Казанда яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәрендә Г.ка бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Андреев С.А. Совершенное ими бессмертно. М., 1976; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза. М., 1987. Т. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ГРАХА́НЬ** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Вятка елгасы буенда. 2008 елда 41 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Башта Семёнов Пүчинкәсе дип атала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр-монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында җирле йөк пристаненнан һәр елны якынча 30 мең пот товар төяп озатыла. 20 йөз башында Г. да земство мәктәбе (1898 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 559 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троицк-Сикәнәс волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 328, 1897 дә — 474, 1908 дә — 602, 1926 да — 636, 1938 дә — 560, 1949 да — 412, 1958 дә — 531, 1970 тә — 435, 1979 да — 258, 1989 да — 112, 2002 дә — 51 кеше.

**ГРА́ХОВО РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнбатышында урнашкан. 1929 елның 15 июлендә оештырыла. Мәйданы — 970,6 *км²*. Үзәге — Грахово шәһәре (Ижевскидан 164 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 10879 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 1132, 1979 да — 900, 1989 да — 701, 2002 дә — 581 кеше. Г.р.нда татарлар (керәшеннәр) 18 йөз ахыры — 19 йөз башында килеп урнаша. 1870 елларда татарлар 6 авылда — Порым (1792 дә нигез салына), Починок Гаранькино (1800), Шарберды, Түбән Тыловай, Мещеряково, Тайшиперка һәм катнаш авыллар — Грахово, Новогорскида яшиләр. 1960 елларга кадәр Порым һәм Түбән Тыловай авылларында башлангыч татар мәктәпләре эшли. Хәзерге вакытта татарлар, башлыча, шушы авылларда яшиләр. Порым авылында керәшен татарларның «Туганай» милли-мәдәни оешмасы, фольклор ансамбле, Керәшен татарларның мәдәният үзәге (2000 нән) эшли.

**ГРАЦИА́НСКИЙ** Николай Павлович (1.10.1886, Рязань губ. Скопин ш. — 4.11.1945, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. д-ры (1934), проф. (1934). Рухани улы. Казан ун-тын тәмамлый (1910). Казан ун-тында профессор стипендиаты (1910–14), приват-доцент (1914–17), доцент (1917–18), проф. (1918–20), Мәскәү ун-ты проф. (1934–36, 1941–45). Бер үк вакытта 1921–45 елларда (бүленеп) СССР ФАнең Тарих ин-тында (1930 елга кадәр Иҗтимагый фәннәр фәнни-тикшеренү ин-тларының Россия ассоциациясе каршында) фәнни эштә, 1922 дән Мәскәү пед. ин-тында урта гасырлар тарихы каф. мөдире. Урта гасырлар бүләкләү грамоталарын өйрәнүнең яңа методикасын эшли. Хезмәтләре соңгы чор Рим империясенең һәм урта гасырларның элгәре дәвере аграр тарихына, борынгы германнар, Көнбатыш славяннар тарихына, варварлардагы хокук мәсьәләләрен өйрәнүгә, историографиягә карый. А.Г.Муравьев б-н берлектә франкларның «Салика хакыйкате»н (6 йөз) рус теленә тәрҗемә итә (1913).

Х е з м.: История промышленного развития Западной Европы в средние века. К., 1911; Западная Европа в средние века. Источники социально-экономической истории. М.–Л., 1925; Борьба славян и народов Прибалтики с немецкой агрессией в средние века. М., 1943.

*Әд.:* Памяти Н.П.Грацианского // Уч. зап. Моск. пед. ин-та. 1946. Т. 37, вып. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ГРАЧЁВ** Константин Аврамиевич (21.5.1865, Казан — 1917 дән соң), терапевт, мед. д-ры (1895). 1889 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1891–1916 елларда шунда ук эшли. Хезмәтләре эчке авыруларга диагноз куюга, йөрәкнең инсуффициенциясе һәм өч капкачлы клапанының зәгыйфьлеге вакытында веналар пульсын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О так называемом физиологическом венном пульсе. К., 1895; О паравертебральном притуплении при плевритических экссудатах и о перкуссии позвоночника. К., 1905.


*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 1.

**ГРАЧЁВ** Михаил Аврамиевич (24.10.1866, Казан губ., Цивиль өязе Рындино а. — 17.8.1925, Казан), астроном. 1892 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1919 елдан проф., Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе директоры. Сатурн, Веста планеталарын, Алголь, Яңа Кучер йолдызларын, кометалар һ.б. объектларны күзәтә. Киңлекләрдәге күзәтүләргә нигезләнеп, Җирнең әйләнү күчәре хәрәкәтен беренче мәртәбә тикшерә (1892 елдан), аберрацион һәм рефракцион константаларны билгели. Җир шары полюсларының хәрәкәтен тикшерүе өчен Г. ка акчалата халыкара бүләк һәм ике тапкыр Рус астрономия җәмгыяте бүләге бирелә. Айдагы бер кратер аның исеме б-н атала.

Х е з м.: Delfinitive Resultate von den Polhohen Beobachtungen zu Kazan von 1892–1901 // Тр. Казан. гор. астрон. обсерватории. 1911. Т. 23; Аберрационное постоянное из казанских наблюдений широты и вероятнейшее значение его. К., 1913.

**ГРАЧЁВ** Михаил Иванович (1916, Сембер губ., Корсун р-ны Пасенки а. — 8.12.1989, Казан), психиатр, сәламәтлек саклау эшлеклесе, РСФСРның атказ. табибе (1973). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), ТАССР мед. учреждениеләрендә эшли, 1951 елдан Казан шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге мөдире, 1953 тән Республика клиник хастаханәсе баш табибе. 1954–59 елларда ТАССР сәламәтлек саклау министры. 1959–81 дә Республика психиатрия хастаханәсе баш табибе урынбасары, баш табиб. Г. җитәкчелегендә ТАССР психиатрия хезмәте үзгәртеп корыла (шәһәр һәм авыл халкын диспансерлаштыру, яңа стационарлар ачу, кадрлар әзерләү). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГРЕБЕНИ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 33 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 16–17 йөзләрдә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек маркиз Паулуччиларның крепостнойлары) катлавына керә; игенчелек, бакчачылык, он тарту кәсебе, известь һәм алебастр алу өчен таш вату б-н шөгыльләнә, бурлак булып эшли. 20 йөз башында Г. дә маркиз Паулуччиларның ел саен 63 мең чиләк спирт куучы аракы ясау з-ды; чиркәү-приход мәктәбе (1886 да ачыла), 3 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана



Гребени авылы. Спирт заводы управляющие Н.Ф.Медведев йорты (19 йөз ахыры – 20 йөз башы).

җире 380 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 97 ир-ат; 1859 да — 238, 1897 дә — 318, 1908 дә — 338, 1926 да — 303, 1938 дә — 298, 1949 да — 199, 1958 дә — 154, 1979 да — 57 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ГРЕБЕНЩИКО́В** Иван Семенович (1813, Казан губ. Лаеш а. — 18.3.1883, Казан), сәүдәгәр, иске дин тарафдарларының (старообрядецларның) Казандагы «Поморско-брачное согласие» җәмгыяте җитәкчесе. Икмәк һәм бакалея товарлары б-н сәүдә итә. 1850 елларда Казанда бай сәүдәгәргә әверелә. Аның

Вознесенский урамында урнашкан йортында гыйбадәтханә эшли, руханилар яши. Җәмгыять ул васыять итеп калдырган мирас хисабына эшли. 1906 да гыйбадәт йорты төзелә (хәзерге Казан Богородица чиркәве).

**ГРЕБЕНЬКО́В** Октябрь Александрович (23.8.1924, Минск ш. — 30.8.2008, Казан), очкыч аппаратлар төзү гыйлеме белгече, техник фән. кандидаты (1954), проф. (1985). 1950 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли (бүлекнеп, 1959–62 елларда Дрезден техник ун-тында, Германия), 1963–87 дә машиналар төзелеше ф-ты деканы, бер үк вакытта 1978–83 елларда очкыч аппаратлар конструкцияләре һәм аларны проектлаштыру каф. мөдире. Хезмәтләре төзелеш техникасына һәм очкыч аппаратларын проектлаштыруга карый. Самолёт канатларының һәм самолёт планёры агрегатларының ныклыгын исәпләү ысулларын эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Конструктивно-силовые схемы и проектировочный расчёт крыльев. К., 1973; Конструкция самолётов. М., 1984; Конструирование агрегатов самолёта. К., 1997; Конструкция самолётов. К., 1999.

**ГРЕ́БНЕВ** Павел Николаевич (27.5.1946, Молдавия ССРның Бельцы ш.), балалар хирургы, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1998). М.Р.*Рокицкий* шәкерте. Казан мед. ин-тын (хәзерге Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1964), Казан клиникаларында эшли. 1978 елдан Казан мед. ун-тында, 1996 елдан балалар торакаль хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта Казанның баш балалар хирургы. Идел буенда беренче Республика балалар клиник хастаханәсендә балалар торакаль бүлеген оештыручы. Фәнни тикшеренүләре кичектергесез, торакаль, эренле авырулар хирургиясенә карый. Г. диагноз кую һәм хирургик дәвалауның 15 тән артык яңа ысулын эшли. 300 дән артык хирургия инстр-ты һәм төрле мед. аппаратлары («Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсе белгечләре б-н берлектә) эшләүдә катнаша, шуларның 16 сы «Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсе, Россия һәм БДБнең мед. инстр-тлары з-длары тарафыннан күпләп җитештерелә, бер өлеше РФнең ТР, Чуаш, Мордовия респ-каларының һ.б. төбәкләре хастаханәләренең балалар хирургиясе бүлекләрендә гамәлгә кертелә. «Балалар хирургиясендә яңа технологияләр эшләү һәм гамәлгә кертү» («Разработка и внедрение новых технологий в детской хирургии») хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1997). Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Неотложная пульмонология детского возраста. Л., 1983 (автордаш); Лапароскопия у детей. К., 1997.

**ГРЕГОРО́ВИЧ** Фадей-Антон Владиславович (28.10.1848, Минск — ?), хокук белгече, җинаятькә каршы хокук д-ры (1880), статский советник (1894). Дворяннар нәселеннән. Дерпт ун-тын тәмамлый (1872). 1875–79 елларда Демидовлар юридик лицее (Ярославль ш.) доценты, 1880–81 дә Дерпт ун-ты доценты, 1881–83 тә Варшава ун-ты приват-доценты. 1890–94 тә Казан ун-тының җинаятькә каршы хокук кафедрасында экстраординар, 1894–98 дә ординар профессор. Хезмәтләре җинаятькә каршы хокукка һәм аның процессына, ш.у. җәзаның котылгысызлыгы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Лекции по общей и особенной части уголовного права и по уголовному процессу. К., 1893; Криминальная антропология перед судом уголовного права. К., 1895; Вопросы так называемого уголовного права. К., 1897.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ГРЕК-РИМ КӨРӘШЕ́** (классик), спорт төре, аерым кагыйдәләр буенча кара-каршы көрәшү. Г.-р.к.ндә, ирекле көрәштән аермалы буларак, каршы көрәшүчене куллар б-н билдән түбән алырга, ш.у. аяклар ярдәмендә алымнар ясарга ярамый. Татарстанда 1890 еллардан профессиональ цирк көрәше буларак билгеле. Кара-каршы көрәшү спорт төре буларак 1908 дән «Беркут» («Бөркет»), «Сила и здоровье» («Көч һәм сәламәтлек») Казан спорт җәмгыятьләрендә үсеш ала, 1926 дан — «Динамо» ирекле спорт җәмгыятендә, 1940 еллар ахырыннан «Крылья советов», «Спартак», «Труд», «Локомотив», «Буревестник», «Урожай» һ.б. ирекле спорт җәмгыятьләрендә үсеш ала. Казанның беренче чемпионы — П.Бредихин (1909). 1920–30 еллардагы иң яхшы көрәшчеләр — Н.И.*Морящичев*, П.Я.Петров (1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында катнашучы, 1928), Т.Г.Жеребцов. Спортның бу төре буенча Казан беренчелеге 1946 дан, Татарстан беренчелеге 1947 дән уздырыла. РСФСР, СССР халыклары спартакиадалары һәм беренчелекләре, халыкара ярышлар чемпионнары һәм приз ияләре: В.Блажков, Ф.Трутиев, Р.Сафин, А.Соколов (1947); Р.Хәйруллин, Ф.Кулагин, И.Бәширов, Л.С.Сәлимуллин, Б.Иванов (1948–50), Р.А.*Азизов*, Т.Поляков (1951), Р.Р.*Шәрәфетдинов*, А.Н.Киров, В.Журавлёв (1967); Р.З.Камалов (1969); М.В.Измайлов, Г.Ф.Новиков, И.М.Мөхәрләмов, Х.Ш.*Тимашев* (1970); А.А.Бозин, А.А.Саенко. Иң яхшы тренерлар — М.М.Сәхәбетдинов, Х.Ш.Тимашев (1985 тән ТР Грек-рим көрәше федерациясе рәисе), А.С.Кузнецов.

**ГРЕ́КОВ** Борис Дмитриевич (9.4.1882, Полтава губ. Миргород ш. — 9.9.1953, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. д-ры (1934), СССР ФА академигы (1935; мөхбир әгъза 1934), СССР Архитектура академиясе академигы (1941). Польша һәм Болгария ФА әгъзасы (1947), Белоруссия ФАнең шәрәфле әгъзасы (1947). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1907). 1910–16 елларда Петербург ун-ты приват-доценты, 1916–20 дә Симферополь ун-ты профессоры. 1921 дән СССР ФАндә, 1937 дән СССР ФАнең Тарих ин-ты директоры. Бер үк вакытта 1944–46 да СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы ин-ты, 1946–51 дә Славяннарны өйрәнү ин-ты директоры; 1946–53 тә СССР ФАнең Тарих һәм философия бүлегендә академик-секретарь; Ленинград һәм Мәскәү ун-тлары профессоры. Бөек Ватан сугышы вакытында Казан ун-ты һәм пед. ин-ты профессоры (1941–42). Хезмәтләре Новгород, Борынгы Русь һәм Көнчыгыш славяннар, рус крәстияннәренең социаль-икътисади тарихына карый. Күп санда тарихи чыганакларны, ш.и. «Татарстан АССР тарихы буенча материаллар: Казан шәһәренең 1566–68 һәм 1646 еллардагы язу кенәгәләре»н («Материалы по истории Татарской АССР: Писцовые книги города Казани 1566–68 гг. и 1646 г.». Л., 1932) бастыра. А.Ю.*Якубовский* б-н берлектә «Алтын Урда: XIII–XIV гасырларда Җүчи Олысының оешу һәм чәчәк ату чоры тарихы очеркы» («Золотая Орда: Очерки истории Улуса Джучи в период сложения и расцвета в XIII–XIV вв». Л., 1937) монографиясен яза. Соңрак монографиянең 2 нче басмасы «Алтын Урда һәм аның җимерелүе» («Золотая Орда и её падение». М.–Л., 1950) исеме белән нәшер ителә. Бу хезмәт Алтын Урда тарихын өйрәнүдә мөһим адым булып тора, анда әлеге дәүләтнең Русь дәүләте б-н мөнәсәбәтләре ачыла. Г. татар халкының болгарлардан килеп чыгышы теориясен яклый. РСФСР (1947–50) һәм СССР (1950–53) ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1943, 1948, 1952). Ике Ленин ордены б-н бүләкләнә. Ш.у.к. СССР Фәннәр академиясе фәнни сессиясе, 1946, 25–26 апр.



Б.Д. Греков.

Х е з м.: Материалы по истории волнений на крепостных мануфактурах в XVIII в. М.–Л., 1937; Киевская Русь. М.–Л., 1939; Культура Киевской Руси. М.–Л., 1944; Крестьяне на Руси с древнейших времен до XVII в.: В 2 кн. М., 1952–54; Избранные труды: В 4 т. М., 1957–60.


*Әд.:* Борис Дмитриевич Греков: Материалы к библиографии учёных СССР. М.–Л., 1947; М а в р о д и н В.В. Борис Дмитриевич Греков. Л., 1968; Ч е р е п н и н Л.В. Отечественные историки XVIII–XX вв. М., 1984.

*Е.Б.Долгов.*

**ГРЕ́КОВ** Степан Тимофеевич (1679, Мәскәү — 1755 тән соң), дәүләти һәм хәрби эшлекле, тайный советник (1754). Чыгышы б-н дворяннардан. 1698 елдан дәүләти һәм хәрби хезмәт башкара. 1700–21 еллардагы Төньяк сугышында катнаша. 1731–33 тә Мәскәү ген.-полицмейстеры. 1733–36 да Доимочный приказ, 1736–38 дә Конфискация канцеляриясе баш судьясы (Мәскәү). 1741 дән Мәскәү губернаторының губ. эшләре буенча иптәше (урынбасары). 1748–55 тә Казан губернаторы. Татарлардан корал, кургаш җыеп алып, губ. шәһәрләрендә һәм өязләрендә хәрби отрядлар урнаштырып, татар халкының күтәрелешен булдырмый кала (1748). 1749 елгы янгыннан соң Казанны торгызу б-н җитәкчелек итә. Яңа Татар бистәсен төзүдә, постау мануфактурасының кирпеч биналарын һ.б. корылмаларны салуда ярдәм итә. Архиепископ Лука (Конашевич) б-н берлектә төбәктәге халыкларны күпләп христианлаштыруда кат-



С.А.Грекова.



А.Н.Гречкин.

наша. Г. вакытында Царёвококшайск, Алабуга шәһәрләрендә (1750), Казанда (1753) яңа чукындырылганнар өчен мәктәпләр ачыла, шәһәр ратушалары һәм магистратлар каршында гәп мәхкәмәләре оештырыла (башкарма органнары булмаган, кичектергесез карар чыгара торган, ярминкә сату-алу бәхәсләрен хәл итүче мәхкәмәләр) (1754), Мишә (Нырсы) бакыр кою з-ды төзелә (1749).

*Е.Б.Долгов.*

**ГРЕ́КОВА** Софья Андреевна (21.2.1879, Дон өлкәсе Новочеркасск ш. — 17.10.1970, Казан), драма актрисасы, ТАССРның атказ. һәм халык артисты (1940, 1954). Сәхнә эшчәнлеген 1913 елда Новочеркасск шәһәрендә В.И.Бабенко антрепризасында башлап җибәрә, аннан соң Воронеж, Минск, Саратов, Самара, Чита, Сталинград, Свердловск шәһәр театрларында, 1934–58 елларда Казан Зур драма театры труппасында уйный. Сәхнәгә шактый җитлеккән яшьтә килеп, Джоконда (шул исем. пьеса, Г. д'Аннунцио), Вера Мирцева (шул исем. пьеса, Л.Н.Урванцов), Лебёдкина, Юленька («Кичеккән мәхәббәт», «Төшемле урын», А.Н.Островский) кебек рольләрдә уйнаганнан соң, драматик героинялар актрисасы булып таныла. Аннан соң Анна («Анна Каренина», Л.Н.Толстой романы буенча), Мария Фёдоровна («Павел I», Д.С.Мережковский), Елизавета («Мария Стюарт», Ф.Шиллер) образларын тудыра. Рус классик репертуары әсәрләрендәге рольләрдә аеруча уңышлы уйный. Аның Наталья Дмитриевна һәм Княгиня Тугоуховская («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Гурмыжская, Турусина, Чебоксарова, Мурзавецкая, Сосипатра Семёновна («Урман», «Һәр акыл иясен гадилек җиңәр», «Котырган акчалар», «Бүреләр һәм сарыклар», «Чибәр ир кеше», А.Н.Островский), Каренина һәм графиня Лидия Ивановна («Анна Каренина», «Тере мәет», Л.Н.Толстой), Войницкая («Ваня абзый», А.П.Чехов), Марья Дмитриевна Калитина («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев) образлары шул чорның җанлы гәүдәләнеше булып тора. Сурәтләү чараларының киң диапазонына, яхшы манераларга ия буларак, үткен, көлкеле характерларны тудырганда да — Анна Андреевна («Ревизор», Н.В.Гоголь), Г-жа Пернель («Тартюф», Ж.Б.Мольер), Миссис Хиггинс («Пигмалион», Б.Шоу), ш.у. драматик рольләрне башкарганда да — Васса («Васса Железнова», М.Горький) — алардан оста файдалана. Хәзерге заман драматургиясе буенча да байтак зур рольләр башкара: Дама Нюрка («Аристократлар», Н.Ф.Погодин), Марья Тарасовна («Платон Кречет», А.Е.Корнейчук), колхозчы Марфа Астахова («Икмәк — тормыш тоткасы», Н.Е.Вирта) һ.б. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Иллялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ГРЕМЯ́ЧИЙ КЛЮЧ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 49 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасының югары агымы буенда. 2008 елда даими яшәүчеләр (руслар) саны 10 нан ким. 1930 елларда нигез салына. Башта Казан авыл р-нына керә, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-ннарында. Халык саны: 1938 дә — 118, 1949 да — 245, 1958 дә — 102, 1970 тә — 48, 1979 да — 35, 1989 да — 3, 2002 дә — 1 кеше.

**ГРЕМЯ́ЧИЙ КЛЮЧ ШӘҺӘРЛЕГЕ́** (Шуран шәһәрлеге), археологик истәлек. Ананьино, Азелино, Болгар һ.б. археологик культураларга нисбәтле торулык калдыклары. Лаеш р-нының Шуран авылы янында урнашкан. Атамасы Гремячий Ключ дип аталган инеш (Кама елгасы кушылдыгы) исеменә бәйле рәвештә бирелә. Г.К.ш. шул инешнең сул ярында болгарлардан калган Кашан шәһәрлеге каршында урнашкан. Хәзер анда чокырлар барлыкка килгән. 1881 елда беренче тапкыр П.А.Пономорёв ача һәм тикшерә. Истәлекнең төп катламы әүвәлге тимер гасырга карый. Археологик казу эшләре барышында ур, чокыр һәм шәһәрлектә зыян күрмәгән байтак мәйданнар тикшерелә. Шәһәрлекне уратып алган җир өемнәренә өч катлам яндырылган кызыл балчык түшәлгән. Г.К.ш.дә учаклы торак, металл кою остаханәсе калдыклары, хуҗалык корылмалары бар. Әйберләрдән балчык савыт-саба, сугыш кораллары (сөяк ук очлыклары, сугыш балталары һ.б.лар), сөяк (мөгез бөтиләр), таш, тимер һәм бронза эшләнмәләр табыла. Сугымга файдаланылган хайван сөякләре күп очрый. Әүвәлге тимер гасырга караган әйберләрдән тыш, Идел буе Болгарын монголлар яулап алу чорына караган тимер ук очлыклары да табыла. Г.К.ш. мәйданында һәм аннан читтәрәк табылган керамика һәм чакматаш эшләнмәләр якынча б.э.к. 8–7 йөзләр б-н билгеләнә.

*Әд.:* Пономарёв П.А. О результатах раскопок в Лаишевском уезде близ с. Шуран и д. Сорочьи Горы летом 1881 г. // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1884. Т. 3; Збруева А.В. История населения Прикамья в ананьинскую эпоху // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1952. № 30; Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ (1945–1952 гг.). К., 1954; Марков В.Н. Городище Гремячий Ключ // Древности Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1987.

*В.Н.Марков.*

**ГРЕМЯ́ЧИНСК ШӘҺӘРЕ́** (1949 дан), *Пермь өлкәсендә,* Пермь шәһәреннән 174 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Кизел ташкүмер бассейнында яңа ташкүмер ятмаларын үзләштерү б-н бәйле рәвештә 1942 елда нигез салына. Халкы — 15100 мең кеше (2008), ш.и. 2668 татар (2002). Татарлар Г.ш.ндә аңа нигез салынганнан бирле яшиләр. 1991 дән «Ләйсән» җыр һәм бию ансамбле эшли. Корбан гаете һәм Сабантуй бәйрәмнәре үткәрелә. Үзәк шәһәр китапханәсе фондында 120 татар китабы исәпләнә.

**ГРЕМЯ́ЧКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе авылыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* ераклыкта. 2008 елда 90 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1619 дан Кривуши авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәр Покровский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, итек тегү, тире эшкәртү, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да Покрау чиркәве (1756 да салына; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1898 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 386 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-ннарында. Халык саны: 1782 дә — 169 ир-ат; 1859 да — 251, 1897 дә — 491, 1926 да — 611, 1938 дә — 684, 1949 да — 538, 1958 дә — 478, 1970 тә — 315, 1989 да — 169, 2002 дә — 121 кеше.

**ГРЕМЯ́ЧКИН** Николай Леонидович (24.4.1905, Казан губ. Столбище а. — 15.5.1990, Свердловск өлкәсенең Первоуральск ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1967). Машиналар төзү техникумын тәмамлый (1925), Уральск политехник ин-тында укый (1938–39). 1925–37 елларда Пермь өлкәсенең Лысьва машиналар з-дында эшли: мастер ярдәмчесе, механика цехы башлыгы. 1937–71 дә Первоуральск яңа торбалар з-дында (Свердловск өлкәсе): ремонтлау-механика цехы башлыгы, баш механик урынбасары, заводның баш механигы (1958 дән). Дәүләт бүләге югары җитештерүчәнлекле «30–102» торба прокатлау станын төзүдә һәм эшләтеп җибәрүдә катнашканы өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Металлурги Урала. Екатеринбург, 2001.

**ГРЕНЬКО́В** Александр Иванович (30.8.1908, С.-Петербург — 24.11.1976, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1966), проф. (1967), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1963). 1938 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1941–52 елларда ВКП(б)ның Казан шәһәр һәм Ленин р-н ком-тларында партия эшендә, 1952–56 да ТАССР МС рәисе урынбасары, КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1959–76 да Авиация технологиясе һәм сәнәгать пр-тиеләрендә җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан филиалы башлыгы. «Ми-8» вертолётларын эшләп чыгаруда, «К-26» вертолётларын һ.б. җитештерүне үзләштерүдә актив катнаша. СССР ФАнең фәнни һәм координацион советлары әгъзасы. 1951–59 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ок-

тябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГРЕ́ЧКИН** Александр Николаевич (4.6.1952, Казан), биохимик, химия фән. д-ры (1992), РФА мөхбир әгъзасы (1997), РФА академигы (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1974), РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында (1974 тән), 1994 елдан эндоген регуляторлар бүлеге мөдире, 2002 дән директор. Бер үк вакытта 1997 дән Казан ун-тында биохимия каф. профессоры. Хезмәтләре үсемлек липидларын һәм липид биорегуляторларын өйрәнүгә карый. Үсемлекләрдә туендырылмаган майлы кислоталарны оксидлаштыручы метаболизмның, ш.и. оксотриеннарны икеләтә диоксигенирлау һәм синтезлау, аллил кетоннарны диоксигенирлау, дивинил эфирларны синтезлауның яңа юлларын таба. Г. алленоксидсинтез ысулы б-н кетоллар һәм циклопентеннарның барлыкка килүе механизмнары турында принципиаль яңа мәгълүматлар ала, үсемлекләрнең зарарланган урыннарын элекке хәленә кайтара торган гормоннар һәм аларның үсүен стимуллаштыручылар, липоксигеназлар һәм тромбоцитларның агрегациясе бактерицидлары һәм югары актив ингибиторлары булган 20 ләп оксилипинны таба. И.А.Тарчевский б-н берлектә эшләгән «Липоксигеназ сигнал юлы» («Липоксигеназный сигнальный путь») хезмәте өчен ТР ФАнең В.А.Энгельгард исем. бүләгенә лаек була (2000).

Х е з м.: The lipoxygenase pathway in garlic (Allium sativum L.) bulbs // Detection of the novel divinyl ether oxylipins. FEBS Lett. 1995. V.371 (автордаш); On the mechanism of biosinthesis of divinyl ether oxylipins by enzyme from garlic bulbs // Eur.J.Biochem. 1997. V.245 (автордаш); Recent developments in biochemistry of the plant lypoxygenase pathway // Progr. Lipid. Res., 1998. V.37; Determinants governing the CYP74 catalysis: Conversion of allene oxide cynthase into hydroperoxide lyase by sitedirected mutagenesis // FEBS Lett. 2008. V. 582 (автордаш).

**ГРЕ́ЧКИН** Николай Павлович (3.9.1912, Спас өязе Арбузов-Баран а. — 16.5.1984, Казан), химик-органик, химия фән. кандидаты (1951). 1940 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–84 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында эшли, 1961–71 дә физиологик актив элементорганик кушылмалар лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре аккургаш-фосфорорганик кушылмалар, фосфорилирланган азотлы гетероцикллар (этиленимин, азетидин, пирролидин), күп төшле хуш исле углеводородлар химиясенә карый. Г. өч валентлы фосфор кушылмалары б-н гликольләр һәм алканоламиннарның үзара тәэсир итүе нәтиҗәсендә пентаковалент гидрофосфораннар барлыкка килү реакциясен ача. Казанда фәннәр тарихы буенча хезмәтләр авторы. А.Е.Арбузовның фәнни биографиясен бастырып чыгара, Казанда элекке аптека бинасында (Карл Маркс ур.) А.М.Бутлеровка мемориаль такта кую, А.Е.Арбузов һәм Б.А.Арбузовларның музей-йортын ачу инициаторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Александр Ерминингельдович Арбузов. М., 1977 (автордаш); Александр Михайлович Бутлеров (его жизнь и деятельность в Казани) // Рассказы о казанских учёных. К., 1983.

**ГРИ́БОВ** Александр Павлович (23.3.1948, Чистай ш. — 28.8.2005, Казан), механика өлкәсе галиме, физ.-матем. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, Оренбург (1979–81), Кама (1981–87), Ульянов (1987–98) политехн. ин-тларында, Ульянов техника ун-тында (1998–2002) эшли. 2002 елдан Казан ун-тының теоретик механика кафедрасы профессоры. Юка пластиналар һәм ирекле формадагы куыш сүрүләр бөгелешенең сызыкча һәм нәсызыкча мәсьәләләрен чишү өчен кырый элементлар ысулын тәкъдим итә. Сингуляр интеграль тигезләмәләр системасын таба, аларның төшләренә санлы кулланылыш өчен яраклы анализ үткәрә. Пластиналар һәм мембраналар теориясенең контактлы мәсьәләләрен чишүдә контактның билгесез өлкәсен эзләү дә кергән яңа алым тәкъдим итә.

Х е з м.: Расчёт тонкостенных элементов конструкций с использованием итерационного метода // Изв. вузов. Машиностроение. 1985. № 3 (автордаш); Поиск границы контакта мембраны, сопротивляющейся сдвигу, при взаимодействии с жёстким телом // Актуальные проблемы механики оболочек: Тр. Междунар. конф. К., 2000 (автордаш); Решение задач нелинейного деформирования пластин и пологих оболочек методом граничных элементов. К., 2002 (автордаш).

**ГРИБОЕ́ДОВ** Александр Сергеевич (4.1.1795, башка мәгълүматлар буенча 1790, Мәскәү — 30.1.1829, Тәһран), язучы, дипломат. 1812 елда Мәскәү гусар полкына корнет хезмәтенә языла. Ул полк 1813 тә Казанда тора. «Студент» (1817, 1889 да басыла) комедиясендә Казан искә алына. 1824 тә язылган атаклы «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») пьесасы цензура тарафыннан тыела. Декабрист Д.И.Завалишин аның кульязма нөсхәсен Казанга алып килә (Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана). 1834 тә комедия Казан шәһәр театры сәхнәсендә үзешчән актёрлар тарафыннан куела, 1836 да аны Пивато антрепризасының проф. труппасы актёрлары уйный, 1853 тә Н.Г.Милославский тарафыннан уйнала һәм 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 20 йөз башына кадәр Казан театры сәхнәсеннән төшми.

*Әд.:* А р и с т о в В.В. Подарок декабриста. К., 1970; А р и с т о в В., Е р м о л а е в а Н. Всё началось с путеводителя. К., 1975.

*Ю.А.Благов.*

**ГРИГО́РИЙ** (Митькевич Николай Васильевич) (1807, Чернигов губ., Чернигов өязе Жуковка а. — 13.4.1881, Калуга ш.), дин эшлеклесе һәм белгече. Чернигов руханилар семинариясен, Киев руханилар академиясен тәмамлый (1831). 1830 елда монахлыкка керә. 1831 дән Киев руханилар академиясе бакалавры. 1833 тән Казан руханилар семинариясе инспекторы, 1844 тән Казан руханилар академиясе ректоры. 1851 дән Калуга һәм Боровск епискобы, 1869 дан архиепискобы. Казан руханилар академиясендә ректор булып торганда, үзен оста җитәкче, фән һәм укыту эшләрен оештыручы итеп таныта. Ул эшләгән елларда академия бинасы төзелә, миссионерлар бүлеге ачыла.

*Әд.:* Двадцатипятилетний юбилей управления Калужской епархией // Калужские епархиальные ведомости. 1876. № 23–24; Б л а г о в е щ е н с к и й А. История Казанской духовной семинарии. К., 1881; З н а м е н с к и й П.В. История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870): В 3 вып. К., 1891–92.

**ГРИГО́РИЙ** (Постников Георгий Петрович) (1.11.1784, Мәскәү губ., Никитский өязе Михайловское а. — 17.7.1860, С.-Петербург), дин эшлеклесе һәм белгече, дини гыйлемнәр д-ры (1817). Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1814), шунда эшли: 1816 елдан инспектор, 1819 дан ректор (1814 тән монахлыкта). Бер үк вакытта 1822 дә Ревель епискобы. 1826 дан Калуга епискобы, 1828 дән Рязань архиепискобы, Изге Синод әгъзасы, 1831 дән Тверь архиепискобы. 1848 дән Казан һәм Зөя архиепискобы, 1856 дан Петербург митрополиты. Кайда гына эшләсә дә, Г. православие дини мәгарифен оештыруга, дини әдәбият нәшер итүгә зур игътибар бирә. Г. *Казан руханилар академиясендә* укытуның һәм фәнни эшчәнлекнең сыйфатын яхшыртуга булышлык итә, аның инициативасы б-н миссионерлык бүлеге ачыла, «Православный собеседник» журналы чыга башлый, Соловки монастырендагы китапханәне академиягә тапшыру мәсьәләсе хәл ителә.

Х е з м.: Слова и беседы на воскресные и праздничные дни в году, с присовокуплением слов и бесед на некоторые особенные случаи: В 5 т. СПб., 1850–59; Житие Святителей и Чудотворцев Гурия, Архиепископа Казанского и Варсонофия Тверского. СПб., 1853; Истинно древняя и истинно православная Христова церковь. Изложение в отношении к глаголемому старообрядству: В 2 ч. СПб., 1854.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П.В. История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870): В 3 вып. К., 1891–92; З н а м е н с к и й Ф. Высокопреосвященный Григорий // Церковные ведомости. 1910. № 24.

**ГРИГОРО́ВИЧ** Виктор Иванович (30.4.1815, Подольск губ. Балта ш. — 19.12.1876, Елизаветград (хәзерге Кировоград) ш.), филолог, тарихчы, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1851), Россиядә славян телләрен, әдәбиятын, мәдәниятен, тарихын һәм славяннар тормышын өйрәнү фәненә нигез салучы. Харьков (1833) һәм Дерпт (1839) ун-тларын тәмамлый. Казан (1842–63), Мәскәү (1848–49), Одесса (1865–75) ун-тлары профессоры. Казанга 1839 елда Н.И.Лобачевский чакыруы б-н килә, серб, поляк, чех, славян, югары лужица, чиркәү-славян телләрен һәм әдәбиятын үзенең дүртьеллык программасы буенча укыта. Рус славистларыннан беренчеләрдән булып болгар телен укыта, чиркәү-славян теле нигезендә болгар һәм македон сөйләшләрен өйрәнә («Борынгы славян теленә кагылышлы мәкаләләр» — «Статьи касающиеся древнего славянского языка», 1852). 1844–47 елларда Балкан-славян җирләренә фәнни сәфәргә бара һәм көньяк славян язуының шактый уникаль ядкәр-



В.Д. Григорьев.



В.А.Григорьев.

ләрен алып кайта. Балкан славяннарының тарихын өйрәнгәндә Византия чыганакларыннан («Сербиянең XIV һәм XV йөзләрдә күрше дәүләтләргә карата мөнәсәбәте турында» — «О Сербии в её отношениях к соседним державам, преимущественно в XIV и XV столетиях», 1858) киң файдалана.

Хезм.: Очерк путешествия по Европейской Турции. К., 1848; Славянские наречия. К., 1884; Собр. соч. (1864–76). Од., 1916.

*Әд.:* Викторов А.Е. Собрание рукописей В.И.Григоровича. М., 1879; Петровский Н.М. Библиографический список печатных трудов В.И.Григоровича // Изв. Отд-ния рус. языка и словесности. Имп. АН. 1914. Т. 19, кн. 3; Сергеев А.В. Исторические взгляды В.И.Григоровича. К., 1978.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**ГРИГОРО́ВИЧ** Иван Артемьевич (8.9.1934, Смоленск өлкәсе, Велиж р-ны Рудомни а.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Ленинград хәрби-механика ин-тын тәмамлый (1959). 1959–96 елларда «Серго исем. завод» җитештерү берләшмәсендә (Яшел Үзән ш.) эшли: инженер-технолог, цех башлыгы (1964 тән), баш технолог урынбасары (1970 тән). Дәүләт бүләге махсус билгеләнгән эшләнмәләрне камилләштергәне һәм аларны эшләп чыгаруның алдынгы технологияләрен булдырганы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГРИГОРО́ВИЧ** Сергей Антонович (13.3.1913, Перовск ш. хәзерге Казакъстанның Кызыл Урда ш. — 13.12.1989, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. элемтәчесе (1977). Одесса элемтә электротехника ин-тын тәмамлый (1939). 1939–41 елларда Полтава өлкә элемтә идарәсенең телефон бүлеге, СССР Элемтә халык комис-тының Полтава шәһәр телефон станциясе башлыгы. 1941–60 та Омск өлкә элемтә идарәсендә элемтә конторасы башлыгы урынбасары, баш инженер, 1952 дән башлыгы. 1960–79 да ТАССРның элемтә җитештерү-техник идарәсе башлыгы. Бу вакыт эчендә республикада элемтә чараларының, бигрәк тә телевидениенең үсеше буенча шактый эш эшләнә. 1977 дә Казанда Үзәк телевидениенең 3 нче программасы тапшырулары, Чаллыда республика телевидениесе программалары өчен ретрансляторлар эшли башлый. Тармакны структуралаштыру эшләре уздырыла. Республика радиотелевидение үзәге, Чаллы шәһәре элемтә җитештерү-техник узелы булдырыла. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Ш.Рахманкулов.*

**ГРИГО́РЬЕВ** Василий Васильевич (15.3.1816, С.-Петербург — 19.12.1881, Павловск ш., хәзерге Ленинград өлкәсе), шәркыятьче галим, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1853). Петербург ун-тын тәмамлый (1834). 1834–36 елларда Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында Шәрекъ телләре гыйльми бүлекчәсендә эшли. 1838–44 тә Одесса шәһәрендәге Ришелье лицеенда Шәрекъ телләре укыта, фәнни максатларда Истанбул, Кишинёв шәһәрләрендә, Кырым ярымутравында була. 1842 елда Мәскәү ун-тында «Алтын Урда ханнарының рус руханиларына биргән ярлыкларының чынлыгы хакында» дигән темага диссертация яклый. 1844–80 дә Тышкы эшләр министрлыгында хезмәт итә. 1851–62 елларда Оренбургта: Сырдәрья төбәгенә оештырылган поход вакытында яу канцеляриясе мөдире (1853), Оренбург чик буе комиссиясе рәисе (1854). 1863 тән Петербург ун-тында, Шәрекъ телләре докторы, Көнчыгыш ф-ты каршындагы Шәрекъ каф. мөдире (1878 гә кадәр). Бер үк вакытта 1873–78 дә Көнчыгыш ф-ты деканы. Россиядә беренче булып Шәрекъ илләре тарихы буенча университет курсы укый. 1867 дә Рус археология җәмгыятенең Шәрекъ бүлекчәсе идарәчесе итеп сайлана. «Правительственный вестник» басмасының мөхәррире була (1869). Соңрак Матбугат эшләре буенча баш идарә җитәкчесе (1874–80). Шәркыятьчеләрнең 3 нче Халыкара конгрессын оештыручыларның берсе һәм аның рәисе (1876, С.-Петербург). Хезмәтләре Россиядәге төрки телле халыкларның географиясенә, тарихы, этнографиясе, нумизматикасы, язма чыганакларына һәм Россия шәркыять фәне мәсьәләләренә карый. Г.ның гыйльми мирасында «Хәзәрләрнең сәяси тарихына күзәтү» («Обзор политический истории хазаров», СПб., 1835), «Алтын Урда башкаласы Сарайның урыны турында» («О местоположении Сарая, столицы Золотой Орды», СПб., 1845), «Сарай хәрабәләре янында табылган Алтын Урда тәңкәләре хәзинәсен тасвирлау» («Описание клада золотоордынских монет, найденных близ развалин Сарая», СПб., 1848) хезмәтләре аерым урын алып тора. Урта Азия тарихына караган «Кабулистан һәм Кафиристан» («Кабулистан и Кафиристан», СПб., 1867) исемле фундаменталь хезмәт һәм К.Риттерның «Шәркый Төркестан» китабы (СПб., т. 1–2, 1869–73) тәрҗемәсенә өстәмәләр авторы.

Хезм.: Еврейские религиозные секты в России. СПб., 1846; Четырехлетние археологические поиски в развалинах Сарая. СПб., 1847; Монеты афганских султанов Индии, найденные в развалинах Сарая. СПб., 1848; Описание Хивинского ханства и дороги туда из Сарайчиковской крепости. СПб., 1861; Императорский Санкт-Петербургский университет в течении первых пятидесяти лет его существования. СПб., 1870.

*Әд.:* Веселовский Н.И. Василий Васильевич Григорьев по его письмам и трудам. 1816–1881. СПб., 1887; Бартольд В.В. Материалы для истории факультета восточных языков. СПб., 1909. Т. 4; Крачковский И.Ю. Очерки по истории русской арабистики. М.–Л., 1950.

*М.Г.Госманов.*

**ГРИГО́РЬЕВ** Вениамин Демьянович (17.1.1932, Зәй р-ны Кече Баграж пос. — 27.5.2005), инженер-химик, Соц. Хезмәт Герое (1981), РСФСРның атказ. химигы (1987), икътисад фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1954 елда Казан химия-технол. ин-тын, 1985 тә СССР МС каршындагы Халык хуҗалыгы академиясенең Идарә итү ин-тын тәмамлый. 1954–70 елларда С.М.Киров исем. Казан ясалма каучук з-дында: мастер, цех башлыгы, 1963 тән баш инженер урынбасары, 1966 дан баш инженер. 1970–84 тә Казан резин-техник эшләнмәләр з-ды директоры, 1984–90 да «Казан резин-техника» җитештерү берләшмәсе ген. директоры, 1990–92 дә «Казан резин-техника» аренда берләшмәсе рәисе, 1992 дән резин-техника («Кварт») АҖ президенты, бер үк вакытта Казан технол. ун-тында, 1996 дан икътисад каф. профессоры. Аның җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла, техника яңартыла һәм өстәмә куәтләр төземи генә дә җитештерүне үстерүдә җитди уңышларга ирешелә. Җитештерүне оештыруның яңа структурасы гамәлгә кертелә. Пр-тие б-н икътисади идарә итүнең комплекслы системасы булдырыла һәм зур социаль программа гамәлгә ашырыла: 165,7 мең $м^2$ торак мәйданы төзелә, тулай торакка, санаторийлар, балалар һәм дәвалау учреждениеләренә булган ихтыяҗ тулысынча тәэмин ителә. 10 нчы бишьеллык йөкләмәләрен үтәү буенча җитештерү өлкәсендә ирешкән зур уңышлары өчен Соц. Хезмәт Герое исеме бирелә. Базар икътисадын булдырудагы хезмәтләре өчен Халыкара бизнес академиясенең Алтын дипломына лаек була (2000). Фән өлкәсендәге эшчәнлеге пр-тие б-н идарә итүне оештыру структурасының комплекслы сыгылмалы моделен төзү һәм тармак б-н идарә итү системасының принципларын формалаштыруга карый. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008, вафатыннан соң). Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм 6 патенты бар. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Интенсификация производства: опыт и проблемы. К., 1988; Промышленные предприятия: механизм ускорения развития. К., 1989; Экономика предприятий химической промышленности. К., 1996.

*Әд.:* Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 1993. Вып. 1.

**ГРИГО́РЬЕВ** Виктор Антонович (18.8.1921, Омск ш. — 23.8.1985, Владимир ш.), Сов. Союзы Герое (12.4.1942), подполковник (1957). 1934–39 елларда Казанда эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 32 нче танк бригадасы (50 нче армия) танк йөртүчесе. Брянск, Көнбатыш, Үзәк һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәүне саклауда (1941–42), Ржев-Вязьма һөҗүм операциясендә (1942), Белоруссияне азат итүдә, Көнчыгыш Пруссия һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1941 нең 3–4 декабрендә Крюково авылы янындагы (Тула өлкәсе, Ленинград р-ны) сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмә-

тен дәвам иттерә; РККАның бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләре хәрби академиясен (1991) тәмамлый. 1957 дән запаста. Владимир шәһәрендә эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ш л е в к а Г.М. Ради жизни на земле. Омск, 1972; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза. М., 1987. Т. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ГРИГО́РЬЕВ** Владимир Евгеньевич (3.11.1943, Мәскәү — 2.6.2008, Казан), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. табибе (2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Төмән өлкәсенең Ханты-Манси автономияле округында эшли. 1973–79 елларда Казан мед. ин-тында. 1979 елдан Казан ГИДУВының (хәзерге Казан мед. академиясе) эпидемиология каф. мөдире. Дифтерия, кызамык, корсак тифы, паратифлар һ.б. йогышлы авыруларның кинәт таралып китүен бетерүдә катнаша; Ханты-Манси милли округында йогышлы авырулар патологиясе профилактикасы эшен оештыра. 1973–76 да йогышлы эчәк авыруларына каршы даими фәнни-гамәли ярдәм күрсәтү өчен еш кына Чаллыда була. Хезмәтләре хастаханәләрдәге йогышлы эчке авырулар, эренле-ялкынсынулы авырулар, туберкулёз, вируслы гепатитлар проблемаларына карый. Г. җитлекмичә туган балаларда язгы-җәйге чорларда эренле-ялкынсынулы авырулар көчәюен ачыклый, дәвалау-профилактика учреждениеләренең тышкы мохитендә стафилококкның табигый әйләнешен теоретик нигезли, төрле профильдәге стационарларда хастаханәдә эренле-ялкынсынулы авырулар б-н көрәшүнең профилактик чаралар комплексын эшли һәм гамәлгә кертә. Йөкле хатыннарның җенес җиңсәсендә патоген микрофлораны бетерү өчен хлоргексидин биглюконат, ш.у. хлоргексидин һәм метацид эремәләре катнашмасының нәтиҗәлелеген исбатлый. Стафилококк имуноглобулинын алу өчен донорларны иммунлаштыруның яңа схемасын әзерли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Применение хлоргексидина биглюконата в качестве профилактического средства гнойно-воспалительных заболеваний среди новорождённых. К., 1988; Эпидемиологический анализ и опыт профилактики новорождённых и родильниц. М., 1991 (автордаш).

**ГРИГО́РЬЕВ** Евгений Иванович (19.1.1876, Казан — 5.9.1950, шунда ук), математик, проф. (1935), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). 1900 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1900–23 елларда Казан, Саратов һәм Вятка (хәзерге Киров ш.) урта уку йортларында матем. укытучысы. 1923–32 дә Казан ун-тында, 1926–30 да физ.-матем. ф-тының декан урынбасары. 1932 дән Казан авиация ин-тының матем. каф. мөдире. Хезмәтләре элементар математикага һәм саннар теориясенә, югары мәктәптә математика укыту методикасына карый. 1947–50 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Плотности и распределение простых чисел // Изв. физ.-матем. об-ва. 1924. Т. 24, вып. 1; Четыре биквадрата. Задача Эйлера // Изв. физ.-матем. об-ва. 1924, вып. 2; Из новой геометрии треугольника // Уч. зап. Казан. ун-та. 1925. Т. 85, кн.1.

**ГРИГО́РЬЕВ** Лев Николаевич (10.1.1924, Казан — 23.12.1977, шунда ук), җылылык техникасы белгече, техник фән. д-ры (1971), проф. (1973). 1952 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1973 тән гидравлика каф. мөдире. Хезмәтләре бинар һәм күп компонентлы катнашмалар кайнаганда җылы алмашуга карый. Катнашмаларның кайнаганда җылы алмашуына аларның составы йогынтысын өйрәнү өчен теоретик һәм тәҗрибә тикшеренүләре уздыра. Катнашмаларның кайнау параметрларын билгеләү өчен тигезләмәләр чыгара, чыгарган тигезләмәләрне төрле аерым очраклар өчен анализлый. Бинар, өч компонентлы катнашмаларның һәм каты матдәләр эремәләренең, кайнаганда җылы бирү процессларында охшашлык шартларын билгели; югары процентлы катнашмалар һәм каты матдәләрнең сыеклыклардагы эремәләре өчен охшашлык критерийларын һәм аларга тиңдәш критериаль тигезләмәләр чыгара. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Теплоотдача при кипении бинарных смесей // Журн. техн. физики. 1958. Т. 28 (автордаш); Образование новой фазы при кипении бинарных смесей // Инженерно-физ. журн. 1963. Т. 6, № 8; Обобщение опытных данных по теплоотдаче при кипении смесей жидкостей с резко отличающимися температурами кипения // Теорет. вопр. теплотехники. 1968. № 1; Число центров парообразования при кипении бинарных смесей // Инженерно-физ. журн. 1969. Т. 17, № 1 (автордаш).

**ГРИГО́РЬЕВ** Николай Николаевич (9.2.1929, Ленинград өлкәсе Кингисепп ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1978). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1959). 1952–94 елларда Казан төгәл машиналар төзү з-дында эшли: автомат цех мастеры, конструкторлык бүлеге башлыгы урынбасары, з-дның баш конструкторы урынбасары (1985 тән). Уйлап табуга өч авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге яңа махсус техника эшләгәне һәм гамәлгә куйганы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.




Ф.В. Григорьев.

**ГРИГО́РЬЕВ** Фёдор Васильевич (8.2.1890, Орёл губ., Витичко а. — 13.8.1954, Мәскәү), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1935), ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1939, 1949). Сәхнә эшчәнлеген Одесса машина төзелеше з-дында эшләгәндә һәвәскәр театрда башлап җибәрә; 1909 елда проф. сәхнәгә чакырыла, Одесса, Николаев, Херсон, Винница, Житомир, Владикавказ, Краснодар, Әстерхан шәһәрләрендә антрепренёрлар Е.А.Калишевская, Л.П.Розановларның драма һәм оперетта труппаларында уйный. Үткен күзәтүчәнлеккә, юмор хисенә, рольләрдә тиз үзгәрүчәнлеккә ия булган Г.ның осталыгы даими үсә бара, гади, водевиль рольләреннән — Осип («Ревизор», Н.В.Гоголь), Расплюев («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Фамусовтан («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов) башлап, ниһаять, 20 елдан артык сәхнәдә уйналган һәм иң көчле рольләренең берсенә әверелгән Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь) образын гәүдәләндерүгә ирешә. 1933 тә Казан Зур драма театры труппасына ул җитлеккән актёр булып килеп керә. Шулай да Г.ның иҗат осталыгы нәкъ менә Казанда зур масштаблылыкка һәм тирәнлеккә, форма төгәллегенә ирешә, шул сыйфатлары аны рус реалистик театр мәктәбенең иң күренекле осталары рәтенә куя. Казанда эшләгән беренче елларында күбрәк көлкеле рольләр башкарган Г. геройларның комик характер үзенчәлекләре артында кеше язмышының драматизмын күрә: Караулов («Чит кеше баласы», В.В.Шкваркин); Шмага, Робинзон, Лыняев («Гаепсездән гаеплеләр», «Бирнәсез кыз», «Бүреләр һәм сарыклар», А.Н.Островский); Скалозуб («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов). Актёр, сәхнә образы чикләрен киңәйтә барып, тамашачыда геройларына карата кызгану һәм аларның хәленә керү хисе уята. Артур Кинселла («Чарасызлык», Т.Драйзерның «Америка фаҗигасе» романы







Ф.В. Г р и г о р ь е в: 1. Городничий («Ревизор», Н.В. Гоголь); 2–3. Несчастливцев, Грознов («Урман», «Дөреслек яхшы, ә бәхет яхшырак», А.Н. Островский) рольләрендә.

нигезендә, 1933), Терентий Бублик («Платон Кречет», А.Е.Корнейчук, 1934), Тетерев («Мещаннар», М.Горький, 1935) образларын тудырып, актёр реаль характерны ача торган психол. күчешләр, тышкы көнкүреш детальләреннән торган форманы ярлыландырмыйча зур масштаблы гомумиләштерүләр аша геройларын әсәрнең төп идеясен чагылдыручылар дәрәҗәсенә күтәрә. 1936 елда уйнаган Боцман («Оптимистик трагедия», В.В.Вишневский), Несчастливцев («Урман», А.Н.Островский) һәм Полежаев («Профессор Полежаев», Л.Н.Рахманов) кебек рольләрдә Г.ның үзенчәлекле комик таланты ачыла. Аның геройлары тарыган хәлләрнең тышкы комизмы, характерларының көлкеле яклары образларның эчке драматизмын ачуга басым ясый. Актёрның иң зур эшләреннән саналган Полежаев образы пьесаның драматургик материалын тагын да баета. Казанда эшләгән елларында Г. Городничий образын өч куелышта башкара (1933, 1938, 1944). Һәр уенында ул классик образны көтелмәгән яктан ачып, традицион штампларны үзгәртеп, аны камилләштерә бара. Ул башкарган Сквозник-Дмухановский дуамал, әшәке, акчага табынучы, карьерага үрмәләү мөмкинлеген күреп, аек акылын югалткан провинциаль тип буларак кына түгел, ә үзенә карата кызгану һәм хәленә керү, нәфрәт һәм ачу, курку һәм күрә алмау кебек каршылыклы хисләр уятучы, Гоголь чорына хас шундый городничийларны һәрдаим тудырып торган социаль мөнәсәбәтләрнең табигате, сәбәпләре турында тирәнтен уйланырга мәҗбүр итүче конкрет кеше образы булып күз алдына килеп баса. В.А.Соловьёвның «Фельдмаршал Кутузов» (1941) драмасында Г. тарафыннан башкарылган Кутузов образы — халык характерының чын гәүдәләнеше. Сила Грознов образы («Дөреслек яхшы, ә бәхет яхшырак», А.Н.Островский, 1944) Г. башкаруында интонацияләрнең байлыгы, нечкә психол. нюанслар, тышкы детальләрнең нәфис эшләнеше б-н аерылып тора. Ул рус актёрлык мәктәбенең иң югары баскычына ирешә. 1946 да Г.ны Мәскәүдәге Кече театрга чакырып алалар. Бу театр сәхнәсендә Городничий һәм Грознов рольләрен уйнап, ш.у. замандашларының байтак күренекле образларын тудырып (Милягин, «Бөек көч», Б.С.Ромашов, 1947, СССР Дәүләт бүләге; Потапов, «Мәскәү характеры», А.В.Софронов, 1948, СССР Дәүләт бүләге һ.б.), театрның әйдәп баручы осталары рәтенә күтәрелә. Башкаруының табигыйлеге, сүз б-н оста эш итүе, характерның һәм тормыш хәлләренең мәгънәсен тирәнтен ачып бирүе ул тудырган һәр образны театр тормышында зур вакыйгага әверелдерә. 1938–47 елларда ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г о р б у н о в а Е. Григорьев-Полежаев // Театр. 1938. № 4; Ш а т р о в а Е. Ф.В.Григорьев // Ежегодник Малого театра за 1953–54. М., 1956; Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*


**ГРИГО́РЬЕВА** Лидия Николаевна (12.8.1945, Украина ССРның Луганск өлкәсе Новосветловка а.), шагыйрә, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1972 елдан Мәскәүдә яши. 1988–93 елларда Бөтенсоюз радиосында (1991 дән «Радио-1») «Әдәби очрашулар» («Поэтические встречи»), «Шагыйрь остаханәсе» («Мастерская поэта») тапшырулары циклының авторы һәм алып баручысы. 1993 тән Лондонда, Би-Би-Си радиостанциясендә хәзерге рус шигърияте турында тапшырулар алып бара. «Марина Цветаева Лондонда» («Марина Цветаева в Лондоне»), «Н.Гумилёв Лондонда» («Н.Гумилёв в Лондоне»), «Лондон станицасы» («Станица Лондонская»), «Мөселман Англиясе» («Англия мусульманская»), «Әхмәдия хатын-кызлары» («Женщины Ахмадии») һ.б. телефильмнар авторы. «Замана билгеләре» («Приметы века», 1974), «Май ае бакчасы» («Майский сад», 1981), «Йөзем яктысы» («Свет виноградный», М., 1984) җыентыклары, «Аралашу даирәсе» («Круг общения», М.,1986) шигъри романы, «Мәхәббәткә сусау» («Любовный голод», М., 1993) дүртьюллыклар китабы, «Акылдан язган бакчачы» («Сумасшедший садовник», М., 1999), «Бакча тәрбияләү» («Воспитание сада», СПб., 2001) китаплары авторы. Рус теленә Дәрдемәнд, М.Җәлил, С.Хәким, Ә.Давыдов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Абай шигырьләрен тәрҗемә итә. Аның шигырьләре инглиз, француз, япон, венгр һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ГРИГОРЯ́Н** Сурен Аршакович (17.8.1947, Тбилиси ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1993). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). 1972 елда Ереван ун-тын тәмамлый. 1976–93 елларда Әрмәнстан Госпланының исәпләү үзәгендә, 1993–95 тә Әрмәнстан милли ФАнең Матем. ин-тында эшли. 1996 дан Казан энергетика ун-тында (бүлекнеп, 1998–2003 тә Казан ун-тының Яшел Үзән ф-лында матем. һәм механика каф. мөдире), югары матем. каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре тигез үлчәмле алгебраларга, гомумиләштерелгән аналитик функцияләргә, төркемнәрдә гармоник анализга, С-алгебраларга карый. Г. гомумиләштерелгән мероморф функцияләрне факторлаштыруны эшли, гомумиләштерелгән аналитик функцияләрнең индуктив чикләмәләрен тикшерә, Бляшке алгебраларын кертә һәм тикшерә, Понтрягинның салынмалар турындагы теоремасын гомумиләштерә. Әрмәнстан Милли ФАнең чит ил әгъзасы (2008).

Х е з м.: Обобщенные аналитические функции // Успехи матем. наук. 1994. Т. 49, вып. 2; О структуре конечных покрытий компактно связных групп // Топология и приложения. 2006. Т. 153, № 18 (автордаш); Shift-invariant uniform algebras on groups. Basel-Boston-B., 2006 (автордаш).

**ГРИ́НБЕРГ** Александр Абрамович (20.4.1898, Петербург — 16.7.1966, Ленинград), химик-нәорганик, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1958; мөхбир әгъза 1943). 1924 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Платина h.б. затлы металларны өйрәнү ин-тында (1924–37) һәм Ленинград технол. ин-тында (1936–66 елларда гомуми һәм нәорганик химия каф. мөдире) эшли. Бер үк вакытта 1928–41, 1944–47 дә 1 нче Ленинград мед. ин-ты һәм 1947–49 да Ленинград ун-тында укыта, проф. (1932). Бөек Ватан сугышы елларында (1941–44) Казан хим.-технол. ин-тының һәм Казан ун-тының нәорганик химия каф. мөдире. Хезмәтләре комплекслы кушылмалар химиясенә карый. Казан хим.-технол. ин-тында эшләгән елларында Г. платинаның фосфор лигандлы координацион кушылмалары химиясе буенча фәнни юнәлеш булдыра. Платинаның комплекслы тозлары төзелешен һәм стереохимиясен, икевалентлы платина аммиакатларының югары темп-рада таркалуын, икевалентлы платина һәм палладий кушылмалары термик изомериясен тикшерә. Геометрик изомерларның төзелешен билгеләүнең яңа ысулын (Гринберг ысулы) тәкъдим итә. Платина семьялыгы металларының комплекслы кушылмаларында оксидлашу потенциаллары барлыкка килү механизмын аңлата. Комплекслы кушылмаларның эремәдә кислота-нигез һәм оксидлашу-кайтарылу үзлекләрен өйрәнә. Платина һәм палладийның магнитка бирешүчәнлеген тикшерү нәтиҗәсендә аларның комплекслы кушылмаларында бәйләнешләр характерын ачыклый. Уран, торий һ.б. элементларның комплекслы кушылмаларын өйрәнә, комплекслы кушылмаларның төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнү өчен тамгалы атомнар куллана. Полярлашу төшенчәләреннән чыгып, транстәэсир закончалыгын аңлата. Молекула комплексында янәшә урнашкан лигандларның кинетик цис-тәэсирен ача. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1946).



А.А. Гринберг.

Х е з м.: Введение в химию комплексных соединений. Л., 1971; Физическая химия комплексных соединений. Л., 1972.

*Әд.:* В а р ш а в с к и й Ю.С., Г е л ь ф м а н М.И. Александр Абрамович Гринберг. 1898–1966. Л., 1974; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**ГРИНЬ** Матвей Петрович (15.11.1927, Украина ССР, Хмельницкий ш. — 24.8.1998, Азнакай ш.), бораулаучы мастер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). Михаил Петрович *Гриньнең* энесе. 1948–50 елларда «Татнефтеразведка» трестының Кырымсарай нефтеразведкасында тракторчы, дизельче, бораулаучы ярдәмчесе булып эшли. 1950–90 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең Азнакай бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы, бораулау мастеры. Г. бригадасы 1972–75 тә СССР Нефть сәнәгате министрлыгында иң яхшылардан санала. Дәүләт бүләге хезмәттәге югары уңышлары һәм хезмәт процессларын камилләштерү нигезендә скважиналар төзү вакытын кыскарту өчен соц. ярыш оештыруы, бораулау эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрүдә резервлардан оста файдалануы, остазлык хәрәкәтен җәелдерүе өчен бирелә. Ленин

орденлары, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2.

**ГРИНЬ** Михаил Петрович (10.3.1924, Украина ССР, Хмельницкий ш. — 12.3.2003, Азнакай ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1959), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1974). 1947 елдан нефть сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. 1952–70 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең Азнакай бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы мастер, 1970–89 да идарә башлыгы урынбасары, 1989 дан шул ук идарә каршындагы «Орлёнок» пионер лагере директоры. Г. бригадасы, беренчеләрдән булып, өч секцияле турбоборау б-н югары режимда бораулауны үзләштерә. Герой исеме нефть сәнәгате үсешендә зур уңышларга ирешкәне өчен бирелә. 1962–66 да СССР ЮС, 1959–66 да ТАССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Азнакай шәһәрендәге бер урамга бертуган Гриньнәр исеме бирелә (1996), алар яшәгән йортка мемориаль такта куела (1997).

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Сагитов Т., Столяров Н. Гринь Михаил Петрович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Ларичева Э.И. Дороже золота. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГРИНЮ́К** Леонард Николаевич (13.6.1938, Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе Чашники а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Белоруссия урман-техник ин-тын (1960), Куйбышев төзүчеләр ин-тын (1969) тәмамлый. 1961 елдан Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында: 1968 дән баш белгеч, 1970 тән җитештерү пр-тиеләрен проектлаштыру бүлеге башлыгы. Дәүләт бүләге фән һәм техника өлкәсендәге «Нефть һәм газ чыганакларында үткәргеч торбаларның эчке өслеген саклаучы капламнар технологиясен эшләү һәм сәнәгый кулланылышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГРИНЯ́СКИ** Каролина Львовна (? – 1900 еллар башы), җырчы (сопрано), педагог. Милан консерваториясен (Лямперти һәм Бон классы) тәмамлый. Россиядә Казан антрепренёры Н.Дмитриев тарафыннан оештырылган Италия опера труппасы примадоннасы. Дж.Россини, Дж.Беллини, Дж.Верди операларында төп партияләрне башкара. 1865 елдан Казанда яши, 40 елдан артык укыта. Казанда вокал белеменә нигез салучыларның берсе. Аның ярдәмендә вокал классы булдырыла. Музыка сөючеләр түгәрәге һәм Нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте каршында хор коллективлары, концертлар оештыру б-н шөгыльләнә. Шәкертләре арасында Казан опера җырчысы һәм вокал педагогы С.Онихимовская-Боржимовская бар.

*Әд.:* Кантор Г.М., Карпова Е.К. Музыкальное образование в Казани в XIX веке // Из истории музыкальной культуры и образования в Казани. К., 1993.

**ГРИ́ПИЧ** Алексей Львович (30.9.1891, С.-Петербург — 1.10.1983, Мәскәү), режиссёр, Әзәрбайҗан ССРның халык артисты (1946). 1913 елда С.-Петербургта В.Э.Мейерхольд студиясендә укый, режиссёрлык эшчәнлеген 1919 да Карелия фронты театрында башлап җибәрә. 1921 дә Петроградта Яңа драма театрын оештыра, 1924–27 елларда Мәскәү Революция театрын, 1927–28 дә Одесса театрын җитәкли. 1928–29 да Казан Зур драма театрында режиссёр һәм сәнгать җитәкчесе. Ул оештырган Казан театр труппасында реж. П.К.Вейсбрем, Н.М.Холмогоров, рәссамнар Р.В.Распопов, В.А.Шестаков, Г.Л.Миллер, актёрлар Е.О.Адамайтис, М.Ф.Астангов, М.П.Бычкова-Дриго, П.И.Герага, М.И.Жаров, Е.Е.Жилина, И.Г.Ингвар, Респ-каның атказ. артисткасы З.Н.Минаева, С.С.Осипов, Е.К.Руднева, М.А.Юрьева эшли. Монда ул «Яшенле яңгыр» — «Гроза» (А.Н.Островский), «Цилиндр» (С.Поливанов), «Утлы күпер» — «Огненный мост» (Б.С.Ромашов), «Мәгърифәт җимешләре» — «Плоды просвещения» (Л.Н.Толстой), «Рельслар гөрелдәгәндә» — «Рельсы гудят» (В.М.Киршон), «Париж Мәрьям Ана соборы» — «Собор Парижской богоматери» (В.Гюго романы нигезендә), «Иң катгый җәза» — «Высшая мера» (Л.В.Никулин), «Чия бакчасы» — «Вишнёвый сад» (А.П.Чехов) спектакльләрен сәхнәгә куя. Мейерхольд иҗаты тәэсирендә Г. экспрессив формага, социаль мотивларны кискенләштерүгә, образларны ачуда гротеск куллануга, революцион пафоска омтыла. Күренешләргә өстәмә персонажлар кертү, күмәк сәхнәләрне үзенчәлекле итеп корып, вакыйгаларның мәгънәсен тирәнтен чагылдыруга ирешә. Стационар театр оештыру максатында тамашачыны театрга активрак җәлеп итәргә тырыша, еш кына эшчеләр янында була, спектакльләр алдыннан чыгышлар ясый, тамашачылар конференцияләре, иҗади очрашулар оештыра. Театрның 1928/29 сезоны шәһәрнең мәдәни тормышында истәлекле вакыйга була. Репертуар төзүдә Г. керткән яңа юнәлеш Казан театрының моннан соңгы тормышына сизелерлек йогынты ясый.

Г. соңыннан Мейерхольд исем. театрда эшли (1931 дән), Мәскәү театр студиясен (1934–38), Баку (1940–46), Саратов (1948–51), Воронеж (1951–52) театрларын, Мәскәүдә Киноактёрлар театр-студиясен (1952–56) һәм Пантомима театрын (1962 дән) җитәкли. 1932 дән Дәүләт театр сәнгате ин-тында укыта, мәдәни-агарту эше б-н шөгыльләнә.


*Әд.:* Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ГРИ́ШИН** Михаил Иванович (1921, хәзерге Ютазы р-ны Аксакүл а. — 13.2.1945), Дан орденының тулы кавалеры (10.4.1944, 2.9.1944, 10.4.1945), гв. өлкән сержанты (1945). 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1944 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1 нче гв. үзйөрешле тупчылар полкының үзйөрешле туп экипажы командиры (4 нче танк армиясенең 6 нчы гв. механикалаштырылган корпусы). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Проскуров-Черновцы, Львов-Сандомир (икесе дә — 1944), Силезия, Түбән Силезия һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 17–18 мартында Скалат шәһәреннән төньяк-көнчыгыштарак (Украина ССРның Тернополь өлкәсе Подволог р-ны) экипажы б-н дошманның 3 танкын сафтан чыгара, дзотын җимерә; 1944 нең 30 июленнән 11 августына кадәр Самбор шәһәре янында (Украина ССРның Львов өлкәсе) дошманның бронетранспортерын, 2 эре калибрлы пулемётын юк итә, 1945 нең 14 гыйнварыннан 4 февраленә кадәр Кельце шәһәре (Польша) янында һәм Одер елгасы буенда плацдарм өчен барган сугышларда дошманның танкын, 6 ут ноктасын һәм 3 бронетранспортёрын юк итә. 1945 нең 13 февралендә хәбәрсез югала.



Матвей П. Гринь.



Михаил П. Гринь.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

**ГРИ́ШИН** Николай Степанович (5.5.1940, Мәскәү өлкәсенең Загорск р-ны Краснозаводск ш.), химия технологиясе һәм экология гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тының механика ф-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли: конструкторлык бүлеге башлыгы (1976–83), сектор башлыгы (1996 га кадәр). 1996 да Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) фармакология һәм экотоксикология лаб-ясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. 1996–2005 тә ТРның төрле пр-тиеләрендә эшли. 2005 тән Казан технол. ун-тының химия производствосы машиналары һәм аппаратлары каф. проф. Хезмәтләре сыеклыклы экстракциягә һәм аналитик лаб-яләр өчен автоматлаштырылган аппаратларны гамәлгә кертүгә карый. Уйлап табуларга 30 авторлык таныклыгы бар. Үзешчән рәссамнарның бөтенроссия күргәзмәләрендә катнаша.

Хезм.: Концентрирование следов органических соединений. М., 1980.

**ГРИ́ШИН** Яков Яковлевич (8.3.1942, Биектау р-ны Эстачи а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1974–79 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-ты пропаганда һәм агитация бүлеге лекторы. 1979 елдан Казан ун-тының гомуми тарих кафедрасында, 1991 дән яңа һәм иң яңа тарих кафедрасында. Казан ун-тының халыкара мөнәсәбәтләр бүлеген оештыручыларның берсе, 1995 тән бүлек мөдире (факультетара бүлек деканы), 2000 нән халыкара мөнәсәбәтләр каф. мөдире, 2003 тән халыкара мөнәсәбәтләр һәм политология ф-ты

деканы. Хезмәтләре славян илләренең иң яңа чор тарихына, Польша-Литва татарлары тарихына, Икенче бөтендөнья сугышы елларында һәм хәзерге этапта халыкара мөнәсәбәтләр торышын тикшерүгә карый. Россия тарих фәнендә беренчеләрдән булып Польша-Литва татарлары тарихын, Казан төбәгенә сөрелгән полякларның язмышын өйрәнә.

Х е з м.: Драматические события в Польше. 1980–1981 гг. К., 1993; Политический поворот в Польше. 1948 г. К., 1994; Польско-литовские татары. К., 1995; Казань и Казанский край глазами польских ссыльных (XVII–XIX вв.). К., 1997; 600 лет совместной жизни: Краткая историческая хроника. К., 1997; Польско-литовские татары: взгляд через века. К., 2000.

*Әд.:* Международные исследования в России и СНГ: Справ. М., 1999; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

**ГРИ́ШКИН** Иван Иванович (1.11.1937, Рязань өлкәсе Спас-Клепики ш. — 29.6.1987, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1983), проф. (1984). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Казан консерваториясендә эшли. 1965–74 елларда Казан авиация ин-тында. 1974–87 дә Казан пед. ин-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре табигать фәннәренең фәлсәфи мәсьәләләренә, хәзерге заман фәнендә гамәлгә кергән «мәгълүмат» төшенчәсен кулланунын фәлсәфи һәм методологик мәгънәсе концепциясе үсешенә карый.

Х е з м.: Понятие информации (логико-методологический аспект). М., 1973; Управление, информация, интеллект. М., 1976.

**ГРИ́ШКИНО** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 20 кеше (руслар) яши. 1792 дә нигез салына. Рев-циягә кадәр Денисовка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, киндер эшкәртү б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында көнлекче булып эшли. 1870 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 61 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 83, 1859 да — 89, 1870 тә — 147, 1884 тә — 90, 1906 да — 131, 1926 да — 249, 1938 дә — 316, 1949 да — 285, 1958 дә — 226, 1970 тә — 194, 1979 да — 131, 1989 да — 32, 2002 дә — 22 кеше.

**ГРИ́ШКИНО** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* төньяктарак, Вятканың уң кушылдыгы Шыя елгасы буенда. 2008 елда 157 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1710 нан Кучу Помаш (Качи Памаш) авылы буларак билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1890 да ачыла), тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 303,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 33 ир-ат; 1859 да — 131, 1897 дә — 197, 1908 дә — 197, 1926 да — 186, 1949 да — 183, 1958 дә — 217, 1970 тә — 254, 1979 да — 222, 1989 да — 182, 2002 дә — 169 кеше.

**ГРО́ЛЬМАН** Лев Владимирович (19.4.1941, Казан), химик-технолог, РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1996), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1985), техник фән. канд. (1969). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1972 елдан лаб. , 1984 тән бүлек башлыгы, 1994 тән баш конструктор. Хезмәтләре махсус билгеләнешле ракета двигательләре, кече калибрлы артиллерия, хәрби, ау, спорт кораллары, газ һәм монтаж пистолетлары патроннары, кыр артиллериясе өчен дарылар, зарядлар эшләүгә карый. РФнең Дәүләт бүләге югары нәтиҗәле хәрби техника эшләнмәләрен эшләгәне һәм җитештерүгә керткәне өчен, РФ Хөкүмәте бүләге (2001) шарсыман дарыларның яңа составын һәм шартлагыч материалларны утильләштерү алымнарын эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 113 авторлык таныклыгы һәм 6 патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1983) б-н бүләкләнә.

**«ГРОМВА́Л»**, Казан шагыйре Г.П.*Каменев* балладасы, рус әдәбиятының романтизм билгеләренә ия булган беренче әсәрләреннән. Сюжет нигезендә сихерче Зломарның батыр сугышчы Громвалның сөйгәне чибәр Рогнеданы урлавы һәм баһадирның «Елан замогы»ндагы явыз көчләрне җиңүе турындагы риваять ята. Рус шигърияте ндә беренче булып, автор, Европа традицияләре (18 йөз рыцарь романнары, «зират фантастикасы» һәм Төн поэтикасы мотивлары) б-н беррәттән, татар милли темалары һәм образларын (Елан тавы турындагы риваять), Шәрекъ шигъриятенә хас булган символларны (роза чәчәге, төш) файдалана. «Г.» В.А.Жуковский балладаларына һәм 19 йөз башы рус романтик шигъриятенә билгеле бер йогынты ясый. Беренче мәртәбә 1804 елда Рус әдәбиятын, фән һәм сәнгатьне сөючеләр иректе җәмгыяте органы «Периодическое издание» дә (СПб.) басыла.

*А.Н.Пашкуров.*

**ГРОМЕ́КА** Ипполит Степанович (27.1.1851, Киев губ., Бердичев ш. — 13.10, 1889, Кутаиси губ., Кутаиси ш.; Седльце губ., Бельск ш. тирәсендәге Вулька-Плебанская а. җирләнгән), гидромеханик, гамәли матем. д-ры (1881). 1873 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1876–79 елларда Мәскәүнең 4 нче һәм 1 нче гимназияләрендә, 1879 да Бельск гимназиясендә укыта. 1879 дан Казан. ун-тының аналитик механика каф-сында, проф. (1882). Хезмәтләре гидромеханикага һәм газлар динамикасына карый. Г. капиллярлыкның, винтсыман һәм аркылы циркуляцияле агымнарның хәзерге заман матем. теорияләре нигезләрен эшли; үзле сыеклыкның тотрыксыз хәрәкәтен, эластик торбаларда сыеклыкның бәрмә дулкыннары таралуны, сыеклыкның сфера өслеге буйлап өермәле хәрәкәтен, идеаль газ тигезләнешен тикшерә. Г. исеме, тоташ тирәлек хәрәкәте тигезләмәсенең аталышына кертелеп, Громека-Лемб тигезләмәсе дип йөртелә.

Х е з м.: Собр. соч. М., 1952.

*Әд.:* В а с и л ь е в О.Ф. Памяти выдающегося русского гидромеханика И.С.Громека (к 100 летию со дня рождения) // Природа. 1951. № 9; К л о к о в В.В. Ипполит Степанович Громека. К., 2006.

**ГРО́МОВ** Виталий Викторинович (25.4.1901 Казан губ. Юкәче а. — 20.3.1972, Казан), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1944), проф. (1951), ТАССРның атказ. табибе (1948), В.Л.*Боголюбов* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1924), Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1926 елдан Казан ун-тының борын, колак, тамак авырулары клиникасында эшли. 1933 тән Өске сулыш юллары физиологиясе үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (Саратов ш.). 1937–71 елларда Казан ГИДУВында, 1950 дән оториноларингология каф. мөдире, бер үк вакытта 1941–50 дә Казан хәрби госпиталендә. 1936 да кеше бугазының үсеше турындагы хезмәтен тәмамлый, аның тарафыннан ЛОР авырулары клиникасы, аларның таралуы һәм профилактикасы өйрәнелә. Хезмәтләре чукрак-телсезлек һәм сугышта алган имгәнүләр проблемаларына карый. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессор Виталий Викторович Громов // Казан. мед. журн. 1972. № 4; П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ГРОСС А.Ф. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Анастасия Фёдоровна Гросс милке. 1900–15 елларда эшли, 5 хезмәткәре була. 1907–15 тә, аерым алганда, «Казан округы аралашу юллары хәбәрләре» («Известия Казанского округа путей сообщения»), «Телеграф бюллетененә өстәмәләр» («Дополнения к телеграфному бюллетеню») һ.б. басыла.

**ГРОСС** Леопольд Германович (4.8.1925, Кырым өлкәсенең Судак ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1988), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). 1950 елда Пермь ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый. 1954 тән Казан пед. ин-тында эшли. 1957–95 елларда Казан техфотопроект фәнни-тикшеренү ин-тында: төркем, лаб-я (1964 тән), бүлек җитәкчесе (1970 тән), лаб-я мөдире (1983 тән). 1995 елдан Германиядә. Хезмәтләре фотография тасмаларының фотоэлектрик үзлекләренә карый. Яктыга үтә сизгер фотография материалларының технологик параметрларын тикшерү методикасын һәм аларның нигезләрен эшли. Төсле негатив тасмаларга каплам ягуның һәм яңа магнитлы мәгълүмат йөрткечләрнең технологик линияләрен төзү һәм җитештерүгә кертә. Уйлап табуга 32 авторлык таныклыгы бар.

**ГРО́ШЕВ** Михаил Алексеевич (20.5.1947, Мурманск өлкәсенең Печенга р-ны Никель штп.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Горький политехника ин-тын тәмамлый (1973). Хезмәт эшчәнлеген 1965 елда Горький автомобиль з-дында ста-

ноклар көйләүче булып башлый. 1969–74 елларда СССР Автомобиль сәнәгате министрлыгының Горький проектлау-конструкторлык технол. ин-тында автоматлаштыру бүлеге инженер-конструкторы. 1974–86 да «КАМАЗ» ҖБнең Зәй автоагрегат з-дында конструкторлык бүлеге башлыгы. 1986 дан (бүленеп) «Алабуга автомобиль заводы» ҖБ АҖдә эшли: технол. бүлегенең баш технолог урынбасары, Станок-инструментлар з-дының баш конструкторы бүлеге башлыгы. 1994–97 дә Сукырлар җәмгыятенең Алабуга укыту-җитештерү пр-тиесендә әйдәп баручы белгеч. Уйлап табуга патенты бар. Дәүләт бүләге 50–80 тонна йөк күтәрешле нефть һәм газ скважиналарын ремонтлау һәм үзләштерү өчен югары техник күтәрү агрегатлары эшләгәне һәм җитештерүгә керткәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГРУ́ЗДЕВ** Викторин Сергеевич (24.1.1866, Кострома губ., Кинешма ш. — 7.2.1938, Казан), акушер-гинеколог, педагог, җәмәгать эшлеклесе, мед. д-ры (1894), хакыйкый статский советник (1915), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934, 1936). Казан акушер-гинекологлар фәнни мәктәбенә нигез салучы. 1891 елда Хәрби мед. академиясен (С.-Петербург) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1900 дән Казан ун-ты профессоры, акушерлык һәм гинекология кафедрасы һәм клиникасы мөдире. 1931 дән проф.-консультант. 1900 еллардан Г. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында акушерлык һәм гинекология буенча лекцияләр курсы укый, бер үк вакытта Кызыл Хач шәфкать туташлары Казан җәмгыятенең баш табибе. 1901 дә клиника каршындагы «Казанның Кодрәтләр кылучы Изге Варсонофий» чиркәвендә ктитор (чиркәү старостасы) итеп раслана, аңа чиркәү өчен акча җыю һәм аны төзекләндерү вазифасы йөкләнә.

Хезмәтләре аналык мускулатурасы морфологиясе һәм үсешен өйрәнүгә, имезүчеләрне ясалма аталандыру мәсьәләләренә карый. Клиник хезмәтләре хатын-кызның җенес органнары шешләрен (аналыкта яман шеш) өйрәнүгә, корсактан ярып алу, җенси әгъзада барлыкка килгән каналны оператив дәвалауга карый. Г. Россиядә беренче мәртәбә аналыкта яман шеш авыруын дәвалау өчен радий куллануны өйрәнә һәм аны куллану техникасын күрсәтә. Дәреслекләр һәм кулланмалар, ш.и. «Акушерлык һәм хатын-кыз авырулары курслары» (1922) китабы авторы. Г.ның табиблек эшчәнлеге стационар һәм амбулаториядә үтә, анда меңләгән йөкле хатыннарга, бала табучыларга һәм гинекологик авыруларга ярдәм күрсәтелә, 3 меңнән артык ярып алу операциясе башкарыла. Аның шәкертләре Н.И.Горизонтов, М.С.Малиновский, А.И.Тимофеев, Н.В.Маненков һ.б. бала тудыру, бала булмаудан дәвалау операцияләре вакытында авыртуны басу ысулларын эшлиләр.

1915 тә Казан ун-тында В.С.Груздев исем. бүләк булдырыла һәм ул Казан ун-тында башкарылган акушерлык, гинекология, ш.у. анатомия, гистология, эмбриология, патологик анатомия, бактериология өлкәсендәге иң яхшы хезмәтләр өчен бирелә.



В.С. Груздев.

Г. «Табигать һәм кешеләр» («Природа и люди») фәнни-популяр ж-лына нигез салучы һәм аның мөхәррире, «Русский архив патологии, клинической медицины и бактериологии», «Практическая медицина» ж-лларында хезмәттәшлек итә, 1897 дә «Казанский медицинский журнал» басмасын чыгаруны яңадан башлап җибәрә.

2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, 4 нче дәрәҗә Изге Апостолга тиң кенәз Владимир орденнары, император Александр III истәлегенә көмеш медаль б-н бүләкләнә. Акушерлык-гинекология клиникасына (1936) һәм Казанның бер урамына В.С.Груздев исеме бирелә.

Х е з м.: Саркомы яичников: Дис. ... СПб., 1894; К патологии и терапии рака матки. [Б. м.], 1911; Гинекология для студентов и врачей. К., 1922; Общая гинекология. К., 1922.

*Әд.:* М а н е н к о в В.П. В.С.Груздев. К., 1952; Неизвестный Груздев. К., 2000; 100 лет акушерско-гинекологической клинике. К., 2000.

*Д.П.Игнатьева, Д.Р.Нуретдинова.*

**ГРУЗИ́НСКИЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Казан-Түбән Новгород автомобиль юлы буенда. 2008 елда 47 кеше (руслар, чуашлар) яши. 1925 тә нигез салына. Башта ТАССРның Арча кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-ннарында. Халык саны: 1926 да — 70, 1938 дә — 141, 1949 да — 300, 1958 дә — 126, 1970 тә — 197, 1979 да — 124, 1989 да — 75, 2002 дә — 74 кеше.


**ГРУ́ША** (Pyrus), розачалар семьялыгыннан яфрак коя торган җимеш агачлары ыругы. 60 тан артык төре бар. Культуралы сортларның күп өлешен китереп чыгарган гади Г. төре киң таралган. Г. агачы 15–20 *м* биеклектә, пирамидага охшаган ябалдашлы була. Яктылык һәм җылылык ярата, корылыкка һәм эссегә чыдам. Кышка чыдамлылыгы алмагачка караганда түбәнрәк, әмма темп-раның кышкы үзгәрешләрен җиңелрәк кичерә. Яфраклары вак, тыгыз, ялтыравыклы. Чәчәкләре ак яисә яшькелт төсмерле, чәчәк төбеннән аерымланган шәмәхә-алсу серкәлек һәм баганачыклары бар.

ТР шартларында слива б-н бер үк вакытта, 10–17 майда иртә чәчәк ата. Үзеннән-үзе серкәләнми. Җимешләре, сортына карап, озынча һәм түгәрәк, аксыл-яшел яисә саргылт, кояшка караган ягында аз гына алсу төстә була, агачның күпьеллык өлешендә, күбесенчә балдакчаларында формалаша. Уссури грушасы б-н гибридлаштырылганнары берьеллык үрентеләрдә дә уңыш бирә ала. Татарстанда үсә торган сортларда җимешнең авырлыгы 50–80 *г.* Иртә өлгерешле (җәйге) сортлары август ахырында, көзге сортлары сентябрь уртасында өлгерә. Җимешләре, тулысынча өлгергәч, саргылт төскә керә, күп сортларының җимеш йомшагы сусыл була. Составында 80% су, 10% шикәр, 0,2–0,4% органик кислоталар, дуплау матдәләре, B, C витаминнары бар; яшел килеш һәм эшкәртеп (киптереп, компот, кайнатма, сок) кулланалар. Татарстанда Г. шәхси һәм коллектив, йорт яны бакчаларында үстерелә. Г. өчен иң яхшы шартлар — югары урыннар, Идел елгасының уң як яр буе (Югары Ослан һәм Кама Тамагы р-ннары). Элек Рус Бортасы (Кама Тамагы р-ны) авылында үстерелгән, анда хәзергә кадәр җимеш бирә торган агачлыклар яхшы сакланган. Г. туфракка талымсыз, ләкин туфрак асты яхшы үткәрүчән булырга тиеш. Корылыкка чыдам, су сибәргә кирәкми. Җирле һәм кыргый сортлар орлыгыннан үстерелгән ялганмага ялгау юлы б-н үрчетәләр. Алмагачтан аермалы буларак, җимеш бирүендә кабатланулар булмый, аның чәчәк бөреләре темп-раның кышкы һәм язгы үзгәрешеннән азрак зыян күрә. Г.ның күп сортлары, кышка чыдамсыз булганга, Татарстанда үстерүгә яраксыз. Селекциянең кышка иң чыдам элекке сортлары: җәйгеләре — «Бессемянка», «Волжская десертная», «Тонковетка», көзгеләре — «Бергамот осенний», «Казанская крупноплодная». Һәвәскәр бакчачылар җәйге сортлардан — «Космическая», «Северянка», «Лада», көзгеләрдән — «Любимица Яковлева», «Нарядная Ефимова», «Память Яковлеву» сортларын, башка төбәкләрдән күчерелгән, ш.у. Г.И.Розанова тарафыннан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында чыгарылган иң яхшы элиталы Г. сортларын үстерәләр. Җирле сортлардан «Бергамот осенний» сорты яхшы санала, җимешнең югары сыйфатлы булуы, җирле шартларга (кышка һәм корылыкка чыдам) җайлашуы б-н аерылып тора. Бу сорт, башкалардан аермалы буларак, үз агачы тамырыннан тамыр үргеннәре җибәреп үрчи. «Осенняя Яковлева» сорты да яхшы дип исәпләнә, ләкин ул кышка чыдамсызрак. Г. корткычларга һәм авыруларга алмагачка караганда чыдамлырак. Төп гөмбә авыруы — кутыр, корткычы — груша җимешашары. Г. табигый ябалдашын яхшы формалаштыра, шуңа күрә формалаштырып кисү кирәкми. Г. — озак яшәүче культура (60–70 елга кадәр җимеш бирә).

*Әд.:* Р у б ц о в Г.А. Груша. М.–Л., 1937; Ж у ч к о в Н.Г. Частное плодоводство. М., 1954; Р о з а н о в а Г.И. Селекция груши // Гр. Татар. НИИ сел. х-ва. 1970. Вып. 3.

*В.А.Наумов, Л.А.Севастьянова.*

**ГРЫЗЛО́В** Борис Вячеславович (15.12.1950, Владивосток ш.), дәүләт эшлеклесе, сәясәт фән. канд. (2001). Ленинград электротехник ин-тын тәмамлый (1973). 1973–77 елларда Коминтерн исем. ФҖБдә, Куәтле радиотөзелеш фәнни-тикшеренү ин-тында, 1977–96 да «Электронприбор» ҖБдә (Ленинград). 1996–98 дә Балтыйк техник ун-тының укытуның яңа технологияләре уку-укыту методик үзәге директоры. 1998 дән РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутаты, 1999 дан «Бердәмлек» блогы фракциясе җитәкчесе. 2001–03 тә РФ эчке эшләр минист-




**Груша сортлары**. 1. «Бергамот осенний»; 2. «Бессемянка»; 3. «Космическая»; 4. «Лада»; 5. «Тонковетка»; 6. «Казанская крупноплодная»; 7. «Чижовская»; 8. «Розановская».

ры. 2003 тән РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы рәисе, бер үк вакытта 2003–08 дә «Бердәм Россия» партиясе рәисе, 2088 дән шушы партиянең Югары советы рәисе. Мәкаләләре җәмгыятьнең сәяси тормышы мәсьәләләренә карый.

**ГРЮНВА́ЛЬД СУГЫШЫ́** (15.7.1410), Польша короле Владислав II Ягелло (Ягайло) җитәкчелегендәге поляк, литва, рус һәм татар гаскәрләренең Грюнвальд һәм Танненберг (Стембарк) авыллары янында немецларның Тевтон ордены гаскәрләрен тар-мар итүе. Польша һәм Литваның Тевтон орденына каршы алып барган сугышында борылышка әверелгән вакыйга. Ул сугышка Орден гаскәрләре тарафыннан яуланган Жемайтия халкының баш күтәрүе (1409) сәбәп була. Польша б-н Литва бу күтәрелешне хуплый. Моңа җавап йөзеннән Орден гаскәрләре сугышка әзер булмаган Польшага һөҗүм итә, Добжа һәм Төньяк Куявиянең тарихи өлкәләрен биләп ала. Җиңелгән Ягелло Литва кенәзе Витовт б-н килешү төзи һәм яңа сугышка әзерләнә башлый. Союзникларның поляк (18 меңлек атлы һәм 12 меңлек җәяүле гаскәр) һәм литва-рус (11 меңлек атлы гаскәр) отрядларыннан, ш.у. *Җәләлетдин ханның* татар атлы полкыннан (2 меңләп сугышчы) торган гаскәрләре 1410 елның 30 июнендә Мазовиядә кушылалар һәм Пруссиягә таба хәрәкәт итә башлыйлар. Аларга Орден гаскәрләре каршы чыга (16 меңлек атлы гаскәр, ш.и. 500 авыр коралланган рыцарь һәм 4 мең ялланган сугышчы, ш.у. 5 меңлек җәяүле гаскәр). 1410 ның 15 июлендә капма-каршы көчләр Грюнвальд һәм Танненберг авыллары арасында очрашалар. Поляк гаскәрләре үзәктә һәм сул флангта, литва һәм татар гаскәрләре берләшкән армиянең уң флангында урнаша. Аларга каршы Орден гаскәре сафлары тора. Аның б-н бөек магистр Ульрих фон Юнгинген җитәкчелек итә. Тупларны һәм арбалетларны ул сафлар алдына чыгара. Сугыш литва-татар кавалериясе һөҗүменнән башлана, бу һөҗүм кире кайтарыла. Сугыш барышында поляк отрядлары Орденның төп көчләрен тар-мар итәләр. Немец гаскәренең бер өлеше кача башлый, икенче өлеше лагерь ныгытмасына кереп яшеренергә тырыша. Берләшкән гаскәри көчләр тарафыннан ул ныгытмалар штурм б-н алына. Немец гаскәре тулысынча тар-мар ителә: берничә мең сугышчы, ш.и. Орденның 203 рыцаре һәм магистр үзе һәлак була. Ирешелгән җиңүне дәвам итеп, союзниклар армиясе Пруссиягә бәреп керә һәм Орденның башкаласы Мариенбургны камап ала. Орденны тәмам тар-мар ителүдән Ливония һәм Германия көчләренең ярдәмгә килүе генә коткарып кала. 1411 нең 1 февралендә яклар арасында солых төзелә, аның шартлары буенча Жемайтия Литвага кайтарыла. Г.с. Төньяк Европа тарихында борылыш пункт була, ул Тевтон орденының кодрәте бетүгә һәм Польшаның күтәрелә башлавына этәргеч бирә.

*Әд.:* Б р я н ц е в П.Д. История Литовского государства с древнейших времён. Вильно, 1889; Д л у г о ш Я н. Грюнвальдская битва. М.–Л., 1962.

*И.Л.Измайлов.*

**ГРЯЗНО́В** Анатолий Васильевич (20.11.1912, Казан — 7.4.1981, шунда ук), химик-технолог, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1938), В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында дозировщик, смена һәм остаханә башлыгы, өлкән мастер, производство һәм 40 номерлы Махсус техник бюро башлыгы (1948 дән), баш инженер (1949 дан), директор (1955–67) булып эшли. 1967–75 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында директор, 1975–81 дә «Союзхимпроект» ин-тының техник бүлегендә баш белгеч (Казан). Аның җитәкчелегендә завод яңадан үзгәртеп корыла. Техник яктан яңартыла, СССРда беренче тапкыр яна торган гильзалар житештерү үзләштерелә; химия продуктлары эшләп чыгару цехлары төзелә (эмальләр, лак, целлулоидлы уенчык, ясалма тукыма, яктырткычлар), алар б-н пр-тие халыкара базарга чыга (1962); фәнни-тикшеренү ин-тының яңа лаб.-конструкторлык һәм тәҗрибә-җитештерү базасы булдырыла һәм ул тармакның төп институтына әверелә. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы бар. СССР МС премиясе бирелә (1979). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Пороховая промышленность: Краткий ист.-биогр. справ. М., 1995; К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998; Из истории отечественной пороховой промышленности. М., 2000.

**ГРЯЗНУ́ХА** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Каманың сул кушылдыгы. Озынлыгы 6,6 *км*, бассейнының мәйданы 52 *км²*. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Галактионов исем. посёлок янында, тамагы Булдыр авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 100 *м*, тамагыныкы 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9%. Г. елгасының 4,8 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, кубесенчә кар сулары исәбенә туена. Елганың гидро-

логик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Г. елгасы ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ГУБА́ЕВА** Тамара Владимировна (27.4.1958, Казан), юрист, филолог, юридик фән. д-ры (1997), проф. (2001). Казан ун-тының филол. ф-тын тәмамлый (1979), шунда ук 1993 елга кадәр рус теле кафедрасында, 1993–98 елларда җинаятькә каршы хокук кафедрасында эшли. 1998–2001 дә Мари ун-тының Россия һәм чит илләр җәмәгать хокукы каф., 2001–02 дә Казан архит-ра-төзелеш академиясенең тормыш куркынычсызлыгы нигезләре һәм хокук каф. профессоры. 2002 дән Россия мәхкәмә эшләре академиясенең Казан ф-лында гомумтеоретик фәннәр каф. мөдире. Хезмәтләре җинаятькә каршы хокук, хокук теориясе, мәхкәмә эше теле, хокук белгечләренең язма һәм сөйләм теле стилистикасы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Практический курс русского языка для юристов. К., 1990; Словесность в юриспруденции. К., 1995; Язык и право. К., 2003.

**ГУ́БАРЕВА** Валентина Степановна (20.2.1932, Мәскәү), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), геол.-минерал. фән. канд. (1964). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), Бөтенсоюз геол. разведкалау нефть фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1988–2000 елларда Казан ун-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре Урал-Идел буеның геология, стратиграфия, палеонтологиясенә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан геологиясе: Стратиграфия һәм тектоника» («Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника», 2003) дигән коллектив монография өчен бирелә.

**ГУБА́ХА ШӘҺӘРЕ́**, *Пермь өлкәсендә*, Пермь шәһәреннән 142 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Халкы — 40,1 мең кеше (2008). 2002 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, татарлар — 3329 кеше. Г.ш.нә татарлар 1905 тә килеп урнаша; шул вакытта җирле тау токымнарын эшкәртү з-дында 1000 нән артык татар эшкә яллана. Завод хуҗасы алар өчен мәчет һәм мәктәп салдыра. Хәзерге вакытта шәһәрдә ел саен Сабантуй бәйрәме үткәрелә. 1999 дан мөселман мәхәлләсе эшли.

**ГУБЕРНА́ТОР САРАЕ́**, Казанда рус архит-расы истәлеге. 1845–48 елларда арх. А.И.Песке тарафыннан арх. К.А.Тон проекты б-н «рус-византия» стилендә Казан губернаторы резиденциясе итеп төзелә. Казан Кремленең төньяк өлешендә, фаразланганча, элек Казан ханнары сарае, соңрак обер-комендант йорты утырган урында урнашкан. Антресоль һәм эргә катлары булган өч катлы симметрияле бина хуҗалык максатындагы корылмалар б-н бергә ярымтүгәрәк ишегалды хасил итә. Кареталар тоту урыны, печәнлек, келәтләр һ.б. булган хуҗалык корпусы бар. Үзәк фасад уртасында 3 аркалы фронтон б-н төгәлләнүче ризалит урнашкан. Сарайның төп керү юлларына баскыч күтәрелә. Г. с. фасадларының эклектик бизәлешендә рус классицизмы, барокко, борынгы рус архит-расы һәм псевдовизантия стильләре элементлары кушылган. 1 нче катта канцелярия һәм хезмәтчеләр өчен бүлмәләр, 2 нче катта чишенү, кабул итү, йокы һәм кунак бүлмәләре, зал һәм эш кабинетларыннан торган губернатор фатиры урнашкан. 3 нче каттагы шундый ук максаттагы бүлмәләр император гаиләсе әгъзаларын кабул итү апартаментлары булып хезмәт иткән. Эчке бизәлеше арх. М.П.Коринфский җитәкчелегендә заманчалаштырылган рус классицизмы стилендә башкарыла. Г.с. янәшәсендә Введение





Губернатор сарае. Казан. Арх. К.А.Тон. 1845–48. 1. 20 йөз башы фотосурәте; 2. Хәзерге күренеше.

чиркәве була (18 йөз, Казан ханлыгы дәверендәге мәчет урынында төзелгән), ул 1849 да сарай чиркәве итеп үзгәртеп корыла һәм ябык галерея ярдәмендә сарай б-н тоташтырыла. Совет чорында Г.с. бинасында ТАССР Министрлар Советы урнаша. Хәзерге вакытта ТР Президенты резиденциясе. 2000 дә Г.с. реконструкцияләнә (И.С.Габдрахманов, Е.И.Прокофьев, В.П.Логинов һ.б. катнашындагы авторлар төркеме).

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; Ф е х н е р М. Великие Булгары, Казань, Свияжск. М., 1978; А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1981; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Т.В.Пашагина.*

**ГУ́БКИН** Иван Михайлович (9.9.1871, Владимир губ., Муром өлкәсе Поздняково а. — 21.4.1939, Мәскәү), нефтьче, СССРда нефть геологиясенә нигез салучы, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1929), СССР ФАнең вице-президенты (1936). Петербург тау ин-тын тәмамлаганнан соң (1910), Россиянең Геология комитетында эшли. 1917 елда нефть сәнәгатен өйрәнү өчен АКШка командировкага җибәрелә. 1918 дән Баш нефть комитетында эшли, 1919 дан Баш сланец комитеты җитәкчесе, 1920–25 елларда Курск магнит аномалиясен өйрәнү буенча махсус комиссия рәисе. 1920 дән Мәскәү тау академиясе профессоры, 1922–30 да ректоры, бер үк вакытта Янучан казылмалар ин-ты (1924–39) һәм Мәскәү нефть ин-ты (1930–31) директоры. 1931 дән Бөтенсоюз ХХСның Дәүләт геол.-разведкалау идарәсе башлыгы. 1930–36 да СССР ФА каршындагы Җитештерүче көчләрне өйрәнү советы рәисе. 1936 дан СССР ФА вице-президенты, 1937 дән СССР ФА Әзәрбайҗан филиалы рәисе. Нефть һәм газ табыла торган чыганакларны тикшерүнең комплекслы ысулын эшли һәм уңышлы файдалана. Ләм вулканнарының килеп чыгышы һәм таралу закончалыклары турында тәгълимат булдыра, аларның нефть чыганаклары б-н бәйләнешен билгели. Г. нефтьнең барлыкка килүе турында оригиналь теория тәкъдим итә, нефть ятмаларының беренчел яки икенчеллеге мәсьәләләрен, нефть һәм газ миграциясен, нефть ятмалары классификациясен өйрәнә һәм аларның таралу закончалыкларын билгели («Нефть турында тәгълимат» — «Учение о нефти». М., 1932). Рус платформасының көнчыгыш р-ннарындагы геол. тикшерүләрне җитәкли һәм Идел-Уралдагы нефтьле һәм газлы төбәкләрнең сәнәгый перспективасын нигезли («Урал-Идел нефть һәм газ өлкәсе» — «Урало-Волжская нефтегазоносная область». М.–Л., 1940). Г. — Татарстанда нефть эзләү эшләренең беренче оештыручысы. 1920 елларда респ-каның көнбатышында битумнарны тикшерү эшләрен үткәрә. СССР ЮС депутаты (1937–39). Ленин бүләге лауреаты (1929). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Шәһәргә, посёлок, район, мәгъдән учагы (рудник), чыганак, ике институт, фәнни тикшеренү судносына аның исеме бирелә. 1949 да СССР ФА нефть геологиясе өлкәсендәге казанышлар өчен акад. И.М.Губкин исемендәге бүләк булдыра.



И.М. Губкин.

Х е з м.: Избранные сочинения: В 2 т. М.–Л., 1950–53.

*Әд.:* К у м о к Я.Н. И.М.Губкин. М., 1968.

**ГУ́БСКАЯ** Валентина Емельяновна (1.11.1949, Чуаш АССРның Алатырь р-ны Керя а.), театр рәссамы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Казан сынлы сәнгать уч-щесенең бизәлеш-декорация рәссамнары бүлеген (1969, Ә.И.Тумашев һәм Л.М.Кальюранд җитәкчелегендә), Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы югары режиссёрлык курсларын (ГИТИС, 1972, Курчак театры бүлеге, җитәкчесе — С.В.Образцов) тәмамлый. 1969–70 елларда Томск курчак театрында рәссам булып эшли. 1972 дән Казан курчак театрының баш рәссамы.



В.Е.Г у б с к а я. Лопейсканың «Ләкләк баласы һәм Карачкы» пьесасы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. Гуашь, акварель. 1990.



А.А.Г у б с к и й. М.Супонинның «Хәлләр ничек, хәйләкәр?» пьесасы буенча куелган спектакльгә ширма эскизы. Гуашь, акварель. 1996.

Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1979). Дөнья классикасы әсәрләренә — «Су кызы» («Русалочка», Г.-Х.Андерсен, 1977), «Золушка» (Ш.Перро, 1987), «Кар патшабикәсе» («Снежная королева», Е.Шварц, 1998), «Рамаяна» (Л.Кожевников, 2001), ш.у. хәзерге заман драматурглары пьесаларына — «Елан күзе» (И.Зиннуров, 1983), «Ак күлмәктә кара елан» (Р.Корбан, З.Думави, 1998), «Чулпан йолдыз калыкканда» (Зөлфәт, 1999), «О, шаян Шүрәле!» (Г.Зәйнашева, 2000) һ.б. нигезләнгән 70 кә якын спектакль өчен сәхнә бизәлеше эшли. 1970–90 елларда Г. иҗаты татар курчак театрында сәхнә бизәлеше сәнгате үсешенә этәргеч бирә. 1975–81 дә Казан театр уч-щесендә курчаклар ясау технологиясен укыта. Россиядә һәм чит илләрдә узган сәнгать күргәзмәләрендә (1976, 1977, 1978, Мәскәү; 1977, Прага; 1979, Ташкент), СССР-да румын драматургиясе фестивалендә (1983, А.Попескуның «Тылсымчы мамык бөртеге» («Пушок-волшебник») буенча куелган спектакль бизәлеше өчен Мактау дипломы), Курчак театрларының халыкара фестивальләрендә (1995, Төркия, Адана ш.; 1997, «Рязанские смотрины», Рязань; 2000, Франция, Канны ш.; 2001, «Пьеро-2001», Болгария, Стара-Загора ш.), «Гостиный двор» халыкара театр сәнгате фестивалендә (2000, Оренбург) катнаша. 1992 дә «Сикерә торган патша кызы» («Прыгающая принцесса», Л.Дворский) спектакле К.Тинчурин исем. респ-ка театр фестивалендә «Сезонның иң яхшы сәхнә бизәлеше» бүләгенә лаек була. Г. әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Дәүләт үзәк театр музеенда, Балалар театрлары музеенда (Мәскәү) саклана.

*Әд.:* С а т т а р о в а Н. Сценографы Татарии // Театр. 1977. № 10; Казанский государственный театр кукол. К., 1984; И г л а м о в Р. День вчерашний — день сегодняшний // Театральная жизнь. 2000. № 11/12; Современная сценография Татарстана: Каталог выставки. К., 2002.

*Р.Р.Солтанова.*

**ГУ́БСКИЙ** Александр Анатольевич (4.8.1950, Украина ССР, Кировоград ш.), театр рәссамы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1990). Казан сынлы сәнгать уч-щесенең бизәлеш-декорация рәссамнары бүлеген тәмамлый (1973, Ә.И.Тумашевта укый). 1976 елдан Казан Курчак театрында куючы рәссам булып эшли, бер үк вакытта Казан театр уч-щесендә (1982–2001), Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә курчаклар ясау технологиясен укыта (1998–2001). Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1983). С.Маршакның «Теремок» (1981), А.Милнның «Винни Пух һәм башкалар» («Винни Пух и все, все, все», 1983), Р.Бохараевның «Йолдызчык-ромашка» («Звездочка-ромашка», 1985), «Апушның тылсымлы төшләре» («Волшебные сны Апуша», 1986), Ю.Коренецның «Нәни Убырлы карчык» («Маленькая Баба-яга», 1993), К.Биссетның «Юлбарыс белән әңгәмә» («Беседа с тигром», 1995), В.Смеховның «Гали баба һәм кырык карак» («Али-баба и сорок разбойников», 2000) һ.б. әсәрләр буенча барлыгы 40 тан артык спектакль өчен сәхнә бизәлеше иҗат итә. Күп кенә спектакльләр өчен курчакларны хатыны В.Е.*Губская* б-н бергәләп ясый. 1970–80 елларда сәхнәне үзенчәлекле бизәү һәм курчакларны сәхнә мәйданында уйнатуның яңа формаларын эзләү омтылышы алар исеме б-н бәйле. Г. Курчак театрларының халыкара фестивальләрендә катнаша (1995, Төркия, Адана ш.; 2000, Франция, Канны ш.; «Пьеро-2001», Болгария, Стара-Загора ш.).

*Әд.:* И г л а м о в Р. День вчерашний — день сегодняшний // Театральная жизнь. 2000. № 11/12; Современная сценография Татарстана: Каталог выставки. К., 2002.

*Р.Р.Солтанова.*

**ГУ́ДИН** Владимир Аркадьевич (30.9.1955, Киров өлкәсе, Верхошимежье р-ны Верхошимежье а.), физиолог, биол. фән. д-ры (2006). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1978), шунда ук эшли. Хезмәтләре а.-х. хайваннарының төрле яшьләрдәге физиологиясен, органнарының функциональ-төзелеш бәйләнешен өйрәнүгә карый. Г. тарафыннан яшьрәк а.х. хайваннарында серотонинергик системаның функциональ активлыгы, ш.у. постнаталь чорда онтогенезның төр үзенчәлекләре һәм закончалыклары турында яңа мәгълүматлар алына.

Х е з м.: Руководство для лабораторно-практических занятий по физиологии сельскохозяйственных животных: В 5 ч. К., 1990 (автордаш); Серотонинергическая система, её роли, закономерности и особенности постнатального становления у сельскохозяйственных животных. К., 2004; Принцип функциональной взаимосвязи и взаимозависимости серотонин-, гистамин- и адренергической систем у животных в онтогенезе // Сельскохозяйственная биология. 2006. № 6 (автордаш).

**ГУ́ДИН** Николай Васильевич (26.4.1916, Вятка губ., Орёл өязе Сушковшина а. — 19.6.2006, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1986, 1993), РФнең югары белем мәктәбе мактаулы хезмәткәре (1997). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация з-дында эшли (1947 гә кадәр). 1951 дән Казан технол. ун-тында, 1972–88 елларда электрохимик җитештерү технологиясе каф. мөдире. Күләмле (электролитларда) һәм өслекле (электродларда) комплекслар хасил булуның ролен; даими һәм импульслы ток кулланып, металлар һәм эретмәләрне электрохимик камау, элементлы легирлау һәм анодта эретү вакытында протоннар тәэсирен тикшерә. ЭПР һәм ТМР алымнары б-н гальванотехникада иң күп кулланыла торган күчеш металларының моно-, поли-, гетерокомплекслары составын һәм электрохимик характерын өйрәнә. Катлаулы профильле детальләрдә һәм эшләнмәләрдә гальваник капламнарны электрохимик юл б-н шомартканда электролизёрларның электрик кыры структурасын өйрәнү өчен автоматлаштырылган җайланма уйлап таба һәм эшләп чыгара. d-Элементлар аминокомплекслары нигезендә бакырлау, цинклау, никельләү, җизләү, көмешләүнең яңа электролитларын эшли һәм җитештерүгә кертә. Бу хезмәтләре өчен СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә. Биомассаны ясалма үстерү өчен биологик актив кислород күчергечләр табуның электрохимик ысулын тәкъдим итә. Югары белем мәктәбендә инженерлык химия-технол. белемен гуманлаштыру һәм экологияләштерүнең инициаторы. Электрохимия һәм экология проблемалары буенча үзенчәлекле эшкәртмәләр авторы. ТАССР МС каршындагы Казан һәм республика сәнәгать пр-тиеләре эшлеклеләре өчен гальванотехника буенча үткәрелгән семинар җитәкчесе (1960–70), Татарстан Респ-касының металларны һәм эретмәләрне коррозиядән саклау ком-ты рәисе (1970–85). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1983) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Роль объёмного и поверхностного комплексообразования при электроосаждении импульсным током цинк-хромовых, цинк-никелевых и никель-фосфорных покрытий // Электроосаждение металлов и сплавов. М., 1991 (автордаш); О механизме электронного акта электрохимического восстановления d-элементов // Прикладная электрохимия: Межвузовский сб. науч. тр. К., 1992 (автордаш); Влияние деполяризации и дофазового осаждения цинка при осаждении с никелем // Электрохимия. 1996. Т. 32, № 3 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГУДКО́ВА-ЛА́МБЕРОВА** Валентина Яковлевна (22.8.1926, Саратов өлкәсе, Петров р-ны Бобровка а. — 4.4.2006, Казан), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1950–81 елларда «Советская Татария» г-тасында эшли (әдәби хезмәткәр, 1961 дән фән, вузлар һәм мәктәпләр бүлеге мөдире). Язмалары ш.у. «Социалистик Татарстан», «Советская культура» (Мәскәү) г-таларында басыла. Замандашлары — фән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре эшчәнлегенә һәм яшь

буынны тәрбияләүгә багышланган публицистик мәкаләләр, очерклар авторы. ТАССР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. республика бүләге иясе (1978).

Ә с ә р.: Завидная судьба // Ради счастья людского. К., 1962; Маресьев из Альметьевского района // Народный учитель. М., 1968; Жизненная высота // Сто дорог — одна твоя. К., 1988.

**«ГУДЫРИ́»** («Күк күкрәү»), иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм әдәби газета. 1918 елның 31 октябреннән 1919 ның апреленә кадәр Алабуга шәһәрендә удмурт телендә нәшер ителә, барлыгы 56 саны чыга. 1921 нең мартыннан Глазов һәм Сарапул шәһәрләрендә, 1921 нең июленнән Ижевск шәһәрендә чыга. Исеме: 1930 дан «Удмурт коммуна» («Удмурт коммунасы»), 1943 тән «Советская Удмуртия» («Совет Удмуртиясе»), 1992 дән «Удмурт дунне» («Удмурт дөньясы»). Беренче өч санын Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе сәяси бүлеге чыгара. Аннан соң газета Алабуга өязе Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы органы буларак чыга. Беренче мөхәррире — удмурт халкы дәүләтчелеген булдыручыларның берсе большевик Т.К.Борисов. Газета битләрендә аның баш мәкаләләре басыла, аларда ул Вятка, Казан, Самара, Пермь һәм Уфа губерналарында күпләп яшәүче удмуртларны берләштергән, башкаласы Сарапул шәһәре булган Кама буе губернасын төзү тәкъдиме б-н чыга. Анда ш.у. удмурт иҗтимагый-сәяси эшлеклеләре, язучы, шагыйрь, мәгърифәтчеләре дә аналитик мәкаләләр һәм этнографик очерклар, хәбәрләр һәм шигырьләрен бастыра. Газета Совет хөкүмәтенең һәм большевиклар партиясе оешмаларының рупоры хезмәтен үти. Аның битләрендә удмуртларның милли-дәүләти, икътисади һәм мәдәни проблемалары күтәрелә. Халык мәгарифен үстерү, удмурт әдәби телен булдыру мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Адмирал Колчак армиясе һөҗүме башлангач, газета чыгудан туктап тора. 1920 нең гыйнварында РСФСР Милләтләр эше халык комис-ты каршындагы Удмурт комис-ты Сарапулда аны яңадан чыгара башлый. 1920 елның ноябреннән, Вотяк автономияле өлкәсе төзелгәч, «Г.» Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар советының өлкә башкарма комитеты һәм РКП(б) өлкә ком-ты органы буларак чыга. Мөхәррире П.Н.Баграшов.

*К.И.Куликов.*

**ГУ́ЛИН** Борис Валентинович (27.10.1939, Казан — 18.04.1986, шунда ук), механика гыйлеме белгече, физика-матем. фән. д-ры (1986), 1962 елда Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый. 1963–66 елларда Казан төзүче-инженерлар ин-тында эшли, 1966 дан СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре юка сүрүләрнең сыгылмалы тутырма б-н, үткәрүчән йомшак сүрүләрнең сыеклык агымы б-н динамик тәэсирләшүләрен тикшерүгә карый. Бу мәсьәләләрне чишкәндә чикле аермалар һәм дискрет өермәләр ысуллары камилләштерә һәм куллана, тукыма сүрүләрнең матем. модельләрен эшли. Каты ягулыклы ракета двигательләрендә, парашют һәм җилдән саклау системаларында бара торган процессларны модельләштерү эшләрен тасвирлый.

Х е з м.: Прочность, устойчивость и динамика оболочек с упругим заполнением. М., 1977 (автордаш); Расчёт оболочек с упругим заполнением. М., 1987 (автордаш); Динамика мягких оболочек. М., 1990 (автордаш).

**ГУ́ЛОВА** Миңҗамал Вәлиулла кызы (1902, хәзерге Лениногорск р-ны Мөэмин-Каратай а. — 1981, шунда ук), әкиятче. Г. әкият жанрының барлык төрләрен дә туплый. 1976 елда фольклорчы Л.Ш.Җамалетдинов аңардан 30 дан артык әкият язып ала.

*Әд.:* Җ а м а л е т д и н о в Л.Ш. Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым // Казан утлары. 1978. № 3.

**ГУ́ЛЬКИН** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чупай елгасы буенда. 2008 елда 319 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 57%, руслар — 33%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1656 дан Пустошь Манчи исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәр Кече Чуаш Батрасы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәч һәм мичкә ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Г. да тегермән була. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 910 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 273, 1912 дә — 584, 1926 да — 507, 1938 дә — 413, 1949 да — 373, 1958 дә — 469, 1970 тә — 415, 1979 да — 286, 1989 да — 214, 2002 дә — 324 кеше. Сов. Союзы Герое Г.Ф.*Ларионов* туган авыл.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ГУЛЯ́ЕВ** Александр Александрович (30.10.1920, Чистай кантоны Аксубай а. — 16.8.1992, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССРның атказ. урманчысы (1968). 1954 елда Бөтенсоюз урман-техника ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1946 дан Аксубай урман хуҗалыгында эшли, 1956 дан директор. 1959 дан ТАССРның урман хуҗалыгы идарәсе башлыгы, 1979–84 елларда ТАССР урман хуҗалыгы министры. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары; 12 медаль б-н бүләкләнә.

**ГУЛЯ́ЕВ** Василий Георгиевич (12.9.1903, Тверь губ., Новоторжок өязе Голубово а. — 21.6.1982, Казан), генерал-майор (1943). Ленинград журналистика ин-тын (1934), Сәяси составны камилләштерү югары курсларын (1943, Мәскәү) тәмамлый. 1935 елдан СССР ФАнең Ленинград бүлегендә фәнни һәм партия эшендә. 1939–41 дә танк бригадасы комиссары, танк дивизиясе командиры урынбасары. Бөек Ватан сугышында 4 нче гв. танк армиясендә дивизия, бригада, корпус комиссары, Хәрби совет әгъзасы. 1946 дан Ленинградтагы Сов. Союзы Маршалы С.М.Будённый исем. Хәрби элемтә академиясендә сәяси бүлек башлыгы. 1949 дан Балтыйк буе хәрби округы Сәяси идарәсе башлыгы, 1950 дән Белоруссия хәрби округының 7 нче механикалаштырылган армиясе штабы башлыгы урынбасары, 1951 дән Идел буе хәрби округы бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләре командующие урынбасары. 1953–55 тә Казан югары техник-бронетанк офицерлар мәктәбендә сәяси бүлек башлыгы. Ике Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Человек в броне. М., 1964.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГУЛЯ́ЕВ** Николай Александрович (17.11.1914, Пенза губ., хәзерге Мордва Респ-касы Краснослободск ш. — 24.3.1986, Тверь ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1957), проф. (1958). Ленинград пед. ин-тын тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947 елдан Томск ун-тында, 1959 дан Казан ун-тында (рус һәм чит илләр әдәбияты каф. мөдире, 1972 дән чит илләр әдәбияты каф. мөдире), 1977 дән Тверь ун-тында (әдәбият теориясе каф. мөдире). 1940–50 елларда чит илләр әдәбиятында классицизм һәм мәгърифәтчелек реализмы проблемаларын, 1950 еллар ахырыннан рус һәм чит илләр әдәбиятлары романтизмының теориясен һәм тарихын, әдәби-тарихи процесста романтизм б-н реализмның үзара бәйләнешен тикшерә (романтизмны «эчке баланска ия булган эстетик система» дип саный һәм аңа карата ике төрле: гносеологик һәм тарихи караш барлыгын дәлилли). Хезмәтләре Көнбатыш һәм рус мәгърифәтчеләре иҗаты һәм эстетикасына, Г.Лессинг иҗатының — классицизм, В.Г.Белинский эстетикасының 19 йөз чит ил әдәбиятлары эстетикасы б-н бәйләнешләрен өйрәнүгә карый. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Лессинг и классицизм. Томск, 1955; В.Г.Белинский и зарубежная эстетика его времени. К., 1961; Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX вв. М., 1983; Теория литературы. М., 1985.


*Әд.:* К а р т а ш о в а И.В. Концепция романтизма в трудах Н.А.Гуляева // Романтизм: открытия и традиции. Калинин, 1988.

*И.В.Карташова.*

**ГУЛЯ́ЕВ** Якуб (Йомагыл) (? — 1770 тән соң), педагог, тылмач, коллегия регистраторы. Оренбургта татар тылмачлары мәктәбен оештыручы һәм аның җитәкчесе (1744–70). Россия илчелеге вәкиле сыйфатында рус сәүдәгәрләренең Харәземгә сәүдә экспедициясендә катнаша (1753).

**ГУМИЛЁВ** Лев Николаевич (1.10.1912, Петербург губ. Царское Село ш. — 15.6.1992, С.-Петербург), тарихчы, географ, этнограф, тарих фән. д-ры (1967). Дворяннар нәселеннән. Ленинград ун-тын тәмамлый (1946). 1931 елдан Себер, Памир, Кырымда геологик,

археологик һәм этнографик экспедицияләрдә катнаша. Берничә тапкыр репрессиягә дучар ителә (1935, 1938–43, 1949–56). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1956–67 елларда Дәүләт Эрмитажы китапханәчесе, 1967–86 да Ленинград ун-ты каршындагы География фәнни-тикшеренү ин-ты хезмәткәре. Кешелек дөньясының һәм аерым этносларның биосоциаль асылын билгеләүче фәнни тәгълиматны нигезли. Г. тикшеренүләрендәге төп тема — Евразия тарихы. «Хунну. Урта Азия борынгы заманнарда» («Хунну. Срединная Азия в древние времена», М. 1960), «Хәзәрстанны ачу» («Открытие Хазарии», М., 1966), «Борынгы төркиләр» («Древние тюрки», М., 1967), «Уйдырма патшалыкны эзләү: «Пресвитер Иоанн дәүләте» турындагы легендалар» («Поиски вымышленного царства: Легенды о «Государстве пресвитера Иоанна», М., 1970), «Каспий тирәсендә меңьеллык» («Тысячелетие вокруг Каспия», Баку, 1991) дип аталган хезмәтләрендә, күчмә халыкларның көнкүреше, мәдәнияте, дине һәм теле турындагы бай материалга нигезләнеп, күчмә һәм утрак кабиләләр арасында кискен каршылыклар булуы теориясен кире кага, алар арасында һәр этносның теге яки бу тормыш рәвешенә хокукын тануга нигезләнгән динамик мөнәсәбәтләр хөкем сөрүен исбатлый. Аның тикшеренүләре нәтиҗәсендә Евразия континентының сәяси яктан өч тапкыр — төркиләр, монголлар һәм Россия тарафыннан берләштерелүе дәлилләнә. «Борынгы Русь һәм Бөек дала» («Древняя Русь и Великая степь», М., 1989), «Русьтан — Россиягә: Этник тарих буенча очерклар» («От Руси к России: Очерки этнической истории», М., 1992) дип исемләнгән монографияләрендә Россия дәүләтчелегенең формалашу тарихы, ш.и. Мәскәү, соңрак Русь дәүләтенең Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда, татар ханлыклары б-н мөнәсәбәтләре яктыртыла. Аның «Этногенез һәм Җир биосферасы» («Этногенез и биосфера Земли», М.–Л., 1987), «Тарихи чорда этносның географиясе» («География этноса в исторический период», Л., 1990) хезмәтләре төрле этносларның борынгы заманнардан хәзерге чорга кадәрге вакыт аралыгында барлыкка килүе һәм үсеше проблемаларына багышлана. Ш.у. тарихи география һәм этнография буенча хезмәтләр авторы. Г.ка Казанда бюст куелган.



Л.Н. Гумилёв.

Х е з м.: Георафические работы Н.Я.Бичурина в Центральном государственном архиве Татарской АССР. Чебоксары, 1960. (автордаш); Хунны в Китае: Три века войны Китая со степными народами. М., 1974; Старобурятская живопись. М., 1975; Ритмы Евразии: Эпохи и цивилизации. М., 1993; Этносфера: История людей и история природы. М., 1993.

*Әд.:* Лев Николаевич Гумилёв: Библиогр. указ. К., 1990; Л а в р о в С.Б. Завещание Л.Н.Гумилёва // Евразия: Народы. Культура. Религия. 1993. № 2; Ч е р е м и с с к а я М.И. Лев Николаевич Гумилёв и его научное наследие: Памяти историка и этнографа // Восток: Афро-азиатские общества: История и современность. 1993. № 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ГУМИЛЁВСКИЙ** Григорий Иосифович (1853, Спас өязе Матвеевка а. — 1926, Казан), физиолог, анатом, проф. (1891). 1878 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1904 елга кадәр шунда ук эшли. 1885 — 86 елларда Берлин, Дрезден шәһәрләрендә хезмәт күнекмәләре ала. 1904–17 дә Харьков вет. ин-ты директоры. Хезмәтләре хайваннарда кан әйләнеше физиологиясенә карый. 3 нче дәрәҗә Изге Станислав һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние сокращения мышц задних конечностей на кровообращение последних. К., 1882; Всасывание в тонкой кишке // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1886. Т. 3.

*Әд.:* Григорий Иосифович Гумилевский // Вестн. обществ. ветеринарии. 1911. Т. 6; Энциклопедический словарь Брокгауза и Ефрона: Биографии. М., 1993. Т. 4.

*О.М.Гыйльметдинова.*

**ГУ́ММЕРТ** Рудольф Августович (12.7.1861, С.-Петербург губ. Ораниенбаум ш. — 7.2.1922, Казан), пианист, педагог, дирижёр, композитор, муз.-җәмәгать эшлеклесе. Россия музыка педагогикасының күренекле эшлеклесе һәм Татарстан музыка белеменә нигез салучыларның берсе. Петербург консерваториясен тәмамлый (1887). 1887–91 елларда А.Орлов-Соколовский (Казан) музыка мәктәбендә укыта. 1891 елда (1893 кә кадәр П.Юргенс б-н берлектә) 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казанда төп музыка уку йорты булган шәхси музыка мәктәбен оештыра. 1904–18 дә Казан музыка уч-щесе директоры, бер үк вакытта 1902–17 дә Рус Император музыка җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе. Фортепиано һәм музыка теориясе фәннәрен укыта, актив муз. агарту эшчәнлеге алып бара: укучылары симф. оркестры б-н чыгышлар ясый, укучылар көче б-н сәхнәгә опералар әзерли. Казан губернасында музыка белеме үсешенә нигез сала (Сарапул, Алабуга шәһәрләрендә музыка класслары ача). 1917 дән Казанда музыка уку йортларында (музыка мәктәпләрендә, музыка укытучылары әзерләү курсларында, Шәрекъ консерваториясендә) укыта, музыка белеме бирүнең яңа формаларын эшләү б-н шөгыльләнә. Симфоник, камера-инструменталь һәм вокаль әсәрләр, укыту-методик әсбаплар авторы.

*Әд.:* Из истории музыкальной культуры и образования в Казани. К., 1993.

**ГУ́МУС** (лат. humus — җир, туфрак) тере организмнар составына кергән, ш.у. үсемлек тукымалары, хайван калдыклары төзелешендә катнашкан кушылмалардан башка туфрактагы барлык органик кушылмалар җыелмасы. Бу төшенчә туфракка нисбәтле; гумумпланетар төстәге гумификациядән аермалы буларак, гумус барлыкка килү туфракта гына бара. Г. составына гумус матдәләре һәм төрле төрдәге биологик чыгышлы индивидуаль органик кушылмалар керә. Г. матдәләре — нигездә, кислота үзлекле карасу төстәге азотлы югары молекуляр кушылмалар Г.ның төп өлешен тәшкил итә. Мондый матдәләрнең барлыкка килүендә теләсә нинди органик кушылмалар — автотроф һәм гетеротроф организмнарның гадәти метаболизмы продуктлары һәм аларның тулы булмаган микроблы таркалышы калдыклары катнаша ала. Г. матдәләренең катгый химик билгеләмәсен аныклау өчен теоретик һәм экспериментальбаза хәзергә кадәр юк, төзелешләре билгеләнмәгән һәм аларның номенклатур схемасын (гумин к-талар, фульвокислоталар, гиматомелан к-талар, гумин) эреткечләргә мөнәсәбәте аша нигезлиләр. Г. — туфракның уңдырышлылыгын билгеләүдә төп күрсәткеч. Үсемлекләрне тукландыруның төп запас элементлары Г. б-н бәйле, аның составына физиологик актив матдәләр керә. Г. уңайлы су-һава режимын, туфракның көпшәклелеген булдыруга, тискәре тышкы шартларга һәм химик пычрануларга тотрыклылык урнаштыруга ярдәм итә. Туфракны авыл-хуҗалыгы максатларында куллану, гадәттә, Г.ның кимеүенә — дегумификациягә китерә. Туфракка эләгә торган үсемлек калдыклары азаю; аэрация арту, микроорганизмнар эшчәнлеге арту һәм артык дымлы җирләрне киптерү аркасында минераллашуның көчәюе, сөрүлекләрдә туфрак юылу процесслары — Г. юкка чыгуның төп сәбәпләре. ТР игенчелегендә гумус балансы тискәре якка күбрәк үзгәрде. Соңгы йөзьеллыкта аеруча гумуслы туфраклар (кара туфрак һәм соры урман туфрагы) Г. күләменең 25–30% ын югалтты. Дегумификацияне булдырмау чаралары органик ашламалар кертүне, су һәм җил эрозиясе б-н көрәшне, фәнни яктан нигезләп үләнкырлары кертелгән чәчү әйләнешен үзләштерүне, фитомелиорацияне, көтү йөртүне җайга салуны үз эченә алырга тиеш.

*Әд.:* Гумус почв Волжско-Камской лесостепи и его роль в плодородии. К., 1972; К о л о с к о в а А.В., Г и л я з о в а С.М., С а к а е в а А.Х. Гумусное состояние почв Волжско-Камской лесостепи. К., 1985; О р л о в Д.С. Гумусовые кислоты почв и общая теория гумификации. М., 1990; Т е й т Р. Органическое вещество почвы. М., 1991.

*А.А.Шинкарёв.*

**ГУН** Карл Фёдорович (1.12.1830, Лифляндия губ., Рига өязе Зиссегалле — 16.1.1887, Швейцария, Давос ш.), нәкышьче, нәкышь академигы (1968). 1852–61 елларда Петербург Сәнгать академиясендә иректе тыңлаучы. 1963–71 дә — Сәнгать академиясенең чит илләрдәге (башлыча, Франциядә) пенсионеры. 1871–74 тә Петербург Сәнгать академиясендә укыта, нәкышь тарихы профессоры (1872). Күчмә сәнгать күргәзмәләре оештыру җәмгыяте эшчәнлегендә актив катнаша (1872 дән). 1874 тән чит илләрдә яши, нәкышьнең тарихи, тормыш-көнкүреш, портрет жанрларында эшли. Әсәрләре сюжет чишелеше, персонажларны, көнкүреш детальләрен бирүдә тарихи дөреслекне саклау б-н аерылып тора. Россиядәге реформалар чоры тормыш-көнкүрешен төгәл чагылдырган күп рәсемнәр һәм акварель әсәрләр иҗат итә. 1851 дә рәссамнар артеле б-н Алабуга шәһәрендәге Спас соборы, Покров һәм Воскресение чиркәүләре иконостасларын язуда катнаша. 1862–63 тә кабат Алабугада була һәм Нократ төбәгендә яшәү-

че халыклар — татар, вотяк (удмурт), чирмешләргә (мари) багышлап, аларның типик өс киемнәре, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан рәсемнәр, акварель әсәрләр сериясен ясый. Алар арасында «Казан губернасы татарлары» («Татары Казанской губернии, 1862») һәм «Мөселман һәм керәшен татар хатын-кыз өс киемнәре һәм бизәмәләре» («Украшения и костюмы татарки-мусульманки и кряшенки», 1860 еллар) әсәрләре бар. 1866 дан төрле күргәзмәләрдә (Сәнгать академиясе, Кучмә сәнгать күргәзмәләре җәмгыяте), ш.и. бөтендөнья күргәзмәләрендә (Париж, Лондон, Брюссель, Вена) катнаша.

*Әд.:* Э л и т А. К.Ф.Гун. 1830–1877. Рига, 1955; Государственный музей ТатАССР. Художественная галерея. К., 1956.

**ГУРЕ́ВИЧ** Пётр Аронович (27.7.1937, Киев), химик-органик, химия фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994), РФнең югары мәктәбе мактаулы хезмәткәре (1997), СССР югары мәктәбе отличнигы (1984), РСФСРның халык мәгарифе отличнигы (1986). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый һәм шунда ук органик химия кафедрасында эшли. 1972 дән өлкән сыйныф укучыларының П.А.Кирпичников исем. «Орбиталь» профильле мәктәбе җитәкчесе, 1995 тән — укучыларның химия буенча халыкара олимпиадаларында катнашу өчен РФнең җыелма командасы кандидатларын укыту-әзерләү җыеннары җитәкчесе. Хезмәтләре фосфорлы индоллар һәм пироллар химиясенә карый. Г. фосфорлы азоллар синтезлау ысулларын эшли. Өчвалентлы фосфор кушылмаларының бервалентлы хром, дүртвалентлы вольфрам, ике валентлы кобальт б-н комплекслар хасил итүен тикшерә. Өчһәм бишвалентлы фосфорлы индол һәм пиррол кушылмаларын синтезлау ысулларын тәкъдим итә, аларның хасил булуның закончалыкларын фосфор атомы тирәлегенә бәйләп аңлата, бу кушылмаларның төзелешен өйрәнә, аларның төзелеше һәм биол. активлыгы арасында үзара бәйләнешне ача (микробка, вируска, холинэстеразга каршы һәм инсектицид). ТРда шәраб ясау өчен кулланыла торган җиләк-җимешләрнең химик составы буенча хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 37 авторлык таныклыгы бар. Татарстанның М.Җәлил исем. комсомол (1976), Ленин комсомолы бүләкләре лауреаты (1987). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорсодержащие производные индола и пиррола // Химия гетероциклических соединений. 2000. № 12; «Орбиталь» — мечта и увлечение. К., 2005; Технологические и биохимические основы алкогольсодержащих напитков. СПб., 2007 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГУ́РИЙ** (Руготин Григорий) (1500 тирәсе, хәзерге Мәскәү өлкәсенең Радонеж ш. — 5.12.1563, Казан), дин эшлеклесе. Ярлы дворян нәселеннән дип фаразлана. Волоколамск Успение монастыренда монахлык кабул итә, 1542 елда игумен дәрәҗәсе ала, шул ук елдан монастырь башлыгы була. 1554 тән Тверь яныннадагы Селижарово Троица монастыре җитәкчесе. 1554 тән — Казан һәм Зөя архиепископы, беренче архиерей. Иван IV хөкүмәте тарафыннан Казан епархиясен оештыру, Урта Идел һәм Урал алды халыкларын чукындыру өчен җибәрелә. Аның җитәкчелегендә *Архиерий йорты* оештырыла, 6 монастырьга, ш.и. Казан Спас-Преображение, Зөя Успение, Елантау монастырьларына нигез салына, *Благовещение кафедраль соборы* төзелә. Г. 1595 тә изгеләштерелә. 5/18 декабрьдә искә алына. Җәсәде Казанның Арча кыры ziратындагы Ярославль чудотворецлары чиркәвендә саклана.

*Әд.:* Григорий (Постников). Житие Святителей и Чудотворцев Гурия, Архиепископа Казанского и Варсонофия Тверского. СПб., 1853; К р е м л е в с к и й А. Святитель Гурий. К., 1905.

**ГУ́РИЙ** (Степанов Алексей Иванович) (3.10.1880, Чабаксар ш. — 1938, Новосибирск ш. янында), дин эшлеклесе һәм белгече, чиркәү тарихчысы, монгол тарихын өйрәнүче, чиркәү тарихы д-ры (1916). 1905 елда монахлыкка керә. Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1906), шунда эшли: 1910 нан — проф., 1912–17 дә — инспектор. Рус православие чиркәвенең 1917–18 дәге Поместный соборы эшендә актив катнаша. 1918–19 да Мәскәүдәге Сретенье һәм Покров монастырьлары башлыгы. 1920 дән Алатырь епископы, 1923 тә вакытлыча Петроград епархиясе б-н җитәкчелек итә, 1924 тән — Иркутск епископы, 1926 дан — Кострома, 1930 дан — Суздаль архиепископы, 1931 дә кафедрадан чыга. 1920 елларда 6 тапкыр кулга алына һәм 6 елын тоткынлыкта үткәрә. 1931 дә тагын кулга алына, 1932 дә хөкем ителә, 1938 дә атып үтерелә. Хезмәтләре буддизм, калмык һәм бурятлар тарихына, алар арасында православие таратуга, «Изге Китап»ны калмык теленә тәрҗемә итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Буддизм и христианство в их учении о спасении. К., 1908; О переводческой деятельности на калмыцкий язык // Православный собеседник. 1910. № 7; Очерки по истории распространения христианства среди монгольских племен: В 2 ч. К., 1916.

**ГУ́РИЙ ӘЛИФБАСЫ́** (Азбука Гурия), кульъязма нөсхә. Казанның булачак беренче архиепископы *Гурий* тарафыннан 16 йөзнең 20 нче елларында төзелә башлап, 1555–60 елларда Казанда төгәлләнгән дип уйланыла. Бер нөсхәсе 1833 елга кадәр Казанда Благовещение кафедраль соборында саклана. Г.ә. рус әлифбалары жанрын формалаштыруда сизелерлек йогынты ясый (Тәүрат, Зәбур, Часослов һ.б. дини китап фрагментлары б-н беррәттән), 17 йөз башына кадәр Мәскәү дәүләте (Мәскәү, Радонеж, Тверь һ.б.) һәм элеккеге Казан ханлыгы җирләрендәге православие мәктәпләрендә укыту әсбабы итеп файдаланыла. Г.ә. 1574 тә Львов шәһәрендә дөнья күргән И.Фёдоров басма әлифбасының әлгәргесе булып санала. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 1610 еллар арасында Г.ә.ның Казан басмаханәсендә басылган булуы да ихтимал (к. «*Аноним басмаханә*»). Кульъязма Г.ә. нөсхәсенең хәзерге язмышы билгесез.

*Әд.:* Е л и с е е в Г.И. Жизнеописания святителей Гурия, Германа и Варсонофия, Казанских и Свияжских чудотворцев. К., 1847; П о з д е е в а И.В., Т у р и л о в А.А. Казань — один из центров раннего книгопечатания // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4; Г р и г о р ь е в Е.И. Начало кириллического книгопечатания в Казани во 2-й половине 16 века // Чтения в усадьбе Боратынских. К., 2001.

*Е.И.Григорьев.*


**ГУРЫЛЁВА** Марина Элисовна (21.12.1961, Казан), гигиенист-эпидемиолог, мед. фән. д-ры (2004). 1987 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Республика туберкулёзга каршы көрәш диспансерында эшли, 1993 тән шунда ук оештыру-методика бүлеге башлыгы. 1996 да мед. тарихы һәм мед. биоэтикасы кафедрасында. Хезмәтләре үпкә туберкулёзы вакытында кан әйләнеше гемодинамикасына һәм үпкәгә ясалма сулыш алдыруга карый. Рациональ тәкъдим һәм 2 монография авторы.

Х е з м.: Гемодинамика большого круга кровообращения и легочная вентиляция при туберкулёзе легких // Сов. медицина. 1986. № 1 (автордаш); Функция печени у больных туберкулёзом органов дыхания // Казан. мед. журн. 1986. № 3 (автордаш); Оценка нарушений печени у больных активным туберкулёзом лёгких // Казан. мед. журн. 1990. № 5 (автордаш); Биоэтика в фармации // Саламат Информ. 1997. № 14; Туберкулёз. К., 1999 (автордаш); Лечение саркоидоза // Рос. мед. журн. 2004. № 6 (автордаш); Саркоидоз детского возраста // Педиатрия. 2004. № 2; Саркоидоз: от гипотезы к практике. К., 2004.

**ГУРЬЕ́** Лилия Измайловна (18.11.1952, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1994), проф. (1998). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый (1974). Казан электрон хисаплау машиналары з-дында инженер-математик (1974–75), «КамАЗ» АҖдә идарә итүнең автоматлаштырылган системалары инженеры (1977–80), СССР ПФАнең Һөнәри-техник педагогика фәнни-тикшеренү ин-тында фәнни хезмәткәр (1984–86). 1986–95 тә РМАнең Махсус урта белем ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1995 тән Казан технол. ун-тында, инженерлык эшчәнлеге методологиясе каф. мөдире. Һөнәри белем бирүнең чагыштырма педагогикасы, югары инженерлык белеме бирү методологиясе, Көнбатыш Европада барган пед. процессларны өйрәнү өлкәсендә фәнни хезмәтләре бар.

Х е з м.: Профессиональный лицей во Франции; традиции и современность. К., 1993; Основы педагогики высшей школы. К., 1999. Проектирование педагогических систем. К., 2004. Проектирование методологической культуры инженера в технологическом университете. К., 2006 (автордаш).

**ГУ́РЬЕВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2008 елда 112 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г.да земство мәктәбе (1901 дә ачыла), 3 җил һәм 2 су тегермәне, тимерчелек, 3 ярмаяргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу



П.Я. Гурьянов.



А.Д. Гусев.

чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1277 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нnарында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 364, 1897 дә — 598, 1908 дә — 517, 1926 да — 514, 1938 дә — 364, 1949 да — 287, 1958 дә — 239, 1970 тә — 250, 1979 да — 199, 1989 да — 139, 2002 дә — 124 кеше.

**ГУ́РЬЕВКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 47 *км* төньяктарак, Вятка елгасы буенда. 2008 елда 47 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. 18 йөздә алпавыт Гурьев нигез сала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да земство мәктәбе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 83 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-ннарында. Халык саны: 1859 да — 170, 1897 дә — 359, 1908 дә — 424, 1926 да — 620, 1949 да — 523, 1958 дә — 413, 1970 тә — 254, 1979 да — 137, 1989 да — 92, 2002 дә — 66 кеше.

**ГУРЬЯ́НОВ** Алексей Ильич (18.1.1937, Казан), химия машиналары төзү белгече, техник фән. д-ры (1997), проф. (2006), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2003). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң шунда ук эшли. 2000 нән Казан энергетика ун-тында: проректор (2004 кә кадәр), бер үк вакытта җылылык-масса алмашы процесслары һәм җайланмалары каф. мөдире (2008 гә кадәр), каф. профессоры (2008 дән). Хезмәтләре энергия һәм ресурслар саклаулы пульсацияле җылылык-масса алмашы аппаратларын төзүгә карый. Г. сыеклык экстракциясе өчен динамик яктан тотрыклы аппаратлар классын; тоташ сыек тирәлекнең симметрияле булмаган пульсацияләре хисабына каты дисперсияне тыгыз катлам рәвешендә агымга каршы күчерү алымын һәм моның өчен яңа тип җайланмалар; нефть скважиналарының дебетын күтәрү алымын һәм шуның җайланмасын эшли. Алар РФ сәнәгатенең химия, нефть химиясе, азык, нефть-газ чыгару тармакларында гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 46 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сопряжённое моделирование и конструирование пульсационных аппаратов. К., 2005 (автордаш); Энергосбережение в гидроимпульсном воздействии на призабойную зону пласта // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2005. № 9–10 (автордаш); Энерго- и ресурсоэффективность диффузионного аппарата // Сахар. 2008. № 2 (автордаш).

**ГУРЬЯ́НОВ** Николай Георгиевич (6.12.1939, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1973 кә кадәр Математика һәм механика фәнни-тикшерү ин-тында, 1994 тән гомуми матем. каф. мөдире. Хезмәтләре пластиналар һәм сүрүләр деформациясен аналитик ысуллар б-н тикшерүгә карый. Локаль йөкләм тәэсирендәге изотроп һәм ортотроп пластиналар һәм сүрүләрнең көчәнеш-деформация халәтен билгели торган кырый мәсьәләләрнең төгәл чишелешләрен төзи.

Х е з м.: Двоякопериодическое решение задачи определения напряжённо-деформированного состояния слоистой сферической оболочки // Изв. вузов. Математика. 1997. № 1; Аналитическое решение системы дифференциальных уравнений, описывающих осесимметрическую деформацию ортотропного полого сферического сегмента // Изв. вузов. Математика. 1999. № 1; Решение задач механики оболочек и пластин аналитическими методами // Тр. междунар. конф. «Актуальные проблемы механики оболочек». К., 2000.

**ГУРЬЯ́НОВ** Павел Яковлевич (15.12.1918, Казан губ., Спас р-ны Ширбәт а. — 16.6.1960, Казан), Сов. Союзы Герое (16.10.1943), сержант. Слесарь булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 622 нче аерым элемтә ротасындагы (13 нче армиянең 74 нче укчы дивизиясе) телефон-кабель взводының отделение командиры. Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Днепр елгасы өчен барган сугышларда (1943), Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1943 нең 24 сентябрендә Комарин бистәсе янында (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагин р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Казанда эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П л е с ц о в К.М. Люди высокого подвига. М., 1962; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

*В.А.Шагалов.*

**ГУ́СЕВ** Александр Дмитриевич (11.2.1900, Самара ш. — 12.10.1983, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның халык (1945), РСФСРның атказ. артисты (1957). Сәхнә эшчәнлеген гимназияне тәмамлагач ук (1918), Самара шәһәр театрында башлап җибәрә. Гражданнар сугышы елларында Колчак армиясенең 54 нче Себер полкы гарнизоны театры актёры, 1920–26 елларда Иркутск, Ростов-Дон, Әстерхан шәһәр театрларында, 1926 да Мәскәү 1 нче эшче театрында, 1927–28 дә Саратов шәһәр театрында эшли. 1933–34 тә Казан Зур драма театрында Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Бродский («Интервенция», Л.И.Славин), Гриффитс («Ликург законы», Т.Драйзерның «Америка трагедиясе» романы нигезендә) рольләрен уңышлы башкара. 1934–35 тә Одесса театрында, 1935–39 да Мәскәүдә Кызыл Армия Үзәк театрында, 1939–65 тә яңадан Казанда эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Карелия фронтының хәрәкәттәге армиясендә концерт бригадасы составында чыгышлар ясый. Нечкә аналитик фикерләүгә ия актёр, күренекле режиссёрлар Н.Н.Синельников һәм А.Д.Поповлар шәкерте буларак, Казан сәхнәсендә театр культурасы тарихында сизелерлек эз калдырган күп кенә образлар иҗат итә. Иҗат палитрасының байлыгы, виртуозлык сәләте аңа төрле пландагы рольләрне бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкару мөмкинлеге бирә (Глумов — «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский; Яго — «Отелло», У.Шекспир; «Иван Грозный», А.Н.Толстой; Корбаччо — «Вольпоне», Б.Джонсон). Ләкин актёрга интеллигентлар, нечкә күңелле, намуслы, кайчакта ярдәмгә мохтаҗ һәм беркатлы, дөньяга романтик күзлектән караучы геройлар якынрак. Актёрның иң яхшы эшләре итеп рус классик әдәбияты әсәрләренә нигезләнеп куелган спектакльләрдәге образларны күрсәтергә мөмкин: Лаврецкий («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев), Райский («Текә







А.Д. Г у с е в: Хлестаков («Ревизор», Н.В. Гоголь); 2. Тузенбах («Өч сеңел», А.П. Чехов); 3. Корбаччо («Вольпоне», Б. Джонсон) рольләрендә.

яр», И.А.Гончаров), Чацкий («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Тузенбах («Өч сеңел», А.П.Чехов), Патша Фёдор Иоаннович (шул исем. әсәр, А.К.Толстой), Рощин («Михнәтле заман», А.Н.Толстой). Башка пьесаларда да Г. тарафыннан тудырылган образлар характерларның тирән психол. эшләнеше б-н аерылып тора: Горлов («Фронт», А.Е.Корнейчук), Фёдор («Ябырылу», Л.М.Леонов), адмирал Макаров («Порт-Артур», А.Н.Степанов, И.Ф.Попов), Янгузов («Үлмәс җыр», Р.Ишморат).

Казан Зур драма театры сәхнәсендә Г. 20 ләп спектакль куя, алар арасында А.Н.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» — «Без вины виноватые», «Соңгы корбан» — «Последняя жертва», «Ярлылык — гөнаһ түгел» — «Бедность не порок» (1948, 1951, 1962), И.А.Гончаровның «Текә яр» — «Обрыв» (1948), Х.Вуолийокиның «Юстина» (1959), А.Н.Арбузовның «Югалган ул» — «Потерянный сын» (1961) һ.б. пьесалары бар. Г. режиссурасына авторга карата ихтирам, геройларның конкрет эшләрен психол. яктан тулысынча нигезләү, тышкы сурәтләү чараларын аз кулланып, вакыйгаларның эчке киеренкелеген ачып бирү хас. Г. спектакльне әзерләү процессында актёрлар б-н эшләүгә зур игътибар бирә. Театр каршындагы студиядә пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә, 20 ел дәвамында (1963–83) Казан театр уч-щесендә укыта.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ГУ́СЕВ** Александр Павлович (11.8.1928, Алабуга р-ны Гусевка а. — 16.4.1999, шул ук р-нның Бехтерево а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. 1940–54 елларда колхозчы, хисапчы. 1954–56 да Алабуга р-нының Бехтерево авыл советы рәисе, 1956–97 дә Бехтерев исем. колхоз рәисе. Ул җитәкчелек иткән елларда хуҗалык бөртекле культуралардан югары уңыш алуы, терлекчелектә мул продукция җитештерүе б-н аерылып тора. Бернечә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС, ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә. 1975–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Бехтерево авылындагы бер урамга аның исеме бирелә.

**ГУ́СЕВ** Александр Петрович (19.6.1946, Горький ш.), генерал-майор (2000), ТРның атказ. юристы (2001). Казан химия-технол. ин-тын (1969), СССР Дәүләт иминлеге ком-ты академиясен (1985, Мәскәү) тәмамлый. 1970–72 елларда В.И.Ленин исем. Казан химия з-ды ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1972–73 тә ВЛКСМның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире, 1973–77 дә 2 нче секретаре. 1977–78 дә В.И.Ленин исем. фәнни-җитештерү берләшмәсе парткомы секретаре урынбасары, 1978–83 тә секретаре. 1985–88 дә ТР Дәүләт иминлеге ком-тының бүлекчә, 1988–92 дә бүлек башлыгы, 1992–99 да рәис урынбасары, 1999–2001 дә рәисе. 2001–2004 тә РФнең ТРдагы Федераль иминлек хезмәте идарәсе башлыгы. 2004 тән ТР Дүләт Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы ком-ты рәисе. 2004 тән ТР халык депутаты. 2005 елдан ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Рубин» футбол клубы президенты. Почёт ордены б-н бүләкләнә.

**ГУ́СЕВ** Александр Фёдорович (23.8.1845, Тверь губ. — 8.7.1904, Казан), дин белгече, рухани язучы, дин гыйлеме д-ры (1895). Петербург руханилар академиясен тәмамлый (1871). 1871 елдан Казан руханилар семинариясендә, 1887–1902 дә Казан руханилар академиясендә эшли, проф. (1889). «Христианлыкка карата мөнәсәбәттә буддизмның әхлакый идеалы» («Нравственный идеал буддизма в его отношении к христианству») дигән магистрлык диссертациясендә (1874) шул заманның әхлакый дин гыйлеме нигезләрен тәкъбирләү омтылышы ясый һәм аның бу хезмәте кайнар бәхәсләргә сәбәп була. Консерватив һәм либераль юнәлештәге журналларда басылган күпсанлы фәнни хезмәтләре, публицистик рухтагы мәкаләләре б-н үзен христианлыкның әхлакый кыйммәтләрен яклаучы һәм дарвинизм, позитивизм, толстойчылык кебек популяр тәгълиматларны кискен рәвештә инкарь итүче буларак таныта. Атеизмны тәнкыйтьләгәндә ул физика, биология кебек табигать фәннәрендәге яңа ачышларга таяна, бу исә ул чор өчен алгарыш буларак бәяләнә. Г. ның фәнни эшчәнлегендәге икенче юнәлеш — дини догмаларны саклау, католицизмны тәнкыйть итү. Заманының күпчелек дин галимнәреннән аермалы буларак, католиклар б-н якынаюга каршы чыга.

Хезм.: Нравственность как условие истинной цивилизации и специальный предмет науки. М., 1874; Потребность и возможность научного оправдания христианства. К., 1887; Разбор возражений Спенсера против учения о Боге как личном существе. К., 1896; К старокатолическому вопросу. Письмо А.А.Кирееву. СПб., 1897; Последнее наше слово о старокатоличестве и его русских апологетах. К., 1904.

*Әд.:* Колокольцев В.Ф. Александр Федорович Гусев. К., 1904; Григорьев К. Памяти профессора Александра Федоровича Гусева: Очерк его литературной деятельности. К., 1905.

**ГУ́СЕВ** Андрей Дмитриевич (1886 — 13.7.1952, Казан), мәхкәмә медицинасы белгече, мед. фән. д-ры (1926), проф. (1923). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1913), шунда ук эшли. 1923–52 елларда Казан мед. ин-тында, мәхкәмә медицинасы каф. мөдире, бер үк вакытта ТАССРның мәхкәмә медицинасы хезмәтен җитәкли. Хезмәтләре канны мәхкәмә медицинасы шартларында тикшерүгә, исбатлау өчен табылган әйберләрдән файдалану, тикшеренү нәтиҗәләрен мәхкәмә медицинасы гамәленә кертүгә карый.

Хезм.: Основы судебной медицины. К., 1938.

**ГУ́СЕВ** Валерий Фёдорович (17.2.1940, Харьков ш.), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983), техник фән. канд. (1984). Таганрог радиотехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Пенза универсаль хисаплау машиналары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1965–88 елларда Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсендә: инженер, лаб., бүлек башлыгы, махсус КБ башлыгы урынбасары, башлыгы, бер үк вакытта ген. директор урынбасары (1980 нән), баш конструктор (1982 дән). 1988 дән Казан авиация ин-тында (1992 дән — Казан техник ун-ты): мәгълүмат-хисаплау үзәге башлыгы, Яңа мәгълүмати технологияләр региональ үзәге директоры (1990 нан) һәм бер үк вакытта Казан техник ун-тының проректоры (1990–96), Казан гамәли электродинамика фәнни-тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (1996 дан). Г. М-222, ЕС-1033 маркалы электрон-хисаплау машиналарының баш конструкторы. Хезмәтләре мәгълүмати технологияләргә һәм телекоммуникацион челтәрләр эшләүгә карый. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге бердәм системадагы ЭВМ төзүдәге һәм гамәлгә кертүдәге хезмәтләре өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Электронно-вычислительная машина ЕС-1033. М., 1982 (автордаш).

**ГУ́СЕВ** Виктор Степанович (1.4.1905, Казан — 9.2.1976, Яшел Үзән ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Казан политехник ин-тын тәмамлый (1930). 1923–25 елларда Казан «Красный путь» з-дында слесарь. 1930–31, 1932–44, 1947–57 дә Яшел Үзән суднолар төзү з-дында: инженер-конструктор, цех башлыгы, баш технолог (1947 дән). 1931–32 дә «Баррикада» з-дында (Сталинград ш.). 1944–45 тә СССР Тышкы сәүдә эшләре халык комис-тының АКШтагы вәкиле. 1945–47 дә Ярославль шәһәрендәге 345 нче з-дның баш инженеры. 1957–63 тә Татарстан ХХСның 1 нче машиналар төзү идарәсендә баш инженер. 1963–76 да Яшел Үзән махсус КБ-м проектлау-конструкторлык бюросы башлыгы, әйдәп баручы инженер. Дәүләт бүләге суднолар төзүдә позицион агым белән эшләү ысулын кертkәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГУ́СЕВ** Владимир Иванович (31.8.1937, Краснодар крае, Ейск ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998), Россиянең атказ. уйлап табучысы (1992), СССР нефть сәнәгате отличнигы (1987). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1966–78 дә Казан органик синтез з-дында, 1977 дән баш инженер урынбасары. 1978 дән «Нефтехимпром» фәнни-тикшеренү ин-тында: ген. директор урынбасары, ген. директор (1981 дән), 2000 нән баш фәнни хезмәткәр, 2004 тән фәнни консультант. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясенә, төп органик һәм нефтехимик синтез технологиясенә, нефть промыселы химиясенә карый. Г. җитәкчелегендә углеводородлар пиролизы, көпшәле һәм автоклав реакторларда этилен полимерлаштыру, этилен оксидын, гликольләр, органик перекисьләр, фенол һәм ацетон җитештерү технологияләрен камилләштерү эшләре үткәрелә. Җир астыннан нефтьне тулырак чыгару, аны әзерләү сыйфатын күтәрү, нефть табу җиһазларының коррозиясен,

аларда тоз һәм парафин утыруны кисәтү һәм киметү максаты б-н нефтегаз сәнәгатен химияләштерү өлкәсендәге тикшеренүләрне башлый. Г. җитәкчелегендә нефть табу сәнәгате өчен эффектив химия продуктлары булдыру концепциясе эшләнә, бактерицидлар, коррозия ингибиторлары, изононилфенол нигезендә деэмульгаторлар, парафин һәм тоз утырым ингибиторлары тәкъдим ителә. Нефть табу сәнәгате өчен азтоннажлы химия продуктларын җитештерү оештырыла. СССР Нефть сәнәгате министрлыгы бүләге лауреаты (1989). ТРның шахматчылар берлеге президенты (1990–96). Беренче Шаляпин опера фестивален оештыручы-спонсор. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование капиллярных процессов, происходящих при течении двух несмешивающихся жидкостей // Журн. прикладной химии. 1984. Т. 57, № 8, 10 (автордаш); Пожароопасные свойства химических реагентов, применяемых в технологических процессах нефтедобычи: В 2 ч. К., 1986–88 (автордаш); Каталог физико-химических и токсикологических свойств химических продуктов, применяемых в технологических процессах добычи нефти и повышения нефтеотдачи пластов. М., 1988 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГУ́СЕВ** Дмитрий Васильевич (?, Пенза губ. — 19.10.1894, Казан), дин белгече һәм чиркәү тарихчысы. Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1870), шунда ук эшли, 1885 елдан — проф. Россиядә патрология (чиркәү атакайларының хезмәтләрен һәм эшчәнлекләрен өйрәнү) фәнни мәктәбен булдыручыларның берсе. А.И.*Дружинин*, В.И.*Писарев*, Н.В.*Петров*, В.И.*Несмелов* — аның шәкертләре һәм тарафдарлары. Вафатыннан соң басылып чыккан патрология дәреслеге руханилар уку йортларында киң кулланыла.

Х е з м.: Ересь антитринитариев III века. К., 1872; Догматическая система Иринея Лионского в связи с гностическими учениями II века // Православный собеседник. 1874. Ч.2–3; Антропологические воззрения Блаженного Августина в связи с учением пелагианства // Православный собеседник. 1876. Ч.2; Учения о Боге и доказательстве бытия Бога в системе Филона // Православный собеседник. 1881. Ч.3; Апология Лица Иисуса Христа в Его земной жизни и деятельности в сочинении Оригена против Цельса // Православный собеседник. 1886. Ч.3; Чтения по патрологии: В 2 ч. К., 1895–98; Святитель Феофил Антиохийский. К., 1898; Тертуллиан, пресвитер Карфагенский. К., 1898.

*Әд.:* Н е с м е л о в В.И. Дмитрий Васильевич Гусев. Некролог. К., 1894.

**ГУ́СЕВ** Николай Андреевич (7.4.1911, Казан — 7.7.1987, шунда ук), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1959), проф. (1967), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). *Үсемлекләрнең су режимы* Казан фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1934), шунда ук эшли (1941 елга кадәр). 1943–45 тә СССР ФАнең Ленинградтан Казанга эвакуацияләнгән Капилляр микроскопия лаб-ясендә, 1946–85 тә СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тында, 1960–75 тә директор. Хезмәтләре үсемлекләрнең физиологиясен һәм төрле стресс шартларында су алмашын өйрәнүгә карый. Г. беренче булып үсемлек тукымаларын тикшерүдә физиология ысулларын — ТМР, инфракызыл спектроскопияне, диэлектрик спектроскопияне гамәлгә кертә. Азот-фосфорлы ашлама б-н өстәмә тукландыруның үсемлекләрнең корылыкка бирешмәвенә, чыдамлылыгына булышуын исбатлый: фотосинтезны гамәлгә ашыручы хлоропластларның күзәнәкләргә бәйләнмәгән су алмашы сәләтенә ия булуын дәлилли (корылык вакытында үсемлек күзәнәкләре суны югалталар, ә хлоропластлар аны үзләренә җыялар). «Үсемлекләрдә су режимының кайбер законлыклары» («Некоторые закономерности водного режима растений», М., 1959) монографиясе кытай теленә тәрҗемә ителә. Бөек Ватан сугышында катнаша. ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы (1971), медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние минерального питания на вoдообмен растений. К., 1957; Некоторые методы исследования водного режима растений. Л., 1960; Состояние воды в растении. М., 1974.

**ГУ́СЕВ** Павел Петрович (14.3.1914, Вологда өлкәсенең Устюг р-ны Терентьево а. — 7.9.2007, Казан), яшелчәче-агроном, биол. фән. канд. (1955), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952), РСФСРның атказ. агрономы (1974). Ленинград җиләк-җимеш-яшелчә ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), Данилиха яшелчәчелек с-зында (Пермь ш.) өлкән агроном булып эшли. 1938 дән Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тының Поляр тәҗрибә станциясендә лаб. мөдире (Мурманск өлкәсе Хибин ш.). 1959–86 да Казан а.х. ин-тында, җиләк-җимеш каф. мөдире (1965–82). Заполярьеның кырыс шартларында яшелчә культураларыннан югары уңыш алу өчен агротехник алымнар комплексын эшли. Яшелчә культураларының 20 сорты авторы һәм автордашы, кәбестәнең — «Пекинская», «Хибинская», аш чөгендеренең — «Полярная», кишернең — «Хибинская» һ.б. сортларга 8 авторлык таныклыгы бар. Нигездә, алар Ерак Төньяк, Урал, Ерак Көнчыгыш һәм РФнең Төньяк-Көнбатыш регионнарында районлаштырылган.

Хезмәтләре яшелчә культураларыннан югары һәм иртә өлгерешле уңыш алуга, плёнка астында кыяр һәм помидор үстерү агротехникасына, салкын үрентелектә башлы суган үстерү технологиясенә, яшелчә культуралары орлыкларын чәчүгә әзерләүгә карый. СССР Дәүләт бүләге яшелчә культураларының яңа сортларын чыгарганы һәм аларны Төньяк зона орлыкчылыгына керткәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. И.В.Мичурин, Н.И.Вавилов исем. медальләр һәм СССР ВДНХсының 7 медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агроуказания по выращиванию овощных культур в Мурманской области. Мурманск, 1939; Опыт выращивания капусты в Мурманской области. Мурманск, 1956; Справочник овощевода. К., 1971; Овощеводство в Татарии. К., 1981; Картофель и овощи на приусадебных участках. К., 1986; Библиотечка овощевода. К., 1989 (автордаш).

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ГУСЕ́ЙНОВ** Фирудин (Фәридун) Ильяс улы (19.11.1959, Әзәрбайҗан ССРның Тауз р-ны Дондар а.), химик, химия фән. д-ры (1999), проф. (2002). 1982 елда Әзәрбайҗан ун-тын тәмамлый, 1983 тән Казан технол. ун-тында, 1999 дан дару препаратлары химиясе һәм технологиясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре элементорганик һәм функциональ алмаштырылган α-галогенокарбонил кушылмалар, полихлорланган аминнар химиясенә карый. Функциональ алмаштырылган галогенальдегидларның нигезләр, СН-кислоталар анионнары һ.б. б-н реакцияләрен һәм яңадан төркемләнүләрен эшли. Микробларга каршы күп тәэсирле «фторхинол» препаратын, гөмбәчекләргә каршы «клотримазол» препаратын, акарицидларга каршы «амитраз» препаратын синтезлауның яңа технологияләрен тәкъдим итә һәм җитештерүгә кертә. 1999 елда, дару чаралары, металлорганик катализаторлар, органик синтез өчен реагентлар субстанцияләре технологияләрен эшли торган «Элтос» фәнни-гамәли пр-тиесен оештыра. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар.

Х е з м.: Синтез и молекулярная структура 1,3-дифенил(диметил)-9,9,10,10-тетрахлор-2,4,6,8-тетраоксадамантанов // Докл. АН СССР. 1998. Т. 359, № 6 (автордаш); Синтез и молекулярная структура бисгидразонов дикарбонил замещённых бутен-2-диалей // Докл. АН СССР. 1998. Т. 358, № 6 (автордаш); Реакции α-хлор-β-оксоальдегидов с анионами СН-кислот // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1999. № 4.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ГУСИ́ХА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 42 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2008 елда 190 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәр Воскресенский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, дирбияләр эшләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Г. да волость идарәсе, янгын сүндерү дружинасы була, Воскресение чиркәве (1875 тә салына; архит-ра истәлеге), фельдшерлык пункты, земство мәктәбе (1882 дә ачыла), китапханә, ятим балалар йорты, 3 тегермән, ярма яргыч, тимерчелек, 2 сырыханә, шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2214,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 566 ир-ат; 1859 да — 1383, 1897 дә — 1296, 1926 да — 1079, 1938 дә — 425, 1949 да — 324, 1958 дә — 230, 1970 тә — 364, 1979 да — 267, 1989 да — 209, 2002 дә — 195 кеше.

**ГУСЫ́НИН** Василий Афанасьевич (1884, Пенза губ., Керенский өязе Черкасск а. — 23.1.1957, Казан), хирург, мед. фән д-ры (1938), проф. (1932), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940), В.Л.*Боголюбов* шәкерте. Варшава ун-тын тәмамлый (1913), 1914–19 елларда госпитальләрдә, 1920–23 тә Самара ун-тында, 1923–54 тә Казан ГИДУВ-

ында эшли. 1954–57 дә Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре нейрохирургия, кичектергесез пластик хирургиягә карый. Г. бит пластикасы ысулын — *Гусынин ринопластикасын* тәкъдим итә. Г. эшләгән алымнар СССР хирургия практикасында стандарт итеп кабул ителә. Казанда ашыгыч ярдәм клиникасы һәм 1930 да хәрби-кыр хирургиясе, 1946 да нейрохирургия клиникасы оештырылу Г. исеме б-н бәйле.

Х е з м.: Пластика лица. К., 1927; Неотложная хирургия. М.–Л., 1931 (автордаш); Восстановительная хирургия на поверхности человеческого тела. К., 1937.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ГУСЫ́НИН РИНОПЛА́СТИКАСЫ**, борында төрле дефектлар булганда яисә ул бөтенләй үсмәгән очракта аның формасын яңадан кайтару ысулы; Казан галиме В.А.*Гусынин* тәкъдим итә (1927). Ринопластика өчен авыруның үз тукымалары (тире, сеңер, сөяк), ш.у. консервланган трансплантатлар, ясалма материаллар кулланыла. Элек авыруның борыныңдагы йомшак тукымаларда, скелетында, өстәмә куышлыкларда, яшь үткәрү куышлыкларында каты һәм дәвамлы ялкынсыну процесслары тулысынча бетерелә. Борынның кимерчәкле өлеше бөтенләй җимерелгән очракта Гусынин тиредән ике түгәрәк сабак рәвешендәге орган ясау һәм соңрак күкрәкнең алгы өлешенә күчерә бару ысулын тәкъдим итә. Ул берничә (6–7) этаптан торган бу операциянең яңа вариантларын эшли.

*Әд.:* Г у с ы н и н В.А. Пластика лица. К., 1926; ш у л у к. Восстановительная хирургия на поверхности человеческого тела. К., 1937.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ГУ́ЩИН** Александр Нилович (7.9.1904, Кострома өлкәсенең Сандогора а. — 13.11.1981, Казан, Мәскәүдә җирләнгән), генерал-майор (1950). Коминтерн исем. командирлар хәрби-инженерлар мәктәбен (1930, Мәскәү) (шунда ук укыта), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1932, Мәскәү) тәмамлый. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1939 елдан Мәскәү хәрби электротехника уч-щесе башлыгы. 1946 дан СССР Кораллы Көчләре Баш инспекциясе инспекторы. 1950–57 дә Казан зенит-прожекторлар уч-щесе башлыгы. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ГҮЗӘЛБА́ЕВ** Яхья Зиннәт улы (18.6.1943, Казан), инженер-электромеханик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), техник фән. канд. (2000), ТРның атказ. машина төзүчесе (1997). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), ГИПОда эшли. 1979 елдан Компрессорлар төзү буенча махсус КБда (хәзер Турбокомпрессорлар фәнни-тикшеренү ин-ты): автоматика бүлеге мөдире, бүлекчә башлыгы һәм баш конструктор (1987 дән); бер үк вакытта, 2001 дән Казан технол. ун-тының компрессорлы машиналар һәм җайланмалар кафедрасында. Хезмәтләре электромагнитлы подшипниклар, автомат идарә итүле үзәктән куучы һәм винтлы компрессорлар төзүгә карый. Г. җитәкчелегендә нәстационар процесслар һәм автотирбәнүләрдән (помпаждан) саклау өлкәсендә комплекслы фәнни-тикшеренү һәм гамәли эшләр башкарыла. Дәүләт бүләге газ суырту-кудыру агрегатларындагы басым тудыру аппаратларының югары нәтиҗәле алмаш агызу өлешләрен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 21 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. «Елның иң яхшы уйлап табуы» дигән респ-ка конкурсы җиңүчесе (2003). 54 нче Бөтендөнья инновацияләр, фән һәм яңа технологияләр күргәзмәсенең (Брюссель, 2005) алтын медале б-н бүләкләнә.

**ГЫЙБАДӘ́Т** (гарәп. عبادة — күплек сандагы ибадә — табыну), мөселманнарның Аллаһка табынуы, дини йолалар һәм кагыйдәләрне үтәү. Шәригатьтә билгеләнгән *фикъһның* биш өлешенең берсен тәшкил итә. *Тәһарәт* алу, көн саен биш вакыт *намаз* уку, *зәкят* бирү, *ураза* тоту, *хаҗга* бару һәм *җиһад* Г.нең өлешләре булып тора.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГЫЙБАДУ́ЛЛИН** Габделхак Габдулла улы (16.3.1952, Мари АССР, Турек р-ны Татар Китнәсе а.), цирк артисты, акробат, хайваннар өйрәтүче (дрессировщик), ТАССРның атказ. артисты (1985), Мари АССРның халык артисты (1987). Мәскәүнең Цветной бульвардагы циркы каршындагы клоуннар студиясен тәмамлый (1977). 1977–94 елларда һәм 1997 дән «Союзросцирк» системасында, 1995–97 дә — Йошкар-Ола шәһәренең 400 еллыгы исем. парк каршындагы Җәнлекләр театрын оештыручы һәм җитәкчесе. Дрессировщик буларак «Хайваннар белән уен» («Игра с животными», реж. Б.Бреслер, комп. Р.Гобәйдуллин) номеры б-н чыгышлар ясый, анда йорт хайваннары — ишәк, каз, эт, кәҗә һ.б. б-н комик характердагы трюклар ясый. Бөтенсоюз цирк сәнгате конкурсы лауреаты (Мәскәү, 1987).

*Әд.:* С т е п а н о в а Г. Игра с животными // Советская эстрада и цирк. 1993. № 34.

**ГЫЙБАДУ́ЛЛИН** Дамир Хәбибрахман улы (13.11.1952, Казан), цирк артисты, акробат, жонглёр, ТАССРның халык артисты (1982), РФнең атказ. артисты (1997). Казан циркы каршындагы Бөтенсоюз цирк сәнгате үзәк студиясен тәмамлый (1970). Күренекле цирк реж. Э.Б.Аберт җитәкчелегендә жонглёрлык б-н шөгыльләнә. Татар цирк коллективы составында «Төркемле акробат-жонглёрлар» («Групповые акробаты-жонглёры») һәм «Җилкә акробатлары» («Плечевые акробаты») (реж. Б.Е.Аберт) номерларында чыгышлар ясый. 1970 елдан «Төркемле акробат-жонглёрлар» номерының җитәкчесе сыйфатында чыгышлар ясый, партнёрлары — М.Б.Гыйбадуллина (Фролова), М.М.Шаһиев, Р.М.Мингалимов һ.б. 1979–82 дә — «Рен тәгәрмәчләре өстендәге гимнастлар» («Гимнасты на Ренских колёсах») номеры җитәкчесе. Техник яктан катлаулы трюклар (өч акробат бер-берсенең җилкәсенә басып һәм өстәгесе манеж уртасында басып торган партнёры б-н жонглёрлык итә; дөм караңгыда



Д.Гыйбадуллин (уңнан беренче, янәшәдә М.Гыйбадуллина) җитәкчелегендәге жонглёрлар төркеме.

янып торган чукмарлар б-н жонглёрлык итү һ.б.) оригинальлекләре һәм югары темпта башкарылулары б-н аерылып торалар. Номерның төркемле жонглёрлык һәм акробатика элементларыннан корылган сюжет сызыгы татар халкының «Бормалы су» һәм «Каз канаты» көйләре фонында бара. Бөтенсоюз цирк сәнгате конкурсы (1982), Энсхеде шәһәрендә узган Халыкара фестиваль (Голландия, 1998) лауреаты, Жонглёрларның Европа ассоциациясе әгъзасы (Швейцария, 1998). Г. җитәкчелегендәге номер дөньяның 20 дән артык илендә күрсәтелә.

*Әд.:* Р у б ц о в а М. Время отсчитывает булавы // Советская эстрада и цирк. 1986. № 1.

*Ю.А.Благов.*

**ГЫЙБАДУ́ЛЛИН** Камил Габделбәр улы (27.11.1942, Казан), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), ТРның атказ. машина төзүчесе (1995), ТРның атказ. уйлап табучысы (2002). 1961 елда БАССРның Октябрьск нефть техникумын, 1976 да Уфа нефть ин-тын тәмамлый. 1963 тән Октябрьск «Нефтеавтоматика» з-ды КБсында эшли, 1969–2006 да Татарстан нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү ин-тында: проектның баш конструкторы (1976 дан), бүлек мөдире (1977 дән), директор урынбасары (1994 тән), бер үк вакытта баш инженер (1998 дән). Хезмәтләре нефть һәм газ промыселлары җиһазлары төзүгә карый. Дәүләт бүләге вакланмаган тузган шиналарны утильләштерүнең экологик чиста технологиясен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне, аларның модульле җайланмалары комплексын сәнәгый җитештерүне оештырганы өчен бирелә. Уйлап табуга 61 авторлык таныклыгы бар.

**ГЫЙБАДУ́ЛЛИНА** Маргарита Борисовна (20.12.1949, Казан), цирк артисты, акробат, жонглёр, ТРның халык артисты (1995). Казан театр уч-щесен (1969), Казан циркы каршындагы Бөтенсоюз цирк сәнгате үзәк студиясен (1970), Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, Мәскәү, 1996) тәмамлый. 1970 елдан Татар цирк коллективы составында «Төркемле акробат- жонглёрлар» («Групповые акробаты-жонглёры») номерында, 1979–82 дә «Рен тәгәрмәчләре өстендәге гимнастлар» («Гимнасты на Ренских колёсах») номеры составында чыгышлар ясый. 1992 дән Мәскәү Зур циркы артисты. 1997 дән үзе иҗат иткән, иллюзион трюклар жонглёрлык элементлары б-н кушылган әкияттәгечә матур, ачык

«Иллюзион миниатюралар» номерын башкара. Артистның башкару манерасы ачык, матур чагылышы, зур осталык, бик яхшы техник эшләнеше б-н аерылып тора. Беренче Бөтенсоюз цирк сәнгате конкурсы (Мәскәү, 1982), Энсхеде шәһәрендә узган Халыкара фестиваль (Голландия, 1998) лауреаты.

*Әд.:* к. Д.Х.*Гыйбадуллин* мәкаләсе янында.

*Ю.А.Благов.*

**ГЫЙБАДУ́ЛЛИНА** Фәүзия Солтан кызы (10.9.1952, Питрәч р-ны Салкын Чишмә а.), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), а.х. фән. д-ры (2005). Ульянов а.х. ин-тын тәмамлый (1977). 1974–77 елларда Питрәч кошчылык ф-касында чебешләр үстерү цехы башлыгы, 1977–78 дә ВЛКСМның Питрәч райкомы 2 нче секретаре. 1978 дән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. 2005 тән фән буенча директор урынбасары. Уйлап табуга 3 патенты бар. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында терлек азыгы җитештерү системасын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ГЫЙЗБУ́ЛЛИН** Наил Гайфулла улы (27.3.1937, БАССРның Дуван р-ны Өлкенде а.), галим-агроном, а.х.фән. д-ры (1982), Украина Аграр ФАнең мөхбир әгъзасы (1993). Дуван а.х. техникумын (1956) һәм Башкортстан а.х. ин-тын (1961) тәмамлый. 1962–66 елларда Башкортстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының шикәр чөгендере бүлеге мөдире, бер үк вакытта Эстәрлетамак тәҗрибә хуҗалыгы директоры. 1968 дән Шикәр чөгендере фәнни-тикшеренү ин-тында (Киев), күчереп утырту орлыкчылыгы лаб-ясе мөдире (1984–86), проф. (1984), орлыкчылык һәм орлык белеме бүлеге мөдире (1986–93), гыйльми секретарь (1993–98), фәнни-оештыру бүлеге мөдире һәм баш фәнни хезмәткәр (1998 дән), ин-т директоры урынбасары (2008 дән). Хезмәтләре орлыклык үсемлекләр биологиясенә һәм шикәр чөгендере орлыкчылыгына (орлыклар экологиясе, орлыкчылыкны районлаштыру, орлык үстерү технологиясе), үсемлекчелектә әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итә торган пестицидлар һәм үсешне көйләгечләр куллану алымнарына карый. Украина кыр тикшеренүләренә булышлык ассоциациясе президенты (2002 дән). Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм 6 патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Семеноводство сахарной свёклы. Киев, 1987 (автордаш).

*Әд.:* Поздравляем юбиляра // Сахарная свёкла. 1997. № 2.

**ГЫЙЗЗӘ́Т** (Гыйззәтуллин) Бәян (Фәтхелбәян) Нурлыгаян улы (16.7.1918, хәзерге БРның Куршнаренко р-ны Талбазы а. — 25.5.1991, Казан), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән канд. (1951), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). 1946 елдан — Татар акад. театрында әдәби бүлек мөдире. 1953–83 тә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1968–81 дә сәнгать секторы мөдире). Г.Коләхмәтов, Т.Гыйззәт тормышын һәм иҗатын өйрәнә; Г.Камал, Г.Кариев, К.Тинчурин, М.Фәйзи, Ф.Бурнаш, Х.Әбҗәлилов, Р.Ишморат, Г.Кутуй, Һ.Такташ, Г.Насрый һ.б.ның иҗат портретларын тудыра. Хезмәтләре татар театры һәм драматургиясе тарихына карый. Г. — «Татар совет әдәбияты тарихы» («История татарской советской литературы», 1965), «Совет драма театры тарихы» («История советского драматического театра», М., 1964–71), «Күпмилләтле совет әдәбияты тарихы» («История советской многонациональной литературы», М., 1971–74), «Октябрьгә кадәрге татар театры» (1988) хезмәтләре авторларының берсе. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м .: Драматург Таҗи Гыйззәт. К., 1957; Гафур Кулахметов. К., 1981.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Әдәбият һәм сәнгать белгече // Казан утлары. 1968. № 7; И ш м о р а т Р., М ә х м ү т о в Һ. Бәян Гыйззәткә 60 яшь // Казан утлары. 1978. № 7.

**ГЫЙЗЗӘ́Т** (Гыйззәтуллин) Таҗи Кәлимулла улы (15.9.1895, Вятка губ., Алабуга өязе Барҗы-Умга а. — 7.3.1955, Казан), драматург, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1940). 1910 елга кадәр авыл мәдрәсәсендә укый. 1913–19 да Ижевск корал з-дында эшли. 1919–20 дә Кызыл Армиядә хезмәт итә, анда үзешчән сәнгатьтә катнаша, беренче шигырьләрен һәм пьесаларын яза. Самара хәрби округы Сәяси идарәсе каршындагы татар драма студиясенә укырга җибәрелә. Аны тәмамлагач, 1921–29 да — Оренбург, Казан, Ульянов, Алабуга, Мәскәү театрларында һәм труппаларында актёр һәм режиссёр. 1920–50 дә Татар акад. театрында эшли, 1930 еллар уртасыннан — театрның сәнгать советы әгъзасы. 1942–44 тә — ТАССР Язучылар берлегенең җаваплы сәркәтибе. Татар театрлары сәхнәләрендә 30 еллык артистлык эшчәнлеге дәверендә ул, татар, рус һәм чит ил классик драматургия әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә күп рольләр башкарып, шактый уңышлы образлар иҗат итә. Татар театры тарихында Г. беренче чиратта драматург буларак билгеле. Г. Татар акад. театры һәм башка театрлар сәхнәләрендә куелган 37 пьеса авторы. Пьесаларының төп үзенчәнлеге — аларның үткен социаль юнәлешле булуы. Г. татар халкының милли һәм социаль изелүгә каршы алып барган көрәшенең әдәби елъязмачысы булып танылa. «Наёмщик» драмасында (1928) 1861 елгы патша Манифестына каршы юнәлдерелгән крәстияннәр чыгышы чагылдырыла. «Ялкын» пьесасында (1943) 1870 елларда татар авылларында дини изүләргә каршы башланган чуалышлар тасвирлана. «Чаткылар» драмасында (1934) Столыпинның җир реформасына каршы юнәлтелгән крәстияннәр чуалышы яктыртыла. «Ташкыннар» (1936–51; «Шомлы көннәр», «Даулы көннәр», «Данлы көннәр») трилогиясендә татар крәстияннәренең 1 нче бөтендөнья сугышында, 1917 елгы Февраль һәм Октябрь рев-цияләрендә катнашулары сурәтләнә. «Бишбүләк» (1938) музыкаль драмасында Гражданнар сугышы вакыйгалары чагылыш таба. Г. 1920–1930 елларда илдә барган күмәкләшү б-н бәйле үзгәрешләрне дә читләтеп үтми. Бу еллардагы халыкның тормышын һәм уй-фикерләрен тасвирлаган «Ил үскәндә» (1930), «Бөек борылыш» (1930), «Бөгелеш» (1930), «Көрәш» (1931), «Ударник Мохтар» (1932), «Җиңү бәйрәме» (1933), «Мактаулы заман» (1936) пьесаларын яза. Халыкның Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыгын «Таймасовлар» (1941), «Төнге сигнал» (1941), «Изге әманәт» (1946), «Чын мәхәббәт» (1948) пьесаларында чагылдыра.



Т. Гыйззәт.

Татар драматургиясендә Г. М.Фәйзи һәм К.Тинчурин нигез салган музыкаль драма жанры традицияләрен дәвам итә. Г. либреттосы буенча (башкорт язучысы Х.Ибраһимовның шул ук исемдәге пьесасы нигезендә) «Башмагым» беренче татар музыкаль комедиясе (1942) язылa (Җ.Фәйзи музыкасы). Киң таралган һәм танылган, күп еллар дәвамында, Татарстаннан тыш, Мәскәү, Киев, Ташкент, Свердловск һ.б. шәһәрләр сәхнәләрендә уңышлы барган «Наёмщик», «Бишбүләк», «Чын мәхәббәт», «Алсу таң» драмаларына (1949–54) музыканы С.Сәйдәшев яза. Г. — матбугатта күпсанлы публицистик чыгышлар, Г.Камал, Ш.Камал, К.Тинчурин, Н.Сакаев, Х.Такташ, Г.Болгарская һ.б. турындагы истәлекләр авторы. Ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1975–78.

*Әд.:* Г ы й з з ә т Б. Драматург Таҗи Гыйззәт. К., 1957; Г ы й з з ә т о в К. Таҗи Гыйззәт. К., 2000; История татарской советской литературы. М., 1965; А р с л а н о в Г. Героико-романтические пьесы Т.Гиззата // Татарское режиссёрское искусство. К., 1996.

*Ф.М.Мусин.*

**ГЫЙЗЗӘТДИ́НОВ** Лотфулла Вәли улы (14.2.1918, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Кариле а. — 12.7.1982, Казан), инженер-механик, Соц. Хезмәт Герое (1971), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1978). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1942). 1942–51 елларда С.П.Горбунов исем. авиация з-дында эшли: мастер, өлкән мастер, остаханә, планлаштыру-диспетчерлык бюросы башлыгы, җитештерү цехы башлыгы урынбасары, 1944 тән завод комсомол оешмасы комсоргы, 1947 дән ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре. 1951–82 дә «Элекон» ҖБндә: серияләп чыгару-конструкторлык бүлеге башлыгы, баш инженер урынбасары (1960 тан), баш инженер (1961 дән), директор (1962 дән), ген. директор (1976 дан). Г. җитәкчелегендә завод җитештерүдә зур уңышларга ирешә, катлаулы агрегатлар, разъёмнар, авиация һәм космик приборлар, көнкүреш компьютерлары һәм халык куллануы товарлары чыгара. Тулай продукция күләме — 9, хезмәт җитештерүчәнлеге — 4,7, эшләүчеләр саны — 2, производство мәйданы — 2,4, разъёмнар чыгару 4,7 тапкыр арта. Герой исеме 8 нче бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне, яңа тех-

ника булдырганы, электрон сәнәгатен үстергәне өчен бирелә. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, дүрт Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда 1972–82 елларда Г. яшәгән йортка мемориаль такта куела (1997).

*Әд.:* Л и с е в и ч М. Мы его звали батей // Респ. Татарстан. 1998. 12 февр.; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГЫЙЗЗӘ́ТОВ** Казбек Таҗи улы (18.1.1925, Ульянов ш.), философ, филос. фән. д-ры (1979), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). Драматург Т.*Гыйззәтнең* улы. 1943–54 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1955–57 елларда Татпромсовет инспекторы, 1962–65 тә «Татарстан коммунисты» ж-лы хезмәткәре. 1965 тән Казан консерваториясендә марксизм-ленинизм каф., 1977 дән — Казан финанс-икътисад ин-тында филос. каф. мөдире. 1987 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында эшли (1997 гә кадәр филос. каф. мөдире). Хезмәтләре милләтара мөнәсәбәтләр, милли идеология, сәнгатьтә миллилек һәм гомумкешелек кыйммәтләренең диалектикасы, сәнгатьчә сурәтләү чаралары һәм мәдәният тәгълиматы мәсьәләләренә карый. Фильм сценарийлары һәм пьесалар, философия һәм эстетика буенча татар телендә уку ярдәмлекләре («Философия», т. 1–2, 2002–03; «Нәфасәт», кит. 1, К., 2004, кит. 2, К., 2006) авторы. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Национальное и интернациональное в советском обществе. К., 1974; Национальная идеология: В 2 т. М., 1999; Тази Гиззат. К., 2000.

*Әд.:* А л е к с е е в П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**ГЫЙЗЗӘ́ТОВ** Ширвән Әдият (Һидият) улы (1.9.1904, Оренбург өлкәсенең Илек р-ны Мухран а. — 30.10.1944, Тисафюред ш. янында, Венгрия), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), лейтенант. Сәяси состав курсларын тәмамлый (1942). 1942 елның мартыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 795 нче укчы полкны (53 нче армиянең 228 нче укчы дивизиясе) взвод командиры. Төньяк-Көнбатыш, Резерв, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Демянск операциясендә (1943), Курск сугышында һәм Днепр өчен барган сугышларда (1943), Кировоград, Корсунь-Шевченко һәм Яссы-Кишинёв (барысы да — 1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 30 октябрендә Тисафюред шәһәре янында Тиса елгасы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы кичә; яулап алган урынны төп көчләр килгәнче кулда тота; аның взводы дошманның 18 һөҗүмен кире кайтара. Яу кырында һәлак була. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*



Абдулла Г. Гыйззәтуллин.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Абдулла Гыйбадулла улы (5.5.1904, хәзерге БРның Чишмә р-ны Ибраһим авылы — 15.3.1945), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), гв. сержанты (1944). МТСта тракторчылар бригадасы җитәкчесе булып эшли. 1942 елның маеннан Кызыл Армиядә. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 60 нчы гв. кавалерия полкының (61 нче армиянең 7 нче гв. кавалерия корпусы 16 нчы гв. кавалерия дивизиясе) отделение командиры. Көнбатыш, Брянск, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия, 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Орёл һөҗүм операциясендә (1943), Карелияне, Балтыйк буен, Белоруссия, Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша (1945). 1943 нең 27 сентябрендә Галки авылы янында (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагин р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Яу кырында һәлак була. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии. Уфа, 1968. Кн. 3; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

*В.А.Шагалов.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Альберт Гыйният улы (20.3.1938, Чиләбе ш.), патофизиолог, гематолог, мед. фән д-ры (1976), проф. (1978). Башкорт мед. ин-тын (хәзер Башкорт мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук эшли. 1967–70 елларда Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе, 1982 дән нормаль физиология каф. мөдире. Хезмәтләре организмга тышкы мохитнең төрле факторлары тәэсире вакытында кан системасы көйләнешен өйрәнүгә, җылынудан саклану чараларын эшләүгә карый. Г. организмның репродуктив функцияләренә нефть чыгаруда файдаланыла торган җир өстендәге актив матдәләрнең тәэсирен өйрәнә. Г. казналардагы сөякләрне алмаштыру ысулын уйлап таба.

Х е з м.: Профилактика стоматологических заболеваний. М., 1986.

*Әд.:* Е н и к е е в Д.Е. Кафедра патофизиологии Башкирского медицинского университета. Уфа, 1997.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Булат Миңнулла улы (29.9.1920, Уфа — 26.9.1989, Казан), журналист, мәдәният эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1970). Казан танк уч-щесен (1942), Казан ун-тын (1950) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–53 елларда «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы мөхәррире, 1955–58 дә «Литературная газета»ның үз хәбәрчесе. 1958–62 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында мәдәният бүлеге мөдире, 1961–73 тә ТАССР мәдәният министры. Республиканың авыл җирләрендә клуб учреждениеләре төзелешен җәелдерүгә, китапханә фондларының матди-техник базасын ныгыту һәм баетуга, мәдәният-мәгърифәт өлкәсендә квалификацияле кадрлар әзерләүне киңәйтүгә, ТР Симфоник оркестрын оештыруга, «КамАЗ» АҖ төзүчеләренә мәдәни-агарту хезмәте күрсәтүне киң планда тормышка ашыруга зур өлеш кертә. 1973–77 дә Казан циркы директоры, бер үк вакытта 1980 гә кадәр баш режиссёры. 1963–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М.Р. Шәриктәшем турында // Мирас. 2002. № 3.

*Г.С.Сабирҗанов.*



Л.В. Гыйззәтдинов.



Ш.Ә. Гыйззәтов.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Васил Нурулла улы (14.3.1953, Саба р-ны Урман хуҗалыгы пос.), урманчы, ТАССРның атказ. урманчысы (1988), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Мари политехник ин-тын тәмамлый (1986). 1975 елдан Саба урман хуҗалыгында: Мишәбаш урманчылыгында урманчы ярдәмчесе, 1984 тән Курса урманчылыгында урманчы, 1989 дан баш инженер, 1999 дан урман хуҗалыгы директоры. Хезмәтләре агачның сыйфатын һәм чыгышын арттыруга карый. ТРның Дәүләт бүләге «Урман кискәндә алдынгы, ресурсларны саклау ысулларын эшләү һәм киң куллануга кертү, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агачларны нык эшкәртүне оештыру, Саба урман хуҗалыгында чыршылар үстерүне тизләтү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Пихта сибирская в лесах Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 2000 (автордаш); Ведение комплексного многоцелевого лесного хозяйства в малолесных регионах. К., 2003 (автордаш).


**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Вәлиулла Гыйззәтулла улы (26.4.1837, Казан губ., Казан өязе Түбән Аты а. — 13.8.1916), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Казан сәүдәгәрлегенә 1878 елда теркәлә. Печән базары мәйданында һәм Балык рәтләре урамында урнашкан кибетләрендә бакалея товарлары һәм Азиядән китерелгән келәмнәр б-н сату итә. 1887–1911 дә Казан шәһәр думасы гласные. Ятимнәр мәхкәмәсе әгъзасы (1886 дан), өстәмә кәсепчелек салымы эшләре буенча Казан палатасы җыены әгъзасы. Мөселманнар арасында Г. «Вәли Ата» кушаматы б-н мәгълүм була. Кадимчелек тарафдары, халык мәгарифе өлкәсендә җәдитчелек алымнары б-н укытуга каршы чыга. Мәрҗани мәчетен тотуга зур күләмдә акчалата иганә кыла.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*



М.С.Гыйззәтуллин.



Хамазан Г.Гыйззәтуллин.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Илдус Закиржан улы (14.5.1935, Казан), радиоинженер, Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе ген. директоры (1988–94). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Казан электрон хисаплау машиналары з-дында эшли: инженер, лаб. мөдире, җыю-көйләү производствосы башлыгы урынбасары, баш инженер урынбасары, баш инженер (1975 тән), завод директоры (1979–88). Г. катнашында һәм җитәкчелегендә ЕС-1033, ЕС-1045, ЕС-1046, терминаль ЕС-1007 электрон хисаплау машиналары, ЕС-7032, ЕС-7036, ЕС-7040 алфавитлы-цифрлы язу җайланмалары эшләнә һәм аларны серияләп җитештерү үзләштерелә. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, көмеш медальләре, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость университета / КАИ: Краткий биогр. справ. К., 2002.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Миңнулла Сөнгать улы (10.11.1925, Лаеш кантоны, хәзерге Балык Бистәсе р-ны Күки а. — 26.9.1993, Казан), Сов. Союзы Герое (23.9.1944), гв. рядовое. Туган авылында колхозда эшли. 1943 елның апреленнән Кызыл Армиядә. 1943 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 20 нче гв. механикалаштырылган бригадасы (1 нче танк армиясенең 8 нче гв. механикалаштырылган корпусы) автоматчысы. 1 нче Украина, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Украина, Белоруссия, Польшаны азат итүдә, Берлинны алуда (1945) катнаша. 1944 нең 30 июлендә Баранув-Сандамерски шәһәре (Польша) янында Висла елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. 1947 дән запаста, Казанда эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н А. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Нур Габделхәй улы (12.7.1928, Актаныш р-ны Яңа Байсар а. — 22.6.2004, Казан, Арча р-ны Кушлавыч а.нда җирләнгән), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1953). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1952–90 елларда — СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, 1920–40 еллар прозасына, К.Нәҗми иҗатына карый. К.Нәҗми әсәрләрен (т. 1–4, 1958–60; т. 1–4, 1981–84) басмага әзерләүдә катнаша. Г. — «Татар совет әдәбияты тарихы» («История татарской советской литературы», М., 1965), «Күпмилләтле совет әдәбияты тарихы» («История советской многонациональной литературы», т. 2, 4, М., 1971–73), «Татар әдәбияты тарихы» («История татарской литературы», т. 4, 5, 1988–89) фәнни хезмәтләренең аерым бүлекләре авторы.

Х е з м.: Кави Нәҗми. К., 1957; Әдәбият белеме сүзлеге / Төз. Н.Гыйззәтуллин. К., 1958; Әдәбият баскычлары. К., 1976 (автордаш).

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Рафис Әхәт улы (8.3.1955, Сарман р-ны Урта Кәшер а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), республикада чыга торган вакытлы матбугат редакцияләрендә эшли. Беренче шигырьләре 1970 еллар башында «Ялкын» ж-лында, «Яшь ленинчы» г-тасында басыла. 1994–97 елларда «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында баш мөхәррир. 2002–04 тә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында. Балалар өчен «Очучы буласым килә» (1984), «Урман юлы» (1987), «Көтелмәгән сорау» (1990) исемле хикәя җыентыклары авторы. Аларда маҗаралы хәлләр балаларга аңлаешлы, гади телдә, матур итеп сурәтләнә. Геройларының бай күңел дөньясын Г. «Кырау» (1996), «Багалмада кунакта» (1996), «Төнге яңгыр» (2001) дип аталган хикәя җыентыкларында да ачып бирә. Г. ш.у. татар әдәбияты һәм сәнгатенә караган әдәби-тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре турында очерклар авторы.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Фоат Лотфулла улы (4.1.1956, Биектау р-ны Олы Кавал а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1992). Хезмәт эшчәнлеген 1972 елда Биектау р-нының «Чулпан» к-зында комбайнчы ярдәмчесе булып башлый. 1977–87 елларда Казан пр-тиеләрендә шофер булып эшли. 1988 дән Биектау р-нының «Чулпан» коллектив пр-тиесендә: рәис урынбасары (1988–92), рәис (1992–2001). «Гыйззәтуллин Ф.Л.» крәстиән-фермер хуҗалыгы җитәкчесе (2001 дән). Г. катнашында хуҗалыкта файдалану өчен уңайсыз җирләргә урман утырту, сөзәклекләрдәге табигый терлек азыгы җирләрен яхшырту, ишелә баручы ерым-ярларны сөзәкләндерү эшләре башкарыла, ландшафтлы игенчелек системасында туфрак эшкәртүдә туфрак саклау технологиясе кертелә. Дәүләт бүләге хуҗалыкта адаптив агроландшафтлы игенчелек системасын үзләштергәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Хамазан Гатаулла улы (10.5.1921, Курган өлкәсенең хәзерге Шадрин р-ны Сибирка а.), Сов. Союзы Герое (30.10.1943), подполковник (1960). Туган авылында колхозда эшли. 1940 елдан Кызыл Армиядә. Кече лейтенантлар курсларын (1944) һәм офицерлар составын камилләштерү курсларын (1953) тәмамлый. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 63 нче танкка каршы аерым дивизионның (65 нчы армиянең 106 нчы укчы дивизиясе) орудие командиры. Сталинград, Дон, Воронеж, Дала һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Украина, Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага операцияләрендә катнаша (1945). 1943 нең 15 октябрендә Лоев бистәсе янында (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. 1945 нең 24 июнендә Мәскәүдәге Җиңү Парадында катнаша. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. 1960 тан Майкоп шәһәрендә, запаста. Ленин ордены, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К о л о с о в с к и й М.Р. Шадринцы — Герои Советского Союза. Челябинск, 1965; Золотые Звёзды курганцев. Челябинск, 1975; Золотые Звёзды Адыгеи. Майкоп, 1980; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

*В.А.Шагалов.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Хәмит Нурислам улы (10.2.1932, БАССРның Зилаер р-ны Чупан а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1977), РФАнең мөхбир әгъзасы (1991). 1963 елда Башкорт ун-тын тәмамлый. 1963–79 да СССР ФА Урал гыйльми үзәгенең Математика һәм механика ин-тында эшли (Свердловск ш.), 1979–85 тә СССР ФА Урал бүлегенең Икътисад ин-тында бүлек мөдире. 1985–91 дә СССР ФА Урал бүлегенең Башкортстан гыйльми үзәге рәисе урынбасары. 1992 елдан РФАнең Икътисад һәм социология ин-ты (Уфа) директоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлеше — металлургия комплексын үстерү һәм эшләтүнең икътисади-матем. модельләре системасы принципларын эшләү һәм төзүгә карый. Аның тарафыннан регионда халык хуҗалыгы структурасын үзгәртеп коруның нәтиҗәлелеген исәпләүнең принципиаль яңа методикасы эшләнә, икътисад б-н табигатьнең үзара бәйләнеше процессларын көйләү проблемалары тикшерелә.

Х е з м.: Математические вопросы согласования показателей регионального развития. Свердловск, 1985; Моделирование металлургического комплекса. М., 1988; Эффективность природоохранной деятельности и моделирование рационального природопользования. Уфа, 1989; Концепция охраны окружающей среды и рационального использования природных ресурсов Республики Башкортстан. Уфа, 1993.

*Әд.:* Научная элита: Кто есть кто в Российской АН. М., 1993.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Хөсәен Гали улы (19.9.1910, Казан өязе Кәче а. — 22.6.1980, Казан), эпизоотолог, иммунолог, вет. фән. д-ры (1956), проф. (1958), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1965, 1975). 1932 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1958–63, 1974–80 дә эпизоотология каф., 1959 дан иммунология лаб-ясе мөдире, 1963–75 тә ректор. Хезмәтләре гомуми эпизоотологиягә, хайваннарда йогышлы авырулар: Себер түләмә-

се, ящур, бруцеллёз һ.б. булдырмау һәм бетерүнең отышлы ысулларын эшләүгә карый. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Активная профилактика болезней сельскохозяйственных животных. К., 1958; Бруцеллёз: его активное предупреждение и искоренение. К., 1960; Чума свиней и современные методы её диагностики. К., 1973.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг). К., 2006.

*О.М.Гыйльметдинова.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИН** Шамил Хәмбәл улы (16.3.1931, Ленинград ш.), хәрби табиб, нейрохирург, мед. фән. д-ры (1999), проф. 2005), мед. хезмәте полковнигы (2005). 1984 елда Хәрби мед. академиясен (Ленинград) тәмамлагач, Урта Азия хәрби округында эшли. 1987 дән Хәрби мед. академиясенең нейрохирургия кафедрасында. 1989 дан И.Н.Бурденко исем. Баш хәрби-клиник госпиталь (Мәскәү) башлыгы, бер үк вакытта Мәскәү мед. академиясенең хәрби-кыр хирургиясе каф. профессоры (2005 тән). Хезмәтләре нейрохирургик авыруларга диагноз кую һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Сугыш барган урыннарда яралаучыларга нейрохирургик ярдәм оештыруда катнаша. «Хәрби казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оружейные черепно-мозговые ранения. М., 1997 (автордаш); Военно-полевая хирургия. М., 2002.

*Әд.:* Б ә д е р т д и н о в Х. Татарстаннан читтәге татар галимнәре. К., 2006.

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИНА** Вафирә Мөхәммәтдин кызы (13.2.1946, Менделеев р-ны Камай а. — 16.9.2001, шунда ук җирләнгән), җырчы, Каракалпак АССР, ТАССРның халык артисты (1980, 1981), РСФСРның атказ. артисты (1988). Казан консерваториясен (В.*Лазько* классы) вокал буенча тәмамлый (1974). 1975–94 елларда Татар филармониясе, 1997 елдан «Татарстан» ДТРК эстрада-симф. оркестры солисты. Г. үзенең репертуарына татар халык, дөнья халыклары җырларын, татар композиторларының (С.Сәйдәшев, З.Хәбибуллин, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Н.Җиһанов, Р.Яхин, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов, С.Садыйкова, Р.Еникиев, М.Макаров) вокаль әсәрләрен кертә. Соло концертлары арасында «Өмет», «Тормышым һәм бәхетем — җырларда», «Горурлык һәм мәхәббәт», Тукайның 100 еллыгына, С.Сәйдәшевнең 90 еллыгына, шагыйрә С.Сөләймановага, хатын-кызларга багышланган һ.б. программалар бар. Ачык матур тавышка, күркәм тышкы кыяфәткә, нечкә лирик хис б-н һәм көчле җылысын бирeп җырлау сәләтенә ия. Г. иҗаты — татар концерт эстрадасында милли академик җырлау сәнгатенең халык һәм эстрада музыкасының иң югары үрнәкләрен үз эченә алган үзенчәлекле күренеш.

Җырчы буларак, гомумхалык мәхәббәтен яулый. 1990 еллардан милли мәдәниятне һәм сәнгатьне яңадан торгызу һәм үстерү өчен барган хәрәкәттә актив катнаша. Россия шәһәрләрендә һәм күп кенә чит илләрдә (Австрия, Германия, Польша, Төркия, АКШ, Куба) гастрольләрдә була. Радиодан һәм телевидениедән даими чыгышлар ясый. «Татарстан» ДТРК фондларында Г.башкаруындагы 50 дән артык халык җыры һәм татар композиторларының вокаль әсәрләре язмалары бар. Воронежда узган Вокалистларның бөтенроссия конкурсы (1974), Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале конкурсы (Гавана, 1978) лауреаты.


В.М. Гыйззәтуллина.

*Әд.:* М у л л а н у р о в а Р. Иреккә омтылу // Сөембикә. 1991. № 11; Т и м б и к о в а К. Сәхнәләрдә йолдыз // Казан утлары. 1991. № 3.


*М.П.Фәйзуллаева.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИНА** Флёра Сабирҗан кызы (6.9.1931, Азнакай р-ны Әсәй а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). 1980 елдан Казанда. Беренче шигырьләре район һәм республика газета-журналларында, «Беренче карлыгачлар» (1968), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда басыла. «Чишмә юлы» (1974), «Сәлам хаты» (1981), «Акчарлагым — асыл кошым» (1983), «Утлы минутлар» (1986), «Сер ачкычым — сердәштә» (1990), «Яшеннәрнең күз яше» (1995), «Йөрәгемдә шаулый карурман» (2001), «Башкаемда дөнья исәпләре» (2007) шигъри җыентыклары б-н Г. укучы күңелендә нечкә хисле лирик, романтик шагыйрә буларак тәэсир калдыра. Аның шигъриятенә тормыш вакыйгаларын табигый, самими хис-тойгылар аша сурәтләү хас. Кайбер шигырьләре, көйгә салынып, популяр җырларга әверелә.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЗЗӘТУ́ЛЛИНА-ВО́ЛЖСКАЯ** Сәхибҗамал Гыйззәтулла кызы (14.5.1885, Казан — 6.4.1974, Чистай ш.), драма актрисасы, режиссёр, ТАССРның атказ. артисты (1926). Беренче проф. татар актрисасы. 1907 елда «Сәйяр» труппасына керә һәм шул вакытта ук татар проф. театрын оештыруда якыннан торып катнаша: репертуар сайлауда, куелырга әзерләнгән пьесаларның идея-сәнгать ягын аңлатуда, спектакль һәм рольләрне режиссёр буларак хәл итүдә активлык күрсәтә. Г.-В. фикеренчә, театр тормышны дөрес чагылдырып кына калмыйча, тамашачыда уңай хисләр уятырга, халыкның рухи укытучысы булырга тиеш. Бу принципиаль фикерләрне Г.-В. үзенең сәхнә эшчәнлегендә тормышка ашыра, героиняларында романтик, күтәренке хисләрне күрсәтергә, аларны көндәлек гади тормыштан югарырак күтәрергә омтыла. Хәтта бары тик көнкүреш темасына караган беркатлы, тәҗрибәсез гимназистка Гайшә яки елгыр фахишә Гайни («Бәхетсез егет», Г.Камал), Хәмзә бай йортындагы аңгыра, пешмәгән асрау кыз Биби («Беренче театр», Г.Камал), Бибиҗамал («Хуҗа һәм приказчик», А.Н.Островский буенча) һ.б. рольләрендә дә актриса героиняларының кабатланмас үзенчәлекләре б-н башкалардан аерылып тора торган сыйфатларын таба. Киң иҗат диапазонына ия буларак, Г.-В. төрле пландагы рольләрдә уйный, драматик яки көлкеле рольләрдә дә бертигез дәрәҗәдә тормышчан була, төгәл табылган чагылдыру детальләре, үткен күзәтүләре б-н тамашачыны сокландыра, еш кына драматург иҗат иткән образларны үзгәртеп, тормыш тәҗрибәсеннән һәм дөньяны үзенчә аңлавыннан чыгып, яңа детальләр өсти. Аның башкаруында гаҗәеп эчкерсезлек, дөреслек, хатын-кыз нәфислеге эчке матурлык һәм затлылык б-н үрелеп бара. Ләкин Г.-В.ның таланты Гөлҗиһан («Надиршаһ», Н.Нариманов), Зәйнәб («Яшь хатын», Д.Таждаров), Кручинина, Катерина («Гаепсездән гаеплеләр», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) кебек драматик образларны тудырганда аеруча көчле ачыла. Аларда актриса фаҗигане күрсәтүнең чын биеклегенә ирешә, шуның б-н үз героиняларына карата тамашачыда, шул чор газеталарында язылганча, «иң көчле һәм иң кайнар кызгану хисләре» уята. Г.-В.ның һәр чыгышы татар театр сәнгатендә зур вакыйга итеп кабул ителә, матбугатта сокланып язылган язмалардан тыш, актриса башкарган образларның социаль әчтәлеге турында җитди уйланулар да тудыра. Г.Тукай аңа шигырьләрен багышлый, аның турында Ф.Әмирхан, Г.Кәрам язалар. Г.-В.ның күп спектакльләрне куюда актив катнашуы, бәйсез, мөстәкыйль фикерли һәм карарлар кабул итә белү осталыгы, режиссура һәм актёрларны өйрәтү б-н мавыгуы аны 1912 елда үз театр труппасы «*Нур*»ны (Уфа ш.) оештыруга этәрә. Ул анда бер үк вакытта актриса, режиссёр, педагог, сәнгать җитәкчесе һәм антрепренёр вазифаларын алып бара: спектакльләр куя, актёрларны укыта һәм тәрбияли, чыгышлар, гастрольләр


С. Гыйззәтуллина-Волжская.


С. Г ы й з з ә т у л л и н а - В о л ж с к а я
Катерина ролендә
(«Яшенле яңгыр», А.Н. Островский).



С.Г ы й з з ә т у л л и н а - В о л ж с к а я «Илһам хан» спектаклендә Гөлчәчәк (уңда) ролендә.

оештыра, биналар арендалау б-н шөгыльләнә һ.б. Г.-В. «труппаның җаны да, йөрәге дә була. Аның таланты, сабырлыгы, тотнаклылыгы барысын да гаҗәпкә калдыра иде», — дип яза күренекле татар актёры Ш.Шамильский үзенең истәлекләрендә. Шуның б-н бергә ул сәнгатькә карата таләпләрендә кырыс әхлакый принципларга таяна. Эшкә бирелгәнлек, тәртиплелек, намуслылык, аралашу культурасы — Г.-В. иҗат эшчәнлегенең аерылгысыз өлеше. Татар театр сәнгатендә героик-романтик юнәлешкә нигез салучы, актриса, режиссёр, педагог буларак, ул татар проф. театрының формалашуында һәм үсешендә күренекле роль уйный. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларын оештыруда һәм аларның эшчәнлегендә актив катнаша. 1920–30 елларда Ижевск шәһәрендә яши, үзешчән театрларга ярдәм итә. Аннан соңгы елларда театр эшчәнлеген калдырып, Казанда һәм Чистай шәһәрендә яши.

Г.-В.ның башка рольләре: Сәгадәт («Фәхретдиннең кайгысы», Н.Вәзиров), Шәфика («Мескен бала», Н.Кәмал), Галия («Алдым-бирдем», Г.И.Исхакый), Зөбәйдә («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», С.Рәмиев), Мәгърифә («Оят», Я.Вәли), Бибиҗиһан («Мескен Бибиҗиһан», З.Сәетзадә), Адриана («Суд ялгышлыгы», А.Деннери) һ.б.

*Әд.:* М о р т а з и н В., Ч е н ә к ә й Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Татар театры. 1906–1926. К., 1926; К а ш ш а ф Г. Беренче артистка. К., 1958; С.Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр. К., 1982; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Аяз Мирсәет улы (17.1.1928, Чаллы кантоны, хәзерге Сарман р-ны Чукмарлы а. — 13.3.2002, Казан), язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978,1985), ТРның халык язучысы (1993). 1948 елда Казан ун-тына укырга керә. 1950 дә «советларга каршы пропаганда өчен» хөкем ителә. Ирекkә чыкканнан соң (1955), университетта укуын дәвам итә. 1957–61 елларда «Чаян», «Азат хатын» ж-лларында әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1963 тә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү). Г. таланты бигрәк тә проза җанрында ачыла. Аның авыл прозасы — татар халкы тормышында булган кискен борылышларны чагылдыруның ачык мисалы. Үзенең беренче хикәяләрендә үк («Рәтле кешеләр» җыентыгы, 1959) Г. шәхес характерын билгеләүдә әхлак принципларына өстенлек бирә. Бу — язучы иҗатында төп тема. 1950–60 елларда иҗат иткән әсәрләрендә Г. әхлаклылык кына кешене бәхетле итә ала дигән гомумкешелек принципларыннан чыгып эш итә. «Дүртәү» (1958) повестенда әхлаклылык идеалы булып шәхси бурычны үтәү хисе торса, «Өч аршын җир» (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Три аршина земли», М., 1966; 1987 дә Татар акад. театрында сәхнәләштерелә) повестеның төп идеясе — туган җиргә тугрылык. «Берәү» (1958), «Качак» (1959), «Зәй энҗеләре» (1963) повестьлары һәм «Урамнар артында яшел болын» (1969; рус теленә тәрҗемәсе «Диляра», М., 1973) романында автор совет җәмгыяте кануннарын тәнкыйть күзлегеннән карый һәм кешенең әхлакый йөзе югала баруын күрсәтә. «Урталыкта» (1969) повесте б-н язучы «нык үскән социализм» дәверенең совет чынбарлыгы картинасын тудыра, кешенең ни өчен конформизмга һәм әхлакый яктан түбәнәя баруына китергән сәбәпләрне эзләргә тырыша. «Җомга көн кич белән» (1979) повестенда этик проблемаларны, шәхес җаваплылыгы, хатын-кызның үзен аямау мәсьәләләрен күтәрә. Авыл тормышын сурәтләгәндә Г. халыкның милли традицияләренә таянса, шәһәр тематикасын яктырткан «Күзгә — күз» (1975), «Мең чакрым юл» (1978) әсәрләрендә мәдәни, интеллектуаль традицияләргә басым ясый, кешенең үз гамәлләренә бәя бирү мәсьәләләрен кискен куя. 1970 еллардагы иҗаты иҗтимагый-фәлсәфи проблемалар, халыкның рухи кыйммәтләрен яңартуны күтәрүе б-н үзенчәлекле. Аларда өлкән буын вәкилләре образлары идеаль герой төсе ала. «Әтәч менгән киртәгә» (1980) повестеның төп герое аркылы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә югары әхлак нормаларын чагылдырган автор идеалы гәүдәләндерелә. Әдипнең 1980–90 еллар прозасы татар әдәбиятында үрнәк булып торырлык әсәрләр. А.Литвин б-н берлектә язылган «Алтынчы августка кадәр ...» (1986–87) роман-хроникасы — Идел буенда Гражданнар сугышы турында. Ул үзенең сурәтләү алымнары б-н дә, жанры б-н дә аерыла. 1980 нән Г. аерым шәхесләргә, хәзерге җәмгыятькә әхлакый бәя бирүгә, социаль-психол. анализ ясауга зур игътибар юнәлтә. «Яра» (1981–88) повестенда автор шәхескә өстенлек бирелгән шундый җәмгыятьнең әхлакый кыйммәтен ачарга омтыла. «Балта кем кулында» (1988–89) романы б-н тоталитар режим шартларында әдәпле, акыллы фикерле, ирекле эш итәргә теләгән интеллигентның фаҗигасен күрсәтә. «Йөгез, бер дога!» (1991–93) роман-истәлеге — Г.нең күпьеллык иҗади эзләнүләренең үзенчәлекле нәтиҗәсе. Анда төрмә тормышы, тоткыннарның хокуксызлыгы турында сүз бара, Сталин режимына карата кырыс хөкем чыгарыла. Драматургиясенә татар халкы тормышында булган катлаулы үзгәрешләрнең мәгънәсен аңлатып бирергә, аларны фәлсәфи күзлектән чыгып бәяләүгә омтылу хас. Татар акад. театрында куелган «Көзге ачы җилләрдә» (1961 дә сәхнәләштерелә), «Әнгер-меңгер» (1971 дә), «Югалган көн» (1976 да), «Китмәгез, тургайлар» (1978 дә сәхнәләштерелә) драмаларында җәмгыять төзелеше һәм әхлак нигезләре, кешенең рухи байлыклары арасындагы үзара бәйләнешләр сурәтләнә. Кеше гамәлләренең тискәре ягы «Сары чәчәк ата көнбагыш» (1974 тә сәхнәләштерелә), «Я кайтырбыз, я кайтмабыз» (1975 тә сәхнәләштерелә) тарихи драмаларында да кискен куела. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1983) һәм РСФСРның А.М.Горький исем. Дәүләт бүләге (1987) лауреаты.



А.Гыйләҗев.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 1993–94; Күңелем серләре: куен дәфтәреннән // Казан утлары. 2000. № 11–12.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Ф. Балта явызлар кулында. К., 1994; С ә х а п о в Ә. Кырыс чынбарлык.К., 1995; А х у н о в Г. Язмыш яздырган кыйсса // Мәдәни җомга. 1996. 9 февр.; ш у л у к. Язучы һәм заман // Казан утлары. 1998. № 1.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Илдус Сабир улы (15.1.1946, Азнакай р-ны Урсай а.), шагыйрь, а.х. оешмасы һ.б. пр-тиеләр җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1976 елдан Азнакай р-ны пр-тиеләрендә: «Ленин юлы» (1976–81), «Коммунизмга» (1981–90) к-злары рәисе, «Актүбәнефть» нефть-газ чыгару идарәсе җитәкчесе урынбасары (1992–94), «Татнефть» АҖнең «Никитинский» с-зы директоры (1999 дан «Туйкә» а.х. кооперативы рәисе). Г.нең шигырьләре публицистик рухта, гражданлык, туган җиргә, аның кешеләренә мәхәббәт хисләре б-н сугарылган («Җир китабы», 1988; «Җилкенү», 1990; «Өмет ае», 1993; «Серле мәгарә», 1995; «Хак сүз», 2000; «Чатыртау тылсымы», 2001, «Яратканга күрә», 2006 җыентыклары). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә. 1985–90 елларда — ТАССР ЮС депутаты.

*Әд.:* В ә л и е в М. Шигырь эшкә барамы? // Каһарманнар кирәк. К., 1990.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Искәндәр Аяз улы (31.8.1958, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2001), проф. (2001).ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982–85 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1985 тән Казан ун-тында, 2000 нән татар филологиясе һәм тарихы ф-ты деканы, бер үк вакытта 2002 дән татар халкы тарихы каф. мөдире. Хезмәтлә-

ре Икенче бөтендөнья сугышы тарихына, татар халкының 16–18 йөзләрдәге социаль-икътисади тарихына, 19–20 йөзләрдә Европа һәм Азия илләрендәге татар эмиграциясе мәсьәләләренә карый. Германия архивларында Икенче бөтендөнья сугышы чорында татар легионерлары тарихына кагылышлы документларны эзләп таба һәм аларны фәнни әйләнешкә кертә.

Х е з м.: Контакты российских татар-мусульман с Западной Европой: поиск новых цивилизованных ориентиров // Ислам и этническая мобилизация: национальные движения в тюркском мире. М., 1998; На другой стороне. Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны. К., 1998; Легион «Идель-Урал»: представители народов Поволжья и Приуралья под знаменем «третьего рейха». К., 2005; Die Wolga-Tataren und Deutschland im ersten Drittel des 20. Jahrhundersts // Muslim Culture in Russia and Central Asia from the 18th to the Early 20th Centuries. Jnter — Refional and Jnter — Ethnic Relanions (Jslamkundliche Untersuchungen). B., 1998. V.2.

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Мансур Аяз улы (29.1.1961, Казан), драматург, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006). Рус телендә яза. Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлагач (1983), Мәскәү проектлаар төзү ин-тында эшли. 1986 елда Казанга кайта һәм үзен язучылык эшенә багышлый. 2001 дән «Рамай» киностудиясендә баш мөхәррир һәм продюссер вазифаларын башкара. Аның пьесалары буенча Татар акад. театрында куелган «Бичура» (1989), «Казан егетләре» (1990), «Тагын Казан егетләре» (1994), «Баскетболист» (2002) спектакльләре Г.кә уңыш китерә. Аларда татар халкының гореф-гадәтләре, көнкүреше гәүдәләнеш таба. Мещанлыкны, ваемсызлыкны фаш иткән «Чаңгыда йөрү өчен кояшлы көн» — «Солнечный день для лыжной прогулки», «Иясез йортның төшләре» — «Сны опустевшего дома», «Коляска», «Метеорит» пьесалары «Ай капкасы» — «Лунные врата», (1990) җыентыгына тупланган. Ч.Айтматовның «Плаха» («Ахырзаман», 1987 дә сәхнәләштерелде), А.Гыйләҗевнең «Яра» (2003 тә сәхнәләштерелде) әсәрләре буенча язылган инсценировкалар авторы. Г.нең пьесалары ш.у. Казан «Әкият» курчак театрында, Әлмәт, Чаллы татар драма театрларында, Казан татар яшьләр театрында, Татар драма һәм комедия театрында һ.б. театрларда куела. Аның сценарие буенча «Күктау» нәфис фильмы (2002) төшерелде.

Ә с ә р.: Бичура. К., 2001; Лунные врата. К., 1990; Словарь любви. К., 2005.

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Миңнегали Йосыф улы (25.9.1951, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Урта Шуни а.), галим-агроном, агрохимик, а.х.фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук эшли: тармак фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1984 тән), агрохимия һәм туфрак белеме каф. мөдире вазифаларын башкаручы (1997 дән), проф. (2004 тән). Хезмәтләре нефть чыгарганда зыян күргән җирләрнең уңдырышлылыгын яңадан торгызу (рекультивация) мәсьәләләренә, җирле чималдан ашлама алу ысулларына карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Изменение некоторых агрохимических свойств выщелоченного чернозёма при загрязнении его нефтью // Агрохимия. 1980. № 12; Рекультивация нефтезагрязнённых земель лесостепной зоны Татарии // Восстановление нефтезагрязнённых почвенных экосистем. М., 1988 (автордаш); Чёрное золото и наши чернозёмы // Панорама-форум. 1997. № 4 (автордаш); Русско-татарский толковый терминологический словарь по агрохимии и почвоведению. К., 2003 (автордаш); Агроэкологическая характеристика и приёмы рекультивации нефтезагрязнённых чернозёмов Республики Татарстан. К., 2003.

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Наил Минһаҗ улы (13.7.1935, Ярославль ш.), слесарь, Соц. Хезмәт. Герое (1971). 1951–57 елларда Казан төгәл машиналар төзү з-дында эшли. 1958–86 да «Теплоконтроль» җитештерү берләшмәсендә инструментлар ясаучы слесарь, цех башлыгы. 1986–90 да Казан шәһәр башкарма комитетында торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге мөдире. 1990–99 да «Стоматология» проект-конструкторлык һәм технол. бюросында инструментлар ясаучы слесарь. Герой исеме 8 нче бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. 1975–79 да РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ихлас сүз. К., 1977.

*Әд.:* У с т и н о в с к и й В. Гилязов Наиль Мингазович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.


**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Рәшит Акмал улы (22.7.1951, Яшел Үзән ш.), нәкышьче, монументальче рәссам, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Лениногорск пед. уч-щесенең рәсем сәнгате бүлеген (1970), 1986 елда СССР САнең И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (акад. Е.Е.Моисеенконың нәкышь остаханәсендә) тәмамлый. 1984–86 да акад. В.Ф.Загонекның иҗат остаханәсендә укый. С.-Петербургта яши. А.И.Герцен исем. пед. ин-тының нәкышь кафедрасында укыта (1981–84), Рәссамнар берлегенең Ленинград бүлекчәсе карамагындагы нәкышь сәнгате комб-тында эшли (1984–90). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1988). Г. — пейзаж, натюрморт, тематик картиналар өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе, ш.у. портрет жанрында иҗат итә.



Н.М.Гыйләҗев.

Г.ның кабатланмас иҗади язу рәвеше һәм үзенчәлекле нәкышь стиле Көнбатыш Европа (импрессионистлар) һәм Шәрекъ сәнгате йогынтысында үсеш алган 19–20 йөзләр рус нәкышь сәнгате («Мир искусства» берләшмәсе) традицияләренә, ш.у. татар халкының гамәли бизәлеш сәнгате алымнарына нигезләнә. Аңа күләм һәм ритмнарның басым ясалган капма-каршылыгы, гадәттән тыш ракурслар хас: «Павлов парклы» (1979); «Җәйге чәчәк бәйләме» (1986); «Гурзуф» һәм «Паланга» пейзажлар сериясе (1990); «Язгы көн» (1990); «Сирень» (1990); «Италия буйлап» (1991); «Мәрҗани мәчете» (1991); «Франция» пейзажлар һәм натюрмортлар сериясе (1992–93) һ.б., Казан шәһәре һәм татар авыллары күренешләре, Баулы, Азнакай, Лениногорск р-ннары табигатен чагылдырылган пейзажлары романтик хисләр б-н сугарылган: «Баулы әкияте» (1992); «Алтын кич. Баулы» (1994); «Казан. Кремль» (1997); «Солтан җамигъ мәчете» (1999). «Чәй табыны» (1971), «Балыкчы» һәм «Төзүчеләр» (икесе дә — 1986), «Печән өсте» (1985), «КамАЗ төзүчеләр» (1991), «Тукайны озату» (1990 еллар) кебек тематик картиналары Татарстанның үткәненә һәм бүгенге тормышына багышланган. Г. замандашлары портретларының тулы бер галереясын булдыра: «Автопортрет» һәм «Яшьлек. Көтү» (икесе дә — 1983), «Зөлфия портреты» (1985), «Муза. Хатыным портреты» (1989); татар мәдәнияте һәм фән эшлеклеләре арасыннан — язучылар Ә.Еники, Н.Фәттах, шагыйрь Зөлфәт, проф. Ә.Халидов, ТР ФА академигы И.Таһиров портретлары (барысы да — 1999).

Татарстанда Г. үзен монументаль жанрда эшләүче рәссам буларак таныта. Ул диварга тарттырылган тукымага бизәк төшерү тех-



Р.А.Г ы й л ә җ е в. 1. «Казан. Кремль». 1997; 2. «Кырымсарай». 1999. Икесе дә ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

никасын булдыра, сынлы һәйкәлләр, дивар рәсемнәре, мозаика, витражлар авторы: район мәдәният йортындагы «Сабантуй» дивар рәсеме (1977) һәм «Октябрь» мәдәният сараенда эретеп ябыштырылган витраж һәм керәч мозаика (Зәй ш., 1979–82), Зәй ГРЭСы биналары эчендәге дивар рәсемнәре, чүкеп ясалган рәсемнәр һәм станлы әсәрләр (1978–87); Баулы шәһәрендәге «Гали» мәчете архит-ра проектының автордашы, аның экстерьерлары һәм интерьерлары бизәлеше авторы (1996); Олы Әтнә авылы җамигъ мәчете интерьерларында витражлар һәм бронза шәмдәлләр бизәлеше (1997); Урыссу бистәсендә Бөек Ватан сугышы корбаннарына куелган һәйкәл (архитекторлары Э.А.Тяхт, И.А.Шахов, 1986).

1971 дән респ-ка һәм бөтенсоюз күргәзмәләрендә, «Татарт» бөтентатар төбәкара күргәзмәсендә (С.-Петербург — Казан, 1991), ш.у. рәссамнар С.Бицираев, С.Обухов б-н бергәләп «ССР Союзы» уртак күргәзмәсендә (1998, С.-Петербург) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1986 (Ленинград, Баулы ш.), 1988 (Мамадыш ш.), 1990 (Латвия ССР, Паланга ш.), 1991 (С.-Петербург; Италия, Неаполь ш.), 1992 (Неаполь ш.), 1993 (Франция шәһәрләре), 1994 (Германиянең Любек, Берлин ш.), 1995–96 (С.-Петербург), 1997 (Мәскәү), 1998 (С.-Петербург, Мәскәү), 1999 (Казан, Мәскәү) елларда уза.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Чаллы шәһәре картиналар галереясында, Баулы туган якны өйрәнү музеенда, Россия, Франция, Германия, Голландия, Италия һ.б. илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Д м и т р е н к о А. Иҗатчы юллары // Сөембикә. 1999. №7; С и б г а т у л л и н а Т. Күңелгә нур иңдерүче // Казан утлары. 1999. №5; Рашид Гилазов: Буклет. К., 1999; К е к у ш е в а Г. Р.Гилязов. Живопись. СПб. 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВ** Ринат Рияз улы (20.12.1943, Яшел Үзән р-ны Түбән Урысбага а.), партия, хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Мари политехник ун-тын тәмамлый (1972). 1965–72 елларда ВЛКСМның Яшел Үзән шәһәр ком-тында бүлек мөдире, 1 нче секретаре, Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1972–74 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1974–84 тә халык депутатларының Чаллы шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. 1984–85 тә ТАССРның көнкүреш хезмәте күрсәтү министры. 1985–88 дә КПССның Казан шәһәр ком-ты секретаре. 1988–94 тә «Тататвтотранс» холдинг компаниясе генераль директоры урынбасары, 1994–96 да ген. директоры. 1996 дан «1 нче номерлы Казан пассажирлар автотранспорт пр-тиесе» ААҖнең директорлар советы рәисе. 1974–87 дә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: С нами ближе до Парижа. К., 1999 (автордаш).

**ГЫЙЛӘ́ҖЕВА** Наилә Фәйзерахман кызы (2.1.1953, Казан), спортчы (фехтование), СССРның атказ. спорт остасы (1976), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1975). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренерлары А.С.Кислюнин (1967 дән), В.В.*Житлов* (1970 тән). 1976–79 да команда беренчелегендә, 1982 дә шәхси беренчелектә — СССР, 1974–75, 1977–79, 1984 тә командә беренчелегендә, 1982 дә шәхси беренчелектә — дөнья, 1976 да команда беренчелегендә Олимпия уеннары чемпионы. 1974 тә



Н.Ф. Гыйләҗева.

дөнья чемпионатында (бронза, шәхси беренчелектә), 1980 дә Олимпия уеннарында (көмеш, команда беренчелегендә) медальләр ала. Европа кубогы иясе һәм бу ярышларда алгы урыннарны алучы (1974–83). 1979 да Бөтендөнья Универсиадасында (команда беренчелегендә), 1974 тә «Көмеш рапира» халыкара турнирында (шәхси беренчелектә) җиңүче. 1974 тән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан советында инструктор. 1997 дән Казанда Г. призына үсмерләр бәйгесе уздырыла. 2000 елда ТРның 20 йөздәге иң яхшы спортчы хатын-кызы дип танылды. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И л д а р х а н о в И.Г. Олимп тавына ничек менәргә? К., 1980; Ж и т л о в В.В. Есть мушкетеры, есть! К., 1988.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВ** Әсхәт Рәүф улы (13.2.1954, Казан), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (1998). 1977 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый һәм Чистай шәһәренең баш архитекторы бүлегендә эшли башлый, 1978 дән — баш архитекторы. 1992 дән Чистай шәһәре хакимияте башлыгының төзелеш һәм архит-ра мәсьәләләре буенча урынбасары, 1995 тән Казанның Архит-ра һәм шәһәр төзелеше баш идарәсе башлыгы — баш архитекторы. 2004 тән «Казгражданпроект» ин-тының баш архитекторы, 2009 дан баш белгеч. Чистайның төньяк-көнбатыш һәм үзәк торак р-ннарын детальле планлаштыру (1985), балалар сәнгать мәктәбе (1985, автордаш) һәм мәчет биналары проектлары авторы. Казанның Шәһәр төзелеше уставын эшләү б-н җитәкчелек итә (1897–98). Казанның Шәһәр төзелеше үсеше концепциясе (1995), Тузган тораклар урнашкан кварталларны үзгәртеп кору программасы (1996) һ.б.ның авторларының берсе.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВ** Җәүдәт Мәхмүт улы (15.4.1930, БАССРның Чишмә р-ны Арыслан а.), социолог, филос. фән. д-ры (1974), проф. (1975). Урта Азия ун-тын (1952, Ташкент) тәмамлаганнан соң, Ташкент ирригация һәм авыл хуҗалыгын механикалаштыру инженерлары ин-тында, 1968–77 елларда Уфа авиация ин-тында эшли. 1977 дән Башкорт пед. ин-тында, 1988 дән Башкорт ун-тында социология каф. мөдире. Хезмәтләре рухият, мәгариф социологиясе, этносоциология, тәрбия мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Национальные и межнациональные проблемы на современном этапе. Свердловск, 1991; Социальные проблемы молодежи в условиях перехода к рыночной экономике. Уфа, 1993.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВ** Илдар Абдулла улы (17.7.1943, Ташкент ш.), нурлар ярдәмендә диагноз кую белгече, мед. фән. д-ры (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук эшли. 1967 елдан Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе). Тикшеренүләре үзәк генезның нейроэндокрин билгеләренә һәм авыруларына нурлар ярдәмендә диагноз куюга, сөяк системасының яман шешләренә диагноз кую максаты б-н яссы табанлылыкны нурлар ярдәмендә тикшерү һәм радиометрик күзәтүдә изотоплар куллану мәсьәләләренә карый. Sm-153 препаратын тикшерүгә караган хезмәтләре дөнья күләмендә танула. «ТРда онкология хезмәте б-н идарә итүне оптимальләштерү һәм яман шеш барлыгы беленгән авыруларга ярдәм күрсәтүне яхшырту, социаль-икътисади зыянны киметү максатында яңа технологияләрне гамәлгә кертү» исемле хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (2003).

Х е з м.: Нейроэндокринные синдромы и заболевания. К., 1990.

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВ** Салават Мөхәммәт улы (1.1.1959, БАССРның Борай р-ны Борай а.), график. Уфа сәнгать ин-тының нәкышь ф-тын тәмамлый (1994). 1997 елдан Уфаның А.Кузнецов исем. 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1998). Станлы графика, китап иллюстрациясе, гарәп хаттатчылыгы (шәмаил) жанрларында эшли. Сирәк очрый торган техника — кәгазьне кулдан ялтырату (конгрев) кулланучы аз санлы рәссамнарның берсе. «Әбекәйне искә алу» (2001), «Балачагымнан» (2001–02), «Туган авылым» (2001), «Ирләр» (2002), «Бөек дала» (2001–02) һ.б. линогравюра, карандаш һәм конгрев эшләре, «Чыңгыз хан» (2000), «Бүре җыры» (2001), «Сак-Сок» (2002) һ.б. станлы картиналар авторы. Г. үз иҗатында борынгы төркиләргә һәм аларның символларына мөрәҗәгать итә, ш.у. Шәрекъ һәм рус китап графикасы традицияләренә таяна. Респ-ка («Башкортстан графиклары», 2002, Уфа), төбәкара һәм халыкара (3 нче Урал басма графика триенналлесы, 2001, Уфа; диплом б-н бүләкләнә) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1994 (Уфа), 1995 (Казан), 1997 (Чаллы), 2002 (Уфа, Мәскәү) елларда уза. Әсәрләре Уфаның М.В.Нестеров исем. сәнгать музеенда саклана.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**ГЫЙЛӘҖЕТДИ́НОВА** Зәйнәп Шәйхи кызы (29.10.1918, Уфа — 1.10.2007, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1973). Ташкент мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1942), шунда ук эшли. 1951 елдан Казан мед. ун-тында. 1952–87 дә Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе), 1971 дән 2 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. Хезмәтләре хатын-кыз организмы нефроморфологиясенә һәм аның нефроэндокрин функциясен көйләүгә, йөрәк-тамырлар авырулы хатын-кызларның йөкле һәм бала табу вакытында авырулар кабатлануын булдырмауга, менопауза алдыннан һәм шуннан соң була торган функциональ һәм патологик үзгәрешләргә карый. Г. җитәкчелегендә махсус гинекологик эндокринология һәм онкология бүлеге оештырыла, акушер-гинеколог табибләрнең укытуын камилләштерүнең тематик планнары һәм программалары төзелә. Г. кафедраның тарихи бинасында Г.Тукайның кече музеен оештыра. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. 1996 да «Санаторий-курорт учреждениесе шартларында йөкле хатыннарны сәламәтләндерүнең яңа системасы» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә.

Х е з м.: Консервативный метод прерывания беременности. К., 1951; Состояние нервных элементов фибромиомы матки у женщин вне и во время беременности в фибромиомии и фибромоподобных образованиях в эксперименте. К., 1965; Туберкулёз женской половой сферы. К., 1970; Бесплодие при нейроэндокринных синдромах и заболеваниях. К., 1998 (автордаш); Туберкулёз и беременность. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Зайнаб Шайхиевна Гилязутдинова // Казан. мед. журн. 1994. № 1; И это всё судьбы счастливые моменты // Мед. вести. 1998. № 20.

**ГЫЙЛЕ́М** (гарәп. علم – белем), Г.нең күпсанлы билгеләмәләре бар. Киң мәгънәдә ул: 1) мөселман традицияләрен үзләштерү; 2) күктән нур иңү; 3) логик фикерләү юлы б-н төшенү; 4) энциклопедик укымышлылык. Г. күренеп торган, яшерелгән һәм эзотерик төрләргә бүленә. Гарәп телен, ш.у. белемнәр һәм гамәлләр арасындагы бәйләнешне белү Г.нең мөһим атрибуты булып тора. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында, фән һәм мәгариф үсеше б-н бәйле рәвештә, Г. яңадан мөселман ислахчыларының кайнар бәхәсләренә сәбәп була. Г. төшенчәсен фәнни белемнәр яисә чын фәннәргә каршы килмәүче белемнәр мәгънәсендә аңлау төп тенденция булып тора.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ГЫЙЛЕ́МОВ** Зәкәрия Галим улы (26.2.1932, БАССРның Илеш р-ны Түбән Яркәй а. — 14.12.2000, Әлмәт ш.), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1981). 1958 елдан Әлмәт татар драма театрында. Проф. сәхнәгә үзешчән театрдан килә, башта кечерәк эпизодларда икенче пландагы рольләрдә уйный. Аеруча уңышлы рольләре: Хәйрүш («Утлар яна учакта», Г.Ахунов), Әкрам («Сабан тургае», Р.Төхфәтуллин), Хәниф («Ялкынлы яшьлек», И.Абдуллин), Мельников («Васса Железнова», М.Горький). Сәхнәдә күркәм кыяфәте, хезмәт сөючәнлеге, образны мөмкин кадәр тулырак ачарга омтылуы Г.ка зур рольләр башкару өчен юл ача. Г. башкарган рольләрдән сугыш юлларын узган крәстиян Ярхәм («Син кайтмадың», Н.Терентьев повесте буенча), Кәримҗан («Кар астында кайнар чишмә», А.Гыйләҗев), ышанучан характерлы Вәлиш карт («Минем җинаятем», Ю.Әминев), вет. фельдшеры Гарифулла («Синнән башка тормыш юк», С.Шәкүров), инвалид солдат Бикторсан («Анам кыры», Ч.Айтматов повесте буенча), Юлдаш бабай («Сармат кызы Сәринә», Н.Фәттах) психол. тирәнлек һәм үткен драматизм б-н аерылып торалар. Персонажның чын тормышчан социаль-психол. портретын тудырырга омтылып, актёр шул ук вакытта үткен сатирик буяуларны да мул куллана; Хәйри бабай («Биш бармакта биш балдак», А.Гыйләҗев), Склад мөдире («Бәйләнчек», Т.Миңнуллин), Нуретдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин) образлары — шундыйлар. Актёрның иң яхшы рольләрендә чын тормыш дөреслеге, хәтта, көлкеле ситуацияләрдә дә тирән җитди эчтәлекне ача белүе ярылып ята.

*Әд.:* Р ә х и м о в Җ. Әлмәт татар дәүләт драма театры. Әлмәт, 1994.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГЫЙЛЕМХА́НОВ** Фарис Хафиз улы (1948, Чиләбе өлкәсенең Копейск ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1988). 1971 елда Новосибирск ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Себер бүлегенең Автоматика һәм электрометрия ин-тында (Новосибирск ш.) эшли, 1988 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре рентген спектрлары һәм лазер физикасы теорияләренә карый. Флуоресценциянең рентген спектрындагы интерференция күренешләрен фаразлый (1975), молекулаларның рентген спектрында йотылу чиген үткәннән соңгы резонансны күпкабат таралыш теориясе нигезендә беренче мәртәбә аңлата (1970, бергәләп). Спектроскопия өлкәсендәге яңа юнәлешкә — яктылык б-н индукцияләнгән газ кинетикасына нигез сала.

Х е з м.: Рентгеновские спектры простых молекул. Новосиб., 1977; Влияние фазовой памяти при столкновениях на работу поля и эффект светоиндуцированного дрейфа частиц газа. Новосиб., 1989 (автордаш); Теория диссипативных солитонов в эффекте светоиндуцированного дрейфа в условиях немонохроматического возбуждения // Журн. эксперим. и теоретической физики. 1995. Т. 108, вып. 6 (автордаш).

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Әмир Зариф улы (24.10.1939, БАССРның Бишбүләк р-ны Аит а.), социолог, социол. фән. д-ры (1993), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Иркутск хәрби авиация-теоретик уч-щесен (1960), Урал пед. ин-тын (1967) тәмамлый. 1960–76 елларда стратегик юнәлештәге ракета гаскәрләрендә хезмәт итә. 1976–77 дә стратегик юнәлештәге ракета гаскәрләренең М.И.Неделин исем. Ростов югары хәрби инженер-командирлар уч-щесенең иҗтимагый фәннәр кафедрасында укыта. 1977–78 дә ракета гаскәрләренең С.С.Бирюзов исем. Рига югары хәрби-сәяси уч-щесенең иҗтимагый фәннәр кафедрасында эшли. 1978–93 тә ракета гаскәрләренең Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесендә иҗтимагый фәннәр каф. мөдире, полковник (1981). 1993–95 тә ТР ФАнең Социаль-икътисад һәм хокук фәннәре ин-тында социаль тикшеренүләр бүлеге мөдире, бер үк вакытта директор вазифаларын башкара (1995 тән директор урынбасары). 2004 елдан Казан социаль фәннәр академиясенең (КСЮИ) белем сыйфаты, эшкә урнашу һәм проф. карьера фәнни-тикшеренү бүлеге җитәкчесе. Хезмәтләре СССРның хәрби интеллегенциясе тарихына, яшьләрнең социаль проблемаларына, мәгариф социологиясенә карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Социалистическая военная интеллегенция в социальной структуре советского общества. М., 1986 (автордаш); Местное самоуправление в Республике Татарстан: Теоретические и прикладные основы. К., 2002.

*Әд.:* Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 1996; Социологи России и СНГ. XIX–XX вв.: Библиогр. справ. М., 1999.

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Әнәс Әнвәр улы (1.1.1957, Арча р-ны Штерә а.), сан. табибе, мед. фән. д-ры (2003), проф. (2006), ТРның атказ. табибе (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Пенза өлкәсенең Балихин сан.-эпидемиология станциясендә сан. бүлеге мөдире булып эшли. 1980 нән Казанның Ленин р-ны сан.-эпидемиология станциясендә баш табиб, 1982 дән хезмәт гигиенасы бүлеге мөдире. 1983 тән Профсоюзларның Татарстан өлкә советының вәкаләтле табибе, 1984 тән бүлек мөдире урынбасары — баш вәкаләтле табиб. 1988–97 дә ГИДУВның көнкүреш гигиенасы кафедрасында (бүленеп, 1991–93 тә «Тылсым» мед. иминияте компаниясе директоры). 1997 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Медсоцэконом» республика үзәге директоры. 2001 дән ТР Сәламәтлек саклау министры урынбасары. Хезмәтләре ТРда сәламәтлек саклауны оештыруга, мед.-көнкүреш һәм икътисад мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге «ТМР-0,06-КХТИ» мед. магнит-резонанслы томографын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Здоровье населения Республики Татарстан на пороге третьего тысячелетия. К., 1999 (автордаш); Служба крови. Нормативы по труду, ценообразование. К., 2003 (автордаш).

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Әнвәр Николаевич (19.11.1948, Әзәрбайҗан ССРның Нахичевань ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1999). 1973 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1975 тән СССР ФАнең Казан физика-техника ин-тында, 1989 дан тоташ мохитләрдә тотрыксыз процесслар лаб-ясе мөдире, 1991 дән РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында шул ук исем. лаб. мөдире (бүленеп, 1996–2000 дә Казан энергетика ун-тында), 2000 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре аэромеханикага карый. Газ динамикасы, аэросыгылмалылык мәсьәләләрен тикшерү өчен программалар комплексы төзи.

Х е з м.: Методы адаптивных сеток в задачах газовой динамики. М., 2000; Применение динамически адаптивных сеток к исследованию течений с многомасштабной структурной потока // Журн.



С.Г.Гыйльманов

вычисл. математики и матем. физики. 2001. Т. 41, № 2; Неотражающие условия на границах расчётной области. М., 2003 (автордаш).

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Галимҗан Хәмитҗан улы (1.2.1957, БАССРның Дүртөйле р-ны Әсән а.), язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982–86 елларда Казан ун-тында укыта. 1986–99 да (бүленеп) — Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1990 нан балалар-яшүсмерләр әдәбияты редакциясе мөдире. 1999–2005 тә ТРның Язучылар берлеге идарәсендә оештыру эшләре буенча рәис урынбасары. 2005 тән ТР Министрлар Кабинеты аппаратының мәдәният һәм Татарстан халыклары телләрен үстерү бүлегенең баш консультанты. Татар балладаларын өйрәнүгә багышланган «Татарская баллада» (1989), татар әдәбиятына караган тәнкыйть мәкаләләрен берләштергән «Заман сүз сорый» (1991) исемле китаплар, хәзерге татар авылы тормышын чагылдырган «Тозлы яңгыр» (1993) исемле повесть-хикәяләр, «Күңелем сурәте» (2003) шигырь җыентыклары авторы. Ш.Бабичның шигырьләр җыентыгын («Зәңгәр җырлар», 1990) һәм «Татар мифлары» (1–2 т., 1996–99) китапларын төзүче. Шигырьләре һәм пьесалары тупланган «Йөгерек гөрләвек» (1998), «Әбием сихерче бугай» (1999), «Көмеш тарак» (2000), «Алдакчы тукран» (2003) китаплары балаларга багышланган. Үзенең «Албастылар» (2001), «Китек ай» (2005), «Оча торган кешеләр» (2007) җыентыкларында тупланган повесть һәм романнары б-н татар прозасында модернистик юнәлештә иҗат итүче язучы булып танылa. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гарифуллин В. Мин — шагыйрь җанлы прозаик // Мәгърифәт. 1994. 5 февр.; Заһидуллина Д. «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар // Казан утлары. 2001. № 11.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Җәмил Ибраһим улы (3.7.1925, Самара өлкәсенең хәзерге Кошки р-ны Төплистан а. — 15.12.1991, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1984), проф. (1985), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). Бөек Ватан сугышында 4 нче Украина фронты гаскәрләре составында Польшаны, Чехословакия һәм Германияне азат итүдә катнаша. Вратимов шәһәрен (Чехословакия) фашистлардан азат итүдә күрсәткән батырлыгы өчен Г.ка «Вратимов шәһәренең мактаулы гражданы» исеме бирелә. 1945 елда Ерак Көнчыгышта японнарның Квантун армиясенә каршы Маньчжур операциясендә катнаша. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), КПССның Яшел Үзән шәһәр ком-ты лекторы булып эшли. 1958–62 дә Казан авиация ин-тында укыта, бер үк вакытта Бөтенсоюз «Белем» җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе рәисе урынбасары. 1962–64 тә «Коммунист Татарии» — «Татарстан коммунисты» ж-лы мөхәррире. 1964–90 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында тарих бүлеге мөдире. Хезмәтләре Бөек Ватан сугышы тарихына карый. Татарстан тарихчыларыннан беренче булып республиканың Бөек Ватан сугышында җиңүгә керткән гомуми өлешен һәрьяклап тикшерә, ш.у. халыкның тылдагы һәм фронттагы батырлыкларын өйрәнә. «Татарстан АССР тарихы» (1973), «Татарстан партия оешмасы тарихыннан очерклар» (1973), «Казан тарихы» (1–2 кит., 1989–91), «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» (2–3 кит., 1983–88), «Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз» (1–3 кит., 1982–85), «Көрәш һәм казанышлар елъязмасы» (1–2 кит., 1985) хезмәтләре авторларының берсе, ул китапларның мөхәррире. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Без сугышта юлбарыстан көчлебез. К., 1989; Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977; Трудящиеся Татарии на фронтах Великой Отечественной войны. К., 1981; Галимджан Сайфутдинов: Очерк жизни и деятельности татарского революционера. К., 1988.

*Әд.:* Гарипова З.Г. Верность воинскому и научному долгу // Научный Татарстан. 2000. № 1; Памяти Зямиля Ибрагимовича Гильманова: Сб. статей. К., 2000.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Кәрим Ибраһим улы (1912, Казан губ., Казан өязе Мүлмә а. — 23.12.1964, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1933) һәм «Эшче» театры труппасына кабул ителә. 1938 елдан Татар акад. театры актёры, 1951–58 дә директоры. Тирә-яктагы мәдәният сарайларында спектакль-концертлар кую, гастрольләр географиясен киңәйтү чараларын күрә, театрны 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы чыгышларына әзерләүдә катнаша. Башлыча, көнкүреш планындагы актёр, эпизодик һәм зур, үзәк рольләрдә дә уйный. Аеруча күренекле рольләре арасында — Мидхәт («Чын мәхәббәт», Т.Гыйззәт), Фәрит («Тормыш җыры», М.Әмир), Тәфкилев («Пугачёв Казанда», Ә.Фәйзи), Шпекин («Ревизор», Н.В.Гоголь), Миловзоров («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Боровский («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв), Самсонов («Мылтыклы кеше», Н.Ф.Погодин), Крофт («Ул кайтты», Д.Пристли) һ.б. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*И.И.Илялова.*

**ГЫЙЛЬМА́НОВ** Сәгыйрь Гыйльман улы (15.4.1930, Минзәлә кантоны, хәзерге Актаныш р-ны Татар Суыксуы а. — 20.9.2005, Казан), бетон коючы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген 1943 елда Актаныш р-ның «Авангард» к-зында башлый. 1949 дан «Кузнецктяжстрой» (Новокузнецк ш.) төзү-монтаж трестында агач эше остасы булып эшли. 1952–60 та Совет Армиясендә хезмәт итә. 1960–98 дә «Татстрой» АҖнең 2 нче эре панельле йортлар төзелеше з-дында (хәзерге «Инвестжилстройсервис» сәнәгать йортлары төзү комбинаты» АҖ) бетон коючы — форма ясаучылар бригадасы бригадиры. Герой исеме 8 нче бишьеллык план йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Низамов И. Гильманов Сагир Гильманович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГЫЙЛЬМА́НОВА** Гыйффәт Харис кызы (10.9.1925, Чистай кантоны, хәзерге Алексеев р-ны Такталы а.), вирусолог, мед. фән. д-ры (1965). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда ук эшли. 1952–74 елларда Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1974 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында. Стрептококклар һәм столбняк таякчыгы антигеннарына карата гумораль иммун җавап реакциясенә тикшеренүләр үткәрә: столбняк агуына антитәнчекләр ясалу закончалыгы ачыклана, индивидуаль иммунлаштыру схемасы эшләнә. Хезмәтләре ТРда урман талпаны энцефалетының эпидемиологик һәм вирусологик үзенчәлекләренә карый: беренче тапкыр урман талпаны вирусы штаммнарының антиген төрлелеге ачыклана, вирусның эпидемия чыганагы булган урында кышкы циркуляциясе күрсәтелә, вирусның сыер сөте б-н тапшырылуы ачыклана. Көчле респиратив йогышлы авыруларны дәвалау һәм булдырмау өчен перспектив матдәләр тәкъдим ителә. Уйлап табуга 72 авторлык таныклыгы бар. Сәламәтлек саклау отличнигы.

Хезм.: Эпидемиологические особенности вспышки клещевого энцефалита в ТАССР. К., 1959.

**ГЫЙЛЬМА́НШИНА** Сүрия Ирек кызы (26.5.1956, Казан), педагог, химик, химия фән. канд. (1991), пед. фән. д-ры (2009). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук химик кибернетика кафедрасында эшли, 1980–83 елларда Саратов шәһәрендә урта мәктәптә укыта, 1983 тән Казан химия-технол. ин-тының физик һәм коллоид химия кафедрасында. 1992 дән Казан пед. ун-тының (хәзер Татар гуманитар-пед. ун-ты) химия кафедрасында, 1998–2003 тә табигать-география ф-ты деканы урынбасары. Хезмәтләре электрохимия, аналитик химиягә, химия укытучыларын әзерләү методикасына карый, химия укыту ярдәмлекләре авторы.

Хезм.: Основы аналитической химии. СПб., 2004; Профессиональное мышление учителя химии и его формирование. К., 2005.

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Альберт Харис улы (27.7.1956, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1999), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1994 тән аналитик спектроскопия

лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта 2000 нән гомуми физика каф. профессоры. 2007 дән ТР Мәгариф һәм фән министры урынбасары, 2009 дан министр. Хезмәтләре атомның аналитик спектроскопиясенә һәм плазма физикасына карый. Спектроскопия өлкәсендә яңа юнәлешкә — фәзада була ала торган атом абсорбциясе спектроскопиясенә нигез сала. Спектроскопиягә аеруча зур өлеш керткән өчен халыкара Atomic Spectroscopy Award бүләгенә лаек була (1995). Медальләр, ш.и. хәзерге заман спектроскопиясенә нигез салган Й.М.Марси исем. медаль б-н бүләкләнә (1998). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010).

Х е з м.: Атомно-абсорбционная спектрометрия с пространственном разрешением // Успехи химии. 2006. Т. 75 , № 4 (автордаш); Spatially Resolved Detection of Analytical Signals in Graphite Furnace Atomic Absorption Spectrometry // Spectrochimica Acta. Part B. 1996. V.51 (автордаш); Multidimensional Integration of Absorbances: An Approach to Absolute Analyte Detection // Spectrochimica Acta. Part B. 1998. V.53; Fundamental Physical and Chemical Processes in Electrothermal Atomizers // Electrothermal Atomization for Analytical Atomic Spectrometry. Chapter A. 1999.

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Әнис Харис улы (10.5.1949, Казан), радиоэлектроника галиме, техник фән. д-ры (2006). 1972 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоэлектроника һәм информацион-үлчәү техникасы каф. профессоры (2005 тән). Бер үк вакытта «Радиоэлектроника» Федераль җитештерү-фәнни үзәгендә бүлек башлыгы (2000 нән) һәм Федераль сәнәгать агентлыгының чит илләр техник разведкасына каршы тору һәм мәгълүматны техник саклау буенча аттестация үзәге җитәкчесе (2001 дән). Хезмәтләре параметрлары бүленгән резисторлы-сыешлыклы элементларны (RC-ЭРП), шулар нигезендә төзелгән фракталь радиоэлектроника җайланмаларын тикшерү һәм куллануга карый. Г. югары дәрәҗәдә тотрыклы һәм көйләнүле актив RC-фильтрлар, ядрәле операторлар синтезлау критерийларын эшли; RC-ЭРП классификациясен тәкъдим итә; гомумиләштерелгән бүленгән элементлар алымын, бер үлчәнешле бериш булмаган, ш.у. ике үлчәнешле бериш RC-ЭРП һәм алар нигезендәге җайланмаларны анализлау һәм синтезлау юлларын эшли. Уйлап табуга 4 патенты һәм авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Синтез широкополосного фазовращателя на основе двухэлектродного RC — элемента с распределёнными параметрами // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2000. № 7/8; Резистивно-ёмкостные элементы с распределёнными параметрами: анализ, синтез и применение. К., 2005; Системные принципы и элементная база фрактальной радиоэлектроники. Ч. 1. Этапы становления и состояния // Радиотехника и электроника. 2008. Т. 53, № 9 (автордаш).

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Гайфетдин Гыйльметдин улы (13.1.1913, хәзерге Балтач р-ны Смәел а. — ?), Сов. Союзы Герое (19.3.1944), гв. сержанты (1943). Туган авылында колхозда эшли. 1938–40 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армиядә. Хәсән күле янында япон милитаристларына каршы бәрелешләрдә (1938) һәм совет-фин сугышында (1939–40) катнаша. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 120 нче гв. укчы полкның (8 нче гв. армиясенең 39 нчы гв. укчы дивизиясе) пулемёт отделениесе командиры. Көньяк-Көнбатыш һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Донбасс (1943) һәм Одесса һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 24 октябрендә Днепропетровск шәһәре янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. 1944 нең июнендә хәбәрсез югала. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Ил Гарәфи улы (25.1.1931, Арча р-ны Ашабаш а. — 1.7.2005, Казан), химик, ТРның атказ. химигы (1991). Ленинград ун-тын тәмамлый (1955). 1955–57, 1980–61 елларда Казан пр-тиеләрендә инженер. 1961–65 тә КПССның Казан шәһәр ком-ты, Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1965–92 дә Казан «Татхимфармпрепаратлар» химия-фарм. җитештерү берләшмәсе ген. директоры; Г. җитәкчелегендә заводның яңа җитештерү мәйданнары, хирургик тегү материаллары з-ды төзелә, дару препаратларының 50 дән артык яңа төрләрен җитештерү үзләштерелә, дарулар һәм кетгут эшләп чыгару ике тапкыр арта. Уйлап табуга 1 патенты, 7 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* На службе здоровья и долголетия. К., 1981.

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Наил Рәхмәтулла улы (2.11.1949, Чаллы ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1975). 1968–71 елларда һәм 1975 тән «Түбәнкамa-нефтехим» акц. җәмгыятендә: мастер, реагентлар һәм җиңел кабынучан сыеклыклар цехы башлыгы, изопрен полимерлаштыру цехы башлыгы, СКИ-3 № 1 з-ды баш инженеры, синтетик каучук җитештерү з-ды баш инженеры (1993–97), АҖ ген. директоры урынбасары (1997 дән). Г. җитәкчелегендә заводта этиленпропилен һәм олигопиперилен каучуклар җитештерү проекты эшләнә, монтажлана һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 34 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Этиленпропилен каучукларны Россиядә беренче эре тоннажлы унификацияле җитештерүне эшләү һәм үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЛЬМЕТДИ́НОВ** Рөстәм Якуп улы (20.9.1954, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1976 елдан Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-тында эшли, 1993 тән күзәнәкле культуралар, азыклы тирәлек һәм гибридом техника лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта Казан вет. медицинасы академиясендә патологик физиология каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре электрофизиологиягә, биофизика, биотехнология һәм гематологиягә карый. Төрле төрдәге хайваннарның электр тогына сизгерлегенең ешлык характеристикалары раслана. Нормада вакытта яки фармакотоксик һәм инфекцияле агентлар тәэсирендә булганда кан күзәнәкләренең электрофоретик хәрәкәтчәнлеге билгеләнә. Организмның иммунологик реакциясен җайга салуда эритроцитларның электрик параметрларының роле чагыштырма-төрләр аспектында күрсәтелә. Яралгы чорда мөгезле эре терлекләрдә гемапоэз (кан ясалу процессы) барлыкка килү өйрәнелә. Төрле йогышлы авырулар, ш.и. аеруча куркынычлыларын китереп чыгаручыларга каршы бер клонлы антитәнчекләр җитештерүче гибридомнар алына.



Г.Г. Гыйльметдинов.

Х е з м.: Клеточный электрофорез при изучении инфекционной патологии сельскохозяйственных животных. К., 1992 (автордаш); Физиология крови. К., 1999 (автордаш); Исследование крови животных. К., 2000 (автордаш); Сравнительная гематология животных. К., 2005 (автордаш).

**ГЫЙЛЬМИ́** (Гыйльманов) Ләбиб Гыйльман улы (12.6.1906, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Баграж а. — 9.5.1938, Казан), язучы. 1923 елда партия мәктәбенә укырга керә (Чистай ш.). 1928–30, 1932–34 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында эшли (1932 дән 2 нче секретарь). 1930–32 дә Улан-Батырда Монголия революцион яшьләр союзында киңәшче булып тора. 1935–37 дә «Яшь ленинчы» г-тасы, «Пионер каләме» ж-лы җаваплы сәркәтибе, 1937 дә ТАССР Язучылар берлеге рәисе. «Сәнәкчеләр» (1930), «Фронттан» (1935) шигъри җыентыклары, «Аучы Хәмит» (1931), «Чимит Дурҗе» (1933), «Хикәяләр» (1936) хикәяләр җыентыклары, «Чын мәхәббәт» (1936) романы, «Кайгылы җыр» (1937) пьесасы авторы. Монгол халкы каһарманы Сухэ-Батыр турындагы «Эмигрант» романы төгәлләнмичә кала. Рев-циягә каршы эшчәнлектә гаепләнә, СССР Югары суды карары б-н атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; М о с т а ф и н Р.Ә., Д а у т о в Р.Н. Репрессияләнгән татар язучылары // Казан утлары. 1992. № 3.

**«ГЫЙЛЬМИ́ МӘҖЛЕ́С»**, 1903–05 елларда Уральск шәһәрендә *«Мотыйгия» мәдрәсәсе* шәкертләренең әдәби түгәрәге. Җитәкчеләре — К.Мотыйгый, Г.Тукай һ.б. Түгәрәк әгъзалары әдәби кичәләр үткәрә, кулдан «Мәгариф» г-тасы һәм «Әл-гаср әл-җәдид» ж-лы чыгаралар.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ГЫЙЛЬМИ́ ҮЗӘ́К** (Академүзәк), 1921–30 елларда ТАССР Мәгариф халык комис-ты карамагындагы гыйльми оешма. Республикадагы фәнни-тикшеренү, фәнни-пед., сәнгать, музей-архив, тәрҗемәчелек эшчәнлекләрен оештыру максатыннан төзелә. 1920 елда оешкан ТАССР Мәгариф халык комис-ты Фәнни бүлегенең дәвамчысы булып тора. Г.Ү. карамагында башта дүрт комиссия — фәнни-сәяси, фәнни-техник, фәнни-пед. һәм сәнгать (бирегә ш.у. матур әдәбият, театр, музыка, рәсем сәнгате, кинематография бүлекләре керә) комиссияләре, баш идарәләр һәм Секретариат оештырыла. ТАССР архивларының, музейларының Баш идарәләре һәм Секретариат Г.Ү.кә буйсына. Җитәкчелек рәис һәм биш кешелек коллегиядән — Дәүләт гыйльми советы, Югары сәнгать комиссиясе, Баш архив, Баш музей рәисләре, Профсоюзларның Татарстан өлкә советы вәкилләреннән гыйбарәт. Рәисләре: Г.Г.Максудов (1922–24), Г.Г.Ибраһимов (1925–1927 нең марты), М.Х.Таһиров (1927 нең марты — 1928), С.С.Атнагулов (1928–30).

Г.Ү. төзелеше берничә тапкыр үзгәртелә: аның карамагында 1923 нең маенда — *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, 1925 нең маенда *Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте*, 1927 дә *Татар мәдәнияте йорты*, 1930 да *Татарстан икътисад фәнни-тикшеренү ин-ты* оештырыла.

Җәмгыятьнең мәдәни тормышында барган зур үзгәрешләр чорында оешкан Г.Ү. белем бирү өлкәсендә, гомуми, башлангыч һәм урта проф. белем бирү мәктәпләрендә укыту планнарын, программалар һәм дәреслекләр әзерләүдә, нәшрият сәясәтен билгеләүдә, татар тел белемен, әдәбиятын, тарихын һәм этнографиясен өйрәнүдә актив эшчәнлек алып бара. Татар театры һәм музыка сәнгатен үстерүгә багышланган беренче дәүләт чаралары Г.Ү. тарафыннан үткәрелә. Аеруча уңышлы эшләгән вакыты атаклы язучы һәм галим Г.Г.Ибраһимов рәислек иткән чорга туры килә. Г.Ү.тә танылган белгеч-галимнәр эшчәнлек алып бара. Төрле елларда Г.Ү.кә зур өлеш керткән галимнәр — Е.И.Чернышёв, В.В.Егерев, Н.Н.Фирсов, Г.Ф.Линсцер, С.П.Сингалеевич, П.М.Дульский, М.Г.Худяков, Г.С.Гобәйдуллин, М.Х.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Г.Х.Алпаров, Гали Рәхим, Җ.Вәлиди, М.Ә.Фазлуллин, Н.С.Надиев һ.б.

Г.Ү.нең татар халкы мәдәни мирасын киң колачлы өйрәнү, аны торгызу мәсьәләләрендә ВКП(б) һәм аның җирле органнары тарафыннан үткәрелгән демократияне чикләү сәясәте б-н килешмәве, ш.у. латин графикасы (к. *Яңалиф*) кертүгә каршы булуы б-н бәйле рәвештә, 1927 нең 2 нче яртысыннан оешманың эшчәнлеге чикләнә, соңрак бөтенләй туктатыла. 1927 нең 4 июнендә ТАССР ХКС Татар мәдәнияте йортын төзү турында карар кабул итә. Аңа Г.Ү. карамагында булган *Китап палатасы*, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы, Татарстан Педагогия җәмгыяте һ.б. җәмгыятьләр күчерелә.

*Әд.:* Т у т а е в М.З. Развитие народного образования в Татарии. К., 1970; Культурное строительство в Татарии. 1917–1941: Сб. док. и материалов. К., 1971; Х а с а н о в М.Х. Галимджан Ибрагимов. К., 1977; Ф а т т а х о в а Г.А., В а л е е в Р.К. Академический центр Татарии в 1920-е годы. К., 2002.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ГЫЙЛЬМИ́** (Гыйльметдинов) Фәрит Гыйльметдин улы (14.4.1947, Мөслим р-ны Уразмәт а. — 16.10.1993, Зәй р-ны Бигеш а.), язучы. Казан ун-тын (1970) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1987). 1970 елдан Әлмәт шәһәрендә: 1972 гә кадәр Тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклау җәмгыятенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркәтип, 1974–78 дә урта мәктәптә укытучы, 1978–83 тә Әлмәт эл. насослары з-дында хезмәтне фәнни оештыру бюросы башлыгы булып эшли. 1988 дән ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә әдәби консультант. Беренче хикәясе «Кызыл таң» г-тасында 1967 дә басыла. «Урсай тау итәгендә» (1977), «Елганың борылган төшендә» (1980) повестьларында сурәтләнгән геройлар — мөстәкыйль тормышка аяк баскан яшьләр образлары.

Ә с ә р.: Урсай тау итәгендә: Повестьлар. К., 1981; Су өстендә чәчәкләр: Хикәяләр. К., 1984.

*Әд.:* Г ы й л ә җ е в А. Истә, һаман да истә // Казан утлары. 1997. № 4.

**ГЫЙЛЬМИ́ДОВ** Фәһим Шәйхи улы (30.6.1930, Мөслим р-ны Дусай а.), двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989). 1955 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, Үзәк авиация моторлары төзү ин-тында (Мәскәү) эшли, 1990 нан күчәрле компрессорлар бүлеге башлыгы, (бүленеп, 1990–91 дә Пекин аэронавтика һәм космонавтика ун-ты һәм Шеньян авиация двигательләрен тикшеренү ин-ты профессоры). Хезмәтләре газ турбиналы двигатель компрессорларының аэродинамикасына, газ динамикасы тотрыклылыгына һәм аларны көйләүгә карый. Газ турбиналы компрессорларның ышанычлы, өзлексез һәм дерелдәми нәтиҗәле эшләвен тәэмин итә торган җайланмалар төзи. Сугыш шартларында вертолёт двигательләре туктап калуын бетерү эшләрендә катнаша. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Руководство по выбору и проверки запасов устойчивости авиационных силовых установок. М., 1976. Вып. 2; Руководство по испытаниям авиационной техники. М., 1984.

**ГЫЙЛЬМИ́ЕВА** Римма Хәмид кызы (6.1.1948, Үзбәкстан ССРның Әндиҗан өлкәсе Ахунбабаев ш.) педагог, ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1996), пед. фән. д-ры (2000). 1973 елда Кострома пед. ин-тының тарих-пед. ф-тын тәмамлый. 1965 тән Казанда, комсомол эшендә. 1973 тән Вахитов р-ны комсомол райкомы секретаре. 1977 дән партия эшендә, КПССның Вахитов райкомы пропаганда бүлеге мөдире (1980–88). 1988–2007 дә Мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-тында, фәнни-методик эш буенча проректор (1993–2007). 2007 дән РМАнең Проф. белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-тында, пед. һәм проф. белем бирү лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта 2007 дән Казан социаль-юридик ин-тында җәмәгатьчелек б-н элемтә буенча проректор. Педагогларга диплом алганнан соң белем бирү учреждениеләрендә инновацион процесслар б-н идарә итү буенча хезмәтләр һәм укыту-методик ярдәмлекләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Профессиональное развитие учителя в современных условиях. К., 1996; Инновации в образовании и повышении квалификации педагогических кадров. К., 1997; Профессиональное развитие учителя: история и современность. М., 1999.

**ГЫЙЛЬМУ́ЛЛИН** Ринат Абрек улы (29.1.1975, Актаныш р-ны Актаныш а.), математик, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты. 1997 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук: теоретик кибернетика кафедрасында (2000–02), «Ясалма интеллект проблемалары» фәнни-тикшеренү лаб-ясендә (2002–09) эшли. 2010 нан ТР ФАнең Гамәли семиотика ин-тында когнитив тикшеренүләр бүлеге мөдире. Хезмәтләре укытуның интеллектуаль технологияләренә карый. Г. соңгы халәтләр автоматлары нигезендә татар теле морфологиясенең тулы компьютер моделен төзи, мәгълүмат эшкәртүнең күптелле системаларын булдыру өчен эвристик тәрҗемә модельләрен төзү алгоритмнарын тәкъдим итә. Татар телендә электрон дәреслекләр эшләүдә һәм аларны гамәлгә кертүдә, Windows Vista операцион системасын һәм Office-2007 гамәли программалар пакетын татар телендә эшләү өчен яраклаштыруда катнаша. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасы мәгариф системасында татар теленең дәүләт теле буларак кулланылуын фәнни, укыту-методик һәм программ-мәгълүмати яктан тәэмин итү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Модуль обучающейся модели татарско-турецкого машинного переводчика // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 2; Разработка файла морфотактических правил для глагольных групп татарского языка // Проблемы сохранения языка и культуры в условиях глобализации: Материалы VII Международ. симпозиума «Языковые контакты Поволжья». К., 2009.

**ГЫЙЛЬФА́Н** (Гыйльфанов) Сафа Гыйльфан улы (1902–1950), шагыйрь, тәрҗемәче. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1934). Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1936–37 елларда Казанда Эшче-крәстиян Кызыл Армия йорты башлыгы. Беренче шигырьләре 1930 елларда басыла башлый. Балалар өчен язылган «Батыр песи» (1936) әкият-поэма авторы. А.П.Гайдарның «РВС» (1934), А.О.Авдеенконың «Я люблю» («Мин сөям», 1935) романнарын, Ги де Мопассан хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Альберт Гыйлемхан улы (12.1.1952, Саба р-ны Шәмәрдән пос.), кларнетчы, педагог, ТАССРның халык артисты (1987). Казан консерваториясен (А.Баранцев һәм А.Геронтьевның кларнет классы) тәмамлый (1975). 1975 елдан Казан консерваториясендә укыта (1993–96 да тынлы агач уен кораллары каф. мөдире). Бер үк вакытта ТРның Дәүләт симф. оркестры (1976 дан кларнет төркеме концертмейстеры), Татар опера һәм балет театры оркестры артисты (1995 тән). Актив концерт эшчәнлеге алып бара, ш.и. «Симха» клезмер ансамбле чыгыш-

ларында катнаша. Классик композиторларның һәм хәзерге авторларның кларнет өчен язган күпчелек әсәрләрен кертеп бай репертуар туплый. Татар музыкасын пропагандалаучы. Шәкертләре арасында Бөтенроссия тынлы агач уен коралларында башкаручылар конкурсы дипломанты Р.Купершмидт бар.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Илдар Габделхак улы (13.4.1943, Казан), инженер-механик. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), РФнең атказ. технологы (1995). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1975). 1971–97 елларда һәм 2002 дән «КамАЗ» АҖдә: баш конструктор бүлегендә инженер-конструктор, инженер-технолог, бюро башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы, баш технолог идарәсе башлыгы урынбасары, башлыгы, бер үк вакытта баш технолог (1987 дән), техник директорның беренче урынбасары һәм техник дирекциянең технол. үзәге директоры (1992 дән), башкарма дирекциянең фәнни тикшеренүләр һәм үстерү департаментында «Модернизацияләнгән автомобильләр» дигән максатлы программа директоры (1996 дан), АҖнең ген. директор урынбасары (2002 дән). Югары йөк күтәрүчән «КАМАЗ-4310» маркалы автомобильләр җитештерүне әзерләүдә, аның модификацияләрен, күчәр йөкләнеше 10–13 *т* булган югары йөк күтәрүчәнлекле автомобильләр, башка төрле йөк, ш.у. аз литражлы автомобиль модельләре эшләүдә турыдан-туры катнаша. 1997–2002 дә «ЕлАЗ» җитештерү берләшмәсе дәүләт унитар пр-тиесе ген. директоры урынбасары, бер үк вакытта техник директоры. Г. җитәкчелегендә нефть чыгару, скважиналарны ремонтлау һәм эксплуатацияләү өчен «КАМАЗ», «Урал» автомобильләре шассиенда машина төзелеше һәм нефть сәнәгате җиһазларының, «ГАЗ» һәм «ЗИЛ» автомобильләре шассиенда дезинфекцияләү җайланмаларының, терлек азыгы урып-җыю комбайнының, пластмасса эшләнмәләрнең, ПВХ-пластизольләрнең яңа төрләре эшләнә; ябыштырып эшләнгән борыслар, пенобетон җитештерү юлга салына. Дәүләт бүләге «Автомобиль сәнәгате өчен ПВХ-пластизольләрнең яңа производствосын булдыру» дигән хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Камил Хәбиб улы (10.5.1952, Актаныш р-ны Иске Байсар а.), җитештерү барышын автоматлаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1999), проф. (2005). 1974 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 2000 нән Казан энергетика ун-тында, технол. процесслар һәм пр-воларны автоматлаштыру кафедрасын оештыручы һәм аның җитәкчесе. Хезмәтләре нәстационар гидродинамик һәм җылылык процессларын, катлаулы динамик системаларны тикшерүгә һәм автоматлаштыруга карый. Г. энергетик җайланмаларның күчәр симметрияле ябык каналларындагы нәстационар җылылык алмашуга башлангыч һәм чик шартлар үзгәреше законының йогынтысын билгеле. Су б-н тәэмин итүнең әйләнешле системаларында энергия һәм ресурс саклау проблемаларын өйрәнә. Төрле процессларны тотрыксыз шартларда тикшерү өчен приборлар уйлап таба. 10 дәреслек һәм уку ярдәмлеге авторы. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007).

Х е з м.: Диагностирование износового состояния энергетических установок по результатам анализа масел. К., 2006 (автордаш); Методика синтеза нестационарных электрических линий с распределёнными параметрами. К., 2006 (автордаш); Опытная установка для изучения характеристик оросителей промышленных градирен // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2006. № 11–12 (автордаш).


**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Марат Равил улы (18.7.1962, Казан), астрофизик, физ.-матем. фән. д-ры (1996). 1985 елда Мәскәү физ.-техника ин-тын тәмамлаганнан соң, РФАнең Космик тикшеренүләр ин-тында, 1997 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта 1996 дан Макс Планк астрофизика җәмгыяте ин-тында (Гаршинг ш., Германия) эшли. Хезмәтләре югары энергияләр астрофизикасына, рентген һәм гамма нурлар астрономиясенә карый. Безнең һәм башка галактикаларда яңа нейтрон йолдызлар һәм кара тишекләрне ача, Галактиканың үзәк өлеше картасын рентген һәм гамма-нурларда төзи (бергәләп), компактлы объектлардагы рентген нурланышы генерациясенең табигатен һәм механизмнарын аңлатуга зур өлеш кертә.

1994 тән Халыкара астрономнар берлеге әгъзасы. Академик Я.Б.Зельдович исем. һәм Космонавтика федерациясенең К.Э.Циолковский исем. халыкара медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гравитационная сепарация дейтерия и гелия в межгалактическом газе скоплений и галактик // Письма в астрон. журн. 1984. Т. 10 (автордаш); Распределение поверхностной яркости скоплений галактик в резонансных линиях тяжёлых элементов // Письма в астрон. журн. 1987. Т. 13 (автордаш); Маломассивные рентгеновские двойные как индикатор звездной массы в галактиках // Записи Королевского астрономического общества. 2004. Т. 349.

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Мәсгут Хәертдин улы (1.4.1940, Зәй р-ны Кушъелга а.), тракторчы-машинист, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1975, 1981, 1986). 1956–2000 дә Зәй р-ның Тукай исем. к-зында механизатор, шикәр чөгендерен игү звеносы җитәкчесе (1968 дән) булып эшли. 1980 нән ул җитәкләгән звено шикәр чөгендерен кул хезмәтеннән башка җитештерүне үзләштерә, 1985 тә һәр гектардан 425 *ц* уңыш алына (гомуми мәйданы 125 *га*). Хезмәт Даны орденнары 9, 10, 11 бишьеллыкларда ирешкән югары күрсәткечләре өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә (1988).

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Нух Хисам улы (12.6.1941, Сарман р-ны Иштирәк а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1993), ТРның атказ. нефтьчесе (2001). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1966). 1966–77 елларда «Сургутнефть» НГДУында



А.Г.Гыйльфанов.

нефть чыгаручы оператор, өлкән мастер, скважиналарны капиталь ремонтлау цехы башлыгы, р-н инженер-технол. хезмәте башлыгы, 1977–78 дә «Фёдоровскнефть» НГДУында (Төмән өлкәсе, Сургут ш.) үзәк инженер-технол. хезмәте башлыгы урынбасары. 1978–97 дә «Татнефть» АҖнең катлауларның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм скважиналарны капиталь ремонтлауның Әлмәт идарәсендә өлкән инженер, цех башлыгы, баш инженер. 1997–2001 дә «Катлауларның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм скважиналарны капиталь ремонтлауның «Татнефть–Әлмәт идарәсе» ААҖнең баш инженеры. Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге «Эксплуатацияләү колоннасын саклау һәм төзекләндерү өчен технологияләр һәм техник чаралар комплексын эшләү һәм сәнәгатьтә киң куллану» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ГЫЙЛЬФА́НОВ** Равил Сөләйман улы (29.5.1929, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944 елда ВЛКСМ ҮК юлламасы б-н Төньяк хәрби диңгез флотының юнгалар мәктәбенә җибәрелә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Балтыйк хәрби диңгез флотында хезмәт итә (1952 гә кадәр). 1957 дән Татарстан «Свияга» ҖБндә эшли: техник, инженер, лаб. башлыгы, баш инженер (1967–93), ген. директор ярдәмчесе (1993 тән). Дәүләт бүләге радиолокация өлкәсендәге хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. 2 нче дәрәҗә Ватан Сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМАДЕТДИ́НОВА** Рәйсә Сәетәбрар кызы (25.1.1940, Спас р-ны Кызыл Сука, хәзерге Үрнәк а.), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1958–97 елларда Татарстан «Свияга» ҖБндә эшли. Дәүләт бүләге хезмәттәге югары уңышлары, хезмәтне оештыру һәм стимуллаштыруда бригада формаларын кертүдәге өлеше өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМАДИ́** Хәйри (Гыймадетдинов Хәйретдин Гыймадетдин улы) (1.9.1912, Казан губ., Зөя өязе Мулла Иле а. — 11.10.1961, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (1949). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1932). 1927–30 елларда Зөя һәм Казан типографияләрендә хәреф җыючы булып эшли. 1932–43 тә Казан пед. ин-тында, 1941–42 дә тарих ф-ты деканы, бер үк вакытта Казан ун-тында укыта. 1943 тән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдә-

бият һәм тарих ин-тында, 1946–59 да тарих секторы мөдире. Хезмәтләре Алтын Урда, Татарстан тарихына, татар халкының этногенезына карый. «Татарстан АССР тарихы»н (1–2 т., 1955–60) нәшер итүдә катнаша: 1 нче томның җаваплы мөхәррире, татарларның этногенезына, болгар халкы тарихына, рухи мәдәниятқә, иҗтимагый хәрәкәтләргә һ.б. багышланган бүлекләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Народы Среднего Поволжья в период господства Золотой Орды // Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1; О трудах К.Насыри в области исторических и археологических материалов // Каюм Насыри. 1825–1945: Материалы научной сессии, посвящ. 120-летию со дня рождения. К., 1948; Употребление термина «татары» // Вопр. истории. 1954. № 8.

*Әд.:* Г и л ь м а н о в З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне. 1941–1945 гг. К., 1977.

*К.Г.Нәҗипова.*

**ГЫЙМАДИ́** Эдуард Хәйретдин улы (1937, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1990). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Себер бүлегенең (Новосибирск ш.) Математика ин-тында эшли. Хезмәтләре матем. кибернетикага карый. Дискрет оптимальләштерү буенча фәнни юнәлеш ача. Якынча исәпләүләрнең нәтиҗәле алгоритмнарын төзи һәм аларның эшләү сыйфатын бәяли.

Х е з м.: О некоторых математических моделях и методах планирования крупномасштабных проектов // Модели и методы оптимизации. 1978. Т. 10; Экстремальные задачи стандартизации. Новосиб., 1978 (автордаш).

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Әсгать Гатият улы (15.5.1944, Оренбург өлкәсенең Алексеев р-ны Яңа Колшәрип а.), двигательләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1961–64 елларда Балашов югары хәрби очучылар уч-щесендә укый. 1968 дә Куйбышев авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук энергетика җайланмаларының автомат системалары кафедрасында эшли. Хезмәтләре авиация двигательләрен ягулык б-н туендыру динамикасы системаларына һәм көйләүгә карый. Параметрларны тикшереп тору һәм идарә итү системалары, химик-технол. һәм нефть җайланмаларының гидравлик системалары басым тирбәнешен сүндерү конструкцияләрен проектлау ысулларын, эшләнмәләрнең тикшерергә кыен урыннарындагы басым пульсациясен, югары темп-ра шартларында турбомашина элементларының дерелдәвен үлчәү өчен җайланмалар эшли. Контроль-үлчәү приборлары өчен тирәлекләрне аергыч, агрессив сыеклыклар өчен яңа тигезлек үлчәгеч конструкцияләрен, казандагы һәм җылылык-энергия электр үзәге турбинасындагы суны сынауга әзерли торган химик тикшерү системасын гамәлгә кертә. Уйлап табуга 48 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. РФ Космонавтика федерациясенең акад. В.П.Глушко исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гасители колебаний давления жидкости для гидромеханических устройств летательных аппаратов. М., 1988 (автордаш); Гидравлические и газовые цепи передачи информации. М., 2000 (соавт.); Prufstand zur Ermittung des Verhaltens Hydraulischer Bauelemente bei Dynamischen Vorgangen // Maschinenbautechnic. 1980. № 7 (автордаш).

*Әд.:* Г е с е л е в Б. Дефицитная профессия // Самарские известия. 2002. 25 мая.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Марат Минһаҗ улы (26.2.1930, Казан — 10.3.2006, шунда ук), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1976), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1954), 1957–60 елларда һәм 1972 дән шунда ук эшли, 1973–95 тә коммуналь гигиена каф. мөдире, проф. (1977). 1960–71 дә Уфа гигиена һәм һөнәри авырулар фәнни-тикшеренү ин-тының хезмәт гигиенасы бүлеге мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре — хәзерге нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләренең әйләнә-тирә мохитне канцероген углеводород б-н пычратудагы роле; канцерогенлыкны өйрәнү һәм яман шешләр үсешен булдырмауда беренчел чаралар эшләү; тиредә һәм сулыш органнарында барлыкка килгән яман шешләр эпидимиологиясе. Г. җитәкчелегендә әйләнә-тирә мохитне саклауның мед. аспектлары буенча проблемалы фәнни-тикшеренү лабораториясе оештырыла. Тикшеренү нәтиҗәләре һава атмосферасында бенз(а)пирен концентрациясенең мөмкин булган концентрациясен нигезләүдә, «ТАССР халыкларының сәламәтлеге» һәм «Әйләнә-тирә мохитне саклау» (1990) республика максатчан программаларын эшләүдә файдаланыла. «Казанский медицинский журнал»ның баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Х е з м.: Атмосфера и человек. К., 1978; Русско-татарский словарь медицинских терминов. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Марат Мингазович Гимадеев // Казан. мед. журн. 2000. № 1.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Равил Шәмсетдин улы (8.2.1947, Буа р-ны Иске Тинчәле а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1999). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Феодосия аэросыгылмалы системалар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүленеп, 1996–2000 дә РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында); 2000–03 тә Херсон техник ун-тының информацион технологияләр каф. мөдире. 2003 тән Казан энергетика ун-тының югары матем. каф. профессоры, проректоры (2004 тән). Хезмәтләре әйләнә-тирә б-н тәэсирләшүче парашют тибындагы йомшак сүрүле конструкцияләрнең деформациясе механикасына карый. Г. парашют тибындагы катлаулы геометрияле фәзаи йомшак сүрүле конструкцияләрнең деформация динамикасын исәпләү ысулын һәм йомшак канат профиленең кысылмаучан тирәлек б-н статик тәэсирләшүен исәпләүнең санча алгоритмын эшли. Төрле чик шартларындагы бер күчәрле йомшак сүрүнең деформация халәтен исәпләү мәсьәләсен якынча аналитик чишүгә ирешә.

Х е з м.: Математическое моделирование формы и края мягких крыльев // Изв. вузов. Авиационная техника. 1997. № 3; Равновесное состояние круглого парашюта с центральной стропой. Оптимизация поверхности // Тр. междунар. конф. по теории оболочек и пластин. Саратов, 1997. Т. 3; Динамика мягких оболочек парашютного типа. К., 2006.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Салих Гыймади улы (1.1.1902, Вятка губ., Малмыж өязе Порхода а. — 30.10.1983, Казан), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1923 елга кадәр крәстиян хуҗалыгында эшли. Донбасснның Луганск округы Краснодон посёлогындагы шахталарда (№ 1, № 3) забойчы (1923–30) булып эшли, шунда ук, 1927 дә аз белемлеләр өчен башлангыч татар мәктәбен тәмамлый. 1930–31 дә Порхода авылы крәстияне, М.В.Фрунзе исем. к-зның беренче рәисе (1931–50), 1950–59 да Балтач р-ның Пыжмара авылы б-н берләштерелгән Сталин исем. к-зны җитәкли, 1959–62 дә Балтач р-ның эреләндерелгән («Алга» к-зы б-н кушылып) М.В.Фрунзе исем. к-зы җитәкчесе. 1962 дән колхозның персональ пенсионеры. Ул җитәкләгән елларда колхоз а.х. продукциясен җитештерү буенча республикада алдынгы урынны тота, үсемлекчелек һәм терлекчелектә ныклы матди-техник база булдырыла. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Сәлимҗан Салих улы (7.8.1948, Арча р-ны Урта Бирәзә а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1993). 1971 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1972–81 дә «Октябрь» к-зында эшли: икътисадчы, рәис (1975 тән). 1981 дән Арча р-ның «Игенче» коллектив пр-тиесе рәисе. ТР буенча Федераль казначейлык идарәсенең Арча р-ны бүлеге җитәкчесе. Г. катнашында хуҗалыкта экологик баланслангaн игенчелек системасы кертелә. Бу система а.х. җирләре һәм чәчү әйләнешенең оптималь нисбәтен һәм урнашуын, эрозияләнгән ландшафтта урман мелиорациясен, а.х. культураларын үстерүдә туфрак саклау технологиясен, гади гидротехник корылмалар системасын булдыра һ.б. үз эченә ала. Бөртекле культураларның уңышы 1981 елда һәр гектардан 14 *ц* булса, 1987 елда 40 *ц* га җитә. Дәүләт бүләге хуҗалыкта адаптив агроландшафтлы игенчелек системасын үзләштергәне өчен бирелә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Үзбәк Ибраһим улы (5.8.1920, БРның хәзерге Авыргазы р-ны Яңа Карамалы а. — 13.9.1987, Уфа), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1984). Эстәрлетамак пед. уч-щесен тәмамлаганнан соң (1939), мәктәптә эшли. 1941–43, 1945–46 елларда «Җиңү өчен» г-тасы мөхәррире (Эстәрлетамак ш.). 1944 тә КПСС ның Авыргазы райкомында партия кабинеты мөдире. КПССның Башкортстан өлкә ком-ты каршындагы партия мәктәбен (1949), КПСС ҮК каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлый (1955). 1949–68 дә «Кызыл таң» г-тасының баш мөхәррире урынбасары. 1968 дән Башкорт ун-тында укыта. Хезмәтләре рев-циягә кадәрге татар сатирик матбугатының идея-эстетик эчтәлегенә, 1917 елдан соңгы башкорт матбугатына, Г.Ибраһимов иҗатына карый. Г. шигырь, пьеса, хикәя, очерклар һәм Г.Ибраһимов турында тәмамланмыйча калган роман авторы.

Х е з м.: Сила сатирического слова. Роль и значение татарских сатирических журналов дооктябрьского периода в развитии национальной литературы. К., 1987; Галимьян Ибраһимов — журналист. Өфө, 1967.

*Әд.:* Узбек Ибрагимович Гимадиев: Библиогр. указ. Уфа, 1981.

**ГЫЙМАДИ́ЕВ** Фердинант Минһаҗ улы (28.6.1945, Казан), балет артисты, педагог, ТАССРның халык артисты (1985). Иҗади эшчәнлеген үзешчән коллективларда башлый. Татоблсовпроф каршындагы балетмейстерлар әзерләү мәктәп-студиясен тәмамлый (1962). 1964–85 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең бию төркеме солисты, 1986 дан педагог-балетмейстер. «Мәдрәсәдә булган хәл», «Аулак өй», «Әпипә», «Өмә», «Туй», «Колхоз яшьләре», «Сабантуй» һ.б.



Ф.М. Гыймадиев һәм Р.К. Мостафина «Әпипә» биюендә.

хореографик композицияләрдә төп партияләрне башкара. Биюенә җиңеллек, сыгылмалылык һәм оста артистлык хас. Педагог-репетитор буларак, татар биюен укыту методикасын, милли традицияләрне һәм татар классик хореография репертуарын тирән белә (Г.Х.Таһиров, Ф.Ә.Гаскәров, А.З.Кәлимуллин биюләре). Карфагенда (Тунис, 1977) фольклор коллективлары фестивалендә катнаша. СССР ВДНХсы бронза медале б-н бүләкләнә.

*В.Н.Горшков.*

**ГЫЙМАДИ́ЕВА** Ләлә Нәгыйм кызы (1.3.1947, Биектау р-ны Мәмдәл а.), журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1969–70 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасы хәбәрчесе. 1970–88 дә Биектау р-ны Олы Битаман урта мәктәбендә эшли (рус теле һәм әдәбияты укытучысы, 1980 нән директор урынбасары). 1988 дән «Сабантуй» г-тасында хәбәрче, 1990 нан җаваплы сәркәтип, 1995 тән баш мөхәррир, 2004 тән җаваплы сәркәтип. Балалар һәм яшьләрне әхлакый яктан тәрбияләүгә багышланган мәкалә һәм язмалары «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга» г-таларында һәм «Сөембикә», «Казан утлары», «Ялкын» ж-лларында басыла.

Ә с ә р.: Кызарган алмалар. К., 1986; Мыеклы фәрештә. К., 2000.

**ГЫЙМА́ДОВ** Әхмәт Зыятдин улы (1915, Казан — октябрь, 1943), язучы. 1930 елларда матбугатта басылган беренче очерклары һәм хикәяләре производство тематикасына багышланган. Аерым шигырьләре «Безнең тавыш» (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Үсәбез» (1941) күмәк җыентыкларына кертелгән. Бөек Ватан сугышында һәлак була.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГЫЙМА́ЕВ** Зөфәр Фоат улы (9.1.1951, Үзбәкстан ССР, Наманган ш.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1970), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1976, А.Д.Зайцев остаханәсе), СССР Сәнгать академиясенең Казандагы Х.Г.Якупов җитәкчелегендәге нәкышь иҗат остаханәсен (1980) тәмамлый. Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта (1976–78, 1982–84), бер үк вакытта 1980 елдан Татарстан Сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980), 2008 дән ТР Рәссамнар берлеге рәисе. Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында уңышлы эшли. «Әбигә хат килде» (1979), «Кичке автобуста»



Ф.М. Гыймадиев.

(1980), «Өч ай» (1997) картиналары тирән тәэсирле эчтәлек, лиризм б-н сугарылган. Г. иҗатында портретлар, ш.и. төркемле портретлар зур урын алып тора. Шәхесләрнең тышкы охшашлыгына ирешү б-н беррәттән, рәссам аларның эчке дөньясын тирәнтен чагылдыру, катлаулы фонда дөрес сайланган аксессуарлар ярдәмендә төгәл һәм үзенчәлекле композиция төзү осталыгына ия («Татарстан акробатлары», 1979; «Икәү чәй эчү. Язучы Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя ханым», 2000). Шулай ук татар артистлары, режиссёрлары, драматурглары портретлары сериясен булдыра («Гаяз Исхакый», 1993; «Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская», 1993; «К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшев», 1993; «Рәфкат Бикчәнтәев», 1994; «Нәкый Исәнбәт», 1995; «Туфан Миңнуллин», 1995; «Кәшифә Тумашева», 1999; «Гали Надрюков», 1999; «Гали Ильясов», 1999; «Дамир Сиразиев», 2001; «Празат Исәнбәт», 2002 һ.б.). «Күкидә кич» (1978), «Өмбе авылында көз» (1982) лирик пейзажлары, «Татар сөлгесе белән натюрморт», «Иске кофе савыты белән натюрморт» (икесе дә — 1978) авторы. Бөтенсоюз, бөтенроссия, төбәкара һәм респ-ка күргәзмәләрендә (1970 тән), Төркия (1991 дән) һәм Словакиядә (1994 тән) узган халыкара күргәзмәләрдә, «Тюрксой» 3 нче халыкара пленэрында (Төркия, Анталия) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1998 (Словакия, Снин ш.), 1995, 2001 (Казан), 2002 (Яшел Үзән ш.) елларда уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, В.Суриков исем. сынлы сәнгать музеенда (Красноярск ш.), Пермь картиналар галереясында, С.Сәйдәшев исем. музейда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында, Татар акад. театрында, ш.у.

З.Ф. Г ы й м а е в.
1. «Туфан Миңнуллин». 1995;
2. «Уйлану. Б.И.Урманче». 1997;
3. «Ак чәчкә. Хәсән Туфан». 2001.









М.М. Гыймазов.



Г.К. Гыйматдинов.

Польша, Словакия, Чехия, Германия, Төркия, Франция, Англия, Израиль, АКШ һ.б. илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Новицкий А. Один из лучших мастеров // Казань. 2002. № 5; Колина С. Освещённые солнцем // шунда ук.

*М.Е.Ильина.*



З.Ф. Гыймаев. «Өч ай». 1997.

**ГЫЙМА́ЕВ** Имам Фәүзи улы (24.10.1918, Уфа губ. Минзәлә өязе, хәзерге Мөслим р-ны Салауз Мухан а. — 21.6.2003, Чистай ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССРның атказ. азык индустриясе хезмәткәре (1990). КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (1958). 1950–60 елларда КПССның Красный Бор район ком-ты, Татарстан өлкә ком-ты, Чистай шәһәр ком-тында партия эшендә. 1960–63 тә халык депутатларының Чистай район советы рәисе. 40 елга якын Чистай ликёр-аракы з-ды директоры булып эшли (1963–2002). Аның җитәкчелегендә пр-тие тулысынча үзгәртеп корыла: юу — эчемлек бүлеп тутыру цехлары, ликёр һәм транспорт участоклары булдырыла; автоматик рәвештә шешәләргә эчемлек бүлеп тутыру линияләре куела; 1997–98 дә су чистарту җайланмасы б-н бергә аракы әзерләүнең яңа технологиясе һ.б. гамәлгә кертелә. Аның исеме б-н аталган «Престижная Гимаевская» аракысы эшләнә (1996). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМА́ЕВ** Ирек Фәрит улы (2.9.1957, БАССРның Дүртөйле р-ны Суыккүл а.), спортчы (алкалы хоккей). СССРның атказ. спорт остасы (1979). Уфа нефть ин-тын тәмамлый. С.Юлаев исем. балалар-яшүсмерләр олимпия әзерлеге махсус спорт мәктәбендә тәрбияләнә (Уфа ш., тренеры М.М.Азаматов). 1979, 1982–83 елларда дөнья (яшьләр арасында, 1977), 1979, 1982–83, 1985 тә Европа (яшүсмерләр арасында, 1976), 1980–87 дә СССР (яшүсмерләр арасында, 1973) беренчелекләрендә җиңүче. Европа (1979–86), Швеция (1980) кубоклары иясе. Дөнья һәм Европа чемпионатларында 26 уенда (5 алка кертә), СССР чемпионатларында 356 уенда (40 алка), Канада кубогына 10 уенда (1 алка) катнаша. «Салават Юлаев» (Уфа ш., 1976–79), ЦСКА (Мәскәү, 1979–87), «Одзи Сейси» (Томакомаи ш., Япония, 1987–91), «Любляна» (Югославия, 1991–92) командаларында уйный. 1979 елдан Мәскәүдә яши.

**ГЫЙМАЗЕТДИ́НОВ** Марсель Гыйльфан улы (11.12.1943, Бондюг, хәзерге Менделеев р-ны Бәзәкә а. — 19.4.1993, шунда ук), шагыйрь. Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1966). Хезмәт эшчәнлеге Менделеев р-ны б-н бәйле: мәктәп укытучысы, Г.Тукай исем. к-з рәисе (1986–90), 1990 елдан халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1991 дән «Татарстан» с-зы рәисе. «Яшәү мәгънәсе» (1990), «Язлардан алалмыйм күземне» (1992), «Син мине белмисең» (1994) исемле шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләрендә яңгыраган төп тема — туган як табигате, хезмәт кешесенең тормышы. Шигырьләренә ягымлы лирик интонация, музыкальлек хас. Г.ның күп кенә шигырьләрен З.Хәйретдинов, М.Иванов, Ф.Хатыйпов, В.Усманов, И.Закиров кебек композиторлар көйгә сала, алар популяр җырларга әверелә.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙМА́ЗОВ** Мөгаллим Минһаҗ улы (3.1.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Баулы а. — 4.3.1982, Азнакай р-ны Актүбә штп.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1959). 1937–39 елларда Баулы МТСында бригадир ярдәмчесе. 1946–74 тә «Татнефть» ҖБнең Азнакай бораулау эшләре идарәсендә моторчы, бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы мастер (1950 дән). Г. җитәкчелегендә нефть чыгару эшендә Татарстанда беренче тапкыр балчык измәсе урынына су кулланыла башлый. Ул җитәкләгән бригада системалы рәвештә скважиналарны рекордлы бораулау тизлегенә ирешә, Бөтенсоюз соц. ярыш нәтиҗәләре буенча иң яхшы бораулау бригадасы дип таныла. Герой исеме нефть һәм газ сәнәгате үсешендә ирешкән зур уңышлары өчен бирелә. 1958–62 дә СССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Актүбә посёлогында Г. яшәгән йортка мемориаль такта куела (1997).

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Горник Г. Гимазов Мугалим Миназович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Ларичева Э.И. Дороже золота. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ГЫЙМАТДИ́НОВ** Габбас Кыям улы (8.2.1925, хәзерге Чирмешән р-ны Туймәт а. — 2.1.1997, Нурлат ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1971), СССРның мактаулы нефтьчесе (1981). Казан пед. ин-тын (1962), Минзәлә совхоз-техникумын (1967) тәмамлый. 1946–52 елларда ВКП(б)ның Беренче Май райкомында партия эшендә 1952–55 тә КПССның Ямаш райкомының 2 нче секретаре. 1956–58 дә Шөгер р-нының «Ленин юлы» к-зы рәисе. 1958–62 дә КПССның Теләче, Саба райкомнарының 1 нче секретаре, 1962–64 тә адм.-хуҗалык эшендә, 1965–87 дә Октябрь райкомының 1 нче секретаре. Герой исеме 8 нче бишьеллык планнарын уңышлы үтәгәне өчен бирелә. 1963–89 да ТАССР ЮС депутаты. Бер үк вакытта ТАССР ЮС рәисе урынбасары. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Нурлат шәһәрендәге Мәдәният йортына һәм бер урамга Г. исеме бирелә, бюсты куела.

*Әд.:* Фасахов К. Гиматдинов Габбас Киямович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Гиматдиновы: Воспоминания. Очерки. Фотографии. Документы. К., 2009.

**ГЫЙМАТДИ́НОВ** Сәяс Кыям улы (26.5.1930, хәзерге Чирмешән р-ны Туймәт а. — 5.5.2003, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Казан авиация ин-тын (радиоинженер белгечлеге) тәмамлый (1953). 1955–59 елларда, «утызменче» буларак, Калинин өлкәсенең «Мир» к-зы рәисе. 1959–68 дә шул ук өлкәдә КПСС райкомының 1 нче секретаре, өлкә ком-тының а.х. бүлеге мөдире, 1968–75 тә Калинин өлкә башкарма ком-тының рәис урынбасары. 1975–86 да Татарстан «Овощепром» тресты директоры, «Татплодоовощпром» респ-ка аграр-сәнәгать берләшмәсе башлыгы, бер үк вакытта ТАССР Агросәнәгать ком-ты рәисе урынбасары. Аның җитәкчелегендә тармакның матди-техник базасы ныгытыла, яшелчәчелек сугаруга күчерелә, яшелчә үстерүгә индустриаль технологияләр кертелә, теплица хуҗалыгы үсеш ала. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙМАТДИ́НОВА** Нәбирә Миннәхмәт кызы (20.10.1956, Аксубай р-ны Карасу а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы әдәби берләшмә б-н җитәкчелек итә. 1989 елдан — «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөхәррире, 2006–09 да — баш мөхәррир. «Су хикәясе» исемле беренче әсәре 1981 елда басыла. Г. — «Ут күбәләге» (1990), «Сихерче» (1993), «Кыргый» (1996), «Ак торна каргышы» (1997), «Икебезгә дә авыр» (2000) «Парлы ялгыз» (2004), «Бер тамчы ярату» (2006) повестьлары авторы. Г.ның әсәрләре үзенчәлекле мистик-фантастик манерада язылган. Алар укучының игътибарын таби-

гатьнең серле, танылмаган көчләренә җәлеп итәләр. Г.ның геройлары — катлаулы язмышлы, нык характерлы, үз фикерләрен кыю яклый белүче гадел кешеләр. Үзенең әсәрләре б-н Г. әдәбиятта көчле рухлы, ирекле, бәхет, мәхәббәт юлында каршылыкларны җиңәргә сәләтле заман герое тудырды. Муса Җәлил исем. Республика бүләге лауреаты (2009).

*Әд.:* Ихсанова Л. Нәбирә Гыйматдинова: Безнең сафта // Казан утлары. 1982. № 12; Фәттах Н. Яшь язучының бер хикәясе // Казан утлары. 1983. № 10.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГЫЙМА́ТОВ** Газиз Мөхәммәтҗан улы (1910, Казан губ., Чистай өязе Каргалы а. — 27.10.1978, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1966). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң (1930), Мәскәү үзәк татар эшче театрына кабул ителә. 1933 елдан — Республика күчмә театрында. Күренекле, үзенчәлекле актёр, образ өстендә эшләгәндә тормыш күзәтүләреннән оста файдалана белә, шуның өчен дә тышкы сурәтләүләрдә һәрвакыт ихлас һәм ышандыручан, шул ук вакытта Г. үз персонажының эчке дөньясын дөрес чагылдырырга, үз геройларының эш-гамәлләрен психол. яктан нигезләргә тырыша. Ул башкарган Шәйхулла карт («Тормыш җыры», М.Әмир) роле аеруча кызыклы. Г. аны әле яшь актёр вакытында уйнаса да, сәхнәдә җанлы, табигый образ тудыра. Тискәре образлар өстендә эшләгәндә файдаланылган гротеск элементлары күренешләр артындагы масштаблылыкны арттыралар. Эшли башлаган елларында уйнаган эпизодик рольләрдән әзлекле рәвештә зур рольләргә күчә барып, Г. нечкә психол. портретлар тудыру осталыгына ирешә. Аның аеруча күренекле рольләре арасында — Габдулла («Сулган чәчәкләр», Д.Җаббарлы), Фәхри («Кара йөзләр», М.Гафури), Кантон («Карагол», Д.Юлтый), Сәгыйт («Яшерен эзләр», Х.Вахит), Сәләхи («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Мәхмүт («Үлмәс җыр», Р.Ишморат), Гарифулла («Улларым», Т.Миңнуллин), Галимулла («Урман егете», Т.Закиров), Маргаритов («Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский), Виталий Карташёв («Елмайган өчен миллион», А.В.Софронов), Прозоров («Палата», С.И.Алёшин) һ.б. бар.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ГЫЙМРА́НОВ** Фидаис Мөбарәк улы (15.1.1947, Актаныш р-ны Актаныш а.), химик технология гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1997), проф. (1999). 1970 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук сәнәгать хәвефсезлеге кафедрасында эшли. Хезмәтләре плёнкалы аппаратлардагы гидродинамик, җылылык-массаалмашу һәм реакцион процессларны матем. модельләштерүгә карый. Үзәктән куып парга әйләндергечләрне, абсорберларны, хемосорберларны хисаплау методикаларын эшли. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Расчёт процесса неизотермической абсорбции в центробежных плёночных аппаратах // Докл. III Междунар. форума «Тепломассаобмен». Минск, 1996; Расчёт производительности рабочего элемента центробежного аппарата // Изв. вузов. 1998. № 2.


**ГЫЙМРА́НОВА** Дания Әхәт кызы (23.10.1937, Казан), театр белгече, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997). Язучылар берлеге һәм РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы. Хезмәт юлын Татарстан радиосында режиссёр булып башлый. А.В.Луначарский исем. дәүләт театр сәнгате ин-тының театр белеме бүлеген (ГИТИС, Мәскәү, 1962) тәмамлый. 1964 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих, 1996 дан Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының сәнгать бүлегендә, 1992 дән өлкән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре татар театры тарихына, театр сәнгатенең күренекле эшлеклеләренең иҗатларын яктыртуга, Татар эшче театры, Татар. республика күчмә театры, Минзәлә, Әлмәт татар драма театрлары тарихына карый.

Әсәр.: Гөлсем Болгарская. К., 1981; Габдулла Шамуков. К., 1985; Сабир Өметбаев исем. Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007; Народные артисты. К., 1980 (автордаш); Альметьевский театр // Из истории Альметьевского региона. Альметьевск, 1999. Вып. 1.

**ГЫЙНИЯ́ТОВА** Хәдичә Гыйният кызы (4.1.1940, Казан), җырчы, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1974), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003). 1964 елда Казан консерваториясен (В.А.*Лазько* классы) тәмамлый. 1964–95 тә Татар опера һәм балет театры солисты, бер үк вакытта (1978 дән) Казан пед. ун-тында укыта. Төп партияләре: Азучена, Амнерис («Трубадур», «Аида», Дж.Верди), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Ольга («Евгений Онегин», П.Чайковский), Тугзак, Хәят («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов), Разия («Самат», Х.Вәлиуллин), Миңниса («Җиһангир», Р.Гобәйдуллин). Җырчының концерт репертуарына Э.Григ, Р.Шуман, Ф.Шуберт, П.Чайковский, С.Рахманинов, Г.Свиридов һ.б. композиторларның әсәрләре керә. Г. иҗатының аерым бер өлешен татар композиторларының вокаль әсәрләре: С.Сәйдәшевнең «Бибисара», «Халисә», Р.Яхиннның «Дулкыннар» һ.б. җырлар тәшкил итә. М.Мозаффаров, Р.Яхин, А.Монасыйпов, М.Яруллин, Р.Еникиев һ.б. композиторларның күп кенә әсәрләрен беренче башкаручы. Татар опера һәм балет театры труппасы составында, солист буларак, БДБ илләре, Россия, Татарстан шәһәрләрендә гастрольләрдә була; республика радио һәм телевидениесеннән чыгышлар ясый (ТР ДТРК фондында 100 дән артык язмасы саклана). Вокалистларның Бөтенроссия конкурсы дипломанты (1973).

*Ф.Ш.Салитова.*

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Габбас Гыйниятулла улы (15.5.1905, хәзерге Чистай р-ны Кызыл Ялан а. — 13.4.1968, шунда ук), Сов. Союзы Герое (17.11.1943), сержант (1943). 1927–29 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 69 нчы механикалаштырылган бригаданың (3 нче гв. танк армиясенең 9 нчы механикалаштырылган корпусы) танкка каршы атучылар отделениесе командиры. Брянск, Үзәк һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Орёл һөҗүм операциясендә (1943), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 22 сентябрендә Григоровка авылы өчен барган сугышта (Черкассы өлкәсе Каневский р-ны, Украина ССР) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында яши. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Г. Гыйниятуллин.

*Әд.:* Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Ирек Ибраһим улы (2.11.1944, Баулы р-ны Баулы а.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1996). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Горький өлкәсе, Уфа, Әгерҗе, Казан поликлиникаларында эшли. 1980 елдан Казан мед. ун-тында, 1992 дән терапевтик стоматология каф. мөдире. Тикшеренүләре теш кариесын булдырмауга карый. Г. төп стоматологик авыруларны дәвалау стандартларын эшли һәм гамәлгә кертә; стрептококк сенсибилизациясенең тешләрне югары дәрәҗәдә кариес б-н зарарлавы ачыклана; балаларда теш кариесын дәвалау өчен вакцинопрофилактика үткәрү мөмкинлекләре күрсәтелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Совершенствование медико-социальной профилактики кариеса зубов у детей дошкольного возраста. К. 1994; Димефосфон в профилактике и лечении стоматологических заболеваний. К., 1996.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Рәшит Әсхәт улы (9.5.1954, Яшел Үзән ш.), физиолог, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1993), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли. Тикшеренүләре синаптик тапшырулар механизмына, АТФның организм функцияләрен көйләүдәге роленә, авырту механизмнарына карый. Г. кыска вакытлы постсинаптик сыгылмалылык күренешен, ялкынсыну гармон-медиаторларының нерв-мускул аппаратына тәэсире механизмын ача, ш.у. АТФ һәм ацетилхолинның рецепторлары десенсибилизациянең көйләү механизмы һәм функциональ күренешләре ачыклана. Дәүләт бүләге «Нерв-мускул системасында күзәнәкара тәэсирнең физиологик нигезләре» дигән хезмәте өчен бирелә.

Хезм.: Играет ли десенситизация физиологическую роль в нервно-мышечном синапсе // Рос. физиолог. журн. 1998. Т. 84.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИН** Тәлгат Әшрәфҗан улы (26.8.1935, Яшел Үзән р-ны Мамадыш-Әкил а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1981). 1964 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. Хезмәт юлын 1953 тә Үзбәкстан ССРның Алмалык шәһәрендә заводта электрик булып башлый. 1962–66 да Яшел Үзән р-ның В.И.Ленин исем. к-зында агроном, 1966–94 тә рәис. Ул җитәкчелек иткән елларда бөртекле культураларның уңышы гектарыннан — 27 *ц* га, бәрәңгенең 177 *ц* га җитә, 760 *га* җирдә сугару

кертелә. Уртача еллык савым 1 сыердан 3300 *кг* га кадәр күтәрелә. А.х. җирләренең 100 *га* исәбенә — 289 *ц* сөт, 73 *ц* ит җитештерелә. Колхозның торак пунктларына газ кертелә, терлекчелек комплекслары, социаль-көнкүреш һәм мәдәният объектлары төзелә. Колхоз РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагы, СССР ВДНХсы, ВЦСПС һәм РСФСР А.х. министрлыгының дипломнары һәм грамоталары б-н бүләкләнә. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ГЫЙНИЯТУ́ЛЛИНА** Асия Кәшшафетдин кызы (17.5.1919, Чиләбе ш. — 20.8.2006, Казан), библиограф. Мәскәү китапханә ин-тын тәмамлый (1945). 1936–38, 1950–56 елларда Казан ун-тының фәнни китапханәсендә эшли, 1942–45 тә Беренче Май р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире, 1948–50 дә «Белем» җәмгыятенең Татарстан респ-ка оешмасында, 1963–67 дә «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» г-таларының берләштерелгән редакциясендә эшли. 1948 дә «Совет әдәбияты» ж-лы һәм «Красная Татария» г-тасы битләрендә басыла башлаган мәкаләләре милли әдәбият, мәдәният һәм сәнгать проблемаларына, милли әдәбиятларның үзара багланышларына, татар язучылары иҗатларна карый. Рус һәм татар телләрендә чыккан «Совет Татарстаны язучылары» (1957, 2 нче басма 1970), «Татар совет язучылары» (1958) биобиблиографик сүзлекләрен төзүче.

**ГЫЙРФА́НОВ** Фирдәвес Гыйльметдин улы (7.6.1940, Казан), рәссам, хаттат. Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1966), Ташкент театр-сәнгать ин-тын (1972) тәмамлый. Чаллыда яши һәм эшли. 1973 елдан 1 нче сынлы сәнгать мәктәбендә укыта, 1973–89 да — шунда директор.

Г. — респ-када татар халкының *шәмаил* сәнгате традицияләрендә эшләүчеләр арасында әйдәп баручы осталарның берсе. Дини эчтәлектәге картиналарны ул фольга ярдәмендә яктылык бирелгән пыяла өслегендә майлы буяулар б-н башкара. Рәссам шәмаилләрнең сәнгатьчә образлылыгын шактый баета. Аның «Болгар шәһәре» (1986), «Кәгъбә» (1994), «Иман баскычлары» (1994), «Болгар бакчасы — сагыш бакчасы» (1995), «99 илаһи исем» (1995), «Тереклек агачы» (1998), «Ислам» (1998), «Намаз уку өчен Казан календаре» (1999), «Ибне Фазлан көймәсе» (2000) һ.б. әсәрләре детальләр байлыгы, үзенчәлекле төсләр чишелеше, мәгълүмат тыгызлыгы б-н аерылып тора. Г. шәмаилләрендә Коръән аятьләре нигез итеп алына һәм алар сурәтле образлар символикасы б-н тулыландырыла. Шәмаил язу өлкәсендәге камил профессиональ белеме нәтиҗәсендә Г. 1990 елларда сәнгатьнең бу төрен яңартуга өлеш керткән аз санлы рәссамнарның берсенә әверелә.

Халыкара күргәзмәләрдә, төбәк һәм респ-ка күргәзмәләрендә катнаша (Гамәли сынлы сәнгать, 1994 — Дубай, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре; «Ике Автошәһәр», 1995, Париж; Татарстан Респ-касы көненә багышланган күргәзмә, 1992, Казан; «Татарстан чәчәкләре», 1995, Казан; Татарстан рәссамнары берләшмәләре, 1995, Болгар ш. һ.б.). Шәхси күргәзмәсе 1988 дә Чаллыда уза. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда, Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле. К., 2003.

*Р.И.Шәмсутов.*

**ГЫЙСМӘТИ́** (Гыйсмәтуллин) Габдулла Төхфәтулла улы (14.3.1883, Тургай өлкәсе Кустанай ш. — 10.6.1938, Уфа), журналист, халык мәгарифе эшлеклесе. Троицк шәһәрендә мәдрәсә тәмамлый (1896). 1907 елдан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә табигыять фәннәре һәм математика укыта. 1913 тән Психоневрология ин-тында (Петроград) укый, 3 курс тәмамлый. 1918–20 елларда Эчке Россия Мөселман эшләре комис-тының Петроград мөселманнар секциясе җитәкчесе, 1920 дән Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-тында (Мәскәү) комиссар. 1924 тән БАССРда җаваплы эшләрдә (Мәгариф халык комис-тында, ХКС рәисе, Үзәк статистика идарәсендә һ.б.). Башкортстанның икътисади географиясенә караган брошюралар авторы, респ-ка р-ннарының картасын төзүче. 1907 дән «Йолдыз», «Кояш», «Әхбар», «Вакыт» г-таларында, «Тәрбия», «Мәктәп», «Ак юл» ж-ларында языша. Мәкалә һәм рецензияләренең күпчелеге татар мәгърифәтчелә-ре, язучы һәм шагыйрьләре иҗаты һәм эшчәнлегенә багышлана (Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, И.Гаспринский һ.б.). Башлангыч мәктәпләр өчен әлифба, татар теле һәм туган тел дәреслекләре авторы. Репрессияләнә, вафатыннан соң аклана.

Хезм.: Гыйльме әшья яки тарих табигый. 1 кис. Милләт рөшди мәктәпләр өчен. К., 1909; Ана теле. Ибтидаи мәктәпләр өчен. К., 1911; Татар теле. 1 кит. Ибтидаи мәктәпләрнең 1-сыйныфында әлифбадан соң укытылыр өчен. К., 1913; Хосусый мәктәпләр, класслар, курслар хакында яңа законнар. П., 1915; Ана теле. 1 бүлем: Ибтидаи мәктәпләрнең икенче сыйныфы шәкертләре өчен кыйраәт китабы. К., 1915; Башкортстан икътисади җәгърәфиясе. Өфө, 1928.

*Әд.:* Әмирхан Ф. Тәрҗемә — тәфсир // Аң. 1916. № 15; Ибраһимов Г. Татар әдәбияты (Хисап урынында) // Татарстан хәбәрләре. 1922. 7 февр.; Габитов А., Терегулов А. Габдулла Гыйсмәти // Кызыл таң. 1938. 8 гыйнв.


*Ф.И.Ибраһимова.*

**ГЫЙСМӘТУ́ЛЛИНА** Хәнифә (19 йөз ахыры, Томск ш. — 20 йөз башы), язучы. Әтисе мәдрәсәсендә белем ала. Сембер губ. Сөнгәләй өязе Иске Тимәш авылында Акчуриннар фабрикасы каршындагы кызлар мәктәбендә, Зөя авылының хатын-кызлар мәктәбендә укыта. Уку-укыту, гаилә, татар хатынының җәмгыятьтәге урыны темаларын чагылдырган «Гакыйдәт әл-әһле хак» («Хак бәндәләренең ышанулары», 1895), «Тәргыйб» («Кызыксыну», 1898), «Мәгъдән әл-мәсаил» («Мәсьәләләр чыганагы», 1900) исемле публицистик китаплар авторы. «Тәргыйб» әсәрендә хатын-кызларны матбугат битләрендә үз хокукларын яклап актив чыгыш ясарга чакыра. «Тәгъзия» («Күңел юату») (СПб., 1897) исемле җыентыкка кергән лирик шигырьләрендә иренең дөнья куюына карата авыр кичерешләре чагыла. Г. — әсәрләре матбугатта басылган беренче татар хатын-кыз язучылардан берсе.

*Әд.:* Бурнашева З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т; Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ГЫЙСМЕТДИ́НОВ** Дамир Минсәгыйр улы (25.1.1949, Чуаш АССРның Батыр р-ны Татар Тимәше а.), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1975–86 елларда «Чаян» ж-лы редакциясендә эшли. 1986–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор, соңрак халыкара мәсьәләләр буенча консультант. 1990–94 тә «Ватан» иҗтимагый җәмгыяте президенты. 2002–2004 тә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма ком-ты рәисенең халыкара мәсь-


1


2

Ф.Г.Гыйрфанов. 1. «Намазлар өчен Казан календаре». Шәмаил. Пыяла, майлы буяу, фольга. 1999; 2. «Биләр шәһәре». Шәмаил. Пыяла, майлы буяу, фольга. 2000. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

әләләр буенча киңәшчесе, чит илләрдә яшәүче татарларның иҗтимагый оешмалары б-н эшләү бүлеге җитәкчесе, 2004 тән — рәис урынбасары. Сатирик хикәяләре кергән «Өметсез шайтан» (1990), шигырь, хикәя һәм публицистик мәкаләләре тупланган «Әйтсәм әйтим» (1999), «Атта да, тәртәдә дә» (2004) җыентыклары, популяр җырлар текстлары авторы. ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2004).

*Әд.:* Н а д и р о в И. Милләт хадиме // Мәдәни җомга. 2008. 11 июль.

**ГЫЙСЪЯНЧЫЛЫ́К** (гарәп. عصيان сүзеннән — фетнә кубару, баш күтәрү, буйсынмау) — урта гасыр мөселман халыклары әдәбиятларында һәм татар әдәбиятында 1910–30 елларда шактый үсеш алган романтик юнәлеш. Ул шәхеснең чикләнмәгән (абсолют) иреккә хокуклылыгын яклау, аның акылын, хис-тойгыларын дини-патриархаль гореф-гадәтләр басымыннан азат итү, феодаль-буржуаз җәмгыятьнең социаль һәм рухи изүенә ризасызлык белдерү б-н сыйфатлана. Мөселман Яңарыш әдәбиятының Мәгарри, Хәйям, Хафиз, Нәсими кебек шагыйрьләре горур һәм ирекле шәхескә мәдхия уку, аны илаһилаштыру, һәрнәрсәгә шик-шөбһә белдерү, дингә һәм голамәләргә каршы кискен фикерләр белдерү, феодаль-патриархаль әхлакны тәнкыйтьләү һәм гаепләү б-н танылалар. Бу шагыйрьләрнең дөньяга карашларына дуализм хас. Бер яктан, алар ихлас әт-Тәһхидкә — Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанганнар; икенче яктан, кешене дә һәрнәрсәнең үлчәме, Галәмнең үзәге дип югары күтәргәннәр. 20 йөз башы татар әдәбиятында, ягъни шәхес азатлыгына һәм милли тәрәккыять мәсьәләләренә игътибар арткан чорда, урта гасырлар мөселман дөньясындагы Г. традицияләренең йогынтысы аеруча тирән һәм киң колачлы була.

20 йөз башы татар Г. романтизмының күренекле вәкиле — шагыйрь С.Рәмиев. Аның иҗаты — кешене илаһилаштыру, Аллаһка карата да тәнкыйди сүзләр белдерү, буржуаз җәмгыять б-н бәйле өметләрдән гайрәт чигү, социаль һәм рухи изүгә ярсып каршы чыгу, шәхеснең хөр фикер йөртүгә хокуклылыгын яклауның ачык мисалы («Таң вакыты», «Мин», «Син», «Алданган», «Дөньяга», «Мәҗид сүзе» һ.б.). «Таң вакыты» шигырендә яфраклары б-н бөтен дөньяны каплаган зур агач кәүсәсе мисалында ул урта гасырлардагыча торгынлык хәлендә яшәвен дәвам итүче 20 йөз башы татар тормышын символлаштыра. Кешенең җирдә һәм галәмдә акылы һәм ихтыяры иҗтиһад кылырга хокуклы икәнлеген раслап, барысын да язмышка сылтап, изге гамәлләрне бары тик Аллаһтан көтеп ятучы, ислам диненең асылын аңламаучы замандашларын кискен тәнкыйтьли. Таң атуны — Яңарышны көзаллаган гыйсъянчы шагыйрь шәхеснең рухи үсешенә, милли алгарышка аяк чалган наданлыкка каршы чыга («Бетмә надан / Туг яңадан / Мәгърифәтле анадан! / Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә, / Хата ул өмид Алладан!»).

Г. мотивлары Г.Тукай («Өмид»), Г.Ибраһимов («Көтүчеләр»), М.Гафури («Юктырсың ла, Алла!»), Ш.Бабич («Газазил») кебек шагыйрьләр һәм прозаиклар иҗатында да күзәтелә.

1905–1907 еллардагы Беренче рус революциясеннән соң, сәяси, социаль, милли идеаллары тормышка ашмаган гыйсъянчы язучылар тирән күңел төшенкелегенә биреләләр. Бу чорда әсәрләрнең төп мотивы — нәфрәт һәм рәнҗү белдерү. Мәс., 1909 да язылган «Дөньяга» шигырендә С.Рәмиев: «Җир-суны да яндырыр һәм / Күкләрен ватар идем!...» — дип яза. Әмма шулай да 1917 елга кадәрге гыйсъянчы язучылар илаһияттән йөз чөермиләр, чын күңелдән Аллаһның барлыгын һәм бердәнберлеген тану фәлсәфәсенә турылыклы булып калалар. Алар иҗатындагы Г. мотивлары типологик яктан Европа һәм рус әдәбиятларындагы «давыл һәм һөҗүм», байрончылык, ницшечелек, иблисчелек ише фәлсәфи-эстетик агымнар белән охшаш.

1920–30 елларда Г. әдәбиятындагы төп мотив марксистик-ленинчыл идеология рухында илдә рәсми дәүләти атеизм урнаштыру, ислам дине, мөселман мәдәнияте б-н бәйле рухи кыйммәтләрне юкка чыгару, Аллаһ һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәдкә карата ачулы гаепләүләр яудыру, Ленин б-н Сталин кебек юлбашчыларга мәдхия уку була.

Сугышчан атеизм, партиялелек, сыйнфыйлыкны алга сөргән большевистик идеология руханиларга каршы аяусыз сугыш ача, динне хорафат дип тамгалап, «галәмнең шаһы», җир йөзендәге бердәнбер Аллаһ дип, бары тик социализм төзүгә юнәлтелгән хезмәтне генә таный. Октябрьдән соңгы чор татар язучылары арасында гыйсъянчыл традицияләрнең дәвамчысы буларак һ.Такташ аерылып тора. «Гыйсъян» (1923) шигырендә ул: «Гыйсъян итеп сезгә каршы, / Сорыкортлар, мин менә / Куркыныч утлар ягып, / Чыктым янар тау өстенә. / Аллагызны, / Дөньягызны /Утка ташлыйм, яндырам, / Җирдә тик эшне илаһ дип калдырам», дип язды. Аның атаклы романтик әчтәлекле «Җир уллары трагедиясе», «Нәләт», «Әшлиләр», «Гыйсъян», «Пасха чаңнары», «Октябрь төне», «Син дошманым минем» кебек шигырьләре дә партиялелек, сыйнфыйлык күзлегеннән чыгып диннән катгый баш тарту б-н сугарылган. Г. мотивлары шулай ук М.Гафури, Г.Камал, С.Сүнчәләй, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Әмири, Ә.Фәйзи, М.Максуд, М.Җәлил һ.б. язучылар әсәрләрендә дә ачык тоемлана.

1920 елларда Г. шигъриятенең аерым тармагы авангард агымнар — имажинизм б-н футуризм була. Авторлар шигъри формаларга революцион үзгәрешләр кертеп, экспрессия б-н сугарылган механика, техника стиленә мөрәҗәгать итәләр, үткән дәверләрдәге мәдәни мирасны, әдәби традицияләрне, көйле шигырьне кире кагалар; «чүкечле аллалар»ның үткәнне җимерү көченә, пролетариатның «канлы гыйсъяны»на, Ницшечә көч һәм агрессия культына дан җырлыйлар (Г.Кутуй «Октябрьдә», К.Нәҗми «Таш шәһәр трагедиясе»).

Гыйсъянчы шагыйрьләр татар поэзиясен хисси-экспрессив башлангыч, күтәренке-романтик һәм бәхәс стиле б-н баеталар, аерым жанрлар һәм ирекле шигырь өлкәсендә кайбер ачышлар ясыйлар, сәнгатьчә фикерләүгә, авангардизмга тартым эзләнүләр алып киләләр.

*Әд.:* Х а л и т Г. Поэзия дерзания. К., 1980; С ә г ъ д и Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1926; С а д р е т д и н о в Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. К.,1973; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; З а р и п о в а - Ч е т и н Ч. Проблема демонизма в творчестве С.Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. К., 2003; З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Романтизм // Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*Р.К.Ганиева.*

**ГЫЙФРИ́Т** (гарәп. عفريت), мөселман мифологиясендә бик зур көчкә ия булган җен. Гарәп халыкларының борынгы мифологиясендә Г. үлгән кешенең җанына тиңләштерелә. Ислам, гарәп фольклоры һәм әдәбияты («Мең дә бер кичә») йогынтысында Г. образы татар фольклорында да киң тарала. Башта Г. геройның риясыз ярдәмчесе булып санала («Балыкчы белән Гыйфрит», «Ак Бүре» һ.б. әкиятләр). Мөгаен, болары Г.нең Сөләйман ханга хезмәт итүе турындагы Коръән мотивы б-н бәйле. Соңрак Г. образына караш үзгәрә һәм ул башка усал затлар рәтенә керә. Мәс., «Өч дус» әкиятендә Г. — диюләр башлыгы, ул аларга хас явыз гамәлләр кыла. Шулай ук Г. татар әдәбиятында да сурәтләнә (Н.Исәнбәтнең «Әңгер җыры» һәм «Хәйләкәр Дәлилә яки «Мең дә бер кичә»дән бер кичә», Зөлфәтнең «Мөмкин!» һ.б.).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; И с ә н б ә т Н. Кырлай егете: Пьесалар. К., 1980; Башҡорт халыҡ ижады: Әкиәттәр. Өфө, 1976; Коран / Пер. смыслов и коммент. В.Пороховой. Дамаск-М., 1996.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ГЫЙФФӘ́Т ТУТА́Ш** (Бурнашева Заһидә Хөсәен кызы) (19.10.1895, Рязань губ., Сасово өязе Әҗе а. — 5.11.1977, Казан), шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе. Башлангыч белемне туган авылында ала. Беренче шигырьләрен 1914–15 елларда «Ил» һәм «Сүз» г-таларында бастыра. Әдәби иҗат б-н шөгыльләнүенә әти-әнисе каршы булганга күрә, 1915 тә өйдән чыгып китә, «Вакыт» г-тасында, «белем алу юлында күпне күргән кызын яклавын» үтенеп, милләтенә мөрәҗәгать итә. «Әнигә хат» (1916) шигырендә өйдән чыгып китүенең сәбәбен үз даирәсе кешеләре тормышы б-н яшәргә теләмәве б-н аңлата. Шул ук елда якташлары ярдәмендә Мәскәүгә барып урнаша, әдәби иҗат б-н шөгыльләнә, укыта. 1917–33 елларда Үзбәкстанда яши һәм эшли. 1918 нең августыннан 1919 ның маена кадәр өяз халык мәгарифе бүлеге мөдире урынбасары (Кәтта-Курган ш.), 1918–20 дә Сәмәркандта «Михнәттәшләр тавышы» г-тасында хезмәткәр, соңрак мөхәррир. 1920–21 дә РКП(б) ҮКның Төркстан бюросында хатын-кызлар б-н эшләү бүлегенә җитәкчелек итә, бер үк вакытта Үзбәкстан хатын-кызлар мәгариф ин-ты директоры. 1920 нең маенда Төркстан хатын-кызларының 1 нче съезды делегаты, М.Фрунзеның чыгышын үзбәк теленә тәрҗемә итә. Шул ук елның июль-августында коммунист хатын-кызларның Мәскәүдә узган 1 нче Бөтендөнья конференция эшендә катнаша. 1921–23 елларда РКП (б)

ҮК хатын-кызлар бүлеге инструкторы. 1924 тә кабат Үзбәкстанга китә: Урта Азия коммунистлар ун-тында бүлек мөдире, Урта Азия ефәк сәнәгате техникумы директоры, Үзбәк дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторы мөхәррире, Урта Азия рев-ция тарихы фәнни-тикшеренү ин-ты фәнни хезмәткәре. 1933–52 дә Кыргызстанда эшли: совет-партия мәктәбендә укыту бүлеге мөдире, Кыргызстан ССР МС каршындагы матбугат буенча Баш идарә җитәкчесе (1941–45 тә әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча Баш идарә җитәкчесе), Бөтенсоюз юридик ин-тының Фрунзе филиалында укыту бүлеге мөдире. 1952 дә Буага күчеп кайта; шәһәр советы башкарма комитеты әгъзасы; партиянең Буа р-ны комитетында пропагандист булып эшли, урта мәктәптә укыта. 1957 дән Казанда яши.

Г.Т. — әдәби тәнкыйтьтә һәм укучыларда зур кызыксыну уяткан, уртак исем б-н чыккан «Гыйффәт Туташ шигырьләре» (М., 1915–17) исемле өч җыентык авторы. Җыентыкларга кергән «Зөһрә йолдызы» экият-поэмасы 1919 да «Заһидә Гыйффәт» псевдонимы б-н кабат басыла. Шигырьләренең төп мотивы — татар хатын-кызының катлаулы язмышы. Г.Т.ның лирик героинясы гаделлеккә омтыла, үз көченә ышана («Әзлим», 1913; «Өмидкә», 1914; «Сәбат», 1915). Аның бай рухи дөньясын ачарга табигать күренешләре ярдәм итә («Көз», 1913), алар аның дөньяга булган мөнәсәбәтен («Тарсыну», 1915) күрсәтә. Г.Т. — «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» (1971) исемле автобиографик китап авторы.

Ә с ә р.: Айсылу. Хәнәфи. Зөһрә йолдыз (Хикәяләр). К., 1919; Зора юлдуз (Звезда Венера). К., 1922.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Гаҗәеп язмыш // Азат хатын. 1985. № 10; Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Өмет йолдызлары: XIX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Р ә м и З. «Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар» // Мәдәни җомга. 1995. 27 окт.

*А.М.Ахунов.*

**ГЫЙФФӘ́Т** Сания (Кадыйрова Сания Хәбирҗан кызы; псев. Уган, Кадыйрия) (1899, Чистай ш. — 12.4.1957, Әнкара ш., Төркия), шагыйрә. «Буби» мәдрәсәсендә укый. 12 яшьтә яза башлый, шигырьләрен «Тормыш», «Сибирия» г-таларында, «Яңа милли юл» ж-лында бастыра. 1917 елда илдән күчеп китә, Кытайда, Финляндия, Төркиядә яши. Татар мәктәпләрендә укыта, татар вакытлы матбугатында язышa. «Сания Гыйффәт шигырьләре» дигән җыентыгы (Уфа, 1918), «Тормыш көзгесе» драмасы (Хельсинки, 1937), басылмый калган «Хан бүләге», «Яңа көй» пьесалары, фин татарлары өчен «Уку китабы» дигән уку әсбабы (Хельсинки, 1938), Г.Тукайга, Г.Исхакыйга һ.б. багышланган әдәби-публицистик мәкаләләр авторы.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х.Й. Чит илләрдәге татар әдәбияты. К., 2007.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ГЫЯСЕТДИ́Н** (Гыязетдин) (? — 1438 яки 1445), Казан идарәчесе (солтаны) (1420 еллар башыннан). *Шадибәк* (башка фараз буенча, *Җәләлетдин хан*) улы. *Идегәй* һәлак булганнан соң (1419), Казанны яулый, Алтын Урда ханы *Олуг Мөхәммәд* исеменнән (1420–22, 1425–32) һәм үз исеменнән (1422–23) акча суктыра. 1423 елда үз олысының бәйсезлеге өчен Олуг Мөхәммәд хан б-н көрәшә. Олуг Мөхәммәднең Алтын Урдада хәле ныгыганнан соң, аның хакимиятен танырга мәҗбүр була. 1432 дән алар арасында яңадан көрәш кабына. Якынча 1437–38 дә Казан аксөякләре ярдәмендә Олуг Мөхәммәд хан шәһәрне ала һәм Г.не җәзалап үтертә (башка чыганаклар буенча, ул 1445 тә һәлак була).

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; М у х а м м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система 12–15 вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

ӨСТӘМӘЛӘР

**ГАЛИ́ЕВ** Фәнәвил Әхми улы (4.1.1960, Арча р-ны Әзәк а.), драма актёры, режиссёр, ТРның халык артисты (2010). Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тының үзешчән коллективлар режиссёр-җитәкчеләре бүлеген тәмамлый (1982, Ш.М.Сарымсаков курсы). 1982–92 елларда Татар драма һәм комедия театрында: актёр, режиссёр; анда шактый үзенчәлекле рольләр башкара. Р.Суфиевның «Мәхәббәт турында куркыныч экият» пьесасын сәхнәгә куя. 1992 дән Казан татар яшь тамашачылар театры актёры һәм режиссёры. Мәскәү Художество театрында актёрлык осталыгы (1993–96) һәм О.П.Табаков театр-студиясендә режиссёрлык эше (2000) буенча стажировка үтә. Төрле пландагы актёр буларак, Г. классик репертуар һәм хәзерге татар драматургиясе әсәрләре буенча күп кенә мөһим образлар иҗат итә: Моталлап («Уеннан уймак», Ш.Зәйни), Ризван («Бер көрешү — үзе бер гомер», Ф.Яруллин), Абдулваһап («Умырзая», Р.Харис), Галим («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Бәхтияр («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Глостер («Король Лир», У.Шекспир), Клеант («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер). Бер үк вакытта ул куючы-режиссёр, драматург. 20 ләп пьеса авторы («Хыялдагы дөнья», «Мисс убырлы», «Узма, яшьлек, заяга», «Җырларым» һ.б.), «Яңа татар пьесасы» конкурсларында актив катнаша, 2009 елда Г.нең «Сәйдәшев вальсы» пьесасы ТР Мәдәният министрлыгының махсус бүләгенә лаек була.



Ф.Ә.Галиев.

**ГАЛИМҖА́НОВ** Илсур Габделхак улы (9.2.1962, Казан), вет. хирургы, вет. фән. канд. (1990), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). 1985 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук вет. хирургиясе кафедрасында эшли, 1997 дән доцент. 1999–2000 елларда вет. медицинасы ф-ты деканы урынбасары. Дәүләт бүләге терлекләрнең үпкә авыруларын дәвалаганда югары күрсәткечле экологик куркынычсыз этиопатогенетик ысуллар эшләп гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

# Д

**ДАВИДО́ВИЧ** Яков Александрович (29.10.1853 — ?), генерал-майор (1901). Польша-Литва татарларыннан. Хәрби-юридик академияне тәмамлый (С.-Петербург, 1883). 1873 елдан Россия армиясендә хезмәт итә. 1884–87 дә Кавказ хәрби округ мәхкәмәсендә хәрби прокурор ярдәмчесе, 1887–98 дә Кавказ хәрби округында хәрби тикшерүче, 1898–1904 тә хәрби судья. 1904–05 тә рус-япон сугышында катнаша: коры җир һәм диңгез көчләре башкомандующие каршында махсус вазифалар башкаручы генерал. 1906 дан Төркестан хәрби округында хәрби судья. 1917 нең августыннан 1918 елның язына кадәр Төркестан хәрби округы мәхкәмәсе рәисе булып эшли. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Я.Я.Гришин.*

**ДАВЫДЕ́НКО** Иван Миронович (6.7.1933, Курск өлкәсенең хәзерге Бельск р-ны Дальние Буды а.), Соц. Хезмәт Герое (1973). 1961–75 елларда «Нефтепроводмонтаж» (Әлмәт ш.) төзелеш идарәсе трестында слесарь-монтажчылар бригадиры. Герой исеме Самотлор–Усть–Балык–Курган–Уфа–Әлмәт нефть үткәргече төзелешендәге уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Низамов И. Давыденко Иван Миронович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ДАВЫ́ДОВ** Әнвәр Мортаза улы (23.3.1919, Самара губ. Камышлы а. — 23.6.1968, Казан), шагыйрь. 1936 елдан «Советская Сибирь» г-тасында (Новосибирск ш.) әдәби хезмәткәр. 1938 дә «Ферганская правда» (Үзбәкстан ССР) г-тасында. 1939–40 та Мордва АССРның Ләмберә р-ны урта мәктәбендә рус теле һәм тарих фәннәрен укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән демобилизацияләнеп (1946), Камышлыга кайта, «Югары уңыш өчен» исемле район г-тасында мөхәррир булып эшли. 1952 дән Казанда. 1953–55 тә ТАССР Язучылар берлегендә җаваплы сәркәтип. 1950 дә «Беренче бөртек» дигән тәүге поэмалар, шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Д. — «Ташу» (1956), «Тормыш лирикасы» (1959), «Кеше бәхете» (1964), «Себер тракты» (1967), «Дәверләр диалогы» (1969; русча тәрҗемәдә «По законам марша», М., 1974) дип исемләнгән шигырьләр һәм поэмалар җыентыклары авторы. Д.ның күп шигырьләре революцион романтика, гражданлык пафосы б-н сугарылган; ул Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең батырлыгы, дуслыгы турында яза. Поэмалары фәлсәфи яктан мәгънәви тирәнлекләре, образлылыклары б-н аерылып тора. «Чорлар чатында» (1961) поэмасы һәм «Йокысыз төннән соң» (1972) роман-симфониясендә автор үз чорын, заман рухын чагылдырырга омтыла. Лирикасына күтәренке рух, метафораларның күплеге, төгәл ритмика, тәэсирлелек хас. Д. балалар өчен дә иҗат итә. М.Җәлилнең сугышчан юлы һәм батырлыгы турындагы «Муса абый» (1964; русча тәрҗемәдә «Мы не забудем тебя», 1966) повесте аеруча киң таныла. Күп кенә шигырьләре һәм поэмалары рус теленә тәрҗемәдә дөнья күрә.

Әсәр.: Кояшлы көн хакына. К., 1979; Түгәрәк бәхет. К., 1984.

*Әд.:* Юзиев Н. Нурлы поэзия // Шигърият дөньясы. К., 1981.


*Р.Ә.Мостафин.*



И.М.Давыденко.



Ә.М.Давыдов.



С.В.Давыдов.

**ДАВЫ́ДОВ** Владимир (Горелов Иван) Николаевич (16.1.1849, Херсон губ. Новомиргород ш. — 23.6.1925, Мәскәү), драма актёры, педагог, Республиканың халык артисты (1922). Рус реалистик театр мәктәбенең зур осталарыннан берсе. Сәхнә эшчәнлеген Орёл театрында А.А.Красовский антрепризасында башлый (1867–70), 1871–72, 1874–75, 1877–78 елларда ул Казанда эшли. П.М.Медведев антрепризасында эшләгәндә, чын актёр буларак формалаша, зур осталыкка ирешә, таланты ачыла. Д. трагедиядән опереттага кадәр төрле жанрларда уйный, дивертисментларда катнаша. Гаҗәеп зур һәм күпкырлы сәләткә, нәзакәтле, югары эчке әхлакый сыйфатларга ия булуы б-н ул тамашачыларда популярлык казана. Сәхнәдә А.Н.Островскийның «Урман», «Шаяннар», «Тәрбиядәге кыз», «Ярлылык гаеп түгел», «Кичеккән мәхәббәт», «Ярлы кәләш», «Воевода», «Күктән төшкән бәхет», «Авыр көннәр» пьесалары буенча куелган спектакльләрдә Буланов, Гольцев, Леонид, Митя, Дормидонт, Милашин, Жилка, Елеся, Андрей Брусков рольләрен; Молчалин («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Хлестаков, Жевакин («Ревизор», «Өйләнү», Н.В.Гоголь), Самозванец («Борис Годунов», А.С.Пушкин) һ.б. рольләр башкара. Казанда бергә эшләгән П.М.Медведев, М.И.Писарев, А.И.Погонин, М.Г.Савина, П.А.Стрепетовалар б-н беррәттән, Д. иҗаты да тормышны тирән белүгә, үткен күзәтүчәнлеккә, социаль юнәлешкә нигезләнә, сәхнәдә реалистик принциплар урнаштыруга ярдәм итә. 1880–1924 елларда С.-Петербургтагы Александр исем. театрда әйдәп баручы актёрларның берсе була; Петербург театр уч-щесендә пед. эшчәнлек алып бара, шәкертләре арасында: В.Ф.Комиссаржевская, Н.Н.Ходотов, Л.С.Вивьен. Д. җитәкчелегендәге студентлар драма түгәрәгендә В.И.Качалов шөгыльләнә; ул 1897 елда Д. тәкъдиме б-н Казан театрына эшкә алына.

Хезм.: Рассказ о прошлом. Л.-М., 1962.

*Әд.:* Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958. *Ю.А.Благов.*

**ДАВЫ́ДОВ** Гавриил (1737 тирәсе — 12.7.1774, Казан), 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Татар милләтеннән. Богырыслан бистәсе кешесе (элегрәк Казан губ. Зөя өязенең Бики а. ясаклы крәстияне). Уложенная комиссия депутаты (1768). 1773 нең декабре башында Е.И.Пугачёв ягына чыга, отряд башлыгы була. Чирмешән кальгасын камауда катнаша (1774). 1774 нең апрелендә әсирлеккә эләгә, Казан төрмәсенә ябыла. Рига шәһәренә каторгага җибәрелергә хөкем ителә. 1774 нең июлендә Казанны Пугачёв гаскәрләре камаган вакытта аны сак офицеры чәнчеп үтерә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ДАВЫ́ДОВ** Селиверст Васильевич (15.1.1918, Казан губ., Лаеш өязе Тегермән Пүчинкәсе а. — 14.5.1992, Түбән Кама ш.), Сов. Союзы Герое (1.11.1943), гв. кече лейтенанты. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1945). Туган авылында колхозда эшли. 1939 елның сентябреннән Кызыл Армия сафларында. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 107 нче гв. истребитель-танкка каршы артиллерия полкының туп командиры (51 нче армиянең 8 нче истребитель-танкка каршы артиллерия бригадасы). Көньяк, Кавказ аръягы, Кавказ, Төньяк Кавказ, Сталинград һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Керчь-Феодосия десант операциясендә (1943) һәм Сталинград сугышында (1942–43), Ростов, Донбасс һәм Мелитополь операцияләрендә катнаша. Мелитополь шәһәренең көньяк читендә дош-

ман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә: аның җитәкчелегендәге туп расчёты шәһәргә бәреп керә; урам сугышларында 5 танкны, дошманның 9 пулемёт ноктасын юкка чыгара, һәрьяклы оборона оештыра; чолганышны өзә. 1946 дан запаска җибәрелә, Шомбыт авылында эшли (Балык Бистәсе р-ны). Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДАЙ́Р (ТАҺИ́Р) МУНЧАСЫ́**, урта гасырларда Казанда җәмәгать мунчасы. 1552 елда патша Иван IV гаскәрләренең шәһәрне алуын тасвирлаган рус чыганакларында искә алына. Казансу яры буенда, Болак елгасы тамагы б-н Нургали капкасы манарасы (соңрак Яшерен манара) янындагы шәһәр дивары астында урнашкан була. *Дженкинсон* рәсемнәренә караганда, Д.м. түбәсе күп гөмбәзле 1 катлы бина булган. 10–14 йөзләрдән башлап, Идел-Кама төбәге шәһәрләрендә киң таралган һәм Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң юкка чыккан борынгы көнчыгыш мунчалары төренә карый. Җимерелү вакыты билгесез.

**ДАЙ́ШЕВ** Мидхәт Исхак улы (1.5.1925, Бөгелмә ш. — 3.2.2001, Краснодар ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1976), проф. (1977), Кубань өлкәсенең атказ. фән эшлеклесе (1995). 1951 елда Урта Азия политехник ин-тын (Ташкент) тәмамлый, шунда ук эшли. 1957 дән Кыргызстан ФАнең Органик химия ин-тында, 1961–69 да азык-төлек сәнәгатенең Краснодар фәнни-тикшерену ин-тында (бүлек мөдире, 1964 тән лаб. мөдире). 1969 дан Кубань технол. ун-тында, шикәрле матдәләр технологиясе каф. мөдире (1993 кә кадәр). Хезмәтләре шикәр җитештерү технологиясенә карый. Сахарозаның сулы эремәләрдәге төзелеше теориясен, шикәр булмаганнарның кальций карбонатында йотылуын, шикәр җитештергәндә актив күмернең буяу матдәләрен йотуын өйрәнүгә яңача караш булдыра. Д. җитәкчелегендә илнең шикәр з-дларында шикәр калдыкларын комплекслы техник эшкәртү мәсьәләләре хәл ителә; аның хезмәтләре нигезендә шикәр чималын эшкәртүче барлык з-длар өчен шикәр сәнәгате хезмәткәрләренең Бөтенсоюз киңәшмәсендә кабул ителгән (Рига, 1972) шикәр чималын чистартуның үрнәк схемасы тәкъдим ителә; чөгендердән шикәр алу һәм сокны кальций карбонаты б-н чистарту схемасы камилләштерелә, һәм ул үтә тиз туендыру-куерту известь-углекислота б-н чистартуның классик схемасына альтернатива була. Шикәр калдыкларының исраф булуын киметүгә, шикәр чыгышын арттыруга һәм ягулык сарыф ителү күләмен азайтуга юнәлтелгән фәнни эшкәртмәләре шикәр сәнәгатенең 30 лап з-дында, ш.и. Буа, Ульянов шәһәрләрендә, БРда, Алтай краенда, Кубаньда гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: К вопросу о теории мелассообразования // Сахарная пром-сть. 1970. № 11; Адсорбционная очистка карбоната и кальция в сахарном производстве // Изв. вузов. Пищевая пром-сть. 1972. № 6; Теоретические основы технологии сахара. Краснодар, 1997. Ч. 1.

**«ДАЛА́»**, комплекслы табигать тыюлыгы. Лениногорск р-ны терр-ясендә урнашкан. 2000 елда оештырыла. Мәйданы 5830 *га*. Урман дала һәм дала формацияләре фрагментларыннан торган 31 участокны (Глазово урман даласы, Глазово урманы, Урдалы сөзәклекләре, Куак сөзәклеге, Шөгер сөзәклеге, Раечка сөзәклеге һ.б.) били. Урманнарның төп өлешен куаклыкта үсүче миләш, чикләвек агачы, кабар агачы, зелпе б-н имән, өрәңге, юкә һәм каен утыртмалары тәшкил итә. Глазово урманы — уникаль һәм матур табигатьле участокларның берсе, 2000 *га* га якын мәйданда борынгы нарат урманы, ул аерым агачлары 100 яшькә җиткән далаланган наратлыктан гыйбарәт. Нарат агачлары төбендә сирәк һәм сакланылучы төрләрдән кара җимешле кызылча, Гмелин тәңкәяфрагы, каурый һәм матур кылган, йөнтәс кырыкбуын һ.б. очрый. Сөбүләр платоларның текә көньяк сөзәклекләрендә ТРның Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләр (кыяклы суган, ачык сары камчау һ.б.) үсүче кылган һәм кылган-солыча болыннары сакланган. Яхшы җылына торган сөзәклекләрдә куак, болын һәм ташлы дала фрагментлары очрый, аларның үсемлекләр капламында исә 100 дән артык төр исәпләнә, шуларның 27 се саклаулы, ш.и. Геннинг мәче борчагы, сары мәтрүшкә яфраклы тубылгы, Ледебур муллабашы. Тыюлыкның хайваннар дөньясында ТРның Кызыл китабына кертелгән кошлар һәм имезүчеләрнең сирәк төрләре: үләт бөркете, кыр һәм болын карчыгасы, колаклы ябалак, йөнтәс аяклы ябалак, сары корташар, дала тычканчыгы, Эверсман әрләне, бөҗәкләрдән — төсен үзгәртүчән күбәләк, адмирал, бикә аю-күбәләк, Ионеллюс төклетурасы яши. Тыюлык составына ТРдагы иң зур Чыршылы сөркә (байбак) колониясе (1972 дә табигать истәлеге) кертелгән, анда 2 меңгә якын сөркә исәпләнә.

**ДАЛА́ ЗӘЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама арьягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 211,3 *км*, бассейнының мәйданы 5 мең *км*². Лениногорск, Бөгелмә, Әлмәт, Зәй һәм Түбән Кама р-ннары терр-ясеннән ага. Елга башы Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының көнчыгыш сөзәклекләрендә, Лениногорск р-ның Михайловка авылыннан көньяктарак, тамагы Түбән Кама р-ның Түбән Афанас авылыннан 4 *км* көнбатыштарак. Урман Зәе б-н кушылган урыннан *Зәй* исеме б-н йөртелә. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагынықы — 53 *м*.

Д.З.нең су җыелу мәйданы геоморфологик бәйләнештә катлаулы терр-яне чагылдыра; гомуми авышлык көньяктан төньякка Кама елгасы үзәненә таба. Су җыелу терр-ясенең югары өлеше Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы чикләрендә урнашкан. Су җыелу мәйданының өслеге, нигездә, татар ярусының түбәнге свитасындагы су эрозиясенә чыдам комлы-балчыклы-алевритлы калын катламнардан төзелгән. Шул сәбәпле, Д.З. бассейнында ерым-сыза челтәренең тыгызлыгы зур түгел. Югары агымында елга үзәне каньонсыман, тар (1,5 *км* га кадәр) һәм тирән; урта һәм түбәнге агымында — асимметрик, трапециясыман, киңлеге 2–3,5 *км* га кадәр. Югары һәм урта агымында (Зәй ш.нә кадәр) уңъяк ярлары текә, урыны б-н өзек-өзек террасалар хасил итеп, су өстеннән 100–200 *м* га калкып торалар. Д.З. елгасының уң яктагы сөзәк яры нарат һәм катнаш урманнар б-н капланган.



Дала Зәе.

Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Тугае ике яклы, аеруча сулъяк яр буенда көчле, киңлеге 3 *км* га кадәр, түбәнге агымында сазлыкланган.

Елга юлы тотрыклы, аз гына бормалы, комлы-ләмле, киңлеге түбәнге өлешендә җәйге саегуда 15–25 *м* дан язгы ташу чорында 40–80 *м* га кадәр җәелә. Елганың уртача тирәнлеге сайлыкларда 0,4–0,6 *м*, тирән урыннарда 1–1,5 *м*; язгы ташу чорында тирәнлекләр 2–3 *м* га арта. Агымның уртача тизлеге 0,25–0,3 *м/с*, елга юлының тарайган урыннарында 1,4–1,5 *м/с* ка җитә. Ярлары елга юлы эрозиясенә дучар булган. Д.З.нең 68 кушылдыгы бар; аеруча зурлары: Бөгелмә Зәе (52 *км*), Урсалы (26,6 *км*), Урман Зәе (60,8 *км*), Зичә (40,2 *км*) — уң; Зәй-Каратай (27,9 *км*), Шумыш (18,8 *км*), Сәрәпәле (18,9 *км*), Шепкә (15 *км*), Инеш (18 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*².

Елганың туенуы катнаш. Гидрологик режимы Зәй р-ны Иске Пәлчекәү авылы янындагы постта өйрәнелә (1958 дән). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 дән 130 *мм* га кадәр, ташу агымы катламы 63 тән 80 *мм* га кадәр. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана һәм 40 көнгә якын дәвам итә. Су биеклегенең уртача еллык тирбәнеше Әлмәт р-ны Рус Акташы посёлогы тирәсендә 3,3 *м* (иң зурысы 3,9 *м*), Иске Пәлчекәү авылы янында 3,4 *м* (иң зурысы 5,3 *м*). Суының иң зур чыгымы 456 *м*³*/с* (1979, Рус Акташы посёлогы), 610 *м*³*/с* (1963, Зәй ш.). Җәйге саегулар тотрыклы, гадәттә, август аенда күзәтелә. Елга тамагында суның иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 6,15 *м*³*/с*. Җир асты сулары б-н туену модуле югары агымында 5–10 *л/с·км*² дан түбәнге агымында 0,2–0,5 *л/с·км*² га кадәр. Кышкы саегу, гадәттә, ноябрьнең беренче, икенче ункөнлегендә башлана. Боз ка-

ту тотрыклы, уртача 110–130 көн дәвам итә. Елга тулысынча боз б-н ноябрь ахыры–декабрь башында ката. Кыш ахырына боз калынлыгы 50–72 *см* га җитә. 1969 елда бозның иң зур калынлыгы (115 *см)* Рус Акташы посёлогы янында билгеләнә.

Югары агымында суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, минеральләшүе 300–600 *мг/л* (нефть чыганакларын эшкәрткәнгә кадәр, су бөтен елга озынлыгында шундый типка кертелгән), агым буенча түбәнгә таба гидрокарбонат-хлорид-кальцийлыдан хлорид-гидрокарбонат-натрийлыга кадәр үзгәрә. Язгы ташу чорында Д.З. суының минеральләшүе 700–1800 *мг/л*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Йөзмә китерелмәләрнең уртача күпьеллык чыгымы Рус Акташы посёлогы янында 1,8 *кг/с*, Иске Пәлчекәү авылы тирәсендә 11 *кг/с*. Йөзмә китерелмәләр агымының уртача еллык модуле шәһәр тибындагы Рус Акташы посёлогы янында 24 *т/км*$^2$ һәм 77 *т/км*$^2$.

Д.З. — ТР урман-дала зонасының иң зур елгаларыннан берсе, су б-н тәэмин итүче мөһим чыганак. Елга бассейнында Зәй (күләме 63 млн. *м*$^3$) һәм Карабаш (52,4 млн. *м*$^3$) сусаклагычлары, 31 буа (гомуми күләме 23,2 млн. *м*$^3$) бар. Елга буенда Әлмәт, Зәй шәһәрләре, шәһәр тибындагы Карабаш, Түбән Мактама, Рус Акташы һ.б. посёлоклар урнашкан.

Д.З. — ТРның табигать истәлеге (1978). Елга бассейнында *Адонис урманы*, *Владимировка сөзәклеге* һәм *Казанка ботаника тыюлыгы* табигать истәлекләре, *Акташ упкыны*, *Яңа-Александровка сөзәклеге*, *Карабаш тавы* һәм *Бохарай наратлыгы* урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**ДАЛА́ КОШЫ́** (Tetrax tetrax), дүдәксыманнар семьялыгындагы кош. Евразия, Төньяк-көнбатыш Африкада таралган. 1920 елларга кадәр Татарстан терр-ясендә сирәк очрый торган, оя коручы төр, хәзер сирәк кенә көньяк-көнчыгыш р-ннарга очып керә. Гәүдә озынлыгы 50 *см* га, авырлыгы 1 *кг* га кадәр. Ата кош ана коштан зуррак. Сырты кара бизәкле соргылт-кызыл, корсагы ак, парлашу чорында ата кошларның муеннарында кара һәм ак сызыклар барлыкка килә. Аяклары өч бармаклы, бармаклары кыска. Бик тиз оча. Аерым парлар булып оялыйлар. Ояларын куе дала үсемлекләре арасында җирдә кора. Үрчү чорыннан башка вакытта төркем булып яши. Кара таплы зәйтүнсыман яшел төстә 2–5 йомырка сала. Орлыклар, бөҗәкләр, моллюсклар б-н туклана. Кышларга сентябрь-октябрьдә очып китә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ДАЛА́ ЛАЧЫНЫ́**, балобан (Falco cherrug), лачын кошлар семьялыгыннан ерткыч кош. Урман-дала һәм дала зонасында, Евразия тауларында яши. ТР терр-ясендә сирәк очрый торган төр. Көньяк-көнчыгыш р-ннарда күренә. Оялау ареалының төньяк чиге Кама елгасының түбәнге агымдагы үзәне буйлап үтә. 5 пардан артык оялый. Апрельдән сентябрьгә кадәр очрый. Озынлыгы 60 *см* га, канат җәеме 130 *см* га кадәр җитә. Каурый капламы сырт өлешендә соргылт көрән, корсагында көрән яки кара чуарлы җирән-ак. Оясын агачларда ясый, еш кына башка кошларның ояларын да файдалана. Кара нокталы 3–5 кызгылт-көрән йомырка сала. Ябылып яшәгәндә дә үрчи. Вак имезүчеләр, кошлар б-н туклана. Кырларда вак кимерүчеләрне юк итеп файда китерә. Күп кенә халыкларда, ш.и. татарларда да элек-электән ау кошы буларак файдаланылган. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ДАЛА́ РО́ЗАСЫ** (Lavatera), тырнакгөлчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләннәр, сирәк кенә куаклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, күбесенчә Урта диңгез буенда таралган. Татарстан терр-ясендә Тюрингия розасы (L. thuringiaca) сирәк кенә барлык р-ннарда да очрый. Далалы болыннарда, сөзәклекләрдә, урман буйларында, куаклыкларда үсә. 60–150 *см* биеклектәге, төкчәле, соргылт яшел күпьеллык үләнчел үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, эре, өчәрле яки бишәрле калаксыман, сабакчыл. Чәчәкләре зур, алсу, уентылы таҗ яфракчыклы, берәрләп яфрак куентыгына урнашкан. Җимеше 20–25 орлыктан тора. Июнь–августта чәчәк ата. Июльдән җимеш бирә башлый. Тамырларында — лайла, яфракларында алкалоидлар, С витамины бар. Д.р. тамырларыннан ясалган төнәтмә йомшарткыч һәм какырык куптару чарасы буларак кулланыла. Яңа җыелып вакланган яфракларын сызлавыкларга, җәрәхәтләргә ябалар. Декоратив, баллы үсемлек. Йорт яны һ.б. бакчаларда өч айлык Д.р. (L. trimestris) декоратив үсемлек буларак үстерелә.

**ДАН О́РДЕНЫНЫҢ ТУЛЫ́ КАВАЛЕРЛАРЫ́**, к. Кушымта, 648 б.


**ДАНАУ́РОВКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 7 *км* көнбатыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 569 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 45%, татарлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, яшелчәчелек, бакчачылык. Урта мәктәп, мәдәният сарае, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да земство мәктәбе була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 356 дис. тәшкил итә. 1931 дә Д.да «Аврора» к-зы оештырыла. 1950 дә «Плодопитомник» (1967 дән — «Смена») с-зына кертелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 186, 1897 дә — 300, 1908 дә — 344, 1926 да — 416, 1938 дә — 342, 1958 дә — 257, 1970 тә — 358, 1979 да — 488, 1989 да — 660, 2002 дә — 532 кеше.

**ДАНИИ́Л** (чын фамилиясе һәм исеме Сивиллов Дмитрий) (1798, Пенза губ. Всесвятское а. — 1871), архимандрит, Кытайны өйрәнүче белгеч. Пенза руханилар семинариясен тәмамлаганнан соң, Петербург мед.-хирургия академиясенә укырга керә, аннан 1819 елда Александр Невский лаврасы семинариясенә күчерелә. 1819–31 дә Пекин руханилар миссиясендә эшли, кытай телен өйрәнә. 1831 дә Россиягә кайта. 1832 дән Мәскәүнең Златоуст монастыре архимандриты. 1837–44 тә Казан ун-тында: Көнчыгыш разрядының кытай-маньчжур әдәбияты каф. ординар профессоры, бер үк вакытта 1837 дән Беренче ир балалар гимназиясендә кытай теле укыта. Төрле елларда төрле дини вазифалар башкара, ш.и. илчелек монастыренең башлыгы һәм Иркутск шәһәрендә әҗнәбиләр арасында вәгазь укучы миссионер була. Хезмәтләре кытай теле белеменә, Кытай тарихы һәм диненә, борынгы кытай язма истәлекләренә, буддизмга карый. Кытай фәлсәфәчеләре әсәрләрен тәрҗемә итә (тәрҗемәләре басылмый).

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Русский биографический словарь. СПб., 1905.

**ДАНИЛА́ЕВ** Пётр Григорьевич (13.12.1945, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (2000), проф. (2001). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1971 дән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. 1977 дән Казан техник ун-тының махсус матем. кафедрасында. Хезмәтләре җир асты гидромеханикасына һәм парабола тибындагы тигезләмәләр һәм аларның кушымталары өчен коэффициентлы кире мәсьәләләрне тикшерүгә карый. Бериш булмаган нефть катламнарында сызыкча һәм нәсызыкча нәстационар сарку вакытында алардагы кысылучан сыеклыкның сарку параметрларын билгеләүнең санча алгоритмын эшли.

Х е з м.: О решении коэффициентных обратных задач методом квазиобращения // Докл. АН СССР. 1990. Т. 310, № 3; Численное решение внутренней обратной задачи для уравнения параболического типа и ее приложения // Моделирование в механике. Новосиб., 1993. Т. 7., № 3; Коэффициентные обратные задачи для уравнений параболического типа и их приложения. К., 1998.



А.Я. Данилевский.

**ДАНИЛЕ́ВСКИЙ** Александр Яковлевич (10.12.1838, Харьков ш. — 18.7.1923, Петроград ш.), биохимик, Россия биохимия фәнни мәктәбенә нигез салучы, мед. д-ры (1863), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1898). 1860 елда Харьков ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. 1863 тә Казан ун-тында дөньяда беренче физиологик химия кафедрасын оештыра һәм җитәкли. 1871 дә галим-анатом П.Ф.Лесгафтны эзәрлекләүгә каршы чыга, профессорлар төркеменә теләктәшлек белдереп, протест игълан итә һәм чит илгә китә, 1872–75 тә Европа илләренең биохимия лаб-яләрендә эшли. 1875 тән Халык мәгарифе министрлыгында. 1886–92 дә Харьков



С.С.Данилов.



С.Н.Данилов.

ун-ты профессоры. 1892–1921 дә Петроград хәрби мед. академиясендә, 1906–10 да җитәкчесе. Хезмәтләре аксымнар табигатен, ферментларның кайтма тәэсирен һәм туклану биохимиясе мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. Д. тәҗрибә юлы б-н аксымга ашказаны асты бизенең үтә тәэсире — гидролиз реакциясе булуын исбатлый; ашказаны асты бизе ферментларын таркатуның адсорбция ысулын эшли; аксым молекуласы төзелеше теориясен эшли, аксым фракцияләренең глобулин, строминһәм нуклеинга бүленешен тәкъдим итә. Д. тарафыннан ашказаны һәм эчәклек юллары тышчасының ашказаны-эчәк юлы ферментларына карата тотрыклылыгы өйрәнелә, үзлегеннән үзләштерелүгә каршы торучы «антипепсин» һәм «антитрипсин» матдәләре тасвирлана. 1888–91 елларда бертуганы В.Я.Данилевский б-н «Физиологический сборник» ж-лын нәшер итүне оештыра.

Х е з м.: О специфически действующих телах натурального и искусственного соков поджелудочной железы: Дис. ... Хар., 1863.

*Әд.:* Б у л а н к и н М.Н. А.Я.Данилевский — основоположник отечественной биохимии. Хар., 1950; В л а д и м и р о в Г.Е. Основоположники отечественной биохимии. Л., 1950.

**ДАНИ́ЛОВ** Александр Иванович (8.3.1916, Тамбов губ., Лебедянск өязе Добрый а. — 27.11.1980, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, тарихчы, тарих фән. д-ры (1958), СССР ПФАнең хакыйкый әгъзасы (1969), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1966). Тамбов читтән торып уку пед. ин-тын тәмамлый (1936). 1934–40 елларда Уварово урта мәктәбендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–58, 1961–67 дә — Томск ун-тында, 1961 дән — ректор. 1958–61 дә Казан ун-тында: проф. (1959), гомуми тарих каф. мөдире (1960 тан). 1967–80 дә РСФСР мәгариф министры, бер үк вакытта Мәскәү ун-тының урта гасырлар тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Көнбатыш Европаның урта гасырлар аграр тарихына, тарих методологиясенә карый. СССР (1966–70), РСФСР (1971–80) ЮСлары депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы аграрной истории раннего средневековья в немецкой историографии конца XIX — начала XX вв. М., 1958; Аграрная история западноевропейского средневековья в трудах советских медиевистов // Средние века. 1960. Вып. 17; О некоторых вопросах дальнейшего изучения теоретико-методологических проблем исторической науки // Вопр. истории. 1961. № 3.

*Әд.:* Ш а р и ф ж а н о в И.И. А.И.Данилов в Казанском университете // Историческая наука в Татарстане: исследовательские и педагогические традиции. К., 1996; Александр Иванович Данилов. 1916–1980. К., 2002; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1990): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ДАНИ́ЛОВ** Валерий Иванович (19.5.1948, Мари АССР, Мари-Турек р-ны Мариец пос.), нейрохирург, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996). ТРның атказ. табибе (1999). 1972 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 2000 нән дипломнан соң уку ф-тының неврология һәм нейрохирургия каф. мөдире. Хезмәтләре кешенең умыртка баганасы элементлары ныклыгы мәсьәләсенә, умырткалыкның этиологиясе, патогенезы һәм дегенератив зарарлануын дәвалауга, цереброваскуляр реактивлыкны дарулар б-н көйләүгә карый. Д. операцияләр һәм баш сөяге-ми травмалары вакытында димефосфон кулланунын клиник-тәҗрибә нигезләмәсен эшли, нерв системасы функцияләрен көйләү өчен димефосфонны вазоактив чара буларак гамәлгә кертүдә катнаша. ТРның Дәүләт бүләге «Димефосфон — нерв системасы функцияләрен көйләүдә оригиналь дару препараты» хезмәте өчен бирелә (1994). Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Некоторые вопросы прочности конструкций позвоночного столба человека // Механика композитных материалов. 1979. № 3; Влияние димефосфона, сермиона и пирацетама на реактивность мозговых сосудов. К., 1994.

**ДАНИ́ЛОВ** Владимир Григорьевич (7.11.1936, Яңа Чишмә р-ны Яңа Чишмә а.), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1960 елда Казан авиация ин-тының радиотехника ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1962 дән Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге: сектор (1963–79), бүлек (1979–83) башлыгы, баш конструктор (1983–2000), баш белгеч (2001 дән). Дәүләт бүләге махсус радиотехник аппаратлар эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ДАНИ́ЛОВ** Иван Васильевич (1.11.1898, Казан губ. Чабаксар өязе, хәзерге Чуаш Респ-касының Козловка р-ны Аттик а. — 2.2.1972, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1952), проф. (1953), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1958). 1924 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Чабаксар өлкә хастаханәсендә, 1930 дан Казан мед. ин-тының акушерлык-гинекология клиникасында эшли. 1952–71 дә Казан ГИДУВында, 1962 гә кадәр ректор, 1956 дан 2 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. Хезмәтләре хатын-кызның җенес органнарында шеш, гормональ тайпылышлар, дистрофик процессларга карый. Д. күкәйлектә яман шеш булган авыруларны дәвалау өчен химик препаратлар куллануны өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об аллергической реактивности матки при её гипертрофии или атрофии. К., 1952; Опухоли наружных половых органов женщины. К., 1968.

*Әд.:* Данилов Иван Васильевич // Казан. мед. журн. 1968. № 6.

**ДАНИ́ЛОВ** Семён Степанович (1910, Казан губ., Зөя өязе Кири а. — 29.10.1971, Казан), Дан орденының тулы кавалеры (9.7.1944, 14.10.1944, 29.6.1945), старшина (1945). Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның июленнән Кызыл Армиядә. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 180 нче аерым сапёрлар батальоны отделениесе сапёры (1 нче гв. армиянең 167 нче укчылар дивизиясе). Көньяк-Көнчыгыш, Сталинград, Дон, Воронеж, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Украина һәм Польшаны азат итүдә, Прага һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 2–10 апрелендә Бугач торак пункты (Тернополь өлкәсе Бугач р-ны) янындагы сугышларда (сугышчылар төркемен җитәкләп, кичү урыннарын ачыклый, дошман оборонасының алгы сызыгында разведка үткәрә, чәнечкеле тимерчыбык һәм миналар аша 7 чыгу юлы ясый); 1944 нең 6 сентябрендә Санок шәһәре (Польша) янындагы сугышта (разведка взводы составында хәрәкәт итеп, дошманның 3 пулемёт ноктасын юк итә); 1945 нең 5–8 мартында Бельско-Бяла шәһәреннән (Польша) 18–20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Струмень, Драгомысль торак пунктлары тирәсендәге сугышларда батырлык күрсәтә: миналы 5 кырны ачыклый, 50 минаны зарарсызландыра. Сугыштан соң Казанда җитен комб-тында эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды Славы. К., 1969; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ДАНИ́ЛОВ** Степан Николаевич (26.12.1888, Витебск ш. — 4.2.1978, Ленинград), химик-органик, химия фән. д-ры (1935), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1943), Артиллерия фәннәре академиясе академигы (1947), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1944, 1960). 1914 елда Ленинград ун-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли. 1930–49 елларда Ленинград технол. ин-тында целлюлозаны химик эшкәртү каф. мөдире. 1949 дан СССР ФА Югары молекуляр кушылмалар ин-тының (Ленинград) целлюлозаны химик әверелдерү лаб-ясе мөдире, 1953–60 та ин-т директоры. Бер үк вакытта П.Ф.Лесгафт исем. Физик белем бирү ин-ты укытучысы (1923–29), Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия академиясе профессоры (1934–37), Пластик массалар ин-тының целлюлоза лаб-ясе фәнни җитәкчесе (1931–38), Ленинград ун-тының Химия фәнни-тикшеренү ин-тында, органик кушылмалар һәм югары молекуляр кушылмалар төзелеше кафедралары мөдире (1945–49), ин-т директоры (1947–49). Бөек Ватан сугышы елларында Казанга эвакуацияләнә, Казан химия-технол. ин-тында (1941–44) целлюлозаны химик эшкәртү каф. мөдире, илнең оборонасына кагылышлы

мәсьәләләрне хәл итү б-н шөгыльләнә. Хезмәтләре табигый һәм ясалма полимерлар химиясенә һәм химик технологиясенә карый. Гидробензоин кушылмаларының, ягъни икенчел-өченчел *a*-гликольләрнең дегидратлашу реакциясе вакытында икенчел һәм өченчел *a*-углерод атомлы альдегидларның кетоннарга әверелеп изомерлашуын ача (Д.И.Менделеев исем. Рус физ.-химия җәмгыяте бүләге бирелә, проф. 1919). Ди-п-толилуксус альдегидының п-дезокситолуоинга, дифенилуксус альдегидының дезоксибензоинга, ди-алмаштырылган ацетальдегидларның кетоннарга изомерлашу механизмын тикшерә. Оксиальдегидларның оксикетоннарга һәм бер нигезле карбон кислоталарына изомерлашуларын тикшеренүләре өчен Рус физ.-хим. җәмгыятенең Н.Н.Зинин һәм А.А.Воскресенский исем. бүләгенә лаек була (1930). Хитинның активлыгын көчәйтү шартларын билгели һәм шуның күп кенә кушылмаларын бүлеп чыгара. Целлюлоза эфирларын синтезлауның яңа ысулларын эшли. Д.ның ксантогенатлар һәм вискоза химиясе өлкәсендәге хезмәтләре вискоза җитештерү технологиясен һәм СССРда ясалма сүс сәнәгатен үстерү өчен мөһим нәтиҗәләр бирә. Шикәрләр химиясе һәм илебезнең күренекле галимнәре турында мәкаләләр авторы. СССР ФА басмасы «Журнал общей химии»нең баш мөхәррире (1946 дан). Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изомеризация оксиальдегидов. 1. Превращение дефенилгликолевого альдегида в бензоин // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Ч. хим. 1927. Т. 59, вып. 9; Академик А.Е.Арбузов — глава казанской школы химиков-органиков // Журн. орган. химии. 1947. Т. 17, вып. 12; Молекулярные перегруппировки и внутримолекулярное окисление-восстановление // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1956. Кн. 4; Химия ксантогенатов и вискозы. 6. Взаимоотношения компонентов вискозы // Журн. органической химии. 1957. Т. 27, вып. 12 (автордаш).

*Әд.:* Степан Николаевич Данилов // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1971. Вып. 46; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДАНИ́ЛОВ** Юрий Михайлович (5.6.1933, Новосибирск ш.), гидромеханика һәм гамәли матем. гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), проф. (1985), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). РФнең мактаулы югары белем мәктәбе хезмәткәре (1999). Казан авиация ин-тын (1957) һәм Казан ун-тын (1986) тәмамлый. «Новатор» тәҗрибә КБнда (Свердловск ш., 1957–63), Казан авиация ин-тында эшли. 1982–99 елларда Казан технол. ин-тында югары матем. каф. мөдире, проф. (1999 дан). Хезмәтләре гидромеханикада хисаплау ысулларына карый. Аерым чыгарылмалы нәсызыкча тигезләмәләр өчен кырый мәсьәләләр чишүнең санча ысулын, «Союз» фәнни-җитештерү берләшмәсендә (Мәскәү өлкәсенең Люберцы ш.) гамәлгә кертелгән «Розан» программасы пакетларын эшли.

Х е з м.: Высшая математика. К., 1999; Инвариантные операторы для численного решения краевых задач. К., 1999.

**ДАНИ́ЛОВА** Ольга Валерьевна (10.6.1970, Бөгелмә), спортчы (чаңгыда узышу), Россиянең атказ. спорт остасы (1995). «Динамо» физкультура спорт җәмгыяте шәкерте (Әлмәт ш., тренеры Р.С.Сафин). Смоленск физкультура ин-тын тәмамлый (1998). СССР беренчелегендә (1986, эстафета 4×5 *км*), яшүсмерләрнең Бөтенсоюз кышкы уеннарында (1988, ярыш 10 *км*, эстафета 4×5 *км*) җиңүче. Дөнья беренчелегендә (1990, яшьләр арасында, ярыш 5 *км*, эстафета 4×5 *км*); һәм дөнья чемпионатында (1995, 1997, эстафета 4×5 *км*), Олимпия уеннарында (1998, ярыш 15 *км*, эстафета 4×5 *км*; 2002, куышып ярышу 5+5 *км*) чемпион. СССР чемпионатында (1989, 20 *км*), «Төньяк бәйрәме» («Праздник Севера») (1989), Олимпия уеннарында (1998, 15 *км*; 2002, ярыш 10 *км*) көмеш медаль ала. Яшүсмерләрнең Бөтенсоюз кышкы уеннарында (1988, 5 *км*), дөнья чемпионатында (1990, яшьләр арасында, 15 *км*; 1995, Гундерсон системасы буенча 10 *км* га), Дөнья кубогы өчен ярышта (1995) бронза медаль ала. 1994 елдан Владимир өлкәсенең Александровск шәһәрендә яши, «Динамо» физкультура спорт җәмгыятендә спортчы-инструктор.

**ДАНИЯ́Р ХАН** (Даниял) (? — 1486), Касыйм ханы (1469 елдан). Касыйм ханның улы, Олуг Мөхәммәд ханның оныгы. Тәхеткә атасы үлгәннән соң утыра. Мәскәү гаскәрләренең Новгородка каршы яуларында (1471, 1477) Касыйм ханлыгының атлы полклары б-н җитәкчелек итә. Килешү грамоталарында бернича тапкыр искә алына, аның казнасына рус кенәзләреннән, ш.и. бөек Мәскәү кенәзеннән ясак килә. Балалары булмый.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Т. 1.

**ДАНЫ́Ш** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 20 *км* көнбатыштарак, Алгама елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. Халкы 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, агачтан әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.та мәчет, мәктәп, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1083,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостенда. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 562, 1897 дә — 888, 1926 да — 516, 1938 дә — 483, 1949 да — 447, 1958 дә — 371, 1970 тә — 285, 1979 да — 214, 1989 да — 153, 2002 дә — 123 кеше.


**ДАРКШЕ́ВИЧ** Ливерий Осипович (17.7.1858, Ярославль ш. — 28.3.1925, Мәскәү), невропатолог, мед. д-ры (1888). 1882 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый һәм Европа (Вена, Лейпциг, Страсбург, Париж) лаб-яләре һәм клиникаларында эшли. 1888–92 дә Мәскәү ун-тында. 1892–1916 да Казан ун-ты мед. ф-тының нерв авырулары каф. мөдире; Казан неврология мәктәбенә нигез салучыларның берсе. 1917–25 тә Мәскәү ун-ты нерв авырулары клиникасы директоры. Бер үк вакытта 3 нче Мәскәү мед. ин-тын (1919–25 тә директоры) һәм Мәскәү өлкә клиник ин-тын (1920–25 тә директоры) оештыра. Д. баш миенең ике түбәле калкулыгы, эпифиз, баш мие кәүсәсе үзәге төзелешен һәм функцияләрен, күрү нервлары йөрешен һәм башка өлкәләрен (Даркшевич үзәге) тикшерә, күрү нервының бәбәктәге җепселләре схемасын төзи. Арка тартышы (нерв системасы зарарлану) авыруының сифилитик табигатьле булуын беренче булып ачыклап күрсәтә. Невроз сәбәпләрен ачыклый (баш мие кабыгы күзәнәкләрендәге элементларның бик нык ару-талуы, кызуы). Россиядә невропатология буенча беренче кулланма — «Нерв авырулары курсы» («Курс нервных заболеваний», 1–3 т., 1904–17) авторы. «*Казанский медицинский журнал*»га нигез салучы һәм беренче мөхәррире.

Х е з м.: О проведении светового раздражения сетчаткой оболочки глаза на двигательный нерв. М., 1888; Важность обучения в школе письму левой рукой с медицинской точки зрения. К., 1912.

**ДА́РСКИЙ** Юрий Александрович (19.2.1916, Пермь ш. — 10.4.1999, Казан), генерал-майор (1968). Чиләбе хәрби уч-щесен (1937), И.В.Сталин исем. Эшче-крәстиян Кызыл Армиясе бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1951, Мәскәү) тәмамлый. 1938–41 елларда Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында танк дивизиясе, бригадасы штабында, 1942 дән Көнбатыш фронтының бронетанк гаскәрләре командалык идарәсендә, 1943 тән СССР Оборона халык комис-тында эшли. 1951 дән Карпат буе хәрби округында механикалаштырылган дивизия командиры урынбасары. 1953–58 дә Германиядәге совет гаскәрләре төркеме составында. 1961–66 да Идел буе хәрби округы идарәсендә. 1966–69 да Себер хәрби округында бронетанк гаскәрләре командующие ярдәмчесе. 1969–71 дә Мисырда хезмәт итә. 1972–74 тә Балтыйк буе хәрби округында бронетанк гаскәрләре хезмәте башлыгы. 1974 елдан Казанда яши. Кызыл Байрак, «Почёт билгесе», «Хәрби хезмәтләр өчен», 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ДАРУГА́** (монгол. «дару» сүзеннән — кемнән яисә нәрсәдәндер өстен, югары тору; татарча синонимы — басу), 1) 13–16 йөзләрдә Җүчи Олысында, Казан ханлыгында, 16–18 йөзләрдә Казан һәм Уфа өязләрендә адм.-терр. бүленеш; 2) Монгол империясендә һәм Җүчи Олысында халыктан алына торган ясаклар җыелмасы; 3) адм. вазифалы зат. Бу термин баштарак теге яки бу терр-ия (өлкә) б-н идарә итү буенча төрле вазифалар башкаручы һәм ясаклар җыю өчен җаваплы югары дәрәҗәле затка карата кулланылган. Тора-бара (фаразлар буенча, 14 йөздә) ясаклар җыела торган терр-ияне белдерүче, ш.у. халыктан



КАЗАН ТӨБӘГЕ ДАРУГАЛАРЫ (16-17 йөзләр)

*Картаны төзегәндә Г.И.Әминова материаллары файдаланылды*

җыела торган ясак төрләре исемнәрен гомумиләштерүче төшенчә булып әверелгән. Казан ханлыгында 5 Д. булуы мәгълүм: *Алат, Арча, Гәреч (Галич), Җөри, Нугай* Д.лары. Ханлык басып алынганнан соң (1552), яшәп килгән адм.-терр. бүленеш патша хакимияте тарафыннан Казан (Алат, Арча, Гәреч (Галич), Җөри, Нугай Д.лары буларак) һәм Уфа (Казан, Нугай, Усы, Себер Д.лары рәвешендә) өязләрендә сакланып кала. Д.ларның терр-яләре төгәл билгеле булмый, аларның чикләре җирләрне тасвирлаган вакытта кабат карала. 16 йөзнең икенче яртысыннан тарихи Д.лар бүленешенә өяз-волость системасы һәм Идел буе Казан төбәгенең башка өязләрендә кертелгән станнарга бүленеш өстәлә. 1708 елда губерналар оештырылганда традицион Д.ларга бүленеш үзгәрешсез кала, ул эш кәгазьләрендә 19 йөз башына кадәр кулланыла. Ш.у. к. *Баскак.*

*Әд.:* Березин И.Н. Ханские ярлыки Тохтамыша, Тимур-Кутлуга и Саадат-Гирея. К., 1851; Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда. Очерк истории Улуса Джучи в период сложения и расцвета в XIII–XIV вв. Л., 1937; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Ермолаев И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. Управление Казанским краем. К., 1982; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2003; Золотая Орда в источниках. Т. 1. Арабские и персидские сочинения. М., 2003.

*Д.Г.Мостафина.*

**ДАРУХАНӘЛӘ́Р**, халыкны һәм дәвалау-профилактика учреждениеләрен дару б-н тәэмин итүче оешмалар. Дөньяда беренче даруханә 8 йөздә Багдадта ачыла. Россиядә беренче даруханәне 1581 елда инглиз Дж. Френч нигезли (Иван IV нең кремль даруханәсе). Фармация өлкәсендә дәүләт идарәсе тарихы 1581 дә Даруханәләр палатасын оештырудан башлана, 1620 дә ул Даруханәләр приказы, 1714 тә Медицина канцеляриясе, 1802 дә Эчке эшләр министрлыгы мед. идарәсенең мед. советы һәм экспедициясе, 1811 дә Медицина советы һәм Медицина департаменты дип үзгәртелә. Россия башкаласында хосусый даруханәләр челтәре Пётр I чорында оеша башлый. Беренче иректе даруханәләр Мәскәүдә (1701) һәм С.-Петербургта (1712) ачыла. 1827 дә Россиядә 400 даруханә исәпләнә. 1860 еллар башындагы реформалардан соң даруханәләр эше Россиядә дәүләт системасы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Татарстан җирлегендә борынгыдан дарулар җитештерү һәм таралуы мәгълүм. Дәвалау чарасы буларак болан мөгезләре, таш тозлар, мускус, белимнитлар, хайван тиресе көленнән майда изеп ясалган мазь, үсемлек яфраклары һәм чәчәкләре төнәтмәләре, бал һ.б. кулланылган. Сөлек ярдәмендә кан суырту гамәлдә булган. Табиб һәм фармаколог Тажетдин бине Юныс әл-Болгари үзенең фармакология буенча «әт-Тиръякъ әл-Кәбир» («Агулануlардан көчле дәва») трактатында (1220) Идел Болгарында киң кулланылган үләннәрдән ясалган популяр дарулар рецептларын искә ала. Әбүгалисинаның «Тыйб гыйльме кануннары» китабы да мәгълүм була.

Казан губернасында беренче даруханәләр 19 йөз башында ачыла. Казанда провизорлар К.К.*Клаус*, Ф.Х.Грахе, И.И.Бренинг, А.Ф.Кешнер, Ю.Ш.Шварц зур даруханәләргә нигез салалар. Ф.Х.Грахе фирмасы даруханәсенең (1855 дә нигез салына) дару складлары, фармакология матдәләре җитештерү лаб-ясе була, анда җимеш сулары һәм минераль сулар, капсулаларда желатин әзерләнә, медик һәм бактериологик анализлар үткәрүгә заказлар алына (1905 тән фирма хуҗасы мед. докторы Э.Ф.Грахе). Беренче земство даруханәләре губернаның Чистай (1869), Тәтеш (1885) шәһәрләрендә ачыла. 1915 тә Казан губернасында 45 хосусый һәм земство даруханәсе санала, аларда 10 провизор һәм 187 фармацевт эшли. 1916 да А.Е.Арбузов Стеарин-сабын кайнату, глицерин һәм химия заводында салицил препаратлар (салицил кислотасы, салициллы әче натрий, аспирин, салол һ.б.) җитештерүне оештыра. 1918 дә РСФСР ХКС даруханәләрне дәүләтнеке итү турында декрет чыгара, соңрак алар ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссариатына тапшырыла. Совет хакимияте елларында Э.Ф.Грахе һәм А.Ф.Кешнер даруханәләре Казанда дәүләт даруханә склады һәм даруханә кибетләре оештыру өчен нигез була. 1931 дә Э.Ф.Грахе фирмасы фармакология фабрикасы итеп үзгәртелә (к. *Татхимфармпрепаратлар*). 1922 дә даруханәләр челтәре б-н җитәкчелек итү өчен Татмедторг оештырыла (җитәкчесе М.Я.Лондон), соңрак — ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссариатының Татарстан даруханәләр идарәсе (директор-идарәче И.И.Беганский, аннары А.И.Сорокин). 1936 да ул РСФСР Сәламәтлек саклау халык комиссариатының Татарстан бүлеге итеп үзгәртелә (Даруханәләр идарәсе башлыклары З.С.Акчурин, Д.А.Аксёнов һ.б.). Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан даруханәләре складлары илнең тыл җирлеген даруханәләр продукциясе б-н тәэмин итәләр. Казан провизорлары Г.Е.Вайнер, М.Н.Хируг, Г.Е.Азарх, Н.И.Шувагин, Н.Ф.Кирьянов, профессорлар Х.Х.Планельес һәм И.Покровский тырышлыгы б-н ит комбинаты лаб-яләрендә сыек гематоген, адонилен, сахарин, спермин, ампулаларда сульфацил эретмәсе, ампулаларда камфара мае, Доверов опийлы порошогы ясала. 1946 дан Татарстан даруханәләр идарәсе РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгы Баш даруханәләр идарәсенең Татарстан бүлегенә әверелә, 1968 дән республикада ТАССР МСның Даруханәләр идарәсе эшли. 1970–80 дә Татарстанда даруханә учреждениеләре челтәре үсеше алга китә, квалификацияле белгечләр әзерләү камилләшә (Казан фармация училищесе, 1921 дән; 1975 тән Казан мед. ин-тының фарм. ф-ты), халыкны дару препаратлары б-н тәэмин итү яхшыра (ТАССР МСның Даруханәләр идарәсе башлыклары М.Г.Байгильдина, Ф.Ю.Ярмөхәммәтова, М.Д.Анисимова һ.б.). 1986 да Казанда товарларны автоматлаштырылган исәпкә алу мөмкинлеге булган механикалаштырылган эре даруханә склады гамәлгә керә. 1993 тә республикадагы даруханәләр саны норматив таләпләргә туры килә, матди базалары, башкарылган эш күләме санитария нормаларына һәм кагыйдәләренә җавап бирә. 1980 еллар башында Даруха-


нәләр идарәсе «Фармация» җитештерү берләшмәсе итеп үзгәртелә. 1990 еллар башында берләшмә «Татарстанфармация» дәүләт пр-тиесенә әверелә. Бер үк вакытта дәүләти булмаган фармация берәмлекләре төзелә. ТРда Дәүләт даруханәләре системасы оешу 1997 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының фармация департаменты төзелүе, «Татарстанфармация» унитар пр-тиесе һәм мөстәкыйль даруханәләр булдыру б-н тәмамлана. Даруханәләр өлкәсендә дәүләтнең роле яңадан үсә башлый. Дарулар турында федераль закон (1998) кабул ителә. 2000 нең гыйнварыннан республикада медикаментоз тәэминатның дәүләт системасын үзгәртеп коруда яңа этап башлана. ТР МК каршында дәүләт һәм муниципаль даруханәләр нигезендә «Татарстан медицина техникасы һәм фармациясе» дәүләт унитар пр-тиесе оештырыла. Дәүләти булмаган даруханәләрнең дә активлыгы нәтиҗәсендә базарның даруларга ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндерелә. «Сәламәтлек» федераль программасын (2006) тормышка ашыру барышында шикәр диабеты, озакка сузылган склероз, онкологик һәм онкогематологик авыруларны дәвалау өчен дарулар б-н тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителә, әгъзалары күчереп утыртылган авыруларны тернәкләндерү-реабилитацияләү чаралары күрелә. 2009 ел башына ТРда 1255 учреждение: 661 даруханә (471е хосусый), 43 хастаханә даруханәсе, 590 даруханә пункты, 2 киоск, 2 дару кибете эшли. Респ-када дарулар б-н тәэмин итү эшендә 4250 белгеч шөгыльләнә; бер кеше елга 3135 сумлык дару куллана.

*Әд.:* В а р а д и н о в Н. Аптекарский устав. СПб., 1880; Адрес-календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1915 г. К., 1914; З и л ь б е р г И. На заре профессионального движения аптечных работников. М., 1926; Фармарынок РТ: грядут перемены // Аптека. 1999. № 19–25.

*М.Д.Анисимова, М.Г.Елисеева.*

**ДАРЫ́**, кислородсыз тирәлектә, җылылык һәм газсыман продуктлар бүлеп чыгарып, тотрыклы януга сәләтле, энергияле каты системалар. Д.ның тышкы оксидлаштыргычлардан башка гына яну сәләте алар составында берьюлы ягулык һәм оксидлаштыргыч (мәс. нитроэфирлар, кислородтан тыш, галоген атомнары да кергән кушылмалар) булу б-н бәйләнгән. Табигате буенча Д.лар *шартлаткыч матдәләргә* (ШМ), төгәлрәге, шартламыйча яки детонацияләнмичә тотрыклы януга сәләтле булган аткыч ШМ классына керә. Д. түбәндәге төрләргә бүленә: ракета, баллистика, артиллерия, миномёт өчен; ату коралы, торпеда миналары, идарә ителүле бомбалар өчен; магнитогидродинамик генераторлар, оборона техникасы үрнәкләре өчен плазмалылар; халык хуҗалыгының нефть чыгаруны интенсивлаштыру, аучылык, башка өлкәләре өчен һ.б. Д. үлчәмнәре һәм геометрик формалары төрле (пластиналар, бөртек һәм бер яки берничә каналлы көпшә, бер яки күп каналлы шашка һ.б.) булган элементлардан торучы корылмалар (зарядлар) рәвешендә кулланыла.

Д. корылмасының массасы берничә граммнан (ату коралында) килограммнарга (артиллерия тубында) һәм уннарча тоннага (кон-




Дары корылмалары (зарядлары) элементлары: а) пластина, б–е) бөртек һәм бер яки берничә каналлы көпшә.

тинентара ракета двигательләрендә) җитәргә мөмкин. Д. корылмасы янганда газ ясалу тизлеге яну тизлегенә һәм дары элементларының формасы б-н билгеләнә торган янучы өслек зурлыгына пропорциональ була. Янучы өслекне кечерәйткәндә газ ясалу тизлеге кими (дегрессив яну), зурайтканда — арта (прогрессив яну). Д.ның яну тизлеге корылманың составына, басымга һәм башлангыч темп-расына бәйле; корылманың яну вакыты бөртек яки шашканың иң кечкенә үлчәме (янучы гөмбәзнең калынлыгы) һәм яну вакыты б-н билгеләнә. Д.ның төп энергетик сыйфатламалары — чагыштырма яну җылылыгы (Q) һәм газсыман яну продуктларының нормаль шартларга китерелгән чагыштырма микъдары ($V_o$). Артиллериядә һәм ату коралларында кулланыла торган Д.ның мөмкинлеге аның көче (f) һәм потенциалы (р) б-н бәяләнә. Ракета дарысының энергиясен импульс берәмлеге зурлыгы ($J_{бер.}$ — двигательнең анда 1 секундта 1 *кг* Д. янгандагы тартуы) б-н билгелиләр. Q б-н $V_o$ никадәр зуррак булса, f, р, J ның кыйммәтләре шулкадәр зуррак була. Составына һәм әзерләү ысулына карап, Д. 3 типка бүленә: целлюлоза нитратлары нигезендә — төтенсез Д. (пироксилинлы, баллистит, кордит, сферик һәм пластификаторсыз); синтетик полимерлар һәм оксидлаштыргычлар нигезендә — катнашмалы Д. яки катнашмалы каты ракета ягулыклары; механик катнашмалар — төтенле Д. ясала.

Утлы ату коралында беренче тапкыр төтенле Д. кулланыла, ул 2 йөздә Кытайда уйлап табылган дип фаразлана. Европада, ш.и. Россиядә, Д.ны 14 йөздә куллана башлыйлар һәм ул 500 ел дәвамында хәрби өлкәдә һәм халык хуҗалыгында файдаланыла торган бердәнбер ШМ була. Пироксилинлы Д.ны беренче тапкыр Франциядә 1884 елда П.Вьель уйлап таба, баллистит Д.ны 1888 дә Швециядә А.Нобель тәкъдим итә, төтенсез Д. 1889 да Россиядә З.В.Калачёв тарафыннан уйлап табыла. Ракета снарядлары өчен баллистит Д. корылмалары беренче тапкыр 1930 елларда СССРда эшләнә һәм Бөек Ватан сугышында кулланыла («Катюша» гвардия минометлары). Реактив двигательләр өчен яңа составтагы катнашмалы Д. һәм алардан корылмалар 1940 елларның икенче яртысында башта АКШта, аннан соң башка илләрдә дә эшләнә башлый.

Казанның писцовый кенәгәләрендә Д. турында беренче язма 1566–68 елларга карый, шәһәрдә инде шул вакытта дары тегермәне була. Пётр I нең Казан воеводасына «дары җитештерүне көчәйтү»гә һәм аны «күп күләмдә» эшләүгә булышлык күрсәтергә кушкан архив документлары саклангән. Екатерина II идарә иткән чорда *Казан дары заводы* төзелә (1786–88). 1892 дә Д.И.Менделеев тарафыннан пироколлоидлы Д. технологиясе эшләнә һәм Бондюг (хәзер Менделеев) химия з-дында аның беренче партиясе әзерләнә. 1930 да Казан хим.-технол. ин-тында Д. технологиясе кафедрасы ачылу һәм 1941 дә Казанның В.И.Ленин исем. з-дында №40 Махсус техник бюро (соңыннан ул тармак фәнни-тикшеренү ин-ты итеп үзгәртелә, к. *Химия продуктлары институты*) төзелү Д. эшләп чыгару өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшчәнлеге үсешенә ярдәм итә. Нитроцеллюлозалы Д. һәм каты ракета ягулыкларының химиясе һәм технологиясе, целлюлоза нитратларының физика-химиясе, махсус полимерлар һәм композицияләр буенча фәнни юнәлешләр билгеләнә. Төрле класс Д.ларның һәм каты ягулыкларның кабыну һәм яну процесслары, көпшәле системаларның баллистикасы өйрәнелә; Д.ны кабат эшкәртүнең теоретик нигезләре, нефть чыгару сәнәгатендә һәм оборона техникасында кулланыла торган җылылыкка чыдам Д. технологиясе, ш.у. пироксилинлы һәм сферик Д. технологияләре һәм аппаратлар б-н тәэмин ителеше эшләнә. Дары җитештерү фәнен һәм технологиясен үстерүгә Казан хим.-технол. ин-ты (Л.И.*Захаров,* К.И.Синаев, А.Е.Коршунов һ.б.), Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-ты (Г.Л.Штукатор, А.В.Рябов, В.И.*Гиндич,* М.А.*Бельдер,* М.С.*Горохов,* А.С.*Ермошкин* һ.б.) галимнәре, Казан дары заводы җитәкчеләре (А.В.Грязнов, С.Г.Богатырёв, Ю.М.*Байгильдин,* Ф.Ф.Газизов) зур өлеш кертә. Фәнни эшләнмәләре ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән.

*Әд.:* Взрывчатые вещества и пороха. М., 1955; С е р е б р я к о в М.Е. Внутренняя баллистика ствольных систем и пороховых ракет. М., 1962; Энергетические и баллистические свойства порохов и твёрдых ракетных топлив. К., 1995.

*А.В.Косточко.*

**ДАРЫ́ ЗАВОДЫ́ БИСТӘСЕ́**, Казанның көнбатыш читендәге торак пункт. Бистәнең барлыкка килүе 1780 елда Казансу елгасының уңъяк ярында, Ягодный авылы янында дары з-ды төзү б-н бәйле. 1808 дә заводның 50 хезмәткәренә үз йортларын төзү өчен завод җиреннән кишәрлекләр бирәләр. 1823 тән заводның отставкага чыккан түбән чиндагы кешеләре, ш.у. офицер дәрәҗәсе алуга ирешкән осталар, эштән киткән очракта Д.з.б.нә күчеп яши алганнар. 1840 елларда завод терр-ясеннән чит кешеләрне чыгара башлыйлар; йортларын сату һәм яңаларын төзү хокукы фәкать завод хезмәткәрләренә генә бирелә (завод җитәкчелеге рөхсәте б-н); йорт хуҗасы үлгәч, аның заводта эшләмәүче варислары йортларын сатарга яки сүтәргә, завод терр-ясеннән китәргә тиеш була. Соңрак бистә халкы үз теләкләре б-н яллanып эшләүчеләр исәбенә арта. Д.з.б.ндә чиркәү, мәчетләр, кантончылар мәктәбе була. Бистәнең мөселман халкы 280 йортта яшәгән (20 йөз башы),

гомуми саны 2000 нән артык кеше (ш.и. 1035 ир-ат) булган 2 мәхәлләгә берләшә. Д.з.б. урамнары: Офицерлар, Идарә, Зур, Фурштат һ.б. 19 йөз ахырында Н.П.Загоскин болай дип яза: «Заводка аның ике — «якын» һәм «ерак» бистәсе килеп кушыла»; «... дары заводы үзенең киң авылы белән Казанның башка халкы тормышыннан бөтенләй аерылган тормыш белән яши». Совет хакимияте елларында Д.з.б. Восстание бистәсе дип атала, Пролетар (Киров) р-ны составында була.

*Әд.:* Глинский А.С. 100 лет Казанского порохового завода. СПб., 1888; Казаков В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ДАСА́ЕВ** Ринат Фәйзрахман улы (13.7.1957, Әстерхан ш.), спортчы (футбол), СССРның атказ. спорт остасы (1988). Мәскәү өлкә физкультура ин-тын тәмамлый. СССР чемпионы (1979, 1987), СССР халыклары спартакиадасында җиңүче (1979), Европа чемпионатында — көмеш (1988), Олимпия уеннарында бронза медаль ала (1980). «Волгарь» (Әстерхан, 1974–77), «Спартак» (Мәскәү, 1978–88), «Севилья» (Испания, 1988–90), СССР җыелма командаларында (1979–90) уйный. СССРның (1982), дөньяның (1988) иң яхшы футболчысы, СССРның иң яхшы капкачысы (1980, 1982–83, 1985, 1987–88) исеме бирелә. 1998 дән «Спартак» (Мәскәү) командасы, 2003–06 да Россия җыелма командасы тренеры, 2007 елдан «Торпедо» (Мәскәү) футбол клубы тренеры.

**ДАСТА́Н** (фарсы داستان — поэма, эпос), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия халыклары, татар һәм башкорт халык авыз иҗатында һәм әдәбиятында эпик жанр; аерым очракларда фольклор әсәрләренең (хикәятләр, риваятьләр, экиятләр) әдәби варианты да була ала. Д. шигъри (төрки «*Идегәй*», кыргыз «Манас», үзбәк «Алпамыш», каракалпак «Кырк кыз»), чәчмә (төрки «*Йиртөшлек*», татар һәм башкорт «*Җик Мәргән*») катнаш (төрки «*Таһир белән Зөһрә*», «*Кузы Курпәч белән Баянсылу*») формаларда, роман (фарсы, үзбәк, таҗик, әзәрбайҗан, татар, башкорт халык авыз иҗаты поэмалары) рәвешендә була. Катнаш Д.ның шигъри өлеше дутар, думбра б-н башкарыла. Д. авторларын һәм башкаручыларын җырау (төрки), җырчы (татар), кобаирчы (башкорт), *чичән* дип атыйлар.

Татар Д.нары борынгы һәм урта гасырлар Шәрекъ әдәбияты тәэсирендә барлыкка киләләр. Жанр үзенчәлекләре ягыннан Д.нар борынгы мифологик, героик, мәхәббәт һәм китап төрләренә аерыла.

«Йиртөшлек», «*Түләк*» (яки «Түләк һәм Сусылу») — борынгы мифологик Д.нар, икесе дә төрки эпосның батырны димләү кебек архаик сюжетына нигезләнгән. «Йиртөшлек» Д.ында вакыйгалар җир асты патшалыгында, «Түләк»тә су асты патшалыгында бара. Әсәр геройларының төп максаты — ике дөнья арасында гаилә мөнәсәбәтләре төзү һәм гармониягә ирешү. Д.нарның иң борынгы версияләрендә герой максатына ирешә, ә соңгыларында һәлак була.

Героик «*Ак Күбек*» һәм «Идегәй» Д.нарында вакыйга Алтын Урдада, эчке чуалышлар һәм таркалу дәверендә бара. Геройлар — билгеле тарихи шәхесләр — ханнар, әмирләр, хәрби җитәкчеләр. Ике Д.да да барлык төп геройлар һәлак була.

Бараба татарларыннан язып алынган «Кузы Курпәч белән Баянсылу» поэмасы — мәхәббәт Д.ының бер үрнәге. Д.да туганчы ук димләп куелган яшьләрнең фаҗигале мәхәббәте хикәяләнә. Беренче тапкыр Д. 1860 елларда тюрколог В.В.Радлов тарафыннан язып алына һәм бастырыла. 1960–70 елларда Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә әлеге әсәрнең тагын 20 варианты табыла.

Д.нарның шактый өлешен Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф», ш.у. «*Буз егет*», «*Сәйфелмөлек*», «*Ләйлә белән Мәҗнүн*», «*Шаһсәнәм һәм Гариб*», «Таһир белән Зөһрә» һ.б. китап Д.нары тәшкил итә. Китап Д.нарының эчтәлеге катлаулырак. Туган йортны саклау, үз мәхәббәтеңне табу һәм гаилә кору — әлеге өч Д.ның төп темасы. Урта гасырларның гаилә-ыруг мөнәсәбәтләре йогынтысында туган Шәрекъ эстетик традицияләре буенча, барлык китап Д.нары фаҗигале тәмамлана.

Россия халыклары Д.нарын теркәү һәм бастыру эшен В.В.Радлов башлап җибәрә. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөзнең башында күпчелек төрки-татар Д.нары, аерым китаплар булып, «Көньяк Себердә һәм Җоңгар даласында яшәүче төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи», т. 1–10, СПб., 1866–1907) исеме астында басылалар.

*Әд.:* Татар халык дастаны «Идегәй» / Н.Исәнбәт җыйнамасы // Совет әдәбияты. 1940. № 11/12; Әхмәтова Ф.В. Татар халык дастаннары // Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Кор-Оглы Х. Дастан // Краткая литературная энциклопедия. М., 1964. Т. 2; Урманчеев Ф. Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ДАСТАНЫ́ БАБАХА́Н»**, 15 йөз (башка чыганаклар буенча 18 йөз) татар әдәбияты ядкәре. Авторы — төрки шагыйрь *Сәйяди*. «Д.Б.»ның сюжеты нигезендә — Шәрекъ дөньясында киң таралган Таһир б-н Зөһрә мәхәббәте тарихы (к. «*Таһир белән Зөһрә*»). Вакыйга Бабахан шаһ идарә иткән легендар Татар шәһәрендә бара. Аның Зөһрә исемле кызы Баһир вәзир улы Таһирга гашыйк була. Моңа ачуы чыккан шаһның боерыгы б-н Таһирны сандыкка салып елгага ташлыйлар. Зур кошлар сандыкны коры җиргә чыгара. Исән калып, Таһир Багдадка килә, шәһәр идарәчесе кызы Маһымга өйләнә, әмма 7 ел дәвамында хатыны б-н дусларча мөнәсәбәттә генә булып, Зөһрәгә тугрылык саклый. Соңрак ул сөйгәне янына кире кайта. Бабахан, моны белеп, Таһирны җәзалап үтертә. Аннан соң Таһир б-н булган фаҗига кайгысыннан Зөһрә, аны сөюче Кара Баһадир һәм Таһирга гашыйк булган Маһым да үләләр. Аларның каберләрендә искиткеч матур чәчәкләр үсеп чыга. Алар арасында яшәүче сандугачлар, Багдад һәм Татар шәһәрләренә килеп, гашыйкларның фаҗигале язмышы турында җырлыйлар. Вакытлар үткәч, әлеге вакыйга бөтен дөньяга билгеле була.

Әсәр эпик жанрга карый, аңлаешлы тел б-н язылган, шундый төрдәге башка әсәрләргә дә хас булганча, гарәп-фарсы алынмалары аз кулланылган. Дастан татар язма әдәбиятында да, фольклорында да киң тарала. Татарстан терр-ясендә дастанның 18–19 йөзләрдә татар каллиграфлары башкарган 5 күчермәсе табыла. Күчермәләрнең аеруча тулы варианты 1818 елда Куян авылыннан (кайда урнашканлыгы билгесез) Йосыф мулла кызы Бибигамбәр тарафыннан күчереп языла. Әлеге нөсхә РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының С.-Петербург бүлегендә саклана. Аңа нигезләнеп, дастан 1998 дә нәшер ителә.

Әсәр.: Сәйяди. Таһир-Зөһрә (Бабахан дастаны). К., 1998.

*Әд.:* Хисмәтуллин Х. Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе («Дастан Бабахан» әсәренә 550 ел тулу уңае белән) // Казан утлары. 1965. № 7; Ахметзянов М.И. Татарские версии сюжета «Тахир-Зухра» // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999; Ахметова-Урманче Ф.В. «Дастан-и Бабахан» Сайяди // шунда ук. 114–118 б.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ДАУ́Д**, Коръәндәге персонаж, пәйгамбәр һәм падишаһ; Библиядәге Давидка тиңдәш. *Коръәндә* Аллаһ хозурындагы тәкъва буларак искә алына (үзе генә йә улы Сөләйман б-н). Аллаһ аңа «Зәбүр»не (псаломнар) иңдерә һәм җирдәге илчесе итә. Д. беренче булып металл эшкәртә башлый, көбә киемнәр әзерли. Металл б-н эш итүчеләрнең яклаучысы булып санала. Д. — Аллаһка мәдһия җырлаучы, мөселман мистиклары арасында популярлык казанган зат. Коръәндә аның образында Аллаһның үзе яраткан бәндәләренә ярдәме турында бәян ителгән төрле вакыйгалар һәм легендалар чагылыш тапкан.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ДАУ́ТОВ** Әхәт Габделхәй улы (15.5.1923, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Барда а. — 10.7.1989, Үзбәкстан ССРның Фирганә өлкәсе Коканд ш.), Дан орденының тулы кавалеры (27.8.1944, 10.3.1945, 27.6.1945), кече лейтенант (1945). Туган авылында урман хуҗалыгында эшли. 1942 елның мартыннан Кызыл Армиядә. 1943 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 57 нче танк полкы отделениесенең танк тубы командиры (3 нче гв. танк армиясенең 9 нчы механикалаштырылган корпусы). Брянск, Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Орёл һөҗүм операциясендә (1943), Украинаны һәм Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 13 августында Голомб станциясе янында (Польшаның Пулавы шәһәреннән 7 *км* төньяктарак) дошман контрһөҗүмен кире кайтаруда (пехотаны алга чыгару өчен, дошманның танкын сафтан чыгара һәм тубын юк итә); 1945 нең 20 февралендә Германия терр-ясендәге сугышларда (дошман танкын һәм орудиесен сафтан чыгара); 1945 нең 22 апрелендә Рангсдорф торак пункты (Германия) өчен барган сугышта ба-

тырлык күрсәтә: танкны сафтан чыгара һәм күзәтү пунктын җимерә. 1947 дән «Төзелеш материаллары» з-дында (Коканд ш.) слесарь булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1967. Кн. 2; К у р г у з о в И.П. Солдатская доблесть. Таш., 1970; Слава солдатская. Пермь, 1984; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ДАУ́ТОВ** Гали Юныс улы (21.8.1931, Яңа Писмән, хәзерге Лениногорск р-ны Мәэмин-Каратай а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1970), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1982, 1995). 1955 елда Казан авиация ин-тының очкыч аппаратлар ф-тын тәмамлый. 1956–59 да «Лениногорскнефтестрой» трестында эшли. 1959–69 да СССР ФА Себер бүлегенең теоретик һәм гамәли механика ин-тында (Новосибирск ш.), лаб. мөдире (1965 тән). 1969 дан Казан техник ун-тында, гомуми физика каф. мөдире (1995 кә кадәр), проф. (1970). Хезмәтләре түбән темп-ралы плазма физикасына карый. Электр дугасында һәм пыскып бушанганда түбән темп-ралы плазма генерацияләнүе теориясен, плазма генераторы — сыйфатламасы б-н шуңа охшаш мәгълүм генераторлар күрсәткечләреннән 2–3 мәртәбә зуррак булган — бүленгән параметрлы плазмотрон төзи. 50 мең К га кадәр темп-ралы плазма алырга мөмкинлек бирә торган плазмотроннар булдыра. Плазма б-н кисү, капламнар салу процессларын, машиналар төзелеше технологияләрен эшли. Югары уку йортлары өчен «Физика» (Т. 1–3, 1999–2002) дәреслеге, ш.у. русча-татарча физика терминнары сүзлеге авторларыннан берсе. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Плазмотроны со стабилизированными электрическими дугами. Киев. 1984 (автордаш); Электродуговые и высокочастотные плазмотроны в химико-металлургических процессах. Киев, 1991 (автордаш); Исследования распределений потенциала и концентрации электронов в пылевой плазме // Вестн. Казан. техн. унта. 2007. № 4 (автордаш).


*Р.Г.Усманов.*

**ДАУ́ТОВ** Искәндәр Садыйк улы (2.9.1923, хәзерге Омск өлкәсе Исилкүл ш. — 26.9.1943, Чернигов өлкәсенең Репкин р-ны Неданчичи а. җирләнә), Сов. Союзы Герое (15.1.1944, вафатыннан соң), гв. рядовое. Петропавловск а.х. техникумының ике курсын тәмамлый (1942). Петропавловск ит комб-тында мастер булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 58 нче гв. кавалерия полкы пулемётчысы (61 нче армиянең 7 нче гв. кавалерия корпусы 16 нчы гв. кавалерия дивизиясе). Брянск һәм Үзәк фронтлар гаскәрләре составында Орёл һәм Чернигов-Припять һөҗүм операцияләрендә (икесе дә 1943) катнаша. 1943 нең 26 сентябрендә Днепр елгасын кичеп, Нивки авылы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагинск р-ны) янында батырлык күрсәтә: беренче булып елганы кичә; сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Петропавловск шәһәрендә Д. бюсты урнаштырыла. Петропавловскида 26 нчы номерлы һөнәри белем бирү уч-щесе һәм Неданчичи авылы урамы аның исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1; Ш л е в к о Г.М. Ради жизни на земле. Омск, 1972; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДАУ́ТОВ ЙОРТЫ́** (Гатаулла бай йорты), Әтнә р-ны Олы Әтнә авылында, татарларның агач архит-ра ядкәре. 19 йөзнең 2 нче яртысында бай җирбиләүче Г.Даутов өчен төзелә. Ике катлы, Т рәвешендә итеп төзелгән бинаның ишегалдына кереп торган өлеше өйалды һәм аның өстенә ясалган кечкенә өскорма — чарлак (мезонин) б-н тәгәлләнә. Өскорма — чарлак үзе түбә астына кертеп эшләнгән парлы колонналар һәм рәшәткәдән корып ясалган култыкса текмәсе б-н аерылып тора; фасадларның фронтоннары а́ркалы тирән куышлар б-н бизәлгән. Д.й. фасадларын бизәгәндә ампир элементлары, татар орнаментлы үрнәкләре һәм төрле буяулар кулланылган. Йорт милли хасиятләрне күздә тотып төзелгән: ирләр һәм хатыннар ягына керү өчен аерым ишекләр, өйалдылары булган. 2 нче каттагы бүлмәләргә һәм чарлакка чыная кирпеч б-н тышланган голланд мичләре ямь биреп торган. Д.й. 1946 елда архит. И.Г.Гайнетдинов тарафыннан үлчәнә. 2001 дә реставрацияләнә, хуҗалык алып бару корылмалары реконструкцияләнә (архит. К.Б.Мусина) һәм район этнография музеена бирелә.



Даутов йортының төп фасады һәм планнары.


Ә.Г.Даутов.



И.С.Даутов.


Олы Әтнә авылында Даутов йорты.
2001 елгы реконструкция.

*Әд.:* Г а й н у т д и н о в И.Г. Национальные черты жилища казанских татар // Архитектурное наследство. 1975. № 23.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ДАУ́ТОВ** Нияз Курамша улы (23.9.1913, Казан — 16.4.1986, шунда ук), җырчы, (лирик тенор), опера режиссёры, педагог, РСФСРның халык артисты (1957), проф. (1986). 1935–38 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (М.Мирзоев классы), 1939–43 тә Мәскәү консерваториясенең вокал ф-тында (А.Аскоченский классы) укый, 1953 тә Урал консерваториясен (Свердловск ш.) тәмамлый. 1941 дә Татар опера һәм балет театрында Җик партиясен («Алтынчәч», Н.Җиһанов) беренче тапкыр башкара. Бөек Ватан сугышы чорында Евг. Вахтангов исем. театрның һәм Бөтенсоюз театр җәмгыятенең фронт труппалары солисты, бер үк вакытта 1943 тә К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченко исем. муз. акад. театры солисты (беренче чыгышында П.Чайковскийның «Евгений Онегин» операсында Ленский партиясен башкара), 1943–56 да Свердловск опера һәм балет театры солисты һәм режиссёры. 1956–60 та Татар опера һәм балет театры солисты һәм баш режиссёры (Д. җитәкчелегендә труппа 1957 дә



Н.К. Даутов.

Мәскәүдә узган *Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында* катнашу өчен әзерләнә), бер үк вакытта Казан консерваториясенең операга әзерлек каф. мөдире. 1960–65 тә Свердловск опера һәм балет театры солисты һәм режиссёры, 1965–75 тә — Чиләбе, 1975 тән Татар опера һәм балет театрларында баш режиссёр, Казан консерваториясенең операга әзерлек каф. мөдире. Яхшы вокал мәктәбенә, кабатланмас матур һәм көчле, йомшак тембрлы чиста тавышка ия була. Башкару осталыгына югары интеллектуаль культура хас. Вокаль һәм сәхнә сәнгатенең гармоник синтезын булдыруга омтыла, бербөтен сәнгати образлар иҗат итә. Д. опера җырчыларында сирәк очрый торган пластикага, матур тышкы кыяфәткә һәм төгәл хәрәкәтләргә ия «җырчы актер» була. Төп опера партияләре: Герцог, Альфред («Риголетто», «Травиата», Дж. Верди), Рудольф («Богема», Дж. Пуччини),



Н.К.Даутов Альфред ролендә («Травиата», Дж. Верди).

Ленский («Евгений Онегин», П.Чайковский), Берендей, Гвидон («Кар кызы», «Салтан патша турында әкият», Н.Римский-Корсаков). Җик, Җәлил («Алтынчәч», шул исем. опера, Н.Җиһанов), Дубровский (шул исем. опера, Э.Направник), Синодал («Демон», Л.Рубинштейн) һ.б. Классик оперетта端ларда төп партияләрне, ш.и. Генрих Айзенштайн («Ярканат» — «Летучая мышь», И.Штраус), Эдвин («Сильва», И.Кальман) партияләрен башкара. Төп рольне Д. башкарган экранлаштырылган «Сильва» опереттасы (Свердловск киностудиясе, 1944) бөтенсоюз тамашачысында зур уңыш казана. Концерт репертуары киң һәм күп кырлы була. Режиссёр



Н.К.Даутов Җәлил ролендә («Җәлил», Н.Җиһанов).



Н.К.Даутов Ромео ролендә («Ромео һәм Джульетта», Ш.Гуно).

буларак, 30 га якын спектакль куя: беренчесе — Дж. Вердиның «Травиата» операсы (1953, Свердловск), П.Чайковскийның «Евгений Онегин», «Опричник», А.Даргомыжскийның «Таш кунак» («Каменный гость»), Н.Римский-Корсаковның «Патша кәләше» («Царская невеста»), Ш.Гуноның «Фауст», Ж.Бизенең «Кармен», Дж.Пуччининың «Богема», Н.Җиһановның «Алтынчәч», Р.Гобәйдуллинның «Җиһангир», Дж.Вердиның «Дон Карлос», «Отелло» һ.б. операларын сәхнәләштерә. Казан консерваториясендәге пед. эшчәнлеге б-н Д. Татарстанның муз. сәхнә сәнгате үсешенә зур өлеш кертә, республиканың әйдәп баручы опера җырчыларының иҗатын үстерүгә булышлык итә. Д. — Бөтенроссия концерт башкаручылары конкурсы (1944), Бөтенсоюз театр яшьләре смотры (1947), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1958).

Х е з м.: Йолдызлардан нур алып... // Азат хатын. 1976. № 8.

*Әд.:* Дебют молодого певца // Огонёк. 1943. № 15/16; Г о л о в а щ е н к о Ю. Н.Даутов. К., 1957; В и т в и ц к и й Н. Лирический певец // Театральная жизнь. 1959. № 3; Народные артисты. К., 1980; Татарский академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля. К., 1994.

*Ф.Ш.Салитова, Р.И.Такташ.*

**ДАУ́ТОВ** Нур Әсгать улы (5.1.1956, БАССРның Бәләбәй р-ны Пахарь пос., хәзерге Пятилетка а.), композитор, педагог. БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Уфа сәнгать ин-тын композиция классы (проф. З.Г.Исмәгыйлев) буенча тәмамлый (1986). 1986 елдан Башкорт филормониясенең эстрада коллективы музыка җитәкчесе, Уфа сәнгать уч-щесендә укытучы. Д.ның иҗаты жанр диапазонының киңлеге б-н аерылып тора. Ул композиторлык техникасының төрле чараларына һәм кешенең эчке дөньясын чагылдыруның күптөрле алымнарын куллану сәләтенә ия.

Төп әсәрләре: «Гөлҗамал» операсы (З.Бишеваның шул исем. поэмасы буенча В.Кәримов либреттосы), «Урал» симф. поэмасы (1984), Симфония № 1 (1993), Симфония № 2 (1995); меццо-сопрано, хор һәм симф. оркестр өчен В.Илимбетов шигыренә язылган «Җиремә тынычлык» («Мир моей земле») кантатасы (1985); катнаш хор һәм симф. оркестр өчен «Буранбай» поэмасы (1988), башкорт шагыйрьләре шигырьләренә «Брест сиреньнәре» («Сирени Бреста», 1987), Ш.Анак шигыренә «Тормыш чынбарлыгы» («Жизнь как есть», 1990) хор цикллары, татар халык җыры «Тәфтиләү» көенә тенор, хатын-кызлар хоры һәм фортепиано өчен эшкәртмә (1996); фортепиано өчен 3 соната (1982, 1983, 1983), 2 кыллы квартет (1982, 1987), альт һәм фортепиано өчен сюита; М.Кәрим, Р.Гарипов шигырьләренә вокаль цикллар (1986, 1987); җырлар, романслар, спектакльләргә музыка һ.б.

*Әд.:* Г а л и н а Г. Творчество Нура Даутова // Композиторы и музыковеды Башкортостана: Очерки жизни и творчества. Уфа, 2002.

**ДАУ́ТОВ** Осман (Госман) Шакир улы (7.9.1942, Казан), гамәли электродинамика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1994), проф. (1998). 1966 елда Казан авиация ин-тының (хәзер Казан техник ун-ты) радиотехника ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли, электрон-хисаплау аппаратлары төзү һәм җитештерү каф. мөдире (1983 тән). Хезмәтләре электродинамиканың кырый мәсьәләләрен чишүгә һәм дефектоскопиядә, электромагнитик диагностикага карый. Д. туры һәм кире мәсьәләләрне чишкәндә санча алгоритмнарны гадиләштерергә мөмкинлек бирә торган электромагнитик күренешләрне тасвирлау өчен тигезләмәләрнең яңа классын тәкъдим итә һәм тикшерә. Махсус антенналардагы диэлектрик сыеңгычларны һәм каршылыкны киметүне хисаплау эшләрен башкара. Электромагнитик диагностикада һәм дефектоскопиядә үлчәү эшләре нәтиҗәләрен эшкәртүнең яңа ысулын тәкъдим итә һәм ул геоэлектроразведкада һәм күп катламлы платларның сыйфатын тикшергәндә файдаланыла. Атмосферада аэрозольләрнең җәелү-таралу кырларын санча исәпләү ысулын тасвирлый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 3 патенты бар.

Х е з м.: Технология и автоматизация производства радиоэлектронной аппаратуры. М., 1989; Распределение массового коэффициента поглощения в теле человека при воздействии дипольной антенны мобильного телефона на частоте 900 Мгц // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2005. № 1–2 (автордаш); Elements of Model of Distribution of Electromagnetic Radiation in Turbullent Atmosphere // Environmental Radioecology and Applied Ecology. 1997. V.3, № 3 (автордаш).

**ДАУ́ТОВ** Рәис Нәүширван улы (15.3.1928, Мамадыш кантоны Шәмәк а. — 28.8.2007, Казан), тәрҗемәче, әдәбиятчы, библиограф, текстолог. СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1972), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан укытучылар ин-тын (1948) һәм Казан пед. ин-тын (1963) тәмамлый. 1953–93 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1992–2003 тә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында татар тексты мөхәррирләре төркеме җитәкчесе. Татар теленә М.Твенның «Янки король Артур сараенда» («Янки при дворе короля Артура», 1958), Ф.Куперның «Соңгы могикан» («Последний из могикан», 1962), М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» («Мухаджиры», 1968), Ф.М.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» («Преступление и наказание», 1974) романнарын, А.И.Купринның хикәя һәм повестьларын

(«Повестьлар», 1988), Р.Солнцевның «Көймә ватылса — утын» («Лодка пойдёт на дрова», 1978) повестен, О'Генри новеллаларын, Э.Хемингуэй хикәяләрен тәрҗемә итә. «Совет Татарстаны язучылары» (1986, Н.Б.Нуруллина б-н берлектә) биобиблиографик белешмәсен төзүче автор. И.Г.Рәмиевнең кулъязмаларын тулыландырып, «Әдәби сүзлек» (2001) китабын бастыра. З.Бигиев, И.Рәмиев, Р.Төхфәтуллин, Әнәс Камал, М.Галәү, репрессиягә дучар булган татар язучыларының иҗатын яктырткан мәкаләләр авторы. Дәрдемәнд («Исә җилләр», 1980), Г.Тукай («Шигырьләр һәм поэмалар» — «Стихотворения и поэмы», Л., 1988) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша. З.Бигиев («Зур гөнаһлар», 1991), С.Максуди («Мәгыйшәт», 1994; «Англиягә сәяхәт», 1995), Г.Камал («Истанбул мәктүбләре», 1999) әсәрләрен басмага әзерли (кереш сүзләр, искәрмәләр, аңлатмалар яза). Д. татар фәнни әдәбиятында яңа жанр — энциклопедистика барлыкка килүгә зур өлеш кертә. Халыклар дуслыгы ордены, ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге б-н бүләкләнә. Дәүләт бүләге «Татар энциклопедия сүзлеге»н (2002) төзүгә керткән хезмәтләре өчен бирелә.

Х е з м.: Балачак әдипләре: Биобиблиогр. белешмәлек. 4 китапта. К., 2002–08.

*Әд.:* Г а м б ә р Н. Учак җылысы // Казан утлары. 1978. № 3; Ю н ы с М. Чишмәләрнең сафлыгы // Казан утлары. 1988. № 3; Ф ә й з у л л и н Р. Тирәбездә яхшы кешеләр // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т. 4.

**ДАУ́ТОВ** Рифгат Әхмәтҗан улы (23.7.1921, Әгерҗе а., хәзер шул ук исем. ш. — 17.11.2001, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1982). 1946 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1950 дән Мари, 1952 дән Казан пед. ин-тларында. 1957–95 елларда Казан ун-тында, радиоэлектроника каф. проф. (1981 дән). Хезмәтләре ферромагнетикларның үзлекләрен өйрәнүгә, ТМР һәм куертылган мохиттәге импульслы спектроскопиягә карый. Ферромагнетикларның резонанс шартларында электр үткәрүчәнлегенең үзгәрүен ачыклый. СССРда беренче мәртәбә спин кайтавазы сигналларын күзәтә (1959, бергәләп), төшнең магнитлавын синхрон тоту буенча тәҗрибәләр һәм аны каты җисемнәрдә координаталарның әйләнмә системасына карата тикшерү уздыра (бергәләп), үтә нәзек дәрәҗәләрдәге икеле төш-төш резонансын һәм уртак диполь системасы аша тәэсирләнү тапшырылуын тикшерә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Измерение времени поперечной релаксации в водных растворах парамагнитных солей методом спинового эха // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1959. Т. 37 (автордаш); Ядерная магнитная релаксация, вызванная случайными переориентациями молекул в кристаллах // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1972. Т. 62 (автордаш); Импульсное изменение температуры резервуара диполь-дипольных взаимодействий в двойном ядерно-ядерном резонансе // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1976. Т. 70.

*Р.Г.Усманов.*

**ДАУ́ТОВ** Рифкат Каюм улы (15.9.1917, Казан губ., Алабуга өязе Мордыбай а. — 6.6.1994, Казан), туфрак белгече, а.х. фәннәре д-ры (1978), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1947). РФА КГҮнең Биология ин-тында эшли (1993 кә кадәр), туфрак белеме лаб-ясе мөдире (1967–87). Хезмәтләре Урта Идел буе ландшафтының төп компонентларында: туфракта, үсемлекләрдә һәм табигый суларда микроэлементларны (B, Mo, Mn, Co, Cu, Zn) тикшерүгә карый. Туфракта микроэлементларның тулаем күләме һәм хәрәкәтчел формалары картограммаларын төзүгә җитәкчелек итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н, ТАССР, Чуаш АССР ЮС Президиумы Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние полезащитных лесных полос на почвы. К., 1959; Значение микроэлементов в сельском хозяйстве Татарии. К., 1964 (автордаш); Опыт составления крупномасштабных картограмм содержания подвижных форм микроэлементов в почвах Волжско-Камской лесостепи // Агрохимия. 1972. № 7.

**ДАУ́ТОВ** Рөстәм Хаҗит улы (28.11.1965, Уфа ш.), шахматчы, халыкара гроссмейстер (1990). «Зенит» ирекле спорт җәмгыятенең олимпия резервы мәктәбендә тәрбияләнә (Уфа ш., тренеры Х.М.Даутов). СССР (1983, яшүсмерләр арасында), Белоруссия ССР (1986), СССР Кораллы Көчләре (1986, 1989), ГФР (1996), Европа (1997, «Итиль» Казан командасы составында) чемпионы. «Урал-89» халыкара турнирында, ш.у. Росток (1985, 1987), Дрезден (1986, 1988–89), Потсдам (1986–87), Берлин (1987), Кечкемет (Венгрия, 1989), Мюнстер, Вильдбад, Мюнхен (1990) шәһәрләрендә узган халыкара бәйгеләрдә, шахмат фестивальләрендә (Халле шәһәрендә — 5 нче, Дрезден шәһәрендә — 7 нче, икесе дә 1987 елда) җиңүче. СССР кубогына (1984, яшүсмерләр арасында), СССР беренчелеге өчен (1989) ярышларда көмеш медаль ала. Европа кубогы иясе (1996, «Таттрансгаз-Итиль» командасы составында). Д. — «Зенит» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советының, армия үзәк спорт клубының (1984–89), Белоруссиянең (1986), Германиянең (1996 дан) җыелма командалары әгъзасы. 1993 тән проф. шахматчы. 1984 тән ГДРда, 1991 елдан ГФРда яши.

**ДАУ́ТОВ** Фидаил Фәсхи улы (29.9.1939, Кукмара р-ны Түбән Үрәс а.), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1967 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1967–73 тә республика мед. учреждениеләрендә. 1973 тән Казан мед. ин-тында, 1977 дән Казан мед. академиясендә, 1983 тән гомуми гигиена каф. мөдире. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитнең пычрануын өйрәнүгә, атмосферадагы зарарлы кушылмаларның халык сәламәтлегенә тәэсирен бәяләүгә карый. Д. авырулар б-н пычраклыкның санлы бәйләнешен билгели. СССР Бөтенсоюз халык хуҗалыгы күргәзмәсе казанышлары медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гигиеническая характеристика загрязнения атмосферного воздуха и количественная оценка его влияния на здоровье детского населения в условиях крупного города. К., 1983; Изучение здоровья населения в связи с факторами среды. К., 1990.

**ДАУ́ТОВ** Шамил Габдулла улы (19.2.1947, Красноярск ш. — 1.4.1983, шунда ук), математик, физ.-матем. фән. канд-ты (1973). 1971 елда Красноярск ун-тын тәмамлау б-н СССР ФА Себер бүлегенең физика ин-тында эшли. Хезмәтләре күбүлчәмле комплекслы анализга, интеграль фаразлауга һәм цифрлы рекурсив фильтрларга карый. Төгәл ялган кабарынкы өлкә читендә интеграллаганда голоморф функцияләргә ортогональ булган тышкы дифференциаль формаларның сигма йомыклыгы теоремасын исбатлый. Неванлинн-Джрбашян классындагы голоморф функцияләрнең нольләре күплеген тәгъбирли.

Х е з м.: О формах, ортогональных голоморфным функциям при интегрировании по границе псевдовыпуклой области // Докл. АН СССР. 1972. Т. 203, № 1; Об интегральных представлениях для комплексных дифференциальных форм // Сибирский мат. журн. 1972. Т. 13, № 4 (автордаш); Differential forms orthogonal to holomorphic functions or forms and their properties. Amer. Math. Soc. Providence. RL, 1983 (автордаш).

*Әд.:* A i z e n b e r g L.A., K y t m a n o v A.M. On the scientific achievements of Shamil Abdullovich Dautov // Selecta Math. Sov. 1989. V.8, № 4.

**ДАУ́ТОВА** Гүзәлия Җәүдәт кызы (15.11.1960, Бөгелмә р-ны Карабаш пос.), педагог, пед. фән. д-ры (2004), проф. (2006). 1984 елдан, Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан шәһәрендәге 24 нче урта һөнәри-техник уч-щедә укыта, 1986 дан СССР ПФАнең Профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1991 дән — Казан пед. ун-тында тәрбия эшләре методикасы, 1996 дан — педагогика, 2004 тән Татар гуманитар-педагогика ун-тының педагогика тарихы һәм этнопедагогика кафедраларында. Хезмәтләре татар халык педагогикасы тарихына, Идел буе төбәкләрендә поликультур белем бирү системасы үсешенә карый.

Х е з м.: Видные татарские педагоги XIX века. К., 1999; Развитие поликультурного образования в Поволжье. К., 2003.

**ДАУ́ТОВА** (Даудова-Әдһәмова) Мәрзия Йосыф кызы (25.11.1901, Әстерхан ш. — 9.1.1962, Баку ш.), драма актрисасы, Хезмәт Батыры (1932), Әзәрбайҗан ССРның, СССРның халык артисты (1936, 1949). Сәхнә эшчәнлеген 1915 елда Әстерхан татар театрында башлый. 1919 да З.Солтанов җитәкчелегендә Әстерхан татар театр студиясен тәмамлый. 1920 дән М.Азизбәков исем. Әзәрбайҗан драма театры труппасында эшли. Кеше шәхесенең героик-романтик характерын чагылдыруга сәләтле актриса буларак, үз замандашлары образларында хатын-кызның чын милли сыйфатларын ача. Ул башкарган Фирәнгиз, Солмаз, Севиль («Ил улы Актай», «Ут кәләше», «Севиль», Җ.Җаббарлы) кебек героинялар көчле ихтыярлы, максатка омтылучан, үз тирәлегенең артта калуы б-н килешмәүчән, үз дәрәҗәләрен һәм бәйсезлекләрен яклап көрәшергә сәләтле хатын-кызлар булып күз алдына килеп басалар. Рухи ирекккә, гасырлардан килгән курку хисен җиңүгә ирешү, үзаңның уяну процессын күрсәтү Д. башкарган Любовь Яровая (К.А.Тренёвның шул исем. пьесасы), Оксана («Эскадраның һәлакәте», А.Е.Корнейчук), Клара («Курку», А.Н.Афи-


М.Й.Даутова.

ногенов) кебек героинялар образларының да төп лейтмотивы була. Гызьетер («Ханнар», С.Вургун), Гөлзар («Шәрекъ иртәсе», Э.Мамедханлы) рольләрендә Д. чын халык вәкиле, халыкның гореф-гадәтләрен саклаучы ана образын иҗат итә. Классик драматургия репертуарыннан Д. башкарган Кручинина, Кабаниха («Гаепсездән гаеплеләр», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Настя, Васса («Тормыш төбендә», «Васса Железнова», М.Горький), Дездемона, Гонерилья, Гертруда, леди Макбет («Отелло», «Король Лир», «Гамлет», «Макбет», У.Шекспир) образлары эмоциональ көчкә, психол. тирәнлеккә ия. Хураман, Ширин («Вагыйф», «Фәрһад һәм Ширин»,


М.Й.Даутова Макбет («Макбет», У.Шекспир) ролендә.

С.Вургун), Хумар, Судабә («Санан шәех», «Сиявуш», Г.Җәвид) рольләре Д.ның әһәмиятле иҗади уңышлары булып тора. Әзәрбайҗан ССРның 2 нче һәм 5 нче чакырылыш ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1948).


М.Й.Даутова Севиль ролендә (Җ.Җаббарлының шул исемдәге пьесасы).

*Әд.:* Мамедов Д. Марзия Давудова. Баку, 1949.

*И.И.Илялова.*

**ДА́ФНИЯЛӘР**, су борчалары (Daphnia), тармакмыеклы кысласыманнар ыругы. 26 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә Д. pulex, Д. magna, Д. cristata, Д. longispina, Д. cucullata һ.б. очрый. Төче сулыклар планктонында күп. 0,5–6 *мм* озынлыкта (аталары аналарыннан ваграк); яннарын каплаган үтә күренмәле кабырчык алгы якта томшыксыман орыга күчә, өскә тырпаеп, ишү органы ролен уйнаучы бер пар тармаклы мыекчасы бар. Башында кечкенә мыекчалар пары (кыска мыекчалар) һәм өзлексез хәрәкәтчел катлаулы зур күз урнашкан. Арка ягында, тән һәм кабырчык арасында, йомырка җитлегә торган оя камерасы бар. Д. аерым җенесле. Ана затлар җәйге чорда партеногенез юсулы б-н (аталанудан башка) үрчиләр һәм бернечә буын бирәләр. Ата затлар, гадәттә, уңай булмаган шартлар башлангач яки көзен күренәләр. Аталанудан соң ана Д. калын тышча б-н капланган 1–2 йомырка сала. Язын алардан ана Д. җитлегә. Д. бактерияләр, беркүзәнәкле суүсемнәр, иң түбән төзелешлеләр һәм үсемлек детриты кисәкчәләре б-н тукланалар. Балыклар өчен яхшы азык; аквариумчылар тарафыннан үрчетелә. Д. magna биотест үткәрүдә кулланыла.

*В.А.Яковлев.*

**ДА́ЧНЫЙ** (Учхоз) посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 6 *км* көнбатыштарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 720 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 36%) яши. Казан ветеринария медицинасы академиясенең укыту хуҗалыгы. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 1960 елларда нигез салына. Халык саны: 1989 да — 639, 2002 дә — 657 кеше.

**«ДА́ЧНЫЙ» УРМА́Н МАССИВЫ́**, к. *КДУ зоостанциясе.*

**ДА́ШКИН** Зөлкарнәй Шаһингәрәй улы (22.6.1861, Оренбург өлкәсенең Түбән Күл пос. — 1919 дан соң), ген.-майор (1918). Татар бәк-морзалары *Дашкиннар* нәселеннән. Оренбург казак юнкерлар уч-щесен (1880), Офицерлар кавалерия мәктәбен (С.-Петербург, 1904) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышы елларында 14 нче Оренбург казак полкы б-н командалык итә. Әлеге полк, сугышып, Суходол шәһәреннән Ченстохов (Польша) һәм Вилькомир (Литва) шәһәрләренә кадәр барып җитә. 1918 елның гыйнварыннан Оренбург казак гаскәре составындагы мөселман частьләре командиры. 1918 нең август-сентябрендә Оренбург шәһәр думасы гласные. Окт. рев-циясеннән соң Советларга каршы «Алаш-Урда» оешмасында катнаша. 1919 да атаман А.И.Дутовның чигенүче гаскәрләре б-н китә. Шуннан соңгы язмышы билгесез. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Бохара алтын йолдызы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Семёнов В.Г. Татары в Оренбургском казачьем войске // Евразийское ожерелье: Альманах. Оренбург, 2001. Вып. 1.

*Д.Н.Денисов.*

**ДА́ШКИННАР**, татар бәк-морзалары. Нәселне башлаучы — кенәз Дашка Ходяков (Худяков) (16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөз башы). Хезмәтләре өчен патша аңа Темников һәм Арзамас өязләреннән крәстияннәре б-н бергә 400 чирек (четверть) җир бирә. 1612 елда аның уллары Сөнчәләй, Ишмәкәй һәм Алмакай искә алына. Сөнчәләй — бәк, калган икесе морза дип аталган. 1699 да Д. нәселе морзалары Кодрак Обраимов (Ибраһимов), Байтер Емлакаев, Устин (Хөснетдин) Нуркаев, Абраим (Ибраһим) һәм Смаил (Исмәгыйль) Ишмаметовлар, Мостай Сәфәров, Алей (Гали) Уразмәмәтов, Бегай (Биги) Абраимов (Ибраһимов), Иванаш Расланов (Арсланов), Халислам һәм Цараслам Плюнбаевлар, Рәҗап Размаметов (Уразмөхәммәтов) — крәстияннәре б-н бергә биләмәләр хуҗалары. 1713 тә бәкләр Арслан Бекбаев (Бикбаев) һәм Иванаш Арслановның Урта Әләзән авылында 11 йорт крепостной крәстияннәре була. Пётр I нең татар морзаларын чукындыру турындагы 1713 елгы фәрманыннан соң Д.ның биләмәләрен һәм крәстияннәрен «государьга» язалар, ә үзләрен Пенза губернасы Краснослободск өязе дәүләт крәстияннәре разрядына күчерәләр. 18–19 йөзләрдә Д. нәселенең бер өлеше Дашкин, Имакай, Кара Суыксу (Краснослободск өязе), Таулы Шуструй һәм Кочалейка (Кадомск өязе) авылларында яши. 1779 да морза Зәет Якупов гаиләсе Бөгелмә өязе Габдулла авылыннан Нугай даругасының Юрмат волостена күчеп утыра. Соңрак бу гаилә Иске Яуыш авылында (хәзер БРның Фёдоровка р-ны) яши. 19 йөз башында Йосыф Бәхтиев гаиләсе дә шунда күчә. Әлеге гаиләләр (Ишмәкәй Д. нәселләре) Сенатның 1791 ел, 3 декабре фәрманы нигезендә дворяннар катлавына күчерелә. 19 йөз башында Д. Пенза губернасыннан Бүздәк, Шланлыкүл (хәзер БРның Бүздәк р-ны), Мәүлет (хәзер БРның Кушнаренко р-ны) авылларына килеп утыралар. Барысы да Сөнчәләй Д. нәселеннән булалар һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керәләр.

*Әд.:* Савелов Л.М. Родословные записи: Опыт родословного словаря русского древнего дворянства. М., 1909. Ч. 3; Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3.

*И.Р.Габдуллин.*

**ДӘВЕ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 14 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 3 *км* читтә. 2008 елда 319 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1717 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы *асаба башкортлар* һәм типтәрләр катлауларына бүленә; игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә, Кама пристаньнарында эшли. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Д. Пугачёв җитәкчелегендәге отрядларның җыелу һәм ял итү урыны була. Д.тә мәчет турында беренче тапкыр 1833 тә телгә алына. 20 йөз башында

2 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3069 дис. тәшкил итә, 1929 да авылда «Алга» к-зы оештырыла, 1959 да ул «Яңа юл» к-зы б-н берләшә (1991 дән — яңадан үзенең иске исеме б-н мөстәкыйль хуҗалык). 1920 гә кадәр Д. Казан губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 186, 1859 да — 718, 1870 тә — 814, 1897 дә — 1310, 1906 да — 1543, 1913 тә — 1696, 1920 дә — 1701, 1926 да — 1419, 1938 дә — 1157, 1949 да — 919, 1958 дә — 870, 1970 тә — 936, 1979 да — 717, 1989 да — 445, 2002 дә — 447 кеше. Д. тирәсендә *Дәвек комплексы* урнашкан.

*Әд.:* Ю с у п о в Ю. Дәвегем — дәү илем. Минзәлә, 2002.

**ДӘВЕ́К КО́МПЛЕКСЫ** (археол.) Минзәлә р-нының Дәвек авылы янында урнашкан. 10 истәлекне, ш.и. таш һәм бронза гасырларга караган туктаулыкларны, Пьянобор, Чулман һ.б. археол. культураларга нисбәтле каберлекне һәм авыллыкны үз эченә ала. 1949 елда Н.Ф.Калинин һәм А.Х.Халиков — палеолит, 1968 дә М.Г.Косменко — мезолит дәверләренә, 1958, 1969–70 елларда Р.С.Габәшев, О.Н.Евтюхова һ.б. бронза гасырга караган туктаулыкларны, 1968 дә А.Х.Халиков, Е.П.Казаков һәм П.Н.Старостин Пьянобор культурасы каберлеген тикшерәләр. Казу эшләре барышында комплекс терр-ясендә чакматаштан эшләнгән хезмәт кораллары, балчык савыт-саба кисәкләре, бронза бизәнү әйберләре һ.б. табыла.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987. Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989.

*Е.П.Казаков.*

**ДӘВЕ́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* читтә. 2008 елда 451 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.тә мәчет, мәдрәсә, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1299,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 435, 1897 дә — 803, 1908 дә — 981, 1920 дә — 915, 1926 да — 877, 1938 дә — 1005, 1949 да — 704, 1958 дә — 769, 1970 тә — 820, 1979 да — 722, 1989 да — 573, 2002 дә — 476 кеше.

*Әд.:* Г а р и п о в а Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. К., 2001. 1 том.

**ДӘВЕ́Ш ХАФИ́З** (17 йөзнең 1 нче яртысы), ташка уеп бизәк ясаучы, хаттат. Риваятьләргә караганда, Д.Х. чыгышы б-н Салагыш авылы (хәзерге Әгерҗе р-ны) кешесе була, Калморза авылында (хәзерге Минзәлә р-ны) яши. Аның исеме Калморзада 19 йөз уртасына кадәр сакланган борынгы зиратлары кабер ташларының берсенә уелган. Кабер ташы известьташтан эшләнгән, калыбы үзенчәлекле, очы ярым түгәрәк формада, зурлыгы 90×40×13 *см*, алгы ягыннан 1–1,5 *см* га чыгып торган, уеп ясалган кайма эченә алынган (киңлеге 8–9 *см*). «Нәстәгъликъ» гарәп имлясы б-н уеп язылган һәм 9 юлдан тора, 5 юл — гарәп телендә, 4 се татарча язылган. Бизәк төшерелмәгән. Кабер ташын 1992 елда М.И.Әхмәтҗанов таба һәм өйрәнә. Моңа охшаган тагын бер кабер ташы да аның тарафыннан Әгерҗе р-ны терр-ясендә табыла.



Д ә в е ш Х а ф и з. Калморза авылы зиратындагы кабер ташы (хәзерге Минзәлә р-ны). Известьташ. Уеп бизәкләү.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Тарихи чыганаклар // Идел. 1994. № 2.

**ДӘҖҖА́Л** (арамей телендә «даггал» — ялган мәгънәсендә), дөньяның һәм кешенең ахыргы язмышы тасвирланган мөселман риваятьләрендәге персонаж, христиан динендәге Антихристка тиңдәш. Исламга кадәрге гарәпләрдә Д. дип ялган пәйгамбәрләрне, күрәзәчеләрне атаганнар, соңрак әлеге образ мөселман эсхатологиясендә төп урыннарның берсен биләгән. Д. *Коръәндә* телгә алынмый, ләкин мөселман дини әдәбиятында еш очрый. Ахырзаман алдыннан Иблис б-н бәйләнешкә кереп һәм үзен *Гайсә* йә *Мәһди* пәйгамбәр дип белдереп, кешеләр арасында иң соңгы коткы таратучы буларак бәян ителә. Д. Тын океандагы утрауда кыяга кадакланган, имеш. Тәненең тиресе кызыл төстә, бер күзле, маңгаена «каф» хәрефе йә «*кяфер*» сүзе язылган булыр. Д., ахырзаман җиткәч, бик зур ишәккә атланып, тирә-ягына динсез һәм монафыйклар туплаган килеш көнчыгыштан килеп чыгар. Мәккә һәм Мәдинәдән кала бөтен дөньяны үзенә буйсындырыр. Д.нең хакимлеге 40 көнгә сузылачак, аннары Гайсә йә Мәһди килеп аны үтерәчәкләр.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ДӘЛИ́Я** (Dahlia), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, декоратив үсемлек. Чыгышы — Үзәк Америка (Мексика). Якынча 15 төре билгеле. Күптөрле Д. (D. variabilis) киң таралган. Катмарсыз, ярым катмарлы һәм катмарлы, төрле төстәге 3–35 *см* (ә ТР шартларында 5–10 *см*) диаметрлы чәчәкле, 30 *см* дан 250 *см* га кадәр биеклектәге куак барлыкка китерә. ТР чәчәкчелегендә төрле кыргый төрләрен серкәләндерү нәтиҗәсендә алынган культуралы Д. (D. cultorum) үстерелә. Яфраклары эре, аерым каурыйсыман, эре пычкысыман читле, кара-каршы урнашкан. Бөреләре чәчәк ботагында өчәр төркем булып формалаша. Чәчәк оешмасы — төрле формадагы, төстәге, зурлыктагы кәрзин. Чәчәк ату вакыты — июльдән сентябрьгә кадәр. Җимеше — орлыкча. Тамыр бүлбеләре бәбәкләре нигезендә (төбендә) агымдагы елда формалаша. 4–6 ел яши. 10 меңнән артык төре (күбесенчә гибрид) бар. Сортларны нигезенә катмарлылык дәрәҗәсе, үлчәме, чәчәк оешмасының формасы, чәчәкләр формасы (катмарсыз, җилдәксыманнар, пионсыман, декоратив, шарсыман, кактуссыман, ярым кактуссыман, катнаш) буенча классификацияләнә. Бүлбеләрен аеру һәм чыбыкча ялгау, сирәк очракта орлыктан (селекциядә) үрчетәләр. Бүлбеләрне үрдерү чорында аералар, март ахыры — апрель башында, ш.у. алдан үрдереп тормыйча май аенда (пленка б-н каплап) һәм июньдә ачык грунтка утыртканда аералар. Чыбыкча ялгау февральдән апрельгә кадәр уздырыла. Көзге кыраулардан соң (октябрь башында) бүлбеләрен казып алалар һәм 3–7°С темп-ралы коры бинада саклыйлар.

Корткычлар һәм авырулар б-н көрәш чаралары: ончыл чык, соры черек авыруларының беренче билгеләре барлыкка килүгә 10–14 көн ара б-н бакыр-сабын эремәсе, фундазол (0,2%), кальций содасы (0,4%); кисәү гөмбәсе авыруын 7–10 көн ара б-н 3 тапкыр бордосс сыекчасы (1%), бакыр хлорокисе (0,5%) сиптереп эшкәртәләр. Авыру үсемлекләрне юкка чыгару һәм Д.не якты урынга утырту вируслы авырулар б-н көрәш чарасы булып санала. Д.не күбесенчә гади әскәккойрыклар, күбекле бөҗәкләр, гөбләләр, пәрәвезле талпаннар зарарлый. Көрәш чаралары: карбофос (0,2%), коллоидлы күкерт (1%), рогор (0,2%), тәмәке, сарымсак, бәрәңге сабагы, кара тилебәрән орлыгы, башлы суган төнәтмәләре сиптереп эшкәртәләр.

*Әд.:* Энциклопедия цветовода. СПб., 2000.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ДӘМИ́НОВ** Руслан Абдулла улы (2.2.1949, Тәтеш р-ны Олы Тархан а.), җырчы (лирик-драматик тенор), ТАССРның атказ. артисты (1986). 1974 елда Казан консерваториясен (М.Кольцов классы) тәмамлый. 1974 тән Татар опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Альфред («Травиата», Дж.Верди), Фауст (шул исем. опера, Ш.Гуно), Рудольф («Богема», Дж.Пуччини), Владимир Игоревич («Князь Игорь», А.Бородин), Лыков («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Җик («Алтынчәч», Н.Җиһанов), Галимҗан («Башмагым», Җ.Фәйзи), Альфред («Ярканат», И.Штраус), Шүрәле («Шагыйрь мәхәббәте», Р.Ахиярова). Классик опера һәм оперетталарда, милли муз. спектакльләрдә Д. башкарган төрле характердагы партияләр (драмадан алып комедиягә кадәр) башкару осталыгы һәм сәхнә плас-

тикасы б-н аерылып тора. Д.ның концерт репертуарына татар, рус, совет, чит ил композиторлары җырлары керә. Ул Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә (Бөекбритания, Финляндия, Төркия, Голландия, Польша, Болгария һ.б.) чыгышлар ясый.

*Р.И.Такташ.*

**ДӘМИ́НОВА** Асия Мисбахетдин кызы (13.10.1913, Екатеринбург ш. — 28.10.1973, Мәскәү) геолог-петрограф, геол.-минерал. фән д-ры (1960), проф. (1961). Казан ун-тын тәмамлый (1936). 1936–39 һәм 1941–43 елларда Таҗикстан ССР Ленинабад шәһәренең геол.-разведка оешмаларында геолог, партия башлыгы; Кансай руда кырында һәм Карамазар руда төенендә кургаш-цинк чыганакларын эзләүдә һәм запасларын билгеләүдә катнаша. 1943 тән Мәскәүдә: Төсле металлар халык комиссариатында өлкән геолог; Төсле металлар ин-тында укытучы, петрография каф. мөдире (1946 дан), П.Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-тының петрография, минерал. һәм кристаллография каф. мөдире (1961 дән). Карелия, Таймырның магматик формацияләрен һәм алар б-н бәйле файдалы казылмалар ятмаларын тикшерә. Таймыр ярымутравының беренче геологик карталарын төзи.

Х е з м.: Петрография магматических горных пород: Учеб. М., 1967; Общие вопросы петрографии метаморфических горных пород. М., 1976.

*Н.Н.Трофимов.*

**ДӘРВИ́Ш** (фарсы. درويش — ярлы, фәкыйрь; «суфи» атамасының синонимы), мистик борадәрлек (тарика) әгъзасы. «Д.» атамасы 11 йөздән мәгълүм, шул вакыттан ук суфиларның остазлар җитәкчелегендәге рәсми булмаган түгәрәкләре оешу киң колач ала (к. *Суфичылык*). Иранда, Урта Азия һәм Төркиядә «Д.» атамасы ш.у. шәхси милке булмаган, ярлылыкта яшәүче мистик-аскет сукбай мәгънәсендә дә кулланылган. Д.ләр ике зур төркемгә — сукбайларга, ил гизеп йөрүчеләргә һәм остаз (ишан, шәех) кул астында даими бер урында яшәүчеләргә бүленә. Соңгыларына борадәрлеккә якын торучылар — үз өйләрендә яшәп эш б-н шөгыльләнүчеләр дә (һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һ.б.) керә. Аларга борадәрлекнең махсус көндәлек гыйбадәтләрен үтәү, яшәү урыннарында атнаның яки айның катгый билгеләнгән көннәрендә җәмәгать намазларында (зикер), шулай ук гадәти дини бәйрәмнәрдә катнашу мәҗбүр итеп куела. Д. Идел буенда Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм. Казан янында Д. б-н бәйле топонимнар сакланган (Олы һәм Кече Дәрвишләр бистәсе авыллары һ.б.).

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар: 2 томда. К., 1887–90; Ислам в Среднем Поволжье: История и современность. К., 2001; De Weese Devin A. Islamization and Native Religion in the Golden Horde: Bada Tukles and Conversion to Islam in Historical and Epic Tradition. University Park Penn., 1994; K e m p e r M. Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: der Islamische Diskurs unter Russicher Herrschaft. B., 1998.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**ДӘРВИ́Ш ГАЛИ́ ХАН** (? — 1558 дән алда түгел, Мәккә ш., Согуд Гарәбстаны), Әстерханның соңгы ханы (1554 елдан). Шәех Хәйдәрнең улы, Әхмәд ханның оныгы. Тәхеткә нугай морзасы *Исмәгыйльгә* һәм рус гаскәрләре көченә таянып утыра. Күрсәткән ярдәмнәре өчен Д.Г.х. русларга ел саен ясак түләргә вәгъдә бирә һәм патша Иван IV кә тугрылыкка ант итә. Исмәгыйль тарафыннан үтерелгән Йосыф морза уллары б-н берлектә 1555 тә *Ямгурчы ханны* җиңә. Исмәгыйльгә каршы сугышта алар җиңелүгә дучар була, һәм Д.Г.х. Хаҗитарханнан куыла. Шул ук елда Иван IV ярдәмендә яңадан тәхеткә утыра. Йосыфның уллары булышлыгында Мәскәү яклы аксөякләргә каршы көрәшә башлый, патша илчесе Мажуровны куып җибәрә һәм Хаҗитарханга төрек гарнизонын кертә. 1556 да И.С.Черемисинов җитәкчелегендәге рус гаскәрләре Хаҗитарханны яулап алгач, Д.Г.х. шәһәрдән кача. Нугайлар һәм Кырым ярдәменә өмет итеп, баскыннарга каршылык күрсәтергә тырыша. Әмма Нугай Урдасындагы үзара каршылыклар һәм 1558 елгы ачлык көчләрне берләштерергә комачаулый. Соңрак Д.Г.х. Азакка, аннан Мәккәгә китә.

*Әд.:* К у р б с к и й А.М. История о Великом князе Московском. СПб., 1913; Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. М.–Л., 1937.

*И.Л.Измайлов.*

**ДӘРВИ́Ш ХАН** (Гали Дәрвиш) (1398 тирәсе — 1419), Алтын Урда ханы (1414–19). Шадибәк ханның улы. Әмир Идегәй ярдәмендә Җаббарбирде ханны бәреп төшерә (1414) һәм Алтын Урда тәхетенә утыра. Д.х. заманында хакимият, асылда, Идегәй кулында була. 1416 елда көньяк рус җирләренә яу чаба, Киевны яндыра. 1419 да Урдага бәреп кергән Туктамыш улы Кадыйрбирдегә каршы сугыш башлый, шунда һәлак була.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Г р е к о в И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды. М., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**ДӘРДЕМӘ́НД** (псевд., чын исем-фамилиясе Закир (Мөхәммәдзакир) Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев) (23.11.1859, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе Җиргән а. — 9.10.1921, Оренбург өлкәсе Орск ш.), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, берничә алтын приискасы хуҗасы. 1862 елда гаиләләре б-н Орск өязе Юлык авылына күчеп киләләр. Анда әтиләре 1869 да алтын приискасы ача. Булачак шагыйрь авыл мәдрәсәсендә, аннары Орск һәм Муллакай авылы мәдрәсәләрендә белем ала. 1880–81 елларда Истанбулда яши, төрек телен һәм әдәбиятын, китап басу эшен өйрәнә. Абыйсы Шакир (Мөхәммәдшакир) б-н аңа әтиләреннән мирас булып 20 прииска кала. 1906 дан башлап алар Оренбург шәһәрендә *«Вакыт»* (нашире Д.) г-тасын, 1908 нең 10 гыйварыннан *«Шура»* ж-лын чыгара башлыйлар. 1909 да *«Вакыт»* типографиясен ачалар (1918 нең февралендә яңа хакимияткә тапшырыла). 1906–1912 дәге басмаларда Д.нең 40 лап шигыре дөнья күрә (1913 тән соң да шагыйрь язуын дәвам итә, ләкин беркайда да бастырмый). 1906 да Д. Оренбург губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасына депутат булып сайлана (мөселман фракциясендә тора), 2 нче, 3 нче чакырылышларының сайлаучысы, Оренбург шәһәр идарәсе, конституцион-демократлар



Дәрдемәнд.

партиясенең Оренбург бюросы әгъзасы була. *«Иттифакъ әл-мөслимин»* партиясен оештыруда катнаша. Хәйрия эше б-н шөгыльләнә: мөселман хәйрия җәмгыяте, мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте, мохтаҗларга ярдәм һәм ятимнәрне тәрбияләү ком-ты әгъзасы була; абыйсы б-н бергә үз хисапларына берничә студентны чит илдә укыталар, мәчет-мәдрәсәләр төзетәләр, аларны китап, дәреслекләр б-н тәэмин итәләр һ.б. Юлык авылында китапханә ача. 1917 дән соң приискаларын дәүләткә тапшыра (абыйсы 1914 тә вафат була), чит илгә китми.

Д.нең беренче басылып чыккан шигыре — «Үткән көннәр» (Р.Фәхретдиннең «Әсма» хикәясенә кергән). Шигырьләренең берничәсе 1902–03 тә «Тәрҗеман» г-тасында басыла. Татар теленә төрек шигырьләрен һәм хикәяләрен тәрҗемә итә («Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» (1884) шигыре генә сакланган). Үзенең поэтик карашларын Д. «Каләмгә хитаб» шигырендә билгели:

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!

Аның иҗатының тональлеген һәм тематикасын әдәбият галимнәре «моңлы уйлар», «бабалар кабере янында күңел зары», «килеп кичмешләр әхвален бәян итү» дип билгеләр. Д. лирикасында Шәрекъ традицияләре өстенлек итсә дә, тулаем алганда, Шәрекъ һәм Гареб традицияләренең тирән синтезы күзәтелә. Бу күренеш 20 йөз башы татар поэзиясенә гомумән хас (мәс., Г.Тукай, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй иҗатларына). Д. поэзиясендә бу синтез поэтик фикерләү нечкәлекләрендә үзен нык сиздерә, мәс., табигать күренешләрен төсләргә төреп тасвирлауда импрессионизм йогынтысы бар («Сеңеп җир-



Дәрдемәнд портреты. Рәссам А.Ә.Абызгилдин. 1996.



«Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналы хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Г.Фәхретдинов, Ф.Кәрими, Р.Рәкыйби, Р.Фәхретдин, Г.Акчокраклы, Дәрдемәнд (З.Рәмиев), Я.Вәли, Б.Шәрәф. Оренбург. 1909.

гә...»). Бу синтез шулай ук татар шигыренең строфикасы яңаруында да («Кораб», «Кыш көннәре», «Ятам кай чакларны моңлап ...», «Бу — ул ...»), фәлсәфи-стилистик эзләнүләрдә дә сизелә. Дөньяны галәм масштабы киңлегендә күзәтү Д. иҗатында, бер яктан, Рудаки һәм Гомәр Хәйямнәрнең фәлсәфи лирикасына, икенче яктан, Гёте поэзиясенә килеп тоташа («Без», «Яз» һ.б.). Халык иҗатына мөрәҗәгать итеп, шагыйрь строфика һәм стиль өлкәсендә яңа ачышлар ясый («Видагъ», «Бүзләрем маналмадым»). Д.нең пейзаж лирикасы пантеистик оптимизм б-н сугарылган («Яз», «Бу — ул ...»).

Социаль гаделлек темасы Д. иҗатының үзәгендә тора. Ул аны төрле аспектларда куя, халык һәм хөкемдар проблемасын традицион яссылыкта хәл итә. Гаделлекнең нигезен хөкемдарның гадел булуында күрә. Идеал итеп Д. Библия һәм Коръән персонажы, борынгы яһүди-христиан һәм мөселман дөньясында зур абруй казанган Сөләйманны (христиан һәм яһүдиләрдә — Соломон) ала. Хөкемдарның чын бөеклеге, Д.нең күзаллавынча, аның гади кешене кайгыртуында чагыла. Тормыш мәгънәсенә һәм галәм серләренә шагыйрь табигать гармониясе аша төшенергә тырыша. Аның пейзаж лирикасы үзенең киң колачлылыгы һәм реалистик төгәллеге, автор һәм лирик геройның рухи һәм хисси якынлыгы, ритм, интонация, строфика һәм структура ягыннан төрлелеге б-н 20 йөз башы татар поэзиясенең кабатланмас күренеше булып тора.

Күренешләрне Д. гомумиләштерә, романтик сурәтләү чараларыннан файдалана. Ләкин аның поэзиясендә реалистик төгәллек үрнәкләре, детальләштерү алымнары, табигать күренешләрен биргәндә эзлекле динамика да бар.

Шагыйрьлек бурычы турында Д. дөнья әдәбиятының бөек гуманистлары рухында болай дип яза:

Караңгы төн исә якын-ераклар,
Хәзин кальбемне вакла — як чыракълар:
Гарибләр, шәм-чыракъ күргәндә юлда,
Дисеннәр: бер заман бар булган ул да ...
(«Кыйтга»)

Д. иҗатын өйрәнгән кайбер галимнәр (Г.Халит) аның поэзиясендә фатализм өстенлек итә дип исәплиләр. Мондый рух, мәс., Д.нең «Кораб» шигырендә үзен сиздерә:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
...
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Әсәрнең катлаулы метафорага нигезләнгән теле урта гасырлар татар шагыйре *Котбка* барып тоташа.

Башка татар зыялылары (Г.Ибраһимов, Г.Камал, Г.Тукай), социаль-эстетик идеал эзләгәндә, милләт өчен тарихи юнәлешләр турында уйланганда, шулай ук кораб образына мөрәҗәгать итәләр. Кешелек язмышы турында фикер йөрткәндә, бу образга Көнбатыш Европа фәлсәфәчесе А.Шопенгауэр да мөрәҗәгать иткән. Д.нең «Кораб» шигыре шагыйрьнең милләт язмышы өчен борчылуын чагылдыра. Үзенең кискен драматизмы, сурәтләр тыгызлыгы, яңа строфикасы, экспрессив хисчәнлеге б-н «Кораб» шигыре Д. иҗатында гына түгел, бөтен татар поэзиясендә күренекле урын ала. Гомумән, котылгысызлыктан чыгу юлларын шагыйрь кешенең рухи үлемсезлегендә һәм мәңгелек мәхәббәт хисендә күрә («Хәят»).

Ә с ә р.: Дәрдмәнд шигырьләре. К., 1929; Сайланма әсәрләр. К., 1959; Агарган кыл. К., 1999.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Татар әдипләре. К., 1978; Х и с а м о в Н.Ш. Дәрдемәнд // Казан утлары. 1989. № 12; Дәрдемәнд. К., 2003; Х а л и т Г. Концепция мира и истории в поэзии Дердменда // Портреты и проблемы. К., 1985; С а я п о в а А.М. Поэзия Дердменда и символизм. К., 1997.

*Н.Ш.Хисамов.*

**ДӘРЕ́ БОТКАСЫ́** (зәре боткасы), к.*Карга боткасы.*

**ДӘРЗАМА́НОВ** Җәүдәт Харис улы (13.10.1945, Лениногорск р-ны Сугышлы а.), язучы, журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1971 елдан (бүленеп) «Татарстан» ДТРКнда башта тапшырулар мөхәррире, 1999 дан әдәбият-сәнгать һәм муз. тапшырулар директоры. 1988–94 тә «Ялкын» ж-лы баш мөхәррире. Д.ның беренче шигырьләре 1960 еллар башында район газеталарында басыла. Күбрәк балалар һәм яшьләр өчен яза. «Солдат булдым» (1977), «Төнге маҗара» (1980), «Гөлназ мәктәпкә бара» (1983), «Безнең әлифба» (1985), «Илләр гизә Илгизәр» (1989), «Айбулат» (1991), «Күзле кычыткан» (2000) исемле шигырь җыентыклары авторы. «Җир авазы» (1987; русча тәрҗемәдә «Зов земли», 2002), «Бизмән йолдызлыгы» (1994) повестьларының сюжет сызыгына фантастик элементлар да кертелгән; язучы монда «әхлаклы, кешелекле, бер-береңә карата түземле булырга кирәк» дигән фикерне алга сөрә. Д. — 2002–2004 тә Татар интеллектуаль милек агентлыгы идарәсе рәисе.

*Әд.:* Б а т т а л Ф. Егетлекнең бер баскычы // Мәдәни җомга. 1985. 3 нояб.; Г а л и м у л л и н Ф. Илле яшьлек сабый // Ватаным Татарстан. 1995. 28 нояб.

**ДӘРИЯ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Брустан елгасының сул кушылдыгы (Ык елгасы бассейны). Озынлыгы 11,6 *км*, бассейнының мәйданы 61,3 *км²*. Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Дружба авылының көнчыгыш читендә, тамагы Маткауш авылыннан 1,4 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Д. елгасының 0,8 дән алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 49 *мм*, ташу агымы катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 300–400 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 0,96 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ДӘҮЛӘКӘ́Н РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1875 *км²*. Үзәге — Дәүләкән шәһәре (Уфадан 105 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 42138 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 11074, 1979 да — 9679, 1989 да — 8764, 2002 дә — 8505 кеше. Районда 96 торак пункт, ш.и. 19 татар, 7 татар-башкорт-рус, 6 татар-башкорт, 6 татар-украин, 4 татар-рус, 4 татар-рус-украин, 2 татар-украин-чуаш торак пункты бар. Иң зур татар авыллары (1999): Чуенчы (509 кеше), Ташлы-Шәрип (380), Имай-Карамалы (345), Искәндәр (322), Аюхан (307), Раев (305). Элеграк нигезләнгән авыллар: Имай-Карамалы, Биккарамалы, Ташлытамак (1748 дән мәгълүм), Чуенчы (1762). 2002/03 уку елында Д.р.ның 6 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 10 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Мерәс авылында Габдерәхим *Утыз Имәни* берникадәр яши һәм шун-

да җирләнә, Дәүләкән шәһәрендә язучы Ә.*Еникинең* балачагы һәм үсмер чагы үтә, Чуенчы авылында БР ФАнең мөхбир әгъзасы Н.Г.*Гатауллин*, тарих фән. д-ры Фәһим Л.*Сәяхов*, Яскаен авылында БР ФАнең мөхбир әгъзасы Фәнил Л.*Сәяхов*, Дәүләкән шәһәрендә пед. фән. д-ры Л.Г.*Сәяхова*, Имай-Карамалы авылында техник фән. д-ры Г.Г.Теләшев туган.

**ДӘҮЛӘКИ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 15 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 376 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында Д.дә мәчет һәм мәдрәсә була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1014 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 600; 1897 дә — 1004, 1908 дә — 1228, 1926 да — 1250, 1938 дә — 833, 1949 да — 823, 1958 дә — 728, 1970 тә — 642, 1979 да — 531, 1989 да — 407, 2002 дә — 399 кеше.

*Әд.:* Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. К., 2001. 1 т.

**ДӘҮЛӘ́Т БА́НКЫНЫҢ КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́**, 1864 елның 15 июнендә губернада кредит системасын җайга салу, акча әйләнешен җиңеләйтү, сәүдә, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы үсешенә ярдәм итү максатында оештырыла. Казан бүлеге тузган кредит билетларын яңаларына алыштыру, акча ваклау һәм эреләтү, биш процентлы билет купоннары буенча процентлар түләү; банкка, контораларга һәм бүлекләргә күчерү өчен казначылыклардан һәм шәхси затлардан акчалар кабул итү; сроклы һәм сроксыз кертемнәр кабул итү; хөкүмәт чыгарган һәм җитештерү тарафыннан гарантияләнгән кыйммәтле кәгазьләр купоннарын, ш.у. банк һәм конторалар биргән шәһадәтнамәләрне исәпкә алу; процентлы дәүләт кәгазьләре, акцияләр һәм облигацияләр, ш.и. Дәүләт банкының биш процентлы билетлары, казначылык билетлары, бурычларны һәм акцияләрне каплау комиссиясе билетлары, Тимер юллар җәмгыяте облигацияләре залогы буенча ссудалар бирү, дәүләт казначылыгы һәм банкы исәбенә вакыты күрсәтелгән документлар буенча түләүләр кабул итү; биш процентлы банк билетларын сатып алу һәм сату б-н шөгыльләнә. 1914 тә Казан бүлеге 119 контора дан һәм бүлекчәдән тора, аның акча әйләнеше 426 млн. сумга җитә. Бүлекнең эше б-н управляющий җитәкчелек итә, аны Дәүләт банкы управляющие тәкъдиме буенча Россия империясенең финанс министры билгели. Казан бүлегенең управляющийлары: В.П.Безобразов (1864–67), В.И.Польский (1872), Ф.Досс (1872), А.В.Рустицкий



Казанда Дәүләт банкы бинасы.
Архитекторы Н.М.Сапунов. 1912–14; 1996.

(1872–90), Н.В.Верховский (1892–1902), А.И.Светлицкий (1902–10), А.Ф.Квецинский (1910–14), Э.А.Берг (1914–17), И.А.Тихенко (1917–18).

1917 нең ноябрендә дәүләт милкенә күчерелә, аның нигезендә РСФСР Халык банкының Казан бүлеге оештырыла (к. *Милли банк*). 1917–18 дә анда Россия алтын запасының бер өлеше саклана (к. *РСФСРның алтын запасы*).

1912–14 тә шәһәрнең үзәк өлешендә арх. Н.М.Сапунов проекты буенча архитекторлар В.А.Трифонов һәм Ф.П.Гаврилов тарафыннан Дәүләт банкы өчен неоклассицизм стилендә модерн элементлары б-н ике катлы махсус бина төзелә. Бина эргә кат өстендә, планда Т рәвешендә салына. Аның озынлыгы буенча акча операцияләре залы урнашкан, фасадта ул ионик ордердагы парлы колонналары һәм зур а́ркасы булган портигы б-н аерылып тора. Портикның эчендә үзәк керү урыны һәм парад баскычлары бар. Залга тоташкан ике катлы ян-як канатларында контора бүлмәләре урнашкан. Дәүләт банкының конструктив төзелешендә металл балкалар, косоурлар, бетон плитәле түбәләр файдаланылган. Фасадлары неоклассицизм стилендә төзелгән, операцияләр залының бизәлешендә модерн архит-расы элементлары һәм мотивлары кулланылган. Уң канаты реконструкция барышында 1996 да төзелә (арх. А.Р.Кәримуллин). Хәзер бинада ТРның Милли банкы урнашкан.

*Әд.:* Государственный банк: Краткий очерк деятельности за 1860–1910 годы. СПб., 1910; Айдаров С.С. Архитектурные наследия Казани. К., 1981; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Банк на все времена. Государственный банк в Татарстане: вчера, сегодня, завтра. Берлин, 1997; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р., Хайрутдинова Л.Ф. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000.

*В.А.Шагалов, Х.Г.Надыйрова.*

**ДӘҮЛӘ́Т ДУ́МАСЫ**, Россиянең чикләнгән хокуклы, законнар чыгаручы вәкилләр учреждениесе (1906–17). 1905 ел, 17 октябрь Манифесты б-н оештырыла. Закон проектларын карау б-н шөгыльләнә. Д.Д.нда кабул ителгән карарлар соңыннан Дәүләт Советында (Россия парламентының югары палатасында) тикшерелә һәм патша раславына тапшырыла. Д.Д. 5 елга сайлана, бу вакыт узганчы император аны тарата алган, ул шул ук вакытта яңа сайлауларның һәм беренче утырышның вакытын билгеләгән. Баштарак 524 кешедән, 1907 нең 3 июненнән 442 кешедән торган. Утырышлар законлы дип табылсын өчен аларда Д.Д. составының аз дигәндә 1/3 өлеше катнашуы таләп ителгән. Депутатларны сайлау тигезсез хокуклы 4 курия буенча күпбаскычлы системада уздырылган: җирбиләүчеләр куриясе буенча һәр 2 мең кешегә 1 сайлаучы билгеләнгән; шәһәр куриясендә һәр 7 мең кешедән, крәстияннәр куриясендә һәр 30 мең кешедән, эшчеләр куриясендә һәр 90 мең кешедән 1 сайлаучы күрсәтелгән. Моннан тыш, утраклылык һәм милек цензлары гамәлдә булган. Халыкның зур өлеше (хатын-кызлар, 25 яшькә җитмәгән ир-атлар, хәрбиләр, полициядә хезмәт итүчеләр, губерна хакимиятендә югары урыннарда эшләүчеләр, укучылар, чит ил кешеләре, җинаять җаваплылыгына тартылучылар, җинаять кылуда шикле кешеләр һ.б.) сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән. Далалы өлкәләрдә (Акмола, Семипалат, Урал, Тургай өлкәләрендә) һәм Төркстан краенда (Җидесу, Каспий аръягы, Сәмәрканд, Сырдәрья һәм Фирганә өлкәләрендә) яшәүче халык өчен, гомуми сайлау законыннан тыш, махсус «Сайлаулар турындагы нигезләмә куллану турында» кагыйдәләр чыгарыла. Бу кагыйдәләр буенча җирле мөселман халкының Д.Д.на сайлауларда катнашу мөмкинлеге чикләнә. Һәр өлкәнең күпмеңле төп халкыннан берәр депутат кына сайлана. Әлеге төбәкләрдә сайлауларның тоткарлануы нәтиҗәсендә күп кенә депутатлар С.-Петербургка бик соңарып киләләр, кайберләре 1 нче Д.Д. таратылганчы килеп тә җитә алмый. 1907 нең 3 июнендә кабул ителгән сайлаулар турындагы закон сайлаучы вәкилләрнең (выборщикларның) санын җирбиләүчеләр һәм буржуазия файдасына үзгәртүне күздә тота. Яңа нигезләмә буенча сайлаучыларны 4 куриягә бүлү саклана, әмма шәһәр куриясе 2 разрядка (1 нчесе — эре шәһәр буржуазиясе, 2 нчесе — урта хәлле һәм вак буржуазия, интеллигенция, чиновниклар, һөнәрчеләр һ.б.) бүленә. Нәтиҗәдә сайлаучы вәкилләрнең 51,3% ын — җирбиләүчеләр куриясе һәм шәһәр куриясенең 1 нче разряды, 22,4% ын — крәстияннәр куриясе, 22,9% ын — шәһәр куриясенең 2 нче разряды, 2,4% ын эшчеләр сайлый. Д.Д.ның гомуми составы кыскартыла. Бу барыннан да элек милли төбәкләр хисабына эшләнә: Якутия өлкәсе һәм Урта Азия бөтенләй вәкиллектән мәхрүм ителә, Россиянең Азия өлешендәге губерналардан һәм өлкәләрдән сайланган депутатларның гомуми саны 44 кешедән 15 кешегә калдырыла. Әчке Россиядәге халыкның зур өлешен мөселманнар тәшкил иткән губерналардан сайланучы депутатларның да саны азайтыла (Уфа губернасыннан 10 урынына — 8, Оренбург губернасыннан 7 урынына 6 депутат). Д.Д. вәкаләтләре исәбенә законнар чыгару, аларны үзгәртү, тулыландыру, туктатып тору яки гамәлдән чыгаруны таләп итүче кануни фаразларны карау; министрлыклар һәм баш идарәләр өчен дәүләт тарафыннан расланган керемнәрне һәм чыгымнарны, земство алдында торган бурычларны үтәү өчен сметаларны тикшерү өстәлә. Д.Д. депутатларына гамәлдәге законнарны

туктату яки үзгәртү, яңа законнар чыгару турында таләпләр кертү, министрларның эшчәнлеген законсыз дип тапкан очракта аларга үз гамәлләрен аңлатуларын сорап мөрәҗәгать итү хокукы бирелә. Закон проектлары Д.Д.на министрлар яки Дәүләт Советы тарафыннан кертелә. Закон проектларын һәм көнүзәк мәсьәләләрне беренчел карау өчен даими эшләүче бюджет, финанс, дәүләт тарафыннан расланган керемнәрне һәм чыгымнарны тикшерү, запрослар, редакция, шәхси состав, фәрманнар чыгару, хәрби һәм диңгез эшләре комиссияләре төзелә. Ш.у. конкрет закон проектларын карау өчен вакытлы комиссияләр сайлап куела. Казан губернасыннан Д.Д.ның һәр чакырылышына 10 ар депутат (1 нче һәм 2 нче Д.Д.на губернадан 9 депутат, Казаннан 1 депутат, 3 нче һәм 4 нче Д.Д.на губернадан 10 депутат), барлыгы 37 кеше (кайберләре кабат күрсәтелә, к. 1 нче кушымта), ш.и. 7 татар (кайберләре кабат депутат була, к. 2 нче кушымта) сайлана. Мөселманнар мәнфәгатьләрен *Мөселманнар фракциясе* һәм *Мөселман хезмәт таифәсе* яклый. Д.Д. Вакытлы хөкүмәт тарафыннан таратыла. Барлыгы 4 чакырылыш сайлана.

**1 нче Д.Д.** (27.4 — 8.7.1906). Рәисе — С.А.Муромцев. Сайлауларның төрле вакытта узуы нәтиҗәсендә Д.Д. тулы булмаган составта (499 депутат) эшли. Партиячел составы буенча Дума кадетлар өстенлек иткән (161 депутат, к. *Кадетлар*) парламент була, 97 депутат хезмәт (трудовиклар) фракциясенә керә, партиясезләр — 103 кеше (фракцияләрнең составы даими булмый). Сайланган 25 мөселман депутатыннан 1 нче Д.Д. эшендә 22 кеше (Уфа губернасыннан — 6, Казан губернасыннан — 3, Баку губернасыннан — 3, Елисаветполь һәм Оренбург губерналарыннан — 2 шәр, Вятка һәм Эриван губерналарыннан, Карс, Терек, Тургай һәм Урал өлкәләреннән 1 әр кеше) катнаша. Сайлауларда Уфа губернасының мөселман халкы аеруча зур активлык күрсәтә, Думага сайланган 10 депутатның 6 сы мөселман була. Дума эшчәнлегенең беренче көннәрендә мөселман депутатларының күпчелеге кадетлар фракциясенә кушыла, әмма соңрак мөселман фракциясен төзү турында карар кабул ителә, аны оештыру җыелышы 21 июньдә була. 1 нче Д.Д.ның кыска гомерле булуы сәбәпле, фракция ахыргача оешып өлгерә алмый. Д.Д. депутатларының эше хөкүмәт сәясәтен тәнкыйтьләү, император исеменә котлаулар юллау һ.б. б-н чикләнә. Утырышларда төрле мәсьәләләр буенча 6 мөселман депутаты чыгыш ясый. Казан губернасы депутатларының зур өлеше кадетлар фракциясе составына керә. Дума эшендә аеруча Г.Ф.*Шершеневич* (җыелышлар иреге турындагы закон проектын төзүчеләрнең берсе) һәм А.В.*Васильев* (ачлыкка каршы көрәш буенча азык-төлек комиссиясе секретаре, аграр мәсьәлә буенча закон проектын эшләүдә катнаша) активлык күрсәтә. Бернинди закон проекты да кабул ителми. 1 нче Д.Д. утырышларында үзәккә аграр мәсьәлә куела. Депутатларның күпчелеге алпавыт җирләренең бер өлешен ирексезләп тартып алуны яклый, әмма бу хөкүмәт тарафыннан катгый рәвештә кире кагыла. Илдә хәл кискенләшкән шартларда хөкүмәт Д.Д.ның мондый составта булуын хәвефле дип таба. 8 июльдә Николай II указы б-н Д.Д. таратыла. Депутатларның бер өлеше протест йөзеннән Выборг шәһәрендә киңәшмә уздыра һәм хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән өндәмә кабул итә (к. *Выборг өндәмәсе*).

**2 нче Д.Д.** (20.2. — 2.6.1907). Рәисе — Ф.А.Головин. Д.Д. эшендә 518 депутат катнаша, аларның 104 е — трудовиклар, 98 е — кадетлар, 65 е — социал-демократлар, 50 се — партиясезләр. Дума составына 36 мөселман депутаты сайлана ( Уфа губернасыннан — 7, Казан губернасыннан — 4, Баку, Елисаветполь, Оренбург губерналарыннан, Дагстан өлкәсеннән һәм Закаталы округыннан — 2 шәр, Әстерхан, Вятка, Самара, Сембер, Таврия, Эриван губерналарыннан һәм Терек өлкәсеннән — 1 әр, Далалы өлкәләрдән — 4, Төркстан крае өлкәләреннән 6 кеше). Мөселман депутатлар Дума составында ике фракция төзиләр, Мөселман фракциясеннән тыш, Д.Д.ның сул канаты йогынтысында Мөселман хезмәт таифәсе оештырыла. Казан губернасыннан сайланган депутатлардан М.Я.*Капустин* (октябристлар фракциясе рәисе, көнүзәк мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый) һәм С.Н.*Максуди* (Д.Д. сәркәтибенең урынбасары булып сайлана) активлык күрсәтәләр. Составы буенча 2 нче Дума тагын да сулрак булып чыга. Хөкүмәтнең тыңлаучанрак Д.Д. турындагы өметләре акланмый. Беренче көннәрдән үк Дума таратылу куркынычы шартларында эшли, шул сәбәпле, депутатларның бер өлеше (башлыча, кадетлар) «Думаны саклау», 1 нче Д.Д.нда күтәрелгән радикаль таләпләрдән баш тарту лозунгын алга куялар. Элеккечә үк үзәктә аграр мәсьәлә тора. Хөкүмәт аны чишүнең үз вариантын тәкъдим итә, әмма ул депутатларның күпчелегендә яклау тапмый. Д.Д. тарату турындагы Манифестта (1907 елның 3 июне) депутатлар закон проектларын карауны сузуда гаепле дип күрсәтелә, аларның бер өлеше (с.-д. фракциясе) дәүләткә каршы заговорда катнашуда гаепләнә.

**3 нче Д.Д.** (1.11.1907 — 9.6.1912). Рәисләре — Н.А.Хомяков (1907–10), А.И.Гучков (1910–11), М.В.Родзянко (1911–12). Д.Д. эшендә 442 депутат катнаша, аларның 125 е — октябристлар, 90 ы — милләтчеләр, 53 е — кадетлар, 51 е — уң партияләр вәкилләре. Яңа сайлау системасы буенча Д.Д.на нибары 10 мөселман депутаты уза (Уфа губернасыннан — 4, Казан губернасыннан — 2, Оренбург губернасыннан, Дагстан өлкәсеннән һәм Закаталы округыннан — 1 әр, Баку, Елисаветполь һәм Эриван губерналарыннан — 1 кеше, Таврия губернасыннан — 1 кеше), аларның 8 е мөстәкыйль фракциягә берләшә, Закаталы округыннан һәм Дагстан өлкәсеннән сайланган депутат И.Гайдәров — с. -д. фракциясенә, Таврия губернасыннан сайланган депутат И.Мөфтизадә октябристлар фракциясенә кушыла. 3 нче Д.Д.нда «үзәк партиясе»нә әверелгән октябристлар партиясе хәлиткеч роль уйный. Столыпин хөкүмәтенең «башта тынычлану, аннан соң реформалар» сәясәтенә теләктәшлек белдереп, Дума составының уң октябристлардан торган күпчелеге кадетлар һәм прогрессистлар тарафыннан кертелгән закон проектларының күбесен (ш.и. Мөселман фракциясендә яклау тапкан гомуми башлангыч белем бирү турындагы проектны) кире кага. Д.Д. 2 нче Дума депутатлары тарафыннан кире кагылган аграр законнарны кабул итәләр, 1910–11 дә алар Бөек Финляндия кенәзлегенең автономиясен чикләгән законны, көнбатыштагы 6 губернада земстволар кертелүен раслаган законны (аның буенча сайлаучылар милли ике төркемгә — поляк һәм рус курияләренә бүленәләр) гамәлгә куялар. Казан губернасыннан сайланган депутатлардан А.Н.*Боратынский*, И.В.*Годнев*, М.Я.Капустин һәм С.Н.Максуди активлык күрсәтәләр. «Бер диннән икенчесенә күчүгә кагылышлы законнарга үзгәрешләр кертү турында» (Д.Д.тарафыннан кабул ителә, әмма Дәүләт Советы аны кире кага), «Сәүдә оешмаларында, складларда һәм конторараларда эшләүче хезмәткәрләрнең ялын тиешенчә тәэмин итү турында» дип аталган закон проектлары мөселман депутатларында кызыксыну уята. Мөселман фракциясе мөселманнарга аларның дине тарафыннан билгеләнгән көннәрдә ял итү хокукы бирү турындагы мәсьәлә б-н мөрәҗәгать итә. Әмма депутатлар законга әлеге үзгәрешләрне кертүне кирәк дип тапмыйлар. Мөселман депутатлары (арада иң активы С.Н.Максуди була) Россия мөселманнарының гражданлык хокукы бозылу, дини изү мәсьәләләре буенча актив чыгышлар ясыйлар. 3 нче Д.Д. депутатлары күп вакыт вак һәм мөһим булмаган закон проектларын карау б-н шөгыльләнәләр.

**4 нче Д.Д.** (15.11.1912 — 6.10.1917). Рәисе — М.В.Родзянко. Д.Д. эшендә 442 депутат катнаша, аларның 96 сы — октябристлар, 88 е — милләтчеләр һәм уртачыл уңнар, 64 е — карагруһчылар, 52 се — кадетлар, 32 се — прогрессистлар. Д.Д.нда мөселманнар иң аз санлы фракция (6 кеше) була. Казан татарлары Думага узмыйлар, чөнки җирле властьларның максатчыл сәясәте нәтиҗәсендә С.Н.Максудиның кандидатурасы үтми. Аз санлы булуы сәбәпле, Мөселман фракциясе прогрессистлар б-н блок төзи. Хөкүмәт эзлекле рәвештә Думаның закон чыгаручы ролен чикләргә тырыша, депутатлар каравына мөһим булмаган закон проектларын тәкъдим итә (1912–14 елларда 2 меңләп закон проекты кертелә), шул ук вакытта Думадан тыш законнар чыгару киң колач ала. 4 нче Д.Д.нда октябристлар үзәк ролне саклыйлар; кадетлар б-н блок оештырып, алар еш кына хөкүмәткә каршы оппозициядә булалар. Беренче бөтендөнья сугышы Д.Д. эшенә зур үзгәрешләр кертә: сессияләр даими рәвештә җыелмый, аларның вакытлары кыскара, законнарны хөкүмәт, башлыча, Д.Д.ннан башка гына гамәлгә куя. И.В.Годнев актив эшләвен дәвам итә, ул берьюлы 6 комиссия составында була, шуларның өчесендә җитәкчелек составына керә. Мөселман депутатлары шөгыльләнгән проблемалар үзгәрешсез кала. Төркиянең Беренче Балкан сугышында (1911–12) җиңелүе рус җәмгыятендә панславянизм рухының кү-

тәрелешенә китерә. Мөселманнарның үз дин кардәшләренә теләктәшлек белдерүен хөкүмәт Россиядә панисламизм һәм сепаратизм шытымнары барлыкка килү дип бәяли, бу Мөселман фракциясенең хәлен катлауландыра. Мөселман депутатлары берничә мәртәбә дәүләтләр арасындагы сугышны диннәр каршылыгына әверелдермәскә чакырып чыгышлар ясыйлар.

**1 нче кушымта** «Казан губернасыннан сайланган Д.Д.депутатлары исемлеге, аларның фракцияләрдә һәм Дума комиссияләрендә әгъзалар булып торуы»:

1 **нче Д.Д.**: Я.А.Абрамов (трудовик), С.Ш.*Алкин* (кадет, гражданнарның тигез хокуклылыгы комиссиясе әгъзасы), Г.С.*Бадамшин* (трудовик), А.В.Васильев (кадет, гражданнарның тигез хокуклылыгы, азык-төлек (сәркәтип), бюджет комиссияләре әгъзасы), М.Н.*Герасимов* (трудовик), П.А.*Ершов* (с.-д., җавап адрес төзү, дәүләт йөкләмәсен үтәү комиссияләре әгъзасы), И.Е.*Лаврентьев* (трудовик), К.В.*Лаврский* (трудовик, аграр комиссия әгъзасы), Ф.-К.М.*Миндубаев* (кадет), Г.Ф.Шершеневич (кадет, Д.д. сәркәтибе иптәше (урынбасары) редакцион комиссия әгъзасы);

**2 нче Д.Д.**: Г.С.Бадамшин (трудовик, бюджет комиссиясе әгъзасы), М.В.Батуров (трудовик, аграр комиссия әгъзасы), М.Я.Капустин (октябрист, Д.д. рәисе иптәше (урынбасары), китапханәләр, халык мәгарифе комиссияләре әгъзасы), Д.А.*Кушников* (кадет), С.Н.Максуди (Мөселман фракциясе, Д.Д. сәркәтибе иптәше (урынбасары), финанс, дин иреген гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән закон проектларын карау комиссияләре әгъзасы), С.Т.*Максутов* (Мөселман фракциясе), Г.М.*Мусин* (Мөселман фракциясе, җирле судны үзгәртеп кору комиссиясе әгъзасы), Г.И.*Петрухин* (трудовик), З.М.*Таланцев* (трудовик, финанс комиссиясе әгъзасы), А.Ф.*Фёдоров* (трудовик);

**3 нче Д.Д.**: А.Н.Боратынский (октябрист, гимназияләр комиссиясе рәисе), И.В.Годнев (октябрист, дәүләт йөкләмәсен үтәү (рәис иптәше — урынбасары), бюджет (сәркәтип), халык мәгарифе, тау эшләре комиссияләре әгъзасы), С.В.*Дунаев* (кадет, эчүчелеккә каршы көрәш комиссиясе әгъзасы), Г.Х.*Еникиев* (Мөселман фракциясе, Д.Д. сәркәтибе иптәше (урынбасары), халык мәгарифе комиссиясе әгъзасы), Н.П.*Ефремов* (кадет), М.Я.Капустин (октябрист, Д.Д. рәисе иптәше (урынбасары), бюджет, халык мәгарифе, Финляндия (рәис ярдәмчесе), иске дин тарафдарлары эшләре комиссияләре әгъзасы), В.А.*Карякин* (октябрист, финанс, дәүләт йөкләмәләрен үтәү, азык-төлек (рәис), эчүчелеккә каршы көрәш комиссияләре әгъзасы), А.Л.*Лунин* (кадет, җир һәм крәстиян эшләре комиссияләре әгъзасы), С.Н.Максуди (Мөселман фракциясе, закон фаразлары комиссиясе әгъзасы), Н.Д.*Сазонов* (монархист), И.И.*Соколов* (прогрессист, чиркәү һәм крәстиян эшләре комиссияләре әгъзасы);

**4 нче Д.Д.**: И.А.Бажанов (октябрист, азык-төлек һәм старообрядецлар эшләре комиссияләре әгъзасы), П.Ф.Бычков (октябрист, сәүдә-сәнәгать комиссиясе әгъзасы), И.В.Годнев (октябрист, дәүләт йөкләмәләрен үтәү (рәис), бюджет (сәркәтип), халык мәгарифе, сәламәтлек саклау (рәис иптәше — урынбасары), ун-тлар уставлары һәм штатлары турындагы закон проектын карау, гимназияләр һәм әзерләү уч-щеләре турындагы закон проектын карау комиссияләре әгъзасы), Ф.Н.*Казин* (монархист, җир эшләре һәм җирле үзидарә комиссиясе әгъзасы), В.В.*Марковников* (октябрист, сәүдә-сәнәгать (сәркәтип), җирле үзидарә, юллар, балыкчылык, Д.д.ның Романовлар нәселенең 300 еллык хакимлек итү юбилеенда катнашу мәсьәләсен тикшерү комиссияләре әгъзасы), И.А.*Рындовский* (җир эшләре, а.х., балыкчылык, сәүдә-сәнәгать, запрослар комиссияләре әгъзасы), Д.Н.*Сверчков* (центрист, җир эшләре һәм суд комиссияләре әгъзасы), А.В.*Смирнов* (октябрист, дәүләт йөкләмәләрен үтәү, чиркәү эшләре, халык мәгарифе комиссияләре әгъзасы), Д.С.*Теренин* (октябрист, финанс, дәүләт йөкләмәләрен үтәү комиссияләре әгъзасы), А.С.*Юхтанов* (октябрист, җир эшләре комиссиясе әгъзасы).

**2 нче кушымта** «Д.Д.ндагы татар депутатлары исемлеге»:

Вятка губернасыннан — Х.С.*Мәсәгутов* (2 нче чакырылыш); Казан губернасыннан — С.Ш.*Алкин* (1 нче чакырылыш), Г.С.Бадамшин (1 нче һәм 2 нче чакырылыш), Г.Х.Еникиев (3 нче һәм 4 нче чакырылыш), С.Н.Максуди (2 нче һәм 3 нче чакырылыш), С.Т.Максутов (2 нче чакырылыш), Ф.-К.М.Миндубаев (1 нче чакырылыш), Г.М.Мусин (2 нче чакырылыш); Самара губернасыннан — Һ.М.*Атласов* (Атласи) (2 нче чакырылыш), М.Г.*Миңлегалиев* (4 нче чакырылыш); Сембер губернасыннан — Г.А.*Нәҗметдинов* (2 нче чакырылыш); Оренбург губернасыннан — М.М.Рәмиев (1 нче чакырылыш), Х.Г.*Госманов* (2 нче чакырылыш); Уфа губернасыннан — Ә.Г.*Әхтәмов* (1 нче чакырылыш), Г.Х.*Байтирәков* (4 нче чакырылыш), Ә.М.*Биглов* (2 нче чакырылыш), С.Д.*Максудов* (1 нче чакырылыш), К.Б.*Тәфкилев* (1–4 нче чакырылыш), К.Г.*Хәсәнов* (2 нче чакырылыш), М.М.*Хәсәнов* (2 нче чакырылыш).

Чыг.: Государственная Дума: Стенографические отчёты. Созыв 1–4. СПб., 1906–17; Указатель к стенографическим отчётам Государственной Думы. СПб., 1906–16; Мусульманские депутаты Государственной Думы России. 1906–17 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* Т у к т а р о в М.Ф. (Усал) Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены первой Государственной Думы. М., 1906; Члены второй Государственной Думы. СПб., 1907; Д ё м и н В.А. Государственная Дума России (1906–1917): Механизм функционирования. М., 1996; У с м а н о в а Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906–1917). К., 1999; ш у л у к. Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России, 1906–1917. К., 2002; Отечественная история: Энцикл. М., 1994. Т. 1.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ДӘҮЛӘ́Т ЗАЁМНАРЫ**, дәүләт бюджетына билгеле бер вакытка бурычка акча җәлеп итүнең бер формасы; дәүләтнең облигацияләр (кыйммәтле кәгазьләр) чыгару юлы б-н ниндидер чыгымнар каплау өчен халыктан бурычка акча алуының махсус кредит төре. Д.з. түләү вакытына карап — кыска вакытлы (1 елга кадәр), уртача (1 дән 5 елга кадәр) һәм озак вакытлы (5 елдан артык); керем төрләренә карап — отышлы яки процентлы (расланган ставка буенча ел саен керем түләнә), урнаштырылу урынына карап, эчке һәм тышкы заёмнарга бүленә. Эчке Д.з. — физик һәм юридик затлардан, финанс оешмаларыннан дәүләт валютасы б-н җәлеп ителгән средстволар, дәүләт керемнәрен тулыландыру чыганагы булып санала, дәүләтнең, мәҗбүри бурычка алучы буларак, түләү йөкләмәсе барлыкка килә. Тышкы Д.з. белән эш иткәндә бурычка биреп торучы бу дәүләтнең резиденты булып саналмый, ул бурычка алып торган илгә икътисади һәм социаль программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыруга рәсми ярдәм буларак бирелә. Д.з. ярдәмендә финанс ягыннан табыш китерми торган җәмгыяви эшләр, хезмәт күрсәтүләр, җиһазларга дәүләт чыгымнары һәм башка төр инвестицияләр финанслана.

Россия тарихында беренче тышкы заём Екатерина II тарафыннан 1769 елда Голландиядән алына, эчке Д.з. 40 ел узгач кына чыгарыла. 1809–1816 елларда 354 млн. сумлык Д.з. таратыла. 19 йөз урталарына кадәр дәүләт бурычының 10% ы — эчке Д.з., калганы заёмнарны чит илләрдә урнаштыру хисабына капланып киленә. Соңрак Д.з. сату, башлыча, Дәүләт банкы аша коммерция банклары яр-



Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы әгъзалары: (сулдан уңга утыручылар) — З.М.Таланцев, М.В.Батуров, М.Я.Капустин, Д.А.Кушников, С.Т.Максутов; 2 нче рәттә — Г.И.Петрухин, А.Ф.Фёдоров, С.Максуди, Г.М.Мусин.

дәмендә гамәлгә ашырыла. Окт. рев-циясеннән соң элекке Д.з. гамәлдән чыгарыла.

1922 елда алтын б-н 100 млн. сумлык 10 елга исәпләнгән беренче акчалата Д.з. чыгарыла. Бу заём облигацияләре, процентлар түләүдән тыш, отыш тиражларында катнашу хокукы да биргән. СССРда 1924 тә 100 млн. сумлык икенче отышлы Д.з. 5 ел вакытка исәпләп чыгарыла. Ике төр заёмны да халык арасында тарату максаты күздә тотыла. 1931–35 елларда 10 елга исәпләнгән биш Д.з. чыгарыла. 1935 тән 1957 гә кадәр дәүләт 40 заём чыгаруны гамәлгә ашыра. 1936–46 дагы заёмнар 1948 елгы 2 процентлы Д.з.на алыштырыла.

Хөкүмәт 1957 дә Д.з. облигацияләрен түләүне 20 елга кичектерү турында карар кабул итә. Совет хөкүмәтенең сугыштан соң чыгарылган барлык заёмнары да 1991 елга түләп бетерелә. РСФСРның 1991 елгы эчке дәүләт заёмы хәзерге Россия кыйммәтле кәгазьләр базарын үстерүдә беренче адым була. Беренче мәртәбә облигацияләрне кабат сатуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган механизмнар эшләнә. Федераль бюджетның РФ Үзәк банкына бирәчәген каплау өчен, заём 30 елга (1991–2021) исәпләп РФ Финанс министрлыгы тарафыннан чыгарыла. 1993 тә валюта заёмы чыгарыла, СССР Тышкы икътисади банкының (Внешэкономбанкның) юридик затлар алдындагы валюта бурычыаны кире кайтаруны гарантияләүче облигацияләргә күчерелә. Заём валютасы — АКШ долларында, процент ставкасы — еллык 3%, заём күләме — 7885 млн. доллар. Облигацияләрне Россиядән читкә чыгару тыела. РФ Финанс министрлыгы 1995 тә әйләнештәге вакыты бер елдан күбрәк булган чагыштырмача табышлы һәм шунлыктан инвесторларны җәлеп итә торган федераль заём облигацияләре чыгара. 1995 тә РФ Президенты Указы нигезендә Финанс министрлыгы тарафыннан РФ терр-ясендә табышы дәүләт кыйммәтле кәгазьләренең башка төрләреннән ким булмаган дәүләт саклык облигацияләре чыгарыла. Андый облигацияләр акчалата түләү мөмкинлеге бирә, алар илнең икътисадын инвестицияләү өчен халыктагы ирекле акча средстволарын җәлеп итү инструменты булып тора.

*Әд.:* Государственные займы СССР. М., 1975; Т е р е б о в В.Н. Каталог облигаций и обязательств внутренних государственных и целевых займов. М., 1990; С а р к и с я н ц А.Г. Система международных долгов. М., 1999; Экономическая энциклопедия. М., 1999.

*Р.А.Борһанова.*

**ДӘҮЛӘ́Т ЗАКАЗЫ́**, билгеле бер вакытка мәгълүм бер төр продукция җитештереп тапшыру, хезмәт күрсәтү, эш башкару хакында дәүләт тарафыннан пр-тиеләргә җиткерелгән йөкләмә. Д.з. — хуҗалык бәйләнешләрен көйләүнең, икътисадка тәэсир итүнең турыдан-туры дәүләти формаларыннан берсе. Д.з.ның икътисадтагы әһәмияте һәм аның киң җәелүе җитәкчелек итүнең үзәкләштерелү дәрәҗәсенә бәйле. СССРда идарә итүнең адм.-команда системасы вакытында Д.з. хуҗалык механизмының төп инструменты, пр-тие һәм оешмалар эшчәнлеген көйләү чарасы буларак файдаланыла, пр-тиеләрнең бәйсез хуҗалык итүләре үзәктән планлаштыру б-н бәйләп алып барыла. Ул беренче чиратта иҗтимагый ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә, фәнни-техник алгарышны үстерүгә, иҗтимагый җитештерү структурасын камилләштерүгә, мөһим натураль-матди пропорцияләр формалаштыруга, илнең оборона сәләтен ныгытуга юнәлтелә. Пр-тиеләрнең җитештерү программасында Д.з.на зур урын бирелә. Эшкәртү сәнәгатендә Д.з.ның күләме 30–40% тәшкил итә, казылма байлыклар чыгару тармагында тагын да югарырак була.

Хуҗалык итүнең базар шартларында Д.з. дәүләт пр-тиеләрендә генә түгел, шартнамә нигезендә яки конкурс үткәрү юлы б-н, башка төр милек формасындагы пр-тиеләрдә дә, халыкның тормыш көнкүрешен тәэмин итү, продукция җитештерүнең кайбер төрләрен чикләү (башлыча, чимал ресурслары), ш.у. илнең оборона куәтен һәм дәүләт иминлеген саклау өчен дә урнаштырылуы мөмкин. Дәүләт органнары һәм әзерләүче пр-тиеләр тарафыннан продукция җитештерүчеләр б-н кулланучылар арасында да Д.з. шартнамәләре төзелә. Шул шартнамәләрдә җибәрелә торган продукциянең номенклатурасы һәм күләме, аларны сатып алучылар, килешенгән бәя, якларның үзара йөкләмәләре һәм санкцияләре билгеләнә. Д.з. үтәүче пр-тиеләргә керем салымыннан ташламалар ясалырга, матди ресурслар б-н тәэмин ителергә, продукция сату һәм аннан алынган табыш гарантияләнергә мөмкин.

ТРда Д.з. системасы 1990 еллар урталарында формалаша башлый. Д.з.ның төп максаты — эчке товар җитештерүчеләрне яклау һәм аларга булышлык күрсәтү, бюджет чыгымнарын киметү, финанс средстволарының респ-кадан читкә чыгуын саклап калу. Д.з. урнаштырганда ТРда респ-ка җитештерүчеләренең, урта һәм кече бизнес пр-тиеләренең, ш.у. конверсияләнгән продукция чыгара торган хәрби сәнәгать комплексларының мәнфәгатьләре дә исәпкә алына. Шул ук вакытта респ-ка пр-тиеләрен тулы көченә эшләтү максатларында җитештерү, чимал һәм комплектлаштыручы эшләнмәләр б-н тәэмин итү, әзер продукция б-н респ-ка кооперациясе дәрәҗәсен күтәрү бурычы куела.

А.х. продукциясенең төп төрләре өчен Д.з. гамәлдә. Д.з. продукция сатуны һәм халыкны эш б-н тәэмин итүне гарантияли.

*Әд.:* А м б а р ц у м о в А.А., С т е р л и к о в Ф.Ф. 1000 терминов рыночной экономики. М., 1993; Н о з д р а ч ё в А.Ф. Государство как заказчик продукции // Государство и право. 1994. № 7; Р а й з б е р г Б.А., Л о з о в с к и й Л.Ш., С т а р о д у б ц е в а Е.Б. Современный экономический словарь. М., 1999.

*Ф.Р.Хәмидуллина.*

**ДӘҮЛӘ́Т КРӘСТИЯННӘРЕ́**, 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында Пётр I фәрманнары (1718–23) б-н крепостной бәйлелектә булмаган, игенчелек б-н шөгыльләнүче халыктан оештырылган аерым катлау. Крәстияннәрнең башка катлауларыннан аермалы буларак, Д.к. казна җирләрендә яшәгәннәр, җир кишәрлекләреннән файдаланганнар, казнага феодаль рента түләгәннәр, хөкүмәт органнары идарәсенә буйсынганнар, шәхси ирекле саналганнар. Казан губернасында Д.к. катлавы, башлыча, 18 йөз ахырында барлыкка килә. Аның составына *ясаклы крәстияннәр*, *йомышлы татарлар*, экономик крәстияннәр (элеккеге *монастырь крәстияннәре*), аерым йортлылар һ.б. керә. 19 йөзнең 1 нче чирегендә Д.к. статусы ирекле игенчеләр, элеккеге отставкадагылар һәм *игенче солдатлар*, *ау кошлары асраучылар*, ямчылар керә. Крәстияннәрнең башка катлаулары арасында Казан губернасында Д.к. күпчелекне тәшкил итәләр (1837 елгы мәгълүматлар буенча, 446535 ир-ат, ягъни 80,2 %). Иң күп Д.к. Чистай (57662 ир-ат — 82,8%), Казан (54000 — 77,3%), Мамадыш (48085 — 98,6%), Ядрин (43412 — 97,8%) һәм Тәтеш (42849 — 85%) өязләрендә була. Казан губернасының Д.к. арасында ясаклы, йомышлы һәм икътисад крәстияннәре 97% тәшкил итә. Милли яктан алганда, Д.к. арасында 36,1% — татарлар, 32% — чуашлар, 21,8% — руслар, 7,7% — марилар, 1,8% — мордвалар, 0,6% удмуртлар исәпләнә. Хуҗалык итүнең төп формасы — игенчелек. Д.к.ндә җирдән авыл җәмәгате б-н бергәләп файдалану гамәлдә була, даими рәвештә җирне тигезләп бүләләр. Казан казна палатасы мәгълүматлары буенча 1800 елда Д.к.ндә 3394440 дис. 1549 сажин җир исәпләнә, бу Казан губернасы терр-ясенең яртысыннан күбрәген тәшкил иткән. Җирнең мәйданы кыскара барган: бер ир-атка 18 йөз ахырында 15 дис., 19 йөзнең 1 нче яртысында 8 дис. туры килгән. Казан губернасында 1838 дә җир кишәрлеге — 7,6 дис., болын кишәрлеге 0,7 дис. күләмендә булган. Д.к. ш.у. умартачылык б-н шөгыльләнгән, читкә китеп эшләгән. Казан губернасының төньяк өязләрендә яшәгән крәстияннәр арасында урманчылык таралыш алган. Д.к.нең төп өлеше казнага акчалата рента түли. Пётр I заманында ул һәр җан башыннан елга 40 тиен күләмендә алына, 19 йөзнең 1 нче яртысында оброк 7 сум 50 тиеннән 10 сумга кадәр була. Удел һәм алпавыт крәстияннәренең бурычлары арткан саен, Д.к. түли торган акчалата рентаның күләме крәстияннәрнең башка категорияләре йөкләмәләре б-н чагыштырганда кими бара. Моннан тыш, Д.к. акчаларын җир ихтыяҗлары һәм дөнья-көнкүреш чыгымнары өчен сарыф итәргә тиеш булалар; алар җан башыннан алына торган салымны түлиләр һәм натураль бурычларны (рекрутлык, лашманлык (к. *Лашманнар*), юл, йөк ташу эшләре һ.б. йөкләмәләрне) үтиләр. 1832–35 елларда Казан губернасында земство җыемы һәр ир-атка 83 тиен тәшкил итә; моңа өстәп, һәр ир-ат земство ярдәм капиталы өчен 21 тиен, земство полициясен тоту өчен 30 тиен, азык-төлек капиталы өчен 25 тиен түләгән. Казан губернасында Д.к.ннән җыела торган еллык акчалата җыемнар һәр ир-ат өчен уртача 14 сум булган. Йөкләмәләрне төгәл үтәүне тәэмин итү өчен күмәк җаваплылык (к. *Авыл җәмәгате*) кертелгән. Чынлыкта натураль бурычларның зур өлеше дәүләт авылы җилкәсенә салынган. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында сәүдә һәм сәнәгать үсеше нәтиҗәсендә Д.к.нең хокуклары арткан: аларга ваклап һәм

күпләп сәүдә итүгә, фабрикалар һәм заводлар ачарга, «буш яткан» җирләрне биләргә рөхсәт бирелгән. 19 йөз башыннан актив рәвештә Д.к. исәбенә сәүдәгәрләр, мещаннар һәм цехчылар катлаулары тулыландырылган. 1806 да Казан губернасы сәүдәгәрләре арасында Д.к. даирәсеннән чыккан 1180 кеше, мещаннар һәм цехчылар арасында 1836 кеше исәпләнгән. Бер үк вакытта, алпавыт эшмәкәрлеге үсүгә бәйле рәвештә, дворяннар Д.к.н крепостнойларга әверелдерергә, үзләренең җир биләмәләрен киңәйтергә омтылганнар (к. *Генераль межалау*). 18 йөзнең 2 нче яртысында хөкүмәт дворяннарга йөзәр мең Д.к.н өләшкән; 19 йөзнең 1 нче яртысында дәүләт утарларын күпләп сату һәм аларны удел ведомствосына тапшыру киң колач алган. Губернада Д.к. б-н идарә итү өч юнәлештә — хуҗалык, суд һәм полиция катнашында башкарылган. Идарә системасы еш кына үзгәреп торган. Хуҗалык мәсьәләсендә дәүләт авылы губерна *казна палатасы* карамагында булган һәм аның составында махсус хуҗалык бүлеге оештырылган. Турыдан-туры идарә авыл хакимияте кулында тупланган, аны хөкүмәт күзәтче һәм салымнар җыючы сыйфатында файдаланган. Ул крәстиян үзидарәсенең нигезен хасил иткән авыл җыенында сайланган. 1837 гә кадәр Казан губернасында 887 авыл җәмәгате булган. Җыеннарда крәстияннәрнең хуҗалык һәм иҗтимагый тормышына кагылышлы мәсьәләләр (дәүләт салымнарын һәм йөкләмәләрен бүлешү, авыл җәмәгате җирләрен бүлү, дөнья-көнкүреш бурычларын билгеләү, гаилә бүленешләре, әҗәтләрне кайтару, старосталар, сотскийларны, десятскийларны, салым җыючыларны сайлау һ.б.) каралган. Моннан тыш, 1797 ел, 7 август Указы б-н крәстиян үзидарәсе системасына *волость идарәсе* дә кертелгән. Волостька бөтенесе бергә 3 меңгә кадәр кеше яшәгән авыллар һәм авыл җәмәгатьләре берләштерелгән. Казан губернасында 1800 дә — 106, 1837 дә 123 волость булган. Суд һәм полиция мәсьәләсендә Д.к. исправник җитәкчелегендәге земство полициясенә һәм түбәнге земство судына буйсынганнар. Земство суды башкарма һәм тикшерү хакимиятенә ия булган; ул земство йөкләмәләрен үтәүнең барышы, дәүләт салымнарын түләү, әҗәтләрне кайтару, рекрутларның туплануы өчен җавап биргән. Земство полициясе «җәмгыять тынычлыгын» саклауга, кандидатларның волость һәм авыл идарә органнарына сайлануына күзәтчелек иткән.

Аз җирлелек һәм бурычлар үсү нәтиҗәсендә 19 йөз башында Д.к.нең хәерчеләнүе һәм әҗәтләр артуы күзәтелгән: 1779 да Казан губернасында әҗәтләр 924470 сум, 1832 дә 3476640 сум тәшкил иткән. 1837–41 дә граф П.Д.Киселёв реформасы үткәрелә: Дәүләт милке министрлыгы һәм аның җирле органнары оештырыла, аларга авыл җәмәгатьләре аша Д.к. б-н идарә итү йөкләнә. Литвада, Белоруссиядә һәм Украинаның Днепрдан уң яктагы өлешендә Д.к.нең барщина йөкләмәләре бетерелә, дәүләт утарларын арендага бирү туктатыла, җан башыннан алынган оброк төгәлрәк күләмле җир-промысел җыемы б-н алмаштырыла. (Казан губернасында яңа салым-йөкләмә системасы 1862 нең язында кертелә). Әмма бу чаралар Д.к. хәленә мөһим үзгәрешләр алып килми. Аз җирлелек саклана, әҗәтләрнең күләме үсә, агротехник чаралар Д.к.нең төп массасы өчен артык кыйммәт була. Дәүләт авылын тамырдан реформалау мөмкинлеге крепостной хокук бетерелгәннән соң гына туа. 1861 елгы Крәстиян реформасын әзерләгәндә граф П.Д.Киселёв реформасы тәҗрибәсе (бигрәк тә крәстиян үзидарәсен оештыру һәм крәстияннәрнең хокукый халәтен билгеләү мәсьәләсендә) исәпкә алына; шул ук вакытта дәүләт авылы реформасы нигезенә крәстиян реформасының гомуми концепциясе кертелә (ул крәстияннәрнең җирне милек буларак сатып алуларын күздә тота). 1866 ның 24 ноябрендә «Дәүләт крәстияннәренең җир төзелеше турында» закон кабул ителә. Бу закон буенча авыл җәмәгатьләренең үз карамакларында булган җирләрне «биләү» (турыдан-туры файдалану) хокукы саклана, әмма җан башына кишәрлекләрнең күләме аз җирле губерналарда 8 дис.дән, күп җирле губерналарда 15 дис.дән артмаска тиеш була. Кишәрлекләрне милек итеп сатып алу хокукы 1886 ел, 12 июнь законы б-н раслана. Бу реформаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Д.к.нең җирләре үзәк губерналарда 10% ка, төньяк губерналарда 44% ка кыскара. Сатып алу өчен түләүләр оброк б-н чагыштырганда 45% ка арта. Түләүләр 1931 елга кадәр дәвам итәргә тиеш була. Ш.у.к. *Крәстияннәр*.

*Әд.:* С о ф р о н о в М.Г. Государственные крестьяне Казанской губернии и реформа П.Д.Киселёва: Дис. ... К., 1952; К а б у з а н В.М. Государственные крестьяне в России в XVIII — 50-х гг. XIX в.: Численность, состав и размещение // История СССР. 1988. № 1; Х а й р у т д и н о в Р.Р. Управление государственной деревней в Казанской губернии в конце XVIII — первой трети XIX вв. К., 2002; Отечественная история: Энцикл. М., 1994. Т. 1.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ДӘҮЛӘ́Т МИЛКЕ́ МИНИ́СТРЛЫГЫ МӘКТӘПЛӘРЕ́** (Киселёв мәктәпләре), башлангыч уку йортлары. Император Николай I нең 1842 елның 27 июне Указына һәм 1843 елда дәүләт милке министры П.Д.Киселёв тарафыннан расланган «Дәүләт крәстияннәре яшәгән урыннарда авыл приход уч-щеләре б-н идарә итү өчен кулланма»га туры китереп ачылалар. Мәктәпләр челтәрен булдыру, дәүләт авылларының көнкүрешен яхшырту буенча П.Д.Киселёв реформасының бер өлешен тәшкил итә. Дәүләт милке министрлыгының губерна органнары тарафыннан бюджет һәм дәүләт крәстияннәренең өстәмә җыемнары хисабына оештырыла һәм финанслана; укыту түләүсез була, укучылар кәгазь һәм язу карасы б-н тәэмин ителә. Мәктәпкә 8 яшьтән кече булмаган малайлар һәм кызлар кабул ителә, 3 ел дәвамында укыйлар, дәресләр кыр эшләре беткән вакытларда алып барыла (елына якынча 7 ай). Уку-язу, арифметика, а.х.ның төп нигезләре, дәүләт крәстияннәренең полиция уставы, христианнар өчен Ходай кануннары өйрәнелә.

Укытучылары, нигездә, руханилар семинариясе тәмамлаган җирле руханилар һәм аларның уллары була, эш хаклары аз түләнә. Уку программалары һәм бу тип мәктәпләр өчен билгеләнгән уку ярдәмлекләре булмаганга, төрле әлифбалар һәм арифметика дәреслекләре сатып алына, күп мәктәпләрдә уку-укыту әсбаплары булмый, 1843–65 елларда 3 меңнән артык мәктәп ачыла, 1866 га 2574 мәктәп эшли.

Казан губернасында 1844 тә 41 мәктәп эшли, 1632 бала укый, 1854 тә — 63 мәктәп, 1806 укучы. Дәүләт крәстияннәре балаларын мәктәпләр б-н тәэмин итү якынча 4% тәшкил итә. Укучылар арасында мөселман-татарлар бөтенләй булмый, керәшен татарлар һәм Идел буеның башка халыклары вәкилләреннән дә укучылар берәмләп кенә санала, чөнки укыту бары тик рус телендә генә алып барыла.

Укыту сыйфаты бик түбән була, начар укучылар, кагыйдә буларак, мәктәптән куп чыгарыла һәм алар бары тик укый-язa гына белә. Күп очракларда мәктәпләргә укучыларны көчләп җыялар, чөнки крәстияннәр балаларын солдатка алудан куркалар. 1866 да крәстияннәрне Эчке эшләр министрлыгы карамагына күчерү сәбәпле, мәктәпләрнең бер өлеше земстволарга тапшырыла, күбесе ябыла.

*Әд.:* З а б о л о ц к и й - Д е с я т о в с к и й А.П. Граф П.Д.Киселёв и его время: В 4 т. СПб., 1882; Д р у ж и н и н Н.М. Государственные крестьяне и реформы П.Д.Киселёва: В 2 т. М., 1958.

**ДӘҮЛӘ́Т** Надир (15.7.1944, Мукден ш., Кытай), тарихчы, тарих фән. д-ры (1982), проф. (1992), ТР ФАнең чит илдәге әгъзасы (2008). Истанбул (1971), Максимилиан (Мюнхен ш., 1974) ун-тларын тәмамлый. 1949 елдан Төркиядә. 1963–67 дә Ислам энциклопедиясе редакциясе, 1967–71 дә Төрек мәдәнияте фәнни-тикшеренү ин-ты хезмәткәре. 1972–84 тә ГФРда «Азатлык» радиостанциясендә (Мюнхен) татар-башкорт программалары редакциясе хезмәткәре. 1984–2001 дә Истанбулда Мәрмәрә ун-тында (бүленеп, 1989–90 да — Колумбия, 1996–97 дә Висконсин ун-тларында (АКШ) укыта); 1997–2001 дә Төрек тикшеренүләр ин-ты директоры. 2001–07 дә Едитепи ун-тында эшли (Истанбул), тарих каф. мөдире. 2008 дән Тиҗарәт ун-тында халыкара мөнәсәбәтләр кафедрасында. Төрки халыклар тарихы буенча күпсанлы хезмәтләр авторы. «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917)» (К., 1998), «Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды» (К., 2005), «1917 елгы Октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт Мәҗлесе (Эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе. 1917–1919)» (К., 2008) дип аталган хезмәтләрендә татар халкы сәяси тарихының актуаль сәхифәләре (1905–18 дә уздырылган Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары, төрки-татарларның Милләт Мәҗлесе эшчәнлеге һ.б.), Ерак Көнчыгыштагы татар эмиграциясе тарихы яктыртыла.

Х е з м.: Rusya Türklerinin Milli Mucadele Tarihi. Ankara, 1985; Ismail Bei Gaspıralı. Ankara, 1988; Cagdas Türk Dünyası. Ist., 1989; 1917 Ekim Ihtilali ve Türk-Tatar Millet Meclisi (Iç Rusya ve Sibirya Musluman Türk Tatarlarının Millet Meclisi — 1917–1919). Ist., 1998; Empires in Eurasia from

Chingis Khan to 20th Century. Ist., 2002; Liderligin Efendisi Çengis Han. Ist., 2007.

**ДӘҮЛӘТБА́ЕВА** Илсөя Муллаҗан кызы (8.8.1955, Казан), химик, химия фән. д-ры (1996), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). 1977 елда Казан ун-тын тәмамлый, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1980 нән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре нәсызыкча-оптик үзлекле полимерларны синтезлауга һәм тикшерүгә карый. Яңа тип антистатик һәм электр үткәрүчән полиуретан материаллар уйлап таба. Д. җитәкчелегендә металларга бәйләнешле мезоген олигомерлар һәм полимерларны синтезлауның төп закончалыклары исбатлана, шундый материаллардагы корылманы күчерү механизмы өйрәнелә; эш нәтиҗәләре Красногорск механика з-дында һәм С.М.Киров исем. Пермь з-дында (махсус билгеләнгән эшләнмәләр әзерләү) гамәлгә кертелә. Анионлы полимерлашу өчен каталитик системалар модификацияләү буенча тикшеренү эшләренә җитәкчелек итә.

Х е з м.: Исследование взаимодействия галогенидов железа с ароматическими изоцианатами в органических растворителях // Журн. прикладной химии. 1994. Т. 67, № 2 (автордаш); Мёссбауэровские исследования структурно-упорядоченных координационных соединений железа и структурированных ими полиуретанов // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 2006. Т. 48, № 6 (автордаш); Химия и технология синтетического каучука. М., 2008 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДӘҮЛӘТБИРДЕ́ ХАН** (? — 1429, Кырым), Алтын Урда ханы (1426 елдан). Таштимер ханның (башка фаразлар буенча — Гыясетдин солтанның) улы. Алтын Урдада тәхет өчен барган көрәштә катнаша; Литваның бөек кенәзе Витовт ярдәмендә Кырымны (1426–27), Түбән Идел буйларын, Хаҗитарханны (1427–28) яулап ала. Тәхеткә утыргач, үз исеменнән акча суктыра. *Олуг Мөхәммәд хан* б-н көрәштә һәлак була.

**ДӘҮЛӘТГИЛДИ́ЕВ** Шамил Хөсәен улы (1.10.1944, Мамадыш ш.), генерал-лейтенант (2004). Казан химия-технол. ин-тын (1967), СССР Дәүләт иминлеге ком-тының Оператив состав югары курсларын (Ленинград, 1973) тәмамлый. 1967–72 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында инженер. 1972–97 дә ТР Дәүләт иминлеге ком-тында. 1997–2001 дә РФнең ТРдагы салым полициясенең Федераль хезмәт идарәсе башлыгының 1 нче урынбасары, 2001–03 тә башлыгы. 2003–05 тә РФнең ТРдагы Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшерү дәүләт ком-ты башлыгы, 2005 тән ТРда коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ДӘҮЛӘТКИЛДИ́ЕВ** Касыйм Салигаскәр улы (11.4.1887, Уфа губ. Күгел а. — 19.1.1947, Уфа ш.), график, нәкышьче. Беренче проф. татар рәссамнарыннан; Башкортстанда сынлы сәнгатькә нигез салучы. Татар морзалары нәселеннән. 1914 елда С.-Петербургта барон А.Л.Штиглицның техник рәсем ясау уч-щесенең (хәзер В.И.Мухина исем. Дәүләт сәнгать-сәнәгать академиясе) дивар нәкыше классын тәмамлый. 1914 тән Уфада яши һәм эшли. Уфа нәкышь сәнгатен сөючеләр җәмгыятен (1913), Революцион Россия рәссамнары ассоциациясенең (АХРРның) Уфа бүлеген (1926) оештыручыларның һәм шулар эшендә катнашучыларның берсе. 1920 еллар ахырында В.И.Ленин исем. клубта сынлы сәнгать студиясе б-н җитәкчелек итә, Уфа сәнгать уч-щесендә (1930–35), татар-башкорт пед. курсларында (1930–37) укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1937). Башкорт халык иҗатын өйрәнә, 1928–35 тә сәнгать музее (хәзер М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музее) тупланмасы өчен этнографик материал һәм башкорт гамәли-бизәлеш сәнгате үрнәкләре җыю буенча Башкортстанның көньяк-көнчыгыш р-ннарына (Баймак, Бөрҗән) оештырылган экспедицияләрдә катнаша. Шушы сәфәрләр нәтиҗәсендә аның «Инҗәр заводы мотивы», «Яңа Усман авылы», «Түбә чишмәсе», «Баймак заводының гомуми күренеше» (барысы да — 1933 тә) исемле пейзаж картиналары барлыкка килә. Д. — акварель нәкыше остасы, иҗатының игътибар үзәгендә — башкорт халкының көнкүреше: «Башкорт кызы», «Зәңгәр күлмәкле башкорт кызы», «Башкорт Ибраһим», «Сунарчы башкорт» (барысы да — 1928). 1930–40 та майлы буяу б-н язылган «Мәҗит Гафури портреты», «Артист Г.М.Минһаҗев портреты», «Пушкин башкортлар арасында» картиналарын иҗат итә. Уфа нәкышь сәнгатен сөючеләр җәмгыяте (1916), Революцион Россия рәссамнары ассоциациясе (1926–28), Мәскәүдә уздырылган бөтенроссия — Окт. рев-циясенең 10 еллыгына багышланган (1927–28), «РСФСР халыкларының тормышы һәм көнкүреше» (1939), «РСФСРның өлкән буын рәссамнары» (1940), чит ил — «Советлар Россиясенең милли төбәкләрендә яшәүче рәссамнар» (1929, Сан-Диего ш., Калифорния, АКШ) исемле күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, БР Милли музеенда (Уфа) саклана.





К.С.Д ә ү л ә т к и л д и е в. 1. «Башкорт йорты болдыры». Кәгазь, акварель. 1928; 2. «Чәчәкләр төрле». Кәгазь, акварель. 1935. Икесе дә – М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда.



К.С.Д ә ү л ә т к и л д и е в. «Зәңгәр күлмәкле башкорт кызы». Кәгазь, акварель. 1928. М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее.

*Әд.:* Художники Советской Башкирии // Искусство. 1955. № 4; БСЭ. 3 изд. М., 1970. Т. 3; Искусство стран и народов мира: Краткая художественная энцикл. М., 1971. Т. 3; Башкортстан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**ДӘҮЛӘ́ТОВ** Әхтәм Әхәт улы (3.9.1950, БАССРның Бәләбәй ш.), хокук белгече, хокук фән. д-ры (1993), проф. (1995). Свердловск хокук ин-тын тәмамлый (1976), 1977–85 елларда шунда ук эшли. 1985 тән РФ Эчке эшләр министрлыгының Екатеринбург югары мәктәбендә: 1994 тән мәктәп башлыгы урынбасары, җинаять эше процессы каф. башлыгы. Хезмәтләре җинаять эше, андагы процессуаль хокук, җинаять эшләрен ачыклау-дәлилләү эшчәнлеге мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Основы уголовно-процессуального познания. Свердловск, 1991; Уголовный процесс. Екатеринбург, 1999 (автордаш).

*Е.Б.Долгов.*

**ДӘҮЛӘ́ТОВ** Бакир Рәхим улы (23.5.1915, хәзерге БРның Благовар р-ны Иске Әмир а. — 31.3.1982, Таҗикстан ССРның Турсунзадә ш.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), гв. өлкән сержанты. БАССР һәм Таҗикстан ССР төзелешләрендә эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 60 нчы гв. кавалерия полкында станоклы пулемёт командиры (61 нче армиянең 7 нче гв. кавалерия корпусы 16 нчы кавалерия дивизиясе). Брянск, Көнбатыш, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия, 1 нче һәм 3 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Белёвтан көньяктарак (хәзер Тула өлкәсендә) барган сугышларда (1942–43), Орёл, Чернигов-Припять (икесе дә 1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә 1945)



Б.Р.Дәүләтов.



Б.Я.Дәүләтов.



М.З.Дәүләтчина.

һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 28–29 сентябрендә Днепрның аръягында Вялье һәм Талки авыллары (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагинск р-ны) тирәсендәге сугышта батырлык күрсәтә: яуланган плацдармда дошманның контрһөҗүмнәрен кайтаруда катнаша. Сугыштан соң Регар шәһәрендә (хәзер Турсунзадә) эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Турсунзадә шәһәрендә бер мәктәп Д. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Сечкина Л.П. Твои Герои, Таджикстан. Душ., 1985; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДӘҮЛӘ́ТОВ** Баян Яркәй улы (8.3.1924, Минзәлә кантоны Татар Әҗбие а. — 21.10.1943, Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе, Лоевск р-ны Бывальки авылында җирләнә), Сов. Союзы Герое (30.10.1943, вафатыннан соң), лейтенант. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1281 нче укчылар полкының взвод командиры (65 нче армиянең 60 нчы укчылар дивизиясе). Үзәк фронт гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Чернигов-Припять (1943) һөҗүм операциясендә катнаша. 1943 нең 17 октябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: взводы б-н Бывальки авылы өчен аяусыз сугыш алып бара; дошманның пулемётларын юкка чыгарып, батальонның һөҗүменә ярдәм итә. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Д. исеме Бывальки авылында сугышта һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлнең мемориаль плитәсендә чокып язылган, Актаныштa мәктәп, урам аның исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДӘҮЛӘ́ТЧИНА** (Дәүләтшина) Мингалләм Зәйни кызы (22.5.1922, Оренбург өлкәсенең Матвеевск р-ны Яңа Әшер а. — 5.9.1992, шул ук өлкәнең Грачевск р-ны Таллы а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1937 елда Грачевск р-нының Коминтерн исем. с-зында сөтчелек фермасында башлап җибәрә һәм шунда 1977 гә кадәр эшли. Д. терлекчелектә яңалыклар кертә, р-нда һәм өлкәдә сөт саву буенча иң югары күрсәткечләргә ирешә. 1969 да сөт савуда рекордлы күрсәткечләр ала — һәр сыердан уртача 6543 *кг*; 1961–70 тә кул б-н 685 *т* сөт сава. Герой исеме терлекчелекне үстерүдәге алдынгы казанышлары һәм сөт савуда югары уңышлары өчен бирелә. 1970 тә ВЛКСМның Оренбург өлкә ком-ты тарафыннан Соц. Хезмәт Герое Дәүләтчина М.З. исем. приз булдырыла, ул ел саен иң яхшы яшь сыер саву остасына бирелә. Оренбург өлкәсе хезмәт ияләре депутатлары советы депутаты (1966–1970). Ике Ленин ордены, ике Октябрь Рев-циясе ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, дүрт көмеш медале б-н бүләкләнә. Грачевск р-нының халык музеенда Д.ның портреты куелган.

Хезм.: Лучше уход — выше надой. Оренбург, 1961.

*Әд.:* Россовский В.П. Герои Труда: Биограф. справ. Калуга, 1999; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006; Оренбургская биографическая энциклопедия. Оренбург, 2000.

*М.Я.Гаитов.*

**ДӘҮЛӘТША́ ИША́Н** (Дәүләтша бине Гаделша, Фазылша) (1767, фаразлар буенча, Уфа губ. Эстәрлетамак өязе, хәзерге БР, Эстәрлебаш р-ны Эстәрлебаш а. — 3.12.1832, Оренбург өязе Түбән Чебенле а.), язучы, дин эшлеклесе. Каргалы бистәсе һәм Бохара мәдрәсәләрендә белем ала. Укып кайтканнан соң, Кышкар, Югары Бирәзә (хәзерге Арча р-ны) мәдрәсәләрендә мөдәррис булып тора. Танылган татар дин эшлеклесе Габденнасыйр Курсави б-н бергә 20 елга якын Казан өязе Югары Курса мәдрәсәсендә укыта. 1821 елда Оренбург губернасына күчеп килеп, укыту эшчәнлеген дәвам иттерә, Түбән Чебенле авылы мәчетендә имам була. Бохарада укыган елларында Ниязколый әт-Төркмәни шәкерте булып, аннан мөридләрне укытуга рөхсәт алган дигән фараз бар. Кульъязма рәвешендә сакланган дини-дидактик эчтәлекле «Рисаләт эн-нәҗатийә» («Котылу китабы») авторы. Курсавиның яклап язган хезмәте булуы мәгълүм. Д.и.ның вафатына багышлап, аның шәкерте Һ.Салихов ике *мәрсия* яза.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1904. 1 җилд, 6 җөзья; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Исkандаров Р.Ш. Верхние и Нижние Чебеньки. Самара, 1999.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Әмирхан Хәсән улы (10.2.1934, Чистай р-ны Иске Роман а. — 30.11.2008, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2000). 1960 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм Чистай р-н үзәк хастаханәсендә хирург-уролог булып эшли. 1969 дан Казан мед. ун-тында оператив хирургия каф., 1991 дән топографик анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта 6 нчы шәһәр клиник хастаханәсенең «Ясалма бөер» үзәге һәм урологик авыруларга кичектергесез ярдәм күрсәтү бүлеге консультанты, организмны чистартуда бөердән тыш ысуллар куллануның шәһәр үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре корсакның эчке травмалары вакытында корсактагы гематомаларны дәвалауга һәм диагноз куюга карый. Д. тарафыннан эмбриогенезда уникеилле эчәкнең батынкы өлешендәге кан тамырларының 4 төре, корсак ярысыннан тышка кан агу чыганаклары тасвирлана, кан тарaлу юлларына топографик-анатомик нигезләмә бирелә, корсакның эчке травмалары вакытында кан китүләрнең өч төп урынына диагноз куюның комплекслы инвазион ысуллары тасвирлана: ашказанынннан алда — корсак өлешенә, корсак куышлыгына һәм корсактан читкә. Д. тарафыннан (Д.М.*Зөбәеров* б-н бергәләп), беренче буларак, корсак ярысы тышындагы гематомалар динамикасын биохимик ысул б-н тикшерү алымы эшләнә (1991). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Хирургия повреждений двенадцатиперстной кишки человека. К., 1998; Резекция желудка с выключением осложнённой дуоденальной язвы. К., 2000.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Гамирҗан Миргаҗан улы (12.8.1950, Сарман р-ны Дүсем а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1976–86 елларда Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының архив мөдире, 1986–96 да иҗтимагый фикер һәм археология бүлекләрендә, 1997–2000 дә ТР ФА Тарих ин-тының Археологик тикшеренүләр милли үзәгендә фәнни хезмәткәр. 2000–2005 тә Татар гуманитар ин-тында тарих каф. мөдире. 2005 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында Татарстан тарихы каф. проф. Д. хезмәтләрендә беренче булып тарих, археология, этнография һәм тел белеме казанышларын гомумиләштерү нигезендә татарларның борынгы һәм урта гасырлардагы (Төрки каганлык, Хәзәр каганлыгы, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы) бабаларының рухи мәдәниятенең гомуми халәте, үсеш дәрәҗәсе һәм үзенчәлекләре билгеләнә. Урта мәктәпләр өчен Татарстан тарихы дәреслекләре автордашы.

Хезм.: Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Волжская Булгария: духовная культура (X – начало XIII вв.). К., 1990; Очерки истории духовной культуры предков татарского народа (Истоки, становление и развитие). К., 2004.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Җәгъфәр Зөфәр улы (27.10.1960, Алексеев р-ны Түбән Тигәнәле а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1986). 1976–84 елларда Алексеев р-ның «Алга» к-зында эшли: а.х. техникасын көйләүче мастер, инженер-мелиоратор. 1984–88 дә урта һөнәри-техник уч-щедә укыта. 1988–90 да Алексеев р-ның «Алпар» с-зында инженер-мелиоратор. 1990–97 дә «Мелиорация» ПМКсында мастер, прораб, баш инженер. 1997–98 дә «Татарстан кыры» ФҖБнең Кама аръягы тәҗрибә кырында әйдәп баручы инженер, 1998 дән Кама аръягы зонасы селекция-орлыкчылык тәҗрибә стан-

циясендә директор урынбасары. Алексеев аграр көллиятендә укытучы. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге үләнчел сорго үстерү технологиясен эшләгәне, орлыкчылыгын оештырганы һәм аны җитештерүгә керткәне өчен бирелә.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Илдус Сөләйман улы (27.2.1947, Иваново өлкәсенең Вичуга ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1994). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1974). 1974–75 елларда Республика совхозларының җитештерү берләшмәсендә инженер. 1975 тән «*Майский*» с-зында, 1994 тән директор урынбасары. Дәүләт бүләге кышкы сезонда экологик зарарсыз яшелчә продукциясен ресурсларны саклап үстерү технологиясен эшләгәне һәм җитештерүгә керткәне өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Илфат Мәҗит улы (5.10.1964, Мамадыш р-ны Олы Өске а.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007), Композиторлар берлеге әгъзасы (1996). 1990 елда Казан мәдәният ин-тын (баян классы), 1995 тә Казан консерваториясен композиция (Р.Н.Белялов классы) буенча тәмамлый. 1990 нан 2003 кә кадәр Казан музыка мәктәпләрендә һәм мәдәният учреждениеләрендә эшли. Төрле симф., камера-инструменталь һәм камера-вокаль музыка жанрларында иҗат итә. Аның әсәрләрендә классик һәм хәзерге композиторларның язу алымнары, татар халкының традицион музыка мирасы табигый рәвештә үрелеп бара. Минзәлә һәм Буа татар драма театрларында куелган 5 спектакльгә музыка, 250 дән артык җыр авторы.

Төп әсәрләре: «1552 ел» (1995) исемле симф. поэма; кыллы оркестр өчен «Нурый» (Р.Н.Белялов истәлегенә, 2007); кыллы квартет өчен «Тәквимел иман» (1992), «Мосафир», «Сахраларда» (1994); флейта, кларнет, виолончель һәм фортепиано өчен «Сак-Сок» бәете (2000); балалар хоры өчен «Уен», Н.Исәнбәт әсәре буенча «Тычканнар җыелышы» (1996); театр, скрипка һәм фортепиано өчен «Әҗәлләргә дәва юк» (әтисе истәлегенә, 2002) вокал-инструменталь әсәрләре; сопрано, скрипка һәм фортепиано өчен «Сөембикә җыруы» (2000); фортепиано өчен «Сонатино» (1993), гобой, кларнет, валторна һәм фагот өчен «Авылда» (1991) исемле әсәрләре.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Илфрит Дәүли улы (5.4.1939, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн а.), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (1993), проф. (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1962–96 елларда Казакъстанда: 1966 га кадәр «Казгипрозем» проект ин-тында, 1966 дан Казакъстан ССР ФАнең Туфрак белеме ин-тында туфрак бонитировкасы лаб-ясе мөдире (1984–86). 1978–80 елларда Ливиядә фәнни командировкада була. 1996 дан Казан а.х. академиясендә. Хезмәтләре туфракның уңдырышлылыгын билгеләүгә, генезисына һәм географиясенә карый. Казакъстанның ярымарид (семиарид) зоналарында сөрүле туфракның бонитировка шкаласын теоретик яктан нигезли һәм төзи. А.х. культураларының уңышын формалаштыруда туфрак бонитеты баллары буенча районлаштыруның яңа алымын тикшерә. ТРның аграр секторында реформаларны камилләштерү концепциясен һәм методологиясен эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Бонитировка неорошаемых почв Казахстана. А.-А., 1976 (автордаш); Структура основной бонитировочной шкалы пахотных почв // Докл. АН Респ. Казахстан. 1992. № 3; Справочник по оценке плодородия пахотных почв Карагандинской области Республики Казахстан. К., 2008.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Камил Салихҗан улы (31.5.1935, Кызыл Армия, хәзерге Чистай р-ны Иске Роман а.), әдәбият белгече, филол. фән. канд. (1972). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1970–72 елларда СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли, 1972 дән Башкорт ун-тында (2003 тән проф.). Хәзмәтләре борынгы һәм урта гасырлар татар поэзиясе тарихына, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Ф.Яруллин иҗатларындагы дәвамчанлык проблемасына, Башкортстан татар шагыйрьләре (М.Вафин, Р.Идиятуллин, М.Нәзиров, С.Рәхмәтуллин һ.б.) әсәрләренең стилистик үзенчәлекләренә карый. Мәүла Колыйның поэтик мирасын текстологик яктан һәм әдәбият белеме кануннарыннан чыгып өйрәнә. Югары уку йортлары өчен укыту программалары, укыту-методик әсбаплар авторы.

Х е з м.: Борынгы татар әдәби мирасы. Мәүлә Колый хикмәтләре. Эстәрлетамак. 2002; Туган як шигърияте: индивидуаль стиль һәм поэтик образлылык мәсьәләләре. Уфа. 2002.

*Әд.:* Б у л а т о в а Д. Бәллүр // Тулпар. 2004. № 4.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Котдус Дәүләтша улы (22.04.1934, Чаллы р-ны, хәзерге Тукай р-ны Куады а. — 12.4.2006, Мәскәү), философ, журналист, философ. фән. д-ры (1998). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1963), ТАССР Язучылар берлегендә эшли (1963–64). 1964–67 елларда Биектау р-н г-тасының мөхәррир урынбасары һәм мөхәррире, 1967–76 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1976 дан СССР МС каршындагы дин эшләре буенча Советның өлкән инспекторы (Мәскәү). 1981 дән РФ Мәгариф (Мәгариф һәм фән — 2004 тән) министрлыгының Милли мәгариф проблемалары ин-тында, бер үк вакытта 1995–2000 дә «Татарские новости» г-тасының (Мәскәү) баш мөхәррире.

*Әд.:* Нации и ислам. К., 1986; Проблемы взаимосвязи национальных и религиозных компонентов культуры и быта. М., 2002.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Мөхәммәт Габделгалим улы (11.10.1923, Оренбург ш.), психолог, педагог, психол. фән. д-ры (1972), проф. (1972), Үзбәкстан ССРның атказ. фән. эшлеклесе (1975). 1955–68 елларда Ташкент пед. ин-тында проректор, 1968 дән гомуми психол. каф. мөдире. Хезмәтләре этнопсихологиягә, пед. кадрлар әзерләүгә карый.

Х е з м.: Способности и их диагностика. Таш., 1979; Национальная программа по подготовке кадров и задачи психологии. Таш., 1998.

*Әд.:* Мухаммад Габдулгалимович Давлетшин. Таш., 1998.

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Мөхәммәтша (1874, Мамадыш өязе Мамалай а. — ?), әкиятче. Аңардан 1939 елда Г.Бәширов язып алган тылсымлы әкиятләр («Аучы», «Алтынчәч», «Алтын алма», «Алтын балдак» һ.б.) «Халык әкиятләре» (1940), «Татар халык иҗаты: Әкиятләр». 1 кит. (1977) җыентыкларында басылып чыга.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Тамырбәк Динмөхәммәт улы (26.5.1904, Уфа губ. Зилдәр а. — 7.9.1983, Мюнхен ш., ГФР), тарихчы, юрист, җәмәгать эшлеклесе. Казан (1924–26), Иркутск (1926–28), Мәскәү (1928–30) ун-тларының юридик ф-тларында укый. 1932–38 елларда Икътисад фәнни-тикшеренү ин-тында (Уфа ш.) эшли, 1934 тән директор. 1938–41 дә Бөтенсоюз юридик ин-тының Казан ф-лында гражданлык хокукы профессоры, ТАССР ЮС Президиумы каршындагы юридик бүлек башлыгы. 1941 дә фронтка китә, җәй ахырында әсирлеккә эләгә, немецлар б-н хезмәттәшлек итә башлый, 1942 дә азат ителә; Берлинда яши, «Идел-Урал» г-тасын (Германия) чыгаруда катнаша. Сугыштан соң ГФРда кала. Татар-Башкорт милли ком-тын оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе (1951–52). 1951–69 да СССРны өйрәнү ин-тында фәнни хезмәткәр. Д. — сугыштан соң татар эмиграциясе идеологларының берсе, СССРның милли-дәүләт төзелешен һәм милли сәясәтен кискен тәнкыйть итеп чыга. Россиядәге татарларның тормышы б-н даими кызыксынып тора. Хезмәтләре Татарстандагы сәяси һәм икътисади халәткә карый. Татарча-немецча сүзлекне (1989) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: The Contemporary Economy of Tatarstan // The East Turkic Review. 1959. № 2; The Development of Tatar Education under the Soviet Regime // шунда ук. 1960. № 3; The Political Status of the Tatar Autonomous Republic // Studies on the Soviet Union. 1961. № 1; Советский Татарстан: теория и практика ленинской национальной политики. Лондон, 1974; Автобиография // Татарстан. 1991. № 11.

*Әд.:* С ә х а п о в Ә. Мюнхен институты профессоры // Йөртә безне язмышлар. К., 1992; Автобиблиография трудов Тамурбека Динмухамметовича Давлетшина // Проблемы лингвоэтноистории татарского народа. К., 1995.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ДӘҮЛӘ́ТШИН** Таһир Зөфәр улы (28.10.1958, Алексеев р-ны Түбән Тигәнәле а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (2000), проф. (2001). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), Алексеев р-нының а.х. идарәсендә баш мелиоратор булып эшли. 1985 тән Казан а.х. ин-тында. 1990 елдан «Татарстан кыры» фәнни-җитештерү берләшмәсенең Кама аръягы тәҗрибә кыры мөдире, 1998 дән Кама аръягы зональ селекция-орлыкчылык тәҗрибә станциясендә директор. Хезмәтләре язгы бодай, шикәр соргосы, Судан үләнен үстерү мәсьәләләренә карый. Судан үләненең «Аида» һәм «Тигәнәле» сортлары авторы. ТР Дәүләт бүләге үләнчел сорго үстерү технологиясен эшләгәне, орлыкчылыгын оештыруы һәм аны җитештерүгә кертүе өчен бирелә (2001).



Ә.М.Дәүләтьяров.



Н.Х.Дәүли.

*Әд.:* Формирование урожая яровой пшеницы на выщелоченном чернозёме Закамья при разных уровнях питания и влагообеспеченности. К., 1989; Культура сорго в Татарстане. К., 1999.

**ДӘҮЛӘ́ТШИНА** Дания Салих кызы (3.3.1934, Чистай ш.), хакимият-хуҗалык, партия эшлеклесе. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1955–56 елларда Алексеев р-ның Урта Тигәнәле авылында укытучы. 1956–60 та ВЛКСМның Алексеев райкомы 1 нче секретаре, 1960–62 дә КПССның Биләр райкомы секретаре. 1962–63 тә ТАССРның Октябрь колхоз-совхоз терр. җитештерү идарәсе инструкторы. 1963–64 тә ТАССРның Чистай колхоз-совхоз җитештерү идарәсендә КПССның партия ком-ты идеология бүлеге мөдире урынбасары, 1964–65 тә ТАССРның Алексеев җитештерү идарәсендә КПССның партия ком-ты секретаре урынбасары. 1965–70 тә Лаеш р-ны башкарма ком-ты рәисе, 1970–79 да КПССның Лаеш райкомы 1 нче секретаре. 1979–90 да ТАССР ЮС Президиумы секретаре. Бер үк вакытта ТАССР Хатын-кызлар берлеге рәисе. ТАССР ЮС депутаты (1971–90). Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ДӘҮЛӘ́ТШИННАР**, татар морзалары. Муллалар нәселеннән. Дворянлык хокукын 18 йөз ахырында алалар. Оренбург губернасы Оренбург өязендә яшиләр. Нәселнең бер вәкиле подполковник Габдулланың Имәнгол һәм Әүстәк авылларында 3396 дис. җире була; хәрби хезмәтләре өчен ике Изге Станислав ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Социальная эволюция служилых татар во второй половине XVI–XVIII веков // Исследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода. К., 1984.

*И.Р.Габдуллин.*

**ДӘҮЛӘТЪЯ́РОВ** Әхмәтсафа Мостафа улы (1905, Оренбург губ. Каргалы а. — 1938), дәүләт эшлеклесе. Татар пед. техникумын (Оренбург ш., 1925), Татар коммунистик ун-тын (Казан, 1930) тәмамлый. 1925–27 елларда Үзбәкстан КП(б) Хива округ ком-тының мәгълүмат һәм стат. бүлеге җитәкчесе. 1930–33 тә Минзәлә р-нында укытучылык эшендә. 1934–36 да ВКП(б)ның Кызыл Йолдыз райкомы секретаре, 1936–37 дә «*Кызыл Татарстан*» г-тасының баш мөхәррире. 1937 дән ТАССР ХКС рәисе. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Белялов У., Габитов Н. Давлетъяров Ахметсафа Мустафович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ДӘҮЛИ́** (Дәүләтшин) Нәби (Нәбиулла) Хәсән улы (1.6.1910, Спас өязе Иске Камка а. — 18.5.1989, Казан), язучы. ФЗӨ мәктәбен тәмамлагач, Донбассның металлургия пр-тиеләрендә эшли. Беренче язмалары Донецк шәһәрендә татар телендә чыга торган «Пролетар» г-тасында басыла. 1935 елда Казанга кайта. «Яшь сталинчы» г-тасында эшли, бер үк вакытта Казан пед. ин-тының кичке бүлегендә укый. Лирик-публицистик характерда «Бәхет» (1937), «Ал чәчәк» (1939), «Уйлар» (1940), «Кырык шигырь» (1941) исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыкларын бастыра. Бөек Ватан сугышы башлангач ук фронтка китә. 1941 нең августында Орша шәһәре янында барган сугышта әсирлеккә төшә, Германиягә озатыла. Фашист концлагерьларының барлык михнәтләрен кичерә. 1945 нең апрелендә төрмәдән кача, декабрендә Казанга әйләнеп кайта. 1956 га кадәр сәнгать оста-ханәләрендә бизәүче-рәссам булып эшли. Әсирлектә булуына шикләнеп карасалар да, Д.нең сугыштан соңгы иҗаты оптимизм һәм гражданлык рухы белән сугарылган. Ул иҗади хезмәт романтикасына, халыклар дуслыгына, Ватанга мәдхия җырлый. 1950 еллар ахырында аның шигырьләре кабат басыла башлый; «Юлда» (1957), «Көндәлек битләре» (1960), «Яңа көннәр туганда» (1962), «Авыл дәфтәре» (1966), «Мин җирдә калам» (1980) җыентыклары дөнья күрә. Д.нең проза әсәрләре документаль-автобиографик характерда. Аның «Яшәү белән үлем арасында» (1958; русчага тәрҗемәдә «Между жизнью и смертью», 1960) повесте авторның фронтта һәм әсирлектә күргән кичерешләрен тасвирлый. Шушы ук тема «Җимерелгән бастион» (1965; русчага тәрҗемәдә «Разрушенный бастион», 1967) повестенда да дәвам итә. Д. — балалар өчен пьесалар, миниатюралар, әдәби-публицистик мәкаләләр, очерклар авторы да. Аның күп кенә әсәрләре рус, башкорт, кыргыз, әзәрбайҗан, казакъ, төрекмән, украин телләренә тәрҗемә ителә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1969; Утро. День. Вечер: Стихи. М., 1975.

*Әд.:* Халит Г. Н.Дәүли шигырьләре уңаеннан // Совет әдәбияты. 1940. № 3; Галиев М. Яшәү белән үлем арасында // Татарстан. 1996. № 9; Маннапов Ш. Кайтмый еллар, кайталар җырлар // Казан утлары. 2000. № 6.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ДӘҮЛИКА́МОВ** Кәлимулла Сабирҗан улы (1.1.1946, Пенза өлкәсенең Каменск р-ны Мөчәләй а.), галим-агроном, селекционер, биол. фән. канд. (1977). Белоруссия ССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1990). Кузнецк вет. техникумын (1964) һәм К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен (1969) тәмамлый. 1971–73 елларда «Мөчәләй» с-зында баш агроном булып эшли. 1976–95 тә Шикәр чөгендере буенча Белоруссия зона тәҗрибә станциясендә шикәр чөгендере селекциясе бүлеге мөдире (Минск өлкәсенең Несвиж ш.), 1995 тән Белоруссиядә Шикәр чөгендере буенча селекция-орлыкчылык фирмасы Strube-Dickmann DL (Германия) вәкиле. Хезмәтләре шикәр чөгендеренең генетикасы, селекциясе һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. Гетерозиска гибридлаштыру өчен ана формаларны сайлап алу ысулын уйлап таба. Шикәр чөгендеренең бер шытымлы «Белорусская МС-27», «Белорусская односемянная 69» һ.б. сортлары авторы. Дәүләт бүләге шикәр чөгендеренең югары уңыш бирүче бер шытымлы интенсив типтагы яңа «Гануссовская односеменная 55» сортын чыгаргань һәм җитештерүгә керткәне өчен бирелә (1990).

*Әд.:* Влияние системы удобрений маточной свёклы и семенников на урожай семян и их качеств. М., 1981 (автордаш); Изменчивость качества семян и прогнозирование эффективности их отбора // Сахарная свёкла. 1982. № 12; Особенности селекции сахарной свёклы в Белоруссии // Достижения и перспективы в селекции сахарной свёклы. Киев, 1987; Продуктивный сорт сахарной свёклы // Сельское хозяйство Белоруссии. 1987. № 1.

**ДӘҮЛИКА́МОВА** Фәридә Илдус кызы (9.3.1967, Казан), невролог, мед. фән. д-ры (2005), проф. (2007). 1990 елда Казан мед. ун-тын тәмамлагач, Республика клиник шифаханәсенең 1 нче неврология бүлегендә эшли, 1996–97 елларда нейрофизиология лаб-ясендә табиб-невропатолог. 1997 дән Республика вертеброневрология үзәгендә, 1999 дан Казан мед. академиясенең вертеброневрология һәм мануаль терапия кафедрасында, 2002–06 да табибларны дипломнан соң укыту деканы, 2006–08 дә проректор. Хезмәтләре неврология, нейрофизиология, вертеброневрология, клиник миология һәм электромиографиягә карый. «Нерв системасының вертеброген авырулары вакытында невраль һәм мускул синдромнары» дигән хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге (2008) бирелә. 1998 дән «Вертеброневрология», 2009 да «Неврологический вестник» ж-ллары баш мөхәррире урынбасары.

Хезм.: Лечение вертеброгенной боли // Лечение нервных болезней. 2002. № 1 (автордаш); Нейрофизиологическая характеристика мимической мускулатуры верхней трети лица после многократного введения ботулотоксина типа А // Вестн. дерматологии и венерологии. 2009. № 1 (автордаш); Лёгкие когнитивные нарушения при сосудистых заболеваниях головного мозга // Неврологический вестн. 2009. Т. 16, вып. 3 (автордаш).

**ДӘҮРА́НОВ** Ирек Газиз улы (2.8.1939, Казакъстан ССР, Алма-Ата ш.), педиатр, иммунолог, мед. фән. д-ры (1985), проф. (1993). 1963 елда Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлый һәм Педиатрия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1981 дән Алма-Ата Диагностика үзәгенең иммунология клиникасы лаб-ясендә, 1993 тән Казакъстан мед. ин-тында. Хезмәтләре яңа туган балалар физиологиясе һәм патологиясенә, тудыру вакытындагы имгәнүләргә, балалар иммунологиясенә карый. Д. балалардагы метаболик статусны өйрәнә, иммунологик дәва ысулларын эшли һәм гамәлгә кертә.

Хезм.: Клетки крови в оценке здоровья детей. А.-А. 1994.

**ДӘФ** (гарәп. دف), чыгышы б-н Көнчыгышка бәйле борынгы татар муз. уен коралы, берьяклы мембранофон төре — агач кыршау торпычасы (диаметры 400 *мм* га кадәр, биеклеге 70 *мм*) бозау тиресеннән махсус эшкәртелгән күн б-н бер яктан тарттырылган. Тор-

пычаның эчке ягы металл алкалы. Д.нең кыеенарак яисә уртасына бармак бәрү мөмкинлегенә карап, аның авазы төрле тембрлар ала. «Гаруз» метроритмы системасына нигезләнгән вокаль әсәрләр б-н бергә башкару өчен, ш.у. сәяхәт итүче дәрвиш-суфилар тарафыннан Аллаһны олылаган догалар укыган вакытта файдаланылган. «Өсүли» ритмик формулалары булган, алар «саригъ», «рәмәл», «хәзаҗ», «мөтакариб», «басит» муз. тактларда бәет, мөнәҗәтләр башкарганда кулланылган. Г.Кандалый, Т.Ялчыгол әсәрләрендә Д. искә алына. Уен коралы 19 йөз урталарында кулланудан төшеп кала.

*Г.М.Макаров.*

**«ДӘФТӘРЕ́ ЧЫҢГЫЗНАМӘ́»** («Дастаны Чыңгызнамә»), 17 йөз ахыры татар әдәбияты ядкәре. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларындагы тарихи язмаларга һәм риваятьләргә нигезләнеп, билгесез автор тарафыннан төзелгән. «Д.Ч.»нең авторы дип 1670–71 еллардагы Крәстияи сугышында катнашкан дин эшлеклесе Идрис хафиз фаразлана. Әсәр Чыңгыз хан нәселе, Аксак Тимер, Гайсә улы Әмәт, Идегәй, төрле ханнарның яшәү урыны, биләмәләре турындагы 6 повесть-бүлектән тора; соңгы өлеше «Татар елъязмасы» буларак та мәгълүм.

Әсәрнең теле гади һәм тасвирлы, әйтемнәргә, фразеологизмнарга бай. «Д.Ч.»не беренчеләрдән булып И.Хәлфин өйрәнә. 1822 елда ул «Д.Ч.» әсәренең җыелма текстын һәм аның кушымта рәвешендә урнаштырылган татарча-русча сүзлеген бастырып чыгара. Басма Казан ун-ты студентларына, Казанның Беренче ир балалар гимназиясе укучыларына татар телен өйрәнү өчен әсбап булып хезмәт итә. «Д.Ч.»нең иң тулы басмасын 1882 дә Ф.Җиһаншин нәшер итә. 40 тан артык күчермәсе билгеле.

*Әд.:* Г а з и з Г., Р ә х и м Г. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники. XVII-XVIII вв. К., 1972; А б и л о в Ш.Ш. Книга дастанов // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999; И в а н и ч М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани. 1233–1556. К., 2002.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«ДӘҺРИ́»** («Атеист»), айлык иҗтимагый, фәнни һәм әдәби журнал. Башкорт алласызлар шурасы һәм ВКП(б)ның Башкорт өлкә ком-ты мәдәни-агарту бүлеге органы. 1928 елдан 1932 гә кадәр Уфа шәһәрендә нәшер ителә (1929 га кадәр татар һәм башкорт телләрендә). 1930 дан башкорт телендә «Аллаһыҙҙар» исемендә чыга. Мөхәррире Б.Ишемгулов. Журнал беренче саннарыннан ук дингә каршы көрәш, яшьләрне, «дини хорафатларга» ышанмыйча, материализм рухында тәрбияләү мәсьәләләрен күтәрә, дәһриләрне дин эшлеклеләренә каршы көрәш өчен белемнәр б-н коралландыру идеясен яклый. Ш.у. сатирик хикәяләр һәм фельетоннар бастыра.

*Әд.:* Башкортостанның милли матбугат альбомы // Ватандаш. 2000. № 3; Мәдәнейәт фырунтында Х йыл. Материалдар йыйынтыгы. Өфө, 1929.

*А.М.Ахунов.*

**ДӘШТЕ́ КЫПЧА́К** (Кыпчак даласы, Кыпчаклар иле), Иртеш елгасыннан Дунай елгасына, Балхаш күленнән Сырдәрьяның түбән агымына һәм Кырымга, Идел буе Болгар дәүләте б-н рус кенәзлекләренең көньяк чикләренә кадәр сузылган, башлыча, *кыпчаклар* күченеп яши торган далаларның 11–15 йөзләрдә гарәп-фарсы тарихи язмаларында кулланылган атамасы. Д.К. Көнбатыш һәм Көнчыгыш Кыпчак биләмәләренә бүленгән. 1220 елларда бу терр-яләрне монголлар басып ала; 1240 еллардан Алтын Урда биләмәсе. 16–18 йөзләрдә Казакъстан терр-ясенең көнчыгыш өлеше атамасы. 13 йөздә, Алтын Урданың этногеографик төбәкләренең берсе буларак, Евразия далаларының атамасына әверелә һәм киң таралыш ала. 14 йөздә «Д.К.» термины Алтын Урданың көньяк-көнбатыш өлешенә, аннары тулаем Алтын Урдага карата кулланыла. Бу чорда термин этник хасиятен югалта һәм историография традициясе элементына әверелә. 14 йөз ахыры — 15 йөз башында «Д.К.» термины «Татарлар иле», «Татария» һ.б. исемнәр тарафыннан актив рәвештә кысрыклап чыгарыла. Мөселман Шәрегында 18 йөзгә кадәр әлеге термин Алтын Урданың традицион исеме сыйфатында кулланыла. Илнең хәзерге тарих фәнендә әлеге терминның катлаулы семантикасы, аның өстенлекле этник характеры, ш.у. вакыт кысалары һәм тарихи картографик традицияләр нигезендә аны куллануны төгәл билгеләү зарурлыгы турындагы фикер ныгып урнашты.

*Әд.:* Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975; А р с л а н о в а А.А. Кыпчаки и термин «Дашт-и Кыпчак» (по данным персидских источников 13–18 вв.) // Национальный вопрос в Татарии в дооктябрьский период. К., 1990.

*И.Л.Измайлов.*

**ДӘШТЕ́ ХӘЗӘ́Р** (Хәзәр даласы), Төньяк Кавказ һәм Каспий (Хәзәр) диңгезе буе даларының 13–15 йөзләрдә гарәп-фарсы язмаларындагы атамасы. Д.Х.не 1220 елларда монголлар басып ала; 1240 еллардан Алтын Урда биләмәсе. Урта гасырлар Көнчыгыш тарих фәнендә Хәзәрстан җирләре атамаларының берсе. 13–15 йөзләрдә Алтын Урданың Хәзәр диңгезе буе төбәген һәм Җүчиләр яулап алган өлкәләрнең берсен атап йөртү өчен кулланылган. Мәс., Х.М.Казвини (13 йөз) бу сүзне «Дәште Кыпчак» төшенчәсе белән алыштырган яки «Саксин» терминын кулланган; фарсы тарихчысы Ш.А.Йөзди һәм Хива идарәчесе Әбелгази Баһадур хан Түбән Иделдәге өлкәне шулай атаганнар. Чынлыкта исә «Д.Х.» термины, этносәяси чынлыкка караганда, күбрәк шул чорның географик традициясен чагылдырган.

*Әд.:* Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**ДВИ́ГАТЕЛЬЛӘР ТӨЗҮ́**, машиналар төзүнең бер тармагы. ТР сәнәгатендә бу тармакка авиация, һава-реактив двигательләре җитештерә торган Казан моторлар төзү берләшмәсе (КМПО) һәм «КамАЗ» АҖнең «КамАЗ-Дизель» з-ды керә.

**Авиация двигательләре төзү.** Казанда авиация һәм моторлар төзү заводларыннан гыйбарәт булган авиация комплексын төзү эшләре 1932 елда башлана. Моторлар төзү з-ды 1938 дә продукция эшләп чыгара башлый. Аның төп җитештерү программасы М-103 моторлары өчен АЦН-2 (авиация үзәктән кугычы) эшләп чыгару була. Моторлар төзү з-дында эшләнгән детальләрдән В.Я.Климов конструкциясендә җыелган беренче ВК-105 двигателе 1941 елда сынап карала һәм В.М.*Петляков* конструкциясендә төзелгән пике ясаучы Пе-2 бомбардировщигына урнаштырыла. 1941–45 елларда Пе-2, ЛаГГ-3, Як-1/9 самолётлары өчен төрле модификациядәге 15 меңнән артык ВК-105 двигателе җитештерелә. 1940–45 тә моторлар төзү з-ды каршында В.П.*Глушко* җитәкчелегендә сыек ягулыклы ракета двигательләре (ЖРД) КБсы эшли. Ягулык компонентларын — азот кислотасы һәм керосинны насос ярдәмендә бирдерә торган сыек ягулыклы ярдәмче РД-1, РД-1х3, РД-2, РД-3 реактив двигательләр төзелә. 1943 тә Пе-2Р двигателе стендта һәм самолёт очышында сынап карала, 1944 тән Оборона дәүләт комитеты карары б-н з-дта РД-1х3 двигателен серияләп җитештерү үзләштерелә.

Реактив техника эшләп чыгаруга күчү 1946 да МиГ-9 самолётлары өчен С.Д.Колосов конструкциясендәге беренче буын РД-20 реактив двигателе җитештерүдән башлана (авиация двигательләре буыннары төп техник күрсәткечләргә: тарту көченә, куәтенә, чагыштырмача ягулык кулланылу күләменә, ш.у. конструкциясенең алдынгылыгына, нәтиҗәле файдаланылуына карап аерыла).

1948 елда Як-23 самолётына урнаштырылган РД-500С двигателе җитештерүгә керешелә. 1951 дә з-дта МиГ-15 самолёты өчен В.Я.Климов конструкциясендәге ВК-1 двигателе эшләп чыгарыла.

А.А.Микулин конструкциясендәге РД-3М-500 двигателе (тарту көче 95кН, икенче буын двигатель) дөньяда беренче реактив пассажир Ту-104 самолётына куела һәм самолёт 1956 дан даими оча башлый (ш.у. двигатель Ту-16 бомбардировщигына да урнаштырыла). 1962 дән Казан моторлар төзү з-ды өченче буын двигательләр — ерак араларга оча торган беренче совет самолёты Ил-62 өчен Н.Д.Кузнецов конструкциясендәге ике контурлы ике валлы реверсив җайланмалы двигатель (тарту көче 105кН) җитештерүгә керешә. НК-8–4 двигательләре ышанычылык һәм ресурс күрсәткечләре ягыннан совет һәм чит илләр үрнәкләре арасында иң яхшылардан санала. Уртача ераклыкларга оча торган Ту-154Б самолёты өчен Н.Д.Кузнецов җитәкчелегендә тәҗрибә КБ шул төрдәге НК-8–2У двигателен эшли.

1980 дә илнең һава юлларына КМПОда җитештерелгән дүртенче буын НК-8 двигательләре (тарту көче 130кН) урнаштырыла һәм 350 пассажирга исәпләнгән киң фюзеляжлы беренче совет аэробуслары Ил-86 лар күтәрелә. Двигательләрнең экономиялелеге, очып китә алу күрсәткечләре яхшыртыла һәм двигатель эшләвенең техник торышын бил-



**Двигательләр төзү**. 1. МиГ-15 самолеты өчен В.Я. Климов конструкциясе буенча эшләнгән ВК-1 двигателе; 2. Газ суырту агрегатлары (ГПА) өчен НК-38СТ двигателе; 3. «КАМАЗ-65115-04» автомобиленең егәрлек агрегаты.

геләү өчен бортка автоматик система урнаштырыла.

Двигательләрне серияләп җитештерү процессында аларның ресурсларын, ышанычлылыгын, экономиялелеге һәм экологиялелеген яхшырту б-н тәҗрибә КБ ф-лы шөгыльләнә, соңрак ул мөстәкыйль оешма — Казан машиналар төзелешен проектлаштыру бюросы итеп үзгәртелә.

1977 дән КМПОда Казан компрессор машиналары төзү з-ды һәм «Электроприбор» з-ды б-н берлектә төзелгән газ суырту агрегатларындагы (ГПА) НК-16–18СТ двигательләрен файдалы эш коэф. югарырак булган НК-38СТ двигателе б-н алыштыру, ш.у. аларны ГПА-16-«Волга» агрегатларына кую өчен тәҗрибә-сәнәгать эшләре башлана, тәҗрибә нәтиҗәләре 2004 тән серияләп җитештерүгә кертелә.

1982 дән КМПО илнең төрле климат зоналары шартларында эшли торган магистраль газ суырту станцияләренең (1 меңнән артык) компрессор күчергечләре өчен җир өстендә кулланыла торган газ турбиналы НК-16СТ һәм НК-16–18СТ двигательләре эшләп чыгара.

1985 тә Яшел Үзән шәһәрендә КМПОның филиалы — газ суырту агрегатлары өчен двигательләр җитештерү буенча Яшел Үзән машиналар төзү з-ды салына.

2002 дән КМПОда бишенче буын двигательләр — Ил-96, Ту-204, АН-70 самолётлары өчен Н.Д.Кузнецов конструкциясендә югары дәрәҗәдәге ике контурлы НК-93 винтовентиляторлы двигательләр җитештерү үзләштерелә. Казан моторлар төзү з-ды, «Прогресс» моторлар төзү КБсы (Украина, Запорожье ш.) б-н берлектә, Ту-324, Як-48 һ.б. самолётлар өчен АИ-22 двигателе җитештерә башлады.

**Автомобиль двигательләре төзү.** Европада дизельле көч агрегатлары җитештерү буенча иң эре пр-тие — «КамАЗ» АҖнең «КамАЗ-Дизель» з-дында автомобиль двигательләре эшләп чыгару 1976 елдан гамәлгә ашырыла, з-д эшли башлаганнан бирле биредә төрле модификациядәге 2,5 млн. нан артык дизель двигателе җитештерелә.

1975 тә двигательләр з-дында вакытлы технология буенча беренче көч агрегаты җыела, 1979 елга 100 меңенче көч агрегаты чыгарыла. 1995 тә 740.11–240, 740.21–240 һәм 740.20–260 двигатель модельләре Россиядә беренче мәртәбә Евро-1 халыкара экология стандартына туры килә торган сертификат ала.

Югары басымлы ягулык насосларыннан файдалану нигезендә двигательләрне камилләштерү һ.б. фәнни-техник үзгәртүләр «КамАЗ» автомобиль двигательләренең 740.30–260, 740.52–260, 710.53–290, 740.51–320, 740.50–360 модельләрен Евро-2 стандартына туры китереп сертификацияләргә мөмкинлек бирә.

«КАМАЗ» автомобиле двигательләрен төрле транспорт чараларына яраклаштыру-җайлаштыру эшләре дә алып барыла. 740.10–20 моделендәге двигатель электр агрегатларында һәм күчмә электр станцияләрендә, ш.у. аэродромнарда самолётларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән күчмә авиация агрегатларында күчергеч итеп тә кулланыла.

А.х. өчен җитештерелгән двигательләр арасында, 740.20–260 двигателе җирлегендә эшләнеп, Евро-1 таләпләре буенча сертификацияләнгән, турбиналы өрдергече һәм арадаш һава өрдергече булган 740.20–240 двигателе беренче тапкыр файдаланыла.

КамАЗда максатчан яңарту программасы эшләнә һәм яңа тип йөк автомобильләре төзелә:

– 260 а.к. егәрлегендәге двигательле, 24 *т* авырлыктагы «КАМАЗ-65115–04» транспорт автомобильләре;

– 260 а.к. егәрлегендәге тулы күчергечле «КАМАЗ-43118» автомобильләре;

– 320 а.к. егәрлегендәге двигательле, 33 *т* авырлыктагы зур йөк күтәрелешле «КАМАЗ-6520» автомобильләре;

– 360 а.к. егәрлегендәге двигатель б-н җиһазланган «КАМАЗ-5460–06» автомобильләре.

Шул программаларны гамәлгә ашыру өчен «КамАЗ» АҖдә экол. күрсәткечләре буенча Евро-1, Евро-2, Евро-3 халыкара стандартлар таләпләрен канәгатьләндерерлек 450 а.к. егәрлегендәге куәтле двигательләр төзү эшләре алып барыла.

Ш.у. к. *Авиация*, *Авиация сәнәгате*, *Казан авиация җитештерү берләшмәсе*, *Казан моторлар җитештерү берләшмәсе*, *КамАЗ*.

*Әд.:* Теория воздушно-реактивных двигателей. М., 1975; Казанскому моторостроительному — 70 лет. К., 2001; Ф а с х и е в Х.А., К о с т и н И.М. Обеспечение конкурентоспособности грузовых автомобилей на этапе разработки. Наб. Челны, 2001; Большая энциклопедия транспорта. М, 1995. Т. 2.; Авиационный транспорт. М., 1995; Политехнический словарь. М., 1977.

*Р.И.Әдһәмов.*

**ДВОРЯННА́Р**, 18 йөз башына кадәр дөньяви феодаллар катлавы төркемнәре, соңрак дөньяви җирбиләүчеләрнең, югары һәм урта дәрәҗәле дәүләт хезмәткәрләренең өстенлекле катлавы. Д. төшенчәсе берничә мәгънәдә кулланыла: 1) мирас өстенлекләренә ия булган дөньяви җирбиләүчеләр. Бу мәгънәдә термин Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә кулланылган. 2) 15–17 йөзләрдә Рус дәүләтендә — утарлары һәм биләмәләре булган, социаль һәм вазифаи статуслары б-н аерылып торган һәм документларда «ватан йомышлылары» дип йөртелгән йомышлы кешеләр. Совет әдәбиятында Д. еш кына хаксыз рәвештә феодаллар сыйныфының югары катлавы булган боярларга каршы куелды. Д., йомышлы катлау буларак, Россиядә Новгород феодаль республикасын Рус дәүләтенә кушканнан соң (1478) һәм Мәскәү кешеләренә Новгород җирләреннән күпләп биләмәләр бирә башлагач оеша башлый. Дворяннар ополчениесе Россия дәүләтенең һәм дәүләт аппаратының төп кораллы көчләрен (воеводалар, судьялар, салым җыючылар һ.б.) тәшкил итә. 16 йөзнең 2 нче яртысында дворяннар ополчениесе акрынлап «яңа строй полклары» б-н алыштырыла, аларда дворяннарның стандарт буенча коралланыуы һәм Европача өйрәтелүе зарур була. Элеккеге Казан ханлыгы территориясендә 16 йөзнең 2 нче яртысында биләмәләр һәм утарлар күпләп бирелә, рус дворяннарының күпсанлы җирле корпорацияләре (чыганакларда — Казан һәм Зөя «йомышлы шәһәрләре») барлыкка килә. Казан төбәгендәге рус дворяннарының күпчелек өлеше Түбән Новгород якларыннан һәм Россиянең үзәк районнарыннан чыккан кешеләрдән тора. Рус Д.ы арасында 14 йөздә бөек рус кенәзләренә хезмәт иткән һәм чукынган татар аксөякләре дә була. Аларның кайберләре (кенәз Мещерскийлар, Урусовлар, *Юсуповлар* һ.б.) Россиянең иң югары аристократиясе составына керә. Йомышлы татарлар (ш.и. руслашмаган яңа чукынганнары да) 16–17 йөзләрдә Д. б-н кушылмаган өстенлекле аерым төркем тәшкил итәләр. 3) Россия империясендә 18–20 йөз башында юридик яктан рәсмиләштерелгән хакимлек

итүче катлау. 18 йөзнең 1 нче яртысында аларны күбрәк «шляхталар» дип атыйлар. 18 йөздә Д.ның өстенлекләре (аеруча крепостной крестьяннар өстеннән хакимлек итү хокуклары) арттырыла, әмма алар гомер буе хәрби хезмәт итәргә тиеш була. Д.ның 16–17 йөзләрдә урнашкан терр. корпорацияләре — «йомышлы шәһәрләр» — җимерелә. «Дворяннарның ireклелеге турында» Манифесты нигезендә (1762) Д.ның дәүләт алдында нинди дә булса бурычы калмый. Шуның нәтиҗәсендә, бер яктан, Д.ның крепостнойларга карата башбаштаклыгы көчәя, икенче яктан, Д. арасында ирекле фикер йөртү башлана, Мәгариф идеяләре тарала (А.Н.Радищев, Н.И.Новиков, декабристлар). Д.ны башка катлаулардан чыккан кешеләр хисабына тулыландыруның төп механизмы — 18 йөздән — түрәләрнең «Ранглар турында табельләр» (1722) буенча үсүе, 19 йөздән югары уку йортларында хезмәт итүеннән гыйбарәт. Д. катлавының үзидарә органнары *Дворяннар җыеннары* була. Д. үз өстенлекләренең шактый өлешен (судтагы, хәрби хезмәттәге, җир биләүдәге) 1860 еллардагы реформалар вакытында югалта, әмма аларның дәүләттәге рәсми төп роле 1917 елгы Февр. рев-циясенә кадәр саклана.

18 йөздә Д. составына элеккеге йомышлы татарларның зур булмаган, нигездә, чукынган, акрынлап руслашкан өлеше генә керә; 18 йөзнең 2 нче яртысында башкорт аксөякләренең шактые Д. хокукы алуга ирешә. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында күп кенә татарлар, Алтын Урданың һәм Казан ханлыгының затлы ыруг нәселләре варислары Д. хокукын суд аша раслатырга тырышалар, әмма моңа кайберәүләр генә ирешә (кенәзләр: Вятка губернасында — Яушевлар, Бөгелмә өязендә — Надыйровлар һ.б.). Танылган мөселман ыругы нәселеннән булган кешеләргә Д. исемен Уфа губернасында күпләп бирәләр (Еникеевлар, Енгалычевлар, Терегуловлар һ.б.). Татар дворяннарының төп өлеше крәстиян тормышы алып баруын һәм дәүләт җирләреннән файдалануын дәвам иттерә, җан башына төшкән салымнардан тыш, крәстияннәргә тиешле барлык йөкләмәләрне башкара. 19 йөз — 20 йөз башында мөселман татарларның бик азы гына хезмәт һәм белем цензы буенча Д. составында була. Польша-Литва җирләрен Россиягә кушкач, Россия Д. составына *Польша-Литва татарларыннан* кенәзләр Тупальскийлар, Крычыньскийлар, *Туган-Барановскийлар* һ.б.ның гаиләләре кертелә. 19 йөз ахырында төрле губерналарның шәҗәрә китапларында 400 дән артык мөселман дворян ыругы теркәлгән була.

*Әд.:* Романович-Словатинский А. Дворянство в России от начала XVIII века до отмены крепостного права. СПб., 1870; Яблочков М. История дворянского сословия в России. СПб., 1876; Троицкий С.М. Русский абсолютизм и дворянство в XVIII в.: Формирование бюрократии. М., 1974; Карелин А.П. Дворянство в пореформенной России, 1861–1904 гг.: Состав, численность, корпоративная организация. Л., 1979; Лотман Ю.М. Беседы о русской культуре. Быт и традиции российского дворянства (XVIII — начало XIX века). СПб., 1994; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001.

*Е.В.Липаков.*

**ДВОРЯННА́Р ҖИР БА́НКЫНЫҢ КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́**, нәселдән килгән җирбиләүче алпавытларга, җир милекләрен закладка салып, озак вакытка ссудалар биреп торучы кредит учреждениесе. 1885 елда оештырыла. Максаты — югары катлауларның җир биләве кимүен туктату һәм дворяннарның икътисади хәлләрен ныгыту. Финанс министрлыгы карамагында була. Кредитларны ташламалы шартларда бирә: ссудалар залогка салынган утар бәясеннән 60–75% ка — 36–48 елга, 1890 нан 38–51 елга бирелә. Банкка ссудалар буенча түләү акционерлык банкларыныкына караганда 1,5–2% ка түбәнрәк була. Д.җ.б.К.б. үз операцияләрен, нигездә, Казан, Пермь һәм Вятка губерналары терр-яләрендә үткәрә. Бүлекнең 4,6 мең дис. җире була (1910). ХКСның 1917 ел, 8 декабрь Декреты б-н дәүләт милкенә әверелдерелә.

Чыг.: Устав Государственного дворянского земельного банка 1890. СПб., 1891.

*Әд.:* Отечественная история: Энцикл. М., 1994. Т. 1.

**ДВОРЯННА́Р ҖЫЕННАРЫ́**, 1766–1917 елларда Россиядә аксөякләр катлавының үзидарә органнары. Дворяннарга кагылышлы һәм җирлектәге гомуми эшләрне карыйлар. 1766 елгы Указ нигезендә өязләрдә төзелә; 1775 тә губерна Д.җ. оештырыла. 1917 елгы Февр. рев-циясенә кадәр яшәгән Д.җ.ның ахыргы структурасы 1785 тә кабул ителгән «Дворяннарга өстенлекләр грамотасы» нигезендә оештырыла. Өяз Д.җ. әгъзасы булып әлеге өяздә җир биләмәләре булган дворяннар тора. Губерна Д.җ.на керү өчен губернаның Шәҗәрә китабына язылырга кирәк булган. Д.җ.н дворяннар башлыгы җитәкләгән, ул өч елга сайланган. Барлык мөһим эшләр губерна Д.җ.нда хәл ителгән: шәхси дворян йөкләмәләренә җыемнар җыю каралган һәм аларны бүлү расланган, сайланулы вазифаи затлар (дворяннар башлыклары, депутатлар һәм сәркәтипләр, дворян опекасы утырышчылары, «җирләрне үзара килешү буенча межалау» өчен арадашчылар) сайланган. Д.җ. дворяннарның иҗтимагый тормышын оештыруда мөһим роль уйнаган: уку йортларын (к. *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты*), гыйбадәт урыннарын, төн куну йортларын, үзара ярдәм кассаларын тоткан, хәйрия стипендияләре булдырган, дворяннарның ялын оештырган, аларның мәнфәгатьләрен бюрократия башбаштаклыгыннан яклаган, дәүләт һәм җирле идарә органнарында дворяннарның йогынтысын тәэмин иткән. Дворяннар башлыгы губернатордан соң икенче вазифаи зат булган, Д.җ. рәисләре губерна б-н идарә итү өчен оештырылган барлык комиссияләргә һәм ком-тларга кергән. 1860 еллардагы реформалар барышында Д.җ.ның йогынтысы яңа оештырылган катлаулардан тыш земство үзидарә органнарына да җәелдерелгән. 1905–17 дә Д.җ. консерватив көчләрнең штабы булып хезмәт иткән. 1906 дан дворяннардан Дәүләт Советына депутатлар сайлаган. Уфа губерна Д.җ.ннан һәм мөселман дворяннар контролендә булган Бәләбәй өязе Д.җ.ннан кала, Д.җ.нда аз санлы татар дворяннарының роле зур булмаган. Күп кенә шәһәрләрдә Д.җ. биналары архит-ра истәлеге булып санала (к. *Дворяннар җыены бинасы*).

Казан губернасы дворяннары башлыклары: М.И.Палицын (1780–82), С.Б.Болховский (1782–87), В.Б.Болховский (1787–90), С.М.Тютчев (1790–93), П.Л.Молоствов (1793–97, 1806–09), В.И.Чемесов (1797–1803), П.И.Вешняков (1803–06), Ф.Ф.Геркен (1809–12), Г.Н.Киселёв (1812–24), А.Н.Евсеьев (1824–30), П.И.Еремеев (1830–42), Н.Д.Булыгин (1842–45), В.Ф.Желтухин (1845–48), Н.И.Чемесов (1848–51), Н.И.Депрейс (1851–54), Х.И.Нейков (1854–60), П.Г.Осокин (1860–71), А.Г.Осокин (1871–87), С.Н.Теренин (1887–1902), Н.Д.Сазонов (1903–12), С.С.Толстой-Милославский (1912–17).

*Әд.:* к. *Дворяннар, Дворяннар җыены бинасы* мәкаләләрендә.

*Е.В.Липаков.*

**ДВОРЯННА́Р ҖЫЕНЫ́ БИНАСЫ́**, Казандагы тарих һәм архит-ра ядкәре. Җыенның яңа бинасын төзү турындагы карар, аның Петропавел тыкрыгында урнашкан элеккеге бинасы 1842 елның августында янганнан соң, 1843 нең мартында кабул ителә. Казан архитекторы М.П.Коринфскийның классицизм стилендәге бина проекты Петербургта кире кагыла. 1844 нең апрелендә расланган яңа проект, фаразлар буенча, Петербург архитекторы Н.Е.Ефимов тарафыннан әзерләнгән дип исәпләнә. 1845 нең маенда Казан дворяннары эчке бүлмәләрнең планын үзгәртергә һәм төп залның күләмен зурайтырга тәкъдим кертәләр. Нәтиҗәдә Н.Е.Ефимов проекты буенча төзеләчәк «П» рәвешле бина планы турыпочмаклык рәвешенә үзгәртелә. Төзелеш (1845–53) б-н Коринфский (төп залның интерьер авторы), аннары И.П.Бессонов җитәкчелек итә. 1868 дә бина ишегалдында псевдорус стилендә кәшәнә төзелә (арх. И.Н.Грицевич, 1920 дә сүтелә), 1870 тә аңа кергә торган портик кушып салына.

Цоколь катына биек итеп күтәртелгән ике катлы, мезонинлы, симметрияле бинаның бер почмагы Театр мәйданы (хәзерге Ирек мәйданы) почмагына туры килә. Мәйдан ягыннан керә торган үзәк ишек а́ркалы портик эчендә калдырылган, өстенә балкон урнаштырылган. Бинаның тышкы күренеше



Казанда элеккеге Дворяннар җыены бинасы. 2000 елгы фоторәсем.

Италиядәге сарайларны хәтерләтә. Коридор һәм бүлмәләр системасы үзара яраштырылып, һәр каты төрле вазифалар үтәүгә нигезләнеп планлаштырылган. Цоколь катында ярдәмче һәм хезмәт башкару бүлмәләре урнашкан. Гражданнар 1 нче катта кабул ителгән, вестибюльдән юл канцеляриягә, дворяннар башлыгы кабинетына, китапханәгә, кече ашханәгә һәм буфетка, чишенү һәм швейцарлар бүлмәсенә илтә. Үзәк бүлмәләр — төп зал, зур ашханә, кунакханә һәм клуб — 2 нче каттa. Түр баскыч бинаның үзәгеннән күтәрелә, мезонинда төп залның төрле кичәләрдә катнашучы хорлары, кунакханә номерлары һәм музыкантлар бүлмәләре урнашкан. Беренче катның диварларында төрле архит-ра бизәкләре, яссы пилястралар урын алган. 2 нче катны зур, классик стильдәге кәрнизләр һәм Коринфский ордеры буенча төзелгән пилястралар бизи. 2 нче каттагы тәрәзә уемнары куш áрка формасында, тимпан фигурасы төшерелгән йөзлек б-н берләштерелгәннәр. Мезониндагы аркалы тәрәзәләр парлы итеп уелганнар. Фасадларның һәм интерьерларның гомуми стиле эклектиканың классик юнәлешендә башкарылган.

Сарайда, җыенның рәсми чараларыннан тыш, төрле тантаналар, концертлар, хәйрия кичәләре, күргәзмәләр дә уздырылган. Бүлмәләрнең бер өлешен Англия клубы һ.б. учреждениеләр арендага алып файдаланган. 1909 да төп залда — Ф.Шаляпин, 1914 һәм 1915 тә Л.Собинов җырлаган, 1910 һәм 1916 да С.Рахманинов һәм А.Скрябин концертлар биргән, 1914 тә футурист-шагыйрьләр В.Маяковский, В.Каменский, Д.Бурлюк чыгыш ясаган. 1917 нең 26 октябрендә биредә Казан губерна Советының утырышы була, анда шәһәрдә Совет власте урнаштырылуы игълан ителә. Окт. рев-циясеннән соң бина профсоюзлар карамагына тапшырыла: биредә бер-бер артлы Эшче сарае, Үзәк эшчеләр һәм студентларның союзара клублары урнаша. 1928 дән — Кызыл Армия йорты, 1940 тан — Офицерлар йорты. 1959 га кадәр бинада ТАССР ЮС утырышлары һәм КПССның Татарстан өлкә оешмасы конференцияләре уза. 1997 дә Казан хакимиятенә тапшырыла, 2002 дән капиталь төзекләндерү һәм реконструкция алып барыла, мезонин каты үзгәртеп корыла (И.Г.Нургалиев); әлеге эшләр 2005 тә тәмамлана. 2005 тән бинада Казан ратушасы урнаша.

*Әд.:* Е г е р е в В.В. Дворянское собрание // Материалы Центрального музея ТАССР. К., 1927; А й н у т д и н о в Р.А., Ч у д и н о в а Т.С. Здание Казанского дворянского собрания: Прошлое и настоящее. К., 2000.

*Т.С.Чудинова.*

**ДВОЯ́ШКИН** Нариман Камил улы (17.1.1950, Дүшәнбе), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1971 елда Дүшәнбе пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Таҗикстан политехник ин-тында эшли, физ. каф. мөдире (1986–88). 1992 дән Әлмәт нефть ин-тында физ. каф. мөдире, бер үк вакытта 1994 тән нефть һәм газ ф-ты деканы. Хезмәтләре сыеклык-күзәнәкле мохит системаларында полимерлар физикасына, сыеклыкларның молекуляр хасиятенә һәм ТМРга карый. Аномаль көчәюче үзлегеннән диффузияләнү үзенчәлеге б-н сыйфатлана торган югары үсешле өслек мохитендә флюидларның яңача торышын ачыклый (1988). ТРның Дәүләт бүләге иясе (2008). РФнең мактаулы югары һөнәри белем хезмәткәре.

Х е з м.: Влияние низкомолекулярных жидкостей на скорость кристаллизации олигоэтиленгликоля // Высокомолекулярное соединение. 1980. Т. 22 Б. № 3; Исследование методом стимулированного спинового эха самодиффузии молекул жидкости в средах со случайными препятствиями // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1992. Т. 101; Возможности градиентного ЯМР в исследовании самодиффузии в пористых средах // Изв. вузов. Нефть и газ. 2009. № 3 (автордаш).

**«ДЕБЮ́Т»**, язгы йомшак бодай сорты. 1999 елда Татарстан А.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Э.Ф.Ионов һәм Н.Э.Ионова тарафыннан ике югары сыйфатлы бодай сортын (көзге «Мироновская 808» һәм язгы «Московская 35» сортларын) серкәләндерү һәм аларның җирле туфрак-климат шартларына җайлашуына карап сайлап алу юлы б-н чыгарыла. Төре Lutescens. Уртача өлгерешле, корылыкка чыдам. Морфологик билгеләре буенча «Мироновская 808» сортына туры килә. Бөртегенең һәм аннан әзерләнгән продуктларның югары сыйфатлы булуы б-н аерылып тора. Көчле бодай. 2003 елда бу сорт ТРда Селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән.

**ДЕВАЛЬВА́ЦИЯ** (лат. de — төшү, киму мәгънәсен белдергәндә кулланыла торган алкушымча, voleo — әһәмиятле, бәһасе бар), чит ил валютасына карата акча берәмлегенең (милли валютаның) кыйммәтен рәсми рәвештә төшерү. Д.нең сәбәбе — инфляция, түләү балансы дефициты барлыкка килү.

Акча системасының эволюциясе процессында Д. төшенчәсе дә шактый үзгәрешләр кичерә. Металл акчалар әйләнеше вакытында Д. алтын яки көмеш б-н тәэмин ителгән акча бәһасе билгеләренең рәсми рәвештә төшүен белдерә һәм ил эчендәге акча әйләнешен тотрыкландыру ысулы булып тора. Сугышлар, сәяси яки социаль афәтләр б-н бәйле рәвештә акча әйләнеше чыгырыннан чыкканда иң түбән нисбәттәге металл акчалар яңага алмаштырыла. 1930 елларда акча берәмлегенә туры килгән алтынга алмаштыру туктатылу б-н Д. кайбер илләрнең тышкы базарда конкурентлык позициясен ныгытуга юнәлтелә һәм валюта сәясәте ысулы буларак кулланыла башлый. Чит илдән кертелгән товарларга бәяләрне автоматик рәвештә арттыру һәм чит илгә әйберләр чыгаруны стимуллаштыру б-н Д. илдә инфляция процессларын үстерүгә ярдәм генә итә. Ул халыкның, бигрәк тә дәүләт бюджетыннан керем алучы катлауның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә китерә.

1998 елда Россиядә сумның Д.ләнүе (3 мәртәбә) сикерешле инфляция (84,4%), финанс системасына һәм банкларга ышаныч кимү, икътисадта базар финанславы мөмкинлекләренең чикләнүе б-н бара. Шуның б-н бергә сумның Д.ләнүе макроикътисадның тотрыклылыгын эзлекле рәвештә торгызу өчен алшартлар да тудыра. 1998–2002 елларда РФ һәм ТРда чит илгә товар чыгаруга юнәлтелгән тармаклар (ТРда *вертолётлар төзү*) өзлексез үсә, чит илдән кертелгән продукция кыйбатлана, илнең сәнәгать товарлары җитештерү күләме арта, түләү балансы, бюджет торышы да яхшыра бара. Әмма Д.нең уңай тәэсире инфляциягә каршы чаралар системасында кыска вакытлы гына. Д. инфляцияне, бюджет һәм тышкы сәүдә балансындагы дефицитны, валюта кыенлыкларының төп сәбәпләрен бетерә алмый.

*Әд.:* Денежное обращение и кредит при капитализме. М., 1989; Н у р е е в Р.М. Деньги, банки и денежно-кредитная политика. М., 1995; Общая теория денег и кредита. М., 1995; Финансы, денежное обращение и кредит. М., 2000.

*Т.А.Денисенко.*

**ДЕВӘТЕРНӘ́** (Тугызбуй) авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 80 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кады елгасы буенда. 2008 елда 488 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1622 дән мәгълүм. 18 йөз ахырына кадәр Тугызбуй дип атала. 17–19 йөзләрдә халкы типтәр һәм асабалар катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сумала кайнату, күмер яндыру б-н шөгыльләнә, көнлекчелек б-н мәшгуль була. 19 йөз ахырында Д.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостена, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 46 ир-ат; 1834 тә- 371, 1859 да — 727, 1890 да — 944, 1926 да — 1424, 1938 дә — 1514, 1949 да — 710, 1958 дә — 1024, 1970 тә — 921, 1989 да — 655, 2002 дә — 546 кеше.

*Әд.:* М ә р д ә н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ДЕ́ВИЧЬЯ ПОЛЯ́НА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 23 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасының сул кушылдыгы Каеклы суы буенда. 2008 елда — 174 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Чистай кантоны Көтеш волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1926 да — 383. 1949 да — 503, 1958 дә — 332, 1970 тә — 527, 1979 да — 397, 1989 да — 211, 2002 дә — 166 кеше.

**ДЕ́ВИШЕВ** Гомәр (Умәр) Галим улы (1897, С.-Петербург — 1964?), актёр, режиссёр. Мәскәүдә Е.Б.Вахтангов җитәкчелегендә театр студиясен тәмамлый (1918), Курск, Харьков (Н.Н.Синельников җитәкчелегендә) шәһәр театрларында актёр. 1924–29 елларда Татар акад. театрында режиссёр, 1927 дән баш режиссёр, анда ул 20 дән артык спектакль куя. Рәссам К.К.Чеботарёв б-н берлектә Е.П.Кар-

пов әсәре буенча куелган «Эшчеләр бистәсе» («Рабочая слободка») исемле беренче спектаклендә үк татар театры сәхнәсенә пьесаны яңача кую культурасы: актёрлар уенында төгәл ансамбльлелек принцибын, сәхнә чишелешләренең образлылыгын, мизансцена күренешләренең төгәллеген алып килә. Д. театр сәнгатендә реалистик юнәлеш тарафдары була, шул ук вакытта милли театрда сәхнә телен тамырдан үзгәртергә, ачык театральлеккә, форманың тасвирлылыгына омтыла, кайвакыт шартлы алымнар да куллана, һәр спектакльдә драматургның төп фикеренә, заман рухына туры килерлек образлы чишелеш эзли. Д. тарафыннан куелган Г.Кутуйның «Балдызкай» (1926), Б.А.Лавренёвның «Разлом» (1928), М.Фәйзинең «Галиябану» (1929), Д.А.Фурманов һәм С.Поливановның «Фетнә» («Мятеж», 1929) әсәрләре республика театр сәнгатендә зур вакыйга буларак кабул ителә, һәм алар татар театрын гомумроссия театраль процессына алып керә. Милли драматургия әсәрләреннән А.Хәмиднең «Һинд кызы», Ф.Бурнашның «Адашкан кыз», «Хөсәен мирза», Ш.Камалның «Ут», Ә.Рахманкуловның «Упкын», «Боз астында дулкын», «Сафура», «Тигәнәк» пьесаларына мөрәҗәгать итеп, Д. аларда социаль киеренкелекне ачарга, тар милли кысалардан чыгарып, киң колачлылык, тирәнлек бирергә омтыла. Ш.у., репертуарны шактый яңартып, В.В.Каменскийның «Степан Разин» (1925), Н.В.Гогольнең «Ревизор» (1926), Р.Лотарның «Сарай серләре» («Шут на троне», 1927), В.В.Ивановның «Бронепоезд 14–69» (1929) әсәрләрен сәхнәләштерә. Сәхнәдә артист буларак та уйный; алар арасыннан аның Байчурин («Адашкан кыз», Ф.Бурнаш), Искәндәр («Сафура», Ә.Рахманкулов), Рәүф («Мансуровлар гаиләсе», Г.Минский) рольләре кызыклы. 1926–28 елларда Татар театр техникумында пед. эшчәнлек алып бара. Бер үк вакытта үзенең кайбер спектакльләренең рәссамы була, аның бизәлеш макетлары Казанда ТатАХРР рәссамнары (1925), Мәскәүдә «СССР халыклары сәнгате» (1927) күргәзмәләрендә күрсәтелә. Д. иҗаты Татар акад. театры үсешенә яңа юнәлеш бирә, театр сәнгатендә тирән эз калдыра. 1929 елдан Кырым татар театрында эшли.

*Әд.:* Арсланов М.Г. Яңалык эзләүче режиссёр // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2007. № 2; шул ук. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992.

*Ю.А.Благов.*

**ДЕВО́Н СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, девон (бу системаның утырмалары беренче булып табылган Девоншир графлыгы (Англия) исеме б-н бәйле), Җирнең геологик тарихында палеозой эратемасының палеозой эрасының дүртенче чорына туры килә торган астан дүртенче системасы. Стратиграфик шкалада силур системасыннан соң һәм ташкүмер системасыннан алда урнашкан. 410 млн. ел элек башлана һәм 60 млн. елга якын сузыла. 3 бүлеккә һәм 7 яруска бүленә (ТРда югары һәм урта бүлекләр һәм 4 ярус — фамен, франк, живет, эйфель сакланган). Девонда экватор хәзерге торышына 55–65° почмак ясап урнаша һәм Кавказ, Көнчыгыш Европа платформасы һәм Скандинавия аша уза. Ул чорда Төньяк полюс, хәзерге Тын океан терр-ясен били. ТР терр-ясе тропик гумид пояс зонасында була.

Бу вакытта үсемлекләр материкларны яулап ала башлый, беренче абагасыманнар, иң борынгы ачыкорлыклылар, буынтыксабаклылар барлыкка килә, җир өсте хайваннары үрчи, континент бассейннарында балыклар киң үсеш ала («балык гасыры»). Девон ахырында чукканатлы балыклардан беренче амфибияләр — стегоцефаллар барлыкка килә, диңгез умырткасызлары: брахиоподлар, остракод, мәрҗәннәр киң үсеш ала, бөҗәкләр арасында челтәрканатлылар арта. ТР терр-ясендә иң борынгы девон утырмалары эйфель (көнчыгышта) һәм живет (көнбатыштан кала) ярусларыннан тора. Алар диңгез утырмалары: комташ, алеврит, известьташ катнаш (көнчыгышта — мәрҗәнле) аргиллитлар, комлы-оолит брекчияле доломитлар, тимерле минераллардан (шамозит, сидерит) гыйбарәт. Урта девон ахырында Пашия (югары девон) вакытында терр-янең азрак күтәрелүеннән соң диңгезнең яңадан күтәрелүе башлана, гипс, ангидрит, мергель, балчыксыл битумлы сланецлар, комташ, балчык катламнары катнаш доломит утырмалары һәм известьташлар аерылып чыга. ТРда девон утырмаларның гомуми калынлыгы 600–800 *м*, урыны б-н алар 150–200 *м* тәшкил итә. Девон утырмаларына Көнчыгыш Европа платформасының кырый өлешенең (Идел-Урал бассейны) уңай структуралары б-н бәйле төп нефть тупланмалары һәм янучан битумлы сланецлар туры килә. Дөньяның башка төбәкләрендә девон утырмаларында ташкүмер, алмаз, Fe, Mn, Ni, Cr, Au h.б. ятмалары табылган.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

*Б.В.Буров.*


**ДЕВЯ́ТАЕВ** Александр Михайлович (24.9.1951, Казан), патофизиолог, иммунолог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1998). 1974 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук патофизиология кафедрасында эшли. Хезмәтләре скелет мускулларының аллергик реакциясе механизмнарын өйрәнүгә карый. Д. диңгез дуңгызы диафрагмасының кыскару үзлекләренә гистамин, интал тәэсирен өйрәнә, скелет мускулының анафилактик кыскару үсешендә нерв факторы ролен ачыклый, эмульсия-май нигезен һәм «Мюстелла» дәвалау-косметика чарасын эшли һәм медицина практикасына кертә.

Хезм.: Механизмы аллергических реакций скелетных мышц. К., 1996.

**ДЕВЯ́ТАЕВ** Михаил Петрович (8.7.1917, хәзерге Мордва Респ-касы Торбеево штп — 24.11.2002, Казан), Сов. Союзы Герое (15.8.1957), гв. өлкән лейтенанты. Казан елга техникумын (1938) тәмамлый. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1940 та Оренбургта очучыларның Чкалов исем. хәрби авиация мәктәбендә укый. 1941 дән Бөек Ватан сугышы



Г.Г.Девишев.




М.П.Девятаев.

фронтларында, 104 нче истребительләр авиация полкында звено командиры (2 нче һава армиясенең 9 нчы истребительләр авиациясе дивизиясе). Көньяк-көнбатыш, Воронеж һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Житомир–Бердичев, Корсунь–Шевченко, Ровно–Луцк һәм Проскурово–Черновцы һөҗүм операцияләрендә катнаша (1944). 1944 нең 13 июль кичендә Д. самолёты истребительләр төркеме б-н дошман авиациясе һөҗүменә каршы очып китә. Львов шәһәре янында Д. яралана, самолётына ут каба. Тәне нык пешкән очучы әсирлеккә эләгә. Сорау алганнан соң, аны абверның разведка төркеменә, соңрак Лодзь хәрби әсирләр лагерена, аннары Заксенхаузен (Кёнигсберг ш.) концлагерена күчерәләр. 1944 нең 13 августында Д. хәрби әсирләр төркеме б-н беренче тапкыр качарга омтылып карый. Качкыннар тотыла. Үлемгә хөкем ителгән әсирләр Балтыйк диңгезе Узедом утравындагы (Германия) ракета кораллары сынала торган («Фау-2» ракеталары) Пенемюнде яшерен полигонына озатылалар. 1945 нең 8 февралендә Д. кабатланмас каһарманлык күрсәтә: 9 хәрби әсир б-н немецларның гадәттән тыш яшерен «Хейнкель-111» самолётын кулга төшереп, фронт сызыгын кичә һәм совет хәрби командованиесенә Пенемюнде полигонындагы яшерен завод, ракета җибәрү өчен диңгез буендагы старт җайланмалары, аларның төгәл координатлары турында стратегик мөһим мәгълүматлар тапшыра. Сугыш беткәч, Д. хәрби трибунал тарафыннан хөкем ителә. 1945 елның сентябрендә конструктор С.П.Королёв Д.ны Польшада элекке әсирләрне тикшерү лагеренда таба һәм аны Пенемюндега чакыртып алдыра. Д. С.П.Королёвка анда ракеталарның кайда ясалуын һәм кайдан җибәрелгәнлеген күрсәтә. Д.Пенемюндедан Брестка, аннары Невель шәһәренә күчерелә. Запастагы гв. өлкән лейтенанты Д. шул елның ноябрендәКазанга кайта. Кулында капитан дипломы булса да, 1946 да ул кыенлык б-н генә Казан елга портына йөкче булып эшкә урнаша, тиздән капитан, аннары су асты канатлы пассажир судносы капитаны, остаз-капитан булып эшли. 1957 елда космик корабльләр ген. конструкторы С.П.Королёв һәм 3 тапкыр Сов. Союзы Герое А.И.Покрышкин булышлыгы б-н Д. аклана, аңа Сов. Союзы Герое исеме бирелә. Д. исеме бөтен дөньяга таныла. 1990 еллар башында күпмиллэтле Казан иҗтимагый-сәяси үзәге идарәсе



С.С.Дегтев.



Г.Л.Дегтярёв.

әгъзасы. 1999–2002 дә «Татарстан яңарышы» («За возрождение Татарстана») республика иҗтимагый-сәяси оешмасының сәяси советы рәисе, ТР Ветераннар советы әгъзасы. Мордва Респ-касы, Казан, Вольгаст һәм Циновичи (Германия) шәһәрләренең мактаулы гражданы. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан шәһәрендә бер урам һәм Казан елга техникумы Д. исемен йөртә, ул яшәгән йортка мемориаль такта куела. Торбеево поселогында Геройга музей ачыла.

Х е з м.: Полёт к солнцу. М., 1972; Побег из ада. Саранск, 1985.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Бессмертие. Саранск, 1970; Во имя Родины. М., 1982; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*Г.С.Сабирҗанов, М.З.Хәбибуллин.*

**ДЕВЯ́ТОВ** Диләвер Хәсән улы (10.6.1944, БАССРның Баймак р-ны Ишбирде а.), металлург, техник фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1967 елда Магнитогорск тау металлургиясе ин-тының җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру ф-тын тәмамлый (хәзер Г.И.Носов исем. Магнитогорск техник ун-ты), шунда ук эшли, хисаплау техникасы лаб-ясе җитәкчесе (1973–77), хисаплау техникасы һәм гамәли матем. каф. мөдире (1988 дән), автоматика һәм хисаплау техникасы ф-ты деканы (1995 тән). Хезмәтләре кара металлургиядә технологик процесслар б-н идарә итүне оптимальләштерүгә карый. Көньяк Уралдагы кыйммәтле таш ятмалары чыганакларын системага сала. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Геммологические запасы Урала. Магнитогорск, 1999 (автордаш); Творцы информации. Магнитогорск, 1999; Оптимальное управление нагревом металла в камерных нагревательных печах. Магнитогорск, 2000.

**ДЕВЯ́ТОВ** Фёдор Владимирович (14.4.1954, Казан), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1996), проф. (1997). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, нәорганик химия каф. проф. (1997 дән). Хезмәтләре су булмаган эреткечләрдәге күчеш хәлендәге металларның координацион кушылмалары химиясенә карый. Протон магнит релаксациясе ысулыннан файдаланып, иттрий төркеме лантаноидлары ионнарының гомо- һәм гетеротөш-цитрат комплекслары хасил булу турында мәгълүматлар ала. Бинар мохиттә комплекслар хасил булу термодинамикасы б-н реагентлар сольватлашуының үзара бәйләнешен тикшерә. Магнит кырында парамагнит икеле нур сынышы, протон магнит релаксациясе һәм матем. модельләштерү ысулларын бергә кулланып, лантаноид (III) гетеросольватларының, ш.у. бакыр (II), кобальт (II), никельнең (II) диметилформамид, диметилсульфоксид, ацетонитрил, гексаметилфосфортриамидлар б-н су катнашмасындагы составын, тотрыклылыгын һәм төзелешен исбатлый. Оптик актив лигандаларның (окси- һәм аминокислоталар) сольватлашу тирәлеген өйрәнү өчен поляриметрик ысул тәкъдим итә.

Х е з м.: Полиядерные комплексы в растворах. К., 1989 (автордаш); Магнетохимия и радиоспектроскопия координационных соединений. К., 1990 (автордаш); Селективная сольватация катионов и протонодоноров в смесях вода-диполярный апротонный растворитель // Координационная химия. 1998. Т. 24, вып. 7 (автордаш).

**ДЕВЯТЬЯ́РОВ** Михаил Тәлгат улы (25.2.1959, Пермь өлкәсенең Чусовой ш.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1988). Пермь пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый. СССР (1986–87), Бөтендөнья универсиадасы (1983, ярыш 30 *км*, эстафета 4x10 *км*), Олимпия уеннары (1988, 15 *км*) чемпионы, СССР кубогы иясе (1986). Дөнья кубогында (1985, эстафета 4x10 *км*), Олимпия уеннарында (1988, эстафета 4x10 *км*), СССР чемпионатында (1989) — көмеш, Бөтендөнья универсиадасында (1981, 15 *км*) бронза медаль ала. Хәрби хезмәткәр, Пермь шәһәрендә яши.

**ДЕГЕТЛЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Дегетле елгасы буенда. 2008 елда 317 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 58%, татарлар — 38%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, ат үрчетү, умартачылык. Кирпеч з-ды. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә Түбән Новгород губернасының Балахна шәһәре кешеләре нигез сала дип фаразлана. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь, Казан Архиерей йортыныкылар) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек эше, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.дә Вознесение чиркәве (1864–75 елларда Мамадыш һәм Алабуга сәүдәгәрләре М.Я.Сухопарова һәм И.И.Стахеев иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), земство уч-щесе (1879 да ачыла), 2 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1595,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында, 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1763 тә — 40, 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 877, 1897 дә — 1225, 1908 дә — 1264, 1920 дә — 1154, 1926 да — 1035, 1938 дә — 522, 1949 да — 310, 1958 дә — 294, 1970 тә — 256, 1979 һәм 1989 да — 175, 2002 елда 202 кеше.

**ДЕГЕТЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Омар елгасының уң кушылдыгы (Кама елгасы бассейны). Озынлыгы 9,5 *км*, бассейнының мәйданы 47,6 *км*$^2$. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Түбән Яке авылыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Букәнле авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 94 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 53%. Д. елгасының 0,9 һәм 3,8 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 5,1–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 145 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суының күләме 0,47 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ДЕ́ГТЕВ** Сергей Сергеевич (14.10.1913, Казан губ., Тәтеш өязе Долиновка а. — 26.3.1988, Куйбышев ш.), Дан орденының тулы кавалеры (25.11.1943, 14.6.1944, 27.6.1945), старшина (1945). Туган авылында колхозда эшли. 1939–40 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 271 нче аерым танкка каршы истребительләр дивизионы отделениесе төзәүчесе, орудие командиры (65 нче һәм 3 нче гв. армияләренең 149 нчы укчылар дивизиясе). Дон, Белоруссия һәм Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Украинаны һәм Польшаны азат итү сугышларында, Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 18 ноябрендә Дубрава һәм Романовка торак пунктлары (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Речица шәһәреннән 25 *км* көньяктарак) өчен барган сугышта дошман һөҗүмен кире кайтарганда 2 танкны сафтан чыгара һәм 2 рота миномётын юк итә; 1943 нең 21 декабрендә Чеповичи посёлогы (Украина ССРның Житомир өлкәсе) өчен барган сугышта дошманның 2 танкын сафтан чыгара, 2 пулемётын юк итә; 1945 нең 24 февралендә Маркендорф торак пункты (Германия) өчен барган сугышта дошманның 2 контрһөҗүмен кире кайтаруда катнашып батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында колхоз рәисе булып эшли. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А н д р е е в Г.И., В а к у р о в И.Д. Солдатская слава. М., 1971. Кн. 3; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ДЕГТЯРЁВ** Геннадий Лукич (27.1.1938, Пермь өлкәсе Тойкино а.), идарә итү процесслары һәм информацион технологияләр гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1983), ТР ФА академигы (1992), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты)

тәмамлый, шунда ук эшли, автоматика һәм идарә итү каф. мөдире (1982 дән), проф. (1983), бер үк вакытта проректор (1985–87), ректор (1987–2008 дә). Хезмәтләре локаль-оптималь идарә итү теориясе һәм ысулларына, детерминирланган һәм стохастик системалар өчен үлчәнешләре тулы алынмаган торыштагы һәм параметрлары таралган системалар б-н идарә итүгә карый. Д. идарә итү көчләренең һәм үлчәгеч билгеләгечләренең урнашуына караган таләпләрне нигезли. Аның тарафыннан эшләнгән ысуллар космик аппаратлар б-н идарә итү алгоритмнарын төзегәндә, адаптив оптик-электрон приборлар һәм космик системаларны нигезләгәндә кулланыла; ул приборлар әйдәп баручы космик пр-тиеләрдә гамәлгә кертелә. РФ хөкүмәте бүләге бирелә (2009). Дуслык ордены, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретические основы оптимального управления упругими космическими аппаратами. М., 1986; Синтез локально-оптимальных алгоритмов управления летательными аппаратами. М., 1991.

**ДЕГТЯРЁВ** Иван Мефодьевич (12.3.1940, Оренбург өлкәсенең Домбаровск р-ны Екатеринославка а.), стоматолог-ортопед, мед. фән. канд. (1968), ТРның атказ. табибе (2001). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Коми АССРның Ижем р-н хастаханәсендә стоматология табибе булып эшли. 1964 елдан Казан мед. ин-тында ортопедик стоматология кафедрасында, доцент (1980 нән), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 2 нче хастаханәсендә консультант (1975–95). Хезмәтләре альвеоляр үсенте сөяк өслегенең гадәти хәлдәге һәм пародонтоз вакытындагы иннервациясен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Пародонтит. К., 1990 (автордаш); Непосредственное протезирование в комплексном лечении болезней пародонта. Проблемы оказания пародонтологической помощи населению г.Казани. К., 2002; Клиника, диагностика и лечение несовершенного дентикогенеза II типа. // Городское здравоохранение. 2008. № 4 (автордаш).

*Әд.:* А н д р е е в И.М., К р а с и л ь н и к о в С.Н. История в биографиях. Казан. гос. мед. ун-т. Стоматологический факультет. К., 1996.

**ДЕГТЯРЁВА** Ирина Александровна (13.9.1963, Баулы р-ны Поповка а.), микробиолог, биол. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1986). 1986–2002 елларда Казан ун-ты каршындагы Ботаника бакчасында эшли, 2001 елдан микробиология лаб-ясе мөдире. 2002 елдан РАХФАнең Татарстан Агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тында, агроэкология һәм микробиология лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре туфрак микробиологиясенә, агрохимиясенә, үсемлекләр биохимиясенә һәм физиологиясенә карый. $C_4$-типтагы фотосинтезлы үсемлекләрдә (амарант, кукуруза һ.б.) углерод һәм азот метоболизмының үзара йогынтысы үзенчәлекләрен тикшерә. Уйлап табуга 2 патенты бар (1997).

Х е з м.: Азотфиксаторы ризосферы амаранта и их использование при возделывании овощных культур // Плодородие. 2004. № 1 (автордаш); Физиолого-биохомическая регуляция взаимодействия растений рода Amaranthush и диазотроф // Уч. зап. Казан. ун-та. 2005. Т. 47, кн. 1 (автордаш); Специфика взаимодействия углеродного и азотного метаболизма у амаранта. К., 2006 (автордаш).

**ДЕДКО́В** Алексей Петрович (1.4.1924, Брянск өлкәсе Дятьково ш. — 29.11.2007, Казан), геоморфолог, геогр. фән. д-ры (1967), проф. (1968), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1989, 1995), Рус геогр. җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1995), Казан ун-тының шәрәфле проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1951), шунда ук эшли, геогр. ф-ты деканы (1963–64, 1968–71, 1979–83), физ. география каф. мөдире (1981–90). 1983–86 елларда Кабул ун-ты (Әфганстан) ректоры киңәшчесе. Хезмәтләре геоморфология, физ. география һәм геологиягә карый. Климатик һәм динамик геоморфологияне, экзоген рельеф барлыкка килүне өйрәнүгә өлеш кертә. Зур тигезлек киңлекләрендә рельеф үсеше б-н тектоник хәрәкәтләр генә түгел, ә бәлки климат алмашынуы да идарә итүен ачыклый. Геоморфологиядә кыр экспериментлары буенча халыкара комиссия әгъзасы (1992–96). Берлин, Лейпциг, Прага, Кабул, Львов ун-тларында лекцияләр укый. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы (2007 елга кадәр). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, Дан (Әфганстан Демократик Респ-касы) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экзотектоническая складчатость платформы. К., 1967 (автордаш); Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Приволжье. К., 1970; Климатическая геоморфология денудационных равнин. К., 1977 (автордаш); Эрозия и сток наносов на Земле. К., 1984 (автордаш); Избранные труды. К., 2008.

*Әд.:* Алексей Петрович Дедков // Геоморфология. 1994. № 2; П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Алексей Петрович Дедков. К., 2004.

**ДЕЗИДЕ́РЬЕВ** Георгий Петрович (11.8.1910, Ярославль губ., Нерехта өязе Арменко а. — 14.5.1965, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1964). 1931 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, Л.Я.Карпов исем. Физ.-химия ин-тында (Мәскәү) эшли. 1932–41 елларда Казан ун-ты каршындагы Химия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1934 тән Казан химия-технол. ин-тында. 1946 дан СССР ФАнең Казан ф-лы Химия ин-тында, директор урынбасары (1963 тән). Хезмәтләре металларны электр б-н утырымга төшерү һәм эретүгә карый. Турыдан-туры электр химиясе реакциясе зонасында катод тирәлегендәге әчелекне билгеләү өчен, металларны утырымга төшерү вакытында катод электродының ролен тикшерү нәтиҗәләренә нигезләп, металл-водородлы электродлар ысулын эшли. Цинкат эремәләре б-н цинклау, корыч детальләрне электр ярдәмендә шомарту, рельсларны анодлы-механик кистерү ысулларын эшли һәм җитештерүгә кертә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологические материалы по электрохимической обработке металлов. К., 1952. Ч. 2; Контроль кислотности никелировочных ванн. М., 1953.

**ДЕИ́ЗМ** (лат. deus — Илаһ), дини-фәлсәфи тәгълимат; Илаһны дөньяның яшәү канунзнары нигезләрен тудырган дөньяви аң, акыл дип таный, әмма дөньядагы хәлләрнең үзгәрешенә катнашмый дигән фикерне алга сөрә. Д.га нигез салучы булып инглиз философы лорд Чербери (17 йөз) санала. Әлеге тәгълимат Мәгърифәтчелек чорындагы фикер ияләре арасында киң тарала. Күренекле деистлар: Бөекбританиядә Дж.Толанд, А.Шефтсбери, Франциядә — Вольтер, Германиядә — Г.В.Лейбниц, Г.Э.Лессинг һ.б.лар. Д. идеяләре Дж. Локка һәм Ж.Ж.Руссога якын була. Россиядә Д.ның күренекле вәкилләреннән берсе — А.С.*Лубкин.* 19 йөз — 20 йөз башында татар зыялылары арасында фикер хөрлеге үсешендә Д.ның әһәмияте зур була (Ш.Күлтәси, К.Насыйри һ.б.).



А.П. Дедков.

*Әд.:* А б д у л л и н Я.Г. Татарская просветительская мысль. К., 1975.

**ДЕКАБРИСТЛА́Р**, 1816–25 елларда Россиядәге яшерен оешмаларда катнашкан, 1825 елның 14 декабрендә («Д.» исеме дә шуннан) самодержавиегә каршы беренче тапкыр ачыктан-ачык кораллы чыгыш ясаган кешеләрнең тарихта һәм мемуар әдәбиятта кабул ителгән атамасы. 1821 дә Д.ның ике зур оешмасы — Көньяк (җитәкчесе П.И.Пестель) һәм Төньяк (җитәкчесе Н.М.Муравьёв) җәмгыятьләре барлыкка килә. Төньяк җәмгыять әгъзалары (С.-Петербургта) конституцион монархия яклы булалар, алар конституцияне революцион юл б-н түгел, ә законлы төстә кабул итү тәкъдиме б-н чыгалар. Көньяк җәмгыять әгъзалары республика идарәсе кертүне һәм крепостной хокукны бетерүне яклыйлар. Император Александр I нең кинәт үлүе б-н бәйле рәвештә төньякныкылар яңа император Николай I гә ант бирү көнендә Сенат мәйданына гаскәрләр кертергә һәм, көч күрсәтеп (хәрби гамәлләр б-н түгел), Сенатны самодержавиене чикләү өчен тавыш бирергә мәҗбүр итәргә ниятлиләр. Ләкин 1825 нең 14 декабрендә таң алдыннан ук сенаторлар һәм армия Николай I гә ант бирәләр, һәм башланганчы ук күтәрелеш җиңелүгә дучар була. 14 декабрь иртәсендә Төньяк җәмгыять җитәкчеләре баш күтәрүдән баш тартырга карар кабул итәләр, әмма җәмгыятьнең кайбер әгъзалары моның б-н килешми.

14 декабрьдә Сенат мәйданына Мәскәү һәм Гренадер гв. полкларының һәм Гв. диңгез экипажының 3 меңнән артык солдаты һәм матросы чыга. Д. арасында шактый санда казанлылар да була. Гаскәрләрне Төньяк җәмгыять әгъзалары Гв. экипажы лейтенанты А.П.*Арбузов*, 8 нче флот экипажы капитан-лейтенанты Н.А.Бестужев, Драгун гв. полкы штабс-капитаны А.А.Бестужев (Марлинский) һәм Мәскәү гв. полкы штабс-капитаны М.А.Бестужев (Казан алпавытлары Бес-

тужевларның якын туганнары) алып чыгалар. Яшерен оешмаларда тормасалар да, мәйданга Гв. экипажы матросларын лейтенантлар Ф.Г.*Вишневский* (Казан ун-тының элекке директоры улы), Е.С.Мусин-Пушкин (Минзәлә алпавыты улы) һәм мичман В.А.*Дивов* (аның әнисе Казанда яши) алып чыгалар. 8 нче флот экипажы лейтенанты, Төньяк җәмгыять әгъзасы казанлы Д.И.*Завалишин* ул вакытта С.-Петербургта булмый: К.Ф.Рылеев аны эш б-н Казанга җибәргән була.

Николай I артиллериягә ут ачарга әмер бирә, һәм шул көннең төненә баш күтәрү бастырыла. Декабрьнең егермеләрендә 14 декабрь вакыйгалары турындагы хәбәр Көньяк җәмгыять эш иткән Украинага барып ирешә. Чернигов пехота полкының Васильков управасы башлыгы подполковник С.И.Муравьёв-Апостол, гәрчә Көньяк җәмгыять җитәкчесе П.И.Пестель ул вакытта кулга алынган булса да, Төньяк җәмгыятьне яклап баш күтәртә. Җәмгыятьтә штабс-ротмистрлар А.И.Барятинский (Казан уделлар конторасы идарәчесе улы), Тульчин управасы рәисе И.П.*Жуков*, ротмистр В.П.Ивашев һ.б. җәмгыять әгъзалары булалар. Чернигов пехота полкы (аңа Александр I заманында 1820 дә башкалада кылган тәртипсезлекләре өчен гвардиядән армиягә күчерелгән элеккеге Семёнов полкы хәрбиләре дә керә) 1825 нең 29 декабрендә баш күтәрә, ә 1826 ның 3 гыйнварында тар-мар ителә. Башка полкларны баш күтәртеп булмый. Черниговлыларга каршы операцияләрдә казанлылар — подполковник, Берләшкән славяннар җәмгыяте әгъзасы А.К.Берстель һәм Көньяк җәмгыятьтә әгъза булып тормаган, ләкин аның эшчәнлеге турында белгән капитан М.И.Пыхачёв та катнаша.

Николай I фетнәчеләрне рәхимсез җәзалый: төп башлап йөрүчеләрне асарга, калганнарын Себергә һәм Кавказга сөрергә әмер бирә. Декабрь чыгышларында гади катнашучылардан күп кеше Кавказга сөрелә, алар анда 1826–28 һәм 1828–29 еллардагы рус-Иран һәм рус-төрек сугышларында, шулай ук Төньяк Кавказдагы тау халыкларына каршы экспедицияләрдә актив катнашалар.

Чернигов полкының баш күтәргән өчен Кавказга күчерелгән солдатлары арасында Казан губернасыннан алынганнары да була: татарлардан — Якуб Тимергалиев (Мамадыш өязе Норма а.), Ишмөгашит Биктимеров (Тәтеш өязе Яңасала а.), Терентий Дурнаев (Тәтеш өязе Фролово а.), Ибраһим Остаев (Тәтеш өязе Болтиево а.), Фәйзулла Баязитов (Лаеш өязе Янтык а.), ш.у. Александр Усов (Спас өязе Вожи а.), Сергей Васильев (Чистай өязе Яңа Спас а.), Степан Александров (Спас ш.) һ.б.

Кавказ корпусы командиры генерал И.Ф.Паскевич Баш штабка Кавказга сөрелгән барлык хәрбиләрне сугышларның алгы сызыгында, иң куркыныч урыннарда куллануы турында рапорт бирә. Югарыда саналган Д.дан тыш, А.А.Фок, Ф.М.Башмаков, М.М.Нарышкин һ.б. яшерен җәмгыятьләрнең эшчәнлеге турында беләләр һәм Казан төбәге б-н элемтәдә торалар. Казан ун-ты проф. Д.А.Корсаков болай дип яза: «Казан һәм аның б-н күрше Сембер губернасы алпавытлары арасында күп кенә декабристлар булган, һәм аларның кайберләре Себергә Казан аша җибәрелгән». 1829 ның җәендә, Себердән Кавказга барышлый, Казанда А.А.Бестужев һәм В.С.Толстой була. 1837 дә ш.у. В.Н.Лихарев, Н.И.*Лорер*, М.А.Назимов, А.И.*Одоевский* һәм А.Черкасов, 1840 та А.А. һәм А.П.Беляевлар Казан аша үтәләр. М.И.Муравьёв-Апостол, С.Г.Волконский һ.б. фәкать 1856 да гына Себердән Казан аша туган якларына кайталар. Д. Николай I үлгәч, баш күтәрүдән соң 30 ел үткәч кенә амнистия алалар.

*Әд.:* Восстание декабристов. Материалы. М.–Л., 1927. Т. 3; Гессен С. Солдаты и матросы в восстании декабристов. М., 1930; Очерки по истории движения декабристов. М., 1954; Нечкина М.В. Декабристы. М., 1984; Гарзавина А.В. «В Казань, профессору К.Ф.Фуксу...». К., 1986; шул ук. «... Отчизне посвятим души прекрасные порывы!». К., 1990.

*А.В.Гарзавина.*

**ДЕКАДЕНТЛЫ́К** (лат. decadentia — төшенкелек), төрле дәверләрдә яшәгән халыклар мәдәниятендә, әдәбиятында иҗтимагый-сәяси, социаль катаклизмнар, рухи кыйммәтләрне яңадан бәяләү нәтиҗәсендә килеп туган, тарихта кабатланып торган рухи кризис халәте күренешләренең гомуми атамасы. Дөньяны кабул итүнең бер фикри-хисси юнәлеше буларак, аңа тарихи үсешкә, тәрәккыяткә шикләнеп карау, җәмгыятьтән читләшү, яшәештән күңел бизү, мәгънә тапмау, өметсезлеккә, иррационализмга, мистикага, формализмга бирелү хас. Декадентларның этик-эстетик карашлары А.Шопенгауэр, Ф.Ницше, А.Бергсон, И.Кант, В.Соловьёв һ.б.ның фәлсәфи идеяләренә барып тоташа.

Татар мәдәнияте һәм әдәбиятында декаданс урта гасырларда барлыкка килә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең 1 нче яртысындагы милли-колониаль изү, Коръәндәге сабырлык фәлсәфәсе һәм суфичылык карашлары б-н аралашып, халыкның иҗтимагый һәм рухи тормышын торгынлыкта, кадимчелектә калдыруга китерә. Урта гасырлар декадансының бу үзенчәлеге уңай вазифа да үти: татар этносын һәм аның ислам мәдәнияте б-н бәйле рухи кыйммәтләрен саклап калырга мөмкинлек бирә.

20 йөзнең 1 нче чирегендә, татар әдәбияты Европа һәм Россиядәге иҗтимагый-фәлсәфи, әдәби-эстетик фикернең төрле модернистик агымнары б-н тыгыз элемтәгә кергән чакта, Ренессанс гуманизмы һәм антропоцентризм б-н янәшәдә күңел төшенкелеген чагылдырган декаданс та тамыр җәя. Декадентлык, сәнгатьчә фикерләүнең Шәрекънең традицион канунчылыгыннан Европа тибындагы баскычына күчеш күренеше буларак, татар әдәбияты тарихында шактый тирән эз калдыра. Билгеле бер дәрәҗәдә символизм, акмеизм, экзистенциализм, экспрессионизм, импрессионизм, «аң ташкыны», футуризм, имажинизм кебек модернистик агымнар йогынтысында булган күп кенә танылган язучылар иҗатында Д. үтә нечкәртелгән сызланулы формалар рәвешендә чагылыш таба.

1905–07 еллардагы рев-ция җиңелгәннән соң, декадентлыкка тартым халәт С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Ш.Камалларның кайбер әсәрләрендә аеруча калку гәүдәләнә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында аның көчәюе Н.Думави, Г.Газиз, М.Хәнәфи, Ш.Бабич һ.б. иҗатларында күзәтелә. Иҗат ирегеn декадентларча аңлап, ислам идеологиясен радикаль рәвештә бәяләү, үткәндәге әдәбият-сәнгать казанышларыннан ваз кичү 1920 еллар татар әдәбиятының авангард агымнарына — Һ.Такташның гыйсъянчылык романтизмына, Г.Кутуй футуризмына, К.Нәҗми имажинизмына хас була.

Кешене илаһилаштыру дәрәҗәсендә олылаган Шәрекъ суфичылыгының пантеистик традицияләре б-н үрелгән, бөтен нәрсәне Ницшеча кире каккан нигилизм, яшәешне мәгънәсезлек дип игълан иткән, шәхеснең чикләнмәгән азатлыгын, индивидуализмын мактаган Д. мотивлары С.Рәмиевнең гыйсъянчылык романтизмында аерата үтемле һәм тәэсирле гәүдәләнә («Алданган», «Мин үләм», «Ямь»).

Символист шагыйрь Дәрдемәнднең фәлсәфи романтизмы да ш.у. Д. мотивлары б-н өртелгән. Аның «Кораб», «Без», «Бүзләрем маналмадым», «Өмидләр», «Куанды ил...» кебек шигырьләрендә кеше гомеренең чикләнгәнлеге, язмыштан узмыш булмаудан туган өметсезлек, борчылу-сыкранулар тасвирлана; тарихтагы иҗтимагый-сәяси тетрәүләр аркасында яшәеш чоңгылларына ыргытылган индивидларның гына түгел, аерым халыкларның хыяллары да тормышка ашуы шөбһәле булу турындагы фәлсәфи уйлар, хис-кичерешләр чагылдырыла. Сәнгатьчә фикерләве б-н экспрессионистларга якын торган Н.Думави «Сугыш тәэссораты» шигырендә капитал дөньясының кан коюлы сугышларына, Ницше фәлсәфәсендәгечә «үтә көчле» кешеләрнең «кызганмыйча када штыкны» дип чакыруларына, вөҗдан чикләүләрен белмичә, халыкны талауларына, юлбасарларча эш итүләренә ironияле ризасызлыгын белдерә һәм күңел төшенкелегенә бирелә. Аның «Алла тигезли» кебек аерым хикәяләрендәге фәлсәфи-эстетик фикерләре А.Шопенгауэрның тумыштан ук кеше табигатенең бозыклыгы турындагы универсаль пессимизмы б-н аваздаш. Француз философы А.Бергсонның интуитивизм теориясе рухында аңлатылган, кешенең ялгызлыгы, үлем каршында көчсезлеге турындагы Д. мотивлары Н.Думавиның М.Метерлинктан тәрҗемә ителгән «Чакырылмаган кунак» («Непрошенная») драмасыннан соң язылган әсәрләрендә дә шактый сизелә. Татар әдипләренең Д. рухындагы карашларны һәм алымнарны кабул итүләрендә рус язучысы Л.Андреев иҗатының да билгеле бер йогынтысы бар. Татар әдәби тәнкыйте аны «мәшһүр һәм мәгърүф» (танылган) декадент дип атый. Л.Андреевның «Ачлык патша» («Царь Голод») драмасын укучыга тәкъдим иткән «Шура» ж-лында (1912) һәм «Вакыт» г-тасында (1913) мондый сүзләр язылган: «Заманыбыз — декадентлык заманыдыр, декадент бина — гүзәл, декадент җи-

һаз — могътәбәр, декадент рәсем — хуш вә декадент әдәбият — назирсыз». Бу рус язучысы иҗатындагы Д. мотивларын, символик образлар б-н аваздашлыкны Ф.Әмирханның «Татар кызы», «Картайдым», «Кадерле минутлар» хикәяләрендә дә табарга мөмкин. Л.Андреевның декаданска тартым һәм экспрессионистик алымнарга бай «Асылган җиде кеше» («Рассказ о семи повешенных») хикәясен 1909 елда татар теленә тәрҗемә итүе дә язучының аның иҗаты б-н кызыксынуы турында сөйли.

Баракларда яшәүчеләрнең натуралистик портретлары, эротик тасвирламалар Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?» повестенда һәм «Теләнче кыз» романында да күренә. Кеше психикасының ихтыярсызлык өлкәсе, геройларның невроз халәте язучының Фрейдка тартым психоаналитик әсәрләрендә — «Фамилия сәгадәте» циклына тупланган «Татар гакылы», «Мәдрәсә йимеше», «Башкорт бәхете», «Көтелгән бикәч», «Шәкерт абый» хикәяләрендә күзәтелә.

Яшәешне декадентларча кабул итүче экзистенциалист язучы М.Хәнәфи, Шопенгауэрның төшенкелек фәлсәфәсенә ияреп, җир тормышын мәгънәсез нәрсә дип исәпли; аныңча, «милләтнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге — барысы да караңгы һәм өметсез»; кешенең дөнья көтүе дә — бары тик алдагыч иллюзия, төш күрү генә; яшәеш, пантеистик суфилар әйткәнчә, индивид б-н илаһият тәңгәллегенең мәңге кабатланып торуы гына; мәхәббәтнең дә асылы берни түгел, газаплы экзистенция генә, чын бәхет илаһи башлангыч б-н шатлыклы кушылуда гына; үлем — җирдәге кайгы-хәсрәтләрдән, җәфа-золымнардан котылу, чын мәгънәсендә азатлыкка ирешү чарасы («Сәгадәт турысында», «Сөю — җәллад», «Бер гөл бакчасында», «Мин бер төш күрдем», «Милләтем»). 20 йөзнең 1 нче унъеллыгында матурлык һәм эротика культын алга сөрүче, җитди социаль-әхлакый мәсьәләләрне актыртудан читләшүче, конфликтлардан азат интим-предметлар дөньясын сурәтләүче, югалган мәхәббәтне сагынып сыктаучы, үткән тарихтагы һәм бүгенге чынбарлыктагы вакыйгаларны акмеистларча бик тә гади юмор, яисә шаярулы ирония ярдәмендә чагылдыручы Д. тенденцияләре б-н үрелгән байтак кына әсәрләр (Ф.Әмирханның «Габделбасыйр гыйшкы», «Куркыныч дошманнар», «Сәмигулла абзый»; К.Тинчуринның «Гыйшык»; Г.Гобәйдуллинның «Скрипкачы Хөсәен», «Форточкалы кәләпүш», «Бу милләт ничек тәрәккый итсен?», «Ул мактанчык түгел иде» әсәрләре) языла.

Күпгасырлык мөселман мәдәнияте традицияләрен һәм кыйммәтләрен пародия ысулы б-н кире кагу Ш.Бабичның «Газазил» поэмасының үзәк мотивын тәшкил итә. Мәзәкче автор, Аллаһ тарафыннан оҗмахтан куылган Иблис образына һәм шау-шулы тамаша күрсәтү алымына мөрәҗәгать итеп, ислам дине мифологиясендәге риваятьләрдән көлә, якын киләчәктә Ницшеның үтә көчле кешеләрен хәтерләткән, большевиклар токымыннан булган кодрәтле җир аллаларының мәйданга чыгачагы турында яза («Чөнки мин зур, чөнки мин нур, мин галим, / Үз-үземә кечкенә бер алла мин!.. /Дөнья беткәнче җиһанны айкарым ... / Инҗилне, Коръәнеңне таптарым ...»).

20 йөзнең 1 нче чирегендә татар әдәбиятында декадансның, Аллаһка каршы чыгуның, дәһрилекнең, Ницше нигилизмының иң югары ноктасы Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе»ндә чагылыш таба. Шагыйрь, Кабил б-н Әкълимә фаҗигасен сурәтләп, мәхәббәт һәм шәфкать кебек гомумкешелек идеалларын яклаудан баш тарткан вәхши Ходайның кирәге калмады, ләгънәтләнгән, залим, хаин Аллаһны күкләрне һәм тәхетләрне җимерүче үтә көчле Җир тәңреләре б-н алыштыру заманы килде, дип яза («Кодрәтемнән җимерәләр / Күкләр, тәхетләр, гаршеләр!! / Тез чүгәр алдымда бар көчләр, / Мәләкләр, Аллалар! / Күктә канлы Алла булса, / Җирдә башка Аллалар бар!!»).

Иҗтимагый-сәяси агымның, сәнгатьчә фикерләүнең кризис халәтен гәүдәләндергән Д. иң элек төрле модернистик юнәлешләрдә чагылыш таба, һәм шул ук вакытта ул, катлаулы тормыш материалын сурәтләгәндә, татар әдәбиятын моңарчы кулланылышта булмаган тәэсирле чаралар, тасвирлау алымнары б-н баета. Еш кына Д. бер үк язучылар иҗатында ренессанс мотивлары б-н тыгыз үрелгән рәвештә дә яши.

Марксистик эстетика Д.ны тискәре бәяли, анда өстен сыйныфларның, буржуаз зыялыларының һәлакәткә дучар ителгән мәдәниятен һәм рухи ярлылыгын күрә. 20 йөз башы татар әдәбиятына караган очеркларда да аңа, партиянең сыйнфый-социологик күрсәтмәләре күзлегеннән чыгып, сәяси бәя бирелә.

20 йөз ахыры — 21 йөз башы татар әдәбияты белеме декадансны реакцион идеологик һәм сәнгати күренеш дип кабул итүдән баш тарта; әдәби процессның аерым чорларында аның калкып чыгуын, кабатланып килүен яшәештәге фаҗигале халәт, «бөек ару», «тарихи авыру» (Ницше), иҗтимагый төшенкелек, якынлашып килүче афәтләр — этносларның, мәдәниятләрнең һәлакәт һәм инкыйраз алдында торулары б-н аңлата.

*Әд.:* XX йөз башында татар әдәбияты. Очерклар. К., 1954; Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. К., 1982; Ганиева Р.К. Декадентлык // Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003.

*Р.К.Ганиева.*

**«ДЕЛОВО́Й ТАТАРСТА́Н»**, к. *«Мир бизнеса»*.

**ДЕМЕ́НТЬЕВ** Пётр Васильевич (24.1.1907, хәзерге Чүпрәле р-ны Үби а. — 14.5.1977, Мәскәү), генерал-полковник-инженер (1976), ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1941, 1977), Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлык академиясен (1931, Мәскәү) тәмамлый. 1931 елдан гражданлык һава флотының фәнни-житештерү ин-тында эшли. 1934–41 дә цех башлыгы, баш инженер, Казан авиация з-ды директоры. 1941 дән СССР авиация сәнәгате халык комиссарының 1 нче урынбасары, 1946 дан министр урынбасары, 1953–57 дә һәм 1965 тән министры. 1957–65 тә Авиация техникасы дәүләт ком-ты рәисе. 1956 дан КПСС ҮК әгъзасы. 1954–77 дә СССР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге авиация сәнәгате үсешенә зур өлеш кертkәне өчен бирелә (1953). Тугыз Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Кутузов, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Д. исемен йөртә, һәйкәл-бюст (авторлары — скульп. М.К.Аникушин, арх. М.Х.Агишев) һәм мемориаль такта куелган.



П.В.Дементьев.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.



Казанда В.И.Ленин исем. Мәдәният сарае янында П.В.Дементьев бюсты.

**ДЕ́МЕРТ** Николай Александрович (псевд. Кушетников, Кушников, Илья Скалозубов, Уездный стенограф) (15.4.1833, Казан. губ., Лаеш өязе Сәләнгеш а. — 21.3.1876, Мәскәү), публицист, җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен (1852), Казан ун-тының юридик ф-тын (1856) тәмамлый. 1857 дә Казан губ. идарәсендә крәстиян эшләре буенча хезмәткәр. Соңрак Түбән Новгород өлкәсенең Варганы авылына китә, анда 2 ел дәвамында алпавыт Демидовлар балаларының гаилә укытучысы була. 1860 тан Чистай шәһәрендә мировой арадашчы, 1864 тә земство идарәсе рәисе. 1865 тә С.-Петербургка китә, анда «Санкт-Петербургские ведомости» г-тасында провинция яңалыклары бүлеген җитәкли. 1860 еллар уртасыннан «Искра» (1867–71), «Современное обозрение» (1869) ж-ллары, «Неделя» (1869) һәм «Биржевые ведомости» (1874) г-талары б-н хезмәттәшлек итә. «Искра» сатирик ж-лында «Иҗтимагый тормыш битләре» һәм «Йортыбыз мәшәкатьләре» рубрикалары астында Д.ның күзәтүләре басыла, аларда Казан шәһәре һәм губернасы хәбәрләренә зур урын бирелә. 1869 дан Д. «Отечественные записки» ж-лының иң популяр публицистларыннан берсе була, анда аның җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ал-



Н.И. Демидов.

ган әсәрләре, ш.и. Казан губернасында 1861 елгы крәстияннәр реформасы үткәрүне анализлаган «Яңа ирек» мәкаләсе басыла (1869, №8–10). Гимназиядә укыганда ук әдәби иҗат б-н шөгыльләнә башлый. Аның басылмаган «Күп гөнаһлы Казан» («Казань многогрешная») шигырен Казанның демократик рухтагы яшьләре яттан белә. Д. бу шигырендә түрәләр коррупциясен фаш итә. Басылып чыккан беренче әсәре «Студентлар истәлекләреннән» («Из студенческих воспоминаний», «Московский вестник», 1860, №34) Казан ун-тына багышлана. «Современник» ж-лында (1861, №7) аның «Өченче сортлы гувернантка музыка белән» («Гувернантка третьего сорта с музыкой») комедиясе басыла. Д. үз әсәрләрендә игътибарны җирле үзидарәләр эшенә юнәлтә, земство эшләрен оештырудагы авырлыкларны күрсәтә. Провинция тормышын һәм крәстиян көнкүрешен белүе Д.ның роман язарга әтәрә, ләкин «Невский сборник»та (СПб., 1867) аның «Кара туфрак көче» («Чернозёмные силы») исемендәге башлангыч өлеше генә басыла.

Х е з м.: Тёмные и светлые стороны нашего общества // Искра. 1871. № 5/6; Наши старые и новые больницы (Из записок опытного чиновника) // Искра. 1871. № 13; Современные жгучие вопросы, остающиеся без ответа, или Кто виноват? // Искра. 1871. № 37; Признаки пробуждения наших сонных провинций: (Корреспонденция из Казани) // Отечественные записки. 1871. № 7/8.

*Әд.:* К у р о ч к и н Н.С. Н.А.Демерт // Отечественные записки. 1876. № 12; Литературные воспоминания // Михайловский Н.К. Полн. собр. соч. М., 1909. Т. 6; Н.А.Демерт // Успенский Г.И. Полн. собр. соч. М., 1953. Т. 6; БСЭ. 2 изд. 1952. Т. 13; Русские писатели. 1800–1917; Краткая литературная энцикл. М., 1964. Т. 2; Биографический словарь. М., 1992. Т. 2.

*К.Н.Куранов.*

**ДЕМИДЕ́НКО** Владимир Петрович (24.10.1934, Украина ССР, Одесса өлкәсе, Ширяев р-ны Качулово а.), хәрби корал гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1970), проф. (1973), генерал-майор (1989), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978), СССРның атказ. уйлап табучысы (1989). 1958 елда Ленинград югары артиллерия инженерлары уч-щесен тәмамлый, шунда ук эшли (бүленеп, 1958–59 да Калинин өлкәсенең Ржев шәһәрендәге хәрби частьтә, 1971–81 дә артиллерия маршалы М.Н.Чистяков исем. Казан югары хәрби инженерлар уч-щесендә идарә итү системалары каф. башлыгы һәм 1976 дан уч-ще башлыгы урынбасары). 1981 дән Михайловск хәрби артиллерия ун-тында (С.-Петербург) хәрби корал каф. башлыгы, 1985 тән уку-укыту бүлеге башлыгы, 1994 тән идарә итү системалары каф. профессоры. Хезмәтләре артиллерия һәм баллистик ракеталар навигациясе приборлары б-н коралланууга карый. Команда-үлчәгеч приборлары куллануны автоматлаштыру системасын эшли, артиллерия коралының катлаулы механик системасы динамикасын тикшерә. Уйлап табуга 80 ләп авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар.

Х е з м.: Теория, проектирование и устройство командно-измерительных приборов АСУ баллистических ракет. К., 1977; Теория автоматического управления и элементы автоматики: В 2 ч. К., 1983 (автордаш); История Михайловской артиллерийской академии. СПб., 1996.

**ДЕМИ́ДОВ** Алексей Иванович (20.3.1952, Лаеш р-ны Урта Девятово а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, а.-х. фән. канд. (1999), ТРның атказ. а.-х. хезмәткәре (1996). Казан а.-х. ин-тын тәмамлый (1974). 1975–77 елларда Лаеш р-ны «Россия» с-зының үсемлекчелек цехы башлыгы, 1977–80 дә с-з директоры. 1980–83 тә халык депутатларының Алексеев р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1983–90 да КПССның Алексеев р-н ком-ты 1 нче секретаре. 1990–2004 тә халык депутатларының Алексеев р-н советы рәисе, 1991–2004 тә Алексеев р-ны хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта 1998–2004 тә ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары. 2004 тән ТР Хисап палатасы рәисе. Хезмәтләре үсемлекчелеккә карый. 1985–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2004 тә ТРның халык депутаты. ТРның Дәүләт бүләге «Үләнчел соргоны үстерү, куллану, орлыкчылыкны оештыру технологияләрен эшләү һәм Татарстан Республикасында аны җитештерүгә кертү» дигән хезмәте өчен тапшырыла (2001). Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ДЕМИ́ДОВ** Анатолий Иванович (23.9.1955, Лаеш р-ны Урта Девятово а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (1999), проф. (1999), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1977). 1977–85 елларда Лаеш р-ны «Волжский» с-зының инженеры, баш инженеры, директоры. 1985–87 дә КПССның Лаеш р-н ком-ты 2 нче секретаре, 1989–91 дә 1 нче секретаре. 1987–89 да халык депутатларының Лаеш р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1991–2002 дә халык депутатларының Лаеш р-н советы рәисе, бер үк вакытта 1992–2002 дә Лаеш р-ының хакимият башлыгы. Хезмәтләре а.х. һәм сәнәгать комплексын үстерү һәм идарә итүгә карый. 1987–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2004 тә ТР халык депутаты.

Х е з м.: Как сделать эффективным агропромышленный комплекс? К., 2002.

*Е.Б.Долгов.*

**ДЕМИ́ДОВ** Виктор Николаевич (6.6.1961, Алабуга ш.), хокук белгече, хокук белеме фән. канд. (1995), проф. (2004). Казан дәүләт ун-тын тәмамлый (1983). 1983–97 елларда РФ Эчке эшләр министрлыгы (1992 гә кадәр СССР Эчке эшләр министрлыгы) академиясе каршындагы Мәскәү юридик читтән торып уку ф-лының Казан бүлегендә укыта. 1997–99 да РФ Эчке эшләр министрлыгы Юридик ин-тының Казан ф-лында криминология һәм җинаятьләрне өйрәнү хокукы каф. башлыгы. 1999–2004 тә РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-ты башлыгы урынбасары. 2004 тән ТР Конституцион суды рәисе. Хезмәтләре җинаять, җинаять-процессуаль хокук, җинаятьне алдан кисәтү һәм криминалогик тасвирлау (характерлау) проблемаларына, җинаять эше процессында материаль чыгымнар мәсьәләләренә карый. Дәреслекләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Уголовный процесс и материальные затраты. М., 1995; Криминологическая характеристика преступности в России и Татарстане (1991–96). М., 1998; Прогнозирование преступности. К., 1999 (автордаш). Криминологическое прогнозирование: анализ, методы и моделирование. К., 2002 (автордаш); Прогнозирование преступности: проблемы, возможности, перспективы. К., 2003 (автордаш); Прогнозирование в криминологии: К., 2004 (автордаш).

*Е.Б.Долгов.*

**ДЕМИ́ДОВ** Николай Иванович (8.4.1933, Лаеш р-ны Урта Девятово а.), генерал-лейтенант (1984). Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1956). 1956 елдан партия, дәүләт эшендә. 1978–83 тә ТАССР эчке эшләр министры. 1983–91 дә СССР эчке эшләр министры урынбасары. 1991–97 дә РФ Эчке эшләр министрлыгы академиясе башлыгы (Мәскәү). 1971–85 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: МВД в Чернобыле: Уроки и выводы. М., 1996; Подвиг сотрудников МВД в Чернобыле и Кыштыме. М., 2002.

*Әд.:* На страже порядка. К., 1997; Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ДЕМИ́ДОВ** Эдуард Дмитриевич (28.5.1946, Казан — 23.10.1998, Мәскәү өлкәсе Пущино ш.), биохимик, биол. фән. д-ры (1994). Милләте буенча татар. Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1972 елдан Пущино шәһәрендә СССР ФАнең Фотосинтез ин-тында эшли (1982 дән — Туфрак белеме һәм фотосинтез ин-ты, 1998 дән — РФАнең Биология фундаменталь проблемалары ин-ты), 1996 дан углерод фотометаболизмы лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре фотосинтезның эндоген көйләнешенә һәм энергетикасына, углерод һәм азот метаболизмына карый. Фотосинтезлаучы организмнарда һәм аерым хлоропластларда беренчел энергия туплау реакцияләренә яктылык көченең һәм сыйфатының йогынтысы буенча яңа мәгълүматлар ала. Энергия һәм газ алмашы арасындагы аерымлану эффекты б-н гликоль кислотасының тирәлеккә бүленеп чыгуы арасында бәйләнешне билгели. Күзәнәкләр эченә углекислоталарны актив күчерүдә циклик фотофосфориллаштыру катнашуы концепциясен һәм шул сәбәпле углекислый газның түбән концентрациясе шартларында фотосинтезның югары нәтиҗәле булуын тәгъбир итә. Фәнни экспедицияләрдә Байкал култыгының симбиотик суүсемнәрен, Баренц диңгезе суүсемнәрен, Урта Азия һәм Памир чүлләрендәге $C_4$-үсемлекләрен тикшерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О связи между выделением гликолевой кислоты и энергетической обеспеченностью кле-

ток хлореллы на свету // Физиология растений. 1978. Т. 25, № 5 (автордаш); Превращение гликолата и глицина в клетках хлореллы // Физиология растений. 1980. Т. 27, № 1 (автордаш); Effect of Dissolved Inorganic Carbon on Non Photochemical Quenching by Selanastrum Minutum Adapted to Ambient Air and $CO_2$ Enriched Air // Photosynthesis: from Light to Biosphere. 1995. V. 5 (автордаш).

**ДЕМИ́ДОВ** Юрий Иванович (27.10.1938, Лаеш р-ны Урта Девятово а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. җиңел һәм туку сәнәгате хезмәткәре (1996). Алабуга пед. ин-тын (1965), КПСС ҮК каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлый (1976). Лаеш р-нының «Комбайн» (1963–67), «Путь Ленина» (1967–68) к-злары рәисе булып эшли. 1968–70 елларда КПССның Лаеш райкомының 2 нче секретаре, 1970–74 тә хезмәт ияләре депутатларының Лаеш р-н советы башкарма ком-ты рәисе, 1976–85 тә КПССның Югары Ослан райкомының 1 нче секретаре. 1985–89 да ТАССР җирле сәнәгать министры. 1989 дан «Татместпром» АҖ ген. директоры, 1993 тән президенты. 1979–86 да ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ДЕМИ́ДОВА** Наталья Николаевна (15.10.1959, Әлмәт ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1983, Мәскәү). 1978 дән «Татнефть» АҖдә эшли: «Елховнефть» НГДУында нефть һәм газ чыгару буенча оператор, «Әлмәтнефть» НГДУының нефть промыселларында оператор, технол. режимнар төркеме инженеры, геолог, әйдәп баручы геолог (1980 нән). Дәүләт бүләге нефть чыгару процесслары б-н идарә итү һәм оператив күзәтүнең кооператив мәгълүмат системасын эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен бирелә.

**ДЕМИДО́ВИЧ** Александр Филиппович (23.4.1897, Минск губ. Копыль а. — 5.11.1965, Казан), агроном-селекционер, а.х. фән. д-ры (1949), проф. (1950). Горецк а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1925), шунда ук ярдәмче хуҗалыкта эшли. 1931 елдан Казан а.х. ин-тында, җиләк-җимеш — яшелчәчелек ф-ты деканы (1943–45), җиләк-җимеш — яшелчәчелек каф. мөдире (1945–54). 1954–65 тә Казан. вет. ин-тында терлек азыгы җитештерү каф. мөдире. Хезмәтләре яшелчә культуралары һәм бәрәңге селекциясе, орлыкчылыгы һәм агротехникасы мәсьәләләренә карый. Бәрәңгенең — «Казанский 520», «Вегетативный гибрид 1», «Сеянец 7035/566»; кәбестәнең — «Клыковская 19/23», аш чөгендеренең «Казанская 58» сортлары авторы. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Селекция картофеля на устойчивость к засухе. К., 1938; Семеноводство картофеля в ТАССР. К., 1952; О методах селекции и семеноводства картофеля. К., 1960.

**ДЕМИДО́ВИЧ** Владимир Михайлович (22.4.1926, Воронеж ш.), машиналар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). 1949 елда Казан авиация ин-тының (хәзер Казан техник ун-ты) моторлар төзү ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли, машина детальләре каф. мөдире (1968–88), конструкцияләү нигезләре каф. мөдире (1988–94), каф. профессоры (1994 тән). Хезмәтләре очкыч аппаратлар двигательләренең ышанычлылыгын һәм озакка чыдамлылыгын арттыруга карый. Д. газ турбиналы двигательләрнең ротор терәкләрендәге подшипникларның җылылык режимын билгеләү ысулын тәкъдим итә һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование теплового режима подшипников газотурбинных двигателей. М., 1978; Проектирование подшипниковых узлов. К., 1995 (автордаш).

**ДЕМИ́ДОВКА** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* төньяктарак, Салман елгасы буенда. 2008 елда 129 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 683 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостена, 1920 дән ТАССРның Спас кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1935 нең 10 февраленнән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 289, 1897 дә — 363, 1908 дә — 398, 1926 — да 201, 1938 дә — 148, 1949 да — 124, 1958 дә — 89, 1970 тә — 119, 1979 һәм 1989 да — 115, 2002 дә — 131 кеше.

**ДЕМИ́ДОВЛАР**, сәнәгатьчеләр һәм җирбиләүчеләр. 18 йөз уртасында Д.ның Россиядәге чуенның 40% ын җитештерүче 55 з-ды була. Нәселне нигезләүче — Тула тимерчесе **Демид Антуфьев** (17 йөз).

**Никита Демидович** (26.3.1656, Тула — 17.11.1725, шунда ук). Төньяк сугышы вакытында (1700–21) рус гаскәрләре өчен корал җитештерә. Заказларны уңышлы үтәве өчен аңа Уралда Верхотурск казна з-длары б-н бергә зур җир биләмәләре бүлеп бирелә. Ул аларның бәясен 5 ел дәвамында тимер әйберләр биреп түләргә йөкләмә ала. Үз заводларына барган вакытта Казанда берничә тапкыр (1703, 1704 һ.б.) була. Чулман, Идел, Ука елгалары буйлап Лаеш һәм Казан аша Мәскәүгә бомбалар, снарядлар, ә 1705 елның язынннан эре калибрлы туплар озата. Казан воеводасы Н.А.Кудрявцев 1708 дә Казанда төзелә торган корабльләр һәм «күпләгән башка дәүләт хаҗәтләре» өчен Демидов судноларыннан 5100 граната, 1475 ядрә һәм бомба, 1709 да — 11 туп һәм 3350 пот тимер бушатырга әмер бирә. Никита Д. з-длары ел саен уртача 20–25 мең пот тимер җитештерә. 1715 нең 12 маенда чыккан фәрман б-н аңа, Баш артиллерия һәм фортификация канцеляриясе б-н берләттән, Петербург адмиралтействосына тимер җибәрергә кушыла. Пётр I нең 1720 ел, 17 декабрь фәрманы нигезендә Казан губернасының Идел һәм Зөя пристаньнарыннан имән бүрәнәләр агызу эше йөкләтелә, губернаторларга аңа комачаулау тыела. Ул 60–70 туплы — дүрт, 54 туплы ике хәрби корабль һәм 5 галера төзелешен агач б-н тәэмин итә. С.-Петербургка нигез салганда һәм аны төзегәндә, Никитаны, хаклы рәвештә, Пётр I нең төп ярдәмчеләреннән берсе дип атыйлар. 1720 дә ул шәхси дворянлыкка ия була. 1717 дә Никита Демидовичка склад төзү өчен Казанда урын бирелә. Аның милкенең шактый өлеше өлкән улы **Акинфий Никитичка** (1678, Тула — 5.8.1745, Чулман елгасы янындагы Җаек Тамагы авылы тирәсе) мирас булып кала; бертуганнары — **Григорий Никитич** (1728/29 да үтерелә) һәм **Никита Никитич** (1750 елларда вафат). Акинфий Никитичка этисеннән Казанда сәүдә йорты, 1 таш, 2 агач йорт, Лаешта агач йорт мирас булып кала. Ул Уралда 17 тимер һәм бакыр эретү з-дына нигез сала, бакыр һәм кургаш рудниклары ача, малахит һәм асбест ятмаларын эшкәртә, көмеш һәм алтын ятмаларын таба. Сәнәгатьне үстерү өлкәсендәге уңышлары өчен императрица Екатерина I 1726 да аңа һәм туганнарына нәселдән күчүче дворянлык дәрәҗәсе бирә. Акинфий Никитич Казанда соңгы тапкыр 1745 тә Уралдагы биләмәләренә барганда була.

Аның уллары — **Прокопий** (8.7.1710, Невьянск – 4.11.1788, Мәскәү), **Григорий** (14.11.1715 – 13.11.1761), **Никита** (8.9.1724 – 1789). Аларның һәрберсе башка мирас б-н бергә Казанда берәр утар ала (Лаештагы утар Прокопийга күчә). Д.ның сәүдә йортларында приказчиклар һәм эш кешеләре яши, алар судноларддан тимер бушату һәм аны җирле базарда сату б-н шөгыльләнә. Приказчиклар кәрван йөртүчеләрне акча б-н тәэмин итә, бәяләрне билгеләү өчен җирле базарда товарга булган ихтыяҗ турында мәгълүмат бирәләр, вексельләр буенча түлиләр һәм Казан сәүдәгәрләреннән аларның бурычларын түләтәләр, якындагы биләмәләр б-н идарә итәләр. Тимер б-н тәэмин иткән өчен Казанда казнадан өлешчә акча түләнә, казнага товар бирү мәсьәләләре буенча Казан адмиралтейство конторасы б-н элемтә тотыла. 1720–27 дә Д. Казан адмиралтействосына 7544 сумга 13300 пот тимер тапшыралар. Лаештагы утар Д.ның Казандагы сәүдә йорты буйсынуында була, ул узгынчы кәрваннарга хезмәт күрсәтә. Казандагы һәм Лаештагы сәүдә йортларыннан тыш, Прокопийның Нугай даругасындагы Чырпы, Новоспасский, Лебяжье, Архангельский, Алексеев, Юркүл һ.б. авылларда, Җөри даругасындагы Воскресенский, Арча даругасындагы Колсәет авылларында җир биләмәләре була, аларда ир-атлардан 1665 крепостной крәстиян исәпләнә (1771–73). Никита Никитичның уллары — 18 йөздән Казан алпавытлары. Алардан **Иван Никитичның** (?-1807) 290 крепостное, Нугай даругасындагы Воскресенский, Көек, Зирекле, Мораса һ.б. авылларда, Арча даругасындагы Иверск авылында җирләре, Казанда йорты була (1770 еллар). 18 йөз ахырында оныгы **Никита Акинфиевич** кына сәнәгать җитештерүе б-н шөгыльләнә, Казанда сәүдә йорты тота. Ул вафат булганнан соң,



С.А.Дёмина.

сәүдә йорты, ш.у. Лаештагы утар аның улы **Николайга** (9.11.1773 — 22.4.1828, Флоренция) күчә. Ул үз акчасына Лаешта госпиталь төзетә һәм аны җиһазлый. Аның уллары — **Павел Николаевич** (6.8.1798 — 25.3.1840) Демидов ятимханәсе оештыра (1832), **Николай Николаевич** (?-?) Казанда сәүдә йорты тота (1822).

Д.ларның 4 нче буын вәкилләре дә Казан алпавытлары була. Григорий Акинфиевичның уллары — **Александр Григорьевич** (1737–1803) һәм Ярославль шәһәрендә Демидов лицеен (1803) оештырган **Пётр Григорьевич** (1740–1826). Аларның Арча даругасы буенча Канбар тимер эшләү з-дында 1771–73 тә 648 «оста һәм эш кешесе» исәпләнә. Аның кызлары башкаланың танылган архитекторларында: Пульхерия Григорьевна (1741–84) — А.Ф.Кокориновта, Наталья Григорьевна И.Е.*Старовта* кияүдә була.

19 йөз уртасында Д. зур җир биләмәләренә хуҗа булалар һәм Казан нәсел кенәгәләрендә исәпләнәләр. Алар инде Россия сәнәгатьчеләре исәбенә кермиләр, әмма Казан губернасында иҗтимагый һәм мәдәни тормышта әһәмиятле роль уйнауларын дәвам итәләр. 1820 елларда Никита Никитичның турыдан-туры оныкварислары — **Владимир Петрович** һәм **Пётр Петрович** Д. А.А.Наумованың әдәби түгәрәгенә йөриләр. Пётр Петровичның оныгы, отставкадагы гвардия поручигы **Александр Александрович** Д. 1862–74 тә Спас өязе дворяннары башлыгы була. Өяздә аның Кызыл Яр һәм Демидовка авылларында 515 крепостное һәм 3257 дис. җире, Каравайда 368 крепостное, 30 хезмәтчесе, 28,42 дис. утар җире һәм 1462,5 дис. сөрүлек җире исәпләнә. Аның хатыны Варвара Таврионовнаның кыз фамилиясе — Молоствова.

*Әд.:* Кафенгауз Б.Б. История хозяйства Демидовых в XVIII–XIX вв.: Опыт исследования по истории уральской металлургии. М.–Л., 1949; Павленко Н.И. Развитие металлургической промышленности России в первой половине XVIII в. М., 1953; Русский энциклопедический словарь. СПб., 1905. Т. 6.

*А.В.Гарзавина.*

**ДЁМИН** Алексей Владимирович (20.10.1960, Казан), җылылык энергетикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), проф. (2003). 1983 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, сәнәгый экология каф. мөдире (2003 тән). Д. җылылык һәм энергия җайланмаларында яну процессларын матем. модельләүне тикшерә, техноген тәвәккәллекләргә анализ ясый һәм алар б-н идарә итү алымын тәкъдим итә, шуңа кирәкле мәгълүмат базасын һәм программаларны төзи. ТР ФА каршындагы «Халык һәм территорияләр куркынычсызлыгы» фәнни советы рәисе урынбасары (2004 тән). Уйлап табуга 2 патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007).

Хезм.: Горение и течение в агрегатах энергоустановок: моделирование, энергетика, экология. М., 1997 (автордаш); Chemical non-eguilibrium engineering model of advanced combustion regimes in a direct-injeted diesel engine // 2008 World Congress Detroit, Michigan, 2008. SAE Technical Paper Series, 2008–01–0842 (автордаш).

**ДЁМИН** Сергей Константинович (14.2.1963, Куйбышев ш.), спортчы, тренер (стендта ату), СССРның спорт остасы (1983), РФнең атказ. тренеры (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1985–94 тә «Электрон» спорт клубында тренер, 1995 тән ТР Физкультура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тының (2001 дән — ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, 2005 тән — ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы) Үзәк спорт клубында өлкән тренер. Шәкертләре арасында — С.А.*Дёмина*, халыкара класслы спорт остасы, Россия һәм Европа беренчелегендә күп тапкыр бүләкләр алган В.А.Мосин бар.

*Әд.:* Правофланговые спорта Республики Татарстан. К., 1997.

**ДЁМИНА** (кыз фамилиясе Якимова) Светлана Александровна (18.4.1961, Вологда өлкәсенең Кирилловск р-ны Розбуй ш.), спортчы (стендта ату), СССРның атказ. спорт остасы (1982). Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1985). «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Тәтештәге олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнә (1975 тән тренеры С.Ю.Потапов, 1986 дан — С.К.Дёмин). СССР һәм Россия (1981, 1983–88, 1990, 1992–93, 1998, 2000–02, 2008 (шәхси), Европа (1983–84, 1986–88, 1990 (шәхси), 1979, 1982, 1984, 1986–88, 1990, 1992, 1998–2002, команда), дөнья (1982–83, 1986, 1990, 1993 (шәхси), 1979, 1994, 1999, 2001, команда беренчелегендә) чемпионы. Европа чемпионатында 1981–82, 1992, 1999 (шәхси), 1980, 1991 (команда беренчелегендә), дөнья 1991 (шәхси), 1986, 1990, 1998, 2002 (команда беренчелегендә); Олимпия уеннарында (2000) көмеш медаль ала. СССР (Россия) 1980, 1982, 1991, 1994, 1996, 1999, Европа 1991, 1993–94 (шәхси), 1981, 1993, 1995 (команда), дөнья 1979, 1994, 1999 (команда беренчелегендә) чемпионатларында бронза медаль ала. СССР (Россия) 1984–86, 1988, 1990–94, 1998, 2000, дөнья (2003) кубоклары иясе. Дөнья кубогына (2001) бәйгедә – көмеш приз, СССР (1982–83), Россия (1995) кубокларына бәйгедә 3 нче урын ала. Дөнья рекордчысы (1999). Д. «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советында тренер (1978–80), ТАССР Физкультура һәм спорт дәүләт ком-тында (1980–81, 1983–93), стендта ату буенча олимпия резервындагы Тәтеш балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1981–83) инструктор, 1993 тән ТР Физкультура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тында (2001 дән — ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, 2005 тән — ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы) спортчы-инструктор.

*Әд.:* Марихин Б.Ф. Тетюшские стрелки. К., 1985.

**ДЕМИРБА́Й** (Тимербай) Хәмидулла Гыйбадулла улы (1897–1988), җәмәгать эшлеклесе, эшмәкәр. Нагоя шәһәренең (Япония) төрки-татар җәмгыяте рәисе. Аның иганәсенә мәктәп ачыла, мөселман зираты өчен җир сатып алына, мәчет һәм мәдрәсә биналары төзелә.

**ДЕ́МНЕР** Леонид Менделевич (3.8.1923, Украина ССР, Черновцы ш.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). 1956 елда Пермь мед. ин-тының стоматология ф-тын тәмамлый. 1956–90 елларда Казан мед. ин-тында, 1969–89 да ортопедик стоматология каф. мөдире, 1990 нан Израильдә. Д. стоматологик авырулар үсешендә организмның түбән резистентлыгы ролен билгели. Д. алынма протезларны тоташ металл нигездә эшләү ысулын, күпер рәвешле протезларны эретеп ябыштыру кулланмыйча ясау методын, казналыкка операцияләр ясау өчен инструментлар һәм кариес куышлыкларны бор машинасыз эшкәртү ысулларын тәкъдим итә; теш-казналык аномалияләренә диагноз кую һәм дәвалау ысулларын, бозык тешне өстәмәләр һәм фарфор коронкалар б-н ортопедик дәвалауны гамәлгә кертә.

Хезм.: Кариес зубов и зубочелюстные аномалии у детей, болеющих туберкулёзом. К., 1962; Значение хронической инфекции (туберкулёза) в патогенезе аномалий зубочелюстной системы. К., 1972.

**ДЕМОГРА́ФИК СӘЯСӘ́Т**, дәүләт органнарының һәм башка социаль ин-тларның халыкның артуын җайга салу өлкәсендәге максатчан эшчәнлеге. Тулаем алганда, Д.с.нең максаты, гадәттә, буыннар алышуның кирәкле режимын формалаштырудан, халык санының структурасы һәм динамикасы өлкәсендәге тенденцияләрне, аларның үзгәреш темпларын, *туым*, *үлем*, гаилә составы, халыкның урнашуы, эчке һәм тышкы миграциясе, сыйфат характеристикасы динамикасын саклау яки үзгәртүдән гыйбарәт. Д.с., кагыйдә буларак, төрле чаралар комплексы аша гамәлгә кертелә. Алар: икътисади (түләүле еллар һәм бала тугач бирелә торган, балалар санына, яшенә, гаилә хәленә бәйле төрле пособиеләр; ссуда, кредит, салым һәм торак буенча льготалар һ.б.); административ-хокукый (никахлашуларны, аерылышуларны, гаиләдәге балаларның хәлен, алимент түләүләрен, ана һәм бала хокукларын саклауны, абортларны, эш б-н тәэмин итү шартларын, эшләүче аналарның хезмәт шартларын, эчке һәм тышкы миграцияне һ.б. проблемаларны җайга салучы закон актлары); тәрбияви һәм пропаганда чаралары (иҗтимагый фикерне, җәмгыятьтә демографик тәртип үрнәкләрен һәм стандартларын булдыру).

1936 елда СССРда күп балалы гаиләләргә акчалата пособиеләр түләү (7 нче һәм аннан соң туган балаларга) кертелә, бала тудыру йортлары һәм балалар бакчалары челтәрен киңәйтү чаралары билгеләнә, алимент түләмәүчеләргә җинаять җәзасы көчәйтелә, ае-

рылышу тәртибе катлаулана, аерылышу турында паспортка тамга салу кертелә, абортлар тыела (тыю 1956 да гамәлдән чыгарыла). 1944 тә аналарга матди һәм рухи ярдәмне көчәйтүче закон акты кабул ителә, 3 нче бала туган очракта — бер тапкыр бирелүче, 4 нче һәм аннан соң туган балаларга (1 яшьтән 5 яшькә кадәр) билгеләнгән пособиеләр кертелә, йөклелек чоры һәм бала тудыру буенча яллар озайтыла, күп балалы аналарга бүләкләр («Ана медале», «Ана даны» ордены, «Герой-ана» исеме) булдырыла. 1981–83 елларда 1 нче һәм 2 нче балага бер тапкыр бирелүче пособиеләр кертелә (тиңдәшле рәвештә 50 һәм 100 сум), 3 нче бала туган очракта пособие күләме арта һәм күп балалы гаиләләрдә пособиеләр үзгәрешсез сакланып кала, 1 яшькә кадәрге баланы карау өчен өлешчә түләүле ял кертелә (1989–90 елларда 1,5 яшькә кадәр озайтыла). 1990 елларда РФнең барлык төбәкләрен диярлек демографик кризис чолгап ала, ул, туымның кимүе, үлемнең артуы сәбәпле, халык санының кимүендә күренә, нәтиҗәдә буыннар алмашыну 60% ка гына үтәлә. Килеп туган демографик хәл законнар чыгаручы һәм башкарма хакимиятнең федераль, ш.у. төбәк дәрәҗәсендә халык санын арттыру, сәламәтлек саклау шартларын тәэмин итү һәм үлемне киметү процессларына максатчан катнашуын таләп итә. РФ Президенты Указы нигезендә расланган кайбер федераль программалар — «2000 елга кадәр Россия Федерациясендә балаларның хәлен яхшырту буенча дәүләт социаль сәясәтенең төп юнәлешләрен раслау турында» (1995), «Дәүләт гаилә сәясәтенең төп юнәлешләре турында» (1996) һ.б. — хатын-кызларның йөклелек чорында һәм бала туганнан соң матди хәлен яхшырту, гаилә һәм бала мәнфәгатьләрен яклауны максат итеп куя: балага һәм ялгыз ана балаларына ай саен бирелүче пособиеләр күләмен арттыру, аз керемле гаиләдәге балаларга уку елы башында өстәмә пособиеләр бирү кертелә, баласы булган гражданнарны адреслы социаль яклау (гаиләдә җан башына уртача туры килгән керемгә бәйле рәвештә), укучы балаларның мәктәптә туклануы өчен компенсацияләр карала. Санаторий-курортларда дәвалануга мохтаҗ балаларга, дәүләт һәм муниципаль белем бирү йортларында укучыларга юлда йөрү ташламалары кертелә, күп балалы гаиләләрне һәм ятим балаларны дәүләт яклавы турында федераль законнар кабул ителә. Халыкның аз керемле катлавына дәүләтнең социаль ярдәме, яшәү минимумы, «кулланучылар кәрзине» турындагы законнар демографик кризисны көчәйтә баручы хәерчелеккә каршы юнәлтелә. Халыкның сәламәтлеген ныгыту, үлем дәрәҗәсен киметү, гомер озынлыгын арттыру максатында халыкның санитар-эпидемиологик хәлен яхшырту, йогышлы авыруларга каршы иммунопрофилактика үткәрү, сәламәтлек саклау системасы, туберкулёз таралуны кисәтү турында федераль законнар кабул ителә. ТРда «Гражданнарны медицина иминиятләштерүе турында» (1993), «Яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» (1999), «Физик культура һәм спорт турында» (1999) респ-ка законнары кабул ителә. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында»гы (2004) ТР законында балалы гаиләләргә (җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләргә, хәрби чакырылыш буенча хезмәт итүчеләрнең, ялгыз аналарның балаларына һ.б. пособиеләр) өстәмә ярдәм чаралары булдыру күздә тотыла. 3 һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә субсидияләр (дарулар сатып алу, укучы балаларга юлда йөрү өчен, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә өстенлекләр) карала. «Ана даны — Материнская слава» медале булдырыла һәм ул, бер тапкыр бирелүче акчалата бүләк б-н бергә, 5 һәм күбрәк бала тудырып һәм тәрбияләп үстерүче (үстергән) аналарга бирелә. Татарстанда аерым гаиләләрне мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә түләүдән өлешчә яки тулысынча азат итү саклана. 2007 дән башлап, уку программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләренә түләүгә өлешчә компенсация бирелә. 16 яшькәчә баласы булган хатын-кызларга хезмәт эшчәнлеген бала тәрбияләү б-н бергә алып бару өчен шартлар тудыру максатында, атнага 2 сәгатьтән ким булмаган буш вакыт яки айга 1 буш көн бирелә, һәм ул өлешчә яки тулысынча пр-тие яки оешма хисабыннан түләнелә. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары кабул ителгән (балаларга ай саен акчалата түләүләр, тәрбиягә бала алган ата-аналарга түләү). 2007 дә РФ Президенты Указы буенча расланган «2025 елга кадәр чорда Россия Федерациясенең демографик сәясәте концепциясе» илдә демографик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән (үлем дәрәҗәсен киметү, туым дәрәҗәсен арттыру, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, гаилә ин-тын ныгыту, миграцияне көйләү). Шул ук елда «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» федераль закон үз көченә керә, аның нигезендә икенче яки аннан соңгы бала туган (яки тәрбиягә алынган) очракта гаиләнең 250 мең сум (2009 дан — 312 мең сум) күләмендә ана (гаилә) капиталы алу хокукы бар. 1,5 яшькә кадәрге балаларга билгеләнгән пособие күләме арта, эшләмәүче аналарга пособиеләр булдырыла, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләрнең күләме арта (16,1 мең сумга кадәр), 2006 елда мед. учреждениеләренең матди кызыксынуын күтәрү максатында кертелгән бала тудыру сертификатының бәясе арта (10 мең сумга кадәр).

*Әд.:* Кваша А.Я. Демографическая политика в СССР. М., 1981; Демография: современное состояние и перспективы развития. М., 1997; Демографическая политика: цели, принципы, приоритеты. М., 2000; Социальная энциклопедия. М., 2000.

*А.М.Шихалёв, О.В.Слепова.*

**ДЕ́МПИНГ** (ингл. dumping, dump сүзеннән), товарларны тышкы һәм эчке базарларда ташламалы, ясалма рәвештә килешенгән, дөнья базарындагы уртача ваклап сату бәяләренә караганда да киметеп, кайчагында үзкыйммәтеннән дә арзанрак бәяләргә сату. Товар, валюта, социаль Д.лар аерып карала. Товар Д.ы чит илгә товар чыгаруны киңәйтү, конкурентларны (көндәшләрне) базардан кысрыклап чыгару юлы б-н базарга үтеп керү өчен уздырыла. Базарда тотрыклы хәлгә ирешкән очракта да, агымдагы зыянны каплауга исәп тотып, дәүләт һәм компанияләр тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурентларын кысрыклап чыгарганчы яки алар б-н килешүләр төзүгә ирешкәнче фирмалар һәм дәүләт еш кына, бер тапкыр булса да, кыска вакытлы Д. чарасы куллана. Д. ш.у. кирәкле акча һәм валюта средстволарын тизрәк алу ысулы буларак та файдаланыла. Д. объекты булып торган илләрдә милли сәнәгатьне үстерүдә кыенлыклар күзәтелә. 1990 еллар башында Д. нәтиҗәсендә ТРда күпчелек җиңел һәм азык-төлек сәнәгате пр-тиеләре («Спартак» җитештерү берләшмәсе, тегү ф-калары, кошчылык ф-калары һ.б.), эчке базарда үзләренең продукцияләрен сата алмыйча, җитештерү күләмен кыскартырга яки туктатырга мәҗбүр була. Әмма дөнья практикасындагы Д. тан яклау ысуллары бирелдә кулланылмый. Илнең сәнәгатен яклау өчен, дөньякүләм икътисади практикада Д. каршы законнар, махсус пошлиналар кертү һ.б. каралган. РФ товарларына карата 2002 елда Бөтендөнья сәүдә оешмасы тарафыннан кертелгән 126 Д. чикләвенең 15 кә якыны турыдан-туры ТР сәнәгатьчеләренең (күкертле нефть, нефть продуктлары, мех һәм мех әйберләр, авиация техникасы чыгару һ.б.) мәнфәгатьләренә кагыла.

Валюта Д.ы вакытында чит илгә товар чыгару дөнья бәяләреннән түбәнрәк бәяләрдә махсус киметелгән валюта курсы б-н гамәлгә ашырыла, чит илгә товар чыгаручы илнең эчке базарында акча кыйммәте тышкы базардагы валюта бәясенә караганда тизрәк төшә.

Социаль Д., илдә эш хакының түбән булуын истә тотып, чит илдән түбән бәя б-н товар тәкъдим ителгән вакытта барлыкка килә. Күп кенә илләр чит илгә товар чыгаргандагы югалтуларны аерым товарларга гына түгел, бәлки сәнәгатьнең һәр тармагын, гомумән, икътисадны субсидияләү юлы б-н каплый. А.х. продукциясен чит илгә Д. буенча чыгарган очракта, дәүләт дотациясен бүлгәндә, җитештерүчеләргә турыдан-туры субсидия бирү юлы киң таралган.

Үз илләрендәге җитештерүне яклау өчен, бер төркем Европа илләре («Гомуми базар») тарафыннан шул илләр арасында чыгарыла һәм кертелә торган товарның бәяләрен көйләүче тариф килешүе төзелә.

Бер үк төрдәге охшаш продукция җитештерүче фирмалар һәм компанияләр арасында конкуренция вакытында Д. буенча товар сату эчке базарда да гамәлгә ашырылырга мөмкин.

*Әд.:* БСЭ. 3 изд. М., 1972. Т. 8; Экономическая энциклопедия. М., 1999.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ДЕ́МЧЕНКО** Сергей Григорьевич (24.4.1938, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1998), проф. (1998), ТРның атказ. икътисадчысы (2001). 1962 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Барнаул, Казан шәһәрләре заводларында инженер булып эш-

ли. 1969–89 елларда «Волга» фәнни-җитештерү берләшмәсендә фәнни-тикшеренү эшендә: лаб. һәм бүлек мөдире (1970–89). 1989–2001 дә Казан финанс-икътисад ин-тында, 1998 дән җитештерү икътисады каф. профессоры. 2002 дән Татар-Америка региональ ин-ты профессоры һәм проректоры. 2005 тән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында: менеджмент (2005–2008), маркетинг һәм икътисад (2008 дән) кафедралары мөдире. Хезмәтләре җитештерү б-н идарә итү өлкәсенә карый.

Х е з м.: Управление основным производством в рыночной экономике. К., 1996; Производственный менеджмент: Практикум. К., 2001; Инновационная политика предприятий сферы туризма. К., 2007; Предпринимательство в контексте промышленной политики. К., 2008.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ДЕ́НИКЕ** Борис Петрович (1885 — 1942, Мәскәү), сәнгать тарихчысы, археолог, музей эшлеклесе, сәнгать белеме д-ры (1925), проф. (1925). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1915), шунда ук сәнгать тарихы һәм теориясе кафедрасында, бер үк вакытта Сәнгать һәм борынгы әйберләр музеенда ассистент булып эшли. Көнчыгыш академиясендә Шәрекъ сәнгате тарихыннан лекцияләр укый (1920–22), *Шәрекъ халыклары сәнгате музеен* оештыру коллегиясе әгъзасы була (1920). 1910 — 1920 еллар башында «Камско-Волжская речь» г-тасында, «Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете», «Учёные записки Императорского Казанского университета», «Казанский музейный вестник», «Казанский библиофил» ж-лларында басыла. 1922 дән Мәскәүдә яши һәм эшли. Мәскәү ун-тында укыта, Иҗтимагый фәннәр фәнни-тикшеренү ин-тының Россия ассоциациясе (РАНИОН) б-н хезмәттәшлек итә. 1925 тән Көнчыгыш мәдәнияте музеенда эшли (1927–28 дә директор), борынгы Термезда казу эшләре б-н җитәкчелек итә. 1932 дән А.С.Пушкин исем. Сынлы сәнгать музее директоры.

Д.ның күпкырлы иҗат эшчәнлеге тарихи-ретроспектив тикшеренүләр, сәнгать тәнкыйтенә караган эшләр, күргәзмә һәм музей эшчәнлеген колачлый. Ул 19 йөзнең 1 нче яртысында яшәгән Казан рәссамнарының мирасын («Л.Д.Крюков — беренче Казан университеты нәкышьчесе», 1916; «Зиновий Ивановның яңадан ачылган эшләре», 1922), борынгы рус сәнгате ядкәрләрен («Рус чиркәве нәкышь сәнгате хәзинәләре», 1911; «Мәскәү иске дин тарафдарлары чиркәүләрендә икона язу», 1915; «Елантау монастыреның гыйбадәт киемнәре стилендәге борынгы рус чигүе», 1917; «Соловки китапханәсе кулъязмаларындагы миниатюралар», 1921 һ.б.), Казанның шәхси тупланмаларындагы әсәрләрне («Казанның сәнгать хәзинәләре» күргәзмәсендәге борынгы портрет һәм миниатюра», 1916) тикшерә һәм фәнни кулланышка кертә. Д. — Казан рәссамнары күргәзмәләрендә даими рецензентларның берсе («Икенче периодик күргәзмә картиналары«» 1913; «Көнчыгыш халыклары мәдәнияте күргәзмәсендә сәнгать», 1920; «Казанда 1920 елгы сәнгать күргәзмәсе», 1920; «Всадник» графика коллективы басмалары», 1921). Казан чорында ук башланган тикшеренүләренең төп юнәлеше — Көнчыгыш сәнгате тарихы. Ул Болгардагы Кече манара орнаментларын, Казандагы Үзәк мөселман китапханәсе тупланмасыннан Хөсрәү Пәхләвинең «Хәмсә» әсәрендәге фарсы миниатюраларын, Алтын Урда табылдыклары арасыннан кытай савытларын һ.б. тикшерә. «Шәрекъ сәнгате: мөселман сәнгате тарихыннан очерклар» исемле (1923) сынлы һәм гамәли бизәлеш сәнгатьләрен (миниатюралар, тукыма, келәм, керәч, нәфис металл һ.б.) һәм архит-расын колачлаган Шәркый мөселман илләре сәнгатенең гомуми тарихын беренче тапкыр рус телендә бастырып чыгара. Д.ның Якын һәм Ерак Көнчыгыш, Урта Азия, Япония, Иран, Кытай сәнгате буенча 1930 елларда язылган хезмәтләре Россия сәнгать белемендә ориенталистика тармагының нигезен тәшкил итә һәм хәзергә кадәр үзенең фәнни әһәмиятен югалтмый.

Х е з м.: Искусство Средней Азии. М., 1935; Японская цветная гравюра. М., 1935; Живопись Ирана. М., 1938, Архитектурный орнамент Средней Азии. М.–Л., 1939; Краткая история искусства Китая. М.–Л., 1948.

*Әд.:* М и х а й л о в с к а я Н. Мы подбирали брошенные традиции // Художник. 1992. № 4/5; К л ю ч е в с к а я Е.П. Из истории искусствознания в Татарстане // Татарстан. 1996. № 10.

*Е.П.Ключевская.*

**ДЕ́НИКЕ** Георгий (Юрий) Петрович (1887, Казан — 1964, Брюссель), сәясәт эшлеклесе, тарихчы. Политехник ин-тта (С.-Петербург) укый. 1907 елга кадәр большевик, аннары меньшевик. 1914 тән Казанда, мәкаләләрен меньшевиклар матбугатында бастыра. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казан Эшче, солдат һәм крәстияннәр депутатлары советы һәм *Җәмәгать иминлеге комитеты* башкарма ком-ты әгъзасы, Казан шәһәр думасы гласные. Окт. рев-циясен кабул итми, Учредительләр җыенын чакыруны яклап чыга. КОМУЧ әгъзасы. 1920–22 дә Мәскәү ун-тында профессор. 1922 дә Берлинга җибәрелә, анда Совет вәкаләтле вәкиллегендә эшли. 1930 ел башыннан эмиграциядә: Германиядә яши, «Социалистический вестник» ж-лының с.-д. канатына кушыла, 1933 тән Парижда, 1941 дән АКШта. Антифашистик каршылык хәрәкәтендә катнаша. 1950 елларда Соц. эшчеләр интернационалы штабында, с.-д. г-талар б-н хезмәттәшлек итә. Меньшевиклар партиясе тарихына багышланган хезмәтне әзерләүдә катнаша.

Х е з м.: Америка на историческом перепутье. М., 1925.

*Әд.:* Г р а ч ё в Е. Казанский октябрь: Хроника революции 1917 г. К., 1926; Л и т в и н А.Л., П а н ю к о в В.М., Т и т о в Л.Н. Защищая революцию. К., 1980.

*А.Л.Литвин.*

**ДЕНИ́СОВ** Иван Андреевич (12.11.1867, Казан — 6.3.1928, шунда ук), нәкышьче, педагог. Петербург Сәнгать академиясен тәмамлый (1894). Казан сәнгать мәктәбен оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе, 1895 елдан башлангыч һәм акварель б-н рәсем ясау классларында укыта, мәктәп мөдире итеп сайлап куела (1917). Бер үк вакытта Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә (1898–1916),



И.А.Д е н и с о в. Император Сәнгать академиясе чиркәвенең перспектив күренеше. Акварель, 1894. Казанда Е.А.Боратынский музее.

земство укытучылар мәктәбендә (1906–18) укыта. 1918 дән Политехник ин-ттагы төзелеш бүлегенең сызма геометрия һәм графика кафедрасында графика сәнгате кабинеты мөдире була. 1924 тән ТатАХРР әгъзасы. Иҗатында әзлекле рәвештә лирик пленэр пейзаж жанрын үстерә. Акварель, пастель һәм майлы буяу техникасы б-н эшли. «Иделдә Ослан таулары күренеше» (1890), «Кыр чәчәкләре бәйләме» (1914), «Аяз көн» (1915), «1916 ның 19 мае карында сирень чәчәкләре» (1916), «Кыңгыраулар» (1920), «Казансуның ташуы» (1926) әсәрләре авторы. Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә (1890), Җирле һ.б. шәһәрләр рәссамнарының периодик күргәзмәләрендә (Казан, 1899–1916), Хәзерге заман рус сәнгате күргәзмәсендә (Казан, 1909), Казанда Беренче дәүләт фән һәм сәнгать күргәзмәсендә (1920), ТатАХРР күргәзмәләрендә (1925–28) катнаша. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 5 нче дәрәҗә кенәз Даниил орденнары б-н бүләкләнә. Д.ның әсәрләре Сәнгать академиясенең фәнни-тикшеренү музеенда (С.-Петербург), ТР Дәүләт сынлы сәнгать һәм Е.А.Боратынский музейларында (Казан) саклана.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1976. Т. 3.

*Е.П.Ключевская.*

**ДЕНИ́СОВ** Иван Фёдорович (19.12.1924, Бөгелмә кантоны Яңа Писмән а. — 14.5.1995, Алма-Ата), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. лейтенанты. Моршанск пулемёт-минomётчылар уч-щесен тәмамлый (1943). 1941 елдан Кызыл Армия сафында. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 102 нче гв. укчылар полкы автоматчыларының взвод командиры (8 нче армиянең 35 нче гв. укчылар дивизиясе). Сталинград, Дон, Көньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Изюм-Барвенковск, Донбасс (икесе дә — 1943 тә), Одесса (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945 тә) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 1 августында Магнушев (Польша) плацдармы өчен бар-

ган сугышта батырлык күрсәтә: аның җитәкчелегендәге взвод беренчеләрдән булып Висла елгасын кичә һәм полк подразделениеләренә елганы кичәргә ярдәм итә. 1946 дан запаска җибәрелә. 1948–50 дә Днепропетровск шәһәре автомобиль з-дында металл модельчесе. 1950–56 да «Прогресс» к-зында хисапчы, тегермәнче (Полтава өлкәсе Бригадировка а.) булып эшли. 1956–59 да Бөгелмә шәһәре 22 нче номерлы төзелеш-монтаж идарәсендә столяр. 1963–65 тә «Берсуат» с-зында (Казакъстан ССР Целиноград р-ны) слесарь-механик. 1966 дан Алма-Атада яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987; Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДЕНИ́СОВ** Юрий Александрович (19.7.1943, Казан — 10.2.2001, шунда ук), график. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1971). «Яшь ленинчы» г-тасында (1970 тән), «Чаян» ж-лында (1971 дән, 1966 дан хезмәттәшлек итә) эшли, Татарстан китап нәшриятының заказлары буенча китаплар бизи (1970 тән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1974). Д. — сатирик рәсемнәр остасы. Аның хезмәтләренә кискен вакыйга сайлый белү, көнкүреш карикатураларында җиңел юмордан алып сәяси сатирада чәнечкеле сарказмга кадәр — сәнгать формасының чарланган булуы һәм композиция камиллеге хас: «Сүзсез (Марс һәм пенсия)» (1976; гуашь, акварель); «Сүзсез (Азатлык һәйкәле)» (1976; гуашь). Рәсемнәрдәге контурның нечкә сызыгы сурәтләнүченең характер үзенчәлекләрен хатасыз тотып ала. Д. китапны барлык элементлары катгый закончалыкларга буйсынган бербөтен сәнгать әсәре итеп күз алдына китерә. Аның бизәвендә әдәби тексттагы персонажларның гадәти үзенчәлекләре дә тулы бер чорда яңадан тугандай була. Аның китап графикасы өлкәсе эшчәнлегендә балалар китабы аерым урынны алып тора, болар — Г.Х.Андерсенның «Әкиятләр» («Сказки») (1980, Ю.М.Каспина-Вургафт б-н бергәләп), Дж. Лондонның «Соры бүре» («Белый клык») (1985) һәм Г.Тукайның «Кәҗә белән Сарык» (2000, тәмамланмаган) китаплары. Республика күргәзмәләрендә (1967 дән), Мәскәүдә, зона — «Зур Идел» (1969, 1980), Бөтенсоюз журналист-рәссамнарның күргәзмәсе (1973), халыкара — «Самира тынычлык өчен көрәштә» (1969, 1973, 1977) һәм «Дөнья исән, чөнки көлә белә» (1973, 1975, 1977) күргәзмәләрендә катнаша. Д. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт шәһәре Картиналар галереясында, Габрово шәһәренең (Болгария) Сатира һәм юмор музеенда саклана.

*Әд.:* Елькович Л.Я. На линии огня. К., 1977; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*




1



2

Ю.А.Денисов. 1. «8 Мартта безнең СМУның барлык ир-егетләре дә хатын-кызлар өчен эшли!» Гуашь, тушь, акварель; 2. «Сыйфатны яхшыртмасаң, аппаратыңны алып китәм». Тушь, гуашь, карандаш. 1969. Икесе дә ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**ДЕРБЕДЕ́НЬ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 124 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Ләке исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.дә 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2074,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1958 нең 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1870 тә — 558, 1897 дә — 1055, 1913 тә — 1486, 1920 дә — 1422, 1926 да — 1405, 1938 дә — 789, 1949 да — 653, 1958 дә — 687, 1970 тә — 596, 1979 да — 377, 1989 да — 170, 2002 дә — 146 кеше.

**ДЕРБЁШКА**, шәһәр тибындагы посёлок, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 42 *км* көнбатыштарак, Кама елгасының сулъяк ярында урнашкан. 1872 елда суднолар ремонтлау остаханәләре оешканда, посёлок буларак нигез салына, 1940 ка кадәр Дербёшка Затоны дип атала. 19 йөз ахырында православие гыйбадәт йорты, тимерче алачыгы, слесарьлык остаханәсе, ашлык киптергеч, 2 кибет эшли. 1920 гә кадәр Д. Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Актаныш р-нында. 1940 ның 26 апреленнән — шәһәр тибындагы



И.Ф.Денисов.



Л.В.Дергунов.

посёлок. 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. 1970 елларда, Түбән Кама сусаклагычында су күтәрелеп, Д. су астында кала. 1998 нең 18 июнендә торак пунктлар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1896 да — 588, 1926 да — 180, 1938 дә — 546, 1949 да — 2938, 1958 дә — 3470, 1970 тә — 2604, 1979 да — 1110, 1989 да — 800 кеше. 1995 тән даими яшәүчеләр юк.

**ДЕРБЁШКА ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Кирмәнчек шәһәрлеге.*

**ДЕРГУНО́В** Василий Сергеевич (14.1.1922, Липецк өлкәсенең Задонский р-ны Алексеевка а. — 17.7.1989, Казан), партия һәм хуҗалык хезмәткәре. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1959). 1941–59 елларда Казандагы 16 нчы з-дта эшли. 1960–76 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында оборона сәнәгате бүлеге мөдире, 1976–78 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1978–86 да 2 нче секретаре. 1986 дан Двигательләр җитештерүне оештыру технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы башлыгы. 1963–80 дә ТАССР, 1980–89 да РСФСР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ДЕРГУНО́В** Лазарь Васильевич (7.2.1907, Сембер губ., Буа өязе, хәзерге Чүпрәле р-ны Яңа Үби а. — 23.12.1974, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1948). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940–41, 1943–60 елларда Чүпрәле р-ның Чапаев исем. к-зы рәисе. Д. җитәкләгән елларда колхоз а.х. культураларының югары уңышы б-н аерылып тора, хезмәтне оештыруда алдынгы формалар кертелә, терлекчелек һәм ярдәмче производствоның материаль-техник базасы ныгытыла. Колхоз берничә тапкыр Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә катнаша. 1955–63 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гарипова З. Дергунов Лазарь Васильевич // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2.

**«ДЕРЕВЕ́НСКИЕ ДУ́МЫ»** («Авыл уй-фикерләре»), иҗтимагый-сәяси крәстиян газетасы. РКП(б)ның Казан губкомы, аннан соң РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты матбугат бүлеге органы. 1920 елда Казанда гыйнвардан августка кадәр рус телендә нәшер ите-

лә, барлыгы 9 саны чыга. «Өмид» басмаханәсендә 24 бит күләмле журнал рәвешендә басыла. Мөхәррирләре — В.М.*Бахметьев*, Г.С.*Гордеев*; газетада М.Ф.Ильина, М.К.Корбут, П.А.Радимов һ.б.ның мәкаләләре урын ала. Крәстияннәр арасында марксистик-ленинчыл идеология тарату максатын алга куя. В.И.Ленин, Л.Д.Троцкий мәкаләләре күчереп басыла, совет хакимиятенең крәстияннәргә караган сәясәте, күмәк хезмәт, а.х. артельләре һәм коммуналары тормышы, җирне күмәк эшкәртүнең һәм күмәк хуҗалыкларга берләшүнең файдасы турында аңлатыла. Гражданнар сугышы фронтларындагы хәлләрне яктырта, крәстияннәрне үзләреннән арткан икмәкләрен Кызыл Армиягә бирергә чакыра. Газетаның төп рубрикалары: «Авыл хәбәрләре», «Җир һәм ирек өчен», «Авыл көнкүреше», «Бер кешедән гаскәр булмый», «Безнең аңгәмәләр». «Сәнгатьле сүз» рубрикасында зур булмаган шигъри һәм чәчмә, ш.и. Д.Бедный, Б.Пильняк әсәрләре басыла. Газета РКП(б) ҮК секретариаты тарафыннан югары бәяләнә. Акча җитмәү сәбәпле чыгудан туктый.

*Әд.:* Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу. К., 1979; Л и т в и н А.Л. Казань: Время гражданской войны. К., 1991.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ДЕРЕВЕ́НСКИЙ** Владислав Павлович (5.7.1942, Казакъстан ССРның Караганда ш.), математик, физ.-матем. фән д-ры (2002), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), СССР ФАнең Казан ф-лында эшли. 1969 елдан Казан архит-ра-төзелеш ун-тының югары матем. кафедрасында, проф. (2002 дән). Хезмәтләре ассоциатив алгебрада гади дифференциаль тигезләмәләргә карый. Д. тарафыннан чишелүчәнлек шартлары билгеләнгән тигезләмәләр: 1 нче тәртип матрицалы квазисызыкча дифференциаль тигезләмәләр (квадратураларда); 2 нче тәртип берьяклы сызыкча тигезләмәләр; икеяклы сызыкча дифференциаль тигезләмәләр; 1 нче тәртип берьяклы сызыкча тигезләмәләр системалары; югары тәртип скаляр сызыкча дифференциаль тигезләмәләр системалары; Банах алгебрасында тригонометрик һәм гиперболик чишелешләре булган 1 нче тәртип нәсызыкча тигезләмәләр; матрицалы Бернулли тигезләмәләре.

Х е з м.: Квазилинейные матричные дифференциальные уравнения // Докл. АН Украин. ССР. Сер. А. 1989. № 3; Матричные двусторонние линейные дифференциальные уравнения // Мат. заметки. 1994. Т. 55, вып. 1; Система матричных линий дифференциальных уравнений первого порядка // Мат. заметки. 1999. Т. 66, вып. 1.

**ДЕРЕВЯ́НКИН** Кузьма Александрович (10.11.1927, хәзерге Мордва Респ-касының Зур Игнатов р-ны Ново-Качаево а. — 4.5.1987, Казан), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, галим-агроном. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1960). 1960–66 елларда Түбән Кама р-нының «Прикамский» с-зында баш агроном. 1966–76 да Аксубай р-нының «МЮД» с-зы директоры. Д. җитәкчелегендә совхоз ел саен а.х. культураларыннан югары уңыш үстерә, җитештерүе табышлы итеп оештырыла. 1976–81 дә Татарстан Респ-касының «Свинопром» берләшмәсе башлыгы, 1981–84 тә Лаеш р-ның «Юбилейный» кошчылык ф-касы директоры. 1970–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ДЕРЕНКО́В А.С. КИТАПХАНӘСЕ́**, Казанда. 1880 елларда вак-төякләр һәм көмеч кибетләре хуҗасы Андрей Степанович Деренков тарафыннан үзлегеннән белем алу түгәрәге б-н бер үк вакытта аның өендә оештырыла (хәзер А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музее). Китапханәдә газета-журналлар, рәсми һәм рәсми булмаган әдәбият, матур әдәбият әсәрләре, тарихи хезмәтләр, К.Маркс һәм Ф.Энгельс, Н.А.Добролюбов, Н.Г.Чернышевский китаплары тупланган була. Китапханәгә йөрүчеләрнең төп өлеше — укучы яшьләр. А.М.Пешков (М.Горький) монда еш була. Ул 2 елга якын А.С.Деренков гаиләсендә яши, аның ипи кибетендә эшли, китапханәдәге китапларның күбесен укып чыга. А.С.Деренков 1888 дә Казаннан киткәннән соң, китапханәнең язмышы билгесез.

*Әд.:* Г о р ь к и й М. Мои университеты. М., 1955; Ч е л ы ш е в Б.Д. Судьба одной библиотеки // В поисках редких книг. М., 1970.

**ДЕРЖА́ВИН** Гавриил Романович (3.7.1743, Казан — 8.7.1816, Түбән Новгород губ. Званка а.), шагыйрь. Нәселе Олы Урдадан китеп Мәскәү кенәзе Василий II гә хезмәткә кергән татар морзасы Бәһрамнан (15 йөз) килә. Казан губернасында Державиннар Мишә буендагы (хәзерге Лаеш р-ны) җир биләмәләренә хуҗа булалар. 1758–61 елларда Д. Казанның Беренче ир балалар гимназиясендә укый. Гимназист чорында ул Болгарга археологик экспедициягә бара, Чабаксар шәһәренең планын төзүдә катнаша. Яхшы укыганы өчен ул инженерлар корпусындагы түбән офицер дәрәҗәсенә (кондуктор) ирешә. 1762 дә Д. хәрби хезмәткә алына һәм Петербургка күчеп китә. Казанда 1763, 1774–75, 1778 дә була. 1784 тә Казан губернаторы урынын сорап үтенеч яза, ләкин Олонец шәһәре (Карелия) губернаторы итеп билгеләнә. «Кенәз Мещерский үлеменә мәрсия» («Ода на смерть князя Мещерского», 1779), «Фелица» (1782), «Ходай» («Бог», 1784), «Морза хыялы» («Видение Мурзы», 1789; басыла 1791), «Шарлавык» («Водопад», 1791–94; басыла 1798) һ.б. шигырьләрендә Екатерина II гә, гаскәр башлыкларына мәдхия җырлый, тәкәббер түрәләрне, патша сарае даирәсенең әхлаксызлыгын фаш итә. «Императрицаның Казанга килүе уңае белән» («На шествие императрицы в Казань», 1779), «Казанда императрицага күрсәтелгән маскарад уңаеннан» («На маскарад, бывший перед императрицей в Казани», 1779) шигырьләрендә, «Язмалар» («Записки», 1811–13; басыла 1859) истәлекләрендә, «Явыз Иван, яки Казанны буйсындыру» («Грозный, или Покорение Казани», 1814) операсы либреттосында Казан мотивлары чагылыш таба. В.И.Панаевка юллаган хатында: «Афина кебек үк, минем туган шәһәрем Казан үзенең иң яхшы тел-әдәбият училищеләре белән дан казаныр», — дип яза. Аның турында А.С.Пушкин: « ... Ул даһиның фикер йөртүе дә татарча иде», — дигән. «Арфа» (1798) шигырендә шагыйрь түбәндәгеләрне яза: «Их, бу алтын вакытның Казанда тәгәрәве! / И минем тәүге көннәремнең бишеге! / Минем пакьлегемнең һәм яшьлегемнең мәркәзе! / Кабат синең таң яктысын күргәндә, / Мин һаман да казанлы булырмынмы? / Миңа мирастан күчкән көтүләремне, / Карт Кама имәннәрен кайчан күрермен икән? / Кайчан Идел буйлап авыллар арасыннан җилкән кебек очып барырмын / Һәм әти-әни каберен кочып җыларммын? /И арфа, җырла миңа гел Казан турында! / Анда Павел пәйда булгандай җырла! / Туган як турындагы яхшы хәбәр безгә бик кадерле: / Туган якның төтене дә безгә татлы һәм хуш исле».



Г.Р.Державин сенатор мундирында. Рәссам В.Л.Боровиковский. 1811.

1847 дә *Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте* инициативасы б-н Казан ун-ты ишегалдында *Державин Г.Р. һәйкәле* куела. Аны татарлар «Бакыр бабай» дип атый. Шунда ук Д. исемен йөртүче бакча утыртыла. ТРның Милли музеенда Д.ның әйберләре (сәгать, өстәл, кәнәфи, язу өстәле), хатынының арфасы һәм Казандагы Д. һәйкәлендәге грация фигурасының башы саклана. 2000 дә ТРның Язучылар берлеге һәм Лаеш р-ны хакимияте күренекле әсәрләр өчен һәр ел бирелә торган Д. исем. әдәби премия булдыра. 2003 тә Лаеш р-ны Сокуры авылында Д.га бюст куела һәм Казандагы һәйкәле торгызыла.

Ә с ә р.: Сочинения, с объяснительными примечаниями Я.К.Грота: В 9 *т.* СПб., 1864–83; Стихотворения. М., 1963.

*Әд.:* Сочинения Державина // Белинский В.Г. Полн. собр. соч. М., 1955. Т. 6; Г.Державин. История и современность. К., 1993.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ДЕРЖА́ВИН** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 19 *км* төньяктарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 452 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1565–67 дә авыл Ячы дип атала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт (дворян Хрущёвларның элекке крепостнойлары) крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тәгәрмәч ясау, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да волость идарәсе урнаша, Николай Чудотворец



Державин авылындагы Никола чиркәве. 1715. 2003 елгы фоторәсем.

чиркәве (1715 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1870 тә ачыла), Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе, тимерчелек, 2 җил тегермәне, 5 кирпеч сугу йорты, казна шәраб кибете, 7 сөт кибете, 2 сыраханә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1372,5 дис. тәшкил итә. 1950 елларда Куйбышев сусаклагычында су күтәрелеп, су астында калган кайбер авыллардан (Татар Агайбашы һ.б.) татарлар Д.га килеп төпләнәләр. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Лаеш өязе Державин волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 144 ир-ат; 1859 да — 734, 1897 дә — 1017, 1908 дә — 1042, 1926 да — 1231, 1938 дә — 708, 1949 да — 355, 1958 дә — 882, 1970 тә — 791, 1979 да — 462, 1989 да — 337, 2002 дә — 466 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**ДЕРЖА́ВИН Г.Р. ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Бөек шагыйрьгә туган шәһәрендә һәйкәл кую идеясе беренче тапкыр Державин үлгән елда, 1816 елның 24 сентябрендә, Казан әдәбият сөючеләр җәмгыятенең тантаналы утырышында аның рәисе И.Ф.Яковкин тарафыннан әйтелә, 1828 дә ул янә тикшерелә. Арх. А.И.Мельников эшләгән һәйкәл проекты 1831 дә раслана, шуннан соң бөтенроссия күләмендә иганә җыю эше башлана. Җыелган акча проектның смета бәясеннән шактый артып киткәнлектән, граф Д.Н.Блудов, һәйкәлнең «Россиянең тәүге шагыйрьләренең берсенә хөрмәтен чагылдыруын, шуның б-н бергә аның империядәге Казан кебек мөһим шәһәрнең бизәге булуын» күздә тотып, проектны үзгәртергә тәкъдим ясый. Николай I әмере б-н конкурс игълан ителә, нәтиҗәдә архит-ра академигы К.А.Тон һәм скульп. С.И.Гальберг проекты сайлап алына. 1836 да Николай I Казанда булган вакытында һәйкәл өчен урынны университет терр-ясендәге Анатомия театры каршында билгели. Һәйкәлгә нигез 1844 нең 15 сентябрендә салына. Монументның гранит өлеше һәм бронза сыны Петербургта эшләнә. Шагыйрьнең өстенә тога һәм аякларына сандал кигән килеш ташта утырган сыны кызыл гранит постаментка урнаштырыла. Шагыйрь тирән уйга чумган, аның уң кулында стило, сул кулы б-н лирага тотынган. Дүртпочмаклы чуен постамент С.И.Гальберг тарафыннан өч яктан барельефлар б-н бизәлгән. Сулда — фетнәне бастыручы алиһә Минерва; Державин аның артыннан бара һәм, Шигърият алиһәсенең үзенә кагылуын сизеп, хәрбиләр арасында тукталып кала һәм беренче җырын башлый (шагыйрьнең беренче шигыре пугачёвчыларны буйсындыру вакытында язылуга киная). Аполлон янәшәсендә Фемида күренә, ул шагыйрьне үзенә хезмәт итәргә чакыра (Державинның киләчәктә дәүләт хезмәтендә булуы). Уңда — шагыйрь грацияләр әйләнәсендә сурәтләнгән, ул лирасы б-н корбан бирү урынына таянган; Фемида, таҗ кидерергә әзерләнеп, шагыйрьне тыңлый. Арткы якта, шагыйрьнең даими шөгыльләре символы сыйфатында Көн һәм Төн сурәтләнгән, алар аңа хөрмәт күрсәтәләр, әсәрләрен чәчәкләргә күмәләр, җырларын җырлыйлар.



Казанда Г.Р.Державин һәйкәле. 2003 елда реконструкцияләнә.

Постаментның алгы ягында — алтынланган язу: «Гавриил Романович Державин, 1846» (һәйкәл уйланылган вакыттан соңрак, 1847 нең 23 августында ачыла). 1870 тә Казан губ. земствосы тәкъдиме б-н һәйкәл Театр мәйданына күчерелә һәм 3 июльдә икенче тапкыр ачыла; һәйкәл тирәли бакча утыртыла. 1924 тә Казанда һәйкәлгә кем күбрәк лаек: Державинмы, әллә Пугачёвмы? — дигән сорау тикшерелә. 1931 нең 7 июнендә «Красная Татария» г-тасы, Державин императрица Екатерина II гә мәдхия җырлаган һәм патшага каршы баш күтәргән крәстияннәрне рәхимсез җәзалаган, дип язып чыга. Шул ук елда Г.Р.Державин һәйкәле юкка чыгарыла. 1993 тә, шагыйрьнең тууына 250 ел тулуны бәйрәм иткәндә, һәйкәлне яңадан торгызу кирәклеге мәсьәләсе кузгатыла. 2000 нең 8 июнендә ТР МК «Россия шагыйре һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Романович Державинның тууына 260 ел тулу уңаеннан аның истәлеген мәңгеләштерү буенча чаралар турында» карар кабул итә. Яңадан торгызылган һәйкәл 2003 елда Горький урамындагы бакчада ачыла (скульп. М.Гасыймов, архит-ра проекты — Р.Нургалиева).

*Әд.:* Пинегин М. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Гарзавина А. Великий казанец Гавриил Державин // Казань. 2003. № 5–6.

*А.В.Гарзавина.*

В.Э.Деринг.



**ДЕРИВА́ЦИЯ** (лат. derivatio — читкә юнәлдерү, барлыкка килү), тамырга аффикслар ялгау, сүзләрне кушу һ.б. чаралар ярдәмендә бер тел берәмлекләреннән икенчеләрен ясау, сүзләрне үзгәртү, яңа сүзләр ясау. Сүзнең икенче мәгънәсе барлыкка килү кайчак ш.у. Д. дип карала (елан — хайван, елан — елгыр). Д. процессында төп (мотивлаштыручы) һәм ясалма (мотивлашкан) тел берәмлекләре арасында үзенчәлекле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Лексик һәм синтаксик Д. була, синтаксик Д. әлеге төп конструкцияне үзгәртү юлы б-н төрле синтаксик конструкцияләр ясалу процессын белдерә (эшчеләр өй салалар, өй эшчеләр тарафыннан салына).

Тамыр морфемалардан яңа лексик берәмлекләр ясалып, алар барлыкка китергән бөтен мәгънәләр дә деривацион мәгънәләргә карый. Мәсәлән, процессны белдерүче **яз** тамырыннан **язма** дигән исем ясарга мөмкин, бу очракта предметны белдерүче деривацион мәгънә барлыкка килә. Шулай ук предмет мәгънәсеннән эшне башкаручы (субъект) мәгънәсен аерып чыгарырга мөмкин: сәяхәтче, терлекче, тарихчы.

*Әд.:* Курилович Е. Деривация лексическая и деривация синтаксическая // Очерки по лингвистике. М., 1962; Никитевич В.М. Теоретические аспекты деривации. Пермь, 1982; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

*Ф.Ә.Ганиев.*

**ДЕ́РИНГ** Виктор Эдуардович (14.8.1921, Кытай, Харбин ш. — 18.5.2009, Казан), саксофончы, эстрада дирижёры, РФнең атказ. (2001), ТРның халык артисты (2001). 1975 елда Казан консерваториясенең оркестр ф-тын саксофон классы буенча тәмамлый. 1937–38 елларда Һинд-Кытайда (Вьетнам) Ханой, Хайфон, Досон шәһәрләре джаз оркестрларында, 1939–46 елларда Кытайда (Шанхай, Циндао ш.) О.Лундстрем җитәкчелегендәге эстрада оркестрында һ.б. оркестрларда музыкант булып эшли. 1947 елда даими яшәү өчен СССРга, Казан шәһәренә кайта. 1947–56 да «Электро» кинотеатры оркестры музыканты, 1956–59 да О.Лундстрем җитәкчелегендәге оркестрда (Бөтенроссия гастроль-концерт берләшмәсе, Мәскәү) артист, 1959 дан яңадан Казанда, Казан шәһәр киночелтәре эстрада оркестрында 1966 га кадәр артист, 1991 гә кадәр аның җитәкчесе, 1991 дән ТР кинематография дәүләт оркестры сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёры. Оркестр репертуарында: илебез һәм чит ил джазы классикасы, А.Ключарёв, А.Монасыйпов, С.Сәйдәшев, Р.Яхин һ.б.ның әсәрләре. Төрле елларда Д. җитәкчелегендәге оркестр



ТР кинематография оркестры. Сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижёр В.Э.Деринг.

б-н танылган җырчылар Р.Волкова, В.Гыйззәтуллина, Э.Җәләлетдинов, Р.Ибраһимов, Р.Ибраһимова, З.Нурмөхәммәтов, З.Сөнгатуллина, И.Шакиров һ.б. җырлый. Коллектив РФ һәм БДБ төбәкләренә ТР сәнгатен җиткерә, радио һәм телевидение аша чыгышлар ясый.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ДЕРМАТОЛО́ГИЯ** (грек. dérmatos — тире һәм ... *логия*), клиник медицинаның бер бүлеге; нормаль һәм патологик тиренең структурасын һәм функцияләрен, дерматитлар — тире һәм аның өстәлмәләре (чәч, тырнаклар) авыруларының этиологиясен һәм патогенезын, диагностикасын, аларны дәвалау һәм булдырмый калу юлларын өйрәнә. Д. *венерология* б-н бердәм дисциплина тәшкил итә, инфекцияле патология б-н дә тыгыз бәйләнештә тора. Тиредәге бактериаль, паразитар, вируслы, гөмбәчел авыруларны, токсидермияләрне аерып өйрәнәләр. Дерматозларга дистрофия, тире ялкынсынулары, псориаз, лихена, куыклы дерматоз, лимфома һәм тире шеше, генодерматоз, васкулит, коллагенозлар һәм эпидермис өстәлмәләре авырулары һ.б. керә.

19 йөз ахырында Казан ун-тында Д. буенча фәнни тикшеренүләр юнәлеше (А.Г.Ге, В.Ф.Бургсдорф, М.С.Пильнов) барлыкка килә, алга таба ул Казан медицина ин-тында (И.Н.Олесов, Н.Н.Яснитский, Г.Г.Кондратьев, Г.Г.Нуриев) һәм ГИДУВта (Я.Д.Печников, В.П.Сергеев, В.Т.Куклин) тагын да үстерелә. Казан ун-тының медицина ф-тында тире һәм венерология авырулары курсын укыту 1872 елда кертелә (каф. мөдире А.Г.Ге). 1900 дә Казанда Финзен ысулы буенча ультрашәмәхә нурлар ярдәмендә дәвалау кабинеты булган тире-венерология клиникасы ачыла. 1902 дә, бактериологик һәм гистологик тикшеренүләр үткәрү өчен, В.Ф.Бургсдорф инициативасы б-н клиник лаб. ачыла; В.Ф.Бургсдорф үзе Деверҗи авыруын тасвирлап бирә (1902), А.А.Хитров Капоша саркомасын клиник — морфологик яктан тикшерә (1909), М.С.Пильнов псориаз вакытында тәнгә чабырып чыга торган тимгелләрнең алсу төсмерен («Пильнов симптомы») тасвирлап күрсәтә, тире туберкулёзы (волчанка) б-н авырганнарны нурлар ярдәмендә дәвалау ысулы уйлап табыла (1927). 1920 дә Казан ГИДУВы карамагында тире һәм венерология авырулары кафедрасына (мөдире И.Н.Олесов) һәм ТАССР Дерматологлар һәм венерологлар җәмгыятенә нигез салына. 1922 дә тире-венерология клиникасы базасында диспансер (1935 тән — Респ-ка тире-венерология диспансеры) эшли башлый.

Казан галимнәре тарафыннан эксперментлар юлы б-н стрептококк һәм стафилококкларның тире компонентларына карата аутосенсибилизация үсешенә стимуллаштыргыч тәэсире исбат ителә, стафилоккок һәм стрептококк этиологияле хроник дерматоз белән авырган кешеләр өчен махсус дәвалау методикасы булдырыла, склеродермияне димексид эремәсе белән тышкы яктан дәвалауның нәтиҗәлелеге нигезләп күрсәтелә (Г.Г.Нуриев, Г.Г.Кондратьев, В.П.Сергеев, Р.З.Зәкиев); ихтиозның клиник-генетик классификациясе тәкъдим ителә, Деверҗи авыруының нәселдән күчүенә мультифакториальлек хас булуы исбатлана, Дарье авыруын дәвалау өчен винилин кушып ясалган май һәм синестролның майдагы эремәсе эмульсиясе тәкъдим ителә (В.Т.Куклин, 1974). Алопеция белән авырганнарны дәвалау өчен кремнеорганик кушылмалы «Силокаст» препараты гамәлгә кертелә. (В.П.Сергеев, 1991). Нәселдән килә торган тире авыруларыннан интегүчеләргә махсус мед.-генетик ярдәм күрсәтү тире-венерология клиникасы карамагындагы Генодерматозлар үзәге (1992 дә ачыла) тарафыннан оештырыла. Үзәк ТР, Идел буе һәм Уралда яшәүчеләргә хезмәт күрсәтә. 2008 елга ТРда 8 тире-венерология диспансеры эшли (к. *Диспансерлар*).

*Әд.:* Куклин В.Т., Суворова К.Н. Многогенные дерматозы. Йошкар-Ола, 1993; Суворова К.Н., Куклин В.Т., Рукавишникова В.М. Детская дерматология. К., 1996.

*Г.Г.Нуриев, В.Т.Куклин.*

**ДЕСЯТИДВО́РКА** (Унөйле) посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2,5 *км* читтә урнашкан. 2008 елда 6 кеше (руслар, чуашлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 89, 1949 да — 66, 1958 дә — 69, 1970 тә — 37, 1979 да — 23, 1989 да — 20, 2002 дә — 12 кеше.

**ДЕТЕКТИ́В ӘДӘБИЯ́Т** (инглиз. detective — шымчы), маҗаралы әдәбиятның җинаятьне тикшерү һәм ачуга корылган бер төре. Татар прозасында Д.ә. әсәрләре 19 йөз ахырында языла башлый. Татар әдәбиятында детектив юнәлешнең барлыкка килүе, бер яктан, шәһәр халкы һәм җинаятьләр саны арту, икенче яктан, рус һәм чит ил әдәбиятларының тәэсире көчәю б-н бәйле. Мәс., З.Бигиевнең сюжеты авыр җинаять эшен ачуга корылган «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар», 1890) романында француз детектив романнарының йогынтысы ачык сизелә. Вульгар социологизм хөкем сөргән 1920–30 елларда Д.ә. торгынлык кичерә, ләкин аның кайбер элементлары аерым әсәрләрдә чагылыш таба. Д.ә. ике юнәлештә үсеш ала. Беренчедән, бу чорда татар әдәбиятына хас булган көчле идеологик йогынтыдан арыну башлана. Икенчедән, әдәби осталык, бигрәк тә кызыклы һәм кискен сюжет төзү осталыгы камилләшә бара. Бу үзенчәлек А.Расих повестьларында ачык чагылыш таба: «Бәхет орлыклары» (1948), «Сәхи бабай маҗаралары» (1956), «Хәвефле сынау» (1958), «Урланган хәзинә» (1961) һ.б. А.Расих детектив әсәрләренең үзенчәлекләре — фәнни фантастиканың җинаятьне ачу һәм романтик маҗаралар б-н үрелеп баруы, фәнни идеяләрне һәм ачышларны пропагандалау. 1970 елларда татар әдәбиятында детектив әсәрләрнең жанр үзенчәлекләре тагын да ачыграк гәүдәләнә, әүвәл аерым элементлар рәвешендә генә булган билгеләр өстенлек итә башлый. Беренче планга сизгер, күзәтүчән, кайбер вак-төякләргә дә зур игътибар бирүчән тикшерүче образы чыга; М.Насыйбуллинның беренче повестьлары «Телсез шаһитләр» (1974), «Алтын алка» (1977) — шундыйлардан. Д.ә.ның 1970–90 еллардагы үсеше, нигездә, М.Насыйбуллин һәм З.Фәтхетдинов исемнәре б-н бәйле. Аларның әсәрләрендәге җинаять (яки мавыктыргыч һәм хәвефле маҗара) мотивы мөстәкыйль характер ала. Җинаять, сюжетның нигезе генә булып калмыйча, төп геройларның образларын ачу юлында доминантка әверелә. Бу елларда детективта хәрәкәт һәм кискенлек арта, вакыйгалар — серлелек, сюжет гадәттән тыш ситуацияләр һәм көтелмәгән борылышлар б-н баетыла. Җинаятьчеләрнең астыртын хәйләкәр эшләрен ачуга игътибар беренче планга чыга. Д.ә. гомумиләштерелгән романтик образлар бирүдән геройларның эчке дөньясының тирән психологиясен ачуга таба үзгәрә, жанр ягыннан төрләнә һәм байый бара. М.Насыйбуллин фәнни детектив жанрын тудыра. Ул сюжетны оста төзи һәм укучыны өзлексез киеренкелектә тота. Бер үк вакытта гомуми әһәмияте булган фәнни идеяләрне пропагандалый, әхлакый-психологик һәм социаль проблемаларга да кагыла. «Тукран тәүбәсе» (1997), «Иблистән иман сорамыйлар» (1998) повестьларында җинаятьче никадәр тырышса да, аның җинаяте барыбер ачылачак, җинаять өчен хөкем ителү котылгысыз, дигән фикер үткәрелә. З.Фәтхетдинов әсәрләре интуитив детективка тартым — «Ачылган сер-

ләр» («Тайна стоит жизни», 1982). Җинаятьче психологиясенә үтеп керү һәм аның гамәлләре логикасын ачу юлында фаразлауга һәм интуициягә зур роль бирелә. Аның әсәрләрендәге җинаятьчеләр хәйләкәр, явыз һәм тапкырлар, шуңа күрә дә уңай геройларның җиңеп чыгуы зур әһәмияткә ия («Үтерүче исемен кем әйтә?» –«Кто назовёт убийцу?», 1998); («Үлем элмәге» – «Сквозь страх», 1991); («Резидент «Кара тол хатын» – «Резидент «Чёрная вдова», 1993). Ф.Галиев («Үтерүчене эзләү» – «Искать убийцу», 1994), Г.Гомәров («Юлбарыс тырнагы», 2000) детективларында тискәре һәм уңай геройлар арасында психологик капма-каршылык бар. М.Хәбибуллин («Сулар үргә акса да ...», 1984), Т.Галиуллин («Элмәк», 1998), Л.Кожевников («Прокурор үлеме» – «Смерть прокурора», 1996) әсәрләрендә мавыктыргыч сюжет аша кискен социаль конфликтлар ачыла.

*Әд.:* С а р ь я н Х. Без капчыкта ятмый // Уеңны уйдырып сал. К., 1977.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ДЕФЛЯ́ЦИЯ** (лат. deflatio — өрү), туфракның һәм тау токымнарының вак кисәкчекләрен җил өреп алып китү. Чүлләрдә аеруча көчле чагыла. Ш.у. җил эрозиясе дип аталучы Д. игенчелек өлкәсенә шактый зыян сала. Агрикультура чорына кадәр Д. ТРның хәзерге чикләрендә зур булмый, елгаларның комлы сайлыклары һәм ялангач текә тау битләре б-н генә чикләнә. Бозлык чорының коры салкын климатында Идел, Кама һәм Вятка елга террасалары комнары көчле Д.гә дучар була. Нәтиҗәдә бозлык чорыннан соң җир өслегендә нарат урманнары б-н ныгытылган дюналы эол рельеф формалаша. Кеше эшчәнлеге, бигрәк тә игенчелек Д.нең үсешенә этәргеч бирә. Язгы һәм җәйге корылыкларда (ТРда төньяктан көньякка таба 15° тан 25° ка кадәр үзгәрә) һәм җил 8–10 *м/с* тан артыграк тизлектә булганда, вак туфрак Д.се барлыкка килә. Җил тизлеге зур булганда (ТРда иң зур күрсәткеч 35–40 *м/с* ка җитә), тузанлы яки кара давыл чыга, Д. бу вакытта 1 *га* басудан сәгатенә 1–2 *т* га җитә. ТРда Д. ихтималы булган җирләрнең мәйданы 294,5 мең *га* тәшкил итә, ш.и. сөрү җирләре — 245,4 мең *га*. Д. аеруча Кама аръягы, Идел алдының кара туфраклы р-ннарында көчле һәм күп өлеше чәчүлек җирләрдә туфракны ныгытучы шытымнар күренгәнче чагыла. Д. гә каршы махсус чаралар күрелә, аерым алганда, җилнең көчен киметүче саклагыч урман полосалары утыртыла, җир эшкәртүнең туфракны саклаучы системалары кертелә.

*А.П.Дедков.*

**«ДЕ́ЯТЕЛЬ»** («Эшлекле»), иҗтимагый-әдәби журнал. *Казан аеклык җәмгыяте* органы. 1896 елның гыйнварыннан 1917 гә кадәр Казанда айга 1–2 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре һәм наширләре — Казан аеклар җәмгыяте рәисләре А.И.Александров, А.Т.Соловьёв була. Җәмгыять әгъзалары — Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе укытучылары һәм профессорлары Е.Ф.Будде, А.Ф.Гусев, Л.О.Даркшевич, И.М.Догель, В.Ф.Залесский, М.Я.Капустин, Н.Ф.Катанов, Ф.Г.Мищенко һ.б., ш.у. руханилар Е.Ф.Сосунцов, В.А.Охотин һ.б. хезмәттәшлек итәләр һәм материалларын бастыралар. Журнал битләрендә аек тормыш итү мәсьәләләре пропагандалана. Спиртлы эчемлекләр б-н сату итүгә кагылышлы хөкүмәт карарлары, аеклык җәмгыятенең җыелыш беркетмәләре, аның бүлекләре эше турындагы хисап материаллары басыла, Россия һәм чит илләрдәге аеклык җәмгыятьләре һәм хәйрия оешмаларының эшләре турында мәгълүмат бирелә. Россиядә шәраб эшләү һәм сатуга дәүләт монополиясе кертүнең барышына йомгак ясала. Рухи-әхлакый, юридик, икътисади, педагогик, медицина-санитария мәсьәләләренә, эчкечелек һәм тәмәке тартуны бетерүгә кагылышлы материалларга


ДѢЯТЕЛЬ

№ 11.

НОЯБРЬ

1900.

СОДЕРЖАНІЕ.

КАЗАНЬ.

«Деятель» журналы. Титул бите.

зур урын бирелә. Газета укучыларны татар мәдәнияте б-н таныштыруда «Шәрекъ библиографиясе» бүлеге әһәмиятле роль уйный (күпчелек мәкаләләрнең авторы Н.Ф.Катанов), шушы бүлек эшеннән татар китапларының библиографиясен төзү башланып китә. Аннотация һәм рецензияләрдә китапның басылу урыны, вакыты турында мәгълүмат, автор һәм әсәрдә урын алган шәхесләр турында биографик белешмәләр, Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәүче татарлар арасында китап тарату турында мәгълүматлар китерелә. К.Насыйри һәм Р.Фәхретдин хезмәтләрен тасвирлауга аерым игътибар бирелә. «Д.» дә бакчачылык, яшелчәчелек, умартачылык һ.б. б-н шөгыльләнүчеләргә киңәшләр басыла. 1905–07 елгы рев-ция вакытында ж-лның юнәлеше кискен үзгәрә; ул «Православие, самодержавие, халыкчылык» шигаре астында чыга башлый. Дәүләт Думасына тискәре карашлы мәкаләләр күренә, монархистик, карагруһчылык карашлары пропагандалана. Шуның өчен ж-л Казанда чыгучы башка г-талар тарафыннан тәнкыйтьләнә. Казандагы монархистик партияләрнең үз басма органнары барлыкка килгәч, «Д.» баштагы тематикасына кире кайта. Журнал Казан аеклык җәмгыяте китапханәләренә җибәрелә һәм, башлыча, Казан губернасы авылларында таратыла.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Книги и люди. К., 1985.

*Г.Р.Заманова.*

**ДЖЕ́НКИНСОН** (Jenkinson) Антоний (1530 еллар тирәсе — 26.2.1610/11), инглиз сәүдәгәре һәм дипломаты. Европа, Азия һәм Африка буйлап сәяхәт итә, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1557–77 елларда Мәскәү компаниясендә (Англия) хезмәт итә, Рус дәүләтендә берничә тапкыр (1558, 1562, 1566, 1571) була. 1558–59, 1562–64 тә сәүдә-дипломатия миссиясе составында Урта Азиягә һәм Персиягә бара, юл уңаеннан Казанда, Әстерханда һ.б. төрки-татар торак пунктларында була. Мәскәүгә (1558), Бохарага (1560) һәм Персиягә (1564) сәяхәтләре турындагы язмалар авторы. Д. аларда үзе күргән шәһәрләрне, халыкларның көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен, сәяси вакыйгаларны тасвирлый, юл координатлары б-н карталар төзи. Д. үз язмаларында татарлар һәм нугайларның тормышы, нугайларның 1558 елгы ачлыкта күпләп үлүләре турында бик тә үзенчәлекле мәгълүматлар китерә.


*Әд.:* Т о л с т о й Ю.В. Первые 70 лет сношений между Россией и Англией. СПб., 1876; Английские путешественники в Московском государстве в XVI в. Л., 1937.

*И.Л.Измайлов.*

**ДЖОРДЖИКИ́Я** Ройн Кондратьевич (28.1.1946, Абхазия АССР, Гудаута ш.), кардиолог, мед. фән. д-ры (2003), ТРның атказ. табибе (2001). 1970 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлагач, шунда ук эшли, 2000 нән 2 нче хирургик авырулар каф. мөдире, бер үк вакытта 2000 нән Н.П.Медведев исем. Казан йөрәк-кан тамырлары хирургиясе үзәге җитәкчесе. Д. көчле перитонит вакытында йөрәк-кан тамырлары системасы бозылуларын өйрәнә, аларны дәвалауның патогенетик ысулларын эшли; йөрәк зәгыйфьлеген аз инвазив операцияләр ярдәмендә дәвалауны, тумыштан килгән каталаулы һәм авырулар сәбәпле килеп чыккан йөрәк зәгыйфьлеген көйләүне, гепато-панкреатодуоденаль зона авыруларын хирургик дәвалауны, үңәчне юан эчәк өлеше б-н ябыштыруны клиникада гамәлгә кертә. Уйлап табуга авторлык таныклыклары бар.

Х е з м.: Патогенетическая терапия сердечно-сосудистых нарушений при остром перитоните. К., 1979; Клиника, диагностика и хирургическое лечение пороков сердца. К., 1995 (автордаш).

**ДЗЮБА́НОВ** (Дзюбан) Прокофий Васильевич (8.8.1874, Харьков губ. Кутянск ш. — 15.4. 1951, Сочи ш.), сынчы. Мәскәүдәге сынлы сәнгать, скульптура һәм төзелеш уч-щесенең С.М.Волнухин остаханәсен (1901) һәм СА югары сәнгать уч-щесенең В.А.Бикләмишев остаханәсен, бер үк вакытта СА каршындагы урта уку йортларында эшләргә хокуклы таныклык бирүче пед. курсларны тәмамлый. Казан сәнгать мәктәбендә скульптура бүлеген оештыручы һәм аның беренче укытучысы (1904–08), мәктәпкә үзенең «Җиңелгән титан» исемле диплом эшен бүләк итә. Аның шәкертләре арасында сынчылар О.А.Арбузова-Витман, Я.С.Кац һ.б. бар. Соңрак Мәскәүдә, Жиздрада (Калуга губ.), Сочи һәм Сухумида яши һәм эшли. Сочидагы «Художник» иҗат студиясендә укыта (1948–51). «Синоп» (Сухуми), «Ривьера» (Сочи) санаторий парклары өчен монументаль-декоратив



П.В.Д з ю б а н о в. «Җиңелгән титан». Гипс. 1904.

һәм бакча-парк сыннарын эшли. 1895 елдан төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә катнаша.

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1976. Т. 3; К л ю ч е в с к а я Е. Из истории скульптурного отделения Казанской художественной школы // Вопр. худож. образования. Л., 1985. Вып. 39.

**ДЗЮДО́** (япон. дзю — йомшаклык, до — юл), ирекле алымдагы япон милли көрәше һәм үз-үзеңне яклау системасы; 1882 елга кадәр Япониядә джиу-джитсу исеме б-н таралган була. Татарстанда 1971 дән үсеш ала, оештыручылары — Ә.Г.Биккинин, Е.А.Зюрнин, В.И.Осипов. Казан, Чаллы, Бөгелмә, Түбән Кама шәһәрләрендә үсеш ала. Рәсми ярышлар республикада 1973 тән ирләр арасында, 1987 дән хатын-кызлар арасында, 1991 дән шәһәр һәм республика беренчелегенә, 2000 нән Г.Ф.Борюшкин, Р.Р.Нуруллин кебек танылган дзюдочылар истәлегенә турнирлар уздырыла. «Труд», «Зенит», «Буревестник», «Трудовые резервы», «Динамо» спорт җәмгыятьләренең үзәк советы һәм Россия беренчелекләрендә, РСФСР халыклары, халыкара спартакиадаларында, Олимпия уеннарында медаль алучылар, чемпион, катнашучы һәм иң яхшы спортчылар — Н.Н.Алексеев, С.Н.Алеханов, Н.Ю.Ащеулова, Г.Ф.Борюшкин, З.Р.*Гарипова*, А.А.Захаров, И.Н.Захарова, А.Д.Кәлимуллин, А.А.Карасёв, Ә.Д.Миңлебаев, П.М.Николаев, А.В.Питиримов, Р.Р.Рәшитов, В.Б.Ситдыйков, Р.Р.Хәмидуллин, С.А.Шарин, И.Шкарин. Иң яхшы тренерлар — Р.С.Әхмәтгәрәев, И.Ю.Ащеулов, Ә.Г.Биккинин, Е.П.Зюрнин, Ф.Ә.Мадияров, В.И.Осипов, Н.В.Репин, Р.Т.Сабиров, И.И.Фәттахов, Г.Х.Хәйруллин, И.Ю.Чичканов.

**ДЗЯДУЛЕ́ВИЧ** Станислав (1872–1943, Юзефов ш.), поляк тарихчысы, педагог. Польша татарларыннан. Варшава ун-тын тәмамлый. Варшава гимназияләрендә укыта. Хезмәтләре Польшадагы татар дворяннары *геральдикасына* карый.

Х е з м.: Herbarz rodzin tatarskich w Polsce. Wilno, 1929. *Я.Я.Гришин.*

**ДИАГНО́СТИКА ҺӘМ ФИ́ЗИК-ХИ́МИК ПРОЦЕССЛА́Р БЕЛӘ́Н ИДАРӘ́ ИТҮ́ ИНСТИТУТЫ́**, фәнни-тикшеренү институты (НИИФХП), 1991 елда Казан техник ун-ты каршындагы тармак фәнни-тикшеренү лаб-ясе (ОНИЛ) нигезендә төзелә. 1979 да әлеге лаб. Казан авиация ин-ты каршында әйләнә-тирә мохитне савыктыру буенча мониторинг программасын эшләү өчен оештырыла. ОНИЛ составында 3 фәнни бүлек эшли: катлаулы системаларга техник диагностика (җитәкчесе Р.Г.Гафуров); йөртүче винтлары җыелып куела торган вертолётлар җирлегендә коткару системасы (җитәкчесе В.А.Павлов), оптик квант генераторлар (җитәкчесе Ю.Е.Польский). «Буран» системасындагы двигатель җайланмасының уникаль радиотехник моделе һәм эшләнә торган водород-кислородлы сыек ягулыклы реактив двигательләр өчен камера эчендәге процессларны тикшерү стенды оештырыла. Илдә беренче мәртәбә лазерлы голографик җайланмалардан, спектраль-оптик, масс-спектрометрик, радиодулкынлы, магнитометрик һәм плазмалы-ионлы системалардан гыйбарәт булган диагностика комплекслары эшләнә һәм үзләштерелә, аларның эше эшче җисемнең электрофизик һәм электромагнит үзлекләрен диагностика факторлары буларак файдалануга нигезләнә. Теркәп баруның тагын да мәгълүматлы физ. ысулларын һәм инерциясез системаларын куллану нәтиҗәсендә камера эче фәзасындагы физ.-химик процессларның барышына беренче мәртәбә төгәл диагноз куела, башлангыч этапта авария булу ихтималлыгын кисәтү һәм бетерү, ш.у. яңа класс энергия җайланмаларын эшләү процесслары б-н фәнни нигездә идарә итү, эшләү срокларын һәм матди чыгымнарны киметү мөмкинлеге бирә.

НИИФХПның фәнни-тикшеренүләр проблематикасы — экологик хәвефсез, энергия саклаучан физ.-химик процесслар, аларның диагностика һәм идарә системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү, ш.у. техник һәм производство объектларының авариясез эшләүләрен тәэмин итү. Әйләнә-тирә мохитне савыктыру, аны зарарлы ташландыклардан саклау һәм ТРдагы производство объектларының авариясез эшләү проблемаларын хәл итүгә Г.Л.Дегтярёв, Ю.Ф.Гортышев, Г.Ю.Даутов, М.Р.Вяселов, А.З.Равилов, Р.Х.Юсупов, Я.Н.Глебов, Р.П.Наумова, Л.П.Зарипова, Г.Г.Гарифҗанов, С.В.Мальцев, Р.Р.Миңнуллин, Ф.Х.Шакиров, А.М.Трофимов, А.А.Озол, Р.Г.Ильязов, В.Ф.Новиков, А.Л.Бикмуллин һ.б. галимнәр җитәкләгән 60 тан артык коллектив җәлеп ителә. Табигый мохиттә (туфракта һәм үсемлекләр дөньясында, һава һәм су бассейннарында, хайваннар дөньясында), ш.у. җитештерү өлкәсендә бара торган процесслар турында тулы, ышанычлы, төгәл һәм даими экологик мәгълүмат алуны контрольдә тоту өчен техник чаралар эшләнә. Автоматлаштырылган системалар ярдәмендә һәм алар нигезендә респ-кадагы күпчелек терр-яләрнең агулы матдәләр б-н зарарлануына, төбәкләр үсешенә һәм экосистемалар эшенә (аерым алганда, Әлмәт һәм Зәй р-ннары) төгәл экологик диагноз куела, бу исә сәнәгатьтә, а.х.нда, энергетикада һәм транспортта фәнни нигезләнгән экологик чиста физ.-химик процесслар эшләү һәм гамәлгә кертү мөмкинлеге бирә. Арча р-нында экологик чиста а.х. культуралары һәм дару үләннәре үстерү, балалар өчен сөт азыклары әзерләү, ит продукциясе җитештерү буенча тиешле технологияләр эшләнә һәм сынала. «Тасма» пр-тиесенең гальваника производствосындагы ташландык суларны авыр металлардан арындыру өчен электролизёрлар үзләштерелә, плазмотроннар җирлегендә агулы матдәләрне утильләштерү һәм зарарсызландыру, ш.у. сәнәгать-көнкүреш калдыкларын, диоксин ясаучы агулар барлыкка китермичә, кабат файдалану чималы калырлык итеп яндыру буенча җайланмалар эшләнә. «Түбәнкаманефтехим» пр-тиесендә җитештерү барышында авария ихтималын вакытында кисәтү, технол. җиһазларны шартлау һәм янгын куркынычыннан саклауны даими контрольдә тоту буенча автоматлаштырылган система булдырыла, һәм ул сәнәгатьтә сынап карала. Үзле ягулыклар, түбән сортлы мазут, нефть калдыкларын һәм табигый газны, газ-мазут б-н эшли торган ТЭЦ һәм котельныйларда ташландык су өстәмәсе кушып яндыру технол.ләренең югары экол. нәтиҗәлелеге раслана. Галимнәрнең күмәк эш нәтиҗәләре тирә-юнь мохитне савыктыру һәм җитештерү объектларының авариясез эшләүләрен тәэмин итүнең бердәм концепциясен этаплап тәгъбирләү мөмкинлеге бирә. Аерым алганда, беренче чираттагы (яшәү тирәлеге өчен куркыныч һәм аеруча куркыныч) объектлар ачыклана, цех, пр-тие һәм, гомумән, төбәкнең ресурсларын һәм матди чыгымнарын исәпкә алып, аларга экологик яктан туры килә торган һәм шартлау хәвефе булмаган технологияләр эзлеклелеге эшләнә, алар теге яки бу объектның экологик куркынычлылыгын һәм аварияләр ихтималын алдан бәяләү һәм аларның тоткарлыксыз эшләү мөмкинлеген анализлау нигезендә гамәлгә кертелә.

1999 елдан НИИФХП ТР автомобиль тармагын илдә җитештерелә торган автомобильләрне һәм аларның комплектларын куллану үзлекләре (сыйфат, ышанычлылык, хәвефсезлек, экономиялелек, экологиялелек, дөнья стандарты дәрәҗәсендәге бәясе) б-н тәэмин итүгә юнәлтелгән үсеш концепциясен төзү буенча респ-ка фәнни-тикшеренү ин-ты һәм КБ эшенә җитәкчелек итә. НИИФХП илдә җитештерелгән двигательләрнең экологик хәвефсезлегe ягыннан Евро-3 нормаларына ирешүнең фәнни нигезләнгән методологиясен һәм шулар нигезендә мини җылылык станцияләре төзү б-н шөгыльләнә. Оештыручысы һәм директоры — Р.Г.Гафуров.

*Р.Г.Гафуров, Р.Г.Усманов.*

**ДИАЛЕ́КТ** (грек. diálektos — сөйләш, шивә), гомумхалык теленең аерым бер төбәк, социаль төркем, профессия кешеләренә хас төре. Терр. һәм социаль Д.лар була. Уртак сыйфатлары б-н берләшкән Д.лар җыелмалары — зур Д.лар — шивәләр, ә кечкенә Д.лар — *сөйләшләр* дип аталырга мөмкин. Терр. Д.лар авазлар төзелеше ягыннан, грамматик, сүз ясалыш, лексик үзенчәлекләре б-н аерылалар. Әлеге аермалар әллә ни зур түгел, һәм билгеле бер телнең төрле Д.ларында сөйләшүчеләр бер-берсен аңлыйлар (мәс., төрки телләр Д.лары). Башка очракларда аермалар шулкадәр зур ки, төрле Д.ларда сөйләшүчеләр үзара я авырлык б-н аңлашалар, яки бөтенләй аңлаша алмыйлар (мәс., немец яисә кытай телләре Д.лары).

Д.лар күп гасырлар дәвамында барлыкка киләләр. Вакыт дәвамында терр. берәмлекләренең үзгәрүе нәтиҗәсендә Д.лар бүленәләр, берләшәләр, яңа төркемнәргә аерылалар. Хәзерге Д.ларның ареаллары кабиләләр, феодаль җирләр, дәүләтләр арасындагы үткән заманнардагы чикләрне чагылдырырга мөмкин. Колбиләүче яисә феодаль дәүләтләр кабиләләренең һәм җирләренең терр. бүленүләре аларның телләрендә диалекталь аермаларның үсүенә булыша.

Д.лар феодализм чорында аеруча актив формалашалар. Әлеге чорның әдәби ядкәрләре җирле Д.ларның үзенчәлекләрен чагылдыралар. Әдәби телләр милләт формалашканда, гадәттә, Д.ларның берсе — илнең сәяси, мәдәни, дини үзәге халкы Д.ы нигезендә барлыкка киләләр. Әлеге Д., нигездә, гомумхалык сөйләм телен — *койнене* чагылдыра. Башка Д.лар, әдәби телне кайбер үзенчәлекләре б-н өлешчә баетып, мөстәкыйльлекләрен, төп үзенчәлекләрен югалталар, шәһәр халкының күпчелек өлеше һәм авыл яшьләре куллана торган ярымдиалектларга әвереләләр.

Социаль Д. — гомумхалык теленнән фәкать лексикасы б-н генә аерылып торган билгеле бер социаль төркемнәр сөйләше. Социаль Д.ларга аучылар, балыкчылар һ.б. ның профессиональ сөйләше; укучылар, студентлар һәм спортчыларның *жаргон сүз*ләре; сыйнфый йөзен югалткан элементларның арго сүзләре; халыкның билгеле бер икътисади, каста, дини һ.б. төркемнәренә хас гомумхалык теле вариантлары керә.

Татар телендә терр. өч диалект: *урта, мишәр* (көнбатыш) һәм *көнчыгыш* Д. бар. Татар әдәби теленең формалашуында һәм үсүендә урта һәм мишәр Д.лары төп рольне уйныйлар; көнчыгыш Д. инде формалашкан татар әдәби теле тәэсирендә соңрак барлыкка килә. Татар диалектологиясендә Д.ларны билгеләүдә нигез итеп терр.-лингвистик яки этник принциплар алына.

*Әд.:* Җ ә л ә й Л. Татар диалектологиясе. К., 1947; Б у р г а н о в а Н.Б., М а х м у т о в а Л.Т. К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. К., 1962. Вып. 2; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

**ДИАЛЕКТИ́ЗМНАР**, терр. *диалектларга* хас тел үзенчәлекләре. Әдәби тел үсешендә тел нормаларыннан читкә китү буларак аерылып чыгалар. Татар телендә фонетик Д.: **җ**-ләштерү (җаулык — әдәби телдә яулык, җәтмә — ятьмә), **ц**-ләштерү (пецән — печән, циләк — чиләк), **й**-ләштерү (йәләү — җәяү, йел — җил); грамматик Д.: -мәгә, -гәле кушымчалы инфинитив формалары (килмәгә, килгәле — килергә), фигыльнең 3 нче затында -ты/-те яисә -дыр/-дер кушымчалары (киләте, киләдер — килә); сүз ясый торган Д.: эрек — эремчек, капкак — капкач; лексик Д. бар. Соңгыларына этнографизмнар — әдәби телдә параллельләре булмаган, билгеле бер җирлектә кулланыла торган предмет һәм төшенчәләрнең атамалары (артмак — күн сумка төре, саравыц — хатын-кыз баш киеме); саф лексик Д. — әдәби телдәге сүзләрнең диалекттагы синонимнары (куй — сарык); әдәби эквивалентларыннан фонетик яктан, ясалу ысуллары, мәгънәсе б-н аерылып торган Д. (картнә — әби, арыш — тәртә) керә. Д. матур әдәбиятта, стилистик чара буларак, персонажларның телен тасвирлау, җирле колорит тудыру өчен кулланылалар.

*Әд.:* Диалектологик сүзлек төзүнең төп принциплары // Татар теленең диалектологик сүзлеге. К., 1993; М а х м у т о в а Л.Т. Современный татарский литературный язык и диалекты // Вопр. татарского языка и литературы. К., 1969; Т у м а ш е в а Д.Г. К вопросу о типах диалектных лексических различий // Советская тюркология. 1973. № 6. *Д.Б.Рамазанова.*

**ДИАЛЕКТОЛО́ГИЯ** (*диалект* һәм ... *логия*), телнең җирле терр. төрләрен — *диалект* һәм *сөйләшләрнең* тарихын һәм хәзерге халәтен өйрәнүче тел белеме бүлеге. Татар Д.се 19 йөз ахырында барлыкка килә (А.Г.Бессонов, Н.Ф.Катанов хезмәтләре). Аның үсешенең башлангыч чорына (1940 елларга кадәр) җирле сөйләшләрне табу, аларны классификацияләргә омтылу хас (Г.Әхмәров, Ж.Вәлиди һ.б.). Фән буларак татар Д.се 1950 елларда Л.Җ.*Җәләй* хезмәтләрендә формалаша. Ул *лингвистик география* б-н бәйләнештә үсә. Татар сөйләшләрен гомуми өйрәнү нәтиҗәсендә, Россиядә татарлар күпләп яшәгән төп терр-ялэрдә: көнбатышта Рязань өлкәсеннән алып, көнчыгышта Курган өлкәсенә кадәр, төньякта Киров өлкәсеннән алып, көньякта Оренбург өлкәсенә кадәр материаллар туплана. Бу, үз чиратында, «*Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы*»н төзергә мөмкинлек бирә.

Татар Д.се үсү процессында сөйләшләрне өйрәнү ысуллары камилләштерелә (анкета тутыру, төрле якларга экспедицияләр оештыру юлы б-н һ.б.), төшенчә билгеләмәләренә төгәллек кертелә (диалект, сөйләш, урынчылык), диалект һәм сөйләшләрне классификацияләү принциплары эшләнә, аларның төп үзенчәлекләре ачыклана.

Диалектологик тикшеренүләр татар лингвистика фәнен баеталар; алынган нәтиҗәләр татар халкы этногенезының иң катлаулы мәсьәләләрен хәл итәргә мөмкинлек бирәләр.

*Әд.:* Җ ә л ә й Л. Татар диалектологиясе. К., 1947; Б о р һ а н о в а Н.Б., М ә х м ү т о в а Л.Т. Татар теле диалектологик атласын төзү өчен материал җыйнау программасы. К., 1959; Б е с с о н о в А.Г. О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журн. М-ва народного просвещения. СПб., 1881. Ч. 216; Валиди Дж. О диалектах казанского татарского языка // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1927. № 6; З а л я й Л.З. Опорный диалект в формировании татарского языка // Вопросы диалектологии тюркских языков. Баку, 1958; М а х м у т о в а Л.Т. Некоторые итоги и проблемы исследования татарских диалектов // Развитие филологических и исторических наук в Татарии. К., 1969; ш у л у к. Краткий обзор истории изучения среднего и мишарского диалектов татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. К., 1989.

**ДИА́НОВА** Эвелина Николаевна (23.8.1932, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1987). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм шунда ук Химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (1989 га кадәр), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1987 дән). Хезмәтләре фосфор һәм мышьякның органик кушылмалары химиясенә карый. P=C һәм As=C бәйләнеше буенча циклокушу реакциясен узды-ра, химиянең яңа — түбән координацияле фосфор һәм мышьяк юнәлешен башлап җибәрә. Беренче тотрыклы бициклик фосфиран һәм арсираннар ала, шуларның изомерлашуын гамәлгә ашыра. Бик күп кушылмаларны синтезлый, шулар арасыннан тәэсир итүне акрынайтучы һәм фунгицид актив матдәләр таба.

Х е з м.: О реакциях циклоприсоединения по P=C связи двухкоординированного атома фосфора // Докл. АН СССР. 1979. Т. 244, № 5 (автордаш); О реакции 5-метил-2-фенил-1,2,3-диазафосфора с 2-диазопропаном // Журн. общей химии. 1984. Т. 54, № 7 (автордаш); Cycloaddition an Verbindungen mit $\lambda^3\sigma^2$-Phosphor- und $\lambda^3\sigma^2$-Arsen-Mehrfachbindungen // Phosphorus and Sulfur. 1986. V. 26, № 2 (автордаш).

**ДИА́РОВ** Альберт Баян улы (17.3.1936, Алма-Ата), геолог, геол.-минералогия фән. д-ры (1997). Казакъстан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), Көньяк Казакъстан геол. идарәсендә. 1979 елдан Казакъстан Респ-касы ФАнең Геол. фәннәре ин-тында, 2007 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта Казакъстан политехника ин-тында укыта (1971 дән). Төп тикшеренүләре Казакъстан терр-ясенең геологиясе һәм алтын металлогениясе б-н бәйле (1966 дан). Казакъстан терр-ясендә күп кенә алтын (Таскор, 1977; Музбель, 1997) һәм лабрадорлы анортозитлар чыганакларын (Тасоба, 1995) беренче булып ачучы. Медальләр, «СССРның җир асты байлыкларын тикшерү отличнигы», «Казакъстан Республикасының мактаулы җир асты байлыкларын тикшерүчесе», «Чыганакларны беренче ачучы» (өч тапкыр) исемнәре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эволюция близповерхностного золотого оруднения Казахстана // Геология и разведка недр Казахстана. 1995. № 5; Закономерности размещения близповерхностных золоторудных месторождений и факторы их локализации // шунда ук. 1997. № 2.

**ДИА́СПОРА**, туган иленнән (яки таралыш ареалыннан) читтә, бүтән этник тирәлектә яшәүче, этник чыгышы ягыннан бердәм һәм тотрыклы халык төркеме. Д. эчке (бер дәүләт эчендә) һәм тышкы (дәүләттән, туган иленнән читтә) була. Татарлар — таралып утырган халыкларның берсе. Барлык татарларның 25% ка якыны гына ТР терр-ясендә яши. Татар милләтен 3 мөстәкыйль үзәк — Идел буе-Урал, Себер һәм Әстерхан төбәге татарлары формалаштыра. Субэтник *Польша-Литва татарлары* төркеме дә бар. 19 йөз ахырында Идел буе һәм Урал яны татарларының зур үсеш алган мәдәнияте нигезендә бердәм татар милләте формалаша. Төрле тарихи шартлар аркасында татарларның ТРдан читтә тупланып яшәгән урыннарының барысында Д. төшенчәсе б-н бәйләп булмый. Татарларның борынгы бабалары Россия төбәкләренең кайбер терр-яләрен (хәзерге Башкортстан, Мари, Мордва, Удмурт, Чуаш Респ-калары, Киров, Самара, Ульянов өлкәләре) *Идел буе Болгар дәүләте* чорыннан ук үзләштерә башлыйлар, һәм алар чынлыкта

бу төбәкләрнең төп халкы булып тора. Татарларның күченүе үзенчәлекле берничә этапта һәм юнәлештә бара. Татар Д.сының формалашуы 14–15 йөзләрдә башлана. Бу вакытта *Белоруссия, Литва* һәм *Польша* терр-яләренә Алтын Урданың йомышлы татарлары урнаша башлый, бу Бөек Литва кенәзлегенә Туктамыш ханның 40 меңлек гаскәре килү б-н бәйле була. 14 йөздә *Мәскәүдә* беренче татар торулыклары барлыкка килә. 15 йөз уртасында Касыйм ханлыгы оештырылгач, татарлар хәзерге Рязань өлкәсе терр-ясендә күренә башлый. Бу чорда йомышлы татарларның күчеп килүләре нәтиҗәсендә Түбән Новгород өлкәсендә татар Д.сы формалаша. 17–18 йөзләрдә Россия хөкүмәте аларны көньяк-көнчыгыш чик буе өлкәләрендә (хәзерге Башкортстан һәм Мордва Респ-калары, Ульянов, Саратов, Пенза өлкәләре) хәрби хезмәттә файдалана, соңрак алар монда төпләнеп кала. Казан ханлыгы җиңелгәннән соң (1552), татарлар Урал төбәгенә күмәк күченә башлыйлар. Шул ук юнәлештә күмәк күченүләр 18 йөзнең 2 нче чирегендә — рус булмаган халыкларны көчләп *христианлаштыру сәясәтенең* иң көчле чорында бара. Иделнең түбән өлешләренә (Әстерхан өлкәсе) Урта Идел буе татарлары 17 йөздә килеп урнаша. *Санкт-Петербургта* татарлар шәһәргә нигез салынганнан бирле яши. *Оренбург өлкәсенең* хәзерге терр-яләренә татарлар 18 йөзнең 2 нче чирегендә күченә башлый: йомышлы татарлар Оренбург казаклары гаскәрләрендә хезмәт итә, ә ясаклы татарлар, яңа Мәскәү юлы буйларына урнашып, казна почтасында эшли. Татарларның Россиянең үзәк төбәкләреннән Урта Азиягә (хәзерге Үзбәкстан Респ-касы терр-ясе) күченүләренең төп сәбәбе — көчләп христианлаштыру сәясәте. 18 йөздә — 19 йөз башында татар яшьләре вәкилләре Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләре мәдрәсәләренә укырга килә. Шул ук вакытта татарлар Казакъстан һәм Кыргызстан терр-яләренә күченә башлый. 1860 еллардан башлап татарлар Урта Азиягә күмәк күченәләр, бу — Россиянең әлеге җирләрне яулап алуы б-н бәйле. Кавказда татар Д.сы 19 йөздә формалаша (иң зур татар җәмгыяте Әзәрбайҗанда була). Шул ук вакытта Идел буе һәм Урал яны татарлары Себер төбәгендә (хәзерге Красноярск крае, Иркутск, Новосибирск, Төмән һ.б. өлкәләр) күренә башлый, аларның күмәк күченүләре 1906–1911 еллардагы Столыпин реформалары чорына туры килә. Татарларның күченү хәрәкәте көньяк-көнбатыш юнәлештә дә дәвам итә: 19 йөз уртасында Идел буе һәм Урал яны татарлары Украина терр-ясендә дә очрый. Совет хакимияте чорында татарларның күченеп йөрүләренең сәбәпләре: 1921–22 еллардагы Идел буендагы ачлык (Себергә, Үзбәкстанга халык күпләп китә), индустрияләштерү сәясәте (Урал төбәгенә, Украинага), күмәкләштерү еллары (Себергә), чирәм җирләрне үзләштерү (Казакъстанга), нефть һәм ташкүмер чыганакларын үзләштерү (Себергә, Украинага). Татар Д.сы ш.у. ерак чит илләрдә дә оеша. Иң зур татар Д.ларының берсе Төркиядә барлыкка килә. Моңа 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Россиянең эчке төбәкләрендә яшәүче татарларның Госманлылар империясенә күченү хәрәкәте сәбәп була (к. *Мөһаҗирләр хәрәкәте*). Бу илгә күченү хәрәкәтенең икенче дулкыны — Россиядә 1907–08 елларда реакция башлану, өченче дулкыны 1917 дәге вакыйгалар һәм Гражданнар сугышы б-н бәйле. СССРда мөселманнарның коммунистлар тарафыннан репрессияләнүеннән Кытайга качкан татар эмигрантлары 1950–60 елларда Төркиягә килеп урнаша. 1950 елларга кадәр татарлар күпләп яшәгән икенче урын — Кытай. Илнең төньяк-көнчыгышында, Маньчжуриядә, татарлар 19 йөз ахырында Кытай-Көнчыгыш тимер юлын төзүчеләр буларак күренә башлый. Төзү эшләре тәмамлангач, күбесе шунда эшләп кала һәм 1950–60 елларга кадәр яши (Төркиягә киткәнче). Татарларның зуррак санлы икенче төркеме 19–20 йөзләр чигендә Кытайның төньяк-көнбатышында — Көнчыгыш Төркестанда формалаша. Бу төркемнең нигезен Көнчыгыш илләре б-н сәүдә итүче татар сәүдәгәрләре тәшкил итә. 1960 елларда Кытайда «культура революциясе» башлану б-н, монда яшәүче күп кенә татарлар Австралия, Төркия, Япония һәм АКШка күчеп китәргә мәҗбүр була. Скандинавия илләрендә татарлар Финляндия Россиягә кушылганнан соң (1809) күренә башлый, алар яңа хәрби гарнизоннарда руслар б-н бергә хезмәт итә. Татарларның Финляндиягә күченүләренең төп дулкыны 19 йөз ахыры — 20 йөз башына туры килә. Соңрак аларның берникадәр өлеше Финляндиядән Швециягә күчеп китә. 1970 тә Даниядә Төркиядән килгән берничә татар гаиләсе татар Д.на нигез сала. СССРдан читтә татар Д.сы Польша, Германия, Румыния, Болгария, Канадада оеша. СССР таркалгач, БДБ һәм Балтыйк буе илләрендәге татар җәмгыятьләре тышкы Д. булып кала. 1990 елларда зыялы татар элитасының бер өлеше чит илләргә китә.

ТР Конституциясенең 14 статьясы нигезендә респ-каның хакимият органнары, ш.у. иҗат берлекләре һәм җәмәгать оешмалары ТР дан читтә тупланып яшәгән татарларга үз мәдәниятен, телен үстерүдә, халкыбызның үзенчәлекле милли көнкүрешен саклауда булышлык күрсәтәләр. Диаспорадагы татарларның милли-мәдәни тормышын оештыру эшен ТР вәкиллекләре (4 тулы хокуклы, 4 даими, 2 сәүдә, 10 сәүдә-икътисади вәкиллек), *Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты*, ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы координацияли.

*Р.Р.Ибраһимов.*

**ДИБА́ЕВА** (Миндубаева) Мәрьям Мозаффар кызы (23.12.1916, Казан), журналист, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966). Казан ун-ты рабфагын тәмамлый (1937). Журналистлык эшчәнлеген 1934 елда «Яшь ленинчы» г-тасында башлый. 1941–71 елларда «Социалистик Татарстан» г-тасында эшли. Мәкаләләре «Яшь ленинчы» г-тасында, «Азат хатын» ж-лында басыла. Язмалары әхлак мәсьәләләренә, замандашларының күркәм эшләрен яктыртуга багышлана. Төп жанрлары — очерклар һәм юлъязмалар. Совет язучыларының шактый әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп бастыра.

Ә с ә р.: Зур тормыш юлында. К., 1960; Күңел күзе белән. К., 1962; Җирдәге әзең. К., 1967.

*Әд.:* А й т у г а н Н. Ерак еллар рәшәсеннән // Сөембикә. 1995. № 5; М а т о н и н а Э. Марьям апа // Журналист. 1970. № 3.

**ДИБА́Й** Ернст Апуш улы (3.8.1931, Казан — 12.11.1983, Мәскәү), астрофизик, физ.-матем. фән. д-ры (1969), проф. (1970). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, П.К.Штернберг исем. Астрономия ин-тында (ГАИШ, Мәскәү) эшли, астрофизика каф. профессоры, бер үк вакытта ГАИШның Кырым станциясе мөдире (1961–77). Хезмәтләре йолдызлар космогониясен һәм актив төшле галактикаларны өйрәнүгә карый. Күп кенә Сейферт галактикаларын ача, астрофизикадагы нәсызыкча эффектларның тоткан урынын беренче булып билгели һәм үлчәнешләр теориясен төзи. Формасы — газ болытларының гравитация һәм магнит кырлары геометриясе, ә үзләре йолдызара мохитнең тыгызлану процессы б-н бәйле кометасыман томанлыкларның табигатен ачыклый. Телескоп көзгеләрен «Ньютон спирале» рәвешендә үзенә бер төрле юка шомарту ысулын тәкъдим итә. Мәскәү ун-тының Көньяк астр. станциясенә һәм астероидларның берсенә Д. исеме бирелә (к. *Дибай астероиды*).

Х е з м.: Размерности и подобие астрофизических величин. М., 1976 (автордаш).

*Әд.:* М а р т ы н о в Д.Я. Активные ядра и звездная космогония. М., 1987.

*Р.Г.Усманов.*

**ДИБА́Й АСТЕРО́ИДЫ**, 2389 нчы кече планета. 1977 елда Кырымдагы астрофизика обсерваториясендә астроном Н.С.Черных тарафыннан ачыла. Е.А.*Дибай* исеме бирелә. Кояштан ераклыгы 1,9–3 *а.б.* Кояш тирәли 3,8 елда әйләнеп чыга.

**ДИБЕРДИ́ЕВ** Мөхәммәдйосыф Мөхәммәдәмин улы (19 йөз ахыры — 15.5.1926), шагыйрь, публицист, фабрикант. Танылган сәнәгатьче Дибердиевләр нәселеннән. Казанда, Уфада һ.б. шәһәрләрдә яши. Абыйлары б-н берлектә Сембер губернасында ф-калар хуҗасы була. Мәчетләр төзүгә, җәдит мәдрәсәләренә акчалата ярдәм күрсәтә. С.-Петербургта мәчет салу өчен акча җыю ком-ты әгъзасы була. Хаҗ кыла. Татар вакытлы матбугаты битләрендә дини реформага кагылышлы мәкаләләр бастыра. Иҗатында шагыйрь *Аллаһияр Суфи* йогынтысы сизелә. «Әшче намазы» (1910), «Олугълык нәрсәдә? Шәрекъ хикәясе» (1912) әсәрләре авторы.

Ә с ә р.: [Муллалар, имамнар хакында] // Шура. 1917. № 10; Җомгада мөнбәр азаны хакында // шунда ук. 1917. № 13.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М., Т а и р о в Н. Дибердиевләр шәҗәрәсе // Татарстан. 1997. № 12; Т а и р о в Н. Благотворительность фабрикантов Дибердиевых // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4.

*Н.И.Таиров, А.М.Ахунов.*

**ДИБЕРДИ́ЕВ** Рөстәм Якуп улы (27.10.1940, Арча штп), химик-технолог, техник фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998, 2007). 1967 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1990

нан полимерларны һәм композит материалларны кабат эшкәртү технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре полимерларга, олигомерларга, шуларны хим. әверелдерүгә, үзгәртүгә һәм эшләнмәләр итеп кабат эшкәртүгә карый. Д. композитполимер материалларның тутырылу кимәле, эретелмәнең халәте, молекуляр массасы, фазаларның сыешучанлыгы б-н идарә итү өчен төрле үзгәртүчән факторлар тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә лазер б-н стимуллаштырылу полимерлаштыруга, киеренке көчеш халәте шартларындагы органик һәм наорганик материалларны каты фазада үзгәртүгә, полимерларны, композит материалларны һәм капламнарны электретлаштыруга, мотор майлары һәм ягулык кушылдыклары алуга һәм куллануга, югары молекуляр кушылмалар алуга, технол. җиһазларны, торба үткәргечләрне тутыгудан саклауга юнәлтелгән тикшеренү эшләре алып барыла. Тикшеренү нәтиҗәләре «Түбәнкаманефтехим», «Органик синтез», «Татэнерго», «Мосэнерго» АҖләрендә, С.-Петербург, Алабуга з-дларында һ.б. гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. ТР Дәүләт һәм РФ хөкүмәте бүләкләре лауреаты (2001, 2004). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Полиоксиметилены. М., 2008; Физико-химические основы протекания быстрых жикофазных процессов. М., 2008 (автордаш); Oligomeric State of substances. N.-Y., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДИБЕРДИ́ЕВЛӘР**, сәүдәгәрләр һәм эшмәкәрләр, нәселдән килгән мактаулы гражданнар. Бертуганнар Ишмөхәммәт (? — 1903), Мәхмүт (? — 1903), Әхмәтҗан (? — ?), Габдулла (? — ?) Д. 1896 елда «Ишмөхәммәт Дибердиев бертуганнарының сәнәгать-сәүдә ширкәте»н оештыралар. Ширкәттә Саратов губернасы Кузнецк өязенең Верхозимье авылындагы постау фабрикасы һәм Пәндәлкә авылында аның бүлекчәсе була (1908 дә фабрикада 597 кеше эшли, елына 630 мең сумлык тукыма җитештерелә). Д. шактый сумманы хәйрия максатларына күчерәләр: мөселман балалар ятимханәләренә ярдәм итәләр, Кузнецк өязендә, С.-Петербург, Түбән Новгородта уку йортлары һәм мәчетләр төзиләр һәм тоталар. Мәккә һәм Мәдинәдә йортлары була, аларда Россиядән хаҗга килүчеләрне кабул итәләр. Ш.у.к. *Дибердиев М.М.*

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М., Т а и р о в Н. Дибердиевләр шәҗәрәсе // Татарстан. 1997. № 12; Т а и р о в Н. Восток — дело тонкое // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 1/2; ш у л у к. Благотворительность фабрикантов Дебердиевых // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4.

**ДИВА́ВИН** Геннадий Валерьевич (24.6.1941, Казан), хуҗалык җитәкчесе, инженер-электромеханик, «Электроприбор» з-ды ген. директоры (1987 елдан). ТССРның атказ. машина төзүчесе (1991). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), «Электроприбор» з-дында: җыю цехы мастеры, технол. әзерлек бюросы башлыгы, цех башлыгы урынбасары, баш инженер (1980–87). Д. җитәкчелегендә пр-тие реконструкцияләнә, хәрби һәм гражданнар авиациясенең төрле типтагы самолётлары һәм вертолётлары өчен әйберләр эшләнә, системаларны, автомобиль сәнәгате өчен комплектлау эшләнмәләрен, мед. техникасын, халык куллануы товарларын күпләп җитештерү гамәлгә кертелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость университета / КАИ: Краткий биогр. справ. К., 2002.

**ДИВА́ЕВЛАР**, татар дворяннары нәселе. 1719 елда йомышлы татарлар Невай Параев (1653-?) һәм аның ике улы — Девай (1679-?) б-н Имай (1689-?) Усы даругасының (хәзер БРның Борай р-ны) Әзәк авылында яшәгәннәр. Девайның уллары — Сөләйман б-н Мөслим. Девай Неваев мишәр старшинасы буларак билгеле. Усы даругасының мишәр старшинасы Сөләйман Д. *Батыршаны* кулга алуда катнашкан. Сөләйманның улы Ишмөхәммәт Д. 18 йөзнең 2 нче яртысында Нугай даругасына күчкән һәм шунда мишәр старшинасы булган. Шул вакыттан соң Д. Тукай авылында (хәзер БРның Бишбүләк р-нында) яшәгәннәр. Нәселнең бер өлеше 1739 да Сыйрышбаш авылына (хәзер БРның Чакмагыш р-нында) килеп утырган. 19 йөздә Тукай авылындагы Д.га нәселдән күчүче дворянлык бирелгән. Татар галиме һәм мәгърифәтчесе Әбүбәкер Диваев (1855–1933) Д. нәселеннән чыккан.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**ДИВА́Н** (гарәп.-фарсы. ديوان — шигырьләр мәҗмугасы), бер яисә берничә әдипнең билгеле кануннар нигезендә төзелгән шигырьләр (элегрәк проза әсәрләре дә кергән) җыентыгы. Якын һәм Урта Көнчыгыш классик әдәбиятында кульязма һәм басма рәвешендә нык таралыш ала (Ясәвинең «Диване хикмәт»е, Алишер Нәвои, Хафиз Ширази Д.нары). Кагыйдә буларак, Д.да әсәрләр жанрлар тәртибендә урнаша (*касыйдә, газәл, мәрсия, кыйтга, робагый* һ.б.), ә шигырьләр рифмалар тәртибендә, ешрак рифмалашкан сүзләрнең соңгы хәрефләре буенча бирелә. Татар әдәбиятында еш кына гади шигъри җыентыклар да Д. төшенчәсе б-н аталып йөртелә (мәс., «Габдулла Тукаев диваны»).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**ДИВА́Н** (гарәп.-фарсы. ديوان — канцелярия, идарәханә), урта гасырлар мөселман илләрендә, ш.и. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында дәүләт вәзирлеге идарәсе, хан карамагындагы дәүләт киңәшмәсе. Аңа 4 *карачы бәк* керә, берсе *бәкләр бәге* дәрәҗәсендә була. Д. рәсми документлар әзерләү, халык санын исәпкә алу, салым түләү барышын күзәтү һ.б. вазифаларны башкарган. Бу эшләрне *битикчеләр* — язу эшләрен башкаручылар, сәркәтипләр алып барган.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. Культура мусульманства. П., 1918; ш у л у к. Работы по истории ислама и Арабского халифата. М., 1966. Т. 6; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*М.Г.Госманов.*

**ДИВЕ́ЕВЛАР**, татар бәкләре нәселе; чыгышы Кырым ханының 1572 елда Мәскәү янында руслар тарафыннан әсир ителгән туганы Дивей морзадан. Ихтимал, Дивей морза мангыт ыругы вәкиледер, 1563 елда Кырым морзалары арасында Дивей Мангыт искә алына. 1613 тә Батыргәрәй Д.ка рус патшасы дәүләт жалованьесы бирә. 1678 дә Д. нәселеннән Дәрбиш Теребердиевнең Кадом өязендә (хәзер Рязань өлкәсе) биләмәләре була. Кадом өязенең 1678 елгы теркәү кенәгәсендә Дәрбиш Д. б-н аның улы Сәфәр полк хезмәтендә исәпләнәләр һәм кенәзләр дип язылалар; рәсми кәгазьләрдә аларның нәсел буыннары да шулай атала. 1685 тә Сөнчәләй һәм Арслан Аюкаев Д. һәм аларның агалары Нурай искә алына. 1699 да Мәмли Артуганов, Мирас Нагайбәков, Мостай һәм Сәфәр Дәрбишевләрнең утарлары була. 18–19 йөзләрдә морза Д. Темников өязенең Бутаково, Иванково авылларында (хәзер Мордва Респ-касы терр-ясендә) яшәгәннәр. 18 йөзнең беренче чирегендә морза Д.ның улы морза Мамадалий Григорьевның Кочетбек авылында 10 крепостной крәстияне була. Пётр I нең 1713 елгы Указыннан соң Кадом өязенең Дивеев һәм Бутаков авылларында яшәүче Д. нәселеннән булган морзалар Бәхтияр Мостаев һәм Мамадалий Мирасовның 1713 крәстияне «государьга» күчереп языла. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Д.ның бер өлеше Бәләбәй өязенең Каргалы (хәзер БРның Благовар р-ны) һәм Бәшир (хәзер БРның Чакмагыш р-ны) авылларына күчеп утыра. Россия империясе Сенатының 1796 ел, 1 декабрь Указы нигезендә Д. нәселенә дворянлык дәрәҗәсе кайтарыла, алар Түбән Новгород, Оренбург һәм Тамбов губерналары дворянлык нәсел кенәгәләренең 4 нче өлешенә, 1833 тә Пенза губерна нәсел кенәгәсенең 5 нче өлешенә кертелә. Сенатның 1852 ел, 22 декабрь билгеләмәсе буенча Сөләйман уллары Моратша б-н Тимербай, Хәникә улы Габит һәм аның улы Габделхалик, Хәникә уллары Хәмит б-н Вәлит, аларның уллары Рәхмәтулла, Вәлиулла, Галиулла Д. татар кенәзләре дәрәҗәсендә расланалар һәм дворянлык нәсел кенәгәсенең 6 нчы өлешенә кертеләләр.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; С а в е л о в Л.М. Родословные записи. М., 1909. Вып. 3; Н о в о с е л ь с к и й А.А. Борьба Московского государства с татарами в XVII в. М.–Л., 1948; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*


**ДИ́ВОВ** Василий Абрамович (25.7.1805, Казан — 9.2.1842), декабрист, Гвардия экипажы мичманы (1821). Дворяннар нәселеннән, Казан җинаять эшләре мәхкәмәсе советнигы Абрам Гаврилович Д.ның (1761–1805) улы. Диңгез кадет корпусын тәмамлый (1816). 1818 елдан Балтыйк флотында хезмәт итә. Яшерен «Гвардия экипажы җәмгыяте» әгъзасы; С.-Петербургта һәм Украинада яшерен оешмалар булуы турында белә, респ-ка идарәсе кертүне һәм хакимияттән император гаиләсен читләштерүне яклый. 1825 нең 14 декабрендә Сенат мәйданындагы баш күтәрүдә катнаша, шуннан соң кулга алына. Мәхкәмә утырышында үзенең актив декаб-

ристлар б-н элемтәдә булуын инкарь итә; аларның язмышын җиңеләйтергә теләп, бөтен гаепне үз өстенә ала. Гомерлек каторга эшләренә хөкем ителә (соңыннан срок 20 елга кадәр киметелә); 1827 дә императорның яшерен әмере б-н мәхкәмә билгеләгән сөрген Бобруйск крепостена җибәрү б-н алыштырыла. Тоткынлыкта булу вакыты 1832 дә — 15, 1835 тә 13 елга кадәр кыскартыла. Азат ителгәч (1839), 2 нче Кара диңгез линия батальонына рядовой итеп билгеләнә, 1841 дә Кавказ сапёрлар батальонына күчерелә. Тау халыклары б-н бәрелеш вакытында җитди яралана.

*Әд.:* Гарзавина А.В. «...Отчизне посвятим души прекрасные порывы!» К., 1990; Декабристы: Биогр. справ. М., 1988.


**ДИДЕ́НКО** Иван Матвеевич (1898, Таврия губ., Днепр өязе Алёшки ш. — 1975), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Ростов-Дон химия-технол. техникумын тәмамлый (1932). 1911–18 елларда «Галея», «Дмитрий Донской» җилкәнле судноларында, «Рома», «Король Альберт» пароходларында матрос булып хезмәт итә. Гражданнар сугышында катнаша. 1924–39 да Ростов-Дон шәһәрендә Окт. Рев-циясе исем. з-дта эшли (1933 тән директор). 1939–42 дә — Ленинград лак һәм буяулар з-ды, 1942–43 тә — 2 нче завод (БАССРның Шафраново ст.), 1943–44 тә — Жилёво химия з-ды (Мәскәү өлкәсенең Жилёво ст.), 1944–46 да Горкино химия з-ды (Ярославль өлкәсенең Горкино ст.) директоры. Д. — Казан резина-техник эшләнмәләр з-ды төзелешен оештыручы, 1946–63 тә аның директоры. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ДИЕ́Н СИ́НТЕЗЫ**, Дильс-Альдер реакциясе, циклокушу, туендырылмаган реагентларга (диенофилларга) цис-1,3-диен системалы матдәләрне (диеннарны) кушып, циклик структуралар хасил итү реакциясе. Реакциягә ачык яки циклик 1,3 — иярешле углеводородлы системалар (бутадиен, циклопентадиен, антрацен, фуран кушылмалары), ш.у. үзара С=С, С=Э бәйләнешләре (биредә Э=О, N, P, Se) булган системалар керә. Активлаштырылган этиленлы яки ацетиленлы бәйләнештәге кушылмалар һәм туендырылмаган гетероатомлы системалар (C=O, C=N, S=O, N=N, N=O, C=S, C=Se) диенофил була ала. 1928 елда немец химик-органиклары О.Дильс һәм К.Альдер бутадиенның (I) малеин ангидриды (II) б-н бүлмә темп-расында югары чыгышлы аддукт (IV) хасил итүен ачалар:




I II III IV

Д.с. реакциясен уздыруның төп закончалыкларын тикшергән һәм ачкан өчен галимнәргә Нобель премиясе бирелә (1950). Гомуми кабул ителгән атамасы — Дильс-Альдер реакциясе (ДАР). Изопрен (V) димеризацияләнгәндә циклогексен кушылмалары (VI һәм VII) хасил булуын беренче мәртәбә акад. В.Н.Игнатьев фаразлый (1887) һәм Е.Е.Вагнер исбатлый (1894):




V VI VII

Бутадиенның циклик димеризациясе дә шул рәвешле уза (1913, акад. С.В.Лебедев), бу очракта бер үк кушылма диен да, диенофил да булып тора, аддуктлар чикләнгән санда гына барлыкка килә. Диенда цисоид конформациясе кирәклеген Б.А.Арбузов исбатлый (бергәләп, 1931), шул реакция б-н абиетин (VIII) һәм левопимар (IX) кислоталарында икеле бәйләнешләрнең урыны билгеләнә:



VIII IX



X

Б.А.Арбузов һәм А.И.Коновалов җитәкчелегендәге Казан химиклары ДАРны өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Орбиталь тәэсирләшү энергиясе ярдәмендә реакциягә керә алу сәләтен тикшерүләр кинетик активлык б-н селективлык арасында гадәти булмаган нисбәтне ачыклый: реагентның активлыгы арту б-н аның үз реакциядәшенә карата селективлыгы да арта. Процесс тизлеген кискен үстерүгә китерүче реагентларның эреткеч һәм катализаторлар б-н специфик тәэсирләшүенең, бәйләнешләр өзелү һәм барлыкка килү энергиясе балансының ДАР реагентлары активлыгына тәэсире раслана. Реагентларның үзлекләренә бәйле рәвештә, диен һәм диенофилның фронталь орбитальләре арасында тәэсир итешүләр өч вариантта булырга мөмкин: диенның югарырак тулы молекуляр орбитале (ВЗМО) б-н диенофилның түбәнрәк тулы булмаган молекуляр орбитале (НСМО) арасындагы реакция сәләтен контрольдә тотучы; диенофилның ВЗМО б-н диенның НСМО үзара тәэсирен контрольдә тотучы; арадаш вариант. Реакцияне югары басым астында уздырганда тизлекнең зурлыгы һәм константалары, тигезләнеш константалары үсә. Синтетик мөмкинлекләрне киңәйтү, төп продуктлар алганда тизлек һәм тизләнешне юнәлешле үзгәртү, реакциягә керү сәләте б-н идарә итү факторларын җентекләп өйрәнү максатыннан, реагентлар б-н эреткечләр һәм катализаторлар арасындагы специфик үзара тәэсирләрнең, темп-ра режимы һәм югары басымның реакциягә комплекслы тәэсире өйрәнелә. Тәҗрибә мәгълүматлары һәм теоретик хисаплау нәтиҗәләре активлаштырылган комплекста (III) бәйләнешләрнең көйләнгән кабат бүленеше механизмына туры килә, биредә диендагы һәм диенофилдагы π(-)бәйләнешләрнең өзелүе аддутта яңа бәйләнешләр барлыкка килү б-н бергә бара. Реакциянең күчеш халәтендә гетероанатомлы чиксез кушылмалар катнашса, яңа бәйләнешләр симметриясе бозылырга мөмкин. Реакцияне термик яктан хәл ителгән, реагентлардан реакция продуктларына күчкәндә орбиталь симметрия саклана торган процесс дияргә була.


*Әд.:* Арбузов Б.А. О присутствии конъюгированных связей в абитиеновой кислоте // Журн. общей химии. 1932. Т. 2; Киселёв В.Д., Коновалов А.И. Факторы, определяющие реакционную способность реагентов в обычной и катализируемой реакции Дильса-Альдера // Успехи химии. 1989. Т. 53; Коновалов А.И., Киселёв В.Д. Реакция Дильса-Альдера. Реакционная способность диен-диенофильных систем. Влияние внутренних и внешних факторов (авторский обзор) // Изв. РАН. Сер. хим. 2003. № 2.


*В.Д.Киселёв.*

**ДИЗА́ЙН** (ингл. design — проектлаштыру, әйбернең функциясен ачыклау; лат. designare — максатны ачыклау, билгеләү), форманы максатка ярашлы итеп төзүдә кулланылган иҗади алым, ш.у. сәнәгать эшләнмәләрен, йорт җиһазларын, эш коралларын, машиналарны проектлауда, матди мохитне һәм хезмәт процессларын оештыруда профессиональ эшчәнлек өлкәсе.

Д. кул эшен машина б-н башкаруга күчү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Профессиональ эшчәнлекнең яңа төре булачак эшләнмәнең проектын кәгазьдә ясау яки моделен төзүгә кайтып кала. «Д.» атамасы 1826 елда, Америкадагы Нәфис сәнгать академиясе Милли дизайн академиясе итеп үзгәртеп корылгач, кулланыла башлый. Д. иҗатында төп принцип: функция — конструкция — эстетик форма (сыйфат). Д. үсешендә 2 юнәлеш барлыкка килә: индустриаль Д. һәм концептуаль (программалы) Д.; җитештерү төрләре буенча ул массачыл һәм уникаль Д.га бүленә. Төп төрләре: сәнәгать (эшләнмәләр) Д.ы (механизмнар, транспорт, көнкүреш приборлары, савыт-саба, кием-салым һ.б.), мохит Д.ы (торак һәм җәмәгать биналарының интерьерлары, шәһәр мәйданнары һ.б.), график Д. (сәнәгать графикасы, газета-журнал графикасы, реклама полиграфиясе һ.б.), реклама Д.ы һ.б.

Россиядә һәм Татарстанда Д. тарихы өч чорга бүленә. Беренчесе — 1920 еллар, җитештерү сәнгате дип аталган, эстетиканы җитештерүгә кертүгә өндәгән яңа стилистик юнәлеш (рәссамнар В.Татлин, А.*Родченко*, Л.Лисицкий, Л.Попова һ.б.лар). Казанда ТатЛЕФ оешмасында һәм аның татар бүлеге «Сулф»та әгъза булып торган рәссамнар И.Никитин, Ф. *Таһиров*, А.*Платунова*, К.*Чеботарёв*, П.Байбарышев, М.*Барашов*, П.Кудряшов, А.*Кашаев*, С.Федотов, Н.Пузанков һ.б., архитекторлар Ф.*Гаврилов*, Д.Фёдоров җитеш-






























**Дизайн мәкаләсенә.** 1. Вакытлы агитацион корылма «Яңалиф – Мәгърифәт капкасы». Казан, Татарстан ур. 1929; 2. Ф.Ш.Таһиров. Трибуна эскизы. Кәгазь, аппликация, гуашь. 1924; 3. Д.Н.Красильников. Г.Кутуйның «Безнең курай» китабына тышлык эскизы. Кәгазь, тушь, гуашь. 1926. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. Ф.Ш.Таһиров. Ф.Таһировның «Театрдан – клубка!» китабына тышлык. Кәгазь, коллаж, гуашь. 1927; 5. Югары разрядлы салон-ателье. Казан, Декабристлар ур. Интерьерларны бизәү авторы — Ф.Х.Вәлиев, гипсны уеп бизәкләүче — С.Иванов. 1958; 6–7. Казанда Көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты интерьерлары. Бизәлеш авторы — В.А.Нестеренко. Дивар бизәге. Рәссамнар — В.А.Нестеренко, О.В.Бойко. Металл яктырткычлар һәм декоратив рәшәткәләр. Башкаручы — Г.И.Такмин. 1976; 8. Мехтан эшләнгән өс киемнәре дизайны. Казан мех берләшмәсендә тегелгән әйберләр. 1970 еллар; 9. «Җырлаучы космос» музыкаль витражы. «Прометей» фәнни-тикшеренү институты тарафыннан эшләнгән. Казан техник университеты музее. 1982; 10. «КамАЗ-Мастер» дизайн-проекты. Авторы — О.И.Якубова. РФнең Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Дәүләт бүләге (2000); 11. Салих Сәйдәшев музее. Экспозиция күренеше. В.А.Нестеренко дизайн-проекты. 1990. Музейларның Красноярск шәһәрендә уздырылган халыкара Бьенналесында «Гран-при» бүләге (2000); 12. Әлмәт шәһәрендәге мемориаль комплекс. С.М.Михайлов, И.Г.Михайлова, А.А.Идрисов, М.И.Белов реконструкция проекты. 2002. ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге (2004), Россия Сәнгать академиясенең Зур көмеш медале (2002); 13. Түбән Кама шәһәрендәге «Титан» мәдәни-күңел ачу үзәге. 2004. Реконструкция һәм дизайн-проект авторлары — Р.М.Абаев, Р.В.Гыймранов, А.Н.Лопаткин, В.А.Нестеренко; 14. Казанда Солтангалиев мәйданындагы әйләнмә-чыршы. С.М.Михайлов, И.Г.Михайлова, Д.Ф.Кошкин, Л.М.Кулиева дизайн-проекты. 1996.

терү, көнкүреш һәм әйләнә-тирәне үз эченә алган яңа синтетик сәнгать оештыруны үзләренең максатлары итеп куялар; милли татар костюмнары нигезендә иҗат ителгән заманча кием-салым формалары һәм көндәлек өс киемнәре, уенчыклар, бәйрәм көннәрендә урамнарны һәм мәйданнарны сәнгати бизәү, аерым әйберләрне (күн, агач, тукыма эшләнмәләре үрнәкләре) проектлау б-н шөгыльләнәләр; үзләрен плакат сәнгатендә, полиграфия эшендә, ш.у. тукыма әйберләр, йорт җиһазлары җитештерү тармагында (Казан сәнәгать пр-тиеләре өчен эшләнмәләр үрнәкләре эскизлары), өлешчә театрларда («КЭМСТ» һәм «Бомба» театр коллективы) күрсәтәләр. Казан рәссамнарының Д. үрнәкләре эскизлары «Казан, алга!» күргәзмәсендә тәкъдим ителә (1924). Җитештерү сәнгате идеясе Казан югары сәнгать-техник остаханәләре (1921) һәм Казан архит-ра-техник ин-ты (1922) итеп үзгәртелгән Казан сәнгать мәктәбенең яңа укыту программаларында да әйдәүче була.

Икенче чор — 1930–50 еллар — сәнәгать Д.ы үсеше, транспорт (автомобильләр) һәм транспорт системасының (Мәскәү метрополитены) яңа төрләре, яңа җитештерү сәнәгате барлыкка килүе б-н тарихка кереп кала. Татарстанда бу чорда күпләп продукция чыгаручы эре җитештерү куәтләре сафка баса (Казан мех комбинаты, галантерея ф-касы, җитен эшкәртү комбинаты, киез басу, фетр җитештерү һәм тегү сәнәгате пр-тиеләре). Сәнәгать Д.ы өлкәсендә П.Байбарышев, Г.Сотонина, В.Лаптев һ.б. рәссамнар эшли; зур күргәзмәләрдә интерьер һәм экспозиция Д.ы барлыкка килә (Мәскәүдәге СССР ВДНХсында ТАССР павильоны — баш рәссам П.*Сперанский*, рәссамнар И.Никитин, Е.Частихина, Б.*Урманче*, А.Крылов, Н.Байбурин, П.Тужилкин; Казандагы ВДНХ павильоннары — баш рәссам А.Крылов, рәссамнар П.Тужилкин, Х.Ибраһимов, Н.Костин һ.б.), җәмәгать биналарының интерьер Д.ы, җиһазлар Д.ы б-н бергә (СССР ФАнең Казан ф-лы — рәссамнар П.Сперанский, С.*Ахун*; Татар опера һәм балет т-ры — баш арх. һәм рәссам И.*Гайнетдинов*; Казандагы югары разрядлы ателье интерьеры — арх. һәм рәссам Ф.Х.*Вәлиев* һ.б.), респ-ка шәһәрләрен бәйрәм көннәрендә бизәү тормышка ашырыла.

Өченче чор — 1960 еллар башы — 1980 еллар — «сәнгати конструкцияләү» дип аталган чор, башта — Көнкүреш сәнгате академиясе (АХБ), аннары ВНИИТЭ (Бөтенсоюз техник эстетика фәнни-тикшеренү ин-ты), аның ф-ллары һәм СХКБ (союздаш сәнгать-конструкторлык бюролары), ш.у. СССР Рәссамнар берлегенең Сенеж студиясе төзелүдән башлана. 1970–80 елларда Татарстанда сәнәгать Д.ы үзәге Баш конструктор идарәсенең баш архитектор һәм реклама бүлекләре каршындагы КамАЗны сәнгати конструкцияләү бюросында оеша. Биредә автомобильләр, модульле транспорт системалары, өлешчә мохит Д.ы өлкәсен үстерү б-н шөгыльләнүче илгә танылган дизайнерларның зур коллективы эшли (В.Хайман, С.Екимов, А.Семёнов, Г.Тяжкин, В.Трифонов, Е.Улькина, Г.Сысоев һ.б.). Моннан тыш эре җитештерү берләшмәләре һәм сәнәгать пр-тиеләре (вертолётлар, самолётлар төзү, «Татнефть», аның ф-ллары һ.б.) каршында да Техник эстетика бюролары оештырыла. Ләкин планлы икътисад шартларында Д. казанышларын гамәлгә кертү һәм файдалану кыен була, шуңа күрә ул, башлыча, фәнни һәм укыту эшчәнлегенең бер төре буларак яшәп килә. Сәнгать Д.ы өлкәсендә җитештерү сәнгате, конструктивизмның яңа эчтәлек б-н баетылган идеяләре яңача үзләштерелә. Бу юнәлештә бөтенсоюз «Сәнгать һәм көнкүреш» күргәзмәсе (Мәскәү, 1964) мөһим этап була, ул сәнгати сәнәгать өлкәсендә массачыл предмет Д.ы барлыкка килүгә алшартлар тудыра. Татарстанда проф. рәссамнар төркемнәре Казан күн галантереясы ф-касында, мех ком-тында, «Татмебель», «Швейник», «Зима», «Модельләр йорты» берләшмәләрендә, Бөгелмә фарфор з-дында һ.б. пр-тиеләрдә формалаша. Мохит Д.ы 1960–80 елларда бизәү сәнгате рәвешендә үсеш ала. Бу юнәлешнең башында рәссамнар В.Халтурин, А.Крылов, А.*Спориус*, Н.*Артамонов*, Ф.Ибраһимов, В.Охотин, Л.Иванова, И.*Бобровицкий*, Г.Нечиталюк һ.б. тора. 1960 елларда алар җәмәгать корылмаларын (аэропорт, «Волга» кунакханәсе, Сәяси мәгариф йорты, ВДНХ павильоннары, «Сосновая роща» һәм «Лунное» кафелары, Казандагы кибетләр һәм укыту-мәгариф оешмалары биналары, Яшел Үзән шәһәрендәге «Волга» ресторанЫ һ.б.), музейләр һәм күргәзмәләр экспозицияләрен (Казандагы А.М.Горький әдәби-мемориаль музее, ВДНХ һ.б.), шәһәрдәге аерым урыннарны (Казандагы Совет мәйданы, шәһәр капкалары һ.б.), кече формаларны (газлы-яктырткыч җайланмалары, күргәзмә агитация стендлары, витриналар һ.б.) бизәү һәм проектлау өстендә эшлиләр. Гамәли һәм сәнәгать графикасы өлкәсендә Л.Иванова, Е.*Киселёва*, С.*Лывин*, Х.*Якупов*, Н.*Артамонов*, Б.Әлминов, М.*Мавровская*, М.Моратов һ.б. хезмәт куя (төрле катыргы тартмалар, реклама плакатлары, мактау грамоталары, чакыру билетлары һ.б.). Шәһәр мохите Д.ы өлкәсендә 1970 еллардан Б.М.*Галиев* җитәкчелегендәге «Прометей» фәнни-тикшеренү ин-ты төсле ут музыкасы өлкәсендәге башлангычларны тормышка ашыра (Казан Кремленең Спас манарасындагы «төсле нәфис кыңгырау тавышы», Казан циркын алмашып торган ут б-н яктырту, «Татарстан» кунакханәсендә музыкаль утлы панно һ.б.). 1970–80 елларда интерьерларны ансамбль рәвешендә бизәү үрнәкләре — Казандагы Химиклар мәдәният сарае, Төзүчеләр мәдәният сарае, «Татарстан» кунакханәсе, Яшьләр үзәге, Көнкүреш йорты, Сәүдә үзәге, Чаллыдагы Энергетиклар мәдәният сарае, «Батыр» кунакханәсе һ.б. 1970 елларның 2 нче яртысыннан Казан дизайнчылары (Н. һәм И.Артамоновлар, Р.*Сафиуллин*, В.Мухин, Е.Голубцов, О.Бойко, В.Нестеренко һ.б.), соңыннан «17 ле төркем»гә берләшеп, «Сенеж» үзәк өйрәнү-тәҗрибә студиясенең (җитәкчесе Е.А.Розенблюм) бөтенсоюз семинарлары эшендә актив катнашалар, архит-ра-тирәлек һәм кирәк-ярак предметлар мохитен гармонияле һәм бербөтен итеп оештыру максаты (җирле Д. һәм мохит Д.ы) б-н комплекслы проектлар иҗат итәләр. Казан дизайнчылары — күп кенә бөтенсоюз объектлары проектларының авторлары. Алар Минск, Баку, Чаллы һ.б. шәһәрләр панорамаларын, Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай музеен (1975; Н.Артамонов, Е.Голубцов), Казандагы Иске татар бистәсен реконструкцияләү һәм төзекләндерү проектын, «Горки» микрорайонының архит-ра-сәнгать тирәлеген, Татар академия театры, «Казан» ресторанЫ, «Бегемот» сыра барын һәм Чаллыдагы КамАЗны бизәү, Әлмәттәге Техниклар сарае, Лейпциг ярминкәсендәге ТАССР экспозициясен бизәү проектларын (1980 еллар; Р.Сафиуллин, Е.Голубцов, В.Нестеренко, А.Мухин, О.Бойко, В.Вязников, А.Симбирин, А.Якупов һ.б.) иҗат итәләр. Әмма күп кенә иҗади ниятләр тормышка ашмыйча, проектлар булып кына кала. 1980 елларда респ-ка дизайнчыларының зур төркеме оеша. 1970 елларда ук Р.Сафиуллин башлангычы б-н ТАССРның Рәссамнар берлеге каршында проектлау һәм бизәү сәнгате секциясе төзелә. Беренче респ-ка Д. күргәзмәсе 1984 тә Казанда уздырыла. Мохит Д.ы өлкәсендә архитекторлардан А.Спориус, З.Низамиев, 1977 дән «ВИАЛЕВ» иҗат төркеме (В.*Логинов*, Е.Прокофьев һәм А.*Чебинёв*) актив эшли. Шәһәр һәм интерьер Д.ы өлкәсендә ш.у. Чаллы (Х.Гыймазетдинов, Э.Бусова, З.Низаметдинова, Р.*Свинин*, Ә.Гәрәев, В.*Акимов*, А.Иванов, Г.Миргалимов һ.б.), Түбән Кама (Ю.Галузин, В.Шиһабетдинов, Ә.*Фәтхетдинов*), Бөгелмә (И.Насретдинов, В.Осокин, Ф.Корнилов), Лениногорск (А.Юдин, О.*Кульпин*, А.Горюнов, Я.Зиннәтуллин), Әлмәт (Р.Агафонов, В.Бушуров) һәм ТРның башка шәһәрләре рәссамнары зур хезмәт куя. Республикада заманча өс киемнәре Д.ы уңышлы үсеш ала. 1989 да Казанда модельер-рәссамнарның 1 нче Россия конкурсы үткәрелә. Д.ның әлеге тармагында Г.Синиченкова, А.Чубукова, Т.Рөстәмова, Т.Смирнова, И.Солдатенкова, Р.Камалова, Г.Андреева, Е.Борисова, Р.Исхаков һ.б. модельер-рәссамнар танылa. Өс киемнәренең үрнәкләрен сәнгать-конструкторлык бюроларында (тегү ф-калары каршында) һәм кулланучылар соравы буенча (Көнкүреш йорты, ателье) әзерлиләр. 1970 еллардан башлап тегүчелектә эре җитештерү тармагы оештырыла: республика Модельләр йорты (1990 елларда Модалы өс киемнәре йорты һәм «Лик» модалар театры б-н бергә «Илдан» фирмасына кушыла), «Трикотаж», «Мелита» берләшмәләре һ.б. (к. *Костюм*) барлыкка килә.

20 йөзнең соңгы унъеллыкларында Д. өлкәсендәге эшчәнлек киңәя һәм яңа эчтәлек б-н тулылана. Д.ның классик төрләреннән кала, архит-ра, гамәли һәм хәтта сынлы сәнгать өлкәсенә үтеп кергән арт-дизайн, график-дизайн кебек яңа төрләр барлыкка килә. Казан архит-ра-төзелеш ун-тында 1991 дә нигез салынган Д. ф-ты һәм архит-ра мохите Д.ы каф. архит-ра Д.ы өлкәсендә белем бирү һәм фәнни проектлар эшләү үзәгенә әверелә. Кафедра Россия югары уку йортлары арасында архит-ра мохите Д.ы өлкәсендә әйдәп

баручыларның берсенә әйләнә; биредә дәреслекләр, белешмәләр һәм С.М.Михайловның «Дизайн тарихы» дип аталган икетомлыгы дөнья күрә. Әлеге хезмәте өчен С.М.Михайлов Халыкара дизайнчылар берлеге дипломына һәм РФнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә (2003) лаек була. Кафедра нигезендә 1994 тә *Татарстан Республикасы Дизайнчылар берлеге* оештырыла (рәисе — С.М.Михайлов). Шул ук елда Чаллыда «Кама — дизайн» иҗат оешмасы төзелә. ТР Дизайнчылар берлеге канаты астында Казанда РФ Дизайнчылар берлегенең IV Ассамблеясе (съезды) һәм 1 нче бөтенроссия «Дизайн дөньясы» фестивале үткәрелә. 1996 да Казанның Баш архит-ра-планлаштыру идарәсе каршында Шәһәр Д.ы идарәсе (җитәкчесе Р.М.Нургалиева) оештырыла. Аның тарафыннан РФ Дизайнчылар берлегенең «Төс һәм яктылык» проекты семинары уздырыла (1996); ел саен (1997–2001) «Снежный барс» боз сыннар конкурсы үткәрелә; Казанның Бауман урамында җәяү йөрү өчен коллектив проект эшләнә h.б. ТР Рәссамнар берлегенең Сәнгать фондында 2001 дән рәсми рәвештә баш дизайнчы вазифасы булдырыла (А.Леухин, 2003 тә — И.Артамонов). 2004 тә биредә интерьерлар бизәү, ландшафтлы Д., кече архитектур формалар, ТР шәһәрләрен бәйрәмчә бизәү (рәссамнар И.Башмаков, Е.Голубцов, В.Выборнов, Н. һәм И.Артамоновлар h.б.) б-н шөгыльләнүче Д. һәм сәнгатьчә проектлау бүлеге (җитәкчесе А.Н.Лопаткин) оештырыла. Дизайнчылар Р.Гыймранов (җитәкче), В.Нестеренко, Р.Абаев, А.Лопаткин h.б.дан торган «ДД» иҗат төркеме Казандагы «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгенең (2003), Түбән Камадагы «Титан» (2004) комплексы h.б.ның сәнгатьчә бизәлешен башкаралар. ТРның Сәнгать фонды дизайнчылары ТР Милли музееның (В.Нестеренко, А.Леухин, Р.Абаев, А.Усманова), Казан ун-тындагы А.А.Штукенберг исем. Геология музееның (2002–04, Н. һәм И.Артамоновлар) яңа экспозиция проектларын эшлиләр, Казан шәһәрендәге объектларның h.б.ның бизәлеш проектларын тәкъдим итәләр. Дизайнчы-рәссамнарның соңгы эшләре 2003 тә уздырылган респ-ка Д. күргәзмәсендә тәкъдим ителә. Д.ның сәнгать юнәлеше өлкәсендә белем бирү Казан сәнгать уч-щесендә (2001 дән) алып барыла; 2003 тә Казан технол. ун-тында (Җиңел сәнәгать ин-тында) Д. һәм конструкцияләү ф-тына нигез салына. 1998 дән «Дизайн и новая архитектура» ж-лы чыга башлый. Казандагы С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы интерьерларының Д. проектлары өчен архитекторлар В.Логинов һәм Е.Прокофьев РФнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек булалар (1999).

*Әд.:* Галеев Б.М., Сайфуллин Р.Ф. Светомузыкальные устройства. М., 1978; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995; Михайлов С.М., Кулеева Л.М. Основы дизайна. М., 2002; Михайлов С.М. История дизайна: В 2 т. М., 2002–03; Воронов Н. Развитие термина «дизайн» и его практики // Декоративное искусство. 2003. № 3/4; Хамматова В.В. Проектирование педагогической системы профессионального обучения дизайнеров. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**«ДИЗА́ЙН И НО́ВАЯ АРХИТЕКТУ́РА»** («ДИНА» — «Дизайн һәм яңа архитектура»), архитектура журналы. 1998 елдан Казанда елга 4 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Д.И.Саттарова, А.В.Гаврилов, В.В.Безносов тарафыннан нигезләнә; 2002 дән оештыручысы — алар тарафыннан булдырылган «Архитектураны үстерү фонды». Нашире һәм мөхәррире — Д.И.Саттарова. Журналда архитекторлар, сәнгать белгечләре, тарихчылар, төбәкне өйрәнүчеләр, төзүчеләрнең мәкаләләре басыла. Журналның максаты — архит-ра үсеше, дизайн һәм төзелеш проблемаларын яктырту, Татарстанның бу өлкәләрдәге казанышларын пропагандалау. Материалларның күпчелеге Татарстанда архит-раның үзенчәлекле традицияләрен яңартуга, тарихи шәһәр мохитенең сәнгати образын саклауга, респ-када архит-ра һәм шәһәр төзелешенең заманча тенденцияләрен ачыклауга багышлана. Журналның Казан, Әлмәт, Лениногорск, Чаллы шәһәрләре төзелеше сәнгатенә, ш.у. ТР һәм РФдә ислам архит-расына багышланган саннары дөнья күрә. Казан архит-ра мәктәбе, Казан бистәләре, Раифа монастыре, Казан ун-ты архит-расы турында язмалар, классик мөселман сәнгатенең хәзерге Татарстан архит-расы формалашуга тәэсире турында материаллар сериясе, «ДИНА-АРТ» бүлегендә Татарстан һәм Казан сәнгате тарихының аз билгеле сәхифәләренә караган мәкаләләр басыла. Журнал ТР архитекторларының төзелеш проектлары б-н таныштыра, респ-каның архит-ра тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар, конференцияләр, семинар һәм симпозиумнар турында хәбәр итә. Мәгълүмати реклама материаллары төзелеш өлкәсендәге, күргәзмәләр оештыру эшчәнлегендәге, ш.у. Идел буе төбәгендә проект һәм төзелеш эшләре базары тәҗрибәләре б-н таныштыруга багышлана. 2003 тән редакция махсус «Татарстан Республикасының төзелеш каталогы» чыгара. Журнал ТРның яшь архитекторлары эшләренең смотр-конкурсларын үткәрә.

**ДИЗЕНТЕРИ́Я** (грекча dys — какшау, бозылуны белдерүче алкушымча, һәм énteron — эчәк), көчле яки хроник антропоноз эчәк инфекциясе. Төрле яшьтәге кешеләрне зарарлый. Эләгү юллары: йогышланган ашамлык, су, пычрак куллар. Инфекция чыганагы — авыру яки үзендә бактерияләр йөртүче кеше. Авыруның барышына карап көчле һәм хроник Д.не аерып йөртәләр. Д. китереп чыгаручы микроорганизмнар ашказаны-эчәк трактының буеннан-буена сеңдерелә торган токсиннар эшләп чыгара, алар, канга эләгеп, гомуми йогышлану-агулану синдромы, нейротоксикоз башлануга, организмнан су һәм тоз югалуга этәргеч булалар. Авыруның көчле формадан хроник формага күчүе дә ихтимал. Шигелла бактерияләре йөртүчәнлек күзәтелә.

Д. Гиппократ заманыннан ук (б.э.к. 5–4 йөзләр) «көчәнүле канлы эч китү» буларак билгеле. Әбүгалисинаның «Тыйб гыйльме кануны» дип аталган энциклопедик хезмәтендә әлеге авыруга хас билгеләр җентекләп, тасвирлап күрсәтелә. Д. кузгатучы микроорганизмны Россиядә беренче булып А.С.Раевский тасвирлап бирә (С.-Петербург, 1875). П.И.Кубасов авыру тудыручы микроорганизмны үлгән кешенең эчке әгъзаларыннан һәм тәрәтеннән аерып ала (Мәскәү, 1889). Д. китереп чыгаручы микроорганизмнар япон микробиологы К.Шиг хөрмәтенә шигеллалар дип йөртелә башлыйлар. Д. патогенезын һәм иммуногенезын өйрәнүдә Казан галимнәренең хезмәтләре әһәмиятле урын алып тора. А.Д.Адо Д. патогенезын тикшерә (1952); Д.К.Бәширова авыру кеше селәгәендә дизентерия антигеннарының булуын исбатлый (1953); А.Е.Резник Д.не бактериофаглар һәм сульфидин б-н дәвалау ысулларын уйлап таба (1947), Д. антигеннарының бәвел б-н бергә бүленеп чыгуларын исбат итә (1963); Н.С.Спасский — Д. китереп чыгаручы микроорганизмнарның Штуцер-Шмитц төрен (1958), А.А.Сорокин Д. вакытында күзәнәк иммунитетын тәфсилләп өйрәнә.

Д. кузгатучы микроорганизмнар тышкы тирәлектә: канализация суларында (25 тәүлектән 30 тәүлеккә кадәр), бүлмә температурасында ипидә (30 тәүлеккә кадәр), сөт ризыкларында (3 тәүлектән 10 тәүлеккә кадәр) яхшы саклана. Д.нең таралуын булдырмый калу дәвалау-профилактика, санитария-гигиена һәм эпидемияләргә каршы чаралар комплексы ярдәмендә гамәлгә ашырыла. 2004 елда ТРда бактериаль Д. б-н авыручылар саны күрсәткече 100 мең кешегә — 24,37, балалар арасында 91,9 булган; 2000 дә — инфекциянең артуы (94,77 һәм 240,75), 2003 тә авыручылар санының кимүе күзәтелгән, 2006 елда 11,0 булган.

*Әд.:* Спасский Н.Н. Экспериментальные материалы к вопросу о токсикозе при дизентерии, вызванной бактериями Штуцер-Шмитца. К., 1958; Баширова Д.К., Сорокин А.А. Клеточный иммунитет у больных различными формами острой бактериальной дизентерии. М., 1979; Лобзин Ю.В., Волжанин В.М., Захаренко С.М. Клиника, диагностика и лечение актуальных кишечных инфекций. СПб., 1999.

*А.А.Сорокин.*

**ДИКАРЁВ** Анатолий Васильевич (1888–1969), хәрби элемтәче һәм уйлап табучы. 1919–23 елларда Кызыл Армия *Радиотелеграф оешмаларының Казан базасы* лаб-ясе башлыгы. Радиотелеграф элемтәсе өчен гетеродин конструкциясен төзи (1919), электр сигналларының параметрларын зурайту өчен көчәйткеч лампа схемасын төзи һәм аның җайланмасын тәкъдим итә (1920), Казан урамнары һәм мәйданнарында радиотрансляция алып бару өчен Россиядә беренче тавышкөчәйткечләр (1921) җитештерү б-н җитәкчелек итә (к. *Дикарёв көчәйткече*).

**ДИКАРЁВ КӨЧӘЙТКЕЧЕ́**, ярдәмче энергия чыганагыннан (батарея) файдалану хисабына электр сигналларының энергетик параметрларын көчәйтү приборы. 1919 елда *Радиотелеграф оешмаларының Казан базасында* (РОКБ) А.В.*Дикарёв* системасындагы алты һәм тугыз лампалы көчәйткечләр эшләнә, сүнми торган тирбәнешләрне көчәйткече детекторлы алгычка кабул итү өчен ге-

теродин төзелә. Ул 1920 дә җитештерелә, 300 *м* дан 2200 *м* га кадәр диапазондагы радиодулкыннарны кабул итә. Шул ук елда андый алгычлар күпләп җитештерелә башлый. Д.к. радиодулкыннарны ерак арадан ышанычлы тоту мөмкинлегенә бирә; беренче радиопеленгатор станцияләре шуның нигезендә төзелә, Д.к. схемасындагы каршылыкларда югары ешлыклы алты көчәйтү каскады, трансформаторларда түбән ешлыклы өч көчәйтү каскады була. Көчсез сигналлар алынган вакытта беренче алты каскад югары ешлыкны көчәйтү режимында эшли, детектор соңгы каскадта бара. Көчле сигналлар алынган вакытта детекторлау беренче каскадта бара, аннары сигналлар түбән ешлык буенча көчәя. Көчәйткечнең югары ешлык буенча кайтма бәйләнешен көйли һәм сизгерлекне шактый арттыра торган көйләгече була. Д.к.нең өстенлеге чиста тавыш б-н эшләүдә, моңа РОКБда җитештерелә торган көчәйткечләрдә яхшы сыйфатлы каршылыклар куелу нәтиҗәсендә ирешелә. Соңрак Дикарёв унике лампалы *Углов көчәйткеченең* чыгу өлешенә телефон тоташтырырга һәм телефонның саклагыч капкачындагы тишемгә тар башы б-н тыгыла торган рупор әзерләргә тәкъдим итә. Шундый җайланма б-н 500 *м* арадагы рупордан яки тавыш көчәйткечтән сүз әйбәт ишетелә. 1921 елдан шундый тавыш көчәйткеч ярдәмендә РОКБда соңгы хәбәрләр һәм музыка тапшырыла. 1921 дә 1 Май бәйрәмендә Казандагы Театр мәйданына (хәзер Ирек мәйданы) һәм Кызыл Армия бакчасына (хәзер Ленин бакчасы) шундый рупорлар урнаштырыла. В.И.Ленин Россия телеграф агентлыгының («Известия ВЦИК», 1921, 7 май) белдерүен укыганнан соң, РСФСР ХКСының эш башкаручысы Н.П.Горбуновка: «Мин бүген газетадан Казанда телефонны көчәйтүче һәм халыкка сөйләүче рупорның сынап каралуы (һәм нәтиҗәсе дә бик шәп) турында белдерү укыдым»,– дип язган һәм шундый җайланмаларны «...Мәскәүдә һәм Питерда куярга...», – дип тә өстәгән. РОКБда җитештерелгән тавыш көчәйткечләр 1921 елның 22 июнендә Мәскәүдәге алты мәйданда урнаштырыла, шулай итеп Россиядә беренче радиотрансляция челтәренә нигез салына. 1922 елның язында шундый җайланмалар радиотапшырулар алып бару өчен дә киң файдаланыла. Ш.у.к. *Тавыш көчәйткеч.*

*Әд.:* Бурлянд А.В., Володарская В.Е., Яроцкий А.В., Советская радиотехника и электросвязь в датах. М., 1975; Орлова А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Первые опыты радиовещания в Татарстане // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998.

*Е.А.Стахов.*

**ДИКГО́Ф** Юрий Александрович (3.9.1911, С.-Петербург — 29.8.1979, Казан), геофизик. Ленинград тау ин-тын тәмамлый (1938). 1931–33, 1938–50 елларда Урта Урал, Белоруссия ССР, Көнбатыш Себер, Төньяк Казакъстан, Төрекмәнстан ССР терр-яләрендә геофизика партияләре җитәкчесе. 1950–53 тә СССР Нефть сәнәгате министрлыгында геофизик разведка бүлегендә. 1953 тән Казан ун-тында, разведкалауның геофизик ысуллары кафедрасын оештыручыларның берсе. Яңа геотектоник гипотеза тәкъдим итә, промысел һәм гамәли (электр разведкасы, сейсмик разведка) геофизикада тикшерү алымнарын өйрәнә һәм камилләштерә. 1944 тә Евро-Азия геофизика җәмгыяте (Мәскәү) тарафыннан Д. исемендәге стипендия булдырыла, ул ел саен Казан ун-тының иң сәләтле студент-геофизигына бирелә.

Хезм.: К вопросу об использовании электрокаротажных зондов большого размера для определения электрических параметров разрезов скважин // Аппаратура, методика и интерпретация геофизических наблюдений. К., 1968 (автордаш); Физико-математические основы гидродинамического способа выявления коллекторов в процессе бурения скважин // Методика и интерпретация геофизических наблюдений. К., 1974( автордаш).

**«ДИ́КОЕ ПО́ЛЕ»** («Кыргый дала»), Днепр елгасы белән Уканың югары агымы, Дон һәм Иделнең түбән, Җаекның югары агымы аралыгындагы далаларның, ягъни а.х. әйләнешенә кертелмәгән җирләрнең рус елъязмаларындагы тарихи атамасы. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш өлеше Казан ханлыгы җирләре белән чиктәш була. Күчмә кабиләләр еш бәреп керү сәбәпле, рус хөкүмәте 16 йөзнең икенче яртысы — 17 йөздә әлеге җирләрнең чикләрендә кирмәннәр һәм саклану корылмалары төзи. «Д.п.» җирләре йомышлы русларга, татарларга, ш.у. чит ил кешеләренә бирелә, аларны стихияле төстә качаклар үзләштерә. Моннан тыш, хөкүмәт сарай крәстияннәрен дә дала районнарына күчереп утырта.

*Д.Г.Мостафина.*

**ДИ́КОЕ ПО́ЛЕ** (Киек) авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 11 *км* төньяктарак, Атмас елгасы бассейнында. 2008 елда — 35 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.П.да чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1456,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 253 ир-ат; 1859 да — 567, 1897 дә — 668, 1908 дә — 788, 1920 дә — 744, 1926 да — 728, 1938 дә — 522, 1949 да — 310, 1958 дә — 294, 1970 тә — 256, 1979 да — 175, 1989 да — 49, 2002 дә — 47 кеше.

**ДИЛО́ГИЯ** (грек. di — ике тапкыр һәм logos — сүз, тәгълимат), эчтәлек, сюжет, геройлар уртаклыгы б-н бәйләнгән мөстәкыйль ике кисәктән торган әсәр. Д. үрнәкләре антик чордан ук билгеле. Татар әдәбиятында революциягә кадәр татар халкы тормышы панорамасын тасвирлаган беренче Д. булып М.Галәүнең «Болганчык еллар» (1930) һәм «Мөһаҗирләр» (1934) романнары санала. 1950 елларда М.Әмирнең Бөек Ватан сугышы елларында тыл хезмәтчәннәре тормышын чагылдырган «Ялантау кешеләре» (1 кисәк, 1954) һәм «Саф күңел» (2 кисәк, 1960) Д.се киң таныла. Соңрак автор аларны, бер китапка берләштереп, «Саф күңел» (1976) исеме б-н чыгара. ТРда нефть чыгару тармагы аякка басу Г.Ахунов Д.сендә чагылыш таба. Аңа «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) романнары керә. Җәмгыятьтә татар халкының тарихына кызыксыну артуга җавап рәвешендә Н.Фәттах Д.се — ике китаптан торган «Сызгыра торган уклар» (1977–85) романы языла. Татар драматургиясендә Д. мисаллары — М.Гыйләҗевнең «Казан егетләре» (1990) һәм «Тагын Казан егетләре» (1994), З.Хәкимнең «Килә ява, килә ява ...» (1998) һәм «Ява карлар, ява карлар...» (2003) пьесалары.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ДИМ** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 85,7 *км*, ТР чикләрендә 56 *км*. Бассейнының мәйданы 1151 *км*$^2$. Оренбург өлкәсенең Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан башлана, Бөгелмә һәм Баулы р-ннары терр-ясеннән ага, Ютазы р-ны Екатериновка посёлогыннан 3,5 *км* көнчыгыштарак Ык елгасына коя. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 98 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Д. үзәне үрге агымында каньонсыман, тирән һәм тар, тамагына таба кискен асимметрик, рельефында урыны-урыны б-н катламнар чыгыла. Д. тугаеның киңлеге үрге агымнарында 50 *м* дан алып тамагына таба 1,5–2 *км* га кадәр. Елга юлы бормалы, тармакланмаган. Д.нең 0,8 дән алып 27,6 *км* га кадәр озынлыктагы 30 кушылдыгы бар, иң зурлары: Сулы (27,6 *км*), Кырым Сарай (18,1 *км*), Акбаш (17 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км*/*км*$^2$.

Елганың туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 дән 10 *л*/*с*·*км*$^2$ га кадәр (кушылдыкларда). Елга режимын күзәтү Татар Димескәе авылы янындагы гидрологик постта алып барыла (1948 елдан). Су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 2,5 *м* (макс. 2,9 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 152 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана, 25–30 көн дәвам итә. Макс. су чыгымы 152 *м*$^3$/*с* (1982). Боз китү ташуның иң көчле вакытына туры килә һәм 3 көнгә якын дәвам итә. Чиләә торыклы, кайвакыт җәйгесе 7 көнләп дәвам итүче яңгыр ташкыннары б-н бозыла. Ташу агымы катламы 70–80 *мм* тәшкил итә. Елга,



Дим елгасы урта агымында.

гадәттә, ноябрьнең беренче декадасында туңа. Кыш азагына бозның калынлыгы 90–95 *см* га җитә. Бозның макс. калынлыгы 185 *см* (1969). Боз катуның уртача дәвамлылыгы 140–145 көн. Суның уртача еллык чыгымы 2,51 $м^3/с$. Д. елгасы китерелмәләренең уртача күпьеллык агымы 35 мең *т*. Суның уртача болганчыклыгы 430 $г/м^3$ (макс. 2400 $г/м^3$ га кадәр). Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе 400–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артыграк.

Д. елгасы бассейнында гомуми күләме 1,87 млн. $м^3$ булган 5 буа бар. Д. ТРның табигать истәлеге (1978). Д. бассейнында *Спас чишмәләре, Петровка наратлары, Татар Димескәе аланы, Урдалы Тау* табигать истәлекләре урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**ДИМЕФОСФО́Н**, метаболизм (матдәләр алмашы) процессларын көйләүче дәвалау препараты. РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында табылып (Б.А.*Арбузов*, А.О.Визель, А.А.*Муслинкин* һ.б.), Казан мед. ун-ты фармакологлары (И.В.*Заиконникова*, И.А.*Студенцова*, Р.С.*Гәрәев* һ.б.) тарафыннан өйрәнелгән. Д. — 1,1-диметил-3-оксобутилфосфон кислотасының диметил эфиры, төссез сыеклык: су, спирт һ.б. органик эреткечләр б-н җиңел кушыла. Д. — нәантихолинэстераз фосфорорганик кушылмалар рәтеннән максатчан эзләп табып алынган беренче дәвалау препараты. Ул төрле этиологияле ацидозлар вакытында организм көйләнешендәге бөер һәм үпкә механизмнарын көчәйтү, тукымалар метаболизмын һәм кан йөрешен көчәйтү хисабына кислота-нигез халәтен нормальләштерә; баш миенең кан әйләнеше көйләнешен яхшырта; вазомотор цефалгияне туктатып, йөрәк эшчәнлеген һәм сулышны активлаштырып, ми метаболизмын җайга сала; күзәнәк мембранасын тотрыклыландыра, ялкынсынуларны дәвалау, иммуномодуляция, антигипоксант, антимутаген һәм радиопротектор тәэсире бар. Билгеле бер урынга сөрткәндә препарат, антисептик тәэсир ясап, тире һәм лайлалы катламнарның саклагыч функцияләрен көчәйтә.

Д.ны системалы рәвештә куллану баш миендә кан әйләнеше бозылганда (ш.и. атеросклероз, гипертония авыруы, вазомотор дистония, дисциркулятор энцефалопатия вакытында), баш сөяге имгәнеп, мигә зыян килгән очракта, Меньер синдромы һәм авыруы күзәтелгәндә; пневмонияләрне, үпкәдәге специфик булмаган хроник авыруларны, авыр уза торган көчле вируслы респиратор инфекцияләрне комплекслы дәвалаганда антиацидотик чара буларак; шикәр диабеты вакытында, операциядән соңгы чорда; балаларда була торган поллиноз һәм бронхиаль астманың атопик формасын дәвалаганда тәкъдим ителә. Препарат тире һәм мускуллардагы инфекция кергән җәрәхәтләрне дәвалаганда, Илизаров аппаратының энәләре чыгып торган урыннар үлекләп ялкынсынган очракларда; гайморит, тире кызару авырулары булганда, тире чабырганда, тәнгә алсу төстәге бетчәләр чыкканда; майлы себорея, ш.у. яман шешләрне нурлар б-н дәвалаган вакытта килеп чыга торган мукозит авыруын булдырмый калу өчен тәнгә сөртелә.

1983 елдан Казан «Татхимфармпрепаратлар» җитештерү химия-фарм. берләшмәсе тарафыннан 100 *мл* лы флаконнарда 15% лы эремә рәвешендә (эчү һәм тәнгә сөртү өчен) һәм Казан бактерияле препаратлар җитештерү пр-тиесе тарафыннан 1 *г* лы ампулаларда актив матдә (инъекция һәм инфузия эремәләре ясау өчен) рәвешендә серияләп эшләп чыгарыла. Бөекбритания, Германия, Швейцария һәм Япониядә патентлар алган.

*Әд.:* Малиновский М.Д. Лекарственные средства. Хар., 1997. Т. 2; Лекарственные препараты в России: Справ. М., 1999.

*Р.С.Гәрәев.*

**ДИМИ́ ТАРЛА́У** (Дөмәй Тарлавы) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2008 елда 150 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында 1705–11 елгы крәстиян баш күтәрүләре җитәкчесе Дөмәй Ишкәев нигез сала. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Д.Т.да мәчет, мәктәп (1913 тә анда 80 шәкерт укый) эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2347,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 660, 1884 тә — 804, 1897 дә — 961, 1920 дә — 1253, 1926 да — 737, 1938 дә — 632, 1949 да — 494, 1958 дә — 430, 1970 тә — 320, 1979 да — 248, 1989 да — 159, 2002 дә — 144 кеше.

**ДИМИ́ТРИЕВ** Василий Дмитриевич (11.1.1924, Чуаш автономияле өлкәсенең Цивиль өязе Түбән Сорбай а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1968), Чуаш Респ-касының Фән һәм сәнгать милли академиясе академигы (1994), Чуаш АССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1974, 1980). Бөек Ватан сугышында катнаша. Чуаш пед. ин-тын тәмамлагач (1948), Чуашстанның Тел, әдәбият, тарих һәм икътисад фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1968–88 елларда директор. Бер үк вакытта 1967 дән Чуаш ун-тында: 1970 тән проф., 1988 дән Ватан тарихы каф. мөдире. СССР ФАнең Археография комиссиясе әгъзасы (1968 дән). Хезмәтләре чуаш халкының этногенезына, Урта Идел буйларының иң борынгы чорлардан башланган тарихына, Идел буе Болгарына, болгар җирләренең Алтын Урда дәверенә, патша хөкүмәтенең Урта Идел төбәгендә алып барган милли-колониаль сәясәте мәсьәләләренә карый. Илнең тарих фәнендә беренче мәртәбә Урта Идел буйларына ясак салыну барышын өйрәнә. Д. татар халкы Алтын Урда чорында төрки-татарлар һәм 11 йөздә Көнчыгыш Европаның көньяк далаларына үтеп кергән көнбатыш кыпчаклар б-н бергә кушылу нәтиҗәсендә формалашкан дигән караштa тора. 1975–91 дә Чуаш АССРның ЮС депутаты. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О ясачном обложении в Среднем Поволжье // Вопр. истории. 1956. № 12; История Чувашии XVIII века. Чебоксары, 1959; Земельный документ времён казанского хана Сафа-Гирея // Исторический сборник. Чебоксары, 1966; Царские наказы казанским воеводам XVII в. // История и культура Чувашской АССР. Чебоксары, 1974; О социально-экономическом строе и управлении в Казанской земле // Россия на путях централизации. М., 1982; Чуваши в эпоху феодализма. Чебоксары, 1986; Мирное присоединение Чувашии к Российскому государству. Чебоксары, 2001.

*Әд.:* Фроянов И.Я., Смирнов Ю.П. Историк, исследователь, учёный В.Д.Димитриев. Чебоксары, 1994.

**ДИМИ́ТРИЙ** (Самбикин Дмитрий Иванович) (3.10.1839, Воронеж губ., Бирик өязе Караяшник а. — 17.03.1908, Казан), дин эшлеклесе һәм белгече, тарихчы, чиркәү тарихы д-ры (1904). Петербург руханилар академиясен тәмамлый (1865). 1866 елдан Воронеж руханилар семинариясе укытучысы, 1881 дән — ректоры (бүленеп, 1872–81 дә Тамбов руханилар семинариясе ректоры). 1887 нең гыйнварыннан Балтика епископы, Түбән Новгород епархиясе викарие, 1887 нең августыннан Подольск епархиясе викарие, 1891 дән Подольск һәм Браслав епископы, 1896 дан Тверь һәм Кашино архиепископы, 1905 тән Казан һәм Зөя архиепископы. Чуалышлар руханиларны һәм дини уку йортларын читләтеп узмаган. 1905–07 нче революция елларында Казан епархиясе белән идарә итә. Студентлар хәрәкәтенә кушылган укучыларны дини уку йортларыннан куулы, рәхимсез җәзалауларны кабул итмәве, барлык мәсьәләләрнең тыныч юл б-н хәл ителүен яклаучы буларак танылa. Дин тоту ирегe кертелүен хуплый. Вәгазьчелек осталыгына, керсез абруйга ия булганга күрә, руханилар һәм дини халык арасында зур хөрмәт казана. Д.ның төп хезмәтләре агиография өлкәсенә — җирле чиркәү һәм гражданнар тарихына карый. Аның башлангычы б-н Казан чиркәү-археология җәмгыяте төзелә.

Хезм.: Месяцеслов русских святых: В 4 т. К., 1893–1903; Собор святых семидесяти апостолов; В 3 т. Тверь, 1900–02. Т. 1–2; К., 1907. Т. 3.

*Әд.:* Высокопреосвященнейший Димитрий, архиепископ Казанский и Свияжский (1839–1908). К., 1908.

**ДИМТАМА́К** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Дим елгасы буенда. 2008 елда 529 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1765 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, читкә китеп эшләү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Д.та мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2378 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александров волостена керә.

1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 230 ир-ат; 1859 да — 765: 1886 да — 866, 1897 дә — 1033, 1920 дә — 1387, 1926 да — 1190, 1938 дә — 742, 1949 да — 707, 1958 дә — 761, 1970 тә — 784, 1979 да — 651, 1989 да — 540, 2002 дә — 549 кеше.

**ДИН** (гарәп. دين — гореф-гадәт, күрсәтмә, хакимият, буйсыну), инану, дини бурычлар җыелмасы. Д.нең төп мәгънәсе *Коръәндә* Аллаһның илаһи көч булуын тану һәм аңа буйсыну; ш.у. «хөкем», «әҗер», «шәхсән инану», «йолалар үткәрү тәртибе» мәгънәләренә ия. «Д.» атамасы исламга һәм башка диннәргә нисбәтле рәвештә дә, мәҗүсилеккә карата да кулланыла. Еш кына өч состав өлешнең җыелмасы буларак аңлашыла, аларны аңлауның үзенчәлеге ислам мәзһәбләренең позициясенә бәйле. Д.нең *әл-Бохари* тарафыннан бирелгән билгеләмәсе киң таралган. Әл-Бохари фикеренчә, Д. — инану (иман), дини бурычларны үтәү (ислам), инануның ихласлыгын камилләштерү (ихсан). Бу бердәм-аерылгысыз өчлеккә аңлатма биргәндә *хәнәфи*ләр аеруча инануның мәгънәсен ассызыклыйлар, әшәриләр — дини кануннарның төгәл үтәлүен өстен күрәләр, хәнбәлиләрнең исә Коръән һәм Сөннәгә карата *тәкълид*чә мөнәсәбәте игътибар үзәгендә тора. Суфилар (к. *Суфичылык*) Д.не өч үсеш дәрәҗәсендә карый, алар: әш-шәрига (иман) — Коръән һәм Сөннәгә төгәл иярү, әт-тарика (ислам) — аскетизм, әл-хакика (ихсан) — Аллаһ турында тулы гыйлемгә ирешү. Киң мәгънәдә Д. — рухи дөньяның матди дөньяга капма-каршы куелуы ул, әмма әлеге төшенчәләрнең бер-берсе б-н бәйләнеше һәм тәэсир итү өлкәсе турындагы мәсьәлә бәхәсле. Мөселман дини әдәбиятында ялгызлык исемнәрендә (мәс. Җәләлетдин, Динмөхәммәт) Д. «ислам» терминының синонимы буларак еш кулланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**«әд-ДИН ВӘ әл-ӘДӘ́Б»** («الدين والادب» — «Дин һәм тәрбия»), дини һәм әдәби журнал. 1906 елның 17 мартыннан 1917 гә кадәр (бүленеп, 1908–13 тә чыкмый) Казанда татар телендә атнага 3 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 122 саны чыга. Мөхәррир-нашире — Г.*Баруди*. Руханилар вәкилләре хезмәттәшлек итә. Журнал битләрендә дини-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең аерым аять һәм хәдисләренә аңлатмалар бирелә, ш.у. мәгариф, әхлак, милли мәдәният мәсьәләләренә багышланган материаллар басыла.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом): 1905–1925. К., 1926; Галимҗан Баруди һәм «әд-Дин вә әл-әдәб» журналы. К., 2001; З а һ и д у л л и н Ә.Ж. «әд-Дин вә әл-әдәб» журналының библиографик күрсәткече. К., 2003; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘ́Т»** («دين و معيشت» — «Дин һәм тормыш»), атналык сәяси, дини һәм әдәби журнал. 1906 елның 31 декабреннән 1918 нең февраленә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 555 саны басыла. 1910–11 дә «Дөнья вә мәгыйшәт» исемендә чыга. Наширләре — Ш.Шәфигуллин, М.Дәүләтшин, аннары В.*Хөсәенов*; мөхәррирләре — В.Хөсәенов, З.Хәйруллин, Ф.Даутов, Г.Ханисламов. Г.Әхмәров, Г.Мансур, Ф.Саймани, Г.Ургани һ.б.ның мәкаләләре басыла. Күпчелек мәкаләләр имзасыз яки псевдоним б-н чыга. Журнал милләтнең әхлакый йөзе, әхлаксызлык куркынычы мәсьәләләрен күтәрә, *җәдитчелек* тарафдарларына каршы була. Радикаль карашлы интеллигенция тарафыннан нык тәнкыйтьләнә.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г а й н у л л и н М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘ́Т» БАСМАХАНӘСЕ́**, 1906 елның 5 декабрендә Оренбург шәһәрендә, «Дин вә мәгыйшәт» ж-лын бастыру максаты б-н, мулла һәм сәүдәгәр В.Г.*Хөсәенов* ача. Дини эчтәлекле китапларны (40 тан артык басма) ул үз хисабына нәшер итә. Сәүдә (коммерция) пр-тиесе буларак, басмаханә заказлар буенча төрле дәреслекләр, ш.и. Исхак Казаковның «Гимназия» исемендәге рус теле дәресләре сериясен бастырып чыгара. Татар язучыларының матур әдәбият әсәрләре, татар халык җырлары һәм казакъ шагыйрьләренең шигъри җыентыклары, хәйрия ширкәтләренең хисаплары, рус теленнән тәрҗемәдә фәнни-популяр басмалар нәшер ителә. Г.Зарифның Оренбург мөселман кадимчеләрен фаш итүче «Дәһшәтле серләр» трагедиясе бастырыла. 1907–17 еллар эчендә 175750 данә тираж б-н 104 исемдә китап дөнья күрә.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**ДИНА́МИК ГОЛОГРА́ФИЯ**, объектларның интерференцион картина (голограмма) мохитендә барлыкка килгән күләмле сурәтләрен язып алуның оптик ысулы, аның сыйфатламалары объектның координаталарына, ш.у. язылу вакытына да бәйле. Голограмма структурасы язылу вакытында үзгәрми торган һәм язып бару кыры б-н бәйле булган традицион голограммадан аермалы буларак, Д.г.дә голограмма структурасы, язылу вакытындагы бәйләмнәрнең үзгәрүенә яраклашып, вакытка бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин, шунлыктан голограммада дифракцияләнгән нурланыш та вакытка карап үзгәрә. Д.г. голография һәм нәсызыкча оптика синтезыннан гыйбарәт, шул ук вакытта, голография закончалыклары — дулкын фронтларын реаль вакыт эчендә әверелдерү максатында, нәсызыкча оптика закончалыклары механизмнарының эшләвен тәэмин итү өчен файдаланыла, шулар ярдәмендә әверелдерү гамәлгә ашырыла. Шундый голограммаларны резонанс мохитендә язу һәм уку уңайлырак, шунлыктан Д.г. буенча беренче тәҗрибә рубинда (АКШ галиме Х.Герритсен, 1967) уздырыла. Аннары нәрезонанс мохитләрдә яктылык дулкыннары кырындагы туенган йотылу б-н бәйле нәсызыкча тәҗрибәләр уздыру дәвам иттерелә. ГИПОда (Казан) Д.г. резонансы КС-19 пыялада һәм аморф селенда бу тирәлекләрне рубин лазеры нурланышы б-н тәэсирләндереп уздырылган тәҗрибәдә (Е.И.Штырков, 1970) ачыклана. Соңрак СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында фазалы хәтерле резонанс хәлендәге мохиттә язу сигналларының тәэсир итү һәм голограммаларны уку моментларының тирәлек релаксациясе вакытыннан да кимрәк вакытта интервалларга чәчелү мөмкинлеге исбат ителә. Андый Д.г. кайтаваз-голография дип атала (В.В.Самарцев, Е.И.Штырков, 1975). Мәгълүм кристалларда (мәс., өч валентлы европий б-н иттрий окисе) сыек гелий темп-расында язылган кайтаваз-голограммаларны 10 сәгать узганнан соң да укырга мөмкин. Д.г. лазер сигналларының дулкын фронтын коррекцияләү (төзәтмә кертү), оптик сурәтләрне эшкәртү һәм көчәйтү, мохитне һәм анда бик тиз уза торган процессларны өйрәнү, динамик голографик элементлар — дефлекторлар төзү, нурланышны объектка фокуслау җайланмалары эшләү өчен кулланыла. Казан галимнәренең Д.г. өлкәсендәге тикшеренүләре С.-Петербург физ.-техника һәм Дәүләт оптика ин-тлары, Белоруссия Респ-касы (Минск) һәм Украина Респ-касы (Киев) ФАнең физика ин-тлары б-н хезмәттәшлектә уздырыла.

*Әд.:* Ш т ы р к о в Е.И. Рассеяние света на периодической структуре из возбуждённых и невозбуждённых атомов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1970. Т. 12; Ш т ы р к о в Е.И., С а м а р ц е в В.В. Резонансная динамическая голография и оптическое сверхизлучение // Электромагнитное сверхизлучение. К., 1975; Д е н и с ю к Ю.Н. Голография и её перспективы // Журн. прикладной спектроскопии. 1980. Т. 33; Н е ф е д ь е в Л.Н., С а м а р ц е в В.В. Оптическая эхо-голография // Журн. прикладной спектроскопии. 1992. Т. 57; G e r r i t s e n H. Nonlinear Effects in Image Formation // Appl. Phys. Lett. 1967. V.10.

*В.В.Самарцев.*

**«ДИНА́МО»**, ТР хокук саклау хезмәткәрләренең физкультура-спорт җәмгыяте. 1926 елда оештырыла (беренче рәисе — И.А.Кадушин). 1926–31 дә «Д.» Казан пролетар-спорт җәмгыяте, 1931–38 дә «Д.» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы, 1938–99 да «Д.» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан республика советы, 1999 дан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең иҗтимагый-дәүләт оешмасы барлыкка килә. Әлмәт, Алабуга, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә бүлекләре бар. Җәмгыять 19 коллективны үз эченә ала. Казанда спорт базасы (ату тиры, «Аккош» күле буенда чаңгы базасы), Лаеш һәм Саба р-ннарында ау хуҗалыклары урнашкан. «Д.» физкультура-спорт җәмгыятендә — көрәш (ирекле, грек-рим көрәше, самбо, дзюдо), волейбол (ирләр командасы, 2003 тән Россия беренчелеге суперлигасында), гер спорты, ишү (академик, байдарка һәм каноэда), кикбоксинг, җиңел атлетика, чаңгы спорты, гамәли янгын сүндерү спорты, кул сугышы, ату спорты, авыр атлетика, фехтование, футбол (ирләр командасы, 1920–30 елларда иң яхшы командаларның берсе), чирәмдәге хоккей (ирләр командасы — Россия чемпионы,

2003–2008), туплы хоккей (ирләр командасы — Европа чемпионнары кубогы иясе, 2009) үсеш ала.

Атаклы спортчылар: Л.А.*Аверьянова*, А.А.*Бородин*, В.Н.*Валюкевич*, О.Б.*Вощакина*, Н.Ф.*Гыйләҗева*, О.В.*Данилова*, О.Н.*Князева*, Н.А.*Колесников*, Г.Т.*Московский*, В.Г.*Никонова*, А.В.*Плюшкин*, Г.И.*Сәмитова*, Н.Ш.*Фәсахов*; тренерлар: Р.А.*Азизов*, И.Б.Брен (фехтование, волейбол), В.Т.*Глухих*, В.А.*Гоголин*, С.К.*Дёмин*, В.В.*Шиблов*, А.А.Маргарян, Н.П.Митянин, Н.И.*Морящичев*, Н.В.Репин, Н.Н.Савощенко, Р.С.*Сафин*, В.В.Сидельников (волейбол), Н.С.*Тетёркин*, Е.А.*Тимерҗанов*, С.М.*Ульянов*, Ф.М.*Хәсәнов*, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*.

**ДИНА́Р** (лат. denarius), урта гасырлардагы (7–15 йөзләр) мөселман дәүләтләрендә алтын тәңкә; хәзерге кайбер гарәп һәм Европа илләрендәге (Гыйрак, Күвәйт, Ливия, Алжир һ.б.) акча берәмлеге. Беренче Д.лар Византиянең акча-үлчәү нормалары нигезендә Багдадта, Өммияләр нәселеннән булган хәлифә Габделмаликнең акча реформасыннан соң сугыла башлый (695 тирәсе). Византия солиды кебек үк, Д. 4,25 *г* авырлыкта булган һәм 10 көмеш *дирһәмгә* тиңләшкән. Гарәп хәлифәлеге таркалу һәм яңа гарәп дәүләтләре барлыкка килү процессында (10–13 йөзләр) Д.га тиңләшкән дирһәмнәрнең саны авырлыкларына бәйле рәвештә үзгәрә. Баштарак тәңкәләрдә дин символы (икамә) б-н Аллаһ һәм



Алтын Урда чоры динары.

Мөхәммәд пәйгамбәр исемнәре, хәлифә исеме, акчаның сугылу вакыты һәм урыны күрсәтелсә, соңрак өлкә хакимнәренең исеме дә өстәлә. 12 йөзгә кадәр тәңкәләргә куфи язуы төшерелә. 13–14 йөзләрдә Д.лар, башлыча, көмештән сугыла һәм 6 дирһәмгә тиңләшә. Алтын Д.лар Төньяк Һиндстанның кайбер төрки солтанлыкларында гына сугыла. Эре көмеш һәм алтын ятмалары булмаган Көнчыгыш Европага урта гасырларда Д.лар сирәк үтеп керәләр, алар күбрәк бизәнү әйберләре (тагылмалар, бөтиләр һ.б.), зәркәнчелектә чимал яки байлык туплау чарасы буларак файдаланыла. Мәс., Алтын Урдага алтын Д.лар (12,77 *г* чамасы авырлыктагы тәңкәләр), башлыча, Дәһли солтанлыгыннан керәләр. Алтын Д. *алтын* буларак мәгълүм, ул 6 ярмакка (9 *г* чамасы) яки сумның (190 *г* тирәсе) егермедән бер өлешенә тиңләшкән.

*Әд.:* Лихачёв А.Ф. Золотой клад из динаров патанских султанов Индии // Записки Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. 1887. Т. 1.; Фёдоров-Давыдов Г.А. К вопросу о денежном курсе золота в Иране и Средней Азии в XIV в. // Краткие сообщения Ин-та истории материальной культуры АН СССР. 1956. № 66; шул ук. Монеты — свидетели прошлого. М., 1985; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; шул ук. Древние монеты Поволжья. К., 1990.

*И.Л.Измайлов.*

**ДИНӘХМӘ́Д БӘК** (Тинәхмәд) (? — 1578), Олы Нугай Урдасы идарәчесе (1563 елдан). *Исмәгыйль бәк*нең улы. Рус дәүләте б-н тыныч мөнәсәбәтләр саклау, Урданы аның б-н сугышка тартмау тарафдары. Үзәк хакимиятне ныгытырга һәм Урданың йогынтысын күрше татар дәүләтләренә таратырга омтыла. Кырым ханнары һәм Төркия солтаннарының Рус дәүләтенә (1564, 1565, 1568) һәм Әстерханга (1569) яулары вакытында сабыр итеп торуны өстен күрә, шул ук вакытта морзаларының әлеге яуларда катнашуына каршы килми. Баш күтәргән Казан татарларына гаскәрләре һәм корал б-н ярдәм итә.

*Әд.:* Новосельский А.А. Борьба Московского государства с татарами в первой половине XVII в. М.–Л., 1948.

*И.Л.Измайлов.*

**ДИНЕ́ЕВ** Фатих Юныс улы (11.8.1923, хәзерге Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Моисеевка а. — 16.3.1971, Украина ССРның Одесса ш.), Дан орденының тулы кавалеры (23.12.1943, 27.7.1944, 24.3.1945), кече лейтенант (1945). Чарджоу шәһәре (Төрекмәнстан ССР) басмаханәсендә матбагачы булып эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 396 нчы аерым разведка ротасы отделениесе командиры (6 нчы һәм 37 нче армияләрнең 333 нче укчылар дивизиясе). Воронеж, Көньяк-Көнбатыш һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Донбасс һөҗүм операциясендә (1943), Украинаны азат итү сугышларында, Яссы-Кишинёв һөҗүм операциясендә (1944), Болгарияне азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 20 декабрендә Новофёдоровка һәм Новосергиевка авыллары (Украина ССРның Запорожье шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак) янындагы сугышларда, сугышчылар төркеме башында дошман оборонасы үзәгенә үтеп, пулемёт ноктасын юк итә; 1944 нең 11 июлендә Фантына-Маскуй торак пункты (Тирасполь шәһәреннән 15 *км* көньяктарак) янындагы сугышта; 1944 нең 28 июлендә шунда батырлык күрсәтә: разведчиклар төркеме башында дошман тылында 2 пулемёт ноктасын юк итә, яралы хәлендә сугыш б-н җитәкчелек итә. 1946 дан Эчке эшләр министрлыгының Одесса шәһәр идарәсендә инспектор булып эшли. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Дубров Б.И. Солдатская слава. Киев, 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*



Ф.Ю.Динеев.

**ДИНИКЕ́ЕВ** Әсгат Әхмәтвафа улы (15.7.1942, БАССРның Бүздәк р-ны Түреш а.), нәкышьче, график, сынчы. 1969 елда Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң, Целиноградта (хәзерге Астана ш., Казакъстан) яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1997). Казакъстанның әйдәп баручы нәкышьчеләренең берсе, милли тема һәм әсәрләренең салмак теле б-н ачылган якты иҗади талант иясе. Д. иҗатына халык йолалары, татар гамәли сәнгате һәм бөтен төрки мәдәниятендәге эстетик принципларның үзенчәлекләре уңай йогынты ясый. Левкас җирлегендә майлы



Ә.Ә.Диникеев. «Атлар». 1996.

һәм темпера техникасы б-н эшли, иҗатының әүвәлге чорында әлеге алым б-н чирәм җирләрне үзләштерү темасына багышланган кечкенә күләмле картиналар иҗат итә («Беренче поезд», «Тәүге буразна», «Беренче шытымнар», барысы да — 1978; «Тәүге икмәк», 1981 һ.б.). Жанрлы әсәрләре татар һәм казакъ халыкларының көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, рухи традицияләренә багышланган темаларны ача («Атлар», 1996; «Кайту», «Әйлән-бәйлән», икесе дә — 1997; «Бәйге», 1999;





Ә.Ә.Диникеев. 1. «Кыз урлау». 2001; 2. «Сабан туе». 2002.

«Хуш килдегез», «Кыз куу», «Остаз», барысы да — 2000; «Айлы төн», «Гашыйк атлар», икесе дә — 2001; «Дала моңы», «Чәй янында», «Сабан туе», барысы да — 2002 һ.б.). Ишем буендагы дала киңлекләре һәм Наратлы күл ландшафтлары, кечкенә күләмле натюрмортлар; «Татар милли уеннары» станлы серияләр («Капчык киеп йөгерү», «Көрәш», икесе дә — 1997 һ.б.); пастель алымы б-н эшләнгән график этюдлар («Базар» сериясе, ш.и. «Пикет», «Яңа казакълар», икесе дә — 1997); күмер, тушь һәм карандаш б-н эшләнгән рәсемнәр («Әнием портреты», 1976; «Базардагы теләнче», 1997 һ.б.); монотипияләр («Революция хәбәрчесе», 1970 һ.б.), шамоттан һәм төс йөгертелгән гипстан эшләнгән кечкенә күләмле сыннар — («Кымыз ясаучы», «Әйлән-бәйлән», икесе дә — 1970; «Автопортрет», 1973) авторы.

Респ-ка («Совет Казакъстанына 50 ел», «СССР — безнең Ватаныбыз», Алма-Ата, 1970, 1972), өлкә (Целиноград рәссамнары әсәрләре, Целиноград ш., 1973, 1976) һәм халыкара (Катарда һәм Мәскәүдә Астана мәдәнияте көннәре, 2002) күргәзмәләрендә катнаша. 1998 дә (Акмола ш.) һәм 2001 дә (Астана) шәхси күргәзмәләре оештырыла. Әсәрләре Астанадагы Заман сәнгате музеенда, Президент мәдәният үзәгендә, ТРның Алма-Атадагы вәкиллегендә, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Асгат Диникеев. Живопись: Каталог. Астана. 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ДИНИЯ́ НӘЗАРӘТЕ́**, к. *Милли идарә.*

**ДИНМӨХӘММӘ́ТОВ** Гали Афзалетдин улы (1892, Казан губ., Чистай өязе Яңа Ибрай а. — 20.8.1951, Казан), дәүләт эшлеклесе. Мәскәү өлкә марксизм-ленинизм курсларын тәмамлый (1931). 1903–16 елларда Чиләбе, Пермь, Омск, Бодайбо шәһәрләрендә төрле эшләрдә эшли. 1916–17 дә Россия армиясендә. 1917 дә Бодайбодагы Федосеев приискында забойчы. 1918 дә приискта оештырылган Кызыл гвардия отрядына керә. Витим елгасы янында ак чехларга каршы сугышларда катнаша. 1919 да Иркутск шәһәрен саклау революцион штабында тәрҗемәче һәм элемтәче. 1920 дә ВКП(б)ның Иркутск губерна ком-тының мөселман секциясе рәисе. 1921–26 да Якутск шәһәрендә азчылык милләтләр арасында партия эшен оештыручы, татар секциясе секретаре, ВКП(б) губерна ком-тының азчылык милләтләр бүлекчәсе мөдире, Томск шәһәрендә губерна халык мәгарифе бүлегенең Азчылык милләтләр мәгариф советы рәисе. 1926–30 да ВКП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт бюросы секретаре, бер үк вакытта 1927 дән РСФСР Азчылык милләтләр комиссариатының Яңа төрки алфавит ком-ты рәисе. 1931 дә ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-тының агитация-масса эшләре бүлеге мөдире урынбасары, 1932 дән Совет-партия контроль комиссиясе рәисе. 1935–36 да Омск өлкәсе буенча партия коллегиясе әгъзасы. 1936 дан ТАССРда: 1937–38 дә ТАССР ҮБК рәисе вазифаларын башкаручы, 1938 дән ТАССР ЮС Президиумы рәисе. 1937–51 дә — СССР, 1938–51 дә РСФСР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы халык хуҗалыгын торгызу елларында Д. республикада фронтка ярдәм күрсәтү һәм, СССР немец-фашист илбасарларыннан азат ителгәннән соң, Сталинград, Орёл шәһәрләрен, ш.у. Донбассны торгызу хәрәкәтен оештыру буенча зур эшләр башкара. Өч Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н а з и п о в а К. Динмухаметов Гали Афзалетдинович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ДИНМӨХӘММӘ́ТОВ ИШМӨХӘММӘТ КИТАПХАНӘСЕ́**, Вятка губ. Малмыж өязенең Түнтәр авылында. Хуҗасы — мәгълүм дин эшлеклесе И.*Динмөхәммәтов.* Тупланмасында татар һәм Шәрекъ телләрендә басма һәм кульъязма китаплар була. 1920–30 елларда китапханә Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең махсус комиссиясе тарафыннан өйрәнелә, кыйммәтле кульъязмалар Казанга җибәрелә һәм Казан ун-тының Фәнни китапханәсе тупланмасына тапшырыла. Басма һәм кульъязма китапларның бер өлеше Түнтәр авылында яшәгән М.Хөсәеновта (1910–87) саклана. 1960 елда ул аларны СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты бүләк итә, аннан китаплар, Казандагы Г.Тукай музее фондларында файдалану өчен, ТАССР Дәүләт музеена тапшырыла. И.Динмөхәммәтовның 19 йөз ахырындагы шәхси язышуларына бәйле документлар оныкларында саклана.

ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында хәзер саклана торган кульъязмалар арасында иң кыйммәтлеләре — Алтын Урда астрономы Камалетдин Төрекмәнинең 12 йөз Харәзем галиме Мәхмүд Чегманиның «Шәрх әл-Мөлләхас» («Кыскача аңлатма») трактатына аңлатмалары (1654 елгы кульъязма күчермә) һәм Пётр I боерыгы б-н Болгарда кабер ташъязмаларын тәрҗемә иткән Шәяхмәт мулла улы Кадыйрмөхәммәтнең Казанда төзегән фикъһе (мөселман хокукы) кульъязмасы (1693). 1891 дә татар каллиграфы Әхмәдгалим Болгариның Бохарадагы «Сара-и Дәшт» мәдрәсәсендә төзегән кульъязмалары да (39 саклау берәмлеге) игътибарга лаек. Китапханә тупланмасында 18–19 йөзләр кульъязмалары шактый.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ДИНМӨХӘММӘ́ТОВ** Ишмөхәммәт (Ишми ишан) (1842, Казан губ., Мамадыш өязе Югары Сөн а. — 1919, Вятка губ. Малмыж ш.), дин эшлеклесе, *кадимчелек* вәкиле. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, аннары *Түнтәр мәдрәсәсендә*, соңрак Бохарада укый. 1877 дән Түнтәр авылы мәчетенең имам-хатибы. 1880 еллар уртасыннан Г.Курсави, Ш.Мәрҗани һәм *җәдитчелекнең* башка вәкилләре карашларына кискен каршы җәмәгать эшлеклесе булып танылa. Ул аларның эшчәнлеген шәригать нормаларыннан читкә тайпылу дип исәпли. 1890 да Түнтәр авылында яңа ысул б-н укытулы мәдрәсә ачылгач, Д., мәхәлләдә традицион ислам нигезләрен сакларга тырышып, җәдитчелеккә каршы тәнкыйтьне көчәйтә. Укырга-язарга өйрәтүдә яңа авазлар алымын кертүгә ризасызлык белдерә, бу алым, «башка дин тотучылардан» алынганга күрә, ислам кагыйдәләренә тамырдан каршы килә, дип саный: «Аваз ысулын көчәйтү Коръәннән йөз чөерүне белдерә, аваз ысулы — ачулану ысулы — Ильминский гамәленең кыллары ул», — дип исәпли. Д. татар милләтен саклап калуның бердәнбер юлы — традицион мөселман белеме һәм башка дин тотучылардан аерым тулы автономия дигән фикердә тора. 1911 дә ул үзенең Бохара системасы нигезендә оештырган укыту проектын тәкъдим итә. Аңа Коръәнне өйрәнү һәм берничә дини хезмәт керә, шул ук вакытта бу системада дөньяви белем алу кирәклеге дә танылa. Д., беренчеләрдән булып, төрле җәзалар һәм ирексезләүләр куллануны кире какмыйча, җәдитчелеккә каршы көрәшкә чакыра. Аны халык арасында ислахчыларга каршы коткы таратуда, әләкләүдә, «Буби» мәдрәсәсе ябылуга астыртын булышлык итүдә гаепләр. Әмма ул ялгызы гына булмый: Д.ка җәдитчеләрне панисламистлар, революционерлар булараk бәяләгән кайбер татар эшмәкәрләре, дәүләт оешмалары вәкилләре ярдәм итә; «Ишми ишан» дигән кушаматы аңа ортодоксаль мөселманнар идеологы буларак бирелә. Большевиклар тарафыннан контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп атыла. Кайбер мәгълүматлар буенча, Вятка губернасының Малмыж өязе Борнак авылында җирләнгән. 1990 еллар ахырында Д. эшчәнлеген артык югары бәяләү күзәтелә: аңа күренекле вәгазьче, дин белгече, публицист, традицион ислам нигезләрен яклаучы шәхес буларак бәя биргән язмалар басыла.

*Әд.:* С а л и х о в Р., Х а й р у т д и н о в Р. «Верноподданническою правдою подтверждаю...» (Ишмухамет Динмухаметов) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2004. № 2; М у х а м е т ш и н Р.Г. Татарский традиционализм: особенности и формы проявления. К., 2005.

*Р.Р.Салихов.*

**ДИНОВЕ́ЦКИЙ** Борис Давидович (10.3.1931, Украина ССР, Харьков ш.), эчке баллистика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1955 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан моторлар төзү з-дының КБнда эшли. 1959 дан Казан технол. ин-тында югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясе кафедрасында. Хезмәтләре дарылар һәм каты ягулыкларга карый. Төрле класс дарылар һәм каты ягулыкларның кабыну һәм яну закончалыкларын, ату кораллары көпшәләренең һәм ракета системаларының эчке баллистикасын тикшерә. Оборона һәм нефть чыгару сәнәгатьләренең төрле системалары өчен блоклы зарядлар (шартлаткыч корылмалар) эшли, яну һәм баллистик проектлаштыруны тикшерүнең методологиясен (берлектә) төзи. 190 лап мәкалә авторы, уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар.

Х е з м.: Энергетические и баллистические свойства порохов и твёрдых ракетных топлив. К., 1995 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**«ДИНСЕЗЛӘ́Р»**, газета, к. «*Сугышчан алласыз*».

**ДИРҺӘ́М** (грек. drachmē̃; гарәп. درهم), урта гасырлардагы мөселман дәүләтләрендә көмеш тәңкә (7–15 йөзләр). Якынча 695 елда Гарәп хәлифәлегендә Өммияләр нәселеннән булган хәлифә Габделмаликның акча реформасы вакытында кертелә. *Динарның* уннан бер өлешен тәшкил итә һәм 3,9 *г* авырлыкта була. Баштарак тәңкәләрдәге язуларда дин символы (икамә) б-н Аллаһ һәм Мөхәммәд пәйгамбәр исемнәре, хәлифә исеме, акчаның сугылу вакыты һәм урыны күрсәтелсә, соңрак өлкә хакимнәренең исеме дә өстәлә. 7–12 йөзләрдә тәңкәләргә куфи язуы төшерелә. Д. Хәлифәлекнең барлык терр-ясендә дә киң таралыш ала; аның форма, авырлык (3 *г* чамасы) һәм язуның үзенчәлеге буенча аерылучы күптөрле вариантлары мәгълүм. 11 йөз башында Шәрекътәге мөселман илләрендә көмеш Д.не сугу туктатыла, 13–15 йөзләрдә ул кабат чыгарыла. Идел буенда куфи язулы Д.нәр 9 йөзнең 1 нче яртысында, Балтыйк-Идел юлы оешып, Шәрекътәге мөселман илләре белән сәүдә багланышлары урнашканнан соң пәйда була (Иске Әлмәт хәзинәсе). 920 еллардан Идел буе Болгар дәүләтендәге Болгар һәм Суар шәһәрләрендә Саманилар Д.е үрнәгендә җирле тәңкәләр сугыла башлый (хәзерге ТР терр-ясенең төрле төбәкләрендә — Зур Тигәнәле, Танкеевка каберлекләрендә, Куйбышев сусаклагычындагы Семёнов утравында (Спас р-ны) һ.б. урыннарда табыла). 10–11 йөзләр чигендә, көмеш чыгаруның азаюы нәтиҗәсендә, Идел буенда Д.нәр сугу вакытлыча туктала (к. *Көмеш кытлыгы чоры*). 11 йөз ахыры — 12 йөз башыннан Болгарда яңадан хәлифә Насыйрлетдин исеменнән Д. сугыла. Алтын Урда чорында беренче Д.нәр Болгарда монгол каганы Мункә исеменнән чыгарыла (1250 еллар). 1260 еллардан Җүчиләр Д.нәре Алтын Урданың барлык эре шәһәрләрендә, беренче чиратта, Болгарда, Сарай әл-Мәхрусәдә, Сарай әл-Җәдидтә, Үкәктә, Бәлҗәминдә сугыла башлый. 1257–66 да, Бәркә хан идарә иткән чорда, Д.нәрдә Җүчи нәселе тамгасы пәйда була, бу исә Җүчи Олысының Монгол империясеннән аерымлануын чагылдыра. 1267 дән тәңкәләр Алтын Урда ханнары исеменнән сугыла. Алтын Урда Д.е алтын динарның алтыдан бер өлешен тәшкил итә (1,2 *г* нан 1,6 *г* га кадәр). Төрки телле чыганаклар мәгълүматлары буенча, Д.нең авырлык нормасы бер ярмакка, ягъни мыскалның алтыдан бер өлешенә туры килә. Җүчиләр Д.нәрендәге язуда (икамәдә) хан исеме, акчаның сугылу вакыты һәм урыны, кайбер очракларда Җүчи нәселеннән булган ханның тамгасы күрсәтелә. Алтын Урда Д.нәрендә ш.у. ике башлы бөркет, арыслан сырты артыннан күтәрелүче кояш сурәтләре һәм Зодиак йолдызлыклары символлары очрый (нәсел башлангычына, дәүләт һәм дин тормышындагы мөһим вакыйгаларга багышланган тәңкәләр). Җүчиләр Д.нәре Алтын Урданың барлык терр-ясендә таралган, аерым алганда, төньяк-көнчыгыш рус кенәзлекләрендә кенәз исеме, акчаның чыгарылу вакыты һәм урыны өстәп сугылган тәңкәләр әйләнештә йөргән. 14 йөзнең 2 нче яртысында Алтын Урдада көмеш Д.нәрнең сыйфаты начарая, авырлыгы кими (0,8–1 *г*), киселгән һәм өстенә кабаттан язу сугылган тәңкәләр пәйда була. 1420 еллардан Алтын Урдада Д.нәр сугу туктала. 15 йөздә Д.нәр Кырым ханлыгында сюзерен, ягъни төрек солтаны исеменнән чыгарыла, ш.у. шәйбаниләр дәүләтендә сугыла.




Семёнов утравында табылган хәзинәдән 10 йөзнең 2 нче яртысына караган дирһәмнәр. ТР ФАнең Тарих институтында сакланалар.

*Әд.:* С а в е л ь е в П.С. Мухаммеданская нумизматика по отношению к русской истории. СПб., 1848; М а р к о в А.К. Топография кладов восточных монет (сасанидских и куфических). СПб., 1910; Я н и н В.Л. Денежно-весовые системы русского средневековья. Домонгольский период. М., 1956; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Находки джучидских монет // Нумизматика и эпиграфика. 1965. Т. 5; ш у л у к. Монеты Московской Руси. М., 1981; ш у л у к. Монеты — свидетели прошлого. М., 1985; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; ш у л у к. Древние монеты Поволжья. К., 1990; В а л е е в Р.М. Волжская Булгария: Торговля и денежно-весовые системы IX — начала XIII веков. К., 1995.

*И.Л.Измайлов.*

**ДИСПАНСЕРЛА́Р**, специальләшкән дәвалау-профилактика учреждениеләре. Функцияләре: авыруларны, авырый башлагач ук барлап, теркәп кую, исәпкә алу, сәламәтлекләрендәге үсеш-үзгәрешләрне күзәтеп тору, махсус медицина ярдәме күрсәтү; авыруларны булдырмый калуга, хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар системасын эшләү, методик-оештыру һәм санитар-агарту эшләре алып бару. Д. аерым бер төркемгә караган кешеләр: эшче һәм хезмәткәрләрнең, авырлы хатын-кызларның, сәламәтлекләре какшаган балалар, яшүсмерләр, спортчыларның сәламәтлегендәге үзгәрешләрне дәвамлы рәвештә даими күзәтеп торалар.

Д.ның элгәрләре булып 18 йөздә Россиядә эшли башлаган түләүсез амбулаторияләр санала. 1804 елда Петербургта шәхси хәйрия акчалары хисабына эшләүче лазаретлары булган «ярлы халык диспенсарияләре» ачыла. Мәскәүдә диспансер тибындагы беренче махсус амбулатория (1904), соңрак — туберкулёзны дәвалау (1918) һәм венерология (1919) диспансерлары эшли башлый. Казанда беренче диспансер учреждениесе көндез килеп дәваланучы туберкулёзлы авырулар өчен ачылган бушлай амбулатория була (1913, мөдире В.В.Фризе). Шул ук чорда туберкулёз б-н авыру ихтималы булган балалар өчен А.Н.Казимбәк җитәкчелегендә җәйге колония оештырыла (Тугаш (Тогашево) авылы). 1921 дә Казанда Туберкулёзны дәвалау үзәк диспансеры ачыла (мөдире А.А.Кулагин). Соңрак ул Респ-ка Д.ы булып китә; 1923 тә туберкулёзны дәвалый торган тагын 2 диспансер ачыла (Елга аръягында һәм Татар бистәсендә); 1922 дә — тире-венерология, 1928 дән наркология диспансерлары эшли башлый.



Казанда тире-венерология диспансеры.

1949 дан сәламәтлек саклау учреждениеләре номенклатурасында түбәндәге төр Д. булдыру карала: туберкулёзны дәвалау, тире-венерология, онкология, психоневрология, трахоманы дәвалау, зобны дәвалау һәм дәвалау-физкультура диспансерлары. Алар теге яки бу авыру аеруча киң таралган урыннарда оештырыла. Д. өлкә, республика, шәһәр диспансерларына бүленеп, аларның эшчәнлеге участок-терр-я принцибына корыла. ТРда 2003 кә 36 Д. хезмәт күрсәтә: 10 туберкулёзны дәвалау диспансеры — Казанда (респ-ка һәм шәһәр диспансерлары), Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Чистай, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә; 2 онкология диспансеры — Казанда (респ-ка һәм шәһәр диспансерлары), 8 тире-венерология диспансеры — Казанда (респ-ка һәм шәһәр), Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән, Лениногорск, Чистай, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә; 5 наркология диспансеры — Казанда (респ-ка һәм шәһәр), Буа, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә, 2 эндокринология диспансеры —



Казанда кардиология диспансеры.

Казанда һәм Лениногорскида; 3 дәвалау-физкультура диспансеры — Казан, Әлмәт һәм Лениногорск шәһәрләрендә; 5 психоневрология диспансеры — Казан, Яшел Үзән, Бөгелмә, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә. 1990 елларда ТРда сәламәтлек саклауны үзгәртеп кору барышында Д. каршында махсус диагностика хезмәтен үз эченә алган районара консультация үзәкләре ачыла: тире-венерология үзәкләре — Әлмәт, Бөгелмә һәм Чистай шәһәрләрендә, генодерматоз үзәкләре — Казанда, психоневрология үзәкләре — Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрендә; наркология үзәкләре — Казан (респ-ка), Буа, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә, эндокринология үзәге — Казанда. Үзәкләрнең бер өлеше ТРдагы тагын да зуррак медицина берләшмәләре составына керә. Ел саен Д. стационарда 6 меңнән артык һәм амбулаторияләрдә 1 млн. нан артык кешегә хезмәт күрсәтә.

*Н.С.Садыйков.*

**ДИССИМИЛЯ́ЦИЯ** (лат. dissimilatio — охшашсызлану), авазларның комбинатор үзгәрешләре, сүз эчендәге ике яки берничә бертөрле яисә охшаш авазлар артикуляциясе төрләренең берсе, алардагы уртак фонетик билгеләрнең юкка чыгуы. *Ассимиляция*гә капма-каршы күренеш. Д. бер типтагы авазлар — сузыклар б-н сузыклар (сузыклар Д.се), тартыклар б-н тартыклар (тартыклар Д.се) арасында барлыкка килә һәм, гадәттә, әйтелешне җиңеләйтүгә юнәлдерелә. Татар телендә, башка телләрдәге кебек, Д. күбрәк гади сөйләмдә, алынма сүзләрнең әйтелешендә (к**ор**идор > к**ыл**идор, ла**м**па > ла**н**па, тра**м**вай > тра**н**вай), балалар сөйләмендә ешрак очрый. Д. диалектларда татар теленең чын үз сүзләрендә күзәтелә: **ш**ашу > **ч**ашу, **ш**ешә > **ч**ешә. Кайвакыт Д. нәтиҗәсендә диалектларда кайбер тартыклар төшеп тә калырга мөмкин: бары**р**га — бары**г**а. Д. юнәлеше ягыннан прогрессив: нә**рс**ә > нә**ст**ә һәм регрессив: б**ри**гадир > б**ыл**гадир; авазларның урнашуы ягыннан контактлы: бо**м**ба > бо**н**ба һәм дистактлы: **ф**уфайка > **к**уфайка булырга мөмкин. Б**ө**т**е**н > б**ү**т**ү**н, ту**г**ыз > ту**к**уз кебек тарихи күчешләрне сузыклар Д.се дип карарга була.

*Әд.:* С а ф и у л л и н а Ф.С. Тел белеменә кереш. К., 1987. 1 кис.; А х м а н о в а О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1966; М а т у с е в и ч М.И. Современный русский язык. Фонетика. М., 1976; Р о з е н т а л ь Д.Э., Т е л е н к о в а М.А. Словарь-справочник лингвистических терминов. М., 1976; Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990.

*М.Ә.Сәгыйтов.*

**ДИСТА́НОВ** Урал Галимҗан улы (28.2.1927, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1975), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948), ЦНИИгеолнерудта: тау-техник чимал геологиясе бүлеге мөдире (1970–78), фән буенча директор урынбасары (1978–88), баш фәнни хезмәткәр (1988 дән). Җир кабыгы үсешенең мезозой-кайнозой чорында кремний тупланууның гомуми теориясен эшли, бу исә СССРның кварц-кремний һәм адсорбция чималларының базасын нигезләү мөмкинлеге бирә; металл булмаган файдалы казылмаларны классификацияләү һәм аларның традицион булмаган яки яңа төрләрен файдалануның алдынгы юнәлешләрен, ш.и. Чернобыль шлейфы терр-ясен экологик реабилитацияләү, углеводородлы һ.б. чималлардан чистарту принципларын эшләүдә катнаша. Аның җитәкчелегендә, металл булмаган файдалы казылма чыганаклар эзләү һәм фаразлауның фәнни нигезе буларак, рудогенез палеобассейннарының геол.-геохимик модельләре, Урта Иделнең палеоген стратиграфия схемасы эшләнә. СССРның Мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (1987). ТР Дәүләт бүләге утырма тышлыкта яңа һәм традицион булмаган файдалы казылмаларны ачканы өчен бирелә (1998). «Почёт билгесе», 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кремнистые породы СССР (диатомиты, опоки, трепелы, спонголиты, радиоляриты). К., 1976; Принципы классификации неметаллических полезных ископаемых. М., 1990; Природные сорбенты СССР. М., 1990 (автордаш); Фанерозойские осадочные палеобассейны России. 2000.

**ДИСТА́НОВ** Әлимир Галимҗан улы (7.3.1931, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1988), проф. (1989). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1953). 1960 елдан РФА Себер бүлегенең Геология һәм геофизика ин-тында (Новосибирск ш.): 1967 дән директор урынбасары, 1978 дән эндоген рудогенез лаб-ясе мөдире, 1997 дән баш фәнни хезмәткәр. Чехословакия, АКШ, Финляндия, Швеция, Канада һәм Кытайда (Чанчундагы Җир турындагы фәннәр ун-тында проф.) халыкара программалар эшләүдә катнаша һәм тикшеренүләр үткәрә. Себер колчедан-полиметалл рудаларының (Холодненск, Озёрный һ.б.) зур чыганакларын беренче булып ачучылардан. Көньяк Себердәге гидротермаль-утырма типтагы чыганакларны тасвирлый. Себер эндоген колчедан-полиметалл чыганаклары рудогенезы һәм руда-формацион анализы теорияләрен үстерә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формационный анализ эндогенных рудных месторождений Сибири. Новосиб., 1966 (автордаш); Холодненское колчеданно-полиметаллическое месторождение докембрия Северного Прибайкалья. Новосиб., 1982 (автордаш); Колчеданно-полиметаллические месторождения Сибири. Новосиб., 1985.

**ДИ́ТТЕЛЬ** Вильгельм Францевич (14.5.1816, Казан — 22.7.1848, С.-Петербург), шәркыятьче галим. Казан ун-тының Көнчыгыш разрядын тәмамлагач (1837), шунда ук эшли. 1842–45 елларда тюрколог И.Н.Березин б-н бергә Кавказга, Гыйрак, Иран, Сүрия, Палестина, Мисыр һәм Төркиягә фәнни экспедициядә катнаша. 1845 тән Петербург ун-тында Көнчыгыш тел белеменең төрек теле кафедрасы адъюнкты, 1846 дан экстраординар проф. вазифаларын башкаручы. Рус археол. җәмгыяте әгъзасы (1847 дән). Ваба авыруыннан иртә вафат булуы сәбәпле, сәяхәтләре вакытында җыелган материаллары гомумиләштерелми, аларның шактый өлеше кульязма килеш кала («Хәлифәлек чорында күрше халыкларның гарәпләр мәгарифенә йогынтысы турында» — «О влиянии соседних народов на образование арабов во время Халифата»; «Көрд диалектлары турында» — «О курдских диалектах» һ.б.).

*Әд.:* С а в е л ь е в П.С. Вильгельм Францевич Диттель: Некролог // Изв. Рус. геогр. об-ва. 1848. Вып. 1; ш у л у к. Восточные литературы и русские ориенталисты // Русский вестн. 1856. Т. 2, кн. 2; Материалы для истории факультета Восточных языков. СПб., 1905. Т. 1; 1909. Т. 4.

*Р.М.Вәлиев.*


**ДИТЯ́КИН** Валентин Тихонович (1.6.1896, Пенза губ., Түбән Ломов өязе Каменка а. — декабрь, 1956, Мәскәү), тарихчы. Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1917), профессор исемен алырга әзерләнү өчен ун-тта калдырыла. 1918–21 елларда иҗтимагый фәннәр ф-ты проф., политэкономия кафедрасы доценты (1922–28), бер үк вакытта Халык ун-ты укытучысы (1931 гә кадәр), аннары Коммунистик академия, СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-ты һәм Славяннарны өйрәнү ин-тында эшли. 1944 тән Мәскәү ун-тының филол. ф-тында славян телләре һәм әдәбияты каф. профессоры. Хезмәтләре ватан һәм чит илләр тарихы, ТАССРның сәяси-икътисади мөнәсәбәтләре һәм хуҗалык-икътисади үсешенә карый.

Х е з м.: Народное хозяйство РСФСР (1917–1920): В 2 вып. К., 1920–21; Задачи восстановления народного хозяйства и научная организация труда. К., 1921; Мировая торговля в эпоху великого экономического кризиса 1917–1921 гг. К., 1921.

*Әд.:* Валентин Тихонович Дитякин // Вопр. истории. 1957. № 1.

*З.Г.Гарипова.*

**ДИФРАКЦИО́Н О́ПТИКА**, махсус оптик элементлар җыелмасы, шул элементлар ярдәмендә яктылык кырлары классик оптик элементлар (линза, призма, көзге, фильтр) куллангандагы сыман үзгәртелә. Яктылык нурлары кайтарыла һәм сына торган классик оптик элементлардан аермалы буларак, дифракцион оптик элементларда яктылык нурлары дифракция хисабына юнәлешләрен үзгәртә (1 рәсем. Рәшәткә тигезләмәсе: $n\lambda=d(\sin\alpha + \sin\beta)$, биредә n — дифракция тәртибе, d — рәшәткә периоды, $\lambda$ — дифракцияләнә торган яктылык дулкыны озынлыгы, $\alpha$ — төшү почмагы, $\beta$ — дифракция почмагы;





1 рәсем. Кайтаручы дифракцион рәшәткә.

θ — «ялтырау» почмагы, ν=1/d — штрихлар ешлыгы, *мм*$^{-1}$).

Гамәли оптиканың аерым бер юнәлеше буларак Д.о. чагыштырмача күптән түгел генә формалаша. Ул бик тиз үсә торган заманча оптика һәм технология өлкәсендәге оптик голография, хисаплау оптикасы, литография, лазер техникасы, юка плёнка капламнар, ион технологиясе һ.б. мөмкинлекләренә һәм казанышларына нигезләнә.

Дифракцион структуралар (амплитуда һәм фаза) ярдәмендә яктылык нурлары бәйләмнәрен үзгәртү мәсьәләләре 16–19 йөзләрдә Көнбатыш Европа галимнәре Х.Гюйгенс, Э.Л.Малюс, О.Ж.Френель, Ш.Соре, Р.Вуд һ.б., соңрак, 1940 елларда, совет галимнәре (Г.Г.Слюсарёв, А.И.Тудоровский, С.М.Райский, А.Л.Дмитриев, В.П.Коронкевич һ.б.) һәм чит ил галимнәре (Д.Дайсон, К.Миямото һ.б.) хезмәтләрендә тикшерелә. 1960 еллар уртасыннан ГИПО ФҖБ дәүләт унитар пр-тиесендә Д.о.ның төрле юнәлешләре: физ. һәм синтезланган голограммалы оптик элементлар (СГОЭ), тар полосалы голографик фильтрлар һәм селектив көзгеләр, рәшәткәле поляризаторлар, прецизион автоматлаштырылган голографик үлчәү ысуллары һәм чаралары, махсус вакуум капламнар (к. *Оптик капламнар*), оптик голография, сырлы һәм голограммалы дифракцион рәшәткәләр буенча тикшеренүләр алып барыла (2 рәсем).




2 рәсем. Үткәрүче дифракцион рәшәткә.

1970 еллардан Казан оптика-механика з-дында АГ-1, АГ-4, ИФК-451 голографик асферометрлар, газодинамик һәм баллистик тикшеренүләр өчен ИАБ сериясендәге интерференцион-күләгәле приборлар, спектрометрлар («Сириус», ДФС-452 һ.б.) эшләп чыгарыла башлый. ГИПО ФҖБндә оптик элементларның һәм үзәкләштерелгән оптик системаларның геом. параметрларын җимермичә контрольлек итүнең югары төгәллектәге голографик ысуллары эшләнә. Шулар ярдәмендә, аерым алганда, «Союз» Казан механика з-дында алмаз б-н кайрау ысулы нигезендә алюминий һәм бакыр эретмәләреннән көзгеләр җитештерү технологиясе үзләштерелә; 500 *мм* га кадәр диаметрлы яссы һәм сферик металл көзгеләрне прецизион җитештерү өчен уникаль станокларны гамәлгә кертү мөмкинлегө бирә.

Тар полосалы голографик фильтрга (Notch-filter) һәм үзгәртеп торган куәтле ИК-лазерлар өчен сырлы дифракцион рәшәткәгә Бөтенроссия эшмәкәрләр советы тарафыннан алтын сыйфат билгесе — «Россия маркасы» бирелә (2000). Д.о.ның төрле типлары арасында оптик приборларда һәм төрле максатлар өчен билгеләнгән җайланмаларда фокуслау, яктылык бүлү, дисперцияләү һәм коррекцияләү функциясен үти торган СГОЭның әһәмияте аеруча зур, аларны компьютерлы голограммалар яки киноформалар дип тә атыйлар. ГИПО ФҖБндә барлык асферик өслек төрләренең оптик сыйфатларына контрольлек итү проблемасы СГОЭ нигезендә хәл ителә. Дифракцияләнгән нурлар очрагы өчен Малюс-Дюлин һәм Леви-Чивит теоремаларын гомумиләштерүне үз өченә алып, әйләнмә һәм сызыкча СГОЭны исәпләү һәм синтезлауның ГИПОда эшләнгән фәнни нигезләре аны хәл итү өчен җирлек булып тора. ГИПО ФҖБндә голографиянең фәнни-техник юнәлешләр буларак барлыкка килүе СССР Оборона министрлыгының ГИПО директоры С.О.*Мирумянцка* (1966) голографиягә кагылышлы мәгълүматны өйрәнергә һәм аны гамәли куллану мөмкинлеге хакында тәкъдимнәр әзерләргә дигән йөкләмәсеннән башлана. Гамәли голография мәсьәләләрен хәл итү РФА акад., «күләмле» голографиягә нигез салучы Ю.Н.Денисюкның гомуми фәнни җитәкчелегендә К.С.*Мостафин* тарафыннан гамәлгә ашырыла, сырлы дифракцион рәшәткәләр технологиясенә караган эшләр С.А.Стрежнев җитәкчелегендә һәм Ф.М.Герасимовның (С.И.Вавилов исем. Дәүләт оптика ин-ты, Ленинград) фәнни җитәкчелегендә башкарыла.

Голограммалы дифракцион рәшәткәләр буенча бергәләп башкарган хезмәтләре өчен РФА КГҮ һәм ГИПО ФҖБ галимнәре А.В.Лукин, А.С.*Макаров*, К.С.Мостафин, С.А.Саттаров, В.А.*Селезнёв*, Ю.П.*Стрельников*, И.Г.*Фәйзрахманов* һәм И.Б.*Хәйбуллиннарга* фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләге бирелә (1998). Р.А.Агачев, Н.М.Балясников, А.Ф.Белозёров, Г.Н.Буйнов, М.П.Кит, В.В.Куинджи, Н.П.Кутикова, Н.П.Ларионов, Я.К.Лукашевич, Т.А.Лукина, Л.Т.Мостафина, Н.К.*Павлычева*, В.И.Протасевич, Р.А.Рафыйков, Т.Б.Сидорова, В.Т.Черных, Н.М.Шиһапова, Е.И.Штырковлар, ш.у. ГИПО ФҖБ директорлары: С.О.Мирумянц, Ю.М.Беляков, А.С.Макаров, В.П.Ивановлар Д.о. юнәлешләрен үстерүгә мөһим өлеш керттәләр.

*Әд.:* Борн М., Вольф Э. Основы оптики. М., 1970; Кольер Р., Брекхарт К., Лин Л. Оптическая голография. М., 1973; Лукин А.В., Мустафин К.С. Голографические методы контроля асферических поверхностей // Оптико-механическая промышленность. 1979. № 4; Синтезированная голограммная оптика // Оптический журн. 2002. Т. 69, № 12; Физика: Большой энцикл. словарь. М., 1999; Subject of New Title from SPIE Press // OE magazine. 2003. November.

*А.В.Лукин.*

**ДИФТЕРИ́Я** (грекча diphtherion — юка тире, яры, кабык), көчле йогышлы авыру (башлыча, балаларда була торган инфекция). Йоткылык өсте, бугаз, трахея (сирәк кенә башка әгъзалар) ялкынсыну, миндальсыман бизләрдә фибриноз ярылар хасил булу, интоксикация, йөрәк-кан тамыры, нерв, бәвел бүлеп чыгару системалары зарарлану б-н характерлана. Инфекция чыганагы булып Д. б-н авыручылар яки организмнарында бактерия йөртүчеләр тора. Авыруның кешедән-кешегә күчүенең төп механизмы — сулый торган һавадан йогу; йогышланган әйберләр (кием-салым, савыт-саба, уенчыклар һ.б.) б-н дә күчәргә мөмкин. Дифтерияне аеруча 1 яшькә кадәрге балалар авыр кичерә. Иммунитет инфекциядән соң (тотрыксыз) һәм прививкадан соң (тотрыклы) барлыкка килә.

Авыруның төрле формаларын француз табибе П.Бретонно тасвирлап күрсәтә (1826), «дифтерит» атамасын куллана; терапевт А.Труссо гомум кабул ителгән Д. атамасын гамәлгә кертә. Д.не кузгатучы Corynebacterium diphtheriae микроорганизмын чиста хәлендә немец бактериологлары Э.Клебс, Ф.Леффлер (1883–84) аерып алалар. Дифтериягә каршы сыворотка бактериологлар Э.Беринг, Э.Ру, Я.Ю.Бардах (1824–94) тарафыннан табыла. Токсин һәм антитоксин катнашмасы б-н актив рәвештә иммунлаштыру методын Э.Беринг (1913) уйлап таба. Микробиолог Г.Рамон иммунлаштыру өчен дифтерия анатоксинын тәкъдим итә (1923), бактериолог П.Ф.Здродовский дифтериягә каршы прививкаларны камилләштерә (1950 еллар).

Казан губернасында дифтерия эпидемияләре 1902–08 елларда кабынып ала, соңрак алар 1918–30, 1942 дә кабатлана. 1950–58 дә республикада ел саен 1,5–2 мең бала авырый, олы яшьтәге балалар арасында авыручылар саны арта, үлем дәрәҗәсе күрсәткече 100 мең кешегә 8,4 кә җитә (1955). Үлемгә китергән көчле эпидемияләр Минзәлә районында теркәлә (1963). 1955 тә башланып киткән гомум иммунлаштыру аркасында Д. б-н авыручылар саны 1960 ка кими башлый (авыручылар саны күрсәткече 100 мең кешегә 6,4 кә төшә), 1969 да авыру чыккан урыннардагы бактерия йөртүчәнлек дәрәҗәсе 1960 ел б-н чагыштырганда 2,3 тапкыр кими; аннан соңгы елларда авыру очраклары сирәгәя. Иммунологик үзенчәлекләре һәм клиник барышы буенча Д.нең күбрәк җиңел формалары күзәтелә башлый. 1977–78 дә бер генә авыру да теркәлмәгән, 1981–91 дә аерым очраклар гына күзәтелә. Авыручылар һәм бактерия йөртүчеләр саны кимүгә зур оештыру чаралары күрү, ГИДУВ, Казан мед. ин-ты, Казан эпид. һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-ты базаларында табибләр әзерләү, Казан мед. уч-щесе каршындагы урта медицина хезмәткәрләренең белемен күтәрү курслары, эпидемия кабынган урыннарга табиб-инфекционистларны җибәрү хисабына ирешелә.

1992 дән ТРда эпидемиологик хәл кинәт начарлана, авырулар саны 1991 ел б-н чагыштырганда 2,4 тапкыр (күрсәткече — 100 мең кешегә 2,7), бактерия йөртүчеләр 1,8 тапкыр арта. Авыру очраклары өлкән яшьтәге иммунлаштырылмаган кешеләр арасында да очрый. 1990 елларда өлкән яшьтәгеләрнең 30–40% ы ревакциналаштырыла. 2000 елга авыруның аерым очраклары теркәлә.

Д. проблемалары Казан галиме Н.П.Кудрявцева («Дифтерия таякчыкларына аллергияне клиник-экспериментал өйрәнү» —

«Клинико-экспериментальное изучение аллергии к дифтерийным палочкам», 1949, 1955), Н.С.Шәмсетдинов, М.Г.Берим («Дифтерия б-н авыруның клиник-патогенетик үзенчәлекләре» — «Клинико-патогенетические особенности течения дифтерии», 1950), В.И.Качурец («Дифтерияне юк итүнең төрле этапларында аның клиник-иммунологик параллельләре» — «Клинико-иммунологические параллели дифтерии на различных этапах её ликвидации», 1960) тарафыннан өйрәнелә.

1956 елда Казан эпидимиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты галимнәре махсус методика буенча көчле активлыктагы югары сыйфатлы Д. анатоксины җитештерүне үзләштерәләр (В.Н.Шаровская, Р.Г.Мөхетдинова, А.И.Оворкина). 1960–80 елларда Д., бума ютәл һәм тартышу авыруларын булдырмый калу өчен чыгарылган препаратларның реактогенлыгы һәм иммунологик нәтиҗәлелеге өйрәнелә (И.Е.Алатырцева, Х.Г.Сәйдәшева, А.Т.Хисаметдинов, Н.Ф.Амфитеатрова һ.б.). Махсус профилактика өчен АКДС яки АДС вакциналары файдаланыла.

Д.не булдырмау дәвалау-профилактика, санитария-гигиена һәм эпидемияләргә каршы чаралар комплексы ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

*Әд.:* Из практики ликвидации дифтерии в сёлах Татарии // Казан. мед. журн. 1968. № 1; Берим М.Г., Шамсутдинов Н.С. О применении индикаторного метода обнаружения к идентификации дифтерийных палочек // Лабораторное дело. 1965. № 2; Федоренко Л.И. Заболеваемость дифтерией в РТ // Казан. мед. журн. 1993. № 6.

*И.М.Хәйретдинова, Д.Р.Нуретдинова.*

**ДИЮ́** (борынгы фарсы ديو — дию, дәү), Идел буе, Көнбатыш һәм Көньяк Себер, Казакъстан, Урта, Якын һәм Кече Азия, ш.у. кайбер Иран төрки халыклары мифологиясендә гаять зур (өч, алты, тугыз яисә унике башлы) зат. Д. образы мәҗүсилек заманында ук булган. Төрки-татар мифологиясендә Д. — мөмкинлекләре чиксез, явыз зат, эпик геройның куркыныч дошманы. Кыяфәте төрлечә тасвирлана, әмма һәрвакыт аның гаять зур гәүдәле булуы ассызыклана: «Башы яктылыкны томалый, гәүдәсе бөтен дөньяны каплый» (татар халык әкияте «Зөлкарнәй батыр»). Кызларны, хатыннарны, кайвакыт картларны һәм балаларны урлый, гадәттә, аларны ашый. Татар халык әкиятләрендә җария кызларның бакыр, көмеш, алтын сарайларда «озын өстәлләрдә кеше гәүдәләрен» юулары тасвирлана. Д. биләмәләренең һәр тарафында кеше сөякләре аунап ята (татар халык әкияте «Мәрмәр тау башында»). Гадәттә, Д. бернигә көнгә сузылган озак, тирән йокыга тала, шуның б-н ул үзен куркыныч астына куя: Д.не үтерә торган кылыч аның үзендә саклана, һәм эпик герой аннан файдалана ала. Кайвакыт Д. кыяфәте б-н кешедән аерылмый, ир кеше яки хатын-кыз рәвешенә керә ала, аның гаиләсе, балалары, бигрәк тә кызлары булырга мөмкин. Тик шулай да татар мифологиясендә, нигездә, Д. ир-ат җенесеннән була. Татар фольклорчысы Л.Ш.Җамалетдинов фикеренчә, Д. — үлеләр патшалыгы хакиме. Төрки-татар мифологиясендә Д. образы шактый үзгәреш кичерә: халык авыз иҗатының соңгырак әсәрләрендә герой күп башлы явыз Д.не җиңә. Аларда инде Д.гә илаһилык хас түгел; аның исеме б-н башка әкияти-мифологик геройларны да атый башлыйлар.

*Әд.:* Татар халык әкиятләре. К., 1956. 2 кит.; Татар халык әкиятләре. Тылсымлы әкиятләр. К., 1994; Җамалетдин Л. Тылсымлы әкиятләрдә Дию образы // Фәнни эзләнүләр юлында. К., 2000; Рак И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана // Зороастрийская мифология. СПб., 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ДИЯ́РОВ** Ирек Нурмөхәммәт улы (20.12.1929, хәзерге Чистай р-ны Татар Ялтаны а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1977), проф. (1979), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). 1958 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, 1962 дән шунда ук эшли, нефть ф-ты деканы (1965–67), нефть һәм газ эшкәртүнең химик технологиясе каф. мөдире (1980–2000). 1978–80 елларда Кабул политехник ин-тында (Әфганстан) химия технологиясе кафедрасын җитәкли. Хезмәтләре нефтьне эшкәртүгә әзерләү процесслары химиясе һәм технологиясенә, табигый битумнар химиясе һәм технологиясенә, сыеклыкларны сыгынтылауның теоретик нигезләренә һәм технологиясенә карый. Нефть сәнәгате өчен тутыгудан саклау деэмульгаторын һәм ингибиторын синтезлый, шуларны куллану технологиясен эшли. Нефть эшкәртү процессларын көчәйтү өчен роторлы пульсацион акустик аппарат төзи (берлектә). Табигый битумнарның химик һәм фракцион составын тикшерә, шуларны эшкәртүнең кулай ысулын тәкъдим итә. Уйлап табуга 30 дан артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Очистка углеводородных газов от сероводорода // Нефтяная пром-сть. Сер. Нефтепромысловое дело. 1980. Вып. 2 (автордаш); Экстрация ароматических углеводородов нитроспиртами // Химия и технология топлив и масел. 1969. № 7; Химия нефти. Л., 1990 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДИЯ́ШЕВ** Рәсим Нәгыйм улы (27.6.1935, Әлмәт р-ны Бигәш а.), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1983), ТАССР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989, 1993), СССРның уйлап табучысы (1988). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), «Татнефть» берләшмәсе промыселларында. 1966 елдан ТатНИПИнефтьтә: скважиналарны тикшерү лаб-ясе мөдире (1966–74), Алжирда контрактның баш инженеры (1974–77), бүлек җитәкчесе (1978–83), директор урынбасары (1983–2003). 2003 тән «Татнефтегеофизика» АҖ ген. директоры киңәшчесе. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: күп катламлы нефть чыганакларын проектлаштыру һәм эшкәртү (скважиналар челтәренең тыгызлыгы, су кудыру режимы); коллекторларны гидродинамик ысуллар б-н тикшерү һәм катламнардан нефть алуны арттыру; авыр нефть һәм битумнарны җылылык ысулы б-н алу. Бу хезмәтләрнең нәтиҗәләре Татарстан һәм Көнбатыш Себер чыганакларын үзләштерүдә файдаланыла. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1982).

Хезм.: Совместная разработка нефтяных пластов. М., 1984; Влияние плотности сетки скважин на нефтеизвлечение на примере месторождений Татарии. М., 1990 (автордаш).

**ДМИ́ТРИЕВ** Анатолий Валентинович (15.5.1954, Лениногорск ш.), инженер-механик, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008), Лениногорск нефть техникумын (1973), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1981) тәмамлый. 1973 елдан «Татнефть» АҖдә (бүленеп): «Лениногорскнефть» НГДУнда слесарь-ремонтлаучы, мастер, өлкән механик, цех башлыгы урынбасары, баш механик, «Татнефть» АҖнең баш механигы (2000 нән). Дәүләт бүләге авыр табыла торган нефть чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен яңа технологияләр һәм җиһазлар комплексын эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 7 патенты бар.

**ДМИ́ТРИЕВ** Виктор Петрович (23.11.1947, Казан), инженер-технолог, пр-тие җитәкчесе, ТРның атказ. җиңел һәм текстиль сәнәгате хезмәткәре (1997). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1974). В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында аппаратчы (1966–67), Казан органик синтез з-дында мастер (1967–69), Казан көнкүреш химиясе з-дында мастер, цех башлыгы (1974–78) булып эшли. 1978–85 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1985–96 да «Казан ясалма күн заводы» АҖнең директоры, 1996–2005 тә ген. директоры.

Д. җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла, плёнка материаллар (линолеум, изоляция тасмасы, аяк киемнәре эшләп чыгаруда, электр үткәргечләрен һәм приборларын изоляцияләүдә кулланылучы пластикат һ.б.) җитештерү гамәлгә кертелә. «Почёт билгесе» ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

**ДМИ́ТРИЕВ** Максим Васильевич (14.9.1913, Казан — 1.11.1990, Киев), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), полковник. Киев танк-техник уч-щесен тәмамлый. Туган шәһәрендә мех ф-касында слесарь булып эшли. 1935 елдан Кызыл Армия сафларында. Хәсән күле янында японнар б-н сугышта катнаша (1938). Совет-фин сугышы елларында 109 нчы аерым разведка батальонында танкның өлкән механик-йөртүчесе (7 нче армиянең 86 нчы моторкучылар дивизиясе). 1940 ның 27 февралендә Карелия муентыгындагы сугышта батырлык күрсәтә: бер совет танкы зарарлангач, Д. иптәшләрен үзенең машинасы б-н каплап саклый һәм дошманның берничә ут ноктасын юк итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Киев танк-техник уч-щесендә начальник урынбасары. 1966 дан запаска җибәрелә. Киевта яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Та-

тарии. К., 1963; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДМИ́ТРИЕВ** Николай Константинович (16.8.1898, Мәскәү — 22.12.1954, шунда ук), тел галиме-тюрколог, филол. фән. д-ры (1938), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1943) РСФСР ПФАнең академигы (1945), БАССРның, Төрекмәнстан ССРның, Чуашстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1947, 1950, 1953). Совет тюркологиясе мәктәбенә нигез салучыларның берсе, милли республикаларда, ш.и. Татарстанда тюркология фәнен үстерүгә өлеш керткән галим. Мәскәү ун-ты тарих-филол. ф-тының классик һәм славян бүлекләрен (1920), СССР ФАнең Мәскәү көнчыгышны өйрәнү ин-тының төрек, фарсы һәм гарәп разрядларын тәмамлый (1922). 1925 елдан Ленинград тере көнчыгыш телләре ин-тында (1929–38 дә проф., 1930 дан төрек теле каф. мөдире); бер үк вакытта 1926 дан Ленинград ун-тында (1930 дан проф., 1944–48 дә төрки филология каф. мөдире); бер үк вакытта 1926–32 дә Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыклары әдәбиятын һәм телләрен чагыштырып өйрәнү фәнни-тикшеренү ин-тында, 1928 дән Мәскәү ун-тында (1929 дан проф., 1930–39 да төрки телләр каф. мөдире, 1940–42 дә төрки филология каф. мөдире, 1943 тән филология ф-тының шәрекъ бүлеге мөдире); бер үк вакытта 1938–54 тә СССР ФАнең Тел белеме ин-тының төрки телләр бүлеге мөдире. Д. — беренче «Кумык теле грамматикасы» («Грамматика кумыкского языка», М.–Л., 1940) авторы. Фәндә беренче булып башкорт телен системалы тасвирлый һәм аның теоретик грамматикасын эшли («Башкорт теле грамматикасы» — «Грамматика башкирского языка», М.–Л., 1948). Төрки һәм славян телләренең үзара бәйләнеше тарихын («Серб-төрек телләре багланышларына караган этюдлар» — «Этюды по сербо-турецкому языковому взаимодействию», ч. 1–4, 1928–29), тел тарихының әһәмиятле чыганагы сыйфатында фольклорны өйрәнә. Д. башкорт, кумык, Кырым татарлары, төрекмән һәм төрек халык авыз иҗатына аеруча игътибар бирә. Лингвистик һәм әдәби аңлатмалар б-н төрки фольклор текстларын (җырлар, әкиятләр) нәшер итә. Күп еллар татар телен өйрәнә, 1926 да татар теле диалектлары, аннары мишәрләр сөйләше турында (1928; 1932, француз һәм немец телләрендә) беренче мәкаләләре дөнья күрә. Татар телен башкорт, чуаш һәм рус телләре б-н чагыштырып тикшерә. Бу мәсьәләгә «Рус булмаган мәктәпләрдә рус телен һәм туган телләрне укыту методикасы мәсьәләләре» («Вопросы методики преподавания русского и родного языков в нерусской школе», 1948, автордашы В.М.Чистяков), «Татар мәктәбендә рус һәм туган телләрне укыту методикасы буенча очерклар» («Очерки по методике преподавания русского и родного языков в татарской школе», 1952, автордашлары Н.З.Бакыева, В.М.Чистяков) исемле хезмәтләре багышлана. Д. К.Насыйри иҗатын анализлый һәм аңа югары бәя бирә («Филолог буларак Каюм Насыйри» – «Каюм Насыри как филолог», 1947). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы изучения хакасского языка и его диалектов. Абакан, 1954 (автордаш); Строй тюркских языков. М., 1962.

*Әд.:* Н.К.Дмитриев — выдающийся тюрколог и педагог. К., 1998; Ш а к и р о в а Л.З. Выдающийся тюрколог и педагог // Научный Татарстан. 1998. № 2; Николай Константинович Дмитриев. М., 2001.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**ДМИ́ТРИЕВ** Сергей Васильевич (19.8.1934, Казан — 13.15.2003, шунда ук), приборлар төзү гыйлеме белгече, техник фән. канд. (1969), проф. (1988), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1958 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, авиация приборлары һәм автоматлар каф. мөдире (1979–99), бер үк вакытта автоматик идарә итү системалары һәм очкыч аппаратлар җиһазлары ф-ты деканы (1975–80), проректор (1981–95). Хезмәтләре кече авиация өчен прибор комплекслары, катлаулы магнит системалары төзүгә карый. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**ДМИ́ТРИЕВ** Сергей Васильевич (6.5.1937, Октябрь р-ны Норлат а.), технол. процессларны автоматлаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1982), проф. (1984), Мари АССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987). 1960 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның авиация пр-тиеләрендә эшли. 1965 тән Мәскәү авиация технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында, 1973 тән фәнни-тикшеренүләр секторы башлыгы. 1975 тән Мари политехник ин-тында, станоклар һәм автоматлар каф. мөдире (1980–83), проректор (1983–93). 2000 нән Кама политехник ин-тында (хәзер Кама инженерлык-икътисад академиясе), сызма геометрия һәм инженерлык графикасы каф. мөдире (2001 дән). Д. эшләгән методикалар: газ турбиналы авиация двигательләрен сынауның автоматлаштырылган технол. процессларын анализлау һәм синтезлау, машиналар төзелешендә җиңел үзгәртелүле җитештерү системаларын ЭВМ һәм роботлар техникасын кулланып проектлаштыру, бу системаларның җитештерүчәнлеген һәм ышанычлылыгын исәпләү. Авиация двигательләрен тикшерүнең комплекслы автоматлаштырылган системасын эшләүдә катнаша (илнең 6 моторлар төзү пр-тиесендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Автоматизация испытаний и контроля авиационных газотурбинных двигателей. М., 1977 (автордаш); Матричные структуры ЭВМ и управляющих систем. М., 1977; Организация автоматизированных систем управления технологическими процессами авиационного машиностроения. М., 1979 (автордаш).

**ДМИ́ТРИЕВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасы буенда. 2008 елда 20 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 62%) яши. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (алпавыт Балашевларның элеккеге крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 2 гыйнварыннан Азнакай р-нында. 1980–90 елларда авыллар исемлегеннән сызыла; 1998 нең 18 февраленнән яңадан теркәлә. Халык саны: 1859 да — 271, 1890 да — 238, 1910 да — 158, 1920 дә — 158, 1926 да — 247, 1938 дә — 219, 1949 да — 145, 1958 дә — 106, 1970 тә — 76, 1979 да — 29, 2002 дә — 26 кеше.



М.В.Дмитриев.



Н.К.Дмитриев.

**ДМИ́ТРИЕВКА** авылы, Баулы районында, Баулы шәһәреннән 40 *км* көньяктарак, Кандыз елгасы буенда. 2008 елда 63 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мордовская Дмитриевка исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1023 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Д.да башлангыч мәктәп, су тегермәне эшли. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Ивановка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 109 ир-ат; 1859 да — 455, 1897 дә — 685, 1926 да — 890, 1938 дә — 570, 1949 да — 406, 1958 дә — 353, 1970 тә — 303, 1979 да — 218, 1989 да — 132, 2002 дә — 90 кеше.

**ДМИ́ТРИЕВКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кама елгасыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 23 кеше (руслар) яши. 1865–67 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Котловка исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, бакчачылык, балыкчылык б-н шөгыльләнә, сәүдәгәр Стахеевларның «Изге чишмә» утарында көнлекче булып эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 169,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонасов волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 41, 1920 дә —

190, 1926 да — 198, 1938 дә — 256, 1949 да — 245, 1958 дә — 187, 1970 тә — 140, 1979 да — 206, 1989 да — 53, 2002 дә — 25 кеше.

**ДМИТРИЕ́ВСКАЯ** Людмила Митрофановна (21.11.1932, Мари АССРның Морки р-ны Морки а.), хокук белгече, ТАССРның атказ. хокук белгече (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1955). 1955–67 елларда Әлмәт юридик консультациясендә адвокат, 1967–79 да мөдир. 1979–84 тә ТР Адвокатлар коллегиясе президиумы рәисе урынбасары, 1984 тән — рәисе.

*Е.Б.Долгов.*

**ДМИТРИЕ́ВСКИЙ** Алексей Афанасьевич (11.3.1856, Әстерхан губ. — 10.8.1929, Ленинград), дин белгече, чиркәү тарихы д-ры (1896), Петерб. ФАнең мөхбир әгъзасы (1903). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1882), шунда ук эшли. 1884–97 елларда Киев руханилар академиясенең Көнчыгыш археологиясе һәм мәдәнияте каф. укытучысы. 1907–19 да Император православие Палестина җәмгыятендә гыйльми сәркәтип. 1919–22 дә Әстерхан ун-тының тарих каф. профессоры, бер үк вакытта Петроград Дини-пастырьлык уч-щесе (1920–28) һәм Югары дини курслар профессоры (1923–28). 1919, 1922 һәм 1929 да кулга алына. Хезмәтләре чиркәү литургикасы, археология, византинистикага карый.

Х е з м.: Богослужение в Русской Церкви в XVI в. К., 1884; Современное богослужение на православном Востоке. Киев, 1891; Древне-иудейская синагога ... К., 1893; Книга «Требник» и ее значение для православного христианина. Киев. 1902; Святой патриарх Гермоген. П., 1912.

*Әд.:* Ц и т и н В. История Русской церкви 1917–1997. М., 1997. Т. 9; Синодик гонимых, умученных ... священнослужителей и мирян Санкт-Петербургской епархии: XX столетие. СПб., 1999.

**ДМИ́ТРИЙ ДОНСКО́Й** (12.10.1350, Мәскәү — 19.5.1389, шунда ук), Мәскәү (1359 елдан) һәм Владимирның (1362 дән) бөек кенәзе. Бөек кенәз Иван II Красныйның (1326–59) улы. Әтисе үлгәннән соң, Д.Д. балигъ булганга кадәр, кенәзлек б-н боярлар идарә итә. 1362 дә, Мәскәү боярлары һәм әмир Мамай булышлыгы б-н, Владимир кенәзлеген җитәкли. Литва кенәзе Ольгерд б-н сугыша (1368, 1370, 1372), 1375 тә Тверь шәһәренә яу б-н бара, Мәскәүнең өстенлеген танытуга һәм Тверь кенәзләренең бөек кенәзлеккә дәгъва кылуларыннан баш тартуларына ирешә. 1370 елларда Мамайга каршы торуын көчәйтә, 1376 да Болгар җирләренә яу б-н барып (к. *Болгарга 1376 елда оештырылган яу*), чынлыкта Мамай б-н сугыш башлый. 1377 дә Д.Д. гаскәрләре Пьяна елгасы янында җиңеләләр, 1378 дә ул Вожа елгасы янында (Ука елгасының уң кушылдыгы) әмир Бигеч гаскәрләрен тар-мар итә. 1380 дә Дон елгасының югары өлешендә Мамай гаскәрләрен җиңә, шул хөрмәткә аңа Донской исеме бирелә (к. *Куликово кыры сугышы*). 1382 дә Д.Д. гаскәрләре Мәскәүне һәм Төньяк-Көнчыгыш Русь җирләрен яулап алган Туктамыш хан гаскәрләре тарафыннан җиңелә. Д.Д. Алтын Урдага буйсынуын танырга һәм яңадан ясак түли башларга мәҗбүр була. Аның үз биләмәләрен киңәйтү һәм Мәскәүнең башка кенәзлекләрдән өстенлеген ныгыту өчен көрәше нәтиҗәсендә, Мәскәү кенәзләре бөек кенәзлеккә мирас хокукы ала (1389). Д.Д. вакытында Мәскәүдә ак таштан Кремль салына (1367).

*Әд.:* Повести о Куликовской битве. М., 1959; Ч е р е п н и н Л.В. Образование Русского централизованного государства в XIV–XV вв. М., 1960; Куликовская битва. М., 1980; К у ч к и н В.А. Формирование государственной территории Северо-Восточной Руси в X–XIV вв. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**ДМИ́ТРОВ** (Димитрово) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 10 *км* төньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2008 елда 109 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1926 да «Труд и знание» («Хезмәт һәм белем») а.х. коммунасы әгъзалары 1917 гә кадәр Алабуга сәүдәгәре И.И.Стахеевныкы булган Каменный утары урынында нигез сала. 1934 тә коммуна Г.Димитров исем. к-з итеп үзгәртелә. 1950 дән — «Заветы Ильича» к-зында, 1970 тән шул ук исемдәге с-зда, 1997 дән — «Нива» а.х. товарлары җитештерү кооперативында. Оешырылган көннән авыл ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 256, 1949 да — 111, 1958 дә — 118, 1970 тә — 187, 1979 да — 114, 1989 да — 87, 2002 дә — 97 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**«ДНЕВНИ́К КАЗА́НИ»** («Казан көндәлеге»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1906 елның 30 июленнән 1907 нең 18 маена кадәр рус телендә нәшер ителә, барлыгы 206 саны чыга. Наширләре — А.К.Шемякин, аннан соң Н.И.Артемьева. Мөхәррирләре — А.К.Шемякин, аннан соң А.Н.Миславский. Журналда элек «Волжский вестник» г-тасында эшләгән хезмәткәрләр, Казан ун-ты студентлары материаллары басыла. «Д.К.» матди ярдәмне Казандагы профсоюз оешмаларыннан ала, шуның өчен ул эшчеләр оешмаларын һәм профсоюзларын берләштерүче орган булырга омтыла. Россия һәм чит ил профсоюзлары эшен яктыртуга зур игътибар бирә. Сәнәгатьнең төрле өлкәләрендә эшләүчеләрнең хәле, профсоюз хәрәкәтенең максатлары һәм бурычлары аңлатыла. Газетада хөкүмәт карарлары, Петербург һәм Россия телеграф агентлыклары телеграммалары, рус һәм чит ил матбугатына күзәтү, өлкә хәбәрләре, фәнни җәмгыятьләрнең утырышлары турында гражданлык һәм җинаять эшләре мәхкәмәләренең хисаплары, шәһәр һәм земство үзидарә органнары утырышлары турында мәгълүматлар, җирле сәүдә-сәнәгать эшләре турында хәбәрләр, матур әдәбият әсәрләре басыла. Ш.у. Дәүләт Думасы тарафыннан эшләнгән закон проектлары турында фикер алышулар үткәрелә. Дума утырышлары хисапларында сул фракция депутатларының чыгышлары урын ала, уң партия программалары тәнкыйтьләнә. Россиядәге уку йортларының хәлен яктыртуга аерым игътибар бирелә; ун-тларга киң автономия бирү принципларын яклый, аларда сәяси митинглар үткәрергә, студентлар оешмалары, якташлык җәмгыятьләре булдырырга чакыра, студентларның ун-т советы эшләрендә катнашу хокукын яклый. Редакция фикеренчә, газетаның чыгудан туктатылуына «цензураның газетага даими басым ясавы, аңа хезмәт иясләре массаларының ихтыяҗларын чагылдыручы, аерым алганда, профсоюзлар органы булуга комачаулавы» сәбәп була.

*Г.Р.Заманова.*

**«ДНЕВНИ́К КАЗА́НСКОГО О́БЩЕСТВА ВРАЧЕ́Й ПРИ ИМПЕРА́ТОРСКОМ КАЗА́НСКОМ УНИВЕРСИТЕ́ТЕ»** («Казан Император университеты каршындагы Казан табибләре җәмгыяте көндәлеге»), фәнни-мед. журнал. *Казан табибләре җәмгыяте* органы. 1872 елның 5 маеннан 1874 кә кадәр, 1880–1915 тә Казанда рус телендә (башта айга 1–2 сан, 1889 дан елга 2–4 чыгарыш) нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — А.В.*Петров*, Н.М.*Любимов*, М.Ф.*Субботин*, А.Я.*Щербаков*, Л.Л.*Лёвшин*, М.Я.*Капустин*, Н.А.*Засецкий*. Казанның күренекле галим-табибләре Е.В.Адамюк, В.М.Бехтерев, Н.А.Виноградов, Н.Ф.Высоцкий, А.Г.Ге, И.М.Догель, Н.О.Ковалевский, Н.И.Котовщиков, И.П.Скворцов, В.И.Разумовский, А.Я.Щербаков һ.б.ның мәкаләләре басыла. Исеме үзгәрә: 1872 дән — «Дневник общества врачей г.Казани» (вакытлыча чыккан «Протоколы общества врачей Казани», «Записки общества врачей», «Известия Императорского Казанского университета» дигән басмаларга кушымта буларак), 1883 тән — «Дневник общества врачей при Императорском университете», 1889 дан — «Дневник Казанского общества врачей при Императорском Казанском университете». Казанда беренче махсуслашкан мед. журналы булдыру җәмгыять эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе — мед.-санитария статистикасының фәнни һәм гамәли нигезләрен эшләү б-н бәйле. Шушы максаттан чыгып, табибләргә җентекләп эшләнгән стат. карталар җибәрелә, соңыннан мәгълүматларны теркәү һәм эшкәртү өчен алар җәмгыятькә кире кайтарыла. «Дневник...» күренекле хирург һәм җәмәгать эшлеклесе Н.И.*Студенский* тырышлыгы б-н нәшер ителә башлый, ул табибләрнең игътибарын җирле халык арасындагы авыруларны җентекләп өйрәнүгә юнәлтә. Соңга таба «летучие листки» дип аталган стат. җыентыклар Казандагы мед. җәмәгатьчелеген канәгатьләндерми башлый, шуның өчен теоретик, клиник, профилактик медицина буенча оригиналь мәкаләләр, табибләрнең съездлары турында хисап материаллары, җәмгыять утырышларының беркетмәләре, әгъзаларның хезмәтләре, Россия һәм чит ил галимнәренең диссертация, реферат кебек мөһим хезмәтләренә язылган рецензияләр басыла башлый. Александр исем. шәһәр хастаханәсенең хирургия бүлеге эшенә зур игътибар бирелә. Казан галимнәренең журнал битләрендә басылган күп тәкъдимнәре Россиянең санитария-эпидемиология өлкәсендәге хәлләрен яхшыртуга, санитария эшен оештыруга кулланула юнәлтелә. Кайбер фикерләр соңыннан эштә гамәли кулланыш таба (мәс., медицина-санитария бюролары, санитария станцияләре, Бактериология ин-ты, микробиол. станция һәм лаб-ялар ачу).

*Әд.:* В а х и т о в М.Х., А л ь б и ц к и й В.Ю. Глашатай идей профилактической медицины // Казан. мед. журн. 1973. № 5.

*Г.Р.Заманова.*

**ДНЕПРО́В** Пётр Алексеевич (16.1.1919, Уфа губ., Минзәлә өязе Островка а. — 23.7.1974, Киев), Сов. Союзы Герое (27.2.1945), гв. майоры. Танкистлар мәктәбен тәмамлый (1941). Урта Азия геол. трестында топограф булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 44 нче гв. танк бригадасының танк батальоны командиры урынбасары (1 нче гв. танк армиясенең 11 нче гв. танк корпусы). Төньяк-Көнбатыш, Воронеж, 1 нче Украина, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Житомир-Бердичев, Львов-Сандомир (икесе дә — 1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945 тә) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 14–18 гыйнварында Польша терр-ясендәге сугышта батырлык күрсәтә: Д. җитәкләгән алдынгы разведка отряды Пилица елгасы ярына чыга, бригаданың бер өлешенә елганы кичүдә ярдәм итә, Бзура елгасы аша салынган миналанган күперне кулга төшерә, аны дошманга шартлатырга ирек бирми. Сугыштан соң Киев шәһәрендә «Облпромбытгаз» пр-тиесендә инженер булып эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДОБРЕНЬКО́В** Герман Александрович (15.10.1922, Казан), физик- химик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988). Казан технол. ун-тының атказ. проф. (1997). 1944 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый һәм 1945 тән шунда ук эшли, 1977–91 дә физик химия каф. мөдире. Хезмәтләре физик химия һәм теоретик электрохимиягә карый. Металл кобальтның аксым кушылмалары б-н үзара тәэсирләшү табигатен һәм факторларын исбатлый. Корылмалы өслекләрдәге ике органик кушылманың бергә йотылуын өйрәнүне башлап җибәрә. Катнаш кушылмаларның электродларда йотылу очраклары өчен металл-эремә фазалары чикләренең теоретик моделен тәкъдим итә. Йотыла торган катламнарны молекуляр-эксперименталь модельләштерү ысулын эшли. Резина һәм басма платалар җитештергәндә полимерларны металлаштыру алымнарын тәкъдим итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Коллоидная химия. К., 1960; К исследованию совместной адсорбции органических веществ на ртутном электроде // Электрохимия. 1969. Т. 5, вып. 7 (автордаш); Краткий курс физической химии. М., 1978 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДОБРОВО́ЛЬСКИЙ** Константин Эрастович (1867, Симферополь ш. — 13.12.1946, Киев), гигиена белгече, мед. д-ры (1904). 1896 елда Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. С.-Петербург клиник учреждениеләрендә, Новгород губ. Тихвин өязендә земство табибе булып эшли. 1901 дән Юрьев ун-тында, 1904 тән Хатын-кызлар мед. ун-тында (С.-Петербург), гигиена каф. приват-доценты (1904–09), 1910–14 тә Казан ун-тында, 1914–45 тә Киев ин-тында гигиена каф. профессоры һәм мөдире. Хезмәтләре гигиена һәм су тәэминаты мәсьәләләрен эшләүгә карый. 1902 елда чит илләргә (Берлин, Париж) суны озон б-н чистарту ысулларын өйрәнү өчен җибәрелә. Кире кайткач, С.-Петербургта озонлаштыру станциясе төзүдә, суны чистартуда табиблек контроле һәм күзәтчелеге булдыруда актив катнаша. Казанда Идел суы сыйфатын өйрәнә; бактериологик ысуллар б-н суның пычрану күрсәткечләрен билгели. Киевта шәһәр су тәэминаты чыганакларын — артезиан һәм Днепр суларын тикшерә, Днепр сууткәргече төзелешендә консультант була.

Х е з м.: Исследование чувствительности наиболее употребительных в санитарной практике способов определения каменноугольных красок. СПб., 1904.

*Әд.:* Памяти профессора К.Э.Добровольского // Гигиена и санитария. 1947. № 10.

**ДОБРОКВА́ШИН** Сергей Васильевич (27.5.1955, Чита ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1999). 1978 дә Казан мед. ин-тын тәмамлый. Россия мед. учреждениеләрендә эшли. 1986 дан Казан мед. ин-тында (хәзер Казан мед. ун-ты) травматология, ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе кафедрасында. Д.ның тикшеренүләре күчле хирургик авырулар, корсак һәм күкрәк читлеге органнарының травматик авырулары клиникасына, диагностикасына һәм аларны дәвалауга карый. Д. тарафыннан корсак ярысы тышындагы кан китүләр моделе эшләнелә, кан агу чыганакларының топограф-анатомик тасвирламасы, туплану формалары, локальләштерү зоналары һәм корсак ярысы тышындагы катламнарда таралу юллары бирелә; корсак травмалары вакытында корсак ярысы тышына кан китүләрнең клиник-анатомик классификациясен төзи; селектив дренаж ысулын патоморфологик яктан нигезли; корсак ярысы тышында кан китү б-н катлауланган корсак травмалары вакытында хирургның диагноз кую һәм дәвалау эшчәнлеге алгоритмын төзи.

Х е з м.: Забрюшинные кровоизлияния при закрытых травмах живота. Метод. рекомендации для врачей. К., 1990; Экспресс-метод диагностики глубины повреждения при закрытой травме живота // Казан. мед. журн. 1993. № 4 (автордаш).

**ДОБРОМЫ́Ш** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 60 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2008 елда 19 кеше (руслар) яши. 17–18 йөзләр арасында Сембер өязенең Үби авылы йомышлы татарлары нигез сала. Башта Топрамыш дип атала. 1750 елларда Д.тагы татарларны көчләп христианлаштыру башлана һәм алар тора-бара башка җирләргә күченәләр. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан Д. халкы — рус крәстияннәре (алпавыт Бестужевларның, 1764 тән соң Обуховларның крепостнойлары). Игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, чана һәм утын чанасы ясау, олаучылык б-н шөгыльләнәләр; алпавыт



П.А.Днепров.

утарында көнлекче булып эшлиләр. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Д.та поташ һәм май язу з-длары, су тегермәне, 20 йөз башында бакалея һәм казна шәраб, ипи кибетләре эшли. 1906 да бер сыйныфлы земство уч-щесе һәм почта-телеграф бүлекчәсе ачыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 182, 1795 тә — 200, 1834 тә — 405 ир-ат; 1870 тә — 816, 1897 дә — 752, 1926 да — 753, 1938 дә — 616, 1949 да — 436, 1958 дә — 323, 1970 тә — 201, 1979 да — 86, 1989 да — 13, 2002 дә — 22 кеше.

**ДОБРОСЕ́РДОВ** Дмитрий Константинович (24.10.1876, Самара ш. — 1.8.1936, Одесса ш.), химик, химия д-ры (1910). 1899 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1912 дән Киев, 1923 тән Одесса политехник ин-тлары профессоры. Хезмәтләре эремәләрнең һәм комплекслы кушылмаларның физика-химиясенә карый. Икеле тозларны һәм тозларның гидратларын, органик кушылмаларның диэлектрик константасын аның составы һәм төзелеше б-н бәйләнештә, ассоциацияләнмәгән сыек эреткеч катнашмаларның диэлектрик константасын өйрәнә.

Х е з м.: Хлорновато-кислый алюминий, его гидраты и ход его разложения при нагревании. К., 1904; Весы и взвешивание. Химические весы, их теория, испытание и употребление. К., 1905; Исследования диэлектрической постоянной смесей жидких неассоциированных органических растворителей. К., 1910.

*Әд.:* К о в а л ё в Т. Дмитрий Константинович Добросердов // Журн. прикладной химии. 1937. Т. 10, вып. 9.

**ДОБРОТВО́РСКАЯ** Светлана Георгиевна (18.11.1965, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2003). 1988 елда Казан ун-тының биол. ф-тын тәмамлаганнан соң, Казанда мәктәптә эшли. 1989 дан Казан ун-тының пед. һәм психол. кафедрасында, 1997 дән Казан технол. ун-тының инженерлык пед. һәм психологиясе кафедрасында, 1997 дән Казан ун-тының валеология һәм мед. белеме (2005 тән кризис һәм экстремаль хәлләр психологиясе) кафедрасында. Хезмәтләре студентларның сәламәт яшәү рәвешенә юнәлеш бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Педагогическая ориентация учащейся молодёжи на здоровый образ жизни. К., 2002; Проблемы антинаркотического воспитания молодёжи. К., 2002.

**ДОБРОТВО́РСКИЙ** Иван Михайлович (10.6.1832, Түбән Новгород губ. — 7.9.1883, Казан), чиркәү тарихчысы. Түбән Новгород руханилар семинариясендә укый (1852), Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1856), шунда ук укыта, экстраординар проф. (1864). 1865 елдан Халык мәгарифе министрлыгында. 1865–67 дә чит илләрдә командировкада (Германия, Греция, Мисыр, Палестина, Төркия) була. Кайтканнан соң, Көнбатыш Европадагы чиркәү тарихы фәне һәм Грек чиркәвенең торышы тасвирланган бәянат туплый. 1863 тән Казан ун-тының чиркәү тарихы проф. Хезмәтләре чиркәү тарихы, секталар һәм иске дин тарафдарлары хәрәкәте тарихына багышланган. Д.ның иске дин тарафдарлыгы һәм сектантлык буенча мәгълүм әсәрләре фаш иткеч тайпылуларсыз әзерләнгән. Ул шулай ук Соловки китапханәсендәге борынгы рус язма әдәби ядкәрләрен өйрәнү, тасвирлау һәм бастыру б-н шөгыльләнә; 1862 дә берничә кульязма буенча «Стоглав»ның тулы җыентыгын бастырып чыгара.

Х е з м.: Обращение иргизских старообрядческих монастырей к единоверию // Православный собеседник. 1858. Ч. 1; Отчёты о заграничной командировке // Журн. М-ва нар. просвещения. 1866. Т. 1. отд. 3; Т. 2. отд. 3; Т. 3. отд. 3; Люди Божие, русская секта так называемых духовных христиан. К., 1869.

*Әд.:* З е ф и р о в М.М. Иван Михайлович Добротворский, ординарный профессор Императорского Казанского университета по кафедре церковной истории. К., 1884; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1814–1904). К., 1904.

*Е.В.Липаков.*

**ДОБРЫ́НИН** Виталий Алексеевич (5.1.1923, хәзерге Кострома өлкәсе Парфеньево ш. — 2.5.1995, Казан), патологоанатом, онколог, мед. фән. д-ры (1968), проф. (1968). 1943 елда Киев хәрби мед. уч-щесен, 1952 дә Иваново мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1960 тан Кемерово мед. ин-тының патологик анатомия каф. мөдире, дәвалау ф-ты деканы. 1963 тән Кубань мед. ин-тында. 1969–93 тә Казан мед. ин-тында, 1989 га кадәр патологик анатомия каф. мөдире. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш патологоанатомы. Д.ның тикшеренүләре яман шешләр морфологиясе һәм клиникасы, тамырлар системасы морфологиясенең гадәти һәм патологик халәтенә карый. Д. инволютив һәм ялкынсыну процессларының үпкә рагы б-н бәйләнешен өйрәнә; бронхлар рагы б-н регенерация, бронхиаль эпителий метаплазиясе процессларының үзара тәэсирен ачыклый, куркынычлылык факторын билгели. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рак лёгкого. М., 1971 (автордаш); Морфология сосудистой системы в норме и патологии. К., 1977.

**ДОБРЯ́НКА РАЙОНЫ́**, *Пермь өлкәсенең* үзәк өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 5192 *км*². Үзәге — Добрянка шәһәре (Пермьнән 63 *км* төньяктарак). Халкы — 61365 кеше (2007), ш.и. 1575 (2002) татар. Алар күбесенчә район үзәгендә, Кыж, Дивья, Ярино һәм Түбән Лух посёлокларында яши. 1917 гә кадәр районда татарлар күп булмый. Д.р.на аларның күпләп күченүе (нигездә, махсус күчерелгән кешеләр арасында) 1930 елларда башлана. Күченү хәрәкәтенең яңа дулкыны 1950 елларда районда агач материаллары әзерләү тармагы үсү б-н бәйле. 1970–80 елларда Пермь ГРЭСы төзелгән чорда татарлар саны күпкә арта. Хәзерге вакытта Д.р. татарларының милли-мәдәни тормышы үзәге — Добрянка шәһәре. Монда татар-башкорт үзәге эшли, 1995 тә «Гүзәл» татар-башкорт ансамбле оештырыла, 1997 дән башлап ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә; 2000 дә мәхәллә оештырыла.

**ДОГА́ДОВ** Александр Иванович (8.8.1888, Казан губ. — 26.10.1938), дәүләт һәм профсоюз эшлеклесе. Россиядәге өч рев-циядә катнаша. 1918 елдан Металл эшкәртүчеләр берлеге секретаре һәм Профсоюзларның яшерен советы үзәк бюросы әгъзасы. 1909 дан Баку шәһәрендә төрле эшләрдә эшли. 1910 да Париж тирәсендәге Лонжюмо шәһәренә партия мәктәбенә укырга җибәрелә. 1911 дән Казанда. Прага партия конференциясе делегаты (1912). 1912 дә кулга алына һәм Вятка губернасына сөрелә. 1914–17 дә Россия армиясендә. 1918 дән — Казан сәнәгать р-ны профсоюзлары советы рәисе, 1920 дән — Профсоюзларның Татарстан советы рәисе. 1921–29 да СССР ВЦСПС Президиумы әгъзасы һәм секретаре, СССР Хезмәт һәм Оборона Советында ВЦСПС вәкиле. 1930 да СССР Халык хуҗалыгы югары советы рәисе урынбасары, 1931–34 тә Кавказ аръягы Совет Федератив Социалистик Республикасының эшче-крәстиян инспекциясе халык комиссары һәм ВКП(б)ның Кавказ аръягы край контроль комиссиясе рәисе. 1934 тән Свердловск өлкәсе буенча СССР ХКС каршындагы Совет контроле комиссиясе вәкиле. СССР БҮБК һәм ҮБК Президиумы әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Борцы за счастье народное. К., 1967; К о р о б е й н и к о в И.И., Т а н я е в А.П. Александр Догадов. К., 1971.

**ДО́ГЕЛЬ** Александр Станиславович (15.1.1852, Ковно губ. Поневежис ш. — 1922, Петроград), гистолог, мед. д-ры (1883). К.А.Арнштейн шәкерте. Нейрогистологлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач (1879), шунда ук эшли. 1888 елда Томск ун-тының гистология каф. мөдире, проф. 1895–1922 елларда Петербург ун-тында, бер үк вакытта, 1897 дән Женева мед. ун-ты гистология каф. мөдире. Хезмәтләре гистологиягә, нерв системасы, сизү органнарын өйрәнүгә карый. Д. хайваннарда тукымалар һәм органнардагы нерв аппараты очлыкларын җентекләп тасвирлый һәм өйрәнә; кеше һәм хайваннарда эчке органнар иннервациясен, мускуллар, тире бизләрен, арка миендәге кушылу юллары төзелешен тикшерә, нерв системасының чагыштырма гистологиясен бирә. Тере организмда нерв элементларын метилен зәңгәр б-н буяу гистологиядә киң кулланыла. Тасвирланган нервлар Д. исеме б-н атала. 1915 елда «Русский архив гистологии, эмбриологии и анатомии» ж-лын оештыра.

Х е з м.: Строение обонятельного органа у ганоид, костистых рыб и амфибий. К., 1886; Концевые нервные аппараты в коже человека. СПб., 1903.

*Әд.:* Д е й н е к а Д. Гистологическая школа Петербургского — Ленинградского университета // Вестник ЛГУ. 1947. № 12.

**ДО́ГЕЛЬ** Иван Михайлович (7.3.1830, Витебск губ. Залесье имениесе — 3.8.1916, Казан), фармаколог, мед. д-ры (1863). Россиядә эксперименталь фармакологиягә нигез салучыларның берсе. 1854 елда С.-Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлый, шунда ук 1854–65 тә хәрби госпитальдә эшли. 1865–68 дә Германиядә стажировка үтә. 1869 дан Казан ун-тында, фармакология каф. оештыра, 1916 елга кадәр каф. мөдире һәм профессоры. Даруларның фармакологик тәэсире мәсьәләләре, йөрәк эшчәнлегенә гликозидлар, мускарин һәм атропин алкалоидларының физиологик тәэсире буенча классик хезмәтләр авторы. Беренче булып, тәҗрибә юлы б-н борынның лайлалы тышчасындагы сизү нерв очлыкларын хлороформ парлары б-н ярсытып, йөрәкне рефлектор туктату мөмкинлеген исбатлый. Чума, холера, тиф эпидемияләрен бетерүдә катнаша; халык алдында лекцияләр сөйли. С.-Петербург хәрби мед. академиясе, Юрьев (хәзер Тарту) ун-тының шәрәфле әгъзасы. Фармакология дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Руководство к фармакологии (Рецептура). К., 1882; Основы фармакологии и рецептуры. СПб., 1900; Сравнительная анатомия, физиология и фармакология кровеносных и лимфатических сосудов. В 2 т. К., 1903–04.

**ДО́ГЕЛЬ** Михаил Иванович (11.9.1865, Германия, Гейдельберг ш. — 25.8.1936, Париж), хокук белгече, халыкара хокук гыйлеме д-ры (1900), хакыйкый статский советник (1913). И.М.*Догель* улы. Казан ун-тының физ.-матем ф-тын тәмамлый (1888), 1889–90 елларда Казан губерна идарәсендә, 1890–91 дә Сенатның (С.-Петербург) 5 нче департаменты канцеляриясендә. 1895–96 да Харьков ун-тында укыта. 1896–1900 дә Казан ун-тының халыкара хокук гыйлеме каф. приват-доценты, 1900–03 тә экстраординар проф., 1903–10 да ординар проф. 1905–07 елгы Рев-ция вакытында монархияне яклап чыга. 1911–17 дә Матбугат эшләре баш идарә советы әгъзасы (Петроград). 1914–17 дә Юрьев ун-тының полиция хокукы кафедрасы ординар профессоры. Октябрь рев-циясеннән соң эмиграциягә китә. 1923 тән Париж ун-тында укыта. Хезмәтләре хәрби хокук гыйлеменә, ш.и. хәрби оккупация мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Юридическое положение личности во время сухопутной войны. Комбатанты. К., 1894; О военном занятии. К., 1898.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета, 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ДОГМАТЧЫЛЫ́К** (грек. dógma — тәгълимат), билгеле бер кагыйдәләрнең тәгаен шартларны исәпкә алмыйча кулланугa, катып калган кануннарга таянуга нигезләнгән фикерләү ысулы. «Д.» атамасы борынгы грек скептиклары Пиррон һәм Зенон тарафыннан кертелә. Алар хак гыйлемгә ирешү мөмкинлеген инкарь итәләр, әйберләрнең асылы турында нинди дә булса ахыргы нәтиҗәләр барлыгын расларга омтылган философларны догматчылар дип атыйлар. Татар җәмәгатьчелегендә (аеруча 18–19 йөзләрдә) догмага нигезләнгән фикерләү кадими мәдрәсәләрдә формалаша һәм үсеш ала (к. *Кадимчелек*).

**ДОКУ́КИН** Иван Семёнович (27.12.1933, Удмурт Респ-касы, хәзерге Алнаш р-ны Кузюмово а.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1989). Киров а.х. ин-тын тәмамлый (1952). 1967 елдан Казан вет. ин-тында. 1984–89 да Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). Хезмәтләре мөгезле эре терлектә гемобластоз-лейкозларны өйрәнүгә карый. Беренче тапкыр гемобластозларның горизонталь таралуын һәм бозауларга сөт аша күчүен исбатлый. Төрле токымлы һәм яшьтәге мөгезле эре терлекләрнең лейкоз вирусы б-н зарарлануы ешлыгын билгели. Терлекләрдә бактериаль һәм вируслы авыруларга каршы иммунлаштырудан соң, гемобластозларның барлыгын ачыклау өчен серологик тикшерүнең оптималь вакытын билгели. Хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекләрдә гемобластозларны юк итүнең фәнни нигезләнгән чараларын тәкъдим итә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Изучение антигенных токсических свойств полимеров и их влияния на некоторые иммунобиологические показатели у морских свинок: Материалы док. науч. конф. // Казанский ветеринарный институт. К., 1967.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006). К., 2006.

**ДО́ЛГАЯ ПОЛЯ́НА** (Озын Алан) авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2008 елда 18 кеше (руслар) яши. Алпавыт Молоствовларның утар йорты — 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1890 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 52,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 117, 1897 дә — 135, 1908 дә — 292, 1920 дә — 121, 1926 да — 137, 1938 дә — 165, 1949 да — 250, 1958 дә — 212, 1970 тә — 140, 1979 да — 35, 1989 да — 26, 2002 дә — 10 кеше.

**ДОЛГО́В** Михаил Филиппович (27.8.1913, Уфа губ., Минзәлә өязе Сәвәләй а. — 18.12.2000, Казан). Татарстанда телевидение тапшыруларын оештыручыларның берсе. Ленинград совет төзелеше ин-тын тәмамлый (1937). 1937–40 елларда ТАССР ХХСның совет төзелеше мәктәбендә укыта. 1941–46, 1973–75 елларда Казанда партия эшендә. 1946–52 дә ТАССР МС каршындагы Радиокомитет рәисе. 1953–55 тә КПССның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире. 1955–58 дә хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1958–62 дә, ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-ты рәисе буларак, ТАССР телевидениесенең матди-техник базасын булдыру б-н җитәкчелек итә. 1963–73 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-ты нәшрияты директоры. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* «Небесные птицы» // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998.

**ДОЛГОРУ́КИЙ** (Долгоруков) Владимир Тимофеевич (1569–1633), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1607). Терекка юнәлдерелгән яуларда (1594, 1604–05), Ялган Дмитрий I не бәреп төшерүдә, Василий Шуйскийның Ялган Дмитрий II гә каршы көрәшендә, К.М.Минин һәм Д.М.Пожарский җитәкчелегендәге 2 нче земство ополчениесендә катнаша. 1615–17 елларда Казанда беренче воевода, Казан һәм Зөя өязләрендәге йомышлы һәм ясаклы татарлар кузгалышын бастыру б-н җитәкчелек итә (к. *Җангали хәрәкәте*). 1624 тән Патриархия идарәсе судьясы, 1628 дә Вологда шәһәре воеводасы. Д.ның кызы Наталья 1624 тә патша Михаил Фёдоровичка кияүгә чыга.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Сказания о роде князей Долгоруковых. СПб., 1842.

*Е.В.Липаков.*

**ДОЛГОРУ́КИЙ** (Долгоруков) Дмитрий Алексеевич (? — 7.11.1673, Архангельск ш.), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1671 тирәсе). Рус-поляк сугышында катнаша, Смоленск шәһәрен алганда (1654) батырлык күрсәтә. 1654–57 елларда Полоцк шәһәре воеводасы. 1659–61 дә Казанның беренче воеводасы. 1668–69 да Новгород шәһәрендә. 1672 дән Архангельскида воевода.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Сказания о роде князей Долгоруковых. СПб., 1842.

*Е.В.Липаков.*

**ДОЛГОРУ́КОВ** Михаил Владимирович (14.11.1667, Мәскәү — 21.11.1750, шунда ук), кенәз, дәүләт эшлеклесе, сенатор (1711), хакыйкый тайный советник (1729). 1685 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1724–28 дә Себер губернаторы. Себер һәм Уралны колонияләштерүдә катнаша, А.Шестаковның Чукоткага хәрби экспедициясенә булышлык итә. 1729–30 да Югары яшерен совет әгъзасы. 1730–31 дә Казан губернаторы. Аның вакытында икенче Кама аръягы чик буе киртәсен төзү башлана. 1731 дә Яңа чукындыру комиссиясен оештыруга булышлык итә һәм хөкүмәттән яңа чукынган әҗнәбиләрне 3 елга дәүләт ясакларыннан һәм бурычларыннан азат итүне күздә тоткан ташламаларны раслатуга ирешә. Императрица Анна Иоанновнаның самодержавиесен чикләүгә исәпләнгән «Кондицияләр» төзүдә катнашканы өчен, 1731 дә Нарва шәһәренә сөрелә, 1739 да Соловки монастырена ябыла, 1741 дән Шлиссельбург шәһәрендә тотыла. Тәхеткә императрица Елизавета Петровна утыргач, 1741 дә азат ителә, югары исемнәре һәм дәрәҗәләре, ә 1742 дән утарлары кире кайтарыла.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Сказания о роде князей Долгоруковых. СПб., 1842; ш у л у к. Российская родословная книга. СПб., 1854; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ДОЛЖЕНКО́В** Валерий Николаевич (20.11.1935, Новгород өлкәсе Иске Русса ш.), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1983), РФнең атказ. геологы (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), Чита геол.-разведка идарәсендә эшли. 1965 елдан ТатНИПИнефтьтә бүлек мөдире (1978–98), промысел геологиясе лаб. мөдире (1998 дән). Д. җитәкчелегендә ТР, Удмурт Респ-касы, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Себер нефть ятмалары запасларын исәпләү һәм эшкәртүне анализлау буенча геол.-промысел анализының һәм геофизик мәгълүматлар интерпретациясенең яңа ысуллары, ТРның Ромашкино һ.б. нефть чыганакларындагы терриген девон һәм карбон катламнарын классификацияләү принциплары эшләнә һәм гамәлгә ашырыла. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу классификации пластов-коллекторов в терригенных отложениях нижнего карбона // Нефть Татарстана. К., 1998 (автордаш).

**ДОЛОМЕ́Д**, к а й м а л ы  а у ч ы (Dolomedes fimbriatus), күчмә аучылар семьялыгыннан булган үрмәкүч. Россиянең барлык Европа өлешендә таралган. Татарстан терр-ясендә Лаеш, Яшел Үзән, Мамадыш р-ннарында күренә. Ана Д.ның озынлыгы — 13–18 *мм*, ата затныкы — 10–12 *мм*. Башкүкрәк һәм корсагы кызгылт көрән төстә, ян кырыйлары буйлап сары сызыклар сузылган, аяклары сары, кара төкчәле. Д., башка үрмәкүчләрдән аермалы буларак, ау ятьмәләре кормый, ә корбанын эзәрлекли. Суда һәм су янында яшәүче бөҗәкләр б-н туклана. Су өстеннән яхшы йөгерә, йөзә һәм чума. Кайвакыт балык маймычларына, чукмарбашларга һөҗүм итә. Аталанулары язын була. 3–4 атнадан соң ана Д. әзерләнгән кузыга 500–600 йомырка сала. Нәсел барлыкка килгәнче, хелицерлары б-н тотып, ул аны барлык җирдә дә үзе б-н йөртә яки яр буе үсемлекләренә асып куя һәм саклый. Яшь үрмәкүчләр җәй уртасында чыга. Агымсыз су буйларында, сазлык үсемлекләре арасында яши. Лишайниклы-мүкле, нарат җиләкле наратлыкларны, усаклык һәм су баса торган болыннарны үз итә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*О.Д.Любарская.*

**ДОЛОМИ́Т** (фр. геологы Гратё де Доломьё исеме б-н бәйле), 1) карбонатлар классы минералы, $CaMg[CO_3]_2$; составы: CaO — 30,4%, MgO — 21,9%, кушылмалары Fe, Mn, Zn һ.б. — 47,7%. Кристаллары пыяласыман ялтыравыклы ромбоэдрик, агрегатлары кристаллик-бөртекле. Төсе соргылт-ак, кайвакыт сарырак, көрәнсу яки яшькелт төсмерле. Катылыгы 3,5–4,0. Уалучан. Тыгызлыгы 2,8–2,9 *г/см³*. Гадәти темп-рада HClда (кальциттан аермалы буларак) кайнап чыкмыйча гына акрын эри. 2) 50% һәм аннан да күбрәк



Аметистлы доломит. Кама Тамагы районы.

Д. минералыннан торучы утырма тау токымы; Д. 25–49% булганда — доломитлы известьташ, 50–89% та — известьле Д. Кальцит, ангидрит, гипс, магнезит, сидерит һ.б. кушылмалар булырга мөмкин. Тыгыз яки каверналы-күзәнәкле була. Диңгезләрдә, диңгез култыкларында, күлләрдә известьле-магнезиаль ләм диагенетик үзгәргәндә, известьташлар метасоматик доломитлашканда, гидротермаль процесслар вакытында барлыкка килә. Эре, вак һәм яшерен кристаллик агрегатлар, гипергенезда еш кына ончыл. Барлык континентларның төрле яшьтәге утырмаларында таралган. Төп чыгаручы илләр — Бөекбритания, Канада, Япония, Россия. Дөньяда (елына млн. *т.* ларда) 40–60, РФдә — 20 гә якын, ТРда — 0,6–0,8 (известьташлар б-н бергә) чыгарыла. РФдә Урал сөзәклекләрендә, Идел елгасы ярларында һ.б. урыннарда табылган. ТР терр-ясендә Д. палеозой һәм венд яшендәге утырмаларда киң таралган. Аларда аның төрле: ак, соры, саргылт-көрән-соры, көрән, вак һәм сирәк кристаллы, балчык катламнары катнаш бөртекле, алевролит, известьташ, линза һәм тамырлар, ш.у. гипслы, ангидритлы һ.б. төсләләре һәм формалылары бирелә. Каверналы Д.ларда — нефть һәм битум ятмалары, тыгыз һәм көпшәк Д.ларда мәрмәр ониксы һәм аметист чагылышлары ачыкланган. Д.ның 72 чыганагы (известьташ б-н бергә) 71 млн. $м^3$ ка (2009) якын запас б-н югары Пермь яшендәге утырмаларда билгеләнгән. Мәс., Пәрәү чыганагында (Лаеш р-ны) Д. запаслары $A+B+C_1$ категорияләре буенча 3,6 млн. $т^3$ тәшкил итә. Д. магнезиаль известь, вакташ, утка чыдам материал, ясалма мәрмәр, ксилолит, фибролит, җылылыкны саклаучы материаллар, пыяла һ.б. ясау өчен яраклы; доломит оны ачы комсу туфракны известьләү өчен кулланыла.

*Әд.:* Сементовский Ю.В., Бобрикова Е.В. Минеральное сырьё. Доломит: Справ. М., 1998; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Ю.В.Сементовский.*

**ДОЛО́ТИН** Искәндәр Ишук улы (16.5.1937, Пенза өлкәсенең Городище р-ны Түбән Әләзән а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (1996), проф. (1996), ТРның атказ. агрономы (1993). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Югары Ослан р-нының «Приволжский» с-зында агроном һәм бүлекчә җитәкчесе булып эшли. 1965 елдан Казан а.х. академиясенең тәҗрибә кырлары мөдире, 1996–2006 да үсемлекчелек каф. мөдире. Д. җитәкчелегендә а.х. культураларын үстерүдә ресурс һәм энергия саклаулы технологияләр буенча тикшеренүләр уздырыла. Хезмәтләре соры урман туфракларын эшкәртү системасы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Система обработки почв Среднего Поволжья. М., 1995; Безотвальная система обработки почвы в Татарстане. К., 1998; Сахарная свёкла. К., 2000; Возделывание сои в Юго-Восточной зоне Татарстана. К., 2003.

**ДОЛОТКА́ЗИН** Али (Гали) Гомәр улы (1901, хәзерге Мордва Респ-касының Кадошкин р-ны Зур Полянка а. — 1987), профсоюз эшлеклесе. Татар коммунистик ун-тында (Казан, 1930–33), ВКП(б) ҮК каршындагы Партия оештыручылары югары мәктәбендә (Мәскәү, 1943–45) укый. 1915–17 елларда Әстерханда: Шибаев икмәк пешерү ширкәте эшчесе. 1917–19 да Донбасста шахтер. 1919–23 тә Кызыл Армиядә, В.И.Чапаев исем. 25 нче дивизия разведчигы. 1923–30 да Донбасс шахталарында (бүленеп) эшли. 1925 тә ВКП(б) сафларына керә. 1930 дан Казанда: 1933–34 тә мех ф-калары парткомының оештыру бүлеге мөдире, 1934–36 да ВКП(б)ның Казан шәһәре Сталин райкомы өлкән инструкторы, секретарь урынбасары, 1936–37 дә Бауман райкомы секретаре, 1937–38 дә Киров райкомы 1 нче секретаре, 1938–39 да ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты секретаре. 1939–43 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тының кадрлар буенча секретаре. 1945–48 дә ВЦСПСның ТАССРдагы вәкиле, 1948–53 тә Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1953 тән Казан тимер юлларының сәяси бүлеге башлыгы урынбасары. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. ТАССР ЮС депутаты (1947–55).

*Әд.:* Мирсияпов Т.А., Фомин А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: история, опыт, проблемы (1905–1995 гг.). К., 1995.

**ДОМБА́РОВКА РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсендә* урнашкан. 1927 елда оештырыла. Мәйданы — 3567,4 $км^2$. Үзәге — шәһәр тибындагы Домбаровка посёлогы. Халкы — 19039 (1.1.2009) кеше, 415 татар (2002). Районда яшәүче татарларның күбесе монда 1950 елларда — яткын һәм чирәм җирләрне үзләштерү чорында төпләнә. Татарларның бер өлешен уку йортларының геол. ф-тын тәмамлап төрле елларда Д.р.на юллама б-н эшкә җибәрелгән белгечләр тәшкил итә. Район торак пунктларында татар телендә җирле телевидение тапшырулары трансляцияләнә.

**ДОМБРО́ВСКИЙ Б.Л. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казандагы «Үзәк басмаханә» («Центральная типография»). 1894 елда элегрәк китап басу эше б-н бөтенләй шөгыльләнмәгән теш табибе Бронислав Людвигович Домбровский барлык җиһазлары б-н Г.М.Вечеслав басмаханәсен сатып ала. Ул полиграфия басмаларының сыйфатлы башкарылуын тәэмин итүче белемле оста хезмәткәрләрне үзләренең эш урыннарында калдыра. 1898 дә басмаханәдә — 38, 1915 тә 45 хезмәткәр була. 1894–1900 дә анда татар телендә 1,5 млн. тираж б-н 173 исемдә китап, башлыча, әлифбалар, уку китаплары, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, Ф.Хәмди, Һ.Максуди, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими хезмәтләре, геометрия һәм тарих дәреслекләре, Коръәннең 10 басмасы, 6 догалык һ.б. дини-әхлакый эчтәлекле китаплар нәшер ителә. Татар телендә иң күп китап (45 басма) 1899 да чыга. Башлыча, татар нашире М.Г.Кадыйров һәм Шәмсетдин Хөсәенов варислары заказлар бирә. Татар телендә А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», Л.Н.Толстой хикәяләренең 5 җыентыгы, Г.Х.Андерсен «Әкиятләр»е, Г.Рәшиди, М.Гафури, Ф.Кәрими, Ф.Халиди хикәяләре, ш.у. казакъ телендә китаплар басылып чыга. 1917 гә кадәр 6 млн. га якын тираж б-н 624 исемдә татар китабы нәшер ителә.

1899 ның сентябреннән басмаханәдә Казан руханилар академиясе һәм Изге Гурий борадәрлеге хезмәтләре, «Известия по Казанской епархии», «Православный собеседник» ж-ллары, Г.С.Саблуков тәрҗемәсендә Коръән, чуаш телендә «Хыпар» г-тасы, П.М.Дульскийның «Иске Казан истәлекләре» («Памятники Казанской старины», 1914) исемле китабы басылып чыга. Әлеге басмалар «Үзәк басмаханә» исеме б-н чыгарыла. Сов. хакимияте тарафыннан дәүләт карамагына алына.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

**ДО́МИНОВ** (Дәминов) Рәшит Рәүф улы (12.12.1946, Әстерхан ш.), театр рәссамы, нәкышьче, график. СССР САнең И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура ин-тын, театр декорацияләре нәкыше остаханәсен тәмамлый (1972). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1975). С.-Петербургта яши. Мәскәү, С.-Петербург, Казан, Тула һ.б. шәһәр театрларында 20 дән артык спектакльнең куючы-рәссамы. Ул бизәгән спектакльләрдән — С.-Петербургтагы Keче драма т-рында Н.А.Островскийның «Корыч ничек чыныкты» («Как закалялась сталь») романы буенча куелган «Язлар белән сиңа кайтырмын» (1977), А.Калягин җитәкчелегендәге «ЕТ CETERA» т-рында Юджин О'Нил пьесасы буенча куелган «Офыклар артында» (1995), Мәскәүдәге А.Н.Островский исем. Дәүләт драма т-рында А.Н.Островский пьесасы буенча куелган «Урман» (2003) һ.б. «Биш кичә»



Р.Р.Доминов. «Канал». 1992.



Р.Р.Доминов. «Бабур». 1998.

(1987), «Пейзаж геометриясе» һәм «Төш» (1988), «В. Хлебниковның «Ладомир» поэмасына фрагментлар» һ.б. график әсәрләр авторы. 1980 нән нәкышь сәнгате өлкәсендә актив эшли: «Минем эти-әнием» (1985), «Автопортрет. Күп еллар аша» (1986–88), «Балачак», «Һиндстан буйлап» (икесе дә — 1986–90), «Җәй» һәм «Көй» (1988), «Иделдә» (1989), «Диңгез буенда» (1990), «Канал» (1992), «Бүлмә саен» (1996), «Әңгәмә» (1997), «Бабур» (1998) һ.б. Д. иҗатына хас төп сыйфатлар — өлкән кеше карашыннан бәяләнүче балачак хатирәсе сюжетлары, Италия Ренессансы, Шәрекъ сәнгате йогынтылары чагылган, романтика вакыт кысасына сыймаган һәм чынбарлыкның театрлаштырылган романтик гәүдәләнеше, башка образлы үрнәкләр.

Чит илләрдә (Германия, Франция, Япония, Польша, Куба, Монголия) узган, бөтенсоюз һәм респ-ка күргәзмәләрендә, Ленинград һәм Мәскәүнең 26 рәссамы әсәрләреннән торган күргәзмәдә (Ленинград, Мәскәү, 1990), төбәкара бөтентатар «Татарт» күргәзмәсендә (С.-Петербург — Казан, 1991) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1983 елда (Тбилиси, Ленинград, Мәскәү), 1993 тә (Миккеле ш., Финляндия), 1996 да (Мәскәү), 1997 дә (Кохэм ш., Германия), 1998 дә һәм 2001 дә (С.-Петербург) уза. Хезмәтләре Дәүләт Рус музеенда (С.-Петербург), Грузия сәнгать музеенда (Тбилиси), Әстерхан, Барнаул, Вологда, Воронеж, Томск, Хабаровск һәм Россиянең башка шәһәрләрендәге картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Мейланд В. Живописные серенады Рашида Доминова // Столица. 1994. № 30; Мочалов Л. Рашид Доминов // Картинная галерея. 1998. № 3/4; Свистунова Ю. Творчество Доминова // Deluxe. 1998. № 2; Логвинова Е. Рашид Доминов: о себе и о времени // Empire of Art. Дек. 2001 — янв. 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ДОМОЛА́ЗОВ** Степан Васильевич (1885, Казан губ., Мамадыш өязе Албай а. — 30.1.1938), хәрби җитәкче. Татар милләтеннән. Керәшен укытучылар әзерләү үзәк мәктәбен тәмамлаганнан соң (1906), хәрби хезмәткә алына. Казан прапорщиклар мәктәбен (1910), Варшава хәрби фехтование мәктәбен, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен (читтән торып укып, 1915), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1925, Мәскәү) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында штабс-капитан Д. Георгий тәресе б-н бүләкләнә. Гражданнар сугышында Казан губернасының Мамадыш өязе хәрби комиссары, 28 нче дивизия (ком. В.М.*Азин*) составындагы 39 нчы полк командиры була. Д. полкы Көнчыгыш фронтта адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы сугыша, 1920 елда Көнбатыш фронтта ак поляклар б-н сугышта катнаша. Гражданнар сугышын Д. дивизия командиры буларак тәмамлый. 1923–25 тә ТАССР хәрби комиссары. 1937 елга кадәр Дон һәм Идел буе хәрби округларында җаваплы вазифалар башкара. Ике Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләр чоры корбаны, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Фёдоров А.Ф. Октябрьские зори. М., 1962; Борцы за счастье народное. К., 1967. Кн. 1; Глухов-Ногайбек М. Казанский Ретро-Лексикон. К., 2002.

**ДО́МРАЧЕВ** Георгий Владимирович (6.2.1894, Вятка губ., Малмыж өязе Әҗим а. — 7.4.1957, Казан), вет. клиникасы белгече, вет. фән. д-ры (1936), ВАСХНИЛның мөхбир әгъзасы (1955), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1948). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1919), шунда ук эшли, клиник диагностика каф. мөдире (1926–37, 1954–57). 1938–48 дә Мәскәү хәрби-вет. академиясендә шул ук исемдәге каф. башлыгы. 1948–50 дә физиотерапия һәм рентгенология каф. мөдире, бер үк вакытта Мәскәү вет. академиясе проректоры. 1950–54 тә Мәскәү хәрби-вет. академиясенең клиника һәм хәрби-кыр вет. терапиясе каф. башлыгы. А.х. терлекләренең йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары тәгълиматына нигез салучы. СССРда беренче булып терлек авыруларына рентген ярдәмендә диагноз куюны, үпкә, сары, чәнчү авырулары классификациясен эшли, терлекләрнең эндокрин системасы авыруларын өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Хезм.: Клиническая диагностика болезней лошадей. М., 1945; Сборник по ветеринарной рецептуре. М., 1947; Аритмии и болезни миокарда у лошадей. М., 1950; Патология и терапия внутренних незаразных болезней сельскохозяйственных животных. М., 1960 (автордаш).

*Әд.:* Данилов Д.Ф. Памяти профессора Г.В.Домрачева. 1894–1957 // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. К., 1959. Т. 46; Курбанов Р.З. Г.В.Домрачев. К 100-летию со дня рождения // Ветеринария. 1994. № 2; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Р.Ж.Корбанов.*

**ДО́МРАЧЕВ** Иван Владимирович (26.10.1889, Вятка губ., Малмыж өязе Әҗим а. — 28.4.1960, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1926), проф. (1936), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). А.В.*Вишневский* шәкерте. 1913 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, шунда ук анатомия кафедрасында В.Н.*Тонков* б-н, бер үк вакытта хирургия кафедрасында эшли. 1914 елда армиягә алына, 1915 тән Казан хәрби госпиталендә хирургия бүлеге мөдире, 1917–21 дә Кызыл Армия күчмә-кыр госпитале баш табибе. 1931 дән Казан мед. ин-тында, 1936 дан ф-т һәм госпиталь хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта 3 нче шәһәр хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире. Фәнни хезмәтләре ашказаны, уникеилле эчәк җәрәхәтләре, простата бизе инервациясе мәсьәләләренә, ш.у. корсак куышлыгы һәм күкрәк хирургиясенең патологик процессларында организмның компенсатор һәм алмаш функцияләрен өйрәнүгә карый (операцияләрнең төрле вариантларын төзи). Д. һәм аның шәкертләре тарафыннан организмда матдәләр алмашы процесслары (холестерин, май, аксым һәм су алмашы) мәсьәләләре өйрәнелә. Д. корсак куышлыгы органнары ялкынсынганда новокаин блокадасының бер төрен эшли; эчәк анастомозы вакытында эчәк җөе методын, кетгутны «коры» стерильләштерү ысулын тәкъдим итә. Д. 30 мең катлаулы операция ясый. Аны «халык профессоры» дип олылыйлар. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Заболевания грудной клетки, позвоночника и молочной железы. К., 1933; К вопросу об оперативном лечении рака толстых кишок // Казан. мед. журн. 1938. № 11/12; К технике оперативного вмешательства по поводу... // Хирургия. 1954. № 8.

*Әд.:* Николаев Г.М. Народный профессор. К., 1982.

**ДО́МРАЧЕВА** Евгения Алексеевна (27.12.1891 — 2.6.1984, Казан), стоматолог, хирург, мед. фән. д-ры (1951), проф. (1956), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1961). 1915 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казан мед. учреждениеләрендә эшли. 1943–72 елларда Казан мед. ин-тында, 1956–68 дә хирургик стоматология каф. мөдире. Д. Бөек Ватан сугышы елларында казналык-бит өлкәсендәге яра җәрәхәтләрен дәвалау ысулларын эшли. Д. җәрәхәтләрне беренчел рациональ эшкәртү һәм организмдагы тукыма б-н ябыштыру юлы б-н дәвалау системасын нигезли; стоматология гамәлендә Вишневский ысулы б-н урынлы анестезия үткәрүне кертә.

Хезм.: Ранняя пластика при ранениях лица. К., 1954.

**ДОН-УРА́Й** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 8 *км* көньяктарак, Урай елгасы буенда. 2008 елда 105 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 58%, татарлар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1917 елга кадәрге рус чыганакларында Донауровский Урай, Богородский исемнәре б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чүлмәк ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 4 чүлмәк ясау остаханәсе, 2 сыраханә, казна шәраб кибете, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1326 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 523 ир-ат; 1859 да — 779, 1897 дә — 911, 1908 дә — 1205, 1920 дә — 1184,

1926 да — 1180, 1989 да — 132, 2002 дә — 161 кеше.

**ДОНАУ́РОВКА** посёлогы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 19 йөз башында нигез салына. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында кибет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 389 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. 2001 нең 27 гыйнварында авыллар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1859 да — 41, 1897 дә — 86, 1908 дә — 139, 1920 дә — 168, 1926 да — 189, 1938 дә — 192, 1949 да — 186, 1958 дә — 65, 1970 тә — 20, 1979 да — 10, 1989 да — 5 кеше.

**«ДОНБА́СС ЭШЧЕСЕ́»**, газета. Профсоюзларның бөтенукраина советы, Украина КП(б)ның Сталино өлкә ком-ты, хезмәт ияләре депутатлары өлкә советы органы. 1930 елның 29 ноябреннән 1939 ның 23 февраленә кадәр Сталино шәһәрендә (хәзер Донецк) татар телендә нәшер ителә, барлыгы 1008 саны чыга. 1937 нең 29 июленә кадәр «Пролетар» исемендә була. Беренче мөхәррире Б.Мансуров. Авторлар арасында А.Әхмәтшин, М.Вәлиев, И.Курманай, Х.Маннапов, М.Сөндекле һ.б. бар. Газетада эшче хәбәрчеләрдән Г.Басыйров, Г.Закиров, А.Җаббаров, Г.Нуретдинов, З.Шакиров һ.б. актив язышa. Донбасс шахталарында һәм металлургия з-дларында эшләүче татар эшчеләренә атап чыгарыла. Индустрияләштерүнең, соц. ярышларның барышын яктыртуга зур игътибар бирелә, произ-во алдынгылары турында очерклар басыла. Редакция эшчеләр өчен татар телендә чыгучы башка газеталар б-н элемтәдә тора. «*Баку эшчесе*» г-тасы б-н берлектә Донбасс эшчеләре һәм әзәрбайҗан нефтьчеләре арасындагы соц. ярыш барышына багышланган алмаш битләр чыгарыла. Горловка, Енакиево, Кадиевка, Макеевка, Чистяково шәһәрләрендә чыгучы татар газеталарыннан материаллар күчереп бастырыла.

*Т.М.Насыйров.*

**ДО́ННИК** (Melilotus), кузаклылар семьялыгыннан икееллык, сирәгрәк берьеллык үсемлекләр ыругы, терлек азыгы культурасы. Яфраклары өч тармаклы, чәчәкләре вак (якынча 7 *мм*), сары һәм ак төстә, куентыкларда чук чәчәкләр урнашкан. Җимеше — 1, сирәгрәк — 2, яисә 4 орлыклы ачылмый торган кузак. Якынча 25 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Африка, Төньяк Америка һәм Австралиядә очрый. Татарстанда 2 төре игелә: сары Д, яисә дару Д. (M. officinalis), ак Д. (M. albus). Д. аксым, витаминнар һәм тозларга бай. Кышкы суыкларга, корылыкка чыдам, карбонатлы, известькә бай туфракны өстен күрә, тозлы туфракларны тозсызландыра, азот б-н баета һәм бу туфракта а.х. культураларын үстерү өчен шартларны яхшырта. Д. чәчелгән туфракта 300 *кг/га* кадәр азот туплана. Д. — бөртекләләр һәм башка культуралар өчен яхшы элгәр санала; көтүлек, печәнлек, силос, сенаж сидераль культуралар сыйфатында игелә; уңышы һәм терлек азыгы буларак люцерна һәм клевердан калышмый. Чәчәк ату вакытында 100 *кг* яшел массада 18,5–19,5 азык берәмлеге һәм 3,1–3,2 *кг* үзләштерелә торган протеин, 100 *кг* печәндә — 44–44,5 азык берәмлеге һәм 11,1–11,9 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Яз, җәй һәм көз көне тар һәм киң рәтле ысуллар б-н чәчәләр. Орлыкларны чәчү нормасы 2–5 *см* тирәнлектә гектарга 20–25 *кг.* Сары Д. һәм ак Д. якынча уңышы һәм азык сыйфаты буенча бер үк мөмкинлекләргә ия. ТРның а.х.да файдалануга тәкъдим ителгән сортлары: ак Д.ның — «Кинельский» (1984), «Медет» (1987), «Поволжский» (1998) һәм сары Д.ның — «Альшеевский» (1996). Республика хуҗалыкларында чәчү мәйданы якынча 20 мең *га* тәшкил итә. 1 *га* дан 200 *ц* дан артык яшел масса һәм 30–50 *ц* печән алына. Д. баллы үсемлек, бал кортлары аңа салкынча вакытта да киләләр. Д.та булган хуш исле кумарин матдәсе аны тәмәке һәм шәраб сәнәгатендә һәм сыр ясаганда файдаланырга мөмкинлек бирә, авыру терлекләргә савыктыргыч тәэсир ясый.

*Әд.:* Артюков Н.В. Донник. М., 1973; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*Х.З.Кәримов.*

**ДО́НОВ** Георгий Макарович (9.4.1921, Казан — 3.1.1996, Бөгелмә ш.), нефтьче-геофизик, РСФСРның атказ. геологы (1982). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948), «Татнефтегеофизика» ҖБндә, трестның баш геологы (1953 елдан), санлы эшкәртү һәм интерпретация партиясенең баш геологы (1985–89). Татарстанда (Бондюг, Яңа Елховой һ.б.), Удмурт Респ-касы, Ульянов һәм Оренбург өлкәләрендәге, Себердәге нефть ятмаларын ачучыларның берсе. Хезмәтләре нефть чыганакларын өйрәнүгә һәм геофизик алымнар б-н эшкәртүгә карый. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1970, 1973). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ДОҢГЫРА́**, традицион татар музыка уен коралы, көтүче барабаны. Бәрмә идиофон. Калынлыгы 25 *мм*, озынлыгы 400–500 *мм*, киңлеге 150–200 *мм* булган коры каен яисә чыршы тактасыннан шомартып эшләнгән киң яңгырашлы уен коралы. Тактаның югары очы бөтерелгән формада. Тактаның кырыйлары на симметрик рәвештә яртылаш бөгелгән ике кадак сугыла, шуның ике очына каеш бәйләнә. Д.ны муенга эләләр. Ул функциональ кулланылышлы уен коралы: башкаручы талдан эшләнгән махсус таякчыклар б-н ритмик сигналлар шакылдата. Көтүчеләр Д.ны иртән — хайваннарны көтүлеккә куу, кичен аларны абзарга куып кертү, ябу өчен куллана. Иртә б-н Д.га кушылып: «Ачыгыз капканы, чыгарыгыз малларны!», кич белән: «Көтү кайтты, көтү кайтты, малларны каршылагыз!» — диган сүзләр әйтелә.

Тавыш ритмы астында көтүче Д.да әлеге сигналларны кабат-кабат башкара. Көндез исә көтүлектә, төрледән-төрле ритмик сигналлар шакылдатып, хайваннарны су эчерү урынына, утламга яки башка урынга җыя.

*Р.Ф.Халитов.*

**«ДОПОЛНЕ́НИЕ К ТЕЛЕГРА́ФНОМУ БЮЛЛЕТЕ́НЮ КАЗА́НСКОГО О́КРУГА ПУТЕ́Й СООБЩЕ́НИЯ»**, к. «*Известия Казанского округа путей сообщения*».

**ДОРГА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 32 *км* төньяктарак, Кугубор (Чутай) елгасы буенда. 2008 елда 292 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 16 йөздә удмуртлар нигез сала. 18 йөз уртасында Д.га керәшеннәр килеп урнаша. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1872 дә ачыла, 1914 тә земство мәктәбе итеп үзгәртелә), кәшәнә, тегермән, вак-төякләр һәм бакалея кибетләре эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда. 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 77, 1763 тә — 78, 1795 тә — 129 ир-ат; 1884 тә — 723, 1897 дә — 755, 1920 дә — 777, 1926 да — 655, 1949 да — 413, 1958 дә — 307, 1970 тә — 303, 1979 да — 278, 1989 да — 262, 2002 дә — 290 кеше.

**ДОРМИДО́НТОВ** Григорий Фёдорович (30.9.1852, Пенза губ. Городище ш. — 16.5.1919, Казан), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1895), хакыйкый статский советник (1902). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1876), шунда ук эшли, Рим хокукы кафедрасының профессор стипендиаты (1880 елга кадәр), 1883–84 тә приват-доценты, 1884–95 тә экстраординар, 1895–1908 дә ординар, 1908 дән атказ. профессоры; бер үк вакытта 1896–1905 тә һәм 1907–09 да юридик ф-т деканы, 1909–18 дә ректор. Хокук белемендә социологик юнәлеш тарафдары. «Мирас төзүченең бурычларына карата варисларның җаваплылыгы» («Об ответственности наследников по обязательствам составителя наследства», 1881), «Күчемсез милекне бүлүгә мирас кануннарының йогынтысы турында» («К вопросу о влиянии законов о наследстве на распределение недвижимой собственности», 1885), «Алдашу-ялганга корылган юридик көнкүреш күренешләрен классификацияләү» («Классификация явлений юридического быта, относимых к области применения фикций», 1895) кебек төп хезмәтләре башка һәм яңа законнарда чагылыш тапкан мирас хокукының гаилә мөнәсәбәтләренең гомуми характеры б-н нык бәйләнешен дәлилләүгә багыш-

ланган. «Рим хокукы системасы» («Система римского права», 1–4 чыг., 1909–15) хезмәтендә фактик материалга таянып шәхси хокук ин-тларына чагыштырмача-тарихи анализ бирә.

Х е з м.: Римское наследственное право. К., 1900; Римское семейное право. [У.К.], [В.К].

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904, Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Бибилиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ДОРН** Борис Андреевич (Иоганн Альбрехт Бернгард (29.4.1805, Шейерфельд, Саксен-Кобург герцоглыгы — 19.5.1881, С.-Петербург, Смоленск лютеран зиратында җирләнгән), рус шәркыятьче галиме, Петербург ФА академигы (1842). Иран һәм семит филологиясе, әфганлылар, Кавказ һәм Каспий буе халыкларының тарихы һәм этнографиясе белгече. Кобург шәһәрендә гимназия тәмамлый, югары белемне Галле һәм Лейпциг шәһәрләре ун-тларында ала (1822–25). Шәркыятьче галим Х.Ф.Френ тәкъдиме б-н Харьков ун-тында Шәрекъ телләре кафедрасын җитәкли, анда гарәп һәм фарсы телләрен укыта (1829–35). Петербург ун-ты проф. (1835–81), монда санскрит һәм әфган телләрен укыта. Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты Шәрекъ телләре ин-тында Шәрекъ тарихы һәм географиясе турында лекцияләр укый (1835 елдан). ФАнең Азия музее директоры (1842 дән). Немец һәм француз телләрендә Шәрекъ белеменә караган хезмәтләр авторы, Dugat, «Histoire des orientalistes» — «Шәрекъ белеме тарихы» (Р., 1868) китабында урын алган хезмәтләрнең библиографик исемлеген төзи, ш.у. Җәмәгать китапханәсенең (С.-Петербург) гарәп, фарсы һәм төрки кульязмаларын тасвирлый. Шәрекъ телләрендә Казанда китап басу тарихына караган бай фактик материал аның фәнни кыйммәтен югалтмаган «Chronologisches Verzeichnis der seit dem Jahre 1801 bis 1866 in Kasan gebruchten arabischen, türkischen, tatarischen und persischen Werke» («1801 дән 1866 кадәр Казанда гарәп, төрек, татар һәм фарсы телләрендә чыккан басмаларның хронологик тасвирламасы», St.-Pb., 1866. B. 1) исемле хезмәтендә урын алган. Д. архивы РФА архивында саклана.

Х е з м.: Академик Френ и его учёная деятельность // Уч. зап. Академии наук. 1855. Т. 3, вып. 3; Азиатский музей Императорской Академии наук // Уч. зап. Академии наук. 1864. Т. 5, вып. 2.

*Әд.:* Б р о к г а у з Ф.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1893. Т. 11; История исторической науки в СССР. Дооктябрьский период: Библиография. М., 1965; Библиогр. словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1974; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992.

**ДОРО́ДНОВ** Анатолий Васильевич (4.5.1908, Сембер губ., Сызрань өязе Усолье а. — 14.11.1988, Казан), математик, физ.-матем. фән. канд. (1940). Н.Г.*Чеботарёв* шәкерте. 1937 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, алгебра каф. мөдире (1971–76). Хезмәтләре алгебрик функцияләр теориясенә, төзүгә карата геометрик мәсьәләләрдә Галуа кулланылышларына карый. Циркуль һәм линейка ярдәмендә түгәрәк (Гиппократ) чокырчыкларны квадрирлау проблемасын тулысынча чишә. Бер үзгәрешле алгебраик функцияләр кырының аскырлары теориясен үстерүгә өлеш кертә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О квадрируемости круговых луночек при помощи конических сечений // Изв. физ.-матем. об-ва. Сер. 3. 1945. Т. 13; Случай существования подполя у гиперэллиптического поля алгебраических функций // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн.26.

**ДОРО́ЖКИН** Валерий Петрович (28.7.1946, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1987), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004), РФнең атказ. химигы (2006), РФнең мактаулы югары һөнәри белем мәктәбе хезмәткәре (1997). 1969 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 1989 дан Түбән Кама химия-технол. ин-тында химия һәм химия технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре полимерларның физик химиясе, югары молекуляр кушылмаларның кинетикасы һәм катализына, шин сәнәгате өчен каучук синтезлауга һәм шин җитештерү технологиясен яхшыртуга карый. Яңа тип полиуретаннар эшли һәм сәнәгатькә кертә (ш.и. космик техникага). Полиуретаннарның химик, топологик һәм молекуляр төзелеше б-н аларның үзлекләре арасында микъдари һәм сыйфат бәйләнешләрен күрсәтә. Нефть-химия производствосында кайбер калдыкларны файдалану химиясе һәм технологиясенә, шин җитештерүне арттыруга кагылышлы тикшеренүләре «Түбәнкамашин» АҖдә гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Определение химической микроструктуры уретановых термоэластопластов с помощью теории регулярных марковских цепей // Докл. АН СССР. 1986. Т. 287, № 3 (автордаш); Образование, структура и свойства сетчатых полиуретанов // Успехи химии. 1989. Т. 8, вып. 3 (автордаш); Математико-статистические методы контроля и управления технологическими процессами. К., 1998 (автордаш); Шины. Некоторые проблемы эксплуатации и производства. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ–КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.



В.А.Дорофеева.



З.И.Досаева.

**ДОРОФЕ́ЕВА** Валентина Александровна (24.7.1937, Оренбург өлкәсенең Богырыслан р-ны Яңа Кудрино а.), нефть һәм газ скважиналарын эксплуатацияләү операторы, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1975, 1981, 1986). Богырыслан нефть промыселы техникумын тәмамлый (1955). 1956–87 елларда «Әлмәтнефть» НГДУның нефть промыселында эшли. Бер пр-тиедә күп еллар эшләгәне һәм хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен орден һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И в а н о в а Г. Главное в жизни // Бесценное богатство. К., 1993; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ДОРОЩУ́К** Елена Сергеевна (29.11.1961, Казан), журналист, педагог, пед. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук эшли: радиотапшырулар редакторы, 1986 елдан педагогика кафедрасында, 1990 нан журналистика кафедрасында, 1998 дән массакүләм электрон мәгълүмат чаралары теориясе һәм практикасы каф. мөдире. Хезмәтләре журналистларны проф. әзерләү методикасына карый.

Х е з м.: Искренность без предела: Педагогика и психология журналисткой деятельности. К., 2000; Деятельностная модель журналистики: Материалы для развития творческих способностей студентов-журналистов. К., 2001.

**ДОСА́ЕВА** Земфира Исхак кызы (12.10.1937, Мәскәү), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1987). Сәхнә эшчәнлеген Әстерхан шәһәре Нариман р-ны халык театрының татар труппасында башлый, анда ул әтисе





З.И.Д о с а е в а: 1. Нина (А.Д.Салынский. «Зарыгып көткәнем», сулда Ф.Фарсин); 2. Гөлүзә (Ю.Әминев. «Өти балак», уңда У.Гилев) рольләрендә.

Исхак Әхмәтҗан улы Досаев (1907–58) һәм әнисе Сылухан Минһаҗ кызы Досаева (1910–76) б-н бергә уйный. 1964 елда Казанда Республика күчмә театры труппасына (хәзер К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры) кабул ителә. 1974 тә Мәскәүдә Театр сәнгате ин-тын тәмамлый. Ю.Әминевнең «Өти балак» пьесасы буенча куелган спектакльдә шәфкатьлелеге, туры сүзлелеге һәм ихласлыгы б-н тамашачы күңелен яулаган яшь кыз Гөлүзә образын башкарып, үзен сәләтле актриса итеп таныта. Күркәм тышкы кыяфәткә, сәхнә тәэсирлелегенә һәм темпераментына ия Д. образлар өстендә эшләгәндә үткен характерлылыктан курыкмый, ышандырырлык көнкүреш детальләрен дә актив куллана. Т.Миңнуллинның «Алай түгел, болай ул» әсәре буенча куелган спектакльдә (1978) төрле яшьтәге дүрт хатын-кыз (яшь кыздан алып карчыкка кадәр) ролен башкарып, һәрберсенә аерым сурәтләү чаралары таба, төрле образларда үзгәрүгә сәләтен күрсәтә. Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә Д. әхлакый яктан бербөтен, психол. тирән, ачык формалы, кабатланмас образлар галереясы булдыра. Алар арасында Самавырчы малай («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Бану («Доклад», К.Тинчурин), Ячучы карчык («Галиябану», М.Фәйзи), Гайнавал («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җиһан («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Зөлфия («Бөркетләр кыяга оялый», И.Юзеев), Фәридә, Әминә, Хөрия («Шомырт чәчәк атканда», «Шикәрем син, балым син», «Ефәк баулы былбыл кош», А.Гыйләҗев), Фәүзия («Әнә килә автомобиль», Ф.Яруллин), Расиха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Мәдинә («Җәяүле Мәхмүт», М.Кәрим), Галя («Трибунал», А.Е.Макаёнок), Нина («Зарыгып көткәнем», А.Д.Салынский), Клава («Ситуация», В.С.Розов) бар.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ДӨБЪЯ́З** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Касыйм елгасы буенда. 2008 елда 1773 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Сөт з-ды, төзү пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу, аны сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да 2 мәчет, мәктәп, тимерче алачыгы, 2 ярма яргыч, 5 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1739,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз р-ны үзәге. 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 163 ир-ат; 1859 да — 930, 1897 дә — 1235, 1908 дә — 1448, 1920 дә — 1299, 1926 да — 1375, 1938 дә — 1428, 1949 да — 1211, 1958 дә — 1330, 1970 тә — 1352, 1989 да — 1580, 2002 дә — 1684 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ДӨБЪЯ́З РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Дөбъяз авылы. 1920 гә кадәр район биләмәсе Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) һәм Казан өязләренә, 1920–30 елларда ТАССРның Арча кантонына керә. Оештырылган көннән Д.р.нында 60 авыл советы, 98 торак пункт була, аларда 59002 кеше яши, ш.и. татарлар — 42653, руслар — 16349 кеше. Районның чикләре һәм адм.-терр. бүленеше берничә тапкыр үзгәртелә. 1935 тә Д.р.ның күп кенә авыл советлары яңа оештырылган Биектау р-нына бирелә. 1940 та аның мәйданы — 827 *км²*, халкы — 40,3 мең кеше була, районга 28 авыл советы, 72 торак пункт керә. 1960 та авыл советлары — 13, торак пунктларның саны 66 га кала. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Д.р. бетерелә, терр-ясе Яшел Үзән р-нына бирелә. 1965 елда элеккеге Д.р.ның торак пунктлары Биектау р-ны составына керә.

**ДӨГӘНӘ́К**, ч ә н ч ү  ү л ә н е (Echinops), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, икеһәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 130 га якын төре билгеле, Евразия һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә ике төр: рус Д. (E. ruthenicus) һәм йомры башлы Д. (E. sphaerocephalus) үсә. Идел алды һәм Кама аръягында очрый. Тау битләрендә, чүпле урыннарда үсә. 30–180 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры — үзәк, юан. Сабагы туры, гади яки өске өлешендә аз гына ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, өске ягы куе яшел, аскы ягы ак, киезсыман, чәнечкеле, каурыйсыман теленмә, кырыйлары тешле. Чәчәкләре ике җенесле, зәңгәр, көпшәсыман, бер чәчәкле кәрзиннәрдә, шарсыман түгәрәк чәчәк түркеменә җыелган. Җимеше — куе булып төшеп торучан бүрекчәле орлыкча. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Декоратив, баллы һәм дару үләне. Җимешләреннән үзәк нерв системасы эшчәнлеген көчәйтүче «Эхинопсин» даруы ясыйлар.

**ДӨМБЕРИ́**, ш ө л д е р л е  б а р а б а н, традицион татар бәрмә музыка уен коралы (мембранофон-шөлдер). Кыршау бер яктан күн б-н тышлана. Кыршау тишекләренә кечкенә оркестр тәлинкәләре формасындагы металл пластинкалар беркетелә. Кыршау эчендә тартылган берничә бауга кечкенә шөлдерләр эленә. Ансамбль б-н уйнау тәҗрибәсендә Д. кызу темптагы җырлар һәм бию көйләрен башкарганда көйнең ритмын бизәү өчен кулланыла. Д.нең күнле ягына уч төбе б-н бәреп, яки аны селеккәләп чыгарган авазлар көйне башкару процессына җыйнаклык һәм ансамбль төзеклеге бирә.

*Р.Ф.Халитов.*

**«ДӨНЬЯ́ ВӘ МӘГЫЙШӘ́Т»**, журнал, к. *«Дин вә мәгыйшәт»*.

**ДӨҢГЫ́Р** (Дөңгыр-Надыйрова) Рабига Рәхмәтулла кызы (1903, Оренбург губ. Каргалы бистәсе — 1984, Оренбург ш.), көмешче. Атаклы Каргалы *зәргәрләре* нәселеннән. Зәркәнчелек эшенә әтисеннән өйрәнә. Эш коралларын, җайланмалар һәм калыпларны аннан мирас итеп ала. Нәселдән-нәселгә күчеп килгән көмешчеләр һөнәре Каргалыда 18 йөздә үк үсеш ала. Д.ның ире, Хурхә авылы (Дагстан) кешесе чечен Али, ш.у. зәркәнчелек б-н кәсеп итә, җепкыр бизәкләр әзерләү б-н шөгыльләнә. Хосусый гаилә артеле җепкыр һәм металлдан коеп ясау ысулы б-н алтыннан һәм көмештән хатын-кызлар һәм ирләр бизәнү әйберләре (алкалар, бил каптырмалары, беләзек-йөзекләр, балдаклар һ.б.) җитештерә. Д. олыгайганчы әлеге һөнәрен ташламый, коеп ясау ысулы б-н мөһерле йөзекләр һәм алкалар, муенсалар, балдаклар эшли, кулланучылар соравы буенча *каралту* һәм *уеплау* б-н бизәлгән тар һәм киң көмеш беләзекләр әзерли. Д. ясаган әйберләр Оренбург татарлары, казакълар, башкортлар арасында киң тарала, Казанда да сатыла. Д.ның эшен аның улларының берсе — Әнвәрбәк Җандаров дәвам иттерә (Оренбургта яши).

*Р.Г.Шаһиева.*

**ДӨРЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Туйма елгасының сул кушылдыгы (Кама елгасы бассейны). Озынлыгы 8,3 *км*, бассейнының мәйданы 24,9 *км²*. Менделеев р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Рус Сарсазы авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Тайгуҗа авылыннан 1,4 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 28%. Д. елгасының 3,4 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,51 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 144 *мм*, ташу агымы катламы 117 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче декадасында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ДӨЯ́ ҮЛӘНЕ́**, т е к ә н ә к (Corispermum), алабутачалар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 60 ка якын төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә өч төре үсә. Иссоп яфраклы Д.ү. (C. hyssopifolium), Маршалл Д.ү. (C. marschallii) елгаларның комсыл ярлары буенда, салынкы Д.ү. (C. declinatum) Кама алды чәчүлекләрендә еш очрый. 10–45 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы төбеннән ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, тар. Чәчәкләре бик вак, күзгә ташланмый, яфрак куентыгында берәрләп урнашкан. Маршалл Д.ү.ндә чәчәк тирәлеге юк, чәчәкләре тыгыз кыска башакка җыелган. Җимешләре яссы, еш кына канатлы. Июль–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Кәҗә һәм сарыклар өчен көтүлек азыгы. Комны ныгытучы үсемлекләр.

**ДРА́ВЕРТ** Пётр Людвигович (Людвикович) (4.1.1879, Вятка ш. — 12.12.1945, Омск ш.), революцион хәрәкәт эшлеклесе,

геолог-минералог, шагыйрь, прозаик. 1897 елдан Казанда. 1899 да Казан ун-тының физ.-матем. ф-тына укырга керә, аны 1914 тә тәмамлый. 1901 нең февралендә студентлар чуалышларында катнашканы һәм 1905 тә революцион эшчәнлеге өчен ике тапкыр ун-ттан чыгарыла. Казан революционерлары берләшмәсе җитәкчеләренең берсе, эсерларның студентлар түгәрәкләрен җитәкли. 1905 тә Казанда агитация һәм пропаганда алып бара, «Волжский листок» г-тасында сәяси яктан үткен эчтәлекле шигырьләр бастыра, 16 октябрьдә ун-т бинасы түбәсенә кызыл әләм элә. 1906 ел башында Якутиягә сөрелә, 1910 да Томскига күчә. 1912–18 дә Казанда яши, җирле с.-д. оешмасы б-н хезмәттәшлек итә; фәнни экспедицияләрдә катнаша; әдәби эш б-н шөгыльләнә, «Камско-Волжская речь» г-тасында хикәяләр, шигырьләр, очерклар бастыра. 1917 дә с.-д. партиясенең шәһәр ком-тын җитәкли, «Голос труда» г-тасы мөхәррире була. 1918 дә Казан губернасындагы, Урал һәм Себердәге җитештерүче көчләрне өйрәнү җәмгыяте оештыра. 1914–18 дә Казан ун-тында укыта, проф. (1918). 1918–30 да Омск а.х. ин-тында, 1920 дән минерал., геол. һәм кристаллография каф. мөдире. 1930 дан Омск төбәкне өйрәнү музеенда. Илнең иң зур метеоритология белгечләренең берсе. 1927 дән Омск метеорит комиссиясен җитәкли, 1939 дан СССР ФАнең Метеоритлар ком-ты әгъзасы. Д. Себер терр-ясенә төшкән 7 метеоритны, Омск тирәсендә каолин төркеме минералы — ермакитны таба. Тупланмаларын Казан ун-тының минерал. һәм геол. кабинетларына бүләк итә.

Хезмәтләре минералогия, метеоритика, гидро- һәм инженерлык геологиясенә карый, ш.и. Чистай соры күмере, Тәтеш кантонының Пермь утырмаларында никель һәм бакыр кушылмалы минераллар табылу турындагы язмалары бар. Шигырь җыентыклары авторы. Беренче шигырьләр китабы — «Күләгәләр һәм кайтавазлар» («Тени и отзвуки») — 1904 тә, «Шигырьләр» («Стихотворения») җыентыгы 1913 тә басылып чыга. Рус География җәмгыятенең Көнбатыш Себер бүлекчәсе хакыйкый әгъзасы (1914 тән) һәм рәисе (1922–23). СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1940).

Х е з м.: Полезные ископаемые Омско-Тарского края. Омск, 1933; Метеориты, наблюдения над их падением и их поиски. Омск, 1944; Стихи о Сибири. Омск, 1958; Северные цветы: Стихи. Новосиб., 1968; Незакатное вижу я солнце: Стихи, проза. Новосиб., 1979.

*Әд.:* Ч и р в и н с к и й П.Н. Пётр Людвигович Драверт // Зап. Всерос. минерал. об-ва. 1946. Ч. 75, вып. 4; Пётр Людвигович Драверт // Омский альманах. 1947. Кн. 6; Русские писатели. 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1992. Т. 2.

*Е.Б.Долгов, С.И.Ионенко.*

**ДРА́МА** (грек. dráma — хәрәкәт), драматургиянең трагедия һәм комедия б-н бер рәттәге төп жанры. Максаты — шәхесне аның башка кешеләр, мохит б-н катлаулы мөнәсәбәтләре аша күрсәтү. Геройлар әхлакый эзләнүләр һәм рухи үсеш процессында тасвирланалар; ләкин аларга, асылда, трагик геройлардан аермалы буларак, гадәттән тыш сыйфатлар хас түгел. Д. кискен каршылыклар, коллизияләр тудырырга омтыла, ләкин андагы конфликтлар трагедиядәге кебек үк киеренке була алмый, һәм алар, ахыр чиктә, уңай хәл ителергә дә мөмкин.

Татар әдәбиятында беренче Д.лар — гаилә, кешенең аңлы-белемле булуы мәсьәләләренә багышланган пьесалар (Г.Исхакый — «Өч хатын берлән тормыш», 1900; Г.Камал — «Бәхетсез егет», 1900–1907). 20 йөз башында Г.Коләхмәтов («Ике фикер», 1906; «Яшь гомер», 1908), Г.Исхакый («Алдым-бирдем», 1907; «Мөгаллим», 1908; «Тартышу», 1908), Ф.Әмирхан («Яшьләр», 1909) Д.га шәхес һәм мохит, шәхес б-н җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләр, иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен алып керәләр. Д.ның романтик (М.Фәйзи — «Кызганыч», 1914; Г.Исхакый — «Мөгаллимә», 1913), психологик (Г.Камал — «Дәҗҗал», 1911; Г.Исхакый — «Зөләйха», 1907–1912), тарихи (Ф.Туйкин — «Ватан каһарманнары», 1912) h.б. төрләре мәйданга килә. Совет чорында Д. жанрында К.Тинчурин («Сүнгән йолдызлар», 1923; «Кандыр буе», 1930), Ф.Бурнаш («Адашкан кыз», 1926), Һ.Такташ («Югалган матурлык», 1927), Т.Гыйззәт («Чаткылар», 1934; «Ташкыннар», 1937), Ә.Фәйзи («Тукай», 1938), эмиграциядә Г.Исхакый («Дулкын эчендә», 1938) уңышлы иҗат итәләр. Бөек Ватан сугышы чорында һәм аннан соңгы елларда Т.Гыйззәт («Изге әманәт», 1944), Н.Исәнбәт («Мәрьям», 1944), М.Әмир («Миңлекамал», 1944; «Тормыш җыры», 1945), Р.Ишморат («Үлмәс җыр», 1956) h.б.ның Д.лары языла. 1960–70 елларда Х.Вахит («Туй алдыннан», 1969), Ю.Әминев («Минем җинаятем», 1968; «Кан кардәшләр», 1972), Ш.Хөсәенов («Әни килде», 1970), Т.Миңнуллин («Ир-егетләр», 1971; «Үзебез сайлаган язмыш», 1973), А.Гыйләҗев («Әңгер-меңгер», 1970; «Хушыгыз, тургайлар», 1978), И.Юзеев («Кыр казлары артыннан», 1976) h.б.ның Д.ларында хезмәт кешесе язмышы, замана үзенчәлекләре чагылыш таба. 1980 еллар уртасыннан татар Д.сында кискен конфликтларга, шәхеснең эчке дөньясындагы каршылыкларга, халыкның рухи һәм милли тормышы мәсьәләләренә, дин әһелләре образларына игътибар көчәя (Т.Миңнуллин — «Хушыгыз!», 1990; «Илгизәр + Вера», 1991; «Сөяркә», 1996; И.Юзеев — «Ак калфакның югалган чагы», 1991; Р.Хәмид — «Олы юлның тузаны», 1986; З.Хәким — «Карак», 1994; «Телсез күке», 2006; М.Гыйләҗев — «Яра», 2003 (А.Гыйләҗев повесте буенча); Д.Салихов — «Чукрак», 1998 h.б.). Үзгәртеп корулар чорына кергәч, татар Д.сының традицион булмаган форма-чаралар, модернистик алымнар б-н баюы, «явызлык театры», «абсурд театры» элементларыннан файдалануы күзәтелә (Т.Миңнуллин — «Саташу», 2001; З.Хәким — «Җүләрләр йорты», 1996–2004; «Шайтан куентыгы», 1999; Д.Салихов — «Алла каргаган йорт», 1996; М.Гыйләҗев — «Баскетболист», 2002; Ф.Бәйрәмова — «Вакыйга җүләрләр йортында бара», 1998; А.Хәлим — «Кияү урлау», 1985–2004 h.б.).

*Әд.:* З а к и р ж а н о в Ә. Заман белән бергә. К., 2004; Ә х м ә д у л л и н А. Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе. К., 2007; А х м а д у л л и н А.Г. Татарская драматургия. М., 1983.

*А.Г.Әхмәдуллин.*



Н.Г.Драцкий.

**ДРАЦЕ́НА** (Dracaena), агавачалар семьялыгыннан мәңге яшел агачсыман һәм куакчыл үсемлекләр ыругы. 150 гә кадәр төре билгеле. Чыгышы — Азия һәм Африка тропиклары. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Киң таралганнары: исле Д. (D. fragrans), Деремень Д. (D. deremensis), Годсеф Д. (D. godseffiana), Гукер Д. (D. hookeriana), кәкре Д. (D. reflexa). Кәүсәләре еш кына ботаксыз, биеклеге 6 *м* га кадәр. Кайбер төрләренең (елан агачы) кабыгы лак ясауда кулланыла торган кызыл чәер («елан каны») бүлеп чыгара. Яфраклары кыяклы яки ланцетсыман, тыгыз, озынлыгы 1 *м* га, киңлеге 8 *см* га кадәр, ачык һәм куе яшел төстә, кайвакыт яфрак буйлап ак полоса яки күп санда ак таплар була; кырыйлары дулкынлы яки дугасыман бөгелгән. Чәчәкләре ак яки сары, гадәттә, себеркәчтә, яңа чабылган печән яки бал исле (бүлмә шартларында сирәк чәчәк ата). Өске ботакларыннан үрчетелә. Талымсыз, ярым күләгәдә яхшы үсә.

**ДРА́ЦКИЙ** Николай Григорьевич (1.6.1930, БАССРның Фёдоровка р-ны Гавриловка а. — 20.5.1982, Әлмәт ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1966). Ишембай нефть техникумын тәмамлаганнан соң (1950), ТАССР нефть сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. 1962–72, 1974–82 елларда «Татнефть» җитештерү берләшмәсенең Әлмәт бораулау эшләре идарәсендә мастер. 1972–74 тә Мангышлак бораулау эшләре идарәсендә бораулау җайланмасы башлыгы. Д. бригадасы беренчеләрдән булып кечерәйтелгән диаметрдагы борау б-н бораулауга күчә. Герой исеме бораулау эшләрен оештыруда һәм технологияләрне камилләштерүдәге уңышлары, нефть скважиналарын бораулауда ирешелгән югары күрсәткечләре өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; М и р о л ю б о в а И.М. Драцкий Николай Григорьевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Ларичева Э.И. Дороже золота. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ДРЕГА́ЛИН** Анатолий Фёдорович (9.10.1936, Ленинград өлкәсенең Павловск ш.), жылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1972), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1982, 1987), Казан техник ун-тының атказ. проф. (1997).

1960 елда Казан авиация ин-тының очкыч аппаратлар двигательләре ф-тын тәмамлый, 1964 тән шунда ук эшли, проф. (1973), махсус двигательләр каф. мөдире (1989 дан), бер үк вакытта Казан техник ун-ты каршындагы Авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика ин-ты директоры (1999–2006 да). Хезмәтләре двигательләрдә һәм энергия җайланмаларында химик ягулык б-н югары темп-ралы процесслар теориясенә һәм аларны хисаплау ысулларына карый. Д. җитәкчелегендә ракета техникасы өчен төрле химик ягулыклар энергиясенең нәтиҗәлелеген фаразлау мәсьәләсе чишелә; реакциягә керүче күп компонентлы гомоген һәм гетероген катнашмаларының тигезләнеш халәтен универсаль хисаплау ысулы эшләнә. Ракета двигательләрендә сыек, каты һәм гибрид ягулыкларның янучанлыгын хисаплау ысуллары аның тарафыннан тәкъдим ителә һәм җитештерүдә гамәлгә кертелә. Д. — «Яну продуктларының термодинамик һәм термофизик үзенчәлекләре» дигән («Термодинамические и теплофизические свойства продуктов сгорания», М., 1971–80) 10 томлы белешмәлек авторларының берсе. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1984, 1991). «Почёт», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчет химического равновесия и процессов при высоких температурах. М., 1966 (автордаш); Общие методы теории высокотемпературных процессов в тепловых двигателях. К., 1974 (автордаш); Теория ракетных двигателей. М., 1989 (автордаш); Основы теории физико-химических процессов в тепловых двигателях и энергетических установках. М., 2000.

**ДРЕЙССЕ́НАЛАР** (Dreissena), ике кабырчыклы моллюсклар ыругы. 10 нан артык төре билгеле, Татарстан терр-ясендә ике: күпрәвешле Д. (D. polymorpha) һәм Буг Д.ы (D. bugensis). Д. кабырчыгы яшькелт-сары төстә, 3–5 *см* озынлыкта, алгы өлеше очланган. Личинкалары — иркен йөзүче велигерлар. Су асты предметларына беркетелү өчен биссус сыекчасы бүлеп чыгаручы махсус бизләре б-н башка кабырчыклы моллюсклардан аерыла. Үрчемле, нык булулары аркасында Д., 1 $м^2$ га 16 меңгә кадәр үрчеп, 10 *м* тирәнлеккә кадәр колонияләр барлыкка китерә. Татарстанда Д. елга тамакларында, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында очрый. Д. колонияләре гидротехник корылмаларның — су агызгычлар, торбалар эшен кыенлаштыра.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**ДРЕСВЯ́ННИКОВ** Александр Фёдорович (29.8.1959, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (2001). 1982 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре электрохимик ысуллар б-н металлар алуга, сулы эремәләрдәге дисперс металларда бара торган гетероген процесслар кинетикасына, сыек һәм каты металлы техноген мохитләрне эшкәртү технологияләренең фәнни нигезләрен һәм ысулларын эшләүгә карый. Металл өслегенең питтинг тутыгуга тотрыклылыгын арттыру шартларын билгели һәм югары лигерланган корычларны, хром-никель эретмәләрен саклау ысулын тәкъдим итә. Коаксиаль диафрагмасыз электролизёр күләмендәге түбән концентрацияле сулы эремәләрдә pH үзгәрү эффектын раслый, pH ның электрохимик коррекцияләү процессын көчәйтү юлын күрсәтә һәм матем. тасвирламасын бирә. Ташландык һәм табигый суны каты катышмалардан чистарту өчен коаксиаль электрохимик реактор, сыек техноген мохиттән цинк, кадмий, никель, ак кургашын, кара кургашын һәм бакыр аерып алу, тимер һәм алюминий нигезендә ике һәм күп компонентлы металл композицияләр алу ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Электрохимическая очистка воды. К., 2004 (автордаш); Кинетика контактного осаждения железа на алюминиевую основу // Защита металлов. 2005. Т. 41, № 6; Физикохимия наноструктурированных алюминийсодержащих материалов. К., 2007 (автордаш).

**ДРО́БИЖЕВА** Леокадия Михайловна (13.1.1933, Мәскәү), социолог, этнолог, тарих фән. д-ры (1981), проф. (1986), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1999). Мәскәү ун-тының тарих ф-тын тәмамлаганнан соң (1955), урта техн. уч-щедә укыта (Мәскәү). 1958 дән СССР ФАнең Тарих ин-тында, 1969–99 да СССР ФАнең Этнография ин-тында (Мәскәү): өлкән фәнни хезмәткәр, директор урынбасары (1982 дән), милли мөнәсәбәтләрнең соц.-психол. проблемалары секторы мөдире (1986 дан), бер үк вакытта Мәскәү ун-тының Белем күтәрү ин-тында укытучы. 2000–05 тә РФАнең Социология ин-ты директоры, 2005 тән шул ук ин-тның «Милләтара мөнәсәбәтләрне тикшерү» үзәге җитәкчесе. Икътисад югары мәктәбе ун-тының гомуми социология каф. профессоры (Мәскәү). Д. — Россия социологиясендә этносоциология юнәлешенә юл салучыларның берсе, шәхес һәм төркем дәрәҗәсендәге милләтара мөнәсәбәтләрне өйрәнү инициаторы һәм оештыручысы. ТАССРда үткәрелгән социологик тикшеренү материалларына нигезләнеп, СССРда Этносоциология буенча төзелгән беренче китапның («Социаль һәм милли» — «Социальное и национальное», М., 1972) автордашы һәм фәнни мөхәррире. РФ республикаларында милли, этник үзаң, социаль тигезлек, конфликтларны көйләү һәм толерантлык проблемаларын хәл итү өчен Татарстан тәҗрибәсе тәкъдим ителгән халыкара проект җитәкчесе. Д. тарафыннан халыкара мөнәсәбәтләр типологиясе, либераль милләтчелек теориясе эшләнә.


Х е з м.: Историко-социологические очерки межнациональных отношений. М., 1981; Демократизация и образцы национализма в Российской Федерации. М., 1996; Социальная и культурная дистанции. Опыт многонациональной России. М., 1998 (автордаш); Социальное неравенство этнических групп: представления и реальность. М., 2002 (автордаш); Социальные проблемы межнациональных отношений в постсоветской России. М., 2003.

**ДРОЗОФИ́ЛАЛАР** (Drosophila), җимеш чебеннәре семьялыгы ыругы. Лат. Д. — чык, дым яратучы. 1200 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә melanogaster D., funebris D., virilis D. торак, яшелчә һәм җиләк-җимеш складларында тереклек итүче синантроп төрләре гадәти санала. Үсемлекләр согы, черек органик матдәләр, личинкалары микроорганизмнар б-н туклана. Д. ареалының киңәюе кешеләрнең чебеннәрне яшелчә һәм җиләк-җимешләр б-н бергә күчерүенә бәйле. Олы затлары кышлый. Аеруча җимеш чебеннәре melanogaster D. киң таралган. Соры төстә, озынлыгы 3 *мм* га якын, күзләре — ачык кызыл. Д. генетиканың классик объекты булып тора. ТР ФА Табигать системалары экологиясе ин-тында мониторинг һәм биоиндикация системасында кулланыла торган melanogaster Д. (500 буыннан артык) чебеннәрнең берничә лаборатор линиясе 20 елдан артык эшләп килә.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. Л., 1970. Т. 5; О к у л о в а С.М., Г р и н ь к о Р.А., К а л и н н и к о в а Т.Б. Влияние промышленного загрязнения атмосферы на эколого-генетические параметры дрозофилы и рыжей полёвки // Казан. мед. журн. 1994. № 1.

*С.М.Окулова.*

**ДРОТОЕ́ВСКИЙ ЙОРТЫ́**, Казанда ампир стилендәге архит-ра ядкәре. 19 йөзнең 1 нче яртысында төзелеп, бик аз санда сакланып калган йортларның берсе. 1837 дә алпавыт Дротоевский өчен арх. Ф.И.Петонди проекты буенча төзелә. Классицизм һәм ампир стильләре архит-расы өчен типик саналган планировкада кирпечтән һәм агачтан салынган ике катлы агач йорт. 1 нче катта хезмәтчеләр яшәгән. 2 нче катны хуҗалар биләгән, анда зур тәрәзәләре урам якка караган кунак-түшем заллары һәм алардан коридор б-н аерылып торган, тәрәзәләре ишегалдына чыккан торак бүлмәләре булган. Алгы якның



Казанда Дротоевский йорты.
Архитекторы Ф.И. Петонди. 1837.

1 нче каты сылап агартылган, 2 нче кат такта б-н тышланган, тышлыкка агачтан кисеп ясалган бизәкләр беркетелгән. Йортның баштагы торышы үзгәрешләр кичергән.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Классицизм в казанском зодчестве. К., 1920; О с т р о у м о в В.П. Казань. Очерки по архитектуре и планировка города. К., 1978; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Т.В.Пашагина.*

**ДРУ́ЖБА** (Дуслык) авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 147 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57%, руслар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, бакчачылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 дә Иске Пьяный

Бор, Дыреевка авылы кешеләре нигез сала. 1929 да авылда «Дружба» к-зы оештырыла, соңрак ул Минзәлә с-зына керә. Оештырылган көннән Д. ТАССРның Минзәлә кантоны Минзәлә волостенда. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1926 да — 69, 1949 да — 296, 1958 дә — 294, 1970 тә — 401, 1979 да — 280, 1989 да — 185, 2002 дә — 169 кеше.

**ДРУ́ЖБА** (Дуслык) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй–Сарман автомобиль юлы буенда. 2008 елда 53 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1930 елларда Ләке авылы кешеләре нигез сала. Оештырылган көннән — Сарман р-нында. Халык саны: 1938 дә — 176, 1949 һәм 1958 дә — 152, 1970 тә — 159, 1979 да — 125, 1989 да — 86, 2002 дә — 58 кеше.

**ДРУ́ЖБА** (Дуслык) посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 49 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2008 елда 140 кеше (татарлар) яши. Урман сәнәгате хуҗалыгы, әрҗә ясау цехы. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1948 дә агач әзерләү участогы посёлогы буларак нигез салына. Башта — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 661, 1979 да — 499, 1989 да — 333, 2002 дә — 181 кеше.

**ДРУЖИ́НИН** Алексей Иванович (1866, Кострома губ., Макарьев өязе Макарово а. — 1933 елдан соң), дин белгече, педагог, дин белеме магистры (1900), протоиерей (1909). 1891 дә Казан руханилар академиясен тәмамлый. 1893 тән Казан руханилар семинариясе каршындагы үрнәк башлангыч мәктәптә укытучы, 1895 тән Казан епархиясенең чиркәү-приход мәктәпләрендә рухани һәм кузәтүче. 1896 дан Казан руханилар академиясендә доцент, 1904–17 елларда педагогика профессоры. Бер үк вакытта, 1897–1902 дә Казан укытучылар ин-тында канунлар укытучысы, 1903–18 дә Казанның Николо-Низский чиркәве башлыгы, 1897–1917 дә епархия уч-щесе советы әгъзасы, 1903–17 дә кызлар гимназияләрендә, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында, хатын-кыз укытучыларга белем бирүче Казан земство мәктәбендә педагогика, дидактика, Ходай кануннарын өйрәнү методикасын укыта. 1920–33 тә Биектау р-нының Усад авылы чиркәве башлыгы. 1933 нең мартында кулга алына, октябрендә азат ителә.

Х е з м.: Образцовая школа при Казанской духовной семинарии за первое десятилетие её существования (1885–1895). К., 1895; Жизнь и труды Дионисия Великого, епископа Александрийского. К., 1900; Образование и нравственность. К., 1904. Значение молитвы в жизни христианина по учению Иоанна Кронштадского // Православный собеседник. К., 1910. Ч. 1; Методика Закона Божия. Курс педагогических классов женских гимназий и учительских школ. К., 1916.

*Е.В.Липаков.*

**ДРЯ́БЛОВ ЙОРТЫ́**, к. *Михляев йорты.*

**ДРЯ́БЛОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. Авдотья Ивановна Михляева (кыз фамилиясе Д.) һәм аның бертуганы Афанасий Иванович Д., Казан сәүдәгәре И.А.*Михляев* үлгәннән соң (1728), аның мөлкәтенең, ш.и. аларга гомерлеккә бирелгән Казан постау мануфактурасының төп мирасчылары булалар. Мануфактурага 530 крәстиян хуҗалыгы беркетелгән була. Афанасий Ивановичның оныгы Иван Фёдорович Д. (15.9.1728 — 24.11.1774, Казан) — Казан сәүдәгәре,голштиния коммерция советнигы, Казан постау мануфактурасы хуҗасы; эшчеләрнең хезмәт хакларын күпкә киметә (к. *Казан постаучылары кузгалышлары*). 1767–69 елларда Казанның беренче шәһәр башлыгы. 1767 да Казанда булганда императрица Екатерина II аның йортында туктый. 1774 тә Е.И.Пугачёвның баш күтәрүчеләр гаскәрләре Казанны алганда Д.ның оныгы Александр һәм кияве И.А.Родионов Воскресенский чиркәве болдырында үтерелә. Бу хәл Иван Фёдоровичның һәм аның хатыны Федосья Гавриловна Осокинаның (? — 1.12.1774) үлемен тизләтә. Д. мөлкәте И.П.Осокинга мирас булып күчә (к. *Осокиннар*).

*Әд.:* А г а ф о н о в Н. Казань и казанцы. К., 1906. Т. 1; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**ДРЯ́ГИН** Кузьма Амфилохиевич (3.10.1897, Казан — 1974, Ленинград), терапевт, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1939), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). 1923 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Казан ун-тының мед. ф-тында госпиталь терапиясе клиникасында, 1930–53 елларда Казан мед. ин-тында шул ук клиникада эшли. 1943 тән госпиталь терапиясе, 1944 тән эчке авырулар пропедевтикасы кафедралары мөдире, 1953–69 да Ленинград педиатрия мед. ин-тында госпиталь терапиясе каф. мөдире. Д. Боткин авыруы, бавыр авыруыннан һуш китү, бронхиаль астма, бөер агулану вакытында кан алмаштыруның әһәмиятен раслый. Стенокардия һәм ашказаны дискинезиясе авыруларын дәвалаганда муенга вагосимпатик новокаин блокадасын (Вишневский ысулы б-н) куллана.

Д. җитәкчелегендә Курган өлкәсендә «Озеро Медвежье» курортында Тарловка кымыз б-н дәвалау шифаханәсе төзелә (1928), ашказаны һәм үт юллары авырган кешеләрне дәвалау оештырыла; яңа бальнеологик фактор — күкертле-углекислый газлы балчык чыганагы ачыла һәм ревматизм авыруын дәвалау өчен кулланыла. Бөек Ватан сугышында катнаша, Ленин һәм «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние коры больших полушарий головного мозга на количество и состав мочи: Дисс.... К., 1939; К вопросу о переливании крови при болезни Боткина. Улан-Удэ, 1960; Лечение холециститов спиртовой настойкой листьев барбариса. Улан-Удэ, 1960 (автордаш).

**ДРЯ́НИЧКИН** Михаил Ефимович (4.12.1909, Казан губ., Тәтеш өязе Чинчурино а. — 30.1.1945, Катовице шәһәрендә җирләнгән, Польша), Сов. Союзы Герое (4.4.1945, үлгәннән соң), капитан. Кече командирлар мәктәбен (1933), Сәяси курслар (1940) һәм «Выстрел» курсларын (1943) тәмамлый. «Ашлык әзерләү» конторасында эшли. 1931–33 елларда һәм 1935 тән Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы фронтларында 1943 тән 904 нче укчы полкның батальон командиры (59 нчы армиянең 245 нче укчылар дивизиясе). Ленинград фронты һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Ленинград сугышында (1941–44), Сандомир-Силезия һөҗүм операциясендә катнаша. 1945 нең 31 гыйнварында Кендзежин (Польша) шәһәреннән көньяк-көнчыгыштарак Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: батальон командиры сыйфатында елганың сул ярында плацдарм яулый, дошманның күпсанлы гаскәрләренең контрһөҗүмен кире кайтара. Сугышта һәлак була. Ленин ордены, Александр Невский ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.


М.Е.Дряничкин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Боевая слава Алтая. Барнаул, 1978; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ДУАЛИ́ЗМ** (лат. dualis — ике яклы), рух һәм материя, идеаль һәм материаль башлангычларның тигез хокуклылыгын, әмма бер-берсенә яраклашуларының мөмкин булмавын тануга нигезләнгән фәлсәфи тәгълимат. «Д.» атамасы немец философы Х.Вольф тарафыннан кертелә һәм ике башлангычны — материаль һәм рухи нигезләрне тануны белдерә. 19 йөз — 20 йөз башы татар фикер ияләре Д.ны реаль чынбарлыкта да, танып белү процессында да теләсә нинди капма-каршы шартларның, якларның тигез хокуклыгын һәм кыйммәтен раслаучы методологик алым буларак кулланалар.

**ДУБИЛЕ́Й** Пётр Владимирович (26.1.1947, Пхеньян, Корея Халык Демократик Респ-касы — 23.4.1993, Казан), физиолог, мед. фән. д-ры (1982), проф. (1984). 1969 елда Алтай мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1976–86 да Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лында, 1985 тән физиология каф. мөдире. 1986 дан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. башлыгы. Хезмәтләре физиологиягә, саклану чаралары гигиенасына карый. Үпкәләрнең барьер функциясен, организмның тернәкләнү процессларын тикшерә. Кешенең саклану чаралары б-н эш иткәндәге халәтенә физиологик бәя бирү ысулын эшли һәм гамәлгә кертә.

Х е з м.: Барьерная функция лёгких по отношению к серотонину и её роль в поддержании гомеостаза. К., 1986; Восстановление функции опорно-двигательного аппарата у спортсменов. К., 1988; Физиология и патология дыхательной системы у спортсменов. К., 1991.

**ДУ́БИН** Абдулла Ибраһим улы (26.3.1941, Әстерхан ш.), телевидение дикторы, тарихи открыткалар коллекцияләүче. Мәскәүдә Те-



И.Х.Дубин.



А.Д.Дубяго.

атр сәнгате ин-тын тәмамлый (1967). 1957–60 елларда Әстерхан өлкә драма театрында актёр, 1960–61 дә Әстерхан телестудиясендә эшли. 1961–84 тә ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында диктор. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы Идел-Кама төбәге тарихына һәм мәдәниятенә багышланган буклет һәм фотоальбомнарның төзүче-авторы («Иске Казан открыткаларда», 1994; «Югалтылганнарга реквием», «Иске Әстерхан открыткаларда», (икесе дә — 1998); «Идел борынгы открыткаларда», 1999; «Казан гасырлар һәм меңьеллык арасында», 2000; «Ике Казан», 2006) һ.б.

*Әд.:* Г а л и м у л л и н Ф. Җитди кешеләр // Тыңлагыз, Казан сөйли! — Слушайте, говорит Казань! К., 1998; М о р о з о в А.В. Персоны. К., 1998; Твоё родное телевидение (К 40-летию ГТРК «Татарстан»). К., 2000.

**ДУ́БИН** Ибраһим Хөсәен улы (16.5.1921, Әстерхан ш. — 1996, шунда ук), Сов. Союзы Герое (16.10.1943), кече лейтенант (1943). Ульянов хәрби пехота уч-щесен (1940), Офицерлар составы белемен камиллләштерү курслары (1946) тәмамлый. 1939 елдан Кызыл Армия сафында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 360 нчы укчы полкының рота командиры (13 нче армиянең 74 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, Үзәк, Брянск, Көньяк-Көнбатыш, Воронеж фронтлары гаскәрләре составында 1 нче Украина, Смоленск (1941), Орёл-Брянск оборона операцияләрендә (1941), Курск (1943), Днепр сугышларында (1943), Украина, Польшаны азат итүдә, Берлин өчен барган сугышта (1945) катнаша. 1943 нең 23–25 сентябрендә Днепр елгасын кичеп, Берёзки авылы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Брагинск р-ны) тирәсендә батырлык күрсәтә. 1946 дан запаска җибәрелә. Әстерхан шәһәренең тәҗрибә машина төзү з-дында эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а р ч е н к о А.Д. Герои двух народов. Хар., 1977; Ветераны в строю. М., 1981; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ДУБИ́НИНА** Ирина Сергеевна (28.11.1923, Воронеж ш.), пианист, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970,1981), сәнгать фән. канд. (1950). 1947 елда Мәскәү консерваториясен (Я.Зак классы) тәмамлый. 1951 дән Казан консерваториясендә укыта (1953–55, 1969–98 дә махсус фортепиано каф. мөдире, 1973 тән проф.). Казан музыка уч-щесе, Казан консерваториясе, Татар филармониясе симф. оркестрлары б-н В.Моцарт, Ф.Шопен, Л. ван Бетховен, С.Рахманиновның фортепиано концертларын башкара. Пианистканың репертуарына төрле стиль һәм жанрдагы 100 дән артык соло концерт программасы, ш.и. И.Бах, П.Чайковский, К.Дебюсси, Д.Шостакович һ.б.ның әсәрләре керә. Камера ансамбле программалары б-н чыгышлар ясый. Д. — Казан пианистлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Аның башкару алымына күтәренке рух, югары тавыш культурасы, стильне нечкә тоемлау хас. Төп пед. принциплары: Россия пианистлары традицияләрен үстерү, сәнгати тулылык, эчтәлекле башкару, интонацион сурәтлелек, тавышка, студентларның табигый сәләтләренә сак мөнәсәбәт. Ул аларның катлаулы цикллы программалары б-н концерт-башкару чыгышларын оештыруга зур игътибар бирә. Мәс.: И.Бахның «Яхшы темперацияле клавир» («Хорошо темперированный клавир»), Ф.Листның «Сәяхәт еллары» («Годы странствий»), Л. ван Бетховен, Р.Шуман, Ф.Шопен, С.Рахманинов, А.Скрябин, С.Прокофьев һ.б.ның әсәрләреннән монографик программалар. Д.ның шәкертләре арасында халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары Ю.*Егоров*, Д.Абдуллина, Удмурт Респ-касының атказ. артисты Е.Валов, Башкортстанның атказ. артисты С.Хәмидуллина һ.б. бар.

*Әд.:* К а з а ч к о в а Н.С. В классе профессора И.С.Дубининой // Из педагогического опыта Казанской консерватории. К., 1996; Ирина Дубинина. Статьи. Воспоминания. Материалы. К., 2008.

*В.М.Спиридонова.*

**ДУБОВИ́ЦКИЙ** Пётр Александрович (18.4.1815, Рязань ш. — 30.3.1868, С.-Петербург), хирург, мед. д-ры (1837), Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1848). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1833). 1837–40 елларда Казан ун-тының гомуми һәм оператив хирургия каф. мөдире, проф. 1841–67 дә Мед.-хирургия академиясендә (С.-Петербург), бер үк вакытта (1844–51) академиянең гыйльми сәркәтибе, 1857 дән президенты, 1867 дән баш хәрби-мед. инспекторы. Д. пластик хирургиягә нигез салучы, медицинада анатомия-физиология юнәлеше вәкиле. Хезмәтләре кан китүләрне дәвалауга, очлыклар ампутациясе, хирургик юл б-н ташлар алуга карый. Казанда эшләү дәверендә ринопластика, литотрипсия һәм тире астында тенотомия операцияләре, күкрәк бизләре ампутациясе, иңбаш сөякләре резекциясе һ.б. үткәрелә. Операцияләр үткәргәндә Д. хлороформ наркозы куллана (әүвәл бу ысулны Н.И.Пирогов файдалана). Д. Россиядә танылган мед. мәгарифен оештыручы. Ул җитәкчелек иткән дәвердә академиянең мед., фарм. һәм вет. бүлекләре тамырдан үзгәртеп корыла; аның проекты б-н яңа хәрби һәм топографик анатомия б-н берләшкән оператив хирургия, гамәли һәм патологик анатомия кафедралары оештырыла. 1860 елларда ачылган клиникадагы амбулатория Д. исеме б-н бәйле. Д. мед. ин-тларында 6 еллык укуны тәкъдим итә; академиядә фәнни һәм укыту эшчәнлеге белгечләрен әзерләү ин-тын ача; клиник китапханә оештыра, Вильдбергның «Диетики» китабын тәрҗемә итә, табибләр өчен гамәли әһәмияткә ия булган «Анатомические таблицы» нәшер итә; Д. тератология буенча беренче хезмәт авторы. «Записки по части врачебных наук» ж-лына нигез салучы һәм аның мөхәррире (С.-Петербург. 1843–1850).

Х е з м.: О кровотечении. СПб., 1847; Записки по хирургии. СПб., 1848; Взгляд на уродливости вообще с приложением к практическим врачебным наукам. СПб., 1847; Учение о ранах. СПб., 1850.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Деятели Императорского Казанского университета (1805–1900). К., 1900.

**ДУ́БОВКА** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 5 *км* көнбатыштарак, Томбарлы елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 10 кеше (руслар, чуашлар) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рус чыганакларында Мирная Дубовка, 1940–50 елларда Кече Дубовка исеме б-н дә очрый. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларга кадәр авыл җәмәгатенең имана җире 342 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 145, 1889 да — 229, 1897 дә — 283, 1926 да — 369, 1949 да — 134, 1958 дә — 129, 1970 тә — 84, 1979 да — 53, 1989 да — 14, 2002 дә — 18 кеше.

**ДУБРО́ВИН** Иван Васильевич (? — 21.5.1866, Казан), Казан китап сатучысы һәм нашире, Казан ун-ты, Казан икътисад җәмгыяте һәм Казан руханилар академиясе (1862 елга кадәр) комиссионеры. 1842 елда китап кибете ача. Әдәбият ун-т студентларын, урта уку йортлары укучыларын һәм укытучыларын күздә тотып сайлана. Фәнни, фәнни-популяр, табигать-математика, гуманитар фәннәрдән, медицинадан уку-укыту әдәбияты, А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, М.Ю.Лермонтов, А.В.Кольцов әсәрләре, Көнбатыш Европа классиклары (Г.Гейне, П.Ж.Беранже һ.б.) әсәрләренең тәрҗемәләре тәкъдим ителә. Ш.у. географик карталар, атласлар, ноталар, балалар өчен китаплар сатыла. Казан басмалары арасында университет һәм руханилар академиясе галимнәре хезмәтләре күпчелекне тәшкил итә. «Отечественные записки», «Искра», «Современник» кебек популяр ж-лларга язылу оештырыла. Кибет каршында китап төпләү остаханәсе эшли. Д.ның 27 басмасы була. Шулар исәбенә проф. Д.И.Мейер һәм А.П.Щапов хезмәтләре дә керә. Ул китапларны күбрәк студентлар сатып ала. Д. Казан гимназиясе укытучысы М.*Мәхмүдовның* «Татар телен өйрәнү өчен практик кулланма» («Практическое руководство к изучению татарского языка», 1857) исемле дәреслеген, В.А.Сбоевның «Казан губернасындагы әҗнәбиләр турында тикшеренүләр» («Исследования об инородцах Казанской губернии», 1856) исемле китабын нәшер итә. Әлеге басманың 60 нөсхәсен диңгез идарәсе уку йортлары китапханәләренә бүләк иткәне өчен бөек кенәз Николай Александровичның рәхмәтен ала.

Вятка, Саратов шәһәрләрендә, Мәкәрҗә ярминкәсендә китап кибетләре була. 1855–62 елларда даими рәвештә, айга 2–3 тапкыр, аннан соң атна саен «Казанские губернские ведомости», «Вятские губернские ведомости» (1860) г-таларында китаплар сату турында игъланнар бастыра. Аның басмалары кыйммәт тора, ә китап кибете зур табыш китерми. Шәһәр банкына булган бурычлары өчен Д. кибете ябыла һәм аукционнан сатылырга билгеләнә (1862). Сатып алучылар булмау сәбәпле, аукцион Д.ның вафатыннан соң уздырыла. Китапларны танылган төбәк өйрәнүче Н.Я.Агафонов, ә аңардан әдип һәм букинист И.А.Ярыгин сатып ала (1877).

*Әд.:* «Благодарность Его Императорского Величества Великого князя ... книготорговцу 3-й гильдии купцу Дубровину за издание им книги «Исследование об инородцах Казанской губернии ...» // Казан. губерн. ведомости. 1856. 22 окт.; Васильев П.П. Некролог // шунда ук. 1866. № 24; Щелыванова Ж.В. Книгопродавец Иван Васильевич Дубровин // Библиотека Казанского университета: фонды, раритеты, история ... К., 1980.

**ДУБРО́ВКА** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2008 елда 71 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1926 да — 117, 1938 дә — 156, 1949 да — 162, 1958 дә — 198, 1989 да — 88, 2002 дә 69 кеше.

**ДУБЯ́ГО** Александр Дмитриевич (18.12.1903, Казан — 29.10.1959, шунда ук), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1941), проф. (1944), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). 1925 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, геодезия һәм гравитация (1941–46), теоретик астрономия кафедралары мөдире (1946–47), 1948 дән астрономия каф. профессоры һәм бер үк вакытта В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе директоры (1954–58). Хезмәтләре кометаларның хәрәкәте, төзелеше, барлыкка килүе һәм эволюциясенә карый. Ул ачкан ике кометага аның исеме бирелә (к. *Бернард-Дубяго кометасы*, *Дубяго кометасы*), халыкара медаль б-н бүләкләнә. Югалган һәм кабат ачылган Брукс (1925), Даниель (1937) кометаларын тикшерү, ш.у. күп кенә вак кисәкчекләрдән гыйбарәт комета төшләренең үзәккә таба тыгызлануын, төзелешен һәм таркалуын өйрәнү б-н шөгыльләнә. Кече планета, комета һәм метеорларның орбиталарын билгеләү буенча кулланма яза. Нәгравитацион көчләрнең тәэсирен билгеләү өчен яңа ысул тәкъдим итә, кометаларның хәрәкәтендә гравитация теориясеннән тайпылу сәбәпләрен исбатлый. Үзгәрүчән йолдызларны күзәтә, геодезия һәм гравитация буенча күп кенә эшләр башкара. Кече планетага Д. исеме бирелә (к. *Дубяго астероиды*).

Хезм.: О некоторых вопросах движения, структуры и распада комет // Астрон. журн. 1942. Т. 19, вып. 1–3; О вековом ускорении движения периодических комет // Астрон. журн. 1948. Т. 25. вып. 6; Определение орбит. М.–Л., 1949; О строении кометных ядер и образовании метеорных потоков // Астрон. журн. 1950. Т. 27, вып. 1.

*Р.Г.Усманов.*

**ДУБЯ́ГО АСТЕРО́ИДЫ**, 1167 нче кече планета. 1930 елда Кырымдагы Симеиз обсерваториясендә астроном Е.Ф.Скворцов тарафыннан ачыла. А.Д.*Дубяго* исеме бирелә. Кояштан ераклыгы 3,1–3,7 *а.б.* Кояш тирәли 6,3 елда әйләнеп чыга.

**ДУБЯ́ГО** Дмитрий Иванович (21.10.1849, хәзерге Смоленск өлкәсенең Соино а. — 22.10.1918, Казан), астроном, астрономия һәм геодезия д-ры (1881). А.Д.*Дубягоның* әтисе. 1872 елда Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң, Пулково астр. обсерваториясендә эшли. 1884–1918 елларда Казан ун-ты профессоры һәм Казан шәһәр астрономия обсерваториясе директоры, бер үк вакытта 1890–99 да физ.-матем. ф-ты деканы, 1899–1905 тә ректоры. В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясенә нигез салучы һәм беренче директоры (1901–18). Казанда беренче булып Айның физ. либрациясен өйрәнә. Хезмәтләре күк механикасына карый. 1869–92 елларда Казан астрономнары алып барган күзәтүләр нигезендә Д. 4281 йолдызның каталогын төзи. Нептун иярчене орбитасын тикшерә һәм Диана кече планетасының хәрәкәт итү теориясен төзи. Айдагы кратерга Д. исеме бирелә.

Хезм.: Исследование орбиты спутника Нептуна по наблюдениям, произведённым Пулковским рефрактором с 1847 по 1876: Дис. ... СПб., 1878; Теория движения планеты Дианы. Определение окончательной орбиты: Дис. ... СПб., 1880.

*Р.Г.Усманов.*

**ДУБЯ́ГО КОМЕ́ТАСЫ**, 1921 елның 24 апрелендә Казан шәһәр астрономия обсерваториясендә А.Д.*Дубяго* тарафыннан сыек томанлык буларак ачыла; шул елның 11 июненә кадәр күренә. Аз санлы Нептун төркеменең бер кометасы дип исәпләнә. Кояш тирәли 67 елда әйләнеп чыга.

**ДУВА́Н РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 3246 *км²*. Үзәге — Мәсәгут авылы (Уфадан 250 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 32016 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 4367, 1979 да — 4237, 1989 — 4240, 2002 дә — 4249 кеше. Районда 51 торак пункт, ш.и. 2 татар — Өлкенде (2001 дә — 1545 кеше) һәм Елантөп (120), ш.у. 6 татар-рус һәм 1 татар-башкорт-рус авылы бар. 2001/2002 уку елында Д.р.ның 2 мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыту татар телендә алып барыла, югары сыйныфларда татар теле фән буларак өйрәнелә. Өлкенде авылында Ә.Ф.*Ерикәй*, биол. фән. д-ры Р.Р.*Әхмәтов* туган.

**ДУГЛА́В** Александр Васильевич (25.7.1950, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), физ.-матем. фән. канд. (1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук, квантлы электроника һәм радиоспектроскопия кафедрасында эшли. Хезмәтләре радиоспектроскопия алымнары б-н матдәне куерган халәтендә тикшерүгә карый. Беренче булып Ван-Флек парамагнетигында акустик төш резонансын күзәтә. Югары темп-ралы $YBa_2Cu_3O_{6,5}$ үтә үткәргечендә атмосферадагы дымлылык парлары үтеп керү процессын тикшерә. Дәүләт бүләге «Магнит резонансы алымнары б-н үтә үткәргечләрнең наноүлчәмле үзлекләре табигатен тикшерү» дигән фәнни хезмәтләр циклы (автордаш) өчен бирелә.

Хезм.: Ядерный акустический резонанс в ван-флековском парамагнетике $PrF_3$ // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1979. Т. 29, № 11 (автордаш); Dynamics and distribution of doped holes in the $CuO_2$ plane of slightly doped $Y_{1-y}Ca_yBa_2Cu_3O_6$ studied by Cu(1)NOR // Phys. Rev. B. 2009. V. 79 (автордаш).

**ДУ́ДИН** Василий Иванович (27.2.1904, Иваново-Вознесенск губ., Шуя өязе Данилово а. — ?), инженер-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). 1928 елда Мстёрск сәнгать-сәнәгать техникумын тәмамлый (Владимир өлкәсе), төсле металларны эшкәртү буенча 1 нче Кольчугино з-дында (Иваново өлкәсе) конструктор булып эшли. 1930–41 дә Мәскәүнең 2 нче сәгать з-дында инструменталь цехның конструкторы, бюро мөдире, техник җитәкче. 1941–55 тә Чистай сәгать з-дында баш технолог, баш механик. Дәүләт бүләге сәгать эшләү производствосында үз илебез инструментларын һәм приборларын үзләштерүне оештырганы өчен бирелә.

**ДУ́ДЫРЕВ** Юрий Игнатьевич (15.12.1929, Киров ш. — 10.8.1985, Казан), зоогигиена белгече, вет. фән. д-ры (1976), проф. (1978). Киров а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Казан вет. ин-тында эшли. 1956 елдан Алтай а.х. ин-тында, зоотехния ф-ты деканы (1962–65). 1967 дән Казан вет. ин-тында, 1969–74 тә проректор, 1977–85 тә зоогигиена каф. мөдире. Чебешләрнең үсүенә һәм җитлегүенә ясалма яктылык чыганакларының, а.х. терлекләре организмының физиологик реакциясенә сәнәгать тавышлары тәэсирен тикшерә. Яшькә, физиологиягә, тукландыру дәрәҗәсенә, терлек абзарларының гигиена торышына бәйле рәвештә мөгезле эре терлекләрнең табигый ныклыгын, организмнарында газ, энергия алмашын, җылылык тапшыру юлларын өйрәнә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Справочник по гигиене сельскохозяйственных животных. М., 1975 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Е.П.Дудырева.*

**ДУ́ЕВ** Станислав Иванович (31.5.1952, Казан), математик, техник фән. д-ры (1994), проф. (1996). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ун-тында эшли, 1994 тән информатика һәм гамәли матем. каф. профессоры (бүленеп, 1981–91 дә Владимир ун-тында). Хезмәтләре матем. модельләштерүгә һәм химик-технол. системаларны тикшерүгә, «реактор — бүлү блогы» рециркуляция системасы теориясенә карый. Реагентларның баштагы һәм арадаш халәтләреннән тулысынча файдалану режимын өйрәнә. Химик реакторда чиксез күп (континуум) стационар торышлар турындагы яңа күренеш ача. Химик системаларда стационар торыш-

ларның континуумы була алу критериен, шуларның тотрыклылыгын тикшерә.

Хезм.: Множественность стационарных состояний в рециркуляционной системе «реактор — блок разделения» // Теорет. основы хим. технологии. 1980. Т. 14, № 6 (автордаш); Явление температурной неоднозначности в рециркуляционной системе «реактор — блок разделения» // Теорет. основы хим. технологии. 1998. Т. 32, № 5 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДУКА́ЛЬСКИЙ** Генрих Станиславович (1885, Витебск ш. — 1971, Мәскәү), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1905 елда РСДРП-ның Витебск шәһәр ком-ты каршындагы сугышчан дружинаны җитәкли. 1907 дә революцион эшчәнлеге өчен кулга алына һәм Архангельск губернасына сөрелә. 1908 дә сөрген урыныннан Норвегиягә кача, Норвегия с.-д. партиясенә керә. 1909 дан АКШта, Чикаго шәһәрендә төрле эшләрдә эшли. 1913 тән «Дөньяның индустриаль эшчеләре» профсоюз хәрәкәте әгъзасы. 1917 дә Россиягә кайта. Окт. рев-циясендә катнаша (Петроград). 1918–20 елларда Вятка губернасы Алабуга өязе азык-төлек комиссары (бүленеп, 1919 дан Воронеж губернасы Азык-төлек ком-ты коллегиясе әгъзасы). 1921–23 тә ТАССР азык-төлек халык комиссары урынбасары, халык комиссары, 1925–27 дә ХКС рәисе. 1927 дән Тулада, Мәскәүдә хуҗалык эшендә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Борцы за народное счастье. К., 1983. Кн. 2.

**ДУЛА́ЕВА** Римма Алексеевна (Дулаты Рагимат Алаутдин кызы) (28.4.1934, Чечен-Ингуш автономияле өлкәсенең Грозный ш.), географ-икътисадчы, геогр. фән. д-ры (1991), проф. (1994), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2004). 1957 елда Төньяк Осетия ун-тын (Орджоникидзе ш.) тәмамлый. Казакъстан ССРның Целиноград өлкәсе халык мәгарифе системасында эшли. 1968–71 дә Могилёв пед. ин-тында. 1971–83 тә Белоруссия ССР Дәүләт план ком-тының Икътисад ин-тында. 1983 тән Казан пед. ин-тында, икътисад һәм социаль геогр. каф. мөдире (1989–99). Хезмәтләре Белоруссия һәм Татарстан халык хуҗалыгын планлаштыру һәм урнаштыруга, базар икътисады мәсьәләләренә карый. Вузлар өчен 3 томлы «Болгар чорыннан хәзерге вакытка кадәр Татарстан географиясе» («География Татарстана с булгарского периода по настоящее время», 2001) дәреслеге авторларының берсе. 1971–78 елларга Минск шәһәренең һәм хәрби-сәнәгать комплексы пр-тиеләренең социаль-икътисади үсеш программасын эшләгәне өчен СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Программно-целевой метод в комплексном планировании. Минск, 1979; ПЭВМ в экономической и социальной географии. К., 1995; Татары на планете Земля. К., 2004; Религии мира. К., 2006.

**ДУЛА́Т АЛИ́** (Алиев Мәхмүт Габделвахит улы) (1.5.1889, Казан — июль, 1920, Башкортстан АССРның Баймак ш.) сәясәт эшлеклесе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1905 елда «әл-Ислах» хәрәкәтенә кушыла, «*әл-Ислах*» г-тасын чыгаруда (1907–09), татар революционеры Х.Ямашевның әдәби түгәрәгендә катнаша. 1907 дән РСДРП әгъзасы. 1912–14 елларда Бохара шәһәрендә Гелкинның тире эшкәртү пр-тиесендә эшли. 1 нче Бөтендөнья сугышы вакытында Төньяк фронтка алына. 1917 елгы Февраль рев-циясеннән соң Мөселманнар соц. ком-ты рәисе, Төньяк фронтның Мөселманнар хәрби ком-ты, 5 нче армиянең фронт ком-ты әгъзасы. «Сугыш сафы» г-тасы чыгара, «Чулпан» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1918 дән Казанда: Россия мөселманнары КП ҮК әгъзасы (1918 нең июнь–ноябре); шәһәрне Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ Халык армиясе частьләреннән саклауда катнаша. Арча ш. совет хәрби комендатурасында эшли. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының 1 нче Бөтенроссия корылтаенда РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыкара коммунистик оешмалары Үзәк бюросы әгъзалыгына кандидат итеп сайлана (1918 нең ноябре). 1918–19 да РКП(б)ның Казан губерна ком-ты каршындагы мөселман секциясе бюросы рәисе, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан. губерна советы президиумы әгъзасы. 1919 ның җәеннән Эстәрлетамакта, Башкортстан ХХСнда бүлек мөдире. Анархистлар тарафыннан атып үтерелә.

*Әд.:* Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ДУЛА́Т-АЛИ́ЕВ** Вадим Роберт улы (12.12.1969, Казан), музыка белгече, педагог, сәнгать фән. д-ры (1999), проф. (2005). 1993 елда Казан консерваториясен тәмамлый, шунда ук эшли, 1999–2007 дә проректор. 2007–09 да татар музыкасы, 2009 дан музыка тарихы һәм теориясе кафедралары мөдире. Тикшеренүенең төп тематикасы — милли мәдәниятнең теоретик проблемалары, татар музыкасы һәм музыка белеменең тарихы. Татар музыкасы тарихы буенча тикшеренүләре өчен Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлык бүләге бирелә.

Хезм.: Татарская музыкальная литература для детских музыкальных школ: В 2 ч. К., 1996–98; Текст национальной культуры: Новоевропейская традиция в татарской музыке. К., 1999; Композитор и национальная история // Век Салиха Сайдашева. К., 2000; Татарская музыкальная литература для музыкальных училищ. К., 2007.

**ДУЛКЫНЧАЛА́Р** (Limantriidae), төн күбәләкләре семьялыгы. 3000 гә якын төре бар. Татарстан терр-ясендә 15 кә якын төре билгеле. Һәр җирдә таралганнар. Эре һәм уртача зурлыктагы, зур гәүдәле төкле күбәләкләр. Канатлары бер төстә генә — ак, сары, сирәк кенә яшел; канат колачы — 20–70 *мм*. Хортумчыгы рудиментар. Еш кына җенси диморфизм күзәтелә — кайбер төрләренең ана затлары канатсыз. Әңгер-меңгердә һәм төнлә активлар. Көндез ата күбәләкләр аналарны эзләп очалар һәм исләре буенча эзләп табалар. Гусеницалары төк б-н капланган, шунлыктан кошлар өчен ашарга яраксыз. Агач яфраклары б-н тукланалар. Урман һәм бакчаларга зур зыян китерергә мөмкиннәр. Аеруча еш очрыйлар: *парсыз ефәк күбәләге*; монах ефәк күбәләге (Lymantria monacha) — алгы канатлары сорырак, зигзагсыман дүртәр кара сызыклы, арткылары — аксыл-соры, гусеницасы ылыслы агачларда үсә; алтынкорсак (Euproctis crysorrhoea) — корсак очы кызыл көрән яки алтынсыман төкләр учмасыннан тора (исеме шуннан), гусеницасы — соргылт кара, җимеш агачларында, имән, юкә һ.б. агачларда туклана.

*Әд.:* Кожанчиков И.В. Волнянки // Фауна СССР. Насекомые чешуекрылые. М.–Л., 1950. Т. XII; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Гордиенко С.Г. Бабочки Татарии. К., 1990.

*Н.П.Шулаев, Н.Г.Петров.*

**ДУЛО́**, 6 йөз ахыры — 7 йөз башында төрки кабиләләр берлеге. Баштарак Җидесуда һәм Җөнгарстанда, 590 елларда Көнчыгыш Төрки каганлыкның көнбатыш өлешендә көченеп йөргән. 5 кабиләне берләштергән. 604–38 елларда Д. юлбашчылары Көнбатыш Төрки каганлыкта өстенлек итү өчен нушиби кабиләләре берлеге б-н көрәш алып барган. Ул таркалганнан соң, Д. вәкилләре *Бөек Болгарга*, аннары *Хәзәр каганлыгына* нигез салганнар.

**ДУ́ЛЬСКИЙ** Пётр Максимилианович (23.3.1879, хәзерге Молдавия Республикасы Оргеев ш. — 8.3.1956, Казан), сәнгать белгече, рәссам, музей эшлеклесе, педагог, сәнгать фән. канд. (1938), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1940). 1899 елдан (бүленеп) Казанда яши. Одесса рәсем мәктәбендә (1895–98, тәмамламый), Казан сәнгать мәктәбенең гравёрлау бүлегендә (1899–1904), Казан ун-тының тарих-филол. ф-тында (1915–19) укый. Д. иҗатының формалашуына төбәк тарихчысы казанлы Н.Я.Агафонов зур йогынты ясый. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Д. Вятка губернасы Слободской шәһәренең һөнәр уч-щесенә рәсем укытучысы итеп билгеләнә. 1911 дә Россия рәссамнарының беренче съездына делегат итеп сайлана. Шул ук елда Казан реаль уч-щесендә рәсем укытучысы булып эшли башлый. 1916 да «Казанның сәнгать хәзинәләре» күргәзмәсенең (Казан, Петроград) оештыру ком-ты секретаре була. 1917–19 да — Су транспорты идарәсенең культура бүлеге мөдире. 1919 да Халык мәгарифе комис-ты бүлеге каршындагы музейлар һәм сәнгать ядкәрләрен, борынгы әйберләрне саклау буенча губерна бүлекчәсе хезмәткәре, шул ук елда конкурс буенча Казан музееның сәнгать галереясын саклаучы хезмәткәр итеп сайлана һәм анда 1925 кә кадәр эшли. 1927–30 да Д. — Казандагы Татар мәдәнияте йортының гыйльми секретаре. 1928 дә РСФСР Халык мәгарифе комис-ты тарафыннан Совет сәнгате күргәзмәсендә Татарстан бүлеген оештыру өчен Парижга һәм Берлинга командировкага җибәрелә. 1930–41 дә Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-ты, 1941–47 дә — авиация ин-ты, 1949–56 да гражданнар төзелеше ин-ты укытучысы, 1935–39 да Казандагы эшен Ленинградтагы Бөтенроссия Сәнгать академиясенең нәшрият бүлегенә мөдирлек итү б-н бергә алып бара. ТАССР Рәссамнар берлеген оештыруда катнаша һәм аның беренче рәисе була (1936–38). Д.ның беренче мөһим хезмәте — Казанның мәдәни-тарихи мирасын саклау идеясе б-н сугарылган «Борынгы Казан ядкәрләре» («Памятники казан-

ской старины», 1914) китабы. Алга таба ул Казан архит-расы буенча да тикшеренүләр алып бара. Аның дөнья күргән хезмәтләре — китаплары һәм мәкаләләре арасыннан аеруча әһәмиятлеләре — «Михаил Петрович Коринфский» (1916), «Казан төзелешендә классицизм» («Классицизм в казанском зодчестве», 1920), «Казанда барокко» («Барокко в Казани», 1922), «Казан XVI–XVII–XVIII йөзләрдә» («Казань в XVI–XVII–XVIII столетиях»), «Казан унтугызынчы йөздә» («Казань в девятнадцатом столетии») (икесе дә — 1943), «Татар республикасы башкаласы Казанның архитектурасы 25 ел эчендә» («Архитектура Казани — столицы Татарской республики за 25 лет», 1945). Д. сынлы сәнгатьне пропагандалау һәм популярлаштыру буенча зур чаралар үткәрүдә катнаша. Музей тупланмалары нигезендә аның тарафыннан «Казан музеенда чит ил нәкышьчеләре» («Иностранные живописцы в Казанском музее», 1920), «Перов Казан музее тупланмаларында» («Перов в собрании Казанского музея», 1921), «Казан музеенда рус осталары» («Русские мастера в Казанском музее») (1922) һ.б. хезмәтләр языла. Д. ш.у. 19 йөз рәссамнары К.Барду, В.Турин, Э.Турнерелли, Я.Крюков иҗатын өйрәнә. Аның «Китап һәм аның сәнгати тышкы күренеше» («Книга и её художественная внешность», 1921), «1905–1906 еллардагы сатирик журналлар графикасы» («Графика сатирических журналов 1905–1906 гг.», 1922), «Балалар китабында иллюстрация» («Иллюстрация в детской книге», 1925) хезмәтләре алга куелган проблемаларны тирәннән өйрәнү б-н аерылып тора. Ул атаклы рәссам Н.И.Фешин турындагы беренче монография — «Николай Иванович Фешин» исемле китап (1921) авторы. 1920 еллар уртасыннан Д. татар халкының сәнгатен һәм шул чорның сәнгать тормышындагы үзгәрешләрен өйрәнүгә күбрәк игътибар бирә. Респ-ка р-ннары буйлап экспедицияләрдә татар орнаментлары, милли агач архит-ра, һөнәрчелек буенча (чигү, милли тукучылык, зәргәрлек эше) материал туплый. Экспедиция нәтиҗәләрен Д. «Казан татарлары сәнгате» («Искусство казанских татар», 1925) китабында, үзәк һәм җирле вакытлы матбугатта басылган күпсанлы мәкаләләрендә бәян итә. Бер үк вакытта замандаш рәссамнарының иҗатлары турында «Хәзерге заман Казан графиклары» («Казанские современные графики», 1925), «Татреспубликада революция еллары сәнгате» («Искусство в Татреспублике за годы революции», 1929), «Революция чорында татар китабы бизәлеше» («Оформление татарской книги за революционный период», 1930) исемле хезмәтләре, П.Д.Беньков, П.А.Радимов, Н.М.Сокольский, С.С.Ахун иҗатына багышланган язмалары дөнья күрә. Д. нәшрият эше үсешенә дә зур өлеш кертә. 1920 дә Россиядә музейлар эшен һәм истәлекләрне саклау турындагы проблемаларны яктыртуга багышланган «Казанский музейный вестник» исемле беренче журналның оештыручысы һәм мөхәррире була, ул «Казанский библиофил», «Вестник научного общества татароведения», «Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТАССР» исемле вакытлы басмалар чыгаруны оештыруда актив катнаша. Аның җитәкчелегендә респ-када сәнгатькә һәм истәлекләрне саклауга багышланган күргәзмәләр һәм китаплар каталоглары төзелә һәм бастырыла.

1930 еллардан башлап Д. ш.у. совет һәм Көнбатыш Европа сәнгате проблемалары, рус архитекторлары һәм нәкышьчеләре иҗатын тикшерү, укыту-педагогика мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Ике басмада дөнья күргән «Иван Иванович Шишкин. 1832–1898» исемле китабы (1955) киң танылa. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Д.ның архивы, китапханәсе, тупланмалары һәм сәнгать әсәрләре ТР Милли архивында, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында саклана.

*Әд.:* Пётр Максимилианович Дульский (75 лет со дня рождения): Каталог выставки. К., 1954; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1976. Т. 3; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*А.И.Новицкий.*

**«ДУ́МА»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. 2 нче Дәүләт Думасы каршындагы Мөселман хезмәт төркеме органы. 1907 елның 21 апреленнән 30 маена кадәр С.-Петербургта татар һәм әзәрбайҗан телләрендә нәшер ителә, барлыгы 6 саны чыга. Рәсми мөхәррире һәм нашире К.Хәсәнов, гамәлдәгесе — Ф.Туктаров. Һ.Атласов, Ш.Әхмәров һ.б. хезмәттәшлек итә. Демократик юнәлештәге басма буларак, «Д.» Дәүләт Думасы эшчәнлеген яктырта, мөселман депутатларның чыгышларына анализ ясый, хөкүмәт сәясәтен тәнкыйтьли. Милли, аграр мәсьәләләрне күтәрә. Петербург шәһәр башлыгы карары нигезендә ябыла, рәсми мөхәррирга каршы җинаять эше кузгатыла.


*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом). 1905–25. К., 1926; Н а ф и г о в Р.И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. К., 1964; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ДУМАВИ́** (псевд., чын исем-фамилиясе Тахтамышев Нәҗип Сибгатулла улы) (19.5.1883, Казан губ., Чистай өязе Яңа Дума а. — 3.5.1933, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд өлкәсе Булунгур пос.), язучы, әдәби тәнкыйтьче, публицист, философ. 1894–1902 елларда Казанда яши, «Касыймия» мәдрәсәсендә укый, рус телен өйрәнә. Әстерханда һәм Гурьевта балык промыселларында эшли, соңрак казакълар арасында мөгаллимлек эшен башкара. 1904 тә армиягә алына һәм рус-япон сугышына җибәрелә, анда яраланып контузияләнә. 1905–07 дәге рев-ция чорында төрле юнәлештәге г-таларда һәм ж-лларда («Азат», «Фикер», «Әлгасрелҗәдид», «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Әлфәт») актив языша. Казанда яшәгәндә үзлегеннән белемен арттыра, фәнни һәм фәлсәфи әдәбият б-н кызыксына, Фалес, Анаксимандр, Ксенофан, софистлар, Протагор, Пифагор, Сократ, Платон, Аристотель, Фараби, Әбүгалисина, Ибне Рөшд, Ибне Халдун, Лютер, Бэкон, Декарт, Дарвин, Руссо, Кант, Шопенгауэр, Вольтер,



П.М.Дульский.



Н.Думави.

Ипполит Тэн, А.Бергсон, Ницше кебек философлар, татар мәгърифәтчесе Ш.Күлтәси хезмәтләрен өйрәнә. 1904–05 тә Чистайда, 1906–07 дә Уралдагы шахтёрлар яшәгән шәһәрләрдә, 1908–11 дә «Буби» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Мәдрәсә ябылганнан соң (к. *«Бубилар» эше*), башка мөгаллимнәр б-н бергә ун айга төрмәгә утыртыла. Азат ителгәч, Рязань губернасындагы Вәрәки авылында балалар укыта. Күпсанлы укыту-пед. һәм методик характердагы мәкаләләр, башлангыч мәктәпләр өчен дәреслекләр яза, хрестоматияләр төзи. 1916 да фронтка алына. 1917–21 дә Чистай шәһәре мәктәпләрендә, укытучылар әзерләү курсларында, өяз мәгариф бүлегендә эшли. 1921–25 тә Яңа Дума авылында яши, мулла, ахун-мөхтәсиб вазифаларын башкара, ликбез курслары оештыра. 1925 тә руханилык вазифасыннан баш тарта һәм 1927 гә кадәр Дагстан пед. техникумында укыта. 1927–33 тә Үзбәкстанда яши, Сәмәркand пед. ин-тында һәм төрле мәдәни-агарту оешмаларында эшли.

Иҗатының башлангыч чорында Д. мәгърифәтчелек реализмы ысулы б-н феодализм калдыкларын, иске карашлы муллалар һәм ишаннарны тәнкыйтьли, милли-колониаль изү күренешләрен сурәтли, шул чор җәмгыятендәге кимчелекләрне, социаль тигезсезлекне фаш итә («Рак, Аккош, Балык», «Вәхшәт — мәдәният», «Көтүчеләр», «Татар», 1906). Мәгърифәтчелек идеалларыннан күңеле кайтып, Д. тормышны иҗтимагый-социаль күзлектән тасвирлауга, тәнкыйди реализм рухында гәүдәләндерүгә күчә. Ул әсәрләрендә ач, җәберләнгән, изелгән халык массалары мәнфәгатьләрен чагылдыра башлый («Байлар (алпавыт) җире», «Революция заманы» 1906; «Җир күмере казучылар», 1907).

Д.ның реалистик иҗаты экспрессионистик алымнар б-н тыгыз үрелеп бара. Бу үзенчәлек аның күп кенә әсәрләрендә чагылыш таба. Д. үз заманын һәлакәт — ахырзаман б-н чагыштыра, күңелсез кара төсләргә буялган контрастлар, кискен эмоциональ бәяләүләр ярдәмендә социаль каршылыкларны күрсәтә. Халык тормышының фаҗигалелеге шигърилектән ерак булган тупас ассоциацияләр һәм натуралистик гиперболалар ярдәмендә ассызыклана. Рәхимсезлек, залимлеккә каршы ризасызлык белдерү йөзеннән Д. буяуларны куерта, күренешләрне куркыныч, дәһшәтле итеп сурәтли, геройларны гадәттән тыш авыр шартларга куя. Мондый реалистик фикерләүгә корылган экспрессив сурәтлелек кеше



Н.И. Дунаев.

б-н мохит арасындагы социаль мөнәсәбәтләрне гәүдәләндергән шигырьләрендә аеруча күзгә ташлана («Эч поша, күңел болгана», 1906; «Җәй дә бетте, көз дә җитте», 1906).

1907–12 дә язылган күпсанлы шигырьләрендә Д. 1907 ел, 3 июнь түнтәрелешеннән соң патша самодержавиесе һәм карагруһ монархиячел партияләр тарафыннан революционерларның рәхимсез эзәрлекләнүен фаш итә («Себер», 1907; «Тавыш», 1908); патша төрмәләрендәге тоткыннарның физик һәм рухи газапларын тасвирлый; халык бәхете өчен көрәшеп йөргән Себергә сөрелүчеләргә теләктәшлек белдерә («Мәхбүс», «Мәңгелек мәхбүс», «Яз үтеп, җәйнең башы ...», «Себер төрмәсендә тәрәзә рәшәткәсенә кунган кошны күреп ...», 1908; «Мәхбүс», 1911; «Мәхбүс дустыма», 1912). Төрмә циклына караган аерым шигырьләре илдәге реакция, хәрби-сәяси һәм полиция террорына каршы көрәшкә өндәгән җыр булып танылалар. Рус-япон һәм Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгалары «Сугыш» (1908), «Сугыш тәэссораты» (1916), «Ватан каһарманы, яки Агач аяк» (1916), «Головка» (1917) әсәрләренең нигезендә ята. Аларда Д. басып алу сугышларының кешелеккә каршы юнәлтелгәнлеген күрсәтә, кан коюга каршы чыга, тылдагы крәстияннәрнең бөлгенлеккә төшүе турында ачынып сөйли. Аның рев-ция елларында азатлыкны татыган геройлары реакциягә бәддога укыйлар, бөтен нәрсә сатып алуга корылган капитал дөньясын гаеплиләр, кеше табигатенең кимчелекләреннән зарланалар («Төн», 1908; «Дөнья», 1908; «Үзенә бер төрле катле нәфес», 1912; «Бу да бер киңәш», 1912); толстойчылык тарафдарлары кебек, шәхесне әхлакый яктан камилләштерүгә, яңаруга чакыралар («Дөнья кайчан ислах улыныр», 1912), кайвакыт, идеал эзләп, дингә дә мөрәҗәгать итәләр. Д.ның рухани лирикасы «Коръән» (1912), «Мәэюскә» (1912), «Сәҗдә» (1912), «Коръәннең зары» (1914), «Бер генә секунд хатирәсе» (1914), «Гаед көне» (1914) шигырьләрендә иң югары ноктасына ирешә. Кайбер шигырьләрендә «җир корты» булган кешене түбәнсетү дә сизелә («Җир кортлары», 1912), икенчеләрендә мескен, кол кешеләргә, Ницше фәлсәфәсендәгечә, көчле шәхес культы каршы куела; өченче бер очракта, Шәрекъ пантеистик поэзиясендәгечә, кеше илаһилаштырыла, күккә чөелә («Син — кеше!», 1916).

1910 елларда Д.ның кешенең эчке дөньясын тасвирлаган, мәхәббәткә мәдхия җырлаган, аның җәмгыятьтән читләшүен күрсәткән, үткән тарихны идеаллаштырып сурәтләгән романтик шигырь, поэма, хикәя, повестьлары дөнья күрә («Алла тигезли», 1912; «Болгар кызы Тойгы туташ», 1915; «Шәрекъ даһие», 1915; «Гыйшык трагедиясе», 1916). Бу чорда эгоистик һәм матди исәп-хисапка корылган буржуаз җәмгыятьнең рухи кыйммәтләрен француз мәгърифәтчесе Ж.-Ж.Руссо рухында тәнкыйтьләү дә көчәя («Серле тамчылар», 1912). «Юкка үлде» (1912) хикәясенең нигезендә Шопенгауэрның «универсаль күңел төшенкелеге»н һәм Ницшеның көчле рухлы кеше культын кабул итмәү ята.

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә Д. еш кына Н.В.Гоголь, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Л.Н.Толстой, Ф.М.Достоевский, А.П.Чехов, М.Горький, Л.Н.Андреев исемнәрен телгә ала, алар иҗаты турында үз фикерен әйтә; татар теленә И.А.Крылов мәсәлләрен, Ж.-Ж.Руссо тарафдары Бердарден де Сен Пьерның «Һинд алачыгы» («Хакыйкать артыннан», 1914), Вольтерның «Микромегас» («Хакыйкать эзләү», 1914) повестьларын, Метерлинкның «Чакырылмаган кунак» (1914) драмасын, М.Горькийның «Кеше» (1923) эссе-нәсерен тәрҗемә итә.

Д. — татар романтик эстетикасына һәм әдәбият белемenә нигез салучыларның берсе. «Бер мөляхәзә» (1916), «Шәрекълән Гаребкә мөнәсәбәте белән» (1916) исемле мәкаләләрендә сәнгать һәм әдәбият фәлсәфәсен Д. француз язучысы, философы Ипполит Тэн нигезләгән мәдәният-тарих мәктәбе карашларына таянып, кан урталыгы (тумыштан килгән милли үзенчәлекләр), мохит (климат, социаль-сәяси шартлар), тарихи мизгел (традицияләр йогынтысы) кебек факторлар б-н бәйләп аңлата.

«Соңгы манара» (1928) шигырендә Д. авыл кешеләренең, большевиклар режимыннан куркып, дөрләп янган мәчеткә битараф карап торуларын күрсәтә. «Хәзерге татар руханилары һәм аларның эшләре» (1929) китабында татар руханилары язмышын объектив рәвештә аңлатуга омтылыш ясаса да, совет чоры идеологиясе басымыннан котыла алмый.

Ә с ә р.: Тормыш сәхифәләре. К., 1985.

*Әд.:* М ә һ д и е в М. «Таң атар, башланыр ак тормыш ...» (Н.Думавиның тууына 100 ел) // Социалистик Татарстан. 1983. 19 май; Г а н и е в а Р. Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре. К., 2003; ш у л у к. Думави Наджиб // Ислам на Европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004.

*Р.К.Ганиева.*

**ДУМБРА́**, ике яки өч кыллы традицион татар музыка уен коралы, ш.у. казакълар һәм башкортларда таралыш алган. Озынлыгы 90–110 *см*. Өчпочмаклы корпусы чыршы яки нарат агачының тоташ кисәген чоку юлы б-н ясала. Муены һәм көрәксыман башы өрәңге яисә каен агачыннан эшләнә, муены нык итеп корпуска тоташтырыла. Өске декасы юка чыршы яисә нарат тактадан ясала. Д.ның сеңердән тарттырылган 12 дән 16 га кадәр лады була. Кыллар төзелеше кварталы яки квинталы. Тавыш рәтләре диатоник. Сеңердән эшләнгән кыллар астан — кылтоткычка, ә өстән башындагы боргычларга беркетелә.



Думбра.


Борынгырак Д.ның кыллары ат койрыгы кылыннан эшләнгән. Корпус биеклегеннән 3–3,5 тапкыр озынрак муенлы инструментлар да кулланылган. Тарихчы һәм язучы Т.Ялчыголның (1768–1838) «Музыка һәм поэзия турында трактат» дигән хезмәтендә Д.ның график сурәте күрсәтелгән. Аның корпусы инструмент озынлыгындагы кыллары һәм ике боргычы булган озын муен б-н тоташкан тигезьянлы өчпочмак формасында. Муенның башы ыргаксыман очы артка караган бөтеркә б-н төгәлләнә; ладларга бүлүче сызыклар кабарынкы түгел.

Традицион Д. җирлегендә яңа үрнәктәге уен кораллары эшләнә. Д.ның төп төрләре: прима, секунда, альт, тенор, бас. Аларда кварта төзелешле кыллар, хроматик тавыш рәтләре бар. Тавыш плектор б-н һәм чиртеп чыгарыла.

*Р.Ф.Халитов.*

**ДУНА́ЕВ** Иван Иванович (1788–1840, Казан), химик, проф. (1826). 1811 елда С.-Петербург пед. ин-тын тәмамлый. Казан ун-тында эшли, 1814–37 елларда технологиягә, сәүдә һәм ф-каларга бәйләнешле фәннәр каф. мөдире. Төбәкнең табигый байлыкларын тикшерүдә катнаша. Оренбург губернасының Богыруслан өязендә табылган табигый (саф) содасы, Идел елгасы, Кабан күле суларын химик яктан анализлый. «Казанские известия» г-тасы мөхәррире (1816–20).

**ДУНА́ЕВ** Николай (сәхнәдә Наил) Иванович (3.5.1937, Зәй р-ны Әхмәт а.), драма актёры, педагог, ТАССРның халык (1982), РФнең атказ. артисты (1996). М.С.Щепкин исем. югары театр уч-щесен тәмамлый (1961). Шул ук елда Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Кече театр (Мәскәү) мәктәбендә тәрбияләнгән актёр буларак, Д. барыннан да бигрәк характерның асылына төшенергә, образның рухи эчтәлеген билгеләүче төп сыйфатларын ачыкларга омтыла. Д. башкаруындагы атом төшен өйрәнүче яшь физик, үлем дәрәҗәсендә нурланыш дозасы алып та, рухи ныклыгын югалтмаган Газиз («Хуш, Назлыгөл!», М.Байҗиев); Т.Миңнуллин пьесалары буенча куелган спектакльләрдәге тыелгысыз эчкече рәссам Нургали («Хушыгыз!»); европача типтагы фабрика хуҗасы, тәкәббер, кешеләрне буйсындырырга яратучан Якуб («Без китәбез, сез каласыз»); Пугачёвның кыю көрәштәше Бәхтияр («Бәхтияр Канкаев»); хәйләкәр, шук, яхшы күңелле чатан Григорий («Гөргөри кияүләре»); булдыксыз, юкка шапырынучан актёр Качкинский («Качаклар», Н.Исәнбәт); рәхимсез, явыз Җиһанша («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин); сәер Күрше («Бичура», М.Гыйләҗев); шат күңелле, җитез хәрәкәтле, «канында кояш уйнаган» Фигаро («Шау-шулы көн», П.Бомарше) образ-


Н.И.Д у н а е в: 1. Күрше («Бичура», М.Гыйләҗев. Күрше хатыны ролендә Н.Гәрәева); 2. Залешин («Җимерелгән бәхет», А.Н.Островский); 3. Кенәз («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир) рольләрендә.

лары шундыйлардан. Башкарган беренче рольләрендә үк — яшь табиб Нияз («Соңгы хат», Х.Вахит), танылган татар язучысы, комиссар Шамил Усманов (шул исем. пьеса, А.Гыйләҗев һәм А.Яхин) Д.ның образ өстендә чын күңелдән бирелеп, үз героеның һәр эш-кыланышын психол. яктан нигезләргә тырышып, жанрның асылын аңлап эшләвен күрсәтә. Д. башкаруында Шамил Усманов романтик рухлы, шул заман сулышына төгәл туры килгән герой булып күзаллана. Василий ролендә («Бер төн», Б.Л.Горбатов) икенче пландагы үтә үзенчәлекле катлаулы образ тудырып, Д. үзен чын сәхнә остасы итеп күрсәтә. Д.ның А.Н.Островский пьесалары буенча куелган спектакльләрдә башкарган рольләре аерым әһәмияткә ия: Подхалюзин («Агай-эне ак мыек»), Залешин («Җимерелгән бәхет»), Паратов («Бирнәсез кыз»), аларда Д.ның автор стилен нечкә тоемлый, шул ук вакытта драматург тудырган образларның бүгенге яңгырашы кискенләгән күрсәтә белүе ачык чагыла. А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте буенча куелган спектакльдәге Мирвәли образы — актёрның иҗади казанышы. Д. башкаруында бәхетле, тормышны һәм туган җирен сөюче яшь крәстиян Мирвәли, үзен кулакка санап рәнҗеткән авылдашлары б-н тигезсез көрәш нәтиҗәсендә барысын да югалткан, шәфкатьсезләнгән, рухи яктан ярлыланган, сынган трагик фигурага әйләнеп, 1930 еллар Россия крәстияне язмышын гәүдәләндерә. Д. Казан театр уч-щесендә (1983–86) һәм Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (1986 дан) пед. эшчәнлек алып бара. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1978) һәм ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1998) лауреаты.

*Әд.:* И л я л о в а И. В каждой роли частичка души // Татарстан. 1997. № 4.

*И.И.Илялова.*

**ДУНА́ЕВ** Сергей Владимирович (24.9.1858 — 1912 елдан соң), җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Казанның Беренче ирләр гимназиясен, Казан ун-тының мед. ф-тын (1883) тәмамлый. Казан губернасы, Лаеш өязенең Емельяново авылында шәхси мед. эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Лаеш өязе земство җыены гласные; Казан губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907–12), кадетлар фракциясе әгъзасы, эшчелеккә каршы комиссия эшендә катнаша. Депутатлык вакыты беткәч, Лаеш өязенә кайта.

*Әд.:* У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ДУНА́Й** Фаяз Хәбибулла улы (псевд., чын исем-фамилиясе Хисмәтуллин Фасих Хәбибулла улы) (15.1.1936, Әлки р-ны Иске Алпар а. — 22.5.2007, шунда ук), язучы, публицист, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1960–70 елларда район һәм республика газета-журналлары редакцияләрендә эшли. 1970 тән Чаллы шәһәрендә яши. «Белеп язуга ни җитә» (1990) әдәби-тәнкыйть, «Таңнарның кадерен белик» (1991) һәм «Иманнар какшаган дәвер» (1995) очерклар, «Җанымның әрнүләре» (1995) исемле шигырь китаплары, «Сөюнең сынаулары бар» (1987) драмасы авторы. Д. иҗатына социаль проблемаларның кискен куелуы, теленең бай, образлы булуы хас.

**ДУҢГЫ́З АСРАУЧЫЛЫ́К**, терлекчелекнең ит, май, тире, кыл алу өчен дуңгызлар үрчетү тармагы. ТРда дуңгыз асрау үсеше турыдан-туры крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә бәйле. 1931 елда колхозларда 55 дуңгыз фермасы оештырыла, аларда 3 мең баш дуңгыз исәпләнә. 1932 дә фермалар — 329 га, ә дуңгызлар саны 24,4 мең башка җитә. 1935 тә дуңгыз фермалары 767 хуҗалыкта була, ә дуңгызлар саны 63,4 мең тәшкил итә. Моннан тыш, с-зларда 34,3 мең дуңгыз үстерелә. 1940 елда аларның гомуми саны 169,9 мең була, 78,2% дуңгыз колхоз-совхозларда асрала.

1941–45 тә дуңгызлар саны шактый кими. Сугышка кадәр булган дуңгызлар саны һәм ит җитештерү күләменә 1949 да гына ирешелә. 1952 дә дуңгызлар саны 345,3 меңгә җитә, 95% тан артыгы колхоз-совхозларда үрчетелә. Бу чорда Д.а. сыйфаты күрсәткечләре түбән, 2031 хуҗалыктагы дуңгыз фермасының күбесе кечкенә була һәм товарлыклы продукция бирми. 1952 дә алынган белешмәләргә караганда, 20 к-зның һәрберсендә — 15–29, ә 7 к-з фермасында 3–4 әр ана дуңгыз асрала. 1950 ел башына 100 ана дуңгыз 576 бала тудыра, ә 1951 дә — 642; шуларның 14,4% — 18,5% ка кадәре үлә. Респ-када ит җитештерүнең гомуми күләмендә дуңгыз ите аз — фәкать 14,8% була (1952). 1957 дә дуңгызлар саны, бер елда 78 меңгә җитә, ягъни 20,8% ка арта. Гомуми ит җитештерү күләмендә 30,6% алып тора. 1956 һәм 1957 дә һәр 100 ана дуңгыз 771 һәм 779 бала китерә. 1957 дә дәүләткә иткә тапшырылган бер баш тере дуңгызның уртача авырлыгы 74 *кг* була.

1960–65 елларда дуңгыз ите зур күләмдә җитештерелә, моңа тармак, эре фермалар һәм азык-төлек әзерләүнең матди базасын ныгыту һәм үстерү сәбәп була; зоотехния эше дәрәҗәсе, үрчетү, ана дуңгызлар сыйфаты һәм аларны файдалану эше яхшыртыла. Дуңгызларны асрау, тукландыру шартларын яхшырту, үрчемне һәм баш санын арттыру чараларын камилләштерү дәвам иттерелә. Нәтиҗәдә 1970 тә 1965 елга караганда баш саны арта, бер ана дуңгыз 29% ка күбрәк бала китерә һәм 100 ана дуңгызга 1744 дуңгыз баласы туры килә. 1965–74 елларда дуңгыз фермалары зурайтыла, аларда дуңгызлар саны арта: 146 хуҗалыкта — 1 меңгә кадәр, 384 хуҗалыкта — 3 меңгә кадәр, 49 хуҗалыкта — 6 меңгә кадәр, 13 хуҗалыкта — 12 меңгә кадәр терлек һәм 12 мең баштан артык дуңгыз исәпләнгән бер хуҗалык була. Ел саен бер ана дуңгыз 16–18 бала китерә, дуңгыз ите күләме 65 мең *т* га җитә. Ит җитештерү өлкәсендә дуңгыз ите 32–35% алып тора. Бу эш б-н 419 к-з һәм 93 с-з шөгыльләнә. 1980 дә хосусый секторда дуңгызлар саны 1 млн. га җитә. Д.а.ның сәнәгый нигезен булдыруга зур әһәмият бирелә.

1990 еллар башында дуңгыз ите җитештерү 50 махсус хуҗалыкта, ш.и. дуңгыз ите гомуми җитештерү күләменең 30% ын тәшкил иткән 13 хуҗалыкара берләшмәдә һәм 6 эре дуңгыз асраучылык комплексында алып барыла. 1989 да Татарстанда дуңгыз ите җитештерү 75–86 мең *т*, 1997 дә — 38,6 мең, 2007 дә — 61,2 мең *т* була. 2007 елга 18 нәселле Д.а. хуҗалыгы исәпләнә һәм анда 84483 баш дуңгыз, ш.и. ата дуңгызлар — 413, ана дуңгызлар: төп баш — 4780, тикшерүгә куелганнар — 4781, 4 айдан өлкәнрәк булганы 6606 баш үрчетелә. Нәселле дуңгызлар үрчетү буенча эре хуҗалыклар: Чистай р-ны «Ромашкино» ҖЧХ (16066 баш), Тукай р-ны «Камский бекон» ҖЧХ нәсел үрчетү з-ды (13418 баш), Саба р-ны «Саба» агрофирмасы (20324 баш), Мамадыш р-ны «Мамадыш» нәселле терлек үрчетү з-ды (4710 баш), Балтач р-ны Тимирязев исем. ҖЧХ (3512 баш), Азнакай р-ны «Уразай» ҖЧХ (3266 баш).

2009 ел башына респ-ка хуҗалыкларында 595 мең баш дуңгыз исәпләнә. Шуларның токым ягыннан күләме: 96,4% — эре ак дуңгыз, 1,4% — ландрас, 0,6% — эре кара токым. Нәселле дуңгызлар һәм товарга җитештерү хуҗалыкларында 4681 ата дуңгыз, төп ана дуңгызлар — 30514, тикшерүгә куелганнар — 30850, 4 айдан өлкәнрәк булганы 45139 баш үстерелә. Тудыру буенча продукция күрсәткечләре: күп тудыру очрагы — 10,2 баш, сөт

бирүчәнлеге — 50,2 *кг*, 1 анага исән 2 айлык дуңгыз балалары — 9,5 баш, бер анадан туганнарының 2 айдан соң гомуми авырлыгы 170 *кг*. Дуңгызлар шәхси хуҗалыкларда да үрчетелә.

*Әд.:* Г р и г о р ь е в Н.В. Животноводство Татарии. К., 1976; К а б а н о в В.Д. Свиноводство. М., 2001; Современное состояние селекционно-племенной работы в хозяйствах Республики Татарстан и пути её улучшения (итоги бонитировки за 2007 год). К., 2008.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ДУҢГЫ́З ГӨМБӘСЕ́** (Paxillus), дуңгыз гөмбәләре семьялыгыннан гөмбәләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә ике төре үсә. Нечкә Д.г. (P. involutus) яфраклы һәм ылыслы урманнарда очрый. Июньнән октябрьгә кадәр төркемләп һәм берәрләп дымлы туфракта үсә. Эшләпәсе соры-көрән, диаметры 5–20 *см*, кырые үзенчәлекле итеп аска кайтарылган. Пластинкалары сары көрән, тулысы б-н яки эре кисәкле булып йомшагыннан аерыла. Сабы кыска, эшләпәсе б-н бер үк төстә. Йомшагы саргылт, йомшак, әчкелтем тәмле. Споралы порошогы көрән. Юан Д.г. (P. atrotomentosus) агач төпләрендә, ауган чыршы һәм нарат кәүсәләрендә үсә. Нечкә Д.г.нән бәрхетсыман кара-көрән сабы һәм итләчрәк булуы б-н аерыла. Споралы порошогы балчыксыл көрән. Нечкә Д.г.ндә пешергәндә таркалмый торган мускарин агуы бар.

**ДУҢГЫ́З УТЫ́** (Achyrophorus), өешма чәчәклеләр семьялыгының үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразия һәм Көньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — тимгелле Д.у. (A. maculatus) ара-тирә барлык р-ннарда да очрый. Нарат урманнарында, куаклар арасында, корылыклы болыннарда үсә. 30–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы коңгырт кара, юан. Сабагы туры, өске өлешендә аз гына ботаклы. Яфраклары озынча-оваль, куе яшел, кызгылт сеңерчәле һәм коңгырт тимгелле. Чәчәкләре лимондай сары, хуш исле, кәрзиннәрендә икешәр-дүртәр булып, сабак очларында урнашкан. Җимеше — бер рәттәге төкчәләрдән торучы бөрекчәле орлыкча. Июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Халык медицинасында яфраклары ялкынсынуга каршы һәм яра төзәтү чарасы буларак файдаланыла. Терлек азыгы.

**ДУРА́СОВО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 5 *км* көньяктарак, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 19 йөзнең 1 нче яртысында Степное Дурасово (хәзерге Самара өлкәсенең Келәүле р-ны) авылыннан күчеп утыручылар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Александровка исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. 1864 елгы мәгълүматларга караганда, Д.да сабын кайнату з-ды һәм су тегермәне эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 30 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 нең 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 291, 1889 да — 177, 1900 дә — 329, 1920 дә — 317, 1926 да — 374, 1938 дә — 241, 1949 да — 228, 1989 да — 67, 2002 дә — 61 кеше.

**ДУРБӘ́К** (14 йөз ахыры — 15 йөз башы), үзбәк шагыйре. Йосыф пәйгамбәр турындагы Коръән сюжетына корылып, билгесез авторның фарсы телендәге поэмасына нигезләнеп язылган романтик «Йосыф-Зөләйха» (Бәлх ш., Әфганстан, 1409) поэмасы авторы. Д. тасвирламасында сюжет үзенең дини төсмерен югалта, җанлы образлар, кичерешләр, көнкүреш детальләре б-н тулыландырыла. Әсәр язучының туган ягында булып узган чын вакыйгаларны чагылдыра. Поэманың кереш өлешендә автор ул елларда Бәлхтә хөкем сөргән катлаулы сәяси вакыйгалар турында җентекләп яза. Поэманың 16–17 йөзләргә караган нөсхәсе 1975 елда Түбән татарларында табыла. Бүтән нөсхәләре Казан, Ташкент, Истанбул һәм Париж архивларында саклана.

Ә с ә р.: Юсуф и Зулейха. Таш., 1980.

*Әд.:* Б е р т е л ь с Е.Э. Узбекский поэт Дурбек и его поэма об Иосифе Прекрасном // Дар. Таш., 1944; История узбекской литературы. Таш., 1987. Т. 1; М а л л а е в Н.М. Ўзбек адабиёти тарихи. Тошкент, 1963. 1 кит.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ДУ́РОВА** Надежда Андреевна (17.9.1783, Киев, башка мәгълүматлар буенча, Херсон ш. — 21.3.1866, Вятка губ. Алабуга ш.), Россиядә беренче хатын-кыз офицер, язучы; «кавалерист кыз» буларак билгеле. Дворяннар нәселеннән (гусар офицер кызы). Балачагы поход тормышы шартларында, фланг гусары Астахов тәрбиясендә уза. 1801 елда земство мәхкәмәсе утырышчысы В.С.Черновка кияүгә чыга, ир бала тудыра; берничә елдан, улын ире б-н калдырып, ата-анасы янына кайта. 1806 ның сентябрендә, ирләр казак киеме киеп, өеннән чыгып китә. Гродно шәһәрендә Александр Васильевич Соколов исемендә Атлы-поляк улан полкына гади солдат булып хезмәткә яллана, 1806–07 дәге Пруссия кампаниясендә катнаша. Офицерның гомерен саклап калганы өчен, солдат Георгий тәресе б-н бүләкләнә. 1807 нең декабрендә С.-Петербургта император Александр I б-н очрашканнан соң, хәрби хезмәтен дәвам итәргә рөхсәт ала, офицер дәрәҗәсе бирелә һәм Александр Андреевич Александров исеме б-н Мариуполь гусар полкына кабул ителә. 1811 нең апрелендә Литва җиңел кавалерия полкына күчерелә. 1812 елгы Ватан сугышында (Бородино сугышында аягы яралана, әмма сафта кала, берникадәр вакыт М.И.Кутузовның ординарецы була), 1813–14 тә чит илләрдәге походларда катнаша. 1816 да штабс-ротмистр дәрәҗәсендә гомерлек пенсия б-н отставкага чыга. Берничә ел С.-Петербургта, бер ел Украинада, аннары әти-әнисе һәм үз гаиләсе б-н бертуган абыйсы яшәгән Сарапул шәһәрендә яши. Д.ның әтисе Андрей Васильевич (1757 — 10.6.1826, Сарапул ш.), 1788 дә секунд-майор дәрәҗәсендә отставкага чыгып, 1789 да Сарапулда городничий вазифасын башкара. 1800 дән — коллежский советник, йорты һәм 18 крепостной крәстияне була. Бертуган энесе Василий Андреевич (10.1.1799 — ?) 1831–35 тә — Алабуга шәһәрендә, 1839 да Сарапулда городничий була. Дуровларның дворянлык нәселе 1845 тә Казан губернасы шәҗәрәләр китабының 3 нче бүлегенә кертелгән. Энесе ярдәмендә Надежда Д. А.С.Пушкин б-н таныша, шагыйрь Д.ның истәлек язмалары б-н бик кызыксына. 1836 да А.С.Пушкин алардан бер өзекне «Современник» ж-лында бастыра. Шул ук елда С.-Петербургта әсәрне «Кавалерист кыз, Россиядә булган хәл» («Кавалерист-девица, происшествие в России») дигән исем б-н И.Г.Бутовский тулы килеш бастырып чыгара. Д. 1840 ка кадәр әдәби эшчәнлек б-н актив шөгыльләнә: 1838–39 да «Литературное прибавление к «Русскому инвалиду» һәм «Отечественные записки» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә, романтик рухтагы берничә повесть «Күкертле чишмә» — «Серный ключ» (1834); «Граф Маврицкий» (1838); «Петербургта бер ел яшәү, яки Анда өченче тапкыр баруның файдасызлыгы» — «Год жизни в Петербурге, или Невыгоды третьего посещения» (1838); «Елена, Т. чибәре» — «Елена, Т-ская красавица» (1887) романын, «Ярчук — күрәзәче эт» — «Ярчук — собака-духовидец» (1840) мәҗаралы повестен, ш.у. «Шау-шулылар» — «Гудишки» романын һ.б. яза. Танылган, популяр кеше булуына карамастан, башкаланың югары җәмгыять вәкилләре Д.ны кабул итми. 1841 дән, үз-үзенә бикләнеп, Алабугада яши; үзенә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешеләрнең гозерләрен җирле хакимиятләргә җиткерә; өен ташландык хәлгә китерә, гарип хайваннар приютына әверелдерә. Хәрби кеше буларак зурлап җирләнә. Алабугада *Дурова А.Н. музей-утары* ачылган, аңа һәйкәл куелган.



Н.А. Дурова. Билгесез рәссам.

Ә с ә р.: Избранное. М., 1984; Избранные сочинения кавалерист-девицы. М., 1988.

*Әд.:* С а к с А. Кавалерист-девица штабс-ротмистр А.А.Александров (Надежда Андреевна Дурова). СПб., 1912; О с ь к и н А.И. Дурова — героиня Отечественной войны 1812 г. М., 1962; Казанское дворянство 1785–1917 гг. Генеалогический словарь. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ДУ́РОВА Н.А. МУЗЕ́Й-УТАРЫ́**, Алабуга шәһәрендә, мемориаль. 1989 елда ТАССР Дәүләт музее ф-лы буларак оештырыла. 1990 да Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгы составына кертелә. Музей 1993 тә, 1812 елгы Бородино сугышының 180 еллыгына туры китереп ачыла. 1841 дә Дурова яшәгән утар йортында урнашкан. Йорт



Алабуга шәһәрендә Н.А. Дурованың музей-утары. Экспозиция күренеше.

һәм утар каралтылары арх. В.В.Лунчев һәм В.Б.Бударин (экспозициянең сәнгать проекты авторлары – И.Воронина һәм Е.Самарцева, С.-Петербург) проектлары буенча үзгәртеп корыла. Әдәби-документаль экспозиция Н.А.Дурованың тормышына һәм иҗат эшчәнлегенә багышлана; типологик әйберләр җирлегендә 19 йөз уртасындагы өяз торак йортының көнкүреш халәте торгызыла. Александр бакчасында Н.А.Дуровага һәйкәл куела (скульптор Г.Н.Зяблицев).

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999. *О.Е.Шелковская.*

**ДУ́РОВА Н.А. ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ́**, Алабугада. Н.А.Дурова Алабугада 1841 елдан бирле яши. 1866 да вафат була, Алабуганың Троицк зиратында хәрбиләргә карата булган хөрмәт б-н зурлап җирләнә. Дуровага беренче һәйкәл 1901 нең 11 октябрендә полкташлары һәм шәһәр кешеләре акчасына Троицк зиратында аның каберенә куела. Ул күп баскычлы пирамида рәвешендә соры мәрмәрдән эшләнгән, очына зур хач куелган. Югары баскычның уң ягында эпитафия ташъязмасында: «Надежда Андреевна Дурова, Император Александр әмере буенча — корнет Александров, хәрби орден кавалеры. Туган илгә мәхәббәт хисе б-н Литва улан полкы сафларына керде. Офицерны коткарып, Георгий тәресе б-н бүләкләнде...» – дип, уеп язылган була. 1930 елларда зират ябыла, һәйкәл юкка чыга. 1962 нең сентябрендә Дурованың җәсәден яңадан күмү оештырыла. Александр бакчасындагы турыпочмаклы соры таш б-н билгеләнгән һәм тәбәнәк металл койма б-н әйләндерелеп алынган кабер өстенә 2 *м* биеклектәге һәйкәл куела (сынчы Г.Я.Зяблицев). Ул, ак мәрмәрдән ясалып, почмаклары шомартылган дүрт кырлы кара гранит постаментка куелган бюсттан гыйбарәт. Постаментта: «Дурова Надежда Андреевна, 1783–1866, фельдмаршал М.И.Кутузовның ординарецы»,– дип язылган. Язу астында ачылган китап, офицер баш киеме, кылыч һәм дәфнә агачы ботагы уеп ясалган. Скульптура Дурованың портрет охшашлыгын гына түгел, аның тәвәккәл характеры үзенчәлекләрен дә чагылдыра. Һәйкәл 2003 тә Дурова музей-утары терр-ясенә күчерелә.

1993 тә Дуровага реалистик стильдәге атлы скульптура традициясендә башкарылган бронза һәйкәл (Мәскәү сынчысы Ф.Ф.Лях) куела. Ул шәһәр мәйданында турыпочмаклы кызыл гранит постаментка урнаштырыла. Атның салмак адымы, «кавалерист кыз»ның горур кыяфәтле гәүдәсе, скульптура формаларының тәэсирле чагылышы 1812 елгы Ватан сугышының кыю героинясы образын тудыра.

*Әд.:* Материалы свода памятников истории и культуры РСФСР. Татарская АССР. М., 1984. Ч. 2; Валеева Н.Г. Елабуга (буклет). К., 1996. *А.И.Новицкий.*

**«ДУС»**, газета. Керәшен татарлар өчен Көнчыгыш рус миссионерлары җәмгыяте, 1917 елдан Көнчыгыш рус мәдәни-агарту җәмгыяте органы. 1916 елның февраленнән 1918 гә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире — епископ *Андрей*. Р.П.*Даулей*, С.М.Матвеев һ.б. хезмәттәшлек итә. Миссионерлык максатында хөкүмәт акчасына чыгарыла. Газета Беренче бөтендөнья сугышының чын максатын һәм сәбәпләрен ачмаска, аның бөтен авырлыгының халык җилкәсенә төшүе турында әйтмәскә тырыша, халыкны сугышта җиңеп чыкканга кадәр сугышырга чакыра.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Григорьев А.Н. Кряшенская художественная литература // Сборник стихов кряшенских поэтов. К., 1931; Глухов-Ногайбек М. Судьба гвардейцев Сеюмбеки. К., 1993. *Р.Г.Әмирханов.*

**ДУСА́Й** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасының уң кушылдыгы Шыя суы буенда. 2008 елда 250 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сосновый Мыс исеме б-н мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 964,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 385, 1897 дә — 731, 1908 дә — 744, 1920 дә — 772, 1926 да — 522, 1970 тә — 415, 1979 да — 347, 1989 да — 272, 2002 дә — 254 кеше.

**ДУСА́Й** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 35 *км* көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы чигендә. 2008 елда 250 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Әмәкәй волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 208, 1938 дә — 318, 1949 да — 363, 1958 дә — 379, 1970 тә — 401, 1979 да — 319, 1989 да — 195, 2002 дә — 209 кеше.

**ДУСА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Калмыя елгасының сул кушылдыгы (Сөн елгасы бассейны). Озынлыгы 12,4 *км*, бассейнының мәйданы 38,3 *км²*. Мөслим р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Дусай авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Сөякәй һәм Бәкәбез авыллары арасында. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 111 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Д. елгасының 0,5 тән алып 2,7 *км* га кадәр озынлыктагы өч кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры–апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 1,15 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.


**ДУСАЙКИЧҮ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 17 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында. 2008 елда 105 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1731 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, олаучылык, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. Мәчет 18 йөзнең 2 нче яртысыннан билгеле, 1831 дә аның каршында мәктәп ачыла. 1929 да Д.дә «Кызыл Кичү» к-зы оештырыла, 1950–58 дә «Донбасс», «Урал» к-зларына, 1958–63 тә Ленин исем. к-зга, 1963 тән «Ык буе» хуҗалыгына, 1960 ның 2 нче яртысыннан яңадан Ленин исем. к-зга керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәлкән волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 230 ир-ат; 1859 да — 276, 1870 тә — 292, 1906 да — 490, 1913 тә — 618, 1920 дә — 611, 1926 да — 622, 1938 дә — 648, 1949 да — 557, 1958 дә — 354, 1970 тә — 356, 1979 да — 305, 1989 да — 215, 2002 дә — 136 кеше.

**«ДУСЛЫ́К» НЕФТЬ ҮТКӘРГЕЧЕ́**, халыкара магистраль нефть үткәргеч. Әлмәт шәһәрендә башланып, Мозырь шәһәренә кадәрге аралыкта Самара, Брянск шәһәрләре аша уза, аннан соң 2 участокка — төньяк

(Белоруссия, Польша һәм Германия терр-яләре буйлап) һәм көньяк (Украина, Чехия, Словакия һәм Венгрия терр-яләре буйлап) юнәлешләргә аерыла. Гомуми озынлыгы 5,2 мең *км* чамасы. 1 нче чираты — 1964 елда, 2 нче чираты (Германия, Чехия, Словакия һәм Венгрия терр-яләрендә) — 1972 дә, 3 нче чираты 1981 дә сафка баса. Үзара Икътисади ярдәмләшү Советының (СЭВ) 10 нчы сессиясе карары (1958) буенча СССР, Польша, Германия Демократик Респ-касы, Чехословакия һәм Венгрия арасындагы хөкүмәтара килешү (1959) нигезендә төзелә. «Д.» н.ү. төзелешендә «Татнефтепроводстрой», «Востокмонжтатгаз», «Татспецстрой», «Строймеханизация» трестлары, Төньяк-Көнбатыш магистраль нефть үткәргечләр идарәсе катнаша. Торбалар б-н Германия Демократик Респ-касы, Чехословакия һәм Польша, автоматлаштыру чаралары һәм үлчәгеч приборлар, кабель продукциясе б-н Венгрия һәм Чехословакия тәэмин итә. Нефть үткәргечнең чыганакка тоташтырылган Әлмәт–Куйбышев өлеше төзелеше 1963 тә төгәлләнә. Илдә беренче тапкыр торбалы үткәргечләр төзү тәҗрибәсендә 820 һәм 1020 *мм* лы диаметрлы торбалар һәм һәрберсе 10 мең $м^3$ сыйдырышлы тимер-бетон резервуарлар кулланыла. Бер үк вакытта технол. объектлар, резервуарлар паркы Әлмәт р-ның Кәләй авылы янында урнашкан төп нефть кудыручы «Әлмәт» станциясе, арадаш нефть кудыру насослы «Баланлы чишмә» («Калиновый ключ», 1964–65) станциясе төзелә. Әлмәт тарафыннан станциягә Әлмәт–Кәләй нефть үткәргече сузыла. Төп нефть кудыручы «Әлмәт» станциясе 1964 нең 4 ноябрендә эшли башлый һәм Ромашкино чыганагыннан нефть «Д.» н.ү. буйлап җибәрелә. Киләчәктә нефть кудыручы «Елизаветинка» (1966) һәм «Горький-3» (1971) станцияләре, Әлмәт–Куйбышев-2 магистраль нефть үткәргеченең линия өлеше (1972), Усть-Балык–Курган–Уфа–Әлмәт трансконтиненталь нефть үткәргеченең көнбатыш участогы (1972), Әлмәт–Горький-3 нефть үткәргече (1971) төзелә. 1972 дә — нефть кудыручы «Дружба-2» станциясе, 1975 тә резервуарлар паркы файдалануга тапшырыла. Нефть кудыручы «Әлмәт» станциясе белән мәйдан 74 *га* га, аның резервуар паркларының гомуми номиналь сыйдыру күләме 570 мең $м^3$ ка җитә. 1973 нең маенда нефть кудыручы «Әлмәт» станциясенә Усть-Балык–Курган–Уфа–Әлмәт нефть үткәргече буенча Көнбатыш Себердәге чыганаклардан алынган нефть килә башлый.

«Д.» н.ү. өр-яңа автоматика, телемеханика һәм телеидарә чаралары б-н җиһазландырылган. Нефть үткәргечләрнең линия өлешләренә һәм насос станцияләренә үзәкләштерелгән хезмәт күрсәтү технологияләре, нефть сыйфатын контрольдә тотуның автоматлаштырылган системасы, торбалы үткәргечләрне капиталь ремонтлау өчен машиналар комплексы гамәлгә кертелгән. Җитешсезлекләр булган участокларны ачыклау һәм алмаштыру максатында нефть үткәргечләренә диагностика уздырыла. 1996–99 да Әлмәт–Куйбышев нефть үткәргечендә капиталь ремонт, резервуарларны һәм технол. җиһазларны ре-

«ДУСЛЫК» ХАЛЫКАРА МАГИСТРАЛЬ НЕФТЬ ҮТКӘРГЕЧЕ




конструкцияләү үткәрелә. Резервуарларны төзекләндерүдә һәм реконструкцияләүдә коррозиядән саклау өчен аеруча ныклы изоляция материаллары, камилләштерелгән һава алыштыру клапаннары, кайтаргыч дисклар, зарарлы калдыкларның тышка чыгуын булдырмаучы газ көйләгеч системалар, объектларның янгынга каршы торучанлыгын көчәйтүче, янгынnarны катлам астында сүндерү системалары кулланыла. 1960–90 елларда «Д.» н.ү. буйлап килгән нефть югарыда искә алынган илләрнең импорт ихтыяҗларының 50% тан 97% ка кадәрге күләмен канәгатьләндерә. Файдалана башлаганнан алып кулланучыларга 2 млрд. *т* дан артык нефть җибәрелә.

*Әд.:* К н я з е в С.Л., Г а т и я т у л л и н Н.С., А б р а ж е е в Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2; Хозяева подземных магистралей. Путь длиною в пятьдесят лет. К., 1999; Т е р е г у л о в З.У., Х у с н у т д и н о в а Р.Р. Труженики подземных артерий 1949–99. История Ромашкинского районного нефтепроводного управления в лицах, фактах и цифрах. К., 2001.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Н.С.Галимов.*

**ДУСМӘ́Т** Теләш углы (17 йөз уртасы), ташка уеп бизәк ясаучы, хаттат. Д. тарафыннан 1659 елда мемориаль шәкелдә иҗат ителгән һәйкәл бүгенгәчә сакланган. Ул башта Салагыш авылы (хәзер Әгерҗе р-ны) янындагы кырга куела, аннары авыл зиратына күчерелә. Зурлыгы 100×50×50 *см*. Һәйкәл формасы б-н үзенчәлекле, Калморза авылы (хәзер Минзәлә р-ны) зиратына куелган кабер ташына охшаш. Озынча түгәрәк рәвешендә очланган, калку кайма б-н әйләндереп алынган (киңлеге 1 *см*). Уемлау ысулы б-н ясалган бизәкле текст тәгълик гарәп язуы үрнәгендә башкарылган. Ташның югары өлешендә гарәп телендә Коръән аяте һәм, «Дусмәт Теләш углы» дип, останың исеме язылган. Аның астында шәһит киткән Бигәш улы Биккол һәм аның ике улы турында гарәп графикасы б-н татар телендә язылган биографик белешмә бар (барлыгы 8 юл). Тексты һәйкәлне 1976 елда тапкан М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан матбугатта бастырыла.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Тарихи чыганаклар // Идел. 1994. № 2.

**ДУСЫ́М** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 10 *км* төньяктарак, Ашыт елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2008 елда 221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1619 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да мәчет, мәктәп, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Җилгелде авылы биләмәсен дә кертеп) 584 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) өязе Кышлау волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 310, 1897 дә — 516, 1926 да — 550, 1938 дә — 605, 1949 да — 487, 1958 дә — 447, 1970 тә — 393, 1979 да — 360, 1989 да — 274, 2002 дә — 234 кеше.

**«ДУТА́Н БАТЫ́Р»**, *алыплар* турындагы әсәрләр циклыннан тылсымлы әкият. Казакъ халкының «Дотан батыр» дастанына барып тоташуы ихтимал. Әкияткә төрки-татар мифологиясе һәм эпосы үзенчәлекләре хас. Герой атасының 9 хатынынннан 40 улы һәм 40 кызы булган (традицион күпхатынлылык архаик мотивы). Дутан — иң яшь хатыннан туган бердәнбер бала (геройның сайлап алыну эпик мотивы). Бер карт (традицион эпик зат) киңәше б-н 40 бертуган үзләренә кәләш эзләргә чыга (батырны димләү традицион эпик мотивы). Алар карурманда ялга туктыйлар һәм йокыга китәләр. Аларны явыз карчык *Җалмавыз* табып ала (мифологик зат) һәм йота (инициация архаик мотивы). Дутан батыр гына исән кала. Ул бертуганнарын азат итүне сорый. Җалмавыз, патша кызы Көнекәйне алып килүне шарт итеп куеп, аның үтенечен үти. Коткарылган бертуганнар Көнекәйне алырга барудан баш тарталар. Юлда батыр биш ярдәмче таба. Алар арасында иң кызыклысы — *дию*. Әлеге әкияттә ул — киләчәктән хәбәр бирүче, кошлар телен аңлаучы уңай зат. Дутан батыр, кирәкле урынга килеп җиткәч, шуны аңлый: кәләш атасының дошманы — ун меңлек гаскәр башында торучы патша — кызны үзенә буйсындырырга уйлый. Дутан батыр гаскәрне җиңә, патша б-н бергә-бер сугыша, аның башын, чабып алып, Көнекәйнең атасына китереп бирә. Кыз батырга бик рәхмәтле була, әмма ул Җалма-

вызның кулына эләгергә теләми. Дутан батыр Җалмавыз һәм башка дошманнар б-н дә көрәшергә мәҗбүр була. Соңыннан ул Көнекәйгә өйләнә, һәм үзе патша була.

Әкият беренче тапкыр 1939 елда Теләче р-нының Максабаш авылында М.Хәмидуллиннан язып алына; «Халык әкиятләре» җыентыгында басыла (1940).

*Әд.:* Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. К., 1994. *Ф.И.Урманчеев.*

**ДҮДӘ́К** (Otis tarda), дүдәксыманнар семьялыгындагы кош. Азия, Европа, Төньяк Африка далаларында яши. ТР терр-ясендә 1930 елларга кадәр Идел алды һәм Кама аръягы төбәкләрендә оялый, соңгы унъеллыкта ара-тирә көньяк р-ннарга да очып килә. Гәүдәсенең озынлыгы 50–120 *см*, авырлыгы 12–16 *кг* га кадәр. Төсе чуар, ата дүдәк анасыннан җирән бүксә һәм авыз кырыендагы тар каурыйлардан торган ак «мыеклар» б-н аерыла.



Аяклары озын, өч бармаклы, арткы бармагы юк. Оясын җирдә ясый. Ачык булмаган көрән тимгелле зәйтүнсыман ашел 2–3 йомырка сала. Нигездә, үсемлекләр, ш.у. бөҗәкләр һәм моллюсклар б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Башкиров И.С., Григорьев Н.Д. Очерк охотничьего промысла Татарии // Работы Волжско-Камской краевед. промысловой биол. станции. 1931. Вып. 1.

**ДҮЛӘНӘ́** (Crataegus), роза чәчәклеләр семьялыгыннан куакчыл үсемлекләр, сирәк кенә биек булмаган агачлар ыругы. Кыргый рәвештә үсүче 200 гә якын төре Евразия һәм Американың уртача поясларында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — җете кызыл Д. (C. sanguinea) Кама аръягында һәм Идел алдында очрый. Урман кырыйларында, сирәкләнгән урманнарда үсә. Яктылык яратучы, салкынга һәм корылыкка чыдам үсемлек. 5 *м* га кадәр биеклектәге куак. Карт кәүсәләренең кабыгы коңгырт соры, ярыклы, яшь ботаклары ялтырап торучан кызыл-көрән төстә, 2,5–4 *см* озынлыктагы туры чәнечкеләре бар. Яфраклары чиратлашкан, сабакчыл, озынча түгәрәк яки киң ромбиксыман, очланган. Май-июньдә чәчәк ата. Чәчәкләре ак, сирәк кенә алсу, калкансыман чәчәк төркеменә җыелган. Җимешләре озынча кызыл алмачыклар, 2–5 төше бар, сентябрьдә өлгерә. Декоратив һәм дару үсемлеге буларак киң үстерелә. Орлыктан, төп үсентесеннән куакны аеру һәм ялгау ысулы б-н үрчетелә. Җимешләре ашарга яраклы, эшкәртелмәгән килеш, ш.у. кайнатма, повидло, джем, желе һ.б. әзерләү өчен кулланыла. Җимешләрендә С витамины, сорбит, органик кислоталар, шикәр, дуплау матдәләре, сапониннар һ.б., чәчәкләрендә эфир мае бар. Җимешләреннән һәм чәчәкләреннән ясалган төнәтмә һәм сыгынтылар йөрәк эшчәнлеге бозылганда, кан тамыры неврозы, гипертоник авырулар вакытында файдаланыла. Баллы. 200 елга кадәр һәм артыграк та үсә ала.

**ДҮРТЕНЧЕ́ А́РМИЯ**, *Көнчыгыш фронт* составындагы хәрби берләшмә. 1918 елның 20 июнендә Аерым армия (1918 нең 20 июленнән Д.а.) буларак оештырыла. Командующийлары: А.А.Ржевский, Т.С.Хвесин, А.А.Балтийский, М.В.Фрунзе, Л.Я.Угрюмов, К.А.Авксентьевский, В.С.Лазаревич, Г.К.Восканов. Штаб башлыклары: Б.А.Буренин, Т.С.Хвесин, Булгаков, В.Л.Попов, С.А.Меженинов, А.А.Балтийский, А.С.Белой, Ф.Ф.Новицкий, В.С.Лазаревич, Л.Я.Годзиковский, А.К.Андерс, Л.И.Дубов, В.И.Преображенский була. Төрле вакытта Д.а.гә 1 нче Орёл, 1 нче Саратов, Вольск, Новоузенск, Уральск пехота дивизияләре, 25 нче, 49 нчы, 50 нче укчы дивизияләр, 2 нче Төркестан, Мәскәү кавалерия дивизияләре керә. 1918–19 да Чех-словак корпусына, КОМУЧның Халык армиясенә, Урал ак казаклар армиясенә каршы сугышларда катнаша. Д.а. частьләре Самара, Уральск шәһәрләрен азат итә, 1919 ның мартында Мәләкәс, Ставрополь, Сызрань, Сөнгеләй өязләрендә дә сугыша, март–июльдә Лбищенск шәһәренең Сломихинская станицасы һәм Уральск шәһәре р-нында Урал ак казакларына каршы оборона сугышы алып бара. Д.а. составында 1 нче мөселман совет полкы да була. 1919 ның апреленнән Д.а. Революцион Хәрби Советы сәяси бүлегенең оештыру-агитация бүлекчәсендә мөселман секциясе яшәп килә, ул «Ышаныч» исемле газета, брошюра һәм өндәмәләр бастырып тарата, кызылармиячеләр өчен татарча спектакльләр һәм концертлар оештыра. 1919 ның августында Д.а. Төркестан фронты составына керә. 1920 нең апрелендә таратыла.

**ДҮРТЕНЧЕ́ АРХЕОЛО́ГИЯ СЪЕЗДЫ́**, 1877 елның 31 июле – 18 августында Казанда уза. Казан Табигыятьчеләр җәмгыяте әгъзалары тырышлыгы б-н чакырыла. 1876 ның 8 декабрендә халык мәгарифе министры Д.А.Толстой, съездны үткәрергә рөхсәт биреп, аның уздыру тәртибен һәм регламентын раслый. Съездны оештыру б-н башында Д.А.Корсаков торган Башлангыч ком-т җитәкчелек итә. Д.а.с.ның максаты — Идел буе һәм Урал алды халыкларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү б-н шөгыльләнүче галимнәрнең һәм төбәкне өйрәнүчеләрнең фәнни-тикшеренү эшчәнлеген көчәйтү һәм билгеле бер юнәлештә алып бару. Анда катнашучыларга уздырыласы фәнни форумда каралачак төп мәсьәләләр (Казан төбәгендәге борынгы истәлекләрне барлау, Россиядәге борынгы ядкәрләрне өйрәнүдә җирле археологларның роле, археологик истәлекләрне саклау һ.б.) хакында алдан ук хәбәр ителә. Башта берничә хезмәт, ш.и. С.М.Шпилевский, К.И.Невоструев, П.Г.Заринский, В.Ф.Миллер хезмәтләре басылып чыга. Казан губернасы терр-ясендә табылган һәм А.Ф.Лихачев коллекциясенә кертелгән борынгы әйберләрдән кечерәк күргәзмә оештырыла. Съезд 1877 нең 31 июлендә Казан ун-тының актлар залында граф А.С.Уваров һәм Казан укыту округы попечителе П.Д.Шестаковның котлау сүзләре б-н ачыла. Аның эшендә Россиянең күренекле археологлары, шәркыятьче галимнәре һәм төбәкне өйрәнүчеләре: П.В.Алабин, Р.Аспелин, И.А.Бодуэн де-Куртэнэ, И.Н.Березин, Ф.К.Брун, В.В.Вельяминов-Зернов, А.Я.Гаркави, Н.П.Загоскин, П.И.Заринский, И.А.Износков, Д.А.Корсаков, А.Ф.Лихачев, Ш.Мәрҗани, В.Ф.Миллер, Н.П.Остроумов, П.А.Осокин, В.Н.Поливанов, В.В.Радлов, В.К.Савельев, В.Г.Тизенгаузен, Н.А.Толмачев, С.М.Шпилевский, А.А.Штукенберг һ.б., ш.у. шәһәр хакимияте һәм җәмәгатьчелек вәкилләре, төрле министрлыкларның чиновниклары катнаша. Съезд борынгы истәлекләр, тарихи география һәм этнография, сәнгать ядкәрләре, көнкүреш (йорт-җир, иҗтимагый һәм дини) ядкәрләре, тел һәм язу ядкәрләре, көнчыгыш ядкәрләре секцияләренә бүленеп эшли. Съездда катнашучылар Казан губернасының Спас өязенә баралар, Ибне Фазланның «Язма»сында тасвирланган русларның (варягларның) курганнарын эзләп табу максаты б-н, Болгар һәм Балымер авылларында булалар, ләкин аларның сәфәре нәтиҗәсез тәмамлана.

Съезд Идел-Урал төбәге халыкларының үткәнен өйрәнүдә Россия тарихчылары, шәркыятьче галимнәре һәм археологларының тырышлыкларын бергә туплау юнәлешендә зур роль уйный, Казан һәм губернаның иҗтимагый тормышында мөһим вакыйга була. Анда Казан ун-ты каршында *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* оештыру турында карар кабул ителә, аның Уставы тикшерелә һәм оештыру советы сайлана (рәисе С.М.Шпилевский).

*Әд.:* Труды IV Археологического съезда в России. В 2 т. К., 1884–91. *С.Ю.Измайлова.*

**ДҮРТЕНЧЕ́Л СИСТЕ́МА** (чор), антропоген система, антропоген, квартер, кайнозой эратемасының соңгы системасы, Җирнең геол. тарихында кайнозой эрасының хәзер дә дәвам итүче соңгы чорына туры килә, моннан 1,8 млн ел элек *неоген системасыннан* (чорыннан) соң башланган. 1760 елда итальян галиме Д.Ардуино барлык тау токымнарын 4 төркемгә бүлә һәм арада иң яшьләрен «тауларның дүртенче бүлекчәсе» дип атый. 1825 елда француз галиме Ж.Денуайе өченчедән соңгы утырмаларга яңа Д.с. дигән исем бирә. 3 бүлеккә: эоплейстоцен, неоплейстоцен һәм *голоценга* бүленә. Дүртенчел чор дәвамында Җир кабыгының көчле тектоник хәрәкәтләре булып уза, вулканнар күренеше көчле була, климат күп тапкырлар үзгәреш кичерә. 10 мең ел тирәсе элек глобаль үзгәрешләр була, океан тигезлеге хәзергедән 100 *м* га диярлек күтәрелә, ландшафт, үсемлекләр капламы үзгәрә, урманнарның чиге йөзләрчә километр төньякка күчә, хайваннарның күп төрләре (мамонтлар, йонлы мөгезборыннар һ.б.) юкка чыга. Дүртенчел чор б-н неоген арасында Африкада хәзерге кешенең борынгы бабалары барлык-

ка килә. ТР терр-ясендә Д.с.ның барлык бүлекләренең дә катламнары бар, аларның калынлыгы 120 *м* га җитә. Алар бозлык чоры, бозлыкара һәм бозлыктан соңгы дымлы, вакыты б-н җылы һәм коры климат шартларында хасил булган континенталь токымнардан (балчыклар, ком, чуерташ һ.б.) гыйбарәт. Бозлык респ-каның төньяк чиген узып чыкмый. Д.с. катламнарында моллюсклар (төче су), суүсемнәр, имезүче хайваннарның (мамонт, бизон, арыслан, дөя, төньяк боланы, антилопа һ.б.) калдыклары, чыршы, нарат, юкә, тирәк, әрем, кыяклыларның һ.б. дала, урман-дала, ярымчүл үсемлекләренең споралары һәм серкәләре очрый. Идел елгасы үзәнендә (Тәтеш р-ны) *таш гасыр* кешеләренең 100 мең ел тирәсе элек төзелгән торулыгы табылган (к. *Красная глинка*). ТР терр-ясендәге Д.с. токымнарында күп кенә файдалы казылмалар: руда булмаган төзелеш материаллары (кирпеч балчыгы, комсыл балчык, комнар, минер. буяулар), мәрмәр оникс, сапропель, соры күмер, торф, дәвалау ләмнәре чыганаклары; алмаз, алтын, титан, цирконий, ильменит, гранат, топаз күренешләре һ.б. ачыкланган.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**ДҮРТМУНЧА́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 38 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бастырма елгасы буенда. 2008 елда 328 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән — Түбән Кабан, рев-циягә кадәрге чыганакларда Кара Елга исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык, чаршау, палас, чыпта сугу һәм чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Д.да мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне эшли, 19 йөз ахыры — 20 йөз башында агач чиркәү төзелә. Күмәкләштерү елларында «Чулпан» к-зы оештырыла, 1958 дә Сталин исем. (1961 дән — Киров исем., 1963 тән — «Игенче», 1998 дән — а.х. кооперативы) к-зга керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 501, 1897 дә — 783, 1920 дә — 1040, 1926 да — 830, 1938 дә — 635, 1949 да — 486, 1958 дә — 433, 1970 тә — 510, 1979 да — 369, 1989 да — 274, 2002 дә — 336 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ДҮРТӨЙЛЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 6 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда 139 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Шимкусь исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.дә мәчет, мәктәп, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 890,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинский-Шонгыт волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 82 ир-ат; 1859 да — 608, 1897 дә — 800, 1908 дә — 940, 1920 дә — 831, 1926 да — 510, 1938 дә — 522, 1949 да — 392, 1958 дә — 327, 1970 тә — 278, 1979 да — 244, 1989 да — 155, 2002 дә — 164 кеше.

**ДҮРТӨЙЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 7 кеше (руслар, татарлар) яши. 19 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Каменный завод исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.дә су тегермәне, 2 сыраханә, казна шәраб һәм бакалея-мануфактура кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 83,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 33, 1897 дә — 56, 1908 дә — 70, 1920 дә — 64, 1989 да — 16, 2002 дә — 10 кеше.

**ДҮРТӨЙЛЕ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы буенда. 2008 елда 291 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кондралеева исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.дә мәчет, мәдрәсә, 4 тегермән, 2 ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1476 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 653, 1897 дә — 1119, 1908 дә — 1122, 1920 дә — 1264, 1926 да — 1257, 1989 да — 317, 2002 дә — 331 кеше.

**ДҮРТӨЙЛЕ́ РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1722 $км^2$. Үзәге — Дүртөйле шәһәре (Уфадан 124 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 62972 кеше (2002). Татарлар: 1970 тә — 25758, 1979 да — 23133, 1989 да — 32623, 2002 дә — 30841 кеше. Районда 88 торак пункт, ш.и. 40 татар, 23 татар-башкорт, 4 татар-рус, 1 татар-мари авылы бар. Иң зур татар авыллары (2001): Иванай (1358 кеше), Күккуян (669), Тайморза (605), Суыккүл (808). Элегрәк төзелгән авыллар: Аюкаш (17 йөзнең 2 нче яртысы), Казаклар, Күккуян һәм Имай-Утар (1713), Мәмәдәл (1727), Тамак һәм Үткен (1736). 2001/02 уку елында Д.р.ның 20 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 27 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Юлдаш» г-тасы нәшер ителә, татар телендә телевидение тапшырулары трансляцияләнә. Районда әдәбият тәнкыйтьчесе Г.Х.*Гыйльманов*, язучы Х.М.*Кәрим*, актриса И.И.*Газетдинова*, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы С.Р.*Рәфыйков*, мед. фән. д-ры М.Ф.*Мусин* туган.

**ДҮСЕ́М** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 19 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 292 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яхшы Каран, Мендеево исемнәре б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Д.дә мәчет, су тегермәне, 20 йөз башында мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 679,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 64 ир-ат; 1859 да — 317, 1897 дә — 581, 1913 тә — 542, 1920 дә — 596, 1926 да — 604, 1938 дә — 490, 1949 да — 559, 1958 дә — 436, 1970 тә — 466, 1979 да — 388, 1989 да — 301, 2002 дә — 286 кеше.

**ДҮСМӘ́Т** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мамадыш–Кукмара автомобиль юлы буенда. 2008 елда 332 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, урман кисү, такта яру, балык тоту ятьмәсе үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.тә Казан Мәрьям Ана чиркәве (1890 да Н.И.Ильминский тырышлыгы б-н төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1891 гә кадәр — Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе), Халык мәгариф министрлыгының хатын-кызлар уч-щесе (1899 да башлангыч мәктәп базасында ачыла), су тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 560,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 253, 1897 дә — 408, 1906 да — 504, 1920 дә — 552, 1926 да — 359, 1949 да — 370, 1958 дә — 374, 1970 тә — 462, 1979 да — 391, 1989 да — 354, 2002 дә — 363 кеше.

**ДЫГА́НОВА** Роза Яхъя кызы (23.10.1946, Таҗикстан ССР, Ленинабад өлкәсе Шураб а.), зоолог, эколог, биол. фән. д-ры (1996). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли. 1996 дан Казан энергетика

ун-тында, сәнәгать җылылык энергетикасы каф. профессоры, инженерлык экологиясе һәм табигатьтән рациональ файдалану каф. мөдире (2000 нән). Хезмәтләре төче сулыклардагы планарияләр төркемнәренең биологик төрлелеген өйрәнүгә, әйләнә-тирә мохитнең халәтенә бәя бирүгә һәм экологик нормалаштыруга, экологик тәрбия һәм белемгә карый. Д. тарафыннан беренчеләрдән булып аз өйрәнелгән бентос хайван группалары — турбелляриияләр (Turbellaria), төрләр күплеге, планарияләрнең яңа төрләре (Tricladida, Paludicola) сурәтләнә, техник югары уку йортларында экологик белем бирү концепциясе эшләнелә, яңа белгечлек — «энергетикада әйләнә-тирә мохитне инженерлык саклавы» методикасы булдырыла.

Х е з м.: Планарии Каспийского моря. К., 1976; Фауна планарий Европейской части СССР. К., 1984 (автордаш); Фауна планарий Азиатской части СССР. К., 1986 (автордаш); Экопаспорт — территориям. Экспертная система экологической оценки техногенных территорий на примере малых городов Республики Татарстан // Ресурсоэффективность в Республике Татарстан. 2007. № 1 (автордаш).

**ДЫ́МКИН** Александр Михайлович (24.11.1924, хәзерге Спас р-ны Кузнечиха а. — 30.1.1992, Мәскәү), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1964), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1981). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли. 1958 елдан Новосибирск ун-тында, проф. (1966). 1977–85 тә СССР ФА Урал гыйльми үзәгенең Геология һәм геохимия ин-тында (Свердловск ш.) директор. 1985–90 елларда Литосфера ин-тында (Мәскәү) директор урынбасары, СССР ФА Президиумының Геология, геофизика, геохимия һәм тау фәннәре бүлегенең акад. секретаре урынбасары. 1990 нан Дәүләт геол.-минералогия музее директоры (Мәскәү). Эре тимер руда кырлары формалашуның полигенлык һәм полихронлык теориясен эшли. Д. җитәкчелегендә Уралның минерал. чимал ресурсларын комсплексчы куллануның фәнни программасы эшләнә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратиформный тип железооруднения и его генетические особенности. М., 1980 (автордаш); Эволюция накопления природных соединений элементов семейства железа в истории развития литосферы. М., 1992.

**ДЫМЛЫЛЫ́К ДЕФИЦИТЫ́**, һаваның су пары б-н тулысынча туенмавы, билгеле бер һава темп-расы һәм атмосфера басымы тәэсирендә атмосферадагы су парының тулы (максимум мөмкин булган) һәм асылдагы басымнары арасындагы аерма. ТР терр-ясендә Д.д. күрсәткече вегетация чоры башында (апрельдә) уртача 2,3–2,9 *гПа*, июньдә максималь — 8,4–9,8 *гПа*, вегетация ахырында 2–2,5 *гПа*. Д.д. туфрактагы дымның кимү тизлеген, үсемлекләрнең үсү шартларын, уңыш өлгерү вакытын, а.х. техникасыннан файдалану мөмкинлеген билгели; үсемлекләрнең дымга булган ихтыяҗын эмпирик исәпләүләрдә һ.б. очракларда киң кулланыла. Һава темп-расының тәүлеклек торышы Д.д. үзгәрешендә мөһим фактор булып тора: көндез темп-ра күтәрелгән саен, Д.д. арта бара һәм төштән соң (14–15 сәгатьләрдә) иң югары дәрәҗәсенә җитә; һава темп-расының төшүе аның кимүенә китерә. Д.д. артса, төнге кыраулар булу ихтималы үсә. Су сибү һәм туфракның тыгызлануы аның кимүенә этәрә.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983.

*М.А.Верещагин.*

**ДЫРДЫГЫ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында. Бөгелмә Зәе елгасының уң кушылдыгы (Дала Зәе елгасы бассейны). Озынлыгы 8,3 *км*, бассейнының мәйданы 48,5 *км²*. Бөгелмә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Иске Сумароково авылыннан 5 *км* төньяктарак, тамагы Түбән Соколка авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 165 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Д. елгасының 1,1 дән алып 4,3 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,2–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 81 *мм*, ташу агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче декадасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,022 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артыграк. Елгада суының күләме 2,1 млн. *м³* булган буа бар.

**ДЫРЕ́ЕВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 20 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. 1715 елдан ясаклы татарлар яши торган авыл буларак мәгълүм. 1770 елларда Д. тирәсендәге биләмәләр капитан А.С.Суворов милкенә күчә, һәм ул монда крепостной крәстияннәрне китереп утырта. 10 нчы ревизия нәтиҗәләре (1858) монда шулай ук дәүләт крәстияннәре яшәвен дә дәлилли. Халык игенчелек, терлек үрчетү, тукучылык б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 640 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Д.да земство мәктәбе эшли. 1929 да «Красный Октябрь» к-зы оештырыла, 1950 елларда Калинин исем. к-з составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәлкән волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеев, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 60 ир-ат; 1859 да — 170, 1870 тә — 219, 1906 да — 310, 1913 тә — 328, 1920 дә — 288, 1926 да — 283, 1938 дә — 229, 1949 да — 187, 1958 дә — 144, 1970 тә — 83, 1979 да — 23, 1989 да — 2, 2002 дә — 31 кеше.

**ДЬЯ́КОНОВ** Владимир Михайлович (11.5.1906, Вильно губ. Вильно ш. — 3.10.1984, Казан), музей эшлеклесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966, 1969). 1913–17 елларда Минск, Владимир, Арзамас, Сембер, Уфа гимназияләрендә укый. 1918 дән Казанда. 1923–36 да пионер һәм комсомол хәрәкәте эшлеклеләренең берсе, журналист; «Кызыл таң» эл. станциясе эшчеләре клубы мөдире, «За Ильичом» г-тасы редакторы, ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты бюросы рәисе урынбасары, Үзәк пионерлар клубы директоры, ТАССР Мәгариф халык комис-тының мәктәпләр секторы инспекторы, «Красная Татария» г-тасы редакциясенең мәдәният бүлеге мөдире. 1937 дән ТАССР Дәүләт музееның гыйльми сәркәтибе, 1941–78 дә директоры, 1978 дән Халыкара музейлар советы әгъзасы. Д. эшләгән елларда музей коллекцияләре тулыландырыла (500 мең саклау берәмлегенә кадәр), экспозиция мәйданы 5 мең *м²* га кадәр киңәйтелә. 1960 елларда музейга ел саен 300 меңләп кеше йөри. Д. музей эшчәнлегенә А.П.Смирнов, Н.И.Воробьёв, В.В.Егерев, П.М.Дульский, Е.И.Устюжанин, Г.Н.Вульфсон һ.б. күренекле галимнәрне җәлеп итә. Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә. 1966 дан ТРның Милли музеенда ел саен музей эшен үстерүгә өлеш керткән галимнәргә багышланган Д. укулары үткәрелә.

Х е з м.: 60 лет музея. К., 1955; Опыт собирательской работы. К., 1957; Жизнь и музей. К., 1963; Первый костёр. К., 1966; Поиски, встречи, находки. К., 1977.

*Е.И.Карташёва.*

**ДЬЯ́КОНОВ** Герман Константинович (11.6.1907, Кострома губ. Хреново а. — 21.4.1953, Казан), җылылык техникасы белгече; техник фән. д-ры (1946), проф. (1947), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1953). 1930 елда Казан энергетика ин-тын тәмамлый. 1932 елдан Казан химия-технол. ин-тында эшли, механика ф-ты деканы һәм җылылык электротехникасы каф. мөдире (1947–53). Хезмәтләре охшашлык һәм физик-химик процессларны якынча модельләштерү теорияләренә карый. Д. технологик процессларны модельләштерү методологиясен төзи. Аның тарафыннан химия производстволарында химик реакцияләрне төрле технологияләрдә модельләштерү буенча тикшеренүләр үткәрү өчен термотехник фәнни-тикшеренү лаб-ясе оештырыла. 1943 тә беренче мәртәбә катлаулы химик процесслар охшашлыгының гомуми шартларын тәгъбирли һәм акад. М.В.Кирпичёв тарафыннан төзелгән якынча җылылык модельләштерү теориясен куллана. Д. әлеге теорияне химик реакторларны хисаплау өчен кирәк булган физик-химик әверелеш процесслары кинетикасын тикшергәндә дә кулланылуы ихтимал икәнен күрсәтә.

Х е з м.: Опыт применения теории подобия к процессу пенообразования // Журн. техн. физики. 1942. № 6; Принципы приближённого моделирования физико-химических превращений // Докл. АН СССР. 1947. № 7; Моделирование процессов физико-химических превращений // Теория подобия и моделирования. М., 1951; Вопросы теории подобия в области физико-химических процессов. М., 1956.

**ДЬЯ́КОНОВ** Герман Сергеевич (11.11.1964, Казан), химик-технол. процессларны матем. модельләштерү гыйлеме белгече, химия фән. д-ры (1994), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы

(2008). 1985 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1995), 1996 дан химия технологиясе процесслары һәм аппаратлары каф. мөдире, бер үк вакытта 2002–07 дә проректоры, Казан технол. ун-тының Нефть һәм химия ин-ты директоры, 2007 дән ун-т ректоры. Хезмәтләре сыек халәтнең молекуляр теориясенә, химия технологиясе процессларын компьютерда модельләштерүгә карый. Молекулаара тәэсирләшү параметрлары нигезендә сыек катнашмаларда термодинамик тигезләнеш сыйфатламаларын һәм масса күчешен исәпләү методикасын төзи һәм программа буларак тәэмин итә. ТР Дәүләт һәм РФ хөкүмәте бүләкләре лауреаты (2001, 2004).

Х е з м.: Влияние диффузных сопротивлений на перенос мономеров у межфазной поверхности // Теорет. основы хим. технологии. 2000. Т. 34, № 1; Расчёт термодинамических характеристик жидких углеводородов на основе потенциалов межмолекулярного взаимодействия // Журн. физ. химии. 2000. Т. 74, № 10; Увеличение коэффициента турбулентной диффузии в зоне реакции как способ улучшения технико-экономических показателей в производстве полимеров // Журн. прикладной химии. 2001. Т. 74, № 1.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДЬЯ́КОНОВ** Сергей Германович (18.7.1937, Казан), химия технол. гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1970), ТР ФА академигы (1992), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984, 1988). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1973), физика каф. мөдире (1975–79), проректор (1979–83), химик технология процесслары һәм аппаратлары каф. мөдире (1983–88), ректор (1988–2007 дә), ТР Президентының фән һәм югары белем мәсьәләләре буенча киңәшчесе (1997 дән). Хезмәтләре химия технологиясенең теоретик нигезләренә карый. Д. сәнәгый аппаратлардагы күренешләрне өйрәнүнең системалы анализлау ысулларына нигезләнгән яңа принципларын үстерә, алар нигезендә бу процесслар аппаратларның үзара тәэсирләшүенә һәм масштабына матем. инвариант булган элементар күренешләрнең иерархик структурасы рәвешендә бирелә. Ул эшләгән «Физик һәм математик модельләштерү җирлегендә матдәләрне аера торган сәнәгый аппаратларны оптималь проектлаштыру» дигән фәнни юнәлеш, кыйммәтле экспериментал тикшеренүләр һәм пилот сынаулары уздырмый гына, лаборатория пакетлары һәм матем. модельләштерү ысуллары ярдәмендә аппаратларның конструкцияләрен һәм технологик режимнарын тикшереп карарга мөмкинлек бирә. Матдәләр аеруның массаалмашу аппаратларын модельләштерү мәсьәләләрен хәл итүнең методологик, матем. һәм эш тәртибе программаларын төзи. Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен РФ Президенты бүләге бирелә (1999). РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1997). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретические основы и моделирование процессов разделения веществ. К., 1993; Влияние условий замыкания в теории RISM при расчёте термодинамических характеристик жидкости // Журн. физ. химии. 1998. Т. 72, № 10; Теоретическое описание физико-химических свойств на основе потенциалов межмолекулярного взаимодействия // Теорет. основы хим. технологии. 1998. Т. 32, № 4.



С.Г. Дьяконов.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ДЬЯ́КОНОВА** Ирина Николаевна (18.5.1917, Ростов-Дон ш. — 30.6.2002, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). 1940 елда Ростов мед. ин-тын тәмамлый, Ростов өлкәсе Новошахтинск ш. хастаханәсендә, Ростов-Дон шәһәре госпитальләрендә табиб-хирург булып эшли. 1946–68 дә Ростов-Дон мед. ин-тының нерв авырулары һәм нейрохирургия кафедрасында. 1968–90 да Казан ГИДУВында нерв авырулары каф. мөдире (1988 гә кадәр), кафедра нигезендә төзелгән фәнни лаб. мөдире. Хезмәтләре таркау склероз патогенезы мәсьәләләренә карый. Д. тарафыннан бу авыруның иммун механизмнары роле турында оригиналь концепция тәкъдим ителә, маймылларда уникаль тикшеренүләр үткәрелә, таркау склерозның тәҗрибә моделе булдырыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Клинико-экспериментальное исследование механизмов гиперкинезов. Ростов н/Д., 1968; Роль зобной железы в патогенезе рассеянного склероза. Ташкент, 1972 (автордаш); Выявление дефектов клеточной иммунной системы при рассеянном склерозе. Л., 1985.

*Әд.:* Ирина Николаевна Дьяконова. К 70-летию со дня рождения // Невропатология и психиатрия. 1988. № 1.

**ДЬЯЧЕ́НКО** Людмила Александровна (18.6.1944, Горький ш.), курчак театры актрисасы һәм режиссёры, ТАССРның, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1987, 2003). Горький театр уч-щесен (1965) һәм Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы югары режиссёрлар курсын С.В.Образцов классында (Мәскәү, 1972) тәмамлый. 1965 елдан «Әкият» Татар курчак театрында актриса, 1969 дан режиссёр. Петрушка («Көч турында әкият», Р.Батулла), Тычкан баласы («Тинтәк тычкан баласы турында әкият», С.Я.Маршак), Мальчиш-Кибальчиш (А.П.Гайдарның «Хәрби сер» повесте буенча), Лис («Кечкенә принц», А.Сент-Экзюпери) рольләрен башкара, нәни тамашачыларга үз геройларының хисләрен генә түгел, хәрәкәт-кыланышларының мәгънәсен дә аңларга булыша. Рәссамнар б-н берлектә Д. курчак театры сәхнәсендә, курчак спектакльләренә хас алымнарны оста файдаланып, һәр персонажның ачык, матур гәүдәләнешле образларын тудырган спектакльләр галереясы булдыра. Курчак б-н актёрның сәхнәдә синхрон уйнау алымнарын куллланып, драматургик материалның тирән мәгънәлелегенә ирешә, курчак театрының мөмкинлекләрен киңәйтә, сәнгать алымнарыннан уңышлы файдаланып, спектакльләрне өлкән тамашачылар өчен дә кызыклы итә. Д. тарафыннан куелган төп спектакльләр: «Бөркет очарга өйрәнә» (А.Фәткуллин, 1977), «Йолдыз тапкан малай» («Звёздный мальчик», О.Уайлд, 1982), «Винни-Пух һәм башкалар» («Винни-Пух и все-все», А.Милн, 1983), «Пётр I һәм солдат» («Пётр I и солдат», Л.А.Кожевников, 1984), «Апушның тылсымлы төшләре» («Волшебные сны Апуша», Р.Бохараев, 1985), «Патша кәләше» («Невеста падишаха», М.Гыйләҗев, 1989), «Юлбарыс белән сөйләшү» («Беседа с тигром», Д.Биссет, 1995), «Назлы йөрәк бәлаләре» («Беда от нежного сердца», В.А.Соллогуб, 1996), «Чегәннәр» («Цыгане», А.С.Пушкин, 1999), «Билгесез мистер» («Мистер Никто», Р.Брэдбери буенча, 2001). Д. куйган спектакльләр бөтенроссия һәм халыкара театр фестивальләрендә, бернечә мәртәбә чит илләрдә гастрольләрдә күрсәтелә. 1966 елдан Казан театр уч-щесендә һәм Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Курчак театрлары өчен язылган пьесалар һәм сценарийлар авторы.

*Әд.:* И г л а м о в Р. День вчерашний — день сегодняшний // Театральная жизнь. 1999. № 11/12; ш у л  у к. Искусство играющих кукол. К., 2004.

*Ю.А.Благов.*

**ДЬЯЧЕ́НКО** Сергей Викторович (4.10.1846, Харьков — 7.1.1907, Казан), хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1891). Дворяннар нәселеннән. Харьков ун-тын тәмамлый (1868). 1868–69 елларда Харьков мәхкәмә палатасында, 1869–70 тә Петербург округ мәхкәмәсендә. 1870–73 тә Казан мәхкәмә палатасы сәркәтибе, 1899–1903 тә — әгъзасы. 1873–83 тә Казан округ мәхкәмәсе әгъзасы, 1883–88 дә рәис иптәше (урынбасары), 1903–07 дә рәисе. 1888–99 да Казан шәһәре башлыгы. 1904 нең ноябрь–декабрь айларында Россиядә иң ихтирам ителгән *Казан Мәрьям Ана иконасын* урлау эше каралган мәхкәмәдә рәислек итә. Казан шәһәре файдасына зур күләмле иганә оештыра, шәһәрне төзекләндерүгә зур өлеш кертә: Черек күл туфрак б-н күмелә, мед.-сан. бүлеге оештырыла, телефон, электр б-н яктырту үткәрелә, трамвай юллары салына, Николаев, Андреев, Фукс бакчалары булдырыла, Кремль янында күперле Кизик дамбасы салына, сәнгать мәктәбе, сукырлар өчен уч-ще оештырыла, шәһәр музее (1895), хезмәт сөю йорты (1896) һ.б. ачыла. Мәскәү–Казан тимер юлы төзелешенә булышлык итә. Казан фән-сәнәгать күргәзмәсен оештыруны башлап җибәрә (1890). Казан өязе (1877) һәм губернасы (1880 нән) земство җыеннары, шәһәр думасы (1886 дан) гласные. Казан ярлыларга ярдәм күрсәтү ком-ты әгъзасы (1874), рәисе (1891). Ксения хатын-кызлар гимназиясенең ярдәм күрсәтү советы әгъзасы (1879 дан) һәм рәисе (1884–96). Казан төрмәләргә ярдәм күрсәтү ком-ты директоры (1885 тән). Казан шәһәр ятимнәр мәхкәмәсе (1888–99), Казан Мария гимназиясе советы рәисе (1888–99). Казан реаль уч-щесенең шәрәфле ярдәм күрсәтүчесе (1889 дан) һ.б.

Чыг.: Достойны памяти потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1907. Ч. 2. *Е.Б.Долгов.*

**ДЬЯЧКО́В** Виктор Васильевич (13.10.1950, Тамбов өлкәсенең Уваров р-ны Яңа Алабушка а.), электроника инженеры, «Ай-Си-Эл КПО ВС» АҖнең ген. директоры (1998 елдан). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974). Казан исәпләү системалары ҖБндә көйләүче инженер, өлкән инженер, төркем җитәкчесе (1974–88), цех башлыгы (1988–91) булып эшли. 1991–98 дә «Ай-Си-Эл КПО ВС» уртак пр-тиесе ген. директоры урынбасары, аны оештыручыларның берсе. Д. җитәкчелегендә пр-тие Россиядә компьютер технологияләре өлкәсендә әйдәп баручыларның берсенә әверелә. «Диспетчерлык идарәсе үзәк пультының автоматлаштырылган җитәкчелек системасы мәгълүматын саклау системасы» проектын эшләве һәм гамәлгә кертүе өчен аңа «Газпром» АҖ бүләге бирелә (2000).

*Әд.:* Выпускники — гордость университета / КАИ: Краткий биогр. справ. К., 2002.

**ДЬЯЧКО́В** Игорь Васильевич (6.10.1949, Ашхабад ш. — 27.8.2008, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Урал комплекслы каротаж экспедициясендә (Пермь өлкәсе) эшли. 1976 елдан ЦНИИгеолнерудта, 2001 дән Татарстан геол.-разведка идарәсендә. Төзелеш материалларының радиацион генетик бәяләү методикасын эшләүдә, Байкал–Амур магистрале зонасының апатит чыганакларын фаразлауда, эзләүдә һәм бәяләүдә катнаша. Ул эшләгән тәкъдимнәр нигезендә ТР терр-ясендә тимер-оксид пигментлары ятмалары ачыла һәм тикшерелә, җирле чималдан минераль буяулар алу бизнес-проекты төзелә һәм яклана, «сурик» һәм «охра» тибындагы тимер-оксид пигментлар алу технологиясе эшләнә. Дәүләт бүләге утырма тышлыкта яңа һәм традицион булмаган файдалы казылмалар ачканы өчен бирелә.

Х е з м.: Минеральные пигменты РТ: перспективы и возможности их промышленного использования. К., 1994 (автордаш); Железоокисные пигменты Татарстана // Разведка и охрана недр. 1996. № 2 (автордаш); Минеральное сырьё. Краски минеральные: Справ. М., 1999.

**ДЮГУ́РОВ** Михаил Васильевич (21.2.1934, Яшел Үзән р-нының Панау а.), оптик-конструктор, СССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1987). Пенза индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), п/я 85 оешмасында (Уфа ш.) мастер булып эшли. 1959–2002 елларда Казан оптика-механика з-дының «Фотон» Үзәк КБда: инженер-конструктор, сектор җитәкчесе — бүлек җитәкчесе урынбасары (1981 дән), әйдәп баручы инженер-конструктор (1999 дан). Дәүләт бүләге тирән су асты геол.-разведка комплексларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр, ш.и. ачык космоста кулланыла торган кинокамералар конструкциясен эшләгәне өчен СССР Космонавтика федерациясенең акад. М.К.Янгель исем. медале б-н бүләкләнә (1987).

*Әд.:* Казанский оптико-механический завод (1940–2000 гг.). К., 2000.

**ДЮ́КОВ** Иван Александрович (6.6.1888, Тверь губернасының Кашин өязе Поречье а. — 26.6.1961, Казан), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1946), проф. (1946), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945, 1947). 1912 елда Юрьев ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый. 1921–58 елларда Казан ун-тында: геофизика (1934–36), геодезия (1937–40) һәм астрономия кафедралары мөдире (1941–58), бер үк вакытта 1937–38, 1941–52 дә проректор, 1940–41 дә физ.-матем. ф-ты деканы. 1942–58 дә Казан шәһәр астрономия обсерваториясе директоры. Хезмәтләре астрометрия һәм гравиметриянең фундаменталь мәсьәләләренә карый. Йолдызларның торышын һәм хәрәкәтләнүләрен күрсәткән 7 каталог төзи. Гравиметрия эшләрен уздыру экспедицияләрен җитәкли. Яктылыгы сүрән йолдызлар каталогын төзүне оештыручыларның һәм инициаторларның берсе.

Х е з м.: Средние места и собственные движения 30 звёзд // Уч. зап. Казан. ун-та. 1925. Т. 85, кн.1; Определение ускорения силы тяжести для Энгельгардтовской обсерватории в марте 1929 г. // Уч. зап. Казан. ун-та. 1929. Т. 89, кн. 5/6 (автордаш); Относительные склонения 1333 звёзд // Уч. зап. Казан. ун-та. 1943. Т. 103 (автордаш); Гнутие казанского меридианного круга в 1932–1935 гг. // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, кн. 1.

*Әд.:* Б е л ь к о в и ч Г.В., К и с е л ё в а В.Г. Иван Александрович Дюков. К., 1945. *Р.Г.Усманов.*

**ДЮМА́** Александр (Dumas) (1802–70), француз язучысы. Тарихи-авантюр романнар: «Өч мушкетёр» («Три мушкетёра», 1844), «Егерме елдан соң» («Двадцать лет спустя», 1845), «Виконт де Бражелон» (1848–50) трилогиясе, «Граф Монте-Кристо» (1845–46) мажаралы романы һ.б. авторы. 1858 елда Россия буйлап сәяхәт итә, Санкт-Петербург, Мәскәү, Переяславль, Кострома, Түбән Новгород, Казан (27 сент. — 4 окт.), Самара, Царицын, Әстерхан шәһәрләрендә, ш.у. Калмыкиядә була. «Россия буйлап сәяхәт тәэсирләре» («Путевые впечатления в России») роман-хроникасының «Казан» бүлегендә ул: «...Казан — сезнең алдыгызга тарих пәрдәсе аша килеп баса торган шәһәрләрнең берсе. Анда татар истәлекләре әле шулкадәр саф ки, аның рус шәһәре булып саналуына ияләшеп бетеп булмый, һәм, чыннан да, нәкъ менә монда 1552 елга кадәр, йола һәм киемнәр күзлегеннән чыгып караганда, Азия башланган. ...Чиркәү б-н мәчет үзара килешеп дус яши һәм хач б-н ярымай арасында бары тик Казанда гына күрергә мөмкин булган кардәшләрчә дуслыкны үрнәк итеп бирә. Казан күн һәм тире б-н дан тота. Минемчә, җир йөзендәге бернинди шәһәрдә дә күнне Казандагы кебек яхшы эшкәртмиләрдер ...», — дип яза.

Ә с ә р.: Полн. соб. соч.: В 24 *т.* СПб., 1912–13; Путевые впечатления в России: В 3 *т.* М., 1993.

*Әд.:* М о р у а А. Три Дюма. М., 1965; А р и с т о в В. Подарок декабриста (По страницам неизвестных рукописей и забытых книг). К., 1970. *Ю.А.Благов.*

**ДЯ́ТЛОВ** Александр Михайлович (28.4.1930, Казан), тренер (футбол), РСФСРның атказ. тренеры (1970). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1953). 1948 елдан «Юность» физкультура спорт җәмгыятендә тренер, 1954 тән өлкән тренер. 1962–64 тә «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятенең РСФСР яшүсмерләр җыелма командасында (РСФСР Халыклары спартакиадасында чемпионнар), ТАССР яшүсмерләр җыелма командасында (РСФСР Халыклары спартакиадасында көмеш приз алучылар) тренерлык эшендә. Шәкертләре В.В.Биканов, Р.Р.Камалетдинов, Ю.С.Ковалёв, В.М.*Колотов*, А.С.Корченов, А.Ф.Машин — СССР, РСФСР җыелма командалары уенчылары.

**ДЯ́ТЛОВ** Иван Николаевич (28.11.1918, хәзерге Пенза өлкәсенең Лунин р-ны Александровка а.), авиация двигательләре төзү һәм проектлаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1975), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990). 1943 елда Казан авиация ин-тының (хәзер Казан техник ун-ты) моторлар төзү ф-тын тәмамлый, шунда ук һава-реактив двигательләр кафедрасында эшли, очкыч аппаратлар двигательләренең кичке ф-тында декан урынбасары, декан (1944–56). Хезмәтләре һава-реактив двигательләренең югары нәтиҗәле яну камераларына карый. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Конструкция и техническая диагностика выходных устройств авиационных газотурбинных двигателей. К., 1988; Распыление топлива в камерах сгорания газотурбинных двигателей. К., 1993; Конструирование и проектирование авиационных поршневых двигателей: В 2 т. К., 2000.

**ДЯ́ТЛОВО** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 39 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2008 елда 479 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 80%) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчә үстерү. 1565–67 дән Кибәч (Бикәч) авылы буларак мәгълүм. 17 йөз чыганакларында Кече Дятлово исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алпавыт Могилатовларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мич чыгару, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Д.да тимерчелек, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 621 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 244, 1897 дә — 340, 1908 дә — 384, 1926 да — 494, 1938 дә — 393, 1949 да — 287, 1958 дә — 290, 1970 тә — 206, 1979 да — 406, 1989 да — 502, 2002 дә — 476 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары. 1997.

# Е

**ЕВГЕ́НЬЕВ** Михаил Иванович (2.1.1949, Чуаш АССРның Комсомол р-ны Кыр Сундоры а.), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1997), проф. (1999), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1976 дан Бөтенроссия кәгазь фәнни-тикшеренү ин-тының Мари ф-лында эшли. 1979 дан Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре органик кушылмаларның аналитик химиясенә карый. Ароматик, алифатик һәм гетероциклик аминнар кушылмаларын, аминокислоталарны агым-инжекцион, хроматографик һәм тест-билгеләгечләр б-н төрле объектларда билгеләгәндә аларны аерып алуның теоретик нигезләрен эшли. Һава мохитендә агулы матдәләр табу һәм билгеләү өчен уникаль индикаторлар системасын тәкъдим итә. Аның тарафыннан төзелгән аналитик методикалар Казан, Мәскәү, Яңа Чабаксар пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Тест-методы для визуального спектрофотометрического и хроматографического определения аминосоединений в воздушных и водных средах // Журн. аналитической химии. 1998. Т. 53, № 2 (автордаш); Тест-методы и экология // Соросовский образовательный журн. 1999. Т. 5, № 11 (автордаш); Reversed-phase Liguid chromatographic determination of isoniazide in human urine as a test of the genetically — predetermined type of biotransformation by acetycation // Talanta. 1998. V. 47, № 10 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЕВГЕ́НЬЕВ** Станислав Сергеевич (15.5.1937, Казан), турбокомпрессорлар гыйлеме белгече, техник фән д-ры (1995), проф. (1999). ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2004). 1960 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1961 дән Воронеж шәһәрендәге авиация двигательләре тәҗрибә КБнда гидросынаулар бүлеге бригадасы башлыгы. 1964 тән турбомашиналар лаб-ясе башлыгы, 1972 дән компрессорлар төзү буенча СКБның хисаплау-тикшеренү бүлегендә лаб. мөдире (Казан). 1973–86 да Казан төзүче-инженерлар ин-тында укыту эшендә (бүленеп, 1977–79 да Конакри политехник ин-ты (Гвинея респ-касы) профессоры). 1986 дан «Казанкомпрессормаш» ФҖБнең Турбокомпрессорлар фәнни-тикшеренү ин-тында, 1987 дән директор урынбасары — турбомашиналар буенча баш конструктор; 1989 дан турбосуыткыч һәм турбодетандер машиналарның баш конструкторы. 1993 тән «Казанкомпрессормаш» АҖдә: баш конструктор — турбокомпрессорлар КБ башлыгы, 1996 дан перспективалы һәм яңа эшкәртмәләрне өйрәнү хезмәте башлыгы. 1998 дән Казан техник ун-тында, турбомашиналар каф. профессоры. Хезмәтләре газ динамикасы һәм чыдамлылык өлкәсенә карый. Авиация, химия, нефть химиясе, нефть газы сәнәгатендә файдаланыла торган турбокомпрессорларда теоретик һәм экспериментал ь тикшеренүләр алып бара. Метонол җитештергәндә, ягулыкны сыекча б-н чистартканда, нефть гидрокрекингында, газ кудырганда файдаланыла торган югары басымлы үзәктән кугыч компрессорлар, газларны һ.б. эшкәртү өчен турбодетандерлар төзи һәм гамәлгә кертә. Северодонецк, Салават, Дзержинск, Нягань, Оренбург, Пермь, Түбән Кама шәһәрләрендәге нефть химиясе пр-тиеләрендә (1962–73, 1986–98) катлаулы турбокомпрессорлар техникасын файдалануга тапшыруда һәм көйләп-эшләтеп җибәрүдә катнаша.

Х е з м.: Характеристика проточной части циркуляционных центробежных компрессоров // Хим. и нефтяное машиностроение. 1967. № 4 (автордаш); Разгрузка осевых сил с целью повышения надёжности турбомашин // Хим. и нефтяное машиностроение. 1995. № 11; Метод оценки усталостной прочности межлопаточных отсеков закрытых рабочих колес центробежных компрессоров // Компрессорная техника и пневматика. 2001. № 9.

**ЕВДОКИ́МОВ** Александр Николаевич (14.4.1893, Вильно губ., Свинцан өязе Покровка а. — ?), адм. хезмәт полковнигы. Ленинград хәрби округы уку үзәге каршында Хәрби мәктәпне тәмамлый (1934). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Гражданнар сугышында — укчылар полкы комиссары, Көнчыгыш һәм Көнбатыш фронтларда сугыша. 1921–38 елларда Ленинград хәрби округы хәрби комиссариатлары системасында. 1938 дән Мәскәүдә: М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә, 1939 дан Штаб командирлары югары мәктәбендә укытучы булып эшли. 1941 дән Казанда, 1941–46 да ТАССР хәрби комиссары. 1946 елдан отставкада, Ленинградка күчеп китә. Ленин ордены, Кызыл Байрак, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЕВДОКИ́МОВ** Юрий Владимирович (9.9.1913, Казан), астроном, физ.-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1974). 1937 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 1937–41 дә СССР МС каршындагы Геодезия һәм картография Баш идарәсенең Свердловск картография ф-касында карталар чыгаручы җаваплы мөхәррир булып эшли. 1941 дән Хәрби картография частендә инженер-картограф. 1945–86 да Казан ун-тында, бер үк вакытта 1957–64 тә Җирнең ясалма иярченнәрен күзәтү буенча СССР ФАнең Астрономия советы станциясе башлыгы (бүленеп, 1967–68 дә Казан төзүче-инженерлар ин-тының геодезия каф. мөдире). Хезмәтләре периодик кометалар, метеорлар һәм Җирнең ясалма иярченнәрен өйрәнүгә карый. 1972 дә Джакобини-Циннер кометасының, 1973 тә югалган Брукс-2 кометасының (кометалар теориясе нигезендә кометаларның парлап берләшүе алымын куллanып) күренәчәген алдан ук әйтә, әлеге кометаларның гасыр эчендә акрынаюлы яки тизләнешле хәрәкәтен билгели. Кометалар һәм метеорлар агышы хәрәкәтен гомуми өйрәнү Е.ка метеорларның комета төшеннән ургыган массасының күләмен үлчәргә, ш.у. 1985 тә Драконид метеорлар яңгыры явачагын һәм 1959, 1965, 1972 дә (алдан фаразлауларга карамастан) яумаячагын әйтергә мөмкинлек бирә. Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1964 тән), Бөтенсоюз астрономия-геодезия җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1958–70). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: История метеорного потока Драконид и вычисление его орбит // Тр. Астрон. обсерватории Казан. ун-та. 1961. Т. 33; Движение кометы Джакобини-Циннер с 1933 по 1946 год // Астрон. журн. 1963. Т. 40, № 3; Исследование движения комет и метеорных потоков в Казанском университете // Тр. Казан. гор. астрон. обсерватории. 1986. Т. 50.

*Р.Г.Усманов.*

**ЕВДОКИ́МОВ** Юрий Кириллович (30.5.1946, Чабаксар ш.), радиотехника һәм электроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1996), проф. (2000). 1970 елда Чуаш ун-тының электротехника ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1973 тән Казан авиация ин-тында (хәзерге Казан техник ун-тында), 1998 дән теоретик радиотехника һәм электроника каф. мөдире. Хезмәтләре турбулентлыкны өйрәнү өчен мәгълүмати-үлчәгеч системалар булдыруга, үлчәгеч системаларның сенсор һәм датчикларын, континуум-үлчәгеч һәм континуум-датчиклар теориясен һәм ысулларын фәнни тикшерүгә карый. Е. физик кырларның бер һәм күп үлчәмле бүленгән датчикларын кулланырга мөмкинлек бирә торган бүленгән үлчәгеч тирәлекләр төзү ысулларын һәм теориясен эшли. Уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Распределённый электрохимический датчик: основы и применение в измерении потоков // Электрохимия. 1993. Т. 29, № 10; О возможности изучения пространственной структуры гидродинамических полей потоков электролитов по результатам стационарной полярографии распределённого электрохимического датчика // Электрохимия.1995. Т. 31, № 10 (автордаш); Распределённые измерительные среды и континуум-измерения // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1997. № 1.

**ЕВДОКИ́МОВА** Антонина Ивановна (15.8.1907, Казан губ., Зөя өязе Турминский а. — 1998, Самара ш.), колхозчы, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1941–1959 елларда Подберезье (хәзерге Кайбыч) р-ның «Революция» к-зында эшли. Герой исеме бодайдан югары уңыш алуы өчен бирелә


А.И. Евдокимова.


(1944 тә — 1 *га* дан 33 *ц*). 1951–55 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Евгеньев П. Трудолюбие // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1948. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЕВДОКИ́МОВА** Тамара Георгиевна (4.2.1934, Киров өлкәсенең Салобеляк р-ны Неверово а.), агроном, селекция белгече, а.х. фән. канд. (1967), ТАССР, РФнең атказ. агрономы (1989, 1996). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Удмурт АССРның Шаркан р-ны Азин исем. к-зында агроном булып эшли. 1965 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, селекция бүлеге мөдире (1993–97). Хезмәтләре борчак селекциясе, генетикасы һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. Борчакның «Татарстан 2» (1989 дан Татарстан, Владимир, Архангельск өлкәләрендә, Коми Респ-касында районлаштырыла), «Казанец», «Таң», «Венец», «Сәламәт», «Варис» сортларының (1996, 2001, 2004, 2005, 2009 да Урта Идел һәм Идел-Вятка төбәкләрендә Дәүләт реестрына кертелгәннәр) автордашы. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Селекция и семеноводство гороха // Тр. Татар. НИИ сел. хоз-ва. 1970. Вып. 8; Селекция и семеноводство гороха // Эффективность научных исследований по селекции. М., 1976; Гороховое поле Татарстана. К., 1992.

**ЕВДОКИ́Я ЧИРКӘВЕ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. Башта 1734 елда Коткаручы Гайсәнең Мәңгелек Образына багышлап провинциаль барокко стилендәге яруслы храм итеп төзелә (фабрикант И.А.Михляевның тол хатыны Евдокия Михляева иганәсенә, дип фаразлана). «Дүрткырлылык өстендә сигезкырлылык» принцибы буенча төзелгән җыйнак, коллоннасыз бер апсидалы храм үрнәге. Чиркәүнең фәзаи үсеше көнчыгыш яктан ярымтүгәрәк алтарь чыгынтысы, көнбатыштан өч катлы, дүрт кыеклы чаң манарасы б-н турыпочмаклык рәвешендәге ашханә б-н чикләнә. Яктылык тәрәзәләре уелган сигезкырлылык тоташ сигез бүлентекле гөмбәз б-н ябылган һәм гөмбәзле түбә, цилиндрлы барабан һәм суганбаш сыман очлык б-н тәгәлләнә. Соңрак газапланучы Евдокия хөрмәтенә храмның төньягына корылма кушып салына, чиркәүнең исеме шуңа бәйле. 1932 дә чиркәү ябыла, интерьерлары сакланмаган. 1999 дан тиешле максатта файдаланыла.


Казанда Евдокия чиркәве. 2004 елгы фоторәсем.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан; Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998.

**ЕВЛА́МПИЕВ** Василий Витальевич (1890, Чистай ш. — 1940, Казан), химик-органик, проф. (1934). 1915 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм Казан фенолосалицил з-дында (Беренче бөтендөнья сугышы елларында шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин һәм химия з-ды җирлегендә оеша) эшли. 1920 дән Казан ун-тында, органик химия каф. мөдире (1932–38), химия ф-ты деканы (1935–39). Хезмәтләре органик химиягә карый. Синтезлау ысулларын өйрәнә, оксикетоннар ацетальләренең үзлекләрен тикшерә.

**ЕВРА́ЗИЯЧЕЛЕК**, Окт. рев-циясеннән соң рус эмиграциясенең беренче дулкыны вәкилләре арасында барлыкка килгән идеячел һәм иҗтимагый-сәяси агым. Аны берләштергән концепция буенча рус мәдәнияте Европаныкы булмаган феномен итеп карала һәм үзендә Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре сыйфатлары кушылуы б-н аерылып тора, бер үк вакытта Көнбатышка да, Көнчыгышка да карый. Билгеле бер идея һәм карашлар җыелмасы буларак, Е. беренче тапкыр «Көнчыгышка кайту» («Исход к Востоку», София, 1921) җыентыгында бәян ителә. Аның авторлары арасында Россиядән киткән 4 эмигрант та була: икътисадчы һәм географ П.Н.Савицкий (1895–1968), филолог Н.С.Трубецкой (1890–1938), философ һәм дин галиме Г.В.Флоровский (1893–1979), публицист һәм музыка белгече П.П.Сувчинский (1892–1985). Китапта рус мәдәнияте, Европа цивилизациясенең бер өлеше булу б-н бергә, бер үк вакытта мөстәкыйль күренеш итеп тә карала. Евразиячеләр фикеренчә, Россиягә Азия тамырлары Көнбатыш башлангычына караганда эчтән якынрак тора. Евразиячеләр рус зыялылары арасында беренчеләрдән булып туран факторын (к. *Пантуранизм*) уңай бәялиләр, рус-татар мөнәсәбәтләрендә Евразия дәүләтчелеге нигезләрен табалар; Россиянең мөстәкыйль цивилизация буларак барлыкка килүен славян һәм туран башлангычларының кушылуыннан күрәләр, ә үзәктән читтәге вак төркемнәргә бүлгәләнгән көнчыгыш славян кенәзлекләрен эре империя үзәгенә әйләндергән Алтын Урда дәвере мирасын рус тарихының мөһим элементы итеп карыйлар. 13 йөздә Киев Русеның көнбатыш һәм көньяк өлешләре, Европа йогынтысына эләгеп, акрынлап сәяси һәм мәдәни мөстәкыйльлекләрен югалталар, ә Алтын Урда составына кергән җирләр соңыннан Россия империясенең үзәк өлешенә әверелә. Н.С.Трубецкой раслаганча, Борынгы Русьның татарлар тарафыннан сакланып калган рухи үзенчәлеге алга таба Мәскәү патшалыгында яңара һәм «Чыңгыз хан мирасы»на кушыла. Әмма Е.нең Евразия киңлегендәге халыкларны һәм дәүләтләрне бергә туплаучы фактор сыйфатында киләчәге булмый, чөнки ул бары тик рус халкының гомуммилли ихтыяҗлары идеясенә генә нигезләнә, ә Евразия мәдәниятенең үзәге итеп православие карала. Е.нең асылын яңача аңлау Л.Н.*Гумилёв* хезмәтләре б-н бәйле. Ул тарихка соңгы дәвер Е. вәкиле һәм яңа Е.не үстерүгә көчле этәргеч ясаган галим буларак килеп керә. Россиянең үзенә бер төрле, әмма башкалардан аерылып торган юлы барлыгын тирәнтен аңлавы, анда яшәүче халыкларның үзара бәйләнешен ачып бирергә омтылуы аның этногенезга һәм пассионарлыкка (актив үсеш чорында үзәгендә миллләтләр һәм аның вәкилләре торган социаль күренеш) таянган тарихи концепциясенең нигезе булып тора. Гумилёвның «Русьтан — Россиягә: этник тарих турында очерклар» («От Руси к России: очерки этнической истории». М., 1992) исемле хезмәтендә Россияне үзендә һәр милләт өчен яшәү мөмкинлеген тәэмин иткән гаять зур Евразия суперэтносы төзүче ролендә күзаллаган тарихи концепциясе чагыла. Россия тарихы әлеге милләтләр тарихыннан аерылгысыз. Үзенең теоретик карашлары нигезендә Гумилёв славян-рус һәм төрки-татар халыкларының милли тарихыннан ачык мисаллар китерә. Мәгълүм фактларны анализлап, галим, Русь һәм Даланың бер-берсенә каршы торуы б-н бергә, аларның бер-берсенә файдалы йогынты ясау процессын да күрсәтә.

20 йөз ахырында Е. идеясе Россия зыялылары арасында киң тарала. 1990 еллар башында алар Көнбатыш цивилизациясе казанышларын тиз арада үзләштерү иллюзияләре б-н яшиләр, Е. идеяләре, нигездә, Россиянең үзенчә үсү юлын отышлы санап, демократик үзгәртеп коруларга каршы чыгучы радикаль сәяси көчләрне үзенә җәлеп итә. Вакыт Россиягә үзенең үсеш юлын озак вакыт эзләргә туры киләчәген күрсәтә. Хәл Россиянең 1990 еллардан башлап БДБ илләрендә үзенең йогынтысын акрынлап югалта баруы б-н катлаулана. Элек Россия тулысынча өстенлек иткән Көнчыгыш Европа, Кавказ һәм Үзәк Азияне Көнбатыш актив рәвештә үзенә тартырга, үзләштерергә керешә. Әлеге шартлар Россия б-н Көнбатыш арасындагы каршылыкларның сәбәпләрен аңлатырга, тупланган проблемаларны хәл итү юлларын ачыкларга, Россия этносларына үз-үзләрен танырга ярдәм итәргә тиешле Е.нең җанлануына китерә. Бүген «Е.» термины сәясәтчеләр телендә, төрле сәяси төркемнәр көрәшендә киң кулланыла. Евразия интеграциясе идеяләренең Россиядә фәлсәфи эзләнүләр өлкәсеннән акрынлап гамәли сәясәткә күчүен һәм Россиянең дөньякүләм сәяси концепциясенең бер өлеше булып баруын чагылдырган тенденцияләр барлыкка килә. 2001 елда Бишкәк шәһәрендә «Европа–Азия Икътисади Бергәлеге» төзелү, Россия җитәкчелегенең «Ислам Конференциясе» оешмасына керү зарурлыгы турында белдерүе шуны дәлилли. Шул ук вакытта Е.нең гомумкешелек

кыйммәтләренә таянган хәлдә славян, төрки һ.б. халыкларның тигез хокуклы берлегендә төзелергә тиешле гомуми Россия суперэтносы идеясе статусына дәгъва итү өчен әлегә җитәрлек төгәл нигезләмәсе юк.

*Әд.:* Евразия: Исторические взгляды русских эмигрантов. М., 1992; Россия между Европой и Азией: Евразийский соблазн: Антология. М., 1993; Евразийский проект модернизации России «за» и «против». М., 1995; К у л ь п и н Э.С. Путь России. М., 1995; Мир России — Евразия: Антология. М., 1995; Т р у б е ц к о й Н.С. История. Культура. Язык. М., 1995; Д у г и н А.Г. Мистерии Евразии. М., 1996; С а в и ц к и й П.Н. Континент Евразия. М., 1997; B o s s O. Die Lehre der Eurasier. Ein Beitr. zur russ. Ideengeschichte des 20. Jh. Wiesbaden, 1961; B a s s i n M. Russia between Europe and Asia: The Ideological Construction of Geographycal Space // Slavic Review. 1991. V. 50, № 1.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**ЕВРЕЙЛӘ́Р** (яһүдләр), тарихи яктан борынгы еврейләргә барып тоташучы халыкларның гомуми этник атамасы. Төрле илләрдә яшиләр. РФдә Е. — 229938, ш.и. ТРда 3472 кеше (2002). ТРдагы Е.нең күпчелеге Казанда яши. Рус телендә сөйләшәләр, бик азы гына идиш, иврит телләрен белә. Дин тотучылары — нигездә, иудаизм тарафдарлары. Е.нең Казан губернасына килеп урнашуы 1825 елда Россия тәхетенә утырган Николай I (1796–1855) идарә иткәндә башлана. Хәрби бурыч турындагы 1827 елгы Указ нигезендә еврей балаларын солдат мәктәпләренә рекрутлыкка җыялар, соңыннан алар 25 ел хәрби хезмәт үтәргә тиеш булалар. Шул Указдан соң Казанда да хәрби кантонистлар батальоннары оештырыла. Кремль терр-ясендә алар өчен бина төзелә (1866 да юнкерлар уч-щесенә бирелә). Еврей-кантонистларның күпчелек өлеше чукындырыла һәм аларга рус фамилияләре бирелә. Ш.у. соңыннан мәҗбүри төстә даими яшәгән урыннарына кайту шарты б-н Польша Корольлегеннән килгән еврейләрнең Казан ун-тында уку очраклары да билгеле. Казанда Е. җәмгате башта отставкадагы «Николай солдатлары» хисабына оеша, закон аларга Е. өчен каралган утраклык чикләреннән читтә яшәргә рөхсәт итә, аннары бу процесс 1 нче гильдия сәүдәгәрләр, югары һәм урта уку йортлары укытучылары һәм аларның гаиләләре тарафыннан алып барыла. 19 йөз ахырында Казан еврей җәмгатендә 597 кеше исәпләнә; алардан тыш, шәһәрдә чукынган 255 еврей яши. Казан еврей җәмгате рәсми төстә 1897 елда теркәлә. Аңарчы барлык гражданлык хәле актларын җәмгать эше тәртибендә Мәскәү һәм Екатеринбург раввиннары теркәп бара. 1915 тә Кече Проломная урамында (хәзер Профсоюз урамы) еврейләрнең гыйбадәт йорты (синагогасы) төзелгәнгә кадәр дини йолалар вакытлыча алып торылган биналарда үткәрелә. Казан Е.енең профессиональ шөгыльләре сәүдә итү һәм һөнәрчелек була: һөнәрчеләр арасында күпчелекне тегүчеләр, слесарьлар, сәгать төзәтүчеләр һәм мөһер ясаучылар тәшкил итә. Соңрак даруханәче, табиб, фармацевт, антлы ышанычлы (адвокат) булып эшләүче Е.нең саны арта. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Е. күчемсез объектларны шәһәрнең сәнәгый бистәләрендә генә түгел — И.Я.Готлицерның (1894), Л.Зальманың (1885) тире з-длары, бертуган В. һәм А. Персоннарның такта яру ширкәтләре һәм агач саклау складлары (1894), хәтта шәһәр үзәгендә дә сатып ала башлыйлар (Персоннарның Покровская (хәзер Карл Маркс урамы), В.В.Мартинсонның Воскресенская (хәзер Кремль урамы) урамнарындагы йортлары). 1914 тә А.С.Меркуловның Зур Проломная урамындагы (хәзер Бауман урамы) йортын капиталь ремонтлаганнан соң Г.А.Розенберг Зур театргa (хәзер Казан Зур драма театры) нигез сала.

Е.ләр сул юнәлештәге җирле вакытлы матбугатта шактый сизелерлек катнаша, бу исә Казан интеллигенциясенең антисемит карашлы даирәләренең ачуын кабарта. Казанда яшәүче Е.нең шактый өлеше полиция күзәтүе астында була, ул «Пиалей Цион» дип



Казан синагогасының гыйбадәтләр залы. 2004.

аталган еврей с. -д. эшчеләр партиясе әгъзаларын үзенең игътибар үзәгендә тота. 1905 нең октябрендә, империянең кайбер шәһәрләрендә карагруһчылар тарафыннан оештырылган погромнар вакытында, еврейләрнең Казандагы гыйбадәт йорты тар-мар ителә. Е.нең Казанда яңадан күпләп артуына Беренче бөтендөнья сугышы елларында шәһәргә Россиянең көнбатыш өлкәләреннән качаклар килү сәбәп була. Революцион хәрәкәтнең күп кенә танылган эшлеклеләре — Н.Э.*Бауман*, Г.Ш.*Ольkеницкий*, Я.С.*Шейнкман* һ.б.ның исемнәре Казан б-н бәйле. Окт. рев-циясеннән соң Е.нең шәһәрнең сәяси һәм иҗтимагый тормышында катнашуы активлаша. Бунд клубы («Литва, Польша һәм Россиядәге гомумеврей эшчеләр берлеге» партия оешмасы), «Маккаби» спорт җәмгыяте, еврей урта мәктәбе ачыла. Әмма чагыштырмача милли үсеш ирегe фәкать 1920 елларның 2 нче яртысына кадәр генә саклана. 1929 ның маенда — синагога, аннары еврей мәдәнияте клубы һәм еврей мәктәбе ябыла. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстанга эвакуацияләнгән меңнәрчә кеше, ш.и. Е. дә килә. 20 йөз уртасына Казан Е. бергә тупланып яшәгән эре үзәкләрнең берсенә әверелә. Респ-каның хуҗалык һәм иҗтимагый тормышының күп кенә өлкәләрендә Е.нең роле шактый сизелерлек була: алар сәламәтлек саклауны, фундаменталь һәм гамәли фәннәрне, сәнгатьне үстерүгә шактый зур өлеш кертәләр (С.А.*Альтшулер*, Г.Н.*Вульфсон*, Г.М.*Коган*, Е.М. һәм Р.И.*Лепскийлар*, А.Ю. һәм Ю.А.*Ратнерлар*, Н.Г.*Рахлин*, Г.Д.*Ригорин*, М.З.*Сигал*, В.И.*Улик*, Д.И.*Фельдман* һ.б.). 1980 елларның 2 нче яртысына кадәр СССРда Е.нең гражданлык хокуклары рәсми булмаган чикләүләр б-н кысылды (аларның һөнәр сайлауда тулы ирекләре булмады, партия-дәүләт аппаратында югары вазифаларга дәгъва итә алмадылар, аларга чит илләргә чыгарга рөхсәтне башкаларга караганда сирәгрәк бирделәр һ.б.). СССР таркалганнан соң, Россиядәге, ш.и. ТРдагы Е. үзләренең милли мәдәниятләрен үстерү мөмкинлегенә алдылар. 1997 дә Казанда еврей җәмгать-хәйрия үзәге ачылды, дини җәмгать үзәгенә синагога бинасы кайтарып бирелде, милли юнәлештә укыту программалы мәктәп, Казан ун-тында еврей халкы тарихы һәм мәдәнияте үзәге ачылды. Хәйрия эшчәнлеге үсеш алды: «Хесед Моше» хәйрия оешмасы һәм аның каршында ирекләләр хәрәкәте барлыкка килде. «Международная еврейская газета»га кушымта — «МЕГ-Татарстан» нәшер ителә. «Симха» музыка ансамбле, еврей яшьләре үзәге «Афифон»ның төрле яклы эшчәнлеге киң танылу алды.

*Әд.:* Народы мира: Историко-этнограф. справ. М., 1988; Российская еврейская энциклопедия: В 4 т. М., 1994–2000.

*Л.М.Жаржевский.*

**ЕВРОИСЛА́М**, татар һәм Европа зыялыларының хәзерге җәмгыятьтә исламның урынын билгеләүдә һәм аның Көнбатыш Европа мәдәнияте кыйммәтләренә ярашу принципларын ачыклауда интеллектуаль эзләнү юнәлешләренең берсен чагылдыручы төшенчә. «Е.» атамасы беренче тапкыр 1990 еллар уртасында Гёттинген ун-ты (ГФР) политология профессоры Б.Тиби (Bassam Tibi) язмаларында кулланыла, ТРда аны Р.С.*Хәкимов* еш куллана. Әмма мәсьәләгә мөнәсәбәт һәм мәгънә ягыннан Е.ның Россия һәм Европа версияләре бер-берсеннән аерылалар. Көнбатыш Европа галимнәре фикеренчә, Е. Көнбатыштагы илләрнең демократик дәүләти төзелеше һәм яшәү рәвешенә тәмам яраклаша алган дөньяви исламнан гыйбарәт. Б.Тиби моңа мисал рәвешендә Балканнардагы 1990 еллардагы сугышка кадәр Боснияд̧ә үсеш алган исламның дөньяви вариантын китерә. Россиядә дөнья күргән хезмәтләрдә «Е.» төшенчәсе, башлыча, «яңа җәдитчелек» атамасының синонимы, исламның яңа интеллектуаль һәм потенциаль мөмкинлекләрен ачу, аның индустриаль җәмгыять шартларына яраклашкан уңайлы модельләрен эшләү формасы буларак кулланыла. Е.га ш.у. исламның төп принципларына тыкшынуга, бигрәк тә аларның үзгәрүенә юл куймаучы, мөселман җәмгыятен тышкы җимергеч йогынтыдан саклаучы үзенчәлекле идеологик сүрү буларак та карыйлар. Е. хәзерге җәмгыятьнең рухи кыйммәтләре яссылыгында исламның үз урынын саклау өчен гаять әһәмиятле күренешләрне һәм фикерләрне ачарга юнәлтелгән; болар: *иҗтиһад*; исламга дини һәм дөньяви асылны берләштерүче мәдәни күренеш итеп карау; мөселманнарның үз белемнәрен баетуга даими омтылышы (мөселманның иң мөһим бурычларыннан берсе); ир-атлар һәм хатын-кызларның тигез хокуклы булуы; толерантлык. Исламның элеккеге Советлар Сою-

зы киңлекләрендә яңаруы индустриаль яки индустрияләшүгә юл тоткан җәмгыять шартларында бара, анда кешеләрне үз дини җәмгыятьләре кысаларындагы традицион шәхси мөнәсәбәтләр һәм гадәтләр генә түгел, идеологиягә әйләнгән максат һәм символлар да берләштерә. Бүген ислам гаилә һәм җәмгыятьнең үзаң формасы гына түгел, ә бәлки этник үзаңның һәм тормышны идеологик күзаллауның мөһим элементы да. Е. исламны эчтән реформалаштыруга юнәлтелгән һәм аның канунлы нигезләрен җимерүгә җирлек әзерли дигән фикердә торучылар аны кискен тәнкыйтьлиләр.

*Әд.:* Х а к и м Р. Где наша Мекка? (Манифест евроислама). К., 2003; ш у л у к. Ислам в Поволжье // Государственно-конфессиональные отношения в современном Татарстане. К., 2003; K h a k i m o v R. Prospects of Federalism in Russia. A View from Tatarstan // Security Dialogue. 1996. Vol. 27(1); ш у л у к. Euro-Islam or Islamic Europe. Berk., 2002; T i b i B. Islamische Zuwanderung. Die gescheiterte Integration. Münch., 2002; ш у л у к. The Challenge of Fundamentalism. Political Islam and the New World Disorder. Berk., 2002; ш у л у к. Taklid and ijtihad // Russia in global affairs. 2003. № 4; шул ук. // Il dzadidismo: lineamenti dell'Euro-islam // Religioni e Societa. 2003. № 47.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**ЕВРО́ПА БАЙБАГЫ́**, к. *Сөркә.*

**«ЕВРО́ПА-А́ЗИЯ»**, халыкара заманча музыка фестивале. Башта (1992 елдан) — Халыкара япон һәм татар музыкасы фестивале, 1993тән хәзерге исемдә. 1996 дан ике елга бер тапкыр Казанда, Мәскәүдә, ш.у. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән һәм ТРның башка шәһәрләренә чыгып үткәрелә. Оештыручылары: ТР Мәдәният министрлыгы һәм Композиторлар берлеге (Казан консерваториясе, ТР шәһәрләре хакимиятләре катнашында). Фестиваль ТР композиторларының халыкара киң багланышлар урнаштыруына, Көнчыгыш һәм Көнбатыш муз.-мәдәни традицияләрен якынайтуга, тыңлаучыларны хәзерге заман музыка сәнгате б-н таныштыруга булышлык итә. Фестиваль программаларының төп нигезен гаять киң стильләрнең камера формалары: европалы булмаган халыкларның традицион музыкасы, джаз, татар классик музыкасы, Татарстанның хәзерге композиторлары, 20 йөз дөнья музыкасы мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре әсәрләре тәшкил итә. Фестиваль программаларына кертелгән күпләгән әсәрләрнең эксперименталь характеры традицион музыка теле кысаларыннан тыш чараларны (компьютер техникасы, театр, бию, пантомима элементларын) җәлеп итүдә чагыла. Фестиваль күпсанлы концерт программаларын, ш.и. күп сәгатьләргә сузылган «марафоннар»ны, катнашучыларның импровизацияле гомуми чыгышларын, танылган композиторлар һәм башкаручыларның лекцияләрен һәм мастер-классларын колачлый. Ш.у. Татарстан һәм чит ил музыкантлары катнашында «арадаш» кече фестивальләр: Франция (1998) һәм Япония (1999) мәдәнияте көннәре, Нидерланд һәм Татарстанның хәзерге заман музыкасы көннәре (2001) үткәрелә. Фестивальдә БДБ илләреннән һ.б. чит илләрдән (АКШ, Япония, Нидерланд, Франция, Швеция, Төркия, Канада, Германия, Норвегия, Польша, Бөекбритания, Украина, Молдавия, Таҗикстан һ.б.) композиторлар һәм башкаручылар катнаша.

*Г.Р.Сәйфуллина.*

**ЕВРЮЖИ́ХИН** Геннадий Егорович (4.2.1944, Биектау р-ны Киндерле а. — 15.3.1998, Мәскәү), спортчы (футбол), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1972), «Ракета» СК тәрбияләнә (Казан). «Ракета» (1962–63), «Локомотив» (Ленинград, 1964), «Динамо» (Ленинград, 1965–66), «Динамо» (Мәскәү, 1966–76) командаларында уйный. СССР чемпионы (1976), СССР кубогы иясе (1967, 1970), СССР (1967, 1970), Европа (1972) чемпионатларында көмеш медаль, СССР чемпионатларында (1973, 1975), Олимпия уеннарында (1972) бронза медаль ала. СССР җыелма командасы (1966–72) составында 37 уен уздыра, 6 туп кертә. Илнең иң яхшы 33 футболчысы исемлегенә кертелә: 1967, 1973 (№ 2), 1970 (№ 1). 1977–98 дә Тышкы эшләр министрлыгында дипкурьер. 1975 елдан Мәскәүдә яши.

*Әд.:* М а к а р о в Д.А. «Рубин» (Казань): история и статистика (1958–2000). К., 2001.

**ЕВСЕ́ВЬЕВ** (1878 гә кадәр Кабаев) Макар Евсевьевич (18.1.1864, хәзерге Чуаш Респ-касының Ибреси р-ны Кече Кармалы а. — 1.5.1931, Казан), мордва мәгърифәтчесе, педагог, этнограф, тел белгече, миссионер. Буа өязенең Шерауты авылында земство мәктәбен, Казан укытучылар семинариясен (1883) тәмамлый, өяз уч-щесе укытучысы исеменә имтиханнар тапшыра (1897). 1892–93 һәм 1900 елларда Казан ун-тының тарих-филол. ф-тында ирекле тыңлаучы була. 1883 елдан Казан укытучылар семинариясе каршындагы мари, 1884 тән мордва үрнәк башлангыч уч-щеләрендә укыта, 1894–1919 да ш.у. семинариянең әзерлек классында укытучы. 1920 дә Казандагы мордва пед. курслары директоры. 1920–29 да ТАССР Үзәк музееның этнография бүлегендә фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта 1922–25 тә Көнчыгыш пед. ин-тында мордва-эрзя һәм мордва-мукшы телләрен укыта, 1925–30 да Татарстан коммунистик ун-тында, Мәскәү, Саранск, Казан шәһәрләрендә мордва укытучылары съездлары һәм курслары җитәкчесе. Е.ның фәнни һәм пед. эшчәнлеге киң колачлы һәм күпьяклы була. Н.И.Ильминский җитәкчелегендә А.Ф.Юртов б-н бергәләп мордва-эрзя һәм мордва-мукшы телләрендә хәзер дә кулланыла торган алфавит төзи. 1893 тә мордва-эрзя мәктәпләре өчен мордва әлифбасы үсешенә башлангыч биргән дәреслекләр (әлифба, уку китабы, рус телен өйрәтү), ярдәмлекләр бастыра, алар 1930 елларга кадәр кулланышта була. 1910 да Е. Инҗилне мордва-эрзя теленә тәрҗемә итеп чыгара, 1929 да — «Эрзя теле грамматикасы»н («Грамматика эрзянского языка»), 1931 дә «Эрзяча-русча сүзлек» («Эрзянско-русский словарь») нәшер итә. 1883 тән 1930 га кадәр һәр җәйдә тел һәм этнография экспедицияләре б-н мордва авылларына чыга, фин һәм рус угро-фин теле белгечләре б-н Россиянең Европа өлешендәге 650 мордва авылында була, фольклор, тел һәм этнография материалларын өйрәнә. Бик күп мордва әкиятләрен, туй һ.б. йолаларның тасвирламаларын бастыра. Этнография буенча җыелган әйберләре ТАССР Үзәк музеенда (хәзерге ТР Милли музее) угро-фин бүлегенең нигезен тәшкил итә. Этнография өлкәсендәге хезмәтләре өчен Рус геогр. җәмгыятенең көмеш медале (1892), Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәсенең алтын медале (1896), Париждагы Бөтендөнья күргәзмәсенең алтын медале (1900) б-н бүләкләнә. 1955 елдан Мордва пед. ин-ты (хәзер пед. ун-ты) Е. исемен йөртә.

Х е з м.: Избранные труды: В 5 т. Саранск, 1961–65.

*Әд.:* З е т к и н а И.А. Педагогическая деятельность М.Е.Евсевьева в Казанской учительской семинарии // Современные проблемы психолого-педагогических наук. Саранск, 1992. Вып. 2; Научно-педагогическая деятельность М.Е.Евсевьева и современность. Саранск, 1992.

**ЕВСЕ́ЕВ** Владимир Иванович (30.8.1945, Чистай ш.), травматолог, ортопед, мед. фән. д-ры (1983), проф. (1986). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1977–80 елларда гыйльми сәркәтип. 1980–87 дә Ижевск мед. ин-тында травматология һәм ортопедия каф. мөдире. 1987 дән «Тернәкләндерүче травматология һәм ортопедия» Бөтенсоюз Курган фәнни-тикшеренү үзәгенең (Ижевск ш.) Казан ф-лында: 1987–89 да директор, 1989 дан буыннарны протезлау лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре буыннар патологиясенә, рентгенодиагностикага, буыннарның анатомик-биомеханик үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Е. сынган тубык сөяген сәламәтләндерү өчен «углотор-репанатор» приборын төзи. Уйлап табуга 25 патенты бар.

Х е з м.: Математическое обоснование механизмов переломов малоберцовой кости и повреждения межберцового синдесмоза // Тр. Казан. НИИ травматологии и ортопедии. 1975. Т. 18; К рентгенологической диагностике повреждений дистального межберцового синдесмоза // Казан. мед. журн. 1975. № 2.



Г.П. Евсеев.

**ЕВСЕ́ЕВ** Гавриил Петрович (15.7.1914, хәзерге Баулы р-ны Потап Томбарлысы а. — 15.5.1973, шунда ук), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), майор (1945). 1932 елдан Баулы р-ны халык мәгарифе бүлегендә инструктор булып эшли. 1936 дан Кызыл Армиядә. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1940). 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 61 нче армиянең 547 нче миномёт полкы дивизион командиры. Брянск, Көнбатыш, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронт-

лары гаскәрләре составында Мәскәү сугышында (1941–42), Орёл һөҗүм операциясендә (1943), Украина, Белоруссия, Польшаны азат итү сугышларында, Берлин операциясендә (1945) катнаша. Нойлитцен торак пункты тирәсендә (Врицен шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Германия) Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында яши. Ленин ордены, ике Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ЕВСТРА́ТОВ** Вадим Данилович (22.12.1935, Воронеж ш.), философ, филос. фән. д-ры (1991), проф. (1992). Воронеж ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Красное Знамя» (Липецк өлкәсе Елец ш.), «Ленинец» (Липецк ш.), «Молодой коммунист» (Йошкар-Ола ш.) г-талары редакцияләрендә, КПССның Татарстан өлкә ком-ты Сәяси мәгариф йортында бүлек мөдире урынбасары булып эшли. 1972 елдан Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты), 1990–96 да филос. каф. мөдире. Хезмәтләре танып белү теориясенә һәм формаль логиканың философик проблемаларына, аңны анализлауның гносеологик принципларын эшләүгә карый.

Хезм.: Сознание как гносеологическая проблема. Саратов, 1984; Логика и теория аргументации. К., 1999; Основы философии. К., 1999.

*Әд.:* Алексеев П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**ЕВТУШЕ́НКО** Евгений Александрович (18.7.1933, Иркутск өлкәсе Зима ст.), язучы, публицист, тәрҗемәче. «Киләчәк разведчиклары» («Разведчики грядущего», 1952), «Энтузиастлар шоссесы» («Шоссе Энтузиастов», 1956), «Наз» («Нежность», 1962), «Ак карлар ява» («Идут белые снеги», 1969), «Ике пар чаңгы» («Две пары лыж», 1982), «Гражданнар, тыңлагыз мине...» («Граждане, послушайте меня...», 1989), «Минем үземнеке генә» («Моё самое-самое», 1995) исемле шигырь җыентыклары; «Җиләкле урыннар» («Ягодные места», 1982), «Үлемнән алда үлмә» («Не умирай прежде смерти», 1993) романнары һ.б. авторы; «Балалар бакчасы» («Детский сад», 1982), «Сталинны күмгәндә» («Похороны Сталина», 1993) кинофильмнарының режиссеры һәм сценарийлар авторы. Е. — «алтмышынчылар» буыны вәкиле. В.В.Маяковский юлыннан китеп, публицистика, риторика, югары пафос хас булган үз стилен булдыра. Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрендә заманның мөһим мәсьәләләренә битараф түгеллеге чагыла. Е. 1970 елларда Казанда була; «Казан университеты» поэмасын язу өчен архив материалларын өйрәнә. Поэмада киң тарихи фонда Россиядә мәгариф системасының тууын, үсүен күрсәтү б-н беррәттән күп кенә әхлак мәсьәләләренә дә тукталып үтә: разночинецлар феномены, укуга мөнәсәбәт, милләтара каршылыклар һәм, киресенчә, рус һәм татар мәдәнияте диалогы: «Казан, Казан, татар башкаласы, / күз алдыңа китерә алмадың / кайнап торган казаныңда синең / Россиянең куәт алганын». Казан шагыйре Н.М.Ибраһимовка багышланган: «Ни кызганыч: аз билгеле факт, / Һәйкәлләргә лаек асылда, / «Во поле березонька...» җырын да / татар чыгарганы ачылды. / Моның өчен сиңа, җан дустым, / Ибраһимов Нигъмәт, дан булсын!» — дигән юллар киң яңгыраш ала. 1970 тә поэма Казан ун-тында укыла. Е. әсәрләре Казан матбугаты битләрендә еш басыла. 1993 елдан бирле АКШта яши. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). 3 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Собр. соч.: В 3 *т.* М., 1983.

*Әд.:* Михайлов А. Поэты и портреты: портреты, проблемы, тенденции военного поколения // Новый мир. 1974. № 4; Сидоров Е. Евгений Евтушенко: Личность и творчество. М., 1987; Агеносов В., Анкудинов К. Современные русские поэты: Справ.-антология. М., 1998.

*А.Э.Скворцов.*

**ЕВТЮ́ГИН** Геннадий Артурович (29.7.1962, Казан), химик, химия фән. д-ры (2000), проф. (2005). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли. 2008 дән аналитик химия каф. мөдире. Хезмәтләре электроаналитик химиягә карый. Әйләнә-тирә мохитне пычранудан саклау өчен биохимик тикшерү чаралары (биосенсорлар) эшли. Ферментлар б-н тупланган потенциометрик электродлар нигезендәге биосенсорлар эчәргә яраклы суның беренчел сыйфатын, табигый һәм сәнәгать агынтылары җыелган су өслекләренең пычрануын тикшерү өчен сынап карала; алар Гидрохим. ин-тында (Ростов-Дон ш.), Бөтенроссия балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), РФА Урал бүлегенең Микроорганизмнар экологиясе ин-тында (Пермь ш.), төбәк һәм үзәк аналитик тикшерү инспекцияләрендә файдаланыла. Табигый суның пычрануын тикшерү өчен билгеләнгән холинэстераз сенсор Бөтенроссия күргәзмә үзәгенең көмеш медаленә лаек була. Е. кешенең иммун статусын, ДНКга аның антитәнчекләрен бәяләүнең, әйләнә-тирә мохит объектларындагы ксеноэстрогеннар һәм генотоксикантларның составын яңача билгеләүнең методикаларын төзи (бергәләп).

Хезм.: Микроконцентрирование в создании электрохимических сенсоров и биосенсоров для определения органических соединений // Рос. хим. журн. 2005. Т. 49, № 2 (автордаш); Электрохимические ДНК-сенсоры для определения биологически активных низкомолекулярных соединений // Рос. хим. журн. 2008. Т. 52, № 2 (автордаш); Polyphenothiasine modified electrochemical aptasensor for detection of human α-thrombin // Elektroanalysis. 2007. V. 19 (автордаш).

**Е́ГЕРЕВ** Василий Васильевич (22.4.1886, Пенза губ. Соболевка а. — 19.07.1956, Казан), инженер-арх., архит-ра белгече. 1918–22 елларда Казан политехник ин-тында укый. Бер үк вакытта дәүләт корылмалары губерна ком-тының өлкән прорабы, 1920 дән архитектура-төзелеш бүлекчәсе мөдире. 1922 дән, ин-тны тәмамлаганнан соң, Татсовнаркомның Төзелеш идарәсе башлыгы (Татарстан респ-касы баш арх.). Бер үк вакытта 1926 дан югары типтагы индустриаль техникумда (элеккеге политехник ин-т) укыта. 1931–41, 1946–56 да Казан нефть сәнәгате төзүче-инженерлар ин-тының архит-ра каф. мөдире, 1941–46 да Казан химия-технол. ин-тында укыта. Хезмәтләре Татарстан архит-расы тарихына карый.

Хезм.: Материалы к истории зодчества Казани // Казан. музейный вестн. 1924. № 1; Внутреннее архитектурное убранство зданий Казани. К., 1927; Архитектурные впадины на булгарских памятниках зодчества // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те, 1928. Т. 34, вып. 1–2; Самобытное расселение народностей Казанского края // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1928. № 8; Сююмбекина башня (Опыт историко-архитектурного анализа). Обмеры. К., 1944.

*Әд.:* Саначин С.П. Влюблённый в Казань. Наследие первого татархитектора Василия Егерева // Казань. 1996. № 7/8.

**ЕГЕРМЕ́ БЕРЕНЧЕ́ МӨСЕЛМА́Н УКЧЫЛА́Р ПО́ЛКЫ**, 1918 елның ноябрендә Пермь шәһәрендә оештырыла. Аны оештыруда Пермь губерна мөселман хәрби коллегиясе, губерна хәрби ком-ты, Көнчыгыш фронтның 3 нче армиясе аерым берләшмәләре штабы идарәсе катнаша. Нигездә татарлар һәм башкортлардан төзелә. Полк составына өч укчы батальон, ш.у. пулемёт, сапёр, элемтә, җәяүле разведчиклар, гренадерлар командалары (барысы 2500 кеше) керә. Командирлары — А.И.Федоровский, И.Й.Ковзель, комиссарлары — Г.Кантуганов, М.Мотыйгуллин. 1918 нең ноябре башыннан полк Көнчыгыш фронтның 3 нче армиясе составында сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша, Кусье-Алексеевск з-дына, Всесвятская станциясенә килү юлларын һ.б. саклый. Бәрелешләр вакытында шактый югалтуларга дучар була: декабрь уртасына полкта 600 кеше кала. Соңрак Усолье шәһәренә җибәрелә, анда 100 кешедән торган 1 нче Усолье коммунистик отряды б-н тулыландырыла һәм Төньяк Урал аерым дивизия составына бирелә. 1919 ның 15 августыннан Көньяк фронтка җибәрелгән 51 нче укчы дивизия (командиры В.К.Блюхер) составында. Днепр елгасының сул ярында Каховка плацдармын саклый, Кырымны барон П.Н.Врангель гаскәрләреннән азат итүдә катнаша.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ЕГИАЗА́РОВ** (Егиазарянц) Соломон Адамович (1.1.1852, Эриван губ., Эриван өязе Давалу а. — 1917 дән соң), хокук белгече, дәүләт хокукы д-ры (1892), хакыйкый статский советник (1908). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1880). 1883–85 елларда Кавказда була, анда «Кавказ аръягы төбәге дәүләт крәстияннәренең икътисади тормышын өйрәнүгә караган материаллар җыентыгы»н («Свод материалов по изучению экономического быта государственных крестьян Закавказского края», Тифлис, 1887) төзүдә катнаша. 1887–92 дә Казан ун-тының энциклопедия һәм хокук тарихы каф. приват-доценты, 1892–93 тә экстраординар профессор, 1893 тән Киев ун-тының дәүләт хокукы каф. экстраординар профессоры, 1894 тән ординар профессоры, 1913 тән атказ. профессор. Хезмәтләре дәүләт оешмалары тарихы, хокук

фәлсәфәсе, Кавказ халыклары икътисады һәм этнографиясенә карый.

Х е з м.: Брак у кавказских горцев. М., 1878; Исследование по истории учреждений в Закавказье: В 2 ч. К., 1889–91; О водовладении в Закавказском крае. Киев, 1896.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ЕГИДЕ́РЕВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 96 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вознесенский исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да земство мәктәбе (1869 да ачыла), 6 җил тегермәне, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3041 дис. тәшкил итә. 1906–16 да иске Вознесение чиркәве урынына Барлык хәсрәт чигүчеләр шатлыгы — Богородица чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 306 ир-ат; 1859 да — 795, 1897 дә — 1017, 1908 дә — 1275, 1920 дә — 1150, 1926 да — 825, 1938 дә — 563, 1949 да — 408, 1958 дә — 411, 1970 тә — 300, 1979 да — 199, 1989 да — 121, 2002 дә — 122 кеше.


**ЕГО́РКИНО** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аксумла елгасы буенда. 2008 елда 930 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, чөгендер үстерү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1742 елдан Аксумла исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, тире иләү, күн аяк киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да волость идарәсе урнаша, чиркәү (1905 тә төзелә, 1929 да ябыла), волость банкы, фельдшерлык пункты, земство мәктәбе (1879 да ачыла), 2 тимерчелек, 2 җил тегермәне, 3 сыраханә, казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете була; җомга саен базар эшли, ел саен 2 ярминкә (Троица һәм 26 сентябрь ярминкәләре) үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3830 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 802, 1897 дә — 1309, 1908 дә — 1374, 1920 дә — 1763, 1926 да — 1548, 1938 дә — 1432, 1949 да — 1247, 1958 дә — 1146, 1970 тә — 1339, 1979 да — 1126, 1989 да — 932, 2002 дә — 1008 кеше.

**ЕГО́РОВ** Вадим Леонидович (21.7.1938, Мәскәү), археолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (1987). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), СССР Мәдәният министрлыгында эшли. 1970–92 елларда СССР ФАнең (1991 дән — РФАнең) Тарих ин-тында. 1992 дән Дәүләт тарих музее директоры урынбасары. Идел буе археол. экспедициясе отряды җитәкчесе сыйфатында Алтын Урданың элекке шәһәрләре Сарай әл-Җәдид (1967), Бәлҗәмин (1967–74), Сарай әл-Мәхрусә (1975–91) терр-яләрендә археол. казу эшләре алып бара. Хезмәтләре Алтын Урда шәһәрләре тарихи географиясенә, тарихына һәм археологиясенә, гомуми тарихына карый.

Х е з м.: Причины возникновения городов у монголов в 13–14 вв. // История СССР. 1969. № 4; Развитие центробежных устремлений в Золотой Орде // Вопр. истории. 1974. № 8; География городов Золотой Орды // Вопр. истории. 1977. № 1; О времени возникновения Казани // Вопр. истории. 1977. № 4; Мавзолеи Водянского городища // Вопр. истории. 1980. № 1; Золотая Орда перед Куликовской битвой // Куликовская битва. М., 1980; Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985.

**ЕГО́РОВ** Виктор Николаевич (6.11.1927, Новгород өлкәсенең Боровичи р-ны Михалино а.), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1982). 1951–72 елларда Боровичи агач эшкәртү станоклары з-дында эшли. 1972–87 дә «КамАЗ» ҖБнең станоклар төзү з-дында. Дәүләт бүләге хезмәттәге зур казанышлары, җитештерүдә югары нәтиҗәгә ирешүе һәм эшенең сыйфаты, экономияле һәм җитештерүчән машина һәм механизмнар булдыру эшенә шәхси өлеш керткәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


**ЕГО́РОВ** Георгий Ефимович (16.4.1925, Барнаул ш. — 6.5.1988, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1980). Барнаул театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1941), Барнаул край курчак театры труппасына кабул ителә. Бөек Ватан сугышында була. Украина фронтында сугыша, Чернигов шәһәрен азат итүдә катнаша. Демобилизацияләнгәннән соң Барнаул край драма театрында (1947–50), Великие Луки, Могилёв, Пенза шәһәр театрларында эшли. 1960 тан Казан Зур драма театрында. 1978–85 тә аның директоры. Казанда башкарган беренче рольләреннән үк (Никита — «Караңгылык патшалыгы», Л.Н.Толстой; Платонов — «Океан», А.П.Штейн; Пётр — «Югалган бала», А.Н.Арбузов; Линьков — «Хуҗа», И.М.Соболев) үзен социаль портретлар остасы итеп таныта, үз геройларының эчке дөньясын кырыс һәм саран тоелган тышкы сурәтләр б-н төгәл тәңгәлләштерү ярдәмендә ачып бирүгә ирешә. Һәр образны, реалист буларак, чынбарлыктагыча тудыра, шул ук вакытта персонажларны уйнаганда берникадәр романтизм элементларын да куллана. Е.башкарган Нагульнов («Күтәрелгән чирәм», М.А.Шолохов), Николай («Туй көнендә», В.С.Розов), Дюжев («Кыргый ярда», Б.Н.Полевой романы буенча), Свидригайлов («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча) рольләре масштаблылыкка һәм шактый зур әһәмияткә ия булалар. М.Горькийның «Зыковлар» пьесасы буенча куелган спектакльдә Антипа Зыковның фаҗигале образын тудырып, актёр әхлакый идеалларның, гадәти тормыш нигезләренең җимерелүен күрсәтә. Генерал Чарнотаны («Качу», М.А.Булгаков) һ.б.ның гәүдәләндергәндә Е. комик гротескка кадәр барып җитә. Е. башкаруында татар драматургиясендә дә шактый әһәмиятле образлар барлыкка килә: Мисбах («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Чемоданлы кеше («Югалган көн», А.Гыйләҗев), Ислам («Әни килде», Ш.Хөсәенов). Казан Зур драма театрында режиссёр буларак та шактый спектакльләр куя (ш.и. О.де Бальзак романы буенча «Руже абзый мирасы» — «Наследство дядюшки Руже (Хищница)» — бу спектакль 10 еллап театр сәхнәсеннән төшмичә уйнала; И.В.Штокның «Ленинград проспекты» — «Ленинградский проспект», П.П.Ершов әкияте буенча куелган «Канатлы ат» — «Конёк-горбунок» һ.б). Үзе автор буларак, С.В.Иванов б-н берлектә «Чәчәк сере» — «Тайна цветка» (татар фольклорына нигезләнеп), «Ай малае» — «Лунный маль-



Г.Е. Егоров.



Г.Е. Е г о р о в генерал Чарнота роләндә (М.А.Булгаков, «Качу»).



Г.Е. Е г о р о в Нагульнов роләндә (М.А.Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романы буенча).

чик» әкиятләрен яза һәм сәхнәгә куя. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ЕГО́РОВ** Герман Анатольевич (12.9.1934, Казан), математик, техник фән. д-ры (1994), проф. (1994). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1960 тан Казан техник ун-тында (1980 нән махсус матем. кафедрасында). Хезмәтләре өзлексез һәм гибрид (дискрет өзлексез) системалар б-н идарә итү һәм аларның тотрыклылыгы, махсус билгеләнүле матем. өлкәләренә карый.

Х е з м.: Об устойчивости гибридных управляемых систем // Изв. вузов. Математика. 1993. № 4; Об устойчивости сложных систем управления движением // Вестн. Казан техн. ун-та. 1995. № 1.

**ЕГО́РОВ** Иван Елисивич (5.1.1853 — 5.1.1915, Ялта ш.), хирург, күз табибе, мед. д-ры (1885). Е.В.*Адамюк* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1875). 1875–79 елларда Казан ун-тының күз авырулары клиникасында эшли. Рус-төрек сугышы чорында (1877–78) Боржоми шәһәрендә яралы һәм авыру сугышчылар өчен Казан ярдәм күрсәтү җәмгыяте госпитален оештыра. 1879–84 тә Сарапул шәһәрендә өяз хирургы-күз табибе. 1986 дан Казан ун-тында күз авыруларына ашыгыч ярдәм күрсәтү кафедрасында, 1890 нан физиол. каф. прозекторы ярдәмчесе. 1891–1905 тә Казан табиблек идарәсендә, Александр исем. хастаханәдә табиб-консультант. 1906 елдан Казан ун-тының мәхкәмә медицинасы каф. прозекторы. Фәнни хезмәтләре буыннар иннервациясен, озын цилиар нервларның күз бәбәге зураюына йогынтысын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О глазном узле. Анатомо-физиологическое исследование // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1886. Т. 16, вып. 3; К учению об иннервации сосудов // Неврологический вестн. 1893. Т. 1, вып. 2.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ЕГО́РОВ** Сергей Петрович (2.10.1899, хәзерге Чуаш Респ-касы Алатырь ш. — 13.12.1969, Казан), нефтьче-геолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). 1919–23 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1929), Уфа, Мәскәү, Казан геол. оешмаларында, «Татгеолбюро» пр-тиесендә партия башлыгы, Мәскәү-Идел һәм Куйбышев гидроүзәк каналлары төзелешендә өлкән геолог. 1940 тан «Татнефтегазразведка» трестында; Шөгер нефтеразведкасында өлкән геолог, геол. бүлеге башлыгы (1947 дән), Казан геология экспедициясе башлыгы урынбасары (1965 тән), бер үк вакытта 1954–57 елларда Казан ун-тында укыта. Татарстан терр-ясендә нефтьнең эре девон чыганаклары разведкасы һәм эзләү методикасы авторларының берсе. Шөгер, Ромашкино (Дәүләт бүләге), Яңа Елховой, Бондюг, Алабуга һ.б. нефть чыганакларын ачуда катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новая тектоническая схема ТАССР // Геология и нефть. 1960. № 2; Тектоника ТАССР // Геология СССР. 1967. Т. 11, ч. 1 (автордаш).

**ЕГО́РОВ** Сергей Юрьевич (18.5.1959, Казан), микробиолог, биол. фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1983), шунда ук эшли. Хезмәтләре микроорганизмнардагы күзәнәктән тыш ферментларның физиологик ролен өйрәнүгә карый. Биотехнологиядә (а.х., азык-төлек сәнәгате, үсемлекләрне саклау чаралары, мед. микробиологиясе) нуклеодеполимеразалар кулланунын нәтиҗәләлеген нигезли. Экология, культивацияләү, микроорганизмнарның яшәү көчен билгеләү алымнары буенча методик уку ярдәмлекләре авторы. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм 4 патенты бар. «Бактериаль ферментлар: биосинтезның молекуляр механизмнары, характеристикасы һәм практик кулланылышын фәнни нигезләү» дигән хезмәте өчен ТР ФАнең В.А.Энгельгардт исем. бүләге бирелә (1996).

Х е з м.: Влияние различных форм РНКазы Bacillus intermedius на размножение олиготрофных микроорганизмов // Микробиология, 1994. Т. 63, № 1 (автордаш); Воздействие фосфатмобилизующих микроорганизмов на растения защищённого грунта // Вестн. Рос. акад. с.-х. наук. 1997. № 4; Регуляция жизнедеятельности микроорганизмов-стимуляторов роста растений. К., 2003.

**ЕГО́РОВ** Тимофей Егорович (1856, Казан губ., Лаеш өязе Янсуар а. — 1927, Казан), миссионер, педагог, Н.И.*Ильминскийның* эшен дәвам итүче. Керәшен татарлардан. Казан үзәк керәшен татар мәктәбен, укытучылар семинариясен тәмамлаганнан соң (1878), керәшен татар мәктәбендә укытучы һәм хор җитәкчесе (1895–1917 елларда директор), бер үк вакытта 1884 тән — дьякон, 1895 тән — рухани, 1906 дан — протоиерей. 1898–1914 тә Е. А.А.Воскресенский б-н бергә, соңрак Р.П.Даулей б-н татар телендә (Ильминский алфавитында) изгеләр тормышын бәян иткән 30 дан артык хикәятне, могҗиза тудыручы иконаларның тасвирламасын һәм миссионерлык эчтәлектәге башка хезмәтләрне әзерли һәм бастырып чыгара, славян көйләрен татар теленә яраклаштырып, керәшен татарлар халык музыка иҗатын үстерүгә сизелерлек йогынты ясый. 1918 дә пед. эшчәнлектән читләштерелә.

*Әд.:* Ч и ч е р и н а С.В. У поволжских инородцев: Путевые заметки. СПб., 1905; П р о к о п ь е в К.П. Николай Иванович Ильминский. К., 1916; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001.

*Е.В.Липаков.*

**ЕГО́РОВ** Юрий Александрович (28.5.1954, Казан — 16.4.1988, Амстердам, Нидерландның Велзен ш. җирләнә), пианист. 1972 елда Казан консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбен (И.С.*Дубинина* классы) тәмамлый. 1972–76 елларда Мәскәү консерваториясендә (Я.И.Зак классы) укый. 1976 дан Амстердамда яши. АКШ, Азия, Европа илләрендә гастрольләрдә була. Дөньяның иң мәртәбәле концерт залларында (Карнеги-холл, Консерт-гебау һ.б.) чыгышлар ясый. Аның репертуарына төрле стильдәге әсәрләр — И.С.Бах һәм В.А.Моцарттан, Р.Шуман һәм Ф.Шопеннан, П.Чайковский һәм С.Рахманиновтан алып К.Дебюсси һәм М.Равельгә, С.Гобәйдуллина һәм А.Шниткега кадәр булган композиторларның әсәрләре керә. «EMI», «Deutsche Grammophon» студияләрендә Е. 20 дән артык диск яздыра. Н.Рахлин, В.Ашкенази, А.Дорати, В.Заваллиш, Р.Бенц кебек дирижёрлар б-н хезмәттәшлек итә. Җырчы Б.Хендрикс, скрипкачы Э.Верхей; фортепиано ансамблендә П.Шифф б-н концертмейстер буларак чыгышлар ясый. Е.ның концерт эшчәнлеге матбугатта югары бәяләнә. «Нью-Йорк Таймс» г-тасы аның талантын бриллиант б-н чагыштыра, ә «Санди Таймс» (Лондон) г-тасы пианистның аудиториягә тәэсир итү көчен иң бөек башкаручыларга хас булган табигыйлегендә күрә. Е. истәлегенә Амстердамда оештырылган «Юрий Егоров фонды» яшь музыкантларга ярдәм итә, Амстердам янындагы Алмир шәһәренең бер урамы аның исеме б-н атала. «Юрий» дигән яңа тюльпан сорты үстерелә. Е. Идел буе яшь пианистларының Д.Б.Кабалевский исем. конкурсы (2 нче бүләк, Куйбышев ш., 1966); М.Лонг һәм Ж.Тибо исем. халыкара (4 нче бүләк, Париж, 1974); П.И.Чайковский исем. халыкара (3 нче бүләк, 1974) конкурслар лауреаты. 1994 елда Казанда Е. истәлегенә муз. фестиваль үткәрелә.

*Әд.:* Ф л и е р Я. Продолжение традиций. Конкурс пианистов // Музыкальная жизнь. 1971. № 17; Г а к к е л ь Л. Победы и проблемы // Советская музыка. 1974. № 11; Ц ы п и н Г. Молодые лауреаты // Музыкальная жизнь. 1975. № 7; Д у б и н и н а И. Его имя узнал весь мир // Казань. 2001. № 8.

*В.И.Спиридонова.*

**ЕГО́РОВА** Наталия Константиновна (26.6.1972, Казан), актриса, ТРның халык артисты (2008). Казан театр. уч-щесен тәмамлаганнан соң (1991), «Әкият» Татар курчак театры труппасына кабул ителә. Бер үк вакытта (2000–04 елларда) Казан сәнгать һәм мәдәният ун-тында укый. Курчак театрында эшләве дәверендә Е. 70 тән артык роль башкара. Курчакларны искиткеч оста уйнатуы һәм һәрдаим яңача гәүдәләндерә алуы игътибарга лаек. Актрисаның әлеге осталыгы бер спектакльдә берничә рольне башкарганда аеруча ачык күренә. Е., нигездә, лирик-героик плandагы актриса. Төп рольләре: Җансылу, Апуш («Ике тиен акча турында әкият», «Апушның тылсымлы төшләре», Р.Бохараев), Машенька («Казлар-аккошлар», Л.А.Кожевников), Земфира («Чегәннәр», А.С.Пушкин поэмасы буенча), Мари («Щелкунчик», Э.Т.А.Гофман), Дюймовочка (Х.К.Андерсенның шул исем. әсәре буенча), Герда («Кар патшасы турында әкият», Е.Л.Шварц). Бу рольләрдә ул үз героиняларының хис-кичерешләрен, нәни тамашачыларның күңелләренә үтеп керә алырлык итеп, бөтен тирәнлеге б-н чагылдыра. Измир (Төркия), Брауншвейг (ГФР), Канны (Франция), Стара Загора (Болгария), Рязань (Россия), Брест (Белоруссия), Меджидия (Румыния) шәһәрләрендә уздырылган халыкара театр фестивальләрендә, ш.у. К.Тинчурин исем. 3 нче республика театр фестивалендә (1994) катна-

ша һәм дипломант була. Торговище шәһәрендә (Болгария) уздырылган «Тылсымлы пәрдә» («Волшебный занавес») фестивалендә Е.га хатын-кыз ролен (Машенька, «Казлар-аккошлар» спектакле) иң яхшы башкаручы дипломы бирелә (2008). Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Игламов Р.М. Искусство играющих кукол. К., 2004.

**ЕГО́РОВА** Светлана Николаевна (12.10.1958, Украина ССР Николаев өлкәсенең Лысая Гора р-ны Лысая Гора а.), фармаколог, провизор, фармакол. фән. д-ры (1999), проф. (1999). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли, 2001 елдан провизорлар белемен күтәрү ф-ты деканы. Е. җитәкчелегендә клофелинның яңартылган дару формасы эшләнә, эмульсияле майлар нигезле ярымфабрикат алына, тирене сәламәт тоту өчен косметологиягә дәвалау-косметология чарасы — «Дебют» лосьоны кертелә (автордаш), димефосфонлы дәвалау-косметик крем алу технологиясе эшләнә.

Хезм.: Теоретическое и экспериментальное обоснование состава и технологии лекарственных форм монофосфонатов. М., 1998.

**ЕГО́РОВА** Светлана Робертовна (29.8.1968, Чабаксар ш.) химик-технолог, химия фән. канд. (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). 1991 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзерге Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре катализ һәм адсорбция процессларына карый. Е. нефть химиясе һәм органик синтез процесслары өчен катализаторлар эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнаша. ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге «Түбәнкаманефтехим» АҖнең этилен з-дында производство куәтләрен һәм эффектлылыгын күтәрү буенча башкарган эшләр комплексы өчен бирелә. Уйлап табуга 7 патенты бар.

Хезм.: Влияние способа декатионирования на тектурные свойства высококремнистого цеолита ZSM-5 // Кинетика и катализ. 2002. Т. 45, № 6 (автордаш); Изменения в процессе реакции и регенерации Pd-Ag/$Al_2O_3$ катализатора селективного гидрирования ацетилена // Кинетика и катализ. 2007. Т. 48, № 3 (автордаш); Технология производства катализаторов. К., 2008.

**ЕГО́РЬЕВО** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 21 *км* төньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 14 кеше (руслар) яши. 17 йөз башында Казан Спас-Преображенье монастыре җирләрендә



Егорьево авылында Богоявление чиркәве. 2003 елгы фоторәсем.

нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богоявленский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да Богоявление чиркәве (1769 да төзелә, архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1883 тә ачыла), халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек уку өе, 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1740,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Державин волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 82 ир-ат; 1859 да — 448, 1897 дә — 492, 1908 дә — 480, 1920 дә — 620, 1926 да — 515, 1938 дә — 506, 1949 да — 132, 1958 дә — 122, 1970 тә — 53, 1979 да — 53, 1989 да — 23, 2002 дә — 10 кеше. Е.да шагыйрь Г.Р.*Державинның* ата-анасы җирләнгән.

**ЕДИНЕ́НИЕ** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 64 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1921 дә Егоркино, Чияле Алан, Каравыл Тавы авылыннан күчеп килгән кешеләр нигез сала һәм «Единение» а.х. хезмәт артелен оештыра. Шушы көннән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 132, 1938 дә — 112, 1949 да — 443, 1958 дә — 250, 1970 тә — 163, 1979 да — 118, 1989 да — 60, 2002 дә — 66 кеше.

**ЕДИХА́НОВ** Андрей Иванович (Габдулла Измаил улы) (1924, хәзерге Волгоград өлкәсенең Палласовка р-ны Бурсы а. — 21.1.1991), Дан орденының тулы кавалеры (27.7.1944, 21.1.1945, 6.5.1991, вафатыннан соң), өлкән сержант (1945). Татар милләтеннән. 1942 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 151 нче аерым разведка ротасы отделениесе (28 нче армиянең 130 нчы укчы дивизиясе) һәм 901 нче укчы полк отделениесе (59 нчы армиянең 245 нче укчы дивизиясе) командиры. Сталинград, Көньяк, 4 нче Украина, 1 нче Белоруссия һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Украина, Белоруссия, Польшаны азат итү сугышларында, Берлин һәм Прага һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 23 июнендә Подосинники авылы (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Октябрьск р-ны) өчен барган сугышта (беренчеләрдән булып дошман траншеясына бәреп керә һәм яралы хәлендә дә сугыш кырын ташламый, отделение б-н дошманның 2 һөҗүмен кире кайтара, дошман турында мөһим мәгълүматлар таба); 1945 нең 19 гыйнварында Краков шәһәре (Польша) өчен барган сугышта (беренчеләрдән булып шәһәргә бәреп керә һәм урам сугышларында дошманга зур зыян китерә); 1945 нең 30 гыйнварында Одер елгасын кичеп Одервальд торак пункты (Глейвиц шәһәреннән 27 *км* көнбатыштарак, хәзерге Гливице ш., Польша) янындагы сугышта (беренче булып ярга чыгып, отделение составында яуланган чикне саклап тора) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Савинка авылында эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**«ЕЖЕНЕДЕ́ЛЬНИК ЛИТЕРАТУ́РЫ, ИСКУ́ССТВА И НАУ́КИ»** («Әдәбият, сәнгать һәм фән атналыгы»), «*Известия ТАТЦИКа*» г-тасына кушымта. 1923 елның 8 июленнән 2 сентябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 9 саны чыга, күләме — журнал форматы б-н 8 табак. «Восток» комб-ты басмаханәсендә басыла. Рубрикалары: «Театр», «Әдәби хроника», «Фән һәм техника», «Кино», «Шахмат бүлеге». Төп урынны җирле авторларның (В.Александровский, М.Березин, П.Логинов, А.Мирский, Н.Новиков-Иванович, В.Покровский, П.Радимов, П.Яровой һ.б.) шигъри һәм чәчмә әсәрләре б-н берррәттән Россиянең күренекле шагыйрьләре (И.М.Вдовин, М.А.Зенкевич, В.В.Маяковский, А.В.Ширяевец һ.б.) әсәрләре алып тора. Бернчә санда М.Гафуриның «Эшче» поэмасы (рус теленә П.Радимов тәрҗ.), ш.у. П.Е.Корнилов, М.В.Нечкина, А.И.Тимофеев һ.б. авторларның әсәрләре басыла. Җирле һәм Россия мәдәни тормышы турында җентекле хроника бирелә, театр спектакльләре, рәссамнар әсәрләренең күргәзмәләре, музей экспозицияләре, иҗат берләшмәләре съездлары, нәшрият яңалыклары турында материаллар, әдәби һәм сәнгать журналларына күзәтүләр бирелә. Хәзерге заман сәнгатенең әһәмияте турында материаллар басыла; бернчә санда шул заман театрының үсеш тенденцияләре турында фикер алышу — бәхәсләр урнаштырыла, аларда С.Виноградов, С.Константинов, П.Логинов, Б.Симолин һ.б. катнаша; футуризм һәм Сул фронт турында мәкаләләр бар. 3 нче санда АХРР һәм Татар рәссамнар ассоциациясе декларациясе (авторы К.Травин) һ.б. урын ала.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЕЖКО́В** Валентин Фёдорович (27.5.1922, ТАССРның Арча кантоны Арча ш. — 19.8.1943, Украина ССР, Донецк өлкәсенең Шахтёр р-ны Степановка а.), Сов. Союзы Герое (19.3.1944, үлгәннән соң), гв. өлкән лейтенанты (1943). 1940 елга кадәр Харьков трактор з-дында эшли. Хәрби пехота уч-щесен (1941) тәмамлый. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 13 нче гв. укчы полкының танкка каршы көрәшү ротасы командиры (2 нче гв. армиясенең 3 нче гв. укчы дивизиясе). Донецк, Сталинград һәм Көньяк фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) сугышында, Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 19 августында Степановка авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: Е. җитәкчелегендәге рота дошманның 12 танкын юк итә. Шул сугышта



В.Ф. Ежков.

һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; М о л ч а н о в Б.Л. Ромашки на пьедестале. М., 1977; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Шёл парнишке в ту пору ... Киев, 1985.

**ЕЖКО́ВА** Галина Олеговна (27.1.1963, Казан), химик-технолог, биол. фән. д-ры (2004), проф. (2006). 1986 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Е., синт. антиоксидантлар кулланып, лизинсинтезлаучы бактерияләр б-н аминокислота биосинтезын гамәлгә ашыра. Мөгезле эре терлек һәм дуңгызлар өчен премикслар һәм аксымлы-витаминлы минераль өстәмәләр рәвешендә комплекслы азык кушылмаларын эшләгәндә микробиол. синтез продуктларын (лизин, азык аксымы) Татарстан чыганакларында булган табигый минераллар б-н бергә файдалануны тәкъдим итә. Әлеге өстәмәләрне кулланганда терлекләрнең минерал һәм аксым алмашы яхшыруын, итнең сыйфаты һәм микъдары үсүен исбатлый. Ит һәм ит продуктларының сыйфатын яхшырту һәм сәнәгать эшкәртүе барышында әзер продукцияне арттыру өчен фосфатларны соя аксымнары, крахмал һәм микроблардан алынган комплексы препарат б-н кушып куллануны тәкъдим итә. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре ТРның Мамадыш, Чистай, Тукай, Буа р-ннары катнаш азык җитештерү пр-тиеләрендә, Шебекино биохимия з-дында (Белгород өлкәсе) тормышка ашырыла.

Хезм.: Влияние антиоксидонтов на рост и состав липидов дрожжей Saccharomyces cerevisiae в различные фазы развития культуры // Изв. РАН. Сер. биол. 1997. № 2 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002 (автордаш); Технология повышения качества мясного сырья PSE и DFD на организменном и тканевом уровне. К., 2008 (автордаш).

**ЕЖКО́ВА** Маргарита Степановна (26.1.1942, Мари АССРның Юрино р-ны Юрино пос.), вет. патофизиологы, патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1985), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1964), 1964–67 елларда Яңа Чишмә р-ны «Красный Октябрь» с-зының вет. табибе. 1967 дән Казан вет. ин-тында, 1987–98 дә гистология каф. мөдире. 1998–99 да Ижевск а.х. академиясенең патологоанатомия һәм гистология каф. мөдире, 1999 елдан Казан вет. медицина академиясенең патофизиология каф. профессоры. Хезмәтләре лейкоз вакытында йогышлы авырулар патофизиологиясе, терлекләрне вакцинацияләү һәм нурландыру, себер түләмәсе һәм лептоспироз патоморфологиясенә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патологоанатомическая диагностика болезней крупного рогатого скота. М., 1987 (автордаш); Общая гистология. К., 1997.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЕЖО́В** Алексей Михайлович (30.3.1924, Калинин өлкәсенең Кимры ш. — 20.10.1991, Яшел Үзән ш.), полковник-инженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Хәрби Һава көчләренең Киев югары инженер-авиация хәрби уч-щесен тәмамлый (1961). 1942–65 елларда Мәскәү, Ленинград, Киев, Карпат буе хәрби округларында, Совет гаскәрләренең Германиядәге төркеме составында. 1965–84 тә «Серго исемендәге завод» ҖБдә СССР Оборона министрлыгының өлкән хәрби вәкиле. Дәүләт бүләге махсус максатлар өчен эшләнмәләрне камилләштергәне һәм аларны әзерләүнең прогрессив технологиясен булдырганы өчен бирелә. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен» ордены б-н бүләкләнә.

**ЕЖО́В** Назарий Яковлевич (1888, Пермь губ. Павлово а. — 1946, Казан), революцион хәрәкәттә катнашучы. Пермь а.х. мәктәбен тәмамлый (1906). Пермь тау сәнәгате округының тимер җитештерү з-дында эшли. 1915 елда Россия армиясенә алына, Пермь шәһәрендә 107 нче пехота запас полкында хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанга прапорщиклар мәктәбенә җибәрелә. 1917 нең июненнән прапорщик, курс офицеры ярдәмчесе. 1917 нең апреленнән РСДРП(б)ның Казан ком-ты б-н актив хезмәттәшлек итә. Казан хәрби округ ком-ты әгъзасы, хәрби-өйрәнү һәм адм. комиссияләр җитәкчесе. 1 нче Хәрби округ конференциясе (1917 нең марты), 1 нче һәм 2 нче Казан хәрби округ съездлары (1917 нең август, ноябре) делегаты. 1917 нең сент.-октябрендә РСДРП(б)ның Казан ком-ты каршындагы хәрби оешма рәисе урынбасары. 1917 нең ноябреннән Казан хәрби округының Комиссарлар (командирлар) советы рәисе. Е. имзасы б-н иске армияне демократлаштыру, атаман А.И.Дутов фетнәсенә каршы көрәш, Идел буе-Урал төбәгендә Кызыл Армия берләшмәләре оештыру турындагы боерыклар чыга. 1918–19 да Хәрби әсирләр һәм качаклар эшләре буенча Идел буе комиссиясе рәисе. 1919–20 дә Төркестанда җаваплы эштә. 1926 да ТАССР Эшче-крәстияннәр инспекциясе халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1927–29 да ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты *Истпарты* җитәкчесе. 1929 дан сәламәтлеге начараю сәбәпле пенсиядә. Истәлекләр авторы.

*Әд.:* Военная Казань в 1917 году. К., 1927; И о н е н к о И.М. Ежов Назарий Яковлевич // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*С.И.Ионенко.*

**ЕКАТЕРИ́НА**, елга, к. *Атмас*.

**ЕКАТЕРИ́НА II** Алексеевна (тумыштан — Софья Фредерика Августа, немец принцессасы Анхальт-Цербстская) (21.4.1729, Германиянең Штеттин ш. — 6.11.1796, Царское Село ш.), Россия императоры (1762 елдан). 1767 нең 26–31 маенда Идел буйлап галераларда сәяхәт иткәндә Казанда була. Сәүдәгәр И.Ф.Дрябловның Кече һәм Зур Проломная урамнары арасында урнашкан йортында туктала. Кремльне, Благовещение соборын, Богородице монастырен, шәһәрнең башка истәлекле урыннарын карый. Дворяннар һәм шәһәр кешеләре, ш.у. мөселман руханиларын кабул итә. 31 майда аның хөрмәтенә бәйрәм оештырыла. Е.II храмнарны төзекләндерүгә хәйрия акчасы бирә, Казанның Беренче ир балалар гимназиясен тотуга акчаны арттыра. Императорның Казанда булуының татар халкы өчен иң мөһим нәтиҗәсе — аның мөселманнарга шәһәрдә мәчет төзергә рөхсәт бирүе. Ул Казаннан граф Н.И.Панинга: «Ошбу шәһәр, һичшиксез, Россиядә Мәскәүдән соң беренче... Казанның зур патшалык башкаласы



Екатерина II портреты. Рәссам Ф.Рокотов. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

икәнлеге һәр нәрсәдән күренеп тора», — дип яза. 2 июньдә Болгар шәһәре хәрабәләрендә булып, шәһәрлекне борынгы истәлек буларак сакларга куша. Соңыннан аның флотилиясе галералары саклау өчен Казан адмиралтейтсвосына тапшырыла, аларны 1804 нең 3 сентябрендә сүтәләр, «*Тверь*» галерасы 1950 еллар уртасындагы янгын вакытында яна. 1774 нең гыйнварында Е.II Казан губернасының патша сарае милкендәге волостьлары рекрутларыннан атлы отряд төзергә һәм аны Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстияннәр кузгалышын бастыру өчен җирле дворяннар тарафыннан оештырылган аерым корпуска кушарга әмер бирә. Пугачёвчылар 1774 нең июлендә Казанны алганнан соң, император шәһәрне торгызуга зур күләмдә акча җибәрә.

Е. II вакытында Россия империясендәге татар халкы тормышында уңай үзгәрешләр була: диннәр тигезлеге игълан ителә (Изге синодның 1773 ел, 17 июнь Указы), Уфада Диния нәзарәте оештырыла (1788), татар морзалары хокукый яктан рус дворяннары б-н тигезләштерелә (1784), татарларга сәнәгать-җитештерүгә һәм сәүдә итүгә рөхсәт бирелә һ.б. Татар халкында Е.II не «әби патша» дип йөртү гадәте дә бар.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; А г а ф о н о в Н.Я. Из Казанской истории. К., 1906. Ч. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЕКАТЕРИ́НА БИСТӘСЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чөкәнеш бистәсе буенда. 2008 елда 483 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1765 тә нигез салына. Соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелгән отставкадагы солдатлар монда беренче булып килеп утыра, алар игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.Б.ндә Троица чиркәве (1875–83; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), 5 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, май язу йорты, 2 сыраханә, казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4070 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 июленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1494, 1897 дә — 1814, 1908 дә — 2682, 1920 дә — 2797, 1926 да — 2560, 1938 дә — 1486, 1949 да — 1056, 1958 дә — 10426, 1970 тә — 10036, 1979 да — 758, 1989 да — 544, 2002 дә — 536 кеше.

**ЕКАТЕРИНБУ́РГ**, шәһәр, *Свердловск өлкәсе* үзәге. Халкы 1293 мең кеше (2002). Татарлар саны: 1897 елда — 586, 1926 да — 3 мең, 1959 да — 30,1, 1970 тә — 39,8, 1979 да — 48,7, 1989 да — 51,1, 2002 дә — 51,9 мең кеше. Е.ка татарларның күмәк күченүе 19 йөз ахырында башлана. Алар, нигездә, күпсанлы завод-фабрикаларда, шахталарда, тимер юл төзелешендә эшли, сәүдә итү, агач материаллары әзерләү, таш чыгару б-н шөгыльләнә. 1919 га кадәр Е. та «Бертуган Агафуровлар» сәүдә йорты (1884 тә нигез салына), гыйбадәтханә (1889 дан мәгълүм), мәдрәсә (1895), «Ф.Ш.Богатиев һәм уллары ширкәте» (20 йөз башы), Мөселман хәйрия җәмгыяте (1907 дә оештырыла), Мөселман хатын-кызлар башлангыч югары уч-щесе (1915), Түләүсез мөселман-рус китапханә-уку өе (1915), Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү өчен вакытлыча оештырылган мөселман ком-ты (1915), Екатеринбург мөселман хәрби советы (1917) эшли. 1917 дә «Урал тавышы» г-тасының берничә саны чыга. Татарларның Е.ка күчеп килүләренең икенче дулкыны 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башына туры килә, һәм ул илне индустрияләштерү сәясәте б-н бәйле. 1919–40 та шәһәрдә татар җәмгыятенең милли-мәдәни тормышы зур үсеш ала. Бу чорда М.Вахитов исем. татар клубы (1919 да оештырыла, 1920 еллар ахырында Милли азчылыкны тәшкил иткән халыклар мәгариф йорты итеп үзгәртелә), *Свердловск татар театры*, берничә башлангыч татар мәктәбе һәм сыйныфы, җидееллык татар мәктәбе (1942 дә ябыла), эшчеләр ф-тының (рабфак) татар-башкорт бүлеге (1927–1930 еллар уртасы), совет-партия мәктәбенең татар-башкорт бүлеге (1922–30), Свердловск пед. ин-ты каршында татар теле һәм әдәбияты бүлеге (1934), Төрки халыкларның халык мәгарифе гамәли ин-ты (1922), Төрки халыклар Урал пед. ин-ты (1932) эшли. Вакытлы матбугат: «*Социализм юлы*», «*Алмашка*», «Сабан һәм чүкеч» (1919–30) г-талары, «Яшь коммунар» кушымтасы (1932–35), «Урал мәгарифе» бюллетене (1930 еллар башында), «Шәпи агай» ж-лы (1924–27) чыга. 1929–1941 дә радиоэфирда татарча «Соңгы яңалыклар» тапшыруы алып барыла. 1920 дән Сабантуй бәйрәме үткәрелә. 1950 елларда татар театры (Уралмашзавод мәдәният йорты каршында), 1970–80 дә «Ләйсән» эстрада ансамбле (Резина-техник әйберләр җитештерү з-ды мәдәният йорты каршында), 1980 елларда «Бәйрәм» эстрада ансамбле (Лавров исем. мәдәният йорты каршында) эшли. Татар милли-мәдәни тормышы бигрәк тә 1980–90 елларда активлаша. Бу чорда «Урал» җәмгыяте (1988 дә оештырыла, 1991 дә Свердловск өлкәсе татар-башкорт мәдәнияте үзәге, 1997 дән «Мирас» итеп үзгәртелә), Екатеринбургта М.Гафури исем. оешма, «Җәмгыяте хәйрия» матди ярдәм күрсәтү үзәге (1994), Татар һәм башкорт иҗтимагый-сәяси оешмасы (1995), Екатеринбург татар милли-мәдәни автономиясе (1997), Свердловск өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономиясе (1997), «Ак барс» милли-мәдәни спорт үзәге (1997), «Ак калфак» татар хатын-кызлар оешмасы (1997), Свердловск өлкәсендәге төрки халыкларның «әл-Табиб» сәламәтлек һәм социаль яклау үзәге (1999), Свердловск өлкәсе татар яшьләренең «Ватан» оешмасы (2001), коммерциячел булмаган «Милли медиа холдинг» хезмәттәшлеге (2002), «Адель» татар-башкорт студентлары оешмасы (2003) эшли. 1993 тән 2003 кә кадәр 27 татар җәмәгать оешмасы теркәлә. 2 татар телен өйрәтү якшәмбе мәктәбе (1989 һәм 2001 дән) эшли. Татар телендә вакытлы матбугат даими чыгып тормый. Алар арасында «Халык авазы» (1991 дә нәшер ителә), «Якташ» (1994), «Урал тау» һәм «Туган ягым» (2000) г-талары бар. 2001 дән «Саф чишмә» г-тасы нәшер ителә. 1994–96 да — «Якташ», 1997 дән «Мирас» радио тапшырулары чыгып килә. 2001 дән «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе вәкиллеге һәм «*Татар-Информ*» агентлыгы эшли. «Хәерле кич» (1999–2001), 2001 дән «Минем илем» телевидение тапшырулары алып барыла. Шәһәрдә Уралмашзавод мәдәният йорты каршында «Яшьлек» татар халык эстрада ансамбле (1960 еллардан), «Екатеринбург йолдызлары» эстрада ансамбле (1990 еллар башыннан), «Күгәрчен» татар һәм башкорт фольклоры балалар ансамбле (1991 дән), «Татар җыры» халыкара конкурс лауреатлары Н.Арысланов һәм Х.Гыйльфановларның иҗат төркемнәре эшли. 1996 дан Е.та ТРның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге (җитәкчесе Р.З.*Бикбов*) бар. Совет власте елларында да эшчәнлеген туктатмаган мөселман җәмгыяте яшәп килә. С.С.*Сәетгалиев*, К.Г.*Мохтаров*, Г. һәм С.Касыймовлар (к. *Касыймовлар*); Сов. Союзы Герое С.Г.*Галимҗанов*, армия генералы М.Ә.*Гәрәев*, генерал-майор И.А.Нуруллин, СССРның атказанган спорт осталары Ә.Б.*Нәҗметдинова*, Л.Б.*Нәҗметдинова*, Р.Г.*Салихова*, халыкара спорт остасы (тау туризмы) С.З.*Хәбибуллинның* тормыш юлы Е. б-н бәйле. 19 йөзнең атаклы татар эшкуарлары К.Агафуров (хәзер Урал сәүдәгәрләренең көнкүреш музее) һәм З.Агафуров (хәзер ТРның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге) йортлары татарларның мәдәни-тарихи ядкәре булып торалар.

*Әд.:* Гурьев Н.А. Национальные меньшинства Урала. М., 1930; Корепанова С.А. Общественная деятельность екатеринбургских купцов Агафуровых // Памяти Онисима Егоровича Клера; К 150-летию со дня рождения. Екатеринбург, 1995; Екатеринбург на рубеже столетий. Екатеринбург, 1999.

*Р.З.Бикбов, Х.М.Гыйльфанов.*

**ЕКАТЕРИ́НОВКА** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 116 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, руслар — 85%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да тегермән һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1632 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 393, 1897 дә — 612, 1908 дә — 667, 1920 дә — 809, 1926 да — 550, 1938 дә — 719, 1949 да — 637, 1958 дә — 615, 1970 тә — 347, 1979 да — 203, 1989 да — 83, 2002 дә — 152 кеше.

**ЕКАТЕРИ́НОВКА** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2008 елда 70 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урта Ачы исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чана, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 34 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 83, 1897 дә — 148, 1908 дә — 145, 1920 дә — 143, 1926 да — 368, 1938 дә — 164, 1949 да — 119, 1958 дә — 98, 1970 тә — 107, 1979 да — 98, 1989 да — 75, 2002 дә — 76 кеше.

**ЕКАТЕРИ́НОВКА** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2008 елда 104 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, руслар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага

кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сандык, тәгәрмәч, арба-чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да земство мәктәбе, 3 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 767 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 267, 1897 дә — 490, 1908 дә — 582, 1920 дә — 615, 1926 да — 660, 1949 да — 441, 1958 дә — 332, 1970 тә — 259, 1979 да — 191, 1989 да — 127, 2002 дә — 122 кеше.

**ЕКАТЕРИ́НОВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 45 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 6 *км* читтә. 2008 елда 116 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 60%, руслар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, агачтан әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да тегермән, вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 647 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Никола Пичкас волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 ноябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 285, 1897 дә — 325, 1908 дә — 356, 1920 дә — 394, 1926 да — 297, 1938 дә — 334, 1949 да — 242, 1958 дә — 191, 1970 тә — 242, 1979 да — 176, 1989 да — 133, 2002 дә — 134 кеше.

**ЕКАТЕРИ́НОВКА** посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Дим елгасы буенда. 2008 елда 13 кеше (татарлар, руслар) яши. 19 йөз башында нигез салына. Башта мордвалар яши, соңрак руслар килеп урнаша. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, читкә китеп эшләү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 890 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1859 да — 380, 1889 да — 401, 1920 дә — 106, 1926 да — 156, 1938 дә — 211, 1949 да — 146, 1958 дә — 115, 1970 тә — 85, 1979 да — 36, 1989 да — 15, 2002 дә — 19 кеше.

**ЕКИ́МОВА** Алсу Мөхәммәтҗан кызы (1.3.1951, Буа ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), ТРның атказ. химигы (2006), химия фән. канд. (1991). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Түбәнкаманефтехим» АҖнең фәнни-технол. үзәгендә эшли: смена инженеры, өлкән, әйдәп баручы инженер, нефть эшкәртү һәм пиролиз лаб-ясе җитәкчесе (1997 дән). Уйлап табуга 43 патенты бар. Дәүләт бүләге түбән олефин, бутадиен һәм бензолны нәтиҗәле җитештерү һәм егәрлеген арттыру эшләре комплексының фәнни һәм гамәли нигезен эшләгәне өчен бирелә.

Х е з м.: Плёнообразователь на основе отходов нефтехимических производств // Нефтепереработка и нефтехимия. 1990. № 9 (автордаш); Влияние углеводородного состава сырья на распределение продуктов процесса инициированного пиролиза // Химия и технология топлив и масел. 2005. № 5 (автордаш); Расширение сырьевой базы для произ-ва низших олефинов // Хим. пром-сть сегодня. 2006. № 12.

**ЕЛА́К КАРЧЫГАЛА́Р** (Buteo), карчыга кошлар семьялыгыннан ерткыч кошлар ыругы. 25 төре билгеле, Европа, Азия, Африка һәм Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре яши: гади Е.к. (B. buteo), йонтәс аяклы Е.к. (B. lagopus), тау карчыгасы (B. rufinus). Күчмә кошлар. Гади Е.к. катнаш якты урманнарда яши. Гәүдә озынлыгы 50 *см* га кадәр, ата кошның авырлыгы 600–800 *г*, ана кошныкы — 800–1200 *г*. Канатлары киң, чагыштырмача кыска. Койрыгы кыска, түгәрәкләнгән. Каурый капламының өске өлеше кара коңгырт, асты кызгылт-көрән. Язын, апрельнең икенче яртысында очып килә. Ояны агачларда ясый. Коңгырт тимгелле 2–3 яшькелт ак йомырка сала. Йонтәс аяклы Е.к. октябрьдә килә һәм декабрьгә кадәр тоткарлана, кайвакыт кышларга да мөмкин. Ата кошның авырлыгы 850 *г*, ана кошныкы 1100 *г* тирәсе. Аркасы кара-коңгырт, каурыйлары соры куныклы. Күкрәгендә тамчысыман тимгелләре бар. Канатлары киң. Койрыгы ачык төстә, түгәрәкләнгән. Төп аерымлык билгесе аякларының шүре өлешенең бармакларга кадәр диярлек йонланган булуы. Ояны җирдә, кайвакыт агачларда ясый. Кызыл-сары тимгелле 2–7 ак йомырка сала. Тау карчыгасы — очраклы очып килүче төр, Нурлат р-нында очрый. Каурый капламы чуар. Гәүдә озынлыгы 65 *см* га кадәр, авырлыгы 1000 *г* га кадәр. Балчыксыл текә ярларда, агачларда оялый. Барлык төрләре дә тычкансыман кимерүчеләр, гомумән алганда, кыр тычканнары, ш.у. җир тычканнары, сукыр тычканнар, сирәк кенә кошлар (миләш чыпчыклары, вак чыпчыклар) б-н тукланалар.

**ЕЛА́Н**, төрки-татар мифологиясендә һәм фольклорында иң архаик һәм гаять киң таралган затлардан берсе. Башка халыклар мифологиясе һәм фольклорында да тиңдәшләре очрый. Бик борынгы төрки-татар үрнәкләрендә Е. культы, аны илаһилаштыру, аңа табыну күзәтелә. Елан образы күпйөзле. Еланнар патшасы Ак Е. — кешеләргә дусларча мөнәсәбәттә, ә Кара Е. адәм баласы өчен куркыныч бер зат итеп сурәтләнә. Ак Е. б-н Кара Е. көрәше — киң таралган мифологик һәм фольклор сюжетларының берсе. Эпик герой, гадәттә, Ак Е.га ярдәмгә килә, Ак Е. да аны яклый. Геройга ш.у. йорт Е.ы да (кешеләр янында яши торган Е.) ярдәм итә. Татарларда бүгенге көндә дә ишегалдында ак елан очраса — бәхеткә, кара елан очраса — кайгыга дигән ышану яши. Күп кенә төрки халык әкиятләрендә Е. кешеләрнең ярдәмчесе һәм яклаучысы буларак очрый (татар әкияте «Ятим бала», башкорт әкиятләре «Бызыр Мәргән», «Көтөүсе» һ.б.). 10–12 йөзләрдә болгарларның Е. турындагы күзаллаулары Ибне Фазлан һәм әл-Гарнати тарафыннан тасвирлана. Вакыт үтү б-н мифология һәм фольклорда Е. образы көчле үзгәреш кичерә: урта гасырларның башлангыч чорында төрки-татар мифологиясендә ул явыз, хәйләкәр һәм бик куркыныч дошман буларак күз алдына килеп баса. Бу Казанга нигез салу урынын сайлап алуга багышланган риваятьләрдә (к. *Елантау*), татар әкиятләрендә («Утыз ул», «Алтын башлы, көмеш беләкле», «Ярлы егет белән Юха елан»), мәкаль һәм әйтемнәрдә (мәс.: «Елан кабыгын салса да, йөрәген үзендә калдыра») чагыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; У р м а н ч е Ф. Ак елан һәм еланнар // Фольклор теле — шигърият теле. К., 2001. Путешествие Ибн Фадлана на Волгу. М., 1939; Авеста в русских переводах (1861–1996). СПб., 1997.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ЕЛА́Н»**, рус геральдикасында «Зилант»,аждаһа яки елан кыяфәтендәге мифик затның символик образы. Казан һәм Казан губернасы гербларында сурәтләнә. Эмблеманың анык билгеләмәсе юк. «Е.»ны ешрак аждаһа яки канатлы елан дип саныйлар. Казан патшалыгы символы буларак 16 йөздә Явыз Иванның «Казан патшалыгы мөһере» дип язылган дәүләт мөһерендә барлыкка килә. Гәүдәсе — хайван, башы телен чыгарган һәм таҗ кидерелгән кош кыяфәтендәге фантастик зат итеп сурәтләнә. «Е.»ның башка төре 17 йөз Казан воеводалары мөһерләрендә сурәтләнгән. Аларда ул күбрәк канатлы еланга охшаган, кылыч кадалган (Казан ханлыгын буйсындыру символы), медальон эченә алынган, шунда ук «Казан патшалыгы» дип язылган яңа туган ай эшләп куелган. «Е.» сурәтенең Ялган Дмитрийнең герблы мөһерендә, патша Алексей Михайловичның байрагында, 1672 елгы хөкүмәт «Титулярнигында», немец сәяхәтчесе Корбның көндәлегендәге рәсемдә һ.б. әйберләрдә сурәтләнүе мәгълүм. «Казан елъязмачысы» кулъязмасында Казанның җамигъ мәчетеннән очып чыгучы «Казан аждаһасы» сурәте бар, ул 17 йөзнең билгесез рәссамы тарафыннан ясалган. Аны Казан көмешче-зәргәрләре (к. *Зәргәр*) үзләренең тамгаларына да төшергәннәр. 1781 елгы Указ Казан гербын раслый: «Алтын таҗ кидерелгән кара елан, Казанныкы, канатлары кызыл, тирәсе — ак». Бу гербта елан койрыклы, канатлы итеп, аяклары тавыкныкына, таҗ б-н бизәлгән башы этнекенә охшатып ясалган. 1856 да Казан губернасы гербы раслана һәм 1920 еллар башына кадәр кулланыла. Ул Казан гербына таңгәл килеп тора диярлек, ләкин биредә аждаһа күбрәк әтәчкә охшаган. «Е.» тарихи мәгънәсеннән әкренләп читләшә һәм акыл, көч, үлемсезлек символыннан әтәчкә яки канатлы әткә охшаган юаш мәхлук затка әйләнә бара. Әлеге образның килеп чыгышын кайбер тикшеренүчеләр рус сәнгате традицияләре б-н бәйләсәләр дә, «Е.»ны 16–17 йөзләр рус дини китапчылары

һәм икона ясаучылары иҗатларындагы рәсемнәргә, аерым алганда, сөңге б-н еланны чәнчегән Георгий Победоносец сурәте булган иконаларга кайтарып калдыру дөрес түгел. «Казанныкыннан» аермалы буларак, «рус» аждаһаларында мөгезсыман үсентеләр һәм таҗ юк, гәүдәсе аякларында басып торучы кошныкына түгел, еланныкына, канатлары ярканатныкына охшатып ясалган. «Рус» аждаһалары Казан гербындагы кебек елан койрыклы һәм эт башлы кошка түгел, ә бәлки койрыклы елан сурәтендәге рус традицияләренә якынрак тора. А.В.Арциховскийның борынгы рус гербларына караган тикшеренүләрендә, 19 йөздә К.Ф.Фукс тарафыннан җыелган болгар эшләнмәләрендә, татар халык әкиятләрендәге һәм риваятьләрендәге аждаһа сурәтләрен чагыштырма анализлауда, хәзерге заман галимнәренең (М.Х.Бакиров, Ф.Х.Вәлиев, Р.Г.Фәхретдинов һ.б.) хезмәтләрендә Казан гербының тарихи нигезе — Елан, аждаһа исеме б-н аталган образ ачыла. «Е.»ның килеп чыгышын татар халкының борынгы гореф-гадәтләре б-н бәйләп караучы тикшеренүчеләр Казан гербындагы елан, кош һәм эт кыяфәтләрен берләштергән полиморф затның генезисын б.э.к. 1 мең ахыры — б.э. 1 мең башы Көнчыгыш Азия канатлы аждаһасында күрәләр. Әлеге хыялый зат хамелеон башлы, сайгак мөгезле, үгез колаклы, елан койрыклы итеп сурәтләнә. Бөгелгән аяк очлары бөркет тырнаклары б-н төгәлләнгән, гәүдәсе балык тәңкәләре б-н капланган. Бу аждаһа көч һәм кодрәтне, кешеләргә муллык иңдерүне гәүдәләндерә. Мондый охшашлыкларны урта гасырлардагы Болгар һәм Биләр казылмаларыннан табылган бронза бизәкләрдәге аждаһа сурәтләрендә дә күрергә мөмкин: әлеге зат эт башлы, бөркет гәүдәле, елан койрыклы; башына сайгак мөгезе куелган, авызыннан озын теле чыгып тора. Эт, бөркет, дала сайгагы сурәтләре дала кешесе — күчмә халыклар яши торган мохитне җанландыра. Алар ш.у. төрки халыкларда тотемнар булып та саналганнар. Төрле җәнлекләрнең сыйфатлары бер затта туплануы, мөгаен, берничә кабиләне берләштергән хаким ыругының эмблемасын белдергәндер. Күрәсең, әлеге сурәт Идел Болгарстаны, соңрак Казан ханлыгының геральдик символы булган. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, әлеге затның сурәте (кылыч б-н чәнчелгән) рус гербының нигезен тәшкил иткән: сайгак мөгезе — таҗга, бөркет гәүдәсе әтәч гәүдәсенә әйләнгән, алар елан койрыгы һәм чыгып торган теле нигез итеп алынган прототипның атрибутлары буларак сакланган. Герб ясаганда (шәһәр башлыклары мөһерләрендә) рәссамнар Казан аждаһасы образының детальләрен бирүгә караганда аның гомуми йөзен, рус коралының мөселман коралыннан өстенлеген күрсәтергә тырышканнар. Шуның өчен дә гамәлдәге эмблема — Казан ханлыгы гербы файдаланылган.



Еланның бер үрнәге – полиморф зат сурәте төшерелгән бронза басма бизәк. 12–13 йөзләр. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы.




Казан патшалыгының Елан сурәте төшерелгән мөһере. 1603. Дәүләт грамоталары һәм шартнамәләре җыелмасы.

*Әд.:* Х у д я к о в Н. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А р ц и х о в с к и й А.В. Древнерусские областные гербы // Уч. зап. Моск. ун-та. 1946. Вып. 93, кн. 1; К а л и н и н Н.Ф. Казань: Ист. очерк. К., 1955; В а л е е в Ф.Х., В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; С у л е й м а н о в а Д.Н. Герб Казани: ещё раз о Зиланте // Идель. 2000. № 11.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЕЛА́Н АБАГАСЫ́**, е л а н т е л (Ophioglossum), елан абагачалар семьялыгыннан абага ыругы. 45 кә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буенча, башлыча, тропикларда киң таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Е.а. (O. vulgatum), нигездә, Көнбатыш Кама алдында очрый. Дымсу болыннарда һәм урман аланнарында үсә. 5–30 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыр системасы вертикаль, күп санда өстәмә озын тамырлары бар. Яфраклары спорасыз һәм споралы 2 өлештән тора. Спорасыз өлеше йомыркасыман яки эллиптик формада, чите бөтен, шома, аска таба тарая төшеп, нигезе б-н споралы сабакның янына тоташкан. Соңгысы — сабак формасында, очында 2 рәт булып тезелгән түгәрәк спорангийлардан торган цилиндрсыман башак б-н төгәлләнә. Споралары июнь–июльдә өлгерә. Августка үсемлекнең җир өсте өлеше үлә. Җылы яратучан. Уңайсыз климат шартларында йокы халәтендә калырга мөмкин. Тамыр үрентесеннән үрчи. ТРның Кызыл китабына кертелгән.


*Ф.З.Вәлиев.*

**ЕЛА́Н КАМЫШЫ́**, с у  н а р а т ы (Hippuris), елан камышчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Дөнья флорасында бер ыруг һәм бер төр — гади су нараты (H. vulgaris) уртача һәм салкын поясларда таралган. ТРда Каманың түбәнге агымындагы р-нннарда очрый. Болын, сазлыкларда, су буйларында үсә. 20–80 *см* биеклектәге үсемлек. Шуышма тамырчалы. Сабагы туры, куыш, куе яфраклы. Яфраклары бөтен, кыяксыман, 8–12 ләп бөҗра рәвешендә урнашкан; су өстендәгеләре сабакка перпендикуляр рәвештә үсә, су астындагылары аска иелгән. Чәчәкләре вак, аксыл яшел, су өсте яфраклары куенында; бер үк үсемлектә ике җенесле һәм аерым җенесле чәчәкләр була. Җимеше — коры төшчә. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм тамырчадан үрчи. Үләндә флавоноид, кумарин, органик кислоталар бар. Е.к. ялкынсынуга каршы һәм бөрештергеч чара буларак кулланыла.

*Ф.З.Вәлиев.*

**ЕЛА́Н КӨПШӘСЕ́** (Anthriscus), чатырчәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТРда бер төре — йонлы көпшә (A. sylvestris) үсә; республиканың барлык терр-ясендә очрый. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, сулык ярлары буенда үсә. 60–150 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры вертикаль, калын. Сабагы туры, эче куыш, тирән җыерчыклы, күптармаклы, өсте ялангач, аскы өлеше кытыршы төкле. Яфраклары чиратлашкан, икешәр яки өчәрләп каурыйсыман урнашкан, аскы яфракларның саплары озын, өскеләренеке — кыска. Чәчәкләре ак, вак, исле, катлаулы чатыр тәшкил итә. Җимеше — 2 өлешкә таркалучы салпы җимешлек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Күләгәгә чыдам үсемлек. Тамырларында — крахмал, органик кислоталар, флавоноидлар, сабак һәм яфракларында эфир мае, С витамины, лигнин бар. Ялкынсынуга каршы, авыртуны басу, тынычландыру чарасы буларак кулланыла. Тәмле исе өчен кулинариядә (ашамлыклар әзерләүдә) файдаланалар. Баллы үсемлек.

**ЕЛА́Н КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында, Яшел Үзән р-ны Бело-Безводный авылыннан көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 2,4 *га*, ш.и. 2 *га* га якын мәйданны сазлык күрәне, камыш үсемлекләре биләп тора. Су күләме 28 мең $м^3$. Озынлыгы 275 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*, уртача тирәнлеге 1,1 *м*, иң зур тирәнлеге 2,5 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Ярлары күтәренке (яр битләренең биеклеге 10–15 *м*), яр буенча киңлеге 5 тән 20 *м* га кадәр, урыны б-н тигез диярлек сөзәклек су-



Елан күле.

зыла. Суы бик йомшак, саргылт төстә, болганчык, сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта. Туенуы күбесенчә атмосфера явым-төшемнәре исәбенә. Күле ләмләнә, үлән б-н каплана бара. ТРның Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрдән сары төнбоек, йөзгәләк, тәңкә яфраклар үсә.

**«ЕЛА́Н ПАТШАСЫ́ ШАҺМАРА́»**, тылсымлы татар халык әкияте. Беренче тапкыр 1936 елда Апас р-нының Танай-Турай авылында К.Әхмәдишиннан Г.Толымбай язып ала. Әкият сюжеты борынгы Шәрекъ мифологиясе һәм әдәбиятында киң таралган. Җир асты патшалыгына эләккән егеткә анда яшәүчеләрнең һөҗүме яный. Егетне еланнар патшасы — Ак елан Шаһмара яклый. Әмма егет патшалыкта озакка кала алмый, һәм ул Шаһмарадан аны өйгә җибәрүен үтенә. Ак елан егетне күргәннәрен сөйләмәскә дигән шарт куеп җибәрә, киресен эшләсә, аның үләчәген әйтә. Егет дәшмәскә ант итә. Бервакыт егет яшәгән шәһәрнең падишаһы авырып китә. Ул үзенең бары тик Шаһмараны күреп кенә терелә алачагын белә. Падишаһның сихерчеләре егетнең серен ачалар һәм аннан Елан яшәгән урынны күрсәтүне таләп итәләр. Егетне җәзалыйлар, ул серен ачарга мәҗбүр була. Шуңа карамастан, Шаһмара үз үлеме б-н дә егеткә яхшылык эшләп калдыра: елан итеннән шулпа эчкәч, егет барлык авыруларны дәвалый ала торган табибкә әйләнә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты. К., 1951; Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Җ а м а л е т д и н о в Л.Ш. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЕЛА́Н УТЫ́**, к. *Түндербаш.*

**ЕЛАНБА́Ш** (Dracocephalum), иренчәчәкләләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төрне үз эченә ала. Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә 2 төре: Руйш Е. (D. ruyschiana), чабыр чәчәкле Е. (D. thymiflorum) барлык р-ннарда очрый. Урманда, куаклар арасында, кырларда, сөзәклекләрдә үсә. 10–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры — чуктамыр. Сабагы туры, 4 кырлы, ботаклы, кызгылт төсмерле. Чәчәкләре зәңгәр, шәмәхә, аксыл шәмәхә, яфрак куентыгында ялган такыяга җыелган. Җимеше — чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Август–сентябрьдә җимеш бирә. Орлыктан үрчи. Җир асты өлешләрендә флавоноид, эфир мае, орлыгында май, органик кислота бар. Халык медицинасында ашказаны-эчәк тракты органнары авырулары вакытында һәм бөрештергеч, спазматик, гомуми ныгыту, яра төзәтү чарасы буларак файдаланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**«ЕЛАНТА́У»**, урта гасырларның башлангыч чорында Казан татарларының риваятьләре һәм легендалары циклы. Төрле сюжетлы хикәяләүләрне (сихерче кыз, Казан каласының яңа урында корылуы турында) үз эченә ала. Вакыйгалар бер урында — Казансу елгасы иске юлының сул ярында, Идел елгасыннан 2 *км* ераклыкта, хәзерге Казан янындагы Елантау калкулыгында бара. Цикл татарларның тау һәм калкулыкларның тылсымы, аларны саклап торучы албастылар һәм яңа бина, яисә шәһәр корганда күктәге көчләргә корбан китерү турындагы (башта корбанга — кеше, соңрак чорларда хайван китерелә, бу үз чиратында Казан каласын яңа урында кору турындагы риваятьләрдә чагыла: хан улы урынына сарай нигезе астына эт күмелә) борынгы карашларын чагылдыра. Беренче тапкыр «Е.» циклы риваятьләрен «Казан елъязмачысы» (*«Казанский летописец»*) терки.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Х а л и к о в А.Х. Беренче дәүләт: Болгар иле. К., 1991; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; В а с и л ь е в М.А. Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды. К., 1924; Казанская история. М.–Л., 1954.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЕЛАНТА́У**, к. *Ялантау.*

**ЕЛАНТА́У МОНАСТЫРЕНЫ́Ң ШӘҺИ́Т КИТКӘН ИЗГЕЛӘРЕ́**, Казан Елантау монастыре (к. *Успение монастыре*) монахлары һәм монах булырга әзерләнүчеләр. 1918 елның 10(23) сентябрендә Казанны алганда, акгвардиячеләргә ярдәм итүдә гаепләнеп, архимандрит Сергей (Зайцев) (1863 тә туган), иеромонахлар Лаврентий (Никитин) (1872 дә туган), Серафим (Кузьмин) (1870 тә туган), иеродиакон Феодосий (Александров) (1864 тә туган), монахлар Леонтий (Карягин) (1870 тә туган), Стефан (фамилиясе билгесез), монахлыкка әзерләнүчеләр Георгий Тимофеев (1880 дә туган), Сергей Галин, Иларион Правдин, Иоанн Сретенский кызылармиячеләр тарафыннан атып үтереләләр. Иеромонах Иосиф (Тюрин) (1853–1919), очраклы рәвештә исән калып, фаҗига турында сөйләп бирә, шуннан соң үтерелгәннәрне җирлиләр. 1998 дә *Казан епархиясенең* җирле искә алынучы изгеләре буларак канунлаштырылалар, 2000 нең августында Россиянең яңа газап чигүчеләре һәм тәүбә итүчеләре исәбенә кертеләләр. Һәлак ителгән көндә искә алыналар.

*Әд.:* Ж у р а в с к и й А.В. Жизнеописания новых мучеников Казанских. Год 1918-й. К., 1996.

**ЕЛА́ЧИЧ** Франц Осипович (1808 — 1888), хирург, мед. д-ры (1832). Вильно (хәзерге Вильнюс) шәһәрендә ун-т тәмамлаганнан соң (1832), шунда ук эшли. 1832 елда дәвалау йортлары эшен өйрәнү һәм хирургия инструментлары сатып алу өчен Вена, Париж, Берлинга җибәрелә. 1834–61 елларда Казан ун-тында: проф., оператив хирургия һәм күз авырулары каф. мөдире, бер үк вакытта мед. ф-ты деканы (1835–36), атказ. ординар проф. (1859). 1844 тә Россиядә беренче булып яман шешле аналыкны җинсә аша алуны башкара (А.А.Китер б-н бергәләп), 1847 дә эфир наркозы куллана. Идел-Урал төбәгендә практик табиб буларак киң танылa.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ЕЛГА́**, Идел алдында. Чынлы елгасының сул кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 9,2 *км*, бассейнының мәйданы 42 *км²*. Елга башы Чүпрәле р-нының Иске Задур авылыннан көнбатыштарак, тамагы Ульянов өлкәсе терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 181 *м*, тамагыныкы — 116 *м*. Е.ның су җыелу терр-ясендә урман үсемлекләре юк. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км²* га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ЕЛГА́ БАССЕ́ЙНЫ**, җир өслегендәге су агымының елгага яки елга системасына аккан өлеше. Е.б.н еш кына елганың су җыелу мәйданы дип атыйлар. Аңа өске субүләр б-н чикләнгән җир өсте су җыелу мәйданы һәм җир асты суы шушы елгага (системага) төшә торган мәйданы керә. Җир өсте һәм җир асты су җыелу мәйданнарының чикләре, кагыйдә буларак, туры килми (аеруча кече елгаларда). Җир асты су җыелу мәйданының чикләрен билгеләргә кыен булганлыктан, гадәттә, Е.б. итеп җир өсте су җыелу мәйданы алына. Е.б.ның төп билгеләре — аның мәйданы (тигез шартларда елганың сулылыгы аңа бәйле), мәйданның биеклекләр буенча бүленеше, уртача биеклеге, озынлыгы, киңлеге һәм авышлыгы.

ТРда өч меңнән артык Е.б. (елгалар саны буенча) бар. Тулысы б-н респ-ка терр-ясендә урнашкан елга бассейннары: Зәй (5020 *км²*), Мишә (4180 *км²*), Казансу (2600 *км²*), Минзәлә (2120 *км²*), Мәллә (1018 *км²*), Актай (1016 *км²*), Үләмә (870 *км²*), Бөрсет (554 *км²*) һ.б. кечкенә елгалар. Гомумән алганда, ТРның барлык терр-ясе Идел елгасы бассейнына керә.

*В.И.Мозжерин.*

**ЕЛГА́ ЕЛАНБАЛЫГЫ́** (Anguilla anguilla), еланбалыклар семьялыгындагы балык. Евразия елгаларында яши. Яшь балыклар Урта Идел бассейнына Югары Идел күлләреннән үтеп керә. Озынлыгы 30–70 *см*, авырлыгы 500–800 *г*. Гәүдәсе ян-яктан кысылган, сирәк кенә түгәрәкләнгән, циклоидсыман тәңкәләр б-н капланган. Е.е.ның төсе аның яшенә бәйле. Сырты кара яшел яки коңгырт кара, корсагы ак яки саргылт, яшьләренең ян-яклары сары, җенси яктан өлгергәннәрендә металлсыман ялтыравыклы, көмешсыман ак. Арка йөзгече койрыкныкы б-н кушылмаган. Озын авызлы. Саңак куышлыгының очында йоткылык тешләре бар. Вак балыклар, уылдык, бакалар һәм умырткасызлар б-н туклана.

Е.е. бөтен гомерен диярлек төче суларда үткәрә, үрчү өчен Үзәк Америка ярлары буена китә, 300–400 *м* тирәнлектә уылдык чәчә. Ул диңгездә тукланмый. Уылдык чәчкәннән соң, олы балыклар үлә. Уылдыктан чыгу б-н личинкаларны агым эләктереп ала һәм аларны Европа ярларына илтә. Гәүдәсе үтә күренмәле. Озын юлның ахырында (2,5–3 ел) яшь

балык олысына охшаш рәвеш ала. Җенси өлгерү башланганчыга кадәр, 6–10 ел төче суда яши.

**ЕЛГÁ КАРАКОШЫ́**, аккойрык бөркет (Haliaeetus albicilla), карчыга кошлар семьялыгыннан ерткыч кош. Евразиянең урман һәм урман-дала зоналарының зур сулык ярлары буенда тереклек итә. ТРда, башлыча, Идел һәм Кама елгалары үзәннәрендә очрый. Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары төзелгәч, Е.к.ның саны шактый кими, хәзерге вакытта 30 пардан күбрәк исәпләнә. Оя коручы күчмә төр, кайберләре кышлый. Гәүдә озынлыгы 1 *м* га кадәр. Канат колачы 2,5 *м* га җитә. Олы бөркетнең авырлыгы 3 тән




Елга каракошы.

6,5 *кг* га кадәр, ана затлар аталардан эрерәк. Төсе көрән, башы һәм гәүдәнең түбәнге өлеше аксылрак. Канатлары киң, озын. Койрыгы кыска, чөйсыман, ак төстә. Аякларының түбәнге ягы каурыйланмаган. Томшыгы зур, ыргаксыман, сары төстә. Е.к. биек кәүсәле карт урманнарда оялый. Ояны февраль–апрельдә ясый башлый. Биек агачларга зур оя ясап, аны күп еллар рәттән куллана. Соргылт төстә 1–3 йомырка сала, ояда ана һәм ата кошлар чиратлашып утыра. Балыклар, имезүчеләр (куян, ондатра, йомран), кошлар (үрдәк, акчарлак, кыр тавыклары), үләксәләр б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Рахимов И.И., Павлов Ю.И. Хищные птицы и совы Татарстана. К., 1999.

**ЕЛГÁ КҮБӘЛӘКЛӘРЕ́**, чәчканатлылар (Trichoptera), умырткасыз бөҗәкләр отряды. 3 меңгә якын төре билгеле, Россиядә 600 тирәсе, Татарстан терр-ясендә 100 гә якын төре очрый. Аеруча еш очраучылар: Neureclepsis bimaculata, Phryganea grandis, Molanna angustata, Agrypnia obsoleta, A. striata, Limnephilidae семьялыгы вәкилләре һ.б. Олы Е.к. коңгырт-көрән төстә, гәүдә озынлыгы 2 дән 24 *см* га кадәр, су буйларында очрый (исеме шуннан). Төп билгеләре: бергә кушылып алга таба сузылган озын җепсыман мыеклары бар; канатлары аркада түбәсыман җыелып тора. Е.к. начар оча, авыз әгъзасы җитлекмәгән, шунлыктан алар тукланмый һәм атнадан артык яшәми. Йомыркаларын суга яки су үсемлекләренә сала. Личинка үсү стадиясе бер ел тирәсе һәм артыграк та сузыла, судагы тормышы ояларында гына урнашкан курчак стадиясе б-н тәмамлана. Личинкалары цилиндрсыман, баш, күкрәк (3 буынтыктан тора) һәм корсак (9 буынтыктан) өлешләренә бүленә; ян-яклары буйлап сызык сузылган һәм трахеяльı саңаклар урнашкан. Күкрәгендә калканчыклар бар, аларның саны һәм формасы Е.к.нең систематикасын ачыклауда зур әһәмияткә ия. Үсемлек б-н тукланучы личинкаларның авыз тишеге — аска, ерткыч личинкаларда алга таба юнәлтелгән. Үсемлек б-н тукланучы личинкалар үз ояларын төрле формада төзи, моның өчен алар эрләү бизләре сыекчасы б-н үсемлек кисәкләрен, кабырчык ватыкларын, ком бөртекләрен ябыштыра; ояларның формасы һәм төзелеше буенча Е.к.нең төрен билгеләргә мөмкин. Хәрәкәт вакытында личинка аннан башын һәм өч пар аяклы күкрәген чыгара һәм, әкрен генә оясын өстерәп, су төбеннән үрмәли; куркыныч янаганда гәүдәнең алгы өлешен тиз генә эченә тарта. Oxyethira һәм Agraylea ыругы личинкалары фәкать үз сыекчаларыннан гына үтә күренмәле оялар төзиләр, шунлыктан яхшы күренәләр. Polycentropodidae, Hydropsychidae һәм Rhyacophilidae семьялыгыннан булган ерткыч личинкалар оялар төземи яисә ау ятьмәләре һәм көпшәләре корылмалары б-н чикләнә. Личинкалар чиста, башлыча, агым суларда яши. Суның пычрануы һәм елга режимын үзгәртеп көйләү сәбәпле, күп кенә төрләрнең саны кими бара. Е.к.нең личинкалары б-н балыклар туклана.




Елга күбәләкләре:
1. Stenophylax permistus;
2. Phryganea grandis:
а — олы бөҗәк, б — аның личинкасы.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 3; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Райков Б.Е., Римский-Корсаков М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**ЕЛГÁ ПОРТЫ́**, судноларның имин тукталышын, комплекслы техник хезмәт күрсәтүне, йөк һәм пассажирлар б-н бәйле эшләр башкаруны тәэмин итүче пр-тие урнашкан, дулкыннардан саклана торган яр буе терр-ясе һәм аның янындагы акватория. Татарстанда елга портлары Идел (Казанда) һәм Кама (Чаллы, Чистай, Түбән Кама шәһәрләрендә) елгаларында бар.

Төбәк терр-ясендә беренче даими табигый пристаньнар 10 йөздән билгеле (мәс., *Ага Базарда, Болакта, Гостиный островта*). *Елга транспорты* үсеше нәтиҗәсендә башка причаллар һәм дебаркадерлар да корыла башлый. Аларны дулкыннардан һәм ташу суларыннан саклау җайланмасы булмый; бөтен төр эшләр дә кулдан башкарыла. Суднолар Парат, Спас, Чистай, Аракчино һ.б. затоннарда кышлый һәм төзәтелә (к. *Суднолар төзелеше*). 19 йөз ахырында Казан тирәсендәге затоннарда гына да ел саен 700 гә якын пароход һәм баржа кышлый. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Казан (Аргы һәм Бирге Усия (Устье) *Бакалда*), Чистай, Чаллы һәм Тәтеш пристаньнары иң эреләрдән санала. Камадан Иделгә китерелә торган йөкләр өчен әһәмиятле туктау пунктлары булып Богородское авылы (хәзер Кама Тамагы штп) һәм Лаеш шәһәрендәге пристаньнар тора. 1860–88 елларда Казан губернасында пристаньнар саны 41 дән 50 гә кадәр арта. 1875 тә Казаннан 7 чакрымда булган причалларга таба атлы трамвай юлы салына. Моннан соң да берничә мәртәбә шәһәр янында Идел б-н канал аша тоташа торган порт кору проектлары эшләнә (алар техник һәм финанс кыенлыклары аркасында гамәлгә ашырылмый кала). 1930 елларда Казан пристанендә тасмалы һәм пластинкалы транспортёрлар, тарту лебёдкалары кулланылышка керә, тимер юллар үткәрелә. Бөек Ватан сугышы елларында фронт һәм хәрби сәнәгать ихтыяҗларын тоткарлыксыз тәэмин иткәне өчен Казан пристане илнең елга транспорты арасында беренче булып Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә (1942). Киләчәктә ул йөк күтәрүчәнлеге 2,5–5 *т* булган йөзмә, портал һәм автомобильле күтәрү краннары, электрокарлар, электро- һәм автотөягечләр б-н җиһазландырыла, транзит йөкләр һәм пассажирларны ташуны тәэмин итә; 1948 елда порт статусы ала. 1953–64 тә Куйбышев сусаклагычын төзү барышында Казан шәһәре эчендә, ясалма саклана торган, тулысынча механикалаштырылган елга вокзалы булган яңа Е.п. сафка баса. Казан Е.п. РСФСР елга флоты министрлыгының тәҗрибә-күргәзмә пр-тиесенә әйләнә (1963), Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1971). 1980 гә Казан портында төяү-бушату эшләрен комплекслы механизацияләү дәрәҗәсе 99% ка җитә.

1970 елларда Түбән Кама сусаклагычын төзү барышында Чаллы, Чистай һәм Түбән Кама пристаньнары тулысынча торгызыла, механикалаштырыла һәм җирле әһәмияткә ия портлар исәбенә күчерелә. Чаллы шәһәрендә ш.у. КамАЗның Идел-Кама буендагы иң зур йөк порты төзелә (сусаклагычның тулып җитмәве аркасында эшләми).

Татарстан Е.п.ларын дамбалар һәм дулкын ваклагычлар саклый, алар судноларны төзәтү өчен техника б-н җиһазландырыла; аларда причаллар, порт өчен яр буе, навига-



Казанда елга вокзалы. 1962.
Арх. И.Г.Гайнетдинов.







1. Казанда «Кавказ һәм Меркурий» пароходчылык җәмгыяте пристане. 20 йөз башы;
2. Казан елга портында пассажирлар һәм йөк причаллары. Хәзерге күренеш.

ция җайланмалары һәм билгеләре, портал һәм йөзмә күтәрү краннары, күчмә һәм стационар транспортёрлар, пневматик, гидравлик һәм насос урнаштыру, бункерлау өчен (судноларны ягулык б-н тәэмин итү) җиһазлар, энергия-көч агрегатлары, яктылык, элемтә һәм янгыннан саклану системалары, ярдәмче судноләр, пассажирлар өчен елга вокзаллары, складлар һәм йөкләрне кыска вакытка һәм озак саклау өчен ачык мәйданчыклар, яннарына ук килгән тимер юллар һәм автомобиль юллары, тимер юл вагоннары өчен рампалар һ.б.ш. бар.

Республиканың төп Казан (мәйданы 22,3 *га*, ш.и. йөк зонасы — 14 *га*) һәм Чаллы (мәйданы 11,4 *га*, ш.и. йөк зонасы — 5,2 *га*) елга портлары «елга-диңгез» классына керүче судноларны кабул итә ала, 34,2 мең *т* га якын, шуңа күрә тәүлеккә 3,6 мең *т* йөкне үткәреп җибәрү, ш.и. туры — су юлы аша да, катнаш — тимер юл-су юллары аша да контейнерлар уздыру мөмкинлекләре бар. Казан Е.п. инфраструктурасына кергән таможня терминалы чит илләрдән китерелгән йөкләр б-н турыдан-туры эш башкаруга юл ача; елга вокзалы тәүлек саен туристлар һәм шәһәр яны теплоходларының 5,5 меңгә кадәр пассажирына хезмәт күрсәтә ала. Татарстан Е.п. шулай ук руда булмаган төзелеш материалларын казып чыгаруны оештыра, респ-ка һәм шәһәр яны линияләре буенча пассажирлар ташый, экскурсияләр үткәрә.

2000 еллар башыннан гидротехник корылмаларны һәм порт инфраструктурасын модернизацияләү буенча җитди чаралар уздырыла. 2005 тән Алабуга шәһәрендә порт төзелә. 2006–10 елларга ТРның транспорт комплексын үстерү программасында портларны торгызуны дәвам итү, яңа стационар причаллар төзү күздә тотыла. Порт хуҗалыгын алга таба үстерү респ-када комплекслы логистик үзәк булдыру б-н бәйле.

*Әд.:* Опыт разрешения задачи о казанском речном порте. К., 1915; Ф у р е р Л.Н., Л у к ь я н о в Г.М., С и н и ц ы н а К.Р. Речники Татарии. К., 1977; А л е к с а н д р о в И. Казанский речной порт: курс на устойчивое развитие // Татарстан. 2007. № 7.

**ЕЛГА́ ТРА́НСПОРТЫ**, төзекләндерелгән, табигый яки ясалма эчке суы булган, судноләр йөрерлек юллар буйлап (халыкара, районара, җирле) пасс. һәм йөкләр күчерүне тормышка ашыручы транспорт төре. Төрле типтагы (үзйөрешле һәм үзйөрешсез) һәм төрле максатта файдаланылучы (транспорт, техник, ярдәмче) судноларны һәм йөк күчерүләрне, судноларга техник хезмәт күрсәтүне тәэмин итүче порт-пристань хуҗалыгын үз эченә ала. Сезон ягыннан чикле булуга карамастан, елга буйлап күчерүләрнең өстенлекләре дә бар: аларның үзкыйммәте тимер юллардан 30% ка, автомобиль юлларыннан 3–5 тапкырга арзангаракка төшә; аларны оештыру чыгымнары тимер юл салуга киткән чыгымнардан 8–10 тапкырга азрак. Татарстанда судноләр йөри алырлык юллар 17 адм. р-н терр-ясе аша Идел, Кама, Вятка һәм Агыйдел елгалары буйлап 1056 *км* га сузыла (2008). Навигация, гадәттә, апрель ахырыннан ноябрь башына кадәр дәвам итә. Күп тармаклы елга челтәре булганлыктан, төбәк терр-ясендә Е.т. иң борынгы заманнардан бирле кулланыла. Сәүдә багланышлары киңәю нәтиҗәсендә ул аеруча актив үсеш ала. 10 йөздә болгар сәүдәгәрләре төрле типтагы, ш.и. йөкләр ташучы зур судноларда Европа һәм Азия арасындагы мөһим сәүдә юллары булып исәпләнгән Идел һәм Кама елгалары буйлап йөзәләр. Төбәкне Рус дәүләтенә кушканнан соң елгаларда, җирле судноләр б-н беррәттән, Югары Идел төбәге, Нократ, Пермь, Әстерхан каеклары йөри башлый, алар тоз, балык һ.б. товарлар ташый. Судноларны юлбасарлардан саклау өчен Казанда коралландырылган «ясаул каеклары» флотилиясе оештырыла. Казан тирәсендә Елантау монастыре янында эре пристань эшли; килеп туктаган корабльләрдән аның файдасына «мыт» җыела; монастырь шулай ук эре судноләр биләүче дә була. Аерым судноларның йөк күтәрүчәнлеге 650 *т* га җитә. Парсыз эшләүче судночылык үсеше 19 йөзнең 1 нче яртысына туры килә. Судночылык промыселында, нигездә, якын-тирә авылларда яшәүчеләр эшли. Мәс., Зөя өязе Югары һәм Түбән Ослан авыллары крәстияннәренең күпчелеге җәй көне лоцман, койрыкчы, сал агызучы булып Иделдә, Вятка губернасы Алабуга өязе Котловка авылыныкылар исә — Камада күчерү эшләрен тәэмин итәләр, кышын судноләр төзиләр һәм ремонтлыйлар. Судноларда махсус хәзерлек таләп итми торган эшләрне, ш.и. судноларны күчерүне *бурлаклар* башкара, 1854 тә алар арасында Иделдә 2,5 мең татар исәпләнә. Бу чорда 50 гә якын типтагы судноdан йөк күтәрүчәнлеге 1 мең *т* га кадәр булган расшивлар аеруча киң таралыш ала. 18 йөздә шулай ук атлы-машиналы судноләр да барлыкка килә. Казан пристаньнары Иделдә судноләр әйләнеше буенча икенче урында тора, биредә ел саен 500 дән артык судноға йөк төяләә һәм бушатыла. 1843 тә Казан *аралашу юллары округы* үзгенә әверелә.

Е.т. үсешендә сикереш пар двигателе һәм металл корпуслар барлыкка килгәннән соң ясала, бу елга флотының тизлеген һәм йөк күтәрүчәнлеген шактый арттыра. Пароходларның Кама һәм Идел буйлап Пермьнән Казанга кадәр беренче рейсы 1817 дә гамәлгә аша. 1840 еллардан башлап төбәк терр-ясендә «Идел буйлап» («По Волге»), «Кавказ һәм Меркурий», «Самолёт», «Кама», «Крестьянин», «Русь» һ.б. акционерлык пароход компанияләре үз эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. 1860 елларга пар көче б-н тарту мускул көче б-н тартуны тулысынча кысрыклап чыгара. Казан пристаньнарында хезмәт күрсәтелә торган судноларның саны 1898–1908 дә 3054 тән 6528 берәмлеккә җитә. Казан губернасы пристаньнарыннан җибәрелгән йөкләр арасында икмәк, металлар, агач һәм агач эшләнмәләр өстенлек итә. 1874–1913 тә Казан губернасы пристаньнарыннан йөк җибәрү 344,5 меңнән 737 мең *т* га кадәр арта. Пар көченә эшләүче Е.т. базар бәйләнешләрен ныгытуга һәм аларның географиясен үзгәртүгә, а.х. р-ннарын специальләштерүгә, читкә эш эзләп китүнең активлашуына, промыселлар һәм *судноләр төзелешенең* үсешенә булышлык итә. Е.т. прогрессын сай сулылык, навигация вакытында (аеруча төнге вакытта) билгеләр аз булу тоткарлый. Су юлларының яхшыруы, башлыча, пристань һәм затоннарга якын урыннарны чистартуда һәм, аз күләмдә булса да, сайлыкларны бетерүдә күренә. 1913 кә губерна буенча судноләр йөри алырлык юлларның озынлыгы 840 *км* га җитә.

Национализация үткәрелгәннән соң (1918) Е.т.да үзәкләштерелгән идарә оештырыла. 1919 да губерна терр-ясендә навигациядә 180 гә якын пароход, 560 баржа, 14 җир казу машинасы катнаша. Судноларның бер өлеше, яңадан җиһазланганнан һәм коралландырылганнан соң, *Идел хәрби флотилиясе* составына күчерелә. Гражданнар сугышы вакытында Е.т. шактый нык туза һәм ватыла, 1913 ел б-н чагыштырганда ташу-күчерүләр күләме 40% ка кими. 1930 елларда Е.т.н тамырдан үзгәртеп кору башлана, 1933 тән масштаблы җир казу, төзәтү, су төбен чистарту, навигацияне яхшырту эшләре алып барыла. Бер үк вакытта флотка паспортизация үткәрелә, судноләр б-н элемтә һәм диспетчерлык идарәсе системалары кертелә. Казан пристанен реконструкцияләү һәм механикалаштыру гамәлгә ашырыла. Аңа тагын 3 яңа пароход, 4 баркас, 3 пассажир катеры беркетелә. 1928–39 да, уздырылган чаралар нәтиҗәсендә, ТАССРда су юлыннан йөкләр ташу 3 тапкырга арта (төп йөкләр: агач — 50% тан артык, икмәк — 20% тирәсе, ягулык-майлау һәм минерал.-төзелеш материаллары — икесе дә 10% ка якын).

Бөек Ватан сугышы чорында составына эвакуацияләнгән Мәскәү–Идел каналы пароходчылыгы да кергән җирле Е.т. фронт һәм хәрби сәнәгать ихтыяҗларын канәгатьләнде-














1. Казансу елгасында паром кичүе һәм пароходлар. 19 йөз ахыры; 2. Казан янында Иделдә пароход. 19 йөз ахыры; 3. «Капитан Кунаев» һава мендәрле пассажирлар катеры; 4. «БТО-604» йөк теплоходы Кама елгасында; 5. Шәһәр яны пассажирлар суднолары («ОМ», «Москва» һ.б.) Казан елга портында; 6. Казан елга портында «Павел Миронов» туристлар теплоходы.

рә, ш.и. Сталинград тирәсендә сугышучы гаскәрләрне кичү урыннары һәм барлык кирәк-яраклар б-н тәэмин итүдә катнаша. Сугыштан соңгы беренче елларда судноларның тузу дәрәҗәсе 40% ка җитә. Күчерү-ташу күләмнәре 1940 ел б-н чагыштырганда 2 мәртәбә диярлек кими.

1940 еллар ахырында елга флотын тулыландыру һәм яңа техника б-н җиһазландыру, су юлларын торгызу, элемтә чараларын үстерү эше башлана. 1948 дә Казан пристане механикалаштырылган елга порты итеп үзгәртеп корыла; аңа беркетелгән флот берничә яңа буксировщик, йөзмә кран, баржа, ярдәмче судно б-н тулыландырыла. Башка пристаньнарда да механизацияләү үткәрелә. Су юлы аша нефть җибәрү өчен Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогында кудыру станцияләре корыла, Чистай шәһәре тирәсендә — торбалардан килүче нефтьне күчереп төяү пункты, Казанда «Волготанкер» пароходчылыгының р-н идарәсе оештырыла. 1949 да Лаеш авылы янында Кама елгасы төбеннән йөзмә краннар ярдәмендә комлы гравий катнашмасын чыгару башлана. 1954 тә респ-када Е.т. буенча төп оешма булып Идел берләштерелгән пароходчылыгының Казан елга порты исәпләнә, аның составына ТАССР МС каршындагы 67 флот берәмлеге б-н җитәкчелек итүче Кече елгаларда транспортны гамәлгә кертү һәм аннан файдалану идарәсе керә (1959).

Куйбышев (1955) һәм Түбән Кама (1978–81) сусаклагычлары төзелүгә бәйле рәвештә судночылык шартлары да үзгәрә: суның биеклеге күтәрелә, сай урыннар юкка чыга, агым тизлеге кими, көчле җилләр (6–8 баллга кадәр), штормнар хасил була. Шул сәбәпле 1950 еллар ахырыннан респ-када парга эшләүче һәм үзйөрешсез судноларны куәтлерәк, уңайлырак һәм сыйдырышлылыгы күбрәк булган «ОМ», «Москвич», «Москва», «МО», «ПТ» тибындагы пасс. теплоходларына, «Белоруссия», «Грузия» һ.б. дизель-электроходларга, «Ракета» (1957 дән), «Метеор-2» (1962 дән) су асты канатлы тизйөрешле теплоходларга, «ОТА» һәм «Волгарь» сериясеннән куәтле буксирлы эттергеч теплоходларга, «СТ» үзйөрешле баржаларга, «РБТ» сериясеннән рейд буксир-бозваткычка һ.б. га алыштыру башлана. Йөзмә краннар, порт механизмнары паркы яңартыла. Казан–Югары Ослан, Зеленодольск–Карамалы Тау, Алексеев–Саескан Тавы кичүләрендә үзйөрешле дизель-электр паромнары кулланыла башлый. Аерым пар суднолары 1970 еллар башына кадәр эшли. 1965 кә Казан порты балансында 85 үзйөрешле (50 дән артык пасс.), 31 үзйөрешсез судно, 15 портал, 19 йөзмә кран, 5 җир казучы снаряд һ.б. исәпләнә.

Бер үк вакытта хезмәт күрсәтелә торган терр-я шактый киңәя, яңа даими пасс. линияләре, ш.и. Казан, Куйбышев, Чабаксар, Тольятти, Горький арасында да ачыла. Судноларның йөрү ешлыгы һәм тукталу пунктлары саны арта. Бөтен Урта Идел буен транспорт чылбыры б-н төп бәйләүче булып Казанның яңа елга порты таныла (1957 дән файдаланыла). Аның каршында транзит флот өчен Югары Ослан авылы янында махсус рейд, комплекслы яр буе хезмәте оештырыла.

Яңадан җиһазландырылган һәм механикалаштырылган Кама Тамагы (икмәк, алебастр ташы), Тәтеш, Болгар, Балык Бистәсе, Печищи, Красновидово (икмәк) һ.б. пристаньнар һәм тукталу урыннарыннан йөкләр җибәрүнең әһәмияте күп тапкырлар арта. Котловка һәм Вандовка (гравийлы-комлы масса ташу), Соколки (саллар агызу), Чистай (Камадан Иделгә һәм киресенчә йөкләр кабул итү һәм озату) махсус участоклары барлыкка килә. 1970 елларда Чаллы, Чистай һәм Түбән Кама пристаньнары порт итеп үзгәртеп корыла. Судноларны эттереп йөртүнең һәм секцияле баржаларда йөкләрне эшкәртүнең (пакетлы, тартмалап-данәләп, контейнерлап күчерү һәм зур йөк составлары — 18 мең *т* га кадәр) тизләтелгән алымнары киң таралыш ала. Елга төпләрен тирәнәйтү снарядлары паркы тулысынча диярлек яңартыла, җитештерүчәнлеге сәгатенә 2500 $м^3$ булган куәтле җир суырткычлар барлыкка килә. 1970 елга төзекләндерү эшләренең күп өлеше (65%ы) механикалаштырылган алымнар б-н башкарыла. Иделдә гарантияләнгән транзит тирәнлек 4 *м* га җитә. Кама юнәлешендәге трассаларны тирәнәйтү эше җәелеп китә. Суднолар йөрешендә навигация шартларында флуорисцент капламалы билгеләр, радиолокацион кайтаргычлар кертелә; ацетиленлы фонарьлар электр ялтырагыч аппаратларга алыштырыла. Е.т. руда булмаган минерал төзелеш материаллары б-н тәэмин итеп торучы эре оешмага әверелә; аларны табып алу өчен исә казылмаларны баета торган җайланмалар б-н яңача җиһазландырылган җир суырткыч снарядлар кулланыла. 1989 да табып алу күләмнәре (млн. $м^3$): гравий — 1,66, баетылган комлы-гравийлы катнашма — 8,14, комлы-гравийлы катнашма — 4,97, ком — 1,67 млн. $м^3$ га җитә (алар илнең 20 дән артык өлкә һәм респ-касына җибәрелә). Е.т. Түбән Кама терр.-сәнәгать үзәген формалаштыруда мөһим роль уйный. Аның тарафыннан «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин», «КамАЗ» берләшмәләре һ.б. пр-тиеләр өчен кирәкле төзелеш материаллары һәм җиһазларының күп өлеше китерелә.

1991 гә кадәр Е.т.ның эш күләмнәре даими үсештә була. Республикадагы барлык йөк күчерү эшләренең 30% ка якыны су юлы аша башкарыла. Төп йөкләр булып минерал төзелеш материаллары, агач, нефть, нефть продуктлары, икмәк, ташкүмер санала.

Татарстанда 1928–2008 елларда елга буйлап йөк күчерү

| Еллар | Йөкләр, млн. *т* | Пассажирлар, млн. кеше |
|---|---|---|
| 1928 | 0,61 | |
| 1939 | 1,90 | 0,4 |
| 1960 | 9,99 | 2,2 |
| 1970 | 25,96 | 5,1 |
| 1980 | 35,30 | 5,3 |
| 1990 | 42,90 | 5,7 |
| 2000 | 6,50 | 1,5 |
| 2008 | 14,90 | 1,0 |

1993 тә Казан елга порты базасында Идел пароходчылыгы составыннан аерылып чыккан «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе оештырыла. 1994 тә аңа 43 йөк судносы (7 теплоход, 23 үзйөрешсез судно, 13 буксир-эттергеч), 6 йөк-пасс. паром суднолары, 61 пасс. судносы, шулай ук рейд-маневр, ярдәмче-хезмәт, экология һәм яр буе суднолары, 30 кран, 21 җир казучы снаряд карый. ТРның суднолар йөрү юлларында 80 нән артык порт, пристань, тукталу урыны һәм кичү эшли. Икътисадтагы гомуми үзгәрешләр нәтиҗәсендә 1990 елларда Е.т.да йөк күчерүләр күләме кискен кими. Инвестицияләр булмау сәбәпле, хәрәкәттәге составның саны берничә тапкырга кыскара, калган фондларның тузу дәрәҗәсе 90,5% ка җитә; суднoларның уртача файдаланылу вакыты 30 елга якын (2008). Мөстәкыйль пр-тиеләр оешкан вакытта йөк суднoларының төп өлеше үзәк пароходчылыкларда калганга күрә, йөк тоннажына кытлык барлыкка килә.

2007 дә, озак вакыт туктап торганнан соң, Чаллы–Казан тизләтелгән пасс. линиясе яңадан ачыла. Казан–Югары Ослан маршрутында декабрьдә һава мендәрле «Марс-2000» судносын эксплуатацияләү башлана, бу пассажирларны ел буе йөртүгә күчәргә мөмкинлек бирә. 2007 дә Е.т.на караган бөтен төр эшчәнлекне алып баручы пр-тиеләр тарафыннан барлык пассажирларның 0,3% ы илтеп куела һәм ТРдагы барча транспорт төрләренә караган күчерүләрнең 19,4% ы башкарыла, 5,8 млн. *т* руда булмаган төзелеш материаллары казып чыгарыла.

Күп кенә структур үзгәртеп корулардан соң Татарстанда Е.т. хезмәте «Азимут» АҖ (Казан һәм Чистай портларын үз эченә ала), җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр: «ТАИФ-Магистраль» филиалы — «Чаллы елга порты» һәм «Казан елга пассажирлар агентлыгы» тарафыннан гамәлгә ашырыла. Су юлларын тәртиптә тоту, елга тамакларын чистарту һәм тирәнәйтү, навигацияне җайга салу су юллары һәм суднолар йөртү дәүләт Идел һәм Кама бассейн идарәләренә йөкләнә. Е.т. пр-тиеләрендә эшләүчеләр 1,8 мең кеше (2008) исәпләнә. Е.т.на хезмәт күрсәтү өчен кадрларны респ-када Идел су транспорты академиясенең Казан филиалы, *Казан елга техникумы*, Чистай шәһәрендәге профтехучилище әзерли.

*Әд.:* Шубин И.А. Волга и волжское судоходство. М., 1927; Дубилет Н., Пак А. Кама: Очерк истории судоходства. Молотов, 1950; Дубилет Н.И., Соколов В.С. Кама сегодня и завтра. Молотов, 1956; Фурер Л.Н. Влияние судоходства на развитие капитализма в Поволжье (середина XIX века). К., 1959; Фурер Л.Н., Лукьянов Г.М., Синицына К.Р. Речники Татарии. К., 1977; Речное судоходство в России. М., 1985.

*С.Г.Белов.*

**ЕЛГА́ УТЫРМАЛАРЫ́**, билгеле бер вакыт эчендә елга суы б-н агып килгән минераль һәм органик кисәкчекләрнең гомуми микъдары; гадәттә, тонналарда исәпләнә. Е.у. бөтен агым буенча күчүче йөзмә утырмалардан һәм елга төбе буйлап ияреп килүче матдәләрдән тора. Барлык Е.у.ның уртача 20% ка якыны соңгылары өлешенә туры килә. Е.у., туфрак эрозиясе һ.б. денудация процесслары нәтиҗәсе буларак, ярларның һәм елга төбенең (су юлы өлеше) ашалуы һәм су җыелу мәйданыннан керүче утырмалар хисабына формалаша. Шунлыктан елга бассейнында эрозия процессларының көчен күрсәтүче Е.у. модуле (елына *т/км²*) аша да билгеләнә. Е.у. язгы су ташу һәм ташкыннар вакытында күзәтелә. Утырмаларның шактый өлеше сусаклагычларда, күлләрдә, елга юллары һәм тугайларда, сызаларда, сөзәклек итәкләрендә утырып кала.

ТР терр-ясендә йөзмә утырмалар төрле вакытларда 50 дән артык гидрологик пост мәгълүматлары буенча билгеләнә. Йөзмә утырмаларны үлчәү 1930 елларда үткәрелә, әмма төгәллеге зур булмау сәбәпле (СССРның барлык терр-ясендәге кебек) туктатыла. Йөзмә матдәләрнең күплеге буенча Казансу һәм Зөя елгасының уңъяк кушылдыклары аерылып тора, аларның еллык күләме 1 *км²* га 100 *т* һәм күбрәк тә була. Иң аз утырмалар Көньяк-Көнбатыш Кама аръягында күзәтелә, бу исә терр-янең хуҗалык максатларында соңрак үзләштерелүе һәм денудациягә чыдам токымнарның таралуы, ш.у. Көнбатыш Кама аръягында рельефның чагыштырмача тигез булуына бәйле. ТР елгаларында йөзмә утырмалар ияреп килгән матдәләр күләменең 10–15% ыннан артмый. Е.у. антропоген факторлар йогынтысында үзгәрә. Су җыелу мәйданнарында урманнарны бетерү һәм җирләрне сукалау Е.у.ның артуына китерә. Ияреп килгән матдәләрне тулысынча һәм йөзмә утырмаларның бер өлешен сусаклагычлар тоткарлый.

*Әд.:* Сток наносов, его изучение и географическое распределение. Л., 1977; Дедков А.П., Мозжерин В.И. Эрозия и сток наносов на Земле. К., 1984.

*В.И.Мозжерин.*

**ЕЛГА́ ҮЗӘННӘРЕ́**, җир өслегендәге сузынкы иңкүлекләр, даими су агымының озакка (меңнәр һәм миллион елларга) сузылган юылу эшчәнлеге — елга эрозиясе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Үзәннәрнең урнашуы еш кына җирнең геол. төзелеше б-н бәйле. Е.ү.нең төп элементлары булып елга юлы, тугай, елга террасалары һәм сөзәклекләр тора. ТРның терр-ясе үзенең зурлыгы, морфологиясе, яше буенча төрле булган Е.ү.нең тыгыз челтәре б-н бүлгәләнгән. Аларның гомуми озынлыгы 20 мең *км* дан артык. Е.ү. челтәренең уртача тыгызлыгы якынча 0,4 *км/км²* тәшкил итә һәм Көнбатыш Кама алдыннан Көнчыгыш Кама алдына таба 0,33 тән 0,58 *км/км²* га кадәр үзгәрә. Үзәннәрнең тирәнлеге Идел аръягы түбәнлекләрендә 100–150 *м* һәм Бөгелмә яссы калкулыгында 200–250 *м*. Идел, Кама һәм Вятка кебек иң зур елгаларның үзәннәре неоген чорында барлыкка килә һәм шактый киң булулары б-н аерыла. Төп сөзәклекләр арасындагы ераклык елга юлының үзгәрү зурлыгына бәйле рәвештә 6 *км* дан 60 *км* га кадәр үзгәрә. *Сөзәклекләр асимметриясе* ачык чагыла. Бу Е.ү.нең уңъяк сөзәклекләре текә (20–30⁰), еш кына төп токымнардан тора, аларда шуышмалар, ишелмәләр һәм коелмалар барлыкка килә. Сулъяк сөзәклекләрдә елга утырмаларыннан торган төрле биеклектәге 5–6 тугай өсте террасасы күзәтелә. Идел һәм Кама тугайлары, ш.у. аларның түбәнге ике тугай өсте террасасы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогыннан түбәндәрәк, тулысы б-н яки өлешчә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары суы астында кала. Зөя, Чишмә, Зәй, Ык, Иж, Олы Чирмешән һ.б. кайбер елгаларның үзәннәре кечерәк булса да, шундый ук төзелешле. Зур Е.ү. кебек үк, аларга да яхшы беленә торган сөзәклек асиметриясе хас, әмма елга юлының авышуы 3–4 *км* дан артмый, ә террасалар биеклеге һәм аллювий калынлыгы зур түгел. Күпсанлы кече Е.ү.нә зур булмаган киңлек (1–2 *км* га кадәр) һәм төрле морфология хас. Аларның күп өлешендә, бигрәк тә Бөгелмә яссы калкулыгында һәм Идел буе калкулыгында, көньяк һәм көнбатышка караган текәрәк (15–30°) яхшы җылынучан калкулык битләрендә инсоляцияле сөзәклек ассимметриясе ныграк чагыла. Каршы як битләре сөзәк (1–3°) һәм уңдырышлы туфраклар формалашкан делювиаль лёссыман комсыл балчыктан тора. Ш.у. кече елгаларның, неоплейстоценда барлыкка килеп, төньяктан төньяк-көнчыгышка, көньяктан көньяк-көнбатышка юнәлешле симметрик авыш сөзәклекләр хас булган кече үзәннәрен аерып билгелиләр. Кайбер, мәс., Чишмә (Сарабиккол авылыннан түбәндә), Урман Чишмәсе (Сугышлы авылы янында) елга үзәннәренең аерым урыннары, нигездә, түбән Казан известьташларыннан барлыкка килгән һәм елга ярлары ашалуга, солифлюкация процесслары тәэсиренә бирешмәүче текә симметрияле сөзәклекләрдән тора.

Е.ү.ндә ТР торак пунктларының шактый өлеше урнашкан, сусаклагычлар һәм буалар төзелгән, ком, балчык, вак чуерташ-чуерлык кебек файдалы казылма запаслары бар, тугайлар печәнлек һәм көтүлек буларак файдаланыла.

*Әд.:* Сементовский В.Н. Геоморфология // Геология Татарской АССР и прилегающих территорий в пределах 109 листа. 1939. Ч. 2; Сементовский В.Н., Батыр В.В., Ступишин А.В. Рельеф Татарии. К., 1951; Дедков А.П. Геоморфологические предпосылки и признаки // Метод. рук. по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых РТ. К., 2000. Ч. 2.

*А.П.Дедков.*

**ЕЛГАБА́Ш** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак

урнашкан. 2008 елда 1 кеше (татар) яши. 1923–26 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. 1963 нең 23 июленнән авыллар исемлегеннән сызыла. 1998 нең 18 февралендә Азнакай р-нындагы торак пункт буларак яңадан теркәлә. Халык саны: 1926 да — 49, 1927 дә — 61, 2002 дә — 3, 2005 тә — 1 кеше.

**ЕЛГАБА́Ш** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы бассейнында. 2008 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1680 елларда нигез салына, 1938 гә кадәр Сасыборын исеме б-н мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эше, тимерчелек, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.та мәчет, мәдрәсә, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2410 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 106 ир-ат; 1870 тә — 614, 1884 тә — 849, 1897 дә — 952, 1920 дә — 1191, 1926 да — 759, 1949 да — 526, 1958 дә — 481, 1970 тә — 453, 1979 да — 373, 1989 да — 268, 2002 дә — 206 кеше.

**ЕЛГАЛА́Р**, табигый юлы буенча агып, бассейннарының җир өсте сулары агышы һәм җир асты сулары агышы хисабына туена торган су агымнары. Һәр елга үзенең кушылдыклары (1 нче, 2 нче һ.б. тәртиптәге) б-н бергә елга системасын хасил итә. Е. халәтенең су биеклеге һәм чыгымының тәүлеклек, сезонлы һәм күпьеллык тирбәнешләре, боз кату күренешләре, су темп-расы, ташкыннар кучергән китерелмәләр күләме, эрегән матдәләрнең составы һәм концентрациясе рәвешендәге закончалыклы үзгәрешләрен Е. режимы дип атыйлар, ул, нигездә, Е.ның туену үзенчәлегенә һәм шул җирлекнең климат шартларына бәйле.

ТР терр-ясендә озынлыгы бернichә йөз метрдан алып берничә йөз километрга җиткән 4 мең тирәсе Е. исәпләнә. Аларның күпчелеген *кече елгалар* тәшкил итә: су җыелу мәйданнары 2 мең *км²* га кадәр һәм озынлыклары 100 *км* дан ким. Эре елгаларга *Идел, Кама, Вятка, Агыйдел* керә; 20 елганың озынлыгы 100 *км* дан артык (*Ык, Зөя, Олы Чирмешән, Кондырча, Иж, Дала Зәе, Чишмә, Мишә,* Кече Чирмешән, *Гөбенә, Минзәлә, Казансу* һ.б.), 400 ләп елганың озынлыгы 10 *км* дан ким түгел. Республика терр-ясендәге барлык елгалар Идел бассейнына керә, аларның гомуми озынлыгы 20 мең *км* дан артык. Елгалар челтәренең уртача тыгызлыгы 0,37 *км/км²*, иң зур тыгызлыгы (0,48 *км/км²*) Көнчыгыш Кама алдындагы *Иж* һәм *Туйма* елгалары бассейнында, иң аз тыгызлыгы (0,33 *км/км²*) Көнбатыш Кама аръягында, бигрәк тә *Үтәк* һәм *Бизнә* (0,20–0,25 *км/км²*) елгалары бассейнында. Еллык су агымының 60–80% ын кар сулары, калганын җир асты һәм яңгыр сулары тәэмин итә. Еллык су агымы модульләре 3–5 *л/с·км²* тирәсе, аның иң күбесе (10 *л/с·км²*) *Илләт*, Казансу, *Шушма* бассейннарында, иң азы (1–1,5 *л/с·км²*) Идел һәм Каманың комлы сулъяк яр террасаларында. Республиканың барлык елгаларына 30–60 көнгә сузыла торган язгы *су ташулар* хас, гадәттә, алар Көньяк-Көнбатыш Идел алдында (Зөянең сул кушылдыкларында) мартның соңгы көннәрендә һәм Төньяк Кама алдында (Шушма һәм Иж бассейннарында) апрельнең 1 нче бишкөнлегендә башлана. Су ташу чорында агып төшкән уртача су катламы 80 *мм*, Идел, Кама, Вятканың комлы сул ярлары террасаларында 20–50 *мм* дан алып, Төньяк-Көнбатыш Кама алдында 100–140 *мм* га кадәр. Җәйге су кимү чорында елгаларда су биеклеге күпкә кими, кайберләре, бигрәк тә Көнбатыш Кама аръягында, кибә. Җәйге саегу көчле яңгырлар нәтиҗәсендә су ташулар б-н уртача 2–3 тапкыр, Зөя бассейнында 4–6 тапкыр өзелә. Шул ук вакытта Е.да су чыгымы уртача 10 тапкырга, иң кечеләрендә 25 тапкырга кадәр арта, көзен су биеклегенең берникадәр күтәрелүе күзәтелә, нигездә, ул парга әйләнүнең кимүе һәм транспирация (көзге явым-төшемнәр грунт сулары запасын тулыландыруга китерә) хисабына керә. Кышын Е.да тотрыклы саегу күзәтелә, бу чорда Е.ны туендыручы җир асты сулары запасы акрынлап кими бара, су чыгымы җәйге чордагыдан 1,5–2 тапкырга кими. Е.да бозлар уртача 31 октябрьдән (Иж бассейны) 6 ноябрьгә (Олы Чирмешән, Ык бассейннары) кадәр күренә башлый; 7–10 көннән соң Е.ның күпчелегендә тотрыклы боз ката, кыш ахырына бозның калынлыгы Көньяк-Көнбатыш Кама аръягында 50 *см* һәм респ-каның төньяк һәм көнчыгыш р-ннарында 75–80 *см* һәм калынрак та була. Бозның тулысынча юкка чыгуы апрельнең 2 нче ункөнлегенә туры килә. Үзендә эрегән тозларның составы буенча сулар, нигездә, гидрокарбонат-хлоридлы-кальцийлы һәм гидрокарбонат-сульфатлы-кальцийлы типта. Терр-янең күпчелек өлешендә суның минеральләшүе 250–500 *мг/л*, урыны б-н 500–750 *мг/л* га кадәр җитә. Суның болганчыклыгы уртача 440 *г/л*, җиңел юылучан балчыклы мезозой токымнары булган Көньяк Идел алды өлешендә 1500 *г/л* га кадәр һәм аннан да югары була.

Е. — табигый мохитнең иң әһәмиятле элементы: эчәргә яраклы һәм сәнәгый сулар чыганагы, табигый су юлы, гидроэнергиянең яңартыла торган чыганагы, балыклар һ.б. төче су организмнарының, суүсемнәрнең тереклек итү урыны. Татарстан терр-ясендә Иделдәге иң зур *Куйбышев сусаклагычы* һәм Камадагы *Түбән Кама сусаклагычы* комплекслы әһәмияткә ия, ш.у. Дала Зәе елгасында *Зәй сусаклагычы* һәм Бөгелмә Зәе елгасында *Карабаш сусаклагычы* бар. Болардан тыш, су б-н тәэмин итү, сугару, балык үрчетү максатларында күп кенә *буалар* төзелгән.

*Әд.:* География Татарстана. К., 1994.

**ЕЛЕНО́ВСКИЙ** посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 44 *км* көньяктарак урнашкан. 2008 елда 24 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1910 елларда нигез салына. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Мөшеге волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1920 дә — 85, 1926 да — 61, 1938 дә — 89, 1958 дә — 66, 1970 тә — 46, 1979 да — 66, 1989 да — 24, 2002 дә — 27 кеше.

**ЕЛИЗАВЕ́ТИНО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 3 *км* читтә. 2008 елда 20 кеше (руслар, чуашлар) яши. 1840 елларда алпавыт Е.П.Теренина нигез сала, Введенка Бистәсе авылындагы крепостной крәстияннәрнең бер өлешен Е. тирәсенә күчерә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1905 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 259 дис. тәшкил итә. 1930 елларда Е.га Чуаштаннан кешеләр күчеп килә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юматов волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1859 да — 133, 1897 дә — 156, 1908 дә — 175, 1920 дә — 300, 1926 да — 334, 1938 дә — 335, 1949 да — 175, 1958 дә — 206, 1970 тә — 158, 1979 да — 80, 1989 да — 28, 2002 дә — 22 кеше.

**ЕЛИЗА́РОВ** Александр Михайлович (14.8.1954, Украина ССРның Закарпатье өлкәсе Иртавск р-ны Долгое а.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1976 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук дифференциаль тигезләмәләр кафедрасында эшли, 1980 нән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында: гыйльми секретарь (1982–90), директор урынбасары (1990–94), директор (1994 тән). Хезмәтләре матем. анализга, сыеклыклар һәм газлар механикасына, матем. физикага һәм информатикага карый. Аналитик функцияләр өчен катнаш кайтма кырый мәсьәләләрнең яңа классларын тикшерә. Аэродинамикадагы кайтма кырый мәсьәләләрнең квази чишелеш теориясен төзи. Аэродинамик оптимальләштерү мәсьәләләрен куя һәм чишә. 1998 дә ТР ФАнең Х.Мөштәри исем. бүләге бирелә.

Х е з м.: Обратные краевые задачи аэродинамики. М., 1994 (автордаш); Mathematical methods of airfoil design (inverse boundary-value problems of aerohydrodynamics). B., 1997 (автордаш).

**ЕЛИЗА́РОВ** Виктор Иванович (8.2.1941, Лаеш р-ны Тарлаш а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2002). Себер технол. ин-тын (1968, Красноярск ш.) тәмамлый, Казан химия-технол. ин-тында укыта. 1993 тән Түбән Кама химия-технол. ин-ты

директоры һәм химик процессларны автоматлаштыру каф. профессоры. Хезмәтләре сәнәгать аппаратларын проектлаштыруга һәм матдәләр аерылу процессларын модельләштерүгә карый.

Х е з м.: Практикум на базе ЭВМ для самостоятельной подготовки по курсу процессов и аппаратов химической технологии. К., 1983; Решение инженерных задач химической технологии с помощью ЭВМ. К., 1985; Теоретические основы в моделировании процессов разделения веществ. К., 1993.

**ЕЛИЗА́РОВ** Георгий Александрович (22.4.1900, Зөя ш. — 26.8.1979, Казан), механик-уйлап табучы, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. җирле сәнәгать отличнигы (1949). Зөя һөнәр уч-щесендә (1911–15) һәм Хуҗалык хезмәткәрләре ин-тында (1939–40, Казан) белем ала. 1915–16 елда бертуган Крестовниковларның фабрика-сәүдә ширкәте з-дында (*Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин, химия заводы*) слесарь; 1916–18 дә Язу машиналарын ремонтлау остаханәсендә (Казан) механик; 1918–19 һәм 1924–25 тә Зөя һөнәр уч-щесендә мастер. 1919–23 тә Кызыл Армия сафларында. 1925 тән ТатЦИКның язу машиналарын һәм хисаплау аппаратларын ремонтлау һәм реставрацияләү остаханәсендә слесарь-механик, 1927 дән мастер. 1931 дән Казан «Пишмаш» язу машиналары з-дында (к. «*Терминал*»): 1933 кә кадәр цех башлыгы, 1933–34 тә — җитештерү, 1935–38 дә экспериментал цех, техника бүлеге башлыгы, 1938–41, 1944–46 да з-д директоры; 1946–65 тә эксперименталь цех һәм техник контроль бүлеге башлыгы. СССР да беренче оригиналь конструкциядәге «Яңалиф» — «Яңа алфавит» язу машинасын оештыручыларның һәм автор-конструкторларның (механик Н.П.Тихонов б-н бергәләп) берсе. 1929 елда татар телендә басу өчен, татар алфавиты нигезендә латин хәрефләре кулланылган махсус язу машинасы төзелә, аннары күпләп җитештерүгә җибәрелә, шуның өчен БҮБК һәм РСФСР ХХС (1930 ел, 23 июнь) карары буенча 1930–31 елларда «Пишмаш» з-ды төзелә. Форд з-дларында язу машиналарын әзерләү һәм җитештерү технологиясен өйрәнү өчен Е. СССР хөкүмәте тарафыннан 1936 ның декабреннән 1937 нең маена кадәр АКШка командировкага җибәрелә.

АКШтан кайтканнан соң, Е. тарафыннан машинага кайбер камилләштерүләр кертелә, 1940 тан СССРдагы 42 милләт алфавитында баса ала торган «Прогресс» язу машиналары эшләп чыгарыла башлый.

Е. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. (Ш.у. к. «*Язу машинасы*»).

*Әд.:* М а р т ы н о в В. Своей собственной рукой // Красная Татария. 1932. 20 нояб.; М а р е в И. 15 лет на одном заводе // Знамя Победы. 1940. 21 мая; Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг. К., 1974; М и л и ц ы н Б.Р. Детище Георгия Елизарова // Казань. 2001. № 1.

*Б.Р.Милицын, Г.С.Сабирҗанов.*

**ЕЛИЗА́РОВА** Мария Николаевна (20.6.1908, хәзерге БРның Дәүләкән р-ны Каранбаш а. — 27.9.1995, Казан), язучы, музей хезмәткәре, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1959). 1924–30 елларда комсомолның Бөгелмә райкомында, 1931–34 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында хатын-кызлар бүлеге инструкторы булып эшли, 1938–41 дә Республика балалар туристик станциясендә методист, соңыннан директор. Бөек Ватан сугышы елларында Көнбатыш һәм 4 нче Украина фронтларында озакка сузылган командировкаларда була. Фронтта алган тәэсирләре «Үз күзләрем белән» («Своими глазами») дигән мәкаләләр циклында тасвирлана. 1941–78 дә Казандагы А.М.Горький музее (хәзер А.М.Горький әдәби-мемориаль музее) директоры. Очерклар, пьесалар авторы; шуларның берсе — «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» («Юность Буревестника», 1954) — Казан Зур драма театры сәхнәсендә куела. Е.ның сценарийлары буенча Казан һәм Куйбышев киностудияләрендә М.Горькийның Казандагы тормышы турында 2 документаль фильм төшерелә. А.М.Горький музее Е. эшләгән елларда Казан, Мәскәү, С.-Петербург, Түбән Новгород, Самара, Ялта музей хезмәткәрләрен һәм күренекле галимнәрен (Н.Ф.Калинин, Е.А.Колесников, Е.Г.Бушканец, М.Г.Гайнуллин, И.А.Груздев, Е.Б.Тагер, Б.В.Михайловский, Б.А.Бялик һ.б.) җәлеп итү нәтиҗәсендә әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүдә иң актив үзәкләрнең берсенә әверелә. А.М.Горькийның хатыны Е.П.Пешкова һәм мәшһүр җырчы Ф.И.Шаляпинның кызы И.Ф.Шаляпина б-н Е.ның шәхси иҗади элемтәләре музей коллекциясен оештыруда хәлиткеч роль уйный. Ш.у. Е. тырышлыгы б-н татар әдәбияты тарихы материаллары фонды туплана, шулардан «М.Горький һәм татар әдәбияты» экспозициясе төзелә; бу фондның материаллары ТАССР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) әдәби бүлеге, Габдулла Тукай әдәби музее һәм Муса Җәлилнең Казандагы музей-фатирының нигезен тәшкил итә. Красновидово авылында А.М.Горький музеен оештыруның башында да Е. тора. «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Не жалейте людям солнца. К., 1975; Они были в Казани. К., 1983; Незабываемые годы. К., 1987.

*Әд.:* П и с а р е в а С. Хозяйка дома писателя: Как Мария Николаевна Елизарова закладывала традиции музея // Казань. 1998. № 4; Б е л о в а Л.Б. Деятельность М.Н.Елизаровой по увековечиванию памяти А.М.Горького в Казани // Максим Горький на пороге XXI столетия. Горьковские чтения. 1998 г. Н.Новгород, 2000. Ч. 2; Г и н и а т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

*Л.Б.Белова.*

**ЕЛИСЕ́ЕВ** Михаил Григорьевич (7.11.1899, хәзерге Тәтеш р-ны Колунец а. — 17.1.1943, Воронеж өлкәсенең Каменский р-ны Татарино а.), Сов. Союзы Герое (19.6.1943, үлгәннән соң), кече сержант (1943). Кызыл Армия сафларына чакырылганчы, Волжск шәһәрендә (Мари АССР) сатучы булып эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 106 нчы танк бригадасының танкка каршы батарея тубы командиры (3 нче танк армиясенең 12 нче танк корпусы). Көнбатыш һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Козельск шәһәреннән (Калуга өлкәсе) көньяктарак барган оборона сугышларында, Острогожск-Россошь һөҗүм операциясендә (1943) катнаша. 1943 нең 17 гыйнварында Татарино авылы (Воронеж өлкәсе) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: расчёт составы б-н бергә дошманның 2 танкын сафтан чыгара, сугыш кораллары һәм азык-төлек төялгән берничә машинасын юк итә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.



М.Г. Елисеев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; К а л и н и н В.В., М а к а р е н к о Д.Г. Герои подвигов на Харьковщине. Хар. 1970; Наши Герои. Йошкар-Ола, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**ЕЛИСТРА́ТОВ** Аркадий Иванович (27.12.1872, Сембер губ., Буа өязе Бурцево а. — 5.1.1955, Мәскәү), хокук белгече, полиция хокукы д-ры (1909), статский советник (1911). Мещаннар катлавыннан. Казан ун-тын тәмамлый (1896), шунда ук эшли: полиция хокукы кафедрасының профессор стипендиаты (1898 елга кадәр), 1898–1906 да приват-доцент, 1906 дан экстраординар проф. 1905–07 елгы рев-ция елларында самодержавие строен либеральләштерүне яклап чыга, хөкүмәт тарафыннан эзәрлекләнә; 1908 дә Казан ун-тында лекцияләр укудан читләштерелә. 1908–09 да Мәскәү ун-ты приват-доценты, 1909–11 дә экстраординар проф., 1911–18 дә ординар проф.; бер үк вакытта 1912–17 дә тәхет варисы Николай лицеенда (Мәскәү) укыта. 1918–20 дә Таврия (Симферополь ш.), 1921–28 дә 1 нче Мәскәү ун-тлары профессоры. «Җинаять эшендә дәүләт тарафыннан яклауны гамәлгә кертү идеясе» («Идея государственного учреждения уголовной защиты», 1900), «Катнаш типтагы җинаятькә каршы процесста алдан башкарылган эш институтларының яшәүчәнлеге» («О жизнеспособности институтов предварительного производства в уголовном процессе смешанного типа», 1900), «Хатын-кыз фахишәләрне теркәү. Врач-полиция күзәтүе» («О прикреплении женщин к проституции. Врачебно-полицейский надзор», 1903), «Европада фахишәлеккә каршы көрәш» («Борьба с проституцией в Европе», 1909) кебек төп хезмәтләре җинаять эше мәхкәмәсе мәсьәләләренә, җинаятьчелек сәбәпләрен анализлауга, җәза бирү принциплары һәм ысулларына карый. «Дәүләт хокукы: Лекцияләргә ярдәмлек» («Государственное право: Пособие к лекциям». М., 1912), «Дәүләт хокукы очеркы» («Очерк государственного права», М., 1915) хезмәтләрендә Е. көчле үзәк хакимиятне яклап чыга һәм Россиядә самодержавиеле хокукый дәүләт концепциясен тәкъдим итә. «Рус административ хокукы дәреслеге» («Учебник русского административного права», вып. 1–2. М., 1910–11), «Административ хокукның төп башлангычлары» («Основные начала административного права», М., 1914),

«Административ хокук очерклы» («Очерк административного права», М., 1922), «Административ хокук» («Административное право». М.–Л., 1929) кебек хезмәтләрендә ул гражданнарның хокукын, иреген һәм абруен яклый.

*Әд.:* Кутафин О.Е., Бельский К.С. Елистратов — выдающийся русский государствовед и административист // Государство и право. 1993. № 12; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета: 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002, Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЕЛФИ́МОВ** Всеволод Александрович (8.1.1949, Казан), спортчы, тренер (алкалы хоккей), РСФСРның атказ. тренеры (1990), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1995). Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лын (1979), Тренерлар югары мәктәбен (Мәскәү, 1982) тәмамлый. 1966–80 дә Урицкий исем. СК һәм Куйбышев шәһәре Армия спорт клубы (1969–71) командаларында уйный. 1981 дән «Итиль» (1995 тән «Ак Барс») командасында тренер, 1988–91, 1994–95 елларда баш тренер. 1995–98, 2003–05 тә «Нефтехимик» (Түбән Кама) командасында баш тренер. Шәкертләре арасында С.Абрамов, С.Закамский, А.Зубков, К.Ибраһимов, С.Киряхин, С.Кофтун, А.Пучков, Р.Фазлыев, Р.Шәвәлиев, В.Шалахин, Р.Якубов бар.

**ЕЛХО́В РАЙОНЫ́**, *Самара өлкәсенең* төньяк өлешендә урнашкан. 1991 елда оештырыла. Мәйданы — 1,2 мең *км*². Үзәге — Елховка авылы (Самара шәһәреннән 95 *км* төньяктарак). Халкы — 10,3 мең кеше (2008), ш.и. 1435 татар (2002). Татарлар Тёплый Стан авылында күп (684 кеше) яши. 20 йөз башында авылда (16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына) 3 мәчет һәм мәдрәсә була. Хәзерге вакытта 3 мәчет эшли. «Чишмә» һәм «Тамчы» фольклор коллективлары бар. Урта мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Е.р.нда генерал-лейтенант Ә.Н.*Рамазанов*, тарих фән. д-ры Ж.И.*Гыйльманов* туган.

**ЕЛХО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Карабаш сусаклагычыннан 3 *км* көньяктарак урнашкан. 2008 елда 25 кеше (чуашлар) яши. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Бөгелмә волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 10 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 12 октябреннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1920 дә — 76, 1926 да — 118, 1938 дә — 135, 1949 да — 76, 1958 дә — 176, 1970 тә — 199, 1979 да — 125, 1989 да — 39, 2002 дә — 29 кеше.

**«ЕЛХОВНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгаруны гамәлгә ашыру, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлаштыру, төзү һәм файдалануга әзерләү б-н шөгыльләнүче нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). Эшләүчеләр саны 3000 ләп кеше (2007). Яңа Елховой нефть чыганагын эшкәртү өчен «Әлмәтнефть» һәм «Лениногорскнефть» нефть промыселлары идарәләренең 3 нче нефть промыселлары җирлегендә «Е.» нефть промыселы идарәсе буларак 1962 елда оештырыла. 1970 тән НГДУ. 2006 да төп производствоны реструктуризацияләү программасы буенча «Е»кә «Зәйнефть» НГДУы кушыла. Эшчәнлегенең терр-ясе Әлмәт, Лениногорск, Чирмешән, Зәй, Түбән Кама адм. р-ннары җирләрен колачлый. «Е.» составында 7 нефть чыгару цехы, 2 катламнардагы басымны саклау цехы, 2 нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы, 2 скважиналарга капиталь ремонт үткәрү цехы, җитештерүне автоматлаштыру цехы, Елховой нефть эшкәртү идарәсе һ.б. бар (2009). 6 нефть чыганагын: Аксар, Көнчыгыш Макаровка, Мельнино, Көньяк Мухино, Соколка, Яңа Елховой чыганакларын эшкәртә. Нефть ятмаларының төп өлеше девонның Паша һәм Кынау катламнарының терриген утырмаларына, түбәнге карбонның Бобриково, Тула катламнарына, ш.у. карбонның Турне һәм Башкорт ярусларының карбонатлы утырмаларына туры килә. Ятмаларның күпчелек өлеше су тутыру алымы б-н эшкәртелә. Нефть җыю системасы герметикланган. Нефть чыгаруда иң зур күрсәткеч бер елга 12,7 млн. *т* тәшкил итә (1976); барлыгы 296,1 млн. *т*, ш.и. 2008 дә 2,86 млн. *т* чыгарылган. Чыгарылган продукциянең сулылыгы — 79%. 2009 ел башына 5541 скважина бораулаган, шуларның 4126 сы нефть бирә.

«Е.» базасында яңа приборлар һәм технологияләрне сынау уздырыла, нефть чыганакларын эшкәртү процессларын көйләү һәм контрольдә тоту (аз үткәрүчән коллекторлар эшләү технологиясе, скважиналар челтәре тыгызлыгының нефть бирүчәнлеккә тәэсире, аны сайлап алып, билгеле бер урынга су кудыру, катламга әледән-әле тәэсир итү, нефть бирүчәнлекне арттыруның гидродинамик һәм физик-химик һ.б.) алымнары эшләнә. Нефтьнең алдынгы алымнар кулланып чыгарылган өлеше 48,9% тәшкил итә.

Күкертле нефтьне югары дәрәҗәдә әзерләү махсус җайланмада башкарыла. Объектлар идарәнең заманча микропроцессорлы станцияләре нигезендә комплекслы автоматлаштырылган һәм телемеханикалаштырылган. Пр-тиенең җитештерү һәм финанс эшчәнлеге б-н идарә итүнең интеграцияләнгән системасы гамәлгә кертелгән.

Елховой нефть эшкәртү идарәсенең нефть эшкәртү җайланмасында девон нефтеннән автомобиль ягулыгы булган Нормаль 80 һәм Регуляр 92 бензиннары, дизель ягулыгы, битум (БНД-90/130) аерып алына. НГДУда әйләнә-тирә мохиткә техноген тәэсирне киметүгә, табигатьне саклауга, эчәргә яраклы су чыганакларын төзекләндерүгә, зыян күргән җирләрне табигый хәленә кайтаруга аеруча әһәмият бирелә. «Е.»нең балаларны сәламәтләндерүче 2 лагере, ял базасы, ат спорты мәктәбе бар. «Е.»нең алдынгы хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә лаек була: Соц. Хезмәт Герое — 1, СССР Дәүләт бүләге лауреаты — 1, Ленин комсомолы бүләге лауреаты — 1, РСФСР нефть һәм газ сәнәгатенең атказ. хезмәткәре — 16, РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре — 10, РФнең атказ. геологы — 1, РФнең атказ. төзүчесе — 1, ТРның атказ. геологы — 1, ТРның атказ. төзүчесе — 8, ТРның атказ. энергетигы — 6, ТРның атказ. нефтьчесе — 34, ТРның атказ. икътисадчысы — 3, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре — 2, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре — 1, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре — 2 кеше; 3 кеше — Ленин ордены, 5 кеше — Октябрь Революциясе, 34 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 4 кеше — Халыклар дуслыгы, 40 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше — Почёт, 1 кеше 1, 2, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» (тулы кавалер), 28 кеше 1, 2 я 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре — Ә.В.Вәлиханов (1962–63), З.Ц.Гитлин (1963–81), Г.Г.Ганиев (1981–84), А.Г.Нугайбәков (1996 елдан).

*Әд.:* Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2; Гиниатуллин М.К. Развитие Татнефти: Статистика и комментарии. М., 2000.

*Н.Н.Фәрхетдинов, К.Ф.Фәсхетдинов.*

**ЕЛХО́ВО АВЫЛЫ́ ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Әлмәт р-ны Түбән Абдул авылында. 1961 елның 20 декабрендә оеша. 1965 нең 8 маенда ачыла. 1990–2006 елларда ТР Дәүләт (2001 дән Милли) музее ф-лы, 2007 дән муниципаль музей. Экспозиция мәйданы — 255 *м*². Коллекциядә 10 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция 7 залны били, бер зал музейны оештыручы һәм аның беренче директоры, клуб мөдире, шагыйрь һәм рәссам Х.Х.Әхмәтшинга багышланган. Экспозициянең төп бүлекләре — «Төбәк археологиясе», «Табигать», «Этнография», «Гражданнар сугышыннан алып күмәкләштерүгә кадәр», «Колхоз төзелеше», «Мәдәният», «Медицина». Төбәк терр-ясендә археологик казулар вакытында табылган һәм бронза гасырга караган әйберләр зур урын били; төбәкнең табигатенә багышланган бүлектә хайваннар һәм кошлар, ш.и. нефть чыгару нәтиҗәсендә зонада экологиянең бозылуын чагылдырган мутантлар препаратлары куелган. Экспозициянең аеруча зур өлешен татарларның этнографик әйберләре: эш кораллары, кием-салым, бизәнү әйберләре, агачтан чокып ясалган савыт-саба, халыкның гамәли бизәлеш сәнгате әйберләре һ.б. коллекцияләр тәшкил итә. Экспозициянең махсус бүлекләре авыл һәм анда яшәүчеләр тарихына багышланган (Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнашучылар, нефть ятмаларын үзләштерү һ.б.).

Иң мөһим экспонатларга 19 йөзгә караган кульъязмалар һәм иске басма китаплар (14 берәмлек), 19 йөз ахыры — 20 йөз башында бизәкләп тукылган (90 лап берәмлек), тамбурлап чигелгән (15 берәмлек) әйберләр коллекцияләре, 19 йөз ахыры — 20 йөз уртасына нисбәтле самоварлар (30 лап берәмлек), акчалар коллекциясе (1500 дән артык берәмлек), Х.Х.Әхмәтшинның картиналары һәм агачтан ясалган скульптуралары (22 берәм-

лек) керә. Музей ел саен Музей оешу, Халыкара музейлар (18 май), Белем (1 сент.) көннәрен билгеләп уза.

Музей басмалары: Хәлиулла Әхмәтшин исем. авыл тарихы музее: Буклет, 1996; Архитектура села Нижнее Абдулово в начале 20 столетия: Справ.: 2000.

**ЕЛЫ́Ш** авылы, Саба р-нында, Байлар Сабасы авылыннан 20 *км* көньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 79 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1716 дан Кече Мишә авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новопоселённая, Сосновый Мыс исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кием тегү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.та Архангел Михаил чиркәве (1868 дә Мамадыш сәүдәгәре Никанор Щербаков иганәсенә төзелә), Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1883 тә ачыла), мәчет, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1199,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 141 ир-ат; 1859 да — 480, 1897 дә — 770, 1908 дә — 808, 1920 дә — 673, 1926 да — 639, 1938 дә — 397, 1949 да — 320, 1970 тә — 259, 1979 да — 339, 1989 да — 102, 2002 дә — 97 кеше.

**ЕЛЬКО́ВИЧ** Леонид Яковлевич (5.6.1919, Петроград — 23.3.2003, Казан), график, сәнгать белеме галиме, педагог, сәнгать фән. канд. (1947). Саратов ун-тының физ.-матем. ф-тын (1941), Саратовта эвакуациядә вакытта Ленинград ун-ты аспирантурасын тәмамлый (1945), ун-т б-н бергә Ленинградка әйләнеп кайта. 1952–58 елларда Алма-Ата һәм Ашхабад музейларында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1956). 1958 дән тормышы Казан б-н бәйле. 1966–81 дә Казан төзүче-инженерлар ин-тында, 1983 тә Казан сынлы сәнгать уч-щесендә сәнгать тарихын укыта. Сатирик графика һәм карикатура остасы. Е.ның рәсемнәре 1935 тән басыла башлый. Ул Саратовта «Агит-тәрәзәләр»не оештыруда (1941), Ленинградта «Сугышчан карандаш» коллективы эшендә (1944–45) катнаша. Казан агитплакат остаханәсен оештыручыларның берсе (1961). «Чаян» ж-лының даими хезмәткәре (1950–1980). Е.ның сатирик графикадагы төп иҗади казанышлары сәяси карикатуралар б-н бәйле: «Кара тәнлене кертегез» (тушь, гуашь, 1964), «Беренче тапкыр ку-клукс-класска» (гуашь, 1964), «Саулык телим, генералым» (тушь, 1965) һ.б. Көнкүреш карикатуралары сюжетның аңлаешлылыгы, метафорага, фольклорга һәм җирле ассоциацияләргә нигезләнүе, көлкеле вакыйгаларга бай булуы б-н үзенчәлекле: «Курыкма, бәләкәч, мин сине ташламам» (тушь, гуашь, 1965), «Барлык Казан рестораннарының адресларын бирегез» (тушь, акварель, 1967), «Сүзсез (йөкләмә)» (шелкография, 1989) һ.б. Рәссам сатирик графика сәнгатенә зур эчтәлек һәм күпкырлы график алымнар (рәсемдәге нечкә контур, штрих, тушь каләме, тап һәм төсле акварель буявы) алып килә. Е.ның сурәтле һәм мәгънәви метафорага корылган образларны сурәтләгән плакатлары эре формалары, төгәл силуэтлары, ачык төсләре б-н аерылып тора: «Барлык диннәрнең асылы бер» (шелкография, 1962), «Бу шайтаннарга капка ябылды» (шелкография, 1963), «Премияләр һәм мактау чыганагы» (шелкография, 1981) һ.б. Иҗат итү б-н бер үк вакытта ул тәнкыйтьче һәм сәнгать белгече буларак та актив эшли. Аның хезмәтләре арасында — республиканың әйдәп баручы рәссамнарына багышланган монографияләр, альбомнар, буклетлар: «Лотфулла Фәттахов» (1961), «В.И.Куделькин» (1960), «Николай Дмитриевич Кузнецов» (1962), «Х.Г.Якупов» (1962), «Э.Б.Гельмс» (1962) һ.б. Үзенең шәхси тәҗрибәсенә таянып, Е. сатирик графика үсешен дә тирәнтен өйрәнә: «Чаян» рәссамнары. Сатира» (1960), «Кыскыч нык элэктерә» (1963), «Ут сызыгында» (1977). Аның «Татарстан рәссамнары» («Художники Татарии», Л., 1965) китабында, ш.у. «РСФСР автономияле республикаларының сынлы сәнгате» («Изобразительное искусство автономных республик РСФСР», Л., 1973) китабының ТАССРга багышланган бүлегендә 1950–60 елларда респ-ка сәнгатенең үсешенә анализ бирелә. Е. «Агит-тәрәзәләр» (Саратов, 1942), Ленинград һәм Ригада «Сугышчан карандаш» плакат күргәзмәләрендә, Совет Төрекмәнстаны рәссамнары әсәрләренең респ-ка (Ашхабад, 1954) күргәзмәләрендә катнаша. 1958 дән ТАССР рәссамнарының респ-ка күргәзмәләрендә, ш.у. Идел буе рәссамнарының төбәк (1960–90), бөтенроссия (1967, 1971), бөтенсоюз (1955, 1963, 1965, 1971), халыкара һәм чит илләрдә үткәрелгән совет сәнгате күргәзмәләрендә (1969, 1973, 1975, 1977) катнаша. Е. хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Әлмәттәге Картиналар галереясында, Габроводагы Сатира һәм юмор музеенда (Болгария) саклана.



Л.Я. Е л ь к о в и ч. «Бернинди хәвеф тә күрмим». Гуашь, фломастер. 1980 еллар. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Л.Я. Е л ь к о в и ч. «Шайтан котырттты». Тушь, акварель. 1987. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

*Әд.:* С т ы к а л и н С., К р е м е н с к а я И. Советская сатирическая печать. 1917–1963. М., 1963; С у з д а л е в П. Советское искусство в период Великой Отечественной войны. М., 1963; М а т а ф о н о в В. Боевой карандаш. Л., 1977; Мастера советской карикатуры. М., 1981; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**ЕЛЬНИКИ́ РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1928 елда төзелә. Мәйданы — 1056 *км*². Үзәге — Ельники авылы (Саранск шәһәреннән 137 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 12147 кеше (2009), ш.и. 1140 татар. Е.р. терр-ясенә Алтын Урда татарлары 13 йөз ахырында урнаша башлый, һәм алар Мукшы елгасы буендагы эре җир биләмәләрен акрынлап үз кулларына туплый. 15 йөз башында җирле татар феодаллары рус подданныйлыгын ала. 16–17 йөзләрдә күп кенә кырлар-басулар һәм монда яшәүче крәстияннәр (ш.и. руслар һәм мордвалар) хәрби хезмәт өчен түләү сыйфатында татар бәкләренә һәм морзаларына таратыла. Иң атаклы алпавытлар арасында Дәүләткилдиевләр, Чегодаевлар, Кугушевлар кебек кенәзләр бар. 1710–20 елларда төбәктә православие динен кабул итәргә теләмәгән татар феодаллары җирләрен тартып алу, 1740–50 елларда халыкны көчләп христианлаштыру кампанияләре уза. 18 йөз ахырында Е.р. терр-ясендә 3 татар һәм 2 рус-татар торак пункты була. 20 йөз башында 4 мәчет (Акчеево, Верзляй, Вачеевка, Ликенье авылларында) һәм 3 мәктәп эшли. Хәзерге вакытта татарлар Акчеево (224 кеше), Чурино (120), Ликенье (43), Зур Мордва Пошаты (331), Яңа Кадыш (73), Лобановка (80), Вачеевка (62) авылларында яши. Районның 2 урта (Мордва Пошаты, Акчеево а.) һәм 2 башлангыч (Вачеевка, Чурино а.) мәктәбендә татар теле укытыла. 5 татар авылында (Чурино, Акчеево, Яңа Кадыш, Вачеевка, Лобановка) мәчет эшли. Е.р.нда Дан ордененың тулы кавалеры З.И.*Мещеров* (Акчеево а.) туган.

*Әд.:* Край Ельниковский: Ист. очерки. Саранск, 1998.

**Е́ЛЬЦИН** Борис Николаевич (1.2.1931, Свердловск өлкәсенең Талица р-ны Бутка а. — 23.4.2007, Мәскәү), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе. Урал политехник ин-тын тәмамлый (1955). 1963 елдан Свердловск йортлар төзү комб-тының баш инженеры, 1965 тән башлыгы. 1968 дән КПССның Свердловск өлкә ком-тының төзелеш бүлеге мөдире, 1975 тән секретаре, 1976–85 тә 1 нче секретаре. 1985–86 да КПСС ҮК секретаре, 1985–87 дә КПССның Мәскәү шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1987–89 да СССР Госстрое рәисенең 1 нче урынбасары — СССР министры. 1989–90 да СССР ЮСның Төзелеш һәм архит-ра ком-ты рәисе. 1981–90 да КПСС ҮК әгъзасы, 1986–88 дә КПСС ҮК Политбюросы әгъзалыгына кандидат. 1978–89 да

СССР ЮС депутаты. 1989–91 дә СССР халык депутаты. 1990–91 дә РСФСР ЮС рәисе. 1991–99 да РФ Президенты. Бәйсез Дәүләтләр Берлеген игълан итүчеләрнең берсе. 1990 нчы елларда берничә тапкыр ТРга килә, республиканың суверенлыкка хокукын таный. 1994 елда РФ Хөкүмәте Рәисе В.С.Черномырдин, ТР Президенты М.Ш.Шәймиев, ТР Премьер-министры М.Г.Сабиров б-н бергә «*Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында*» шартнамәгә кул куя. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исповедь на заданную тему. М., 1990; Записки президента. М., 1994; Президентский марафон: Размышления, воспоминания, впечатления. М., 2000.

*Әд.:* К о р ж а к о в А.В. Борис Ельцин: от рассвета до заката. М., 1997; Ш е в ц о в а Л.Ф. Режим Бориса Ельцина. М., 1999.

**ЕЛЬЦО́В** Виктор Николаевич (1.9.1951, Лаеш р-ны Лаеш штп.), төзүче-инженер, «*Камгэсэнергострой*» ЖБ, АҖ ген. директоры (1989–2003), Удмурт Респ-касының, ТРның атказ. төзүчесе (1999, 2004). Казан төзүче-инженерлар ин-тын (1973), Халык хуҗалыгы академиясен (Мәскәү, 1989) тәмамлый. 1973 елдан «Камгэсэнергострой» ҖБндә, 1977 дән төзелеш-монтаж идарәсенең баш инженеры; «Автозаводстрой» төзелеш идарәсендә баш инженер урынбасары (1982 дән), башлык (1983 тән, Чаллы ш.), «Тракторзаводстрой» төзелеш-монтаж тресты управляющие (1985 тән, Алабуга ш.), берләшмәнең баш инженеры (1986 дан). 2008 дән «Росграница» Федераль агентлыгы җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе. Е. җитәкчелегендә Татарстанда, Россиянең һәм БДБнең башка төбәкләрендә мөһим сәнәгать, энергетика, торак һәм мәдәният-тарих объектлары төзелә һәм яңартып корыла (ш.и. янгыннан соң 1994 тә «КамАЗ» АҖнең Двигательләр з-ды торгызыла), яңа төзелеш технологияләре гамәлгә кертелә. 1990–93 тә РСФСР ЮС, 1990–2003 тә ТР халык депутаты, РФ Дәүләт Думасы депутаты (2003–08). Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2002). «Почёт билгесе», Почёт орденнары б-н бүләкләнә.

**ЕМАНЖЕЛИ́НСК**, *Чиләбе өлкәсендәге* шәһәр (1951 елдан) (Чиләбе шәһәреннән 50 *км* көньяктарак). 1931 дә Еманжелинск ташкүмер шахталары каршындагы посёлок буларак төзелә. Халкы — 52391 кеше (2002), ш.и. 2685 татар. Татарлар Е.ка 1930 елларда махсус күчерелгән кешеләр буларак килеп төпләнәләр. 1940 елларның 2 нче яртысында мондагы ташкүмер шахталарына Татарстан һәм Башкортстан АССРдан, Чиләбе өлкәсенең Брединский, Нагайбәк, Коншак, Аргаяш р-ннарыннан татарлар эшкә килә. Хәзерге вакытта шәһәрдә «Дуслык» татар-башкорт мәдәният үзәге (1989 дан), «Агыйдел» үзешчән сәнгать ансамбле (1989 дан) эшли. Мәчет бар (2001 дән).

**ЕМЕ́ЛЬКИНО** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәмсу елгасы буенда. 2008 елда 267 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 2 тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 960 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 158, 1897 дә — 201, 1908 дә — 355, 1920 дә — 402, 1926 да — 365, 1938 дә — 376, 1949 да — 342, 1958 дә — 520, 1970 тә — 515, 1979 да — 429, 1989 да — 290, 2002 дә — 265 кеше.

**ЕМЕЛЬЯ́НОВ** Вадим Михайлович (25.4.1942, Мәскәү — 24.5.1978, Североморск ш.), спортчы (бокс), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1964). Спорт б-н Казан Суворов хәрби уч-щесендә (1953–62) шөгыльләнә башлый, тренерлары — В.М.Лукоянов, Р.С.Немшилов. П.Ф.Лесгафт исем. Ленинград физкультура ин-тының хәрби ф-ты каршындагы югары тренерлар мәктәбен (1965), Ф.Э.Дзержинский исем. югары хәрби-диңгез инженерлар уч-щесен (Ленинград, 1968) тәмамлый. СССР чемпионы (1960–61, яшүсмерләр арасында), Европа кубогы иясе (1962), СССР чемпионатларында (1961, 1966), Олимпия уеннарында (1964) бронза медаль ала. Североморск шәһәрендә Е. истәлегенә бокс буенча Россия турнирлары уздырыла (1987 дән).

**ЕМЕЛЬЯ́НОВ** Виктор Михайлович (16.10.1950, Казан), биотехнолог, эколог, техник фән. д-ры (1989), проф. (1989), ТР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998, 2008). ТР Дәүләт бүләге иясе (2007). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, фәнни-тикшеренү секторы башлыгы (1979–85), химик кибернетика каф. мөдире (1985 тән), проректор (1989–95), бер үк вакытта Казан технол. ун-ты каршындагы Биотехнология өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм белемнәрен күтәрү Казан үзәге директоры (1989–91 дә). 2004 тән Азык-төлек продуктлары производстволары һәм технологияләре ин-тында азык технологияләре ф-ты деканы, 2005 тән директор урынбасары. Хезмәтләре масса күчерү процессларын, химик технол. объектларын оптимальләштерүгә карый. Ферментация системаларында, тараткычлардан файдаланып, кислород эретүнең интенсификацияләү ысулын эшли. Микроблар биомассасын (икмәк пешерү һәм терлек азыгы чүпрәсе) һәм биологик актив матдәләр (аминокислоталар, ферментлар, дару препаратлары), ш.и. алыштыргысыз L-лизин аминокислотасын алуны, ш.у. биотехнол. җитештерү ысулларын, биореакторның яңа конструкциясен гамәлгә кертә. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы һәм 5 патенты бар.

Х е з м.: Аппаратурно-технологическое оформление промышленного участка получения чистой культуры спиртовых дрожжей // Темат. сб. науч. тр. Вестн. КГТУ. К., 1998 (автордаш); Разработка биосорбционной технологии очистки хромосодержащих сточных вод // Хим. пром-сть. 1998. № 3; Аэробное выращивание посевной культуры сахаромицетов в биореакторе с мембранной стерилизацией кислорода // Биотехнология. 2005. № 3 (автордаш); Системный анализ и принятие решения. Математическое моделирование и оптимизация объектов химической технологии. СПб., 2007 (автордаш).

**ЕМЕЛЬЯ́НОВ** Михаил (төбәкне өйрәнү хезмәтләрендә — Филипп) Емельянович (1761, Казан — 1820 дән соң), архитектор, рус классицизмы вәкиле. Казан гарнизоны мәктәбендә һәм В.И.*Кафтыревта* укый. 1785 елдан Казан гарнизонында солдат, офицер, В.И.Кафтырев ярдәмчесе. 1794 тән Казанда губерна механигы, 1796–1804 елларда губерна архитекторы. 1798 дән В.И.*Чемезов йорты* һәм *Казан Богородица монастыре* төзелешләренә җитәкчелек итә. Әлеге монастырьның Богородица храмын төзегәндә И.Е.Старов сызымнарына нык таяна, әмма 1804 тә, соборның тышкы күренеше буенча монастырь башлыгы б-н бәхәс чыгу сәбәпле, монастырьдагы эшеннән һәм губерна архитекторы вазифасыннан читләштерелә. Отставкага чыккач, күчемсез милеккә салымнар билгеләүче комиссия өчен шәһәр йортларын бәяләү һәм шәхси практика б-н шөгыльләнә. Х.Л.Молоствов йорты (1798), *Гостиный двор* (1803), Казан Богородица монастыреның баш соборы иконостасы проектлары авторы (1798–1804).

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**ЕМЕЛЬЯ́НОВ** Яков Емельянович (16.8 (?). 1848, Казан губ., Лаеш өязе Алан-Полян а. — 3.2.1893, шул ук өязнең Үри а.), шагыйрь. Татар милләтеннән, дәүләт крәстияннәреннән. 1864 елдан Казанда яңа ачылган Үзәк керәшен татарлар мәктәбендә укый. 1867 дән Е. Үри авылында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбендә, 1873 тән Казанда Үзәк керәшен татарлар мәктәбендә, 1874 тән Әрнәш авылында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбендә укыта (анда дьякон да булып тора). 1880 нән — Юкәче авылында, 1882 дән — Югары Чура, 1888 дән — Үрәс-Учи (хәзерге Танькино), 1891 дән Үри Чаллысы авылларында поп була.

Шигырьләрен мәктәптә укыган елларда яза башлый. Кириллицада басылган «Стихи на крещёно-татарском языке. Дьякон Я.Емельянов стихлары» (1879; 2 нче басма, 1888) дип исемләнгән бер үк исем астындагы ике шигъри җыентык авторы. Һәр җыентыкта 12 шәр шигырь, шуның 7 се кабатлана. Арада иң уңышлысы саналган «Ярлы тормыш» шигырендә крәстияннәрнең авыр көнкүреше тасвирлана. Бу тема шигырьләренең күбесендә чагылыш таба. Социаль тигезсезлек, кешеләрдәге шөһрәт ярату, карунлык, икейөзлелек һ.б. кимчелекләр шагыйрьне рәнҗетә («Олысыманлык», «Әләк», «Саран

бай» һ.б.). Е. кабиләдәшләренең наданлыгы турында әрнеп яза, керәшеннәр арасында киң таралган им-том итүдән көлә («Күремчене хөрмәтләү»). Шуңа да карамастан, Е.ның лирик герое тормышка оптимистик караште, авырлыкларга түзем, якты киләчәккә өмет б-н карый. Шагыйрь укучыны яхшылыкка, ярдәмчел булырга өнди. Аерым шигырьләрендә православие динен мактый («Ходай сине илдән алган», «Саташканны уяту»). Бу исә рухи остазы Н.И.*Ильминскийның* көчле йогынтысы б-н аңлатыла. Кайбер шигырьләре рус шагыйрьләре, аерым алганда, И.С.Никитин шигырьләренең тәрҗемәсе яки күчермәсе булып тора. Е.ның шигъри теле, кагыйдә буларак, сөйләм теленә якын, аңа фольклор традицияләренә нигезләнгән шигырь төзелеше хас. Мәс., шагыйрь еш кына «ялгау» алымын файдалана (шигъри юлның яки строфаның соңгы сүзе киләсе шигъри юлның яки строфаның башында кабатлана). Шигырьләрендә сюжетлылык өстенлек итә. Әсәрләренең аһәңлеге һәм көйлелеге өчен Е.ны халык арасында «җырчы Җәкәү» дип йөрткәннәр.

Ә с ә р.: Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. К., 1979; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

*Әд.:* Г л у х о в М. «Егылмас иде сыналган җан...» // Казан утлары. 1973. № 3; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Ф ә й з у л л и н Р. Шагыйрь, поп һәм якташ // Казан утлары. 1998. № 10; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1979; С а ф и н С. Гражданским духом осиянный // Аргамак. 1998. № 5/6.

*Х.Й.Миңнегулов, Е.В.Липаков.*

**ЕМЕЛЬЯ́НОВО** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бырыс елгасы буенда. 2008 елда 74 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына — 1557 дән рус авылы. Башта Екимень (Икимень, Искимень) дип атала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Знаменский, Маматово исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да Знаменский чиркәве (1784 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1876 да ачыла), Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек уку өе, кредит бирүче ширкәт, 2 тимерчелек, 2 су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете, шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 836,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1944 нең 19 февраленнән — Салтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 233 ир-ат; 1859 да — 378, 1897 дә — 471, 1908 дә — 575, 1926 да — 740, 1938 дә — 592, 1949 да — 442, 1958 дә — 268, 1970 тә — 302, 1979 да — 216, 1989 да — 114, 2002 дә — 90 кеше.

**ЕНАЛЕ́Й** Шугуров, к. *Җангали.*

**ЕНАЛИ́ЕВ** Барый (Борис) Муса улы (15.6.1914, хәзерге Пенза өлкәсенең Неверкин р-ны Октябрьск а. — 10.12.1982, Баку), Сов. Союзы Герое (31.5.1945), сержант (1945). 1939–41 елларда Бакуда заводта слесарь булып эшли. 1941 нең июленнән Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 694 нче укчы полк автоматчысы (33 нче армиянең 383 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, 2 нче, 3 нче һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү сугышында (1941–42), Ржев-Вязьма, Смоленск (1943) һөҗүм операцияләрендә, Белоруссия һәм Польшаны азат итү сугышларында, Берлин операциясендә (1945) катнаша. 1945 нең 24 апрелендә Шпрее елгасын кичеп, Радинкендорф (Германия) торак пункты тирәсендә барган сугышта батырлык күрсәтә: бер төркем сугышчылар б-н дошманның ут ноктасын бастыра һәм, төп көчләр килгәнче, яуланган плацдармны кулда тота. Сугыштан соң Баку шәһәрендә эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Б.М. Еналиев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Золотые Звёзды Азербайджана. Баку, 1975; Герои и подвиги. Саратов, 1976. Кн. 3.

*В.А.Шагалов.*

**ЕНАЛИ́ЕВ** Сөләйман Бикмөхәммәт улы (1894, Пенза губ., Инсар өязе Зур Алан а. — 14.9.1938, Казан), күз табибе, сәламәтлек саклау эшен оештыручы. 1925 елда 2 нче Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлый. Бер үк вакытта 1924 тән РСФСР Мәгариф халык комис-тында эшли. 1926 дан ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тында: халык комиссары урынбасары, халык комиссары. 1928–37 елларда Казан мед. ун-тында укыта, бер үк вакытта 1935 тән директор урынбасары, директор. 1931–32 дә АКШта фәнни эшләр буенча командировкада була. Е. ин-ты җитәкләгән чорда морфология бинасы, студентлар тулай торагы төзелә. Аның эшчәнлеге укыту-тәрбия эшен камилләштерүгә, милли кадрлардан табибләр әзерләүгә, фәнни-тикшеренү эшен активлаштыруга һәм дәвалау эшен яхшыртуга юнәлдерелә. Хезмәтләре күз эчендәге яңа барлыкка килгән шешләр иммунологиясенә һәм цитопатологиясенә карый. 1937 дә репрессияләнә; вафатыннан соң аклана.

**ЕНАЛИ́ЕВА** Диләрә Шакир кызы (26.3.1930, Казан), йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (1983), проф. (1983), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). 1954 елда Казан мед. ун-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, йогышлы авырулар каф. мөдире (1980–2000). Е.ның фәнни тикшеренүләре актуаль йогышлы авыруларны патогенетик дәвалауга багышлана; аның тарафыннан гриппны, рожа (йогышлы тире авыруы), вируслы гепатит, менингококк инфекциясе, бизгәк, сальмонеллёз, дизентерияне дәвалау өчен тәкъдим ителгән *димефосфон* препараты (РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшләнә) кулланышка кертелә. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1984).

Х е з м.: Справочник по реаниматологии. Минск, 1978 (автордаш); Тромбогеморрагический синдром при менингококковой инфекции. К., 1983 (автордаш); Менингококковая инфекция. Йошкар-Ола, 1985 (автордаш).

**ЕНӘ́Й** (Янәй) авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 22 *км* көнбатыштарак, Акбаш елгасы буенда. 2008 елдан даими яшәүчеләр юк. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1920 дә — 67, 1926 да — 77, 1938 дә — 294, 1949 да — 329, 1958 дә — 231, 1970 тә — 156, 1979 да — 119, 1989 да — 24, 2002 дә — 6 кеше.

**ЕНБА́ЕВ** Гариф (Ариф) Мөхәммәтҗан улы (1892, Рязань губ., Касыйм өязе Кошчыкллы а. — 1937), сәясәт эшлеклесе. Касыйм урта-техник уч-щесен тәмамлый (1912). Харьков технол. ин-тында укый (1912–15). 1917 елдан Россия армиясендә, анда сул эсерлар төркеменә кушыла. Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасын оештыру киңәшмәсендә (1918 елның мае) катнаша, Оештыру съездын чакыру комиссиясе әгъзасы. 1918–19 да Үзәк мөселман хәрби комис-ты әгъзасы, 1920–24 тә РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-тының ТАССРдагы вәкиле, ТАССР җир эшләре халык комиссары урынбасары. 1923 тә *РКП(б) ҮКның Дүртенче киңәшмәсе* эшендә катнаша, Татарстанның башка сәясәт эшлеклеләре б-н беррәттән М.Х.Солтангалиевкә карата законсыз репрессиягә каршы чыга. 1924 тән Мәскәүдә кооперация системасында эшли. 1929 да репрессияләнә һәм үлем җәзасына хөкем ителә, әмма үлем карары 10 елга лагерьларга сөрелү б-н алыштырыла. 1937 дә атып үтерүгә хөкем ителә (к. «*Солтангалиевчеләрнең Мәскәү үзәге» эше*); үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Ш а р а ф у т д и н о в Д. Енбаев Ариф Мухаммаджанович // Возвращённые имена. К., 1990.

*Б.Ф.Солтанбәков.*

**ЕНГАЛЫ́ЧЕВ** Йосыф (Осип) (1719 тирәсе — 13.2.1774, хәзерге Алексеев р-ны Биләр а.), морза, 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнашучы. Баш күтәрүчеләр аны йөзбашы итеп сайлыйлар. Е. отряды Бөгелмә яныннан Биләркүл авылына кадәр (хәзер Нурлат р-нында) сугышып бара. Күп авылларда булып, Е. крәстияннәрне Е.И.Пугачёв манифестлары һәм указлары б-н таныштыра, дәгъваларны карый, алпавытларны һәм дин әһелләрен җәзага тарта. 1774 нең гыйнвар ахырында отряд Чирмешән кирмәненә каршы яуда катнаша. Е. кулга алына һәм 2 февральдә Казанга ящерен

комиссиягә озатыла, аның карары нигезендә асып үтерелә.

*Әд.:* Алишев С.Х. Князь Йосыф Енгалычев һәм башкалар // Казан утлары. 1973. № 8; шулук. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973.

**ЕНГАЛЫ́ЧЕВ** Сәгыйдмөхәммәт (? — 1918 дән соң), сәясәт эшлеклесе. 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң татар милли хәрәкәтендә актив катнашучы. Саратов мөселман социалистлары башлыгы, «*Мохтарият*» г-тасы мөхәррире. Бөтенроссия мөселманнарының беренче һәм икенче корылтайларында катнаша. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18), *Идел-Урал Штатын гамәлгә керту һәйәте* әгъзасы. Җирле мохтарият нигезләрен әзерләү комиссиясе эшендә актив катнаша. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Д.М.Госманова.*

**ЕНГАЛЫ́ЧЕВЛАР**, татар бәкләре. Шәҗәрә башында кыпчак бәге Бехан (Бәдши) тора. Бехан улы Мәскәү бөек кенәзенең 1539 елгы ярлыгында телгә алына. Җир биләмәләре хәзерге Мордва Респ-касында булган. Бу нәсел вәкилләренең берсе 1767 дә император Екатерина II нең Идел буйлап сәяхәтендә була. Й.*Енгалычев* 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында катнаша. 19 йөздә Е. — Оренбург губернасында вак түрәләр.

*С.Х.Алишев.*

**ЕНДАКО́В** Михаил Елизарович (8.11.1886, Казан — 1.1.1930, Кырым ш.), профсоюз эшлеклесе. Казан һөнәр уч-щесен тәмамлый (1900). 1902 елдан Бишбалта бистәсендәге тимер эшкәртү з-дында эшли. 1905–07 дәге рев-циядә катнаша (Казан). 1908–11 дә Россия армиясендә. 1911–14 тә Казан, Пермь, Рыбинск з-дларында. 1914 тә кабат Россия армиясенә алына. 1918 дә Казанда металл эшкәртүчеләр профсоюзы идарәсе секретаре. 1919 да адмирал А.В.Колчак җитәкчелегендәге акгвардиячеләр отрядларына каршы сугышларда катнаша. 1919 да — Бөтенроссия ҮБК, 1920 дә ТАССР ҮБК әгъзасы, 1921–24 тә Профсоюзларның Татарстан советы рәисе. 1924 елдан Белоруссиядә һәм Кырымда профсоюз эшендә.

*Әд.:* Смыков Ю. Ендаков Михаил Елизарович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**ЕНЕ́ЙКИНА** Татьяна Александровна (25.12.1948, Казан), химик-технолог, химия фән. канд. (1981), РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1996). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, баш белгеч (2000 нән). Тикшеренүләре шарсыман дары әзерләү технологиясенә карый. Ату коралларына, кече калибрлы артиллерия системаларына бер нигезле шарсыман дары эшләгәне өчен Дәүләт бүләгенә, шарсыман дарының яңа составын һәм шартлаткыч материалларны утильләштерү ысулларын уйлап тапканы өчен РФ Хөкүмәте бүләгенә (2001) лаек була. Уйлап табуга 84 патенты һәм авторлык таныклыгы бар.

**ЕНИКИ́** (Еникиев) Әмирхан Нигъмәтҗан улы (17.2.1909, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Каргалы а. — 16.2.2000, Казан), язучы, ТАССРның халык язучысы (1989). Морзалар нәселеннән. 1911 елда гаиләләре б-н Дәүләкән авылына күчеп киләләр; Е. авыл мәдрәсәсендә укый. 1925 тән Казанда яши. 1926 да Казан ун-ты рабфагына укырга керә. 1927 дә Донбасска китә, татар шахтёрларын ликбез курсларында укыта. 1941 гә кадәр Казанда һәм Бакуда төрле



Ә.Еники.

оешмаларда һәм пр-тиеләрдә эшли, Маргелан шәһәрендә (Үзбәкстан ССР) балалар укыта, 1931–33 тә Казанда Хезмәтне фәнни оештыру ин-тында читтән торып укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң «Совет әдәбияты» ж-лында, ТАССР МС каршындагы радиофикация ком-тында эшли, Казан авиация техникумында укыта.

Е.нең беренче «Озын көй тыңлаганда» исемле хикәясе 1926 да «Безнең юл» ж-лында басыла. Соңрак башка хикәяләре, «Дус кеше» (1929) повесте языла. Әдәби тәнкыйть яшь язучы иҗатының уңай (геройларның эчке дөньясына игътибар) һәм тискәре (китапчылык йогынтысы, артык хиссилек) якларына да игътибар итә. Зур әдәбиятка Е. үзенең сугыш елларында язылган хикәяләре б-н килеп керә. Аның «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Мәк чәчәге» (1944), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады?» (1956), «Әйтелмәгән васыять» (1965) һ.б. хикәяләренә тирән психологизм, лирик һәм фәлсәфи әһәмиятлелек хас. Авторның фәлсәфәсе тормыш чынбарлыгына, халкының киләчәгенә оптимистик карашка нигезләнә. Е. әсәрләрендә аталар һәм балалар мөнәсәбәте анык һәм принципиаль идея-эстетик концепциягә корылган. Язучының традицион милли сыйфатларга ия булган өлкән яшьтәге кешеләр образлары аеруча уңышлы (милли характерлы олы буын кешеләре образы — Е. казанышларының берсе). Алар арасында Галимҗан абзый б-н Мәрьям абыстай («Бер генә сәгатькә»), Хәмидә («Тауларга карап»), Акъәби, Миңлебай карт («Әйтелмәгән васыять») бар. Бу геройларда чын мәгънәсендә кешенең иң яхшы сыйфатлары тупланган. Шуңа күрә дә Е. буыннар арасында сакланган өзелмәс чылбыр идеясен алар б-н бәйли.

Мәхәббәткә багышланган әсәрләрендә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җентекле, тирәнтен тикшерелә. Язучы мәхәббәткә каратә җавапсыз мөнәсәбәт көтелмәгән авыр кичерешләргә этәрергә мөмкин дип кисәтә. «Ялгызлык» (1957), «Төнге тамчылар» (1964) хикәяләрендә, «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968) повестьларында катлаулы кеше язмышлары аеруча тормышчан тасвирлана.

Язучыны, беренче чиратта, кешенең эчке дөньясы, аның хис-кичерешләре, әхлагы кызыксындыра. Е. әсәрләрендә эш-хезмәт сферасында була торган конфликтлар, ясалма актуальлек артыннан куу, әзер чишелешләр, тормышны катгый әдәби схемага буйсындыру юк. Язучы үз идеясен ачыктан-ачык күрсәтми, үз карашларын персонажларына такмый. Теге яки бу күренешләрне объектив тасвирлап, нәтиҗә ясауны укучының үзенә калдыра. «Рәхмәт, иптәшләр» (1952), «Саз чәчәге», «Рәшә», «Вөҗдан» повестьларында әхлакый мәсьәләләрне яктырту укучыга көчле эмоциональ тәэсир ясауга буйсындырылган; психологик ситуацияләр зәргәрчелек осталыгы б-н анализланган; барлык дәлилләр төгәл һәм җентекле эшләнгән. Е. әсәрләре тирән психологизм б-н сугарылган. Повестьларында мещанлык, байлыкка омтылу, икейөзлелек һәм эгоизм кебек сыйфатларны фаш итү заманында төрлечә бәяләнә, көчле бәхәсләр тудыра. Ләкин тормыш һәрвакыт автор карашларының дөреслеген раслап килә.

Е. геройларының кичерешләре музыка, җыр б-н үрелеп бара. Бу авторның традицион романтик концепциягә тугры булып калуы турында сөйли. Сәнгатьчә стиль үзенчәлекләрен чагылдырган ирония, сатира һәм юмор язучы иҗатында зур урын алып тора. Тасвирлы, мәгънәле теле, кайвакыт сарказмга тиң юморы хикәяләренә кабатланмас тәэсир көче өсти («Чәнечкеле хикәяләр», 1962; «Салават күпере», 1966; «Шило в мешке» — «Без капчыкта ятмый», 1967 җыентыклары). «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1978) романы композитор С.Сәйдәшев тормышындагы бер мәхәббәт тарихына багышланган.

Гомеренең соңгы елларында язылган «Хәтердәге төеннәр» (1983), «Соңгы китап» (1986), «Кояш баер алдыннан» (1996) әсәрләрендә автор үзенә генә хас булган җентеклелек б-н гомеренә һәм иҗатына нәтиҗә ясый, үтеп барган гасырның сәяси, иҗтимагый һәм әдәби вакыйгаларын анализлый, аларга үзенең бәясен бирә, татар халкының, бөтен илнең тарихы һәм киләчәге турында уйлана. Моны язучының киләчәк буын укучыларына мөрәҗәгате, алар б-н әңгәмәсе дип тә, шул ук вакытта өлкән буын җибәргән хаталарны кабатламасыннар өчен кисәтүе дип тә кабул итәргә мөмкин.

Е. тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, М.С.Бубеннов, О.Гончар, К.Г.Паустовский, Э.Г.Казакевич, Ч.Айтматов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1984); 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Әсәрләр: 5 томда. К., 2000–04; Юлчы. К., 1979; Глядя на горы. М., 1974; Страницы прошлого. К., 1998.

*Әд.:* Сверигин Р., Хатипов Ф. Рәшәле дөнья // Мирас. 1999. № 3–4; Мустафин Р. Целебное озеро // Образ времени. К., 1981; Халит Г. С любовью к человеку // Портреты и проблемы. К., 1985.

*Р.Х.Сверигин.*

**ЕНИКИ́-ЧИШМӘ́** (Түбән Кыярлы) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 60 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 157 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб.

18 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.-Ч.дә мәчет, 4 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1150,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 657, 1897 дә — 889, 1908 дә — 1064, 1920 дә — 1128, 1926 да — 907, 1938 дә — 836, 1949 да — 836, 1958 дә — 511, 1970 тә — 494, 1979 да — 365, 1989 да — 241, 2002 дә — 181 кеше.

**ЕНИКИ́ЕВ** Вил Гомәр улы (19.10.1936, Уфа ш.), авиация технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1984), проф. (1985). РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1959 елда Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый. 1967 дән Ленинград а.х. ин-тында (хәзер С.-Петербург аграр ун-ты) проректор (1984 тән), агросәнәгать комплексында исәпләү техникасы һәм информацион тәэмин итлеш каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. производствосындагы технол. процессларны автоматлаштыруга карый. Е. а.х. агрегатларында технол. һәм энергетик процессларның сыйфатын тикшерү системаларына микропроцессорлы җайланмалар өчен матем. модельләштерү һәм программалар эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕНИКИ́ЕВ** Гайса Хәмидулла улы (2.7.1864, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Каргалы а. — 1931, Уфа ш.), сәясәт эшлеклесе, педагог, татар һәм башкорт җырларын җыеп туплаучы. Дворяннар нәселеннән. Оренбургтагы рус булмаганнар өчен мөгаллимнәр семинариясен тәмамлаганнан соң, шул ук семинария каршындагы башлангыч уч-щедә мөгаллим булып эшли. 1890 елдан Оренбургта рус-татар башлангыч уч-ще мөдире. 1895 тә Дәүләт банкының Оренбург бүлекчәсенә эшкә керә, бер үк вакытта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1903 тә постау ф-касы директоры (Сембер губ.). 1906 дан сәүдәгәр Ә.Г.Хөсәенов акчасына төзелгән укыту-тәрбия һәм иганәчелек учреждениеләренең баш идарәчесе. 3 нче (Казан губернасыннан) һәм 4 нче (Оренбург губернасыннан) Дәүләт Думасы депутаты (1907–17), 4 нче Дәүләт Думасы секретаре ярдәмчесе, *Мөселманнар фракциясе* әгъзасы, Россия мөселманнарының Вакытлы Үзәк бюросы әгъзасы. 1917 нең маенда Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтаенда катнаша. 1918–19 да Вятка губернасы халык мәгарифе комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1923 тән Уфада, 1928 гә кадәр Башкортстан а.х. банкы инспекторы. Хезмәтләре а.х. статистикасына карый. Кульъязма җыентык авторы, аңа ул 1883–93 тә Казан, Оренбург, Самара һәм Уфа губерналарында җыйган 500 татар һәм башкорт халык җырларын туплаган.

Ә с ә р.: Авыл хуҗалыгы буенча статистик мәгълүматлар. Уфа, 1912.

*Әд.:* О л ь ш а н с к и й Н.Н. Четвёртая Государственная дума. Портреты и биографии. СПб., 1913; Мусульманские депутаты Государственной думы России (1906–1917): Сб. док. и материалов. Уфа, 1998; У с м а н о в а Д.М., Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

*Д.М.Госманова.*



Г.Х. Еникиев.

**ЕНИКИ́ЕВ** Дамир Әхмәт улы (1.1.1939, Уфа ш.), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1989), Башкортстанның атказ. фән эшлеклесе (1993). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли, 1987 елдан патофизиология каф. мөдире, 1988–95 елларда дәвалау ф-ты деканы. Е.нең тикшеренүләре җәрәхәтләнү, шок, кан югалту, стресс, кома, агулану, асфиксия китереп чыгарган экстремаль һәм үлем алды халәте патофизиологиясе мәсьәләләренә багышлана. Ул организмның реанимациядән соңгы аллергик реакциясен өйрәнә. Югары мед. уку йортларының стоматология ф-тлары өчен патофизиология дәреслеге һәм укыту программасы авторлашы. Башкортстан патофизиологлар фәнни мәктәбе җитәкчесе. Уйлап табуга 24 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Патология системы скольжения при внутрисуставных переломах и пути её коррекции. Уфа, 1996; Взаимовлияние иммунизации и реанимации. Уфа, 1997 (автордаш); Местные аллергические реакции и реанимация. Уфа, 1999.

**ЕНИКИ́ЕВ** Дәрд Гили (Гәләй) улы (21.3.1925, БАССРның Бәләбәй ш.), психиатр, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1980). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Башкортстан мед. учреждениеләрендә эшли. 1966 елдан Башкорт мед. ин-тында. 1973–91 елларда Казан ГИДУВының психиатрия һәм наркология каф. мөдире. Хезмәтләре эчкечелектән, агуланудан, шизофрениядән дәвалау ысулларын эшләүгә карый; Е. дәвалау чорында биохимик һәм неврологик күрсәткечләр үзгәрешен ачыклый, патографиягә яңа билгеләмә тәкъдим итә. Казан невропатологлар һәм психиатрлар фәнни җәмгыяте рәисе (1981–91). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение больных шизофренией // Казан. мед. журн. 1974. № 3; Победивший себя — могуч. К., 1986 (автордаш).

**ЕНИКИ́ЕВ** Заршат Дәүләтша улы (29.3.1932, БАССРның Чишмә р-ны Сәфәр а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1992), проф. (1992), БАССРның, РФнең атказ. юристы (1981, 2002). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1953–55 елларда БАССРның Бозаяз р-ны, 1955–59 да Нуриман р-ны, 1959–63 тә Уфа шәһәренең Киров р-ны прокуратурасы тикшерүчесе. 1963–65 тә БАССР Эчке эшләр министрлыгының тикшерү бүлеге башлыгы, 1965–73 тә Респ-ка прокуратурасының тикшерү бүлеге прокуроры. 1973 тән Башкорт ун-тында эшли: 1984–89 да вузара совет хокукы кафедрасы, 1989–91 дә дәүләт хокукы һәм совет төзелеше, 1991 дән җинаятькә каршы хокук һәм җинаятькә каршы процесс кафедралары мөдире; бер үк вакытта 1992–99 да юридик ф-т деканы, 1999 елдан Хокук ин-ты директоры. Хезмәтләре җинаятькә каршы процессуаль хокукка, хокук яклау эшчәнлегенә, гаделлек һәм шәхес хокукын яклау мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы эффективности мер уголовно-процессуального пресечения. К., 1982; Принципы применения мер пресечения по уголовным делам. Уфа, 1997; Уголовное преследование. Уфа, 2000; Механизм уголовного преследования. Уфа, 2001.

*Е.Б.Долгов.*

**ЕНИКИ́ЕВ** Нигъмәтулла Сәлимгәрәй улы (1893, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Каргалы а. — 1971, февраль, Үзбәкстан ССРның Фирганә ш.), хәрби эшлекле, бригада комиссары (1937). «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укый. 1914 елдан Россия армиясендә, Бәләбәй шәһәрендә 152 нче запас пехота полкында хезмәт итә, өлкән унтер-офицер. Окт. рев-циясеннән соң Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Бәләбәй өяз советы әгъзасы, Пермь губернасы Мөселманнар комис-ты әгъзасы. Пермь шәһәрендә мөселман частьләрен оештыруда катнаша. 1919 ның мартыннан Кызыл Армиядә, Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясендә сәяси бүлек хезмәткәре, Беренче аерым Идел буе татар укчы бригадасының сәясәт бүлеге башлыгы. 1920 нең сентябреннән Бохара Халык Совет Респ-касы Хәрби нәзарәтенең (халык комис-ты) сәяси бүлеге башлыгы. 1921 дән Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик ун-ты (Мәскәү) лекторы. 1923–26 да Үзәк төрки хәрби-сәясәт мәктәбе башлыгы, комиссары. 1926–35 тә ТАССР ҮБК исем. 6 нчы Берләшкән татар-башкорт хәрби мәктәбе (Казан) комиссары һәм башлыгы. 1935–37 дә ВКП(б) ҮК каршындагы курсларда укый, аларны тәмамлагач, Омск хәрби уч-щесенең сәяси бүлеге комиссары һәм башлыгы. 1937 дә ялган гаепләү нигезендә кулга алына, соңрак азат ителә. 1940 елдан отставкада, Үзбәкстан ССРда төрле адм.-хуҗалык эшләрендә. Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И.Г. Еникеев Нигматулла Салимгараевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; ш у л у к. Стойкость духа // Коммунист Татарии. 1988. № 11.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ЕНИКИ́ЕВ** Ренат Әхмәт улы (13.6.1937, Казан), композитор, пианист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979, 1987), ТРның халык артисты (2002). 1961 елда Казан консерваториясен (А.Леманда композиция һәм Н.Рецкерда фортепиано буенча) тәмамлый. 1956–57 дә Казан музыка уч-щесендә муз.-теоретик фәннәр һәм композиция укыта, 1961–63 тә Татар академ. театрында музыка бүлеге мөдире, 1963–73 тә Татар филармониясендә солист-пианист, концертмейстер, бер үк вакытта 1972–74 тә ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радиотапшырулар ком-ты хезмәткәре. 1990 нан ТРның Композиторлар берлеге идарәсе рәисе урынбасары һәм консультанты. Е. —

хәзерге әйдәп баручы татар композиторларыннан берсе, төрле жанрдагы күпсанлы әсәрләр авторы. Е. иҗатында үзәк урынны инструменталь һәм вокаль әсәрләр, балалар өчен музыка алып тора. Композиторның аеруча киң танылган әсәрләре — Х.Туфан шигыренә хор, симфоник оркестр, орган һәм сәнгатьле уку өчен «Муса Җәлил истәлегенә» поэмасы; Фортепиано һәм оркестр өчен концерт; симфоник оркестр өчен «Рапсодия» һәм «Крылов буенча дүрт мәсәл» (соңгысы театральләштерелгән хикмәтле миниатюралар циклы, татар музыкасында яңа сатирик юнәлешнең ачылуы). Е. татар камера инструменталь музыкасы (3 квартет; кыллы трио; скрипка, виолончель һ.б. уен кораллары өчен концерт пьесалары һ.б.) үсешенә зур өлеш кертә. Е. фортепиано музыкасы өлкәсендә даими һәм уңышлы эшли, иҗатында ул төрле жанрларны (концерт, соната, сонатиналар, цикллар, пьесалар һ.б.) колачлый. Композиторның 3 сонатасы милли фортепиано музыкасы тарихында драматик юнәлеш б-н бәйле яңа бер сәхифәне ача. Е. сонаталарына масштаблылык, чын мәгънәсендә симфоник колач, Европа музыкасы традицияләренең иҗади үсеше хас. Композитор Беренче сонатасында (3 кисәкле) С.Прокофьев иҗаты традицияләренә таяна. Х.Ямашев истәлегенә багышланып, «Анам кабере» дигән татар халык җырына нигезләнгән Икенче сонатасында (бер кисәкле) Ф.Лист тарафыннан эшләнгән бер темалылык (монотематизм) принцибына таяна. Е. татар музыкасының балаларга багышланган өлешен баетуга зур өлеш кертә. Сонатиналар, сюиталар, вариацияләр, фортепиано өчен «Төрки моңнар» альбомы, Җ.Дәрзаман шигырьләренә «Солдат булдым» вокаль циклы, аерым җырчылар һәм хор өчен җырлар, скрипка, фортепиано өчен пьесалар һәм инструменталь ансамбльләр хәзерге заман башкару һәм укыту практикасында киң кулланыла. Е.ның иҗади ачышларыннан берсе — автор транскрипциясендә иҗат ителгән татар музыкасында яңа жанр булып торган «Сәйдәштстан» фортепиано циклындагы 20 пьеса — аларның нигезен С.Сәйдәшевнең вокаль әсәрләре тәшкил итә. Е., оригиналларның үзенчәлеген саклаган хәлдә, аларның кайбер аерым параметрларын (бигрәк тә, гармония һәм фактурасын) кыю рәвештә яңартып, бу музыканың югары кыйммәтен һәм матурлыгын фортепианога хас үзенчәлекле яңгыраш б-н тулысынча ачып салуга ирешә. Композиторның иҗатында гражданлык, патриотик һәм лирик эчтәлекле популяр җырлар һәм романслар — «Үрләреңне менгәч» (С.Хәким шигыре), «Ак дулкыннар», «Ләйсән» (М.Хөсәен), «Синең эзләр» (Роберт Әхмәтҗанов), «Бәхет» (М.Җәлил), «Яңгыр» (Г.Тукай) һ.б. лаеклы урын ала. Е. татар халык җырларын эшкәртү остасы, алар оригинальлеге һәм фольклорның тирән үзенчәлекле ачылышы б-н аерылып тора. Е.ның образлы иҗат дөньясы киң һәм күптөрле: динамик тәэсир һәм лирик хис, драматик җанлылык, фаҗигале пафос, импрессионистик нечкәлек һәм шигъриятлелек, тирән фикерләү, психол. кичереш һәм



Р.Ә.Еникиев.

юмор. Композитор һәр жанрның табигатен бик яхшы сиземли, аның үзенчәлекле формаларын һәм ысулларын файдалана. Е.ның иҗаты камера принципларына һәвәслеге б-н үзенчәлекле. Аның музыкасында психологизмга, штрихларның нечкә, җентекле булуына, кыскалык һәм ачыклыкка, форманың һаман чарлана баруына, һәр детальнең җиренә җиткереп эшләнешенә өстенлек бирелә. Композитор өчен татар халык көйләре традицияләренә таяну хас. Ул үзенең әсәрләрендә фольклор үрнәкләрен еш куллана һәм аларның жанр табигатенә тәңгәл рәвештә киң колачлы үсешенә ирешә (Фортепиано өчен балладалар, 2 нче соната һ.б.). Е., халык башкаручыларының көйләү һәм фикерләү рәвешен нечкә сиземләп, аны үз әсәрләрендә үзенчәлекле һәм ачык чагылдыра. Композитор башка халыкларның фольклорына да мөрәҗәгать итә. «Крылов буенча дүрт мәсәл» — башкорт халык җырларына; «Төрки моңнар» казакъ, үзбәк, кыргыз һ.б. күп кенә төрки халыклар көйләренә нигезләнгән. Е.ның музыкасы хәзерге концерт һәм пед. репертуарларында тотрыклы урын алып тора. Композитор солист һәм ансамблист, ш.у. үз әсәрләрен интерпретацияләүче буларак та уңышлы чыгышлар ясый. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1983).

Төп әсәрләре: вокаль-симфоник әсәрләр: Х.Туфан шигыренә катнаш хор, симфоник оркестр, орган һәм сәнгатьле уку өчен «Муса Җәлил истәлегенә» поэма (1981), «Дошманнар» — Г.Тукай шигыренә тенор һәм оркестр өчен монолог (2000), «Карьят батыр» — баритон һәм оркестр өчен халык көйләренә сюита (1973); симфоник әсәрләр: Фортепиано б-н оркестр өчен концерт (1961, 2 нче ред., 1978); «Крылов буенча дүрт мәсәл» (1977), «Рапсодия» (1986), Виолончель һәм оркестр өчен диптих (1986), Скрипка һәм оркестр өчен триптих (1997); камера ансамбльләре: скрипка, альт һәм виолончель өчен трио (1958, 2 нче ред., 1981), 2 скрипка, альт һәм виолончель өчен 3 квартет (1960, 2 нче ред. 1991; 1972, 1996), скрипка һәм фортепиано, виолончель һәм фортепиано өчен пьесалар; фортепиано өчен: вариацияләр (1957), баллада (1979), 3 соната (1967, 1971, 1972), 5 сонатина, 5 сюита, «Сәйдәштстан» (2000), «Төрки моңнар» (2002) цикллары; вокаль әсәрләр: Җ.Дәрзаман шигырьләренә фортепиано б-н сопрано өчен «Солдат булдым» балалар җырлары циклы (1978), 60 тан артык җыр һәм романс; «Тукбикә» — контральто һәм фортепиано өчен 8 җыр (1979), румын татарлары халык җырларына эшкәртмәләр; спектакльләргә музыка: Н.Исәнбәт пьесасы буенча «Гөлҗамал» (1964), Н.Фәттахның «Кол Гали» (1974) һәм «Сармат кызы Сәринә» пьесаларына (1986) һ.б.

*Әд.:* Х ө с н и я р З. Якутлар табыладыр вакыт белән // Азат хатын. 1987. № 6; Ә й д и Т. Рухы нык — үргә менә // Казан утлары. 1997. № 6; К а с а т к и н а Г. Обновление традиций // Советская музыка. 1970. № 10; ш у л  у к. Ренат Еникеев // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; С п и р и д о н о в а В. О новых стилевых тенденциях в татарской фортепианной музыке (1960–1970-е годы) // Народная и профессиональная музыка Поволжья и Приуралья. М., 1981; ш у л  у к. Фортепианные сонатины Р.Еникеева. К., 1992; Ш а р а ф у т д и н о в а Р. Роль инонациональных музыкальных традиций в творчестве Р.Еникеева // Взаимовлияние и взаимообогащение культур народов СССР. К., 1983; Г у р а р и й С. Диалоги о татарской музыке. К., 1984; Г а б я ш и Р. Рыцарь гармонии // Казань. 1997. № 12; А л м а з о в а Т. Творческий тандем // Музыкальная академия. 1999. № 3.

*Т.А.Алмазова.*

**ЕНИКИ́ЕВ** Саттар Мөхәммәтҗан улы (1885, Урал өлкәсе Гурьев ш. — 1939), сәясәт эшлеклесе. 1917–18 елларда Әстерханда Мөселман социалистлар ком-тын оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе. 1918–19 да Әстерхан крае Мөселманнар эшләре ком-ты рәисе. 1920–30 да ТАССР мәгариф халык комиссары урынбасары, социаль тәэминат халык комиссары, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-тында ТАССР вәкиле. «Татарстан» г-тасы мөхәррире. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.


*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ЕНИКИ́ЕВ** Сөләйман Гыйниятулла улы (26.3.1914, Уфа губ., Бәләбәй өязе Каргалы а. — 2.2.2005, Казан), үсемлекләр физиологы, а.х. фән. д-ры (1959), проф. (1960), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1974). Кыргыз а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1942), Үсемлекләр физиологиясе ин-тында (Мәскәү) эшли. 1947–60 елларда Кыргыз а.х. ин-тында ботаника каф. мөдире (1951 дән). 1960–63 тә Кыргыз ун-тында үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире. 1963–84 тә Казан а.х. ин-тында, үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1978 гә кадәр). Хезмәтләре кыр культуралары физиологиясенә һәм биохимиясенә карый. Ясалма сугарыла һәм сугарылмый торган игенчелектә шикәр чөгендеренең су режимын, фотосинтезын, сулавын һәм туклануын фәнни тикшерә, аны эшкәртү агротехникасын тирәнтен өйрәнә. Шикәр чөгендере тамырында аномалияләр барлыкка килү механизмнарын ача һәм тасвирлап бирә (авторлык таныклыгы, 1969). СССР ВДНХсының Мактау китабына кертелә (1939). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в ботанику и физиологию растений с основами микробиологии. К., 1966; Полевая практика по физиологии растений. К., 1967 (автордаш); Практикум по физиологии и биохимии растений. К., 1972 (автордаш).

**ЕНИКИ́ЕВ** Таң Гомәр улы (1.10.1948, Уфа ш.), театр рәссамы, нәкышьче, график, БАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1980, 1994). В.И.Суриков исем. Мәскәү сынлы сәнгать ин-тының нәкыш ф-ты сәхнә бизәлеше бүлеген (1975), академиклар В.Рындин һәм М.Курилко, проф. М.Пожарский остаханәләрен тәмамлый. 1973–80 елларда М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театрының куючы-рәссамы, 1980–2000 дә баш рәссамы. 1990 нан «Нур» Уфа татар акад., Татар акад., Татар яшьләр, Әлмәт татар дра-

ма, М.Горький исем. Оренбург драма, И.С.Тургенев исем. Орёл акад. театрлары һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. Мәскәүдәге Евг. Вахтангов исем. дәүләт акад. театрында стажировка үтә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). РФнең әйдәп баручы рәссамнарыннан берсе, үзәген дизайн элементлары тәшкил иткән сәхнә мохитенең нәфислеген яңа сыйфат югарылыгына күтәреп, сәхнә бизәлеше өлкәсендә актив һәм нәтиҗәле эшләп килә. Аның сәнгать теле стилистикасында образларны төсле яктылык ярдәмендә бизәү, рус



Т.Г.Е н и к и е в. Т.Таһиров һәм Р.Исрафиловның «Галия» пьесасына декорация эскизы. Темпера, майлы буяу. 1985. М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее.

классик һәм татар милли сәнгате традицияләренә мөрәҗәгать итү мөһим роль уйный. Символик метафоралар дип аталучы юнәлеш тарафдары. 150 дән артык спектакль бизи. Татар акад. театрында Ф.Борнашның «Яшь йөрәкләр» (1993), Ю.Сафиуллинның «Идегәй» (1994), Т.Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре» (1996), З.Хәкимнең «Күрәзәче» (1998) һ.б.; Казан Зур драма театрында Н.Саймонның «Мәзәк кешеләр» («Весельчаки», 1997); Ә.Мөбарәков исем. Сибай драма театрында Ж.Б.Мольерның «Дон Жуан» (1997); М.Горький исем. Оренбург драма театрында А.С.Пушкин повесте буенча «Капитан кызы» (1999); Әлмәт татар драма театрында М.Фәйзинең «Ак калфак» (1999); Туймазы татар драма т-рында М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» (1997), Н.Исәнбәтнең «Портфельле кияү» (1999) һ.б. спектакльләргә декорацияләр, костюмнар һәм макетлар эскизлары авторы. 1972 дән бөтенроссия — «Сезон нәтиҗәләре» (Мәскәү, 1974, 1975); бөтенсоюз — «Театр һәм кино» (Мәскәү, 1979; Казан, 1985); халыкара «Прага квадриеналлесе» (1975, 1983), «Совет театр рәссамнары» (Финляндия, 1983; Польша, 1984), РФ Дәүләт бүләкләре лауреатлары (Мәскәү, 1996) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре Мәскәүдәге А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда, М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда (Уфа ш.) саклана. РФнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләге М.Гафури исем. Башкорт акад. театрында Ф.Бүләков пьесасы буенча куелган «Бибинур, аһ, Бибинур» спектаклен бизәгәне өчен (1995), Г.Саләм исем. Башкортстан комсомолы бүләге шул ук театрда күп кенә спектакльләрнең сәнгать бизәлеше өчен бирелә (1982). Төрки телле театрларның 2 нче Халыкара «Туганлык» фестивалендә «Гран-при»га (1996) лаек була.

*Әд.:* Г а л л я м о в а Л.Г. Тан Еникеев // Краски Башкирии: Очерки. Уфа, 1997; К а ш а п о в а Э. Пространство и метафоры Тана Еникеева // Рампа. 1997. № 1; Л у ц к а я Е. Пристань воспоминаний // Сцена. 1998. № 12; М и р з о я н И. Возобновлённое знакомство, или Новая встреча // шунда ук; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЕНИКИ́ЕВ** Хәсән Казыйм улы (29.1.1910, Уфа губ., Бәләбәй өязе Каргалы а. — 17.12.1984, Мәскәү), селекция галиме, биол. фән. д-ры (1958), проф. (1960), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1961). Мичуринск шәһәрендә Җиләк-җимеш ин-тын тәмамлаганнан соң (1935), Мичуринск шәһәре җиләк-җимеш селекциясе питомнигында (хәзер Үзәк генетик лаб.) эшли. 1945–84 елларда Кара туфраклы булмаган полосаның бакчачылык фәнни тикшеренү ин-тында (1960 ка кадәр Мәскәү җиләк-җимеш тәҗрибә станциясе) селекция бүлеге мөдире (1961–67), лаб. мөдире (1967–84). Хезмәтләре төшле җимешләр селекциясенә карый. РФ һәм ТРда районлаштырылган чия («Багряная», «Гриот московский», «Молодёжная») һәм сливаның («Скороплодная», «Красный шар», «Память Тимирязева» һ.б.) бик күп сортлары авторы. Бу сортлар югары уңдырышлылыгы һәм суыкка чыдам булулары б-н аерылып тора. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Слива. М., 1956 (автордаш); Биологические особенности сливы и выведение новых сортов. М., 1960; Вишня. М., 1983.

*В.А.Наумов.*

**ЕНИКИ́ЕВА** Разия Исмәгыйль кызы (15.12.1947, Казан), композитор, пианист, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). 1971 елда Казан консерваториясен (Э.*Монасзон* классы) фортепиано буенча, 1977 дә (А.Луппов классы) композиция буенча тәмамлый. 1975–99 да Казан консерваториясендә укыта. 1993 тә РФдә беренче шәхси нәшрият — «Еникиева нәшрияты»н ача. Концерт эшчәнлегенә соло программалары, симф. оркестр, радио һәм телевидениедән татар, рус, Көнбатыш Европа композиторлары һәм үзенең шәхси әсәрләре программалары б-н чыгышлары керә. Хәйрия эшчәнлеге, ш.и. балалар музыкасы конкурсларын оештыру б-н шөгыльләнә.

Төп әсәрләре: Оркестр б-н фортепиано өчен 1 нче, 2 нче номерлы концертлар (1978, 1986); Симфоник оркестр өчен рапсодия (1987); фортепиано пьесалары; җырчы һәм фортепиано өчен вокаль цикллар; җырлар һ.б.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЕНИКИ́ЕВА** Светлана Әхмәт кызы (16.4.1946, Уфа ш.) иммунолог, аллерголог, гаилә һәм хезмәт хокукы юристы, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1996), БАССРның атказ. табибе (1986). Башкорт мед. ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан Уфа фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер «Иммунопрепарат» дәүләт унитар пр-тиесе), 1981 дән иммуноглобулиннар лаб-ясе җитәкчесе. Хезмәтләре кан сүле нигезендә иммун системасын көйләүче яңа препаратлар булдыруга карый. Ул аллергиягә каршы иммуноглобулин, «орозин» препаратлары, антиоксидант-церулоплазмин уйлап таба; «Иммунопрепарат» пр-тиесендә Fab-фрагментлар нигезендә күпләп җитештерүгә кертелгән $a^1$-антитрипсин, радиопротектор аксымы, иммуноглобулиннар алу технологиясен эшли. БРның ЮС депутаты (1995–2000).

Х е з м.: Взаимовлияние иммунизации и реанимации. Уфа, 1997 (автордаш); Иммунодиагностика и иммунокоррекция в педиатрической практике. Уфа, 1998 (автордаш); Современное лечение аллергических заболеваний у детей. М.–Уфа, 1999.

**ЕНИКИ́ЕВЛӘР**, татар дворяннары. Нәселне башлаучы — морза **Еники Кулдашев**. 1629 елда крепостной крәстияннәре булган Темников морзалары арасында Алакай, Туган һәм Идей Е. искә алына. Полянка (Идей Пучинкәсе) авылы морзасы Идей Е.нең биләмәләре Темников һәм Кадом өязләрендә була. 17 йөзнең 1 нче яртысында Еники Кулдашев оныгының улы Будалай Усаналиев Темников өязендә Олы Оксель, Урей, Чюкалей, Чёрная елгалары буендагы, Мокша станының Азарарик, Кадом өязенең Куликов һәм Касыйм өязенең Тонеев авылларындагы, Пустошь Пичучинскаядагы утарларны (барлыгы 165 чирек сөрүлек җире) били, ә Алакай Е.тә Велизима авылындагы 6 крәстиян һәм бобыль хуҗалыгы, Ирсит авылындагы 4 крәстиян һәм бобыль хуҗалыгы исәпләнә. 18 йөздә морза Е. Темников өязенең Идей һәм Кормай авылларында яшәгәннәр. 1777 дә Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Каргалы авылына (хәзер БРның Благовар р-ны) күченеп киткәннәр. 1836 да аларның нәселендә 178 ир-ат булган. Сенатның 1790 ел, 15 гыйн. фәрманы б-н Е.гә морза дәрәҗәсе кайтарыла. Е. нәселеннән язучы Ә.*Еники* чыккан.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Х а й р у т д и н о в Р.Р. Татарская феодальная знать и российское дворянство: проблемы интеграции на рубеже XVIII–XIX вв. // Ислам в татарском мире. История и современность: Материалы междунар. симп. (Казань, 29 апр. — 1 мая 1996 года). К., 1997; Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999.

*И.Р.Габдуллин.*

**ЕНИКИ́ЕВЛӘР**, татар бәкләре. Бихан бәк нәселеннән. Нәселне башлаучы — 16 йөзнең 1 нче яртысында Темников шәһәрендә кенәзлек иткән **Еники Тенишев**. Патша Иван IV кенәз Еникигә, морзалар Емаш б-н Исәш Тенишевларга, Кугушевларның балаларына Мешёрада, Подлесье волостенда, Югары Пылнов авылында биләмәләр бирә. Иван IV нең грамотасы буенча Темников кенәзе Еникейга (Еники-бәйгә) бирелә һәм «аңа Темниковта яшәүче татарлар, тарханнар, башкортлар һәм мажарларны элеккечә, аның әтисе Тениш кебек үк хөкем итәргә һәм тотарга кушыла». Казанны алуда (1552) һәм Казан сугышында (1552–56) катнаша. Соңыннан Темниковта воевода. Аның 5 улы була: Колынчак (кенәз Колынчаковлар нәселен башлаучы), Күбәк, Ишмәмәт, Елмәмәт, Сабакай. 1629 елда крепостной крәстияннәре булган Е. нәселендәге Темников морзалары арасында Бре-

шәй, Елмәмәт һәм Ишмәмәт Е., ш.у. Китәй һәм Ютәй Сабакаевлар искә алына. Е. нәселеннән Бегиш Елмәмәтовның Темников өязендә биләмәсе була, 1654 тә Иске Городище авылында аның биләмәсендә 2 крәстиян һәм 4 бобыль хуҗалыгы исәпләнә. 1699 да Обраим Үмрәков, Вәлиша Усейнов, Касыйм Асянов, Смайко Уразов, Иванаш, Декелмай һәм Мостафа Мамадалиевләр, Үмрәк Үтәмишев, Ураз һәм Нөркә Уразмәмәтовлар, Кондрак Корнаев, Али Сөләйманов, Иван Шетимаев, Ураз Бахмаев, Елбай Мостаев, Хани Салтанов, Ураз Хамураев (Хансверов), Мамадали Тимаев, Батырша, Вәлиша һәм Хантимер Хановлар, Үмрәк Байтимеров, Гаделша Исеновның утарлары була. 18 йөздә кенәз Е. Темников өязенең Муса һәм Кара авылларында яшиләр. Православие динен кабул итмәгән Е.нең биләмәләре 1713 елгы Указ нигезендә «государьга» язылa, ә үзләре Инсар һәм Краснослободск өязләре дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. Сенатның 1796 ел, 10 май Указы нигезендә Муса авылыннан Уфа губернасы, Бәләбәй өязе Бәшир авылына (хәзер БРның Чакмагыш р-ны) күчкән мөселманнарга дворяннар дәрәҗәсе һәм кенәз титулы кайтарыла. Е. нәселеннән ислам динендәге барлык кешеләр дәүләт крәстияннәре катлавында кала. 19 йөздә кенәз Е. ш.у. Яңа Мортаза һәм Иске Калмаш авылларында (хәзер БРның Чакмагыш р-ны) яшиләр.

*Әд.:* С а в е л о в Л.М. Родословные записи. М., 1909. Вып. 3; История Татарии в документах и материалах. М., 1937; Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3; Х а й р у т д и н о в Р.Р. Татарская феодальная знать и российское дворянство: проблемы интеграции на рубеже XVIII–XIX вв. // Ислам в татарском мире. История и современность: Материалы междунар. симп. (Казань, 29 апр. — 1 мая 1996 года). К., 1997; Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999.

*И.Р.Габдуллин.*

**ЕНИЛЕ́ЕВА** Наилә Хөсәен кызы (9.8.1932, Рязань өлкәсенең Сасово р-ны Бостан а.), зоолог, биол. фән. д-ры (1991). Сәмәрканд ун-тын тәмамлый (1957). 1959–97 елларда Үзбәкстан вет. фәнни тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре паразитология һәм энтомологиягә карый. Бөгәлчәннәр аркасында килеп чыга торган а.х. хайваннары авыруларына (мөгезле эре терлектә гиподерматоз, сарыкларда эстроз, атларда ринэстроз һәм гастрофилёз) каршы профилактика үткәрү өчен хлорофос кулланунның Е. тарафыннан тикшерелгән алымнары һәм күрсәтмәләре вет. медицинасында киң кулланылыш таба (Үзбәкстан).


Х е з м.: Гастрофилёз лошадей и меры борьбы с ним // Ветеринария. 1977. № 7 (автордаш); Экологические особенности желудочных оводов лошадей в Узбекистане // Паразитология. 1987. № 21.

**ЕНИСЕ́Й РАЙОНЫ́**, *Красноярск краеның* төньягында урнашкан. 1924 елның 4 апрелендә оештырыла. Мәйданы — 22 мең *км*². Үзәге — Енисейск шәһәре (Красноярск шәһәреннән 338 *км* төньяктарак). Халкы — 31315 кеше (2002). Татарлар саны: 592 кеше (2002). Район терр-ясендә крайга буйсынулы *Лесосибирск* шәһәре дә урнашкан, анда бернichә мең татар яши. 1917 гә кадәр Енисейскида мәчет (1905 тә ачыла), мәдрәсә була. 1940 еллар башына кадәр татар мәктәбе, 1957 гә кадәр пед. уч-щедә татар бүлеге, 1961 гә кадәр М.Вахитов исем. татар клубы эшли. 1989 дан районда татар мәдәни үзәге, «Туган тел» фольклор ансамбле оештырыла, ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

**ЕНО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 31 кеше (руслар, мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлекчелек. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аполлинарьевка исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1889 да — 61, 1920 дә — 79, 1926 да — 134, 1938 дә — 163, 1949 да — 150, 1958 дә — 80, 1970 тә — 66, 1979 да — 65, 1989 да — 28, 2002 дә — 24 кеше.

**ЕПАНЕ́ШНИКОВ** Александр Николаевич (5.8.1954, Алабуга ш. — 23.8.1993, шунда ук), РФ Герое (21.6.1994, вафатыннан соң), майор (1990). Балашов югары хәрби авиация очучылары уч-щесен тәмамлый (1975). 1975 елдан Арктикада, Әзәрбайҗан, Польша, Мәскәү яны һәм Воркутада катнаш авиация эскадрильясенең эзләү-коткару отряды командиры ярдәмчесе. 1993 нең 23 августында Энгельс–Әстерхан маршруты буенча очыш башкарганда батырлык күрсәтә: самолёт двигателе эшләми башлагач, экипаж командиры Е. егылып төшүче машинаны Волгоград шәһәре өстеннән читкә борып алып китә. Алабугада ул яшәгән йортка мемориаль такта куела, Е. музее ачыла, 3 нче мәктәп аның исемен йөртә.

*М.З.Хәбибуллин.*



А.Н. Епанешников.

**ЕПА́РХИЯ УЧИ́ЛИЩЕЛӘРЕ**, дини катлаудан булган кыз балалар өчен урта гомуми белем бирү һәм пед. уку йортлары. 1868 елның 20 сентябрендә Синод тарафыннан расланган Уставка туры китереп ачыла һәм эшлиләр. Епархия архиерее идарәчелегендә була һәм епархия акчасына финанслана. Е.у.нә шул уч-ще кергән епархия чиркәүләренең поп, дьякон һәм руханилары кызлары конкурс буенча кабул ителә. Укырга керүчеләрнең башлангыч белемле булуы таләп ителә. Беренче уч-щеләр икешәр еллык һәм өч сыйныфлы, 1901 елдан алты сыйныфлы була. Укучыларның күпчелеге, төп курсны тәмамлаганнан соң, өстәмә берьеллык пед. сыйныфка укырга керә. Һәр уч-ще каршында пед. практика үтү өчен үрнәк башлангыч мәктәп эшли. Укыту югары дәрәҗәдә диярлек була, чөнки өлкән сыйныфларда, башлыча, руханилар академияләрен тәмамлаучылар укыта. Шулай да уку программалары шактый дөньяви, гомуми белем бирә торган була. Е.у. укытучы кадрлар әзерләүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Төбәктә 1868 дән Е.у. программалары һәм укыту планнары буенча дини карамактагы Казан кыз балалар уч-щесе эшли. 1889 да Казан епархия уч-щесе ачыла. Анда, рухани гаилә балаларыннан тыш, Ольга һәм Александра ятим балалар приютларында тәрбияләнүчеләр укый. 1892–99 елларда Е.у. өчен арх. А.Е.Остовский проекты буенча биналар комплексы (архит-ра истәлеге) төзелә. 1899 дан Вятка епархиясендә Алабуга (Стахеевларныкы) епархия уч-щесе эшли, аның өчен Г.Ф.Стахеева акчасына 1903 елда арх. И.А.Чарушин проекты буенча өч катлы корпус төзелә (архит-ра истәлеге; хәзер Алабуга пед. ун-тының төп корпусы).

*Әд.:* Расширение и обновление Казанского епархиального женского училища. К., 1900; Т а н а е в с к и й С. Историческая записка об открытии Елабужского Епархального женского училища. Вятка, 1903; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в пореформенной России. Казанская губерния. К., 1999.

*Е.В.Липаков.*

**ЕПИ́СКОП** (грек. epískopos — күзәтеп торучы, сакчы), христиан (православие, католик, англикан) чиркәвендә чиркәү округы (епархия, диоцез) б-н идарә итүче югары дәрәҗәле рухани. Е. турында беренче мәгълүматлар 2 йөз башына карый («Игнатий Антиохийский хәбәрләре»). 4 йөздән Е.лар арасында иерархия барлыкка килә: алар *патриархлар, митрополитлар* (шуларның бер төркеме *архиепископлар*) һәм Е.ларга бүленә. Киев Русенда Е.лар 10 йөздә барлыкка килә. 1448 елга кадәр аларны бөек кенәзләр билгели, Константинополь патриархлары раслый, соңрак бу хокук *православие руханиларына* күчә. Е.лар Казан епархиясе б-н 1738–62 дә һәм, бүленүләр б-н, 1917–96 да идарә итәләр.

**«ЕРА́К ШӘРЕ́КЪ»**, татар эмигрантларының иҗтимагый-сәяси, фәнни, әдәби периодик басмасы. 1920 елның 25 гыйнварыннан 1925 кә кадәр Харбин шәһәрендә (Кытай) айга 3 тапкыр татар телендә (баштa ж-л, 1924 тән атналык г-та буларак) нәшер ителә. Җитәрлек акча б-н тәэмин ителмәү һәм әбунәчеләре аз булу сәбәпле, зур өзеклекләр б-н чыгарыла. Нашир һәм мөхәррире — Г.Әхмәди. Кулдан язып әзерләнә, ташбасма ысулы б-н басыла. Күпчелек материал псевдоним б-н (Казанлы, Бикбау, Сакмари, Харбинлы һ.б.) языла. Бүлекләре: «Ислам дөньясында», «Төрле ил һәм төбәк хәбәрләре» (ТАССР яңалыклары да була), «Кытай мөселманнары тормышы», «Харбин яңалыклары», «Газета битләреннән» һ.б. Икътисади һәм иҗтимагый-сәяси эчтәлекле мәкаләләр, мәс., Г.Гобәйдуллинның «Төркиләр һәм Совет хөкүмәте», З.Кадыйриның «Идел-Урал крае», Г.Әх-

мәдинең «Исламизм һәм милли агымнар» дигән нейтраль-мәгълүмати характердагы материаллары басыла. Әдәби әсәрләргә шактый урын бирелә: чәчмә һәм шигъри әсәрләр, мәс., Р.Аратның (псевд. Казанлы) «Килде!», «Сандугачка» һ.б. шигырьләре, Х.Габдүшнең «Табышмак», «Юк» хикәяләре һ.б. басыла. Газетада Ерак Көнчыгыштагы татар сәүдәгәрләре тормышы яктыртыла, АКШ ун-тларында белем алучы татар студентлары турында сөйләнә.

*Әд.:* Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7.

*А.М.Ахунов.*

**«ЕРАК ШӘРЕ́КЪ ТӨРКИ́-ТАТА́Р МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ДИНИ́-МИЛЛИ́ ИДЕ́Л-УРА́Л МӘРКӘЗЕ́»**, Ерак Көнчыгышта эмиграциядәге татар вәкилләренең иҗтимагый-сәяси оешмасы (1935–45). *Мукден конгрессында* оештырыла (1935). Мәркәз татарларның мәдәни-дини тормышы б-н өч юнәлештә — дин, мәгариф, финанс эшләре буенча җитәкчелек итә. Якташлык җәмгыятьләренең үзара бәйләнешләрен җайга сала, бәхәсле мәсьәләләрне хәл итә, мәктәпләр, китапханәләр, типографияләр эшчәнлеген җитәкли. Басма органнары: «*Милли байрак*» г-тасы һәм «*Шәкертләр таңы*» ж-лы.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ЕРА́СТОВ** Олег Александрович (22.8.1940, Киров өлкәсе, Слободской р-ны Вахруши пос. — 6.11.1988, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1976). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1965–88 елларда СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физ. химия ин-тында эшли (бүленеп, 1970–75 тә Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире), 1975 тән азоторганик кушылмалар лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре органик һәм фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Дикарбонил кушылмаларның кето-еноль таутомериясен тикшерә. Е. җитәкчелегендә фосфор-борлы кушылмалар химиясе эшләнә, яңа тип тозлар комплексы таутомериясе ачыла. Функциональ алмаштырылган фосфиннарны бер үк вакытта молекулага башка элементлар (бор, кремний, алюминий) кертеп өйрәнә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Функционально-замещённые фосфины и их производные. М., 1986.

**ЕРЕМЕ́ЕВ В. ҺӘМ ШАША́БРИН А. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Тарихы Н.М.Чижова басмаханәсеннән башлана, 1910 елда аңардан В.З.Еремеев сатып ала. 1911 дән «В.Еремеев һәм А.Шашабрин сәүдә йорты басмаханәсе» дип атала. Наширләре — китап сатучы Ш.Хөсәенов варислары — «Галия» мәдрәсәсенең казакъ шәкертләре, казакъ язучылары К.Турагельдин һәм Р.Телешов, православие миссионерлары. Дини эчтәлекле дәреслекләр, догалыклар, Коръән; Г.Рәшидинең 12 шигъри җыентыгы, В.Җәләл шигырьләре, «Кызлар дөньясы» исемле хикәяләр җыентыгы; инглиз философы Г.Спенсерның «Педагогика» исемле хезмәтенең русчадан татарчага тәрҗемәсе; медицинадан хезмәтләр, стена һәм өстәл календарьлары, «Журнал строительной комиссии по постройке городских казарменных зданий в г.Казани» (1911) ж-лы, «Дәүләт ополчениесе дружинасы әгъзасының куен дәфтәре» («Записная книжка дружинника дружины государственного ополчения») һ.б. нәшер ителә. 1910–15 еллар эчендә 377140 данә тираж б-н 62 исемдә татарча китап чыгара. Сугыш, кәгазь булмау һәм эшчеләр җитешмәү сәбәпле, 1916 дан басмаханәдә нәшер ителгән татарча басмалар кими, «Камско-Волжская речь» г-тасы кушымтасы чыгудан туктый. 1916 елдан соң басмаханә турында мәгълүматлар юк.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**ЕРЕМЕ́ЕВ** Валерий Павлович (13.5.1953, Чуаш АССРның Саланчик пос.), күперләр төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1993), проф. (1998), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1988). 1975 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын, 1982 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1976 дан Казан архит-ра-төзелеш ин-тында, күперләрне сынау һәм яңарту лаб. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре күперләрне файдалану, төзәтү һәм торгызуга карый. Автомобиль юлларындагы күперләрне һәм инженерлык корылмаларын файдалану системасын нигезли һәм эшли. Е. җитәкчелегендә беренче мәртәбә углеродлы корычтан ябыштырылма шпунтлы конструкцияләр эшләнә, аларны җитештерү Кама металл конструкцияләр (Чаллы ш.) һәм «Стройкоммаш» (Казан) з-дларында җайга салына. Кама елгасы аша салынган күпердә шпунт куллану шул төр продукцияне чит илдән кертүне туктату һәм ТР пр-тиеләрен эш б-н тәэмин итү мөмкинлеге бирә.

Хезм.: Предельное и аварийное состояние мостов. К., 2004.

**ЕРЕ́ПКИНО** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы бассейнында урнашкан. 2008 елда 119 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 20 йөз башында нигез салына. Беренче исеме — Никольское Товарищество. 1917 дә Е. халкының 1961 дис. җире була. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1908 дә — 110, 1920 дә — 159, 1926 да — 204, 1938 дә — 214, 1949 да — 226, 1958 дә — 234, 1970 тә — 267, 1979 да — 233, 1989 да — 128, 2002 дә — 119 кеше.

**ЕРЁМИН** Михаил Васильевич (3.6.1942, Рязань өлкәсенең Ермишинск р-ны Яңа Георгиевка а.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1967 дән шунда ук эшли, квант электроникасы һәм радиоспектроскопия каф. профессоры (1989 дан). Хезмәтләре каты җисемнең электронлы төзелешенә, диэлектриклар һәм үтә үткәргечләр физикасына карый. Күчеш төркемнәре ионнарының анион төркемнәре аша үзара супералмашу теориясен үстерә. Төрле анион күперчекләре аша алмашу процессларының квант интерференциясе эффектын тасвирлый. Катламлы купратларда динамик корылма сизгерлегенең аналитик аңлатмасын таба һәм аларда шуышма корылма-ток дулкыннары фазалары булуын дәлилли. ТР Дәүләт бүләге иясе (2007).

Хезм.: $41^{n-1}$ 5d конфигурации ионов в кристаллах // Оптика и спектроскопия. 1970. Т. 29; Двухмостиковые механизмы косвенного обмена // Физика твердого тела. 1982. Т. 24; Влияние процессов переноса заряда на электронную структуру центров с незаполненными d- и f-оболочками // Оптика и спектроскопия. 1990. Т. 68; Динамическая спиновая восприимчивость дырочных ВТСП в модели синглетно-коррелированной зоны проводимости // Журн. эксперим. и теорет. физики. 2008. Т. 133, № 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**Е́РЗИН** Мөхәммәт Габдулла улы (16.8.1908, Каспий аръягы өлкәсе (хәзерге Төрекмәнстан Респ-касы), Керки ш. — 29.4.1986, Казан), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1958), проф. (1959), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1964, 1971). А.Д.*Адо* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук патофизиология кафедрасында эшли. 1941–45 елларда Норлат станциясендәге эвакогоспиталь башлыгы. 1948–53 тә Стоматология ин-тында патофизиология каф. мөдире, бер үк вакытта фәнни-укыту эшләре буенча проректор. 1953–78 дә Казан мед. ин-тында патофизиология каф. мөдире, бер үк вакытта 1956–59 да укыту эшләре буенча проректор. Хезмәтләре аллергик реакцияләр патофизиологиясенә карый. Е. А.Д.Адо б-н бергәләп үтә тиз типтагы аллергик реакцияләр механизмында интерорецептив сизүчәнлекнең ролен өйрәнә. Е. беренчеләрдән булып аутоаллергик реакцияләр механизмнарын өйрәнү буенча күптөрле эксперименталь тикшеренүләр үткәрә. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. Чехословакия Соц. Респ-касы ФАнең Я.Пуркинье исем. медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Изменение некоторых функциональных систем организма при аутоиммунных реакциях. К., 1964; Комплексное изучение вопросов аллергии в стоматологии. К., 1967; Морфофункциональное изучение коры надпочечников при гетеро- и аутоиммунизации. К., 1967.

**Ё́РЗИН** (Эрзин) Салих Йосыф улы (1833, Тамбов губ. Әзи а. — 1911, Мәскәү), Мәскәү сәүдәгәре һәм эшмәкәре, Мәскәүнең нәселдән күчмә мактаулы гражданы (1863), иганәче. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. Мәскәүдә мех б-н сәүдә итүче татар сәүдәгәре кибетендә эшли. 1905 елда уллары Садыйк һәм Әхмәт б-н бергәләп «Салих Ерзин һәм улларының Шәрекъ сәүдә фирмасы»н нигезли, ефәк, мех, тире, мамык һ.б. товарлар б-н сәүдә итә. 1910 да Е. 1 нче гильдия сәүдәгәр булып языла. Касыйм шәһәрендәге бәрән тиресе эшкәртү остаханәләре, күпләгән кибетләр һәм Мәскәүнең Елга аръягындагы йортлар хуҗасы; анда яшәүче татарларның җәмәгать һәм мәдәни тормышында күренекле роль уйный. Үзенең иганәчелек эшчәнлеге б-н киң билгеле: 1880 дә Мәскәү мәчетен яңартып

коруга, аның яңа манарасын төзүгә, мөселман зиратын таш койма б-н әйләндереп алуга зур суммалар бирә; Әзи авылында мәчет салуга акчалата ярдәм итә, аның мәдрәсәсенә һәм Касыйм шәһәренең Ярлы мөселманнарга иганәлек итү җәмгыятенә (1911 дә оештырыла) матди ярдәм күрсәтә. Мәскәү җамигъ мәчете төзелешенә (Выползов тыкрыгы, 7) акча бирեп (алтын б-н 40 мең сум), Е. аеруча киң таныла. Е.ның кылган игелекләре хөрмәтенә 1999 да мәчеттә мемориаль такта куела. Аталары үлгәч, сәүдә эшләрен уллары дәвам иттерә.


*А.А.Сибгатуллин.*

**ЕРИКӘ́Й** (Ерикеев) Әхмәт Фазыл улы (16.12.1902, Уфа губ., Златоуст өязе Өлкенде а. — 15.9.1967, Мәскәү), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. 1920 елдан Уфа губернасы оешмаларында эшли. 1927 дә Мәскәүгә килә: Журналистика ин-тында укый, бер үк вакытта «Эшче», «Игенчеләр» г-талары, «Ударниклар» ж-лы редакцияләрендә эшли; СССР халыклары иҗат секторын һәм 1932 дән Гослитиздат каршында милли сектор оештыра. Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясе эшендә катнаша: җырлар, опералар өчен либретто текстлары яза, рус һәм чит ил опера әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1942 дән «За честь Родины» дигән фронт г-тасында мөхәррир урынбасары. 1945–50 дә ТАССР Язучылар берлеге рәисе. «Ташлы дулкыннар» исемле беренче китабы 1930 елда Мәскәүдә басыла. Е. — татар җыр поэзиясен башлап җибәрүчеләрнең берсе, С.Сәйдәшев, Р.Яхин, Җ.Фәйзи, А.Ключарёв, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, Н.Җиһанов көйләр язган, зур популярлык казанган 300 дән артык лирик җыр, романс текстлары авторы. Үз әсәрләрендә Е. мәхәббәткә, ирекле хезмәт романтикасына, туган як матурлыгына мәдхия җырлый. Табигый яңгырашлы, эчкерсез, ягымлы аһәңле шигырьләр — аның поэзиясенә хас сыйфатлар. Бөек Ватан сугышы елларында Е. вакытлы матбугатта фашист илбасарларына каршы көрәшкә өндәүче, дошманны җиңәргә рухландыручы шигырьләр яза. Көрәш темасын яктырткан «Сугыш җырлары» (1941) шигырьләр җыентыгы, сугыш геройлары турында «Салават Кәримов» (1943) һәм «Геннадий Гобәйдуллин» (1943) дигән очерклар авторы. Е.нең «Лирика» (1934), «Язгы җырлар» (1941), «Мәхәббәт җырлары» (1949; русчага тәрҗемәдә «О дружбе, о любви», М., 1955), «Судьбы и люди» (М., 1974), «Энҗе чәчәк» (1959; русчага тәрҗемәдә «Жемчужина», 1961), «Ике йөз җыр» (1982), «Җырланмаган әле безнең җыр» (2002) исемле шигырь җыентыклары укучыларга яхшы таныш. «Кечкенәләр өчен әкиятләр» (1938), «Нәниләргә шигырьләр» (1938), «Весенний гром» (1948; татарчага тәрҗемәдә «Язгы күкрәү», 1950) китаплары балаларга багышланган. А.Твардовскийның «Василий Тёркин» (1946) поэмасын татар теленә тәрҗемә итә. Рус композиторлары, шагыйрьләре, тәрҗемәчеләре б-н тыгыз элемтәдә яши. А.Шапорин, Н.Мясковский, С.Кац һ.б. композиторлар Е. сүзләренә романслар иҗат итә. Е.нең шигырьләре һәм поэмалары П.Васильев, П.Антокольский, С.Васильев, Д.Бедный, М.Исаковский, Б.Ахмадуллина, В.Рождественский, В.Тушнова, А.Жаров, В.Державин, С.Липкин, Е.Евтушенко, В.Ганиев тәрҗемәләрендә рус укучыларына да билгеле. 1946–54 елларда СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әсәрләр: Шигырьләр, җырлар. К., 1950; Сайланма әсәрләр: Поэмалар, шигырьләр, җырлар. К., 1971; Избранное: Стихи. М., 1982.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Әхмәт Ерикәй шигырьләре // Язучы һәм тормыш. К., 1979; С а ф и н Ф. Җырчы шагыйрь // Казан утлары. 1982. № 12; М и ң н у л л и н К. Ах, җырларым... // Ватаным Татарстан. 1993. 5 гыйн.; Х у с а и н М. Песенный взлёт // Советская Татария. 1982. 19 дек.

*В.Х.Ганиев.*



Ә. Ерикәй.



В.Ф. Ерин.

**Е́РИН** Виктор Фёдорович (17.1.1944, Казан), армия генералы (1993), РФ Герое (8.10.1993). Алабуга милиция махсус урта мәктәбен (1967), СССР Эчке эшләр министрлыгы югары мәктәбен (1973, Мәскәү) тәмамлый. 1964–83 елларда — ТАССР Эчке эшләр органнарында. Җинаятьчеләрне эзләү системасында оперуполномоченныйдан ТАССР Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе башлыгына кадәр хезмәт юлы уза. 1980–81 дә совет гаскәрләренең Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1983–88 дә — СССР Эчке эшләр министрлыгының Үзләштерүләргә каршы көрәш баш идарәсе башлыгы (Мәскәү). 1988–90 да — Әрмәнстан ССР эчке эшләр министры урынбасары. 1990 нан — РСФСР эчке эшләр министры урынбасары, 1 нче урынбасары. 1991 нең декабреннән — РСФСР дәүләт иминлеге һәм эчке эшләр министры урынбасары. 1992–95 тә РФ эчке эшләр министры, бер үк вакытта 1993 тән Россия Иминлек Советы әгъзасы. 1995 елдан РФ Тышкы разведка хезмәте директоры урынбасары. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* На страже порядка. К., 1997; Современная политическая история России (1985–1998 гг.). М., 1999. Т. 2.

**ЕРМАКО́В** Владимир Васильевич (23.7.1929, Саратов өлкәсенең Ивантеевка р-ны Ивантеевка а. — 13.1.1991, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Саратов а.х. механикалаштыру ин-тын тәмамлый (1952). 1952–53 елда Алексеев механикалаштыру уч-щесе укытучысы, 1953–56 да директоры, 1956–59 да Бөгелмә механикалаштыру уч-щесе директоры. 1959–60 та КПССның Бөгелмә шәһәр ком-ты секретаре, 1962–63 тә 1 нче секретаре, 1965–72 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1972–88 дә ТАССР Дәүләт планы ком-ты рәисе. Бер үк вакытта 1981–88 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1967–75 тә РСФСР, 1963–67 дә, 1976–90 да ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕРМАКО́В** Иван Иванович (8.9.1935, Тамбов өлкәсенең Лысогорск р-ны Горелое а.), ракеталар төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000), полковник (1975). Тамбов артиллерия уч-щесен (1954) һәм Ф.Э.Дзержинский исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1963) тәмамлый. Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә эшли, автоном идарә итү системалары каф. башлыгы (1975–90 да), укыту һәм фәнни эшләр буенча уч-ще башлыгы урынбасары (1985–90 да), махсус каф. профессоры (1990–95, 2001 дән), физика һәм механика каф. мөдире (1995–2001 дә), эл. җиһазлары каф. профессоры (2002 дән). Хезмәтләре команда үлчәү приборлары, автоном идарә итү системалары төзү һәм проектлаштыру мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы бар. 3 нче дәрәҗә «СССР Хәрби Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гироскопические устройства. М., 1968; Теория, конструкция и проектирование автономных систем управления: В 2 ч. М., 1979–89 (автордаш); Теория автоматического управления и элементы автоматики. М., 1983.

**ЕРМАКО́В** Фирдәүс Хәсән улы (21.3.1927, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), юл хәрәкәте иминлеген оештыру белгече, техник фән. д-ры (1999), проф. (1999), ТРның атказ. а.х. механизаторы (1995). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда Идел буе урман-техник ин-тын (Йошкар-Ола ш.), 1960 та Юристлар белемен күтәрү югары курсларының автотехник суд экспертлары бүлеген (Мәскәү) тәмамлый. 1952 дән ТАССР һәм Мари АССР урман хуҗалыкларында; 1959 дан РСФСР Юстиция министрлыгының Казан суд экспертизасы фәнни-тикшеренү лаб-ясендә; 1968–2008 дә Казан аграр ун-тында. Хезмәтләре юл хәрәкәтен оештыруга, анда катнашучыларның иминлеген һәм юл-транспорт һәлакәтләрен техник яктан тикшерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары проф. белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Зона повышенного внимания // Автомобильный транспорт. 1988. № 12; Организация безопасного дорожного движения на транспортных узлах и пешеходных переходах. К., 1991; Технические вопросы расследования дорожно-транспортных происшествий. К., 1996; Безопасность участников дорожного движения: совершенствование его организации и расследования ДТП. К., 2001.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Владимир Васильевич (18.12.1946, Уфа ш.), слесарь-инструментчы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1988). 1972 елдан «КамАЗ» ҖБнең «КамАЗ инструментспецмаш» з-дында бригадир булып

эшли. Дәүләт бүләге хезмәттәге алдынгы казанышлары һәм эшләп чыгарылган автомобильләрнең техник дәрәҗәсен күтәрүгә зур өлеш керткәне өчен бирелә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Владимир Михайлович (22.1.1931, Казан авыл р-нының Столбище а.), спортчы, тренер, судья (полиатлон), биш төр ярыш буенча СССРның спорт остасы (1962), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994), халыкара категорияле судья (1999). П.Ф.Лесгафт исем. Ленинград физкультура ин-ты каршындагы хәрби ф-тны тәмамлый (1958). Ветераннар арасында полиатлон буенча Россия (1990, 1992, 1996–98, 2000, 2002–03), дөнья (1992, 2001, 2003) чемпионы. Е.ның шәкертләре: Россия чемпионнары В.Я.Горовацкий (1971), Р.Х.Кәлимуллин (1972), хәрби-гамәли күп төр ярыш; Ә.Г.Сиразиев (1990), Л.М.Лыкина (1990), ветераннар арасында кышкы полиатлон; дөнья чемпионнары А.А.Шачнев (1999, 2003), ветераннар арасында кышкы полиатлон; СССР чемпионатларында көмеш медаль алучылар К.В.Корж (1970), ветераннар арасында хәрби-гамәли күп төр ярыш, Л.М.Лыкина (1990), ветераннар арасында ГТО буенча кышкы күп төр ярыш; дөнья чемпионы И.Р.Латыйпов (1998), ветераннар арасында кышкы полиатлон. 1950–79 елларда хәрби хезмәткәр, 1980 елдан Казан техник ун-тының физик тәрбия һәм спорт кафедрасында укытучы, проф. (1999). Фәнни һәм методик уку-укыту ярдәмлекләре авторы. 1999 елдан Халыкара полиатлон ассоциациясенең спорт-техник комиссиясе рәисе.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Дмитрий Сергеевич (28.3.1843, С.-Петербург — 21.10.1894, Казан), анатом, мед. д-ры (1872). 1867 елда С.-Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1872–91 елларда Казан ун-ты профессоры, анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре кешенең аяк табаны төзелешен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О синовиальных влагалищах мышц стопы. СПб., 1872.

*Әд.:* Казанский медицинский институт 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Игорь Петрович (2.4.1932, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1983), проф. (1986), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994), РФнең атказ. югары мәктәбе хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), шунда ук эшли, 1973–80 елларда проректор, 1989–99 да 20 йөзгә кадәрге ватан тарихы каф. мөдире. Бер үк вакытта Казан Яшь тамашачылар театрының әдәби бүлек мөдире (1959), Казан телевидение студиясе режиссёры (1962–64). Хезмәтләре Россиянең һәм Урта Идел буеның 16–18 йөзләрдәге сәяси-социаль һәм соц.-икътисади тарихын һәм тарихи хронологиясен өйрәнүгә карый. Аның катнашында «Рус Хакыйкате» («Русская Правда», 1959, 3 басма, 1985), «СССР тарихы» («История СССР», 1971), «Иң борынгы заманнардан алып 19 йөз ахырына кадәр ватан тарихы» («Отечественная история с древнейших времен до конца 19 в.», 1996), «Россия тарихы» («История России», т. 1–2, 1997–98) һ.б. уку әсбаблары әзерләнә. 3 нче дәрәҗә Изге Даниил ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Ч е р н о б а е в А.А. Историки России. Саратов, 1998; В кругу учеников, коллег, друзей: К 70-летию И.П.Ермолаева. К., 2002; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Men of achievement. Camb., 1995.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Олег Петрович (20.1.1957, Биектау р-ны Семиозёрка а.), геогр. фән. д-ры (2001), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли, ландшафт экологиясе каф. мөдире (1999–2008). Хезмәтләре геоморфология һәм ландшафт экологиясе мәсьәләләренә карый. Рус тигезлегенең көнчыгышы мисалында бассейннар эрозиясе структурасын билгели. Урта Идел һәм ТРның ландшафтлы районлаштыру схемасын төзи. ТР ландшафтларына тулы тасвирлама бирә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004).

Х е з м.: Пояса эрозии в природно-антропогенных ландшафтах речных бассейнов. К., 1992; Электронное атласное картографирование как инструмент реализации парадигмы устойчивого развития // Вест. Татарстанского отд-ния Рос. экол. акад. 2000. № 3; Эрозия в бассейновых геосистемах. К., 2003.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Сергей Михайлович (5.10.1932, Горький өлкәсенең Арзамас р-ны Криуша а.), эшче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1990). 1955–98 елларда «Казан вертолёт заводы» ҖБдә (1994 тән АҖ) пресс машинисты, очкыч аппаратларның детальләрен эшләүче слесарь. Аның тырышлыгы б-н пр-тиедә хезмәтне оештыруда бригада формасы булдырыла — 1957 дән пресс машинистлары бригадасын җитәкли. Дәүләт бүләге хезмәттә, машина һәм механизмнарның техник дәрәҗәсен күтәрү һәм сыйфатын яхшыртуда күрсәткән казанышлары өчен бирелә. «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕРМОЛА́ЕВ** Юрий Петрович (27.5.1928, Казакъстан ССРның Аральск ш. — 23.1.2007, Казан), радиоэлектроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1975), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (1997). 1950 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, радиоэлектрон аппаратуралар җитештерү (1970–76), микроэлектрон һәм радиоэлектрон аппаратуралар төзү (1976–86), микроэлектрон аппаратуралар төзү һәм җитештерү (1986–92) кафедралары мөдире; проф. (1992 дән), бер үк вакытта микроэлектрониканың проблемалы лаб-ясе фәнни җитәкчесе (1963–99). Хезмәтләре радиоэлектрон чараларны проектлаштыру һәм җитештерүгә карый. Микросхемаларның интеграль технология буенча эшләнә торган плёнкалы элементлары төгәллеген һәм тотрыклылыгын корреляцияләү теориясен төзи. Электрон аппаратураны оптимальләштерүнең күп критерийле ысулын тасвирлый. Радиоэлектрон аппаратураның техник-икътисади сыйфатламаларын фаразлаганда векторлы һәм корреляцион анализ ысулларын тикшерә. Е. хезмәтләре оборона сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Конструкция и технология микросхем. М., 1980 (автордаш).

*Әд.:* Ю.П.Ермолаев // Электронное приборостроение. 1998. № 6.

**ЕРМОЛА́ЕВА И.В. ҺӘМ АНЫ́Ң ДӘВАМЧЫЛАРЫ́ БАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Басмаханә 1906 елның 9 мартында Ермолаевага аның этисе В.М.Ключниковтан күчә. Шул ук елның апрелендә аның составына Казан сәүдәгәре А.М.Петровтан Ермолаеваның ире сатып алган басмаханә дә керә. Басмаханәнең хуҗалары — Инна Вениаминовна һәм Сергей Степанович Ермолаевлар сәясәттә сул карашлар тарафдарлары һәм хакимияткә карата оппозициядә булалар.

1905–07 елгы рев-ция дулкынында, цензура булмаган 1906 елда һәм 1907 нең башында басмаханәдә сул юнәлештәге «Волжский вестник», «Волжский курьер», «Волжский листок», «Метеор», «Крестьянская газета», «Таң йолдызы» г-талары басыла; татар телендә с. -д. юнәлештә 15 брошюра, ш.и. «Халык җилкәсендәге түләүләр»; рус телендә педагогика һәм медицинадан хезмәтләр: А.Воскресенскийның «Букәй мәктәпләре турында язмалар» («Заметки о букеевских школах»), «Хасталар б-н әңгәмә» («Беседа с больными») һ.б. чыгарыла.

Реакция көчәю һәм цензура кертелү сәбәпле, 1907 дә рәсми рәвештә с. -д. әдәбият чыгару туктатыла. Басмаханә дәреслекләр, сүзлекләр, календарьлар, татар (Ф.Халиди, К.Бикколов), рус (Л.Толстой, А.Чехов), чит ил (К.Дойл, Ж.Верн) язучыларының әсәрләрен, философия буенча хезмәтләр, ш.у. татар телендә дини китаплар чыгара башлый.

Басмаханәдә 300 мең данә тираж б-н чыккан 70 исемдәге китапның 40 ка якынын «Мәгариф» нәшрияты, калганнарын «Идрисов, Галиев һәм К°», «Китаб» нәшриятлары, С.Сканов, Х.Әбүзәров, Г.Кильдешев, Г.Рәхмәтуллин һ.б. наширләр чыгара. Кайбер басмалары хакимияткә каршы булганлыктан, китап басу эшчәнлегенең башыннан ук И.В. һәм С.С. Ермолаевлар рәсми хакимият тарафыннан эзәрлекләнә. Шул сәбәпле, 1909 ның апрелендә басмаханә ябыла һәм шул ук елда нәселдән килгән дворян Н.М.Чижова мөлкәтенә күчә. Ул элеккеге хуҗабикә эшчәнлеген дәвам иттерә: басмаханәдә Ермолаева кабул иткән заказлар басыла, төп заказчы булып «Мәгариф» нәшрияты сакланып кала. 1909–10 елларда татар телендә 140500 данә гомуми тираж б-н 37 басма чыга; шуларның яртысыннан күбрәге «Мәгариф» нәшрияты заказлары, ш.и. К.Насыйриның «Буш вакыт»ының 4 чыгарылышы, И.Богдановның «Югалган хатын» комедиясе, К.Бикколовның балалар өчен хикәяләре, балалар календарьлары, дәреслекләр була. Басмаханәдә ш.у. Ф.Халиди, Х.Әбүзәров, С.Ю.Саинов, М.Сами, Ә.Биктимеров әсәрләре, нашир Ш.Хөсәенов варислары, Ключников китап кибете хуҗалары үз китапларын бастыралар.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Из истории татарской дореволюционной книги // Здравствуй, книга! К., 1989.

**ЕРМО́ЛЕНКО** Виктор Степанович (27.7.1956, Алма-Ата өлкәсенең Талгар ш.), спортчы (парашют спорты), СССРның халыкара классльы спорт остасы (1985). 1974 елдан Казанда яши. Казан аэроклубында тәрбияләнә. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1981). 1981–99 елларда СССР, РФ җыелма командалары әгъзасы. СССР чемпионатында (1981–90), халыкара ярышларда (1985, 1988, 1990, 1995) чемпион. Парашют б-н җиргә төгәл төшү өчен сикерү (төнлә, көндез) ярышларында дөнья рекордчысы (1985–86). 8 меңнән артык сикереш ясый. 1981–91 дә Казан ДОСААФ укыту-авиация үзәгендә инструктор, 1991 дән оча торган «МВЕН» аппаратларының парашют-коткару системаларын җитештерү пр-тиесендә техник директор, бер үк вакытта 1992 дән ТР Парашют спорты федерациясе рәисе (2002 елдан ТР Авиация спорты федерациясе президенты). Парашют-коткару системалары өлкәсендә уйлап табулар авторы.

**ЕРМО́ЛОВКА** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 21 *км* көньяктарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2008 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорыннан Кече Норма авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Страховка исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да су тегермәне, икмәк саклау-сату амбары, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 511 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 30 ир-ат; 1859 да — 324, 1897 дә — 415, 1908 дә — 421, 1920 дә — 373, 1926 да — 451, 1938 дә — 358, 1949 да — 228, 1958 дә — 228, 1970 тә — 158, 1979 да — 120, 1989 да — 71, 2002 дә — 52 кеше.

**ЕРМО́ШКИН** Аркадий Сидорович (11.7.1930, Октябрь, хәзерге Нурлат р-ны Якушкино а. — 13.1.2004, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1952 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. Красноярск шәһәрендәге оборона пр-тиеләрендә эшли. 1954–62 елларда В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында. 1962 дән Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында: баш инженер, директор урынбасары (1967 дән), лаб. мөдире (1984 тән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1997– 2002 дә). Хезмәтләре катлаулы порошоклы-җепселле суспензияләр агышына карый. Катлаулы суспензияләр агышының теориясен төзи, бу исә целлюлозаның нитрокалдыкларын кабат эшкәртү технологиясен тамырдан үзгәртү мөмкинлеге бирә. Тармак пр-тиеләрендә шарсыман продукцияне яңача җитештерүне гамәлгә керткәне, Соликамскидагы «Урал» з-дында объект проектлаштырганы һәм төзегәнe өчен СССР МС бүләге (1982), яңа буын ату коралларына һәм кече калибрлы артиллерия системаларына бер нигезле шарсыман дары эшләгәне һәм җитештерүне гамәлгә керткәне өчен РФ Дәүләт бүләге (1996) бирелә. 320 ләп фәнни хезмәт авторы.

*Әд.:* З а б е л и н Л.В. В а л е е в Г.Г. Аркадий Сидорович Ермошкин // Из истории отечественной пороховой промышленности. М., 2003; Выпускники — гордость технологического университета: КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЕРО́В** Юрий Васильевич (17.10.1950, Куйбышев, хәзерге Спас р-ны Полянки а.), галим-агроном, а.х. фән. канд., ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2000), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Тәтеш совхоз-техникумын (1970), Казан а.х. ин-тын (1988) тәмамлый. 1970–72 елда Әлмәт р-нының «Уңыш» к-зында өлкән агроном, 1972 дә «Полянский» с-зы агрономы, 1973–79 да Куйбышев р-нының «Антоновский» с-зында бүлек управляющие. 1979–82 дә терлек азыгы җитештерү буенча директор урынбасары, 1982–84 тә Питрәч р-нының «Ленино-Кокушкино» с-зында баш агроном. 1984–88 дә ТАССР а.х. министрлыгында, Агросәнәгать ком-тында: игенчелектәге гомуми мәсьәләләр бүлегендә баш агроном, 1985–86 да министр урынбасары, 1986–88 дә ком-т рәисе урынбасары. 1988 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты а.х. һәм азык сәнәгате бүлеге мөдире урынбасары, 1988–90 да КПССның Куйбышев райкомы 1 нче секретаре, 1990–92 дә халык депутатларының район советы рәисе. 1992–95 тә Спас р-ны хакимияте башлыгы. 1995 тән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: җитештерү буенча директор урынбасары, бер үк вакытта «Элитные семена Татарстана» ассоциациясендә ген. директор (2000 нән). 1990–95 елларда ТР ЮС депутаты. Дәүләт бүләге «Фәнни дәлилләнгән система нигезендә уҗым арышының югары продуктив сортларын булдыру һәм тиз арада җитештерүгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**ЕРО́ШИНА** (кыз фамилиясе Нургаева) Радия Нури кызы (17.9.1930, Ижевск ш.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1958). Спорт б-н Ижевск механика з-ды физкультура коллективында 1948 елда шөгыльләнә башлый, тренеры — Н.И.Замастьянов. 1955 тә (ярыш, 10 *км*), 1957 дә (ярыш, 5, 10 *км*), 1959 да (ярыш, 5 *км*) СССР, 1958 дә (эстафета, 4×5 *км*) дөнья чемпионы. 1956 да Олимпия уеннарында (ярыш, 10 *км*), (эстафета, 4×5 *км*), 1960 (эстафета, 4×5 *км*) көмеш медаль ала. 1962 елгы дөнья чемпионатында (ярыш, 10 *км*), Олимпия уеннарында (1960, ярыш, 10 *км*) бронза медаль ала. 1944 елга кадәр — Минзәлә р-нында, 1952 гә кадәр Ижевскида, 1952 дән Мәскәүдә яши. 1960 еллардан тренер-укытучы. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ЕРСУБА́Й** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 55 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Баграж суы буенда. 2008 елда 544 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Баграж, Ярсубаево, Баграж исемнәре б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, йон тетү, тегүчелек, аучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Е.да волость идарәсе урнаша, Казан Мәрьям Ана чиркәве (1886 да Алабуга хәйрия ком-ты ярдәме б-н төзелә), Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 2 су тегермәне, 2 икмәк саклау-сату кибете һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1664,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1722 дә — 13, 1747 дә — 41, 1782 дә — 96 ир-ат; 1795 тә — 241, 1859 да — 398, 1870 тә — 489, 1897 дә — 676, 1912 дә — 894, 1920 дә — 895, 1926 да — 691, 1938 дә — 683, 1949 да — 700, 1958 дә — 670, 1970 тә — 773, 1979 да — 657, 1989 да — 477, 2002 дә — 530 кеше.

**ЕРШО́В** Андрей Николаевич (8.2.1955, Казан), социолог, социология фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан ун-тын (1979), Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1983). 1978–89 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында (бүленеп, 1985–86 да — ВЛКСМ ҮКдә) эшли. 1989–91 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инспекторы. 1991–92 дә РМАнең Махсус урта белем ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре, 1992–97 дә ТР Президенты аппаратында өлкән референт. 1997–2001 дә ТР Дәүләт хезмәткәрләре белемен күтәрү респ-ка үзәге директоры булып эшли. 2001 дән ТР Президенты каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә академиясе ректоры. Хезмәтләре җирле үзидарә проблемаларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Социально-экономические проблемы развития местной промышленности. К., 1984; Становление местного самоуправления в современных условиях (опыт социологического исследования). М., 1999; Социальные ресурсы местного самоуправления (опыт социологического анализа в Республике Татарстан). К., 2001.

**ЕРШО́В** Николай Евгеньевич (20.1.1892, Воронеж губ., Новохопёрск өязе Дмитриевка а. — 5.1.1928, Мәскәү), 1917 елның октябрь-ноябрендә Казанда Октябрь кораллы баш күтәрелеше җитәкчеләренең берсе. Саратов коммерция уч-щесен тәмамлаганнан соң, 1914 тә Мәскәү коммерция ин-тына укырга керә. 1916 да Россия армиясенә алына, Мәскәүдә пехота прапорщиклары әзерләүче 2 нче мәктәпне тәмамлый, Петроград гарнизонының 1 нче запас пулемёт полкына җибәрелә. 1917 нең июлендә полк таратылгач, Казанга 2 нче запас артиллерия бригадасына җибәрелә. 1917 нең сентябренә кадәр сул эсерлар



Р.В.Ерыгин.

партиясе тарафдары була, сентябрьдән РСДРП(б) әгъзасы. Сентябрь ахырыннан РСДРП(б)ның Казан ком-ты каршындагы хәрби оешманы җитәкли. 24–26 октябрьдә Казанда Кораллы баш күтәрү рев-ция штабы рәисе. 26 октябрьдә Казан хәрби округы гаскәрләре командующие итеп билгеләнә. Казан хәрби округының 2 нче съезды тарафыннан 1917 нең ноябрендә атаман А.И.Дутов фетнәсен бастыру өчен Омск шәһәренә җибәрелә. 1918 дә Советларның Себер ҮБК әгъзасы, Себер гадәттән тыш комиссия коллегиясе, Байкал арьягы хәрби-революцион штабы әгъзасы. 1918 нең ахырыннан Ерак Көнчыгышта партизаннар хәрәкәтендә катнаша, 1919 да Благовещенск шәһәрендә кораллы баш күтәрүне әзерләгән җитәкчеләрнең берсе, 1920–21 дә партизаннар полкы командиры. Соңрак Мәскәүдә һәм Петроградта хуҗалык эшендә. 1923 тән ОГПУ органнарында.

*Әд.:* Х а н и н Л. Ершов Николай Евгеньевич // Борцы за счастье народное. К., 1967; И о н е н к о С.И. Николай Ершов. К., 1987.

*С.И.Ионенко.*

**ЕРШО́В** Пётр Андреевич (1879, Вятка губ., Яран өязе Заозерье а. — ?), җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. Казанда 1896 елдан, Казан дары з-дында сызымчы булып эшли. Казан губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасында депутат, җавап адресы язу һәм дәүләт язуларын башкару комиссияләре әгъзасы; Думада җыеннар үткәрү ирege турында чыгыш ясый. Социал-демократлар мәсләген яклый (меньшевик). 1906 ның июлендә хөкүмәткә каршы *Выборг өндәмәсенә* кул куя. Полициянең яшерен күзәтүе астында яши. Окт. рев-циясеннән соң кооператив рәисе. 1921 нең сентябрендә Ачларга ярдәм күрсәтү ком-тының яшерен җыенын җыю өчен кулга алына, эше Гадәттән тыш коллегия тарафыннан каралгач азат ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

Ә с ә р.: Химики в 1905 году // Пролетарий Татарстана. 1925. № 11.

*Әд.:* Члены первой Государственной Думы. М., 1906; Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2002. Т. 5; У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной Думе России. 1906–1917. К., 2006.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЕРШО́В** Пётр Павлович (22.2.1815, Тобол губ., Ишем өязе Безруково а. — 18.8.1869, Тобол ш.), шагыйрь. Петербург ун-тын тәмамлый (1834). 1836 елдан Тобол шәһәрендә яши. Гимназиядә укытучы, инспектор, директор булып эшли. Язучы буларак Е.ны «Канатлы ат» («Конёк-горбунок», 1984) исемле әкияте таныта. Е. Себер халыклары, ш.и. Себер татарлары фольклорын өйрәнә; фольклор әсәрләренә нигезләнеп, әдәби әсәрләр яза. 1838 дә С.-Петербургта «Современник» ж-лында басылган «Сүзге» поэмасы нигезендә Урта Иртеш татарларының Себер ханы Күчүмнең икенче хатыны турындагы легендасы ята. В.Г.Белинский поэмага уңай бәя бирә. 1896 да Тобол композиторы И.Е.Корнилов поэма сюжетына «Сүзге» операсын яза. 1920 дә шул ук сюжетка Е.Г.Маляревский драма иҗат итә, ул һәвәскәр һәм проф. сәхнәләрдә куела. 1940 та поэма татар теленә тәрҗемә ителә. Е.ның Себер татарлары риваятьләренә нигезләнеп язылган хикәяләрендә фольклорның әзенчәлекле стиле һәм теле уңышлы файдаланыла. «Тимерче Бәзим, яхуд Зирәк ярлы» («Кузнец Базим, или Прозорливость бедняка») пьесасы үзәгендә — прототибы җирле татар тимерчесе булган булдыклы кеше образы сурәтләнә.

Ә с ә р.: Сочинения. Омск, 1950; Сузге. Иркутск, 1984.

*А.С.Иванов.*

**ЕРЫ́ГИН** Роман Владимирович (9.11.1960, Курск ш.), драма актёры. ТРның халык артисты (2002). Курск өлкә драма театры каршындагы студияне һәм бер үк вакытта Курск пед. ин-тын тәмамлый (1981). 1976–88 елларда Курск, 1988–89 да Орёл өлкә драма театрында, 1989 дан Казан Яшь тамашачылар театрында эшли. Сәхнә персонажының эчке дөньясы логикасын җентекле рәвештә төзүе, үз героен гәүдәләндергәндә тышкы чараларны (грим, костюм) аз гына кулланып та, тиешле максатка ирешүе аңа Казан Яшь тамашачылар театрында шактый күркәм образлар тудырырга ярдәм итә. Алар арасында Мой-Сей («Тар-мар итү», Б.Л.Васильев повесте буенча), Ян Сун («Сычуаньнан килгән мәрхәмәтле кеше», Б.Брехт), Просперо һәм Антонио («Давыл», У.Шекспир), Гильденстерн («Розенкранц һәм Гильденстерн вафат», Т.Стоппард), Войницкий («Ваня абзый», А.П.Чехов), Утешительный («Уенчылар», Н.В.Гоголь) образлары бар. Актёрның Роман («Качучы юлаучылар», А.Н. Казанцев), Утешительный («Уенчылар», Н.В.Гоголь) рольләре зур осталык б-н башкарылулары, социаль-психол. анализ тирәнлеге б-н аерылып торалар. Е. режиссёр буларак үз композицияләрен дә куя: «МТ 1/2, яки надан, мәгънәсез адәмнәр төркеме әкиятләре» — «МТ 1/2, или сказки тупой, бессмысленной толпы», (А.С.Пушкин әсәрләре буенча, 1999), кече залда — «Өлкәннәр өчен уик-энд» — «Уик-Энд для взрослых» (Т.Уильямс әсәрләре буенча, 1998) һәм «Бик сәер кешеләр» (А.де Сент-Экзюпериның «Кечкенә принц» — «Маленький принц» аллегорик әкияте буенча, 1999); соңгы спектакль Бөтенроссия театр фестивалендә тәкъдим ителә (Самара, 2002). «Эфир» Телекомпаниясендә «Шәһәр» («Город») программасын алып бара (2003 тән).



Р.В.Е р ы г и н  Утешительный ролендә («Уенчылар», Н.В.Гоголь).

**ЕРЫКЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында. Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 9 *км*, бассейнының мәйданы 37,2 $км^2$. Елга башы Самара өлкәсендә, тамагы Лениногорск р-нының Туктар Урдалысы авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагыныкы — 122 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 32%. Е.ның 0,6 дан 3 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә бераз гына арта. Җир асты туену модуле 3–5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 142 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЕРЫКЛЫ́ СУЫ́**, Көнбатыш Кама арьягында. Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,3 *км*, бассейнының мәйданы 62,3 $км^2$. Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Самара өлкәсе чигендә, Фома авылыннан 1,5 *км* ераклыкта, тамагы Чулпан авылы янында. Елга башының абс. биеклеге — 130 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу терр-ясендә урман үсемлекләре юк. Е.С.ның 2,9 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$ га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Гадәттә, плёслы күлләр системасына бүленеп, җәен елга кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу агымы катламы 85 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЕРЫКСА́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Бужай елгасының уң кушылдыгы (Туйма, Кама елгалары бассейны). Озынлыгы 22,4 *км*, ТР чикләрендә 6,2 *км*. Бассейнының мәйданы 191,2 $км^2$. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Менделеев р-нының Камай авылыннан 1,6 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 14%. Елганың 2 дән алып 18,4 *км* га кадәр

озынлыктагы 9 кушылдыгы бар, иң зурысы — Кокшан суы елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км²* га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 144 *мм*, ташу агымы катламы 117 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЕРЫМНА́Р**, текә сөзәклекләрдә яңгыр һәм кар сулары эрозиясе эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килүче ерганаклар. Озынлыгы уннарча метрдан берничә километрга кадәр, тирәнлеге берничә дистә метрга җитә. Җимерелү, ишелү, убылу нәтиҗәсендә үсә баручы ялан текә битләүләрдән гыйбарәт. Төпләре, гадәттә, тар була. Үсеш барышында Е. берничә стадия үтә: тирән булмаган ерганактан битләүләрнең үсеше туктаганга һәм аларның үсемлекләр б-н каплануына кадәр һәм шулай сызага әверелүе. Аларны беренчел (битләүне беренче тапкыр кисеп узучы) һәм икенчел яки төптәге (сыза һәм уйсулык төпләренә уеп кергәннәр) Е.га бүлеп йөртәләр. Е. дала һәм урман-дала зоналары өчен типик күренеш. Аларның үсеше, нигездә, урманнарның бетерелүе һәм җирләрне сукалауга бәйле. Е. челтәренең тыгызлыгы һәм Е. үсү тизлеге битләүләрнең озынлыгы һәм текәлегенә, тау токымнары һәм туфракның составына һәм үзлекләренә бәйле.

Татарстан терр-ясендә ерым эрозиясе шактый киң таралыш алган. Е.ның уртача тыгызлыгы 0,23 *км/км²* тәшкил итә, иң гади елга бассейннары буенча 2,5 *км/км²* га кадәр җитә. Идел алды төбәге ерым эрозиясенә бигрәк тә нык дучар ителгән (уртача тыгызлыгы 0,38 *км/км²*), чөнки аңа текә сөзәклекләрнең күп булуы, урманнарның азлыгы, эрозиягә бирелүчән балчыксыл токымнарның киң таралуы хас. Кама Тамагы һәм Югары Ослан р-ннарында Е. челтәре аеруча тыгыз. Ерымнар челтәре тыгызлыгының шуңа якын зурлыклары Кама алдында билгеләнә — көнбатышта 0,36 *км/км²* һәм көнчыгышта 0,4 *км/км²*, иң зуры — Алабуга һәм Балык Бистәсе р-нnarында. Кама аръягы, аеруча аның көнбатыш өлешендәге түбәнлек (0,1 *км/км²* дан күп түгел) Е.ның аз булуы б-н аерылып тора. Көнчыгыш Кама аръягында иң зур абс. биеклекләр булуга карамастан, ерым челтәренең тыгызлыгы зур түгел (0,12 *км/км²*), бу исә эрозиягә чыдам тау токымнарының (тыгыз известьташлар, доломитлар) киң таралуы, терр-янең шактый урманлы булуы б-н аңлатыла. Барлык Е.ның өчтән ике өлешенә якыны икенчел, аларда кар һәм яңгыр сулары туплана. Е.ның шактый өлешендә (өчтән береннән дә ким булмаган) үсеш тукталган. Е. үсешенең уртача еллык тизлеге каты токымнарда берничә дециметр



Көрнәле елгасы үзәненең уңъяк битләвендә зурая баручы ерым.

һәм метрдан алып көпшәк токымнарда уннарча метрга кадәр җитә.

Е. үсеше халык хуҗалыгының төрле тармакларына, аеруча игенчелеккә зур зыян китерә. Аңа каршы көрәштә саклаучы урманнар утырту, туфракны рельеф үзенчәлекләрен исәпкә алып эшкәртү, ныгыту һ.б. чаралар ярдәмендә алып барыла.

*Әд.:* Овражная эрозия востока Русской равнины. К., 1990.

*А.П.Дедков.*

**ЕСАУ́ЛОВА** Наталия Константиновна (20.11.1948, Казан — 16.7.2003, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1998), ТР-ның атказ. геологы (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук эшли, 1997 дән гомуми геология һәм гидрогеология каф. мөдире. Флора һәм фауна буенча (ш.и. конодонт һәм аммонит) Идел-Урал өлкәсенең югары Пермь схемасын төзүчеләрнең берсе. Россия ведомствоара стратиграфика ком-тының бюро әгъзасы (1997 дән), стратиграфия подкомиссиясе әгъзасы (1997 дән) һәм палеозой флорасы буенча Халыкара геологик конгрессның подкомиссия әгъзасы (1997 дән).

Х е з м.: Флора казанского яруса Прикамья. К., 1986; Комплексная характеристика верхнепермских стратотипов Волго-Уральского бассейна. К., 1991; Новые виды папоротников из казанских отложений Прикамья // Палеонтологический журн. 1996. № 4.

**ЕСЕЛЕ́ВИЧ** Ирина Эдуардовна (17.5.1934, Мәскәү — 13.12.1992, Ижевск ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1980), проф. (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), Чипья авылында (Удмурт АССР) урта мәктәптә укыта. 1960–80 елларда Казан ун-тында, рус теле каф. мөдире (1974–79). 1980 нән Удмурт ун-тында. Хезмәтләре тарихи фонетика, морфология, сүз ясалышы, язу тарихы, рус теле лексикографиясе, иске славян теле фонетикасына карый; 11–14 йөз борынгы рус пергамент кулъязмаларының һәм алардагы өстәмә язмаларның телен өйрәнә.

Х е з м.: Закон открытого слога и его отражение в старославянском языке. К., 1970; Из истории категории собирательности в русском языке. К., 1979; Историческая грамматика русского языка. Фонетика. К., 1981.

*Әд.:* Памяти Ирины Эдуардовны Еселевич // Вестн. Удмурт. ун-та. 1993. № 4.

*Г.А.Николаев.*

**Е́СИПОВ** Анатолий Викторович (1.2.1952, Лениногорск ш.), инженер-электромеханик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1982). 1973–78 елларда «Союзнефтеавтоматика» берләшмәсе «Средневолжскнефтеавтоматика» трестының Лениногорск монтажлау-көйләү идарәсендә инженер. 1978–92 дә Лениногорск шәһәрендә хакимият-хуҗалык һәм партия эшендә. 1992 дән «Силен» фирмасы» ҖЧҖ (Лениногорск) директоры, 1999 дан ген. директоры. Уйлап табуга 9 патенты бар. Дәүләт бүләге аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүдә яңа термо-имплозион һәм перфорацион-имплозион экспресс-технологияләр эшләгәне һәм киң масштабта гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Экспресс-технология добычи нефти // Научный Татарстан. 1997. № 2 (автордаш).

**Е́СИПОВ** Павел Петрович (1768 — 4.7.1814, Казан), алпавыт, антрепренёр. Казан губернасы, Зөя өязе Юматовка авылындагы утарында крепостной театр тота. 1798 елда, Казанга император Павел I килүеннән файдаланып, Казанда махсус бина төзү шарты б-н халык өчен ачык шәһәр театры оештырырга рөхсәт бирүләрен сорый. 1802 дә С.-Петербургтагы Император театрлары дирекциясеннән рәсми рөхсәт алуга ирешә һәм театр бинасын төзү эшенә керешә. Казанда Попов тавында үзенең шәхси йорты булса да, ул театрда яши. «Казанские известия» г-тасының 1814 елгы 1 август санында «г. Есипов, театр сөюче һәм аның белгече буларак, аны төзү һәм торгызу өчен бер нәрсәсен дә кызганмый», — дип язылa. Театр салу аркасында бөлгенлеккә төшкәч, Е. 1810 елда, театрны тоту өчен субсидия (акчалата ярдәм) бүлеп бирүләрен сорап, Казан губернаторы Б.А.Мансуровка мөрәҗәгать итә, ләкин аның үтенече кире кагыла. Ш.у.к. *Есипов театры.*

**Е́СИПОВ ТЕА́ТРЫ** (1802–14), Казанда халык өчен ачык театр. Казан алпавыты П.П.*Есипов* тарафыннан оештырыла. Ул үз акчасына шәһәр уртасында (хәзер биредә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты бинасы) таш нигезгә агачтан бина салдыра. Труппада Есиповның крепостной актёрлары һәм ялланып эшләүчеләр (М. һәм Ф.Аникиевлар, М.Калмыков, А.Комякова, Н.Комяков, Ф.Львов, Волков, Грузинов, Прытков, Расторгуев) була. Труппа каршында комп. А.В.Новиков җитәкчелегендә оркестр эшли. Е.т. сәхнәсендә А.П.Сумароков («Ялган Дмитрий» — «Дмитрий Самозванец», «Мода колы» — «Модник»), В.А.Озеров («Фингал», «Эдип Афинада»), Я.Б.Княжнин («Бал ширбәте коючы» — «Сбитенщик», «Рослав», «Тит шәфкатьлелеге» — «Титово милосердие»), Д.И.Фонвизин («Җитлекмәгән егет» — «Недоросль»), Вольтер («Мөхәммәт» — «Магомет»), А.Коцебу («Наумбург янында гуситлар» — «Гуситы под Наумбургом», «Мәхәббәт җимеше» — «Сын любви», «Граф Вальтрон») пьесалары һәм А.О.Аблесимовның («Тегермәнче — сихерче, ялганчы һәм яучы» — «Мельник — колдун, обманщик и сват»), М.А.Матинскийның («Санкт-Петербург кунакханәсе» — «Санкт-Петербургский гостиный двор»), В.Мартин-и-Солерның («Сирәк очрый тор-



Валентин В. Ефимов.



Владимир В. Ефимов



А.Е. Ефремов.

ган әйбер» — «Редкая вещь», «Җыр ярату» — «Песнолюбие») комик опералары һ.б. куела. 1805 тә Е.т. труппасында актёр һәм драматург П.А.Плавильщиков чыгышлар ясый. Ул Казан сәхнәсендә үзенең «Ялгызак» («Бобыль») һәм «Ермак» пьесаларын куя һәм шуның б-н театр актёрларының башкару осталыгын үстерүгә шактый зур йогынты ясый. Замандашлары фикеренчә, Есипов үз театрын «шундый дәрәҗәгә күтәрә ки — театр бары башкала театрларыннан гына калышкандыр». («Казанские губернские ведомости», 1849, № 40). Есипов үлгәннән соң, труппа берникадәр вакыт спектакльләр куя да таркала. 1815 елда Е.т. бинасы сатыла һәм сүтелә.

*Әд.:* А к с а к о в С.Т. Воспоминания // Собр. соч. СПб., 1909. Т. 3; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958.

**ЕФА́НОВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 13 *км* көньяктарак. Дала Зәенең уң кушылдыгы Зәй елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 157 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1828 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Ефановка исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 805 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 220, 1889 да — 194, 1920 дә — 509, 1926 да — 556, 1938 дә — 508, 1949 да — 523, 1958 дә — 399, 1970 тә — 397, 1979 да — 326, 1989 да — 240, 2002 дә — 166 кеше.

**ЕФА́НОВКА** т и м е р  ю л  р а з ъ е з д ы  п о с ё л о г ы, Бөгелмә шәһәреннән 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2008 елда 14 кеше (руслар) яши. 1950 елларда нигез салына. Халык саны: 1970 тә — 34, 1979 да — 20, 2002 дә — 7 кеше.

**ЕФИ́МОВ** Валентин Владимирович (7.11.1916, Сембер губ., Буа өязе Кыят а. — 10.11.1981, Казан), зоотехник, Соц. Хезмәт Герое (1966), ТАССРның атказ. зоотехнигы (1966). Сура зоотехника техникумын (Куйбышев өлкәсе, 1939) тәмамлый. 1946–73 елларда Октябрь (хәзерге Нурлат) р-нының «Төрнәс» с-зында зоотехник, баш зоотехник. 1973 тән Татарстан нәселле терлек хуҗалыклары трестында өлкән зоотехник. Е. җитәкчелегендә нәселле терлекләр: Бестужев токымлы мөгезле эре терлек, эре ак токымлы дуңгыз көтүләре, нәселле атлар дәүләт конюшнясы булдырыла. Герой исеме терлекчелекне үстерүдә, сөт, ит, йомырка, йон һ.б. а.х. продукциясе җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ф а с а х о в К. Ефимов Валентин Владимирович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЕФИ́МОВ** Владимир Васильевич (9.6.1936, Украина ССРның Житомир өлкәсе, Базар р-ны Базар а.), технолог, машиналар гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1989), ТР ФА акад. (2000), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997), Ульянов өлкәсенең мактаулы гражданы (2001). 1960 елда Ленинград хәрби-механика ин-тын тәмамлаганнан соң, Красноярск машиналар төзү з-дында баш технолог булып эшли. 1973 тән Ульянов техник ин-тында, 1979 дан проректор, 1989–2000 дә ректор, Өстәмә һөнәри белем бирү үзәге директоры (2002 дән), сыйфат б-н идарә итү каф. мөдире (2002 дән). ТР ФАнең Ульянов региональ бүлеге рәисе (2000 нән). Хезмәтләре материалларны механик рәвештә һәм әзерләнмәләрне төркемләп эшкәртү процессларын һәм машиналар төзү продукциясенең сыйфатын тикшерүгә карый. Майлау-суыту сыекчаларының материалларны микрокисү процессына тәэсир итүен тикшерә. Шомарту производствосында типлашкан модульләрне проектлаштыруның технол. нигезләрен эшли. Әзерләнмәләрне төркемләп эшкәртү өчен санлы программалар б-н идарә ителә торган станоклар комплектлау һәм модульләп проектлаштыруның фәнни нигезләрен тәкъдим итә. Е. җитәкчелегендә машина агрегатлары һәм детальләренең конструкторлык һәм технологик төзелешенә караган уникаль туплanма булдырыла. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Технологические основы проектирования типовых шлифовальных гибких производственных модулей. Ульяновск. 1997 (автордаш); Управление качеством. Ульяновск. 2000; Расчёт цены и конкурентоспособности продукции // Методы менеджмента качества. 2000. № 8; Прогнозирование надёжности узлов и агрегатов машин // Автомобиль и техносфера. К., 2001; Спираль качества. Ульяновск, 2002.

**ЕФИ́МОВА** Александра Михайловна (5.5.1903, Казан — 12.1.1990, шунда ук), археолог. Шәрекъ педагогия ин-тын тәмамлый (Казан, 1926). 1926–31 елларда Казанның 6 нчы мәктәбендә җәмгыять белеме укытучысы. 1931–36 да Хезмәтне фәнни оештыру һәм саклау ин-тында эшли. 1937–58 дә ТАССР Дәүләт музеенда, 1942–53 тә тарих бүлеге мөдире. СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы ин-ты, Дәүләт тарих музее, ТАССР Дәүләт музее экспедицияләре составында Болгар шәһәрлегендә эшли (1939–41, 1944–54; СССР ФА Куйбышев археол. экспедициясенең Болгар отряды башлыгы), Балымер шәһәрлегендә (1955) үткәрелгән археол. казу эшләрендә катнаша. Беренчеләрдән булып Идел буе Болгар дәүләтендәге кара металлургия торышын, гидротехник корылмаларны, халыкның этномәдәни составын һәм болгар шәһәрләре барлыкка килүен өйрәнүгә керешә. ТАССР Дәүләт музееның археол. коллекцияләре (ш.и. *Бутаиха хәзинәсе*) каталоглары авторы. Хезмәтләре болгар шәһәрләре тарихы һәм археологиясенә карый.

Х е з м.: Металлургические горны в городе Болгары // Краткие сообщения Института истории материальной культуры АН СССР. М., 1951. Вып. 33; Гидротехнические сооружения древнего Болгара // Материалы и иссл. по археологии СССР. 1954. № 42; К вопросу о происхождении городов Волжской Болгарии. К., 1957; Кладбище у ханской усыпальницы на Болгарском городище // Древности Восточной Европы. М., 1969.

*Е.П.Казаков.*

**ЕФИ́МОВА** Татьяна Алексеевна (16.9.1943, Яшел Үзән р-ны Юдино станциясе), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). 1962–2001 елларда «Казан медицина инструментлары заводы» АҖдә (1990–1994 тә ҖБ) токарь. Дәүләт бүләге хезмәттәге казанышлары, эчке резервларны табу нигезендә эшенең сыйфаты һәм югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕФРЕ́М** (? — 26.12.1613, Казан), дин эшлеклесе. 1606–13 елларда Казан һәм Зөя митрополиты. 1609–10 да патша Василий Шуйскийга тәләктәшлек итә. 1611 дә Беренче ополчениегә баручы Казан гаскәренә Казан Мәрьям Ана иконасын тапшыра. Патриарх Гермоген кулга алынып, Е. иң югары дәрәҗәле архиерей булып калганнан соң, шәһәрләргә К.Минин һәм Д.Пожарский ополчениесен оештырырга ярдәм иткән хатлар тарата. 1613 тә Земский соборда катнаша. 1613 нең 11 июлендә Михаил Фёдорович Романовка патша таҗы кидерү тантанасында була. Казан Кремлендәге Спас-Преображенье монастыре ишегалдындагы куышлыкта җирләнә. Сөякләре 1995 нең 13 сентябрендә эзләп табыла, Сретенье храмында (*Петропавел соборының* түбән чиркәвендә) саклана.

*Әд.:* Казанский митрополит Ефрем, венчавший на царство Михаила Фёдоровича Романова. К., 1908; Святитель Ефрем, митрополит Казанский и Свияжский: К 300-летию со дня его блаженной кончины. К., 1914; М у х и н В. Митрополит Казанский и Свияжский Ефрем. К., 1996.

**ЕФРЕ́МОВ** Александр Александрович (14.9.1940, Буа ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССРның атказ. мелиораторы (1975). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1964). 1966–78 елларда «Татсельхозводстрой» трестының Буа механикалаштырылган күчмә колоннасы башлыгы. 1978–83 тә КПССның Кама Тамагы район ком-ты секретаре, 1985–90 да 1 нче секретаре. 1983–85 тә халык депутатларының Апас район советы башкарма ком-ты рәисе. 1990–91 дә ТАССР МС-

ның Аграр-сәнәгать комплексы бүлеге баш референты. 1991–2001 дә ТРның Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт ком-ты рәисе. 2001 дән ТР җир кадастры хезмәте җитәкчесе. 1985–91 елларда ТАССР, ТССР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЕФРЕ́МОВ** Александр Ефремович (10.9.1910, Сембер губ., Буа р-ны Чуаш Янтуганы а. — 16.3.1998, Буа ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1948). Казан бакчачылык техникумын тәмамлый (1931). 1932 елдан Буа МТСында агроном, өлкән агроном, 1942 дән директор. 1958–61 дә Буа район башкарма ком-тының а.х. буенча инспекция башлыгы, 1961–72 дә Буа р-ның «Сельхозтехника» берләшмәсе управляющие. Е. җитәкчелегендә хезмәтне оештыруда алдынгы формалар һәм алымнар кертелә, МТСның һәм «Сельхозтехника» берләшмәсенең матди-техник базасы ныгытыла, Буа МТСы республикада алдынгылар рәтенә чыга. Е. районда бөртекле ашлык һәм а.х.ның башка продуктларын җитештерүгә зур өлеш кертә. 1951–55 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А л е к с е е в с к и й А. Борец за высокую культуру земледелия // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1948. Кн. 1.

**ЕФРЕ́МОВ** Анатолий Васильевич (18.8.1938, Бөгелмә р-ны Спас а.), педагог, пед. фән. д-ры (1995), проф. (1996), ТАССРның (1975), РФнең (2002) атказ. мәктәп укытучысы, «Россиянең ел укытучысы — 94» конкурсы лауреаты. Мәләкәс пед. ин-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый (1961). 1964 елдан Бөгелмә шәһәренең 6 нчы урта мәктәбендә математика укытучысы, бер үк вакытта (1994 тән) ТР Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү Бөгелмә үзәге директоры. Казан технол. ун-тының Бөгелмә ф-лында 1995 тән декан, 1998–2007 елларда директор. Укытучы-новатор, мәктәптә матем. укыту, укучыларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, төбәк тарихын өйрәнү буенча хезмәтләр авторы. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. 1990–95 елларда ТР ЮС депутаты. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (1998).

Х е з м.: Алгебра и элементарные функции. М., 1972; Пётр Иванович Рычков. М., 1991 (автордаш); Алгебра и начала анализа (10–11 кл.). К., 1992; Рычков Пётр Иванович: историк и просветитель. К., 1995; Феномен академика Эрдниева. К., 1999; О математике и математиках. К., 2001.

**ЕФРЕ́МОВ** Николай Дмитриевич (19.4.1896, Казан — 1930 еллар), сәясәт эшлеклесе. Казанда 1 нче реаль уч-щене (1913), Петергоф прапорщиклар мәктәбен (1917) тәмамлый. Константинов ызан ин-тында укый (1914–16). 1917 елда Казан эсерлар хәрби оешмасы рәисе, сул эсерлар фракциясеннән РСФСР БҮБК әгъзасы, шәһәр думасы гласные. 1918 дә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Казан советы рәисе урынбасары, Казан Эшче-Крәстиян Совет Респ-касының ХКС әгъзасы, Казан губерна хәрби комиссары. 1918 елгы сул эсерлар фетнәсендә турыдан-туры катнашмый, ләкин РКП(б)га карата оппозициядә кала. 1918 нең июлендә, башка эсерлар кебек үк, вазифаларыннан азат ителә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* С т а р и н о в С.В. Политическая борьба в Поволжье. Левые социалисты в 1917–1918 гг. Йошкар-Ола. 1996.

*С.И.Ионенко.*

**ЕФРЕ́МОВ** Николай Прокофьевич (1860-?), җәмәгать эшлеклесе. Җирбиләүче, урман сәнәгатьчесе. Өй шартларында белем ала. Казан губернасыннан сайланган 3 нче Дәүләт Думасы депутаты, кадетлар партиясе әгъзасы. 1908 елда депутатлык вәкаләтләрен калдыра. 1919 да Казан халык хуҗалыгы советы бүлеге мөдире. 1919 ның 9 февралендә эсерлар оешмасы әгъзасы буларак кулга алына, аннары ireккә чыгарыла. 1938 дә Мәскәү коммуналь төзелеш инженерлары ин-ты профессоры. Шул ук елда кулга алына, 1938 нең 18 февралендә НКВДның Смоленск өлкәсе органнары тарафыннан атылуга хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.


*С.И.Ионенко, А.Ф.Степанов.*

**ЕФРЕ́МОВ** Фёдор Герасимович (12.7.1906, Пенза губ., Наровчатск өязе Рузвель а. — 30.3.1972, БАССРның Бөре ш.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). 1939 елда С.М.Киров исем. сәнәгать академиясен (Мәскәү) тәмамлый. Үзбәкстан ССРның «Калининнефть» трестында (1923–47) эшли. 1947–49 елларда Татарстан геол.-разведка трестында баш инженер, 1949–50 дә «Татарнефть» тресты җитәкчесе. Дәүләт бүләге Ромашкино нефть чыганагын ачканы өчен бирелә.

**ЕФРЕ́МОВ** Филипп Сергеевич (1750, Вятка ш., хәзерге Киров ш. — 1811 елдан соң), рус офицеры; европалылардан беренче булып борынгы сәүдә юлы б-н Көнчыгыш Төркестаннан Кашмирга һәм Һиндстанга бара. 1763 елда Түбән Новгород пехота полкына алына. 1774 тә ул унтер-офицер була һәм Донгуз заставасына (Оренбург губ.) хезмәткә җибәрелә, тиздән Е.И.Пугачёвка әсирлеккә эләгә, аннан кача. Яңадан күчмә кыргызлар тарафыннан әсир ителә һәм Бохара әмирлегенә коллыкка сатыла. Е. Бохара әмиренә хәрби хезмәткә барырга мәҗбүр була, әмма ислам динен кабул итми. Йөзбашы дәрәҗәсенә күтәрелә. Качып китә: Яркенд сәүдәгәре кыяфәтендә Көнбатыш Тибет һәм иң биек Куньлунь, Каракорым үткелләре аша чыгып, Һиндстанга барып җитә, аннан диңгез юлы б-н Англиягә бара һәм 1782 дә Россиягә әйләнеп кайта. Е.ның Урта һәм Үзәк Азия географиясенә, әлеге илләрдә яшәүче халыкларның этнографиясенә караган мөһим мәгълүматлары б-н кыйммәтле юлъязмалары биш тапкыр басылып чыга («Бохарада, Хива, Персия һәм Һиндстанда ун елга сузылган сәяхәт һәм маҗаралар, аннан Англия аша Россиягә кайту» — «Десятилетнее странствование и приключение в Бухаре, Хиве, Персии и Индии и возвращение оттуда через Англию в Россию», СПб., 1786; «Тугыз елга сузылган сәяхәт ...». — «Девятилетнее странствование ...», М., 1952). 1783 елда Ватан алдындагы хезмәтләре өчен Екатерина II Е.ны прапорщик дәрәҗәсенә күтәрә, нәселдән килә торган дворянлык бүләк итә; ул Тышкы эшләр коллегиясенә көнчыгыш телләр тәрҗемәчесе итеп билгеләнә. 1785–1809 да Россиянең төрле губерналарында административ вазифалар башкара. Отставкадан соң (1810) Казанда төпләнә, 1811 дә Казан ун-ты профессоры П.С.Кондырев редакциясендә аның китабының үзе исән чактагы 3 нче басмасы дөнья күрә.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В.В. История изучения Востока в Европе и России. Л., 1925; М у р з а е в Э.М. Непроторёнными путями. М., 1948.

*Ф.Ф.Гулова.*


РОССІЙСКОГО
унтеръ-Офицера Ефремова,
нынѣ
Коллежскаго Ассесора
Десятилѣтнее
СТРАНСТВОВАНІЕ
и
ПРИКЛЮЧЕНІЕ
въ Бухаріи, Хивѣ, Персіи
и Индіи,
и возвращеніе оттуда чрезъ
Англію въ Россію.
писанное имъ самимъ.
Въ Санктпетербургѣ,
печатано съ дозволенія Указнаго
у Гека 1786 года.

Ф.С.Ефремов китабы 1 нче басмасының титул бите.

**ЕФУ́К** Самуил Гершкович (11.4.1913, Киев өлкәсенең Золотоноша р-ны Глемязово а. — 23.10.1986, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1931–33 елларда Югары архит-ра-төзелеш ин-тында укый (Мәскәү). 1933–41 дә Мәскәү пр-тиеләрендә эшли. 1941 дән Казанда: Казан авиация з-дының капиталь төзелеш идарәсе башлыгы урынбасары, башлыгы, директор ярдәмчесе; 1946 дан 387 нче з-дның директор урынбасары, капиталь төзелеш бүлеге башлыгы, тәҗрибә-конструкторлык бюросы башлыгы урынбасары, 1952 дән Казан инженерлык саклау корылмалары төзү идарәсе башлыгы урынбасары, 1953 тән Авиация сәнәгате министрлыгының 14 нче трестында тәэминат башлыгы, управляющий урынбасары, 1957 дән ТАССР ХХСның Тәэминат һәм сату-урнаштыру идарәсе башлыгы урынбасары, 1963 тән Казан химия з-ды директоры урынбасары, СССР Госснабының Баш территориаль идарәсе башлыгы (1966–79). Е. Татарстанда Госснабның территориаль-җитештерү комплексын формалаштыруга, пр-тиеләрне һәм төзелешләрне матди-техник яктан тәэмин итүне оештыруга зур өлеш кертә. 1971–79 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**ЕШЕ́ВСКИЙ** Степан Васильевич (2.2.1829, Кострома губ. Кологрив ш. — 27.5.1865, Мәскәү), тарихчы, гомуми тарих магистры (1855), коллежский советник (1863). Дворяннар нәселеннән. 1846–47 елларда Казан ун-ты сту-

денты. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1850). 1850–53 тә Мәскәү тәрбия йорты каршындагы Николай исем. ятимнәр ин-ты укытучысы. 1853–55 тә Ришелье лицее (Одесса ш.) адъюнкты. 1855–57 дә Казан ун-тының рус тарихы кафедрасы, 1858 дән Мәскәү ун-тының гомуми тарих кафедрасы адъюнкты, экстраординар профессоры. Казан ун-ты каршында этнография музее булдыруда башлап йөри, аңа үзенең ядкәрләр коллекциясен бүләк итә. Тарихка карата Көнбатыш тарафдарлары идеяләренә якын булган эволюцион карашта тора. Дөнья историографиясендә беренчеләрдән булып Борынгы Рим провинцияләренең роле мәсьәләсен тикшерә. Хезмәтләре антик һәм урта гасырларның элгәреге дәверенә, 18 йөз Россия тарихына карый; алар арасында — «Рим дөньясы үзәге һәм аның провинцияләре» («Центр Римского мира и его провинции». М., 1859), «Мәҗүсилек һәм христианлык турында очерклар» («Очерки язычества и христианства». М., 1859), «Халыкларның күчеш дәвере һәм Каролинглар» («Эпоха переселения народов и Каролинги». М., 1863–64), «Елизавета Петровнаның патшалык итүе турында очерк» («Очерк царствования Елизаветы Петровны». М., 1868). Соловки монастыре китапханәсе кулъязмаларын фәнни әйләнешкә кертә (Казан руханилар академиясендә сакланганнар) һәм «Русларның төньяк-көнчыгыш крайны колонияләштерүе» («Русская колонизация северо-восточного края». М., 1866), «Россиядә миссионерлык» («Миссионерство в России». М., 1867) дигән хезмәтләрен бастыра. Казанда масоннар әсәрләре җыелмасын сатып ала, ул аңа «Новиков турында берничә искәрмә» («Несколько замечаний о Новикове». М., 1857) һәм «Узган гасырның сиксәненче елларында Мәскәү масоннары» («Московские масоны восьмидесятых годов прошедшего столетия». 1–2 кисәк, М., 1864–65) мәкаләләре өчен материал булып хезмәт итә. М.М.Щербатовның «Россиядә әхлакларның бозылуы турында» («О повреждении нравов в России». М., 1858) памфлеты кисәкләрен беренче булып нәшер итә. Е.ның Идел буе Болгары һәм Биармия тарихы проблемалары б-н кызыксынуы «Пермьнең борынгы ядкәрләре турында мәкалә» («Заметка о пермских древностях». М., 1859), «Пермь җыентыгы» («Пермский сборник»), «Әдәби мәкаләләр» («Литературные заметки». М., 1859) һ.б. язмаларында чагылыш таба.

Ә с ә р.: Сочинения: В 3 ч. М., 1870; Сочинения по русской истории. М., 1900.

*Әд.:* Б е с т у ж е в - Р ю м и н К.Н. Биографии и характеристики. СПб., 1882; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЕШКУ́Л** (Cerastium), канәферчәләр семьялыгыннан бер-, ике- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр. 100 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында диярлек, күбесенчә Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре: басу Е. (C. arvense) һәм кәс Е. (C. holosteoides) барлык р-ннарда очрый. Болын, сөзәклек, кырларда, су буйларында үсә. 8–40 *см* биеклектәге күпьеллык үләнчел үсемлек. Тамыры тармаклы, туфракта тирәнгә китми. Сабагы ботаклы. Басу Е.ның яфраклары тар, ланцетсыман яки кыяклы, кәс Е.ның — озынча түгәрәк. Чәчәкләре ак яки алсу, сабак очында көпшәк ярымчатырга җыелган. Җимеше — тартмачык. Апрель-октябрьдә чәчәк ата. Июньнән җимеш бирә башлый. Күбесенчә орлыктан үрчи. Е.ның җир асты өлешләрендә флавоноид, сапонин, углеводлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе тынычландыру чарасы буларак кулланыла.

**«ЁРШ»** («Шыртлака»), юмор һәм сатира журналы, «*Известия ТАТЦИКа*» г-тасына атналык кушымта. 1922–23 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Беренче саны 1922 елның 15 октябрендә чыга. Даими рәвештә чыкмый, 1922 нең декабреннән 1923 нең апреленә кадәр нәшер ителми. 2 нче дәүләт басмаханәсендә һәм «Восток» комб-ты басмаханәсендә басыла, күләме – 4 бит. Журнал бюрократларны тәнкыйтьли, аларны «совбурлар» һәм «совдурлар» дип атый, ришвәтчеләрне фаш итә, руханилардан, басылып чыккан газета-журналлардагы хаталардан көлә. «Ё.»ның төп сатира объектларының берсе нэпманнар була; журнал: «Нэпман кәрәкәсе симермәсен өчен дә Казанда инде ул «Шыртлака» («На то и «Ёрш» в Казани, чтобы нэпмановский карась не жирел») девизы астында чыга. Редакция халыкара мәсьәләләргә багышланган мәкаләләргә дә урын бирә; эмигрантларны караңгы буяулар б-н сурәтли. Төрле жанрдагы материаллар: фельетон, көлкеле шигырь һәм хикәяләр, такмаклар, көнкүреш күренешләре, карикатуралар һ.б. басыла. Күпчелек авторлар псевдоним куллана. С.Оков, А.Мирский һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләре басыла. «Сатирикон» һәм «Крокодил» ж-ллары үрнәгендә редакция «Почта ящигы» рубрикасы алып бара.

*Р.А.Айнетдинов.*

# Ж

**ЖА́ВОРОНКОВ** Владимир Фёдорович (9.6.1937, Ростов-Дон ш. — 25.11 2009, Казан), анестезиолог-реаниматолог, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1979), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1995). Минск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Белоруссиядә эшли. 1969 елдан Казан мед. ун-тында, 1977 дән анестезиология каф. мөдире. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш балалар анестезиологы һәм реаниматологы (1972–98). Хезмәтләре үлем алды халәтендәге авыруларны интенсив дәвалауга карый. Ж. йөрәк ритмы бозылуын дәвалаган чакта дефибриллятор файдаланганда электр тогы тәэсире механизмын, үпкәләргә ясалма рәвештә һава өрдергәндә сулыш һәм кан әйләнеше системаларында патофизиологик үзгәрешләрне өйрәнә. Балалар, ш.и. яңа туган сабыйларның үпкәләрендә табылган патологияне дәвалаганда дефибриллятор параметрларындагы электр тогы бушануын куллану ысулын эшли.

Х е з м.: Интенсивная вентиляция лёгких у детей. Ростов н/Д., 1978; Справочник по реаниматологии. Минск, 1978; Лазерная терапия в комплексе лечения синдрома интоксикации у детей. Уфа, 1995.

**ЖА́КОВ** Михаил Степанович (13.10.1928, Бөгелмә кантоны Иске Куак а. — 2004, Витебск ш.), патологоанатом, вет. фән. д-ры (1967), проф. (1968), Белоруссия ССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли. 1956 елдан Витебск вет. ин-тында, 1968–97 елларда патологик анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта ректор. Хезмәтләре а.х. терлекләренең йогышлы, йогышлы булмаган һәм ассоциатив авырулары вакытында иммуноморфология һәм иммунопатологиягә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ патологоанатомического вскрытия животных. Минск, 1977; Патологоанатомическая диагностика болезней крупного рогатого скота. М., 1991; Практикум по патологической анатомии сельскохозяйственных животных. М., 1997 (автордаш); Патологическая анатомия сельскохозяйственных животных. М., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЖАРГО́Н** (фр. jargon), сөйләм төре, кешеләрнең профессиясенә (проф. Ж.), җәмгыятьтәге урынына, нәрсә б-н кызыксынуына яисә яшенә (социаль Ж.) бәйле рәвештә формалаша. Гомуммиллләт теленең әдәби төрлелегеннән үзенчәлекле лексикасы һәм фразеологиясе б-н аерыла. Ж.ның лексик системасы гомумхалык теле чаралары нигезендә (төрле семантик һәм морфологик үзгәрешләр юлы б-н) яисә яңа сүзләр (гыйбарәләр) барлыкка китерү юлы б-н формалаша. *Социолингвистика* тарафыннан өйрәнелә. Татар телендә Ж.нар әлләни күп түгел. Сүзләрнең күпчелеге мәктәп укучылары, студентлар (стипа — стипендия, шпора — шпаргалка), хәрбиләр (каптри — капитан третьего ранга), җинаятьчеләр Ж.ы (мент — милиционер, пахан — баш кеше) — рус теленнән алынган сүзләр яисә калькалар (дәресне тозлау — просолить, дәресне калдыру дигәнне аңлата, койрык — хвост, тапшырылмаган зачёт яисә имтиханны белдерә).


Ж. сүзләрнең азчылыгын татар теленең күчерелмә мәгънәдәге үз сүзләре һәм гыйбарәләре яисә тирә-юньдәге кешеләр өчен аңлаешсыз, теге яки бу эшчәнлекнең үзенчәлеген белдерә торган сүзләр (арго) тәшкил итә, мәс., акбаш (аракы), багана (100 сум), рәтче (кесә карагы), кышты (пычак) һ.б. Кайбер татар һәм төрки Ж. сүзләр рус теленә үтеп керәләр һәм аерым социаль төркемнәрнең Ж.ына әвереләләр: чумара (файда, табыш) — чумарить, калым (иҗтимагый нормаларны бозып алынган табыш) — калымить. Арго сүзләр әдәби әсәрләрдә персонажлар телен чагылдыру өчен кулланыла. М.Мәһдиевнең «Фронтовиклар» (1972), М.Насыйбуллинның «Телсез шаһитләр» (1974), А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога» (1995), Т.Галиуллинның «Тәүбә» (1996) һ.б. язучыларның әсәрләрендә мондый мисаллар еш очрый.

*Әд.:* С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; К у р б а т о в Х.Р. Сүз сәнгате. К., 2002; А х м а н о в а О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1969.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЖАРКО́В** Василий Никифорович (25.2.1921, Мамадыш кантоны Борчаклы Яз а. — 1982, Казан), җырчы (бас), РСФСРның атказ. артисты (1957). 1950 елда Мәскәү консерваториясен (Е.Енохович классы) тәмамлый. 1950–80 елларда М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры солисты. Җырчы иҗатына реалистик башкару манерасы, тәэсирле мимика, ачык дикция хас. Ж. киң диапазонлы, чиста яңгырашлы, төрле тембрлы тавышка ия. Татар телен яхшы белүе аңа милли репертуардагы партияләрне уңышлы башкару мөмкинлеге бирә. Төп партияләре: Дон Базилио («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Мефистофель («Фауст», Ш.Гуно), Иван Сусанин (шул исем. опера, М.Глинка), Гремин, Кочубей, Рене («Евгений Онегин», «Мазепа», «Иоланта», П.Чайковский), Борис Годунов (шул исем. опера, М.Мусоргский), Борис Тимофеевич («Катерина Измайлова», Д.Шостакович), Аблай, Хан («Качкын», «Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов), Сандр («Наёмщик», С.Сәйдәшев һәм А.Ключарёв). Эстрада концертларында чыгышлар ясый.

*Ф.Ш. Салитова, Р.И.Такташ.*



В.Н. Жарков.

**ЖАРКО́В** Иван Степанович (1740 — 1.5.1813, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. Казанда сабын (6 казан, 11 эшче, елына 8550 пот сабын җитештерелә) һәм сыра кайнату з-длары, Казан губернасы Спас өязендә, Идел һәм Чулман елгаларында балык тоту промыселларына ия була. Казна подряды буенча армия өчен күлмәк һәм кием әчлеге тукымасы, итекләр һәм каешлар җитештерә. 1782–84. 1799–1800 дә Казан шәһәре магистраты бургомистры, 1802–04 тә Казан шәһәре башлыгы. Болак аша күпер салуга һәм Успение соборын төзекләндерүгә (1799) акчалата ярдәм итә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Т. 1; ш у л  у к. Казанский некрополь. К., [е.к.].

*Л.М.Свердлова.*

**ЖАРКО́В** Игорь Васильевич (28.5.1910, Уфа губ., Уфа өязе Мәсәгут а. — 20.4.1974, Белоруссия ССР, Гомель ш.), зоолог, эколог, биол. фән. д-ры (1968), проф. (1970). А.А.*Першаков* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1934), Идел-Кама төбәге сунарчылык биол. станциясендә, 1936–41, 1946–49 елларда — Кавказ, 1949–51 дә — Куйбышев, 1953–69 да Воронеж саклаулыкларында эшли. 1969 дан Гомель ун-тында зоология һәм дарвинизм каф. мөдире. Хезмәтләре зоология, сунарчылык белеме, тыюлык эшләре өлкәсенә карый. «СССР саклаулыклары» («Заповедники СССР». М., 1964) китабын төзүчеләрнең берсе һәм мөхәррире. Самолёттан кондызларның күпләп тереклек итү урыннарын сан ягыннан исәпкә алу ысулын тикшерә (СССР ВДНХсының алтын медале). Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Данные по биологии и промыслу водяной крысы в Татреспублике. К., 1931 (автордаш); Строение меха и осенняя линька зайца-беляка. К., 1931; Бригадная организация промысла крота и водяной крысы. К., 1936 (автордаш); Речные бобры в дельте Волги // Тр. Воронежского заповедника. 1960. Вып. 9.

**ЖА́РОВ** Михаил Иванович (14.10.1900, Мәскәү — 15.12.1981, шунда ук), драма актёры, СССРның халык артисты (1949), Соц. Хезмәт Герое (1974). Эшчеләр оешмаларының сәнгать-мәгърифәт берлеге каршында Ф.Ф.Комиссаржевский җитәкчелегендәге театр студиясен тәмамлый (1919), педагогла-

ры — А.П.Зонов, В.М.Бебутов, В.Э.Мейерхольд, С.М.Волконский. 1 нче фронт күчмә театрында, Мәскәүдә Сафонов исем. театрда, Героик-тәҗрибә театрында, Мейерхольд исем. театрда, Баку эшче театрында эшли. 1928 елда реж. А.Л.Грипич тарафыннан Казан Зур драма театрына чакырыла. 1928–29 да Казан сәхнәсендә шактый рольләрдә уйный. Алар арасында Васька-Окорок («Бронепоезд 14–69», В.В.Иванов), Тихон («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Вово («Мәгърифәт җимешләре», Л.Н.Толстой), Епиходов («Чия бакчасы», А.П.Чехов), король Людовик («Париж Мәрьям Ана соборы», В.Гюго романы буенча), Пикар («Ике ятим кыз», А.Деннери),



М.И.Ж а р о в Епиходов ролендә (А.П.Чехов, «Чия бакчасы»).

Пьер («Кюре һөнәрен үзгәртә», А.Вотейль), Вася («Түгәрәк квадратурасы», В.П.Катаев), Лучков («Цилиндр», С.Поливанов), Злобин («Рельслар гүли», В.М.Киршон), матрос Орёл («Амба», З.Чалая) һ.б. бар. Казан тамашачысы аның уйнавына югары бәя бирә. Аннан соң Ж. Мәскәүдә Реалистик, Камера театрларында эшли. 1938 дән — Кече театр труппасында. Иң күренекле киноактёрларның берсе. 1924 елдан кинофильмнарда төшә. Кинодагы рольләре арасында Жиган («Тормышка путёвка», 1931), Дымба («Максим турында трилогия», 1935–39), Меньшиков («Пётр Беренче», 1937–39) һ.б. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1941, 1942, 1947).

Әсәр: Жизнь, театр, кино: Воспоминания. М., 1967.

*Әд.:* М е т т е р И. Михаил Жаров. М., 1939; К р а с н о в П. Народный артист СССР М.И.Жаров. М., 1951; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ЖДА́НОВ** Николай Васильевич (1860/64 – ?), җәмәгать эшлеклесе. Самара губернасы Бөгелмә өязендә җирбиләүче. Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Самара шәһәрендә табиб булып эшли, типография тота. Самара шәһәр думасы һәм Самара губернасы земствосы гласные була. Самара губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907–12), октябристлар фракциясе әгъзасы, эчүчелеккә каршы комиссия рәисе ярдәмчесе (урынбасары). Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* У с м а н о в а Д.М. Депутаты Государственной Думы от Юго-Восточного региона Татарстана // Из истории Альметьевского региона. Альметьевск, 1999. Вып. 1.

**ЖДА́НОВ** Ринат Ибраһим улы (11.10.1944, Казан), биохимик, химия фән. д-ры (1986), проф. (2004), ТР ФАнең шәрәфле академигы (2008). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1970 тән СССР ФАнең Табигый кушылмалар химиясе ин-тында, 1973 тән Химик кушылмаларны биологик сынау фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1985–95 елларда Мед. сәнәгате министрлыгының Биотехнология ин-тында лаб. мөдире, ген. директор ярдәмчесе, 1995 тән РМФАнең (Мәскәү) Биомед. химиясе фәнни-тикшеренү ин-тында геннар терапиясе лаб-се мөдире, бер үк вакытта 1996 дан РФАнең Теоретик һәм экспериментал биофизика ин-тында баш фәнни хезмәткәр (Мәскәү өлкәсе, Пущино ш.). Хезмәтләре биол. һәм мед. химиясенә карый. Тотрыклы радикалларның үзәк нейротроп тәэсирен, шуларның седатив, антиагрегацион, ишемиягә, шокка каршы активлыгын тасвирлый. Иректә радикал табигатьле яңа тип парамагнитик дарулар (биоантиоксидантлар) уйлап таба. Фосфолипид-нуклеинлы тану гипотезасын, нуклеин кислоталарының мембраналар б-н тәэсирләшүенең төп принципларын тәгъбирли һәм фосфолипид-нуклеин комплексларының формалашу закончалыкларын ача. Геннар терапиясен күздә тотып, генетик материалны күзәнәкләргә һәм тукымаларга күчерү өчен, вируссыз системаларның яңа типларын эшли. Фәннең яңа юнәлешенә — функциональ геномиканың липидомика бүлегенә нигез сала.

Х е з м.: Иминоксильные радикалы в химии и биологии. М., 1973; Парамагнитные модели биологически активных соединений. М., 1981; Нитроксильные радикалы: синтез, химия и приложения. Спиновые метки в биологии и медицине. М., 1987 (автордаш).

**ЖДА́НОВ** Сергей Васильевич (8.9.1900, Казан губ., Чистай өязе Бүре Бистәсе а. — 2.11.1972, Казан), зоолог, биол. фән. д-ры (1949), проф. (1951), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1960). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1925), Казан вет. ин-тында эшли, 1949–72 елларда зоология каф. мөдире. Хезмәтләре сусаклагычлардагы азык ресурсларыннан файдалану мәсьәләләренә (1933–45), умарта кортлары эчәклегенең гистологик төзелешен, нозематоз вакытындагы морфологик үзгәрешләрен өйрәнүгә карый. Нозематоз б-н көрәшүнең биол. нигезләрен, җирле умарта кортлары нәселен яхшырту буенча тәкъдимнәр эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша (1941–42). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гистологическое строение кишечника пчелы // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те. 1936. Т. 56. Вып. 1–2; Периоды в годовом цикле жизни пчелиной семьи: XVIII Междунар. конгресс по пчеловодству. М., 1961; Внедрение паразита Wosema apis в клетку хозяина: XXI Междунар. конгресс по пчеловодству. М., 1967.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЖДА́НОВ** Шаһимәрдан Хәсән улы (7.11.1905, Казан губ. Чистай ш. — 4.11.1991, Казан), гигиена белгече. 1931 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук социаль гигиена кафедрасында эшли, бер үк вакытта институтта әзерлек курсларын алып бара, кичке уку ф-теты директоры, гомуми теория ф-ты деканы; сан.-гигиена, дәвалау ф-тлары деканы ярдәмчесе (1931–37), 1938–40 елларда Хабаровск хәрби госпитале табибе, 1945 тә демобилизацияләнә, янәдән Казан мед. ин-тында эшли башлый. 1946 дан гомуми гигиена каф. доценты. 1953 тән сан.-гигиена ф-ты деканы, 1957 дән коммуналь гигиена, 1961 дән гомуми гигиена кафедралары мөдире. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохит гигиенасына, Казан атмосферасы пычрану күрсәткечләрен өйрәнүгә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЖДА́НОВА** Гөлсем Габделгазиз кызы (10.6.1923, Ростов өлкәсе Шахты ш. — 23.2.1997, Казан), педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1973, 1977), пед. фән. д-ры (1988). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1953). Украина ССРның Дрогобыч өлкәсе Рудки шәһәре (1943–46), Кама Тамагы р-ның Олы Кариле (1949–53) урта мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1961 дән Казанда: Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында рус теле һәм әдәбияты кабинеты мөдире, 1963–95 тә РФ Мәгариф министрлыгы Милли мәгариф проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында (1984 кә кадәр аның мөдире) эшли. 1962–66 елларда РСФСР Пед. җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе. Тикшеренүләре рус телен укыту теориясе һәм методикасына карый. Гомуми белем бирү мәктәпләренең 5–8 класслары өчен рус теле укыту программалары, методик ярдәмлекләре, дәреслекләре 1980 еллардан 2000 еллар уртасына кадәр күп мәртәбә кабат басылып чыга.

Х е з м.: Слухо-зрительный курс русского языка в татарской школе. К., 1971; Методика применения технических средств при обучении русскому языку в татарской школе. К., 1977; Актуальные вопросы преподавания родного, русского языков и литератур в татарской школе. К., 1979; Методика преподавания русского языка в национальной средней школе. Л., 1981.

**ЖЕВА́НОВ** Иван Григорьевич (1770 — 21.10.1830, Казан), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1816). Дворяннар нәселеннән. 1787–98 елларда Екатеринослав һәм Новороссийск губерналарында дәүләт хезмәтендә. 1798–99 да Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе казначее. 1800 дән С.-Петербургта: Сенат генерал-прокуроры канцеляриясендә (1802 гә кадәр); 1802–12 дә Хәрби министрлыкта, 1812–23 тә Адмиралтействолар коллегиясе канцеляриясе идарәчесе. 1829 дан Казан гражданнар губернаторы. Казанны төзекләндерү турында кайгырта, шәһәр урамнарына һәм мәйданнарына таш җәйдерүне оештыра, ун-ты һәм башка уку йортларын үз яклавы астында тота, полициянең җинаятьчелеккә каршы көрәшен яхшыртуга ирешә. Казанда ваба (холера) авыруы эпидемиясе вакытында (1830 ның сентябрь-октябре) авыруның губерна терр-ясенә таралмавы өчен көрәш оештыра. Аның боерыгы буенча карантин кертелә, кешеләр җыела торган барлык урыннар һәм базарлар ябыла, мед. д-ры К.Ф.Фукска шәһәр халкына мед. ярдәме күрсәтүне оештыру тапшырыла. Ваба авыруыннан үлә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Ч. 1; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ЖЕГА́ЛОВ** Валентин Иванович (7.6.1934, Ульянов өлкәсе Сөнгәләй ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1957 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1991–98 дә дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире. Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләр теориясенә карый. Трикоми, Геллерстедт һәм Франкль мәсьәләләрен нелокаль гомумиләштерә, күп үлчәмле гиперболик тигезләмәләрне чишү буенча Риман вариантының классик методын төзи (1962); чиктәге шартларда нормаль чыгарылмалы мәсьәләләр тасвирламасын тикшерә; югары тәртиптәге бер дәрәҗәдәге тигезләмәләр чишүнең структур формуласын чыгара.

Х е з м.: Краевая задача для уравнения смешанного типа с граничными условиями на обеих характеристиках и с разрывами на переходной линии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1962. Т. 122, кн.3; Задача Франкля со смещением // Изв. вузов. Математика. 1979. № 9; Трехмерный аналог задачи Гурса // Неклассические уравнения и уравнения смешанного типа. Новосиб., 1990; Структура решения одного уравнения в частных производных // Дифференциальные уравнения. 1997. Т. 33, № 12.

**ЖЕЛЕЗНО́В** Борис Леонидович (10.2.1927, Украина ССРның Житомир ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1948). 1948–56 елларда ТАССР прокуроры ярдәмчесе, Столбище р-ны прокуроры. 1956–61 дә Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. 1961 дән Казан ун-тында укыта. Бер үк вакытта 1991–95 тә ТР Конституцион күзәтчелек ком-ты әгъзасы. ТССРның дәүләт суверенлыгы турындагы декларациясен (1990), ТР Конституциясен (1992), «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында»гы шартнамәне эшләүдә катнаша. Хезмәтләре федерализм, Татарстанда милли-дәүләт төзелеше мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Компетенция РСФСР и её субъектов. К., 1974; Автономия подлинная и мнимая. К., 1981; АССР — высшая форма советской автономии. К., 1984; Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996 (автордаш); Конституционный контроль в субъектах Российской Федерации. К., 2001 (автордаш).


*Е.Б.Долгов.*

**ЖЕЛЕЗНЯКО́В** Евгений Васильевич (29.1.1951, Яшел Үзән ш.), электромонтёр, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1969 елдан «Серго исемендәге завод» ЖБ федераль дәүләт унитар пр-тиесендә көйләүче, слесарь-ремонтлаучы, эл. б-н эретеп ябыштыручы, эл. җиһазларына хезмәт күрсәтүче һәм ремонтлаучы электромонтёр. Дәүләт бүләге махсус максатлар өчен булган эшләнмәләрне камилләштергәне һәм аларны әзерләүнең прогрессив технологиясен булдырганы өчен бирелә.

**ЖЕЛЕЗЦО́В** Александр Васильевич (23.7.1938, Казан), идарә итү процесслары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1968–76 елларда Бөтенсоюз физ.-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында, бүлек башлыгы (1972 дән). 1976–85 тә Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында. 1985–93 тә Казан ракета гаскәрләре югары хәрби команда инженерлары уч-щесендә. 1993–95 тә Казан а.х. академиясендә. 1995–2008 дә Мәскәү коммерция ун-тының Казан ф-лында менеджмент каф. мөдире. Хезмәтләре энергиянең традицион булмаган чыганакларына, идарә итү системаларына һәм әйләнә-тирә мохитне саклауга карый. Ж. нефть химиясе продуктларын тикшерү өчен үрнәк стандартларның прецизион электрохимик ысулларын, мәгълүмат сигналларының әзлеклелеген тызлау ысулын эшли.

Х е з м.: Магнитные явления в растворах // Электронная обработка материалов. 1976. № 6; Нелинейная переменно-токовая полярография // Прогрессивные электрохимические методы аналитического контроля. Куйбышев, 1977; Определение микрокомпонентов в сточных водах // Журн. аналитической химии. 1980. Т. 35, № 6; Проектирование полупроводниковых стабилизаторов напряжений. К., 1985 (автордаш); Метод вольтамперометрии Фарадея // Измерительная техника. 2002. № 1.

**ЖЕЛТУ́ХИННАР**, Казан губернасындагы дворяннар нәселе. Нәселне башлаучы — Коломна городовое дворян Яков Григорьевич (17 йөз). Аның оныгы **Алексей Исакович** (? — 1725), Преображенский полкы подполковнигы. Оныгының улы **Фёдор Алексеевич** (? — ?), шул ук полкның отставкадагы прапорщигы (1748). Аның улы **Фёдор Фёдорович** (1740–1817), сенатор, тайный советник, бригадир, Казан вице-губернаторы (1780), Казан (1781), Тобол (1784) һәм Вятка (1785–96) наместниклыклары идарәчесе (генерал-губернаторы). Зур җир биләмәләре (ш.и. Казан губернасында да), 9 мең крепостной крәстияне була. 19 йөз башында отставкага чыккач, Казанда яши. Аның балалары: **Сергей Фёдорович** (1776–1833), генерал-лейтенант (1824), 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813–14 тә чит илләрдәге яуларда катнаша. 2 нче, 3 нче, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә. **Пётр Фёдорович** (3.10.1778, Казан — 11.10.1829, Бухарест, 17.3.1830 да Казандагы Кизик монастыре зиратына күчереп җирләнә), генерал-лейтенант (1827), 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813–14 тә чит илләрдәге яуларда катнаша. Бородино сугышында күрсәткән батырлыгы өчен генерал-майор дәрәҗәсе бирелә (1812). 1824 тә, авыруы сәбәпле, отставкага җибәрелә. Казан губ., Лаеш өязенең Ялан авылындагы утарында яши. 1826 ның башында Николай I боерыгы буенча Казан ун-тына ревизия үткәрә, нәтиҗәдә Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий үз вазифаларыннан азат ителә. 1827 дә —



С.Ф. Желтухин.



П.Ф. Желтухин.

Киев генерал-губернаторы, 1829 да Молдавия һәм Валахия кенәзлекләре диваннары рәисе итеп билгеләнә. 3 нче, 4 нче дәрәҗә Изге Георгий, алмазлар б-н бизәлгән 1 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә. **Владимир Фёдорович** (21.6.1783 — 1848, Казан), статский советник, камергер. 1799 елда паж (хәрби уку йортында тәрбияләнүче). Аустерлиц янындагы сугышта катнаша, поручик (1806). Шуннан соңгы хәрби хезмәте турында мәгълүматлар юк. Дини эшләр һәм халык мәгарифе министрлыгы чиновнигы (1821 дән), Казан уку-укыту округы попечителе М.Н.Мусин-Пушкин каршындагы аерым эшләр буенча чиновник (1827). Казан икътисад җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1841), Казан губернасы дворяннары башлыгы (1845–48). Казанда яши, аның милкендә Казан губернасында — 1489, Саратов губернасында 939 крепостной крәстиян исәпләнә. 2 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә. Ж. йортында Казан ун-ты студентлары Л.Н.Толстой еш була.

*Әд.:* Л о б а н о в - Р о с т о в с к и й А.Г. Русская родословная книга. СПб., 1895. Т. 1; Великой памяти Л.Н.Толстого: Казанский университет 1828–1928. К., 1928; В и г е л ь Ф.Ф. Записки. М., 1928. Т. 1; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеалог. словарь. К., 2001.

*А.В.Гарзавина.*

**ЖЕМКО́В** Юрий Михайлович (9.9.1937, Октябрь р-ны Норлат эшчеләр пос.), машина төзүче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Ульянов политехник ин-тын тәмамлый (1977). 1956–59 елларда Норлат шикәр з-дында электрик. 1959–64 тә Куйбышев тимер юлының Ульянов бүлеге Димитровград юл дистанциясендә баш механик. 1964–2002 дә «Норлат машиналар төзү заводы» АҖндә: 1982 гә кадәр баш инженер, 2002 гә кадәр директор. Дәүләт бүләге «Чәчү алдыннан туфрак эшкәртү өчен модульле-блоклы культиваторлар төзү, технологик нигезләү һәм җитештерүне үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Перспективы развития и новые технологии в жилищно-коммунальном производстве // Жилищное и коммунальное хоз-во. 1987. № 2.

**«ЖЕМЧУ́ЖИНА»**, санаторий, Кама елгасы буенда Чаллы шәһәрендә урнашкан. 1984 елда ачыла. Табигый-дәвалау факторлары: сульфат-магний-натрийлы минераль су, күкертле-водородлы ләм. Санаторий терәк-хәрәкәт системасы авыруларын: остеохондроз, арт-

рит, артроз, полиартрит, түбән очлыкларда кан әйләнеше бозылып, шул урыннардагы ишемик некрозларны, ревматизмны; нерв системасы авыруларын: невроз, неврастения, невралгия, төнге энурезларны (сидекне тота алмау) һ.б.ны; йөрәк-кан тамырлары авыруларын: йөрәккә кан килү азаю, стенокардия, кардиосклероз (йөрәк мускулында тоташтыргыч тукыманың артык үсүе), миокард инфаркты, 1 һәм 2 нче дәрәҗә кан басымы авыруы, кан тамырлары тонусы кимү; сулыш, ашкайнату әгъзалары һәм тире авыруларын дәвалау юнәлешендә эш алып бара. Санаторий комплексы үзара күчү юллары б-н тоташкан алты катлы 2 һәм ике катлы 1 бинадан гыйбарәт; диагноз кую лаб-яләре, функциональ диагностика һәм төрле дәвалау кабинетлары бар.



Чаллы шәһәрендә «Жемчужина» санаторие. Торак һәм дәвалау корпуслары.

Дәвалау комплексына минераль һәм коры углекислый ванналар, галокамера, ләм, ингаляция, су, электр б-н дәвалау, магнит, мануаль, лазер терапиясе һәм энәләр кадап савыктыру, психотерапия, эчәкләрне чистарту, диеталы туклану, массаж, физик күнегүләр б-н дәвалау керә. Китапханә, клуб, спорт залы бар. Санаторий ел буена эшли.

*М.Й.Ибраһимова.*

**ЖЕРЕБЦО́В** Евгений Петрович (14.1.1941, БАССРның Краснокама р-ны Никола-Берёзовка а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), «Әлмәтнефть» НГДУында эшли, 1992 дән катлам басымын тоту һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру буенча бүлек башлыгы. Татарстан терр-ясендә төп нефть чыганакларын эзләүдә катнаша. Дәүләт бүләге «ТРның нефть чыгару районнарында техноген мониторинг, халык сәламәтлеге һәм экологик хәлне яхшырту чараларын сәнәгый кулланылышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. СССР ФАнең И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1989). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**ЖЕРЕБЦО́В** Николай Георгиевич (псевд. Верден) (15.11.1904, Казан — 17.5.1979, шунда ук), спортчы (авыр атлетика), цирк артисты (1933–44 елларда проф. көрәшче), ТАССРның атказ. артисты (1969). Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлый (1933). Ике кул б-н гер күтәрү буенча 1 нче Бөтентатар физкультура бәйрәмендә (1928), «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Бөтенсоюз беренчелегендә (1929) җиңүче, 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында бронза медаль иясе (1928), СССР һәм дөнья рекордчысы (1928). 1919–24 елларда Казан циркында эшли. «Русский богатырь» (1944) көч аттракционын, «Яшьлек» («Юность») татар цирк коллективын оештыра. 1980 нән Казанда ел саен Н.Г.Жеребцов истәлегенә гер спорты ярышлары (1994 тән Дөнья кубогына, 1999 дан дөнья чемпионаты) уздырыла. 1 нче дәрәҗә Хезмәт ордены (Вьетнам) б-н бүләкләнә.



Н.Г. Жеребцов.

**ЖИВЕ́ТИН** Владимир Борисович (22.1.1940, Казакъстан ССР Гурьев ш.), мәгълүмат технологияләре гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997). 1969 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, 1966 га кадәр Иркутск политехник ин-тында, 1969 елга кадәр Казан спорт авиациясе тәҗрибә КБнда эшли. 1970–97 дә Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты), югары метаматика каф. мөдире (1979–86), проф. (1995–97), бер үк вакытта Өзлексез белем бирү үзәге директоры. 1996–2000 дә Түбән Кама муниципаль ин-ты ректоры, 2000 нән Муниципаль ин-т ректоры (Мәскәү өлкәсе Жуковский ш.). Хезмәтләре аэромеханик үлчәүләргә карый. Самолёт очышының критик режимнарын тасвирлый һәм дәлилли. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Способ определения веса и центровки в полёте, а также устройство для его реализации. К., 1977; Устройство для контроля силы, приложенной к тросу. К., 1993.

**ЖИ́ВОВ** Дмитрий Егорович (1896, Рязань губ., Егорьевск өязе Селиваниха а. — 1939), сәясәт эшлеклесе. Техник уч-ще (Егорьевск ш.), РКП(б) ҮК каршындагы Марксизм-ленинизм курсларын (Мәскәү, 1926) тәмамлый, Мәскәү сәнәгать ин-тында укый (1931–33). 1917 елның октябреннән РКП(б)ның Егорьевск шәһәр ком-тын җитәкли. Егорьевскида 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрүендә катнаша. 1918 дә Егорьевск өяз башкарма ком-ты секретаре, 1919–21 дә РКП(б)ның Рязань губерна ком-ты секретаре, губерна башкарма ком-ты президиумы әгъзасы. 1922–23 тә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре, 1926–30 да ВКП(б)ның Дон округ ком-ты һәм Кырым өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1933 елдан Тимер юлларның Донецк, соңрак Ульянов бүлекчәләрендә сәясәт бүлеге башлыгы. Репрессияләр корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С а р к и н В. Живов Дмитрий Егорович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ЖИГА́ЛКО** Юрий Павлович (4.2.1937, Алма-Ата — 4.8.2002, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1991). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1962 дән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, 1976 дан теоретик механика кафедрасында. Хезмәтләре рәвеше үзгәрүчән каты җисем механикасына карый. Аның тарафыннан яңа фәнни юнәлеш — локальләшкән энергия агышлары б-н тәэсир итешүче сүрүләр механикасы төзелә; нормаль һәм орынма өслек көчләренең изотроп, ортотроп һәм биметалл цилиндрик сүрүләре тәэсире хакындагы мәсьәләләр чишелә; җылылык тупланган тирәлектәге әйләнмәле цилиндрик сүрүләрнең киеренке деформацияләнгән торышы мәсьәләләренең чишелешен таба. Ж. иреклe әйләнү сүрүләре өчен фундаменталь чишелешләр матрицасын төзүнең гомуми ысулларын эшли.

Х е з м.: О фундаментальном решении температурной задачи для круговой цилиндрической оболочки // Прикладная механика. 1965. Т. 1, № 4; Обобщённое решение контактных задач для упругих пластин и оболочек // Изв. АН СССР. Механика твёрдого тела. 1989. № 2 (автордаш); Вынужденные колебания оболочек и пластин. К., 1990.

**ЖИГУ́НИН** Владимир Данилович (16.11.1943, Куйбышев өлкәсе Тимәш пос. — 17.11.2001, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), проф. (1991). РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2001). Казан ун-тын (1967) һәм аспирантураны (1970) тәмамлагач, шунда ук эшли, 1986 елдан — гомуми тарих, 1991 дән борынгы заман һәм урта гасырлар тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре эллинизм тарихына, антик чор историографиясенә, тарихи процессның методологиясенә һәм фәлсәфәсенә карый.

Х е з м.: Международные отношения эллинистических государств в 280–220 гг. до н. э. К., 1980; Периодизация всемирной истории. К., 1984 (автордаш); Древность и её место в историческом процессе. Самара, 1996; Философия истории: формирование и эволюция основных идей. Самара. 1997.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

**«ЖИЗНЬ»** («Тормыш»), атналык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. 1912 елның 18 ноябреннән 1915 нең 6 декабренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 153 саны чыга. 1914 нең 1 ноябреннән әбунәчеләргә *«Казанская жизнь»* г-тасына кушымта буларак таратыла. Наширләре — И.А.Скворцов, аннан соң Н.А.Ильин; мөхәррире — И.А.Скворцов. Журнал битләрендә башкала һәм Казан язучыларыннан А.А.Блок, С.М.Городецкий, М.А.Волошин, Ю.А.Еленев, Л.В.Никулин, А.Ф.Мантель һ.б.ның әсәрләре басыла. Петроград һәм Мәскәүнең А.Н.Бенуа, А.Ф.Гауш, Д.Н.Кардовский, К.С.Петров-Водкин, А.П.Остроумова-Лебедева, Н.К.Рерих, П.Т.Сенников-Сперанский һ.б. күренекле рәссамнары әсәрләренең репродукцияләре, тәнкыйть язмалары басыла. «Ж.» рус һәм чит ил сәнгатендәге яңа агымнар б-н таныштыра. Идея-әхлак, эстетик тәрбия мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Редакция үз укучыларын борынгы истәлекләрне саклау турында кайгыртырга чакыра. Казанның истәлекле урыннарына багышланган иллюстрацияләнгән очерклар сериясендә тарихи һәйкәлләр турында кызыклы мәгълүматлар бирелә. Шулай ук Казан тормышының төрле мәсьәләләренә, ш.и. медицина

һәм халык мәгарифенә кагылышлы мәкаләләр дә урын ала. «Белдерүләр» бүлегендә Казанда үткәреләчәк әдәби-муз. һәм хореографик кичәләрнең алхәбәрләре игълан ителә. 1914 нең 27 октябреннән 8 декабренә кадәр «Жизнь» журналы телеграммалары» (иртәнге һәм кичке чыгарылышлар) басыла.

*Г.Р.Заманова.*

**ЖИ́ЛИНА** Елена Ефимовна (27.4.1890, Казан — 29.1.1963, Украина ССРның Винница ш.), драма актрисасы, ТАССР, РСФСР, ССРның халык артисты (1944, 1954, 1957). 1922 елда Казан Зур драма театры каршындагы З.М.Славянова җитәкчелегендәге студияне тәмамлый (педагоглары — В.С.Зотов, В.И.Окунева, Е.М.Лидова, Ю.В.Соболев). 1921 дә Казан Зур драма театрында беренче ролен башкара (Саша — «Иванов», А.П.Чехов) һәм театр труппасына кабул ителә. 1936 дан Архангельск шәһәре театрында, 1942 дән яңадан Казан Зур драма театрында. Сәхнәдә эшли башлаган елларыннан ук үзен көчле, үзенчәлекле актриса итеп таныта. Героинялар рольләрен башкара (Авдотья Романовна, Варвара Ардалионовна — «Җинаять һәм җәза», «Идиот», Ф.М.Достоевский; Чуха — «Петербург җимерекләре», В.В.Крестовский; Василиса — «Василиса Мелентьева», А.Н.Островский). Комик характердагы, гади халыктан чыккан үткен акыллы, тормыш авырлыкларына бирешмәүчән, юмарт күңелле, юмор хисенә бай образларны тудырганда аеруча зур уңышка ирешә. Настасья Гулячкина («Мандат», Н.Р.Эрдман), Марья («Любовь Яровая», К.А.Тренёв), Варвара Шишкина («Җир тетрәү», П.С.Романов), Лиза Гракова, Аглая («Константин Терёхин», «Рельслар гүли», В.М.Киршон) образлары Ж. башкаруында төгәл социаль характерлары б-н аерылып тора. Классик драматургия образлары өстендә эшләгәндә актрисага җете ачык буяулар куллануы, сөйләм интонациясенең байлыгы, персонажларының тышкы кыяфәтләрендәге детальләрне төгәл чагылдыра алуы ярдәм итә: Феклуша, Анфуса Тихоновна, Коринкина, Огудалова («Яшенле яңгыр», «Бүреләр һәм сарыклар», «Гаепсездән гаеплеләр», «Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Акулина Ивановна, Василиса («Мещаннар», «Тормыш төбендә», М.Горький), Марселина («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше). Берничә штрих б-н Ж. теге яки бу героиняның биографиясен генә түгел, әхлакый нигезләре б-н бергә бөтен бер чорны гәүдәләндерә (Графиня әби — «Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов; Бочкарёва — «Платон Кречет», А.Е.Корнейчук). Ж. образны ачканда комик хәлләрне бик оста куллануы б-н гаҗәпкә калдыра (Караулова — «Чит кеше баласы», В.В.Шкваркин һ.б.). 1935 тә беренчеләрдән булып аңа ТАССРның атказ. артисты исеме бирелә. 1940–50 елларда аның иҗат диапазоны киңәя, ул драматик рольләрне еш рак уйный башлый. Харитонова («Рус кешеләре», К.М.Симонов, 1942), Таланова («Ябырылу», Л.М.Леонов, 1943), Полозова («Мәскәү характеры», А.В.Софронов, 1948), Агриппина («Мәскәүдә таң ата», А.Суров), Параскева Димитрова («Лейпциг, 1933», Л.В.Компанейц, Л.И.Кронфельд), Орта («Ис әйдә, җил, ис», Я.Райнис, барысы да — 1951) образларында актриса хатын-кызның күпкырлы рухи дөньясын, аның үз-үзен корбан итәргә сәләтле булуын, чыдамлылык, батырлык, үз дәрәҗәсен белү, тормышны ярату, әчке бәйсезлек кебек сыйфатларын чагылдыра. Екатерина Ивановна Лагутина («Үз балаларының анасы», А.Н.Афиногенов, 1955) образы Ж. башкаруында халыкның иң яхшы сыйфатларын үзендә туплаган, зирәк акыллы Ана булып күз алдына килеп баса. Тискәре образларны уйнаганда актрисаның иҗаты сатирик гротеск төсмере ала. Мещаннарның мәгънәсезлек, җайлашучанлык, байлыкка табыну, кәпрәю, үзләрен зурга кую кебек сыйфатларын аяусыз фаш итә. Анна Андреевна, Коробочка («Ревизор», «Үле җаннар», Н.В.Гоголь, 1944, 1952), Глафира Глумова, Чебоксарова («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», «Котырган акчалар» А.Н.Островский, 1946, 1948), Полина Бардина («Дошманнар», М.Горький, 1952), Диана Михайловна («Фамилияләрен әйтмичә», В.П.Минко, 1953) образлары Ж. тарафыннан, кеше характерының бөтен нечкәлекләрен белеп, бик оста эшләнгәннәр. Рус реалистик мәктәбенең күренекле остасы Ж.ның чын халыкчан иҗаты театр сәнгатен баета, Казанда театр культурасы үсешенә сизелерлек йогынты ясый.



Е.Е.Жилина.

Актриса Бережкова («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Фелицата, Домна Пантелеевна, Галчиха («Дөреслек яхшы, ә бәхет яхшырак», «Талантлар һәм аларга баш иючеләр», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Квашня, Целованьева, Захаровна («Тормыш төбендә», «Зыковлар», «Карт», М.Горький), Наталья Ковшик («Балан кукаклыгы», А.Е.Корнейчук), Лукерья («Бирнәле туй», Н.М.Дьяконов) рольләрен дә башкара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А в д е е в А. Е.Жилина. К., 1957; Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*







Е.Е.Ж и л и н а: 1. Василиса («Василиса Мелентьева», А.Н.Островский); 2. Коробочка («Үле җаннар», Н.В.Гоголь поэмасы буенча); 3. Лагутина («Үз балаларының анасы», А.Н.Афиногенов) рольләрендә.

**ЖИЛО́Й РУДНИ́К** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 6 *км* көнбатыштарак, Норма елгасы буенда. 2008 елда 245 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 66%, руслар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 1 нче яртысында Таишев бакыр кою з-ды өчен руда казучылар посёлогы буларак нигез салына (1741–1851). 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, завод ябылганнан соң, игенчелек, эрләгән җеп һәм киндер тукыма ману, Вятка елгасы буендагы судноларһәм урман сәнәгате хуҗаларына киндердән аркан һәм корабль баулары ишеп сату б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Ж.Р.та сәүдәгәр Родыгиннарның киез аяк киеме ф-касы эшли. 1929 га кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Меринов волостена, 1929 дан Вятка округына, 1930 дан — Түбән Новгород, 1934 тән Киров крайларына, 1936 дан Киров өлкәсенә, 1951 нең 26 июненнән ТАССРга керә. Халык саны: 1859 да — 313, 1897 дә — 261, 1904 тә — 238, 1958 дә — 132, 1970 тә — 121, 1979 да — 119, 1989 да — 102, 2002 дә — 225 кеше.

**ЖИЛЯ́ЕВ** Геннадий Георгиевич (4.5.1934, Ставрополь ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1988), проф. (1989), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 1956 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1962 дән Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1963 тән директор урынбасары, баш фәнни консультант (1998 дән). Хезмәтләре төрле эшчәнлек шартларында, авария очракларын да кертеп, кешене агулы, агрессив матдәләр, җылылык факторлары тәэсиреннән саклауга карый. Интенсив җылылык агымының күзәнәкле полимер системалар б-н тәэсирләшү процессларын тикшерү нигезендә кешене үтә көчле яктылык, пешү тәэсиреннән саклау чарасын эшли. Пар һәм югары токсинлы матдә тамчыларының күп катлаулы күзәнәкле полимерлар система-

сы аша узу процессларын өйрәнү кешене озак һәм ышанычлы, ш.и. комплекслы саклауның нәтиҗәле чараларын эшләү мөмкинлеге бирә; шуларның 30 дан артыгы сәнәгатьтә үзләштерелә. Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша. Россия «Чернобыль» союзының Татарстан Респ-касы инвалидлар оешмасын оештыручы һәм президенты (1991 дән). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние физико-гигиенических свойств материалов защитной одежды на продолжительность работы в ней // Гигиена и санитария. 1991. № 11 (автордаш); Концепция комплексной защиты человека в промышленности // Безопасность труда в промышленности. 1993. № 5 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета: КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЖИРИ́ЦКИЙ** Георгий Сергеевич (8.10.1893, Тула губ. Крапивино ш. — 4.6.1966, Казан), газ динамикасы һәм җылылык техникасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1937), проф. (1925). ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1953, 1961). 1915 елда Киев политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, судноларга төзү з-дларында (Николаев ш., Севастополь ш.) конструктор булып эшли. 1918–29 да Киев политехник ин-тында укыта, механика ф-ты деканы (1926 дан). Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесендә (1929–30), Мәскәү энергетика ин-тында (1930–37) пар турбиналары кафедралары мөдире, бер үк вакытта җылылык техникасы ф-ты деканы. 1937–41 дә НКВДның махсус КБнда баш конструктор урынбасары (Мәскәү). 1941 дән Казанда, Казан моторлар төзү з-дында В.П.Глушко җитәкчелегендә эшли һәм ракета двигательләренең турбокомпрессор агрегатлар бүлегенә җитәкчелек итә. 1945–66 да Казан авиация ин-тында, реактив двигательләр каф. профессоры (1947 гә кадәр), турбомашиналар каф. мөдире (1947–66). Газ динамикасы һәм турбомашиналар детальләренең ныклыгы өлкәсендә фәнни мәктәпкә нигез сала. Хезмәтләре пар-җылылык техникасына, газ динамикасына, пар һәм газ турбиналары детальләренең ныклыгына карый. А.Д.Чаромский җитәкчелегендә турбокомпрессорлар төзүдә катнаша. Югары темп-ралы суытыла торган газ турбиналарының агым өлешендә җылылык алмашуын һәм газ динамикасын, катлаулы формадагы детальләрнең киеренке халәтен тикшерә. Илебездә беренче сыек ягулыклы ракета двигательләре төзүчеләрнең берсе. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Айның күренми торган ягындагы бер кратер Ж. исеме б-н атала.

Х е з м.: Паровые турбины: В 2 т. М., 1936 (автордаш); Газовые турбины. М., 1948; Газовые турбины авиационных двигателей. М., 1963 (автордаш); Конструкция и расчёт на прочность деталей паровых и газовых турбин. М., 1968 (автордаш).

**ЖИТКО́В** Григорий Васильевич (29.1.1876, Саратов губ., Аткара өязе Баланда а. — 1951, Казан), нәкышьче. Петербургта барон Штиглицның Үзәк техник рәсем ясау уч-щесен тәмамлый (1896). Саратов сынлы сәнгать



Г.В.Ж и т к о в. «Колсәет». 1940. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

уч-щесендә шөгыльләнә (1908, 1910–14). 1915–38 елларда Баланда авылы мәктәбендә рәсем дәресләре, бизәү эшләре алып бара. 1938 дән Казанда яши, «Татхудожник» берләшмәсендә эшли. 1939–40 та Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта. Нәкышь б-н актив шөгыльләнә, пейзаж һәм тарихи-революцион, хәрби-патриотик һәм көндәлек темаларга кагылышлы тематик картиналар жанрларында эшли: «Столыпин реформасы көннәрендә» (1939), «Борынгы Казан йөкчеләре» (1941), «Фронттан хәбәр» (1941), «Тукайның балачагы» (1945), «Сыер савучылар» (1947). «Тегермән» (1942), «Беренче кар» (1945), «Казансуда язгы ташу» (1946) пейзажлары лирик хисләр тирәнлеге, ягымлы һәм зәвыклы булулары б-н ае-



Г.В.Ж и т к о в. «Тукай Печән базарында». 1945. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

рылып тора. Ж.ның иҗат эшчәнлеге 1930–40 та респ-ка сәнгатендә тематик картиналар жанрының барлыкка килүенә һәм үсешенә булышлык итә. Республика (1939–50), төбәк — Идел буе рәссамнары (1943–45, 1947), бөтенроссия — үзәктән читтә яшәүче төбәкләр рәссамнары (1940) күргәзмәләрендә катнаша. Ж. әсәрләре Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә ТАССР рәссамнары күргәзмәсендә күрсәтелә (1957). Аның әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.М.Горький әдәби-мемориаль музеенда саклана.

*Әд.:* Изобразительное искусство Советского Татарстана: Альбом. К., 1957; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**ЖИТЛО́В** Владимир Васильевич (1.2.1940, Пенза ш.), тренер (фехтование), СССРның атказ. тренеры (1973), РСФСР, ТРның атказ. физ. культура хезмәткәре (1985, 1994). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын тәмамлаганнан соң (1962), физкультура укытучысы булып эшли. Казан пед. ин-тының спорт дисциплинасы кафедрасында укытучы (1963–66), өлкән укытучы (1967–71). Казандагы 3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә укыту бүлеге мөдире (1966–67), өлкән тренер (1971–83, 1990–94), директор (1994–97). 1989–90 елларда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан советында өлкән тренер. 1983–90 да Казан ун-тының физик тәрбия каф. мөдире (1987 дән доцент), бер үк вакытта (1973–90 да) СССР җыелма командасы тренеры. 1997 дән РФ Саклык банкының Татарстан бүлегендә әйдәп баручы тренер. Шәкертләре О.Б.*Вощакина*, Җ.С.Галиев, Н.Ф.*Гыйләҗева*, Р.Б.Дубов, О.Н.*Князева*, В.Г.*Никонова*, Г.Сафин — күп тапкыр РСФСР, СССР, дөнья чемпионатларында, Европа кубогы, Олимпия уеннарында бүләк алучылар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Есть мушкетёры, есть! К., 1988; Индивидуальный подход к предсоревновательной подготовке фехтовальщиц. К., 1988.

**ЖИ́ХАРЕВ** Валентин Александрович (10.3.1947, Көньяк Сахалин өлкәсенең Анива ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1998). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында эшли, 1996 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1999 дан Казан технол. ун-тында югары матем. каф. мөдире. Хезмәтләре үткәргечләрнең магнит радиоспектроскопиясенә, каты җисемнәрнең радиацион физикасына карый. Металларда электроннарның спин кайтавазы теориясен төзи (бергәләп), ЭПР-спектроскопиянең туннель ысулын тәкъдим итә (бергәләп), тәртипкә китерелмәгән үткәргечләрдә төш кинетикасы теориясен үстерә (бергәләп). М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге лауреаты (1976).

Х е з м.: Теория спиновой индукции и эха электронов проводимости // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1974. Т. 67 (автордаш); Кинетика ядерной намагниченности в неупорядоченном проводнике // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1989. Т. 49; Tunnel EPR spectroscopy // Journal of Physics. C. 1982. V.15 (автордаш); Магнитные свойства кремния, имплантированного ионами железа в магнитном поле // Казанский физико-технический институт им. Е.К.Завойского. К., 2006 (автордаш).

**«ЖИ́ЧЕ ТАТА́РСКЕ»** («Życie tatarskie» — «Татар тормышы»), айлык рәсемле журнал. *Речь Посполита татарларының Мәдәни-агарту берлегенең* Вильно бүлеге органы. 1934–39 елларда Вильно шәһәрендә (Польша) поляк телендә нәшер ителә, барлыгы 69 саны чыга. Мөхәррире С.Туган-Барановский. Авторлар коллективы, башлыча, Польша-Литва татарларыннан тора. Еш кына С.Туган-Барановский, тарихчылар А.Воронович, М.Александрович, С.Крычыньский, гимназия укытучысы М.Гембицкий, мөфти

Я.Шынкевич, Вильно ун-ты студенткалары һәм аны тәмамлаган С.Мишкевич, А.Муха, Г.Туган-Барановскаяларның мәкаләләре басыла. Башка милләт журналистлары Якын Көнчыгышка барудан алган тәэсирләре б-н уртаклашалар. Матди ярдәмне Икенче Речь Посполитаның Дин һәм мәгариф эшләре министрлыгы күрсәтә. Мөхәррир басманың төп максаты итеп авылда һәм кечерәк шәһәрләрдә яшәүче татарларның мәдәниятен үстерүне, аларны бөтендөнья мөселманнары тормышы б-н таныштыруны куя. Журналның тематикасы — тарих, дин, авыл хуҗалыгы,




«Жиче татарске» журналы.

һөнәрләр, сәламәтлек саклау, мәгариф. Популяр поляк журналларында дөнья күргән материаллар да күчереп басыла. «Ж.т.» битләрендә дөньякүләм мөһим иҗтимагый-сәяси, ш.у. Речь Посполита тормышына кагылышлы мәсьәләләр дә күтәрелә. Гминалар, Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеге бүлекләре һәм укчы дружиналар эшләре киң яктыртыла. Төрле чаралар — дини һәм дөньяви еллыклар үткәрү, иптәшләрчә очрашулар турында хәбәрләр басыла, Польша татарларыннан гимназия һәм вуз тәмамлаучыларның исемлеге китерелә. 1935–37 елларда Кырым һәм Идел буе татарларының тарихына һәм хәзерге тормышына кагылышлы мәкаләләргә зур игътибар бирелә. 1998 дән журнал яңадан чыгарыла башлый. 2 айга 1 тапкыр Сокулки шәһәрендә (Польша) чыга. Баш мөхәррире Ю.Конопацкий. «Үлгәнне, онытылганны терелтергә, искә төшерергә, үткәндәге традицияләргә яңа яңгыраш бирергә» дигән максат куела.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я. Польско-литовские татары (наследники Золотой Орды). К., 1995; M i s k i e w i c z A. Tatarzy polscy w 1918–1939. Warsz., 1990. *Я.Я.Гришин.*

**ЖМА́КИН** Александр Яковлевич (15.10.1780, Саратов губ., Петров өязе Богородское а. — 19.11.1850, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, тайный советник (1837). Дворяннар нәселеннән. 1797 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1802–08 елларда Казанда: дворяннар җыены казначее, 1803 тән өяз экспедициясе советнигы ярдәмчесе. 1808–11 дә Кострома уделлар конторасы башлыгы ярдәмчесе, 1811–17 дә Вятка уделлар конторасы башлыгы. 1817–21 дә Вятка, 1821 дән Казан вице-губернаторы. 1823–26 да Казан гражданнар губернаторы вазифаларын башкаручы. Казан губернасында дәүләт салымнарын һәм йөкләмәләрен җыюны тәэмин итә, юллар һәм почта станцияләре төзүне оештыра. Ялган акча ясаучыларның Идел буе төркемен ачуда актив катнаша. Казанны төзекләндерү турында кайгырта. Аның заманында шәһәр урамнарына таш җәю башлана (1826). Уку-укыту йортларын үз кайгыртуы астына ала, Казан ун-тына һәм хәрби ятимнәр бүлекләренә иганә акчалары бирә. 1826–31 дә Сембер гражданнар губернаторы. Сембер губернасында әҗнәбиләрне күпләп христианлаштыруны үткәрә. 1831 дән С.-Петербургта: Дәүләт хуҗалыгы һәм публика йортлары департаменты (1833 кә кадәр), Башкарма полиция департаменты (1837 гә кадәр) директоры, Россия Эчке эшләр министрлыгы советы әгъзасы (1837). Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1826). Удел крәстияннәренең хәле, дәүләт төзелеше турындагы язмалар авторы.
*Е.Б.Долгов.*

**ЖО́ГИН** Николай Венедиктович (29.11.1914, Рязань губ., Сасово өязе Глядково а. — 31.3.2002, Мәскәү), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1968). Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1946). 1937 елдан Рязань өлкәсендә: тикшерүче (1938 гә кадәр), Клепики (1938–39), Михайлов (1939–41) р-ннарында прокурор. 1941–42 дә Рязань шәһәрендә, 1942–46 да Көнбатыш Казакъстан өлкәсендә, 1946–48 дә Иркутск шәһәрендә, 1948–58 дә Таҗикстан ССРда прокурор. 1958–61 дә ТАССР прокуроры. 1961–73 тә СССР ген. прокуроры урынбасары. 1973–80 дә Бөтенсоюз җинаятьчелекнең сәбәпләрен өйрәнү һәм аны кисәтү чараларын эшләү фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары (Мәскәү). 1948–58 дә Таҗикстан КП ҮК әгъзасы. 1948–58 дә Таҗикстан ССР, 1958–61 елларда ТАССР ЮС депутаты. Хезмәтләре җинаятькә каршы процессуаль хокукка, тикшерү һәм тәгаенләү өстеннән прокурор күзәтчелеге булдыруга карый. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы, өч «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Советская общественность на страже социалистической законности: По материалам Татарской АССР. К., 1959; Решая судьбу человека: Записки прокурора. К., 1960; Прокурорский надзор за предварительным расследованием уголовных дел. М., 1968; По следам преступлений. М., 1969 (автордаш); Обвинение предъявлено: Очерки. М., 1972 (автордаш).
*Е.Б.Долгов.*

**ЖО́ЛОБОВ** Олег Феофанович (29.4.1957, Киров ш.), тел белгече, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), шунда ук эшли. 1995–97 елларда Гессен ун-тының (Германия) Славистика ин-тында фәнни стажировкада була. Исемнәрнең грамматик яктан үзгәрүен, борынгы рус теленең сан формаларын; рус һ.б. славян телләрендә икеле санның сан һәм квантитатив конструкцияләрнең тарихын өйрәнә.

Х е з м.: Символика и историческая динамика славянского двойственного числа. Fr/M., 1998; Двойственное число // Историческая грамматика древнерусского языка. М., 2001. Т. 2 (автордаш); Морфосинтаксис древнеславянских числительных // Славянское языкознание. XIII Международный съезд славистов. Любляна, 2003.

**ЖУЗЕ́** Пантелеймон Крестович (чын исеме һәм фамилиясе Бандали ибн Салиба әл-Җәүзи) (20.7.1870, Палестина, Иерусалим ш. — 19.1.1942, Баку), шәркыятьче галим, гарәп теле һәм әдәбияты д-ры (1921), статский советник (1911). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1896), 1916 елга кадәр шунда эшли. Бер үк вакытта 1911–12 дә Казанда Урта белем тарату җәмгыяте гимназиясендә, 1912–13 тә Казан руханилар семинариясендә укыта. 1916–19 да Казан ун-тының мөселман хокукы каф. приват-доценты, 1919–20 дә профессоры. 1920–37 дә Әзәрбайҗан ун-тында: гарәп теле һәм әдәбияты каф. профессоры, 1922–26 да Шәрекъ ф-ты деканы, Якын Көнчыгыш халыклары тарихы һәм этнографиясе каф. мөдире. 1937 дән СССР ФАнең Әзәрбайҗан ф-лы Тарих ин-ты хезмәткәре. Яңа латин алфавиты ком-ты (Баку) эшчәнлегендә актив катнаша. «Тулы русча-гарәпчә сүзлек»не («Полный русско-арабский словарь», 1–2 кис., 1903) төзүче. Аның «Мөгътәзилиләр. Ислам өлкәсендә догматик-тарихи тикшеренү» («Мутазилиты. Догматическо-историческое исследование в области ислама», 1899), «Мәккә Мөхәммәде һәм Мәдинә Мөхәммәде» («Мухаммед Меккский и Мухамммед Мединский», 1906), «Коръән» («Коран», 1914) кебек мөселман дине тарихына караган хезмәтләре үзенчәлекле ислам энциклопедиясе булып тора. Якын Көнчыгыштагы чиркәү мәсьәләләре б-н кызыксынуы Ж.ның «Иерусалим чиркәве тарихыннан» («Из истории Иерусалимской церкви», 1910), «Чиркәүнең Шәрекътәге борынгы тарихыннан очерклар» («Очерки древней истории церкви на Востоке», 1912), «Кәнганның беренчел тарихына карата» («К первоначальной истории Ханаана», 1914) кебек хезмәтләрендә чагылыш таба. Кавказ арьягының 7–17 йөзләр тарихын өйрәнә. Тәбани, Белазури, Ибн Мискавейх, Ибн әл-Әсир, Якут әл-Хәмави һ.б. гарәп язучыларының тарихи әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. Казанда Урта белем тарату җәмгыятен оештыручы һәм аның әгъзасы (1907–17).

Х е з м.: Грузия в XVII столетии по изображению патриарха Макария. К., 1905; К выяснению значения слова «тат». Баку, 1930; Материалы по истории Грузии и Кавказа: В 3 т. Тб., 1937 (автордаш).
*Е.Б.Долгов.*

**ЖУЙКО́В** Вячеслав Викторович (25.6.1960, Яшел Үзән р-ны Юдино штп), электрохимик, химия фән. д-ры (1996). 1982 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, бер үк вакытта Бордо 1 (1994–95, Бордо ш., Франция) ун-тының Милли фәнни-тикшеренү үзәгендә Металлоорганик химия лаб-ясе фәнни хезмәткәре. 2000 нән Ренни 1 ун-ты профессоры (Франция). Хезмәтләре элементорганик кушылмаларны электр б-н синтезлау-

га карый. Элементорганик кушылмалар катнашындагы электрохимик процессларның селективлыгы б-н идарә итүнең һәм электрохимик реакциягә сәләтен анализлауның молекуляр-термодинамик яктан теоретик нигезләрен эшли. Электронның күчеш тибын, электрогенерирланган интермедиантларның табигатен һәм реакциягә керә алуын билгели торган, электрон, орбиталь һәм стереоэлектрон тәэсирләшүләрнең, молекуляр төзелешнең ролен гомумиләштерә. Теоретик тикшеренүләр Ж.ка эремәләрдә алкилсиланнарның анион радикаллары, силил катионнары һәм радикаллары хасил булуын фаразларга, беренче мәртәбә тәҗрибәдә расларга һәм күп кенә электрохимик процессларны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Франциядә яши (2000 елдан).

Х е з м.: Введение в теоретическую органическую электрохимию. К., 1994; Ступенчатый и диссоциативный механизм переноса электрона в электрохимических реакциях кремнийорганических соединений. Молекулярно-термодинамическое приближение // Электрохимия. 2000. Т. 36, вып. 2.

**ЖУ́КОВ** Евгений Григорьевич (25.8.1948, Пенза өлкәсенең Земетган р-ны Салтыков а. — 2.2.2008, Казан), вет. радиобиологы, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1992). 1973 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли. 1985–87 елларда Бөтенсоюз вет. ин-тында. 1987 дән хәзерге Казан вет. медицинасы академиясендә, 1990–92 дә гражданнар иминлеге һәм радиобиология, 1992–2008 дә экология һәм хайваннарны саклау кафедралары мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләрендә нурланыш патологиясен өйрәнүгә карый. А.х. терлекләренең нурлар б-н зарарлануын башлангыч чорында ачыклау ысулларын, терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясенең радиоактив зарарлануын билгеләүнең экспресс ысулын эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Работа службы защиты животных и растений ГО при ликвидации последствий аварийного выброса Чернобыльской АЭС в животноводстве. К., 1988 (автордаш); Работы службы защиты животных и растений ГО по повышению устойчивости функционирования сельскохозяйственных объектов. К., 1990 (автордаш); Радиобиология. Алматы, 1998 (автордаш); Радиобиологические эффекты у животных. М., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЖУ́КОВ** Иван Васильевич (23.5.1914, Чимкент волосте Чубаровка а., хәзерге Казакъстан Респ-касы — 1968, Чимкент ш.), җырчы (баритон), Казакъстан ССРның атказ. (1947), ТАССРның халык артисты (1957). 1934 елда Үзәк театр сәнгате техникумын (Мәскәү) тәмамлый. 1938–50 дә Казакъ акад. опера һәм балет, 1950–59 да Татар опера һәм балет, 1959–62 дә Мордва муз. драма театрларында солист. Төз, матур гәүдәле, киң диапазонлы көчле тавышка ия җырчы, сәхнәдә истә калырлык, ышандырырлык образлар тудыра. Төп партияләре: Жермон («Травиата», Дж.Верди), Марсель («Богема», Дж.Пуччини), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Мазепа, Елецкий, Роберт («Мазепа», «Пики дамасы», «Иоланта», П.Чайковский), Мизгирь («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков), Андре («Җәлил», Н.Җиһанов) һ.б.

*Ф.Ш.Салитова, Р.И.Такташ.*

**ЖУ́КОВ** Иван Петрович (29.7.1798, Казан губ. — 1847 дән соң, Казан), декабрист, принц Оранскийның Белорус гусар полкы штаб-ротмистры (1824). 1817 елда лейб-гвардия Гренадерлар полкына керә, 1820 дә генерал-майор П.Ф.Желтухинга адъютант итеп билгеләнә. 1824 нең башында М.П.Бестужев-Рюмин аны Украинадагы декабристларның Көньяк җәмгыятенә кабул итә. Баш күтәрүне оештыруда актив катнашкан Васильково управасы әгъзасы. Ж. Көньяк җәмгыятьнең максаты итеп «законнарны яхшыртуны һәм конституция кабул итү»не саный. Аның фатирында җәмгыятьнең стратегиясе һәм тактикасы мәсьәләләре буенча утырышлар үткәрелә, патшаны үтерү проектлары тикшерелә. Баш күтәрү көне алдыннан шәхси хәлләр Ж.ны җәмгыять эшләреннән читләштерә. Принц Оранский полкы Чернигов полкы декабристлары чыгышын якламый. Ж. 1826 ның гыйнварында кулга алына, Архангелогород гарнизон полкына штабс-капитан итеп күчерелә. 1828 нең ахырында үзенең үтенече буенча Кавказ корпусының Кура пехота полкына җибәрелә, рус-төрек сугышында катнаша (1828–29). А.А.Бестужев-Марлин б-н бергә хезмәт итә, Шәрекъ телләрен өйрәнә. Бестужев Ж.ка «Яу чабулар» («Наезды») повестен багышлый, аның б-н язышып тора. Отставкага чыккач, Ж. Казан губернасы, Лаеш өязе Сергиев авылындагы утарында, 1836 дан Казанда яши. 1838–40 та Казан ун-тында ирекле тыңлаучы, 1842 дән — гарәп теле, 1843–46 да гарәп-төрек телләре һәм тел белеме, фарсы теле һәм тел белеме укытучысы. Шәрекъ тел белеме кандидаты. 1843 тән студентлар инспекторы ярдәмчесе. 1861 елда Ж.ның хатыны һәм балаларының Лаеш өязенең Көрнәле авылында 181 крепостной крәстияне була.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Профессора и преподаватели Императорского Казанского университета. К., 1904. Т. 1; Ф р у м е н к о в Г.Г., В о л ы н с к а я В.В. Декабристы на Севере. Архангельск, 1986; Декабристы: Библиогр. справ. М., 1988; Казанское дворянство 1787–1917: Генеал. словарь. К., 2001. *А.В.Гарзавина.*

**ЖУ́КОВ** Константин Павлович (14.4.1907, Казан — 10.10.1976, шунда ук), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Бөек Ватан сугышында катнаша. КПСС ҮК каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1953). 1930–35 елларда Симферопольдә күн з-дларында эшли. 1935–36 да Казандагы «Спартак» күн-аяк киеме комб-тында цех мөдире, 1937–38 дә директор. 1938–41 дә, 1950–53 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1953–57 дә ТАССРның җиңел сәнәгать министры. 1957–59 да ТАССР МС рәисе урынбасары. 1959–62 дә Казан фотожелатин з-ды директоры. 1959–63 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**ЖУ́КОВ** Леонид Алексеевич (8(20).4.1890, Мәскәү — 3.11.1951, шунда ук), балет артисты, балетмейстер, РСФСРның атказ. артисты (1933). 1909 елда Мәскәү театр уч-щесен тәмамлый. 1909–26, 1931–34, 1942–44 елларда Зур театр солисты. 1944–47 дә Татар опера һәм балет театрының баш балетмейстеры. 1947 дән Кыргыз опера һәм балет театры (Фрунзе) баш балетмейстеры. Казанда классик хореография нигезендә «Шүрәле» (Ф.Яруллин, 1945, I–III актлар), «Жизель» (А.Адан, 1945), «Бакчасарай фонтаны» (Б.Асафьев, 1946), «Аккош күле» (П.Чайковский, 1947) балетларын куя. Ж.ның югары башкару осталыгы аның балетмейстерлык эшчәнлегендә дә чагыла. Классик бию тарафдарларыннан санала.

*В.Н.Горшков.*

**ЖУ́КОВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2008 елда 232 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 67%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Еремеево исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, урман кисү, балта эшләре, мич чыгару, тимерчелек, руда чыгару б-н шөгыльләнә; тегермәнчеләр, приказчиклар, көтүчеләр булып эшли. 20 йөз башында Ж.да чиркәү, земство мәктәбе була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 537 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 873, 1880 дә — 715, 1910 да — 510, 1913 тә — 501, 1920 дә — 475, 1926 да — 467, 1938 дә — 474, 1949 да — 271, 1958 дә — 176, 1970 тә — 75, 1979 да — 215, 1989 да — 238, 2002 дә — 249 кеше.

**ЖУКО́ВСКИЙ** Павел Тимофеевич (1833, Кострома ш. — 1.3.1900, Казан), архитектор, 1848–54 елларда С.-Петербург төзүчеләр уч-щесендә укый. 1854 тән Казан губерна төзелеш комиссиясендә. 1856 дан Казан шәһәр архитекторы. 1866 дан, төзелеш комиссиясен Казан төзелеш бүлеге итеп үзгәрткәннән соң, штаттан чыгарыла. 1871 дән ялда. 1867–72 дә Казан өяз уч-щеләре советы әгъзасы. 1874–77, 1880–83 тә Казан губернасы земство җыены гласные (10 чакырылыш дәвамында), биредә шәһәрне төзекләндерү һәм төзелеш комиссиясе эшендә катнаша. Ж. проектлары буенча Казанда костёл (1855–58), округ психиатрия хастаханәсе (1866–69, А.Т.Жуковский б-н бергәләп), торак йортлар төзелә. Төзелеш мәсьәләләренә караган күп кенә мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Несгораемые крестьянские строения и опыт постройки их в Казанской губернии // Зодчий. 1881. № 2.

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы кон. 18 в. — нач. 20 века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М. Мортазина.*

**ЖУРАВЛЁВ** Борис Леонидович (25.4.1946, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1993), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1969 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, химик технологияләр ф-ты деканы (1996–2007 дә), Нефть, химия һәм нанотехнологияләр ин-тында директор урынбасары (2007 дән). Хезмәтләре локаль тутыгу процесслары теориясенә, металларны тутыгудан саклауга карый. Ж. күп катламлы гальваник капламнарның кыр (коррозион станцияләр) һәм лаб-я шартларында электрохим. коррозия халәте закончалыкларын билгели. Коррозион сынау шартлары агрессивлыгының коррозион станцияләр урнашкан р-ннардагы метеорологик үзенчәлекләргә бәйле булуын ачыклый. Коррозион сынау шартларының агрессивлыгы критерие һәм капламнарның тутыгуга чыдамлыгы нигезендә гальваник капламнарның файдалы эш вакытын фаразлау ысулын эшли. Капламнарның тутыгуга чыдамлыгын билгеләү өчен кулонометрик алым куллана. Металларның тутыгуга тотрыклылыгы динамикасын саклый, тутыгуны акрынайту процессларын көчәйтә, металлар өслеген эшкәртүнең тутыгуга бирешми торган ысулын тәкъдим итә.

Х е з м.: Прогнозирование коррозионной стойкости гальванических покрытий // Гальванотехника и обработка поверхности. 1994. Т. 3. № 4 (автордаш); Резонансные явления при анодном растворении пассивирующихся сплавов // Электрохимия. 1999. Т. 35, № 6 (автордаш); Диаграмма коррозионной стойкости бинекель-хромовых покрытий // Гальванотехника и обработка поверхности. 2001. Т. 9, № 3.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ–КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЖУРАВЛЁВ** Иван Игнатьевич (17.4.1833, Уфа губ., Бәләбәй өязе Нагайбәк а. — 1884), нәкышьче, педагог. 1861 елдан — САнең ирекле укучысы, 1866 да гимназияләрдә рәсем укытучысы дәрәҗәсе ала. Казанда эшли, Казан укытучылар ин-тында рәсем предметын укыта (1876–83). «Крәстиян», «Билгесез кеше портреты» (1871), «Г.И.Панаева портреты», «Капитан В.П.Филиппович портреты» (1870 еллар) кебек реалистик психол. портретлар иҗат иткән аз санлы осталарның берсе. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.



П.Т. Ж у к о в с к и й. Казанда психиатрия клиникасы. 1869.

*Әд.:* Т р о и ц к и й С. Историческая записка о Казанском учительском институте за 25 лет его существования. К., 1901; Д у л ь с к и й П.М. Русские мастера в Казанском музее // Казан. музейный вестн. 1922. № 2; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1983. Т. 4.

**ЖУРАВЛЁВ** Иван Николаевич (? — 17.5.1895), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, шәһәрнең нәселдән күчмә мактаулы гражданы, җәмәгать эшлеклесе. Аның этисе 1 нче гильдия сәүдәгәр, Ярославль губернасы Рыбинск шәһәренең нәселдән күчмә мактаулы гражданы Николай Михайлович (? – 1872) эре сәнәгатьче һәм йөк кораблары хуҗасы була (аның пр-тиеләренең еллык гомуми кереме 52 млн. сумга җитә, аларда 2800 кеше эшли). Ж. — ярма яру (Бишбалтада) һәм аракы з-длары (Казан өязе, Сабакай вол., Усад а.) хуҗасы. Ашлык, ярма һәм он б-н сату итә. 1873 елдан Казан шәһәр думасы гласные. Казан сәүдәгәрләр биржасы рәисе. 1886 да бертуганы Михаил б-н Рыбинскида «Николай Журавлёвның уллары» сәүдә йортын оештыра (капиталы 100 мең сум); буксир пароходлары һәм арканнар б-н сәүдә итәләр. Ж. 1885 тә Казанда 288 кешелек бушлай төн кунып чыгу йорты ачуга һәм аны тотуга акчалата ярдәм итә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Т. 1; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**ЖУРАВЛЁВ** Тихон Кононович (13.8.1913, хәзерге Воронеж өлкәсенең Лиски р-ны Залужный а. — 24.1.1985, Казан), язучы. 1937–46 елларда Мәскәү хәрби округының «Красный воин» г-тасында, «На разгром врага», «Суворовец», «На страже Родины» фронт г-таларында эшли. 1949 дан Казанда яши. Хәрби-патриотик тема язучы иҗатында сугыштан соң да күп еллар дәвам итә: «Рядовой Антипов» (1950) повесте, «Сугыш турында хикәяләр» («Рассказы о войне», 1958), «Плацдарм» (1960), «Солдат турында сүз» («Слово о солдате», 1962), «Батырлык» («Подвиг», 1963), «Хәрби повестьлар» («Военные повести», 1972) хикәя һәм повестьлар җыентыклары, «Сугыш булды» («Была война», 1961) новеллалар җыентыгы. «Комбайнчылар» («Комбайнёры», 1954) повесте, «Курган» (1955) романы, «Авыл өстендә йолдызлар» («Звёзды над селом», 1966), «Авыл повестьлары» («Сельские повести», 1980) җыентыкларына кергән әсәрләре авыл тормышыннан алып язылган. Ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Ш к е р и н М. Военные повести Тихона Журавлёва // Красная звезда. 1958. 15 июля; Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ЖУРБЕ́НКО** Лариса Никитична (21.2.1948, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2000). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлый. Казан технол. ун-тында эшли, югары матем. каф. профессоры (2000 нән). Хезмәтләре кире кырый мәсьәләләрнең корректлылыгын тикшерүгә карый. Ж. аналитик функцияләр теориясендәге кире кырый мәсьәләләр чишелешенең тотрыклылыгын тикшерә һәм технол. ун-ты студентларын күппрофильле матем. әзерләү өчен дидактик система эшләп гамәлгә кертә.

Х е з м.: Вопросы корректности в обратных задачах // Труды семинара по краевым задачам. К., 1979. Вып. 16 (автордаш); Дидактическая система гибкой математической подготовки. К., 1999; Математика: Уч. пос. М., 2006 (автордаш).



И.И. Журин.

**ЖУ́РИН** Иван Иванович (28.3.1915, Казан губ., Казан өязе Осиново а. — 16.10.2001, Яшел Үзән р-ны Осиново а.), тимерьюлчы, Соц. Хезмәт Герое (1959). 1932–75 елларда Горький тимер юлының Казан бүлеге Юдино станциясендә эшли. Герой исеме тимер юл транспорты эшен үстерүдә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р у м я н ц е в Е. Журин Иван Иванович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; А р х и п о в В. Осиновские страницы. К., 2002; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003..

*И.Н.Афанасьев.*

**ЖУРНА́Л**, вакытлы матбугат басмаларының бер төре. Казан губернасында беренче Ж. «*Казанский вестник*» 1821 елда нәшер ителә башлый. 1834 тән 19 йөзнең 1 нче яртысында шул юнәлештәге Ж.лар арасында иң яхшыларыннан саналган «*Учёные записки Казанского университета*» ж-лы чыга башлый. «*Заволжский муравей*» исемендә хосусый ж-лның дөнья күрүе Россия матбугаты тарихында күркәм бер күренеш буларак кабул ителә. «*Волжский вестник*»ның чыга башлавы Идел-Кама төбәгенең мәдәни тормышында зур вакыйга була. Төрле вакытта төрле уку йортлары, оешмалар, фәнни җәмгыятьләр тарафыннан том, кисәк, чыгарылыш саннары күрсәтелгән Ж. һәм җыентыклар нәшер ителә: «Учёные записки ветеринарного института», «*Известия Астрономической обсерватории Энгельгардта*», «*Труды Казанского фотографического общества*», «*Труды Казанского общества пчеловодства*», «*Журнал Казанского общества пчеловодства*» һ.б. Казан уку-укыту округы басмаларында («*Начальственные распоряжения по Казанскому учебному округу*», «*Циркуляр по Казанскому учебному округу*») попечитель боерыклары, попечительләр советы, гимназияләрнең пед. совет утырышлары беркетмәләре, еллык хи-




саплар, мәктәпләрнең саны турында мәгълүматлар басыла. Казан ун-ты каршында фәнни җәмгыятьләр оештырылу күпсанлы фәнни басмалар нәшер итүгә шартлар тудыра («Труды Казанского общества любителей отечественной словесности», «*Записки Императорского Казанского экономического общества*», «*Дневник Казанского Общества врачей при Императорском Казанском университете*», «*Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете*», «*Известия физико-математического общества при Казанском университете*», «*Неврологический вестник*»), аларда, шул җәмгыятьләрнең эшчәнлеген төрле яклап яктырту, утырыш беркетмәләрен, эшчәнлекләре турындагы отчётларын биреп бару б-н беррәттән, гуманитар һәм фәнни-табигыять фәннәре турында да мәгълүматлар бирелә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башларында махсус һәм хуҗалык тармакларына караган Ж.лар нәшер ителә: «*Городской и сельский учитель*», «*Вестник образования и воспитания*», «*Казанский медицинский журнал*», «*Пчеловод*», «*Самодеятельность*», «*Трудовой путь*», «*Шкура, кожа и обувь*». Православие һәм миссионерлык журналларында («*Православный собеседник*», «*Инородческое обозрение*», «*Церковно-общественная жизнь*», «Сотрудник Приволжской миссии») дин эшлекләренең, күренекле Казан галимнәренең (тарихчылар, тюркологлар, телчеләр, этнографлар) православие нигезләрен пропагандалаучы мәкаләләре урын ала, әҗнәбиләр (башка диндәге кешеләр) мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре, ислам турындагы материалларга урын бирелә, татар һәм чуаш телендә чыккан басмаларга библиографик күзәтүләр басыла. 1905–07 елгы рев-ция җиңелгәннән соң, илдә реакция хөкем сөргәндә, декадентлык юнәлешендәге күп кенә әдәби-нәфис, рәсемле Ж.лар барлыкка килә, аларда Казан зыялыларының идея һәм рухи эзләнүләре чагыла; «*К свету*», «*Волжские дали*», «*Метеор*», «*Муравейник*», «*Наш край*», «*Театр и экран*» шундыйлардан.

19 йөз башыннан ук татар җәмгатьчелеге туган телдә вакытлы матбугат басмалары чыгару хокукын даулый, ләкин бу хокукны ул 1905–07 елларда гына алуга ирешә. Россиядә татар телендә нәшер ителгән беренче басма Ж.лар арасында — Оренбургта чыккан «*Карчыга*» (1908–17), «*Чукеч*» (1906–10), «*Шура*» (1908–17); «*Әл-гаср әл-җәдид*» (Җаек ш., 1906–07) һ.б. Татар телендә беренче басма Ж. «*әд-Дин вә әл-әдәб*» 1906 елда Казанда чыга башлый. 1905 тә беренче татар Ж.лы Россиядән читтә дә барлыкка килә: Истамбул шәһәрендә «*Казан*» ж-лы чыга башлый. Татар телендә чыккан Ж.ларның нигезен иҗтимагый-сәяси басмалар тәшкил итә. Аларда татар халкы язмышына, аның милли яңарышына, мәдәнияте һәм мәгарифе үсешенә кагылышлы кискен мәсьәләләр куела. Рев-циягә кадәр чыккан журналлар татар милли хәрәкәтенең революцион-демократик, буржуаз-либераль һәм консерватив юнәлешле төп агымнары арасында барган көрәшне чагылдыра. Консерватив агымның иң күренекле вәкиле — «*Дин вә мәгыйшәт*» ж-лы (Оренбург ш., 1906). «Карчыга», «*Туп*» (Әстерхан ш., 1907), «*Яшен*» (Казан, 1908–09), «*Ялт-йолт*» (Казан, 1910–18) ж-ллары демократик лагерьга карыйлар, аларда искелек калдыкларынаябышып ятучылар еш кына сатирик рәвештә фаш ителә. Казанда чыккан «*Аң*» (1912–18), «*Тәрбия*» (1908), «*Мәктәп*» (1913–14) ж-ллары демократик идеяләрне үткәрәләр. Либераль юнәлештәге «Шура», «*Сөембикә*» (Казан, 1913–18) һ.б., нигездә, мәдәни-агарту эшләрен максат итеп куялар. Демократлар кебек үк, либераль матбугат та халыкларның тигез хокуклылыгы идеясен пропагандалый, патша хөкүмәтенең изү, хатын-кызлар хокукларын кысу сәясәтенә каршы чыга. Татар ж-ларының күпчелегендә милли әдәбият үсешенә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә, күренекле һәм башлап язучы авторларның оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләре басыла. Бу мәсьәләдә бигрәк тә «Әл-гаср әл-җәдид», «Аң», «Шура», «Ялт-йолт» ж-ллары үрнәк булып тора. Аларда татар әдәби теле, әдәбият белеме, әдәби тәнкыйтькә кагылышлы мәсьәләләр яктыртыла. «*Акмулла*» (Җаек ш., 1911–16), «*Кармак*» (Оренбург ш., 1915–17), «Карчыга», «Туп», «*Уклар*», «*Чикерткә*» (Оренбург ш., 1906), «*Чүкеч*», «Яшен» аеруча популярлык казана. Күп профильле, иҗтимагый проблемаларны киң яктыртырга омтылучы ж-ллар б-н беррәттән махсуслаштырылган басмалар да чыгарыла. Вакытлы матбугатта татарларга белем бирү, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләренә зур урын бирелә. Бу проблемалар «Тәрбия», «Мәктәп», «*Мөгаллим*» (Оренбург ш., 1913–14) ж-лларында яктыртыла; балалар өчен «*Тәрбиятел-әтфаль*» (Мәскәү, 1907), «Ак юл» (Казан, 1913–16) нәшер ителә. Икътисад үсеше мәсьәләләре «Икътисад» (Самара ш., 1908–13), «*Русия сәүдәсе*» (Казан, 1912–17) ж-лларында урын ала. Хатын-кызлар өчен «Сөембикә» ж-лы чыгарыла, анда хатын-кызның иҗтимагый тормышта тоткан роле, аның икътисади хәле, хокукларын яклау проблемалары күтәрелә. 1917 елга кадәр Россиядә татар телендә Ж. тибындагы 30 лап басма чыга. «Казан» ж-лыннан тыш, Төркиядә 1917 гә кадәр төрек телендә — «*Тәгарифе мөслимин*», «*Түрк юрду*», гомумтөрки телдә әдәби-дини җыентык «Ислам» һ.б. нәшер ителә. Февр. рев-циясе Россиядә татар вакытлы матбугаты үсешенә яңа этәргеч ясый. 1917 дә татар телендә чыгучы ж-ларның саны арта, яңалары: дини, иҗтимагый-сәяси «*Мохтарият*» (Уфа ш.), икътисади «*Уфа кооператоры*» (Уфа ш.), сатирик ж-ллар «*Чаян*» (Ташкент), «*Садак*» (Верный ш.), хатын-кызлар өчен «*Азат ханым*» (Әстер-

хан ш.), балалар өчен «*Балалар дөньясы*» (Казан) һ.б. чыга башлый.

Октябрь рев-циясеннән соңгы социаль-сәяси режим һәм өстенлек итүче идеологиянең үзгәрүе нәтиҗәсендә вакытлы матбугатның характеры да яңара. Казанда шактый иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис, икътисади ж-ллар нәшер ителә башлый. 1920 нең декабрендә ТАССРда әйдәп баручы ж-лларның берсе — «*Вестник Татарского областного комитета ВКП(б)*»ның 1 нче саны чыгарыла. Совет хакимиятенең беренче елларында чыккан иҗтимагый-сәяси ж-ллар арасында «Красный террор» (Чех-словак фронтында контрреволюциягә каршы көрәш буенча Гадәттән тыш комиссия органы, 1918), «Молодые побеги» (РКСМның Казан губкомы органы, 1919), «Молодой коммунист» (РКСМның Татарстан өлкә ком-ты органы, 1920), «*Шурамтус*» (РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршындагы Үзәк чуаш бүлеге органы, 1919–21) була. Шулай ук ведомстволарга караган ж-ллар барлыкка килә: «Вестник народного хозяйства» (Казан Халык хуҗалыгы советы һәм Профсоюзлар советы органы, 1918–20), «Вестник отдела управления города Казани и губернии» (1918–19), «Бюллетень Наркомпрода Татреспублики» (1918–20), «Вестник труда» (ТАССР Хезмәт халык комис-ты органы) һ.б. Крәстиянгә Совет идеологиясенең тәэсирен көчәйтү өчен рус телендә «*Казанский земледелец*», татарча «*Авыл тормышы*», «*Татарстан авыл хуҗалыгы*», мари телендә «*Куралшэ*», чуаш телендә «*Сер еслекен*» һәм «*Ана*» ж-ллары чыгарыла башлый. Революциягә кадәрге басмаларның күбесе чыгудан туктый яки ябыла. Казандагы фәнни ж-ллардан «Известия Астрономической обсерватории Энгельгардта», «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете», «Известия Физико-математического общества при Казанском университете», «Казанский медицинский журнал», «Учёные записки Казанского университета» басмаларына бу язмыш кагылмый, алар чыгуларын дәвам иттерәләр. Революциядән соңгы беренче елларда яңа фәнни ж-ллар чыгарыла башлый: «*Вестник Казанской областной с.-х. опытной станции*», «*Вестник просвещения ТССР*», «*Казанский библиофил*», «*Казанский музейный вестник*», «*Пути революции*».

Совет хакимиятенең большевистик булмаган вакытлы матбугат басмаларын ябу сәясәте күп кенә татарча ж-лларның, ш.и. «Аң», «Балалар дөньясы», «Дин вә мәгыйшәт», «Мохтариат», «Сөембикә», «Шура», «Ялт-Йолт» һ.б.ның ябылуына китерә. Октябрь рев-циясеннән соң татар интеллигенциясенең шактый өлеше чит илләргә китә. Аларның тырышлыгы б-н татар эмигрантлары тормышында әһәмиятле урын тоткан ж-ллар чыгарыла башлый: Төркиядә — «Идел-Урал», «Казан», «Түрк юрду»; Германиядә — «*Азат Ватан*», «*Азат Шәрекъ*», «*Германча-татарча белешмә — Дойч-татаришес нахрихтенблат*», «*Яңа милли юл*»; Финляндиядә — «*Шималь очкыннары*»; Польшада — «*Жиче татарске*», «*Рочник татарски*»; Кытайда — «Азат Шәрекъ», «*Ерак Шәрекъ*», «Пилмән», «Шәкертләр таңы», «Шәрекъ авазы», «Ялкын»; Япониядә — «*Яңа япон мөхбире*» һ.б.

1920 еллар башында РСФСРда барлыкка килгән икътисади авырлыклар аркасында матбугатны үзфинанслауга күчерүдән туган кризис вакытында басмаларның шактые чыгудан туктый («Рабочий», «Рабочий химик» һ.б.). 1923 тә ТАССРда Ж. тибындагы 20 басма чыга. РКП(б) ҮКның «Ведомство матбугатын чыгаруны кыскарту турында»гы карарыннан соң 1924 тә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты «Казанский музейный вестник», «Вестник просвещения ТАССР», «*Сельское и лесное хозяйство Татарстана*», «*На страже законности и порядка*» һ.б. Ж.лар, Мәгариф халык комиссариаты һәм Казан шәһәр советы бюллетеньнәре чыгудан туктатыла. 1925 ел ахырына ТАССРда 10 Ж. кала, шуларның 6 сы татар телендә була. Бу чаралар иҗтимагый-сәяси басмаларга кагылмый. 1925 тә профсоюз ж-лы «*Пролетарий Татарстана*» чыга, 1926 да РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты татар телендә — «*Җитәкче*», 1928 дән ТАССР ҮБК рус һәм татар телләрендә «*Татарстан Советлары*» ж-лларын чыгара башлыйлар. 1920–30 елларда чыккан яңа фәнни ж-ллар арасында «*Вестник Казанского института научной организации труда*», «*Вестник Научного общества татароведения*», «*Вопросы трахомы*», «*Записки Центрального архива Татарской Соц. Сов. Республики*», «*Известия Казанского института сельского хозяйства и лесоводства*», «*Татарстан*» һ.б. була.

1920 елларда СССРда формалашкан партия-совет матбугаты системасына үзәк ж-ллардан «*Кызыл Шәрекъ*», «*Яшь эшче*», «*Кечкенә иптәшләр*», «*Юлдаш*» (барысы да Мәскәүдә) һ.б., республика, өлкә һәм губерна ж-ллары — «Коммунист» (Эстәрлетамак ш.), «*Кызыл юл*» (Ташкент), «*Ленин юлы*» (Уфа ш.) һ.б. керә. 1920–30 елларда мәгариф органнары да шактый ж-ллар бастыра; ТАССРда — «*Мәгариф*», «*Татарстан педагогия җәмгыяте хәбәрләре*», «*Уку ударнигы*», «*Укучы сәхифәсе*», «*Укытучы*», «*Яшь педагог*» һ.б., ш.у. башка өлкәләрдә — «*Мәгариф атнасы*» (Ташкент), «*Мәгариф эшләре*» (Эстәрлетамак, Свердловск ш.), «*Мәгариф эшчесе*» (Мәскәү), «*Методик җыентык*» (Мәскәү, Самара, Свердловск), «*Очкын*» (Ташкент) һ.б. ж-ллар чыга. Бу елларда: сатирик — «*Бабич*» (Уфа ш.), «*Чаян*» (Казан), «*Сәнәк*» (Уфа ш.)», «Чаткы» (Царицын ш.); яшьләр өчен — «*Колхоз яшьләре*» (Казан), «*Ударниклар*», «*Яшь авыл*» (Мәскәү); атеистик — «*Сугышчан алласызлар*» (Казан), «*Сугышчан алласыз*» (Мәскәү); хатын-кызлар өчен — «*Азат хатын*» (Казан); балалар өчен — «*Октябрь баласы*» (Мәскәү) ж-ллары нәшер ителә. Керәшен татарлар өчен РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты махсус «*Белемнек*» ж-лын чыгаруны оештыра. 1930 еллар ахырына, милли сәясәтнең үзгәрүе сәбәпле, ТАССРдан читтә чыгучы ж-лларның күбесе ябыла.

1980 елларның 2 нче яртысы — 1990 еллар башында иҗтимагый-сәяси тормышның демократияләшүе нәтиҗәсендә ж-лларның эчтәлекләре сыйфат ягыннан үзгәреш кичерә. Кайберләре исемен үзгәртә, мәс., «Коммунист Татарии» — «*Татарстан*», «Азат хатын» — «*Сөембикә*», «Совет мәктәбе» — «*Мәгариф*» исемендә нәшер ителә. 1989 дан яшьләр өчен әдәби «*Идел*» ж-лы чыгарыла башлый. 1990 елларда «*Казань*», «*Мирас*» ж-лларының барлыкка килүе республиканың иҗтимагый һәм мәдәни тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Шулай ук яңа фәнни ж-ллар чыгарыла башлый: «*Вертеброневрология*», «*Научный Татарстан*», «*Неврологический вестник*», «*Татарика*», «Татарская археология», «*Панорама-форум*», «*Фән һәм мәктәп*», «*Фән һәм тел*» һ.б.

2010 елның 1 гыйнварына ТРда 303 журнал, ш.и. 28-е татар телендә теркәлгән.

Чыг.: Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Әд.:* Татарча беренче педагогик журналлар // Совет мәктәбе. 1983. № 3; Мәһдиев М. Татар журналлары // Казан утлары. 1989. № 6; Ибраһимов Ф. Татарча белем һәм тәрбия журналлары // Мәгариф. 1993. № 4; Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7; Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Пономарёв П.А. Казанская периодическая пресса: Библиогр. заметки // Казанский литературный сборник. К., 1878; Петровский Н.М. По поводу столетия Казанской периодической печати // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1911. Т. XVII, вып. 3; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; шул ук. Голос времени. Газеты и журналы на татарском языке 1905–1990 гг.: Указ. К., 1992; Гимадиев У.И. Сила сатирического слова. К., 1987; Мусульманская печать России в 1910 г. Оксфорд, 1987; Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать (1905–1907). М., 1988; Казанская периодическая печать XIX — начала XX века: Библиогр. указ. К., 1991; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX века: Библиогр. указ. К., 2000.

*Р.А.Айнетдинов, Г.Р.Заманова.*

**ЖУРНАЛИ́СТИКА**, мәгълүмат туплау, эшкәртү һәм аны газета, журнал, радио, телевидение, кино, Интернет һ.б. массакүләм мәгълүмат чаралары аша тарату эшчәнлеге; иҗтимагый-сәяси, мәгълүмати һәм иҗади эшләрнең бер төре. Ж. Татарстанда күп милләтле булып формалаша. Казан губернасында беренче басмалар рус телендә 19 йөзнең 1 нче яртысында барлыкка килә («Казанские известия» (1811–20), «Казанские губернские ведомости» (1830–1917) г-талары; «Заволжский муравей» (1832–34), «Учёные записки Казанского университета» (1834 тән) ж-ллары һ.б.).

Татар телендәге вакытлы матбугат Казанда 1841 елда «Горрәнамә» исемендә басылган календарьдан (нашире Р.Әмирханов) башланып китә. Еллык өстәл календарьлары нәшер итү б-н К.Насыйри шөгыльләнә, 1871–95 елларда аның тарафыннан 24 календарь чыгарыла. Беренче төрки-татар телендә чыккан «*Тәрҗеман*» г-тасы 1885–1918 дә Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) нәшер ителә. Татар телендә газета һәм журнал-

ларның чыгарыла башлавы 20 нче йөз башларына карый. Аларның берсе — «Хөррият» г-тасы Казанда 1904 елда гектограф ысулы б-н басыла. Беренче басма г-та «*Нур*» 1905–17 елларда Петербургта нәшер ителә. Казанда татар вакытлы матбугаты «*Казан мөхбире*»ннән (1906–17) башланып китә.

Татарстанда чуаш, мари, удмурт газеталары чыгарыла башлый. Хәзер ТРда 600 дән артык басма исәпләнә: газеталарның барлык төрләре (республика, тармак, шәһәр, район, күп тиражлы; яшьләр, хатын-кызлар өчен; көндәлек, атналык h.б.) һәм журналлар (иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис, фәнни, сатирик h.б.) татар, рус, чуаш, удмурт телләрендә нәшер ителә. ТРдан читтә татар телендә 30 дан артык газета чыгарыла (к. *Газета*).

Ж.ның состав өлешен радиожурналистика тәшкил итә. Казанда беренче радиотапшырулар 1918 дә барлыкка килә. Татарстанда даими радиотапшырулар 1927 нең 7 ноябрендә татар һәм рус телләрендә, 1933 тән чуаш, 1958 дән удмурт телләрендә оештырыла. Радиотапшыруларның төп өлеше «*Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе*, «*Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе* тарафыннан алып барыла. ТРның һәр районында радиоредакция һәм коммерция радиостанцияләре эшли.

ТРдан читтә яшәүче татарлар өчен «Татарстан авазы» тапшырулары трансляцияләнә. 1959 ның 7 ноябрендә Татарстанда телевидение тапшырулары башлана. Моның нәтиҗәсендә массакүләм мәгълүмат чаралары системасы киңәя. 1960 ның гыйнварында Казанда күчмә телевидение станциясе файдалануга тапшырыла, август аеннан телевизион кинофильмнар төшерү эшенә керешелә. 1960–70 елларда Казан телеүзәгенең куәте арттырыла, аның тапшыруларының язмалары Үзәк телевидениедән, ш.у. Идел буе, РСФСР һәм Урта Азиянең кайбер респ-калары студияләреннән трансляцияләнә башлый. Видеоязмалар һәм төсле телевизион тапшырулар барлыкка килә. Хәзер ТР шәһәрләрендә һәм кайбер районнарда җирле телевидение тапшырулары арта бара, барлыгы 65 телерадиокомпания теркәлгән (2004).

1920 еллар башында Казанда журналистлар әзерли торган төрле курслар эшли. Бераз вакыттан соң редакцияләргә Казанда һәм Мәскәүдә гуманитар вузларны тәмамлаган белгечләр эшкә килә башлый. Җитәкче кадрлар Мәскәү, Ленинград, Куйбышев, Горький шәһәрләре партия мәктәпләрендә әзерләнә, үз белемен күтәрә. 1950 еллар ахырында Казан ун-тының татар филологиясе бүлегендә Ж. буенча махсус белем бирү өчен специальләштерү эше башлана. 1962 дә Казан ун-тының тарих-филол. ф-тында Ж. кафедрасы һәм бүлеге ачыла. Ж. белгечләре журналистика һәм социология ф-тында белем алалар, рус һәм татар телендә яза торган студентлар өчен специальләштерү үткәрелә.

ТРда Ж., фән буларак, Казан ун-тында Ж. кафедрасы булдырылганнан соң үсеш ала. Татар Ж. тарихы, теориясе һәм практикасы турындагы хезмәтләрнең авторлары — Ф.И.Әгъзамов, А.К.Айнетдинов, В.З.Гарифуллин, Е.С.Дорощук, Т.С.Карлова, Р.М.Нуруллина, И.Г.Пехтелев, Л.М.Пивоварова, И.М.Низамов, А.А.Роот.

1918 нең декабрендә Казанда Журналистлар берлеге оештырыла, 1919 да ул Казан һәм губерна журналистларының коммунистик берлеге дип үзгәртелә. 1957 нең июлендә ТАССР Журналистлар берлеге төзелә. 1992 елда Устав кабул ителә, аның буенча *ТР Журналистлар берлеге* БДБ илләре журналистлар берлекләре конфедерациясе составына керүче бәйсез иҗат оешмасы дип танылa. Ул матбугат, теле- һәм радиотапшырулар, китап нәшриятлары, мәгълүмат агентлыкларында эшләүче 700 ләп хезмәткәрне берләштерә. 1993 тә Президент Указы нигезендә ТРда һәм аннан читтә яшәүче татарлар тормышы хакында сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни мәгълүматлар туплау һәм аларны тарату максатында ТР мәгълүмат агентлыгы «*Татар-информ*» оештырыла. Матди-техник әзерлекне ныгыту, дәүләт һәм Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү б-н Респ-каның матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «*ТАТМЕДИА*» (2003 тән) шөгыльләнә. ТР Журналистлар берлеге ел саен «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» (к. *Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге бүләкләре*), яшь журналистларның «Алтын каләм — Золотое перо» конкурслары үткәрә. Ш.у. к. *Журнал, ТРда радиотапшырулар, Массакүләм мәгълүмат чаралары, ТРда телевидение тапшырулары*.

Чыг.: Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Әд.:* Әгъзамов Ф.И. Яшәү көче. К., 1977; шул ук. Үзәктә — кеше. К., 1982; Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. К., 1981; Жанры журналистики. К., 1972; Нуруллина Р.М. Татарская революционно-демократическая печать в период подготовки Октябрьской революции. К., 1974; шул ук. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–25). К., 1978; Пивоварова Л.М. Русский очерк 80–90-х годов XIX века. К., 1978; Роот А.А. История жанра передовой статьи. К., 1980; шул ук. «Колокол» возрождённый. 1868–1869. К., 1989; Агзамов Ф.И. Гуманизм советской журналистики. К., 1984; шул ук. Тукай — журналист. К., 1986; шул ук. Журналистское исследование активности личности. К., 1989; Айнутдинов А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984; шул ук. Центральная пресса: Жизнь автономных республик. К., 1985; Гарифуллин В.З. Типы структурной организации журналистского текста. К., 1997; Дорощук Е.С. Искренность без предела. Педагогика и психология журналистской деятельности. К., 2000.

*Ф.И.Әгъзамов, Р.А.Айнетдинов.*

**ЖУТА́ЕВ** Александр Михайлович (22.11.1930, Буа р-ны Недремаевка а. — 20.2.2002, Лениногорск ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1989). Әзәрбайҗан индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Әзәрбайҗан ССР нефть промыселларында инженер, өлкән инженер. 1956–61 елларда «Татбурнефть» (Лениногорск ш.) тресты тампонаж конторасының торба-турбиналар цехында инженер, җитәкче. 1961–63 елларда Лениногорск үзәк ремонтлау-механика з-дында баш инженер, 1963–65 тә директор. 1965–92 дә «Татнефть» ҖБнең «Лениногорскбурнефть» бораулау эшләре идарәсендә баш механик. Дәүләт бүләге бораулау җайланмаларын һәм чәчрәүләрне киметү җиһазларын булдырганы һәм сәнәгатьтә үзләштергәне өчен бирелә.

# Ж

**ҖАББАРБИРДЕ́ ХАН** (рус чыганакларында Иерем-Фәрдән) (? — 1417), Алтын Урда ханы (1416 елдан). Туктамыш ханның улы. Чокрый хан тәхеттән куылгач (1416) хан дип игълан ителә. Литваның бөек кенәзе Витовт ярдәменә таяна. Сарай аксөякләре арасында ныклы элемтәләре булмый. Идегәй тарафыннан бәреп төшерелә, Кырымдагы Италия колонияләрендә яклау табарга өмет итеп, шунда кача. Моңа җавап йөзеннән Идегәй Азак тирәсендәге Тана шәһәрен яулый, аны талап, Кафа шәһәрен камый һәм итальяннарны Җ.х.ны куарга мәҗбүр итә. Литвага барганда фетнәчеләр тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Г р е к о в И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды. М., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**ҖАББА́РОВ** Әхтәм Хөсәен улы (4.1.1945, Матвеевка, хәзерге Минзәлә р-ны Калморза а.), җәнлек үрчетү белгече, а.х. фән. д-ры (1995), проф. (2007), ТАССРның атказ. зоотехнигы (1985). 1970 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1970–74 елларда ТАССР А.х. министрлыгында зоотехник, өлкән зоотехник. 1970–81 дә Питрәч р-ны «Коммунар» җәнлек с-зы зоотехнигы. 1981–99 да Яшел Үзән р-ны «Раифа» җәнлек с-зы директоры. 1999 дан «Плодородие» фәнни-тикшеренү ин-ты дәүләт унитар пр-тиесе директоры. Беренчеләрдән булып чәшкеләр асрау өчен ябык абзарлар конструкциясен эшли. Җ. тәкъдим иткән күп катлы читлекләр кулланышта тикшерелә, тукландыру, эчерү, туклану калдыкларын һәм тирес чыгаруның комплекслы механикалаштырылган системасы әзерләнә. 1990–95 тә ТР халык депутаты. «Почёт билгесе» ордены, 2 медаль б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Промышленная технология содержания зверей. К., 2000; Переработка продукции животноводства. К., 2001 (автордаш); Специфика взаимодействия углеродного и азотного метаболизма у амаранта. К., 2006.

**ҖАББА́РОВ** Каюм Закир улы (7.3.1920, Казан губ., Лаеш өязе Агачбашы а. — 14.1.1996, Лаеш р-ны Державин а.), Дан орденының тулы кавалеры (6.5.1944, 6.3.1945, 15.5.1946), старшина (1946). Казан авиация з-дында эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 629 нчы укчы полкның 76 *мм*лы туп расчёты командиры (69 нчы армиянең 134 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Дала һәм 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Днепр (1943), Украина, Польшаны азат итү өчен барган сугышларда, Берлин һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 30 апрелендә Серкизув торак пункты (Украина ССРның Волынь өлкәсе Турийск р-ны) янындагы сугышта; 1945 нең 14 гыйнварында Висла елгасының сулъяк ярындагы Кохануг торак пункты (Польша, Пулавы шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак) тирәсендә дошман оборонасын өзүдә (расчёт б-н бергә 4 ут ноктасын юк итә); 1945 нең 24 апрелендә Альт-Мадлитц торак пункты (Германия, Франкфурт-Одер шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак) өчен барган сугышта (аның расчёты дошманның 3 ут ноктасын һәм 2 тубын сафтан чыгара) батырлыклар күрсәтә. 1946 дан Казанда яши. Казан механика з-дында компрессорчы булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш е в ч е н к о Н.Я. Звезды Славы. К., 1969; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ҖАББА́РОВ** Марсель Бакир улы (12.3.1947, Әтнә р-ны Түбән Бәрәскә а.), драма актёры, ТССРның халык артисты (1991), РФнең атказ. артисты (2004). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1968), Республика күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театры) труппасына кабул ителә. 1960 елларда фикер тарлыгына, катып калганлыкка каршы чыккан, заман проблемаларын бөтен тирәнлеге б-н аңлаган яшь кеше образын гәүдәләндергән рольләр башкара. Алар арасында комсомол райкомы секретаре Шакиров («Йөрәк янар өчен бирелгән», Т.Миңнуллин), Шамил (шул исем. пьеса, Р.Ишморатова), шагыйрь Сергей Чекмарёв («Онытма мине, кояш!», А.Абдуллин), Илһам («Мәхәббәт турында җыр», Ә.Атнабаев), Гөлүс («Бөркетләр кыяга оялый», И.Юзеев), Вафа («Хөкем алдыннан», К.Әмиров), Юрий («Мәхәббәтем хакына», Ю.Эдлис) һ.б. рольләре бар. Үз героеның киеренке фикер сөрешен оста сурәтләве — Җ. иҗатының характерлы үзенчәлеге. Җ. башкарган Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Пәрвяз («Ана йөрәге», А.Балакаев), Владик («Зарыгып көткәнем», А.Салынский), Пётр Христов («Вөҗданың ни әйтер?», Г.Данаилов) образлары сурәтләнү үзгәлеге б-н аерылып торалар. Яшь скульптор Айтуар («Хәтерлим мин гүзәл мизгелне», И.Юзеев), колхоз рәисе Солтан Фатыйхов («Кырларым-тугайларым», Т.Миңнуллин), Автор («Кара йөзләр», М.Гафури), нефтьче Кәрим («Хәзинә», Г.Ахунов), чекист Жура Сәетов («Соңгы атыш», У.Умарбәков), Микита карт («Сагышларым, гомер агышларым», А.Дударев) образлары өстендә эшләгәндә актёр этик проблемаларны чишүгә, кешелеклелек сыйфатларын чагылдыруга игътибар итә. Аның геройлары аз сүзле, тышкы пафос һәм рәсмилектән ерак, аларның тормышы рухи яктан бай, кылган гамәлләре мәгънәле. Психол. портрет остасы буларак, Җ. тискәре рольләрдә дә гаять кызыклы. Зөфәр Сабитов («Рәшә», Ә.Еники) образы аша обыватель фәлсәфәсен, Тәминдар («Сихерче», Н.Гыйматдинова) ролендә тормышта үз урынын таба алмаган кеше фаҗигасен, Поп («Кураж Ана һәм аның балалары», Б.Брехт) ролендә башкалар фикере б-н исәпләшмәүче, аларның кайгы-хәсрәтләренә битараф кеше образын гәүдәләндерә. Җ. башкарган мөһим рольләрдән Әхмәт Риза («Сәер кеше», Н.Хикмәт), Садыйков («Сөяркә», С.Шәкүров), Утташ кам («Ител суы ака торур», Н.Фәттах), Идрис Мусин («Мәхәббәтне саклагыз», Х.Төхфәтуллин) һ.б.ны күрсәтергә мөмкин.1985 елдан режиссёр буларак та Татар драма һәм комедия театрында берничә спектакль куя. Алар арасында «Кич» («Вечер», А.Дударев), «Гөнаһлы хатын» («Грешница», М.Сторожева), «Динсезләр» (Р.Ханнанов), «Карт гашыйк» (С.Шәкүров) һ.б. бар. Тәрҗемәләр, инсценировкалар, телевизион сценарийлар авторы. 1996 дан Казан гуманитар-пед. ун-тында яшьләр театры җитәкчесе.



К.З.Җаббаров.



М.Б.Җаббаров.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ҖАББА́РОВ** Ренат Солтан улы (21.8.1936, Үзбәкстан ССР, Әндиҗан ш.), генерал- майор (1982). Ташкент танк хәрби уч-щесен (1958), Сов. Союзы Герое Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1969, Мәскәү) тәмамлый. 1974–79 да Кавказ аръягы хәрби округында: танклар часте, 1975 тән мотоукчылар берләшмәсе командиры. 1979 дан Киев хәрби округында: танклар берләшмәсе командиры, 1986 дан гомумгаскәри берләшмә командиры урынбасары, 1988 елдан танклар берләшмәсе командиры урынбасары. Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ҖАГАЛДА́Й** (Яголдай, Jagoldai), 15–16 йөзләрдә Бөек Литва кенәзлеге карамагындагы зур булмаган ярым мөстәкыйль татар биләмәсе (хәзерге Курск өлкәсе терр-ясендә һәм аңа чиктәш җирләрдә булган дип фаразлана). 1438 елда Алтын Урдадан аерылып чыгучы-

лар нигез сала. 16 йөз башына кадәр Литва кенәзләренең вассал биләмәсе рәвешендә саклана.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Spuler B. Die Goldene Horde. Die Mongolen in Russland (1223–1502). Wiesbaden, 1965.

*И.Л.Измайлов.*

**ЖАЙДАКЛА́Р**, элпәканатлылар отрядыннан сабаксыман корсаклы паразит бөҗәкләр семьялыклары һәм өссемьялыклары төркеме. Гәүдә озынлыгы 0,21–45 *мм*. Йомырканы башка бөҗәкләрнең гәүдәсенә салалар, еш кына корбанына атланып (исеме шуннан), аларга личинкаларын яки йомыркаларын тышкы яктан беркетәләр. Личинкалары тәңкәканатлылар, элпәканатлылар, катыканатлыларда һ.б. бөҗәкләрдә, ш.у. үрмәкүчләрдә паразитлык итәләр. Ж. арасында аерым бер төргә генә җайлашкан паразитлар очрый. Кайберләре башка Ж.ның паразитлары булып тора. Чын Ж. семьялыгы (Ichneumonidae) төрләргә аеруча бай. 30 меңгә якын төре билгеле (башка бәяләмәләр буенча 100 меңнән артык). Россиядә 2 меңнән артык төре билгеле, Татарстан терр-ясендә 30 төр, аеруча Netelia agnatus еш очрый. Ж. личинкалары а.х. үсемлекләре корткычларында паразитлык итә, аларның санын көйләүче булып тора һәм үсемлекләрне биологик саклауда файдаланыла. Трихограмма (Trichogramma) ыругының кайбер төрләре яшелчә һәм җиләк-җимеш культуралары корткычларына каршы куллану максатыннан ясалма рәвештә үрчетелә. Табучы эфиальт төре (Ephialtes manifistator) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЖАЛМАВЫ́З**, татар, башкорт, казакъ, кыргыз фольклорында киң таралган җиде башлы явыз карчык образы. Кайбер галимнәр (Р.Г.Әхмәтьянов һ.б.) Жалмавыз сүзе гомумтөрки йолма — жалма (ялап алу, комсызлык б-н йоту мәгънәсендә) сүзеннән килеп чыккан дип саныйлар. Ж. гаять озын телле («җиде чакрымнан ялап ала»), корбаннарын тоташ килеш, чәйнәмичә генә йота. Кайвакыт *убырлы карчыкны* хәтерләтә («Яхшылыкка кире явызлык» дигән татар халык әкиятендә ул патша кызының канын эчә). Карурманнарда, тау куышлыкларында, кое төпләрендә яши (казакъ халык әкияте «Вәзир»). Ж.ның хәзерге образы шактый үзгәрешләр кичергән. Кайвакыт ул әкият геройларына ярдәм итәргә мәҗбүр: авыруларны, кулсызларны, аяксызларны йота һәм сәламәт килеш кире төкереп чыгара. Монда Ж. образы борынгы инициацияләрдә файдаланылган агач потлар б-н тиңләштерелә: Ж. тотемик хайван, нәселгә нигез салучы хатын-кыз вазифасын үти.

*Әд.:* Ярми Х., Жамалетдинов Л. Татар халык әкиятләре // Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. К., 1977. Т. 1; 1981. Т. 3; Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЖАМАЛЕТДИ́Н әс-САБАВИ́** (1780, хәзерге Саба р-ны Байлар Сабасы штп — 11.5.1866, шунда ук), шагыйрь, дин эшлеклесе. Габденасыйр *Курсави* шәкерте. Дини һәм шигъри әсәрләр авторы. Аеруча киң таралганы — силлабик шигырь б-н язылган һәм кеше гомеренең баскычлары турында бәян ителгән «Адәм угылы» фәлсәфи поэмасы (1812). Аның бу әсәре кулъязмалары татарлар яши торган күп урыннарда табыла. Берничә нөсхәсе ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында саклана.

*Әд.:* Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 том; Жамалетдин әс-Сабави // Нәҗмиев Т., Хуҗин М. Яшә, Саба-Йорт! К., 1999.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Габделгани Гафиятулла улы (10.8.1927, Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе, Кызыл Октябрь р-ны Писцы а. — 13.2.1980, Мәскәү), конструктор, 1955 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлый. 1948–80 елларда СССР Авиация министрлыгының 51 нче з-ды тәҗрибә КБнда (хәзер Мәскәү өлкәсе Реутов-6 шәһәрендәге «Машиностроение» ФҖБ) катлаулы ракета-космик комплекслар конструкторы, бер үк вакытта 1973 тән СССР Дәүләт оборона ком-ты йөкләмәсе буенча тәҗрибә КБнда төзелә торган «Алмаз» ракета-космик комплексның баш, әйдәп баручы конструкторы. СССР Хәрби Диңгез Флоты корабльләрен яңадан коралландыру өчен континенталь баллистик ракеталар төзүдә катнаша, идарә ителә торган «Салют-2», «Салют-3», «Салют-5» орбиталь станцияләрен әзерләү һәм җибәрү б-н җитәкчелек итә. Ике Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Илтөзәр Сарас улы (29.3.1944, Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.), невропатолог, психол. фән. д-ры (1991), проф. (1992). Космик психологиягә нигез салучыларның берсе. Кыргыз мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Совет Армиясендә: невропатолог, Төркестан һәм Урта Азия хәрби округлары психиатры. 1971 елдан Мәскәү хәрби округында, Ю.А.Гагарин исем. космонавтлар әзерләү үзәгендә, 1974 тән әйдәп баручы психолог. Үзара килешүчәнлек экологик-психологик концепция авторы. Тикшеренүләре иҗади фикерләү, сөйләм, төркемдә аралашу психологиясенә, экстремаль шартларда яшәргә яраклашу психологиясенә карый.

Хезм.: Авиационная и космическая медицина. М., 1980; Психология труда, инженерная психология. М., 1991.

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Ленар Шәйхи улы (17.12.1935, Буа р-ны Күзби а.), фольклорчы, филол. фән. канд. (1993), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1964–70 елларда ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тының муз. тапшырулар мөхәррире, 1970 тән Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Төп хезмәтләре татар халык әкиятләрен өйрәнүгә карый. «Татар халык иҗаты» исемле күптомлы фольклор җыентыгын төзүчеләрнең берсе (т. 1–13, 1976–93). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1989).

*А.Х.Садыйкова.*

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Нариман Кыяметдин улы (13.7.1946, Чүпрәле р-ны Югары Каракитә а.), нефтьче, «Татнефть» АҖнең «Прикамнефть» НГДУы башлыгы (1985 елдан), ТРның атказ. нефтьчесе (1993), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1997). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1971). 1964–68, 1971–85 елларда «Лениногорскнефть» НГДУында торбаларны пыялалау буенча слесарь, оператор, скважиналарны җир астында ремонтлау цехы башлыгы урынбасары, башлыгы (1982 дән), НГДУ башлыгы урынбасары, 1983 тән башлыгы булып эшли. Ж. җитәкчелегендә Зәй р-нында Зичәбаш (1989), Тукай р-нында Бикләң, Борды (1989), Сарайлы (1992), Минзәлә р-нында Бакчасарай (1994) чыганаклары эшкәртелә. 1990–95 тә ТР халык депутаты. ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Рәдиф Рифкать улы (27.10.1969, Чүпрәле р-ны Кече Чынлы а.), тел белгече, филол. фән. д-ры (2004), 1995 елда Казан пед. ун-тын тәмамлый. 1994–96 да ТР Мәгариф министрлыгының Республика фәнни-методик үзәгендә эшли. 1996 дан Татар гуманитар-пед. ун-тында (бүлекнеп, 1999–2002 дә ТР МК Аппаратының ТР халыклары телләрен үстерү бүлегенең баш референты); 2002–04 тә татар филол. ф-ты деканы, бер үк вакытта 2003 тән гомуми һәм чагыштырма филол. каф. мөдире, 2004 тән проректор, 2008 дән ректор. Хезмәтләре татар телен укытуның лингводидактик нигезләренә, татар теленең этник һәм мәдәни лексикасына, татар милли тел чаралары аша дөньяны танып белү нигезләренә карый. Татар халкының матди һәм рухи дөньясын тел аша тикшерә.

Хезм.: Лингводидактические основы обучения чтению на татарском языке учащихся начальных классов русских школ. К., 1999; Внутренний и внешний мир носителей татарской культуры через призму языка. К., 2003; Татарская культура в языковом отражении. М.–К., 2004.

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВ** Юнер Фәсхетдин улы (27.2.1927, Уфа ш. — 7.1.2005, Казан), инженер-механик, Татарстан «Радиоприбор» ЖБ ген. директоры (1971–94), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1983). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1952). 1952–53, 1957–59 елларда Казанда сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1959–60 та «Теплоконтроль» з-ды партия ком-ты секретаре, 1960–62 дә КПССның Казан шәһәре Идел буе райкомының 2 нче, 1962–66 да 1 нче секретаре. 1966–71 дә Татарстан «Радиоприбор» дәүләт пр-тиесе директоры, 1994–2000 дә ген. директоры киңәшчесе. Илнең авиация приборлары төзелеше үсешенә өлеш кертә. Ж. җитәкчелегендә һәм аның турыдан-туры катнашында Әлмәт, Лениногорск, Гродно (Белоруссия) шәһәрләрендә радио һәм приборлар з-длары, Казанда кою-механика производствосы оештырыла, җитештерү-техника һәм халык куллануы товарлары чыгару шактый арта. 1963–90 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость университета: Краткий биогр. справ. / КАИ. К., 2002.

**ЖАМАЛЕТДИ́НОВА** Лилия Юнер кызы (29.12.1955, Казан), гамәли матем. өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000). 1979 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң шунда ук эшли, гамәли матем. һәм информатика каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре идарә органнарының автоматлаштырылган системаларын проектлауга карый. Җ. җитәкчелегендә республика социаль саклау хезмәте оешмаларының автоматлаштырылган идарә системасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Обобщённая методика проектирования прикладных информационных технологий // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1999. № 3; Структура и состав распределённой автоматизированной системы управления налогообложения физических лиц // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2000. № 4.

**ЖАМАЛИ́ЕВ** Гаяз Җамали улы (17.12.1925, Мамадыш кантоны Түбән Арбаш а. — 28.04.2009, Арча р-ны Үрнәк пос.), урманчы, РСФСРның атказ. урманчысы (1968) Идел буе урман-техник ин-тын тәмамлый (Йошкар-Ола, 1951). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–53 елларда Балтач урманчылыгында урманчы ярдәмчесе, 1953–59 да Сорнар урманчылыгында урманчы, 1959–90 да Арча урман хуҗалыгында баш урманчы. Җ. җитәкчелегендә дәүләт урман фондының якынча 10 мең *га* мәйданында ясалма урман утыртмалары, Арча һәм Балтач р-ннарында якынча 5 мең *га* мәйданда кыр ышыклау урман полосалары үстерелә, алдынгы технологияләр кертелә, утырту материалларын үстерү, урман кисү, урманнарны карау эшләре механикалаштырыла. Республика урманчылары өчен киңәш-тәкъдимнәр авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ЖАМАЛИ́ЕВ** Салих Шакир улы (25.12.1921, Буа р-ны Кырык Садак а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1969). Сызрань танк уч-щесен (1942) һәм Бөтенсоюз читтән торып уку икътисад ин-тын (Мәскәү, 1957) тәмамлый. 1949–50 елларда Казан ашханә һәм ресторраннар тресты директоры урынбасары, 1951–53 тә Харьков өлкәсенең «Главрыбсбыт» конторасы управляющие урынбасары, 1954–57 дә Харьков сабын з-ды директоры урынбасары, 1958–65 тә Харьков ХХС Ит-сөт сәнәгате идарәсенең тәэминат, сату һәм транспорт бүлеге башлыгы урынбасары, 1965–69 да Украина ССР ФА Икътисад ин-тының Харьков бүлегендә бүлек җитәкчесе. 1969–92 дә Харьков җәмәгать туклануы ин-тында, тармак икътисады каф. мөдире (1981 гә кадәр). Хезмәтләре ит-сөт сәнәгатендә эрҗә-кап хуҗалыгына карый. Югары уку йортлары өчен «Халык хуҗалыгы тармаклары икътисады» («Экономика отраслей народного хозяйства», Киев, 1976) дәреслеге редакторы һәм автордашы, «Икътисади социаль үсеш методологиясе нигезләре» («Основы методологии экономического социального развития», Харьков, 1989) уку ярдәмлеге авторы. Татар телендә әдәби әсәрләр дә яза: «Минем дус» (1954), «Мин хәтерлим» (Харьков, 1997). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы повышения эффективности тарного хозяйства в молочной промышленности. Киев, 1968; Тара и экономика. Хар., 1969.

**ЖАМАЛИ́ЕВА** Фәния Фәйзрахман кызы (25.10.1958, Арча р-ны Дүртөйле пос.), биолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТР ның атказ. агрономы (2000), а.-х. фән. д-ры (2009). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүленеп): бәрәңге үрчетү лаб. мөдире (1997 дән), биотехнология бүлеге җитәкчесе (2000 нән), 1982–87 дә Казан вет. ин-тында. Дәүләт бүләге ТРда яхшыртылган нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләгәне һәм гамәлгә кертүкәне өчен бирелә.

**ЖАМАНАКЛЫ́** (псевд., чын исем-фамилиясе Рәшидов Кәрим Рәшид улы) (21.1.1905, Таврия губ., Кизләү өязе Җаманак а. — 1.8.1965, Алабуга ш.), шагыйрь, фольклорчы, әдәбият галиме. Кырымтатар һәм рус телләрендә яза. 1934 елда Симферополь пед. ин-тын тәмамлый. 1941 гә кадәр Бакчасарай шәһәрендә яши. Бөек Ватан сугышында катнаша. Туган җиреннән мәҗбүри сөрелүгә дучар була. 1944 тә Сәмәрканд ун-тында укыта, 1945 тән Алабуга пед. ин-тында. Беренче шигырьләре 1924 тә «Яңа дөнья», «Яшь куәт» г-таларында, «Әлгәре» ж-лында дөнья күрә. Бакчасарайда басылып чыккан «Азадлыкъ йырлары» (1927), «Балаларга Ленин акъкында» (1939), «Ананынъ йыры» (1940), «Бахытлы халкънынъ йырлары» (1940) һәм «Достларга» (Ташкент, 1978) шигъри җыентыклар авторы. Кырымтатар фольклорын өйрәнү һәм бастырып чыгару б-н шөгыльләнә. Кырымтатар шагыйрьләре Х.Туктаргази, У.Инчи иҗатларын өйрәнә. Аерым хезмәтләре Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил иҗатларына багышлана.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблогр. белешмә. К., 1986; Крымскотатарская энциклопедия. Симферополь, 1993.

*В.Х.Ганиев.*

**ЖАМИ́ГЪ** (гарәп. — туплаучы), җомга намазы *хөтбә* укып үткәрелә торган җамигъ мәчет. «Җ.» төшенчәсе 10 йөздә барлыкка килә. Баштарак шәһәрләрдә берәр җамигъ мәчет кенә булган. Акрынлап, шәһәрләрнең зураюына бәйле рәвештә, әлеге сүзнең «туплаучы», «җыючы» мәгънәсе югала, тора-бара теләсә-кайсы зур мәчетне «Җ.» дип атый башлыйлар. Идел буе Болгар дәүләтендә беренче Җ.лар 10 йөздә барлыкка килә. Казан ханлыгы яулангач, мәчетләр төзү туктала диярлек, бары тик 18 йөзнең 2 нче яртысыннан гына татарларда Җ.лар торгызыла башлый — *Каргалы бистәсендә*, Казанда җамигъ мәчетләр төзелә (ш.у. к. — *Касыйм хан мәчете*).

**ЖАН**, кешенең эчке дөньясына нисбәтле карашны белдерә торган төшенчә; диндә үзенчәлекле, тәннән бәйсез, матди булмаган башлангыч. Төрле халыкларның мифологик системаларында һәм фольклорында Җ. турындагы күзаллаулар күп яклары б-н охшаш. Кайбер халыкларның мифлары һәм әкиятләрендә Җ. иректә (тәнгә бәйләнешсез) яши дигән ышану хас. Төрки-татар мифологиясендә явыз *дию*, *аждаһаның* Җ.ы тәннәреннән аерым яши дигән фикер таралган. Ә диндар, гөнаһсыз кешеләрнең җаннары үлгәннән соң күккә аша (көтүче Зариф турында татар халык әкияте, үзбәк дастаны «Алпамыш» һ.б.) диелә. Ислам дине буенча кешеләрнең җанын үлем фәрештәсе *Газраил* ала.

*Әд.:* Жан // Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. К., 1981. 3 том; Ч е р н е ц о в В.Н. Представление о душе у обских угров // Исследования и материалы по вопросам первобытных религиозных верований. М., 1959; Б а с к а к о в Н.А. Душа в древних верованиях тюрков Алтая // Советская этнография. 1973. № 5; Т о к а р е в С.А. Религия в истории народов мира. М., 1976.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЖАН АРСЛА́Н** (Янарслан) (? — 1615 тирәсе), нугай морзасы, яубашы. Ырыс бәкнең улы. Әтисе б-н Рус дәүләтенә каршы яуларда катнаша. Әтисе үлгәч, сугышны дәвам иттерү, Кырым һәм Төркия б-н бердәм булу тарафдары. Динәхмәд ханның уллары — морзалар Ырыс Мөхәммәд һәм Иштирәк б-н сугыша. 1590 еллар башында Җаек казаклары, Җ.А. олысына һөҗүм итеп, үзен һәм уллары Урак б-н Зәрбәкне әсирлеккә төшерәләр. Җ.А. русларга хезмәткә күчә, Әстерханда яши. Улларын Мәскәүгә китерәләр, Пётр һәм Александр исемнәре биреп, чукындыралар. Соңрак Пётр (Урак) Урусов «*Болгавыр заман*»да Россия тарихында әһәмиятле роль уйный, кенәз Урусовлар династиясенә нигез сала.

*Әд.:* Н о в о с е л ь с к и й А.А. Борьба Московского государства с татарами в первой половине XVII в. М.–Л., 1948.

*И.Л.Измайлов.*

**ЖАНА́Й ХАН** (?-1512 тирәсе), Касыйм ханы (1506–12). Нурдәүләт хан улы. Тәхеткә бертуган абыйсы Сатылган хан үлгәннән соң утыра. 1505–07 елларда Мәскәүнең Казанга каршы яуларында катнаша. 1508 дә Торонецта Литва гаскәрләренә каршы яуда кенәз Оболенский б-н бергә полкка җитәкчелек итә.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2.

*И.Л.Измайлов.*

**ЖАНГАЛИ́** (рус чыганакларында Еналей Шугуров) (?-1616), татар бәге, 1615–16 еллардагы *Җангали хәрәкәте* җитәкчесе. «*Болгавыр заман*»да 1606–10 да «законлы патша» Дмитрий Ивановичны тәхеткә кайтару лозунгы астында барган баш күтәрүдә катнаша (к. *Казан ханлыгы яулангannan соңгы фетнә-чуалышлар*). 1609 да бәкләр Б.Еникеев, И.Смиленев һ.б. б-н бергә Зөя төбәгендә баш күтәрүчеләрне җитәкли. 1609 ның мартында Зөядән ерак түгел, Борындык авылы янында О.Зюзинның һәм А.Хохловның Казаннан килгән отрядлары баш күтәрүчеләрне җиңә. Соңрак Җ. ясаклы һәм йомышлы кешеләрнең салым көчәюе нәтиҗәсендә 1615 тә башланган чыгышына җитәкчелек итә. Баш күтәрүчеләр Түбән Новгород — Казан юлын ябалар, Арзамас һәм Муром шәһәрләренә яу б-н барырга әзерләнәләр, Казан бистәләрен камый-



Г.Х.Жантимерова.



С.С.Жантурин.

лар. Күтәрелеш бастырыла. Ж. әсирлеккә алына, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. Жангали батыр // Мирас. 1993. № 10; Д и м и т р и е в В.Д. Восстание ясачных людей Среднего Поволжья и Приуралья 1615–1616 годов // Труды НИИ языка, литературы, истории и экономики при СМ Чувашской АССР. 1980. Вып. 105; Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. (Управление Казанским краем). К., 1982.

**ЖАНГАЛИ́ ХАН** (1516, Касыйм ш. — 25.9.1535, Иске Казан ш.), Касыйм (1519–32) һәм Казан (1532–35) ханы. Шәех Аллаһияр хан улы, Шаһгали ханның энесе. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III тарафыннан Касыйм ханлыгы тәхетенә утыртыла. Ж.х. идарә иткәндә татар полклары рус гаскәрләренең Кырым ханлыгына каршы яуларында (1531) катнаша. 1525 елда Мәскәүдә Австрия илчесе С.Герберштейн б-н очраша. 1532 дә Казан тәхетенә утыртыла. Чынлыкта ханлыкның идарәчеләре карачы бәк *Булат Ширин* һәм *Гәүһәршад* ханбикә булалар. Рус хөкүмәте һәм Казан карачы бәкләре ризалыгы б-н 1535 нең июлендә Ж.х. Нугай Урдасы идарәчесе кызы Сөембикә б-н никахлаша. Бөек кенәз Василий III үлгәч, Булат Ширин җитәкчелегендә Казан феодаллары тарафыннан тәхеттән төшерелә һәм Иске Казанга сөрелә.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2; Х у д я к о в М. Очерки истории Казанского ханства. К., 1923; Казанская история. М.–Л., 1957.

*И.Л.Измайлов.*

**ЖАНГАЛИ́ ХӘРӘКӘТӘ́**, Урта Идел һәм Урал буйларындагы ясаклы һәм йомышлы кешеләрнең 1615–16 елларда Россия хакимиятенә каршы кузгалышы. Анда татарлар, марилар, чуашлар, удмуртлар катнаша. Җитәкчесе — *Жангали*. Сәбәбе — салым изүенең көчәюе: 1615 нең августында бишенче өлеш акча (күчемсез милек һәм керемнең биштән бер өлеше күләмендәге салым) җыю башлана. Ж.х. 1615 нең август ахыры — сентябрь башында Орёл шәһәре янында полякларга каршы көрәшкән Казан сугышчылары Россия армиясеннән киткәч башланып китә. Баш күтәрүчеләр Түбән Новгород — Казан юлын ябалар, Арзамас һәм Муром шәһәрләренә яу б-н барырга әзерләнәләр; Казан шәһәре истәләрен камыйлар; Сарапул һәм Усы кирмәннәрен яулап алырга омтылалар; Н.Зузин һәм С.Онучинның стрелецлар отрядларын тар-мар итәләр. Михаил Романов хөкүмәте баш күтәрүчеләргә каршы воеводалар кенәзләр Ю.Я.Сулешов һәм А.М.Львов җитәкчелегендәге гаскәрләр (1,3 меңнән артык кеше) җибәрә. Әмма баш күтәрүчеләрне Казан воеводалары кенәзләр В.Т.Долгорукий һәм С.Н.Гагарин җибәргән хәрби көчләр җиңә. Сәнәгатьче Строгановлар коралландырган отрядлар Сарапул һәм Усы янында баш күтәрүчеләрне тар-мар итә. Жангали әсирлеккә эләгә. 1616 ның февралендә тикшерү һәм җәза чаралары уздыру өчен Казанга кенәз Г.П.Ромодановский җитәкчелегендә комиссия килә. Әсир итеп алынган дистәләрчә баш күтәрүчеләр төрле җәзаларга дучар ителә һәм үтерелә.

*Әд.:* Д и м и т р и е в В.Д. Восстание ясачных людей Среднего Поволжья и Приуралья 1615–1616 годов // Труды НИИ языка, литературы, истории и экономики при СМ Чувашской АССР. 1980. Вып. 105.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЖАНИБӘ́К ХАН** (?–1357/58 тирәсе), Алтын Урда ханы (1342 елдан). *Үзбәк хан* улы. Үләр алдыннан Үзбәк үзенең варисы итеп өлкән улы Танибәкне билгели. Аксөякләр фетнәсе нәтиҗәсендә Танибәк һәм аның бертуганы Хызыр үтерелә. Ханлык тәхетенә Ж. утыра, ул атасының үзәк хакимиятне ныгыту сәясәтен дәвам иттерә. Аның заманында һөнәрчелек һәм сәүдә үсеше, Урданың мәмлүкләр Мисыры б-н дипломатик бәйләнешләры дәвам итә (1342). 1342–47 дә Ж.х. актив рәвештә вассал рус кенәзлекләре эшләрен күзәтеп тору сәясәте алып бара. 1346 дан сәүдәнең сүрелүе, корылык, ачлык, чума эпидемиясе һәм аерым өлкәләрнең, олысларның аерылып чыгу омтылышлары нәтиҗәсендә Ж.х.ның хакимияте көчсезләнә башлый. 1356 елга ул кыска гына вакытка хакимиятне ныгытуга һәм кайбер әмирләрнең сепаратизмын бастыруга ирешә. 1357 дә Ж.х. зур гаскәр туплап Төньяк Әзәрбайҗанга бәреп керә һәм Тәбриз шәһәрен ала. Улын гаскәрләр б-н җитәкчелек итәргә калдырып, Ж.х. Урдага кайта һәм авырып үлә (кайбер мәгълүматлар буенча, улы Бирдебәк һәм бәкләр бәге Тәглу фетнәсе нәтиҗәсендә үтерелә).

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; З а к и р о в С. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом. М., 1966.

*И.Л.Измайлов.*

**ЖАНТИМЕ́РОВА** Гөлсинә Хөснулла кызы (6.3.1943, Казан), аппаратчы, Соц. Хезмәт Герое (1976). 1961–94 елларда «Органик синтез» АҖндә өлкән аппаратчы. Эшләнә торган продукциянең сыйфатын яхшырта, җиһазларның ритмлы эшләвенә ярдәм итә торган рационализаторлык тәкъдимнәре кертә. 1994 тән «Синтез-Сандра» АҖндә эшли. Герой исеме бишьеллык план (1971–75) йөкләмәләрен үтәгәндә ирешкән казанышлары һәм химия сәнәгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен бирелә. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г о р н и к Г. Зантимерова Гульсина Хуснулловна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЖАНТУ́РИН** Сәлимгәрәй Сәетхан улы (1864 — 14.5.1926, Казан), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, филолог. Уфа губернасы дворяннарыннан, казакъ ханнары нәселеннән. Эре җирбиләүче. Мәскәү ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый (1889). Уфа губернасы Бәләбәй өязендә земство хәрәкәтендә актив катнаша: мировой судья (1894–91), земство башлыгы (1894–02), Бәләбәй өязе һәм Уфа губерна земстволары гласные (берничә тапкыр). 1903–06 елларда Уфа губернасында крәстияннәр эше буенча учреждение әгъзасы, Мөселманнар либераль хәрәкәте җитәкчеләренең берсе. Бөтенроссия мөселманнар корылтайларында (1905–06 һәм 1914) катнаша, 1 нче корылтайда сәркәтип, 3 нчесендә «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясе ҮК әгъзасы итеп сайлана. Уфа губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасында (1906) депутат, мөселманнар фракциясе әгъзасы, аның бюро сәркәтибе, җир комиссиясе әгъзасы. Башкорт җирләрен сатуны тәртипкә салырга, старшиналарның һәм көченеп килгән байларның башбаштаклыгын чикләргә чакыра. Дума куып таратылгач, хөкүмәткә каршы «Выборг өндәмәсе»нә кул куя, шуның өчен өч айга төрмәгә утыртыла. 1906 дан Уфада: Мөселман иганәчеләр җәмгыяте рәисе, «Мусульманский мир» г-тасын оештыручыларның берсе (1906–07), Ярлы мөселманнарны кайгырту идарәсе рәисе (1908 елдан), «*Галия*» мәдрәсәсен төзүгә 30 мең сум акча бирә. 1913–16 да «*Милләт*» г-тасын нәшер итүчеләрнең берсе. 1914 тә Бөтенроссия мөселман җәмгать оешмалары вәкилләре корылтаенда катнаша, Хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча Вакытлы мөселман ком-ты секретаре һәм әгъзасы булып сайлана (1915–17). 1916 да Мөселманнар арасында мәгърифәт тарату җәмгыяте рәисе урынбасары. 1916–17 дә Уфа губернасы мировой судьясы, Ятимханәләр б-н идарә итү комиссиясе әгъзасы. 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң Россия мөселманнары бюросының Вакытлы үзәге составына керә, Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче һәм 2 нче корылтайларын әзерләүдә һәм аларның эшендә катнаша. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18, төркичеләр фракциясе), *Милли идарә* әгъзасы. 1920–23 тә Иркутск шәһәрендә, 1924 тә Мәскәүдә төрле учреждениеләрдә статист булып хезмәт итә. 1925 тән Казанда, ТАССР Сәүдә халык комис-тында эшли. Татар телендә кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре лөгатьлеге авторы (Лөгать. Уфа, 1911).

*Әд.:* Т у к т а р о в М.Ф. (Усал). Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены первой Государственной Думы. М., 1906; С у л т а н б е к о в Б. Дворянин, политик, просветитель // Татарстан. 1996. № 5; У с м а н о в а Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906–1917). К., 1999.

**ЖАФФА́РОВ** Әкрәм Жаффар улы (27.3.1939, Горький өлкәсе Кызыл Октябрь р-ны Әндерә а.) математик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1990). 1963 елда Арзамас пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Новосибирск

пед. ин-тында эшли, 1972 дән геометрия каф. мөдире, 1981 дән проректор, Новосибирск ун-ты каршында Гамәли дидактика фәнни-тикшеренү ин-тын оештыручыларның берсе. Хезмәтләре матем. кибернетикага, мәгариф мәсьәләләренә карый. Икътисад һәм демографиянең матем. модельләрен эшли, укучыларны (профильле система) һәм студентларны (дистанцион система) укыту технологиясенең мәгълүмати вариантын төзи.

Х е з м.: Аналитическая геометрия. Новосиб., 1993; Теория устойчивости динамических дискретных моделей экономики и демографии. Новосиб., 1996; Математическая статистика. Новосиб., 2000.

**ҖӘБРАЙЛ** (гарәп. جبريل), фәрештә, Аллаһ б-н *Мөхәммәд* пәйгамбәр арасында баш арадашчы. *Коръәндә* Җ. Мөхәммәд пәйгамбәрне канат астына алучы, аңа Аллаһ әмере б-н Коръәнне иңдерүче итеп тасвирлана. Мөселманнар күзаллавынча, башка пәйгамбәрләрнең тормышында да аның йогынтысы зур булган: Адәмгә җәннәттән куылганнан соң (к. *Җәннәт*) ярдәм итә, *Нухны* һәм *Ибраһимның* улы *Исмәгыйльне* коткара, *Йосыфны* күптөрле телләрдә аңлашырга, *Даудны* тимер эшкәртергә өйрәтә. Җ.нең мөселман магиясенә дә йогынтысы зур. Аның исеме магик квадратларның кырларына башка фәрештәләрнең исемнәре б-н бергә языла. Дин белгечләре фикеренчә, Җ. образы Библиядәге Гавриил фәрештәдән килә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ҖӘГЪФӘ́Р әл-ӘГЕРҖЕВИ́** (? — 1821), дин эшлеклесе һәм хаттат. Вятка губернасы Әгерҗе авылы имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Аның кулы б-н язылган Коръән нөсхәләре Казан төбәгендә тарала. Габденнасыйр Курсави б-н язышкан хатлары сакланган. 1821 елда хаҗга барганда вафат була.

**ҖӘГЪФӘ́Р** бине Абдуллаһ. к. *Алмас илтәбәр*.

**ҖӘДИТЧЕЛЕ́К** (гарәп. جديد сүзеннән — яңа), 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Идел буе, Кырым, Кавказ аръягы, Урта Азия мөселманнарының мәгърифәтче-ислахчылык иҗтимагый-сәяси яңарыш хәрәкәте. Җ., күренеш буларак, үзенең формалашуы процессында татар җәмәгатьчелегендә кискен бәхәсләр тудыра. Зыялыларның алдынгы карашлы өлеше аңарда татар җәмгыятен күпгасырлык торгынлыктан алып чыгарга сәләтле интеллектуаль һәм идеологик көчне күрә. Татар кадимчеләре (к. *Кадимчелек*) әлеге хәрәкәт мөселман бергәлегенә җитди куркыныч яный дип исәплиләр, алар фикеренчә, Җ. җәмгыятькә атеизм б-н янәшә торучы хөр, иреклe фикер алып килә. Совет чорындагы ватан тарихы фәнендә Җ.нең күп төрле юнәлешләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. 1920 елларда ул интеллектуаль-мәдәни хәрәкәтнең аерым төре (Җ.Вәлиди) яки дини яңарыш формасы (Р.Ибраһимов) буларак тикшерелә. 1930 еллардан башлап «Җ.» төшенчәсе күбрәк сәясиләштерелгән төсмер ала, Җ. татар милли буржуазия идеологиясе итеп карала (А.Аршаруни, Х.Габидуллин). 1960–70 елларда Җ. реакцион күренеш (С.Г.Батыев), яңа ысуллы мәктәп оештыруы б-н башкалардан аерылып торган билгеле бер уңай адымнарга (алар арасында яңа ысуллы мәктәпләр оештырылу аерым игътибар үзәгенә алына) сәләтле милли буржуазия эшчәнлегенең бер формасы (Р.И.Нәфыйгов, К.Ф.Фасиев), ш.у. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында татар җәмәгатьчелегендә милли-демократик хәрәкәтнең идеологик чагылышы (Я.Г.Абдуллин) буларак бәяләнә. 1986–90 елларда Җ.нең төрле аспектлары Д.Лаззерини, А.-А.Рорлих, А.Холид (АКШ), И.Мараш, А.Канледере (Төркия), Д.М.Исхаков һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Татарстанда совет дәвереннән соңгы җәмгыять белемендә Җ. ике төрле караш аша аңлатыла: беренчесе буенча ул халыкның иҗтимагый һәм рухи тормышына исламның әйләнеп кайтуы өчен иң файдалы, нәтиҗәле форма, республикага ят дини агымнар үтеп керүгә каршы торучы ышанычлы киртә итеп карала; икенче караш дини гореф-гадәтләрне кабат яңартуда Җ. мөмкинлекләренә карата игътибарлырак мөнәсәбәттә булу кирәк дип таба, чөнки әлеге күренеш исламга ревизия ясарга юнәлдерелгән һәм традицион ислам өммәсе нигезләрен җимерергә сәләтле гаять күп идеологик һәм сәяси фикерләрне һәм максатларны колачлый. Әгәр берәүләр Җ.не яңача ысуллы мәдрәсәләр оештыру юлы б-н мәгариф системасын яңарта дип уйласалар, икенчеләр аңарда исламның татар варианты асылын күрәләр. Тикшеренүчеләрнең күпчелеге Җ.нең төп принципларын үсешен һәм формалашуын И.*Гаспринский* эшчәнлеге б-н бәйлиләр һәм шуның б-н әлеге агымның мәгърифәт-мәгариф юнәлешенә өстенлек бирәләр. Кайбер белгечләр, Җ.нең асылындагы сәяси-идеологик сыйфатларны ассызыклап, аның үсеп китүенә *Морад мулла* һәм *Батырша* имам эшчәнлеге этәргеч биргән дип саныйлар. Җ.нең башлангычында күренекле дин эшлеклесе Г.*Курсави* торган дигән фикер дә яшәп килә, аның тарафдарлары әлеге күренешнең асылын мөселман ислахчылыгы б-н тәңгәлләштерәләр (к. *Мөселман ислахчылыгы*).

18 йөз – 19 йөз ахырында татар җәмәгатьчелегенең иҗтимагый-сәяси тормышын өч юнәлеш билгели: традиональлек, мөселман ислахчылыгы, модернизм. Традициональлек мөселман бергәлегенең тотрыклы нигезләрен саклап калуга омтыла, ислахчылык исламга элегрәк хас булмаган мәдәният, сәяси тормыш кагыйдәләрен үзенең рухи байлыгы итеп сайлап алырга һәм җайлашырга сәләтле процессларга этәргеч ясау юлы б-н мөселман җәмәгатьчелеген яклауга юнәлдерелә. Модернизмның нигез шарты: Россиядә хөкем сөргән социаль-сәяси хәл һәм татар җәмәгатьчелегенең рухи торышы кичекмәстән мөселман өммәсенең интеллектуаль һәм сәяси көчләрен торгызу зарурлыгына күрсәтә. Бу, үз чиратында, икътисади мөнәсәбәтләрне, мәгариф системасын камилләштерүне, сәяси көчләрне берләштерүне таләп итә. Татар җәмгыятендә ислахчылык һәм модернизм юнәлешләренең бер-берсе б-н үрелеп баруы нинди дә булса сәяси ин-тларны яңадан торгызырга мөмкин булмаган шартларда татарларда җәмгыятьне берләштерүче социаль-мәдәни интеграция факторы сыйфатында, коллектив аң формасы буларак, исламның алгы планга чыгуы б-н бәйле. Шуңа карамастан, ислахчылык һәм модернизм — төрле социаль төркемнәрнең һәм катламнарның мәнфәгатьләрен чагылдыручы ике төрле юнәлеш. Татар җәмәгатьчелегендә ислахчылык — Г.Курсави, Г.*Утыз Имәнидән*, модернизм исә татар җәмгыятен сәяси яктан үзгәртеп кору проблемасын алга куйган Морад мулла һәм Батыршадан башлангыч ала. Җ.И.Гаспринский эшчәнлегендә һәм хезмәтләрендә аеруча тулырак чагыла; шуңа күрә аның үсешен хаклы рәвештә мәгариф системасын реформалаштыру б-н бәйлиләр. Россия мөселманнарының тормышын һәрьяклап колачлаган иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә мөселман мәгарифе модернизмның төп юнәлешләрен билгели: 19 йөз шартларында мәгариф алгарышы җәмгыятьнең рухи яңарышы һәм интеллектуаль потенциалы үсешенең бердәнбер мөмкин формасы була. Моннан тыш, яңа социаль көчләр Россия җәмгыятендә капиталистик мөнәсәбәтләрнең формалашып килүе шартларында сәләтле кадрларга мохтаҗлык кичерә. Мөселман мәгарифе системасының яшәеше күп мәсьәләләрдә хәйрия оешмаларына (к. *Иганәчелек*) һәм мәгариф системасы реформаларының соңгы нәтиҗәләре б-н кызыксынган фондларга бәйле була. 20 йөз башында татар җәмгыятендә сәяси яңарышның нигезен төзү, Җ.не тагын да камилләштерү өчен яңа мөмкинлекләр туа (к. *Бөтенроссия мөселманнарының корылтайлары*, «*Иттифакъ әл-мөслимин*», *Мөселманнар фракциясе*). Бу исә социаль-сәяси проблемаларны тамырдан хәл итү өчен тагын да уңайлы шартлар тууын күрсәтә. Модернизм татар җәмгыятендә иҗтимагый-рухи тормышны әйдәп баручы юнәлешләрнең берсенә әверелә. Казандагы «Мөхәммәдия», Уфадагы «Галия», Оренбургтагы «Хөсәения», Троицкидагы «Рәсүлия», Әстерхандагы «Низамия», Иж-Бубый авылындагы «Буби» мәдрәсәләре Җ.нең төп үзәкләре була. Җ.нең күренекле вәкилләре — Й.*Акчура*, Г.*Баруди*, Г.*Буби*, Җ.*Вәлиди*, Р.*Ибраһимов*, Ф.*Кәрими*, С.*Максуди*, Ф.*Туктаров*.

*Әд.:* А р ш а р у н и А., Г а б и д у л л и н Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931; Б а т ы е в С.Г. Татарский джадидизм и его эволюция // История СССР. 1964. № 4; Ислам в татарском мире: История и современность. К., 1997; И с х а к о в Д.М. Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. К., 1997; А б д у л л и н Я.Г. Джадидизм среди татар: возникновение, развитие и историческое место. К., 1998; М у х а м е т ш и н Р.М. Татары и ислам в XX веке. К., 2003; L a z z e r i n i E d w a r d j. Ismail Bey Gasprinskij and Muslim Modernism in Russia, 1878–1914. Wash., 1973; ш у л у к. Ethnicity and the Uses of History: The case of the Volga Tatars and Jadidism // Central Asian Survey. 1982. Vol. 1, № 2/3; A z a d - A y s e R o r l i c h. The Tajid and Jadid Movement a mong the Kazan Tatars (1809–1917). Conciliation or Conflict? Ist., 1997; K h a l i d A. The Politics of Muslim Cultural Reform: Jadidism in Central Asia. Berk and Los Ang., 1998; M a r a s I. Türk Dünyasinda Dini Yenilesme (1850–1917). Ist., 2002.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**ҖӘЕ́Н** (Silurus glanis), җәенсыманнар семьялыгындагы ерткыч балык. Балтыйк, Каспий, Кара һәм Азов диңгезләре бассейннарында таралган. Татарстан терр-ясендә Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычларында яши. Озынлыгы 1,5 *м* дан, авырлыгы 100 *кг* нан артык. Гәүдәсе лайлалы ялангач тире б-н капланган, яшькелт-кара төстә; йөзгечләре чәнечкесез, аксыл кайма б-н әйләндереп алынган саргылт яки кызгылт төстә. Аналь йөзгечләре озын, арка йөзгече — бик кыска. Башы киң булып яссыланган, үткен тешле, киң авызлы. Өске иренендә бер пар озын, ияегендә ике пар кыска мыегы бар. Ж. — өлешләп уылдык чәчүче төр. Уылдыкны соң гына чәчә. Май–июнь ахырында, суның темп-расы 19–20 °С булганда, вак сулыкларда сала. Җенси җитлегү ата Ж.дә 7–8 яшендә, аналарда 9–10 яшендә була. Абс. үрчемлелеге 10–12 яшьтә 100 дән 405 мең уылдык бөртегенә кадәр тирбәлә. Балык, бака, эре моллюсклар б-н туклана. Кәсәбә балыгы. Илл. к. *Балыклар* мәкаләсендә.

**ҖӘЙ**, ел фасылы, елның мәгълүм билгеләр буенча (астрономик, календарь, климатик, фенологик һ.б.) бүленгән периоды. Астрономиядә Ж.гә кояшның күктә иң озак торышы (21–22 июнь) б-н көзге көн-төн тигезлеге (22–23 сентябрь) арасындагы чорны кертәләр. Гадәттә, июнь, июль, август җәй айлары (календарь Ж.) дип санала. Климатик сезон буларак, Ж. һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 15 °С тан күтәрелгән датадан башлана һәм 10 °С тан төшкәннән соң тәмамлана. ТР терр-ясендә Ж.нең озынлыгы якынча 3,5 ай — май ахырыннан 15–20 сентябрьгә кадәр.

ТР терр-ясендә Ж.нең климат һәм һава торышы шартлары килеп керүче һава массалары трансформациясе йогынтысында формалаша. Яз б-н чагыштырганда, җәен антициклон күренешләре азрак, циклоннар күбрәк кабатлана. Тулаем алганда Ж. җылы һәм еш кына эссе, уртача дымлы, кояш радиациясе күләме зур. Һаваның айлык уртача темп-расы июньдә 16,6–17,8 °С, июльдә 18,2–20 °С, августта 16,4–18,1 °С, сентябрьдә 10 — 11,5 °С. Абс. иң югары темп-ра 37–40 °, иң түбән темп-ралар июньдә –2 дән –6 ° ка, июльдә 2 дән –2 °С ка, августта 2 дән –3 °С ка, сентябрьдә –6 дан –10 °С ка кадәр. Сезонда һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 15 °С һәм югары булган чор 84–98 көн дәвам итә (15 °С тан югары уңай темп-ралар суммасы 1510– 1720 °С тәшкил итә), темп-ра 10 °С һәм югары вакыт — 129–142 көн (темп-ралар суммасы 2060–2270 °С). Туфрак өслегендә уртача айлык темп-ра июньдә 20–24 °С, июльдә 22–25 °С, августта 19–21°, сентябрьдә 11–12 °С. Абс. иң түбән темп-ра июньдә –5 °С тан –8 °С ка кадәр, июльдә –3 °С, августта –4 °С, сентябрьдә –12 °С.

Җәен ТР терр-ясендә явым-төшемнәр аеруча күчле. Җылы чорда уртача 18–22 көндә тәүлеклек явым-төшем 5 *мм* һәм күбрәк була (суык чорда — 4–7 көн). Явым-төшемнәрнең уртача айлык күрсәткечләре июньдә 45–58 *мм*, июльдә 53–65 *мм*, августта 46–57 *мм* тәшкил итә; айлык иң күп явым-төшем — 130–170 *мм*. Тәүлеклек иң зур явым-төшем 121 *мм* (1899 ның 29 июле, Казан), 90 *мм* (1904 нең 26 июне, Минзәлә, 1949 ның 8 августы, Кама Тамагы).

Җәен көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш җилләре өстенлек итә. Җилнең уртача тизлеге 3–4 *м/с*. Җәйге сезонда көчле җилләр (15 *м/с* һәм күбрәк) уртача 3–4 көн була. Җәйге һава торышының уңайсыз күренешләре — көчле яңгыр, *яшенле яңгыр*, боз, коры җилләр, *корылык*. Җылы чорда явым-төшемнәр суммасы 15–20 *мм* булган (иң күбе 95 *мм* 1949 да, Тәтеш) уртача 4–5 көчле яңгыр билгеләнә. Боз еш булмый, җәйгә 1–2 көн, аерым елларда 4–8 көнгә кадәр, әмма игенчелеккә, яшелчәчелеккә, бакчачылыкка һ.б. шактый зыян китерә. Коры, киптерүче җилләр, югары темп-ра һәм һава дымлылыгы чагыштырмача түбән булганда, басу культураларына зарарлы йогынты ясый. Республика терр-ясендә май–сентябрь айларында акрын коры җилләр — 38–50 көн, уртача коры җилләр — 4–10 көн, бик көчле коры җилләр 3 көнгә кадәр күзәтелә. Корылыклар ешрак май һәм июнь айларында була.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983.

*Э.П.Наумов, Ф.Г.Борһанов.*

**ҖӘЙЛӘ́Ү** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Борды елгасы буенда. 2008 елда 124 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Клуб. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ейлева, Явли, Яйлева исемнәре б-н билгеле. 18 йөз башында башкортлар һөҗүме вакытында яндырыла. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, йон тетү, урман кисү, тегүчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1160,1 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Ж.дә кәшәнә, су тегермәне, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1859 да — 322, 1870 тә — 424, 1884 тә — 533, 1897 дә — 607, 1920 дә — 822, 1926 да — 622, 1938 дә — 649, 1949 да — 474, 1958 дә — 359, 1970 тә — 358, 1979 да — 253, 1989 да — 135, 2002 дә — 106 кеше.


**ҖӘЛА́Л** (Җәләлов) Вакыйф (1886–1922, Ташкент), шагыйрь. Дистәгә якын, ш. и. «Сәда-и мәдәният» (1908), «Күз нурларым» (1913), «Яңа Гөлстан» (1917), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (1918) шигъри җыентык, «Кара тормыш» (1913) исемле хикәя авторы. Әсәрләрендә үз заманының социаль каршылыкларын чагылдыра, татар халкын гыйлемгә өнди. Тулаем алганда, Ж. иҗатына күңел төшенкеле хас. 1920 еллар башында Урта Азиягә китә, фаҗигале төстә һәлак була.

*Әд.:* Г ы й л а җ и е в а Р. Ялкынлы моң // Казан утлары. 1992. № 5; Ә х м ә т җ а н о в М. Шагыйрь Вакыйф Җәлал эзләреннән // Мирас. 1994. № 9.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ҖӘЛА́Л** Садри (псевд., чын исем-фамилиясе Вәлидов Садрислам Хәйретдин улы) (1891, Тәтеш өязе Апас а. — 29.7.1943, Казан), язучы. Ж.*Вәлидинең* энесе. «Буби» мәдрәсәсендә (1906–10), Казан татар укытучылар мәктәбендә (1911–15) белем ала. 1918 елдан Арча кантонында укытучылар әзерләү курсларында укыта, 1919–26 да «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан» г-таларында, «Безнең юл», «Чаян» ж-лларында эшли, 1927–32 дә Татар рабфагында, Казан театр-сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта. Ж.нең беренче хикәяләре «Ак юл», «Аң» ж-лларында 1913–14 тә басылып чыга. Аны киң катлау укучыга 19 йөз морзалары тормышыннан язылган «Дим буенда» (1914) исемле мәхәббәт турындагы романтик повесте таныта. «Кадерле кунаклар», «Иртә беләп», «Кызыл солдатның хатирә дәфтәреннән» (1919 да басыла) исемле әкият һәм *нәсерләрендә* Гражданнар сугышы вакыйгалары, Окт. рев-циясеннән соң яңа тормышка аяк баскан гади кешеләр образлары чагылыш таба. Ж. «Чаян» ж-лында юмористик хикәяләр һәм фельетоннар б-н катнаша, публицистик мәкаләләр һәм рецензияләр яза, татар теленә Ф.Шиллерның «Вильгельм Телль», 1920 («Вилһелем Телль») драмасын, П.К.Бессальконың «Катастрофа», 1922 («Һәлакәт») повестен, М.Горькийның «Макар Чудра» (1927), «Мальва» (1928) хикәяләрен, Д.А.Фурмановның «Кызыл десант» («Красный десант», 1930) повестен, Д.Н.Мамин-Сибиряк, Дж.Лондон хикәяләрен һ.б. тәрҗемә итә. 1931 елда М.Х.Солтангалиев эше (к. «*Солтангалиевчелек*») буенча кулга алына һәм биш елга хөкемгә тартыла. 1935 тә иреккә чыгарыла. 1937 дә кабат кулга алына, үләр алдыннан гына азат ителә. Вафатыннан соң аклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1964.





Җәйге пейзажлар.

*Әд.:* Агишев Я. Садри Җәләл // Җәләл С. Сайланма әсәрләр. К., 1964; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*З.З.Рәмиев.*

**ҖӘЛӘ́ЕВ** Радик Инсаф улы (1.11.1936, Шөгер р-ны Иске Иштирәк а.), торбалар салучы слесарь, Соц. Хезмәт Герое (1977), ТАССРның атказ. төзүчесе (1975). 1966–96 елларда «Камгэсэнергострой» АҖ пр-тиеләрендә эшли. Герой исеме КамАЗның беренче чиратын төзегәндә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лукьянов Г., Алаев Ю. Заляев Радик Инсафович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши Земляки. К., 2003; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ҖӘЛӘ́Й** (Җәләлетдинов) Латыйф Җәләлетдин улы (17.11.1893, Самара губ., Мәләкәс өязе Татар Урайкиносы (Иске Кызылсу) а. — 1.8.1966, Казан), тел белгече, педагог, филол. фән. д-ры (1954), проф. (1958). Мәләкәс мәдрәсәсендә белем ала (1911). 1921 елдан Самара шәһәрендә: балалар йорты мөдире, пед. техникумында укытучы. 1928–29 да халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1929–32 дә Кузнецк һәм Мәләкәс шәһәрләре партия мәктәпләрендә эшли. 1933 тән Казанда. 1935–44 тә Казан пед. ин-тында. 1944 тән Казан ун-тында, бер үк вакытта 1962 гә кадәр СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1951–53, 1956, 1961 дә тел белеме секторы мөдире). Хезмәтләре татар теле тарихы, орфоэпиясе, стилистикасы, диалектологиясе, тарихи тел белеме, татар халкының борынгы әдәби ядкәрләрен өйрәнүгә карый. Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, А.Шамов һ.б. татар язучыларының иҗаты турында әдәби-тәнкыйди мәкаләләр; мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.


Хезм.: Татар диалектологиясе. К., 1947; Татар теленең орфоэпик нигезләре. К., 1953; Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. К., 1954; Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. К., 1957 (автордаш).

*Әд.:* Сабиров К. Профессор Л.Заляй и татарское языкознание // Вопр. татарского языкознания. К., 1965. Кн. 2; Якупова Г. Латыф Залялетдинович Залялетдинов // Советская тюркология. 1974. № 6.

**ҖӘЛӘЛЕТДИ́Н ХАН** (1380 тирәсе — 1412), Алтын Урда ханы (1411–12). Туктамыш ханның улы. Әтисе б-н бергә Идегәйгә каршы сугыша. Әтисе үлгәч (1406), бөек Мәскәү кенәзе Василий Дмитриевичка хезмәткә күчә. 1408 елның кышында, Идегәй Мәскәүне камаганда, Сарай әл-Җәдидкә һөҗүм ясый, шуның б-н Идегәйне чигенергә мәҗбүр итә. Алтын Урда б-н Мәскәү арасындагы солых шартлары нигезендә аны Идегәйгә тотып бирү таләп ителгәч, бөек Литва кенәзе Витовт янына качып китәргә мәҗбүр була. 1409–11 елларда аның ягында Тевтон Орденына каршы яуда катнаша. *Грюнвальд сугышында* батырлык күрсәтә (15.7.1410). Идегәй хакимиятенең көчсезләнүеннән файдаланып, Тимер ханны бәреп төшерә һәм Сарай әл-Җәдидне яулап ала (1411). Анда үзенең акчасын суга (1411–12). Җ.х.ның сәясәте аксөякләрнең фетнәсенә сәбәп була, бертуганы *Кәримбирде* тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Греков И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды. М., 1975; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.


*И.Л.Измайлов.*



Р.И. Җәләев.



Л.Җ. Җәләй.



Э.Г. Җәләлетдинов.

**ҖӘЛӘЛЕТДИ́НОВ** Эмиль Госман улы (2.7.1933, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), җырчы (баритон), ТАССРның халык (1973), РСФСРның атказ. артисты (1982). 1962 елда Казан консерваториясен (В.Воронов классы) тәмамлый. 1962–92 елларда Татар филармониясе солисты. Татар җырчыларыннан иң актив концерт бирүчеләрнең берсе. Җ.нең репертуары татар, рус, Көнбатыш Европа композиторларының җырлары, романслары, опера арияләренә бай һәм күптөрле. Аның концерт программаларында шактый зур урынны С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, З.Хәбибуллин, Н.Җиһанов, Ә.Бакиров, Р.Яхин, Р.Еникиев, И.Якупов, М.Макаров һ.б.ның вокаль әсәрләре алып тора. Җ. иҗатына югары профессиональ башкару культурасы, җылылык, авторларның текстларына сак караш һәм игътибарлылык хас. Җырчының ялгыз тематик концерт программалары арасында — «Татар халык җырлары», «Рус халык җырлары», «Борынгы рус романслары», «Дөнья вокаль классикасы әсәрләре», «Италия композиторларының вокаль әсәрләре», «Ф.Шуберт һәм Р.Шуман әсәрләре», «А.Пушкин музыкада» һ.б. бар. Җырчы илебездә һәм чит илләрдә күпләгән гастрольләрдә була. В.Мещерин җитәкчелегендәге электр музыкасы инструменталь ансамбле б-н Чехословакиядә (1970) һәм Венгриядә (1973), ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле б-н Туниста, Монголиядә һ.б. чит илләрдә чыгышлар ясый. Җ.С.Сәйдәшев, М.Җәлил, Г.Тукай, М.Горький, Б.Урманче музейлары һәм төрле оешмалар б-н иҗади дуслыкта яши. Ул РФ һәм ТР Композиторлар берлекләре съездлары һәм пленумнарының концерт программаларында, төрле музыка фестивальләрендә катнаша. Радио һәм телевидениедән даими чыгышлар ясый. 1960–80 елларда Җ. Бөтенсоюз радиосында һәм «Мелодия» фирмасында татар көйләрен яздыра.

*Ф.Ш.Салитова.*


**ҖӘЛӘЛЕТДИ́НОВА** Луиза Наил кызы (8.4.1956, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (2002). 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук — фармакология кафедрасындагы Үзәк фәнни лаб-янең онкология төркемендә, 1984 тән фармакология кафедрасында эшли. Хезмәтләре микроэлементлы композицияле аминокислоталар арасында яңа даруларның агулы фармакология үзенчәлекләренә карый. Уйлап табуга 8 патенты, 3 авторлык таныклыкы бар.

Хезм.: Влияние димефосфона на миелотоксический побочный эффект цитостатистической терапии злокачественных новообразований // Казан. мед. журн. 1995. № 3 (автордаш); Перспективы поиска новых лекарственных средств среди композиций аминокислот с микроэлементами // Фундаментальные исследования как основа создания лекарственных средств. Волгоград, 1995. (автордаш); Противоязвенная активность нового аминокислотного комплекса лития в эксперименте // Человек и лекарство. М., 1996. (автордаш); Влияние новых композиций аминокислот с микроэлементами на опухолевый рост // Человек и лекарство. М., 1997. (автордаш).

**ҖӘЛӘЛИ́ЕВ** Рәшит Әгъзам улы (25.8.1950, Арча р-ны Яңа Кенәр а.), фтизиатр, мед. фән. канд. (2001), Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Совет Армиясе сафларында: хәрби табиб, мед. хезмәте башлыгы. 1996 елдан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәр туберкулёз хастаханәсе баш табибе. 1999 дан туберкулёзга каршы көрәш буенча ТРның «Ак ромашка» иҗтимагый фонды президенты. Үпкәләрдә туберкулёз авыруы вакытындагы патологик үзгәрешләрне Җ. тәкъдим иткән ысул б-н билгеләү гамәлгә кертелә. Бу ысул туберкулёзның активлык дәрәҗәсен ачыклау, вакытында һәм нигезле диспансер теркәве төркемен билгеләү, актив терапия куллануны сирәгәйтү мөмкинлеге бирә. Медальләр б-н бүләкләнә. Уйлап табуга патенты бар (2001).

Хезм.: Деструкция тканей и инициирование свёртывания крови при туберкулёзном воспалении // Проблемы туберкулёза. 1994. № 4; Маркеры альтерации тканевых структур как показатели туберкулёза лёгких // Проблемы туберкулёза. 2002. № 7.

**ҖӘЛӘЛИ́ЕВА** Мәдинә Шәйхи кызы (29.9.1925, Арча р-ны Югары Шашы а. — 5.5.2005, Казан, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.нда җирләнә), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1966). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1950 елга кадәр Бөре укытучылар ин-тында, 1953–86 да Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре урта гасырлар татар әдәбияты тарихына (кеше концепциясе), жанрлар эволюциясенә, әдәбият теориясенә (дөнья әдәбияты б-н бәйләнештә татар прозасында вакыт һәм пространство образы), татар фольклоры поэтикасына, аерым язучылар иҗатына (Ә.Баян, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, Ә.Еники, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, К.Тинчурин, Г.Ту-



Х.Б. Җәләлов.

кай) карый. Югары уку йортлары өчен укыту программалары, урта мәктәп өчен әдәбият дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Борынгы татар әдәбиятында кеше образы. К., 1968; Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. К., 2001; Гумер Баширов. К., 1959.

**ҖӘЛӘ́ЛОВ** Абдуллаҗан Абдулкадыйр улы (17.1.1933, Чүпрәле р-ны Югары Каракитә а.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1988), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Җиләк-җимеш ин-тын тәмамлый (Мичуринск ш., 1957). 1962–69 һәм 1985–98 елларда РФА КГҮнең Биология ин-тында, 1985 тән үсемлекләрнең су режимы лаб-ясе мөдире. 1969–85 тә Казан вет. ин-тында, 1999 дан ТР ФА каршындагы Экология проблемалары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре үсемлекләрдә су алмашуы көйләнү механизмын өйрәнүгә карый. Барьерлар үткәрүчәнлегенең су балансы үсемлекләрнең корылыкка чыдамлылыгын көйләүдә билгеләүче роль уйнавын күрсәтә. Авызчыктан тыш транспирациянең көйләү механизмын ачыклый һәм тасвирлый, үсемлектә калий ретранспортының физиологик процессын билгели, үсемлекләр буенча су күчерүдә аның ролен ача. Тикшерү нәтиҗәләре үсемлекләрнең су алмашы тәгълиматы нигезендә ята һәм а.х. культураларында су режимын оптимильләштерү технологиясенең теоретик базасын тәшкил итә. Коры җир үсемлекләренең су-энергия үзләштерү концепциясен булдыра. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы. ТР ФАнең В.А.Попов исем. бүләге (2008), ТР Дәүләт бүләге (2010) лауреаты.

Х е з м.: Водный обмен сельскохозяйственных растений. К., 1983; Физиолого-термодинамический аспект транспорта воды в растении. М., 1984; Устранение движущей силы транспирации увеличивает энергетические затраты растений // Докл. РАН. 1999. Т. 369, № 2 (автордаш); Water Flows in Higher Plants Phisiology Enolution and System Analysis // Rassian Journal of Plant Physiology. 2004. V. 51, № 4.

**ҖӘЛӘ́ЛОВ** Илдар Надир улы (26.7.1953, Әлки р-ны Базарлы Матак а.), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1998), проф. (1999), ТРның атказ. вет. табибе (2003). 1978 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый, шунда ук патологик анатомия кафедрасында эшли. Фәнни тикшеренүләре хайваннар организмына көч бирүче препаратлар тәэсире дәрәҗәсен бәяләүгә һәм аларны куллану ысулларын эшләүгә карый. Терлекчелекнең төрле тармакларында хайваннар организмын ныгытучы препаратлар һәм чараларны гамәлгә кертә. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Изменение биологических ритмов эпифиза норок синтетическим мелатонином // Ветеринарный врач. 2000. № 3; Уровни проявления апоптоза, гармональной активности в клетках коры надпочечников норок при кормовой депривации // Материалы Всероссийской научно-методической конф. патологоанатомов ветеринарной медицины. Сб. научных трудов. Омск, 2000.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ҖӘЛӘ́ЛОВ** Кыям Җәләл улы (10.1.1925, Лаеш кантоны Шәдке а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1961). Бөек Ватан сугышында катнаша, 1945–46 елларда Теләче р-ны башкарма ком-тының финанс бүлегендә эшли, 1947–49 да Шәдке авыл советы рәисе. 1953–85 тә Саба, хәзерге Теләче р-нының «Большевик» к-зы рәисе. Җ. җитәкчелегендә колхозда а.х. культураларын үстерүнең алдынгы технологияләре кертелә, терлекчелек комплекслары, башка производство һәм социаль-мәдәният объектлары төзелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 гектардан 6,5 *ц* дан (1953) 21,4 *ц* га кадәр (1985), 1 савым сыердан савылган сөт 800 *кг* нан 3230 *кг* га кадәр арта. 100 *га* а.х. җирләренә 300 *ц* сөт, 99 *ц* ит җитештерелә. А.х. производствосындагы уңышлары өчен колхозга КПСС ҮК, СССР ЮС Президиумы, МС, ВЦСПСның Мактау грамотасы бирелә (1970). Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ҖӘЛӘ́ЛОВ** Ринат Гыйният ( Гыйниятулла) улы (10.7.1949, Балтач р-ны Ор а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән канд. (1999), ТРның атказ. элемтәчесе (1995). Куйбышев элемтә электротехника ин-тын тәмамлый. 1972–79 елларда Питрәч элемтә цехы, 1979–86 да Арча эксплуатация-техник элемтә үзәге, 1986–93 тә Казан шәһәре телефон челтәре башлыгы. 1993–2005 тә ТР элемтә министры. 2005–2009 да «Связинвестнефтехим» ААҖ директорлар советы рәисе киңәшчесе, 2009 дан «Сайда» ҖЧҖ фирмасының икътисад буенча баш консультанты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ҖӘЛӘ́ЛОВ** Хәлим Бәдри улы (27.4.1940, Балык Бистәсе р-ны Олы Солтан а.), драма актёры, ТРның халык артисты (1992). Казан театр уч-щесен тәмамлагач (1965, Р.Бикчәнтәев остаханәсе), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Үзенчәлекле актёр буларак, бик күп кызыклы образлар тудыра. Алар арасында сәхнәдә 600 мәртәбәдән дә күбрәк уйналган ваемсыз, чая Шәкүр («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Гайфи, Гыймран («Күк капусы ачылса», «Ике килен-килендәш», Х.Вахит), хәйләкәр Бикәмәт; мәнсез, кәпрәйгән Холай («Зифа», «Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Рәшит («Назлы кияү», К.Тинчурин) рольләре бар. Аның геройларында ачык темперамент, динамизм, оптимизм кебек сыйфатлар лиризм, шигърилек, рухи юмартлык, киң күңеллелек б-н бергә үрелеп бара. Җ. башкаруында Шәвәли («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), Адаш («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Гыймади («Зөләйха», Г.Исхакый), Ильяс («Агыйдел», М.Әмир), Севка («Ата хакы — тәңре хакы», В.В.Лаврентьев) образлары — шундыйлардан. Комик характерлар өстендә эшләгәндә Җ. кайвакыт фарс чаралары куллана: Помпей («Чамасына күрә чарасы», У.Шекспир), Бригелла («Болан-Патша», К.Гоцци), Курносов («Әшнәләр», В.М.Шукшин). Нәфис сүз остасы буларак та чыгышлар ясый. 1998 дән ТР Язучылар берлеге әгъзасы.

Ә с ә р.: Корчаңгы тай һәм Таз малай. К., 1993; Шәрә бүре. К., 1996; Турай батыр. К., 2004; Пәриле күл буенда. К., 2006.

*Әд.:* И л я л о в а И. Үзебезнеке, халыкныкы! // Казан утлары. 1992. № 1.

*И.И.Илялова.*

**ҖӘЛӘ́ЛОВА** Зөләйха Абдуллаҗан кызы (9.5.1966, Казан), педиатр, мед, фән. д-ры (2005). 1989 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм Республика балалар клиник хастаханәсенең неврология бүлегендә эшли. 1992 елдан Казан мед. ун-тының неврология кафедрасында. Хезмәтләре церебраль паралич б-н авырган балаларның шәхси үзенчәлекләрен клиник-психологик тикшеренүләргә карый.

Х е з м.: Экстрапирамидальные проявления, сопутствующие лечению нейролептиками // Казан. мед. журн. 2001. Т. 82, № 2; Современные подходы к диагностике и лечению болезни Вильсона-Коновалова // Казан. мед. журн. 2003. Т. 84, № 2; Опыт применения пирибедила при лечении болезни Паркинсона // Практическая медицина. 2004. № 3.

**ҖӘЛӘ́ТОВ** Марс Шәйхразый улы (7.8.1939, Әлмәт р-ны Түбән Мактама штп), нефтьче, «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУы башлыгы (1985–2005), 2005 тән «Татнефть» АҖ ген. директоры киңәшчесе. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1983), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1993). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1967). 1960 тан «Татнефть» АҖндә. Аның эшләү елларында НГДУда беренче тапкыр нефть промыселларын комплексло автоматлаштыру тормышка ашырыла, энергия ресурсларын, торба үткәргечләрне коррозиядән саклаучы технологияләр системасы барлыкка килә. Җ. эре хәйрия акцияләрендә: Биләр тарихи-археологик һәм табигать музей саклаулыгын төзекләндерүдә, Әлмәт мөселман дини-агарту үзәген төзүдә, «Әлмәт энциклопедиясе»н әзерләүдә актив катнашучыларның берсе. Уйлап табуга 37 патенты бар. Дәүләт бүләге Татарстан нефть промыселларында энергия ресурсларын саклаучы технологияләрне эшләү һәм эре сәнәгать күләмендә кулланылышка кертүдәге хезмәтләре өчен бирелә. 1990–95 елларда ТР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Дуслык» ордены, медальләр, ТАССР һәм ТР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Подготовка и закачка технологических жидкостей: Справ. М., 1993; Организация производства ремонта скважин // Нефтяное хозяйство. 1998. № 7; Как выжить в условиях кризиса: Технология НГДУ «Альметьевнефть». М., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Ю с у п о в Д., Ш ә м с е т д и н о в а М. Мәдхия. Иләктән иләнгән заман. К., 1999.

**ҖӘЛИ́Л** (Җәлилов) Муса Мостафа улы (15.2.1906, Оренбург губ. Мостафа а. — 25.8.1944), шагыйрь, Советлар Союзы Герое (1956, үлеменнән соң). 1914–19 елларда Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсендә, 1919–24 тә Татар халык мәгарифе ин-тында укый. 1925–27 дә Оренбург, Орск шәһәрләрендә ВЛКСМның өяз ком-тларында инструктор булып эшли. 1927–38 дә Мәскәүдә яши. 1928 дән — «*Кечкенә иптәшләр*», 1929 дан — «*Октябрь баласы*» ж-лларының җаваплы мөхәррире, бер үк вакытта Мәскәү ун-тында укый (1927–31). 1933 тән «Коммунист» г-тасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге, 1935 тән Мәскәүдәге Татар опера студиясенең әдәбият бүлеге мөдире. 1939–41 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе.



М. Җәлил.

1919 да «Кызыл йолдыз» г-тасында беренче шигырьләрен бастыра. «Барабыз» исемле тәүге шигъри җыентыгы 1925 тә Казанда дөнья күрә. 1920 еллардагы иҗатында рев-ция һәм Гражданнар сугышы героикасына дан җырлый («Үткән юллар» поэмасы, 1924–29), социализм төзүче гади кешеләрнең романтик образларын («Орденлы миллионнар», 1934; «Хат ташучы», 1938, җыентыклары 1940 та басыла) тудыра. 1930 елларда, романтик шартлылыктан һәм Шәрекъ метафораларыннан ваз кичеп, яңа реалистик тәсмерләр таба; иҗатында психологизм һәм эмоциональлек көчәя. Г.Тукайга ияреп язудан һәм *гаруз* ритмикасын файдаланудан башлап, Җ. әкренләп Һ.Такташ шигъриятенә һәм халык силлабик шигыренә хас булган тоник үлчәмгә күчә. Ул — популяр җырлар, романс һәм либреттолар авторы (ш.и. «*Алтынчәч*» операсы, СССР Дәүләт бүләге, 1948).

Җ. иҗаты лозунгка корылган, ачык публицистик поэзиядән («Бәхет», «Ил халкына») башлап, тасвирлы, эмоциональ поэтик сөйләм («Чишмә», «Сагыну») юнәлешендә үсә. Аның әсәрләре арасында балалар өчен булган гади шигырьләр дә, көн кадагына сугып язылган поэтик репортажлар да, шигъри фельетоннар да бар. Г.Кутуй, К.Нәҗми, Һ.Такташ, Х.Туфан һ.б. яшь шагыйрьләр б-н бергә Җ. 1920–30 еллардагы новаторлык эзләнүләрдә катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында 2 нче удар армиянең «Отвага» г-тасы хәбәрчесе. 1942 елның июлендә авыр яраланып әсирлеккә эләгә; Польша, Балтыйк буе, Германиядәге фашист лагерьларында була. Әсирлектә вакытта Г.Кормаш төзегән, татар хәрби әсирләреннән торган яшерен төркем эшчәнлегендә катнаша, аның идея рухландыручысына әверелә. Бу төркем йөкләмәсе б-н Җ. татар хәрби әсирләрен «Идел-татар легионы»на тарту максатында пропаганда эшен алып бару өчен немецлар тарафыннан төзелгән «Tatarische Mittelstelle» («Татар арадашлыгы», Берлин) оешмасында эшли; анда легионга көчләп кертелгән хәрби әсирләр арасында мәдәни-агарту, гитлерчыларга каршы җимерү эшләре алып бара (к. «*Җәлилчеләр төркеме*»). Яшерен оешмада катнашкан ун иптәше б-н бергә фашистларның Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелә.



«Хөкем алдыннан» (М.Җәлил 1944 елда Берлиндагы Моабит төрмәсендә). Рәссам Х.Г.Якупов.

Җ.нең сугыш еллары иҗаты хәрби-патриотик лирика үрнәге булып тора («Окоптан хатлар», 1944). Ул әсирләр лагеренда да, үлемгә хөкем ителгәннән соң елдан артык утырган Моабит төрмәсендә дә язудан туктамый. Аның шигырьләре антифашистик листовкалар б-н бергә яшерен оешма әгъзалары арасында кулдан-кулга күчеп йөри. 1942–44 тә әсирлектә язылган 93 шигырьдән торган ике дәфтәр, Франция, Бельгия аша катлаулы юллар үтеп, 1946–47 елларда илгә кайта. «*Моабит дәфтәре*» (1953) циклында аның сугышка кадәрге лирикасының героик һәм романтик мотивлары аеруча ачык чагыла. Бу дәфтәрләр совет халкының чыдамлыгы һәм батырлыгы, бөек Җиңүнең ни бәрабәренә яулап алынуы хакында сөйләүче җан тетрәткеч документ булып торалар. Бер үк вакытта төрле жанрда һәм стильдә язылган ул шигырьләрне югары поэзия дип тә атап була. Аларда эчке культура, шигъри каләмнең ныклыгы, тирән милли нигез бар. «Моабит дәфтәре»ндә якынлашып килүче үлемне көтеп яшәгәндә кеше гомеренең ни дәрәҗәдә кыйммәт булуын аңлау таң калдыра. Циклның асылын яхшылык б-н явызлык, яшәеш б-н үлем арасындагы мәңгелек көрәш тәшкил итә. «Серле йомгак», «Вәхшәт», «Алман илендә» исемле шигырьләрендә шагыйрь фашизмның бөтен тереклек дөньясына дошман булуын күрсәтә; аның өчен «фашизм» һәм «үлем» төшенчәләре янәшә тора. Соңгы шигырьләре — Ватан саклаулары батырлыгына гимн.

Муса Җ.нең шигъри мирасы күпмилләтле совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлешен тәшкил итә. Татар поэзиясенең гражданлык яңгырашын ул героик мотив б-н яңартты һәм баетты. Җ. совет чоры татар поэзиясенә лирик шагыйрь буларак та, җыр текстлары язучы буларак та, зур лироэпик поэмалар авторы буларак та үзеннән зур өлеш кертә. «Моабит дәфтәре» циклы дистәләрчә мәртәбә рус, татар телләрендә басылып чыга, башка телләргә тәрҗемә ителә, 1957 елда Ленин премиясенә лаек була. 1968 дә Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге булдырыла (1997 дән М.Җәлил исем. Респ-ка бүләге), 1966 да Казанда Җ.гә һәйкәл куела (сынчы В.Е.Цигаль, арх. Л.Г.Голубовский), 1970 тә Минзәләдә шагыйрьнең мемориаль музее, ә 1983 елда Казанда музей-фатиры ачыла.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 5 томда. К., 2006; Избранные произведения. Л., 1979.

*Әд.:* Ю з и е в Н. Муса Җәлил поэмалары. К., 1960; К а ш ш а ф Г. Муса Җәлил. К., 1961; Муса Җәлил турында истәлекләр. К., 2006; М у с т а ф и н Р. По следам оборванной песни. М., 1974; ш у л у к. Муса Джалиль. Жизнь и творчество. Довоенный период. К., 1986.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ҖӘЛИ́Л**, шәһәр тибындагы посёлок, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 35 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы чыганагы янында урнашкан. 2008 елда 14,1 мең кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 82,1%, руслар — 15,4%) яши. 2 урта мәктәп, гимназия, музыка, сәнгать мәктәпләре. Мәдәният сарае. Мәчет. Нефть чыгару сәнәгате («Җәлилнефть» НГДУы), кондитерлык цехы. 1963 тә нефтьчеләр посёлогы буларак төзелә, торак пункт сыйфатында 1964 нең 25 мартында теркәлә, 1968 нең 27 июненнән — шәһәр тибындагы посёлок. Башта — Әлмәт, 1972 нең 25 маеннан Сарман р-нында. Халык саны: 1979 да — 7,3 мең, 1989 да — 11,3, 2002 дә — 14,8 мең кеше.



Җәлил посёлогында «Җәлилнефть» идарәсенең администрация бинасы.

**«ҖӘЛИ́Л»**, героик-трагик опера-поэма, 7 күренештә. Н.Җиһанов музыкасы (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1958), Ә.Фәйзи либреттосы. Беренче мәртәбә 1957 елның 15 маенда Татар опера һәм балет театрында куела (дирижёры К.К.Тихонов, куючы-режиссёры Б.А.Покровский, рәссамы Ә.Х.Нагаев; Җәлил — И.Д.Ишбүләков, Н.К.Даутов). Шул ук елның 29 маенда опера Мәскәүнең К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченко исем. муз. театрында күрсәтелә. Операның төп герое — татар патриот шагыйре М.Җәлил. Сюжет нигезендә — шагыйрьнең «*Моабит дәфтәре*». Опера авторы М.Җәлилнең героик язмышын, Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгын, аның герой-шагыйрь образын күпкырлы, бик тә көчле һәм ышандырырлык итеп тасвирлый. Җәлил шигырьләре операның сәнгати эчтәлегенә табигый үрелеп бара. Алар ария һәм вокаль номерларның нигезен тәшкил итә. Операның 7 күренешендә дә «Моабит дәфтәре»ндәге шигырьләр эпиграф булып яңгырый. Әсәр опера-поэма жанрында иҗат ителгән һәм монологик үзенчәлеккә ия. Җәза көнен көтеп, Моабит төрмәсендә газапланучы

герой үзенең тормышындагы иң якты хатирәләрне исенә төшерә, шул истәлекләр сәхнәдәге вакыйгаларны гәүдәләндерә. «Җ.» музыкасында тыныч тормыш һәм кырыс сугыш чынбарлыгы күренешләрен чагылдырганда көчле лиризм, шигърилек, романтика чынбарлык б-н бергә кушыла. Опера көйгә бай һәм тәэсирле. Аның милли колоритлы нигезен татар халык җырлары тәшкил итә. Төрле милләт вәкилләре — опера персонажлары образларын тудырганда әсәрнең муз. палитрасы рус, казакъ, чуаш, француз халыкларының музыка элементларын куллану исәбенә баетыла. «Җ.» драматургиясе тоташ симфоник үсеш, лейтмотивлык б-н (лейтмотивы — Туган илнең татар халык җыры




Н. Җиһановнның «Җәлил» операсы куелу турында Прага милли театры афишасы.

«Зиләйлүк» темасына нигезләнгән муз. символ) аерылып тора; күренешләрне бер-берсе б-н бәйләүче оркестр уйнавы, геройны теге яки бу мизгелдә чолгап алган тормыш мизгелләрен гәүдәләндерүче яки персонажларны тасвирлаучы хор күренешләре мөһим роль уйныйлар. Җәлил арияләре («Җырларым», «Сау бул, Казан», «Соңгы үпкә») — опера эчтәлегенең төп идея-мәгънәви эчтәлеген чагылдырган аеруча күтәренке рухтагы җырлар. «Җ.» операсы совет һәм чит ил опера һәм балет театрлары (Зур театр, Прага милли театры һ.б.) сәхнәләрендә күп тапкырлар куела. «Җ.» операсы Татар опера һәм балет театрының даими репертуарына кертелә.



«Җәлил» операсының СССР Зур театрында куелышы. Җәлил — И. Ишбүләков, Андре — СССРның халык артисты П. Лисициан. 1959.

*Әд.:* Гиршман Я. Назиб Жиганов. М., 1975; Татарский государственный академический театр оперы и балета имени Мусы Джалиля. К., 1994.

**«ҖӘЛИ́Л» АСТЕРО́ИДЫ**, 3082 нче кече планета. 1972 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Т.М.Смирнов тарафыннан ачыла, татар шагыйре М.Җәлил исеме б-н атала. Кояштан ераклыгы 2,4–2,8 *а.б.* (астрономик берәмлек). Кояш тирәли 4,1 ел эчендә әйләнеп чыга.

**ҖӘЛИ́Л МУСА́ МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЕ́**, Минзәлә шәһәрендә. Пед. уч-щесе коллективы (директоры И.Б.Уткин) тырышлыгы б-н оеша, 1970 елның 3 мартында ачыла. 1984–85 тә яңартып корыла (рәссам Ф.А.Равилов). 1993 тән ТРның Милли музее ф-лы, 2006 дан муниципаль музей. Элеккеге реаль уч-ще бинасында (1912, хәзер пед. көллияте) урнашкан, 1941 дә биредә М.М.*Җәлил* хәрби-сәяси курслар тәмамлый. Бинага мемориаль такта куела (1985). Музей гомуми мәйданы 70 $м^2$ булган бер аудиторияне били. Аның фондларында 2000 саклау берәмлеге исәпләнә. Тарихи-документаль экспозиция Җәлилнең Минзәләдәге тормышына багышлана: фоторәсемнәр, шагыйрьнең туганнары һәм көрәштәшләре хатирәләренең кулъязмалары, сирәк китаплар коллекциясе; Волхов фронтының Җәлил яраланган һәм әсирлеккә төшкән «Үлем үзәне»ндә табылган сугыш кораллары, солдат кирәк-яраклары һ.б.; курсантларның тормышын һәм көнкүрешен чагылдыручы төрле әйберләр (сугыш, йорт кирәк-яраклары, хезмәт кораллары), рәссамнар Н.Хәбибуллин, Н.Бикташев, А.Каретниковның М.Җәлилгә багышланган нәкышь һәм графика әсәрләре тупланган. Музейның аеруча мөһим экспонатлары булып Җәлилнең әдәби-мемориаль әйберләре: урындык, мандолина, патефон, шагыйрьнең Минзәлә р-ны җитәкчеләренә фронттан язган хатлары, имзасы куелган «Хат ташучы» җыентыгы санала.

Музей директорлары: В.Һ.Һадиев (1970–96), Ф.С.Һадиева (1996–99), А.В.Григорьева (1999 дан).

**ҖӘЛИ́Л МУСА́ МУЗЕ́Й-ФАТИРЫ́**, Казанда. ТАССР Дәүләт музее (хәзер ТРның Милли музее) ф-лы буларак, халык депутатлары Казан шәһәр советы башкарма ком-тының 1982 елның 27 гыйнварында кабул иткән карары һәм ТАССР МСның шул ук елның 18 маенда чыгарылган карары нигезендә оештырыла. 1983 нең 15 февралендә М.М.*Җәлил* гаиләсе б-н 1940–41 дә яшәгән һәм армиягә алынган йортта (1940, арх. В.А.Дубровин) ачыла. Музей, шагыйрьнең хатыны Әминә Котдус кызы киңәшләре буенча торгызылган мемориаль фатирны, ш.у. күргәзмә залын һәм әдәби салонны кертеп, гомуми мәйданы 126,5 $м^2$ булган 2 фатирны били. Музей фондында 2 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә, шуларның 402 се «М.Җәлилнең Казандагы тормышы һәм иҗаты сәхифәләре (1939–41)» мемориаль экспозициясендә саклана, болар: шагыйрьнең фоторәсемнәре, хатлары, Сов. Союзы Герое (1956) һәм Ленин премиясе лауреаты (1957) грамоталары, биографик һәм иҗади характер-



Казанда М. Җәлилнең музей-фатиры. Экспозициядән күренеш.

дагы кулъязмалары, шәхси әйберләре, әсәрләренең басмалары. Тупланманың иң мөһим өлешенә: 1935 тә шагыйрь Мәскәүдә сатып алган язу өстәле, аның шәхси китапханәсе урнаштырылган китап шкафы (татар һәм рус классикларының 216 китабы, сүзлекләр, әдәбият энциклопедиясе, музыка сәнгате буенча басмалар), Җәлилнең 1937 дән 1941 гә кадәрге вакыт аралыгында туплаган фотоальбомы (шагыйрьнең, гаилә әгъзалары һәм дусларының фоторәсемнәре), Җәлилнең үзе исән чакта һәвәскәр рәссам Г.Тимербулатов тарафыннан эшләнгән беренче бюсты (1936), шагыйрьнең 1934 тә сатып алган мандолинасы, «*Моабит дәфтәре*»нең немец, чех, болгар, корея, гарәп, инглиз телләрендә дөнья күргән чит ил басмалары (1958–81) керә. Музей җитәкчеләре Л.Г.Вәлиева (1983–87), И.З.Минһаҗева (1987–89), Г.Р.Сакаева (1991–2008), Н.Г.Фәттахова (2008 дән).

*Әд.:* Мингазова И.З. В сопровождении почётного эскорта // Советский музей. 1984. № 4; Шулук. Музей Джалиля в Казани: Путеводитель. К., 1984; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

**ҖӘЛИ́Л МУСА́ ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. 1944 елда фашистлар төрмәсендә һәлак булган герой-шагыйрьнең 60 еллык юбилее уңаеннан 1966 да куела (к. М.М.*Җәлил*). Һәйкәл (скульп. В.Е.Цигаль, арх. Л.Г.Голубовский) төп 3 өлештән — мәйданчык (стилобат), скульптура һәм гранит дивардан торган архит-ра комплексыннан гыйбарәт. Трапеция формасындагы гранит мәйданчык җир өсте тигезлегеннән күтәрелеп тора. Ул тигезсез калкулык — 1 нче Май мәйданы рельефын тигезли һәм зур сәнгати-композицион әһәмияткә ия. Бауман урамыннан һәйкәлгә таба көнбатыш яктан киң гранит баскыч күтәрелә. Композиция үзәгендә мәйданчык конфигурациясен кечерәйтеп кабатлаучы чәчәклек ясалган. Ян-якларына шомартып ялтыратылган гранит эскәмияләр урнаштырылган. Скульптура трапециянең кече нигезеннән 7,9 *м* га күтәрелгән. Скульптура б-н бербөтенлек тәшкил иткән бронза нигездә «М.Җәлил» факсимиле имзасы бар. Монумент мәйданның ансамбленә органик рәвештә кушыла. Аның ачык силуэты күк фонында аерылып тора; Кремль манаралары вертикальләре скульптураның куәтле пластикасын ассызыклыйлар һәм көчәйтәләр. Җәлил сынында тыелгысыз омтылу чагыла. Көрәшче-шагыйрь үзен бәйләгән богауларны өзеп

ташларга җыена сыман. Скульптураның композициясе үзенчәлекле динамика б-н аерылып тора: горур күтәрелгән баш, буйсынмас, тәвәккәл караш батырлык, рухи көч һәм каһарманлык турында сөйли. Сәнгати образ идеясенең гәүдәләндерү осталыгы б-н кушылуы скульптурага көчле, баһадирларга хас чагылыш бирә.

Мәйданчыкта бераз ялтыратылган һәм җиңелчә эшкәртелгән гранит блоклардан тәбәнәк дивар корылган. Блокларда, стильләштерелгән карлыгачлар фонында, Муса Җәлил шигырьләреннән татар һәм рус телләрендә 3 цитата китерелә:

1. «Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
   Җырлап килдем тормыш языма».
2. «Яшәү хозурлыгы хөрлектә,
   Гомер озынлыгы ирлектә».
3. «Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
   Үлемем дә яңгырар җыр булып».



Казанда Муса Җәлил һәйкәле. 1966.

Һәйкәлнең идеясен ачып, скульптор В.Е.Цигаль: «Минем күзаллавымда ул әсирлекнең чәнечкеле богаулары аша тоткынлыктан ireккә ыргылган көрәшче буларак үсә барды, көрәшче образы шагыйрь образын бераз күләгәдә калдыргандыр да. Шуңа да карамастан, ул чакта миңа җәмгыятьтә геройга бәяләмә бирү өчен дә, Җәлилнең үзе һәм аның якыннары өчен дә минем бу омтылышым һәйкәлдә чагылырга тиешле иң мөһим хасият булып тоелды. Аны хәтердә саклау өчен. Тик янәшәдәге диварда гына аның шигырьләре уелган. Алар, Ватанга кайткан кошлар кебек, барыбызга да Шагыйрьнең фаҗигале язмышы турында сөйлиләр төсле», — дип язды.

1995 тә тәбәнәк гранит диварга «*Җәлилчеләр төркеме*» әгъзаларының В.Е.Цигаль тарафыннан эшләнгән барельеф-портретлары урнаштырыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Гарзавина А.В., Новицкий А.И. Моя Казань. К., 1984; Знаменитые люди о Казани и о Казанском крае. К., 1999.

*А.И.Новицкий.*

**«ҖӘЛИЛНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгаруны гамәлгә ашыру, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлаштыру, төзү һәм файдалануга әзерләү б-н шөгыльләнүче нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). Эшләүчеләр саны — 2194 кеше (2008). 1959 елда «Әлкинефть» нефть промыселы идарәсе буларак оештырыла. 1968 дә 2 мөстәкыйль идарәгә (1970 тән НГДУ) — «Җәлилнефть» һәм «Сөләйнефть»кә бүленә. 1997 дә алар «Ж.» б-н берләштерелә. Эшчәнлегенең терр-ясе Сарман, Әлмәт, Азнакай, Зәй р-ннары җирләрен колачлый. «Ж.» составында 7 нефть чыгару цехы, 2 катламнардагы басымны саклау цехы, 2 нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы, 2 скважиналарны җир астында ремонтлау цехы, җитештерүне автоматлаштыру цехы, коррозиядән саклау һәм техник диагностика цехы бар. Ромашкино чыганагындагы 5 мәйданны (Чишмә, Ташлыяр, Сарман, Көнчыгыш Сөләй, Әлки мәйданнарын) һәм түбән карбонның Бобриково катламындагы 12 һәм 31 нче ятмаларын эшкәртә. Эшкәртүнең төп файдалану объектлары югары девонның Кынау һәм Паша катламнарыннан гыйбарәт. «Ж.» чыгарган нефтьнең 75% тан артыграк өлеше шуларга туры килә. Барлык мәйданнар һәм ятмалардагы нефть, контур тирәли су кудырып, катламнардагы басымны саклау алымы б-н эшкәртелә. Объектлар комплекслы автоматлаштырылган һәм телемеханикалаштырылган. НГДУда күбрәк нефть алу өчен продуктив катламнарга төрлечә тәэсир итү максатында гамәлгә ашырылган проектлар арасында — катламнарга циклы тәэсир ясау, басымлы скважиналарга төрле полимерлар кудыру һ.б. бар. Нефть чыгаруда иң зур күрсәткечкә 1977 дә ирешелә — 21,9 млн. *т*. Барлыгы 535,8 млн. *т*, ш.и. 2008 дә 4,486 млн. *т* чыгарылган. Чыгарылган продукциянең сулылыгы 85,8%. 2009 ның 1 гыйнварына 6672 скважина бораулаган, шуларның 3396 сы (башлыча, насос ярдәмендә) нефть бирә. «Ж.» эшчәнлегендә әйләнә-тирә мохиткә техноген тәэсирне киметүгә, зыян килгән җирләрне элекке хәленә кайтаруга, әчәргә яраклы су чыганакларын төзекләндерүгә аеруча әһәмият бирелә. «Ж.»нең чаңгы спорты комплексы, шифаханә-профилакторие, балаларны сәламәтләндерү лагере бар. «Ж.» — шәһәр төзүче пр-тие, шәһәр тибындагы Җәлил посёлогында һәм Сарман р-нында җәелгән төзелешләр заказчысы: ул торак йортлар, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәният, спорт объектлары, мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениеләре һ.б. төзү эшләре алып бара. Алдынгы хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә лаек була: Соц. Хезмәт Герое — 2, СССР, РФ нефть һәм газ сәнәгатенең атказ. хезмәткәрләре — 29, ТАССР, ТРның атказ. нефтьчесе — 84, СССР Дәүләт бүләге лауреаты — 2 кеше; 8 кеше — Ленин ордены, 12 кеше — Октябрь Революциясе, 59 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 6 кеше — Халыклар дуслыгы, 49 кеше — «Хезмәт даны», 3 кеше 2 нче, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны», 71 кеше «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Нефть промыселы идарәләренең җитәкчеләре: «Әлкинефть» — В.Ю.Филановский (1959–62), Г.М.Әхмәдиев (1962–68), «Сөләйнефть» — Б.Г.Ихсанов (1968–75), В.А.Тачаев (1975–97); «Ж.» НГДУ — Г.М.Әхмәдиев (1968–72), Р.Н.Тукаев (1972–78), Ш.Ф.*Тәхәветдинов* (1978–83), Р.С.Нурмөхәммәтов (1983–86), Н.З.*Мортазин* (1986–2001), М.З.*Таҗиев* (2001–05), М.Ш.Каюмов (2005 елдан).

*Әд.:* Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2; 25 лет коллективу НГДУ «Сулеевнефть». Альметьевск, 1993; Наперекор ветрам. Альметьевск, 1994; Гиниатуллин М.К. Развитие Татнефти: Статистика и комментарии. М., 2000.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ҖӘЛИ́ЛОВ** Садыйк Закир улы (14.6.1911, Сәмәрканд ш. — 11.9.1982, шунда ук), зоолог, а.х. фән. д-ры (1970), проф. (1971). Үзбәкстан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук эшли. 1933–38 елларда Казан ун-тында. Оренбург пед. ин-тының зоология (1938–41, 1946–48), Сәмәрканд ун-тының генетика (1948–53), Сәмәрканд а.х. ин-тының терлекләр үрчетү кафедраларын (бер үк вакытта проректор) җитәкли (1953–82). Хезмәтләре продуктлы терлек бонитетлауга һәм аның генетикасына, тут ефәкчесен үрчетүгә карый. Бозаулардагы сезонлы үзгәрешләрне әйләнә-тирә темп-раның үзгәрүе б-н бәйле булган клиник (тән темп-расы, сулыш һәм пульс ешлыгы) һәм гематологик (эритроцитларның утыру тизлеге, гемоглобин һәм эритроцитлар саны) күрсәткечләрдә билгели. Ромен сортлы салат яфракларын яңа туган тут ефәкчесе гусеницалары өчен азык итеп кулланылуның нәтиҗәлелеген исбатлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Опыт выведения новых белококонных пород тутового шелкопряда // Тр. Самаркандского с.-х. ин-та. Сер. зоотехническая. 1963. Т. 14; Опыт кормления гусениц тутового шелкопряда салатом // Тр. Самаркандского с.-х. ин-та. Сер. зоотехническая. 1966. Т. 16 (автордаш); Некоторые клинические и гематологические показатели чистопородных и помесных телят // Тр. Самаркандского с.-х. ин-та. Сер. Ветеринария. 1967. Т. 17 (автордаш).

**«ҖӘЛИЛЧЕЛӘ́Р ТӨРКЕМЕ́»**, 1942–43 елларда немец гаскәрләре басып алган Польшада һәм Германия терр-ясендә фашистларга каршы яшерен эш алып барган совет хәрби әсирләре оешмасы. 1942 елда Совет Армиясе лейтенанты Гайнан Кормаш тарафыннан Польшадагы Демблин крепостенда тотылучы совет хәрби әсирләреннән оештырыла. Сугыш башлангач ук ул, «иң ышанычлы офицер» буларак, дошман тылына җибәрелә. Баштарак бу төркем составына Таҗикстан ССР Сәүдә халык комис-тының элеккеге хезмәткәре Фоат Сәйфелмөлеков (төркем җитәкчесе урынбасары), БАССРның Кандыр р-ны башкарма ком-тының элеккеге рәисе Муллаян (Муллаҗан) Тимеркәй улы Габдуллин (1943 нең сентябрендә фашистлар әсирлегеннән кача, совет хәрби әсирләре лагерьларында яшерен төркемнәр эшләве турында беренче язма хәбәр калдыра, 1944 нең мартында фронтта һәлак була), Абдулла *Алиш* (шагыйрь), Фоат Зыятдин улы Булатов (төзүче инженер, аның яшьлеге Оренбург шәһәрендә М.*Җәлил* б-н бер ишегалдында



Г. Кормаш.


А. Алиш.



Ә. Атнашев.



А. Батталов.


Ф. Булатов.



С. Бохаров.



М. Җәлил.


Ф. Сәйфелмөлеков.


Р. Саттар.


Ә. Симаев.


З. Хәсәнов.


Г. Шабаев.

«Җәлилчеләр төркеме» яшерен антифашистик оешмасы әгъзалары.

уза), Гомәров (М.Җәлилнең яшерен фамилиясе), Гариф Хафиз улы Шабаев (Үзбәкстан ССР Сәүдә халык комис-тының элеккеге хезмәткәре), Әхмәт Садретдин улы Симаев (журналист, шагыйрь), Абдулла Вазыйх улы Батталов (сугыш алдыннан хәзерге Алексеев р-ны Олы Тигәнәле авылында клуб мөдире), Зиннәт Хөснулла улы Хәсәнов (Казан совет сәүдәсе техникумын тәмамлый, лейтенант, рота командиры), Әхәт Мәхмүт улы Атнашев (сугышка кадәр Казакъстанның Петропавловск шәһәрендә бухгалтер), Сәлим Бохаров (Галләнур Мостафа улы Бохараев, Башкортстанның Миякә авылында бухгалтер) керә. Бу төркем эшендә ш.у. Рәхим *Саттар* (журналист, шагыйрь) һ.б. катнаша.

1942 дә Вермахт командованиесе, рус булмаган хәрби әсирләрдән милли легионнар төзеп, аларны Советлар Союзына каршы сугышта файдалану турында карар кабул итә. Әлеге планнар нигезендә 1942–43 тә Германиядәге Идел буе- Урал татарларының сәяси оешмасы — *Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлеге* төзелә. Милли легионнар оештыру планнарын гамәлгә ашыра башлаганда яшерен төркем җитәкчелеге татар, башкорт һәм Идел буенда яшәгән башка милләт совет хәрби әсирләрен *«Идел-Урал» легионына* җәлеп итәргә тырышуларга бойкот белдерә, әмма тиздән башка — легионга язылырга һәм аның әгъзалары арасында аңлату эшләре алып барырга дигән тактика кабул ителә. Муса Гомәров исеме б-н танылган татар шагыйре Муса Җәлил йөргәнен белгәч, фашистлар аны үз максатларында файдаланмакчы булалар һәм Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлегенә керергә тәкъдим итәләр. Бу исә Германия буйлап иркенләп йөрү һәм яшерен эшне киңрәк җәелдерү мөмкинлекләре ачканлыктан, М.Җәлил, Г.Кормаш белән киңәшеп, ризалык бирә һәм озакламый совет хәрби әсирләре яшерен төркемнәренең идея ягыннан рухландыручысына әверелә. Яшерен оешма әгъзалары 5 кешелек сугышчан төркемнәргә бүленә, аларның һәрберсе үз төркеме җитәкчесен генә белә; легионерлар арасында коралны немец армиясенә каршы юнәлдерергә өндәгән листовкалар таратыла. Оешма эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1943 нең феврале ахырында Идел буе татарларының Көнчыгыш фронтка җибәрелгән беренче (Вермахт документларында 825 нче) батальоны (900 дән артык кеше) белорус партизаннары ягына күчә; батальон б-н җитәкчелек иткән немец офицерлары юк ителә. Яшерен оешма әгъзалары бөтен «Идел-Урал» легионын баш күтәртергә, якында гына урнашкан әрмән легионы, поляк партизаннары б-н берләшергә, аннары, сугыша-сугыша, һөҗүм итеп килүче Кызыл Армия частьләре б-н кушылырга әзерләнәләр. Партизаннар б-н элемтә дә урнаштырыла. Ләкин сатлык җанның хыянәте аркасында (Кустанай өлкәсеннән Мәхмүт Җамалетдинов — М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге «Җәләлетдинов — хыянәтче ...» дигән язуы нәтиҗәсендә табыла), 1943 нең 11 августында оешма тар-мар ителә. Сатлык ниндидер Гали Корбанов (яшерен оешмада Мичурин) булган, дигән мәгълүматлар да бар. Өченче Рейхның икенче империя судының 1944 ел, 12 февраль карары нигезендә Плетцензее төрмәсендә (Берлин) «немец рейхының хәрби куәтен җимерүләре» һәм «дошманга булышулары өчен» яшерен оешма әгъзалары 1944 нең 25 августында җәзалап үтерелә: беренче итеп — төркем җитәкчесе Г.Кормаш, икенче — аның урынбасары Ф.Сәйфелмөлеков, аннары төркемнең башка әгъзалары: А.Алиш, Ә.Атнашев, А.Батталов, Ф.Булатов, С.Бохаров, М.Җәлил, Ә.Симаев, З.Хәсәнов, Г.Шабаевның башлары гильотинада кистерелә.

«Җәлилчеләр төркеме»нең батырлыклары турында беренче ышанычлы мәгълүматларны безнекеләргә Германиядә антифашистик яшерен оешма эшендә катнашкан Р.Б.Хисаметдинов җиткерә. Ул Кызыл Армия офицеры була, Гайнан Кормаш, Муса Җәлил һәм бу төркемдәге башка патриотлар б-н актив хезмәттәшлек итә.

*Әд.:* Мостафин Р.Ә. Өзелгән җыр эзеннән. К., 1982; шул ук. Җәлилчеләр. К., 1988.

*Р.Ә.Мостафин, Г.С.Сабирҗанов.*

**«ҖӘМӘГА́ТЬ ИМИНЛЕГЕ́ КОМИТЕТЛАРЫ́»**, 1917 елның марты-ноябрендә буржуаз һәм вак буржуаз партияләрнең вәкиллекле оешмалары. Шәһәр думалары һәм земстволар башлангычында хакимиятнең яңа структураларын оештыру максатында төзеләләр. Алар составына шәһәр думалары, земстволар, хәрби-сәнәгый ком-тлар, биржа берләшмәләре, кооперативлар, хастаханәләр кассалары һ.б. вәкилләре керә. Үз эшчәнлекләрендә Вакытлы хөкүмәт ярдәменә таяналар: Вакытлы хөкүмәтнең губерна һәм өяз комиссарларына ком-тлар б-н тыгыз элемтәдә эшләргә кушыла. Казанда ком-т 1917 нең 5 мартында оештырыла. Президиум: В.Д.Боронин (рәис), С.М.Ефимов, А.М.Поспеев һәм Ю.П.Денике (рәис иптәшләре (урынбасарлары)), В.Н.Иванов һәм Б.Н.Нелидов (секретарьлар). Ком-тта төрле комиссияләр эшли, аларның составы үзгәреп тора: башта хәрби (А.И.Абдрин, Б.Е.Агапов, Р.А.Лурия, Н.И.Зенгилевский, Н.И.Дамперов); адм. (А.Н.Нехотяев, М.С.Бухов, В.И.Кудрявцев, Ф.С.Лозовой, Л.Мостафин); финанс (П.П.Набоков, П.Г.Зайцев, В.Ибраһимов, А.Д.Чернояров, В.С.Әхмәдуллин); азык-төлек

(П.А.Дубровин, А.П.Полянин, И.Ф.Аносов, А.Мостафин, Лосев); оешмалар һәм җыелышлар төзелеше тәртибе (А.Г.Бать, Хансуаров Исхак, В.И.Вегер, Захаров, П.И.Чекунов) комиссияләре оештырыла; соңрак юридик, контроль һәм редакцион комиссияләр барлыкка килә. 29 мартта ком-т яңадан сайлана, аңа 31, ш.и. Казан эшче һәм солдат депутатлары Советыннан 12 вәкил керә. 12 апрельдә состав яңартыла: аңа профсоюз һәм җәмәгать оешмалары, ш.и. Мөселман социалистлар ком-ты вәкилләре кертелә. «Җ.и.к.» ш.у. Казан губернасының барлык өязләрендә дә (Цивильскида — 6 мартта, Царёвококшайскида һәм Чистайда — 7 мартта һ.б.) оеша. Чистайдагы ком-т 68 кешедән тора, 4 секция (халык милициясен оештыру, тынычлык саклау һәм яңа стройны яклау, мәгариф, ш.у. азык-төлек буенча) эшли. Июльдән, халыкка мәгълүматлар тарату, милиция оештыру кебек баштагы вазифалардан тыш, «Җ.и.к.»на крәстиян чыгышлары активистларына каршы репрессияләр оештыру бурычы да йөкләнә. Ком-тлар эшчәнлеге халыкта хуплау тапмый, алар Вакытлы хөкүмәтнең урыннардагы таянычына әверелә алмыйлар. Өяз ком-тлары еш кына халык тарафыннан таратыла (мәс., Чабаксарда).

*Әд.:* В а л е е в Р.К. Кризис местных органов Временного правительства летом и осенью 1917 г. (по материалам Поволжья) // Октябрь в Поволжье и Приуралье (источники и вопросы историографии). К., 1972; З а х а р о в Н.С. Советы Среднего Поволжья в период борьбы за диктатуру пролетариата. К., 1977.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ҖӘМӘГА́ТЬ СУДЫ́** (мировой суд), сайлап куела торган мәхкәмә органы. Россиядә 1864 елгы Суд реформасы нәтиҗәсендә оештырыла, Казан губернасында 1869 ның маенда кертелә. Сословиеләргә бүленмәү, хакимияткә бәйле булмау, судьяларның алыштыргысызлыгы принципларына таянып эшли. Губерна терр-ясе, өязләр санынча, башында җәмәгать судьялары торган 12 җәмәгать округына бүленгән була. Участок һәм шәрәфле җәмәгать судьялары өяз земство җыелышларында 3 елга сайланып, Сенат тарафыннан раслана. Алар вак гражданлык һәм җинаять эшләрен, ш.и. милеккә кагылышлы 500 (соңрак 1 мең) сумга кадәр дәгъваларны, хокук бозуларны, үзләре генә (антлы утырышчылардан башка һәм, еш кына, адвокатлар катнашыннан тыш) хәл итәләр. Җәмәгать судьяларына караган эшләр буенча апелляция инстанциясе булып Казан губернасының җәмәгать судьялары съезды санала. 1889 ның 12 июлендә кабул ителгән положение һәм 1889 ның 29 декабрендә гамәлгә кергән «Суд эшләрен башкару турындагы кагыйдәләр» нигезендә губернада Җ.с. (Казаннан кала) бетерелә, аның вазифалары авыл җирлегендә — *земство башлыклары*, шәһәрләрдә шәһәр судьялары кулына күчә; аерым эшләрне *Казан округ судының* өяз әгъзалары карый. «Җирле судны үзгәртеп кору турында»гы 1912 ел, 15 июнь законы б-н Җ.с. торгызыла (хәзер инде җәмәгать судьялары барлык катлаулардан сайланып, хөкүмәт тарафыннан расланалар); әмма ХКСның «Суд турында»гы 1 нче номерлы 1917 ел, 22 ноябрь Декреты б-н яңадан бетерелә. РФнең 1998 ел, 11 ноябрь һәм ТРның 1999 ел, 17 ноябрь законнары б-н Җ.с. ТРда гомуми юрисдикция суды буларак кабул ителә һәм РФнең бердәм суд системасына керә. Татарстанда җәмәгать судьялары җитәкчелегендә 168 суд участогы оештырыла, судьялар ТР Президенты тәкъдиме буенча ТР Дәүләт Советы тарафыннан 5 елга сайлап куела, алар бәйсезләр һәм фәкать законга гына буйсыналар. Судьялар үзләре генә җинаять (3 елга кадәр иректән мәхрүм итү җәзасы каралган булса) һәм гражданлык эшләрен карыйлар (мәхкәмә боерыгын тапшыруны; ир б-н хатын арасында балалар өчен бәхәс булмаган очракта, ир б-н хатынның аерылышу мәсьәләсен; ир б-н хатынның уртак милкен бүлүне; башка төрле гаилә-хокук мөнәсәбәтләрен; милектән файдалану тәртибен билгеләүне; дәгъва бәясе 500 минималь хезмәт хакына кадәр булганда, милекне бүлүне; хезмәт мөнәсәбәтләрен). Җәмәгать судьяларының карарлары һәм күрсәтмәләре мәҗбүри санала һәм үтәлергә тиешле була.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр.2. СПб., 1867. Т. 39, отд.2. № 41473, 41475, 41476; Собр.3. СПб., 1894. Т. 11. № 7775; П., 1915. Т. 32. № 37328; Декреты Советской власти. М., 1957. Т. 1. № 85.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Органы суда в Казанской губернии XVIII — начала XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3; Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 3.

*Е.Б.Долгов, М.М.Мәүләтшин.*

**ҖӘМӘГА́ТЬ ТӘРБИЯСЕ́ ПРИКАЗЫ́** (Казан җәмәгать тәрбиясе приказы), губерна хакимияте органы. 1775 елгы Губерна реформасы үткәрелгәндә оеша һәм 1781 нең 27 декабрендә ачыла (1798–1801 дә аның вазифаларын Казан шәһәр идарәсенең камераль департаменты башкара). Халык мәктәпләрен һәм уч-щеләрен төзекләндерү, аларның эшчәнлегенә күзәтчелек итү; ятимханәләр, гарипләр һәм акылга зәгыйфьләр йортлары, хастаханә, гыйбадәтханә, даруханәләр оештыру; ведомство карамагындагы учреждениеләргә укытучылар һәм күзәтчеләр билгеләү; аларда тәртип урнаштыру; васыятьнамәләрнең ятимнәр һәм гыйбадәтханәләр файдасына башкарылуын контрольдә тоту һ.б. б-н шөгыльләнә. Җ.т.п. дәүләт тарафыннан һәр губерна буенча ел саен 15 мең сум исәбеннән финанслана. Акчаларын арттыру максатында аңа иганә алу, саклауга кертем кабул итү, күчемсез милекне һәм дәүләт процент кәгазьләрен залогка салу хисабына ссуда бирү, хәйрия чаралары үткәрү, даруханәләрдән табыш алу рөхсәт ителә. Губернатор рәислек итә. Башта идарәханә югары земство мәхкәмәсеннән, губерна магистраты һәм югары мәхкәмәдән икешәр утырышчыдан гыйбарәт була. Кирәк чакта утырышка дворяннарның җирле җитәкчеләре, шәһәр башлыклары чакырыла. Җ.т.п. утырышында халык уч-щеләре директоры, губерна табибләре идарәсе инспекторы һәм 1826 дан мәҗбүри әгъзасы (эчке эшләр министры тарафыннан билгеләнә) катнашырга тиеш була. 1861 дән идарәханәгә дворяннардан, сәүдәгәрләр һәм дәүләт крәстияннәреннән өч кеше керә. Сенатка, губерна идарәсенә, 1810 нан Полиция министрлыгына, 1816 дан Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. 1866 да гарипләр һәм акылга зәгыйфьләр йортлары Казан губерна идарәсенә һәм Казан төрмәләр буенча попечительләр ком-тына тапшырыла. Җ.т.п. 1869 елның 1 гыйнварында бетерелә, мөлкәте һәм вазифалары Казан губерна земствосы идарәсенә тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 20. № 14592.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ҖӘМӘГА́ТЬ ТӘРТИБЕ́ ИДАРӘСЕ́**, Россия шәһәрләрендә полиция органы. Казанда 1782 елның 8 апрелендә «Тәртип уставы» («Устав благочиния») яисә Полиция уставы нигезендә оеша. Губерна һәм шәһәр хакимияте закон һәм боерыкларын, мәхкәмә хөкемнәрен гамәлгә ашыру; сәүдә кагыйдәләрен, паспортлар турында законнарны үтәү, аралашу юллары һәм күперләрнең торышын, чиркәү тәртибен саклау, лотереяларны күзәтү; рәсми булмаган оешмаларны эзәрлекләү, комарлы уеннарны тыю, әдәпсезлекне кисәтү б-н шөгыльләнә. Вак җинаятьләрне һәм 20 сумга кадәр дәгъвалы гражданлык эшләрен карый. Приставлар көн саен кулга алынучыларның исемлекләрен раслый. Губернаторга буйсына, полицмейстер идарә итә. 1800 елның 6 сентябрендә Павел I Указы нигезендә бетерелә.

*Әд.:* Е р о ш к и н Н.П. Очерки истории государственных учреждений дореволюционной России. М., 1960.

*С.А.Фролов.*

**ҖӘМӘГА́ТЬ ТУКЛАНУЫ́**, кулинария продукциясе җитештерү һәм сату б-н шөгыльләнүче төрле оештырылу-хокукый формадагы пр-тиеләр һәм эшмәкәр гражданнар эшчәнлеге өлкәсе. Татарстанда 278 мең урынга исәпләнгән һәм 20 мең кеше эшләүче 4432 объектны колачлый (2008); ш.и. 215 ресторан, 1043 кафе, 121 ашханә, 690 «Бистро» тибындагы кабымлыкханә, 52 кулинария кибете, 1756 мәктәп ашханәсе, 555 сәнәгать пр-тиеләре һәм учреждениеләре каршындагы ашханә. 2008 елда ТРда Җ.т.ның әйләнеше 20,5 млрд. сум тәшкил итә, шуның 96% ы дәүләти булмаган секторга туры килә. Татарстан терр-ясендә Җ.т.ның беренче оешмалары Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы заманнарында ук булуы мәгълүм. Кәрвансарайлар каршында җәмәгать кухнялары, шәһәр капкалары янында урнашкан кунып чыгу йортларында кабаклар эшләгән; аларда, ризыклардан тыш, исерткеч эчемлекләр сатылган (шәһәрдә исерткеч сату тыелган). 1804 тә Казанда 10 трактир (алар 18 йөз ахырында ачыла башлыйлар), 1839 да — 24 трактир һәм кунакханә, 25 ашханә, 2 кофе йорты,







1. Татар ашлары йорты; 2. Татар гуманитар-педагогика университетының студентлар ашханәсе;
3. 116 нчы гимназия ашханәсе. Барсысы да Казанда.

38 исерткеч эчемлекләр эчү йорты исәпләнә. 1861 дә Казан губернасында — 126, 1913 тә 236 Җ.т. оешмасы була. Казаннан тыш, алар Чистай, Мамадыш, Лаеш, Зөя, Арча шәһәрләрендә һ.б. җирләрдә эшләп килә. Эшчеләргә исәпләнгән кечерәк ашханәләр бертуган Крестовниковларның, И.И.Алафузовның, П.К.Ушковның, М.М.Гликинның һ.б.ның сәнәгать пр-тиеләрендә эшләгән. Ачлык елларда (1892 дә, 1912 дә һ.б.) төрле җәмәгать оешмалары һәм шәхси иганәләр хисабына хәйрия ашханәләре ачыла. Сов. хакимияте урнашкач, күп кенә рестораннар һәм трактирлар эшчеләр һәм аларның гаилә әгъзалары туклануы өчен җәмәгать ашханәләре итеп үзгәртелә (алар ш.у. сәнәгать пр-тиеләре, уку йортлары каршында һ.б. урыннарда ачыла). 1921 нче массакүләм ачлык елында җәмәгать туклану пунктлары оештырыла. 1922 нең 1 июленә караган мәгълүматлар буенча, җәмәгать ашханәләрендә 1,6 млн.нан артык кеше туклана. 1930 да шәһәрләрдә һәм тулаем күмәкләштерү төбәкләрендә кулланучылар кооперациясе ашханәләре ачыла башлый; 1931 дә аларның саны 256 га, ш.и. авыл җирендә 174 кә җитә. 1940 елга республикада дәүләт сәүдәсенә караган 702 һәм 213 кооператив Җ.т. пр-тиесе (659 ы — шәһәрләрдә, 256 сы — авыл җирендә) исәпләнә; сәүдә әйләнеше 20,8 млн. сумга җитә (респ-када товарларны ваклап сату тулаем әйләнешенең 13% ы). Бөек Ватан сугышы башлану б-н, Җ.т. пр-тиеләренең саны 813 кә кадәр кими, 1944 тә 944 кә кадәр арта; товар әйләнеше 396,4 млн. сум тәшкил итә. Бу чорда Җ.т. эшләүче шәһәр халкы туклануының төп формасына әверелә. 1960 елга Җ.т пр-тиеләренең саны 1515 кә кадәр (50 мең урынлы) җитә, сәүдә әйләнеше 70,4 млн. сум исәпләнә (ш.и. 46% үзләрендә җитештерелгән продукцияне сатудан керә). 1965–80 дә Җ.т. челтәре 1140 пр-тиегә арта (127 мең урын), аларның күпчелеге дәүләт милкендә була. Эре сәнәгать җитештерү берләшмәләре (авиация, моторлар төзү, вертолёт, «КамАЗ», «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин», «Татнефть» һ.б.) каршында Җ.т. комб-тлары оештырыла. Мәс., «КамАЗ» ҖБ комб-ты ашханәләрендә 15–20 *мин* дәвамында берьюлы 35 мең кеше туклана.

1990 еллардагы үзгәртеп корулар шартларында Җ.т. пр-тиеләренең зур өлеше хосусый һәм катнаш милеккә күчә, кайберләре ябыла. 1990–98 дә тармак пр-тиеләре саны 40% ка, эшләүчеләр — 36% ка, урыннар саны — 36% ка, сәүдә әйләнеше, чагыштырырлык бәяләргә күчереп исәпләгәндә, 69% ка (1999 да 73% ка) кими.

2000 нән Җ.т.ның күләме үсә башлый, 2005 кә, 1999 б-н чагыштырганда, ул икеләтә арта (чагыштырырлык бәяләрдә) һәм 10,5 млрд. сум тәшкил итә (гамәлдәге бәяләрдә). 2000 еллар башыннан Җ.т. хезмәткәрләре маркетинг эшчәнлеге алып баралар; пр-тиеләрнең җитештерү юнәлешләре үзгәртеп корыла, яңа продукция эшләп чыгару үзләштерелә. «Бистро» һәм кабымлыкханәләр, «хәләл» (ризыкларны шәригать таләпләренә туры китереп әзерләүчеләр) тибындагы пр-тиеләр челтәре киңәя. Республикада ел саен 600 ләп җәйге кафе хезмәт күрсәтә, аларда 2 мең кеше эшли. «2002–2005 елларда Татарстан Республикасының сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү үсеш программасы»н гамәлгә ашыру барышында хосусый инвестицияләр җәлеп итү нәтиҗәсендә Җ.т.ның 714 яңа объекты сафка баса, сәүдә әйләнеше үсешенең уртача еллык темпы 6,7% тәшкил итә. Төрле халыкларның милли кухнялары булган пр-тиеләре ачылу хисабына ризыкларның төрләре шактый күбәя. Җ.т. өчен кадрларны Казан технол. ун-ты, Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ф-лы, Казан кооператив ин-ты; Әлмәт сәүдә-икътисад техникумы, Казан сәүдә-икътисад техникумы, Бөгелмә шәһәрендә ф-лы булган Казан кооператив техникумы, Казан механика-технол. техникумы; 23 башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе әзерли.

*Әд.:* Мироевская Н. Под силу каждому // Общественное питание. 1990. № 1; Баязитов К.С., Шакиров Р.В. Больше века на службе людям. К., 1995.

*Б.К.Шаһиева, М.Я.Гаитов.*

**ҖӘМӘГА́ТЬ ФАЙДАЛАНУЫНДАГЫ́ ТАТА́Р КИТАПХАНӘЛӘРЕ́**, Казанда. Җәмәгать файдалануындагы татар китапханәләренең башлангычы татар трактирлары каршындагы «газета уку өчен кабинетлар»га барып тоташа. 1900 еллар башында «Сарай» мөселман кунакханәсе рус, татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге 20 газета һәм журнал алдыра. Алар кунакханәдә торучыларга гына түгел, теләгән барлык кешеләргә дә тәкъдим ителә, нәтиҗәдә вестибюль уку залына әверелә.

Татарлар өчен җәмәгать файдалануындагы беренче китапханә — «Китапханә-и исламия» — 1905 елда Казан шәһәр Думасы тарафыннан Ә.Н.*Максуди* тырышлыгы б-н шәһәр җәмәгать китапханәсе ф-лы буларак ачыла. Фондның нигезен Казан наширләре һәм китап б-н сәүдә итүчеләр (Ә.Н.Максуди, Г.Камал, Кәримовлар һ.б.) иганә кылган китаплар тәшкил итә. Китапханә татар, рус, гарәп, төрек телләрендәге китаплар, Россия шәһәрләрендә нәшер ителә торган татар газеталары, башкалада чыгучы һәм җирле газета-журналлардан туплана. Китапханәгә укучылар, укытучылар, әдәбиятчылар, контора хезмәткәрләре, приказчиклар, сәүдәгәрләр һ.б. йөри. 1913 нең ахырында китапханәдән татар хатын-кызлары да файдалана башлый. 1916 елгы мәгълүматлар буенча, фондта 2263 исемдәге китап (3805 мең данә), ш.и. Шәрекъ телләрендә 1496 (1828 мең), рус телендә — 767 (1977 мең данә) китап саклана. Китапханә 35 исемдәге газета һәм журнал алдыра, аларның 13 е — татар һәм Шәрекъ телләрендә, 22 се — рус телендә. Китапханәдән көнгә 60 тан артык укучы файдалана. Ул Кәримовларның Тихвин (хәзерге Тукай) урамындагы йортында урнашкан була.

1906 да Бишбалта бистәсенең 1 нче мәчете имамы Ш.Х.Абызов башлангычы б-н Алафузов ф-калары һәм з-дларының халык-белем йорты китапханәсендә мөселман бүлеге ачыла.

1908 елда Шәрекъ клубы каршында китапханә оеша, анда клуб әгъзаларына хезмәт күрсәтүче уку залы эшләп килә. Проектлаштырылган милли музей каршында татар җәмәгать китапханәсе (1913), Г.Барудиның китап тупламалары нигезендә халык китапханәсе (1913), Г.Тукай исем. балалар китапханәсе (1914) ачу тәкъдимнәре тормышка ашмый кала.

Совет чорында һәм хәзерге вакытта Казанның барлык җәмәгать китапханәләре татар китаплары б-н тәэмин ителә.

*Әд.:* Габдельганеева Г.Г. Татарские библиотеки Казани в начале XX века // Библиотековедение. 2006. № 3.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕ́К КАРАМАГЫНДАГЫ́ ҖИР БИЛӘҮЧЕЛЕ́К**, коллектив милекнең бер төре. Ыруглык мөнәсәбәтләре таркалган чорда барлыкка килә һәм феодализм вакытында тәмам формалашып бетә. Җ.к.ж.б. Казан төбәгендә Идел буе Болгары,

Казан ханлыгы дәверләрендә җыен б-н җир биләү формасында урнаша башлый. Ханлык җирләре Рус дәүләте карамагына күчкәч (1552), Җ.к.җ.б.нең төп ин-тлары тәмам формалаша. 1861 елгы крәстияннәр реформасы нәтиҗәсендә Җ.к.җ.б. иманаларга бүлеп файдалану тәртибен ала. 1907 дә Казан губернасында җәмәгатьчелек милкендә 3430471,2 дис., ш.и. 3231687,8 дис. уңайлы (96,4%) һәм 198784,4 дис. уңайсыз (3,6%) җир була. Ләкин җитештерүнең капиталистик ысулы үсә барган саен, Җ.к.җ.б. үз әһәмиятен югалта башлый. 20 йөз башында 2992 авыл җәмәгатенең 940 ында (31,4%) крәстияннәрнең шәхси милекләрендә, 1860 еллардагы аграр реформалар нәтиҗәсендә алган имана җирләреннән тыш, җирләрнең 17% ы һәм барлык крәстиян җирләренең 3–4% ы була. 314 җәмәгатьтә — ширкәтле, 416 сында — шәхси, 220 сендә теге яки бу формадагы җир милке исәпләнә. Җ.к.җ.б. кысаларында крәстиян җирләре авыл җәмәгате эчендә нык вакланганга күрә, еш кына җәмәгать крәстияннәре төрле урында бернечә җир кишәрлегенә ия була. Җир кишәрлекләренең таралып урнашуы елдан-ел арта бара: 20 йөз башында 2992 авыл җәмәгатенең бары тик 1788 ендә генә имана җире бер урында була. Җ.к.җ.б.нең котылгысыз юлдашлары булган җирнең кишәрлек аша урнашуы, вак кишәрлек, еракта урнашкан җирләр җитештерүчәнлеккә һәм игенчелекне үстерүгә тискәре йогынты ясыйлар.

*Столыпинның аграр реформасы* дәвамында Җ.к.җ.б. әкренләп шәхси кишәрлекле җир биләү б-н алыштырыла (к. *Отруб, Хутор*). Җ.к.җ.б.ны хосусыйлаштыру процессы большевикларның авылда үткәргән аграр реформасы чорында туктала, барлык җирләр диярлек (ш.и. шәхси милектәгеләр — 714 мең дис. тирәсе) яңадан Җ.к.җ.б.кә күчә, анысы исә җирләрдән колхоз һәм совхоз формасында файдалану кертелгәнгә кадәр яши.

*Әд.:* к. *Авыл җәмәгате.*

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ҖӘМӘ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1747 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Җ.тә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 959,25 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1936 ның 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1870 тә — 411, 1897 дә — 633, 1920 дә — 880, 1926 да — 429, 1989 да — 207, 2002 дә — 210 кеше.

**«ҖӘМГЫЯТЕ́ ГЫЙЛЬМИЯ́»**, Троицк шәһәрендәге «Рәсүлия» мәдрәсәсе шәкертләре оештырган җәмгыять (1901–02). Әйдәп йөрүчеләре М.*Гафури*, Х.Искәндәров, М.Халиков, Й.Шәркый (Диликамов). Максаты — укучы яшьләр арасында гыйлем тарату һәм гыйлем эстәү өчен Бәйрут, Каһирә һ.б. алдынгы ислам илләре мәдрәсәләрендә белем алу омтылышын яклау.

**ҖӘМИ́ЛОВ** Хөсәен Мәмәт улы (15.1.1946, Үзбәкстан ССР, Ташкент өлкәсе Осман Юсупов исем. а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1977), РФАнең мөхбир әгъзасы (1990), БР ФАнең акад. (1991), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). 1968 елда Казакъстан химия-технол. ин-тын тәмамлый (Чимкент ш.). 1970–92 елларда РФА Уфа гыйльми үзәгенең Органик химия ин-тында, каталитик синтез лаб. мөдире (1977 дән) һәм директор урынбасары (1981 дән), проф. (1983). 1992 дән БР ФАнең Нефть химиясе һәм катализы ин-ты директоры һәм лаб. мөдире. РФА Уфа гыйльми үзәге рәисе урынбасары (1993 тән). Хезмәтләре органик, металлорганик химиягә, комплекслы металлар катализына карый. Металл-углерод һәм металл-водород бәйләнешләрең каталитик активлыгы көчәюен тикшерә. Уникаль төзелешле полициклик кушылмаларны бер стадияле синтезлау, кече молекула һәм атомнарның каталитик активлыгын көчәйтү, диеннарның водородның актив атомнары кергән кушылмалары б-н реакциягә керүчәнлеге, күчмәүчән металлар һәм аз тотрыклы молекулаларның гетероатом кушылмаларын каталитик синтезлау фәнни юнәлешләрен үстерә. Ж. җитәкчелегендә нефть сәнәгате өчен мономерлар, реагентлар, фунгицидлар, үсемлек иммуностимуляторлары, мед. препаратлары алуның традицион булмаган технологиясе эшләнә. 1000 нән артык фәнни хезмәт авторы, уйлап табуга 400 дән артык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1990).

Х е з м.: Норборнадиены в синтезе полициклических напряжённых углеводородов с участием металлокомплексных катализаторов // Успехи химии. 1987. Т. 46, вып. 1; Synthesis and Transformations of «non-Grignard» Organomagnesium Reagents obtained from 1,3-Dienes // J. Organomet. Chem. 1991. V.406, № 1–2 (автордаш).

**ҖӘМИ́ЛОВА** Әлфия Әнвәр кызы (15.8.1951, Казан), театр һәм гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы. Казан сәнгать уч-щесен (1970) һәм И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1976) тәмамлый. 1976–87 елларда Казан Яшь тамашачылар театрының баш рәссамы, 1987–92 дә Татар академ. театрының куючы рәссамы, 1993–95 тә Татар драма һәм комедия театрының баш рәссамы. 1995 тән Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Театр эшлеклеләре берлеге (1970), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1996). Казан театрлары сәхнәсендә 60 ка якын спектакль бизи. Җ.ның сәхнә эшчәнлегенә төгәллек, сәхнәне якты образлылык һәм бизәлеш б-н бергә бәйләү хас. Төп әсәрләре: В.Аграновскийның «Малаховны туктатыгыз!» («Остановите Малахова!», 1977), Ф.Борнашның «Таһир-Зөһрә» (1987), Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур» (1993), П.Бомаршенең «Фигароның өйләнүе» («Женитьба Фигаро», 1995) спектакльләренә декорацияләр һәм костюмнар. Җ. ш.у. күн каю алымында иҗат итеолгән «Кабырчык», «Хәтер» һ.б. декоратив паннолар авторы (2000). Республика — «Татарстанның бүгенге сәхнә бизәлеше» (2002, Казан); төбәк — «Зур Идел» (1985, Чабаксар); бөтенроссия — «Театр, кино, телевидение рәссамнары» (1986, Казан) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* С у л т а н о в а Р.Р. Современная сценография Татарстана. К., 2002; её же. Ожившая магия // Татарстан. 2002. № 11.

*Р.Р.Солтанова.*

**ҖӘМИ́ЛОВА** Фатыйма Низаметдин кызы (2.2.1909, хәзерге Арча р-ны Кызылъяр а. — 26.5.1994, шунда ук), халык остасы-зәркәнчесе, нәселдән килгән Арча зәргәрләреннән. Җ. гаиләсендә аның ире Габделбарый (1971 елда вафат), иренең атасы Мөхәммәтсафа Җәмиловлар оста зәргәрләр булалар; башлыча, заказ буенча һәм сату өчен алтын һәм көмештән хатын-кыз бизәнү әйберләре эшлиләр. Җ. кою, каралту һәм җепкыр алымнарын яхшы белә. 1980 нән шәхси кулланучылар үтенече буенча каралтылган көмештән алка,



Ф.Н.Җ ә м и л о в а. Беләзекләр.
Көмеш, каралту. 20 йөз уртасы.

беләзек, йөзекләр эшли. Җ.ның каралту алымы б-н бизәлгән зәркән әйберләре Арча р-ны (Яңа Кишет, Олы Мәңгәр, Әтнә һ.б.) халкы арасында нык таныла. Җ. — дини җыр-мөнәҗәтләр чыгара һәм башкара, изгеләр турында риваятьләр дә сөйли, гармунда уйный, шәл бәйләү һәм кулланучылар үтенече буенча традицион өс киемнәре тегү б-н дә шөгыльләнә.

*Әд.:* Ш а һ и е в а Р. Тылсым иясе // Азат хатын. 1990. № 1.

*Р.Г.Шаһиева.*

**ҖӘМИ́ТОВ** Кадыйм Җәлил улы (15.1.1946, Саба р-ны Олы Арташ а.), сынчы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Удмурт пед. ин-тының сынлы сәнгать-графика сәнгате ф-тын тәмамлый (1970), Мәскәү сынчысы В.А.Табах остаханәсендә өйрәнә (1973–78). 1973 елдан Мәскәүдә яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Әйдәп баручы рәссамнарның берсе, станлы жанр, ш.и. портрет, монументаль-декоратив һәм вак пластика остасы. Әсәрләрен төс йөгертелгән гипс, шамот, таш, гальванопластика, агач, бронза һәм бакырдан иҗат итә. Аның урта гасырлар тарихына һәм фольклорына багышланган әсәрләре («Курайчы», 1971; «Шатлык», 1985; «Савыгу», 1986; «Зөһрә йолдыз», 1989; «Тәңрем», «Дога», «Бичура», барысы да — 1990; «Ай кызы», 1991; «Сак белән Сок», «Өрәк», «Ак бүре», барысы да — 1992; «Чыңгыз хан», 2002–03); «Шагыйрь» (Г.Тукай, 1988); «Дус-

лар» («Г.Тукай, Ф.Әмирхан», 1989) һәм «Г.Тукай һәм ул яшәгән чор» («Г.Камал», «Ф.Әмирхан», «С.Сүнчәләй», «С.Рәмиев», «К.Мотыйгый», барысы да — 1992) темаларына портретлар сериясе; Г.Тукай әсәрләреннән алынган образлар («Шүрәле», «Су анасы», икесе дә — 1989 һ.б.) татар сынлы сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Җ. татарлардан мәдәният һәм фән эшлеклеләренең, күренекле сәясәтчеләрнең «Замандашлар» (М.Шәймиев, Б.Урманче, Р.Фәйзуллин, И.Таһиров, М.Сәлимҗанов, М.Җәлил һ.б.) портретлар галереясын иҗат итә (1996–2004). Вак пластика өлкәсендә анималистик («Төш. Әтәч», 1981; «Кызыксыну. Мәче», 1982; «Козгын», 1984) һәм сюжетлы-тематик («Уйлану», 1976; «Картлык», «Көй», икесе дә — 1981; «Коенып чыккач», 1986) жанрлардагы әсәрләр авторы. Бронзадан коелган «Хөррият» монументаль сынын (1997, «Казан» Милли мәдәният үзәге бинасы янындагы стелага куелган), Оренбург шәһәрендә М.Җәлил һәйкәлен (1999), Ататөрек һәйкәлен (2001, Котәһия шәһәренең Ун-т үзәгенә куелган, Төркия), татар мәдәнияте эшлеклеләре һәйкәлләренең эскиздагы өлгеләрен (М.Солтангалиев, Б.Урманче һ.б.) эшли. Җ. иҗатының пластик теле форманы стильләштерү һәм декоратив гомумиләштерү юлы б-н бөтенлеккә һәм ачыклыкка, монументаль тирән мәгънәгә ия. 1971 дән башлап күргәзмәләрдә: Мәскәүдә автономияле республикаларның бөтенсоюз күргәзмәсендә, «Скульптура һәм мохит» халыкара күргәзмәләрендә (ГФР, 1985; Австрия, 1991), «Татарт» төбәкара бөтентатар күргәзмәсендә (С.-Петербург — Казан, 1991) һ.б.да катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1978, 1980 (Мәскәү), 1982 (Вена, Австрия), 1994 (Казан), 1999 (Әнкара, Төркия) елларда уза. Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында, Милли нәфис сәнгать музеенда (Вена, Австрия), «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Томск, Новосибирск, Омск, Пермь, Ижевск шәһәрләре сәнгать музейларында, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.



К.Җ. Җ ә м и т о в. «Су анасы». Шамот. 1989. «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музее.



К.Җ. Җ ә м и т о в. «Дога». Шамот, агач. 1990. «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музее.

*Әд.:* Выставка произведений московских художников. Живопись. Скульптура. М., 1990; Кадим Замитов: Альбом. К., 1993; В а л е е в а - С у л е й - м а н о в а Г. Быть созвучным времени // Идель. 1994. № 9–10; ш у л у к. Сынчы Кадим Җәмитов // Казан утлары. 1992. № 4.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ҖӘМЛИХА́НОВ** Гали Вәлиулла улы (14.10.1914, Самара ш. — 6.12.1992, Казан), гармунчы, ТАССРның атказ. артисты (1964). 1930–37 елларда Казан концерт-эстрада бюросы солисты һәм аккомпаниаторы, 1937–80 дә Татар филармониясендә. Төрле конструкцияле концерт гармоннарында күбесенчә татар халык көйләрен башкара. Җ.ның иҗатына милли уен коралларында уйнау үзенчәлеген тирәнтен аңлау, виртуозлык, тәэсирле, үтә сизгер артистлык хас. Тыңлаучылар арасында зур популярлык казана. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**ҖӘНӘ́Й** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 24 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 43 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 19 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, баш киеме һ.б. әйберләр тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Җ.дә су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 165,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда. 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1859 да — 177, 1897 дә — 294, 1908 дә — 338, 1920 дә — 280, 1926 да — 311, 1938 дә — 208, 1949 да — 174, 1970 тә — 103, 1979 да — 79, 1989 да — 40, 2002 дә — 42 кеше.

**ҖӘНЛЕКЧЕЛЕ́К**, мех, тире җитештерү өчен мехлы җәнлекләр үрчетү; терлекчелек тармагы. Җ.нең төп объектлары — төрле төстәге чәшке, кеш, төлке һәм күк төлкеләр. Татарстанда мех җитештерү кәсепчелегенең тарихы бай. Мех әзерләү һәм җитештерү б-н *Идел буе Болгар дәүләтендә* дә шөгыльләнәләр. Табигать һәм климат шартлары бу терр-ядә җәнлекләрнең күп төрләренә: тиен, ас, ондатра, кондыз, сусарларга яшәү өчен уңай һәм җайлы була. Төбәк халкы аларга ау оештыра, тиреләрен эшкәртеп, өс һәм аяк киемнәре җитештерә.

Республикада куян үрчетү киң җәелдерелә. 1930 елда бу эшне оештыру һәм сәнәгый нигездә куяннар үрчетү, сату, аларның итен, тиресен, мамыгын куллану, калдыкларын юк итү б-н шөгыльләнүче «Кроликовод» акц. ширкәте оештырыла.

1930 ның яз айларында ТАССРның Арча кантонында беренче куян үрчетү с-злары — «Кроликовод-1» («Бөреле»), «Кроликовод-2» («Үрнәк») ачыла, аларда янутлар үрчетү эше дә башлана. 1931 дә «Бөрсет» һәм «Чистай» җәнлек с-злары оештырыла, республика җәнлек совхозлары тресты төзелә. 1932 дә махсуслаштырылган 6 совхоз санала. 1930 елларда куянчылык үсеше югары дәрәҗәгә ирешә. 1937–38 дә 63 районда 381 колхоз фермасында 20788 куян исәпләнә, һәр ана куяннан уртача 8 бала алына.

1931 дә «Бөреле» һәм «Бөрсет» с-зларына 300 һәм 150 баш төлке, 1941 дә «Бөреле» с-зына 47 ак төлке, 1948 дә 470 чәшке, 1950 дә 350 кеш китерелә. Бу вакытта барлык җәнлек совхозларында чәшке үрчетелә. 1958 дә «Кощак», 1968 дә «Әлмәт», «Матюшино», «Раифа», 1969 да «Восточный», «Тойма», «Нагорный» җәнлек с-злары оештырыла. 1970–74 елларда аерым җәнлек совхозларында янут, көзән, кызыл төлке үрчетү башлана. 1974 ел башына республикада 9 җәнлек совхозы исәпләнә. Шул ук чорда саз кондызы, елга кондызы, шиншилла һәм ондатра үрчетү эше үзләштерелә.

Чәшке, төлке, ак төлке һәм кеш ит, балык б-н тукландырыла, саз кондызы, асылда, үсемлек б-н туклана. Тукландыру өчен ат, сыер, сарык, дуңгыз ите, суелган хайваннарның әгъзалары, балык (вак һәм сортсыз), сөт, аертылган сөт, эремчек, сыр кайнатканнан калган калдыклар, коры терлек азыклары (балык оны, ефәк корты), бөртекле азык (бодай, арпа, кукуруз, тары, солы), май сәнәгате калдыклары файдаланыла. Рацион төзегәндә җәнлекләр өчен типик нормаларга таянып эш итәләр: җәнлекнең яше, тере килеш авырлыгы, физиологик халәте һәм ел фасылы исәпкә алына. Җәнлекләр ике кыеклы түбә астына рәтләргә тезелгән читлекләрдә асрала.

Мехлы җәнлекләрнең кушылу чоры елга бер була (саз кондызларының ел әйләнәсе булырга мөмкин), буаз вакыты бала имезү б-н бер үк вакытка туры килүе ихтимал. Ата җәнлек 4–5, саз кондызы исә 10 га кадәр ананы аталандыра. Төлке, ак төлке, чәшке, кешләр март-май айларында балалый. 3–4 атналык балаларны өстәмә ашата башлыйлар. 40–50 көнлек балаларны анадан аерып, ата һәм ана җенесле җәнлекләрне парлап, аерым челтәр читлеккә урнаштыралар. Августта төлке, ак төлке балаларын тамгалыйлар, нәселгә калдыруга һәм суюга каралганнарга аералар. Чәшкеләрне анадан аерганда бүләләр. Октябрь, ноябрьдә яшь җәнлекләргә бонитетлау үткәрелә, аннан соң суеп, тиреләр эшкәртү башлана.

Җ.тә нәсел үрчетү эше җәнлекләрнең зурлыгына, яшәү сәләтенә, үрчемлелегенә, кыйммәтле мехының сыйфатына карап алып барыла.

ТРда Җ. б-н 4 хуҗалык: «Бөрсет» ААҖ агрофирмасы, «Бөреле» нәсел үрчетү з-ды, «Кощак» ААҖ, «Матюшино» ААҖ шөгыльләнә. 2009 елда алынган яшь җәнлекләр саны: чәшкеләр — 141830, төлке — 9378, ак төлке — 1128, кеш — 3432 баш. 2010 ел башында ана җәнлекләр саны: чәшкеләр — 51938, төлке — 1980, ак төлке — 450, кеш — 2660 баш.

*Әд.:* Ильина Е.Д., Кузнецов Г.А. Основы генетики и селекции пушных зверей. М., 1983; Романов О.А. Мягкое золото Татарии. К., 1986.


*Г.Б.Вәлиев, А.Х.Җаббаров, Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ҖӘННӘ́Т** (гарәп. جنة — бакча; фарсы синонимы — фирдәүс), исламда оҗмахның киң таралган исеме. *Коръән* буенча, гомерләрен тәкъвалык б-н кичергән кешеләрнең теге дөньяда мәңгелек рәхәткә ирешәчәк урыны. Ике мәгънәдә кулланыла: оҗмах бакчасы һәм «теге дөньяда яшәү урыны», Коръәни Җ. күләгәле бакчалардан һәм төрле сулыклардан тора, тәкъваларны җиләс һава, тынлык, мәңге яшь парлар һәм хур кызлары урап ала. Тәкъваларның төр үзенчәлекләренә карап, Җ. берничә дәрәҗәгә бүленә. Оҗмахтагы төп сулыклар арасында әл-Кәүсәр елгасы яки буасы аерылып тора, аңа оҗмахтагы барлык елгалар да агып төшә. Җәннәтнең капкаларын Ризван җитәкчелегендәге фәрештәләр саклый. Җ.нең мөселманнардагы образы Якын Көнчыгыш халыкларының күзаллауларына барып тоташа. 19 — 20 йөз башы татар дини әдәбиятында Җ. турындагы күзаллауларның образлы тасвирлануы аның символик аңлатмасы б-н үрелеп бара.


**«ҖӘНҮ́Б ТАВЫШЫ́»** («جنوب طاوشى» — «Көньяк тавышы»), атналык газета. Россиянең көньягындагы төрки-татар демократик һәм эшчеләр оешмаларының башкарма ком-ты органы. 1918 елда Харьков шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире Н.Шахбази. Башта литография, аннары типографик ысул б-н басыла. Милли мәсьәләләрне яктырта, эшчеләр хокукларын яклаучы мәкаләләр бастыра.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом): 1905–1925. К., 1926.

**ҖӘҺӘННӘ́М** (гарәп. جهنّم), исламда тәмугның төп исемнәреннән берсе. *Коръәндә* һәм мөселман эсхатологиясендә гөнаһлылар һәм җеннәрнең җәзага тартылачак урыны. Тәмугта газапланулар образы Коръәндәге вәгаз-нәсыйхәтләрдә тәэсирле төп инандыру чараларының берсе булып тора: анда чылбырлап куелган гөнаһлылар утта янар һәм башка җәзаларга тартылыр. Бәндәләр, гөнаһларының дәрәҗәләренә карап, Җ.нең үзләренә билгеләнгән катларына урнаштырылыр. Аның капкаларын Мәлик җитәкчелегендәге зобани фәрештәләр саклый. Коръәндә Җ. образы ике төрдә бирелә: беренчесе — гөнаһлыларны йотучы коточкыч хайван, икенчесе — тирән упкын, аңа юл җиде капка аша уза. Мөселман дине белгечләре гөнаһлыларның



Җыелма җәя. 13 йөз. Новгород. А.Ф. Медведев реконструкциясе.



Җәяләр. Урта гасырлар миниатюраларыннан рәсемнәр. 14 йөз.

Җ.дә булу вакыты турында төрле фикердә тора. Мәс., сөнни исламда бары тик кяферләр генә мәңгелек җәһәннәм утында яна, ә гөнаһлы мөселманнар исә вакытлар үтү б-н газап чигүләрдән котыла, диелә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**әл-ҖӘҺӘ́БИ** (ألذهبى) Шәмседдин Әбү Абдулла бине Мөхәммәд (1274–1348), гарәп тарихчысы. Димәшкътә яшәгән. «Ислам елъязмалары» дигән хезмәтендә Алтын Урда тарихына караган мәгълүматлар бар.

Әсәр.: Из летописи ал-Джаххаби // Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1.

**ҖӘЯ́**, ук ату җайланмасы. Сыгылмалы ике җилкә-«мөгез» утыртылган дугадан һәм аны тарттырып торган керештән (җәя бавыннан) гыйбарәт. Евразия Җ.ләренең дуга озынлыгы 1,5 метрга җитә. Җ.дән ук ату дугадагы сыгылмалы җилкәләрнең үзәктәге һәм кереш беркетелгән җилкә очларындагы киеренлелек б-н бергә эш итүе нәтиҗәсендә ирешелә. Җ.ләрне камилләштерү өчен сөяк һәм мөгез җилкәләрнең дуга б-н ярашу үзенчәлекләре аеруча әһәмиятле. Җ.ләр 3 төргә аерыла: гади (тоташ бер агачтан), катлаулы (мөгез һәм сөяк җилкәле агачтан) һәм җыелма (катлаулы составлы, агач, мөгез, ташның төрле төрләреннән). Гади Җ. Идел-Чулман төбәгендә таш гасыр дәверендә, башкалары 7 йөздә барлыкка килә. Евразия зонасы Җ.ләре, гадәттә, төрле җилкәле була.

Үтерү көчен саклаган хәлдә, ату ераклыгы гадәттә 50–100 метрга җиткән; җәядән 500 метрга кадәр ату турындагы мәгълүматлар сакланган.

*Әд.:* Медведев А.Ф. Ручное метательное оружие VIII–XIV вв. М., 1966; Измайлов И.Л. К истории сложного лука Волжской Булгарии середины VIII–X вв. // Военная археология. Оружие и военное дело в исторической и социальной перспективе. СПб., 1998; Горелик В.М. Армии монголо-татар X–XIV вв. М., 2002.

**ҖЕПКЫ́Р** (филигрань, бөтеркә, челтәр бөгү, сөркә), зәргәрчелек ысулы; яньчеп шомартылган һәм ишелгән яки кырые сырлы нечкә металл чыбыктан эшләнгән бизәк. Җ.ның чыбыкларын тарттыру өчен төрле зурлыктагы тишекләре булган яссы металл (такыл) кулланылган. Спираль рәвешендә бөгелгән чыбыклардан һәм беркетелгән бөтеркә бизәкләрдән тоташ рәсем — яссы челтәрле Җ. җыела. Бизәк яссы фонга ябыштырылгач, беркетелгән Җ. барлыкка килә. Татар зәргәрләре *купертмә җепкыр* дип аталган уникаль ысул куллана башлыйлар, ул 18 йөз уртасында киң тарала. Бизәнү әйберләрендә Җ., кагыйдә буларак, *бөртекләү* б-н бергә була. Әлеге технологияне татар зәргәрләре элек «бөтеркә-сөркә» дип атаганнар.

18–20 йөзләрдә Җ.дан эшләнгән *чулпы, муенса, чигә асылмасы, яка чылбыры,* бөтеркәле җиз тәңкәләр б-н бизәлгән *хаситә* һәм *изү*, бил *каптырмалары*, беләзек, алкалар һ.б. кыйммәтле татар бизәкләре зәргәрчелек сәнгатенең тиңдәшсез үрнәкләреннән санала. Шул ук вакытта зәргәрләр бизәнү әйберләрен күпләп җитештерү мөмкинлекләрен эзлиләр, Җ.га охшатып, коеп ясалган бизәкләр җитештерә башлыйлар. Күчермәләр, гадәттә, кыйммәтле Җ. әйберләрдән эшләнгән. Моннан тыш, 15–16 йөзләрдә һәм соңрак та, зәргәрләр Җ. бизәк үрнәкләрен бик юка табаклы көмешкә кул б-н басу өчен калып (матрица) итеп файдаланганнар (к. *Басма*).

Нечкә зәркән Җ. эшләү өчен чиста алтын яки саф көмеш кулланылган. Тупасрак, арзанрак җепкыр бизәмәләр көмеш яки алтын йөгертелгән аккургаш һәм җиз кушылмала-



Коръән тартмачыгы. Алтын, фирәзә. Җепкыр. 15 йөз — 16 йөзнең 1 нче яртысы. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

рыннан ясалган. Гадәттә, чыбыкларны башта җылытканнар (җылытып йомарлау), анннары такыл аша карга борыны б-н тарттырганнар (кыздырып тарту). Бик нечкә чыбык такыл үзәгенең тишеменә куелган алмаз яки сапфир аша тартылган. Чыбыкны тартканда бер якка борганнар, аннары аңа яссы чүккеч белән сугып сыр ясаганнар. Чыбык кәтүккә чорнап та тарттырылган. Янчеп юкарту өчен бөлсә кулланылган. Бизәк өслегенә юка чыбыклардан челтәр бөгеп төрле сурәтләр төшерелгән. Ж.ның барлык элементларын бизәкнең нигезенә беркетә барганнар, аннары шомартканнар һәм ялтыратканнар. Кургаш коеп



Яка чылбыры (фрагмент). Көмеш, алтын йөгертү. Беркетелгән җепкыр. 18–19 йөзләр. ТР Милли музее.

беркетү ут өрдерү көпшәсе ярдәмендә башкарылган. Әгәр дә челтәр бизәк металл нигезендә әзерләнсә, аның өслегенә сурәт төшерелгән һәм ул шунда ук беркетеп тә куелган.

Ж.дан бизәнү әйберләре ясау б-н иң оста зәргәрләр (җепкырчылар, челтәр төзүчеләр) шөгыльләнгән. Ж. җитештерүче үзәкләр Казанда, ш.у. хәзерге Арча, Саба, Мамадыш, Лаеш һ.б. р-ннардагы авылларда урнашкан. Алардан чыккан кайбер осталар Идел-Урал буйларының башка төбәкләренә китеп тә эшләгәннәр.

Татар Ж.ы технологиясендәге һәм бизәкләрендәге традицияләр урта гасырларда Европада үзенчәлекле Ж. сәнгатен тудырган Идел буе болгарлары бизәмәләренә (чигә асылмалары, муенсалар, Коръән савытлары һ.б.) барып тоташа. Беркетелгән Ж. алымын үстергән Шәрекъ осталарыннан аермалы буларак, болгар, соңрак татар зәргәрләре төрле асылташлар б-н бизәлгән челтәрле Ж. сәнгатен чын осталарча үзләштергәннәр. Алтын Урда чорында, башлыча, аксөякләр өчен эшләнгән нәфис, зиннәтле алтын һәм көмеш әйберләрне бизәүче беркетелгән Ж. сәнгате камилләшә (*Мономах бүреге*, Коръән савытлары, беләзекләр, алкалар, йөзекләр). Бөртекләү техникасы актив кулланылган болгар Ж.ы б-н чагыштырганда Алтын Урда чоры бизәнү әйберләрендә бөртекләү икенчел дәрәҗәдәге роль уйнаган. Казан ханлыгы чорының челтәрле һәм беркетелгән Ж. алтын эшләнмәләре (берничә бил каптырмасы, татар морзалары костюмнарының декоратив төймәләре, уникаль Коръән тартмачыклары) асылташлар б-н кырланган. Алар чыбыклардан үрү ысулы б-н бөтеркә бизәк ясап, бөртекләү техникасы б-н төгәлләнүләре, өслеккә бизәккә ныклык бирүче 4–5 кырлы параллелепипедка охшаган миниатюр борыслар беркетелеп эшләнүләре б-н аерылып тора.

18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз уртасында татар Ж. сәнгатендә югары сыйфатлы һәм үзенчәлекле стильдә башкарылуы б-н аерылып торган классик әсәрләр иҗат ителә. Әлеге чор өчен бөтерелгән җеп б-н башкарылган югары тыгызлыктагы, еш кына бөртекләү б-н тулыландырылган челтәрле бизәкләр, бөтеркә бизәкләр рәвешендә кабатланып килгән, бөгелгән, бер яки ике рәтле чыбыклардан төзелгән катлаулы Ж. технологиясе, бизәкләрне ябыштырудагы гадәттән тыш чисталык һәм асылташлар б-н зиннәтләп кырлау хас. Күпертмә Ж. сәнгате чәчәк аткан чор 18 йөзнең 2 нче яртысына туры килә.

19 йөзнең 2 нче яртысындагы Ж. бизәкләр бөтеркәләрнең зурлыгы һәм сирәкләндерелүе б-н аерылып тора. Ж.ысулы б-н эшләнгән татар бизәмәләре күпләп җитештерелә башлый һәм Казан татарлары арасында гына түгел, бәлки татар-мишәрләр, Әстерхан, Себер, Касыйм татарлары, башкорт, казакъ һәм үзбәкләр арасында да тарала башлый (чулпылар, алкалар, бил каптырмалары). 20 йөз башында татар Ж.ы традицияләре әкренләп сүрелә бара. Затлы формалы һәм эшләнешле Ж. әйберләре урынын фабрикаларда җитештерелгән арзан һәм модалы продукция ала.

1920 еллар ахырында кулаклар сыйныфына кертелгән зәргәрләр үзләренең һөнәрләрен туктатырга мәҗбүр булалар. 1940 елларның 2 нче яртысыннан соң аерым халык осталары Казан арты авылларында һәм Татарстанның көнчыгыш р-ннарында, Ж.ны гади бизәлешле әйберләрдә файдаланып, хезмәтләрен дәвам иттерәләр (Саба р-ныннан Х.*Ганиев*, Ж.Хисамиев, Арча р-ныннан К.Шәмсетдинов, Ф.*Җәмилова*, Әлмәт р-ныннан С.Дәүләтшин һәм Йосыповлар гаиләсе, Оренбург өлкәсеннән Р.*Доңгыр* һ.б.). 1960 еллар уртасыннан Ж. традицияләре татар милли бизәкләренә стильләштерелгән төрле бизәнү әйберләре, Коръән тартмачыклары һ.б. иҗат иткән проф. һәм үзешчән рәссамнар Е.Бакакин, И.Васильева, В.Ковалевский, С.Ковалевская-Шәкүрова, Р.Мөхәммәтшин, Т.Соловьёва, И.Фазылҗанов, Л.Хисамиева иҗатларында яңара.



С.В. Ковалевская-Шәкүрова. «Алтынчәч» муенсасы. Көмеш, асылташлар. Челтәрле җепкыр. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Татар зәркәнчеләренең Ж.дан ясалган иҗат үрнәкләре Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында, Дәүләт тарих музеенда, Мәскәүнең Халык иҗаты һәм гамәли-бизәлеш сәнгате музеенда, Россия этнография музеенда, Дәүләт Эрмитажында (С.-Петербург), Татарстан Респ-касы, Касыйм, Әстерхан, Тобол, Төмән шәһәрләре музейларында сакланалар.

*Әд.:* Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Ювелирное искусство // Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; шул ук. Декоративное искусство Татарстана (1920 — начало 1990 г.). К., 1995; шул ук. Татарская филигрань в контексте генезиса и развития ювелирного искусства // Из истории татарского народного искусства. К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЖИДЕ́ КИЗЛӘ́Ү** авылы, Апас р-нында, Апас посёлогыннан 22 *км* төньяктарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2008 елда 84 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 33%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгызчылык. Башлангыч мәктәп. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Семи-Ключи исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ж.К.дә земство мәктәбе (1891 дә ачыла), су тегермәне, казна шәраб һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 341 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1935 нең 5 гыйнварыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 309, 1897 дә — 392, 1908 дә — 483, 1920 дә — 433, 1926 да — 408, 1938 дә — 287, 1949 да — 253, 1958 дә — 249, 1970 тә — 191, 1979 да — 141, 1989 да — 120, 2002 дә — 99 кеше.

**«ЖИДЕ́ КЫЗ БӘЕТЕ́»**, татар халык бәете. Бәеттә чынбарлыкта булган вакыйгалар тасвирлана. 1826 елда җиде байның бер төндә туган һәм бер берсенә охшаган җиде кызы, ирләр киеме киеп, Каргалы (Оренбург өлкәсе) мәдрәсәсенә килә һәм 17 ел буена үзләренең кем икәнлекләрен белдермичә шәкертләр арасында укып йөри. Әмма соңыннан сер ачыла, кызлар мәдрәсәдән куыла. Бу хәл вакыйганы тагын да кызганычрак итә. Шәригать кануннарын бозуга карамастан, бәеттә кызлар гаепләнми, хәтта аларның берсенә мулла үзенең улын өйләндерә. Бәеттә татар хатын-кызының тар гаилә тормышы кысаларыннан котылырга омтылуы чагыла. Сюжетның мажаралылыгы «җенес алмаштыру» б-н бәйле. Бәетне беренче тапкыр Г.Толымбай матбугатта бастырып чыгара.

*Әд.:* Бәетләр (революциягә кадәргеләр). К., 1935; Урманчеев Ф. Ник акмадым дәрьяга боз булып // Казан утлары. 1973. № 11; Кржижа-

н о в с к и й Ю. Девушка-юноша (К истории мотива «перемена пола») // Русский фольклор. Т. 8. Народная поэзия славян. М.–Л., 1963.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ҖИДЕГӘНЧЕЛӘ́Р» ЭШЕ́**. 1920 еллар ахырында, бер төркем татар-башкорт язучыларын контрреволюцион эшчәнлектә гаепләп, махсус оештырылган җинаять эше. Оешма Г.Кутуй б-н Г.Минский 1929 елда Уфага баргач оештырыла, аның җитәкчеләре Г.Кутуй б-н Н.Исәнбәт булган дип исәпләнә. Әлеге эш буенча С.Агиш, С.Борһан, Н.Исәнбәт, Г.Кутуй, Г.Минский, Т.Ченәкәй җавапка тартыла. Ул чордагы көндәлек басмаларда ш.у. Ф.Борнаш, Н.Гальгаф, М.Бөдәйли, Г.Рәхим, З.Галим исемнәре дә күрсәтелә. Тикшерү 1929–30 елларда бара: җинаятьләре исбатланмау сәбәпле, гаепләнүчеләр аклана һәм сак астыннан азат ителә. Шуңа да карамастан, алар үз вазифаларыннан читләштерелә һәм матбугатта нык тәнкыйтькә дучар ителә.

*Әд.:* В ә л и е в Р.К., М ә һ д и е в М.С. Узган ел авазы // Казан утлары. 1992. № 1.

*Р.К.Вәлиев.*

**«ҖИЗНӘКӘ́Й»**, татар халкының шаян җыры. Туйларда җырлана. «Җ.»нең көе татар һәм башкорт халкында киң таралган. Җырның тексты кыска һәм үткен фразалардан торган диалог рәвешендә бара: кияү балдызы б-н шаяра, ул да аңа шаяртып җавап кайтара. Күңел күтәрүчән һәм юмор рухында булуы «Җ.» җырын популярлаштыра. Беренче тапкыр текст ноталары б-н бергә этнограф С.Г.Рыбаков тарафыннан басыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; Р ы б а к о в С.Г. Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897; М ы ш к о в В.А. Мелодии ногайских и оренбургских татар // Изв. Об-ва археологии, этнографии и истории при Казан. ун-те. 1898. Т. 14.

*Ф.И.Урманчеев.*


**ҖИК** (?–?), болгар бәге. 1235–36 елларда монголлар ягына чыга һәм, аларның төп көчләре киткәч, болгарларның монголларга каршы кузгалышын җитәкли (к. *Баян белән Җик кузгалышы*). Монгол гаскәрләре б-н бәрелештә һәлак була.

**«ҖИК МӘРГӘ́Н»**, татар һәм башкорт фольклорында киң танылган архаик-героик дастан. Сүз ил батырының башбаштак хан хакимиятенә каршы көрәше турында бара. Ил башлыгы дошманнар б-н сугышта һәлак булгач, Тугзак әби, үзенең тугыз улын бер тирәгә җыеп, Агыйдел буйларында гомер итә башлый. Аның уллары батырлыклары б-н бөтен тирә-якта дан казаналар. Көтмәгәндә хан бу ыруга каршы яу чаба. Гадәттәгечә, вакыйгалар батырлык дастаннары традицияләре нигезендә сурәтләнә: Тугзак әбинең уллары уңышлы яуга барып кайтуларын зур табын артында билгеләп утәләр һәм, арып-талып, тирән йокыга талалар. Нәкъ шул мизгелдән файдаланып, хан батырларның барысын да юк итә. Ырудан бары кече кыз һәм аның сабый улы гына исән кала. Бераздан яшь хатын да кайгы-хәсрәттән дөнья куя, малай ялгыз кала. Аны төрле җәнлекләр, кыргый хайваннар үстерә. Шулай бервакыт әлеге егет үзе туган йортның хәрабәләре янына килеп чыга һәм бирелә кайчандыр булып узган зур сугыш эзләренә тап була. Егет арып йокыга китә һәм төш күрә: аның янына кайчандыр дошманнар б-н бәрелештә һәлак булган әтисе килә, аңа Җик Мәргән (сүзгә сүз — төз атучы) дип исем куша һәм, хан б-н көрәшеп, нәсел-ыруы өчен үч алырга дип, ук б-н җәя тапшыра. Әтисе ихтыярына күнеп, улы кыю егетләрдән гаскәр җыя һәм хан ягына уңышлы яулар ясый. Әмма соңгы сугышта батырның барлык гаскәре яу кырында ятып кала, ә батыр үзе дошманга әсирлеккә төшә. Эпик традицияләр таләбе буенча, яуда батыр я җиңәргә, я һәлак булырга тиеш. Вакыйгаларның мондый борылыш алуы әлеге традицияләргә каршы килә. Бәлки бу язма әдәбият йогынтысы булгандыр. Сюжетның моннан соңгы борылышы да жанр кануннарына сыймый: Җик Мәргән ханга гаҗәеп матур бер аккош тотып бирә, һәм хан Җик Мәргәнне тоткынлыктан азат итә. Шул рәвешчә, дастандагы эпик герой гадәти дәрәҗәгә төшә, ә әсәр үзе авантюристик тормыш-көнкүреш прозасына якыная. Шулай итеп, дастандагы архаик элементлар (тугыз ул, хатын-кызның ыру яисә кабилә башлыгы булуы, йоклаган дошманга һөҗүм итү, изге төш) соңрак өстәлгән өлешләр б-н үрелеп бара. Беренче тапкыр «Аң» ж-лында басыла (1916, № 14). «Җ.м.» дастанының сюжеты «*Алтынчәч*» операсына нигез итеп алына.

*Әд.:* Ф ә й з и. Фәйзи хикәяләре. К., 1918; Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; М ә р г ә н К. Башкорт халкының эпик ҡомарт ҡыллары. Өфө, 1970; У р м а н ч е е в Ф. Традиции тюркского эпоса в сказании «Джик Мерген» // Советская тюркология. 1980. № 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ҖИКӘНБА́Ш** (Typha), җикәнбашчалар семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, күбесенчә Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре үсә. Тар яфраклы Җ. (T. angustifolia) һәм киң яфраклы Җ. (T. latifolia) барлык р-ннарда да очрый. Күк Җ. (T. glauca), Лаксманн Җ. (T. laxmannii) — сирәк төрләр. Агымсыз һәм акрын агучы сулык ярлары буенда, сазлыкларда үсә. 80–200 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы озын, шуышма. Сабагы юан, цилиндрсыман, буыннары юк, төбе суганчасыман юанаеп тора. Яфраклары киң яки тар кыяксыман, озын, сабак төбендә урнашкан. Чәчәкләре бер җенесле, чәчәк тирәлеге юк, сабак очында кара-көрән хәтфә цилиндрсыман куе чәчәк төркемендә — чәкәндә урнашканнар. Җимеше — чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре көзен өлгерә һәм җил, су б-н тарала. Яфракларыннан кәрзин үрәләр. Крахмалга бай тамырчасы ондатра, җофар, саз кондызы өчен кыйммәтле азык; бактерицид, антисептик үзлекләргә ия, кан туктату чарасы буларак кулланыла. Җ. суларны зарарлы кушылмалардан чистарта.



**ҖИКӘНЛЕКУ́Л** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы — Сарман автомобиль юлы буенда. 2008 елда 22 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1909 да нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 215, 1926 да — 165, 1938 дә — 157, 1949 да — 110, 1958 дә — 110, 1970 тә — 75, 1979 да — 54, 1989 да — 36, 2002 дә — 36 кеше.

**ҖИЛ**, һаваның җир өслегенә карата хәрәкәте, атмосфера басымының тигезсез горизонталь үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Тизлеге һәм юнәлеше (кайдан исә) б-н билгеләнә. Җ., тизлеге 6–12 *м/с* булганда — уртача, 12 *м/с* тан күбрәк — көчле, 20–30 *м/с* — *шторм* (давыл), 30 *м/с* тан күбрәк булганда ураган дип санала. Җ.нең 20–30 *м/с* ка кыска вакытлы кискен үзгәрүе шквал, бөтенләй җилсез булу штиль дип атала. Җәйге аяз көннәрдә Җ.нең көндәлек хәрәкәте (төштән соң иң зур, төнлә иң аз) яхшы сизелә. Җ.нең еллык режимы *атмосфера циркуляциясе* үзенчәлекләренә һәм җирле шартларга бәйле. ТРда сентябрьдән апрельгә кадәр һәм, гомумән алганда, ел буена көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан (уртача тизлеге 4–6 *м/с*), җәен — горизонтның төньяк-көнбатыш ягыннан искән Җ.ләр өстенлек итә. Ел дәвамында тизлеге 2–5 *м/с* (45–60%) булган җилләр күпчелекне тәшкил итә. 10–25% булган очракта, күбесенчә җәен көчсез Җ. (0–1 *м/с*) күзәтелә. Тизлекләре арту б-н көчле Җ.нең кабатлануы кими. Кышкы чор бик көчле Җ.ләр б-н үзенчәлекле. Ел буена 5–20 көн 15 *м/с* һәм аннан да күбрәк тизлектәге Җ.ләр күзәтелә. Сирәк кенә ураган, давыл һәм 45 *м/с* тизлектәге өермәләр булып уза. Илл. к. *Атмосфера явым-төшемнәре* мәкаләсендә.

*Әд.:* К о л о б о в Н.В. Ветровой режим в Татарии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, кн. 3.

*Э.П.Наумов.*

**ҖИЛ ҮЛӘНЕ́**, качим (Gypsophila), канәферчәләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр, сирәк кенә ярымкуаклар ыругы. Евразиянең уртача поясында 120 гә якын төре билгеле, бер төре Австралиядә таралган. ТРда өч төре үсә. Биек качим (G. altissima) һәм дуңгәләк (G. paniculata) респ-каның барлык терр-ясендә очрый, күбесенчә Кама аръягында; Жигули Җ.ү. (G. zhegulensis) Көнчыгыш Кама алдында очрый. Ташлы сөзәклекләрдә, болыннарда, юл буйларында үсә. 50–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры үзәк, калын. Яфраклары утырма, кара-каршы. Чәчәкләре вак, ак, алсу яки җете кызыл, җепсыман озын чәчәк сабында, киң җәелгән чәчәк төркеменә-себеркечкә җыелган. Җимеше — шарсыман вак тартмачык. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Күп төрләренең тамырында («сабынлы ак тамыр» исеме б-н билгеле) шактый күләмдә сапонин бар. Дуңгәләк тамыры төнәтмәсе халык медицинасында эч йомшарту, костыру,

авыртуны басу чарасы буларак кулланыла. Агулы, баллы үсемлекләр. Дуңгәләк һәм биек качим декоратив үсемлек буларак үстерелә; 3 төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ҖИЛ ЭРО́ЗИЯСЕ**, к. *Дефляция.*

**ҖИЛӘ́Н** (фарсы — جلان), татарларның традицион җиңел өс киеме. Күбрәк бер төстәге (сары, яшел), кайчак нәзек буй төшкән йон, киҗе-мамык тукымалардан, эчлек куеп, каптырмасыз яисә күкрәк турысына бер төймә тагып тегелә. Озын һәм туры арттакталы итеп, почмаклы җиң төпләре б-н, тар озын җиңнәр һәм зур булмаган, күбесенчә шәлсыман, яка калдырып киселә. Кием чабуны ныграк каплап торсын өчен, теккәндә итәкләренең алгы ягына киң ялгаулар кертелә. Ж. үзенең өлгесе буенча күрше чуаш, мари (шобор), удмурт (шотдерем) халыкларының борынгы киемнәренә, ш.у. Урта Азия халыкларының традицион туры арттакталы киемнәренә якын тора. Гадәттә, Ж.не өлкән яшьтәге ир-атлар озын камзул яисә казаки б-н бергә кияләр. Хатын-кыз Ж.нәренең өлгесе ирләрнеке кебек үк. 19 йөз ахырыннан аларны, башлыча, таза тормышлы кешеләр, рухани хатыннары киеп йөри, кулларын җиңнәргә тыкмыйча гына, Ж. б-н баштанаяк төренеп, үзенә күрә бер япма буларак файдаланалар.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Шулпук. Одежда и украшения // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ҖИЛБЕГӘ́Н**, Себернең төрки халыклары фольклорында канатлы, җиде башлы, кеше ашаучы коточкыч зат. Аның башка кайбер сыйфатлары Алтай фольклорында чагылыш тапкан. Ул кешеләрне генә түгел, җир йөзендәге барлык тереклекне ашый; зәңгәр үгезгә атланып йөри; аның төп коралы — айбалта, хатыны б-н үтеп чыга алмаслык кара урманда тирмәдә яшиләр. Ж.нең уллары (өч яки җиде) җир асты патшалыгында гомер итәләр, еланнар һәм бакалар б-н тукланалар, әмма алар җир өстенә дә чыгарга, кешеләрнең көтүлекләренә дә ташланырга мөмкин. Ж. шулкадәр куәтле ки, илаһи көчләр — тауларны, диңгез дулкыннарын терелтүче көчләр һәм җиңелмәс күк баһадиры Тәнек бәк («Ак-Каган» героик эпосы, «Ай-Мәргәчи» хикәяте) ярдәменнән башка бернинди баһадир да аны җиңә алмый.

Бу образга соңрак өстәлгән фаразлар Себер татарлары фольклорында чагылыш тапкан. Ж. чүл уртасында таш йортта яши, кеше телендә сөйләшә, аның хатыны, кагыйдә буларак, кеше затыннан; үзе — акбүз ат иясе, төп шөгыле — аучылык, әмма хайваннарны урлауга да хирыс («*Кадыш Мәргән*» дастаны). Кайвакыт Ж. зур кара атка атланган тимер зат итеп сурәтләнә. Аның гәүдәсе тауның бер өлеше кадәр зурлыкта тасвирлана. Әмма, бик зур гәүдәле булуына карамастан, баһадир аны авырлыкларсыз җиңә («*Йәстәй Мөңке*» дастаны). «*Алтаин Саин Сумә*» архаик героик-мифологик дастанда Ж. — хатын-кыз җенесендә. Мәс., Р.Г.*Әхмәтьянов* Ж. б-н кабардин-балкар мифологиясендә хатын-кыз җенесендә тасвирланган Әмәгән персонажларын янәшә куеп чагыштыра.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981; Суразаков С.С. Алтайский героический эпос. М., 1985.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ҖИЛГЕЛДЕ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 3 *км* төньяктарак, Ашыт елгасы буенда. 2008 елда 9 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. Башта Илгильда дип атала. 1917 гә кадәр авылның статистик мәгълүматлары Дусым авылын да кертеп исәпләнә. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ж. һәм Дусымда мәчет, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Дусым авылын да кертеп) 584 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Краснококшай (1919 га кадәр — Царёвококшай) өязе Кышлау волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 мартыннан Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 259, 1897 дә — 320, 1908 дә — 835 (Дусым авылын да кертеп), 1920 дә — 313, 1926 да — 230, 1938 дә — 226, 1949 да — 218, 1958 дә — 128, 1970 тә — 123, 1979 да — 92, 1989 да — 29, 2002 дә — 13 кеше.

**ҖИЛДӘ́К**, анемона (Anemone), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык тамырчалы үләнчел үсемлекләр (сирәк кенә ярымкуаклар) ыругы. 150 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап диярлек таралган. ТР терр-ясендә өч төре үсә. Казаяксыман Ж. (A. ranunculoides) һәр җирдә очрый, урман Ж. (A. sylvestris) — Кама аръягында һәм Идел алдында, Алтай Ж. (A. altaica) — Кама алдында. Яфраклы һәм катнаш урманнарда үсә. 10–30 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары бармаксыман теленмә яки аерым, тамыр янындагылары озын сапта, сабактагылары бөҗра ясап урнашкан. Чәчәкләре ак яки сары, берле яки чатырсыман чәчәк төркемендә. Җимеше — күпчикләвекчек. Апрель-майда чәчәк ата. Орлыктан яки тамырчаны бүлеп үрчи. Җир өсте өлешләрендә танин, сумалалар, сапонин бар. Халык медицинасында Ж. төнәтмәсе тир чыгару, авыртуны басу чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлек, бакча һәм паркларда үстерелә. Алтай Ж. һәм урман Ж. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ҖИЛКӘНКАНАТЛЫЛА́Р** (Papilionidae), чукмармыеклы көндезге күбәләкләр семьялыгы. 530 дан артык төре билгеле, күбесе тропикларда тереклек итә; Россиядә якынча 40 төре бар. Канат җәеме Европа төрләрендә 90 *мм*, тропик төрләрдә 250 *мм*; арткы канатлары эчке кырые буенча дугасыман уемлы һәм корсагына тиеп тормый. Аксыл һәм төрле төстә. Аяклары яхшы үскән. Гусеницаларының күкрәк алдында чәнечкесыман итчел исле бизләре бар, куркыныч янаганда алар тышка чыга һәм сыекча бүлеп чыгара. Чатырчәчәклеләр, кантибәрчәләр h.б. үсемлекләрдә һәм агачларда яшиләр. Курчаклары, гадәттә, ачыктан-ачык асылынып тора. Семьялыкның исеме күбәләкләрнең очу рәвешеннән алынган — канатлары б-н берничә тапкыр җилпенеп, иркен очалар. Татарстан терр-ясендә 5 төре билгеле: *махаон*; подалирий (Iphiclides podalirius), канат җәеме 68–87 *мм*, тонык сары төстә, аркылы кара буйлар бар, арткы канатларының өстендә айсыман зәңгәр тимгелләр, аскы ягында берәр кызыл тап бар, июньдә оча; поликсена (Zerynthia polyxena), 45–56 *мм*, кара чуар сурәтле, сары төстә, апрель-майда оча; *аполлон*; мнемозина яки кара аполлон (Parnassius mnemosyne), 52–60 *мм*, ак төстә, сирәк кенә кара вак таплары бар; майдан июль уртасына кадәр оча. 5 төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*С.Г.Гордиенко.*

**ҖИЛКӘНЛЕ́ СПОРТ**, җилкәнле спорт көймәләрендә үткәрелүче ярышлар. 2 типтагы көймә катнаша: күтәрмә киле (шверт) көймә төбендәге тишек аша алына торган швертботлар һәм кильле яхталар.

Халыкара ярышларның, ш.и. Олимпия уеннарының программалары даими рәвештә үзгәреп тора, чөнки аңа популярлыгын югалткан суднолар урынына иң популяр класслы суднолар өстәлә. 2008 елгы Олимпия уеннары программасына «Neil Pryde RS:X» (җилкәнле такта — ирләр, хатын-кызлар); бер



Казансу елгасында ТР беренчелегендә җилкәнле көймәләрдә узышу. 2008.

урынлы динги «Лазер» (ирләр) һәм «Лазер-Радиал» (хатын-кызлар); ике урынлы динги «470» (ирләр, хатын-кызлар); кильле яхталар «Звёздный» (ирләр) һәм «Инглинг» (хатын-кызлар); катнаш экипажлар «Финн» (бер урынлы динги), «49ер» (скиф), «Торнадо» (катамаран) керде. Ж.с. төбәк терр-ясендә «Казан елга яхт-клубы» спорт җәмгыятендә (1913 тән), Казан авиация ин-ты спорт клубында (1956 дан), С.П.Горбунов исем. Казан Авиация ҖБнең иректе спорт җәмгыятендә (1957 дән), Воровский исем. спорт клубында (1962–88), «Электрон» физкультура коллективында (1970–91), «Рубин» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1986 дан, 1996 дан — «Авиатор»), «Локомотив» физкультура-спорт клубында (1993–2007), «Навигатор» балалар-яшүсмерләр спорт клубында (Чаллы ш., 2002 дән) үсеш ала. ТРда Ж.с.ны башлап җибәрүчеләр (оештыручылары, тренерлары) — М.В.Великанов, Л.И.Гинзбург, Г.Г.Зайцев, В.А.Карягин,

Г.И.Клевинкий, М.И.Макаров, Ш.Р.Мортазин, А.Л.Попов, А.Ф.Сорокин. ТР һәм Казанның яхтачылар җыелма командалары түбәндә саналган респ-ка, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашып килә: Идел кубогына Идел-Кама туристлык регатасы «Салкынча җил» («Свежий ветер») (2001 дән катнаша), «Вечерняя Казань» г-тасы кубогына (2003 тән уздырыла), Идел-Кама крейсерлы яхталары һәм җилкәнле туристлык судноларының «Татарстан җилкәннәре» («Паруса Татарстана») регатасы (2005 тән — ТРның ачык чемпионаты), «Казан Кремле кубогы», бөтенроссия регатасы (1993 тән уздырыла), Онега күле кубогына бөтенсоюз крейсерлы яхталар ярышы (1979, бронза медаль, «Капелла» классы), «ИнфоЛада» ҖЧҖ призына җилкәнле регата (2006, көмеш); командалы узышлар буенча Россиянең яшьләр беренчелеге (1994, көмеш). 1997–99 да «Локомотив» физкультура-спорт клубының «Норд Стар» яхта экипажы Җир шары тирәли йөзеп чыга (капитаны О.Б.Тюрин; А.Л.Онегин, А.В.Тощев, И.Н.Поликасов). ТРның иң оста яхтачылары (җиңүчеләр, приз алучылар) — А.Л.Абакумов (Россия беренчелегендә җиңүче, 2007), А.А.Алеев, Р.Ф.Вәлиев (СССР беренчелеге чемпионы, 1990, «Оптимист» классы), Л.А.Вилков, А.Елисеев, Р.Р.Закирова (Россия чемпионы, 1996–98), И.Я.Исмәгыйлев, А.А.Кириллов, Г.А.Кириллов, Р.А.Куклин (Россия чемпионы, 2006), А.Минеев (СССР беренчелегендә көмеш медаль алучы, 1990), И.Н.Мостафин («Интерволга-93» халыкара ярышында бронза медаль алучы), В.Петухов, А.Л.Попов, В.Семёнов, А.Урсу. Иң яхшы тренерлар — Л.И.Гинзбург, Б.Г.Зайцев, А.М.Куклин, И.И.Поликасов, С.П.Червяков. ТРның Ж.с. Федерациясе җитәкчеләре — А.Л.Попов (1979–86), Э.М.Соркин (1986–93), В.И.Башкатов (1993–2006), Р.С.Хәкимов (2006 дан президент).

**«ҖИЛКӘНСЕЗЛӘ́Р»**, К.Тинчуринның 3 пәрдәле трагикомедиясе. 1926 елда языла, 1928 дә яңа редакциядә басыла. Татар театрының милли репертуарында күренекле урын алып тора. Әсәрдә революциядән соңгы елларда әхлакый ориентирларын югалткан татар буржуазиясе вәкилләренең язмышы чагылыш таба. Спектакльнең премьерасы 1926 елның 9 декабрендә була. Аны сәхнәгә автор



Татар академия театрында куелган «Җилкәнсезләр» спектакленнән күренеш. 1958. Режиссёры — Ш.М.Сарымсаков. Нуретдин — Г.Шамуков, Зәйнетдин — Х.Сәлимҗанов, Рокыя — А.Хәйруллина, Дилбәр — Ш.Әсфәндиярова.

үзе куя. Рольләрне башкаручылар: З.Солтанов (Мисбах), Н.Сакаев (Нуретдин), К.Тинчурин (Батырхан), Н.Арапова (Рокыя), Ф.Ильская (Дилбәр), Ш.Шамильский (Даут), Х.Сәлимҗанов (Сөнгать). Башта пьеса «Ишкәксез» исемендә була, 8 картинадан тора һәм 2 кич дәвамында уйнала. 1928 дә «Ж.» не Г.Девишев бераз кыскартып куя; Нуретдин



Казан Зур драма театрында куелган «Җилкәнсезләр» спектакленнән күренеш. 1969. Режиссёры — Ш.М.Сарымсаков.

ролен Х.Әбҗәлилов, Батырханны Ш.Шамильский башкара. Аннан соң «Ж.». Татар акад. театрында берничә мәртәбә куела: 1933 тә, реж. — С.Булатов, Батырхан ролендә — М.Мутин; 1958 дә, реж. — Ш.Сарымсаков, рольләрне Х.Әбҗәлилов (Мисбах), Г.Шамуков (Нуретдин), Ф.Колбарисов (Батырхан), Ш.Әсфәндиярова (Дилбәр), А.Хәйруллина (Рокыя), Х.Сәлимҗанов (Зәйнетдин) башкара. Спектакльнең режиссёры һәм актёрлар Х.Әбҗәлилов, Ф.Колбарисов, А.Хәйруллина ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясенә лаек була. 1969 да пьеса Казан Зур драма театры сәхнәсендә куела (русчага Р.Зәйнуллин тәрҗемәсе), реж. — Ш.Сарымсаков, рольләрне С.Ярмолинец, Ю.Федотов (Батырхан), В.Остропольский (Нуретдин), Г.Егоров (Мисбах), П.Маслов (Зәйнетдин), В.Кешнер (Нияз), М.Кобчикова (Дилбәр), Г.Ишкова, Ю.Карева, Л.Маклакова (Рокыя) башкара. 1984 елда пьеса Әлмәт татар драма театрында куела (реж. Р.Абдуллаев).

*И.И.Илялова.*

**ҖИЛЛӘНҮ́**, җир өслегендә яки аңа якын урыннарда темп-ра үзгәрешләре йогынтысында атмосфераның, суның һәм суда эрегән матдәләрнең, организмнарның химик тәэсирендә тау токымнарының химик үзгәрүе һәм таркалу процессы. Физик, химик һәм биологик Ж.не билгелиләр. Физик Ж. тау токымнарын составларын үзгәртмичә генә механик вакланугa китерә. Тау токымнарының күләме үзгәрүен, чатнавын һәм тагын да кечерәк дезинтеграциясен темп-ра тирбәнешләре, туңу һәм эрүләр китереп чыгара. Химик Ж. вакытында нигезләр селтесезләнү, гидратация, гидролиз, оксидлашу бара һәм җир өслегендәге шартларга чыдам яңа минераль формалар барлыкка килә. Биологик Ж. организмнарның эшчәнлеге нәтиҗәсендә токымнарның механик вaклануында яки составлары үзгәрүдә чагыла. Тау токымнарын үзгәртеп һәм йомшартып, Ж. аларның денудациясенә булышлык итә һәм *туфрак ясалу процессында* катнаша. Үзләре барлыкка килгән урында калган Ж. продуктларын элювий яки Ж. кабыгы (ашалу кабыгы) дип атыйлар.

ТР терр-ясендә Ж.нең өч төре дә күзәтелә. Химик Ж. урман зонасында көчле бара, анда кислоталы (ачы) тирәлек шартларында элювиаль профильнең өске өлешеннән кремнезёмнан башка барлык минераль продуктлар чыгарыла. Тимер һәм алюминий оксидлары, тыгыз иллювиаль горизонт барлыкка китереп, профильнең түбәнге өлешендә туплана. Туфрак-үсемлек катламы темп-ра тирбәнешләрен киметкәнлектән һәм грунтның тирән туңуына каршы торганлыктан, физик Ж. табигый ландшафт шартларында бөтенләй диярлек күзәтелми. Бары тик тау токымнары турыдан-туры җир өслегендә яткан урыннарда гына туңудан һәм инсоляцион физик Ж. үсеш алган. Соңгысы бигрәк тә текә ялангач ерганак, сыза, үзәннәр сөзәклекләрендә көчле. Ул тау токымнары дезинтеграциясен һәм аларның ишелүен китереп чыгара. Бозлану эпохаларының салкын климатында туңудан Ж. үсеш алган, шул чорда формалашкан 1–2 *м* калынлыктагы балчыксыл вакташлы элювий хәзерге вакытта да яхшы саклanган. ТР фундаментының кристаллик токымнарында Ж.нең латерит, каолинит һәм тагын да катлаулырак профильдәге борынгы кабыгы билгеләнгән. Аның иң зур калынлыгы (40 *м* га кадәр) Кама җимерелүләре зонасында һәм гөмбәзсыман күтәрелмәләр периферияс бүйлап таралган.

*Әд.:* Почвы Татарии. К., 1962; Д е д к о в А.П. Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Приволжье. К., 1967; Л а п и н с к а я Т.А., Ж у р а в л ё в Е.Г. Погребённая кора выветривания фундамента Волго-Уральской нефтеносной провинции и её геологическое значение // Тр. Моск. ин-та нефтехим. и газовой пром-сти им. И.М.Губкина. М., 1967. Вып. 72.

*А.П.Дедков, Л.М.Ситдыйкова.*

**ҖИЛПӘВЕ́Ч КАНАТЛЫЛА́Р** (Strepsiptera), бөҗәкләр отряды. 300 гә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә төр составы өйрәнелмәгән. Көчле җенси диморфизмлы махсус эндопаразитлар. Ата затлар — ирекле яшәүчеләр, хитинлы йомшак каплам б-н капланган тигез бүлгәләнгән гәүдәле, 1–6 *мм* озынлыкта. Канат җәеме 2–8 *мм*. Авыз аппараты кыскарган. Ана затлар эндопаразит яшәү рәвеше алып бара һәм бөҗәкләргә аз охшаган. Гәүдәләре суалчансыман, очлыклары юк, сегментлашмаган башкүкрәк һәм сегментлашкан корсак өлешенә бүленә. Ж.к., нигездә, тигезканатлылар (Homoptera) һәм элпәканатлылар (Hymenoptera) отрядыннан булган бөҗәкләрдә паразитлык итә. Ж.к. б-н агуланган бөҗәкләрнең яшәү активлыгы түбәнәя, еш кына алар үләләр.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ҖИМЕ́Ш КУЛЬТУ́РАЛАРЫ**, культуралы үсемлекләр төркеме, нигездә, җиләк-җимеш һәм чикләвекләр алу өчен үстерелә. Ашарга яраклы җимеш бирүче 200 ыругны һәм 1000 нән артык күпьеллык үсемлекләрне берләштерүче кырыкка якын семьялык билгеле. Аларны орлыклыларга (алмагач, груша, кара миләш һ.б.), төшлеләргә (чия, слива һ.б.), җиләклеләргә (карлыган, крыжовник, кура җиләге, каен җиләге, бөрлегән һ.б.), чикләвеклеләргә (фундук һ.б.), цитруслы, тропик, субтропик төрләргә аерып йөртәләр. Ж.к. төрле семьялыкка карый: розачалар (алмагач, груша, чия, слива, кура җиләге, каен җиләге) крыжовникчалар (карлыган, крыжовник), сәдәф утчалар (әфлисун, лимон һ.б.), анарчалар (анар һ.б.). Татарстан терр-ясендә Ж.к. Идел буе Болгар дәүләте заманыннан билгеле, 12 йөз — 13 йөз башы культуралы катламында алма, чия орлыклары табыла. 17 йөз ахырыннан Ж.к. Иделнең уңъяк ярында зур мәйданнарда үстерә башлыйлар (к. *Бакчачылык*). ТРда Ж.к.ның киң таралганнары — орлыклылар, төшлеләр, җиләклеләр; орлыклылар арасында — *алмагач* һәм *груша*, төшлеләр — *чия* һәм *слива*, җиләклеләр — кара һәм кызыл *карлыган*, *каен җиләге*, *кура җиләге* һәм *крыжовник*. Республикада Ж.к. сәнәгать пр-тиеләре бакчаларында якынча 2 мең *га* мәйданда, коллектив бакчаларда якынча 30 мең *га* мәйданда һәм йорт яны бакчаларында якынча 20 мең *га* мәйданда үстерелә. Соңгы елларда Татарстан бакчаларында әлүчә, абрикос, төче чия, зелпе, лимонник һ.б. үстерелә. Алмагач — Татарстанда төп җимеш культурасы, бакчаларда аңа мәйданның 60–80%ы бирелә. Мәйданы буенча икенче урында чия, өченче урында слива тора. Орлыклы һәм төшле культуралардан торган бакчалар, нигездә, ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә — Идел алдында урнашкан. Орлыклы һәм төшле культуралар күтәренке урыннарда, уңдырышлы, уртача балчыксыл, нейтраль яисә аз ачылыклы туфракларда яхшы үсә һәм җимеш бирә. Ж.к. җиләк-җимеш питомникларында үрчетелә (бакчачылыкның Буа, Нурлат, Шөгер, Тәмте бүлекләрендә). Ж.к. бөтен җирдә үстерелә. Орлыклы һәм төшле культураларның үсентеләре яз көне яхшы үсеп китә, җиләклеләрнең — көз көне. Орлыклы культуралар — 3–5 елдан соң, төшлеләр — 2–4, җиләклеләр 1–2 елдан соң җимеш бирә башлый. ТРның барлык категория (төр) хуҗалыкларында җиләк-җимеш культураларының мәйданы 50 мең *га* дан артык (2007).

*Әд.:* Х а л и к о в Н.А. Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX — начала XX вв. М., 1981; С а м о щ е н к о в Е.Г., П а ш к и н а И.А. Плодоводство. М., 2000; В и т к о в с к и й В.Л. Плодовые растения мира. СПб., 2003; Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

*Г.Е.Осипов.*

**ҖИМЕШАШАРЛА́Р**, яфрактөрчәләр семьялыгыннан булган күбәләк төрләренең гомуми исеме. Гусеницалары, башлыча, үсемлек җимешләрендә үсә. 50 гә якын төре билгеле, аларның күбесе культуралы үсемлек корткычлары. Канат җәеме 8–20 *мм*, киңнәр (киңлеге озынлыгының яртысын тәшкил итә). Татарстан терр-ясендә — алмагач Ж. (Laspeyresia (Carpocapsa) pamonella), слива Ж. (L. (Grapholitha) funebrana) һәм борчак Ж. (L. nigricana). Алмагач Ж. — алмагачның иң куркыныч корткычы, ш.у. груша, слива һ.б. җимеш культураларын зарарлый. Канат җәеме 15–19 *мм*, май–июльдә оча. Ана затлар йомыркаларны (180 гә кадәр) яфракларга яки өлгереп җитмәгән җимешләргә сала. Берәр атнадан йомыркалардан гусеницалар чыга, җимеш йомшагы һәм орлыгы б-н тукланганда тукымаларны кимереп юллар ясыйлар. Слива Ж.ы өлгереп җитмәгән сливаларны зарарлый. Беренче күбәләкләр сливаның иртә өлгерүче сортларында, чәчәк тирәлеге коелган вакытта күренә. Ана затлар йомыркаларын җимешләргә, сирәк кенә яфракларга салалар. Гусеницалар җимеш йомшагын ашап үсә. Борчак Ж.ы Laspeyresia nigricana борчак һ.б. кузаклы культураларны зарарлый. Бер елда 1 буын үсеп җитә. Гусеницалар туфракта кышлый. Күбәләкләр борчакның чәчәк ату вакытында очып чыга. Ана затлар йомырканы күбесенчә яфракларга сала. Гусеницалар кузак эченә керә һәм борчак бөртеген кимерә. Алмагач Ж.ы б-н көрәш ысуллары — иртә язда агач кәүсәләрен корыган кайрылардан чистарту, җимеш агачларына фосфорорганик препаратлар (метатион яки метафос) сиптерү; слива Ж.ы — бакчада туфракны җәен йомшарту, көзен эшкәртү, югарыда күрсәтелгән химик препаратлар б-н бөркү; борчак Ж.ы — көздән җирне тирән итеп сукалау, 2 тапкыр трихограммалар җибәрү, чәчүлек мәйданга метафос сиптерү.

*С.Г.Гордиенко.*

**ҖИҢЕ́Л АТЛЕ́ТИКА**, ТРда спортның иң массакүләм төрләреннән берсе. Ул йөгерү (ш.и. каршылыклар б-н, эстафеталар), төрле дистанцияләрдә спортча йөрү, йөгереп килеп озынлыкка һәм биеклеккә сикерү (ш.и. колга б-н), ыргыту (диск, сөңге, чүкеч), ядрә этәрүне — Ж.а.ның күптөр ярышын үз эченә ала. Ж.а.ның аерым төрләре буенча рәсми (рекордларны теркәү б-н) беренчелекләре «Бөркет» (1909), «Көч һәм сәламәтлек» (1911) спорт җәмгыятьләре тарафыннан уздырыла. Татарстанда Ж.а., спорт төре буларак, 1920 еллар башыннан физкультура түгәрәкләрендә («Лачын», «Санитас», «Флорида», Физик культура, совет сәүдә хезмәткәрләре үзәк йортларында һ.б.), 1936 дан — профсоюзларның үзәк һәм республика ирекле спорт җәмгыятьләре советларында, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә үсеш ала. 2 нче (1923) һәм 3 нче (1924) Идел буе олимпиадаларында, җәйге Бөтентатар физкультура бәйрәмендә, 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында (1928), «ТАССР–Германия» матчында, Урал-Кузбасс спартакиадасында (1932), 1 нче (1934) һәм 2 нче (1935) Идел буе спартакиадаларында, Идел буендагы 9 милли респ-каның җәйге спартакиадаларында (1938–40), «Спартак», «Медик» ирекле спорт җәмгыятьләренең үзәк һәм республика советлары, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятьләре беренчелегенә ярышларда катнашучылар һәм приз алучылар, иң көчле Ж.а. спортчылары түбәндәгеләр — С.Аверин, Б.Глейзер, С.Динаменко, А.Иевлев, А.Казаков, И.Кашаев, Н.Т.*Колчин*, Н.Конев, Н.Крюков, А.Люппен, Е.Д.Масленникова (СССР рекордчысы, 1922), Н.П.Митянин (СССР рекордчысы, 1940, 1943), А.Панкова, П.Я.Петров, М.Рыбалко, К.Свешников, А.Червецова, Е.Шангина.1950–70 елларда РСФСР, СССРның иң көчле спортчылары (СССРның спорт осталары, ТАССРның берничә тапкыр рекордчылары) — Э.И.Әүхәдиев, Ж.Б.Афанасьева, В.Голованов, Н.С.Зубрилова, Е.Т.Козлова, В.А.Михеев, А.Мендельсон, М.Таҗетдинов, Ж.Л.Хайкина, Ю.Худяков, В.Н.Чумаков.

ТРның иң көчле Ж.а. спортчылары, Олимпия уеннарында, дөнья, Европа кубокларында, дөнья, Европа, СССР, РФ чемпионатларында, СССР, РСФСР халыклары спартакиадаларында, профсоюзларның Бөтенсоюз ирекле физкультура-спорт җәмгыятьләре үзәк советлары беренчелекләрендә, 4нче Ислам хатын-кызлары уеннарында катнашучылар һәм приз алучылар — Т.Х.Әбҗәлилов, Н.К.Афанасьев, И.И.Әхмәтшин, Е.С.Бикулова-Маськина, И.А.Вострикова, Ф.И.Зарипов, Ю.Зиновьева, С.Н.Ишмулкин, Д.В.*Капустин*, Р.И.*Кашапов*, Е.С.*Кондратьева*, С.Н.Манаков, А.В.Мастров, Е.С.Мигунова, К.Х.Мохтаров, Л.Ф.*Нуретдинова*, Г.Н.Панин, И.Н.Переведенцев, Н.А.Переведенцева, И.Э.Пермитина, О.М.*Рукавишникова*, А.Г.Сальников, О.В.Сальникова, Г.И.*Сәмитова-Галкина*, А.Г.Сираҗиев (ветераннар арасында), В.И.Стариков, Ю.И.Стариков, Ф.Р.Солтанова, Н.Х.Хөснуллин, А.Р.Чинкин (ветераннар арасында). Тренерлар — Н.И.Волков, В.М.Жданов, И.С.Кашаев, Ю.М.*Красильников*, Ю.И.Лапицкий, В.Н.Мастров, Х.М.*Мортазин*, Г.А.Мөхәммәдов, Ф.Ш.*Нуретдинов*, О.И.Павлова, С.И.Попов, А.А.Семагин, Б.М.Толстяков, С.А.Трошина, Н.Д.Федяков, Г.В.Цыганов, М.Н.*Чинкин*, С.Е.Шашников, Р.Р.Шурыгина, А.Н.Яшин, Ж.Л.Яшина. 1929 дан даими рәвештә «Республика Татарстан» («Красная Татария», «Советская Татария») г-тасы призына җиңел атлетика эстафетасы, 1981 дән — Казан тынычлык марафоны уздырыла. ТРда Ж.а. б-н шөгыльләнү һәм ярышлар үткәрү өчен җиһазландырылган 7 спорт комплексы, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә Ж.а. буенча 29 бүлек, Олимпия резервындагы 2 махсуслаштырылган һәм 2 комплекслы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли (2006).

*Әд.:* С и б г а т у л л и н Л. Звёзды лёгкой атлетики Республики Татарстан. К., 2003.

**ҖИҢЕ́Л СӘНӘГА́ТЬ**, сәнәгатьнең күпләп кулланылучы әйберләр җитештерүче махсуслаштырылган тармаклары җыелмасы. ТРда күн, җитен, мех, аяк киемнәре, текстиль, трикотаж, тегү, киҗе-мамык сәнәгатьләре үсеш алган. Чималны беренчел эшкәртү һәм сәнәгатьнең мебель, авиация техникасы, автомобильләр, азык-төлек җитештерүче һәм башка тармакларында, авыл хуҗалыгында, сәламәтлек саклау өлкәсендә һ.б.да кулланылучы әзер продукция чыгару б-н шөгыльләнә.

Татарстанда Җ.с.нең төп үзәкләре — Казан, Әлмәт, Чистай, Түбән Кама, Алабуга, Арча, Мамадыш шәһәрләре, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы. Кечерәк пр-тиеләр Бөгелмә, Менделеев, Лениногорск шәһәрләрендә, Алексеев, Спас, Менделеев, Балтач, Буа, Лаеш, Саба һ.б. р-ннарда урнашкан. ТР терр-ясендә (2009) барлыгы 300 дән артык пр-тие (шулардан 24 эре һәм уртача), ш.и. 293 текстиль, тегүчелек һәм мехчылык, 28 күнчелек, аяк киемнәре пр-тиеләре бар, аларда 8,8 мең кеше (ТР сәнәгатендә эшләүчеләрнең 2,4% ы) эшли. Җ.с. пр-тиеләренең 84,4% ы — хосусый, 6,6% ы — дәүләт, 0,3% ы — муниципаль, 8,7% ы катнаш һ.б. милектә. Күн, аяк киемнәре сәнәгате гомуми продукция күләменең 27% ын, текстиль, тегү һәм мех сәнәгате 73% ын тәшкил итә. Җ.с. пр-тиеләренә төп җитештерү фондларының 0,2,% ы, республика сәнәгате продукциясенең 0,4% ы туры килә. Җ.с. елга 3145,6 млн. сумлык продукция җитештерә. Татарстан Җ.с.енә, башлыча, терлекчелектән алынган чимал эшкәртүче һәм әзер продукция җитештерүче пр-тиеләр хас. Җитештерелүче эшләнмәләр арасында — күн, киез, резина аяк киемнәре, каты, юфть, хром күннән тегелгән товарлар, киҗе-мамык, җитен тукымалар һәм эрләнгән җеп, өс һәм баш киемнәре, оеклар һәм оекбашлар, галантерея товарлары, мамык, юылган йон, полипропилен капчыклар, техник максатларда чыгарылган башка төрле әйберләр һәм ярымфабрикатлар.

Татарстан җирендә Җ.с.нең барлыкка килүе һәм үсеше төбәкнең уңайлы сәүдә-географик урыны һәм чимал ресурслары, югары үсешкә ирешкән җирле кустарь кәсепчелек һәм шәһәр һөнәрчелеге б-н бәйле. Аларның күбесе болгарлар һәм болгарларгача дәверләр традицияләренә барып тоташа (к. *Күн эшләү һөнәрчелеге, Тире иләү-эшкәртү кәсепчелеге*). Элек-электән Татарстан терр-ясеннән Россиянең үзәк сәнәгый өлкәләрен көнчыгыштагы чимал төбәкләре б-н тоташтыручы мөһим сәүдә (су һәм коры җир) юллары узган. Беренче чагыштырмача эре пр-тиеләр — *күн эшкәртү мануфактуралары* Казанда 17–18 йөзләр чигендә барлыкка килә. Армия һәм флотны тәэмин итү өчен казна тарафыннан *Казан постау мануфактурасы* һәм *Помпа каеш-күннәре заводы* оештырыла. 18 йөзнең икенче яртысында татар сәүдәгәрләренең *комач мануфактуралары* оеша. Аларда татарлар эшли, мастерлар вазифаларын Бохарадан килгән кешеләр башкара; чимал (мамык, ефәк җебе) да Бохарадан китерелә. 1812 елга губернада 104 пр-тие исәпләнә: ш.и. 4 постау пр-тиесе, аларда 145 станокта 2313 кеше эшли, 150 мең аршыннан артык постау һәм йон тукымалар җитештерелә; 91 тире-күн эшкәртү пр-тиесе — 528 тире иләү чаны, 811 эшче, 375 мең данә төрле сортлы күн; 9 киҗе-мамык эрләү (комач) пр-тиесе — 307 стан, 534 эшче, 514 мең аршын киҗе-мамык, яулык тукымалары һәм комач; 2 киндер (җитен туку) пр-тиесе — 17 станок, 39 эшче, 1713 аршын киндер; 1 аркан ишү пр-тиесе — 3 станок, 26 эшче, 3,5 мең пот аркан, трос, ятьмә һәм җеп. Пр-тиеләрнең 35% ы (барлык эшчеләрнең 31% ы) татар эшмәкәрләре милкендә була. Казаннан тыш пр-тиеләр Чабаксар шәһәрендә, Царёвококшай өязенең Служилая Ура, Казан өязенең Ягодный, Алабуга өязенең Никольский авылларында урнаша. Дәүләт һәм дворяннар милкендәге пр-тиеләрдә — крепостной һәм посессион крәстияннәр, сәүдәгәр, мещан һәм крәстиян пр-тиеләрендә ялланган эшчеләр эшли. Продукция Мәскәүдә, Эрбет һәм Мәкәрҗә ярминкәләрендә сатыла, ш.у. Кяхта, Әстерхан, Оренбург аша Кытайга, Персиягә һәм Урта Азиягә җибәрелә.

Мануфактура җитештерүендә, бигрәк тә текстиль сәнәгатендәге техник алгарыш сәнәгатьтә борылыш башлануга һәм капиталистик мөнәсәбәтләр үсешенә сәбәпче була. 1830 да Г.И.Осокин постау мануфактурасында тарау, эрләү һәм туку станоклары урнаштыру нәтиҗәсендә мануфактура ф-кага әверелә (шул ук вакытта эшчеләрнең саны өч мәртәбә диярлек кыскара). 1840 елларда Казанда тагын өч киҗе-мамык ф-касында станоклар куела. Озак еллар дәвамында барлык җиһазлар да диярлек Англиядән һәм Бельгиядән китертелә.

19 йөз уртасына, озакка сузылган көрәштән соң (к. *Казан постаучылары чуалышлары*), посессион һәм крепостной эшчеләр мещаннар һәм дәүләт крәстияннәре төркеменә күчерелүгә ирешәләр. Крепостнойлар хезмәте кулланылган мануфактуралар яллы эшчеләр хезмәтенә нигезләнгән капиталистик мануфактуралар тарафыннан тулысынча кысрыклап чыгарыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында (бигрәк тә 1861 дән соң) Җ.с. тармакларының күпчелеге тиз үсә башлый: ширкәтләрдә һәм акц. җәмгыятьләрендә капитал туплана, машиналар б-н җитештерүгә корылган эре пр-тиеләр оеша. Сәнәгый борылыш башка тармакларны да — күн, тире эшкәртү, *киез итек-киез җитештерүне* колачлый. 1888 гә губернада Җ.с.кә караган 97 эре пр-тие исәпләнә, аларда 2957 эшче эшли, еллык җитештерү күләме 2,3 млн. сум тәшкил итә (ягъни губернадагы барлык эшчеләрнең 34% ы һәм барлык җитештерүнең 19% ы). 1890 еллар уртасына Җ.с. пр-тиеләренең 40% ыннан артыгында төрле дәрәҗәдә сәнәгый борылыш була. Губерна һәм, гомумән, Россия сәнәгатендә *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү-сәүдә ширкәте* пр-тиеләре аерым урын били, аларда 1884 тә — 1 меңнән артык, 1913 тә 4,5 меңнән артык кеше эшли. 1890 елларда бу пр-тиеләрдә (илдә беренчеләрдән булып) газ б-н яктырту — электр яктыртуы, пар машиналары электр моторлары б-н алмаштырыла. Эре һәм техника б-н югары дәрәҗәдә тәэмин ителгән пр-тиеләр исәбенә Казанда Ә.Я.Сәйдәшев һәм Б.М.Субаевның тире эшкәртү, А.О.Тихомировның, И.В.Чернышёвның постау җитештерү, М.И.Үтәмишевнең киҗе-мамык тукымаларману, Чистайда Ф.Л.Кекинның киҗе-мамык пр-тиеләре һ.б. керә. 1913 тә гомум җитештерү күләме һәм эшчеләренең саны буенча Җ.с. пр-тиеләре (азык-төлек сәнәгате з-д, ф-каларыннан кала) губернада 2 нче урынны били. Башлыча, Казан, Мамадыш, Лаеш, Царёвококшай өязләрендә таралган кустарь кәсепләр (күн эшкәртү, читек тегү, тире иләү, туку, чыпта-кап сугу, комач җитештерү, мамык сыру һ.б.) элеккечә үк зур роль уйный.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында хәрби заказлар Җ.с. үсеше өчен нигез була. В.Г.Шабанов, ширкәттәшләре б-н бергәләп, Казанда сугышчылар өчен өс киемнәре тегүче «Победа» һәм аяк киемнәре җитештерүче «Поляр» (к. «*Спартак*») ф-каларын оештыра, аларда 8 меңләп кеше эшли. Тиздән тагын өс киемнәре тегүче яңа 8 ф-ка һәм остаханәләр барлыкка килә. Алафузовларның пр-тиеләре тулысынча хәрби продукция җитештерүгә күчә, ашыгыч хәрби заказларга бәйле рәвештә аларда эшләүчеләрнең саны 16 мең кешегә җитә. Окт. рев-циясеннән соң тармак пр-тиеләренең күпчелеге дәүләт милкенә тапшырыла. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армияне тәэмин итүдә алар зур роль уйный; сугыш кием-салымнары тегү буенча, Мәскәү пр-тиеләреннән кала, 2 нче урынны били. 1920 гә елына 325 мең шинель, 632 мең пар аяк киеме, 300 мең баш киеме, 221 мең гимнастёрка, 1,5 млн. эчке кием комплекты җитештерелә. Шул ук вакытта, 1914 ел б-н чагыштырганда, аяк киемнәре тегү — 5 мәртәбә, җитен тукымалар җитештерү — 71% ка, күн эшләнмәләр чыгару 87% ка кими, 1921 дә — Таткожтрест, соңрак Татодежда (Татшвейтрест), Татваленок, Текстильтрест трестлары оештырыла; аларда 10 меңнән артык эшче эшли. Вак һәм уртача зурлыктагы пр-тиеләрнең бер өлеше арендага, ш.и. элеккеге хуҗаларына бирелә.

1926–40 та республикада 12 яңа пр-тие, ш.и. илдә иң эреләрдән саналган Казан мех комб-ты (к. «*Мелита*»), М.Разумов исем. киез аяк киемнәре ф-касы (к. «*Валком*»), илдәге беренче ясалма күн ф-касы (к. *Казан ясалма күн заводы*) төзелә. Алабугада, Чистайда, Мамадышта тегү пр-тиеләре ачыла. «Спартак» күн-аяк киемнәре ком-ты, В.И.Ленин исем. җитен комб-ты, «Кызыл күнче», «Труд» күн з-длары һ.б. яңартып корыла. 1935 тә Казан мехчылары СССРда чыгарылган барлык мех әйберләрнең 50% ын җитештерәләр. 1940 та Җ.с. гомуми җитештерү күләме буенча ТАССР сәнәгате продукциясе арасында 1 нче урынны били (29,8%). Бөек Ватан сугышы елларында респ-ка пр-тиеләрендә шинельләр, гимнастёркалар, чалбарлар, җылы киемнәр һәм костюмнар, маскировка халатлары, одеаллар, йоклау капчыклары, жилетлар, колакчын бүрекләр, перчаткалар, бияләйләр, мех итекләр һ.б. аяк киемнәре, очучылар өчен комбинезон һәм шлемофоннар, яктырту ракеталары өчен парашютлар һәм һавада элеңү җайланмалары һ.б. җитештерелә. Эвакуацияләнгән ф-калар нигезендә трикотаж сәнәгате барлыкка килә (Чистайда) һәм киҗе-мамык җитештерү сәнәгате тергезелә (Алабугада һәм Мамадышта).

Сугыштан соңгы елларда халык өчен яңа продукция, әйберләрнең яңа төрләрен һәм модельләрен чыгару җайга салына. Алга таба җитештерү комплексլы механикалашты-

рыла һәм конвейерлаштырыла. Бер рельслы транспорт, пневмотранспорт, тасмалы транспортёрлар файдалануга кертелә. Ясалма һәм синтетик материаллар куллану арта. 1960 елларның 2 нче яртысында төп пр-тиеләре Казанда булган күн, күн-аяк киемнәре, мех һәм төп пр-тиесе Алабугада урнашкан киҗе-мамык берләшмәләре оештырыла. 1940–70 тә Ж.с. продукциясенең гомуми күләме 5 тапкыр арта. Әзер товарлар һәм ярымфабрикатларның 60–80% ы республикадан читкә озатыла. 1970 елларда илдә җитештерелгән мех әйберләрнең 25% ы чамасы һәм киез аяк киемнәренең 20% тан артыгы Татарстанда чыгарыла. Продукциянең байтак өлешен СССР Оборона министрлыгы һәм Эчке эшләр министрлыгы заказлары тәшкил итә. Җитештерелгән әйберләр дөньяның 30 дан артык иленә озатыла. Чималның 50% ы чамасы респ-каның а.х.ннан алына. Мамык (100%), җитен сүсе (50%, 1960 еллар башыннан — 100%), йон, синтетик сүсләр (40%ка кадәр) башка төбәкләрдән китерелә. Казан химия-технол. ин-тының (хәзер Казан технология университеты) Ж.с. ф-тын, 2 техникум һәм 7 һөнәри-техник уч-щене кертеп, 30 дан артык белгечлек буенча эшчеләр һәм инженер-техник кадрлар әзерләү системасы булдырыла.

1970–80 елларда җитештерү чаралары һәм куллану әйберләре чыгаручы тармаклар үсешендә тигезсезлек барлыкка килә. Үзәк һәм җирле дәүләт һәм хуҗалык органнары тарафыннан Ж.с.нең роле икенче дәрәҗәгә төшерелә, ул «калдык принцибы» буенча финанслана. Бу техник паркның таушалуына һәм искерүенә, җитештерелүче продукциянең күләме азаюга һәм сыйфаты начараюга китерә. 1990 елларда базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә дәүләт заказының азаюы, читтән китерелгән арзан товарлар көндәшлеге, икътисади элемтәләрнең бозылуы нәтиҗәсендә Ж.с. җитештерүенең күләме 5–10 тапкыр, эшләүчеләр саны 3 тапкыр кими. 20 дән артык эре һәм уртача зурлыктагы пр-тие бөлә һәм ябыла. Башка пр-тиеләрдә җитештерү мәйданнарының 50% тан азрак өлеше генә файдаланыла, төп җитештерү фондларының тузу дәрәҗәсе 42% тәшкил итә. Җирле чимал (йон, күн, тире) базасы 80% ка кими. Аны ныгыту максатында «ТРда җитен игүне яңарту», «ТРда сарык үрчетү» респ-ка программалары кабул ителә. Тармакның социаль-икътисади һәм финанс-хуҗалык хәлен тотрыкландыру өчен ТР МК 2003–2004 елларда респ-ка Ж.с. пр-тиеләрен финанс ягыннан савыктыру концепциясен гамәлгә кертә. Хәзерге вакытта «Мелита», «Спартак», «*Сафьян*», «*Алсу*» *Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы*, «Адонис», «*Кукмара киез итек-киез комбинаты*», «Кукмара тегү фабрикасы» АҖләрендә яңартып техник һәм технологик кораллану, җитештерү күләмнәрен үстерү мәсьәләләре уңышлы хәл ителә. Ш.у.к. *Күн җитештерү, Җитен эшкәртү сәнәгате, Аяк киеме җитештерү сәнәгате, Текстиль сәнәгате, Трикотаж сәнәгате, Киҗе-мамык җитештерү сәнәгате, Тегү сәнәгате.*

*Әд.:* История Татарии в материалах и документах. М.–Л., 1937; Индустриализация ТАССР. 1926–1941 гг.: Док. и материалы. К., 1968; Рабочий класс Татарии. К., 1981; Промышленность и рабочий класс Татарии (1946–1980): Док. и материалы. К., 1986; История Казани: В 2 т. К., 1988–91.

*К.Ф.Фәсхетдинов, С.Г.Белов.*

**ЖИҢЎ ПА́РКЫ**, Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә мемориаль комплекс. 20 йөз ахырында Казанның Мәскәү р-нында Ямашев проспекты буенда элеккеге сазланган терр-ядә төзелә һәм 2000 елның 6 маенда ачыла. 42 *м* лы һәйкәлташ безнең якташларның сугышчан һәм хезмәт батырлыгын гәүдәләндерү максатында урнаштырыла. Аның нигезендә кылычлы сугышчының скульптур композициясе, сул кулы б-н бала тоткан һәм күтәрелгән уң кулында дәфнә ботагы тоткан ана; һәлак булганнар хәсрәтеннән кайгырып, алар башларын игәннәр. Истәлек ташында татар һәм рус телләрендә: «Бөек Ватан сугышында катнашучыларга тирән ихтирам белән» дигән язмалар бар. Мемориаль комплекска: танылган татарстанлылар — Сов. Союзы Геройлары, Соц. Хезмәт Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары — исемнәре мәңгеләштерелгән мәрмәр такталар куелган колоннада керә. Коллоннада үзәгендә Мәңгелек ут яна. Парктагы музейда ачык һавада хәрби техниканың Ватан сугышы чорындагы төп экспонатлары: «катюша» урнаштырылган «ЗИС-5» автомобиле, ракета җайланмалары, югары тизлекле Пе-2 бомбардировщиклары, танклар, бронетранспортёрлар һ.б. бар.

2005 елның 24 августында ТР Президенты М.Ш.Шәймиев гаиләсеннән бүләк итеп, һәлак булган сугышчыларга хәсрәтләнүче бронзадан ясалган 4 *м* лы ана һәйкәле урнаштырыла; ул кушырылган кулларында, Җиңү көненә кадәр яши алмаганнар хатирәсе билгесе итеп, лалә чәчәген тоткан. Мемориаль комплекс проекты Бөек Ватан сугышының мөһим вакыйгаларына багышланган истәлек билгеләре аллеясын булдыруны күздә тота.

Илл.: к. *Казан* мәкаләсендә.

*А.И.Новицкий.*

**ҖИР АСТЫ́ ГИДРОМЕХА́НИКАСЫ**, сыеклыклар, газлар һәм алар катнашмаларының күзәнәкчел һәм ярыклы тирәлекләрдә хәрәкәте турындагы фән. Мондый хәрәкәтне фильтрлау дип атыйлар. Җ.а.г. үсешенә француз инженеры А. Дарси (1856) тарафыннан нигез салына. Суны фильтрлау теориясенә Россия галимнәре Н.Е.Жуковский, Н.Н.Павловский, П.Я.Полубаринова-Кочина зур өлеш кертә. Җ.а.г. нефть һәм газ чыганакларын эшкәртүнең теоретик нигезен тәшкил итә. Бу юнәлеш Л.С.Лейбензон, С.А.Христианович, И.А.Чарной, В.Н.Щелкачёв һ.б. хезмәтләрендә үстерелә. Татарстанда Җ.а.г. буенча фәнни тикшерүләр 1950 нче елларда — нефть сәнәгате үсешенә бәйле рәвештә башланып китә. Казан ун-тында Г.Г.*Тумашев* һәм Һ.С.*Салехов* җитәкчелегендә шәһәр семинары оештырыла. Җ.а.г. буенча тикшеренүләрнең төп юнәлешләре — күзәнәкчел тирәлектә нефтьне су б-н этеп чыгару (Г.Г.Тумашев, В.Л.*Данилов*, С.Ф.*Сайкин*), нефть ятмаларын эшкәртүне имитацияләү һәм модельләштерү (В.Я.*Булыгин*), катламга җылылык б-н тәэсир итү юллары (Н.Н.*Непримеров*, М.А.*Пудовкин*), нефть чыганакларын эшкәртү проектларын оптимальләштерү (В.Д.*Чугунов*), катлам параметрларын идентификацияләүнең кире мәсьәләләре (В.Я.Булыгин, М.Х.Хәйруллин, Г.В.Голубев, П.Г.Данилаев, П.А.Мазуров), Җ.а.г.нда уеннар теориясе алымнары (А.Я.Чилап), нәсызыкча фильтрлау һәм аномаль нефтьне фильтрлау (Ю.М.*Молокович*, Э.В.*Скворцов*, Е.Г.*Шешуков*), релаксацияле фильтрлау (Ю.М.Молокович, П.П.Осипов, В.Ф.*Шәрәфетдинов*), бериш булмаган катламнарда физик-химик күренешләрне исәпкә алып күп компонентлы күп фазалы фильтрлау (А.Н.*Чекалин*, В.М.Конюхов, А.И.Никифоров). Катламның физик һәм электр модельләрендә (Б.И.Плещинский, Ю.А.Корнильцев, Б.А.Мифтахетдинов), чыганакларда катламнар һәм скважиналарның параметрларын билгеләү (Н.Н.Непримеров, А.В.Штанин, М.Н.Овчинников) буенча тикшеренүләр алып барыла. 1980 нче еллардан Җ.а.г. буенча тикшеренүләр тематикасы нефть чыгару кысаларыннан чыга. Фильтрацион консолидация теориясе (А.Б.*Костерин*, М.И.Дроботенко), фильтрлаучы грунтларның туңуы проблемасы (К.Г.Корнев, М.М.Алимов, А.Г.Егоров) буенча эшләр циклы башкарыла, тау токымнары геомеханикасының һәм деформацияләнүче катламнарда фильтрлауның иярешле мәсьәләләре (А.В.Костерин, Э.В.Скворцов) куела һәм чишелә, җир асты сулары пычрану модельләштерелә (А.В.Костерин, А.Н.Чекалин, В.М.Конюхов), туендырылмаган күзәнәкчел тирәлектә дым күчергәндә бармаклар хасил булу күренешенең моделе эшләнә (Р.З.Даутов, А.Г.Егоров). Җ.а.г. буенча тикшеренүләр Казан ун-тының Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, РФА КФҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында алып барыла.

*Әд.:* Очерки истории НИИ математики и механики им. Н.Г.Чеботарёва. К., 1989; Обзор исследований по механике сплошной среды (к 50-летию КНЦ РАН). К., 1995; Научно-исследовательский институт математики и механики им. Н.Г.Чеботарёва. 1993–1997. К., 1998.

*Э.В.Скворцов.*

**ҖИР АСТЫ́ СУ ЧЫГАНАКЛАРЫ́**, ч и ш м ә, к и з л ә ү л ә р, җир асты суларының табигый рәвештә җир өслегенә чыгуы. Җ.а.с.ч., кагыйдә буларак, еш кына үзара бәйле ике фактор нәтиҗәсендә барлыкка килә: геоморфологик — сулы горизонтларда рельефның эрозияле формалары (елга һәм инеш үзәннәре, ерымнар, сыза, күл казанлыклары һ.б.) б-н ачылышы һәм җирлекнең геологик-структур үзенчәлекләре — аерым зоналарның тектоник җимерелүләре, литологик яктан төрле булган токымнарның үзара контакты, флексур (буынлы) бөгелешләр аркасында югары дәрәҗәдә ярыклануы. Җир асты суларының җир өстенә чыгу рәвеше буенча Җ.а.с.ч. өскә күтәрелеп агучы һәм түбән агучы төрләргә бүләләр. Җир асты суларының чишмә эшчәнлеген билгеләүче төп күрсәткеч — чишмә дебиты — бер берәмлек вакыт эчендә агып чыккан суның күләме.

ТР терр-ясендә җир асты суларының табигый чыгуы, нигездә, Пермь системасының

терриген-карбонатлы утырмалары б-н бәйле. Ж.а.с.ч.ның формалашуы өчен аеруча уңай шартлар — тау битләренең түбәнге өлешләрендә һәм итәгендә төбенә балчыксыл токымнар түшәлгән яхшы үткәрүчән су горизонтлары (яргаланган комлыклар, известьташ һәм доломитлар) булу. Су чыганаклары суның аз үткәрүчән катламнары аша түбәндәрәк ятучы аскы басымлы горизонтларга агып чыгу, яисә эрозия нәтиҗәсендә ясалган уемнар стеналарыннан чишмәдәй бәреп чыгуы рәвешендә барлыкка килә. Инфильтрацион



Жир асты су чыганаклары. Баулы районы Покрау Ырыстамагы авылы янындагы Аккай чишмәсе.

туену зур һәм дренаж шартлары әйбәт булганда, жирле дренаж базисыннан югарырак (иң якын елга өслегеннән биегрәк) урнашкан сулы горизонтлар үзара түбән төшә торган вертикаль фильтрлашуга бәйләнгән. ТР терр-ясендә түбән агучы чишмәләр рәвешендә, кагыйдә буларак, төче жир асты сулары бәреп чыга. Жирле дренаж базисыннан түбәнрәк урнашкан сулы горизонтларда суның бәреп чыгуы аз үткәрүчән катламнар аша, башлыча, зур елга юлларына һәм өстәрәк урнашкан сулы горизонтларга күтәрелә торган фильтрлашу юлы б-н, ш.у. елга үзәннәре төбендә һәм тау итәкләрендә аз үткәрүчән каплагыч горизонтларның ярыклары һәм ташлы (литологик) тәрәзләр аша күтәрелеп агучы су чыганаклары рәвешендә бара. Күтәрелеп агучы Ж.а.с.ч., гадәттә, минеральләшүе югарырак булган сулар б-н бәйле. Мәс., Казан тирәсендәге Зәңгәр күл — түбән Пермьнең сакмар ярусы сульфатлы-карбонатлы утырмаларыннан күтәрелгән жир асты минераль суларының көчле ташкыны. Бу чыганак — гаять зур тектоник җимерелүдән хасил булган карстлы убылма нәтиҗәсе. Чишмәнең дебиты 600–700 *л/с*.

Ж.а.с.ч.ның зур күпчелеге 1 *л/с* ка кадәрле дебитка ия. Иң кечкенә дебитлар ТРның төньяк-көнбатыш р-ннарында киң таралган юра һәм акбур утырмаларына хас. Татар ярусы утырмалары б-н бәйле сулы горизонтлар үз чыганакларының уртача (0,4 *л/с*) дебитлары б-н үзенчәлекле. Иң зур дебитлар (0,3 *л/с* ка кадәр) татар утырмалары киселешенең түбәнге өлешенә хас. Күпсанлы Ж.а.с.ч. югары Казан асъярусы комлыклары һәм доломитлары б-н бәйләнгән. Аларның дебитлары 0,1–1 *л/с*, сирәгрәк 2,5–3 *л/с* тәшкил итә. Югары дебитлы чишмә чыгышлары түбән Казан асъярусының сулы горизонтларына хас. Көнчыгыш Кама аръягында түбән Казан утырмаларыннан чыгучы 22% тирәсе Ж.а.с.ч.ның дебиты 5 *л/с* тан артык. Чишмә елгасы һәм аның уң кушылдыгы — Кичүй елгасы үзәннәрендә чишмәләрнең дебиты еш кына 15–30 *л/с* ка җитә. Тектоник җимерелүләргә бәйле рәвештә аеруча яргаланган зоналар булган очракта (бу зоналар үз тирәсендәге азрак яргаланган токымнарга карата үзенчәлекле жир асты дрены ролен үти) аларның эрозия ясаган уемнар стеналарына чыккан урыннарында югары дебитлы, бергә тупланган чишмәләр барлыкка килә. Югары дебитлы чишмәләр (10 *л/с* тан артык) респ-каның көньяк-көнчыгыш р-ннарында киң таралган, бу күренеш анда жир кабыгының өске өлеше шактый катлаулы геол.-структур төзелешкә ия булуы һәм рельефның югары дәрәҗәдә бүлгәләнүе б-н аңлатыла.

Чишмәләр туенуы климат шартларына, иң мөһиме, атмосфера явым-төшемнәре күләменә бәйле, һәм ул ел дәвамында үзгәреп тора. Иң югары дебитлар яз ахыры — җәй башында, иң түбәннәре кышкы саегу чоры ахырында күзәтелә. Дебитның иң зур үзгәрешләре — жир өслегеннән соң килүче беренче сулы горизонтка, иң азлары жирле дренаж базисы биеклегендә ятучы горизонтларга хас. Иң күп сандагы чишмәләр Идел һәм Кама елгаларының уньяк яр буйларында, ш.у. Лениногорск, Тәтеш һәм Саба р-ннарында очрый. Чишмәләрне су б-н тәэмин итү чыганаклары сыйфатында яки декоратив максатларда файдалану өчен каптажлар — жир асты суларын пычранулардан саклый һәм аларны алу өчен уңайлы шартлар тудыра торган махсус корылмалар эшләнә. ТР терр-ясендә Лениногрск, Арча, Бөгелмә, Азнакайны су б-н тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасында чишмәләр киң кулланыла. Лениногорскиның су үткәргечләр челтәренә 25 чишмәдән тәүлегенә 22 мең $м^3$ су керә, һәм ул шәһәр халкын эчәргә яраклы су б-н тулысынча тәэмин итә.

Казанда беренче шәһәр су үткәргече 1874 елда Киндерле елгасының югары өлешендә татар утырмаларыннан агып чыгучы Пановка чишмәләренә нигезләнеп төзелә. Бу чишмәләрдән су чүлмәк торбалар буйлап Әки су күтәртү станциясенә агып керә, аннан соң шәһәргә кудыртыла (тәүлеккә уртача 3 мең $м^3$).

Чишмәләрнең санитар-экологик торышын тәэмин итү максатында ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан аларны паспортлаштыру һәм инвентарьлаштыру эше алып барыла. 2006 елга 3,7 меңнән артык чишмә исәпкә алынган; аларның 79% ы эчәргә яраклы су алу өчен файдаланыла. *Боровецкий чишмәләре, Спас чишмәләре* ТРның табигать истәлекләре булып санала.

*С.И.Поляков.*

**ЖИР АСТЫ́ СУЛАРЫ́**, тау токымнарының ярык һәм куышлыкларындагы сулар. Татарстанда өске катлам сулары, грунт сулары һәм катламара (артезиан) сулар; төче (тозлылыгы 1 *г/л* га кадәр), аз тозлы (1–10 *г/л*), тозлы (10–36 *г/л*) һәм нык тозлы (318 *г/л* га кадәр); салкын (20°С ка кадәр), җылы (20–37 °С) һәм кайнар (90 °С ка кадәр, Әлмәт шәһәре янында); эчәргә яраклы, техник, минераль һәм сәнәгать сулары бар. Сәнәгать Ж.а.с. ташкүмер һәм девон катламнарында һәм техноген суларда билгеләнгән. Алар составында югары концентрацияле 15–20 химик элемент исәпләнә, аш тозы, кальций гипохлориды, яндырылган магнезия, стронций карбонаты, техник бром, йод алу мөмкинлеге бар. Кайнар (термаль, энергетик) Ж.а.с. җылылык энергетикасы ихтыяҗларында: эл. энергиясе, җылылык һәм кайнар су б-н тәэмин итү өчен кулланылырга мөмкин. ТРда Ж.а.с. запасы тәүлеккә 3,8 млн. $м^3$. Татарстан халкының Ж.а.с. ресурслары б-н тәэмин ителеше югары — бер кешегә елга 1,2 $м^3$ мең су туры килә. Ж.а.с.н өйрәнү Казан ун-тында, ЦНИИгеолнеруд-та, «Татнефть» АҖнең җитештерү берләшмәләрендә һ.б.; Ж.а.с. мониторингы — сусаклагычлар янындагы стационар гидрогеологик полигоннарда, Ж.а.с. күп алына торган һәм сәнәгать, көнкүреш калдыклары күмелә торган урыннарда алып барыла. Ж.а.с. турында мәгълүмат ел саен Татарстан Респ-касында табигый ресурсларның һәм әйләнә-тирә мохитне саклауның торышы турында Дәүләт докладында басыла. Ш.у. к. *Су ресурслары, Минераль сулар.*

*Әд.:* Геологическое изучение земных недр Республики Татарстан. К., 2002; Минерально-сырьевая база Республики Татарстан. К., 2006.

*Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**ЖИР АСТЫ́ ЮЛЛАРЫ́**, Казанда, жир катламы астында үткәрелгән һәм жир өстендәге объектларны яшертен рәвештә тоташтыручы яки кирмән диварлары һәм сарайларның тышкы ягына яшерен чыгу өчен казылган ясалма галереялар. Казанны саклау системасындагы Ж.а.ю. турында рус елъязмаларында, мәс., 1552 елгы камалыш вакытында шәһәр халкының Нурали манарасыннан Казансу елгасы ярындагы чишмәгә йөрү юлы (соңрак шартлатыла) хакында хәбәр ителә. 1830 еллар уртасында Яшерен манараны реставрацияләгәндә төзүчеләр Кремльгә илтүче жир асты галереясы калдыкларына килеп юлыгалар.

1895 тә Иван мәйданында (*Беренче Май мәйданы*) император Александр II һәйкәленә урын әзерләгәндә өске ягы кирпеч б-н дугалап ныгытылган жир асты галереясы табыла. Кремль ягына юнәлгән жир асты юлының 10 метрдан кимрәк арадагы өлеше сакланган, аның дәвамы туфрак ишелеп томаланган була. Һәйкәл төзелешенә комачауламасын өчен, әлеге юл куышын күмәләр. 1950 еллар ахырында бу урында күренекле тарихчы Н.Ф.Калинин казу эшләре уздыра һәм жир асты юлының Кремльдән Гостиный двор ягына юнәлгән булуын ачыклый. Яшерен юл, кирпеч б-н түшәлеп, өсте гөмбәзсыман ярымтүгәрәк формада эшләнгән. Туфрак һәм кирпеч өемнәре комачаулавы сәбәпле, аны ахыргача үтү һәм кайсы урында жир өстенә чыгуын ачыклау мөмкин булмый.

Кайчакта Кремль калкулыгындагы иске корылмаларның күбесе бер-берсе б-н тоташ-

кан һәм, мөгаен, кайчандыр бердәм җир асты коммуникацияләр челтәрен тәшкил иткән подвалларны Җ.а.ю.на тәңгәлләштерәләр. Кремль янындагы борынгы йортларда казылулары һәм юнәлешләре билгесез булган, туфрак б-н күмелгән җир асты галереялы, тирән, күпьярусллы подваллар барлыгы ачыкланды. Тикшеренүчеләргә Месетников (Кремль урамы, 13) һәм Болдырева (Кремль урамы, 7) йортларының подвалларыннан Кремльгә таба сузылган, туфрак б-н күмелгән җир асты галереялары булуы мәгълүм. 1894 тә Месетников йортының подвал бүлмәләре тикшерелә. Йортның гөмбәз сыман түшәмле 3 ярусллы подвалы, подвалда бүлмәләр, күчү, төшү, менү урыннары була. Бүлмәләрнең түбәнге ярусы җир өстеннән 10–12 *м* тирәнлектә урнаша, тышкы диварда томаланган, ихтимал, җир асты галереясына нисбәтле а́рка табыла.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Х о м я к о в Н.М. К вопросу о подземных ходах в Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. К., 1910. Т. 26, вып. 3.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ҖИР БАКАЛАРЫ́** (Pelobatidae), койрыксыз җир-су хайваннары семьялыгы. 64 төре билгеле, Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Җ.б. (Pelobates fuscus) барлык р-ннарда да очрый. Яфраклы һәм ылыслы урманнарда, елга тугайларында, көтүлекләрдә, кырларда һәм яшелчә бакчаларында яши, йомшак туфракны өстен күрә. Гәүдәсенең озынлыгы 7 *см* га кадәр җитә. Өсте кара һәм кызыл ноктaлы, коңгырт, аскы ягы кара таплы саргылт төстә. Тиресе шома. Күзләре арасында маңгае кабарынкы. Күз бәбәге вертикаль. Ата Җ.б.ның җилкәсендә овал биз чыгып тора; үрчү чорында табан һәм җилкәләрендә вак төерләр барлыкка килә. Тире бизләре сарымсак исе килә торган сыекча бүлеп чыгара. Җир астында яши. Арт аякларындагы мөгезләнгән эре үкчә калкулыклары булу Җ.б.на үз өстенә туфракны атып, арты б-н тиз генә җиргә күмелергә мөмкинлек бирә. Җ.б. кимерүчеләр, сукыр тычканнарның тирән өннәрендә сентябрьдән апрельгә кадәр кышлыйлар. Уылдыкны апрель-майда чәчә. Ана Җ.б. 10–100 *см* тирәнлектә су асты үсемлекләренә тигезсез рәтләр б-н 2,5 меңгә кадәр уылдык бөртеген беркетелгән җепләр рәвешендә сала. Бер атнадан чукмарбашлар күренә башлый. Яшәешенең 3 нче елында җенси яктан өлгерә. Табигатьтә 4 елдан артык яши. Үрмәкүч, кырмыскалар, яңгыр суалчаннары, гусеницалар б-н туклана.

**ҖИР БИЛӘ́Ү**, хуҗаларның хокукларын һәм бурычларын ачыклаучы билгеле бер хокукый дәлилләргә нигезләнеп (милек, файдалану) җир биләү. Башта Казан төбәгендә җир уртак файдалануда була; төрле чорларда аны Ананьино, Пьянобор, Городец, Азелино, Имәнкискә һ.б. археол. культураларга караган кабиләләрнең терр. берләшмәләре били. Урта Идел буе төбәгенә төрки телле кабиләләр (*болгарлар, савирлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, биләрләр* һ.б.) килеп урнашу процессында аерым ыругларның, кабиләләрнең һәм аларның этносәяси берләшмәләренең җир биләмәләре (Болгар, Суар кенәзлекләре һ.б.) чикләре билгеләнә, Көнчыгыш Европаның төрки, фин-угор һ.б. халыклары биләгән терр-яләр бер-берсеннән аерыла. Бу чорда, хезмәт тарлавы хокукына нигезләнеп, эшкәртелүче кишәрлекләр аерым бер гаиләләрнең милкенә әверелә. Җир мөнәсәбәтләре гадәти хокук б-н көйләнә. Идел буе Болгар дәүләте чорында хосусый Җ.б.нең төрле формалары барлыкка килә; ирекле авыл җәмәгате әгъзалары үз кишәрлекләрен биләү һәм аларга хуҗа булу хокукларын саклаган хәлдә, бәк җирнең иң югары милекчесе булып исәпләнә. Аерым феодаль округларның идарәчеләре (бәкләр һ.б.), хәрби-йомышлы аксөякләр (чуралар һ.б.) бер-бер артлы аерым терр-яләрне хосусый файдалану максатында яулап алалар, шәхси биләмәләргә ия булалар. Аерым болгар бәкләренең нәселләре көчәюе нәтиҗәсендә Идел буе Болгар дәүләтендә феодаль-вотчина рәвешендәге Җ.б. формалаша. Алтын Урда, соңрак Казан ханлыгы чорларында ясаклы Җ.б.нең тәгаенләнү процессы бара (к. *Кара халык, Ясаклылар*). Алпавыт (дворян) Җ.б.е нигезләре оеша башлый. Ханның хәрби-йомышлы аксөякләргә бүләк итеп җирләр бирүе арта бара. Җир мөнәсәбәтләре кануни актлар б-н көйләнә (*ярлыклар, сөйүргаллар, тарханнар* һ.б.). Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушканнан соң (1552), патшаның җирле йомышлыларга (к. *Йомышлы татарлар*) һәм килгән рус халкына (к. *Патша сарае крәстияннәре*), ш.у. чиркәүләргә һәм монастырьларга (к. *Монастырь крәстияннәре*) җирләр бирү очраклары күбәя. Йомышлы кешеләрне аталары исеме буенча «урнаштыру» барышында Идел-Кама төбәгендә алпавыт Җ.б. оеша (к. *Алпавыт крәстияннәре*). Дәүләт җирләрен өләшү аркасында җирле ясаклы кешеләрнең һәм татар морзаларының җирләре кискен кими, бу исә соңгыларының бөлгенә китерә (к. «*Чабаталы морзалар*»). Шул ук вакытта туганнар арасында бүлешүләр нәтиҗәсендә бербөтен җирләр бүлгәләнә һәм хосусый биләмәләрнең иминлекле саклану дәрәҗәсе акрынлап кими бара. 17–18 йөзләрдә Казан төбәгендә хосусый һәм монастырь вотчиналарының саны шактый арта. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан Казан губернасында Җ.б.нең удел, казна, сәүдәгәрлек, мещанлык һ.б. формалары оеша башлый. Крепостнойлык хокукы бетерелү (1861) б-н элекке җир мөнәсәбәтләре таркалу чорына керә. Алар, башлыча, крәстиян (к. *Җәмәгатьчелек карамагындагы җир биләүчелек*), ш.у. сәүдәгәрлек һәм мещанлык Җ.б. тарафыннан акрынлап кысрыклап чыгарыла. Руханилар милкендә азсанлы хосусый биләмәләр саклана. *Столыпинның аграр реформасы* барышында вак хосусый Җ.б. ин-ты оешу процессы көчәя. Милекчеләр арасындагы җир бүленешендә яшәгән тигезсезлек, җир биләүчеләр һәм игенчеләр категорияләренең тәңгәл булмавы милек объекты сыйфатындагы җирнең хуҗалык итү объекты булган җирдән аерымлануына китерә. 1916 елга Казан губернасында Җ.б.нең түбәндәге формалары хөкем сөрә.

| № | Җир биләүчеләр категорияләре | Дисәтинәләр саны | % ларда |
|---|---|---|---|
| 1. | Шәһәр җәмгыятьләре һәм земстволар | 31486,0 | 0,6 |
| 2. | Дворяннар | 430992,0 | 8,1 |
| 3. | Руханилар, монастырьлар | 926,9 | – |
| 4. | Крәстиян җәмәгатьләре | 6230920,8 | 60,3 |
| 5. | Крәстиян җир банкы | 12796,1 | 0,2 |
| 6. | Сәүдәгәрләр | 116995,1 | 2,2 |
| 7. | Уделлар ведомствосы | 32778,1 | 0,6 |
| 8. | Уку йортлары, хәйрия учреждениеләре, казна | 1329153,3 | 24,8 |
| 9. | Хуторларда яшәүчеләр, җир эшкәртү ширкәтләре | 117066,6 | 2,2 |
| 10. | Цех учреждениеләре | 15886,6 | 0,3 |
| 11. | Шәхси эшмәкәрләр | 5808,7 | 0,1 |
| | Барлыгы | 8324890,2 | 99,4 |

Сов. хакимияте урнаштырылганнан соң (1917), җирне национализацияләү барышында дәүләт җирнең бердәнбер милекчесенә әверелә. Компетентлы дәүләт органнары тарафыннан бирелгән очракта гына гражданнар файдалану хокукы б-н җир били алалар. Җир мөнәсәбәтләрендә аны сату-алу тулысынча тыела, җир товар әйләнеше, әманәткә бирү, арендага бирү, бүләк итү, васыять буенча варислык объекты булудан туктый. Дәүләт күзәтчелегеннән һәм рөхсәтеннән башка җирдән файдаланучылар арасында алмашу тыела. 1990 елларда базар икътисады шартларында акрынлап җир товарга әверелә башлый: җир кишәрлекләрен арендалау һәм хосусыйлаштыру рөхсәт ителә. Ш.у. к. *Җирдән файдалану*.

*Әд.:* к. *Җирдән файдалану* мәкаләсе.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ҖИР БОРЧАЛАРЫ́** (Chrysomelidae), яфрагашар коңгызлар ассемьялыгы. Арткы аяклары сикерү өчен җайлашкан вак коңгызлар (1–5 *мм*). 5 меңгә якын төре билгеле, Татарстанда 60 лап төре бар. Төрле биотоплар — болын, урман, агроценозларда яшиләр. Үсемлек б-н тукланалар. Олы борчалар яфракны кимереп тишәләр һәм үсү ноктасын юк итәләр. Куркыныч янаганда җир өслегендә яшеренәләр. Үсемлек калдыклары астында яки туфракта кышлыйлар, язын үсемлек шытымнарына җыелалар. Личинкалары суалчансыман, сары, туфракта яки сабак эчендә үсә. Күп кенә төрләре яшелчә һәм басу культураларына зур зыян сала. Аксыл аяклы, уемлы, дулкынсыман борчалар әвернә чәчәклеләрдә яши. Зур сабак, гади сабак, иген сабагы борчалары, гадәттә, кыяклыларда була. Чөгендердә — гади чөгендер борчасы һәм коньяк чөгендер борчасы, бәрәңге һәм томатта — бәрәңге, киндер һәм колмакта киндер борчалары очрый. Җ.б.на каршы көрәштә көздән кырларны тирән итеп сөрү, чәчү алдыннан орлыкларны һәм шытымнарны инсектицидлар б-н эшкәртү чаралары кулланыла.

*Әд.:* Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. Киев, 1974. Т. 2.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ҖИР КАБЫГЫНЫ́Ң ГЕОЛО́ГИК ТАРИХЫ́**, терр-янең геол. үсеш процессы. ТРда 3 этапка бүленә: архей-протерозой (к. *Архей, Протерозой*), соңгы протерозой һәм фанерозой (к. *Палеозой эратемасы, Мезозой эратемасы, Кайнозой эратемасы*). Беренче этап-

та — кристаллик фундамент, соңгы икесендә 1,5 *км* дан калынрак утырма тышлык формалаша. Җ.к.г.т. үз эченә 2,7 млрд. елдан артык вакыт аралыгын ала. Ш.у. к. *Геохронология.*

**ҖИР КОМИТЕТЛАРЫ́**, Россиядә 1917–18 еллардагы җир органнары. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Вакытлы хөкүмәт тарафыннан Җир эшләре министрлыгы каршында җир реформасын эшләү һәм Учредительләр җыенын чакырганга кадәр җиргә кагылышлы бәхәсләрне хәл итү өчен төзелә. Җ.к. карамагында түбәндәге мәсьәләләр була: җир фонды мәйданнарын һәм халык санын ачыклау; җирләрне кулланырга яраклылыгы һәм категорияләре буенча бүлү; хуҗалыкларны биләмәләрнең күләме буенча төркемләү; аз җирле һәм бөтенләй җирсез хуҗалыклар санын ачыклау; җирдән файдалану проблемаларын хәл итү – җирне тапшыру һәм арендага бирү; аерым районнар буенча табигый һәм икътисади шартларга туры килә торган азык-төлек һәм хезмәт нормаларын билгеләү. 1917 нең 19 мартында Баш Җ.к. оештырыла. 1917 нең 21 апрель карары нигезендә урыннарда (губерна., өяз һәм волость) Җ.к. барлыкка килә. Казан губернасында өяз һәм волость Җ.к. 1917 нең май–июнендә оештырыла башлый. Күп кенә өяз һәм волость учреждениеләре Җ.к. оештыру буенча үз инструкцияләре нигезенә Вакытлы хөкүмәтнең Казан губернасы комиссары, өяз һәм волость комиссарлары һәм секретарьлары б-н үткәргән киңәшмәсендә (1917 нең 15–17 июне) эшләнгән кагыйдәләр салына. 1917 нең 19 июнендә Казан губерна Җ.к. оештырыла. Аңа: Казан губерна земство идарәсенең икътисад бүлекләреннән — Н.А.Бухалов, Б.М.Ермолаев, И.Н.Малахов, И.И.Штуцер һ.б.; өяз Җ.к.ннан — Н.И.Бесчастнов (Тәтеш ш.), И.В.Волков (Лаеш ш.), А.Ф.Дорофеев (Спас ш.), С.Е.Емельянов (Козьмодемьян ш.), В.И.Ивановский (Чистай ш.),А.Я.Комаров (Зөя ш.), П.И.Мочалов (Царёвококшай ш.), Н.П.Пудовик (Цивильск ш.), З.В.Сперанский (Чабаксар ш.), Н.И.Строгонов (Казан өязе), А.В.Троицкий (Ядрин ш.), И.В.Христофоров (Мамадыш ш.); Казан җәмгать иминлеге ком-тыннан — Ф.Ф.Феофанов; Казан округ судыннан — Д.А.Плетнёв; Казан губерна контроль палатасыннан — Н.В.Янишевский; Казан мөселман социалистлар ком-тыннан — М.М.Вахитов; башка учреждениеләр вәкилләре керәләр. 20 июньдә губерна Җ.к.ның башкарма органы — җир идарәсе сайлана (рәисе — И.И.Штуцер, әгъзалары — А.Л.Коллегаев, Ф.С.Лозовой, И.Н.Малахов, З.В.Сперанский, И.В.Христофоров һ.б.). Җ.к.на крәстияннәр, земство интеллигенциясе, сәүдәгәрләр, армия һәм флот вәкилләре һ.б. керә. 1917 нең көзенә Казан губернасы терр-ясендә 12 өяз һәм 181 волость Җ.к., ш.и. Казан өязендә — 20, Козьмодемьян — 10, Лаеш — 18, Мамадыш — 19, Зөя — 11, Спас — 15, Тәтеш — 18, Царёвококшай — 11, Цивиль — 12, Чабаксар — 11, Чистай — 21, Ядрин өязендә 14 волость Җ.к. оеша.

Казан губерна Җ.к. аграр реформаның инструкциясен һәм проектын эшли, аларның нигезенә «җирне социальләштерү» идеясе салына. Казан губернасы Җ.к. проектында (1917 нең 9 декабре) түбәндәге нигезләмәләр ята: а.х. кулланудагы барлык җирләр һәм болынлыклар сатылмыйча, гомуми нигезләрдә хезмәт халкына бирелергә тиеш; җирне үз көче б-н эшкәртергә теләгән җирбиләүчеләргә (алпавытларга һ.б.) һәм хосусый җирләрне арендалаучыларга җир мәйданнары хезмәт халкы б-н бер үк төрле шартларда бирелә; югары культуралы утарлар һәм биләмәләр орлыкчылык хуҗалыклары һәм нәселле терлекләре б-н бергә конфискацияләнә һәм Крәстиян депутатлары советлары тарафыннан ышанычлы кешегә тапшырыла, һәм волость Җ.к. контроленә бирелә; а.х. пр-тиеләре, ат з-длары, пар һәм су тегермәннәре җирле хезмәт артельләренә яисә башка сәнәгать берләшмәләренә арендага бирә ала торган Җ.к., азык-төлек ком-тлары, кооперативлар һ.б. оешмалар карамагына тапшырыла; сәнәгать характерындагы җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары хосусый биләмә буларак тартып алыналар һәм күргәзмә бакчачылык эше алып бару өчен озак вакытлы арендага тапшырылалар; хосусый утарлар, төрле хуҗалык корылмалары аларда мәктәпләр, училище, театр, халык йортлары, фермалар, башка социаль-мәдәни һәм хуҗалык эшләре учреждениеләре оештыру өчен земстволарга һәм Җ.к.на биреләләр; хосусый биләмәдән тартып алынган нәсел һәм эш терлекләре, инвентарь һ.б. милек бушлай губерна һәм өяз Җ.к.на, алар аша земстволарга һәм авыл халкына тапшырыла; җирләр фәкать күмәк берәмлекләргә — авыл җәмгате, ширкәт, кооперативларга сроксыз файдаланугa бирелә (з-д һәм ф-каларга — аерым); авыл җәмгатенә кишәрлекләр хуҗалары өчен эшләнгән кагыйдәләрне гамәлгә кертү һәм, волость Җ.к. рөхсәте б-н, эш яки куллану нормалары чикләрендә ялланган хезмәт куллану хокукы бирелә; балык тоту һәм сәнәгать характерындагы башка оброк маддәләре (урманнан тыш), аренда сыйфатында хуҗалык эшләрендә файдалану өчен җирле Җ.к. карамагына тапшырыла. Совет хакимияте урнашкач, губернадагы барлык Җ.к. да диярлек үз вазифаларыннан баш тарталар. 1918 нең февралендә Казан губерна Җ.к. Казан Совет Эшче-Крәстияннәр Респ-касы ХКСның Җир эшләре комис-ты итеп, ә өяз һәм волость Җ.к. Казан губерна крәстияннәренең 4 нче корылтаеның «Хакимиятне оештыру турында»гы карары нигезендә Крәстиян депутатлары советлары каршындагы өяз һәм волость бүлекләре итеп үзгәртеләләр. 1918 елның август-октябрендә, КОМУЧ хакимлек иткән чорда, Җ.к.н торгызырга омтылыш ясала.

*Әд.:* Ч е р н ы ш е в Е.И. Материалы по истории крестьянской революции в Казанском крае в 1917 г. // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1925. № 1–2; И о н е н к о И.М. Крестьянство Среднего Поволжья накануне Великого Октября. К., 1957; Д и н д а р о в А.И. К вопросу о времени создания земельных комитетов Казанской губернии в 1917 г. // Историческая наука в Казанском университете. К., 2000.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ҖИР МИЛЕГЕ́**, җиргә хуҗа булуның мәгълүм иҗтимагый-тарихи формасы, җирдән файдалану һәм аңа хуҗа булуның җитештерү-хокукый мөнәсәбәтләрен белдерә. ТРның Җир кадастры (1998) буенча җир хосусый милек, дәүләт милке, җирле үзидарә оешмалары һәм милекнең бүтән формалары милке булып та исәпләнергә мөмкин. Гражданнар һәм юридик затлар җир биләү хокукына шәхси рәвештә яки бергәләп хуҗа була алалар. Җиргә шәхси (индивидуаль) милек буларак ия булганда барлык хокуклар һәм бурычлар бер зат — физик яки юридик зат кулында туплана. Җир 2 яки берничә зат милке булганда, гомуми хокук милекнең билгеле бер өлешенә (өлешле милек) яки, андый өлешләргә бүленмәгәндә, уртак милек хокукына ия. ТРда җир милкенә ия булу хокукының 2 ысулы гамәлдә. Беренчесе — хосусыйлаштыру — гражданның җирне дәүләттән алуы яки үзенә бүлеп бирелгән җир өлеше б-н күмәк хуҗалыктан аерылып чыгуы. Икенчесе — гражданнарның, юридик затларның җирне сатып алганда, бүләк буларак яки мирас итеп алганда, җир кишәрлеген алыштырганда, ягъни җир хокукына гражданлык законында каралган ысул б-н ия булуы. Торак пункт эчендәге һәм аннан тыштагы җирләр үзидарә органы милке булып санала.

ТРда җирләрнең гомуми мәйданы 6,7 млн. *га* тәшкил итә, шуның 2,7 млн. *га* чамасы — гражданнар милке, 7,8 мең *га* — юридик затлар милке, 4,1 мең *га* яки 60,6% ы — дәүләт милке.

Чыг.: Конституция Республики Татарстан от 6 ноября 1992. К., 1993; Земельный кодекс Республики Татарстан от 10 июля 1998. К., 1998; Закон РТ № 2353 «О государственной собственности и собственности местного самоуправления» от 15 сент. 1999 // Ведомости Гос. Совета Татарстана. 1999. № 10.

*Әд.:* Т и х о м и р о в Ю.В. Комментарий к земельному законодательству Российской Федерации. М., 1998; Вехи российского землеустройства: Время, события, люди. М., 2000; Большой юридический словарь. М., 1998.

*Г.З.Минсафин.*

**ҖИР МИНДАЛЕ́** (Cyperus), күрәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәгрәк икеһәм берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 300 дән артык төре билгеле, тропик, субтропик, сирәк кенә уртача поясларда таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — көрән Җ.м. (C. fuscus) үсә. Ара-тирә барлык р-ннарда да очрый. Дымлы болыннарда, елга, буа, күл буйларында үсә. 5–30 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Тамыр системасы чуксыман. Сабаклары өч кырлы, бәйләмдә. Яфрак кырыйлары кытыршы, кыяксыман тар, сабагының түбәнге өлешендә урнашкан. Башакчыклары күп чәчәкле, кыска, чатырсыман чәчәк төркемендә урнашкан. Җимеше — чикләвекчек. Июль-сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август-сентябрьдә өлгерә.

**ҖИР РЕФО́РМАСЫ**. Россиядә Җ.р. берничә тапкыр уздырыла. 1861 елгы реформа крепостной хокукны бетерә һәм крәстияннәргә җирне, башлыча, сатып алу юлы б-н җәмгать милке итү мөмкинлеге бирә. 1906–11 еллардагы Столыпин реформасы авыл җәмгате милкен таркатуга һәм җирне турыдан-туры крәстияннәргә бүлеп бирүгә юнәлтелгән була. 1917 дә җирләр дәүләт милкенә әверелә. 1990 елларда башланган ре-

форма җирләрнең шактый өлешен элекке хуҗаларына кайтаруга, җиргә хосусый милекнең күптөрлелеген урнаштыруга юнәлтелә. Аның үзенчәлеге — Совет хакимияте елларында дәүләт милке булган җирләрне, РФ Конституциясенә туры китереп, муниципаль (коммуналь), физик һәм юридик затларга хосусый милек итеп тапшырудан гыйбарәт. Җир кишәрлекләренә күптөрле хокуклар барлыкка килә. Дәүләт милке 2 төргә: федераль һәм РФ субъектлары милекләренә бүленә; муниципаль берәмлекләр милке барлыкка килә; алар җирле хакимият органнары исеменнән милек хокукын гамәлгә ашыралар; гражданнарга, барыннан да элек, юридик затларга, гомерлеккә мирас итеп даими (срогсыз) файдалану хокукы бирелә, җир кишәрлекләренең күп өлеше хосусый милек булып әверелә. Гражданнарның хосусый милеккә ия булу хокукы шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче, дача, бакча, яшелчә үстерү хуҗалыклары алып баруга да кагыла. Һәм ул РФнең «Россия Федерациясе гражданнарының җир кишәрлекләрен шәхси ярдәмче, дача хуҗалыклары һәм шәхси торак төзелешләрендә файдалану өчен хосусый милек итеп сатып алу яки сату турындагы хокуклары» (1992) дигән закон б-н дә ныгытыла.

Җ.р.н гамәлгә ашыру барышында җиргә дәүләт монополиясе бетерелү б-н ТРда җир төзелешенең яңа нигезләре барлыкка килә. Җирләр яңадан бүленә: хәзерге вакытта 40%, ш.и. барлык а.х. җирләренең өчтән ике өлеше физик һәм юридик затлар милкендә. 460 меңнән артык авыл эшчәннәренә һәм социаль сфера хезмәткәрләренә 2,5 млн. *га* җиргә хосусый милек хуҗасы хокукы бирелә. К-з һәм с-зларны үзгәртеп кору нәтиҗәсендә акц. җәмгыятьләре, ширкәтләр, күмәк пр-тиеләр, а.х. продукциясе җитештерү кооперативлары оеша, 120 мең *га* мәйданда 1600 ләп крәстиян (фермер) хуҗалыклары эшли.

Респ-када гражданнарга күмәк бакчачылык, шәхси торак йортлар төзү өчен җир кишәрлекләре бүлеп бирү проблемасы хәл ителә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү өчен шартлар тудырыла, 1 млн. нан артык гражданга шул максатларны гамәлгә ашыруда җир кишәрлекләре бүлеп бирелә. 150 мең *га* яки шул төрдәге җирләрнең 53% ы гражданнарга бушлай хосусый милек итеп тапшырыла. Җиргә хосусый милек иясе булуны тотрыкландыру максатында респ-када дәүләт милке карамагындагы һәм гражданнарга уртак милек итеп бирелгән а.х. җирләренең терр. чикләре билгеләнә. Җир кишәрлекләре хуҗалыкларына һәм алардан файдаланучы милекчеләргә җир хокукына ия булуын раслаучы 940 меңнән артык документ бирелә һәм бу гомуми санның 82% ын тәшкил итә.

ТР законнарына туры китереп, җирле үзидарә органнарының җир милке хокукына ия булулары танылa. Бу хокук элек алар карамагында булган җирләрне үзидарә органнарына тапшыру юлы б-н хәл ителә. Җ.р.н уздыру барышында җирдән файдалану буенча комплекслы түләү кертелү җир ресурсларының бюджетка акча кертүдә тотрыклы чыганак булып әверелүе гамәлгә ашырыла. Җирне арендага бирү буенча күптөрле эшләр башкарыла. Җир өчен түләү күләменә карап аренда түләү өлеше дә арта (2004 ел башына 30% ка якын). Шул ук вакытта арендага түләү өлеше җир салымыннан уртача 4 мәртәбә кыйммәтрәк. Җирне гражданнар файдалануы әйләнешенә кертү өчен кирәкле шартлар булдырыла.

*Әд.:* Алакоз В.В., Киселёв В.И., Шмелёв Г.И. Зачем России земельная реформа. М., 1999; Вехи российского землеустройства. Время, события, люди. М., 2000.

*Г.З.Минсафин.*

**ҖИР ТЕТРӘҮЛӘ́Р**, җир өслегенең җир асты селкенүләре, тирбәнешләре (тетрәүләре); табигый сәбәпләр (башлыча, тектоник процесслар, эре метеоритлар төшү) яки кеше эшчәнлеге аркасында килеп чыга. Җ.т. көче Җир өслегендә тетрәү дәрәҗәсен күрсәтүче (Җ.т. чыганагының тирәнлегенә бәйле) сейсмик балларда (1 дән 12 гә кадәр) бәяләнә. Татарстан терр-ясендә булган көчле Җ.т. якынча 2,5 мең ел элек Кама һәм Идел елгасы үзәннәрендәге торулыкларны юкка чыгарган (А.Х.Халиков һ.б. тарафыннан фаразлана, 1991). 5–6 баллга кадәрге көч б-н җир асты селкенүләре Казан тирәсендә — 1845, 1865, 1909, Алабуга янында — 1857, 1914, Әлмәт һәм Бөгелмә тирәлегендә 1866, 1914 елларда күзәтелә. Идел һәм Камада ясалма сусаклагычлар төзү, ш.у. нефть чыгарганда катламнарга су кудыру һәм су б-н тәэмин итү өчен су чыгару респ-када техноген Җ.т. барлыкка килүгә китерә. 1967–87 дә ТРның көнчыгыш р-ннарында 600 дән артык Җ.т. теркәлә, шуларның 50 гә якыны 4–6 балл б-н бәяләнә. Кайбер тикшерүчеләр (И.А.Исхаков, К.М.Мирзоев) бу р-ннарда 7–8 баллга кадәрле Җ.т. булырга мөмкин дип исәпли. Җ.т.нең күпчелеге 2–4 *км*, сирәк кенә (иң көчлеләре) 10–11 *км* тирәнлектә була.

1985 елдан «Татнефть» АҖ хезмәткәрләре Татарстан терр-ясендә хәзерге сейсмотектоник активлыкны тикшерәләр, 1986 дан сейсмик режимны өзлексез күзәтүләр «Геодинамика» фәнни-җитештерү үзәге тарафыннан алып барыла. 1990 нан башлап, ел саен Ромашкино нефть чыганагы тирәлегендә җир өслегенең вертикаль хәрәкәтен геодезик күзәтүләр үткәрелә, Җ.т.нең ихтимали иң зур саны бәяләнә, 1:500000 масштаб б-н ТР терр-ясенең сейсмоген зоналар картасы төзелә. ТР терр-ясе 6–7 баллы сейсмик зонага кертелгән. Торак, юл, җитештерү биналары һ.б. проектлаштырганда сейсмологлар мәгълүматы файдаланыла.

*Әд.:* Ананьин И.В. К вопросу о проявлении некоторых землетрясений в восточной части Восточно-Европейской платформы // Вопр. инженерной сейсмологии. 1988. Вып. 29; Кавеев И.Х., Камалетдинов М.А. Геодинамика зон сейсмических деформаций района надвигов Южно-Татарского свода // Тектоника, палеомагнетизм и магнетизм горных пород. Уфа, 1989; Изучение и оценка сейсмичности платформенных территорий // Разведка и охрана недр. 1996. № 2; Сейсмическая безопасность Республики Татарстан: Науч.-произв. программа // Мониторинг. 1997. № 1; Целевая программа сейсмологических исследований территории Татарстана // Мониторинг. 1997. № 3.

*К.М.Мирзоев.*

**ҖИР ТӨЗҮЧЕЛЕ́К**, җирдән нәтиҗәле файдалану максатында аны рациональ куллануны көйләү буенча чаралар системасы. Проект-эзләнү, картага төшерү һәм тикшеренү эшләрен, җирдән файдаланучыларга тармакара, хуҗалыкара һәм хуҗалык эчендәге җир төзүчелек буенча тәкъдимнәр сыйфатындагы юридик, икътисади, техник һәм технол. документлар, хисаплаулар һәм тасвирламаларны эшләп тапшыруны; табигать-саклау, эрозиягә каршы чараларны; технол., техник-икътисади күрсәткечләрне; җир төзүчелек тәкъдим иткән схемаларны гамәлгә кертү планнарын үз эченә ала. Беренче язма межалау Россиядә 17 йөз уртасында уздырыла. Казан губернасында Екатерина II фәрманы (1775) нигезендә губерна землемеры, һәр өяздә землемерның присяжные вазифалары раслана. Сенат фәрманы (1792) нигезендә җирләрне дәүләт межалавы кысаларында Казан наместниклыгы җирләрен межалау эшләре башлана (моны Пенза шәһәреннән Казанга күчерелгән межалау конторасы башкара), бу эшләр 1802 елда төгәлләнә. Николай I фәрманы (1838) нигезендә Казан губернасында ике бүлекчәдән торган Дәүләт милке палатасы оештырыла; аларның берсе (хуҗалык буенча) казна, запастагы, халык яшәгән һәм буш ята торган җирләр һәм салым маддәләре б-н идарә итү, ш.у. имана җирләрен межалау һәм бүлүне язып кую функцияләрен башкара. 1861 елгы реформа уздырыла башлагач, яңа Җ.т. Зөя, Казан, Лаеш һәм Спас өязләрендә алпавыт крәстияннәре файдалануында булган 73,3% мәйданда үткәрелә башлый. Николай II фәрманы (1906) б-н Столыпинның аграр реформасын тормышка ашыру өчен Казан губернасында губерна (губернатор җитәкчелегендә) һәм өяз Җ.т. комиссияләре оештырыла, алар шактый күләмдә Җ.т. һәм җир бүлү эшләре башкара.

Башланып киткән Беренче бөтендөнья сугышы, рев-ция вакыйгалары һәм Гражданнар сугышы реформа нәтиҗәләреннән гамәлдә файдалану мөмкинлеге бирми. Окт. рев-циясеннән соң җир эшләрен Казан губерна җир ком-ты (1917), губерна җир идарәсе (1918), Казан губерна җир эшләре бүлеге (1918–20) алып бара. 1920 дә ТАССР Җир эшләре халык комис-ты каршында Җир төзүчелек һәм мелиорация идарәсе оештырыла. 1918–29 да хуторларны, бүлеп бирелгән җир кишәрлекләрен бетерү, алпавыт һәм монастырь җирләрен крәстияннәргә бирү, беренче с-з һәм а.х. коммуналарын оештыру сәбәпле, дәүләт фонды җирләрен исәпкә алу һәм җир төзүчелек, крәстияннәр җирләрен полосаларга бүлү эшләре башкарыла. Җ.т. эшләрен Татарстанда 1932 дән (а.х. коллективлаштыру барышында) Госземтрест (Дәүләт җир эшләре тресты) белгечләре, 1933 тән ТАССР Җир эшләре халык комис-тының Җир төзүчелек, мелиорация һәм торф идарәсе, 1939 дан СССР А.х. министрлыгы Җир төзүчелек баш идарәсенең Татарстан респ-ка җир төзүчелек һәм чәчү әйләнеше идарәсе алып бара. 1935–36 елларда 3834 колхозда Җ.т. эшләре башкарыла, 3752 колхозга җирдән файдалану өчен вакыты чикләнмәгән

дәүләт актлары бирелә; 1930–40 та триангуляция һәм нивелирлау эшләре, мелиоратив фәнни-тикшеренүләр, МТСларга җирләр бүлеп бирү һәм аларның терр-яләрен билгеләү, болын һәм көтүлекләрне геоботаник тикшерү, туфракны тасвирлау, булачак Кама гидростанциясе төзелеше б-н бәйле проектлау эшләре, Казан шәһәренең Ленин р-ны һәм Яшел Үзән шәһәре өчен җирләр билгеләү һәм терр-яне сәнәгать объектларына бирү һ.б. үткәрелә.

1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында к-з, с-з һәм р-ннарны эреләндерү һәм кечерәйтү, үсемлекчелек һәм терлекчелекне интенсивлаштыру, а.х.н индустриаль нигезгә күчерү, җир эшләренә реформа ясау нәтиҗәсендә 1961 елда ТАССР А.х. министрлыгында җирдән файдалану һәм җир төзүчелек бүлеге, «Росгипрозем» ин-тының Татарстан җир төзүчелек экспедициясе булдырыла, башта ул «Волгогипрозем» ин-тының филиалы итеп, соңыннан Татарстан җир төзүчелек-тикшеренү пр-тиесе, 1998 дә «Республика җир-кадастр үзәге» дәүләт унитар пр-тиесе (ДУП) итеп үзгәртелә.

Россия һәм Татарстандагы икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсендә 1991 дә ТР Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт ком-ты барлыкка килә, аңа 45 район һәм шәһәр ком-тлары, ш.у. район һәм шәһәр кадастр бюролары б-н аның ведомствосындагы Республика җир-кадастр үзәге кушыла. Хуҗалык эчендәге Җ.т. проектларын, терр. район оешмалары һәм җир массивлары проектларын эшләү һәм җирдән рациональ файдалану турындагы башка мәсьәләләр 2002 дә ТР МК тарафыннан Республика кадастр үзәге «Җир» АҖнә (2002 дә «Республика җир-кадастр үзәге» дәүләт унитар пр-тиесе җирлегендә оештырыла), ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгына, ТР Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм ТР буенча Җир кадастры хезмәтенә (2001 дә ТР Җир ресурслары һәм җир реформасы дәүләт ком-тын үзгәртеп оештыру нәтиҗәсендә барлыкка килә) тапшырыла. Татарстанда Җ.т. буенча кадрлар әзерләү өчен Казан җир төзүчелек техникумы ачыла (1925), ул Зөягә, аннары Югары Ослан р-нының Ключище авылына, соңрак Тәтеш шәһәренә (1961 дә ябыла) күчерелә; 1991 дән Җ.т. буенча кадрлар Чистай а.х. техникумында әзерләнә. ТРда Җ.т. үсешенә җир төзүчелек хезмәте җитәкчеләре һәм белгечләре А.В.Борчан, А.В.Коржец, А.М.Мөхетдинов, Т.А.Жуков, Б.Г.Лаишевский, В.В.*Люлин*, М.М.Кофман, И.Я.Шаталин, И.Н.Назарьев, А.Ф.Котунов, В.А.Шинкарёв, А.В.Баклашов, А.К.Дружин, А.А.Ефремов, Н.Б.Бакиров зур өлеш кертәләр. Ш.у. к. *Җирдән файдалану*.

Чыг.: Государственный комитет Республики Татарстан по земельным ресурсам и земельной реформе. К., 1997; Государственный доклад «О состоянии земель в Республике Татарстан в 2000 году». К., 2001.

*Әд.:* Бакиров Н.Б. Земельный кадастр Татарстана: прошлое, настоящее, будущее. К., 2002.

*И.Н.Афанасьев.*

**ҖИР ТЫЧКАННАРЫ́** (Soricidae), бөҗәк ашаучылар отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 21 ыругны, 300 гә якын төрне үз эченә ала. Һәркайда (поляр өлкәләрдән, Австралия һәм Көньяк Америкадан тыш) таралганнар. ТР терр-ясендә 3 ыругка (көрәнтешләр, актешләр, *шолганнар*) караучы 6 төре билгеле. Җ.т. кулканатлы ярканатлар б-н беррәттән булган имезүчеләрдән иң кечкенәләре: гәүдә озынлыгы 4–18 *см*, койрыгы 1–12 *см*. Тышкы кыяфәте б-н тычканнарга охшаш, әмма, алардан аермалы буларак, йөзе очланып сузылган. Күзләре кечкенә, кара сәйлән бөртегедәй. Күпчелегенең колак яфрагы бөтенләй диярлек йон б-н капланган. Йон капламы кыска, тыгыз, ялтыравыклы. Җир өстендә, җир астында һәм яртылаш суда яшиләр. Тәүлек әйләнәсе активлар, кышын йокыга талмыйлар. Елына берничә тапкыр үрчиләр. Бер оядә 3 тән 12 гә кадәр бала була. Саны бөҗәкләр һ.б. умырткасызларның күплегенә, ш.у. метеорологик шартларга (аз карлы салкын кышлардан һәм корылыктан соң кискен кими) бәйле. Урман һәм а.х. өчен файдалы, зарарлы бөҗәкләрне күпләп юк итәләр. 12–15 ай яшиләр. Гади шолган ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Животный мир Татарии. К., 1988.

**ҖИР ФОНДЫ́**, а.х., шәһәр һәм авыл торак пунктлары, сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә һәм махсус файдаланудагы, аерым саклаудагы терр-яләр һәм объектлар, урман һәм су фондлары карамагындагы, запастагы җирләрнең җыелмасы. ТРның Җ.ф. 6783,7 мең *га* тәшкил итә, шуларның 71,2% ы а.х. карамагындагы җирләргә туры килә. Уртача алганда, Идел буе федераль округы төбәкләрендә андый җирләрнең өлеше — 58,9%, РФ буенча тулаем 32,9% били. Җ.ф.ннан файдалану тәртибе РФнең җир турындагы законнары һәм ТРның Җир кодексы б-н билгеләнә.

А.х. җирләре файдаланыла торган җирләргә (4325,6 мең *га*) һәм тармак, а.х. үсеше өчен кирәкле коммуникацияләр, хуҗалык эчендәге юллар, биналар һәм корылмалар биләгән җирләргә бүленә. А.х.нда файдаланыла торган җирләргә сөрүлекләр (3449,4 мең *га*), ш.у. күпьеллык үсентеләр (38,5 мең *га*), яткын җирләр (0,7 мең *га*), печәнлекләр (131,9 мең *га*) һәм көтүлекләр (926,3 мең *га*) алып торган җирләр керә. Крәстиян (фермер), шәхси ярдәмче хуҗалыклар оештыру һәм үстерү, бакчачылыкны җәелдерү максатында җирләрне яңадан бүлү дәүләт фонды булдырыла.

Аерым саклаудагы терр-яләрнең җирләре (31,6 мең *га*) — дәүләт табигать саклаулыклары һәм тыюлыклары, милли, табигый һәм дендрологик парклар, ботаника бакчалары биләгән җирләр, ш.у. аерым экологик, фәнни, тарихи-мәдәни, рекреацион һәм савыктыру әһәмиятенә ия участоклар. Саклау, тикшеренүләр алып бару һәм консервация өчен билгеләнгән җирләрдә һәртөрле хуҗалык эшчәнлеге тыелырга мөмкин.

Урман фонды җирләренә (1220,3 мең *га*) урманнар б-н капланган һәм капланмаган (урман хуҗалыгы алып бару өчен файдаланыла торган сөрүлекләр, печәнлекләр, көтүлекләр, юллар һ.б.) җирләр керә.

Запастагы җирләр — консервация нәтиҗәсендә хуҗалык эшчәнлеге даирәсеннән аерып чыгарылган, файдаланылмый торган дәүләт милкендәге җирләр (ТРда 2,5 мең *га*).

Җир мөнәсәбәтләрендәге үзгәртеп коруларга һәм хуҗалык итүнең күпукладлы ысуллары үсешенә бәйле рәвештә, ш.у. җир төзү-бүлү һәм кадастр эшләре нигезендә исәпкә алу мәгълүматларына төгәллек кертү сәбәпле, җирнең аерым категорияләренең чагыштырма өлешләре зур үзгәрешләр кичерде (к. табл.).

2009 елның 1 гыйнварына ТР җир фондының категорияләр буенча бүленеше (мең *га*)

| № | Җир категорияләре | Гомуми мәйданы | Шулардан а.х. җирләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыл хуҗалыгы җирләре | 4636,7 | 4325,6 |
| 2. | Торак пунктлар җирләре ш.и.: | 376,3 | 185,3 |
| 2.1. | шәһәр торак пунктлары җирләре | 145,0 | 39,4 |
| 2.2. | авыл торак пунктлары җирләре | 231,3 | 145,9 |
| 3. | Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә биләгән һәм махсус файдаланудагы җирләр | 78,2 | 4,1 |
| 4. | Аерым саклаудагы территорияләр һәм объектлар биләгән җирләр | 31,6 | 2,7 |
| 5. | Урман фонды җирләре | 1220,3 | 20,0 |
| 6. | Су фонды җирләре | 438,1 | 0,7 |
| 7. | Запастагы җирләр | 2,5 | 1,4 |
| | Барлыгы | 6783,7 | 4539,8 |

Чыг.: Земельный кодекс РТ от 10 июня 1998 г. К., 1998; Республика Татарстан: Стат. ежегодник. К., 2008.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«ҖИР ҺӘМ КЕШЕ́» МУЗЕЕ́**, Чүпрәле р-ны Иске Шәйморза авылында. 1956 елда мәктәп музее, 1982 дә ТАССР Берләштерелгән Дәүләт музее (хәзер ТРның Милли музее) ф-лы буларак ачыла, 2007 дән муниципаль музей. Элеккеге колхоз идарәсенең агач бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 220 $м^2$. Коллекциядә 9500 дән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Музей коллекцияләренең төп өлешен укытучы А.З.Азизова җи-



Иске Шәйморза авылында «Җир һәм кеше» музее. Экспозиция күренеше.

тәкчелегендә мәктәп балалары туплаган һәм авыл тарихына багышланган коллекцияләр алып тора. Экспозициянең төп бүлекләре: «Иске Шәйморза авылы тарихы», «Авылда колхоз төзелеше», «Авылда пионер һәм комсомол хәрәкәтләрен оештыручылар», «Бөек Ватан сугышы елларында авылда яшәүчеләрнең тормышы», «Шәйморзалыларның хезмәт даны», «Социалистик Хезмәт Герое Ә.Ш.Әбдриевнең тормышы һәм эшчәнлеге», «ТРның халык артисты Г.М.Рәхимкуловның тормышы һәм иҗаты», «Татарларның милли традицияләре». Экспозицияләрне В.А.*Попов* бизи. Музейның аеруча мөһим экспонатлары булып татарлар һәм чуашларның 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы көнкүреш әйберләре, 18–20 йөз акчалары, гарәп хәрефләре б-н язылган китаплар, авиаинженер Н.Әхтәмов, М.Азизов, Ә.Әбдриевләрнең шәхси әйберләре, документлар, сирәк китаплар һәм 1952–67 дә Япониядә эшләгән совет разведчиклары Б.Алимова һәм Ш.Хәмзинның документлары һәм фотосурәтләре коллекцияләре санала. Музей ел саен Җиңү (9 май), Халыкара музейлар һәм «Бүләк кабул итү» (10–18 май), Татарстан Респ-касы (30 авг.), Укытучылар (5 окт.) көннәрен билгеләп уза.

**ҖИР-СУ**, төрки-татар мифологиясендә җир һәм су алласын, туган җирне гәүдәләндерә. Борынгы төркиләр аны Ыдук Йер-Суб (Изге Җир-Су) дип атаганнар һәм аны баш алла, үзләренең саклаучысы дип санаганнар. Алтайлылар Җ.-С.ны тау һәм елга башларында яши торган 17 мәрхәмәтле алланың берлеге (синтезы) итеп күзаллаганнар. Иң кодрәтле, иң зур хөрмәткә ия алла булып Йо-кан саналган. Ул күккә кадәр җиткән чыршы — Дөнья агачы үсеп утырган җир үзәгендә яши икән. Кайбер галимнәр раславынча (М.Бакиров һ.б.), борынгы төрки телле халыклар әлеге агачның 17 ботагы бар дип санаганнар; татар хатын-кызлары муенсасындагы тәңкәләр санының 17 булуы нәкъ шуның б-н бәйле. Г.Рубрукның төрки кешене күмгәндә 17 атны корбан китерү турындагы хәбәре дә бик кызыклы. Хакасларның күзаллауларында Җ.-С. — таулар, урманнар, елга һәм күлләр рухы — хуҗасы, татарлардагы *ияга* тиң. Татар фольклоры һәм әдәбиятында Җ.-С. образы туган җиргә булган мәхәббәтне чагылдыра.

*Әд.:* Д ә ү л ә т ш и н Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Б а к и р о в М. Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. К., 2001; С т е б л е в а И.В. К реконструкции древнетюркской религиозно-мифологической системы // Тюркологический сборник. М., 1972; Б а с и л о в В.Н. Йер-Су // Мифы народов мира. М., 1987. Т. 1.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ҖИР-СУ ХАЙВАННАРЫ́**, амфибияләр (Amphibia), умырткалы хайваннар классы. Җир шарында 3 отрядка: койрыксызлар, койрыклылар һәм аяксызларга керүче 4 меңнән артык төре исәпләнә. Антарктидадан кала җир йөзенең барлык өлешендә таралган. ТР терр-ясендә 11 төр, шуның 2 се — Җ.с.х.ның койрыклылар отрядына (*тритоннар*), 9ы койрыксызлар отрядына (*су «үгезләре»*, *җир бакалары*, *гөберле бакалар*, *бакалар*) керә. Зурларының ике пар аягы бар. Тиресе шәрә, лайлалы, мөгез катламы (тәңкә, төк, каурый, чәч) юк. Склеты тулысынча сөякләнмәгән. Өлкән Җ.-с.х.нда сулыш органнары булып капчык рәвешендәге үпкә хезмәт итә (личинкалар саңаклары б-н сулый), ш.у. сулыш алуда билгеле бер рольне кан тамырлары күп булган лайлалы куышлык һәм юка тире үти. Йөрәге өч камералы. Бүлеп чыгару органнары булып гәүдә бөерләре хезмәт итә. Җ.-с.х. коры җирдә гәүдәсен күтәреп хәрәкәт итә. Җенси яктан 3–4 яшендә өлгерә. Яшәү рәвешләре буенча су һәм җир өсте хайваннары. Суга уылдык чәчеп үрчиләр, тереләй туу һәм уылдыкны ана япмаларында (пиплар) һәм аталарның авыз куышлыгында (ринодермалар), оя сумкасында йөртү (сумкалы агач бакалары) дә очрый. Җ.-с.х. — экосистеманың мөһим компонентлары, күпләгән умырткасызларның санын җайга салалар, кошлар, имезүчеләр, балыклар һ.б. өчен азык булып хезмәт итәләр. 3 төре (сырлач сыртлы тритон, кызыл корсаклы су «үгезе», соры гөберле бака) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И.Земноводные и пресмыкающиеся Волжско-Камского края. М., 1983.

**ҖИРӘ́Н ГӨМБӘ́** (Lactarius deliciosus), ал гөмбәчәләр семьялыгыннан сөтчел гөмбәләр ыругы. Евразия, Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә ылыслы урманнарда, күбесенчә яшь чыршылык һәм нартлыкларда очрый (чыршы һәм нарат б-н микориза хасил итәләр). Кишер төсендә. Эшләпәсенең диаметры 3–11 *см*, үзәктә яшькелт боҗралары була, яшь гөмбәләрнең кырыйлары бөгелгән, өлгергән гөмбәләрнең — туры. Пластинкалары ябышып үскән яки аз гына салынкы, яшькелт тимгелле кызгылт-сары төстә. Сабы 2–6 *см* биеклектә, 1–2 *см* юанлыкта, цилиндрсыман, тигез, яшь гөмбәләрдә тыгыз, картларында куыш, эшләпәсе б-н бер үк төстә. Йомшагы ак, эшләпә асты һәм сабы кызгылт, сынган урыны яшелләнә. Сөтчел сыекчасы кызгылт-сары, чәерле җимеш исле. Июнь–октябрь айларында очрый. Ашарга яраклы, яңа җыелган, тозланган, маринадланган килеш тә кулланыла.

**ҖИРӘ́Н ЧИЧӘ́Н**, татар, башкорт, казакъ фольклорында киң таралган персонаж (к. *Чичән*). Татар һәм казакъ фольклоры әсәрләрендә ул — халык мәнфәгатьләрен яклаучы. Дәрәҗәле кешеләрнең капма-каршысы буларак, шат, хәйләкәр, тапкыр, зирәк; алар б-н бәхәстә һәрвакыт өстен чыга. Әлеге персонаж татар язучысы Н.Исәнбәтнең «Җирән чичән б-н Карачәч сылу» комедиясендә урын ала. Башкорт фольклорында бу образ башкача бирелә: «Бәндәбикә һәм Ерәнсә сәсән» риваятендә ул казакъ торакларына һөҗүм итә, җиңелүгә дучар була һәм, ахыр чиктә, үз-үзенә кул сала.

*Әд.:* Җирән чичән белән Карачәч сылу // Исәнбәт Н. Әсәрләр. К., 1989. 3 том; М ә х м ү т о в Х. Канатлы сүз — хикмәтле сүз. К., 1999; Ә у е з о в М. Уакыт және әдәбиет. А.-А., 1962; Башҡорт халыҡ ижады. Риүәйттәр, легендалар. Өфө, 1997; Казахские народные сказки. М., 1952; Казахский фольклор в собрании Г.Н.Потанина. А.-А., 1972.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ҖИРДӘ́Н ФАЙДАЛАНУ́**, гадәт яки закон тәртибендә җирдән файдалану. Җ.ф. системалары җир биләү формалары, хуҗалык итүнең табигый-климатик үзенчәлекләре һәм тарихи традицияләре б-н билгеләнә. Б.э.ның 1 нче меңьеллыгының 2 нче яртысында Идел-Кама төбәгенә болгар кабиләләре килеп утыру чорында формалашкан Җ.ф. үзенчәлекләре соңрак дәверләрдә дә саклана. Әлегрәк имәнкискә, фин-угор кабиләләре биләгән җирләрнең бер өлеше тартып алына, ш.у., ихтимал, җир биләмәләрен килешенеп бүлү очраклары да гамәлдә булгандыр. Яңа, башлыча, урманлы җирләр еш кына авыл җәмәгатьләре берләшмәләренең а.х. оештыру юнәлешендәге уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә үзләштерелә. Болгар кабиләләренең яңа мәйданнарны үзләштерүгә булачак феодаль биләмәләр оешу өчен җирлек тудыра; аларның әгъзалары җир кишәрлекләре билиләр, әмма шул ук вакытта алар болынлыкларда, көтүлекләрдә, урманнарда һ.б.да да милектәшләр булалар. Идел буе Болгар дәүләтенең урманнар, елгалар, сазлыклар, таулар һ.б. табигый объектлар б-н бүлгәләнгән җирләрен ирекле авылдашлар берләшмәләре били. 11–12 йөзләрдә бәкләр авыллары барлыкка килә, аларда киләчәктә феодаль бәйлелектәге *кара халыкка* әвереләчәк кешеләр яши. Җ.ф.да милек, биләмә, файдалану төшенчәләре әлегә бер-берсеннән төгәл генә аерылмый. Алтын Урда чорында, халык көченүләренең зур колач алуына бәйле хәлдә, җирләр алга таба күмәк рәвештә түгел, бәлки аерым гаиләләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә үзләштерелә. 13 йөздән феодаль-утарлыклы Җ.ф. тәртибе урнаша башлый (к. *Сөйургал, Тархан*). Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушканнан соң (1552), шартлы алпавыт һәм чиркәү җир биләүчелегенең киң таралуы Җ.ф.га мөһим төзәтмәләр кертә. 16–17 йөзләрдә хәрби-йомышлы җир биләүнең үсеше нәтиҗәсендә Казан төбәгендәге *ясаклыларның* Җ.ф. системасында үзгәрешләр була, аларның җирләре дәүләт милке дип игълан ителә, бу җирләрдән ясаклы һәм йомышлы кешеләр, посад һәм рус крәстияннәре файдалана башлый (к. *Патша сарае крәстияннәре, Игенче солдатлар*).

19 йөз ахырында Казан губернасы терр-ясе 55,9 млн. кв. чакрым чамасы тәшкил итә, шуның якынча өчтән бер өлеше эшкәртүгә яраксыз җирләргә (сазлыклар, тозлы туфраклар, чокырлар, сызалар һ.б.) туры килә. Халык хуҗалыгында, башлыча, аграр өлкәдә 2,84 млн. дис. сөрүлекләр (гомуми җир мәйданының 50% ы) файдаланыла. Көтүлекләр һәм утлавыкларның өлеше — 621 мең дис. (11%), урманнар 1,9 млн. дис. (33%) били. Моннан тыш, җирдә торак пунктлар, грунт юллар, сәүдә һәм сәнәгать оешмалары, пр-тиеләр урнаша. Җир банкларыннан кредит алу өчен залог буларак файдаланыла, кайбер чакта спекулятив сату-алу предметы була. 20 йөз башында а.х. җирләренең зур өлеше вак товар җитештерүчеләр, башлыча, крәстияннәр тарафыннан эшкәртелә.

Крәстияннәрнең Җ.ф.ының (губернадагы эшкәртүгә яраклы җир мәйданының 2,4 млн.

дис. чамасы) нигезен өлешчә (сатарга ярамаган) *авыл җәмәгате* милкендә булган имана җирләре тәшкил итә. Моннан тыш, крәстиян җәмәгатьләре карамагында 484,5 мең дис. болынлыклар һәм утлавыклар, 254,7 мең дис. урманнар исәпләнә. Авыл җәмәгатенең һәр әгъзасы (гадәттә, ир-атлар) җиргә хокуклы була. Чәчүлек мәйданнар — җәмәгать-имана, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары — хуҗалык-кишәрлек файдалануына, ә көтүлекләр һәм утлавыклар уртак файдалануга карый. Җәмәгать сатып алулар һәм салым түләүләрнең кертелүе өчен коллектив рәвештә җавап тота. Ж.ф.ның җәмәгать системасы б-н бергә арендага алу тәртибе дә тарала. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, башлыча, хосусый милеккә әверелгән, ш.у. *Столыпинның аграр реформасы* нәтиҗәсендә бирелгән җирләрдә (к. *Отруб, Хутор*) ялгыз крәстияннәрнең Ж.ф. өлкәсе киңәя.

Хосусый биләнгән җирләрдә Ж.ф. мөһим үзенчәлекләре б-н аерылып тора. Башлыча, дворян-алпавыт җирләрендә эре җир хуҗаларының бер өлеше сөрүлекләрне үз а.х. кораллары б-н һәм яллы а.х. эшчеләре (батраклар) хезмәтеннән (хуҗалык алып баруның «капиталистик» системасы) яки тирә-юньдәге крәстияннәрнең эш терлекләреннән һәм коралларыннан файдаланып («бурычлы эш» — «отработка», «өлешкә эшләү» — «издольщина») үз хуҗалыгын алып бара. Шул ук вакытта алпавытларның зур өлеше, кагыйдә буларак, эре утар хуҗалары, үз хуҗалыкларын алып барудан баш тарта һәм җирләрен арендага бирә. Шулай ук җирне хуҗалар да, арендачылар да эшкәрткән Ж.ф.ның катнаш системасы да яшәп килә. Хосусый биләнгән Ж.ф. 369,5 мең дис. эшкәртүгә яраклы җирләрне, 120,5 мең дис. болынлыкларны һәм утлавыкларны, 246,3 мең дис. урманнарны колачлый. Ж.ф.ның удел һәм казна формалары Казан губернасында киң таралмый: 35,8 мең дис. эшкәртүгә яраклы җирләр, 16 мең дис. болынлыклар һәм утлавыклар, 1357,6 дис. урманнарны тәшкил итә.

Совет хакимияте урнашканнан соң (1917), национализацияләнгән а.х. җирләренең зур өлеше бушлай күмәк Ж.ф.га: крәстиян җәмәгатьләренә, *җирне бергәләп эшкәртү ширкәтләренә, совхозларга, колхозларга, авыл хуҗалыгы коммуналарына* һ.б. оешмаларга (учреждениеләргә) бирелә. Авыл җәмәгатьләре кишәрлекләр хуҗалары өчен кабул ителгән җирле кагыйдәләрне гамәлгә кертү хокукына ия булалар. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында крәстиян хуҗалыкларын ирексезләп күмәкләштерү тулысынча Ж.ф.ның дәүләт системасы хакимлеге урнашуга китерә. Бу система: а.х.н, сәнәгатьне, транспортны үстерү һ.б. төрле халык хуҗалыгы ихтыяҗлары, социаль-мәдәни максатлар өчен җирләр бирелгән дәүләт пр-тиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре Ж.ф.ы; колхозлар, колхозара һ.б. кооперация пр-тиеләре Ж.ф.ы; җәмәгать оешмалары (профсоюзлар, спорт җәмгыятьләре һ.б.) Ж.ф.ыннан гыйбарәт. Аерым гражданнарга җир индивидуаль торак төзелеше, индивидуаль һәм коллектив яшелчәчелек һәм бакчачылык үстерү (к. *Бакчачылык ширкәте*), шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелә. А.х. җирләреннән төп файдаланучылар к-злар һәм с-злар була. Аларга җир бушлай һәм мәңгелек файдалануга тапшырыла. К-з һәм с-зларда гражданнарга файдалануга бүлеп бирелә торган кишәрлекләрнең зурлыгы законнар һәм хуҗалыкларның уставлары б-н билгеләнә (к. *Шәхси ярдәмче хуҗалык*). 1990 еллардан базар икътисады шартларында җир милкен хосусыйлаштыру башлангач, ТРда к-з һәм с-злар белән бергә, авылдагы җир хуҗалары ассоциацияләре һәм акционерлык җәмгыятьләре, фермерлык хуҗалыклары (к. *Крәстиян (фермер) хуҗалыгы*), ш.у. сәнәгый һәм а.х.на катнашы булмаган пр-тиеләр җирдән файдаланучыларга әвереләләр. 2000 елга ТРның җир фонды 6383,7 мең *га*, ш.и. а.х. җирләре 4523,4 мең *га* тәшкил итә. Ж.ф. формалары буенча а.х. җирләре түбәндәгечә бүленә (мең *га*): а.х. пр-тиеләре һәм оешмалары җирләре — 4265,9, фермер хуҗалыклары — 121,3, аерым гражданнарның җирләре — 136,2. Ш.у. к. *Җир биләү*.

Чыг.: Статистика землевладения 1905 г.: Свод данных по 50 губерниям Европейской России. СПб., 1907; Республика Татарстан 1920–2000 гг.: Стат. сб. К., 2001.

*Әд.:* Халиков Н.А. Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX — начала XX вв. М., 1981; шул ук. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (Социально-экономическое исследование). М., 1984; Шайдуллин Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ҖИРНЕ́ БЕРГӘЛӘ́П ЭШКӘРТҮ́ ШИРКӘТЕ́** (ЖБЭШ), 1920–30 елларда ТАССРда а.х. житештерү кооперациясе формаларының берсе. Баштарак бу ширкәтләрнең эшчәнлеге «Социалистик җир төзелеше һәм социалистик җир эшкәртүгә күчү чаралары турында»гы нигезләмәгә (Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан 1919 елның 14 февралендә раслана), аннары «Җирне эшкәртү буенча авыл хуҗалыгы кооператив ширкәтенең үрнәк уставы»на (РСФСР Җир эшләре халык комиссариаты 1923 тә чыгара) таяна. «*Хәрби коммунизм*» һәм *яңа икътисади сәясәт* елларында эшләгән ЖБЭШләрнең шактый өлеше бер төркем кешеләрнең ирекле килешүе һәм дәүләт органнары раслаган ширкәт шартнамәсе принципларына нигезләнгән җир эшкәртү берлекләреннән гыйбарәт була. Аларның уртак кулланууында, нигездә, крәстияннәрнең имана җирләре исәпләнә; хезмәт һәм житештерү чаралары, гадәттә, а.х. эшләре вакытында берләштерелә; шәхси хуҗалык булу да инкарь ителми. Уртак хуҗалык эшчәнлегеннән алынган керемне бүлүнең төгәл чикләре булмый, ул куелган хезмәткә, җан башына, житештерү чараларына карап (пай формасында) бүленә. Хуҗалык итүнең мондый формасын, гадәттә, ярлырак, ш.у. житештерү чаралары яки эшче куллары булмаган авыл кешеләре файдалана. Кагыйдә буларак, ЖБЭШләрнең күпчелеге Совет дәүләтенең булышлыгы һәм матди ярдәме б-н оештырыла, крәстияннәр арасында әлеге хуҗалык башлангычын алып баручы энтузиастлар була. Ширкәтләргә берләшкән крәстияннәрнең күбесендә хосусыйлыкка хас фикерләү саклана, алар төп житештерү чаралары, эшче куллар һәм эш терлекләре барлыкка килгәч, кагыйдә буларак, ширкәттән чыга һәм яңадан хуҗалык итүнең хосусый формасына күчә. Нәтиҗәдә күпчелек ширкәтләр 3–4 елдан артык яшәми. ЖБЭШләрнең еш таркалуы аркасында күпләгән хуҗалык кыенлыклары, көнкүреш каршылыклары туа, дәүләт структураларына («икътисади һәм сәяси кураторларга») аларның эчке эшләренә еш тыкшынырга туры килә, чөнки алар эшчәнлегенең төп шарты сыйнфый принципны саклау була. Татарстанда 1925 елның 1 октябренә — 183, 1928 нең 1 октябренә 140 ширкәт исәпләнә. ЖБЭШләрнең күпчелеге хезмәт житештерүчәнлеге, оештыру-хуҗалык структурасы һәм җир эшкәртү агрокультурасы буенча шәхси крәстиян хуҗалыкларыннан берни б-н дә аерылмый диярлек, аларның шактый өлеше дәүләтнең матди ярдәме һәм кредитлары исәбенә яши. 1920 еллар ахыры — 1930 елларда крәстиян хуҗалыкларын *күмәкләштерү* чорында ЖБЭШләрнең күпчелеге колхозлар итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Залялов А.М. Социалистические преобразования сельского хозяйства Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**«ЖИТӘКЧЕ́»**, журнал, к. «*Татарстан коммунисты*».

**ЖИТЕ́Н** (linum), житенчәләр семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләнчел үсемлек ыругы. Якынча 230 төре билгеле, иң киң таралганы игүле житен — Евразия астөре, 4 төрдәге төркемне үз эченә ала: озын Ж. яисә сүс житене; май Ж. яки көдрәш, урта Ж. һәм шуышма Ж. Сүс һәм май үсемлеге буларак үстерелә. Килеп чыгышы — Һиндстан һәм Кытайның, Урта диңгез һәм Кавказ аръягының таулы районнары. Грузия терр-ясендә (Колхида), Мисырда — б.э.к. берничә мең ел элек, Европада — б.э.к. 2 нче меңьеллыкта культуралы үсемлек буларак игелә башлый. Россиядә 10–13 йөзләрдә барлык җирләрдә таралган була. 15 а.х. культуралары арасында Ж. Идел буе Болгар дәүләтендә игелә. 1960 елларга кадәр Россиянең кара туфраклы зоналарында, ш.у. Кама алдында төп техник культура буларак санала.

Ж.нең сүсе бик озын күзәнәкләрдән (сабакның кабык өлешендә бәйләм булып җыелган гади сүсләрдән) тора, аның озынлыгы сабакның ботакланмаган өлешенең озынлыгына бәйле. Ж. сүсеннән төрле максатлар өчен тукымалар эшләнә. Озын житен 80–100 *см* лы һәм аннан да биегрәк, озын шома сабаклы, аз сандагы орлык җимешле (тартмачыклы), нигездә, сүс алу өчен үстерелә, уртача 25% сүс һәм 10% ка кадәр майдан тора (майлылыгы — 37% ка кадәр). Көдрәш Ж. — май культурасы, 30–35 *см* биеклектәге кыска сабаклы, сабак төбендә нык ботакланган, күп санда тартмачыклары бар (200 данәгә кадәр);

52% ка кадәр майдан торган орлыклары югары уңыш бирә, бу май азык-төлек һәм медицина сәнәгатендә, буяу, лак, олиф эшләгәндә, кыска сүсләре капчык, брезент, шпагат ясаганда кулланыла. Урта Җ. үзенең сыйфатлары буенча озын Җ. б-н көдрәш Җ. арасында урталыкны алып тора.

1998 дән Татарстанда озын Җ. яңадан җитештерелә башлый. 2008 дә Мамадыш, Саба р-ннарында 880 *га* мәйданда үстерелә.

Озын Җ.нең җитештерүгә кертелгән сортлары: «Белочка» (1998), «Нептун» (1998), көдрәш Җ.нең (майлы) сортлары — «Кинельский 2000» (2004). Орлыклары 2-3°С темп-рада шытып чыга башлый. Вегетация чорының дәвамлылыгы озын Җ.нең 75–90 көн, көдрәш Җ.нең 150 көнгә кадәр. Көдрәш Җ. б-н чагыштырганда озын Җ. дымлылыкны күбрәк, ә җылылыкны азрак ярата; шытымнары — 4°С кадәр кырауларга чыдам. Җ. чәчүлеге өчен туфракны төп эшкәртүгә лущильниклар б-н камыллы җирне йомшарту, сөрү катламы тирәнлегендә сабан һәм ал тәрәннәр б-н каплатып сөрү кирәк.

Яз көне, туфрак өлгерүгә карап, кырны тырмалыйлар (бер үк вакытта өстен тигезләп баралар), орлыклар күмеләсе тирәнлектә культивациялиләр. Чәчү иртә срокта, җылынган туфракка махсус тар рәтле житен чәчкечләр ярдәмендә 1,5–3 *см* (көдрәш Җ. — 3–7 *см*) тирәнлектә башкарыла; чәчүлек орлыкның нормасы 1 *га* га 120–140 *кг* (көдрәш Җ. — 50–60 *кг*). Чәчү б-н бергә рәтләргә азотлы һәм катлаулы гранулулы минераль ашламалар кертелә. Чәчүлекне тәрбияләүгә шытымнар чыкканчы җиңел һәм челтәрле тырмалар б-н тырмалау (туфрак өсте каткан очракта), чүп үләннәрдән, корткычлардан (җитен борчалары, җитен коңгызы — яшерен хортумлы, трипс, җимешашар, гамма ябалакчылар, болын күбәләкләре), авырулардан (фузариоз, күгәрек, полиспороз, антрокноз, аскохитоз, пасмо) саклану өчен гербицидлар, инсектицидлар һәм фунгицидлар куллану кирәк.

Җ.не иртә сары булып өлгергән чорында тезөмнәргә салып яисә комбайн б-н турыдан-туры җыялар. Рулонлы технология б-н җыйганда хезмәт җитештерүчәнлеге 4–5 тапкырга арта, ул җитен з-дына җибәрү өчен рулоннар формалаштыручы прессҗыйгыч б-н йолкыганнан соң саламы тасмаларга салынган җитенне җыеп алуны үз эченә ала. Сабаклары сүс аерып алу өчен беренчел эшкәртелә (җебетү яисә пешекләп йомшарту, киптерү, талку һәм тетү). Ш.у. к. «*Казан җитене*».

*Әд.:* Сизов И.А. Лён. М., 1955; Справочник льновода. М., 1985; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Пути повышения эффективности масличных культур // Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**ҖИТЕНСАБА́К**, к. *Баллы чәчәк.*

**ҖИТЕ́Н ЭШКӘРТҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, к. *Җиңел сәнәгать*, «*Казан җитене*».

**ҖИҺА́Д** (гарәп. جهاد — көч кую, тырышлык), дин өчен көрәш. *Коръәндә* Җ.ка карата төрлечә аңлатма бирелә: югары Җ. — рухи-дини камилләшү (Җ. турында Мөхәммәд пәйгамбәр болай ди: «Иң бөек Җиһад — ул кешенең үз-үзе белән көрәшүе»), Коръән вәгазе б-н Исламны тагын да алга җибәрү; кече Җ.: 1) динсезләрне исламга өндәп күндерү; 2) үз-үзеңне саклау максатында ислам дошманнары б-н көрәшү. Изге айларда «кяферләр» б-н көрәшү рөхсәт ителми. Элегрәк Җ. көрәшенә исламны яклау һәм тарату өчен күтәрелгәннәр (газават). Җ.ның андый мәгънәдәге хокукый категориягә ия булуы Өммияләр (661–750) һәм Габбасыйлар династиясе идарә иткән чорга туры килә. Соңрак Җ. термины яңача аңлатыла башлый: 1) «йөрәк Җ.ы» (рухи камиллек өчен көрәш); 2) «тел Җ.ы» («яхшылык эшләргә кушу һәм ярамаган эшне тыю»); 3) «кул Җ.»ы (шәригать кануннарын бозучыларны тәртипкә өйрәтү); 4) «кылыч Җ.ы» (коралл көрәш). Хәзерге заман ислам дини тәгълиматында Җ. социаль-икътисади һәм мәдәни үсеш программаларын гамәлгә ашыру, икътисади һәм хәрби куәткә ирешү өчен күп көч кую дип карала.


*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**«әл-ҖИҺА́Д»** («ألجهاد») — «Иман өчен көрәш»), *Вюнсдорф лагерендагы* мөселман хәрби әсирләре өчен чыгарылган газета. 1915 елның февраленнән гарәп, рус һәм татар телләрендә гектограф ысулы б-н басыла һәм, башлыча, лагерь эчендә таратыла. Регуляр рәвештә чыкмый, айга 1–4 мәртәбә чыга. Газета 1917 елның гыйнварында рус телендә, 1918 нең августында татар телендә, 1918 нең октябрендә гарәп телендә чыгудан туктый дип фаразлана. Төрле елларда мөхәррирләре: Адлер, Г. фон Гизенапп, Г.Мюллер, граф Ранцау, проф. Шпатц., Р.Ибраһимов һәм Г.Идриси хезмәттәшлек итәләр. Газета Германия Генштабы булышлыгы б-н Антанта илләре хәрби әсирләре арасында агитация алып бару максатыннан чыгарыла. Төп урынны хәрби сводкалар, метрополия һәм колонияләрдәге хәлләр турында хәбәрләр, дини темага караган мәкаләләр алып тора. «ә.-Җ.»та басылган материаллар хәрби әсирләргә Германия сәясәтен аңлаталар, аның индустриясенең куәтен пропагандалыйлар, Көнчыгыш б-н сугышучы аерым мөселман хәрби частьләренә язылырга үгетлиләр, ш.у. күп кенә мөселман халыклары үзләренең милли азатлык өчен көрәшләрендә Германия ярдәменә таяналар дигән фикерне алга сөрәләр.

*Әд.:* Heine P. Al-Gihad — eine deutsche Propagandazeitung im 1. Weltkzieg // Die Welt des Islams. 1980. № 3–4; Höpp G.Arabische und islamische Periodika in Berlin und Brandenburg 1915 bis 1945: geschichtlicher Abriss und Bibliographie. B., 1994.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ҖИҺАНГИ́РОВ** Мөхәммәт Солтангәрәй улы (1923, Үзбәкстан Респ-касы, Ташкент өлкәсе Янгиюл р-ны — 30.9.1943, Днепропетровск өлкәсе, Солянск р-ны Войсковый а.), Сов. Союзы Герое (19.3.1944, үлгәннән соң), ефрейтор (1943). Кызыл Армия сафларына алынганчы туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 198 нче аерым укчы полкта автоматчы (6 нчы армия). Воронеж һәм Көньяк-Көнбатыш фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Ворошиловград, Урта Дон операцияләрендә (икесе дә — 1942), Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 26–30 сентябрендә Войсковый авылы янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә, шул сугышта һәлак була. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



М.С.Җиһангиров.

*Әд.:* Джураев Т.Д. Верные сыны Родины. Таш., 1964; Березняк Н.Г. Герои Советского Союза — узбекистанцы. Таш., 1984.

*В.А.Шагалов.*

**ҖИҺАНГИ́РОВ** Фәрит Нургали улы (15.3.1954, Киров ш.), спортчы (чирәмдәге хоккей, туплы хоккей), СССРның атказ. спорт остасы (1984). СССР чемпионы (1973, 1975–76, 1978–79, 1982–83, 1985–87), СССР халыклары спартакиадасында җиңүче (1979, 1983), СССР чемпионатында көмеш (1974), Олимпия уеннарында бронза (1980), Европа чемпионатында көмеш (1983) медальләр ала, Континентара кубок (1984) һәм СССР кубогы (1986–87) иясе. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1985). Алма-Ата шәһәрендә яши.

**ҖИҺАНГИ́РОВА** Шәмсия Гатуф кызы (28.2.1951, Мөслим р-ны Баек а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1981–88 елларда Татарстан китап нәшриятында корректор, соңрак мөхәррир булып эшли. 1988–92 дә ТР Мәдәният министрлыгының Республика фәнни-методик үзәгендә бүлек мөдире. 1992 дән — «Татарстан» ДТРКсында мөхәррир, музыкаль тапшырулар алып баручы. «Төсле моң» (1985), «Балачак кая китә?» (1989), «Ни өчендер безнең язмыш шундый» (1996), «Җирсү» (2001) шигырь җыентыклары авторы. Шигырьләре нечкә лиризм, гражданлык пафосы белән сугарылган. «Яшел гармун» повестенда әдәп-әхлак проблемаларын күтәрә. Композиторлар Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари, И.Дәүләтшин, А.Монасыйпов, З.Хәйретдинов белән берлектә иҗат иткән җырлары халык арасында популярлык казана.

*Әд.:* Рәшит Ә. Кояш нуры тамган шигырьләр // Мирас. 1997. № 3; Әюп Х. Якты моңнар иясе // Казан утлары. 2001. № 2.

*Г.М.Габделхакова.*

**ҖИҺА́НОВ** Нәҗип Гаяз улы (15.1.1911, хәзерге Казакъстан Респ-касы Уральск ш. — 2.6.1988, Уфа, Казанда җирләнә), композитор, муз.-җәмәгать эшлеклесе, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1940), СССРның халык артисты (1957), проф. (1953), Соц. Хезмәт Герое (1981). 1938 елда Мәскәү консерваториясенең композиция ф-тын (Г.Литинский классы) тәмамлый. 1939–77 елларда ТАССР Композиторлар берлегенең оештыру ком-ты һәм идарәсе рәисе, 1941–43 тә Татар опера һәм балет театрының сәнгать җитәкчесе, 1945 тән Казан консерваториясе ректоры. Илнең һәм

Татарстанның музыка сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш кертә. 1937 дә Җ.ның Беренче симфониясе башкарылу б-н — Татар филармониясе, 1939 да «Качкын» опера спектакле куелу б-н Татар опера һәм балет театры ачыла. 1940–60 елларда Җ. муз. театр жанрлары өлкәсендә аеруча актив эшли һәм 8 опера, 3 балет иҗат итә. Аның әсәрләрендә беренче тапкыр татар халкы тормышында булып узган мөһим вакыйгалар опера сәнгатендә тасвирлана: «Качкын» (1773–75 елгы Крәстияннәр сугышында татарларның катнашуы) һәм «Ирек» (Казан губернасында 1917 елгы революция алды вакыйгалары) әсәрләре киң танылу ала. Либреттолары татар эпосы мотивларына нигезләнгән легендар-героик «Алтынчәч» (СССРның Дәүләт бүләге, 1948), «Түләк һәм Сусылу» операларының символик образларында халык азатлыгы өчен көрәш темасы чагыла. «Илдар», «Шагыйрь» опералары Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына һәм «Намус» операсы авыл хезмәтчәннәре тормышына багышлана. Мәшһүр каһарман шагыйрь М.Җәлилнең гражданлык һәм иҗади батырлыгы турындагы «Җәлил» опера-поэмасы гитлерчылар башлаган басып алу сугышының вәхшилеген, патриотик бурычның мәгънәви асылын, ватанны саклау идеясенә тугрылык темаларын фәлсәфи яктан ачуга ирешә.

Җ. — татар музыкасы тарихында зур композитор-симфонист буларак танылa. Беренче симфониясе Мәскәү консерваториясендә укыганда языла (1935). Аннан соңгы иҗади кызыксынуы программ симф. музыка жанрына туплана. «Кырлай» симф. поэмасы (Г.Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасы мотивына корылган) музыка чаралары б-н туган як табигатен сурәтли, оркестрның колоритлы яңгырашында популяр әкияти образларны гәүдәләндерә. Татар музыка фольклорының төрле катламнарын иҗади эшкәртү нигезендә туган Татар темаларына сюитасы (СССР Дәүләт бүләге, 1950) һәм «Симфоник җырлар»ы халык көйләрен оста һәм сәнгати файдалануы б-н аерылып тора. «Нәфисә» увертюрасында «Намус» операсы музыка материалы файдаланыла. «Симфоник новеллалар» сюитасы нигезендә кытай халык легендасы мотивлары, тәмамланмаган «Сары ләкләк» балеты музыкасы ята. 1960 еллар ахырыннан Җ. иҗатында симфония төп жанрга әверелә. Шигъри, лирик рух б-н сугарылган, та-



Н.Г. Җиһанов (сулда) һәм Р.Х. Яхин. 1960 еллар.

тар милли бәйрәме атмосферасының тормышчанлыгын ачык һәм бай итеп чагылдырган Икенче «Сабантуй» симфониясе (СССР Дәүләт бүләге, 1970) киң танылу ала. 1970–80 дә Җ. тагын 15 симфония иҗат итә, алар циклның төп идеяләрен тыңлаучыга җиткерүдә төрлелек, тембрлы һәм драматик чишелешләрнең яңалыгы, композиторлык техникасы алымнарының киң диапазоны б-н аерылып тора. Җ.ның әсәрләре татар музыка сәнгатендә опера, балет, симф. жанрларының үсүенә ярдәм итә. Композитор иҗатында татар опера-симфония мелодикасының яңа тибы формалаша, 1950–80 елларда пентатоник муз. культураларның интонацион нигезенә таянып иҗат итү өчен стилистик үрнәк булган форма һәм алымнар кулланылмый башлый. Җ.ның стиле ачык чагылышлы индивидуальлеге, миллилеге һәм шуның б-н бергә рус һәм чит ил классиклары традицияләренә таянуы б-н үзенчәлекле. Аның әсәрләренә фәлсәфи фикер тирәнлеге, көй һәм гармонияне үстерү һәвәслеге, оркестрлаштыру осталыгы, муз. форманың ачыклыгы, татар муз. фольклорының төрле алымнарын куллану хас. Җ.ның мәшһүр әсәрләре татар музыкасын халыкара танытуга булышлык итә. «Җәлил» операсы Советлар Союзының Зур театрында (1959), Прага милли театрында (1960) куела. Җ. үзенең иҗат юлы дәвамында камера-вокаль әсәрләр дә яза. Күпләгән җырлары һәм романслары киң танылу ала һәм концерт репертуарларына керә. Алар: «Сиреньнәр хуш ис тарата» (Ә.Ерикәй сүзләре, 1956), «Зарыгу» (Б.Старчиков сүзләре, 1964), «Җир йөзендә әкият бар» (М.Таҗетдинов сүзләре, 1966) һ.б. Ул камера-инструменталь әсәрләр авторы, аларның күбесе пианистларның пед. һәм концерт репертуарларында киң кулланыла: «Балалар өчен альбом»га берләштерелгән фортепьяно пьесалары (1946), «Фортепьяно өчен сюита» (1962), «Фортепьяно өчен ун пьеса» (1972), «Фортепьяно өчен 12 күренеш» (1976), «Матюшино эскизлары» (1980) керә.



Н.Г. Җиһанов (уңнан икенче) «Алтынчәч» операсының либретто авторы М. Җәлил (уң кырыйда) белән. 1940.

Җ. Казан консерваториясен һәм аның каршындагы махсус урта музыка мәктәбен төзүдә һәм Дәүләт симф. оркестрын оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Татарстанда проф. муз. белем бирү системасын формалаштыруда да Җ.ның роле зур. 2001 дә Казан консерваториясенә Җ. исеме бирелә. Татар композиторлык мәктәбен оештыруга, Идел буе һәм Урал алды респ-калары музыка сәнгатен үстерүгә Җ.ның иҗади, пед. һәм оештыру эшчәнлеге көчле йогынты ясый. Казан консерваториясендә Җ.ның инструментовка классын тәмамлаган композиторлар Ф.Әхмәтов, Р.Белялов, Р.Еникиев, Р.Кәлимуллин, Л.Любовский, А.Монасыйпов, Б.Мөлеков, Б.Трубин, Ш.Шәрифуллин, М.Яруллин һ.б. — татар музыка сәнгатенең күренекле вәкилләре.

Җ. актив муз.-җәмәгать эшчәнлеге дә алып бара: СССР Композиторлар берлеге идарәсе әгъзасы (1948 дән), РСФСР (1957 дән), СССР (1962 дән) Композиторлар берлекләре идарәләре секретаре, Г.Тукай исем. Дәүләт



Н.Г. Җиһанов. 1987.

бүләге ком-ты әгъзасы (1958 дән), Ленин премиясе һәм СССР МС каршындагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Дәүләт премияләре ком-тлары әгъзасы (1961 дән). РСФСР (1951–59), ТАССР (1963–67 һәм 1971–88), СССР (1966–70) ЮСлары депутаты. СССРның Дәүләт (1948, 1950, 1970), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре (1958) лауреаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Кече планеталарның берсенә Җ. исеме бирелә (1997).

Төп әсәрләре: опералар — «Качкын» (Ә.Фәйзи либр., 1938), «Ирек» (З.Сафин, 1940), «Алтынчәч» (М.Җәлил, 1941), «Илдар» (М.Җәлил, 1942; 2 нче редакциясе «Җиңү юлы», 1954), «Түләк» (Н.Исәнбәт, 1944; 2 нче редакциясе «Түләк һәм Сусылу», 1967), «Шагыйрь» (Ә.Фәйзи, 1947), «Намус» (Ә.Исхак, 1950), «Җәлил» (Ә.Фәйзи, 1956); балетлар — «Фатыйх» (Г.Таһиров, 1943), «Зөһрә» (Ф.Гаскәров, 1944; 2 нче редакциясе Д.Арипова, 1969), «Нжери» (Н.Җиһанова, 1969); 17 симфония; «Кырлай» симф. поэмасы (1946), Симф. оркестр өчен татар темаларына сюита (1949), симф. оркестр өчен «Нәфисә» увертюрасы (Г.Бәшировның «Намус» романы буенча, 1952), «Симфоник новеллалар» (1963), «Симфоник җырлар» (1965);

кантаталар — «Минем республикам» (Н.Арсланов сүзләре, 1960), «Исәнме, Мәскәү» (Р.Харис сүзләре, 1980); инструменталь камера әсәрләре, романслар, җырлар, халык көйләре эшкәртмәләре.

*Әд.:* М а н с у р о в Ф. Нәҗип Җиһанов — татар музыкасында беренче номерлы шәхес // Татарстан. 2001. № 2; Г и р ш м а н Я. Назиб Жиганов. М., 1975; С п и р и д о н о в а В. Фортепианные произведения Назиба Жиганова в педагогическом репертуаре. К., 1980; Ш а м с у т д и н о в а Ф. Выдающийся мастер татарской музыки // Музыкальная жизнь. 1981. № 3; К а с а т к и н а Г. Художник щедрого таланта, неиссякаемой энергии // Советская музыка. 1981. № 11; С а л е х о в а З. «... И приумножить её добрую славу»: Портрет Назиба Жиганова в документах // Казань. 1966. № 5–6; Назиб Жиганов: Контексты творчества: Сб. науч. статей. К., 2001; П о к р о в с к и й Б. Назиб Жиганов — оперный драматург // Казань. 2001. № 1; Н.Жиганов. Материалы и воспоминания. К., 2005.

*В.Р.Дулат-Алиев.*

**ҖИҺА́НОВ НӘҖИ́П МУЗЕ́Й-ФАТИРЫ́**, Казанда, мемориаль музей; ТРның Милли музее ф-лы. ТССР МКның 1991 елның 30 июлендә кабул ителгән карары нигезендә оеша. 2001 нең 2 мартында ачыла. Музей Н.*Җиһанов* 20 ел (1968 дән) дәвамында яшәгән һәм эшләгән фатирда урнашкан, йорт республика күләмендәге әһәмиятле һәйкәлләрнең дәүләт саклау реестрына кертелгән. Музейның гомуми мәйданы — 100 *м²*, экспозициясендә: Н.Г.Җиһановның кабинеты һәм кунак бүлмәсе; фондларында 2 мең саклау берәмлеге исәпләнә. Фатирның мемориаль күренеше (рояль, язу өстәле, китапханә,



Казанда Н.Г.Җиһановның музей-фатиры. Экспозициядән күренеш.

гаилә әгъзалары фотосурәтләре һ.б.) һәм композиторның 1920–80 елларда тупланган архивы (шәхси документлар, кулъязмалар, фотолар, ноталар һәм белешмәлек әсбаплар, китапханә) саклана. Ноталар архивына Җиһановның барлык әсәрләренең кулъязмалары, ш.и. каралама вариантлары, эскизлары, ш.у. композиторның сирәк очрый торган библиографик басмалар рәтенә кергән партитуралары һәм клавирлары керә. Музей фондларында музыка сәнгатенең атаклы эшлеклеләре: Д.Шостакович, А.Хачатурян, Т.Хренников, Р.Щедрин, Б.Покровский, Н.Рахлин, Г.Литинский һ.б.ның хатлары саклана. Музей китапханәсендә композиторның автографы һәм сәнгать эшлеклеләренең бүләк язулары булган китаплар бар. Музей ел саен Н.Г.Җиһановның туган көнен (15 гыйнв.) һәм аны искә алу көнен (2 июль) билгеләп уза. Музей директоры — композиторның хатыны Н.И.Җиһанова (2001–09), Л.А.Яковлева (2010 нан).

**ҖИҺА́НОВА** Светлана Нәҗип кызы (31.3.1936, Мәскәү — 5.12.1998, Казан), җырчы (меццо-сопрано), педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979). 1958 елда Казан ун-тының тарих ф-тын, 1963 тә Казан консерваториясенең вокал ф-тын (В.А.*Лазько* классы) тәмамлый. 1966 дан Казан консерваториясендә (1990 нан операга әзерлек каф. мөдире, 1998 дән проф.) укыта. Опера студиясе ачуга, консерватория студентлары көче б-н опера спектакльләре куюга булышлык итә. Методик эшләр (татар музыкасы җирлегендә югары музыка уку йортларының вокал ф-тлары өчен методик тәкъдимнәр һәм программалар авторы) алып бара. Шәкертләре арасында Р.Ибраһимов, Г.Ластовка, Т.Зорина, Р.Идрисов, Р.Сәхәбиев, Л.Хохлова, В.Гыйззәтуллина, Г.Колчина, Р.Үзбәкова бар. Җ. яхшы вокал мәктәбен узган шәхес, тулы диапазонлы матур меццо-сопрано тавышка ия буларак, үзен камера җырчысы итеп таныта. Репертуарына Д.Б.Перголези, Г.Ф.Гендель, Дж.Россини, Дж.Верди, Ж.Бизе, П.И.Чайковский, С.С.Прокофьев, Д.Д.Шостакович, Р.К.Щедринның, ш.у. татар композиторларының төрле стильдәге вокаль әсәрләре керә.

*Г.Б.Гобәйдуллина.*

**ҖИҺА́НШИН** Абдулла Абдрахман улы (22.6.1917, Казан губ., Чистай өязе Татар Талкышы а.), агроном, кыр белгече, а.х. фән д-ры (1969), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1998). Чистай а.х. техникумын (1934), Казан а.х. ин-тын (1939) тәмамлый. 1939–41 елларда Дөбъяз, Актаныш, Акташ сорт участоклары мөдире. 1945–50 елларда Казан селекция станциясе директоры урынбасары, 1950–52 дә ТАССР А.х. министрлыгының а.х.н пропагандалау идарәсе башлыгы. 1952–55 тә Казан а.х. ин-ты проректоры, 1955–61 дә Казан югары партия мәктәбенең а.х. каф. мөдире, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары (1965–74), Мари ун-тының (1974–80) һәм Казан а.х. ин-тының (1955–61, 1963–65, 1980–90) үсемлекчелек кафедралары мөдире, 1990 нан профессор. Җ. җитәкчелегендә а.х. культураларын үстерү технологияләрен алдан исәпләнгән, программалы нигезгә күчерүнең теоретик базасы булдырыла, практик алымнары эшләнә. Югары уңыш алу өчен (1 *га* дан 40–60 *ц*) а.х. культураларын чәчүлекләрдә урнаштыру, бөртекле, бөртекле-кузаклы культураларны, бәрәңге, люцерна һ.б. өчен туфрак әзерләү, ашламалар куллану, сугару, сортлар сайлау, чәчү, карау һәм җыюның үзенчәлекләре өйрәнелә. Җ. — игенчелек системасының төп звенолары, ш.и. Биектау р-нының «Чулпан» хуҗалыгында адаптив игенчелек системасы буенча Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының стационар тәҗрибәләр инициаторы һәм беренче җитәкчесе. Республика терр-ясенең хәзер гамәлдә булган табигый-икътисади зоналарга бүленешен нигезли. Монография-



Абдулла А. Җиһаншин.

ләр авторы. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы. ТР Дәүләт бүләге (2001) үләнчел сорго үстерү, куллану, орлыкчылыгын оештыру технологиясен эшләгәне һәм аны житештерүгә кертканә өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша, танк гаскәрләрендә хезмәт итә. Ставрополь, Ростов-Дон, Минск, Бреславль һ.б. шәһәрләрне азат итүдә катнаша. Рядовой булып алынып, сугыштан майор дәрәҗәсендә кайта. Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе», «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агротехника полевых культур в Татарской АССР. К., 1952 (автордаш); Возделывание зернобобовых культур. К., 1953 (автордаш); Полеводство Татарии. К., 1960; Севообороты Татарии. К., 1973; Озимая рожь в лесостепи. М., 1974 (автордаш); Факторы запрограммированных урожаев. К., 1974 (автордаш); Зернофуражное поле. К., 1985 (автордаш); Интенсивные технологии и программирование урожайности. К., 1987.

*Әд.:* Воины-татары в боях за Родину. К., 1945; Д ю р я г и н Г.М. Верный сын Родины: страницы фронтовой жизни. К., 1971; Д а в л е т ш и н Т.З. К тайнам высоких урожаев. К., 1987; А в е р ь я н о в Г.Д., М е щ а н о в В.Н. Абдулла Зиганшин // Казань. 2001. № 12.

**ҖИҺА́НШИН** Айрат Госман улы (1.1.1960, Тукай р-ны Олы Әтнә а.), фармаколог, нейрофизиолог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1999). 1983 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1987 дән Үзәк фәнни тикшеренү лаб-ясенең бүлек мөдире, 1992 дән мөдире, 1997 дән фармакология кафедрасы профессоры, 2009 дан проректор. АТФның яңа төрләренә фармакологик анализ ясый, висцераль яисә тамыр тукымаларының пуринорецепторлары өчен селектив булган эффектлы агонист $P_2X$ һәм $P_2V$ пуринорецепторларын ачыклый, аларның максатлы синтезын тәкъдим итә.

Х е з м.: Экспериментальная и клиническая фармакология. М., 1997; Фармакология рецепторов АТФ. М., 1999 (автордаш).

**ҖИҺА́НШИН** Альварес Абдулла улы (7.11.1937, Казан— 20.4.2010, шунда ук), галим-агроном, а.х. фән. канд. (1968), ТАССРның атказ. агрономы (1986), РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1960). 1961–67 елларда Биләр сорт сынау участогын җитәкли. 1967–2006 да ТР Дәүләт сорт сынау хезмәте җитәкчесе. Югары продукцияле сабан бодае, арпа, солы, борчак һ.б. а.х. культураларының яңа сортларын булдыра (акад. Э.Д.*Неттевич* һәм А.М.*Шевченко* б-н бергәләп). Җ., рәсми дәүләт сынавына кадәр үк, сортларны өйрәнү

һәм аларга бәя бирү юлы б-н тиз гамәлгә кертү, ш.у. җирле селекциядәге эре бөртекле карабодай сортын тарату эшен башлый. Җ. тырышлыгы б-н ТР сыра кайнату өчен арпа җитештерү зонасына кертелә. Дәүләт бүләге солының киң шартларга яраклашкан һәм югары сыйфатлы яңа сортларын булдырганы һәм үзләштергәне өчен бирелә.

**ҖИҺА́НШИН** Әсхәт Рәхимҗан улы (13.3.1938, Куйбышев, хәзерге Самара өлкәсенең Шонталы р-ны Шонталы а.), кече сержант, СДБ-4 тибындагы үзйөрешле баржа старшинасы. Шонталы авыл хуҗалыгын механикалаштыру уч-щесен тәмамлый (1956), Шонталы МТСында тракторчы булып эшли. 1958 елда хәрби хезмәткә алына һәм Советская Гавань шәһәренә, аннан Южно-Сахалинск шәһәренә рулевой-старшиналар мәктәбенә укырга җибәрелә, анда 8 айлык курслар тәмамлаганнан соң, Итуруп утравына озатылып, үзйөрешле десант баржасы (экипажы 4 кешелек) старшинасы итеп билгеләнә. 1960 ның 17 гыйнварында, көчле кар яуганда, җилнең көче 70 *м/с* ка җиткән шторм баржаны Җ. һәм аның хезмәттәшләре рядовойлар Анатолий Фёдорович Крачковский, Филипп Григорьевич Поплавский (икесе дә Украинадан) һәм Иван Ефимович Федотов (Амур өлкәсеннән) б-н бергә ачык океанга алып китә. Ягулык беткәч, баржа идарә ителү сәләтен югалта. Судно җил һәм дулкыннар тәэсирендә стихияле хәрәкәт итә, эчәргә яраклы су һәм азык-төлек запаслары бетә. 49 тәүлектән соң, 1960 ның 7 мартында, аларны табалар, Американың «Кирсардж» авианосецы Сан-Франциско шәһәренә алып кайта. Коткарылган экипажны Нью-Йорк шәһәрендә АКШтагы совет илчелеге вәкилләренә тапшыралар. Ватаннарында аларны геройлар кебек каршылыйлар. 1960 та Җ. һәм аның иптәшләренә Ленинград хәрби-диңгез урта техник уч-щесенә юллама бирәләр. Аны тәмамлаганнан соң (1964), Җ. Ломоносов шәһәрендә (Ленинград өлкәсе) авария-коткару отрядында өлкән механик булып эшли башлый.

Хәрби бурычны үтәгәндә күрсәткән батырлыклары һәм стихия көчләре б-н көрәштә күрсәткән ныклык өчен Җ. һәм аның баржадагы хезмәттәшләре Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: 49 дней и океан. Куйбышев, 1960.

*Әд.:* С т р е л ь н и к о в Б. Победители морской стихии // Правда. 1960. 16 марта; ш у л  у к. Обыкновенные, советские! // Огонёк. 1960. № 13; ш у л  у к. Славные советские парни // Огонёк. 1960. № 15; М я с н и к о в В.Н. Собр. соч. Т. 3. Четверо и океан. Самара, 2000; Ш а ф и к о в Я. 49 дней и вся жизнь // Татарстан. 2003. № 6.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ҖИҺА́НШИН** Әхмәтша Җиһанша улы (11.2.1909, Казан губ., Мамадыш өязе Түбән Искүбаш а. — 16.12. 1971, Приморье крае Артём ш.), шахта төзүче, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1927–39 елларда Донбасс шахталарында забойчы, 1939 дан «Челябуголь» трестының «Красная Горнячка» 21 нче һәм 8 нче шахталарында проходчик (күмер казучы), 1968 дән «Приморскуголь» комб-ты шахталарында (Артём ш.). Анда шахтёрлар арасында беренчеләрдән булып Соц. Хезмәт Герое исеменә лаек була. Герой исеме күмер чыгарудагы, күмер шахталарын торгызу һәм төзүдәге казанышлары, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итүче алдынгы алымнар керткәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Артём шәһәрендә Җ.га һәйкәл, Түбән Искүбаш урта мәктәбе каршында геройның бюсты куела. Артём шәһәренең «Амур» шахтасы р-нындагы бер урамга аның исеме бирелә. Шахтада Җ. исем. күчмә приз оештырыла. Артём шәһәренең төбәкне өйрәнү музеенда Җ. мемориалы ачыла.


*Әд.:* Б е л ь ч е н к о В. Артём. Вчера, сегодня, завтра. Владивосток, 1974; Герои Социалистического Труда. М., 1988.

*И.Н.Афанасьев.*

**ҖИҺА́НШИН** Булат Госман улы (12.5.1966, Чистай р-ны Каргалы а.), а.х. механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005), проф. (2009). 1990 елда Казан а.х. ин-тын (хәзерге Казан аграр ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, фәнни-тикшеренү секторы башлыгы (1995–99), Механикалаштыру һәм техник сервис ин-ты директоры (2008 елдан). Хезмәтләре машина технологияләрен терлек азыгы әзерләү, сөт саву, үсемлекчелектәге машина технологияләрен камилләштерү мәсьәләләренә карый. Җ. рәшәткәсез чүкечле ваткычта ваклау, энергия саклый торган вакуумлы насосларны проектлау һәм исәпләүнең теоретик нигезләрен эшли; игенчелектә ресурс саклый торган технологияләр куллану мәсьәләләрен тикшерә. Җ. эшләгән техник чаралар: терлек азыгын һәм бүлбетамыр-тамыразыкларны ваклагычлар, кече габаритлы комбиазык һәм сөт саву агрегатлары, сенаж һәм силос өчен ротор тибындагы төягеч һ.б. ТРның а.х. җитештерүенә кертелә. Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең (Мәскәү) Халыкара һәм Россия агросәнәгать күргәзмәләре медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологии и технические средства приготовления кормов. К., 2003; Совершенствование вакуумных средств механизации в молочном животноводстве. К., 2006 (автордаш); Алгоритм проектирования производства сельскохозяйственной продукции — начало технологического реформирования АПК РТ // Вест. Казан. аграрного ун-та. 2008. № 2(8).

**ҖИҺА́НШИН** Габдрахман Җиһанша улы (10.1.1933, Кама Тамагы р-ны Көрлебаш а.), автоматлаштырылган идарә итү системалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (2000). 1948–51 елларда Тәмте р-нының «Кызыл маяк» к-зында бухгалтер. 1951–52 дә Артём шәһәрендә (Приморье крае) салым инспекторы ярдәмчесе булып эшли, 1952–57 дә Эчке эшләр министрлыгы органнарында (Сахалин өлкәсе) хезмәт итә. 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, лаб. мөдире (1967–72). 1980–90 да Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында лаб.-сектор башлыгы. 1991–95 тә Технол. комплекслар б-н автоматлаштырылган идарә итү системалары фәнни җитештерү пр-тиесе директоры. 1995 тән Казан энергетика ун-тында, инженерлык каф. мөдире (1996–2002). Хезмәтләре автоматик идарә итү теориясенә, икътисади процессларны модельләштерүгә һәм алар б-н идарә итүгә карый. Идарә итүнең нәсызыкча системаларын тикшерә. Идарә итүнең инвариант системаларын синтезлау ысулын эшли, пр-тиенең әйләнештәге средстволары икътисади схемасын төзи, кече һәм зур икътисади системаларның динамик үзенчәлеген билгели.



Ә.Р. Җиһаншин.



Ә.Җ. Җиһаншин.

Х е з м.: Построение уравнения водоподготовки на ТЭЦ по потенциальным уравнениям // Вестн. Казан. фил. Моск. энергет. ин-та. К., 1996; Двухпараметрическая модель гидротурбины / КФ МЭИ (ТУ) // Межвуз. сб. науч. тр. К., 1997; Теория моделирования и управления экономическими процессами. К., 2001.

**ҖИҺА́НШИН** Галимҗан Җиһанша улы (12.4.1924, хәзерге Мамадыш р-ны Дусай а. — 8.10.1994, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978), Мамадыш р-нының «Чулпан» к-зы рәисе (1947–85). Бөек Ватан сугышында катнаша. Җ. җитәкчелегендә хуҗалыкның матди-техник базасы үсеш ала, социаль-көнкүреш шартлары яхшыртыла, колхоз респ-када алдынгыларның берсенә әверелә. 1955–59 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ҖИҺА́НШИН** Госман Шаһи улы (26.9.1926, Арча кантоны Олы Әтнә а. — 12.11.1992, Казан), а.х. производствосын оештыручы, галим-агроном. Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1960). 1953–57 елларда Әтнә р-нының «Коммунизм таңы» к-зы рәисе, 1958–60 та Тукай р-ны башкарма ком-тында а.х. инспекциясе башлыгы. 1960–62 дә КПССның Тукай райкомы 2 нче секретаре. 1962–65 тә ТАССРның Куйбышев р-ны колхоз-совхоз терр. идарәсе башлыгы. 1965–71 дә КПССның Арча һәм Сарман райкомнары 1 нче секретаре. 1971–83 тә ТАССР а.х. министры. 1983–87 дә ТАССРның А.х. продукциясен әзерләү һәм сыйфатын булдыру дәүләт инспекциясе башлыгы. 1967–85 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ҖИҺА́НШИН** Ильяс Исхак улы (18.9.1964, Тәтеш р-ны Алабирде а.), дин эшлеклесе. Казан а.-х. ин-тын тәмамлый (1984). 1986–92 елларда Ульянов авиация сәнәгате комплексы

хезмәткәре. 1992–96 да Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исем. Казан югары мөселман мәдрәсәсендә укый. 1996 дан әлеге мәдрәсәнең проректоры, соңрак ректоры, бер үк вакытта 1999 дан ТР мөселманнарының Диния нәзарәте аппараты җитәкчесе.

*Әд.:* Гыйлемле булу — олуг бурычтыр.К., 2001.

**ЖИҺА́НШИН** Рафаил Рәхимҗан улы (23.6.1950, Казакъстан ССР, Темир ш.), физика плазмасы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук физика һәм техника плазмасы бүлегендә эшли. 1981–91 дә «Вакууммаш» фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. башлыгы (1986 дан), директор урынбасары (1987 дән), «Вакууммаш» АҖнең ген. директоры урынбасары — фәнни-техник үзәк башлыгы (1991 дән). «Албак» ФҖБ ген. директоры (2001–09, Алабуга ш.), бер үк вакытта 2002дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә машиналар конструкцияләү нигезләре каф. мөдире (Чаллы ш.). Хезмәтләре вакуумдагы түбән темп-ралы плазманың физикасы һәм техникасына карый. Материаллар һәм капламнарны сылау һәм сынау өчен эре габаритлы ион-плазмалы җиһазлар комплексын тикшерә, эшли һәм гамәлгә кертә (РФ һәм чит илләрнең төрле сәнәгать тармакларында киң кулланыла). Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Плазменные способы нанесения покрытий // Плазменная техника и технология и их применение. К., 1984; К теории аномального тлеющего разряда в скрещенном электрическом и магнитном полях // Вакуумная техника и технология. 1997. Т. 7, № 3 (автордаш); Формирование плазменного потока с помощью разряда с низким электролитным потоком и его характеристиками // Вестник КГТУ им. А.Н.Туполева. 2008, № 3 (автордаш).

**ЖИҺА́НШИН** Рәшит Вәли улы (2.5.1930, Свердловск өлкәсе, Карпинск ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1982), РСФСРның атказ. табибе (1979). Пермь мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Тобол, Төмән, Төмән өлкәсе мед. учреждениеләрендә эшли. 1974 елдан Төмән мед. ин-тында, факультет хирургиясе каф. мөдире, 1974 тән проректор. Корсак хирургиясе өлкәсендә фәнни юнәлеш буларак «хәтерле» эретмәләр эшләү һәм куллануны гамәлгә кертә. Ж. титан никелидыннан ясалган «хәтерле» имплантатның операция вакытын кыскартуын һәм операциядән соң авыруларның хәлен җиңеләйтүен ачыклый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сплавы с «памятью» в медицине. Тюмень, 1986; Имплантаты с «памятью». Тюмень, 1992.

**ЖИҺА́НШИНА** Лилия Евгеньевна (19.6.1962, Үзбәкстан ССР, Бохара ш.), фармаколог, мед. фән. д-ры (1995), проф. (2000), 2000 елдан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш клиник фармакологы, 1985 тә Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. 1998 дән Казан мед. академиясендә, 2001 дән клиник фармакология һәм фармакотерапия каф. мөдире. Димефосфонның урынлы тәэсирен, монофосфонатлар һәм $P_2$-пуринорецепторлары агонистларының кеше организмы тукымасында шешү, ялкынсынуга каршы тәэсирен өйрәнә, дару препаратларының дәвалау нәтиҗәлелеге пациентларның фенотипик һәм генотипик үзенчәлегенә бәйле булуын күрсәтә, димефосфонлы яңа дару формалары (гель, лосьон, крем) эшли һәм гамәлгә кертә.

Х е з м.: Фармакология рецепторов АТФ. М., 1999 (автордаш); Фармако-эпидемиологический анализ подходов к назначению антибактериальных препаратов при лечении острых респираторных вирусных инфекций у детей // Казан. мед. журн. 2000. Т. 81, № 2.

**ЖИҺА́НШИНА** Нәсимә Мансур кызы (1.4.1926, Минзәлә кантоны Пучы а.) драма актрисасы, РСФСРның атказ. артисты (1957). 1946 елда Минзәлә колхоз-совхоз театры труппасына кабул ителә. Матур йөз-кыяфәте һәм җырлау сәләте яшь артистка муз. спектакльләрдә Мәликә («Акчарлаклар», Ә.Фәйзи), Рәмзия («Идел буенда», Г.Насрый), Җәүһәрия («Кошның да үз канаты була», Ю.Әминев), Әлфия («Әйтер идем йөрәк серемне», Р.Ишморатова), Тәлли («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков) кебек героиняларны уйнарга мөмкинлек бирә. М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасы буенча куелган спектакльдә Галиябануны актриса романтик рухта, нәфислек б-н башкара һәм үзәк матбугатта да мактаулы бәягә лаек була. «Советская культура» г-тасында Ю.Әминевнең «Язылмаган законнар» пьесасы буенча куелган спектакльдә Ж. башкарган Фәридә образы «спектакльнең зур уңышы» буларак бәяләнә. Саҗидә, Гыйззәниса («Тамырлар», «Кеше күңеле», Ю.Әминев), Сылубикә («Һәйкәл», Ә.Баянов), Сәрбиҗамал («Ана йөрәге», С.Кайтов), Татта («Куендагы елан», Ә.Мирзаһитов), Зөһрә, Сәрвиназ («Таң йолдызы», «Уракчы кыз», С.Шәкүров), Мәүгыйзә («Ардуан батыр», Г.Ахунов), Хафизә («Соңгы каракош», Г.Баһаветдинов), Сәлимә («Язмышлар хәл ителгәндә», Р.Хәмид), Мәфтуха («Түгелмә, бәхет», Ш.Рәхмәтуллин) кебек рольләрне башкарып, Ж. хатын-кыз характерының күптөрле төсмерләрен, милли сыйфатларын ачу б-н бергә аларны заман рухына туры китереп күрсәтә ала. Актриса классик драматургия репертуарында да уңышлы образлар тудыра. Андыйлардан Гафифә, Мәхүпҗамал («Беренче театр», «Бүләк өчен», Г.Камал), Заһирә, Бикә («Зәңгәр шәл», «Ил», К.Тинчурин), Лариса («Бирнәсез кыз», А.А.Островский), Розаура («Дуслык никахы», К.Гольдони), Джудит («Шайтан шәкерте», Б.Шоу), Зорька («Гади кеше», Б.Нушич) образларын билгеләп үтәргә мөмкин.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ЖИҺА́НШИНА** Рәшидә Габдуллаҗан кызы (17.10.1917, Казан — 7.5.2003, шунда ук), драма актрисасы, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1966, 1981). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң (1936), Татар акад. театры труппасына кабул ителә, 1964–75 елларда шул театрның директоры була. Ж. иҗатының башлангыч чорында иҗат ителгән образлары — тормыштагы катып калган иске гадәтләргә каршы көрәшүче, тирән хисләргә бирелүче Надя («Дошманнар», М.Горький, 1936), үз эшенә чын күңелдән бирелгән вет. табибе Людмила («Мактаулы заман», Т.Гыйззәт, 1936), энергиясе ташып торган, эшчән-булган Нәфисә («Дәүләт Бәдриев», Г.Иделле, 1937), тыйнак, сөйкемле кыз Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт, 1937), кырыс табигатьле, максатына ирешүчән Лена («Чик сакчылары», В.Н.Билль-Белоцерковский, 1937) — актрисага яшь ягыннан да, тормыш тәҗрибәсе ягыннан да бик якын торган кызлар, аларда энтузиазм, комсомол дәрте кайнап тора, һәм алар шул чорның яшьлеген чагылдыралар. Ж. аларның һәрберсен яратып, тормышчан итеп уйный. Халык батыры Мәрьям (Н.Исәнбәтнең шул исем. пьесасы буенча куелган спектакль, 1943), тыл фидакаре Гайни («Миңлекамал», М.Әмир, 1944) — Ж. башкаруында шул чорның героизм идеяләре б-н сугарылган. Аннан соңгы елларда Ж. аерылып торган, үзенчәлекле характерлы актриса буларак формалаша. Аның төп рольләре арасында: Туганым, Гөлҗиһан («Банкрот», Г.Камал, 1944, 1962), Бәрбәрия, Гөлчирә («Чын мәхәббәт», «Ташкыннар», Т.Гыйззәт, 1948, 1949), Заһирә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин, 1956), Зәйнәп («Фатыйма Сабри», С.Җамал, 1967), Фәйрүзә, Мәчтүрә, Тәңкәбикә («Ялгыз каен», «Җырланмаган җыр», «Ай тотылган төндә», М.Кәрим, 1951, 1962, 1965), Зөбәрҗәт («Югалган матурлык», Һ.Такташ, 1956), Зөһрә («Таң атканда», Ш.Шаһгали,





Р.Г.Ж и һ а н ш и н а: 1. Смельская («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», А.Н.Островский); 2. Императрица Екатерина («Канкай углы Бәхтияр», Т.Миңнуллин, сулда Һ.Солтанов) рольләрендә.

1959), классик драматургия әсәрләрендә — Коринкина, Смельская («Гаепсездән гаеплеләр», «Талантлар һәм аларга баш июучеләр», А.Н.Островский), Надежда, Клеопатра («Варварлар», «Дошманнар», М.Горький), Беатриче («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Тизба («Анджело», В.Гюго) образлары бар. А.Гыйләҗевнең «Әңгер-меңгер» әсәре буенча куелган спектакльдәге (1971) Зөһрә, Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Хәмдебану (1976), «Моңлы бер җыр»дагы Ана (1981) образлары эчке кичерешләрнең психологик тирәнлеге б-н аерылып торалар. Актриса алардагы әдәплелек, саф күңеллелек, олы җанлылык хисләрен тормыштагы хәлләр б-н бергә үреп, бу образларны гомумиләштерелгән символик югарылыкка күтәрә. Эшлекле, инициативалы, оештыру сәләтенә ия Җ. берничә мәртәбә җәмәгать органнарына сайлана. Бөек Ватан сугышы елларында фронтта концерт бригадалары б-н чыгышлар ясый. Театр директоры буларак, коллективның иҗат тормышын тамырдан яңартуга ирешә. 1970–88 елларда Бөтенроссия театр җәмгыятенең (ВТО) Татарстан бүлеге идарәсе (хәзер Театр эшлеклеләре берлеге) рәисе була. Сәхнә ветераннары өчен хәйрия ярдәме фонды «Инсаният»кә нигез сала (1991), пьесалар, истәлекләр авторы. 1966–74 тә ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



Р.Г.Җиһаншина.

Ә с ә р.: Күңелем түреннән. К., 1991; Тормышым минем — театр. К., 1997; Сәхнә. К., 2000.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986; Д а н и л о в а Г., К о р н е в а О. Отцы и дети // Театральная жизнь. 1993. № 7.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ҖИҺА́НШИНА** Эра Гарәф кызы (1.2.1944, Казан), драма актрисасы, РСФСРның атказ. артисты (1982). Казан Яшь тамашачылар театры студиясендә (1960–61, пед. Н.И.Басин), Мәскәүдә Б.В.Щукин исем. театр уч-щесендә (1961–64), Ленинград Зур драма театры студиясендә (1964–65, пед. Г.А.Товстоногов) укый. 1965–70, 1976–99 елларда Ленин комсомолы исем. Ленинград театрында эшли. Киң иҗат диапазонлы актриса буларак, ачык, нәфис, кайвакытта эксцентрик, сәер характерлы форманы психол. тирәнлек, чын драматизм б-н оста үреп, рус һәм дөнья драматургиясе әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә күп кенә әһәмиятле образлар иҗат итә. Аның иҗатына хас юмор хисе актрисага кайвакыт сәхнәдә очрый торган парадоксаль хәлләрдә дә үзен табигый тоту мөмкинлеге бирә. Ул уйнаган рольләр арасында — Нелли («Түбәнсетелгәннәр һәм җәберләнгәннәр», Ф.М.Достоевский романы буенча), Оль-Оль («Тормышыбыз көннәре», Л.Н.Андреев), Аркадина («Акчарлак», А.П.Чехов), Софья («Соңгылар», М.Горький), Катя («Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз», А.М.Володин), Ангелика («Кентаврлар», В.Жалакявичюс киноповесте буенча), Мария («Авылдашлар, акча кирәк» В.Г.Распутин), Ольга («Алексей һәм Ольга», И.А.Герасимовның «Биш ял көне» повесте буенча), Галина («Үрдәк аулау», А.В.Вампилов), Нина («Тамада», А.М.Галин), Марта («Прафауст», И.В.Гёте), Ирэн Гофман («Процесс», Э.Манн әсәре буенча), Пилар («Чаң кемгә кага», Э.Хемингуэй романы буенча), Люси («Өч тиенлек опера», Б.Брехт, К.Вейль) рольләре бар. Башка театр сәхнәләрендә уйнаган рольләре: Зойка («Зойка фатиры», М.А.Булгаков, Ленинград комедия театры), Клотильда («Фердинандо», А.Ручелло, Роман Виктюк театры), Кабаниха («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский, Мәскәү Яшь тамашачылар театры). Кинофильмнарда Җ. башкарган рольләр: Люба («Давыл алдыннан», М.Горькийның «Соңгылар» пьесасы буенча), Александра («Таш венок», Ф.Ф.Кнорре), Ольга («Беренче шатлыклар», К.А.Федин әсәре буенча).

*А.С.Иванов.*

**ҖОМАГЫ́ЛОВ** Әнәс Хафиз улы (26.6.1937, Тәтеш р-ны Олы Тархан а.), а.х.да җитештерүне механикалаштыру гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2004), ТССРның атказ. уйлап табучысы (1991). Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлый (1966), шунда ук эшли, хезмәт иминлеге каф. мөдире (1985–2002), 2002 дән проф. Хезмәтләре машина-трактор агрегатларының нәтиҗәлелеген, а.х. техникасы һәм җиһазлары гидросистемаларының ышанычлылыгын арттыруга карый. Туфракны эшкәртү, а.х. культураларын чәчү, урып-җыю чараларын һәм технологияләрен эшли, шуларның күбесе ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Казан аграр ун-тында, 1989 дан башлап ике дәүләт телендә укыта, ун-тта техник һәм махсус фәннәрне укытуны татар телендә дә алып баруны оештыручы. Техник терминнар һәм а.х.да хезмәт иминлеге буенча русча-татарча сүзлекләр төзүдә катнаша (2000, 2008). Җ. җитәкчелегендә һәм аның катнашы б-н каф. хезмәткәрләре тарафыннан 1989–2008 дә татар һәм рус телләрендә 9 дәреслек, 56 методик ярдәмлек эшләнә. Уйлап табуга 78 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хезмәттәге иминлек. К., 1996; Тракторлар һәм автомобильләр. К., 1999; Пути улучшения работы машинно-тракторного агрегата. К., 1980 (автордаш).

*Әд.:* Г а л и Ә. Көн яктысы. К., 1993.

**ҖОМГА́** (гарәп. جمعة — җыелыш көне), балигълык яшендәге сәламәт мөселманнарның мәчеттә төш вакытында җомга намазы уку һәм *хөтбә* тыңлау өчен җыела торган бәйрәм көне (эш көне булмавы мәҗбүри түгел). Мөселманнарның атнаның аерым бер көнендә җыелулары Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәдинә шәһәрендә яшәгәндә башлана. Өлешчә яһүдиләр биләгән әлеге шәһәрдә җомга (яһүдиләрнең бәйрәм көне шимбәдән алда килүче) базар көн була. Җомга көнне бергә җыелып намаз уку күпчелек мөселманнарга сәүдә мәнфәгатьләрен дини вазифалар б-н бергә аралаштырып башкарырга мөмкинлек бирә. Өйлә вакыты көннең иң эссе чагына туры килсә дә, намаз уку өчен нәкъ менә шул сәгатьләр сайлап алына, чөнки ул вакытта сәүдә итү тәмамлана. Җомга намазын уку өчен түбәндәге шартларның үтәлүе мәҗбүри: 1) мөселманнарныкы дип аталырга хаклы җирдә булу; 2) имамның булуы; 3) имамнан башка янә өч намаз укучы булу; 4) җамигъ мәчет; 5) өйлә вакыты җитү; 6) җомга намазына хәтле хөтбә уку. Җ.да мәчеткә килү һәрвакытта дини-сәяси бурыч булып саналган һәм хөтбәдә исеме аталган хакимгә тәләктәшлек белдерү булып та исәпләнгән. Мөселманнарда җомга намазында катнашуның бурыч саналуы күпсанлы халыкны сыйдырырлык махсус җамигъ мәчетләр барлыкка килүгә китерә һәм мөселман гыйбадәтханәләре архитектурасына йогынты ясый. Хәзерге вакытта күпчелек мөселман илләрендә җомга рәсми рәвештә ял көне булып исәпләнә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ҖОФА́Р** (Desmana moschata), сукыр тычканнар семьялыгыннан имезүче хайван. Идел, Дон һәм Урал елгалары бассейнында гына очрый. ТР терр-ясендә 1983 елга кадәр Идел алдының көньяк өлешендә күренә. Иж елгасы бассейнында сакланып калуы мөмкин. Гәүдәсе тыгыз, 20 *см* га кадәр озынлыкта. Авырлыгы 520 *г* га кадәр. Башы зур, хәрәкәтчән озын борын б-н тәмамлана. Койрыгы 17–20 *см* озынлыкта, ике ягыннан кысылган, кабырчык һәм сирәк төк б-н капланган, койрык төбендә исле майлы матдә бүлеп чыгаручы мускус бизләре урнашкан. Май тиресе юешләнүдән саклый. Аяк бармаклары арасында киң йөзү ярылары бар; арткы аяклары алгыларыннан озынрак һәм көчлерәк. Йон капламы ефәксыман, куе, өске ягы кара-коңгырт, аскы ягы — көмешсыман соры төстә. Яртылаш суда тереклек итә. Өнен, чыгу юлларын су астында калдырып, текә ярларда куак тамырлары астына казый. Әңгер-меңгердә һәм төнлә активлык күрсәтә. Суда яшәүче умырткасызлар, вак балык, үсемлекләр б-н туклана. Ана Җ. елга бер тапкыр 1–5 бала китерә. ТРның Кызыл Китабына кертелгән.

**ҖӨЙЛЕ́ ГӨМБӘЛӘ́Р** (Gyromitra), калаксыманнар семьялыгыннан гөмбәләр ыругы. Өч төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясындагы урманнарда таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре очрый. Гади Җ.г. (G. esculenta) яфраклы һәм ылыслы урманнарда, кисентеләрдә, юл буйларында, яшь утыртмаларда үсә. Апрель–май айларында күренә. Еш очрый, әмма күпләп түгел. Эшләпәсе түгәрәк, эче куыш, тирән җыерчалы, коңгырт-көрән яки саргылт-көрән, диаметры 13 *см* га кадәр. Йомшагы балавызсыман, юка, бик ватылучан. Споралы порошогы ак. Споралары эллипссыман, шома, үсентеләре юк. Сабагы аксыл яки соргылт, куыш. Көчле хуш исле. Гигант Җ.г. (G. gigas) яфраклы һәм ылыслы урманнарда үсә. Апрель–май айларында күренә. Гөмбә зур (5–15 *см* биеклектә, 30 *см* га кадәр киңлектә). Эшләпәсе формасыз, өслеге дулкынсыман җыерчалы, ачык коңгырт төстә, тулысы б-н сабына ябышып үскән. Сабы кыска, юан. Йомшагы ак яки

соргылт, тәме һәм исе юк. Шартлы ашарга яраклы гөмбә саналалар.

**«ҖӨМҖӨМӘ́ СОЛТА́Н»**, 14 йөз татар әдәбияты ядкәре. Авторы *Хисам Кятиб*. Ф.*Гаттарның* шул ук исемдәге фарсы телендә язылган әсәренә назирә дип фаразлана. Бу дини-дидактик эчтәлекле лироэпик әсәрдә сүз төп геройның авыр язмышы, аның ахирәттә күргән михнәтләре турында бара. Хикәяләү чүлдә Гайсә пәйгамбәр б-н очрашып җанланган, аңа үзенең үткән гомере турында сөйләүче баш исеменнән бара. Җөмҗөмә солтан тиңсез байлыкларга, меңләгән коллар һәм кәнизәкләргә ия була. Фәкыйрьләргә һәм дәрвишләргә карата юмартлык күрсәтсә дә, үлгәч җәһәннәмгә эләгә һәм чиксез газаплар кичерә. Бу хәлне «Җ.С.»ның авторы Җөмҗөмә солтанның Аллаһка, аның кодрәтенә ышанмавы б-н аңлата. Ләкин Аллаһ әмере б-н ул үзенең элекке кыяфәтендә яңадан терелә, ислам динен кабул итә һәм калган гомерен намаз укып, тәүбә кылып уздыра. Әсәрнең 30 га якын кульязма нөсхәсе бар, алар Казан, С.-Петербург, Ташкент, Париж архивлары һәм китапханәләрендә саклана. 1872 елдан алып «Җ.С.» Казанда берничә тапкыр басылып чыга. Әсәрне өйрәнүгә Җ.Алмазов, Х.Госман, Г.Таһирҗанов, Х.Курбатов, Р.Исламов һ.б. үз өлешләрен кертә. 1881 елда М.Юмачиков әсәрне татарча варианттан казакъ теленә тәрҗемә итә (барлыгы 10 басмасы чыга).

*Әд.:* Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. К., 1981; Ә х м ә т җ а н о в М. «Җөмҗөмә дастаны» тәрҗемәсе // Әдәби мирас. К., 1996. 3 кит.; Хөсам Кятиб. Җөмҗөмә солтан. К., 2000; Ж у к о в с к и й В. Джумджума-наме. Легенда об Иисусе и черепе в персидском стихотворном сказе Аттара // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 7; И с л а м о в Р.Ф. Письменный памятник татарской литературы XIV в. «Джумджума султан» // Катановские чтения: Сб. статей. К., 1998.

*А.М.Ахунов.*

**ҖӨМЛӘ́**, синтаксисның төп категорияләреннән берсе. Киң мәгънәдә — сөйләм, ишетеп (сөйләмдә) һәм күреп (язуда) кабул итүгә исәпләнгән нәрсәдер турында хәбәр итү. Тар, грамматик мәгънәдә — билгеле бер тел законнарына нигезләнеп ясалган, чынбарлык турында хәбәр итә торган махсус синтаксик конструкция. Татар телендә җөмләгә хәбәрлек һәм модальлек хас, ягъни Ж.дә фикер формалаша, хәбәр ителә һәм сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, сөйләмгә мөнәсәбәте белдерелә. Хәбәрлекнең ничә булуына карап, гади (бер) һәм кушма (ике һәм аннан күбрәк) Ж. дигән төрләргә бүлү кабул ителгән. Чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки инкяр итүгә бәйле рәвештә җөмләләр раслау һәм инкяр җөмләләргә аерыла. Җөмләдә баш кисәкнең бер генә яки ике булуыннан чыгып, аларны бер составлыга һәм ике составлыга бүләләр. Иярчен кисәкләр булу-булмауга карап, Ж.ләрнең җыйнак һәм җәенке төрләре була. Җыйнак Ж.ләр баш кисәкләрдән, ягъни ия б-н хәбәрдән, я бер баш кисәктән генә тора, ә җәенке Ж.ләрдә иярчен кисәкләр дә (тәмамлык, хәл, аергыч) була. Әйтү максатыннан чыгып, Ж.ләр хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру Ж.ләргә бүленә. Барлык семантик (мәгънәви) компонентлары да тулысынча белдерелсә — тулы Ж., өлешчә белдерелсә, ким Ж. дип атала. Ике яки икедән күбрәк хәбәрлеге булган җөмлә кушма Ж. хасил итә. Кушма Ж. составында ничә җөмлә булуга карап, аларны ике компонентлы яки гади кушма Ж.гә, икедән артса — катлаулы кушма Ж.гә бүләләр. Бәйләнеш төренә карап, кушма Ж.ләр тагын тезмә кушма һәм иярченле кушма Ж.ләргә аерыла.

*Әд.:* З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Синтаксис. К., 1974; Татар грамматикасы. К., 1999. Т. 3; С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; С е в о р т я н Э.В. Некоторые вопросы сложноподчинённого предложения в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. М., 1961. Т. 3; С и б а г а т о в Р.Г. Основные признаки предложения. Уфа, 1980.

**ҖӨМЛӘ́ КИСӘКЛӘРЕ́**, *җөмләдә* билгеле бер семантик-синтаксик функция башкаручы сүз һәм сүзтезмәләр. Татар телендә баш (ия һәм хәбәр) һәм иярчен (төгәлләүле, аныклаулы, модаль) Ж.к.ен аерып күрсәтәләр. Бер составлы җөмләләрдә җөмләне оештыручы предикатив (хәбәрлекле) нигез булып бер кисәк тора. Ул баш кисәк дип атала. Ике составлы җөмләләрдә предикатив (хәбәрлекле) нигез ике кисәктән — ия һәм хәбәрдән тора. Җөмләдә баш килештәге сүз б-н бирелеп, бер җөмлә кисәгенә дә буйсынмыйча, хәбәр б-н генә бәйләнеп килгән баш кисәк ия дип атала. Ия башка Ж.к.ен, ш.и. хәбәрне дә үзенә буйсындыра. Ия исем, фигыль, алмашлык, сыйфат, сан, рәвеш һ.б. б-н белдерелә ала. Хәбәр — төрле мәгънә (үтәүче, объект һ.б.) белдерүче ия турында хәбәр итә һәм аңа грамматик буйсына торган баш кисәк. Барлык мөстәкыйль сүз төркемнәре дә җөмләдә хәбәр булып килә ала. Бирелүләренә һәм мәгънәләренә карап, хәбәрләр ике төрле була: исем хәбәр (фигыльдән башка сүз төркеме б-н белдерелә) һәм фигыль хәбәр. Татар әдәби телендә фигыль хәбәрләр киң таралган.

Төгәлләүле мөнәсәбәткә нигезләнеп ясалган икенче дәрәҗәле Ж.к., ягъни төгәлләгечләр (тәмамлык, хәл, аергыч), үзе буйсынган сүз алдыннан килеп, аның мәгънәсенә төрле яклап төгәллек бирә. Җөмләнең процесс белдерүче кисәгенә ияреп, эшнең объектын, үтәүчене, билгеле бер хәл кичерүче әйберне, затны белдерүче иярчен кисәге тәмамлык була. Әгәр тәмамлык процесс турыдан-туры кагыла торган әйберне, төшенчәне белдерсә, туры тәмамлык дип йөртелә. Процесс турыдан-туры кагылмый торган әйберне, затны белдерүче тәмамлык кыек тәмамлык була. Тәмамлык булып исемнәр, алмашлыклар, инфинитив фигыльләр килергә мөмкин. Җөмләнең фигыль, сыйфат, рәвеш һәм процесс белдерүче башка сүзләр б-н бирелгән кисәгенә ияреп, процессның билгесен яисә процессның үтәлү рәвешен, вакытын, урынын, юнәлешен, максатын, сәбәбен, шартын, күләм-дәрәҗәсен белдерә торган кисәкләр хәл дип йөртеләләр. Җөмләнең предмет төшенчәсен атаучы кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә (нәрсәгә) каравын белдерүче кисәк аергыч була. Төрле грамматик формадагы төрле сүз төркеме б-н белдерелә. Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа өстәмә аныклык бирә торган кисәк аныклагыч дип атала. Сөйләүченең чынбарлыкка, сөйләм эчтәлегенә һәм төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләрне модаль кисәкләр дип атыйлар. Сөйләм төбәлгән затны, әйберне белдерүче сүзләр эндәш сүзләр дип аталалар. Кеше исемнәре, фамилия, әтисенең исеме (отчество), гаилә әгъзаларына карата әйтелгән сүзләр, теге яки бу эш төре буенча әйтелгән мөрәҗәгать сүзләре эндәш сүзләр булып килә ала. Кереш сүзләр сөйләмнең эчтәлегенә, төзелешенә, шартларына карата сөйләүченең төрле экспрессив һәм эмоциональ мөнәсәбәтен белдерәләр.

*Әд.:* З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксисы һәм пунктуациясе. К., 1984; Татар грамматикасы. К., 1999. Т. 3; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

**«ҖӨМҺҮРИЯ́Т»** («جمهوريت»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Мөселман Милли Шурасы органы. 1917 елның 14 сентябреннән 1918 нең апреленә кадәр Сембер шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — И.Бикколов, аннан соң Г.Шаһиди, Н.Госманов. «Җ.»тә милли-патриотик юнәлештәге мәкаләләр басыла. Татар халкының милли яңарышын яклап чыга, аның элекке көч-куәте, тарихы турында сөйли.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом): 1905–1925. К., 1926.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ҖӨРИ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 34 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2008 елда 374 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1710–11 еллардан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, курыс төшерү һәм мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ж.дә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1871 дә ачыла), тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 775,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 484, 1897 дә — 782, 1908 дә — 818, 1920 дә — 790, 1926 да — 949, 1949 да — 573, 1958 дә — 671, 1970 тә — 749, 1979 да — 665, 1989 да — 507, 2002 дә — 430 кеше.

**ҖӨРИ́ ДАРУГАСЫ́**, Казан ханлыгында (фаразлауларга караганда, «Чуаш» исеме б-н йөргән), аннары 15–18 йөзләрдә шул ук исемдәге өяздә адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Казаннан көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгышта, Арча даругасыннан төньяктарак һәм Нугай даругасыннан төньяктарак урнашкан. Ж.д.на Чулман елгасы һәм аның кушылдыкларының (Мишә, Минзәлә, Уратма, Ык, Шилнә, Мәләкәс, Чаллы, Биклән, Иж, Танай, Тойма, Бәтке, Әгерҗе һ.б.) ике ягындагы, өлеш-

чә — Нократ елгасы һәм аның бассейнындагы елгаларның (Шушма, Ушман, Норма, Нурминкә, Сикәнәс һ.б.), өлешчә Казансу елгасы һәм аның кушылдыкларының (Нокса, Сола, Ия һ.б.) ике ягындагы җирләр керә. Үзәге — төбәкне Чулманның югары өлеше буйлап көнбатыштан — көнчыгышка, көньяк-көнчыгышка таба кисеп үткән, Казаннан Мамадыш аша Минзәләгә таба (Шигали, Знаменский, Кече Зирекле авыллары аша) дәвам иткән, аннары Оренбург төбәгенә барып җиткән сәүдә-транспорт юлында урнашкан Җөри авылы. Ж.д. волостьларга һәм йөзлекләргә бүленгән. Ж.д. терр-ясендә Шигали, Шәпше, Ястачы, Пермяк, Шиһазда, Олы һәм Кече Ялан, Кишкилде, Коцак Улановский, Черемыш, Яңасала, Зур һәм Кече Клыки, Самосырово (Дүртөйле), Олы Шиһазда, Карамыш Олан, Янгилде, Олы һәм Кече Питрәч, Кадылы, Никольский (Ачы), Норма, Алан (Балыклы), Күкчә, Омар, Поповка, Чаллы, авыллары б-н Мамадыш, авыллары б-н Алабуга, Әгерҗе, Кодаш, Ишери, Сәрби, Әҗмәк, Сәләнгеш, Иске Йорт, Югары һәм Түбән Уратма, Прости, Соболеково, Бәтке, Батрак, Минзәләнең тирә-ягы, Яңа Чишмә, авыллары б-н Иске Чишмә һ.б. торак пунктлар урнашкан. Ж.д. халкын күпчелеге *ясаклылар* булган татарлар, марилар, чуашлар һәм руслар (17 йөздән) тәшкил итә. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан Ж.д.нда патша сарае биләмәләре барлыкка килә, җирбиләүчелекнең йомышлы (рус алпавытлары, йомышлы морзалар, татарлар, яңа чукындырылганнар, йомышлы чит ил кешеләре, 17 йөздән) һәм чиркәү-монастырь формалары оеша башлый. Кешеләр игенчелек (борай, арпа, тары, солы, карабодай, арыш, борчак, киндер һ.б.), терлекчелек, балыкчылык, чолыкчылык һ.б. кәсепчелек (урман кисү һәм агач әзерләү, руда чыгару, игенчелек һәм терлекчелек продуктлары эшкәртү һ.б.) б-н шөгыльләнә. Ж.д. чикләре, төгәл билгеләнмәү сәбәпле, берничә тапкыр яңадан карала. 17 йөз дәвамында авылларны Ж.д. б-н Уфа өязе арасында бүлү очраклары була. 1708 елда Казан губернасын оештырганда традицион катлаулы адм.-терр. бүленеш (юллар һәм йөзлекләр) өязләргә һәм волостьларга беркетелә. Ж.д. — Казан губернасының Казан өязенә, 1719 да — губерналарның Казан һәм Уфа провинцияләренә, 1782 дә Казан, Вятка һәм Уфа губерналарының шул ук исемдәге наместникләклары составына керә. Уфа губернасы составына кергән җирләрнең бер өлеше кемгә буйсынуы 18 йөздә берничә тапкыр кабат карала. 19 йөздә Ж.д.ның терр-ясе Казан губернасының — Казан, Мамадыш, Уфа губернасының — Минзәлә, Уфа, Вятка губернасының Алабуга өязләре арасында бүленә. Эш кәгазьләрендә «Ж.д.» атамасы 19 йөз башына кадәр кулланыла.

*Әд.:* Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов. К., 1978.

*Д.Г.Мостафина.*

**ҖУНУ́СОВ** Мәсгуд Садыйк улы (18.2.1919, Пржевальск ш., хәзерге Кыргызстан Респ-касы — 4.3.2002, Мәскәү), социолог, филос. фән. д-ры (1956), проф. (1974). Кыргыз пед. ин-тын тәмамлый (1940, Фрунзе ш.). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1943 елдан Кыргызстан ССР Хөкүмәте аппаратында инспектор. 1948–62 дә Кыргыз пед. ин-тының филос. каф. мөдире. 1963–68 дә СССР ФА Философия ин-тының тарихи материализм секторы өлкән фәнни хезмәткәре, 1968–72 дә пролетар интернационализм һәм милли мөнәсәбәтләрнең филос. проблемалары секторы мөдире (Мәскәү), бер үк вакытта Мәскәү ун-ты укытучысы. 1972–88 дә СССР ФА Социология ин-тының милли мөнәсәбәтләр секторы мөдире. Хезмәтләре милли мөнәсәбәтләр, милләтләрнең үзбилгеләнүе, суверенлык теориясе мәсьәләләренә карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы теории интернационального воспитания. Таш., 1980; Буржуазный национализм: принципы критики. М., 1986; Национализм в различных измерениях. А.-А., 1990; Суверенитет как социальный феномен. М., 1994; Национализм: Словарь-справ. М., 1998.

*Әд.:* А л е к с е е в П.П.Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**әл-ҖҮВӘЙНИ́** (ألجويني) Әбүл Газали Әбү-әл-Малик ибне Әбү Мөхәммәд (1228–86), фарсы тарихчысы. 1249–53 елларда Монгол империясендә яши. Урта Азия, Иран һәм монгол яулары тарихына багышланган «Тарихе җиһан-гушай» («Җиһангир тарихы») китабы авторы.

**ҖҮКӘТА́У** (рус елъязмаларында Жукотин), урта гасырлардагы (10–15 йөзләр) болгар шәһәре. Чулманның сул ярында, хәзерге Чистай тирәсендә булган. Уңайлы географик урында урнашып, Чулман буйлап үткән сәүдә юлларын һәм аны кичү урыннарын күзәтчелектә тоткан. 10–13 йөзләрдә — Чулман аръягы болгарларының эре сәүдә-икътисад үзәге. 13–14 йөзләрдә *Җүкәтау бәклеге* мәркәзе. Берничә тапкыр (1360, 1366, 1391) рус ушкуйниклары һөҗүменә дучар була, бу исә аның көчсезләнүенә китерә. 15 йөздә шәһәр элеккеге әһәмиятен югалта һәм Казан ханлыгының гади торак пункты булып кала. Җәмәгать биналары, хуҗалык корылмалары хәрабәләре һ.б. сакланган (к. *Җүкәтау комплексы*).

*Әд.:* к. *Җүкәтау бәклеге.*

*И.Л.Измайлов.*

**ҖҮКӘТА́У БӘКЛЕГЕ́**, 13–15 йөзләрдә Көнбатыш Чулман яр буйлары, Актай б-н Шушма елгалары аралыгындагы болгар бәклеге. Үзәге — *Җүкәтау* ш. Идел буе Болгар дәүләте таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Алтын Урдага буйсынулы җирләр хокукына кергән, аның бәге идарә итүгә рөхсәтне Алтын Урда ханлыгыннан алган. Ж.б. халкын болгарлар, фин-угор, кыпчак һәм нугай төркемнәре тәшкил иткән. Халыкның төп шөгыле игенчелек һәм терлекчелек булган. Нократ, Югары Чулман тирәсе, Көньяк Урал яны б-н сәүдә итү зур урын тоткан. 13 йөз — 14 йөзнең беренче яртысында Ж.б. мөстәкыйль сәясәт алып бармый. 1360–80 елларда, Алтын Урда хәлсезләнә бару сәбәпле, бәклек Чулман буйларында үз йогынтыларын көчәйтергә омтылучы рус кенәзләренең басымын тоя башлый. 1360 елда Түбән Новгород ушкуйниклары Җүкәтауны һәм аның тирә-ягын бөлгенлеккә төшерәләр. Ж.б. ярдәм сорап Алтын Урдага мөрәҗәгать итә. Хызыр хан әмереннән соң рус кенәзләре ушкуйникларны һәм алар талап алган байлыкларны кире кайтарып бирәләр. Үзара сугышлар вакытында Алтын Урданың көчсезләнүеннән файдаланып, ушкуйниклар 1366 да Ж.б.нә яңадан һөҗүм ясыйлар. Алтын Урданың көчәюе һәм аның болгар бәклекләрен яклавы нәтиҗәсендә 1380 дә түбән новгородлыларның һөҗүм итүләре кими, әмма 1391 дә, Урта Азия хакиме Аксак Тимернең Алтын Урдага яуларыннан файдаланып, ушкуйниклар Җүкәтауны һәм башка торак пунктларны яңадан талыйлар. Алтын Урданың ярдәме белән, 1409 да Ж.б. флоты ушкуйникларның Анфал Никитин отрядын тар-мар итә. 1411 елда Ж.б. гаскәрләре Лысково янындагы сугышта Мәскәү кенәзлегенә каршы Суздаль кенәзләре ягында була. Үзара даими сугышулар, ушкуйникларның һөҗүмнәре һәм рус кенәзләренең яулары бәклекне бөлгенлеккә төшерә һәм көчсезләндерә. 1430–40 елларда Ж.б. *Казан ханлыгы* составына кушыла.

*Әд.:* П о н о м а р ё в П.А. Данные о городах Камско-Волжской Булгарии. Владения липовогорских князей // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1893. Т. 10, вып. 5; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**ҖҮКӘТА́У КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Чистай р-ның Данауровка авылы янында урнашкан. Ж.к.ның истәлекләре К.С.Мильковичь, И.А.Износков, Н.А.Толмачёв, П.А.Пономарёв, А.С.Башкиров, Н.Ф.Калинин, Ф.Ш.Хуҗин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Җүкәтау шәһәрлеген, 10 йөзгә — 13 йөз башына караган Данауровка һәм Крутая Гора авыллыкларын, кабер ташлары сакланган мөселман зиратын үз эченә ала. Шәһәрлек 6 *га* чамасы мәйдан били, ул 3 рәт ур һәм 2 рәт чокыр б-н ныгытылган. Торак һәм хуҗалык корылмалары калдыклары, ш.и. тимер һәм



Җүкәтау шәһәрлеге. Гомуми күренеше.

бакыр эшкәртү, чүлмәк ясау остаханәләре, хуҗалыкта файдаланылган чокырлар һ.б. табылган. Цилиндр рәвешле һәм җәенке авызлы, чиратлашкан дулкыннар сыман бизәкләр төшерелгән озынча муенлы һәм касә формасындагы балчык савыт-саба, сугыш һәм эш кораллары, керәч һәм пыяла предметлар, ш.у. көмеш һәм алтын бизәнү әйберләре калдыклары табылган (к. *Җүкәтау хәзинәсе*).

*Әд.:* А р т е м ь е в А. Древний Болгарский город Жукотин // Журн. М-ва внутр. дел. 1851. № 1, ч.32;



Н.Г. Җүрәева.

Х л е б н и к о в а Т.А. К истории Жукотина (Джукетау) домонгольской поры (по работам 1970–1972 гг.) // Советская археология. 1975. № 1; Н а б и у л л и н Н.Г. Раскопки в ремесленном районе Джукетау // Проблемы древней и средневековой археологии Волго-Камья. К., 1999.

**ҖҮКӘТА́У ХӘЗИНӘСЕ́**, 14–15 йөзләргә караган болгар зәркәнчелек әйберләре табылдыгы. 1924 елда Чистай р-нының Данауровка авылы янында табыла. Җ.х.нә карата уздырылган фәнни-тикшеренүләрнең нәтиҗәләре 1925 тә В.Ф.Смолин тарафыннан нәшер ителә. 194 берәмлекне, ш.и. буынтыклы алтын беләзекләр, тагылмалар, сөрмә савыты,



Җүкәтау шәһәрлегендә табылган керәч кыйпылчыклары.

Дәһли солтаннары тәңкәләре (1304–41), берничә энҗе бәйләме, брошкаларга куелган пыяла кашларны үз эченә ала. Җ.х.ндәге әйберләр югары проф. дәрәҗәдә эшләнгән: кою һәм чәкәнләү ысуллары, бизәкләү максатында бөтерү һәм бөртекләү алымнары кулланылган. Җ.х.ндәге әйберләр 14 йөзнең 2 нче яртысына — 15 йөз башына караган башка археол. истәлекләрдәге (мәс., Симферополь хәзинәсе) табылдыкларга тартым. Җ.х. әйберләренең күпчелеге 1957 дә юкка чыга (урлана); беләзекләрнең берсе Дәүләт Эрмитажында (С.-Петербург) саклана.

*Әд.:* С м о л и н В.Ф. Клад восточных золотых предметов из болгарского города Джукетау // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1925. № 3; К а л и н и н Н.Ф. Из жизни археологического отдела // Материалы Центр. Музея ТССР. 1930. № 2; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975.
*К.А.Руденко.*

**ҖҮРӘ́ЕВА** Нурдия Гариф кызы (2.6.1937, Казан), хор дирижёры, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1986, 2003), ТРның халык артисты (1995). 1964 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1963–72 елларда Казан музыка уч-щесе укытучысы, 1972 дән Казан консерваториясендә, бер үк вакытта Татар опера һәм балет театрының баш хормейстеры (1981–82, 1985–2006), 2006 дан хормейстеры. ТРның әйдәп баручы дирижёр-хормейстерларының берсе. 1982–85 тә ТАССР мәдәният министры урынбасары, 1987 дән ТР Музыка җәмгыяте идарәсе рәисе, 1992–98 дә ТР Мәдәният фонды рәисе.

**ҖҮЧИ́** (Җуҗи) (1185 — 19.2. яисә 20.3.1227), монгол яубашы, *Җучи олысы* ханы (1224 елдан); *Җучиләрнең* нәсел башы. *Чыңгыз ханның* өлкән улы. 1207–08 дә Көньяк Себергә юнәлдерелгән яуны җитәкли, Тува, Хакасия, Алтайны Монгол империясенә куша. Чыңгыз ханның Кытайга (1211–15), Урта Азиягә (1219–22), *Дәште Кыпчакка* (1223) оештырган яуларында катнаша. Атасыннан биләмә сыйфатында Иртеш елгасыннан Уралга кадәрге һәм аннан да көнбатыштарак яткан җирләрне ала. 1222 дән башлап, *Каракорымнан* бәйсез сәясәт үткәрергә тырыша. Фетнә нәтиҗәсендә үтерелә. Җ. олысы аның улы *Батуга* күчә.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Рашидаддин. Сборник летописей. М.–Л., 1952. Т. 1; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Б а р т о л ь д В.В. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. М., 1963. Т. 1.
*И.Л.Измайлов.*

**ҖҮЧИ́ ОЛЫСЫ́**, к. *Алтын Урда.*

**ҖҮЧИ́ ТӘҢКӘЛӘРЕ́**, к. *Нумизматика.*

**ҖҮЧИЛӘ́Р** (Җүчи нәселе), Чыңгыз ханның олы улы *Җучи* варислары. Алтын Урдада һәм соңрак барлыкка килгән татар ханлыкларында идарә иткән нәсел. Җ. өлкән тармак вәкилләре — Бату, Бәркә ханнар токымы идарә иткән *Ак Урда* һәм кече тармак вәкилләре — Урда Иҗен, Тука-Тимер ханнар варислары идарә иткән *Күк Урда* ханнарына бүленә. 1227 елдан Җүчи олысында Җүчи варислары идарә итә, алар хокукый яктан олысның күмәк хуҗалары булалар. 1260 елларда Җ. *Монгол империясеннән* тулы бәйсезлек алалар. *Алтын Урдада тәхет чуалышлары* елларында Ак Урда Җ.е үзара көрәш-сугышларда кырылып бетә, хакимлек итү Күк Урда Җ.енә күчә. 18 йөзгә кадәр Алтын Урда һәм *татар ханлыкларында* тәхеткә фәкать Җ. нәселе вәкилләре генә утыра алган, шунлыктан хәтта көчле, абруйлы әмирләр дә ханнар исеменнән генә идарә иткән (к. *Нугай бәк, Мамай, Идегәй*). Алтын Урда таркалгач, татар ханлыкларында хакимиятне Җ.нең аерым нәселләре яулап ала.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975.
*И.Л.Измайлов.*

**ҖЫЕЛМАКАНАТЛЫ́ ШӨПШӘЛӘ́Р** (Vespoidea), шөпшәләр ассемьялыгы. Тыныч халәттә канатлары урталай җыелып, бүленгән ике буй рәвешендә гәүдә өстендә ята (исеме шуннан). 4 меңгә якын төре билгеле, киң таралганнар; Россиядә — 350 меңнән артык, Татарстан терр-ясендә ике семьялыктан 20 гә якын төре яши: чын шөпшәләр яки җәмгыяви шөпшәләр (Vespidae) һәм эвмен шөпшәләре (Eumenidae). Чын шөпшәләр семьялыгы вәкилләре (ТРда 7 төр) гаилә булып, кәгазьгә охшаш материалдан (үзагач җепселләрен үзенчәлекле ферментлар б-н эшкәртү нәтиҗәсендә) ясалган ояларда яши. Оялары ике төрле: ачык һәм күзәнәкләре (кәрәзләр) балавызга охшаш материалдан ясалган пластинкаларда урнаша (Polistes ыругы шөпшәләрендә) яки аста чыгу тишеге булган шарсыман формада (мәс., *зур шөпшәләрдә*) була. Кайбер төрләре — клептопаразитлар, иректә яшәүче төрләрнең ояларында җитлегә. Политрофлар личинкаларын вакланган хайван яки үсемлек азыгы б-н туендыралар. Эвмен шөпшәләре ялгыз яшиләр, ояларын төрле куышлыкларда төзиләр яки күзәнәкле ачык балчык оялар ясыйлар. Личинкаларга азыкны параличланган бөҗәкләрдән, еш кына аларның личинкаларыннан (коңгызлар, кисмәннәр, сирәк кенә үрмәкүчләр) әзерлиләр. Татарстанда чын шөпшәләрнең аеруча киң таралганнары: Европа шөпшәсе яки гади зур шөпшә (Vespa crabo) — җәмгыяви Җ.ның иң зурысы; эшче умарталарны юкка чыгарып, умартачылыкка зарар китерергә мөмкин; урта шөпшә (Dolichovespula media) һәм гади шөпшә (Paravespula vulgaris) — аларның гомумбилгеле киң таралган төре.
*Е.А.Сапаев.*

**ҖЫЕ́Н**, билгеле бер социаль-тарихи һәм мәдәни-көнкүреш функцияләрне берләштергән иҗтимагый-терр. берәмлек, ыруглык берлеге; татарларның календарь бәйрәме. Җ., Казан татарларының традицион берләшү формасы буларак (кайбер урыннарда), 1930 еллар башына кадәр яшәп килә (к. *Авыл җәмәгате*). Баштагы феодаль чорда, әле ыруглык җәмгыятенең икътисади нигезе — сөрү җирләренә, болыннар һәм көтүлекләргә һ.б.ларга гомуми милек — сакланганда болгарларда социаль оешманың борынгы төркиләрдән мирас булып калган терр.-округ принцибы гамәлдә була. Берничә (кайчак дистәдән артык) авыл кешеләре Җ.га берләшәләр, патронимия (зур кардәш бергәлекнең архаик формасы) нигезендә билгеле бер Җ. округы төзиләр. Ул төп авыл исеме б-н атап йөртелә, анда иҗтимагый әһәмияткә ия барлык чаралар: җыелышлар, аксакаллар киңәшмәләре, Җ. бәйрәме уздырыла. 3 тән 20 гә кадәрге Җ. округлары үз чиратында кайчандыр кардәш булган халыкларның тагын да зуррак берләшмәләрен оештыралар. Җәмгыятьнең шушы билгеле бер дәрәҗәдә ябык икътисади, мәдәни төркемнәре (ячейка) фәнни әдәбиятта «Җ. округлары конфедерацияләре» буларак мәгълүм. Җыен конфедерацияләре үзәкләренең күпчелеге феодаль округлар үзәкләре б-н тәңгәл булуы ачыкланды. Җ. оешмасының нигезләре — икътисади, канкардәшлек мөнәсәбәтләре, терр. бөтенлек, феодаль таркаулыктан арыну процессында акрынлап, ә Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушканнан соң (1552), кызурак темплар б-н җимерелә бара. Товар-акча мөнәсәбәтләренең бик тиз үсеше нәтиҗәсендә,

Ж. борынгы ыруглык общинасыннан катлаулырак оешмаларга, тора-бара авыл җәмәгатьләренә әверелә. Ж.ның социаль-оештыру функциясе әкренләп югала барса да, аның мәдәни-көнкүреш роле сакланып кына калмый, бәлки тагын да үсә. Ж. округларының һәм конфедерацияләренең төп авыллары ел саен халык бәйрәм итәргә җыелган көннәрдә сәүдә ярминкәсе үзәкләренә әверелә. 19 йөз башына общиналар эчендә туганлык бәйләнешләре генә түгел, милли нигезләр дә какшый: татар халкының традицион бәйрәмендә күрше халыклар — руслар, чуаш, мари, удмуртлар да катнаша башлый. Кайбер урыннарда татарлар көчләп чукындырудан соң да Ж. бәйрәмен уздыруны дәвам итәләр, алай гына да түгел, Ж.ның теге яки бу христиан бәйрәме белән туры килүенә карап, үз тантаналарын шуңа ярашлы итеп атый башлыйлар — Тихон Ж., Троица Ж., Питрау Ж. һ.б. Бу бигрәк тә 14–17 йөзләрдә хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгыш җирләренә, Башкортстанның төньяк-көнбатышына күчеп утырган Казан татарларының соңгы дәверләрдә оешкан Ж.нары өчен хас. Казан татарлары элек-электән тупланып яшәгән төбәкләрдә, мәс., Казан артында, ыруглык-община мөнәсәбәтләре һәм Ж. бәйрәмен уздыруның традицион тәртибе озаграк саклана. Ж. язгы-җәйге чорда, чәчү төгәлләнеп, печән чабу эшләренә кадәрге вакыт аралыгында уздырыла. Бер төбәктә урнашкан авыллар Ж.ны чиратлап бәйрәм иткән. Күрше авыллардан кунаклар чакырып үткәрелгән гаилә тантаналары, яшьләрнең күңел ачулары һәм кичке уеннар 3–5 көнгә сузылган. Авыл ярминкәләрен ачу, туй тантаналары һ.б. әлеге бәйрәмгә туры китереп оештырылган. 1920–30 елларда Ж. акрынлап икенче милли бәйрәмгә — *Сабан туена* кушылып китә.

*Әд.:* Хисамутдинов Г.М. Общественные отношения // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Уразманова Р.К. Праздники // Татары. М., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**«ЖЫЕ́Н»**, 1990 елда оештырылган Татар телен һәм мәдәниятен саклау, үстерү «Жыен» хәйрия фонды нәшрияты. Фәнни китаплар, ш.и. элек тыелган яки библиографик сирәк китапларны (М.Г.Худяковның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» («Очерки по истории Казанского ханства», 1990) монографиясен), К.Ф.Фукс, Һ.Атласи, Т.Дәүләтшин, М.Чанышев, Н.Дәүләт, Х.Фәизханов, И.Гаспринский, Г.Рәхим, Г.Әхмәров, Г.Сәгъди, Ф. һәм К.Туйкиннар, Д.Сиражиев, И.Шакиров һ.б.ның истәлекләре һәм документлары җыентыкларын, хезмәтләрен һәм биографияләрен бастыра. 2003-08 дә Г.Камал исем. Татар дәүләт акад. театры б-н берлектә һәр елда уздырыла торган «Яңа татар пьесасы» конкурсы кысаларында 8 томда иң яхшы 65 пьеса нәшер ителә. Китаплар шәһәр, район һәм авыл китапханәләренә бушлай тапшырыла, үзкыйммәтеннән түбәнрәк бәягә сатыла. Фонд нәшрияты басылган китапларны тәкъдим итүне, авторлар б-н очрашулар, иҗади кичәләр оештыра.

**ЖЫЕРЧАЛЫ́ ГӨМБӘЛӘ́Р** (Morchella), җыерчалылар семьялыгыннан гөмбәләр ыругы. 15 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка, Австралиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре: чын Ж.г. (M. esculenta) һәм конуссыман Ж.г. (M. conica) үсә. Апрель-май айларында, яфраклы, ылыслы һәм катнаш урманнарда, известькә бай уңдырышлы туфракта күренә башлый. Комлы, мүкле урыннарда, урман буйларында, юл читләрендә, кисентеләрдә еш очрый. Чын Ж.г. берәрләп үсә. Эшләпәсе саргылт-көрәннән көрән төскә кадәр, йомыркасыман формада, читләре төбенә ябышкан була. 3–6 *см* биеклектә, бормалы-җыерчалы, күзәнәкчел («җыерчыклы»). Сабы куыш, буразналы. Йомшагы балавызсыман, ак, йомшак, ватылучан, тәме һәм хуш исе бар. Споралы порошогы саргылт. Спoралары эллипссыман, шома. Конуссыман Ж.г. берәрләп яки төркем булып үсә. Чын Ж.г.дән конуссыман Ж.г. озынча эшләпәсе б-н аерыла, биеклеге 5–10 *см*, чәлтәрсыман өслекле. Эшләпәсе зәйтүн төсеннән коңгырт-көрәнгә кадәр. Сабы аксыл, куыш, өнчыл кунык б-н капланган. Пешергәннән соң ашарга яраклы.

**ЖЫЛЫЛЫ́К ТӘЭМИНАТЫ́**, үзәкләштерелгән энергетика системасының торак, җәмәгать һәм сәнәгать биналарының коммуналь-көнкүреш һәм технологик ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җылылык бирүне тәэмин итүче төп өлеше; икътисадның иң зур күләмдә энергия кулланучы, социаль яктан мөһим өлеше. Ж.т. системасы күпкатлы, ул респ-ка, муниципаль һәм хосусый челтәрләрне үз эченә ала; эшчәнлек һәм оештырылу рәвеше буенча төрле терр-яләргә һәм ведомстволарга буйсына, гомуми уртак структур-инвестицион һәм оештыру сәясәте кысаларына кермәгән буыннарга бүленә. Тармакның үзенчәлеге — ел дәвамында кайнар су б-н тәэмин итүдән тыш, сезонлы тәүлеклек эш режимының саклануыннан гыйбарәт. Җылылык чыганакларының һәм аларны йөртүче матдәләрнең (кайнар су, пар) темп-ра режимына тыштагы һаваның темп-расы зур йогынты ясый; көчле салкыннарда ягулык һәм энергия куллану кискен арта. Үзәкләштерелгән Ж.т. системасына җылылык чыганагы һәм челтәре, челтәргә җылылык пунктлары аша тоташтырылган җылылык кулланy җайланмалары керә. Үзәкләштерелгән Ж.т. шартларында җылылык чыганаклары сыйфатында катнаш рәвештә эл. һәм җылылык энергиясе эшләп чыгаручы җылылык-эл. үзәкләре (ТЭЦлар), бары тик җылылык энергиясе генә җитештерүче зур егәрлекле казанлы җайланмалар (котельныйлар), сәнәгатьтә кулланылган җылылык калдыкларын утильләштерүче корылмалар файдаланылырга мөмкин. Шулай ук бер яки берничә бинага хезмәт күрсәтүче җирле Ж.т. системалары да була; аларда җылылык чыганагы буларак төрле егәрлектәге казанлы җайланмалар, мичләр, су җылыту казаннары һәм суҗылыткычлар кулланыла. 2007 елда ТРда 1897 котельный (шуларның 1117 се авыл җирлегендә) эшли, алар елга 10,9 млн. *Гкал* җылылык энергиясе җитештерә. Республикада җитештерелгән җылылыкның 20%ы алар өлешенә туры килә. Үзәкләштерелгән Ж.т.нда җылылык йөртүчеләр — 150 °С га кадәрге кайнарлыктагы су һәм 7–16 атм. басымындагы пар. Җылылык энергиясен төп җитештерүчеләр һәм тапшыручылар: «*Татэнерго*», «Татгазэнерго», «Генерацияләүче компания», «Казан җылылык челтәре компаниясе», «Чаллы җылылык челтәре компаниясе», ТРның авыл җирләрендәге торак-коммуналь хуҗалыгы республика ЖБ — «Татсельжилкомхоз» (48 пр-тие), «Таткоммунэнерго» респ-ка ЖБ (2 пр-тие), «*Урыссу ГРЭСы* территориаль генерацияләүче компания» АҖләре, «Казэнерго» ЖБ муниципаль унитар пр-тиесе. Матди-техник тәэминат һәм хезмәт күрсәтү мәсьәләләре б-н «ИНВЭНТ» компанияләр төркеме» (15 пр-тие), «Камэнергоремонт-холдинг» (10 пр-тие), «Жилэнергосервис» ҖЧҖләре, «Таткоммунпромкомплект», «Таттеплосбыт» (3 төбәк бүлекчәсе), «Татарстан» төбәк диспетчерлык идарәсе» («БЭС системалы операторы» АҖ ф-лы) АҖләре шөгыльләнә.

1920 еллар — 1930 еллар башында ТАССРда ведомстволарга беркетелгән аз куәтле кеч-кенә котельныйлар челтәре файдаланыла. Сәнәгать һәм төзелеш үсеше шартларында җылылык энергиясенә ихтыяҗ арта. Үзәкләштерелгән Ж.т. 1933 тән, Казанның катнаш рәвештә җылылык һәм электр энергиясе җитештерүче 1 нче җылылык-эл. үзәге (ТЭЦ-1) файдалануга тапшырылып, сәнәгать пр-тиеләре пар хәлендәге җылылык энергиясе ала башлагач гамәлгә керә. Шул ук елда Татарстан «Татэнерго» район идарәсе (1931 дә нигезләнә) җирлегендә Казан энергетика комб-ты оештырыла (ул 1943 кә кадәр эшли) һәм шәһәрнең барлык энергетика хуҗалыгы аның карамагына тапшырыла. 1938 дә Казанның 2 нче җылылык-эл. үзәге (ТЭЦ-2) эшли башлый (к. *Казан җылылык-электр үзәкләре*).

1930 елларда Бөгелмә, Алабуга, Чистай шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Юдино бистәсендә һ.б. торак пунктларда энергетика хуҗалыклары оештырыла, төрле егәрлекле котельныйлар төзелә. Респ-када җылылык энергиясе җитештерү елдан-ел арта бара һәм 1936 да аның гомуми күләме 230 мең *Мкал*га җитә (1933 тә 58,4 мең *Мкал*дан артмый). Эл. станцияләрендә ягулык сыйфатында януучан сланец, нефть, мазут, ташкүмер, утын, агач калдыклары һ.б. кулланыла.

Бөек Ватан сугышы чорында сыек ягулыкта (нефть, мазут) эшләүче җылылык эл. станцияләре вакытлыча туктатыла. 1944 тә эл. һәм җылылык энергиясе эшләп чыгаручы Урыссу ГРЭСы файдалануга тапшырыла (2008 дә анда 145,6 мең *Гкал* энергия җитештерелә). 1956 да С.П.Горбунов исем. Казан авиация ЖБ җылылык челтәрләре җирлегендә 130 *Гкал/сәг.* егәрлекле Казан җылылык челтәрләренә нигез салына, 1965 тә Казан берләштерелгән котельныйлар һәм җылылык челтәрләре пр-тиесе оештырыла (1981 дән — «Казан җылылык челтәрләре предприятиесе» МУП; 2003 тән «Казэнерго» ЖБ МУП). Төрле елларда пр-тие составына Түбән Кама, Чаллы шәһәрләренең җылылык челтәрләре, Казан р-ннарында урнаш-

кан «Горки-2», «Азино», «Савиново» котельныйлары керә.

1960–70 елларда *Зәй ГРЭСы*, *Түбән Кама җылылык-электр үзәге*, Казандагы 3 нче җылылык-эл. үзәге (ТЭЦ-3), *Чаллы җылылык-электр үзәге* файдалануга тапшырыла. 1966–70 тә респ-ка ТЭЦларының егәрлеге 1,4 тапкыр үсә, җитештерелгән җылылык энергиясендә аларның өлеше 50% ка җитә, аны кулланучыларга тапшыру күләме ике тапкыр арта һәм 9,6 млн. *Гкал* тәшкил итә; бу энергиянең 70% ы торак-коммуналь өлкәдә кулланыла, нәтиҗәдә аз егәрлекле котельныйлар (Казанда — 169 дан 60) ябыла. Авыл җирләрендә Ж.т. б-н «Татсельжилкомхоз» АҖ (1970 тә оештырыла) шөгыльләнә, аның карамагында 700 мең *Гкал* җылылык энергиясе җитештерүче 732 котельныйны берләштергән 48 муниципаль коммуналь пр-тие исәпләнә (2007). Энергия һәм җылылык җитештерүче 18 пр-тиенең эшчәнлеген үзара яраклаштыру өчен 1972 дә Респ-ка «Таткоммунэнерго» энергетика идарәсе (хәзер — Республика «Таткоммунэнерго» ЖБ» АҖ) төзелә, аның составына Мамадыш һәм Нурлат җылылык челтәрләре керә; 2007 дә пр-тие 155 мең *Гкал* җылылык энергиясе озата. 1970 елларның 2 нче яртысыннан респ-каның энергетика системасы газ ягулыгына күчерелә. 1996 да 110 *Гкал/сәг.* егәрлекле Алабуга ТЭЦы файдалануга тапшырыла. 2000 дә респ-када җылылык энергиясе җитештерү 46,7 млн. *Гкал* тәшкил итә, бу 1965 елгы күрсәткечтән 9,5 тапкырга күбрәк.

Икътисад һәм төзелеш үсеше җылылык энергиясен кулланучыларга җибәрүнең күләме артуга, газ ягулыгына һәм эл. энергиясенә бәяләр күтәрелүгә бәйле рәвештә аның үзкыйммәте һәм тарифлары үсүгә китерә. Җылылык трассаларының мораль һәм физик яктан тузуы, челтәрләрдәге җылылык үткәргечләрнең тиешенчә изоляцияләнмәве, җылылык җитештерүнең, аны куллануны исәпкә алуның һәм көйләүнең җитәрлек дәрәҗәдә яңартылмавы һәм автоматлаштырылмавы җылылык энергиясен күпләп югалтуга (12–21%) китерә. Ел саен котельныйлар, җылылык челтәрләре һәм бойлер биналары төзекләндерелә. Энергия җитештерүдә зур күләмдә ягулык, су, химик реагентлар һ.б. ресурслар кулланыла; җитештерү калдыкларын утильләштерү өчен әйләнә-тирә мохитне пычратмауга яки, зыян килгән очракта, аны тазартырга юнәлдерелгән тирәлекне саклау программалары эшләнә. Мәс., «Татэнерго» АҖ холдинг компаниясе уздырган чаралар нәтиҗәсендә 1998–2007 дә һаваны пычратучы матдәләрнең атмосферага чыгарылуы 2 тапкыр киметелә, калдыкларның 90% тан артыгы икенче мәртәбә файдаланыла яки зарарсызландырыла, чүплекләргә һәм полигоннарга җибәрелүче калдыкларның күләме 3 тапкыр азая, су куллану — 40% ка, су бүлү 30% ка кими.

Үзәкләштерелгән Ж.т. елларында тармакта фәнни-техник алгарыш казанышлары гамәлгә кертелә, реконструкция һәм модернизация уздырыла, ресурсларны азрак сарыф итә торган технологияләр үзләштерелә. 1970 еллардан Казанда җылылык челтәрләрен эл. коррозиясеннән саклау өчен катодлы алым кулланыла башлый, нәтиҗәдә торбалы үткәргечләрдән файдалану вакыты 2 тапкыр озая; 50 су җылыту казанына АПК һәм ПМАВ маркалы автоматик корылмалар куела; җылылык челтәрләре пр-тиеләрендә торбалы үткәргечләрне кислород коррозиясеннән саклау өчен деаэрацион (судан газларны бүлеп чыгаручы) җайланмалар урнаштырыла. Җиргә җибәрелгән токлар тудыра торган коррозиягә каршы торбаларны электрохимик саклау җайланмалары киң кулланыла. 1980 елларда торбалар өслеген пыялалы эмаль катламы б-н каплату технологиясе үзләштерелә, нәтиҗәдә торбаларның файдалану вакыты 3–5 елдан 15–20 елга кадәр арта. Казанның 2 нче җылылык-электр үзәгендә, Зәй ГРЭСында, Уруссу ГРЭСында, 2000 елларда Чаллы җылылык-эл. үзәгендә, Казанның 1 һәм 2 нче җылылык-эл. үзәкләрендә, ш.у. аларның җылылык челтәрләрендә реконструкция уздырыла. Идел буе төбәгендә беренчеләрдән булып Казанның 1 нче җылылык-эл. үзәгендә һәм Түбән Кама җылылык-эл. үзәгендә пар турбиналы җайланмалар газ турбиналарына алмаштырыла, заманча пар-газ технологияләре гамәлгә керә. Ж.т.нда Даниянең «Альстом» фирмасы эшләп чыгарган һәм файдалану вакыты 50 елгача исәпләнгән, Россия һәм Канаданың уртак «Мосфлоулайн» компаниясе (Мәскәү) җитештергән күбекле полиуретан һәм полиэтилен сүрү б-н төрелгән торбалар, ш.у. тиз арада зарарлану урынын ачыклау мөмкинлеге бирә торган оператив дистацион күзәтчелек системасы б-н җиһазландырылган һәм тышкы тәэсирләрдән саклаучы махсус катлам б-н капланган 125–1200 *мм* диаметрлы пластмасса торбалар кулланыла башлый. Андый трассаларда җылылык югалту 2–3% тан артмый. Кайнар су б-н тәэмин итүдә тегелгән полиэтиленнан эшләнгән «изопрофлекс» тибындагы торбалар файдаланыла. Нәтиҗәдә Ж.т.ның ышанычлылыгы һәм экономиялелеге арта. Ж.т.н алга таба үзәкләштерү җылылык челтәрләрен куәтле ТЭСларга һәм эре котельныйларга тоташтыру юлы б-н бара. Казандагы җылылык-эл. үзәкләренең өчесе дә, ш.у. шәһәр р-ннарындагы эре котельныйлар яңа җылылык магистральләре бердәм системасы бөҗра итеп үзара тоташтырылган. Нәтиҗәдә җылылык хакы 2 тапкырга диярлек арзаная, җәйге чорда төзекләндерү эшләренә бәйле өзеклекләр кими. Казанда һәм Чаллыдагы магистраль үткәргеч торбаларда 638 җылылык энергиясен исәпкә алу узелы урнаштырыла; әлеге шәһәрләрнең 4 җылылык-электр үзәгендә технол. процесслар б-н автоматлаштырылган идарә итү системалары (АСУ-ТП), автоматлаштырылган җылылык пунктлары сафка баса, бу исә җылылык энергиясен кирәксезгә сарыф итүне 20% ка кадәр киметә. «2000–2005 елларда Татарстан Республикасында энергиядән сакчыл файдалану» программасын үтәү нәтиҗәсендә, эл. энергиясен экономияләү б-н бергә, 1000 сумлык тулай региональ продукция (ТРП) җитештерүгә исәпләгәндә, җылылык энергиясен куллану кими һәм 2001 дәге 0,176 *Гкал* урынына 2005 тә 0,147 *Гкал* тәшкил итә. «2006–2010 елларда Татарстан Республикасында энергия һәм ресурслар нәтиҗәлелеге» программасы тормышка ашырыла. Энергетика системасы хезмәткәрләре һәм, гомумән, респ-ка халкы өчен мөһим социаль проектлар гамәлгә кертелә. «Татэнерго» холдинг компаниясе яңа куәтләрне сафка бастыру, гамәлдәге пр-тиеләрне реконструкцияләү һәм модернизацияләү планлаштырылган, 2030 елга кадәр исәпләнгән инвестицион программаны тормышка ашыра.

Татарстан — 1990–2000 елларда РФдә беренчеләрдән булып энергетика системасын тамырдан үзгәрткән, ягъни ул тармактагы пр-тиеләре акционерлаштырылган, базар икътисады мөнәсәбәтләренә күчкән төбәкләрнең берсе. «Татэнерго» АҖне үзгәртеп кору нәтиҗәсендә эшмәкәрлекнең аерым төрләре б-н шөгыльләнүче мөстәкыйль структуралар оештырыла. Шуларның берсе — РФдә иң эреләрдән саналучы «Генерацияләүче компания» АҖ (2007 дә төзелә). Аның составына Казанның 3 җылылык-электр үзәге, ш.у. Чаллы, Түбән Кама, Алабуга җылылык-электр үзәкләре, Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы, Казан р-ннарының котельныйлары керә. Эл. станцияләренең гомуми җылылык куәте — 15 мең *Гкал/сәг.*, эшләүчеләр саны — 18 мең кеше. Елга 23 млрд. *кВт/сәг.* эл. һәм 30 млн. *Гкал* җылылык энергиясе (респ-када җитештерелгән җылылык энергиясенең 54%ы) эшләп чыгарыла.

2008 дә ТРда 52,6 млн. *Гкал* җылылык энергиясе җитештерелә, бу 2000 елдагы күләмнән 12,9% ка күбрәк. Җылылык энергиясен файдаланучылар: сәнәгать пр-тиеләре (65,9%), халык (18,9%), күпләп кулланучылар һәм яңадан сатучылар (8,1%), бюджет оешмалары (3,8%), теплица-парник хуҗалыклары, кошчылык ф-калары, коммуналь хуҗалык (3,3%). Тармак өчен кадрлар Казан энергетика ун-тында, Казан энергетика техникумында, «Энергетик» Идел буе кадрлар әзерләү төбәк үзәге»ндә (Казан) әзерләнә.

*Әд.:* М у л л и н а Л.Б., Т ы р и н о в В.В. Казанское предприятие тепловых сетей. К., 1989; История энергетики Татарстана (1920–2000 гг.): Док-ты и материалы. К., 2001; М а р т ы н о в Е.В. База данных по системе теплоснабжения Республики Татарстан // Ресурсоэффективность в Республике Татарстан. 2004. № 2; Тематическая подборка к 75-летию энергосистемы Татарстана // Энергетика Татарстана. 2006. № 4.

*М.Я.Гаитов.*

# З

**«ЗА ЗЕ́МЛЮ И ВО́ЛЮ»** («Җир һәм ирек өчен»), иҗтимагый-сәяси газета. «*Социалист-революционер*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның 27 сентябреннән 1918 нең 19 июленә кадәр Казанда рус телендә атнага 3 тапкыр, 1918 дә көн саен нәшер ителә, барлыгы 180 саны чыга. Сул эсерлар партиясенең (интернационалистлар) Казан губерна ком-ты, крәстиян депутатлары советының Казан шәһәре башкарма ком-ты һәм эсерлар партиясенең хәрби оешмалары органы. «Үз хокукыңны син көрәштә яуларсың!» дигән девиз б-н чыгарыла. Мөхәррирләре — Л.С.Венецианов, К.Ю.Шнуровский. Редколлегия составына А.Л.*Колегаев* керә. Сул эсерлар партиясе ҮК әгъзаларының (ш.и. Казан авторлары Г.Верховцев, Т.Емельянов, А.Иванов, Я.Кострин, А.Нестеров, К.Слепов, Н.Троицкий, А.Устинов, К.Шнуровский) мәкаләләре, нотыклары, Казан губернасы крәстиян съездлары, Бөтенроссия крәстиян депутатлары советлары съездлары, эшче һәм солдат депутатлары советлары, сул эсерлар партиясе съездлары һәм конференцияләренең беркетмәләре, карарлары һ.б. басыла. Башка партияләрнең программалары анализлана. Уң эсерларның буржуазия һәм алпавытлар б-н килешүчәнлек сәясәте тәнкыйтьләнә. Сул эсерлар б-н большевиклар сәясәтендәге аерымлыкларга зур игътибар бирелә. Материалларның бер өлеше Учредительләр җыенын әзерләүгә багышлана. Крәстиян депутатлары советы һәм сул эсерлар партиясе исемлекләре өчен тавыш бирергә чакырып агитация һәм пропаганда алып барыла, сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүматлар басыла. Соңрак газета Учредительләр җыенын тарату турындагы фикерне яклап чыга. 1918 нең башыннан урыннарда хакимиятнең советлар кулына күчү этапларын яктырта, дәүләтнең авылларда хуҗалык эшләренә тыкшынуына каршы протест белдерә, земстволарны һәм җир ком-тларын калдыруны яклый. Россиядә рев-циягә кадәрге земство оешмаларының яңа җирле үзидарә органнарыннан аерымлыгын аңлатып, шәһәр һәм земство үзидарә органнарын бетерүгә, аларның вазифаларын советларга тапшыруга каршы чыга. 1918 нең җәенә газетаның большевикларга мөнәсәбәте үзгәрә. 1918 дәге Брест солыхы шартлары большевикларның рус һәм чит ил буржуазиясенә ташламалар ясавы нәтиҗәсе дип бәяләнә. «Большевиклар крәстиян һәм эшче депутатлары советлары хакимиятенә каршы көрәш алып баралар» дип билгеләнә. Большевикларның сул эсерларны законнан тыш дип белдерүеннән соң, газета чыгудан туктатыла. «За землю и волю, за рабочую долю» һәм яңадан «За землю и волю» (1 нче саны 1918 елның 1 августында чыга) исемендә чыгарырга тырышулар гамәлгә ашмый. Контрреволюция һәм саботажга каршы көрәшкә нигезләнеп, Гадәттән тыш комиссия карары б-н икесе дә ябыла.

*Г.Р.Заманова, Т.М.Насыйров.*

**«ЗА КУЛЬТУ́РНУЮ РЕВОЛЮ́ЦИЮ»** («Культура революциясе өчен»), иҗтимагый-пед. журнал. ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1929–32 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. 1929–30 да «Просвещение и жизнь» («Мәгариф һәм тормыш») исемендә чыга. 1931 дә исеме үзгәрә һәм айлыктан 20 көнгә бер чыга торган, төбәктә мәгариф эше б-н җитәкчелек итүче, барлык төр мәдәни-агарту хезмәткәрләре өчен методик һәм гамәли кулланма булырлык басмага әверелә. Төрле елларда мөхәррирләре А.М.Колосов, Б.П.Рождественский, П.А.Казаков була. ТАССР Мәгариф комис-ты хезмәткәрләре, галимнәр В.М.Горохов, И.Ш.Рәхмәтуллин һ.б. әйдәп баручы педагог һәм методистларның мәкаләләре басыла. Төп бүлекләре: «Гомуми бүлек», «Политехник мәктәп өчен», «Педагогик тәҗрибә», «Коммунистик тәрбия», «Урыннардан хәбәрләр», «Марксистик педагогика мәсьәләләре», «Программа-методика», «Хроника һәм информация», «Библиография». Журнал педагоглар алдына рев-циягә кадәрге авыр иске мирастан котылу һәм марксистик теория б-н коралланy бурычын куя, җәмәгатьчелекне педагогиканың теоретик-гамәли мәсьәләләрен чишүгә җәлеп итәргә, мәгариф хезмәткәрләрен культура рев-циясе процессына тартырга тырыша. Журналда ТАССР Мәгариф комис-ты карарлары һәм боерыклары, пед. җәмәгатьчелекнең киңәшмә һәм утырышлары материаллары басыла, халык мәгарифе системасындагы реформалар турында бәхәсләр алып барыла. Редакция ш.у. мәгариф хезмәткәрләренең көнкүреш һәм матди-хокукый хәлләрен, дингә каршы пропаганда, төбәкне өйрәнү һәм мәктәптә пионерлар б-н эшләү, балаларның ялын оештыру һ.б. мәсьәләләрне яктырта.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЗАБОЛО́ТНОВ** Пётр Павлович (17.12.1858, Казан губ., Козьмодемьянск өязе Покров а. — 26.10.1935, Саратов ш.), патологоанатом, микробиолог, мед. д-ры (1900). Н.М.*Любимов* шәкерте. 1884 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Казан губернасының Чабаксар өязе мед. учреждениеләрендә эшли. 1894–1911 елларда Казан ун-тының патологик анатомия кафедрасында: прозектор ярдәмчесе, прозектор, ассистент, приват-доцент; бер үк вакытта 1900 дән бактериология ин-тында. 1911 дән Саратов ун-тында: экстраординар профессор, 1913 тән ординатура профессоры, 1914–18 дә ректор, патологик анатомия кафедрасын оештыручы, ун-т каршындагы «Эчке медицина һәм патология җәмгыяте» («Общество внутренней медицины и патологии») җитәкчесе. И.И.Мечников җитәкчелегендә микробиология һәм иммунитет проблемаларын өйрәнә (Париж). 1910 да чума эпидемиясен (Саратов ш.) бетерүдә катнаша. Хезмәтләре корсак тифы һәм дифтерит вакытында нерв күзәнәкләре патологиясенә карый. З. тарафыннан бөер өсте бизе тибындагы яман шешләр, борындагы глиомалар, плазматик күзәнәкләрнең миеломалары өйрәнелә.

Х е з м.: Случай первичного рака лёгкого // Казан. мед. журн. 1901. № 8; Современное состояние учения о чуме // Казан. мед. журн. 1911. № 2.

*Әд.:* А н т о н о в А.М. Профессор П.П.Заболотнов // Архив патологии. 1959. Т. 21; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета: 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ЗАБО́РНАЯ ПОЛЯ́НА** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 60 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2008 елда 41 кеше (чуашлар, татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 20 йөз башында нигез салына. Авыл башта Заборная Поляна артеле дип атала. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1920 дә — 96, 1926 да — 70, 1938 дә — 87, 1949 да — 194, 1958 дә — 161, 1970 тә — 127, 1979 да — 102, 1989 да — 64, 2002 дә — 50 кеше.

**ЗАБО́ТИН** Владислав Иванович (2.11.1945, Казан), математик, техник фән. д-ры (2000). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан техник ун-тында эшли, 1995 тән гамәли матем. һәм информатика каф. профессоры. Хезмәтләре экстремаль мәсьәләләрнең гомуми теориясенә, Җирнең ясалма иярченнәре системасының баллистик структураларына карый. Аның тарафыннан өлешчә тәртипкә салынган фәзада матем. программалаштырыла һәм оптималь идарә ителә торган мәсьәләләрдә экстремумның кирәкле шартлары алына, кабарынкылык алды күплекләре, чагылдырулары төшенчәләре гамәлгә кертелә, аларның үзлекләре һәм экстремаль мәсьәләләр теориясендә кулланылышлары тикшерелә. З. төрле матем. модельләрне өйрәнә, Җирне күп тапкырлар күзәтү системаларын анализлау һәм синтезлау алгоритмнарын тәкъдим итә, Җирне иярченнәр системалары б-н каплап алуны проектлаштыру мәсьәләләрен һәм төрле тип орбиталарда урнаштырылган күп каналлы глобаль элемтә системаларын анализлый.

Х е з м.: Модели спутниковых систем глобальной связи на эллиптических орбитах // Исслед. Земли из космоса. 1994. № 5; Достаточные условия существования спутниковых систем многоканальной глобальной связи // Космические иссл. 2000. Т. 38, № 1.

**ЗАБО́ТИН** Иван Петрович (9.10.1908, С.-Петербург — 17.3.1955, Казан), язучы. Казанда 1919 елдан. Казан урман-техника ин-тын тәмамлый (1930). Күперләр, плотиналар, сәнәгать объектлары төзелешендә эшли, хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советында төзелеш бүлеген җитәкли, Бөек Ватан сугышы елларында оборона пр-тиеләрендә хезмәт итә. 1947–55 елларда Татарстан Язучылары берлегендә рус язучылары секциясен җитәкли. 1950 елларда беренче әсәрләре басылып чыга башлый. Балалар өчен язылган «Безнең балалар бакчасы» («Наш детский сад», 1952), «Бөркетләр турында кыйсса» («Сказание об орлах», 1953), «Тиздән мәктәпкә» («Скоро в школу», 1958) хикәяләр җыентыклары авторы. «Лобачевский» (1953) романы б-н автор укучыга таныла. М.Гафуриның «Без бәләкәй чакларда» («В далёком детстве», 1948) хикәяләр җыентыгын, А.Әхмәтнең «Үги кыз» («Падчерица», 1948) һәм «Серләр» («Тайны», 1948) пьесаларын, М.Әмирнең «Миңлекамал» («Минникамал») пьесасын, Ш.Камалның «Хикәяләр» («Рассказы», 1952) җыентыгын, «Акчарлаклар» («Чайки», 1952) повестен һ.б. рус теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ЗАБО́ТИН** Ярослав Иванович (20.11.1930, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1975), проф. (1978), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). 1953 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1960–66 да Хисаплау үзәге, 1978 дән икътисади кибернетика каф. мөдире, бер үк вакытта проректор (1980–85), хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты деканы (1988–93). Хезмәтләре матем., сызыкча, уйланма кабарынкы программалаштыруга карый. Нәсызыкча программалаштыру теориясе һәм санлы методлары, уйланма кабарынкы, дифференциалланмый торган функционалларны киметү ысуллары өстендә эшли. З. икътисадта, җитештерү б-н идарә итүдә, икътисади географиядә матем. ысуллар тәкъдим итә. «*Известия высших учебных заведений. Математика*» ж-лының баш мөхәррире (1991 елдан). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Математико-географические методы исследования городских поселений. К., 1970 (автордаш); Об одной модификации метода штрафных оценок для задач нелинейного программирования // Изв. вузов. Математика. 2000. № 12.

**ЗАБУГО́РОВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 7 *км* көньяктарак, Зәй елгасы чыганагы (Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 222 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 1267 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 305, 1889 да — 575, 1897 дә — 654, 1920 дә — 921, 1926 да — 825, 1938 дә — 733, 1949 да — 582, 1958 дә — 489, 1970 тә — 490, 1979 да — 423, 1989 да — 266, 2002 дә — 231 кеше.

**ЗА́БУСОВ** Георгий Ипполитович (18.10.1899, Казан — 29.3.1981, шунда ук), гистолог, мед. фән. д-ры (1945), проф. (1945). А.Н.*Миславский* шәкерте. 1926 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1930 дан Казан мед. ин-тында, гистология каф. мөдире (1959–71), бер үк вакытта педиатрия ф-ты деканы (1946–56). Хезмәтләре нерв системасының вегетатив бүлеге төзелешенә, эчке органнар иннервациясенә карый. Беренчеләрдән булып фәнни тикшеренүләрдә яңа гистохимик һәм микроскопик ысуллар — фаза-контрастлы һәм флуоресцент микроскопия куллана. З., колак яны бизе каналын бәйләгәч, аның төзелеше үзгәрүен, үпкәләр иннервациясен өйрәнә, сизүчән нерв очлыкларының яңа классификациясен тәкъдим итә.

Х е з м.: Опыт экспериментально-морфологического анализа иннервации лёгких млекопитающих. К., 1945; Анализ структурной и цитохимической организации механорецепторов // Тр. Казан. мед. ин-та. 1970. Т. 32.

*Әд.:* Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989.

**ЗА́БУСОВ** Ипполит Петрович (30.1.1872, С.-Петербург — 4.7.1917, Казан), зоолог, зоология д-ры (1911). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1894), шунда ук эшли, чагыштырма анатомия һәм физиология каф. проф. (1917). Бер үк вакытта (1898 дән) Казан реаль уч-щесендә табигать тарихын укыта. Хезмәтләре умырткасызлар — планарияләр һәм турбелляриияләр морфологиясе һәм систематикасына карый. Онега күле, Ак һәм Кара диңгезләрнең төкле суалчаннарын (Turbellaria), Байкал күленең планария фаунасын өйрәнә. М.М.*Усов* б-н бергәләп «Казан тирәсендәге сулыкларда тереклек итүче туры эчәкле турбелляриияләрне тасвирлау» («Описание прямокишечных турбеллярий, водившихся в водах окрестностей г.Казани», 1894) хезмәтен яза. Бу хезмәт ун-тның алтын медаленә лаек була. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Очерк фауны прямокишечных турбеллярий окрестностей г.Казани. К., 1895; Наблюдения над ресничными червями (Turbellaria) Соловецких островов. К., 1900; Заметки по морфологии и систематике Tricladida. К., 1901; Исследование иннервации летательной перепонки летучих мышей. К., 1910; Исследования по морфологии и систематике планарий озера Байкала. К., 1911.

**ЗАВА́ДСКИЙ** Владимир Васильевич (12.4.1938, Севастополь ш.) машиналар технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. канд-ты (1970), проф. (1988). 1960 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлый. 1960–86 елларда В.И.Ленин исем. Уфа приборлар төзү з-дында: цехның техник бюро башлыгы, магнитлы һәм сыгылмалы элементларның махсус конструкторлык технол. бюросы җитәкчесе, бер үк вакытта 1971–86 да Уфа авиация ин-тында. 1986–94 тә Караганда политехник ин-тының Петропавловск ф-лында: машиналар төзү технологиясе каф. мөдире (1987 дән), механика-технол. ф-ты деканы (1991 дән). 1994 тән Кама политехник ин-тында (Чаллы ш.), икътисад һәм менеджмент каф. мөдире (1998 дән). Хезмәтләре машиналар һәм приборлар төзү технологиясенә карый. З.ның җитештерүне заманча интеграль автоматлаштыруга караган эшләнмәләре Петропавловск авыр машиналар төзү з-дында гамәлгә кертелә (1989). Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнительный анализ методов расчёта температурных погрешностей магнитно-твёрдых материалов // Технология авиационного приборо-агрегатостроения. 1981. № 4; Системы современных технологий. Наб. Челны, 1996; Экономика недвижимости. М., 2000 (автордаш); Технологические основы экономического развития. Наб. Челны. 2004.

**ЗАВА́ДСКИЙ** Владимир Ромулович (7.7.1846, Таврия губ. Тендра утравы — 21.5.1913, Ялта ш.), хокук белгече, сенатор (1901), тайный советник (1901). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1871). 1872–73 елларда Лаеш өязендә мәхкәмә тикшерүчесе. 1873–75 тә Сембер округ мәхкәмәсе прокуроры урынбасары, 1875 тән Самара округ мәхкәмәсе прокуроры урынбасары, 1879–83 тә прокуроры. 1883–94 тә Казан мәхкәмә палатасы прокуроры урынбасары, 1899–1901 дә прокуроры. 1894–99 да Казан округ мәхкәмәсе рәисе. 1901–04 тә Иркутск, 1904–06 да Тифлис мәхкәмә палаталарының өлкән рәисе. 1906–10 елларда Сенатның гражданнар кассациясе департаментында эшли. Мәкаләләре Россиядә мәхкәмә төзелеше һәм процессына карый.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗАВА́ДСКИЙ** Игорь Владимирович (25.1.1875, Сембер ш. — 27.12.1944, Ростов-Дон ш.), терапевт, мед. д-ры (1908). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1899). 1900–03 елларда Новороссийск ун-тының Терапия клиникасы ординаторы. 1904 елдан хәрби табиб. 1907–13 тә С.-Петербург мед. учреждениеләрендә: 1907 дән Эксперим. мед. ин-тында, 1909 дан Петропавловск хастаханәсендә, 1912 дән Женева мед. ин-тында. 1913 тән Казан ун-тында, профессор, мед. ф-тының табиблек диагностикасы каф. мөдире. 1916–31 дә Варшава ун-тының госпиталь терапиясе кафедрасында. 1935 тән Ростов-Дон шәһәрендә Тропик авырулар клиникасы мөдире. З. Төньяк Кавказда тимгелле тиф (1918–19) һәм бизгәк (1920) эпидемияләре б-н көрәшүдә катнаша. Хезмәтләре организмның рефлектор эшчәнлеге мәсьәләләренә (шартлы рефлексларны тоткарлау һәм яңадан торгызу) карый. Беренчеләрдән булып бруцеллёз авыруын, аның таралу юлларын һәм авыруга каршы көрәш ысулларын өйрәнә.

Х е з м.: К вопросу о судьбе салициловой кислоты в животном организме. СПб., 1909; Клиника, диагностика и лечение малярии. М., 1948.

**ЗАВАЛИ́ШИН** Фёдор Семенович (19.2.1915, Тула өлкәсенең хәзерге Ефремовск р-ны Зур Корчажка а. — 15.1.1985, Воронеж ш.), механика гыйлеме белгече, техник фән д-ры (1966), проф. (1966), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981). 1939 елда Воронеж а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бийск крае механиклар мәктәбендә эшли. 1946–54 елларда Үзәк кара туфраклы җирләр полосасы а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының механикалаштыру бүлеге мөдире (Воронеж ш.). 1954–85 тә Казан (1966 га кадәр), Воронеж а.х. ин-тларында машина-трактор паркын файдалану һәм ремонтлау кафедралары мөдире. Хезмәтләре а.х.н механикалаштыруга, үсемлекчелеккә һәм а.х. операцияләрен һәм процессларын проектлаштыруга карый. Органик ашламалар керткәндә транспорт-тарату процессларын, ш.у. бөртекле культураларны җыйганда транспорт-җыю процессларын тикшерә. Уйлап табуга 10 таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы расчёта механизированных процессов в растениеводстве. М., 1973; Методы исследований по механизации сельскохозяйственного производства. М. 1982 (автордаш).

**ЗАВАЛИ́ШИННАР**, Казан губернасындагы дворяннар нәселе. **Иван Максимович** (18 йөз), патша сарае советнигы. 1770 еллардагы Казан алпавытлары исемлегендә Нугай даругасы Балымер авылында утар һәм 10 крепостной крәстиян хуҗасы буларак теркәлә. Аның улы **Иринарх Иванович** (21.6.1763, Казан — 17.8.1821, Сембер ш.), Казан алпавыты, генерал-майор, А.В.Суворовның көрәштәше, Әстерхан полкы һәм казак гаскәрләре шефы. И.П.Тургеневның Дуслык гыйльми җәмгыятенә керә, әсәрләре «Санкт-Петербургский журнал»да басыла. Россиянең географиясе турындагы «Җирне ... кыскача тасвирлау» («Сокращенное ... землеописание», 1793) китабы, рус батырларының каһарманлыкларына һәм Суворовның Польшага яуларына багышланган «Героида» (1793) һәм «Сувороида» (1796) поэмалары авторы. Аның икенче хатыны — Казан алпавыты Надежда Львовна Толстаяның (1774–1854) Лаеш өязендәге Чырпы авылында 280 крепостной крәстияне, 2,4 мең дис. җире, тегермәне һәм бакчалы зур утары, Казанда йорты була. **Николай Иринархович** (18.10.1799 — 1846, Кронштадт), флот офицеры, 2 нче ранг капитаны, Кронштадт хәрби губернаторы каршында дежур штаб-офицер. Диңгез кадет корпусын тәмамлый. Барон Ф.П.Врангель һәм географ Ф.П.Литке б-н 1819–22 елларда поляр диңгезләргә ике фәнни экспедициядә катнаша. 1826–29 да Литке б-н «Сенявин» судносында җир тирәли экспедициядә була, бу вакытта Каролина тезмәсендәге кечкенә утраулар төркеме ачыла; «Каролина утрауларының үрнәк тасвирламасы»н төзи, аңа чит ил гидрографлары югары бәя бирә. **Ипполит Иринархович** (16.9.1808, Әстерхан ш. — 1881 дән соң). Тарихчы һәм язучы М.П.Погодин җитәкчелегендә өйдә белем ала. 1823 тә Артиллерия уч-щесенә юнкер булып керә, 1826 да 14 нче артиллерия бригадасында. 1826 ның 22 июнендә, үз туганы Дмитрийны «чит дәүләтләр файдасына шпионлыкта, сатылуда» гаепләп, император Николай I гә хат җибәрә. Гаепләү нигезсез дип табыла, Ипполит рядовойлыкка төшерелә һәм Оренбургка күчерелә. 1827 дә ул Оренбургтагы яшерен оешмада катнашучылар өстеннән 3 шикаять яза, 1832 дә Оренбург суды тарафыннан 15 елга Себергә каторгага җибәрелергә хөкем ителә; өстәвенә суд, гаепләнүче яшерен оешмада катнашучыларны «тугрылык саклау хисеннән түгел, вакытлар үткәч, аның үз «эшчәнлеге» дә ачылыр, дип курку аркасында саткан», дигән нәтиҗәгә килә. Курган шәһәрендә яшәгәндә хакимият вәкилләре өстеннән шикаятьләр яза. 1865 тә аңа Мәскәүгә вакытлыча кайтырга рөхсәт ителә: Казан губернасы Лаеш шәһәре буенча сәүдәгәрлеккә кертелә, Казанда еш була. 1870–81 елларда Самара шәһәрендә яши, әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә (әдәби псевдонимы — Ипполит Прикамский). «Себер истәлекләре» («Сибирские воспоминания»), «Көнбатыш Себерне тасвирлаулар» («Описания Западной Сибири») һ.б. китаплар авторы. «Самара белешмә кәгазе» («Самарский справочный листок») редакторы. **Дмитрий Иринархович** (13.6.1804, Әстерхан ш. — 5.2.1893, Мәскәү), декабрист, 8 нче флот экипажы лейтенанты (1824), публицист. Диңгез кадет корпусын тәмамлагач (С.-Петербург, 1819), шунда укытучы итеп калдырыла. 1822 нең 17 августында М.П.Лазарев командалыгындагы «Крейсер» фрегатында Җир шары тирәли сәяхәткә китә. 1822 дә Лондоннан император Александр I гә, аның карашынча, Верона конгрессы (20 окт. – 14 дек., 1822, Верона, Италия) практикасында җибәрелгән Изге берлек (Европа монархлары берлеге, 1815) башлангычларыннан чигенешләр турында яза. 1822 нең көзендә С.-Петербургка император хозурына чакырыла. Юл уңаеннан Казанга керә, туганнары б-н очраша, сәяхәте һәм үзе оештырырга ниятләгән оешма — Торгызу Ордены турында сөйли. Әлеге оешманың максаты — дөньяда мәгърифәт һәм хакыйкать тарату, изелгәннәрне яклау, гадел законнарны торгызу, ә бу максатлар исә оешманы Германиядәге Иллюминатлар Ордены һәм Тугенбунд, Италиядәге карбонарияләр, Польшадагы филадельфлар б-н якынайтырга тиеш була. 1824 нең 11 ноябрендә Дмитрий С.-Петербургка килә. «Башкару өчен уңайсыз» булу сәбәпле, Торгызу Ордены император Александр I хөкүмәте тарафыннан кире кагыла. Россиянең Калифорниягә йогынтысын ныгыту турындагы тәкъдиме дә яклау тапмый. Анда булган вакытта ул рус колониясе «Форт-Росс» идарәчеләрен, соңыннан колонияне Россиягә кушу максатында, Мексикадан бәйсез дип игълан иттерергә тырыша. Торгызу Орденына Ф.Лутковский, Альтемир, Лепже һ.б., декабристлардан А.П.Арбузов керә. Орден бурычларына «вәкаләтле һәм республика идарәләрен торгызу өчен» революцион эшчәнлек тә өстәлә. 1825 елның гыйнварында Завалишин 8 нче флот экипажына билгеләнә. Ул К.Ф.Рылеев б-н якыная, декабристларның Төньяк оешмасына керә, аның эшендә актив катнаша. Җәмгыятьнең ф-лын ачу өчен, 1825 нең җәендә Рылеев б-н бергә Кронштадтка бара. Кузгалышка күп калмастан, «урыннарда революцион көчләрне ачыклау һәм А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен тарату максатында» Мәскәүгә, Казан, Сембер һәм Киевка җибәрелә. 1825 нең 14 декабрендә Дмитрий Казанга килә. Казан шагыйрәсе А.А.*Наумованың* әдәбият түгәрәгендә Грибоедовның казанлыларга әлегәчә таныш булмаган комедиясен укый, ул аны авторның үз диктовкасыннан язып алган була. В.П.Ивашев б-н бергә илдәге сәяси хәл һәм үзгәрешләр кирәклеге турында әңгәмәләр алып бара. Төньяк җәмгыятьнең бүлекчәсен төзү максатында, Казанда хәрбиләр б-н якынаерга тырыша. Завалишин б-н Ивашев берничә көн Казанда булалар, аннары, С.-Петербургта башланган хәлләр турында уйларына да китермичә, авылга китәләр. Дмитрий 30 декабрьдә Сембердә кулга алына. 1826 ның 18 гыйнварында азат ителә. Абыйсы П.Л.Толстой аша ул С.-Петербургтан үги әнисе б-н апасы Екатерина яшәгән Казанга, «әле кулга алынмаганнарны кисәтеп кую өчен», кәгазьләр җибәреп өлгерә. Март аенда ук, энесе Ипполитның шикаяте буенча, яңадан кулга алына. Тикшерү дәвамында Дмитрий Иринарховичның «Төньяк җәмгыятьнең көче һәм эшләре, Көньяк җәмгыятьнең яшәве һәм кылган гамәлләре, 1 нче армиядә булган әгъзалар турында» белүе ачыклана. Беренче разряд буенча гомерлек каторгага хөкем ителә, соңрак җәза 20 елга калдырыла. 1827 нең гыйнварында Себергә сөрелә. 1839 да Читага җибәрелә. 1856 ның 28 августында акланганнан соң да Себердә кала. Мәкаләләр, ш.и. түрәләрнең һәм Көнчыгыш Себер губернаторы Н.Н.Муравьёв-Амурскийның гаеп эшләре турында яза. Губернаторның гаризасы нигезендә император Александр II З.ның «Себердә булуын зарарлы дип санап... гафу ителгән дәүләт җинаятьчесе дворян Дмитрий Завалишинны Себердән сөрергә, яшәү урынын эчке губерналарның берсендә билгеләп, анда аның эш-гамәлләренә җентекле полиция күзәтүе оештырырга «боера». 1863 елның 14 августында ул Читадан Казанга җибәрелә. Казанда яшәүчеләргә йогынтысыннан куркып, губерна идарәчеләре 1863 нең октябрендә З.ны Мәскәүгә җибәрүгә ирешәләр. Ул журналистика б-н шөгыльләнүен дәвам иттерә, кызыклы истәлекләр калдыра («Древняя и новая Россия» ж-лында (1879, № 4), «Грибоедов турында истәлекләр», «Русский вестник» ж-лында (1884, № 2); «Декабристлар», «Декабрист язмалары», (Т. 1–2, Мюнхен, 1904)). Тарихчылар билгеләп үткәнчә, аларда уйдырма фактлар юк, әмма авторның роле күпертелеп күрсәтелә. Л.Н.Толстой декабристларның барлык истәлекләреннән Завалишин язмаларын үзе өчен иң мөһимнәре дип саный.

*Әд.:* Восстание декабристов: Материалы и док. М.–Л., 1927. Т. 3; М., 1986; Т. 16; Ш т р а й х С.Я. Моряки-декабристы. М.–Л., 1946; Ш а т р о в а Г.П. Декабрист Д.И.Завалишин. Красноярск, 1984; Г а р з а в и н а А.В. «... Отчизне посвятим души прекрасные порывы!». К., 1990.

*А.В.Гарзавина.*



И.А. Заварыкин.

**ЗАВАРЫ́КИН** Иван Александрович (23.10.1916, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Куак а. — 21.2.1945, Литва ССР, Мажейкяй ш.), Сов. Союзы Герое (13.4.1944), капитан (1944). Энгельс хәрби авиация уч-щесен (1938) тәмамлый. 1936 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 206 нчы штурм авиациясе дивизиясенең 806 нчы штурм авиациясе полкы командиры урынбасары (8 нче һава армиясенең 7 нче штурм авиациясе корпусы). Көньяк-Көнбатыш, Көньяк һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Украина һәм Балтыйк буен азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең ноябренә кадәр 104 сугышчан очыш ясый, шул вакытта дошманның 7 самолётын, 40 танкын, 130 автомашинасын юк итә, 20 артиллерия батареясының утын бастыра. Сугышчан бурычны үтәгәндә һәлак була. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. З.га туган авылында обелиск куела, Лениногорск шәһәрендә бер урам аның исемен йөртә.

*Әд.:* Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАВО́Д** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 35 кеше (руслар) яши. 1920 еллар башында нигез салына. Башта Иске Завод дип атала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 156, 1938 дә — 37, 1949 да — 148, 1958 дә — 68, 1970 тә — 33, 1979 да — 131, 1989 да — 16, 2002 дә — 45 кеше.

**ЗАВО́Д-НЫРТЫ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 22 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 119 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Башта Мишә Заводы дип атала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, Мишә бакыр кою з-дында эшли (1749–1874). 20 йөз башында З.-Н.да суд тикшерүчесе һәм стан приставы фатирлары, Петропавел чиркәве, почта бүлекчәсе, земство мәктәбе, хастаханә, вет.-фельдшерлык пунктлары, су тегермәне, 2 вак-төякләр һәм 1 казна шәраб кибете, 2 сыраханә, 3 тимерчелек, 2 кирпеч сугу һәм 2 тукыма ману бинасы, юлаучылар йорты була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 134,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 16 ир-ат; 1859 да — 733, 1897 дә — 1452, 1908 дә — 1116, 1920 дә — 1403, 1926 да — 1193, 1938 дә — 765, 1949 да — 443, 1970 тә — 181, 1979 да — 131, 1989 да — 74, 2002 дә — 144 кеше.

**ЗАВОДОУ́КОВСК РАЙОНЫ́**, *Төмән өлкәсенең* көньяк өлешендә урнашкан. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 2959 *км²*. Үзәге — Заводоуковск шәһәре (Төмән шәһәреннән 128 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 22708 кеше (2002), ш.и. 553 татар. Татарлар Түбән Ингал авылында да (234 кеше) яши. 1920 еллар ахырына кадәр монда мәчет эшли. 1960 елларга кадәр җирле мәктәптә укыту татар телендә алып барыла. Татар мәдәни үзәге, «Ләйсән» фольклор ансамбле бар.

**ЗАВО́ЙСКИЙ** Евгений Константинович (28.9.1907, Подольск губ. Могилёв-Подольский ш. — 9.10.1976, Мәскәү), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1945), СССР ФА академигы (1964; 1953 тән мөхбир әгъза), Соц. Хезмәт Герое (1969). *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбенә* нигез салучыларның берсе. 1930 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, физика каф. мөдире (1933 тән), проф. (1946). СССР ФАнең Казан ф-лы Физ.-техника ин-тын нигезләүчеләрнең берсе (1984 тән З. исем.) һәм бер үк вакытта шул ук ин-тның физика секторы мөдире (1946–47). 1947 дән Мәскәүдә: КБ-11 дә (Арзамас-16), И.В.Курчатов исем. Атом энергиясе ин-тында (1951–71) эшли; «Успехи физических наук» ж-лының баш мөхәррире (1976 дан). *Электрон парамагнит резонансы* күренешен ача, шуның нигезендә физиканың яңа бүлеге — магнит радиоспектроскопиясе башланып китә (1944). Бу ачыш физика, химия, биология һәм техникада киң кулланыла. Космик элемтә һәм тонык кына ялтыраучан объектларны астрофизик тикшерүләр өчен түбән кимәлдәге тавышлы парамагнитлы квант көчәйткечләре төзи. З. җитәкчелегендә тиз узучан ($10^{-9}$-$10^{-14}$ *с*) яктылык нурлары һ.б. процессларны өйрәнү өчен (к. *Завойский-Фанченко ысулы*) электрон-оптик әверелдергечләр куллану буенча эшләр циклы уздырыла. З. магнит тозакларында плазманы җылыту өчен магнитлы тавыш резонансы ысулын, термотөш плазмасы алу өчен турбулент җылыту ысулын, плазманы инерцион туктатулы идарә ителә торган термотөш синтезын гамәлгә ашыруның яңа юлын тәкъдим итә һәм эшли (бергәләп). СССР Дәүләт (1949), Ленин (1957) бүләкләре лауреаты. Өч Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 1982 елдан *Завойский укулары* уздырыла, 1991 дә *Завойский Е.К. исемендәге халыкара бүләк* булдырыла. Казан ун-ты, РФА КГҮнең Физ.-техника ин-ты биналарына һәм Мәскәүдә мемориаль такталар, ш.у. Казан ун-тының физика ф-ты корпусы алдына галимнең бронза бюсты урнаштырыла (2004). Казандагы бер урам З. исеме б-н атала. 1997 елда Казан ун-тының З. ЭПРны беренче мәртәбә күзәткән лаб. бүлмәсендә музей ачыла.



Е.К. Завойский.

Хезм.: Об изучении сверхбыстрых световых процессов // Докл. АН СССР. 1955. Т. 100, № 4 (автордаш); О применении многокаскадных электронно-оптических усилителей света в астрофизике // Докл. АН СССР. 1958. Т. 121, № 5 (автордаш); Коллективные взаимодействия и проблема получения высокотемпературной плазмы // Атомная энергия. 1963. Т. 14, вып. 1; Электронный парамагнитный резонанс и физика плазмы: Избр. труды. М., 1990; Spin-magnetic resonance in paramagnetics // Jounrnal of Physies (USSR). 1945. V.9, № 3; Paramagnetic absorption in some salts in perpendicular magnetic fields // шунда ук. 1946. V.10, № 2; Turbulent heating of plasma by means of a current // Mucleas Fusion. 1969, Special supplement, p.235–241 (автордаш).

*Әд.:* Альтшулер С.А. Козырев Б.М., Митин А.В. Парамагнитный резонанс: Казан. школа радиоспектроскопии 1944–1971 гг. М., 1974; Завойский В.К. Академик Е.К.Завойский. К., 1986; Чародей эксперимента: Сб. статей об акад. Е.К.Завойском. М., 1994; Салихов К.М. Е.К.Завойский: Материалы к биогр. К., 1998.

*Н.Е.Завойская, И.И.Силкин.*

**ЗАВО́ЙСКИЙ Е.К. ИСЕМЕНДӘГЕ́ ХАЛЫ́КАРА БҮЛӘ́К**, ЭПРның хәзерге үсешенә һәм аны фән-техниканың төрле өлкәләрендә кулланудагы зур казанышлар өчен бирелә. 1991 елда К.М.*Салихов* тырышлыгы б-н, РФА КГҮнең Физика-техника ин-ты, Казан ун-ты, ТР ФА галимнәре берлеге һәм «Шпрингер» нәшрияты (Вена, Нью-Йорк) тарафыннан булдырыла. Ел саен Казанда тапшырыла. Составына Россия һәм чит ил галимнәре кергән халыкара ком-т карары б-н бирелә. Ел саен ком-т ЭПР буенча белгечләргә (40 кешедән артык) кандидатларны атауны сорап язмача мөрәҗәгать итә. Бүләккә күрсәтелүчеләр турында «Applied Magnetic Resonance», «Амперский бюллетень» һәм «Бюллетень международного общества ЭПР» ж-лларында белдерүләр басыла. Агымдагы елның 1 апреленә кадәр күрсәтелгән барлык кандидатлар да тикшерелә. Тәкъдим итү кандидат казанышларының кыскача әчтәлегеннән гыйбарәт булып, ул ком-тның гыйльми секретарена җибәрелә. Лауреат күпләп фикер алышулардан соң сайлана. Сайлау нәтиҗәләре алда күрсәтелгән басмаларда чыгарыла. Лауреатка диплом, медаль һәм акча чегы тапшырыла. Диплом тапшыру тантанасы «Магнит резонансы буенча хәзерге казанышлар» дигән еллык халыкара конференция б-н туры китерелә, ул көз көне «Казан» милли мәдәният үзәге бинасында ТРның югары дәрәҗәдәге рәсми вәкиле рәислегендә үткәрелә. Тантанада чит ил кунаклары, ш.у. ун-тлар һәм фәнни-тикшеренү ин-тларының галимнәре һәм студентлары катнаша. Лауреатның исемен бүләкне билгеләү ком-ты рәисе игълан итә. Лауреат үзенең казанышлары турында лекция укый («Applied Magnetic Resonance» ж-лында басыла). Бүләк ияләре: В.Мимс (АКШ, 1991), Б.Блини (Бөекбритания, 1992), А.Швайгер (Швейцария, 1993), Дж. Норрис (АКШ, 1994), К.Мёбиус (Германия, 1994),

Я.С.Лебедев (РФ, 1994), Дж.Хайд (АКШ, 1995), Дж. Фейер (АКШ, 1996), К.Ә.Вәлиев (РФ, 1997), Дж. Фрид (АКШ, 1998), Дж. Ван-дер-Ваальс (Нидерланд, 1999), Х.Мак-Коннелл (АКШ, 2000), «Брукер Аналитик» ГмбХ (Германия, 2000), К.Мак-Лохлан (Бөекбритания, 2001), В.Любитц (Германия, 2002), У.Хаббелл (АКШ, 2003), Д.Штелик (Германия, 2004), К.М.Салихов (РФ, 2004), Х.Шварц (АКШ, 2005), Я.Шмидт (Нидерланд, 2006), Б.Хоффман (АКШ, 2007), М.Меринг (Германия, 2008), Д.Гольдфарб (2009). 2001 елдан башлап конкурс нәтиҗәләре «Казанский физико-технический институт им. Е.К.Завойского» еллык басмасында чыгарыла. 1997 дә Казан администрациясе эксперименталь, теоретик физика һәм аның кулланылышы буенча әһәмиятле казанышлары өчен яшь галимнәргә Е.К.Завойский исем. бүләк билгели.


*Әд.:* Международная премия имени Е.К.Завойского // Казанский физико-технический институт им. Е.К.Завойского. К., 2001.

*Р.Г.Усманов.*

**ЗАВО́ЙСКИЙ УКУЛАРЫ́**, Казан ун-тында 1982 елның 15 октябрендә Е.К.*Завойскийның* тууына 75 ел тулу хөрмәтенә С.А.*Альтшулер* тарафыннан оештырыла. «Космик нурлар» темасына беренче докладны акад. В.Л.Тинзбург укый, соңыннан «Академик Е.К.Завойскийның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге турында» доклад б-н С.А.Альтшулер чыгыш ясый. Әлеге чыгышлар Казанның фәнни җәмәгатьчелеге һәм илнең төрле почмакларыннан килгән галимнәр тарафыннан югары бәяләнә. 1983 нең гыйнварында физиканың иң яңа казанышлары һәм бурычлары б-н танышу максатында З.у.н даими үткәрү һәм аңа әйдәп баручы галимнәр һәм белгечләрне чакыру турында карар кылына. С.А.Альтшулерның вафатыннан соң З.у.н оештыру б-н Б.И.Кочелаев шөгыльләнә. Укулар Казан ун-ты (магнит радиоспектроскопиясе каф. һәм лаб-ясе, теоретик физика кафедрасы), РФА КГҮнең Физ.-техника ин-ты һәм Казан физика җәмгыяте тарафыннан үткәрелә. З.у.нда академиклар К.Ә.Вәлиев, Л.В.Келдыш, Роальд З. Сәгъдиев, А.С.Боровик-Романов, Е.К.Завойскийның бертуганы — физ.-матем. фән. д-ры В.К.Завойский һәм кызы Н.Е.Завойская һ.б. катнаша. 2009 елга 8 уку оештырыла. Һәрбер лекторга истәлек дипломы тапшырыла.

*Б.И.Кочелаев.*

**ЗАВО́ЙСКИЙ-ФА́НЧЕНКО ЫСУЛЫ́**, бик кыска вакыт арасында ($10^{-9}$–$10^{-14}$ *с*) үтә тиз узучан яктылык процессларын өйрәнү ысулы. 1956 елда И.В.Курчатов исем. Атом энергиясе ин-тында (Мәскәү) Е.К.*Завойский* б-н С.Д.Фанченко тарафыннан тәкъдим ителә һәм нигезләнә. З.-Ф. ы. нигезендә электрон-оптик үзгәрткечләрнең (ЭОП) — оптик сурәтне бер спектр өлкәсеннән икенчесенә күчерү яки сурәт яктылыгын көчәйтү өчен алдан куелган электрон-вакуумлы приборларның үтә инерциясезлеге ята. Оптик сурәтне электрон сурәткә үзгәрткеч фотокатод (бу ысул рәсемдә ачык аңлатыла) — ЭОПның төп элементы. Объектив (О) ЭОП фотокатодында яктылык чыганагының (А) сурәтен ($А^1$) бирә. Фотокатодтан очып чыга торган электроннар тизләткеч балдаклардан (Б1, Б2) һәм диафрагмадан (Д) гыйбарәт булган электрон система ярдәмендә фокуслаша. Флуоресценцияләүче экранга (Э) төшү алдыннан электроннар тиз әйләнүчән магнит яки электр кыры (К) өлкәсе аша таралалар, шуңа күрә экранда (Э) яктылык чыганагындагы сурәт мизгел эчендә җәелеп өлгергән була. Исәпләве мөмкин булган минималь вакыт арасы өчен түбәндәге аңлатма алына: $\Delta t = T/2\pi R\delta$, биредә Т — кырның әйләнү периоды, R — экрандагы җәелмә әйләнәсе радиусы, δ — экранда 1 *см* сурәттәге штрихлар саны. Бу аңлатмада әһәмиятле мәгънәви зурлыклар: $T=10^{-10}$ *с*, R=5 *см*, δ=300 штрих/1 *см*, $\Delta t=10^{-14}$ *с*, ягъни 10 фемтосекунд (бер фемтосекунд $10^{-15}$ *с* ка тигез). Шундый югары сыйфатлы ысул фемтосекундлы лазер импульслары оптикасында һәм фемтосекундлы лазер спектроскопиясендә кулланыш таба.




Электрон-оптик әверелдергеч.

*Әд.:* З а в о й с к и й Е.К., Ф а н ч е н к о С.Д. Физические основы электронно-оптической хронографии // Докл. АН СССР. 1956. Т. 118; А х м а н о в С.А., В ы с л о у х В.А., Ч и р к и н А.С. Оптика фемтосекундных лазерных импульсов. М., 1988; Л е б е д е в В.В. Экспериментальная оптика. М., 1994.

*В.В.Самарцев.*

**«ЗАВО́ЛЖСКИЙ МУРАВЕ́Й»** («Идел аръягы кырмыскасы»), рәсемле әдәби-нәфис журнал. Казандагы беренче шәхси басма. 1832 елның гыйнварыннан 1834 кә кадәр айга 2 тапкыр нәшер ителә, 72 кит. (том) чыга. Нашир һәм мөхәррирләре М.В.Полиновский, М.С.*Рыбушкин*. «З.М.»ны нәшер итү идеясен Казан ун-ты профессорлары М.В.Полиновский, М.С.Рыбушкин, К.Ф.Фукс, Ф.И.Эрдман һ.б. бирә. Казан ун-ты укытучылары, студентлары һәм ун-тны тәмамлап чыккан белгечләр (И.А.Верниковский, Г.Н.Городчанинов, А.А.Гундарев, Н.Н.Кафтанников, Г.И.Солнцев, К.Ф.Фукс, Ф.И.Эрдман һ.б.) мәкаләләре, Мәскәү әдәбиятчылары (С.Н.Глинка, Д.П.Ознобишин, Д.И.Хвостов), Казан шагыйрьләре (В.А.Жмакин, Л.Н.Ибраһимов, Ф.М.Рындовский, В.Т.Феонов, А.А.Фукс) әсәрләре басыла. Иллюстрацияләр сыйфатында В.Турин тарафыннан эшләнгән литография һәм гравюралар файдаланыла. «З.м.»ның программасы шактый киң, ләкин эчтәлеге, башлыча, җирле характерда була. Һәр сан фәнни, әдәбият-тәнкыйть, чәчмә әсәрләр һәм шигърият бүлекләреннән тора. Төбәк тарихы, этнографиясе, икътисады, Россиянең эчке һәм тышкы сәясәте турында кызыклы мәгълүматлар бирелә. Идел буе, Урал, Себер төбәкләрендә яшәүче рус булмаган халыкларның (татар, башкорт, чуаш, тау чирмешләре, мордва, немец, бурят, тунгус һ.б.) тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, тарихларына кагылышлы очерклар, юлъязмалар басыла. Казан губернасы урманчылыгы, халыкларның диннәре, монастырьлар тарихына, аларның икътисади хәленә, риваятьләргә урын бирелә. Йортлар, аларда яшәүчеләр, гарипләр йортлары һәм аларда тәрбияләнүчеләр, трактир һәм аракы сату кибетләре, янгын сүндерүчеләр командалары саны турында, шәһәрләрдәге санитария хәлләре, фабрика һәм заводлар, сәнәгать торышы, фабрикантлар һәм эшчеләрнең саны, читтән кертелә һәм чит илләргә чыгарыла торган товар бәяләре китерелә.

Болгар шәһәрендәге хәрабәләр, борынгы татар язмаларына багышланган материаллар, Болгарга һәм Казан ханлыгы тарихына караган төрле тарихи документлар, кульязмалар (грамоталар, рескриптлар, нотыклар,




«Заволжский муравей» журналы.

хатлар) басыла. «Болгарлар, яки бу халыкның хәрабәләре» («Болгары, или Развалины сего народа»), «Болгарга һәм Биләргә бару» («Поездка в Болгары и Билярск»), «Казан тарихы» («История Казани») кебек мәкаләләрдә болгарлар турындагы тарихи мәгълүматларны системага салырга тырышу күренә. Журналда повесть, роман, лирик шигырьләр, эпиграмма, альбом багышлаулары, юмористик язмалар, фельетоннар, сатирик күзәтүләр; рус, Көнбатыш Европа, Америка авторлары әсәрләреннән өзекләр (мәс., И.А.Верниковский тәрҗемәсендә А.Мицкевич әсәре), С.Б.Күкләшев тәрҗемәсендә Шәрекъ шагыйрьләре әсәрләре басыла. Матди кыенлыклар һәм Рыбушкинның Казаннан китүе сәбәпле журнал чыгудан туктый.

*Әд.:* Казанский литературный сборник. К., 1878; Указатель статей по археологии, истории и этнографии, помещённых в журнале «Заволжский муравей» (1832–1834) // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 2; Е г о р о в а Н.А. «Заволжский муравей» (1832–1834): Указ. содерж. // Казанская периодическая печать XIX — начала XX века: Библиогр. указ. К., 1991.

*Г.Р.Заманова.*

**ЗАВЬЯ́ЛОВА** Татьяна Петровна (31.5.1918, Казан — 1983, шунда ук), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1967), ТАССРның атказ. табибе (1966). Казан мед. ин-тын тәмамлаган-

нан соң (1942), шунда ук эшли. 1943–78 елларда Казан травматология-ортопедия фәнни тикшеренү ин-тында, 1955 тән балаларның терәк-хәрәкәтләнү органнары авырулары бүлеге мөдире. Хезмәтләре балаларда сөяк сынуларны дәвалауга карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Лечение врождённых вывихов бедра, переломов бедренной кости у детей. К., 1962; Переломы костей предплечья в детском возрасте // Ортопедия и травматология. 1962. № 4.

**ЗАВЬЯ́ЛОВО РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* үзәк өлешендә урнашкан. 1937 елның 1 июнендә оештырыла. Мәйданы — 2202,8 *км*². Үзәге — Завьялово авылы (Ижевск шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 59145 кеше (1997), ш.и. 2482 татар. Татарлар, нигездә, Завьялово, Пирогово авылларында, Октябрьск һәм Вираксино посёлокларында яши. 1996 дан З.р.нда Республика бөтентатар иҗтимагый үзәге бүлекчәсе эшли. Пирогово авылы мәктәбенең милли сыйныфларында татар теле фән буларак өйрәнелә, Октябрьск посёлогы мәктәбендә татар теле факультатив дәрес (татар балалары өчен) буларак укытыла. Мәктәпләрдә татар әдәбияты классикларына багышланган тематик кичәләр, ачык дәресләр үткәрелә.

**ЗАГО́РСКИЙ** Иван Васильевич (22.1.1899, Ташкент ш. — 27.1.1973, Казан), драма актёры, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1954, 1960). Сәхнә эшчәнлеген 1919 елда Полторацк (хәзерге Ашхабад) шәһәр драма театрында башлап җибәрә. Театр студиясен тәмамлаганнан соң (1920), Сәмәрканд, Уфа, Харьков, Архангельск, Владивосток, Курск, Баку, Омск, Ярославль шәһәр театрларында эшли, бертуган Роберт һәм Рафаил Адельгеймнар (1924–25) һәм В.И.Лихачёв (1926–27) гастрольләрендә катнаша. 1938 елдан — Казан Зур драма театрында. Ул башкарган рольләр арасында Кассио («Отелло», У.Шекспир), Дантес («Шагыйрь һәм патша», Н.Н.Лернер), Квазимодо («Париж Изге Ана соборы», В.Гюго романы буенча), Незнамов, Андрей Колычев («Гаепсездән гаепләләр», «Василиса Мелентьева», А.Н.Островский), Фурманов («Чапаев», Д.А.Фурманов романы буенча) образлары бар. Черкасов («Көмеш тарлавык», Н.Ф.Погодин, 1938), кенәз Шаховский («Патша Фёдор Иоаннович», А.К.Толстой, 1940), Лаврецкий («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев, 1941), генерал Раевский («Фельдмаршал Кутузов», В.А.Соловьёв, 1941) рольләрен башкарып, үзен рус реалистик мәктәбе тарафдары, җитлеккән оста итеп таныта. Күркәм тышкы кыяфәте, сәхнәдәге сөйкемлелеге, темпераменты ул башкарган образларның эчке рухи көчен гәүдәләндерергә ярдәм итә. Сугыш еллары репертуарында уйналган Сафонов («Рус кешеләре», К.М.Симонов, 1942), Горлов («Фронт», А.Е.Корнейчук, 1942), Давыд Васильев («Бик күптәннән», А.К.Гладков, 1943), Кондратьев («Флот офицеры», А.А.Крон, 1944), полковник Иван Петров («Прага каштаннары астында», К.М.Симонов, 1946), генерал Ковров («Җиңү сере», В.А.Соловьёв, 1946) һ.б. рольләре б-н батыр солдат, Ватан алдындагы бурычын үтәргә һәрвакыт әзер торучы, көчле, кыю, тәвәккәл кешеләр образларын гәүдәләндерә. Телегин («Михнәтле заман», А.Н.Толстой, 1947), Годун («Разлом», Б.А.Лавренёв, 1952), поручик Борейко («Порт-Артур», А.Н.Степанов, И.Ф.Попов, 1953) рольләре шундыйлардан. З. рус классикасы әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә дә шактый әһәмиятле образлар иҗат итә: Скалозуб («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Ноздрёв («Үле җаннар», Н.В.Гоголь), Марк Волохов («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Васильков, Андрей Белугин, Флор Прибытков, Великатов («Котырган акчалар», «Белугинның өйләнүе», «Соңгы корбан», «Талантлар һәм аларга баш июючеләр», А.Н.Островский), Лопахин («Чия бакчасы», А.П.Чехов). З.ның Роман Дубровин («Иделдә күргән төш», А.Н.Островский), Васька Пепел («Тормыш төбендә», М.Горький), Прохор Громов («Хәсрәт дәрьясы», В.Я.Шишков романы буенча) кебек геройлары үзләренең баш бирмәүләре, балаларча беркатлы булулары б-н үзләренә җәлеп итәләр, өстәвенә билгеле бер дәрәҗәдә рус милли характеры сыйфатларын чагылдыралар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.



И.В.Загорский.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*







И.В.Загорский: 1. Ноздрёв (Н.В.Гогольнең «Үле җаннар» поэмасы буенча); 2. Вершинин (А.П.Чехов, «Өч сеңел»); 3. Васька Пепел (М.Горький, «Тормыш төбендә») рольләрендә.

**ЗАГО́РЬЕ** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1940 елларда Вахитов исем. совхозның 1 нче бүлекчәсе буларак нигез салына, 1962 нең 28 сентябреннән хәзерге исемен йөртә. Оештырылган көннән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1958 дә — 216, 1970 тә — 173, 1979 да — 131, 1989 да — 82, 2002 дә — 80 кеше.

**ЗАГО́СКИН** Николай Павлович (20.7.1851, С.-Петербург — 6.2.1912, шунда ук), тарихчы, хокук белгече, дәүләт хокукы д-ры (1880), публицист, нашир, җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1902). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлагач (1874), шунда ук эшли: 1875–78 елларда приват-доцент, 1878–79 да доцент, 1879–80 дә экстраординар проф., 1880–1900 дә ординар проф., 1900–12 дә рус хокукы тарихы кафедрасының атказ. профессоры; 1905 тә юридик фак-т деканы, 1906–09 да ректор. Бер үк вакытта 1879–82, 1910–11 дә Казандагы Югары хатын-кызлар курсларында укыта. Үзенең тарихи карашлары буенча историографиядәге дәүләт мәктәбе вәкилләренә керә. Төп хезмәтләре 18 йөзгә кадәрге Россия дәүләт ин-тлары тарихына карый: «Петрга кадәрге Русьта йомышлылар катлавының оешуы һәм килеп чыгышы турында очерклар» («Очерки организации и происхождения служилого сословия допетровской Руси», 1875), «XIV–XVI йөзләрдәге җирле хөкүмәт идарә тәртибен билгеләүче устав грамоталары» («Уставные грамоты XIV–XVI вв., определяющие порядок местного правительственного управления», вып. 1–2, 1875–76), «Мәскәү дәүләте шәһәрләрендә утарлар биләү хокукы турында» («О праве владения городскими дворами в Московском государстве», 1877), «Мәскәү дәүләтенең хокук тарихы» («История права Московского государства», т. 1–2, 1878–79), «Мәскәү дәүләтенең үзәк идарәсе. Боярлар думасы» («Центральное управление Московского государства. Дума Боярская», вып. 1, 1879). З. — «Казан Император университетының беренче 100 елдагы тарихы. 1804–1904» («История Императорского Казанского университета за первые 100 лет его существования. 1804–1904», т. 1–4, 1902–06) дигән фундаменталь хезмәт авторы. Бу китап фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелгән архив материалларының киң комплексы нигезендә язылган. З. редакциясендә һәм автор буларак катнашында чыккан «Император Казан университеты профессорлары һәм укытучыларының биографик сүзлеге. 1804–1904» («Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета. 1804–1904», ч. 1–2, 1904) әлеге тикшеренүнең дәвамы булып тора. Идел буеның Казан төбәге тарихы б-н шөгыльләнә. «Болгавыр заманда Казан төбәге» («Казанский край в Смутное время», 1891), «А.С.Пушкин Казанда» («А.С.Пушкин в Казани», 1892), «Император Павел Беренче Казанда: 1798 ел» («Император Павел Первый в Казани: 1798 год», 1893), «Граф

Л.Н.Толстой һәм аның студентлык еллары» («Граф Л.Н. Толстой и его студенческие годы», 1894) дигән китаплар һәм мәкаләләр авторы. Мәгълүматларының байлыгы һәм төрлелеге б-н аерылып торган «Казан буйлап юлдаш» («Спутник по Казани», 1895) З.ның төбәкне өйрәнүләре нәтиҗәсе була. З. — Казан шәһәр музеен төзүчеләрнең берсе. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең (1878) оештыручы-әгъзасы, аның «Хәбәрләр»енең («Известия...») (1884 кә кадәр) секретаре һәм мөхәррире. Ул чорда Россиядәге провинциаль вакытлы басмаларның иң яхшысы булган «*Волжский вестник*» г-тасын нигезли, нәшер итә һәм редакцияли (1883–91). Газета редакциясе җирле интеллигенциянең үзенчәлекле клубы, Казанның иҗтимагый тормышының үзәге була. Либераль эшлеклеләрне, язучыларны һәм сәяси сөрелгәннәрне г-тада хезмәттәшлек итүгә тартып, З. анда үзе дә күп кадагына суккан фельетоннар, рецензияләр, төбәкне өйрәнүгә кагылышлы очерклар һ.б. бастыра. 1896–98 дә — «Камско-Волжский край» г-тасы мөхәррире. Казан либераллары лидерларының берсе. 1900 елларда Казан шәһәр думасы гласные. 1911 дән Россия Дәүләт советы әгъзасы.



Н.П. Загоскин.

Хезм.: Верховники и шляхетство 1730 г. К., 1881; Материалы исторические и юридические района бывшего Приказа Казанского дворца. К., 1882; Из летних скитаний: Путевые наброски и впечатления. К., 1888; Казанская старина: Очерки г.Казани и казанской жизни в 40-х гг. К., 1891–92; Из времён Магницкого: Страничка из истории Казанского университета 20-х годов. К., 1894; Русские водные пути и судовое дело в допетровской России. К., 1910.

*Әд.:* Крыльцов И.Н.П.Загоскин: Некролог // Уч. зап. Казан. ун-та. 1912. Кн. 12; Тельберг Г.Г. Н.П.Загоскин, профессор истории русского права в Казанском университете: Критико-биогр. заметка. М., 1914; Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1992. Т. 2; Казанский университет (1804–2004); Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ЗАГРЯ́ЖСКИЙ** Артемий Григорьевич (1675 — 1754), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-аншеф (1753). Дворяннар нәселеннән. 1690 еллардан хәрби хезмәттә. 1696 да Азовны яулауда, Төньяк сугышында (1700–21), Польша варислыгы өчен барган (1733–35), рус-төрек (1735–39) сугышларында катнаша. 1705 ел ахыры — 1706 ел башында Казанда Б.П.Шереметев штабында була, аннары хөкүмәт гаскәрләре составында Әстерхан кузгалышын — стрелецлар, солдатлар, посад һәм эшле кешеләрнең феодалларга каршы хәрәкәтен бастыруда катнаша. 1741–48 дә Казан губернаторы. 1742 елгы янгыннан соң Казанны торгызу б-н җитәкчелек итә. Зөя шәһәрендә рус булмаганнар мәктәбен ачуда (1745), Казан губернасында ятимханәләр оештыруга һәм аларны тотуга булышлык итә. 1742–44 тә ясаклы татарлар кузгалышын бастыруны җитәкли. Аның заманында төбәктә яшәүчеләрне көчләп чукындыру көчәеп китә, мәчетләр күпләп җимертелә, яңа чукындырылган башка милләт кешеләре арасында исламның таралуы сәбәпләре тикшерелә. Мөселманнарның сакланып калган гыйбадәт кылу биналары губерна канцеляриясендә исәпкә куела. 1744 тән З., Сенат боерыгы буенча, Казанда һәм кимендә 200 ир-ат яшәгән, православие динендәгеләр булмаган авылларда яңа мәчетләр төзергә рөхсәт итә. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Руммель В.В., Голубцов В.В. Родословный сборник русских дворянских фамилий. СПб., 1886. Т. 1; Сборник биографий кавалергардов. 1724–1762. СПб., 1901. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗАДВО́РНОВ** Олег Анатольевич (29.3.1961, Казан), математик, физ.-матем. фән. д-ры (2007). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «Нефтехимпромавтоматика» махсус проектлар КБсында эшли. 1986 дан Казан ун-тында, хисаплау математикасы каф. профессоры (2008 дән). Хезмәтләре вариацияле тигезсезлекләр чишүнең санлы матем. алымнарына карый. З. фильтрлаштыруның һәм челтәрле йомшак сүрүләр теориясенең гомумиләштерелгән нәсызыкча мәсьәләләре куелышларын тәкъдим итә; гомумиләштерелгән чишелешләр булу теоремасын исбатлый. Гильберт һәм Банах фәзаларында монотон типтагы операторлы вариацияле тигезсезлекләр чишүнең итерацион юлларын эшли.

Хезм.: Постановка и исследование стационарной задачи о контакте мягкой оболочки с препятствием // Изв. вузов. Математика. 2003. № 1; Исследование нелинейной стационарной задачи фильтрации при наличии точечного источника // Изв. вузов. Математика. 2005. № 1; О сходимости итерационного метода двойственного типа решения смешанных вариационных неравенств // Дифференциальные уравнения. 2006. Т 42, № 8 (автордаш).

**ЗА́ЕВ** Александр Алексеевич (15.3.1915, Уфа губ., Минзәлә өязе Смыловка а. — 12.4.1966, Киров өлкәсе Христофорово штп.), Дан орденының тулы кавалеры (21.8.1944, 25.8.1944, 24.3.1945), кече лейтенант (1945). Туган авылында бухгалтер булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче аерым чаңгы батальонының рота старшинасы (7 нче армиянең 33 нче аерым чаңгы бригадасы), 60 нчы укчы полкы отделениесе командиры (14 нче армиянең 65 нче укчы дивизиясе). Төньяк һәм Карелия фронтлары гаскәрләре составында Карелиядәге оборона сугышларында (1941–44), Ленинград оборонасында, Свирь-Петрозаводск (1944) һәм Петсамо-Киркенес (1944) һөҗүм операцияләрендә, Норвегияне азат итү сугышларында катнаша. Халлин-Лампи күле янында Питкярант шәһәреннән төньяк-көнчыгыштарак (Карелия АССР) дошман оборонасын өзеп чыкканда 1944 нең 9 июлендә (һөҗүмгә беренче булып күтәрелә, расчёты б-н бергә дошман пулемётын сафтан чыгара, 12 минасын зарарсызландыра); Суоярви шәһәреннән (Карелия АССР) 35 *км* төньяк-көнбатыштарак 1944 нең 24–27 июленә кадәр барган бәрелешләрдә (дошман пулемётын кулга төшерә, ярала́нган 7 сугышчыга беренче мед. ярдәме күрсәтә); Петсамо шәһәреннән (хәзер Мурманск өлкәсе Печенга штп) 37 *км* көньяк-көнбатыштарак 1944 нең 21 октябрендә булган сугышта (пулемёт уты б-н дошманның туплы 2 автомобилен һәм 2 пулемёт ноктасын юк итә) батырлык күрсәтә. 1947 дән Христофоровода бухгалтер-ревизор булып эшли. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.



А.А. Заев.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ЗА́ЙКИН** Александр Евгеньевич (1.1.1959, Рязань өлкәсенең Скопин р-ны Заречный пос.), химик-технолог, химия фән. д-ры (2000). 1981 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, пластик массалар технологиясе каф. профессоры (2000 елдан). Хезмәтләре полиолефиннарны каталитик синтезлауга, күпкомпонентлы полимер системаларына карый. Полимерларның гетероген катнашмаларындагы каты дисперс кисәкчекләрнең (тутыргычларның) фазаара чиктәге локальләшүе закончалыгын өйрәнә, тутыргычларны фазалар бүленеше чигендә локальләштергәндә катнашманың ныклыгы арту һәм аддитив электр үткәрүчәнлеге көчәю күренешен ача. Полимерларның гетероген катнашмалары үзлекләре б-н тутыргычның фазаларга бүленүе арасындагы бәйләнешне билгели, бу исә гади технологик алымнар ярдәмендә полимерлар нигезендә төзелгән материалларның үзлекләре б-н идарә итү, техниканың төрле өлкәләре өчен күп кенә электр үткәрүчән полимер композицион материаллар эшләү мөмкинлеге бирә. «Полимерлар химиясе һәм физикасы буенча практикум» («Практикум по химии и физике полимеров», М., 1994) уку ярдәмлеге автордашы.

Хезм.: Влияние способа получения наполненной смеси полимеров на взаимную растворимость её компонентов // Высокомолекулярные соединения. 1999. Т. 41, № 3 (автордаш); Изучение локализации частиц технического углерода на границе фаз в гетерогенной смеси полимеров // Коллоидный журн. 1999. Т. 61, № 4 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЗАИКО́ННИКОВА** Ирина Витальевна (21.12.1921, Казан — 13.9.1991, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1968), проф. 1970), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1943), шунда ук эшли, фармакология каф. мөдире (1968–89). Фәнни тикшеренүләре фосфорорганик табигатьле яңа дару препаратларын (*нибуфин, армин,* цидифаз, *мебикар, димефосфон, ксимедон,* фосфабензид) эзләп табу һәм өйрәнүгә карый. СССР Дәүләт бүләге генетик инженерия, биотехнология һәм медицина өчен нуклеаз микроблар препарат-

лары һәм төрдәш ферментлар эшләгәне өчен бирелә (1987). Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы һәм 9 патенты бар.

Х е з м.: Новое противоглаукомное средство нибуфин // Казан. мед. журн. 1961. № 2; Некоторые итоги экспериментального и клинического применения транквилизатора мебикара // Фармакология и токсикология. 1986. № 2; Влияние димефосфона на воспалительную реакцию // шунда ук. 1988. № 3.

*Әд.:* Фармакология и токсикология фосфорорганических и других активных веществ: Тез. докладов Рос. конф., посв. 75-летию проф. И.В.Заиконниковой. К., 1996; Кафедра фармакологии Казанского государственного медицинского университета // Очерки отечественной фармакологии. М., 2001.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ЗА́ИМОВ** Халик Шакир улы (13.11.1914, хәзерге Чиләбе өлкәсе Аргаяш р-ны Солтан а. — 9.2.1977, Уфа), композитор, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе. Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясендә (В.Белый композиция классы) укый (1938–40). 1952 елда Мәскәү консерваториясенең (А.Александров классы) композиция ф-тын тәмамлый. 1956–63 тә Мәскәү өлкәсе Лыткарино посёлогында муз. мәктәбе директоры. 1963–71 дә Уфа сәнгать уч-ще-се директоры. Төп әсәрләре: «Акбүзат» операсы (А.Э.Спадавеккиа б-н бергәләп, либретто авт. Б.Бикбай һәм К.Даян, 1942; 2 нче редакциясе 1953); «Кара йөзләр» балеты (А.Г.Чугаев б-н бергәләп, либретто авт. Н.Г.Канин һәм Х.Мостаев, 1955); симф. оркестр өчен: Сюита (1949), Бию сюитасы (1949), Увертюра (1952); хор өчен: солистлар, хор һәм симф. оркестр өчен Б.Бикбай сүзләренә «Башкортстан» кантатасы (1947); К.Даянның «Көз» шигыренә (1949) а капелла хоры өчен әсәр; инструменталь камера әсәрләре: 1 нче, 2 нче номерлы кыллы квартетлар (1954, 1955), Скрипка һәм фортепьяно өчен сюита (1944), җырчы тавышы, скрипка һәм фортепьяно өчен трио (1947), ике скрипка өчен 4 дуэт (1952), фортепьяно өчен 24 прелюдия; халык җырларына эшкәртмәләр, җырлар һ.б.

*Әд.:* К а р и м о в а С. Халик Займов // Композиторы и музыковеды Башкортостана. Уфа. 2002.

**ЗА́ЙМИЩЕ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Казанның Киров р-ныңдагы Юдино тимер юл станциясе янында урнашкан. Исеме элеккеге Займище авылы б-н бәйле. 1907 елда П.А.Пономарёв, 1917 дә Б.Ф.Адлер, 1949–50, 1952–53 тә А.Х.Халиков тарафыннан тикшерелә. Таш (неолит), бакыр һәм бронза гасырларга караган 6 туктаулыкны үз эченә ала. Неолит дәверенә нисбәтле материаллар Чулман (Займище V туктаулыгы) һәм Балахна (Займище III туктаулыгы; чокырлы-тарак эзе сыман бизәкле балчык савыт-саба) археол. культураларына баглы чакматаштан эшләнгән әйберләрдән һәм әвәләп ясалган чүлмәк кисәкләреннән гыйбарәт. Энеолит дәвере табылдыкларын — *Волосово археол. культурасы* савыт-сабасы ватыклары (Займище III һәм V туктаулыклары), бронза гасыр материалларын Казан яны археол. культурасына нисбәтле торак калдыклары тәшкил итә. Археол. табылдыкларның төп өлеше (таш, металл, керамик әйберләр) бронза гасырга карый. А.Х.Халиков фаразынча, комплекста табылган әйберләрнең күпчелеге Казан яны культурасының Займище, Балым-Карташиха һәм Маклашеевка чорларына карый.


*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л ук. Приказанская культура // Свод археологических источников. М., 1980. Вып. 1–24.

*Е.П.Казаков.*

**ЗА́ЙПИН** Гали Мостафа улы (1875–1918, Казан), скрипкачы, 19–20 йөзләр чигендә киң танылган татар башкаручыларының берсе. 1890 елларда күренекле татар җырчылары һәм музыкант-инструменталистлары б-н бергә Мәскәүдә, Петербург, Уфа, Оренбург, Түбән Новгород һ.б. шәһәрләрдә чыгышлар ясый. Халык алдында беренче татар концертларын оештыруда актив катнаша, инструменталь ансамбльләр төзи, «Сәйяр» труппасы б-н хезмәттәшлек итә. 1907 дән Казандагы Шәрекъ клубында скрипкачы-солист һәм пианист-аккомпаниатор булып эшли. Граммофон тәлинкәләренә музыкаль әсәрләр яздыра, муз. фольклор язмаларын җыю б-н шөгыльләнә. З. репертуарының төп өлешен үзе аранжировка ясаган халык көйләре, Европа классик композиторларының, ш.у. үзенең («Садә» маршы, пьесалар, биюләр) әсәрләре тәшкил итә. Аның уйнавы замандашлары һәм мәшһүр татар сәнгать эшлеклеләре тарафыннан югары бәяләнә.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ЗА́ЙЦЕВ** Александр Михайлович (20.6.1841, Казан — 19.8.1910, шунда ук), химик-органик, химия д-ры (1870), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1885). А.М.*Бутлеров* шәкерте. 1862 елда Казан ун-тын тәмамлый, атаклы химиклар А.В.Г.Кольбе (Магдебург ун-ты, Германия) һәм Ш.А.Вюрц (Югары мед. мәктәбе, Париж) лаб-яләрендә эшли. 1865 елдан Казан ун-тында, 1871 дән профессор, органик химия лаб-ясе һәм каф. мөдире. З. азот кислотасы тиоэфирларының оксидлашу реакциясен өйрәнүне А.В.Кольбе лаб-ясендә башлап җибәрә, күкертле органик кушылмаларның яңа классын ача. «Теоэфир оксидлары турында» дигән хезмәте өчен Лейпциг ун-ты тарафыннан аңа философия д-ры дигән гыйльми дәрәҗә бирелә (1866). Шуннан соңгы тикшеренүләрде *химик төзелеш теориясен* үстерүгә һәм камилләштерүгә юнәлтелә: З. натрий амальгамасы б-н майлы кислоталар хлорангидридларын кайтарып, чикле спиртлар синтезлауның гомуми ысулын эшли, бу исә нормаль беренчел бутил спирты алу мөмкинлеге бирә (аның барлыгы химик төзелеш теориясе б-н фаразланган була). Е.Е.*Вагнер* б-н бергәләп диэтилкарбинолны цинк һәм иодлы этил б-н кырмыска кислотасының этил эфирына тәэсир итеп синтезлый. З. әлеге хезмәте б-н химик төзелеш теориясе нигезендә карбонил төркемендәге кислородны эфирлардагы углеводород радикаллары б-н алмаштыру (карбонил төркеме радикаллар б-н кушылмаган очракта) мөмкинлеге турындагы фаразының дөреслеге чыгуын раслый. Алкингалогенидлардан галогенводород кислоталары элементлары һәм/яки спирттан су аерылып чыгу кагыйдәсен (к. *Зайцев кагыйдәсе*) һәм галогенводород кислоталары элементларының чиксез углеводородлар б-н кушылуы кагыйдәсен исбатлый (к. *Зайцев-Вагнер кагыйдәсе*). Галоген-аллил-цинкорганик кушылмаларының эфирлар, карбон кислоталары ангидридлары, кетоннар б-н үзара тәэсирләшүеннән чиксез спиртлар синтезлауны гамәлгә ашыра. З. аллил радикаллы өченчел спиртлар алу ысулын икенчел һәм өченчел чиксез спиртлар синтезлауда да куллана (к. *Зайцев-Вагнер реакциясе*). Күп кенә чиксез углеводородлар синтезлый, шуларның (бутил, диаллил һ.б.) төзелешен исбатлый, органик кушылмаларның яңа классын — лактоннарны ача. З. тарафыннан эшләнгән синтезлау ысуллары аңа (шәкертләре б-н берлектә) бик күп чикле һәм чиксез спиртлар (күп атомлыларын да) һәм аларның кушылмаларын, чиксез кислоталар, оксикислоталар алу һәм өйрәнү мөмкинлеге бирә. Шәкертләр плеядасы тәрбияли, алар арасында Е.Е.Вагнер, С.Н.*Реформатский*, И.И.*Канонников*, А.А.*Альбицкий*, А.Я.*Богородский*, А.Е.*Арбузов* һ.б. бар. 1905 елда Рус физика-химия җәмгыяте президенты итеп сайлана.



А.М.Зайцев.

Х е з м.: Новый синтез алкоголей // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1874. Т. 6 (автордаш); Синтез диэтилкарбинола, нового изомера амильного алкоголя // шунда ук. 290–308 б. (автордаш); Курс органической химии. К., 1890–92.

*Әд.:* А р б у з о в А.Е. Казанская школа химиков. К., 1971; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**ЗА́ЙЦЕВ** Валерий Иванович (23.10.1943, Калинин өлкәсе, Рамешковский р-ны Семунино а. — 16.4.2007, Бөгелмә ш.), нефтьче, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2004), техн. фән. канд. (1984), ТРның атказ. нефтьчесе (2006). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), «Татнефтегеофизика» (Бөгелмә ш.) трестында эшли, 1970 елдан ТатНИПИнефтьтә, 2006 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нефть чыгару барышында төш-геофизик, гидродинамик һәм экологик тикшеренүләргә карый. Дәүләт бүләге Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышында табигатьне саклау чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру максатыннан геомәгълүмати системалар эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Индикаторный метод для контроля за работой технологического оборудования // Нефтяное хоз-во. 1987. № 9 (автордаш); Радиационная безопасность персонала и предотвращение загрязнения окружающей среды при добыче и подготовке нефти // Нефтяное хоз-во. 2005. № 3 (автордаш).

**ЗА́ЙЦЕВ** Владимир Григорьевич (24.2.1898, Казан губ., Цивиль өязе Батеево а. — 1962, Казан), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1940), проф. (1941). Казан. вет. ин-тын тәмамлый (1925). 1930 елдан шунда ук эшли, 1938–57 елларда оператив хирургия, 1957–60 та хирургия кафедралары мөдире.

Хезмәтләре баш һәм арка миләренең топографик анатомиясенә, дару препаратларын куллану ысулларын эшләүгә, тәннең бер өлешендә һәм бөтен тәндә авыртуны бастыру юлларын өйрәнүгә, терлекләрдә тояк яралгарын, ревматик ялкынсынуны, тартышу авыруын дәвалауга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кранновентрикулярная пункция у лошадей и других домашних животных // Уч. зап. Казан вет. ин-та. К., 1937. Т. 48; К клинике односторонней и двусторонней резекции вагосимпатического нерва у овцы, телёнка и верблюда // Уч. зап. Казан вет. ин-та. 1939. Т. 50.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЗА́ЙЦЕВ** Михаил Григорьевич (28.2.1891, Казан губ., Цивиль өязе Урмар а. — 1970, Казан), вет.-сан. эксперты, вет. фән. д-ры (1941), проф. (1941), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1961). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1921). 1921–25 елларда Кызыл Армиядә вет. табибе. 1925–67 дә Казан вет. ин-тында, 1952–63 тә вет.-сан. экспертизасы каф. мөдире. Хезмәтләре организмның төрле терлек итен эшкәртүен өйрәнүгә карый. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Распределение соли в различных частях туши домашних животных при консервировании по способу Моргана // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1930. Т. 39; О вспышке трихинеллёза в г.Кирове // шунда ук. 1961. Т. 81; Бухгалтерский учёт в мясной и молочной промышленности. М., 1969 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*В.П.Фролов.*

**ЗА́ЙЦЕВ** Михаил Михайлович (30.8.1845, Казан — 10.3.1904, шунда ук), химик-органик, философия д-ры (1872), А.М.*Зайцевның* энесе, А.М.*Бутлеров* шәкерте. Петербург технол. ин-тында, Казан ун-тында укый, 1872 елда Лейпциг ун-тын тәмамлый. 1873–78 елларда Казан ун-тында эшли. 1876 дан Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицирин җитештерү химия з-дында (Казан) техник җитәкчеләрнең берсе. Хезмәтләре каталитик кайтарылу реакцияләренә карый. Кара палладий һәм платина катнашында органик кушылмаларны әверелдерү ысулын эшли. Нитробензолдан гидразобензол һәм анилин, хлорлы бензоилдан бензальдегид ала. Органик кушылмаларны сыек фазалы гидрогенлаштыру ысулын беренче мәртәбә нитрофенолны аминофенолга, нитрометанны метиламинга әверелдерү өчен куллана. Беренче чиксез өченчел спирт (аллилдиметилкарбонолны) һәм чиксез оксикислота (диаллил серкә кислотасын) синтезлый. З. хезмәтләре майларны сәнәгый гидрогенлаштыруның нигезе булып хезмәт итә, аны дөньяда беренче мәртәбә С.А.*Фокин* гамәлгә ашыра.

Х е з м.: Синтез и свойства аллилдиметилкарбинола // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1879. Т. 8, вып. 9 (автордаш); О действии двусернистокислого натрия и сернистой кислоты на олеиновую и эруковую кислоты // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Ч. хим. 1892. Т. 24, вып. 7 (автордаш).

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**ЗА́ЙЦЕВ КАГЫЙДӘСЕ́**, икенчел яки өченчел алкингалогенидлардан галогенводород аерып алынганда (яки спирттан суны аерганда) галоген б-н бергә (яки гидроксид ион б-н бергә) иң аз водородлы күрше углерод атомыннан водород аерылып чыгудан һәм күбрәк дәрәҗәдә алкиллашкан олефин хасил булудан гыйбарәт. 1875 елда А.М.*Зайцев* тарафыннан тәгъбирләнә. Соңрак Е.Е.*Вагнер* З.к.нең реакцияләрдә өстенрәк юнәлешен, ш.у. вакытта күбрәк водородлы углерод атомыннан да бик аз дәрәҗәдә водород аерылуы күзәтелгәнен әйтә, мәс.:

$$CH_3CH_2\underset{\substack{|\\ Br}}{C}HCH(CH_3)_2 \xrightarrow{-\,Hbr} CH_3CH_2\underset{85\%}{CH = C}(CH_3)_2 +$$


$$+\ CH_3\underset{15\%}{CH = C}HCH(CH_3)_2$$

**ЗА́ЙЦЕВ-ВА́ГНЕР КАГЫЙДӘСЕ́**, водород атомнары саны кабат бәйләнештә тигез булган симметриясез туендырылмаган углеводородларга протонлы кислота кушылганда, кислотаның водород атомы алкил калдыгы зуррак булган углерод атомына кушыла, мәс.:

$$CH_3CH_2CH_2CH = CHCH_3 + HCL \rightarrow$$
$$\rightarrow CH_3CH_2CH_2CH_2CHCLCH_3$$

1875 елда А.М.*Зайцев* һәм Е.Е.*Вагнер* тарафыннан исбатлана.

**ЗА́ЙЦЕВ-ВА́ГНЕР РЕА́КЦИЯСЕ**, цинк һәм алкилгалогенидларның карбонил кушылмаларына (альдегид, кетон, катлаулы эфирлар, хлорангидрид һәм кислота ангидридлары) тәэсир итеп, икенчел һәм өченчел спиртлар алу:



биредә X = J, Br

Беренче мәртәбә өченчел спирт алу өчен цинкорганик синтезлау ысулы А.М.Бутлеров тарафыннан 1864 елда кулланыла. 1875 елда А.М.*Зайцев* һәм Е.Е.*Вагнер* тарафыннан җентекләп эшләнә. Кетоннардан — өченчел, альдегидлардан икенчел спиртлар барлыкка килә (озак вакытлар бу спиртларны «Зайцев спиртлары» дип атаганнар). Туендырылмаган спиртлар синтезлау өчен туендырылмаган радикаллы галогенорганик кушылмаларны кулланалар. Реакция ацетилен спиртлары алу өчен файдаланыла. З.-В.р.нә нигезләнгән С.Н.*Реформатский реакциясе* элементорганик кушылмалар химиясен башлап җибәрә.

*Әд.:* В а ц у р о К.В., М и щ е н к о Г.А. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**ЗАКИРҖА́НОВ** Кәбир Закирҗан улы (10.4.1931, БАССРның Кыйгы р-ны Еланлы а.), тел белгече, педагог, пед. фән. д-ры (1979), проф. (1981), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1960 елдан Башкорт ун-тында, 1980–96 да хәзерге заман рус теле каф. мөдире. Икетеллелек, милли мәктәпләрдә рус теле укыту, рус һәм башкорт телләрен типлаштыру мәсьәләләре буенча фәнни эшләр, ш.и. монографияләр, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Программированное обучение русскому языку в национальной школе. Пермь, 1973; Двуязычие и интерференция. Уфа, 1984; Двуязычие и национальная школа. Уфа, 1991.

*Әд.:* Ш а к и р о в а Л.З. П р о ф е с с о р К.З. Закирьянов // Русский язык в СССР. 1991. № 9.

**ЗАКИ́РОВ** Айрат Вәгыйз улы (6.3.1937, Казан – 27.7.2010, шунда ук), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсенең махсус конструкторлык бюросында инженер, лаб. бүлек башлыгы, баш инженер урынбасары. 1988–97 елларда хисаплау системалары фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) баш инженер. Дәүләт бүләге микропрограммалы принцип б-н төзелгән һәм автомат программалаштыру системасы кертелгән «Наири» электрон-хисаплау машиналары семьялыгын планлаштырганы һәм эшләгәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Выпускники — гордость университета: Краткий биогр. справ. / КАИ. К., 2002.

**ЗАКИ́РОВ** Айрат Фикус улы (21.4.1964, Әлмәт ш.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), техн. фән. канд. (2000). 1986 елда Куйбышев политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУында эшли: оператор, мастер, нефть һәм газ чыгаручы 6, 5, 2 нче цехларда әйдәп баручы геолог, фәнни-тикшеренү һәм производство эшләре цехы җитәкчесе, нефть чыгару һәм производствоны үстерү буенча технол. бүлек җитәкчесе, баш инженер урынбасары, баш инженер, бер үк вакытта НГДУ җитәкчесенең беренче урынбасары (1999 дан). З. җитәкчелегендә, Ромашкино нефть чыганаклары һәм югары горизонттагы ятмаларның Миңлебай һәм Төньяк Әлмәт мәйданнарында инженер-коммуникацияләренең агымдагы хәлен исәпкә алып, катламнардагы басымны тотрыклы тоту системасын камилләштерү юлы б-н оптимальләштерү һәм планлаштыру проектлары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 50 патенты бар. Дәүләт бүләге «Нефть һәм газ чыганакларында эчәргә яраклы су катламнары аралыгында экологик хәл мониторингы өчен скважиналы контактсыз инфракызыл җылылык үлчәүнең (АМК СНТ ИК) геофизик аппаратлы-методик комплексын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Обобщение опыта разработки нефтяных объектов на примере Миннибаевской площади // Нефтяное хоз-во. 2002. № 9; Разработка методов эффективной эксплуатации системы нефтесбора НГДУ «Альметьевнефть» // шунда ук. С. 49–51; Сколько служить скважине // Нефть и жизнь. 2004. № 1.

*Әд.:* Д р о н о в а Т., Д р о н о в П. Философский камень НГДУ «Альметьевнефть». Наб. Челны, 2003.

**ЗАКИ́РОВ** Әнәс Рәхим улы (11.11.1931, Мәскәү), график, нәкышьче, журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1971). Госзнак техникумын (1951), Мәскәү полиграфия ин-тын (1961) тәмамлый. СССР ВДНХсының матбугат бүлегендә баш рәссам (1951–61), «Турист» (1961–90), «Лес-



Г.З. Закиров.

ная Новь» (1990 нан) ж-лларында рәссам булып эшли. 1980 елларда Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә, «Б.Урманче» (1983), «Г.Тукай» (1986), «Л.Фәттахов» (1990) һ.б. альбомнарны бизи. Бер үк вакытта станлы нәкышь б-н шөгыльләнә, күбесенчә пейзаж жанрында эшли. Төп әсәрләре: «Чернышевскийның Саратовтагы йорты» (1961), «Өйлә вакыты. Кавказ» (1964), «Абхазиядә чәй плантацияләре» (1969), «Иделдә» (1979), «Март. Мәскәү янында» (1981), «Битцево паркы» (1989), «Яз елмаюы» (1997), «Зөя буендагы авыл» (1999), «Дельфиниум» (2001).

*К.С.Миңлебаев.*

**ЗАКИ́РОВ** Әхмәтлатыйп Закир улы (23.9.1923, Бөгелмә кантоны Мөсәгыйть а.), табиб-терапевт, җәмәгать эшлеклесе, ТССРның Дәүләт премиясе лауреаты (1991). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1963), 1983 елга кадәр шунда эшли: укытучы, аспирантура һәм ординатура мөдире, РСФСР мед. уч-щеләре укытучылары белемен күтәрү ф-ты деканы; бер үк вакытта мед. ин-ты каршындагы поликлиниканың баш табибе. 1972–75 тә чит илдә (Әфганстан) махсус хезмәттә. 1980 еллар ахырында Татарстан атом электр станциясен төзү мәйданын сайлау эшләрен оештыруда каршылык күрсәтә. Татарстанда атом төш коралына каршылар җәмгыятенең актив әгъзасы. Дәүләт бүләге респ-када экологик халәтне яхшырту мәсьәләләрен тикшерү эшләренә керткән өлеше өчен бирелә. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А б с а л я м о в а М. Укрощение монстра. К., 2001.

**ЗАКИ́РОВ** Гали Закир улы (1910, Казан губ., Мамадыш өязе (хәзер Саба р-ны) Байлар Сабасы а. — 1944 нең феврале), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), гв. кече сержанты (1943). 1940 елга кадәр туган авылында колхозда, Төньяк Казакъстан өлкәсе, Ленин р-ны Ильинка авылы МТСында эшли. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 8 нче гв. һава десанты полкының 3 нче укчы батальоны отделениесе командиры (60 нчы армиянең 3 нче гв. һава десанты дивизиясе). Воронеж, Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Дон елгасының сулъяк ярындагы оборона тоту (1942), Курск (1943) сугышларында, Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 9 октябрендә Ясногородка авылы тирәсендә (Киев өлкәсе Вышгород р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Украина терр-ясендә сугышларның берсендә һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Ильинка авылында һәм туган җирендә Геройның бюстлары куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАКИ́РОВ** Гали Салихҗан улы (15.9.1928, Актүбә өлкәсенең Уил р-ны Уил а., хәзер Казакъстан Респ-касы — 20.7.2003, Казан), педагог, пед. фән. канд. (1968), проф. (1991), ТАССР, РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1976, 1999). Каракалпак пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Дүрткүл урта мәктәбендә матем. укытучысы, директор урынбасары. 1952–54 елларда Бөгелмә укытучылар ин-тында укытучы, 1954–60 та Бөгелмә шәһәре халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1960 тан ТАССР Мәгариф министрлыгында, 1961 дән КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1963 тән Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында директор. 1966–2003 тә Казан пед. ун-тында, 1988–98 дә гуманитар ф-тларның пед. каф. мөдире. Хезмәтләре укучыларның үз белемнәрен күтәрүгә һәм проф. ориентация мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Самообразование учащихся. К., 1967; Самообразование школьников. К., 1974; Об организации педагогической профориентации молодёжи. К., 1988.

**ЗАКИ́РОВ** Данир Галимҗан улы (26.2.1939, Апас р-ның Дәвеш а.), энергетик, техн. фән. д-ры (1995), проф. (2000), РФнең атказ. шахтёры (1998). Пермь политехник ин-тын тәмамлый (1966). 1956 елдан Апас р-ының Дәүләки МТСында эшли. 1958–86 да Пермь өлкәсенең күмер чыгару пр-тиеләрендә: шахтада проходчик, электрослесарь, мастер, баш энергетик, баш механик, «Кизелуголь» ҖБнең матди-техник тәэминаты һәм транспорты буенча директор урынбасары (1976 дан). 1986 дан Тармакара ягулык-энергетика комплексы экологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының (Пермь ш.) директор урынбасары, 1992 дән — директоры. Бер үк вакытта 1997 дән Көнбатыш Урал энергетиклар ассоциациясенең ген. директоры. Хезмәтләре сәнәгать җитештерүенең энергетик һәм экологик куркынычсызлыгы проблемаларына карый. З. җылылык тәэминаты максатларында сәнәгый суларның түбән мөмкинлекле җылылыгын утильләштерү технологиясен, шахта котельныйларыннан чыгарыла торган пычраткыч матдәләрне тотып алу өчен җиһазлар (күмер чыгару сәнәгатендә һәм коммуналь-хуҗалыкта гамәлгә кертелә) эшли. Уйлап табуга 38 патенты бар. «Известные татары Прикамья» («Кама алдының күренекле татарлары», Пермь, 2005) китабы авторы. «Энергосбережение и проблемы энергетики Западного Урала» ж-лының баш мөхәррире (2008 тән). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Энергосбережение и экологическая безопасность объектов малой энергетики. М., 1995; Энергосбережение и проблемы экологической безопасности в угольной промышленности. М., 2001 (автордаш); Пермская область: на пути к энергоэффективной экономике. Пермь, 2002.

**ЗАКИ́РОВ** Зариф Гали улы (17.6.1953, Казакъстан ССРның Күкчәтау ш.), автоматлаштыру һәм телекоммуникацияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1991 елдан «Таң» кече фәнни-җитештерү пр-тиесе директоры, 1995 тән Казан технол. ун-тының гетероген системалар химиясе һәм технологиясе каф. профессоры. 1997–99 да һәм 2006 дан «ТАИФ» АҖ ген. директоры урынбасары. 1999–2005 тә «ТАИФ-Телком» АҖнең, 2005–2006 да «Телерадиокомпания «ТВТ» АҖнең ген. директоры. Бер үк вакытта, 2000 нән Казан техник ун-тының радиоэлектрон һәм телекоммуникацион җайланмалар каф. профессоры. Хезмәтләре химик физика процессларын матем. модельләштерүгә, автомат проектлаштыру системаларын булдыруга, кәрәзле элемтәне үстерүгә карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О зажигании газифицирующего топлива тепловым импульсом // Хим. физика. 1987. Т. 6, № 11 (автордаш); Адаптивный алгоритм разрешения многоэлементных сигналов // Телекоммуникации. 2003. № 11 (автордаш); Сотовая связь стандарта GSM. М., 2004 (автордаш).

**ЗАКИ́РОВ** Зыя Закир улы (8.12.1918, Уфа губ., Минзәлә өязе, хәзер Тукай р-ны Әҗмәкәй а. — 27.12.1985, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. 1939 елда Минзәлә а.х. техникумын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–73 елларда Чаллы р-ның «Гигант» к-зы рәисе (1970 кә кадәр), «*Гигант*» с-зы директоры. Ул җитәкләгән елларда, респ-ка буенча 1 *га* дан уртача 10,9 *ц* уңыш алынганда, хуҗалыкта бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 19 *ц*, 1 савым сыердан савылган сөт 3 мең *кг* га җитә; терлекчелек фермалары төзелә, бөтен уңайлыклары булган яңа үзәк утарның проекты эшләнә һәм төзелә башлый. 1959–66 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАКИ́РОВ** Илгизәр Галиәхмәт улы (1.2.1948, Үзбәкстан ССРның Наманган өлкәсе, Тура-Курган р-ны Холмат а.), инженер-җылылык энергетигы, техн. фән. д-ры (2006), ТРның атказ. энергетигы (1993), ТРның мактаулы энергетигы (2000), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Куйбышев политехник ин-тын тәмамлый (1972). 1965–82 елларда Зәй ГРЭСында: ремонт-механика цехында токарь, 2 нче казан-турбина цехында машинист, блокның өлкән машинисты, смена, станция җитәкчесе, 1 нче казан-турбина цехы җитәкчесе урынбасары, җитәкче. 1982–2007 дә «Татэнерго» АҖнең Казандагы 3 нче ТЭЦында: баш инженер урынбасары, баш инженер, директор (1984–85 һәм 1987 дән). 2007 дән «Генерацияләүче компания» («Генерирующая компания») АҖ ген. директорының инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары. З. җитәкчелегендә 3 нче ТЭЦта термотозсызландыру комплексы кертелә, газ бүлү җайланмаларының беренче чиратында пик һәм энергетика казаннары газүткәргечләре яңартыла, химик су әзерләүче фильтрлар

чылбырын регенерацияләүнең ресурслар саклый торган каршы һәм туры агымнар технологиясе үзләштерә һәм гамәлгә кертелә, минераллашкан агынтыларны һ.б.ны эшкәртүне һәм утильләштерүне яхшырта торган югары нәтиҗәле, экологик чиста технология эшләнә. З. Казандагы 3 нче ТЭЦның 2 нче чиратын төзүдә катнаша. Россиянең «Ел менеджеры — 2002» конкурсы лауреаты. Дәүләт бүләге «Югары басым казаннары өчен термик су әзерләүнең югары нәтиҗәле һәм экологик камил технологиясен эшләү һәм кулланууга кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование способа нестехиометрического сжигания природного газа и мазута // Теплоэнергетика. 1997. № 9; Нестехиометрическое сжигание природного газа и мазута на тепловых электростанциях. М., 2001 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в энергетике России: Биогр. справ. СПб., 1999; Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 2002. Вып. 6.

**ЗАКИ́РОВ** Илдар Гали улы (1.4.1956, Бөгелмә ш.), йогышлы авырулар белгече, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1979), 2 нче дәвалау-профилактика бүлегендә (Казан) эшли. 1980 елдан ГИДУВта йогышлы авырулар кафедрасында, 2003–2008 елларда каф. мөдире. Хезмәтләре гепатология, баш мие йогышлы авырулары, пневмацисоз, лептоспироз, токсоплазмоз өлкәләренә карый.

Х е з м.: Дисбактериоз кишечника при хронических вирусных гепатитах. Монография. К., 2002; Хронические вирусные гепатиты в Республике Татарстан. К., 2002; Опыт применения амиксина при лечении и профилактике некоторых вирусных инфекционных заболеваний // Клиническая медицина. 2002. № 12; Цирроз и рак печени, ассоциированные с вирусными гепатитами В и С, в Республике Татарстан. Микробиология. 2003. № 1.

**ЗАКИ́РОВ** Илдус Мөхәммәтгали улы (15.6.1938, Балтач р-ны Балтач а.), машиналар төзү технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1986), ТР ФА академигы (1992), ТР һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994, 2008). 1961 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1989), очкыч аппаратлар җитештерү каф. мөдире (1987–2002), проректор (1992–95), инновацион менеджмент каф. мөдире (2002 дән); бер үк вакытта (1995 тән) Казан авиация технологиясе фәнни-тикшеренү ин-ты ген. директоры. Хезмәтләре титан эретмәләреннән профильле балдаксыман детальләрне һәм киң фюзеляжлы самолётларга югары ресурслы торба үткәргеч системалары детальләрен әзерләү процессларының фәнни нигезләрен тикшерүгә һәм эшләүгә карый. Яңа фәнни юнәлешкә — эластик тирәлектә юка стеналы детальләргә ротацион форма бирүгә нигез сала. Титан эретмәләреннән балдак әзерләнмәләре ясау процессларының экономияләлеген тикшерә. Машиналар төзелешенең төрле тармаклары өчен исәпләү процессларының, фәнни нигезләрен һәм ысулларын, технол. рекомендацияләр, программа комплекслары эшли. З. — самолёт фюзеляжы конструкцияләрендә җыерчыклы тутыргычлардан файдалану инициаторларының берсе;



И.М.Закиров.

«КДТУ» (1993), «Казан» (1996) технопаркларын, «ИТЦ-КНИАТ» (1998) инновацион-технол. үзәген оештыручы. Сәнәгатьнең төрле тармаклары пр-тиеләрендә формалаштыруның оригиналь технол. процессларын һәм югары җитештерүчән җиһазларны гамәлгә кертү материалдан файдалануның коэффициентын күтәрергә, самолётларда торба үткәргеч системаларның ресурсын һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга мөмкинлек бирә. Уйлап табуга 85 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР МС бүләге лауреаты (1989). СССР ВДНХсының ике алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электроконтактный нагрев листовых профильных заготовок из титановых сплавов // Кузнечно-штамповочное производство. 1996. № 7; Пластические формообразования тонкостенных деталей авиатехники. Теория и расчёт. М., 1983 (автордаш); Базисные функции в приближённых решениях краевых задач. К., 2000; Изменение геометрии складчатой конструкции при изгибе // Полёт. 2004. № 2l Rotary shaping with the use of elastic mediums. Brat., 1997.

**ЗАКИ́РОВ** Илсөяр Вәгыйз улы (15.7.1949, Азнакай р-ны Әсәй а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1978). 1978–81 елларда Азнакай р-нының Чапаев исем. к-зында механик, рәис, 1981–98 дә «Әсәй» с-зы директоры, 1998 елдан «Закиров һәм К°» ышанычлылык ширкәте ген. директоры. «Әсәй» ЖЧЖ директоры (2007 дән). ТР Дәүләт бүләге фәнни нигезләнгән орлыкчылык системасын куллланып, уҗым арышының яңа сортларын тиз арада үрчеткән өчен бирелә (2000).

**ЗАКИ́РОВ** Исхак Кадыйр улы (14.9.1911, Казан — 14.7.1944), шагыйрь. Казан. финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1934). 1941 елга кадәр Татарстан китап нәшриятында, ТАССРның Язучылар берлегендә эшли. Партриотизм һәм интернационализм б-н сугарылган беренче шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1930 елларда күренә башлый. Бөек Ватан сугышы елларында фронт г-таларында, «Совет әдәбияты» ж-лы битләрендә басыла. Аның шигырьләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961), «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемле коллектив җыентыкларга кергән. Бөек Ватан сугышында Витебск шәһәре тирәсендә барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ЗАКИ́РОВ** Локман Фатыйх улы (19.2.1928, Мамадыш р-ны Түбән Ушма а.), язучы. Рус телендә яза. Киев гражданнар авиациясе инженерлары ин-тын тәмамлый (1967). 1952–69 елларда Совет армиясенең авиация частьләрендә офицер булып хезмәт итә. 1970–80 дә Татарстан Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында, 1980–95 тә Сәламәтлек саклау министрлыгында инженер булып эшли. «Абитуриентлар» («Абитуриенты», 1993), «Самолётны мәҗбүри утырту» («Вынужденная посадка», 1995), «Очучылар китабы» («Лётная книжка», 1995), «Мостафа» («Мустафа», 1995) повестьлары, «Күке оясы» («Гнездо кукушки», 2003) публицистик мәкаләләр җыентыгы, «Айсберг түбәсе» («Вершина айсберга», 2008) повестьлар һәм хикәяләр китабы авторы.

**ЗАКИ́РОВ** Марат Хәлил улы (27.4.1969, Мамадыш р-ны Дусай а.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1993). «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр (1990–92), Татар дәүләт яшьләр театрында әдәби бүлек мөдире (1992–93), «Идел» ж-лында бүлек мөхәррире (1993–2001), 2001 елдан «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөхәррире булып эшли. «Төшкә керүче елан» (1996), «Гаптери маҗаралары» (1997) повестьлары, «Кояшлы төн» (2005) шигырь җыентыгы авторы.

**ЗАКИ́РОВ** Мөхәммәтгали Закир улы (8.8.1907, хәзер Балтач р-ны Нөнәгәр а. — 1.5.1972, Казан), партия эшлеклесе. Чистай укытучылар техникумын (1934), Казан югары партия мәктәбен (1952) тәмамлый. 1920–29 елларда төрле эштә. 1931–37 дә Балтач р-нында педагог: укытучы (Нөнәгәр а.), башлангыч мәктәп мөдире (Борнак а.), җидееллык мәктәп директоры (Шода авылы). 1937 дән совет һәм партия эшендә: Балтач (1937–42), Кайбыч (1942–44) р-н башкарма ком-тлары рәисе, КПССның Норлат (1944 тән), Калинин (1950 дән), Актаныш (1960 тан), Арча (1963 тән) райкомнары 1 нче секретаре. 1955–67 дә ТАССР ЮС депутаты, 1959–67 дә ТАССР ЮС Президиумы әгъзасы. КПССның 21 нче съезды (1959), СССР кулланучылар кооперациясенең 6 нчы съезды (1961) делегаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. районның а.х. тармагындагы казанышлары өчен СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А х у н о в Г. Без бит Арча яклары // Казан утлары. 1978. № 8; И г н а т ь е в С. Растут и крепнут кадры, лучше идут дела // Партийная жизнь. 1960. № 12.

**ЗАКИ́РОВ** Нәгыйм Сафа улы (3.9.1936, Түбән Новгород өлкәсенең хәзерге Пилнә р-ны Петрякс а. — 30.8.1998, шунда ук), терлекче, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1952–94 елларда туган авылында Жданов исем. к-зда (1959 елдагы берләштерүгә кадәр Чкалов исем. к-з) терлекче, ат, дуңгыз караучы булып эшли. Дуңгыз ите җитештерүне арттыру буенча районндагы соц. ярышның инициаторы. Дуңгызчылыкта хезмәтне оештыруда агымлы ысулны кертә: симертү төркемнәрен яхшы карау нәтиҗәсендә (500–800 баш) ит җитештерү ел саен 100 *т* тәшкил итә. З. хезмәт иткән ферма базасы җирлегендә районның алдынгы тәҗрибә мәктәбе эшли. 1976–80 дә һәр терлектән уртача 754 *г* тәүлеклек артым алуга ирешә, ш.и. 1980 дә — 838 *г*. Герой исеме терлекчелекне үстерүдә, җитештерүне арттыруда, ит һәм башка продукция әзерләүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1967–85 тә



Н.С. Закиров.

Горький өлкә Советы депутаты. КПССның 26 съезды (1981), колхозчыларның 3нче Бөтенсоюз съезды (1969) делегаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006; Нижегородские татары: Биогр. словарь. Н.Новгород, 2008. Т. 1.

*М.Я.Гаитов.*

**ЗАКИ́РОВ** Ринат Зиннур улы (1.8.1948, Чистай р-ны Нарат-Елга а.), җәмәгать эшлеклесе, тарих фән. д-ры (2007), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында инструктор, пропаганда һәм мәдәният-масса эшләре бүлеге мөдире урынбасары, мөдире булып эшли. 1980 елдан КПССның Татарстан өлкә ком-тында мәдәният бүлеге инструкторы, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары. 1988–91 дә В.И.Ленин Үзәк музееның Казан ф-лы директоры, 1991–96 да «Казан» шәһәр мәдәният үзәге директоры, 1996 дан «Казан» милли мәдәният үзәге директоры. Бер үк вакытта Казан хакимиятенең Мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары (1996 дан), ТР Мәдәният министрлыгының Мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары (2002 дән), Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты рәисе (2002 дән). Җәмәгать эшчәнлегендә З. төп игътибарын татар халкы милли-мәдәни үсешенең төп проблемаларын хәл итүгә: милли мәгариф системасын камилләштерүгә, татар теле һәм мәдәниятен саклау һәм үстерүгә, гореф-гадәтләрне торгызуга, ш.и. *Сабан туе* кебек милли бәйрәмне РФдә татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә һәм чит илләрдә үткәрүгә юнәлтә. Аның тырышлыгы б-н Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты структурасында Этнологик мониторинг үзәге оештырыла.

**ЗАКИ́РОВ** Рифкат Хәйдәр улы (16.6.1938, Актаныш р-ны Усы а. — 27.6.2007, Казан, Актаныш р-ны Киров исем. совхоз авылында җирләнгән), шагыйрь. Минзәлә авыл хуҗалыгы уч-щесен тәмамлый. Гремячинск шәһәрендә (Пермь өлкәсе) шахтёр булып эшли. Шахтада күмер басып имгәнгәннән соң, 1980 еллар ахырында Казанга кайта. «Беренче карлыгачлар» (1968), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыккан шигырьләре б-н укучыларга таныла. «Шахтёр моңы» (1983), «Ай сөярмен, ел сөярмен» (1987), «Йөрәк уты» (1993), «Җан җылысы» (2006) исемле шигырь китаплары авторы. З.ның геройларына ихласлылык, кешелек дөньясын борчыган проблемаларга битараф булмау хас.

*Әд.:* Г а т а ш Р. Авыл улы, шахтёр, шагыйрь // Казан утлары. 1998. № 6.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗАКИ́РОВ** Рөстәм Фәйзрахман улы (16.11.1952, Сарман р-ны Теләнче Тамак а.), төзүче-инженер, ТРның атказ. төзүчесе (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). 1975 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң, «Спецатоммонтаж» трестының Чаллы монтаж идарәсендә мастер, прораб, өлкән прораб, баш инженер урынбасары, баш инженер (1987–90) булып эшли. 1990–97 дә «Спецатоммонтаж» трестының «Гидромонтаж» кече пр-тиесендә директор (Казан). 1997–99 да «Татарстан Республикасы күперләре» АҖдә ген. директор. 1999–2001 дә ТР МК каршындагы Дәүләт юл хезмәте директоры. 2001 дән ТРның юл хуҗалыгын һәм Татарстанның юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе директоры. Дәүләт бүләге «Күперләр төзүдә математик модельләштерүне Казансу елгасы аша салынган күперне яңартуда һәм Саескан тавы авылы янындагы Кама елгасы аша корылган күперне проектлаштыру һәм төзүдә куллану» дигән хезмәте өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗАКИ́РОВ** Сөмбәт Нәби улы (9.10.1936, Уфа ш.), нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1972), проф. (1973). 1959 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында газ һәм газ конденсаты чыганакларын әзерләү һәм файдалану кафедрасында эшли. 1987 дән РФАнең Нефть һәм газ проблемалары ин-тында (Мәскәү) катламнарның нефть, газ, конденсат бирүчәнлеге лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү теориясенә һәм практикасына карый. Газ һәм нефть газы чыганакларын эшкәртү процессына актив тәэсир итеп, алардан компонент алуны арттыру буенча тикшеренүләр алып бара. Нефть һәм газ чыганакларын эшкәртүнең яңа технологияләрен эшли. Тикшеренү нәтиҗәләре Оренбург, Битковск, Уренгой, Братск, Дулисьминск һ.б. углеводород чыганакларында гамәлгә кертелә. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге бирелә (1983). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1986). Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Разработка газовых, газоконденсатных и нефтегазоконденсатных месторождений. М., 1998; Анализ проблемы «Плотность сетки скважин — нефтеотдача». М., 2002; Новые принципы и технологии разработки месторождений нефти и газа. М., 2004 (автордаш).

**ЗАКИ́РОВ** Урал Нури улы (22.10.1933, Свердловск ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1998). 1957 елда Хәрби һава көчләренең К.Е.Ворошилов исем. Югары хәрби авиация инженерлары уч-щесен, 1966 да Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1958 дән М.К.Тихонравов исем. Фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе), 1960 тан «Энергия» фәнни җитештерү берләшмәсендә (Королёв ш.) әйдәп баручы инженер, 1971 дән СССР ФАнең Фәнни-техник советы (Мәскәү) хезмәткәре. 1977 дән Казан авиация ин-тында, 1978 дән СССР ФА Казан ф-лының Физ.-техника ин-тында, 1991 дән РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында, әйдәп баручы хезмәткәр (1998 дән). Хезмәтләре теоретик космонавтикага, составы үзгәрүчән системалар физикасына карый. Тупланган үзгәрүчән массаның релятивистик механикасы нигезләрен Эйнштейнның гомуми һәм махсус чагыштырмалылык теориясе кысаларында төзи һәм үстерә. Аның тарафыннан тоташ мохитнең масса-энергия чыганагын (агышын) исәпкә алып, энергия-импульс саклану законы тәкъбирләнә, тикторышта тупланган массаның импульслары һәм энергиясе тигезләмәләре алына. З. тикторыштагы үзгәрешле массалы җисемнең оптималь бүленүе турындагы теореманы исбатлый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Механика релятивистских космических полётов. М., 1984; Анализ устойчивости и динамики сложных систем // Обзоры исследований по механике сплошных сред. К., 1995.

**ЗАКИ́РОВ** Шамил Зиннур улы (15.3.1945, Чистай р-ны Нарат-Елга а.), театр эшлеклесе, педагог, ТССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1991, 2007). Казан химия-технол. ин-тын (1970), Ленинград мәдәният ин-ты аспирантурасын (1995) тәмамлый. 1969–72 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда һәм мәдәният-масса эшләре бүлеге инструкторы. 1975 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында укыта (бүленеп, 1979–82 дә Чаллы шәһәрендә «Энергетик» мәдәният сарае директоры, 1982 дән Чаллы шәһәр советы башкарма ком-тының мәдәният бүлеге мөдире). 1985 тән Татар акад. театры директоры. З. үзен театр сәнгате производствосын оста оештыручы, спектакльләр кую культурасын күтәрү һәм шул ук вакытта коллективның иҗади үсеше турында даими кайгыртучы, сәхнә җиһазларын техник яктан камилләштерү буенча сәләтле җитәкче буларак күрсәтә. Ул репертуар формалаштыруга, актёрларның иҗади эш б-н тәэмин ителүенә, кадрларны сайлап алуга зур игътибар бирә. Театрда яңа структуралар: балалар һәм яшүсмерләр өчен спектакльләр куючы «Балачак» театр-студиясе, ветеран актёрларның иҗат эшчәнлекләрен дәвам иттерү мөмкинлеге бирү максатыннан оештырылган «Инсаният» труппасы булдырыла. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты каршында татар театрлары өчен актёрлар әзерләүче бүлек ачылуга зур тырышлык куя. З. җитәкчелегендә театр Мәскәү, С.-Петербург, Уфа, Оренбург, Ташкент, Алматы, Бишкәк, Бакуда, Россиянең һәм якын чит илләрнең башка шәһәрләрендә; ш.у. Финляндиядә, Германиядә, Төркиядә, Англиядә гастрольләрдә уңышлы чыгышлар ясый. ТРда уздырыла торган театр фестивальләрен оештыруда З. актив катнаша, төрки халыкларның 1998, 2002, 2005 һәм 2009 елларда Казанда үткәрелгән «Нәүрүз» халыкара театр фестивальләренең директоры була. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге иясе.

*Әд.:* С а ф и у л л и н а Г. Бертуган Закировлар // Сөембикә. 1995. № 9; Ю с у п о в а Р. Ач пәрдәңне, галиҗәнап Театр!.. // Казан утлары. 2006. № 12; Д а н и л о в а Г. Можете называть это болезнью или любовью... // Театральная жизнь. 1993. № 7; И г л а м о в Н. Любовь к театру как неустанный труд // Казань. 2008. № 3.

*И.И.Илялова.*

**ЗАКИ́РОВА** Венера Гыйлемхан кызы (10.12.1961, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2002). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук эшли, 2004 тән башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү педагогикасы каф. мөдире, бер үк вакытта 2004–2008 елларда шул ук исемдәге ф-т деканы, 2008 дән яшьләр сәясәте һәм тышкы элемтәләр буенча проректор. Хезмәтләре кече яшьтәге укучыларга гуманистик тәрбия һәм башлангыч белем бирү теориясе һәм методикасы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Семейная педагогика у татар: исторический аспект. К., 2000; Традиционная педагогическая культура татарской семьи. К., 2002; Теория и методика начального образования. К., 2007.

**ЗАКИ́РОВА** Сәрия Мәгъруф кызы (10.4.1961, Пермь ш.), спортчы (академик ишү), СССРның атказ. спорт остасы (1986). Днепропетровск физкультура ин-тын тәмамлый (1989). Спорт б-н Чаллы шәһәрендә шөгыльләнә башлый (1978 елга кадәр), аннан соң Көньяк машина төзү з-дының (Днепропетровск ш.) «Метеор» спорт клубында; 1981 дә



С.М.Закирова.

СССР һәм Украина ССРның атказ. тренеры Е.Г.Чесноковта шөгыльләнә. 1985–88 елларда (к. *Академик ишү*), 1990–91 дә А-2П классында СССР, А-8 РсР классында 1985–86 да А-8 РсР классында дөнья чемпионы. «Игелекле уеннар»да (1990) җиңүче (А-2П классы) һәм бронза медаль алучы (А-1П классы). Олимпия уеннарында катнаша (1988, 4 нче урын). 1979 дан Днепропетровск шәһәрендә яши. 1999 елдан Днепропетровск физкультура һәм спорт ин-тында өлкән укытучы.

**ЗАКИ́РОВА** Эльмира Мизхәт кызы (19.12.1955, Актаныш р-ны Иске Байсар а.), журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1978 елдан «Ялкын» ж-лында эшли: бүлек мөхәррире, җаваплы сәркәтип, 1995 тән баш мөхәррир. «Мәгариф», «Сөембикә», «Салават күпере» ж-лларында, «Сабантуй», «Ватаным Татарстан» г-таларында язышa. З.ның мәкаләләре, язмалары, интервьюлары яшүсмерләрне тәрбияләү, балалар хокукларын яклау, мәдәният һәм сәнгать мәсьәләләренә багышлана.

**ЗАКРЖЕ́ВСКИЙ** Юлиан Фёдорович (29.9.1852, Галиция — 25.4.1915, Казан), җырчы (драм. тенор). Львов консерваториясендә (К.Микуля классы) укый. 1871 елдан Прага (беренче тапкыр чех һәм немец труппаларында җырлый), Венеция (1874), Львов, Краков, Варшава (1876) опера сәхнәләрендә чыгыш ясый; 1870 еллар уртасыннан Россиядә башкала һәм провинция, ш.и. Киев (1878–82), Саратов, Пермь (1897–98) шәһәрләре опера театрларында солист. 1882–84 тә Зур театрда җырлый. 1884–89 һәм 1898–1907 дә Казан опера театрында солист буларак зур популярлык казана. Төп партияләре: Рауль («Гугенотлар», Дж.Мейербер), Манрико, Радамес («Трубадур», «Аида», Дж.Верди), Хозе («Кармен», Ж.Бизе), Синодал («Демон», А.Рубинштейн) һ.б. Мәшһүр җырчы буларак, З. иҗатына Ф.И.Шаляпин яхшы бәя бирә. Күпсанлы замандашлары фикеренчә, З. игътибарга лаек сәхнә кыяфәте, искиткеч вокаль мөмкинлекләре, үзенчәлекле тавыш тембры, бигрәк тә югары тесситурада җырлый торган көчле тавышы б-н аерылып тора. Җырчының осталыгы образларны үзенә генә хас үзенчәлекле башкаруы б-н характерлы була. Казанда укыту эшчәнлеге алып бара.

*Әд.:* Т а у б е Е.Ф. Четверть века Казанской оперы (1874–1901) // Из музыкального прошлого. М., 1960; К а н т о р Г.М. Музыкальный театр в Казани XIX — начала XX века. К., 1997; Энциклопедический музыкальный словарь. М., 1966; Музыкальная энциклопедия. М., 1974. Т. 2; Музыка: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

**ЗАЛА́КОВ** Әнвәр Мәхмүт улы (2.1.1949, Яңа Чишмә р-ны Акбүре а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1979). 1971–75 елларда «Сельхозтехника»ның Әлки р-ны бүлеге инженеры, җитәкчесе урынбасары. 1975–89 да «Татмелиоводстрой» трестының Юхмачы механикалаштырылган күчмә колоннасы башлыгы. 1989–91 дә «Әлкиагропромхимия» ҖБ рәисе, 1991–95 тә «Татсельхозтехника» холдинг компаниясе» АҖ президенты. 1995–99 да Сарман р-ны хакимияте башлыгы, бер үк вакытта халык депутатларының Сарман р-н советы рәисе. 1999 дан «Татмелиорация» траст компаниясе АҖ ген. директоры, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары. Хезмәтләре а.х. б-н идарә итү мәсьәләләренә карый. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2004 елларда ТРның халык депутаты. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, СССР ВДНХсының алтын медале; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Повышение эффективности использования уборочной техники. К., 1997; Техническое обеспечение уборки зерновых культур. К., 1998; Стратегия государственного регулирования экономики и преодоления её кризисного состояния. М., 2000.


**ЗАЛАРИ́ РАЙОНЫ́**, *Иркутск өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1926 елда оештырыла. Мәйданы — 7597 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Залари посёлогы (Иркутск шәһәреннән 195 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 32010 кеше (2002), ш.и. 1071 татар. З.р. терр-ясенә татарлар 19 йөз ахырында килеп урнаша башлый: 1910–14 тә Уфа һәм Казан губерналары кешеләре Харагун, Чирмешән, Хор-Бутырино авылларына нигез сала, күп кенә татарлар Залари авылына күчеп килә. 1910 елгы халык исәбе буенча, татарлар Чирмешән (350 кеше), Хор-Бутырино (255), Сенная Падь (169), Харагун (148), Залари (100) торак пунктларында яши. 1917 гә кадәр район терр-ясендә 2 мәчет (Залари, Чирмешәндә) эшли. 1920 елларда мәчет биналарында татар мәктәпләре ачыла. Хәзерге вакытта татарлар Холмогой (212), Чирмешән (146) авылларында, район үзәгендә яшиләр. 1996 дан Залари авылында татар мәдәни үзәге, мөселман җәмгыяте бар, 1999 дан «Родник» мәдәният йорты каршында этнография бүлмәсе оештырыла. Татар үзешчән сәнгать клубы, «Йолдыз» фольклор ансамбле эшли.

**ЗА́ЛЕ** (Залит) Карл Фрифевич (Иохан Карлис Леонхард) (6.10.1888, Курсишу бистәсе, Латвия — 19.2.1942, Инчукалне бистәсе, Латвия ССР), сынчы, проф. (1936), Латвия Сынлы сәнгать академиясенең шәрәфле әгъзасы. Нәселдән килүче ташчылар гаиләсеннән. Казан сынлы сәнгать мәктәбендә В.С.Богатырёвта укый (1908–13), Казандагы күп кенә төзелешләргә, ш.и. Хатын-кызлар югары курслары бинасына (1912, арх. В.А.Трифонов; хәзер Татар дәүләт гуманитар-пед. ун-тының физик культура ф-ты бинасы) әвәләп ясалган бизәкләр эшли, 1812 елгы Ватан сугышының тәмамлануына 100 ел, Романовлар йортына 300 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан урамнарны бизәү өчен монументаль-декоратив сыннар иҗат итә. 1914 тә Мәскәүдә С.Д.Эрьзя остаханәсендә эшли. Г.Р.Залеманның Сынлы сәнгатькә кызыксындыру җәмгыяте мәктәбендә (Петроград, 1915), А.Т.Матвеевның Дәүләт Иркеле сәнгать остаханәсендә (1921) осталыкка өйрәнә. 1922–23 елларда Берлинда яши, Конструктивчылар конгрессы эшендә катнаша (Дюссельдорф ш., 1922), «Эпоха» ж-лы чыгара, рәссамнар И.Пуни һәм А.Дзиркалис б-н бергәләп «Синтез» төркемен оештыра. Ленинның монументаль пропаганда планын тормышка ашыруда катнаша, Петроградта Н.А.Добролюбов (1918), Дж.Гарибальди (1919), Витебскида К.Маркс (1919) һәйкәлләрен эшли. 1923 тән Ригада яши. Күренекле латыш монументаль сынчысы, ул Ригада туганнар каберлегендәге һәйкәлне (1924–36, арх. А.Бирзениекс) һәм Азатлык һәйкәлен (1935, арх. Э.Штальберг), Яунпиебалгеда туганнар каберлегендәге һәйкәлне (1930) һәм мемориаль ансамбльләр иҗат итә. 1936 дан Латвия САндә укыта.


*Әд.:* К л ю ч е в с к а я Е.П. Из истории скульптурного отделения Казанской художественной школы на рубеже 1900-х гг. // Науч. конф., посвящённая 100-летию со дня рождения скульптора Карлиса Зале. Рига, 1988; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1983. Т. 4, кн. 1.

*Е.П.Ключевская.*

**ЗАЛЕ́ЖСКИЙ** Владимир Николаевич (7.9.1880, Казан губ., Лаеш өязе Ачы а. — 2.2.1957, Мәскәү), революцион хәрәкәт эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. 1890 елларда Казан реаль уч-щесе укучысы. 1902 елдан Казанда «Эшче-революционерлар төркеме» җитәкчесе, шәһәр эшчеләре һәм губерна крәстияннәре арасында пропаганда алып бара. 1903 тә кулга алына һәм Архангельск губернасы Холмогоры шәһәренә сөрелә. 1905 тә Казан губернасында революцион хәрәкәттә актив катнаша. 1910 да Казанга тыелган әдәбият җибәрүне оештыра. 1915, 1917 елларда РСДРП(б) ҮКның Рус бюросы әгъзасы. Окт.



В.В. Заленский.



М.Д. Залесский.

рев-циясеннән соң Россия Почта һәм телеграфлар халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, халык комиссары урынбасары. 1918 дән Кызыл Армия Ген. штабы академиясе комиссары. 1920 дә 1 нче атлы армиянең сәяси бүлеге башлыгы. 1923 тән Мәскәүдә фәнни һәм педагогик эштә. Мемуарлар авторы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мои первые шаги: Воспоминания старого подпольного работника // Пути революции. 1922. № 2; Борьба за Балтийский флот. М., 1925; Борьба за партию: В 2 вып. Л., 1925; Восемь побегов — двенадцать арестов. М., 1925; На партийном фронте между двумя революциями. М.–Л., 1925; На путях революции (1896–1906). М.–Л., 1925; Из воспоминаний подпольщика. Хар., 1931.

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. Залежский Владимир Николаевич // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗАЛЕ́НСКИЙ** Владимир Владимирович (27.1.1847, Полтава губ., Шахворостовка а. — 26.10.1918, Севастополь ш.), зоолог-эмбриолог, Петербург ФА акад. (1897, 1893 тән мөхбир әгъзасы). Харьков ун-тын тәмамлый (1867). Казан (1871–81) һәм Новороссийск (Одесса ш., 1882–97) ун-тлары профессоры, 1897 дән Петербург ФАнең Зоология музее директоры, бер үк вакытта 1901 дән Севастополь биостанциясе директоры. Хезмәтләре кайбер умырткалылар (Идел чөгәсе) төркеменең һәм Кабан күле, Казан тирәсендәге башка сулыклардагы күпчелек умырткасызларның яралгы үсешенә карый. И.И.Мечников һәм А.О.*Ковалевский* тарафыннан эшләнгән чагыштырма эмбриологик эволюция юнәлешен үстерә. Сальпаларда (иркен йөзүче колониаль хайваннар) фолликуляр бүленү дип аталган күренешне язып чыга. Бу вакытта үсешнең беренче стадияләре һәм төп әгъзаларга нигез салыну аталанмаган фолликуляр күзәнәкләр ярдәмендә тормышка ашырыла. Божралы суалчаннарда баш нерв ганглиен (төенен) һәм умырткалыларда баш мие үсешенең үзенчәлекләрен күрсәтә.

Х е з м.: Материалы к флоре водорослей Казанской губернии // Приложение к протоколу № 178 отчёта о деятельности Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те в 1-м десятилетии (1869–79) его существования. К., 1879; История развития стерляди (Acipenser ruthenus) // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1878. Т. 7, ч. 3; 1880. Т. 10, вып. 2.

*Әд.:* Н а с о н о в Н.В. Владимир Владимирович Заленский: Некролог // Изв. РАН. Сер. 6. 1919. Т. 13, ч. 2; Биологи: Биогр. справ. Киев, 1984.

**ЗАЛЕ́ССКИЙ** (Залеский) Владислав Францевич (30.1.1861, Казан — 15.2.1922, Томск ш.), икътисадчы, хокук белгече, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, сәяси икътисад д-ры (1899), хакыйкый статский советник (1908). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тының физ.-матем. (1885), юридик (1889) ф-тларын тәмамлый. 1889–97 елларда Казан губернасы Лаеш округының шәрәфле җәмәгать судьясы. Бер үк вакытта 1890–94 тә Казан мәхкәмә палатасы округында антлы вәкил ярдәмчесе, 1894–1900 дә антлы вәкил. 1893–95 тә Казан ун-тының сәяси икътисад һәм статистика каф. приват-доценты, 1895–1900 дә доценты, 1900–01 дә экстраординар профессоры, 1901–19 да фәлсәфә энциклопедиясе һәм тарихы каф. ординар профессоры. Моннан тыш, 1900 елларда Казан губернасы земствосында бәяләү бюросы мөдире, крәстиян бюджетларын өйрәнү һәм җир биләмәләрен бәяләү мәсьәләсе б-н шөгыльләнә. Карашлары буенча — уң монархист. Парламентаризм һәм либерализм идеяләрен тәнкыйтьли, аларны Россиядә куллану мөмкин түгел дип исәпли. 1905 нең декабреннән «Рус патша-халык берлеге»нең («Царско-народный русский союз») һәм «Рус халкы берлеге»нең («Союз русского народа») Казан бүлекләрен оештыручыларның берсе һәм рәисе, «Черносотенец», «Сошники» (1906–07), «Предвыборная газета» (1912) г-таларын нәшер итә.

З. Казанда еш кына монархистлар чыгышларын оештыра һәм аларда катнаша. 1917 елгы Февр. һәм Окт. рев-цияләренә кискен каршы чыга, аклар хәрәкәтен яклый; Казаннан Себергә кача. 1919 дан Томск ун-ты профессоры. З.ның икътисадка караган төп хезмәтләре «Кыйммәт турындагы тәгълимат» («Учение о ценности», 1893), «Кыйммәтнең дөньяви кануны» («Мировой закон ценности», 1894), «Кәгазь-акча әйләнеше теориясе» («Теория бумажно-денежного обращения», 1896), «Капитал табышының килеп чыгышы турында тәгълимат» («Учение о происхождении прибыли на капитал», разделы 1–2, 1893–98 — кыйммәтнең хезмәт теориясен кире кагуга һәм табышның хезмәт куймыйча ирешелгән керем буларак законлыгын дәлилләүгә багышлана. Хокук теориясе һәм фәлсәфәсенә караган хезмәтләр, ш.и. «Хакимият һәм хокук. Субъектив хокук фәлсәфәсе» («Власть и право. Философия субъективного права», 1897), «Хокук фәлсәфәсе тарихыннан лекцияләр» («Лекции истории философии права», 1902), «Хокук энциклопедиясеннән лекцияләр» («Лекции энциклопедии права», вып. 1–4, 1902–03) авторы. З. — Казан ун-ты тарихы белгече, «Казан Император университеты хокук факультетының 1805–1903 еллардагы тышкы тарихының аеруча мөһим мәгълүматларга караган хокук фәлсәфәсен укыту тарихы» («История преподавания философии права в Казанском Императорском университете в связи с важнейшими данными внешней истории юридического факультета 1805–1903 гг.», 1903) монографиясе авторы. Күп тапкырлар Казан чиркәү тарих-археология җәмгыяте җыелышларында докладлар б-н чыгышлар ясый, төбәк тарихына багышланган «Борынгы Казан истәлекләре» («Из казанской старины», 1910), «XVIII йөздә Казан төбәге әҗнәбиләрен агарту тарихына карата» («К истории просвещения инородцев Казанского края в XVIII столетии», 1911) дип аталган хезмәтләрен бастыра. З.ның Россия һәм чит илләр материалларына нигезләнгән «Төп Көнбатыш Европа дәүләтләрендә законда һәм гамәлдә ярлыларны кайгырту системасы» («Система призрения бедных в законодательстве и практике главнейших западноевропейских государств», 1912), «Тәрбиячесез һәм ташландык хәлдәге балаларны кайгырту» («Попечение о беспризорных и покинутых детях», 1916) кебек хезмәтләрендә тәрбиячесез балалар проблемасы анализлана. З. ш.у. а.х. эволюциясе, община җир биләве мәсьәләләренә, урта һәм югары мәктәп реформасына һ.б. караган хезмәтләр һәм «Сугыш кайтавазлары» («Отклики войны», 1915) исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

Х е з м.: Крестьянские бюджеты: В 2 вып.., К., 1899–1900; К вопросу о реформе средней школы. К., 1900; Гражданская практика казанских судебных установлений начала XIX века. СПб., 1905; Грюнвальдский бой — прообраз единения славян: К тысячелетию борьбы славян с немцами. К., 1911; Первое дополнение к лекциям истории философии права. К., 1912; Лекции энциклопедии права: Доп. 1–2. К., 1912–13; Казанские лашманы. [У.к.], [Е.к.].

*Әд.:* З а л е с с к и й В.Ф. Опыт характеристики. Хар., 1914; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета: 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗАЛЕ́ССКИЙ** Михаил Дмитриевич (3.9.1877, Орёл ш. — 22.12.1946, Ленинград), палеоботаник, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1929). Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1900), Екатеринославск югары тау уч-щесендә, 1903–40 та — Россия Геол. ком-тында һәм Мәскәү, Ленинград геол. ин-тларында эшли. Хезмәтләре Пермь һәм ташкүмер утырмаларының борынгы флорасына һәм күмер ятмалары геологиясенә карый. Чагыштырма анатомик алымнар кулланып, үсемлекләрнең күп сандагы яңа ыругларын һәм төрләрен ача. Татарстан, Донбасс, Урта Азия һ.б. регионнар терр-ясенең борынгы флорасына нигезле тикшеренүләр үткәрә.

Х е з м.: Пермская флора Уральских пределов Ангариды. Л., 1927.

**ЗА́ЛЮШЕВ** Мөнир Әмир улы (4.3.1956, Казан), кинооператор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998). С.А.Герасимов исем. Бөтенроссия кинематография ин-тын (О.А.Родионов остаханәсе, 1984) тәмамлый. 1974 елда оператор ассистенты («Кырлай» фильмын төшерүдә катнаша), 1982 дән Казан телевидение студиясендә кинооператор, 1992 дән «Татарстан» ГТРКда кинооператорлар бүлеге мөдире. 100 дән артык документаль һәм телевизион фильм төшерә. Аның мөстәкыйль рәвештә эшләгән беренче фильмы «Зилә Сөнгатуллина җырлый» (реж. Р.Кадыйрова) 1982 дә чыга, 1983 тә реж. В.И.Беспалов б-н бергә «Мәхәббәт турында» («Любви негромкие слова») һәм «Нефть

тудырган шәһәр» («Город, рождённый нефтью»; ТР Кинематографистлар берлеге дипломы, 1983) фильмнарын төшерә. Реж. Р.Хисамов б-н эшләнгән «Иске гармун» («Старая гармонь», 1988), «Без кайттык» («Мы вернулись»), «Без — дусларыбыздан соң яшәүчеләр» («Мы, пережившие друзей») — икесе дә 1989, әфган сугышында катнашучылар язмышы турында, «Күке балалары» («Кукушкины дети», 1990), «Тормышка талон» («Талоны на жизнь», 1991) фильмнары үткен публицистик рухлары б-н аерылып торалар. 1997 елда реж. А.Ю.Долбин б-н бергәләп «Виртуаль тәэсирләр» («Виртуальные впечатления») дигән гомуми исем астында рәссам Илдар Ханов, Казандагы авангардист рәссамнарга, Иерусалимга баручыларга багышланган 20 видеофильм төшерә. 1989 да комп. Р.Кәлимуллинның «Болгар дәрвише» («Странник в Булгаре», реж. В.А.Чеботарёв), 1994 тә Татар опера һәм балет театрының Голландиядә узган гастрольләре турында тулы метражлы «Театрның комментарийлы автопортреты» («Автопортрет театра с комментариями», реж. Р.Г.Хисамов), 1999 да «Пушкин Казанда» («Пушкин в Казани», реж. А.Ю.Долбин) документаль фильмнарын эшли. Реж. Ә.Зарипов б-н бергәләп «Урын» (1999), «Капка» (2001) нәфис фильмнарын, реж. Н.В.Прокофьев б-н «Ак барс» су асты көймәсе экипажы турында «Диңгездә дә синең юлларың» («И в морях твои дороги») документаль фильмын (2000) төшерә. Берничә ел хөкүмәт вәкилләренең чит илләрдәге эшләре турында хроникаль фильмнар, ш.и. ТР Президентының АКШка, ТР Премьер-министрының Франция һәм Австралиягә визитлары турында, 2000 дә реж. Р.Г.Хисамов б-н бергәләп «Хакимият — ул минем эшем» («Власть — моя работа») фильмын эшли. З. үз иҗат палитрасын төрләндерә, режиссёрның төп идеясен төрле чагылдыру чаралары б-н баета, шуның б-н төгәл композиция сурәтләре барлыкка китерә. 1999 да ТРның иң яхшы кинооператоры дип таныла һәм ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бүләгенә лаек була.

*Е.П.Алексеева.*

**ЗАЛЯ́ЛОВ** (Җәләлов) Азат Михаил (Мирза) улы (15.5.1929, Тәтеш ш. — 9.6.2004, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1978), проф. (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1951). 1954–80 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1980 елдан Казан мед. ун-тында. 1980–90 да фәнни коммунизм каф. мөдире, 1990–96 да сәясәт тарихы һәм социология каф. профессоры. 1996 дан Мәскәү коммерция ун-ты ф-лы — Казан ин-тында. 1997 дән дөнья икътисады каф. мөдире. Хезмәтләре комсомол тарихы, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү, Татарстанның социаль-икътисади үсеше мәсьәләләренә карый. З. — «Татарстан пролетар революциянең җиңүе өчен көрәштә» («Татария в борьбе за победу пролетарской революции», 1957), «Татарстан Бөек Ватан сугышы чорында» («Татария в период Великой Отечественной войны», 1963), «1927–1937 елларда Татарстан АССРның авыл хуҗалыгын күмәкләштерү» («Коллективизация сельского хозяйства Татарской АССР — 1927–1937», 1968) документаль җыентыклары төзүчеләренең һәм мөхәррирләренең берсе.

Х е з м.: Комсомол Татарии в бою и труде. К., 1968; Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974.

**ЗАМА́Н** (лингв.), эш-хәлнең сөйләм барышына мөнәсәбәтен белдерә торган фигыль грамматик категориясе. Ул төрләнә, телдә бер-берсенә каршы куелган формалар системасы аша белдерелә. Фигыль заманнары турыдан-туры кулланылганда (абсолют З.), вакыйганы сөйләү моментына мөнәсәбәттә билгелиләр, мөнәсәбәтле кулланылганда (мөнәсәбәтле З.), вакыйгалар башка эш-хәлнең заманына нисбәттә билгеләнә. Татар телендә мөнәсәбәтле З. юнәлеше затланышсыз фигыль формаларына (*сыйфат фигыль* һәм *хәл фигыль*), абсолют З., башлыча, хикәя фигыль формаларына хас. Заман формалары өч буынлы рәт тәшкил итә һәм сөйләү моменты б-н туры килә торган эш-хәлне (хәзерге З.), сөйләү моментыннан алда булган эш-хәлне (үткән З.), сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлне (киләчәк З.) белдерә. Бу мәгънәләр татар телендә түбәндәге формалар б-н белдерелә: хәзерге З. кушымчалары **-а/-ә** (бара, килә); **-ый/-и** (укый; сөйли); үткән З. кушымчалары: **-ды/-де** (барды, килде); **-ган/-гән** (барган); **-а иде** (бара иде); **-ган иде** (барган иде); **-а торган иде** (бара торган иде); киләчәк З. кушымчалары: **-р/-мас** (барыр, бармас); **-ачак** (барачак); **-ачак иде** (барачак иде).

Татар телендә үткән һәм киләчәк З. формаларының күплеге алар арасындагы аспектуаль һәм модаль мәгънәләр аермасы б-н аңлатыла (тәмамланганлык-тәмамланмаганлык, процесслык-нәтиҗәлелек, билгесезлек-катгыйлык һ.б.). Мәс., **-ды/-де** кушымчалы билгеле үткән З. үткәндәге, тәмамланган, сөйләүче үзе күргән, катгый, билгеле эш-хәлне белдерә (ул килде); нәтиҗәле (билгесез) үткән З. нәтиҗәлелек мәгънәсен билгесезлек төсмере б-н белдерә (ул килгән); **-ган иде** күптән үткән З. формасы сөйләү моментыннан күпкә алда булган эш-хәлне белдерә (килгән иде). З. категориясе системасын тәшкил иткән тугыз заман формасыннан тыш, татар телендә шактый гына тасвирлама формалар (барган булган, барачак булган, бара торган булган һ.б.) һәм темпораль мәгънәле (барганы бар, барганым юк) төрле грамматик конструкцияләр бар.

*Әд.:* Т у м а ш е в а Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1964; Татар грамматикасы. К., 2002. Т. 2.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; С е р е б р е н н и к о в Б.А. Система времён татарского глагола. К., 1963; Т у м а ш е в а Д.Г. Татарский глагол. К., 1986.

*Ф.М.Хисамова.*

**«ЗАМА́Н»,** Зәй р-нындагы а.х. җитештерү кооперативы. 1973 елда «Кызыл Маяк» к-зында (1990 нан «Зәй» с-зы) мөгезле эре терлек симертү буенча төзелгән р-н хуҗалыкара берләшмә җирлегендә 1998 дә оештырыла. 2003 тән «Зәй шикәре» агрофирмасы» җәмгыяте составында. Үзәк утары — Поручиково а.; Зур Батрас, Канаш, Нератовка, Сарапала авылларын берләштерә. Эшләүчеләр саны якынча 300 кеше. 2002 дә а.х. җирләренең мәйданы — 7338 *га*, ш.и. сөрүлек җирләре — 6290 *га*. Хуҗалыкның төп тармагы — терлекчелек (ит җитештерү). 4,5 меңнән 8,5 мең башка кадәр мөгезле эре терлек тотыла. Бөртекле культураларның уңышы (1 *га* дан *ц*): 1992 дә — 40,2, 1997 дә — 50,3, 2001 дә — 64,2, 2002 дә — 56,1. 100 *га* а.х. җирләренә ел саен 110 *ц* дан 200 *ц* га кадәр ит җитештерелә. Хуҗалык җитәкчеләре: З.Н.Галиуллин (1973–86), Ф.А.*Вәлиев* (1986–99); 2000 нән — А.Н.Лотфуллин.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ЗАМА́Н-ТАТАРСТА́Н»** («Zaman-Татарстан»), иҗтимагый-сәяси, мәдәни-агарту газетасы. 1993 елның апреленнән 2004нең июненә кадәр Казанда атнага 1 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Башта Татарстан-Төркия г-тасы, «Вакыт» АҖ органы. Төрле елларда мөхәррирләре — М.Мурат, М.Палабыек, Т.Доган, Ю.Саглам. Еш язышa торган авторлар арасында — М.И.Әхмәтҗанов, Р.В.Әхмәтҗанов, Р.И.Вәлиев, Р.К.Гатауллин, Ф.С.Гыйззәтуллина, Н.М.Гыйматдинова, Т.А.Миңнуллин, Ф.Г.Яруллин. Дөнья хәлләре яктыртыла, мөселман һәм төрки илләр халыкларына, Татарстан б-н Төркия арасындагы мөнәсәбәтләргә зур игътибар бирелә. Татарлар күпләп яши торган төбәкләрдән алынган мәкаләләр басыла. Газетада төрки һәм татар әдәбиятларына багышланган аерым бүлекләр була, гаилә мәсьәләләре, сәламәтлекне саклауга, төрек телен өйрәнүгә караган мәсьәләләр яктыртыла. 2003 елның июленнән газета татар басмасы буларак нәшер ителә.



Х.З.Заманов.

**ЗАМА́НОВ** Хәсән Заман улы (1912, Уфа губ., Минзәлә өязе Куҗәкә а. — 20.11.1956, Свердловск өлкәсе Покровск-Уральск штп), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), рядовой. Сугышка кадәр Ижевск машина төзелеше з-дында эшли. 1942 дән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 465 нче укчы полк автоматчысы (38 нче армиянең 167 нче укчы дивизиясе). Брянск һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең сентябрь–ноябрендә Киев өчен барган сугышта (1943) батырлык күрсәтә. 3 ноябрьдә Киевның Пуща-Водица бистәсе янындагы сугышта авыр яралана. Сугыштан соң Ижевск шәһәрендә, аннары Покровск-Уральскида яши. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К у л е м и н И.Г. Героев наших имена. Ижевск, 1975; Р а к и п о в Ш.З. Хранить вечно. К., 1980; К у л е м и н И.Г., С е н т е м о в а Л.Ф., И с л е н т ь е в а Р.А. Герои Советского Союзы — наши земляки. Устинов, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАМА́НОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. **Аит Бики улы** (1731–97), ике династия — З. һәм *Аитовларның* сәүдә династияләрен нигезләүче. Тире эшкәртү б-н шөгыльләнгән. Аның уллары: 1) **Исай Аит улы** (? — 1812 елдан соң) Иске Татар бистәсендә сабын кайнату з-ды хуҗасы (1812 дә 5 казан эшләгән, ел саен 5 мең пот сабын җитештергән). 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышын бастыруда катнашканы өчен Андреев тасмалы алтын медаль б-н бүләкләнә. Бертуганы Даут б-н Икмәк базарында (шәһәрнең үзәк өлешендә) 12 кечкенә кибет тота. **Хәят Исай улына** (? — ?) Иске Татар бистәсендә сабын кайнату з-ды мирас булып кала; **Әхмәт Исай улы** (? — ?) Пләтәндәге сабын кайнату з-ды хуҗасы (елына 5 мең пот сабын җитештерә). Икмәк базарында 5 кечкенә кибет тота. Эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен медальләр б-н бүләкләнә. Аның балалары - **Мостафа** һәм **Мөхәммәтвәли** сабын кайнату б-н шөгыльләнүләрен дәвам иттерәләр. Мөхәммәтвәли Яңа Татар бистәсендә кәҗүл з-ды тота. **Салих** Мостафа улы (? — 1868) 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, сабын кайнату з-ды, ике катлы агач йорт хуҗасы. Үлгәннән соң түли алмаслык бурычлы дип игълан ителә. 2) **Даут Аит улы** (? — 1805 ел тирәсе), Пләтәндәге шәм һәм сабын кайнату з-длары хуҗасы. Аның эшен улы **Йосыф** һәм оныгы **Мостафа** дәвам иттерә. Соңгысы 1842 елда Казанда коелма шәмнәрне иң күп җитештерүчеләрнең берсе булып санала.

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**ЗАМА́РИН** Лев Григорьевич (6.3.1924, Самара ш. — 2003, шунда ук), вет. табибе, вет. фән. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1984, 1995). 1941–42 елларда Саратов ун-тында укый. 1946 да Мәскәү Хәрби-вет. академиясен тәмамлый һәм СССР Эчке эшләр министрлыгы системасында вет. табибе булып эшли. 1947–69 да Саратов зоовет. ин-тында. 1969 дан Казан вет. ин-тында, 1971–92 дә терапия каф. мөдире. Хезмәтләре матдәләр алмашы бозылуга диагноз кую, югары продукцияле сыерлар һәм нәселле үгезләрне диспансерлау, а.х. терлекләрендә ашказаны-эчәк, респиратив авыруларны булдырмауга карый. Өч монография, югары уку йортлары өчен дәреслек, а.х. терлекләренең эчке авырулары буенча 12 методик кулланма автордашы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы морфологии и физиологии сельскохозяйственных животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1978. Т. 130; Кальциевый обмен в организме животных // Ветеринарное и зоотехническое обслуживание животноводства в новых условиях хозяйствования. К., 1989 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЗА́МОВ** Наил Кәлим улы (8.10.1940, Куйбышев ш.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, гамәли матем. каф. мөдире (1991–2007) һәм бер үк вакытта проректор, ректор вазифаларын башкара (2001–02). 2007 дән ректор киңәшчесе. Системалы анализ һәм мәгълүмат технологияләре каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре логик программалаштыруга, математик логикага карый. Предикатлар исәпләүнең классик формулаларының мәгълүм классы өчен хәлиткеч булган теоремаларны автоматик исбатлауның нәтиҗәле стратегиясен эшли; ш.у. модаль логикалар өчен резолюцион типтагыларына тулы исәпләү ясый, шуның нигезендә беренче мәртәбә пропозициональ модаль логикалар өчен нәтиҗәле чишелеш алгоритмнары төзелә. «*Известия высших учебных заведений. Математика*» ж-лының баш мөхәррире урынбасары (1979 дан). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Метод резолюций без скулемизации // Докл. АН СССР. 1987. Т. 293, № 5; Модальные резолюции // Изв. вузов. Математика. 1989. № 9; Deductive synthesis of Solutions for Technological Tasks // Journ. of Logic Progr. 1990. № 9 (автордаш); Resolution Methods for the Decision Problem // LNAT, Springer-Verlag. 1993. Т. 679.

**ЗА́МОВА** Мәрьям Вәли кызы (4.8.1911, Самара губ., Богырыслан өязе Иске Котлымбәт а. — 13.11.2003, Казан), хакимият эшлеклесе. Куйбышев энергетика техникумын (1933), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1957) тәмамлый. 1934–36 елларда 4 нче з-дта (Куйбышев ш.) техник-электрик. 1936 елдан «Казэнерго» район идарәсенең абонемент хезмәте башлыгы. 1941–47 дә Казан мед. инструментлары з-дында: электр-ремонт цехы башлыгы, баш инженер, җыю цехы башлыгы. 1947–51 дә 708 нче з-дта (Казан) баш энергетик, партия бюросы секретаре. 1951 дән КПССның Татарстан өлкә ком-тында җиңел сәнәгать бүлеге мөдире, 1952 дә ТАССР МС рәисе урынбасары. 1952–53 тә КПССның Казан шәһәр ком-ты секретаре, 1953 тән администрация һәм сәүдә-финанс органнары бүлеге мөдире. 1958–65 елларда хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма комитеты рәисе урынбасары. 1951–59 да ТАССР ЮС депутаты, бер үк вакытта 1955–59 да аның рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

**«ЗАПИ́СКИ ИМПЕРА́ТОРСКОГО КАЗА́НСКОГО ЭКОНОМИ́ЧЕСКОГО О́БЩЕСТВА»** («Казан Император икътисад җәмгыяте язмалары»), иҗтимагый-сәяси, фәнни журнал. *Казан икътисад җәмгыяте* органы. 1854–61 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. 1857 елга кадәр ай саен, 1858–59 да елга 3 әр кисәк (һәрберсендә 3 әр сан), 1860 тан аерым чыгарылыш (1860 та — 2 чыг., 1861 дә — 1 чыг.) булып чыга. Барысы 75 китап басылган. Төрле елларда мөхәррирләре — М.Я.*Киттары*, А.К.*Чугунов*, Е.С.Фальков. Казан ун-ты профессорлары һәм укытучылары: Казан икътисад җәмгыятенең хакыйкый әгъзалары, мөхбир әгъзалары, әгъза-комиссионерлары А.М.Бутлеров, И.К.Бабст, Н.П.Вагнер, С.В.Пахман, П.А.Пель, С.В.Степанов, ш.у. сәүдәгәрләр, сәнәгатьчеләр, табибләр, крәстияннәр һ.б. авторлар хезмәттәшлек итә. А.х. һәм мануфактура сәнәгатенә караган мәкаләләрдә Казан губернасы тормышына зур игътибар бирелә, яңа фәнни казанышлар, ачышлар пропагандалана. Хөкүмәт указлары, норматив-оештыру документлары, Казан икътисад җәмгыятенең эш хисаплары, җыелыш һәм утырышлар беркетмәләре, әгъзалар исемлекләре, җәмгыять эшчәнлегенә кагылышлы тарихи материаллар басыла. Кушымта итеп икътисад


ЗАПИСКИ
ИМПЕРАТОРСКАГО
КАЗАНСКАГО ЭКОНОМИЧЕСКАГО
ОБЩЕСТВА.
ГОДЪ ПЕРВЫЙ.
КАЗАНЬ.

«Записки Императорского Казанского экономического общества» журналы.

һәм хуҗалык мәсьәләләренә кагылышлы басмалар чыгарыла. Фәнни хезмәтләр, мәкаләләр, уйлап табучылар эшчәнлегенә, тәҗрибәләргә, а.х. күргәзмәләре турындагы язмаларга урын бирелә. Сәнәгать, сәүдә, һөнәрчелек, агрономия фәнен үстерү, инженерлык, а.х. машиналары һәм коралларын камилләштерү һәм гамәлгә кертү мәсьәләләренә багышланган мәкаләләргә аерым игътибар бирелә. Журнал крепостнойлыкка каршы караштагы, социаль-икътисади реформалар үткәрүне яклый, халыкка аң-белем бирү кирәклегенә басым ясый. Алпавытларның әхлагы һәм тормыш-көнкүреш рәвеше тәнкыйтьләнә. Н.А.Демерт, П.А.Муллов, П.А.Перцларның публицистик мәкаләләрендә һөнәрчеләр, фабрика эшчеләре һәм крәстияннәрнең эш һәм тормыш шартлары мәсьәләләре күтәрелә. 1858 елдан ж-лда Россиядә крепостной хокукны бетерү кирәклеге турындагы бәхәсле материаллар күренә башлый. 1858–59 елларда «Библиография» бүлегендә мөхәррир ярдәмчесе Муллов Россиядә чыга торган вакытлы матбугат басмаларына күзәтүләр ясый һәм анализ бирә.

*Әд.:* Н у р е е в а Ф.Ф. К изучению «Записок Казанского экономического общества» как исторического источника // Сб. аспирантских работ. Гуманитарные науки. История. К., 1975; У т к и н А. Либеральные идеи на страницах казанской прессы накануне отмены крепостного права (1856–1861 гг.) // Фән һәм мәктәп — Наука и школа. 2000. № 8/9; Записки Казанского экономического общества. 1854–1861: Указ. содерж. К., 1990.

*Г.Р.Заманова.*

**«ЗАПИ́СКИ ЦЕНТРА́ЛЬНОГО АРХИ́ВА ТАТА́РСКОЙ СОЦ. СОВ. РЕСПУ́БЛИКИ»** («Татарстан Совет Соц. Республи-

касы Үзәк архивы язмалары»), журнал. ТАССРның Үзәк архив идарәсе органы. 1925–33 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. 1925 елның сентябрь-октябрендә Е.Жаков мөхәррирлегендә беренче сынау саны дөнья күрә. Даими рәвештә «Бюллетень Центрального архивного управления Татарской Республики» исемендә 1928 нең 5 июнендә чыга башлый; 1933 тә «Центральный архив Татарстана» исемендә басыла. Барысы 23 сан (сынау өчен чыкканы б-н бергә). Мөхәррирләре булып архив идарәсе җитәкчеләре М.Зайцев, И.Васильев, Г.Әбдрәшитов, Е.Медведев эшли. Даими авторлар арасында Казан архивлары хезмәткәрләре А.Волочков, А.Максимов, Е.Медведевлар була. Беренче саннары кульъязмада була, аннары машинкада басыла һәм ташбасма ысулы б-н басыла. Төп бүлекләре: «Рәсми бүлек», «Мәгълүмат-инструкторлык бүлеге», «Архивлар тормышы», «Почта тартмасы», «Библиографик күрсәткеч» һ.б. Идарә журнал алдына ТССР үзәк, район, кантон ведомстволары архивлары б-н тыгыз элемтә урнаштырып эшләү бурычын куя. Баштарак анда архив эшенә кагылышлы законнар чыгаручы органнар актлары, боерыклар, күрсәтмәләр, циркулярлар һәм шуларга аңлатмалар басыла. 1930 ның маеннан 1931 нең мартына кадәр «акча һәм вакыт» булмау сәбәпле, журнал чыкмый тора. 1931 дән ул басманың проблематикасын шактый киңәйтеп, рәсемле булып чыга башлый, архив чыганакларын фотокопияләр һәм аңлатмалар б-н бирә, аерым архив фондларына күзәтүләр ясый. Тарихи темага караган мәкаләләр, татарлар арасында миссионерлык эшенә кагылышлы, патша Россиясендә татар халкының хәле, Казан губернасында сыйнфый көрәш мәсьәләләре турындагы мәкаләләр басыла; Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы, фабрика һәм заводлар тарихына, Ульяновлар гаиләсе әгъзалары биографиясенә һ.б. караган материалларга аерым игътибар бирелә. 1931 дән ТАССРда архивлар аппаратын үзгәртеп кору һәм латин графикасына күчү кампаниясе башлану сәбәпле, журналда татар теленә тәрҗемә ителгән мәкаләләр дә басыла. Архив хезмәткәрләренең эше артык күп булганлыктан, журнал чыгудан туктый. 1995 елдан ТР МК каршындагы Баш архив идарәсе «*Гасырлар авазы — Эхо веков*» исемендә яңа ж-л чыгара башлый.




«Записки Центрального архива Татарской Соц. Сов. Республики» журналы.

*Әд.:* Садыкова Р., Шамсутдинова Р. Продолжая традиции ... // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 1/2.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ЗАПО́ЛЬСКИЙ** Иван Ипатович (Эрнест Августович) (1773 — 20.12.1810, Казан), философ, физик, математик, җәмәгать эшлеклесе. Севск һәм Белгород руханилар семинарияләрендә, Киев руханилар академиясендә, 1796 дан Мәскәү ун-тында белем ала. 1799–1804 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укыта. 1805 тән Казан ун-ты адъюнкты, бер үк вакытта физ. кабинеты мөдире, проф. (1810). 1808 дә рус һәм татар телләрендә атналык «*Казанские известия*» («Казан хәбәрләре») г-тасын чыгару проектын әзерли, 1809 да газетаны рус телендә чыгаруга рөхсәт алуга ирешә. Системалы метеорологик күзәтүләр алып баруны оештыручы. З. шәкертләре арасында — Н.И.Лобачевский, И.М.Симонов, Д.М.Перевощиков (соңыннан Мәскәү ун-ты ректоры).

Х е з м.: Рассуждения о самолюбии // Тр. Казан. об-ва любителей отечественной словесности. К., 1815.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподователей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

**ЗАРЕ́ЦКИЙ** Марк Давидович (24.1.1937, Киев — 9.3.2003, Казан), шагыйрь, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Хабаровск шәһәре пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Казанда яши. 1964–92 елларда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлегенең өлкән мөхәррире булып эшли. Шигырьләре 1955 елда басыла башлый. Аларга заманны фәлсәфи яктан аңларга омтылу, афористик стиль хас. «Сүз» («Речь», 1987), «Дәрт» («Азарт», 1991) исемле поэтик җыентыклар авторы. Дәрдемәнд, Г.Тукай, Һ.Такташ, С.Хәким, Н.Дәүли, Ә.Маликов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Хаиров А. Весна на Заречной улице // Казань. 2003. № 3; Черняева Е. Учитель // шунда ук. 73 б.

**ЗАРЕ́ЧНЫЙ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 32 *км* көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 395 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 43%, руслар — 27%, чуашлар — 27%) яши. Урман сәнәгате хуҗалыгы. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1936 да Октябрь урман сәнәгате хуҗалыгы җирлегендә төзелә. 1964 нең 23 апрелендә хәзерге исеме б-н теркәлә. Оештырылган көннән Октябрь (1997 нең 1 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1970 тә — 701, 1979 да — 536, 1989 да — 424, 2002 дә — 379 кеше.


**ЗАРЕ́ЧЬЕ** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2008 елда 67 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 76%) яши. Кырчылык, мөгезле эре терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1940 елларда Вахитов исем. с-зның 2 нче бүлекчәсе посёлогы буларак нигез салына, 1962 нең 28 сентябреннән хәзерге исемен йөртә. Оештырылган көннән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1958 дә — 179, 1970 тә — 178, 1979 да — 168, 1989 да — 96, 2002 дә — 78 кеше.

**ЗАРИ́НСКИЙ** Платон Егорович (16.2.1830, Түбән Новгород — 12.12.1881, Казан), дин эшлеклесе, тарихчы. Түбән Новгород руханилар семинариясен тәмамлый (1848). 1848–58 елларда Мәскәүдә, Киев, Ярославль һ.б. шәһәрләрдә хәрби рухани. 1858–64 тә Казан дары з-дының Никольский хәрби чиркәве башлыгы (настоятеле). Бер үк вакытта 1861–64 тә з-д каршындагы халык мәктәбен оештыручы һәм аның җитәкчесе. 1864 тән Казан Кремленең Спас хәрби чиркәве протоиерее. Археология казынулары һәм тикшеренүләре үткәрә, Казан Кремлендә музей оештыра. Хезмәтләре урта гасырлар Казан шәһәре һәм Кремле тарихына, өлкән яшьтәгеләрне укырга-язарга, дин сабакларына өйрәтү методикасына карый. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1878 дән).


Х е з м.: Заметка учителя народной школы относительно деятельности комитета грамотности по поводу статей об этом предмете, появляющихся в русских периодических изданиях. СПб., 1864; Краткая историческая записка о Казанской кремлёвской во имя Спасителя (военной) церкви в г.Казани. К., 1870; Очерки древней Казани. К., 1877; Церковные древности г.Казани. К., 1877; Апология исламизма новейшей английской работы. К., 1878; Сборник исторических и археологических исследований о Казанском крае. К., 1880; Ч. 1, вып. 1.

*Әд.:* Агафонов Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Ч. 1. *Е.Б.Долгов.*

**ЗАРИ́ПОВ** Әхтәм Исмәгъҗан улы (15.7.1935, БАССРның Илеш р-ны Таҗи а.), театр һәм кино актёры, телевидение һәм радио режиссёры, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). М.С.Щепкин исем. югары театр уч-щесен (1961), Бөтенсоюз телевидение һәм радиотапшырулар хезмәткәрләре ин-тын (Мәскәү, 1972) тәмамлый. Актёрлык эшчәнлеген 1961 елда Татар акад. театры сәхнәсендә башлый. Төп рольләре: Габдрүш («Без аерылышмабыз», Ш.Шаһгали), Сираҗи («Банкрот», Г.Камал), Дәүли («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Әлмөхәммәт («Әни килде», Ш.Хөсәенов). З. катнашкан радиоспектакльләр: «Беренче укытучы» (Ч.Айтматов), «Төнге тамчылар» (Ә.Еники), «Язгы җилләр» (К.Нәҗми) һ.б. 1972 дән «Татарстан» ГТРКның Казан телевидение студиясендә эшли: нәфис тапшырулар режиссёры, 1987 дән баш режиссёр, 1994 тән куючы кинорежиссёр. Телефильм һәм телеспектакльләрнең сценарийлары авторы һәм куючы режиссёры, телевизион очерклар, юмористик һәм лирик язмалар, замандашларының һәм атаклы татар актёрларының иҗат портретлары турында «Замандаш» тапшырулар циклының авторы. Төп нәфис телефильмнары: «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт, 1978), «Җомга көн кич белән» (А.Гыйләҗев, 1984), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал, 1984), «Намус» (Г.Бәширов, 1985), «Яшьтәшләр» (Г.Ибраһимов



З.З.Зарипов.



И.К.Зарипов.

әсәрләре буенча, 1987), «Габбас хәзрәт» (Г.Ахунов, 1991), «Килен киленне сынар» (Ә.Зарипов, 1995), «Истәлек өчен Гыйлемханга» (Р.Мөхәммәдиев, 1995), «Тукай» (Ә.Зарипов, 1996), «Могҗиза» (Ә.Зарипов, 1998), «Кияү» (Т.Галиуллин, 1999), «Капка» (Ә.Зарипов, 2001).

**ЗАРИ́ПОВ** Габделхак Зариф улы (1902, Казан губ., Казан өязе Урта Пошалым а. — 29.6.1938), партия хезмәткәре. 1923 елдан комсомол эшендә, 1926 да ВЛКСМның Арча кантоны, 1927–31 дә Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1931 дән ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, соңрак — Иркутск шәһәрендәге металлургия з-дында партия ком-ты секретаре. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Ф.С.Хәбибуллина.*

**ЗАРИ́ПОВ** Данис Зиннур улы (26.3.1981, Чиләбе ш.), спортчы (хоккей), Россиянең атказ. спорт остасы (2009). «Мечел» (Чиләбе ш.) хоккей командасында тәрбияләнә, «Мечел» (1996–98, 1999–2001), «Звезда» (Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл ш., 1997–98), «Свифт Каррент Бронкос» (Канада, 1998–99), «Ак Барс» (Казан, 2001 елдан) командаларында уйный. Россия (2006, 2009), дөнья (2008, 2009) чемпионы, Европа чемпионнары кубогы (2009), Континенталь кубок (2008), Континенталь хоккей лигасының Гагарин кубогы (2009), дөнья чемпионатының бронза (2007), Россия чемпионатларының көмеш (2002, 2007) һәм бронза (2004) медальләре иясе, Россия чемпионатының иң яхшы снайперы (2007), «Алтын кәшәкә» призы (2009) иясе. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә.

**ЗАРИ́ПОВ** Зиннур Зариф улы (10.3.1915, БРның хәзерге Дүртөйле р-ны Түбән Әлкәш а. — 11.7.1995, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (29.4.1944, 21.10.1944, 29.6.1945), старшина (1945). Туган авылында кохозда эшли. 1941 елның августыннан Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 623 нче артиллерия полкының артиллерия расчёты командиры (38 нче армиянең 183 нче укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Брянск, Воронеж, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Киев оборона операциясендә (1941), Донбас операциясендә (1942), Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Украина, Польшаны азат итүдә, Прага һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 19–20 мартында Винница шәһәре (Украина ССР) өчен барган сугышларда (расчёт б-н командалык итеп, 7 ут ноктасын юкка чыгара); 1944 нең 25–27 июлендә Львов шәһәре (Украина ССР) өчен барган сугышта (дошманның 5 орудиесен, 2 миномётын, 4 дзотын, 8 күзәтү пунктын юк итә); 1945 нең 12–13 февралендә Струмень шәһәре (Польша) янындагы сугышта (орудиеләрне сафтан чыгара) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Дүртөйле посёлогында яши. 1 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 5; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАРИ́ПОВ** Зөфәр Ибраһим улы (5.9.1950, Казан), җылылык физикасы галиме, техник фән. д-ры (2005), проф. (2007). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук җылылык техникасының технол. нигезләре кафедрасында эшли. Хезмәтләре энергетикада һәм химия технологиясендә җылылык йөрткечләрнең үзлекләрен өйрәнүгә карый. З. сыеклыкларның җылылык үзлекләрен исәпләү һәм фаразлау алымнарын аларның халәт параметрлары үзгәрешенең киң диапазонында эшли, автоматлаштырылган тәҗрибә җайланмалары төзи. Этилен рәтендәге чикле бром-алмашынулы углеводородларның һәм чиксез углеводородларның термик һәм физик-җылылык үзлекләрен 298–363 К темп-ралар һәм 196 *МПа* гә кадәр басымнар аралыгында, полиэтилен һәм полипропиленгликольләрнең, полиэтиленгликольләрнең бинар һәм өчле катнашмаларының, селтеле металлар тозларының судагы эремәләрен 298–363 К темп-ралар һәм 147 *МПа* гә кадәр басымнар аралыгында физик-җылылык үзлекләрен тикшерә.

Х е з м.: Обобщение экспериментальных данных по термическим коэффициентам бромзамещённых и непредельных углеводородов этиленового ряда // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2003. № 1–2 (автордаш); Теплоёмкость и температуропроводность водных растворов солей щелочных металлов в широком диапазоне давлений // Журн. физ. химии. 2004. Т. 48, № 5 (автордаш).

**ЗАРИ́ПОВ** Изаил Харис улы (27.2.1927, хәзерге Сарман р-ны Зур Нөркәй а. — 18.12.1999, Әлмәт ш.), журналист, язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Рус телендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1968). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1953 елдан «Татбурнефть» трестының бораулау бригадаларында эшли. 1954–57 дә «Знамя труда» (Әлмәт ш.) г-тасында бүлек мөдире, 1957–60 та «Комсомолец Татарии» г-тасы үзхәбәрчесе. 1963–68 дә Лениногорск телевидениесе студиясендә иҗтимагый-сәяси тапшырулар хәбәрчесе, соңрак өлкән мөхәррир вазифаларын башкара. 1968–75 тә ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тының Лениногорск һәм Әлмәт шәһәрләрендәге студияләрендә өлкән мөхәррир. 1977–80 дә оештыру-хуҗалык эшендә. 1950 еллар башында респ-ка матбугатында һәм күмәк җыентыкларда язмалары басыла башлый. З.ның очерк һәм хикәяләре нефть чыга торган урыннарны үзләштерү, шул өлкәдә эшләгән алдынгыларның хезмәт уңышлары турында. Татарстан нефтьчеләренә багышланган «Бораулаучылар» («Буровики», 1957), «Күмәк иҗат» («Коллективное творчество», 1961), «Остакуллар» («Мастер», 1975), «Тугызынчы вал» («Девятый вал», 1982), «Тормыш юлдашларым» («О тех, с кем прожита жизнь», 1997), «Елхов кешеләре» («Слово о елховцах», 2000) китаплары укучыларга яхшы билгеле.

*Г.М.Габделхакова.*


**ЗАРИ́ПОВ** Илдар Касыйм улы (15.11.1939, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976), РСФСРның атказ. рәссамы (1983), РФнең халык рәссамы (2002). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1961), В.И.Суриков исем. Мәскәү сынлы сәнгать ин-тын тәмамлый (1968), Д.К.Мочальскийда укый, Мәскәүдә СССР САнең Нәкышь остаханәсендә Г.М.Коржевта осталык мәктәбе уза (1968–70). РСФСР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1970). Казан сынлы сәнгать студиясендә укыта (1970–75), РСФСР Рәссамнар берлегенең идарә әгъзасы (1972–80). З.ның үзенчәлекле иҗаты Россия сынлы сәнгать тарихына бигрәк тә 1960–80 елларда, «Гәп куертканда» (1970), «Өйдә» (1971), «Сугыш икмәге» (1975, 1978), «Нефтьче Әхәт абый» (1974), «Казан чибәре Зөлфия» (1984), «Катюша», «Батыр» (икесе дә — 1985), «Кырлай көйләре» (1986, 1988), «Кустодиев истәлегенә» (1986), «Авылда» (1987) кебек жанрлы картиналар, «А.С.Пушкин» сериясеннән пейзажлар (1980) һ.б. эшләр олпат оста иҗаты булып керә. 1990 еллардан ул — Россиядә һәм чит илләрдә танылу алган әйдәп баручы нәкышьчеләрнең берсе. З.ның татар һәм рус сәнгате традицияләрендә реализм һәм символизм кебек стиль юнәлешләре киселешендә неопримитивлык һәм модернизм агымнары йогынтысында иҗат иткән тематик һәм пейзажлы нәкышь, натюрморт, портретлары гомумкешелек кыйммәтләренә ия, халыкчанлык сыйфатлары, реалистик образлылыклары б-н популярлык яулыйлар; декоратив тасвирлау осталыгы б-н дөньяны эчкерсез һәм билгеле дәрәҗәдә самими тоюны берләштерәләр. Рәссамның иҗатына, нигездә, җылы, йомшак, аеруча ул яраткан кызыл (ал төстән алып куе-чия төскә кадәр), җирән, куе кызгылт-көрән, сары һ.б. (жанрлы нәкышь) төсләр, пейзажларына, натюрмортларында капма-каршы төсләрне берләштерү, буяулар катламында рельефлы үзенчәлекләр хас. Күпчелек картиналарының композициясе яссылыклары һәм киңлекне тасвирлау ысулларының шартлы булуы, халык сәнгате алымнары — фронталь сурәтләү, орнаментлы ритмнар, декоратив хәрәкәтләр һ.б. кулланылу б-н аерылып торалар. З. әсәрләренең сюжетлары татар авылы тормышына, Бөек Ватан сугышы һәм хәзерге индустрияләштерү чоры темаларына багышлана, татар (Г.Тукай шигърияте бизәкләре) һәм рус (А.С.Пушкин иҗаты) халыкларының фольклор һәм әдәби мирасын чагылдыралар, символик-аллегорик һәм шигъри-романтик яңгырашлы хатын-кыз образларын





































**И.К. Зарипов мәкаләсенә**. 1. «Өйдә». 1971. Дәүләт рус музее. С.-Петербург; 2. «Казан чибәре Зөлфия». 1972. Дәүләт Третьяков галереясы; 3. «Әти». 1972; 4. «Нефтьче Әхәт абый». 1974. Дәүләт рус музее. С.-Петербург; 5. «Җәй». 1973; 6. «Хатирә». 1983. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Курай моңы». 1998; 8. «Искиткеч көн». Катыргы, катнаш техника. 2000. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. «Авылда». 1999–2001. Рәссам Илдар Зариповның галерея-студиясе; 10. «Көзге пейзаж». 1998; 11. «Сөембикә улы белән». 1990. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. «Кунакка». 1988–2002. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. «Чыгыр». 2001. Рәссам Илдар Зариповның галерея-студиясе.



Максут М. Зарипов.

яктырталар («Шатлык», 1970; «Җәй», 1973; «Бәйрәм», 1973–74; «Сугыш чоры хатын-кызлары», 1975; «БАМ», 1975 һ.б.). 1990 еллар ахырыннан башлап, З. портрет жанрына мөрәҗәгать итә — «Татар мәдәнияте эшлеклеләре» сериясе (Т.Миңнуллин, М.Сәлимҗанов, Р.Шәрәфиев, Ш.Биктимеров портретлары); пейзажлар («Туган як» сериясе, 1995–2004; «Кызыл авыл» картинасы 2004 тә Саранск шәһәрендә уздырылган «Зур Идел» күргәзмәсендә 1 нче дәрәҗә дипломга лаек була), тематик картиналар («Иҗатчы туганда», 1998; «Чыгыр», 2003 һ.б.) иҗат итүен дәвам итә.

Республика, төбәк («Зур Идел», 1969 дан), бөтенроссия (1967 дән; «Совет Россиясе» 1975 тән), бөтенсоюз (1972 дән; «СССР — безнең Ватаныбыз», Мәскәү, 1972 һәм 1982; «Россия — 10», Мәскәү, 2003) һәм халыкара («Совет сәнгате күргәзмәләре», АКШ, 1975; Франция, 1977; ГФР, 1977; «Реализм сәнгате», София, 1979; «Татарстан рәссамнары», Стамбул, 1992 һ.б.) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1982 (Казан, Мәскәү), 1996 (Брауншвейг ш., Германия), 2000 (Казан), 2008 (Мәскәү) елларда уза.

Әсәрләре Мәскәүдәге Третьяков галереясында, С.-Петербургтагы Рус музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Киев, Ташкент, Самара, Ижевск, Пермь, Саранск, Петрозаводск, Чабаксар, Чита, Уфа, Красноярск, Тольятти һ.б. шәһәрләрдә, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә (Франция, Англия, Германия, Италия, Голландия, Израиль, АКШ һ.б.) саклана. 2004 тә Казанда И.Зарипов галерея-студиясе ачыла. Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Россия Сынлы сәнгать академиясенең көмеш медале иясе (1997).

*Әд.:* К о р з у х и н А. Радость бытия // Искусство. 1977. № 7; Ильдар Зарипов: Каталог выставки. М., 1981; Ильдар Зарипов. Живопись: Альбом. К., 2000; Е г о р о в а М. Щедрый талант. Галерея-студия Ильдара Зарипова // Казань. 2002. № 11/12.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЗАРИ́ПОВ** Илдар Нәкыйп улы (30.6.1947, Казан), химик-технолог, химия фән. канд-ты (1974), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991), СССРның химия һәм нефть химиясе сәнәгате отличнигы (1991). 1970 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1976–2007 дә Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. мөдире (1986–97 дә), директор урынбасары (1999 дан). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмаларга карый. Дәүләт бүләге җитештерү шартларында һәм авария очракларында кешене агулы, агрессив матдәләр тәэсиреннән, пешүдән саклый торган комплексль чаралар эшләгәне һәм күпләп җитештерүне оештырганы өчен бирелә. Махсус билгеләнгән 11 эшләнмә эшли һәм гамәлгә кертә (башкалар б-н бергәләп), аларны Уфа, Саранск, Ярославль резинотехник эшләнмәләр з-дларында күпләп җитештерү оештырыла. З. тарафыннан эшләнгән кешене комплексль саклау чаралары химия һәм нефть химиясе производстволарында («Түбәнкаманефтехим» АҖ, Томск нефтехим комб-тында, «Ставропольполимер» ҖБдә һ.б.) файдаланыла. Уйлап табуга 20 патенты, 40 тан артык авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Распределение по молекулярной массе и типам функциональности олигоизобутиленов, полученных озонированием изобутилен-диеновых сополимеров в растворе // Высокомолекулярные соединения. 1976. Т. 18А, № 10 (автордаш); Кинетические параметры реакции структурирования олигоизобутилендикарбоновой кислоты эпокси соединениями // шунда ук. 1980. Т. 22А, № 3 (автордаш); Огнезащита материалов для фильтрующей защитной одежды // Безопасность труда в промышленности. 1997. № 11 (автордаш).

**ЗАРИ́ПОВ** Ирек Айрат улы (27.3.1983, Эстәрлетамак ш., БАССР), спортчы (чаңгы спорты). Россиянең атказанган спорт остасы (2010). «Идел» спорт клубында тәрбияләнә (тренеры Ф.Н.Габдуллин), 2005 елдан Россия паралимпиада җыелма командасында (тренеры Ә.А.Гомәров). Россия чемпионатында (2009, чаңгыда узышу, 5 *км*), Паралимпиада уеннарында (2010, чаңгыда узышуларда һәм биатлонда) 4 тапкыр чемпион, дөнья чемпионатында (2009), Паралимпиада уеннарында (2010, чаңгыда узышу, 1 *км*) көмеш медальләр яулый. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, БРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗАРИ́ПОВ** Мадияр Фәхретдин улы (11.5.1929, Казакъстан АССР Актүбә ш. — 15.4.2006, Әстерхан ш.), мәгълүмат системалары гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1968), проф. (1972) БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1977), РФнең атказ. югары белем бирү хезмәткәре (1999). 1956 елда Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый. Куйбышев (1961–64) һәм Ташкент политехник (1964–72), Уфа авиация (1972–80) ин-тларында мәгълүмат-үлчәү техникасы кафедралары мөдире, бер үк вакытта СССР ФАнең Башкорт ф-лында техник кибернетика лаб-ясе мөдире. 1980–92 елларда Ташкент а.х. сугару һәм мелиорация ин-тында электротехниканың теоретик нигезләре каф. мөдире. 1993–2002 дә Әстерхан техник ун-тында технол. процессларны автоматлаштыру каф. мөдире, 2002 дән информацион системалар каф. профессоры. Хезмәтләре төрле физик табигатьле параметрлары бүленгән идарә итү һәм мәгълүмат системалары элементларын һәм җайланмаларын анализлау һәм синтезлау нигезләрен эшләүгә карый. Даими һәм алмаш токларның контактсыз, сызыкча һәм функциональ элементлары, тизлекләр, тизләнеш һәм күчеш сизгечләре, фаза әйләндерү һәм башкару җайланмалары теориясе өлкәсендә тикшеренүләр уздыра. З. җитәкчелегендә төрле физик табигатьле һәм параметрлары бүленгән идарә итү системалары элементларын машинада синтезлау һәм тикшерү өчен кирәк булган мәгълүмат модельләренә тиңдәшле һәм охшатып төзелгән ысуллар эшләү үсеш ала. З.ның тикшеренү нәтиҗәләре нефть, химия-технол. һәм авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 230 дан артык авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре, БАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1979).

Х е з м.: Элементы теории информационных моделей преобразователей с распределёнными параметрами. Уфа, 1983 (автордаш); Энергоинформационный метод анализа и синтеза чувствительных элементов систем управления // Датчики и системы. 1999. № 5 (автордаш); Use of Integrated Base of Knowledge on Physical Effects During Training the Engineers // Proceedings of the 30th SEFI Annual Conference «The Renaissance Engineer of Tomorrow». Firenze. Italy. 2002 (автордаш).

**ЗАРИ́ПОВ** Максут Мөхәммәтҗан улы (8.9.1929, Мәскәү өлкәсе Подольск ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1966), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992). ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1979, 2005). Казан ун-тының атказ. проф. (2004). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1963 тән квант электроникасы һәм радиоспектроскопия каф. мөдире, проф. (1967). 1971–88 дә РФА КГҮнең Физ.-техника ин-тында ЭПР лаб-ясе мөдире (бер үк вакытта 1972–88 дә директоры), 1988 дән каты җисем физикасы лаб. мөдире, 1993 тән баш фәнни хезмәткәре. СССР ФАнең Казан ф-лы Президиумы рәисе (1972–82). Хезмәтләре кристалларда магнит радиоспектроскопиясе ысулы б-н катышма магнит үзәкләрен тикшерүгә карый. ЭПР спектроскопиясе ярдәмендә парамагнетик ионнарны тикшерү ысулларын эшли. ЭПР буенча төп эшне — Ван Флек парамагнетиклары спектроскопиясен башкаруга ирешә. Квант парамагнетик көчәйткечләрендә актив мохит итеп файдаланырга мөмкин булган күп кенә кристалларны тәкъдим итә. Парамагнетик кристалларда үзара тәэсир итешүнең сүлпән алмашынуын өйрәнә. Тимер төркемендә табигатьтә очрамый барган сигез координацияле элементларның электрон структурасын тикшерә. 1957 елда Н.С.Гарифҗанов, Б.М.Козырев б-н берлектә тимер изотобы - $^{57}$Fe спинын ачыклый, 1973 тә И.Б.Хәйбуллин һ.б. б-н бергәләп *лазер нурында чыныктыру* күренешен ача. 1975–85 елларда ТАССР ЮС депутаты. СССР һәм ТРның Дәүләт бүләкләре лауреаты (1988, 2006). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сверхтонкое расщепление простых электронных уровней парамагнетиков // Изв. АН СССР. 1956. Т. 20, № 11; Парамагнитный резонанс в синтетическом рубине // Журн. эксперим. теорет. физики. 1956. Т. 30 (автордаш); Локальная структура центров двухвалентной меди в кристаллах : исследование методом ДЭЯР // Физика твёрдого тела. 2001. Т. 43 (автордаш); Аномалии в магнитных свойствах кластеров примесной меди в кристаллах фтористого бария // Физика твёрдого тела. 2005. Т. 47 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**ЗАРИ́ПОВ** Марат Нәби улы (1.6.1956, Литва ССРның Капсукас ш.), скрипкачы, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык артисты (1999). 1979 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1979–89 да Казан музыка уч-щесендә, 1989 да Казан консерваториясендә (1988–98 дә башкаручылар ф-тлары деканы) укытучы, бер үк вакытта 1980 нән Казан консерваториясе кыллы квартеты, 1996 дан ТР Дәүләт квартеты артисты. Кыллы квартет өчен әсәрләр җыентыкларын төзүче һәм редакторы. Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә квартет составында (2 нче скрипка) концертларда катнаша. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1987).

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ЗАРИ́ПОВ** Марсель Харис улы (23.10.1931, хәзерге Сарман р-ны Янурыс а.), язучы, журналист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981, 1987). Рус телендә иҗат итә. Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1956–58 елларда «Әлмәтнефть» берләшмәсендә электрик булып эшли, бер үк вакытта «Знамя труда» г-тасы белән хезмәттәшлек итә. 1962–66 да — «Советская Татария», 1966–91 дә «Советская Россия» г-таларында үзхәбәрче, 1992–98 дә — «Татар-информ» информация агентлыгы хезмәткәре. З.ның хикәя һәм повестьлары «Ятларның ширбәт ае» («Чужой медовый месяц», 1968) һәм «Квартирага ордер» («Ордер на квартиру», 1976) исемле җыентыкларына кертелгән. Аның язмалары күбесенчә әдәби очерк жанрында язылган, геройлары — нефтьчеләр, нефтехимиклар, авыл хезмәтчәннәре. «Без Казаннан, Иделдән» («Мы из Казани, с Волги», Г.Ахунов белән берлектә, М., 1971), «Тугызынчы биеклек» («Девятая высота», 1973), «Үрләр» («Вершины», 1981), «Түбән Каманың йолдыз сәгате» («Звёздный час Нижнекамска», 1981; Г.Тукай исем. ТР Дәүләт премиясе, 1987), «Отышлы вариант» («Выгодный оборот», 1986), «Алтын хәзинә» («Чёрное сокровище», т. 1–2, М., 1998), «Тәхет йөге» («Бремя престола», 2002) җыентыклары авторы. Рус теленә Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» («Завещание», 1966), Г.Ахуновның «Артышлы тау буенда» («За горой Артыш», 1973), В.Нуруллинның «Аккан су юлын табар» («С ношей гору не обходят», 1982) повестьларын, Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур» («Итиль-река течёт» , 1978) романын тәрҗемә итә. Умартачылыкка караган «Баллы оҗмах» («Сок из росы небесной», 1995), «Балның файдасы» («Мёд на все случаи жизни», 1996), «Умартачы календаре» («Год на пасеке», 2001) китапларының төзүче-авторы.

*Әд.:* М о с т а ф и н Р. Түбән Каманың бәхетле язмышы // Казан утлары. 1982. № 3; Д а в ы д о в В. В семье российской, братской // Лит. газета. 1971. 20 авг.; М а х м у т о в А. Где пел Сайдаш, писал Такташ // шунда ук. 1972. 13 дек. ; Н у р у л л и н И. Един в двух лицах // Советская Татария. 1987. 17 апр.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ЗАРИ́ПОВ** Мәхмүт Мөбарәкша улы (12.12.1918, Казан — 16.6.1998, шунда ук), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1982), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 27 нче з-дта (моторлар төзү, Казан) электрофизика лаб. башлыгы булып эшли. 1955–78 елларда Казан вертолёт з-ды тәҗрибә КБнда фәнни-тикшеренү эшендә, бер үк вакытта Казан пед. ин-тында теоретик физика (1984–89), физика (1989–93) кафедралары мөдире. Хезмәтләре сыек системалардагы магнит резонансына һәм релаксациясенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә. 1941 елда репрессияләнә, 1992 дә аклана.

Х е з м.: О влиянии формы молекул на скорость магнитной релаксации в жидкостях // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1962. Т. 42, № 2 (автордаш): Теория электронной парамагнитной релаксации в жидких растворах // Теорет. и эксперим. химия. 1976. Т. 12, № 4; Влияние процессов гидролиза на квадрупольную релаксацию // Журн. физ.-химии. 1979. Т. 53, № 1 (автордаш).


*Р.Г.Усманов.*

**ЗАРИ́ПОВ** Равил Хаммат улы (20.6.1954, БАССРның Бакалы р-ны Яңа Тымытык а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. канд. (1997), ТРның атказ. машина төзүчесе (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Радиоприбор» з-дында эшли (Әлмәт ш.). 1980–90 елларда «КамАЗ» ҖБнең ремонт-инструментлар з-дында: станок-инструментлар участогы башлыгы, цех башлыгы урынбасары, башлыгы (1984 тән), станок-инструментлар корпусы башлыгы (1989 дан). 1990 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты оборона сәнәгате бүлеге инструкторы. 1990 нан «АлАЗ» ҖБнең станок-инструментлар з-ды директоры. 1992–2009 да «АлАЗ» дәүләт унитар пр-тиесе ААҖ ген. директоры. 1998–2003 тә «Алабуга» ирекле икътисади зонасы (ИИЗ) хакимияте башлыгы, 2003–2009 да ИИЗ җирлегендә оештырылган «Алабуга» сәнәгать мәйданы терр-ясендәге инвестиция программалары дирекциясе» директоры. 2009 дан ТР сәнәгать һәм сәүдә министры.


З. җитәкчелегендә АлАЗда машина төзелеше, нефть-газ чыгару сәнәгате, а.х., төзелеш өчен продукция җитештерүче күп профильле производство оештырыла, җиңел автомобильләр, махсус техника, автомобиль детальләре һ.б. эшләп чыгаручы уртак пр-тиеләр төзелә. Янучан катнашманың өерле агымын көчәйтү юлы б-н эчке янулы двигательләрнең экономиялелеген һәм экологик куркынычсызлыгын арттыруга караган хезмәтләр авторы. Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын ремонтлауда югары технологияләр кулланып эшләнгән күтәрү агрегатларын эшләве һәм җитештерүе өчен бирелә. ТР халык депутаты (1999 елдан). Дуслык ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бензиновые двигатели с подачей в цилиндры дополнительного воздуха. К., 1995 (автордаш); Результаты опытов на высокофорсированном двигателе с дополнительным завихрением зарядов. К., 1996.

**ЗАРИ́ПОВ** Ренат Нәҗип улы (30.5.1951, Казан), педагог, техн. фән. канд-ты (1981), пед. фән. д-ры (2001), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1977 елдан Казан технол. ун-тында җылылык техникасы теоретик нигезләре кафедрасында эшли, 1982 дән югары



М.Х.Зарипов.



Р.И.Зарипов.

матем. кафедрасында. Бер үк вакытта, 1991 дән идарә итү һәм автоматлаштыру ф-ты деканы. Хезмәтләре химия-технол. процессларында матем. методлар куллану өлкәсенә, инженер кадрлар әзерләү методологиясенә, инженерларга матем. белем бирү нигезләрен тәэмин итүгә карый.

Х е з м.: Новые обязательные технологии в подготовке инженеров для наукоёмких производств. К., 2001.

**ЗАРИ́ПОВ** Рим Ибраһим улы (26.9.1937, Балтач р-ны Балтач а. — 12.3.2009, шунда ук), партия, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, Соц. Хезмәт Герое (1986). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), ТАССРның Балтач район а.х. инспекциясендә нәселле терлек үрчетү буенча зоотехник. 1961–70 елларда Вахитов исем. (1967 дән «ВЛКСМга 50 ел») к-з рәисе, 1970–80 дә КПССның Балтач райкомы 2 нче секретаре, р-н башкарма ком-ты рәисе. 1980–90 да КПССның Кукмара райкомы 1 нче секретаре, шул ук вакытта Кукмара р-нының халык депутатлары советы рәисе. 1990–91 дә КПССның Татарстан респ-ка ком-ты секретаре. 1991–92 дә Теләче р-ны хакимият башлыгы. 1992–95 тә ТР ЮСның аграр мәсьәләләр комиссиясе рәисе. 1995 тән РФ Саклык банкының Кукмара бүлеге, 1996–2003 тә Балтач бүлеге управляющие. Герой иceме а.х. продуктлары җитештерүне һәм дәүләткә сатуны арттыру буенча планнарны һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүдә күрсәткән казанышлары һәм югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. КПССның 27 һәм 28 съездлары (1986, 1990), СССР колхозчыларының 3 нче съезды (1969), ВЛКСМның 15 нче съезды (1966) делегаты. 1986–95 тә ТР ЮС депутаты, ТР ЮС Президиумы әгъзасы (1992–95). Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТАССР, ТР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. З. исеме Кукмара р-нының Байлангар урта мәктәбенә бирелә; Балтач авылында З. яшәгән йортка мемориаль такта куела; Чепья авылында Халыклар дуслыгы музеенда экспозиция ачыла (икесе дә Балтач р-нында).

*Әд.:* Ф а т т а х о в Р. Рим Ибрагимович Зарипов // Татарстан. 1998. № 7; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003. Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЗАРИ́ПОВ** Ринат Гыйрфан улы (2.11.1947, Закарпатье өлкәсе Мукачёво ш.), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры

(1996), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Казан ф-лы Физ.-техника ин-тында эшли. 1991 дән РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-тында, 1996 дан тоташ мохит механикасы лаб. мөдире, 1998 дән гыйльми эшләр буенча директор урынбасары, бер үк вакытта 1996 дан Казан техник ун-тының югары матем. каф. профессоры. Хезмәтләре рәвеше үзгәртелә торган каты җисем механикасына, юка стеналы металл сүрүләр, «парашют» һәм «парус» тибындагы йомшак сүрүләр динамикасына, тоташ мохиттә нәсызыкча һәм тәртипсез тирбәнешләр, тышкы тирәлектәге ачык системаларның үзлекләреннән оешу һәм үзлекләреннән таркалу проблемаларына карый. Беренче мәртәбә газларда субгармоник режимдагы тирбәнешләрнең периодик бәрмә дулкыннарын ачыклый һәм тасвирлый (1976). З. тарафыннан «сүрү-газ» системаларының нәсызыкча тирбәнешләрен өйрәнү өчен эксперименталь җайланма төзелә; Пригожин-Глансдорф эволюциясенең термодинамик критерие һәм әйләнә-тирәдәге ачык системалар эволюциясенең статик критерие тәкъбирләнә.

Х е з м.: Нелинейные колебания газа в открытой трубе // Акустический журн. 1977. Т. 23, вып. 3; Экспериментальные исследования разрушения оболочек при воздействии ударных волн // Проблемы прочности. 1979. № 1 (автордаш); Информация различия и переходы беспорядок-порядок. К., 1999.

**ЗАРИ́ПОВ** Рудольф Хафиз улы (29.10.1929, Казан — 8.9.1991, Мәскәү), кибернетика, музыка иҗатын машинада модельләштерү гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. канд-ты (1958). 1949 елда Казан музыка уч-щесен тәмамлый, 1947 дә Казан ун-тына укырга керә. 1952 дә Мәскәү ун-тында укуын төгәлли. 1952–60 елларда махсус учреждениедә эшли (бүленеп, 1956–59 да Ростов ун-тында), 1961 дән хәрби частьтә, 1964–84 тә Гомуми һәм пед. психология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1991 гә кадәр СССР ФАнең Хисаплау үзәгендә (Мәскәү). Хезмәтләре музыканың стат. анализына, муз. логикасының структур закончалыкларына карый. Төрле музыкаль төшенчәләрнең иерархиялелегенә нигезләп, ихтималый-стохастик композицияләү, программаларны алгоритмлаштыру ысулларын эшли. З.ның эш нәтиҗәләре сәнгать, эстетика, фикерләү психологиясе, философия һәм кибернетиканың гомуми теориясе өлкәләренә дә керә. З. музыкада интеллектуаль системалар куллануның түбәндәге өлкәләрен аерып күрсәтә: авазны яңгырату, яки авазлар синтезы; музыкаль ориентлашкан программалау теле, муз. әсәрләрне анализлау; муз. әсәрләрне (текстларны) синтезлау; муз. текстларны компьютерга кертү һәм аннан чыгару. Нәтиҗәдә «Музыка һәм ЭВМ» проблемасы буенча гомуми танылуга ирешә.

Х е з м.: Кибернетика и музыка. М., 1963; Машинный поиск вариантов при моделировании творческого процесса. М., 1983.

*Әд.:* Информатика: Энцикл. словарь для начинающих. М., 1994; Ю н у с о в Г. Неправильное рондо // Казань. 2004. № 5; V a n e c h k i n a I. In commemoration of R.Zaripov // Leonardo. 1997. V.30, № 3.

*Б.М.Галиев.*



Ф.Ф. Зарипов.

**ЗАРИ́ПОВ** Фоат Фәхретдин улы (4.2.1953, Зәй р-ны Чыбыклы а.), драма актёры, ТАССР һәм БРның атказ. (1984, 1997), ТРның халык артисты (1994). 1970 елда Әлмәт татар драма театрында режиссёр ярдәмчесе булып эшли башлый, бер үк вакытта шул театрда Г.Хөсәенов җитәкләгән студиядә укый. Әлмәт театрының әйдәп баручы актёрларыннан берсе. Персонаж характерын тирән уйлап, төгәл эшләнгән сәхнә формасына туры китереп уйный. Шундый рольләрдән Малтабар («Игезәкләр», Ә.Атнабаев), Галим («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Рәшит («Их, сез, егетләр!», Ф.Садриев), Җайнак («Анам кыры», Ч.Айтматов әсәре буенча), Алексей («Барабанчы кыз», А.Д.Салынский), Физат («Менә без дә үсеп җиттек», Ю.Сафиуллин) образларын китерергә була. Драматург Т.Миңнуллин махсус бу артистка багышлап «Бәйләнчек» пьесасын яза һәм З. бу спектакльдәге принципиаль, гадел, үз вазифаларына намус б-н караучы, кешелеклелек сыйфатларын туплаган яшь кеше — Абдуллин образын зур осталык б-н гәүдәләндерә. Эшлексезлек, намуссызлыкка каршы көрәшүче кеше темасы З. башкарган Равил, Мөдәррис («Ач тәрәзәң», «Кандырдан килгән балдыз», Ф.Садриев), Наил, Ренал («Синең урыныңа кайттым», «Иске йорт кешеләре», Р.Хәмид), Флорес («Сафура бураннары», Ю. Әминев), Буков («Күңелемнең җиде тамыры», А.Гыйләҗев) образларында ачык чагыла. Билгеле бер характердагы, конкрет образ өстендә эшләнгәндә, З. ш.у. вакытта образның фәлсәфи тирәнлеген, драматургның төп идеясен ачарга омтыла. Аның Сәйфулла («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Кадыйр («Алла каргаган йорт», Д.Салихов), Айдар («Юллар ярда өзелә», Н.Гаетбаев), Йырыскол («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Җамалетдин («Банкрот», Г.Камал), Алтынбай («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), Сабир («Зәхмәт», З.Хәким), Габдулла («Сөясеңме, сөймисеңме?», Ф.Бүләков) рольләре актёрның иҗат казанышлары булып тора, алар спектакльләрнең эчтәлеген идея-сәнгать ягыннан баеталар. З. башкарган Хәбир («Сөяркә», Т.Миңнуллин), Азат («Сафиулла», М.Гыйләҗев), Альберт («Сагынырсың әле син дә бер ...», Г.Каюмов), Арыкбаев («Җырланмаган җыр», М.Кәрим), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) рольләре тышкы хәрәкәтләрне саран чагылдыру чаралары б-н ачык пластик бизәкләрне бергә куллануы аркасында уңышка ирешә. Театр репертуарында булган бик күп әсәрләрдәге рольләрне башкарып, З. үз иҗатында Әлмәт татар драма театрының иң яхшы традицияләрен дәвам иттерә.

*Д.Гыймранова.*



Х.Г. Зарипов.

**ЗАРИ́ПОВ** Хөсәен Габдрахман улы (31.3.1916, Курган өлкәсенең хәзерге Әлмән р-ны Әскар а. — 17.8.1956, шул ук р-нның Юламан а.), Дан орденының тулы кавалеры (25.5.1944, 29.7.1944, 24.3.1945), старшина (1945). Туган авылында колхозда эшли. 1943 елның сентябреннән Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 439 нчы сапёрлар батальоны сапёры (52 нче армиянең 373 нче укчы дивизиясе), 53 нче мотоукчылар бригадасы автоматчысы (5 нче гв. танк армиясенең 29 нчы танк корпусы). 2 нче Украина, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Украина, Молдавия, Польшаны азат итү сугышларында, Яссы-Кишинёв (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Яссы шәһәреннән (Румыния) төньяктарак булган бәрелешләрдә 1944 нең 17 маенда (разведка төркеме составында дошманның алгы сызыгында инженерлык разведкасы ясый, траншеяга бәреп кереп пулемёт ноктасын юк итә һәм, дошманны әсир итеп, «тел» алып кайта); шул ук елның 25 маенда (дошман уты астында разведка төркеме б-н миналы кырларда үтү юллары ясый, ут ачып, басып алу төркеменә ярдәм итә); Польша терр-ясендә 1945 нең 18 гыйнварыннан 4 февраленә кадәр барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Коркино шәһәренең (Чиләбе өлкәсе) «Коркиноуголь» трестында эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.


*М.З.Хәбибуллин.*

**ЗАРИ́ПОВ** Шамил Хуҗи улы (24.3.1959, Балтач р-ны Чепья а.), механика белгечлеге галиме, физ.-матем. фән. д-ры (2005). 1981 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, газлар динамикасы бүлеге мөдире (1991–95), 1995 тән экологик системаларны модельләштерү кафедрасында, проф. (2005 тән). Хезмәтләре аэрозольләр механикасына һәм газлы лазерлар модельләштерүгә карый. З. тарафыннан газлы $CO_2$ лазерының оптик резонаторындагы актив тирәлек б-н яктылык кырының үзара тәэсире турындагы мәсьәлә көзгеләрнең җылылыктан деформацияләнүен исәпкә алып чишелә; лазер бәйләмен кирегә бора торган оптик резонаторның матем. моделе үстерелә; төп тирәлекнең тизлек годографы яссылыгында аэрозоль кисәкчекләренең траекториясен исәпләү алымы тәкъдим ителә. З. аэрозольнең сферик үрнәк җыйгычына ясаган аспирациясе мәсьәләсе өчен матем. модель эшли һәм аерым ноктолар теориясен үстерә; аэрозоль тамчыларның сызыкча тезелгән, үсә баручы тамчыларның нәстационар җылылык конвекциясе шартларында һәм аэрозоль кисәкчекләрнең тыгыз урнашкан шарлар арасындагы хәрәкәтләре өчен матем. модельләр тәкъдим итә.

Х е з м.: Calculation of aerosol particle trajectories in the velocity hodograph plane // Fluid Dynamics.

1994. V. 29; Theoretical study of aerosol sampling by an idealised sampler in calm air // J. of Aerosol Science. 2003. V. 34 (автордаш); Hydrodynamically interacting droplets at small Reynolds numbers // International Journal of Multiphase Flow. 2005. V. 31 (автордаш).

**ЗАРИ́ПОВ** Эрот Якуб улы (20.07.1938, Свердловск өлкәсенең Уинск р-ны Иштирәк а. — 12.5.2009, Казан), график, ТАССР-ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985). И.Фёдоров исем. Львов полиграфия ин-тын тәмамлый (1965). 1966 елдан Татарстан китап нәшриятында: бизәлеш редакторы (1966–69), баш рәссам (1978–81), штаттан тыш рәссам (1969–72; 1981–90). 1975–78 елларда СССР



Э.Я. З а р и п о в. «Бабай». Линогравюра. 1973.

ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты фәнни хезмәткәре. 1990 нан ТР Милли китапханәсендә рәссам. ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). З. — китап һәм станлы графика өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнардан. 15 кә якын китапны, ш.и. М.Фәйзуллинаның «Шаян ай» (1966), И.Юзеевнең «Исәнме, туган җир!» (1970), «Пони малае нәни Җирәнкәй» (1971), Р.Вәлиевнең «Хыялый песи малае» (1976), Ә.Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» (1968), «Габдулла Тукай. Альбом» (1978) һ.б. бизи һәм аларга рәсемнәр ясый; 100 гә якын китап тышлыгы авторы. Станлы графика өлкәсендә линогравюра, монотипия, офорт, акварель, карандаш техникасы б-н тематик һәм пейзаж жанрларында эшли: «Туган авыл» (1966–70), «Казанның архитектура һәйкәлләре» (1979–80), «Нефтьчеләр турында» (1980) линогравюралар сериясе; «Болгарлар» (1978), «Борынгы Львов» (1963) төсле монотипияләр сериясе һ.б. 1990 нан З. иҗатында төп урынны портрет жанры алып тора, аларда — замандашлары образлары, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре; шагыйрьләр, мәгърифәтчеләр, галимнәр, язучылар, композиторлар, рәссамнар. Бу жанрдагы эшләре «Татар мәгърифәтчеләре» линогравюралар сериясеннән башлана һәм төсле катнаш техникада башкарылган әсәрләрендә дәвам иттерелә (барлыгы 200 табактан артык). Портретлар арасында — «Ш.Мәрҗани», «К.Насыйри», «Г.Тукай», «Г.Курсави», «Дәрдемәнд», «Һ.Такташ», «Б.Урманче» һ.б. 1996 да башланган «Багышлау» биографияләр сериясе И.Юзеев, Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, Г.Ахунов, Р.Миңнуллин һ.б. шагыйрь һәм язучыларга багышлана, һәркайсының туган җирләрендә күрсәтелә. 1963 тән респ-ка, төбәк («Зур Идел», 1974, 1980, 1985 һ.б.), бөтенроссия (автономияле респ-калар рәссамнарының әсәрләре, Мәскәү, 1971), халыкара («Китап — 77» бөтендөнья күргәзмә — ярминкәсе, 1977) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре; 1980 (Минзәлә шәһәре), 1984, 1988, 1995, 1996, 1998, 1999, 2002, 2003, 2005, 2006, 2008, 2009 (вафатыннан соң) (Казан) һ.б. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТРның Сынлы сәнгать музеенда, Г.Тукай музеенда, ТР Милли китапханәсендә (Казан), Лодзь Сынлы сәнгать музеенда (Польша), Казанның 2 нче татар гимназиясендә, район мәктәпләрендә саклана.



Э.Я. З а р и п о в. «Скрипка уйнаучы әткәм портреты». Линогравюра. 1974.



Э.Я. З а р и п о в. «Буа янында». Линогравюра. 1984. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Х е з м.: Сүнмәс йолдызлар // Ялкын. 1973. № 8; Яшь рәссамнар // Ялкын. 1973. № 11; Акчарлаклар Идел өстендә // Ялкын. 1975. № 2; Хисләр һәм төсләр // Идел. 1975. № 6; Тамчыларда кояш чагыла // Ялкын. 1977. № 11; Наши художники // Детская литература. 1975. № 8; Заман көзгесе: Альбом. К., 2006; Мәшһүр татар зыялылары. К., 2008.

*Әд.:* Аһәң. Эрот Зарипов әсәрләре // Азат хатын. 1988. № 11; З а к и р М. Җан аһәңе // Казан утлары. 2003. № 6; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЗАРИ́ПОВА** Зөлфирә Сафа кызы (15.6.1953, Әтнә р-ны Түбән Бәрәскә а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2007). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1974), Татар акад. театрында эшли. Көчле эчке драматизмга ия актриса буларак, З. рольгә тулысынча керә белә, психологик тирәнлеккә омтыла, образның логик асылын аңлап эшли. Күп кенә комедияләрдә уйнаса да, мәс., Мөршидә («Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Марианна («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Гөләндәм («Талак-талак», Х.Вахит), Сәхибҗамал («Җан Баевич», Г.Исхакый), Люция («Баскетболист», М.Гыйләҗев), Заһирә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин) һ.б., З. комедия актрисасы гына түгел. Үзенең иң яхшы рольләрен ул драма әсәрләрендә башкара. Бу — кырыс, котылгысыз хәерчелек аркасында өметсезлеккә бирелгән Гайнавал («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), сагышлы, йомшак холыклы Әдилә («Туй алдыннан», Х.Вахит), тормыш авырлыкларын сабырлык б-н кичерә белүче, зыялы Зифа (шул исем. спектакль, Н.Исәнбәт) һ.б. образлар.



З.С. Зарипова.

Иң көчле образларының берсе — Миңлекамал (шул исем. спектакль, М.Әмир). З. башкаруында Миңлекамал гадәттән тыш батыр йөрәкле, кыю, чая хатын булып истә кала. Ул гражданлык бурычын тирәнтен аңлый, артка калган колхозда рәиснең авыр йөген дәһшәтле сугыш елларында үз җилкәсенә алуның никадәр мөһим һәм авыр икәнен чын йөрәгеннән аңлап, дәртләнеп эшкә бирелә. З.ның тетрәндергеч рольләреннән тагын берсе — Ч.Айтматов әсәре буенча куелган «Ахырзаман» спектаклендә Акбүре образы. Үз балаларына булган чын мәхәббәт хисләрен, нәни балаларын һәм аларның аталарын үтергән кешеләрнең кансызлыгын, шәфкатьсезлеген аңлый алмыйча гаҗиз булган ана бүренең тирән кайгысын актриса искиткеч осталык б-н гәүдәләндерә.

Башка рольләре: Полинка («Солдат хатыны», Н.Анкилов), Нурсолтан, Наталья («Канкай углы Бәхтияр», «Илгизәр+Вера», Т.Миңнуллин), Миңзифа («Кичер мине, әнкәй», Р.Батулла), Мөршидә («Мин төш күрдем», З.Хәким), Зөләйха («Яра», А.Гыйләҗев повесте буенча), Гайшә («Мирас», Г.Каюмов), Хәмидә («Бүләк өчен», Г.Камал), Расиха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Мәрфуга («Күрәзәче», З.Хәким), Кавато («Ханума», А.Цагарели) һ.б. ТАССР комсомолының М.Җәлил исем. дәүләт бүләге лауреаты (1988).

*Әд.:* И л я л о в а И. Артисты Театра им. Г.Камала. К., 2005.

*И.И.Илялова.*


**ЗАРИ́ПОВА** Лидия Павловна (12.10.1931, Түбән Новгород өлкәсе, Вача р-ны Сапун а.), а.х. терлекләрен тукландыру белгече, а.х. фән. д-ры (1981), ТР ФА академигы (1995), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1980, 1995). Мәскәү тире-мех ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Бөтенсоюз терлекчелек ин-тында эшли. 1957–60 елларда РСФСР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Якутия җир төзү экспедициясе комплексында зоотехник-икътисадчы. 1960–69 да Казан а.х. ин-тында укыта. 1969 дан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында тукландыру һәм азык технологиясе лаб. мөдире (1969–82), бер үк вакытта 1974 тән фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1982–87 дә Казан вет. ин-тының терлекчелек



Л.П. Зарипова.



Т.Г. Зарипова.



Г.З. Зарифов.



Г.П. Зарубин.

технологиясе каф. мөдире. 1987–96 да РАХФАнең «Семеновод» фәнни-җитештерү берләшмәсе (1990 нан «Нива Татарстана») ген. директоры, 1996–98 дә ген. директорның киңәшчесе — баш фәнни хезмәткәр. 1998 дән Казан вет. медицина академиясенең терлекләрне тукландыру каф. профессоры, бер үк вакытта 2001 гә кадәр ТР ФАнең а.х. фәннәре бүлеге академик-сәркәтибе. Хезмәтләре терлекчелектә кулланыла торган азык төзелешен, туклыклылыгын һәм бәрәкәтле файдалануны өйрәнүгә, экологик зыянсыз а.х. продукциясе җитештерүнең яңа технологияләрен эшләүгә карый. Уйлап табуга 4 патенты һәм 4 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Научные основы рационального использования протеина в животноводстве. К., 2000; ш у л у к. Оценка питательности кормов, повышение их качества и рациональное использование в животноводстве. К., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЗАРИ́ПОВА** Тәүзихә Гәрәй кызы (12.1.1930, Баулы р-ны Мортаза а.), сарык караучы, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1944–46 елларда Баулы р-нының «Ирек» к-зында бригадир, 1951–54 тә сарык фермасында хисапчы. 1962–86 да Баулы р-нының Киров исем. к-зында сарык караучы, сарык үрчетү фермасы мөдире (1975 тән). З. 1966 да 163 сарыктан 176 бәрән, һәр сарыктан 3,3 *кг* йон, 1970 тә һәр 100 сарыктан 120 бәрән, һәр сарыктан 4,7 *кг* йон ала. Герой исеме а.х. үстерүдә һәм бишьеллык (1966–70) планны үтәүдә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* М а т в е е в а Е. Зарипова Таузиха Гараевна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЗАРИ́ФОВ** Габдрахман Закир улы (1917, Вятка губ., Малмыж өязе Борнак а. — 8.5.1984, Казан), педагог, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1963), Соц. Хезмәт Герое (1968). 1940 елда Красноярск пед. ин-тын тәмамлый, 1941 дән Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1948–79 елларда Казанның 94 нче мәктәбендә физика укыта, физика укыту методикасын эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эзең калсын. К., 1980.

*Әд.:* Г у д к о в а В. Зарифов Абдрахман Закирович // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2.

**ЗАРИ́ФОВ** Шамил Габдрахман улы (1.9.1948, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1977). 1974–83 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында. 1983–84 тә Татпотребсоюзның хуҗалык исәбендәге җәмәгать туклануы берләшмәсе, 1984–86 да Казанның Ленин р-ны җәмәгать туклануы комб-ты директоры. 1986–93 тә ТР МКның эшләр идарәсе җитәкчесе урынбасары, 1993–95 тә ТР МК секретариаты башлыгы урынбасары. 1995–96 да Чехия Респ-касында ТРның сәүдә-икътисад вәкиле, 1996–97 дә ТРның Чехия һәм Словакия Респ-каларындагы даими вәкиле һәм сәүдә вәкиле урынбасары. 1997–2002 дә ТР Президентының эшләр идарәсе җитәкчесе; 2002 елдан «Тандем» Инвестиция-төзелеш компаниясе» ЯАҖ ген. директоры. ТРның Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАРИФУ́ЛЛИН** Фирдәвес Забихулла улы (25.12.1961, Яшел Үзән р-ны Күгеш а.), язучы, журналист. Казан ун-тын тәмамлый (1990). Казанның төрле оешмаларында электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы, Кемерово өлкәсе Прокопьевск шәһәрендә шахтёр, КПССның Татарстан өлкә ком-ты нәшриятында китап басучы булып эшли. 1989 дан «Татарстан» ДТРКда әдәби мөхәррир, 1994 елдан «Мирас» ж-лының, 2008 дән «Шәһри Казан» г-тасының баш мөхәррире урынбасары. З. — татар халкының рухи яңарышына, яшь буынны тәрбияләүдә әхлак проблемаларын яктыртуга багышланган «Татлы җәй» (2001), «Кайту» (2002), «Мин көтәрмен сине» (2003), «Пар дулкын» (2004) исемле проза, «Чишмә» (2007) исемле хикәя һәм әкиятләр җыентыклары авторы.

**ЗАРУ́БИН** Георгий Петрович (12.12.1928 — 28.6.1995), гигиенист, мед. фән. д-ры (1962), РМФА мөхбир әгъзасы (1993), РСФСРның атказ. табибе (1969). В.В.*Милославский* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганннан соң (1953), БАССРның Республика сан.-эпид. станциясендә, 1956 елдан Казан ГИДУВында, 1959 дан Казан Гигиена фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1960 тан Мәскәүдә: Бөтенсоюз тимер юл транспорты фәнни-тикшеренү ин-тында, Ф.Ф.Эрисман исем. Мәскәү гигиена фәнни-тикшеренү ин-тында, 1962 дән СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 4 нче идарәсенең сан.-эпид. станциясе баш табибе, бер үк вакытта Н.А.Семашко исем. Мәскәү стоматология ин-тының гигиена каф. профессоры; 1993 тән РФ Югары аттестация комитеты идарәсе башлыгы. Хезмәтләре гомуми һәм көнкүреш гигиенасына, су тәэминаты һәм ташландык сулар системасы мәсьәләләренә, сусаклагычларны саклау, сан.-эпид. хезмәтен оештыруга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Современные методы очистки и обеззараживания питьевой воды. М., 1976; Научно-технический прогресс, наука и человек. М., 1977; Окружающая среда и здоровье. М., 1977; Гигиена города. М., 1986 (автордаш).

**ЗАРЯ́** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 21 *км* төньяктарак, Саурыш елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 72 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1929 да нигез салына. Башта Чистай кантонының Яңа Әдәм волостена, 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 155, 1949 да — 169, 1958 дә — 186, 1970 тә — 146, 1979 да — 108, 1989 да — 62, 2002 дә — 73 кеше.

**ЗАРЯ́** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2005 елның гыйнварында авыллар исемлегеннән сызыла. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1938 дә — 7, 1958 дә — 168, 1970 тә — 125, 1979 да — 111, 1989 да — 45, 2002 дә — 11 кеше.

**«ЗАРЯ́» КОНДИ́ТЕР ФА́БРИКАСЫ**, азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 1 мең кешедән артык (2003). Тарихы 1920 елдан, Е.С.Смоленцевның национализацияләнгән кустарь ф-касы (1890 да нигезләнә, Университет урамында 35 нче йортта урнаша) җирлегендә 1 нче кондитер ф-касы оешкан вакыттан башлана. Фабрика елга 1 мең пот кондитер ризыклары эшләп чыгара, төрле сорттагы конфетлар җитештерә. 55 кеше эшли (1922). Ягулык сыйфатында утын һәм агач күмере кулланыла. 1922 дә таратылган 3 нче кондитер ф-касының җиһазлары 1 нче кондитер ф-касына тапшырыла һәм ф-ка каршында елга барлыгы 475 поттан артык прәннек, сохари һәм вареньe җитештерүче «Красное звено» прәннек остаханәсе эшли башлый. 1923 нең маенда «Кызыл Шәрекъ» сыра кайнату з-ды бинасында пар-механикалы кондитер ф-касын оештыру эшләре башлана; кондитер ф-касын да эл. энергиясе б-н тәэмин итүче эл. станциясе төзелә. «Светоч» дип аталган ф-ка 1924 нең 25 июнендә ачыла. Карамель, конфет, прәннекләр эшләп чыгарыла. 1933 тә үзгәртеп корылган элеккеге салат кайнату биналарындагы (Щербаков тыкрыгы) прәннек цехы җирлегендә Прәннек ф-касы ачыла, ул 1934 тә А.И.Микоян исем. кондитер ф-касы дип үзгәртелә. Бөек Ватан сугышы елларында анда Мәскәүдәге «Красный Октябрь» һәм «Большевик» ф-каларыннан эвакуацияләнгән конфет-шоколад җитештерүче җиһазлар һәм бисквитлар эшләүче агрегат урнаштыры-

ла. 1957–62 дә «Заря» кондитер ф-касы. 1962 дә «Заря» һәм «Светоч» ф-калары Казан «Заря» кондитер ф-касына берләшәләр, ул Зәй, Әлмәт шәһәрләрендәге һәм Сарман р-нының шәһәр тибындагы Җәлил посёлогындагы пр-тиеләрне үз эченә алган «Заря» ҖБнең баш пр-тиесенә әверелә. 1993 тән АҖ, 2002–03 тә «Сладко» кондитер берләшмәсенең Казан ф-лы. 1970–2000 дә фабрикада камыр ризыклары җитештерүче цех, җитештерү-көнкүреш корпусы һ.б. файдалануга тапшырыла; карамель һәм конфет производстволары реконструкцияләнә, төп технол. процесслар механикалаштырыла һәм автоматлаштырыла. Германиядә һәм Югославиядә печенье, вафли, пирожныйлар җитештерүче конвейерлы-механикалаштырылган линияләр сатып алына. Күп хезмәт таләп ителгән процессларны механикалаштыру продукция җитәп чыгару күләмен күп тапкырлар арттыру мөмкинлеген бирә. Продукциянең төрлелеген, күләмен үстерүгә һәм аның сыйфатын яхшыртуга аерым игътибар юнәлтелә. Кондитер ризыклары электән килгән һәм пр-тие белгечләре тарафыннан эшләнгән яңа рецептлар буенча җитештерелә. Пр-тиенең үз эшләнмәләре: «Татарстан», «Белоснежка», «Смуглянка», «Шатлык» тортлары, «Сандугач», «Маугли», «Пикантные», «Тайна», «Волшебство», «Мираж», «Тропиканка» конфетлары, «Новость», «Мечта», «Фиеста», «Сливки», «Малибу» карамельләре һ.б. Төп чимал бирүчеләр — ТРның шикәр з-длары, «Российские крахмалопродукты» сәнәгать пр-тиеләре төркеме, «Волжанка» кондитер фабрикасы» АҖ (Ульянов ш.), «Шугар Трейдинг Компани», «Союзснаб» (Мәскәү), «Байер», «РАС» ҖЧҖләре (Казан), «Орхус Олье» (Дания) (2003). Төп продукциясе — печенье, вафли, тортлар, карамель һәм конфетлар. Фабриканың күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 10 кешегә — РФнең, ТРның атказ. азык-төлек индустриясе хезмәткәре, 1 кешегә — ТАССРның атказ. икътисадчысы дигән мактаулы исемнәр бирелә; 2 кеше — Ленин ордены, 18 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 14 кеше — «Почёт билгесе», 10 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны», 1 кеше — Дуслык орденнары, 172 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре арасында — З.И.Хубулава (1966–2002, 2004–05), А.А.Василец (2002–04), М.Х.Төхвәтуллин (2005–08). 2008 елда фабрика ябыла. Ш.у. к. *Кондитер сәнәгате*.

*С.И.Роднина, Г.Я.Мәүлетова.*

**«ЗАРЯ́ ТАТА́РИИ»,** чия сорты, уртача — иртә өлгерешле. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында А.М.Тверитинов һәм Л.А.Севастьянова тарафыннан «Крупноплодная № 6» сорты («Степная» һәм «Пенсильванская» сортларының очраклы гибриды) чәчкененнән чыгарыла. 1977 елда дәүләт сорт сынавына тапшырыла, Татарстанда 1988 дән районлаштырыла. Озынча яисә киң пирамидасыман җыйнак ябалдашлы куак. Берьеллык үрентеләре юан, аз гына бөгелгән — дугасыман, аксыл-соры төстә. Яфраклары уртача зурлыкта, түгәрәк ялтыравыклы. Чәчәкләре зур. Җимешләре эре (4,2 *г*), түгәрәк, ачык кызыл төстә. Җимеш йомшагы сусыл, әчкелтем. Аннан әзерләнгән продуктлар (компот, кайнатма) яхшы сыйфатлы. Коры матдәләр — 14%, шикәр — 10,5%, органик кислоталар — 1,7%, С витамины — 14,6 *мг* %. Бу сорт салкынга чыдам, коккомикоз авыруына бирешми, яхшы регенерация сәләтенә ия. Элек районлаштырылган, коккомикоз авыруы б-н нык зарарлана торган «Полжир» сортын алыштыра. Иң яхшы серкәләүчеләр — «Краса Татарии», «Маяк», «Владимирская». «Обыкновенная» сорты чәчкеннәренә бөре һәм яшел чыбыкчалар ялгау ярдәмендә әйбәт үрчиләр. «З.Т.» чиясеннән югары уңыш (1 *га* дан 50–60 *ц* га кадәр) «Мишә», «Түбән Кама», «Кайбыч» җимеш с-зларында алына. Югары рельефлы һәм тиешенчә уңдырышлы туфракта, бигрәк тә Идел алдында яхшы үсә. «З.Т.» сорты Тамбов өлкәсе һәм Донецк тәҗрибә станциясендә үстерелә.


*Л.А.Севастьянова.*

**ЗАСЕ́ЦКИЙ** Николай Александрович (19.8.1855, Вологда губ. — 16.3.1917, Казан), терапевт, мед. д-ры (1883). В.А.*Манассейн* шәкерте. 1880 елда С.-Петербург Мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1886 дан Казан ун-тында, шәхси патология һәм дәвалау, 1903–12 дә госпиталь терапиясе кафедралары мөдире, бер үк вакытта земство хастаханәсенең өлкән табибе һәм 1897 дән Казан губернасы фельдшерлар мәктәбе директоры. Хезмәтләре ашказаны авыруларына диагноз кую һәм дәвалауга, бизгәкнең матдәләр сеңүенә һәм алмашына тәэсирен өйрәнүгә карый. З. туберкулёз клиникасын һәм кымыз б-н дәвалауны өйрәнә.

Х е з м.: Лекции по частной патологии и терапии внутренних болезней. К., 1896; К вопросу о введении санитарной организации в Казанской губернии. К., 1912.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Материалы к истории кафедры частной патологии и терапии императорской Военно-медицинской академии (1798–1898). СПб., 1898. Ч. 2.

**ЗАСО́РИН** Иван Михайлович (8.4.1913, Калуга өлкәсе, хәзерге Козельск р-ны Стенино а. — 29.5.1985, Яшел Үзән ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), майор (1955). Артиллеристлар курсын тәмамлый (1941). 1935 елдан Кызыл Армия сафларында. Хәсән күле янында японнарга каршы сугышта катнаша (1938). 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 11 нче артиллерия бригадасының 525 нче җиңел артиллерия полкы батарея командиры (46 нчы армиянең 7 нче артиллерия дивизиясе). Кавказ, Төньяк-Кавказ, Көньяк-Көнбатыш, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Кавказ өчен барган сугышта (1943), Донбасс һөҗүм операциясендә (1943), Днепр елгасы буендагы сугышларда (1943), Украина, Молдавия, Румыния, Болгария, Венгрия, Австрия һәм Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1944 нең 5 декабрендә Эрчи шәһәре (Венгрия) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам иттерә. 1955 тән запаска җибәрелә, Яшел Үзән шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Яшел Үзәндә бер урам Герой исемен йөртә.


И.М.Засорин.

*Әд.:* П о л е н к о в К.А., Х р о м и е н к о в Н.А. Калужане — Герои Советского Союза. Калуга, 1963; А н д р е е в С.А. Совершённое ими бессмертно. М., 1976; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАСТЕ́ЛА** Юрий Кириллович (25.4.1910, Харьков губ., Валковск өязе Иске Водолага а. — 5.8.1988, Казан), авиация двигательләре төзү гыйлеме белгече, техник фән. канд. (1951), проф. (1964), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). 1937 елда Харьков авиация ин-тын тәмамлый. Харьков шәһәре г-таларында хәбәрче (1928–32), Коминтерн исем. з-дта техник бюро башлыгы (1937–40), Харьков авиация ин-тында укытучы (1940–42) булып эшли. 1942 елдан Казан авиация ин-тында, авиадвигательләр теориясе каф. мөдире (1953–79), бер үк вакытта моторлар төзү ф-ты деканы (1951–55), ректор (1955–67), проф.-консультант (1979 дан). Хезмәтләре газ турбиналы двигательләрнең ышанычлылыгына һәм ресурсларына карый. Реактив двигательләрнең яну камераларындагы процессларны көйләү мәсьәләләрен тикшерә. Реактив-һава двигательләренең яну камераларындагы яну тирәлеген тотрыкландыруның яңа ысулын эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1963–67 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, «Почет билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новый способ стабилизации в камерах сгорания газотурбинного двигателя // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1955. Вып. 29; Новый способ стабилизации в камерах сгорания ВРД // шунда ук. 1961. Вып. 1; Экспериментальное исследование влияния отбора и перепуска воздуха на характеристики ТРДФ // Испытания авиац. двигателей. Уфа, 1971. Вып. 1; Термогазодинамический расчёт и расчёт высотно-скоростных характеристик газотурбинных двигателей. К., 1981; Теория воздушно-реактивных двигателей. К., 1982.

**ЗАТ**, фигыльнең эш башкаручы б-н сөйләүче арасындагы мөнәсәбәтне махсус кушымчалар ярдәмендә белдерүче грамматик категориясе. Татар телендә зат категориясенең берьюлы затны да, санны да белдерә торган алты формасы бар. Һәрбер форма ике морфологик вариантта кулланыла, һәм алар ике параллель парадигма хасил итә. 1 нче зат — эш-хәлнең сөйләүчегә: **мин укыйм**, **без яшибез**, 2 нче зат — эш-хәлнең сөйләм юнәлгән адресатка: **син укыйсың**, **сез яшисез**, 3 нче зат — эш-хәлнең сөйләмдә катнашмаучы затка яки предметка: **ул укый**, **алар яшиләр** — каравын белдерә.

Хикәя, шарт, шартлы теләк фигыль формаларының тулы парадигмалары бар. Боерык фигыльнең 2 нче һәм 3 нче зат формалары була, әгәр боеруның төп адресатын белдерә торган 2 нче зат формасы үзәк форма дип санала.

Эшне башкаручы зат алмашлыклары б-н белдерелә ала. Зат категориясенә мөнәсәбәте ягыннан барлык фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз төрләргә бүленә. Зат б-н төрләнә торган, ягъни зат кушымчалары ала торган фигыль формалары — затланышлы дип, ә зат б-н төрләнми торган фигыль формалары затланышсыз дип атала. Затланышлы фигыльләргә — хикәя, боерык, шарт һәм теләк фигыльләр; затланышсыз фигыльләргә сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив керә.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 2002. Т. 2; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

*Г.Ф.Гобәйдуллина.*

**ЗАТО́Н**, күл, Идел алды төбәгендә. Элекке су юлында сакланып калган. Зөя елгасының сулъяк тугаенда. Буа р-ны Адав-Толымбай авылыннан 2,1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 10,5 *га*. Озынлыгы 2270 *м*, иң зур киңлеге 80 *м*. Формасы сузынкы, урак сыман. Ял итү урыны.

**ЗАУСА́ЙЛОВ** Василий Иванович (1845, Казан — 1913), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән килгән мактаулы граждан, җәмәгать эшлеклесе, коллекционер. Казан ун-тының химия ф-тын тәмамлый. Колсәет авылындагы «Себер номерлары» кунакханәсе, берничә, ш.и. Казан өязе Савин авылындагы дача хуҗасы. 1891 елда Казанда иң күп җитештерүче тегермән төзи. «Казанда А.А.Печёнкин ширкәте һәм К[0]» банкирлык конторасы хуҗасы һәм чынлыкта җитәкчесе. Әлеге конторага 1871 дә нигез салына, 1880 еллар уртасында капиталы 13 млн сум тәшкил итә, Саратов, Екатеринбург, Түбән Новгород шәһәрләрендә бүлекчәләре була. З. — 1888 дә С.-Петербургта төп капиталы 25 млн сумлык булган «Россиянең имиинуятләштерү һәм өстәмә имиинуятләштерү буенча беренче милли ширкәт» акционерлык җәмгыятен оештыручыларның берсе. 1905 тә җәмгыять бөлгенлеккә төшә. Үзешчән археолог буларак, З. 1887 дә Екатеринбург күргәзмәсендә бронза гасыр эш кораллары коллекциясе өчен Зур алтын медаль ала. Актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара: 1870 тән Казан шәһәр думасы гласные (идарә әгъзасы), 1883 тән Казан ятимнәр мәхкәмәсе рәисе. Казан шәһәр музеена нигез салучыларның берсе һәм беренче директоры. Музейга бронза гасыр эш кораллары коллекциясен бүләк итә. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (1878 дән) һәм Казан икътисад җәмгыяте (1881 дән) хакыйкый әгъзасы. «Казан руханилар академиясенең мохтаҗ студентларына ярдәм итү җәмгыяте»нең гомерлек әгъзасы. Ш.у. к. *Заусайлов коллекциясе*.

*Л.М.Свердлова.*

**ЗАУСА́ЙЛОВ КОЛЛЕ́КЦИЯСЕ**. 1878–1905 елларда Казан сәүдәгәре һәм төбәк тарихчысы В.И.*Заусайлов* тарафыннан Вятка һәм Казан губерналары терр-яләрендә тупланган археол. һәм этнографик артефактлар (табылдыклар) җыелмасы. Төрле дәверләргә (палеолиттан урта гасырларның соңгы чорына кадәр) караган 10935 берәмлектән, ш.и. 5482 таш, 1292 бакыр һәм бронза, 1417 тимер, 1010 сөяк, 1639 балчык һәм пыяла, 295 этнографик предметтан гыйбарәт. 1909 да коллекцияне Финляндия Милли музее сатып ала (шунда саклана). Коллекциянең материалларын өлешчә 1880 дә В.И.Заусайлов, 1916–18 дә А.М.Тальгрен матбугатта бастырып чыгара, нәшер итә. 1961 дә А.Х.Халиков тимер гасырга һәм урта гасырларга нисбәтле 4 меңнән артык предметны тасвирлый һәм рәсемгә төшерә. З.к.нең материаллары «*Татарстан Республикасының археологик картасы*»н («Археологическая карта Республики Татарстан») төзегәндә файдаланыла.

*Әд.:* Tallgren A.M.Collection Zaussailov historique de Finlande a Helsingfors. Hels., 1916–18. V.1–2.

*Е.П.Казаков.*

**ЗАХА́РОВ** Александр Имаметдинович (13.4.1938, Самара ш. — 28.11.1992, Украина Респ-касының Днепропетровск ш.), генерал-лейтенант (1989). Милләте буенча татар. СССР Һава һөҗүменнән саклану гаскәрләренең Энгельс хәрби-техник уч-щесен (1958), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1970, Мәскәү) тәмамлый. 1982 дән Төркестан хәрби округы гаскәри берләшмәсенең сәяси бүлек башлыгы урынбасары, башлыгы; 1989–92 елларда округның сәяси идарә башлыгы. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга Хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ЗАХА́РОВ** Алексей Васильевич (13.3.1953, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1991). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук чагыштырмалылык теориясе һәм гравитация кафедрасында эшли (бүленеп, 2000–03 тә Казан энергетика ун-тында хисаплау математикасы каф. мөдире). Хезмәтләре чагыштырмалылык теориясенә, астрофизикага, космологиягә карый. Матдә составында бәрелешми торган кисәкчек (нейтрино) булуын исәпкә алып, киңәя баручы Галәмдәге гравитацион ярсынулар теориясе төзи. Чагыштырмалылыкның гомуми теориясендә гравитацион кисәкчекләр өчен релятивистик кинетик тигезләмә чыгара.

Хезм.: Релятивистская кинетическая теория и космология. К., 1989; Макроскопические уравнения Эйнштейна с точностью до членов второго порядка малости по взаимодействию // Журн. эксперим. и теорет. физика. 1997. Т. 112, вып. 4 (автордаш); Макроскопическая гравитация. М., 2000.

**ЗАХА́РОВ** Алексей Васильевич (10.7.1940, Казакъстан ССРның Күкчәтау ш.), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1991), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1969 елдан Казан ун-тында, координацион кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1992–2005 тә), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2005 тән). Хезмәтләре координацион кушылмалар эремәләрендәге реакцияләр кинетикасына һәм механизмнарына карый. Бакыр (II) эремәләрендәге сольватомолекулалар һәм лигандаларның химик алмашу реакцияләре тизлеге һәм механизмнары үзгәрүнең төп закончалыкларын тәгъбирли. Бакыр (II)/бакыр (III) һәм тимер (III)/тимер (IV) оксидлашу-кайтарылу реакцияләренең термодинамикасын һәм кинетикасын тикшерүгә яңача якын килүне тәкъдим итә. Координацион кушылмалар эремәләрендәге тиз узучан комплексара ассоциация, сольватлар, лигандалар, протоннарның алмашу һәм электроннарның үзалмашу реакцияләренең механизмнары турында яңа төшенчәләр үстерә. Шешләргә, бәвел килүгә, микробларга каршы кулланыла торган һ.б. тәэсирле күп кенә биологик препаратлар синтезлый (бергәләп).

Хезм.: Быстрые реакции обмена лигандов. Исследование лабильных комплексов переходных металлов. К., 1985 (автордаш); Физико-химические методы исследования координационных соединений в растворах. К., 1988 (автордаш); Кинетика и механизмы реакций замещения лигандов в координационных соединениях меди (II) // Координационная химия. 1989. Т. 15, № 4 (автордаш).

**ЗАХА́РОВ** Борис Фёдорович (22.3.1946, Пенза өлкәсенең Сосновобор р-ны Топоровка а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан а.х. ин-тын (1970), Россия Хезмәт һәм мәшгульлек академиясен (1998) тәмамлый. 1970 елдан Алексеев р-нында: 1971–75 тә «Красный Восток» с-зы баш агрономы, 1975–78 дә Бутлеров исем. с-з директоры, 1978–80 дә а.х. җитештерү идарәсе башлыгы — халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1980–91 дә КПССның Бөгелмә шәһәр ком-ты секретаре, 1 нче секретаре. 1990–95 тә Халык депутатларының Бөгелмә советы рәисе. 1992–96 да Бөгелмә р-ны һәм шәһәре хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта 1995–96 да халык депутатларының Бөгелмә берләштерелгән советы рәисе. 1996–2001 дә ТРның Хезмәт һәм мәшгульлек дәүләт ком-ты рәисе. 2001–2007 дә ТРның хезмәт һәм мәшгульлек министры, 2007 дән министр ярдәмчесе, 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–96 елларда ТР халык депутаты.

**ЗАХА́РОВ** Василий Петрович (7.1.1953, Чистай р-ны Кече Полянка а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1976 елда а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлый, 1977 дән шунда ук эшли, а.х. икътисады каф. мөдире (1997 дән). Хезмәтләре җитештерү структурасын оптимальләштерүгә, агросәнәгать комплексында аграр ресурслар потенциалын бәяләү методикасына, а.х.да базар мөнәсәбәтләрен камилләштерүгә карый.

Хезм.: Государственное регулирование АПК при переходе к рынку. Йошкар-Ола, 1994 (автордаш); Эффективность сельскохозяйственного производства: факторы, резервы и пути повышения. К., 1994; Концепция и методология совершенствования реформ в аграрном секторе Республики Татарстан. К., 1997 (автордаш).

**ЗАХА́РОВ** Вячеслав Михайлович (17.11.1939, Воронеж ш.), радиофизик, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1961–96 елларда Казан ун-ты каршындагы Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, кибернетика бүлеге мөдире (1982–95), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1996 дан Казан техник ун-тында ЭВМ каф. профессоры. Хезмәтләре мәгълүматны дискрет үзгәрткечләр өлкәсенә карый. Ихтималый дискрет мәгълүмат үзгәрт-

кечләр өлкәсендә техник чишелешләр эшли. Уйлап табуга 26 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Моделирование. Вероятные дискретные модели. К., 1998; Полиномиальное представление конечно-автоматных случайных последовательностей над полем Галуа // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2003. № 2.

**ЗАХА́РОВ** Геннадий Михайлович (25.10.1921, хәзерге Түбән Новгород өлкәсе, Арзамас р-ны Селема а. — 26.1.1969, Ленинград ш.), Сов. Союзы Герое (26.10.1943), майор (1949). Хәрби элемтә уч-щесен (1942), Сов. Союзы Маршалы С.М.Будённый исем. Хәрби элемтә академиясен (Ленинград, 1949) тәмамлый. 1930 елдан Казанда яши. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 107 нче аерым элемтә ротасының телефон-кабель взводы командиры (7 нче армиянең 8 нче гв. укчы дивизиясе). Дала фронты гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск (1943), Украинаны азат итү сугышларында катнаша. 1943 нең 25–27 сентябрендә Днепр елгасын кичеп, Домоткань авылы (Днепропетровск өлкәсе Югары Днепропетровск р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә. 1959 да отставкага чыга. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б а с о в и ч Я.И., Т ю л ь н и к о в Л.К. Герои Советского Союза — горьковчане. Г., 1981; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1. *В.А.Шагалов.*

**ЗАХА́РОВ** Геннадий Николаевич (16.3.1935, Куйбышев өлкәсенең Петровский р-ны Петровка а.), хакимият-финанс эшлеклесе. Куйбышев а.х. ин-тын тәмамлый (1957). 1957 елдан Минзәлә р-нында пед. һәм хуҗалык эшендә: 1961 гә кадәр Минзәлә а.х. техникумы укытучысы, 1961–62 елларда Воровский исем. с-зның баш инженеры, 1962–65 тә «Сельхозтехника» производство идарәсенең баш инженеры. 1965–66 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор, 1966–68 дә а.х. бүлеге мөдире урынбасары. 1968–83 тә «Татсельхозмонтаж» тресты управляющие — Татарстан «Сельхозтехника» берләшмәсе рәисе урынбасары. 1983–85 тә ТАССР мелиорация һәм су хуҗалыгы министры, 1985–88 дә ТАССР МС Рәисенең 1 нче урынбасары — Татарстан респ-ка агросәнәгать берләшмәсе Советы рәисе. 1988 дән СССР Саклык банкының Татарстан респ-ка идарәсе башлыгы — РФ Саклык банкының «Татарстан» банкы рәисе, 2001 елдан Идел — Вятка банкы идарәсе рәисе урынбасары — РФ Саклык банкының «Татарстан банкы» бүлеге управляющие. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗАХА́РОВ** Лев Иванович (20.2.1901, Чернигов губ., Глухов өязе Шостка ш. — 2.8.1972, Казан), химик-технолог, проф. (1946), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1961). 1924 елда Шостка химия-технол. ин-тын тәмамлый, Шостка химия з-дында эшли. 1931–34 тә Шостка химия-технол. ин-тында, химия ф-ты деканы. 1934–68 дә Казан хим.-технол. ин-тында; каф. мөдире һәм директор урынбасары. Хезмәтләре нитратцеллюлоз дарылар һәм каты ракета ягулыклары химиясенә һәм технологиясенә карый. Дары эшкәртү процессларының теоретик нигезләрен төзи, аларның үзлекләрен тикшерә. 260 фәнни мәкалә авторы, уйлап табуга 75 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Физико-химические свойства порохов. М., 1940.

*Әд.:* Профессора, доктора наук: Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЗАХА́РОВ** Николай Иванович (20.9.1929, Чистай кантоны (хәзерге Нурлат р-ны) Иске Чаллы а. — 17.7.2002, шунда ук), тракторчы, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1947–91 елларда Октябрь р-нының Синдряков исем. к-зында эшли (бүленеп, 1955–60 та Октябрьск МТСында тракторчы), колхоз рәисе урынбасары (1972 дән). Герой исеме а.х.н үстерүдә, дәүләткә игенчелек һәм терлекчелек продуктлары сатуда бишьеллык (1971–75) планны үтәүдә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Нурлат шәһәрендәге бер урам З. исеме б-н атала.

*Әд.:* Ф а с а х о в К. Захаров Николай Иванович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЗАХА́РОВ** Николай Степанович (11.4.1924, Казан — 24.2.2002, шунда ук), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1979), проф. (1982), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан юридик ин-тын тәмамлый (1949). 1952–59 елларда Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тында укыта. Бер үк вакытта, 1952 дән Казан ун-тының тарих, дәүләт теориясе һәм хокук кафедрасында эшли. Хезмәтләре Россиядә дәүләтчелек үсешенә, декабристлар тарихы һәм идеологиясенә, Россиядә җинаятькә каршы көрәш һәм хокук законнары мәсьәләләренә карый. «Татарстан АССРның оешуы һәм дәүләти-хокукый хәле» («Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР», 1960) документлар җыентыгы, вузлар өчен уку ярдәмлекләре авторы. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Государственный строй Российской империи в первой половине XIX века. К., 1960; Советское государство и право в период иностранной военной интервенции и гражданской войны (1918–1920 гг.). К., 1962; Советы Среднего Поволжья в период борьбы за диктатуру пролетариата. К., 1977; Правонарушения несовершеннолетних и их предупреждение. К., 1983 (автордаш).

*Е.Б.Долгов.*

**ЗАХА́РОВ** Пётр Иванович (19.1.1917, Вятка губ., Алабуга өязе Олы Шүрнәк а. — 24.12.1981, Магнитогорск ш.), Дан орденының тулы кавалеры (22.2.1944, 10.3.1945 (10.11.1970 тә 1 нче дәрәҗәгә үзгәртелгән), 27.4.1945), сержант. Туган авылында тракторчы-комбайнчы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1126 нчы укчы полкның 76 *мм* лы туп төзәүчесе, соңрак 610 нчы истребитель-танкка каршы артиллерия полкы өлкән разведчигы (43 нче һәм 39 нчы армиянең 334 нче укчы дивизияләре). Көнбатыш, 1 нче Балтыйк һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү (1941–42), Смоленск (1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 9 февралендә Городок торак пункты (Витебск өлкәсе) тирәсендәге сугышларда (яралана, ләкин сугыш кырын ташламый, дошманның 10 ут ноктасын юк итә); 1945 нең 13 гыйнварында Пилькаллен торак пункты (Калининград өлкәсе, хәзер Краснознамёнск р-ны Добровольск пос., Көнчыгыш Пруссия) тирәсендәге сугышта дошманның 5 пулемёты һәм тубының координатларын ачыклый һәм безнекеләргә тапшыра); 1945 нең 6–7 апрелендә Рабмекен торак пункты (Кёнигсберг, хәзерге Калининград шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнбатыштарак) янындагы сугышта (дошманның тубы һәм 2 пулемёты координатларын ачыклый һәм безнекеләргә тапшыра, яраланган хәлдә сугышуын дәвам итә) батырлык күрсәтә. Демобилизациядән соң (1946) Магнитогорск шәһәрендә яши; «Челябэнерго» системасында электромонтёр, шофёр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.



Г.М.Захаров.



Н.И.Захаров

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**ЗАХА́РОВА** Анна Андреевна (10.3.1950, Биектау р-ны Олы Пучинкә а.), бухгалтер-икътисадчы, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. икътисадчысы (1984). ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1993, 1997). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972) Биектау р-нында эшли: «Алга» к-зында баш бухгалтер; «Урак һәм Чүкеч» к-зы баш бухгалтеры (1974), рәисе (1988 дән), а.х. җитештерү кооперативы (1994 тән), «*Урак һәм Чүкеч*» ЖЧЖ (2003 тән) директоры. З. җитәкләгән хуҗалык а.х. продукциясен реализацияләүдә һәм җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен берничә тапкыр СССР, РФ, респ-ка һәм район а.х. оешмаларының байрагы, дипломы, грамоталары б-н бүләкләнә, хәзерге вакытта ел саен югары күрсәткечләргә ирешә. 2007 дә бөртекле ашлыкның уңышы 1 *га* дан 24,9 *ц*, бәрәңгенең — 101,1 *ц* тәшкил итә, 1 савым сыердан елына 6468 *кг* сөт савыла. 100 *га* файдалану җирләренә 736 *ц* сөт, 51,8 *ц* ит җитештерелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗАХА́РОВА** Евгения Ивановна (19.4.1955, Алексеев р-ны Языково а.), туфрак белгече-агрохимик, а.х. фән. канд. (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1979 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында. Гыйльми секретарь (2000 нән), бер үк вакытта «Татарстан кыры» фәнни-производство ж-лында җаваплы сәркәтип (2005 тән). Хезмәтләре туфракны эрозиядән саклау өлкәсенә, агроландшафт нигезенә көйләнгән игенчелек системасы мәсьәләләренә карый. «Туфрак структурасын булдыру» («Структурообразователь почв», 1990) өлкәсенә караган авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге «ТРның Биектау р-ны «Чулпан», Арча р-ны «Игенче» к-злары үрнәгендә агроландшафтлы игенчелек системасын эшләү һәм гамәлгә кертүне үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә (1999). СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ЗАХА́РОВА** Светлана Григорьевна (3.5.1946, Казан), музыка белгече, концерт программаларын алып баручы һәм режиссёр, ТАССР һәм РФнең атказ. артисты (1983, 1996). 1969 елда Казан консерваториясенең (А.Леман классы) фортепиано бүлеген тәмамлый. 1969–86 да Казан консерваториясендә һәм бер үк вакытта Казан пед. ин-тында, музыка уч-щесендә концертмейстер булып эшли һәм укыта. Концертмейстер буларак, Татарстанның күренекле җырчылары Э.Җәләлетдинов, З.Сөнгатуллина, Х.Бигичев, Р.Мифтахова, К.Румянцева һ.б. б-н чыгышлар ясый. 1977 дән барлык төр муз. белгечлекләр буенча музыкант-башкаручыларның халыкара, бөтенсоюз, бөтенроссия конкурс-фестивальләренең оештыру ком-тлары әгъзасы, муз. редакторы һәм алып баручысы (ш.и. Сочида уздырылган совет җырлары, Мәскәүдә — П.И.Чайковский исем. конкурслар). З. — ТР Дәүләт симфоник оркестры һәм Н.П.Осипов исем. Милли академик оркестрның (Мәскәү) лекторы — музыка белгече. П.И.Чайковский исем. Концерт залында һәм Гнесиннар исем. Россия музыка академиясендә (Мәскәү) — «Россия дирижёрлары» («Дирижёры России»), «Пәнҗешәмбе очрашулары» («Встречи по четвергам»), «Укытучы һәм укучылар» («Учитель и ученики»), «Халык уен коралларында иң яхшы башкаручылар» («Лучшие исполнители на народных инструментах»), «Россия балалары җырлый» («Поют дети России») һ.б. абонемент концертларын алып бара. З. 1989 елдан «Яңа исемнәр» («Новые имена») халыкара программасы б-н хезмәттәшлек итә. Мәскәүдә һәм Казанда танылган җырчылар һәм коллективлар (Л.Казарновская, Д.Хворостовский, З.Соткилава, А.Ведерников, Э.Грач, В.Третьяков, В.Стрельченко һ.б.) катнашындагы концерт программаларын, балалар аудиторияләре өчен махсус программалар һәм абонементлар алып бара.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ЗАХВА́ТКИНО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 4 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2002 елда даими яшәүчеләр теркәлмәгән. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 119, 1949 да — 136, 1958 дә — 189, 1970 тә — 135, 1979 да — 61, 1989 да — 13 кеше.

**ЗАХВА́ТОВ** Герман Иванович (29.7.1940, Казан), электрохимик, техн. фән. д-ры (1991), проф. (1992). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), СССР ФА Казан ф-лы Химия ин-тында эшли. 1970 елдан Казан төзүче инженерлар ин-тында (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты), автоматика һәм электротехника каф. мөдире (1985 тән). Хезмәтләре сәнәгый экологиягә карый. З. су системаларын электрик нейтральләштерүнең һәм регенерацияләүнең реагентсыз алымын эшли, ш.у. эремәләр һәм агынты суларны регенерацияләү һәм чистартуның аз энергия тотып эшли торган югары эффектив, тулысынча автоматлаштырылган җайланмаларын проектлаштыра. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Регенерация растворов на базе безагентных электрических методов // Материалы 5 междунар. симп. «Ресурсоэффективность. Энергосбережение». К., 2002; Электрохимический метод стабилизации качества оборотной воды // 7 Междунар.-практ. конф. «Природоресурсный потенциал, экология развития регионов России»: Сб. статей. Пенза, 2010.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Илдус Котдус улы (1.1.1963, Балтач р-ны Яңгул а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1985–88 елларда Балтач р-ны Түнтәр урта мәктәбендә укытучы. 1990–93 тә РФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1993–97 дә Татар көллияте (1996 дан Татар гуманитар ин-ты) директоры, ин-тның беренче ректоры, 1997–98 дә проректоры. 1998 дән ТР ФА Тарих ин-тында урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире (бүленеп, 2006 да Россия ислам ун-ты ректоры). Хезмәтләре татар халкы һәм Россия империясе ислам ин-тлары тарихына карый.

Х е з м.: Перепись 1897 года и татары Казанской губернии. К., 2000; Исламские институты в Российской империи: Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII — начало XX вв. К., 2003; Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи: (Европейская часть России и Сибирь). К., 2006; Исламские институты в Российской империи: мечети в европейской части России и Сибири. К., 2007.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Равил Габделбәшир улы (Равил Заһидулла) (28.10.1960, Казан), нәкышьче. Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1984). 4 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укыта (1987–90). 1990 елдан ТР Сынлы сәнгать фондында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). Тарихи картиналар жанрында эшләүче әйдәп баручы рәссамнарның берсе; аның картиналары, рәсемнәре татар халкының урта гасырлардагы тарихына багышлана, Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихы вакыйгаларын яңадан торгыза. Образларны, әйләнә-тирә мохитне, вакыйгаларны картиналарга этнографик, документаль төгәллек б-н диярлек күчереп, иҗат юлын реалистик стильдә башлый («Җәй уртасы», 1984; «Безнең әбиләр»,



Р.Г.З а һ и д у л л и н. «Казан. Җомга». 2001.

1986), детальләрдәге гаҗәеп төгәллекне саклаган хәлдә, әкренләп сынлы сәнгать теленең декоратив тәэсирлелегенә, композиция чишелешенең яссылыкта гәүдәләнешенә күчә бара. З. әсәрләрендә даими эзлеклелек б-н гарәп язма хәрефләре, 16 йөз нидерланд нәкыше һәм рус тарихи нәкыше йогынтысы нык сизелә. Төп әсәрләреннән — «Урак өсте» (1987), «Сабан туе» (1989), «Җәйге көннәр» (1991), «Борынгы Казан» (1992), «Дәрвиш» (1996), «Хан авы» (2000) һ.б. Республика («Г.Тукайның тууына 100 ел тулу уңаеннан», 1985, Казан), төбәк («Зур Идел», 1991, Казан һ.б.), бөтенроссия («РСФСРның автономияле республикалары, өлкәләре һәм милли округлары рәссамнары», 1989, Мәскәү; «Россия-9», 1999, Мәскәү), бөтенсоюз (Яшьләр күргәзмәсе, 1986, Мәскәү), халыкара («Казан сынлы сәнгате», 1994, Зутфен ш., Нидерланд) күргәзмәләрендә, «Ислам һәм татар халкының дини мәдәнияте» ретроспектив күргәзмәләрендә (2000, Шәрекъ халыкларының дәүләт музее, Мәскәү) катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1997, 2002 (Казан). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда саклана.

*Әд.:* Е г о р о в а М. Гармония һәм Тәэссорат // Сөембикә. 1998. № 10; С и д о р о в В. Единство // Художник. 1990. № 14.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*





Р.Г.З а һ и д у л л и н. «Болгарлар Идел буенда» (диптих). 1985.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Рамил Равил улы (30.11.1965, Казан), спортчы (тимераякта шуу), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1985), 500 *м* га йөгерүдә дөнья рекордчысы (1984). Спорт б-н Казандагы 9 нчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый. Тренерлары — Л.А.Булычкова (1976–80), Е.А.Жарков (1980 нән, «Труд» ирекле спорт җәмгыяте). Волгоград физкультура ин-тының Чаллы ф-лын тәмамлый (1991). СССР беренчелегенә ярышларда (1982, яшьләр арасында; 1984, яшүсмерләр арасында), СССР кубогына ярышта (1985, 500 *м* га йөгерү), 3 шугалак турнесы (1986, ГФР, Австрия, Италия), СССР–ГДР матчларында (1986) җиңүче. СССР кубогы иясе (1986). СССР чемпионатында (1984, спринтерларның күп төр ярышлары), Дөнья кубогы этапларында (1986) бронза медаль ала.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Рәис Газиз улы (30.3.1932, Кайбыч р-ны Кайбыч а. — 29.5.1998, Казан), шофёр, Соц. Хезмәт Герое (1966). Васильево автотранспорт техникумын тәмамлый (1975). 1946–51 елларда Казандагы сәнәгать пр-тиеләрендә токарь булып эшли. 1955–59 да Казан инженерлык-саклау идарәсенең автотранспорт конторасында шофер, механик. 1959–97 дә Казан йөк ташу автотранспорты җитештерү берләшмәсендә шофёр, механик, автоколонна җитәкчесе, машина йөртүче-остаз. З. бригадалап йөк ташу ысулын кертә, зур автопоездларны төзү һәм йөртүнең инициаторы, беренче «КАМАЗ» автомобильләрен җыю һәм сынауда катнаша. Герой исеме халык хуҗалыгы йөкләрен һәм пассажирлар ташу, автомобиль юлларын карап тоту, ремонтлау һәм төзү буенча җидееллык план йөкләмәләрен (1959–65) үтәүдә ирешелгән казанышлары өчен бирелә. 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г о р н и к Г. Загидуллин Раис Газизович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Рәшит Муллагали улы (18.11.1964, Пермь өлкәсе, Губаха р-ны Широков пос.), режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998), РФнең атказ. артисты (2008). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1988), Казан Яшь тамашачылар театрына кабул ителә. Бер үк вакытта Татар филармониясендә режиссёр булып эшли. 1993 елда Б.В.Щукин исем. театр уч-щесенең (Мәскәү, Е.Р.Симонов остаханәсе) режиссёрлык ф-тын тәмамлый һәм К.Тинчурин исем. Татар драма һәм комедия театрының баш режиссёры итеп билгеләнә. Бу вакытта иҗат коллективы күчмә театр статусыннан стационарга күчә торган катлаулы чор кичерә. З., Вахтангов мәктәбе тәрбиясе алган, аның эстетик принципларын үзләштергән белгеч буларак, һәр спектакльдә эчтәлек б-н форманың уңышлы тәңгәллəшүенә ирешә. Театр телен яңарту кирәклеген тоеп, яңа тасвирлау чаралары эзли, классик драматургия әсәрләрен яңача сәхнәләштерергә тырыша. К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» мелодрамасы З. куелышында тирән фәлсәфи мәгънәле, киң колачлы фаҗига булып күз алдына килеп баса. Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур» тарихи романы халык дастаны жанрында куела (1993). Татар проф. театры сәхнәсендә беренче тапкыр Б.Брехтның «Кураж ана һәм аның балалары» әсәрен яңача уйнау ысуллары кулланып сәхнәләштерә (2000). Жанрларны төрләндерүгә омтыла: И.Грекова повесте буенча эшләнгән «Тол хатыннар көймәсе» психол. драмасын, Т.Гыйззәт һәм Җ.Фәйзинең «Башмагым» муз. комедиясен, классик буффонада жанрында Ж.Б.Мольерның «Де Пурсоньяк әфәнде», халык көнкүреше темасына Х.Вахитның «Тагын мәхәббәт турында», Г.Зәйнашеваның «Гайфи бабай, өйлән давай!», ш.у. К.Тинчуринның «Назлы кияү», П.Бомаршеның «Фигароның өйләнүе» әсәрләрен сәхнәгә куя. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында, Казан театр уч-щесендә укыта.

*И.И.Илялова.*

**ЗАҺИДУ́ЛЛИН** Фәхретдин Гыйльметдин улы (1911, Казан губ., Мамадыш өязе Байлангар а. — 16.3.1998, Кемерово ш.), Сов. Союзы Герое (21.7.1944), сержант. 1933–41 елларда Кемерово шәһәрендә завод азык-төлек базасының тәэминат хезмәте башлыгы. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 913 нче сапёрлар батальоны отделениесе командиры (7 нче армиянең 4 нче укчы корпусы). Карелия фронты гаскәрләре составында Свирь елгасы (Ленинград өлкәсе) буенда барган оборона сугышларында, Свирь-Петрозаводск һөҗүм операциясендә (1944), Ленинград блокадасын өзүдә катнаша. 1944 нең 21 июнендә Свирь елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. Сугыштан соң Кемерово шәһәренә кайта. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Кемерово шәһәрендә З. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Героям Родины — слава! Петрозаводск. 1985.

*В.А.Шагалов.*

**ЗАҺИДУ́ЛЛИНА** Әлфия Гафиятулла кызы (7.9.1936, Үзбәкстан ССРның Коканд ш. — 25.6.2004, Казан), җырчы (сопрано), педагог, ТАССРның халык (1981), РСФСРның атказ. артисты (1987). 1966 елда Казан консерваториясен (З.Хисмәтуллина классы) тәмамлый. 1963–76 елларда Татар опера һәм балет театры, 1976–88 дә Татар филармониясе солисткасы. Төп партияләре: Сусылу («Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов), Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи), Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Татьяна («Евгений Онегин», П.И.Чайковский), Наташа («Су кызы», А.С.Даргомыжский), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе) һ.б. З.ның иҗади йөзен югары вокаль культура, татар, Көнбатыш Европа, рус композиторлары җырларын һәм романсларын, опера партияләрен, татар халык җырларын ихлас күңелдән тәэсирле итеп башкаруы аерып тора. Җырчының концерт репертуарын 600 гә якын әсәр тәшкил итә. Филармония һәм театр труппасы составында Россия шәһәрләре буйлап гастрольләрдә була, радио һәм теле



Рәис Г. Заһидуллин.



Ф.Г. Заһидуллин.

видениедән чыгышлар ясый. 1969–2001 дә Казан консерваториясендә укыта. Шәкертләре арасында Г.Ибушев, З.Хәйретдинов, И.Сафин, Л.Әхмәтова, А.Ланцовлар бар.

*А.Р.Рахмани, Ф.Ш.Салитова.*

**ЗАҺИДУ́ЛЛИНА** Гөлсинә Мансур кызы (6.9.1955, Казан), төзүче-инженер, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (1997). 1977 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, икътисад һәм төзелештәге эшмәкәрлек каф. мөдире (1989 дан), бер үк вакытта икътисад ф-ты деканы (1999 дан). Күчемсез милекне бәяләү белгече. Хезмәтләре төзелеш оешмаларын үстерү икътисадына, төзелеш эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек базарын үстерүгә карый. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратегия развития строительного предприятия в условиях рынка. К., 1996; Анализ финансовой устойчивости и инвестиционной привлекательности строительной организации. К., 1999 (автордаш); Инвестиционное планирование. К., 1999 (автордаш).

**ЗАҺИДУ́ЛЛИНА** Дания Фатих кызы (1.10.1964, Мөслим р-ны Әмәкәй а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2001), проф. (2002). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, баш гыйльми сәркәтибе (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1986), 1989 елдан шунда эшли. КДУның татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре татар әдәбияты теориясе һәм тарихына, урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасына карый.

Х е з м.: Әдәбият кануннары һәм заман. К., 2000; Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. К., 2000; Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003; Дөнья сурәте үзгәрү. XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. К., 2006; Яңа дулкында. К., 2006.

**ЗАҺИДУ́ЛЛИНА** Лия (Елизавета) Михайловна (25.4.1946, Казан), актриса, телевидение дикторы, журналист, ТССРның халык, РФнең атказ. артисты (1990, 1997). Казан театр уч-щесен (1966), Казан ун-тын (1974), Бөтенсоюз телевидение һәм радио хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-тын (Мәскәү, 1982) тәмамлый. 1966 елдан «Татарстан» ДТРКның Казан телевидение студиясе дикторы. Бер үк вакытта 1993 тән дикторлар төркеме җитәкчесе, 1997 дән «Диктор-ТВ» студиясенең сәнгать җитәкчесе. Яңалыклар, әдәби һәм концерт программаларын алып бара. 1980 елларда «Чын күңелдән»,



Л.М. Заһидуллина.



С.С. Заһирова.

1989 дан — элекке һәм хәзерге чорның атаклы хатын-кызларына багышланган «Ханым» программасының (рус һәм татар телләрендә), Төркия, Венгрия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Туниска багышланган телефильмнарның авторы һәм алып баручысы. Казанның 1000 еллыгына багышланган «Шәһәр портретына штрихлар» атналык тапшыруларын алып бара (2001–2005). Россия һәм чит илләрнең күпсанлы телевизион конкурс һәм фестивальләре лауреаты һәм дипломанты. «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» (1999, 2001), РФ Журналистлар берлеге (2000) бүләкләре лауреаты.

*Әд.:* М о р о з о в А.В. Персона. К., 1998.

**ЗАҺИ́РОВ** Мәгъсүм Мөдәррис улы (29.5.1937, Баулы р-ны Хансуәр а.), нефтьче, техник фән д-ры (1986), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Новосибирск геол. идарәсенең нефть эзләү мастеры, өлкән инженеры. 1965–68 елларда «Гипротөмәннефтегаз» ЖБдә лаб. мөдире. 1968 дән ТатНИПИнефтьтә лаб., бүлек мөдире. 1995–2004 тә ТатНИПИнефть каршындагы «Нефть чыгару җиһазларын тутыгудан саклау һәм катламдагы басымны күтәрү» фәнни җитештерү берләшмәсендә директор. Тикшеренүләре нефть һәм газ табуда гамәли проблемалар, торбаларны футеровкалау, торбалар, резервуарлар, бикләвеч арматураларны саклагыч катлам б-н каплау өчен технологик комплекслар эшләү, нефть чыганакларын эшкәрткәндә экологик иминлек чараларын булдыру б-н бәйле. СССР, ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1988, 1996).

**ЗАҺИ́РОВ** Наил Хәйбулла улы (20.11.1925, БАССРның Учалы р-ны Ураз а.), тау инженеры, техник фән д-ры (1970), проф. (1971), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1982). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда М.И.Калинин исем. Мәскәү төсле металлар һәм алтын ин-тын (хәзер М.И.Калинин исем. Красноярск дәүләт алтын һәм төсле металлар академиясе) тәмамлый, шунда ук эшли, ректор (1959–62), руда чыганакларын җир астында эшкәртү каф. мөдире (1964 тән). Төсле металлургия укыту-фәнни үзәген Мәскәүдән Красноярск шәһәренә күчерүне оештыручы (1959). Хезмәтләре уран, тимер рудасы, алтын һәм төсле металлар чыганакларын җир астында эшкәртүгә карый. Красноярск рудникларында кертелгән катламлап ишеп төшерә торган җитештерү системаларының оптималь параметрларын төзи; каты файдалы казылма запасларының чыгаруга әзерлеген оптимальләштерүнең фәнни юнәлешен җитәкли (1970). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Актуальные проблемы ресурсосбережения при добыче и переработке полезных ископаемых. Красноярск, 1996; Избранные труды к 50-летию инженерной, научной и педагогической деятельности. Красноярск, 2000; Проектирование образовательной программы для непрерывного образования // Тр. Междунар. семинара «Инженерное образование в 21 веке». Тамбов, 2001.

**ЗАҺИ́РОВА** Сания Сабир кызы (13.2.1918, Казан губ., Казан өязе Олы Мәңгәр а.), аяк киеме өлгесе кисүче, Соц. Хезмәт Герое (1966). «Спартак» күн-аяк киеме комб-тының ФЗӨ мәктәбен тәмамлый (1939). 1940–46 елларда кибеттә сатучы (Әтнә р-ны Олы Мәңгәр а.). 1946–47 дә Казан ат дирбиясе эшләү ф-касында өлге кисүче. 1948–73 тә «Спартак» сәүдә-сәнәгать аяк киеме берләшмәсендә өлге кисүче. Герой исеме җиңел сәнәгать продукциясен җитештерүдә югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне һәм җиделлык план (1959–65) йөкләмәләрен үтәгәндәге казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л а т ы п о в М. Загирова Сания Сабировна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЗАҺИ́ТОВ** Гази Казыйхан улы (20.8.1921, хәзерге БРның Мишкә р-ны Янагыш а. — 23.8.1953, шунда ук), Бөек Ватан сугышы герое. Бөре мед. уч-щесендә укый. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1945 тә 136 нчы армиянең Режец артиллерия бригадасы өлкән сержанты, разведчигы. 1945 нең 30 апрелендә капитан В.Н.Маков төркеме составында (өлкән сержантлар А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко, сержант М.П.Минин) Рейхстагны штурмлауда катнаша; күкрәгендә үтәли җәрәхәт булуга карамастан, 22 сәгать 30 минут-


Министерство обороны Российской Федерации

Ордена Красной Звезды
ИНСТИТУТ
ВОЕННОЙ ИСТОРИИ

[illegible]

НАЧАЛЬНИК ИНСТИТУТА
Генерал-майор
В.Золотарев

Г.К. Заһитов һәм аның сугышчан иптәшләренең батырлыгы хакында яңа документларның берсе.



Г.К.Заһитов.

та, М.А.Егоров һәм М.В.Кантариягә кадәр үк, М.П.Минин б-н бергә беренче булып Рейхстаг бинасындагы «Җиңү алиһәсе» дигән скульптур төркем өстенә үз частенең байрагын кадап куя. Бу батырлыклары өчен 3 нче Удар армиянең командующие генерал-полковник В.И.Кузнецов әлеге төркемнең башка кешеләре б-н бергә Заһитовны Сов. Союзы Герое исеменә тәкъдим итә, әмма 1 нче Белоруссия фронты командующие Г.К.Жуков карары буенча алар барысы да Кызыл Йолдыз ордены б-н генә бүләкләнә. 1946 елдан З. БАССРның Мишкә р-ны Урьязы МТСнда механик, Янагыш авыл советы рәисе булып эшли. З.ның тормышы һәм батырлыгына багышлап Ш.З.Рәкыйпов «Геройлар үлмиләр» (К., 1978) һәм И.Ә.Абдуллин «Рейхстаг өстендә кабынган байрак» (Уфа, 2007) исемле китаплар язалар. Кызыл Йолдыз, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р ә к ы й п о в Ш. Чын тарих шуннан гыйбарәт... // Шәһри Казан. 2002. 8–11 май; В ы с о ц к и й В.Н. Мероприятие «Терминал». Потсдам, 1945. М., 1975; Е г о р о в М.А., К а н т а р и я М.В. Знамя Победы. Бой первый — бой последний // Лит. запись Б.Данюшевского. М., 1975; И в а н о в Н.Д. Кто поднял знамя над Рейхстагом? // Рос. газета. 1995. 29 апр.; Я м с к о й Н. Знамя № 5 // Лит. газета. 2001. 16–22 мая;

*Ш.С.Мостафин, Г.С.Сабирҗанов.*

**ЗАҺРЕТДИ́НОВ** Габбас Мингали улы (11.11.1936, Кама Тамагы р-ны Олы Салтык а.), метрология һәм системаларның ышанычлылыгы гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2000), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация технол. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүленеп, 1986–89 да Казан двигательләр җитештерү технол. фәнни-тикшеренү ин-тында сектор башлыгы), 1999 дан системаларның сыйфаты һәм ышанычлылыгы, газ турбиналы двигательләрнең стенд сынауларын матем. программалар б-н һәм метрологик тәэмин итү секторы башлыгы, 2003 тән шул исем. лаб. башлыгы. Хезмәтләре гамәли математикага, ышанычлылык теориясенә, метрологиягә һәм метрологик тәэмин итүгә карый. Катлаулы техник объектларны автоматлаштырылган тикшерүнең (контрольнең) дөреслеген хисаплау һәм аның төгәллеген арттыру, автоматлаштырылган тикшерү системаларында үлчәү нәтиҗәләренең төгәллеген арттыруның матем.-стат. ысулларын эшли. Дистәләгән газ турбиналарында автоматлаштырылган системаларны тикшерүнең ышанычлылыгын исәпләү эшләрен башкара. З. җитәкчелегендә, тикшерү системаларының үлчәү каналларындагы очраклы төгәлсезлекләр таралу законнарын исәпкә алып, автоматлаштырылган метрологик аттестация системасы эшләнә. Автоматлаштырылган тикшерү

системаларының икътисади һәм техник нәтиҗәлелеген анализлау методикасы төзелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Достоверность автоматизированного контроля. К., 1980; Достоверность автоматизированного контроля ГТД при испытаниях. К., 2001 (автордаш); Статистические методы повышения точности измерений в системах автоматизированного контроля и испытания газотурбинных двигателей. К., 2002; Таблицы расчёта достоверности контроля параметров и ее характеристик. К., 2003 (автордаш); Достоверность автоматизированного контроля технических объектов. К., 2005; Обеспечение систем автоматизированного контроля запасными элементами. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Ф а з ы л җ а н о в а Ф. Очкычларның хәлен белешеп // Гүзәл Кама Тамагы. К., 2006.

**ЗАҺРИ́ЕВ** Васыйх Васыйл улы (1.12.1930, Тәкәнеш р-ны Түбән Шандыр а. — 8.3.1994, Мәскәү өлкәсенең Пушкино ш.), урманчылык белгече, а.х. фән. д-ры (1981), проф. (1989). Лубян урман техникумын (1949) һәм Бөтенсоюз читтән торып уку урман-техник ин-тын (Ленинград, 1957) тәмамлый. 1949–59 елларда Ленинград аэрофотоурмантөзү трестының урман төзү партиясендә инженер-таксатор, партия башлыгы. 1959 елдан Бөтенсоюз урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Пушкино ш.), 1980 нән урманнарны бәяләү лаб-ясе мөдире. З. урман утыртмаларының үсеш типларын өйрәнүне нигезләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре агач үсүен классификацияләү, аны билгеләү һәм куллану ысулларына, урманның өлгергәнлеген, киселәсе агачларның яшен билгеләү, урманнан файдалану күләмен исәпләү мәсьәләләренә карый. З. җитәкчелегендә, илдә беренчеләрдән булып, барлык урман хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тлары катнашында урманнарның үсеше һәм аларның продуктлылыгы хакында Россия һәм дөнья мәгълүматларын туплау, анализлау һәм бәяләү буенча киң колачлы эшләр башкарыла. Шулар нигезендә З.ның фәнни редакциясендә Россия һәм БДБ илләре урманнарын бәяләү өчен бөтенсоюз һәм төбәк норматив-белешмәлекләренең бердәм 16 томлык сериясе әзерләп чыгарыла. Монографияләр һәм дәреслекләр, ш.и. «Урманнарны бәяләү нигезләре» («Основы лесной таксации». М., 1975) һәм «Урманнарны бәяләү һәм урман төзү нигезләре» («Основы лесной таксации и лесоустройства». М., 1991) дәреслекләре авторы. 1970 еллар башыннан урманнарны бәяләү проблемалары буенча илдәге фәнни-тикшеренүләр җитәкчесе һәм координаторы, РФ Урман хуҗалыгы федераль хезмәтенең техник советы әгъзасы. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт размера лесопользования. М., 1973; Географические закономерности роста и продуктивности древостоев. М., 1978; Прирост леса. М., 1981; Общесоюзные нормативы для таксации лесов. М., 1992.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ЗӘБИ́Р** бине Касук (19 йөзнең соңгы чиреге — 20 йөзнең 1 нче чиреге, хәзерге Әлмәт р-ны Иске Баграж-Елховой а.), ташка уеп язу остасы, хаттат. З.б.К. эшләгән кабер ташларының берсе Иске Баграж-Елховой авылы зиратында саклана. Ул 1916 елда Минһаҗетдин Гыйсметдин улы каберенә куелган. Кабер ташы ак таштан әзерләнгән, турыпочмаклы плитә (үлчәмнәре 60×36×15 *см*) ярымтүгәрәк дуга б-н очланган, алгы ягына — Аллаһка багышлау һәм мәрхүмне җирләү вакыты турында мәгълүмат, артында вафат булучы б-н ташка язучы исемнәре уелган. Истәлек татар телендә, гарәп язуының сөлес ысулы б-н һәм тирән итеп уеп язу техникасында башкарылган. Бизәкләр кулланылмаган. Мәрхүмнең туу һәм үлү еллары һиҗри һәм милади ел исәпләрендә гарәп саннары б-н күрсәтелгән. Текст уйма кыса эченә алынган.



Зәбир бине Касук. Кабер ташы. Уеп бизәкләү. Иске Баграж-Елховой авылы (хәзерге Әлмәт районы). 1916.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЗӘБИРИ́** (Зәбиров) Хәбибрахман Габделвәли улы (псевд. Чистапули) (1881, башка мәгълүматларда 1880, Казан губ., Чистай өязе Зирекле а. — 14.1.1942, Казан), язучы, педагог. 1901 елга кадәр мәдрәсәдә укый, аннары Чистай шәһәрендә, мәктәпләрдә укыта. Соңыннан «Хөсәения» (Оренбург ш.) мәдрәсәсендә эшли. 1908 дән Казанда, «*Тәрбия*» ж-лының фактик мөхәррире. 1908–16 да «Сабах» нәшриятында, 1916–21 дә И.Н.Харитонов типографиясендә, 1921–29 да төрле дәүләт нәшриятларында эшли. Мәгърифәтчелек идеяләре б-н сугарылган «Гыйлем вә җәһел, яхуд Нури әфәнде илә Мөхәммәтҗан карт» исемле хикәясе, 10 га якын юмористик мәзәге, «Төшенү, яки Указ бәласы» исемле комедиясе («Сәйяр» труппасы тарафыннан 1907 елда куела) 1906 елда «Әл-гаср әл-җәдид» ж-лында (Уральск шәһәре) басылып чыга. 1914 елда «Ил» г-тасында (Петербург) Г.Тукай турында язылган «Габдулла әфәндenең Уфадан Петербургка баруы» дигән мәкаләсе басыла. З. — «Мәктәп балаларына юлдаш, яки Рәсемле әлифба» (1907) исемле беренче татар әлифбасы, башлангыч мәктәп өчен язылган физика, этика, тарих дәреслекләре авторы. Репрессияләнә, вафатыннан соң аклана.

*Әд.:* Ш ә һ и д у л л и н Ш. Заман календаре. К., 1915; И б р а һ и м о в Ф. Белем әлифбадан башлана. К., 1973; Р ә м и И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001; Хәтер китабы. К., 2002. Т. 3.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ЗӘБИ́РОВ** Миншәех Харис улы (10.11.1932, Кыргызстан АССРның Ош ш. — 26.4.2009, Казан), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Казан ун-тын (1958), КПСС ҮК каршындагы югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1967) тәмамлый. 1958–60, 1962–65 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында (әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, 1962 дән баш мөхәррир). 1960–62 дә «Яшь ленинчы» г-тасында җаваплы сәркәтип. 1967 дән «Социалистик Татарстан» г-тасында бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары, җаваплы сәркәтип. 1990 нан «Шәһри Казан» г-тасында җаваплы сәркәтип, бүлек мөдире, әдәби хезмәткәр, 1995–2005 елларда «Мәдәни җомга» г-тасында баш мөхәррир урынбасары. Мәкаләләрендә әдәбият, сәнгать һәм мәдәният мәсьәләләрен яктырта. 1994 тән татар «Мөселман календаре»н төзүче һәм гамәлгә куючыларның берсе. ТР Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (1993). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а м м а т о в Ш. Газета һәм әдәбият дуслыгы. К., 1979; М о р а т Г. Түбә. К., 1998.

**ЗӘБИ́РОВ** Наил Гали улы (5.9.1953, Казан), химик, химия фән. д-ры (1995). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1995 тән). Хезмәтләре элементорганик һәм микроциклик кушылмалар химиясенә, аларның комплекслар хасил итү үзлекләренә карый. Кабатлы углерод-азот бәйләнешләре булган кушылмаларның дүрт координацияле фосфор кислоталары б-н реакцияләрен тикшергәндә кайтма төркемләнү күренешен ачыклый. C(X)NHP(Y) (бирелә X,Y=O,S) фрагментлы булган кушылмалар синтезлауның нәтиҗәле һәм универсаль яңа ысулларын эшли. Аларның төзелешен, химик һәм комплекслар хасил итү үзлекләрен тикшерә. Металларның бер үк вакытта «каты» һәм «йомшак» ионнарын комплексларга бәйләүче яңа тип комплекс ясагычлар таба, комплекслар хасил итүдә «кыскыч» һәм «кунак-хуҗа» механизмнарының икесен бергә куллана. Цикллары составына металл атомнары кергән супрамолекуляр кушылмаларның яңа классын синтезлауны гамәлгә ашыра. Синтезланган фосфорорганик кушылмалар арасыннан гамәли файдалы үзлекләргә ия булган матдәләр (эффектив комплекслар хасил итүчеләр, экстрагентлар, металларны тутыгудан саклаучы ингибиторлар, пестицидлар, дару чаралары, май кушылдыклары, желатин иләгечләр, төсле фотоматериалларга өстәмәләр, газ-сыекча хроматографиясе өчен күчми торган фазалар, полимерларга өстәмәләр) таба. Уйлап табуга 43 авторлык таныклыгы бар. «Плизер» фирмасын оештыручы һәм ген. директоры (1991 дән), «Дилайт» фирмасы директоры (1996 дан). М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге лауреаты (1984). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: N-фосфорилированные амиды и тиоамиды // Успехи химии. 1991. Т. 60, вып. 10 (автордаш); Спектроскопия ЭПР и динамическое поведение комплексов меди (II) с N-(тио)фосфорилированными тиоамидами // Журн. неорганической химии. 1996. Т. 41, вып. 7 (автордаш); Синтез и комплексообразующие свойства N-(тио)фосфорилированных био(тио)мочевин // Журн. общей химии. 2000. Т. 70, вып. 8 (автордаш).

**ЗӘБИ́РОВ** Рамил Әхмәт улы (3.8.1946, Оренбург өлкәсе, Бурта р-ны Гирьял а.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1989). 1970 елда Оренбург мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1989 дан оториноларингология каф. мөдире. Хезмәтләре органнарны сәламәтләндерү хирургиясенә карый. З. озакка сузылган мезотимпанит авыруларына мирингопластика өчен трансплантант, озакка сузылган колак ялкынсынуын, бугаз алды яман шеш авыруын хирургик дәвалауның яңа ысулларын эшли. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Органовосстанавливающие методы хирургического лечения рака преддверия гортани. Самара, 1992 (автордаш); Результаты лечения воспаления трепанационной полости после радикальной операции на ухе // Материалы XVI съезда оториноларингологов РФ. Сочи, 2001.

**ЗӘБИ́РОВ** Хәсән Шәрифҗан улы (15.3.1958, Пенза өлкәсенең Неверкино р-ны Октябрьское а.), юллар, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, инженер, техник фән. д-ры (2001), проф. (2001), РФнең атказ. транспорт хезмәткәре (2003). Хезмәт эшчәнлеген 1977 елда юл төзәтүче буларак башлый. Мәскәү тимер юл транспорты инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Горький тимер юлында эшли: станциядә дежур торучы, маневрлар үтәүче хезмәткәр, станция диспетчеры, баш инженер (1988 дән), Горький-Сортировочный станциясе башлыгы (1990 нан); Горький бүлеге башлыгының 1 нче урынбасары (1992 дән), юл башлыгы урынбасары — ташу-күчерү хезмәте башлыгы (1995 тән), юл башлыгы (1999 дан). 1998–99 да Ерак Көнчыгыш тимер юлы башлыгының 1 нче урынбасары (Хабаровск ш.). 2002 дән РФ юллары министры урынбасары, 2003 тән 1 нче урынбасары. 2003 тән «Россия тимер юллары» АҖнең 1 нче вице-президенты. З. ярдәме б-н ТРда шәһәр яны һәм пассажирлар ташу хәрәкәт паркы шактый яңартыла; яңа шәһәр яны маршрутлары ачыла; Буа, Зөя, Арча, Кукмара, Шәмәрдән станцияләрендә вокзаллар, Казанда пассажирларга хезмәт күрсәтү бинасы төзелә; Казан, Әгерҗе, Каратун станцияләрендәге вокзаллар яңартып корыла. Уйлап табуга 40 тан артык авторлык таныклыгы бар. З. җитәкчелегендә ташу-күчерү процессларын, поездларны файдалануның ышанычлылыгын тәэмин итү һәм хәрәкәтнең иминлеге б-н идарә итүне автоматлаштыру өлкәсендә башкарылган фәнни эшләнмәләр Россия тимер юлларында киң кулланыла. Түбән Новгород өлкәсенең Законнар чыгару җыены депутаты (2002 дән). РФ хөкүмәте бүләге лауреаты (2003).

**ЗӘБИ́РОВА** Фәридә Мөхәммәт кызы (11.2.1954, Казан), архитектор, ТРның атказ. архитекторы (2001). Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1976). 1977 елдан «Росреставрация» берләшмәсенең Татарстан махсус фәнни-реставрация остаханәсе архитекторы. 1981 дән Баш архит-ра-планлаштыру идарәсендә проект эшләре секторы башлыгы, 1986 дан һәйкәлләрне саклау производство төркеме җитәкчесе, 1991–2005 тә ТР Архитектура һәм шәһәр төзү баш идарәсенең Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм файдалану дәүләт контроле идарәсе башлыгы. 1991–2000 дә ТР Архитекторлар берлеге идарәсе рәисе. 1993 тән шәхси иҗат остаханәсен җитәкли. 2008 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында укыта. Казан Кремлендәге Тупчылар йортын һәм Губернатор сараен, ш.у. *Кекин йортын*, *Мәрҗани мәчетен* реставрацияләү проектлары, Казан, Алабуга, Болгар, Лаеш шәһәрләрендәге, Зөя авылындагы саклау зоналары проектлары авторы, Казан Кремлен, Иске-татар бистәсен саклау һәм үстерү концепцияләре автордашы.

**ЗӘБИ́РОВА** Халидә Сафа кызы (9.9.1914, Кыргызстан Респ-касы, ЫсСык күл өлкәсе Пржевальск ш. — 9.2.1979, Казан), җырчы (меццо-сопрано), ТАССРның атказ. артисты (1944). 1934–38 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (Е.Милькович классы) укый. 1939–64 тә Татар опера һәм балет театры солисткасы. Башкарган партияләре: Азучена, Амнерис («Трубадур», «Аида», Дж.Верди), Зибель («Фауст», Ш.Гуно), Любовь («Мазепа», П.Чайковский), Бикә, Сабира, Тугзак («Качкын», «Илдар», «Алтынчәч», Н.Җиһанов), Җиһан («Башмагым», Җ.Фәйзи) һ.б. Яхшы вокал мәктәбе үткән, киң диапазонлы көчле тавышка ия җырчы. Татар опера сәнгате әсәрләрендә аеруча кызыклы сәхнә образларын тудыра. З.ның концерт репертуарында төп урынны татар композиторларының әсәрләре алып тора.

**ЗӘЙ** елгасы, Дала Зәе елгасының Урман Зәе елгасы б-н кушылган урыныннан (Зәй ш.) тамагына кадәрге исеме. Каманың сул кушылдыгы. Озынлыгы 55 *км*. З. елгасының үзәне трапециясыман, асимметрик, киңлеге 3–3,5 *км*. Елганың уңъяк яры, нигездә, текә һәм биек, тамагына таба сөзәк. Тугае ике яклы, киңлеге 1–1,5 *км* га кадәр, болыннар биләп тора, урыны белән җирләр сөрелгән, түбәнге агымы сазлыклы. Елга юлы комлы-ләмле, киңлеге 15–20 *м*, түбәнге агымында бормалы, тармаклары һәм борынгы күлләр бар. Кушылдыклары: Зичә (40,2 *км*), Кушай (13 *км*) — уң; Инеш (18 *км*), Шепкә (15 *км*) — сул. Елганың гидрологик режимы Зәй р-ны Иске Пелчекәү авылы янындагы су үлчәгеч постта өйрәнелә. Ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Су өсте тигезлегенең уртача еллык тирбәнешләре 3,4 *м* (иң күбе 5,3 *м*). Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Суының иң күп чыгымы 610 *м³/с* (1963). Боз кату ноябрь башында башлана. Боз калынлыгы кыш ахырына 54 *см* га (иң күбе — 115 *см*) җитә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы, тамагы өлешендә хлорид-гидрокарбонат-натрийлы, бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе 900–1000 *мг/л* га кадәр. Йөзмә китерелмәләрнең уртача еллык агымы 350 мең *т*. Суы хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. ТР табигать истәлеге (1978).



Зәй елгасы түбән агымында.

**ЗӘЙ**, республика карамагындагы шәһәр, Зәй р-ны үзәге. Әгерҗе — Акбаш тимер юлы буенда Дала Зәе һәм Урман Зәе елгалары кушылган урында, Казаннан 287 *км* ераклыкта урнашкан. З. аша Чаллы–Әлмәт автомобиль юлы уза. Мәйданы — 58,4 *км²* (шәһәр составына кергән авылларны да кертеп). 2008 елда 42065 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча татарлар — 52%, руслар — 44,6%) яши. «Зәйнефть» НГДУы, Зәй ГРЭСы. Заводлар: «КамАЗ автотехника» ҖЧҖ, модульле металл конструкцияләр җитештерү з-ды. Сәнәгать-төзү материаллары комб-ты, азык-төлек җитештерү пр-тиеләре (шикәр, сөяк оны, икмәк, сөт з-длары, кондитер ф-касы). Машиналар төзелеше техникумы, 12 гомуми белем бирү мәктәбе, 1 музыка һәм 1 спорт мәктәбе, Балалар иҗаты мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе, 12 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 3 клуб, төбәк тарихын өйрәнү музее, 3 китапханә, 2 хастаханә. Мәчет, 2 православие храмы. Шәһәр тибындагы Зәй посёлогы, шәһәр тибындагы Яңа Зәй посёлогы, тирә-юнь-



Зәй шәһәре. Яңа шәһәрнең гомуми күренеше.



Зәй крепосте. 1650–60 еллар. Макет.

дәге авыллар 1978 нең 5 апрелендә бергә кушыла һәм хәзерге шәһәргә нигез салына. Шәһәр тибындагы З. посёлогы (Иске Зәй) тарихы 1652 дә Кама аръягы чик буенда (к. *Иске Кама аръягы чик буе*) төзелгән З. крепостеннан башлана. Беренче булып монда Чаллы төрмәсеннән гаиләләре б-н 100 стрелец һәм 1654 тә Смоленскидан китерелгән тоткын поляк шляхтичлары (81 кеше) күчеп утыра. 1670 еллардагы рәсми документларда З. шәһәр (бистә) дип билгеләп үтелә. 17 йөзнең 2 нче яртысы — 18 йөзнең 1 нче яртысында берничә тапкыр нугайлар һәм башкортлар һөҗүменә дучар була (1707 дә басып алына һәм яндырыла). 1708 дән — Казан, 1744 тән Оренбург губернасында. Беренче ревизия нәтиҗәләре буенча (1719) З.дә 300 дән артык хуҗалык һәм 895 ир-ат исәпләнә. 1730 елларда яңа төзелә торган Яңа Кама аръягы һәм Оренбург ныгытма сызыкларыннан күчерелгән йомышлы крәстияннәр урынына хезмәт итү срогын тутырган солдатлар һәм унтер-офицерлар килеп урнаша. 1770 елларда ир-атларның саны 1 меңгә якынлаша (512 хуҗалык). З. тарихында 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышы мөһим вакыйга булып тора. 1774 нең 15 гыйнварында З. сугышсыз гына Е.И.Пугачёв отрядына бирелә, 17 гыйнварда аны Ю.Б.Бибиков командалыгындагы хөкүмәт гаскәрләре штурм б-н ала. 5 нче ревизия нәтиҗәсе буенча (1795) бистә халкын казаклар тәшкил итә һәм алар ташламалардан файдалана, 19 йөз башында дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. 1790 елларда З. — Зәй волосте үзәге. 1865 тә *Минзәлә өязе* б-н бергә Уфа губернасына керә. Көнчыгыш Кама аръягындагы мөһим адм. үзәкләрнең берсе була. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында монда полиция станы, волость идарәсе, күрше волостьларга хезмәт күрсәтүче учреждениеләр (хастаханә, суд, ветеринария һәм хәрби хезмәткә алу бүлекләре) урнаша. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, З.дә Крестовоздвижение чиркәве (1826 да төзелә, архит-ра истәлеге), 2 сыйныфлы уч-ще, 1 җил һәм 2 су тегермәне, 14 кибет була; сишәмбе саен базар эшли. 1875 тә кыз балалар уч-щесе, 1896 да китапханә ачыла, 1881 дә Богоявление чиркәве төзелә. 1882 дә земство хастаханәсе беренче тапкыр телгә алына. 1913 тә югары башлангыч уч-ще (прогимназия) ачыла. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, чыпта сугу, мичкә ясау. Гражданнар сугышы чорында З. халкы 1920 елгы



Зәй шәһәре. Энергетиклар урамы.

*«Сәнәкчеләр» фетнәсендә* актив катнаша, монда баш күтәрүчеләр штабы урнаша. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1926 да авыл торак пункты буларак билгеле. 1930 ның 10 августыннан Ширәмәт р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй р-ны үзәге, 1957 нең 29 августыннан — шәһәр тибындагы посёлок, 1963 нең 1 февралендә, Зәй р-ны бетерелү сәбәпле, Чаллы р-нына кушыла. 1956 да Зәй ГРЭСы төзелеше башлану б-н, З. янында Яңа Зәй энергетиклар посёлогы төзелә, 1962 нең 9 июленнән ул шәһәр тибындагы посёлок итеп үзгәртелә, 1972 нең 1 ноябреннән — яңадан торгызылган Зәй р-ны үзәге. Халык саны: 1870 тә — 2362, 1897 дә — 4045, 1920 дә — 3679, 1926 да — 2906, 1938 дә — 2358, 1949 да — 2207, 1979 да — 30,3 мең, 1989 да — 36,6, 2002 дә — 41,4 мең кеше.

*Әд.:* М а л а х о в В.С. Очерки по истории Заинска. Наб. Челны, 1992; ш у л  у к. Заинские миллионы (историко-краеведческие очерки). К., 1996; Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЗӘЙ** т и м е р  ю л  с т а н ц и я с е  п о с ё л о г ы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2008 дә 29 кеше (руслар) яши. 1920 еллар ахырында нигез салына. Оештырылган вакыттан ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 85, 1949 да — 189, 1958 дә — 177, 1970 тә — 136, 1979 да — 81, 1989 да — 47, 2002 дә — 32 кеше.

**ЗӘЙ ГРЭСЫ́**, РФдә блоклы типтагы иң эре конденсацияле җылылык электр станцияләренең берсе. Эшләүчеләр саны — 1000ләп кеше (2010). Зәй шәһәре янында Дала Зәе елгасы буенда төзелгән.

1956 елда төзелә башлый. 1 нче энергия блогы — 1963 тә, 12 нчесе 1972 дә файдалануга тапшырыла. 2009 ның 1 гыйнварына гомуми егәрлеге — 2200 *МВт*. Техник ихтыяҗлар өчен суыткыч буасы булган гидроузел төзелә (1962). Ягулык өчен газ һәм мазут кулланыла. Пр-тиенең төп өлешләре: ягулык цехы, 2 казан-турбиналар цехы, электр цехы, гидрокорылмалар, тышкы һәм җир асты коммуникацияләре, үзәкләштерелгән ремонт, технол. процессылар б-н автоматлаштырылган идарә итү цехы, химик цех. 2007 гә кадәр ГРЭС РФнең Бердәм энергетика системасының тулы хокуклы өлеше, бүлекчәсе хокукында «Татэнерго» АҖ системасына керә. 2007 дән «Генерацияләүче компания» АҖ филиалы. Эшләп чыгарылган электр энергиясе 110, 220, 500 *кВ* көчәнеш б-н тапшыру линияләре буенча җибәрелә. Файдалануга тапшырылганнан соң, 1990 да — 17, 1996 да — 6,7, 2002 дә — 16, 2009 да — 8, барлыгы 537 млрд. *кВт·сәг.* электр энергиясе эшләп чыгарылган. ГРЭС — шәһәр барлыкка китерүче пр-тие. Алдынгы хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. мактаулы исемнәргә лаек була: РФнең атказ. энергетигы — 22, ТРның атказ. энергетигы — 34, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре — 1; 1 кеше — Ленин ордены, 4 кеше — Октябрь Революциясе, 12 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 17 кеше — «Почёт билгесе», 11 кеше — 1, 2, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 1018 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре — В.И.Бутин (1956–60), Н.А.Банықин (1960–78), Н.А.Бутряков (1979–88), В.И.Шишкин (1988–91), В.В.Будилкин (1991–2001), Ю.В.Кожарин (2001–06), Р.З.Гыйззәтуллин (2006–10), Ә.М.Хаҗиев (2010 елдан).



Зәй ГРЭСының гомуми күренеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.


*Н.А.Баныкин, Г.Я.Мәүлетова.*

**ЗӘЙ РАЙОНЫ́**, ТРның үзәк өлешендә урнашкан. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1842,4 *км*². 22 җирле үзидарә советын (ком-тын), 83 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Зәй шәһәре. 2008 елда 16,3 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 74,6%, руслар — 22,4%) яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 9 кеше. Район 1935 нең 10 февралендә оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Уфа губернасының — Минзәлә һәм Казан губернасының Чистай өязләренә керә, 1920–22 дә ТАССРның — Минзәлә һәм Чистай, 1922–30 да Чаллы кантонында, 1930–35 тә — Акташ, Сарман, Ширәмәт, Чаллы р-ннарында. Районның чикләре һәм адм.-терр. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1237 *км*², халкы — 42,6 мең кеше, 32 авыл советы, 96 торак пункт була. 1959 ның 26 мартында таркатылган *Акташ районы* терр-ясенең бер өлеше З.р.на керә. 1960 та районның мәйданы — 1624,5 *км*², 1 посёлок һәм 18 авыл советын, 115 торак пунктны берләштерә. ТАССРның адм. берәмлекләрен эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә З.р. таркатыла, терр-ясе Әлмәт һәм Чаллы р-ннарына бирелә. 1972 нең 1 ноябрендә район яңадан торгызыла. 1995 тә Әлмәт р-нының Иске Ялан авылы З.р.на күчү б-н районның адм.-терр. бүленеше тулысынча

рәсмиләштерелә. 2005 нең 26 гыйнварында З.р. муниципаль район дип үзгәртелә.

Район Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының төньяк тармагында урнашкан (уртача биеклеге — 210 *м*). Дала Зәе һәм аның кушылдыклары, Урман Зәе, Зичә елгалары ага. Җирләре районның көньягында селтесезләнгән һәм көлсуланган кара туфраклы; төньягында күбрәк аксыл-соры һәм соры урман, кәсле карбонатлы туфраклы. Терр-янең 25,4% урманнар били. Нефть, битум, вак таш, балчык, акташ һ.б. төзелеш өчен чимал ятмалары бар.

Табигать саклаулыклары: *Дала Зәе* елгасы, *Баграж аучылык тыюлыгы*, *Бохарай наратлыгы* табигать истәлеге. З.р.нда Буралы Курган һәм Имәнкискә культуралары чоры авыллары һәм кешеләр яшәгән урыннарда 30 лап археологик истәлек табыла. А.х. җирләре — 122,1 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 83,4 мең *га*




тәшкил итә (2008). Сабан бодае, арыш, арпа, карабодай, борчак игелә; бәрәңге, шикәр чөгендере үстерелә. Ит-сөт терлекчелеге, сарык үрчетү алга киткән. 3 агрофирма («Зәй шикәре», «Восток», «Ялкын»), 127 фермер хуҗалыгы бар (2009). Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә тупланган. Урман хуҗалыгы эшли. З.р. терр-ясе буйлап Әгерҗе–Акбаш тимер юлы, Чаллы–Әлмәт, Зәй–Сарман автомобиль юллары уза. Районда 45 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 20 башлангыч, 5 тулы булмаган урта, 20 урта мәктәп (2008/09 уку елында барлыгы 1698 укучы), 6 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 41 клуб, 36 китапханә, 25 урынлы хастаханә эшли. 31 мәчет, 3 чиркәү бар. Татар телендә «Зәй офыклары», рус телендә «Новый Зай» р-н г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЗӘЙ СУСАКЛАГЫЧЫ́**, *Зәй ГРЭС*ының суыту сулыгы. Зәй шәһәре янында Дала Зәе елгасында гидроузел (су агызу буасы, 2,5 *км* озынлыктагы өелмә дамба, читкә җибәрүче каналлар) төзү нәтиҗәсендә булдырыла. Су 1962–63 елларда җыела. Гадәти биеклектә (73 *м*) су өслегенең мәйданы 20,5 $км^{2}$ тәшкил итә, тулы күләме — 63 млн. $м^{3}$,



Зәй сусаклагычы.

файдалы күләме — 34,8 млн. $м^{3}$, уртача тирәнлеге 3,1 *м*; озынлыгы 15 *км* га кадәр (ташу вакытында); иң зур киңлеге 3,2 *км*. ГРЭСны техник су б-н тәэмин итү ихтыяҗлары өчен файдаланыла. Кышкы чорда сусаклагычның төбенгә өлеше җылы су килү сәбәпле катмый. Сулык фаунасында балыкларның 18 төре бар. Промысел нигезен корбан балык, чабак тәшкил итә. Үсемлекләр б-н туенучы балык төрләре интродуцияләнгән: ак амур, ак һәм чуар ташмаңгай. Карп үрчетелә. Елга агымы б-н йөзмә матдәләр (елына 57 мең *т* га кадәр) килү сәбәпле, сулык ләмләнә бара. Уртача еллык минеральләшүе 1 *г/л* дан арта. Сусаклагыч ярлары буенда ял итү урыннары урнашкан.

**ЗӘЙ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Зәй шәһәрендә. 1990 нан ТРның Берләштерелгән (хәзер Милли) музее ф-лы, 2007 дән муниципаль музей. 1985 елда ачыла. 1 нче гильдия сәүдәгәр И.Н.Бекетов йортында (1902–03, тарих һәм архит-ра истәлеге) урнашкан. Экспозиция мәйданы — 125 $м^{2}$, күргәзмә залы — 88 $м^{2}$, коллекция 10 меңгә якын саклау берәмлегеннән тора. Экспозиция 8 залны били, төбәкнең борынгы чорлардан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын чагылдыра. Төп бүлекләре: палеонтология, Зәй шәһәренең төзелү тарихы, 20 йөз төбәк тарихы. Палеонтология, этнография, нумизматика коллекцияләре, документлар, атаклы зәйлеләрнең фоторәсемнәре һәм мемориаль әйберләре урын алган. «Кама аръягы саклау чиге» экспозиция бүлеге Зәй шәһәренең 17 йөз уртасы тарихын ача. Экспонатлар арасында: Зәй крепосте макеты (авторы Е.Ф.Хохлов), 1675 тә патша Алексей Михайловичның Зәйгә хезмәткә җибәрелгән воевода И.Л.Тургеневка бирелгән «Боерык кәгазе»нең («Наказная память») фотокүчермәсе, беренче мәртәбә халык са-



Зәй шәһәре. Төбәк тарихы музее бинасы.

нын исәпкә алу (1719) мәгълүматлары буенча крепостьта яшәүчеләрнең исемлеге (1719), 1830 елларда Яңа Чишмә полкына кергән Зәй гарнизоны составы, капитан Николай Рычковның 1769–70 еллардагы «Көндәлек язмалар журналы» («Журнал для дневных записок»), 1774 нең гыйнварында Зәй крепостеның Е.И.Пугачёв гаскәренә бирелүе турындагы суд тикшерүе документлары тупланган «Капитан Мертвецов, секунд-майор Лопатин һәм майор Савинич эше»нең фотокүчермәләре һ.б. бар.

1917 дән соңгы төбәк тарихына багышланган экспозиция бүлегендә 1920 елгы *«Сәнәкчеләр» фетнәсе* турында материаллар: фоторәсемнәр, документларның һәм шаһитлар хатларының төп нөсхәләре урын алган. Этнография бүлегендә руслар, татарлар, чуашларның костюмнары һәм көнкүреш кирәк-яраклары, халыкның гамәли бизәлеш сәнгате һәм нәфис һөнәрчелек әсәрләре күрсәтелә. Музейда Зәй рәссамнары: М.А.Голов, С.А.Цыганов, Г.Л.Уразайкин, В.В.Хрулёв, В.В.Панов һ.б.ның әсәрләре коллекцияләре саклана. Музейның аеруча мөһим тупламалары арасында палеонтологик, археологик, 18–19 йөзләргә караган нумизматик коллекцияләр бар. Экспонатлар исәбендә — Зәй мәгърифәтчесе Н.С.Гушинның сәгате (19 йөз уртасы), Златоуст осталары эшләгән кынлы кылыч (1896), дугага асыла торган кыңгыраулар (19 йөз ахыры — 20 йөз башы) һәм 1930–80 еллардагы совет фарфор коллекцияләре. Ел саен Халыкара музейлар көне (18 май) уздырыла.

Музей директоры — Л.М.Симонова (1991 дән).

**ЗӘЙ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Зәй, Түбән Кама, Яңа Чишмә һәм Әлмәт р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1959 елда Ширәмәт урман хуҗалыгын (1931 дә оешкан) һәм Ширәмәт урман сәнәгате хуҗалыгын (1936 да төзелгән) берләштерү юлы б-н Зәй урман сәнәгате хуҗалыгы буларак оештырыла. 1992 дән хәзерге исемендә. 2007 ел башына З.у.х.ның гомуми мәйданы 58093 *га*, ш.и. Зәй урманчылыгының — 14165 *га*, Болгар — 10306 *га*, Кушниковский — 8832 *га*, Өргәнче — 12237 *га*, Ямаш — 12553 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе Зәй шәһәрендә. Эшләүчеләр саны — 217 кеше.

1 нче төркем урманнар 12590 *га* мәйданны били, ш.и. аеруча саклаулы табигать терр-яләре — 1017 *га*, шәһәрләрнең яшел зона урманнары — 3897 *га*, әйләнә-тирә табигать мохитен саклауда әһәмиятле башка урманнар — 3910 *га*, автомобиль юллары буендагы саклаучы полосалар — 2639 *га*. 2 нче төркем — җирле әһәмияткә ия урманнар мәйданы 45503 *га*. Урман культуралары 11098 *га* мәйданны алып тора. Токым составы ягыннан йомшак яфраклылар — 73%, каты яфраклылар — 14%, ылыслылар 13% урман фонды мәйданын алып тора. Урман мәйданының 54% ын күптәнге имәнлекләрне алыштырган усаклыклар һәм сырмавыклы каенлыклар, төрле үләнле юкәлекләр били. Өрәңгеле-юкәле һәм өрәңгеле-каенлы имәнлекләр, күбесенчә биек кәүсәле, 6483 *га* мәйданны алып тора,

50% ка якыны кулдан утыртылган. Нарат һәм чыршы урманнары 6815 *га* мәйданны били, кулдан утыртылган яшь һәм урта яшьтәге агачлардан гыйбарәт. Утыртмаларга уртача 45 яшь. Урманнарның 58% ы югары тыгызлыкта, агачның уртача запасы 1 *га* урман мәйданына 150 $м^3$. Гомуми агач запасы 7263 мең $м^3$, ш.и. өлгергән һәм картайган агачлар 2453 мең $м^3$.

Болгар урманчылыгында, Кама елгасының сулъяк яры буенда (Вятка елгасы тамагына каршы) «*Борок урман дачасы*» табигать истәлеге — нарат урманының уникаль участогы, Өргәнче урманчылыгында — язгы адонисны һ.б. сирәк үсемлекләр төрләрен саклап калу максатыннан булдырылган ботаника тыюлыгы аерып алынган. 1988–90 елларда утыртылган культуралы чыршы, үз ареалыннан читтә җимеш бирүче Маньчжур чикләвеге агачлыклары бар. Ел саен 400 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла; урманны карау һәм чистарту нисбәтеннән 1800 *га* мәйданда кисү эшләре башкарыла, шул вакытта 24 мең $м^3$ агач әзерләнә. Урман хуҗалыгы питомнигында агач-куак токымнарының 3,5 млн.га якын үсентесе һәм чәчкене үстерелә. Урман хуҗалыгы үсешенә ТРның атказ. урманчылары П.А.Гудошников, М.Г.Гарәпшин, А.К.Хөсәенов, А.Г.Куянова зур өлеш кертә. 2007 ел ахырында шул ук исем. урманчылык дип үзгәртелә.

**ЗӘЙ ШИКӘ́Р ЗАВОДЫ́**, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе. Зәй шәһәрендә урнашкан. Эшләүчеләр саны 700 кеше чамасы (2009). 1962 елда төзелә башлый, 1967 дә файдалануга тапшырыла. 1990–94 тә аренда пр-тиесе, 1994 тән АЖ, 2002 дән — «Зәй шикәре» АЖ. Шикәр чөгендереннән шикәр җитештерү сезонлы рәвештә, өзлексез технологик процесс буенча алып барыла. 1970 елларның 2 нче яртысында яңа техник нигездә з-дта реконструкция уздырыла, җитештерү технологиясе камилләштерелә. 1977–78 дәге шикәр кайнату сезонында з-д проекттагы егәрлегенә ирешә. 1978–79 да чөгендернең шикәрлелек дәрәҗәсен билгеләүче 2 линия, 60 *т* күтәрешле автоүлчәү урнаштырыла; алдагы елларда җиһазларны камилләштерү дәвам итә, известь яндыру миче корыла, котельный киңәйтелә, газ б-н тәэмин итү системасы яңартыла, сок дефекаторы, диффузион пычакларны кайрау һәм әзерләү линиясе сафка баса, киптерү агрегаты урнаштырыла, кристаллаучы вертикаль болгату җайланмалары куелу исәбенә продукция цехы киңәйтелә. Җитештерүне яңа җиһазлар б-н үзгәртеп кору нәтиҗәсендә чөгендер эшкәртүнең тәүлеклек күләме 1,5 мең *т* дан (1967) 3 *т* га (2000) кадәр арта. 2003 тә җитештерүнең күләме 82,8 мең *т* га, 2009 да 72,1 мең *т* га җитә. Эшкәртү өчен шикәр чөгендере Азнакай, Зәй, Түбән Кама, Тукай һәм Чирмешән р-ннарыннан китерелә. 1995–2004 тә сезонара чорда з-дта Куба, Бразилия, Гватемаладан китерелгән шикәр чималы эшкәртелә (2001 дә тәүлеклек җитештерү күләме 750–780 *т* га җитә). 2002 дә пр-тиедә яңадан реконструкция башлана, нәтиҗәдә чөгендерне тәүлеклек эшкәртү куәте 6000 *т* га җиткерелә, түпне киптерү һәм гранууллау системасы гамәлгә кертелә. З-д ш.у. меласса (чөгендер калдыклары) эшләп чыгара. Пр-тие җитәкчеләре — П.А.Дадачко (1967–75), Н.Б.Тамарин (1975–81), Н.И.Аргунов (1981–89), И.Ф.Яковлев (1989–95), Р.Ш.Фәрдиев (1995–99), И.В.Таҗиев (1999–2002), Р.А.Сөләйманов (2002–2007), З.Н.Хәсәнов (2007 елдан).

*Н.М.Ткачёв.*

**ЗӘЙ-КАРАТА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәенең сул кушылдыгы. Озынлыгы 27,9 *км*, бассейнының мәйданы 147,6 $км^2$. Елга башы Әлмәт р-нының Васильевка авылыннан 1,6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Бөгелмә р-нының Иркен авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге — 280 *м*, тамагыныкы — 120 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 38%. З.-К.ның 1 дән 7 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 $км/км^2$. Туенуы катнаш, 50% ка якынын кар сулары тәшкил итә. Җир асты туену модуле 1–5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,298 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. З.-К. бассейнында гомуми күләме 1,1 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.



Зәй-Каратай елгасы.

**ЗӘЙ-КАРАТА́Й** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй-Каратай елгасы буенда. 2008 елда 1208 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1720–40 елларда нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сату эше б-н шөгыльләнә, көнлекче булып эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.-К.да мәчет була. Авыл халкы 1878–79, 1897 елгы крәстияннәр хәрәкәтендә актив катнаша. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5404 дис. тәшкил итә. 1904–09 елларда яңа ысуллар кулланып эшләүче 2 мәктәп була, 1917 дә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр З.-К. — Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратай волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1746 да — 42, 1782 дә — 153 ир-ат; 1859 да — 1032, 1883 тә — 1283, 1897 дә — 1941, 1920 дә — 2238, 1926 да — 2614, 1938 дә — 2291, 1949 да — 2372, 1958 дә — 2200, 1970 тә — 2131, 1979 да — 1686, 1989 да — 1226, 2002 дә — 1251 кеше.

*Әд.:* Рахимов З. Шугур — край сокровищ = Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе. К., 1997.

**ЗӘЙ-САРАЙЛЫ́ БӨГЕЛЕШЕ́**, Сарайлы бөгелеше, Сарайлы билдәве, Татар гөмбәзенең Төньяк һәм Көньяк өлешләрен бүлүче кристаллик нигездәге һәм утырма тышлыгындагы тискәре (батынкы) эре тектоник структура. З.-С.б.нә 1650 *м* тирәнлектә (Алабуга ш. янында) ятучы, соңгы архей яшендәге (2698±12 млн. ел) эре гранитлы Бакалы массивының төньяк-көнбатыш өлеше туры килә. Кама елгасы агымы буйлап диярлек Чистай–Яуширмә линиясе буенча төньяк-көнчыгыш юнәлешкә таба 50–60 *км* га сузыла. Югары ятучы девон утырмалары буенда бөгелеш саклана, аның киңлеге (60 *км* га кадәр) һәм амплитудасы (180 *м* га кадәр) зурая, бортларда рифоген структуралар барлыкка килә (к. *Кама-Кинель бөгелешләр системасы*). Түбән ташкүмер утырмалары буенда бөгелеш азрак чагыла, түбән Казан утырмаларында чагылмый, аның урынында күп сандагы аерым күтәрелмәләр барлыкка килә. Барлык терр-янең озакка сузылган күтәрелешләреннән соң, соңгы Пермь вакытында, борынгы Кама һәм 100 *м* га кадәр һәм күбрәк калынлыктагы акчагыл утырмаларының формалашуы б-н бер үк вакытта, неогенга яңадан шактый зур түбәнәю башлана. Нефть, бентонит, төзелеш материаллары һ.б. файдалы казылма ятмалары киң үсеш алган.


*Әд.:* Войтович Е.Д., Гатиятуллин Н.С. Тектоника Татарстана. К., 1998. Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. К., 2003.

**ЗӘЙ-ЧИШМӘ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дала Зәе елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2008 елда 293 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балык тоту, мичкә һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 18 йөздән З.-Ч. янында бакыр рудасы чыганагы табыла. 20 йөз башында земство мәктәбе (1902 дә ачыла), икмәк кибете, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1823,1 дис. тәшкил итә. 1930 да «Дружина» к-зы (1957 дән «Акташ» с-зында) оештырыла, 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волос-


Р.Р. Зәйдулла.


Х.В. Зәйдуллин.


Г.Х. Зәйнашева.


Җ.С. Зәйнәгов.

тенда. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 33 ир-ат; 1816 да — 162, 1859 да — 278, 1870 тә — 340, 1897 дә — 561, 1920 дә — 711, 1926 да — 652, 1938 дә — 632, 1949 да — 392, 1958 дә — 554, 1970 тә — 541, 1979 да — 413, 1989 да — 288, 2002 дә — 262 кеше.

**ЗӘЙДУЛЛА́** (Зәйдуллин) Ркаил Рафаил улы (23.1.1962, Чуаш АССРның Комсомольск р-ны Чичкан а.), шагыйрь, прозаик, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1985–87 елларда «Яшь ленинчы», 1987–89 да «Татарстан яшьләре» г-таларында эшли. 1989–2009 да — «Идел» ж-лында бүлек мөхәррире, 2010 нан — ТР Язучылар берлегендә әдәби консультант. Әсәрләре 1970 еллар ахырында матбугатта басыла башлый. «Кояшлы күзләр» (1984), «Күрәзә» (1988; Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге, 1990), «Урыс кышын озату» (1993) дип исемләнгән шигъри җыентыклар авторы. Проза әсәрләре «Ил» (2000) җыентыгына тупланган. «Саташкан сандугач» (Татар акад. театры 2001 дә сәхнәләштерә) пьесасында автор хәзерге тормыш каршылыклары аша чын хакыйкать һәм ялганга корылган кыйммәтләрне күрсәтә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2010).

Ә с ә р.: Мәгарә: Шигырьләр, поэмалар. К., 2005.

*Әд.:* В ә л и е в М. Учагың сүрелмиме? // Учагың сүнмәсен. К., 1988; Г ы й л ь м а н о в Г. Күрәзә // Заман сүз сорый. К., 1991; З ө л к а р н ә е в Ф. Р.Зәйдулла иҗаты // Чакма чакмый ут чыкмый. К., 1991; З а к и р М. Йомшак агачны корт баса // Казан утлары. 2002. № 1.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӘЙДУ́ЛЛИН** Хәмит Вәли улы (12.5.1934, БАССРның Ярмәкәй р-ны Сөярмәт а. — 23.11.1993, Баулы р-нының Яңа Зареченский штп.), тракторчы-машинист, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1946–90 елларда Баулы р-нының «Баулы» с-зында эшли. Герой исеме бодай, арыш, карабодай һ.б. бөртекле һәм терлек азыгы культураларын җитештерү һәм әзерләүне арттыруда, техниканы югары җитештерүчән куллануда ирешкән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К е р ж е н е в и ч Р. Зайдуллин Хамит Валеевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЗӘЙНА́Ш МОРЗА́** (? — 1552 дән соң), Казан ханлыгында дәүләт эшлеклесе. 1552 елда камалышта калган Казанны саклаучыларның берсе. Үзе җитәкләгән сугышчылар төркеме б-н камаучыларга каршы һөҗүмнәр оештыра, русларның берничә махсус һөҗүм корылмасын юк итә. *Идегәр Мөхәммәд* хан б-н русларга әсир төшүе мәгълүм. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

**ЗӘЙНА́ШЕВА** Гөлшат Хисам кызы (13.1.1928, хәзерге Тукай р-ны Иске Теләнче а. — 1.4.2005, Казан), шагыйрә, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1949). 1949–65 елларда (бүленеп) — ТАССР МС каршындагы радиокомитетта әдәби-драма, соңрак муз. тапшырулар мөхәррире. 1952–63 тә Татарстан китап нәшриятында редактор, 1973–83 тә кадрлар бүлеге инспекторы. 1950 еллар ахырында матбугатта һәм күмәк җыентыкларда беренче язмалары басыла. «Тыңларсыңмы җырларымны» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1958 дә дөнья күрә. «Замандашыма» (1967), «Үз илемдә» (1969), «Җырлап яшик!» (1971), «Гөлләр иле» (1977), «Мәхәббәт һәм җыр» (2000) җыентыкларына тупланган шигырьләре мәхәббәт, туган якның матурлыгы, кешеләренең күңел байлыгы турында. «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Җырчы миләш» (1982), «Көмеш тавышлар» (2008) җыентыклары балаларга багышланган. Композиторлар М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Р.Яхин, С.Садыйкова, З.Гыйбадуллин, Җ.Фәйзи, З.Хәбибуллин, Б.Мөлеков, А.Монасыйпов, Б.Гайсин б-н бергәләп иҗат иткән җырлары «Илле җыр» (1988; ТССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1991) җыентыгын тәшкил итә. «Гөлсем Сөләйманова» (1957), «Сара Садыйкова» (1987) очерклары З.ның замандашлары — татар музыка сәнгатенең күренекле вәкилләре тормышы һәм иҗаты турында. З. пьесалар авторы да. Аның әсәрләре буенча Татар драма һәм комедия театрында «Гайфи бабай, өйлән давай!» (1996), «Җаным җәл түгел сиңа» (1997), Минзәлә татар драма театры сәхнәсендә — «Бәхет кошым» (1964), «Кем гүзәл?» (1970), «Комиссия килгәч» (1976), «Яшел сумка» (1982), «Язмышлар һәм ялгышлар» (2000), «Әкият» татар курчак театрында «И, кызык Шүрәле» (2000) спектакльләре куела; З. сценарийлары буенча «Татарстан — Яңа гасыр» телевидениесе тарафыннан «Моңсара» (1996), «Салих Сәйдәшев» (2000), «Тузган тоpактан күчкәндә» (2004) телефильмнары төшерелә. 2006 да Казанда З.ның музей-бүлмәсе ачыла.

Ә с ә р.: Пьесалар. К., 1974; Сайланма әсәрләр. К., 2006.

*Әд.:* Н ә җ м и Н. Илле шатлык // Шәһри Казан. 1991. 12 апр.; Г а т а ш Р. Моңнар бәйрәме // Казан утлары. 1998. № 1; С и б г а т у л л и н а - Н и г ъ м ә т җ а н о в а Д. Мең кыллы күңел // Мәйдан. 2002. № 5; Г а и т о в М. Җырга багышланган гомер // Казан утлары. 2008. № 1; Г а л и у л л и н Т. Сандугач картаймый, диләр... // Мәдәни җомга. 2008. 18 гыйнв.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӘЙНӘ́ГОВ** Җәмил Сирай улы (20.5.1926, Бөгелмә кантоны Сугышлы а. — 12.12.1999, Казан), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1941–43 елларда Лениногорск р-нының Калинин исем. к-зында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1951–88 дә Ромашкино р-н нефть үткәрү идарәсендә технол. насослар машинисты. Герой исеме нефть чыгаруда җидееллык план (1959–65) йөкләмәләрен үтәүдә һәм эштә югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л а р и ч е в а Э. Зайнагов Зялиль Сираевич // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Хозяева подземных магистралей. Путь длиною в пятьдесят лет. К., 1999; Т е р е г у л о в З.У., Х у с н у т д и н о в а Р.Р. Труженики подземных артерий. 1949–1999. К., 2000; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЗӘЙНЕЛГАБИДИ́Н** (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче чирегe), ахун, ташка уеп язу остасы, хаттат. Хәзерге Мари Респ-касы Бәрәңге авылы зиратына куелган эпиграфик һәйкәлләр авторы. Кабер ташлары ак известьташтан турыпочмаклы плитә рәвешендә эшләнгән, очы ярымтүгәрәк булып төгәлләнгән. Уеп язылган истәлек гарәп графикасының тәгълыкъ алымы б-н башкарылган. Бизәкләр кулланылмаган. Шундый үрнәкләрнең берсе — 1918 елның 19 декабрендә вафат булган Гайшә Шакирҗан кызы кабер ташы. Истәлек ташларында останың имзалары да бар.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЗӘЙНЕТДИ́НОВ** Ситдыйк Мәһди улы (1854, Тобол губ., Татар өязе Аубаткан а. — 1927, Омск өлкәсенең Большеречье р-ны Еланлы а.), «*Идегәй*» дастанын оста сөйләүче. Тара шәһәре (хәзерге Омск өлкәсе) мәдрәсәсендә белем ала. 1919 елда журналист һәм педагог Н.Хәким З.тан дастанның Себер татарлары вариантларының берсен язып ала; бу язма дастанның иң тулы варианты булып санала. Шәркыятьче галим, акад. А.Н.Самойлович: «Бу язма сөйләүченең ораторлык талантына ия булуын, телдән сөйләнә торган әсәрләрне бик яхшы истә калдыруын, анда импровизаторлык сәләте дә барлыгын күрсәтә», — дип исәпли.

*Әд.:* И с х а к о в а С.М. Ситдык Зайнитдинов // Янарыш. 1990. № 13; В а л е е в Ф.Т. Сибирские татары. К., 1933; Тюркологический сборник. М., 1972.

*С.М.Исхакова.*

**«ЗӘЙНЕ́ФТЬ»,** нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгаруны гамәлгә ашыру, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлашты-

ру, төзү һәм файдалануга әзерләү буенча «Татнефть» АҖнең нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). Эшләүчеләр саны 1,5 мең кешедән артык (2003). 1989 елда оештырыла. Үзәкләштерелгән сәнәгый базалары Зәй шәһәрендә һәм р-нында, Әлмәт р-нындагы Рус Акташы посёлогында урнашкан. «З.» составында — 3 нефть чыгару, катламнардагы басымны саклау, фәнни-тикшеренү һәм җитештерү, төзелеш-ремонт, 5 җитештерү базасына хезмәт күрсәтү һәм технол. транспорт цехлары бар. Яңа Елховой чыганагының Акташ мәйданында, Зәй һәм Түбән Кама р-нна-рында урнашкан Соколка, Көнчыгыш Макаровка, Аксар, Мельнино чыганакларын эшкәртә. Төп файдалану объекты — эшкәртүнең



«Зәйнефть». 3 нче нефть промыселының суырту скважиналары.

соңгы стадиясендәге девон катламнарының терриген утырмалары. НГДУ эшкәртә торган нефть запасларының 80% тан артыгы — авыр чыгарылучан, үтә үзле, авыр компонентлар катнашкан мул сулы ятмалар. Аларның күпчелек өлеше контур тирәли су кудыру алымы б-н катламнардагы басымны саклау нигезендә эшкәртелә. Нефть бирүчәнлекне арттыру өчен катламнарга тәэсир итүдә алдынгы гидродинамик, физ.-химик, геол.-физ. алымнар кулланыла. «З.»тә тармакта беренче мәртәбә буларак скважиналарны горизонталь бораулау ысулы гамәлгә кертелә (1991), насос штангаларын диагностикалау һәм торгызу линиясе сафка бастырыла (1996), нәтиҗәдә скважиналарда авариясез һәм ремонтсыз эшләү чоры арта. Су һәм нефть үткәргечләр төзү өчен металл-пластмасса торбалар җитештерү линиясе эшли. Нефть әзерләүдәге технол. процессларны контрольдә тоту мөмкинлеген бирә торган мәгълүмат-үлчәү комплексы файдаланыла. Нефть промыселлары



«Зәйнефть» идарәсенең администрация бинасы.

комплекслы автоматлаштырылган һәм телемеханикалаштырылган. Нефтьнең 50% тан күбрәк өлеше катламнарга тәэсир итүнең алдынгы алымнарын кулланып чыгарыла. Нефть чыгаруда иң зур күрсәткеч бер елга 6,64 млн. *т* тәшкил итә (1977); барлыгы 109,5 млн. *т*, ш.и. 2001 дә 1,3 млн. *т* чыгарылган. 2002 ел башына 2160 скважина борауланган, шуларның 1114е нефть бирә. Зыян килгән җирләрне табигый хәлenә кайтаруга, әчәргә яраклы су чыганакларын төзекләндерүгә, әйләнә-тирә мохиткә техноген тәэсирне киметүгә аеруча әһәмият бирелә. НГДУның социаль объектлары — ял базасы, спорт залы, балаларны сәламәтләндерү лагере бар. «З.»нең алдынгы хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә, ш.и. мактаулы исемнәргә лаек була: ТР Дәүләт бүләге лауреаты — 1, ТРның атказ. нефтьчесе — 13, ТРның атказ. геологы — 1, ТРның атказ. икътисадчысы — 1, ТРның атказ. төзүчесе — 1, ТРның атказ. энергетигы — 3, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре — 2, РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре — 13 кеше; 1 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — «Почёт билгесе», 2 кеше — «Хезмәт даны» орденнары, 35 кеше медальләр б-н бүләкләнә. «З.» җитәкчеләре — Г.В.Зимин (1989–99), Г.Н.Шариков (1999 дан).

2006 елда производствоны реструктуризацияләү программасы буенча «З.» «Елховнефть» НГДУына кушыла.

*Әд.:* Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2; Малахов В.С. Заинские миллионы (историко-краеведческие очерки). К., 1996; Шишкина Н.А. Нефть, ставшая судьбой. Наб. Челны, 1999; Гиниатуллин М.К. Развитие «Татнефти»: Статистика и коммент. М., 2000.

*К.Ф.Фәсхетдинов, И.З.Чупикова, В.А.Винокуров.*

**ЗӘЙНУ́ЛЛИН** Альберт Габидулла улы (1.9.1940, Бөгелмә р-ының Берлек а.), нефтьче, техник. фән. канд., ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). 1971 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлый, 1959–64 тә «Татнефтегазоразведка» трестының (Бөгелмә ш.) 1 нче бораулау-разведка конторасында бораулаучы. 1964–2002 дә ТатНИПИнефтьтә эшли: скважиналар ныклыгын торгызу лаб-ясе мөдире (1991–97), сектор мөдире (1997–2002). 2003 тән «Наука» ААҖндә (Бөгелмә ш.). Хезмәтләре юдыргыч эремәнең скважиналарны бораулау процессын катлауландырып йотылу сәбәпләрен тикшерүгә, бу сәбәпләрне булдырмау өчен техн. чаралар һәм технологияләр эшләүгә карый. З. күп көпшәле нефть скважиналарын төзүгә зур өлеш кертә. Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын махсус һәм киңәюле торбалар кулланып беркетү өчен яңа технологияләр һәм техник чаралар эшләгәне һәм гамәлгә кертканә өчен бирелә. Уйлап табуга 82 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ВДНХсының 8 медале (ш.и. 2 алтын һәм 5 көмеш) б-н бүләкләнә. «СССРның уйлап табучысы» билгесенә ия.

Х е з м.: Ремонт промежуточной колонны на Тюменской сверхглубокой скважине СГ-6 // Нефть Татарстана. 2000. № 1 (автордаш); Expandable lines isolate sloughing zones in directional, horizontal wells // Oil and Gas Journal. 2003. № 6 (автордаш).

**ЗӘЙНУ́ЛЛИН** Габделҗәмил (Җәмил) Габделхак улы (11.7.1946, Беренче Май, хәзерге Чирмешән р-ны Иске Кади а.), филолог, шәркыятьче галим, филол. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Ташкент ун-тын тәмамлый (1974). 1974 елдан Казан ун-тында (1994 тән Көнчыгыш телләре каф. мөдире, 2000 нән Көнчыгышны өйрәнү ин-ты директоры). Гарәп, фарсы, үзбәк, иске татар телләрен, гарәп әдәбиятын укыта. Хезмәтләре 16–20 йөз гарәп-фарсы-төрки чыганакларына, 18–20 йөз татар дини әдәбиятына, гарәп, фарсы, иске татар телләрен укыту методикасына карый. Коръәнгә гарәп һәм татар телләрендә аңлатмаларны тикшерә. Урта мәктәпләр өчен гарәп теле дәреслеге, 16 йөз татар әдәбияты буенча уку ярдәмлекләре авторы. «Шәрык алынмалары сүзлеге»н төзүче (1994).

Х е з м.: Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба. К., 1989; Кәлилә вә Димнә. Борынгы татар әдәби истәлеге. К., 1996; XVIII–XX йөз башында татар рухани әдәбияты. К., 1998; Татарская историческая письменность на основе арабской графики. К., 1998; Персидский язык. К., 2003.

**ЗӘЙНУ́ЛЛИН** Зәки Лотфулла улы (10.7.1933, БАССРның Стәрлебаш р-ны Стәрлебаш а.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1986), проф. (1988), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1955 елда Иркутск хәрби авиация-техник уч-щесен, 1963 тә Рига югары команда-инженерлык ракета уч-щесен тәмамлый. 1955–88 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1989–90 да Уфа авиация ин-тында. 1993 тән ТР ФАнең Механика, математика һәм машиналар белеме бүлеге каршындагы фотосыгылмалылык лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре очкыч аппаратлар һәм двигательләрнең ныклыгына, махсус билгеләнгән техникага карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Күп кенә әдәби әсәрләр авторы: «Үрләр аша» (1988), «Сугыш алды малайлары» (1991), «Полковникны озату» («Проводы полковника»,1992), «Ник ямансу бу көзләр» (1998). Бөтентатар иҗтимагый үзәге лидерларының берсе (1995–2001). Ш.Мәрҗани исем. Мәдәни җәмгыять президенты (1990–95). Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Агыйделнең аръягында. К., 2001; Һаваларда ялгыз торна. К., 2003; «Сражения внутри Советской Армии». К., 2007.

**ЗӘЙНУ́ЛЛИН** Насифулла Гыйззәтулла улы (28.10.1931, БАССРның Илеш р-ны Яңа Аю а. — 18.12.1981, Әлмәт ш.), электр б-н эретеп ябыштыручы, Соц. Хезмәт Герое (1971), ТАССРның атказ. төзүчесе (1970). 1949–80 елларда «Татспецстрой» трестының 48 нче махсуслашкан идарәсендә электр б-н эретеп ябыштыручы, мастер, прораб, 1973 тән җитәкче урынбасары. Герой исеме бишьеллык план (1971–75) йөкләмәләрен үтәүдәге зур казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Әлмәт шәһәрендә З. яшәгән йортка мемориаль такта куелган. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.Г. Зәйнуллин.

*Әд.:* Четверть века на марше. Альметьевск, 1982; Сагитов Т. Зайнуллин Насифулла Гизатуллович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

**ЗӘКИ́** Шәмсетдин (псевд., чын исем-фамилиясе Гобәйдуллин Шәмсетдин Ярмөхәммәт угылы) (Шәмсетдин Суфи) (1821, бүтән мәгълүматларга караганда — 1822 яки 1825, Оренбург губ. Башкорт кантоны, хәзерге БРның Көергәзе р-ны Әзәк-Ишмәт а. — 1865 окт., Таганрог ш.), суфи-шагыйрь. Псевдонимы туган авылы исеменнән алынган. Чыгышы б-н мулла гаиләсеннән. Тумыштан сукыр. Башлангыч белемне туган авылында ала, соңыннан күрше авыл мәдрәсәләрендә укый. 23 яшендә Казанга килә, Күл буе мәдрәсәсендә 7 ел белем ала. Белемле, сәләтле кеше була; Коръәнне, хәдисләрне, мөселман фикъһе буенча хезмәтләрне, Шәрекъ әдәбиятының күпчелек әсәрләрен яттан белә, матур җырлый. Укыган елларында ук яшь шәкертләргә белем бирүдә катнаша. Туган авылында мәдрәсә ачылгач, 30 яшендә шунда укытырга кайта. 3 елдан соң, авыл аксакаллары б-н низагка керүе аркасында, бер төркем шәкертләр б-н Уфа губернасы Эстәрлебаш авылына күчеп китәргә мәҗбүр була, анда 4 ел укытканнан соң, туган авылына кайта, һәм шунда укыта. Шәкертләре арасында М.Акмулла, Г.Чокрый һ.б. шагыйрьләр була. З. Мәккәгә барганда юлда вафат була.

Шигъри мирасының төп өлешен газәл, мәдхия, робагый, фәрд һ.б. жанрларда язылган лирик әсәрләр тәшкил итә (46 шигыре — татар, 6 сы — гарәп, 1 се — фарсы телендә). Шагыйрь иҗаты дини-суфи идеяләр, тормыш мәгънәсе турында уйланулар б-н сугарылган. Аның шигъриятендә югары әхлак идеаллары раслана, суфиларча яшәү рәвеше мактала. З. урта гасыр һәм төрки-татар поэзиясе традицияләрен дәвам иттерә. Аның лирикасына эмоциональлек, фикер һәм хисне туплый белү осталыгы, ритмиканың аныклыгы һәм аһәңлеге хас. Җәмгыятьтә хөкем сөргән гаделсезлек, реаль тормышны кабул итмәү аның лирик героенда үзенең эчке дөньясына мистик халәттә кереп бикләнү теләге тудыра. Аның «Булгай, булмагай», «Өйрәнмәк кирәк», «Бу үлем бәңа дошман дүгел» һ.б. шигырьләренә тормыш хакында тирән фәлсәфи уйланулар, теленә тапкырлык һәм үткенлек хас. «Йә, Иляһи, бер нәзар кылгыл...», «Акыздым канлы яшем...» шигырьләре Аллаһка мистик мәхәббәт б-н сугарылган. З. нең чәчмә әсәрләре исламның төрле күрсәтмәләренә багышланган, Коръәннең аерым өлешләренә мөнәсәбәтле аңлатмалар тәшкил итә. Аның гарәп телендә язылып танылган «Әр-рисаләт әл-фәризә» («Дини кагыйдәләр җыентыгы») кулъязма китабы суфичылык мәсьәләләренә багышлана. Аерым шигырьләре 1982 дә басылган «XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре» җыентыгына кергән; 2002 елда Ә.Каргалый шигырьләре б-н бергә «Мөнәҗәтләр. Хикәятләр» китабында урын алган. Аның тормышы һәм иҗаты Р.Фәхретдин, З.Мөхәммәт-Рәхими, М.Х.Гайнуллин, Х.Й.Миңнегулов, М.В.Гайнетдинов һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Р.Фәхретдин З. иҗатын Мәгарри һәм Физули иҗатлары б-н чагыштыра.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1907. 2 том, 13 җөзья; Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар әдәбияты ядкәрләре. К., 1982; Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Шарипова З.Я. Пером и словом. Уфа, 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ЗӘКИ́ЕВ** Әүфар Зәки улы (16.4.1938, Сарман р-ны Сарысаз-Тәкермән а. — 2.2.1994, Казан), төзүче-инженер, ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1978), ТАССРның атказ. төзүчесе (1980). Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1968). 1962–69, 1974–94 елларда «Татстрой» концернында: 2 нче трестта инженер, производство-техника бүлеге башлыгы, баш инженер, управляющий (1975 тән), «Главтатстрой» башлыгы урынбасары (1980 нән), концернның баш инженеры (1987 дән). 1969–74 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты төзелеш бүлегендә инструктор. Яңа төзелеш технологияләре, Казанда һәм респ-ка р-ннарында мөһим сәнәгать һәм мәдәният-көнкүреш объектлары төзелешен үсешенә зур өлеш кертә. Дәүләт бүләге ТР Рәссамнәр берлегенең Күргәзмә залы төзелеше өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы З. исеме б-н аталып йөртелә.

**ЗӘКИ́ЕВ** Мирфатыйх Зәки улы (14.8.1928, Бөгелмә кантоны Зәйпе а.), тел һәм тарих белгече, җәмәгать эшлеклесе, филол. фән. д-ры (1963), ТР ФА академигы (1991), Халыкара төрки академиянең Татарстан бүлеге акад.-секретаре (1997 елдан), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1976). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли (1960 тан татар теле белеме каф. мөдире, 1964 тән проф.). 1965–86 да — Казан пед. ин-тында (проректор, 1967 дән ректор, бер үк вакытта татар теле белеме каф. мөдире). 1986 дан РФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты; 1992 дән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты директоры; 2001 дән шунда ук тел белеме бүлеге мөдире, 2008 дән лексикология һәм диалектология бүлеге мөдире. Хезмәтләре татар теле синтаксисы, этнолингвистика, тел сәясәте, милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә карый. З. тюркологиядә, беренчеләрдән булып, төрки морфонология нигезләрен ачыклый, татар телендә эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен белдерүнең деривацион-грамматик системасын тасвирлый, төрки телләрдә килешләрнең күплеген билгели. Болгар-татар эпиграфикасын, төрки-татар әдәби әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләрен өйрәнә. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. 3 томлы «Татар грамматикасы» («Татарская грамматика», 1992–93; ТРның Дәүләт бүләге, 1994) авторлар коллективының фәнни җитәкчесе. 1990 еллар ахырында татар халкының тел тарихы мәсьәләләренә һәм төрки-татар этногенезына багышланган зур хезмәтләрен бастыра. 1980–90 елларда ТАССР ЮС рәисе. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



М.З. Зәкиев.

Х е з м.: Төрки-татар этногенезы. М.-К., 1998; Синтаксический строй татарского языка. К., 1963; Современный татарский литературный язык: Синтаксис. М., 1971; Проблемы языка и происхождения волжских татар. К., 1986; Татары: проблемы истории и языка. К., 1995; Происхождение тюрков и татар. М., 2003; История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие). М., 2008; Türklerin ve Tatarların kökeni. Ist., 2007.

*Әд.:* Тенишев Э.Р., Ганиев Ф.А., Юсупов Р.А. Мирфатых Закиевич Закиев // Советская тюркология. 1988. № 5; Академик Мирфатых Закиев. М., 1998; Hatice Sirin. Prof. Dr. Mirfatih Zekiyev (Hayatı ve Eserleri) // Türk Dünyası. Dil ve Edebiyat Dergisi. 2003. № 16.

**ЗӘКИ́ЕВ** Рафил Зәки улы (11.8.1941, Киров өлкәсенең Вятские Поляны р-ны Сосмак а.), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның атказ. табибе (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), армиядә хезмәт итә: хәрби табиб, полк мед. пункты башлыгы (1970–72). 1972 елдан Казан мед. учреждениеләрендә. 1977 дән Казан мед. ин-тында, 1989 дан дерматовенерология каф. мөдире. Хезмәтләре оялап урнашкан склеродермияне дәвалаганда демиксидның дәвалау отышлылыгын билгеләүгә карый. Псориаз, аллергодерматозлар, балаларда озакка сузылган дерматитларның социаль профилактикасы мәсьәләләрен тикшерә, органик склеродермия авыруын демиксидның 50–60% эретмәсе б-н тышкы дәвалау ысулларын эшли. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Терапевтическая эффективность димексида у больных очаговой склеродермией. М., 1983; Клиническая характеристика отдельных результатов лечения больных очаговой склеродермией, находящихся под диспансерным наблюдением // Сб. тр. Горьковского науч. кожно-венерол. ин-та. Горький, 1987.

**ЗӘКИ́ЕВ** Рәшит Карип улы (28.9.1937, Азнакай р-ны Тымытык а.), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). Казан ун-тын (1960), Ленинград югары партия мәктәбен (1971) тәмамлый. 1960–67 елларда «Колхозчы», «Дуслык» район г-таларында, 1967–69, 1971–72 дә «Социалистик Татарстан» г-тасында эшли. 1972–75 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1975 тән «Чаян» ж-лының баш мөхәррире. Язмалары, очерк, шигырь, фельетоннары

«Советская Татария», «Татарстан яшьләре», «Советская Россия», «Правда» (Мәскәү) г-таларында, «Коммунист Татарии» ж-лында басыла. «Күңел чәчәкләре» (1967), «Тәрәзәгә чиртер мизгел» (1986), «Гореф-гадәтләргә ышанмагыз» («Не верьте в приметы», 1980), «Йөремсәк анекдот» («Ходячий анекдот», 1994), «Монолит кисәге» («Кусочек монолита», 1995), «Казан мәзәкләре» («Чаян» басмасы, «Казанский анекдот от «Чаяна», 2008) дигән җыентыкларында З.нең шигырьләре һәм юморескалары басылган.

**ЗӘКИ́ЕВ** Ринат Карип улы (20.2.1940, Азнакай р-ны Тымытык а.), генетик, биол. фән. канд. (1971), проф. (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли. 1971 дән Казан пед. ин-тында, 1989 дан генетика һәм биология укыту методикасы каф. мөдире. Хезмәтләре дрозофилаларда радиацион-индуцирланган анеуплодияләр механизмына карый. Нурланыш алган ана затлар мейозында бер пар хромосома буенча гиперплоидны икенче пар хромосома буенча гипоплоидка каршы кую механизмы булуын фаразлый. Радиацион-индуцирланган анеуплодияләр ешлыгының хромосомалар озынлыгына бәйле икәнен күрсәтә. Ф.Г.Ситдыйков б-н бергәләп «Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек» («Биологический русско-татарский толковый словарь», 1998) төзүдә катнаша.

Х е з м.: Генетика һәм селекция нигезләре. К., 1997; Избранные главы генетики. К., 1993; Полевая практика по генетике с основами селекции. К., 2007.

**ЗӘКИ́ЕВ** Фәрит Әдип улы (22.1.1952, Азнакай р-ны Тымытык а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТРның атказ. нефтьчесе (1995). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), «Татнефть» АҖдә, 1991 дән баш технолог, бер үк вакытта нефть һәм газны комплексны әзерләү һәм күчерү бүлеге башлыгы. Дәүләт бүләге Татарстан нефть промыселларында энергия ресурсларын саклау технологияләрен эшләгәне һәм сәнәгатьтә кулланышка кертүдәге хезмәтләре өчен бирелә.

**ЗӘКИҖА́Н** бине Мортаза бине Габделгафур (Зәки мулла) (1873, Самара губ., Бөгелмә өязе Габдрахман а. — 1929), ташка уеп язучы, хаттат. Бөгелмә өязе Әлмәт авылы мәчетендә имамлык итә (1900–29), репрессияләнә. З. иҗат иткән кабер ташлары Кама-Исмәгыйль, Бигәш (хәзер Әлмәт шәһәре составында), Әлмәт авыллары зиратларында саклана. Очлары ярымтүгәрәк итеп ясалган турыпочмаклы плитәләр Чупай авылы янәшәсендәге карьерлардан чыгарылган ак таштан әзерләнгән. Ташның алгы ягындагы текст еш кына аның арткы ягында да дәвам иткән, гарәп графикасының тәгъликъ алымы б-н башкарылган, плитә формасында уелган кайма рам эченә алынган. Яшәү еллары гарәп саннары б-н Григориан календаре буенча бирелгән. Текст астына оста: «Язучы — Әлмәт аулының Зәки мулла Мортаза углы», — дип, үзенең исемен уйган. Кабер ташларындагы текстларның юллар саны 19 га җитә, һәр юлы кыйммәтле генеалогик мәгълүматка, бай тарихи фактларга ия. Барысы да диярлек татар телендә язылган.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЗӘКЯ́Т** (гарәп. زكاة — пакьләнү), шәригать буенча мөселманнардан мохтаҗлар файдасына алына торган салым. Татарларда «З.» сүзе урынына «сәдака» төшенчәсен кулланалар. Бүләк итүче тарафыннан турыдан-туры яки рухани затлар аша бирелә. Мөселман *фәкыйһлары* әлеге төшенчәне «пакьләнү» мәгънәсендә аңлаталар (З. түләнгән малдан файдалануның гөнаһы булмый). Коръәннең Мәккәдә иңгән сүрәләрендә З. игелекле эш, матди ярдәм, хәер мәгънәләрендә ия. Мохтаҗлар файдасына һәрдаим салым түләү, мөгаен, Хиҗрәттән соң ук — Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхәбәләренең Мәккәдән Мәдинәгә күчкән елыннан (622) башлангандыр. Шулай да ярдәмгә мохтаҗлар исемлеге иң соңгы сүрәдән алдагысында гына телгә алына. Бу З. күләменең элгерәк теркәлмәгәнлеген дәлилли (З. күләме һәрвакыт аерым билгеләнгән). З. түләү тәртибен билгеләү 2 нче «тәкъва» хәлифә Гомәр (634–644) идарә иткән чорга туры килә. Салым чәчүлекләрдән, йөзем бакчаларыннан, хөрмә пальмаларыннан (яшелчә культуралары хакында фикерләр төрлечә), алтын-көмештән, мал-туардан, товарлардан алына башлый, һәм аны бары тик эшкә яраклы мөселманнар гына түли. Игенчелек продуктларына З., урып-җыю эшләре тәмамлангач, уңышның 1/10 өлеше күләмендә салынган, башка керемнәрдән аларның 1/40 өлеше күләмендә ел дәвамында түләп барылган. Җыелган сумма казыйда сакланган, ул ел дәвамында һәм җыеп алынган төбәктә генә тотылырга тиеш булган (*газават* өчен җыелган мөлкәттән башка). З. алырга хокуклылар исемлегенә фәкыйрьләр, З. җыючылар, бурычларын түләргә мөмкинлекләре булмаганнар, газаватта катнашучылар, яшәгән җирләренә әйләнеп кайту өчен чарасыз калган мосафирлар, мөкәтәбләр (мөкәтәб әл-габед, үзе өчен үзе түләп иреккә чыгу турында язма килешү төзегән коллар) кергән.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.



Зәкиҗан бине Мортаза бине Габделгафурга куелган кабер ташы. Уеп бизәкләү. Кама-Исмәгыйль авылы (хәзерге Әлмәт районы). 1898.

**ЗӘМЗӘ́М** (гарәп. زمزم), Мәккә шәһәрендә әл-Мәсҗид әл-Хәрам мәчете янындагы изге чишмә. З. суының төрле үзлекләргә — авырулардан сихәтләндерү, ачлыкны басу һ.б. сыйфатларга ия булуын икърар итәләр. Мәетне З. суында юылган кәфенгә төреп җирләү аеруча диантәле гамәлдән санала. Мәгълүм фаразлар буенча, бу чишмә җир асты юллары аша дөньядагы барлык атаклы мәчетләрнең коелары б-н тоташкан. Мөселман риваятьләре аның сихәтлелеген сабый чагында чүлдә әнисе Һаҗәр б-н эсседән җәфа чиккән Исмәгыйльнең аяк баскан урынында агып чыгуыннан күрә. Соңрак З. ташландык хәлдә кала һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең бабасы Габделмоталлиб аны яңадан ача. Пәйгамбәр һәм тәкъва хәлифәләр яшәгән чорда З. чишмәсенең могҗизалы көченә ышану Өммия хәлифәләр (Өммәвиләр) идарә иткән елларда (661–750) кими башлый. Алар дәверендә (мәс., Габделмалик хәлифә заманында, 685–705) Сабир тавы янындагы башка чишмә суыннан файдаланалар. Әлеге яңалыкка күпчелек мөселманнар дошманлык б-н карый. 759 да Габбасыйлар хәлифәсе әс-Сәффах боерыгы б-н З. чишмәсенең статусы кабат торгызыла. З. чишмәсенең суы б-н юыну һәм аның суын эчү — Мәккәгә *хаҗ* һәм гомрә (кече хаҗ) кылырга килгән мөселман хаҗиләр үтәргә тиешле йолаларның мөһим өлеше булып тора, әмма әлеге гореф-гадәт мөстәкыйль мәгънәгә ия түгел.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ЗӘНКИ́ БАБА́Й** (Зәнги), татарларның һәм Урта Азия халыкларының ышануларында һәм традицияләрендә мөгезле эре терлекне саклаучы, көтүче. Башка төрки халыклар б-н чагыштырганда, Идел буе татарларының мөселман дини карашлары системасына З.б. соңрак килеп керә. З.б.ны еш кына «Хайваннар пәйгамбәре» дип йөрткәннәр, әүлияне зурлаган кебек зурлаганнар, аңа догалар багышлаганнар. Татар фольклорына караган кайбер әсәрләрдә З.б. исеме *Бакыргани* б-н бәйле рәвештә бирелә. З.б. аның иң яраткан мөрите булган һәм, Бакыргани вафатыннан соң, аның тол хатыны *Гамбәр-анага* өйләнгән, имеш. З.б. турындагы легендалар Урта Азия һәм Идел буе мөселман халыклары арасында киң таралган була. Ш.у. к. *Абзар иясе*.

*Әд.:* Б а я з и т о в а Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; С и б г а т у л л и н а Ә. Илаһи гашыйклар юлыннан. К., 1999; С н е с а р е в Г.Г. Реликты домусульманских верований и обрядов у узбеков Хорезма. М., 1969; Казахские народные сказки. А.-А., 1971. Т. 3; Казахский фольклор в собрании Г.Н.Потанина. А.-А., 1972.

*Ф.И.Урманчеев.*


**ЗӘНКИ́ЕВ** Якуб Камали улы (6.4.1917, Иркутск ш. — 7.3.2003, Тобол ш.), язучы, педагог, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1957). Түбән укытучылар ин-тының физ.-матем. бүлеген тәмамлый (1940). 1934 елдан Төмән шәһәренең урта мәктәпләрендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән кайткач (1946), укытучылык эшен дәвам итә. 1952–55 елларда Тобол р-н халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1955–75 тә Тобол р-ны Епанчы сигезьеллык мәктәбе директо-

ры. Себер татарлары тормышы турында «Иртеш таңнары» (1–2 кит., 1994; русча тәрҗемәсе «Зори Иртыша», Төмән, 1996–98; ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2002), «Ялкында өтелгән мәхәббәт» (Төмән, 1999) романнары, балалар өчен «Кайчыколак» (Төмән, 1994) исемле хикәяләр җыентыгы авторы. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

*Әд.:* А л и ш и н а Х. Себер татарлары елъязмачысы // Мәдәни җомга. 1997. 11 апр.; Х ә м и т о в Г. Яшисең икән, димәк, юкка түгел... // Татар иле. 2001. 18 май; Луноликая красавица Сузге. Тюмень, 1997.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӘҢГӘ́Р КҮЛЛӘ́Р**, табигать тыюлыгы, Биектау р-ны терр-ясендә (Щербаково авылы янында). 1994 елда билгеләнә. Мәйданы — 1910 *га*. Башлыча, Казансу елгасының уңъяк ярында, югары Пермьнең түбән Казан асъярусының су б-н юылмаучы токымнарыннан (известьташ, доломит) торган калкулыкны көнчыгыштан әйләнеп үтүче борылмада урнашкан. 80% ка якын мәйданны урманнар,



Кече Зәңгәр күл.

нигездә, чыршы катнаш юкә һәм имән урманнары били. Аллювиаль комлы утырмалардан торучы сул якның түбәнге террасаларында күпчелеге нарат агачлары булган ылыслы-киң яфраклы урманнар үсә. Уң яктагы биек террасаларның итәгендә һәм елганың үзәк ярында «зәңгәр» дип йөртелүче уникаль күлләр урнашкан. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, суы үтә күренмәле, нык минеральләшкән, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Алар арасында иң зурысы *Олы Зәңгәр күл* (әдәбиятта еш кына Зәңгәр күл буларак телгә алына) — 1972 дән табигать истәлеге. Елга агымының күлдән өстәрәк өлешендә дугасыман рәвештә суы көчле ташкын булып елгага кушыла торган Кече Зәңгәр күлләр системасы сузыла. Күлләрнең туенуын бүрәнкәсыман тирән упкыннардан («чоңгыл») чыгучы җир асты сулары тәэмин итә. Күлләрдә су темп-расы ел дәвамында даими (6-8 °С). Казансу елгасы Зәңгәр күлләр тирәсендә туңмый. Узган гасырларда күлләрдә су тегерменнәре төзелгән була, алар 1950 елларга кадәр эшли. Әле К.Ф.Фукс һәм А.В.Фаворский күл төбендә-



Зәңгәр күлләр тыюлыгының Казансу елгасы ягыннан күренеше.

ге ләмнең дәвалау үзлекләре барлыгын күрсәткән була. Тыюлык терр-ясендә 900 дән артык югары төзелешле үсемлекләр төре үсә. Олы Зәңгәр күлнең хайваннар дөньясы: кисек, сузынкы, сазлык әкәм-төкәмнәре, каймалы һәм бормалы кәтүкләр; югары төзелешле кыслалар-яньйөзәрләр, суйөзәрләр, түбән төзелешле кыслалардан — циклоплар. ТРның Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләрдән сөтсу ак планария (ТРда бердәнбер урын), су чаяны, кайгылы күбәләк, зур бөркет, алтынсыман корташар яши. 1990 елларда күлләр яны терр-ясендә төзекләндерү эшләре башкарыла. Биредә балаларны сәламәтләндерү лагерьлары, «Крутушка» санаторие урнашкан.

*Әд.:* В о р о б ь ё в Н.И., С е м е н т о в с к и й В.Н. Физико-географические экскурсии в окрестностях г.Казани. К., 1940; К у р б а н г а л и е в а Х.М., К а ш е в а р о в а О.В. Гидробиологическая характеристика Голубого озера // Уч. зап. Казан. ун-та. 1946. Т. 106, вып. 3; Очерки по географии Татарии. К., 1957; К о р о л ё в М.Е., С о к о л о в М.Н., Н е л и д о в Н.Н. Геологические экскурсии в Приказанском районе. К., 1974; Памятники природы Татарии. К., 1977.

*О.В.Ерёгин.*

**ЗӘҢГӘ́Р МӘЧЕ́Т** (Дүртенче җамигъ мәчет), Казанда татар дин архит-расы истәлеге. Атамасы диварларының төсенә карап бирелгән. 1815–19 елларда Казан сәүдәгәре Әхмәт Исхаков (Заманов) иганәсенә төзелә. Архитектоны билгесез. Башта ул ике катлы, ике заллы, түбә уртасына куелган манаралы классицизм стилендәге була. Буй як фасадларның өч тәрәзәсендә портиклар элек өчпочмаклы фронтоннар (сакланмаган) б-н төгәлләнгән. 1864 тә



Казандагы Зәңгәр мәчет. 1815–19.

мәчет сәүдәгәр Г.Б.Мөстәкыймов иганәсенә көньягыннан киңәйтелә һәм койма б-н уратып алына (арх. П.И.Романов проекты). Нәтиҗәдә мәчетнең турыпочмаклы михраб урнашкан залы киңәя, аның астында — 1 катта әйберләр саклау урыны була. 1907 дә Казан сәүдәгәре Г.Ә.Ишморатов иганәсенә көнбатыш һәм көнчыгыш якларында 2 катлы янкормалар төзелә, алар мәчетнең баштагы өлеше б-н бер үк стильдә бизәлә. Бина «Т» рәвешендәге форма ала. 1930 еллар башында мәчет ябыла, манарасы сүтелә. Көньягындагы янкормасы биегәйтелә һәм икенче каты 2 яруска бүленә, фасадында өстәмә тәрәзәләр уела. З.м. 1993 тә дин тотучыларга кире кайтарыла.

*Әд.:* Х а л и т о в И.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1982; Мечети Татарстана / Сост. Надырова Х.Г., Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. К., 2000.

*И.Х.Халитов.*

**ЗӘҢГӘ́Р ТУПЫЙБА́Ш** (Succisa), төкчәләләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Дөнья флорасында бер төр — болын З.т. (S. pratensis) Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә сирәк кенә барлык р-ннарда да очрый. Дымлы болыннарда, куаклар арасында, сирәкләнгән урманнарда үсә. 30–90 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры — чук, кыска. Сабагы аз гына төкчәле. Яфраклары йомыркасыман — эллиптик, бөтен, очлы. Чәчәкләре вак, күксел шәмәхә, зәңгәрсу шәмәхә, башаксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — орлыкча. Июльдә чәчәк ата. Җимешләре сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Декоратив үсемлек. Баллы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.


**«ЗӘҢГӘ́Р ШӘЛ»,** татар халкының популяр лирик җыры. Беренче мәртәбә 1920 елларда язып алына. Берничә варианты мәгълүм. Аларның һәрберсенә 2 юллык строфадан соң килгән 6 юллык кушымтаны кабатлау хас. «З.ш.»дә бер-берсен өзелеп сөюче егет һәм кызның фаҗигале язмышы бәян ителә. Бәхет эзләп чит җирләргә чыгып киткән егет туган ягына әйләнеп кайта һәм яраткан кызы б-н очраша. Җырның сюжеты К.Тинчуринның «З.ш.» мелодрамасына нигез итеп алына, көе шул әсәрнең төп темасы булып тора. Бер үк исемдәге пьеса язу һәм аны сәхнәләштерү җырның популярлыгын тагын да арттыра.

*Әд.:* К л ю ч а р ё в А. Татар халык көйләре. К., 1955; Ф ә й з и Җ. Халык җәүһәрләре. К., 1971.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ЗӘҢГӘ́Р ШӘЛ»,** К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшевнең 5 пәрдәдән торган муз. драмасы. Премьерасы 1926 елның 20 декабрендә Татар акад. театрында уза (реж. К.Тинчурин, дириж. С.Сәйдәшев, рәссамы П.Беньков). Төп рольләрне К.Тинчурин (Булат), Р.Кушловская (Мәйсәрә), З.Солтанов (Ишан) башкара. Драмада революциягә кадәрге татар халкының авыр тормышы, бай бәтчәләргә каршы стихияле каршылык күрсәтергә тырышуы сурәтләнә. Төп сюжет линиясе лирик характерда — геройлар арасындагы мәхәббәт тарихы. «З.ш.» драмасы музыкасында яңгыраган татар халык җырлары арасында шул исемдәге җыр лейтмотив булып тора. Төп муз. тамаша С.Сәйдәшевнең оригиналь музыкасына







Татар академия театрында куелган «Зәңгәр шәл» спектакленнән күренешләр:
1. 1926; 2. 1957; 3. 2000 еллар.

корылган. Композиторның төп герой Булат образын муз. яктан ачуы шул заман өчен яңалык булып тора. Геройның өч җыры — арияләре әсәрнең муз. драматургиясе нигезен тәшкил итә. Беренчесенең оптимистик характеры туган ягына зур өметләр б-н кайткан геройның кәефен чагылдыра; икенчесе — «Кара урман» җыры аның гади кеше өлешенә төшкән сынаулар турындагы уйлануларын чагылдыра: ул тормышны яхшы атсыз һәм ышанычлы дусларсыз үтеп булмаган кара урманга тиңли. Булатның өченче җыр-ариясе драманың кульминациясенә әверелә, анда баш күтәрүгә чакыру-өндәү ишетелә. Әлеге муз. номерлар драманың идеясен һәм тәэсирле-фикри эчтәлеген ачып салалар. «З.ш.» — татар театрының иң популяр әсәрләреннән берсе, ул милли сәхнәдә даими яңартылып тора.

*Әд.:* Егерменче елларның икенче яртысында Татар дәүләт академия театры // Татар совет театры. К., 1975; Салитова Ф.Ш. Творческое содружество драматурга Тинчурина и композитора Сайдашева // Традиции и новаторство в творчестве Карима Тинчурина. К., 1975; шул ук. Музыкальные драмы С.Сайдашева. К., 1988; Илялова И.И. Театр имени Камала. К., 1986.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЗӘҢГӘРКҮ́Л** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чошы елгасы бассейнында. 2002 елда 130 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1940 ка кадәр Келәнче (Каерлы Келәнче) исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.дә мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 273 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 7 ир-ат; 1859 да — 175, 1897 дә — 296, 1908 дә — 312, 1920 дә — 304, 1926 да — 332, 1949 да — 315, 1958 дә — 328, 1970 тә — 360, 1989 да — 185 кеше.

**ЗӘРГӘ́Р** (зәркән), затлы металлардан — алтыннан (алтынчы), көмештән (көмешче), еш кына алтын йөгертелгән көмештән (ялдызчы), ш.у. табигый һәм ясалма ташлардан (җәүһәрче) әйберләр ясаучы оста. З.ләр ялгыз яки кечкенә артельләргә оешып, аерым кулланучылар соравы буенча яки сәүдә базарына эшләгәннәр. Татарларда зәргәрчелек сәнгате күпләп җитештерү рәвешендә үсеш алмаган. 18 йөз — 20 йөз башында З. остаханәләренең эре үзәкләре Казанның татар бистәләрендә һәм Казан арты авылларында (хәзерге Арча, Саба, Мамадыш һәм Лаеш р-ннары) туплана; зәргәрчелек сәнгате аларда зур үсешкә ирешә. З.ләр остаханәләре ш.у. Әстерхан, Касыйм, Уфа, Оренбург, Троицк, Тобол, Томск һ.б. шәһәрләрнең татар бистәләрендә дә була. Авылларда З. һөнәрчелеге б-н еш кына җир эшеннән бушаган крәстияннәр дә шөгыльләнгән. Кышын осталар акча эшләү максатында күрше һәм ерак өлкәләргә — башкорт һәм Оренбург далаларына, Себер, Казакъстан, Урта Азия якларына чыгып киткәннәр, шәхси заказлар буенча бизәнү әйберләре эшләгәннәр, әзер эшләнмәләр б-н сату иткәннәр. З. һөнәре нәселдән килгән һәм буыннан буынга ул һәм кызларга, якын туганнарга мирас булып күчкән. Осталык серләре, аеруча Казан һәм якын-тирә авыллардагы З.ләр генә белгән *күпертмә җепкыр* техникасы яшереп сакланган. Авыл артельләренә, гадәттә, якын туганнар берләшкән; алар арасыннан берәүләре әйбернең төп корылышын эшләгән, икенчеләре аны бизәгән, өченчеләре исә ялтыраткан һ.б. З.ләрнең иң осталары булып җепкырчылар саналган. Алар «ак эш», ягъни алтын һәм көмеш җепкырдан бизәнү әйберләре ясау б-н генә шөгыльләнгән. З.ләр һөнәри ысуллары б-н генә түгел, ә бәлки бизәнү әйберләренең төрләре б-н дә аерылган. Бу исә хәтта кайбер авыл исемнәрендә дә чагылыш тапкан. Хәзерге Саба р-ның Чулпыч авылының исеме, мәс., 18 — 20 йөз башында авыл осталарының хатын-кыз чәч толымнарына чулпылар эшләве б-н бәйле. З. һөнәре б-н ирләр генә шөгыльләнмәгән, иң нечкә, катлаулы эшләрне хатын-кызлар башкарган (мәс., 19 йөз ахыры — 20 йөз башында хәзерге Арча р-ны Мөндеш авылыннан Габдҗикамал Вафина, хәзерге Әлмәт р-ны Түбән Абдул авылыннан Миңсафа Мифтахова; ш.у.к. Ф.Н.*Җәмилова*, Р.Р.*Дөңгыр-Надырова*). Гаиләдә ир-ат булмаган очракта, һөнәренең серләрен, гадәттә, З. хатынына яки кызларына тапшырган. З.нең эш кораллары — металл эретү өчен савыт, сандал, кечкенә чүкечләр, җепкырны үрү өчен кыскычлар, калай кисү өчен кайчылар, металл чыбык ясау өчен



Зәргәрләр нәселеннән Ф.Хисамиев.
Саба р-ның Йосыф-Алан авылы. 1980 еллар.

төрле зурлыктагы тишекләре булган металл такта — такыл, тишкеч, басма суккыч һ.б. — үзләренең формалары б-н археологик казулар вакытында табылган Болгар һәм Алтын Урда чорындагы күпчелек төрдәшләре б-н охшаш; алар, осталык күнекмәләре, бизәү ысуллары һәм үрнәкләре кебек үк, буыннан буынга тапшырылган (к. *Х.Ганиев*).

З.ләр, гадәттә, ясаган әйберләренә исемле тамга сукмаганнар, чөнки еш кына түбән сыйфатлы көмеш, аның катнашмалары б-н эшләгәннәр, бу исә Дәүләт Проба палатасы таләпләренә туры килмәгән. З.ләрнең күпчелеге өчен бизәнү әйберләре җитештерү, бигрәк тә авылларда, өстәмә хезмәт хакы чыганагы булган. З.ләрнең кириллица (АО, ВХ, ИС, ХВ), гарәп хәрефләре, тугра, тамга, яңа туган ай, кеше сурәтле тамгалары кайвакыт Россия дәүләт этнография музее (С.-Петербург) һәм ТР Милли музее фондларында саклanучы эшләнмәләрнең аерым төрләрендә (беләзек кырыйларында, Коръән тартмачыкларында) очрый. 18–19 йөзләрдән башлап, рус ювелирларына үзләренең эшләнмәләренә шәхси, исемле тамгаларын сугу мәҗбүри була. Казанда эшләгән ювелирлар, гадәттә, үз тамгалары итеп Елан туграсын (1742 дән очрый) сурәтлиләр һәм эшләгән елны, останың исемен аерым билгеләп куялар (к. *Казан көмешчеләре*).

Татар киемнәрендә милли бизәнү әйберләренең юкка чыгуы һәм алар урынына фабрикада җитештерелгән үрнәкләрнең киң файдалануы сәбәпле, зәргәрчелек 20 йөз башыннан кимүгә таба бара. 1920 еллар ахырында З.ләр кулак сыйныфына кертеләләр һәм үз шөгыльләрен ташларга мәҗбүр булалар. 1940 елларның икенче яртысында кайбер З.ләр Казан арты һәм респ-каның көнчыгыш р-ннары авылларында үз һөнәрләрен дәвам итте-




**Зәргәрчелек сәнгате**. 1. Үрдәк сыны урнаштырылган чигә асылмасы. Алтын. Җепкыр, бөртекләү. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Муенса. Фрагмент. Көмеш. Бөртекләү, җепкыр. 10–14 йөзләр. ТР Милли музее; 3. Киемгә беркетелә торган бизәк. Алтын, энҗе. Җепкыр. 13–14 йөзләр. Дәүләт Эрмитажы (С.-Петербург); 4. Бөти савыты. Алтын, асылташлар. Басма. 13–15 йөзләр. Дәүләт Эрмитажы (С.-Петербург); 5. Хәситә. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Яссы һәм күпертмә җепкыр. 19 йөз. Россия этнография музее (С.-Петербург); 6. Бил каешы каптырмасы (уңъяк өлеше). Алтын, Җепкыр, бөртекләү. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы; 7. «Казан таҗы». Алтын, асылташлар. Уеп бизәкләү, каралту. 15 йөз – 16 йөзнең 1 нче яртысы. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы; 8. Изү. Парча, бәрхет, көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Күпертмә һәм челтәрле җепкыр, эстамп. 19 йөз. ТР Милли музее; 9. Алка-муенса. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр. 18 йөз – 19 йөз башы. ТР Милли музее; 10. Яка чылбыры. Көмеш, алтын йөгертү, фирәзә, бәллүр, асылташлар. Җепкыр, бөртекләү. 19 йөз. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Көянтәле чулпы. Көмеш, фирәзә, ясалма сердолик. 19 йөз. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. Алкалар. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр. 19 йөз. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. Хәситә. Тукыма, укалы тасма, алтын, көмеш, асыл һәм ярымасылташлар. Күпертмә һәм челтәрле җепкыр, глиптика. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 14. Бил каешы каптырмасы. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 15. Аел. Көмеш, асылташлар. Җепкыр. 19 йөз. ТР Милли музее; 16. Аел. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр. 19 йөз. ТР Милли музее; 17. Беләзек. Көмеш. Чүкеп бизәкләү, уеплау. ТР Милли музее; 18. Бил каешы каптырмасы. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Күпертмә җепкыр. 19 йөз. ТР Милли музее; 19. Брошка. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 20. Беләзек. Көмеш. Уемлау, чүкеп бизәкләү. 19 йөз. ТР Милли музее.

рәләр (Саба р-ны Йосыф-Алан авылыннан Җәлил Ганиев, Фәйзрахман Хисамиев, хәзерге Әлмәт р-ны Иске Әлмәт авылыннан Сабир Дәүләтшин һәм Йосыповлар гаиләсе һ.б.), халык соравы буенча алка, беләзек, кашлы йөзек, балдаклар ясыйлар. 1960 еллар уртасыннан З.ләр традицияләре проф. һәм һәвәскәр рәссамнар иҗатында дәвам итә (В.Ковалевский, С.Шәкүрова, И.Фазылҗанов, Е.Бакакин, Л.Хисамиева, И.Васильева, В.Соловьёва һ.б.). Традицияләр һәм инновацияләр синтезы авторларның шәхси стилендә, татар З.ләренең эшләү алымнарына хас яңача бизәлеш формаларында чагыла. З.ләрнең үзенчәлекле һәм югары сәнгатьле әсәрләре Мәскәү, С.-Петербург, Казан, Уфа, Касыйм, Тобол һ.б. шәһәрләр музейлары тупланмаларында саклана.

*Әд.:* Постникова-Лосева М.М., Платонова Н.Г., Ульянова В.Л. Золотое и серебряное дело XV–XX вв. М., 1983; Ювелирное искусство // Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Ювелирное искусство // Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; шул ук. Татарская филигрань: в контексте генезиса и развития ювелирного искусства // Из истории татарского народного искусства. К., 1995; Рахимова Р.К. Лексика и словарь татарского ювелирного дела. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЗӘРГӘРЧЕЛЕ́К СӘНГАТЕ́**, гамәли бизәлеш сәнгате төре, татар милли сәнгатенең аеруча таралган һәм киң танылган төрләренең берсе. Асылташлар һәм бизәү ташлары кулланып, металлардан (алтын, көмеш, бронза, бакыр һ.б.) сәнгать әйберләре җитештерү. З.с.нең төп техник ысуллары — җепкыр (челтәрле, беркетелгән һәм күпертмә җепкыр), бөртекләү, каралту, уеплау, чүкү (төймә), басма, асылташлар һәм пыяла б-н кырлау. Тарихи тамырлары сарматларда, һуннарда, борынгы төркиләрдә, протоболгарларда металларны югары дәрәҗәдә нәфис эшкәртү сәнгатеннән килә. З.с.нең үзенчәлекле традицияләре үсеше Идел буе болгарларының 8–12 йөзләрдәге эшләнмәләреннән 18 йөз уртасы — 19 йөз ахырында иҗат ителгән классик үрнәкләргә кадәрге әйберләрдә чагылыш таба. Болгар зәргәрләре челтәрле җепкыр эшләүдә тиңдәшсез осталар булалар, кайбер әсәрләрдә ул бөртекләү һәм асылташлар б-н бизәлә. З.с.нең җәүһәрләре — алтыннан һәм көмештән эшләнгән, томшыгына бөртек капкан үрдәк сынлы чигә асылмалары (10–12 йөзләр), Болгар муенсалары, беләзекләре, алкалары, кечкенә бөти савытлары формаларының нәфислеге һәм бик оста эшләнүләре б-н аерылып торалар. Алтын Урда зәргәрләренең затлы эшләнмәләре (мәс., «Мономах бүреге») формасы һәм бизәлешләренең купшылыгы б-н рус һәм Европаның күп кенә халыклары З.с.нә йогынты ясый (баш киемнәре, беләзекләр, бөти савытлары, ярымай рәвешендәге бизәмәләр, бил каешы асылмалары бизәлешендәге спираль бизәкле беркетелгән җепкыр, асылташлар б-н кырлау, басма). З.с.нең Казан ханлыгы дәверенә караган күренекле үрнәкләре (атаклы «Казан бүреге», бил каешы каптырмалары, Коръән савыты) Мәскәүдә Кораллар палатасында саклана. Алар, беркетелгән һәм челтәрле җепкыр, каралту, үтәли кисү ысуллары б-н эшләнеп, асылташлар б-н кырланганнар.

16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Казан ханлыгы дәвере сәнгать традицияләре сакланган хәлдә, татар З.с. Казан артының эре татар авылларында үсешен дәвам иттерә. 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз уртасында ул иң югары үсешкә ирешә. Зәргәрләр тарафыннан эшләнгән бизәнү әйберләре татарларда гына түгел, руслар, башкорт, удмурт, мари, чуаш, казакъ һәм үзбәкләр арасында да популярлык казана. Бизәмәләргә ихтыяҗ зур булу З.с. үсешенең киң таралуына китерә. Бизәү өчен файдаланудан тыш, бизәнү әйберләре баштарак им-том кылуда һәм бөти сыйфатында кулланыла, соңрак аларга байлык дәрәҗәсен күрсәтү роле өстәлә (алка, беләзек, чулпы, муенсалар, Коръән савытлары, йөзекләр), аларның күбесе, кием-салымның мөһим өлеше буларак, милли костюм комплексы б-н бергә үсеш кичерә (бил каешы каптырмалары, яка асылмалары, изү, хаситә, зиннәтле төймәләр). Изге теләкләр һәм догалар рәвешендәге, уеплау, глиптика, ярымасылташлар һәм асылташлар (фирәзә, рубин, алмаз, тау бәллүре, гранат, аметист, ахак, энҗе, мәрҗән) б-н кырлау ысуллары кулланып бизәлгән гарәп язулары символик һәм магик мәгънәгә ия була.

Тотрыклы сәнгати принциплар һәм милли зәвык уникаль, затлы һәм арзанлырак гаммәви — бизәмәләрдә чагылыш таба. Осталар алтын, көмеш, кайбер очракларда бакыр һәм аларның эретмәләрен кулланалар. Татарларда катлаулы техник ысуллар (мәс., җепкыр һәм бөртекләү) кулланып, югары сәнгать дәрәҗәсендә эшләнгән бизәмәләргә өстенлек бирелгәнгә күрә, аларда зәргәрчелек кәсепчелек рәвешендә (мәс., Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе кебек) таралмый. 18 йөздә — 20 йөз башында З.с. традицион нәфис һөнәрчелек кысаларында Казанның Иске Татар һәм Яңа Татар бистәләрендә, хәзерге Арча, Саба, Мамадыш, Лаеш р-нарына кергән авылларда үсеш ала, ул төбәкләрдә чәчәк ату чорын кичерә. Зәргәрләрнең остаханәләре Әстерхан, Касыйм, Уфа, Оренбург, Троицк, Богырыслан шәһәрләренең татар бистәләрендә, ш.у. Кама аръягының көнчыгышындагы, Урал алды төбәгендәге авылларда да таралыш ала. Авылларда, гадәттә, зәргәрчелек һөнәре б-н крәстияннәр кыр эшләреннән бушаган вакытта шөгыльләнәләр. Кышка кергәч, осталар акча эшләү нияте б-н күрше һәм ерак өлкәләргә — Башкортстан, Оренбург төбәкләренә, Себергә, Казакъстанга, Урта Азиягә чыгып китәләр, шәхси заказлар буенча бизәмәләр ясыйлар яисә әзер эшләнмәләрен саталар.

19 йөз ахырыннан традицион З.с. акрынлап сүрелә башлый. Моңа милли костюмның традицион комплексындагы үзгәрешләр сәбәпче була. Нәфис формалы һәм эшләнешле әйберләрне фабрикалар җитештергән модалы эшләнмәләр кысрыклап чыгара. 1917 елгы Окт. рев-циясе З.с. үсешендә җимергеч роль уйный. Совет хакимияте елларында зәргәрләр кулак катлавына кертелә, аларның күбесе борынгы һөнәрдән баш тартырга мәҗбүр була. Шулай да Казан артындагы (Коллар, Арча янындагы Мөндеш, ш.у. Саба р-нындагы Тенеки, Эзмә, Килдебәк), Татарстанның көнчыгыш районнарындагы кайбер авылларда халык осталары заказлар буенча сугыштан соңгы елларга кадәр эшлиләр, алар гади формалы алкалар, беләзекләр, йөзекләр ясыйлар. 1950 еллар башыннан татар З.с.ндә яңарыш процесслары күзәтелә. 1960 елларда Казан өйдә эшләүче һөнәрчеләр комб-тында һәм Саба р-ны шәһәр тибындагы Шәмәрдән посёлогында җепкыр ысулы б-н стильләштереп татар сувенир эшләнмәләрен — беләзекләр, йөзекләр, каралту ысулы б-н традицион бизәмәләр эшләү (халык остасы Х.Ганиев) җайга салына. Казанда зәргәрчелек б-н Кострома өлкәсенең Красное авылында укып-өйрәнеп кайткан рәссамнар коллективы (С.В.*Ковалевская-Шәкүрова*, Р.Әлминов, Р.Нуриев, Л.Хисамиева) шөгыльләнә. Ләкин 1980 еллар башында остаханәләр ябыла һәм З.с. традицияләре электән килгән бизәмәләрнең хәзерге формаларын тудыручы профессиональ рәссамнар (Ковалевскийлар гаиләсе, И.Фазылҗанов, Ә.Шәмсетдинов, Е.Бакакин, И.Васильева, Т.Соловьева) иҗатында дәвам иттерелә.

Татар З.с. әсәрләре Мәскәүдә Дәүләт тарих музеенда, Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында, Халык иҗаты һәм гамәли бизәлеш сәнгате музеенда, С.-Петербургта Дәүләт Эрмитажында, Россия этнография музеенда, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Уфа, Әстерхан, Төмән, Тобол, Томск, Омск, Касыйм һ.б. шәһәрләрнең музейларында, район һәм авыллар музейларында саклана.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Ювелирное искусство // Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Ювелирное искусство // Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; Ювелирное искусство // шул ук. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

**ЗӘРГӘРЧЕЛЕ́К ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ́**, 19–20 йөз башында Казан губернасында киң тарала. З.һ. б-н 19 йөздә татарлар, башлыча, Казанда, Казан артында, Казан, Мамадыш һәм Чистай өязләрендә, Пермь губернасының Пермь өязендә шөгыльләнәләр. 19 йөз уртасы — татар З.һ. чәчәк аткан вакыт; тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, бизәнү әйберләренә булган җирле ихтыяҗны күпчелек очракларда татар осталары канәгатьләндерә. 19 йөз ахырында руслар яшәгән төбәкләрдә — Лаеш өязенең Балык Бистәсе, Тәтеш өязенең (хәзерге Кама Тамагы р-ны) Богородское авылларында, Тәтеш шәһәрендә дә З.һ. үсеш ала. Рус осталарының күпләп җитештергән әйберләре сыйфат ягыннан татар осталарыныкыннан түбәнрәк була, шунлыктан арзанрак торалар. Балык Бистәсе осталары югары сыйфатлы әйберләр дә эшлиләр, һәм аларга чит илләрдә дә (Германия, Бөекбритания, Англия, Америкада) ихтыяҗ зур була. Татар осталары күбесенчә алтын һәм көмеш, еш кы-

на алтынланган көмеш б-н эш иткәннәр. Кою, чүкү, уеплау, каралту, җепкыр, ш.у. бөртекләү, кырлау алымнары кулланганнар. Беренче ике алым гадирәк һәм арзанрак әйберләр (тәңкәсыман аеллар, жетоннар, асылмалар) эшләгәндә кулланылган. Беләзекләр һәм йөзекләр ясаганда уеплау һәм каралту ысуллары бергә кушып башкарылган. Җепкыр, бигрәк тә аның татар осталары гына булдыра ала торган күпертмә яки рельефлы үрнәкләре аеруча матур, катлаулы һәм зиннәтле була. Бизәкләү өчен асылташлар һәм ярымасылташлар кулланылган, зәңгәр һәм яшел, сирәгрәк сары һәм кызыл төсмерле минераллар өстенлек иткән. Һөнәрчелек б-н, асылда, гаиләнең барлык әгъзалары да шөгыльләнгән. 1911 елда Казан губернасында З.һ. б-н 290 кеше (ш.и. 109 рус) мәшгуль булган.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары: этнографическое исследование материальной культуры доактябрьского периода. К., 1953; Суслова С.В. Татарские ювелирные украшения. К., 1980; Халиков Н.А. Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1998.

**ЗӘРДӘ́** (Thalictrum), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 гә якын төре Европа, Азия, Америка һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә 5 төре үсә. Вак З. (Th. minus), гади З. (Th. simplex), аксыл З. (Th. lucidum), сары З. (Th. flavum) барлык р-ннарда очрый. Болын, алан, елга буйларында, куаклар арасында үсә. Суҗыяр яфраклы З. (Th. aquilegifolium) — сирәк төр. 50–150 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары каурыйсыман, икешәр, өчәр яки өчәрле яфраклы. Чәчәкләре вак, саргылт, күп сандагы кызыл серкәчләр б-н, озын чәчәк сабагында калкансыман себеркәчкә җыелган. Җимеше — күп чикләвекчек. Июнь-июльдә чәчәк ата. Августта җимеш бирә. Орлыктан һәм тамырчаларны бүлү ысулы б-н үрчи. Җир өсте өлешләрендә алкалоидлар, сапониннар, дуплау матдәләре, майлар бар. Төнәтмәсе һәм үлән суы бәвел кудыру, эч йомшарту чарасы буларак кулланыла. Бактерицид үзлеккә ия. Сары З., вак З., гади З. бакчаларда культуралы үсемлек буларак үстерелә. Барлык төрләре дә агулы. Суҗыяр яфраклы З. һәм аксыл З. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЗБА́РСКИЙ** Борис Ильич (15.7.1885, Каменец-Подольский ш. — 7.10.1954, Мәскәү), биохимик, СССР МФА акад. (1944), Соц. Хезмәт Герое (1945). 1911 елда Женева һәм 1912 дә Петербург ун-тларын тәмамлый. 1916–18 елларда Бондюг (хәзер Менделеев) химия з-дында баш химик. 1918 дә РСФСР Халык Хуҗалыгы Югары Советы каршындагы Үзәк химия лаб-ясен (1931 дән Л.Я.Карпов исем. Физ.-химия фәнни-тикшеренү ин-ты), 1920 дә РСФСР Сәламәтлек саклау халык комиссариатының Биохимия ин-тын оештыруда катнаша. 1930–45 тә СССР МФАнең Туклану ин-ты, 1945–52 дә Рак биохимиясе лаб-ясе җитәкчесе, 1930 дан Мәскәү 2 нче мед. ин-тында каф. мөдире, 1934 тән 1 нче Мәскәү мед. ин-ты профессоры һәм бер үк вакытта Бөтенсоюз эксперим. мед. ин-ты лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре аксымнар биохимиясенә карый. З. аксымнар йөртүдә һәм алмашуда эритроцитларның ролен, аксымнарның тукланудагы ролен, төрле физиологик һәм патологик халәттәге тукыма аксымнарының аминокислота составын өйрәнә. Онкологиягә караган хезмәтләр авторы. Тукымаларда үсә торган яман шеш нигезендә аксымнарның аномаль синтезы ята дигән теория бәян итә. Антицептик бактерицид препарат уйлап таба. В.И.Ленин һәм Болгария МС рәисе Г.М.Димитров гәүдәләрен бәлзәмләүдә катнаша. Өч Ленин ордены, башка орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Белки и злокачественные опухоли // Врачебное дело. 1947. № 2–3; Роль эритроцитов в обмене белков. М., 1949 (автордаш); Биохимическая химия. Л., 1972 (автордаш).

*В.Г.Абзалова.*

**ЗБРУ́ЕВА** Анна Васильевна (1894, Мәскәү — 1965, шунда ук), археолог, тарих фән. д-ры (1952). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1925), ун-тның халыкларны өйрәнү һәм археол. музейларында, Дәүләт тарих музеенда эшли. 1936–62 елларда СССР ФАнең Материаль культура тарихы ин-тында, 1959 дан Археология ин-тында фәнни хезмәткәр. Бөек Ватан сугышы елларында ин-т б-н бергә Алабуга шәһәрендә эвакуациядә була. Татарстанда археол. казу эшләрендә катнаша. Хезмәтләре Идел-Урал төбәге бронза һәм башлангыч тимер гасырлар тарихына, Ананьино археол. культурасына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: История населения Прикамья в ананьинскую эпоху // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1952. № 30; Памятники эпохи поздней бронзы в Приказанском Поволжье и Нижнем Прикамье // шунда ук. 1960. № 80. Культуры поздней бронзы в Прикамье в связи с вопросом о сложении ананьинской культуры // Советская археология. 1957. № 2.

*Е.П.Казаков.*

**ЗВА́НКА** авылы, Питрәч р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 18 *км* көнчыгыштарак, Нокса елгасы бассейнында. 2008 елда 406 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 49%, татарлар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — ат асрау. Кымыз цехы. Клуб, китапханә. 19 йөзнең 1 нче яртысында Кощак авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, игүчелек, итек тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 133 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 71, 1897 дә — 115, 1908 дә — 110, 1920 дә — 97, 1949 да — 136, 1958 дә — 124, 1970 тә — 136, 1979 да — 177, 1989 да — 234, 2002 дә — 381 кеше.

**ЗВЕНИ́ГОВО РАЙОНЫ́**, *Мари Республикасының* көньяк-көнбатышында урнашкан. 1924 елның 28 августында оештырыла. Мәйданы — 2748 *км²*. Үзәге — Звенигово шәһәре. Халкы — 45,7 мең (2008), ш.и. татарлар — 1919 кеше. Татарлар күпләп Красногорский (1031 кеше), Суслонгер (437), Мочалище (317) посёлокларында, район үзәгендә (155) яшиләр. Татарлар З.р. терр-ясенә 1930 елларда килеп урнаша, бу яңа сәнәгать пр-тиеләре төзелү б-н бәйле. Алар, нигездә, Татарстанның Арча һәм Кукмара, Мари Респ-касының Бәрәңге р-ннарыннан килгән кешеләр була. Хәзерге вакытта Звенигово шәһәрендә Яшьләрнең мәдәни-ял итү үзәге каршында «Дуслык» татар клубы (2003 тән) эшли. Красногорский посёлогында мәчет төзелә (2003 тән).

**ЗВЕНИ́ГОРОД ИСЕМЕНДӘГЕ́ ГВА́РДИЯ УКЧЫЛА́Р ДИВИ́ЗИЯСЕ,** 1942 елның март-июнендә ТАССРда 18 нче сапёрлар бригадасы базасында 120 нче укчылар дивизиясе буларак оештырыла. Дивизия командиры — генерал-майор К.К.Джахуа, 1942 нең 2 сентябрендә Сталинград янындагы Ерзовка авылы тирәсендә сугышка керә. Сталинград янында уңышлы сугышканы өчен 69 нчы гвардия укчылар дивизиясе итеп үзгәртелә. Соңрак Курск сугышында (1943), Кызыл Армиянең Корсунь-Шевченко һәм Яссы-Кишинёв (икесе дә — 1944) һөҗүм операцияләрендә, Румыния, Венгрия, Австрияне азат итүдә катнаша. 1945 нең 8 маенда дивизия частьләре Австриядәге Альп таулары итәгендә Американың 80 нче армиясе частьләре б-н очраша. Корсунь-Шевченко операциясе вакытындагы сугышчан хезмәтләре өчен «Звенигород» дигән мактаулы исемгә лаек була. Яссы-Кишинёв операциясендәге уңышлары өчен Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Дивизия полклары да мактаулы исемнәргә лаек була һәм орденнар б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Дюрягин Г.М. Говоров М.В. Ни шагу назад. К., 1978.

*В.Ф.Телишев.*

**ЗДАНО́ВСКИЙ** Александр Болеславович (1909, Петербург — ?), химик, химия фән. д-ры (1955), проф. (1960). 1931 елда Ленинград химия-технол. ин-тын тәмамлый, Бөтенсоюз Галургия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, физ.-хим. анализ лаб-ясе мөдире (1941 дән). 1959 елда Украина ССР ФАнең Минералогия ресурслары ин-тында физ.-химия анализ бүлеге мөдире; шул ук елда Казан ун-тының нәорганик химия каф. мөдире булып сайлана. 1965 тән Ленинград химия-технол. ин-тында шул ук исем. каф. мөдире. Хезмәтләре сулы-тозлы системаларга карый. З. үзара химик тәэсир итешми торган изотоник электролит эремәләр катнашканда пар басымы һәм эремәләр активлыгы үзгәрмәү турындагы кагыйдәне тәгъбирли. Тоз күлләрен, тоз тигезләнешен тикшерә, табигый тоз суыннан файдалануга зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Справочник экспериментальных данных по растворимости солевых систем: В 4 т. Л., 1953–63; Галургия. Л., 1972.

*Әд.:* Аверко-Антонович И.Н. Химия в Казанском университете. К., 1968; Ключевич А.С. История неорганической (общей) химии в Казанском университете за 175 лет // Исслед. в области химии простых и комплесных соединений некоторых металлов. К., 1979.

**ЗДОРО́ВЫЙ КЛЮЧ** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 38 *км* көнчыгыштарак, Үшнә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 7 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 204, 1949 да — 188, 1958 дә — 144, 1970 тә — 68, 1989 да — 16, 2002 дә — 12 кеше.

**ЗЕБЛО́В** (Зяблов) Назар Иванович (1832 — 1868 дән соң), нәкышьче. Алпавыт В.В.Обухов крепостное. 1855 елдан Петербург САндә Б.П.Виллевальдедә ирекле йөреп укый, 1858 дә сыйныфсыз рәссам дәрәҗәсе бирелә. Казанда яши һәм эшли. «Өч ат» (1857), «Көндәлек тормыш» (1858), «Чанага утырган Качалов портреты» (1858), «Мадонна рәвешендәге хатыным портреты» (1860) картиналар авторы. 1867 елда Казандагы Вознесение чиркәвендә Мәрьям Ана тормышыннан дивар рәсемнәре һәм Библия сюжетларына 10 әсәр иҗат итә.

*Әд.:* Харлампович К.В. Исторические очерки церквей города Казани. К., 1913; Каталог выставки картин «Художественные сокровища Казани». П., 1916; Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1983. Т. 4, кн.1.

**ЗЕ́ДЕРШТЕДТ** Иван Иванович (10.12.1820, С.-Петербург — 1892, Казан), терапевт, акушер, мед. д-ры (1850), экстраординар проф. (1862). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1843), Казан хәрби госпиталендә эшли (1843–56). 1862 елдан Казан ун-тында: факультет (1863–70), госпиталь (1870–76) терапиясе кафедралары профессоры, мөдире, 1858–85 тә терапия клиникасы профессоры. 1883 елда атказ. профессор исеме бирелә. Хезмәтләре акушерлык, баба авыруына диагноз кую һәм дәвалауга карый.

Хезм.: De cholera orientali: Дис. ... К., 1850.

*Әд.:* Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1894. Т. 12; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. 2002. Т. 1.

**ЗЕ́ЙЛИГЕР** Дмитрий Николаевич (12.5.1864, Тирасполь ш. — 25.6.1936, Ростов-Дон ш.), математик, гамәли матем. д-ры (1894), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1927). 1887 елда Новороссийск ун-тын тәмамлый. 1892–1914, 1917–29 елларда Казан ун-тында эшли, механика (1897–1914) һәм теоретик механика (1927–29) кафедралары мөдире, бер үк вакытта Казан политехник ин-ты ректоры (1919–25). С.-Петербург (1914–17), Донецк (1929–32), Новочеркасск (1932–35) һәм Ростов-Дон (1935) шәһәрләре ин-тларында укыта. 1907–14 һәм 1919–29 да Казан ун-ты каршындагы Физика-матем. җәмгыяте рәисе. Хезмәтләре охшаш үзгәрүчән җисемнәр механикасына, геометриядә һәм механикада винтча хисаплауны куллануга карый. З. охшаш үзгәрүчән җисемнәрнең, ягъни шундый ук сыгылмалы, рәвеше үзгәргәннән соң да баштагы рәвешенә охшаш җисемнәрнең статикасын, кинетикасын һәм динамикасын төзи. Сызыкчалы геометриядә үзе төзегән винтча хисаплау алымнары буенча А.П.Котельников идеяләрен үстерә. Шәкертләре — Н.Г.Четаев, И.Г.Малкин, Б.А.Фукс.

Хезм.: Теория движения подобно изменяемого тела // Уч. зап. Казан. ун-та. 1892. № 4–6; Об одном способе получения общих интегралов некоторых систем дифференциальных уравнений // Уч. зап. Казан. ун-та. 1897. № 1; Комплексная линейчатая геометрия. М.–Л., 1934.

**ЗЕ́ЙФМАН** Пётр Товьевич (1823, Варшава — 1903, шунда ук), вет. табибе, мед. д-ры (1879). Польшада ветеринариягә нигез салучы. Варшава югары вет. мәктәбен тәмамлый (1848), 1860–73 елларда аның директоры. 1874–81 дә Казан вет. ин-тының беренче ректоры, проф. (1881). Вет. белеме бирүне үзгәртеп коруда активлык күрсәтә, вет. табибен югары квалификацияле белгеч һәм белемле кеше итеп әзерләү тарафдары. Бу югары уку йорты б-н З. җитәкчелек иткән елларда үз эшчәнлекләре б-н институтны танытуга өлеш керткән талантлы галимнәр: Петербург мед.-хирургия академиясеннән А.О.Стржедзинский, И.Н.Ланге, Дерпт вет. ин-тыннан К.Г.Блюмберг укытырга чакырыла; 8 кафедра, анатомия һәм зоол. музейлары, физиол. һәм химия лаб-яләре, клиника — Казандагы беренче вет. хастаханәсе, фәнни китапханә ачыла. Хезмәтләре а.х. терлекләрендә котыру, трихинеллёз, йогышлы һәм йогышлы булмаган авыруларны өйрәнүгә карый. 2 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.), К., 2006.

*О.М.Гыйльметдинова.*

**ЗЕЛЁНАЯ РО́ЩА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Сулы елгасының (Дим елгасының сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2008 елда 1227 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 38%) яши. Халкының төп шөгыле — орлыкчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда Забугоровка авылыннан күчеп килгән кешеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 153, 1938 дә — 168, 1949 да — 144, 1958 дә — 116, 1970 тә — 912, 1979 да — 903, 1989 да — 1028, 2002 дә — 978 кеше.

**ЗЕЛЁНАЯ РО́ЩА**, шәһәр тибындагы посёлок, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 803 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 72%, руслар — 14%) яши. Нефть чыгару. Колбаса з-ды. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1940 елларда Шөгер нефть промыселлары карамагындагы посёлок буларак нигез салына. 1949 ның 24 декабреннән — шәһәр тибындагы посёлок, хәзерге исемен йөртә. Оештырылган көннән — Шөгер, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1956 да — 1600, 1970 тә — 1191, 1979 да — 1072, 1989 да — 672, 2002 дә — 822 кеше.

*Әд.:* Рахимов З. Шугур — край сокровищ = Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе. К., 1997.

**ЗЕЛЕНКО́ВА** Наталия Петровна (22.10.1921, Петроград — 13.10.2003, Казан), цитофизиолог, гистолог, биол. фән. д-ры (1975). Ленинград ун-тын тәмамлый (1948). 1952–57 елларда Ленинград стоматология ин-тында эшли. 1958–62, 1985–89 елларда Казан ун-тында. 1963–82 дә Казан мед. ин-тының фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре эксперименталь онкология өчен цитохимия, цитофизиология, радиоавтография, цитофотометрия ысулларын эшләүгә карый. Фосфорорганик кушылмалар йогынтысында хайваннарның күзәнәк һәм тукымаларында функциональ-төзелеш үзгәрешләрен өйрәнә. Цитохимия һәм тамгалы атомнар ысулларын кулланып, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында (1960 елларда) шешкә каршы синтез юлы б-н китереп чыгарылган яңа препаратлар (цидифос, глицифон һәм аларның структур аналоглары) тәэсиренең күзәнәк механизмын ача. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Влияние некоторых фосфорорганических соединений на морфологические и физиологические свойства клеток опухолей в эксперименте in vitro и in vivo // Материалы 1-го Всесоюзного съезда патофизиологов. Баку, 1970 (автордаш); Радиоавтографическое изучение влияния цидифоса на синтез ДНК и митотическую активность клеток асцитного лимфолейкоза // Моделирование, методы изучения и экспериментальная терапия патологических процессов. М., 1973 (автордаш); Реактивные свойства клеток, содержание и синтез нуклеиновых кислот в процессе роста асцитной опухоли и при химиотерапии цидифосом // Опухоль и организм. Киев, 1973 (автордаш).

**ЗЕЛЕНО́В** Николай Александрович (28.5.1932, Горький өлкәсенең Лысково ш.), химик-технолог, «Түбәнкамашин» ЖБ, АҖнең президенты — ген. директоры (1977–97), ТАССР, РСФСРның атказ. химигы (1984, 1988), СССРның атказ. сәнәгать хезмәткәре (1991). Мәскәү нечкә химик технологияләр ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Воронеж шин з-дында эшли. 1971 елдан төзелеп килүче Түбән Кама шин з-ды директоры. Аның җитәкчелегендә з-д төзелеп бетә һәм билгеләнгән сроктан 2 тапкыр тизрәк файдалануга тапшырыла (1974), СССРда һәм Европада җиңел һәм йөк машиналары, тракторлар һ.б. техника өчен шиннар чыгаручы иң эре үзәккә әверелә. 1991 ел башына пр-тие елга 12 млн. шин җитештерүгә ирешә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Түбән Кама шәһәренең социаль үсешенә зур өлеш кертүе өчен шәһәрнең мактаулы гражданы исеме бирелә (1984). 1985–2000 дә ТАССР ЮС, ТР ДС депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ЗЕЛЕНО́В** Юрий Никандрович (25.4.1932, Горький өлкәсе, Воскресенск р-ны Нестиары а.), физиолог, биол. фән. д-ры (1992), проф. (2000). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Горький өлкәсе, Кетовск р-ны «Коминтерн» с-зының баш вет. табибе. 1959 елдан Казан вет. ин-тында, 1966–72 дә зоотехния ф-ты деканы. Хезмәтләре эндокринологиягә, а.х. терлекләре организмына радиоактив һәм фосфорорганик кушылмаларның тәэсирен ачыклауга карый. Уйлап табуга

2 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Радиобиологические эффекты у животных. М., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЗЕЛЕНО́ВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2008 елда 108 кеше (руслар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1678 дән Усад исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, кирпеч сугу һәм киндер туку б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете, 1 су һәм 3 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1156 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 127 ир-ат, 1859 да — 409, 1897 дә — 790, 1908 дә — 812, 1920 дә — 816, 1926 да — 762, 1938 дә — 871, 1949 да — 522, 1958 дә — 440, 1970 тә — 253, 1979 да — 200, 1989 да — 130, 2002 дә — 107 кеше.

**ЗЕЛЕНОДО́ЛЬСК** ш., к. *Яшел Үзән.*

**ЗЕЛПЕ́** (Lonicera), зелпечәләр семьялыгыннан куаклар ыругы. 200 дән артык төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 2 төре: урман З.се, яки бүре җиләге (L. xylosteum), һәм татар З.се (L. tatarica) үсә. Урман З.се бөтен респ-када очрый. Катнаш һәм яфраклы урманнарда әрәмәлекләр хасил итәләр. Татар З.се декоратив, бакча һәм паркларда үстерелә. 90–250 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы җирнең өске катлавында, куе тармаклы. Кайрысы көрән яки саргылт-көрән, яшь сабаклары шома. Яшь ботаклары җәенке. Яфраклары вак, озынча-эллиптик яисә ланцетсыман. Чәчәкләре вак, алсу, сары, яфрак куентыгында, хуш исле. Җимеше — шарсыман сусыл җимеш, урман З.сендә кара-кызыл, татар З.сендә — саргылт кызыл төстә. Май-июньдә чәчәк ата. Июль-сентябрьдә җимешләре өлгерә. Орлыктан, чыбыкчадан, үрентедән үрчи. Күләгәгә чыдам. Урман полосалары, тере киртәлекләр барлыкка китерү, ерымнарны, сөзәклекләрне ныгыту өчен утырталар. Җир асты өлешләрендә флавоноид, дуплау матдәләре, сапонин, микроэлементлар, органик к-талар бар. Халык медицинасында гади З. яфраклары бөрештергеч чара буларак, чәчәк һәм җиләкләре йөрәк кан тамырлары, бавыр һәм үт куыгы авыруларын дәвалау өчен файдаланыла. Ашарга яраксыз. Үзагачы вак-төяк әйберләр ясауга китә. Баллы.

**ЗЕМЛЯКО́В** Александр Сергеевич (26.4.1939, Казакъстан ССР Щучинск ш.), механика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1965 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук автоматика һәм идарә итү кафедрасында эшли (2008 гә кадәр). Хезмәтләре Ляпуновның вектор функцияләре нигезендә катлаулы системаларны тикшерүгә карый. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984).

Хезм.: Динамика и управление внеатмосферными астрономическими обсерваториями // Тр. 6 го Междунар. симп. ИФАК по автоматическому управлению в пространстве. М., 1976; Метод векторных функций Ляпунова в теории устойчивости. М., 1987; Динамическое исследование угловой стабилизации космического аппарата с избыточный системой // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2001. № 1; Управление угловым положением космического аппарата с избыточной системой гиродинов // шунда ук. 2001. № 4.

**ЗЕМЛЯ́НОВ** Сергей Андреевич (1851 — 1917 елдан соң) 1нче гильдия Казан сәүдәгәре. Икмәк, бакалея товарлары б-н сәүдә итеп, шактый капитал туплый һәм аны Иделдә үз пароходчылыгын төзүгә тота. 20 йөз башында З.ның 7 буксир пароходы һәм 54 баржасы була. Милкенең бәясе 500 мең сумнан артып китә. 1896–1917 елларда Казан шәһәр думасы гласные, 1901–17 дә Казан шәһәр банк җәмгыяте исәп-хисап ком-ты, 1909–17 дә шәһәр финанс комиссиясе әгъзасы. 1904–08 дә Елга уч-щесе попечительләр советы рәисе. Казанда әлеге уч-щене төзүгә 25 мең сум акча һәм җир биләмәсе, ш.у. рус православие чиркәвенә шактый акча бирә. Иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**«ЗЕ́МСКАЯ НЕДЕ́ЛЯ»** («Земство атнасы»), рәсемле атналык журнал. Казан губернасы земство идарәсе органы. «*Казанская газета*»ның дәвамчысы. Төрле елларда мөхәррирләре — Д.А.Теренин, Н.А.Мельников, В.В.Молоствов. Башлыча, Казан губернасы һәм өяз земство идарәләре әгъзалары һәм хезмәткәрләре, Казан а.х. җәмгыяте әгъзалары, а.х. белеме галимнәре, земство мәктәпләре укытучылары мәкаләләре басыла. Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгалары яктыртыла, Петроград телеграф агентлыгы, Верховный Башкомандующий хәбәрләре, күзәтмә мәкаләләр, ш.у. хәрби хроника материаллары (авторы — Казан хәрби уч-щесенең тактика укытучысы Н.В.Колесников) басыла. Кушымта рәвешендә фронтларның аңлатма карталары, төрле армияләрнең хәрби техникасы рәсемнәре, сугыш күренешләре фоторәсемнәре, хәрби җитәкчеләрнең, дәүләт эшлеклеләренең, депутат-парламентарийларның фотопортретлары чыгарыла. Россиянең икътисади тормышы (а.х. һәм сәнәгать, сәүдә, кооперация һ.б.) яктыртыла. Казан губернасындагы өяз земство идарәләренең хисаплары басыла, земство мәктәпләренең хәле турында мәгълүмат бирелә. «Авыл авазы» дигән бүлектә җирле үз хәбәрчеләренең авыл көнкүрешеннән аерым күренешләр, авыл халкының земство башлангычларына мөнәсәбәте турындагы хәбәрләр урын ала. Кырчылык һәм терлекчелек продуктларының бәяләре турында мәгълүмат, Казан ун-тының метеорология обсерваториясе бюллетеньнәре басыла. 1916 елның гыйнварыннан 1918 нең мартына кадәр журналга бушлай кушымта итеп шул ук исемдә газета чыгарыла (елга 48–52 сан).

*Г.Р.Заманова.*

**ЗЕ́МСТВО** (земство учреждениеләре), Россиядә җирле бөтенкатлау үзидарә системасы. 1864 елда «Губерна һәм өяз земство учреждениеләре турында нигезләмә» тарафыннан Земство реформасы барышында кертелә. 1865 тә З.лар — 19 губернада, ш.и. Казан губернасында ачыла. З.ларның җитәкче органнары — губерна яки өяз җыелышлары, башкарма органнары *земство идарәләре* була. З. җыелышлары яшерен тавыш бирү юлы б-н 3 елга сайланучы гласныйлардан торган. Сайлаулар милек цензы һәм куриаль система нигезендә үткәрелә (бүленеш нигезендә катлау түгел, ә икътисади принцип ята). Аларда 25 яшьтәге, билгеле бер урында кимендә бер ел яшәгән ир-ат катнаша. Сайлаучылар 3 куриягә (разрядка) бүленә: 1) кимендә 200 дис. җире булган җирбиләүчеләр һәм 15 мең сумнан артык күчемсез милек ияләре яисә елына 6 мең сумнан артык керем алучылар; 2) елына кимендә 6 мең сум кереме сәүдә яки сәнәгать оешмасына, яисә 500 дән 3 мең сумга кадәрле күчемсез милеккә ия булган шәһәр кешеләре; 3) авыл җәмәгатьләре вәкилләре (алар өчен сайлаулар күп баскычлы була). Губерна З. җыелышларына гласныйларны өяз З. җыелышларында яшерен тавыш бирү нигезендә сайланганнар (6 өяз гласныеннан 1 гласный). 1890 елның 12 июне нигезләмәсе гамәлгә кертелгәч, гласныйларның гомуми саны киметелә, дворяннар катлавының вәкиллеге башка катлаулар, аеруча крәстияннәрне киметү исәбенә шактый арттырыла. Сайлаучылар саны кыскартыла (җир яки башка күчемсез милеккә кимендә бер ел хокукы булган физик һәм юридик затлар гына сайлый ала), милек цензы арттырыла. 1864 елгы нигезләмәдә күрсәтелгәнчә, Казан губернасында 313 өяз гласные (1890 елгы нигезләмә буенча — 274), ш.и. җирбиләүчеләрдән — 126 (124), авыл җәмәгатьләреннән — 145 (112), шәһәр кешеләреннән — 42 (38), губерна гласныйлары 51 (41) була. Казан губернасы З. җыелышларында дворяннар өстенлек итә. 1890 елгы реформага кадәр өяз земстволарында дворяннар — 39,1% (1889), реформадан соң — 44,1% (1892); крәстияннәр — 47,6% (1889), 45,4% (1892); шәһәр кешеләре — 13,3% (1889), 10,5% (1892) була. Гласныйлар хезмәт иткән өчен хезмәт хакы алмаган. 1865 нең 12 октябрендә — өяз, ә 20 ноябрьдә Казан губерна З. җыелышлары эшли башлый. Чираттагы һәм чираттан тыш губерна һәм өяз З. җыелышлары үткәрелә. Чираттагы җыелышлар өчен сессияләрне үткәрү һәм аларның иң күп дәвам итү вакыты билгеләнә. Чираттагы өяз сессияләре — сентябрьдән (дәвамлылыгы 10 көннән дә артык булмый), губерналарныкы декабрьдән дә соңга калмый (20 көннән дә артык булмый) җыелырга тиеш була. Губерна З. җыелышында — губерна дворяннарының, өяз З. җыелышларында өяз дворяннары башлыгы рәислек итә. Эшләрне алдан карау өчен гласныйлардан даими (мәс., гомуми, протест белдерүче, доклад әзерләүче, юридик, техник) һәм вакытлы әзерлек комиссияләре оештырыла. Ревизия комиссиясе генә мәҗбүри була. Барлык комиссияләр так сандагы гласныйлардан

тора һәм яшерен тавыш бирү юлы б-н сайлана. З.лар утырыш беркетмәләре алып барырга һәм журналлар яки З. җыелышлары карарларын нәшер итәргә тиеш була. З. органнары җитәкчеләрен сайлау, эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгеләү, белгечләр сайлау һәм аларны өйрәтү мөстәкыйль рәвештә алып барыла. Шул ук вакытта аларның бөтен эшчәнлеге хакимиятнең ныклы контроле астында була: З. карарларын, заемнар б-н эшләү (З.ның юридик статусы була), смета проектларын, идарә рәисен сайлауларны — губернатор, ә 1890 елдан З. һәм шәһәр эшләре буенча Казан губерна идарәханәсе (присутствиесе) карый һәм раслый. 1867 елгы закон З. докладларын һәм журналларын цензура аша үткәрүне таләп итә, З. җыелышы рәисләренең вәкаләтләрен киңәйтә. З.ның барлык эшчәнлеге үзфинанслауга нигезләнә: аларга чыгымнарны каплау өчен махсус салымнар кертү рөхсәт ителә, кергән акчаларның бер өлеше күчемсез милектән алына. Эшчәнлек даирәсенә түбәндәге мәсьәләләр керә: юлларны һәм юл корылмаларын төзек хәлдә тоту; *Земство почтасы*н оештыру һәм тоту, ярлыларны, авыруларны, акылдан язганнарны, ятимнәрне һәм гарипләрне иҗтимагый карау-тәрбияләү (гыйбадәт кылу урыннары, приютлар, бушлай чәйханәләр һәм ашханәләр ачу); сәламәтлек саклау (к. *Земство медицинасы*); авыл халкына табиблек ярдәме күрсәтүне үстерү (даруханәләр, хастаханәләр төзү); халык мәгарифе (к. *Земство мәктәпләре*); авыл хуҗалыгын үстерү һәм терлекләрнең күпләп үлүен булдырмау; янгынга каршы чаралар күрү; крәстиян хуҗалыгын, сәүдәне һәм сәнәгатьне үстерүгә булышу (З. кредиты, ссуда-саклык кассалары, агрономия хезмәтләре оештыру; а.х. складлары төзү); мөлкәтне З. иминиятләштерүен идарә итү; хөкүмәтнең җирле ихтыяҗлар һәм керемнәр турында кайгыртуына ирешү. З. бюджеты елдан-ел арта бара: 1890 да аның чыгым өлеше — 1612,7 мең, 1902 дә 2395,8 мең сум тәшкил итә. Чыгымнар медицинага (1890 да — 21%; 1902 дә — 31,1%), халык мәгарифенә (1890 да — 16,2%, 1902 дә — 18%), җир идарәсенә (1890 да — 8,5%, 1902 дә — 10,2%), хөкүмәт чыгымнарына (1890 да — 18%, 1902 дә — 4,6%), икътисади тотрыклылыкны ныгытуга (1890 да — 4,1%, 1902 дә — 3,6%), юлларга (1890 да — 3,7%, 1902 дә — 9,8%); җәмәгать тарафыннан карау-тәрбияләүгә (1890 да — 7,6%, 1902 дә — 5,5%), башкаларга (1890 да — 20,9%, 1902 дә — 17,1%) бүленә. Профессиональ әзерлек таләп итүче З. вазифаларын башкару өчен З. идарәләре хезмәткәрләрне (табибләр, мөгаллим, статист, агроном, ветеринар, инженер, техник, фельдшер, акушерларны һ.б.) чакыра алган. Басмалары — «*Казанская газета*» һәм «*Земская неделя*» ж-лы. З.лар 1918 елда Совет хөкүмәте декреты б-н бетерелә. Ш.у.к. *Земство статистикасы, Земство телефон челтәре*.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1864; Т. 39, отд. 3. Прил.; шунда ук. Собр. 3. СПб., 1890. Т. 10, отд. 1. № 6924.

*Әд.:* В е с е л о в с к и й Б.Б. История земства за сорок лет: В 4 т. СПб., 1909–13; Б р о д А.Д. К пятидесятилетию Земских учреждений 1864–1914. К., 1914; А б р а м о в В.Ф. Казанское земство в пореформенный период (1865–1890 гг.): Дис. ... Л., 1989; Г е р а с и м е н к о Г.А. Земское самоуправление в России. М., 1990; Н и з а м о в а М.С. Казанское земство в конце XIX — начале XX вв.: местное самоуправление и земское общественное движение: Дис. ... К., 1995.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЗЕ́МСТВО БАШЛЫКЛАРЫ́** (земство участоклары башлыклары), крәстияннәр өстеннән адм.-суд хакимлеген гамәлгә ашыручы, кагыйдә буларак, нәселләре җирле дворяннардан булган җаваплы кешеләр. Казан губернасында З.б. ин-ты 1889 елның 12 июлендә кабул ителгән Нигезләмә буенча Россия Дәүләт Советының император Александр III тарафыннан 1891 нең 16 июнендә расланган фикере нигезендә оештырыла. Губерна терр-ясе 65 земство участогына бүленгән була (Казан өязендә — 7, Козьмодемьян өязендә — 3, Лаеш өязендә — 6, Мамадыш өязендә — 7, Зөя өязендә — 4, Спас өязендә — 5, Тәтеш өязендә — 6, Царёвококшай өязендә — 4, Цивиль өязендә — 5, Чабаксар өязендә — 5, Чистай өязендә — 9, Ядрин өязендә — 4). Алар башында губернатор һәм губерна дворяннар җитәкчесе тәкъдиме б-н эчке эшләр министры тарафыннан билгеләнгән З.б. тора. Алар крәстияннәрнең җәмәгать идарәсе органнарының эшчәнлеген күзәтәләр, крәстияннәр һ.б. буйсынган катлаулар өчен беренче мәхкәмә инстанциясе булып торалар (өязләрдә бетерелгән крәстияннәр эшләре идарәханәләре һәм *җәмәгать судлары* урынына). Авыл җәмәгатьләре тәкъдим иткән кандидатлардан волость мәхкәмәләрен билгелиләр (элегрәк крәстияннәр тарафыннан сайлана). Авыл һәм волость җыеннарының, волость мәхкәмәләренең теләсә нинди карарларын гамәлдән чыгара, карар кабул иттерә, буйсынган хәлдәге кешеләрне вак гаепләре өчен тән җәзасына тарта, 3 көнгә кадәр тоткын итә, 6 сумга кадәр штраф түләттерә алганнар. П.А.Столыпинның аграр реформасын үткәрүдә актив катнашалар. З.б. һәм волость мәхкәмәләре карарларына апелляция инстанциясе — З.б.ның өяз съездлары тарафыннан башкарыла (алар хакимият һәм мәхкәмә идарәханәләреннән тора). Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 30 июнь карары б-н 1917 елның 1 октябрендә бетереләләр.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1894. Т. 11. № 7775.

*Әд.:* З ы р я н о в П.Н. Социальная структура местного управления капиталистической России (1861–1914) // Ист. зап. 1982. Т. 107.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗЕ́МСТВО ИДАРӘЛӘРЕ́**, 1864–1918 елларда *земствоның* губерна һәм өяз башкарма органнары. 1864 елгы Нигезләмә буенча З.и. гласныйлар арасыннан земство җыелышларында 3 елга сайланып куела. 1865 нең 20 ноябрендә Казан губернасы земство идарәсенең беренче составы сайлана. Өяз земстволары, рәистән тыш, идарәнең 6 әгъзасын (гадәттә, 2–3 әгъза) сайлау хокукына ия булган. Губерна З.и. 7 кешелек составта каралган, ләкин еш кына әгъзаларның саны 4 кешедән артмаган. Өяз З.и.нең рәисе — губернатор, губернаныкы эчке эшләр министры тарафыннан расланган. Земство хезмәткәрләрен билгеләү һәм эштән азат итү рәис вазифасына кергән. 1890 елгы Нигезләмә буенча З.и. әгъзаларын гласныйлардан гына түгел, сайлаучылар арасыннан да сайлау рөхсәт ителгән; администрация идарә рәисенең һәм әгъзаларның вазифаларга керешүен раслаган; дәүләт хезмәтен башкарырга хокуклы затлар гына З.и.нең рәисләре була алган; идарәләрнең рәисләренә һәм әгъзаларына дәүләт хезмәткәрләре хокуклары бирелгән, аларны тиешле вакыттан алда вазифалардан читләштерү администрация иркендә булган. Идарәләрнең әгъзалары арасында бурычлар земствоның эшчәнлеге юнәлешләреннән чыгып билгеләнгән. Казан губернасы земство идарәсе даими рәвештә (3 айга 2 тапкыр) өяз З.и. вәкилләре киңәшмәләрен уздырган, бу чаралар земство эшен тәртипкә салырга мөмкинлек биргән. З.и. түбәндәгеләр б-н шөгыльләнгән: земство җыелышлары күрсәтмәләрен башкару, земство милке һәм хуҗалыгы б-н идарә итү; керемнәр һәм чыгымнарның исәбен, бүленешен һәм хисапларын төзү; булачак җыелышлар өчен кирәкле мәгълүматлар әзерләү һәм нәтиҗәләр чыгару; земство керемнәренең җыелуына күзәтчелек итү; земство акчаларының сарыф ителүен контрольдә тоту; земствоның милеккә кагылышлы дәгъвалары буенча мәхкәмәдә эш йөртү һәм З.и.нә карата шикаятьләрне тикшерү. З.и. вазифаларына ш.у. земство хезмәткәрләрен туплау да кергән, 1914 тә 1 меңнән артык хезмәткәр исәпләнгән. З.и.нең хисаплары земство җыелышларында каралган һәм расланган. Казан губернасы земство идарәсенең төрле еллардагы рәисләре: П.Н.Арцыбашев (1865–67), В.И.Образцов (1867–69), П.П.Перцов (1870, 1883), В.М.Молоствов (1871–72), В.А.Ермолаев (1873–76), М.М.Рот (1877–82), П.Х.Куприянов (1884–85), И.Н.Аристов (1886–87), П.М.Останков (1888–1899), В.В.Марковников (1900–03), П.И.Геркен (1904–07), Н.А.Мельников (1908–1916), А.Н.Плотников (1917).

*Әд.:* к. *Земство* мәкаләсе.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЗЕ́МСТВО МӘКТӘПЛӘРЕ́**, 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Россиядә башлангыч уку йортлары. Шулай ук земство башлангыч уч-щеләре, күбесенчә авыл уч-щеләре буларак билгеле. Аеруча массакүләм типтагы мәктәпләр; аларда илдәге барлык укучыларның яртысыннан артыгы белем ала. Өяз земство идарәләре тарафыннан ачыла һәм финанслана, халык уч-щеләре директорлары һәм инспекторлары тарафыннан күзәтелә, халык уч-щеләренең 1864, 1884 һ.б. елгы Уставлары нигезендә эшлиләр. Казан, Вятка, Сембер губерналарында 1865 тән, Уфа губернасында 1875 тән ачыла башлый. Күбесенчә бер класслы, уку срогы 3 ел булган һәм бер укытучылы З.м. киң тарала; укучылар саны 50 дән артса, укытучыга ярдәмче билгеләнә. 5 еллык уку срогы б-н ике классл мәктәпләр дә булган. 20 йөз башыннан бер классл мәктәпләрне 4 еллык укытуга күчерү бара. З.м. күбесенчә катнаш була, ш.у. кызлар, малайлар аерым да укыйлар. З.м.ндә укучылар Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан расланган китаплар нигезендә уку, язу, ариф-

метика буенча белем алалар. Ходай кануннарын җирле (урындагы) дин әһелләре укыта. Күп мәктәпләрдә китапханәләр булдырыла. Әҗнәбиләргә З.м.ндә белем бирү, кагыйдә буларак, *Ильминский системасы* буенча алып барыла. 20 йөз башында земстволар татар авылларында рус-татар башлангыч уч-щеләре ача башлыйлар. Баштарак мәктәпләр вакытлыча укыту эшенә яраклаштырылган биналарда алып барыла, соңрак күбесе өчен махсус биналар төзелә. З.м. өчен пед. кадрлар (күбесе кыз балалар гимназияләрен һәм епархия уч-щеләрен тәмамлаучылар) Казан укытучылар семинариясендә һәм Казан земство мәктәпләрендә әзерләнә. Мәктәпләр челтәрен киңәйтеп, земстволар бу мәктәпләрне барлык крәстиян балалары укырлык итәргә тырышалар. 1874 елда ук Казан губернасында — 114, 1900 елга — 600 дән арта, 1914 тә — 1050, 1917 дә 1076 З.м. була; 1914 тә укучылар саны 46 меңгә җитә. 1912 дән Казан губернасының өяз земстволары, Вятка губернасының Алабуга земствосы, Уфа губернасының Минзәлә земствосы гомуми башлангыч белем бирүне кертү программасын тормышка ашыра башлыйлар. 1918 елда З.м.нең күбесе 1 нче һәм 2 нче баскыч мәктәпләр итеп үзгәртелә, кайберләре финанслау туктатылу сәбәпле ябыла. Күпчелек укытучылар совет чорында үз эшләрен авыл мәктәпләрендә дәвам иттерә.

*Әд.:* Азаматова Г.Б. Деятельность Уфимского земства в области народного просвещения: Дис. ... Уфа, 2000; Железнякова Ю.Е. Земская школа Казанской губернии. 1865–1917: Дис. ... К., 2002.

*Е.В.Липаков.*

**ЗЕ́МСТВО МӘХКӘМӘЛӘРЕ́**, Россиядә җирле мәхкәмәләр һәм хакимият-полиция органнары. Казан губернасында 1775 елгы «Губерналар турында учреждениеләр» («Учреждения о губерниях») нигезендә оештырылалар, 1781 нең 27 декабреннән гамәлгә керәләр. Башта Югары һәм 13 Түбән мәхкәмәгә бүленәләр. Югары земство мәхкәмәсе — дворяннар өчен сословие мәхкәмәсе була. Аның тулы идарәханәсенә Сенат тәкъдиме б-н император тарафыннан билгеләнгән 2 рәис, дворяннар тарафыннан 3 елга сайланган 10 утырышчы керә; мәхкәмә каршында прокурор, дәүләт һәм җинаять эшләрен алып бару тәртибен күзәтүчеләр була. Җинаять һәм гражданлык эшләре департаментларына бүленә. Югары З.м.нә *өяз мәхкәмәләре*, дворяннар опекасы һәм Түбән З.м. буйсына. Түбән мәхкәмәләрнең карарларына апелляцияләр, дворяннар арасындагы шикаятьләр, низаглар, гражданлык һәм җинаять эшләре, ш.у. вотчиналар, өстенлекләр, васыятьләр, мирас алу хокукы турындагы һәм дәгъва эшләре (100 сумга кадәр) Югары мәхкәмә карамагында була; яклар карар б-н риза булмаган очракта эшләр *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасына* күчерелә. Барлык җинаять эшләре *Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы* тарафыннан тикшерелә. Мәхкәмә карары күпчелек тавыш б-н раслана. Югары земство мәхкәмәсе 1796 ның 31 декабрендә Казан губернасының яңа штаты (оешмалар һәм җаваплы шәхесләр исемлеге) нәшер ителгәч бетерелә.

Түбән З.м. өяз мәхкәмәләреннән түбәнрәк торучы орган була. Өязләрдә мәхкәмә-полиция вазифаларын башкаралар (шәһәрләрдә шундый ук вазифаларны шәһәр башлыклары һәм Җәмәгать тәртибе идарәсе башкара). Земство исправнигыннан (капитан-исправник), 2–3 утырышчыдан тора; моннан тыш, Түбән земство мәхкәмәсенә Түбән расправадан дәүләт крәстияннәре эшен карауда катнашу өчен 2 утырышчы җибәрелә. Өязләрдә тикшерү эшләре алып баралар, законнар үтәүне күзәтәләр, губерна хакимияте әмерләрен үтиләр, качып киткән крәстияннәрне эзләү һәм кулга алу б-н шөгыльләнәләр, «әхлак, әдәп һәм тәртип» саклауны, юллар һәм күперләр төзеклеген, сәүдә һәм бәяләрнең торышын күзәтәләр, карарларны тормышка ашыралар һ.б. Шәхси состав дворяннар тарафыннан 3 елга сайлана һәм губернатор тарафыннан раслана. 1837 нең 3 июнендә кабул ителгән «Земство полициясе турында нигезләмә» («Положение о земской полиции») буенча Түбән З.м. З.м. дип үзгәртеләләр, утырышчылар саны киметелә һәм становой приставлар ин-ты оештырыла.

З.м. земство исправнигы (рәис), мәҗбүри баш утырышчы (дворяннар тарафыннан сайлана), дәүләт крәстияннәреннән 2 авыл утырышчысы составында эшли. Тикшерү эшләре үткәрү һәм карарлар кабул итү өчен урыннарда З.м.нең исправниктан, становой приставтан һәм өяздәге дәүләт һәм җинаять эшләрен алып бару тәртибен күзәтүчедән торган вакытлы идарәханәләре оештырыла. З.м.нең башкарма органнары — волость идарәләре, өяз приказлары, вотчина идарәләре һ.б. 1837 дә «земство полициясенә хезмәт итүчеләр» постлары оештырыла (десятскийлар һәм сотскийлар), ә шәһәр полициясе булмаган бистә һәм шәһәрләрдә исправник тысяцкий һәм пятисотскийларны билгели. З.м. 1862 елның 25 декабрендә кабул ителгән «Вакытлы кагыйдәләр» («Временные правила») нигезендә бетерелә һәм *полиция идарәләре* б-н алыштырыла.

*Әд.:* Ефремова Н.Н. Судоустройство России в XVIII — 1-й половине XIX вв. М., 1933; Долгов Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и раннее новое время. М., 1996; шул ук. Органы суда в Казанской губернии XVIII — начала XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗЕ́МСТВО МЕДИЦИ́НАСЫ** (1864–1918), 1864 елгы земство реформасы нигезендә земство — җирле үзидарә тарафыннан Россия халкына медицина ярдәме күрсәтү өчен оештырылган система. Россия Сенаты губерна һәм өяз земство учреждениеләре һәм алар өчен земство бурычлары, халык өчен билгеләнгән азык-төлек һәм иҗтимагый ярдәм күрсәтү эшләре буенча вакытлы кагыйдәләр турындагы нигезләмәне раслый. Нигезләмә 33 губернада, ш.и. Казан губернасында гамәлгә кертелә. Земство органнары тарафыннан хезмәт күрсәтүне, халыкның керем дәрәҗәсе һәм социаль хәленә бәйсез рәвештә, теге яки бу ярдәмне алуны һәркемнең хәленнән килерлек итеп оештыру программасы булдырыла. З.м. земство акчасына көн күрә, авыл җирендә яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүнең участок формасы сан.-гигиена эшләрен оештыру б-н бергә бара. З.м. гамәлгә кертелгәнче, 220 мең кеше яшәгән Казан өязендә мед. ярдәме күрсәтү өлкәсендә нәтиҗәле дәвалау һәм профилактика чаралары булмый. Медицина ярдәме хәрби госпиталь, мед. участоклары, чәчәк авыруына каршы прививка ясаучылар, кендек әбиләре, халык табибләре тарафыннан күрсәтелә. Казанда беренче дәвалау пункты 1800 елда ачыла, 1809 да хәрби госпиталь эшли башлый; Казан шәһәр хастаханәсе (1807), Болгар (1837), Чистай (1844) шәһәрләрендә хастаханәләр, Казан ун-тының «Иске клиника»сы (1840), Казанда Александр хастаханәсе (1860) ачыла. Алар өчен кадрларны 1837 дә ачылган фельдшерлар мәктәбе һәм ике теш дәвалау мәктәбе әзерли. Иҗтимагый ярдәм учреждениеләре ш.у. чәчәккә каршы прививкалар ясауны оештыру б-н дә шөгыльләнергә тиеш була. Хөкүмәт земстволарга кыйммәтле кәгазьләр рәвешендә губерна капиталы (1862 елның 1 июль Указы) һәм 5 млн. сум өстәмә акча бирә, әлеге акчалар кагылгысыз фонд булып исәпләнә; алардан алынган процентлар хәйрия өчен һәм картлар йортларын карауга тотыла. Земстволар хастаханә, даруханә, поликлиникалар тотуга, дару, инвентарь, җиһазлар алуга, медицина буенча китаплар яздырып алуга һәм социаль кирәк-яракка акча бүлеп бирә. Земствоның өязләрдәге төп эше гамәлдәге мед. учреждениеләрен үз карамагына алудан башлана (1866). Иске биналар яңартып корыла, яңа өяз участок хастаханәләре төзелә, фельдшерлык пунктлары, санитария хезмәтләре һ.б. булдырыла, мед. хезмәткәрләренә хастаханә карамагында коммуналь хезмәтләр күрсәтелүче фатирлар бирелә. Земство мед. ярдәме күрсәтү системасын камилләштерү турында кайгырта, земство табибләренә матди ярдәм билгели, уңайлы торак шартлары булдыруны контрольдә тота, табибләрне транспорт чаралары б-н тәэмин итә. Казанда Губерна психиатрия хастаханәсе (1869), Лихачёв исем. бала тудыру йорты (1874), Адмиралтейство, Болак арты (1885, 1889), Балалар (1899) һәм Шамов (1910) хастаханәләре сафка баса, алар Казан ун-тының клиника базалары булып та хезмәт итә. 19 йөз ахырына авылларга табибләр килү сизелерлек арта. З.м.ның структур берәмлеге булып табиблек участогы санала. Хастаханәләрнең күп өлеше өяз үзәкләрендә (Алабуга, Лаеш, Чистай, Минзәлә) һәм авылларда (Чаллы, Богоявленский-Горки, Иске Чишмә, Кәкрекүл, Изгар, Петропавловка) ачыла; алар шәхси яки арендага алынган йортларда урнаша. Өяз хастаханәләрендә табибләр — хастаханә мөдирләре булмый. Авыруларны өяз яки шәһәр табибләре күзәтеп-дәвалап тора, кайбер хастаханәләр хәтта фельдшерларсыз эшли. Авырулар өчен тиешле шартлар бары тик Чистай шәһәрендә 1814 тә сәүдәгәр Колпаков тарафыннан төзелгән хастаханәдә (20 урынлы) генә тудырылган була; әлеге хастаханә-



Алабуга шәһәрендә земство хастаханәсе.



Чистай шәһәрендә земство хастаханәсе.

нең 100 урынга исәпләнгән икенче бинасын сәүдәгәр Челышев төзетә. Ә 1876 елда Зөя шәһәрендә үзәктән җылытыла торган, вентиляция системасы куелган һәм сууткәргеч кертелгән, бәдрәф, кухня, кер юу бүлмәләре, даруханәсе, складлары һәм төрбәләре булган 10 урынлы хастаханә (С.-Петербургтагы Рождественский хастаханәсе тибында) төзелә. Өяздә 3 дәвалау участогы (Зөя шәһәрендә, Фёдоровка һәм Тәмте авылларында) оештырыла. 1900 елга үз биналарында — Арча шәһәрендә (24 урынлы), Ключи һәм Семиозёрка авылларында (10 урынлы), арендага алынган биналарда — Чыпчык һәм Хәтнә авылларында (10 ар урынлы) хастаханәләр эшли. Питрәч, Усад, Алат, Олы Мәңгәр, Балтач, Мәмдәл авылларында Казан дәвалау участогы контрольлегендә фельдшерлык пунктлары хезмәт күрсәтә. Лаеш өязендә өяз (Лаеш ш.) һәм участок (Балык Бистәсе, Рус Кызылы, Пановка авыллары) хастаханәләре, 4 дәвалау участогы һәм фельдшерлык-акушерлык пункты эшли.

1909 елда Мамадыш өязендә 7 табиб эшли; Мамадыш шәһәрендә, Кукмара посёлогында яңа хастаханәләр сафка бастырыла; Чүриле, Нырты авылларында авыруларны кабул итү бүлекләре булган дәвалау участоклары эшли. Спас өязендә 25 урынлы өяз хастаханәсе хезмәт күрсәтә; Полянка, Сихтерма, Спас Затоны авылларында хастаханәләр һәм табиблек участоклары ачыла. Тәтештә агачтан 2 катлы хастаханә төзелә (25 урынлы): Яльчик, Богородское, Шонгаты, Васильево авылларында стационар табиблек участоклары (15 урынга исәпләнгән) ачыла. 20 йөз башында Казан губернасында 52 хастаханә һәм табиблек участогы (1630 урын) хезмәт күрсәтә. Казан. ун-тының мед. факультетын тәмамлап чыккан табибләр шешләрне, катаракталарны дәвалау, төрле ампутацияләр һ.б. катлаулы операцияләр ясыйлар. Иҗтимагый гигиена кагыйдәләрен үтәү, тиешле белгечләр булмаганлыктан, табибләргә һәм полиция городовойларына йөкләнә. Вакытлы матбугат югары квалификацияле белгечләр: земство табибләре — акушер-гинеколог Н.В.Кедрова, хирург А.М.*Боголюбов* һ.б. эшчәнлеген яктырта. 1863 елда *Казан табибләр җәмгыяте* (рәисе А.В.Петров) оештырыла. 1880 елдан «Врач» ж-лы нәшер ителә башлый. Табибләр җәмгыяте каршында санитария тикшерүләре, ветеринария күзәтүе, чәчәккә каршы прививкалар ясау һәм халыкны физик тәрбияләү б-н шөгыльләнүче санитария комиссиясе оештырыла. Гигиена программалары төзү, санитария статистикасы мәгълүматлары җыюда шәһәр думасы әгъзалары профессорлар Н.А.*Виноградов*, А.И.*Козлов*, Н.И.*Котовщиков*, А.В.*Петров*, А.И.*Якобий* катнаша. Медицина хезмәткәрләре хезмәтенә яхшы түләнә. 1880 елларда табиб ел саен 1800 сум акча ала, 1912 дә хезмәт хакына эшләгән һәр 3 ел саен 300 әр сум өстәп түләнә башлый. Фельдшер ставкасы — елына 300–500 сум, провизорныкы 1300 сумга кадәр җитә. 1872 дә Казанда табигать фәннәре белгечләренең 4 нче съезды уза, анда җәмәгать гигиенасы мәсьәләләре тикшерелә. 1885 тән әлеге съездлар Пирогов съездлары дип йөртелә башлый. 1920 дә Земство медицинасы гамәлдән чыгарыла. Авылларда земство тарафыннан оештырылган мед. ярдәме мед. фәне үсешенә зур йогынты ясый һәм мед. өлкәсендә профилактика юнәлешенең алга китүенә этәргеч була. Земство медицинасының профилактика юнәлеше, мед. ярдәме күрсәтүдәге участоклар принцибы, сан.-гигиена хезмәте элементлары, төрле конференцияләр, съездлар уздыру Совет чорында да саклана.

*Әд.:* Е р м а к о в В.В. Крестьянство Восточного Закамья. Наб. Челны. 2000.

*Г.Г.Павлухин.*

**ЗЕ́МСТВО ПО́ЧТАСЫ**, 1860 елларның 2 нче яртысында *земстволар* тарафыннан оештырылган җирле почта хезмәте. Баштарак шул ук исем б-н 19 йөз башында оештырылган мәхкәмә-полиция хат-хәбәрләрен йөртүче дәүләт курьерлары хезмәте атала. 1860 елларга кадәр дәүләт почтасы хатлар ташуда монополиягә ия була. Кагыйдә буларак, казна почтасы бүлекчәләре губерна һәм өяз шәһәрләрендә, ш.у. почта трактларында урнашкан эре торак пунктларда эшләп киләләр. Өяз земство идарәләре волость идарәләре б-н элемтәдә тору өчен үз почта хезмәтләрен булдыралар. Сенатның 1870 ел 27 август фәрманы б-н рәсми рәвештә земстволарга казна почталары булмаган урыннарда З.п. оештырырга рөхсәт бирелә. 1870 елга З.п. Россиянең 65 өязендә, ш.и. Казан губернасында да эшли. З.п. вазифаларына: казна һәм земство хат-хәбәрләрен, казна почтасы бүләкчәләреннән шәхсән җибәрелгән әйберләрне күрсәтелгән адресларга илтү һәм, аларны кабул итеп, алга таба дәүләт почтасы аркылы озату; өяз эчендә казна почтасы бүлекчәләре булмаган торак пунктлар арасында почта йөртү; хат-хәбәрләрнең тиешле урынга җиткерелүе һәм сакланышы өчен җаваплылык йөкләнә. 1900 елга Казан губерна земствосы чыгымнарына 1115 чакрым почта юллары төзелә һәм карап тотыла. Казна һәм земство хат-хәбәрләре бушлай җибәрелә, аерым затларның хезмәт күрсәтүе өчен түләү турындагы мәсьәләне земство җыены карый. Әгәр дә ул шәхси хат-хәбәрләрне җибәрү өчен түләү алу турында карар кабул итсә, З.п.на дәүләтнекеннән аермалы үз почта маркаларын чыгарырга рөхсәт бирелә. Казан губернасы Казан һәм Лаеш өязләренең земство почталары маркаларының гамәлдә йөрүе мәгълүм. З.п. системасына өяз земстволары идарәләре каршындагы почта конторалары һәм волость идарәләре каршындагы почта бүлекчәләре керә. Казна почтасының үсеш дәрәҗәсенә бәйле рәвештә З.п. бүлекчәләре ябыла бара. З.п.ның төзек системасы эшчәнлеге нәтиҗәсендә 20 йөз башына Россиянең Европа өлешендәге барлык терр-ясендә диярлек почта хат-хәбәрләре иң ерак торак пунктларга да барып ирешә. 1918 елда З.п. бетерелә. Ш.у.к. *Почта.*

*Әд.:* Б р о д А.Д. К пятидесятилетию Земских учреждений 1864–1914. К., 1914; Земские почтовые марки. М., 1925; Б а з и л е в и ч К.В. Земская почта в России (1865–1917). М., 1926.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЗЕ́МСТВО СТАТИ́СТИКАСЫ**, *земстволар* үткәрә торган статистик тикшеренүләр. Башта З.с. үз ихтыяҗларына киткән чыгымнарны капларга халыктан алыначак салым ставкаларын билгеләү өчен алып барыла, соңрак тулаем мәгълүматлар туплау, исәпкә алу-язу б-н шөгыльләнә башлый. Беренче статистик тикшеренүләр барышында З.с.ның 2 төп төре формалаша: Мәскәүчә (һәр хуҗалык берәмлеге һәм халык тормышының гомуми шартлары турында мәгълүмат алу) һәм Черниговча (туфракларны классификацияләү). 1887 елда барлык земстволар өчен дә тикшеренүләрнең бердәй программасын билгеләгән күрсәтмә чыгарыла. Үзләренең бурычлары, ысуллары һәм оешулары буенча З.с. төп (хуҗалыкларның гомуми хәлен ачыклау) һәм агымдагы (аерым хуҗалык еллары буенча күренешләрнең периодлылыгын өйрәнү) статистикаларга бүленәләр. З.с. үзенең эшчәнлеген, башлыча, экспедиция тикшеренүләре рәвешендә алып бара: статистика учреждениесе вәкилләре тикшерелә торган р-нда элек эшләнгән формулировкалар буенча, нигездә, телдән сорап мәгълүматлар җыялар; өйрәнелә торган объектларны карау һәм язма чыганакларны тикшерү ярдәмче рольне башкара. Крәстиян хуҗалыкларын тикшерүнең төп элементы йорт һәм каралты-кураны исәпкә алу булган. Йорт һәм каралты-кураны исәпкә алуның гадәти программасы түбәндәгеләрне күздә тоткан: халыкны тикшерү (яшь һәм эшкә яраклылыгы, белеме буенча тасвирлау); җир биләү һәм җирдән файдалану формаларын; җирне эшкәртү һәм аны хуҗалыкта файдалану ысулларын; инвентарьны; халыкның һөнәрчелек б-н шөгыльләнүен һ.б.ны исәпкә алу. З.с. үсү белән бергә йорт һәм каралты-кураны өйрәнү программалары шактый җентекләбрәк эшләнә. Тулаем «авыл» һәм «җәмәгать хәлен» тикшеренүләр крәстиян хуҗалыкларын тикшерүнең мәҗбүри состав өлешенә әвере-

лә. Торак пунктларны «тоташ» исәпкә алу б-н бергә «тоташ булмаганы», ш.у. йорт хуҗалыкларын тикшергәндә «тоташ булмаган сорашу» кулланыла, аларны статист үзе сайлый (яисә йорт һәм каралты-кураларның билгеле бер өлешен исәпкә алу алдан ук билгеләнеп куела). Агымдагы З.с. төп игътибарны а.х. тормышының көндәлек вакыйгаларына юнәлдерә: уңыш һәм бәяләр турындагы мәгълүмат — ел саен, һөнәрчелек, читтән эшләп тапкан акчалар, күченү, а.х. техникасы үсеше турындагы мәгълүмат аларны өйрәнүгә ихтыяҗ туган саен тикшерелә. Андый мәгълүмат, нигездә, ирекле хәбәрчеләр аша җыела, аларга ел дәвамында махсус сорап белешү кәгазьләре җибәрелә.

Казан земствосы статистик тикшеренүләр үткәрү зарурлыгы б-н 1880 еллар башында халыктан җыемнар җыю арту нәтиҗәсендә очраша. Земствоның 17 нче җыенында азык-төлек бурычлары бер кешегә 15 сумнан арткан авылларны һәрьяклап тикшерү турында карар кабул ителә. 1882 дә статистика эшләрен оештыру өчен танылган икътисадчы-статист Н.Ф.Анненский җәлеп ителә, ул тикшеренүләрнең планын һәм программасын төзи. Хәлне тулысынча күзаллау өчен бурычлы авылларны гына түгел, аларның янәшәдәгеләрен дә тикшерергә булалар. Нәтиҗәдә Казан губернасының Мамадыш, Тәтеш, Чистай һәм Лаеш өязләрендә 138 авылда йортлар һәм каралты-куралар тикшерелә («1883 елда Казан губерна земствосы җибәргән статистика экспедициясе хезмәтләре», 1884 — «Труды статистической экспедиции, снаряжённый в 1883 году Казанским губернским земством», 1884). Тикшеренү нәтиҗәләре Казан губернасында статистика эшләрен алга таба оештыру өчен сәбәп була. Губернаның чираттагы 20 нче җыенында, даими эшләүче орган буларак, Статистика бюросы оештырыла, аны Н.Ф.Анненский җитәкли. Средстволарны янга калдыру максатында, Казан губернасы земство җыены мәгълүматларны Чернигов губернасы үрнәгендә җыю б-н чикләнү турында карар кабул итә. Әмма Казан һәм Зөя өязләрендә мәгълүмат җыелгач, мондый үрнәктәге тикшеренүләрнең җитешсезлеге 1884 тә үк ачыклана. 1885 тә тикшеренүләр программасы киңәйтелә. Ул түбәндәгеләрне үз эченә ала: һәр авылда йорт хуҗалары санын исәпкә алу, аларны имана җирләре булганнарга, җирсезләргә, үз авылларында яисә читтә яшәүчеләргә аеру; йорт һәм каралты-курага билгеләп, эш терлеген исәпкә алу; йорт хуҗалыклары арасында имана җирләрен һәм имана җирендә хуҗалык итү ысулын бүлү. 1885 тән башлап, губернадагы төп тикшеренүләргә өстәмә рәвештә ирекле хәбәрчеләр ярдәмендә агымдагы а.х. мәгълүматларын теркәү чоры башлана. Н.Ф.Анненский җитәкчелегендә Казан губернасы авыллары һәм бистәләре тикшерелә, Казан, Зөя, Тәтеш һәм Цивиль өязләрендә җир биләмәләре чагыштырмача бәяләнә. 1887 дән Статистика бюросын А.Д.Коршунов җитәкли. Аның җитәкчелегендә 1891 гә Казан губернасының барлык өязләрен исәпкә алу төгәлләнә, 1892 дә элек исәпкә алынган 5 өяз буенча өстәмә тикшеренүләр үткәрелә. Тикшеренүләр йомгаклары буенча «Казан губернасы өязләрендә җир биләмәләрен чагыштырмача бәяләү өчен материаллар» («Материалы для сравнительной оценки земельных угодий в уездах Казанской губернии», вып. 1–12, 1886–93) нәшер ителә, аларда өязләрнең терр-яләре, яшәүче кешеләр һ.б. турында җентекле мәгълүматлар туплана.

*Әд.:* Материалы для сравнительной оценки городов и посадов Казанской губернии. К., 1885.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ЗЕ́МСТВО ТЕЛЕФО́Н ЧЕЛТӘРЕ́**, Казан губернасында 1906 елда эшли башлый. З.т.ч. үткәрү турындагы мәсьәлә 1902 дә Казан губ. земство идарәсе тарафыннан кузгатыла һәм барлык өяз шәһәрләрен бердәм телефон линиясе белән тоташтырырга карар кылына. Исәпләүләрне, смета һәм планнарны Петербургтагы Р.К.Кольбе фирмасы эшли. Линияне төзү 1905 тә башлана. Проектта каралганча, 3 кабель үткәрелә: Чулман елгасы аша Саескан Тавы — Мурзиха линиясе буйлап (4 парлы, озынлыгы 3500 *м*, ш.и. 1300 *м* җир астыннан һәм 1600 *м* су астыннан, файдалануга 1906 ның 2 сентябрендә тапшырыла) һәм 2 се Идел аша (беренчесе — Аракчино һәм Печище янында: 8 парлы, озынлыгы 2990 *м*, ш.и. 1300 *м* җир астыннан һәм 1600 *м* су астыннан; икенчесе — Николай тимер юл күпере буйлап: 10 парлы, озынлыгы 1600 *м*, файдалануга 1908 нең 17 сентябрендә һәм 1913 нең 14 октябрендә тапшырылалар). З.т.ч. түләүле рәвештә гомуми куллану өчен ачыла. Аның белән идарә итү өчен Казан губерна земство идарәсенең техник бүлегендә мөстәкыйль 2 хезмәт: линияләр хезмәте (телефон линияләре сузу һәм аларны төзекләндерү белән шөгыльләнә) һәм файдалану хезмәте (телефон челтәрләре эше өчен җавап бирә, керемнәр һәм чыгымнар исәп-хисабын алып бара) оештырыла. З.т.ч. шәхси абонентларга алар исәбенә телефоннар кертә (еллык абонент түләве — 77 сум), автомат аппаратлар белән җиһазландырылган шәһәрара сөйләшү станцияләре булдыра (түләү — 1 минут сөйләшүгә 3 тиен), телефонограммалар кабул итә (бер сүз өчен 2 тиен һәм җибәргән өчен 10 тиен). 1912 дә Казан губерна З.т.ч. линияләренең гомуми озынлыгы 3294 чакрым булган 45 станцияне берләштерә, алар елына 63056 сум 83 тиен керем кертә. 1917 дә 195 абонентлы 47 станция була.

Чыг.: Список абонентов телефонной сети Казанского Губернского Земства на 1917 год. К., 1917.

*Әд.:* Телефонная сеть Казанской Губернской Земской Управы. К., 1908; Телефонная сеть Казанского Губернского земства (1905–1912 гг.). К., 1914.

*Л.М.Айнетдинова, Г.Я.Мәүлетова.*

**«ЗЕНИ́Т»,** машина төзелеше, оборона пр-тиеләре, оешмалары эшчеләре һәм хезмәткәрләре профсоюзларының ирекле спорт җәмгыяте. Республика «З.» ирекле спорт җәмгыяте 1937 елда оештырыла, 1957 дә бетерелә һәм 1967 дә яңадан эшли башлый. «Зенит» җәмгыятендә спортның чаңгыда узышу, җиңел һәм авыр атлетика, бокс, көрәш (грек-рим, ирекле, дзюдо), тимераякта шуу, җилкән, су (моторлы), ориентлашу, футбол («Рубин» СК), регби («Стрела» СК), гандбол (Воровский исем. СК), алкалы хоккей (Урицкий исем. СК), туплы хоккей («Ракета» СК) кебек төрләре үсеш ала. СССРның 5 халыкара класслы спорт остасы, 208 спорт остасы әзерләнә. Иң яхшы тренерлар һәм спортчылар — Җ.Б.*Гафиятуллин*, В.А.*Елфимов*, И.Ш.Ибниәминов, В.В.*Краснов*, С.Г.Минин, А.В.*Муравьёв*, Г.Г.*Мөхәммәтов*, В.И.Осипов, И.И.Переведенцев, А.Г.Романов, Н.И.*Сентябрёв*, С.Ф.*Тимофеев*, А.К.*Хаматов*. 1987 дә «З.» үзенең эшчәнлеген туктата (к. *Профсоюзлар физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан Республика советы*).

**«ЗЕНИ́Т»**, «Зенит-Казан» волейбол клубы командасы. 2000 елда Казанның Эчке эшләр идарәсе инициативасы б-н «Динамо» командасы буларак оештырыла. Исеме алышына: 2005 тән «Динамо-Таттрансгаз», 2008 дән «Зенит-Казан». Башлап йөрүчеләре: С.В.Куропаткин, А.А.Лебедев. 2000 нән Россия чемпионатының 1 нче лигасында, 2001 дән — югары «Б», 2002 дән югары «А» лигасында, 2003 тән суперлигада. Россия чемпионы (2007, 2009), Россия кубогына ярышларда (2004, 2007, 2009), чемпионнар лигасында (2008) җиңүче; клуб командалары арасында Россия (2004–05, 2007), дөнья (2009) чемпионатларында бронза медаль алучы. Иң яхшы уенчылары: А.В.Абросимов, Н.С.Апаликов, Г.С.Афиногенов, В.А.Бабичев, А.В.Бовдуй, А.В.Богомолов, Л.Болл, А.Н.Егорчев, А.С.Ермаков, П.В.Зайцев, П.А.Колесников, А.Б.Корнеев, А.Б.Косарев, Р.И.Олихвер, К.А.Сиденко, К.Стенли, С.Ю.Тетюхин, Д.А.Фомин, В.А.Хамутцких, А.А.Черемисин, М.В.Шпилёв, И.Ю.Шулепов. Баш тренерлары: А.А.Лебедев (2000), В.В.Сидельников (2001–08), В.Р.Алекно (2008 дән).

**ЗЕНИ́ТОВ** Андрей Михайлович (15.5.1913, Казан — 20.10.1975, шунда ук), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1936). 1936–59, 1963–75 елларда Казан ясалма каучук з-дында эшли: инженер, лаб., цех җитәкчесе, баш инженер (1949–59, 1963–73), техник бүлек җитәкчесе (1973 тән). 1959–63 тә ТАССР ХХСның Химия сәнәгате идарәсендә баш инженер. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге ясалма каучукның яңа төрен (салкынга чыдам бутадиен) эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Зрелость. Страницы истории Казанского завода СК имени С.М.Кирова. К., 1986; Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ – КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЗЕНИ́ТОВА** Любовь Андреевна (13.9.1943, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре уретанлы эластомерларның югары молекуляр кушылмаларына, синтезына һәм кулланууга карый. Чылбырында изоционурат бөҗралар булган полиуретаннар алуның принципиаль яңа техноло-

гиясен, эластик пенополиуретаннар, уретан лаклар, җилемнәр, капламнар, полиуретан композицион материаллар технологиясен эшли. Полиуретан калдыкларын кабат эшкәртү ысулын тәкъдим итә. Ул эшләгән технологияләр «Түбәнкаманефтехим», «Хитон» АҖләрендә һ.б. гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Безотходная технология получения литьевых полиуретанов // Журн. прикладной химии. 1997. Т. 70, вып. 9 (автордаш); Использование метода обращённой газовой хромэтографии для оптимизации рецептур синтеза полиуретанов // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 2000. Т. 42, № 10 (автордаш); Определение физико-механических свойств каучуков и резин на их основе. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет (1976–2001): Краткий биогр. справ. К., 2001.

**ЗЕРНИ́Т** Бруно Иванович (9.8.1914, Лифляндия губ. Скриверово а. — 6.12.1960, Казан), шагыйрь. 1920 еллар ахырыннан Казанда яши. Казан җитен комбинатында эшли, 1939 елдан «Советская Татария» г-тасы редакциясендә (әдәбият бүлеге мөдире, җаваплы сәркәтип). СССР язучыларының 1 нче Бөтенсоюз съезды эшендә катнаша (1934). «Каршыга килүче 140 нчы поезд» («140 — встречный») исемле беренче шигъри җыентыгы 1931 дә дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында «Гаделлек өчен сугышка» («В бой за дело правое», 1941), «Үлемнән көчлерәк» («Сильнее смерти», 1944) исемле шигъри җыентыклары чыга. Сугыштан соңгы иҗаты эпик жанрга тартым. «Иделдә кыяташ бар...» («Есть на Волге утёс...», 1949) һәм М.Җәлилгә багышланган «Плахада яңгыраган җыр» («Песня на плахе», 1957) поэмалары, Бөек Ватан сугышы геройлары турында очерклар авторы.

Ә с ә р.: Избранное. К., 1955.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ЗЕРНО́В** Сергей Алексеевич (29.5.1871, Мәскәү — 22.2.1945, Ленинград), зоолог-гидробиолог, СССР ФА акад. (1931). Россиядә гидробиологиянең экологик юнәлешенә нигез салучыларның берсе. Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук эшли. Революцион эшчәнлеге өчен 1897 елда Вятка губернасы Малмыж өязенә сөрелә. Анда 1899 га кадәр була. Бу вакытта Шушма һәм Вятка елгалары планктонын өйрәнә, Казан ун-тының зоология музее коллекциясен тулыландыра һәм каталогларны тәртипкә сала. 1902–14 елларда Севастополь биология станциясе директоры; 1914 тә Мәскәү а.х. ин-тында (хәзер К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. ин-ты) гидробиология каф. оештыра. 1924 тән СССР ФАнең Зоология музее директоры, шул ук вакытта Мәскәү ун-тында гидробиология каф. мөдире (1930 га кадәр). 1931–42 елларда СССР ФАнең Зоология ин-тында (Ленинград) директор. 1938–44 елларда «Зоология журналы»нда («Зоологический журнал») җаваплы мөхәррир. Хезмәтләре планктонга, гидрологиягә, лимнологиягә карый. Төп игътибарны билгеле бер биоценозларның формалашуына һәм аерым төр су организмнары яшәешенең экологик шартларын билгеләүгә юнәлтә. Югары уку йортлары өчен рус телендә беренче «Гомуми гидробиология» («Общая гидробиология». М.–Л., 1934) дәреслегенең авторы. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Заметки о животном планктоне рек Шошмы и Вятки Малмыжского уезда Вятской губернии // Изв. Об-ва любителей естествознания: Дневник Зоол. отд-ния. 1901. № 2; К вопросу об изучении жизни Чёрного моря. Севастополь, 1913; О пределах жизни при отрицательных температурах в незамёрзшей воде в природных условиях // Докл. АН СССР. 1944. Т. 44, № 2.

*Әд.:* П а в л о в с к и й Е.Н., Б е р г Л.С. Памяти академика Сергея Алексеевича Зернова. М.–Л., 1948; С к а д о в с к и й С.Н. Сергей Алексеевич Зернов. М., 1957; Биологи: Биогр. справ. Киев, 1984.

**ЗЕФИРА́НТЕС** (Zephyranthes), амариллисчалар семьялыгыннан суганчалы үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле. Чыгышы — Төньяк һәм Көньяк Американың субтропик һәм уртача пояслары. ТРда бүлмә гөле буларак үстерелә. Аеруча киң таралганнары: эре чәчәкле З. (Z. grandiflora) һәм алсу З. (Z. rosea). Яфраклары тар, кыяклы, озынлыгы 30 *см* га якын. Чәчәкләре шактый эре, ак, алсу яки сары, бүрәнкәсыман, биек булмаган чәчәк сабында 1–2 булып урнаша. Чәчәкле чәчәк сабы тиз үсә, һәм 1–2 көннән чәчәк ата. З. суганчалардан үрчи. Яктылык яратучы үсемлек.

**ЗЕФИ́РОВ** Андрей Львович (2.10.1950, Казан), физиолог, мед. фән. д-ры (1988), Россия МФА мөхбир әгъзасы (2004), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994, 2001). Г.И.*Полетаев* шәкерте. 1973 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли, 1988 дән физиол. каф. мөдире, дәвалау ф-ты деканы (1987), проф. (1989). Тикшеренүләре нерв системасы һәм хәрәкәтләнү аппараты физиологиясенә карый. З. нерв очлыклары формалашуы һәм җитлегүе теориясен эшли. Мускулның хәрәкәт нерв очлыкларында ион токларын, ион каналлары бүленешен, медиатор секрециясе көйләнү механизмын өйрәнә һәм тасвирлый; синапсны фәзада чикләнгән актив зоналарның гетероген, пластик, интеграль системасы буларак күзаллауны формалаштыра. ТРның Дәүләт бүләге иясе (1995). Россия Физиология җәмгыятенең И.П.Павлов исем. медале (2001), ТР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пространственно-временные характеристики квантовой секреции медиатора в синапсе. К., 1986; ГАМК — основной медиатор возбуждения на ранних этапах развития гиппокампа // Успехи физиолог. наук. 1998. № 2 (автордаш); Везикулярная гипотеза освобождения медиатора в синапсе // Соросовский образоват. журн. 2000. № 6–9.

*Әд.:* Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**ЗЕФИ́РОВ** Лев Николаевич (26.10.1926, Казан — 1.10.1996, шунда ук), физиолог, биол. фән. д-ры (1968), проф. (1968). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), шунда ук эшли. 1965–91 елларда Казан ун-тының кеше һәм хайваннар физиологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре нерв һәм нерв-мускул системаларының төрле өлешләрендә медиаторларның көйләгеч роленә карый. Ацетилхолинның нерв-мускул һәм ганглионар синапсларда ярсыну арадашчысы булу өстенә, эзле ион токларына һәм күзәнәк метаболизмына да көйләгеч тәэсире булуын күрсәтә. В.А.Алатырев б-н бергәләп хәрәкәтне идарә итү проблемаларын тикшерә. Эчке органнарның ялкынсынуын һәм терәк-хәрәкәт аппараты бозылуның клиник диагностикасын иртә билгеләү мөмкинчелеген бирүче, мускулларның рефлексив саклагыч электрик активлыгы концепциясен эшли. 1930 елларда туктатылып торган хезмәт психофизиологиясе буенча тикшеренүләрне Казан ун-тында яңадан башлап җибәрә. «Казан физиология мәктәбе тарихыннан» («Из истории Казанской физиологической школы», 1978) китабы авторларының берсе һәм мөхәррире.

Х е з м.: Защитное напряжение мышц брюшной стенки. К., 1971 (автордаш); Медиаторы: обмен, физиологическая роль и фармакология. К., 1975 (автордаш); Электромиография брюшной стенки в диагностике острых заболеваний органов живота. К., 1978 (автордаш); Постишемические изменения функций спинного мозга. К., 1982.

*В.В.Костюшко.*

**ЗЕФИ́РОВ** Тимур Львович (3.5.1955, Казан), гистолог, физиолог, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2000). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006), РФнең мактаулы югары проф. белем бирү хезмәткәре (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1978). Казан пед. ун-тының анатомия һәм физиология кафедрасында эшли. Хезмәтләре нейроннарның йөрәккә һәм тою рецептор аппаратына трофик йогынтысын өйрәнүгә карый. Сизгер нейроннарның тою рецепторларына индукцияле тәэсирен күрсәтә. Постнаталь онтогенезда имезүчеләрдә йөрәк эшчәнлеген көйләүче механизмнар формалашуын тикшерә. Төп рольне постганглионар парасимпатик нейрон үтәгәндә йөрәк кыскару ешлыгын көйләүнең оригиналь схемасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Нервная регуляция сердечного ритма крыс в постнатальном онтогенезе. К., 1999; Формирование «акцентированного антогонизма» симпато-парасимпатических регуляторных взаимодействий в сердце крыс // Нейронауки: теоретические и клинические аспекты. 2007. № 1; $M_3$ холинорецепторы участвуют в постнатальном развитии холинергической регуляции работы сердца крыс // Бюлл. эксперим. биологии и медицины. 2007. № 8.

**ЗИБЫ́К УТЫ́** (Mercurialis), сөтлегәнчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 8 төре билгеле, Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — күпьеллык З.у. (M. perennis) сирәк кенә барлык р-ннарда да очрый. Катнаш һәм ылыслы киң яфраклы урманнарда үсә. 20–30 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы озын, шуышма. Сабагы туры, түгәрәк, аскы өлеше яфраксыз. Яфраклары сабаклы, ланцетсыман киң, сабак очында каршыдаш урнашканнар. Чәчәкләре бер җенесле, вак, яшькелт, башаксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — каты төкчәле яньчелгән шарсыман тартмачык. Апрель-майда чәчәк ата. Җимешләре май-июньдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив рәвештә (тамырчаның җәелүе) үрчи. Агулы үсемлек. Халык медицинасында яфраклары эч йомшарту һәм бәвел кудыру чарасы буларак файдаланыла.

**ЗИ́ГМУНД** Фёдор Францевич (31.8.1905, С.-Петербург — 11.5.1977, Казан), механика һәм җылылык алмашу гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1968), проф. (1970). 1927–29 елларда Казан Көнчыгыш пед. ин-тында укый. 1932 дә Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: лаб. мөдире (1937–40), сугыш кирәк-яраклары ф-ты деканы (1940–43), процесслар һәм аппаратлар, гидравлика һәм гомуми химия-технологиясе (1943–47), процесслар һәм аппаратлар (1954–56) кафедралары мөдире. 1972–77 дә Казан төзүче-инж. ин-тында җылылык техникасы каф. мөдире. Хезмәтләре җылылык алмашу аппаратларында темп-ра бүленешен исәпләү закончалыкларын һәм ысулларын өйрәнүгә карый. Күп юллы җылы алмаштыргычлардагы темп-раның уртача аермасын исәпләүнең графоаналитик ысулын эшли һәм җылы алмаштыргычларда темп-ра бүленешен яхшыртуның конструктив мөмкинлекләре турында тәкъдимнәр кертә.

**ЗИГОКА́КТУС** (Zygocactus), кактусчалар семьялыгыннан эпифит үсемлекләр ыругы. 800 гә якын (башка чыганаклар буенча 3 меңгә якын) төре билгеле. Чыгышы — Бразилия тропиклары. ТРда гибрид формалары күп булган кисек З. (Z. truncatus) үстерелә. Сабаклары буынлы. Кышын чәчәк ата («декабрист», «Варвара чәчәге» исемнәре шуннан). Чәчәкләре төзек булмаган формада, алсу, гибрид формаларда — күптөрле төсмерләрдә (ак, кызгылт сары, шәмәхә). Ботактан, ялгаудан үрчи. Туры кояш нурын яратмый.

**ЗИМАКО́В** Юрий Андреевич (20.1.1938, Мәскәү), фармаколог, токсиколог, биол. фән. д-ры (1993). 1969 елда 2 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлый. 1971 дән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1997 дән фармакологик һәм көчле агулы матдәләрне, пестицидларны контрольгә алу һәм индикацияләү лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре җирдә сирәк очрый торган элементларның кушылмалары фармакологиясенә, фосфорорганик кушылмалар, пестицидлар һәм техноген экотоксикантлар б-н агулануларга диагноз куюга, аларны булдырмауга һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Пропионаты лантана и лантаноидов // Докл. АН СССР. 1970. Т. 190, № 6; Фармакологические эффекты комбинаций некоторых психотропных препаратов, применяемых в комплексной фармакотерапии // Фармакология и токсикология. 1987. № 1 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.), К., 2006.

**ЗИМАКО́ВА** Ирина Евгеньевна (7.6.1935, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1984). Казан мед. ун-тын тәмамлый (1959). 1959–61 елларда Республика психоневрология хастаханәсендә һәм Казан психоневрология диспансерында табиб. 1964–83 тә Казан мед. ин-тында (бүленеп, 1971–72 дә 2 нче Мәскәү мед. ин-тында). 1983 тән Казан мед. академиясендә, 1986 дан клиник фармакология каф. мөдире. Хезмәтләре бициклик бисмочевина, диазиридин, нитроимидазол, пиримидин һ.б. кушылмаларның биологик активлыгын өйрәнүгә карый. З. РФА-ның Органик химия ин-тында (Мәскәү) синтезлаштырылган яңа класс матдәләр — бициклик бисмочевина төрләренең фармакологик эффектын ача. Шуларның берсе — *мебикар* — кардиалгияләрне, эчкечелек, наркоманияне, тәмәке тартудан дәвалау өчен тәүлек буена кулланылучы транквилизатор сыйфатында һәм психотроп препаратларның тискәре тәэсирен төзәтүче буларак (2001 дән «Татхимфармпрепарат» пр-тиесе җитештерә) клиника гамәленә кертелә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм 5 патенты бар.

Х е з м.: Биологическая активность некоторых нитрокетонов и нитродиолов. К., 1967; Экспериментальное обоснование внедрения в клиническую медицину нового биологически активного класса веществ производных бициклических бисмочевин. К., 1978.

**ЗИМИ́Н** Александр Александрович (22.2.1920, Мәскәү — 25.2.1980, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (1959), проф. (1970). Урта Азия ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1942). 1947–73 елларда Мәскәү тарих-архив ин-тында. Бер үк вакытта 1951 дән СССР ФА Тарих ин-тында. Хезмәтләре 9–18 йөзләрдәге Россия тарихына, историографиягә, чыганакларны өйрәнүгә карый. Феодализм чорын өйрәнүдә бердәм Россия дәүләте барлыкка килү һәм ныгу процессын аңлатучы яңа юнәлешкә нигез сала. «И.С.Пересветов һәм аның замандашлары» («И.С.Пересветов и его современники», М., 1958), «XV йөз ахыры — XVI йөз рус елъязмалары һәм хронографлары» («Русские летописи и хронографы конца XV–XVI вв.», М., 1960), «Иван Грозный реформалары» («Реформы Ивана Грозного», М., 1960), «Россия яңа чорга кергәндә» («Россия на пороге нового времени», М., 1972), «Россия XV–XVI йөзләр чигендә» («Россия на рубеже XV–XVI столетий», М., 1982), «Иван Грозный чорындагы Россия» («Россия времени Ивана Грозного», М., 1982; автордаш), «Баһадир юллар чатында (1425–1462)» («Витязь на распутье (1425–1462)», М., 1991) исемле монографияләрендә 15–16 йөзләрдә Россиянең татар ханлыклары б-н үзара мөнәсәбәтләрен тикшерә, Иван IV нең Казанга яуларын һәм Казан ханлыгы җимерелгәннән соң Урта Иделне колонияләштерүне өйрәнә.

Х е з м.: Методика изучения древнерусских актов. М., 1959; Крупная феодальная вотчина и социально-экономическая борьба в России (конец XV–XVI вв.). М., 1977; В канун грозных потрясений: Предпосылки первой крестьянской войны в России. М., 1986.

*Әд.:* К а ш т а н о в С.М. Александр Александрович Зимин — исследователь и педагог // История СССР. 1980. № 6; Александр Александрович Зимин: Биобиблиогр. указ. М., 2000.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗИМИ́Н** Геннадий Васильевич (1.1.1945, Әлмәт р-ны Ямаш а. — 15.6.1999, шунда ук), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999, үлгәннән соң). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1968) һәм Әзәрбайҗан нефть һәм химия ин-тын (1976) тәмамлый. «Татнефть» АҖдә эшли: 1961–80, 1985–87 елларда «Әлмәтнефть» НГДУында (нефть һәм газ чыгару операторы, техник бүлек инженеры, цех, производствога хезмәт күрсәтү базасы җитәкчесе); 1989–99 да «Зәйнефть» НГДУ җитәкчесе. 1980–84 тә «Томскнефть» ҖБнең «Стрежевойнефть» НГДУында: идарә башлыгы, үзәк технол. хезмәте җитәкчесе. 1984–85 тә СССР Госгортехнадзорының Көнбатыш Себер округы идарәсендә район тау-техника инспекциясе җитәкчесе (Томск өлкәсе Стрежевой ш.). Дәүләт бүләге «Татарстанның авыр чыгарыла торган нефть запаслары чыганаклары ятмаларында нефть чыгаруны арттыру технологиясе комплексын эшләү һәм сәнәгатьтә гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. 1995–99 да ТР Дәүләт Советы депутаты. Халыклар дуслыгы ордены, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗИ́МНИЦА**, күл, *Кавал күлләре* системасының төньяк өлешендә. Лаеш р-ны Столбище авылыннан 1 *км* көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 11 *га*. Су күләме 92 мең *м³*. Озынлыгы 720 *м*, уртача киңлеге 140 *м*, уртача тирәнлеге 0,8 *м*, иң зур тирәнлеге 2 *м* га якын. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба дугасыман сузынкы. Төньяк-көнчыгыш өлешендә Олы Кабан авылы ягыннан күлгә зур гына су җыелу мәйданы булган шактый озын ерым-сызалар системасы чыга. Күл яңгыр һәм кар суларының комлы-балчыклы китерелмәләре аркасында әкрен генә ләмләнә һәм саега бара. Ял итү урыны.



Зимница күле.

**ЗИМНИ́ЦКИЙ** Семён Семёнович (24.12.1873, Могилёв губ., Мстиславск өязе, Хиславичи торак пункты — 10.12.1927, Казан), терапевт, мед. д-ры (1901), проф. (1906). 1898 елда С.-Петербург Хәрби-мед. академиясен тәмамлый, шунда ук эшли. 1902–04 елларда Европаның фәнни үзәкләрендә стажировка үтә. 1906 дан Казан ун-тының шәхси патология һәм терапия каф. мөдире, бер үк вакытта 1910–27 дә Казан хәрби госпиталендә консультант. Казан ГИДУВының йогышлы авырулар кафедрасына нигез салучы, 1924–27 дә мөдире. Хезмәтләре кан әйләнеше органнарының, үпкә, ашказаны, үт юллары, бөерләр иммунологиясе, бактериологиясе, функциональ патологиясе мәсьәләләренә карый. Үпкәләрдә утлы коралдан барлыкка килгән яралар үзенчәлекләрен өйрәнә, пневмонияне дәвалау ысулын эшли. В.М.Аристовский б-н бергәләп туберкулёзга бактериобиологик диагноз куюны, «Пиркенең градусларга бүленгән тикшерү пробасы»н тәкъдим итә. З. артериаль гипертензияне өйрәнүдә новатор булып тора. Бавыр, үт

бүлеп чыгару системасы һәм ашказаны-эчәк юлларының гастродуоденаль бүлеге патологиясен өйрәнә. З. бөерләрнең функциональ торышын билгеләү ысулын тәкъдим итә (к. *Зимницкий пробасы*). З. илнең курортологиясе үсешенә өлеш кертә, гастроэнтерологик һәм нефрологик патологияле авыруларны балчык-ләм б-н дәвалау (бальнеотерапия) өчен тәкъдимнәр кертә.

Х е з м.: Отделительная работа желудочных желёз при задержке жёлчи в организме. СПб., 1901; Маньчжурский тиф, его клиническая картина и возбудитель. М., 1910 (автордаш); Заболевания лёгочной паренхимы и плевры. К., 1922.

*Әд.:* Семён Семёнович Зимницкий (к 100-летию со дня рождения) // Казан. мед. журн. 1973. № 12.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ЗИМНИ́ЦКИЙ ПРО́БАСЫ**, бөерләрнең функциональ мөмкинлекләрен диагностикалау ысулы. С.С.*Зимницкий* тарафыннан тәкъдим ителеп (1922), «Брайт авыруын дәвалау» китабында (1928) тасвирлап бирелә. Ысулның асылы: уртача физик авырлыкны һәм гадәти ашау режимын саклаган хәлдә, сидекне тәүлек дәвамында һәр 3 сәгать саен (8 өлеш) аерым банкаларга җыялар, һәр өлеш күләмен (*мл* ларда), тыгызлыгын (чагыштырма авырлыгын), составындагы хлоридларның (хлорокинез), бәвелчәнең (азотокинез) күпме булуын билгелиләр, көндез һәм төнлә бүленеп чыккан сидекнең микъдарын (диурез) исәпләп чыгаралар. Сәламәт кешенең гомуми диурезы эчелгән сыеклыкның 65–75% ын тәшкил итә; көндез тәүлеклек сидек күләменең 2/3 яки 3/4 өлеше бүленеп чыга. Нормада төрле өлешләрнең чагыштырма авырлыклары үзгәреп тора, берсенең күрсәткече 1,02 дән зуррак булырга тиеш.

Функциональ тикшерү ысулларына түбәндәгеләр дә керә: су аерып алу пробасы (эретү пробасы), бу очракта авыруга ач карынга 1,5 *л* су эчертеп, 4 *сәгать* буена һәр 30 *минут* саен бүленеп чыккан сидек микъдарын үлчәп торалар; коры-сары ашатып, проба алу: авыру аксымга бай коры ризык кына ашап тора, сидекне иртәнге 8 дән кичке 8 гә кадәр җыялар. Зимницкий күп су эчертеп, коры-сары ашатып пробалар алуны тәнкыйтьләп чыга, үзе тәкъдим иткән ысул ярдәмендә бөерләрнең сидек бүлеп чыгару сәләтен билгеләү, хлоридларны һәм азотны эретү һәм туплау, бөерләр эшчәнлегенең характерын, аларның гадәти һәм артык эшләвенә ни дәрәҗәдә яраклаша алуын белү мөмкинлегенә бирә торган өстенлекле якларын исбатлый.

Бөер функцияләрен өйрәнү нәтиҗәләрен автор үзенең «Нефропатия өлкәсендәге этюдлар» («Этюды в области нефропатии») сериясенә тупланган хезмәтләрендә тасвирлый. С.П.Боткин мәктәбе традицияләрен дәвам иттерүче буларак, Зимницкий нефритларны аерым авыруның гына түгел, ә бөтен организмның авыруы күрсәткече дип карау тәгълиматын үстерә.

*Әд.:* З и м н и ц к и й С.С. В чем заключается наша методика функциональной диагностики почек и что она разрешает // Казан. мед. журн. 1922. № 1; Б о г о я в л е н с к и й В.Ф. Профессор С.С.Зимницкий. К., 1970.

*В.Ф.Богоявленский.*

**ЗИ́МНЯЯ ГО́РКА** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 26 *км* төньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 16 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Лаеш р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 164, 1949 да — 176, 1958 дә — 180, 1970 тә — 77, 1979 да — 33, 1989 да — 24, 2002 дә — 20 кеше.

**ЗИМО́ВЬЕ МӘГАРӘСЕ́**, к. *Кама Тамагы спелеология системасы.*

**ЗИМЧӘЧӘ́К** (Anthemis), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел, сирәк кенә ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә өч төре үсә. Буяу З.ге (A. tinctoria) барлык р-ннарда, сасы З. яки эт шепкәне (A. cotula), рус З.ге (A. ruthenica) — Көнбатыш Кама алдында очрый. Кыр, болын, ташландык урыннарда үсә. Тамыры — күп, үзәк тамырлы, юан. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, каурыйсыман теленмә, сирәк кенә кыяклы. Чәчәк төркеме — чирәп тышлы һәм элпәле чәчәк түшәкле кәрзин. Кырыйдагы телчәчәкләре ак яки сары, җимешлегә бар, уртадагылары — көпшәчәчәкләр, сары төстә, ике җенесле. Җимшәне — орлыкча. Буяу З.ге һәм сасы З. тәмсез исле. Июнь-сентябрьдә чәчәк ата. Буяу З.генең кәрзиннәрендә флавоноидлар, гликозид, эфир майлары бар; халык медицинасында тир чыгару, үт кудыру һәм кан туктату чарасы буларак файдаланыла. Сасы З. — сабан чәчүлекләрендә чүп үлән. Буяу З.ге декоратив үсемлек буларак үстерелә.

**ЗИ́НИН** Николай Николаевич (13.8.1812, Елизаветполь губ., хәзерге Әзәрбайҗан Респ-касы Шуша ш. — 6.2.1880, Петербург), химик-органик. Россия химия фәнни мәктәбенә нигез салучы (А.А.Воскресенский б-н бергәләп), Петербург ФА академигы (1885). 1833 елда Казан ун-тын тәмамлый, физика һәм механика фәннәрен укыта, проф. (1841 елдан). 1837 елда чит илләргә командировкага җибәрелә. Парижда эшли. Англия, Голландия, Бельгия з-длары лаб-яләрендә була. Берлинда матем. өйрәнә, химия һәм биологиядән лекцияләр тыңлый. Гессен ин-тында немец химигы Ю.Либих лаб-ясендә З. бензоил кушылмалары буенча беренче мәртәбә тәҗрибәләр үткәрә. 1841 дә Петербург ун-тында докторлык диссертациясе яклый, диссертациясендә бензальдегидны куертып — бензоин, бензоинны нитрат к-тасы б-н оксидлаштырып бензил алуын тәкъбирли. 1848–74 тә Петербург мед.-хирургия академиясендә, химик эшләр буенча директор (1864 тән). Ароматик нитрокушылмаларның аминнарга кайтарылуын ача (к. *Зинин реакциясе*), *анилинны*, *а*-нафтиламин, *м*-фенилендиамин, дезоксибензоин һәм бензидинны синтезлый. З. синтезлары ясалма буяу матдәләре, шартлагыч матдәләр, фарм. препаратлар җитештерүнең сәнәгый нигезе булып хезмәт итә. Кислоталар б-н тәэсир итеп, гидразобензоллар төркемләнүен (бензиден-



Н.Н.Зинин.

лы төркемләү) ача. Аминнарның төрле к-талар б-н тозлар хасил итәргә сәләтле нигезләр булуын күрсәтә, уреидларны ача һәм тәгъбирли, аллил горчица маен (аллилизотиоцианат) синтезлый һәм аның аминнар б-н тәэсирләшүеннән тиңдәш тиомочевиналар таба. Органик к-таларның аллил эфирлары синтезын һәм әверелүләрен тикшерә, аллилацетатны таркатып беренче мәртәбә аллил спирты ала. Биш хлорлы фосфорның бензилга тәэсире б-н дихлорбензил һәм тетрахлорбензилны синтезлый, тетрахлорбензилдан 2 атомын аерып чыгару юлы б-н дихлорстильбен таба. Лепиденның (тетрафенилфуран) бензальдегид б-н концентрацияләнгән (куертылган) тоз к-тасы реакциясенең төп продукты булуын күрсәтә. 1853 тән нитроглицеринның шартлаткыч матдә булуын өйрәнү буенча зур эш алып бара һәм 1854 тә генерал-лейтенант В.Ф.Петрушевский б-н бергәләп аны рус армиясе техникасында файдаланырга тәкъдим итә. Рус химия җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм беренче президенты (1868–1878). Германия һәм Лондон химия җәмгыятьләренең шәрәфле әгъзасы. 1880 елда Рус химия җәмгыятенең Химия бүлеге Н.Н.Зинин һәм А.А.Воскресенский исем. бүләк булдыра. Казандагы урамнарның берсе аның исеме б-н атала, Казан ун-тының А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты бинасына мемориаль такта куела.

Х е з м.: Описание некоторых новых органических оснований, полученных при действии на соединения углеводородов с азотноватой кислотой // Успехи химии. 1943. Т. 12, вып. 2; Труды по органической химии. М., 1982.

*Әд.:* А р б у з о в А.Е. Казанская школа химиков. К., 1971; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**ЗИ́НИН РЕА́КЦИЯСЕ**, аммоний сульфиды, күкертле водород яки селтеле металлар сульфидлары б-н тәэсир итеп ароматик нитрокушылмалардан аминнарны кайтару:

$$ArNO_2 + 3H_2S \rightarrow ArNH_2 + 3S + 2H_2O$$

1842 елда Казанда Н.Н.Зинин тарафыннан *а*-нитронафталин һәм нитробензолдан тиңдәшле рәвештә *а*-аминонафталин һәм *анилин* кайтарылуы тәҗрибәсендә ачыла. Кайтаручылары — күкертле водород һәм аммоний сульфиды. З.р.нең органик синтезны үстерүдәге әһәмияте шактый зур, сәнәгый синтетик буяу, шартлаткычлар, дару һ.б. матдәләр җитештерү өчен нигез булып хезмәт итә. Антрахинон рәте аминнарын алу, өлешчә ди- һәм полинитрокушылмалар кайтару өчен кулланыла.

*Әд.:* В а ц у р о К.В., М и щ е н к о Г.А. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**ЗИННӘ́ТОВА** Рәмзия Шәйди кызы (23.06.1954, Казан), график, нәкышьче. Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1973), И.Е.Репин

исем. Ленинград нәкышь, сын һәм архит-ра ин-тының графика ф-тын тәмамлый. Казан сынлы сәнгать уч-щесендә (1980–81), В.А.Серов исем. Ленинград сынлы сәнгать уч-щесендә (1981–85) укыта; 1981 дән С.-Петербургта яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1985). З. — зур талантка ия график, аның хезмәтләрендә татар халык сәнгате традицияләре чагыла, ул төсләрне нечкә тоемлый һәм полихромияне киң куллана. З. — төсле линогравюра, литография һәм шелкография, катнаш техника, акварель, карандаш ысулы белән



Р.Ш. З и н н ә т о в а. «Самавыр янында». Төсле линогравюра. 1985. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

станлы графика жанрында башкарылган әсәрләр авторы. Аның картиналары образларның эчтәлекле ачылышында төс һәм композиция үзенчәлекләре б-н аерылып тора. З. татар тормышына, аның характерлы якларына, көнкүренеш мизгелләренә, авыл табигате күренешләренә, татар йортының эчке бизәлешләренә, аның сәнгати җиһазлануына, татар киемнәренә мөрәҗәгать итә, шуның б-н әсәрдәге образларга декоратив, тәэсирле чагылыш өсти, композицияләрне төзегәндә кыска һәм ачык сәнгати тел, контраст формалар, нәкышь ясау принципларын куллана («Минем Татарстаным», «Казан» серияләре; «Сарык йоны кырку», «Кибән янында», икесе дә — 1980; «Сөйләшү», «Капка янында», икесе дә — 1983; «Самавыр янында», «Өйгә», икесе дә — 1985; «Татар кызы Дрездендә», 1987; «Өзлексез хәрәкәт», 1993; «Икар», 1994 һ.б.). З.ның станлы нәкышенә аның график әсәрләрендә чагылыш тапкан үзенчәлекләр хас («Алтын сулар эчерәм», 1991; «Таң йолдызы», «Уф, Алла!», «Салават күпере» — барысы да 1997 һ.б.). Урыны белән зәңгәр, ак, сары, яшел, кызыл төсләр гаммасын контраст һәм төсле таплар рәвешендә куллануы, форманы караңгы контур б-н йөртеп чыгу, композициянең ритмлы хәрәкәте татар гамәли сәнгать әсәрләре б-н (күн каю, чигү, йортны төрле төсләргә буяу) охшаш. 1990 еллар ахырыннан башлап, З. фарфор савытлар ясау өчен рәсем эскизлары эшли, 20 предметтан торган «Казан» чәй сервизы һ.б. әйберләрнең эскизлары авторы. Аларны материалда С.-Петербург рәссамы Н.Каюмова иҗат итә. З. — шәһәр, респ-ка, бөтенроссия һәм чит ил күргәзмәләрендә 1980 нән бирле катнаша; аның графика әсәрләре Дания (Копенгаген, 1980), Германия (Дрезден, 1987), Швейцария (Женева, 1994), Италия (Неаполь, 1994; Милан, 2000), Франциядә (Ницца, 1999) уздырылган халыкара графика күргәзмәләренә куела. Мәскәүдәге бөтенсоюз күргәзмәләрендә — «Туган ил буйлап» (1982), «Илнең яшьлеге», «Тынычлыкны саклыйк» (икесе дә — 1984); станлы графика күргәзмәләрендә (Мәскәү, 1987); «Петербург рәссамнары Ратхаузда» күргәзмәсендә (Майнц ш., Германия, 1993), «Татарт» төбәкара бөтентатар күргәзмәсендә (С.-Петербург–Казан, 1991), Мәскәүдә Татарстан рәссамнары әсәрләре күргәзмәсендә (1980) һ.б. катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1983, 1997 (Казан), 1989 (Ленинград). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Дрездендагы хәзерге заман графикасы музеенда (Германия), шәхси тупланмаларда (Германия, Япония, АКШ, Италия, Франция һ.б.).

*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Рәссам Рәмзия Зиннәтова // Казан утлары. 1993. № 3; Х ә к и м о в а Ф. Уф, Алла арбасы // Сөембикә. 1997. № 11.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*



Р.Ш. З и н н ә т о в а. «Алтын сулар эчерәм». 1991. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

**ЗИННӘТУ́ЛЛИН** Зиннур Зиннәтулла улы (13.1.1938, Кукмара р-ны Манзарас а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1985), проф. (1987), Удмурт Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1961–69 елларда СССР Эчке эшләр министрлыгының Алабуга милиция махсус урта мәктәбендә укыта. 1970–85 тә Удмурт ун-тының җинаяти-процессуаль хокук каф. мөдире. Җинаяти-процессуаль хокук һәм мәхкәмә корылышы буенча дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Возмещение материального ущерба в уголовном процессе. К., 1974; Уголовно-процессуальное принуждение и его эффективность. К., 1981; Подследственность уголовных дел. К., 1985; Общие проблемы обвинения и защиты по уголовным делам. Ижевск, 1997.

*Е.Б.Долгов.*

**ЗИННӘТУ́ЛЛИН** Назыйф Хәтмулла улы (17.1.1936. Актаныш р-ны Актаныш а.), гидромеханик, техник фән. д-ры (1986), проф. (1988), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1958 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, Пермь шәһәрендәге оборона пр-тиеләрендә эшли. 1964 тән Казан технол. ун-тында, гидравлика каф. мөдире (1989–2002), 2002 дән химик технология процесслары һәм аппаратлары каф. профессоры. Хезмәтләре химик технологиянең теоретик нигезләренә һәм классик булмаган гидромеханикага карый. Юка, сыек, үзле һәм реологик катлаулы плёнкаларда масса күчерү күренешен тикшерә; катлаулы реологик тирәлекне эшкәртә торган үзәктән кугыч аппаратларның төп гидродинамик параметрларын исәпләү ысулын эшли; күбек барлыкка килүе һәм юкка чыгуының гидродинамик шартларын билгели, нефть скважиналарын бораулаганда осмотик процессларның тәэсир итүен һәм куышлык хасил булу процессын өйрәнә; горизонталь һәм авыш скважиналарда утырган шламнардан арыну теориясен төзи. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Устойчивость плёночного течения вязкой жидкости в поле центробежных сил // Прикладная механика. 1976. Т. 12, № 7; Нестационарное каплеобразование // Теорет. основы хим. технологии. 1997. Т. 31, № 2; Расчёт насосного эффекта частично погружённого в вязкую жидкость вращающегося усечённого конуса // шунда ук. 1998. Т. 32, № 6; Гидродинамика и теплообмен плёночного течения вязкой жидкости и поверхности ротора. К., 2004 (автордаш).

**ЗИННӘТУ́ЛЛИН** Фернан Гыйбай улы (28.11.1936, Уфа), график, нәкышьче, РФнең атказ. рәссамы (2003). Владивосток сәнгать уч-щесен (1959), Эстония ССР сәнгать ин-тын тәмамлый (1965). СССРның халык рәссамнары П.Лухтейннан һәм Э.Окастан өйрәнә. 1965–95 елларда РСФСР Сәнгать фондының Приморье бүлегендә эшли, 1974–88 дә баш рәссам (бүленеп, шунда ук), Владивостоктагы сәнгать уч-щесендә (1969–79), Икътисад һәм сервис ун-тында (1999–2007), 2003–06 да рәсем һәм нәкышь каф. мөдире (шунда ук). РСФСРның Рәссамнар берлеге әгъзасы (1966).

Приморье краеның әйдәп баручы рәссам-графикларының берсе, станлы һәм китап графикасында гравюра (линогравюра, офорт), тушь һәм акварель алымнары кулланып эшли. Нәкышь картиналар авторы. Төп әсәрләре: графика — «Эстония балыкчылары» (1965), «Путятин атавы» (1966), «Ба-



Ф.Г. З и н н ә т у л л и н. Ю. һәм Л. Семнарның «Геойорт» әкиятләренә иллюстрация. 1974.

лык комбинаты» (1972) гравюралары серияләре, аерым әсәрләре: «Иске суднолар» (1971), «Май киче» (хатыны портреты) (2009), «Тынлык» (2009); китап бизәү һәм иллюстрация — «Ерак Көнчыгыш халыклары әкиятләре» сериясеннән С.Валабинның «Прииск эшчеләре» (1966), И.Кравченконың «Ерактагы көтүләр» (1973), Ю. һәм Л.Семнарның «Геойорт» (1974), Н.Ершовның «Канатлы ат» (2009, барысы да — Ерак Көнчыгыш кит. нәшрияты); станлы нәкышь — «Көтү» (1969), «Очрашу» (1973), «Балык комбинатында



Ф.Г.З и н н ә т у л л и н. «Ятьмәләрне бушату», «Путятин атавы» сериясеннән. Линогравюра. 1966.

кич» (1972), «Казан» (1990), «Ерактагы өлкәләр» (1998–99).

Күргәзмәләрдә 1965 тән катнаша: төбәк — «Совет Ерак Көнчыгышы» (Владивосток, 1968, 1974; Улан-Удэ, 1969); бөтенроссия: «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1967, 1975; Ленинград, 1970), «Совет властеның 50 еллыгы» (Мәскәү, 1967), «Россиянең яшь рәссамнары» (Мәскәү, 1968); бөтенсоюз: СССР сәнгать вузлары студентларының диплом эшләре күргәзмәсе (Мәскәү, 1965), эстамп күргәзмәләре (Мәскәү, 1967, 1971); халыкара: «30 Жиңүле ел» (Мәскәү, 1975), чит илләрдәге күчмә: Аргентина (1972), ГДР (1972–74), Польша (1973), Франция (1994), АКШ (1995–98), Украина (1999).

Әсәрләре Владивостоктагы Приморье картиналар галереясында, Хабаровск, Чита шәһәрләрендәге сәнгать музейларында, Джерси-сити шәһәрләрендәге (АКШ) хәзерге заман сәнгате музеенда саклана. Бөтенсоюз эстамп күргәзмәсе лауреаты (Мәскәү, 1971).

*Әд.:* Художники народов СССР: Биобиблиогр. словарь. М., 1983. Т. 4.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЗИННӘТУ́ЛЛИНА** Клара Зыя кызы (2.8.1935, Актаныш р-ны Иске Семиостров а. — 24.7.2007, Казан), тел белгече, филол. фән. канд. (1968). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), урта мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыта (Пермь ш.). 1962 елдан Казанда. 1965 тән Казан пед. ун-тында (1996 дан татар филологиясе ф-ты деканы, 1997 дән татар теле белеме каф. профессоры). Хезмәтләре татар теле белеменә, татар һәм рус телләренең чагыштырма типологиясенә карый. 3 томлы «Татар грамматикасы» («Татарская грамматика», 1992–93; ТРның Дәүләт бүләге, 1994) авторларының берсе. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре, уку ярдәмлекләре һәм программалары, татар телен укыту методикасы буенча ярдәмлекләр авторы.

Х е з м.: Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1972; Залоги глагола в современном татарском литературном языке. К., 1969; Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. К., 1977; Диалектные фразеологические сочетания татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. К., 1989. Вып. 7.

*Әд.:* Ш ә р и ф у л л и н а Э. Күңеле җылы, күге биек // Мәгърифәт. 2000. 7 окт.

**ЗИ́ННЕР** Лев Яковлевич (31.12.1938, Волгоград өлкәсенең Палласовск р-ны Палласовка а.), электротехник, техник фән. д-ры (1980), проф. (1981), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1994). 1962 елда Томск политехник ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли (1970 кә кадәр). 1970–77 елларда Куйбышев политехник ин-тында. 1977–99 да Казан технол. ун-тында электротехника каф. мөдире. Хезмәтләре даими һәм алмаш ток б-н эшли торган вентильле электр машиналарына карый. Яңа класс электр машиналары теориясе һәм аларны практикада куллану буенча тикшеренүләр алып бара. Күп кенә принципиаль яңа электр машиналары төзи һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 47 авторлык таныклыгы бар. 2000 елдан Германиядә яши.

Х е з м.: Вентильные двигатели постоянного и переменного тока. К., 1981 (автордаш).

**ЗИННУ́Р** (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь. Аның исеме «Моны язган, Зиннурдыр — минем атым» исемле китап авторы буларак «Кыйсса-и Хуҗа Гаффан» (2 басма, 1880) дастан-поэма ахырында телгә алына. Поэмада, бөлгенлеккә төшеп, хатыны б-н улын хәерчелектә калдырып, шәһәреннән чыгып качкан сәүдәгәр Гаффан турында сүз бара. Поэмасын язганда З. Шәрекъ дастанныарының әкияти сюжет элементларыннан файдалана. Шуның б-н беррәттән, автор халык көнкүрешен, түбән катлау кешеләренең реаль тормышын, җәмгыятьтә хөкем сөргән социаль гаделсезлекне тасвирлауга да зур игътибар бирә. Бу хәлдән чыгу юлларын мәгърифәтче язучы төрле һөнәрләрне үстерүдә, җәмгыятькә файда китерә торган хезмәт б-н шөгыльләнүдә күрә. Поэманың теле гади, халык сөйләм теленә якын, казакъ теле элементларына бай. Поэма берничә мәртәбә басыла.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ЗИННУ́РОВ** Илдус Нәсыйх улы (21.10.1946, Аксубай р-ны Яңа Дума а.), режиссёр, педагог, ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1982, 2004). Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тын тәмамлый (1976). 1968–71 елларда Казан курчак театрында актёр, 1976 дан режиссёр, 1977 дән баш режиссёр. Хәзерге заман театры казанышлары тәҗрибәсенә нигезләнеп, курчакларның сәнгать мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан, төрле рәссамнар б-н бергә эшләү нәтиҗәсендә күп кенә уңышлы тамашалар булдыра, ш.и. «Елан күзе» (үз пьесасы буенча, 1976), Г.Х.Андерсен әсәрләре буенча «Су анасы» («Русалочка», 1977) һәм «Кар патшасы турында әкият» («Снежная королева», 1998), К.Тинчуринның «Хан кызы» (1980), А.Попескуның «Йөнтәс тылсымчы» («Пушок-волшебник», 1981), М.Җәлилнең «Алтынчәч» (1985), Зөлфәтнең «Ат өреккән шомлы төн» (1994), Л.Кожевниковның «Казларым-аккошларым» («Гуси-лебеди», 1999), Г.Зәйнашеваның («И, кызык Шүрәле!», 2000). Курчак театрының җитди идея-сәнгать мәсьәләләрен күтәрергә дә мөмкинлеге зур булуын күрсәтү максатыннан, өлкәннәр өчен дә спектакльләр куя башлый («Гасырдан да озын көн» — Ч.Айтматовның шул исем. романы буенча, 1988). Репертуарны яңарту һәм киңәйтү өстендә даими эшли, классик драматургия әсәрләренә мөрәҗәгать итә, театрга яңа авторларны җәлеп итә, үзе дә пьесалар һәм сценарийлар яза. З. тарафыннан куелган спектакльләр күп мәртәбә халыкара театр фестивальләрендә күрсәтелә: ш.и. 1977 елда — Халыкара балалар сәнгате фестивале (Шибенек ш., Югославия), 1994 тә (Брауншвейг ш., ФРГ), 1995 тә (Адана ш., Төркия), 2000 дә (Канны ш., Франция), Халыкара курчак театрлары фестивальләрендә дипломнар б-н бүләкләнә. Шулай ук Чаллы, Самара курчак театрларында, Польшаның Ломжа шәһәре курчак театрында спектакльләр куя. 1975 тән Казан театр уч-щесендә, 2000 нән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта, Берлинда (ГФР, 1989) театр ин-тында пед. практика уздыра. Халыкара Курчак театры эшлеклеләре берлеге конгрессларында катнаша.

*Әд.:* И г л а м о в Р. День вчерашний — день сегодняшний // Театральная жизнь. 1999. № 11/12; И г л а м о в Р. Искусство играющих кукол. К., 2004. *Ю.А.Благов.*

**ЗИННУ́РОВ** Ильяс Авзал улы (6.4.1952, Мөслим р-ны Торыш а.), зоотехник, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Минзәлә совхоз-техникумын (1972), Мәскәү а.х. академиясен (1979) тәмамлый. 1972 елдан Бөгелмә р-нының Энгельс исем. к-зында зоотехник. 1974–2001 дә Мөслим р-нында: Куйбышев исем. к-зда зоотехник (1974), үсемлекләрне саклау буенча район станциясе җитәкчесе (1979–81), ВЛКСМ райкомының 1 нче секретаре (1981–84), КПСС райкомының оештыру бүлеге инструкторы (1984–85); игенчелек һәм терлек азыгы җитештерү бүлеге башлыгы, бер үк вакытта район а.х. идарәсе җитәкчесе урынбасары (1985–89), үсемлекчелек буенча р-н агросәнәгать берләшмәсе рәисе урынбасары (1990–95), халык депутатларының р-н советы рәисе урынбасары (1995), р-нның а.х. идарәсе башлыгы (1996–2001). 2001 дән ТР а.х. һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек бүлеге башлыгы урынбасары, терлек азыгы үсеше бүлеге башлыгы (2005 тән), азык-төлек базары мониторингы идарәсе башлыгы (2006 дан), азык-төлек базары үсеше бүлеге башлыгы (2007 дән). Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасында терлек азыгы җитештерү системасын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ЗИННУ́РОВ** Мөхәммәт (1908, хәзерге Апас р-ны Кормаш а.), корыч коючы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Металлчылар



Н.Ш. Зиннуров.



Т.З. Зиннуров.

курсын тәмамлый (1933). 1931–32 елларда Магнитогорск металлургия комб-тының мартен һәм прокат цехлары төзелешендә; 1932–59 да шул комб-тта корыч коючы. Бөек Ватан сугышы елларында беренчеләрдән булып пр-тиедә броня өчен корыч җитештерүне үзләштерә һәм корыч коюның тизләтелгән алымын эшләүдә катнаша. 1950 нең 11 апрелендә 3 нче мартен миче корыч эретүчеләре В.Захаров һәм И.Семёнов б-н бергә металлургия агрегатларын югары экономияле эшләтү өчен Бөтенсоюз соц. ярышы инициаторы була. 1950 нең декабренә З. планнан тыш 16 мең *т* корыч коя (1 млн. сумнан артык акча экономияләнә). Дәүләт бүләге соц. ярышлардагы зур уңышлары, инициатива һәм новаторлык күрсәткәне, корыч коюның тизләтелгән ысулларын керткәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Магнитогорск шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* К о л ь ц о в А.А. Культурное строительство в РСФСР в годы первой пятилетки (1926–32 гг.). М., 1960; К о н д а к о в А. Стальное сердце Родины. М., 1962; Слово о Магнитке. М., 1979; Юность Магнитки. М., 1981.

*К.А.Нәҗипова.*

**ЗИННУ́РОВ** Нәбиулла Шәфикъ улы (20.5.1922, Зөя кантоны Татар Мәмәтхуҗасы а. — 1956, Казан), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), кече лейтенант (1943). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 15 нче укчы полк батальоны комсоргы (38 нче армиянең 167 нче укчы дивизиясе). Брянск, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Украина, Польша, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1943 нең 3–5 ноябрендә Киевны азат итү сугышында батырлык күрсәтә. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1.

**ЗИННУ́РОВ** Тимергали Зиннур улы (18.11.1949, Лаеш р-ны Пәрәү а.), драма актёры, ТАССРның атказ. (1981), ТРның халык (1993) артисты. 1967–82 елларда Казан курчак театры актёры. Шактый күп рольләрдә уйный: Хан («Хан кызы», К.Тинчурин), Муса («77 баһадир», Р.Батулла), Таңбатыр һәм Девон бабай («Бирнәле кыз», Ә.Маликов), Кыятыш батыр һәм Күл хуҗасы («Энҗеле үрдәк», Н.Фәттах), Дию («Кәрлә — мәктәп баласы», Т.Миңнуллин). Үзен курчакларга тавыш бирүче генә түгел, ә һәр әсәрнең жанры таләп иткәнчә, аларның характерларына хас үзенчәлекләрен ачарга сәләтле актёр итеп күрсәтә. Аның хәтта тискәре пландагы геройлары да үзләренең мөлаемлыклары б-н кечкенә тамашачы күңеленә юл яралар. 1982 дә З.ны Татар драма һәм комедия театрына чакыралар, анда ул үзен чын сәхнә остасы итеп таныта. Актёрга хас сәхнә мөлаемлылыгы, образның психологиясен тирәнтен аңлавы, лирик, драматик, ш.у. комик рольләрне дә бертигез җиңеллек б-н уйнавы аңа истә калырлык күп кенә матур образлар тудырырга мөмкинлек бирә. Шундыйлардан — Мияссәр («Ефәк баулы былбыл кош», А.Гыйләҗев), Иршат, Гармунчы, Мәрди («Без бит авыл малае», «Алай түгел, болай ул», «Уйна, гармун!», Т.Миңнуллин), Бики («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Әкбәр, Сәет («Кыр казлары артыннан», «Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Гыймран («Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Максут («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Заһит («Сөяркә», С.Шәкүров), Сәлим морза («Ак калфак», М.Фәйзи), Алмыш хан («Әтил суы ака торур», Н.Фәттах), Зиннур («Сынган беләзек», Р.Сәгъди), Галим («Мәхәббәтеңне сакла», Х.Төхфәтуллин), Васил («Тол хатыннар көймәсе», И.Грекова), Франциск («Шау-шулы көн», У.Шекспир) образлары игътибарга лаек.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ЗИННУ́РОВ** Фоат Канафи улы (10.5.1959, Биектау р-ны Ямаширмә а.), милиция генерал-майоры (2009), психол. фән. канд. (2005), ТРның Эчке эшләр органнары атказ. хезмәткәре (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1984). Чаллы шәһәренең Автозавод р-ны эчке эшләр бүлегендә: 1984–87 елларда өлкән инспектор, 1989–91 дә башлык урынбасары, сәяси бүлекчә башлыгы, 1991–93 тә башлык урынбасары; 1993–99 да Чаллы шәһәре Эчке эшләр идарәсе башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы. 1999–2008 дә ТР Эчке эшләр министрлыгында Кадрлар идарәсе башлыгы. Бер үк вакытта, 2004–08 дә, ТРның эчке эшләр министры урынбасары. 2008 дән РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-ты башлыгы. Эшчәнлекләре югары дәрәҗәдә куркыныч янау б-н бәйле төркемнәрдә шәхесара мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләрен, Татарстанның эчке эшләр органнары өчен хезмәткәрләрне проффесиональ яктан дөрес сайлау үзенчәлекләрен яктырткан хезмәтләре бар. Җинаять процессы, юриспруденция буенча уку ярдәмлекләре авторы. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЗИНО́ВЬЕВ** Дмитрий Николаевич (1769–1819 елдан соң), әдип, нашир. Казан губернасы алпавыты, Казан губ. идарәсе советнигы улы. Казан югары расправа учреждениесендә җинаять эшләрен алып баруны күзәтүче (1786–93, авыру сәбәпле аннан китә), Казан җинаять эшләре мәхкәмәсе палатасында утырышчы (1805), Казан губернасы ландмилициясенең Тәтеш өязе буенча пятисотенные (1806), Казан гражданлык эшләре мәхкәмәсе палатасында утырышчы (1810–19), губерна идарәсе басмаханәсе (Казандагы беренче рус басмаханәсе) хуҗасы (1807) була. Казан масоны С.А.Москотильниковның якын танышы. Финляндия икътисад һәм Харьков филотехника җәмгыятьләре әгъзасы, император Ирекле икътисад җәмгыяте мөхбир әгъзасы. Бу җәмгыять алпавыт хуҗалыгын төрле яктан камилләштергәне өчен З.ны 3 тапкыр алтын медаль б-н бүләкли. 1818 дә җәмгыять, карап-тикшереп чыгу максатында, Казан ун-тына З.ның «Казан губернасының хуҗалык тасвирламасы» («Хозяйственное описание Казанской губернии») хезмәтен тәкъдим итә, кайбер җитешсезлекләрне төзәтү өчен ул авторына кире кайтарыла, әмма хезмәтнең аннан соңгы язмышы билгесез. 1809 да Казан халык уч-щесе директоры вазифасын алырга өмет итә, әмма Казан уку-укыту округы башлыгы С.Я.Румовский аның дәгъвасын кире кага. 1812 елгы зур янгын вакытында, гомерен куркыныч астына куеп, башка чиновниклар б-н бергәләп Табибләр идарәсе, Җәмәгать тәрбиясе приказы, губерна идарәсе, Җинаять һәм Гражданлык эшләре палатасы архивларының бер өлешен коткаруда катнаша.

З. «Казан каласы һәм аның өязенең топографик тасвирламасы» («Топографическое описание города Казани и его уезда». М., 1788) хезмәтен бастырып чыгара. Бу хезмәтен ул үзенең күзәтүләренә һәм Казан архивлары мәгълүматларына, башлыча, П.И.Рычковның «Борынгы һәм урта заман Казан тарихы тәҗрибәсе» («Опыт казанской истории древних и средних времён». СПб., 1767), «Оренбург губернасы топографиясе» («Топография Оренбургской губернии». СПб., 1762. Ч. 1–2) исемле хезмәтләренә һәм А.И.Лызловның «Скифлар тарихы» («Скифская история». СПб., 1776; 2-е изд., 1787) хезмәтенә таянып яза. Әлеге хезмәт бүгенге көндә дә кыйммәтен югалтмаган.

З. ш.у. «Тантана итүче яхшылык иясе, яисә Язмыш тарафыннан куылган Сәлим тормышы һәм маҗаралары» («Торжествующая добродетель, или Жизнь и приключения гонимого фортуной Селима». М., 1789; 2 изд., 1791) исемле маҗаралы роман да иҗат итә. «Прохладные часы» ж-лында хезмәттәшлек итә, анда ул «Кенәз П.С. Мещерскийга мактау сүзе»н («Похвальное слово [...] князю П.С.Мещерскому», ч. 2, 1793) бастыра.


З.ның икенче бер әсәрен — «Михельсон Казанда булган баш күтәрүдә» («Михельсон в бывшее в Казани возмущение». М., 1807) исемле хезмәтен А.С.Пушкин «Пугачёв фетнәсе тарихы» («История Пугачёвского бунта». СПб., 1834) әсәрендә файдалана. З.ның әлеге хезмәтендә Пугачёв заманы шаһитларының хикәяләре (башлыча, Казандагы Спас-Преображение монастыре архимандриты Платон Любарскийның тарихчы Н.Н.Бантыш-Каменскийга язган хатыннан өземтә) китерелә. Казанда З. губерна басмаханәсендә басылган тәүге китапларның берсен — «Французлар б-н сугыш уңаеннан чаң кагу» («Набат по случаю войны с французами», 1807) исемле патриотик памфлетын нә-

шер итә. 1811 нең апреленнән Казанда беренче газета — «Казанские известия»не чыгара, анда ул Зөя каласының кайда урнашуы, алпавыт хуҗалыгын камилләштерү турындагы һ.б. мәкаләләрен бастыра. 1811 нең августыннан (19 нчы саннан) г-та Казан ун-ты каршында нәшер ителә башлый, ә З.дин әһелләрен ихтирам итмичә язганы һәм «иҗек һәм тел» хаталары җибәргәне өчен эштән алына (чыннан да, ун-т тарихчысы проф. Н.Н.Булич З.ның «шактый хаталы» язылган хатларын укыган). Алдагы саннарда (1818 елга кадәр) З. тарих, статистика, хуҗалык эшчәнлеге, сәнәгать, медицина һ.б. өлкәләргә караган мәкаләләр, ш.и. шәһәрнең урнашуы һәм тышкы күренеше турында «Казан язмалары»н («Казанские записки») бастыра.

*Әд.:* Патриотические анекдоты // Казан. изв. 1815. № 79; З а г о с к и н Н.П. История Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1903. Т. 2, ч.1; Б у л и ч Н.Н. Из первых лет Казанского университета: 1805–1819. СПб., 1904. Ч. 1; К у р а н о в К.Н. Универсализм Дмитрия Зиновьева, первого Казанского журналиста // Мастерство очеркиста. К., 1970. Вып. 1; Словарь русских писателей XVIII века. Л., 1988. Вып. 1; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеалог. словарь. К., 2001. *И.А.Новицкая.*

**ЗИНО́ВЬЕВ** Иван Дмитриевич (17.1.1905, Самара губ., Бөгелмә өязе Дубовка а. — 1942), Сов. Союзы Герое (26.4.1940), полковник (1941). 1927 елдан НКВД гаскәрләре сафларында. 1939–40 та совет-фин сугышында катнаша, 4 нче чик сакчылары полкының рота командиры (НКВД гаскәрләре). 1940 ның гыйнвар-февралендә Уома (Финляндия) торак пункты янында фронт коммуникацияләрен саклаганда батырлык күрсәтә. 1940–41 дә М.В.Фрунзе исем. хәрби академиядә (Мәскәү) укый. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, укчы дивизия командиры. 1942 елның 29 маеннан фашист тоткынлыгында; хәрби әсирләрне концлагерьдан качарга әзерләгәне өчен атыла. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Ими гордится Туркменистан. Аш., 1973; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. *В.А.Шагалов.*



И.Д.Зиновьев.

**ЗИРА́Т**, мәетләрне җирләү өчен билгеләнгән җир участогы; каберлек. Гадәттә, З. өчен җир авылдан читтә бүлеп бирелә һәм киртәләп куела. Күпгасырлык тарихы булган эре авыллар янында, гамәлдәге З.лардан тыш, аеруча хөрмәтләнә торган иске каберлекләр (иске З.) дә бар. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан һәм Касыйм ханлыклары чорларыннан сакланып калган таш төрбәләр, язулы кабер ташлары булган З. калдыклары аеруча мөһим тарихи һәм сәнгати мирасны тәшкил итәләр, халык өчен иң изге урыннар булып саналалар. Гадәттә, каберләр гади коймa (киртә, рәшәткә) б-н әйләндереп алына һәм аның өстенә мәет озаткан гаилә *тамгасы* уелган агач багана утыртыла яки кабер өстенә тамгалы таш куела. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, иң элек шәһәрләрдә яшәүчеләр арасында, кабергә (җирләү көнендә) вакытлы истәлек ташы (мөселманнарда агач яисә металл ярымай сурәте б-н, керәшен татарларда — хач сурәте б-н) кую йоласы барлыкка килә, ул соңрак кабер ташы яисә плитәсе б-н алыштырыла. Каберләр өстенә күбрәк кайгы-хәсрәт агачы дип исәпләнүче каен агачы утыртыла. Казан арты р-ннарында элегрәк каен агачын хатын-кызлар каберләренә генә утырткканнар, ә ир-атлар җирләнгән каберләргә нарат агачы сайланган. Каберләрне матәм такыялары, чәчәк түтәлләре б-н бизәү — татарлар көнкүрешендә чагыштырмача яңа күренеш. Дини бәйрәмнәр вакытында З.ка барып туганнарны һәм барлык әрвахларны догалар укып искә алу элек-электән килгән йола. «Зиярәт кылу» дип аталган бу йоланы мөселманнар *Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме* көннәрендә, керәшен татарлар Пасха һәм Покров бәйрәмнәре алдыннан үтиләр.

*Әд.:* У р а з м а н о в а Р.К. Семейные обычаи и обряды // Татары. М., 2001. *Ф.Ф.Гулова.*

**«ЗИРӘ́К КАРТ»,** татар халык көнкүреш әкияте. Төп идеясе — бер падишаһның әхлаксыз гамәлләрен хөкем итү: ул 70 яшькә җиткән картларны, тормышка яраксыз дип, үтерергә боера. Бервакыт падишаһның вәзире егеткә берсеннән-берсе катлаулы 3 бирем бирә. Егет биремнәрне зирәк акыллы әтисе ярдәме б-н башкарып чыга. Бары шул чакта гына падишаһ тормышта яшьлек көче генә түгел, ә картлык тәҗрибәсе дә кирәк булганлыгына төшенә.

Әкият 1945 елда Х.Гатина тарафыннан Буа р-ны Иске Суыксу авылында яшәүче Әхтәм Камалетдинов сөйләгәннәрдән язып алына. Беренче тапкыр «Татар халык әкиятләре» (1950) җыентыгында басылып чыга.

*Әд.:* Җ а м а л е т д и н о в Л. Көнкүреш әкиятләре // Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1981. 3 кит. *Ф.И.Урманчеев.*

**ЗИРЕ́К** (Alnus), каенчалар семьялыгыннан агач һәм куаклар ыругы. 40 тан артык төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. ТР терр-ясендә өч төре үсә. Җилемле З. яки кара З. (A. glutinosa), соры яки аксыл З. (A. incana) барлык р-ннарда да, йөнтәс З. (A. hirsuta) — Көнбатыш Кама алдында очрый. Елга ярлары буенда, ерымнарда, урман тугайларында үсә. 25 *м* биеклеккә кадәр җитә. Ябалдашы түгәрәк яки йомыркасыман озынча, кәүсәсенең кабыгы караңгы көрән, соры, шома. Үрентеләре ялангач яки төкле, төрле төсмердә, аксыл яки саргылт ясмыкчыклары бар. Яфраклары чиратлашкан, овал яки түгәрәк, кырыйлары теленмә. Чәчәкләре аерым җенесле: ата чәчәкләр — өч чәчәкле дихазиядән торган озын алкалар; ана чәчәкләрдә чәчәк тирәлеге юк, берәрле кыска башакларда яки 2–6 шар булып чукларда ике чәчәкле дихазия хасил итәләр. Җимеше — бер орлыклы ике канатлы вак чикләвекчек. Апрельдә — май башында чәчәк ата. Җимешләре сентябрь — октябрьдә өлгерә. Җимешләре өлгергәндә ана башаклар тәлгәшләр хасил итеп, җәелеп үсеп китә. Алар күркәләр дип атала һәм февраль-мартта ачыла. Орлыктан, ш.у. үсентедән, кайбер төрләре тамыр үрентесеннән үрчи. З. кышка чыдам, дым яратучан һәм туфрак аэрациясенә талымчан булуы б-н аерылып тора. Урман барлыкка китерүдә әһәмиятле токым. Сулыкларны саклауда, ярларны ныгытуда һәм урман хуҗалыгында әһәмияте зур: күп кенә башка токымнар тереклек итә алмаган артык дымлы урыннарда үсә; азот б-н баетып, туфракны яхшырта. З.нең үзагачы көрән кызыл, сыгылучан һәм җитәрлек дәрәҗәдә нык: фанер, агач йорт җиһазлары җитештерүдә, әрҗәләр ясауда кулланыла. З. күркәләрендә дуплау матдәләре, алкалоидлар, органик к-талар һ.б. бар. Күркәләреннән ясалган препаратлар эчне ныгыту, ялкынсынуга каршы һәм кан туктату чарасы буларак; халык медицинасында кабыгыннан һәм яңа җыеп вакланган яфракларыннан ясалган төнәтмә суык тию, ревматизм авыруларына каршы кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек. 80–100 ел яши.

**ЗИРЕКЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,1 *км*, бассейнының мәйданы 21,8 $км^2$. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Пономарёвка авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Татар Сөнчәлесе авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 145 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 28%. З. елгасының озынлыгы 0,8 *км* га кадәр булган 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга еш кына бөтен озынлыгына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу агымы катламы 89 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Ноябрьнең беренче унконлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 0,007 $м^3/с$. Суы бик каты; язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЗИРЕКЛЕ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 59 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2008 елда 237 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимер-

челек, балта эше, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.дә чиркәү-приход мәктәбе (1897 дә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 901 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1963 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 540, 1897 дә — 762, 1908 дә — 901, 1920 дә — 928, 1926 да — 926, 1938 дә — 929, 1949 да — 694, 1958 дә — 620, 1970 тә — 429, 1979 да — 348, 1989 да — 244, 2002 дә — 243 кеше.

**ЗИРЕКЛЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 27 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2008 елда 380 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Зирекле исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.дә 2 мәчет, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Фомкино авылын да кертеп) 3946 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимкино волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 184 ир-ат; 1859 да — 692, 1897 дә — 1097, 1908 дә — 1213, 1920 дә — 1443, 1926 да — 1159, 1938 дә — 781, 1949 да — 690, 1958 дә — 685, 1970 тә — 743, 1979 да — 643, 1989 да — 425, 2002 дә — 426 кеше.

**ЗИРЕКЛЕ́** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 6 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда 6 кеше (руслар, татарлар) яши. 1946 да нигез салына. Халык саны: 1970 тә — 10, 1979 да — 8, 2002 дә — 18 кеше.

**ЗИРЕКЛЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кичү елгасы буенда. 2008 елда 701 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, авыл тарихы музее, клуб, китапханә, хастаханә. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1857 дә З.дә мәчет төзелә. 20 йөз башында волость идарәсе, почта станциясе урнаша, 2 мәчет (икенче мәхәллә мәчете 1905 тә ачыла; архит-ра истәлеге), 5 бакалея кибете, базар һәм ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2462 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халкы саны: 1782 дә — 170 ир-ат; 1859 да — 812, 1897 дә — 1485, 1908 дә — 1831, 1920 дә — 1905, 1926 да — 1455, 1938 дә — 1768, 1949 да — 1505, 1958 дә — 1695, 1970 тә — 1808, 1979 да — 1353, 1989 да — 946, 2002 дә — 808 кеше.

**ЗИРЕКЛЕ́ КАРА́Н** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дим елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2002 елда даими яшәүчеләр юк. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Баулы, 1935 нең 1 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән Баулы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 180, 1949 да — 140, 1958 дә — 111, 1970 тә — 82, 1979 да — 66, 1989 да — 24 кеше.

**ЗИРЕКЛЕ́ ХАЛЫ́К ИҖАТЫ́ ҺӘМ КӨНКҮРЕШЕ́ МУЗЕЕ́**, Яңа Чишмә р-нында, 1982 елда укытучы М.Г.Газыймов тырышлыгы б-н мәктәп музее буларак ачыла. 1992 дән ТРның Берләштерелгән дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы, 2007 дән муниципаль музей. Элеккеге мәктәп бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы 102 $м^2$, коллекцияләрдә 1300 саклау берәмлеге исәпләнә. Архивы һәм фәнни китапханәсе бар. Экспозициянең төп бүлекләре: «Зирекле урта мәктәбен тәмамлаучылар һәм аларның укытучылары», «Халыкның гамәли бизәлеш сәнгате әйберләре», «Зиреклелеләр Бөек Ватан сугышы фронтларында һәм тылда». Экспонатларның мемориаль бүлегендә авыл халкының шәхси әйберләре, документлары, фоторәсемнәре урын алган; аларның 70% тан артыгы 19–20 йөзләрдә халык тарафыннан иҗат ителгән декоратив-гамәли сәнгать әйберләре: кырык шырпылы чүпләү ысулында суккан ашъяулыклар, чигелгән сөлгеләр, кашагалар, намазлыклар, татар хатын-кызларның традицион костюмнары; көнкүреш әйберләре һәм эш кораллары (җеп эрләү кабасы, савыт-саба һ.б.) б-н туплана.

Музейның халык иҗаты бүлегендә фольклор әсәрләре — 119 бәет тексты бар. Аеруча әһәмияткә ия экспонатлар — кырык шырпылы чүпләү ысулы б-н суккан (252 саклау берәмлеге) һәм чигелгән сөлгеләр (96 саклау берәмлеге), чигелгән намазлыклар (57 саклау берәмлеге), стенага эленә торган чигүле бизәкләр (170 саклау берәмлеге), ашъяулыклар (60 саклау берәмлеге), чәй төргәкләре һәм конфет кәгазьләре (5 меңгә якын) коллекциясе бар. Ел саен Халыкара музейлар көне (18 май), Хәтер (22 июнь), Казанны яулап алганда һәлак булганнарны искә алу (15 окт.) көннәре билгеләп үтелә.

Директоры М.Г.Газыймов (1992 дән).

*Әд.:* Газымов М.Г. Капли памяти. Нижнекамск, 2001; Музей народного творчества и быта села Зирекле: Буклет. К., 2002; Новошешминск — уголок тихий мой. Нижнекамск, 2002; На Засечной черте; Из прошлого и настоящего Новошешминского района Татарстана. К., 2007.

**ЗИЧӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зәй елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 40,2 *км*, бассейнының мәйданы 577,3 $км^2$. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Зичәбаш авылыннан 3,6 *км* көнчыгыштарак, тамагы Бүре-Сарай авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 59 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 37%. З. елгасының 3 тән алып 23 *км* га кадәр озынлыктагы 16 кушылдыгы бар. Иң зурлары: Бастырма (11,1 *км*) — сул; Борды (14,4 *км*), Аулаш (23 *км*) — уң. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,44 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,2–1 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу агымы катламы 51 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең соңгы көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы чыгымы 0,433 $м^3/с$. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. З. бассейнында гомуми күләме 5,8 млн. $м^3$ булган 11 буа бар. Су ресурслары сугару һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**ЗИЧӘБА́Ш** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 38 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 156 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, олаучылык, тимерчелек, арба һәм чана төзәтү б-н шөгыльләнә. 1890 елларда Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, З.та кәшәнә, тегермән эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1065 дис. тәшкил итә. 1929 да З.та Сталин исем. к-з оештырыла, берникадәр үзгәрешләрдән соң, 1958 дә ул «Игенче» к-зына (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 318, 1897 дә — 539, 1920 дә — 795, 1926 да — 620, 1938 дә — 650, 1949 да — 544, 1958 дә — 589, 1970 тә — 600, 1979 да — 388, 1989 да — 250, 2002 дә — 182 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ЗИЯРӘ́Т** (гарәп. زيارة — килү, бару), пәйгамбәрләрнең, изгеләрнең, шигый имамнарның, Төньяк Африкада — суфи шәехләрнең каберләренә бару. З. кылу мөселманнарда төрле урыннарда барлыкка килә, җирле дини ышанулар йогынтысында изгеләр культы формалашу барышында гамәлгә керә (к. *Әулия*). З. кылуның үзенчәлекләре: 1) табыну урыннарының буыннан-буынга күчүе; 2) исламга кадәрге һәм ислам чорындагы гореф-гадәтләрнең синтезы; 3) ислам илләрендә таралган йолаларның күптөрлелеге. Мөселман изгеләренә табыну кебек, З. кылу да динчеләр тарафыннан көчле каршылыкка очрый. «Чиста» ислам идеясен яклаучылар аңа бидгать игълан итә. З. кылуның кануни булуы әле дә бәхәсле. Шуңа карамастан, аеруча хөрмәтләнгән шәехләрнең, изгеләр-

нең каберләренә баш ию, табыну Мәккәгә кече хаҗ кылырга бару йоласы б-н тиңләшә дигән фикер яши. З. кылу йоласы, гадәттә, аларның туган көннәрендә (к. *Мәүлид*) үтәлә һәм дини бәйрәм итеп уздырыла. Мазар янында дога кылу — аларның догасын, фатихасын алуга, *бәрәкәткә* ирешүгә тиңләп карала. Йола, гадәттә, кабер янында Коръәннән аерым сүрәләр (аеруча Фатиха сүрәсе), остазлар, әүлияләр рухына багышланган догалар укуны, кабер тирәсен әйләнеп чыгу, аны агач ботаклары, төрле төстәге корамалар б-н бизәү, корбан чалу, ш.у. хәер өләшүне эченә алган чаралардан тора. З. кылуның аерым бер төре — Мәккәдә хаҗ кылганнан соң Мөхәммәд пәйгамбәрнең каберен күрергә бару. Татарларда Идел буендагы борынгы Биләр, Болгар шәһәрләре урыннарына бару, ш.у. андагы әүлияләрнең каберләренә З. кылу гадәте яши.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Ислам: Карманный словарь. СПб., 2002.

**ЗЛАТОУ́СТ**, *Чиләбе өлкәсендәге* шәһәр, Чиләбе шәһәреннән 108 *км* көнбатыштарак урнашкан. 1754 елда нигез салына. Халкы — 191174 кеше (2008). Татарлар — 12813 кеше (2002). З.та татарлар шәһәргә нигез салынган вакыттан бирле яши. 1917 гә кадәр мәчет (1938 дә җимерелә) һәм аның каршында мәдрәсә була. 1990 нан «Нух» татар-башкорт мәдәни үзәге, шәһәр үзәк китапханәсе каршында Ә.Г.Даушев исем. татар-башкорт әдәбияты секторы эшли. «Сандугач», «Чулпан», «Яшь моңнар» милли ансамбльләре бар. Мәчет төзелә.

**ЗЛАТОУ́СТОВА** Любовь Владимировна (30.8.1924, Чистай ш.), тел белгече, филол. фән. д-ры (1969), проф. (1970). Казан ун-тын тәмамлый (1948). 1951 елдан Казан, 1964 тән Мәскәү ун-тларында. Хезмәтләре Идел-Кама буе рус сөйләшләренең экспериментал фонетикасына, башка телләр б-н чагыштыру мисалында рус сөйләменең просодия теориясенә карый.

Х е з м.: Фонетическая структура слова в потоке речи. К., 1962; Фонетические единицы русской речи. М., 1980.

**ЗМАЧИ́НСКИЙ** Леонид Январьевич (10.9.1933, Минск өлкәсенең Пуховичи р-ны Пуховичи а.), Яшел Үзән суднолар төзү з-ды директоры (1978–84). Ленинград корабльләр төзү ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Балтыйк буе «Янтарь» суднолар төзү з-дында эшли (Калининград ш.): төзүче, өлкән төзүче, баш инженер (1972–74), директор урынбасары (1974–78). 1984–91 елларда СССР Суднолар төзү сәнәгате министрлыгының 2 нче Баш идарәсендә баш инженер. З. җитәкчелегендә Хәрби диңгез флоты өчен көймәләргә каршы сугышучы һәм сакчы 20 корабль, балык туңдыручы 2 океан судносы, су асты канатлы 84 «Метеор» пассажир теплоходы төзелә; пр-тие яңартып корыла; корпус эшкәртүче цех, зур табаклы кою участогы сафка баса. СССР Дәүләт бүләге иясе (1974). «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ЗМЕ́ЕВО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 15 *км* төньяктарак, Үшнә елгасы буенда. 2008 елда 9 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1565–67 еллардан Кишкильдеево исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да 2 вак-төякләр һәм 1 икмәк саклау кибете, су тегермәне, 2 тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 859 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Черемыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат, 1859 да- 365, 1897 дә — 548, 1908 дә — 582, 1920 дә — 747, 1926 да — 768, 1949 да — 327, 1958 дә — 342, 1970 тә — 187, 1979 да — 78, 1989 да — 22, 2002 дә — 7 кеше.

**ЗМЕ́ЕВО** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы яры буенда. 2008 елда 21 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Змеево Городище, Воскресенский исемнәре б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, балта эше, дилбегә һәм бау үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да Воскресение чиркәве (1742 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1886 да ачыла), бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 518 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 476 ир-ат; 1859 да — 999, 1897 дә — 1597, 1908 дә — 1460, 1920 дә — 1342, 1926 да — 1261, 1938 дә — 600, 1949 да — 454, 1958 дә — 472, 1970 тә — 246, 1979 да — 102, 1989 да — 42, 2002 дә — 21 кеше.

**ЗНА́МЕНСКИЙ** Пётр Васильевич (27.3.1836, Түбән Новгород — 2.5.1917, Казан), тарихчы, чиркәү (1873) һәм рус тарихы (1902) д-ры. А.П.*Щапов* шәкерте. Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1860), шунда ук укыта, 1866 елдан рус тарихы, 1870–97 дә рус чиркәве тарихы кафедралары профессоры. Хезмәтләре Рус православие чиркәве тарихына багышлана. Дини һәм дөньяви даирәләрдә төрле карашлар уяткан «Рус чиркәү тарихына кулланма» («Руководство к русской церковной истории», 1870) дәреслегенең дөнья күрүе З.га Россия күләмендә танылу китерә: З.ны чиркәү кануннарыннан чигенүдә һәм либерализмда гаеплиләр. Шуңа карамастан, китап руханилар семинарияләрендә һәм күп кенә дөньяви уку йортларында рус чиркәве тарихы буенча төп дәреслеккә әверелә. *Изге Гурий борадәрлеге* әгъзасы була. Педагог, миссионер Н.И.Ильминский архивын тасвирлап чыга, нәтиҗәдә миссионерлык тарихы буенча дәвамлы хезмәтләр сериясе, ш.и. Н.И.Ильминскийның биографиясе аеруча тулы, фәнни яктыртылган «Николай Иванович Ильминский ядкәре» («На память о Николае Ивановиче Ильминском») исемле китабы дөнья күрә. З.ның берничә хезмәте, ш.и. «Казан татарлары» («Казанские татары», 1910) Идел буе халыклары этнографиясенә багышланган. «Яшәешенең беренче (реформага кадәрге) чорында Казан руханилар академиясе тарихы») («История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период её существования», ч. 1–3, 1891–92) фундаменталь хезмәтендә Россия чынбарлыгы фонында әлеге уку йортының тулы тарихы тасвирлап бирелә. Эштән киткәннән соң, З. Россиядә 19 йөзнең 2 нче яртысында барган дини бәхәсләр тарихына мөрәҗәгать итә, дин белгече А.М.Бухаревның православие идеяләрен таратуга һәм популярлаштыруга багышланган хезмәтләрен бастыруда булышлык итә.

Х е з м.: Очерки из истории славянской мифологии. К., 1866; Приходское духовенство на Руси. К., 1867; Приходское духовенство в России со времени реформы Петра. К., 1873; Чтения из истории русской церкви за время царствования имп. Александра I. К., 1885; О православии в отношении современности. СПб., 1906; Духовные школы в России до реформы 1808 года. СПб., 2001.

*Әд.:* П о к р о в с к и й И.М. Пётр Васильевич Знаменский // Православный собеседник. 1917. № 2; Х а р л а м п о в и ч К.В. Историк-художник. К., 1922.

*Е.В.Липаков.*

**«ЗНА́МЯ РЕВОЛЮ́ЦИИ»,** газета, к. «*Республика Татарстан*».

**«ЗНА́МЯ ТРУДА́»,** газета, к. «*Республика Татарстан*».

**«ЗНА́НИЕ — СИ́ЛА»** («Белем — көч»), фәнни-популяр журнал. Башта «Кызылармиячеләр, эшче һәм крәстияннәр өчен фәнни листок» дигән өстәмә исеме була. *Республиканың запастагы армиясе* сәяси бүлеге һәм Казан губернасының халык мәгарифе бүлеге органы. 1920 елның 5 февраленнән 14 июленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 19 саны чыга. Максаты — аң-белем тарату һәм фәнни белемнәрне популярлаштыру. Иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис темаларга караган фәнни-популяр мәкаләләр басыла. «Хроника» бүлегендә сәяси бүлек тарафыннан үткәрелгән мәдәни чаралар турында материаллар, эшләп килүче түгәрәкләр саны, күрсәтелгән спектакльләр, концертлар, лекция һәм чыгышлар турында мәгълүматлар бирелә.

*Әд.:* Н а с ы р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975. *Р.А.Айнетдинов.*

**ЗОБНИ́Н ЙОРТЫ́**, Казанда архитектура ядкәре. 1914 елда фабрикант Зобнин өчен арх. Ф.П.Гаврилов проекты буенча романтик модерн стилендә Шәрекъ һәм готика архит-ра элементлары б-н шәһәр йорты төзелә. Күләмнәре бер-берсенә карата асимметрик композициядә үзгәртелгән, вестибюль һәм аркасыман порталга охшаган төп ишек өлеше уң ягына кушып эшләнгән ике катлы бина. Хәзер монда Респ-ка офтальмология хастаханәсе урнашкан.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

**ЗО́БОВ** Владимир Васильевич (3.1.1957, Чуаш АССР, Канаш ш.), молекуляр фармакология һәм токсикология өлкәсе галиме, биол. фән. д-ры (2007), проф. (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1981 елдан РФА КГҮнең

Органик һәм физик химия ин-тында эшли, химик-биологик тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (2008 дән).

Хезмәтләре «төзелеш-активлык» бәйләнешен һәм урацилның тетраалкиламмонлы чыгарылмалары -ацетилхолинэстераза ингибиторларының яңа селектив классының тәэсир итү механизмы үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Хәрәкәт мускулларында транссинаптик күчерүнең сайлаулы модуляциясенә сәләтле ацетилхолинэстеразаның органнар һәм тукымалар өчен махсус — әһәмиятле органнарга тискәре тәэсире иң аз булган ингибиторларын тудыруның принципиаль мөмкинлекләрен күрсәтә. З. һәм аның коллегалары тарафыннан ачылган ацетилхолинэстераза ингибиторларының яңа классы медицинада терәк-хәрәкәт аппараты, Альцгеймер авыруларын һ.б. дәвалауда кулланыла. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Фосфорилированные и тетраалкиламмониевые производные урацила: безопасность и избирательность миорелаксантного действия // Современные проблемы токсикологии. 2004. № 3; Избирательная блокада локомоторных мышц урацилсодержащими тетраалкиламмониевыми ингибиторами ацетилхолиэстеразы // Докл. РАН. 2005. Т. 401, № 1; Роль особенностей химической структуры тетраалкиламмониевых N-гетероциклических соединений в избирательности их влияния на локомоторные мышцы // Токсикол. вест. 2006. № 2.

**ЗО́БОВА** Нина Николаевна (1.1.1940, Горький өлкәсе, Лукоянов р-ны Неверово а. — 9.4.1993, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1983), проф. (1987). 1962 елда Чабаксар пед. ин-тын тәмамлый. 1966 дан Казан ун-тында, 1985 тән Казан а.х. ин-тының гомуми химия каф. мөдире. Хезмәтләре туендырылмаган һәм гетерокумулен системалар химиясенә, гетероцикллы һәм күпфункцияле кушылмалар синтезына карый. Ацилизоцианатларның электрон, фәзаи төзелешен һәм реакциягә керүчәнлеген тикшерә. Ацилизоцианатларның туендырылмаган кушылмалар б-н яңа реакциясен ача. Биологик актив кушылмаларны: үсемлекләрне саклау чараларын (үсеш регуляторлары, гербицидлар һәм фунгицидлар) һәм фармакологик актив матдәләрне (анальгетик, ялкынсынуга каршы, кардиостатик) синтезлау ысулларын эшли.

Х е з м.: Биологически активные соединения в сельском хозяйстве. К., 1987; Cycloaddition reactions of aliphatic and aromatic acyl isocyanates // Synthesis. 1974. № 7 (автордаш); Addition of aliphotic acylisocyanates to unsaturated compounds // шунда ук. 1982. № 6 (автордаш).

*В.Г.Абзалова.*

**ЗОЛОТОНО́СОВ** Яков Давидович (3.7.1947, Украина ССРның Кобеляки ш.), химик-технолог, гидромеханик, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында, 1978–90 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1990–95 тә Волгоград политехник ин-тында. 1995–2008 дә Казан энергетика ун-тында, инженерлык графикасы каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре сыеклык — сыеклык, пар — сыеклык системаларында экстракция һәм җылылык алмашы процессларын фәнни тикшерүгә карый. Махсус композицияләрне грануллаштыру технологиясен гамәлгә кертә. Уйлап табуга 54 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Исследование физико-химических и теплофизических характеристик растворов полимеров на основе нитратов целлюлозы // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1997. Т. 40, вып. 3; Центробежные аппараты смешения для получения эмульсий, микроэмульсий и растворов // Хим. и нефтегазовое машиностроение. 1999. № 6; Математическая модель течения инжектирующей жидкости во вращающемся осесимметричном конвергентном канале центробежного струйного подогревателя // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2001. № 5, 6.

**ЗОНТЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р**, к. *Чатырчәчәклеләр.*

**ЗО́О**... (грек. zōon — хайван, тере җан иясе), хайваннар дөньясына мөнәсәбәтлелекне күрсәтүче кушма сүзләрнең (мәс., зоология, зоогеография) бер кисәге.

**ЗООЛО́ГИЯ** (*зоо*... һәм ...*логия*), хайваннар турындагы, аларның төзелешен, тереклек итү эшчәнлеген, тарихи һәм индивидуаль үсешен, таралышын, әйләнә-тирә мохит б-н бәйләнешен өйрәнүче фән. Биологиянең состав өлеше. Тикшеренүләрнең бурычларыннан чыгып, З.не түбәндәге төп тармакларга: систематика, морфология, физиология, эмбриология, хайваннар экологиясе, зоогеография, палеозоология һ.б.; тикшеренү объектлары буенча умырткасызлар З.сенә һәм умырткалылар З.сенә, тагын да бүлеп, энтомология, ихтиология, герпетология, орнитология һ.б.га аералар.

Фән буларак, Борынгы Грециядә барлыкка килгән З. 500 гә якын хайван төрен аерган, аларны классификацияләү буенча беренче омтылыш ясаган Аристотель исеме б-н бәйле (б.э.к. 384–322 еллар). Яңарыш чорында З. шактый үсеш ала. 16–17 йөзләрдә хайваннарның күптөрлелеге, аларның төзелеше, яшәү рәвеше турында белемнәр туплана; микроскоп уйлап табылгач, микроскопик хайваннар дөньясы ачыла. Хайваннар дөньясының хәзерге системасына нигез 17 йөз ахыры — 18 йөзнең беренче яртысында, барыннан да элек хайван төрләре исемнәренә икеләтелгән номенклатура кертүче К.Линней (1707–78) хезмәтләрендә салына. Табигать турындагы башка фәннәр кебек үк, Россиядә З. үсешенә император Пётр I нең яңалыклар кертүе, аерым алганда, Россиядә беренче зур музей-Кунсткамера һәм 1724 елда Петербург ФАнә нигез салыну, аннары Казан губернасында оештырылган *академия экспедицияләре* (П.С.Паллас һ.б.) этәргеч бирә. Татарстан терр-ясендәге хайваннар дөньясы турындагы беренче мәгълүматлар П.И.Рычковка карый («Оренбург губернасының топографиясе», «Топография Оренбургской губернии», ч. 1–2, СПб., 1762).

19 йөздә Казан ун-ты Россиянең Европа өлеше көнчыгышындагы хайваннар дөньясын фәнни тикшерү үзәгенә әверелә. 1806 елда К.Ф.Фукс анда З.не укыта башлый һәм *зоология музее* нигезен тәшкил итүче зоология коллекциясен җыю эшенә керешә. Соңрак хәзерге вакытта төп 5 фәнни юнәлешкә бүленгән Казан зоология мәктәбе барлыкка килә.

Эволюцион-морфология юнәлешенең башында умырткалы һәм умырткасыз хайваннарның эмбриологик һәм физиологик үсеш закончалыкларын чагыштырма өйрәнүгә нигез салучы А.О.Ковалевский (бу төркемнәрнең эволюцион якынлыгын исбатлый һәм умырткасызларның фагоцитар органнарын ача), В.В.Заленский (хезмәтләре умырткасызлар һәм балыклар нерв системасының чагыштырма эмбриологиясенә карый), Э.А.Мейер (диңгезләр фаунасын һәм бөҗралы суалчаннар эмбриологиясен тикшерә), Казан зоолог-морфологлар мәктәбенә нигез салучы, ун-тның зоотомия кабинетын оештыручыларның берсе М.М.Усов (балыкларның, сөрүләләрнең, башаяклы моллюскларның нерв системасын тикшерү б-н шөгыльләнә) торалар. 19 йөз ахырыннан бу юнәлешне: морфологияне, планарияләрнең һәм турбелляриләр систематикасын өйрәнүче И.П.Забусов; соңрак хайваннар морфологиясендә экологик-функциональ юнәлешкә нигез салучы һәм күп күзәнәкле хайван типлары берләшмәләрен анализлау алымын эшләүче Н.А.Ливанов; 1970 еллардан — электрон микроскопия алымын кулланып, А.И.Голубев җитәкчелегендәге умырткасызлар З.се кафедрасы хезмәткәрләре үстерәләр.

Тетраподология фәнни юнәлеше (җир өсте умырткалы хайваннарын өйрәнү) тарихы 19 йөзнең 1 нче чирегендә Э.И.Эйхвальд һәм Э.А.Эверсман хезмәтләре б-н башлана. Соңгысының «Оренбург өлкәсенең табигый тарихы» («Естественная история Оренбургского края») хезмәте — ландшафт географиясе өлкәсендә фундаменталь (ч. 1, Оренбург, 1840) һәм ш.у. төбәктәге имезүчеләр һәм кошлар фаунасы буенча беренче җыентык була (ч. 2, 1850; ч. 3, 1866). 1860 еллар ахырыннан тикшеренүләрне орнитолог һәм зоогеограф М.Н.Богданов (Н.П.Вагнер б-н бергә 1869 елда Казан ун-ты каршында Табигыятьчеләр җәмгыятенә нигез сала) һәм 25 ел буе Казан губернасы һ.б. төбәкләр фаунасын өйрәнгән М.Д.Рузский дәвам иттерә. 1920 еллардан соң бу юнәлешне А.А.Першаков һәм аның күпсанлы шәкертләре һәм тарафдарлары — Татарстанның, Урта Идел, Урал буе төбәкләренең умырткалы хайваннар фаунасын, биологиясен, аларны нәтиҗәле куллану, саклау һәм торгызу мәсьәләләрен өйрәнүче эколог-тетраподологлар И.С.Башкиров, Д.И.Асписов, Н.Д.Григорьев, В.П.Теплов, В.И.Тихвинский, И.В.Жарков, В.А.Попов, соңгысының шәкертләре һәм хезмәттәшләре: Н.П.Воронов, Ю.К.Попов, Г.П.Приезжев, Т.М.Кулаева, В.И.Гаранин, Ю.Е.Егоров, Ю.Т.Артемьев, В.Г.Ивлиев, Ә.С.Әюпов, П.К.Горшков, Ю.А.Горшков һ.б. дәвам иттерәләр. Имезүчеләр, кошлар, амфибияләр турында басмалар чыга (к. *Хайваннар дөньясы*).

19 йөз ахырыннан Казан ун-тында А.А.Остроумов эшчәнлеге нәтиҗәсендә гидробиология юнәлеше формалаша башлый. 1916 елда Зөя елгасы тамагы янында ун-тның зоология станциясе оештырыла (к. «*КДУ зоостанциясе*»). Ихтиофауна һәм балык ресурсларын нәтиҗәле файдалану (М.Е.Маку-

шок, А.Я.Недошивин, А.В.Лукин), Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының экосистемасы формалашу процесслары (А.В.Лукин, В.А.Кузнецов, А.А.Попов, Ю.М.Махотин, Э.П.Цыплаков һ.б.), диңгез һәм төче су умырткасызларының фауна һәм биоэкология аспектлары (В.В.Изосимов, Х.М.Корбангалиева, Н.А.Порфирьева, Р.Я.Дыганова һ.б.) өйрәнелә.

Төбәктәге җир өсте умырткасызларын беренче өйрәнүләр 19 йөзнең 2 нче яртысына һәм 20 йөз башына карый. Умырткасызларда педогенез күренеше ачыла (Н.П.Вагнер, 1862), З.нең һәм энтомологиянең гомуми мәсьәләләре (Н.М.Мельников), урман корткычлары (Н.В.Шмелёв) өйрәнелә. 1905–07 елларда М.Д.Рузскийның 2 кисәктән торган «Россия кырмыскалары» («Муравьи России») монографиясе басыла. 1950 еллардан СССР ФА Казан ф-лының Биология ин-тында туфрак З.се — туфрак умырткасызларының фаунасы, зоогеографиясе, саны, әһәмияте (М.М.Алейникова, Н.М.Утробина, Т.И.Артемьева), Казан ун-тында мицетобионтлар — гөмбәләрдә яшәүчеләр буенча (А.Б.Халидов) өйрәнүләр үткәрелә башлый.

М.И.Волкованың төбәктәге парканатлы канәүкечләр фаунасын һәм экологиясен тикшеренүләреннән соң паразитология фәнни юнәлеше туа (1940 еллар). Борчалар (И.В.Назарова, 1981), иксод талпаннары (В.А.Бойко һ.б., 1982), вак имезүчеләр эктопаразитлары (И.В.Назарова, В.И.Борисова, 1992), кошлар эктопаразитлары (ред. В.А.Бойко, 1991), кеше һәм хайваннарда урынлы-табигый авыруларның паразит комплекслары трансформациясе (ред. В.А.Бойко, 2001) буенча басмалар, ш.у. хайван эндопаразитлары турында күпләгән хезмәтләр басыла (В.Г.Эвранова, В.Л.Вагин, О.Д.Любарская, М.И.Смирнова, Ф.Г.Соколина һ.б.).

З. хайваннар дөньясын саклауда һәм файдалануда, а.х. һәм урман культураларына зыян салучы, кеше һәм хайваннарда куркыныч авырулар китереп чыгаручы төрләрнең санын җайга салу ысулларын эшләүдә фәнни нигез булып хезмәт итә. Ул мед., вет., а.х. б-н тыгыз бәйләнгән; аның кайбер бүлекләре паразитология, гидробиология һ.б. кебек комплекслы фәннәрнең состав өлешенә керә. Татарстанда зоологик тикшеренүләр, нигездә, Казан ун-тында, ТР ФА каршындагы Экология һәм җир асты байлыклары проблемалары ин-тында, Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-тында, Казан вет. медицинасы академиясендә, Татар гуманитар-педагогика ун-тында, Идел-Кама табигать саклаулыгында, тармак учреждениеләрендә алып барыла.

*Әд.:* Остроумов А.А. К истории зоологического кабинета Казанского университета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1926. Т. 86, кн. 1; Шмидтов А.И. Кафедра зоологии позвоночных // Уч. зап. Казан. ун-та.. 1960. Т. 120, кн. 3.

*В.И.Гаранин, В.А.Бойко.*

**ЗООЛО́ГИЯ МУЗЕ́Е**, Э.А.Эверсман исемендә, Казан ун-тының биология-туфрак ф-ты составындагы кафедраара фәнни уку-укыту бүлекчәсе. Музей статусын 1945 елда табигать фәннәре тарихы һәм



Музей экспозициясенең беренче залы. А.О.Ковалевскийның мәрҗәннәр коллекциясенең бер өлеше.

зоотомик коллекцияләр кабинетларын берләштерү нәтиҗәсендә ала. 2004 тән Э.А.Эверсман исемендә. Төп бинаның көнчыгыш ягындагы 8 залны били. Ике бүлектән тора: умырткалы (5 меңләп берәмлек) һәм умырткасыз (43,5 меңләп берәмлек) хайваннар. Экспозиция структурасы таксономик билгеләре буенча төзелгән (умырткалылар өчен — семьялык, ассемьялык; умырткасызлар өчен, башлыча, отрядлар дәрәҗәсендә).

З.м.ның барлыкка килү тарихы 1798 дә император Павел I фәрманы нәтиҗәсендә Казанның Беренче ир балалар гимназиясе тапшырган коллекцияләрдән башлана. 1819 да 133 берәмлек имезүчеләр, кошлар, сөйрәлүче хайваннар, буынтыгаяклылар һәм суалчаннар исәпләнә. Соңрак К.Ф.Фукс Ф.К.Броннерның 578 кабырчыктан торган конхиологик тупланмасын сатып ала; шуларга Э.И.Эйхвальдның Арал-Каспий экспедициясе вакытында җыйган зоология һәм палеонтология коллекцияләре өстәлә. 1828–60 та музей үсешендә Э.А.Эверсман эшчәнлеге мөһим роль уйный, ул эшләгән елларда зоология коллекцияләре системалаштырылган тупланма рәвешен ала; шәхси коллекционерлардан һәм Германиядән, бигрәк тә Гамбургтагы сәүдә фирмасы хуҗасы Брандтан сатып алынган кыйммәтле экспонатлар б-н шактый тулыландырыла. 1844 нең 1 гыйнварына музейда 5735 әйбер исәпләнә, аннан соңгы 10 ел эчендә тагын 400 гә якын экспонат, ш.и. 57 берәмлек имезүче хайваннар һәм 208 берәмлек кошлар коллекциясе өстәлә. Моннан соңгы елларда кабинет б-н Н.П.Вагнер (1860–71), Н.М.Мельников (1871–97) җитәкчелек итә. Соңгысы вакытында атаклы химик А.М.Бутлеров тәңкә канатлылар коллекциясен (1138 төр) бүләк итә, 157 берәмлек диңгез хайваннары (башлыча, умырткасызлар) коллекциясе сатып алына. 1890–97 дә Казан губернасыннан 978 берәмлектән торган кошлар коллекциясе җыела (М.Д.Рузский, И.Н.Стрельников, С.О.Билькевич). 20 йөз башында А.А.Остроумов җитәкчелегендә беренче тапкыр кошларның (С.Д.Лавров, 1907, 1911), балыкларның (В.И.Мейснер, 1907) системалы каталоглары төзелә. Чагыштырма анатомия укытыла башлау б-н 1843 тә П.И.Вагнер җитәкчелегендә зоотомия кабинеты төзелә (соңрак Н.П.Вагнер һәм В.В.Заленский җитәкли). 1850 гә анда умырткалылар буенча — 818, умырткасыз хайваннар буенча 100 остеология, спланхнология, антология һәм неврология препаратлары исәпләнә. 1883–1900 дә кабинетның коллекциясе М.М.Усов җыйган бай материал б-н тулыландырыла. 1906–07 дә ун-тның төп бинасын үзгәртеп кору вакытында залларны төзекләндерүдә һәм аннан



Энәтиреләләр коллекциясенең бер өлеше.

соң зоотомия кабинетын җиһазландыруда Э.А.Мейер һәм Н.А.Ливанов актив катнашалар. Соңгысының инициативасы б-н 1945 тә зоология музее барлыкка килә. Музей төзелешендә аның мөдирләре Г.П.Приезжев (1950–60), А.В.Попов (1960–91), таксидермистлар П.Романов, Э.Д.Пельцам, Я.П.Коксин, Е.В.Прохоров зур өлеш кертәләр. З.м.ның фәнни һәм мәдәни әһәмияткә ия коллекцияләре хайваннар дөньясының күптөрлелеген (иң түбән төзелешле бер күзәнәклеләрдән алып приматларга кадәр) тулы итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Материалларының байлыгы буенча музей РФдәге тармак музейлары арасында алдынгы урыннарның берсен алып тора. Анда барлык континентлар фаунасының Кызыл китапларга кертелгән дөньякүләм әһәмиятле эндемик һәм реликт төрләре тупланган: элеккеге СССР терр-ясендәге парнассиусларның уни-



Имезүче хайваннарга багышланган зал.



Орнитология залы.

каль коллекциясе, император җилкәнканаты, голиафлар, геркулеслар (аеруча эре коңгызлар), Мәдинә кысласыманнары, Тын океандагы Хуан-де-Фука сыртыннан китерелгән вестиментифера, оча торган кәлтә (Ява утравыннан), гаттерия, игуаналар, Малайя чукырчасы, кызыл бүксәле казарка, кара гриф, стерх, зәңгәр бугазлы попугай, киви, ехидна, үрдәкборын, җофарлар, кар барсы һ.б. тупланган. 150 еллар элек юкка чыккан (дөньяда 10 лап кына карачкы-экспонат сакланган) тау зебрасы (Equus quagga) — З.м.ның горурлыгы булып тора. Музейның тарихи әһәмияте зур; монда мәшһүр галимнәр эшләгән, экспонатлар коллекциясе препаратлау сәнгатенең, таксидермиянең барлыкка килүен һәм үсешен тасвирлый.

*Әд.:* Остроумов А.А. К истории Зоологического кабинета Казанского университета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1926. Т. 86, кн. 1; Ливанов Н.А. Кафедра зоологии беспозвоночных // шунда ук. 1960. Т. 120, кн. 3; Шмидтов А.И. Кафедра зоологии позвоночных // шунда ук. С. 65–74; Гаранин В.И. Зоомузей Казанского университета и изучение фауны позвоночных // Музей и личность. Сыктывкар, 1994; шул ук. Э.А.Эверсман и Зоологический музей Казанского университета // Животный мир Южного Урала и Северного Прикаспия. Оренбург, 1995.

*В.И.Ануфриев.*

**ЗООТЕ́ХНИЯ** (*зоо...* һәм грекча te̒chne — сәнгать, осталык), а.х. терлекләрен үрчетү, тукландыру, асрау, файдалану һәм яңа нәселләр булдыру, терлекчелекнең теоретик асылы турындагы фән. Фәнни тикшеренүләр (респ-када терлекчелек торышын өйрәнү, продуктив сыйфатлы нәселләрне ачыклау һәм аларны тагын да камилләштерү юлларын табу) 1930 елда Казан вет. ин-тында зоотехния ф-ты ачылу б-н башлана.

1930–2004 елларда мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык, ат һәм куяннарның токымнарын кушу юлы, ш.у. чиста токым үрчетү алымы б-н эш итеп, терлекләрнең хуҗалыкка файдалы сыйфатлары, биологик үзенчәлекләре һәм җирле шартларга яраклашуы өйрәнелә. Болар нәсел үрчетүне максатчан алып бару һәм Татарстан өчен а.х. терлекләрен районлаштыру планын төзү мөмкинлеге бирә (И.П.Попов, В.М.Пичугин, П.Я.Сырнев, Н.Н.Солдатов, Ә.Х.Фазылҗанов, А.Ф.Минькин, А.М.Барсков, А.П.Онегов, Г.А.Палкин, Б.В.Галиев, А.П.Солдатов, А.Н.Калмыков, Н.А.Габитов, Р.Г.Хәйретдинов, Г.С.Шәрәфетдинов (1920–2008)). Ш.у. мөгезле эре терлекләрнең — бестужев, холмогор, швиц һәм кара-чуар токымнарының — нәселдән күчемлелеге, коррелятив үзгәрүчәнлеге, барлык планлаштырылган токым терлекнең, ш.у. аерым линияләр кысасында продуктлылыгының башка селектив-генетик күрсәткечләре, интерьер үзенчәлекләре, сөт бирүчәнлеге, экстерьеры, конституцияләре өйрәнелә (Г.А.Палкин, Л.К.Бурая, Г.Х.Җамалетдинов, Н.А.Габитов, Г.С.Шәрәфетдинов), мөгезле эре терлекне селекцияләүнең отышлы ысуллары эшләнелә (1980–2008).

Дуңгыз асраучылык турында тикшеренү эшләрен Казан зоотехния мәктәбе вәкилләре Ф.Ф.Федотов, З.А.Ротэрмель, А.К.Рәсүлев, Л.К.Бурая, В.А.Хлебов, В.Ш.Әскәров, Д.Ш.Фазлыев, М.С.Игнатов, Е.А.Ковальчук, Д.У.Бикташев алып бара (1930–2002). Алар тарафыннан төрле тип тукландыруның дуңгызларның үсүенә, продуктлылык сыйфатына тәэсире; протеинлы тукландыру дәрәҗәсе, рационнарның аминокислоталы һәм витаминлы составы; токымнарны интенсив үрчетү һәм камилләштерү: дуңгыз балаларын анадан иртә аеру, эре ак, эре кара, уржум, ак озынколаклы, эстон беконы, брейт һ.б. нәсел дуңгызларын сәнәгый нигездә кушып үрчетү ысуллары өйрәнелә. Мәс., эре ак дуңгыз токымын чиста үрчетеп, яхшы ит һәм симертү сыйфатларына ия булган нәселне дәвам иттерүче линияләр, гаиләләр, ата-ана парлары ачыклана.

1948–49 да П.Я.Сырнев җитәкчелегендә ТАССРда сарыкларны токымара кушу нәтиҗәләрен өйрәнү экспедициясе үткәрелә. 1945–60 та күп йон һәм ит бирүе б-н аерылып торган яңа токымлы сарыклар чыгарыла (П.Я.Сырнев, А.П.Солдатов, Б.В.Галиев). 1961–90 да прекос токымлы сарыклар нәселен һәм продуктлылыгы сыйфатын яхшырту эшләре башкарыла (Ә.Х.Фазылҗанов, Н.И.Брунко). 1968–98 дә Татарстанда үрчетелә торган барлык сарыклар сынала, аларны илдәге һәм чит илләрдәге токымнар б-н кушу нәтиҗәләре өйрәнелә; яшь-җенес төркемдәгеләренең һәрберсе өчен тукландыру рационы эшләнә, үсеп җиткән сарыкларны һәм интенсив рәвештә үстерелә торган алмаш бәрәннәрне симертү өчен концентрат азыклар нормасы, сарыклар асрау технологиясенең башка юллары өйрәнелә (Ә.Х.Фазылҗанов, А.Ф.Минькин).

1960–72 дә бройлерлар җитештерүдә файдаланыла торган үзебезнең һәм чит ил тавык токымнарының ит юнәлешендәге линияләре продуктлылыгы өйрәнелә. Ак рус, айланд токымлы тавыкларның нәсел сыйфатларын бәяләү һәм яхшырту эшләре үткәрелә. Йомырка сала торган тавыкларны файдалану чорының икътисади нигезләмәсе булдырыла (П.А.Ситников, Е.П.Трухина, С.И.Лонщаков).

Татарстан куянчылыкны сәнәгый нигезгә күчерүдә әйдәп баручылардан санала. 1971 дә Н.Б.Вәлиев җитәкчелегендә механикалаштырылган беренче куян фермасы төзелә һәм аның «Куянчылыкны сәнәгый нигездә оештыру һәм аның отышлы яклары» («Организация кролиководства на промышленной основе и её эффективность», 1974), «Куянчылыкны — сәнәгый нигезгә» («Кролиководство на промышленную основу», 1975) исемле китапларында куянчылык продукциясе җитештерүнең яңа технологияләрен булдыру тәҗрибәсе тасвирлана. 1960 еллардан җәнлекләрнең күп үрчем бирүче нәселен үрчетүнең сәнәгый һәм икътисади отышлылыгын өйрәнү үткәрелә. Куяннарның (ак зур, көмешсыман) һ.б. җәнлекләрнең токымнарын камилләштерү системасы, аларны асрау технологияләре эшләнә (И.И.Каплевский, Ф.В.Никитин, Г.А.Палкин, М.Н.Юдин, Ә.Х.Җаббаров).

Авыл хуҗалыгы терлекләрен яңадан үрчетү һәм ясалма аталандыру мәсьәләләрен өйрәнүдә мөһим нәтиҗәләргә ирешелә. 1930–60 та А.П.Студенцов тарафыннан хайваннарның кысыр калуы сәбәпләренең тәгълиматы булдырыла, яңа үрчем булдыру мәсьәләләре буенча оештыру-хуҗалык, зоотехника һәм дәвалау-профилактика чаралары комплексы тәкъдим ителә; югары уку йортлары өчен СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Ветеринарное акушерство и гинекология» (М., 1949) дәреслеге бастырып чыгарыла.

1950–90 да терлекчелек биналары гигиенасы мәсьәләләре буенча тикшеренүләр (В.М.Пичугин, П.Т.Маширов, Ю.И.Дударев, Н.А.Нефёдов) үткәрелә.

Казан вет. ин-тында, Казан а.х. ин-тында, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында азык әзерләү ысуллары (химик консервлау, чүпрә б-н эшкәртү) һәм аның сыйфатын бәяләү критерийлары (химик составы, ашказанында эшкәртелгән протеин, витаминнар, минераль матдәләр микъдары), терлекләрне тукландыру системасын эшләү, тукландыру максатында хлорелла, сапропелларны файдалану мөмкинлеге өйрәнелә (А.М.Барсков, С.Н.Рәхмәтуллин, Л.П.Зарипова, Ш.К.Шакиров, И.Ф.Таняшин), болын һәм көтүлекләрнең уңдырышлылыгын арттыру юллары билгеләнә (Ү.А.Биктимеров, Ф.Х.Хәбибуллин, М.М.Маликов).

1980–2000 дә Татарстанда З. үсешенең төп үзенчәлекләре булып терлекләрне төгәл генетик ысуллар б-н бәяләү һәм югары сыйфатлы нәсел үрчетүчедән актив рәвештә файдалану нигезендә эре масштаблы селекция эшләрен гамәлгә кертү, ш.у. ЭВМ ярдәмендә нәсел яхшырту эше б-н идарә итү алымын куллану тора. Болар исә терлекләрнең яңа токымнарын, типларын, линия, гибрид һәм кроссларын булдыру, булганнарын камилләштерү процессын тизләтү мөмкинлеге бирә.

З. буенча фәнни тикшеренүләр Казан вет. медицинасы академиясендә, Казан аграр ун-тында, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында үткәрелә.

*Әд.:* Григорьев Н.В. Животноводство Татарии: опыт, проблемы, перспективы. К., 1976; Фазульзянов А.Х. Овцеводство в условиях интенсивного земледелия. К., 1976; Палкин Г.А., Чернышёв Н.Р. Внедрение достижений Казанской зоотехнической школы в практику животноводства. К., 1980; Палкин Г.А., Герасимов И.С., Чернышёв Н.Р. Достижения науки — в практику животноводства. К., 1982; Мухаметгалиев Н.Н. Зооинженерному факультету 70 лет // Современные проблемы животноводства. К., 2000.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ЗО́РИН** Александр Николаевич (19.3.1961, Тула ш.), этнограф, тарихчы, тарих фән. д-ры (1992), проф. (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1986 елдан Казан, 1994 тән Ульянов ун-тларында эшли. Хезмәтләре Идел буе шәһәрләре тарихына һәм этнографиясенә карый. Этнография буенча уку ярдәмлекләре авторы.

Хезм.: Уездные города Казанского Поволжья. К., 1989; Горожане Среднего Поволжья во второй половине XVI — начале XX вв. К., 1992; Основы этнографии. К., 1994; Очерки городского быта дореволюционного Поволжья. Ульяновск, 2000 (автордаш); Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

**ЗО́РИН** Николай Владимирович (25.2.1923, Чуаш Респ-касы Норусово а., хәзерге Калинино а. — 8.5.2006, Казан), этнограф, географ, тарих фән. канд. (1969), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли: этнография музее мөдире (1963 елга кадәр), 1965 тән физик һәм икътисади геогр. кафедралары, 1980 нән физик геогр. каф. доценты. Хезмәтләре Урта Идел буенда яшәүче русларның этнографиясенә карый. Урта Идел буе халыклары этнографиясе буенча уку ярдәмлекләре авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Русское население Чувашской АССР. Чебоксары, 1960 (автордаш); Общественный и семейный быт русского сельского населения Среднего Поволжья. К., 1973 (автордаш); Русская свадьба в Среднем Поволжье. К., 1981. Очерки городского быта дореволюционного Поволжья. Ульяновск, 2000 (автордаш); Русский свадебный ритуал. М., 2001; Этнография в Казанском университете. К., 2002 (автордаш).

**ЗО́РИНА** Светлана Олеговна (24.12.1967, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Геол.-минерал. фән. канд. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1990), Якутия геол. идарәсендә эшли. 1994 елдан ЦНИИгеолнерудта, гыйльми секретарь (2003 тән). Хезмәтләре мезозой геологиясе һәм стратиграфиясенә карый. Дәүләт бүләге «Татарстан геологиясе: Стратиграфия һәм тектоника» («Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника», К., 2003, автордаш) монографиясе өчен бирелә.

**ЗОТЕ́ЕВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Провальная Яма исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 119 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 334, 1897 дә — 251, 1908 дә — 241, 1920 дә — 276, 1926 да — 250, 1938 дә — 234, 1949 да — 174, 1958 дә — 95, 1970 тә — 77, 1979 да — 47 кеше.

**ЗО́ТОВ** Александр Васильевич (5.5.1936, Ульянов өлкәсе, Карсун р-ны Потьма а.), ташчы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1986). Ульянов мастерлар мәктәбен тәмамлый (1953). 1959–71 елларда «Южуралтяжстрой» трестында (Оренбург өлкәсе Медногорск ш.) эшли. 1971–93 тә «Камгэсэнергострой» АҖнең 51 нче төзү-монтаж идарәсендә ташчылар бригадиры. Бөтенсоюз смотры нәтиҗәләре буенча З. бригадасы архит-ра һәм төзелеш өлкәсендә яхшы сыйфатлы эшләре өчен СССР МСы дипломы б-н бүләкләнә (1973). Дәүләт бүләге хезмәттә ирешкән казанышлары, яңа техника үзләштерү нигезендә энергетика куәтләрен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен бирелә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б е л я е в Р.К. Подвиг на Каме. К., 1978; Товарищ плакат. М., 1979.

**ЗО́ТОВ** Василий Никитич (1669, Мәскәү — 1729, шунда ук), дәүләт һәм хәрби эшлекле, генерал-майор (1725). Дворяннар нәселеннән. 1687 дән хәрби хезмәттә. 1700–21 еллардагы Төньяк сугышында катнаша. 1708 елдан — Нарва, 1711–14 тә Ревель коменданты. 1715–18 дә Сенат генерал-ревизоры. 1718–24 тә Халык санын исәпкә алу эшләре канцеляриясе башлыгы. Россия империясендә 1 нче ревизия — ир-атлар санын исәпкә алуны (ш.и. Казан губ. терр-ясендә дә) үткәрүгә күзәтчелек итә. Җирле халык санын исәпкә алганда күпләгән бозуларны ача. 1725–27 дә Мәскәү сарай мәхкәмәсе президенты. 1727–28 дә Казан губернаторы. Губернаның рус булмаган милләтләре һәм калмыклар өстеннән күзәтчелекне көчәйтеп, башкортларның баш күтәрүен булдырмаска тырыша. Әстерхан шәһәрендә үлат афәте вакытында аның боерыгы б-н карантин постлары куела, шуның нәтиҗәсендә Казан төбәгендә авыру таралуга юл куелмый. Аның заманында 1727 дә Вятка һәм Соликамск провинцияләре Казан губернасы составына кертелә. 1728 дән Мәскәүдә.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1855. Ч. 2; Л ю б и м о в С. Опыт исторических родословий. П., 1915.

**ЗО́ТОВ** Василий Сергеевич (12.9 (башка мәгълүматларда 30.1) 1882, Түбән Новгород ш. — 4.4.1932, Смоленск ш.), драма актёры, педагог, режиссёр, Республиканың (РСФСР) атказ. артисты (1926). Рус провинциаль театрларының күренекле актёрларыннан берсе. Түбән Новгород коммерция уч-щесен тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1898 елда Түбән Новгород сәнгать клубы труппасында башлый, беренче сәхнә дәресләрен М.Ф.Андреевадан ала. 1901 дә К.Н.Незлобин труппасына керә (Вильно-Рига, 1901–05), реж. К.А.Марджанов җитәкчелегендә эшли, М.Горький әсәрләре буенча куелган «Дачада яшәүчеләр» һәм «Тормыш төбендә» спектакльләрендә Влас һәм Васька Пепел рольләрен башкара. 1910 нан бер үк вакытта режиссёр буларак та эшли. Казанда З.А.Малиновская (1913–15), В.Ф.Каразина (1917–18) труппаларында уйный, Яңа театрда актёр һәм сәнгать җитәкчесе була. Незнамов, Жадов, Тихон, Андрей Белугин, Великатов, Васильков («Гаепсездән гаеплеләр», «Төшемле урын», «Яшенле яңгыр», «Белугинның өйләнүе», «Талантлар һәм аларга баш июучеләр», «Котырган акчалар», А.Н.Островский), Рогожин, Дмитрий Карамазов («Идиот», «Карамазовлар», Ф.М.Достоевский), Иванов, Астров, Лопахин, Тузенбах («Иванов», «Ваня абый», «Чия бакчасы», «Өч сеңел», А.П.Чехов), Никита, Федя («Караңгылык патшалыгы», «Тере мәет», Л.Н.Толстой), Онуфрий, Сторицын («Карт студент», «Профессор Сторицын», Л.Н.Андреев) рольләрен башкара. Замандашлары фикеренчә, З. «тамашачыны үзенең искиткеч көчле темпераменты..., гади һәм ихлас күңелдән уйнавы б-н җәлеп итә ...» («Известия ТатЦИКа», 1923, 31 гыйн.). 1919–24 елларда З. — Казан Зур драма театрында актёр, режиссёр, директор. Аның ярдәме б-н театрда студия оештырыла, нәтиҗәдә Казан театрында беренче даими эшләүче труппа формалаша. Профессиональ әзерлеге, башкару осталыгы ягыннан театр бу елларда башка провинциаль театрлар арасында иң яхшыдан санала. 1921 нең җәендә З. пароходта «Йөзмә театр» булдыра, Казан пр-тиеләре эшче-хезмәткәрләренең театрга күмәк йөрүләрен оештыруны гамәлгә кертә. Казан Зур драма театрында шактый спектакльләр куя: Н.В.Гогольнең «Ревизор» (1922), И.С.Тургеневның «Дворяннар оясы» (1923), А.К.Толстойның «Патша Фёдор Иоаннович» (1923), А.Н.Островскийның «Козьма Захарьич Минин-Сухорук» (1914), «Талантлар һәм аларга баш июучеләр» (1921), «Белугинның өйләнүе» (1921), Л.Н.Толстойның «Мәгърифәт җимешләре» (1920), «Тере мәет» (1921), А.Н.Толстойның «Анфиса» (1922), «Касатка» («Яр карлыгачы», 1922), С.А.Найдёновның «Ванюшин балалары» (1922), Ф.М.Достоевскийның «Идиот» (1923), Л.Н.Андреевның «Карт студент» (1923), «Тормышыбыз көннәре» (1924). Театр каршындагы студиядә, Югары Халык мәгарифе ин-тында укыта. Казан Зур драма театрының баш режиссёры һәм сәнгать җитәкчесе буларак, Казан театры тормышында, үсешендә шактый роль уйный. 1924–25 тә Одесса шәһәре театрында, 1926–30 елларда Әстерхан шәһәре театрында эшли.



В.С. З о т о в Илья ролендә (А.Н. Толстой, «Касатка»).

*Әд.:* Смоленская область. Т. 1. Персоналии: Энцикл. Смоленск, 2001.

*Ю.А.Благов.*

**ЗО́ТОВ** Михаил Егорович (21.11.1903, Казан губ., Тәтеш өязе, хәзер Тәтеш р-ны Нармонка а. — 25.1.1988, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1948). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945–47 елларда Тәтеш р-ның «Новый мир» к-зында баш агроном, 1947–58 дә колхоз рәисе, 1958–66 да Нармонка авыл советы рәисе. Герой исеме


М.Е.Зотов.


Н.И.Зотов.

бөртекле культуралардан югары уңышка ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Нармонка авылының бер урамы З. исеме б-н атала.

*Әд.:* К р ы л о в В. Организатор производства // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1948. Кн. 1; Б е л о к о п ы т о в В. Зотов Михаил Егорович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЗО́ТОВ** Николай Иванович (4.12.1917, Казан губ., Тәтеш өязе Иске Колмәт а. — 30.10.1993, Болгар ш.), Дан орденының тулы кавалеры (18.2.1944, 29.7.1944, 24.3.1945), гв. старшинасы (1945). Тәтеш зоотехниклар техникумын тәмамлый (1938). Алексеев р-нында зоотехник булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 48 нче гв. кавалерия полкы артиллерия расчёты командиры (13 нче армиянең 13 нче гв. кавалерия дивизиясе). Үзәк, Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Днепр өчен барган (1943) сугышларда, Украинаны, Польшаны азат итү һәм Венгрия, Берлин һөҗүм операцияләрендә (1945) катнаша. 1944 нең 31 гыйнварында Олыка авылы (Украина ССР, Волынь өлкәсе Киверцы р-ны) өчен булган сугышта (дошманның 3 автомобилен сафтан чыгара); 1944 нең 30 мартында Гай хуторы (Украина ССР, Львов өлкәсе Броды р-ны) тирәсендәге сугышта (дошманның 2 бронетранспортёрын, 2 автомобилен, танкын яндыра); 1944 нең 8–9 октябрендә Дебрецен шәһәре (Венгрия) өчен барган сугышта (дошманның бронемашинасын, бронетранспортёр һәм танкын сафтан чыгара) батырлык күрсәтә. Сугыштан соң совхозда баш зоотехник булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Октябрь Революциясе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лобода В.Ф.Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды Славы. К., 1969; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ЗӨБӘЕ́Р** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасы буенда. 2008 елда 308 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, иген-


Д.М.Зөбәеров.

челек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. Мәчет беренче тапкыр 1813 тә телгә алына. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3832 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 214, 1834 тә — 378, 1859 да — 623, 1870 тә — 687, 1884 тә — 1009, 1897 дә — 1077, 1913 тә — 1370, 1920 дә — 1260, 1926 да — 855, 1938 дә — 733, 1949 да — 548, 1958 дә — 540, 1970 тә — 708, 1979 да — 522, 1989 да — 317, 2002 дә — 288 кеше.

**ЗӨБӘЕ́РОВ** Диләвәр Мирзагабдулла улы (5.9.1931, Казан — 22.9.2010, шунда ук), биохимик, мед. фән. д-ры (1965), ТР ФА академигы (1992), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1976, 1997). 1955 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1964 тән биохимия каф. мөдире, проф. (1966), А.Д.*Адо* шәкерте. Хезмәтләре кан оешуның патофизиологиясе һәм биохимиясенә карый. З. кан агышында актив тромбин ферменты әйләнешен ача. Ул организмда канның туктаусыз оешу процессы теориясен эшли, кан тамырларының эчке ягы даими чыланган булуны ача (1963), бу хезмәте РФ Дәүләт премиясенә лаек була (1991). З. кешенең кайбер авырулары вакытында күзәнәк мембраналарының көчле микровезикуляциясен ача. Шул күренеш нигезендә авыруларның халәтен диагнозлау ысулы эшләнелә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар. 1974 тән «Казанский медицинский журнал»ының баш мөхәррире. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. ТР ФАнең В.А.Энгельгардт исем. премиясе иясе.

Х е з м.: Свёртываемость крови. К., 1966; Биохимия свёртывания крови. М., 1978; Молекулярные основы свёртывания крови и тромбообразования. К., 2000; Микровизикулы в крови. Их функции и роль в тромбообразовании. М., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Дилявер Мирзабдуллович Зубаиров // Гематология и трансфузиология. 1992. № 2.

**ЗӨБӘЕ́РОВА** Диләрә Гази кызы (9.1.1930, Сарман р-ны Күтәмәле а. — 15.12.2000, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1952), Татарстан китап нәшриятында балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1955–59 елларда авыл мәктәбендә укытучы, район газеталарында әдәби хезмәткәр һәм тәрҗемәче. 1960–62 дә «Социалистик Татарстан» г-тасында, 1962–85 тә «Азат хатын» ж-лында бүлек мөдире. 1950 елларда «Яшь сталинчы» г-тасында беренче язмалары басыла. Күмәк җыентыкларда публицистик мәкаләләре дөнья күрә. Яшьләр тормышы б-н кызыксынуы аның «Кичер, сөеклем!» (1971), «Кызлар, кызлар» (1977), «Яшьләр күңеле» (1980) исемле җыентыкларына кергән хикәя һәм повестьларының төп темасын билгели. Публицистик мәкаләләре «Халкым хаклы» (1990) исеме б-н аерым китап булып басылып чыга.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӨБӘ́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дим елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,9 *км*, бассейнының мәйданы 54 *км²*. Бөгелмә р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Зур Покровка авылыннан көнчыгыштарак, тамагы Бәкер авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 130 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 27%. Зур булмаган 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км²*. Туенуы катнаш, кар сулары өлеше аз гына артык. Җир асты туендыру модуле 0,2–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Җәен елга еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы чыгымы 0,09 *м³/с*. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**ЗӨЛКАРНӘ́ЕВ** Ринат Габдулла улы (27.10.1932, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1988). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Арча р-н үзәк хастаханәсендә эшли. 1960 елдан Казан фәнни учреждениеләрендә: Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1964 тән Казан ГИДУВында, 1967 дән Казан мед. ин-тында, 1984 тән травматология, ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе каф. мөдире. Кортикостероидлар файдаланганда, катлаулы һәм күпсанлы җәрәхәтләнүләр өстәлгән эчке әгъзалар авырулары вакытында скелет сөякләре үзгәрешләрен тикшерә. Терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарлану һәм аларның авырулары вакытында экспресс эндопротезлау системасын эшли. З. илебездә җилкә-калак сөяге периартриты авыруларына багышланган беренче монография авторы. Уйлап табуга таныклыгы бар.

Х е з м.: Экспресс-эндопротезирование с использованием быстродействующих полимеров. К., 1984; Применение местных инъекций кортикостероидов. К., 1990.

**ЗӨЛКАРНӘ́Й** (Зөлкарнәев) Габдулла Галим улы (3.10.1905, Петропавловск ш. (хәзерге Казакъстан) — 6.9.1935, Казан), драматург. 1925 елдан Казанда яши. Татар театр техникумын тәмамлый (1930). 1930–34 елларда Сәнгать хезмәткәрләренең республика профсоюзы ҮК (ТАТРАБИС) рәисе. 1934 тә Татар укчы полкы взводы командиры, бер үк вакытта хәрби часть клубы мөдире. «Партизаннар», «Кан тамчылары», «Серләр чишел-

де», «Пычакка каршы пычак», «Өермә» (1932 елда Татар акад. театрында куела), «Ил чигендә» (1932), «Повар» (1933), «Ана» (1934) һ.б. пьесалар авторы.

*Әд.:* Өермә // Кызыл Татарстан. 1932. 2 нояб.

**ЗӨЛКАРНӘ́Й** Ләис Мәүлит улы (псевд., чын фамилиясе Харрасов) (2.4.1962, БАССРның Бакалы р-ны Саскүл (Бишкаен) а.), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1984). 1983–93 елларда (бүленеп) — «Ялкын», 1993 тән «Идел» ж-лларында бүлек мөхәррире. «Балачак күге» (1984), «Кар өстендә алмалар» (1988) исемле шигырь җыентыклары, ш.у. хикәяләр авторы. З.нең иҗатына нечкә лиризм хас, эмоцияләргә бай. А.Алиш исем. бүләге лауреаты (1990).

*Әд.:* Вәлиев М. Егермедәгеләр // Учагың сүнмәсен. К., 1988.

**ЗӨЛКАРНӘ́Й** (Зөлкарнәев) Фәез Мәүлит улы (4.12.1951, БАССРның Бакалы р-ны Сөендек а. — 18.7.1997, Казан), әдәби тәнкыйтьче, язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын (1979) һәм А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1989) тәмамлый. 1980–83 елларда «Ялкын» ж-лында бүлек мөхәррире, 1983–87 дә Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. 1989–97 дә «Идел» ж-лында (1990 нан баш мөхәррир). 1969 елдан район һәм респ-ка вакытлы матбугатында язмалары басыла башлый. 1979 дан «Идел» альманахында, «Казан утлары», «Ялкын» ж-лларында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре б-н чыгыш ясый. Татар язучыларының иҗатына һәм хәзерге әдәби процесска багышланган «Кешем, асылың кем?» (1984), «Әверелеш: шигырь парадокслары» (1988), «Чакма чакмый ут чыкмый» (1991), «Күләгә күбәләге» (2002) китаплары, «Мәхәббәт алмасы» (1997) исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

*Әд.:* Корбанов Р. Шигырь эзләп китте // Идел. 2001. № 11; Латыйфи Ф. Кеше китә — җыры кала // Идел. 2001. № 12.


*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӨЛКАРНӘ́ЙН** (гарәп. ذوالقرنين, сүзгә-сүз тәрҗемәсе — ике мөгезле), борынгы гарәп мифологиясендә, Шәрекъ һәм татар фольклорында Аллаһ тарафыннан көнбатыш һәм көнчыгышка яуга җибәрелгән герой. Ике якта да З., начар кешеләргә җәзасын бирә-бирә, яхшы кешеләргә ярдәм итә-итә, җир читенә кадәр барып җитә; көферлек таратучы яәҗүҗ һәм мәәҗүҗ халыкларыннан саклаучы дивар төзи. Кайбер мөселман динчеләре һәм хәзерге аерым тикшеренүчеләр З.не Александр Македонский б-н тиңләштереп карыйлар. З.не тасвирлаучы бер чыганак — Гарәбстанда исламның башлангыч чорында киң танылу тапкан «Искәндәр турында роман» әсәре. Башка чыганаклар булып борынгы гарәп мифологиясе һәм фольклоры тора. Аларда «З.» кушаматы Александр Македонскийга карата киң кулланылыш тапкан (Македония патшасының ике мөгезле борынгы Мисыр алласы Амон кыяфәтендәге сурәтеннән алынган дип фаразлана). Дини З. Иран мифологиясендә, Якын Көнчыгыш һәм Урта Азия халыкларының урта гасырлар әдәбиятында *Искәндәр* образының барлыкка килүенә юл ачкан. Аларда ул еш кына, Искәндәр З. дип, ике исем б-н йөргән. З. образы төрки-татар фольклорында («Картлар җыры» циклы, «Зөлкарнәен патша», «Мөгезле патша» әкиятләре, «Искәндәр Зөлкарнәен һәм патшабикә турында» дастан) һәм әдәбиятында (Т.Ялчыголның «Тәварихы Болгарийә» һәм Х.Әмирхановның шул ук исемдәге әсәре, Шәрифнең «Шаһнамә»се һ.б.) киң чагылыш тапкан.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1978. 2 кит.; Әмирхан Х. Тәварихы Болгария. К., 2000; Әхмәтҗанов М. Татар кульъязма китабы. К., 2000; Климович Л.И. Книга о Коране, его происхождении и мифологии. М., 1986; Пиотровский М.Б. Коранические сказания. М., 1991.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЗӨЛФӘ́Т** (псевд., чын исем-фамилиясе Маликов Дөлфәт Госман улы) (3.1.1947, ТАССРның Мөслим р-ны Яңа Сәет а. — 15.5.2007, Казан), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тында укый. А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1979) тәмамлый. «Чаян» ж-лында (1969–74), (1983–2007), «Яшь ленинчы» г-тасында (1979–83) әдәби хезмәткәр булып эшли. «Беренче карлыгачлар» җыентыгында (1968) тәүге шигырьләре басыла. «Язмышлар ярында» (1971), «Утлы бозлар» (1978) (русчага тәрҗемәдә «Осенние костры», 1985), «Адашкан болыт» (1990), «Ике урман арасы» (1995) исемле шигырь җыентыклары авторы. З. поэзиясендә чагылган темалар күптөрле. Шагыйрьне бигрәк тә татар халкының тарихи үткәне («Сөембикәнең хушлашу догасы», 1978; «Нәсел тамгасы», 1999), аның мәдәнияте һәм тел язмышы («Татар теленең каргышы», 1978) борчый. Шагыйрь күпләрнең тормышын бозган чорның фаҗигале вакыйгалары турында борчылып уйлана («Марш», 1986; «Халык дошманы турында бер истәлек», 1986; «1937», 1999), замандашларының эш-гамәлләрен бәяләргә омтыла, мәхәббәт турында күп яза. Аның әсәрләрендә тыелгысыз хисләр, экспрессив тәэсирлелек өстенлек итә. Ул чынбарлыктагы, табигатьтәге кечкенә генә деталь, факт, күренеш аша поэтик фикерне калку, колачлы итеп җанландыру осталыгына ия; аңа публицистик кайнарлык, ихласлылык, халык иҗатына, әкият, бәет, дастан, җырларга нигезләнгән романтик образлылык, җыйнак композиция, төзек ритмика хас; теле символ-метафораларга бай. З. — Һ.Такташ традицияләрен дәвам иттерүче романтик шагыйрь; «традицион» шигырь формаларына өстенлек бирсә дә, анда субъектив һәм кискен каршылыкларга корылган, үзенә генә хас үзенчәлек бар. Боз һәм Ялкын, Мәхәббәт һәм Нәфрәт, Яшәү һәм Үлем, Мизгел һәм Мәңгелек кебек төшенчәләрне чагыштырып бирү аша З. образлы фикерләү тудыра. Аның шигъриятендә һәрвакыт фәлсәфи төсмер өстенлек итә. З. — комп. Л.Хәйретдинова музыкасына «Мәкерле песи» (1974; ТАССРның М.Җәлил исем. комсомол премиясе, 1978) исемле беренче татар балалар операсы либреттосы, «Әкият» Казан курчак театрында куелган «Җен кызы»



Зөлфәт.

(1992), «Таңга — Чулпан, Айга — Зөһрә» (1999) пьесалары авторы да. Аның шигырьләренә Ф.Хатыйпов, З.Гыйбадуллин һ.б. композиторлар тарафыннан язылган җырлар халык арасында популярлык казанды. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2000).

Әсәр.: Йөрәгемне былбыл чакты. К., 1999.

*Әд.:* Шабаев М. Сандугач язмышлы шагыйрь // Казан утлары. 1996. № 5; Зәйдулла Р. Без гөл өзгән кырларда // Идел. 2000. № 2; Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы // Казан утлары. 2007. № 1.

*Т.Н.Галиуллин, Р.Ә.Мостафин.*

**«ЗӨЛХӘБИРӘ́»,** татар халык бәете. Татарлар яши торган барлык төбәкләрдә дә киң таралган. Күп кенә тикшеренүчеләр вакыйгаларның 1820–30 еллар б-н бәйле булуын күрсәтә. «З.»дә татар тормышына хас булмаган вакыйгалар сурәтләнә: Мостафа исемле мулла, карта уйнап, кызын һәм үзенең бар мөлкәтен җирле исправникка оттыра. Кыз, мондый хурлыкны күтәрә алмыйча, үз-үзенә кул сала (башка вариантларда — исправникны үтереп каторгага әләгә). Беренче тапкыр бәет 1915 елда Г.Рәшиди тарафыннан нәшер ителә. Кульъязма вариантлары Казан ун-ты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә, ш.у. ТР ФАнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кульъязмалар һәм текстология бүлегендә саклана.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ЗӨҺРӘ́»,** татар халык әкияте. Төп героиня исеме б-н атала. Карт б-н карчыкның балалары бер-бер артлы үлеп баралар, шул сәбәпле яңа туган кызларын чит-ят күзләрдән яшереп үстерәләр. Зөһрәгә 14 яшь тула. Шулай бервакыт кыз су коеныега китә. Нәкъ шул чакта аны бик зур Елан тотып ала. Кыз 4 елдан соң аңа кияүгә чыгачагы турында сүз бирә. Сөйләшенгән вакыт килеп җиткәч, Елан З.не су асты патшалыгына алып китә. Анда ул бик матур егеткә әверелә. Яшьләр бәхетле гомер итәләр, әмма З. әтисе б-н әнисен бик сагына. Бервакыт кыз, якыннарын күрү нияте б-н, яр буена чыга. Әмма анасы кызын кире җибәрергә теләми, алдап, еланны үз янына чакыра һәм аның башын чабып өзә. Башы чабылган ирен күреп, З. акылдан яза. Балаларын сандугач, карлыгач һәм сыерчыкка әверелдереп, үзе күгәрченгә әйләнә. «З.»нең сюжеты борынгы чорларга барып тоташа. Әкиятнең берничә варианты билгеле. Берсе 1900 елда Т.Яхин тарафыннан нәшер ителә. 1958 дә язучы Э.Касыймовның Пенза өлкәсендә Шемышейка р-ны Оз авылында яшәүче Х.Шабанов сөйләгәннәрдән чыгып язган вариант та мәгълүм.

*Әд.:* Яхин Т. Дәфгыль — кәсәл мин әс-саби вә сабият. К., 1900; Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Исәнбәт Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-биюле йөз төрле уен. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЗӨЯ́** елгасы, Идел алды төбәгендә. Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 377,4 *км*, ТР чикләрендә — 161,2 *км*. Бассейнының мәйданы 17 мең *км*$^2$ га якын. ТР чикләрендә — 7,1 мең *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Ульянов өлкәсе терр-ясендә, ТРда — урта һәм түбәнге агымнары Буа, Апас, Кайбыч, Яшел Үзән, Югары Ослан р-ннары терр-ясендә. Елга тамагы Зөя утравыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елганың Югары Ослан р-ның Соболевский авылыннан төньякта аккан түбәнге өлеше Куйбышев сусаклагычы суы астында кала һәм Зөя култыгы дип йөртелә башлый. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының уртача биеклеге 164 *м*, урманлылыгы 11%.

З. бассейны тар полоса рәвешендә Идел үзәне буйлап меридиан юнәлешендә сузылган; калкулыклы дулкынсыман тигезлектән гыйбарәт, аның уңъяк яр өлеше биегрәк һәм катлаулы рельеф хасил итә. Су җыелу мәйданы асимметрияле: сулъяк яр өлеше шактый



Зөя елгасы.

зуррак һәм мәйданның 73% ка якынын тәшкил итә. Елга үзәне күбесенчә трапециясыман, аз гына бормалы, асимметрияле: уңъяк сөзәклеге текә (7$^0$-20$^0$), сул ягы сөзәк (2$^0$-5$^0$). Үзән сөзәклекләре күп кенә урыннарда зур ерым, сызалар б-н кискәләнгән һәм рельефның карстлы формалары б-н катлауланган. Урта һәм түбәнге агымында үзән 10 *км* га һәм тагын да зуррак киңлеккә җитә. Тугае биек, тоташ, күбесенчә ике яклы, урыны б-н сазлыклы, комлы туфраклы һәм комлы-ләмле грунтлардан тора; киңлеге урта агымында 1–2 *км* дан түбәнге өлешендә 4,5–5 *км* га кадәр җитә. Тугаенда элекке күлләр бар. Елга юлы бормалы, аерым өлешләрендә утраулар, сайлыклар хасил итеп, тар тармакларга бүлгәләнгән. Суның иң аз вакытында елга киңлеге югарыгы агымда 5–10 *м* һәм түбәнге өлештә 40 *м* га кадәр. Плёсларда 2–4 *м* һәм сай урыннарда 0,3–1 *м* тирәнлек өстенлек итә. Елганың тирәнлеге түбәнге агымда урыны б-н 5–6 *м* га җитә. Агым тизлеге сай сулы урыннарда (перекат) — 0,5–1 *м/с*, тирән сулы урыннарда (плёслар) — 0,1–0,2 *м/с*. З. ярлары текә, урыны б-н өзек-өзек, биеклеге 1,5–2 дән 5–8 *м* га кадәр, комлы яки комлы туфраклы, шактый җире куаклыклар б-н капланган. З.нең 79 кушылдыгы бар, ТР терр-ясендә аеруча зурлары: Кылна (32,7 *км*), Үләмә (72 *км*), Коры Үләмә (46 *км*), Сөлчә (43,1 *км*) — уң; Чынлы (54,1 *км*), Карлы (88,4 *км*), Лашчы (21 *км*), Бола (117 *км*), Бөя (40 *км*), Бәрле (48 *км*), Гөбенә (165,1 *км*), Әрә (44,2 *км*), Буа (31 *км*), Сәкел (29,4 *км*) — сул кушылдыклар. Сул кушылдыкларның суы мулрак һәм алар гомуми агымның 75% ка кадәрен бирәләр. З. бассейны челтәренең тыгызлыгы төрле өлешләрендә 0,28 дән 0,33 *км/км*$^2$ га кадәр. Туенуы катнаш, кар сулары өлешенә яртысыннан күбрәге туры килә. Җир асты туену модуле субүләрләрдә 0,5–5 *л/с·км*$^2$ дан төп елга юлында 10 *л/с·км*$^2$ га кадәр.

Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н сыйфатлана. Елга режимы Ульянов өлкәсенең Ивановка (1953–54), Буа р-ны Ивашевка (1931–96), Апас р-ның Дәвеш (1931–37) һәм Биеш (1959–62), Кайбыч р-ның Борындык (1933–62), Югары Ослан р-ның Патрикеево (1932–33) һәм Гаврилково (1932–36) авыллары янында су үлчәү постларында өйрәнелгән. 1999 елдан Буа шәһәре янында гидрологик пост эшли. Ел фасыллары буенча агымның бүленеше тигез түгел. Еллык су агымының уртача купьеллык катламы 50–150 *мм*, язгы ташу агымы катламы 46–64 *мм*. Ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана һәм уртача 26 көн дәвам итә. Борындык авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәнеше 6,9 *м* (иң зуры 8,4 *м*). Иң зур чыгымы 1979 елда билгеләнә һәм ул 1560 *м*$^3$*/с* тәшкил итә (Ивашевка а.). Язгы боз китү, гадәттә, апрельнең икенче ункөнлегендә башлана, еш кына текә борылышларда, күпер терәүләре алдында, елга юлының тарайган урыннарында боз тыгылулар барлыкка килә. Бозның төп массасы килгәнче кайвакыт тугай су астында кала. Ул вакытта боз тугай буйлап та ага, аннары сайлыкларда туктый һәм шунда эреп бетә. З., гадәттә, ноябрьнең икенче яртысында туңа. Боз катуның уртача дәвамлылыгы 136–142 көн. Кыш ахырына бозның калынлыгы 90–95 *см* га җитә. Елганың аерым өлешләре грунт сулары чыккан урыннарда кыш буена диярлек боз б-н капланмый. Җәйге саегулар тотрыклы. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 13,7 *м*$^3$*/с*.

Суы югары һәм урта агымында гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, түбәнге өлештә сульфат-гидрокарбонат-натрийлы. Суының катылыгы ел дәвамында бик нык үзгәрә: ташу вакытында 1,5–3 *мг-экв/л* дан җәйге саегуда 3–6 *мг-экв/л* га кадәр. Гомуми минеральләшүе язын 150–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–700 *мг/л*. З. бассейнында гомуми күләме 30,9 *млн. м*$^3$ булган 47 буа бар. З. һәм кушылдыкларының су ресурслары сугару һәм а.х. пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла.

З. — ТРның табигать истәлеге (1978). З. елгасы ярларында *Ивашев В.П. Утар-паркы* һәм *Тау наратлыгы* табигать истәлекләре урнашкан. Елганың түбәнге агымының уңъяк ярында «Казан» тау спорты сәламәтләндерү комплексы бар.

*О.Н.Урбанова.*

**«ЗӨЯ́»,** комплекслы табигать тыюлыгы, Югары Ослан һәм Яшел Үзән р-ннары терр-ясендә урнашкан. 1998 елда Идел алды табигать комплексларын торгызу һәм саклау, рекреацияне көйләү, экологик-агарту эшчәнлеге алып бару максаты б-н оештырыла. Мәйданы 12656 *га*. Күп санлы култык, ермаклар б-н Зөя елгасының тамак өлешен, киң яфраклы урман участокларын алып тора. Материк, утрау һәм су экосистемаларыннан гыйбарәт булган Зөя елгасы тугаеның сулы-сазлыклы өлешләре күп кенә кошларның оялау һәм азык табу урыннары булып тора; Зөя култыгы акваториясе шактый гына балык төрләренең, ш.и. промысел балыкларының уылдык чәчү урыны. Үсемлекләр дөньясында көпшәле үсемлекләрнең 500 дән артык



«Зөя» табигать тыюлыгы.

төре, ш.и. сирәк һәм югала баручы төрләр — тармаклы наратбаш, йөзгәләк сальвиния, ап-ак төнбоек, шифалы песи борчагы үсә. Хайваннар дөньясында балыкларның — 42, амфибияләрнең — 10, рептилияләрнең — 6, кошларның 171 төре, имезүчеләрнең 40 төре яши. ТРның Кызыл китабына кергән төрләрдән: гади тупалакбаш, Идел подусты (түбәнавыз), соры гөберле бака, сырлач сыртлы тритон, бакыр кәлтә (җизбаш), гади кара елан, зур күлбога, кыр һәм болын карчыгасы, үлән шөлдие, зур саз шөлдие, нәни акчарлак, гади төн күгәрчене, гади яр чыпчыгы, сары корташар, гади шолган, зур колаклы көрән ярканат, сулык төн ярканаты, зур йоклач очрый.

*А.П.Галанина.*

**ЗӨЯ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасының Иделгә кушылган урынында урнашкан. *Куйбышев сусаклагычы* төзелгәннән соң утрауда кала. 2008 елда 256 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, руслар — 90%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1551 дә Углич тирәсендә әзерләнгән саллар Иделдән агып килә һәм 4 атна эчендә З. кальга буларак калкып чыга. Казан камалышта калган чорда (1552) З. рус гаскәрләре өчен хәрби база булып тора. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан З. — өяз шәһәре, сәүдә-һөнәрчелек үзәге. 1565–67 елларда теркәү кенәгәсендә ул 4 ату уемы, 33 тубы, 342 хуҗалыгы, 254 кибете булган 12 манаралы кальга буларак билгеләп үтелә.

Кальга янәшәсендәге посадта 782 хуҗалык исәпләнә. З.дә барлыгы 5,5 меңләп кеше яши, бу — аның иң зур үсеш чоры була. 17 йөздә шәһәр үзенең хәрби әһәмиятен саклый. 1636 да монда 125 бояр (дворян) балалары, 265 йомышлы татар, 450 стрелец, 28 йомышлы чит ил кешесе хезмәт итә. 1708 дән — Казан губернасында, 1719 да — Зөя провинциясе үзәге, 1781 дә Казан наместниклыгының (1796 дан — губернасының) өяз шәһәре итеп билгеләнә. 1716–27 елларда З.дә Адми-

ралтейство коллегиясе карамагындагы арифметика мәктәбе эшли. Озак еллар шәһәр православие дине үзәге булып тора. 18 йөз уртасында 3 монастырь: Троица-Сергий (1551 дә нигез салына, Успение (1555), Иоанн Предтеча (16 йөз ахыры); 8 чиркәү исәпләнә. 1731 дә З.дә Урта Идел буенда миссионерлык эшчәнлеге б-н җитәкчелек итүче *Яңа чукындырылганнар конторасы* оештырыла, Успение монастыре каршында эшләүче чит ил кешеләре балалары өчен мәктәп (1754 кә кадәр эшли), (к. *Яңа керәшен мәктәпләре*) була. 18 йөз ахырына кадәр шәһәр мөһим сәүдә үзәге булып кала, анда таможня, ям йорты, кабак конторасы була, 319 сәүдәгәр яши. Монда Мәскәү, Ярославль, Түбән Новгород һ.б. җирләрдән сәүдә итүче кешеләр җыела. Тора-бара З. әкренләп үзенең сәүдә-сәнәгый әһәмиятен югалта. Халкының төп шөгыле — балыкчылык, балык тоту кирәк-яраклары бәйләү, өй янындагы хуҗалыкны алып бару. 20 йөз башында өяз идарәсе урнаша; почта-телеграф бүлекчәсе, телефон станциясе, 2 кунакханә, 4 юлаучылар йорты, 2 монастырь (Успение ирләр һәм Иоанн Предтеча хатын-кызлар монастырьлары), 5 чиркәү, шәһәр уч-щесе (1817 дә өяз уч-щесе буларак ачыла, 1881 дә — алтыеллык шәһәр уч-щесе, 1913 тә югары башлангыч уч-ще итеп үзгәртелә), кызлар прогимназиясе (1911), ирләр һәм хатын-кызлар приход уч-щеләре (1853 һәм 1861), кызлар өчен чиркәү-приход мәктәбе (1885), башлангыч һөнәрчелек мәктәбе (1906), ятим балалар йорты, китапханә, 40 урынлы земство хастаханәсе, дарулар склады, 2 пар тегермәне, 4 икмәк кибете һәм икмәк пешерү йорты, 11 тимерчелек, сыраханә, 2 бакалея б-н сәүдә итүче шәраб подвалы, казна шәраб һәм 42 бакалея кибете, төзелеш өчен агач склады була; ел саен ярминкә (8 июльдә), шимбә саен базар эшли. Җәйге чорда шәһәр халкы гыйбадәт кылучыларның күпләп килүе исәбенә шактый арта. Совет чоры З.нең тулысынча таркалыш заманы була. 1920 еллар ахырында ул тоткыннар өчен сөрген урынына әйләнә, 1956 га кадәр анда озату төрмәсе урнаша. 1950 еллар уртасында Куйбышев сусаклагычы су б-н тутырылгач, җирле халыкның күбесе башка урынга күчеп утыра, утрауда дәүләт учреждениеләре бетерелә, күп кенә торак йортлар башка җиргә күчерелә. Монда калган халык психиатрия шифаханәсендә (1956–93) һәм акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-мәктәп тә эшли. 1920 дән З. ТАССРның — Зөя кантоны, 1927 нең 14 февраленнән Зөя р-ны үзәге. 1931 нең 20 октябрендә, Зөя р-ны бетерелү сәбәпле, Югары Ослан р-нына бирелә. 1932 нең 1 февралендә шәһәрләр исемлегеннән сызыла һәм авыл җирлегенә кертелә. 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Югары Ослан, 1997 нең 20 ноябреннән — Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 452 ир-ат; 1859 да — 1274, 1897 дә — 2365, 1908 дә — 2991, 1926 да — 2600, 1938 дә — 2769, 1949 да — 2547, 1958 дә — 1578, 1970 тә — 1464, 1979 да — 1176, 1989 да — 747, 2002 дә — 268 кеше. З.нең үсеш перспективасы аның зур туристлык үзәгенә әверелүе б-н бәйле. 1960 тан ул — Россиянең тарихи-мәдәни ядкәрләре, 1990 да РФнең тарихи шәһәрләре һәм торак пунктлары исемлегенә, ш.у. ЮНЕСКОның мәдәни һәм табигый мираслар исемлегенә тәкъдим ителә. Монда федераль әһәмияте булган — 19, респ-ка әһәмияте булган 18 тарихи һәм мәдәни ядкәр теркәлә. Алар арасында: Константин һәм Елена чиркәве (16 йөзнең 2 нче яртысы), Никола чиркәве (1556; 17–19 йөзләрдә үзгәртеп корыла), Успение соборы (1560; архиепископ *Герман* 16 йөздә фрескалар б-н төзеткән), Троица чиркәве (1551, 18–19 йөзләрдә үзгәртеп төзелә), Сергий чиркәве (1570–1604), архимандрит (17 йөзнең 2 нче яртысы) һәм борадәрләр корпусы, монастырь уч-щесе бинасы (17 йөз ахыры — 18 йөз башы), «Хәсрәтлеләр юанычы» Изге Ана соборы (1898–1906) була. З.дә рев-циягә кадәрге Россиядә гадәти өяз шәһәрләре ансамбленең иң яхшы сакланып калган үрнәкләре (шәһәр уч-щесе (1913–14), земство управасы архивы биналары (1890 — 20 йөз башы); казна корылмалары (1838), земство хастаханәсе (1875), һөнәрчелек мәктәбе (19 йөз уртасы), янгын сүндерү олавы (1877), күпсанлы торак биналары (19–20 йөз башы) комплекслары бар.

*Әд.:* Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892; Х о в а н с к а я О.С. Свияжск. К., 1951; О с т р о у м о в В.П., Ч у м а к о в В.В. Свияжск. История планировки и застройки. К., 1971; Ф е х н е р М.В. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978.

**ЗӨЯ́ КАНТОНЫ́**, 1920–27 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Зөя өязенең 11 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — Зөя шәһәре. Мәйданы 3326 *км*[2]. Халкы 153384 кеше, ш.и. руслар 64,4%, татарлар — 33,4%, чуашлар — 2% (1926). 2600 е — шәһәрдә, 150784 кеше авылда яши. Халыкның уртача тыгызлыгы 1 *км*[2] га 46,1 кеше, авыл җирендә — 45,3 кеше. 300 торак пунктны берләштерә, 8 волостька бүленә: Олы Ачасыр, Кошман, Макыл, Мәлки, Норлат, Зөя, Тәмте, Ульянково. Печән пресслау (Карамалы Тау а.), механика-суднолар төзәтү (Печище а.), аракы-шәраб (Гребени а., Куралово а.) з-длары, тегермәннәр эшли (1923). Кустарь-һөнәрчелек сәнәгатендә 2600 дан артык кеше эшли (1926). 1925 кә З.к.нда 31199 крәстиян хуҗалыгы, 62 а.х. кооперативы исәпләнә, сөрүлек җирләрнең мәйданы 207626 дис. тәшкил итә. Чәчүлекләр (дис.ләрдә): арыш — 58719, солы — 23965, бәрәңге — 5301, ясмык — 5071, карабодай — 4524, бодай — 4009, тары — 2651, борай — 2059. 252669 баш мал асралган, ш.и. 41094 мөгезле эре терлек, 21873 ат, 168264 сарык, 12101 дуңгыз булган. 1927 дә З.к. бетерелә, биләмәсендә Зөя, Норлат-Ачасыр (Норлат), Ульянково (Кайбыч), Тәмте р-ннары оештырыла.




*Әд.:* Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928–29. Вып. 1–5.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЗӨЯ́ ӨЯЗЕ́**, 1708–1920 елларда Казан губернасында. Үзәге — Зөя шәһәре. 1551 елда нигез салынган Зөя кирмәненнән һәм Иделнең уң ярында аның янында урнашкан җирләрдә 16 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Ханлык яулап алынуның беренче ун елында өяз Нугай, Иске Йеркүл, Чуаш, Арча, Алат, Атыз даругаларына бүленешне саклый. 17 йөздә станнарга бүленү кертелә (Каменка, Тау асты, Кирельск, Моратов). 1708 дә Казан губернасы составына керә. 1719 да —



Зөя авылы. Хәзерге күренеше.

Зөя провинциясенә, 1781 дә Казан наместниклыгына беркетелә. Өяз губернаның үзәк өлешендә урнаша. Төньяктан һәм көнчыгыштан Казан өязе, төньяк-көнбатыштан Чабаксар, көнбатыштан Цивиль, көнчыгыштан Лаеш, көньяктан Тәтеш өязләре б-н чикләшә. Идел, Зөя, Гөбенә, Бәрле, Имерлей һ.б. елгалар б-н сугарыла. Мәйданы 2,8 мең кв. чакрым. Халкы 126,6 мең кеше, ш.и. руслар — 68,7%, татарлар — 30% (1897). 11 волостьтан торган. Өяз халкы игенчелек (солы, бодай һ.б.), бакчачылык, балык тоту, известь




чыгару һ.б. б-н шөгыльләнгән. Өяздә керосин з-ды, шырпы ф-касы эшләгән. Сату өчен ашлык, җитен орлыгы, гипс, известь җитештерелгән. 19 йөз ахырында өяздә 48 башлангыч мәктәп, 28 чиркәү-приход һәм грамотага өйрәтү мәктәпләре, 3 Изге Гурий борадәрлеге миссионерлар мәктәбе, 45 татар мәктәбе һәм мәдрәсәсе, 1 татар уч-щесе була. 1920 дә өяз таратыла, аның нигезендә *Зөя кантоны* оештырыла.

Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861. Т. 8; Б е р с т е л ь К.П. Список селений Казанской губернии. К., 1908.

*Әд.:* С п а с с к и й Н. Очерки по родиноведению. Казанская губерния. К., 1912.

*Д.Г.Мостафина.*


**ЗӨЯ́ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1927 елның 14 февралендә оештырыла. Үзәге — Зөя шәһәре. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Зөя өязенә керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. Оештырылган көннән З.р.на 36 авыл советы, 83 торак пункт була, аларда 40628 кеше (руслар — 40122, татарлар — 473, төрле халык — 33 кеше) яши. Р-нның мәйданы — 730 *км*² була. 1931 нең 20 октябрендә З.р. таркатыла, терр-ясе Югары Ослан һәм Норлат р-ннарына бүлеп бирелә.

**ЗӨЯ́ ЯГЫ́**, 16 йөзнең 2 нче яртысында элеккеге Казан ханлыгы терр-ясенең уңъяк ярдагы өлеше. Атама, патша гаскәрләре тарафыннан Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, беренче ун ел эчендә кертелә. Ул Иделнең уңъяк яры буендагы җирләрнең баштагы *Тау ягы* атамасын алыштыра. З.я.ның чикләре төгәл билгеләнмәгән була. 1560 еллар уртасында өязләргә бүленү нәтиҗәсендә бу атама кулланылыштан төшеп кала.

*Әд.:* Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. К., 1982.

*Д.Г.Мостафина.*

**ЗУБЕ́Ц** Прокофий Филиппович (21.7.1915, Полтава губ., Ромодан станицасы — 8.1.1996, Мәскәү), конструктор, авиация һәм ракета двигательләре төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1968), проф. (1972). З. — двигательләр төзүнең фәнни-техник мәктәбенә нигез салучы. ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1956, 1966). 1939 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, инженер-конструктор, конструкторлар төркеме башлыгы. 1941–43 елларда Мәскәү һәм Куйбышев шәһәрләрендәге авиация з-дларында әйдәп баручы конструктор. 300 нче з-дның тәҗрибә КБнда (Мәскәү) баш конструктор урынбасары. 1953 тән Казанда: 16 нчы моторлар төзү з-дының тәҗрибә КБ башлыгы (бер үк вакытта 300 нче з-д тәҗрибә КБнда ген. конструктор); 1957–78 дә Дәүләт ОКБ-16 да (Моторлар төзү проектлар бюросы); 1978–83 тә җаваплы җитәкче — Казан моторлар төзү з-дының (хәзер «Союз» тәҗрибә КБсы) баш конструкторы. 1983–96 да авиация системалары фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре очкыч аппаратлар двигательләрен төзүгә карый. Ил-2 штурмовиклары өчен АМ-38, АМ-42 пешкәкле двигательләре төзүдә катнаша; еракка оча торган Ту-16, М-4, МС бомбардировщиклары һәм Ту-104 пассажир самолётлары өчен илебездә беренче АМ-3 турбиналы двигателен төзүдә әйдәп баручы конструктор. З. җитәкчелегендә Ту-104А, Ту-104Б пассажир самолётлары һәм еракка оча торган бомбардировщиклар өчен РД-3М, РД-3М-500 двигательләре әзерләнә; ярдәмче ТГ-16 (турбиналы генератор) көч җайланмасы (Ил-18, Ан-10, Ан-12, Ан-24, Ан-26, Ан-32 самолётлары өчен двигательне кабызуны һәм борттан туендыруны тәэмин итү өчен) эшләнә, Казандагы 16 нчы моторлар төзү з-ды аны серияләп җитештерүне үзләштерә. 1959 дан ракеталардан һәм һава һөҗүменнән саклану, һөҗүм авиациясен коралландыру өчен каты ягулыклы ракета двигательләре (РДТТ) төзүгә җитәкчелек итә. Аның җитәкчелегендә двигательләр сынауның энергетик, эчке баллистик параметрларын исәпләүнең, матем. модельләштерүнең газодинамик ысуллары эшләнә; юнәлешле тарту векторы б-н идарә итүнең газодинамик системасы төзелә һәм уникаль тәҗрибә-тикшеренү эшләре ярдәмендә нигезләнә (Үзәк авиация моторлары төзү ин-ты б-н берлектә). Шулай ук үтә чыдам корычлардан һәм җепсел чорнаулы композицион материаллардан, РДТТ корпусларын цилиндрик һәм конус рәвешле төзүнең; әре габаритлы соплолар, технол. процессылар өчен тышкы һәм эчке җылы саклагыч материаллар, эрозигә чыдам композицион материал конструкцияләрен формалаштыруның фәнни-техник нигезләре салына. Коралланугa 10 төрле РДТТ эшләп тапшырыла, алар арасында илнең барлык ракета-космик саклану системасы ракеталары, зур (С-300в) һәм урта («бук») ераклыкка оча торган һава һөҗүменнән саклану комплекслары, тавыш тизлегеннән тизрәк очучы МиГ-31 перехватчиклары һәм Ту-22М ракета йөрткечләре комплекслары


П.Ф.Зубец.

өчен двигательләр бар. З. гибрид ракета двигательләре төзү буенча тәҗрибә-тикшеренү эшләрен җитәкли. Аның җитәкчелегендә, И.В.Курчатов исем. Атом энергиясе ин-ты хезмәткәрләре б-н берлектә, металларны эретеп ябыштыру, кисү һәм ныгыту өчен лазер технологиясе эшләнә. Уйлап табуга 41 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1959–63 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин (1957), СССР Дәүләт (1978) бүләкләре лауреаты. Ленин ордены (ике тапкыр), Хезмәт Кызыл Байрагы (ике тапкыр), 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Д.М.Гальперин.*

**ЗУБКО́В** Михаил Иванович (1889, Вятка губ., Алабуга өязе Черкас а. — 1929, Казан), сәясәт эшлеклесе. 1918 елда «Алга таба», «Кызыл солдат» г-талары мөхәррире, Көнчыгыш фронт сәясәт бүлегенең татар секциясе җитәкчесе, 1920 дә РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-тының Үзәк керәшен бүлеге рәисе. 1920 елларда ТАССР прокуратурасында эшли. Авиация һәлакәтендә вафат була.

*Әд.:* Образование Татарской АССР: Док. и материалы. К., 1963.

*М.С.Глухов.*

**ЗУ́БОВА** Наталья Дмитриевна (30.10.1945, Иваново өлкәсе Иваново ш.), энергетик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Иваново энергетика ин-тын тәмамлый (1970). 1970–76 елларда Владивостокта (Приморье крае) 2 нче ТЭЦ инженеры, 1976–83 тә Көньяк Сахалиндагы 1 нче ТЭЦта капиталь төзелеш бүлегенең инженер-җылылык технигы, «Сахалинэнерго» энергетика идарәсенең район электростанцияләре җайланмаларын ремонтлау һәм файдалану хезмәтендә өлкән инженер. 1983–2006 да «Татэнерго» АҖнең Казандагы 3 нче ТЭЦында: өлкән инженер, производство-техника бүлеге башлыгы урынбасары, җитәкчесе. Дәүләт бүләге «Югары басым казаннары өчен термик су әзерләүнең югары нәтиҗәле һәм экологик камил технологиясен эшләү һәм куллануга кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗУБР КЫЯГЫ́** (Hierochloë), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле. Европа, Азия, Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә 3 төре үсә. Арктик З.к. (H. arctica) һәм үрмәле З.к. (H. repens) Кама алдында, хуш исле З.к. (H. odorata) — нигездә Кама аръягында очрый. Зур елга тугаеның калкулыклы урыннарында, коры болыннарда, куаклар арасында үсә. 20–70 *см* биеклектәге, озын шуышма тамырчалы үсемлек. Сабагы туры, шома. Яфраклары яссы, тамыр тирәсендәгеләре — озынча булып очланганнар, сабактагылары — ланцетсыман кыяклы. Башакчыклары — вак, алтынсу көрән, ябалдашлы себеркәчтә. Җимеше — озынча бөртекчә,

кара коңгырт төстә. Апрель-июнь башында чәчәк ата, июльдә орлыклары өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив органнардан үрчи. Составында кумарин бар, шунлыктан әчемлекләрне хуш исләндерү өчен һәм тонәтмәләр әзерләгәндә файдаланыла. Халык медицинасында З.к. төнәтмәсе аппетитны яхшырту, ашкайнату трактының эшчәнлеген арттыру өчен файдаланыла.

**ЗУ́ЕВ** Евгений Владимирович (23.12.1923, хәзерге Калинин өлкәсе Хвошня а. — 31.10.1989, Казан), нәкышьче, ТАССРның халык рәссамы (1986). Эстония ССРның Дәүләт сынлы сәнгать ин-тын тәмамлый, Э.Я.Китс һәм В.М.Орешников шәкерте (Таллин, 1953). Казан сынлы сәнгать уч-щесендә (1953–81) һәм балалар сынлы сәнгать мәктәбендә (1970–75) укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964). З. иҗаты — Татарстан сәнгатендә якты һәм үзенчәлекле күренеш. Төп жанры — гомумкешелек кыйммәтләрен чагылдыручы тематик картиналар югарылыгына күтәрелгән натюрморт: күбесенчә җирнең барлык нигъмәтләре, гади һәм көндәлек кирәк-яраклар сурәтләнә. З.ның нәкыше якты, ачык, җирле төсләрнең куе гаммасы, гомумиләштерелгән сурәтләве, монументаль-декоратив тасвирлау теленә якын торган киң колачы, күпкырлы һәм ачык аңлаешлы композицияле чишелешләре б-н аерылып тора. Рәссам 4 картинадан торган «Яз», «Җәй», «Көз», «Кыш» (1956–57), җиләк-җимешләрнең, чәчәкләрнең һәр айга хас үзенчәлекләрен чагылдырган («Июль. Җиләкләр», «Август. Икмәк», «Сентябрь. Алмалар» һ.б.) 12 картинадан торган «Ел фасыллары» (1970) натюрмортлар сериясен иҗат итә, әзлекле рәвештә җир нигъмәтләре муллыгы темасын ачуга омтыла. «Татар ашлары» триптихында (1978–79) милли ашларның муллыгы, татар халык декоратив-гамәли сәнгате әсәрләренең үзенчәлекләре тасвирлана. 1980 елларда З.ның нәкыше күбесенчә декоративлылык ягына үзгәреш кичерә, колорит төсләр контрастлыгына корыла, рәссам композициянең күп планлы һәм вак әйберләрнең күп булуыннан баш тарта, предметлар эреләнә, форманы яктылык б-н модельләштерү юкка чыга: «Архангельск сувенирлары» (1981), «Гәрәбә. Паланга турында истәлек» (1981), «Бәйрәм натюрморты» (1983), «Казан сувенирлары» (1986), «Шәфталулар» (1987), «Икмәк — ил toткасы» (1989) һ.б. Респ-ка сынлы сәнгатендә әйдәп баручы натюрморт остасы булап, З. натюрмортның башка сәнгать жанрлары янәшәсендә тигез хокуклы булуын раслый, аның үсешенә сизелерлек йогынты ясый. З. пейзаж жанрында да иҗат итә, ватан тарихына, мәдәният истәлекләренә багышланган картиналар яза, аларда көньяк табигатенең гүзәллегенә, урта рус төбәгенең матурлыгына дан җырлый: «Кырым тауларында кич» (1958), «Казан. Суконный базары» (1962), «Көзге Идел» (1962), «Дагстан. Дербент, иске мәчет» (1965), «Төньякта. Валдай күле» (1984), «Ильмень күле өстендә. Новгород» (1988), «Казан Кремле» (1989) һ.б. Күргәзмәләрдә 1944 тән («10 нчы гвардия армиясе фронтовик-рәссамнары күргәзмәсе», 2 нче Балтыйк буе фронты фронтовик-рәссамнары күргәзмәсе), респ-ка (1954 тән), төбәк (1958 дән), бөтенроссия күргәзмәләрендә (1970, 1971), 6 нчы халыкара күргәзмәдә (1977) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1958, 1966 да (Н.И.Гаделев һәм Т.А.Зуева б-н бергәләп), 1973–74 елларда Казанда, 1957, 1961, 1979 да Яшел Үзән шәһәрендә, 1967 дә (Т.А.Зуева б-н бергәләп), 1981– 1983 тә Әлмәттә, 1984 тә Чаллыда уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Н.Я.Ярошенко музеенда (Кисловодск ш.), Яңа Кырлай авылындагы Г.Тукай музей комплексында, Яшел Үзәндәге халык иҗаты һәм этнография музеенда, Серпухов тарих-сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында. РФ һәм чит илләрдә шәхси тупланмаларда саклана.







Е.В.З у е в. 1. «Өрек җимешләре». 1965; 2. «Август. Икмәк». 1970; 3. «Тубаллар һәм җиләк-җимеш». 1979. Барысы да — ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.


*Әд.:* Выставка произведений художников Татьяны Андреевны Зуевой, Евгения Владимировича Зуева, Науфаля Исмагиловича Адылова: Каталог. К., 1968; Искусство автономных республик Российской Федерации. Л., 1973; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1975; Каталог выставки произведений Евгения Владимировича Зуева. К., 1999.

*Т.В.Голубцова.*

**ЗУ́ЕВА** Татьяна Андреевна (27.01.1929, Эстония, Таллин), график, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Эстония ССРның Дәүләт сынлы сәнгать ин-тын тәмамлый (Таллин, 1953). Казан сынлы сәнгать уч-щесендә (1953 елдан), Казан театр уч-щесендә укыта (1971–2000). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). Респ-ка сәнгатендә әйдәп баручы графикларның берсе, 1960–90 елларда аның иҗаты эстамп сәнгате үсешенә этәргеч бирә. Басма һәм оригиналь графиканың төрле материаллары һәм техник алымнары (офорт, коры энә, акватинта, линогравюра, төсле карандаш, сангина, тушь, пастель, фломастер б-н эшләнгән рәсем) б-н иркен эш итә. З. иҗаты жанрлар төрлелеге б-н аерылып торса да (пейзаж, портрет, көнкүреш жанры композицияләре), аның лирик таланты, сизгер күзәтүчәнлеге, композицияләр төзү осталыгы тематик серияләрдән торган шәһәр пейзажларында аеруча тулы чагылыш таба. Шуларның иң тәүгеләренең берсен З. Таллинга багышлый (1960 еллар).

Казан темасы рәссамның гомере буена иҗат иткән һәм киң тематик диапазонына кергән серияләренең нигезен тәшкил итә, ул шәһәрнең истәлекле урыннары һәм архит-расы, А.С.Пушкин, А.М.Горький, В.В.Маяковский, башка язучылар һәм шагыйрьләрнең исемнәре б-н бәйле урыннар сурәтләнгән әсәрләрдә чагылыш таба. Сәфәрләр вакытында ясалган рәсемнәрдән «Дагстан сериясе» (1965), «Россиянең борынгы шәһәрләре буйлап» (1970), «Кабат килдем мин ...» (1970), «Петербургка багышлана» (1980), «Казан. Ел фасыллары» (1976–78) иҗат ителә. З. урынның, архит-раның үзенчәлекләрен чагылдырып кына калмый, бәлки графика әсәрләрендә матур күренешләр өстәүче заман рухын, табигать халәтен, һава якты-





Т.А.З у е в а. 1. «Таллин. Виру капкасы». Акварель. 1961; 2. «Казан. Бауман урамы». Кәгазь, балавыз карандаш. 1976. Икесе дә — ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

лыгын да күрсәтә белә. Бу яктан «Таллинда борынгы урам» (кәгазь, гуашь, акварель, 1961), «Малайлар» (линогравюра, 1963), «Идел башланган урыннар» (линогравюра, 1964), «Дагстан. Ахты авылы» (акварель, тушь, 1965), «Казанда В.И.Ленин музей-йорты» (карандаш, 1969) һ.б. әсәрләре игътибарга лаек. Респ-ка (1961 дән), төбәк (1967 дән), бөтенроссия (1971) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1966 да (Е.В.Зуев һәм Н.И.Гаделев б-н бергәләп),





Т.А.Зуева. 1. «Куе таллар ышыгында», «Кабат килдем мин...» сериясеннән. Пастель. 1974; «Әкият булып Казан күтәрелә» триптихының уң ягы. Карандаш. 1978. Икесе дә — ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

1971, 1977, 1979, 1989, 1999 елларда Казанда («Карандаш белән Париж буйлап»), 1979 да Яшел Үзәндә, 1967 дә (Е.В.Зуев б-н бергәләп) Әлмәттә уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Архангельскидагы туган як тарихын өйрәнү музеенда, Пятигорск шәһәрендәге М.Ю.Лермонтов музей-йортында, Красноярск краеның Шушенский авылы музеенда, Элиста шәһәрендәге Картиналар галереясында, Сиэтлдагы (АКШ) заманча сәнгать музеенда, Италия, Төркиядәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Выставка произведений художников Татьяны Андреевны Зуевой, Евгения Владимировича Зуева, Науфаля Исмагиловича Адылова: Каталог. К., 1968. *Т.В.Голубцова.*

**ЗУ́ЕВО** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 103 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 41 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Клуб. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Сарапул өязенең Козловка волосте Бобровка авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Зуев Починок. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тимерчелек, буяу ясау б-н шөгыльләнә, үзләре җитештергән буяу б-н Уфа губернасының Бәләбәй һәм Бөре өязләрендә сату итә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 633,7 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1930 ның 10 июленнән — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 355, 1890 да — 462, 1920 дә — 428, 1926 да — 494, 1938 дә — 461, 1949 да — 394, 1958 дә — 308, 1970 тә — 249, 1989 да — 107, 2002 дә — 78 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ЗУЙКО́В** Владимир Александрович (17.2.1946, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Казан оптика-механика з-дының Үзәк КБнда эшли. 1971 елдан Казан пед. ин-тында. 1976 дан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2009 дан). Хезмәтләре оптик күчеш процесслары физикасына, нәсызыкча оптикага, когерент оптик спектроскопиягә карый. З. бериш булмаган киңәюче резонанслы тирәлекләрдә беренчел фотон кайтавазы сигналларының төп ешлыгы үзгәрүен ярсытучы кыска лазер импульсларының дулкын векторлары арасындагы почмак үсүгә бәйле икәнлеген күрсәтә, бу үзгәреш резонанслы тирәлекләрдә почмакча оптик спектроскопияне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Икенчел һәм өченчел ярсыткыч лазер импульслары фәзада капма-каршы юнәлгән очракларда $LaF_3:Pr^{3+}$ кристалларында озак вакытлы фотон кайтавазы сигналлары һәм озак вакытлы фотон индукциясе булуын һәм кристалларда кабатланучан озак вакытлы фотон кайтавазы сигналлары барлыгын күрсәтә. $LaF_3:Pr^{3+}$ кристалларында ике төстәге оптик үтә нурланыш күренешен ачыклый.

Хезм.: Обращённое световое эхо в рубине // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1980. Т. 31, № 11 (автордаш); Корреляция формы сигналов светового эха с формой возбуждающих импульсов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1980. Т. 32, № 4 (автордаш); Optical superradiance in $laF_3:Pr^{3+}$ crystals // Laser Physics. 1999. V. 9. № 4 (автордаш).

**ЗУР АКСУ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 18 *км* көньяктарак, Олы Яклы елгасы буенда. 2008 елда 899 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә; ирләр шәһәрләрдә кара эшче булып эшли, Донбас шахталарына акча эшләргә китә. 20 йөз башында З.А.да 10 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1394,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 777, 1911 дә — 1705, 1920 дә — 1726, 1926 да — 1841, 1938 дә — 2035, 1949 да — 2481, 1958 дә — 1630, 1970 тә — 2282, 1979 да — 2033, 1989 да — 1128, 2002 дә — 928 кеше. *Әд.:* Субаев Р.С. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар (Район тарихыннан очерклар). Чүпрәле, 2000.

**ЗУР АЛА́Н** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасының югары агымы буенда. 2005 елдан даими яшәүчеләр юк. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. 1930 елларда нигез салына. Башта — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1938 дә — 270, 1949 да — 188, 1958 дә — 172, 1970 тә — 153, 1979 да — 80, 1989 да — 30 кеше.

**ЗУР ӘТРӘ́Ч** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Шоңгаты елгасы буенда. 2008 елда 310 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Шоңгаты, Иске Әтрәч, Теңеш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөз башында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.Ә.тә мәчет була. 20 йөз башында монда йон-тукыма ману йорты, 4 җил тегермәне, ярмаяргыч, 4 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1530 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 688, 1897 дә — 1406, 1908 дә — 1698, 1920 дә — 1514, 1926 да — 903, 1938 дә — 961, 1949 да — 670, 1958 дә — 675, 1970 тә — 776, 1979 да — 669, 1989 да — 485, 2002 дә — 347 кеше.

**ЗУР БИРӘЗӘ́** авылы, Арча р-нында, шәһәр тибындагы Арча посёлогыннан 2 *км* көнбатыштарак, Бирәзә елгасы буенда. 2008 елда 379 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, киез итек басып сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.Б.дә мәчет, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 648,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда.

1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 365, 1897 дә — 583, 1908 дә — 632, 1920 дә — 539, 1926 да — 765, 1938 дә — 604, 1949 да — 391, 1958 дә — 325, 1970 тә — 387, 1979 да — 369, 1989 да — 371, 2002 дә — 370 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885.

**ЗУР БӨРЕЛЕ́** (Иске Бөреле) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 154 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1550 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Благовещенский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, сарык тиресе эшкәртү, челтәр бәйләү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.Б.дә Благовещение чиркәве (1794 тән эшләүче кечкенә чиркәү урынында 1847 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1870 тән эшләүче хосусый мәктәп җирлегендә 1882 дә ачыла), 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 445 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенск, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 55, 1782 дә — 254 ир-ат; 1859 да — 354, 1897 дә — 336, 1908 дә — 345, 1920 дә — 566, 1926 да — 675 (Түбән Бөреле, Кызыл Бакча (Красный Сад) авылларын да кертеп), 1938 дә — 480, 1949 да — 403, 1958 дә — 347, 1970 тә — 173, 1989 да — 152, 2002 дә — 153 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**«ЗУР ИДЕ́Л»**, Урта һәм Түбән Идел буе: Татарстан, Калмык, Удмурт, Чуаш, Мари республикалары һәм Әстерхан, Волгоград, Түбән Новгород, Тверь, Кострома, Самара, Саратов, Ульянов һәм Ярославль өлкәләренең сынлы сәнгать әсәрләре төбәк күргәзмәләре; гадәттә, 2–6 ел саен оештырыла. «З.И.»дә нәкышь, графика, скульптура, монументаль-бизәлеш, театр декорациясе һәм гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләре куела.

«З.И.» Идел буе сәнгать үзәкләрен, сынлы сәнгать осталарының иҗат коллективларын берләштерүгә, милли мәдәниятләрнең үзара йогынты ясавына һәм таралуына этәргеч бирә. Оештыру функцияләрен төбәк күргәзмә комитетлары башкара; 1–3 һәм 5 нче «З.И.» күргәзмә комитетлары рәисе Х.Г.Якупов була. Беренче «З.И.» 1964 елда Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәрендә Окт. рев-циясенең 50 еллыгына әзерлек уңае б-н, сынлы сәнгать осталарының иҗат хисапларына әйләнгән башка төбәк күргәзмәләре б-н бергә үткәрелә. Анда 342 авторның 858 әсәре куела. Бөек Окт.нең 50 еллыгына багышланган икенче «З.И.» күргәзмәсе 1967 дә Волгоградта уза. 450 авторның 1000 әсәре, ш.и. ТАССР рәссамнарының 104 иҗат үрнәге күрсәтелә. В.И.Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап ачылган өченче «З.И.» 1969–70 тә Ульянов шәһәрендә эшли. 400 дән артык рәссам, ш.и. ТАССРдан 44 рәссам 76 әсәре б-н катнаша. 1974 тә Горький шәһәрендә узган дүртенче «З.И.»дә 600 дән артык рәссамның 1500 әсәре, ш.и. Татарстаннан 56 рәссамның 106 иҗат үрнәге күрсәтелә. Бишенче «З.И.» 1980 дә Казанда (584 авторның 1300 әсәре, ш.и. ТАССРдан 115 рәссамның 204 әсәре




«Зур Идел» күргәзмәсенә багышлап чыгарылган каталогның тышлыгы. 1979. Казан.

куела), алтынчы «З.И.» 1985 тә Чабаксарда (ТАССРдан 136 рәссам) ачыла. Җиденче «З.И.» 1991 дә Казанда үткәрелә (623 авторның 2100 әсәре куела, шуларның 356 сы Татарстан рәссамнарыныкы). Ул башка күргәзмәләрдән Ленин тематикасының булмавы, хезмәткә бәйле жанр картиналарының аз куелуы б-н аерылып тора. Камера портретлары, пейзажлар, натюрмортлар өстенлек итә.

Сигезенче «З.И.» 1998 дә Түбән Новгородта ачыла. Анда 730 авторның 2000 гә якын әсәре, ш.и. Татарстаннан 57 рәссамның 90 хезмәте тәкъдим ителә. Аның алдына җәмәгатьчелекне рәссамнарның ирекле иҗатка нигезләнгән эшчәнлекләренең нәтиҗәләре б-н таныштыру бурычы куела. Күргәзмәнең төп мәгънә бирүче идеясе тематик картиналарда чагыла; рәсемнәр җирле төбәк тарихына, милли образларга багышлана символлар һәм метафоралар теле б-н тасвирлана.

*Әд.:* «Большая Волга», посвященная 50-летию Советского государства: Каталог, Волгоград, 1967; Десять зональных выставок: Сб. статей. Л., 1967; III зональная художественная выставка «Большая Волга». 1969–70: Каталог. Л., 1970; IV зональная художественная выставка «Большая Волга»: Каталог, Горький, 1974; V зональная тематическая художественная выставка «Большая Волга». 1979–80: Каталог. К., 1979; VII зональная тематическая художественная выставка «Большая Волга»: Каталог. К., 1991; Региональная художественная выставка «Большая Волга»-98: Каталог. Н.Новгород, 1998.

*М.Е.Ильина.*

**ЗУР КАДРӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 39 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 5 кеше яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кодряково, Кодряковы Челны исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт (элек алпавыт Якобиларның крепостнойлары) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.К.тә Никольский чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, кирпеч з-ды, су тегермәне, 2 тимерчелек, аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе, казна шәраб һәм вак-төякләр кибете, чәйханә, 2 сыраханә эшли; шимбә саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 679,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 652, 1908 дә — 768, 1920 дә — 431, 1926 да — 410, 1938 дә — 327, 1949 да — 221, 1958 дә — 283, 1970 тә — 99, 1989 да — 29, 2002 дә — 8 кеше.

**ЗУР КИЗА́Й** күле, Көнчыгыш Кама аръягында. Ык елгасы бассейнының сулъяк өлешендә, Азнакай р-ны Чәкән авылыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,52 *га*. Озынлыгы 320 *м*, иң зур киңлеге 70 *м* (1984), уртача тирәнлеге 0,94 *м*, иң зур тирәнлеге 1,45 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы аз минеральләшкән, йомшак (катылыгы 1,96 *мг-экв/л*), төссез, иссез, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, үтә күренүчәнлеге 55 *см*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**ЗУР КЛЫКИ́** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында, Нокса елгасы буенда. 2000 елда 1174 кеше (1989 елгы халык саны исәбе буенча, руслар — 62%, татарлар — 36%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элеккеге экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, яшелчәчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.К.да земство мәктәбе (1886 да ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 983,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенский волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында: 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында, 1998 нең 25 октябреннән Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1646 да — 162, 1782 дә -68 ир-ат; 1859 да — 337, 1897 дә — 424, 1908 дә — 471, 1920 дә — 464, 1926 да — 525, 1949 да — 464, 1958 дә — 560, 1989 да — 1405 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ЗУР КЛЮЧИ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 1801 кеше (2002 елгы халык

исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык; агропромхимия пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ключи исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1832 дә З.К.да Иоанн Богослов (архит-ра истәлеге) чиркәве төзелә. 20 йөз башында земство хастаханәсе, кредит бирү ширкәте, 2 земство мәктәбе, 5 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 3 сыраханә, казна шәраб һәм 15 вак-төякләр кибете эшли; чәршәмбе саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4466,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1957 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 223 ир-ат; 1859 да — 1462, 1897 дә — 2470, 1908 дә — 2885, 1920 дә — 2149, 1926 да — 1310, 1938 дә — 1473, 1949 да — 1152, 1970 тә — 1788, 1979 да — 1693, 1989 да — 1548, 2002 дә — 1716 кеше.

**ЗУР КОЛАҢГЫ́**, к. *Урта Колаңгы.*

**ЗУР КУКМАРА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 3 *км* көнбатыштарак, Норма елгасы буенда. 2008 елда 1911 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сумала кайнату, вак-төякләр сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.К.да 2 мәчет, 2 мәктәп, ярма яргыч, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1755,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 131 ир-ат; 1859 да — 781, 1897 дә — 1276, 1908 дә — 1327, 1920 дә — 1242, 1926 да — 1345, 1938 дә — 1487, 1949 да — 1080, 1958 дә — 1328, 1970 тә — 1578, 1979 да — 1523, 1989 да — 1418, 2002 дә — 1839 кеше.

**ЗУР КУШАЯ́К**, ж и р  к у я н ы (Allactaga major), кушаяклылар семьялыгыннан имезүче хайван. Евразиядә , Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә Идел алдында һәм Кама аръягында очрый. Юл буйларында, сыза битләүләрендә, көтүлекләрдә, инеш буйларында тереклек итә. Гәүдәсенең озынлыгы 19–25 *см*, койрыгыныкы 30 *см* га кадәр. Сырты кызыл-көрән яки саргылт, асты ак. Койрыгы кара, очы соры. Ирен нәрендә өнендә яшәргә ярдәм итә торган озын каты мыеклары бар. Арткы аяклары алгыларына караганда берничә тапкыр озынрак. Колаклары зур, озын һәм тар. Тирән итеп казылган өннәрендә яши, алар кышлый торган, даими, көндезге, вакытлы төрләргә бүленә. Төнлә активлар. Көзен йокыга тала. Кушылу апрельдә — йокы тәмамлануга ук башлана. Йөклелек чоры айдан артык дәвам итә. 1–4 бала китерә. Үләнчел үсемлекләрнең җир өсте һәм җир асты өлешләре б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЗУР КҮККҮ́З** авылы, Апас р-нында, Апас авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2008 елда 347 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 16 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.К.дә мәчет була. 20 йөз башында җил тегермәне, йон-тукыма ману остаханәсе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2001,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 124 ир-ат; 1859 да — 600, 1897 дә 1180, 1908 дә — 1390, 1920 дә — 1377, 1926 да — 1111, 1938 дә — 825, 1949 да — 613, 1958 дә — 556, 1970 тә — 525, 1979 да — 495, 1989 да — 322, 2002 дә — 336 кеше.

**ЗУР КҮЛ**, Идел алды төбәгендә. Кайбыч р-ны Каргалы авылыннан төньякта урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,6 *га*. Күләме 66 мең $м^3$. Озынлыгы 150 *м*, иң зур киңлеге 120 *м*, уртача тирәнлеге 4,1 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы түгәрәк. Җир асты туенуы тотрыклы. Суы аз минеральләшкән (121,8 *мг/л*), йомшак (катылыгы 7,8 *мг-экв/л*), яшел төстә, иссез. Күл ләмләнә бара. ТРның табигать истәлеге (1978).

**ЗУР КҮЛ**, Идел алды төбәгендә. Элеккеге су юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Кайбыч р-ны Кече Мәми авылының көнчыгыш читендә. Су өслегенең мәйданы 19,48 *га*. Озынлыгы 1790 *м*, иң зур киңлеге 160 *м*.

**ЗУР КҮЛ**, Идел алды төбәгендә. Элеккеге су юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Апас р-ны Кабык Күпер авылының көнчыгыш читендә. Су өслегенең мәйданы 5,32 *га*. Озынлыгы 2450 *м*, иң зур киңлеге 160 *м*. Күлгә Бия елгасы коя.

**ЗУР КҮЛ**, Идел алды төбәгендә. Элеккеге су юлында сакланып калган күл. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Буа р-ны Адав-Толымбай авылының көнчыгыш читендә. Су өслегенең мәйданы 19,4 *га*. Озынлыгы 3370 *м*, иң зур киңлеге 150 *м*.

**ЗУР КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 13 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кызылъяр, Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1795 тә З.К.да Казан Богородица чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, земство мәктәбе, тимерчелек, казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 622 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Красноярск волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 233 ир-ат; 1859 да — 557, 1897 дә — 797, 1908 дә — 882, 1920 дә — 960, 1926 да — 937, 1949 да — 269, 1958 дә — 261, 1970 тә — 239, 1979 да — 147, 1989 да — 71 кеше.

**ЗУР КЫРЛАНГЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* көнчыгыштарак, Тоша елгасы буенда. 2008 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.К.да мәчет, мәдрәсә, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1432,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 697, 1908 дә — 1327, 1920 дә — 1146, 1922 дә — 1130, 1926 да — 677, 1938 дә — 573, 1949 да — 389, 1958 дә — 325, 1970 тә — 409, 1979 да — 382, 1989 да — 221, 2002 дә — 156 кеше.

**ЗУР ЛЫЗИ́-1** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 2 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасының уң ярында. 2008 елда 245 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, удмуртлар — 50%, руслар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Казан ханлыгы чорында удмуртлар нигез сала. Руслар монда 17 йөзнең 2 нче яртысында килеп урнаша. 1730–40 елларда христиан динен кабул итмәгән удмуртлар Түбән Ушма авылына күчеп китәләр. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сарык тиресе эшкәртү б-н шөгыльләнә. 19 йөздән арендага биреп торылган су тегермәне эшли. 1884 тә З.Л.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла, 1907 дә земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1033 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 154 ир-ат; 1859 да — 296, 1897 дә — 487, 1908 дә — 509, 1920 дә — 535, 1926 да — 556,

1938 дә — 324, 1949 да — 258, 1958 дә — 215, 1970 тә — 217, 1979 да — 119, 1989 да — 168, 2002 дә — 233 кеше.

**ЗУР ЛЫЗИ́-2** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 3 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасының сулъяк ярында. 2008 елда 70 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларга кадәр Зур Лызи авылы 2 түгел, ә бер торак пункт буларак билгеле. Халык саны: 1938 дә — 328, 1949 да — 282, 1958 дә — 206, 1970 тә — 188, 1979 да — 186, 1989 да — 89, 2002 дә — 82 кеше.

**ЗУР МӘШЛӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 49 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2008 елда 346 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет, Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау өчен такта һ.б. материаллар хәзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.М.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1097,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 295, 1897 дә — 488, 1908 дә — 568, 1920 дә — 592, 1926 да — 455, 1938 дә — 703, 1949 да — 576, 1958 дә — 1215, 1970 тә — 555, 1989 да — 252, 2002 дә — 368 кеше.

**ЗУР НАРАТЛЫ́К**, Алабуга р-нында урнашкан урман массивы, «*Түбән Кама*» милли паркының бер өлеше. Кама һәм аның кушылдыгы Туйма елгалары арасындагы 6760 *га* мәйданны алып тора; төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба иң зур озынлыгы — 18 *км*, иң зур киңлеге — 8 *км*. Терр-ясе — Камага таба кисәк текәләнеп Туйма елгасы үзәненә сөзәкләнеп күчә торган, көньякка һәм көньяк-көнбатышка юнәлгән авыш яссы калкулык. Рельефы — эрозион-денудацияле, ерганакланган сызалардан — Кама елгасының уңъяк биек ярларындагы чокырлардан тора (Бай чокыр, Куралы чокыр, Олы Ерхов чокыры һ.б.); урман массивының көньяк өлешендә материк дюналары һәм дюна тезмәләре таралган. Өслеге югары Казанның төп утырмаларыннан һәм дүртенчел системаның комсыл балчыкларыннан һәм комнардан тора. З.н.ның үсемлек капламында караңгы ылыслы (чыршы, ак чыршы) һәм киң яфраклы (имән, юкә) токымнар даими катнашкан, катлаулы төзелеше б-н аерлып торган нарат урманнары өстенлек итә. Наратлыкларның үләнле куакчыл ярусына урман-дала (төньяк йогырты, каурыйсыман кыска сабак, Альп тукранбашы, төкле миләүшә, кызыл яран) һәм тайга (нарат җиләге, кара җиләк, ике яфраклы май чәчәге, төньяк Линней үләне һ.б.) үсемлекләре хас.

З.н.та аеруча таралган урман төре төркемнәрен катлаулы, куаклы-мүкле һәм мүкле наратлыклар тәшкил итә. Катлаулы наратлыклардагы агачлар арасында юкә (юкәле наратлыклар) һәм имән (имәнле наратлыклар) үсә. 1 нче яруста тулысынча нарат өстенлек итә, югары җитештерүчән утыртмалар барлыкка китерә. 2 нче яруста чыршы, сирәк кенә ак чыршы; яхшы үскән куаклыкта миләш, урман зелпесе, сөялле кабар агачы һәм юкә, имән, чыршының яшь агачлары күпчелекне тәшкил итә. Үлән капламы бореал (нарат җиләге, кара җиләк, каеш яфрак) һәм неморал (сәрдә, тайтояк, тонык күкебаш) төрләр кушылмасыннан; урыны б-н кураксыман күрәннән һәм бөркет канатыннан тора.



Зур наратлык.

Туфракның өске капламында дулкынсыман дикранум, Шребер плеврозиумы һ.б. мүкләр үсә. Уңай климат шартларында наратның чыршы б-н табигый рәвештә алышынуы бара, катлаулы чыршылыклар барлыкка килә. Куаклы-мүкле наратлыклар Кама елгасының кәсле һәм уртача көлсу туфраклы югары террасаларына туры килә. Алар төзелеше буенча тайганың яшел мүкле наратлыкларына якын, әмма миләш, кабар агачы, тал-тирәктән торучы куаклыклар тагын да куерак. 1 нче ярус нарат агачларыннан гыйбарәт; 2 нче яруста үсүче агачның 30% ка кадәрен чыршы тәшкил итә, кайвакыт аңа имән, юкә кушыла. Үлән капламы яхшы үскән һәм мүкле наратлыклар өчен хас нарат җиләге, кара җиләк, кызыл бөрлегән, каен җиләкләре һ.б. үләннән һәм куакчыклардан тора. Тоташ кисентеләрдә күпчелек юкә, каен һәм усактан торучы ясалма утыртмалар яңартыла. Мүкле наратлыклар Кама елгасының түбәнге террасаларында үсеш алган кәсле һәм үтә көлсу комлы туфраклы көньяк-көнчыгыш һәм көньяк кварталларда таралган. Составы буенча алар — яшел мүкле типик наратлыклар, 1 нче яруста аз гына каен катнаш нарат өстенлек итә. Субстратның коры булуы сәбәпле чыршы аз, 2 нче яруста сирәк очрый. Куаклык һәм үлән капламы аз үсеш алган: яхшы үскән мүк капламында яктылыкка чыдам төрләр — Шребер плеврозиумы, дулкынсыман дикранум, артышсыман политрихум өстенлек итә. Тоташ кискәндә наратлыклар күрәнле каенлыклар б-н алышына. З.н.та үсемлекләр капламының уртак үзенчәлеге — хуҗалык эшчәнлеге һәм янгыннар нәтиҗәсе буларак, икенчел каен бергәлекләренең һәм усаклыкларның киң таралуы.

1972 елда З.н. составында Кама елгасы буенда урнашкан шул исемдәге табигать истәлеге (гомуми мәйданы 1200 *га*) бүленеп алына. Истәлекнең сөзәкле-чокырлы биогеоценозларын, нигездә, караңгы ылыслы, киң яфраклы урманнар төзи. Аларның составында төп рольне юкә һәм Себер ак чыршысы алып тора. Ак чыршы һәм аерым чыршылар б-н «күрән сәрдә юкәлеге» тибындагы бергәлекләр өстенлек итә; карама һәм элмә агачлары б-н бергә 2 нче ярусны юкә формалаштыра (15–20 *м* биеклектәге бернича сөзәклек), 1 нче яруста — 70–80 елда 30–35 *м* га житүче ак чыршы һәм чыршы үсә. Куаклыкта — ак чыршы һәм яфраклы токымнарның яшь агачлары б-н бергә катнаш урманның гадәти куаклары. Үлән ярусы яхшы үскән, ул чәчсыман күрән һ.б. киң яфраклы урман төрләреннән һәм эре үләннәрдән (биек аю көпшәсе, Урал төймәчәчәге — Татарстан флорасының сирәк төре) тора. Ылыслы һәм катнаш урманнарның гомуми фонында буйлы һәм төрле төстәге мергел катламнары киселеше ачылуы пейзажга гадәттән тыш матурлык өсти. Каманың уңъяк таулы участогы «Кама Жигулие» исеме б-н билгеле. Табигый урыннарның берсе — «Бай чокыр» И.И.Шишкин картиналарында сурәтләнгән («Нарат урманы», «Вятка губернасындагы мачталар урманы»).

*Әд.:* Гаранин В.И., Марков М.В. Охрана ландшафта и памятников природы // Природа Татарии и её охрана. К., 1971. Вып. 2; Порфирьев В.С. Лесные памятники природы. Большой Бор // Памятники природы Татарии. К., 1977.

*Ә.С.Тайсин.*

**ЗУР НӨРКӘ́Й** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 14 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 664 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Нөркәй исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.Н.дә мәчет һәм су тегермәне эшли. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 7418,8 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 3 мәчет, мәдрәсә һәм 3 мәктәп эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. 1970 елларда З.Н.гә Кече Нөркәй авылы кушыла. Халык саны: 1859 да -1553, 1897 дә — 2242, 1926 да — 1541, 1949 да — 582, 1958 дә — 610, 1970 тә — 967, 1979 да — 790, 1989 да — 626, 2002 дә — 596 кеше.

**ЗУР ӨТӘ́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 37 *км* көньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2008 елда 73 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1565–67 еллардагы чы-

ганакларда Зур Утяково исеме б-н мәгълүм. 18 йөз –19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.Ө.тә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 649 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир-ат; 1859 да — 320, 1897 дә — 520, 1908 дә — 634, 1926 да — 502, 1938 дә — 576, 1949 да — 346, 1958 дә — 234, 1970 тә — 252, 1979 да — 206, 1989 да — 119, 2002 дә — 100 кеше.

**ЗУР ПОКРО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 14 *км* көнчыгыштарак, Зөбәй елгасы буенда. 2008 елда 48 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 20 йөз башында Покровский посёлогы буларак нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 266, 1938 дә — 18, 1949 да — 190, 1958 дә — 134, 1970 тә — 123, 1979 да — 66, 1989 да — 36, 2002 дә — 47 кеше.


**ЗУР ПОЛЯ́НКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бәрән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 456 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, руслар — 47%, мордвалар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Полянки, Галкины Полянки исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1862–68 дә З.П.да Спас чиркәве төзелә, 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, земство хастаханәсе, земство уч-щесе, су һәм 3 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 620 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1963 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 318, 1897 дә — 406, 1908 дә — 505, 1920 дә — 415, 1926 да — 504, 1938 дә — 399, 1949 да — 304, 1970 тә — 515, 1979 да — 511, 1989 да — 465, 2002 дә — 438 кеше.

**ЗУР СӘРДЕ́К** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2008 елда — 974 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чыпта-капчык сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.С.тә 2 мәчет, мамык тукыма җитештерү ф-касы эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 1448, 1884 тә — 1534, 1920 дә — 1576, 1926 да — 1466, 1938 дә — 1077, 1949 да — 873, 1958 дә — 798, 1970 тә — 1045, 1979 да — 1009, 1989 да — 944, 2002 дә — 978 кеше.

**ЗУР СУКАЕ́Ш** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Сукаеш елгасы буенда. 2008 елда 502 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1742 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.С. та мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3075,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 293 ир-ат; 1859 да — 896, 1890 да — 1291, 1920 дә — 1586, 1926 да — 944, 1938 дә — 1052, 1949 да — 765, 1958 дә — 603, 1970 тә — 548, 1979 да — 449, 1989 да — 462, 2002 дә — 455 кеше.

**ЗУР ТИГӘНӘЛЕ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 23 *км* көньяктарак, Тигәнәле елгасы буенда. 2008 елда 576 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; асфальт з-ды, Алексеев бизәкләп туку ф-касы ф-лы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 1878–79 да З.Т. татар крәстияннәр чуалышы үзәкләренең берсе була. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су һәм 7 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, йон тетү йорты, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3366,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 157 ир-ат; 1859 да — 1319, 1897 дә — 1861, 1908 дә — 2160, 1920 дә — 2270, 1926 да — 1926, 1938 дә — 1407, 1949 да — 1015, 1958 дә — 900, 1970 тә — 822, 1979 да — 659, 1989 да — 530, 2002 дә — 618 кеше. Авыл янында *Зур Тигәнәле каберлеге* урыны саклана.

**ЗУР ТИГӘНӘЛЕ́ КАБЕРЛЕГЕ́**, Алексеев р-нының Зур Тигәнәле авылы янындагы 9 йөзгә караган археол. истәлек. 1974 елда юл төзегәндә табыла. 1970–80 елларда А.Х.*Халиков* һәм Е.А.*Халикова* тарафыннан тикшерелә. 110 мәҗүсиләр кабере өйрәнелә.



Зур Тигәнәле каберлеге.
Ир-ат кабере планы һәм кирәк-яраклары.
Казан ун-тының археология музее фондлары.

З.Т.к. терр-ясендә ат сөякләреннән торган корбан бирү комплекслары табыла. Мәетләр тирән булмаган (50–100 *см*) чокырларда, нигездә, башлары көнбатышка каратып җирләнгән. Каберләрдә ш.у. төрле әйберләр (көмеш бизәкләр ябыштырылган мәет битлекләре, әвәләп ясалган, тарак эзе һәм кисек-кисек бизәкләр төшерелгән йомры төпле савытлар (алар соңгы дәвер Кушнаренко һәм Караякуп культуралары керамикасына тартым), көкре кылычлар, сөңге һәм ук очлыклары, садаклар, җәяләр, ат дирбиясе, бронза һәм көмеш бизәмәләр, кием-салым һәм культ әйберләре һ.б.) табыла. З.Т.к.нең каберләре Урал артыннан килгән угор телле күчмә ка-



1



2

Зур Тигәнәле каберлеге. 1. Бил каешы җыелмасы; 2. Балчык савыт-саба.
Казан ун-тының археология музее фондлары.

биләләргә (А.Х.Халиков һәм Е.А.Халикова фикеренчә, мажарларга) нисбәтле дип фаразлана. Алар Идел буе болгарлары мәдәниятe формалашуда билгеле бер роль уйныйлар. Киемнең көмеш детальләре: бай үсемлексыман бизәкләр, канатлы атлар, аждаһалар, эт сурәте б-н бизәлгән аеллар, каеш очлыклары һәм тагылмалар кучмә угорларның Урта Азия илләре б-н бәйләнешләре булуы турында сөйләргә нигез бирә.

*Әд.:* Халиков А.Х. Новые исследования Большетиганского могильника (О судьбе венгров, оставшихся на древней Родине) // Проблемы археологии степей Евразии. Кемерово, 1984.

*Е.П.Казаков.*

**ЗУР ФРОЛО́ВО** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 407 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Николай Чудотворец (архит-ра истәлеге, 19 йөз ахыры) кәшәнәсе. 1679 да нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Николаевский, Фролов Ясак, Никольский Ясачный исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау, балта эше, йон-тукыма мануу, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, З.Ф.да 10 җил тегермәне, 2 ярма яргыч була. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Казан Богородица чиркәве (1780 елларда төзелә; архит-ра истәлеге), земство уч-щесе, чиркәү-приход мәктәбе, кредит бирү ширкәте, тимерчелек, 3 йон-тукыма ману остаханәсе, казна шәраб кибете эшли; чәршәмбе саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 813,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1935 нең 10 июленнән Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 460 ир-ат; 1859 да — 1764, 1897 дә — 2571, 1908 дә — 2836, 1920 дә — 2794, 1926 да — 2940, 1949 да — 1139, 1958 дә — 1007, 1970 тә — 1108, 1979 да — 981, 1989 да — 566, 2002 дә — 441 кеше.

*Әд.:* Буа ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**ЗУР ЧЫНЛЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 24 *км* көнчыгыштарак, Чынлы елгасы буенда. 2008 елда 1034 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1674 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре (элеккеге лашманнар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, З.Ч.да 2 мәчет була. 20 йөз башында 18 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4021,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Зур Чынлы волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1935 нең 10 февраленнән — Буденный, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1444, 1910 да — 2547, 1920 дә — 2503, 1922 дә — 2890, 1926 да — 2228, 1938 дә — 2045, 1949 да — 1615, 1970 тә — 2308, 1979 да — 1877, 1989 да — 1193, 2002 дә — 1091 кеше.

*Әд.:* Субаев Р.С. Чүпрәле: узган еллар, үткән юллар (Район тарихыннан очерклар). Чүпрәле, 2000.

**ЗУР ШӨПШӘЛӘ́Р**, боҗаннар (Vespa), чын шөпшәләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, киң таралганнар; Россиядә 5–7 төре яши. Татарстан терр-ясе өчен Европа З.ш. яки гади З.ш. (V. crabo) гадәти. Татарстанда тереклек итүче җәмгыяви җыелмаканатлы шөпшәләрнең иң зурысы (гәүдә озынлыгы 3 *см* га кадәр). Оясы шарсыман формада, диаметры 25 *см* тирәсе, агач куышларында, сыерчык ояларында, агач корылмаларда һәм чормаларда оя кора. Ояны З.ш. кәгазьгә охшаган материалдан (шунлыктан кайвакыт аларны кәгазь шөпшәләре дип тә атыйлар) ясыйлар. Бу материал каенның яшь ботакларын кимереп әзерләнә. Кыш чыккан аталанган ана зат үзе туган оядан файдалана яки яңасын төзи. Башта ул яңа ояның стенасын «кәгазь» б-н тышлый, аннан соң аска карап торган күзәнәкләрдән кәрәз ясый. Гаилә зурайгач, беренче кәрәзгә икенчесе эленә һәм шулай дәвам итә. Эре ояларда 6 катка кадәр кәрәз була, мондый ояның диаметры ярты метрга җитәргә мөмкин. Ата затлар августта күренә башлый һәм кушылганнан соң тиз генә үләләр. Җитлеккән З.ш. төрле азык б-н туклана. Личинкаларын туендыру өчен ана З.ш. һәм эшче боҗаннар эре чебеннәрне, бал кортларын, сирәк кенә ялгыз кыргый умарталарны тоталар. Умарталыклар янына урнашып, умартачылыкка сизелерлек зыян китерергә мөмкиннәр. З.ш. угы кеше өчен куркыныч.

*Е.А.Сапаев.*

**ЗУР ШЫЯ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* төньяктарак, Шыя елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2008 елда 297 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Шыя исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1885 тә З.Ш.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла. 20 йөз башында 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 978,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат; 1859 да — 417, 1897 дә — 561, 1908 дә — 688, 1920 дә — 537, 1926 да — 344, 1938 дә — 480, 1949 да — 322, 1958 дә — 391, 1970 тә — 415, 1979 да- 384, 1989 да — 302, 2002 дә — 311 кеше.

**ЗУР ЭНӘ́ КАРАГЫ́** (Aeschna grandis), энәкараклары семьялыгыннан. Гәүдә озынлыгы 7 *см* га җитә, канат колачы 10 *см* кадәр, төсе кызыл көрән. Күзләре зур, ялтырап тора, баш артында тоташалар. Татарстанның бөтен терр-ясендә очрыйлар, сан ягыннан бик аз. Акмый торган сулыклар янында яшиләр. Бер көчәеп, бер акрынаеп, тиз оча. Ерткычлар. Олы З.э.к. бөҗәкләр б-н туклана, корбанын очканда тота. Ана затлар йомыркаларны суга, су үсемлекләре тукымаларына, сирәк кенә дымлы яр буе туфрагына салалар. Личинкалары үсемлекләр б-н капланган акмый торган яки әкрен агучы сулыкларда үсә; чукмарбашларга һәм балык маймычларына һөҗүм итәләр. З.э.к. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЗУХРА́БОВ** Мирзабәк Гашим улы (18.2.1953, Дагстан АССР, Табасар р-ны Тураг а.), вет. акушер-гинекологы, вет. фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Дагстан а.х. ин-тын тәмамлый (1978). 1981 елдан Казан вет. медицина академиясендә, 1999 дан акушерлык, гинекология һәм үрчетү каф. мөдире. Хезмәтләре матдәләр алмашына бәйле авыруларга диагноз куюга, аларны дәвалау һәм булдырмауга, төбәктәге экологик мохит торышына бәйле рәвештә терлекләрнең үрчемсезлеге мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 3 патенты бар.

Хезм.: Изучение некоторых аспектов патогенеза и лечения анемии молодняка животных. Астана, 2003; Изучение хронической токсичности топинамбура // Ветеринария. 2003. № 1; Плазменно-фогометрические методы анализов. Методические указания. К., 1999; Половая этология животных // Зоотехника. 2002. № 1.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ЗҮЗӘ́Й** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сәләнгеш елгасы буенда. 2008 елда 136 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Клуб. 1930 еллар башында нигез салына. Оештырылган көннән — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1938 дә — 355, 1949 да — 394, 1958 дә — 370, 1970 тә — 306, 1979 да — 220, 1989 да — 151, 2002 дә — 170 кеше.

**«ЗЫНҖЫРЛЫ́»,** мәдрәсә. 1501 елда Бакчасарай шәһәрендә Миңлегәрәй хан нигез сала. Атамасы капка а́ркасына ярымбожра рәвешендә асылган 2 зур тимер чылбырга (кырым-татар телендә — зынҗыр) нисбәтле. Мәдрәсәгә кергән һәрбер кеше, фән һәм белем үзәген хөрмәтләү йөзеннән, башын иеп керергә тиеш була. Риваятьләр буенча, Миңлегәрәй хан төзелештә үзе катнаша һәм мәдрәсә ачылганда чыгыш ясый. «З.»ның архит-ра йөзе ул замандагы мөселман уку йортлары өчен хас була. Мәдрәсә таш диварлар б-н әйләндереп алына, эчендә шәкертләр өчен периметр буенча 13 бина урнаша. Дәресләр аерым зур бүлмәдә (хөҗрә) алып барыла. Кырым ханлыгын Россия басып алгач (1783), «З.» төбәктә иң зур ислам гыйлеме бирү үзәге булып кала бирә. Ул Миңлегәрәй хан тарафыннан Олы Күл авылы тирәсендә махсус бүлеп бирелгән һәм ел саен 10 мең сум күләмендә табыш китерүче бернич мең дис. сө-

рүлек һәм печәнлек җирләрдән килүче керем — *вакыф* хисабына тотыла.

1890 да «З.»да яңа ысул б-н укытуга күчү башлана, аны 1889 да мөдәррис итеп сайлап куелган имам Хаҗи Хәбибулла (1823–95) башлап җибәрә. Ул вакыф исәп-хисапларын тәртипкә сала, уку йортының уставын эшли, уку процессын тулысынча үзгәртеп кора. Укырга Коръәнне белүче һәм язу күнекмәләре булган үсмерләр алына. Барлык укучыларга вакыф хисабына форма киемнәре бирелә. Алар мәдрәсәдә кырыс тәртиптә яшиләр. Хаҗи Хәбибулла санитария-гигиена нормаларына һәм укыту шартларына аерым игътибар бирә. Аның тәкъдиме б-н мәдрәсәдәге дәресләр һәм яшәү өчен билгеләнгән уңайсыз бүлмәләр урынына якты һәм җылы биналар булдырыла. 20 йөз башында мәдрәсә уставы нигезендә «Кырым мәдрәсәләренең программасы һәм гомуми кагыйдәләре» эшләнә. Хаҗи Хәбибулла реформасы 10 еллык уку курсларын кертә, бу курс дәвамында төрек һәм гарәп грамматикасы, каллиграфия, арифметика, астрономия, әхлак, логика, риторика, шигырь төзелеше, мөселман хокукы, илаһият, Сөннә, Коръән, рус теле өйрәнелә. Шәкертләрнең белемен бәяләүдә имтихан алу тәртибе кертелә. Еллык имтиханнар һәр сыйныф һәм бүлек өчен июнь аенда галим-голәма һәм «З.» укытучылары катнашында уздырыла. Хаҗи Хәбибулла мәдрәсә каршында китапханә оештыра, аңа үзенең китаплар җыелмасын бирә. 20 йөз башында мәдрәсәдә якынча 100 шәкерт укый. «З.» Россиянең төрки-мөселман халыкларының прогрессив фикер йөртүче вәкилләре өчен үрнәк булып тора. Укытучылары арасында Ә.Н.*Максуди* (1894–96) була. 1917 елның 8 ноябрендә «З.» дөньяви белем бирә торган милли Миңлегәрәй ин-ты дип үзгәртелә. 1920 елда ябыла.

*Әд.:* Музафаров Р. Крымско-татарская энциклопедия. Симферополь, 1993; Танкевич В.Ю. Крымско-татарские медресе. Симферополь, 2001.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ЗЫЯКА́ЕВ** Зиннур Нурфаяз улы (2.10.1954, Баулы р-ны Баулы штп), тау инженеры, РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1983). 1972 елдан «Татнефть» АҖнең «Баулынефть» НГДУында: бораулаучы, инженер, цех башлыгы, баш инженер; бер үк вакытта 1992 дән НГДУ башлыгының 1 нче урынбасары (бүленеп, 1978–79 елларда «Нефтемаш» махсус КБнда инженер-технолог, Баку). Уйлап табуга 8 патенты бар. Дәүләт бүләге штангалы тирәннән суырту насосы җайланмаларының ышанычлылыгын арттыру буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләгәне өчен бирелә.

Хезм.: Парогазовый шнур гидроциклона. Уфа, 1997 (автордаш); Проблемы нефтегазового комплекса в условиях становления рыночных отношений. Уфа, 1997 (автордаш).

**ЗЫЯТДИ́Н** бине Хисаметдин бине Корамшаһ бине Корбангали (1870–1930, фаразлау буенча, хәзерге Әлмәт р-ны Чупай а.), ташка уеп язучы, хаттат. З. тарафыннан 1920–21 елларда эшләнгән кабер ташлары Колшәрип, Мәмәт, Чупай авыллары зиратларында саклана. Кабер ташлары акташтан, турыпочмаклы һәм очлары ярымтүгәрәк формада эшләнгәннәр. Үлчәмнәре якынча 80×47×15 *см*. Өске өлешләрендә, гадәттәге ташларга хас булганча, яңгыр суы җыела торган уем уелган — бу аларга кунган кошлар эчәр өчен ясалган. Кабер ташының алгы ягындагы язулар гарәп графикасында сөлес һәм тәгълик стиле б-н, яссы рельефта һәм тирән итеп график ысул кулланып уелганнар; гадәттәгечә, туры сызыкларга бүленгән 9 рәткә урнашканнар, бизәкләре юк. Текст, нигездә, гарәп телендә язылган. Ел вакытлары гарәп



Зыятдин бине Хисаметдин. Кабер ташы. Уеп бизәкләү. Мәмәт авылы (хәзерге Әлмәт р-ны). 1921.

саннары б-н Европа календаре системасында китерелгән. Ташка уеп язучының «Кәтәбә — Зыятдин» («Язучы-Зыятдин»), «Кәтәбә Зыятдин бине Хисамеддин бине Корамшаһ бине Корбангали», «Кятиб Зыятдин бине Хисаметдин Чупай карьясеннән» рәвешендә исеме язылган.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000. 47, 149–150 б.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Азат Шәймулла улы (20.1.1939, Балтач р-ны Таузар а.), химик-технолог, җәмәгать эшлеклесе, техник фән. д-ры (1991). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001). ТРның атказ. химигы (1995). 1968 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли, Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә эшләре идарәсенең каталитик тикшеренү лаб. башлыгы (1981 дән), фәнни-технол. үзәк директоры (1997–2008), проф. (1999), ТР ФА вице-президенты (2009 дан). З. җитәкчелегендә ацетофенонны гидрирлау катализаторы, изопренны ацетилен углеводородларыннан чистарту һәм соңгыларын гидрирлау; бутил спиртлары, метилфенилкарбинол. 2-этилгексанол, циклопентадиен, пропилен тримерларын һәм тетрамерларын алу; ясалма каучук, нефтеполимер сумала, лак-буяу материаллары алу өчен эреткечләр, бутилкаучук алу һәм тотрыкландыру технологияләре; автобензиннар алу җайланмасы һәм технологиясе; бутанны чистарту процесслары; гади эфирларның яңа маркалары эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. н-Пентанны изомерлаштыру процессы оптимальләштерелә, барботаж һәм градиентсыз реакторлар, пиролиз өчен көпшәсыман мич, түбән олефиннар, хлорланган бутилкаучук алу өчен җайланмалар эшләнә. Хезмәтләре тәҗрибәләрне планлаштыруга, нефть химиясе процессларының нәтиҗәлелеген күтәрүгә, сәнәгый органик реакцияләр кинетикасына һәм аларның механизмнарын ачыклау өчен статистик ысуллар куллануга карый. Уйлап табуга 90 лап авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Түбән Кама шәһәрендә милли хәрәкәт җитәкчеләреннән, мәчет, балалар бакчалары, мәктәпләр төзүне оештыручыларның берсе. Газета-журналларда иҗтимагый-сәяси темаларга, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә багышланган 30 дан артык мәкалә авторы. Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданы (1999). 1990–95 тә, 2009 дан ТР ЮС депутаты. ТР Дәүләт бүләге иясе (2006). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Такташка хатлар // Сөембикә. 2001. № 1–2; Исследования кинетики реакции гидрирования ацетофенона в метилфенилкарбинол на катализаторе КГА-43 // Журн. прикладной химии. 1988. Т. 61, № 3 (автордаш); Анализ множественных стационарных состояний на зерне сплавного катализатора СКНМ-35 в процессе гидрирования этилена // Журн. прикладной химии. 1991. Т. 64, № 1.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Бакый Шәймулла улы (19.1.1930, Арча кантоны Таузар Иле а.), төбәк тарихчысы, педагог, ТАССРның, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1980, 1987). 1956 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1950 дән Карадуган һәм Балтач авылы мәктәпләрендә укытучы булып эшли, 1955 тән Кенә мәктәбендә укыта, директор (1957–60). 1960–62 дә Балтач р-ны халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1962–94 тә Карадуган мәктәбе директоры. Карадуган авылындагы М.Җәлил, «Себер трактындагы почта станциясе тарихы» музейлары директоры (1992 дән). Себер тракты, Балтач һәм Арча р-ны авыллары тарихына караган хезмәтләр авторы. 2 нче һәм 3 нче Бөтендөнья татар конгресслары делегаты (1997, 2002). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Себер юлы серләре. 1999; Мәгърифәтле Таузар Иле. К., 2004; Рәхмәт сиңа, Хәсәншәех! К., 2006.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Вакыйф Кыям улы (1.7.1929, Балык Бистәсе р-ны Югары Ырга а.), журналист, тәрҗемәче, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы (1966), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1968), СССРның мәгариф отличнигы (1981). РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1953–56 елларда хәзерге Тукай р-нының Теләнче Тамак урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1956–89 да «Совет мәктәбе» ж-лында (әдәби хезмәткәр, 1958–77 дә җаваплы сәркәтип, 1977–1989 да баш мөхәррир), 1998–2008 елларда ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында (энциклопедик басмаларны татар телендә әзерләү бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр). Рус һәм

совет язучылары әсәрләрен, пед. һәм фәнни-популяр хезмәтләрне татар теленә тәрҗемә итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Миңлебаев К. Тәрҗемә үрләре // Казан утлары. 1979. №6; Вәлиуллин М. Абруйлы каләмдәшебез // Мәгариф. 1999. №6; Миннибаев К.С. Перевод — это искусство. К., 2004.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Васил Билал улы (31.10.1955, Кукмара р-ны Адай а.), табиб-ортопед, мед. фән. д-ры (2003), ТРның атказ. табибе (1996). 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1979–90 елларда Балтач р-ны Чепья участок һәм р-нның үзәк хастаханәләре табибе, баш табибе. 1990–92 дә Алабуга шәһәренең сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы. 1992 дән Балаларны туберкулёздан дәвалау «Обсерватория» респ-ка санаторие баш табибе, 1999–2006 да Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы. 2007 дән «ТРда гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибе урынбасары. З. җитәкчелегендә күп кенә дәвалау учреждениеләре биналары төзелә, Казанның Совет, Идел буе, Авиатөзелеш р-ннарында амбулаторияләр ачыла. Хезмәтләре балалар ортопедиясенә карый. Балаларның терәк-хәрәкәтләнү аппараты авыруларын (сколиоз, Пертес авыруы һ.б.) дәвалау ысулларын эшли һәм мед. гамәленә кертә. ТРда вабаны бетерү өчен дәвалау-профилактика чаралары оештыра.

Хезм.: Маркетинг в здравоохранении. К., 2001; Организация противоэпидемической работы в лечебно-профилактических учреждениях города Казани. К., 2002; Холера. К., 2002.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Габделгазиз Габдрахман улы (15.7.1904, Уфа губ., Уфа өязе Чуалкип а. — 28.10.1991, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1968). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң (1929), Әстерхан татар драма театрында (1929–30), Мәскәү үзәк эшче театрында (актёр һәм директор урынбасары, 1930–32), Ленинград татар театрында (1933–34) эшли. 1934 елда Татар акад. театрына кабул ителә. Урал шахталарында, Себердә, махсус бурыч үтәүче сугышчан отрядта хезмәт итеп, кырыс тормыш мәктәбе үткән З. тормышны тирәнтен белүе б-н сәхнәдә үзе иҗат иткән образларның төгәллегенә, тормышчанлыгына ирешә. З.ның уңай геройлары да, тискәреләре дә үз-үзләрен тотуда кыюлык, рухи көчкә ия булулары б-н аерылып торалар. Мәс., барысын берсүзсез үзенә буйсындырырга тырышучы дорфа Нури («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов) З. башкаруында усаллык һәм явызлыкның җанлы гәүдәләнеше булып, ә Конь образы («Дошманнар», М.Горький), караңгы, күңелсез иске тормышның миңгерәү бер фигурасы булып күз алдына килеп баса. Тайгадагы аучы Соколов («Таня», А.Н.Арбузов), урман каравылчысы Василий («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Хөсәен Ямашев («Тукай», Ә.Фәйзи), эшче Мирвәли («Шомлы көннәр», Т.Гыйззәт), Глоба («Рус кешеләре», К.М.Симонов) образлары мөлаемлык, романтик хисләр б-н өртелгән. Тархан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Мәүлән («Ефәк сүзәнә», А.Каххар), Шәйхи («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Риппафратта («Трактирщица», К.Гольдони) образлары З. башкаруында һәрберсе кызыклы, үзенчәлекле итеп, җентекләп эшләнгән образлар булып тамашачы күңелендә саклана. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*И.И.Илялова.*


**ЗЫЯТДИ́НОВ** Камил Шәһәр (Шәһәретдин) улы (10.7.1951, Буа р-ны Әлки а.), хирург, сәламәтлек саклау эшлеклесе, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2003), СССР сәламәтлек саклау отличнигы (1991), ТР һәм РФнең атказ. табибе (1992, 2000). 1978 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан мед. учреждениеләрендә эшли: Буа р-н үзәк хастаханәсендә хирург-травматолог (1978–80), поликлиника мөдире (1980–84). 1984–89 елларда Казанның 20 нче поликлиникасы баш табибе, 1989–91 дә шәһәрнең 18 нче хастаханәсе баш табибе, Казан шәһәре Идел буе р-ны баш табибе (1991–94). 1994–2007 дә ТР сәламәтлек саклау министры. 2007 елдан Казан медицина академиясе ректоры. Хезмәтләре иминиятләштерүгә һәм гаилә медицинасына күчерү мәсьәләләренә, халык сәламәтлеге торышына күзәтүләр үткәрүне планлаштыруга, респ-ка сәламәтлек саклау системасында экология мониторингы һәм техногенез булдыруга, медицинада югары технологияләрне гамәлгә кертүгә (компьютер томографиясе, диагноз куюда нурлар б-н эш итү ысуллары һ.б.), сәламәтлек саклау системасын үзгәртеп кору чорында идарә итү мәсьәләләренә һ.б. карый. ТРның халык депутаты (1990–95), ТР Дәүләт бүләге «ТРның коньяк-көнчыгышында техноген һәм экологик мониторинг, ТРның нефть чыгару р-ннарында халык сәламәтлеге һәм экологияне төзекләндерү чараларын гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә (1996).

Хезм.: Лучевые методы исследования в диагностике заболеваний органов гепатопанкреатодуоденальной зоны и мочевыводящей системы // Казан. мед. журн. 1993. № 2 (автордаш); Здравоохранению Республики Татарстан — 75 лет // Материалы науч.-практ. конф. «Здравоохранению Республики Татарстан — 75 лет». К., 1996; Компьютерная томография в диагностике и лечении хирургических заболеваний // Материалы респ. науч.-практ. конф. «Современные методы диагностики и лечения больных в клинике». К., 1996 (автордаш); Дневные стационары (Стационарозамещающие формы организации оказания медицинской помощи населению). М., 2000 (автордаш).

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Надир Низам улы (28.4.1948, Казан), химик-технолог, эколог, техник фән. д-ры (2002), проф. (2003). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли: 1988 дән «Системотехника» үзәгендә директор урынбасары, бер үк вакытта 1996–98 дә Идел буе һәм Урал югары уку йортлары укытучыларының белемнәрен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәгендә директор урынбасары, 2001 дән өстәмә һөнәри белем бирү ин-тында директор урынбасары, 2002 дән югары уку йортлары укытучыларының белемнәрен күтәрү ф-ты деканы, бер үк вакытта химия кибернетикасы каф. профессоры. Хезмәтләре химик-технол. һәм биотехнол. системаларны оптимальләштерүне синтезлау һәм анализлауга, химия, нефть химиясе һәм биотехнол. производстволары технологиясен матем. модельләштерүгә карый. З. тарафыннан ташландык суларны биол. чистартуның сәнәгый процессларын матем. модельләштерү һәм оптимальләштерү, этилен һәм этаноламин җитештерүне ректификатлаштыру эшләре үткәрелә. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре «Казаноргсинтез» АҖдә гамәлгә кертелә (1997–2000). Уйлап табуга патенты бар.



Г.Г.Зыятдинов.



Н.З.Зыятдинов.

Хезм.: Характеристика различных подходов к оптимизации химико-технологических систем // Оптимизация химико-технол. процессов. Теория и практика. М., 1984; О расчёте стационарных режимов сложных химико-технологических схем // Докл. АН СССР. 1980. Т. 253, № 2; Синтез химико-технологических систем модифицированным методом структурных параметров // Теорет. основы хим. технологии. 1997. Т. 31, № 1; Процессы сорбции и биоокисления во флокулах активного ила // Хим. пром-сть. 2001. № 3.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Нәҗип Зыятдин улы (25.7.1925, Бөгелмә кантоны Тайсуган а. — 10.1.2008, шунда ук, хәзер Әлмәт р-ны), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1976). 1962 елда югары партия мәктәбен тәмамлый (Горький ш.). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950–58 елларда Әлмәт р-ның «Ярыш» к-зы рәисе, 1962–73 тә Баулы р-ның «Баулы» с-зы директоры, 1973–96 да Тукай р-ның «*Гигант*» с-зы директоры. Аның җитәкчелегендә сугарулы җирләрдә (2,9 мең *га*) а.х. культураларын үстерүдә интенсив технологияләр кертелә, бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 1986 да — 65,1 *ц*, 1994 тә — 67 *ц*, 1997 дә 57,9 *ц* тәшкил итә; 100 *га* а.х. җирләренә 490 *ц* сөт җитештерелә. Барлык уңайлыклары булган посёлок, сөт комплексы һ.б. производство объектлары төзелә. 1955–59 һәм 1971–75 тә ТАССР ЮС, 1989–91 елларда СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Подвиг хлебороба. К., 1987.

*Әд.:* Ларичева Э. Зиатдинов Назип Зиатдинович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг): Док. очерки. К., 1980; Магдеев М.С., Гилязов А.М., Галиев М.Б. Доброта. К., 1988.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Раил Шәһәретдин улы (23.2.1949, Буа р-ны Әлки а.), а.х. производствосын оештыручы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), икътисад фән. д-ры (1997), ТАССРның атказ. агрономы (1984), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1994). Казан а.х. ин-тын

тәмамлый (1973). 1978–85 елларда Яшел Үзән р-нының «Норлат» с-зы директоры, 1985–86 да Яшел Үзән р-ны агросәнәгать берләшмәсе советы рәисе, 1986 дан «Татплодовощпром» концерны башлыгы, 1992 дән идарә рәисе. Аның җитәкчелегендә производствога яшелчә һәм җиләк-җимешне эшкәртү, саклау эшенә алдынгы технологияләр кертелә. ТР Дәүләт бүләге кышкы сезонда экологик чиста яшелчә үстерүдә ресурс саклаулы технологияләр булдырганы һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. ТР халык депутаты (1999 елдан). Почёт, Дуслык, «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары, медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ЗЫЯТДИ́НОВ** Фарсель Сәхап улы (1.6.1937, хәзерге Актаныш р-ны Качкын а.), язучы, икътисад белгече, икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2010), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан ун-тын (1965) һәм Казан а.х. ин-тын (1966) тәмамлый. 1964–70 елларда ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында эшли, 1970–86 да Татар а.х. фәнни тикшеренү ин-тында бүлек мөдире, бер үк вакытта Казан ун-тында укыта (1978–87). 1986 дан Казан финанс-икътисад ин-тында, 2004 тән житештерү икътисады каф. профессоры, бер үк вакытта 1993 елдан Татар энциклопедиясе ин-тында (2003 кә кадәр икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге мөдире), 2003 тән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында икътисад каф. мөдире. Беренче әсәрләре 1960 еллар башында басыла башлый. Балаларга атап язылган «Кызык дөнья» (1974), «Гыйльми белән Белми» (1983), «Онытылмас авазлар» (1988), «Икътисад әлифбасы» (2000) исемле шигырь һәм хикәяләр жыентыклары авторы. Туган җиргә мәхәббәт һәм тугрылык хисләре б-н сугарылган лирик шигырьләре «Тагын килде язлар» (1991) җыентыгында тупланган. «Изге йорт» (1997) повесте селекционер галимнәргә багышланган. «Кырлар батыры» (1975), «Яшәү мәгънәсе» (1998), «Кыенлыклар аша йолдызларга» (русча тәрҗемәсе «Через тернии к звёздам», 1999) җыентыкларына кергән документаль хикәя һәм повестьлары публицистик рухта язылган. З. — агросәнәгать комплексында җир, матди-техник, хезмәт ресурсларын бәяләү һәм нәтиҗәле куллану проблемалары буенча тикшеренүләр авторы. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ямь һәм тәм яки безнең бакча. К., 2010. Интенсификация и трудовые ресурсы колхозов. К., 1974; Слагаемые рентабельности. К., 1977; Крупяное поле Татарии. К., 1979; Уровень квалификации и производительность труда сельского механизатора. К., 1979; Ресурсный потенциал АПК: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001.

*Әд.:* М а н н а п о в Ш. Туган жирдән көч алып // Казан утлары. 1997. № 6; Ф ә й з у л л и н Р. Фарсель Зыятдинов турында // Идел. 1997 № 11.

**ЗЫЯТДИ́НОВА** (Зыялы) Сәйдә Закир кызы (27.3.1941, Теләче р-ны Шәдке а.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1971 дән «Яшь ленинчы» г-тасында, 1983 тән «Азат хатын» ж-лында эшли, 1993–97 елларда «Татарстан» ж-лында мәдәният бүлеген җитәкли. «Айның туган чагы» (1991), «Сулар үргә акмый» (2010) шигырьләр җыентыклары, «Кайнар сукмаклар» (1990), «Кар карасы» (1994) повестьлары, хикәя, очерк, публицистик мәкаләләр авторы.

Ә с ә р: Ачылмаган бөре. К., 2006.

*Әд.:* Г ы й з з ә т у л л и н а Ф. Айның туган чагы // Социалистик Татарстан. 1991. 16 июль; Х у ж и н М. Ямь һәм гамь // Казан утлары. 2001. № 2.

**ЗЫЯТДИ́НОВА** Фирая Гали кызы (5.9.1945, Әтнә р-ны Мамыш а. — 23.4.2006, Казан), шагыйрә, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1969–2001 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор. Беренче шигырьләре 1950 еллар ахырында респ-ка газета-журналларында басыла башлый. «Матур буласым килә» (1986), «Язгы ярсу» (1988), «Ташкын» (1991), «Мин кояшка елмаям» (2000), «Утның яшисе килә» (2005), балалар өчен «Айнур» (1995) исемле шигырь җыентыклары авторы. З.ның шигъриятенә нечкә лиризм, ихласлылык һәм туган җиргә мәхәббәт хас. Аның шигырьләренә композиторлар Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари, Р.Кәлимуллин, М.Шәмсетдинова, Р.Әхиярова һ.б. популяр җырлар иҗат итә. Алар арасында — «Мин сине шундый сагындым», «Китмим әле яшьлегемнән» (икесе дә Л.Батыр-Болгари музыкасы). З. — К.Г.Паустовскийның «Яңгырлы иртә» («Дождливое утро», 1985) хикәяләр җыентыгын, шулай ук мәктәпләр өчен тарих, икътисад һәм география фәннәре буенча дәреслекләрне татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г а б и д и Ә. Мәхәббәт яктысы // Казан утлары. 1988. № 4; В ә л и М. Кызлар йөрәге // Мәдәни җомга. 2000. 2 сент.; М у л л а н у р о в а Р. Яме бар бит көзләрнең дә // Сөембикә. 2001. № 8.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗЫЯТДИ́НОВА** Флёра Газиз кызы (18.2.1947, Казан), социолог, социол. фән. д-ры (1993), проф. (1997), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан ун-тын (1970), РФ Тышкы эшләр министрлыгының Дипломатия академиясен тәмамлый (Мәскәү, 2002). 1980–83 елларда КПССның Түбән Кама, 1983–88 дә Казан шәһәр ком-тлары секретаре. 1988–92 дә ТР Мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү ин-тында иҗтимагый фәннәр каф. мөдире. 1992–97 дә ТР Тышкы икътисади элемтәләр министры урынбасары. 1997 дән ТР Президенты Тышкы элемтәләр департаментының дәүләт протоколы идарәсе башлыгы. 1999–2003 тә РФ Дәүләт Думасы депутаты, Халыкара эшләр ком-ты рәисе урынбасары, геополитика, балигъ булмаганнар һәм яшьләрне караучысыз, тәрбиячесез калудан яклау һәм наркомания таралудан саклау мәсьәләләре буенча комиссияләр әгъзасы. 2004–2009 елларда ТР Дәүләт Советы депутаты. 2004 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында, философия һәм социология каф. мөдире. Хезмәтләре мәгариф системасы хезмәткәрләренең социаль хәле мәсьәләләренә карый. 1 һәм 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медальләре, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Воспитательное взаимодействие школы, семьи, трудовых коллективов в социально-педагогическом комплексе. К., 1985; Социальные проблемы образования. М., 1999.

**ЗЮ́ЗИНО** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2008 елда 52 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1565–67 еллардан Ячы (Ахча) исеме б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында З.да волость идарәсе урнаша, Никола чиркәве (1797 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), вак кредит учреждениеләре, 2 тегермән эшли; сишәмбе саен базар, Троица көнендә ярминкә уздырыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 924 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир-ат; 1859 да — 228, 1897 дә — 315, 1908 дә — 329, 1920 дә — 386, 1926 да — 298, 1949 да — 212, 1958 дә — 163, 1970 тә — 214, 1989 да — 57, 2002 дә — 62 кеше.

**ЗЯ́БЛИКОВА** Татьяна Александровна (11.5.1942, Казан — 7.2.2002, шунда ук), физик-химик, химия фән. д-ры (1999). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1965 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. Хезмәтләре ТМР спектроскопиясе ысулларына карый. Катлаулы молекулалар төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнүгә ТМР параметрларының элементорганик кушылмалар структур факторларына бәйлелеге нигезендә комплекслы якын килүне үстерә. Тимер төркеме парамагнит комплексларының фосфорорганик һ.б. кушылмалар молекулалары б-н молекулаара тәэсирләшүләрен өйрәнү өчен водород һәм фосфор төшләренең спинлы динамик гетеротөш чишелеше методикасын төзи. Фосфор төшләренең магнитлы экранлашу һәм спин-спинлы тәэсирләшү константаларының иң якын алмашларының үзлекләренә һәм структур факторларга бәйле үзгәреше закончалыкларын билгели.

Х е з м.: Строение 1,2,3-диоксасилафосфацинов в растворе. Экспериментальное и теоретическое исследование // Журн. общей химии. 1999. Т. 69, вып. 7 (автордаш); Nuclear Magnetic Resonance of the Oxygenation of CD (II) Aculhydrazone Complex // Oxidation Communications. 1991. V. 14, № 3–4 (автордаш).

# И

**ИА́КОВ** (Пятницкий Иван Алексеевич) (22.9.1844, Калуга губ. Брынь а. — 1922, Томск ш.), дин эшлеклесе, дин гыйлеме магистры (1878). Калуга руханилар семинариясен (1866), Мәскәү руханилар академиясен (1870) тәмамлый. 1886 елдан монахлыкта. 1891 дән Умань епископы, 1904 тән — архиепископы. Кишинёв, Ярославль, Сембер епархияләрен җитәкли. 1910 нан Казан һәм Зөя архиепископы, 1917 дән митрополит. 1918 елда Казаннан Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясе б-н бергә китә. Акгвардияче гаскәрләр биләгән төбәктә Томск епархиясе б-н идарә итә. Совет хакимияте тарафыннан кулга алына, сак астында яшәгәндә вафат була.

**ИБА́КЪ (Упак, Айбакъ, Ибраһим) ХАН** (? — 1495), Себер ханлыгы идарәчесе (1450 еллардан). 1470–80 елларда Себер олысларын (төмәннәрен) берләштерү өчен көрәшә. 1480 дә нугай морзалары б-н бергәләп *Әхмәд хан* гаскәрен тар-мар итә. 1480 елларда Алтын Урданың көнчыгыш җирләрен кире кайтару өчен көрәш башлый. 1492 елда, туганы Мамык б-н бергәләп, нугай морзалары булышлыгында Хаҗитарханны талый һәм үз станын Идел аръягына күчерә. *Мөхәммәд Тайбуга* җитәкчелегендәге аксөякләр фетнәсе вакытында үтерелә.

*Әд.:* Миллер Г. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; Материалы по древней истории Сибири. Улан-Удэ, 1964.

*И.Л.Измайлов.*

**ИБӘ́ТОВ** Равил Ибраһим улы (18.1.1958, Беренче Май, хәзерге Чирмешән р-ны Әмир а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2006), проф. (2007). 1980 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол. ин-тында эшли, 1986–2007 дә Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, 2007 дән Казан аграр ун-тында, гамәли информатика һәм матем. каф. мөдире. Хезмәтләре химия һәм нефть сәнәгатендә төрле технол. процессларны матем. модельләштерүгә карый. И. үзәктән куулы кырда гетероген катнашмаларның юка катламлы агымнарын исәпли. Суспензияләрне фильтрлау һәм үзәк тирәли әйләндерү вакытында гидромеханик процессларны исәпләү алымнарын эшли. Күпфазалы системаларны аеруның гидромеханик процессларын матем. модельләштерүне тирәлекнең реологик законы нәсызыкчалыгын, чикләрнең үтешлелеген һәм эффектларның инертлыгын исәпкә алып үстерә.

Х е з м.: Математическое моделирование динамики дисперсной фазы // Теорет. основы хим. технологии. 2005. Т. 39, № 2 (автордаш); Течение многофазной среды по проницаемой поверхности с образованием осадка // Инженерно-физ. журн. 2005. Т. 78, № 2 (автордаш); Математическое моделирование течения многофазной гетерогенной среды по проницаемому каналу // Теорет. основы хим. технологии. 2007. Т. 41, № 5 (автордаш).

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Әмир Әмин улы (17.10.1939, Казан), радиофизик, физ.-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2002). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, сектор башлыгы (1972–76). 1978 дән Казан ун-тында, радиофизика каф. профессоры (2000 нән). Хезмәтләре электромагнитик ярашуга, сигналларны статистик эшкәртү ысулларына карый. И. тарафыннан сигналлар классларын идентификацияләү кагыйдәләрен, импульслы сигнал класслары генераторларын, импульслы классларын, класслар саны мәгълүм һәм билгесез булганда бер һәм күпүлчәмле сигналлар классларын оптималь һәм квазиоптималь чишү алгоритмнарын анализлау һәм синтезлау; ш.у. электромагнитик ярашу шартлары синтезы; комачау шартларын анализлау, тәҗрибәгә нигезләнмәгән мәгълүматның хәл итү процессына йогынтысын бәяләү уздырыла. 2001 елдан «Приём и обработка информации в сложных информационных системах» җыентыгының фәнни мөхәррире. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Принятие решений в сопряжённых информационных системах. К., 1986; Электромагнитная совместимость и помехоустойчивость информационных систем. К., 1989; Методы разрешения классов стохастических сигналов // Изв. вузов. Радиоэлектроника, 1995. Т. 38; Фильтрация оценок информационных параметров сигналов при разрешении их классов // Изв. вузов. Радиоэлектроника. 2006. Т. 49, № 1.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Илгиз Абдулла улы (14.8.1931, Мәскәү), хирург, мед. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1956), Яшел Үзән шәһәрендә табиб булып эшли. 1959 елдан Үзәк ГИДУВта (Мәскәү), 1974 тән А.В.Вишневский исем. Хирургия ин-тында, 1976 дан А.Н.Бакулев исем. Йөрәк-кан тамырлары хирургиясе ин-тында. 1981 дән Новокузнецк ГИДУВында, оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. 1985 тән Казан мед. академиясендә, 1990 нан оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре клиник анатомиягә һәм оператив хирургиягә (ангиологиягә) карый. И. лимфа агышларының һәм стресс халәттә бөер өсте бизләре артериаль системасының клиник-морфофункциональ бәйлелегенең төп мәсьәләләрен өйрәнә; лимфа системасы һәм аның патологиясенең сегментар төзелеш классификациясен булдыра; лимфа системасының асимметрик төзелешен ачыклый һәм аның клиник күренешендәге ролен билгели; кече оча сөягендәге һәм арт сандагы патологик процессларны клиник-анатомик чикләүне (локальләштерү) тәкъдим итә. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Новые медицинские технологии в хирургии // Материалы конф. к 185-летию Казан. гос. мед. ун-та. К., 1999. Т. 1; Гомеостаз и артериальная гипертензия. Сегментарное строение лимфатической системы и его клиническое значение. К., 2003.



К.Х. Ибәтуллин.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Илдус Ибәтулла улы (22.3.1946, Куйбышев р-ны Көек а.), а.х. терлекләрен тукландыру белгече, а.х. фән. д-ры (1993), проф. (1995), Украинаның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998). 1970 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1971 дән Украина а.х. академиясендә: 1980–85 елларда а.х. терлекләрен туклandыруны химияләштерү лаб-ясе мөдире, 1985–86 да аграр тәҗрибә станциясе директоры урынбасары, 1996 дан проректор. Хезмәтләре азыкларның, сәнәгать чималын эшкәртү калдыкларының химик составын һәм туклыклылыгын, аларны отышлы файдалану ысулларын өйрәнүгә, Украинаның урман, урман-дала зонасындагы терлекләрне туклandыруда азыкларга өстәмәләр һәм биологик актив матдәләр кертү алымнарын эшләүгә карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Кәримулла Хәким улы (6.3.1928, Арча кантоны Бикнарат а.), ташчы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1947 елдан 237 нче з-дның капиталь төзелеш идарәсендә (Казан) эшли. 1953–88 дә «Главтатстрой» идарәсенең 2 нче тресты 8 нче төзелеш-монтаж идарәсендә. 1988–90 елларда «Теплоконтроль» АҖндә. Герой исеме җидееллык планны (1959–65) үтәүдә, капиталь төзелештә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Кәшиф Ибәтулла улы (17.3.1926, Саба р-ны Юлбат а. — 10.10.2003, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. сәүдә хезмәткәре (1975). Мәскәү совет сәүдәсе ин-тын тәмамлый (1967). 1952–55 елларда Саба һәм Молотов



Р.Р. Ибәтуллин.

р-ннары башкарма ком-тларында сәүдә бүлеге мөдире, Казан өлкә сәүдә бүлегендә колхозлар сәүдәсе секторы башлыгы булып эшли. 1955–58 дә РСФСР буенча Сәүдә һәм товарлар сыйфаты дәүләт инспекциясенең Татарстан бүлекчәсендә инспектор, өлкән инспектор. 1958–64 тә һәм 1966–67 дә ТАССР Сәүдә министрлыгында: сәүдә бүлеге башлыгы урынбасары. 1964–66 да Казан «Восток» тегү ҖБнең директоры урынбасары. 1967–92 дә ТАССР МС каршындагы Җәмәгать туклануы идарәсе башлыгы. 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Морат Мәсгут улы (13.2.1953, Казан), нейрохирург, мед. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. табибе (1996). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1976), Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1981 елдан А.Л.Поляков исем. ин-тта (Ленинград ш.), 1984 тән Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1987 дән Мулаго шәһәре (Уганда Респ-касы) госпиталендә нейрохирург. 1991 дән Республика мед.-диагностика үзәгенең (Казан) магнит-резонанс томографиясе бүлегендә табиб-рентгенолог. 1999 дан Төбәкара клиника-диагностика үзәгенең нурлар б-н диагноз кую бүлеге мөдире. Фәнни тикшеренүләре нейрохирургиягә, үзәк нерв системасы авыруларын магнит-резонанслы диагнозлауга карый. И. баш мие шешләренә һәм үзәк нерв системасының чыганаклы башка авыруларына диагноз куйганда магнит-резонанслы дәвалау ысулын гамәлгә кертә.

Х е з м.: Рекомендации по магнитно-резонансной диагностике очаговых заболеваний головного мозга. К., 2002; Диагностика аномалий центральной нервной системы. К., 2003 (автордаш).

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Равил Рөстәм улы (30.8.1958, Лениногорск ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1995), ТР ФА академигы (2004). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1980). 1985 елдан ТатНИПИнефтьтә эшли: 1986 дан нефть бирүчәнлекне арттыру лаб-ясе мөдире, 1997 дән директорның беренче урынбасары, 2000 нән — директор. Өслекчә актив нәионоген матдәләр нигезендә катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру алымнарын эшли, микробиологик тәэсир итеп, нефть табуны интенсивлаштыру һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру технологияләрен, сульфат редукциясен киметү, су һәм туфракны нефть б-н пычранудан микробиологик чистарту технологияләрен тикшерә. 2015 елга кадәр ТРның нефть-газ комплексының үсеш концепциясен һәм 2020 гә кадәр ТР энергетика стратегиясен төзү буенча тикшеренүләр координаторы һәм җитәкчеләренең берсе. Уйлап табуга 80 авторлык таныклыгы бар. ТР ФА Президиумы һәм Халыкара инженер нефтьчеләр җәмгыяте әгъзасы. РФ Хөкүмәте (1995) һәм ТР (1999) Дәүләт бүләкләре лауреаты.

Х е з м.: Проблемы экологической химии Республики Татарстан. К., 1998 (автордаш); Биометоды увеличения нефтеотдачи. М., 2003 (автордаш); Увеличение нефтеотдачи на поздней стадии разработки месторождений. М., 2004; Reservoir modeling for giant Romashkino field // Proceeding of European Petroleum Conference. P., 2000.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Рафаэль Гыйният улы (11.6.1944, Казан), балет артисты, балетмейстер. 1964 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагоглар Б.В.Шавров, И.Д.Бельский), 1983 тә Дәүләт театр сәнгате ин-тының (Мәскәү) режиссёр-балетмейстерлар бүлеген тәмамлый. 1964–70 елларда Татар опера һәм балет театрында, 1970–74 тә Омск филармониясенең «Ритм-балет» төркеме солисты, 1974–75 тә Мәскәү оперетта театрында, 1975–85 тә Москонцерт балет труппасында, бер үк вакытта 1982–89 да Чуаш муз. театрында (Чабаксар) баш балетмейстер. Зигфрид («Аккош күле», П.Чайковский), Базиль, Солор һәм Божок («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Ильяс («Әсәл», В.Власов), Фәрһад («Мәхәббәт турында легенда», А.Меликов), Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин) һ.б. партияләрдә чыгышлар ясый. Бертуганы Р.Ибәтуллин б-н берлектә эстрада бригадасында эшли, заманча юнәлештәге хореографик композицияләрне башкара. Зур артистлык сәләтенә һәм югары бию техникасына ия. Балетмейстер буларак, Казанда А.Петровның «Дөнья яралу» («Сотворение мира», 1981), С.Рахманиновның «Алеко» операсындагы биюләрне (1983); Чабаксарда: «Дөнья яралу» («Сотворение мира», А.Петров, 1982), «Мисыр төннәре» («Египетские ночи», А.Аренский, 1983), «Доктор Айболит» (И.Морозов, 1984), «Сарпиге» (Ф.Васильев, 1985), «Фаренгейт буенча 451 градус» («451 градус по Фаренгейту», С.Корнилов, 1987) әсәрләрен куя. Эстрада артистларының бөтенроссия (1972, 3 нче бүләк) һәм бөтенсоюз (1984, 3 нче бүләк) конкурслары лауреаты. 1989 дан Мәскәүдә эшли, 1992 елдан Мехикода (Мексика) шәхси балет мәктәбен җитәкли.

*В.Н.Горшков.*

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Рөстәм Хәмит улы (6.12.1931, Беренче Май р-ны Иске Баграж, хәзерге Әлмәт р-ны Елховой а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), техник фән. канд. (1966), СССРның мактаулы нефтьчесе (1978), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). 1955 тә Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татнефть» трестының җитештерү берләшмәләрендә, 1965 тән «Татбурнефть» трестында баш инженер, 1968 дән «Әлмәтбурнефть» тресты җитәкчесе. 1978 дән ТатНИПИнефть директоры, 1997 дән директор урынбасары. Хезмәтләре бораулау технологиясенә һәм техникасына карый. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы һ.б. орденнар, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1970) б-н бүләкләнә.

**ИБӘТУ́ЛЛИН** Юныс Баһаветдин улы (30.6.1898, Пермь ш. — 9.12.1954, Казан), генерал-майор (1945). 1918 елдан Кызыл Армиядә. 1940 тан Урал хәрби округы хәрби комиссары. Бөек Ватан сугышында 3 нче Белорусссия фронты 11 нче гв. армиясенең тыл башлыгы. 1946 дан Ленинград хәрби округының 10 нчы гв. армиясе тыл башлыгы. 1948 дә 24 нче гв. укчы корпус командиры урынбасары. 1949 да 38 нче армиянең тыл башлыгы. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИБЛИ́С** (гарәп. إبليس, сүзгә-сүз — өметсезлеккә бирелгән), исламда күктән куылган, «Аллаһның дошманы»на әверелгән, кешеләрне хак юлдан яздыручы явыз рух. Коръәндә барлык фәрештәләр Аллаһ бар иткән беренче кеше — *Адәм* алдында аның өстенлеген танып баш игәндә, Аллаһ әмеренә буйсынмыйча, И.нең аңа баш имәве турында бәян ителә. «Мин аннан камилрәк, Син мине уттан, аны балчыктан яраттың», — ди И. Бу тәкәбберлеге өчен ул күктән сөрелә һәм җәһәннәм газапларына хөкем ителә. Әмма И. Аллаһтан әлеге җәзаны Мәхшәр көненә кадәр кичектереп торуны сорый; Аллаһның ризалыгын алгач, кешеләрне аздырырга, хак юлдан яздырырга ант итә. Сиздермичә генә җәннәт бакчасына кереп, Аллаһның тыюына карамастан, Адәмнән көнләшеп һәм үзенең аңардан өстен булуын исбатлау өчен, Адәм б-н *Хауваны* җәннәт агачындагы тыелган җимешне авыз итәргә күндерә. Шуннан соң беренче кешеләр үзләренең шәрә икәнлекләрен аңлыйлар, бу хәлләреннән оялалар һәм гаурәтләрен җәннәт агачлары яфраклары б-н каплый башлыйлар. Аллаһ сүз тыңламаган өчен җәзасын бирә: Адәм б-н Хаува җәннәттән куыла, ә аларның нәсел-нәсәбе Аллаһ б-н И. арасында барган көрәш объектына әверелә. Коръәннән соң туган риваятькә караганда, җеннәр-шайтаннар башлыгы булган И. (ул аларны үзе барлыкка китерә) җирдә яши; хәрабәләр, базарлар, мунчаларда, бозыклык урыннарында көн күрә. Аннан бары тик Коръән сүрәләрен кычкырып укып кына сакланырга мөмкин. Ахырзаман җиткәч, И.не һәм аның йогынтысында торган затларның барысын да җәһәннәм көтә.

**ИБНЕ́ әл-ӘСИ́Р** (إبن ألأثير) Гыяз-әд-дин Әбүл-Хәсән Гали (12.5.1160, Җәзират-ибне-Гомәр ш. — 1233, Мосул ш.), гарәп тарихчысы. 1181 елда Мосулга килеп урнаша, озак вакыт җирле әмиргә хезмәт итә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәштәшләре турында биографик сүзлек «Әсәд әл-габа...» («Урман арысланнары») һәм Мосул хакимнәре тарихына кагылышлы әсәр («Мосул атабәкләре тарихы») авторы. Төп әсәре — «Тулы тарих»та («Кәмаль әт-тәварих»; аның бер өлеше, яңа табылган чыганаклардан файдаланып, гарәп тарихчысы әт-Табариның «Илчеләр һәм патшалар тарихы»н эшкәртүдән гый-

барәт) Евразия халыклары тарихына караган мәгълүматлар бар; анда болгарларның монголларга каршы 1223 елда уңышлы сугышы җентекле тасвирлана.

Ә с ә р.: Chronicon quod perfectissimum imscribitur... Leiden, 1851–76. V. 1–14.

**ИБНЕ́ БАТТУ́ТА** (ابن بطوطه) Әбү Абдаллаһ Мөхәммәд ибне Абдаллаһ әл-Лавати әт-Танҗи (24.2.1304, Танжер ш., Марокко — 1377, Фес ш., шунда ук), гарәп сәяхәтчесе. 1325 елда Мәккәгә хаҗга китә, Мисыр, Палестина, Сүрия, Гарәбстан, Иракта була. 1328–30 да Мәккәдә яши. 1330–31 дә — Йәмәнгә һәм Көнчыгыш Африкага, 1332–33 тә Кече Азиягә бара. 1334 нең май–декабрендә Алтын Урдада, Үзбәк хан урдасында яши. Көньяк рус кенәзлекләренә сәяхәт кыла, Иделгә барып җитә, берничә көн Болгар шәһәрендә булып китә. 1335–42 дә Дәһлидә казый вазифасын башкара. 1343–46 да Мальдив утраулары, Цейлон, Бенгалия һәм Тибет аша Кытайга барып җитә. 1347 дә Гарәбстанда була, 1349 да Мароккога әйләнеп кайта. И.Б. истәлекләре нигезендә Мөхәммәд ибне Җөзәй «Төхфәтен-наззар фи гараибел-әмсар вә гаҗәибел-әсфар» («Төрле шәһәрләр һәм сәфәрләрдә гаҗәеп хәлләргә шаһит булучыларга бүләк») исемле сәяхәтнамә яза, анда Алтын Урданың, Сарай, Солхат, Үргәнеч, Азак, Хаҗитархан, Болгар һ.б. шәһәрләрнең тарихы, мәдәнияте, дәүләт ин-тлары турында мәгълүматлар бар. (Ул Сарайны «гадәттән тыш зурлыкка ирешкән иң матур шәһәрләрнең берсе» дип атый). 1917 дә Оренбургта «Ибне Баттутаның Дәште-Кыпчакда сәяхәте» дигән китабы Р.Фәхретдин тәрҗемәсендә татар телендә басылып чыга.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н о в Р. Болгар вә Казан төрекләре. К., 1993; Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941; Т и м о ф е е в И.В. Ибн Баттута. М., 1983; И б р а г и м о в Н. Ибн Баттута и его путешествия по Средней Азии. М., 1988.

**ИБНЕ́ әл-ГАРӘБИ́** (ابن ألعربي) Әбү Бәкер Мөхәммәд (7.8.1165, Мурсия ш., Испания — 16.11.1240, Димәшкъ), мөселман мистик-философы, шагыйрь. Традицион мөселман гыйлеме ала. *Суфичылык* идеаллары йогынтысында яшь чагында ук дөньяви шөгыльләрдән читләшә һәм суфичылык тәгълиматын кабул итә (1184). Абруйлы суфи остазлар эзләп Андалусия (Испания) һәм Төньяк Африка буйлап илләр гизәргә чыгып китә. Шул елларда үзенең фәлсәфи һәм эзотерик фәннәрне өйрәнүгә сәләтле, киң карашлы булуы һәм тәкъвалыгы аркасында суфилар даирәсендә абруй һәм хөрмәт казана. И.ә.-Г.гә тамырлары неоплатончылыкка барып тоташкан традицияләрне дәвам иттерүче Альмерия шәһәре (Испания) суфиларының йогынты ясавы ихтимал. Ул ш.у. Шәрекъ мөселман философлары һәм дин галимнәре әл-Хәким әт-Тирмизи, әл-Харраз, әл-Хәлләҗ, әл-*Газали* һ.б.ның хезмәтләре б-н таныш була. 1200 елда хаҗ кыла. 1201 дән Мәккәдә яши, шунда «Тәрҗеман әл-әшуак» («Гыйшыклык тасвирламасы») дигән шигырьләр җыентыгын туплый һәм суфичылык гыйлемнәренең төрле тармаклары буенча хезмәтләр яза. Биредә ул мистик гыйлемнәрнең асылын тасвирлаган Футухат әл-мәкийә («Мәккә хакыйкате») дигән фундаменталь хезмәтен язарга керешә (1995 тә С.-Петербургта рус телендә басыла). 1204 тә Мосул шәһәренә (Гыйрак) китә, анда Мисыр дин белгечләре б-н бәхәстә чак кына һәлак булмый кала. Берничә елын Византиядә үзенең күпсанлы шәкертләре арасында үткәрә. 1223 тән дини һәм сәяси хакимият яклавы астында Димәшкътә яши. Анда ул «Мәккә хакыйкате» дигән хезмәтен тәмамлый һәм «Акыл ташлары» исемле яңа әсәрен яза. Аның иҗат мирасында 300 ләп әсәр исәпләнә. Димәшкъ бистәсендә җирләнә. 16 йөз башында төрек солтаны Сәлим I әмере б-н аның кабере өстендә дөрбә корыла. И.ә.-Г. тәгълиматының нигезен Коръәнне аллегорик аңлату һәм бөтен нәрсәне колачлаган синкретизм тәшкил итә. Ул Коръән символикасы һәм мифологиясе ярдәмендә суфичылык космогониясе, Аллаһның рәхим-шәфкатьлелеге, кешенең Аллаһ тарафыннан яратылган булуы һәм дөньяның яратылу сәбәпләре турындагы тәгълиматны җентекләп эшли, мистик юлның «тукталышлар»ы («мәкәмәт») һәм «халәтләр»е («әхвал»), мөселман изгеләре иерархиясе («әүлия») һәм «мистик полюс» (суфичылык доктринасында Аллаһны танып-белүнең иң югары дәрәҗәсе), пәйгамбәрлек һәм изгелекнең үзара нисбәте турындагы карашларын системага сала. И.ә.-Г. тәгълиматында аның илаһи Абсолютта 2 капма-каршы — трансцендент һәм матди якларны берләштерүче «арадаш» дөнья турындагы фикере аеруча әһәмиятле. Аның карашынча, мистик көч, әлеге өлкәгә үтеп кереп, чынбарлыкның яшерен серләрен аңлауга ирешә. И.ә.-Г.нең бай мирасы күпсанлы тикшеренүчеләр өчен фәлсәфи һәм дини белемнәр чыганагына әверелә. 20 йөзнең 1 нче яртысында татар дин белгече М.*Бигиев* үзенең хезмәтләрендә аның идеяләренә еш мөрәҗәгать итә.

*Әд.:* К р а ч к о в с к и й И.Ю. Избранные сочинения: В 6 т. М.–Л., 1955–60; С м и р н о в А.В. Великий шейх суфизма. М., 1993.

**ИБНЕ́ РӨШД** (ابن رشد) (латинлаштырылган исеме — Аверроэс) Ибне Рөшд Әбү әл-Вәлид бине Әхмәд (1126, Кордова ш., Испания — 10.12.1198, Марракеш ш., Марокко), гарәп философы, Көнчыгыш аристотелизм вәкиле, табиб. 1171 елдан Севильядә, соңрак Кордовада казый вазифаларын башкара, 1182 дән — сарай табибе. 1195 тә, бидгатьчелектә (еретиклыкта) гаепләнеп, эзәрлекләнүгә дучар ителә: медицина, математика һәм астрономия буенча язылган хезмәтләреннән тыш, барлык китаплары Кордова урамнарында яндырыла, И.Р. үзе Мароккога кача.

И.Р. солтан кушуы буенча Севилья һәм Кордовада Аристотель хезмәтләрен шәрехли. Бу аңлатмалар гарәп метафизикасында платончылыкның аерым бер төре өстенлек иткән чорда янә грек галиме философиясенә карата кызыксыну уята. И.Р. Аристотель тәгълиматын исламият гыйлеме б-н берләштерергә омтыла, бөтен кешеләр өчен уртак булган һәм җаннарга читтән тәэсир итүче иясез субстанция — бердәнбер Илаһи аң гына бар дип саный (шуңа бәйле рәвештә аерым кеше җанының үлемсезлеген инкарь итә). И.Р. яратылган дөньяның мәңгелек булуы турындагы тәгълиматны яклый. Ул динне рациональ (сайланганнар өчен) һәм образлы-аллегорик (барлык кешеләр дә лаек булган) өлешләргә бүлә; бу исә ике яклы хакыйкать турындагы тәгълиматны тудырган чыганакларның берсе. И.Р. фәлсәфә б-н дин арасында бернинди каршылык юк дип исәпли (аныңча, беренчесе икенчесенә нигезләнә). Коръән белгече буларак, И.Р. һәр мөселман исламның төп кануннарын үтәргә бурычлы, интеллектуаль сәләткә ия кеше фәлсәфәне дә өйрәнергә тиеш дип саный.

Х е з м.: Опровержение опровержения. Киев–СПб., 1999.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Ибне Рөшд. К., 1905; Г р и г о р я н С.Н. Великие мыслители Арабского Востока. М., 1960; С а г д е е в А.В. Ибн-Рушд (Аверроэс). М., 1973; И г н а т е н к о А.А. В поисках счастья. М., 1989.

**ИБНЕ́ РУСТӘ́** (ابن رسته) Әбү Гали Әхмәд бине Гомәр (9 йөзнең 2 нче яртысы — 10 йөз башы), гарәп сәяхәтчесе һәм географы. Чыгышы б-н фарсылардан. Якын һәм Урта Шәрекътә, Көнчыгыш Европада була. «Китаб әл-гилан ән-нәфисә» («Кыйммәтле хәзинәләр китабы») әсәре авторы. Әлеге хезмәтнең безнең көннәргә килеп җиткән 7 нче томында Идел буе Болгар дәүләте турында кыйммәтле мәгълүматлар бар. И.Р., болгар җирләрендә барсил, әсәгел һәм болгар кабиләләре яши, алар бер үк рәвешле тормыш алып бара, дип искә ала; болгарларның күбесе һәм аларның хакиме Алмыш ислам дине тота, ә дәүләттә мәчетләр һәм дини уку йортлары — мәдрәсәләр бар, дип ассызыклый; ш.у. болгарлар бодай, арпа, тары һ.б. бөртекле культуралар игә, алардан икмәк пешерә, дип билгеләп үтә. Халык патшага ясакны атлар б-н түли; хәзәрләр руслар б-н сәүдә итешә, читтән кыйммәтле мехлар (кеш, ас, куян) кертәләр. Сәүдәгәр кораблары болгар патшасына пошлина — товарларының уннан бер өлешен түли. Акча әйләнешендә тәңкәләр урынына сусар тиреләре, алар б-н янәшә мөселман илләре дирһәмнәре кулланыла. Болгар сугышчылары атка атланып йөриләр, көбә кияләр, «тулысынча коралланалар» һәм еш кына бортас җирләренә һөҗүм итәләр, аларның торак пунктларын туздыралар, кешеләрен әсирлеккә алалар, дип яза.

*Әд.:* Х в о л ь с о н Д.А. Известия о хазарах, буртасах, булгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста. СПб., 1869; К р а ч к о в с к и й И.Ю. Арабская географическая литература: Избр. соч. М.–Л., 1957. Т. 4.

**ИБНЕ́ СИНА́** (ابن سينا; латинлаштырылган исеме — Авиценна, Әбү Гали әл-Хөсәен бине Габдулла бине Сина, Әбүгалисина), (980 тирәсе, Бохара ш. янындагы Афшана а. — 18.6.1037, Хамадан ш., Көнбатыш Иран), философ, Көнчыгыш аристотелизм вәкиле, табиб. 985–96 елларда Бохарадагы башлангыч мәктәпләрнең берсендә укый; соңрак өендә белем ала — математика, физика, логика, астрономия, философия һ.б. фәннәрне өйрәнә. 10 яшендә Коръәнне яттан белә. 1002 дә эре галимнәр даирәсен берләштергән «Мамум Академиясе» урнашкан Гургәнч (хәзерге Үр-

гәнеч) шәһәренә күчеп китә. Солтан М. Газнәвигә хезмәт итүдән баш тартканнан соң (1008), җәберләүләргә дучар була, Хорасанда һәм Табарстанда ил гизеп йөри. 1015–24 тә Хамаданда яши. Төрле ил хакимнәрендә табиб һәм вәзир вазифаларын башкара. Борынгы грек философы Платон һәм гарәп галиме әл-Фараби хезмәтләрендә чагылыш тапкан неоплатончылык б-н бәйләп, Көнчыгыш аристотелизм принципларын эшли. Үзенең төп хезмәтләрендә («Савыктыру китабы», «Күрсәтмәләр һәм үгетләүләр китабы», «Белемнәр китабы») И.С. дөнья вакытка бәйле рәвештә барлыкка килгән дигән фикерне кире кага, дөнья Аллаһның вакытка бәйсез эманациясе ул, бу эманациядән иерархик тәртиптә аңнар, җаннар һәм тәннәр барлыкка килгән, дип аңлата. Политеизм б-н килешкән неоплатончылардан аермалы буларак, ул — катгый монотеист, әмма шулай да сөнни дин белгечләре аны бидгатьчелектә (мәс., дөньяның яратылмавына ышану дөньяның барлыкка китерелүе турындагы тезиска каршы килә) гаепliләр. И.С. әл-Газалинең «Философларны инкарь итү» хезмәтендә кискен тәнкыйть ителә. Ул ш.у. «Тыйб гыйльме кануннары» энциклопедиясе авторы буларак (кит. 1–5, Ташкент, 1954–60), әлеге хезмәтендә медицинаның теоретик нигезләрен бәян итә, төрле авыруларның төгәл һәм тулы клиник билгеләрен тасвирлый. 12–17 йөзләрдә Европа илләрендә табибләрне әлеге китап буенча әзерлиләр. И.С.ның гарәп һәм фарсы телләрендә язылган аз санлы шигырьләре сакланган. Аристотельнең «Поэтика»сын шәрехләп, ул үзен әдәбият теоретигы итеп тә таныта. Классик фарсы әдәбиятын формалаштыруга зур йогынты ясый. И.С.ның гыйльми хезмәтләре бөтен дөньяда популярлык казана, татарлар арасында да киң тарала.

Х е з м.: Четверостишие // Литературный Таджикистан. Душ., 1953. Кн. 5; Данишнаме. Душ., 1957; О душе // Избранные произведения мыслителей стран Ближнего и Среднего Востока IX–XIV вв. М., 1961; Математические главы «Книги знания». Душ., 1967; Избранные философские произведения. М., 1980; Лирика. М.–СПб., 2001.

*Әд.:* С а г д е е в А.В. Ибн-Сина (Авиценна). М., 1980; И г н а т е н к о А.А. В поисках счастья. М., 1989; Б о л т н е в М.Н. Абу Али ибн Сина — великий мыслитель, учёный-энциклопедист средневекового Востока. М., 2002; C o r b i n H. Avicenne et recit visionnaire: Etude sur le cycle des recits avicenniens. P., 1979.

**ИБНЕ́ ФАЗЛА́Н** (Фадлан) (ابن فضلان) Әхмәд ибне әл-Габбас ибне Рәшид ибне Хаммад (10 йөз), гарәп сәяхәтчесе. Багдад хәлифәсе сараенда хезмәт итә. 921–22 елларда *Болгарга әл-Моктәдир илчелеге* сәркәтибе. Юл язмалары алып бара, соңыннан шулар нигезендә Идел буе Болгар дәүләтенә барулары турында сәяхәтнамә төзи.

Багдадтан 921 нең 21 июнендә чыгып киткән зур илчелек башта Шәрекънең кече һәм зур калалары аша үтә, аннан соң Бохарага килеп җитә, әмир тарафыннан кабул ителә. Тик Бохара әмире аларга юлны дәвам итәргә рөхсәт бирми, илчелеккә 28 көн Бохарада тоткарланырга туры килә. Аннан илчелек кәрваны Харәземгә килеп керә һәм әл-Җөрҗанда (Иске Үргәнеч) туктала. Суыклар башлану сәбәпле, илчелек кышны Иске Үргәнечтә үткәрергә мәҗбүр була.

Яз җиткәч, илчелек кабат юлга кузгала. Харәзем өлкәсе чигендә урнашкан Төркләр капкасын (Баб ат-Төрк) узып, төрки-угызлар яшәгән далага килеп керә. 15 көн дәвамында буш даладан баргач, төрки-угызлар кабиләсе белән очраша. Юлда очраган берничә елга аша чыгып, бәҗәнәкләр янында бер төн кунганнан соң, илчелек зур югалтулар б-н Җаекны кичә һәм башгырт кабиләләре яшәгән җиргә аяк баса.

922 елның 12 маенда илчелек Болгар иле җирләренә килеп җитә. Бу вакыйга һәм болгарларның ислам динен кабул итүе уңаеннан зур тантаналар башлана. Китапта болгар идарәчесенең кунакларны кабул итү йоласы, аларның, хәзәрләрнең, русларның, Идел-Урал төбәгендә, Урта Азиядә яшәгән башка халыкларның һәм кабиләләрнең көнкүреше, хуҗалыгы һәм гореф-гадәтләре җентекләп тасвирлана.

Көндәлек-сәяхәтнамәдә И.Ф.ның Идел буе Болгар дәүләтеннән шул ук елда, «көннәр кыскара башлагач» китүе турында хәбәр ителә. Аның шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н о в Р. Болгар вә Казан төрекләре. К., 1993; К о в а л е в с к и й А.П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Хар., 1956; К р а ч к о в с к и й И.Ю. Арабская географическая литература: Избр. соч. М.–Л., 1957. Т. 4; Z e k i V.T. Ibn Fadlans Reisebericht. Lpz., 1939.

**ИБНЕ́ ФАЗЛА́Н ЯЗМАЛАРЫ́**, Багдад хәлифәлегеннән Идел буе Болгар дәүләтенә җибәрелгән илчелек (921–23) сәркәтибе Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе. Сәяхәтнамәнең кайбер өзекләре, аның тулырак нөсхәсе табылганчы ук, шәркыятьче галимнәргә билгеле була. Аларның бүгенге көндә билгеле иң тулы нөсхәсен 1923 елда Ә.*Вәлиди* Иранның Мөшһәд шәһәрендәге бер китапханәдә таба һәм 1939 да Германиядә Лейпциг шәһәрендә бастырып чыгара. 1920 елларда Р.Фәхретдин И.Ф.я.н татар теленә тәрҗемә итә. А.П.Ковалевский рус телендә матбугатка әзерли һәм ул 1956 елда И.Ю.Крачковский редакциясендә басылып чыга (к. *Ибне Фазлан*).

Ибне Фазлан илчелек үткән юлны, сәфәр вакытында очрашкан халыклар — болгарлар, хәзәрләр, руслар, Идел буе, Урал яны, Урта Азиядәге башка халык-кабиләләрнең гореф-гадәтләрен тасвирлый.

Ул төрки-угызларның һәм башгыртларның мәҗүсилек үзенчәлекләренә игътибар итә, башгыртлар хакында: «Арадан берсе минем уникe иям бар дип әйтте һәм санап күрсәтте: кыш иясе, җәй иясе, яңгыр иясе, җил иясе, агачлар иясе, кешеләр иясе, атлар иясе, су иясе, төн иясе, көн иясе, әҗәл иясе, җир иясе, ә Тәңре ияләрнең иң зурысы һәм көчлесе — күктә яши икән», — дип билгеләп үтә.

Илчелекне Болгар илендә кабул итүләре турында: «Болгар патшасына килеп җитәргә бер тәүлек ара калганда ул безне каршыларга үзенең дүрт биен, ир туганнарын һәм улларын җибәрде. Алар безне кулларына икмәк, ит, тары тоткан килеш каршыладылар һәм юлны бергәләп дәвам иттерделәр. Патша безне урдасына ике фәрсах (12–14 чакрым) ара калганда каршы алды... Без болгар патшасына 12 нче мөхәррәмдә ял көнне (922 елның 12 мае) килеп җиттек», — дип яза. Төрле яктан җыелган кабиләләр алдында Багдад хәлифәсе әл-Моктәдирнең хатын укуны Ибне Фазлан болай тасвирлый: «Тылмач укылган һәр сүзне тәрҗемә итә барды. Хат укылып беткәч, алар барысы берьюлы дәррәү күтәрелеп «Аллаһе әкбәр!» дип шундый итеп кычкырдылар, бу авыздан хәтта җир тетрәнеп куйды». Исламны рәсми рәвештә кабул итү тантанасы тәмам булганнан соң, Алмыш илтәбәр илчелек җитәкчеләрен үз тирмәсенә чакыра. «Кабилә башындагы биләр аның уң кулында утыралар иде, безгә ул сул кулдан урын күрсәтте. Ә уллары аның каршында урнаштылар. Илтәбәр үзе рум парчасы ябылган тәхеттә утыра иде». Болгар илендә Ибне Фазлан зур игътибар б-н болгарлар яшәгән җәмгыятьне, андагы тәртипләрне, аларның яшәү рәвешен, көнкүреш шартларын, мәҗүсилектән акрынлап ислам диненә күчә баруларын, болгарларның тирмәләрдә яшәүләрен, бодай, арпа игүләрен хәбәр итә. Болгарларның җирләре «кара һәм юеш», саклау өчен тиешле биналар булмау сәбәпле, ашлыкның шактый өлеше юкка чыга. Болгар идарәчесенә һәр йорт салым — елына бер кеш тиресе түли. Ибне Фазлан килгәнче үк инде болгарларның күпчелеге һәм аларның идарәчесе Алмыш илтәбәр ислам дине тоталар; мәчетләре була, аларда мөселман дин әһелләре хезмәт итә. Автор, болгарларның суар кабиләсенең бер өлеше исламны кабул итүдән баш тарта һәм Алмышка буйсынудан чыга, дип билгеләп үтә. Болгарларның идарәчесе хәзәрләр каганына ясак түли һәм аңа бәйлелектә яши. Хәзәр яуларыннан саклану өчен, Алмыш кирмәннәр төзергә ниятли һәм Багдад хәлифәсеннән ярдәм сорый. Алмыш һәр сәүдә корабыннан пошлина — табышның уннан бер өлешен үзенә ала; коллар б-н сату итүче руслар һәр ун колның берсен бирергә тиеш була. Зур базар (мөгаен, Ага Базардыр) турында да искә алына. Болгар иле б-н Хәзәр каганлыгы арасында урнашкан шактый киеренке сәяси мөнәсәбәтләр турында кызыклы хәбәрләр китерә. Болгарлар арасында берничә ай яшәү дәверендә Хәзәр каганлыгы турында да кыйммәтле мәгълүматлар туплый («Олуг хакан» дип аталган хәзәр патшасы халык алдына 4 айга бер тапкыр гына чыга... Аның урынбасары «хакан бәк» дип йөртелә. Анысы һәр җирдә алдан йөри, гаскәр башы санала, дәүләт эшләрен дә ул алып бара», «Итил елгасы буенда хәзәр хаканының зур шәһәре җәелеп ята», «хәзәрләр дә, аларның хаканы да — яһүди динендә.., бу шәһәрдә мөселманнарның җамигъ мәчете бар»). Болгар иле идарәчесе Алмыш илтәбәрнең хәзәр каганы кул астыннан чыгарга омтылуын билгеләп үтә. Ибне Фазлан ш.у. Болгар иленә сәүдә эшләре б-н килгән руслар — варяглар тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары, ышанулары турында да кызыклы мәгълүматлар китерә.

И.Ф.я. 10 йөз башында яшәгән угыз, болгар, башгырт, хәзәр, рус-варяглар тарихы буенча гаять кыйммәтле, ышанычлы чыганак

булып тора. Шушы чыганакка таянып, безнең заманда язучы Н.Фәттах болгарлар тормышын, Болгар иле б-н Хәзәр каганлыгы арасындагы мөнәсәбәтләрне яктырткан «Әтил суы ака торур» романын иҗат итте. Ш.у.к. *Бохарага һәм Багдадка Алмыш илтәбәр илчелеге, Болгарга әл-Моктәдир илчелеге* (921–23).

*Әд.:* Фәхретдинов Р. Болгар вә Казан төрекләре. К., 1993; Ибне Фазланның Идел елгасына сәяхәте = Путешествие ибн Фадлана на реку Итиль. К., 1999; Шамси С. Свет, пришедший с Востока // Путешествие Ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама. К., 1992.

*С.С.Шәмси.*

**ИБНЕ́ ХАЛДУ́Н** (إبن خلدون) Вәли-әд-дин Габдеррахман Әбү Зәйд әл-Мәлики әл-Хәдрами (27.5.1332, Тунис — 17.3.1406, Каһирә), гарәп тарихчысы һәм философы. 1348–75 елларда Туниста, солтан Әбү Исхак сараенда, ш.у. Мәгъриб һәм Испания идарәчеләрендә киңәшче, дипломат һәм шәхси сәркәтип булып хезмәт итә. 1375–79 да ерак кирмәндә сөргендә була. Гомеренең соңгы елларын Каһирәдә уздыра, казый вазифасын башкара һәм мәдрәсәдә мөселман кануннары укыта. Гомере ахырында Урта Азия хакиме Аксак Тимергә хезмәткә кучәргә ниятли, әмма Сәмәркандка барыр алдыннан үлә. Күп хезмәтләр, ш.и. «Китаб әл-гыйбар...» («Үгет-нәсыйхәтләр китабы һәм бөек күләмнәрдә хакимияткә ия булган гарәпләрнең, фарсы, бәрбәрләрнең һәм аларның замандашларының башлангычлары һәм көннәре турында җыентык») авторы. Анда Алтын Урда дәүләте һәм аның Җучидән алып Туктамышка кадәрге ханнары турында кыскача мәгълүматлар бар.

*Әд.:* Бациева С.М. Историко-социологический трактат Ибн Хальдуна «Мукаддима». М., 1965; Игнатенко А.А. Ибн Хальдун. М., 1980.

*И.Л.Измайлов.*

**ИБНИ́ЕВА** Гүзәл Вазыйх кызы (10.6.1965, Түбән Кама ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2007). Казан дәүләт ун-тын тәмамлый (1989). 1995 елдан шунда ук Ватан тарихы кафедрасында эшли. Хезмәтләре Екатерина IIнең Россиядә империячел сәясәте тарихына, императорлар церемониалына карый.

Хезм.: Путешествие Екатерины II: опыт «освоения» имперского пространства. К., 2006.

**ИБРА́ЕВ** Габдулла Касыйм улы (21.1.1928, Пермь краеның Барда р-ны Кызыл Яр (Краснояр) а. — 27.7.1986, Пермь ш.), механика өлкәсе галиме, техн. фән. д-ры (1976), проф. (1978). Ленинград хәрби-механика ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), 1952–60 елларда шунда ук эшли. 1947–52 дә Урал авыр машиналар төзү з-дында (Свердловск ш.) конструктор. 1960 тан Пермь политехник ин-тында; 1967 дән Пермь ун-тында, деформацияләнүчән каты җисем кафедрасын оештыра һәм җитәкли (1977). Хезмәтләре материалларның ныклыгы мәсьәләләренә, металл конструкцияләрне оптималь проектлаштыруга һәм аларны җитештерү технологияләренә карый. И. эшләнмәләре Ф.Э.Дзержинский исем. Машиналар төзү з-дында (Пермь ш.) производствога күпләп кертелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Асимптотические методы в нелинейных задачах теории тонких оболочек. Пермь. 1975.

**ИБРА́Й КАРГАЛЫ́**, к. *Керкәле* (Чирмешән р-ны).

**ИБРАҺИ́М**, Коръән персонажы, пәйгамбәр, беренче булып бер аллаһлык тәгълиматын таратучы; гарәпләрнең һәм яһүдләрнең борынгы уртак бабасы; Библиядәге Авраам. Коръәндә «Аллаһның хәлиле» («Аллаһның дусты»), имамы, «хәнифәсе» («бер аллаһлык динен тотучы») дип белдерелә. Коръәндә ш.у. «И. милләте» («И. дине») төшенчәсе дә бар; аның исеме изге «Сөхеф» һәм «Китап» дигән язмаларда да телгә алына; И.ның тормыш юлы тулы итеп бәян ителә; үсмер чагында ук ул потларга, йолдызларга, Кояшка табынуларның мәгънәсезлеген аңлый, аннары аңа бер һәм бердәнбер Аллаһка инану хакында вәхи иңә. Әлеге инануны ул әтисенә һәм бүтән кешеләргә аңлатып, төшендереп карый, әмма алар бу уе өчен аны утта яндырырга телиләр. Ләкин И. могҗиза б-н үлемнән котыла: Аллаһ аны Палестинага күчерә һәм үлемнән коткара. И. үзенең улы *Исмәгыйль* б-н бергә Мәккәдә гыйбадәтханә — Кәгъбә төзи. И. исеме үзен Аллаһка бирелгәнлеген күрсәтү өчен улы Исмәгыйльне корбан итәргә әзер булуы турындагы риваять б-н дә бәйле: И.ның инануының көчле һәм ихлас булуына ышанган Аллаһ бу корбанны кирәксез дип белдерә. Коръәндә И.ның Аллаһтан үзенә угыл бүләк итүен сорап гыйбадәт кылуы, Лут пәйгамбәр өммәтенең гөнаһларын кичерүне, үзенең халкына фатиха бирүне сорап Аллаһка мөрәҗәгать итүе хакында бәян ителгән сүрәләр байтак. Әтисенең гөнаһларын кичерүдән Аллаһның баш тартуын И. кяфер бабалар өчен бирелгән котылгысыз җәза буларак кабул итә. И. дин тарихында аерым урын алып тора: ул яһүди дә, христиан да түгел, ул — бер аллаһлык тәгълиматын таратучы («хәнифә»); Мөхәммәд пәйгамбәр нәкъ менә шул динне яңадан торгыза. Ш.у. к. *Корбан бәйрәме.*

*Әд.:* Пиотровский М.Б. Коранические сказания. М., 1991; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ИБРАҺИ́М** (Бряхим), урта гасырларда (11–12 йөзләр) Идел буе Болгар дәүләтендәге шәһәр. Эре сәяси һәм икътисади үзәк була. Рус елъязмаларында Владимир-Суздаль кенәзе Андрей Боголюбскийның 1164 елда Идел буе Болгарына яу б-н баруы уңаеннан искә алына (аның И.ны яулап алуы турында мәгълүматлар да бар). Шулай ук И. урнашкан урын да күрсәтелә — Чулман елгасы буе. И. «Казан тарихы»нда («Казанская история») Брягов дип атала. Тексттан күренгәнчә, ул феодаль даирәнең хәрби-сәяси үзәге була, аның хакиме Биләр шәһәре әмиренә буйсына. Күп кенә тарихчыларның фаразлавынча, шәһәр Болгар әмире Ибраһим исеме б-н аталган. Кайбер тикшеренүчеләр И.ның археол. калдыкларын — Болгар, икенчеләре Алексеев шәһәрлеге б-н тәңгәлләштерәләр.

Чыг.: Летописец Переяславля Суздальского. М., 1851; Приселков М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950; Казанская история. М.–Л., 1954.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Смолин В.Ф. Болгарский город Бряхимов // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии. 1925. Т. 33, вып. 1; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

**ИБРАҺИ́М**, к. *Ибакъ.*

**ИБРАҺИ́М бине ГАБДУЛЛА́ әл-БАРЫШИ́** (? — 1781 яки 1782), дин эшлеклесе һәм белгече. Казан губернасы Казан өязенең Ташкичү, Казаклар, Арбор авыллары мәдрәсәләре мөдәррисе. Хезмәтләре исламият гыйлеменә карый.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. К., 2003.

**ИБРАҺИ́М бине ЙОСЫ́Ф әл-БӘРӘСКӘВИ́** (1717–87), Казан сәүдәгәре. Казан артында хәйрия эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, мәчетләр, ш.и. Казан губернасы Казан өязенең Түбән Бәрәскә авылындагы мәчет төзелешенә акча бирә.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1900.

**ИБРАҺИ́М бине МӨХӘММӘ́Д-ТҮЛӘ́К** (Ибраһим бине Мөхәммәд-Түләк бине Бикмөхәммәд Орынбурҗы, Бәтчә ахун дип тә мәгълүм) (? — ?), туган, үлгән урыннары билгеле түгел. Якынча XVIII гасыр башында туган. 1755 елда исән, Оренбургта яшәгән. Дин эшлеклесе, хаттат, ташка уеп язу остасы. Оренбург шәһәре корыла башлаганда, генерал-майор К.М.*Тәвкилев* (Котлымөхәммәт бине Тәвкил бине Мәмәш) хезмәтендә дин эшләре башкара.

Оренбург янындагы *Каргалы бистәсе* иске зиратының Хәдичә бикә дөрбәсендә Ибраһим ахун кулы б-н эшләнгән 37×68×146 *см* зурлыгындагы мәрмәр кабер ташы саклана. Ташның шомартылган йөзлегенә гарәп алфавитының сөлес имлясында эре итеп — 15, вак итеп 9 юл текст язылган. Анда татар һәм гарәп телләрендә Котлыг Мөхәммәд хатыны Хәдичәнең 1751 елда, 33 яшендә вафаты хакында хәбәр ителә.

Әлеге эпиграфик истәлек Оренбург якларында яхшы хәлдә сакланган иң борынгы кабер ташы үрнәге. Ибраһим ахун ясаган эпиграфика һәйкәле, ихтимал, элек Оренбург шәһәренең уртасында калган иске татар зиратында да булгандыр. Кызганычка, зират 1930 да җимерелә, аның өстенә торак йортлар салына.

Тарихта Ибраһим ахунның *Батырша хәрәкәтендә* катнашуы хакында да хәбәрләр саклана.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1901. 2 нче җөзья.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ИБРАҺИ́М бине ХУҖА́Ш әл-КАЗАНИ́** (?, Самара губ., Бөгелмә өязе Шарлама а. — 1825), дин эшлеклесе һәм галиме. Казан губернасы Казан өязенең Утар Аты һәм Яңа Кишет авыллары мәчетләре имам-хатибы. 1793 елдан Казан мәчете имамы. Исламият гыйльменә нисбәтле (указлы муллалар, кыз урлау, мәхрәм — тыелган нәрсәләр турында) 6 хаты мәгълүм.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Асар. К., 2003.

**ИБРАҺИ́М САБИ́Т УГЫЛЫ́** (19 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. Кульъязмада сакланып калган «Кыйссаи Хөсәен разый Аллаһе

ганһе» (1833) исемле дини-тарихи поэма авторы. Әсәрдә тарихи шәхес — шигыйлар имамы Хөсәеннең (626–80) тормыш юлы, Өмәвиләр хәлифәсе Йәзидкә каршы көрәше һәм шул көрәштә газаплы үлем б-н дөньядан китүе сурәтләнә. Хөсәен имам әсәрдә гади халык мәнфәгатьләрен яклаучы буларак тасвирлана.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ИБРАҺИ́М ХАН** (? — 1479, Казан), Казан ханы (1467 дән). *Мәхмүд ханның* улы. Тәхеткә *Хәлил хан* вафатыннан соң утыра, аның хатыны *Нурсолтанга* өйләнә. Бу чорда Казан аксөякләре арасында килеп туган каршылыклардан файдаланып һәм Рус дәүләтенең хәрби көченә таянып, Мещёра кенәзе Касыйм Казанны яулап алырга ниятли, ләкин җиңелүгә дучар була (1467). 1467–69 елларда Рус дәүләте б-н сугыша, сугыш Иван III гаскәрләренең Казанга яу б-н баруы һәм рус әсирләрен кайтарып бирү, русларның Казан ханлыгы эшләренә тыкшынмавы шарты б-н солых төзеп тәмамлана. Солых И.х.га үз хакимиятен ныгыту һәм илнең эчке хәлләрен җайга салу мөмкинлеге бирә. 1478 дә Нократ һәм Югары Чулман төбәге өчен Рус дәүләте б-н яңа хәрби бәрелешләр башлана, аның нәтиҗәсендә 1478 елның язында рус гаскәрләре Казанга яу б-н бара.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**ИБРАҺИМИЯ́** (Ибраһимова) Рокыя (19 йөз ахыры — 20 йөз башы), шагыйрә. 1913–16 елларда «Аң», «Сөембикә» ж-лларында басылган шигырьләренең кайберләре «Өмет йолдызлары» (1988) исемле җыентыкка керә. Иҗатында Г.Тукай йогынтысы сизелә. И. аның идеяләрен һәм карашларын уртаклаша. Шигырьләренең төп мотивы — белем алуга, шәфкатьлелеккә, гаделлеккә өндәү («Теләк», 1914; «Бәйрәмме бу?», 1915 һ.б.). Г.Тукай истәлегенә багышланган «Китте шагыйрь» (1914) шигырендә ул аны «хатыннар хамисе», «милләтнең каһарманы» дип атый.

*Әд.:* Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988.

**ИБРАҺИ́МОВ** Альберт Эдуард улы (17.7.1965, Казан), радиоинженер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1991). 1985–88 елларда «Медфизприбор» фәнни-җитештерү берләшмәсендә өлкән техник, инженер. 1988–92 дә Казан авиация ин-тында. 1992–94 тә «Авис» фәнни-коммерция фирмасы (Казан) директоры. 1994 тән Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәгендә, директор (2001 дән). Уйлап табуга 4 патенты бар. Дәүләт бүләге «Нефть һәм газ чыганакларында эчәргә яраклы су катламнары аралыгында экологик хәлне мониторинглау өчен скважиналы контактсыз инфракызыл (АМК СНТ-ИК) җылылык үлчәүнең геофизик аппаратлары һәм методикасы комплексын эшләү һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**ИБРАҺИ́МОВ** Әнис Исмәгыйль улы (7.5.1961, Бөгелмә ш.), педиатр, мед. фән. д-ры (2006). 1984 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның 6 нчы балалар шифаханәсендә эшли. 1985 тән ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү станциясе табибе. 1989 дан Казан мед. ин-тының сәламәтлек саклауны оештыру кафедрасында, 1999 дан мед. иминияте һәм хокукы курслары мөдире, 2005 тән мед. экспертизасы каф. мөдире. Хезмәтләре балалар сәламәтлеген саклауга һәм катлаулы гаиләләрнең яшәү рәвешен мед.-социаль бәяләүгә карый.

Х е з м.: Характеристика образа жизни и здоровья в семьях с отцом-алкоголиком. К., 1998; Образ жизни и состояние здоровья детей, воспитывающихся в семьях с отцом, злоупотребляющим алкоголем // Казан. мед. журн. 1999. № 6; Показатели выздоровления и социального устройства детей-сирот (по материалам РТ) // Нижегород. мед. журн. 2001. № 2.

**ИБРАҺИ́МОВ** Галимҗан Гыйрфан улы (28.3.1887, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Солтанморат а. — 21.1.1938, Казан), язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1928). Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә һәм башлангыч рус мәктәбендә ала. 1898–1905 елларда — Оренбург шәһәрендә Вәли мулланың кадими мәдрәсәсендә, 1906–08 дә «*Галия*» мәдрәсәсендә укый. 1909 да Казанга килә, татар вакытлы басмалары б-н хезмәттәшлек итә. 1912 дә Киевка китә, анда мөселман студентлары җәмгыяте эшендә катнаша, аларның Бөтенроссия корылтаен әзерләвенә кушыла. Сәяси эшчәнлеге өчен 1913 нең 17 апрелендә кулга алына. Шул ук елда, төрмәдән чыгарылганнан соң, Казанга кайта, «Аң» ж-лының җаваплы сәркәтибе булып эшли башлый. 1914 тә кабат Киевка, аннан Уфага китә; 1915–17 дә «Галия» мәдрәсәсендә укыта. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң иҗтимагый-сәяси тормышта активлык күрсәтә. 1917 дә язучы Ф.Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш.Сүнчәләй б-н бергә «*Ирек*» г-тасы чыгара. Татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясен оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе. Милләт Мәҗлесе (1917–18) һәм Учредительләр җыены депутаты. 1918 дә М.Вахитов һәм Ш.Манатов б-н бергә РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршындагы Эчке Россия Мөселманнары эшләре комис-тын оештыруда катнаша. 1919–20 дә *Үзәк мөселман хәрби коллегиясе* әгъзасы, бер үк вакытта РКП(б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе һәм «Кызыл Шәрекъ» ж-лы хезмәткәре. 1920 дән ТАССР Мәгариф халык комис-тында, «*Безнең юл*» һәм «*Мәгариф*» ж-лларын оештыручыларның берсе һәм мөхәррире. 1925–27 дә *Гыйльми Үзәк* рәисе, бер үк вакытта *Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы* рәисе. Авыру сәбәпле, 1927 дә актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән читләшә.

И. иҗатына башта ук чынбарлыкка романтик мөнәсәбәт хас була. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаннары» (1908) исемле беренче хикәяләрендә һәм «Татар хатыны ниләр күрми» (1909, рус теленә тәрҗемәдә «Татарка», 1935) повестенда татар мәдрәсәләрендә иске ысул б-н укыту һәм тәрбияне оештыру, яшь буынны тормышка әзерләүдәге кимчелекләр кискен тәнкыйтьләнә, шәхес иреге, хатын-кызларга тигез хокуклар бирү мәсьәләләре куела.

И.ның иҗаты тулы көченә Казанда ачыла. «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1910), «Сөю-сәгадәт» (1911) хикәяләрендә ул гадәти булмаган, көчле рухлы, романтик, рухи яктан кырыс мохит б-н туктаусыз көрәштә булган геройлар образларын иҗат итә. Тормыш мәшәкатьләреннән, шәһәр ыгы-зыгысыннан арып-туеп, алар табигатьтән җан тынычлыгы эзлиләр, ләззәт алалар, башкача яшәү рәвеше — матур, күтәренке рухлы, гадел тормыш турында хыялланалар. Бу — авторның җәмгыятьтәге социаль тәртипләргә протестының үзенчәлекле бер формасы. И.ның геройлары өзлексез рәвештә идеал, тормыш мәгънәсен эзләп яши.


И.ның язучылык таланты, тәнкыйди рухлы романтик буларак, «Яшь йөрәкләр» (1912; рус теленә тәрҗемәдә — «Молодые сердца», 1980) романында аеруча ачык чагыла. Әсәрнең идея-тематик пафосын аталар һәм балалар арасындагы каршылык (автор үзе язганча, «яңаның искелек белән көрәше») тәшкил итә. Ул Җәләш мулла һәм аның улы, яшь буын идеалларын алга сөрүче, дөньяга карашы 20 йөз башындагы социаль тетрәнүләр б-н билгеләнгән Зыя образлары аша чагыла. Зыя татар җәмгыятендәге искелек калдыкларына каршы көрәшүнең төп коралы итеп шәхес ирекен саный, мәхәббәткә мәдхия җырлый, патриархаль җәмгыять томаналыгына кешеләрнең рухи-әхлакый сафлыгы-камиллеген каршы куя. Романда ш.у. язучының иҗади сәнгать чараларын чынбарлык буяулары б-н баетуга омтылышы чагыла.

1912 дән башлап И. социаль проблемаларны тагын да активрак күтәрә, хезмәт кешеләре образларын иҗат итә («Карт ялчы» (1912), «Көтүчеләр» (1913) хикәяләре). И.ның социаль каршылыкларга игътибарын юнәлтүен соңрак язылган «Табигать балалары» (1914), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914), «Габдрахман Салихов» (1916) хикәяләре дә дәлилли.

1914 тә үк тәмамланып, бастырып чыгару тыелган «Безнең көннәр» романы дөнья күргәч (1919, 2 нче редакциясе — 1934; русчага



Г. Ибраһимов һәм Ш. Әхмәдиев. 1922.



Г.Ибраһимов.

тәрҗемәдә — «Наши дни», 1962), И.ның иҗат биографиясендә яңа чор башлана. Автор романның язылу вакытын 1914–20 еллар дип билгели, бу еллар дәвамында ул аны камилләштерә. Әлеге әсәр И. иҗатының рев-циягә кадәрге иҗатына йомгак ясап кына калмый, ә бәлки татар әдәбияты тарихында яңа, совет чоры башлануын да билгели. Автор анда үзгәргән чынбарлыкны, аның төп вакыйгаларын күрсәтергә, яңа геройлар — яшь революционерлар образларын тудырырга омтыла. Романда татар җәмгыятенең күп яклары — мәгарифнең торышы, шәкертләрнең белем бирүне үзгәртү өчен көрәше, татар интеллигенциясенең идея эзләнүләре (революционерлар Давыт Урманов, Хәбиб Мансуров, Баязит Карилар үрнәгендә), татар хатын-кызларын (Нәфисә, Гөлбикә, Һаҗәр образлары) иҗтимагый-сәяси тормышка җәлеп итү чагылыш таба.

И.ның «Яңа кешеләр» драмасы (1920), ш.у. «Кызыл чәчәкләр» повесте (1920) Идел буенда һәм Уралда Гражданнар сугышы темасына багышлана. Соңгысында 1917 елгы Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы вакыйгалары тарафыннан баррикаданың ике ягына куелган авылдаш биш егетнең язмышы күрсәтелә. Авыл сәүдәгәре улы Гали Колчак гаскәрендә сугыша; руханилар катлавы вәкиле Фазыл, Ак армиянең һәлакәткә дучар икәнлеген аңлап, Совет хакимияте ягына чыга. Балта остасы улы Гыйлаҗины акгвардиячеләр үтерә. Иң ярлы крәстияннәр вәкилләре Солтан б-н Шаһбаз үз язмышларын яңа җәмгыять б-н бәйлиләр, тормышны социалистик үзгәртеп коруда актив катнашалар.


«Алмачуар» хикәясе (русчага тәрҗемәдә — «Чубарый», 1922) татар әдәбиятында һәм тулаем ул вакыттагы милли прозада мөһим күренеш була. Анда автор крәстиян малаеның якты, истә калырлык образын тудыра, аның психологиясен ача, татар авылы кешеләренең хисләр дөньясы байлыгын һәм кичерешләрен күрсәтә.

1924 тә «Казакъ кызы» (русчага тәрҗемәдә — «Дочь степи», 1934) романы басылып чыга, хакимиятләр аны ике тапкыр (1911 дә Оренбургта, 1913 тә Киевта) конфискацияли. Язучы казакъ далаларында яшәүчеләрнең рев-циягә кадәрге тормышын сурәтли, колониаль изүнең, социаль каршылык күрсәтүнең кискен картиналарын гәүдәләндерә. Төп геройлар Карлыгач-Сылу б-н Арысланбайның традицион романтик мәхәббәтләре темасы органик рәвештә социаль проблематика б-н кушыла. И. романы — казакълар арасындагы яңа иҗтимагый көчләрне әдәби тасвирлауның беренче тәҗрибәсе, СССРдагы төрки халыклар әдәбиятлары үсешендә мөһим этап була.

Совет Шәрегы язучыларыннан беренчеләрдән булып, И. социаль роман жанры нигезләрен сала. «Тирән тамырлар» романында (1928) татар халкы тормышының нэп чорындагы социаль-сәяси асылына әдәби анализ ясала.

1920 еллар уртасыннан башлап, марксистик-ленинчыл эстетика тарафдарлары көчләп таккан социалистик реализм ысулы И. әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен, проблематикасын һәм эчтәлеген билгели. Шуңа да карамастан, аның бу чор иҗатына чынбарлыкны колачлы фикерләү, чын тормыш вакыйгаларын аларның бөтен катлаулылыклары һәм каршылыклары б-н яктырту хас. Аның «Казакъ кызы» романы, яңадан эшләнгән «Татар хатыны ниләр күрми?» повесте һәм Идел буенда 1921–22 еллардагы ачлыкны чагылдырган «Адәмнәр» повесте (1923) — шундыйлардан.

Әдәби әсәрләр б-н беррәттән, И. бай публицистик һәм әдәби тәнкыйть мирасы калдыра. 1910 еллардагы мәкаләләрендә үк ул милли әдәбиятны үстерүнең принципиаль мәсьәләләрен күтәрә, аның төп асылын «милли рух һәм характер көзгесе» буларак билгели. Әдәбиятның эчтәлеген һәм әдәби формасын баетуда И. фольклорга зур әһәмият бирә; киң




Г.Ибраһимовның кайбер җыентыклары.

халык массаларын рус, Шәрекъ һәм Европа классик әдәбиятлары хәзинәләре б-н таныштыруны татар интеллигенциясенең мөһим бурычы дип саный.

И.ның революциягә кадәрге романтик эстетикасының үзенчәлекләре С.Рәмиев, Дәрдмәнд, Г.Тукай иҗатларын анализлауга багышланган «Татар шагыйрьләре» дигән тәнкыйть мәкаләсендә (Оренбург, 1913) аеруча ачык чагыла.

И.ның «Галия» мәдрәсәсендә эшләгән еллары эстетик теорияне һәм әдәби тәнкыйтьне үстерү һәм үзләштерү өчен уңышлы була. Нәкъ менә шул чорда ул үзенең зур теоретик мәкаләсе б-н «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз»ен (1915) чыгара, әдәбият теориясе буенча «Әдәбият кануннары» (1916) дигән мөһим хезмәт яза. Үткәндәге мәдәни мираска, татар совет әдәбиятын үстерүгә мөнәсәбәте мәсьәләләре Окт. рев-циясеннән соң да И.ның игътибары үзәгендә була. Болар «Имла, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924) китапларында чагылыш таба, аларда ул татар әдәбият белемендә марксистик-ленинчыл методология принципларын ныгыта. Әлеге методология кысаларында милли мәдәниятләрнең асылын һәм үзенчәлекләрен, пролетар диктатура шартларында аларның үсеш перспективаларын тагын да тирәнрәк өйрәнүгә омтылышлар ясый («Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?», 1927).

И. — татар филологиясе һәм лингвистика буенча «Татар сарыфы» (1911), «Татар телен ничек укытырга?» (1916), «Имла-хәреф мәсьәләсе» (1924) һ.б. хезмәтләр авторы.

Күп кенә хезмәтләрендә И. татар халкы тарихының, революцион хәрәкәтенең һәм татарлар арасында мәгърифәтчелекнең аерым этапларын тикшерә. Алар арасында «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» (1925) аерым урын алып тора. Ул — Ш.Мәрҗани, К.Насыйри турындагы мәкаләләр, «Шәрекънең бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» (1919), «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1922), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «Урал һәм уралчылар» (1927) дигән тарихи һәм тарихи-публицистик хезмәтләр авторы.

Авыруы сәбәпле, И. гомеренең соңгы елларын Кырымда уздыра, шунда, «*Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә* катнашуда гаепләнеп, кулга алына. Каты авыручы И.ны Казанга китерәләр, ул төрмә хастаханәсендә үлә. Вафатыннан соң аклана.

И. әсәрләре СССРдагы һәм чит илләрдәге күп кенә халыклар телләренә тәрҗемә ителә. Аның иҗаты казакъ, үзбәк, төрекмән, башкорт һәм башка халыклар әдәбиятлары үсешенә зур йогынты ясый.

Казанда Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тына, Казан проспектларының берсенә И. исеме бирелә. Туган авылында музей-йорты ачыла (1987).

Ә с ә р.: 8 томда. К., 1974–87; 2000, Т. 9; Избранное. К., 1957; Советские писатели: Автобиографии. Т. 3. М., 1966.

*Әд.:* С ә й ф и Ф. Галимҗан Ибраһимов // Яңалиф. 1928. № 4; Х ә с ә н о в М. Галимҗан Ибраһимов. К., 1964; Г.Ибраһимов турында истәлекләр. К., 1966; М ө х ә м м ә д е в а Г. Олы юл. К., 1994; Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. К., 2003; Х а л и т Г. Галимджан Ибрагимов // История татарской советской литературы. М., 1965; Г и м а д и е в У. Галимджан Ибрагимов — журналист. Уфа, 1967; Н у р у л л и н И. Путь к зрелости. К., 1971; Х а с а н о в М.Х. Галимджан Ибрагимов. К., 1977; ш у л у к. Учёный, писатель, революционер. М., 1987; Писатель, революционер, учёный: Материалы науч. конф., посвященной 90-летию Галимджана Ибрагимова. К., 1980; Г а б с а л я м о в а Ф.Г., Г и м а д и е в У.И. Галимджан Ибрагимов: Библиогр. указатель (1907–1977). Уфа, 1979.

*М.Х.Хәсәнов.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Гариф Ибраһим улы (15.1.1922, Чаллы кантоны Каенлы а.), Дан орденының тулы кавалеры (20.5.1944, 29.10.1944, 27.6.1945), старшина (1945). Мәскәүдә төрле эшләрдә эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 49 нчы укчы полкның 45 *мм* лы туп төзәүчесе, туп командиры (52 нче армиянең 50 нче укчы дивизиясе). 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украинаны азат итү, Яссы-Кишинёв (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 9 маенда Вултуру торак пункты (Румыния, Яссы шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнбатышта-



Г.И. Ибраһимов.

рак) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: артиллерия расчёты составында дошманның 3 пулемётын, тубын юк итә, яралана, әмма сафта кала; 1944 нең 20–24 августында Яссы сугышында 3 пулемётны, дзот һәм автомашинаны сафтан чыгара; 1945 нең 16–20 апреленә кадәр Центендорф, Кальтвассер, Кляйн-Крауш һәм Левенберг торак пунктлары (Германия) тирәсендәге сугышларда расчёт составында 7 пулемётны юк итә. 1948 дән шәһәр тибындагы Марьяновка посёлогында (Украина ССРның Волынь өлкәсе Горький р-ны) шикәр з-дында эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Д у б р о в Б.И. Солдатская слава. Киев, 1987; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1987; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Грант Евгеньевич (6.4.1951, Баку ш.), цирк артисты, акробат, хайваннар өйрәтүче, РФнең халык артисты (1992). Казан циркы каршындагы Бөтенсоюз үзәк цирк сәнгате студиясен (1970), Дәүләт театр сәнгате ин-тын (Мәскәү) тәмамлый. 1970–75 елларда Татар цирк коллективында «Иңсә акробатлары» номерында эшли, 1975 тән Союзгосцирк (хәзерге Росгосцирк) системасында хайваннар өйрәтүче артист, бер үк вакытта 1997 дән Омск шәһәрендә цирк директоры.



Р.Н. һәм Г.Е.Ибраһимовлар.

Р.Н.*Ибраһимова* б-н бергә «Аюлар бенефисы» (1987 дән — «Чалыш аяклар грациясе» — «Косолапая грация») номерын эшли. И. күп илләрдә гастрольләрдә була. Халыкара цирк сәнгате фестивале (Гавана, 1981), Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале (Мәскәү, 1985) лауреаты.

*Әд.:* Н и к о л а е в М. История одного трюка // Советская эстрада и цирк. 1985. № 4.

**ИБРАҺИ́МОВ** Илдар Габдулла улы (15.7.1932, Ленинград), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1966), РФА академигы (1997; 1990 елдан СССР ФАнең мөхбир әгъзасы). Ленин бүләге лауреаты (1970). 1956 да Ленинград ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, проф. (1967). 1973 тән РФА Математика ин-ты Ленинград бүлегендә лаб. мөдире. Хезмәтләре ихтималлылык теориясенә, матем. статистикага, саннар теориясенә карый. Ихтималлылык теориясенең чикләмәле теоремаларына, стационар очраклы процессларга, стат. бәяләү теориясенә кагылышлы тикшеренүләр уздыра һәм билгеле бер нәтиҗәләр алуга ирешә.



И.Г. Ибраһимов.

Х е з м.: Асимптотическая теория оценивания. М., 1979 (автордаш); Предельные теоремы для функционалов от случайных блужданий. СПб., 1994 (автордаш).

*Әд.:* Ildar Ibragimov's biography. Ann. Inst. H.Poincaré. 2002. V. 38, № 6.

**ИБРАҺИ́МОВ** Илдар Рифкать улы (16.8.1967, Казан), шахматчы, халыкара гроссмейстер (1993). Р.Г.Нәҗметдинов исем. Олимпия резервының үзәк балалар-яшүсмерләр махсус шахмат мәктәбендә тәрбияләнә (Казан). Тренерлары — Р.Г.Нуруллин (1973 елдан), В.М.Волошин (1977–84), С.В.Кузнецов (1984 тән). Дөнья беренчелегендә (1991, студентлар арасында), дөнья чемпионатында (1991, команда зачётында), СССР беренчелегендә (1991, яшь спорт осталары арасында) җиңүче. 2001 елдан АКШта яши.

**ИБРАҺИ́МОВ** Илфак Мирза (Мирзамөхәммәт) улы (псевд. Мөхәммәт Мирза) (1.3.1953, Актаныш р-ны Чалманарат а.), шагыйрь. Казан мәдәният ин-тын тәмамлагач (1975), Актаныш р-нында эшли: җирле радиотапшырулар мөхәррире (1975–79), ВЛКСМ райкомының 1 нче секретаре (1979–84), район эчке эшләр бүлеге башлыгы урынбасары (1984–96), район хакимиятенең мәдәният бүлеге мөдире (1996–2001). 2001–2005 елларда ТР мәдәният министры урынбасары. 2005 тән ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998), «Киек каз юлында» (2003), русчага тәрҗемәдә «Дорога к тебе» (2006), «Тере су» (2007), «Адәм баласы» (2009), «Агыйделдә ак пароход» (Уфа, 2009) исемле шигырь җыентыклары авторы.


*Әд.:* Ш а г ы й р ь җ а н Л. Шагыйрь буласың килсә — бул! // Казан утлары. 1998. № 11; А к м а л Н. Шигырьне сагыну // Казан утлары 2003. № 11.

**ИБРАҺИ́МОВ** Йосыф Ихсан улы (14.8.1895, Җидесу өлкәсе Пржевальск ш. — 1961), хәрби һәм сәяси эшлекле. 1914 елда коммерция уч-щесен (Ташкент), 1915 тә тизләтелгән хәрби уч-ще тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 4 нче Төркестан укчы полкының рота командиры. 1917 нең ноябрендә Төньяк фронтның Мөселман солдатлар башкарма ком-ты комиссары итеп сайлана. 1918 нең гыйнварыннан РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршындагы Эчке Россия мөселманнары комис-тының хәрби бүлеге мөдире. Татарлар һәм башкортлардан иреклеләр отрядлары оештыру б-н шөгыльләнә. 1918 нең апреленнән РСФСР Хәрби эшләр комис-ты каршындагы Үзәк мөселман хәрби һәйәте әгъзасы; Төркестанга җибәрелә. Төркестан ҮБК әгъзасы, Оренбург фронтының Илецк (Тозтүбә) төркеме штабы башлыгы, Каспий арьягы фронтының хәрби-сәяси штабы әгъзасы. 1919 ның апреленнән *Беренче аерым Идел буе татар укчылары бригадасы* командиры. Төркестан фронты Революцион Хәрби Советы әгъзасы (1920). 1920–21 дә Бохара Халык Совет Җөмһүриятенең хәрби назире (халык комиссары). 1921 дә Төркестан АССР Эчке эшләр халык комис-ты һәйәте әгъзасы. Соңрак Төркестан ҮБК каршындагы Авыл хуҗалыгына булышлык итү ком-ты рәисе, Урта Азия а.х. банкы идарәчесе. 1932–41 дә Ташкент ун-тында, Сәмәрканд укытучылар пед. ин-тында хәрби әзерлек башлыгы. Бөек Ватан сугышында 95 нче, 87 нче укчы бригадаларда, 212 нче укчы дивизиядә һәм башка хәрби частьләрдә командир вазифаларын башкара.

*Әд.:* Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. Комбриг Юсуф Ибрагимов. К., 1990; Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*Д.Р.Шәрәфетдинов.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Лев Николаевич (22.2.1816, башка мәгълүматлар буенча 1818 — 1867 дән соң), шагыйрь, педагог. Н.М.*Ибраһимовның* улы. 1837 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Беренче ир балалар гимназиясендә укыта. 1832–34 елларда «Заволжский муравей» ж-лында язышa, соңыннан әсәрләре башкаларның матбугат чараларында — «Санкт-Петербургские ведомости» (1837), «Библиотека для чтения» (1839) һ.б.да басыла. 1841 дә Казанда аның беренче шигъри җыентыгы дөнья



СТИХОТВОРЕНІЯ

КАЗАНЬ.

Л. Ибраһимов шигырьләр җыентыгының титул бите. Казан. 1841.

күрә. Рус фольклор поэтикасына мөрәҗәгать итүе И.ка зур уңыш китерә. «Җаныкаем, чибәр кыз...» («Ты душа ль моя, красна девица...») исемле танылган шигыренә Н.И.Бахметьев, соңыннан А.Ф.Львов музыка яза, һәм ул популярлашып китә. Җыр, романс стилендә язылган «Кара урман шаулый...» («Шумят, шумят во сыром бору...»), «Кыңгырау» («Колокольчик»), «Романс», «Күзләр» («Очи») (соңгысына 1856 елда комп. Н.Кравцов музыка яза) шигырьләренә эчкерсезлек, гадилек һәм аһәңлелек хас. Казанда югары даирә вәкилләренә эпиграммалар язып та-

ныла. 1844 тә Казаннан китә. Пермь губернасында тау эшләре чиновнигы булып хезмәт итә. 1866 да Түбән Тагилга күчә, бөлгенлеккә төшә. 1867 дә Кынов приход уч-щесендә укыту өчен рөхсәт алырга тырышып карый. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

Ә с ә р.: Стихотворения Льва Ибрагимова. К., 1841.

*Әд.:* А р и с т о в В.В. Два забытых поэтических имени // Казанские находки. К., 1985; Русские писатели: Библиогр. словарь. М., 1992. Т. 2.

*М.М.Сидорова.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Мөнәвәр Гомәр улы (25.7.1943, Апас р-ны Апас а.), нефтехимик, техник фән. канд. (1973), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Уфа химия з-дында эшли. 1967 дән Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, массаалмашу процессларын тикшерү һәм исәпләүләр лаб-ясе мөдире (1978 дән), директор урынбасары (1991 дән). Хезмәтләре СССР, РФ һәм БДБ илләренең нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләрендә углеводород чималын эшкәртүне һәм яңа процессларны әзерләүне, «Татнефть» АҖ промыселларында нефть әзерләү процессларын камилләштерүгә карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын күкерт кушылмаларыннан арындыру һәм катализаторлар җитештерү технологиясен эшләгәне, «Татнефть» АҖдә, «Тенгизшевройл» Россия-Америка уртак пр-тиесендә, Россия нефть эшкәртү пр-тиеләрендә гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ИБРАҺИ́МОВ** Наил Габделбари улы (28.4.1955, Әлмәт ш.), нефтьче, техник фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. нефтьчесе (2001). 1977 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң, «Әлмәтнефть» НГДУында эшли: оператор, нефть һәм газ чыгару мастеры, өлкән технолог, нефть һәм газ чыгару цехы җитәкчесе урынбасары, цех җитәкчесе, производствога хезмәт күрсәтү базасы җитәкчесе, баш инженер, бер үк вакытта идарә җитәкчесенең беренче урынбасары (1988 дән). 1999 дан «Татнефть» АҖдә баш инженер, бер үк вакытта ген. директорның беренче урынбасары. Дәүләт бүләге «Штангалы тираннан суырту насосы җайланмаларының ышанычлылыгын арттыру буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләү һәм сәнәгатьтә киң кулланышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 76 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологии управления инженерно-техническим потенциалом НГДУ // Нефтепромысловое дело. 1999. № 10; Интегрирование геоинформационной системы и гидродинамической модели месторождения для оптимизации системы нефтесбора // Нефтяное хоз-во. 2001. № 10 (автордаш); Анализ и выбор средств измерения расходов в системах ППД и газосборных сетях // Нефтяное хоз-во. 2002. № 3 (автордаш).

**ИБРАҺИ́МОВ** Наил Гомәр улы (1.6.1942, Арча р-ны Чиканас а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005), РФнең атказ. химигы (1998). РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1999). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында (Пермь ш.) эшли, 1993 тән бүлек мөдире. Хезмәтләре энергия тупланган куертылган системаларга карый. Куертылган системалар нигезендә хәрби техниканың төрле өлкәләрендә һәм халык хуҗалыгы продукциясе җитештерүдә файдалану өчен уникаль составлар эшли. РФнең Дәүләт бүләге икеле технологияләр өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Фәнни эшкәртмәләре (эшләнмәләр, составлар, компонентлар) кораллану системаларындагы өч пр-тиедә 30 дан артык төрдә күпләп заряд әзерләүдә, халык хуҗалыгы продукциясе җитештерүдә гамәлгә кертелә; күп кенә составлары экспортка җибәрелә торган сугыш кирәк-яракларын туплаганда кулланыла. Уйлап табуга 280 авторлык таныклыгы һәм 45 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние октогена на механизм горения баллиститных порохов // Физика горения и взрыва. 1996. Т. 32, № 3 (автордаш); К механизму катализа при горении современных баллиститных порохов // шунда ук. 1999. Т. 35, № 5 (автордаш).

*Әд.:* Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энциклопедия. М., 2006.

**ИБРАҺИ́МОВ** Наил Хәйрулла улы (18.1.1939, Ютазы р-ны Урыссу а.), математик, физ.-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1977). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987). 1965 елда Новосибирск ун-тын тәмамлый, СССР ФА Себер бүлегенең (Новосибирск ш.) Гидродинамика ин-тында эшли. 1980–87 елларда СССР ФА Башкорт ф-лының физика һәм математика бүлегендә. 1987 дән СССР ФАнең Гамәли математика ин-тында, 1990 нан РФАнең Бөтенроссия матем. модельләштерү үзәгендә. Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләрне төркемләп анализлауга карый. Нәтривиаль комформ төркемле Риманча күптөрлелекләрнең гиперболик тигезләмәләре өчен Гюйгенс принцибы турындагы Ж.Адамар проблемасын чишә.

Х е з м.: Группы преобразований в математической физике. М., 1983; Lie-Backlund Transformations in Applications. Phil., 1979.

**ИБРАҺИ́МОВ** Нәфис Мөдәррис улы (14.4.1957, Әлмәт р-ны Миңлебай а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 1983 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татнефтегаз» идарәсендә эшли. 1991 дән «Татэкспорт» АҖдә, ген. директор урынбасары (1993 тән). Дәүләт бүләге Татарстан нефть промыселларында энергия ресурсларын саклаучы технологияләр эшләүдәге һәм сәнәгатьтә кулланышка кертүдәге хезмәтләре өчен бирелә.

**ИБРАҺИ́МОВ** Николай Мисаилович (1778, Мәскәү (?) — 17.4.1818, Казан), педагог, шагыйрь. 1791–98 елларда ун-тның разночинецлар гимназиясендә һәм Мәскәү ун-тында укый. 1798 елдан яңа ачылган Казан гимназиясендә: славян-рус классында, 1804 тән югары рус классында укытучы. 1807–13 тә инспектор вазифасын башкаручы, 1815 тән гимназия инспекторы. Бер үк вакытта 1814 тән латин теле укытучысы, 1817 дән Казан ун-тының рус тел белеме адъюнкты. Педагог буларак, И. студентлар арасында киң популярлык казана; рус һәм славян грамматикасын өйрәнүнең нәтиҗәле алымын эшли, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерә, аларны яңа рус әдәбиятының иң яхшы әсәрләре б-н таныштыра, талантлы нәфис сүз остасы була. С.Т.Аксаковның иҗаты формалашуга зур йогынты ясый. Аксаков «Гаилә хроникасы һәм истәлекләр»ендә («Семейная хроника и воспоминания») аның турында болай яза: «Фамилиясе һәм тышкы кыяфәте аның чыгышы б-н татар яисә башкорт икәнлеген күрсәтә. ... Әдәбиятны бик нык ярата, тапкыр сүзле һәм, гомумән, сәләтле кеше иде». Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыятен төзү инициаторы була, аның уставын эшләүдә катнаша (П.С.Кондырев б-н бергәләп) һәм беренче булып җитәкли. Әле студент чакта ук «Приятное и полезное времяпрепровождение» ж-лында (Мәскәү) латин теленнән шигырьләр тәрҗемә итеп бастыра. «Труды Казанского общества любителей отечественной словесности» ж-лында (1815) 14 шигырен, «Сын Отечества» ж-лында (Мәскәү) «Синонимнар турында» («О синонимах») фәнни тикшеренүләрен бастыра. И.ның кайбер шигырьләре: «Кыз кичен чибәр» («Вечерком красна девица», 1815), «Кырда кечкенә каен тора» («Во поле берёзонька стояла», вафатыннан соң «Благонамеренный» ж-лында басыла, 1825) музыка дөньясына халык җырлары буларак керәләр. Овидийның «Метаморфозалар» («Метаморфозы») исемле мифологик эпосы тәрҗемәсенең һәм шигырьләренең басылмаган кульязмалары Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* П а н а е в В.И. Воспоминания // Вестн. Европы. СПБ., 1867; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Воспоминания // Аксаков С.Т. Собр. соч. М.–Л., 1955. Т. 2; А р и с т о в В.В. Казанские находки. К., 1985; ш у л у к. Первое литературное общество Поволжья (К истории Казанского общества любителей отечественной словесности в 1806–1818 гг.) К., 1992.

**ИБРАҺИ́МОВ** Рәшит Габдрахман улы (28.7.1927, Ульянов өлкәсенең Богдашкино, хәзерге Чынлы р-ны Кәшә а.), язучы, очучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Богырыслан граждан авиациясе уч-щесен тәмамлый (1953). 1953–86 елларда Казан берләштерелгән авиация отрядында эшли: По-2, Ан-2, Ли-2 самолётлары очучысы, Ил-14, Ту-124 корабльләре командиры. Авиация тарихына караган, очучы профессиясенең романтикасын чагылдырган «Көмеш канатлар» (1971), «Татарстан канатлары» («Крылья Татарстана», 1985), «Алтын йолдызлы лачын» (1987), «Көмеш канатлар — зәңгәр хыяллар» (1989), «Ерак илләргә сәяхәт» (1990), «Канатлыга — зәңгәр биеклек» (1995), «Очар вакыт» («Время летать», 2003), «Бөркетләр кыядан курыкмый» (2008), балалар өчен «Кечкенә «тулар» эпопеясы» («Эпопея маленьких «тушек» («Казань» ж-лы,



Рәшит Ибраһимов.



Р.И. Ибраһимов.

1999, № 3–4) исемле хикәяләр, ш.у. «Туган авылым тугайлары» исемле шигъри җыентыклар (2008) авторы. И.ның күп әсәрләре автобиографик характерда. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Хәмитов М. Көмеш канатлар // Казан утлары. 1972. № 1; Әхмәтсафа Ш. Рәшит Ибраһимовка — 70 яшь // Казан утлары. 1997. № 7.

**ИБРАҺИ́МОВ** Рәшит (Габдерәшит) Гомәр улы (23.4.1857, Тобол губ. Тара а. — 31.8.1944, Токио), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист. Тобол һәм Казан губерналарындагы авыл мәдрәсәләрендә башлангыч белем ала. 1879–85 елларда Мәдинә, Мәккә һәм Истанбулда укуын дәвам иттерә. 1885 тә Тарада җамигъ мәчет имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. 1892 дә *Оренбург Мөселман Диния нәзарәте* казые итеп сайлана. 1894 тә бу вазифаны калдырып, Төркиягә китә; Истанбулда «Таң йолдызы» исемле китабы дөнья күрә. Патша хөкүмәтенең мөселманнарны руслаштыру сәясәтен кискен тәнкыйтьләгән өчен китап Россиядә тыела, әмма яшерен рәвештә тарала. 1897–1900 дә И. мөселман һәм Европа илләре буйлап озакка сузылган сәяхәт кыла. Россиягә әйләнеп кайткач, С.-Петербургта «*Мирьат*» дип аталган китаплар һәм брошюралар сериясен, «*Өлфәт*», «*Нәҗәт*» г-таларын, «*әт-Тилмиз*» атналыгын нәшер итә. 1905–06 да «*Иттифак әл-мөслимин*» съездлары эшендә катнаша, әлеге партиянең ҮК әгъзасы була, аның программасын әзерләүдә катнаша. 1907 дә С.-Петербургтан китеп, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә сәяхәт итә. 1908 дә Көньяк-Көнчыгыш Азия илләренә ерак сәфәргә кузгала. Япониядә ислам турында лекцияләр б-н чыгышлар ясый, принц Ито б-н таныша. 1909 да, Токиода японнар арасында исламны җәелдерү максаты б-н, И. «Ислам сәүдә җәмгыятен» оештыруда катнаша. Шушы сәяхәт нәтиҗәсендә Казанда нәшер ителүче «*Бәянелхак*» г-тасында очерклары басыла, Истанбулда аерым китабы дөнья күрә. 1911 дә, Төркиянең Африкадагы төньяк биләмәләрен басып алу өчен Италия алып барган сугышта мөселманнарга ярдәм итү максаты б-н, И. яшерен рәвештә Триполи шәһәренә килә, мөселман оешмаларының кораллы каршылык күрсәтүдә берләшүләре өчен көрәшә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында составына Төркия дә кергән Австрия-Германия хәрби-сәяси блогы мәнфәгатьләрен яклау акцияләрендә катнаша. 1917–21 дә И. Россиядә яши, мөселман халыклары проблемаларын хәл итүдә Совет хакимиятенә зур өметләр баглый. 1922–33 тә Төркиядә, 1933 тән Япониядә яши. 1937 елда аның тырышлыгы б-н Токиода җамигъ мәчет төзелә, ул аның имам-хатибы була. И. Токиодан ерак түгел мөселман зиратында җирләнә.

Хезм.: Тәрҗемәи хәлем. К., 2001; Дәүре галәм. К., 2001.

*Әд.:* Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917). М.–П., 1923; Turkoglу I. Sibiryalı Meşhur Abdurreşid Ibrahim. Ankara, 1997.

**ИБРАҺИ́МОВ** Ренат Ислам улы (20.11.1947, Украина ССРның Львов ш.), җырчы (баритон), ТАССРның (1980), Каракалпак АССРның (1980), РСФСРның (1981) халык артисты. 1973 елда Казан консерваториясен (С.Җиһанова классы) тәмамлый. 1973–88 дә Татар опера һәм балет театры, 1988–90 да Татар филармониясе солисты. 1990 нан Мәскәүдә: 1998 гә кадәр «Сәфәр» Татар мәдәни үзәгенең сәнгать җитәкчесе һәм солисты, 1998–99 да РАЖ «Газпром»ның мәдәният идарәсе (Мәскәү) башлыгы. 1999 дан «Ренат Ибраһимов җыр театры»ның сәнгать җитәкчесе һәм солисты. Ул вокаль музыканың төрле жанрлары үзенчәлекләрен яхшы белеп эш итә. Матур, ягымлы йомшак тавышы, сәхнәдә мөлаемлыгы, профессиональлеге, үтә тәэсирле һәм ихлас башкару осталыгы җырчыга бөтенроссия тамашачысы алдында популярлык казаныйрга мөмкинлек бирә. И.ның опера партияләре: кенәз Игорь (шул исем. опера, А.Бородин), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Евгений Онегин, Елецкий («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский). Җырчыга аеруча эстрада концерт эшчәнлеге зур уңыш китерә. И. репертуарын опера, оперетта һәм мюзиклларда ариялар, классик романслар, Россия һәм чит ил авторларының популяр эстрада җырлары тәшкил итә. «Италия контракты» («Итальянский контракт») муз. нәфис фильмының продюсеры һәм төп рольне башкаручы (1992). Россиядә һәм чит илләрдә (Германия, АКШ, Италия, Бельгия, Куба, Финляндия һ.б.) гастрольләрдә була. Мәскәү һәм ТР телевидениесе һәм радиосы буенча даими чыгышлар ясый. Эстрада артистларының 5 нче Бөтенсоюз (Мәскәү, 1974), «Ал канәфер» («Алая гвоздика») халыкара фестивале (Сочи ш., 1975) конкурслары (1 нче бүләк), Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1979) лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова, А.Р.Рахман.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Сәгадәт Мөгаллим улы (25.5.1928, хәзерге Азнакай р-ны Таллыбүләк а. — 5.10.2008, Казан), тел белгече, филол. фән. канд. (1964), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1951), урта мәктәпләрдә татар теле укыта, вакытлы матбугат редакцияләрендә эшли. 1960 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре татар теле синтаксисы һәм стилистикасына карый. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре һәм программалары авторы.

Хезм.: Татар телендә аналитик төзелмәләр. К., 1964; Татар телендә синтаксик синонимнар. К., 1976; Синтаксик стилистика. К., 1989.

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С. Щедрый дар души // Казанский университет: Время, события, люди. К., 1994.

**ИБРАҺИ́МОВ** Фаил Мирза (Мирзамөхәммәт) улы (29.11.1950, Актаныш р-ны Чалманарат а.), режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Минзәлә пед. уч-щесен (1970), Казан мәдәният ин-тын (1975), Мәскәү театр сәнгате ин-ты каршындагы режиссёрлар югары курсларын (1987) тәмамлый. 1975–78, 1979–82 елларда — Актаныш, 1982–84 тә Чаллы халык театрлары режиссёры. 1978–79 да Минзәлә татар драма театрының режиссёр-стажёры, 1985 елдан баш режиссёры. 1990 нан Чаллы татар драма театрының сәнгать җитәкчесе, 1998 дән режиссёр, 2002 дән баш режиссёры. Актаныш театры сәхнәсендә «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), «Хуш, Назлыгөл» (М.Байҗиев), «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла), Чаллы халык театры сәхнәсендә «Американ» (К.Тинчурин) спектакльләренең куелышы гадәти булмаган образлы чишелешләре б-н игътибарны җәлеп итә. Минзәлә театрында куелган «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Ярым ятларга кала» (Р.Батулла), «Сөйгәнемнең туган көне» (И.Юзеев), «Тын урамда гауга», «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), «Өй салуның ние бар» (Ф.Шәфигуллин), «Сүнмәс учагым» («Негаснущий костёр», А.Крымко) һ.б. — И.ны режиссёр буларак үз эшенең остасы итеп таныткан спектакльләр. Образлы фикерләү, мизансцена композицияләренең мәгънәви тирәнлеге, драматургик материалның жанр табигатен төгәл сиземли белү нәтиҗәсендә әлеге спектакльләр татар театр сәнгатендә зур вакыйга буларак кабул ителә. Чаллы драма театры б-н җитәкчелек иткән чорда И. ныклы труппа туплый, коллективның иҗади укуын оештыра. Биредә куелган спектакльләрдә чагылыш тапкан төгәл иҗтимагый анализ, поэтик рух һәм якты театраль күренеш б-н күтәрелгән проблемаларның гомуми берлеге режиссёрның сәнгать юнәлешен билгеләр («Күбәләк булып җаның кайтыр», Р.Батулла; «Язлар моңы», Ә.Гаффар; «Курку», З.Хәким; «Сөясеңме, сөймисеңме», Ф.Бүләков; «Гашыйклар тавы», И.Юзеев; «Тигезәкләр», Р.Хәмид; «Саташу», Т.Миңнуллин). Әлмәт татар драма театры («Көзнең соңгы яфраклары», Р.Хәмид; «Сафиулла», М.Гыйләҗев; «Көзге романс», З.Хәким; «Мәкер вә мәхәббәт» — «Коварство и любовь», Ф.Шиллер), Татар академ. театры («Ярым ятларга кала», Р.Батулла), Уфаның «Нур» театры («Сихерче», Н.Гыйматдинова; «Яр», Б.Сәлахов) сәхнәләрендә спектакльләр куя, аларда да рух киеренкелеге, фикер ачыклыгы өстенлек итә. М.Җәлил исем. республика бүләге лауреаты (2007).

*Әд.:* Гыймранова Д. Сәхнә — илһам мәйданы // Казан утлары. 2009. № 6.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Фатих Исхак улы (25.2.1916, Самара губ. Бөгелмә өязе, хәзерге Лениногорск р-ны Кирлегәч а. — 20.1.1995, Казан), педагог, журналист, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966), РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1972). Пед. рабфак (1937), Казан пед. ин-тын (1956) тә-

мамлый. Хезмәт эшчәнлеген 13 яшеннән башлый, туган авылы мәктәбендә дәресләр алып бара. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 елдан журналистлык хезмәтендә: «Социалистик Татарстан» г-тасында (1945–50) эшли, «Чаян» (1950–60), «Совет мәктәбе» (1960–77) ж-лларында баш мөхәррир. 1977 дән РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында. Фәнни-тикшеренү эшләренең төп юнәлеше — татар теленә өйрәтүнең теориясе һәм методикасы, татар әлифбасы тарихы. Балаларга гаилә тәрбиясе, мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия бирү проблемаларын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Мәктәпкәчә учреждениеләр, әзерлек класслары, ата-аналарга пед. белем бирү өчен программалар, уку ярдәмлекләре, хрестоматияләр, ш.у. пед. һәм филол. буенча вакытлы матбугатта басылган күп кенә мәкаләләр авторы.

Х е з м.: Белем әлифбадан башлана. К., 1973; Бүләк. К., 1975; Сезгә, ата-аналар. К., 1979.

*Әд.:* В ә л и у л л и н М.Ә. Матбугат ветераны // Мәгариф. 1996. № 5; И б р а һ и м о в а Ф.И. Сәлатле иде // Татар иле. № 18, 6 май, 2006.

**ИБРАҺИ́МОВ** Фәрит Таҗетдин улы (13.2.1893, Лаеш өязе Югары Ырга а. — 1943, Үзбәкстан Респ-касының Сәмәркand өлкәсе, хәзерге Янгарабат р-ны Хәтерче а.), шагыйрь. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1916 елдан Пермь, Ташкент, Пешпәк мәктәпләрендә мөгаллимлек итә. Ташкентта Коммунистик ун-тны тәмамлаганнан соң, шунда һәм Сәмәркand Коммунистик ун-тында укыта. 1924 тә Казанда рабфак тәмамлый һәм янә Үзбәкстанга китә. Шигырьләрен «Аң», «Сөембикә», «Ак юл», «Балалар дөньясы» ж-лларында; «Кояш», «Сибирия» г-таларында бастыра. 1912 дә «Уйларым», «Өмидемнең нурлары» исемле беренче шигъри җыентыклары дөнья күрә. И. — татар фольклор әсәрләренә нигезләнеп язылган «Авылым» (1916), «Халык арасында» (1918), «Өрәк» (1918), «Төшләр» (1918) исемле поэмалар авторы. Аерым шигырьләре «Милли моңнар» (1919), «Табигать моңнары» (1919), «Көрәш җырлары» (1923) исемле күмәк җыентыкларда урын алган. Алар ш.у. «Татар поэзиясе антологиясе»нә дә (1956, рус. телендә 1957) кергән.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Г. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Хәбибулла Ибраһим улы (18.1.1912, Вятка губ. Малмыж өязе, хәзерге Балтач р-ны Куныр а. — 18.10.1975, Куныр а.), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), подполковник (1958). Кече лейтенантлар (1938), Команда составын камилләштерү (1943) курсларын, Югары офицерлар бронетанк мәктәбен (1947) тәмамлый. Сугышка кадәр колхозда эшли. 1934 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 128 нче танкка каршы дивизион батарея командиры (7 нче армиянең 86 нчы мотоукчылар дивизиясе). Төньяк-Көнчыгыш фронт гаскәрләре составында 1940 ның 3–9 мартында Виипури шәһәре (хәзер Выборг ш.) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: кече лейтенант И. җитәкчелегендәге батарея Вилайоки авылы янында, дошманның ут нокталарын бастырып, пехотаның уңышлы һөҗүменә булышлык итә; аннан соң Фин култыгы бозы аша дошманның Виипури янында ныгытылган р-ны тылына чыга һәм аны яулаганда пехотага артиллерия уты б-н ярдәм итә. Бөек Ватан сугышында үзйөрешле артиллерия полкы командиры урынбасары. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифаларын дәвам итә. 1954 тән запаска җибәрелә, Казан шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Бои в Финляндии. М., 1941. Ч. 2; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Хәбибулла Кәлимулла улы (29.12.1894, Оренбург ш. — 16.3.1959, Уфа), композитор, драматург, муз.-җәмәгать эшлеклесе, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1951). 1910 елларда Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1915 тән концертларда пианист-аккомпаниатор һәм халык көйләре темасына импровизацияләр башкаручы буларак чыгышлар ясый. Гражданнар сугышы чорында Төркестан фронтының сәяси бүлеге каршындагы театр труппасында музыка җитәкчесе. 1920–37 елларда (бүленеп) Башкорт драма акад. театрының музыка җитәкчесе. 1922–26 да Петербургта Көнчыгыш халыклары ин-тының музыка ф-тында укый. 1937–39 да Мәскәү Үзәк радиокомитетында музыка редакторы. 1940–50 дә Уфа шәһәрендә хор коллективларын оештыручы һәм җитәкчесе. Хәзерге проф. башкорт муз. культурасын булдыруда мөһим роль уйнаган муз.-драма жанрына нигез сала.

Төп әсәрләре: «Башмагым», «Җизнәкәй» һ.б. муз. комедияләр; «Ватан өчен» (1943, Ф.Е.Козицкий б-н бергәләп) операсы (С.Кудаш либреттосы); драма спектакльләренә музыка; 30 дан артык җыр; башкорт һәм татар халык көйләре эшкәртмәләре; тынлы оркестр өчен «Салават» маршы һ.б.

*Әд.:* А т а н о в а Л.П. Композиторы Башкирии: Краткий биогр. справ. Уфа. 1982; Первые шаги профессиональной музыкальной культуры (1917–1941) // Очерки по истории башкирской музыкальной культуры. Уфа. 2001. Вып. 1; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа. 1996.

**ИБРАҺИ́МОВ** Хәбир Кәбир улы (19.11.1958, Апас р-ны Борнаш а.), язучы, драматург. Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1980). 1985–88 елларда Казан үзешчән сәнгать йортында эшли. 1990–94 тә «Татарстан» ДТРКнда телевизион тапшырулар мөхәррире. 1994–99 да «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» г-талары, «Татарстан» ж-лы редакцияләрендә хәбәрче, әдәби мөхәррир. 1999–2001 дә Татарстан китап нәшриятында, 2001 дән «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөхәррире, бер үк вакытта 2006 дан ТР Язучылар берлеге идарәсендә әдәби консультант. «Аһәң» (2001) шигырьләр һәм поэмалар, «Йокыга талган гүзәл» (2002) хикәяләр, «Газиз ярым» (2006) пьесалар җыентыклары



Ибраһимов
Хәбибулла
Ибраһим улы.

дөнья күрә. Аның пьесалары буенча эшләнгән «Артык гомер» (1993), «Төнге шаяру» (1994), «Кызыма килер йөз кеше» (1995), «Газиз ярым» (1997), «Бәхетле килен» (1997), «Җиденче кияү» (2005), «Ялгыз каен күзе» (2007) спектакльләре Татар драма һәм комедия, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Минзәлә, Оренбург театрларында, Уфа «Нур» театрында куела. ТРТ каналында И. сценарие буенча «Ялгыз тәкәрлек» (2002) телефильмы төшерелә.

*Әд.:* З ә й д у л л а Р. Лирика — шигъри сурәт, моң // Идел. 1990. № 2.

**ИБРАҺИ́МОВ** Хәсәнхөсәен Ибраһим улы (28.8.1950, Дагстан АССРның Новолак р-ны Новочуртах а.), педагог, пед. фән. д-ры (1994), РМАнең мөхбир әгъзасы (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Дагстан ун-тын тәмамлый (1973). 1975–80 елларда Хасавюрт шәһәрендә урта һөнәри-техник уч-щедә укыта. 1980 нән СССР ПФАнең Проф.-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). 1991 дән Казан пед. ин-тында (хәзерге Татар гуманитар-пед. ун-ты). 1995 тән Проф. белем бирү системасында җитәкче хезмәткәрләр һәм белгечләрнең квалификациясен күтәрү үзәк ин-тының Казан ф-лында директор урынбасары, 2006 дан социаль-икътисад ф-ты деканы, проф. (1996). Хезмәтләре укытуны оештыру формаларын камилләштерү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Педагогические технологии развития мышления учащихся. К., 1993 (автордаш); Концентрированное обучение в средней профессиональной школе. К., 1998 (автордаш); Формы организации обучения: теория, история, практика. К., 1998; Урок в условиях диверсификации среднего профессионального образования. К., 2002 (автордаш).

**ИБРАҺИ́МОВ** Шаһимәрдән Мирас улы (1841, Оренбург губ. — 1892, Җиддә ш., Согуд Гарәбстаны), дәүләт эшлеклесе, дипломат, хакыйкый статский советник. Дворяннар нәселеннән. Себер хәрби уч-щесен тәмамлый (Омск ш., 1863). 1864 елда Петропавловск шәһәр полиция идарәсендә тәрҗемәче, аннары коллежский секретарь, бүлек башлыгы булып эшли. 1867 дән Төркестан ген.-губернаторлыгында губернатор ярдәмчесе, 1878–82 дә дипломатия хезмәте чиновнигы. Бу чорда Бохара һәм Хива ханлыкларында, Иранда, Һиндстанда, 1879 да Франциядә, Германиядә була. 1880–81 дә Бохарада рус илчелеген җитәкли. 1881 дән Кашгариядә консул. 1886–90 да Юл канцеляриясе (С.-Петербург) каршында Төркестан ген.-губернаторы вәкиле. 1890 нан Россиянең Согуд Гарәбстанындагы консуллыгы ген. консулы.

1891 дә Мәккәдә була. 1870–81 дә Россиядә төрки телдә беренче «Төркестан вилайәтенең гәзите»н («Туркестанские ведомости»га кушымта) оештыручы һәм аның мөхәррире. Анда Урта Азия халыклары этнографиясе һәм фольклоры турындагы мәкаләләр бастыра. Фарсы теленнән «Мең дә бер кичә»не тәрҗемә итә (1870 еллар), казакъ халкының мәгърифәтчесе Ч.Вәлиханов турында истәлекләр яза. Үзбәк телендә 1871, 1872 (Ташкент) һәм 1873 (Мәскәү) елларга календарьлар төзи һәм бастыра.

Х е з м.: Оренбургские казаки. Таш., 1869; Мангышлакские казаки. Таш., 1870.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Н и г ъ м ә т у л л и н Э. Татар илчесе // Татарстан. 1993. № 12; Б е к х о ж и н Х. Казак баспа сөзінің даму жолдары. Алматы, 1964; Ш а р и п о в Ж. Узбекистонда тәрҗемә тарихындон. Тошкент, 1965; Узбекистон миллий энциклопедияси. Тошкент, 2002. Т. 4.

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Шәймәрдән Нуриман улы (4.4.1899, Мәскәү — 12.2.1957, шунда ук), партия эшлеклесе. 1914 елдан революцион хәрәкәттә катнаша башлый, 1915 тә металлчылар профсоюзларының Благуш р-н советы — «Бердәмлек» («Единение») секретаре итеп сайлана. Революцион эшчәнлеге өчен 1916 да кулга алына һәм 1917 елгы Февр. рев-циясенә кадәр төрмәдә була. Мәскәүдә 1917 елгы кораллы күтәрелештә катнаша, РКП(б)ның Благуш-Лефортово райкомы секретаре, бер үк вакытта металлчылар профсоюзының район бүлекчәсе секретаре вазифаларын башкара. Гражданнар сугышында катнаша. Мобилизация бүлекчәсе рәисе, РКП(б)ның армия бюросы әгъзасы, Ташкент тимер юлыннан көньякка хәрәкәт итүче аерым төркем башлыгы. 1919 да Казанда Мөселман пехота курслары комиссары урынбасары, Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы секретаре. ТАССР ҮБК әгъзасы (1920). 1921 дән РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты һәйәте әгъзасы, РКП(б) ҮКның җаваплы инструкторы, Моссовет башкарма ком-ты әгъзасы, Төркестан КП ҮК секретаре. 1937 дән Псков, Мәскәү шәһәрләрендә хакимият-хуҗалык эшендә. Бөек Ватан сугышы елларында Төньяк-Көнбатыш һәм Ленинград фронтларында сугыша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәүдә бер урам И. исемен йөртә.

*Әд.:* Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*М.А.Сәйдәшева.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Шәүкәт Шиһабетдин улы (22.10.1923, Казан — 26.12.1989, Алма-Ата), физик, техник фән. д-ры (1965), Казакъстан ССР ФА академигы (1970), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1982). Казакъстан ССР Дәүләт бүләге лауреаты (1978). 1948 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, Мәскәү, Казан авиация з-дларында эшли. 1956–69 елларда Атом энергиясен тынычлык максатында файдалану буенча дәүләт комитетының Физика-энергетика ин-тында (Обнинск ш.), лаб. мөдире. 1969–89 да Казакъстан ССР ФАнең Төш физикасы ин-тында (Алма-Ата): директор (1970–87), проф. (1977), лаб. мөдире (1987 дән). Бер үк вакытта 1974–86 да Казакъстан ССР ФАнең вице-президенты. Хезмәтләре каты җисем физикасына, радиацияле материаллар белеменә, атом энергетикасына, төш техникасына карый. И. радиацион нурланыш нәтиҗәсендә металларның рекристаллашу процессының акрынаюы, катлаулы эретмәләрне нурланыш б-н чыныктыру, нурландырылган металларда бүленгән кисәкчекләр диффузиясенең акрынаюы, эрү темп-расына якын темп-рада нурландырылган металларда гелий күзәнәкләренең кабат эрү күренешләрен ача һәм тикшерә. Саф металларның нейтроннар һәм корылган кисәкчекләр б-н нурландыру нәтиҗәсендә ныгуы, уалмаучанлыгы, физик үзлекләре үзгәрүе закончалыкларын исбатлый. И. һәм аның шәкертләре үз хезмәтләрендә легирлаучы һәм катнашма элементлар микъдарының һәм башлангыч структурасының, киеренке халәттәге пластик деформация дефектларының һәм нурланыш темп-расының металл материалларның фаза-структур халәте тотрыклылыгына, нурланыш б-н зарарлану дәрәҗәсенә йогынтысын ачыклыйлар. И. тарафыннан күп кенә гамәли күрсәтмәләр һәм тәкъдимнар эшләнә, аларны гамәлгә ашыру төш энергетикасында кулланыла торган материалларның нурланышка чыдамлыгын, төш-энергетика җайланмаларының экономиялелеген күтәрүгә һәм хәвефсезлеген артыруга ярдәм итә. Казакъстан ССР ЮСның 10 нчы һәм 11 нче чакырылыш депутаты. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Ш.Ш. Ибраһимов.

Х е з м.: Проблемы радиационной физики низких и средних энергий // Изв. АН СССР. Сер. физ.-мат. 1979. Т. 43; Влияние облучения протонами с энергией 7 Мэв на электросопротивление железа // Изв. АН Казахской ССР. Сер. физ.-мат. 1982. № 4 (автордаш); Наблюдение взаимодействия примесь-междоузлие в облучённом ниобии // Докл. АН СССР. 1982. Т. 25, № 2; Радиационные повреждения металлов и сплавов. М., 1985 (автордаш).

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

*Р.Г.Усманов.*

**ИБРАҺИ́МОВ** Якуб Хәмзә улы (13.5.1947, Аксубай р-ны Иске Ибрай а.), травматолог, ортопед, мед. фән. д-ры (2003), проф. (2004), РФнең уйлап табу һәм рационализаторлык отличнигы (2004), ТРның атказ. уйлап табучысы (2004). 1971 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, ТАССР мед. учреждениеләрендә эшли. 1979 дан Иске Ибрай участок хастаханәсендә хирург, баш табиб; 1985 тән Чаллы шәһәре «Ашыгыч медицина ярдәме» хастаханәсенең районара пешүләрдән дәвалау үзәге мөдире. 1975–77 дә һәм 1985 тән Татарстан «Травматология һәм ортопедия сәламәтләндерү» фәнни-тикшеренү үзәгендә: 1988 дән балаларның очлыклары патологиясе бүлеге мөдире, 2002 дән директор урынбасары. Фәнни тикшеренүләре эре буыннар патологиясен өйрәнүгә, умырткалык һәм күкрәк читлеге патологиясен дәвалау мәсьәләләренә карый. И. умырткалык, күкрәк читлеге, очлыклар җәрәхәтләре һәм деформациясен дәвалау өчен аппаратлар эшли һәм клиник куллануга кертә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы һәм 23 патенты бар. Көрәш буенча спорт мастеры. Акад. Г.А.Илизаров фонды премиясе лауреаты.

Х е з м.: Насосная функция сердца у больных в покое и при выполнении физической нагрузки // Казан. мед. журн. 2001. № 1; Успешное хирургическое лечение больного с травматическим кифосколиозом и вторичной нижней параплегией // Неврологический вестн. 2002. Вып. 3–4.

*Әд.:* М у х т а р о в К. Приём Якуба, наследника Абугалисины // Гасырлар авазы- Эхо веков. 2002. № 3/4.

**ИБРАҺИ́МОВА** Әлфия Галим кызы (12.10.1924, Казан), физиотерапевт, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1974). 1946 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Олы Мәңгәр участок хастаханәсендә мөдир; 1947–57 елларда (бүленеп) Казан ГИДУВында, 1957 дән Казан мед. ин-тында, физиотерапия һәм дәвалау физкультурасы каф. мөдире (1974). 1986 дан Республика клиник хастаханәсендә. Хезмәтләре ревматизм б-н авыручыларны дәвалау өчен ультрашәмәхә нурланыш һәм ультратавыш куллануны клиник-физиологик нигезләүгә, ревматоид артрит һ.б. ревматизм авырулы кешеләрдә гормональ һәм нейрогормональ системаның функцияләрен өйрәнүгә карый. И. магнит б-н дәвалауны гамәлгә кертә, хроник пиелонефрит авырулы балаларның бөер өсте бизләре тирәсен ультратавыш б-н дәвалау ысулын эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Светолечение. К., 1976; Заболевания внутренних органов, лечение и реабилитация больных. К., 1985.

**ИБРАҺИ́МОВА** Галимә Вафа кызы (28.12.1909, Казан губ., Мамадыш өязе Шандер а. — 26.3.1984, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык (1957), РСФСРның атказ. (1971) артисты. Татар театр-сәнгать техникумының театр бүлеген (1929), Мәскәүдә Үзәк театр сәнгате техникумын (1932) тәмамлаганнан соң, Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Лирик героиня рольләрен төп башкаручы; ул аларның эчке тетрәнүләрен, рухи кичерешләрен табигый чагылдыра. Иң әһәмиятле рольләре арасында беркатлы, назлы, чын мәхәббәт хисләрендә янучы Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), эчкерсез, саф күңелле Полина («Төшемле урын», А.Н.Остров-



Г.В. И б р а һ и м о в а  
Сәгыйдә ролендә  
(«Акчарлаклар»,  
Ш.Камал).

ский), үзенең нинди гаебе барлыгын аңлый алмыйча һәлак булган Дездемона («Отелло», У.Шекспир), ягымлы, сабыр холыклы, нәзакәтле Корделия («Король Лир», У.Шекспир), сөйкемле, чибәр Сәлви («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), хәйләкәр, шаян Хафизә («Ефәк сүзәнә», А.Каххар) образлары бар. Хәзерге заман драматургиясе әсәрләре куелышында да күп кенә күренекле, истә калырлык образлар иҗат итә. Алар арасында Мәрьям (Н.Исәнбәтнең шул исем. пьесасы буенча), Маһруй, Хәмдия («Кызыл Йолдыз», «Ак калфак», М.Фәйзи), Сара («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин), Горелова («Диңгездәгеләр өчен», Б.Лавренёв) образлары бар. Аның героинялары кыюлыклары, максатчанлыклары, тыйнаклыклары һәм эчке нәзакәтлелекләре б-н аерылып торалар. Шуннан соңгы елларда И. өлкән яшьтәге героинялар рольләрен башкара. Андыйлардан Туктабикә («Кыз урлау»,



Г.В. Ибраһимова



Г.В.И б р а һ и м о в а Ана ролендә (Ш.Хөсәенов, «Әни килде»).

М.Кәрим), Актүти («Көзге ачы җилләрдә», А.Гыйләҗев), Лариса Даниловна («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Михеевна («Соңгы корбан», А.Н.Островский) образлары игътибарга лаек. Актрисаның иң уңышлы рольләреннән берсе — Ш.Хөсәеновның «Әни килде» пьесасы буенча куелган спектакльдә Ана образы. Ул анда зифа буйлы, сабыр, мәһабәт кыяфәтле, балаларын чын йөрәктән яратучы, гаепләрен дә кичерә белүче, шул ук вакытта аларның әхлаксызлыклары, рухи гариплекләре өчен үзен гаепле санап, әчтән газаплanучы Ана образын гәүдәләндерә. И. башкаруында бу образ символик мәгънә ала. Шулай ук күп кенә радиоспектакльләрдә, ш.и. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» (Галия), М.Җәлилнең «Хат ташучы» (Фәйрүзә) әсәрләре буенча куелган тапшыруларда катнаша.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*И.И.Илялова.*

**ИБРАҺИ́МОВА** Галина Камил кызы (29.4.1928, Мамадыш ш.), терапевт, ТАССРның атказ. табибе (1967), СССРның халык табибе (1980). 1949 елда Казан мед. ун-тын тәмамлый һәм Чирмешән р-н хастаханәсендә (Беренче Май р-ны) эшли. 1954 елдан Әлмәт шәһәре хастаханәсендә (1963 тән Әлмәт үзәк хастаханәсе) табиб-венеролог, 1955 тән баш табиб урынбасары, 1957 дән терапия бүлеге мөдире. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ИБРАҺИ́МОВА** Елена Михайловна (9.11.1951, Украина ССРның Ивано-Франковск өлкәсе, Рожнятов р-ны Липовица а.), педагог, пед. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1996). 1976 елда Черновцы ун-тын тәмамлый. 1980 нән СССР ПФАнең Проф.-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). 1989 дан Казан пед. ун-тында (хәзер Татар гуманитар-пед. ун-ты), 1992–96 елларда пед. каф. мөдире, 2001 дән пед. белем каф. мөдире, шунда ук педагогика һәм хокук фәннәре ф-ты деканы. Өзлексез пед. белем бирү һәм укучыларда пед. белемнәр формалаштыру мәсьәләләре турындагы хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Занимательная педагогика для школьников. К., 1999; Непрерывная педагогическая подготовка учителя: Теорет.-эксперим. иссл. К., 2002; Формирование педагогической культуры у старшеклассников. К., 2002.

**ИБРАҺИ́МОВА** Раиса Николаевна (6.12.1951, Украина ССРның Кировоград өлкәсе Тишковка а.), цирк артисты, жонглёр, хайваннар өйрәтүче, ТАССРның атказ. (1977), РФнең халык (1992) артисты. Казан циркы каршындагы Бөтенсоюз үзәк цирк сәнгате студиясен тәмамлый (1970). 1970–75 елларда Татар цирк коллективында Д.Гыйбадуллин җитәкчелегендәге «Акробат-жонглёрлар төркеме»ндә эшли. 1975 тән Союзгосцирк (хәзер Росгосцирк) системасында, Г.Е.*Ибраһимов* б-н бергәләп «Аюлар бенефисы» (1987 дән «Чалыш аяклар грациясе» — «Косолапая грация») номерында хайваннар өйрәтүче артист буларак катнаша. Үзенчәлекле бу номерда күп кенә катлаулы трюклар бар. Халыкара цирк сәнгате фестивале (Гавана, 1981), Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале (Мәскәү, 1985) лауреаты.

*Әд.:* Д м и т р и е в Ю. На фестивале в Гаване // Советская эстрада и цирк. 1981. № 12.

**ИБРАҺИ́МОВА** (Таишева) Рима Мөбарәк кызы (15.7.1950, Балтач р-ны Түбән Кенә а.), җырчы, ТАССРның халык артисты (1984). Бөтенроссия эстрада студиясендә Г.Виноградовтан белем ала. 1979 елда Казан музыка уч-щесен тәмамлый. 1969–94 тә Татар филармониясе солисткасы. 1998 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Татар халык һәм эстрада җырларын популяр башкаручы. Җырчының репертуарына халык җырларыннан «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Су буйлап», «Сибелә чәчәк», «Салкын чишмә» һ.б., татар композиторлары әсәрләре керә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1987). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИБРАҺИ́МОВА** Рокыя Габдерәхим кызы (20.1.1913, Казан — 28.4.1998, шунда ук), баянчы. 1934–60 елларда татар драма театрларында аккомпаниатор (1941 дән Татар акад. театрында). 1960–68 дә Татар филармониясендә солист-башкаручы. Россия, Урта Азия, Финляндиянең татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә зур концерт эшчәнлеге алып бара. Татар муз. фольклорын җыю һәм аны пропагандалау б-н шөгыльләнә. Баян өчен әсәрләр һәм җырлар авторы.


**ИБРАҺИ́МОВА** Саимә Ибраһим кызы (1.3.1928, Сарман р-ны Зур Нөркәй а.), журналист, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1974). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1954 елга кадәр мәктәптә укыта, шуннан соң Татарстан китап нәшриятында (1954–57), «Азат хатын» ж-лында (1957–60), «Яшь ленинчы» (1960–83), «Дөнья» (1992–95), «Мәдәни җомга» (1995–97) г-таларында, «Сөембикә» (1998–2006) ж-лында эшли. Рус теленнән татар теленә Р.Л.Стивенсонның «Хәзинәләр атавы» романын («Остров сокровищ», 1971), Я.Козакның «Марьяна Радвакова» (1965), С.Григорьевның «Александр Суворов» (1975) повестьларын, А.П.Чехов, А.Зегерс, А.Гайдар хикәяләрен һәм повестьларын; татар теленнән рус теленә Д.Аппакова хикәяләрен (1957) тәрҗемә итә. Казан ханбикәсе Сөембикә турында «Сөембикә ханбикә» исемле китапның (2001) төзүчесе.

*Әд.:* А х у н җ а н о в Г. Җыйнак, табигый тел белән // Казан утлары. 1976. № 4; Т у ф и т у л о в а Р. Саимә Ибраһимовага — 70 яшь // Сөембикә. 1998. № 3.

**ИБРАҺИ́МОВА** Фатыйма Исхак кызы (15.3.1928, Бөгелмә кантоны, хәзерге Лениногорск р-ны Кирлегәч а.), әдәбият галиме, текстолог, филол. фән. канд. (1969), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1952). 1962 елга кадәр урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1965–2000 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. М.Җәлил (т. 1–4, 1975–76), Г.Камал (т. 1–3, 1978–81) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша; М.Гафури (т. 1, 1980; т. 4, 1988), Ф.Әмирхан (т. 1, 1984), Г.Ибраһимов (т. 9, 2000), Г.Исхакый (т. 8, 2001) әсәрләренең аерым томнарын басмага әзерли. «Балалар әдәбияты» (2004) хрестоматиясен төзүче. Хезмәтләре татар балалар әдәбияты тарихына, 20 йөз башы татар язучыларының әдәби мирасына карый.

Х е з м.: Заман белән бергә. К., 1971; Сабыйларны үз итеп. К., 1998; Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. К., 2003 (автордаш).

**И́БУШЕВ** Георгий Мефодьевич (20.10.1957, Мамадыш р-ны Владимир а.), җырчы (лирик тенор), ТРның халык артисты (2000). Татар милләтеннән. 1985 елда Казан консерваториясен (М.Кольцов һәм Ә.Заһидуллина классы) тәмамлый. 1985 тән Татар филармониясе солисты. Җырчының тавыш тембры йомшаклыгы, башкару манерасының лирик үзенчәлеге б-н аерыла. И.ның репертуарында татар, рус һәм чит ил композитор-



Г.М.Ибушев.

лары операларыннан ариялəр, романслар, җырлар, татар халык җырлары бар. И. тарафыннан башкарылган татар халык җырлары «Әллүки», «Тəфтилəү», «Су буйлап»; Ж.Фəйзинең «Урман кызы» (Х.Такташ шигыре), С.Сəйдəшевнең «Кандыр турында җыр» (К.Тинчуринның «Кандыр буе» пьесасыннан), Р.Яхинның «Китмə, сандугач» (Г.Зəйнашева шигыре), Ф.Әхмəтовның «Күрешербез əле» (Р.Харис шигыре), М.Макаровның «Көзге романс» (Н.Нəҗми шигыре) һ.б. вокаль əсəрлəр; А.Ключарёв, Р.Яхин, А.Монасыйпов, М.Шəмсетдинова, Л.Батыр-Болгари, М.Макаров һ.б. җырлары халык арасында һəрвакыт зур популярлык казана. Җырчы опера ариялəрен дə зур осталык б-н башкара: Ленский ариозосы («Евгений Онегин», П.Чайковский), Надир романсы («Энҗе эзлəүчелəр», Ж.Бизе), Герцог җыры («Риголетто», Дж.Верди); М.Глинка, С.Рахманинов романслары һ.б. Халык җырларын башкаручыларның Бөтенроссия конкурсы дипломанты (Краснодар, 1985), Бөтенсоюз «Татар җыры» конкурсы лауреаты (Казан, 1989).

Ә с ə р.: Рəхмəт сиңа, җыр. К., 2007.

*Әд.:* Ф ə й з у л л и н Р. Җырчы шагыйрь // Казан утлары. 2005. № 5.


*Ф.Ш.Салитова.*

**ИВА́Н III** Васильевич (22.1.1440, Мəскəү — 27.10.1505, шунда ук), Мəскəү кенəзлегенең бөек кенəзе (1462 елдан). Василий II нең улы. 1450 дəн чыганакларда əтисенең идарəдəше буларак искə алына. И. III идарə иткəн елларда элек формаль яктан бəйсез булган рус кенəзлеклəре кушыла, гомумрус дəүлəтчелеге ныгытыла һəм бөекдержавачыл идеология формалаштырыла. Ул Ярославль (1463), Ростов (1474), Тверь (1485) кенəзлеклəрен, Новгород респ-касын (1478), Вятка җирен (1489) буйсындыра. Актив тышкы сəясəт алып бара. Казан ханлыгы б-н сугыша (1467–69, 1478). 1487 дə, озак камап торганнан соң, Казанны яулап ала, тəхеткə *Мөхəммəдəмин ханны* утырта. Үзен «Болгар кенəзе» дип игълан итə. 1492–94 һəм 1500–03 елларда Бөек Литва кенəзлеге б-н сугышлар алып бару нəтиҗəсендə Брянск, Вязьма, Чернигов һ.б. җирлəрне Мəскəүгə куша. Олы Урда б-н сугыш алып бара: 1480 дə Әхмəд ханга каршы яу оештыра (к. «*Угра буенда капма-каршы тору*»). И. III идарə иткəн чорда удел кенəзлəренең мөстəкыйльлек хокукларын чиклəү көчəя, хезмəттəге дворяннар катлавы үсə. Бер үк вакытта «Мəскəү — Өченче Рим» дигəн идея нигезендə державачыл идеология формалаштырыла, И. III нең улы Дмитрийга, Византия даны варисы буларак, «патша» таҗы кидерелə. Моңа 1472 дə И. III нең Византия императоры бертуганының кызы Зоя (Софья) Палеологка өйлəнүе булышлык итə. И. III дəүлəтнең чиркəүгə йогынтысын көчəйтə. Аның заманында суд реформасы үткəрелə (1479); Кремльне, аның храмнарын һəм Грановитая палатаны төзү эшлəре алып барыла.

*Әд.:* Б а з и л е в и ч К.В. Внешняя политика Русского централизованного государства. 2-я половина XV века. М., 1952; З и м и н А.А. Россия на рубеже XV–XVI столетий. М., 1982; А л е к с е е в Ю.Г. Государь всея Руси. Новосиб., 1991.

*И.Л.Измайлов.*

**ИВА́Н IV ГРО́ЗНЫЙ** (татарларда Явыз Иван, Мөдһиш Иван) (25.8.1530, Коломенский а. — 18.3.1584, Мəскəү), «бөтен Русьның» бөек кенəзе (1533 елдан), беренче рус патшасы (1547 дəн). *Василий III* нең улы. 1549–60 елларда хөкүмəт — чынлыкта А.Ф.*Адашев* җитəклəгəн Сайланган Рада катнашында идарə итə. Бу чорда үзəк һəм җирле идарə, армия, хокук һ.б. өлкəлəрдə реформалар уздырыла («ашатулар» системасы бетерелə, Губа реформасы (губа — 16–17 йөзлəрдə Рус дəүлəтендə терр. округ) төгəллəнə, Земство реформасы үткəрелə, 1550 дə Судебник (мəхкəмə кануннары җыелмасы) булдырыла, мөһим приказлар (идарəлəр) оештырыла, даими стрелецлар гаскəрлəре төзелə һ.б.). И. IV сəяси дошманнарын рəхимсез



җəзалый, 1565 тə опричнина кертə (1572 дə гамəлдəн чыгара). Ул идарə иткəн заманда крепостной изү көчəя (крəстияннəрнең Юрий көнендə ирекка чыгу хокукы бер көн б-н чиклəнə, 1570 тəн бөтенлəй бетерелə). 1545 тəн Казан ханлыгы б-н сугышлар башлап җибəрə (к. *Казанга Рус дəүлəте яулары*). Аның 1545, 1547–48, 1549–50 еллардагы яулары уңышсыз тəмамлана. 1551 дə Казан ханлыгыннан Тау ягын аерып ала, Зөя шəһəренə нигез сала. 1552 нең 2 октябрендə көчле штурмнан соң (сугышлар 41 көн дəвам итə), аның гаскəрлəре Казанны яулап ала (к. *Казанның яулап алынуы*). Елъязмаларда əйтелгəнчə, И. IV боерыгы нигезендə шəһəрдəге ир-атлар юк ителə, Казан рус сугышчыларына талауга бирелə («... повеле царь ... ратных... избити всех...», «... многая сокровища казанская велел всему своему воинству имати...»). И. IV төбəк халкын үз ягына җəлеп итəргə тырыша: «кыңгыр эшлəр кылган» «ясаклы кара кешелəргə» ирек игълан итə, алына торган ясакның элекке нормаларын гамəлдə калдыра. И. IV Казаннан киткəч, төбəктə башланган күтəрелеш җəза отрядлары тарафыннан рəхимсез төстə бастырыла (к. *Казан җирлəрендə азатлык сугышлары*). Россия дəүлəте терр-ясен киңəйтүне дəвам иттереп, 1556 да И. IV Әстерхан ханлыгын яулап ала. 1570–80 елларда җирле халыкны бастыру өчен гаскəрлəрен яңадан Казан төбəгенə җибəрə (к. *Казан ханлыгы яулангaннан соңгы фетнə-чуалышлар*). Элеккеге Казан ханлыгы билəмəлəре б-н идарə итү өчен И. IV заманында *Казан сарай идарəханəсе* оештырыла, *воевода идарəсе* кертелə, төбəкнең Казан, Зөя һ.б. шəһəрлəренə рус наместниклары һəм воеводалары билгелəнə. И. IV яулаган җиңү нəтиҗəсендə русларның Урта Идел буен колониялəштерүенə юл ачыла, Чабаксар (1555), Тəтеш (1558), Кокшайск (1574), Козьмодемьянск (1583) һ.б. шəһəр-кирмəннəргə нигез салына. И. IV басып алынган җирлəрдəге халыкларны (аеруча татарларны) христианлаштыруга зур əһəмият бирə. Казан яулап алынганнан соң, мəчетлəр җимертелə, əсир ителгəн казанлылар, ш.и. Ядегəр Мөхəммəд хан чукындырыла. И. IV заманында Казан епархиясе оештырыла (1555), беренче архиепископ Гурий И.IV тəн Күрсəтмə (к. *Иван IV нең Казан архиепископы Гурийга җибəргəн күрсəтмəсе*) ала, анда Идел буе халыкларын христианлаштыру турында əмер бирелə. 1558–83 тə Балтыйк диңгезенə чыгу өчен Ливон сугышы алып бара, анда татар сугышчылары отрядлары да катнаша.

*Әд.:* В и п п е р Р.Ю. Иван Грозный. М.–Л., 1944; З и м и н А.А. Реформы Ивана Грозного. М., 1960; ш у л у к. Опричнина Ивана Грозного. М., 1964; Ш м и д т С.О. Становление российского самодержавства. М., 1973; С к р ы н н и к о в Р.Г. Иван Грозный. М., 1975; Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. К., 1982; К о б р и н В.Б. Иван Грозный. М., 1989; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

*И.Р.Вəлиуллин.*

**ИВА́Н IV НЕҢ КАЗА́Н АРХИЕПИ́СКОБЫ ГУ́РИЙГА ҖИБƏРГƏ́Н КҮРСƏТМƏСЕ́**, Россия тарихында рус булмаган халыкларны *христианлаштыру* буенча беренче күрсəтмə (1555). Казан ханлыгын яулаганнан соң, православие чиркəве анда актив миссионерлык эшчəнлеге җəелдерə. Җирле мөселман һəм мəҗүси халыкларны христианлаштыру аларда күндəмлек формалаштырырга һəм идеологик яктан яңа хакимиятлəргə буйсындырырга ярдəм итəргə тиеш була. Шундый максат б-н 1555 елда архиепископ *Гурий* җитəкчелегендə *Казан епархиясе* төзелə. Гурий Иван IV тəн һəм митрополит Макарийдан күрсəтмə ала, күрсəтмəдə Казан төбəгендə миссионерлык эшен оештыру буенча конкрет бурычлар куела. Бу тəкъдимнəр, мөгаен, элеккеге Казан ханлыгы терр-ясендə азатлык хəрəкəте барган шартларда (к. *Казан җирлəрендə азатлык сугышлары*) җирле халыклар б-н мөнəсəбəтлəр кору тəҗрибəсен истə тоткандыр. Дини өлкəдə алар б-н катгый каршылыкка керү нəтиҗəсендə җирле халыкның буйсынмавы көчəймəсен һəм төбəктəге хəл тискəре якка үзгəрмəсен өчен, күрсəтмə православие диненə ирекле рəвештə күндерергə чакыра. Шуңа күрə татарларга карата «тыныч, ягымлы мөгамəлəдə, кырыс һəм тупас сөйлəшмичə генə», «басынкылык» б-н эш итəргə, «аларны куркытып түгел, бəлки инандырып чукынырга ризалатырга» кушыла. Чукынганнан соң, аларның «иң яхшылары» Архиерей йорты карамагына күчəргə тиеш була. Татарларның бер өлешен чукындыру өчен монастырьлар-

га «өләшергә» фәрман бирелә. Яңа чукындырылганнар, ш.у. мөселман татарлар үтенечләр б-н архиепископка мөрәҗәгать иткән очракта архиепископ аларны табын янына чакырырга, «квас» һәм «бал» б-н сыйларга тиеш, диелә. Күрсәтмәдә гаепләре булып, хакимиятләр «җәзасы»ннан Гурий янына качкан татарлар арасында да миссионерлык эше алып барырга кушыла. Әгәр дә андый татарлар чукынырга теләк белдерсәләр, аларны архиепископ янында калдырырга, хакимиятләргә тапшырмаска рөхсәт ителә; яңа чукындырылганнарны Казанда яшәтү, «хыянәт иткән» очракта Мәскәүгә озату карала. Гурийга ш.у. башка татарларның үтенече буенча хакимиятләр тарафыннан хөкем ителгән татарларны якларга, «гозерләре булмаса да», аларны хакларга тәкъдим ителә. Мөселманнарның ирекле рәвештә православиягә күчүләренә өмет баглау акланмый, бу исә 16 йөз ахырында Идел буе халыкларын ирексезләп христианлаштыруның көчәюенә китерә (к. *Патша Фёдор Иванович фәрманы*). Төбәктә миссионерлык эше оештырудан тыш, Гурий, үгет-нәсыйхәтләр, тыюлар, патшага мөрәҗәгать итүләр юлы б-н, җирле халыклар («төрле кешеләр») тарафыннан, иң элек воеводалар һәм «бояр уллары» ягыннан «хрестьян канунына» карата «әдәпсезлек» күрсәтүләргә юл куймаска тиеш була. Гурийга зур вәкаләтләр бирелә: дини эшләрне хәл иткәндә өстенлек; воеводалар б-н бергәләп дәүләт эшләрен тикшерү; кайбер очракларда (әгәр дә «шәһәрдә тәртипсезлек хөкем сөрсә») дөньяви хакимият эшчәнлегенә тыгылу.

Чыг.: Акты, собранные в библиотеках и архивах Российской империи Археологической экспедицией Императорской Академии наук. СПб, 1836. Т. 1, № 241.

*Әд.:* З а г и д у л л и н И.К. Христианизация татар Среднего Поволжья во второй половине XVI–XVII вв. // Уч. зап. Татар. гос. гуманитарного ин-та. 1997. № 1; Н о г м а н о в А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002. *И.Р.Вәлиуллин.*

**ИВА́Н (ИОА́НН) МӘЙДАНЫ́**, к. *Беренче Май мәйданы.*

**ИВАНА́ЕВО** (Туплат) авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 189 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1714 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә, 20 йөз башында И.да чиркәү-приход мәктәбе, 2 су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 792 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 327, 1897 дә — 642, 1908 дә — 819, 1920 дә — 753, 1926 да — 742, 1938 дә — 727, 1949 да — 576, 1958 дә — 458, 1970 тә — 509, 1989 да — 307, 2002 дә — 229 кеше.

**ИВА́НИЧЕВ** Георгий Александрович (10.4.1946, Чуаш АССРның Шумерле р-ны Икенче Ялдры а.), невропатолог, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1989), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997, 2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Я.Ю.*Попелянский* шәкерте. 1970 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли (бүленеп, 1972–75 елларда Республика клиник хастаханәсендә), 1988 дән рефлексотерапия каф. мөдире. 1996 дан Казан мед. академиясенең невропатология һәм рефлексотерапия каф. мөдире. Хезмәтләре мануаль терапиягә, мускул авыртуы синдромнарына карый. И. неврологик авыруларда арка баганасы полисинаптик рефлексын тасвирлый, аның диагностик әһәмиятен билгели, мимик мускуллар һәм кәкре муен контрактурасын дәвалауның үзенчәлекле ысулын тәкъдим итә, акупунктура эффектларын гамәлгә ашыруда сенсорлы тәэсир итешү концепциясен үстерә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Мануальная медицина. М., 1998; Мануальная терапия. М., 2001.

**ИВАНО́В** Александр Изосимович (11.2.1946, БАССРның Уфа р-ны Шәмәк а.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), РФнең атказ. геологы (1993), РФ Ягулык энергетикасы министрлыгының атказ. хезмәткәре (1996). Пермь политехник ин-тын тәмамлый (1972). 1967–85, 1989–2000 елларда «Татнефть» АҖнең «Баулынефть» НГДУында эшли: геолог, скважиналарны капиталь ремонтлау цехында катлаулы эшләр буенча инженер, өлкән инженер, лаб. җитәкчесе; 1989 дан баш геолог һәм бер үк вакытта НГДУ җитәкчесе урынбасары. 1985–89 да «Татнефть» АҖнең «Урьевнефть» НГДУында тикшерү-өйрәнүләр бүлеге җитәкчесе, баш геолог, бер үк вакытта җитәкче урынбасары. 2000 елдан Мәскәүдә эшли. Дәүләт бүләге «Аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүнең термоимплозион һәм перфорацияле имплозион яңа экспресс-технологияләрен эшләү һәм киң масштабта кулланышка кертү» дигән хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геологическое строение и разработка Бавлинского нефтяного месторождения. М., 1966 (автордаш); Построение и применение карт текущей нефтенасыщенности пластов на месторождениях Республики Татарстан. Альметьевск, 1993 (автордаш); Экспериментальная разработка Бавлинского месторождения // Нефтяное хоз-во. 1996. № 12.

**ИВАНО́В** Анатолий Александрович (24.1.1938, Ростов өлкәсенең хәзерге Белокалитвинский р-ны Түбән Серебряковский хуторы), тарихчы, тарих фән. д-ры (2002), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1965). 1967–71 елларда ВЛКСМның, 1974 тән КПССның Татарстан өлкә ком-тларында. 1989–94 тә «*Хәтер китабы*» редакциясендә мөхәррир, 1994 тән баш мөхәррир. Бер үк вакытта 2002 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының тарих һәм культурология каф. профессоры. Бөек Ватан сугышы елларында хәбәрсез югалганнарга һәм һәлак булганнарга, сәяси репрессия корбаннарына багышланган күптомлы басмаларның баш мөхәррире. «Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында (1941–1945)» — «Татарстан в годы Великой Отечественной войны (1941–1945)» китабын (2000, 2009) һәм «Татарстан тарихы» дәреслеген (2001, 2006, 2009) төзүче-авторларның берсе. ТР Дәүләт бүләге күптомлы «Хәтер»–«Память» китабын әзерләп чыгаруга керткән хезмәтләре өчен бирелә (2000). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Боевые потери народов Татарстана в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. К., 1998; Авиаторы Татарстана в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. К., 2000; Боевые крылья Татарстана. К., 2005.

**ИВАНО́В** Анатолий Васильевич (16.3.1939, Чуаш АССРның Ибреси р-ны Андрюшево а.), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1999), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1996). 1967 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Түбән Кама шәһәрендә сан.-эпид. станциясе табибе. 1969 дан Казан мед. ун-тында, 1995 тән гигиена, хезмәт медицинасы каф. мөдире. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитне сәламәтләндерү чараларын эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә карый.

Х е з м.: Концепция экологического мониторинга Республики Татарстан. К., 1993; Мониторинг природной среды при разработке битумных залежей. К., 1995 (автордаш); Техногенез и экологический мониторинг юго-востока Республики Татарстан. К., 1995.

**ИВАНО́В** Аркадий Васильевич (4.4.1950, Чистай р-ны, Югары Кондрата а.), вет. терапевты, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2000), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1990), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан вет. ин-тын (1976), КПСС ҮКның Югары партия мәктәбен (Саратов ш., 1979) тәмамлый. 1979–80 елларда Яшел Үзән р-ны «Майский» с-зында партком секретаре. 1980–98 дә Казан вет. академиясенең тәҗрибә хуҗалыгы директоры, бер үк вакытта терапия кафедрасында каф. профессоры. 1998–2004 тә ТР МКнда Баш ветеринария идарәсе башлыгы. 2004 тән «Бөтенроссия фәнни-тикшеренү ветеринария институты» федераль фәнни учреждениесе (Казан) директоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: а.х. терлекләрендә бруцеллёз авыруына каршы профилактика үткәрү һәм дәвалау ысулларын эшләүгә, а.х. терлекләре пестицидлар б-н агуланганда диагноз кую һәм аеруча куркыныч, йогышлы авыруларга профилактика һәм дәвалау чараларын эшләүгә карый. 8 монография, ветеринариягә караган норматив документлар эшләүдә 15 тәкъдим авторы. ТР ФАнең К.Г.Боль исем. бүләге лауреаты (2001). Уйлап табуга 18 патенты бар. ТРның Мактау грамотасы, медаль б-н бүләкләнә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты.

Х е з м.: Инфекционные болезни свиней (этиология, эпизоотология, диагностика, профилактика). М., 2006 (автордаш); Методические рекомендации по диагностике, лечению и профилактике отравлений животных хлор- и фосфороорганиче-

скими пестицидами. М., 2007 (автордаш); Микотоксикозы сельскохозяйственных животных. М., 2008 (автордаш); Радиовакцины: проблемы и перспективы. К., 2008 (автордаш); Радиоэкотоксикологическая микробиология. М., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.) К., 2006.

**ИВАНО́В** Борис Евгеньевич (31.12.1929, Казан — 8.9.2000, шунда ук), химик-органик, химия фән. д-ры (1970), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1955–60 елларда Ижевск механика ин-тында эшли, гомуми химия каф. мөдире (1956 дан). 1960–97 дә РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, полимерлар химиясе лаб-ясе мөдире (1964 тән), проф. 1972). 1997 дән Казан технол. ун-ты каршындагы Эластомерлар әзерләү үзәгендә баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре элементорганик һәм югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. Диен кушылмаларының оксидлашуын тикшерә. Алюминийны һәм аның эретмәләрен электрохимик металлау ысулын эшли. Күп кенә электрофиль реагентлар кертү-катнаштыру юлы б-н Арбузов төркемләүләренең чикләрен киңәйтү мөмкинлеген өйрәнә. Төрле функциональ төркемле фосфорорганик кушылмаларны синтезлый. Арбузов реакциясендәге арадаш продуктларны ачыклый, өч валентлы фосфор кушылмаларының амбидентлыгын һәм реакциягә ике төрле керә алуын өйрәнә. Фосфорның моно- һәм дивинил кушылмалары радикаль полимерлашу теориясен төзи, югары молекуляр фосфорлы полимерлар ала, аларның фән һәм техниканың күп кенә өлкәләрендә кулланылу мөмкинлеген өйрәнә. Янмаучан полимерлар һәм композицияләрне гамәли әзерләүгә һәм теориясен төзүгә өлеш кертә. Элементлы фосфор катнашындагы реакцияләрне системалы өйрәнү И.ка аларның механизмнары үзенчәлеген ачыкларга һәм беренче мәртәбә гипофосфитлар, диалкилфосфитларның һәм дитиофосфатларның кушылмаларын алуның югары селектив, экологик хәвефсез ысулларын эшләргә мөмкинлек бирә. Оксиэтилендифосфон кислотасын алу ысулы («Химпром» җитештерү берләшмәсендә, Волгоград ш.), җепсел полиэфир термостабилизаторлары («Химволокно» җитештерү берләшмәсе, Могилёв ш.), «фенол сумаласы»ннан файдалану алымы («Органик синтез» җитештерү берләшмәсе, Казан), изопрен һәм стиролны ингибирлауның яңа ысулы эшләнә һәм гамәлгә кертелә (башкалар б-н бергәләп). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реакционная способность производных трёхвалентного фосфора // Успехи химии. 1970. Т. 39, вып. 5 (автордаш); Радикальная сополимеризация моновинильных производных фосфора // Высокомолекулярные соединения. 1975. Т. 17 (А), № 4 (автордаш); Белый фосфор и его реакции в условиях нуклеофильного катализа // Журн. общей химии. 1993, Т. 63, вып. 12 (автордаш).

**ИВАНО́В** Борис Николаевич (9.4.1949, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2001), проф. (2008). 1971 елда Казан химия технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 2002 елдан гомуми химия технологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре аз куеручан дизель ягулыгы, югары сыйфатлы сыек парафиннар һәм аларның кислородлы кушылмаларын алуга, нефть әзерләү һәм нефть эшкәртү процессларын аналитик модельләштерүгә, традицион булмаган технологик алымнар куллануга карый. Нефть-су системаларының югары ешлыклы кырлар б-н структуралаштырылуын исбатлый. Углеводород гомологларын башка класс углеводородлар катнашмасы б-н аеруның җиңелрәк икәнлеген күрсәтә. Карбамидлы парафинсызлау процессында карбамид-парафин комплексының һәм активатор-эреткечләр классының үзенчәлекле төзелешен ачыклый. Парафиннар оксидлашу процессларының пульсацияле, импульслы һәм вакуумлы режимнарын эшли. Табигать белемендәге кайбер мөһим төшенчәләрнең мәгънәләрен аңлатып бирә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Модернизация процессов окисления парафинов // Нефтепереработка и нефтехимия. 2000. № 3–4 (автордаш); Волновая природа процессов генезиса, добычи и подготовки нефти // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2008. № 3–5 (автордаш); Общий базис процессов и средств стимуляции добычи и подготовки нефти // Нефтепереработка и нефтехимия. 2008. № 11 (автордаш).

**ИВАНО́В** Василий Григорьевич (1.7.1950, Краснодар краеның Гулькевичи р-ны Воздвиженский хуторы), педагог, химик-технолог, техник фән. канд. (1986), пед. фән. д-ры (1997), проф. (1993), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1976 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1982–89 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-тында). 1989 дан проректор, 1996 дан беренче проректор, бер үк вакытта 1995 тән югары һөнәри белем бирү методикасы һәм пед. каф. мөдире, 1998 дән Өстәмә һөнәри белем бирү ин-ты директоры. Хезмәтләре химия-технол. системалары теориясенә, инженерлык белеме бирүдә кадрлар б-н тәэмин итү проблемаларына, инженерлар һәм фәнни кадрларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Синтез ХТС. Подсистема выделения целевого продукта. К., 1993; Введение в теорию химико-технологических систем. К., 1997 (автордаш); Проектирование содержания профессионально-педагогической подготовки преподавателей высшей технической школы. К., 1997.

**ИВАНО́В** Василий Николаевич (1.1.1933, Питрәч р-ны Крутоовражка а.), төзүче, ТССРның, РФнең атказ. төзүчесе (1991, 1992). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1978). 1955–61 елларда Донецк өлкәсенең төзелеш оешмаларында. 1961–94 тә Казан эре панельле йортлар төзү комб-тында: 7 нче төзү-монтаж идарәсе участогы, 2 нче механикалаштырылган эшләр идарәсе, 7 нче һәм 4 нче төзү-монтаж идарәләре башлыгы, директоры (1979 дан). 1994 тән «Жилсервис» АҖнең ген. директоры. Татарстанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә мөһим сәнәгать һәм мәдәни-көнкүреш объектлары төзелешләренә, яңа төзелеш технологияләре үсешенә зур өлеш кертә. И. җитәкчелегендә 3860 мең $м^2$ чамасы торак, 10 мәктәп, 18 балалар бакчасы, 2 хастаханә, а.х. объектлары төзелә. 1988 елдагы җир тетрәүдән соң Спитак шәһәрен (Әрмәнстан) торгызуда катнаша. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИВАНО́В** Виктор Алексеевич (12.9.1942, Киров өлкәсенең Килмез р-ны Зеквай а.), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1984), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлый, СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында эшли. 1983 тән Казан технол. ун-тында машиналар белеме, машиналар төзелеше технологиясе һәм стандартлаштыру каф. мөдире, проф. (1985). Хезмәтләре сүрүләр һәм пластиналарның әйләнә-тирә мохит б-н үзара тәэсирләшү теориясенә һәм механика мәсьәләләрен аналитик ысуллар б-н чишүгә карый. И. рәвеше үзгәрүчән каты җисем механикасы өлкәсендә сүрүләрнең һәм алар б-н тәэсирләшүче әйләнә-тирә мохитнең ныклыгы, тотрыклылыгы, тирбәнүләре теориясен төзи һәм мәсьәләләр чишү ысулын эшли.

Х е з м.: Прочность, устойчивость и динамика оболочек с упругим заполнителем. М., 1977; Расчёт оболочек с упругим заполнителем. М., 1987.

**ИВАНО́В** Виктор Николаевич (25.1.1928, Арча кантоны Крутоовражка а. — 22.3.2000, Мәскәү), сәнәгать җитештерүен оештыручы, икътисад фән. канд. (1975). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1954). 1949–66 елларда Казан авиация з-дында мастер, инженер, цех башлыгы, баш инженер урынбасары. 1966–79 да Казан электрон хисаплау машиналары з-ды директоры. И. җитәкчелегендә пр-тие яңартып корыла, күп кенә конструкторлык һәм технология мәсьәләләре хәл ителә, нәтиҗәдә электрон хисаплау машиналарының берничә буынын кыска вакыт эчендә серияләп чыгару мөмкин була. 1979–88 дә СССР Радио сәнәгате министрлыгының Баш идарәсе башлыгы, 1988–94 елларда «Персей» ФҖБ ген. директоры (Мәскәү). Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выпускники — гордость университета: Краткий биогр. справ. / КАИ. К., 2002.

*М.Ш.Бәдретдинова.*

**ИВАНО́В** Владимир Васильевич (12.4.1939, Чистай р-ны Югары Кондрата а. — 23.10.2004, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1971), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1963–68 елларда Томск ун-тында, 1969–70 тә Казан пед. ин-тында укыта. 1971–76 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире, 1976–80 дә ТАССР мәгариф министры. 1981–85 тә Казан ун-тында, 1985–88 дә Казан пед. ин-тында, 1988 дән Казан финанс-икътисад ин-тының филос. һәм социология каф. мөдире, проф. (1981). ТР ФА Гуманитар фәннәр бүлегенең социология гыйльми советы җитәкчесе (2002 дән).

Хезмәтләре тарих фәне, социаль танып-белү һәм рухи тормыш методологиясенә карый. «Почёт билгесе» ордены, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Соотношение истории и современности как методологическая проблема. М., 1973; Методология исторической науки. М., 1985; Методологические основы исторического познания. К., 1991.

*Әд.:* Академия наук Республики Татарстан. К., 2002.

**ИВАНО́В** Владимир Петрович (30.1.1951, Казан), физик, техник фән. д-ры (2001), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008), проф. (2004), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1973 елда Казан ун-тының геогр. ф-тын тәмамлый. «НПО ГИПО» унитар пр-тиесендә эшли: сектор башлыгы (1987–93), Тәҗрибә з-ды директоры (1993–98), ген. директоры (1998 дән). Бер үк вакытта Казан техник ун-тының оптик-электрон системалар каф. профессоры (1997 дән). Хезмәтләре гамәли оптик атмосфера модельләре эшләүгә, оптоэлектроника һәм тепловидениегә карый. Тепловидениенең эшче спектраль диапазоннарында атмосфера каналын үткәрүнең ихтимальлый моделен ясый. Дөньяда беренче мәртәбә руда карьерларындагы газ-тузан режимын оператив тикшерү аппаратурасы төзи һәм җитештерүгә кертә. Җир тропосферасының оптик-геофизик моделен ясый. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар. СССР ФАнең акад. С.И.Вавилов исем. бүләге лауреаты (1980, 1982). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Динамика оптической погоды. К., 1986 (автордаш); Моделирование распределения прозрачности атмосферы в ближней инфракрасной области спектра // Оптика атмосферы. 1990. Т. 3, № 8 (автордаш); Основы теории анализа и синтеза воздушной тепловизионной аппаратуры. К., 2000 (автордаш); Прикладная оптика атмосферы в тепловидении. К., 2000; Современная оптоэлектроника. К., 2002 (автордаш).

**ИВАНО́В** Владимир Степанович (29.9.1917, Казан — 7.8.1993, шунда ук), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан коммуналь хуҗалык инженерлары ин-тын (1941), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1958) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 елдан «Серго исем. завод»та (Зеленодольск ш.): баш инженер (1949 га кадәр), капиталь төзелеш бүлеге башлыгы (1949–50), КПСС ҮК парторгы (1950–54), партком секретаре (1954–56). 1958–63 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире. 1963–66 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР МСның Партия-дәүләт контроле ком-ты рәисе урынбасары. 1966–80 дә ТАССРның торак-коммуналь хуҗалык министры. 1959–80 елларда ТАССР ЮС депутаты. Октябрь революциясе, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**ИВАНО́В** Вячеслав Осипович (27.2.1930, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1991). 1957 елда Ленинград киноинженерлар ин-тын тәмамлый. 1950–75 тә В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-дында эшли: 1968 дән баш инженер, 1970 тән директор. 1975–94 елларда Казан техфотопроект фәнни-тикшеренү ин-тында: директор, 1987 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре фотография материаллары җитештерүгә карый. Саклаганда югары тотрыклы сенситометрик үзлекле кинофотоплёнкалар җитештерү технологиясенең фәнни нигезләрен эшли. Процессның активлашу энергиясен билгеләү юлы б-н эмульсия катламнарының картаюын тизләтеп сынау ысулын тәкъдим итә. И. җитәкчелегендә күп кенә органик һәм нәорганик кушылмаларның эмульсион катламга тотрыклы тәэсир итү механизмы өйрәнелә, бентонит балчык һ.б. сорбентлар ярдәмендә желатинны йоттырып чистарту технологиясе эшләнә. Уйлап табуга 67 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу о стабильности фотографических эмульсий // Успехи науч. фотографии. 1970. Т. 14 (автордаш); Процессы старения и сохраняемость фотографических материалов. Л., 1976 (автордаш); Кинетика и энергия активации старения эмульсионных слоёв в условиях термического и химического разрушения центров чувствительности // Журн. науч. и прикладной фотографии и кинематографии. 1987. Т. 32, № 2 (автордаш).

**ИВАНО́В** Иван Дмитриевич (1864–1917 дән соң), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән килгән мактаулы граждан. Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре булган әтисе эшен дәвам иттерә: икмәк-бакалея товарлары б-н сәүдә итә. Капитал туплап, төзелеш материаллары сәнәгый җитештерүдә куллана: Казан өязенең Ометьево (Әмәт) һәм Зур Клыки авылларында 5 кирпеч һәм 1 известь з-ды хуҗасы. Казанда 4 йорты була. 1908–17 елларда Казан шәһәр думасы гласные, 1901–17 дә Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе Исәп-хисап ком-ты әгъзасы. Ярлылар-мохтаҗлар, балалар, халык мәгарифе, православие чиркәве ихтыяҗларына шактый күләмдә акча бирә. 1895 тән императрица Мария Александровнаның Сукырлар хакына попечительлеге Казан бүлекчәсе әгъза-хезмәткәре, 1906 дан балалар ятимханәләренең Казан губерна попечительлеге мактаулы әгъзасы, 1913 тән *Александра исем. балалар ятимханәсе* директоры. Актив җәмәгать һәм иганәчелек эшчәнлеге өчен 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

**ИВАНО́В** Иван Захарович (15.4.1927, Мамадыш кантоны Зур Арташ а.), урман хуҗалыгы инженеры, Соц. Хезмәт Герое (1985), ТАССРның атказ. урманчысы (1977), РФнең атказ. урман сәнәгате хезмәткәре (1985). Мари урман техник ин-тын тәмамлый (1978). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1943–91 елларда Кама урман хуҗалыгында эшли: мастер, бухгалтер, төзүче, урман пункты җитәкчесе (1954 тән), урман хуҗалыгы директоры (1966 дан). Герой исеме урман ресурсларыннан рациональ файдалану һәм яңадан җитештерү эшендә ирешкән казанышлары һәм 11 нче бишьеллык (1981–85) йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәгәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.



И.З. Иванов.

*Әд.:* Ш а л ь н о в С. Если взяться по-хозяйски // Советская Татария. 1978. 3 окт.; Н о в и к о в А. Лесовод — Герой Труда // Лесное хоз-во. 1986. № 5; М о р о з о в Н. А лес растёт // Правда. 1990. 11 янв.; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ИВАНО́В** Иван Филиппович (15.9.1901, Сембер губ., Буа өязе Шеморшы а. — 1972, Мәскәү), нейрогистолог, биол. фән. д-ры (1937), проф. (1937), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1969). 1927 елда Себер вет. ин-тын (Омск ш.) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Троицк (1931–35), Казан (1936–48) вет. ин-тларының, Мәскәү вет. академиясенең (1948–72) гистология кафедралары мөдире. Хезмәтләре ашкайнату юллары нервлары бәйләнешенең цитоархитектоникасына карый. И. тарафыннан ашкайнату юлларындагы кабатланучан иннервациянең морфологик субстраты ачыклана.

Х е з м.: Общая гистология с основами эмбриологии домашних животных. М., 1957; Гистология с основами эмбриологии домашних животных. М., 1962 (автордаш); Цитология, гистология, эмбриология. М., 1969 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ИВАНО́В** Леонид Иванович (1.10.1939, Чуаш АССРның Канаш р-ны Урта Кибәч а. — 16.6.1995, Иваново ш.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1988), проф. (1990). 1964 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, Красноярск крае Новоселово р-нында баш вет. табибе булып эшли. 1968 дән Казан вет. ин-тында, 1989–92 елларда вет. эшен оештыру һәм аның икътисады каф. профессоры. 1992–95 тә Иваново а.х. ин-тының эпизоотология һәм микробиология каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләре авырулары вакытында вет. чараларының икътисади үтемлелеген өйрәнүгә, вет. хезмәткәренең эшен нормалаштыруга, терлекчелек продукциясе җитештерүне интенсивлаштыру шартларында вет. хезмәте б-н идарә итүгә һәм аның икътисадына карый.

Х е з м.: Нормы времени на выполнение ветеринарных работ на животноводческих фермах, комплексах, птицефермах. М., 1984 (автордаш); Рекомендация по планированию противоэпизоотических мероприятий в свиноводческих комплексах. К., 1985 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ИВАНО́В** Мартиниан (Мартемьян) Иванович (1812 — ?), филолог, педагог. Оренбург шәһәрендәге Неплюев кадетлар корпусында укый (1825–31). Гимназия укытучысы хокукына ия булу өчен, Казан ун-тының Көнчыгыш разрядында татар һәм фарсы



Николай Петрович Иванов.



П.А.Иванов.

телләреннән имтихан тапшырганнан соң (1832), Неплюев кадетлар корпусында татар теле укыта, бер үк вакытта Оренбург хәрби губернаторы канцеляриясендә төрки телләрдән тәрҗемәче булып хезмәт итә. Татарча үрнәкләрдән тыш, башкорт һәм казакъ телләреннән дә мисаллар китерелгән «Татар грамматикасы» («Татарская грамматика», 1842), татар халык фольклоры һәм матур әдәбияты әсәрләреннән, рус, башкорт, кыргыз һ.б. телләрдәге тәрҗемәләрдән төзелгән беренче «Татар хрестоматиясе» («Татарская хрестоматия», 1842) авторы. Басмалары РФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-ты С.-Петербург бүлегенең кулъязмалар фондында саклана.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Ю., Садретдинов Ш. XIX йөз татар хрестоматияләре. К., 1982; Краткий очерк истории Оренбургского Неплюевского кадетского корпуса. Оренбург, 1913; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Доoктябрьский период. М., 1989.

**ИВАНО́В** Николай Алексеевич (3.12.1813, Түбән Новгород ш. — 30.3.1869, Дерпт ш.), тарихчы, философ, филос. д-ры (1819), статский советник. Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын (1833), Дерпт профессорлар ин-тын (1839) тәмамлый. 1839 елдан Казан ун-тында: экстраординар проф. (1843 кә кадәр), 1843–55 тә рус тарихы кафедрасында ординар проф.; бер үк вакытта 1847–54 тә — юридик, 1854–55 тә тарих-филол. ф-тлары деканы. 1855–59 да Дерпт ун-тында ординар проф., 1869 да доцент. 1859–66 да Оберпален утарында укытучы, 1866–68 дә Митава гимназиясендә (Курляндия губ.) өлкән укытучы. Гегельнең «рәсми халыкчанлык» фәлсәфәсе һәм теориясе нигезендә рус халкы тарихи үсешенең үзенчәлеге турындагы концепциясе эшли. Ф.В.Булгаринның «Северная пчела» г-тасында хезмәттәшлек итә, анда Н.И.Лобачевский, И.М.Симонов, Ф.И.Эрдман һ.б.ның докладлары турындагы отчетларга нигезләнеп «Казан университеты профессорларының гыйльми җыелышлары» («Учёные собрания профессоров Казанского университета», 1842) исеме б-н мәкаләләр бастыра. Хезмәтләре Россия тарихына, чыганакларны өйрәнүгә, историографиягә карый.

Хезм.: О необходимости содействия философии успехам отечественного просвещения. К., 1843; Краткий обзор русских временников, находящихся в библиотеках санкт-петербургских и московских. К., 1843; Общее понятие о хронографах и описание некоторых списков их. К., 1843.

*Әд.:* Котляревский А. Н.А.Иванов. Некролог // Журн. М-ва нар. просвещения. 1869. Ч. 142; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904): В 2 ч. К., 1904; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ИВАНО́В** Николай Павлович (19.8.1839, Сембер губ., Курмыш өязе Медяны а. — 19.6.1903, Мәскәү), хокук белгече, халыкара хокук магистры (1874), статский советник (1881). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1860), шунда ук эшли: профессор стипендиаты (1863 елга кадәр), приват-доцент (1865–70, 1872–74), доцент (1874–84), халыкара хокук каф. экстраординар профессоры (1884–85). Бер үк вакытта 1864–70 елларда Казанда Икенче ир балалар гимназиясендә укыта. Россиядә халыкара хосусый хокукның фәнни юнәлешенә нигез салучыларның берсе. Халыкара җәмәгать хокукының төп ин-тларын аларның тарихи үсеше яссылыгында тикшерә. Халыкара юрисдикция теориясенә нигез сала, дәүләтләрнең суверенлык принцибын яклап чыга.

Хезм.: Основания частной международной юрисдикции. К., 1865; О значении права войны, в связи с общим понятием о международных отношениях // Уч. зап. Казан. ун-та. 1873. № 9; 1874. № 10; Характеристика международных отношений и международного права в историческом развитии. К., 1874.

*Әд.:* Факультет на котором учился Ленин. К., 1990; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ИВАНО́В** Николай Петрович (15.11.1904, хәзерге Чуаш Респ-касы, Яльчик р-ны Яльчик а. — 27.1.1959, Казан), Сов. Союзы Герое (7.8.1943), полковник (1954). Команда составын камилләштерү курсларын, Ф.Э.Дзержинский исем. Хәрби академия каршындагы Югары офицерлар академиясе курсларын (Мәскәү, 1947) тәмамлый. 1926–27 елларда һәм 1934 тән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 872 нче гаубица артиллериясе полкы командиры (13 нче армиянең 32 нче гаубица артиллериясе бригадасы). Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (икесе дә — 1943), Украинаны (1943–44) һәм Польшаны (1944) азат итүдә, Берлин һәм Прага һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1943 нең 5–6 июлендә Курск сугышы барышында Протасово авылы янында (Орёл өлкәсе Малоархангельск р-ны) батырлык күрсәтә: И. командалыгында полк сугышчылары 2 көн эчендә дошманның 18 танкын, 8 артиллерия һәм миномёт батареясын юк итәләр. Сугыштан соң Совет Армиясендә командирлык вазифалары башкара. 1954 тән запаска җибәрелә, Тәтештә яши. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Суворов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Тәтеш шәһәренең һәм туган авылының бер урамы И. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Наши земляки — Герои Советского Союза. Чебоксары, 1980; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИВАНО́В** Пётр Артемьевич (1909, Казан губ., Тәтеш өязе Чолы а. — 13.4.1944, Украина ССР, Кырым өлкәсе Ашага-Джамин а.), Сов. Союзы Герое (16.5.1944, үлгәннән соң), рядовой. Тәтеш МТСнда эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 91 нче мотоциклет батальоны отделениесе мотоциклчысы (19 нчы танк корпусы). 4 нче Украина фронты гаскәрләре составында Кырымны азат итүдә катнаша. 1944 нең 13 апрелендә Ашага-Джамин авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә; танклы разведка төркеме составында сугышта яраланып, әсирлеккә эләгә һәм үтерелә. Һәлак булганнар истәлегенә Ашага-Джамин авылының исеме Геройский итеп үзгәртелә. Туганнар кабергенә һәйкәл урнаштырыла, Саки шәһәрендә Сигез Герой исемле урам һәм алар хөрмәтенә куелган истәлек ташы бар. Шулай ук Симферополь шәһәрендә дә Геройларга һәйкәл куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои боёв за Крым. Симферополь, 1972; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИВАНО́В** Сергей Николаевич (11.4.1922, Петроград — 5.4.1999, С.-Петербург), әдәбият галиме, тәрҗемәче, филол. фән. д-ры (1969), проф. (1970), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), 1953 елга кадәр Бохара пед. ин-тында, 1953–96 елларда Ленинград ун-тында эшли (1972–88 дә төрки филол. каф. мөдире). Хезмәтләре төрки тел белеменә, тюркология тарихына, төрки классик әдәбият поэтикасына, шигъри тәрҗемә теориясенә карый. Әбелгазый Баһадур ханның «Төркиләр шәҗәрәсе», Й.Баласагуниның «Котадгу белег» («Игелекле белем»), А.Нәвоиның «Лисан ут-тайр» («Кошлар теле») әсәрләрен, үзбәк шагыйрьләре шигырьләрен, Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» («Сказание о Йусуфе») әсәрен, Г.Тукайның «Шүрәле» («Шурале») поэмасын һ.б. әдәби ядкәрләрне өйрәнә һәм рус теленә тәрҗемә итә. Н.Ф.Катановның тормышы һәм иҗаты турындагы китап авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советские тюркологи. М., 1989. Т. 1.

*В.Х.Ганиев.*

**ИВАНО́В** Юрий Сергеевич (6.1.1945, Казан — 26.1.2003, шунда ук), физик, педагог, пед. фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1969 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан моторлар төзү-проектлау бюросында эшли. 1972 дән Казан пед. ин-тының теоретик физика кафедрасында, 1988 дән информатика һәм хисаплау техникасы каф. мөдире. 1998 дән Казан техник ун-тының инженерлык психологиясе һәм пед. кафедрасында. Хезмәтләре когерент нурланышның матдә б-н үзара тәэсир итешүе, компьютерлашты-

рылган укыту теориясе һәм технологиясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Численный анализ задач оптического и акустического сверхизлучения // Световое и звуковое сверхизлучение. К., 1976; Параметрическое моделирование в системах автоматизированного обучения и управления. К., 1994.

**ИВАНО́ВА** Галина Ивановна (1.6.1950, Казан), химик, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2001). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, баш белгеч (1998 дән). Хезмәтләре сыек кристаллы кушылмаларны синтезлауга һәм фәнни тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге парамагнитик сыек кристаллар өлкәсендәге ачышы өчен бирелә.

**ИВАНО́ВА** Минодора Макаровна (1.10.1922, Орёл өлкәсенең, Карачевский р-ны Речица а.), геолог, геол-минерал. фән. д-ры (1974), проф. (1976), РСФСРның мактаулы нефтьчесе (1972), РСФСРның атказ. геологы (1973). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1946). «Дальнефть» берләшмәсенең җитештерү һәм фәнни оешмаларында (1946–50): «Эхаби» (Сахалин) комплекслы нефть промыселында баш геолог; «Татнефть»тә: «Бөгелмәнефть» нефть промыселы идарәсендә баш геолог (1950–60), «ТатНИИнефть»тә директор урынбасары (1960–61). 1962 дән Мәскәүдә: СССР фән һәм техника буенча Дәүләт ком-ты баш белгече; 1965 тән СССР нефть сәнәгате министрлыгының Баш геологик идарәсе башлыгы урынбасары; 1975 тән Мәскәү нефть-химия һәм газ сәнәгате ин-тында промысел геологиясе каф. мөдире, 1991 дән профессор. Кудыру скважиналары системасы ярдәмендә катламнарны кисү юлы б-н су тутыру кулланып, нефть утырмаларын эшкәртүнең яңа системасын эшләүдә катнаша. Нефть чыганакларын эшкәртүне проектлаштыруны камилләштерүгә, катламнарның эчке басымын тикшерүгә һәм идарә итүгә зур өлеш кертә. Ленин бүләге (1962), СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге (1977, 1983) лауреаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефтегазопромысловая геология: Терминол. справ. М., 1983.

*Әд.:* М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России. М.–СПб., 2000.

**ИВАНО́ВА** Раиса Гавриловна (11.7.1922, Чуаш авт. өлкәсенең Мариинский Посад ш. — 21.11.2009, Казан), ботаник-систематик, флора белгече. Казан ун-тын тәмамлый (1946), шунда ук эшли (1991 гә кадәр). Хезмәтләре Татарстан флорасына карый. ТР терр-ясендә үсә торган 1315 югары төзелешле үсемлек төренең исемлеген төзи һәм системалаштыра. И. тарафыннан җыелган гербарийга 20 меңгә якын үсемлек төре кергән. ТРдагы кайбер табигать истәлекләрен (Чатыр Тау, Урдалы Тау, Кликовка сөзәклеге, Коржинский сөзәклеге һ.б.) ботаник яктан сурәтли; «Татарстанның ашарга яраклы кыргый үсемлекләре» («Дикорастущие съедобные растения Татарии», 1987), «Татарстан флорасы буенча сүзлек-белешмәлек» («Словарь-справочник по флоре Татарии», 1988), ТРның Кызыл китабын төзүчеләрнең берсе (1995). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт изучения взаимоотношений между растениями в чистых посевах культурных растений. К., 1964 (автордаш); Определитель растений Татарской АССР. К., 1979 (автордаш).

**ИВА́НОВКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 7 *км* төньяктарак, Казансу елгасыннан 1 *км* читтә. 2008 елда 17 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Башта Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 125, 1949 да — 212, 1958 дә — 89, 1970 тә — 74, 1989 да — 24, 2002 дә — 14 кеше.

**ИВА́НОВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 13 *км* көньяктарак, Бор елгасы буенда. 2008 елда 636 кеше яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чуаш Ивановкасы исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1136 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында И.да 2 су тегермәне, 1879–1915 елларда укырга-язарга өйрәтү мәктәбе эшли. 1929 да «Память Ленина» к-зы төзелә, 1957 дән — «Лениногорский» с-зына, 1967 дән «Октябрьский» с-зына керә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сходнев волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 238, 1889 да — 382, 1897 дә — 397, 1920 дә — 572, 1926 да — 577, 1938 дә — 620, 1949 да — 596, 1958 дә — 498, 1970 тә — 650, 1979 да — 488, 1989 да — 519, 2002 дә — 605 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИВА́НОВКА** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 17 *км* көнбатыштарак, Чөкәнеш елгасының югары агымы буенда. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Чистай кантоны Яңа Чишмә волостена керә. 1930 елның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. 2001 нең 27 июнендә авыллар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1938 дә — 212, 1949 да — 166, 1958 дә — 372, 1970 тә — 157, 1979 — 146, 1989 да — 69 кеше.

**ИВА́НОВКА** (Мокай) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 24 *км* көньяктарак, Салкынсу елгасы (Минзәлә елгасының сул кушылдыгы) бассейнында. 2008 елда 4 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше, тегүчелек, мич чыгару б-н шөгыльләнә, күрше алпавыт утарында ялланып эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 159 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында, 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 217, 1884 тә — 356, 1920 дә — 147, 1926 да — 165, 1938 дә — 192, 1949 да — 172, 1958 дә — 110, 1970 тә — 45, 1979 да — 29, 1989 да — 9, 2002 дә — 7 кеше.



М.М. Иванова.

**ИВА́НОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 10 *км* көньяктарак урнашкан. 2008 елда 87 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1927 дә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 204, 1949 да — 202, 1958 дә — 199, 1970 тә — 169, 1979 да — 156, 1989 да — 107, 2002 дә — 125 кеше.

**ИВА́НОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 11 кеше (чуашлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 202, 1958 дә — 145, 1970 тә — 113, 1979 да — 71, 1989 да — 33, 2002 дә — 12 кеше.

**ИВА́НОВО ӨЛКӘСЕ́**, РФдә, Россиянең Европа өлешендә урнашкан. Үзәге — Иваново шәһәре. 1929 елның 14 гыйнварында төзелә. Мәйданы — 21,4 мең *км*². Халкы — 1148329 кеше (2002), ш.и. 8205 (1989 да — 9910) татар. Татарлар, башлыча, Иваново (5970 кеше), Вичуга (365), Кинешма (425), Родники (356), Тейково (404), Фурманов (400), Шуя (220) шәһәрләрендә, Приволжский р-нында (211) яшиләр. И.ө.ндә татарлар 19 йөзнең 2 нче яртысында төпләнә башлыйлар. Башлыча, алар Идел буе губерналарыннан килеп, туку ф-каларына вакытлыча эшкә ялланган крәстияннәрдән тора. Татарстан һәм Түбән Новгород якларыннан татарларның күпләп күченүе 1921–22 елгы ачлык б-н бәйле. 1920–30 елларда Ивановода татар үзешчән сәнгать түгәрәкләре эшли, кайбер башлангыч мәктәпләрдә татар теле өйрәнелә. 1999 да И.ө. татарларының милли-мәдәни автономиясе (рәисе — Ф.У.Ляпин) төзелә, аңа «Көнчыгыш Шәрекъ» җәмгыяте (1993 тән эшли), «Ак калфак» хатын-кызлар советы, «Нур» татар яшьләре берлеге керә. 1994 тән Ивановоның 4 нче балалар иҗат үзәге каршында татар якшәмбе мәктәбе, «Милләтем» театр студиясе (җитәкчесе — РФнең атказанган артисты М.Б.Кашаев) эшли. 1992 дә шәһәр-

дә «Мәхәллә» мөселман дини җәмгыяте оештырыла, 2003 тә мәчет ачыла. Шулай ук Вичуга, Заволжск, Кинешма, Родники, Тейково, Шуя, Фурманов шәһәрләрендә дә мөселман оешмалары бар. «Сабантуй» милли бәйрәме (Ивановода — 1995 тән, Кинешмада — 2004 тән) үткәрелә. И.ө. б-н ТР арасында тыгыз мәдәни һәм икътисади элемтәләр урнашкан. ТР И.ө.нә йон, медицина җиһазлары, шасси һәм КАМАЗ автомобильләре бирә. «Татарстан — Иваново сәүдә йорты» ассоциациясе оештырыла. Өлкә үзәгенең иҗат коллективлары (драма театры, «Миллләтем» театр студиясе) б-н Әлмәт драма театры, «Казан» Милли мәдәният үзәге, Тәтеш р-ны иҗат коллективлары арасында гастрольләр һәм концерт программалары алмашу җайга салынган.

**ИВА́НОВСКИЙ** посёлогы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2008 елда 80 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Клуб. 1910 елларда нигез салына. Башта Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1922 дән Чистай кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1920 дә — 84, 1926 да — 85, 1938 дә — 128, 1949 да — 128, 1958 дә — 136, 1970 тә — 156, 1979 да — 107, 1989 да — 71, 2002 дә — 85 кеше.

**ИВА́НОВСКИЙ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 54 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2008 елда 4 кеше (руслар) яши. 17 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да волость идарәсе урнаша, Иоанн Златоуст чиркәве (1732 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1882 дә ачыла), тимерчелек, су тегермәне, бакалея, 3 вак-төякләр һәм казна шәраб кибете, 2 сыраханә була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1624 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 884, 1897 дә — 781, 1908 дә — 995, 1920 дә — 841, 1926 да — 548, 1938 дә — 311, 1949 да — 165, 1958 дә — 167, 1970 тә — 84, 1979 да — 38, 1989 да — 20, 2002 дә — 6 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ИВА́НОВСКИЙ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасы буенда. 2008 елда 136 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сумки исеме б-н дә мәгълүм. Башта И. Казан Елантау-Успение монастыре биләмәсе була. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, урманчылык эше б-н шөгыльләнә. 1840 та И.га православие диненнән исламга күчкән бернičә татар гаиләсе килеп урнаша. 20 йөз башында Иоанн Предтеча чиркәве (1879 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1883 тә ачыла), Казан аеклык җәмгыяте бүлекчәсе, китапханә-уку өе, җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1076,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир-ат; 1859 да — 285, 1897 дә — 530, 1908 дә — 599, 1920 дә — 752, 1926 да — 702, 1938 дә — 587, 1949 да — 400, 1958 дә — 284, 1970 тә — 170, 1979 да — 109, 1989 да — 134, 2002 дә — 119 кеше.

**ИВАНО́ВСКИЙ** Александр Викторович (6.11.1881, Казан — 12.1.1968, Ленинград), кинорежиссёр, сценарист, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1936). Казан ун-тын тәмамлый (1906), бер үк вакытта Казан театрында Н.И.Собольщиков-Самарин антрепризасында опера режиссёрлыгына өйрәнә. 1904–17 елларда Мәскәүдә Зимин опера театрында режиссёр булып эшли. 1918 дән — кинода, режиссёр ассистенты (Я.А.Протазановның «Сергий атакай» («Отец Сергий») фильмы), режиссёр. «Станция караучысы» (А.С.Пушкинның «Станционный смотритель» повесте буенча), «Пунин һәм Бабурин», «Өч портрет» (И.С.Тургеневның «Пунин и Бабурин», «Три портрета» әсәрләре буенча), ш.у. «Сарай һәм ныгытма» («Дворец и крепость», 1924, О.Д.Форшның «Одеты камнем» һәм П.Е.Щёголевның «Таинственный узник» әсәрләре буенча) фильмнарын төшерә, соңгысы С.М.Эйзенштейнның «Потёмкин броненосецы» («Броненосец Потёмкин») фильмына күпмедер дәрәҗәдә эстетик яктан тәэсир итә. 1934 тән тавышлы фильмнар төшерә башлый: «Иудушка Головлёв» (1934, М.Е.Салтыков-Щедринның «Господа Головлёвы» романы буенча, совет киносының иң яхшы фильмнарыннан берсе булып таныла), «Дубровский» (1936, А.С.Пушкинның шул исем. повесте буенча), «Дошманнар» (1938, М.Горькийның шул исем. пьесасы буенча), «Музыкаль вакыйга» («Музыкальная история», 1940, Г.М.Раппопорт б-н бергәләп; СССР Дәүләт премиясе, 1941), «Антон Иванович ачулана» («Антон Иванович сердится», 1941), «Сильва» (1945, И.Кальманның шул исем. опереттасын экранлаштыру; Н.К.*Даутов* Эдвин ролендә), «Балет солисткасы» («Солистка балета», 1947), «Юлбарысларны буйсындыручы» («Укротительница тигров», 1955, Н.Н.Кашеварова б-н бергәләп) һ.б. Үзе төшергән күпчелек фильмнарның сценарийлары авторы.

Ә с ә р.: Воспоминания кинорежиссёра. М., 1967.

*Әд.:* Кино: Энцикл. словарь. М., 1987.

*Ю.А.Благов.*

**ИВАНО́ВСКИЙ** Виктор Викторович (20.10.1854, Казан губ. Мамадыш ш. — 18.8.1926, Казан), хокук белгече, социолог, полиция хокукы д-ры (1886), хакыйкый статский советник (1900). Дворяннар нәселеннән. 1878 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1879–82 дә профессор стипендиаты, 1882–86 да доцент, дәүләт хокукы каф. ординар профессоры, 1907–19 да хокук ф-тының полиция хокукы каф. атказ. профессоры, 1919–20 дә иҗтимагый фән. ф-тының җәмәгать хокукы каф. профессоры; бер үк вакытта 1906–07, 1910–18 дә хокук ф-ты деканы. Рев-ция елларында (1905–07) самодержавиегә каршы студентлар кузгалышларын, Россиядә конституцион реформалар үткәрүне яклап чыга, көн үзәгендәге сәяси темаларны яктырткан мәкаләләр бастыра. Хокук белемендә социологик юнәлешне яклый. «Россиядә земство үзидарә органнары эшчәнлеген өйрәнү тәҗрибәсе» («Опыт изучения деятельности органов земского самоуправления в России», 1882), «Франция һәм Пруссиядә үзидарәне оештыру» («Организация самоуправления во Франции и Пруссии», 1886) кебек хезмәтләрендә Европа илләрендә һәм Россиядә җирле үзидарәнең эшчәнлеге мәсьәләләрен анализлый. Төп хезмәтләре, ш.и. «Рус дәүләт хокукы» («Русское государственное право», вып. 1–7, 1895–98), «Элек һәм хәзерге көндә административ хокук фәне» («Наука административного права в её прошлом и настоящем», 1903), «Административ хокук дәреслеге» («Учебник административного права», 1904), дәүләт хокукы һәм административ хокук, дәүләтне психологик яктан аңлау мәсьәләләренә карый; социологиягә нисбәтле хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Административное устройство наших окраин. К., 1891; Вопросы государствоведения, социологии и политики. К., 1899; Лекции по государственному праву. К., 1906; Указ и закон по действующему русскому законадательству. К., 1912; Социология как наука и как предмет исследования во Франции. [У.к.], [Е.к.].

*Әд.:* Е м е л ь я н о в а И.А. Юридический факультет Казанского государственного университета 1805–1917 гг.; Очерки. К., 1998; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета 1905–1917. К., 1986; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ИВАНО́ВСКИЙ** Владимир Николаевич (17.7.1867, Вышний Волочёк ш. — 4.1.1939, Ленинград ш.), дин галиме, философ, тарихчы. Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1890), «Вопросы философии и психологии» ж-лында сәркәтип булып эшли (1893 кә кадәр). 1896–1900 елларда Мәскәү психол. җәмгыятендә сәркәтип. 1899 да Мәскәү ун-тында приват-доцент. 1900–03 тә чит илләрдә командировкада. 1903 тән Мәскәүдә Югары ха-

тын-кызлар курсларында, бер үк вакытта 1904–12 елларда Казан ун-тында укыта. 1912–14 тә чит илләрдә. 1914–17 дә Мәскәү ун-ты, Югары хатын-кызлар курслары приват-доценты. 1917 нең маеннан — Казан, 1918–21 дә — Самара, 1921–27 дә Белоруссия ун-тлары профессоры. Ассоциатив психология тарихы, философия тарихы буенча хезмәтләр яза. И. беренчеләрдән булып «төсле сүз» мәсьәләләрен өйрәнә башлый. Д.С.Милльнең «Силлогистик һәм индуктив логика системасы» («Система логики силлогистической и индуктивной». М., 1900), У.Джемсның «Укытучылар белән әңгәмәдә психология» («Психология в беседах с учителями». М., 1901) хезмәтләрен һ.б. тәрҗемә итә.

Х е з м.: Ассоциационизм психологический и гносеологический. Ист.-крит. исслед. К., 1909; Введение в философию. К., 1909; Методологическое введение в науку и философию. М., 1923.

*Әд.:* А л е к с е е в П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**ИВА́НОВСКИЙ НАРАТЛЫГЫ́**, табигать тыюлыгы. Куйбышев сусаклагычында, Кама елгасының сулъяк тугае террасасы су астында калу сәбәпле барлыкка килгән утрауда урнашкан. 1991 елда Алексеев р-ны Ивановский посёлогыннан төньяк-көнбатыштарак оештырыла. Мәйданы 587 *га*. Тыюлык терр-ясенең 60% ка якынын чиста нарат урманнары б-н бергә, аз санда каен катнаш нарат урманнары тәшкил итә. 70 еллык нарат кәүсәсенең диаметры 26 *см* га, биеклеге 24 *м* га кадәр җитә. Төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш өлешләрдә нарат, урыны б-н юкә катнаш каенлыклар таралган. Урман астында һәм ачык урыннарда югары төзелешле үсемлекләрнең 200 дән артык төре үсә. Фауна составында умырткалыларның 170 кә кадәр төре, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләр: кара елан, зур ак челән, соры торна, ысылдык аккош, елга каракошы, үләт бөркете, балыкчы карчыга, төн лачыны, яр песнәге, ак песнәк бар. И.н. фәнни һәм мәдәни агарту әһәмиятенә ия. Антропоген факторларның (күпләп терлек көтүе йөртү, рекреация) йогынтысы зур.



Ивановский наратлыгы.

**ИВАНО́ВСКИЙ** Николай Иванович (1840, Архангельск губ. — 25.10.1913, Казан), дин галиме, тарихчы, дин гыйлеме д-ры (1883). Архангельск руханилар семинариясен, Петербург руханилар академиясен (1865) тәмамлый. 1865–1911 елларда Казан руханилар академиясендә: 1869 дан каф. профессоры, 1877–85 тә — инспектор. Миссионерлык карашларыннан чыгып язылган хезмәтләре раскол һәм секталар, иске дин тарафдарлары тарихына һәм аларның шул чордагы халәте мәсьәләләренә карый. И.ның хезмәтләре әһәмиятле фактик материалга бай, алар иске дин тарафдарларына нисбәтле әдәбиятны тирәнтен өйрәнүгә, әлеге дин эшлеклеләре б-н шәхси элемтәләр урнаштыруга, полиция архивлары материалларына нигезләнгән. И.ның гамәли миссионерлык эшчәнлеге 1872 дән башлап 30 елдан артык дәвам итә, Казанда, Мәскәүдә, С.-Петербургта, Түбән Новгород ярминкәсендә төрле фикердәге иске дин тарафдарлары б-н алып барылган бәхәсләр б-н бәйле.

Х е з м.: Руководство по истории и обличению старообрядческого раскола: В 3 ч. К., 1886–87; Сочинения. СПб., 1897.

*Әд.:* Тридцатилетие миссионерской деятельности профессора Н.И.Ивановского // Православный собеседник. 1902. Ч. 2; В а с и л ь е в с к и й М.Н. Профессор Н.И.Ивановский: Некролог. К., 1913; Х а к и м о в Т.Ю. Библиография трудов Ивановского по расколу // Точка зрения: Сб. науч.-иссл. статей. К., 2000. Вып. 2.

*Е.В.Липаков.*

**ИВАНЦО́В** Николай Максимович (29.12.1913, Брянск ш. — 27.2.2002, Мәскәү), инженер-гидротехник, Соц. Хезмәт Герое (1972), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Мәскәү су хуҗалыгы инженерлары ин-тын тәмамлый (1937). 1938–50 елларда СССР НКВД Гидропроектында (Мәскәү) инженер, өлкән инженер, бүлек җитәкчесе. 1950–56 да Куйбышев ГЭСы төзелеше проекты баш инженеры урынбасары, Куйбышев гидроузелы су корылмалары төзелешендә баш инженер (Ставрополь ш.). 1956–59 да Саратов ГЭСы төзелешендә баш инженер, 1962–70 тә җитәкче (Балаково ш.). 1959–62 дә Гидропроект директоры (Мәскәү). 1970–81 дә СССР энергетика һәм электрофикация министры урынбасары, бер үк вакытта, 1971–74 тә, «Камгэсэнергострой» ҖБ җитәкчесе. 1981–84 тә «Союзгидроэнергострой» Бөтенсоюз төзелеш-монтаж берләшмәсе җитәкчесе (Мәскәү). 1984–85 тә СССР Энергетика һәм электрофикация министрлыгының Фәнни-техник советы рәисе урынбасары. 1985–87 дә «Гидроспецстрой» махсуслаштырылган ин-тында баш белгеч. 1988–91 дә «Оргэнергострой» Бөтенсоюз ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. 1991 дән «Каскад» инженерлык үзәге (Мәскәү) директоры. СССР МС бүләге иясе (1976), ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2000).



Н.М.Иванцов.

*Әд.:* Камгэсэнергострой: ступени роста. Набережные Челны, 2004; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**ИВА́ШЕВ В.П. УТА́Р-ПА́РКЫ**, табигать истәлеге. Буа р-ны Ивашевка авылы тирәсендә, Зөя елгасының сулъяк ярында урнашкан. 1987 елда билгеләнә. Мәйданы 4 *га*. Декабрист В.П.Ивашевның әтисе П.Н.Ивашевның нәселдән килгән утар-паркы (к. *Ивашевлар*), 18 йөз ахырында нигез салына. Паркта 100 дән артык агач, күбесенчә, юкә, сирәк кенә нарат, каен, өянке сакланып калган.

**ИВА́ШЕВКА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасы буенда. 2008 елда 8 кеше (руслар) яши. 1670 елларда нигез салына. Халкы 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә (И. — декабрист В.П.Ивашевның әтисе П.Н.Ивашевның нәселдән килгән утары), игенчелек, терлек үрчетү, балта эше, тегүчелек б-н шөгыльләнә, ит һәм сөт продуктлары б-н сәүдә итә. 20 йөз башында И.да земство мәктәбе, ат з-ды эшли. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 622, 1859 да — 571, 1880 дә — 766, 1897 дә — 899, 1913 тә — 600, 1920 дә — 663, 1926 да — 737, 1938 дә — 643, 1949 да — 449, 1958 дә — 366, 1970 тә — 176, 1979 да — 109, 1989 да — 32, 2002 дә — 11 кеше.

*Әд.:* Буа Ягым — Тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

**ИВА́ШЕВЛАР**, Казан губернасындагы дворяннар нәселе. **Никифор** (18 йөз), алпавыт, Ивашевка авылы (хәзерге Буа р-нында) хуҗасы. **Пётр Никифорович** (1767 — 21.11.1838, Сембер губ. Ундоры а. (Сембер шәһәрендәге Покров монастыре зиратында җирләнә), генерал-майор, Георгий кавалеры, А.В.Суворовның адъютанты, аның штабы башлыгы. Аңарда Суворовның безнең көннәргә килеп җитмәгән язмалары сакланган. Ялын Казанда уздыра. Хатыны — **Вера Александровна** (? — 27.5.1837), Казан алпавыты А.В.Толстойның кызы. Ул 1820 елда Сембер Хезмәт сөючеләр йорты — ятим кызлар уку йортының попечителе була. **Василий Петрович** (13.10.1797 — 28.12.1840, Тобол губ. Туринск ш.), лейб-гв. Кавалергард полкы ротмистры, 2 нче армия башкомандующие граф П.Х.Витгенштейнның адъютанты (1819), декабрист, «Иминлек берлеге» («Союз Благо-

денствия») җәмгыяте (1819–20), Көньяк җәмгыять (1820) әгъзасы. Рәссам (аның тарафыннан ясалган Ивашевка авылындагы утар рәсеме сакланган), шагыйрь («Стенька Разин» поэмасы, «Балыкчы» элегиясе авторы). Өйдә тәрбияләнә. 1812 дә император сараена паж итеп билгеләнә. Паж корпусын тәмамлый. 1815 тә Кавалергард полкында корнет, 1816 дан поручик, 1818 дән штаб-ротмистр. 2 нче армиядә хезмәт иткәндә (Тульчин ш., Украина) күп кенә декабристлар б-н дуслаша, П.И.Пестель б-н бер фатирда яши, беренчеләрдән булып «Рус хакыйкате» («Русская правда») тексты б-н таныша. 1821 дә Көньяк җәмгыять киңәшмәсендә «республика идарәсе кертелүгә ризалаша; тәхетне бетерүгә юнәлдерелгән, революцион ысул б-н хәрәкәт итүне» хуплый. Аерым управа башлыгы булып сайлана, ләкин 1821 дән авырып китүе аркасында бөтенләйгә ялга җибәрелә, аның эшчәнлегендә катнашмый. 1825 нең февраленнән әти-әнисе янында Сембердә, озак вакыт туганнары янында Казанда һәм Черпы авылында яши. А.А.*Наумова* әдәби түгәрәге әгъзасы. 1826 да Сембердә император Николай I гә тугрылык саклау турында ант бирә. Василий Петровичны кулга алу турындагы әмер ул киткәннән соң гына килә (әтисе Пётр Никифорович улын Муромда куып җитә һәм аны бу хакта искәртә). Ул 1826 ның 23 гыйнварында Мәскәүдә кулга алына, 2 нче разряд буенча хөкем ителә, 1827 нең 17 февралендә Себергә 20 елга каторгага җибәрелә. 1828 нең гыйнварында Пётр Никифорович Казаннан улына: «Кичә, минем йөрәк дустым, бирегә бердәнбер максат белән мөхтәрәм Наталья Дмитриевна Фонвизин б-н дулкынландыргыч очрашуга килдем... [...]. Юл аны алҗыткан иде, мин аның янына атаклы Фуксны алып килдем һәм, бергәләп үтенеп, аны монда ике көнгә калырга күндердем», — дип яза. 1831 нең җәендә В.А.Ивашева һәм М.П.Ле-Дантю В.П.Ивашевның кәләше Камилла Петровна Ле-Дантюны (15.6.1808 — 30.12.1839, Туринск ш.) Себергә озату өчен Казанга киләләр. 1838 нең августында Елизавета Петровна Ивашева абыйсы янына Себергә барып кайта. Камилла Петровна һәм Василий Петрович вафат булганнан соң, аларның балалары әбиләре — М.П.Ле-Дантю тәрбиясенә кала. 1841 дә аларга Сембер губернасына, аннан соң Казан губернасы Спас өязенең Бураково авылында яшәргә рөхсәт бирелә. Алар берничә ел Бураково авылында туган апалары Е.П.Хованская янында яшиләр, соңрак С.-Петербургка күчеп китәләр. Балалары: Мария (7.1.1835, Пётр заводы — 28.4.1897) 1854 тән К.В.Трубников б-н никахта. Хатын-кызлар хәрәкәте лидерларының берсе, Надежда Стасова, Варвара Тарновская, Анна Философова көрәштәше. Аның кызлары «Кара бүленеш» («Чёрный передел») революцион төркеме әгъзалары булалар; Пётр (1837, Туринск ш. — 29.1.1896), артиллерист, Е.А.Лебедевага өйләнә; Вера (7.12.1838, Туринск ш. — ?), «Җир һәм азатлык» («Земля и воля») оешмасы әгъзасы, революционер А.А.Черкасов хатыны.

*Әд.:* Буланова О.К. Декабрист Ивашев и его семья // Былое. 1922. № 19; Памяти декабристов: Сб. материалов. Л., 1926. Вып. 2; Гарзавина А.В. «В Казань, профессору К.Ф.Фуксу...». К., 1987. *А.В.Гарзавина.*

**ИВАШКЕ́ВИЧ** Виталий Борисович (26.3.1937, Пермь өлкәсе Краснокамск ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1975), проф. (1977), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). РФнең атказ. икътисадчысы (1997). 1959 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1964 тән бухгалтерлык эше каф. мөдире, бер үк вакытта проректор (1972–84). Хезмәтләре бухгалтерлык эшенә һәм пр-тиеләрнең хуҗалык эшчәнлеген анализлауга карый. И.ның тикшеренү нәтиҗәләре РФнең исәп-хисап һәм аудит стандартларын эшләгәндә кулланыла. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Проблемы учёта и калькулирования себестоимости продукции. М., 1974; Проблемы управленческого учёта. М., 1999; Бухгалтерский учёт в промышленности. К., 2002; Бухгалтерский управленческий учёт. К., 2003.

**ИВА́ШКИНО** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы (Чишмә елгасы бассейны) буенда. 2008 елда 587 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 елларда нигез салына. Халкы 1860 елларга кадәр дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да Сретение Господня чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1566 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 515, 1897 дә — 1241, 1908 дә — 1425, 1920 дә — 1455, 1926 да — 935, 1949 да — 854, 1958 дә — 867, 1970 тә — 1068, 1979 да — 836, 1989 да — 621, 2002 дә — 623 кеше.

**И́ВОЧКИН** Владимир Фёдорович (1906, Төмән ш. — 1968, Ленинград), корабльләр төзү инженеры, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Ленинград корабльләр төзү ин-тын тәмамлый (1934). 1923–28 елларда Барнаул, Омск, Новосибирск, Севастополь шәһәрләре пр-тиеләрендә эшли. 1934–35 тә Балтыйк з-дында (Ленинград) махсус суднолар төзүче, 1935–46 да 199 нчы з-дта (Комсомольск-Амур ш.) төзүче, җаваплы тапшыручы, заводның баш инженеры. 1946–49 да А.М.Горький исем. Зеленодольск суднолар з-дында баш инженер, директор. 1949–52 дә 444 нче з-д директоры (Николаев ш., Украина). 1952–59 да 194 нче з-дның баш төзүчесе, 1959–68 елларда «Алмаз» үзәк КБнда (Ленинград) баш конструктор. Дәүләт бүләге суднолар төзүдә агымлы-позицияле алымны кулланышка кертkәнә өчен бирелә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**И́ВШИН** Яков Васильевич (19.2.1953, Удмуртия АССРның, Селтин р-ны Шаклеи а.), электрохимик, химия фән. д-ры (2002). 1975 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре металларны электр ярдәмендә утырымга төшерүгә карый. Корычка бакыр капламнары ябыштыруны яхшырту ысулын эшли. Агулы булмаган нәцианид электролитлардан корыч эшләнмәләрне турыдан-туры бакырлау өчен яңа текстурланган бакыр капламы алу механизмын һәм ысулын тәкъдим итә. Селектив кара кобальт капламнарның электр ярдәмендә утырымга төшү процессын гелиоэнергетикада куллану максатында кояш энергиясен электр энергиясенә әверелдерү юлы б-н өйрәнә. Функциональ гальваник капламны электр б-н формалаштырганда бара торган башка реакцияләрнең ролен билгели.

Хезм.: Упрощённый итерационный метод расчёта протекторной защиты металлических сооружений от коррозии // Защита металлов. 1999. Т. 35, № 3; Методы исследования процессов электроосаждения металлов. К., 2006 (автордаш); Азотфосфорсодержащие ингибиторы коррозии нефтепромыслового оборудования. К., 2009 (автордаш).

**И́ВШИНА** Галина Васильевна (22.10.1953, Казан), педагог, математик, пед. фән. д-ры (2000), проф. (2003). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1988 дән функцияләр һәм якынчалыклар теориясе кафедрасында, 2003 тән квалификацияләрне күтәрү ф-ты деканы. Хезмәтләре матем. модельләштерүгә, идарә итү системалары теориясенә, мәгариф системасында мәгълүмат технологияләренә һәм укыту системаларының сыйфатына мониторинг үткәрү мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Компьютерные технологии в условиях мониторинга качества образовательных систем (дидактические основы). К., 2000.

**ИГАНӘЧЕЛЕ́К** (гарәп. إعانة — ярдәм), җәмәгать оешмалары, дәүләт учреждениеләре һәм аерым затларның мохтаҗларга ярдәм күрсәтүе. И. Россиядә төрле формада була: чиркәү, иҗтимагый, земство, шәхси, хөкүмәт иганәчелеге. Эш итү вакытлары буенча И. җәмгыятьләре даими һәм вакытлыча эшләүчеләргә бүленә. Вакытлыча эшләүче җәмгыятьләр үтә дә кискен хәлләрдә — иген уңмаган елларда, сугыш, эпидемия, янгыннар һ.б. вакытында барлыкка килә. Россиядә иҗтимагый И. эшчәнлеген дәүләт башлап җибәрә. «Йөз бүлекле устав»та («Стоглав», 1551) эшкә сәләтле ярлыларны эшкә урнаштыру, «махау авырулылар һәм картлар өчен» йортлар булдыру, 1649 елгы Собор җыелмасында әсирләрне түләп алу өчен средстволар җыю зарурлыгы турында белдерелә. Пётр I патшалык иткәндә караучысыз балаларны кабул итү өчен казна исәбенә «гошпитал»лар оештыра башлыйлар (1715). 1721 дә И. учреждениеләре һәм чаралары полиция вазифаларына кертелә, хәерчеләр һәм тыелу белми яшәүчеләр өчен тынычландыру йортлары һәм социаль түбән тәгәрәгән хатын-кызлар өчен «предиль» (эш) йортлары оештырыла. Екатерина II идарә иткәндә И. мәгърифәтле абсолютизм сәясәтенең аерылгысыз өлеше булып

исәпләнә. 1775 тә губерналарда җәмәгать тәрбиясе приказлары (учреждениеләре) оештырыла (Казан губернасында *Җәмәгать тәрбиясе приказы* 1786–1869 елларда эшли). Аларны, гадәттә, губернаторлар җитәкли. Алар мәктәпләр, хастаханәләр, ятимнәр йортлары, гыйбадәтханәләр һәм шундый учреждениеләр б-н идарә итү өчен оештырыла. 1797, 1801, 1809 һ.б. еллардагы фәрманнар нигезендә мохтаҗлар турында кайгырту авыл һәм шәһәр җәмәгатьләренә һәм мәхәлләләренә йөкләнә. Шул ук вакытта И. мәсьәләләре буенча төгәл закон актлары булмау аның үсешен үзәк һәм җирле хакимиятләргә бәйле итә. И. средстволарын бүлү, суммаларны тиешле урынга тапшыру турындагы квитанцияләрне бирүне дә кертеп, җирле администрация контролендә була. Шәхси кешеләр хәйрияне бары тик полицмейстерның рөхсәте булганда гына җыя ала. 1890 да И. җәмгыятьләренең Эчке эшләр министрлыгына ел саен хисап бирүен таләп иткән закон кабул ителә. Император нәселе вәкилләре иганәчелек җәмгыятьләренә һәм фондларына ярдәм итәләр, шул рәвешле, җәмәгатьчелек игътибарын аларга җәлеп итеп, мода һәм традиция формалаштыралар. Губерналарда император нәселе яклавында булган И. җәмгыятьләре рәисләре һәм попечительләре вазифаларын, югары урын биләүче зат буларак, губернаторлар башкара. Казанда түбәндәгеләр оештырыла: Император Кешеләрне кайгырту җәмгыятенең Казан ярлылар попечительлеге комитеты (1816), Император Мария ведомствосы учреждениеләренең Казан губерна балалар ятимханәләре попечительлеге (1843), Казан телсез-чукракларны тәрбияләү һәм аларга белем бирү җәмгыяте (1877), Император Мария Александровнаның сукырларны кайгырту попечительлегенең Казан бүлекчәсе (1890). 1894 тә шәраб җитештерүгә казна монополиясе кертелү уңаеннан Финанс министрлыгы халык аеклыгы попечительлеге оештыра. Аның карамагында исерткеч эчемлекләр кулланылмаган чәйханәләр, ашханәләр, уку бүлмәләре, ятимханәләр һәм хастаханәләр була (к. *Казан аеклар җәмгыяте*).

Россиядә чиркәү иганәчелеге дә киң тарала: Чиркәүләр каршында — гыйбадәтханәләр — «ходай йортлары», зиратлар янында «фәкыйрьләр каберләре» («скудельница»лар) оештырала. Приход попечительлекләре ятимханәләр һәм мәктәпләр тотуга акча бирә. 1864 елгы закон буенча Казан епархиясе каршында чиркәү-приход попечительлеге ачыла, 20 йөз башында аның карамагында 597 попечительлек бүлекчәсе була; чиркәүдә хезмәт итүчеләр өчен Казан епархиясенең Ярлы руханилар попечительлеге оештырыла.

1860 тан земство һәм шәһәр И. үсә башлый. 1890 елга земстволар И.кә, медицина ярдәменә бирелгән чыгымнарны санамыйча, үз бюджетларының 10%ын (3 млн. сум чамасы) тоталар. Дәвалап булмаслык авыруларга, эшкә яраксыз кешеләргә, фәкыйрьләргә ярдәм итәләр; һөнәр мәктәпләре, үзара ярдәм җәмгыятьләре ачалар, йортсызлар өчен вакытлыча биналар (кайчак азык-төлек өләшеп, «туклану станцияләре» оештыралар), күченүчеләр һәм эшчеләр өчен «мосафирханәләр» төзиләр; эшчеләрнең бер урыннан икенчесенә күчүен, эш эзләүләрне теркәү өчен белешмә конторалары ачалар. Казан губерна земствосы ятимнәр йорты (меңнән артык бала) һәм гыйбадәтханә (189 кеше) тота. 19 йөз ахырында ярлылар өчен шәһәр участок попечительлекләре ачыла (к. *Балалар ятимханәләре*).

19 йөз ахырында шулай ук һөнәри билгеләр буенча — әлеге тармакта эшләүчеләргә үзара ярдәм күрсәтү өчен хәйрия җәмгыятьләре, мәс., Казан губерна укытучылар хәйрия җәмгыяте (1890), Китап басучылар хәйрия җәмгыяте (1884), *Приказчиклар хәйрия җәмгыяте* (1866) барлыкка килә.

Шәхси И. Россиядә оешкан формаларда 18 йөзнең 2 нче яртысыннан, 1860 еллардан аеруча тиз үсә башлый. 1781 елгы Фәрман нигезендә шәхси хәйрия биналары ачуга рәсми рөхсәт бирелә; 1862 дә аларның эшчәнлегенә рөхсәт бирү хокукы императордан Эчке эшләр министрлыгына тапшырыла. 1890 елларга И.кә тотылган чыгымнарның 75% ы — шәхси затларга, 25% ы казнага, земстволарга, шәһәрләргә, социаль катлаулар һәм дин оешмаларына туры килә. Кайбер кешеләр, мәс., О.И.*Александрова-Гейнс*, И. эшчәнлеген үзләренең төп шөгыльләренең берсенә әверелдерәләр. Казан губернасында эре иганәчеләрдән сәүдәгәрләр С.Е.*Александров* (килгән авырулар өчен Казанда шифаханә оештыра һәм тота), С.А.Арефьев (керәшен татар балалары мәктәбе өчен бина сатып ала), И.П.Петров (Казан һөнәрилек идарәсе каршындагы гыйбадәтханәгә акчалар бирә һәм аның попечителе була), И.И.*Стахеев* (ул биргән акчалар 5 млн. сум исәпләнә), В.Л.*Челышев* (аның акчасына Чистай шәһәрендә хатын-кызлар гимназиясе төзелә), Я.Ф.*Шамов* (Казанда хастаханә төзи — к. *Шамов хастаханәсе*), И.И.*Алафузов* (Бишбалта бистәсендә хастаханә тота), И.Н.*Журавлёв* (төн кунып чыгу бинасы төзүгә акча бирә, анда китапханә булдыра) танылалар. Кайбер сәүдәгәр-иганәчеләрнең исемнәре Казан тарихына кереп калган: Лихачёвның бала табу бүлекчәсе, Евдокия б-н Сергей Павловлар һәм Екатерина Прибыткова гыйбадәтханәсе, Юнысовлар балалар ятимханәсе (к. *Мөселман балалар ятимханәсе*). 1900 елгы мәгълүматларга караганда, Казан губернасында 30 дан артык җәмгыять һәм 46 учреждение, ш.и. 32 гыйбадәтханә (Казанда — 14) һәм 14 балалар ятимханәсе (Казанда — 5: к. *Николай исемендәге балалар ятимханәсе, Александра исемендәге балалар ятимханәсе*). Хәйрия җәмгыятьләренең средстволары әгъзалык кертемнәреннән, хәйрия акчаларыннан, төрле җыемнардан, капитал процентларыннан һәм күчемсез милек керемнәреннән җыела. Шәхси И., аеруча сәүдәгәрләрнеке, һәрвакытта да эчкерсез булмый. Башкаларга ярдәм итеп, сәүдәгәрләр үз абруйларын күтәрәләр, ватандашлары алдында танылалар, хакимиятләрнең игътибар үзәгенә эләгәләр (аеруча зур хәйрияләр өчен аларга төрле дәрәҗәләр, мактаулы исемнәр, дворянлык бирәләр, алар орден-медальләр б-н бүләкләнәләр).

1917 елга кадәр Россиядә И.нең төп юнәлеше — яралы, авыру һәм карт сугышчыларны һәм аларның гаиләләрен карау-тәрбияләү була. Казандагы Яралы һәм авыру сугышчыларны карау-тәрбияләү җәмгыяте (1874) 1879 да Кызыл Хач җәмгыяте итеп үзгәртелә, Качакларга ярдәм күрсәтүче Казан шәһәр ком-ты (1915–17) эшли. Дәүләт Думасындагы мөселманнар фракциясе инициативасы б-н Петроградта *Мөселман хәйрия җәмгыяте* оештырыла. Татарлар арасында И.не үстерүдә ислам дине зур роль уйный. Мөселманнарда аның борынгыдан килгән мохтаҗлар файдасына зәкят бирү рәвеше була. Мәчет-мәдрәсәләр төзү һәм тоту мөселманнарда изге гамәлләрнең берсе санала. Рәсми теркәлгән беренче татар хәйрия җәмгыятен 1867 дә С.-Петербургта Касыйм татарлары төзи (к. «*Бикбулатовның С.-Петербургта Касыйм татарларына үзара ярдәм күрсәтү җәмгыяте*»). 1917 дә Россиядә 100 гә якын хәйрия җәмгыяте була (С.-Петербургта, Казан, Троицк, Касыйм, Петропавловск, Әстерхан, Оренбург һ.б. шәһәрләрдә). 18 йөз ахырыннан 1917 елга кадәр татарлар арасында шәхси И. киң тарала. Татар сәүдәгәрләре *Аитовлар, Акчуриннар, Апанаевлар, Казаковлар, Рәмиевләр,* Хәкимовлар, *Хөсәеновлар, Юнысовлар* И.кә аеруча зур өлеш кертәләр, алар иганәсенә мәчетләр, мәдрәсәләр («Касыймия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия» һ.б.), ятимнәр йортлары, Оренбург, Троицк, С.-Петербург мөселман хәйрия җәмгыятьләре, Оренбург һәм Уфа мөселман хатын-кызлар җәмгыятьләре, Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте, Чиләбе мөселман халык китапханәсе, Оренбург «Белек» җәмгыяте оештырган И.Гаспринский исем. китапханә һ.б. төзелгән һәм тотылган, татарча китаплар, газета-журналлар нәшер ителгән. Иң киң танылган татар хәйрия җәмгыятьләре — «*Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте*», С.-Петербургтагы Мөселманнар хәйрия җәмгыяте, Оренбургтагы Мөселманнар җәмгыяте, Пермь Мөселманнары мәдәни-этник һәм хәйрия җәмгыяте, Оренбургтагы Мөселман шәкертләрне кайгырту җәмгыяте һ.б. Православие приход җәмгыятьләреннән аермалы буларак, татар җәмгыятьләре акча җыюның дөньяви ысулларын да кулланалар: хәйрия спектакльләре, концертлары куялар, әдәби-музыкаль кичәләр, милли Сабан туе бәйрәмнәре һ.б. оештыралар. Җыелган акчалар мәктәп, китапханә, хастаханәләр тотуга һ.б. бирелә. Әлеге җәмгыятьләр, чиста иганәчелек һәм мәдәни-агарту бурычларыннан тыш, билгеле бер күләмдә татар халкының иҗтимагый-сәяси тормышында да катнашалар. 1914 тә мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае була (к. *Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае*), ул мөселманнар арасында И. эшчәнлеген тәртипкә салу мәсьәләсен алга куя. Аның инициативасы б-н 1915 нең 5 февралендә С.-Петербургта сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә яр-

дәм итү буенча вакытлы мөселман комитеты төзелә, ул мөселманнар тупланып яши торган төбәкләрдә, ш.и. Казанда 100 ләп бүлекчә ача (к. *Мөселманнар комитеты*). 1918 дә барлык хәйрия җәмгыятьләре дә үз эшчәнлекләрен туктаталар. Совет заманында И. дәүләти форма ала.

Шәхси И. 1990 елларда яңадан торгызыла башлый, күп кенә хәйрия җәмгыятьләре барлыкка килә (к. *Бөтентатар Кызыл Ярымай җәмгыяте*). 2007 ел Татарстанда Хәйрия елы дип игълан ителә.

*Әд.:* Сборник сведений по общественной благотворительности: В 7 т. СПб., 1880–86; Максимов Е.Д. Историко-статистический очерк благотворительности и общественного призрения в России. [Б. м.], 1894; шул ук. Законодательные вопросы попечения о нуждающихся. СПб., 1907; Благотворительные учреждения Российской Империи: В 3 т. СПб., 1900; Ильинский В. Благотворительность в России. СПб., 1908; Спасский Н.А. Очерки по родиноведению. К., 1910; Казанское общество призрения и образования глухонемых детей. К., 1912; Боханов А.Н. Коллекционеры и меценаты в России. М., 1989; Хайруллина А.Д. Казанские газеты как исторический источник изучения благотворительности (1861–1895 гг.). К., 1993; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Ж.С.Миңнуллин, Л.М.Айнетдинова.*

**ИГӘНӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 50,7 *км*, бассейнының мәйданы 507 *км²*. Елга башы Сарман р-нындагы Мостафин авылыннан 1,2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Минзәлә р-нындагы Наратлы-Кичү авылында. Елга башының абс. биеклеге 230 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. 14 кушылдыгы бар. Иң зурлары Инеш (17,8 *км*) — сул, Игәнә Суы (13,1 *км*) — уң. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 113 *мм*, ташу агымы катламы 82 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. И. елгасы ноябрьнең беренчеункөнлегендә ката.



Игәнә елгасы Минзәлә районының Наратлы Кичү авылы янында.

Елга тамагында суының иң аз вакыттагы чыгымы 0,545 *м³/с*. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын һәм кышын 300–400 *мг/л*. И. бассейнында күләме 11,9 млн. *м³* булган 9 буа бар. Су ресурслары сугару өчен тотыла, ТРның табигать истәлеге (1978). Бассейнында табигать тыюлыгы Сөлек урманы бар.

**ИГӘНӘ́ СУЫ** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Игәнә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,1 *км*, бассейнының мәйданы 39,9 *км²*. Сарман р-ны терр-ясеннән ага: елга башы Игәнәбаш авылыннан көньяктарак, тамагы Петровский Заводы авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 238 *м*, тамагыныкы — 120 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 6%. 4 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 78 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. И.С. ноябрь башында ката. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы чыгымы 0,025 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*).

**ИГӘНӘБА́Ш** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 8 *км* көнбатыштарак, Игәнә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 75 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. 1923 тә Иләксаз авылыннан күчкән кешеләр нигез сала. ТАССРның Минзәлә кантоны Сарман волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1926 да — 410, 1938 дә — 449, 1949 да — 326, 1958 дә — 333, 1970 тә — 291, 1979 да — 228, 1989 да — 135, 2002 дә — 80 кеше.

**ИГӘ́Т** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,4 *км*, бассейнының мәйданы 46,7 *км²*. Елга башы Тукай р-нындагы Малтабар авылыннан 0,5 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә р-нының Гөлек авылыннан 2 *км* төньяктарак Түбән Кама сусаклагычының Ык култыгына коя. Елга башының абс. биеклеге 119 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу терр-ясендә урман үсемлекләре юк. 7,9 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 78 *мм*, ташу агымы катламы 72 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. И. ноябрьнең беренче көннәрендә ката. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы чыгымы 0,01 *м³/с*. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**«ИГЕ́Н ИГҮЧЕ́»**, журнал. РКП(б)ның Казан губкомы керәшен татарлар секциясе органы. 1918 елның июнь–июлендә Казанда татар телендә 2 саны нәшер ителә. Мөхәррире — Л.Ишкинов.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать. К., 1999.

**«ИГЕНЧЕ́»**, Казандагы нәшрият. ТАССР Җир эшләре халык комис-ты каршында Бөтентатар Үзәк Башкарма ком-тының 3 нче сессиясе карары б-н 1921 елның 22 маенда а.х. мәсьәләләренә караган әдәбият (фәнни-популяр брошюра, листовка, плакат, рәсми белешмә басмалар, вакытлы матбугат) тарату һәм пропагандалау максатында оештырыла. 1920 еллар уртасыннан нәшрият фәнни китаплар һәм дәреслекләр дә чыгара башлый. Басмаларның тематикасы: терлекчелек һәм сөт җитештерү; ветеринария; туфрак белеме һәм җир эшкәртү, бакчачылык; декретлар, законнар, рәсми материаллар, артель һәм коммуналар уставлары.

Нәшрият хуҗалык исәбендәге пр-тие буларак оештырыла. Үзенең басмаханәсе булмый, заказлары «Мәгариф», «Милләт», «Татарстан», «Татполиграф» басмаханәләрендә урнаштырыла. Рев-циягә кадәрге татар басмаларыннан торган а.х.на багышланган китапханәсе, Крәстиян йорты каршында китап кибете (1926 дан) була. Китаплар авылларга, ш.у. Идел буе, Башкортстан, Казакъстан шәһәрләренә чыгып сатыла.

Редколлегия б-н күренекле галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре (Ю.Вәлидов, Ф.Сәйфи, Т.Дитякин, А.Остряков, А.Гордягин һ.б.) һәм тәрҗемәчеләр (А.Апанай, М.Әмирханов, Җ.Вәлиди, З.Назыйрова, К.Халитов, К.Әмири, Ф.Бурнаш, Г.Хөсәенов) хезмәттәшлек итә. Аларның күбесе ш.у. авторлар да була. Басмаларны бизәүдә күренекле китап басу остасы һәм китап рәссамы М.Идриси катнаша. Коллектив тарафыннан татар телендә а.х. терминнары сүзлеге эшләнә. Ул татар телендә чыккан беренче терминологик сүзлек була.

Эшчәнлегенең беренче елында нәшрият 86,8 мең данә тираж б-н 13 исемдә китап чыгара; татар телендә «Игенче» һәм рус телендә «Сельское хозяйство Татарстана» ж-ллары чыга башлый. Китап басу эше авырлык кичерү сәбәпле, 1922 дә татар телендә гомуми тиражы 128 мең данәдә бары тик 18 исемдә (планлаштырылган 300 урынына) китап дөнья күрә. 1925 тә 84 исемдәге 253,2 мең данә һәм 1926 да 82 исемдәге 298,4 мең данә китап басыла. 1921–1930 елларда татар телендә гомуми тиражы 1317 мең данә булган 404 исемдәге китап нәшер ителә.

Нәшрият Мәскәүдә 1 нче Бөтенсоюз а.х. һәм вак һөнәрчелек күргәзмәсендә 1 нче дәрәҗә диплом (1923), Бөтентатар сәнәгать күргәзмәсендә 1 нче дәрәҗә диплом б-н (1926) бүләкләнә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1929 ел 13 ноябрь карары б-н «И.» нәшрияты *Татиздатка* кушыла. 1922 елның гыйнварыннан нәшрият б-н К.Г.Халитов җитәкчелек итә.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Издательство «Игенче». К., 1987.

**ИГЕНЧЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шилнә елгасы (Каманың сул кушылдыгы) бассейнында. 2008 елда 71 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Мысы-Чаллы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1926 да — 108, 1938 дә — 273, 1949 да — 217, 1958 дә — 162, 1970 тә — 213, 1979 да — 161, 1989 да — 84, 2002 дә — 87 кеше.

**ИГЕНЧЕ́** посёлогы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 15 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2008 елда 183 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларда «Овцевод» с-зы бүлекчәсе посёлогы (1954 тән — «Мөслим») буларак нигез салына, 1960 еллар уртасыннан хәзерге исемен йөртә. Оештырылган көннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 98, 1949 да — 92, 1958 дә — 201, 1970 тә — 246, 1979 да — 197, 1989 да — 195, 2002 дә — 189 кеше.

**«ИГЕНЧЕ́»**, Кукмара р-нындагы крәстиян хуҗалыклары берләшмәсе. Колхоз җирлегендә оештырыла (1930 елда нигез салына; 1980–94 тә «Коммунизмга» к-зы, 1994 тән хәзерге исемдә). 2007 дән «Бор» агрофирмасы составында. Үзәк утары — Зур Сәрдек а. Берләшмәгә Адай, Аш-Буҗи, Кара елга, Купка, Чишмәбаш авыллары керә. Эшләүчеләр саны якынча 318 кеше. А.х. җирләренең мәйданы — 6289 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 4990 *га*. «И.» — бөртекле ашлык, бәрәңге, ит-сөт җитештерү алга киткән күп тармаклы хуҗалык. Мөгезле эре терлек — 1413 баш, ш.и. 650 баш сыер (2006). Бөртекле культураларның уңышы (1 *га* дан ц): 1992 дә — 41,1, 2001 дә — 49; 2006 да — 32,0; бәрәңгенеке: 1992 дә — 231,8, 2001 дә — 170, 2006 да — 157,8. Бер сыердан савылган сөт (*кг* да): 1992 дә — 3962, 2000 дә — 3765, 2006 да — 2962; 100 *га* а.х. җирләренә күчереп исәпләгәндә 292 *ц* сөт җитештерелә (2006). Хуҗалыкта көчле матди техник база булдырыла: а.х. техникасын ремонтлау остаханәләре, 2 мең баш мөгезле эре терлек, 3 мең баш дуңгыз, 2 мең баш сарык өчен тораклар, социаль-мәдәният йортлары төзелә, авылларга газ кертелә. Бөтенсоюз соц. ярышлардагы уңышлары өчен хуҗалык ике тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә (1966, 1987). 2008 дән «И.» «Бор» агрофирмасы» ҖЧҖ составында бер бүлек. Хуҗалык җитәкчеләре: Соц. Хезмәт Герое К.Ф.*Шакиров* (1959–79), Г.Г.*Шәмсетдинов* (1979–99), И.К.Шакиров (1999 дан).

*И.Н.Афанасьев.*

**«ИГЕНЧЕ́»**, журнал, к. *Татарстан авыл хуҗалыгы.*

**«ИГЕНЧЕ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Казан крәстиян депутатлары советының мөселман сул фракциясе һәм Казан губерна земствосы органы. 1917 елның 14 августыннан 1918 елның 10 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 55 саны чыга. Беренче мөхәррирләре — М.*Вахитов* һәм Г.*Сәйфетдинов*. М.Вахитов Учредительләр җыенында катнашу һәм Мөселман комис-тында эшләү өчен Петроградка киткәннән соң, мөхәррире Ш.Абдиев (Ш.Габди) була. Газета үзен халык массаларын революцион рухта тәрбияләүне, буржуазиягә һәм буржуазия матбугатына каршы көрәшне үзенең максаты итеп куйган, татар крәстияннәре мәнфәгатьләрен чагылдырган матбугат органы итеп белдерә. Газета ш.у. милләт өчен әһәмиятле булган сәяси вакыйгалар (мәс., Бөтенроссия мөселман советының оешуы һәм аның эшчәнлеге һ.б.) турында да яза. Мөхәррире Ш.Абдиев булганнан соң, басманың сул һәм радикаль булуы кими төшә, ул большевиклар тарафыннан тәнкыйть утына алына. Аның генераль сәяси юнәлешкә туры килмәве һәм земство оешмаларының таратылуы сәбәпле, газета ябыла.

*Әд.:* Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975.

*Д.М.Госманова.*

**ИГЕНЧЕ́ СОЛДАТЛА́Р**, Россиядә 18 йөз ахыры — 19 йөзнең 1 яртысында отставкага чыккан түбән чин гаскәриләрдән оештырылган крәстияннәр катлавы. 1736 елның 27 декабрь фәрманы нигезендә Анна Иоанновна «авыру, өлкән яшькә җитү аркасында отставкага чыккан, үз авыллары һәм туклану чыганаклары булмаган унтер-офицерларны һәм рядовойларны» Идел елгасы һәм аңа коючы елгалар, ш.у. Иске Чишмә, Яңа Чишмә, Зәй, Тиинск, Ерыклы, Биләр бистәләре тирәләрендәге салым салына торган җирләргә күчереп утыртырга боера. Соңрак И.с. Россиянең көньяк җирләренә күчеп утыралар. 19 йөзнең 30 нчы елларында Екатеринослав, Иркутск, Казан, Оренбург, Сембер, Таврия һәм Томск губерналарында төркемнәргә тупланган гражданнар булып яшиләр. Гомуми исәбе — 25597 ир-ат. Аларның күбесе Оренбург губернасында — 13334 кеше, Казан губернасында — 6058, Сембер губернасында 3691 кеше яши. И.с. Казан губернасында, башлыча, Чистай өязендә яшиләр. 1789 елгы фәрман нигезендә И.с. земство полициясенә буйсына. И.с. бистәләре б-н эчтән идарә итү өчен старшиналар сайлана. 1810 да бистәдә хәрби идарә кертелә. Хөкүмәтнең И.с.ны ташламалы хәлгә күчерергә җыенуы сәбәпле, 1816 да хәрби идарә бетерелә. 1831 дә И.с. бистәләре һәм җирләре халкын волостьларга бүлү, волость идарәләре оештыру башлана. Баштарак И.с., яшәргә яңа килгән кешеләр өчен йортлар төзелешен санамаганда, барлык дәүләт салымнарыннан һәм бурычларыннан азат ителәләр. 1760–70 елларда Сенат И.с.га салым салу проектларын берничә тапкыр тикшерә. 1783 тә отставкадагы солдат балаларына, «җирләр белән тәэмин итеп, барлык күченеп утырганнар белән тигез дәрәҗәдә хезмәт хакы куярга ... һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә алардан рекрутлар алырга» дигән фәрман чыгарыла. 1789 да аларны яңадан салым түләүдән азат итәләр. Моның бәрабәренә 20 яшькә җиткән күченеп утырганнар, кече улдан кала, армиядә хезмәт итәргә тиеш булалар. Хезмәтне тутыргач, алар үз авылларына кайталар, аларга җир бүлеп бирелә (1821 дә Казан һәм Екатеринослав губерналары И.с. аерым күрсәтмә чыкканчы рекрутлык бурычларыннан азат ителәләр). 1816 да хөкүмәт Казан, Оренбург һәм Сембер губерналары И.с.н «җан башына оклад»ка күчерү, алардан гомуми нигездә рекрутлар алу һәм аларны казна крәстияннәре дип атау турында карар кабул итә. Әмма 1817 дә җан башыннан салым җыйганда хакимият вәкилләре Чистай өязе И.с.ның ачыктан-ачык каршылыгына очрый, 48 кеше судка бирелә һәм төрлечә тән җәзасына тартыла. 1818 дә И.с.дан салым алу «аерым аңлатуга кадәр» туктатыла. 1831 дә И.с.ны дәүләт крәстияннәре төренә кертүнең яңа этабы башлана: алардан дәүләт салымы түләтергә һәм рекрутлыкка алырга кушыла, Чистай өязендә үзәкләре Биләр һәм Яңа Чишмәдә булган волость идарәләре оештырыла. И.с. яңадан җирле хакимияткә ныклы каршылык күрсәтәләр (к. *Игенче солдатлар фетнәсе*). Кузгалышлар казак отрядлары тарафыннан бастырыла. 1830 елларда И.с. дәүләт крәстияннәренең гомуми массасы б-н кушыла. 1831 дә күпләгән хәрби авыллар (1810 да Александр I тарафыннан кертелгән, хәрби хезмәт һәм а.х. б-н шөгыльләнү өчен берләштерелгән аерым гаскәри оешма) И.с. округлары дип үзгәртелә. 1857 дә И.с. округлары бетерелә.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Р. Управление государственной деревней Казанской губернии (конец XVIII — первая треть XIX в.). К., 2002.

*Р.Р.Хәйретдинов.*

**ИГЕНЧЕ́ СОЛДАТЛА́Р ФЕТНӘСЕ́**, 1831 елда Казан губернасы Чистай өязе *игенче солдатларының* салымнар түләүче катлауга күчерелүгә каршы чыгышы. Сәбәбе — 1831 нең 15 апрель фәрманы. Аның нигезендә игенче солдатлар салымнар түләргә һәм хәрби хезмәт үтәргә тиеш була. Игенче солдатлар б-н идарә итү өчен Биләр һәм Яңа Чишмә авылларында волость идарәләре оештыру күздә тотыла. Фетнәгә 12 авыл кушыла. Авыл җыеннарында игенче солдатлар салымнар түләүдән баш тарту, император Николай I гә үтенеч мөрәҗәгате җибәрү турында карар кабул итәләр. Хакимиятләргә элеккеге хокукларда калу яки бөтен җәмагать б-н хәрби хезмәткә алыну теләге белдерелә. Игенче солдатлар берничә ай дәвамында җирле хакимияткә көчле каршылык күрсәтәләр. Фетнәне бастыру өчен Казан губернаторы урынбасары Е.В.Филиппов өч йөз кешелек казаклар отряды җибәрә. Сентябрь ахырында фетнә бастырыла. 19 кешене хөкемгә тарталар. Аларның 4есен хәрби хезмәткә яраклы дип табалар һәм Кавказга җибәрәләр, калганнары Себергә сөрелә.

*Әд.:* Хайрутдинов Р.Р. Управление государственной деревней Казанской губернии конец XVIII — первая треть XIX в. К., 2002.

*Р.Р.Хәйретдинов.*

**«ИГЕНЧЕЛӘ́Р»**, атналык авыл хуҗалыгы газетасы. ВКП(б) ҮК каршындагы Үзәк татар-башкорт бюросы органы. 1924 елның 2 февраленнән 1931 елның 30 декабренә ка-

дәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 369 саны чыга. Җаваплы сәркәтибе — Б.*Мансуров.* Газетаның иң актив авторлары — С.Атнагулов, Г.Баязитов, М.Бикбулатов, А.Бикмиев, Л.Гайсин, Г.Гобәйдуллин, Г.Исмәгыйлев, М.Кормаш, Ф.Мансурова, М.Мишурин, С.Сагиев, Н.Сәйфи, Т.Салихов, Х.Янбарисов. «И.» алдына партиянең аграр сәясәтен пропагандалау, авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору буенча партия күрсәтмәләрен тормышка ашыру, фән һәм техника өлкәсендәге яңа казанышларны, наданлык б-н көрәшүне яктырту кебек бурычлар куела. Басманың шигаре: «Эшче һәм крәстияннәр берлеге яшәсен!». «И.»дә басылган мәкаләләр, башлыча, җирдән файдалану, авыл хуҗалыгының кече һәм урта звеносын үстерү һәм аңа кредит бирү, мәгариф эше, кулакларга, хосусый сату итүчеләргә каршы көрәш, комсомол һәм партия оешмалары б-н эшләү, авылларда мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре булдыру кебек мәсьәләләргә багышлана. «И.» битләрендә алдынгы колхозчылар һәм хуҗалыклар турында мәкаләләр, а.х. культураларының уңдырышлылыгын күрсәткән таблицалар урын ала. Газетаның даими рубрикалары: «Авылдан хатлар», «Киңәшләр һәм җаваплар», «И.» илнең төрле өлкәләрендә яшәүче татарлар арасында тарала.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ИГЕНЧЕЛЕ́К**, 1) азык, техник, терлек азыгы һ.б. а.х. культураларын җитештерү буенча а.х. тармагы; 2) *агрономия* бүлеге, туфракка тәэсир итү алымнарын өйрәнә, җирдән нәтиҗәлерәк файдалану һәм югары уңыш алу өчен туфракның уңдырышлылыгын күтәрү ысулларын эшли. И. Татарстанда бик күптәннән традициягә әверелгән. Аның үсеш үзенчәлекләре җирле халыкның яшәү рәвеше, географик, туфрак һ.б. шартлар б-н бәйле рәвештә урман (Кама алды һәм Урал буе өлеше), урман-дала (Идел алды һәм Көнбатыш Кама арты) һәм дала (Кама арты һәм Көньяк Урал буе) зоналарына аерыла.

Башлангыч чорда И.нең гади төрләре — сазлык, яшелчә бакчалары, сөрү системалары була. Урман зонасына төпләп-яндыру И. системасы хас. Бу системаны Идел алды терр-ясендә *Балановo* һәм *Волосово культурасы* кабиләләре, Идел-Вятка елгалары арасында *Ананьино культурасы* кабиләләре куллана, *Азелино*, *Городец, Имәнкискә культурасы* кабиләләре 3–7 йөзләрдә сөрүле И. б-н шөгыльләнә. Китмән, сука, соңрак сабан җирне эшкәртүче төп кораллар була. Сөрелгән (сукаланган) мәйданнар 4–5 ел буе, башлыча, сабан культуралары чәчү өчен файдаланыла, ә аннан соң ял итәргә буш калдырыла һәм берничә елдан соң кабат чәчү әйләнешенә кертелә. И.нең яткын җир системасы Кама түбәнлеге терр-ясендә урнашкан болгар кабиләләре өчен дә хас була (8 йөз). Аны пар системасы алыштыра. Ул, Болгар чорында барлыкка килеп, 10–16 йөздә үсеш ала, корылыклы р-ннарда хәзерге көндә дә кулланыла. 18 йөз уртасыннан И.нең культура алыштыру системасы формалаша башлый, чәчү әйләнешендә планлы рәвештә кузаклылар (клевер, борчак), көзге (арыш, бодай), язгы бөртекләләр (бодай, арпа, солы), соңрак — сызма культуралар (кукуруз, бәрәңге, тамыразыклар) аралаштырыла, туфракның уңдырышлылыгы югары дозада минераль һәм органик ашламалар куллану нәтиҗәсендә кабат торгызыла. 1920 елларда И.нең үлән чәчү системасы фәнни нигезләнә һәм гамәлгә кертелә башлый, бу очракта туфракның уңдырышлылыгы аерым мәйданнарда күпьеллык кузаклы һәм кыяклы үләннәр чәчү хисабына күтәрелә. 1950 елларда И.нең бөртекле-үләнчел, сөрүле, яхшыртылган бөртекләләр системалары тәкъдим ителә. Бу системаларны кулланганда туфракның уңдырышлылыгы минераль һәм органик ашламалар, химик мелиорация хисабына яхшы хәлдә саклана. Бөртекле ашлык җитештерүне арттыру максатында күпьеллык үлән чәчүлекләрен сөрү туфракта су һәм җил эрозиясе процессларының көчәюенә һәм И.нең туфрак саклау алымнарын куллану кирәклегенә китерә.

Хәзерге вакытта И.нең ТРда кулланыла торган фәнни нигезләнгән зональ системалары 1970–80 елларда эшләнә. Алар җитештерү процессларын югары дәрәҗәдә механикалаштыру нигезендә, үсемлекләрне авырулардан, корткыч һәм чүп үләннәрдән бердәм саклау системасын кулланып, бөртекләләр, терлек азыгы, техник һ.б. культуралардан программалаштырылган уңыш алу өчен туфрак саклау һәм ресурс саклау технологияләрен күздә тоталар. Иң камил, туфрак уңдырышлылыгын тагын да киметми тотучы булып И.нең адаптив агроландшафтлы системасы санала. И.нең заманча системаларында бөртекле культураларга сөрүле җирләр мәйданының 50–55% ы, бәрәңге, яшелчә, техник һәм терлек азыгы культураларына 33–36% ы (шуларның 15–18% ы күпьеллык үләннәргә) бүлеп бирелә. Сөрүле җирләрнең 10–14% ы чиста һәм сидераль парга туры килә. ТРда барлык чәчүлек мәйданы, 1920 ел б-н чагыштырганда, 1940 та 1,5 тапкырга, 1965–75 тә 1,75 тапкырга арта. 2000 дә ул 2991,4 мең *га* тәшкил итә. Көзге арышның чәчүлек мәйданы, 1920 ел б-н чагыштырганда, 3 тапкырдан да күбрәккә кими, бодай, арпа, борчак чәчүлекләре арта.

1980–90 да И.нең интенсив системасын үзләштерү бөртекле ашлык һ.б. а.х. культуралары җитештерүне арттырырга мөмкинлек бирә (к. *Бөртекле ашлык хуҗалыгы, Бәрәңге үстерүчелек, Терлек азыгы җитештерү*).

И. фән буларак агрономиянең үсемлекчелек, туфрак белеме, агрохимия, мелиорация һ.б. фәннәре б-н үзара бәйләнештә тора. И.не фән дип, беренче тапкыр рим галиме Марк Теренций Варрон игълан итә (б.э.к. 116–27 еллар). И. фәне 18 йөздә интенсив үсеш ала, Юнг (Бөекбритания), А.Тэер, Ю.Либих (Германия), Ж.П.Буссенго (Франция), А.Т.Болотов, И.М.Комов, М.Г.Павлов (Россия) һ.б. галимнәрнең тикшеренүләре нәтиҗәсендә үсемлекләрне минераль тукландыру теориясе нигезләнә, И.нең төп законнары ачыла. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан И. фәненә Россия галимнәре А.В.Советов, И.А.Стебут, А.Н.Энгельгардт, П.А.Костычев, В.В.Докучаев, К.А.Тимирязев, Н.М.Тулайков, А.Г.Дояренко, Д.И.Прянишников, В.Р.Вильямс зур өлеш кертәләр. Алар тарафыннан туфрак турында фән булдырыла, югары нәтиҗәле И.нең принциплары эшләнә, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү юллары тәкъдим ителә. И.нең заманча системалары үсеше берничә юнәлештә бара. Туфрак уңдырышлылыгын яңадан торгызу проблемалары б-н Н.З.Милащенко, А.М.Лыков, В.В.Егоров, И.П.Котоврасов, туфракны эрозиядән саклау буенча — А.Н.Каштанов, М.Н.Заславский, А.И.Бараев, Д.Е.Ванин, Е.И.Рябов, О.Г.Котлярова, чәчү әйләнешенең төп проблемалары б-н — С.А.Воробьёв, В.М.Дудкин, В.Г.Лошаков, туфрак эшкәртү системасының гомуми мәсьәләләре б-н — К.Г.Шульмейстер, В.И.Румянцев, С.С.Сдобников, В.А.Чернышов, Д.М.Буров, В.П.Нарциссов, туфракны яссы кисеп эшкәртү теориясе б-н — Э.Ф.Госсен, калаксыз сабан технологиясе б-н туфрак эшкәртү системасы буенча — Т.С.Мальцев, туфракны аз эшкәртү буенча А.И.Пупонин, С.И.Долгов, В.М.Круть һәм А.П.Спирин кебек галимнәр шөгыльләнә. И.нең нәтиҗәлелеген күтәрүнең технологик өлешен К.И.Саранин, М.И.Сидоров, А.И.Шабаев һ.б. эшли.

И.не фәнни нигезгә күчерү шәхси хуҗалыкларны күмәкләштерү һәм кыр эшләрен механикалаштыру б-н бергә алып барыла. Бу чорда Татарстанда Бөгелмә, Лаеш, Спас тәҗрибә кырлары, 1920 дә Казан а.х. тәҗрибә станциясе булдырыла. 1920 елларда И.И.*Штуцер* тарафыннан а.х. культураларын үстерүдә районлаштыру тәкъдим ителә; И.В.Благовещенский тарафыннан чиста һәм чәчүле парларны чагыштырып өйрәнү уздырыла, органик һәм минераль ашламалар куллануның кайбер проблемалары тикшерелә. 1920–40 елларда И.нең үсеше В.П.*Мосолов* исеме б-н бәйле. Аның җитәкчелегендә басу культураларын, ш.и. күпьеллык үләннәрне үстерү, кәсле-көлсу туфракларны эшкәртү һәм яхшырту алымнары, калын сөрү катламын булдыру һәм тирәнәйтү мәсьәләләре өйрәнелә.

1950–60 елларда чиста парны чәчүле пар б-н алмаштырып, борчак һәм берьеллык үләннәр чәчелә, бөртекле культуралар һәм кукуруз чәчү мәйданнары киңәйтелә. Бу ысуллар чәчүлекләрдә чүп үләннәргә каршы химик чаралар б-н көрәш алымнарын куллануга китерә. Әлеге мәсьәләләр буенча төп тикшеренүләрне — Х.Х.*Хәбибрахманов*, А.С.Грузкова, ә шикәр чөгендере чәчүлекләрендә химик чаралар куллану буенча тикшеренүләрне П.М.Крайнов алып бара. Туфракны калаксыз сабан б-н эшкәртү системасын тикшерүне М.И.Павлов уздыра. Ул С.А.Глухов б-н берлектә чәчүле пар культураларыннан соң көзге арыш өчен туфракны минималь эшкәртүне тәкъдим итә. 1965–70 елларда В.Н.Мещанов туфракны калаклы һәм калаксыз сабан б-н эшкәртүнең ашламалар нәтиҗәлелегенә, бөртекләләр һәм бөртекле-кузаклы культураларның уңышы һәм сыйфатына тәэсир итүен ачыклый. Күп еллар дәвамында бөртекләләр чәчү әйләнешендә

туфракны яссы кискечләр б-н эшкәртү буенча тикшеренүләрне И.И.Долотин (1966 дан) һәм В.Ф.Мареев (1980–2000) уздыра.

А.А.*Җиһаншин* җитәкчелегендә 1964 тә оештырылган тәҗрибә кырларында чәчү әйләнеше, ашламалар һәм туфрак эшкәртү системалары, чүп үләннәренә каршы көрәш чаралары, язгы бодай үстерү алымнары эшләнә. А.П.*Пухачёв* тарафыннан уздырылган дәвамлы стационар тәҗрибәләр сөзәк (кашлак) җирләрдә туфракны су эрозиясеннән саклау буенча күп кенә проблемаларны чишәргә ярдәм итә. 1970–80 елларда Г.Д.Аверьянов, М.С.Матюшин, В.Ф.Кирдин, А.А.Шаламова, Г.Х.Хөснетдинов тәҗрибә кырларында кара туфраклы һәм соры урман туфраклы җирләрне эшкәртү системаларын өйрәнәләр. Калаксыз сабан системасын 3–4 елга бер тапкыр куллануның өстенлекләре ачыклана, күп басулы бөртекле сызма культуралар һәм бөртекле культура — пар чәчү әйләнешендә туфрак эшкәртүне минимальләштерү мөмкинлекләре күрсәтелә, кара солыга каршы көрәш чаралары эшләнә.

20 йөз ахырында И.не биологияләштерү буенча фәнни тикшеренүләр активлаша, алар күпьеллык кузаклы үләннәр чәчү, үсемлек калдыкларын куллану, сидераль культуралар үстерү һ.б. факторлар хисабына туфракны яхшыртуга юнәлтелә (Х.Х.Хәбибрахманов, Р.З.Нәбиуллин, Р.С.Шакиров). И. проблемалары б-н Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты, Казан аграр ун-ты, Россия А.х. академиясенең Агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты, «Татарский» агрохимия хезмәте үзәге һ.б. фәнни оешмаларның хезмәткәрләре шөгыльләнә. Ш.у. к. *Авыл хуҗалыгы*.

*Әд.:* Вильямс В.Р. Почвоведение. Земледелие с основами почвоведения. М., 1949; Халиков Н.А. Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX — начала XX вв. М., 1981; Система земледелия Татарской АССР. К., 1988; Зиганшин А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001.

*Г.Д.Аверьянов.*

**ИГЕНЧЕЛЕ́К СИСТЕ́МАСЫ**, к. *Игенчелек.*

**ИГИ́М НАРАТЛЫГЫ́**, табигать истәлеге. Минзәлә р-нының төньяк-көнчыгыш өлешендә Түбән Кама сусаклагычының Ык култыгы ярында урнашкан. 1972 елда билгеләнә. Мәйданы 543 *га*. Көнбатыштан Ык елгасының элеккеге юлы, көнчыгыштан Көләгеш сазлыгы б-н чикләнүче комлы таулыкны (Кама елгасының 2 нче террасасы өлеше) били. Рельефы тигез, урыны б-н дюнасыман калкулыклы. Кама аръягында сакланып калган табигый нарат урманнары массивының берсе (Юртау урманчылыгының Минзәлә участок урманчылыгы), биредә тайга, урман-дала һәм дала үсемлек төрләре бергә кушыла. Моңарчы кулланылган яшел мүкле наратлыклар төшенчәсе урынына М.В.Марков бу урманнарны үләнле наратлыкларга кертә. 1970 елларда Казан ун-ты галимнәре тарафыннан антропоген тәэсирләр (тоташ кисү, агач әзерләү һ.б.) аркасында наратлыкларның шактый үзгәрешләр кичерүе исбатлана. Ылыслы токымнар (нарат, чыршы, ак чыршы) яфраклылар (өрәңге, каен, юкә, имән) б-н алышына. Агачлар төбендә кара җиләк, нарат җиләге һәм артыш җиләге б-н бергә дала чиясе, ә үлән капламында үсемлекләрнең дала төрләре: бuркынсыман мәче борчагы, буяу сырмавыгы, Альп тукранбашы, бүлбеле кияү камчысы, Румын люцернасы, дарулы әспе үләне, вак чәчәкле җилсем үлән, Тюрингия розасы, кытыршы күкбаш (төймәбашы), чуар куян тукранбашы, шома ябышкак үлән һ.б. үсә. Үсемлекләрнең сирәк төрләреннән төньяк Линней үләне, җәрәфи үлән, тимгелле башмакчәчәк, кызыл серкәбаш, гади чыршылык үләне, кыска таҗлы һәм Цингер мәче борчаклары очрый.

Күлле-сазлыклы комплекста урнашканлыктан И.н.ның хайваннар дөньясы күптөрле. 1940 еллар уртасында беренче тапкыр биредә кәҗәболан күренә (Көньяк Уралдан керә). Төрле елларда җофар, ондатра җибәрелә.



Игим наратлыгы.

Бурсык, янутсыман эт, төлке, ас, чәшке күренгәли. Фаунасында — җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләрнең 4 әр төре, кошларның 73 төре, имезүчеләрнең 17 төре. ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләрдән: соры гөберле бака, җизбаш, гади кара елан, бытбылдык, соры торна, төн лачыны, кыр һәм болын карчыгасы, бөркет, үләт бөркете, тавышлы зур каракош, елга каракошы, чын лачын, балыкчы карчыга, байгыш, озын койрыклы ябалак, сазлык ябалагы, ябалакчыклар, гади төн күгәрчене, чал тукран, ак песнәк очрый.

*Әд.:* Першаков А.А. Птицы, наблюдавшиеся в Прикамской части бывшего Мензелинского кантона ТАССР // Тр. Об-ва изучения Татарстана. 1930. Т. 2; Марков М.В. Лес и степь в условиях Закамья // Уч. зап. Казан. ун-та. 1939. Т. 98. кн. 1; Памятники природы Татарии. К., 1977.

*Ф.Г.Борһанов.*

**ИГЛИ́Н РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2455 *км²*. Үзәге — Иглин авылы (Уфадан 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 45392 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 10192, 1979 да — 9007, 1989 да — 8249, 2002 дә — 3394 кеше. Районда 130, ш.и. 18 татар, 3 татар-рус, 1 татар-башкорт торак пункты бар. Иң зур татар авыллары (1999 ның 1 гыйнварына) — Акбирде (513 кеше), Үктәй (401), Турбаслы (378), Карамалы (355). Иң борынгы авыллар — Бейбакты (1731), Келәш, Үктәй (1739). 1994/95 уку елында И.р.ның 8 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 8 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә.

**ИГНА́ТЬЕВ** Василий Игнатьевич (12.3.1917, Псков губ., Святогорск өязе Загоски а. — 20.3.2002, Казан), геолог-стратиграф, геол.-минерал. фән. д-ры (1962), проф. (1963), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Псков пед. ин-тын (1939), Казан ун-тын (1945) тәмамлый. 1945 тән Чуаш пед. ин-тының геология кафедрасын җитәкли. 1951–97 дә Казан ун-тында. Урта Идел геол. идарәсенең консультанты (1945 тән). СССР геол. картасының бер өлеше булган Идел-Урал геол. картасы авторларының берсе (1976). Югары Пермь утырмаларының җентекле стратиграфик схемасын төзи, Татар ярусы утырмаларын 3 өлешкә бүлә, Казан ярусында Бөгелмә горизонтын, Татар ярусында Вятка горизонтын билгели. Кызыл төстәге континенталь утырмаларның беренче генетик классификациясен төзи, палеозой утырмаларында палеотуфраклы фацияләрне беренче булып билгели. Татарстан терр-ясендә бакырлы һәм битумлы фацияләр миграциясенең закончалыгын ачыклый. Урал алдыннан һәм Каспий буеннан Рус платформасына нефтьнең ерак миграциясе юлларын һәм чикләрен билгели, кызыл төстәге континенталь утырмаларны өйрәнү методикасын һәм палеотектоник анализ ысулын эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татарской ярус центральных и восточных областей Русской платформы: В 2 ч. К., 1962–1963; Методика историко-геологического анализа на примере ... Волго-Уральской антеклизы. К., 1985.

**ИГНА́ТЬЕВ** Виктор Николаевич (16.11.1944, Чистай р-ны Булдыр а.), хисаплау математикасы өлкәсе галиме, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1993), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Себер бүлеге Хисаплау үзәгендә эшли, лаб. мөдире (1978–89) (бүленеп, 1974–78 дә Омск ун-тының хисаплау һәм гамәли матем. каф. мөдире). 1989 дан Казан техник ун-тында, югары матем. каф. мөдире (1993 тән). Хезмәтләре сызыкча һәм нәсызыкча дифференциаль тигезләмәләрнең санлы чишелешенә, аэрогидродинамика мәсьәләләрен матем. модельләштерүгә карый. Полимер өстәмәләре булган үзле сыеклыкта диффузия процессларын сурәтли торган матем. модуль һәм чик катлам тигезләмәләрен чишүнең эффектив санлы алгоритмнарын эшли. И. яну камераларында углеводородлы ягулык янгандагы физик-химик процессларны матем. модельләштерү буенча гамәли программа пакетлары булдыра. Тикшеренү нәтиҗәләре Ил-76 самолётлы өчен газ турбиналы двигатель проектлаштырганда һәм төзегәндә кулланыла (ярдәмче җайланма).

Хезм.: Об одной схеме повышенной точности для расчёта двумерного ламинарного пограничного слоя // Числ. методы механики сплошной среды. 1970. Т. 1, № 3 (автордаш); О схеме повышенного порядка точности для расчёта турбулентного пограничного слоя // Числ. методы механики сплошной среды. 1972. Т. 3, № 4; Разностная схема для нелинейного сингулярного возмущённого уравнения 2-го порядка // Журн. вычисл. математики и матем. физики. 1990. Т. 30, № 9 (автордаш).

**ИГНА́ТЬЕВ** Виктор Петрович (10.11.1918, хәзерге Лениногорск р-ны Спиридоновка а. — 13.3.1992, Казан), график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978), пед. фән. кандидаты. 1922 елдан Казанда яши. Казан ун-тының геогр. ф-тын тәмамлый (1942). Бөек Ватан сугышында катнаша, 1956 га кадәр Совет Армиясендә хезмәт итә. 1956 дан Казан пед. ин-тында укыта, бер үк вакытта сынлы сәнгать б-н шөгыльләнә, портрет, пейзаж, натюрмортлар яза, агачтан вак пластик әсәрләр иҗат итә, респ-ка һәм бөтенроссия вакытлы матбугаты б-н хезмәттәшлек алып бара, Татарстан китап нәшрияты өчен китаплар бизи. Журналистлар берлеге (1960), Рәссамнар берлеге (1974) әгъзасы. И.ның рәсемнәре «Чаян», «Азат хатын», «Новое время», «Агитатор», «Советский воин» һ.б. ж-лларда, «Советская Татария», «Учительская газета»,



В.П. И г н а т ь е в. «Сүзсез дә аңлашыла». Тушь, каләм, төсле карандаш, фломастер. 1983. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

«Новгородская правда», «Социалистик Татарстан», «Комсомольская правда» һ.б. г-таларда басыла. Сатирик графика өлкәсендә И.ның таланты аеруча тулы ачыла. Аның рәсемнәренә зирәклек, тапкырлык, композиция төзү осталыгы, графиканың төрле техникаларын иркен куллану хас. Рәссам сурәтләү метафораларыннан, гротесктан, комик шаржлардан уңышлы файдалана, аларны ышандырырлык жанрлы күренешләр б-н яраклаштыра: «Чыгарырга» (тушь, акварель, 1956), «Кем кемне» (тушь, акварель, 1961), «Б да түгел, м да түгел» (тушь, гуашь, 1963) «Юкка өрә, безнең арыслан инде күпме этнең башына җитте» (тушь, пастель, 1969) һ.б. 1970 еллар башыннан И. иҗатында көнкүреш сатирасы б-н беррәттән халыкара темаларга багышланган сәяси карикатура да күренерлек урынны алып тора: «Гомуми базар («Кисекбаш» буенча)» (акварель, 1976) һ.б. И.ның Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлеге нәтиҗәле була, ул анда натурадан ясалган һәм тексты булган рәсемнәре тупланган «КамАЗ башлана» (1972), «Түбән Кама — нефть химиясе шәһәре» (1976), «Алтын алка» (1988) һ.б. альбомнарын бастыра.

Республика (1947 дән), төбәк — «Зур Идел» (1964, 1969) күргәзмәләрендә, Рәссам-журналистларның 2 нче бөтенсоюз күргәзмәсендә (1975); халыкара — «Сатира тынычлык өчен көрәштә» (1969, 1973, 1977), «Чили халкына ирек» (Болгария, 1973–74), «Көлү дөньяны коткарды» (Болгария, 1977) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда уза (1960, 1967, 1972, 1978, 1983). Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Габрово сатира һәм юмор музеенда (Болгария), Әлмәт, Чаллы картиналар галереяларында саклана. Х.Ямашев исем. республика бүләге лауреаты (1972); «Сатира тынычлык өчен көрәштә» (1969) күргәзмәсенең халыкара жюри, Совет тынычлыкны яклау ком-ты (1977), СССР СА (1977) дипломнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С т ы к а л и н С., К р е м е н с к а я Е. Советская сатирическая печать 1917–1961. М., 1963; Е л ь к о в и ч Л.Я. На линии огня. К., 1977; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**ИГНА́ТЬЕВ** Игорь Михайлович (7.10.1954, Сарман р-ны Сарман а.), хирург, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). А.Н.*Веденский* шәкерте. 1979 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казанның 12 нче клиник хастаханәсендә эшли. 1980 нән Республика клиник хастаханәсендә (микрохирургия бүлеге) табиб-хирург. 2001 дән Төбәкара диагностика үзәгендә кан тамырлары хирургиясе бүлеге мөдире. Тикшеренүләре реконструктив хирургиягә, веналарның хроник авыруларына, очлыклардагы кан тамырларының тумыштан килгән авыруларына диагноз куюга һәм дәвалауга, ш.у. веналар хирургиясендә матем. модельләштерүгә, вена системасы авыруларына ультратавыш б-н диагностика ясауга карый. И. хирургик флебологиядә операцияләрне сайлау, аларны фаразлау һәм нәтиҗәләрен бәяләүне билгеләргә мөмкинлек бирүче яңа юнәлеш ача; түбән очлыклар веналарының хроник авырулары вакытында кан әйләнешен яңартуның яңа ысулларын эшли. Уйлап табуга 5 патенты бар.

Х е з м.: Ангиология и сосудистая хирургия. К., 1998; Диагностическое нарушение венозной гемодинамики и принципы их хирургической коррекции при тяжёлых формах посттромбической болезни. К., 1999.

**ИГНА́ТЬЕВ** Семён Денисович (1904, хәзерге Украинаның Карловка а. — 27.11.1983, Мәскәү), партия, дәүләт эшлеклесе. И.В.Сталин исем. Бөтенсоюз сәнәгать академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1935). 1919 елда Бохара тимер юлының баш депосы комсомол ячейкасы секретаре. 1920 дән Бөтенбохара Гадәттән тыш комиссия органнарында, 1921–22 дә шунда ук хәрби бүлек вәкиле. 1922–25 тә Төркестан АССР Коммунистик яшьләр берлеге ҮКның оештыру бүлеге мөдире урынбасары. 1925–28 дә Ташкентта Совет сәүдә хезмәткәрләре берлегенең өлкә бүлеге идарәсе секретаре, рәисе. 1928–29 да Кыргызстан АССР Профсоюзлар советының тариф-икътисад бүлеге мөдире. 1929–31 дә Ташкентта ВЦСПСның Урта Азия бюросы массалар б-н эшләү бүлеге мөдире. 1935–37 дә Мәскәүдә ВКП(б) ҮКның сәнәгать бүлеге мөдире ярдәмчесе. 1937–43 тә — ВКП(б)ның Бурят-Монголия, 1943–46 да Башкортстан өлкә ком-тлары секретаре. 1947–49 да Белоруссия КП ҮКның а.х. һәм әзерләүләр буенча секретаре. 1949–51 дә яңадан Ташкентта: ВКП(б) ҮКның Урта Азия бюросы секретаре, ВКП(б) ҮКның Үзбәкстан ССР буенча вәкиле. 1951–53 тә СССР дәүләт иминлеге министры, 1952–53 тә КПСС ҮК Президиумы әгъзасы, 1953 тә КПСС ҮК секретаре. 1953–57 дә КПССның Башкортстан, 1957–60 та Татарстан өлкә ком-тлары 1 нче секретаре. 1958 нең маенда «Татар гомуми белем бирү мәктәпләренең хәле һәм аларның эшен яхшырту турында»гы мәсьәлә буенча КПССның Татарстан өлкә ком-ты пленумы утырышы уздырыла. И.ның яклавы нигезендә пленум карарларында татар мәктәпләрен югары квалификацияле педагогик кадрлар б-н тәэмин итү, дәреслекләр б-н тулыландыру, туган тел һәм әдәбиятны укыту дәрәҗәсен күтәрү, ш.у. халык хуҗалыгы өчен татар телен белгән белгечләр әзерләүне яхшырту чаралары күздә тотыла; бу проблемаларга карата игътибарның кимүе өчен ТАССР МС, ТАССР Мәгариф министрлыгы, КПССның Татарстан өлкә ком-ты бюросы, район, шәһәр ком-тлары нык тәнкыйть ителә. 1955–59 да — РСФСР, 1958–62 дә — СССР, 1959–63 тә ТАССР ЮСлары депутаты. КПССның 19 нчы һәм 20 нче съездларында КПСС ҮК әгъзасы итеп сайлана. Дүрт Ленин ордены, Октябрь революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С у л т а н б е к о в Б. Судьба любимца Сталина // Респ. Татарстан. 1999. 9 окт.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**ИГНА́ТЬЕВ** Юрий Геннадиевич (4.8.1947, Украина ССРның Львов ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1985 тән Казан пед. ун-тында геометрия каф. мөдире. Хезмәтләре гравитация кырындагы физик күренешләрне өйрәнүгә карый. И. гравитация кырындагы күп компонентлы плазманың статистик тигезләнеше теориясен төзи, йолдызлардагы плазманың стратификация эффектын һәм пульсарларның аннигиляцион нурланышын алдан әйтә, тикторыштагы нейтрино массасына фаразланган космологик чикләүләрнең булмавын билгели, Галәмдә гравитацион тәэсир итешүнең кинетик теориясен төзи һәм шул теория нигезендә ерак астрофизик чыганаклардан килә торган яктылык таралу теориясен, әүвәлге Галәмдәге бариогенезның кинетик теориясен, релятивистик тартылу кырындагы магнитик актив плазманың хәрәкәте теориясен, шуның нигезендә нәсыйкча күренешләрнең яңа классын — нейтрон һәм үтә яңа йолдызларның гравитацион нурланышын йотылуга китерүче бәрмә гравимагнит дулкыннар классын ача. 1994 елдан халыкара «Gravition and cosmology» ж-лы редакторы.

Х е з м.: Бесстолкновительный газ в поле плоской гравитационной волны // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1981. Т. 81, № 2; Релятивистская кинетика бариогенезиса в горячей Вселенной //

Астрон. журн. 1985. Т. 62, № 4; Динамическая модель сферических возмущений во вселенной Фридмана. III. Запаздывающие решения для ультрарелятивистского уравнения состояния // Изв. вузов. Физика. 2008. Т. 41, № 12 (автордаш).

**ИГНАТЮ́К** Владимир Евгеньевич (2.9.1943, Мәскәү), кинорежиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Бөтенсоюз кинематография ин-тын (Мәскәү, 1983) тәмамлый, М.И.Ромм һәм Л.Н.Дербышева классларында укый. 1969–71, 1973–79, 1982–90 елларда — Казан кинохроника студиясендә, 1971–72 дә — Казан телевидение студиясендә, 1980–82 дә — Үзәк документаль фильмнар студиясендә, «Молдова-фильм», «Беларусь-фильм» киностудияләрендә, 1990–98 дә — «Мизгел» киностудиясендә һәм ТР Кинематография дәүләт ком-тында, 1998 дән «Казан» телестудиясендә режиссёр булып эшли. 50 ләп фильм төшерә, алар арасында «Күк шундый зәңгәр» («Такое синее небо», 1974), «Кара туфраклы булмаган зона. Һава торышына карамастан» («Нечерноземье. Независимо от погоды», 1975; Кара туфраклы булмаган зона турындагы фильмнарның 1 нче конкурсы призы, Ярославль ш.), «Түбән Кама шәһәре гербы» («Герб города Нижнекамска», 1976), «Студентлар» («Студенты», 1982, ТР Кинематографистлар берлеге дипломы), «Нефть, табигать, кеше» («Нефть, природа, человек», 1986), «Саклану законы» («Закон сохранения», 1988), «Мин үземне кызгана белмим...» («Себя жалеть я не умею», 1989), «Татарстан. Гасырлар һәм еллар» («Татарстан. Века и годы», 1990), «Бөтендөнья татар конгрессы» («Всемирный конгресс татар», 1992), «Чорлар бәйләнеше» («Связь времён», 1995), «Тере су» («Вода живая», 2000) фильмнары бар. Ул төшергән фильмнарның геройлары — Чаллы йортлар салу комбинаты башлыгы М.Ш.Бибишев, КамАЗ төзелеше җитәкчесе Е.Н.Батенчук, Соц. Хезмәт Герое Е.Мосунова. Шулай ук Казан рәссамы А.А.Аникеенок («Саумы, Лёша!» — «Здравствуй, Лёша!», 1987), 1960 еллар язучылары Р.Солнцев, В.Мостафин, шагыйрь Н.Беляев турында («Яшәешнең биек баскычы» — «Вершина бытия», 1989), Казан революционеры Н.Е.Федосеев турында («Булмый калган очрашу» — «Несостоявшаяся встреча», 1988) фильмнар төшерә. И. — 100 дән артык киножурнал режиссёры: «Киң Иделдә» («На Волге широкой»), «Совет Белоруссиясе» («Советская Белоруссия»), «Устурич», «Ватан», «Татарстан» һ.б. И.ның режиссёрлык осталыгы тасвирлауның югары культуралы, тәэсирле булуы, монтажлауның төгәллеге б-н аерылып тора. Сценарийлар, шигырьләр авторы. Бөтенсоюз кинофестивалендә (Минск, 1985), СССР ВДНХсында узган Бөтенсоюз хроникаль-документаль фильмнар смотр-конкурсында (Мәскәү, 1987) алтын һәм көмеш медальләргә лаек була.

Ә с ә р.: Мосты. Сценарий не снятого кино // Казань. 1997. № 5/6; Круги // Казань. 1999. № 7/8; Сонеты прошлого и другие стихи // День и ночь. 1999. № 2.

*Е.П.Алексеева.*

**ИГО́ШКИН** Виктор Семёнович (5.10.1933, Пенза өлкәсенең, Сосноборск р-ны Сосновка а.), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1981), проф. (2000), ТССРның атказ. икътисадчысы (1991), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000). 1973 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1958–65 тә Пенза шәһәрендәге пр-тиедә диспетчер, инженер. 1965–77 дә Казан «Элекон» з-дында бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары. 1978 дән Казан финанс-икътисад ин-тында, 1992 дән ректор ярдәмчесе. Фәнни тикшеренүләре базар икътисады шартларында халык куллану товарлары җитештерү һәм куллану проблемаларына, халыкара икътисади мөнәсәбәтләргә карый. «Мировая экономика» («Дөнья икътисады») (1998) исемле уку ярдәмлеге авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Товары для народа: производство и потребление. К., 1985; Международные экономические отношения. К., 1993.

**ИГРА́ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* төньяк өлешендә урнашкан. 1937 елда оештырыла. Мәйданы — 2267,8 *км²*. Үзәге — Игра посёлогы (Ижевскидан 92 *км* төньяктарак). Халкы — 46,7 мең кеше (2001), ш.и. 700 ләп татар. Алар, нигездә, район үзәгендә, Факел, Лоза посёлокларында, Чутыр, Яңа Зятцы, Зура авылларында яши. И.р.нында татарлар 1940–50 елларда, районда агач әзерләү тармагының нык үсүе б-н бәйле рәвештә килеп урнаша. Татарлар (нигездә, Татарстан һәм Башкортстаннан килгән югары әзерлекле нефть белгечләре) күчеш икенче дулкыны 1970 елларның 1 нче яртысына туры килә һәм бу районда нефть чыгара башлау б-н бәйле.

**ИГУ́МНЫЙ БИСТӘЛӘРЕ́**, 17 йөздә Казанның көнбатышында, Казансуның уңъяк яры буенда, *Бишбалта бистәсенә* каршы, Успенье (Зилант) һәм Кизик монастырьлары тирәсендә барлыкка килгән Зур һәм Кече бистәләр. И.б.ндә күн товарлар җитештерелгән, П.К.Ушаковның химия з-дында җилем кайнатылган. 20 йөздән шәһәр сызыгына керә.

*Әд.:* Б а ж е н о в Н. Плавание к Зилантовому монастырю и Казанскому памятнику. М., 1846; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**ИГЪЛА́МОВ** Мәхмүт Камал улы (22.4.1908, Казан губ., Спас өязе Урта Йорткүл а. — 30.3.1977, Казан), архитектор, 1929–38 елларда Казан һәм Ленинград коммуналь төзелеш инженерлары ин-тларында укый. 1938 елдан «Татпланпроект» ин-тында эшли (Казан). 1941–44 тә Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944 тән шул ук ин-тның проектлау-планлаштыру конторасында архитектор. Бер үк вакытта 1939–41 дә һәм 1944–64 тә Архитекторлар берлегенең Татарстан фондында җаваплы секретарь. 1968 дән «Татгражданпроект» ин-тында проектларның баш архитекторы.

И. проектлары буенча Казанда хастаханә (хәзер Клиник диагностика үзәге корпусларының берсе, 1951), Казан ун-тының химия корпусы (к. *Казан университеты* мәкаләсенә илл., 1957), «Победа» кинотеатры (фасадлар эшләнеше, 1958), мед. ин-тының төп корпусы (к. *Казан медицина университеты* мәкаләсенә илл., 1959), торак йортлар төзелә. Совет неоклассицизмы («Сталин ампиры») стилендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.



М.К.И г ъ л а м о в. «Победа» кинотеатры.

**ИГЪЛА́МОВ** Рәүф Мәхмүт улы (19.10.1941, Казан), театр белгече, сәнгать фән. канд., ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан театр уч-щесен (1966), Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын (1971) тәмамлый. 1971–2001 елларда хәзерге Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында, Казан театр уч-щесендә укыта. Басылып чыккан хезмәтләре татар һ.б. милли театрлар тарихын һәм үсеш проблемаларын яктыртуга багышлана.

Ә с ә р.: Выдающийся драматург. К., 1989; Казанский театр кукол. К., 1995; Искусство играющих кукол. К., 2004.

**«ИГЪЛА́НЕ ХАКЫЙКА́ТЬ»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1936 елда Токиода татар телендә нәшер ителә, барысы 5 саны чыга. Оештыручысы һәм мөхәррире җәмәгать һәм дин эшлеклесе Мөхәммәд-Габделхәй Корбангалиев (1889–1972) була. 1919 елның октябрь–ноябрь айларында Омск шәһәрендә ул «Каһарман башкорт» г-тасын нәшер итә. Японияга күчеп киткәннән соң, Токиода мөселман җәмгыяте җитәкчесе була, мәдрәсә ача. «И.х.» г-тасы, «*Яңа япон мөхбире*» ж-лы кебек үк, Корбангалиев оештырган «Матбагаи исламия» басмаханәсендә басыла.

*Әд.:* Ю н у с о в а А.Б. Ислам в Башкортостане. Уфа, 1999; Курбангалиевы // Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*Т.М.Насыйров.*

**ИДАРӘ́ ИТҮ́ ТЕО́РИЯСЕ**, техникада һәм кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә нәтиҗәле автоматик идарә системалары төзү өчен системалар, объектлар һәм процесслар б-н идарә итү закончалыкларын һәм алымнарын өйрәнүче фән тармагы. Сызыкча һәм нәсызыкча системаларны матем. тикшерү алымнарына нигезләнә, гамәли математика, кибернетика, информатика б-н тыгыз бәйләнгән.

И.и.т. 19 йөзнең 2 нче яртысында, теоретик механиканың пар һәм эл. машиналарын автоматик көйләү процессларын өйрәнү бүлеге буларак барлыкка килә. Кулланыла торган алымнарның универсаль булуы абстракт матем. модельләр төзүгә күчү мөмкинлеге бирә. 20 йөзнең 2 нче яртысында инде И.и.т. икътисад һәм терек табигать процессларын тикшерүдә киң кулланыла.

1950 елларда Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты) *хәрәкәт тотрыклылыгы теориясе* идеясе йогынтысында И.и.т.

өлкәсендә эшләр башлана; 1960 елларда идарә итүнең оптималь законнарын төзү алымнарын үстерү буенча яңа фәнни юнәлеш барлыкка килә (к. *Оптимальләштерү*). Программалы хәрәкәт б-н идарә итү өлкәсендә (А.С.Галиуллин), оптималь идарә итү теориясендә (Н.В.Куршев, Т.К.Сиражетдинов, Ю.В.Кожевников), күп үлчәмле нәсызыкча идарә системалары теориясендә (И.И.Әхмәтгалиев), катлаулы идарә системаларын динамик тикшерүдә (В.М.Матросов), локаль-автомат идарә синтезында (Г.Л.Дегтярёв), идарә итүнең технол. процессларын автоматлаштыруда (А.Ф.Фафурин, Казан технол. ун-ты), техник-икътисади системалар б-н идарә итү (В.Н.Куршев) өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә һәм гамәли нәтиҗәләр алына.

Т.К.Сиражетдинов һ.б. галимнәр бүленгән параметрлы системаларны динамик программалаштыруның төп тигезләмәсен алу өчен Ляпунов функцияләре һәм Беллманның динамик программалаштыру алымнарының уртаклыгы идеясен кулланалар. Әлеге алымнарны эшләгәндә абстракт процесслар өчен Беллманның оптимальлек принцибын куллану чикләре билгеләнә.

Ю.С.Кожевников очраклы үзлекле системаларга карата Понтрягин максимумы принцибын куллана; алынган нәтиҗәләр системаның билгеләнелгән яки идарә итүнең очраклы параметрларына бәйле сыйфатларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Ул очкыч аппаратларның төп проект параметрларын һәм хәрәкәт программаларын оптимальләштерү мәсьәләләрен, аларны куллану максатлары һәм шартларының күплеген исәпкә алып хәл итү өчен «уртачада оптимальлек» принцибын эшли.

В.А.Боднер һәм Н.Е.Роднищев тарафыннан чик шартлары булган синтезлау мәсьәләләренә карата динамик программалаштыру алымы нигезләнә. Өзлексез стохастик системалар синтезы һәм программалы оптималь идарә итү мәсьәләләре, очраклы параметрлы, үзгәрүчән һәм сикерешле структуралы, мультипликатив һәм аддитив комачаулыклары булган системалар тикшерелә. Колмогоров-Фоккер-Планк тигезләмәсен якынча чишүгә нигезләнеп, стохастик системаларны оптимальләштерү мәсьәләләрен якынча чишү юллары ачып бирелә. А.С.Земляков космик аппаратның почмакча хәрәкәте б-н оптималь идарә итү мәсьәләсен тикшерә; Ляпуновның векторлы функцияләр алымын идарә системалары синтезына карата куллана.

И.и.т.нең яңа юнәлеше — объектның каһәгатьләнерлек эшчәнлеге эксплуатациясенең барлык режимнарында да тәэмин итүче һәм алдан куелган барлык таләпләр дә үтәлә торган идарә системаларын проектлаштыру үсеш ала (А.И.Богомолов, Т.К.Сиражетдинов, Г.Л.Дегтярёв, В.Н.Куршев һ.б.). ЭВМда күп үлчәнешле идарә системалары буенча тикшерү эшләре үткәрелә.

*Әд.:* Сиразетдинов Т.К., Богомолов А.И., Дегтярёв Г.Л. Аналитическое проектирование динамических систем. К., 1978; Галиуллин А.С. Аналитическая динамика. М., 1989; Куршев В.Н. Теория управления. Технико-экономические системы. К., 2004; шул ук. Теория управления. Социотехнические системы. К., 2007; Матросов В.М., Измоденова-Матросова К.В. Учение о ноосфере, глобальное моделирование и устойчивое состояние. М., 2005.

*В.Н.Куршев.*

**ИДАРӘ́ ИТҮНЕ́Ң ТӨП МӘСЬӘЛӘСЕ́**, системаның уңышлы эшләве критерийларына карата алдан бирелгән таләпләрне канәгатьләндерү шартларыннан параметрлар, функцияләр, схемалар сайлап алып, тигезсезлекләр системасы рәвешендә күрсәтү. И.и.т.м.нең куелышын беренче тапкыр 1973 елда Казан авиация ин-ты (хәзер Казан техник ун-ты) галимнәре Т.К.*Сиражетдинов* һәм А.И.*Богомолов* тәкъдим итә. Авиация төзелешендә, космонавтикада, төбәк икътисады б-н идарә итүдә һ.б. гамәли мәсьәләләр чишелә. И.и.т.м.н сызыкча мәсьәлә куелышында чишү (Н.Л.Алиев), очкыч аппаратларның билгесез грунтка вертикаль төшереп утырту җайланмаларын аналитик проектлау (А.М.Богомолов, Ю.П.Горшенин, А.В.Свилин һ.б.), атмосфераның тыгыз катлауларына кергәндә тормоз калканнарын ачу (Г.Е.Круглов) ысуллары эшләнә. Очкыч аппаратны билгесез ярсынулар, көйләгечләрнең параметрик синтезы шартларында утырту б-н идарә итүнең параметрлары синтезы мәсьәләсе (Н.Г.Зарипов, В.М.Деваев, В.Н.Куршев, П.К.Семёнов, Р.Т.Сиражетдинов, С.В.Смирнов, П.В.Смирнов); нәньютонча сыеклык хәрәкәте б-н идарә итү (В.И.Елизаров); сыгылмалы канатларның тиз тәэсире б-н оптималь идарә итү (Е.А.Клестов, Э.Т.Смирнова); канатның сыгылмалы тирбәнешләрен демпфирлау (И.Х.Халитов); очкыч аппаратларның канатларын аналитик проектлау (М.А.Богомольный, А.В.Халкин) һ.б. мәсьәләләр куела һәм чишелә.

*Әд.:* Сиразетдинов Т.К. Методы решения многокритериальных задач синтеза технических систем. М., 1988; шул ук. Основная задача управления и проектирования многорежимных технических объектов // Вест. Казан. техн. ун-та. 1995. № 1.

*Р.Т.Сиражетдинов.*

**ИДЕГӘ́Й** (1352–1419), Алтын Урда әмире (1399 елдан), Нугай Урдасына нигез салучы. 1377/78 дә *Туктамыш ханга* Күк Урда тәхетенә утырырга ярдәм итә. Соңрак, ханга каршы фетнә оештырылуы ачылгач (1389), *Аксак Тимер* тарафына кача һәм, аның ягыннан торып, Туктамышка каршы сугыша (1391). *Тимер Котлыгъ хан* җитәкчелегендә Идел арьягында ярым мөстәкыйль олыс оештыра. 1397 дә Аксак Тимердән чираттагы җиңелү кичергән Туктамышка каршы көрәш башлый һәм аны Кырымнан Литвага куып җибәрә. 1399 да Литваның бөек кенәзе Витовт б-н Туктамышның берләштерелгән гаскәрен тар-мар итә (к. *Бурсыклы (Ворскла) елгасы буендагы сугыш*). Алтын Урданың бердәмлеген торгызып, И. *Шадибәк хан* һәм *Булат Солтан хан* вакытында чынлыкта дәүләтнең идарәчесе була. 1408 дә Мәскәүгә һөҗүм ясый һәм аннан кабат ясак түләтә башлый. 1410 да сарай аксөякләре фетнәсе нәтиҗәсендә хакимияттән читләштерелә, Харәземгә кача, аннан 1414 тә куыла, үзенең урдасы б-н Идел һәм Урал елгалары арасында яңа дәүләт (Мангыт йорты) оештыра. 1416 да Руська яу б-н бара, Киевны яндыра. Тәхет өчен барган сугышта һәлак була. И.нең Алтын Урданың бердәмлеге өчен көрәше халык эпосы «*Идегәй*»нең нигезен хасил итә.

*Әд.:* Идегәй: татар халык дастаны. К., 1988. Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. Л., 1974; Татарский народный эпос. К., 1990; Измайлов И.Л. Идегей: жизнь, ставшая легендой // Татарстан. 1992. № 1/2.

*И.Л.Измайлов.*

**«ИДЕГӘ́Й»**, татар халкының тарихи героик-эпик шигъри дастаны. Ул *Туктамыш хан* һәм *Идегәй* әмир турында язылган күпсанлы риваять һәм легендалардан гыйбарәт. 17–18 йөзләрдә тулысынча формалашып бетә. «И.»нең алтай, башкорт, казакъ, каракалпак, Кырым татарлары, нугай, төркмән, үзбәк милли версияләре дә мәгълүм.

Дастанда Алтын Урданың таркалу чорындагы катлаулы һәм каршылыклы вакыйгалар бәян ителә. Алар Идел буеннан алып Урта Азия һәм Төньяк Кавказга кадәр сузылган гаять зур киңлекләрдә бара. Идегәй — дастанның баш герое, Алтын Урдада хан хакимиятенә каршы көрәшкә күтәрелгән каһарман. Дастанда Идегәй-хөкемдарның бөеклегенә, тәвәккәллегенә, батырлыгына һәм гаделлегенә дан җырлана; илдә чирек гасыр буена чагыштырмача тынычлык булдыруга китергән алдан күрүчәнлек сәясәте һәм дипломатиясе хуплана. Аның дошманы Туктамыш хан да — гайрәтле каһарман. «И.»дә уздырылган төп идея түбәндәгедән гыйбарәт: илдә хакимлек өчен барган көрәш, эчке чуалышлар, үзара низаг кешеләрне зур газапка сала, илне һәлакәткә китерә. Дастанның иң элек барлыкка килгән сюжетларының татар телендә язылa башлавы 17 йөз башына карый. «И.»нең беренче тулы язмасын 1919 елда Н.Хәким Себердә яшәүче С.*Зәйнетдиновтан* язып ала. Әсәрне фәнни яктан тикшерүгә беренче омтылышлар ясалу В.В.Радлов, П.М.Мелиоранский, А.Н.Самойлович исемнәре б-н бәйле, әлеге әдәби истәлекне өйрәнүгә Н.Исәнбәт зур өлеш кертә: ул Башкортстанда һәм Себердә кулланылышта йөргән версияләрне язып ала, 17–18 йөзләрдәге башка чыганакларны да өйрәнә һәм шулар нигезендә җыелма текст төзи. Текст «Совет әдәбияты» ж-лында (1940, № 11–12) басылып чыга. «И.» дастанына нигезләнеп, Н.Исәнбәт шул ук исемдәге трагедия яза. 1944 елның 9 августында ВКП(б) ҮК тарафыннан кабул ителгән «*Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында*» карары, аның артыннан ук ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросының 1944 елның 6 октябрендә чыгарылган карары нигезендә «И.» «зыянлы» дип, «ханнар-феодаллар» эпосы дип табыла, һәм 1990 елларга кадәр аны өйрәнү тыела. Хәзерге вакытта «И.»нең дистәләгән варианты бар. 1990 да дастанның С.Липкин тарафыннан 1942 елда рус теленә тәрҗемә ителгән варианты басылып чыга.

*Әд.:* С а м о й л о в и ч А.Н. Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н.Хакимовым // Тюркологический сборник. М., 1973; Ж и р м у н с к и й В.М. Тюркский героический эпос. Л., 1974; У с м а н о в М. О трагедии эпоса и трагедиях людских // Идегей. Татарский народный эпос. К., 1990; У р м а н ч е Ф. Народный эпос «Идегей». К., 1999; Йәзеүкәй менән моразым. Өфө. 1994; Rustem Eulti. Edigey. Ankara, 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ИДЕ́Л** (борынгы исеме Ра; урта гасырларда — Итил), Россиянең Европа өлешендә, Европада иң зур һәм дөньяда океанга коймаучы иң озын елга. ГЭСлар каскады һәм сусаклагычлар төзелгәнгә кадәр озынлыгы 3690 *км*, хәзер 3530 *км* (ТР чикләрендә 180 *км*), бассейнының мәйданы 1360 мең $км^2$ (ТР чикләрендә Кама елгасы бассейныннан тыш 30 мең $км^2$).

Валдай калкулыгыннан 228 *м* абс. биеклектә башлана, 28 *м* биеклектә Каспий диңгезенә коя (гомуми агып төшү биеклеге 256 *м*, ТР чикләрендә Куйбышев сусаклагычы су б-н тулганчы 9,5 *м* — 43,5 тән 34,0 *м* га кадәр була). И.дә 9 сусаклагыч төзелгән, аларның иң зурысы *Куйбышев сусаклагычы*, хәзерге вакытта И. агымлы күлләр системасыннан гыйбарәт. Мондый зур елга өчен агымның гомуми юнәлеше гадәти түгел — континент читеннән үзәгенә таба юнәлгән. Казанга кадәр И. географик киңлек юнәлешендә диярлек, ә аннары меридиан юнәлешендә ага. Тамак өлешендә 500 гә якын кушылдыгы һәм тармагы булган 12 мең $км^2$ га якын мәйданлы дельта хасил итә. И. бассейнының елгалар системасы гомуми озынлыгы 574 мең *км* булган 151 мең елга һәм инешне үз эченә ала. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 $км/км^2$. И. бассейны төньяктан көньякка — 1910 *км* га, көнбатыштан көнчыгышка 1805 *км* га сузыла. И. елгасының үзәне кискен асимметрик: уңъяк битләүләре текә һәм биек, төп токымнардан тора; сулъяк битләүләр сөзәгрәк, анда аллювиаль террасалар киң урын алып тора.

И. елгасының гидрологик режимын системалы рәвештә күзәтүләр 1876 елдан алып барыла, ш.и. ТР терр-ясендә Югары Ослан авылы, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы, Тәтеш шәһәре постларында; 1902 дән (1923–28 елларда тукталып тора) — Яшел Үзән р-нының Карамалы Тау авылындагы, ш.у. төрле елларда Кама Тамагы р-нының Красновидово (1936–56) һәм Олы Тархан р-нының Долиновка авылындагы (1931–34, 1938–55) постларда.

И.не 3 өлешкә бүлү кабул ителгән: югарыгы И. (башыннан Ока елгасы тамагына кадәр), урта И. (Ока елгасы тамагыннан Жигули тауларына кадәр), түбәнге И. (Жигули тауларыннан елга тамагына кадәр). Югарыгы И. дымлы урман зонасыннан үтә, шунлыктан елга буенча түбәнгә таба сулылыкның бик тиз артуы күзәтелә (сусаклагычлар б-н агымны ясалма көйләгәнгә кадәр суның уртача еллык чыгымы Тверь шәһәре янында — 182, Ярославльдә — 1110, Түбән Новгородта 2970 $м^3/с$ тәшкил иткән). Бассейнына ТРның барлык терр-ясе кергән урта И. тагын да мул сулырак (ТРның көнбатыш чигендә суның уртача еллык чыгымы 3500 $м^3/с$ тирәсе). ТРнда аңа иң зур кушылдык — Кама кушыла. И. елгасы б-н кушылган урында аның уртача еллык чыгымы (4100 $м^3/с$) И.некенә караганда зуррак. Тарихи традиция б-н хисаплашмасак, И. Кама елгасының кушылдыгы дип исәпләнелер иде. ТР терр-ясендә И.гә Зөя, Казансу һ.б. вак елгалар коя. Урман һәм урман-дала зонасында урнашкан урта И. һәм, аның кушылдыкларыннан аермалы буларак, түбәнге И. нигездә дала һәм ярымдала буйлап ага, шунлыктан сулылыгының артуы сизелерлек түгел (уртача еллык чыгымы Самара янында 7720 $м^3/с$, Волгоград янында — 8380 $м^3/с$).

И.нең төрле урыннарында кар сулары хисабына туену өлеше 50–65% (уртача 60%), грунт суларының — 21–43% (уртача 30%), яңгыр суларының 9–15% ка (уртача 10%) тигез. И.нең барлык бассейны өчен су балансының төп еллык элементлары:

явым-төшемнәр 660 *мм* (897 $км^3$)
елгалардан гомуми агым 187 *мм* (254 $км^3$)
ш.и. җир өсте агымы 136 *мм* (185 $км^3$)
җир асты агымы 51 *мм* (69 $км^3$)
гомуми парга әйләнү 453 *мм* (643 $км^3$)
ш.и. транспирация 142 *мм* (193 $км^3$).

Табигый шартларда И.дә ачык рәвештә язгы су ташу (апрель–июнь) һәм, җәйге, кышкы саегу чоры б-н аралашып, җәйге-көзге, нигездә, көзге яңгыр ташкыннары күзәтелгән. Су биеклегенең еллык тирбәнешләр амплитудасы югарыгы И.дә уртача 4 тән 8 *м* га кадәр, урта И.дә ТР чикләрендә уртача 10–11 *м*, иң күбе 15–17 *м* (хәзер 5–6 *м* дан күп түгел), түбәнге И.дә уртача 3–5 *м* тәшкил иткән. Суның иң зур чыгымы ташу вакытында Кама елгасы тамагында күзәтелгән һәм 60–67 мең $м^3/с$ булган. Бу режимга тиңдәш рәвештә агым тизлеге дә үзгәргән. Суның иң аз вакытында Карамалы Тау авылыннан Тәтеш шәһәренә кадәр булган өлештә агымның уртача тизлеге 0,8 дән 1,2 *м/с* ка кадәр, ташу вакытында 2–2,5 *м/с* ка җиткән. Хәзерге вакытта бу өлештә тизлекләр үзгәреше ел дәвамында зур түгел, уртача 0,1–0,2 *м/с* тәшкил итә.

Ел саен бөтен И. боз б-н каплана. Элегрәк елганың катуы ноябрь ахырында башланган һәм якынча 10 көн дәвам иткән. Сусаклагычлар төзелгәч, боз 3–5 көнгә алданрак күренә башлый, 120–140 көн дәвам иткән боз кату 5–10 көнгә озая. Бозның макс. калынлыгы арта (60–80 *см* га яки 15–20% ка кадәр). Куйбышев сусаклагычын төзегәннән соң, суның июльдә күзәтелә торган иң югары темп-расы 22 дән 24 °С ка күтәрелә.

Ел саен И. Каспий диңгезенә 26 млн. *т* га якын йөзмә һәм 45 млн. *т* эрегән матдәләр алып килә (Казан янында агымның каты китерелмәләре тиңдәшле рәвештә 7,5 һәм 15 млн. *т*). Агымны ясалма көйләгәннән соң, төпкә утыру нәтиҗәсендә йөзмә материаллар чыгышы 8 млн. *т* га кадәр кими, эрегән материаллар чыгышы, пычрану аркасында елына 65–70 млн. *т* га кадәр арта. Уртача еллык су болганчыклыгы зур булмый: Карамалы Тау авылы һәм Тәтеш шәһәре янында бары тик 50–100 *мг/л*, су ташу вакытында 200–500 *мг/л* га кадәр күтәрелгән. Хәзерге вакытта ул тагын да түбәнрәк: су юып ашалучы ярлар янында уртача 20–50 *мг/л* дан зур түгел, сусаклагычның үзәк өлешләрендә 5–10 *мг/л*. ТР чикләрендә суның иң аз вакыттагы уртача минеральләшүе 250 дән 400 *мг/л* га, ташу вакытында 210 нан 260 *мг/л* га кадәр җитә (иң зур күрсәткечләр даими рәвештә И.нең Кама елгасы тамагыннан түбәнрәк өлешендә билгеләнә).

И.нең үсемлек һәм хайваннар дөньясы бай һәм күп төрле. Үсемлек төрләренең гомуми саны 1360 (аларның 342 се — югары төзелешле), хайваннарның — 2288 (ясалма көйләгәнгә кадәр аларның 74 е балыклар була, сусаклагычлар төзегәннән һәм акклиматизация эшләреннән соң бу сан 88 гә тигез).

Иделнең Ослан тауларыннан күренеше.





Иделнең Лобач тавыннан күренеше.

Аеруча кыйммәтле балык түбәнге И.дә һәм аның дельтасында үрчи һәм тотыла. XX йөз башында монда 2 млн. *ц* дан артык балык тотылган (мәрсин балыгы гына 270 мең *ц*). Шул ук вакытта уылдык чәчү миграцияләре вакытында мәрсин, сөләйман, сельдлар Татарстанның барлык эре елгаларына кадәр күтәрелгән. Хәзерге чорда үтеп йөрүче балыкларның төп массасы Волгоград янындагы ГЭС плотиналарында тоткарлана, бик сирәкләре генә Куйбышев сусаклагычының түбәнге бьефына килеп җитәләр. Шул ук вакытта сусаклагычларда (ш.и. Куйбышев) балыкчылык көтелгәнчә үсеш бирми. Промыселда һәм һәвәскәр балыкчылыкта корбан балык, судак, чабак, чуртан, густера өстенлек итә.

Куйбышев сусаклагычын төзегәннән соң агымның әкренәюе һәм И. суында биоген матдәләр концентрациясенең артуы аркасында, җәен фитопланктонның күпләп үсүе (суның «чәчәк атуы») күзәтелә. Аннан тыш, тугайлардагы көтүлек, печәнлек, аучылык җирләренең продуктив төп өлеше су астында кала (аеруча ТРда). Абразия һәм аның тарафыннан тизләтелә торган шуышмалар һ.б. сөзәклек күренешләре, яр буйларының су астында калуы — болар барысы да торак пунктларны, транспорт коммуникацияләрен һ.б. саклауда шактый гына чыгымнар таләп итә. ТР терр-ясендә И.нең уникаль елгадан агымлы күлгә әйләнүен танырга кирәк. Ландшафтны тулысы б-н үзгәрткән үзәндә бөтенләй яңа экосистема формалашкан.

Сусаклагычлар төзелү зур зыян сала торган су басулар (һәлакәтле су басу 1926 ның маенда була) куркынычын бетерә. Суднолар йөрү һәм сал агызу өчен шартлар шактый яхшыра. Сусаклагыч ярлары буенда урнашкан барлык эре шәһәрләрнең хуҗалык-көнкүреш, коммуналь һәм сәнәгый су б-н тәэмин ителеше тотрыклы төс ала. Яр буйларын рекреация максатларында куллану мөмкинлеге үсә. Казан, Яшел Үзән һәм шәһәр тибындагы Васильево посёлоклары тирәсендә ял йортлары, санаторийлар, балалар лагерьлары, дачалар һ.б. төзелә. Ирригация өчен шартлар яхшыра (бигрәк тә су б-н тәэмин ителеше аз булган Көнбатыш Кама аръягы р-ннары өчен). И. ГЭСларында елына уртача 33 млрд. *кВт·сәг.*кә якын электр энергиясе җитештерелә.

И. ярлары буенда күп кенә саклаулы терр-яләр билгеләнгән, аеруча мөһимнәре: Идел-Кама саклаулыгы, Лобач тавы, Тәмте кылган даласы, «Дачный» урман массивы («КГУ зоостанциясе»), Тархан имәнлекләре, Печище геологик киселеше һ.б.

И. елгасы бассейнында 60 млн. тирәсе кеше яши. И. ярларында 9 өлкә үзәге һәм 2 респ-каның баш калалары урнашкан. ТР чикләрендә И. буенда урнашкан шәһәр һ.б. торак пунктларда 1,3 млн.нан артык кеше яши (ТР халкының 35% ка якыны). И. элек-электән транспорт артериясе буларак билгеле. И.дә ТРда иң эреләрдән булган *Казан-Яшел Үзән сәнәгать төйнәлеше* формалашкан, Казан елга порты урнашкан.

И. ярларында Идел буеның борынгы шәһәрләре төзелгән була (Итил, Болгар, Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид, Үкәк, Казан һ.б.). Хәзәр каганлыгы, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан һәм Әстерхан ханлыклары да И. буенда урнашкан була.

И. елгасының матурлыгы, олылыгы, куәте аның ярлары буенда яшәүче барлык халыкларның риваять, легенда, җырларында, рәсем сәнгатендә тасвирлана. Аңа Н.А.Некрасов, И.Е.Репин, И.Е.Левитан, А.М.Горький, Н.Д.Кузнецов, А.С.Ключарёв, Б.И.Урманче, М.Г.Усманов һ.б. дан җырлый.

*Әд.:* Бассейн р.Волги ниже г.Чебоксары // Ресурсы поверхностных вод СССР. Л., 1971. Т. 12, вып. 1; Доманицкий А.П., Дубровина Р.С., Исаева А.И. Реки и озёра Советского Союза. Л., 1971; Водохранилища Верхней Волги. Л., 1975; Волга и её жизнь. Л., 1978; Гидрометеорологический режим озёр и водохранилищ. Куйбышевское и Саратовское водохранилища. Л., 1979; Бассейн рек Волги (среднее и нижнее течение) и Урала // Государственный водный кадастр. Л., 1985. Раздел 1, сер. 3, ч. 1, 2, т. 1, вып. 24; Средняя Волга: Геоморфологический путеводитель. К., 1991; Авакян А.Б. Волга в прошлом, настоящем и будущем. М., 1998; Малые реки волжского бассейна. М., 1998.

*В.И.Мозжерин.*

**«ИДЕ́Л»**, карабодайның эре бөртекле, диплоидлы сорты. 1983 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Н.Н.Петелина, Ф.З.Кадыйрова, В.М.Галактионова һәм Л.С.Нижегородцева тарафыннан салкынга каршы торучанлыкны формалаштыра торган питомник үсентеләре арасыннан аерым һәм үзара серкәләнүчеләрне сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Билгеле сортлардан эре бөртекле, тиз һәм бер вакытта өлгерүчәнлеге б-н аерыла. 1000 бөртекнең авырлыгы 32 *г.* Вегетация чоры 64–70 көн. Бу сорт экстремаль темп-ра шартларына һәм сөрлегүгә бик чыдам. Сынау нәтиҗәләре «И.»нең җиде өлкәдәге сорт участокларында районлаштырылган сортлар б-н чагыштырганда югары уңыш бирүен күрсәтә. Җитештерү бәяләмәсен 1984 елда Әлмәт р-ны кырларында ала. Уңыш бирүе буенча «И.» сорты районлаштырылган «Майская» сортыннан «Россия» к-зында 1 *га* дан 4 *ц* га (чәчүлек мәйданы 80 *га*), «Кичү» с-зында 1 *га* дан 1,1 *ц* га (чәчүлек мәйданы 100 *га*) югарырак. Бу сорт ТРда 1987 дә районлаштырыла.


*Әд.:* Крупяное поле Татарии. К., 1979; Крупноплодные диплоидные сорта гречихи. К., 1991.

**«ИДЕ́Л»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1907 елның 26 июленнән 1914 нең 27 гыйнварына кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 623 саны чыга. Беренче мөхәррире һәм нашире — З.Шәрифуллин. 1907 нең 20 ноябреннән Г.*Гомәри* басмаханәсендә басыла. Иң актив авторлар арасында — иҗтимагый-сәяси, икътисади мәсьәләләр буенча — И.Бәдигый, Г.Камачкина, А.Локман, К.Сәгъди, Х.Йосыфи, З.Янгалычев һ.б., мәдәни, мәгърифәтчелек һәм әдәби мәсьәләләр буенча — В.Җәлал, Н.Гасрый, Г.Ибраһимов, Б.Киләчи, Г.Ниязи, К.Патый, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, М.Тимергалин, М.Фәйзи һ.б. Газета редакциясе үз алдына мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалау, татарларның милли хәрәкәтендә милли бердәмлеккә ирешү, Россиядәге һәм аннан читтәге иҗтимагый-сәяси хәлләрне яктырту максатын куя. «И.» — татар телендә чыга торган газеталар арасында зыялыларга йөз тотучы, татар милли хәрәкәтендә аерым агымга кушылмаган басмаларның берсе. Төп тематикасы: шәкертләр хәле, мәдрәсәләрдә белем бирү системасына үзгәрешләр кертү (реформа ясау); хатын-кызларның хокуклары; а.х., сәүдә, медицина һ.б. торышы. Татарларның мәдәни тормышын яктыртуга зур урын бирелә; әдәбият бүлегендә күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре басыла. 1910 да «Коръән турында киңәшмә» (№ 606), «Төркия һәм Европа» (№ 607), «Төркиядә христианнар эшчәнлеге» (№ 609) мәкаләләрен бастырганы өчен газета ябыла. Газетаның цензоры Г.Гомәри Әстерхан губернаторы И.Искәндәров б-н дустанә мөнәсәбәтләрдә торган. 1910 елның 27 апреленнән, З.Шәрифуллин Казанга киткәннән соң, газетаның мөхәррире итеп Г.Гомәри билгеләнә һәм «И.» яңадан чыга башлый.

*Әд.:* Гыйниятова Ф. «Идел» газетасында поэзия // Әдәбият чыганаклары һәм текстология. К., 1992; Рәхимов С. Остазлар һәм шәкертләр // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 4.

*Ф.Х.Җәүһәрова.*

**«ИДЕ́Л»**, ТАССР яшь язучыларының әдәби-публицистик альманахы. ТАССР Язучылар берлеге органы. «*Үсү юлы*» альманахының дәвамчысы. 1958–60 елларда (4 сан), 1970–89 да (21 сан) Казанда татар телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — Г.*Хуҗи*, Х.*Сарьян*, М.*Шабаев*, Ф.*Шәфигуллин*, М.*Вәлиев*, Х.*Халиков*, К.*Кәримов*, Н.*Гыйматдинова*. Альманахта М.Әгъләмов, М.Галиев, Зөлфәт, К.Кәримов, Э.Мостафин, С.Хафизов һ.б. язучылар һәм шагыйрьләрнең чәчмә һәм шигъри әсәрләре басыла. Басманың бизәлешендә Л.Насыйров, С.Насыйрова, Р.Има-




«Идел» альманахы.

шев h.б. рәссамнар катнаша. Татарстан Язучылар берлегенең «*Идел*» ж-лы басыла башлагач чыгудан туктый.

**«ИДЕ́Л»**, айлык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. Гамәлгә куючылар: ТР Язучылар берлеге һәм журнал редакциясе коллективы. Нәшер итүче: «Татмедиа» ЯАҖ. 1989 елның июленнән Казанда татар һәм рус телләрендә чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — Р.С.*Вәлиев*, Ф.М.*Зөлкарнәев*, Р.М.*Низамиев* (1997 дән), Н.М.*Гыйматдинова* (2006 дан), Р.Ә.*Фәттахов* (2009 дан). Сугыштан соңгы елларда Татарстанда яшьләр өчен чыга торган беренче журнал. Башта «Әдәбият, мәдәният, яшьләр, заман» дигән икенче исем б-н чыга. Күбесенчә яшь һәм башлап язучы авторларның чәчмә, шигъри һәм публицистик әсәрләре басыла. Татар әдәбиятында тарихи хикәяләр жанрын үстерү максатыннан «И.» тарихи хикәяләргә конкурс үткәрә. Журналның төп тематикасы: яшьләр проблемалары, республикадагы әһәмиятле вакыйгалар, атаклы кешеләр тормышы, ТРның иҗтимагый-сәяси үсешенең актуаль проблемалары, Татарстанда татарлар h.б. халыкларның тарихы, татар теле һәм мәдәниятенең үсеше, республикадан читтә яшәүче татарлар тормышы һәм мәдәнияте, әхлак һәм дин мәсьәләләре. Төп рубрикалары: «Яңа дулкын», «Вәзгыять», «Мирас», «Бөекләр», «Очрашу», «Сәхнә», «Мин!», «Сәяхәтнамә», «Яшьләр галәме», «Югалган йортлар шәүләсе», «Ша-ярыш», «Йолдызнамә» h.б.

*Әд.:* Судьин А. Журнал «Идель» как трибуна татарского национального движения (обзор за 1993–1997 годы) // Вестн. Евразии. 1999. № 1/2.



«Идел» журналы.

**ИДЕ́Л АЛДЫ́**, ТРның физик-географик төбәге. Иделнең уңъяк ярында урнашкан. Мәйданы 12,6 мең *км²*. *Идел буе калкулыгының* төньяк-көнчыгыш өлешен алып тора. Иң зур биеклеге (280 *м*) Чүпрәле р-нының көньяк-көнбатышында. И.а., Зөя елгасының түбәнге агымындагы үзәне б-н мәйданнары буенча якын 2 өлешкә бүленә: көнчыгыш өлеш рельефы буенча калкулыклы һәм катлаулы, көнбатыш өлешенең биеклеге кимрәк һәм тигезрәк. Елга челтәренең тыгызлыгы күбесенчә 0,3–0,4 *км/км²*. Зөянең аеруча зур кушылдыклары: Чынлы, Карлы, Бола, Гөбенә (сул) һәм Кылна, Үләмә, Сөлчә (уң). Төбәкнең төньяк өлештәге өслеге Пермь системасының Казан һәм татар яруслары токымнарыннан (известьташ, доломит, гипс, мергель) тора. Буа шәһәреннән көньяктарак урнашкан киңлекләрдә юра һәм түбән акбур системасы балчыклары һәм комташлары, көньяк-көнбатыш читендә югары акбур системасының известьле мергельләре аеруча таралыш алган. Балчык утырмаларда шуышмалар



Идел алды.

көчле җәелә бара. Казан ярусының известьташ һәм гипсларында карст упкыннары бар. Идел үзәненең уңъяк сөзәклегендә мәгарәләр комплексы формалашкан (к. *Кама Тамагы спелеология системасы*). И.а. климаты чагыштырмача җылы һәм дымлы җәй, салкынча һәм уртача карлы кыш б-н аерыла. Гыйнварның уртача күпьеллык темп-расы көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба –13°С тан –13,6 °С ка кадәр, июльдә — көнбатыштан көнчыгышка таба 18,9 °С тан 19,6 °С ка кадәр үзгәрә. Иң түбән абс. темп-ра –48 °С (1942, Буа), иң югары темп-ра 39 °С (1971, Буа). 1960 еллар уртасыннан гыйнварда уртача темп-ра 1,5–1,6 °С ка, июльдә 0,1–0,3 °С ка арта. Суык булмаган вакыт озынлыгы көнбатыштан көнчыгышка таба 125 тән 146 көнгә кадәр тирбәлә. Еллык явым-төшем 500–540 *мм*, ш.и. җылы чорда 340–360 *мм* тәшкил итә. Кар капламының калынлыгы 32–43 *см*. И.а. урман-дала зонасында урнашкан. Аның төньяк өлешендә соры һәм көрән-соры урман туфраклары, көньякта, мезозой балчыкларында, селтесезләнгән һәм көлсуланган кара туфраклар формалашкан. Соңгы 200 елда И.а.ның урманлылыгы 3 тапкыр кимегән (10% ка кадәр). Яфраклы урманнарның шактый зур өлеше көньяк-көнчыгышта (Чуртан тауларында) сакланган. А.х. җирләре (нигездә, сөрү җирләре) көнчыгышта барлык мәйданның 50–60%н, көнбатышта 80–85% ка кадәрен алып тора. Файдалы казылмалардан балчык, известьташ чыганаклары гадәти, гипс һәм янучан сланецларның республикадагы төп сәнәгый запаслары тупланган, битум, акбур, фосфорит, цеолит чыганаклары бар.

И.а. төбәгендә аеруча сакланулы табигать истәлекләре шактый күп билгеләнгән. Идел елгасы үзәненең уңъяк текә сөзәклегендә, югары Пермьнең югары Казан (к. *Печище геологик киселеше*, *Ташлы ерым*) һәм түбән татар асярусларында (к. *Черёмушки*) халыкара әһәмияткә ия киселешләр ачыла. Беренче 2 се ЮНЕСКОның дөньякүләм геологик мирасы исемлегенә кертелгән (1998). Иделнең уңъяк ярында ш.у. табигать саклаулыклары урнашкан: «*Зөя*» комплекслы табигать тыюлыгы, *Лобач тавы*, *Лабыш таулары*, *Озын Алан*. Төрле р-ннарда табигать истәлекләре билгеләнгән: урман (*Тау наратлыгы*, *Турминка урман дачасы*, *Кайбыч имәнлекләре*, *Тархан имәнлекләре*); ботаник (*Кликовка сөзәклеге*, *Тәмте кылган даласы*, «*Таштау*», *Кирәмәт*); зоол. (*Яңа Тинчәле сөркә* (*байбак*) *колониясе*, *Утинкә сөркә* (*байбак*) *колониясе*); елгалар — (*Зөя*, *Үләмә*, *Бәрле*, *Сөлчә*); күлләр — (*Сал күле*, *Сабакай күле*, *Урман күле*, *Карамалы күле*, *Күл*, *Зур күл*).

*Әд.:* Физико-географическое районирование Среднего Поволжья. К., 1964.

*А.П.Дедков.*

**ИДЕ́Л АЛДЫ́ ИКЪТИСАДИ́ РАЙОНЫ́**, аграр төбәк, Идел елгасының уңъяк ярында, ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы 7455,5 *км²* (ТР терр-ясенең 11%). 6 административ р-н (Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш), 2 шәһәр (Буа, Тәтеш), 4 шәһәр тибындагы посёлок (Апас, Кама Тамагы, Куйбышев Затоны, Тенеш) керә. 2007 елның башында 153,8 мең кеше, ш.и. шәһәр халкы 28,7%, эшкә яраклы яшьтәгеләр 54,7%. Туым (1 мең кеше исәбенә) — 9,3, үлем — 16,9, халыкның табигый кимүе 7,6. И.а.и.р. терр-ясеннән Зөя–Ульянов тимер юлы, федераль әһәмияткә ия Казан–Ульянов автомобиль юлы уза. А.х. җирләре 575,4 мең *га* (ТР а.х. җирләренең 12,6%), ш.и. сөрү җирләре 448,9 мең *га*. Уҗым арышы, уҗым һәм сабан бодае, арпа, борчак игелә, шикәр чөгендере, бәрәңге h.б. культуралар үстерелә. Терлекчелектә төп тармаклар — ит-сөт җитештерү, дуңгыз, сарык үрчетү. 2006 да ТР а.х. тулаем продукциясенең 12,4%ы җитештерелә, ш.и. 14,5% бөртекләләр, 52,6% шикәр чөгендере, 13,4% бәрәңге, 3,3% яшелчә, 11,2 әр % ит һәм сөт, 3,6% йомырка, 18,8% йон. Сәнәгать пр-тиеләре, нигездә, Буа шәһәрендә һәм р-нында (шикәр, машина төзү, спирт-аракы, Әхмәт электромеханика з-длары, мамык ф-касы, май-сыр комб-ты), шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы һәм Кама Тамагы р-нында (гипс руднигы — ТРда гипс ташын төп чыгаручы, «Камойл», Куйбышев исем. ремонт-эксплуатация нефть флоты базасы, «Волготанкер» вәкиллеге) урнашкан. Башка р-ннарда ит һәм сөт эшкәртү,

ашлык кабул итү пр-тиеләрендә он һәм ярма җитештерү, балык тоту һәм эшкәртү, икмәк пешерү сәнәгате пр-тиеләре эшли. Буа һәм Тәтештә махсус урта белем бирү йортлары бар. *Ф.Г.Борһанов.*

**«ИДЕ́Л АРТЫ́ ХӘРБИ́-СӘЯСИ́ ИДАРӘСЕ́ ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1920 елда Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 2 саны чыга. Беренче саны 1920 нең 5 июнендә дөнья күрә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом): 1905–1925. К., 1926; Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать. К., 1999.

**ИДЕ́Л А́РЪЯГЫ ТҮБӘНЛЕГЕ́**, Идел елгасының сулъяк яр буендагы аккумулятив тигезлек, төньякта Кама елгасының түбәнге агымыннан киң полоса (120–180 *км*) булып 500 *км* га, көньякта Каспий буе түбәнлегенә кадәр сузылган. Көнбатышта Куйбышев һәм Саратов сусаклагычлары, көнчыгышта Биек Идел аръягы калкулыгы (Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы, Гомуми Сырт) сөзәклекләре б-н чикләнә. Иң зур биеклекләре 100–160 *м*. ТР терр-ясен (*Көнбатыш Кама аръягы* чикләрендә), Ульянов, Самара һәм Саратов өлкәләренең бер өлешен үз эченә ала. И.а.т. Самара Дугасы р-нында (Тольятти–Самара–Сызрань участогында Идел борылмасы) Жигули таулары б-н *Мәләкәс батынкылыгына* тоташкан төньяк һәм Бозаулык батынкылыгына туры килүче көньяк өлешләргә бүленә. Неоген һәм дүртенчел чорның елга, күл, эол һәм диңгез (Каспий) утырмаларыннан барлыкка килгән. Дүртенчел чор ятма балчыклары һәм комсыл балчыклар киң таралган. Урыны б-н югары Пермь балчыклары, мергель, комташ, доломитлар җир өслегенә чыга. Рельефы җиңелчә бүгәләнгән, авыш сөзәкле, аз үсеш алган ерымнар челтәреннән (төньяк өлештә 0,1 *км/км*² га кадәр) гыйбарәт. Төп елгалары — Иделнең сул кушылдыклары, төньяк өлештә Актай, Бизнә, Үтәк, Олы һәм Кече Чирмешән, Кондырча, көньякта — Чапаевка, Чагра, Олы һәм Кече Иргиз. Елгаларның туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Климаты уртача континенталь (гыйнварда уртача темп-ра −12 дән −14 °С ка кадәр, июльдә 20–22 °С); Идел буе калкулыгы б-н чагыштырганда дымлылык кимрәк. Явым-төшем күләме төньяктан көньякка таба 450–500 *мм* дан 250–350 *мм* га кадәр кими. Коры җилләр һәм корылыклар еш була. Үсемлекләр зонасына туры килүче 2 туфрак зонасын билгелиләр. Түбәнлекнең төньяк өлеше — соры урман туфраклары б-н беррәттән, көлсуланган һәм селтесезләнгән кара туфраклы урманлы дала зонасы (урманнар аерым участокта сакланган), көньякта шактый өлеше сукаланган, типик кара туфраклы дала зонасы. Халкы күбесенчә авылларда яши. Игенчелек алга киткән. Хайваннар дөньясы өчен төньяк (бүре, поши, ак куян, тиен, җофар һ.б.), урман-дала (җирән йомран, Эверсман әрләне) һәм дала (кече йомран, зур колаклы керпе, кече чыелдык, төлке-корсак һ.б.) төрләре хас. *А.П.Дедков.*



Идел аръягы түбәнлеге күренеше.

**«ИДЕ́Л БУЕ́»**, газета, к. *«Ялкын»*.

**«ИДЕ́Л БУЕ́ АЗ САНЛЫ́ ХАЛЫКЛАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́»**, иҗтимагый оешма. 1917 елның 22 мартында Казанда оештырыла; уставы беренче гомуми җыелышта кабул ителә. Төп оештыручыларның берсе — чуаш җәмәгать эшлеклесе, галим Н.В.*Никольский* (рәис итеп сайлана). Максаты — Идел буе аз санлы халыкларының милли мәдәниятен, телен һәм мәгарифен үстерү. Казанда яшәүче, укучы һәм хезмәт итүчеләрдән чуаш (1917 нең августында — 193 кеше), мари (47 кеше), керәшен татарлар (27 кеше), удмурт (7 кеше) һәм мордва милли секцияләре оештырыла. Җәмгыятькә теләктәшлек итүчеләр сыйфатында руслар (36 кеше) һәм башка халыклар вәкилләре керә. Устав нигезендә җәмгыять советына рәис, аның урынбасары, секретарь, казначы, секциясе булган халыклардан берәр вәкил керә (әгъзалары: И.Яковлев, М.Евсевьев, М.Филиппов, С.Гаврилов, М.Костылёв, А.Межуев, И.Межуев (казначы). Җәмгыятькә шулай ук Идел буенда яшәүче теләсә кайсы аз санлы халык вәкиле (чуаш, мари, удмурт, мордва, коми-пермяк, коми-зырян, керәшен татар, мишәр, нагайбәк, калмык) керә ала. Җәмгыятьтә Идел буе халыкларының мәдәнияте һәм көнкүрешенә кагылышлы агымдагы мәсьәләләр, укытучылар әзерләү һәм туган телдә укыту мәктәпләре булдыру мәсьәләләре карала, аз санлы халыклар телләренә китаплар тәрҗемә ителә һәм басыла, уку йортлары һәм китапханәләр оештырыла. Җәмгыять инициативасы б-н 1917 нең 15 маенда Казанда Идел буе аз санлы халыкларының 1 съезды була (500 дән артык кеше катнаша). Аны үткәрүгә акчаны Дәүләт Думасының Вакытлы ком-ты бирә (7 мең сум). Съездда кабул ителгән резолюциядә болай диелә: «Учредительләр җыенына, түбәндәгеләрне тәэмин итеп, Россиядә демократик республика урнаштырырга кирәк, дип табарга: 1) иң киң автономия: җирле шартларга туры китереп, аерым һәм үзенчәлекле үткәне булган окраиналарга — сәяси; барлык халыкларга — мәдәни һәм 2) Россия Державасының барлык халкына иң киң үзидарә». Чуаш телендә «Хыпар» («Хәбәр») г-тасы чыгара. 1918 дә яшәүдән туктый.

Чыг.: Устав Общества мелких народностей Поволжья. К., 1917. *Л.М.Айнетдинова.*


**ИДЕ́Л БУЕ́ БОЛГА́Р ДӘҮЛӘТЕ́** (Идел буе Болгары, Идел-Чулман буе Болгар дәүләте), урта гасырларда Идел-Урал төбәгендәге (10 йөз башы — 1236) төрки феодаль дәүләт. *Болгарларның* 7 нче йөз ахырында Урта Донның уңъяк яры буйларыннан Идел буена күчеп килүләре нәтиҗәсендә барлыкка килә. Баштарак алар Идел буендагы Самара Дугасыннан Чулман тамагына кадәрге терр-яне биләгәннәр. Тора-бара болгарлар балт-славян кабиләләрен («Имәнкискә культурасы» халкын) кысрыклап чыгаралар яки басып алалар, *бәрәнҗәрләрне, барсиллар, сувар*лар, *әсәгелләр, биләрләрне* һ.б. төрки һәм фин-угор телле кабиләләрне буйсындыралар. Соңрак И.б.Б.д. халкы составына угыз-бәҗәнәк һәм кыпчак кабиләләренең, ш.у. күрше халыкларның (*бортаслар, маҗарлар, муромлылар* һ.б.) аерым төркемнәре керә. Дәүләт оешу барышында болгарларның *Алмыш илтәбәр* җитәкчелегендәге этносәяси берләшмәсе (кабиләләр берлеге) көчлерәк булып чыга, ул 10 йөзнең 1 нче яртысында Болгар һәм Суар әмирлекләрен төзи (к. *Суар бәклеге*). *Хәзәр каганлыгының* тар-мар ителүе (10 йөз ахыры) нәтиҗәсендә бердәм Болгар дәүләте барлыкка килә. 11 йөз башында И.б.Б.д. көнбатышта Ука-Зөя елгалары аралыгыннан, көнчыгышта Көньяк Уралга, көньякта Сура буйларыннан һәм Самара Дугасыннан төньякта Чулман алды төбәгенә кадәр җәелгән терр-яләрне били. 12 йөздә Болгар идарәчеләре үзләренең йогынты өлкәләрен Югары Чулман буена һәм үзәге *Саксин* шәһәре булган Түбән Идел буена кадәр киңәйтәләр. 922 елда И.б.Б.д. дипломатик танылуга ирешә — ул Багдад хәлифәлеге б-н илчеләр алмаша (к. *Бохарага һәм Багдадка Алмыш илтәбәр илчелеге, Болгарга әл-Моктәдир илчелеге*). 985 тә Болгар идарәчесе Киев кенәзе Владимир I б-н солых төзи, шул рәвешле тигез хокуклы һәм үзара файдалы мөнәсәбәтләр урнаштыра. 10 йөздә — 11 йөзнең беренче утыз елында хакимлек иткән Болгар идарәчеләреннән *Шилки*, Алмас (Алмыш), *Микаил бине Җәгъфәр*, Микаил бине Әхмәд, *Абдуллаh бине Микаил*, *Та-*

*либ бине Әхмәд, Мөэмин бине Әхмәд, Мөэмин бине Хәсән*, Абдрахман бине Мөэмин, Әбү Исхак Ибраһим бине Мөхәммәд исемнәре билгеле.

Болгар дәүләте югары үсешкә ирешкән социаль структурага ия була. Чыганаклар (ш.и. нумизматик мәгълүматлар) болгарларның Алмыш нәселеннән килгән идарәчеләре династиясе — Җәгъфәриләр хакында хәбәр итә. Алар 10 йөз башында илтәбәр (10 йөз уртасыннан — әмир) титулы йөртәләр һәм тулы хокуклы идарәчеләр булалар, аларның исеме (хәлифәдән соң) көн саен укыла торган догада (хөтбәдә) искә алына, алар дәүләт сәясәтен билгелиләр һәм үз акчаларын сугалар. Болгар җәмгыятенең социаль өстен катлауларының бер-берсенә буйсыну тәртибе язма чыганакларда төгәл генә күрсәтелми; аларда аерым җирләр һәм шәһәрләр б-н идарә итүче бәкләр, хәрби аксөякләр (чуралар) һәм мөселман дин әһелләре искә алына. Халыкның төп массасы ирекле авыл җәмәгате әгъзаларыннан һәм шәһәрдә яшәүчеләрдән (һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр һ.б.) — дәүләт казнасына йорт башыннан салым түләүче ясаклы кешеләрдән тора. Антропологик нисбәттә И.б.Б.д. халкы бертөрле була һәм катнаш европа-монгол субурал тибы буларак характерлана (к. *Антропология*).

Болгарларның хуҗалык итү нигезен гади дала рәвешендәге игенчелек, ярымутрак һәм утрак терлекчелек, балыкчылык, кәсепчелекнең аерым төрләре (затлы мехлы җәнлек аулау, чолыкчылык һ.б.), төрле һөнәрләр (тимер һәм бронза әйберләр эшләү, агач эшкәртү, сөяктән әйберләр, пыяла, чүлмәк, зәргәрчелек эшләнмәләре, корал ясау һ.б.), төбәктәге һәм халыкара сәүдәдә катнашу тәшкил итә. Төп сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләре *Болгар* (*Ага Базар* бистәсе б-н), *Биләр, Суар, Җүкәтау, Ашлы* шәһәрләре була, моны табылган тәңкәләр, төрле илләрдән китерелгән әйберләр дәлилли. И.б.Б.д.нең Русь, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европаның башка илләре, ш.у. Кавказ артындагы һәм Кара диңгез буендагы дәүләтләр б-н актив сәүдә-икътисади багланышлары ныгый. Читкә кыйммәтле мех, тире, күн (ш.и. аның аеруча яхшы эшкәртелгән, «болгари» атамасы б-н танылган төре — к. *Сафьян*), ашлык, бал һәм балавыз чыгарыла, читтән бизәнү әйберләре, аш тәмләткечләр, ефәк, корал, көмеш (9–10 йөзләрдә), гәрәбә һ.б. кертелә. Казнаның иң мөһим керем чыганакларының берсе сәүдәдән алынган салым — пошлина (дисәтинә, ягъни уннан бер өлеш) була.

И.б.Б.д. терр-ясе торак пунктларның куе челтәре б-н каплана. Язма һәм археол. чыганаклар буенча 150 ләп шәһәр (ш.и. *Болгар шәһәрлеге, Биләр шәһәрлеге, Богдашкино шәһәрлеге, Җүкәтау шәһәрлеге, Суар шәһәрлеге*), 800 дән артык авыл, ш.у. кечерәк шәһәрчек-ныгытма калдыклары билгеле. 10 йөздә Болгарда һәм Суарда болгар акчалары сугыла. Дәүләт башкалалары: 10 йөз — 12 йөзнең 1 нче яртысында — Болгар, 12 йөз уртасыннан — Биләр. Шәһәр төзелешенең *Болгар культурасы* кайбер төрки дәүләтләр (Төрки каганлык, Бөек Болгар, Хәзәр каганлыгы




һ.б.), ш.у. мөселман Шәрегы илләре һәм Русь традицияләрен колачлый. И.б.Б.д.нең күп кенә шәһәрләре, урындагы рельефка бәйсез хәлдә, ныгытмалар б-н эчке һәм тышкы шәһәрләргә бүленеп төзелә (Биләр, Суар, Җүкәтау һ.б.). Болгар шәһәрләренең күпчелеге утар-кварталлар рәвешендә була. Кайчак шәһәр ныгытмалары артында кәрвансарай корылмалары урнаша. Шәһәрләр күбесенчә агач йортлардан, ярымземлянкалар һәм землянкалардан, ш.у. хуҗалык корылмаларыннан (һөнәрчелек-кәсепчелек остаханәләре, металл эретү һәм чүлмәк яндыру-киптерү мичләре) гыйбарәт була. Алар арасында монументаль архит-ра корылмалары — кирпечтән һәм ак таштан салынган җәмәгать биналары (мәчетләр, мунчалар, кәрвансарайлар һ.б.) һәм төрбәләр аерылып тора. Аларны салганда таш блоклар (240×240×300 *мм*), кирпечләр (250×250×50 *мм*) һ.б. материаллар кулланыла. Кайбер очракларда эре шәһәрләрдән ерак түгел зур булмаган, ныгытылган торулыклар, ихтимал, аксөякләрнең ныгытмалары төзелгән (мәс., Биләргә якын урнашкан Никола-Баран II һәм Горка шәһәрлекләре). Шәһәрләрнең чокырлар һәм туфрактан өелгән урлар рәвешендәге ныгытмалар системалары була, урлар өстенә төрле конструкциядәге агач диварлар корыла.

И.б.Б.д.ндә төп дин — ислам өстенлек итә, ул Идел-Урал төбәгенә 10 йөзнең 1 нче яртысыннан Төньяк Европа һәм Шәрекъ илләре арасында сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырылу нәтиҗәсендә үтеп керә башлый. Исламның Идел буенда таралуы Урта Азиядән (Харәзем һәм Саманилар дәүләтеннән) вәгазьчеләр килү б-н бәйле. Болгарларның тарихи риваятьләрендә И.б.Б.д.ндә ислам кабул ителү Бохарадан килгән вәгазьчеләр («фәкыйһләр») эшчәнлегенә бәйләп тасвирлана. 9 йөз ахыры — 10 йөз башында ук инде сәүдә багланышлары сәяси элемтәләргә китерә, Болгар дәүләте ныгыгач, шәһәрләр барлыкка килгәч һәм Болгар идарәчеләре мөселманлык кабул иткәч, ислам төп дин булып әверелә (900–920 еллар тирәсе). Багдад хәлифәсе әл-Моктәдирнең илчелеге бу илдә булып киткәннән соң (922), исламның йогынтысы нык көчәя. Баштарак мөселман җәмәгатьләре Болгар, Суар, Биләрдә һ.б. эре шәһәрләрдә барлыкка килә. 10 йөз ахырына илнең барлык халкы диярлек мөселманлаша, бу хакта археология мәгълүматлары дәлилли: 10–11 йөзләрдән башлап һәркайда каберлекләрдә мөселман йолалары киң тарала (мәет кыйблага каратып, гәүдәсе аз гына уң якка янтайтып, яны һәм йөзе Мәккә ягына борып җирләнә; кагыйдә буларак, кабергә әйберләр куелмый һ.б.). И.б.Б.д.ндә исламны кабул итү нәтиҗәсендә аның мәдәни багланышлары Шәрекъ илләренә юнәлдерелә. Ислам Болгар җәмгыятенең рухи тормышына зур йогынты ясый, мәҗүсилек культын хорафатлар буларак кысрыклап чыгара. 10 йөз ахырына И.б.Б.д. «классик ислам» иленә әверелә, анда күп кенә танылган мөселман галимнәре һәм дин белгечләре яши һәм иҗат итә. И.б.Б.д. ислам дине таралган иң ерак төньяк иле була.

Әлеге нык үскән Болгар дәүләте шартларында интенсив рәвештә шәһәр тибындагы

мәдәният формалаша, төрле диалектларны берләштергән шәһәр сөйләме (ул, ихтимал, әле төрки-болгар кабиләләренең төрле диалектлары рәвешендә яшәгән кыпчак-угыз тибындагы төрки тел нигезендә барлыкка килә). Бу хакта, аерым алганда, көнкүреш әйберләрендәге язулар дәлилли. Аның нигезендә Урта Азия (караханилар) традицияләре йогынтысында болгар әдәби теле формалаша. Бер үк вакытта халыкның бер өлеше, ихтимал, аксөякләр огур тибындагы — ротацизм, ламбдаизм һ.б. архаик үзенчәлекләре булган төрки тел кулланган (к. *Болгар теле*).

Гамәли-бизәлеш сәнгате, музыка һәм әдәбият үсеше турында төрле мәгълүматлар бар. Барлык эре җәмәгатьләрдә укырга-язарга һәм дин нигезләренә өйрәтүче *мәктәпләр* һәм *мәдрәсәләр* була. Аерым алганда, астрономия, астрология, медицина, дин белеме, хокук, география фәннәре алга китә. Болгар тарих фәне традициясе *Ягъкуб бине Ногманның* «Тәварихы Болгарийә»сендә чагылыш таба. Болгар дин галимнәре, фәлсәфәчеләре һәм әдипләре: *Сөләйман бине Дауд әс-Саксини әс-Сувари, Әбү-л Галә Хәмид бине Идрис әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари, Хуҗа Әхмәд әл-Болгари*, фармоколог *Таҗетдин бине Юныс әл-Болгари* һ.б. исемнәре билгеле. И.б.Б.д. чорыннан атаклы әдәби ядкәр — *Кол Галинең* «Кыйссаи Йосыф» (1233) поэмасы сакланган.

И.б.Б.д.ндә гамәли-бизәлеш сәнгате җирле традицияләр нигезендә, әмма мөселман мәдәниятенең көчле йогынтысы астында үсә. Болгар зәргәрчеләре алтын һәм көмештән алып бакыр һәм кургашка кадәр төрле металлар һәм эретмәләр б-н эш иткәннәр, һөнәрчелек техникасы һәм металлны нәфис эшкәртүнең алымнарын: нәфис кою, чүкү, уеплау, бизәк төшерү (к. *Басма*), кысып нечкәртү, өсьяпмалау, бөтеркә (к. *Җепкыр*), бөртекләү һәм, ихтимал, каралту ысулларын кулланганнар. И.б.Б.д.ндә сөякне, таш һәм агачны, ш.у. асылташларны һәм ярымасылташларны уеп бизәү югары үсешкә ирешә (к. *Глиптика*). Үзенчәлекле эшләнмәләр арасыннан хатын-кызлар бизәнү әйберләрен — муенсаларны, көмеш чигә асылмаларын, алкаларны, беләзекләрне, йөзекләр һ.б.ны (к. *Бутаиха хәзинәсе*), каеш тагылмаларын, тантана-бәйрәмнәрдә кулланылган коралларны (барыннан да элек, бизәкләнгән алтын-көмеш өслек б-н капланган кечерәк балталар), ат дирбиясен, металл савыт-сабаны, көнкүреш әйберләрен — йозакларны (к. *Маклашеевка җайдаклары*), штампларны, көзгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин. Шәрекъ һәм Көнбатыш Европа үрнәкләре нигезендә пыяла ясау, ш.и. көнкүрештә һәм алхимиядә кулланылучы савыт-саба, тәрәзә пыяласы, муенсалар һәм ялтыравык (сыек пыяла) йөгертелгән керамик савыт-саба ясау алга китә. Мискиләр, кружкалар, яктырткычлардан алып кувшиннар, зур чүлмәк, су һәм азык-төлек саклау өчен метр ярым биеклектәге хумнарга кадәр төрле керамик әйберләр ясау зур үсеш ала. Кагыйдә буларак, әлеге савыт-сабага хас элемент — аның урта һәм өске өлешендә, ш.и. тамагында ритмлы рәвештә чираттлашып урнашкан төрле киңлектәге сызыклардан һәм полосалардан гыйбарәт бизәк була; кайчак кувшиннарның тоткалары фигуралы итеп, төрле хайваннарның — поши, сарык тәкәсе, аюларның стильләштерелгән башлары рәвешендә ясала (к. *Болгар сәнгате*).

Болгар дәүләтенең чәчәк атуы, шәһәрләр үсү, гомумболгар теле оешу һәм илнең бөтен терр-ясендә мөселман тибындагы бердәй рухи һәм матди мәдәният барлыкка килү һәм урнашу нигезендә бердәм этник берләлек — илнең төп халкын тәшкил иткән болгар халкы формалаша. Болгар составына ш.у. көнчыгыш фин (мордва, мари һәм удмуртларның бабалары), төрки (бәҗәнәкләр, кыпчаклар) һәм угор (маҗарлар) халыклары керә. И.б.Б.д.нең халкы татар этносының нигезен тәшкил итә (к. *Татарлар*). И.б.Б.д.нең мәдәнияте — татар халкының тарихи-мәдәни мирасының иң мөһим компонентларының берсе.

И.б.Б.д.нең әмир гвардиясеннән («хашам») һәм төрле өлкәләрдән җыелган, бәкләр җитәкләгән отрядлардан тупланган гаскәрендә 50 мең чамасы сугышчы исәпләнгән. Армиянең төп нигезен хәрби хезмәттәге аксөякләр тәшкил иткән, алар арасыннан хәрби башлыклар сайланган һәм авыр коралланган җайдаклар (чуралар) отрядлары оештырылган. Сугыш хәрәкәтләрендә җәяүлеләр ярдәмче роль уйнаган. Гаскәрләрне йөртү өчен еш кына елга флоты файдаланылган. Оператив-тактик сәнгать үскән: һөҗүм итү сугышларында төп тактика көтмәгәндә ябырылудан, ә һөҗүмне кире кайтарганда актив оборонадан гыйбарәт булган. Ачык кырда сугышканда болгарлар маневрлар кулланганнар, алар дошманны чолгап алганнар. И.б.Б.д. Идел-Урал төбәгендә зур сәяси-хәрби йогынты көченә ия булган һәм ул заманда халыкара мөнәсәбәтләрдә мөһим роль уйнаган. 11 йөздән болгарлар еш кына көчәнеп йөргән кыпчаклар һәм йәмәкләр б-н бәрелешкәннәр. 12 йөз башында болгарлар кыпчакларның берничә һөҗүмен кире каккан (1113 елда кыпчакларның *Әййүб хан* үтерелгән). 12 йөзнең 2 нче яртысында йәмәкләр берничә тапкыр Саксинга һәм И.б.Б.д.нә һөҗүм иткәннәр; үзара низаглардан файдаланып, алар болгар бәге җитәкчелегендә 1183 тә Биләргә яу белән килгәннәр. И.б.Б.д. ш.у. Киев Русе, соңрак башка борынгы рус кенәзлекләре (бигрәк тә Владимир-Суздаль кенәзлеге) б-н тыгыз хәрби-сәяси багланышта булган. Владимир-Суздаль Русе б-н мөнәсәбәтләр Урта Идел буе җирләре өчен үзара көндәшлек б-н билгеләнә. 12 йөз башында И.б.Б.д. Сура-Зөя елгалары аралыгын күзәтчелектә тота, үз мәнфәгатьләрен яклау максатында рус шәһәрләренә (мәс., 1088 дә Муромга, 1107 дә Суздальга) яу б-н бара. Юрий Долгорукий (1125–57) идарә итәргә керешкәч, рус кенәзләре Идел буена зур яулар б-н бара башлыйлар. Болгарлар аларның һөҗүменә каршы Идел буйлап рус шәһәрләренә (мәс., 1152 дә Костромага) яулар оештыралар. Андрей Боголюбский (1157–74) һәм *Всеволод III Большое Гнездо* (1176–1212) идарә иткән чорларда рус гаскәрләре И.б.Б.д.нә берничә тапкыр (1164, 1172, 1183, 1185, 1205) бәреп керәләр. Берләшкән рус кенәзләренең Биләргә яу б-н килүе (1183) аеруча зур колач җәя. Мордва җирләрендә сугышлар алып бару һәм һөҗүмнәр ясау нәтиҗәсендә, Владимир-Суздаль кенәзләре Югары Ука буйларын яулыйлар. Русларның Чулман буендагы активлыгына җавап йөзеннән, болгарлар Устюг шәһәрен кулга төшерәләр һәм яндыралар (1218), ә рус кенәзләре Ашлыны штурм б-н алалар (1220). Шуннан соң Идел буенда тынычлык урнаша (к. *Болгар-рус килешүләре, Болгарлар белән рус кенәзлекләре сугышлары, Болгарларның рус кенәзлекләренә яулары*). 13 йөзнең 2 нче чирегендә И.б.Б.д.нә монгол ханнары б-н берничә тапкыр сугышырга туры килә. 1223 тә болгарлар үз биләмәләренә бәреп кергән монгол баһадуры Сөбедәй гаскәрләрен җиңәләр, ә 1229 һәм 1232 елларда монголларны илнең төп үзәкләренә керүдән туктатып калалар. 1236–37 дә И.б.Б.д. монголларның *Бату хан* җитәкчелегендәге берләштерелгән гаскәрләре тарафыннан басып алына (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). Монгол гаскәрләренең төп көчләре киткәч, 1238 дә Болгарда Баян һәм Җик бәкләр җитәкчелегендә болгар халкының (к. *Баян белән Җик кузгалышы*), ә Түбән Идел буенда һәм Көньяк Уралда Бачман бәк җитәкчелегендә кимәкләр кузгалышлары (к. *Бачман хәрәкәте*) башлана. Монголларга каршы кузгалышлар Сөбедәй б-н Борындай җитәкчелегендәге гаскәрләр тарафыннан бастырыла. И.б.Б.д. Җүчи олысы (к. *Алтын Урда*) составына керә, ә Болгар шәһәре Бату ханның беренче хәрби ставкасы була. 13 йөз ахыры — 14 йөз башында Болгар берничә әмирлеккә — *Болгар бәклеге, Җүкәтау бәклеге, Казан бәклеге, Кашан бәклегенә* таркала.

Чыг.: Летописец Переяславля Суздальского. М., 1851; Хвольсон Д.А. Известия о хазарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда... Ибн-Даста. СПб., 1869; Худуд аль-Алам. Рукопись Туманского. Л., 1930; Аннинский С.А. Известия венгерских миссионеров XIII–XIV вв. о татарах и Восточной Европе // Ист. архив. 1940. № III; Приселков М.Д. Троицкая летопись. М.–Л., 1950; Ковалевский А.П. Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Хар., 1956; Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. М., 1962. Т. 1; Путешествие Абу Хамида аль-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). М., 1971.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. К., 1989; Халиков А.Х. Беренче дәүләт. К., 1991; Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Березин И.Н. Болгар на Волге. К., 1853; Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Смирнов А.П. Очерки по истории волжских булгар // Тр. Гос. ист. музея. 1940. Вып. 11; Греков Б.Д., Калинин Н.Ф. Булгарское государство до монгольского завоевания // Материалы по истории Татарии. К., 1948; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Айдаров С.С. Архитектурные комплексы средневекового Болгара. М., 1976; Валеева Д.К. Искусство волжских булгар (10 — начало 13 вв.). К., 1983; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Халикова Е.А. Мусульманские некрополи Волжской Булгарии 10 — начала 13 вв. К., 1986; Валеев Ф.Х., Валеева-Су-

л е й м а н о в а Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; Д а в л е т ш и н Г.М. Волжская Булгария: духовная культура (домонгольский период, 10 — начало 13 вв.). К., 1990; М у х а м а д и е в А.Г. Древние монеты Поволжья. К., 1990; К а з а к о в Е.П. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; П о л у б о я р и н о в а М.Д. Русь и Волжская Болгария в 10–15 вв. М., 1993; Х а л и к о в А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1994; В а л е е в Р.М. Волжская Булгария: Торговля и денежно-весовые системы 9 — начала 13 веков. К., 1995; И з м а й л о в И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии 10 — начала 13 вв. Магадан-К., 1997; Х у з и н Ф.Ш. Волжская Булгария в домонгольское время (10 — начало 13 веков). К., 1997; История татар. Т.2. Волжская Булгария и Великая степь. К., 2006; G o l d e n P.B. An Introduction to the History of the Turkic Peoples. Ethnogenesis and State-Formation in Medieval and Early Modern Eurasia and the Middle East. Wiesbaden, 1992.

*И.Л.Измайлов.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ БОЛГА́Р ДӘҮЛӘТЕНӘ́ МОНГО́Л ЯУЛАРЫ́** (1223–36). *Калка елгасы буендагы сугышта* (1223) рус-кыпчак гаскәрләрен тар-мар иткәннән соң, Сөбедәй баһадир һәм Җәбә җитәкчелегендәге монгол гаскәре Идел буе Болгары тарафына юнәлә. Самара Дугасы төбәгендә сагалап торып, болгарлар монголларны җиңәләр (4 меңләп кеше качып котыла). 1229 елда монголларның Күкдәй б-н Сөбедәй җитәкчелегендәге атлы гаскәре болгарларның Җаек елгасы буенда чик сагында торган отрядларын тар-мар итә. 1232 дә монголлар *Биләр шәһәрен* басып алуга омтылыш ясыйлар. 1235 тә монгол феодалларының *Каракорымда* уздырылган корылтаенда Идел буе Болгарын, Русьны һ.б. илләрне басып алу максаты б-н яу оештыру турында карар кабул ителә. 1236 ның көзендә монголларның *Бату хан* җитәкчелегендәге берләштерелгән гаскәрләре Җаек елгасын кичә һәм Идел буе Болгарының төп шәһәрләренә, иң беренче чиратта Биләргә юнәлә. Озакка сузылган камау нәтиҗәсендә шәһәр яулап алына. Фарсы тарихчысы *әл-Җувәйни* мәгълүматлары буенча, күп кенә кешеләр үтерелә һәм әсирлеккә төшерелә. Рус елъязмаларында «карт-корыдан башлап күкрәк балаларына кадәр кырып бетерелде, бик күп товарлар талап алынды, ә аларның шәһәре яндырылды», — диелә. Аннан соң Болгар, Җүкәтау, Ибраһим, Суар һ.б. шәһәр-кальгалар яулап алына. 1236–37 нең көз һәм кыш айларында, 1237 нең язында сугышлар Идел буе Болгарының үзәк һәм көнчыгыш җирләрендә бара. 1237 нең язы ахырында — җәе башында монголларның алдагы отрядлары Идел буе Болгарының көньяк һәм көньяк-көнбатыш җирләренә аяк басалар. Бату хан гаскәрләренең бер өлеше Түбән Идел буена Бачман һәм Качир-Үкүле җитәкчелегендәге күтәрелешне (к. *Бачман хәрәкәте*) бастырырга китә. 1237 нең көзендә монгол гаскәрләре Иделне кичәләр һәм болгарларның Самара Дугасындагы кала-авылларын бөлгенлеккә төшерәләр. 1238 дә илбасарларга каршы көрәшне Баян һәм Җик җитәкли. Ләкин *Баян белән Җик кузгалышы* монгол гаскәрләренең Сөбедәй җитәкчелегендәге явы вакытында бастырыла, Идел буе Болгарының терр-ясе Җүчи Олысы составына кертелә.

*Әд.:* Г и м а д и Х.Г. Монгольское иго и вопрос о происхождении казанских татар // Происхождение казанских татар. К., 1948; Х а л и к о в А.Х. Монгольское нашествие и судьба Великого города // Археологические памятники Нижнего Прикамья. К., 1984; Волжская Булгария и монгольское нашествие. К., 1988.

*И.Х.Хәлиуллин.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ КАЛКУЛЫГЫ́**, Көнчыгыш Европа тигезлеге калкулыкларының берсе, Иделнең уңъяк ярында, төньякта Түбән Новгород б-н Казан, көньякта Волгоград б-н Казан арасында урнашкан. Төньяк һәм көнчыгыш өлешләрендә Иделгә таба (хәзер Чабаксар, Куйбышев, Саратов, Волгоград сусаклагычларына таба) текә тау битләре б-н өзелә; көнбатышта сөзәкләнеп Ока-Дон түбәнлегенә төшә; көньякта тарая һәм Ерген калкулыгына күчә. Көнчыгыш өлешнең иң зур биеклекләре Хвалынск шәһәре тирәсендә



Идел буе калкулыгы.

(367 *м*) һәм Жигули тауларында (370 *м*). Субүләр платолар ике ярустан тора, елга үзәннәренең тыгыз челтәре, сызалар һәм ерымнар б-н телгәләнгәннәр. Югарыгы биегрәк плато (300–360 *м*), төп елга араларының үзәк өлешләрендә су б-н юылудан сакланган. Өслекнең өлешчә җимерелүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән түбәнге плато (180–240 *м*) киңрәк таралыш тапкан. Иң зур елгалар: Иделнең уң кушылдыклары — Сура (864 *км*), Зөя (402 *км*), Терешка (276 *км*) һәм Донның сул кушылдыклары — Медведица (692 *км*), Иловля (341 *км*). Калкулык палеоген чоры ахыры — неоген башында, юра, акбур һәм палеогенның диңгез утырмалары (балчык, комлык, акбур, трепель һәм диатомитлар) тупланган Ульянов-Саратов бөгелешен үз эченә алган тектоник күтәрелеш нәтиҗәсендә барлыкка килә. Төньяк өлешендә Пермь токымнары (известьташ, доломит, гипс, мергельләр) үсеш алган, төньяк-көнбатыш өлеше дүртенчел чор бозлыгы б-н капланган була. Жигулиның Алатырь елгасы бассейнында һәм Иделнең уңъяк ярында шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы тирәсендә Пермь системасының гипс һәм известьташларында карст күренешләре үсеш алган. Идел буеның Ульянов һәм Саратов тирәсендәге юра һәм түбән акбур балчыкларында көчле шуышмалар булгалый. И.б.к.ның төньяк өлеше — көрән урман туфраклы, селтесезләнгән һәм көлсуланган кара туфраклы урман-дала зонасына, көньяк өлеше — типик кара туфраклы һәм каштан туфраклы дала зонасына керә. Терр-янең күп өлеше сукаланган. Төньякта урыны б-н киң яфраклы урманнар, палеоген һәм дүртенчел система комнарында — нарат урманнары сакланган. Нефть, битум, янучан сланец (Самара өлкәсе) һәм табигый газ (Саратов өлкәсе), ш.у. известьташ, гипс, акбур, балчык һ.б. төзелеш материаллары чыганаклары бар. Калкулыкның төньяк-көнчыгыш өлешендәге 12,6 мең $м^3$ мәйдан Татарстан Респ-касы составына керә һәм аның аерым физик-географик төбәген — *Идел алдын* тәшкил итә.

*А.П.Дедков.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ О́КРУГЫНЫҢ ФЕДЕРА́ЛЬ АРБИТРА́Ж СУДЫ́**, РФнең суд (мәхкәмә) органы. РФнең 1995 елның 28 апрелендә чыккан Федераль конституцион законы нигезендә оештырыла һәм 1995 нең 25 декабрендә ачыла. Әстерхан, Волгоград, Саратов, Самара, Пенза, Ульянов өлкәләре һәм Татарстан Респ-касы арбитраж судлары тарафыннан 1 нче һәм апелляция инстанцияләрендә кабул ителгән карарларның законлылыгын кассация инстанциясендә тикшерү б-н шөгыльләнә. Аның составына рәис, президиум, ш.у. гражданлык һ.б. хокук мөнәсәбәтләре аркасында туган бәхәсләрне тикшерү; адм. хокук мөнәсәбәтләре аркасында туган бәхәсләрне тикшерү буенча суд коллегияләре керә. Судьялар РФ Президенты тарафыннан РФнең Югары арбитраж суды рәисенең тәкъдиме буенча билгеләнә, И.б.о.ф.а.с. РФнең Югары арбитраж судына буйсына. Рәисләр: Ф.Ф.Сөнгатуллин (1995–2008), Е.З.Васютин (2008 дән).

*Е.Б.Долгов.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ РАЙОНЫ́**, *Әстерхан өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә, Идел елгасы тамагында урнашкан. 1980 елның октябрендә Нариман р-нының бер өлешеннән оештырыла. Мәйданы — 841 $км^2$. Үзәге — Началово авылы (Әстерхан шәһәреннән 7 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 41588 кеше (2008), ш.и. татарлар — 13453 кеше. Татарлар, нигездә, Началово, Три Протока (Җәмил), Кулаковка (Клакау), Карагали (Каргалы), Килинчи, Осыпной Бугор, Татар Башмаковкасы, Фунтово, Яксатово торак пунктларында яшиләр. Үзләренең өй яны кишәрлекләрендә (помидор, кыяр, баклажан, борыч) үстереп, Әстерхан һәм башка шәһәрләр базарларын яшелчә б-н тәэмин итәләр. Татарлар күпләп яшәгән авылларда мәчетләр бар. Җәмил авылында татар халык ансамбле эшли. И.б.р. терр-ясендә ел саен өлкәнең татар милли бәйрәме Сабантуй үткәрелә.

**ИДЕ́Л БУЕ́ РУН (ЧӨЙ) ЯЗУЫ́ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ́**. *Борынгы төрки рун язуы* б-н бирелгән. Безнең көннәргә кадәр бары тик сугыш коралларында, металл һәм керамик савыт-сабаларда, сөяктән, таштан эшләнгән әйберләрдә һ.б.да сакланган аз сандагы текстлар гына килеп җиткән. Күбесе Х.Р.Курбатов тарафыннан өйрәнелә һәм язып алына. Аларның кайберләре: 1. Лаеш р-ны Имәнкискә авылы тирәсендә табылган кылыч йөзендәге язма (Хельсинкида Финляндия милли музеенда саклана): «Имән Кискә үзә бәкү алкыйш киши күчлүш Җикүгин сүңүш калучу» — «Атаклы бәк (идарәче), данлыклы кеше, кодрәтле Җикүгин — Имән Кискәнең — сугыш

кылычы». 2. 1888 елда Вятка губернасының (хәзерге Удмурт Респ-касы) Глазов өязендә болгар авылы урынында табылган көмеш савыт сабындагы язма: «Кагу дәг кунча гәлүнчәй кавушу гүмүши» — «Аккошка тиң бәк кызына никах хөрмәтенә көмеш». 3. 1987 дә Балык Бистәсе р-ны Троицкий Урай авылы тирәсендә табылган балчык савыт-саба кыйпылчыгындагы язма: «Сулы ич» — «Сулы савыттан эч». 4. 1983 тә Биләр шәһәре терр-ясендә табылган керәч савыт сабындагы язма: «Ачуткан» — «Оеткы өчен савыт». 5. 1958 дә Мари АССРның Юрино посёлогында табылган ташка төшерелгән язма: «Күч үзә дашум» — «Золымга каршы — минем ташым». 6. 1992 дә Алексеев р-ны Урманасты Шонталысы авылы янында табылган бәрән ашыгы сөягендәге язма: «Кузначык» (ягъни комарлы уеннар сөяге). 7. Алабуга терр-ясендә табылган орчык башындагы язма: «Багыш күбәзи» — «Күзләр явы». 8. Биләрдән 100 *км* ераклыкта урнашкан Әҗмәр авыллыгында табылган сланецтан эшләнгән орчык башындагы язмалар: «Келдиш, Сату, Йолдаш» (ялгызлык исемнәр).

*Әд.:* Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Истоки татарского литературного языка. К., 1988; Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. К., 1990; Старостин П.Н. Новые находки у Подлесной Шенталы // Формы взаимодействия татарского и русского языков на современном этапе. К., 1992.

*Р.А.Закиров.*

**«ИДЕ́Л БУЕ́ ТӨБӘГЕНДӘ́ МӨСЕЛМА́Н ТАТАРЛА́Р ЙОГЫНТЫСЫНА́ КАРШЫ́ ЧАРАЛА́Р БИЛГЕЛӘҮЧЕ́ МАХСУ́С КИҢӘШМӘ́»**, 1910 елның 10 гыйнварында С.-Петербургта булып уза. МС рәисе П.А.Столыпин башлангычында чакырыла. Православие чиркәве, Халык мәгарифе һәм Эчке эшләр министрлыклары вәкилләре (алар арасында — Казан губернаторы М.В.*Стрижевский*, Казан руханилар академиясе ректоры, Чистай епископы Алексий, Оренбург уку-укыту округы попечителе Н.А.*Бобровников*) катнаша. Киңәшмәнең Идел-Урал төбәгендәге этнодини вәзгыятьне җентекләп анализлаган бәяләмәләре, хөкүмәтнең һәм православие чиркәвенең Россиядәге әҗнәбиләргә татар-мөселман йогынтысы нәтиҗәләрен бетерү буенча бергәләп чаралар күрү программасы кергән материаллары махсус журналда басылып чыга.

Киңәшмәдә катнашучылар тарафыннан Идел буе татарларының активлашу сәбәпләре сыйфатында панисламчылык һәм пантөркичелек идеяләренең милли-дини хәрәкәтнең барлыкка килүенә һәм күтәрелешенә йогынтысы, исламның халыкара рухани үзәкләре б-н элемтә булу күрсәтелә; Идел буе татарларының күчмә яки ярымкүчмә тормыш алып барган диндәшләрен, ш.у. Идел-Кама төбәгендәге мәдәни үсешнең түбән баскычында торган төрки һәм фин-угор этник төркемнәре вәкилләрен үзенә җәлеп итүче югары дәрәҗәле мәдәнияте; Россиянең Европа һәм Себер өлеше тулысынча диярлек мөселман руханиларының, тулаем алганда татар руханилары контролендә булган Оренбург Мөселман Диния Нәзарәтенә буйсынуы; дини мәктәпләрнең уку программаларына кертелгән дөньяви белем бирү фәннәрен татар милләтчелеге рухында укыту, дини мәктәпләр өстеннән дәүләт контроле бөтенләй булмау; мөселман әҗнәбиләре арасында милләтчелекне пропагандалау максаты б-н мөселман-татар укытучыларын әзерләү; ислам руханиларының Россиянең Европа өлеше мөселман халкы аңында дини һәм этник асыл төшенчәләренең бердәйлеген формалаштыру юнәлешендәге эшчәнлеге; милли-дини идеологияне пропагандалауда матбугатның роле үсү; 1905 елдан соң барлык диндәшләрне Төркия б-н якынайту максатында сәяси агитация алып бару өчен киң мөмкинлекләр ачкан дин тотудагы һәм сәяси ирекләрнең йогынтысы; Россиянең барлык мөселман халыкларын милли-дини һәм мәдәни автономия нигезендә берләштерү юнәлешендә хәрәкәт итү буенча элиталы татар программасы формалашу аерып күрсәтелә.

Татар-мөселман йогынтысына каршы тору өчен 34 чара проекты эшләнә, чараларның 3 категориясе билгеләнә: 1 — рухани-мәгърифәти чаралар (гамәлдәге Изге Гурий борадәрлеге мәктәпләренә ярдәм итү; миссионерлык оешмаларының матди хәлен яхшырту; әҗнәби приходларда эшләү өчен шәркый әҗнәбиләрнең теле, дини карашлары һәм көнкүреше б-н таныш миссионерлар һәм руханилар әзерләү, Казан руханилар академиясе каршындагы миссионерлык бүлекчәсенең эшчәнлеген ныгыту; әҗнәби халыклар яшәгән епархияләрдәге рухани семинарияләрдә җирле телләрне укыту; рухани ведомствоның ике сыйныфлы укытучылар әзерләү мәктәпләре санын арттыру, аларда мәҗбүри рәвештә җирле телләрне өйрәнүне гамәлгә кертү; мөселманнарга каршы юнәлдерелгән, һәркем укый алырлык әдәбият тарату максатында Казан руханилар академиясе каршында рус һәм татар телләрендәге махсус матбугат органы оештыру; әҗнәбиләр приходларындагы авыл руханиларының матди хәлен яхшырту); 2 — мәдәни-мәгърифәти чаралар (мөселманнарны һ.б. әҗнәбиләрне рус мәдәниятенә җәлеп итү; мөселманнарның гомуми белем бирү һәм дини мәктәпләрен аерымлау, соңгыларында гомуми белем бирү фәннәрен укытуны тыю; мәдрәсәләрдәге һәм мәктәпләрдәге рус сыйныфларын бетерү, киләчәктә аларның ачылуына юл куймау; мөселман дини мәктәпләрендә укытылачак фәннәрнең исемлеген төгәл билгеләү, моның өчен Эчке эшләр министрлыгы каршында мөселманнарның мәктәп эшен белүче затлардан һәм ш.у. мөселман руханияте вәкилләреннән торган махсус комиссия оештыру; мөселманнарның гомуми белем бирү мәктәпләрен мәгариф ведомствосының җирле органнары тарафыннан гомуми нигездә тәртипкә китерелгән һәм контрольгә алынган хосусый уку йортлары итеп үзгәртү; гомуми белем алырга теләүчеләрне дәүләт мәктәпләренә җәлеп итү; гамәлдәге рус-әҗнәби мәктәпләренең санын арттыру; мөселман уку йортлары өстеннән күзәтчелекне көчәйтү, халык уч-щеләре инспекторларының санын арттыру; гомуми белем бирү мәктәпләре өчен җирле телләр һәм шартлар б-н таныш укытучылар әзерләү; укытучылар семинарияләрендә җирле телләрне өйрәнүне яхшырту; мөселманнарның укытучылар семинарияләрендә белем алуына юл кую); 3 — административ чаралар (губернаторларга мөселманнар эшләре б-н бәйле барлык мәсьәләләрне даими өйрәнүне, мәгълүматларны үзәк хөкүмәткә җиткерүне йөкләү; мөселман дөньясын аларның матбугатын күзәтү аша системалы рәвештә һәм киң колачлы өйрәнүне оештыру; мөселман руханилары даирәсендәге фәннәргә нисбәтле мөселман хокукы җыентыгын төзү һәм аны рус теленә тәрҗемәдә бастырып чыгару; мулла дәрәҗәсенә сынау уздыруның гомуми программасын эшләү һәм аны Эчке эшләр министрлыгында раслау; Оренбург Мөселман Диния Нәзарәтенең терр. вәкаләтләрен чикләү, аларны мөселман халкы аеруча төпләнеп яшәгән җирләрдә урнашкан берничә учреждение арасында бүлү).

Киңәшмә тәкъдимнәрен исәпкә алып, татар милли хәрәкәтенең, вакытлы матбугатының, җәдиди мәктәпләренең, китап кибетләренең һ.б.ның актив эшлекләренә каршы берничә җәза чарасы уздырыла. 1910 да Казан губернасында 97 җәдиди мәктәп ябыла; 1911 нең гыйнварында хәрби көч кулланып Вятка губернасының Сарапул өязе Иж-Бубый авылындагын «*Буби*» мәдрәсәсе тар-мар ителә (мәктәп ябыла, укытучылар куыла).

Чыг.: Особое совещание по Приволжскому краю: противодействие империи: Док. и комментарий // Татарстан. 1992. № 9–10.

*Әд.:* Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917). К., 1982; Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Ист. зарисовки. К., 2005.

**ИДЕ́Л БУЕ́ ТӨРКИ́ ТЕЛЕ́**, 10 йөздән Дәште Кыпчакта, Идел һәм Урал буенда кулланылган төрки тел. Гомумболгар *көйнесе, болгар теле* һәм *кыпчак теле*, шулай ук җирле диалектлар нигезендә үсеп чыга.

И.б.т.т. лексикасының төп өлешен борынгы төрки телнең сүзлек фонды тәшкил иткән: ана, ата, ай, йол (юл), эр (ир), алтын һ.б. Телнең фонологик структурасына: а) «а»ның — а⁰ - кара — ка⁰ра — дип иренләшеп әйтелүе; б) тар ирен сузыкларының киңәюе: у>о, ӱ>ө — тур>тор, ӱч>өч; в) кайбер тартыкларның параллель кулланылуы: б-м + бӓн — мӓн (мин), з-й — изӓ — ийӓ (ия), г-w — ағыр — awыр (авыр) һ.б. хас. Морфологиясенең үзенчәлекләре: а) сыйфат фигыльнең угыз — мыш һәм кыпчак — ган формаларының параллель кулланылуы — килмеш — килгән; б) хикәяләү наклонениесенең хәзерге һәм киләчәк заман функцияләрендә — р кушымчалы фигыльнең кулланылуы — ул барыр; в) боерык һәм шарт фигыльләрнең борынгы формаларын куллану — барың, баргыл; г) шарт фигыльнең аналитик формалары да булу — барыр ирсә һ.б.

13–16 йөзләрдә И.б.т.т.нә караханлылар — уйгыр һәм харәзем — төрки әдәби телләренең язу традицияләре тәэсире бик көчле була. Ул халык авыз иҗаты әсәрләре, сөйләм теле,

гарәп, фарсы һ.б. телләрдән алынган сүзләр исәбенә байый. 19 йөз уртасына кадәр әдәби тел функциясендә яши. *Иске татар әдәби теле* барлыкка килүнең беренче баскычы булып санала. И.б.т.т.ндә сәнгать, фәнни, тарихи-публицистик, дини әсәрләр иҗат ителә. Шулай ук бу телдә язылган Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларының хан ярлыклары, документлар, тарихи трактатлар, эпистоляр һ.б. кулъязма ядкәрләр саклanган.

*Әд.:* Җ ә л ә й Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. К., 1954; Х а к о в В.Х. Татар әдәби теле тарихы. К., 1993; ш у л у к. Тел — тарих көзгесе. К., 2003; Б о г о р о д и ц к и й В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. К., 1934; Языки народов СССР. Тюркские языки. М., 1966. Т. 2.

*В.Х.Хаков.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ УГЛЕВОДОРО́Д ЧИМАЛЫ́ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Бөтенроссия углеводород чималы институты.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Апас, Югары Ослан, Яшел Үзән һәм Кайбыч р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1954 елда механикалаштырылган урман хуҗалыгы буларак оештырыла. 2007 ел башына И.б.у.х.ның гомуми мәйданы 27608 *га*. Урман хуҗалыгы составына 5 урманчылык керә: Зөя (7409 *га*), Ключище (5422 *га*), Чулпан (5349 *га*), Шыланга (5426 *га*), Тәмте (4002 *га*). Урман хуҗалыгы дирекциясе Югары Ослан р-ның Фурцево авылында. Эшләүчеләр саны — 58 кеше.

Урманның 80% ка якыны саклаучы урманнар категориясенә керә, ш.и. аеруча саклаулы табигать терр-яләре (370 *га*), яшел зоналар, урман парклары (9400 *га*), су объектлары ярлары буенда тыюлык урман полосалары (4330 *га*) һ.б. Файдаланыла торган урманнар — 5814 *га*. Урман б-н капланган мәйдан — 26269 *га*, ш.и. ылыслы токымнар — 10%, каты яфраклылар — 55%, йомшак яфраклылар 35% ны, тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: имән (53,4%), юкә (14%), усак (12,4%), нарат (6,6%), каен (6%), ш.у. чыршы (культурада), өрәңге, карама, агачсыман тал һ.б. Урманнарның яшь буенча структурасы: яшь урманнар (16%), урта яшьтәгеләр (36%), өлгереп килүчеләре (16%), өлгергәннәре һәм картайганнары (32%). Урман культуралары 5662 *га* мәйдан алып тора. Агачның гомуми запасы 4163,4 мең $м^3$ тәшкил итә; ылыслылар — 422,2 мең $м^3$, каты яфраклылар — 2123 мең $м^3$, йомшак яфраклылар өлешенә 1613,5 мең $м^3$ туры килә. Агачның уртача гомуми еллык үсеше — 80,8 мең $м^3$. Урманны карау максатыннан 600 *га* мәйданда кисү эшләре башкарыла, шулай 15 мең $м^3$ агач әзерләнә. 2007 елда урман торгызу эшләре 55 *га* мәйданда алып барыла. 40 *га* мәйданда саклаучы утыртмалар (урманнар), юл буе һәм кыр ышыклау полосалары булдырыла. Урман хуҗалыгы питомникларында агач һәм куак токымнарының 1 млн. *га* кадәр чәчкене һәм үсентеләре үстерелә. И.б.у.х. терр-ясендә *Лабыш таулары* табигать тыюлыгы, «*КДУ зоостанциясе*», *Тау наратлыгы* табигать истәлекләре билгеләнгән. Урман хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш керткәннәрө өчен К.Н.Скотников, А.И.Зайцев ТРның атказ. урманчысы исеменә лаек булалар. 2007 ел ахырында шул ук исемдәге урманчылык дип үзгәртелә.

*Д.И.Зарипов.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ ХӘРБИ́ О́КРУГЫ**, 1918–2001 елларда РФдә хәрби частьләрнең, берләшмәләрнең, хәрби-уку оешмалары һәм хәрби учреждениеләрнең терр. гомумгаскәри берләшмәсе. Округ идарәсе төрле елларда Самара, Казан, Түбән Новгород, Сембер, Саратовта урнаша. Баштарак Әстерхан, Самара, Саратов, Сембер, Пенза губерналары һәм Урал өлкәсе, 1918 нең июленнән Казан губернасы җирләрен били. Округ терр-ясе берничә тапкыр үзгәрә. Гражданнар сугышы чорында анда сугыш хәрәкәтләре булып уза: округ хәрби частьләрне җыя, туплый, әзерли һәм фронтка озата (1918–19 да барлыгы 418930 кеше җыйган 42 мобилизация үткәрелә, 4 дивизия, 4 бригада, 27 полк, 53 батальон һәм дивизион, 88 рота һәм батарея туплана). 1919 да стратегик резерв әзерләү һәм Кызыл Армияне тулыландыру өчен округ терр-ясендә *Республиканың Запас армиясе*, 1920 дә Республиканың Запас армиясе һәм И.б.х.о. идарәсе оештырыла (1921 дә армия таратылгач, И.б.х.о. идарәсе дип атала). 1920 дә округ терр-ясенең бер өлешендә Идел аръягы хәрби округы оештырыла (1921 дә И.б.х.о. б-н кушыла). 1922 дә И.б.х.о. һ.б. округлар составына таратылган Урал яны хәрби округы гаскәрләре һәм терр-ясе бирелә. 1920–30 елларда округның хәрби-уку йортларында (Казан пехота, 12 нче Сембер пехота, 3 нче Оренбург кавалерия, Оренбург зенит артиллериясе, Ульянов һәм Самара бронетанк мәктәпләрендә, Оренбург, Вольск, Пермь һ.б. шәһәрләрдәге авиация мәктәпләрендә һ.б.) команда составы әзерләнә. 1935 тә И.б.х.о.ннан Урал хәрби округы аерып чыгарыла. Бөек Ватан сугышы алдыннан И.б.х.о. Куйбышев, Оренбург, Саратов һәм Пенза өлкәләре, Идел буе немецлары АССР һәм ТАССР терр-яләрен били (1.12.1941–29.10.1943 тә ТАССР Мәскәү хәрби округы, 1.8.1945–28.2.1946 да Казан хәрби округы составына керә). Бөек Ватан сугышы фронтларында И.б.х.о.нда оештырылган 10 нчы, 21 нче һ.б. армияләр, *Витебск исемендәге укчы дивизия, Орша исемендәге укчы дивизия* һ.б. сугыша. 1970 еллар ахырында И.б.х.о.на Куйбышев, Оренбург, Саратов, Ульянов һәм Пенза өлкәләре, Татарстан, Башкортстан, Мари, Мордва һәм Чуаш АССРлар керә. 1970 еллар ахыры — 1990 елларда И.б.х.о. хәрби хезмәткәрләре Әфганстанда хәрби бурыч үтиләр, Чернобыль АЭСы һәлакәтләре нәтиҗәләрен бетерүдә, Чечен Респ-касында конституцион тәртипне торгызуда катнашалар. 1989 да И.б.х.о. һәм Урал хәрби округы базасында Самарадагы штаб һәм идарәсе б-н — Идел буе-Урал хәрби округы (штабы һәм идарәсе Самарада урнаша), 1992 дә яңадан — Урал хәрби округы, 2001 дә Екатеринбургтагы идарәсе б-н Идел буе-Урал хәрби округы оештырыла (элеккеге И.б.х.о.нда штабы Самарада булган армия оештырыла). Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Төрле елларда И.б.х.о. б-н җитәкчелек итүчеләр: А.Ф.Долгушин, И.И.Межлаук, И.Л.Коган, П.А.Петряев, Б.И.Гольдберг, Д.П.Оськин, С.В.Мрачковский, А.И.Седякин, Г.Д.Базилевич, Б.М.Шапошников, И.Ф.Федько, П.Е.Дыбенко, М.Н.Тухачевский, М.Г.Ефремов, П.А.Брянских, К.А.Мерецков, Т.И.Шевалдин, В.Ф.Герасименко, М.Т.Попов, С.А.Калинин, М.С.Хозин, В.Н.Гордов, В.А.Юшкевич, Г.Н.Перекрестов, В.И.Кузнецов, В.Н.Комаров, А.Т.Стученко, И.Г.Павловский, Н.Г.Лященко, Н.В.Огарков, А.М.Паршиков, Ю.А.Науменко, П.Г.Лушев, В.Н.Кончиц, А.Я.Ряхов, В.А.Патрикеев, А.М.Макашов, А.И.Сергеев.

*Әд.:* Краснознамённый Приволжский: История войск Краснознамённого Приволжского военного округа. М., 1984.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ИДЕ́Л БУЕ́ ХӘРБИ́ ФЛОТИ́ЛИЯСЕ**, 1918 елның июнендә Түбән Новгородта оештырыла башлаган беренче совет елга хәрби флотилиясе. Аның составына җирле пассажир пароходлары һәм Балтыйк флотының Идел елгасына җибәрелгән кайбер хәрби корабльләре керә. И.б.х.ф.нең төрле елларда командующийлары: Р.М.Бернгардт, Ф.Ф.Раскольников, В.Н.Варваци, П.И.Смирнов. И.б.х.ф.нә 1918 нең августы ахырында — 3 миноносец, 9 коралլы пароход, ш.и. «*Ваня*», ш.у. 2 йөзмә батарея, 4 катер һәм авиаотряд (4 самолёт); 1919 да — 36 корабль (20 канонер көймәсе, 6 сак судносы һәм 10 ярдәмче судно), йөзмә батарея, авиадивизион (9 самолёт), 1 аэростат, 850 дән артык кешелек десант отряды керә. И.б.х.ф. *Көнчыгыш фронт* гаскәрләре б-н бергәләп хәрәкәт итә. 1918 дә И.б.х.ф. КОМУЧ Халык армиясенә һәм Чех-словак корпусына каршы сугыша. Август ахырында — Зөя һәм Югары Ослан янындагы сугышларда, сентябрьдә Казанны азат итүдә һәм Чистай, Алабуга шәһәрләре, Яр Чаллы авылы өчен барган сугышларда, октябрьдә — Сызрань, Самара шәһәрләре, октябрь ахыры — ноябрь башында Ижевск шәһәре һәм Воткинск з-ды өчен барган сугышларда катнаша. 1918 нең сентябрендә И.б.х.ф. 2 отрядка бүленә: берсе — Идел, икенчесе Чулман елгасында хәрәкәт итә. Октябрьдә аның составына Вольск, Хәрби-Идел һ.б. флотилияләр һәм отрядлар кушыла. 1919 да И.б.х.ф. Чулман, Агыйдел, Нократ, Уфа елгаларында адмирал Колчак гаскәрләренә каршы сугыша, Көнчыгыш фронтның 2 нче, 3 нче, 5 нче армияләренә сугыш хәрәкәтләре алып баруда булышлык итә. 1919 ның маенда — Чистай, Алабуга, июньдә Сарапул шәһәрләрен азат итүдә катнаша. 1919 ның июлендә Идел-Каспий хәрби флотилиясе составына кертелә.

*Әд.:* Ч е б а е в с к и й Ф. Волжская военная флотилия в гражданской войне (1918–1920) // Ист. журнал. 1944. № 2–3; М о р д в и н о в Р.Н. Волжская военная флотилия в гражданской войне (1918–1920 гг.). М., 1952; Вспоминая былые походы: Сб. воспоминаний ветеранов Волжской военной флотилии. Г., 1968.

**ИДЕ́Л-КА́МА БА́НКЫ**, к. «*БТА-Казан*».

**ИДЕ́Л-КА́МА САКЛАУЛЫГЫ́**, дәүләт табигать биосфера саклаулыгы, табигатьне саклау, фәнни-тикшеренү һәм экологик агарту учреждениесе. 1960 елда Казан Идел аръягының уникаль табигать экосистемаларын саклау максатында оештырыла. Идел елгасының борынгы алювиаль террасаларында урнашкан. Раифа һәм Саралан участокларыннан тора.

Раифа участогы Яшел Үзән р-нында, Казаннан 25 *км* көнбатыштарак. Мәйданы 5921,2 *га*. Терр-я урта дүртенчел системаның Идел террасасын алып тора һәм сөзәклекләре рельефның борынгы эрозия, упкынлы һәм эол формалары б-н катлауланган казансыман түбәнлектән гыйбарәт. Берничә күл бар. Иң зурысы *Раифа күле* (32,3 *га*), аның яры буенда Раифа Богородица монастыры (17 йөз) урнашкан. Раифа түбәнлегенең үзәк өлешен алып торучы Сәр-Болак һәм Сумка елга үзәннәренең абс. билгеләре 60–65 *м*, участокның төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш кырый нокталарында — 110 һәм 105 *м*. Ком, комсыл һәм балчыксыл токымнардан яралган, нигездә, кәсле-көлсу туфрак. Казанлык битләүләрендә туфракның механик составы буенча өстән аска закончалыклы бүленеше (авырраклардан башлап җиңелләргә таба) күзәтелә. Үсемлек капламы шуңа ярашлы рәвештә бүленә: имән б-н юкәдән торучы киң яфраклы урманнар — юкә һәм чыршыдан торучы ылыслы — киң яфраклы урманнар, ә аннан соң нарат урманнары, ягъни Россиянең Европа өлешендәге барлык урман зонасы киңлекләре кабатлана. Участок составына керүче элекке монастырь урманнары Көнчыгыш Европада иң борынгылардан санала. Киң яфраклы урманнарның үлән капламы өчен язгы эфемероидлар һәм куе үләнлек хас: сәрдә, күпьеллык зибык уты, Европа тайтоягы, имәнсәр йолдызагы, үрмәле колмак h.б. Ылыслы урманнар тайга табигатенә охшаш. Агачлар төбендә төньяк Линней үләне, сыңар чәчәк, киң яфраклы цинна, күләгә миләүшәсе, каеш яфрак, сәхләбчәләр, плауннар үсә. Түбәнлекләрне арктобореаль үсемлекләр: җиңсәле мамыкбаш, акчыл, күк җиләк, мүк җиләге, шейхцерия, түгәрәк яфраклы чыклыут, күрәннең төньяк төрләре үскән сфагнум мүкле сазлыклар били; комлы дюналар түбәләрендә — лишайниклар, аю табаны, рус ракитнигы, тау бөҗәк чәчәге, ачык йокы үләне үсә. Хайваннардан: гади көрәнтеш, гади шолган, соры һәм кызыл кыр тычканнары, тиен, сусар, ак куян, поши, суер, бoҗыр, озын койрыклы ябалак, өч бармаклы тукран, җизбаш, соры гөберле бака очрый; 1996 елда кабат кондыз кертелә.

Саралан участогы Лаеш р-нында Кама елгасы тамагында урнашкан. Мәйданы 4170 *га*, аннан тыш Куйбышев сусаклагычы акваториясенең 1353 *га* мәйданы керә. Терр-я нарат урманнары биләгән «утрау» (соңгы дүртенчел системаның Идел буе террасаларының сусаклагыч суы астында калган комлы таулары, абс. билгесе 60–70 *м*) һәм киң яфраклы урманнардан торган «материк» өлешләргә (100–120 *м* абс. билгеләре б-н урта дүртенчел система террасасы) бүленә. Каен һәм усак катнаш урта яшьтәге агачлыклар өстенлек ала. Урманнарда чыршы юк, наратлыклар далалашкан. Идел буе сөзәклекләрендә каурый кылган, күгелҗем келерия, дала чиясе, чәнечкеле чия, җете кызыл татлы тамыр үсә. Хайван төрләреннән: урман йоклачы, үр куяны, бурсык, кәҗәболан, кабан дуңгызы, көртлек, гади урман күгәрчене, һөд-һөд кошлар, гади кара елан яши. Участокның кушылдык һәм култыклары корбан балык, сазан, чуртан, судак, шамбы (налим) балыкларының сусаклагычтагы иң эре уылдык чәчү урыннары булып тора. Язгы очып кайту һәм көзге китү вакытларында каз, үрдәк, шөлди көтүләре туктала. Елга каракошының (Халыкара табигатьне саклау союзының Кызыл китабына кертелгән) Европада иң тыгыз оялау урыннарының берсе шушы участокта. Шулай ук су яны биотоплары өчен янутсыман эт, Америка чәшкесе, соры челән, зур күлбога, елга акчарлагы, кыр үрдәге, чытырдавык чүрәкәй, саз карчыгасы, яр чыпчыгы, камыш чыпчыклары хас. Саклаулык терр-ясендә барлыгы: көпшәле үсемлекләр — 850 төр, мүкләр — 170, суүсемнәр — 400, лишайниклар — 120, гөмбә — макромицетлар — 750, имезүчеләр — 56, кошлар — 200, сөйрәлүчеләр — 6, җир-су хайваннары — 11, балыклар — 30, умырткасызлар — берничә дистә мең төр саклана. Шулардан РФ Кызыл китабына кертелгәннәр: үсемлекләр — 3 төр, гөмбәләр — 9, хайваннар — 11; ТР Кызыл китабына кертелгәннәр: үсемлекләр — 156, гөмбәләр — 27, хайваннар — 128. Саклаулык көчле антропоген тәэсир астында яши. Саклаулык сулыкларының ләмләнүенә һәм пычрануына китерүче эрозия процесслары аеруча куркыныч. ТР МК карары (1995) буенча саклаулык тирәли саклау зонасы булдырылган. Саклаулык (хәзерге Раифа участогы терр-ясендә) оештыруда беренче омтылышны 1917 дә А.Я.Гордягин ясый. 1927 дә ТАССР хөкүмәте тарафыннан Татарстан милли саклаулыгы (769 *га*), 1943 тә — Раифа саклаулыгы (3468 *га*) проекты раслана. А.Е.Арбузов, В.И.Баранов, Н.А.Ливанов, Д.И.Морохин, В.А.Попов, В.С.Порфирьев И.-К.с.н. оештыруда мөһим роль уйныйлар. 1921 дә *Идел-Кама саклаулыгы дендрарие* оеша, аның коллекциясендә Европа, Азия һәм Төньяк Америкадан китерелгән агач-куак үсемлекләренең 400 дән артык төре, сорты һәм формасы исәпләнә; саклаулыкта табигать музее булдырылган. Саклаулык табигатен өйрәнү И.-К.с.ның фәнни бүлеге тарафыннан алып барыла. Саклаулык экосистемасының төп компонентларын мониторинг күзәтүләр «Табигать елъязмасы» («Летопись природы») дип аталган махсус отчётта ел саен гомумиләштерелә. Тикшеренү нәтиҗәләре экологик фаразлау, табигатьне саклауның фәнни нигезләрен эшләү, төбәкнең табигый ресурсларын рациональ файдалану һәм яңадан җитештерү өчен кулланыла. 2005 тән ЮНЕСКОның «Кеше һәм биосфера» дигән халыкара программасында катнаша. Саклаулыкта Казан ун-ты, ТР ФА ин-тлары, Татарстан урман тәҗрибә станциясе, ТР һәм РФнең башка фәнни учреждениеләре галимнәре тикшеренүләр үткәрәләр. Казан вузлары студентлары биология, география һәм экология буенча 2 стационарда кыр практикасы үтә. «Труды» (1968, вып. 1; 1972, вып. 2; 1977, вып. 3; 2001, вып. 4) басмасы чыгарыла. Ш.у.к. *Раифа урманы, Саралан урманы*.

*Әд.:* Волжско-Камский государственный заповедник. К., 1975; Заповедники СССР: Заповедники европейской части РСФСР. М., 1989. Ч. 2; Опыт оценки состояния природных комплексов заповедников и национальных парков Ассоциации «Средняя Волга». Йошкар-Ола, 1997.


*О.В.Бакин, Ю.А.Горшков.*




Идел-Кама саклаулыгы. Раифа участогы.

**ИДЕ́Л-КА́МА САКЛАУЛЫГЫ́ ДЕНДРА́РИЕ**, Яшел Үзән р-ны Садовый посёлогында урнашкан. Мәйданы 21,5 *га*. 1921 елда Казан ун-тының урман ф-ты укытучылары инициативасы б-н оештырыла. Европа, Азия, Американың уртача киңлекләрендә ачык грунтта үсә торган 400 дән артык төр һәм төрчәне (94 ыруг, 39 семьялык) үз эченә алган агач-куак коллекциясе Татарстанда иң эреләрдән санала. И.-К.с.д.ндә коллекция кишәрлегеннән тыш, интродукцияле үсемлекләр питомнигы, тал, тирәк плантацияләре, парк кишәрлеге бар. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: агач һәм куак үсемлекләрен климатка яраклаштыру, биологик төрлелекне саклау, халыкны экологик яктан агарту.

Дендрарий башта Н.К.Вехов җитәкчелегендә урман ф-тының уку базасы буларак нигезләнә һәм 0,46 *га* мәйданлы дендрологик питомниктан гыйбарәт була. 1926–28 елларда М.Л.Стельмахович җитәкчелегендә питомникта җыелган материал нигезендә 3,84 *га* мәйданда дендрарий коллекциясе урнаша. 1934–60 та дендрарий Татарстан ур-








Идел-Кама саклаулыгы дендрарие. 1. Көнбатыш туясы аллеясы; 2. Үзәк аллея; 3. Шикәрле өрәңге.

ман-тәҗрибә станциясе карамагында була. Бу чорда Б.М.Алимбәк җитәкчелегендә питомник киңәя, парк участогына нигез салына, дендрарий хәзерге мәйданына җитә. 1960 тан саклаулык составында.

И.-К.с.д.нда төрле елларда илебезнең танылган дендролог һәм урман белгечләре: В.К.Войт, Л.И.Яшнов, М.Л.Колпиков, Д.И.Морохин, Н.В.Напалков эшли.

Дендрарий җирлегендә 519 агач һәм куак төре климатка яраклашу (акклиматизация) тәҗрибәсе уза. Россия, Украина, Литва, Германия, АКШның ботаника учреждениеләреннән китерелгән 1 меңнән артык үсемлек орлыгы үрнәкләре файдаланыла.

И.-К.с.д. РФнең ботаника бакчалары советына керә. Анда ел саен 3,5–4 мең экскурсант була; торак пунктларны яшелләндерүгә 5 меңгә якын үсенте җибәрелә.

*Әд.:* Опытное дело Лесфака: Опытные работы по дендрологии // Изв. Казан. ин-та сел. хоз-ва и лес-ва. 1928. № 3; Напалков Н.В., Мустафина В.К. Дендрологический сад Волжско-Камского заповедника // Тр. Волжско-Камского гос. заповедника. 1968. Вып. 1; Иванов В.Б. Основные направления деятельности дендрария Волжско-Камского государственного природного заповедника // Актуальные экологические проблемы РТ. К., 1997; Иванов В.Б. Удивительная коллекция. Дендрарий Волжско-Камского заповедника // Казань. 2000. № 2/3.

*В.Б.Иванов.*

**«ИДЕ́Л-ПРЕСС» ПОЛИГРА́ФИЯ-НӘШРИЯ́Т КО́МПЛЕКСЫ**, Казанда. РФдәге эре полиграфия пр-тиеләренең берсе. 1969 елда КПССның Татарстан өлкә ком-ты нәшрияты буларак төзелә; 1991 дә Татарстан газета-журналлар нәшрияты итеп үзгәртелә; 2000 нән дәүләт унитар пр-тиесе, 2005 тән «И.-П.» п.-н.к» АҖ. 2010 нан «ТАТМЕДИА» ААҖ ф-лы. 1972 дә җирле һәм үзәк газеталарның беренче нөсхәләре басыла. 1973–74 тә хәреф җыю һәм журнал цехлары файдалануга тапшырыла. 1974 тә 14 катлы корпусны төзү тәгәлләнә, анда республика газеталары һәм журналлары редакцияләре урнаша. Төп производство цехлары: басуга кадәр әзерләү, газеталар, китап-журнал производстволары; рулонлы кәгазьне битләргә кисү; лабораторияләр; ярдәмче производство: ремонт-механика, автотранспорт цехлары һ.б.

Нәшрият тарафыннан ел саен 2,5 меңнән артык заказ башкарыла. Анда бөтенроссия һәм республика вакытлы матбугаты басмалары (120 дән артык исемдәге газеталар һәм журналлар), дәреслекләр, фәнни һәм матур әдәбият, иллюстрацияле күптомлы Татар энциклопедиясе, брошюралар, буклетлар һ.б. нәшер ителә. Тулай продукциядә 58% — китапларга, 27% — газеталарга, 7% — журналларга, 8% башка продукциягә туры килә (2006). Заказчылар арасында — «*Мәгариф*» нәшрияты, ТР ФАнең *Татар энциклопедиясе институты*, «Хәтер», «Заман» (Казан), «Высшее образование», «Владос», «Сфера», «Дрофа», «Вече», «Белый город», «Зебра», «Юрайт» (Мәскәү), «Академия» (Ярославль ш.), «Сократ», «Средне-Уральское» (Екатеринбург ш.), «Белая река» (Башкортстан) һ.б. 2010 да газеталар — 100 млн., китаплар — 8 млн., журналлар — 2 млн. нөсхә күләмендә; сынлы сәнгать басмалары — 25 млн. сумлык, халык куллану товарлары 4,5 млн. сумлык (барлыгы 400 млн. сумлык) күләмдә чыгарыла.

1998–2006 да уздырылган халыкара һәм бөтенроссия күргәзмәләрендә һәм конкурсларында пр-тие «Алтын Меркурий», «Алтын эталон» призлары, Халыкара инвестицияләр консалтингы үзәге, «Гасыр меценатлары» халыкара хәйрия фонды, Полиграфистларның төбәкара ассоциациясе, Россия Китап берлеге мактау дипломнары (2003, 2005, 2006) б-н бүләкләнә.

Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 10 кешегә ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре, 1 кешегә ТРның атказ. халыкка хезмәт күрсәтү хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә, 2 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — «Почёт билгесе», 5 кеше 2 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 59 кеше медальләр, ш.и. 1 кеше 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, 21 кеше РСФСР, ТАССР ЮСлары Президиумнары, ТР Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: М.Ф.*Долгов* (1963–72), В.А.Гаврилов (1972–93), Д.Т.Хәйруллина (1993–99), И.Г.*Әхмәтҗанов* (1999 дан).

*Әд.:* Гафуров В.З., Мифтахов З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарии. К., 1977; Из истории казанской прессы. К., 1977; Сидорова Т. Мы — профессионалы! 30 лет ГУП «Полиграфическо-издательский комплекс «ИДЕЛ-ПРЕСС». К., 2001; 35 лет в авангарде полиграфии // Новости полиграфии. 2006. № 20.

*М.Ж.Гаитов.*

**ИДЕ́Л-КА́МА УРМА́Н СӘНӘГАТЕ́ ИНСТИТУТЫ́**, фәнни-тикшеренү ин-ты. 1928 елда Казанда Идел-Кама сал агызу тәҗрибә станциясе буларак оештырыла. 1933–64 һәм 1989–91 дә Сал агызу үзәк фәнни тикшеренү ин-тының Идел-Кама ф-лы. 1964–89 һәм 1991–2003 тә мөстәкыйль Идел-Кама фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык-технол. урман-су транспорт ин-ты. 2003 тән хәзерге исемендә. 1991 гә кадәр ин-т структурасында 14 бүлекчә, ш.и. проблемалар өстендә эшләүче фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык бүлекләре, эксперименталь җитештерү з-ды эшли. 2008 ел башына ин-тта 3 фәнни-тикшеренү бүлеге эшли: түбәнге урман складлары һәм чимал биржалары; техникалаштыру; су мохитен саклау. Урман сәнәгате комплексы проблемалары буенча тикшеренү һәм конструкторлык-технологик эшләр алып бара. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: агачларны яр буена җыю, суднолар б-н ташу, сал агызу такелаж процесслары өчен технологияләр эшләү, аларны механикалаштыру һәм автоматлаштыру, су мохите һәм яр буе зонасы экологиясе. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре РФ респ-калары һәм өлкәләренең, БДБ илләренең күп кенә урман сәнәгате пр-тиеләре комплексына кертелгән. Ин-тта ТРның 5 атказ. уйлап табучысы эшли. 1500 дән артык авторлык таныклыгы алынган, уйлап табуга РФнең 7 патенты бар. «Труды» (1954–71, вып. 1–11) басмасын нәшер итә.

*А.А.Аксянов.*

**ИДЕ́Л-ТАТА́Р ЛЕГИОНЫ́**, к. *Идел-Урал легионы*, *Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлеге*.

**ИДЕ́Л-УРА́Л БУЕ́ РЕСПУ́БЛИКАЛАРЫ КОМПОЗИ́ТОРЛАРЫНЫҢ МУ́ЗЫКА ФЕСТИВАЛЕ́**. ТАССР Композиторлар берлеге башлангычы б-н оештырыла, беренче фестиваль 1982 елда Казанда уза. 1995 кә кадәр һәм 2002 дән алып ел саен Идел-Урал буе респ-калары башкалаларында чиратлаштырылып үткәрелә. Фестивальнең төп максаты — композиторларның иҗатын популярлаштыру, агымдагы процесслар буенча фикер алышу, төбәкнең муз. культурасы үсеше проблемаларын ачыклау һәм хәл итү. Фестиваль программаларында әйдәп баручы башкаручылар һәм иҗат коллективлары чыгыш ясый, музыка белгечләре һәм эшлекләре катнашында конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләр, киңәшмәләр үткәрелә. 2006 да Казанда 19 нчы

фестиваль уздырыла, 2009 елда 22 нче фестиваль Сыктывкар шәһәрендә була.

*Әд.:* Возобновление традиций // Музыкальная академия. 2003. № 2; Регион Поволжья и Приуралья: Фестиваль восемнадцатый // Музыкальная академия. 2006. № 2.

*Ф.Ш.Салитова.*

**«ИДЕ́Л-УРА́Л» ЛЕГИОНЫ́** (Идел-татар легионы), Икенче бөтендөнья сугышы чорында Германия Хәрби көчләре составында татар, башкорт һ.б. милләт хәрби әсирләреннән төзелгән гаскәри берәмлек. Легионга туплау эше Россия әсирләрен хәрби һәм сәяси яктан әзерләү буенча төп үзәкләр урнашкан Польша һәм Украина терр-ясендә җәелдерелә. Идел буе халыкларыннан сугышта әсирлеккә эләгүчеләр өчен Сельце һәм Демблин шәһәрләрендә лагерьлар оештырыла. Легионда хезмәт итәргә теләк белдерүчеләр Радом шәһәре янындагы Едлино авылындагы төп лагерьга җибәрелә. Хәрби әзерлек 12 атна дәвам итә, шуннан соң легионерларны кыр батальоннарына язалар; батальоннар 4 укчы һәм 1 штаб роталарына бүленә. Һәр батальонга 950 ләп ирекле һәм 27 немец керә. Батальоннарның командирларын, ш.у. адъютантларны, табибләрне һәм казначыларны бары тик немецлар, рота командирларын өлешчә легионерлар, взвод командирларын фәкать легионерлар арасыннан билгеләп куялар. Башта барлык Көнчыгыш (Төркестан, Әрмән, Грузин, Әзәрбайҗан, Төньяк Кавказ һәм Идел-татар) легионнарының штабы Радомда урнаша, командующие итеп генерал Ральф фон Хайгендорф билгеләнә. 1943 елның көзендә штаб Франциягә (Ле-Пюи а.) күчерелә. «И.-У».л. б-н формаль рәвештә *Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлеге* җитәкчелек итә, чынлыкта барлык төп хәрби вазифаларны Верхмат офицерлары үти. 7 батальон оештырыла. 1942 нең 25 ноябрендә тупланган 825 нче батальон 1943 нең февралендә белорус партизаннарына каршы сугышка озатыла; ул тулаем диярлек кораллары б-н партизаннар ягына чыга (аның сугышчылары Захаров һәм Бирюлинның партизаннар бригадалары составында сугышалар). 1943 нең 15 гыйнварында җыелган 826 нчы батальон 1943 нең мартында Голландиягә җибәрелә (1944 нең 10 августында француз партизаннары ягына чыга). 1943 нең 10 февралендә — 827 нче һәм 1943 нең 1 июнендә 828 нче батальоннар оештырыла, алар Көнбатыш Украина терр-ясендә С.Ковпакның партизаннар армиясенә каршы файдаланыла (легионерларның яртысы диярлек партизаннарга кушыла, калганнары, ышанычсыз саналып, Бельгия, Голландия һәм Франциягә күчерелә). 1943 нең 24 августында 829 нчы батальон туплана, чынлыкта ул хәрби хәрәкәтләргә кертелми, 1944 нең августында таратыла. 1943 нең сентябрь–октябрь айларында 830 нчы һәм 831 нче батальоннар төзелә, алар Польша терр-ясендә урнаштырыла. 1943 нең көзендә рәсми рәвештә 832 нче, 833 нче һәм 834 батальоннар оештырыла, әмма алар чынлыкта кәгазьдә генә теркәлеп кала. Сугышчан батальоннардан тыш, дистәләрчә Идел-татар төзелеш роталары туплана, алар аерым немец формированиеләренә беркетелә. Легионерларның ышанычлы булмавы рәсми немец документларында даими рәвештә ассызыклана. Легион составында яшерен антифашистик төркемнәр актив хәрәкәт итә: 1942 нең көзендә өлкән лейтенант П.К.Финансов Варшава янында подпольщиклар отряды оештыра; 1942 нең декабрендә яшерен ячейканың эше ачыла (аның әгъзалары 6 елга каторга төрмәсенә хөкем ителә); 1942 нең җәендә Польша терр-ясендәге хәрби әсирләр лагеренда Г.Кормаш совет хәрби әсирләренең яшерен антифашистик оешмасын төзи (к. *Җәлилчеләр төркеме*). Күп кенә легионерлар, беренче мәртәбә мөмкинлек тугач та, партизаннар ягына чыга. Берничә йөз легионер Ле-Пюине һәм Беанс округындагы шәһәрләрне азат итү өчен партизаннар көрәшендә катнаша. Легионнан качкач, 1 меңләп хәрби әсир партизаннар отрядларына кушыла һәм Польша, Чехословакия, Югославия, Франция, Бельгия, Голландия, Италия Каршылык хәрәкәтендә катнаша. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң легионерларның күп өлеше ватанга кайта, ләкин аларның күбесе кулга алына һәм совет концлагерьларына җибәрелә; бер өлеше эмиграциядә кала.


*Әд.:* Г и л я з о в И.А. Легион Идель-Урал. К., 2005.

**ИДЕ́Л-УРА́Л НЕФТЬ-ГАЗ ТӨБӘГЕ́** («И к е н ч е Б а к у»), РФдә нефть-газ чыгара торган иң эре регион. РФнең Көнчыгыш Европа өлешендәге Татарстан Респ-касы, Башкортстан, Мари, Удмурт респ-калары, Пермь, Киров, Ульянов, Самара, Оренбург, Саратов, Волгоград, өлешчә Свердловск һәм Пенза өлкәләре терр-яләрен үз эченә ала. Мәйданы 700 мең *км*$^2$.

Идел буенда нефть һәм асфальт чыгышлары 18 йөздән билгеле, планлы рәвештә нефтьне эзләү 1920 еллардан башлана. Беренче нефть чыганагы 1929 елда Верхнечусовские Городки посёлогы (Пермь өлкәсе) янында ачыклана, 1932 дә Ишембай чыганагы (БАССР), 1940–42 елларда газ чыганаклары ачыла (Саратов өлкәсе). 1940 елга 15 нефть һәм газ чыганагы табыла һәм алар базасында СССРның Европа өлешендә барлыкка килгән нефть чыгару һәм эшкәртү сәнәгате бик нык үсә һәм 1940 та инде И.М.Губкин бу терр-яне «икенче Баку» дип атый. 1950 дән соң Татарстан һәм Башкортстан төп нефть чыгару төбәге булып таныла.

ТР терр-ясендә системалы рәвештә нефть эзләү эшләре 1930 елларда башлана. 1943 тә карбон утырмаларында Шөгер чыганагы (соңыннан аның Ромашкино чыганагының бары тик бер өлеше булуы ачыклана), 1944 тә — Баулы, 1948 дә Ромашкино чыганагының югары дебитлы ятмалары ачыла. 2010 елга И.-У.н.-г.т.дә 1100 дән артык нефть һәм газ чыганагы ачыла. Иң зур нефть чыганаклары: *Ромашкино нефть чыганагы, Яңа Елховой нефть чыганагы* (Татарстан), Туймазы, Арлан (Башкортстан), Муханов, Кулешов (Самара өлкәсе), Ярино-Каменоложск (Пермь өлкәсе) һ.б.; газ һәм газ конденсатлылар — Оренбург (Оренбург өлкәсе), Коробково, Степное (Саратов өлкәсе).

Үзара геологик бәйләнештә И.-У.н.-г.т. Көнчыгыш Европа платформасының көнчыгыш өлешенә һәм Урал алды бөгелешенә (к.: рәс.) туры килә. Югары протерозой һәм фанерозой утырма капламның калынлыгы (бераз мезозой токымнарының катнашы б-н) көнбатышта 1,5 *км* дан алып төбәкнең көнчыгыш өлешендә 12 *км* га кадәр һәм артыграк. Девон, карбон һәм Пермь утырмалары нефть-газлы (нефть запасының 50% ыннан артыгы), кембрийгача яшьтә, ш.у. кристаллик фундаментта нефть күренешләре күзәтелә. Продуктив горизонтлар 0,5 *км* дан алып 5 *км* га кадәр һәм тирәнрәк тә ята. Ятмалар, нигездә, катламлы гөмбәзле, литологик экранлашкан катламлы һәм азрак күләмдә тектоник экранлашкан. Төбәктә нефть-газлы күп кенә өлкәләр билгеләнгән (Татар, Югары Кама, Пермь–Башкорт, Көньяк Урал алды, Мәләкәс–Абдулин, Урта Идел, Түбән Идел, Уфа–Оренбург), аларга Казан–Кажим, Вычегодск бөгелешләренең, Коми–Пермяк гөмбәзе һәм Татар гөмбәзенең Төньяк өлешләренең нефть-газлы р-ннары һәм перспектив җирләре керә. Татарстан терр-ясендә нефть запасларының төп массасын югары тәртиптәге эре структуралар: Ромашкино чыганагы — Көньяк Татар гөмбәзе, Яңа Елховой һәм Баулы чыганаклары — аның сөзәклекләре контрольдә тота, бу исә чыганакларның зурлыгын билгели. Шулай да чыганакларның шактый өлеше локаль структураларга туры килә. Еш кына чыганаклар гөмбәзле, күп катлы, күп катламлы, кайвакыт нефть-газлылыкның киң диапазонына ия. Нормаль гидростатик басым шартларында скважиналар дебиты уртача (100–200 *т/с* кадәр) һәм зур түгелләр. Ятмаларны эшкәртү, кагыйдә буларак, катлам басымын саклап һәм суландыруны кулланып тормышка ашырыла. Башлыча, нефтьләр парафинлы типта, уртача һәм югары тыгызлыкта (820–890 *кг/м*$^3$), күкертле (1,8%) һәм сумалалы. Гомумән алганда, төбәк буйлап төньяктан көньякка һәм көнбатыштан көнчыгышка таба нефть тыгызлыгының әкренләп кимүе, аларда күкертнең азаюы һәм эрегән газның артуы, парафинлы-нафтенлы типка күчүе күзәтелә. Түбән Пермь утырмаларының ирекле газлары метанлы, күкертле (5,5% ка кадәр), аз микъдарда азотлы. Төньяк р-ннарның ташкүмер утырмалары нефтендәге газ катламы һәм эрегән газларда азот газы 98% ка кадәр була. Карбонның Бобриков горизонтындагы күмер катламында метанның шактый зур запаслары урнашкан. 1960 елларда И.-У.н.-г.т.нең нефть-газ ресурслары базасында СССРда иң эре нефть-газ чыгару һәм эшкәртү сәнәгате формалаша. Табылган барлык нефтьнең 1940 та — 6%ы, 1960 та 70,6% ы И.-У.н.-г.т.нә туры килә. Нефть чыгаруның яңа өлкәләрен үзләштерү сәбәпле (Себер, Мангышлак), гомумсоюз нефть чыгаруында И.-У.н.-г.т.нең өлеше 1970 елларда 50% ка кадәр диярлек кими, ә 20 йөз ахырына 30% ка кадәр төшә. 1970 елларда илнең аерым бер төбәгендә беренче булып ТАССРда елга 100 млн. *т* нефть чыгаруга (И.-У.н.-г.т.дә табылган нефтьнең яртысы кадәр) ирешелә, бу




күрсәткеч 7 ел буена үзгәрми. 1990 еллар ахырына нефть чыгару 4 тапкырдан артык кими. Татарстан, нефть чыгаручы регион буларак, мәйданы буенча И.-У.н.-г.т.нең уннан бер өлешен били. 2010 елның 1 гыйнварына эре чыганакларның саны, запасларның торышы (58%), чыгарылу күләме (1/3 кә якын) һәм чыгарылган нефть (3,0 млрд. *т* дан күбрәк) буенча төбәктә 1 нче урынны ала.

И.-У.н.-г.т. промыселларында чыгарылган нефтьнең шактый өлеше нефтьүткәргечләр буенча җирле нефть эшкәртү з-дларына китә (Башкортстан, Самара өлкәләре һ.б.), РФнең төньяк-көнбатыш з-дларына һәм экспортка җибәрелә. Нефть-газ чималы нигезендә күп төрле нефть химиясе производстволары 100 дән артык төрдә продукция эшләп чыгара. Табигый газ җирле энергетик ягулык буларак кулланыла. Нефть-газ чималын чыгаруның һәм эшкәртүнең артуы иске шәһәрләрнең (Бөгелмә, Уфа, Эстәрлетамак һ.б.) үсеш алуына һәм яңа шәһәрләр (Түбән Кама, Әлмәт, Салават һ.б.) барлыкка килүгә этәрә. Газның күп өлеше, ш.у. нефть эшкәртү һәм нефть химиясе производствосы продуктлары Россиянең күп кенә төбәкләренә һәм аннан читкә җибәрелә. Әлмәттән дөньяда иң зур нефтьүткәргечләрнең берсе булган «Дуслык» («Дружба») үткәргече башлана һәм ул РФ шәһәрләрен, якын һәм ерак чит илләрнең кайберләрен нефть б-н тәэмин итә. Идел буе газы илнең төрле төбәкләренә газүткәргечләр буенча, нефть продукциясенең бер өлеше су юлы һәм тимер юллар буенча җибәрелә.

*Әд.:* Нефтегазоносные провинции СССР. М., 1979; Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996; В о й т о в и ч Е.Д., Г а т и я т у л л и н Н.С., Т а р а с о в Е.А. Развитие поисков и разведки нефти в РТ // Геология и минерально-сырьевые ресурсы Европейской территории России и Урала // Материалы региональной конф. Екатеринбург, 2000. Кн. 1; Нефтегазоносность Республики Татарстан. Геология и разработка нефтяных месторождений: В 2 т. К., 2007.

*Р.Х.Мөслимов.*

**«ИДЕ́Л-УРА́Л ӨЛКӘСЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. *Мөселман халык комиссариаты* органы. «*Безнең тавыш*» г-тасының дәвамчысы. 1918 елның 24 мартыннан 27 сенә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 2 саны чыга. Мөхәррире — А.Габидуллин. И.Алмашев, И.Атнагулов, Н.Әхмәд углы, Ф.Басыйров, А.Биглов, Г.Габдерәшитов, С.Лафчетский, Ф.Мөхәммәдъяров, С.Палтаржитский, Г.Ракаев, А.-С.Таһиров, К.Терегулов, А.Якубовский һ.б. авторларның мәкаләләре басыла. «Яшәсен мөселман демократиясе!» шигаре астында чыга. Газетаның максаты: революция һәм мөселманнар демократиясе, Идел-Урал Штаты идеалларын яклау, РСФСРдагы барлык мөселманнарны бергә туплау. Мөселманнарның 2 нче хәрби съезды, Казан губернасы крәстияннәре съезды, Мөселман халык комиссариаты материаллары басыла. Төркестан, Казакъстан, Башкортстанда һ.б. урыннарда татар телендә газеталар чыгу турында белдерүләр бирелә.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ИДЕ́Л-УРА́Л ТӨБӘГЕ́ СОВЕТЛАРЫ́ СЪЕЗДЫ́**, 1918 елның 8–9 гыйнварында Казанда эшли. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы инициативасы б-н чакырыла. Максаты — милли мәсьәләне хәл итүнең *Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае* тарафыннан *Идел-Урал Штаты* игълан ителүгә каршы формалар эзләү. Съездны оештыру бюросына К.Я.Грасис, Н.Д.Ефремов, М.П.Жаков, Н.П.Пономарёв, М.Х.Солтангалиев һ.б. керә. 1918 нең гыйнвар башында Казан советы Идел-Урал төбәге советларына булачак корылтай «Милли үзбилгеләнүгә омтылучы Идел-Кама бассейны халыкларының Учредительләр җыенын чакыру турында»гы мәсьәләне хәл итәчәк, дигән телеграмма җибәрә. Советларга һәр губерна һәм өяз советыннан 3 әр, һәр губернада яшәүче һәр халыкның милли оешмасыннан 1 әр делегат сайларга тәкъдим ителә. Кайбер милли оешмаларга, ш.и. Уфа мөселман хәрби шурасына хәбәр аерым тәртиптә җибәрелә. Казан советы рәисе К.Я.Грасис «Знамя революции» г-тасында «Советларның өлкә корылтаена» («К областному съез-

ду Советов», 1918, 19 февр.) дигән махсус мәкалә бастыра, анда хәл ителергә тиешле төп проблема сыйфатында милли мәсьәлә күрсәтелә. Съездда Әстерхан, Вятка, Казан, Түбән Новгород, Оренбург, Пенза, Пермь, Самара, Саратов, Сембер, Уфа губерналары Эшче, солдат һәм крәстиян советлары һәм милли оешмалары вәкилләре, барлыгы 89 делегат, ш.и. Казан губерна советыннан — 28, Сембер губерна башкарма ком-тыннан 10 кеше катнаша. Съездда Хәрби Шура һәм *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәте* җитәкчеләре И.С.Алкин һәм Г.Ш.Шәрәфтә була. Съездның җитәкчесе — Казан губерна башкарма ком-ты рәисе Я.С.*Шейнкман*, рәис урынбасарлары: мөселманнардан — М.Х.Солтангалиев, сул эсерлардан — А.А.Денисов. Милли мәсьәлә буенча доклад б-н К.Я.Грасис чыга, ул Мөселман шурасының һәм Украина Радасының контрреволюцион асылына басым ясый, милли мәсьәлә һәр совет респ-касында анда яшәгән халыкка карап хәл ителәчәк, ди. Съездда К.Я.Грасис б-н мөселман вәкилләре арасында кискен бәхәс туа. Съезд төбәк халыкларының Идел-Урал Совет Республикасы формасындагы үзбилгеләнүе турында резолюция кабул итә. Ул түбәндәге карарларны чыгара: 1. Аерым совет республикаларына кирәк очракта халыкның этник составына пропорциональ рәвештә хакимият органнары булдырырга; 2. Совет республикалары каршында милләтләр эшләре комиссариатлары булдырырга; 3. Өлкә федерациясе оештырганда аерым халыклар эшләре буенча ген. комис-т булдырырга.

Чыг.: Образование Татарской АССР: Сб. док-тов и материалов. К., 1963.

*Әд.:* Х а й р у т д и н о в Р.Г: Трудное возрождение. К., 1992.

**ИДЕ́Л-УРА́Л ТӨБӘГЕ́ ТАТА́Р-БАШКО́РТ СУЛ ЭСЕРЛА́Р ПА́РТИЯСЕ**, к. *Татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясе.*

**ИДЕ́Л-УРА́Л ШТАТЫ́**, татар һәм башкорт халыкларының ниятләнгән милли дәүләт (автономия) формасы. И.-У.Ш.н төзү һәм аның закон чыгару, башкарма органнарын оештыру турындагы карар 1917 елның 29 ноябрендә *Милләт Мәҗлесендә* кабул ителә. Бу вакыйга аның эшчәнлегенең мөһим нәтиҗәсе була, милли-мәдәни автономия (төркичеләр) һәм милли-терр. автономия (тупракчылар) тарафдарлары арасында үзара килешүгә ирешелә. Милләт Мәҗлесе резолюциясенең беренче пунктында, Штаттагы барлык халыкларның милли һәм икътисади мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен, халыкның күпчелеген татарлар һәм башкортлар тәшкил иткән терр-яләрдә И.-У.Ш. игълан итү турында белдерелә; икенчесендә Штатның терр-ясе билгеләнә, аңа тулысынча Казан һәм Уфа губерналары, өлешчә Вятка, Оренбург, Пермь, Самара, Сембер губерналары өязләре (ш.у. чуаш һәм мари җирләре дә — анда 7 млн. нан артык кеше яши, халыкның 51% ын татарлар һәм башкортлар тәшкил итә) кертелә; өченчесендә хакимиятнең югары органы дип гомуми, тигез, туры һәм яшерен сайлаулар нигезендә сайлана




торган парламент игълан ителә, аның вазифасына, федераль парламентка бирелгәннәреннән тыш, барлык мәсьәләләр карый, һәм ул иң югары закон чыгару органы дип белдерелә; дүртенчесендә федерация вәкаләтләре катгый ассызыклана, аларга почта, телеграф, тимер юллар һәм су юллары, авырлык һәм озынлык үлчәү берәмлекләре, акча системасы нигезләре, гражданлык, җинаять, сәүдә һәм вексель хокуклары нигезләре, гомумфедераль салымнар, халыкара заемнар, тышкы сәясәт һәм таможня эшләре (фәкать бу мәсьәләләрдә генә федераль парламент законнары җирле парламент законнарыннан өстенлек итә) керә; бишенчесендә милләтләр, телләр һәм диннәр тигезлеге игълан ителә; алтынчысында Штат парламентының федераль законнар эшләүдә һәм үзәк гомумдәүләт оешмалары эшләрендә катнашмавы турында әйтелә. 1918 нең 22 гыйнварында «Безнең юл» г-тасында басылган мәкаләдә Эчке Россия һәм Себер төрки-татарлары Милләт Мәҗлесенең Төп Законны кабул итүе һәм И.-У.Ш.ның терр. автономиясе турындагы карары татар-башкортларны халыкара мәйданның хокукый дәрәҗәсенә күтәрүе, халыкның үз иленә үзе контрольлек итүе турында әйтелә. И.-У.Ш.ның югары башкарма органы итеп *Милли идарә* билгеләнә, ул өч министрлыктан — Малия (Финанс), Мәгариф, Диния (Дини идарә) нәзарәтләреннән һәм ике ком-ттан — Хәрби һәм Тышкы эшләр ком-тларыннан тора. 1918 нең 5 гыйнварында Милли идарә рәисе итеп С.*Максуди* сайлана.

Штатны төзү буенча гамәли эшләр Милләт Мәҗлесе карары б-н оештырылган *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәтенә* йөкләнә. Һәйәт Урта Идел буенда һәм Урал янында яшәүче төп халыклар вәкилләре б-н булачак Штатның этник төзелеше, сәяси һәм икътисади статусының принциплары турында сөйләшүләр алып бара. Әмма әлеге эш барышында ул Идел буе һәм Урал яны халыкларының төрле милли төркемнәре вәкилләре арасында берничә йөз еллар дәвамында тупланып килгән күпсанлы этносәяси һәм этник каршылыкларга очрый. Бу каршылыклар татар һәм башкорт милли хәрәкәтенең төп вәкилләре арасында аеруча кискенләшә. 1918 нең 5 гыйнварында Учредительләр җыены тарафыннан «Россиянең дәүләт төзелеше турында карар» чыгарылып, Россия «Россия Демократик Федерациясе» дип игълан ителгәч, Башкорт Шурасы һәм Башкорт корылтае делегатлары мөстәкыйль Башкортстан автономиясен төзү идеясен күтәрәләр. 1918 нең 6 гыйнварында башкорт милләтчеләре җитәкчесе Ә.Вәлиди Милләт Мәҗлесе утырышындага чыгышында И.-У.Ш. төзү турындагы карар б-н ризалашмавын белдерә һәм «татарларга урын булган, әмма рус килмешәкләренә урын булмаган» Гомумбашкорт съездының «Автономияле Башкорт Республикасы» оештыру турындагы резолюциясен тәкъдим итә. Г.*Шәрәф* башкорт милли лидерларының сәяси башбаштаклыгына каршы кискен чыгыш ясый, «Штатның барлык халыклары өчен тигез хокуклылык» идеясен тәкъдим итә. Әлеге каршылыклар милли-дәүләт төзелеше мәсьәләсе буенча татар һәм башкорт милли лидерлары арасында тәмам этносәяси аерымлануга китерә. Мондый хәлдә Һәйәт, үз эшен туктатып, Уфа шәһәреннән Казанга күчәргә, И.-У.Ш. советларының Оештыру корылтаен чакыруны көтеп тормастан, *Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтаенда* (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*) Штатны төзү турында игълан итү тәкъдимен кертергә мәҗбүр була. Корылтайда И.-У.Ш.н төзүнең принциплары һәм аның картасы турындагы

төп докладны Й.*Мозаффаров* ясый. Аның фикеренчә, Штат РСФСРның состав өлеше була һәм анда Бөтенроссия дәүләт органнары үрнәгендә ҮБК һәм ХКС төзү күздә тотыла. Булачак милли берәмлекнең дәүләт хакимияте формаларын тикшерү барышында Учредительләр җыены һәм Совет хакимияте тарафдарлары арасында каршылык туа, соңгылары (сул фракция әгъзалары) корылтайны ташлап чыгып китә. Большевиклар Петроградта 1917 елның 5–6 гыйнварында эшләгән Учредительләр җыенын куып тараткач, татар һәм башкорт милли хәрәкәтләре лидерлары арасындагы сәяси каршылык тагын да көчәя, Советларның милли оешмаларга идеологик басымы арта. Әмма, шуңа да карамастан, И.-У.Ш.н оештыру эше тукталмый, Штатны оештыру турында универсал төзелә һәм аны игълан итү көне итеп 1918 нең 1 марты билгеләнә. 1918 нең 16 гыйнварында «*Эчке Россия һәм Себер төрки-татар мөселманнарының милли автономиясе* турындагы төп нигезләмәләре» игълан ителә. 1918 нең февралендә Һәйәт рәисе Г.Ш.Шәрәф телеграмма б-н Уфа мөселман хәрбиләр советына Һәйәтнең якын арада Штат терр-ясен РСФСРның бер өлеше дип игълан итәчәге турында карар чыгаруын җиткерә. Бу исә Милләт Мәҗлесе делегатларының бер өлешенең һәм Башкортстан Вакытлы Революцион Советының Башкортстан терр-ясен Штат составына кертүгә каршы кискен протестын тудыра.

И.-У.Ш.н төзүгә каршы тору максатында Казан Советы 26 февральдә башбаштак рәвештә *Казан Совет Эшче-Крәстиян Республикасын* оештыра, аның Я.С.Шейнкман җитәкләгән хөкүмәтен төзи, Казанда хәрби хәл игълан итә һәм 28 февральдә хәрби корылтай җитәкчеләрен кулга ала. Кулга алуга җавап итеп, корылтай җитәкчеләре советы 1918 нең 1 мартында Казанда татарларның күпмеңлек (10 мең кешегә кадәр) демонстрациясен оештыра, анда катнашучылар хакимият алдына кулга алынганнарны иреккә чыгару һәм милли дәүләтчелек игълан итү таләбен куялар. Хәрби корылтай делегатлары 57 мең мөселман солдатлары исеменнән Милләт Мәҗлесенә тугрылыкка ант итәләр. Аннан соң булган фаҗигале вакыйгалар совет тарих фәнендә «*Болак арты республикасы*» дигән исем ала, 1918 нең гыйнварында В.И.Ленин һәм И.В.Сталинның М.М.Вахитов, Г.Г.Ибраһимов һәм Ш.А.Манатов б-н очрашуыннан соң РСФСР Милләтләр эшләре халык комис-ты каршында Мөселман комис-ты оештырыла (к. *Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариаты*), аңа И.-У.Ш.на «Татар-Башкорт автономиясе» формасындагы альтернатив вариант эшләргә кушыла. Комис-т съездның И.-У.Ш. турындагы Идел-Урал төбәге өлкә советлары һәм Милләт Мәҗлесе резолюцияләрен берләштерү юлы б-н «*Татар-башкорт Совет Социалистик Республикасы*» турындагы нигезләмәне эшли (1918 нең 22 мартында басылып чыга). 26 мартта И.В.Сталин Оренбург советына җибәргән телеграммасында болай дип белдерә: «Көньяк Урал һәм Урта Идел буе территориясе Россия Совет Федерациясенең Татар-Башкорт Совет Республикасы дип игълан ителә». «Татар-Башкорт Республикасы» турындагы нигезләмәне И.-У.Ш.на альтернатива сыйфатында тәкъдим итеп, Совет җитәкчелеге татар-башкорт милли-дәүләт төзелешенә үзенең тулы контролен урнаштыра һәм Урта Идел буе терр-ясендә берничә «курчак» автономия төзи, шул рәвешле Штат төзү идеясен тәмам юкка чыгара. И.-У.Ш. татар халкының үзенең чын милли дәүләтчелеген торгызу юлындагы беренче тәҗрибәсе була.

*Әд.:* Татар-башкортлар һәм Татарстан Республикасы. К., 1920; Давлетшин Т. Советский Татарстан: теория и практика ленинской национальной политики. Лондон. 1974; Юлдашбаев Б.Х. Национальный вопрос в Башкирии накануне и в период Октябрьской революции. Уфа, 1984; Исхаки Г. Идель-Урал. К., 1991; Тагиров И.Р. История татарского народа и Татарстана. К., 2000.

*Р.К.Вәлиев, Р.В.Шәйдуллин.*

**ИДЕ́Л-УРА́Л ШТАТЫ́Н ГАМӘЛГӘ́ КЕРТҮ́ ҺӘЙӘТЕ́**, *Милләт Мәҗлесе* карары б-н 1918 елның 7–8 гыйнварында оештырыла. Рәисләре — Г.Шәрәф, И.Алкин; әгъзалары — И.Атнагулов, Г.Гобәйдуллин, С.Енгаличев, Ф.Мөхәммәдъяров, Ф.Сәйфи-Казанлы, Н.Хәлфин, әгъзалыкка кандидатлар — Г.Абызов, Ш.Әхмәдиев, С.Габдулов, И.Габитов. Аның составына руслардан — 5, чуашлардан — 2, марилардан 1 вәкил кертү күздә тотыла. Һәйәт милли һәм иҗтимагый оешмалар б-н сөйләшүләр үткәрергә һәм алар б-н бергәләп *Идел-Урал Штатын* төзү турында белдерергә, вакытлы конституция кабул итәргә, Уфа шәһәрендә конференция чакырырга, вакытлы хөкүмәт оештырырга һәм булачак дәүләтнең чикләрен билгеләргә тиеш була. Һәйәтнең үз эшчәнлеген Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы б-н килештерү күздә тотыла. Штат булдыру мәсьәләсе буенча Ф.Мөхәммәдъяров һәм Ф.Сәйфи-Казанлы Совет б-н сөйләшүләр алып бара, ләкин анда бер як та килешергә теләми, сөйләшүләр нәтиҗәсез тәмамлана. Һәйәт Оештыру җыенын чакыруны озакка сузгач, Штат төзү инициативасын Хәрби Шура үз кулына алырга тырыша. 1918 нең гыйнвар-февралендә Казанда үткән Бөтенроссия мөселман хәрбиләренең 2 нче корылтаенда 1918 нең 1 мартында митингта Идел-Урал Штатын төзү турындагы резолюцияне тантаналы рәвештә игълан итәргә карар кылына, әмма 27 февральдән 28 февральгә каршы төндә корылтай җитәкчеләре Д. һәм И.Алкиннарны, Й.Мозаффаровны, О.Токымбәтовны Казан советы карары буенча кызылармиячеләр отряды кулга ала (к. «*Болак арты республикасы*»). Татар-Башкорт ССРны төзү турындагы нигезләмә игълан ителгәч һәм 1918 нең апрелендә милли оешмалар (Хәрби Шура, *Милләт Мәҗлесе* һ.б.) таркатылгач, Һәйәтнең эшчәнлеге тыела.

*Әд.:* Вәлиев Р.К. Болак арты республикасы. К., 2003; Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

*Р.К.Вәлиев.*


**«ИДЕ́Л-УРАЛЧЫЛА́Р ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́**, 1938 елда ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты тарафыннан бер төркем кешеләргә карата оештырылган ялган гаепләү эше. Алар Совет хакимиятен бәреп төшерү һәм төрки-татар дәүләте — *Идел-Урал Штаты* төзү максатында буржуаз-милләтчел диверсион оешма булдыруда гаепләнә. Әлеге «эш» буенча җәлеп ителгәннәргә ш.у. чит илләргә киткән татар милләте вәкилләре аша чит ил разведкалары б-н шпионлык элемтәсендә тору, аларның кушуы буенча СССРга каршы разведка-җимерү эшләре алып бару гаебе дә тагыла. Татарстаннан, Башкортстан, Урта Азия һәм СССРның башка төбәкләреннән, ш.у. Мәскәүдән (Г.Габдрәхимов, Г.Абызов, Р.Алмаев, И.Әмирханов, И.Әхтәмов, Х.Габидуллин, Г.Гобәйдуллин, Р.Ибраһимов, Ә.Мөхетдинова, Г.Нигъмәтуллин, С.Садыйков, К.Тәрҗемани, И.Уразмөхәммәтов, И.Хәйруллин, С.Хәсәнкаев, Х.Хәсәнов, Г.Шәрәф һ.б.) һәм эмиграциядәге татарлардан (А.Агиев, Й.Акчура, Г.Баттал, Ә.Вәлиди, А.Идриси, С.Максуди, Г.Терегулов, О.Токымбәтов, Ф.Туктаров, Я.Шынкевич һ.б.) барлыгы 230 кеше гаепләнә. 1938 дә Казанда бу «эш» буенча җәлеп ителүчеләрнең кайберләренә суд була. ТАССР эчке эшләр халык комиссары В.И.Михайлов әйткәнчә, «татар милли фашизмы»н «бер селтәнүдә» юк итү буенча киң колачлы ниятне гамәлгә ашыруга Н.И.Ежовның СССР эчке эшләр халык комиссары вазифасыннан читләштерелүе б-н бәйле 1939 елгы үзгәрешләр комачаулый. «Эш»тә катнашучыларның кайберләреннән гаепләүләр алына, эзәрлекләү туктатыла. 1956 да СССР Югары мәхкәмәсе коллегиясе карары б-н барлык гаепләнүчеләргә карата булган хөкем юкка чыгарыла һәм, аларның эш-гамәлләрендә җинаять булмау сәбәпле, эш туктатыла, күпчелеге аклана.

*Әд.:* Гайнетдинов Р.Б. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века — 30-е годы. Наб. Челны, 1997.


*И.М.Мөлеков.*

**ИДЕ́Л-ЧУЛМА́Н БУЕ́ БОЛГА́Р ДӘҮЛӘТЕ́**, к. *Идел буе Болгар дәүләте.*

**ИДЕ́Л-ЧУЛМА́Н БУЕ́ КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Урта Идел буенда һәм Чулман янында неолит дәверендә яшәүчеләргә нисбәтле археол. культура (якынча б.э.к. 5 нче – 3 нче меңьеллыклар). А.Х.*Халиков* тарафыннан аерылып чыгарыла; аның фикеренчә, 5 этапны, ягъни: керамик савыт-саба кулланышка кергәнче, элгәреге керамика (уемлы-сырлы балчык савыт-саба), ныk үскән (башлыча, вак тешле бизәкле савыт-саба), соңгы дәвер (башлыча, уртача тешле бизәкле савыт-саба) һәм иң соңгы (чокырлы һәм эре тешле бизәкле савыт-саба) этапларын колачлый. Р.С.Габәшев һәм В.В.Никитин И.-Ч.б.к.ның «элгәреге керамика этабы» истәлекләрен мөстәкыйль культура буларак аералар. И.-Ч.б.к. халкы җиләк-җимеш, гөмбә, үсемлек, үлән тамырлары җыю, аучылык, балыкчылык һәм терлекчелек б-н көн күргән. Тораклар, гадәттә, турыпочмаклы яки түгәрәк рәвешендә, 40–69 $м^2$ мәйданда җиргә ярты-лаш казып салынган. Татарстан терр-ясендә И.-Ч.б.к. истәлекләре Апас р-ның Ка-



Г.С. Иделле.



Фәрит Иделле.

бык-Күпер, Спас р-нының Ширбәт, Алексеев р-нының Лебедино авыллары янында һ.б. урыннарда табыла.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Г а б я ш е в Р.С. Памятники с накольчато-прочерченной керамикой приустьевой части Камы // Из археологии Волго-Камья. К., 1976; ш у л у к. Население Нижнего Прикамья в V–III тысячелетиях до нашей эры. К., 2003; Н и к и т и н В.В. Каменный век Марийского края. Йошкар-Ола, 1996.

*Р.С.Габәшев.*

**ИДЕЛБИКӘ́** (псевд., чын исем-фамилиясе Лена Биньямин кызы Садыйкова-Сабитова) (19.8.1930, БАССРның Мәчетле р-ны Яңа Мөслим а.), шагыйрә. 1973 елда Ульянов пед. ин-тын тәмамлый. 1946–85 елларда Ташкент, Новокузнецк, Ульянов шәһәрләрендә техник-картограф, техник-сызымчы булып эшли. Матбугатта шигырьләре 1990 елларда басыла башлый. Алар «Сембер язлары» (1995) исемле күмәк җыентыкка керә. «Мәхәббәтнең мең фасылы» (Ульянов, 1997), «Бәхеткә үс, кеше» (Ульянов, 2000), «Дөнья авазлары» (2003), «Юллар һәм уйлар» — «Дороги и думы» (Таулы Алтай, 2005, рус теләндә), «Күңел күккә омтыла» (2007) шигъри җыентыклар авторы. И.нең лирик героена камиллеккә омтылу, хатын-кыз зирәклеге хас. Вакытлы матбугат битләрендә әдәби-публицистик мәкаләләр б-н чыгышлар ясый.

*Әд.:* М у л л а н у р о в а Р. Мәхәббәтнең мең фасылы // Сөембикә. 1998. № 11.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ИДЕЛЛЕ́** (псевд., чын фамилиясе Усманов) Газиз (Габделгазиз) Сәлах улы (26.12.1905, Әстерхан — 27.7.1985, Казан), язучы. 1923 елда Свердловск индустриаль техникумына укырга керә. Аны тәмамламыйча, «Сабан һәм чүкеч» г-тасы редакциясендә эшли башлый: мәкаләләр, очерклар, фельетоннар яза. Әсәрләрен «Шәпи агай» исемле сатирик ж-лда да бастыра. 1926 дан Казанда яши. Татарстан ҮБК аппаратында эшли, 1929 дан республика вакытлы матбугатында: «Безнең юл», «Атака» ж-лларында, «Кызыл Татарстан» г-тасында җаваплы сәркәтип, «Совет әдәбияты» ж-лында мөхәррир, Татарстан радиокомитетында баш мөхәррир. 1930–40 елларда Совет Армиясендә хезмәттә. Бөек Ватан сугышы елларында фронт газеталарында эшли, туган илне дошманнардан саклаучылар турында хикәяләр һәм очерк цикллары бастыра. 1949–57 дә ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант. «Пумала башлар» (1930), «Икмәк һәм хатын» (М., 1931), «Тормышка мәхәббәт» (1959), «Ул көннәр» (1967), «Күргәннәрем, белгәннәрем» (1975) исемле хикәя җыентыклары, «Дәүләт Бәдриев» драмасы (1936; Татар акад. театрында 1937 тә куела), «Язучы һәм аның китабы» (1964) исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы авторы. А.Фадеевның «Тар-мар» («Разгром», 1933), П.Павленконың «Бәхет» («Счастье», 1950) әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1937 дә нахакка гаепләнә, 1939 да аклана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1955; Беренче зур сәяхәт: Истәлекләр, очрашулар, уйланулар. К., 1980.

*Әд.:* Ә п с ә л ә м о в Г. Газиз Иделле // Совет әдәбияты. 1956. № 3; И ш м о р а т Р. Каләмдәш дустыбыз // Социалистик Татарстан. 1975. 31 дек.

**ИДЕЛЛЕ́** Фәрит (псевд., чын исем-фамилиясе Аги Фәрит Әмрулла улы) (16.4.1943, Кытай, Чанчунь ш.), радиожурналист. 1963–66 елларда Төркиядә Истанбул ун-тының тюркология ф-тында укый. 1966–69 да төрек армиясендә хезмәт итә. 1969 дан «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясендә хәбәрче, программа күзәтүчесе, комментатор, тәрҗемәче (Мюнхенда, 1995 тән Прагада), 1984 тән «Азат Европа радиосы / Азатлык радиосы» корпорациясенең татар-башкорт редакциясендә директор урынбасары, 1989–2006 да директор. «Г.Тукай исем. яшьләр клубы»на (Истанбул) нигез салучыларның берсе, «Тукай бюллетене» ж-лының редколлегия әгъзасы. Татарстан суверенлыгы һәм татар милли хәрәкәтенә багышланган «Татарлар тавышы» исемле документаль фильм сценарие авторы һәм аның продюсеры (1991, Бавария телекомпаниясе б-н берлектә). Фильм берничә тапкыр Германия телевидениесендә күрсәтелә. 1–3 нче Бөтендөнья Татар конгрессляры эшендә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Kazak ve Tatar Türkleri. Ist., 1972 (автордаш).

**ИДИА́ТОВА** Венера Рәис кызы (6.10.1962, Әлмәт), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУында эшли: оператор, нефть һәм газ чыгару цехы геологы, төркемнең әйдәп баручы геологы, нефть һәм газ чыгару цехының «Армитс» төркеме җитәкчесе урынбасары (2004 тән). Дәүләт бүләге нефть чыгару процесслары б-н идарә итү һәм оператив күзәтүнең кооператив мәгълүмат системасын эшләгәне һәм сәнәгатькә кертүе өчен бирелә.

**ИДИО́МА**, к. *Фразеологизмнар.*

**ИДИЯТУ́ЛЛИН** (Һидиятуллин) Рево Рамазан улы (2.10.1938, Казан), партия һәм хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1966). 1956–67 елларда «Радиоприбор» җитештерү берләшмәсендә эшли. 1967 дән партия эшендә: 1967–69 да Казанда КПССның Идел буе райкомында инструктор, сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире, 1969–73 тә «Теплоконтроль» з-дында партия ком-ты секретаре, 1973–80 дә Казан шәһәр ком-тының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, 1980–83 тә КПССның Идел буе, Вахитов р-н ком-тларының 1 нче секретаре, 1983–85 тә Казан шәһәр ком-тының 2 нче секретаре, 1985–88 дә Халык депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. 1988 дән КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1990–91 дә Татарстан респ-ка ком-ты 1 нче секретаре. 1994–98 дә Татарстан-Төркия-Россиянең уртак «ТАТУРОС» пр-тиесе президенты. 1985–90 да РСФСР ЮС депутаты.

**ИДИЯТУ́ЛЛИНА** (Һидиатуллина) Клара Салих кызы (11.2.1955, Октябрь, хәзерге Нурлат р-ны Победа пос.), тарихчы, сәясәт фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1981 дән Казан технол. ун-тының дәүләт идарәсе, тарих, социол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре региональ сәяси лидерлык, региннарда сәяси процесслар үсеше, дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Региональное политическое лидерство в России: пути эволюции. К., 1997; Политическое лидерство как фактор регионального развития (на материалах национальных республик Российской Федерации). К., 2003.

**ИДРӘ́С-ТИНКИ́** (Тиңкә-Идрәс) авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Идрәс-Тенишево исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, күн аяк киеме, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.-Т.дә мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төяклә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 973,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинка-Шонгыт волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 86 ир-ат, 1859 да — 353, 1897 дә — 705, 1908 дә — 743, 1920 дә — 799, 1926 да — 573, 1938 дә — 545, 1949 да — 398, 1958 дә — 342, 1970 тә — 314, 1979 да — 302, 1989 да — 211, 2002 дә — 191 кеше.

**ИДРИСИ́** Галимҗан (Алимҗан) Ибраһим улы (1.5.1887, Кызылъяр, хәзерге Петропавловск ш. — 1959), журналист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Истанбул ун-тын тәмамлаганнан соң (1912), «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укыта, «Шура» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. 1913–14 елларда Лозанна (Швейцария) һәм Льеж (Бельгия) шәһәрләрендә телләр һәм филос. өйрәнә. 1914–15 тә «Төрк юрду» ж-лы (Истанбул) редакторларының берсе. 1915 тән Германиядә Чит ил эшләре министрлыгы хезмәткәре (1921 гә кадәр). 1916–22 дә имам, *Вюнсдорф лагере* җитәкчеләреннән берсе. 1922–24 тә Бохара Халык Совет Респ-касының Германиядәге рәсми вәкиле. СССРдан Германиядә укырга җибәрү өчен мөселман студентларын туплый. «Россия мөселман студентларына ярдәм җәмгыяте»н (1918–24), «Аллаһыны олылау мөселман берләшмәсе»н (1924–28) оештыру-

чыларның һәм аларның җитәкчеләренең берсе. И. Германиянең мөселман общинасы тормышында актив катнаша, матбугатта чыгышлар ясый, лекцияләр укый. 1929–30 да Берлин ун-тының филос. ф-тында ирекле тыңлаучы. 1934–39 да Германия Чит ил эшләре министрлыгы фәнни хезмәткәре (консультанты); 1939–45 тә Пропаганда министрлыгында, гарәп һәм төрек редакцияләрен җитәкли, радиопропаганда алып бара. 1944 тә Көнчыгыш төркиләрнең хәрби берләшмәсе өчен хәрби-кыр муллалары әзерләү мәктәбенә шеф-укытучы (җитәкче) итеп билгеләнә. И. карашларының кискенлеге б-н аерылып тора, нацистлар режимын яклый, СССРдагы төрки халыкларның «азатлык» көрәшендә аларның ярдәменә исәп тота. Бер дәүләт эчендә «төрки бергәлек» идеясе тарафдары буларак, эмигрантлар арасында танылу алмый, тәкәбберлеге һәм сәяси яктан килешмәүчәнлеге аркасында татар эмиграциясенең барлык лидерлары б-н катлаулы мөнәсәбәттә тора. Сугыштан соң И. Мисырга күчеп китә, король Фарук сараенда тәрҗемәче булып эшли. Мисырда элеккеге татар хәрби әсирләреннән торган авыллар төзергә тели, 1952 дә, король бәреп төшерелгәннән соң, Согуд Гарәбстанына китә, тәрҗемәче булып эшли.

*Әд.:* Г и л я з о в И.А. Судьба Алимджана Идриси // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4.

*И.А.Гыйләҗев.*

**ИДРИ́СИ** Мөхәммәд Ибраһим улы (1882, Казан — 28.9.1948, Мәскәү), полиграфист, картограф, каллиграф, рәссам-график, бердәм калыпка салынган гарәп шрифтын барлыкка китерүче, төрки һәм шәрекъ телләре белгече. Татар китабының беренче проф. рәссамнарыннан. «Халык көйләре» (1910) китабының иллюстрацияләре авторы. Нашир һәм китап сәүдәгәре И.Идрисов гаиләсеннән. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый, әтисенең — «Идрисов, Галиев һәм Кº» ширкәте хуҗасының китап кибетендә, ш.у. Казанның төрле типографияләрендә (И.Н.Харитонов һ.б.) өйрәнчек була. Төркия, Ливан һәм Мисырда сәфәрдә (1905) вакытында каллиграфияне, типография эшен өйрәнә, гарәп, фарсы, төрки телләрдә сөйләмен камилләштерә. Гарәп графикасы нигезендә Россиядә китап бастыру эше тәҗрибәсе б-н танышу өчен Мәскәүдәге «Леман һәм Кº» АҖ типографиясендә эшли, Лазарев Шәрекъ телләре ин-ты, Отто Гербек, М.Оттай типографияләрендә эшнең куелышын өйрәнә (1908–09). Казанга күчеп килгәч, «Милләт» типографиясендә эшли, бер үк вакытта хәреф җыючы, гравёр, хәреф эретеп коючы, пуансонист, инженер-механик, аннары эшне оештыручы һәм мөдир булып хезмәт итә. Аның эскизлары буенча типография каршындагы хәреф кою остаханәсендә гарәп-төрки шрифтлары әзерләнә. 1911 елда немец типографияләренең эшен өйрәнү һәм яңа технологияләр үзләштерү өчен Германиягә (Мюнхен, Лейпциг, Франкфурт-Майна шәһәрләренә) командировкага җибәрелә. Аннан кайткач, шул ук типографиядә эшен дәвам иттерә, бер үк вакытта Вараксин литографиясендә гравёр һәм сызымнар сызучы булып эшли. И. Россиянең Шәрекъ матбугаты тарихында беренче булып күптөсле континенталь географик карта төзи. Әлеге карта алга таба татар мәктәпләре өчен география дәреслекләрендә күп тапкырлар басыла. Шулай ук татар һәм казакъ мәктәпләре өчен глобуслар әзерли. Татар телендә географик терминология төзи. 1917 елның сентябреннән 1918 елның уртасына кадәр Мәскәү, Оренбург, Наманган, Ташкент һ.б. шәһәрләрдәге татар типографияләре өчен үз куллары б-н бердәм калыпка салынган 638 пот 12 фунт хәреф әзерли. Казанны ак чехлардан азат иткәннән соң, совет власте органнары, Кызыл Армия типографияләре һ.б. учреждениеләр өчен шул ук эшен дәвам иттерә. И.ның бердәм калыпка салынган графикасы 1920 елларда да татар китапларын бастыруда файдаланыла.

1924 тә И. Мәскәүдәге СССР халыклары үзәк нәшриятында хәреф кою остаханәсе мөдире итеп билгеләнә, СССРда язулары яңа барлыкка китерелгән халыклар өчен шрифтлар төзүдә катнаша; И. җитәкчелегендә һәм аның рәсемнәре буенча Урта Азия, Казакъстан, Кавказдагы типографияләр өчен гарәп-төрки хәрефләре коела. Гарәп-төрки хәрефләрне камилләштерү һәм бердәм калыпка салу эшен дәвам иттерә. Аерым алганда, сузыкларны язуга күчкәндә «СССР халыклары үзәк нәшриятындагы гарәп шрифтлары, литера үрнәкләре» белешмәсен («Образцы арабских шрифтов, литер Центрального издательства народов СССР», М., 1924), «Шрифт нигезләре» («Основы шрифта», М., 1926) һәм «Баш хәрефләр турында» («О заглавных буквах», М., 1926) хезмәтләрен әзерли. И. эшләгән шрифтлардан файдалану хәрефләрне линотипта (машинада) җыюны кертүгә мөмкинлек бирә, гарәп-төрки графикасы нигезендә язу машиналары төзүгә, аларны күпләп җитештерүгә булышлык итә. Латин шрифтына күчкәч, И. әзерләгән графика СССРда кулланылыштан чыга, әмма Икенче бөтендөнья сугышыннан соң ул яңартылган рәвешендә күп кенә чит илләрдә (Һиндстан, Мисыр, Әфганстан, Сүрия һ.б.) тарала һәм 1960 елларга кадәр файдаланыла.

1931–34 тә И. СССР ҮБК каршында милли унитар стенография һәм машинада басу буенча оештырылган югары педагогик курсларда укыта. Бер үк вакытта 1931 дән Мәскәү полиграфия сәнәгате фәнни тикшеренү ин-тының стандартлаштыру секторында эшли. 1936 дан 5 төрле телләр төркеме: төрки-татар, иран, яфәт, монгол һәм угор-фин телләре өчен клавиатуралар проектын әзерләү б-н шөгыльләнә.

Казанга эвакуацияләнеп (1941–43) кайткач, И. 3 нче шрифтлар кою з-дында гравёр булып эшли. 1947 дә Полиграфмаш фәнни-тикшеренү ин-тына әйләнеп кайта: шрифтлар бюросында өлкән рәссам, аннары яңа шрифтлар бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр. И. — география һәм арифметика дәреслекләре, графиканы бердәм калыпка салу турында китап авторы, «Аң» ж-лында Мөхәммәт И. псевдонимы б-н хикәяләре басыла. И.ның архивы Полиграфмаш фәнни-тикше-



М.И.Идриси.



Г.Ж. Идрисов.

ренү ин-тында һәм Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Книги и люди. К., 1985.

*И.А.Новицкая.*

**ИДРИ́СОВ** Алмас Әхтәм улы (6.5.1950, Шөгер р-ны Иске Иштирәк а.), архитектор, ТР ның атказ. архитекторы (2004). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). 1973 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый. 1976 дан Бөгелмә шәһәрендәге Татарстан нефть ин-тының архит-ра-конструкторлык бүлегендә, 1978 дән Бөгелмә шәһәр башкарма ком-ты архитекторы, 1989 дан Бөгелмә архит-ра-планлаштыру бюросы башлыгы. 1990 нан Лениногорск шәһәренең баш архитекторы, 1992 дән Түбән Новгород шәһәрендә «Три ангела» төзелеш фирмасы архитекторы, 1996 дан Казан архит-ра-төзелеш академиясе укытучысы. 2001 дән ТРның Көньяк-көнчыгыш районара архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы, Әлмәт шәһәренең баш архитекторы. 2006 дан Әлмәт р-ны башкарма ком-тының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы. И. проектлары буенча (Айваз А.Идрисов б-н берлектә) Әлмәт шәһәрендә «Менеджер» мәктәбе бинасы, Әлмәт нефть ин-ты корпусы, «Татарстан» универмагы һ.б. төзелә; Чехов, Гагарин, Тукай, Җәлил, Ленин урамнары, Төзүчеләр проспекты, Комсомоллар паркы һ.б. реконструкцияләнә.

И.ның нәкышь әсәрләре Татарстанның «Бабалар һәм аталар җире. Бөек Болгар» яшь рәссамнар күргәзмәсендә (Казан, 1982) күрсәтелә, шәхси күргәзмәләре 1983 (Бөгелмә), 1991 (Казан), 2006 (Әлмәт) елларда уза. ТР Дәүләт бүләге Әлмәт шәһәрендә башкарылган шәһәр төзү эшләре сериясе өчен бирелә. Медальләр, ш.и. САнең Зур көмеш медале (2003), РФ Баш архитекторлар советының «Кентавр» билгесе (2007) б-н бүләкләнә.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ИДРИ́СОВ** Газыйм Җиһанша улы (1.4.1938, Буа р-ны Кайбыч а.), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1977), ТР ФА академигы (1992), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1991, 1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). 1964 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1979 дан патоанатомия каф. мөдире, проф. (1980), бер үк вакытта 1988–99 елларда ректор. Патоморфология һәм иммуноморфологиядә яңа юнәлешкә нигез салучы. Хезмәтләре бруцеллёз, туберкулёз, себер түләмәсе патоморфологиясе патогенезына һәм иммуноморфологиясенә карый. Уйлап табуга 5 патенты бар.



Г.И. Идрисов.

Х е з м.: Патологоанатомическая диагностика болезней крупного рогатого скота. М., 1991 (автордаш); Туберкулёз сельскохозяйственных животных. К., 1992 (автордаш); Патологическая анатомия сельскохозяйственных животных. М., 1999; Туберкулёз крупного рогатого скота. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ИДРИ́СОВ** Гыйлемхан Идрис улы (16.9.1913, БРның хәзерге Благовар р-ны Яңа Абзан а. — 5.2.1977, шунда ук), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты (1945). Колхозда эшли. 1937–39 елларда һәм 1942 нең маеннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 290 нчы гв. укчы полкның орудие командиры (5 нче гв. армиянең 95 нче гв. укчы дивизиясе). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украинаны (1943–44), Польшаны (1944) азат итү сугышларында, Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 12 гыйнварында Пинчув шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: туп уты б-н дошманның 5 пулемёт ноктасын һәм тубын сафтан чыгара, плацдармны яулап алуга булышлык итә. Сугыштан соң туган авылында авыл советы рәисе булып эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1979. Кн. 4.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИЕРЕ́М-ФӘРДӘ́Н**, к. *Җаббарбирде хан.*

**ИЖ** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 226 *км*, ТР чикләрендә — 97 *км*. Бассейнының мәйданы 8478 *км²*, ТР чикләрендә — 1700 *км²*. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-нының Салагыш авылыннан 6 *км* көнбатыштарак. Елганың түбәнге агымы Түбән Кама сусаклагычы сулары б-н сазланган. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. И.ның су җыелу урыны рельефы ике калкулыклы тигезлектән гыйбарәт: Можга — Иж һәм Вятка елгалары үзәннәре арасында (абс. биеклеге 230–250 *м*) һәм Сарапул — Иж һәм Кама елгалары үзәннәре арасында (абс. биеклеге 170–250 *м*). Су җыелу урынының ерым-сыза челтәре чагыштырмача зур түгел. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40% тан артык. И. елгасының үзәне асимметрияле, сул яктан сөзәклекләре беркадәр текәрәк, шактый өлеше урман б-н капланган. Елга тугае ике яклы, уңъяк яры буйлап киңрәк. Елга юлы бормалы, ергакланмаган, күбрәк 2–3 *м* тирәнлектә, киңлеге 20–30 *м*.



Иж елгасы түбән агымында.

Иж елгасының 62 кушылдыгы бар, иң зурлары: Кырыкмас (100 *км*), Әзи (22,9 *км*) — сул; Чаж (50 *км*), Бубый (40,5 *км*), Әгерҗе (31,3 *км*), Барҗы (27 *км*), Барҗы (24,4 *км*), Мөвиҗә (19 *км*), Бәркләт (15,2 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км²*. Туенуы катнаш, җәйге челләдә җир асты сулары исәбенә тотрыклы. Җир асты туендыру модуле 0,5–5 *л/с·км²*.

ТР терр-ясендә елга режимы Әгерҗе шәһәре (1931–90) һәм Лебединое озеро авылы (1933–68) янындагы гидрологик постта өйрәнелә. Су биеклегенең уртача тирбәлеше Әгерҗе шәһәре янында 4,3 *м* (иң күбе 5 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 141 *мм*, ташу агымы катламы 84 *мм*. Язгы ташу (уртача дәвамлылыгы 50 көн), гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана, су тигезлегенең кочле күтәрелүе б-н характерлана, озакка сузылмыйча чагыштырмача тиз кими. Иң зур чыгымы 587 *м³/с* (1979). Җәйге саегулар тотрыклы. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 12,5 *м³/с*. Яңгырлар ташуы ел саен күзәтелсә дә, сизелерлек түгел. Бассейнда ташулар агымының уртача катламы 4,2 *мм*. И., гадәттә, ноябрьнең беренче унконлегендә ката. Боз кату тотрыклы, дәвамлылыгы 135–140 көн. Боз калынлыгы кыш ахырына 40–60 *см* га җитә. Суының уртача күпьеллык чыгымы 17,7 *м³/с*. Елга кителрмәләренең уртача еллык агымы 41 мең *т*. Суының уртача болганчыклыгы 70 *г/м³*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. И. елгасы бассейнында гомуми күләме 6,6 млн. *м³* булган 7 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. И. — ТРның табигать истәлеге (1978). И. бассейнында *Кичке Таң* тыюлыгы урнашкан.

**ИЖ МИНЕРА́ЛЬ СУЛАРЫ́**, дәвалау һәм эчү өчен яраклы, составы хлорид-сульфатлы һәм магний-кальций-натрийлы су чыганагы. Түбәнге Пермьнең Сакмар ярусындагы карстланган известьташ һәм доломит токымнарыннан торган сулы Эстәрлетамак катламында 130–150 *м* тирәнлектә скважиналар ярдәмендә ачыла. Кама елгасының уңъяк ярында, Иж елгасы тамагыннан 1 *км* түбәндәрәк, Менделеев р-ны Ижевка авылының көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан. Суның химик составы (6/82 номерлы скважина):

$$\frac{SO_4 62 CL 35 HCO_3 3}{(Na+K) 44 Ca 35 Mg 21}$$

минеральләшүе 4,7 *мг/л*, темп-расы 7,3 °С, рН 7,4.

Артезиан скважиналарыннан алына һәм шул исемдәге бальнеологик курортта дәвалану өчен файдаланыла. Сату өчен шешәләргә тутыру оештырылган, товар билгесе — «Шифалы су». Тәүлек эчендә 150 *м³* су алына.

Иж елгасының уңъяк яры итәгендәге Пермь утырмалары катламнарыннан чыгучы Иж чыганагы элек-электән тирә-як халкын үзенә җәлеп иткән. Алар, җирле табибләрнең күрсәтмәләренә таянып, бу суны ашказаны-эчәк һәм бөер авырулары вакытында кулланганнар. 1903 елда землемер Д.Ф.Спиридонов чыганакны арендага ала һәм төрле учреждениеләрдә су анализы алуны оештыра. Беренче тулы химик анализ 1907 дә Казан ун-тында үткәрелә (К.В.Бенинг). Соңыннан чыганакның геол. шартлары һәм генезисы тикшерелә (П.И.Кротов, М.Э.Ноинский һ.б.). 1910 да су «Спиридонов минераль сулары» («Спиридоновские минеральные воды») исеме астында сатуга чыгарыла. 1914 тә суны сатуга әзерләү буенча шул ук исемдәге АҖ оеша (1 млн. шешә чыгарыла), 1915 тә ул «Ижевский источник» АҖ дип үзгәртелә (су тутыру елына 4 млн. шешәгә кадәр арта). 1924 тә чыганактан 1,5 *км* ераклыкта санаторий төзелә (хәзер «*Иж минераль сулары*» курорты). 1928 дә «Ижминводы»га дәүләт АҖ статусы бирелә, чыганак гомумсоюз әһәмияткә ия була. И.м.с.ның табигый чыгу юллары 1978–81 елларда Түбән Кама сусаклагычы төбендә кала.

*Әд.:* Ижевский минеральный источник. К., 1930; Г а л а н и н С.Ф., С а х а б у т д и н о в Ю.Е., Ф р о л о в А.Л. «Ижминводы — Шифалы су» — старейший курорт Татарстана. К., 2001.

*Ф.Г.Борһанов.*

**«ИЖ МИНЕРА́ЛЬ СУЛАРЫ́»** («Ижминводы»), бальнеологик курорт, Казаннан 250 *км* ераклыкта. Кама елгасының уңъяк ярына, Менделеев р-ны Ижевка авылы тирәсендә урнашкан. 1924 елда ачыла. Төп табигый дәвалау факторлары: магний, кальций, натрий ионнары кушылган хлоридлы-сульфатлы, дәвалау үзлекләренә ия булган «Шифалы су», бромга баетылган хлорлы-натрийлы куе тозлыклар (уртача минеральләшү дәрәҗәсе 4,6–5,4 *мг/л*); торфлы балчык («Таборли-3» чыганагы). Курорт ашказаны-эчәк тракты, сидек бүлеп чыгару, терәк-хәрәкәт, сулыш, нерв системасы авырулары, ир-ат һәм хатын-кызларның җенес әгъзаларында, авыз куышлыгында була торган авыруларны дәвалау буенча специальләшкән. Курортта ял итүчеләр яши торган 400 урынлы корпус, клиник лаб., биохимия һәм бактериология лаб-яләре, физиотерапия, ультратавыш, функциональ, нурлар, эндоскопия диагностикасы кабинетлары урнаштырылган дәвалау корпусы эшли. Эчәкләрне һәм ашказаның юдырту ысуллары, төрле душ һәм ванналар, тәнне шифалы балчык б-н дәвалау, балчык һәм озокерит б-н аппликацияләр ясау, эңәләр





«Иж минераль сулары» курорты.
1. Төп корпус; 2. Тоз мәгарәсе.

б-н дәвалау, лазер терапиясе (ш.и. лазер литотрипсиясе) һәм мануаль терапия, фито-, арома-, апи- һәм спелеотерапия, массаж, дәвалау физкультурасы һ.б. кулланыла. Терренкур һәм чаңгы маршрутлары булган парк, клуб, видеосалон, китапханә, сауна, йөзү бассейннары, бильярд залы, спорт мәйданчыгы, теннис корты бар. Балыкка йөрү, ауга чыгу, атта йөрү мөмкинлекләре каралган. Курорт ел буена хезмәт күрсәтә.

*Ф.З.Әхмәтҗанов.*

**ИЖ ТАМАГЫ́**, к. *Ижевка.*

**ИЖ-БӘЙКИ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 12 *км* көньяктарак, Иж елгасы буенда. 2008 елда 221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1640 елдан мәгълүм. 18 йөз чыганакларында Иж исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, колмак үстерү б-н шөгыльләнә, сәүдә итә (ш.и. Оренбург, Пермь губерналарында), Алабуга өязенә көнлекче булып эшкә йөри. 1890 елгы мәгълүматларга караганда, И.-Б.дә мәчет, мәдрәсә эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 188,5 дис. тәшкил итә. 1909 да рус-татар земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Вотяк губернасының Сарапул өязе Әгерҗе волостенда. 1920–21 елларда Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 389, 1890 да — 607, 1920 дә — 870, 1926 да — 825, 1938 дә — 765, 1958 дә — 789, 1970 тә — 377, 1989 да — 235, 2002 дә — 195 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф. Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ИЖ-БОРИ́СКИНО** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 53 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бизнә елгасыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 268 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 61%, чуашлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1691 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агач эше, тимерчелек, тегү, итек басу, арба көпчәкләре ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.-Б.да чиркәү-приход мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, ярма яргыч, йон тетү йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1974,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 519, 1897 дә — 792, 1908 дә — 1026, 1920 дә — 1011, 1926 да — 576, 1938 дә — 362, 1949 да — 287, 1958 дә — 314, 1970 тә — 346, 1979 да — 312, 1989 да — 227, 2002 дә — 252 кеше.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**ИЖ-БУБЫ́Й** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 5 *км* көньяктарак, Бубый елгасы буенда. 2008 елда 690 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Абыйлы-энеле Бубилар йорты, сәүдәгәр М.Әхмәтҗанов утары, мәчет бинасы — 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге. 1640 тан мари авылы буларак билгеле. 17 йөз ахырыннан монда татарлар килеп урнаша. 18 йөз –19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә, Мәскәү, Пермь, Оренбург, Екатеринбург шәһәрләренә, Мәкәрҗә ярминкәсенә, Урта Азия һәм Себергә сәүдә эше б-н йөри. 18 йөз ахырыннан *«Буби» мәдрәсәсе* эшли, 1890–1900 елларда ул Идел буе һәм Урал буе төрки халыкларының мәгърифәт учагы була. 19 йөз ахырында И.-Б.да 2 су тегермәне эшли. 1905 тә малайлар өчен бер сыйныфлы мәктәп, 1907 дә кызлар өчен бер сыйныфлы мәктәп ачыла. Уку йортларын Сарапул земствосы үз хисабына тота. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Әгерҗе



Иж-Бубый авылы.
Сәүдәгәр М.Әхмәтҗанов йорты. 19 йөз ахыры.

волостена керә. 1920–21 елларда Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1716 да — 104, 1762 дә — 130, 1859 да — 1131, 1890 да — 1326, 1920 дә — 1530, 1926 да — 1326, 1938 дә — 1062, 1958 дә — 1106, 1970 тә — 827, 1989 да — 646, 2002 дә — 668 кеше. И.-Б.да мәгърифәтче-педагог Габдулла, Гобәйдулла, Мөхлисә Бубилар (Нигъмәтуллиннар) туган.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ИЖБО́ЛДИН әл-БӘКРИ́** (Ижболдин Борис әл-Бәкри) (1899, Мәскәү — 1982, Нью-Йорк штаты, АКШ), икътисадчы, тарихчы, икътисад фән. д-ры (1926). Татар морзалары нәселеннән. Мәскәү император лицеен тәмамлый (1917). Окт. рев-циясеннән соң Германиягә китә, Берлин ун-тының Коммерция мәктәбен тәмамлый (1925). 1926–28 елларда Кёльн ун-ты профессоры. 1928 дән Париж ун-тының Рус икътисад һәм хокук ин-ты адъюнкт-профессоры, бер үк вакытта 1928–30, 1932–39 да Белград ун-тының Рус гыйльми ин-ты профессоры. 1939 дан АКШ-та: Сент-Луис шәһәрендәге ун-тның икътисад профессоры, бер үк вакытта Кёльн ун-тында һәм Европадагы кайбер башка ун-тларда икътисад буенча лекцияләр укый. Халыкара социаль хәрәкәт ин-ты (Париж, 1937), Британия фән һәм белем алуга химаячелек итү фәнни җәмгыяте (1938), «Россия тарихы һәм русларның шәҗәрә агачы» җәмгыяте (Нью-Йорк, 1944), Америка икътисад җәмгыяте (1945) әгъзасы. Хезмәтләре 1930 еллар һәм Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы чор дөнья икътисады, сәүдә сәясәте мәсьәләләренә карый. И. — Алтын Урданың, татар халкының Рус дәүләте тарихындагы роле яктырылган «Татарлар тарихы очерклары» («Essays on Tatar history», New Delhi, 1963) китабы авторы. 1960 елларда китап Европа һәм Азиянең күп кенә инглиз телендә аралашучы илләрендә киң яңгыраш таба. 2003 тә татар телендә нәшер ителә («Татар тарихы»).

Хезм.: Die russische Handelpolitik der Gegenwartena, Gustav Fischer. 1930; Die lehre von der «beseselten» Betriebswirtschaft. Belgrade, 1931; The Eurasian Movement // Russian Review. Spring, 1956; Economic Synthesis. [S.I], 1958.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ИЖБУЛА́ТОВ** Йосыф (Ишбулат мулла) (?-1723 тән соң), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче. 17 йөз ахырында Казанның Иске татар бистәсендә имам вазифаларын башкара. 1722 елда император Пётр I кушуы буенча (К.Сүнчәләев б-н берлектә) Петербург ФА өчен 50 гә якын болгар кабер ташлары язмаларын күчереп ала һәм тәрҗемә итә. 1722–23 еллардагы Иранга каршы яуда тәрҗемәче сыйфатында катнаша. Мөхәммәд Авабинең «Дәрбинд-намә» дип аталган тарихи әсәрен (17 йөз) фарсы теленнән татар теленә тәрҗемә кыла һәм аны Пётр I гә бүләк итә (1722).

*М.В.Гайнетдинов.*

**ИЖБУЛА́ТОВ** Хаҗиәхмәт Исхак улы (16.3.1851, хәзерге БРның Благовар р-ны Өд-



Х.И. Ижбулатов.

рәкбаш а. — 1921, Эстәрлетамак ш.), генерал-майор (1908). Оренбург кадетлар корпусын тәмамлый. Отставкага чыкканчы (1908) Уфа, Оренбург, Варшава, Брест-Литовск, Казан шәһәрләрендә хезмәт итә. Беренче бөтендөнья сугышы башлану б-н хәрби хезмәткә алына, запастагы пехота батальоны, соңрак Казан хәрби округы полкы б-н җитәкчелек итә. 1918 елның гыйнварыннан маена кадәр 1 нче мөселман укчы бригадасы башлыгы. Гражданнар сугышында Көнчыгыш фронтта адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы сугыша, Башкорт корпусы б-н җитәкчелек итә. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И ж б у л а т о в М.Р. Генерал Ижбулатов нәселе // Мирас. 2000. № 4; ш у л у к. Генерал Ижбулатов // Тулпар. 2001. № 3; Х а м м а т о в Я. Грозовое лето. М., 1978; И ж б у л а т о в М.Р. И продлится связь времён // Идель. 1991. № 5; В а л и д и А х м е т - З а к и. Воспоминания. Уфа, 1994.

*М.Р.Ижбулатов.*

**ИЖБУ́ЛДИН** Гыйльметдин Гыйбадетдин улы (1857–1921), халык музыканты, скрипкачы. Казан, Бөгелмә, Чистай, Петропавел, Актүбә, Эрбет, Златоуст шәһәрләрендә яшәүче татарлар алдында концертлар куя. 1896 елдан Уфа шәһәрендә яши, беренче милли әдәби-муз. кичәләрдә катнаша, кыллы музыка кораллары ансамбльләре оештырып, солист һәм ансамблист буларак чыгышлар ясый. И. репертуарына халык җырлары һәм бию көйләре, Европа композиторларының пьесалары керә. «Атбасар», «Көй», «Таң җыры» һ.б. популяр әсәрләр авторы. Замандашлары И.ның иҗади йөзен, виртуоз инструменталь башкаручы буларак, музыканы тирәнтен тоемлап, ихлас күңелдән бирелеп уйнаучы иде, дип бәялиләр. И. халыкта зур популярлык казана.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**ИЖЕ́ВКА (ИЖ ТАМАГЫ́)** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 23 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычындагы Ижевский Источник (Иж Чишмәсе) пристане. 2008 елда 1000 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 58%, руслар — 37%) яши. Урта мәктәп, китапханә. *«Иж минераль сулары»* курорты. 1681 дән Тихая Гора исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (элеккеге сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, олаучылык б-н шөгыльләнә, Кама пристаньнарында йөкче булып эшли. 19 йөз ахырында И.да земство станциясе, су тегермәне, ашлык саклау амбары, тимерчелек, май язу йорты, шәраб кибете эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1836 да — 391, 1859 да — 600, 1887 дә — 736, 1920 дә — 805, 1926 да — 697, 1938 дә — 990, 1949 да — 700, 1958 дә — 463, 1970 тә — 697, 1979 да — 530, 1989 да — 793, 2002 дә — 930 кеше.

**ИЖЕ́ВСК**, *Удмурт Республикасы* башкаласы. 1760 елда (шәһәр 1918 дән) нигез салына. Халкы — 632,1 мең кеше (2000). 1989 елгы халык исәбе буенча, 61117 татар яши. И.да татарлар шәһәргә нигез салынган вакыттан бирле яшиләр. Алар тимер эшкәртү з-дын төзүдә катнашалар, завод янында Ижевск заводы посёлогы төзелә. Татарлар ш.у. 1807 дә Корал з-дын төзүдә катнашалар. 1897 дә И.ның Заречный өлешендә 1185 татар яши.



Ижевск шәһәре. Җамигъ мәчет.

Алар арасында, завод эшчеләреннән тыш, эшмәкәрләр, крәстияннәр була. 1845–46 һәм 1918 дә И.да мәчетләр төзелә. 1920–30 елларда ТАССРның Әгерҗе, Минзәлә, Актаныш р-ннарыннан күченүчеләр исәбенә татарлар саны шактый арта. 1933 тә И.да 7784 татар исәпләнә. 1933–40 та татар телендә «Ленин юлы» («Путь Ленина») г-тасы нәшер ителә. Сугыштан соңгы чорда татар мәктәбе эшли. Хәзерге вакытта И.ның 11 мәктәбендә татар сыйныфлары бар. Удмуртия республика төбәкне өйрәнү музеенда татар тарихы бүлеге эшли. Шәһәрнең 2 китапханәсендә (аларның берсе М.Җәлил исемен йөртә) татар бүлекләре бар. «Гүзәл», «Сандугач» татар үзешчән ансамбльләре, «Йолдыз» иҗат берләшмәсе эшли. «Яңарыш» (1991), «Саф иман» г-талары нәшер ителә. «Удмуртия» Дәүләт телерадиокомпаниясенең «Очрашу» радиотапшыруы һәм «Хәерле кич» телевидение тапшыруы чыга. Республика нәшриятында татар телендә китаплар басыла.

**ИҖА́Т ЫСУЛЫ́**, чынбарлыкны сәнгати үзләштерүдә билгеле бер дәвернең иҗтимагый фикерендә дөнья һәм кеше концепциясе йогынтысында барлыкка килгән төп үзенчәлекләре бөтенлеге. Барлык иҗат ысуллары өчен уртак принциплар бар: эстетик яктан үзләштерелүче чынбарлык һәм яңадан тергезелгән әдәби чынбарлык арасындагы мөнәсәбәтне чагылдыручы иҗат принцибы; эстетик идеал һәм чынбарлык арасындагы мөнәсәбәт б-н характерланучы эстетик бәяләү принцибы; образ һәм аның асылын ачыклаучы иҗади гомумиләштерү принцибы. Сәнгати образның яңадан тудырылган чынбарлыкка карата эзлекле мөнәсәбәтен ачыклау мәсьәләсе беренче мәртәбә борынгы грек галимнәре хезмәтләрендә күтәрелә. «Табигатькә охшату» таләбе тормышны мөмкин кадәр төгәл кабатлап сурәтләүгә чакыру кебек яңгырый. Платон фикеренчә, әдәби әсәр турында сүз алып барганда, башта анда нәрсә тасвирланган, аннан соң гына — дөрес тасвирланганмы-юкмы дигән сорау куеп була. Аристотель исә «охшату» атамасын иҗатның гомуми законына әйләндерә. Охшату теориясе башлангыч мәгънәсендә бары тик натурализм И.ы. туу өчен нигез була ала. Башка иҗат ысуллары охшату теориясенең кыйммәти нигезен үстереп яки аның б-н бәхәсләшеп барлыкка киләләр (романтизм, символизм һ.б.). И.ы. атамасы фәлсәфәдән алынган, ул РАПП (Россия пролетар язучылары ассоциациясе) идеологлары хезмәтләрендә формалаша. 1920–50 еллар совет тәнкыйтендә марксистик эстетиканың аерым бер категориясе буларак беркетелә, ләкин РАПП тәкъдим иткән «Диалектик-материалистик иҗат ысулы» сәнгатьне иҗади фикер формасы итеп караудан ерак тора. Бу соңрак сәнгать тарихын кискен реалистик И.ы.ның «антиреалистик» И.ы.на (яки «идеалистик», «романтик») каршы торуы кебек бүлүгә китерә. 1950–60 елларда совет әдәбият белеме бу атаманы идеологик эчтәлектән арындыра, аны фәкать сәнгати планда куллау омтылышы ясый. Ләкин төшенчә дөньякүләм таралыш тапмый. Бүгенге әдәбият белемендә төрле И.ы. — классицизм, сентиментализм, романтизм, модернизм, мәгърифәтчелек реализмы һ.б., ш.у. ярымәдәби ысул — натурализм да билгеләнә. Хәзер кайбер әдәбият галимнәре «И.ы.» атамасын кулланмаска тырышалар. Эре иҗат күренешләрен (реализм, романтизм) иҗади юнәлешләр яки иҗат типлары дип атыйлар. Ә аларның төрләрен (мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, социалистик реализм, крәстиян реализмы, символизм, экспрессионизм, сюрреализм һ.б.) иҗади агымнар дип йөртәләр. «Иҗат ысулы» атамасын яклаучылар да бар.

Татар әдәбият белемендә И.ы.ларын аеру һәм төркемләү мәсьәләсен беренче тапкыр Г.Ибраһимов («Әдәбият кануннары», 1916) күтәреп чыга. 1920–30 елларда «метод» һәм «стиль» атамалары синоним буларак кулланыла. Г.Сәгъди һәм Г.Нигъмәти хезмәтләрендә романтизм, символизм (модернизм), реализмның теоретик нигезләре, билгеле бер шартларда пәйда булган иҗат типларының төрле сыйфатлары тирәнтен өйрәнелә. Шул ук вакытта реализмны сәнгатьнең дөреслеге б-н тиңләү күзәтелә. Бу күренеш исә милли әдәбиятларда реалистик булмаган ысулларны тискәре бәяләүгә китерә. Әлеге мәсьәләгә (социологик примитивлыктан баш тарту, милли мәдәни кыйммәтләрнең әһәмиятен тану) яңача караш 1960–70 елларда формалаша башлый. М.Гайнуллин, Г.Халит, Й.Нигъмәтуллина, И.Нуруллин, Р.Ганиева һ.б. татар галимнәренең хезмәтләрендә төрле И.ы.ның татар әдәбиятында барлыкка ки-

лү һәм кулланылыш үзенчәлекләрен аңлау-төшенүгә нигез салына. Бу үзенчәлекләрнең иң мөһимнәре булып мәгърифәтчелек реализмының, романтизмның, тәнкыйди реализмның, символизмның 19 йөз ахыры –20 йөз башы татар язучылары иҗатында янәшә үсеше һәм үзара йогынты ясавы санала. 20 йөз ахырында татар әдәбиятчы-галимнәре тарихи-әдәби процесста И.ы.ның гомуми принциплары тормышка ашырылуны (поэзия өлкәсендә Т.Н.Галиуллин, драматургиядә А.Г.Әхмәдуллин, 20 йөз башы әдәбиятында Р.К.Ганиева, аерым әдипләр иҗатында А.М.Саяпова һ.б.) игътибар үзәгенә куялар.

*Әд.:* Х а л и з е в В.Е. Теория литературы. М., 1999; Литературная энциклопедия терминов и понятий. М., 2001; Л е й д е р м а н Н.Л., Б а р к о в с к а я Н.В. Теория литературы. Екатеринбург, 2002.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ИҖТИҺА́Д** (гарәп. إجتهاد — карар чыгару), илаһият-хокук комплексы мәсьәләләрен өйрәнгәндә кулланылучы принциплар, алымнар һәм ысуллар системасы; мөселман *фәкыйһның Коръән* һәм *Сөннә*, ш.у. *фикъһның* төп алымнары нигезендә дини һәм иҗтимагый тормыштагы мөһим мәсьәләләр буенча хөкем чыгару хокукы. Традиция буенча, И. Мөхәммәд пәйгамбәр исән чакта ук аның хак И.ияләреннән саналган сәхәбәләре даирәсендә барлыкка килә. И.ның төп шартлары: 1) гарәп телен белү; 2) Коръәнне яттан белү һәм аны аңлата алу сәләте; 3) Сөннә һәм *хәдисләрне* белү; 4) фикъһ мәсьәләләре буенча иҗмагъ (уртак фикер) һәм төрле карашлар булуын белү; 5) сайлап алынган материалны интерпретацияли, ягъни аңлата белү; 6) мәсьәләне аңлау; 7) нәтиҗәләрне төгәл бәяләү; 8) иман ныклыгы һәм аңа тугрылык. И.ның төп үзәкләре булып Мәккә, Мәдинә, Куфа, Басра, Димәшкъ, Бәйрүт шәһәрләре санала. 7 йөз ахырында — 11 йөздә исламны теоретик нигезләү ихтыяҗыннан дин гыйлеме тикшеренүләре алып барыла. Әлеге чор ахырында төп илаһият-хокук мәктәпләре — *мәзһәбләр* барлыкка килә, һәм алга таба ислам принципларын эшләү туктатыла. 4 зур мәзһәбкә нигез салучыларны *сөнниләр* соңгы *мөҗтәһидләр* дип саныйлар. Алардан соң 10 йөздә «И. капкалары ябыла». Татар илаһият галимнәре Г.*Курсави*, Ш.*Мәрҗани*, М.*Бигиев*, З.*Камали* татар җәмгыятенә соңгы өстәмәләрдән азат һәм мөселман динен кайтаруда мөһим юлларның берсе булган «И. капкаларын ачу» идеясен тәкъдим итәләр. Ш.у.к. *Мөселман ислахчылыгы.*

*Әд.:* А л ь - К а р д а в и Ю. Современный иджтихад: от беспорядка к порядку. К., 2001.

**ИЗАФӘ́** (гарәп. إضافه — кушу, өстәмә), кайбер төрки һәм иран телләрендәге ике буынлы да (аергыч һәм аерылмыш) исем б-н белдерелгән сүзтезмәләр. Төрки телләрдә, ш.и. татар телендә 3 төрле И. кулланыла: 1) янәшә тору юлы б-н барлыкка килгән кушымчасыз исем сүзтезмәләр: алтын тәхет, тимер көрәк; 2) аергычы кушымчасыз исем һәм аерылмышы -е/-ы, -се/-сы 3 нче зат тартым кушымчасы ялганып ясалган исем сүзтезмәләр: татар теле, концерт залы, чебен гөмбәсе, мәктәп бакчасы; 3) аергычы иялек килешендәге исем б-н белдерелеп, аерылмышы 3 нче зат тартым кушымчасы б-н бәйләнгән исем сүзтезмәләр: китапның бите, әнинең кулы, әтинең бүлмәсе, дустымның туган-тумачасы. И. типлары компонентлар арасындагы семантик-синтаксик мөнәсәбәтләре б-н аерыла.

**«ИЗВЕ́СТИЯ»**, к. «*Республика Татарстан*».

**«ИЗВЕ́СТИЯ АСТРОНОМИ́ЧЕСКОЙ ОБСЕРВАТО́РИИ ЭНГЕЛЬГА́РДТА»** («Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе хәбәрләре»), фәнни журнал. Шул исемдәге оешма органы. 1908–94 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 58 томы чыга. Журналның баштагы 18 томы «Publications de L'Observatoire Astronomique Engelhardt de L'Universite de Kazan» дип атала. 1952 гә кадәр журнал «*Учёные записки Казанского университета*» ж-лының «Астрономия» бүлегенә кергән бер өлеше була. Төрле елларда фәнни мөхәррирләре булып обсерватория директорлары Д.И.*Дубяго*, М.А.*Грачёв*, Д.Я.*Мартынов*, А.Д.*Дубяго*, А.А.*Нефедьев*, О.И.*Белькович* һәм директор урынбасары Н.Г.*Ризванов* эшли. Кайбер аерым томнары И.А.*Дюков*, Ш.Т.*Хәбибуллин*, А.И.*Нефедьева* мөхәррирлегендә чыга. Журналда киңлекнең үзгәрүчәнлеген тикшерү, җир атмосферасында яктылык рефракциясен өйрәнү нәтиҗәләре турында, фундаменталь астрометрия мәсьәләләренең чишелеше (М.М.Грачёв, И.А.Дюков, А.И.Нефедьева); гравиметрия мәсьәләләре буенча (Т.А.Банахевич, В.А.Баранов, И.А.Дюков); кометалар хәрәкәтен өйрәнү (А.Д.Дубяго); йолдызларның караңгыланып-алмашып тотылуларын өйрәнү (М.И.Лавров, Д.Я.Мартынов); Айның селенодезиясе һәм динамикасы проблемалары буенча (Ш.Т.Хәбибуллин, А.Я.Яковкин) фәнни мәкаләләр басыла. Журнал Астрономия обсерваториясе китапханәсен дөнья астрономия фәнни үзәкләренең вакытлы матбугат басмалары б-н алмашу хисабына тулыландыру хезмәтен үти.

*Н.Г.Ризванов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ВРЕ́МЕННОГО ЦЕНТРА́ЛЬНОГО БЮРО́ РОССИ́ЙСКИХ МУСУЛЬМА́Н»** («Россия мөселманнарының Вакытлы мәркәз бюросы хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. *Россия мөселманнарының Вакытлы мәркәз бюросы* органы. 1917 елның март-апрель айларында (тәртипле рәвештә түгел) Петроградта рус телендә нәшер ителә дип фаразлана. Мөхәррире — Ә.*Цаликов*. Мөселман җәмәгать эшлеклеләренең Ибнеәмин Әхтәмов рәислегендә узган киңәшмәсендә (Петроград, 1917 нең марты уртасы) Россия мөселманнарының Вакытлы мәркәз бюросын оештыру һәм аның басма органын булдыру турында карар кабул ителә. Газета битләрендә Россия мөселманнарын Беренче Бөтенроссия съездын җыярга чакырган өндәмәләр басыла. Барлык мөселманнарны «яулап алынган азатлыкны сакларга» һәм «дәүләтне төзүдә бергәләп катнашырга», «Россиянең дәүләт төзелешен азатлык, тигезлек һәм бердәмлек нигезендә үзгәртеп корырга» чакырган мәкаләләр басыла. Россия дәүләт төзелешендә федерализм, унитаризм проблемалары, дин, мөселман хатын-кызларына белем бирү һәм аларның хокуклары мәсьәләләре яктыртыла. Ш.у.к. «*Известия Всероссийского мусульманского совета*».

*С.М.Исхаков.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ВСЕРОССИ́ЙСКОГО МУСУЛЬМА́НСКОГО ВОЕ́ННОГО ШУРО́»** («Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. *Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы* органы. 1917 елның 19 октябреннән 1918 нең 26 февраленә кадәр Казанда рус телендә баштa атнага ике, аннан соң бер тапкыр нәшер ителә. «Өмид» ширкәтенең ташбасмаханәсендә басыла. Җаваплы мөхәррире — башта Х.Еникиев, соңыннан (3 нче санда мөселманнарның Бөтенроссия мөселманнары шурасына ышанычларын югалтулары турында авторсыз (аноним) мәкалә басылганнан һәм Еникиев комиссия составыннан чыгарылганнан соң) — Җ.*Алкин* рәислегендәге редколлегия. Газетада Х.Еникиев, М.Солтангалиев, И.Алкин, Д.Алкин, Й.Мозаффаров мәкаләләре басыла. «Газеталардан», «Хроника», «Шура хроникасы», «Соңгы хәбәрләр» рубрикаларында мөселман дөньясы вакыйгалары яктыртыла. Төп игътибар мөселман полкларын формалаштыруга, Казанда Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче хәрби съездын әзерләп үткәрүгә, мөселман халыклары арасында милли хәрәкәт мәсьәләләренә бирелә. Мөселман съездларының эш хисаплары, резолюцияләре, өндәмәләре, Мөселман хәрби шурасы башкарма ком-тының утырыш беркетмәләре һәм карарлары басыла. Соңрак Совет хакимиятенә газетаның мөнәсәбәте үзгәрә: хакимият урнаштыруның беренче көннәрендә ХКС эшчәнлеге хуплап каршы алына, соңга таба аның эше б-н канәгатьсезлек күрсәтү чагылган, Учредительләр җыенын чакыруны яклаган язмалар урын ала. 1917 елның 17 декабрендә Совет үзен хәрби мөселманнарның югары органы, сәяси яктан барлык мөселман хәрби частьләренең югары идарәсе, дип карар чыгарганнан соң, газета урыннарда да, үзәктә дә федератив нигездә төзелгән социалистик хакимият булдыруны яклап чыга. Совет хакимияте декретларын тормышка ашырырга чакырып, газета, башлыча, большевиклар яклы була. Шулай да Казанда «*Болак арты республикасы*»ның эшчәнлеге бетерелгәннән соң газета чыгудан туктый.

*Әд.:* Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан. Теория и практика ленинской национальной политики. Лондон, 1977; Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*С.М.Исхаков.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ВСЕРОССИ́ЙСКОГО МУСУЛЬМА́НСКОГО СОВЕ́ТА»** («Бөтенроссия мөселманнары советы хәбәрләре»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. *Бөтенроссия мөселманнары советы* органы. «*Известия Временного центрального бюро российских мусульман*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның 23 июненнән 29 декабренә кадәр Петроградта рус телендә нәшер ителә, барлыгы 26 саны чыга. «Сельский вестник» г-тасы басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — Ә.*Ца-*

*ликов*. Күпчелек мәкаләләрнең авторлары — Ә.Цаликов, У.Токымбаев, И.Шаһиәхмәтов. Вакытлы хөкүмәтнең мөселман халкына кагылышлы боерыклары, мөселман съездлары документлары, карарлары, өндәмәләре, Бөтенроссия мөселманнар советы башкарма ком-ты утырышлары беркетмәләре, Петроградтагы яңа хакимият органнарына мөселманнар тарафыннан җибәрелгән телеграммалар һ.б. басыла. Илнең иҗтимагый-сәяси тормышы, халыкара сәясәт, Россиядәге мөселман халыклар тормышы вакыйгалары яктыртыла. Беренче Бөтенроссия мөселманнар съезды (Мәскәү, 1917, 1–11 май) карары


ИЗВѢСТІЯ ВСЕРОССІЙСКАГО МУСУЛЬМАНСКАГО СОВѢТА

ВЫХОДЯТЪ ЕЖЕНЕДѢЛЬНО по ПЯТНИЦАМЪ.

Вниманію Мусульманъ.

КО ВСѢМЪ МУСУЛЬМАНАМЪ РОССІИ.

«Известия Всероссийского мусульманского совета» газетасы.

басылганнан соң, газетада сугыш империалистик сугыш дип белдерелә. Аграр, дин-әхлак мәсьәләләренә, мөселман хәрби частьләре проблемаларына зур игътибар бирелә. Дәүләт (Мәскәү, 1917, 8–10 авг.) һәм Бөтенроссия демократик киңәшмәләрендә (Петроград, 1917, 14–22 сент.) мөселман вәкилләренең чыгышлары, Учредительләр җыенына кандидатлар исемлекләре басыла.

«Мөселман матбугаты фондына», «Мөселман тормышы хроникасы», «Бөтенроссия мөселманнар советы фондына» дигән рубрикаларда мөселман газета һәм журналларына күзәтүләр басыла, илдәге мөселманнар тарафыннан язылган хатларга урын бирелә. 1917 нең окт. уртасыннан газетаны бушлай тарату туктатыла, край, губ., өяз, волость мөселман оешмаларына газетага язылырга тәкъдим ителә. Вакытлы хөкүмәт бәреп төшерелгәч, газетада Гражданнар сугышы башлану һәм аңа мөселманнарны тарту турында борчылу белдерелгән материаллар күренә башлый. Анда Бөтенроссия мөселманнар советының төп максаты — Учредительләр җыенында мөселман вәкилләренең күпчелек урын алуларын тәэмин итү дигән фикер үткәрелә. Бөтенроссия мөселманнар советы эшчәнлеге туктатылганнан соң, газета чыгарылмый, 1918 елның гыйнварыннан Совет хөкүмәте тарафыннан тыела.

*С.М.Исхаков.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ВЫ́СШИХ УЧЕ́БНЫХ ЗАВЕДЕ́НИЙ. АВИАЦИО́ННАЯ ТЕ́ХНИКА»** («Югары уку йортлары хәбәрләре. Авиация техникасы»), фәнни-техник журнал. Оештыручылары — РФ Мәгариф министрлыгы, Казан техник ун-ты. Нашире — Казан техник ун-ты. 1999 елда халыкара статус ала, аны нәшер итүгә «ОКБ Сухого» АҖ, Мельбурн Король технол. ун-ты, Мәскәү авиация ин-ты, Н.Э.Бауман исем. Мәскәү техника ун-ты, Авиация җиһазлары фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү), Самара һәм Харьков аэрокосмик ун-тлары, Самара фәнни-техника комплексы, Эмбри-Риддл аэронавтика ун-ты (АКШ), Уфа авиация-техника ун-ты, «Камов» фирмасы (РФ), Үзәк аэрогидродинамика ин-ты (Мәскәү) булышлык итәләр. 1958 елдан Казанда рус телендә елга 4 сан нәшер ителә. Оештыручы һәм беренче мөхәррире — Ю.Г.Одиноков. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Г.С.*Жирицкий*, А.В.*Талантов*, М.Б.*Вахитов*, В.А.*Фирсов* (1997 дән). Журналда вузларның, фәнни-тикшеренү, проектлау һәм производство оешмаларының авиация һәм ракета фәне һәм техникасы өлкәсенә караган фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләре нәтиҗәләре басыла. Төп бүлекләр: авиация техникасы; очу аппаратларын проектлау; очу аппаратларының төзелеш механикасы һәм ныклыгы; очу аппаратлары һәм аларның двигательләренең аэро- һәм газодинамикасы; авиация һәм ракета двигательләре теориясе һәм аларны проектлау; авиация приборлары һәм үлчәү-исәпләү комплекслары; авиация производствосы технологиясе; авиация техникасын проектлау һәм җитештерүне автоматлаштыру; авиациядә икътисад мәсьәләләре; авиация техникасын һәм производствоны конверсияләү; авиациядә экология мәсьәләләре. Шулай ук материалларга күзәтүләр, фәнни хроника, бәхәсләр, депонирланган (басылмый калган) мәкаләләргә аннотацияләр бирелә. 1974 елдан журнал «Allerton Press» (АКШ) нәшрияты тарафыннан «Russian Aeronautics» исемендә инглиз телендә басыла.

*Әд.:* Богомолов А.И. Журнал для учёных-авиаторов // Науч. Татарстан. 1996. № 3.

**«ИЗВЕ́СТИЯ ВЫ́СШИХ УЧЕ́БНЫХ ЗАВЕДЕ́НИЙ. МАТЕМА́ТИКА»** («Югары уку йортлары хәбәрләре. Математика»), айлык бөтенроссия фәнни-теоретик журналы. Оештыручылары — РФ Мәгариф министрлыгы, Казан ун-ты. Нашире — Казан ун-ты. 1957 елдан Казанда рус телендә нәшер ителә. 1967 гә кадәр елга 6 тапкыр чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — А.П.*Норден*, А.В.*Сульдин*, Я.И.*Заботин* (1992 дән). Журналда Казан, Мәскәү, Екатеринбург, Түбән Новгород, Новосибирск, Иркутск һ.б. шәһәрләрнең күренекле галимнәре, ш.у. БДБ һәм ерак чит илләр (АКШ, Бөекбритания, Германия, Кытай, Һиндстан, Польша, Болгария, Сербия һ.б.) математикларының мәкаләләре басыла. Гыйльми тикшеренүләрнең нәтиҗәләре, математика (ш.и. кибернетика һәм информатика), механика (аерым математик әһәмияте булса) буенча узган конференция материаллары, ш.у. математикага кагылышлы актуаль проблемаларга күзәтүләр басыла. 1990 еллар башыннан периодик рәвештә алгебра, геометрия, оптимальләштерү ысулларына, исәпләү математикасы, дифференциаль тигезләмәләр, дискрет математика, математик логика мәсьәләләренә караган аерым тематик саннар нәшер ителә. 1990 елларда гамәли математикада яңа юнәлешләр барлыкка килү сәбәпле журналның тематикасы шактый киңәя. Журналда депонирланган (басылмый калган) мәкаләләргә аннотацияләр бирелә башлый. 1974 елдан «Allerton Press» (АКШ) нәшрияты тарафыннан «Russian Mathematics. Izvestia VUZov» исемендә инглиз телендә басыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ И УЧЁНЫЕ ЗАПИ́СКИ ИМПЕРА́ТОРСКОГО КАЗА́НСКОГО УНИВЕРСИТЕ́ТА»** («Казан император университетының хәбәрләре һәм гыйльми язмалары»), к. «*Учёные записки Казанского университета*».

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО ВОЕ́ННО-ОКРУЖНО́ГО КОМИТЕ́ТА»** («Казан хәрби округы комитеты хәбәрләре»), көндәлек газета. *Казан хәрби округы комитеты* органы. 1917 елның маеннан ноябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Идел буе һәм Урал буе гарнизоннары солдат һәм офицерларыннан җыелган акчага чыгарыла. Күпчелеге эсер һәм меньшевиклардан торган башкарма ком-тының төп позициясен чагылдыра. Газетаның сәяси программасы беренче саннарның баш мәкаләләрендә аңлатыла («Берлектә — көч»), («Армия һәм революция» һ.б.): барлык демократик көчләрне берләштерү, сугышны дәвам иттерү, Вакытлы хөкүмәтне яклау. 1917 елның июне дәвамында редакция 2 нче хәрби округ конференциясе материалларын бастыра, аларны демократик позициядән чыгып аңлата. Конференция эше тәмамланганнан соң һәм фронтта җиңелү башлангач, газетада большевикларны кискен тәнкыйтьләгән мәкаләләр басыла башлый. Корнилов фетнәсе вакытында газета, Казан хәрби округы ком-тының суллары ягыннан торып, революцион-демократик көчләрне яклый, социалистларны эзәрлекләүне туктатырга, җирне демократик ком-тларга бирергә, җитештерү һәм куллануга дәүләт контроле булдырырга, армияне демократлаштырырга (командирлар составын яңарту, комиссарларның сайлап куелуы һ.б.) чакыра. Казан хәрби округы гарнизоннарында армияне демократлаштыруга багышланган утырыш һәм җыелышларның беркетмәләре басыла. Газета милли хәрби частьләр булдыруны яклый. Казан хәрби округы ком-ты составында Бөтенроссия мөселманнар хәрби советы вәкилләре булганлыктан, газетада даими мөселман бүлеге ачыла. 110 нчы саннан газета исемен алыштыра («Революционный трибун»), үзен «аннексия һәм контрибуцияләрсез солых», «халыкларның үзбилгеләнү хокукы», «большевикларсыз социалистик хөкүмәт», «децентрализация нигезендә халык хакимияте һәм үзидарәгә ирешү өчен көрәшүче социалистик блок органы» дип билгели. Окт. рев-циясеннән һәм большевикларның җиңүеннән соң, 2 нче округ хәрби съездында Казан хәрби округы ком-ты таратыла һәм *Казан хәрби округы башкарма комитеты* оештырыла, ул «Часовой на революционном посту» г-тасын чыгара башлый.

*Әд.:* Ионенко И.М., Цейтлин Р.С. Казанский военно-окружной комитет (апрель–октябрь 1917 г.) // Общественно-политическое движение и классовая борьба на Средней Волге. К.,

1972; Ц е й т л и н Р.С. «Известия Казанского военно-окружного комитета» (май–ноябрь 1917 г.) как исторический источник // Октябрь в Поволжье и Приуралье (Источники и вопросы историографии). К., 1972.

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО ГУБЕ́РНСКОГО КОМИССАРИА́ТА»** («Казан губерна комиссариаты хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. «*Казанские губернские ведомости*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның мартыннан 1918 нең мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 21 саны чыга. 1918 нең 6 мартыннан 29 мартына кадәр «Известия комиссариата Казанского губернского совета крестьянских депутатов» исемендә 20 сан чыга. Мөхәррире — Б.В.Бартольд. Газета, башлыча, губерна хакимияте һәм идарә органнары эшчәнлеген яктырта.

*Т.М.Насыйров.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО ГУБЕ́РНСКОГО СОВЕ́ТА КРЕСТЬЯ́НСКИХ ДЕПУТА́ТОВ»** («Крәстиян депутатларының Казан губерна советы хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. 1917 елның 12 июленнән 21 сентябренә кадәр Казанда атнага 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Н.И.Строганов. «Өмид» басмаханәсендә басыла. Максаты — крәстиян депутатларының Бөтенроссия һәм Казан губернасы советлары сәясәтен, илдәге сәяси вакыйгаларны аңлату, төбәктәге крәстияннәр хәлен яктырту. Газета крәстияннәрне крәстиян депутатлары советы тирәсенә берләштерүгә, аларны өяз советлары һәм волость ком-тлары оештыруга чакыра, крәстияннәрнең Бөтенроссия советына альтернатив булган Бөтенроссия крәстиян берлеге съездын чакыруга каршы чыга, Вакытлы хөкүмәт һәм оборончылар сәясәтен яклый. Крәстиян депутатларының Бөтенроссия советы карарларын пропагандалый (бөтен җирне халыкка йолым түләтмичә генә хезмәт нормасы буенча тигезләп бүлеп бирү, федератив демократик республика урнаштыру һ.б.). Газетада Учредительләр җыенына сайлаулар тәртибе җентекләп аңлатыла. 1 нче санда «Казан губернасының барлык халкына» ачлыктан интегүче эшчеләргә һәм армиягә ярдәм итүне сораган өндәмә, губерна азык-төлек идарәсенең алпавытлардан алынган икмәкне азык-төлек ком-ты пунктларына тапшырырга тиешлеге турындагы карары басыла. «Крәстиян тормышы» дигән бүлектә уңышның торышы, урманны файдалануга күзәтчелек итү турында һ.б. материалларга урын бирелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО ГУБЕ́РНСКОГО СОЮ́ЗА СЕ́ЛЬСКИХ ХОЗЯ́ЕВ»** («Авыл хуҗаларының Казан губерна союзы хәбәрләре»), атналык газета. 1917 елның июненнән 1918 нең 21 февраленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 28 саны чыга. Газетада Казан губернасы земствосының атналык «Земская неделя» г-тасы мөхәррире Н.А.Мельников, Н.А.Теренин һ.б. авторларның мәкаләләре басыла. Басма үзалдына Союз эшчәнлеген яктыртып бару максатын куя. Газета Казан губернасы һәм өяз земстволары, земство идарәләре эшчәнлеге турындагы материалларны бастыра, аларда халык мәгарифе, мед. хезмәте күрсәтү (бигрәк тә яраланган солдатларны дәвалау), юл хуҗалыгы, почта хезмәте күрсәтү һ.б. мәсьәләләр яктыртыла. Казан губернасында а.х. эшләренең барышы турында сөйләнә, өязләрдә ашлык һәм яшелчә культураларының уңышлары турында мәгълүматлар бирелә. Агрономнар һәм вет. табибләре орлыкны, бәрәңге һәм яшелчәне эшкәртү һәм саклау, терлек карау, аларның авыруларына каршы көрәш чаралары турында киңәшләр б-н чыгалар. Газетада басылган материалларда Беренче бөтендөнья сугышы аркасында эшчеләр һәм тарту көче җитешмәү сәбәпле а.х. эшләрендә туган авырлыклар турында сөйләнә. А.х. берлеге бетерелгәннән соң, 1918 елның башында газета чыгудан туктый.

*Т.М.Насыйров.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО ИНСТИТУ́ТА СЕ́ЛЬСКОГО ХОЗЯ́ЙСТВА И ЛЕСОВО́ДСТВА»** («Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты хәбәрләре»), фәнни журнал. 1925–30 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Башта «Сборник научных статей Казанского института сельского хозяйства и лесоводства» исемендә чыга. 3 төп бүлектән тора: 1) ин-т һәм студентлар оешмаларының гыйльми һәм җәмәгать эшләре; 2) ин-т хезмәткәрләренең гыйльми эшләре; 3) библиография бүлеге. Редакция үз алдына Идел-Кама төбәгендә агрономия, урманчылык проблемаларын яктырту максатын куя. Ин-т кырларында һәм фермаларында галимнәр алып барган тәҗрибәләрнең, Раифа өйрәнү-тәҗрибә урман хуҗалыгы эшләренең нәтиҗәләре, институт эшчәнлеге турында хисап материаллары басыла. 1 нче санда редакция ин-т тарихына багышланган мәкаләләр бастыра: «Казанда югары авыл хуҗалыгы институты булдыру турында очерк» (проф. А.Н.Остряков), «Казанда югары урманчылык мәктәбе ачу тарихы» (проф. А.А.Юницкий). 1926 елда 5 нче саннан журнал исемен үзгәртә. Башта редколлегия составында профессорлар Н.Н.Парфентьев, Л.И.Яшнов, В.П.Ищереков була, 6 нчы саннан (1926) — профессорлар А.Я.Гордягин, В.В.Винер, А.А.Юницкий керә. 1927 дән басма 2 төп бүлектән тора (агрономия һәм урманчылык), 1928 дә журнал 3 сериягә (рәсми, агрономия, урманчылык) бүленә. 5 нче санда (1926) С.-Петербургта Урманчылык җәмгыяте тарафыннан нәшер ителә торган «Лесной журнал»да (1906–18) басылган мәкаләләр күрсәткече кушымта итеп басыла. 1933 тән «Известия Казанского сельскохозяйственного института» ж-лы нәшер ителә, 1937 елдан «Труды Казанского сельскохозяйственного института» исемендә чыга.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ КАЗА́НСКОГО О́КРУГА ПУТЕ́Й СООБЩЕ́НИЯ»** («Казан округы аралашу юллары хәбәрләре»), газета. 1914 елның 29 апреленнән 1916 га кадәр Казанда рус телендә көн саен нәшер ителә. 1897–1913 елларда чыккан «Дополнение к телеграфному бюллетеню Казанского округа путей сообщения» г-тасының дәвамчысы. Дистанция башлыкларына, казна судноларына, земснарядларга, пассажир һәм буксир пароходларына таратыла. Аралашу юллары министрлыгына, Баш физ. обсерватория (Петроград), «Правительственный вестник», «Новое время» редакцияләренә, биржа ком-тларына, суднолар хуҗалары съездлары советына мәҗбүри данәләре җибәрелә. Газетаның һәр санында су үлчәү пунктларыннан алынган суның арту һәм кимүе, су ташу вакытын билгеләү, округ терр-ясендә газета чыккан көндәге һава торышын күрсәткән телеграф бюллетеньнәре, Баш физ. обсерваториясенең үткән көн өчен метеорологик бюллетене, перекатларның тирәнлек, һава һәм су температурасы таблицалары, су юлларының җайге тирәнлеге, су төбен казу снаряды һәм краннарының исемлекләре, аларның эшләү урыннарын күрсәткән мәгълүматлар бирелә. Округ башлыгы һәм аралашу юллары министрының законнары, кагыйдәләре, боерыклары; санитария-табиблек бүлекләре буенча күрсәтмәләр һәм штрафлар турында әмерләр; навигация, кышлау, су төбен казулар, төзү һәм тикшеренү эшләре турында мәгълүматлар басыла. Маҗаралы хәлләргә — судноларның комга утыруы, бәрелешүләре һәм һәлак булулар, янгыннар, бәхетсезлек очраклары турындагы мәкаләләргә күп урын бирелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ КОМИССАРИА́ТА КАЗА́НСКОГО ГУБЕ́РНСКОГО СОВЕ́ТА КРЕСТЬЯ́НСКИХ ДЕПУТА́ТОВ»**, газета, к. «*Известия Казанского губернского комиссариата*».

**«ИЗВЕ́СТИЯ О́БЩЕСТВА АРХЕОЛО́ГИИ, ИСТО́РИИ И ЭТНОГРА́ФИИ ПРИ ИМПЕРА́ТОРСКОМ КАЗА́НСКОМ УНИВЕРСИТЕ́ТЕ»** («Император Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»), фәнни журнал. *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* органы. 1878–1929 елларда Казанда рус телендә елга 3–6 саны чыга. Аерым 124 китаптан торган 34 томы дөнья күрә. Исеме үзгәрә: 1878–1916 да «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете», 1919–21 дә «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете», 1925–29 да «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском государственном университете имени В.И.Ульянова-Ленина». Редакция ком-ты әгъзалары катнашында җәмгыять сәркәтибе мөхәррирлегендә чыга. Беренче мөхәррире — Н.П.*Загоскин*, төрле чыгарылышларның мөхәррирләре — Н.Ф.*Катанов*, С.Кузнецов, А.Т.Соловьёв, А.С.*Архангельский*, Н.В.Никольский, П.В.Траубенберг, И.Н.*Смирнов*, Н.З.Тихов, К.В.*Харлампович* һ.б. Журналны нәшер итүдә Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзалары Г.Әхмәров, Ш.Әхмәров, Н.А.Бобровников, П.М.Дульский, Г.Ибраһимов, Н.Ф.Калинин, М.К.Корбут, С.Е.Малов, В.И.Огородников, М.Н.Пинегин, И.М.Покровский, П.А.Пономарёв, А.А.Спицын, М.Г.Худяков, Е.А.Чернышёв, ш.у. Казан ун-ты профессор-

лары Б.Ф.Адлер, А.И.Александров, В.А.Богородицкий, М.В.Бречкевич, Н.Ф.Высоцкий, В.Ф.Смолин, Н.Н.Фирсов, С.М.Шпилевский, А.А.Штукенберг катнаша. Журнал б-н җәмгыятьнең башка шәһәрләрдә (Будапешт, Гельсингфорс, Красноярск, С.-Петербург, Упсалы һ.б.) яшәүче әгъзалары да хезмәттәшлек итә.

Редакция үз алдына «Урал-Алтай дөньясын һәрьяклап өйрәнү» бурычын куя, шул сәбәпле Идел-Урал төбәгенә, Себер һәм Урта Азиягә караган материалларга зур урын бирә. Журналда ш.у. якут, монгол, серб, чех, фин һ.б. халыклар турында мәкаләләр басыла. «Хроника» бүлегендә археология, археография, антропология һәм этнография экспедицияләре вакытында ачылган һәм Россия музейлары коллекцияләренә тапшырылган табылдыклар турында хәбәрләр басыла. Җәмгыять советы утырышларына, археология, тарих һәм этнография бүлекләре җыелышлары беркетмәләренә, хисапларына урын бирелә, әгъзаларның исемлекләре, китапханә һәм музей каталоглары, фәнни чараларның программалары, җәмгыять планы буенча эшләнгән тикшеренү эшләре нәтиҗәләре басыла. Беркетмәләргә кушымта итеп күренекле тарихчыларның (К.А.Фукс, С.М.Шпилевский, М.Н.Пинегин, Ш.Мәрҗани һ.б.) хезмәтләре басыла, аерым тарихи вакыйгалар яктыртыла, Казан губернасы терр-ясендәге археол. казу эшләренең нәтиҗәләре (ш.и. таңкәләр, борынгы шәһәрлекләр тасвирламалары һ.б.), Идел буе Болгары һәм Казан ханлыгы шәһәрләре, чиркәүләр һәм монастырьлар турындагы мәкаләләр басыла. Төрле халыкларның көнкүреше, туй һәм мәет күмү йолалары, халык сынамышлары, дәвалау ысуллары турындагы язмаларга күп урын бирелә. Халык иҗаты әсәрләре (ш.и. шигырьләр, әкиятләр, ноталы җырлар) урнаштырыла, ш.у. Казан губернасы терр-ясендә яшәгән борынгы халыкларның исемнәре, төрки сүзләрнең этимологиясе турында лингвистик язмалар басыла. Библиография бүлегендә Россиядә һәм чит илләрдә чыккан вакытлы матбугат басмаларыннан «Известия ...» журналы тематикасына караган китап һәм мәкаләләргә күзәтүләр, систематик күрсәткечләр, археологларның 4 нче съезды һәм төрле фәнни экспедицияләрнең хезмәтләре, Император археол. комиссиясе хисаплары басыла. Казандагы күренекле галимнәрнең тормышлары һәм эшчәнлекләре яктыртыла. Журналда беренчеләрдән булып күпсанлы тарихи чыганаклар, ш.и. шәһәрләрнең писцовый һәм разряд кенәгәләре, генеалогия агачы (шәҗәрә), актлар, грамоталар һәм документлар фәнни әйләнешкә кертелә.

*Әд.:* Альфонсов И.В. Указатель к «Известиям Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете» за 1878–1905 годы (т. 1–21). К., 1906; Воробьёв Н.И. Указатель к «Известиям Общества археологии, истории и этнографии» за 1906–1927 годы (т. 22–33). К., 1928.

*Г.Р.Заманова.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ПО КАЗА́НСКОЙ ЕПА́РХИИ»** («Казан епархиясе хәбәрләре»), журнал. Башта Казан руханилар академиясе, аннан соң Казан епархия советы органы. 1867 елның апреленнән 1919 га кадәр Казанда рус телендә — айга 2, 1904 тән айга 4 тапкыр нәшер ителә. 1917 дән чыгу вакыты бозыла, 1918–19 елларда бары 5 саны гына чыга. Архиепископ *Антоний* (Амфитеатров) тырышлыгы б-н чыга башлый. Төрле елларда мөхәррирләре — Казан руханилар академиясе профессорлары һәм галимнәре, Казан руханилар консисториясе әгъзалары Е.А.*Малов*, П.В.*Знаменский*, С.А.*Терновский*, В.И.Протопопов, И.М.*Покровский*, Н.Н.Писарев, И.Ф.Григорьев, А.А.Лебедев, епископ *Анатолий* (Грисюк). Казан руханилар академиясенең күренекле галимнәренең мәкаләләре басыла. Журналның рәсми бүлегендә Рус православиесенә кагылышлы указлар, Синод, епархия башлыгы боерыклары, чиркәү оешмалары — руханилар һәм чиркәү уку йортлары, руханилар съездлары, хәйрия һәм миссионерлар җәмгыятьләренең чиркәүләргә кагылышлы эшләре турында хисаплар басыла. Рәсми булмаган өлешендә төбәк тарихы турында материаллар, ш.у. дин галимнәренең, чиркәү тарихчылары һәм хокук белгечләренең чыгышлары, вәгазь, үгет-нәсыйхәтләре, истәлекләр, укучылар хатлары, некрологлар урнаштырыла. Казан губернасының төп халкының этнографиясенә, храм һәм приходлар, ислам дине, иске дин тарафдарлары, мәҗүсилек тарихларына караган мәкаләләр басыла. Хакимияткә большевиклар килгәннән соң, журналда чиркәү оешмаларының юридик хокуклары бетерелү, мәктәптә Дин Законнарын (Закон Божий) укытуны туктату турында мәкаләләр урын ала. 1918 елның сентябрендә Казан губернасында большевиклар тарафыннан атып үтерелгән руханиларның исемлеге бирелә.

*Әд.:* Терновский С. Содержание Известий по Казанской епархии за 1867–1900 гг. К., 1905.

*Е.В.Липаков.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ТАТАРСТА́НА»** («Татарстан хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. Казанда рус телендә нәшер ителә. Оештыручылары — ТР Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинеты, 1995 елдан — газета редакциясе коллективы. 1991 нең февралендә сынау саны чыга, 1 нче саны 1991 нең 30 августына — Республика Көненә туры китереп чыгарыла. 1991 дә атнага бер тапкыр, 1992 дән һәр көнне басыла. 1995 нең маенда, оештыручылары алышынганда, «Халык депутатлары советы газетасы» дигән өстәмә исеме «Эшлекле даирәләр газетасы» итеп үзгәртелә. Мөхәррире — Ю.П.*Алаев.* Даими язышучы авторлары — Т.Мамаева, Т.Сидорова, С.Сайганова, Г.Такташ, Д.Туманов һ.б. Төп рубрикалары: «Республика», «Дуслык», «Заман һәм акча». Газетада ТР Дәүләт Советы кабул иткән законнар һәм карарлар, ТР Президенты указлары басыла, Татарстанның социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышы яктыртыла. 1995 нең октябреннән чәршәмбе көннәрендә «Телерадиопресса» мәгълүмат агентлыгы б-н берлектә «Реформа һәм җәмгыять» исемендә кушымта чыгарыла. Оештыручылары кабат үзгәргәч, «И.Т.» редакциясе дә үзгәреш кичерә: 1995 нең 24 ноябреннән җомга көннәрендә «*Время и деньги*» исемендә яңа газета чыга башлый.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ТАТЦИ́КА»**, к. «*Республика Татарстан*».

**«ИЗВЕ́СТИЯ ТОЦ»** («Татар иҗтимагый үзәге хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. *Бөтентатар иҗтимагый үзәге* органы. 1992–95 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — Р.Садыйков, Э.Минһаҗев, Н.Галиев була, редколлегия составына Н.Зәйнуллин, М.Мөлеков, Ф.Уразаев, М.Шәмсетдинов керә, газетада күбесенчә аларның мәкаләләре басыла. Газетаның өстәмә исеме: «Сәясәт, икътисад, милли мәсьәләләр». Башлыча, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең милли мәсьәләгә, эчке




«Известия ТОЦ» газетасы.

сәясәткә, ТР һәм РФнең дәүләт төзелешенә кагылышлы карашларын чагылдыра. Газетада татар милли хәрәкәте үсеше, татар халкының тупланувы, тел һәм мәдәниятен яңадан торгызу, ТРда милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре күтәрелә. Бөтентатар иҗтимагый үзәге президиумы утырышлары, БТИҮ вәкилләре советы пленумнарының хисаплары, кабул иткән программ документлары басыла. БТИҮ съездлары алдыннан газета аның сәяси платформасын, ТРның социаль-икътисади үсеш концепциясен, съезд резолюцияләре проектларын аңлата. Татарстанда тотрыклылык һәм милләтара бердәмлекне саклау буенча Координацион совет эшчәнлеген чагылдыра (ул совет эшендә БТИҮ дә катнаша). 1994 тә (№ 4, 5) Россия һәм Татарстан хөкүмәтләренең РФ һәм ТР арасындагы Шартнамә (1994 елның 15 феврале) нигезендә кул куелган килешүләре басыла. Төрки халыклар, Идел-Урал төбәге, азчылык милләт халыклары язмышына аерым игътибар бирелә. Мәс., газетаның кайбер саннары тулысынча фин-угор халыкларына (1992, № 5а), Исемнәре күрсәтелмәгән милләт һәм халыклар оешмасына (1992, № 9а сан) багышлана.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ИЗВЕ́СТИЯ ФИ́ЗИКО-МАТЕМАТИ́ЧЕСКОГО О́БЩЕСТВА ПРИ КАЗА́НСКОМ УНИВЕРСИТЕ́ТЕ»** («Казан университеты каршындагы Физика-математика җәмгыяте хәбәрләре»), фәнни-теоретик журнал. *Казан физика-математика җәмгыяте* органы. 1891–1923, 1945–49 елларда Казанда, 1924–38 дә Мәскәүдә рус телендә серияләп, Җәмгыять советы мөхәррирлегендә елга 3–4 сан нәшер ителә. Беренче мөхәррире — А.В.*Васильев*, 1924 тән редакция ком-ты

составында Казан ун-ты профессорлары В.А.*Баранов*, Д.Н.*Зейлигер*, А.П.*Норден*, А.П.*Котельников*, Н.Н.*Парфентьев*, К.П.*Персидский*, В.А.*Ульянин*, П.А.*Широков*, Н.Г.*Чеботарёв*, Н.Г.*Четаев* була. Исеме берничә тапкыр үзгәрә: 1891–1917 дә — «Известия физико-математического общества при Императорском Казанском университете», 1925–33 тә — «Известия физико-математического общества при Казанском университете им.В.И.Ульянова-Ленина», 1936–38 дә — «Известия физико-математического общества и научно-исследовательского института математики и механики при Казанском университете им.В.И.Ульянова-Ленина», 1945–49 да — «Известия Казанского физико-математического общества при Казанском государственном университете им.В.И.Ульянова-Ленина». Журнал серияләп чыгарыла, 1 нче сериясен «Император Казан университеты каршындагы табигать фәннәре белгечләре физика-матем. җәмгыяте секциясенең утырышлар беркетмәләре җыелмасы»ның 8 томы (1883–91) тәшкил итә, 2 нче сериягә 25 томы (1891–1925), 3 нче сериягә 14 том (1926–49) керә. Соңгы том «Учёные записки Казанского университета» ж-лының 4 нче китабы, 109 нчы томы була. Журнал 2 бүлектән тора: беренче бүлектә җәмгыять утырышларында укылган, ш.у. Н.И.Лобачевский исем. бүләкне алу конкурсына җибәрелгән математика, механика, астрономия, физика өлкәсенә караган оригиналь һәм тәрҗемә ителгән материаллар урнаштырыла; икенчесендә җәмгыять елъязмаларын чагылдыручы (еллык отчётлар, ш.и. керем-чыгым сметалары, җәмгыять әгъзаларының исемлекләре, уздырылган төп чаралар, күренекле галимнәрне данлау һ.б. турында) мәкаләләр урын ала. Физика-математика фәннәренең килеп чыгышы һәм үсеше тарихына күп игътибар бирелә. Җәмгыять китапханәсенә аерым кешеләр һәм оешмалар тарафыннан бүләк ителгән, сатып алынган китаплар һәм вакытлы матбугат басмаларының исемлекләре, бу тематика буенча Казан кибетләрендә сатыла торган китаплар турында белдерүләр, физика-математика фәннәре турында илдә һәм чит илләрдә барлыкка килгән хезмәтләрнең библиографияләре, фән яңалыклары, халыкара фәнни конференцияләр турында мәгълүматлар бирелә. Исемнәре дөнья күләм билгеле күренекле галимнәрдән А.В.Васильев, В.Г.Имшенецкий, М.А.Ковальский, П.И.Котельников, П.С.Назимов, Н.Н.Парфентьев, П.С.Порецкий, Ф.М.Суворов, Н.Г.Чеботарёв һ.б.га багышланган мәкаләләр, истәлекләр, некрологлар басыла, журналның кайбер саннары аерым галимнәргә багышлана. Н.И.Лобачевскийның тормышы һәм фәнни эшчәнлегенә аерым игътибар бирелә: аның хатлары, фәнни хезмәтләре кушымта итеп басыла. Иллюстрация материалларына: чишү өчен мәсьәләләр һәм сорауларга, формулалар, сызымнар, рәсемнәргә күп урын бирелә. Физика-математика җәмгыятенең гомерлек әгъзасы булганнар һәм әгъзалык взносларын түләп баручылар журналны бушлай ала.

*Г.Р.Заманова.*

**ИЗВЕСТЬЛЕ́ ТУФ**, күзәнәкле тау токымы, салкын яки кайнар углекислоталы чыганаклардан үсемлек калдыкларына $CaCO_3$ ның (кальцит яки арагонит) утыруы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Еш кына үсемлек, әкәм-төкәм һ.б. эзләре була. Соры, сары, көрәнсу төсләрдә. Күзәнәклелеге 2 дән 40% ка кадәр. ТРда Кама Тамагы, Түбән Кама р-ннарында И.т.ның A+B+C категориясе буенча 7,4 мең *м*³ запаслы чыганаклары ачыкланган (1996).



Известьле туф.

Катламнарның калынлыгы 0,28–3,8 *м*, $CaCO_3$ микъдары 85–99%. Төзелеш материалы буларак, киселмә һәм декоратив таш, төзелеш известе алу, цемент җитештерү, туфракны известьләү өчен кулланыла.

*Әд.:* Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан: В 3 ч. К., 1999.

**ИЗВЕСТЬТА́Ш**, тау токымы, нигездә кальциттан, сирәк кенә арагониттан тора; еш кына аңа доломит, сидерит, кварц һ.б. минераллар, балчыксыл (балчыксыл И., мергель) һәм комсу кисәкчекләр кушыла; кайбер очракта составында известь скелетлы казылма организм калдыклары очрый. Ас төрләре — *акбур, известьле туф, мәрмәр ониксы*, мәрмәр һ.б. Тыгыз, сизелер-сизелмәс кристаллик, күп очракта катламлы. Төсе актан карага кадәр. Пыяла сыман ялтырый. Катылыгы 3 (пычак б-н җиңел кырыла). Уалучан. Сыегайтылган HCl тәэсирендә чыжылдап таркала. Килеп чыгышы биоген, хемоген, вакланган һәм катнаш. Бөтен континентларның төрле яшьтәге утырмаларында очрый, утырма токымнарның барлык массасының 20% ын тәшкил итә. Запаслары (доломит б-н бергә): РФдә — 12 млрд. *м*³, ТРда — 71 млн. *м*³ ка якын; чыгышы — 80 һәм 0,6–0,8 млн. *т* (2009). Татарстан терр-ясендә урта гасырлардан алып фундамент салу, стена өю (Казан Кремле), яндырып известь алу максатында кулланыла.



Известьташ.

Нигездә, палеозой яшендәге токымнар арасында таралган, Чүпрәле р-нында ш.у. мезозой (югары акбур) яшендәге утырмаларда да очрый. ТРда мәрмәр ониксы ятмалары б-н органоген, оолит, вакланган һәм кристаллик төрләре билгеләнгән. Күзәнәкчел һәм ярыкланган И.ларда нефть, газ, битум һәм җир асты сулары ятмалары бар. Саргылт, көрән һ.б. төсмерләр б-н аксыл соры һәм ак төстә. 340 тан артык чыганак билгеле (доломит б-н бергә), шуның 265 е Көнчыгыш Кама аръягында һәм Кама буенда тупланган. Иң зурлары Красновидово (Кама Тамагы р-ны), Үтәк (Чистай р-ны), Пәрәү (Лаеш р-ны); чыганакларның файдалы катлам калынлыгы 15 *м* га җитә. Кисү, стена һәм стена каплау ташы буларак (кристаллик төре яхшы шомара), төзелеш известе (һавалы-кальцийлы), силикат кирпеч, вакташ (200–600 лы марка), бут ташлы (200 ле марка), күзәнәкле җиңел төзелеш материалы, цемент, рубероид, известь (агрономик), пыяла ясау, кәгазь агарту һ.б. өчен яраклы.

*Әд.:* Проблемы геологии твёрдых полезных ископаемых Поволжского региона. К., 1997; Семеновский Ю.В. Минеральное сырьё. Известняк: Справ. М., 1999.

**ИЗГА́Р** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,4 *км*, бассейнының мәйданы 94,1 *км*². Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чулпан авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, тамагы Рус Ялтаны авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 118 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 27%. И.ның 6,1 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры килгән елларда елганың югары агымы кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 82 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. И. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 0,006 *м*³/*с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. И. бассейнында күләме 0,098 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИЗГА́Р** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 204 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никитино, Городище, Рождественский исемнәре б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да Рождество чиркәве, земство хастаханәсе, мәктәп, пар һәм 6 җил

тегермәне, 5 тимерчелек, йон һәм тукыма ману йорты, казна шәраб, 8 вак-төякләр кибете, 2 сыраханә була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2764 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның — Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 585 ир-ат; 1859 да — 1383, 1897 дә — 2047, 1908 дә — 2053, 1920 дә — 2351, 1926 да — 1948, 1938 дә — 1516, 1949 да — 944, 1958 дә — 803, 1970 тә — 645, 1979 да — 334, 1989 да — 211, 2002 дә — 236 кеше.

**ИЗГЕ́ ГУ́РИЙ БОРАДӘРЛЕГЕ́** (Изге Гурийның миссионерлык җәмгыяте), миссионерларның иҗтимагый оешмасы. 1864 елда патша Александр II тарафыннан расланган «Чиркәү борадәрлекләрен оештыру кагыйдәләре»нә яраклаштырып, 1867 нең 4 октябрендә ачыла. Аның оештырылуына турыдан-туры 1866 да ислам диненә кайтырга теләгән керәшен татарларның киң җәелгән чуалышлары йогынты ясый. Оешманың вазифаларына «православие динендәге керәшен әҗнәбиләрне иманга китерүгә, аларның балаларын православие дине рухында тәрбияләүгә, дини мәктәпләр ачу һәм аларның туган телләрендә китаплар тарату юлы б-н ... ислам динен тотучылар һәм мәҗүсиләр арасында христиан динен таратуга булышлык итү» керә.

Оешма проекты Н.И.Ильминский җитәкчелегендәге төркем тарафыннан тәкъдим ителә. Борадәрлекнең эшчәнлеге б-н еллык хисап җыелышында сайлана торган Совет җитәкчелек итә. Эшне оештыруда, нигездә, Казан руханилар академиясе профессорлары Н.И.Ильминский, Е.А.Малов, П.В.Знаменский, соңрак М.А.Машанов, ш.у. руханилар В.Т.Тимофеев, Т.Е.Егоров һәм химаяче сәүдәгәрләр П.В.Щетинкин, П.В.Прибытков һ.б. мөһим роль уйныйлар. 19 йөз ахырында җәмгыятьнең иң алдынгы эшлеклеләрен шул ук оешмаларның тырышлыгы б-н руханилык дәрәҗәсе алган әҗнәби руханилар тәшкил итә. Мәс., 1892 елга кадәр 48 керәшен татар, 8 чуаш, 3 мари, 2 удмурт рухани дәрәҗәсе ала. И.Г.б. эшчәнлегенең төп юнәлеше рус булмаган халыклар яшәгән авылларда (күпчелеге иске дин тарафдарларыннан торган кайбер рус авылларында да) православие дине мәктәпләре ачудан һәм аларның штатын тотудан гыйбарәт була. 1868 дә — 22, 1878 дә — 57, 1884 тә — 71, 1892 дә — 122, 1909 да 133 мәктәп эшли. 20 йөз башында аларда 5000 ләп бала белем ала. 1890 да оешма үз пед. уку йортын ача. Алар арасыннан чуаш (Козьмодемьян өязе Ишаки а., 1894), мари (Царёвококшай өязе Унжа а., 1898) мәктәпләрен күрсәтергә мөмкин. Керәшен-татар мәктәпләре өчен укытучы кадрлар *Үзәк керәшен-татар мәктәбендә* әзерләнә. Ул әлеге җәмгыятькә буйсынмый, әмма аннан дотация алып тора. Борадәрлек мәктәпләрендә *Ильминский системасы* буенча укытыла.

Оешма эшчәнлегенең икенче юнәлеше — Библия, православие дине әдәбиятын, борадәрлек мәктәпләре һәм православие миссионерлар җәмгыяте мәктәпләре өчен дәреслекләр тәрҗемә итү һәм бастыру була. Борадәрлек каршында тәрҗемә комиссиясе оештырылгач (1875), эш тагын да активлаша. Китап бастыру эше дәүләт тарафыннан финанслана. Оешма татар, чуаш, мари, мордва-эрьзя һәм мордва-мукшы, удмурт, бурят, калмык, алтай, эвенк (тунгус), нанай (гольд), якут, селькуп телләрендә 500 дән артык исемдә китаплар һәм брошюралар бастырып чыгара. Тиражның яртысына якынын татар телендәге китаплар тәшкил итә. Тәрҗемә комиссиясе эше б-н Н.И.Ильминский, соңрак Н.А.Бобровников җитәкчелек итә. Аның эшендә Г.С.Саблуков, И.Я.Яковлев, В.В.Миротворцев, Н.Ф.Катанов, Е.А.Малов һ.б. катнаша.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында борадәрлекнең баш эшлеклесе итеп архимандрит Андрей (кенәз Ухтомский) билгеләнгәч, аның структурасында мөһим үзгәрешләр була. Үз әгъзалыклары, бюджеты һәм программасы булган сектачыларга каршы көрәш бүлеге (1901) һәм Туташлар түгәрәге (1909) ачыла. 1909 дан «Сотрудник Братства Святителя Гурия» («Изге Гурий Борадәрлеге хадиме») ж-лы чыга.

*Әд.:* Знаменский П.В. На память о Николае Ивановиче Ильминском. К., 1892; Машанов Н.А. Обзор деятельности Братства Святителя Гурия за двадцать пять лет его существования. 1867–1892. К., 1892.

*Е.В.Липаков.*


**ИЗГЕ́ ГУ́РИЙНЫҢ МИССИОНЕРЛЫ́К ҖӘМГЫЯТЕ́**, к. *Изге Гурий борадәрлеге.*

**ИЗГЕ́ ЕКАТЕРИ́НА КИ́РХАСЫ** (Sankt-Katarinen Kirhe), лютераннар чиркәве, архит-ра ядкәре. Кирханың әүвәлге бинасы 1773 елда төзелә, барокко белән классицизм стильләрен берләштергән дүрт кыеклы түбә астындагы ике катлы һәм турыпочмаклы йортны хәтерләтә. 1861–62 елларда арх. Л.К.Хрщонович проекты буенча реконструкция үткәрелә. Ике кат арасындагы түшәм сүтеп алына, бинаның бөтен күләме биек гыйбадәт залына әйләнеп кала, хезмәткәрләр бүлмәләре алтарь артына урнаштырыла. Бинага көнбатыш яктан өйалды терәлеп урнашкан. Шунда ук балконга хор өчен баскыч урнаштырылган. Бинага килүчеләр чаң манарасының 1 нче ярусындагы ишектән кергәннәр. Готика үрнәкләрен хәтерләткән эклектика формалары кулланылган. Урам һәм ишегалды фасадлары бер үк симметрик композициядә төзелгән. Үзәк өлеш фланглардан өстәмә кырланган колонкалар белән капланган һәм югарыда түгәрәк тәрәзәле өчпочмак б-н төгәлләнгән. Колонналар һәм өчпочмаклы бизәкләр биек чатыр түбәле кечкенә манара-пирамидалар б-н төгәлләнгәннәр. Фасадның үзәк өлешендә архивольтлар б-н берләштерелгән биек уксыман өч тәрәзә уелган. Аларны флангларда шундый ук тәрәзәләр һәм уемнар кабатлый. Аркатура-колонна сыман пояслар фасад диварының почмак рәвешендәге өске өлешен һәм кәрниз кыекларын бизәп тора — ян өлешендәге ишекләре биек баскычлы болдырга урнаштырылган. Кирпеч стена ак төсле архитектур бизәкләр б-н контраст хасил итә. 1927 дә кирха ябыла, бина Менжинский исем. клуб итеп үзгәртелә. Аның бер өлеше 1996 елда К.Фукс исем. Немец җәмгыятенә бирелә. Кече гыйбадәт залы 1996 дан лютераннар тарафыннан үз максатында файдаланыла.

*Әд.:* Нугманова Г.Г. Архитектурно-строительное законодательство Российской империи и храмы Казани // Региональное многообразие архитектуры России. К., 2007.

*Г.Г.Ногманова.*

**ИЗГЕ́ УРЫННА́Р**, күпчелек диннәрдә төрле риваятьләргә бәйле рәвештә дини халык тарафыннан табыну өчен изгеләштерелгән гыйбадәт кылу урыны. Татарларда И.у.га табыну исламга кадәрге мәҗүси һәм исламча күзаллаулар җыелмасын үзенә сеңдергән халык исламының мөһим өлеше булып тора (к. *Гореф-гадәт*). Мөселман татарларда И.у. — изгеләр (әүлияләр) каберләре, зиратлар, чишмәләр, ш.у. шәһәр хәрабәләре. Чардуганнарга, агач ботакларына һ.б.га төсле



Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы. Биләр изгеләр чишмәсе өстендәге павильон. 1997.

тасмалар, яулыклар, кечкенә әләмнәр бәйләп кую И.у.ның характерлы билгеләреннән санала. И.у.ны зиярәт кылалар, алар янында күмәкләп дога укыйлар, еш кына изге урын тирәли әйләнеп чыгу йоласы үтәлә, корбан чалына, сәдака калдырыла һ.б. И.у.да дин тотучылар төрле сырхаулардан савыгу, йорт-җиргә иминлек, сәфәр көткәннәргә хәерле юллар һ.б. сорыйлар. ТРда И.у.дан саналган изгеләр каберләре (Аксубай р-ны Иске Кыязлы авылында — Хаҗи-Мәхмүдзадә Керкания, Яңа Чишмә р-ны Бакташ авылында — Голяма Дувания, Балык Бистәсе р-ны Бирдебәк авылында — Хаҗи Хәбибулла, Биектау р-ны Татар Әйшәсе авылында — Гайшәбикә һ.б. каберләре); борынгы зират калдыклары (Биектау р-ны Калинин, Арча р-ны Иске Кишет авылларында һ.б.); борынгы шәһәр хәрабәләре (Әтнә р-ны Әйшияз авылы, Спас р-ны Болгар шәһәре, Лаеш р-ны Ташкирмән авылы һ.б.); «изге таш»лар (Теләче р-ны Теләче а., Сарман р-ны Иске Минзәләбаш а. һ.б.); чишмәләр (Алексеев р-ны Биләр шәһәрлегендә) бар. 1990 еллардан башлап, И.у.ны торгызу, аларны олылау традицияләренең җанлануы күзәтелә.

*Әд.:* Гольциер И. Культ святых в исламе. М., 1938; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татары. М., 2001.

*А.В.Климин.*

**ИЗЕРГИ́Н АСТЕРО́ИДЫ**, 1271 нче кече планета. Семеиз обсерваториясендә (Кырым) 1936 елда ачыла һәм Казан ун-ты студентлары җыенында (1987) катнашкан П.В.Изергин исеме б-н атала. Кояштан ераклыгы 2,7–3,6 а.б. Кояш тирәли 5,6 ел эчендә әйләнеп чыга.

**ИЗМА́ЙЛОВ** Аббас Хәлиулла улы (15.9.1920, хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк р-ны Зур Труев а. — 5.1.1992, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (15.2.1944, 5.4.1944, 10.4.1945), кече лейтенант (1946). Туган авылында тракторчы булып эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1433 нче үзйөрешле артиллерия полкы отделениесе туп төзәүчесе (4 нче танк армиясе 6 нчы гв. механика корпусы, 59 нчы армиянең 120 нче укчы дивизиясе). Ленинград һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Ленинградны саклауда (1941–44), Польшаны азат итү сугышларында, Берлин һәм Прага һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 28 гыйнварында Высоко-Ключевое торак пункты (Ленинград өлкәсенең Гатчина шәһәреннән 10 *км* көньяктарак) янындагы, 1944 нең 15 мартында Вайвара-Кирин торак пункты (Нарва шәһәреннән 16 *км* көнбатыштарак) тирәсендәге сугышларда батырлык күрсәтә: җимерелгән танкны дошман уты астында алып чыгып, яраланган экипаж әгъзаларын коткара; 1945 нең 15 гыйнварында Пословице торак пункты (Польша, Кельце шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнбатыштарак) тирәсендә барган сугышта иптәшләре б-н дошманның 2 контрһөҗүмен кире кайтара, танкын яндыра. 1946 дан запаста, совхозда эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лобода В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; И родом они пензенские. Саратов-Пенза, 1968; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*В.А.Шагалов.*

**ИЗМА́ЙЛОВ** Габдрахман Йосыф улы (1889, Казан — 1957), сәясәт эшлеклесе. 1901–06 елларда Казан ун-ты басмаханәсе эшчесе. 1905–07 дә рев-циядә катнаша. 1907 дән РСДРП әгъзасы. 1911 дә Россия армиясенә алына. 1917 дән Казанда: бертуган Кәримовлар басмаханәсендә хәреф җыючы, эшче депутатларының Казан губерна Советы әгъзасы. 1918 дә РКП(б)ның Казан губкомы каршындагы Мөселман бюросы җитәкчеләренең берсе. 1919 да Эстәрлетамак шәһәренә җибәрелә, анда Бөтенбашкорт Гадәттән тыш Комиссиясе рәисе итеп билгеләнә. 1920–21 дә ТАССР эчке эшләр халык комиссары. 1921–23 тә Тау халыклары АССР ҮБК Президиумы секретаре (Төньяк Кавказ). 1923–29 да Казанда хакимият-хуҗалык һәм партия эшендә: ТАССР Эшче-крәстиян инспекциясе, Хезмәт халык комис-тларында бүлек мөдире, ВКП(б)ның Югары-шәһәр райкомы секретаре, Камил Якуб исем. полиграфия-нәшрият комб-ты директоры, «Яңа китап» нәшрияты идарәсе рәисе урынбасары. 1930–31 дә язу машиналары остаханәсендә Шәрекъ телләре буенча консультант, хәреф җыючылар әзерләү курсларында укытучы. 1932 дә репрессияләнә (к. *«Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы» эше*); 1957 дә аклана.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**ИЗМА́ЙЛОВ** Гомәр Әхәт улы (17.9.1914, Верхнеудинск, хәзерге Улан-Удэ ш. — 6.12.1976, Мәскәү), инженер-радиотехник, техник фән. канд. (1971). 1939 елда Ленинград элемтә инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанда радиоэлемтә челтәре инженеры булып эшли. Совет-фин (1940) һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1941 дә әсирлеккә эләгә, Германия концлагерьларында тотыла, «Сименс» з-дларына эшкә җәлеп ителә. 1945–46 да Совет хәрби администрациясендә (Берлин) тәрҗемәче. 1946 да «Идел-Урал» оешмасына керүдә гаепләнеп репрессияләнә. 1948–54 тә СССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгының элемтә аппаратлары һ.б. махсус техника төзү лаб-ясендә эшли (Мәскәү өлкәсенең Марфино пос.), телефоннан сөйләшүләрнең яшеренлеген тәэмин итүче аппаратуралар төркеме җитәкчесе (1951 дә аклангannan соң — ирекле хезмәткәр). И. катнашында шаулауга охшаш сигналлар кулланып, телефоннан сөйләшүләрнең яшеренлеген саклау принциплары һәм техник җайланмалары эшләнә. И. төрмәдән А.И.Солженицынның кульязма материалларын алып чыга һәм саклый (язучы И.ны үзенең «Беренче әйләнәдә» («В круге первом», М., 2006) романында Амантай Булатов исеме б-н бирә). 1954–76 да И. Бөтенсоюз Кара металлургия автоматлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, кислородлы-конверторлы производствоны автоматлаштыру лаб-ясе мөдире (1968 дән). Хезмәтләре аэрозольләр һәм газ-тузан катнашмаларын өйрәнүгә, казып чыгару һәм эшкәртү сәнәгатендә һаваның һәм газның тузанлануын тикшерүче аппаратлар уйлап табуга карый. Автоматлаштыруга караган эшкәртелмәләре Азовсталь, Чиләбе, Караганда шәһәрләренең металлургия комб-тларында гамәлгә кертелә. 1956–76 елларда «Применение электроники» реферативжлының редакторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

*Әд.:* Копелев Л. Утоли моя печали. М., 1991; Калачёв К.Ф. В круге третьем. М., 2001.

**ИЗМА́ЙЛОВ** Искәндәр Лерун улы (12.12.1960, Магадан өлкәсенең Среднекан р-ны Сеймчан пос.), археолог, тарихчы, тарих фән. канд. (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1986–94 елларда Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1991 гә кадәр — СССР ФАнең Казан ф-лы, 1991 дән РФАнең Казан гыйльми үзәге, 1993 тән ТР ФА составында) эшли. 1995–96 да ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты фәнни хезмәткәре. 1996–98 дә «Родина» ж-лының үз хәбәрчесе. 1997–2006 да ТР ФА президенты киңәшчесе. 2006 дан ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-тында. Төп хезмәтләре Идел буенең урта гасырлар тарихына һәм археологиясенә, татар халкы этногенезына һәм этник тарихына, Идел-Урал төбәге халыкларының милли-сәяси һәм милли-мәдәни тарихына, урта гасырларда Идел буенда яшәгән халыкларның сугыш кораллары һәм хәрби-сугыш сәнгате тарихына, татарларда тарих фәненең барлыкка килүе һәм үсеше мәсьәләләренә карый. «Татарларның борынгы заманнардан килгән тарихы» («История татар с древнейших времен». К., 2006. Т. 2) авторларының берсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы әгъзасы (2002 дән).



А.Х.Измайлов.

Хезм.: Идел Болгарстаны. К., 2001 (автордаш); Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII в.в. Магадан-Казань, 1997; Этнополитическая история татар (III — середина XVI вв.). К., 2007 (автордаш); Введение в этногенез и этническую историю татарского народа. К., 2007 (автордаш); Защитники «Стены Искандера». К., 2008.

*Әд.:* Измайлов Искандер Лерунович // Тюркологи современного Татарстана: Справ. М., 1997; Измайлов Искандер Лерунович // Национальный центр археологических исследований: Библиография научных сотрудников (1987–2006 гг.). К., 2007.

**ИЗМА́ЙЛОВ** Наил Вәли улы (18.10.1948, Казан — 10.4.2009, шунда ук), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1971). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Тренерлары — А.Д.Кузьминых (1960–63), Н.И.*Морящичев*, Г.М.Кондратьев (1963 тән). Әлмәт физкультура техникумын тәмамлый (1980). СССР (1966, яшүсмерләр, 1969, яшьләр арасында), «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең үзәк советы беренчелекләрендә (1969–71), Европа турнирларында (Италиядә, 1966, Польшада, Швециядә, ГДРда, Болгариядә — 1970) җиңүче. 1974–78 дә «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә, 1978–85 тә республиканың югары спорт осталыгы мәктәбендә өлкән тренер, 1985–94 тә «Ракета» спорт клубы рәисе (Казан).

**ИЗМА́ЙЛОВ** Рафис Талип улы (27.6.1940, Мөслим р-ны Мәллә тамак а.), журналист, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан ун-тын (1969) һәм КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1981) тәмамлый. Үзәк басмаларда эшли: «Советская Россия» г-тасында (1969–1979), КПСС ҮКның «Агитатор» ж-лында (1981–1989) һәм атналык «Литературная Россия» г-тасында (1990) бүлек мөхәррире һәм редколлегияләр әгъзасы, РСФСР коммунистлар партиясенең Үзәк контроль комиссиясе рәисе референты (1991), РФ Федераль иминлек хезмәтенең «Служба безопасности:


Ш.С. Измайлов.


А.С. Измайлова.


Г.Б. Измайлова.

новости разведки и контрразведки» ж-лы баш мөхәрриренең беренче урынбасары (1991–94, 1996–2000). Вьетнам, Польша, Болгария, Чехословакия, Венгрия, Югославия, Тунис, Греция, Германия һәм Кубада командировкада була. Әсәрләре «Аргун», «Волга», «Дон», «Дальний Восток», «Литературное обозрение», «Казан утлары» һ.б. әдәби журналларда басыла. 1994–96 да һәм 2000 елдан башлап Россия Федерациясендә ТР Вәкаләтле вәкиллегенең матбугат үзәге җитәкчесе. Медальләр б-н бүләкләнә. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бүләге лауреаты (2004).

**ИЗМА́ЙЛОВ** Рөстәм Ильяс улы (13.12.1926, Казан — 13.10.2005, шунда ук), химик, химия фән. д-ры (1972). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1955–96 да РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, каталитик процесслар лаб-ясе мөдире (1971 дән). 1996 дан Казан технол. ун-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нефть химиясенә карый. Платина, палладий, никель һәм родий сыман матдәләр йөгертелгән катализаторларның каталитик үзлекләренә үзгәртүчән компонентларның тәэсирен тикшерә. Платиналы металларның каталитик үзлекләренә изомерлашу, гидрирлау, дегидрирлау һәм углеводородларны таркату реакцияләрендә үзгәртүчән өстәмәләрнең тәэсир итүен ачыклый. Катализаторларның күзәнәкле структурасын билгеләү ысулын эшли, катализаторның чагыштырмача металл өслеген билгеләүнең хроматографик ысулын тәкъдим итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение газовой хроматографии для определения физико-химических свойств веществ. М., 1970 (автордаш); Хемосорбция водорода на модифицированных алюмоплатиновых катализаторах изомеризации пентана // Нефтехимия. 1999. Т. 36, № 6.

**ИЗМА́ЙЛОВ** Сергей Геннадьевич (27.9.1958, Мордва АССР, Саранск ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1996), РФнең атказ. табибе (2002). 1982 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1986 дан Казан мед. академиясендә. 1996 дан Түбән Новгород мед. академиясе каршындагы Чик буе гаскәрләре ин-тында хирургик авырулар каф. башлыгы. Хезмәтләре йомшак тукымаларда үлекле яраларны, трофик җәрәхәтләрне булдырмау һәм дәвалауга, түбән очлыкларда веналарның варикоз авыруларын дәвалауда хирургия технологияләренә карый. И. лапаротом яраларны тегүнең яңа ысулын тәкъдим итә. Уйлап табуга 29 авторлык таныклыгы һәм патенты бар, шуларның 2 се СССР ВДНХсының көмеш медаленә лаек була.

Х е з м.: Способы ушивания ран. К., 1992 (автордаш); Болезнь Фурье. Н.Новгород, 1998; Послеоперационные эвентрации. Н.Новгород, 1999.

**ИЗМА́ЙЛОВ** Шакир Сафиулла улы (7.12.1897, Сембер ш. — 1937), сәясәт эшлеклесе, дипломат. Сембер тау эшләре уч-щесен (1914), Казан хәрби-техник курсларын (1917), СССР Тышкы эшләр халык комис-ты курсларын (Мәскәү, 1930) тәмамлый. 1917 елның февраленнән Россия армиясе сафларында, Самара мөселман социалистлар ком-ты составына сайлана. 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелеше вакытында Самара шәһәрендә Совет хакимияте урнаштыруда актив катнаша. 1918 дә РКП(б)ның Самара губкомы мөселман секциясе секретаре. 1919 да Көнчыгыш фронт гаскәрләрен оештыру, туплау һәм өйрәтү идарәсе сәяси бүлегендә. Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмаларының 2 нче Бөтенроссия съезды депутаты (1919 ның ноябрь–декабре, Мәскәү). 1921 дә Сембер татар сов.-партия мәктәбе укытучысы. 1922–24 тә РКП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт бюросы секретаре, 1925–29 да ТАССР хезмәт халык комиссары, ТАССР ҮБК составына сайлана. 1929 да ВЦСПС инструкторы. 1930 елдан дипломатик эштә: СССРның Согуд Гарәбстанындагы Вәкаләтле вәкиллегенең 1 нче секретаре, СССР Тышкы эшләр халык комис-тының 1 нче көнчыгыш бүлегендә җаваплы референт. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Г и з з а т у л л и н И. Измайлов Шакир Сафиуллович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ИЗМА́ЙЛОВА** Асия Сафиулла кызы (1903, Сембер ш. — 3.1.1993, Мәскәү), җырчы (меццо-сопрано), педагог, ТАССРның халык артисты (1939). Концерт эшчәнлеген Окт. рев-циясеннән соң Кызыл Армия сугышчылары алдында татар халык җырларын башкарудан башлап җибәрә. 1919 елда Сембер шәһәрендә татар драма труппасы спектакльләрендә катнаша. 1920–22 елларда ВКП(б)ның Сембер губкомы һәм губерна халык мәгарифенең хатын-кызлар бүлеге инструкторы. 1922 дә Мәскәү Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик ун-тының эшчеләр ф-тына укырга керә, бер үк вакытта А. һәм Н.Рубинштейннар исем. Дәүләт музыка техникумында вокал дәресләре ала. 1924 тән Мәскәү үзәк татар эшче театрын оештыруда катнаша һәм шул театр б-н ил буйлап гастрольләрдә йөри, радиодан чыгышлар ясый. 1927–29 да Казанда яши, концерт эшчәнлеге алып бара, беренче радиоконцертларда катнаша. 1929–34 тә Мәскәү филармониясе солисткасы. 1934–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый, бер үк вакытта Бөтенсоюз радиосыннан концертлар бирә. 1939–44 тә Казанда Татар опера һәм балет театрында төп солистка, бер үк вакытта Бөек Ватан сугышы чорында Мәскәүдә Совет Армиясе Үзәк йорты тарафыннан оештырылган фронт концерт бригадалары составында чыгышлар ясый. 1944–50 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе һәм А.В.Луначарский исем. Дәүләт театр сәнгате ин-тының Татар драма студиясе директоры һәм педагогы. 1963–92 дә Мәскәү консерваториясендә ялгыз җырлау классын алып бара. Төп партияләре: Бикә («Качкын», Н.Җиһанов), Ячы карчык («Галиябану», М.Мозаффаров), Зибель («Фауст», Ш.Гуно), Ольга («Евгений Онегин», П.Чайковский) һ.б. «Зиләйлүк», «Шахта» һ.б. татар халык җырларын оста башкарып зур популярлык казана. Мәскәүдә, Ленинградта, Идел буе шәһәрләрендә, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш, Украина, Урта Азиядә концертлар б-н чыгышлар ясый. Матур тышкы кыяфәткә һәм киң диапазонлы көчле тавышка ия була. И.ның башкару манерасы үзенең ихласлылыгы, аһәңле, тәэсирле, эчтәлекле булуы б-н аерылып тора.

Х е з м.: Октябрьгә кадәрге татар җырчыларының җырлау «техникасының» кайбер үзенчәлекләре // Совет әдәбияты. 1962. № 1.

*Әд.:* С ө л ә й м а н о в а Г., Ш а һ и ә х м ә т о в М. Халык артисткасы // Азат хатын. 1963. № 8; Асия Измайлованың тууына 60 ел тулуга багышланган җыелыш // Совет әдәбияты. 1963. № 12; К у т у й А. Певец свободы и красоты // Передовая интеллигенция орденоносной Татарии. К., 1940; И л ь я с о в Р. Измайлова Асия Сафиулловна // Народные артисты. К., 1980.

**ИЗМА́ЙЛОВА** Галия Баязит кызы (12.2.1923, Томск ш. – 4.10.2010, Ташкент), балет артисты, балетмейстер, Үзбәкстан ССРның (1951), СССРның халык артисты (1962). Мәскәү театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) хореография уч-щесен (1941), Ташкент театр ин-тын (1958) тәмамлый. 1941 дән — Үзбәк опера һәм балет театры балет солисты. Хореография партияләре арасында: Семург («Ак-Биляк», С.Василенко), Аврора, Одетта-Одиллия («Йокыга талган гүзәл», «Аккош күле», П.Чайковский), Китри («Дон Кихот», Л.Минкус), Сванильда («Коппелия», Л.Делиб), Жизель (шул исем. балет, А.Адан), Тао Хоа («Кызыл мәк», Р.Глиэр), Гөлнара («Балерина», Г.Мушель) һ.б. И.ның образлары драма вакыйгалары б-н тулыландырылып иҗат ителә. Артистка зур пластик сыгылмалы, виртуоз башкару сәләтенә ия. 1957 елдан Үзбәк опера һәм балет театры балетмейстеры (1977–85 тә баш балетмейстер).

Куйган спектакльләре: П.Чайковскийның «Аккош күле» (1957), Н.А.Римский-Корсаковның «Шәһрезадә»се, И.Штраус музыкасына «Штраусиана» (1960), М.Әшрәфнең «Мәхәббәт амулеты» (1969), А.Меликовның «Мәхәббәт турында легенда»сы (1979) һ.б. СССРның, Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. Дәүләт бүләкләре лауреаты (1950, 1970). Ике Ленин ордены, «Почёт билгесе», Үзбәкстан-

ның «Дуслык», «Хезмәткә дан» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Авдеева Л. Галия Измайлова. Ташк., 1975.


**ИЗМА́ЙЛОВА** Галия Гыйлаҗи кызы (15.5.1909, Казан — 10.9.1983, шунда ук), хакимият эшлеклесе. 1924 елдан Казан җитен комб-тында: ФЗӨ мәктәбен тәмамлаганнан соң (1927), җеп эрләүче, профорг (1932–34), хезмәтне саклау инспекторы (1934–37), партком секретаре булып эшли (1937–38). 1938 дән ТАССРның социаль тәэминат, 1939 дан җиңел сәнәгать, 1940 тан азык-төлек сәнәгате халык комиссары. 1943–51 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында азык-төлек, соңрак җиңел сәнәгать бүлеге мөдире. 1951 дән хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1955–59 да шунда ук а.х. бүлеге мөдире. 1938–51 дә РСФСР, 1938–59 да ТАССР ЮСлары депутаты, бер үк вакытта 1943–47 дә һәм 1951–55 елларда ТАССР ЮС рәисе. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ИЗМА́ЙЛОВА** (Мирзаянова) Нурия Халит кызы (1.1.1950, БАССРның Шаран р-ны Базгыя а.), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1972–78 елларда Башкортстан китап нәшриятында җаваплы мөхәррир. 1981–82 дә Мәскәүдә «Наука» нәшриятында эшли. 1996 дан АКШта яши. «Яратам» (1981, русчага тәрҗемәдә «Ива на ветру», М., 1986), «Минем җәй» (1987), «Җирдә» (1993) җыентыкларына кергән шигырьләрендә кешеләргә, мәхәббәткә ышаныч, өмет хисләре чагыла. чит илдә язылган әсәрләрендә («Язылмаган хатлар» (2003), «Адашкан» (2004) җыентыклары) туган җирне юксыну, читтә яшәгән кеше хисләре калкурак гәүдәләнеш тапкан, эчке драматизм б-н сугарылган.

*Әд.:* Вәли М. Америкада татар әдибәсе // Казан утлары. 2001. № 9.

**ИЗМА́ЙЛОВО** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 35 *км* көньяктарак, Кандыз елгасы (Ыкның сул кушылдыгы) буенда. 2008 елда 220 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1890 елгы мәгълүматларга караганда, И.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 836 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Иваново волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 183, 1889 да — 250, 1897 дә — 337, 1920 дә — 409, 1926 да — 424, 1938 дә — 362, 1958 дә — 320, 1970 тә — 268, 1979 да — 206, 1989 да — 122, 2002 дә — 221 кеше.

**ИЗНО́СКОВ** Илиодор Александрович (15.8.1835, Казан губ., Мамадыш өязе Таишев заводы — 1917, Петроград), тарихчы, математик, этнограф, педагог, нумизмат, хакыйкый статский советник (1883). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлый (1858). 1858–59 елларда Казан өяз уч-щесенең шәрәфле күзәтчесе, 1859–66 да Казан беренче ирләр гимназиясе өлкән укытучысы. 1866–69 да Козьмодемьян өязе җәмәгать арадашчысы, 1869–71 дә Лаеш өязе җәмәгать судьясы. 1871–74 тә Казан губернасы халык уч-щеләре инспекторы, 1874–89 да директоры. 1889–96 да Казан реаль уч-щесе директоры. 1896–1907 дә Изге Синод обер-прокуроры каршында аерым йөкләмәләр үтәүче чиновник. Казан шәһәр музеен оештыручыларның берсе (1896). «Тау чирмешләренең гореф-гадәтләре» («Обычаи горных черемис», 1869), «Козьмодемьян өязендәге тау чирмешләре приходлары» («Горно-черемисские приходы Козьмодемьянского уезда», 1869), «Казан губернасы өязләрендә мәктәп эшенең торышы турындагы мәгълүматлар җыелмасы» («Собрание сведений о состоянии школьного дела в уездах Казанской губернии», 1882), «Идел буеның җырлары һәм әкиятләре» («Песни и сказки Поволжья», 1888), «Казан төбәге әҗнәбиләрен христианча агарту тарихыннан материаллар» («Материалы для истории христианского просвещения инородцев Казанского края», вып. 1–3, 1893–95) кебек хезмәтләрендә Урта Идел буе халыкларының икътисадын һәм көнкүрешен, кәсепләрен һәм гореф-гадәтләрен, тарихын һәм мәдәниятен тикшерә. «Халык мәгарифе тарихыннан материаллар. Казан губернасында халык училищелары» («Материалы по истории народного образования. Народные училища в Казанской губернии», 1889) китабын төзүче һәм аның мөхәррире. И.ның археологиягә карата мөнәсәбәте «Казан губернасындагы шәһәрчекләр, курганнар һәм борынгы тораклар, аларда очраучы табылдыклар турында язмалар» («Заметки о городах, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии, и о встречающихся в них находках», 1878), «Казан губернасы Спас өязен тарихи-археологик күзәтү буенча материаллар» («Материалы для историко-археологического обозрения Спасского уезда Казанской губернии», 1895), ш.у. «Казан губернасының археологик картасына карата аңлатма язуы» («Объяснительная записка к археологической карте Казанской губернии», 1890) кебек хезмәтләрендә чагылыш таба. Казан һәм Лаеш өязләрендәге торак урыннарын тасвирлый, татар топонимнары турында мәгълүматлар җыя. Төбәкне христианлаштыру, урта гасырлардагы татар чуалышлары, Изге Гурий борадәрлеге, яңа чукындырылганнар мәктәпләре турындагы хезмәтләр, ш.и. «Казан епархиясе авыл руханиларының миссионерлык эшчәнлеге» («Миссионерская деятельность сельского духовенства Казанской епархии», 1909), В.Г.Имшенецкий, А.Ф.Попов турындагы мемуарлар, математика буенча кулланмалар авторы. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1878).



И.А. Износков.

Хезм.: Список населенных мест Казанской губернии с кратким их описанием: В 2 вып. К., 1885–95; О деятельности Лобачевского в Казанском экономическом обществе. К., 1894; Миссионерская Братства Святителя Гурия школа в селе Ишаках Казанской губернии. К., 1895; О сенокосах и других земельных угодьях в окрестностях г.Казани в конце XVIII века. К., 1895; Об отпавших и отпадающих из православия инородцах. К., 1907; Полные численные квадраты. К., 1914.

*Әд.:* Катанов Н.Ф. Нумизматическая коллекция И.А.Износкова. К., 1896; Агафонов Н.Я. Казань и казанцы. К., 1907. Ч. 2; Венгеров С. Критико-биографический словарь русских писателей и учёных. П., 1915. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ИЗОГЛО́ССА**, к. *Лингвистик география.*


**ИЗОЛО́МА**, к. *Колерия.*

**ИЗО́СИМОВ** Всеволод Владимирович (28.10.1899, Казан губ., Чистай өязе Ширәмәт а. — 25.12.1974, Казан), биолог, биол. фән. д-ры (1950), проф. (1933). 1924 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли. 1931 дән Казан мед. ин-ты һәм Казан ун-тының гомуми биол. кафедралары мөдире. 1940 ка кадәр Казан ун-тында гидробиология укыта, СССР ФАнең Казан ф-лында зоология секторын оештыруда катнаша (1946); стоматология ин-ты деканы (1934–38) һәм проректоры (1940–46), мед. ин-ты проректоры (1952–58). И. Байкал күле, Идел-Кама сусаклагычы планктонын: гельминтозларның тышкы мохиттә (суда, туфракта, яшелчәдә, торак йортларда, көнкүреш куллану әйберләрендә) таралуын тикшерә. Мед. ин-ты галимнәре б-н бергәләп балалар учреждениеләре өчен гельминтозлардан дәвалауның дәвалау-профилактика чаралары комплексын эшли. И. җитәкчелегендә Fusarium poin гөмбәсе культурасыннан поин антибиотигын алу ысулы эшләнә. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: О происхождении фауны люмбрикулид Байкала. К., 1933.

**ИЗО́ТОВ** Владимир Сергеевич (22.4.1947, Арча р-ны Төбәк Чокырча а.), төзелеш материаллары технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005). 1970 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2006 дан төзелеш материаллары каф. профессоры. Хезмәтләре биналар һәм төзелеш корылмаларының сыйфат һәм ышанычлылыгы проблемаларына, төзелеш материаллары җитештерүенең энергия сыешлылыгына, үзле материаллар һәм бетон җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә карый. ТЭЦ калдыкларын (көлне) тимер-бетон конструкцияләр һәм эшләнмәләрне серияләп җитештерүдә куллану мәсьәләсен тикшерә (нәтиҗәләре Казан пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 20 авторлык патенты бар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә (1990).

Хезм.: Методические рекомендации по организации контроля качества на предприятиях стройиндустрии. К., 1995 (автордаш); Цеолитсодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001 (автордаш); Химические добавки для модификации бетона. М., 2006 (автордаш).

Бизәкле күкрәкчә — изү. Тукыма, укалы тасма, көмеш, алтынлау, асылташлар. Бөтеркә. 19 йөз. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее.

**ИЗҮ́**, күлмәкнең күкрәк уемы; төрле төстәге тасмалар һәм ука б-н бизәлгән хатын-кыз күкрәкчәсе. 18 йөз ахырына Казан татарларында, башка этник һәм терр. татар төркемнәреннән йөз елга диярлек элегрәк, бер төстәге буяуга манылган киндер һәм алача өйдә сугылган ак тукыманы кысрыклап чыгара. Бу исә татарларда бер үк вакытта эчке кием дә, күлмәк тә булып саналган хатын-кыз күлмәкләрен бизәүдә билгеле бер үзгәрешләргә китерә. Аерым алганда, традицион чигү урынына күлмәкнең күкрәк уемын тагын да ачыграк төсләр б-н калкурак итеп бизәкләр тегеп каймалау гамәлгә керә. Вакытлар узу б-н күкрәккә киелә торган бизәмә салынмалы мөстәкыйль бизәнү әйберенә әверелә. И.не, гадәттә, хатын-кызлар үзләре тегәләр. Уем рәвешен китерү өчен күкрәкчәнең үзеге буйлап тукымадан эшләнгән, еш кына ярымовал рәвешендә сырылган өслек тирәсенә ука, ефәк, атлас тасмалардан бала итәкләр бөреп тегелә. И.не кайчак көмеш тәңкәләрдән, нәфис калайдан эшләнгән бизәкләр дә тулыландыра. Кыйммәтле кул эшен бүләк итү, мәс., кәләшнең кайнанага туй бүләге рәвешендә И. бирү гадәте булган. 19 йөздә бәйрәмнәрдә кия торган хатын-кыз киемендәге бу затлы бизәнү әйбере иңсәле киемнәрдәге контраст фактуралар һәм төсләр ярашуын һәм үзенә бер төрле милли баш киемнәренең ансамбль тәңгәллегенә тәэмин итә. 20 йөзнең 1 нче чирегендә, татарларның гомумевропа стилендә киенүгә күчүе вакытында киң кулланыштан төшеп кала.

*Әд.:* З а в ь я л о в а М.К. Татарский костюм. К., 1996; М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; С у с л о в а С.В., М у х а м е д о в а Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000; С у с л о в а С.В. Одежда // Татары. М., 2001. *Ф.Ф.Гулова.*

**ИЗЮ́МОВ** Алексей Сергеевич (2.2.1895, Мәскәү — 9.4.1973, шунда ук), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТАССРның беренче азык-төлек халык комиссары (1920–21). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1940). 1910–12 елларда А.х. министрлыгының Җир төзелеше һәм җир эшләре баш идарәсендә эшли. 1912–17 дә Щукин мануфактурасы хезмәткәре, 1917–18 дә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларның Замоскворечье район советы азык-төлек бүлегендә. 1918–20 дә Казан һәм Вятка губерналарында азык-төлек комиссары. 1921 дән РСФСР Җир эшләре халык комис-тының тәэминат идарәсе башлыгы. 1922–25 тә «Всекомбанк» бүлекчәсенең идарә рәисе, 1926–29 да «Россельбанк» (Мәскәү) идарәсе әгъзасы, 1928–33 тә РСФСР Госторгы коллегиясенең һәм Сәүдә халык комис-тының идарә әгъзасы, 1933–37 дә А.х. культураларының тулай җыемы күләмен һәм уңышын билгеләү буенча үзәк дәүләт комиссиясе вәкиле. 1937–58 дә СССР А.х. министрлыгы каршындагы Бөртекле культураларның сортларын сынау дәүләт комиссиясендә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ИКЕ́ БАСУ́ АРТА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 329 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1909 дан), су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 329 дис. тәшкил итә. 1930 да «Биектау» к-зы оештырыла, 1958 дән «Дружба» к-зына, 1960 тан «Икшермә» с-зына, 1990 нан «Арташ» с-зына (1995 тән — күмәк пр-тие) керә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостена керә, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 14 ир-ат; 1859 да — 156, 1897 дә — 317, 1908 дә — 375, 1920 дә — 388, 1926 да — 688, 1938 дә — 407, 1949 да — 257, 1970 тә — 416, 1979 да — 365, 1989 да — 332, 2002 дә — 341 кеше.

*Әд.:* Ике Басу Арташ авылы // Г а р и п о в а Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. К., 2001. 1 т.

**ИКЕ́ ЙӨЗ КЫРЫГЫНЧЫ́ ЗАПА́С УКЧЫЛА́Р ПО́ЛКЫ**, Казан хәрби округында 1916 елда оештырыла; Казанда урнаша. 1917 нең 1 гыйнварына сугышчылары саны 7850 кеше тәшкил итә. 1917 елгы Февр. рев-ция се барышында полк ком-ты төзелә. Солдатлар Вакытлы хөкүмәткә каршы чыга, 10 апрельгә 1000 нән артык кеше частьтән рөхсәтсез чыгып китә. 20 майда бер төркем солдат Вакытлы хөкүмәт карары б-н чыгарылган «Азатлык заёмы»на каршы «Рабочий» г-тасында чыгыш ясый. Полк Вакытлы хөкүмәтнең оборона рухын көчәйтү һәм Россия союзникларының хәрби хәрәкәтләрне активлаштыру таләпләрен канәгатьләндерү максатындагы карары нәтиҗәсендә Россия армиясенең июньдәге һөҗүмнәре уңаеннан хөкүмәткә каршы демонстрациядә катнаша; хәрби диктатура урнаштыру максаты куйган Л.Г.Корнилов җитәкчелегендәге кораллы чыгышны гаепли. Октябрьдә большевикларга теләктәшлек белдерә; кораллы күтәрелеш вакытында полкта революцион штаб урнаша. Полк Казанда Совет хакимияте урнаштыруда катнаша. 1918 нең язында таратыла.

*Әд.:* Великая Октябрьская социалистическая революция: Энцикл. М., 1987.

**ИКЕ́ КАБЫРЧЫКЛЫ́ МОЛЛЮ́СКЛАР** (Bivalvia), кабырчыклы моллюсклар классы. 80 меңгә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә 50 гә якын (авыр ачыклanучы *бөрчеклеләр* — Pisididae семьялыгын исәпләмичә) төре яши. Иң күп таралганнары — *тешсез әкәм-төкәмнәр, дрейсеналар, перловицалар*, шаровиклар, бөрчеклеләр. Бу төркем моллюсклары өчен арка ягында кушылган ян кабырчыклы ике капкач, ш.у. баш һәм кыргычлы йоткылык редукциясе хас. Су мохитендә яши. Пластинкалы саңаклар пары (пластинкасаңаклылар — Lamellebranchia исеме шуннан) ярдәмендә сулыйлар. Суны йөзмә кисәкчәләрдән чистартуда актив катнашып, фильтрация ысулы б-н тукланалар. Эре И.к.м. — азык буларак, перловицалар һәм тешсез әкәм-төкәм кабырчыклары төймәләр җитештерүдә кулланыла.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**ИКЕКОЙРЫКЛЫЛА́Р** (Diplura), бөҗәкләр отряды. 300 дән артык төре билгеле, күпчелеге тропикларда һәм субтропикларда яши. Татарстан терр-ясендә бер төре киң таралган — камподеидлар семьялыгыннан (Campodeidae) гади И. (Campodea plusiochaeta). Сөтсыман ак яки саргылт төстә, кайвакыт көрән төстәге соңгы корсак сегментлары б-н каты хитинлашкан вак бөҗәк. 2–8 *мм* зурлыкта, канатсыз, кортсыман, сыгылмалы, корсак соңында озын оры (чыгынты) пары — церков бар. Кимерүче авыз аппараты булган йомры башлы, барлык аяклары да бертигез. Җиңеләйтелгән, тулы булмаган әверелеш кичерә. Кабыгын ювениль яшьтә генә түгел, җенси җитлегү хәлендә дә сала. Җирдә, урман түшәмәсендә, черегән агачта, ташлар астында яши. Таркалган үсемлек калдыклары, бөҗәкләр һ.б. туфрак хайваннары, гөмбә кисәкләре, споралар, сүүсемнәр б-н туклана; кайвакыт вак туфрак буынтыкаякларына һөҗүм итә.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1964. Т. 1.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ИКЕНЧЕ́ АЕРЫ́М ИДЕ́Л БУЕ́ ТАТА́Р УКЧЫЛАРЫ́ БРИГА́ДАСЫ**, Республика Революцион Хәрби Советының 1919 ел, 17 июнь боерыгы нигезендә Казан, Сембер,

Самара һәм Оренбург губерналарыннан чакырылган татарлардан оештырыла. Командирлары: Х.А.Мөхетдинов, Ә.В.*Алимбәков*, Г.Г.Рәҗәпов, А.Габидуллин, хәрби комиссарлары: Б.Д.*Белоусов*, Г.К.Әлмөхәммәтов, М.Ш.Ильясов. Өч укчы полктан һәм берничә ярдәмче бүлекчәдән тора. 1919 ның декабреннән — 2 нче Төркестан укчы дивизиясенең 2 нче Идел буе татар укчылары бригадасы, 1920 нең февраленнән — 2 нче Төркестан кызыл коммунарлар укчы дивизиясенең 3 нче (апрельдән — 6 нчы) Идел буе кызыл коммунарлар татар бригадасы, 1920 нең июленнән — 23 нче дивизиянең 68 нче татар укчы бригадасы (ноябрьдән — 3 нче дивизия, 1921 нең мартыннан — 4 нче армиянең 3 нче Казан укчы дивизиясе). Бригада 2 нче Төркестан кавалерия дивизиясенең Совет хакимиятенә каршы фетнәсен бастыруда, барон П.Н.Врангель армиясенә каршы һәм Кырымны азат итү өчен барган сугышларда, Красный Кут — Александров Гай, Александров Гай — Эмба тимер юл участокларын төзүдә катнаша.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ИКЕНЧЕ́ А́РМИЯ**, *Көнчыгыш фронт* составындагы гаскәри берләшмә. 1918 елның 20 июнендә оештырыла. Командирлары: В.В.Яковлев (К.Мячин), Ф.Е.Махин, А.И.Харченко, К.Н.Блохин, И.Ф.Максимов, В.И.Шорин. 1919 да И.а. Революцион хәрби советы әгъзаларының берсе М.Х.*Солтангалиев* була. Штаб башлыклары: Е.А.Кельчевский, Н.Г.Семёнов, Ф.М.Афанасьев, А.О.Зундблад, Дмитриев. И.а.гә керәләр: 1 нче Орёл пехота дивизиясе (1918 нең сентябре), 5 нче укчы дивизия (1919 ның апрель–июле), 7 нче укчы дивизия (1919 ның февраль-июне), 21 нче укчы дивизия (1919 ның гыйнвар-июле), 28 нче укчы дивизия (1918 нең сентябре — 1919 ның августы), Вятка махсус дивизиясе (1918 нең октябрь–декабре). 1918 нең июнь–июлендә Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ Халык армиясе частьләре б-н сугышлар вакытында И.а. Чулман һәм Агыйдел елгалары бассейннарында хәрәкәт итә, соңрак аның частьләре Арча, Минзәлә шәһәрләре, Вятка Аланы авылы тирәләренә чигенәләр. 1918 нең декабре — 1919 ның февралендә Көнчыгыш фронтның контрһөҗүме вакытында И.а. *Казанны азат итү операциясендә* һәм Ижевск-Воткинск операциясендә катнаша. 1918 нең декабре — 1919 февралендә адмирал А.В.Колчак сугышчыларының Пермь төркеменә каршы һәм Көнгер, Усы шәһәрләре тирәсендә сугышлар алып бара. 1919 ның март-маенда Нократ елгасына чигенә. Май аеннан И.а. Көнчыгыш фронтының контрһөҗүмнәрендә катнаша, июнь–июльдә Ижевск, Көнгер, Екатеринбург шәһәрләрен азат итә. 1919 ның апреленнән И.а. революцион хәрби советы сәяси бүлеге каршында милләтләр бүлекчәсе эшли (Алексеев, М.И.Зубков, А.Коричев, С.Русских, Г.Г.Ялымов), ул рус, татар, мари, удмурт һәм чуаш телләрендә «Кызыл сугышчы» г-тасы чыгара; сәяси хезмәткәрләр әзерләүче ике атналык мөселман агитатор-инструкторлык курслары эшли; армия татар драма труппасы (режиссёр Л.Аитов) кызылармиячеләр өчен спектакльләр һәм концертлар куя. 1919 ның 16 июлендә таратыла.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**«ИКЕНЧЕ́ БАКУ́»**, к. *Идел-Урал нефть-газ төбәге.*

**ИКЕНЧЕ́ БӨГЕЛДЕ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 2,5 *км* төньяктарак урнашкан. 2008 елда 109 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1906–11 дә нигез салына. Күмәкләштерү чорында И.Б.дә Молотов исем. (1957 дән — Пушкин исем.) к-з оештырыла, 1959 да 21 нче партсъезд исем. к-зга керә, 1998 дән — «Нур» а.х. товарлары җитештерүче кооператив. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1913 тә — 168, 1920 дә — 172, 1926 да — 209, 1938 дә — 185, 1949 да — 226, 1958 дә — 272, 1970 тә — 244, 1979 да — 155, 1989 да — 84, 2002 дә — 106 кеше.

**ИКЕНЧЕ́ КЛАСС МӘКТӘПЛӘ́Р**, чиркәү-приход мәктәпләре системасындагы тулы булмаган урта уку йортлары, 1895 елның 20 декабреннән Изге Синод каршындагы Укыту ком-ты карары буенча ачыла. Чиркәү мәктәпләре (икееллык гади мәктәпләр) укытучылары әзерләү өчен билгеләнәләр. Чиркәү-приход һәм земство башлангыч мәктәпләрен тәмамлаучылар кабул ителә. Алар өч ел укытыла.

Аз санлы укучыларга белем бирүче уку йортлары; һәрберсендә 10–15 укучы һәм 3 укытучы исәпләнә. И.к.м. б-н приход рухание җитәкчелек итә. 1902 гә кадәр аларның укытылырга тиешле фәннәр исемлеге һәм укыту программалары, төгәл хокукый статусы булмый. 1902 нең 1 апреле карары нигезендә Православие дине ведомствосындагы чиркәү мәктәпләренең укыту программалары раслана: гомуми белем бирүгә рус теле, Ватан тарихы, «табигать күренешләре хакындагы мәгълүматларга бәйле география», «геометрик сызым һәм рәсем» фәннәре кертелә. Дин Канунына (Закон Божий), борынгы славян теленә, чиркәүдә җырлауга зур игътибар бирелә. Махсус фәннәрдән дидактика укытыла, пед. практика уздырыла. Әҗнәби һәм катнаш И.к.м.ендә уку вакыты бер елга озайтыла.

20 йөз башында Россиядә 349 И.к.м. була. Хәзерге ТР терр-ясендә эшләгән И.к.м.: Лаеш өязендә — Бәтке (1897 дә ачыла), Дусмәттә рус-керәшен-удмурт (1896 да ачыла), Кощаково (1896 да ачыла, 1899 га кадәр *Кизик монастырендә* урнашкан була); Спас өязендә — кыз балалар өчен Надежда (Б.Полянки а., 1903 тә ачыла), Памфамировка (Бугровка а., 1900 дә ачыла); Чистай өязендә — Саурыш рус-чуаш (1896 да ачыла); Тәтеш өязендә — кыз балалар өчен Сумароков (1900 дә ачыла); Зөя өязендә — Тәмте (1896 да ачыла), кыз балалар өчен Юматов (1899 да ачыла); Сембер губернасының Буа өязендә — чуашлар өчен Хорновар Шигали (1898 дә ачыла). Гомуми һәм проф. әзерлек дәрәҗәсенең түбән булуы, укытучыларның куелган таләпләргә җавап бирмәве нәтиҗәсендә И.к.м. махсус пед. уку йорты статусын югалтып, гомуми белем бирүче тулы булмаган урта мәктәпләргә әвереләләр, шуларның берничәсендә генә крәстиян балалары укый алган. 1917 елга И.к.м.не Казан губернасында якынча 1,5 мең кеше тәмамлый, чама б-н шуларның яртысы укуларын - *Казан укытучылар семинариясендә, Порецкий укытучылар семинариясендә, Казан чиркәү-укытучылар мәктәбендә*, башкалары пед. юнәлештә булмаган уку йортларында — дини семинарияләрдә, техник уч-щеләрдә һ.б.да дәвам итәләр. Совет хакимиятенең беренче елларында И.к.м. 2 нче баскыч мәктәпләр итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Исторический очерк развития церковных школ за истёкшее двадцатипятилетие (1884–1909). СПб., 1910; З а х а р ь е в с к и й П.И. Церковные школы Казанской епархии за 25 лет их существования (1884–1909) // Известия по Казанской епархии. К., 1910.

*Е.В.Липаков.*

**ИКЕТЕЛЛЕ́ СҮЗЛЕКЛӘ́Р**, сүзләрнең яисә фразеологизмнарның мәгънәләре бер телдән икенче телгә тәрҗемә ителеп бирелгән сүзлекләр төре. Иң борынгы болгар-кыпчак, иске татар теле глоссарийлары, сүзлекләре кульязма хәлендә сакланган: «Китаб-е мәҗмуг тәрҗеман төрки вә араби» («Төрки һәм гарәп телләренә аңлатмалар җыелмасы», 13 йөз), «Китаб әл-идрак ли лисан әл-этрәк» («Төрки телләргә аңлатма китабы», 14 йөз), «Китаб әл-төхфәт әз-зәкийә фи-л-лөгати әт-төрки» («Төрки телләр турында зиһен китабы», 14 йөз), «Китаб-е бүлгәт әл-мөштакъ фи-л-лөгать әт-төрк вә-л-кыпчак» («Төрки һәм кыпчак телләрен белүне канәгатьләндерә торган китап», 14 йөз), 16 йөздәге гарәпчә-төркичә сүзлек һ.б. 17 йөздән русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзү эше активлаша: рус сәүдәгәрләре өчен русча-татарча сүзлек (17 йөз), М.Котельников, Ф.Попов сүзлекләре (18 йөз). Шуларның иң әһәмиятлесе — 1785 елда С.Хәлфин төзегән, 20 мең сүзне эченә алган 2 томлы сүзлек. Беренче басма И.с. 19 йөз башында барлыкка килә, алар — И.Гиганов (1804), И.Хәлфин (1822), А.Троянский (1833–35), С.Кукляшев (1859), Л.З.Будагов (1869), К.Насыйри (1878), А.Воскресенский (1894) сүзлекләре. 20 йөз башында үз заманы өчен әһәмиятле булган М.Юнысов (1900), Ш.Иманаев (1901), Н.Катанов (1912), С.Рахманкулов һәм Г.Кәрам (1911), И.Березин (1914) һ.б.ның сүзлекләре, ш.у. Т.Ильяси (1912) һәм Ә.Максудиның (1915) гарәпчә-татарча сүзлекләре басыла. 1920 еллардан башлап төрле гомумфилологик һәм махсус терминологик И.с. даими нәшер ителә. М.Корбангалиев, Р.Газизов, И.Кулиевның татарча-русча сүзлеге (1927), русча-татарча яңа сүзлек (1929), Г.Нугайбәк, Ф.Әмирханов, М.Корбанов, С.Фәйзуллинның русча-татарча сүзлеге (1938; 3 нче басма, 1941), Р.Газизов, Н.Исәнбәт, Г.Ишмөхәммәтовның татарча-русча сүзлеге (1950) һ.б. 4 томлы русча-татарча (1950–59), 1 томлы татарча-русча (1950; 4 нче басма, 1995), русча-татарча (1971; 3 нче басма, 1991; 2 томлы татарча-русча, 2007) сүзлекләр нәшер ите-

лә. Соңгы басмаларда сүзнең кулланылыш өлкәләрен һәм чикләрен (гади сөйләм, сөйләм теле, китап теле, искергән сүзләр һ.б.) билгели торган грамматик һәм стилистик аңлатмалар бирелә. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан уку-укыту И.с. нәшер итүгә зур игътибар бирелә: «Мәктәпләр өчен русча-татарча сүзлек» — «Школьный русско-татарский словарь», 1967 (М.Мәхмүтов), «Тематик русча-татарча сүзлек» — «Тематический русско-татарский словарь», 1989 (Ф.Сафиуллина һәм К.Галиуллин), «Тематик русча-татарча уку-укыту сүзлеге» — «Учебно-тематический русско-татарский словарь» (Л.Бәйрәмова), Ф.Ганиев мөхәррирлегендә «Татарча-русча уку-укыту сүзлеге» (1993) һ.б. 1990 елларда татарча-инглизчә (1994), татарча-төрекчә (1997), төрекчә-татарча (1998) сүзлекләр нәшер ителә.

*Әд.:* Н о г м а н М. 17–18 йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр. К., 1969; С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; М и ң н у л л и н К., В ә л и у л л и н Р. Татар теле сүзлекләрдә: Библиогр. күрсәткеч. К., 1998; Б а с к а к о в Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Х а к о в В.Х. Роль глоссарий в развитии лексических норм древне- и старотатарского литературного языка // Язык утилитарных и поэтических жанров памятников татарской письменности. К., 1990.

*В.Х.Хаков.*

**ИКЕТЕЛЛЕЛЕ́К** (билингвизм), билгеле бер социаль мохит эчендә аерым кешенең (кешеләр төркеменең) ике тел куллануы. И. берьяклы яисә икеяклы (паритетлы) була. Паритетлы И. хөкем сөргәндә билгеле бер терр-ядә яшәүче халыкларның күпчелек өлеше икетелле була. Берьяклы И. шартларында милли азчылык вәкилләре генә ике телне белә. Ике телнең берсенең кулланылу дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, И. актив һәм пассив төрләргә бүленә. Славян-төрки билингвизмының дәвамы булган рус-татар И.ге тарихның кайбер чорларында икеяклы да була. 1920–30 елларда эш кәгазьләрен татар телендә алып бару һәм дәүләт оешмаларында милли кадрлар санын арттыру максатында үткәрелгән киң кампания вакытында республика халкының татар булмаган шактый өлеше татар телен өйрәнә һәм куллана башлый. Әмма 1940 еллардан дәүләтнең мәдәни сәясәтендә рус теленә нигезләнгән берьяклы И.не кабул итәргә тырышу өстенлек ала. 1970 еллардан бу юнәлеш яңа тарихи бергәлек — бердәм совет халкы булдыру сәясәтенең бер өлешенә әверелә. 1990 еллардан, җәмгыять тормышы тамырдан үзгәртелә башлаган шартларда, милли телләрне торгызу һәм функциональ яктан үстерү, паритетлы И.не кертү эше башлана. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы ТР Законы (июль, 1992) нигезендә урта мәктәпләрдә һ.б. уку йортларында рус телле укучы яшьләргә татар телен укыту кертелә.

*Әд.:* Двуязычие: типология и функционирование. К., 1990; З а к и е в М.З., Б а й р а м о в а Л.К., Ю с у п о в Р.А. Двуязычие и гармонизация межнациональных отношений в Татарстане // Возрождение культуры России: язык и этнос. СПб., 1995; Б а й р а м о в а Л.К. Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. К., 2001.

*М.З.Зәкиев.*

**«ИКМӘ́К ӨЧЕ́Н»**, газета, к. «*Күмәк хуҗалык*».

**ИКМӘ́К ПЕШЕРҮ́ ҺӘМ МАКАРО́Н СӘНӘГАТЕ́**, төрле сорт икмәк, икмәк-күмәч, клиндер, сохари, макарон, кондитер әйберләре һ.б. продукция җитештерүче азык-төлек сәнәгате тармагы. 2008 ел башына ТРда 100 дән артык (Татпотребсоюз пекарняларын кертеп), ш.и. 35 эре һәм уртача зурлыктагы пр-тие, ш.у. 300 дән артык мини-пекарня исәпләнә; 10 меңнән артык кеше эшли. Аларның иң эреләре: «Чаллы икмәге», «Казанның 3 нче икмәк заводы», «Казанның 1 нче икмәк заводы», «Казан икмәк-клиндер комбинаты», «Күмәч-кондитер комбинаты» (Казан), «Әлмәт икмәк комбинаты», «Яшел Үзән икмәк комбинаты», «Алабуга азык-төлек комбинаты», «Чистай икмәк заводы», «Түбән Кама икмәк комбинаты», «Лениногорск икмәк заводы», «Зәй икмәк заводы» АҖләре. Тармак пр-тиеләренең күпчелеге универсаль эшчәнлек алып бара, төрле продукция җитештерә. Тармак өлешенә ТР азык-төлек сәнәгате җитештерүенең 10% ы, анда эшләүчеләрнең 28% ы туры килә.

17 йөздә Казан төбәгендә, икмәкне өйләрдә пешерү б-н бергә, зур булмаган махсуслашкан оешмалар барлыкка килә башлый. 1840 та Казанда 14 — күмәч, 4 — клиндер, 7 кондитер әйберләр җитештерүче оешма исәпләнә. 1858 дә шәһәрдәге 34 оешмада 157 кеше эшли, 72 мең сумлык продукция чыгарыла. Казанда беренче өлешчә механикалаштырылган макарон ф-касына 1858 дә сәүдәгәр В.Я.Устинов варислары тарафыннан нигез салына (соңыннан аның хуҗасы Е.В.Вараксина була, 1905–14 тә анда 50 ләп кеше эшли; елга 35 мең сумлык макарон һәм вермишель җитештерелә). 1920 дә фабрика национализацияләнә һәм дәүләт пр-тиесе итеп үзгәртелә, бу вакытта ул тәүлеккә 2,7 *т* продукция эшләп чыгара. Икмәк пекарнялары башка шәһәрләрдә һәм зур авылларда да барлыкка килә. Мәс., Чистай шәһәрендә 25 пекарня һәм 1 прәннек пешерү оешмасы булып, аларда җәмгысе 211 кеше эшли. Казан губернасында икмәк пешерү сәнәгатьнең иң артта калган тармакларының берсе була.


Сәнәгый рәвештә икмәк пешерү 1929 дан, Казанда тәүлеккә 30 *т* продукция чыгару куәтенә ия булган беренче икмәк з-ды сафка басканнан соң башлангыч ала. 1931 дә Татарстан икмәк пешерү сәнәгатенең республика сәнәгый тресты (Татпромхлебтрест) оештырыла, аның составына еллык җитештерү күләме 14 мең *т* тәшкил иткән 13 пр-тие керә. 1930 елларда тәүлеккә җәмгысе 315 *т* продукция җитештерү куәтенә ия 6 икмәк з-ды төзелә һәм файдалануга тапшырыла. 1931 дә *Казан макарон фабрикасы* оештырыла, ул елга 14 мең *т* чамасы продукция чыгара. Шулай ук Бөгелмә, Буа, Алабуга, Яшел Үзән, Мамадыш, Чаллы, Спас, Тәтеш, Чистай шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Арча, Васильево, Кукмара, Спас затоны, Юдино посёлокларында, Бондюг посёлогында, Кама Тамагы, Сөйке (Кама Тамагы р-ны), Шәмәрдән (Саба р-ны), Шөгер һ.б. авылларда өлешчә яки тулысынча механикалаштырылган пекарнялар төзелә һәм сафка баса; кулланучылар кооперациясе системасында да 162 пекарня эшли (1935), алар ш.у. сәнәгать, транспорт һ.б. оешмаларның тәэминат бүлекләрендә дә оештырыла. Республикада продукция җитештерү үсә бара. 1940 та икмәк һәм икмәк-күмәч 294 мең *т*, макарон 4,5 мең *т* эшләп чыгарыла.

1950 елларда Казан, Бөгелмә, Әлмәт (2 з-д), Минзәлә, Чаллы, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Зәй, Баулы, Васильево (Яшел Үзән р-ны), Актүбә (Азнакай р-ны), Нурлат посёлокларында яңа икмәк з-длары файдалануга тапшырыла. 1955–59 да продукциянең сыйфатын яхшырту һәм төрләрен арттыру (40 лап исемдә) буенча зур эш башкарыла. Бу вакытта сатуга, башлыча, арыш һәм арыш-бодай оныннан пешерелгән икмәк, төрле күмәчләр чыгарыла. 26 икмәк з-дының 17 сендә пар казаннары эшли, 9 ы газлаштырыла; ш.у. продукция Татпотребсоюз системасындагы 168 пекарняда җитештерелә. 1959 да тармакта тәүлеклек гомуми җитештерү 677 *т* дан 1235 *т* га кадәр үсә (ш.и. 137 *т* яңа төзелгән пр-тиеләргә карый). 1960 елларда тәүлеккә 132 *т* продукция чыгаруга сәләтле яңа пр-тиеләр: Казанның 7 нче, Яшел Үзәннең 2 нче, Алабуга, Лениногорск, Түбән Кама икмәк з-длары сафка баса, Чистай шәһәрендә, Карабаш (Бөгелмә р-ны), Сүбәләк (Чаллы р-ны) авылларында механикалаштырылган пекарнялар, Әлмәт макарон ф-касы (1964–2005 елларда эшли, елга 7 мең *т* дан күбрәк күләмдә 14 төрдә әйберләр җитештерә) ачыла. Нәтиҗәдә тармак пр-тиеләренең гомуми тәүлеклек җитештерүчәнлеге 1602 *т* га җитә (1967). 1970 тә икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре 415,7 мең *т* (1960 тагы күрсәткечтән 46% ка күбрәк), макарон эшләнмәләр — 16,6 мең *т*, кондитер әйберләре 1,5 мең *т* җитештерелә.

1972 дә Түбән Кама шәһәрендә 2 нче икмәк з-ды файдалануга тапшырыла; алар берләшкәннән соң, Түбән Кама икмәк комб-ты барлыкка килә. Әлмәт икмәк з-дында тәүлеккә 40 *т* күмәч-кондитер әйберләре (60 исемдә) чыгаруга сәләтле яңа цех эшли башлый. Чаллы шәһәрендә тәүлеклек җитештерү куәте 140 *т* булган икмәк-күмәч әйберләр пешерүче икенче з-ды сафка баса; 1974 тә Чаллыдагы ике икмәк з-ды берләшү нәтиҗәсендә Чаллы икмәк комб-ты хасил була. 1979 да аның составына 1978 дә оештырылган һәм тәүлеккә 87 *т* күмәч һәм 3 *т* кондитер әйберләре җитештерүгә сәләтле Икмәк — кондитер комб-ты кушыла (1993 тә «Чаллы икмәге» АҖ итеп үзгәртелә). Бу елларда тармак пр-тиеләре тарафыннан 400 исемдә ш.и. 40 исемдә икмәк-күмәч һәм кондитер әйберләренең яңа төрләре эшләп чыгарыла, 1980 дә җитештерелгән бу ризыкларның гомуми күләме 504,2 мең *т* һәм 42,6 мең *т* га җитә.

1980 елларда тәүлеккә 70 *т* продукция җитештерүгә исәпләнгән Чехиядә эшләнгән җиһазлар урнаштырылган Күмәч-кондитер комбинаты (Казан), Чистай (65 *т*), Минзәлә (30 *т*), Менделеев (30 *т*), Азнакайның 3 нче (28 *т*) икмәк з-длары файдалануга тапшыры-


1


2


3


4

**Икона мәкаләсенә.** 1. Смоленск Седмиозёр Мәрьям Ана иконасы образы; 2. Смоленск Седмиозёр Мәрьям Ана иконасы. 15 йөз. Казандагы Петропавел соборы. 3. Грузия Мәрьям Ана иконасы образы; 4. Грузия Мәрьям Ана иконасы. 17 йөз. Раифа Богородица пустыне Грузия соборы.

ла. 1985 тә икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре җитештерү 510 мең *т* га җитә. 1990 да икмәк һәм икмәк-күмәч ризыклары 482 мең *т*, макарон 24,4 мең *т*, кондитер әйберләре 66,6 мең *т* җитештерелә. 2000 дә бу саннар нибары 263,9 һәм 33,6 мең *т* тәшкил итә. 1990 елларның 2 нче яртысында күп кенә пр-тиеләр АҖләргә әверелә, хосусый мини-пекарнялар барлыкка килә. 2000 елларда диверсификация процессы һәм технологияне камилләштерү нәтиҗәсендә пр-тиеләрдә икмәкнең һәм икмәк-күмәч әйберләренең, макарон һәм кондитер ризыкларының яңа сортлары, икмәк квасы, коймак оны һ.б. җитештерелә башлый; продукциянең сыйфаты, төргәкләү дизайны яхшыра. Базар мөнәсәбәтләренә күчү б-н фирма сәүдә челтәре оештырыла, ш.у. башка эре сәүдә оешмалары аша продукция сату җайга салына, нәтиҗәдә товар әйләнеше шактый арта. 2008 елда Чаллы шәһәрендә Германиядә эшләнгән җиһазлар куелган һәм тәүлеккә 40 *т* продукция җитештерүгә сәләтле «Колобок» ҖЧҖ икмәк комб-ты файдалануга тапшырыла.

1996–2000 елларда тармак пр-тиеләрен чит илләрдә җитештерелгән җиһазлар кулланып, югары инновацион дәрәҗәдә үзгәртеп кору киң колач ала. Тармак пр-тиеләрендә чималның, ярымфабрикатларның һәм әзер продукциянең күләмен һәм сыйфатын контрольдә тотучы компьютерлаштырылган системалар, продукциянең сыйфатын һәм зарарсызлыгын тәэмин итүче халыкара ИСО — 9001–2000 һәм ХАССП системалары гамәлгә кертелә, И.п.һ.м.с.нең 2006–10 елларга исәпләнгән үсеш программасы тормышка ашырыла.

Тармакка онның 90% тан күбрәк өлешен җирле җитештерүчеләр — «Алтын башак» холдинг компаниясе, «Чаллы икмәк продуктлары комбинаты», «Печище икмәк продуктлары комбинаты», «Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» АҖләре җибәрә. Онның калган өлеше Волгоград, Омск, Оренбург өлкәләреннән, Башкортстан Респ-касыннан кертелгән бодайдан тартыла һәм икмәк-күмәчнең һәм макаронның сыйфатын яхшырту өчен кулланыла. 1970–90 елларда чималның 75%ы чамасын Краснодар, Ставрополь крайларыннан, Ростов өлкәсеннән, ш.у. Австралиядән, Аргентина, Канада, АКШ, Франциядән китерелгән бодайдан тартылган он тәшкил итә.

2003 тә РФдә беренче тапкыр «Чаллы икмәге» АҖндә «басу-завод-сәүдә» йомык циклы булдырыла: ашлык җәмгыятьнең үз агрофирмасы кырларында үстерелә, пр-тие тегермәннәрендә онга тартыла.

Продукциянең сыйфатын күтәрү максатында тармак пр-тиеләре РФ Дәүләт икмәк пешерү фәнни-тикшерену ин-ты (Мәскәү), РФ Икмәк пешерүчеләр берлеге, Татарстан ФА, ш.у. кайбер чит ил компанияләре б-н партнёрлык элемтәләре җәелдерә. Алар ярдәме б-н яңа технологияләр, продукциянең яңа төрләрен чыгару үзләштерелә.

2008 дә тармак пр-тиеләре тарафыннан 400 дән артык исемдә төрле эшләнмәләр: 220,4 мең *т* — икмәк һәм икмәк-күмәч, 4,4 мең *т* — макарон, 44 мең *т* кондитер ризыклары җитештерелә.

1998–2009 дә Татарстанның И.п.һ.м.с. продукциясе халыкара һәм Бөтенроссия конкурсларында югары бүләкләргә лаек була.

«Россиянең 100 иң яхшы товары» Бөтенсоюз конкурсында Татарстанда җитештерелгән ризыкларның 20 дән артык төре иң яхшы товарлар дип таныла һәм алтын медальләргә лаек була.

Продукция, нигездә, җирле сату челтәренә, шулай ук РФнең 15 регионына, БДБ илләренә (Казакъстан, Украина) һәм ерак чит илләргә (Израиль, Канада, АКШ) дә чыгарыла.

Әлеге тармакта эшләү өчен югары белемле белгечләрне Казан технол. ун-ты, Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-ты (Казан); эшче кадрларны Казандагы 136 нчы һөнәри лицей әзерли.

*Әд.:* Хлеб Татарстана. К., 2001; М а т в е е в а И.В. Хлебопекарная промышленность сегодня: меняются ли приоритеты // Хлебопродукты. 2007. № 10. *М.Я.Гаитов.*

**ИКО́НА** (грек. eikēn — сурәт, образ), православие һәм католиклар динендә Гайсә, Мәрьям Ана һәм изгеләрнең илаһи мәгънә салынган сурәтләре. Христианнарда (православиедә һәм католикларда) И. гыйбадәтханәләрдә һәм дингә инанучыларның яшәү урыннарында булырга тиешле төп әйбер санала. Христианнар И. алдында аңа түгел, Илаһка, изгеләргә табыналар. И.лар Изге Синод яки Поместный соборлар раслаган тасвирламага туры китереп язылалар. Могҗиза тудыручы И.лар китереп чыгарган гаҗәеп хәлләр Илаһның шәфкать иясе булуын исбатлый, дип исәплиләр. Рәсми рәвештә булмаса да, күп кенә И.лар халык арасында могҗиза тудыручылардан санала (20 йөз башында Казан губернасында гына да аларның саны 30 дан артып китә, Казан епархиясендә алар хәзер дә бар). Чиркәү тарафыннан рәсми рәвештә могҗиза тудыручылар дип танылган И.лар календарьларга кертелә, алар хөрмәтенә гыйбадәт кылулар оештырыла, храмнарга исемнәре бирелә, дингә инанучылар арасында таратылачак күчермәләре алына. Россиядә иң хөрмәт ителгән И.лар исәбенә *Казан Мәрьям Ана иконасы* да керә. Татарстанда иң танылган И.лар: Казанны һәм Зөяне үләт кизүләреннән коткарып калучы буларак 1650 елларда шөһрәт казанган, 1650 елда язылган (яңа стиль б-н 4 сентябрьдә бәйрәм ителә) Грузия Мәрьям Ана И.сы (Раифа *Богородица пустынендә* саклана), 15 йөздә Великий Устюг шәһәрендә иҗат ителгән, Октябрь рев-циясенә кадәр Седмиозёр пустынена куелган, хәзер Казандагы Петропавел соборында саклanучы Смоленск Седмиозёр Мәрьям Ана И.сы (яңа стиль б-н 9 июльдә, 10 августта, 26 октябрьдә бәйрәм ителә).


*Әд.:* Сказание о Седмиозёрной Богородицкой пустыни и Чудотворной иконе Божия Матери Смоленския. К., 1893; Б у с л а е в Ф. О русской иконе. Общие понятия о русской иконописи. М., 1997; Шедевры русской иконописи. М., 1999; И по плодам узнаётся древо. Русская иконопись XV–XIX веков. Из собрания Виктора Бондаренко. М., 2003.

**ИКО́ННИКОВ** Павел Софронович (11.1.1879, Чита ш. — 1.1.1915, Петроград), хирург, мед. д-ры (1906), коллегия асессоры (1908). 1903 елда Хәрби мед. академиясен (С.-Петербург) тәмамлагач, Мәскәү клиник госпиталендә эшли; сайлаган белгечлегендә камилләшү өчен Европа клиникаларына җибәрелә. 1914 елдан Казан ун-ты клиникасында, госпиталь хирургиясе кафедрасының

экстраординар профессоры. Хезмәтләре холецистит вакытында үт куыгының ялкынсыну авыруларын өйрәнү мәсьәләләренә карый. Рус-япон сугышында (1904–05) катнаша. 3 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены, медаль б-н бүләкләнә. 1908 дә, коллегия асессоры итеп, титуляр советник дәрәҗәсендә раслана.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета, 1905–1917. К., 1986.

**ИКОНОСТА́С** (*икона* һәм грек. stásis — тору урыны), православие чиркәвендә алтарьны (чиркәүнең төп, көнчыгыш өлешен) интерьерның төп өлешләреннән аерып торган, билгеле бер тәртиптә иконалар куелган урын. Борынгы рус И.ның композициясе тулысынча диярлек 14–15 йөзләрдә төзелеп бетә: иконалар катгый иерархик эзлеклелектә бизәкле балкаларга урнаштырыла. Астагы рәткә, тәре урнаштырылган урта ишекнең як-ягына җирле хөрмәт ителүче һәм чиркәү иконалары куела; югарырак Гайсәгә, бәйрәмнәргә, пәйгамбәрләргә, ыруг аталарына багышланган һәм тәрегә кадакланган Гайсә сыны б-н тәмамланган иконалар беркетелә. И.ның 3 ишеге була: «патша капкасы» (тәре урнаштырылган үзәк ишек), төньяк һәм көньяк капкалар (дьякон ишекләре). «Патша капкасы»ның йөзлегенә — Изге хәбәр, түбәнгәрәк — евангелистлар сурәте куела; кайвакыт литургиягә нигез салган изге Бөек Василий һәм Иоанн Златоуст иконалары куела. И. Изге тарихтагы төп вакыйгаларны күзаллау һәм ике дөньяны — җир һәм күкләрне берләштерү идеясен гәүдәләндерү өчен хезмәт итә. Татарстанда иң борынгылардан борыслы И.лар санала. 16 йөзнең икенче яртысында Зөя храмнарында: Троица чиркәвендә 4 яруслы бүрәнә И. һәм Успение монастыреның Успение соборындагы 5 ярусл И. бар (17–18 йөзнең беренче яртысында беркадәр үзгәртелгән хәлендә саклаалар; иконалар ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмасына куелалар). 16 йөзнең 2 яртысына караган Казан храмнарыннан Благовещение соборы, Спас Нерукотворный чиркәве һ.б. «патша төзелешләренең» (Явыз Иван) И.лары турында күзаллаулар Н.В.Борисов һәм Д.А.Кикинның теркәү китабында бирелә (1567). Кагыйдә буларак, И. чиркәүне төзегән артель тарафыннан ук корыла. 17–18 йөзләрдә И.ларга яңа чиннар: газап чигүчеләр, апостоллар, ыруг аталары һ.б. кертелә. Борыслар һәм тәрәкләрне алтынланган сыр, басма, төймә б-н бизиләр. Барокко стиленең күренекле ядкәре булып Казандагы Петропавел соборының 1723–26 елларда бизәк төшерүче Гусев җитәкчелегендәге Казан осталары тарафыннан эшләнгән 7 ярусл И. санала (иконалар 1824–25 тә С.Турин, 1864–65 тә — Н.А.Мензитов тарафыннан яңартыла, И. үзе 1864–65 тә оста М.А.Тюфилин тарафыннан реконструкцияләнә). 18–19 йөзләрдә эре монастырь соборлары һәм приход чиркәүләренең И.лары әлеге чиркәүне төзегән архитекторларның проектлары буенча иҗат ителгән: Ф.Е.Емельянов проекты буенча Казан Богородица монастыре храмы И., П.Г.Пятницкий проекты буенча Казан ун-тының Крестовоздвиженский чиркәве И. һ.б. корыла. 19 йөздә барокко, классицизм, ампир, рус-византия стиле, эклектика, псевдоготика һ.б. йогынтысында И.ның традицион формалары үзгәрә. И.лар храмнарның үзәк монументаль-бизәү җиһазы булып әверелгәннән соң, катлаулы, колачлы-конструктив чишелешләргә ия була баралар (челтәрле колонналар һәм кабарынкы пилястралар, профильләштерелгән һәм ныгытылган ниргәләр һәм кәрнизләр, баш киеме формасында очланган фронтоннар һ.б.). Халык мәгарифе министры А.Н.Голицынның өй чиркәве җиһазларын кабатлаучы Казан ун-тының Крестовоздвиженский чиркәвендәге И. гайре табигый формага ия була (рәссам В.Чухломинның нәкышь б-н бизәлгән, үсемлекләр б-н үрелгән латин тәресе рәвешендәге иконалары). Казандагы бик күп чиркәүләрнең: Кизик монастыреның Георгий, Духосошествие, Введение чиркәүләре, Никола-Вишняковский, Михаил Архангел һ.б. чиркәүләрнең И.лары оста итеп эшләнгән бизәкләр, күп декора-



**Иконостас мәкаләсенә.** 1. Казандагы Петропавел соборы иконостасы. 1723-26. 1864-65 елларда М.А.Тюфилин тарафыннан реконструкцияләнә; 2. Казандагы Ярославль могҗизачылары чиркәве иконостасы; 3. Яшел Үзән районы Гәр авылындагы Петропавел чиркәве иконостасы. 1830 еллар; 4. Питрәч районы Аркатау авылындагы Смоленск-Богородица чиркәве иконостасы (бер өлеше); 5. Казан Богородица иске дин тарафдарлары чиркәве иконостасы.



Зөя авылындагы Троица чиркәве иконостасы. 17 йөз башы.

тив детальләр б-н аерылып торган. 19 йөздә Казанда берничә И. ясау остаханәләре эшли. М.А.Тюфилин, И.А.Фешин, С.Я.Спиридонов һ.б. тоткан остаханәләрдә иҗат ителгән И.лар Казан епархиясендәге барлык храмнар өчен махсус әзерләнә. Арада иң зур остаханә Тюфилинныкы була. Анда Казан һәм Казан губернасы б-н бергә Вятка һәм Түбән Новгород губерналарындагы, Арзамас, Муром шәһәрләрендәге чиркәүләр өчен дә заказлар алына. «Рәсемнәрнең матурлыгы, җиренә җиткереп башкарылуы, агачка төшерелгән бизәкләрнең гаҗәеп камиллеге, рус бизәкләренең асылын һәм иконостас эшләнмәләргә алтын йөгертүнең ныклыгын күрсәткәне өчен» остаханә Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсе тарафыннан мактаулы бәя ала (1890). Остаханә хуҗасы М.А.Тюфилинның улы А.М.Тюфилин («М.А.Тюфилинның иконостаслар ясау остаханәсендә рәсемнәр төзегәне һәм аның эшенә күзәтчелек иткәне өчен») һәм И.А.Фешин остаханәсе («агачка оста итеп уеп бизәкләр төшергәне, рәсемнәрнең төрлелеге, остаханәдә эшнең дөрес куелышы өчен») ш.у. күргәзмәнең зур көмеш медале б-н бүләкләнә. Беренче рәсемнәрен бирегә ясый башлаган күренекле рәссам Н.И.Фешинның иҗади таланты да нәкъ менә әтисенең остаханәсендә ачыла. 20 йөзнең 1 нче чирегендә, чиркәүләр күпләп ябыла башлагач, И.ларның байтагы юкка чыга. И.лар 19 йөздә Казан Богородица чиркәвендә (Казандагы Царицын бистәсе), Смоленск-Богородица (Питрәч р-ны Аркатау а.), Казан-Богородица (Буа р-ны Зур Фролов а.), Спас-Преображенье (Лаеш р-ны Зур Кабан а.), Иоанн-Предтеча (Алабуга р-ны Костенеево а.), Петропавел (Яшел Үзән р-ны Гәр а.) һәм кайбер башка чиркәүләрдә сакланып кала. ТР терр-ясендә православие чиркәүләрен торгызу һәм төзү эшләре башлангач, 1980 ахыры — 1990 башында иконостаслар ясау эше яңара (традицион борынгы рус формаларын кабатлаучы Казан Богородица иске дин тарафдарлары чиркәве И.ы, Казандагы Богоявление, Пятницкий, Иоанн Кронштадский чиркәүләре, Чистайдагы Никола соборы, Алабугадагы Покров чиркәве, Чаллыдагы Вознесение һәм Козьмодемьянский чиркәүләре, Богородица пустынендагыТроица һәм Грузин соборларындагы И.лар).

*Әд.:* Казанская научно-промышленная выставка 1890 г. Список наград, присуждённых на Казанской научно-промышленной выставке 1890 г. К., 1890. *Е.П.Ключевская.*

**ИКСА́НОВА** (Гарипова) Илсөяр Вазыйх кызы (7.2.1966, Лаеш р-ны Татар Сараланы а.), шагыйрә. Казан ун-тын тәмамлый (1988). «Яшь ленинчы» (1989–91), «Шәһри Казан» (1991–97) г-талары, «Ялкын» ж-лы редакцияләрендә эшли. 1999–2003 елларда «Салават күпере», 2003 тән «Сөембикә» ж-лларында бүлек мөхәррире. «Ышанасы килә» (1990), «Кышкы канәферләр» (2000), «Син язган язмышым» (2000), «Кырык кыл» (2008) исемле шигъри җыентыклар авторы. И.ның шигырьләрендә лиризм, хатын-кызның бай күңел дөньясын нечкә тоемлау өстенлек итә.

**ИКСУА́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 6 кеше (татарлар) яши. 1925 тә нигез салына. Башта Иске Йорт дип атала. ТАССРның Арча кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1949 да — 108, 1958 дә — 112, 1970 тә — 67, 1979 да — 14, 1989 да — 2, 2002 дә — 4 кеше.

**«ИКЪТИСА́Д»**, айлык икътисади журнал. 1908 елның 15 сентябреннән 1913 нең июненә кадәр Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 55 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Ф.Ш.*Мортазин.* Иң актив авторлар арасында — Ә.Әһлиуллин, М.Алишев, А.Бикмиев, И.Дибирдиев, М.Исхаков, Ф.Кәримов, Х.Латыйфи, Г.Рәхмәтуллин, Ф.Фәхри, Г.Хисамов, С.Чәләби, М.Шиһабзадә һ.б. Редакция Идел буе һәм Урал



«Икътисад» журналы.

яны төбәкләрендә яшәүче татарларның икътисади һәм иҗтимагый-сәяси хәлләрен яктыртуны максат итеп куя. «И.» — ил һәм дөнья икътисадына махсус багышлап татар телендә чыгарылган беренче журнал. Журналның тематикасы киң: а.х.на, җир эшкәртү, сәүдә, сәнәгать, ш.у. дин, мәгариф, медицина һ.б. темаларга багышланган мәкаләләр басыла. Акча җитмәү сәбәпле чыгудан туктый.

*Әд.:* Тәрҗеманов Ф. Самарада татар басмалары: «Икътисад» журналы // Бердәмлек. 1991. 21–27 гыйнв.; Хисмәтова Г. «Икътисад» журналының фәнни-библиографик күрсәткече: 1908–1913 еллар // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 1/2; Мәрдиева М. «Милләт малына сарыфта икътисад юлына күрсәтмәк...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 2; Нафигов Р.И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. К., 1964; Газизуллин Ф. Дорогой к правде (Социально-экономические интересы классов и татарская экономическая литература: (1880–1917 гг.). К., 1979. *А.Ә.Хәсәвнех.*

**ИКЪТИСА́Д, ИДАРӘ́ ИТҮ́ ҺӘМ ХОКУ́К ИНСТИТУТЫ́ (ИИХИ)**, дәүләт карамагында булмаган югары уку йорты. 1994 елда Казанда ачыла, дәүләт аккредитациясен 2000 елда ала. Факультетлары: икътисад, юридик, менеджмент һәм маркетинг, психология, гуманитар, өстәмә белем бирү. Укыту финанс һәм кредит, бухгалтерлык исәп-хисабы, анализ һәм аудит, салым һәм салым салу, дәүләт һәм муниципаль идарәчелеге, хокук фәннәре, маркетинг, информатика, оештыру менеджменты, җәмәгать туклануы продуктлары технологиясе, психология, педагогика һәм психология, нәшрият эше белгечлекләре буенча алып барыла. Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә филиаллары, Тәтеш, Яңа Чабаксар (Чуаш Респ-касы), Чистай шәһәрләрендә вәкиллекләре эшли. 2007 елга көндезге бүлектә якынча 3 мең студент, читтән торып уку бүлекләрендә якынча 5 мең, филиаллары һәм вәкиллекләрендә 10 мең чамасы студент укый. Өстәмә белем бирү факультеты төбәкләрдә белем бирү һәм консалтинг үзәген, һөнәри бәяләү үзәкләрен, эшсез калган гражданнарны һәм запастагы хәрби хезмәткәрләрне яңадан һөнәри әзерләүне һ.б. курс һәм семинарларны үз эченә ала. Аларда һәр елны якынча 1,5 мең кеше укый. Институт каршында икътисад-хокук көллияте — урта һөнәри уку йорты (белгечлекләре: икътисад һәм бухгалтерлык исәп-хисабы, хокук фәннәре, маркетинг, кунакханә сервисы), Казан мәктәпләре һәм лицейларында махсуслаштырылган класслар эшли. Укытучылар коллективында якынча 130 кеше эшли, күпчелеге гыйльми дәрәҗәгә ия, ш.и. 28 фәннәр д-ры бар. Институтта базар икътисадының һәм хокукый дәүләтнең яшәү механизмы мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла. Аспирантура эшли. Укыту һәм матди-техник базасы китапханәне (якынча 200 мең саклау берәмлеге), аудио- һәм видеотека, «Тәгълимат» нәшрияты, типография һ.б.ны үз эченә ала. Институтка нигез салучы һәм ректоры — В.Г.Тимирясов. *Ф.С.Зыятдинов.*

**ИКЪТИСАДИ́ АКТИ́В ХАЛЫ́К**, халыкның товар җитештерү максатында һәм хезмәт күрсәтү өчен үз хезмәтен тәкъдим итүче өлеше. Икътисадта мәшгульләр һәм эшсезләр җыелмасы б-н билгеләнә (к. *Эшсезлек*).

ТРда 2008 елда И.а.х. 1974,9 мең кеше исәпләнә (15–72 яшьтәге халык санының 67,4%). И.а.х. арасында ир-атлар һәм хатын-кызлар саны якынча тигез (тиңдәшле рәвештә 50,3 һәм 49,7%). Аеруча югары икътисади активлык дәрәҗәсе (И.а.х. — 51,9%) 30–49 яшьтәгеләргә туры килә, И.а.х.ның уртача яше — 38,8 яшь. 1990 еллар башы б-н чагыштырганда түбәнрәк яшь төркемнәрендә икътисади активлык дәрәҗәсенең кимүе, өлкәнрәкләрдә үсүе (эшләүче пенсионерлар) күзәтелә. Югары проф. белемле кешеләр — 24,6% (1992 дә 13,2%), урта һәм башлангыч проф. белемлеләр 43,3% (1992 дә 27,3%). И.а.х.ның 91,8% ын икътисадта мәшгуль кешеләр тәшкил итә. Халыкның әлеге категориясе, җитештерүнең кискен түбәнәюе сәбәпле, 1990 еллар ахырында кими (1999 да 89,5%). 2008 дә икътисадта мәшгульләрнең 28,7%ы дәүләт яки муниципаль оешмаларда (2000 дә 42,2%), 56,5% шәхси секторда (2000 дә 30,8%) эшли. Икътисади эшчәнлек төре буенча: табу һәм эшкәртү производствосында эшләүчеләр 23,1%, мәгариф һәм сәламәтлек саклау системасында — 19,5%, күпләп һәм ваклап сатуда,

автотранспорт чараларын һәм көнкүреш техникасын ремонтлауда — 16,4%, төзелештә — 9,9%, авыл һәм урман хуҗалыкларында — 8,8%, транспорт һәм элемтә системасында — 7,1%. 2008 дә эшсезләр саны 96,1 мең кеше тәшкил итә (2000 дә 147,7 мең кеше), ш.и. мәшгульлек хезмәтендә рәсми статуска ия 25,5 мең кеше (2000 дә 19,6 мең кеше). И.а.х. саны һәм хезмәт активлыгы күрсәткечләре икътисади үсешне фаразлау һәм планлаштыру, ш.у. *хезмәт ресурсларыннан* тулырак һәм рациональрәк файдалану чараларын эшләү өчен зур әһәмияткә ия.

*Ф.Г.Борһанов.*

**ИКЪТИСА́НОВ** Валерий Әсгат улы (8.6.1966, Әлмәт ш.), нефтьче, техн. фән. д-ры (2002). 1988 елда Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң шунда ук эшли. 1992–93 тә «Техсервиснефть» Россия-Британия уртак пр-тиесендә әйдәп баручы белгеч (Мәскәү). 1993–98 дә Әлмәт нефть ин-тында; 1998 дән «ТатНИПИнефть» ин-тында (Бөгелмә ш.) скважиналарны гидродинамик тикшеренү лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре нефть чыганакларын эксплуатацияләүгә карый. И. углеводородлар чыгарганда газ-сыеклык катнашмаларының хәрәкәтен исәпләү алымнарын тәкъдим итә; нәсызыкча үзлеккә ия булган эластик изотроп материаллар өчен реологик модель эшли, сыеклыкны релаксацион фильтрлау нигезләрен булдыра, катлаулы архитектуралы скважиналар өчен фильтрлау процессларын модельли. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Определение фильтрационных параметров пластов и реологических свойств дисперсных систем при разработке нефтяных месторождений. М., 2001; Гидродинамические исследования и моделирование многоствольных горизонтальных скважин. К., 2007.

**ИЛ**, борынгы дәвердә һәм урта гасырларда төрки халыкларда 1) мәмләкәт, дәүләтнең, кабиләләр берләшмәсенең, халыкның атамасы; 2) ватан, туган җир.

**«ИЛ»**, иҗтимагый-сәяси газета, 1913 елның 22 октябреннән Петербургта, 1914 нең ноябреннән 1918 нең апреленә кадәр Мәскәүдә татар телендә атнага 3 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 292 саны чыга. Өстәмә исеме — «Көнкүреш мәсьәләләренә караган төрки-татар газетасы». Нашире — Г.*Исхакый*, мөхәррирләре — Г.Исхакый һәм М.А.Мәүләмбердиев (Н.*Гасрый*). Исеме үзгәрә: 1915 нең декабреннән 1916 ның июненә кадәр — «Сүз», 1916 ның 10 ноябреннән 1918 нең апреленә кадәр — «Безнең ил». Газетада Г.Абизов, Ш.Алкин, М.Акчурина, З.Вәлиди, Г.Дивишев, Н.Думави, Г.Кариев, Г.Кәримов, М.Максудова, К.Мустакаев, Ш.Мөхәммәдъяров, К.Сәгыйд, А.Сартанова, С.Сүнчәләй, Ф.Туктаров, М.Фуад, М.Хәлили, С.Якупова һ.б.ның мәкаләләре басыла. Редакция төрки-татар халкының мәдәни дәрәҗәсен һәм милли үзаңын күтәрү, Россия мөселманнарының рухи бердәмлегенә ирешү, ислам дөньясында бара торган хәлләрне, Россиянең тышкы сәясәтен җентекләп, дөрес итеп яктырту максатын куя. 1916 дан газета «Яшәсен халык республикасы!», «Россиядәге барлык мөселман халыкларының тәрәккыяте һәм аларның башка милләтләр б-н тигез хокуклы булуы өчен!» дигән лозунглар астында чыгарыла. Газета бик күп мәсьәләләрне яктырта: тышкы сәясәтнең республиканың икътисади хәленә, сәүдә һәм сәнәгате үсешенә тәэсире; эчкечелек, фахишәлек, җинаятьчелек, эшсезлек б-н көрәш; Россиянең законнар чыгару мәсьәләләре, аларны мөселманнарга аңлату; китап, журнал, газеталар нәшер итү һ.б. мәсьәләләр. Г.Тукай, М.Гафури, Н.Думави, С.Сүнчәләй, М.Шәрифи, К.Эмре, Гыйффәт туташ шигырьләре; Г.Исхакый, К.Тинчурин, Г.Рәхим, Н.Гасрый, Х.Еникиев һ.б.ның хикәя һәм



«Ил» газетасы.

фельетоннары; яңа әдәби әсәрләргә рецензияләр; Көнбатыш Европаның алдынгы илләрендә фән, мәгариф, икътисад өлкәсендәге казанышлар турындагы мәкаләләр басыла. Мәскәү, Оренбург, Казан, Әстерхан шәһәрләрендә эшләп килүче «Хәйрия җәмгыятьләре»нең эшләре яктыртыла. Мөселман халык ком-тына, Бөтенроссия мөселман советына һ.б. оешмаларга акчалата ярдәм күрсәткән кешеләрнең исемлеге бирелә. Газета төрле төбәкләрдә яшәүче укучылары б-н элемтә урнаштыра, хәтта чит илләрдән дә (мәс., Финляндия, Төркия) язмалар килә. Татар газета-журналларыннан «Йолдыз», «Вакыт», «Илче», «Кояш», «Ак юл», «Ялт-Йолт», «Сөембикә» б-н хезмәттәшлек итә. Газетада татар мәдәни тормышында зур роль уйнаган «Дар эл-мөгаллимин», «Мудафага нисван», «Шәрекъ клубы» һ.б. җәмгыятьләр эшчәнлеге яктыртыла. Татар зыялылары вәкилләре б-н әңгәмә-сөйләшүләр, некрологлар басыла. Ирләр б-н хатын-кызларның тигез хокуклылыгы турындагы мәкаләләр «Хатын-кыз тавышы» рубрикасында бирелә.

«И.» дини белем бирүне дөньяви укытудан аеруны, укыту программасына гомуми тарих, рус әдәбияты, география, ислам белеме, Россия дәүләте тарихы, хокук, химия, медицина, икътисад һ.б. фәннәрне мәҗбүри дисциплина буларак кертүне яклап чыга. Газетада мөселман съездлары эше турында язмалар басыла. Россия хөкүмәтенең милли сәясәте (рус булмаган халыкларның милли, мәдәни һәм дини үзенчәлекләре б-н исәпләшмәү, аларның үзбилгеләнү хокукын читкә кагу) тәнкыйтьләнә. Редакция әгъзалары берничә мәртәбә судка тартыла, газетаның кайбер саннары конфискацияләнә. 1918 елның апрелендә ул бөтенләй ябыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ИЛ»**, Үзбәкстан Респ-касындагы татар рәссамнарының иҗади берләшмәсе. 1966 елның 10 октябрендә Ташкентта оеша. 2000 дә элегрәк төзелгән (1993 тән) «Нәфис» иҗат коллективы базасында тупланган 17 рәссамны берләштерә. Алар арасында — М.Ф.Садыйков (1996 дан — рәис), Д.М.Мөрсәлимов, Д.А.Уразаев, О.Г.Хәбибуллин, С.Рахмонов һ.б. «И.»нең максаты — Үзбәкстанда яшәүче татар рәссамнарын берләштерү, милли традицияләр, сәнгать теленең ачыклыгы нигезендә аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү; Татарстандагы мәдәният эшлеклеләре һәм учреждениеләре б-н хезмәттәшлек итү; чит ил тамашачыларын татар сәнгате б-н таныштыру һәм күргәзмәләр уздыру. Ташкентта һәм Үзбәкстандагы башка шәһәрләрдә «И.» рәссамнар күргәзмәләрен оештыра. Чит илләрдә Финляндиядә (1997), Германиядә (1998), ш.у. Татарстанда (Казан, 1999) күргәзмәләр үткәрелә.

**«ИЛ БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. 1917 елда Коканд шәһәрендә (Төркестан) татар һәм үзбәк телләрендә нәшер ителә. Мөхәррире — Б.М.*Салиев*.

**ИЛ КАГА́Н** (кытай чыганакларында — Хели, әрмән чыганакларында — Йал-тегин) (? — 630 елдан соң), *Төрки каганлык* идарәчесе. Шиби каганның энесе. 603 тә Төрки каганлык үз идарәче династияләре булган Көнчыгыш Төрки һәм Көнбатыш Төрки каганлыкларына таркала. Көнчыгыш Төрки каганлыкта Шиби каганның (609–19) хакимияте көчәя. Аның үлеменнән соң тәхеткә И.к. утыра (620). Ул ил белән идарә итүдә тәртип урнаштыра һәм аның хәрби куәтен көчәйтә. Кытайдагы низаглардан (613–18) һәм Суй династиясенең хакимияттән төшерелүеннән (618) файдаланып, ул төньяктагы җирләргә 67 яу оештыра. 626 ның сентябрендә гаять зур гаскәре б-н Тан империясе башкаласы Чанъань диварлары янына килеп җитә, ләкин аны яулый алмый. 627–29 елларда терлекләрнең күпләп кырылуы һәм ачлык башлану төркиләрнең хәрби куәтен кискен какшата. 629 да И.к. гаскәрләре Шаньси провинциясендә кытай гаскәрләре тарафыннан җиңелә. Төркиләр хакимиятенең көчсезләнүе нәтиҗәсендә уйгыр, сеяньто һәм байырку кабиләләре баш күтәрә. Моннан файдаланып, 630 да кытай гаскәре далага бәреп керә, И.к. гаскәрен тар-мар итә һәм үзен әсирлеккә ала.

*Әд.:* К л я ш т о р н ы й С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964; Г у м и л е в Л.Н. Древние тюрки. М., 1967; К л я ш т о р н ы й С.Г., С а в и н о в Д.Г. Степные империи древней Евразии. СПб., 2006.

*И.Л.Измайлов.*

**«ИЛ ТЕЛЕ́»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты*ның (КОМУЧ) агитация һәм мәдәни-агарту бүлеге органы. 1918 елның 25 ноябреннән 9 декабренә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 5 саны чыга. Мөхәррире — Х.Ф.*Искәндәров*; соңгы саны редколлегия имзалыгында чыга. Барлык мәкаләләре дә авторлары күрсәтелмичә басыла. Газета Россиянең демократик юнәлештә, федератив дәүләт буларак үсешен яклый.

«Бөтен власть — Учредительләр җыенына!», «Яшәсен Федератив демократик Республика!», «Яшәсен милли-мәдәни автономия!» лозунглары астында чыга. «И.т.» сыйнфый көрәш теориясенә каршы була, милләтләр арасында социаль тынычлык идеясен яклый: «Милләт бердәм булсын, барлык кешеләр — сатучы, укытучы һәм укучы, эшче, ярлы һәм байлар бердәм булсыннар!» — дигән идеяне яклый. Россиядәге һәм чит илләрдәге мөһим сәяси хәлләр турындагы материаллар басыла. Уфада яңадан торгызылган «Милли идарә» оешмасының, аның нәзарәтләренең эше яктыртыла, 1918 нең сентябрендә Уфа директориясен булдыру турында языла. 1918 нең ноябрендә Омск шәһәрендә булган хәлләргә зур игътибар бирелә (анда күчкән Уфа директориясе урыныннан төшерелә һәм хакимият адмирал А.В.Колчак кулына күчә). Газета А.В.Колчакның милли мәсьәләләрдәге шовинистик сәясәтен гаепләп чыга: Омскидагы переворottан соң идарәнең безнең ихтыяҗларны яклавы турында сүз дә булуы мөмкин түгел, шуның өчен без Колчак властена каршы чыгарга тиешбез, диелә газетада. Колчак боерыгы буенча КОМУЧ бетерелгәч, газета чыгудан туктый. Уфа Кызыл Армия тарафыннан азат ителгәч, Х.Ф.Искәндәров Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясенең «Кызыл яу» («Кызыл Армия») г-тасында эшли башлый.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом): 1905–1925. К., 1926; М ә һ д и е в М. Ачы тәҗрибә. К., 1993; Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать. К., 1999.

*Т.М.Насыйров.*

**ИЛӘБӘ́Р** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 10 *км* төньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 451 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тегү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 782,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир-ат; 1859 да — 294, 1897 дә — 461, 1908 дә — 494, 1920 дә — 549, 1926 да — 470, 1938 дә — 459, 1949 да — 379, 1970 тә — 302, 1979 да — 310, 1989 да — 474, 2002 дә — 436 кеше.

**ИЛӘ́К РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* көньяк өлешендә урнашкан. 1927 елның 30 маенда оештырыла. Мәйданы — 3684 *км²*. Үзәге — Иләк авылы (Оренбург шәһәреннән 128 *км* көнбатыштарак). Халкы — 30414 кеше (2001). 1989 елгы халык исәбе буенча, татарлар 3441 кеше. Татарлар, нигездә, Озёрки (1395), Нижнеозёрный (680), Мохран (522) авылларында яши. 1917 гә кадәр бу торак пунктларда мәчетләр эшли. 1925–55 тә Нижнеозёрный, 1970–81 дә Озёрки авылларында татар мәктәпләре була. Хәзерге вакытта Озёрки авылы мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә, мәдәният йортында татар үзешчән сәнгать коллективы эшли. Озёрки авылында Сов. Союзы Герое Ф.С.Шаһгалиев һәм генерал-майор Г.И.Мөхәммәтҗанов туган, Мохран авылында Сов. Союзы Герое Ш.Ә.Гыйззәтов яшәгән.

**ИЛБӘ́К** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 281 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1779 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, И.тә мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2415 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 426, 1889 да — 768, 1897 дә — 784, 1920 дә — 951, 1926 да — 579, 1938 дә — 609, 1949 да — 338, 1958 дә — 339, 1970 тә — 313, 1979 да — 236, 1989 да — 165, 2002 дә — 289 кеше.

**ИЛБУ́ХТИНО** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шилнә елгасы буенда. 2008 елда 302 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 83%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1656 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Макарьево исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше һәм урман кисү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да волость идарәсе урнаша, Макарий Унженский чиркәве (1820 дә төзелә), земство мәктәбе, 2 су тегермәне була; шимбә саен базар, ярминкәләр (25 июльдә, 22 сентябрьдә, 25 декабрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6376,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарьево волостенда. 1920 дән ТАССРның Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 1271, 1897 дә — 1451, 1913 тә — 1630, 1920 дә — 1458, 1926 да — 1162, 1938 дә — 948, 1949 да — 677, 1958 дә — 436, 1970 тә — 445, 1979 да — 293, 1989 да — 220, 2002 дә — 262 кеше.

**«ИЛДА́Н»**, җиңел сәнәгать пр-тиесе, җитештерү-сәүдә фирмасы. Россиядә өс-баш киемнәре (мехтан, текстильдән), трикотаж эшләнмәләр, җиңел күлмәкләр җитештерә торган иң эре фирмаларның берсе. 1981, 1986, 1989 елларда нигезләнгән «Золотое руно» ф-касы, Модельләр йорты һәм «Лик» мода театры җирлегендә 1990 да оештырыла. 1996 дан 2005 кә кадәр — АҖ.

Баштарак фирма пальтолар тегү б-н шөгыльләнә. Пр-тиенең структурасын 6 төп җитештерү цехы, мех эшкәртү ф-касы, проф. «Илдан-Лик» мода театры, Казан һәм Түбән Камадагы кибетләр челтәре, ярдәмче хуҗалык тәшкил итә. Цехларда чит илләрдә танылган «Зингер», «Пфафф», «Файт» фирмаларының җитештерү линияләре урнаштырылган. «И.» шәхси заказлар буенча модельле һәм модалы ир-ат һәм хатын-кыз өс-баш киемнәре һәм күлмәкләре тегә, сарык тиреләрен һәм затлы мехларны (кеш, чәшке, шиншилла, каракүл, ак төлке, көмешсыман-кара төлке һ.б.) эшкәртү, мехларны буяу-ману б-н шөгыльләнә; мех киемнәрнең, ир-ат һәм хатын-кыз баш киемнәренең яңа үрнәк төрләрен эшли һәм тегә.

2003 тә «И.» 9 мең пальто, 4 мең мех һәм кайры тун, 4 мең куртка, 3 меңнән артык баш киеме тегеп сата. Соңгы елларда товар сату һәм хезмәт күрсәтү күләмнәре: 1998 дә — 53,8; 1999 да — 89,3; 2000 дә — 109; 2001 дә — 113,3; 2002 дә — 121,6 һәм 2003 тә 130 млн. сум.

Пальтолар өчен тукымалар — Италия, Германия, Франциядән һәм Россиядәге «Купавна», «Пётр Алексеев ширкәте», «Ивантеевская тонкорунная фабрика» фирмаларыннан, тун өчен эшкәртелгән сарык тиреләре Татарстан һәм Башкортстан а.х. пр-тиеләреннән, кыйммәтле мехлар ТР һәм РФнең җәнлек с-зларыннан кайтарыла.

1998 дән күп кенә эшләнмәләр бөтенроссия конкурсларында берничә тапкыр «Россиянең иң яхшы 100 товары» дипломнарына лаек була. «Югары сыйфат. Яңа эра» конкурсында Америка-Россия сәүдә-сәнәгать палатасы пр-тиене алтын медаль б-н бүләкли (2002). «И.» — Татарстанда көн дә кия торган модалы өс киемнәре (pret-a-porte) коллекцияләрен җитештергән бердәнбер пр-тие. Өс киемнәре коллекцияләре «Русский силуэт», «Серебряная нить», «Зөбәрҗәт», «Кутюрье года» бөтенроссия һәм халыкара конкурсларында призлы урыннар яулый.

2005 елдан «И.»ның җитештерү базасының төп өлеше 100 дән артык кече һәм уртача күләмдәге эшмәкәрлек пр-тиесенә арендага тапшырыла. Пр-тие директоры — Н.П.Прохоров (1990 елдан).

*Әд.:* Г е р а с и м о в а А. Слава отечества — это «Ильдан» // Время и деньги. 2000. 26 дек.; Б о г а ч ё в Е. Прямая речь. К., 2001.

*М.В.Киреева.*

**ИЛДА́Р** (Абдюшев) Мәҗит (Габделмәҗит) Хуҗи улы (10.1.1898, Оренбург губ. Семёново а. — 29.6.1952, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1945). Сәхнә эшчәнлеген Оренбург татар театрында башлый. Уфа, Казан, Әндиҗан татар театрларында актёр, режиссёр булып эшли. 1933 елдан Татар акад. театры труппасында. Күп кенә истә калырлык рольләр башкара. Алар арасында Сабир, Касыймхан, Коновалов («Чаткылар», «Ташкыннар», «Чын мәхәббәт», Т.Гыйззәт), Җамалетдин («Банкрот», Г.Камал), Рузий («Мәйсәрәнең хәйләсе»,


Илдар Мәҗит.

Х.Хәмзә), Мәрҗани («Каюм Насыйри», М.Гали, Х.Уразиков), Хәнәфи («Тукай», Ә.Фәйзи), Эдмунд («Король Лир», У.Шекспир), Граф («Трактирщица», К.Гольдони), Монахов, Михаил Скроботов («Варварлар», «Дошманнар», М.Горький) һ.б. образлар бар. Социаль-психол. портретлар остасы буларак, ул һәр рольнең төгәл, тормышчан, истә калырлык детальләрен табып, характерның асылын чагылдыра белә.

*И.И.Илялова.*

**ИЛДАРХА́НОВ** Илдус Гәрәй улы (12.10.1944, Мөслим р-ны Шуган а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан пед. ин-тын (1969), ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбен (1973) тәмамлый. 1969–71, 1973–74 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында (әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире), 1974–90 да «Социалистик Татарстан» г-тасында (хәбәрче, бүлек мөдире) эшли. 1992–95 тә «Татарстан хәбәрләре» г-тасында бүлек мөдире, баш мөхәррир урынбасары, 1990–92 дә «Шәһри Казан» г-тасында баш мөхәррирнең беренче урынбасары, 1995 тә бүлек мөдире, 1996–2003 елларда баш мөхәррир. Мәкаләләре «Советская Татария», «Вечерняя Казань» г-таларында, «Спортивная жизнь России» ж-лында (Мәскәү) басыла. Басмалары Татарстанда спорт үсеше, хәрби-патриотик тәрбия, халык гореф-гадәтләре мәсьәләләренә карый. ТАССРда «Татарча көрәш» милли спорт көрәше федерациясе рәисе (1988–91). Хәрби-патриотик һәм спорт темаларына язылган китаплар авторы һәм төзүчесе. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. ТР журналистларының «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бәйгесе бүләге иясе.

Әсәр.: Олимп тавына ничек менәргә? К., 1980; Халык һәм спорт уеннары. К., 1982; Без көрәшле халык. Чабаксар, 2003; Без көрәшче халык. К., 2009.

*Әд.:* Газиз Л. Летопись мгновений. К., 2000; Үсү юлында // Әхмәдуллина Ш. Без бит бер халык балалары. К., 2002; Көрәшчеләр нәселеннән // Баһаутдинов Ф.Н. Без Мөслим балалары. К., 2006.


**ИЛДУ́С** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 35 *км* төньяктарак, Шушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Арча кантоны Мәмсә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 283, 1949 да — 185, 1958 дә — 201, 1970 тә — 140, 1979 да — 93, 1989 да — 44, 2002 дә — 56 кеше.

**ИЛЕКСА́З** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 3 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2008 елда 444 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.да мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 20 йөз башында анда 3 мөселман мәхәлләсе була, 1913 тә 3 мәктәптә 150 укучы укый. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2607,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 827, 1897 дә — 1412, 1913 тә — 1881, 1920 дә — 1620, 1926 да — 758, 1938 дә — 723, 1949 да — 660, 1958 дә — 568, 1970 тә — 607, 1979 да — 486, 1989 да — 408, 2002 дә — 456 кеше.

**ИЛЕ́Ш РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Үзәге — Үрге Яркәй авылы (Уфадан 160 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 36281 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 9951, 1979 да — 5468, 1989 да — 11007, 2002 дә — 4958 кеше. Районда 89 торак пункт, ш.и. 6 татар, 33 татар-башкорт, 2 татар-рус, 1 татар-удмурт авылы бар. Иң зур татар авыллары (1999 ның 1 гыйнварына): Базытамак (1676 дан мәгълүм), Әтәс (1740 еллардан), База-Куян (1762–83), Мәнәвез (1777). И.р. терр-ясен үзләштерү чорында татарлар башкорт торак пунктларына килеп урнаша. Татарлар беренче булып Игъмәт (1697), Абдулла (1718), Нәдир (1777) авылларында төпләнә. 1994/95 уку елында И.р.ның 12 мәктәбендә укыту татар телендә бара, 49 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Сеңрән авылында ТР ФАнең мөхбир әгъзасы Ә.Г.*Мөхәммәдиев* туган.

**ИЛКӘ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасы буенда. 2008 елда 7 кеше (татарлар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, ятьмә үрү б-н шөгыльләнә. 1880 елларда И.дә мәктәп, тегермән, ашлык саклау-сату кибете эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1836 да — 78, 1859 да — 110, 1887 дә — 267, 1911 дә — 328, 1920 дә — 407, 1926 да — 357, 1938 дә — 407, 1949 да — 275, 1958 дә — 181, 1970 тә — 100, 1979 да — 69, 1989 да — 25, 2002 дә — 6 кеше.

**ИЛЛӘ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 204 *км*, ТР чикләрендә — 34 *км*. Бассейнының мәйданы 6471 *км*$^2$. Елга башы, төп агымы һәм тамагы Мари Респ-касы терр-ясендә (И. Волжск шәһәреннән 4 *км* көнбатыштарак Иделгә коя). Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. ТРда Биектау р-нының төньяк-көнбатыштагы өлешендә урман массивы буйлап ага. И.нең су җыелу мәйданы комлы, сирәк кенә балчыксыл утырмалардан торган дулкынсыман тигезлектән гыйбарәт, кушылдык үзәннәре, сызалар, уйсулыклар б-н тирәнтен бүлгәләнгән; карстлы бүрәнкәләр һәм күлләр очрый. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 60%. И. үзәне, башлыча, артык сизелмәүче кабарынкы сөзәк тау битләреннән гыйбарәт. Тугае ике яклы, күбрәк урманлы, урыны б-н су баскан. Үрге агымында тугай киңлеге 30–50 *м*, түбәнге агымында — 5,5 *км*. Елга юлы бормалы, тармакланмаган, күп кенә суга баткан агачлар б-н пычранган. Су ташу вакытында су астында калучы утраулар очрый (озынлыгы 0,6–1,4 *км*, киңлеге 140–250 *м*, суының иң аз вакытындагы тигезлектән биеклеге 0,3–0,5 *м*).


Илләт елгасы Биектау районы Наратлык авылыннан көньяктарак агымында.

Елга юлының урта һәм түбәнге агымы буенда тугайда күп санда элеккеге елга юллары очрый. Югары агымында елга аз сулы, тирәнлеге 0,2–0,5 *м*, киңлеге 5–10 *м*; тамагына таба елганың киңлеге 45–55 *м* га кадәр арта, андый урыннарда тирәнлек 1,5–3,6 *м* га җитә. Агым тизлеге 0,1 дән 0,3 *м/с* ка кадәр. Елга төбе тигез түгел, башлыча, комлы, сирәк кенә балчыксыл, сайлыкларда урыны б-н ташлы. Сай сулыкларны күрән һәм төнбоеклар каплаган. И. елгасының 56 кушылдыгы бар, ТР терр-ясендә аеруча зурлары: Яран (24,2 *км*), Ашыт (83 *км*), Питиал (53,6 *км*), Шура (48,8 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. И. елгасы бассейнының җир асты туендыру модуле төрле өлешләрендә 0,1 дән 10 *л/с·км*$^2$ ка кадәр. Елга режимы Мари Респ-касының Красногорск авылы янындагы гидрологик постта өйрәнелә (1941 дән). Язгы ташу (уртача дәвамлылыгы 40 көн), гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Ташу агымы катламы 83 *мм*. Суының иң зур чыгымы 1180 *м*$^3$ (1947). Җәйге саегу тотрыклы. Яңгыр ташкыннары сизелерлек түгел һәм сирәк, һәм аларның уртача дәвамлылыгы 5–10 көн, ташкын агымының катламы 1,5–3 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы күпьеллык чыгымы 20 *м*$^3$*/с*. Иң аз чыгымнар августта күзәтелә. И., гадәттә, ноябрь башында туңа. Бозлануның уртача дәвамлылыгы 140–150 көн. Бозның ка-

лынлыгы кыш азагына 40–50 *см* га җитә (иң күбе 80 *см*). Җир асты суларының чыгу юллары булган урыннарда елга кыш буе боз б-н капланмый. Суы гидрокарбонат-кальцийлы, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–150 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000–1400 *мг/л*.

*О.Н.Урбанова.*

**ИЛМӘ́Т** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасы буенда. 2008 елда — 294 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, И.тә мәчет була. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 409, 1887 дә — 829, 1920 дә — 1098, 1926 да — 1028, 1938 дә — 873, 1949 да — 572, 1958 дә — 608, 1970 тә — 637, 1979 да — 450, 1989 да — 366, 2002 дә — 366 кеше.

**ИЛНӘ́Т** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Ерыкса елгасы буенда. 2008 елда 391 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Ярыкса исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, И. тә ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне эшли. 1871 дә миссионерлык мәктәбе ачыла. 1887–88 елларда завод хуҗасы П.К.Ушков шушы мәктәп өчен бина (хәзер архит-ра истәлеге) төзи, бу бина бер үк вакытта чиркәү булып та хезмәт итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 16 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 288, 1870 тә — 306, 1920 дә — 579, 1926 да — 607, 1938 дә — 544, 1949 да — 479, 1958 дә — 419, 1970 тә — 553, 1979 да — 457, 1989 да — 362, 2002 дә — 354 кеше.

**ИЛОВА́ЙСКИЙ** Дмитрий Иванович (11.2.1832, Рязань губ. Раненбург ш. — 15.2.1920, Мәскәү), тарихчы, рус тарихы д-ры (1870), тайный советник. Мещаннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1854), 1860–61 елларда шунда ук укыта. 1862 дә отставкага чыккач, фәнни һәм әдәби-публицистик эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Историографиядә консерватив юнәлеш вәкиле. Рязань кенәзлеге, Литва тарихын тикшерүче. «Россия тарихы» («История России», т. 1–5, М., 1876–1905) дигән төп хезмәтендә, Н.М.Карамзин концепциясенә нигезләнеп, иң борынгы заманнардан алып 17 йөз ахырына кадәр Россия тарихына гомуми күзәтү ясый. И., барлык «тарихи» халыкларның прогрессы «дәүләти көнкүреш» формаларында тәмамлана, дип исәпли һәм халык тарихын өйрәнүне дәүләтчелекнең идарәчеләр «гамәлләре»ндә чагылган үсеш тарихы б-н чикли. Һуннар һәм болгарларның славяннардан килеп чыгуы, «Азов алды Русе» — Бөек Болгария булуы турында фараз тәкъдим итә. Рус дәүләтенең Идел буе Болгары, Алтын Урда дәүләтләре, татар ханлыклары б-н үзара мөнәсәбәтләрен тикшерә; Алтын Урда хакимиятенең удел кенәзлекләренә һәм Мәскәү Русена йогынтысын күрсәтә; Мәскәү кенәзләре һәм патшаларының Көнчыгышка карата сәясәтен, ш.и. Иван IVнең Казан ханлыгына каршы яуларын һәм 1552 дә Казанны яулап алуын җентекләп тасвирлый. Рус тарихы һәм гомуми тарих дәреслекләре авторы. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы.


Х е з м.: Сочинения: В 3 ч. М., 1884–1914; Мелкие сочинения, статьи и письма: В 2 вып. М., 1888–96.

*Әд.:* Ц в е т а е в Д.В. К 50-летию учебно-литературной деятельности Д.И.Иловайского. М., 1908; Очерки по истории исторической науки в СССР. М., 1960. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ИЛТӘБӘ́Р**, урта гасырларда феодаль титул. Беренче тапкыр *Күлтәгингә куелган һәйкәлташтагы* (732) борынгы төрки язмада телгә алына. Хәзәр каганлыгында И. — каганга буйсынган ил хакиме титулы, Идел буе Болгарында — дәүләт идарәчесе (мәс., *Алмыш* илтәбәр).

**ИЛТӘ́Н-БОТА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2008 елда 405 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шубуян, Түбән Бота исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәч ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.-Б.да 2 су тегермәне, 20 йөз башында миссионерлык мәктәбе (1890 да ачыла), 3 бакалея кибете, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1379,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 133, 1834 тә — 229, 1859 да — 326, 1870 тә — 414, 1897 дә — 891, 1913 тә — 848, 1920 дә — 1125, 1926 да — 857, 1938 дә — 782, 1949 да — 718, 1958 дә — 692, 1970 тә — 737, 1979 да — 632, 1989 да — 392, 2002 дә — 371 кеше.



Д.И. Иловайский.



М.Ә. Илһамов.

**ИЛҺА́М ХАН** (1450 еллар — 1490 еллар тирәсе), Казан ханы (1479–87, бүленеп), *Ибраһим ханның* өлкән улы. 1482 дә Рус дәүләте б-н солых төзи. 1485 тә Мәскәү гаскәрләре ярдәмендә *Мөхәммәдәмин хан* тарафыннан Казаннан куыла. Шул ук елда Нугай гаскәрләре ярдәмендә тәхетне кайтарып ала. 1487 дә, Иван III гаскәрләре Казанны озак вакыт камап торганнан соң, тәхеттән төшерелә һәм Вологда шәһәренә сөргенгә сөрелә.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*С.Х.Алишев.*

**ИЛҺА́МОВ** Марат Әкъсән улы (7.4.1934, БАССРның Әбҗәлил р-ны Ярлыкап а.), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1970), РФА мөхбир әгъзасы (1991), БР ФА академигы (1998). 1957 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлый. 1962–91 елларда СССР ФАнең Казан филиалы Физика-техника ин-тында, 1971 дән лаб. мөдире, проф. (1972), 1989 дан директор урынбасары. Бер үк вакытта 1977–89 да СССР ФАнең Казан филиалы Президиумы рәисе. 1991–96 да РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-ты директоры. 1996 дан РФА Уфа гыйльми үзәге Механика ин-тында лаб. мөдире, бер үк вакытта РФА Уфа гыйльми үзәге Президиумы рәисе урынбасары һәм БР ФА вице-президенты. Хезмәтләре юка стеналы сыгылмалы сүрүләрнең сыеклык, газ һәм рәвеше үзгәрүчән җисем б-н үзара тәэсирләшү теориясенә карый.

И. контакт өслегендәге зур көчешләрне исәпкә алып, юка стеналы конструкцияләрнең сыеклык һәм газ б-н үзара көчле тәэсирләшү теориясен, гидроаэросыгылмалыкның нәсызыкча мәсьәләләрен санча чишү ысулларын үстерә, мохит-корпус системасының резонанс ешлыгы янындагы периодик бәрмә дулкыннарны тәҗрибәдә таба һәм теоретик яктан аңлатып бирә. Эшләнмәләрнең динамик ныклыгын сынау ысулын тәкъдим итә һәм технол. аппаратларның физик модельләрен эшли. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Колебания упругих оболочек, содержащих жидкость и газ. М., 1969; Прочность, устойчивость и динамика оболочек с упругим заполнителем. М., 1977 (автордаш); Введение в нелинейную гидроупругость. М., 1991; Статистические задачи гидроупругости. К., 1994.

**ИЛЧЕ́**, урта гасырларда феодаллар титулы. 6–8 йөзләрдә төрки каганлыкларда идарәчене (каган вәкилен) яки илчене аңлаткан. 9–16 йөзләрдә төрки, монгол дәүләтләрен-

дә, ш.у. татар ханлыкларында — илче, йомыш үтәүче. Ихтимал, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында И. ясак җыючы вазифасын башкаргандыр.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Материалы для истории Крымского ханства. СПб., 1864; Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. Л., 1969; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

*И.Л.Измайлов.*

**ИЛЧЕБА́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 8 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2008 елда 99 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1747 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Беренче тапкыр мәчет турында И.да 1812 дә телгә алына, 1852 дә авыл мәхәлләсе рәсми теркәлә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1080 дис. тәшкил итә. 1913 елгы мәгълүматларга караганда, 83 хуҗалыктагы 88 кеше төрле кәсеп б-н шөгыльләнә. 1929 да «Бүләк» к-зы төзелә, соңрак «Таулар» к-зына керә (хәзер а.х. кооперативлары берләшмәсе). 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостенда. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 223, 1834 тә — 382, 1859 да — 515, 1870 тә — 632, 1897 дә — 538, 1908 дә — 644, 1913 тә — 688, 1920 дә — 282, 1926 да — 320, 1938 дә — 292, 1949 да — 169, 1958 дә — 148, 1970 тә — 181, 1979 да — 123, 1989 да — 107, 2002 дә — 98 кеше.

**ИЛЧЕЛЕ́К КЕНӘГӘЛӘРЕ́**, 15 йөз — 18 йөз башында Россиядә Илчелек приказының эш йөртү материаллары (чит илләр илчеләрен кабул итү турындагы отчётлар, халыкара хәбәрләрнең төп нөсхәләре һәм тәрҗемәләре, илчеләргә наказлар һ.б.). Баштарак И.к. теге яки бу дипломатик юнәлешкә кагылышлы документлар җыелмасыннан гыйбарәт була, соңрак алар дәфтәрләр булып тегелә, ә дәфтәрләр кенәгәләр итеп төпләнә. Карамалары б-н бергә дипломатия документлары Илчелек приказы архивында саклана. 16 йөз ахыры — 17 йөз башында — «Болгавыр заман» чорында күп кенә документлар һәм кенәгәләр югала. Илчелек приказы архивында Европа дәүләтләре (Польша, Италия, Швеция, Австрия, Англия һ.б.), татар дәүләтләре (Кырым ханлыгы, Нугай Урдасы), ш.у. Якын һәм Урта Шәрекъ (Төркия, Грузия, Персия) б-н булган элемтәләргә нисбәтле 93 И.к. исәпләнә. И.к. Россиядә тышкы сәяси проблемалар буенча карарлар кабул итү тәртибен, хөкүмәтнең дипломатия ведомствосы б-н үзара хезмәттәшлеген, Илчелек приказы структурасы һәм аның эшчәнлеген, ш.и. илчелек хезмәтен оештыру буенча карарлар кабул итү тәртибен торгызу мөмкинлеге тудыра. И.к. 15–17 йөзләрдә Евразия дәүләтләренең тышкы сәясәте, дипломатия тәртибе һәм этикеты, ш.у. аларның тышкы сәясәте тарихы буенча мөһим чыганак булып тора. Нугай Урдасы (бүленеп, 1489–1582) һәм Кырым ханлыгы б-н язышу материаллары Мәскәүнең татар дәүләтләре б-н дипломатия мөнәсәбәтләрен күзаллау мөмкинлеге бирә. И.к. өлешчә бастырылып чыгарылган. Мәскәү кенәзләренең һәм патшаларының Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары ханнары б-н язышуына кагылышлы И.к. югалган.

*Әд.:* Обзор посольских книг из фондов-коллекций, хранящихся в ЦГАДА (конец XV — начало XVIII вв.). М., 1990; Рогожин Н.М. Посольские книги России конца XV — начала XVII вв. М., 1994; Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1551–1561 гг. К., 2006.

*И.Л.Измайлов.*

**ИЛЬИ́Н** Алексей Иванович (25.5.1923, Бөгелмә кантоны Аверьяновка а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Казан югары партия мәктәбен тәмамлый (1958). 1950–54, 1958–62 елларда партия эшендә. 1962–84 тә Бөгелмә р-нының «Семеновод» тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында директор. И. җитәкчелегендә хуҗалыкта, туфракны төрле тирәнлектә яссы кисеп әйләндереп салу юлы б-н эшкәртеп, туфрак саклагыч система кертелә, бөртекле культураларның уңышы 1 гектардан 15 *ц* дан 30–35 *ц* га кадәр арта, а.х. культураларының элиталы орлыкчылык базасы булдырыла, мөгезле эре терлек комплексы, башка җитештерү объектлары төзелә, тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы республикада алдынгылар рәтенә чыга. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ИЛЬИ́Н** Владимир Кузьмич (10.5.1962, Ширәмәт р-ны Зеленый Бор а.), машиналар төзелеше өлкәсе галиме, техн. фән. д-ры (2004). 1984 елда Казан а. х. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1987 дән Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында (хәзер Казан энергетика ун-ты), читтән торып уку ф-ты деканы (2000 нән), проректор (2005 тән). Хезмәтләре термодиффузион туендыру алымнары б-н а. х. машиналарының ышанычлылыгын күтәрүгә карый. И. механик-химик абразив таушалу шартларында эшләүче машина детальләрен кабаттан торгызу һәм ныгытуның теоретик нигезләрен; термодиффузион хромлау, борлау, күп компонентлы цинклау алымнарын; туендыручы катнашма составларын эшли. Аның җитәкчелегендә ун-тта укытуның яңа формалары (читтән торып, икенче югары белем алу, квалификация күтәрү курслары һ.б.) оештырыла.

Х е з м.: Восстановление и упрочение деталей машин методами диффузионной металлизации. К., 2003.

**ИЛЬИ́Н** Герман Иванович (12.4.1940, Приморье краеның Раздольный штп), радиоэлектроника гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000). 1963 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, радиоэлектроника һәм квант җайланмалары каф. мөдире (1998 дән). Хезмәтләре радиотехник системаларның һәм киң диапазондагы үлчәү җайланмаларының комачауларга тотрыклылыгын арттыруга карый. Зур динамик диапазонлы сигналлары булган үлчәү системаларының гомуми теориясен төзи; охшаш системаларның үткәрә алучанлыгына караган Шеннон формуласын аныклый; әйләнә-тирә мохит мониторингы өчен программалар төзи.

Х е з м.: Динамический диапазон и точность радиотехнических и оптоэлектронных измерительных систем // Успехи науки и техники. Сер. Радиотехника. 1989. Т. 39 (автордаш); Система накачки лидеров с дозирующим конденсатором // Оптика атмосферы и океана. 1994. Т. 7, № 10 (автордаш); Оценка влияния разъюстировок зеркал на пространственные характеристики лучевых потоков в коаксиальных лазерах лидерных комплексов // шунда ук. 1997. Т. 10, № 2 (автордаш).

**ИЛЬИ́Н** Серафим Андрианович (8.6.1913, Чуаш Респ-касының Яльчик р-ны Ак Күл а. — 1992, Ярославль ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1967), проф. (1967). 1932 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1934–40 та Мари югары коммунистик а.х. мәктәбендә һәм Казан а.х. ин-тында, 1940–41 дә Ленинград а.х.н механикалаштыру ин-тында, 1941–44 тә Казан а.х. ин-тында а.х.н оештыру каф. мөдире; 1944–55 тә Ленинград ун-тында, 1956–65 тә Ленинград а.х. ин-тында шул исем. каф. мөдире, доцент. 1965–68 дә Казан а.х. ин-тында каф. мөдире, 1968–71 дә ректор. 1971 дән Ярославль ун-тында, статистика һәм бухгалтерлык эше каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. икътисады мәсьәләләренә, бәрәңге һәм яшелчә үстерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә карый. «Почет билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Интенсификация — решающее условие повышения доходности сельскохозяйственного производства // За повышение производительности труда в сельском хозяйстве. Л., 1959; Интенсивное использование земли в пригородных хозяйствах // Экономика сел. хоз-ва. 1962. № 8; Картофель в Татарии. К., 1970 (автордаш).

**ИЛЬИ́Н** Сергей Семёнович (17.3.1905, хәзерге Аксубай р-ны Сөнчәле а. — 1978, Ярославль ш.), агрохимик, агроном-үсемлекчелек белгече, а.х. фән. д-ры (1952), проф. (1952). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1930). 1930–46 елларда Казан селекция станциясенең агрохимия бүлеген җитәкли. Ульянов (1946–55) һәм Ярославль (1955–57) а.х. ин-тларында, Башкорт ун-тында (1957–62), Казан пед. ин-тында (1962–65) укыта. 1966–70 тә СССР ФА Биология ин-тының Башкорт ф-лында. Татарстанның төрле туфракларында а.х. культураларының кертелгән ашламаларны үзләштерүен өйрәнү буенча массакүләм тәҗрибәләр оештыра. Хезмәтләре агрохимиягә (ашламалар куллану), игенчелек һәм үсемлекчелеккә карый.

Х е з м.: Удобрения и гербициды // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. К., 1968. Вып. 58.

**ИЛЬИ́НКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Кама елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2008 елда 34 кеше (руслар) яши. 1922 дә нигез салына. 1932 дә «Спартак» к-зы (1957 дә «Красный Ключ» с-зына кушыла) төзелә. ТАССРның Чаллы кантоны Афанас волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 370, 1938 дә — 95,

1949 да — 119, 1958 дә — 110, 1970 тә — 31, 1979 да — 5, 1989 да — 61, 2002 дә — 24 кеше.

**ИЛЬИ́НКА КҮЛЕ́** (Уразла күле), Иделнең сулъяк ярында. Сумка елгасы үзәне иңкүлегендә, Яшел Үзән р-нының Ильинский авылыннан төньяктарак, Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогы чикләре янында. Су өслегенең мәйданы 20 *га*. Су күләме 1200 мең $м^3$. Озынлыгы 600 *м*, иң зур киңлеге 338 *м*. Уртача тирәнлеге 6 *м*, иң зур тирәнлеге 19 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы катлаулы, турыпочмаклыкка якын. Көньяк өлешендә ярлары текә һәм калкулыклы; көньяк



Ильинка күле.

һәм көньяк-көнчыгыш ярлары комлы-ташлы. Төньяк-көнбатыш яры сөзәк, биредә сай сулыклар һәм су астында калучы болыннар бар. Яр кырыйларында 1 *м* киңлектә су үсемлекләре; сай сулы урыннарда укъяфрак, җир-су карабодае, бака тәңкәсе үсә. Суы бик йомшак, гидрокарбонат-хлорид-магнийлы типта. Суының үтә күренүчәнлеге 53 *см*. Туенуы катнаш, күбесенчә атмосфера явым-төшемнәре исәбенә. Күл агымлы, аның аша Сумка елгасы ага. Хуҗалык-көнкүреш һәм рекреация (ял итү) максатларында файдаланыла.

**ИЛЬИ́НКА СЫЗАСЫ́**, табигать истәлеге. Яшел Үзән р-ны Ильинский авылыннан көньяк-көнчыгыштарак. 1981 елда билгеләнә. Мәйданы 30 *га*. Грунттан һәм җир өстеннән дымлану аркасында үрге сазлыкларга һәм сфагнум утраучыкларына хас булган биоценозлар формалашкан. ТРның Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең сирәк төрләре үсә: Лапландия талы, тараксыман калканлы абага, баткак күрәне, җиңсәле мамыкбаш, саз шейхцериясе, кондыз үләне, гади мүк җиләге, саз акканаты һ.б. Бөҗәк аулаучы сирәк үсемлек — түгәрәк яфраклы чыклыут очрый. И.с.ның көнбатыш сөзәгендә яшь чыршы һәм имәннәр б-н ылыслы-киң яфраклы урман фрагменты сакланган. Агачлар төбендә абагалар — ата һәм ланцетлы-тараксыман абагалар, ана абага, сынучан куык абага, Линней өер абагасы, ш.у. ике яфраклы май чәчәге, күпьеллык зибык уты, төкле күрән һ.б. таралган. Фаунасында амфибияләр (6 төр), кошлар (31), имезүчеләр (11) очрый. ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләр: кыр карчыгасы, колаклы ябалак, һөд-һөд, Бранд төн ярканаты, бөҗәкләрдән — махаон очрый. И.с. фәнни һәм фәнни танып белү әһәмиятенә ия.



Ильинка сызасы.

*Әд.:* Р о г о в а Т.В. Голубое и зелёное. К., 1984; Г а р а н и н В.И., П о р ф и р ь е в В.С., Р о г о в а Т.В. Охрана достопримечательных объектов природы // Проблемы охраны природы Татарии. К., 1985.

**И́ЛЬИНО** (Лашовка) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 7 *км* төньяктарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 235 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. ТАССРның Арча кантоны Калинин волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1926 да — 22, 1938 дә — 27, 1949 да — 256, 1958 дә — 254, 1970 тә — 282, 1989 да — 229, 2002 дә — 244 кеше.

**ИЛЬИ́НСКАЯ** Ольга Николаевна (18.1.1958, Минзәлә ш.), микробиолог, биол. фән. д-ры (1999), проф. (2001). ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1980), шунда ук каф. мөдире булып эшли (2004). Хезмәтләре химик матдәләрнең генетик токсинлыгын өйрәнүгә карый. Күзәнәкләрдә һәм төрле эволюцион дәрәҗәдәге организмнарда целлюлоза нитроэфирларының биодеструкциясен һәм микроб рибонуклеозаларының биологик эффектын билгели. Целлюлотик фермент продуцентлары — микромицентларны үрчетү алымын тәкъдим итә. Уйлап табуга 3 патенты бар. Фән һәм техника өлкәсендәге казанышлары өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (2008).

Х е з м.: Биназа не индуцирует поликлональный Т-клеточный ответ // Докл. РАН. 2006. Т. 407 (автордаш); Геномные детерминанты биосинтеза оксида азота у Lactobacillus plantarum: потенциальные возможности и действительность // Молекулярная биология. 2007. Т. 41 (автордаш); Binase and other microbial RNases as potential anticancer agents // BioEssays. 2008. V. 30 (автордаш).

**ИЛЬИ́НСКИЙ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 12 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2008 елда 85 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уразлино исеме б-н дә мәгълүм. Башта авыл Раифа *Богородица пустыне* биләмәсе була. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек асрау, бакчачылык, умартачылык, тимерчелек, балта эше, киндер сугу, агач күмере әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да волость идарәсе урнаша, Илья чиркәве (1816–27 елларда төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1875 тә ачыла), 2 су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1116,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостена керә. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 546, 1908 дә — 572, 1920 дә — 680, 1926 да — 767, 1938 дә — 573, 1949 да — 700, 1958 дә — 435, 1970 тә — 308, 1979 да — 292, 1989 да — 145, 2002 дә — 91 кеше.

**ИЛЬИ́НСКИЙ** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 10 *км* төньяктарак, Үләмә елгасы буенда. 2008 елда 48 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөз башларында нигез салына. Башта авыл Тәтеш Покров монастыреныкы була, 1640–50 елларда Сембер Спас хатын-кызлар монастырена күчерелә. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, тимерчелек, мичкә ясау,



Ильинский авылында Илья чиркәве. 1816–27.

тукымаману-бизәк төшерү, тукыма туку б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да Илья чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 760 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Красная Поляна волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 392, 1897 дә — 617, 1908 дә — 734, 1920 дә — 696, 1926 да — 703, 1938 дә — 589, 1949 да — 444, 1958 дә — 384, 1970 тә — 238, 1979 да — 149, 1989 да — 98, 2002 дә — 69 кеше.

**ИЛЬИ́НСКИЙ** посёлогы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 19 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 28 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. 1930 елларда нигез салына. Казан авыл р-нына керә. 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1949 да — 215, 1958 дә — 214, 1970 тә — 97, 1979 да — 54, 1989 да — 39, 2002 дә — 26 кеше.

**ИЛЬИ́НСКИЙ** Николай Борисович (31.5.1932, Казан), механика гыйлеме белгече, физ.-матем. фән. д-ры (1970), проф. (1973). ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1984, 1992). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли: 1958–60 та Хисаплау үзәгендә; 1960 тан Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, кырый мәсьәләләр бүлеге мөдире (1968 дән), директор (1981–90), баш фәнни хезмәткәр (1993 тән). Хезмәтләре аэрогидродинамиканың кайтма кырый мәсьәләләренә, саркыту һәм шартлау теорияләренә карый. И. конструкцияләрнең җир асты контурларын рациональ проектлаштыру мәсьәләләрен чишүнең аналитик һәм санча ысулларын эшли, шартлатып ыргытуга һәм тоткарлыкны тишеп үтүгә тәэсир итүчән импульслы-гидродинамик модель вариантларын тәкъдим итә һәм аларның кулланылу кысаларын исбатлый. Һава агымы б-н идарә итә торган җайланмалары булган канат профильләре формаларын төзүгә һәм оптимальләштерүгә караган күп кенә мәсьәләләрне чишә, алдан билгеләнгән аэродинамик сыйфатланмалары буенча, самолётларның канат профильләрен төзегәндә, математик физиканың төгәл куелмаган мәсьәләләре квазичишелеше теориясенә таянып, катгый нигезләнгән математик якын килүне дәлилли. ТР ФАнең Х.Мөштәри исем. бүләге лауреаты (1999). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы построения подземного контура гидротехнических сооружений. Обратные краевые задачи теории фильтрации. К., 1963 (автордаш); Краевая задача напорной фильтрации // Докл. АН СССР. 1965. Т. 161, № 5; Краевые задачи теории взрыва. К., 1986 (автордаш); Обратные краевые задачи аэрогидродинамики. М., 1994 (автордаш); Построение безотрывно обтекаемого крылового профиля с отбором внешнего потока в некотором диапазоне углов атаки // Изв. РАН. Механика жидкости и газа. 2000. № 4 (автордаш).

**ИЛЬИЧЁВКА** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Түбән Кама сусаклагычы янында. 2008 елда 33 кеше (руслар, татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 65, 1949 да — 88, 1958 дә — 47, 1970 тә — 75, 1979 да — 46, 1989 да — 53, 2002 дә — 28 кеше.

**ИЛЬМИ́НСКИЙ** Николай Иванович (23.4.1822, Пенза — 27.12.1891, Казан), шәркыятьче галим, педагог-миссионер, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1870). Казан дини академиясен тәмамлый (1846); 1845 елның гыйнварыннан А.К.Казимбәктә академиянең укыту планына булачак миссионерларны әзерләү өчен кертелгән гарәп һәм татар телләрен өйрәнә. Бакалавр дәрәҗәсе алгач, академиянең гарәп һәм татар телләре кафедрасына укытучы итеп билгеләнә, ләкин аңа табигать фәннәре һәм яһүд теле буенча лекцияләр уку йөкләнә. 1847 дә И. татар телен яхшырак үзләштерү өчен Татар бистәсенә яшәргә күчә, мәдрәсәгә йөри. 1850 еллар уртасында Петербургка тәрҗемә ком-тына күчерелә, 1851 нең июлендә Изге Синод тәкъдиме б-н Николай I тарафыннан 3 елга Якын Көнчыгышка (Төркия, Мисыр, Палестина, Сүрия, Ливан) ислам динен һәм Көнбатыш Европа католик миссионерларының мөселман гарәпләр арасындагы эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен командировкага җибәрелә.



Н.И. Ильминский.

1854 тән Казан руханилар академиясендә гарәп һәм татар телләре укыта. Аның Рус Православие чиркәвенең булачак миссионерларын ислам нигезләренә тирәнтен өйрәтергә тырышуы мөселманлыкны пропагандалау итеп бәяләнә. 1858 нең сентябрендә И., академияне ташлап, Оренбургка китәргә мәҗбүр була, анда 1861 нең ахырына кадәр Оренбург чик буе комиссиясе каршында кече тәрҗемәче булып эшли.

1861 нең декабреннән 1872 гә кадәр Казан ун-тында (1863 тән төрек-татар телләре кафедрасында экстраординар проф.), бер үк вакытта 1863–70 тә Руханилар академиясендә укыта.

Якын Көнчыгыш илләреннән кайткач (1854), аеруча 1860 елларда, И. Россия империясенең рус булмаган халыкларын — әҗнәбиләрне (беренче чиратта мөселманнарны, ә алар арасында — татарларны) христианлаштыруның форма һәм алымнарын камилләштерү проблемасы өстендә ныклап эшли . Чукындырылган татарларга гыйбадәт кылу өчен чиркәү әдәбияты тәрҗемәләренең аңлаешлылыгын өйрәнү максатында Мамадыш өязе авылларына бара, Казан губернасының Чистай һәм Спас өязләрендә була һәм, православие чиркәвенең миссионерлык эшен тамырдан үзгәртергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Үз идеяләрен һәм тәкъдимнәрен тормышка ашыру өчен И. 1864 тә *Казан үзәк керәшен-татар мәктәбен* ачуга ирешә, соңыннан бу уку йорты Казан һәм күрше губерналарның миссионер мәктәпләре өчен фәнни-методик үзәк ролен үти.

И.ның әҗнәбиләрне христианлаштыру буенча тәкъдимнәре һәм карашлары (к. *Ильминский системасы*) Россия җәмгыятендә көчле бәхәсләр тудыра, әмма ул Казан укыту округы попечителе П.Д.Шестаковның, халык мәгарифе министры Д.А.Толстойның яклавын таба, Изге Синод һәм Александр II тарафыннан хуплана. 1872 дә И. *Казан укытучылар семинариясенә* нигез сала, бу семинария татар, чуаш, мордва, мари һәм удмурт миссионер мәктәпләре өчен укытучылар әзерли. Ул ачылгач, И. Казан ун-тындагы укытучылык эшен бөтенләй ташлый һәм тулысынча семинария эшенә бирелә, гомеренең ахырына кадәр аның директоры булып кала. Миссионерлык эшчәнлегендә И. 1867 дә Казанда оештырылган *Изге Гурий борадәрлеге* тарафыннан көчле яклау һәм ярдәм ала.


И. миссионер мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре бастыра: керәшен татарлар өчен кириллица нигезендә әлифбалар, казакъ теле грамматикасы һәм сүзлеге, казакъ мәктәпләре өчен рус телен үзлегеңнән өйрәнү дәреслеге һ.б.; татар теленә Бытие китабын, Матфейдан бирелгән Инҗилне, пасха гыйбадәте текстын һ.б. тәрҗемә итә.

Көнчыгышны өйрәнүдә И. 16 йөзгә караган чагатай әдәбиятының күренекле истәлеге «Бабурнамә яисә Бабур солтан язмалары»н табуы һәм 1857 дә бастырып чыгаруы б-н билгеле. Руська монгол ханнары яулары тарихы, Казан ханлыгы, татар, казакъ тел белемнәре тарихы мәсьәләләре буенча язмалар авторы. Аның шәкертләре һәм эшен дәвам итүчеләр арасында В.Т.*Тимофеев*, казакъ педагог-мәгърифәтчесе И.Алтынсарин (1841–89), И.Я.*Яковлев*, Н.А.*Бобровников* бар. Ш.у. к. *Ильминский алфавиты*.

Х е з м.: История пророков Рабгузы на джагатайском наречии. К., 1859; Самоучитель русской грамоты для киргизов. К., 1861; О фактических отношениях между чувашским и тюркским языками // Изв. и уч. зап. Имп. Казан. ун-та. 1865. Т. 5; Из переписки по поводу применения русского алфавита к инородческим языкам. Казанская центральная крещёно-татарская школа. К., 1883.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П.В. На память о Николае Ивановиче Ильминском. К., 1892; Р о ж д е с т в и н А. Николай Иванович Ильминский и его система инородческого образования в Казанском крае. К., 1900; Николай Иванович Ильминский: Сб. статей. К., 1916; Библиографический словарь отечественных тюркологов. Дооктябрьский период. М., 1989. *Г.С.Сабирҗанов.*

**ИЛЬМИ́НСКИЙ АЛФАВИТЫ́**, керәшен татарлар өчен эшләнгән махсус букварь (әлифба). Библиянең аерым китаплары һ.б. дини әдәбиятның Н.И.*Ильминский* һәм В.Т.*Тимофеев* эшләгән тәрҗемәләрен бастыру барышында 19 йөзнең 2 нче яртысында (1862 елдан башлап) төзелә. Башта татар текстларын рус алфавиты хәрефләре б-н бастыру күздә тотыла, ләкин уку процессын оештыру һәм миссионерлык әдәбиятын тарату тәҗрибәсе татар телендәге авазларны бирү өчен өстәмә хәрефләр кирәклеген күрсәтә. Алар акрынлап кертеләләр. Керәшен-татар мәктәпләре өчен әлифбаларда (1862) бер хәреф өстәлә, Гайсә, Сирах улы Китабының икенче басмасында (1866), барлык өстәмә хәрефләр дә кулланыла. Алфавит һәм язу нормалары 1874 елда төзелгән әлифбада ту-



БУКВАРЬ

ДЛЯ КРЕЩЕНЫХЪ ТАТАРЪ.

Татарскій отдѣлъ.

А, а. Л, л. Ал, А-ла. Ал-ла.

М, м. Ал-ла-м. Ма-л. А-ла-м. Ал-ма. Ал-ма-м.

Т, т. Ат. А-та. А-та-м. Тал. А-та-ла. А-та-лам.

Ш, ш. Аш. А-ша. А-ша-ма. А-шат. А-шат-ма. Таш. Таш-ла. Таш-ла-ма. Таш-лаш.

У, у. Ул. Ут. Мул. У-ша. Ту-та. Ту-там. Ау. А-ул. Шау. А-шау. Лау.

1874 елгы букварьның бер бите.

лысынча рәсмиләштерелә, ул 11 тапкыр яңадан бастырыла һәм 1917 елга кадәр миссионерлык, борадәрлек, земство, чиркәү-приход мәктәпләрендә керәшен татарлар өчен бердәнбер әлифба була. Рус алфавитындагы хәрефләргә бары 4 яңа хәреф өстәлә; «в», «ц», «ф», «щ», «ъ» хәрефләре, ш.у. 1918 елда гамәлдән чыгарылган «і», «ѳ» хәрефләре бары тик рус сүзләрендә генә кулланыла. Алфавит дәүләт инстанцияләре тарафыннан расланмый, китаплар «керәшен-татар шивәсендә рус хәрефләре б-н» басылалар, — дип санала. И.а.ында 160 исемнән артык китап басыла, ш.и. Изге язма, гыйбадәт китаплары, яшәеш турындагы һәм дини әдәбият тәрҗемәләре, ш.у. башлангыч мәктәпләр өчен дәреслекләр, гигиена һәм а.х. буенча брошюралар, шигырь җыентыклары басыла. И.а.нда «*Сугыш хәбәрләре*», «*Дус*» г-талары чыга. Совет чорында И.а. башлангыч мәктәпләрдә, Казан керәшен пед. техникумында кулланылуын дәвам итә, 1918–29 да 90 нан артык исемдә китаплар бастырыла: дәреслекләр, В.И.Ленин, И.В.Сталин әсәрләренең тәрҗемәләре, коммунистик агитация һәм фәнни-популяр әдәбият, шигырьләр, пьесалар. 1930 да бердәм татар алфавиты буларак *яңалиф* кертелү б-н И.а. кулланыштан чыга. 1990 еллар башыннан Рус Православие чиркәве һәм Библия җәмгыяте революциягә кадәрге китапларны яңадан бастыруда һәм шулай ук Изге Язманың, гыйбадәт китапларының яңа тәрҗемәләрендә И.а.н кабат кулланышка кертә. И.а. ш.у. керәшен-татар иҗтимагый оешмаларының басмаларында кулланыла.

*Е.В.Липаков.*

**ИЛЬМИ́НСКИЙ СИСТЕ́МАСЫ**, Рус Православие чиркәвенең Урта Идел, Урал буе һәм Россия империясенең рус булмаган халыклар арасында миссионерлык эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар җыелмасы. 1860 елларда Казан руханилар академиясе һәм Казан ун-ты проф. Н.И.Ильминский тарафыннан эшләнә. Министр граф Д.А.Толстой рәислегендә Халык мәгарифе министрлыгы советының (коллегиясенең) 1870 елның 2 феврале карары б-н барлык әҗнәби христиан мәктәпләренә кертү тәкъдим ителә. И.с.ның төп идеяләрен Александр II хуплаганнан соң, 1870 нең 26 мартында Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан «Россиядә яшәүче әҗнәбиләргә белем бирү чаралары турында кагыйдәләр» («Правила о мерах к образованию населяющих Россию инородцев») басыла. Үз системасын нигезләп Ильминский рус булмаган халыкларны тупас адм.-полиция чаралары б-н көчләп христианлаштыру һәм руслаштыру аларны рус халкыннан һәм православиедән читләштерә генә, чөнки алар миссионерларның үгет-нәсихәтләрен рус телендә аңлый һәм кабул итә алмыйлар, дип дәлилли. Әҗнәбиләр православиене аңлап һәм тизрәк кабул итсеннәр өчен, укыту-өйрәтүне аларның ана телендә алып барырга кирәк, ди.

И.с. буенча Россиянең бөтен рус булмаган халыклары 3 категориягә бүленә. Беренче категориягә ана теле үзенчәлекләре, исламга һәм мөселман культурасына тугрылыклары аркасында христианлаштыруга һәм руслаштыруга начар бирелүче халыклар — беренче чиратта, татарлар, ш.у. башкортлар, Урта Азия халыклары, казакълар, Төньяк Кавказ халыклары һәм чуашларның мөселманлашкан өлеше керә. «Кагыйдәләрдә» «христиан укуларын...» аларның үз ана телләрендә, ләкин рус алфавитында язылган дәреслекләр буенча башлау каралган. Моннан тыш, Ильминский, православие китапларын татар теленә тәрҗемә иткәндә, укымышлы татарларга гына аңлаешлы булган әдәби телне кулланмаска, ә халыкның сөйләм лексикасыннан файдаланырга кирәк, дип саный. Бу төркем халыкларның балалары, рус алфавиты нигезендә укырга-язарга өйрәнүе дәрәҗәсенә карап, тулысынча рус телендә укытуга күчерелергә тиеш була. Икенче төркемгә, күптән инде руслар арасында яшәп, рус культурасыннан күп нәрсәне үзләштергән халыклар керә, мәсәлән — мордва, удмурт һәм чуашларның бер өлеше һ.б. Бу төркем халыкларның балалары өчен мәктәпләрдә укыту баштан ук рус телендә алып барылырга тиеш була, ләкин укытучылардан укучының ана телен белүе дә таләп ителә: укучыларга аңлашылмаган әйберне аларның ана телендә төшендерә белү кирәк. Өченче төркемгә телләр буенча якын халыклар керә: белорус, украин һ.б. Бу мәктәпләрдә ана телен куллану тыелган булырга тиеш.

Керәшен татарлар, чуаш, мари, удмурт балаларын укыту өчен Ильминский тарафыннан рус графикасы нигезендә махсус әлифба эшләнә һәм 1862 дә керәшен татарлар өчен әлифба басыла (1864 һәм 1867 дә аның төзәтелгән һәм камилләштерелгән басмалары чыгарыла). Укытучы-миссионерлар әзерләү өчен Ильминский тырышлыгы б-н 1864 тә *Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе* ачыла, 1866 дан аның ф-ллары Казан губернасы, Чуаш, Удмурт, Мари төбәкләре авылларында ачыла башлый. 1871 дә *Сембер чуаш укытучылар мәктәбе* оештырыла. 1872 дә Ильминский җитәкләгән *Казан укытучылар семинариясе* эшли башлый.

И.с. исламга һәм кайбер рус булмаган халыкларда сакланган мәҗүсилеккә генә түгел, ә бәлки Урта Идел, Көньяк Уралның аз сандагы рус булмаган халыкларына, казакъ һәм кыргызларга татар теле һәм мәдәниятенең йогынтысын йомшартуга, ә киләчәктә тамырдан юкка чыгаруга юнәлтелгән була.

И.с., патша хөкүмәтенең озакка сузылган сәяси басымы б-н кушылып, Россия империясенең рус булмаган халыклары арасында православиенең таралуына китерә. Аерым алганда, 19 йөз ахырына 98% чуашлар, 97% марилар, 100% мордвалар христиан динен кабул итә. 19 йөздә якынча 200 мең татар православиегә күчерелә, шуларның якынча 130 меңе хәзерге Татарстан терр-ясендә яшәүчеләр була.

И.с. 1917 елның февраленә кадәр кулланыла. Ул, рус булмаган халыкларны христианлаштыру һәм милли ассимиляцияләү б-н беррәттән, ирексездән алар арасында грамоталылыкның үсүенә, милли педагогик кадрлар әзерләүгә ярдәм итә, нәтиҗәдә күп шәхесләр үз халыкларының мәдәни-милли яңарышы өчен актив көрәшчеләр булып китәләр (И.Я.Яковлев, М.Е.Евсевьев, И.С.Михеев, А.Ф.Юртов һ.б.).

Чыг.: Сборник документов и статей по вопросу об образовании инородцев. СПб., 1869; Ильминский Н.И. О системе просвещения инородцев и о Казанской центральной крещёно-татарской школе // Курсив и дополнения А.А.Воскресенского. К., 1913.

*Әд.:* Рождествин А. Николай Иванович Ильминский и его система инородческого образования в Казанском крае. К., 1900; Николай Иванович Ильминский: Сб. статей. К., 1916; Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей, как один из методов национальной колониальной политики царизма в Татарии (с половины 16 в. до февраля 1917 г.) // Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1. С. 226–285.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**И́ЛЬСКАЯ** (Хуҗасәетова) Фатыйма Салих кызы (13.12.1902, Оренбург ш. — 16.11.1984, Казан), драма актрисасы, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты (1939, 1967). Сәхнә эшчәнлеген 1915 елда Оренбургтагы «Ширкәт» театр труппасында башлый, 1916 дан «Сәйяр» труппасында, 1918–19 да Ташкент татар драма театрында, 1919–21 дә Көнчыгыш фронтның Идел буе политбүлеге театрында эшли. 1922–23 тә яңадан Ташкентта, 1924 елдан Казанда Татар дәүләт театрында (хәзерге Татар акад. театры). С.Гыйззәтуллина-Волжскаяның героик-романтик традицияләрен дәвам итеп, югары пафос һәм күтәренке романтик хисләрнең хатын-кызларга хас мөлаемлык, кайчакта шаянлык һәм үткенлек б-н үрелеп бара торган кабатланмас үз стилен булдыра. Ул тышкы бизәкләрне, аерым детальләрне, сурәтләү чараларын сайлауга зур игътибар бирә, һәр героиняның үзенә генә хас, драматургик материалның һәм ш.у. тарихи чорның стиленә туры килерлек сыйфатларын таба. И. башкарган үзенчәлекле һәм романтик рольләрдән Турандот («Хан кызы Турандот», К.Гоцци, 1927), Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1934), Трильби (шул исемдәге пьеса, Г.Г.Ге, 1924) образларын күрсәтергә мөмкин. Артистка башкарган Сюзанна («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше, 1938) чын мәгънәсендә үз халкының кызы: аның шаянлыгы, кызу темпераменты артында каршылыклы характер, эчке бәйсезлеккә омтылу хисләре ята. Джульетта ролендә («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир, 1940) И. героиняның юаш кына кыздан



Ф.С. Ильская Таня ролендә (А.Н. Арбузовның шул исемдәге пьесасы).



Ф.С.Ильская.

үз-үзен яклый алырлык, үз бәхете өчен көрәшергә әзер торырлык акыллы хатын-кыз булып җитешкән образын гәүдәләндерә. И. Катериналың («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский, 1944) чын фаҗигасен, артык иркә, тәкәббер Диананың («Печән өстендәге эт», Лопе де Вега, 1942) шуклыгын, нәфислеген ышандырырлык итеп күрсәтә. Татар драматургиясе әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә дә шактый әһәмиятле образлар тудыра: Фатыйма («Тормыш җыры», М.Әмир), Рокыя («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Зөһрә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Факиһә («Беренче театр», Г.Камал), Дилбәр («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Айсылу («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт). А.Н.Арбузов әсәре буенча куелган «Таня» спектаклендәге (1940) Таня образы актриса уйнаган иң уңышлы рольләрдән санала. И. сабыйларча беркатлы, бераз җилбәзәк, үзен генә кайгыртучы кызның көчле характерлы, кеше кайгысына битараф



Ф.С.И л ь с к а я Зөһрә ролендә (Ф. Бурнаш, «Таһир-Зөһрә»).

булмаган, киң күңелле хатын-кыз булып формалашу процессын психол. төгәллек б-н гәүдәләндерә. Аннан соңгы елларда да И. характерлар өстендә эшләүгә зур игътибар бирә; тышкы бизәкләргә, аерым детальләргә тагын да ныграк таләпчәнлек күрсәтә. Аның героинялары — Софья («Соңгылар», М.Горький, 1952), Җир-Ана («Умырзаялар», Ю.Әминов, 1960), Фатыйма Сабри (С.Җамалның шул исем. әсәре, 1967), Кончетта («Бәйрәм кичендә», Э. де Филиппо, 1966) — аз сүзле, зирәк акыллы, сабыр холыклылар. Глафира, Чебоксарова («Соңгы корбан», 1968; «Котырган акчалар», 1962, А.Н.Островский), Тутакай («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт, 1968) образлары яңача чагылдырылулары б-н аерылып торалар: алар тормыш сөючән, үз максатларына ирешү өчен бернидән дә куркып тормыйлар. Сәхнә мөлаемлылыгына ия, тамашачыны хисләренең тирәнлеге һәм көчлелеге б-н таң калдыручы актриса буларак, И. татар театры тарихына зур сәхнә остасы булып кереп кала. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Башка рольләре: Эльмира («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Корделия («Король Лир», У.Шекспир), Беатриче («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Елена («Ят күләгә», К.М.Симонов), Сабира («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Маргыйдә («Хөррият», М.Әмир).

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*И.И.Илялова.*

**ИЛЬЯ́ЗОВ** Рафаэль Шәрифзыя улы (22.3.1942, Баку), дипломатия хезмәткәре, юридик фән. канд. (1974), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1952–60 елларда «Гюрганнефть» (Баку) НГДУында эшче. 1961–65 тә Каспий югары хәрби-диңгез уч-щесе инженеры. 1966–68 дә Казанда: ВЛКСМның Ленин райкомы оештыру бүлеге мөдире. 1968–70 тә СССРның Төньяк-Көнбатыш төбәге а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты (Ленинград) кече фәнни хезмәткәре. 1973–91 дә Әзәрбайҗан КП ҮКнда эшли. 1991–93 тә Әзәрбайҗан таможня идарәсенең дежурлык хезмәте башлыгы, Әзәрбайҗан МКның Тышкы икътисади элемтәләр идарәсендә әйдәп баручы белгеч. 1993–2005 тә ТРның Әзәрбайҗандагы даими вәкиле.

*Әд.:* Кто есть кто. Баку, 2000.

**ИЛЬЯ́ЗОВ** Роберт Гыйниятулла улы (10.5.1954, Чүпрәле р-ны Иске Дуван а.), эколог, радиобиолог, биол. фән. д-ры (1992), проф. (1992), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001). 1982 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, Чүпрәле р-нының Калинин исем. к-зында баш вет. табибе булып эшли. 1983–86 елларда Бөтенсоюз вирусология һәм микробиология вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Владимир өлкәсе, Покров ш.). 1986–98 дә Белоруссия Респ-касы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Радиология фәнни-тикшеренү ин-тында. 1998–99 да «Татарстан кыры» ФҖБндә экология лаб-ясе мөдире. 1999–2000 дә Казан техник ун-тында Физик-химик процесслар ин-ты директорының фән буенча урынбасары, бер үк вакытта 1999 дан ТР ФА а.х. фәннәре бүлегенең гыйльми сәркәтибе, ТР ФАнең экологик мәсьәләләр лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре экологик чиста а.х. продукциясе җитештерүнең теоретик нигезләрен эшләүгә һәм гамәли ысулларын кертүгә, радиацион һәлакәттән соңгы һәм нефть табу индустриясе, нефть-химия сәнәгате тәэсире зоналарында агроэкосистеманың техноген пычрану шартларында продукция бирүче терлекләрне саклауга һәм а.х. җирләрен яңадан файдалануга тапшыруга карый. Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша. Батырлык ордены б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы, 2 патенты бар.

Х е з м.: Радиоэкология сельскохозяйственных животных. К., 2000 (автордаш); Радиационные аварии и ликвидации их последствий в агросфере. К., 2004.

**ИЛЬЯ́ЗОВА** Эльмира Ибраһим кызы (5.5.1942, Әзәрбайҗан Респ-касы, Нуха ш., хәзер Шеки ш.), биотехнолог, техник фән. д-ры (1991), проф. (2001). Әзәрбайҗан ун-тын тәмамлый (1965). Совет сәүдәсе ин-тының Казан ф-лында укыта (1970–72). 1972–80 елларда Әзәрбайҗан ССР ФАнең Биологик тикшеренүләр фәнни үзәгендә хезмәткәр. 1980–88 дә Әзәрбайҗан халык хуҗалыгы ин-тында, 1989–90 да Ленинград финанс-икътисад ин-тының Баку ф-лында, 1990 нан Әзәрбайҗан коммерция ин-тының азык-төлек товарлары белеме каф. профессоры. Хезмәтләре бодай гибридларының биологик-технол. үзенчәлекләрен тикшерүгә карый. Бөртектә һәм бөртекле азыкларда аксымнарның дисульфид-тиоллы алмашында мөһим роль уйнаучы һәм клейковинаның физ. күрсәткечләренә йогынты ясаучы селеноферментны (глутатионпероксидаза) ача. Икмәк ризыклары әзерләүнең яңа алымнарын тикшерә һәм производствога кертә. 1996 дан Ш.Мәрҗани исем. Әзәрбайҗан хәйрия фонды президенты.

Х е з м.: Иммунохимическое исследование белков межродовых и межвидовых гибридов пшеницы и их родительских форм. М., 1971; Хлеба Азербайджана. Баку, 1985; Совершенствование технологии и улучшение качества национальных хлебопродуктов Азербайджана. М., 1988.

**ИЛЬЯ́С** (Ильясов) Габдулла (1905–1938), язучы. 1927–32 елларда кызылармиячеләр тормышы турында «Штык» повестен (1931), «Фонтан» (1927), «Промыселлар чатында» (1928), «Получка» (1929), «Тимер адымнар» (1929), «Көләч иртә» (1931), «Хикәяләр җыентыгы» (1932) исемле повесть һәм хикәяләр җыентыкларын бастыра. Мәскәүдә яшәп, андагы пролетар язучылар ассоциациясенең (МАПП) татар секциясе әгъзасы булып тора.

**ИЛЬЯ́С** (Ильясов) Рахман (Габдрахман) Вәкил улы (15.3.1908, Зөя өязе Карамасар а. — 23.8.1943), язучы. 1920 елларда Төньяк Кавказда нефть промыселларында эшли. 1931–32 елда Татар коммунистик ун-тында укый (Казан), 1933 тән газеталар редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында, Язучылар берлегендә, Главлитта эшли. Әсәрләрендә төп игътибарын нефтьчеләр һәм тау халыклары тормышына юнәлтә: «Кем гаепле?» (1930), «Шәрифҗамал» (1932), «Таулар арасында» (1935), «Чыныгу» (1933) һ.б. «Танышлар» (1939) , «Фонтан» (1940) исемле пьесалар авторы. 1941 дә үз теләге б-н фронтка китә, Харьков тирәсендә барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* Д а у т о в Р.Н., Н у р у л л и н а Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ИЛЬЯСИ́** Габдрахман Мөхәммәдәмин улы (1856, Казан — 1895, шунда ук), драматург, археограф. «Касыймия» мәдрәсәсендә укый. Рус теле һәм әдәбиятыннан дәресләр ала. Контора хезмәткәре, хисапчы булып эшли. К.Насыйридан төгәл фәннәр нигезен өйрәнә, йолдызларны күзәтә. Аның б-н бергә татар авылларына чыгып, фольклор әсәрләре, язма чыганаклар җыя. Татар телендәге тарихи кулъязмаларны өйрәнә, алар турында Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә чыгышлар ясый. 1855 елдан бу җәмгыятьнең әгъзасы була. 1887 дә, үз мөхәррирлегендә татар телендә «Казан» г-тасы чыгару өчен рөхсәт сорап,

Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Матбугат эшләре баш идарәсенә мөрәҗәгать итә. Рөхсәт бирелми. И. — татар әдәбияты тарихында беренчеләрдән булып хатын-кыз мәсьәләсен яктырткан автор. Аның «Бичара кыз» әсәре (1887) — татар матбугатында беренче булып басылган пьеса. Әсәрдә заманы өчен актуаль булган шәхес иреге, хатын-кызларның ирләр б-н бертигез хокукка ия булу, татарларны укыту мәсьәләләре күтәрелә. Әсәрнең төп героинясын — укымышлы Маһитапны — залим, карун атасы бай малае исерек Җантимергә кияүгә бирмәкче була. Маһитапның күңеленә тәрбияле, укымышлы Җанбай һуш килә. Пьесада һәртөрле яңалыкка, прогрессив карашларга каршы чыгучы тискәре типлар да бар.

Әсәр җанлы, халык сөйләменә якын тел б-н язылган, персонажлар сөйләмендә диалект сүзләре дә очрый. Аерым кимчелекләре (композициясенең артык гадилеге, образларның гел бертөрле булуы, хәрәкәт җитмәү) булса да, пьеса куелган мәсьәләләрнең актуальлеге б-н кызыксыну уята. Бу әсәргә ияреп, Ф.Халиди «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасын яза. И.нең «Яшь кыз вә хатынларга һәдия» (1887) исемле нәсыйхәт-публицистик рухта язылган китабы гаиләдә балалар тәрбияләү мәсьәләсенә кагыла. Бу китапның кереш сүзендә автор хатын-кызларга багышланган тагын да күләмлерәк китабын басмага әзерләве турында яза. Ләкин ул китапның язмышы билгесез.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ИЛЬЯ́СОВ** Әхәт Вахит улы (2.7.1936, Казан), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1974), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), академигы (2009), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1986, 1995). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1962 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында: радиоспектроскопия лаб-ясе мөдире (1974 тән), баш фәнни хезмәткәр (2002 дән). Бер үк вакытта 1980–90 да Казан химия-технол. ин-ты профессоры һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка мед. диагностика үзәгендә ТМР-томография төркеме җитәкчесе. 2007 дән ТР ФА Президенты киңәшчесе. Хезмәтләре органик химиядә һәм медицинада магнит радиоспектроскопиясен куллanышка кертүгә карый. И. ион радикалларын һәм комплексларын электрохимик генерирлау җайланмасын һәм методикасын эшли, ул Латвия, Швейцария, Германиянең фәнни учреждениеләрендә файдаланыла; аның тарафыннан яңа ирекле радикаллар — фосфорлы нитроксиллар һәм иминоксиллар классы табыла һәм үзлекләре өйрәнелә. И. фосфор төшенең химик полярлашу күренешен ача (1972) һәм реакциягә керү механизмын ачыклый; ТМР-томография ярдәмендә диагноз кую ысулын, тере тукымаларда барлыкка килгән яман шешне киметү өчен локаль гипертермия ысулын үстерә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). СССРның уйлап табучысы (1990). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Спектры ЭПР органических ион-радикалов. М., 1980 (автордаш); Фосфоросодержащие нитроксильные и иминоксильные свободные радикалы // Конформационный анализ элементоорганических соединений. М., 1983 (автордаш); Спектры ЭПР и стереохимия фосфоросодержащих свободных радикалов. М., 1985 (автордаш); ESR of Elektrochemical generated radical ions and complexes // Magnetic resonance review. USA. 1993. V. 16 (автордаш); Медицина диагностикасында ТМР-томография // Фән һәм тел. 2001. Т. 2 (автордаш).

**ИЛЬЯ́СОВ** Гали (Әхмәтгали) Гани (Миңнегани) улы (24.7.1936, Сучан ш., хәзер Приморье крае Партизанск ш. — 16.11.2000, Казан), җырчы (тенор), ТАССРның халык (1979), РСФСРның атказ. артисты (1987). 1965–94 елларда Татар филармониясе солисты, 1994–98 дә «Иҗат» берләшмәсендә вокал укытучысы. Үзен лирик пландагы җырчы буларак таныта. И.ның киң диапазонлы иҗат мөмкинлекләре, тавышының бай тембр төсмерләре аеруча аерылып тора. Искиткеч зур вокаль мөмкинлекләренә таянып, ул концерт репертуарына опералардан арияләр, камера вокаль әсәрләрен, эстрада һәм халык җырларын кертә. Опералардан И. башкарган Рудольф («Богема», Дж.Пуччини), Ленский («Евгений Онегин», П.Чайковский), Левко («Май төне», Н.Римский-Корсаков), Алеко (шул исем. опера, С.Рахманинов) арияләре, ш.у. рус һәм чит ил композиторларының романслары аеруча киң танылa. Җырчы татар композиторларының вокаль музыкасын пропагандалауга зур өлеш кертә. Шулай ук үзе дә вокаль әсәрләр авторы буларак киң танылa, «Мандолина» (Г.Зәйнашева шигыре), «Синең өчен» (Җ.Дәрзаман), «Татар кызы» (Н.Арсланов), «Әнкәй, синең куллар» (К. Шәфикова) кебек шактый популяр җырлар иҗат итә. Бу җырлар күп кенә җырчыларның репертуарына керә. И. актив концерт эшчәнлеге алып бара, ш.и. Англия, Германия, Австрия, Италиядә, Африкада гастрольләрдә була; радио һәм телевидениедән даими чыгышлар ясый. Вокалистларның Бөтенроссия конкурсы лауреаты (1972).

*Ф.Ш.Салитова, А.Р.Рахмани.*

**ИЛЬЯ́СОВ** Дәллюс Гали улы (26.12.1922, Әстерхан ш. — 16.8.1981, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. һәм халык артисты (1957, 1974). Г.С.*Камскаяның* улы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Совет Армиясе сафларыннан демобилизацияләнгәннән соң, Мәскәү Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы татар студиясен (ГИТИС, 1949) һәм шул институтның актёрлык ф-тын (1955) тәмамлый. 1949–50 елларда Бөгелмә рус драма, Казан Яшь тамашачылар театрларында эшли. 1950 дән Татар акад. театры труппасында. Күпкырлы, пластик, музыкаль, җырчы тавышына ия, күркәм тышкы кыяфәтле актёр буларак, И. муз. драма һәм комедияләрдә баш рольләрне башкара: Хәлил, Бакый («Галиябану», «Ак калфак», М.Фәйзи), Ильяс («Казан сөлгесе», К.Тинчурин). Беренче рольләрендә үк образны психол. яктан күрсәтергә, һәр персонажның үзенчәлекле тышкы бизәкләрен табарга омтыла. Характерлы рольләрне башкарганда актёрның сәләте тагын да ныграк ачыла. И. тарафыннан башка-



Г.Г.Ильясов.



Д.Г.Ильясов.

рылган Пена («Чамасына күрә чарасы», У.Шекспир), Базиль («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), Һашим («Ефәк сүзәнә», А.Каххар), Камәретдин («Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Галим («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин) образлары фантазиянең байлыгы, импровизаторлык сәләте, төгәл тормышчанлыгы б-н аерылып торалар. Сәнгатьтә реалистик юнәлеш тарафдары буларак, актёр образ өстендә эшләгәндә конкрет тормыш һәм социаль тирәлек хәлләрен төгәл бирергә, үз героеның һәр эш-хәрәкәтен психол. яктан нигезләргә тырыша. Ул башкарган күренекле рольләр арасында Сибгат («Тын



Д.Г.И л ь я с о в һәм Г.Г.Камалова Г.Камалның «Беренче театр» спектаклендә.

алан», С.Кальметов), Игорь («Туган туфрак», С.Шәкүров), Низами («Тирән тамырлар», Г.Ибраһимов), Актай («Кол Гали», Н.Фәттах), Ханбик («Бәхтияр Канкаев», Т.Миңнуллин), Родриго («Отелло», У.Шекспир), Самохвалов («Ешрак елмаегыз», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов) образлары бар. Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әлмәндәр картның сугыштан гарипләнеп кайткан улы Искәндәр образы И. иҗатында аеруча әһәмиятле урын алып тора. Озак еллар дәвамында сәүдә хезмәткәрләре клубында, ТАССРның 10 еллыгы исем. мәдәният сараенда үзешчән театр коллективларын җитәкли, театр сәнгате турында лекцияләр укый.

Ә с ә р.: Үзешчән театр. К., 1957 (автордаш).

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*И.И.Илялова.*

**ИЛЬЯСО́В** Җәүдәт Хәсән улы (16.2.1929, БАССРның Ярмәкәй р-ны Исламбахты а. — 19.6.1982, Ташкент), язучы. Рус телендә яза. 1931 елдан Ташкентта яши. 1953 тән «Комсомолец Узбекистана», «Физкультурник Узбекистана», «Ташкентская правда» г-таларында эшли, «Звезда Востока» ж-лында поэзия бүлеге мөхәррире була. Беренче шигырьләре һәм хикәяләре 1949 да Ташкентта басылып чыга. Язучының иҗат кыйбласын тарихның борылыш мизгелләрендә халыклар язмышы б-н кызыксыну билгели. Аның геройлары — гаделлек, ирек һәм бәйсезлек өчен көрәшүчеләр, аларның прототиплары булып аерым очракларда чын тарихи шәхесләр тора. «Нәфрәт сукмагы» («Тропа гнева», 1956) исемле беренче тарихи повесте массагетларның Урта Азиягә басып кергән фарсыларга каршы көрәшен чагылдыра. «Согдиана» романы (1959) Александр Македонскийның Урта Азиягә походын тасвирлый. «Тимгелле үлем» («Пятнистая смерть», 1964) романы да тарихи тематика б-н бәйле. Аның сюжетына «Томирис» балеты языла (У.Мусаев муз., О.Узаков либр.) һәм ул Кыргыз опера һәм балет акад. театрында (Фрунзе, 1982) һәм А.Нәвои исем. Үзбәк Зур опера һәм балет театрында (Ташкент, 1984) куела. 1965 тә И.ның (А.Ташкенбаева б-н берлектә, 1963) сценарие буенча «Канатта йөрүче» («Канатоходец») исемле нәфис фильм төшерелә (реж. Р.Батыров). «Алтын пот» («Золотой истукан», 1973) повестенда автор дин, тормыш мәгънәсе, язмыш, яхшылык б-н явызлык арасындагы мәңгелек каршылык турында фикер йөртә. 1979 да урта гасырлар галиме һәм шагыйре Гомәр Хәйямгә багышланган трилогиянең беренче китабы — «Еланнар әфсенләүче» («Заклинатель змей») басылып чыга. Трилогиянең «Тынлык манарасы» («Башня молчания») исемле икенче китабы язылып бетми кала. Авторның вафатыннан соң басылган «Анахита үче» («Месть Анахиты», 1984) повестенда гаскәр башлыгы Марк Красснның Парфиягә походы (б.э.к. 52 нче ел), Рим легионнарының җиңелүе һәм һәлакәте тасвирлана. И. рус теленә гарәп, корея, үзбәк, таҗик, башкорт, каракалпак язучылары һәм шагыйрьләре (М.Сумадах, Г.Голәм, Д.Угая, К.Даян, Ә.Мохтар, Җ.Мөхетдин, Миртимер, С.Әмин һ.б.) әсәрләрен тәрҗемә итә. И.ның әсәрләре үзбәк, татар, словак телләренә тәрҗемә ителә.

Ә с ә р.: Заклинатель змей. Башня молчания. Таш., 1986.

*Әд.:* Писатели Советского Узбекистана: Биобиблиогр. справ. Таш., 1977; Я ш е н К. Творческое вдохновение — на службу народу // Звезда Востока. 1981. № 1.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ИЛЬЯ́СОВ** Миңлегали Әхсән улы (9.3.1900, Әстерхан ш. — 13.9.1970, Казан), драма актёры, режиссёр. Сәхнә эшчәнлеген 1922 елда Әстерхан татар драма театрында башлый. Мәскәүдә Үзәк театр сәнгате техникумын тәмамлый. 1926–33 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театрында актёр, режиссёр, баш режиссёр булып эшли. Анда ул Ш.Камалның «Козгыннар оясында», «Ут», «Таулар», Р.Ишморат һәм К.Тинчуринның «Тургай», Ә.Камалның «Борылыш» әсәрләрен сәхнәләштерә, алардагы образларны заман сулышын тоеп, психол. яктан җентекләп эшли. Бер үк вакытта актёр буларак та шактый рольләр башкара: Оештыручы (С.Батталның шул исем. әсәре), Насрый («Козгыннар оясында», Ш.Камал), Директор («Тормыш көлә», Г.Ильяс). 1933 тә Мәскәү эшче театры Татар акад. театрының колхоз ф-лы итеп үзгәртелеп, Казанга күчерелә. Коллектив б-н бергә күчкән И. биредә К.Нәҗми һәм К.Тинчуринның «Булат бабай семьясы», Ш.Усмановның «Кичеккән фәрман», И.Сәлаховның «Мәхәббәт», Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», А.Н.Арбузовның «Алты сөекле яр» («Шестеро любимых») әсәрләрен куя. 1937 елда нигезсез репрессияләнә; реабилитациялəнгәч (1956), Казанга кайта. Әлмәт татар драма театрында С.Кальметовның «Зәкия», Г.Ахуновның «Чулпы җыры» әсәрләрен сәхнәләштерә.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ИЛЬЯ́СОВ** Радик Сабит улы (27.5.1951, Кукмара р-ны Түбән Арбаш а.), инженер-технолог, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТРның һәм РФнең атказ. химигы (2000, 2004). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), «Түбәнкамашин» АҖдә (бүленеп, 1982-85 елларда «Гидромонтаж» трестының монтаж участогы мастеры, Зәй ш.) эшли: җиһазлар бүлеге инженеры, смена башлыгы, цех башлыгы урынбасары, «Түбәнкамашин» ЖБ парт-комы секретаре, җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары б-н багланышлар бүлеге башлыгы, АҖнең ген. директоры урынбасары (1995 тән), ген. директоры (1997 дән). И. җитәкчелегендә АҖндә тамырдан үзгәртеп кору уздырыла; җиңел машиналар өчен елга 2 млн. данә «КАМА-EURO» радиаль шиннар (2004), экологик материаллардан резина катнашмалары (2007), автобуслар һәм йөк автомобильләре өчен елга 1,2 млн. данә тоташ металл кордлы шиннар җитештерү, «Конштрукта» фирмасының (Словакия) гермокатлам эшләү линияләре һ.б. файдалануга тапшырыла. Уйлап табуга 20 дән артык авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). 1999 дан ТР Дәүләт Советы депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ИЛЬЯ́СОВ** (Ильязов) Рафаил (Рафаэль) Зариф улы (28.4.1939, Чүпрәле р-ны Түбән Чәке а.), җырчы (тенор), музыка эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984), ТРның халык артисты (1991). 1963 елда Казан консерваториясен (Н.Г.Зуевич классы) гобой уен коралы буенча тәмамлый. 1964 тән ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тының (1992 дән «Татарстан» Дәүләт телерадиокомпаниясе) муз. тапшырулар бүлегендә өлкән редактор, бүлек мөдире булып эшли. Татар, рус, чит ил музыкасын пропагандалау буенча актив муз.-җәмәгать эшчәнлеге алып бара. Милли башкару сәнгате үсешенә зур өлеш кертә, Татарстанның танылган музыкантлары һәм җырчылары башкаруында татар җырларыннан, татар композиторларының әсәрләреннән фонд язмалары туплый. Авторлык проектлары арасында: «Осталык һәм остазлык», «Музыкаль редакция почтасыннан» исемле программалары, ш.у. танылган музыкантлар һәм җырчыларның иҗатына, тормышына багышланган аерым тапшырулар бар. Радио эшчәнлеген актив концерт эшчәнлеге б-н бергә алып бара. Вокаль башкаручы буларак зур популярлык казана. Җырчының бай репертуарына татар халык җырларыннан «Шахта», «Галиябану», «Рәйхан», «Шомыртым», «Алмагачлары», «Зөбәрҗәт», «Кошларга» һ.б.; С.Сәйдәшев, А.Ключарёв, Р.Яхин, С.Садыйкова, М.Макаров, Л.Батыр-Болгари, Р.Ахиярова, Ә.Бакиров, М.Мозаффаров һ.б. композиторларның әсәрләре керә. Җырлау манерасы көйне һәм текстны үтә нечкә сиземләве, милли вокаль башкару үзенчәлекләрен тирәнтен тоя белүе, тәэсирле нюансларга сәләтле булуы б-н аерылып тора. Россия һәм чит илләрдә (АКШ, Индия, Төркия, Финляндия, Польша, Австралия, Германия) гастрольләрдә чыгышлар ясый.



Р.З.Ильясов.

**ИЛЬЯ́СОВ** Шамил Гыймалетдин улы (20.8.1937, Казакъстан ССРның Акмола өлкәсе Яңа Ишем а.), химик-технолог, СССР, ТР Дәүләт премияләре лауреаты (1991, 2009), техн. фән. канд. (2002), ТРның атказ. төзүчесе (2003). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук, «Союзхимпромпроект» ин-тында эшли: баш инженер (1976 дан), директор (1990 нан). Хезмәтләре шартлаткыч матдәләр җитештерү технологияләрен проектлаштыруга һәм эшләүгә, авторлык күзәтчелегенә һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә карый. Махсус химия өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР МС (1982) һәм СССР Дәүләт премияләренә лаек була. ТР Дәүләт премиясе Казан дары з-дында конкурентлык сәләтенә ия булган продукция җитештерүнең диверсификацион технологияләрен булдыр-



Ә.Р.И л ь я с о в а. «Җимеш өзүче Мәрьям». 1992.



Ә.Р.Ильясова. «Кызыл һәм ак». 1993.

ганы өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ИЛЬЯ́СОВА** Әлфия Ринад кызы (20.10.1967, Казан), нәкышьче, график, гамәли-декоратив сәнгать рәссамы. 1986 елда Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый. 1986 дан ТРның Сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). И. иҗатында заманча постмодернистик рәсемнәр ясау тенденцияләре аеруча ачык чагыла: төрле чорларның Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләренә хас (Көнчыгыш урта гасырлар миниатюрасы, беркатлы-самими сәнгать, модернистик агымнар) стиль концепцияләре үзара үрелә. Баштарак мөмкинлекләрен *гобелен* сәнгатендә сыный («Намазлык», 1990), соңрак станлы графикага мөрәҗәгать итә, литография техникасында эшли, бу юнәлештә «Пегас», «Назлы иртә», «Күл буенда», «Шәүлә» (барысы да — 1992), «Төнге фәрештә», «Фатыйма киче», «Гарәфә көне», «Кәрван», «Кунакка» (барысы да — 1993) әсәрләрен тудыра. Нәкышь әсәрләре: «Җимеш өзүче Мәрьям», «Ай тотылганда» (икесе дә — 1992), «Фатыйма», «Корбан бәйрәме» (икесе дә — 1993), «Ак киемнәр» (1994), «Кол хатыннар» (1995), «Мадонна» (2000), «Ак атта», «Кәләш», «Туй» (барысы да — 2001) авторы. Аларда Библия һәм Коръән сюжетлары, гыйбрәтле хикәяләр, аллегорияләр чагылыш тапкан. И. үз картиналары стилендә ислам сәнгате традицияләренә таяна (гарәп миниатюрасы), сәнгать теленең шартлы-декоратив системасын (композициянең яссылыкта урнашуы, фронтальлеге, төсле локаль тапларның контрастлы кушылмасы, форманың төгәл стильләшүе) мифологик образлар системасы б-н берләштерә.

Респ-ка (1986 дан, ш.и. ТАССРның төзелүенә 70 ел тулуга багышланган; Казан, 1990); төбәк — «Зур Идел» (Казан, 1991; Түбән Новгород ш., 1998); бөтенроссия — «16 автономияле республика» (Мәскәү, 1991); бөтенсоюз — «Бөтенсоюз графика күргәзмәсе» (Владимир ш., 1992); халыкара — «Арт-Миф» (Мәскәү, 1993); чит илләрдә уздырылган — «Казаннан килгән сәнгать» (Зутфен ш., Нидерланд, 1995), «Филд Галлери» өчен Россиядән» (Изге Марфа утравы, АКШ, 1996) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре уза (Казан, 1994, 2004). Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда, «Туран» милли мәдәният үзәге фондында, чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Шаһиева Р. Ай тотылган көн // Казан утлары. 1994. № 5; Ахметова Д. «И к Вечной правде устремилось сердце» // Татарстан. 1996. № 2; Шагеева Р. День величиной в пятьдесят тысяч лет // Казань. 2002. № 11/12.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**ИЛЬЯ́СОВА** Гөлфия Хәлиулла кызы (1.6.1948, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кыр Бикшеге а.) вет. вирусологы, микробиолог, вет. фән. д-ры (1993). 1972 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1983 тән Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре аеруча куркыныч йогышлы авыруларга диагноз кую чараларын һәм ысулларын, иммунитетны фармакологик төзәтү ысулларын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 8 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.


**ИЛЬЯ́СОВА** Зөһрә Хәмит кызы (17.11.1950, Уфа), балет артисткасы, педагог, БАССРның халык (1979), РСФСРның атказ. артисты (1983). 1968 елда Ленинград хореография уч-щесен тәмамлый. 1969–79 да Башкорт опера һәм балет театры (Уфа ш.), 1980–90 да Татар опера һәм балет театры солисткасы. 1990 нан Уфа хореография уч-щесендә классик бию буенча педагог. И. үзен камил бию техникасына һәм югары профессиональлеккә ирешкән оста башкаручы итеп таныта. Төп партияләре: Сильфида (шул исем. балет, Х.Лёвеншель), Жизель (шул исем. балет, А.Адан), Одетта-Одиллия, Маша, Аврора («Аккош күле», «Щелкунчик», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», Р.Паулс музыкасы), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин).

*В.Н.Горшков.*

**ИЛЮ́ТКИНО** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* көнбатыштарак, Аксумла елгасы буенда. 2008 елда 311 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында Гәйтән авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Лаврандаево исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да земство мәктәбе, җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1477 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимовка волостенда, 1920 дән — ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 425, 1897 дә — 672, 1908 дә — 702, 1920 дә — 818, 1926 да — 744, 1938 дә — 640, 1949 да — 487, 1958 дә — 485, 1970 тә — 568, 1979 да — 412, 1989 да — 319, 2002 дә — 319 кеше.

**ИЛЯ́ЛОВА** Фәүзия Шаһимәрдән кызы (18.8.1924, Зөя кантоны Тутай а. — 6.7.1991, Казан), халык мәгарифе эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1980). 1948 елда Казан юридик ин-тын, 1963 тә КПСС ҮК каршында югары партия мәктәбен тәмамлый. 1948 дән СССР Юстиция министрлыгында, 1951 дән Татарстан курорт, шифаханә, ял йортлары идарәсендә, 1957 дән Татарстан Халык хуҗалыгы советында. 1959 дан КПССның Казан шәһәр ком-тында инструктор, 1960 тан КПССның Идел буе райкомы секретаре, 1963 тән КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1966–82 дә Татарстан респ-ка һөнәри-техник белем бирү идарәсендә. 1982–87 елларда ПФАнең һөнәри-техник пед. ин-тында. Октябрь революциясе ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**ИЛЯ́ЛОВЛАР** (Һилаловлар), мәдәният эшлеклеләре гаиләсе. *Һилалов* **Исмәгыйль Гобәйдулла улы**, музыкант-башкаручы, мандолиначы. **Исхак Гобәйдулла улы** (4.11.1899, Троицк ш. — 24.10.1966, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог. Троицк рус гимназиясен тәмамлый. 1919 елда Троицк татар театрында сәхнә эшчәнлеген башлый. 1922–26 да Уфа татар-башкорт театрында актёр, 1927–31 дә Ташкент үзбәк театрында режиссёр, 1931–33 тә Уральск татар-башкорт эшче театрында сәнгать җитәкчесе, 1933–35 тә Татар акад. театрында, 1935–42 дә Үзбәкстан акад. драма театрында актёр һәм режиссёр, 1942–48 дә Хорезм өлкә муз.-драма театрында сәнгать җитәкчесе, 1948 дән Ташкент театр ин-тында актёрлык осталыгы укытучысы. Куелган аеруча киң танылган спектакльләре: К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Ил», А.Нәвоиның «Фәрхәд һәм Ширин», «Таһир-Зөһрә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», К.Яшенның «Басып алучыларга үлем», М.Горькийның «Егор Булычов һәм башкалар», У.Шекспирның «Гамлет», Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» әсәрләре. **Һаҗәр Йосыф** кызы (7.3.1902, Троицк ш. — 14.4.1980, Казан), драма актрисасы. Исхак хатыны. Троицк рус гимназиясен тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеге 1919 да Троицк татар театрында башлана. 1922–26 да Уфа татар-башкорт театры, 1926–28 дә Ташкент үзбәк театры, 1928–30 да Әстерхан татар театры, 1931–33 тә Уральск татар-башкорт эшче театры, 1933–35 тә Татар акад. театры, 1935–42 дә Х.Хәмзә исем. үзбәк акад. драма театры, 1942–46 да Хорезм өлкә муз.-драма театры актрисасы. Актриса сәхнәдә искиткеч сөйкемле, драматик темпераментка, яхшы җырчы тавышына ия була. Төп рольләре: Офелия («Гамлет», У.Шекспир), Амалия («Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Адельма («Принцесса Турандот», К.Гоцци), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Гөлйөзем («Наёмщик», Т.Гыйззәт), Сара («Мирза Хөсәен», Ф.Борнаш), Гөлбаһар («Бай һәм батрак», Х.Хәмзә), Варвара («Яшенле яңгыр», А.Островский), Шурка («Егор Булычов һәм башкалар», М.Горький), Ильтани («Загмук», А.Глебов), Панова («Любовь Яровая», К.Тренёв) һ.б. *Һилалов* **Рәмзи Ибраһим** улы, язучы. Исмәгыйль һәм Исхак И.ның туганнан



Исмәгыйль Г. Илялов.

туган энеләре. **Ильтани Исхак** кызы (8.2.1932, Свердловск ш.), театр белгече, сәнгать фән. канд. (1965), ТАССРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1983, 2000). Исхак һәм Һаҗәр И.ның кызы. Ташкент театр ин-тын тәмамлый (1955). 1963–64 тә, 1968–89 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият, тарих ин-ты фәнни хезмәткәре, 1964–67 дә ТАССР Мәдәнияят министрлыгының сәнгать бүлеге башлыгы. Күпләгән китаплар, мәкаләләр, театр тарихына һәм хәзерге проблемаларына караган язмалар, ш.и. «Нәби Рәхимов» (Таш., 1962), «Хәзерге татар театрында актёрлык осталыгы» (1978), «Халык артистлары» (1980, автордаш), «Татар театрының милләтара элемтәләре» (1985), «Камал исемендәге театр» (1986), «Рус театры Казанда» (1991, автордаш), «Марсель Сәлимҗанов» (1993), «Шәүкәт Биктимеров» (1993), «Г.Камал театры артистлары: биографик белешмәлек» (1996, 2005) хезмәтләре авторы. И.Илялованың тикшеренүләре архив материалларына, режиссёрлар һәм актёрларның иҗади эшчәнлегенә хәзерге театр сәнгате контекстында анализ ясауга нигезләнә. Мәкаләләре, рецензияләре, иҗат портретлары «Театр», «Театральная жизнь», «Татарстан», «Идел» ж-лларында, үзәк һәм респ-ка газеталарында басыла. 1990 елдан Казан театр уч-щесендә, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында пед. эшчәнлек алып бара.

**ИЛЯ́ШКИНО** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 130 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостена керә. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 467, 1926 да — 528, 1938 дә — 496, 1949 да — 419, 1958 дә — 418, 1970 тә — 435, 1979 да — 406, 1989 да — 220, 2002 дә — 130 кеше.

**ИМ ҮЛӘНЕ́** (Bupleurum), чатырчәчәклеләр семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләннәр, сирәк кенә куак һәм ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — сары И.ү. (алтынсыман) (B. aureum) үсә. Барлык р-ннарда да очрый. Якты урманнарда, аланнарда, ерымнарда, елга тугайларында үсә. 15–20 *см* биеклектәге туры сабаклы күпьеллык үләнчел үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, озынча, аскылары ботаклы, өскеләре — утырма, сабакны әйләндереп үсә. Чәчәк төркеме — катлаулы чатыр. Чәчәкләре сары, кыска чәчәк сабында. Җимеше — озынча-эллиптик икеорлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Үләнендә сапониннар, алкалоидлар, каротин, дуплау матдәләре бар. Үлән суы һәм төнәтмәсе үт кудыру, яра төзәтү һәм тонусны күтәрү үзлегенә ия. Баллы үсемлек.

**ИМ-ТОМ** (ырымнар), халыкчан-поэтик иҗатның борынгы жанры; нинди дә булса әйбер яки күренешләргә сихри тәэсир итү максатыннан сүз б-н әйтелә торган тылсымлы тәгъбирләр. Табигатьтәге өстен көчләрне күзаллаулар б-н бәйле, гадәттә, нинди дә булса гореф-гадәтләр нигезендә башкарыла. Алардан башка И.-т. сүзләрен әйтү нәтиҗә бирми дип саналган. Вакытлар узу б-н магия тәэсирендә кылынган эш-гамәлләрнең нәтиҗәлелегенә ышаныч какшый, ә сүз көченә ышану гамәлдә кала бирә. Кагыйдә буларак, И.-т. сүзләре шигъри формада әйтелә, ритмга салына. Аларга күп чагыштырулар, эпитет, метафора, аллегория һ.б. хас. Эчтәлеге ягыннан И.-т.ны берничә төргә бүләләр: 1) авыл хуҗалыгы И.-т.; 2) көнкүреш И.-т. (чирдән, күз тиюдән, янгыннан саклаучы, сихерләп сөйдерү һ.б.); 3) явыз көчләрдән саклаучы И.-т. (су кызы, су анасы, өй ияләре). Фольклорчы Х.Мәхмүтов фикеренчә, кайбер яхшы теләкләр һәм каргауларның үрнәкләре дә И.-т.га барып тоташа (к. *Алкышлар һәм каргышлар*).

*Әд.:* Н а д и р о в И. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Б а к и р о в М. Фольклор жанры буларак ырымнар // Фольклор жанрларын анализлау. К., 1986; М ә һ д и е в М. Йола фольклоры // Фольклор жанрларын система итеп тикшерү. К., 1987; Н а с ы й р о в К. Поверья и обряды казанских татар // Зап. Имп. Рус. геогр. об-ва. СПб., 1880. Т. 6.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ИМАЖИНИ́ЗМ** (ингл. image — образ), әдәби агым; 20 йөз башы инглиз һәм Америка поэзиясендә барлыкка килә (Э.Паунд, Э.Лоуэлл, Ф.Форд, Т.Хьюм һ.б.). Фәлсәфи нигезе булып А.Бергсонның интуитивизм теориясе һәм тормыш фәлсәфәсе тора. Шуңа таянып, Т.Хьюм И.ның эстетик принципларын тәкъдим итә: метафоралар кулллануны көчәйтү, шигырьне «образлар каталогына» әверелдерү, тәэсир-хисләрнең әһәмиятен арттыру, алымнар сайлауда иреклелек.

Россиядә И. Окт. рев-циясеннән соңгы беренче елларда рус авангардының (аерым алганда футуризмның) эзләнүләре нәтиҗәсе буларак барлыкка килә. Россиядәге И. үзенең төп эстетик принциплары б-н инглиз И.на охшаш була, аның принципларын һәм традицияләрен үстерә. В.Г.Шершеневич, С.А.Есенин, А.Б.Мариенгоф һ.б. кергән имажинист шагыйрьләр төркеме (1918 елда оеша) күп төсле һәм фаҗигале чынбарлыкны образлар аша күрү концепциясен яклап чыга. Имажинистлар иҗаты үзгәндә — зур шәһәрдә югалып калган ялгыз шәхес. Алгы планга янәшә куела алмый торган әйберләрне, күренешләрне, төшенчәләрне чагыштыру юлы б-н, сүзнең гадәти мәгънәсен бозу ярдәмендә туган образ чыга.

Татар әдәбиятында И. чын мәгънәсендә мөстәкыйль әдәби агым булып оешып җитә алмый һәм 1920 елларның бер күренеше генә булып кала. 1923 тә К.Нәҗми үзен символист-имажинист шагыйрь дип белдерә һәм төп темасы «үлеп баручы иске тормыш»ны чагылдырган «Өермәләр» җыентыгын чыгара. Аерым әсәрләрендә сукбайлык, яңа тормыш төзү мотивлары чагылыш таба (мәс., «Тормыш төбендә» шигырендә чор рухына бәя бирелә, «кан б-н юылган ертык күңел» образы барлыкка килә). К.Нәҗминең имажинистик образлары (мәс., «Иске көннәр канлы эзләргә басып йөгерделәр», «Мин күрәм / һәрбер йөрәктә шүрләгән куян эзен», «Ертык күңел каны бетеп шиңде», «Кыйналган эт кебек еллар елап шыңшыдылар», «Төн канаты белән җирне сөртеп, / Салкын буран очкын иләде») яңалыклары, «кече образлар»ның мөстәкыйльлеге б-н сокландыра.

Ул еллар вакытлы матбугатында яшь татар шагыйрьләренең К.Нәҗмигә ияреп язган шигырьләре басыла. И. б-н мавыгу озакка бармый: 1924 нең 31 августында «Правда» г-тасында С.А.Есенин һәм И.В.Грузинов үз төркемнәренең таралуы хакында ачык хат б-н чыгалар. Алар артыннан К.Нәҗми дә И.ның татар әдәбиятында «вакытлыча туктатылып тору»ы турында үзенең шаян «Манифест»ын бастыра.

*Әд.:* Н и г ъ м ә т и Г. Әдәбият мәйданында. М., 1925; С ә г ъ д и Г. Символизм турында. М., 1932; Теория литературы. Т. 4. Литературный процесс. М., 2001.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ИМА́М** (гарәп. إمام — алда торучы, нәрсәнеңдер җитәкчесе), мөселманнарның мәчеттә бергәләп намаз укуына җитәкчелек итүче; мөселман мәхәлләсе башлыгы. Еш кына И.нар иң гади дини белемнәргә, җамигъ мәчетләрдә исә, кагыйдә буларак, махсус исламият гыйлеменә ия. Баштарак И. вазифаларын Мөхәммәд пәйгамбәр үзе, аның вафатыннан соң хәлифәләр (кайбер мөселман дәүләтләрендә — ил башлыклары) башкарган. Берьюлы дини һәм сәяси хакимиятне бергә кушып идарә итү алга таба мөселман өммәтендә И. хакимиятенең асылы турындагы мәсьәләләр буенча фикер каршылыклары килеп чыгуга һәм дини халыкның *сөнниләр* һәм *шигыйларга* бүленүенә китерә. Сөнниләрдә барлык мөселманнарның И.ы булып җәмәгать тарафыннан сайланып куелган хәлифә исәпләнгән, ул дин сагында торган һәм дәүләт б-н идарә иткән. Шигыйларда исә И. хакимияте югарыдан билгеләнә (ягъни И.ның сайланып куелуы инкарь ителә). Хәзерге вакытта шигыйларда И. — абруйлы дини зат. Ш.у. к. *Мөселман руханилары.*

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ИМАМЕТДИ́НОВ** Мәгъсүм Имаметдин улы (1898, БРның хәзерге Янаул р-ны Кызылъяр а. — 11.3.1945, Польша, Ополе ш. янында җирләнгән), Сов. Союзы Герое (10.4.1945, үлгәннән соң), рядовой, сапёр. Колхозда һәм авыл хуҗалыгы артелендә эшли. 1941 елның октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 76 нчы аерым штурм инженер-сапёрлар батальоны сапёры (16 нчы штурм ин-

женер-сапёрлар бригадасы). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украинаны (1943–44) һәм Польшаны (1944) азат итү сугышларында катнаша. 1945 нең февралендә Грошовице торак пункты (хәзер Ополе шәһәренә керә) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: Одер елгасы аша күпер төзүдә катнашып, фронт гаскәрләренең һөҗүмне тизләтүен тәэмин итә. Сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


М.И. Имаметдинов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1968. Кн. 3; Ракипов Ш.З. Хранить вечно. К., 1980.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИМА́МОВ** Алмас Әзһәр улы (2.3.1964, Казан), мед. фән. д-ры (1998), 1987 елда Казан мед. ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1993 елдан Респ-ка сан.-эпид. станциясе табибе. Бер үк вакытта 1994 тән Респ-ка гигиеник сертификацияләү һәм лицензияләр бирү үзәге баш табибе. Тикшеренүләре гигиена, токсикология һәм экология өлкәсенә карый. И. ТРда туфракның пестицидлар б-н пычрануын сан.-гигиеник яктан бәяли, пестицидларны куллану дәрәҗәсен ачыклый, аларның туфракка әләгү ихтималлыгын фаразлый, тотрыклы һәм аеруча агулы пестицидларның төп төркемнәренең таркалу закончалыкларын билгели. Профилактика максатыннан тотрыклы пестицидлар кулланууны тыю һәм чикләү буенча практик күрсәтмәләр тәкъдим итә.

Хезм.: Тяжёлые металлы в окружающей среде. К., 1995 (автордаш); Санитарно-гигиенические аспекты обеспечения экологической безопасности при применении пестицидов. К., 1998.

**ИМА́МОВ** Вахит Шәех улы (18.3.1954, Актаныш р-ны Иске Байсар а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1982 елдан Чаллы шәһәрендә башта урта мәктәп укытучысы, соңрак КамАЗда мастер булып эшли. 1991 дән «КамАЗ» нәшриятының баш мөхәррире. 1997 дән ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе. И. әдәбиятка «Ир канаты» (1988), «Нәзер» (1991) исемле повестьлар һәм хикәяләре белән килеп керә һәм татар халкы тарихына багышланган «Сәет Батыр» повесте (1994), «Утлы дала» романы (2002) һәм «Татарларның Ватан сугышы» (1993), «Запрятанная история татар» (1994) очерклар җыентыклары, «Казан дастаны» (2005; русчага тәрҗемәдә «Казанская крепость», 2005) җыентыгы б-н танылa. Аларда туган җиргә карата көчле мәхәббәт хисләре, комсызлар һәм хыянәтчеләрне кискен гаепләү күзәтелә. Иҗатында тарихи темалар белән беррәттән заман проблемаларын яктырткан әсәрләре дә бар. «Тозлы яра» романы (2004) белән И. тоталитар җәмгыятьнең чын йөзен татар авылы призмасы аша ачып бирә. «Япун татары» романында (2004) Ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булганнар — эмигрантлар — язмышын сурәтләп, халкыбызның киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итә. «Өмет» (1992), «Нәзер» (1993) повестьлары буенча телефильмнар төшерелгән.

Әсәр.: Безнең төбәк тарихы. Чалыш көзге. Чаллы, 2008.

*Әд.:* Ахунов Г. Һәркемнең үз кулында // Казан утлары. 1987. № 5; Вәлиев М. Тукай яшен узганда // Казан утлары. 1989. № 6.

**ИМА́Н** (гарәп. إيمان — ышану) *исламның* хаклыгына ышану, мөселман диненең аерылгысыз өлеше. И. — исламда иң төп һәм аеруча күп бәхәсләргә сәбәп булган төшенчә. Дин һәм хокук аерылгысыз саналган әүвәлге исламда И. проблемалары б-н илаһият галимнәре дә, хокук белгечләре дә шөгыльләнгән. 8 йөздән башлап, И. төшенчәсе төрле илаһият һәм дини-хокук мәктәпләре арасында фикер алышулар кузгалта: бәхәсләр И.ның асылы, төп элементлары турында бара. Гомумән, мөселман илаһиятчылары аның тулаем төп 3 элементын аерып күрсәтәләр: 1) Аллаһның хаклыгын, аның Китапларын һәм рәсүлләрен телдән тану; 2) Аллаһның хаклыгына ихлас инану, эчтән килешү; 3) ислам кушканны, дини бурычларны төгәл үтәү. Әүвәлге гадәтләр тарафдарларының күпчелеге, Мөхәммәд пәйгамбәргә таянып, барлык 3 элементны да таныйлар. И.ның асылын аңлауга бәйле рәвештә мөселман илаһиятчылары инану дәрәҗәсе, аның арту яки кимү мөмкинлекләре турындагы мәсьәләне төрлечә хәл итәләр. Мәс., мөгътәзилиләр буйсынуның барлык төрләрен инануның бер өлеше яки үзе дип таныйлар. Инануны телдән тануга тиңләүчеләр (мөрҗигыйлар) аның үзгәрешсезлеген икърар итәләр. Хәзерге сөнни илаһиятчылары, терминнарны беркадәр үзгәртеп, И.ны ш.у. 3 төргә бүләләр: әүвәлге гадәтләргә таянып инану, гыйлемгә таянып инану, эчке ихтыяҗи инану. Шигыйлардагы инануның асылы сөнниләрнекенә якын тора. Исмәгыйлиләрдә инануны «тышкы» (телдән тану) һәм «эчке» (күңелдән ышану) инануга бүлеп карау гадәте дәвам итә.

*Әд.:* Ислам. Энцикл. словарь. М., 1991.

**«ИМА́Н»**, мөселман газетасы. Оештыручысы «Иман» ислам мәдәниятенең яшьләр мәркәзе. 1992 елның сентябреннән Казанда татар телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире — В.*Ягъкуп*. Һәр санында җомга вәгазе тексты басыла. Төп урын Татарстанда һәм дөньяда яшәүче мөселманнар тормышы, ТР мөселманнары Диния нәзарәте эше турындагы материалларга бирелә. «И.» күренекле дин галимнәре (әл-Газәли Әбү Хәмид, Әбү Хәнифә ән-Ногман ибн Сабит һ.б.) әсәрләреннән, рев-циягә кадәрге дин тәгълиматчылары (Ш.Мәрҗани, М.Бигиев һ.б.) хезмәтләреннән өзекләр бастыра; дин эшлеклеләре б-н интервьюларга, мөселманнарның дини һәм иҗтимагый тормышы турындагы очеркларга урын бирә. «Сораулар һәм җаваплар» рубрикасы була.

**«ИМА́Н НУРЫ́»**, айлык мөселман журналы. Оештыручысы Апанай мәчете мәхәлләсе. 1993 елның декабреннән Казанда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — В.*Ягъкуп*. Төп игътибар Ислам дине тәгълиматларына бирелә. Күренекле мөселман дине белгечләре хезмәтләреннән өзекләр, Татарстан һәм Россия мөселманнары җәмгагытьләренең тормышын һәм проблемаларын яктырткан материаллар басыла.

**ИМАНА́ЕВ** Шәйхаттар Хәсән улы (7.8.1875, Вятка губ., Алабуга өязе Тирсә а. — 8.1.1939, Казан), хокук белгече, филолог. Казан ун-тының хокук (1897) һәм тарих-филол. (1902) ф-тларын тәмамлый. 1900 елда Казан мәхкәмә палатасы округының Присяжный вәкилләр корпорациясенә керә. «*Хокук вә хәят*» ж-лы нашире һәм мөхәррире (1913–14), «*Бәянелхак*» г-тасының соңгы мөхәррире (1914). «Мөселман», «Имам», «Нашир» псевдонимнары куеп яза. Туган тел, милләтләрнең тигезлеге, кеше хокукы, татарларның хокукны белү дәрәҗәсе мәсьәләләрен күтәрә. «Төрек-татар теленең фәнни грамматикасы тәҗрибәсе» («Опыт научной грамматики турецко-татарского языка», 1910) һәм «Татар теленең нәхүе һәм сарыфы» (1910) исемле китаплар авторы. И.ның «Иҗтимагый күренеш нәтиҗәсе буларак мөселман гражданлык юридик строе» («Мусульманский гражданский юридический строй как результат общественности», 1926) исемле монографиясе мөселман хокукына багышлана. 1933–36 елларда репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.


*Әд.:* Гайнуллин Х. Юлыбыз адаштырмас // Шәһри Казан. 2003. 23 дек.; Емельянова И., Ахунов А. Шейх-Аттар Иманаев (1875–1939) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.

**ИМАНГАЛИ́ЕВ** Равил Нәүрузгали улы (29.9.1948, Оренбург өлкәсе, Сакмар р-ны Татар Каргалысы а.) тарихчы, тарих фән. д-ры (2002). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. Хезмәтләре 18 йөз ахыры — 19 йөз ахырында Германиядә сәяси консерватизм тарихы һәм теориясенә карый.

Әсәр.: Прусский консерватизм в первой половине — середине XIX века: проблемы истории и теории. К., 1999; Становление политического консерватизма в Пруссии в конце XVIII — середине XIX веков. К., 2001.

**ИМАНГУ́ЛОВ** Равил Гариф улы (12.10.1921, Самара ш.), хәрби табиб, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1972). 1943 елда Н.И.Пирогов исем. Мәскәү мед. ин-тының хәрби ф-тын тәмамлагач, Совет Армиясендә хәрби табиб булып хезмәт итә, 1946 елдан Химик саклану хәрби академиясендә. 1962–82 дә Хәрби мед. академиясендә (Ленинград) укытучы, каф. башлыгы. Хезмәтләре сугышчыларны һәм халыкны массакүләм юк итү коралыннан мед. саклавына карый. И. шәхси саклану чараларына, хәрби частьләр, мед. хезмәте учреждениеләре, халыкны саклау чараларына карата куелган физиол.-гигиеник таләпләргә бәя бирә. Мед. кадрлары әзерләү системасында, фәнни-гамәли һәм укыту дисциплинасы буларак, мед. саклавы үсеше мәсьәләләрен өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Особенности влияния фильтрующих противогазов на хирургических больных // Науч. сессия, посв. 175-летию Воен.-мед. акад. Л., 1974;


З.М.Иманов.


Р.Ф.Имашев.

Медицинская служба и защита от оружия массового поражения. М., 1988.

*Әд.:* Гончаров Л.П. Очерки истории Военно-медицинской академии в послеоктябрьский период. Л., 1968.

**ИМАНКОЛЫ́Й** Мөхәммәд-Садыйк, к. *Мөхәммәдсадыйк Иманколый.*

**ИМА́НОВ** Зөфәр Минтимер улы (1.1.1945, Актаныш р-ны Адай а. — 4.10.2001, Чаллы ш., туган авылында җирләнгән), шомартучы, Соц. Хезмәт Герое (1984), Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (1999). 1967 елдан Ижевск моторлар з-дында токарь. 1973–2001 дә «КамАЗ» АҖ «Кама пресс-рам заводы»нда шомартучы, токарь, бригадир (1980–91). КамАЗның 1 һәм 2 чиратлары төзелешендә эшли. Рационализаторлык эшендә актив катнаша (штамп җайланмалары конструкциясен һәм штамплар әзерләү технологиясен үзгәртү нәтиҗәсендә инструментлар корычы чыгымы кими). Герой исеме производство йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. И. яшәгән йортка мемориаль такта куелган (2005).

*Әд.:* Казаков Б. Твоя строка в историю. Наб. Челны. 2001; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**ИМА́ШЕВ** Мәсгут Габдрахман улы (5.7.1930, Пермь өлкәсе, Барда р-ны Березники а.), педагог, җырчы (баритон), композитор. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984), РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). 1964 елда Казан консерваториясен (В.Воронов классы) тәмамлый. 1964–70 тә Әлмәт музыка уч-щесе, 1970–76 да Казандагы 1 нче балалар музыка мәктәбе, 1976–81 дә Татар опера һәм балет театры, 1981–97 дә Казан театр уч-щесе директоры. Татар, башкорт, рус композиторларының вокаль әсәрләре һәм халык җырларыннан тупланган репертуары б-н концертларда, радио һәм телевидениедән чыгышлар ясый. Популяр җырлар һәм радиопостановкаларга, телевизион спектакльләргә язылган музыка авторы. И.ның «Туй күлмәге» (М.Шиһапов шигыре), «Кукмара» (Г.Зәйнашева), «Туган як каеннары» (И.Юзеев), «Саубуллашу вальсы» (С.Сөләйманова) җырлары Татарстанның танылган башкаручылары репертуарына керә.


*Ф.Ш.Салитова, А.Р.Рахман.*

**ИМА́ШЕВ** Рәшит Фатыйх улы (30.3.1939, БАССРның Бишбүләк р-ны Азнай а. — 11.3.2007, Казан), нәкышьче, график, ТРның халык рәссамы (2003), ТАССР һәм БРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986, 1995). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1963), В.И.Суриков исем. Мәскәү дәүләт сынлы сәнгать ин-тын (1970) тәмамлый. 1970–71 елларда Уфада яши, 1971 дән Казанда, Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта (1972–74). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1973). Киң иҗади колачлы рәссам, тарихи, көнкүреш һәм портрет жанрларындагы нәкышь картиналары, китап һәм журнал графикасы, монументаль-декоратив һәм бизәү сәнгате әсәрләре авторы. 1959 дан И. «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Татарстан яшьләре» г-талары, «Азат хатын», «Чаян» ж-ллары редакцияләре б-н хезмәттәшлек итә. Рәссамның «Чаян»дагы төп темасы — көнкүреш сатирасы; жанр күренешләре чын, ышандырырлык итеп, тапкырлык сыйфатлары аша бирелә. Бу жанрдагы иҗатының мөһим үрнәкләре: «Милиция көне хөрмәтенә эчтем» (тушь, акварель, 1962), «Зинһар, тормышка якынрак килик» (тушь, акварель, 1963) һ.б. 1960–70 тә И. «Детская литература» нәшрияты өчен И.Нуруллинның «Кырлай авылыннан чыккан шагыйрь» («Поэт из деревни Кырлай», 1965), Г.Ахуновның «Канатлар кая илтә» («Куда несут крылья», 1967), К.Киньябулатованың «Геройлар утравы» («Остров героев», 1967); Татарстан китап нәшрияты өчен М.Рәфыйковның «Синә нишә яшь?» (1972), Г.Ахуновның «Артышның аръягында» (1974) һ.б. китапларын бизи. Рәссам әдәби образларны тирәнтен аңлау, аларга яраклы сурәтләү чараларын табу сәләтенә ия. И. шәһәр һәм авыллардагы җәмәгать һәм торак йортларының фасадлары һәм интерьерлары өчен байтак монументаль-декоратив композицияләр эшли. Мәс.: Салават шәһәрендәге торак йортларның диварларындагы «Сабантуй» һәм «Бию» (сграффито, 1967), «Спорт» (мозаика, 1972), Биектау посёлогындагы «Ак каен» ресторанындагы «Ак каен» (гипска уеп ясау, 1975, автордашлар И.Закиров, Н.Сәләхиев, Р.Ф.Андреев), Әлмәттәге җәмәгать бинасының интерьерында «Татарстан» (дивар бизәге, 1979), Питрәч мәктәбенең интерьерында «Спорт» (фреска, 1980), Түбән Камадагы «Җәлил» кинотеатрының интерьерында «Җәлил». И. иҗатының аеруча көчле ягы — нәкышь һәм график портретлар. Рәссам иҗат иткән зур портретлар галереясы әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, КамАЗ, Байкал-Амур магистрален төзүчеләр, нефтьчеләр һәм авыл хезмәтчәннәре портретларыннан гыйбарәт. Алар: «Ф.Әхмәтов», «М.Кәрим» (1970), «Р.Гамзатов», «К.Кулиев» (икесе дә — 1971), «Г.Ибраһимов» (1975), «Көзге җилләр. Тукай портреты», «Х.Туфан» (икесе дә — 1976), «С.Хәким» (1979), «М.Гафури», «Н.Җиһанов», «М.Җәлил» (барысы да — 1980), «Р.Кутуй» (1991), «А.Аббасов» (2000), «М.Сәлимҗанов» (2001) һ.б. Рәссам картиналарына геройларның рухи дөньяларын ачуы, җентекләп сайланган азсанлы детальләр, рәсемнең төгәллеге һәм тәэсирлелеге, гомумиләштерелгән монументаль образларга тартылу хас. Респ-ка (1961 дән), төбәк — «Зур Идел» (1974, 1980, 1991), бөтенроссия — «Туган ил буйлап» (1972), «Советлар Россиясе» (1975); «Кара туфраксыз төбәк» (1977–78), «Россия рәссамнары — Бөек Җиңүнең 35 еллыгына» (1980) һ.б., бөтенсоюз — «СССР — безнең Ватаныбыз» (1972–73), «Героик 60 ел (Кораллы Көчләрнең 60 еллыгына багышлана)» (1978) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1972 (Уфа), 1979, 1990 (Яшел Үзән), 1986, 1999 (Казан), 1991 (Мәскәү) елларда уза. Әсәрләре Дәүләт Третьяков галереясында, Дәүләт Рус музеенда, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, шәхси тупланмаларда (АКШ, Австралия, Франция, Һиндстан, Шри-Ланка) саклана. Башкортстанның Ф.Кәрим исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Ильясов Х. Фатихалы юл бәрәкәткә илтә // Мәдәни җомга. 2004. 11 июнь.

*М.Е.Ильина.*




Р.Ф.Имашев. 1. «Студент кыз». 1972. ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Салих Сәйдәшев портреты». 1983; «Зәки Нури портреты». Кәгазь, тушь, каләм. 1995.

**ИМА́ШЕВА** Галия Шакир кызы (17.5.1915, Алтай крае Камень на Оби ш. — 5.1.1995, Уфа ш.), театр рәссамы, БАССР, РСФСРның халык рәссамы (1970, 1973), БАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1943, 1955). 1934 елда Уфа сәнгать техникумын тәмамлый (педагоглар К.*Дәүләткилдиев*, А.Тюлькин). 1934–36 елларда — Баймак театры (БАССР), 1936 дан М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театры (1946–88 дә — баш рәссам), 1944–46 да Үчәле татар драма театры рәссамы. БАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1938). 1965–71 дә БАССР Рәссам-



Г.Ш. И м а ш е в а. М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» әсәре буенча куелган спектакль өчен декорация эскизы. 1967. М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее.

нар берлеге идарәсе рәисе. 1966–72 дә РСФСР һәм СССР Рәссамнар берлеге идарәсе секретаре. Башкортстанда сәхнә бизәү сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Күп кенә театрлар һәм сәнгать коллективлары б-н хезмәттәшлек итә (Башкорт опера һәм балет, Уфа респ-ка рус драма, Салават драма, В.Короленко исем. Удмурт драма театрлары, Ф.Гаскәров исем. Башкорт халык бию ансамбле һ.б.). 200 дән артык спектакльне, ш.и. М.Фәйзинең «Галиябану» (1937, 1946, 1972, 1979), Х.Ибраһимовның «Башмагым» (1937, 1944), М.Гафуриның «Кара йөзләр» (1946, 1948, 1955), И.Абдуллинның «Бәҗәйлар» (1952), И.Йомагуловның «Нәркәс» (1967), А.Н.Островскийның «Бу хәл һәр кешедә дә булырга мөмкин» (1973), В.Гюгоның «Мария Тюдор» (1974), Ә.Атнабаевның «Ут» (1975), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1981), Л.Н.Толстойның «Тере мәет» (1984) пьесалары буенча куелган спектакльләрне, Г.Гаҗибәковның «Аршин мал алан» (1972), М.Вәлиевнең «Сакмар» (1943), Х.Заимов, А.Спадавеккианың «Акбүзат» (1943) опералары; Н.Сабитова һәм Х.Әхмәтовның «Салават» (1979) балетын һ.б.ны бизи (декорация эскизлары һәм костюмнар). «Алтын аттагы җайдак» кинофильмына («Мосфильм», 1979) ясалган костюмнар авторы. И.ның театр-сәхнә бизәлешенә образны монументаль гомумиләштерелгән-пластик рәвештә гәүдәләндерү, спектакльнең психологик һәм эмоциональ яңгырашын, еш кына төснең символик, ассоциатив чагылышын тудыручы капма-каршы һәм интенсив колоритка корылган үзенчәлекле нәкышь формасы, яктылык һәм күләгәнең ритмик бүленеше аша тирбәлүле яктылык бирүче мохитне тудыру, чынбарлыкны кабул итүдә милли традицияләр рухында метафоралар һәм аллегорияләр б-н эш итү хас. И.ның үзенчәлекле, сәнгатьчә төзелешле әсәрләре совет һәм Россия сәхнәсе бизәлеше тарихында иң яхшы үрнәкләрдән санала.

1937 дән бөтенроссия — «РСФСР республикаларының театр рәссамнары» (Казан, 1949); бөтенсоюз — «Театр һәм кино рәссамнары әсәрләре» (Мәскәү, 1956, 1987), «Театр һәм кино рәссамнары» (Ленинград, 1974), «Театр һәм кино» (Мәскәү, 1979), «РСФСР автономияле республикаларының театр бизәлеше сәнгате» (Казан, 1961), «Театр һәм кино» (Казан, 1985); халыкара — «Прага квадриенналесы» (1975), «Совет театр рәссамнары Польшада» (1984) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1972, 1974, 1985 елларда — Мәскәүдә, 1973, 1975 тә — Ленинградта, 1977, 1978 дә — Алма-Атада, 1978 дә — Ташкентта, 1978, 1979 да Уфа шәһәрендә уза. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр сәнгате музеенда (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Уфа) һ.б. урыннарда саклана. М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» пьесасы буенча куелган спектакльнең сәхнә бизәлеше өчен РСФСРның К.С.Станиславский исем. Дәүләт бүләге бирелә (1968); Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» пьесасы буенча куелган спектакльнең (1956) сәхнә бизәлеше өчен РСФСР Мәдәният министрлыгының (1957) һәм СССР Рәссамнар берлегенең (1959) 1 нче дәрәҗә дипломнарына лаек була. Ике «Почёт



Г.Ш. И м а ш е в а. Н.Хикмәтнең «Сәер кеше» әсәре буенча куелган спектакль өчен декорация эскизы. Киндер, темпера. 1968. М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее.


билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П и к у н о в а Г.Р. Галия Имашева. Уфа, 1968; Н и к о л а е в а Г.В. Галия Имашева. Л., 1983; Е в с е е в а С.В. Выставка произведений художников-сценографов Республики Башкортостан: Каталог. Уфа, 2000; Ф е н и н а Э.П. Имашева Галия Шакировна // Художники Башкортостана. 20 век. Уфа, 2002; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ИМӘЛЛЕ́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 31 *км*, бассейнының мәйданы 147,1 $км^2$. Елга башы Кайбыч р-ны Кече Урсак авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, Апас р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Кайбыч р-ны Яңа Патрикеево авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 23%. И.нең 0,7 дән 8,4 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 $км/км^2$. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты туендыру модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга түбәнге агымында кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 60 *мм*, ташу вакытында агым катламы 57 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,012 $м^3/с$. Суы уртача катылыкта (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. И. бассейнында гомуми күләме 1,2 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИМӘ́Н** (Quercus), бүкчәләр семьялыгыннан агач яисә куак ыругы. 500 гә якын төре билгеле. Төньяк ярымшарның уртача һәм тропик поясларында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — сабакчалы И. яки гади И. (Q. robur) үсә. 18–40 *м* биеклектәге яфрак коючан агач, кәүсә юанлыгы 1–1,5 *м*. Тамыр системасы үзәкле, 5 *м* га кадәр тирәнлеккә китә. Күп ботакланган, төзек булмаган ябалдашлы агач. Яфраклары калаксыман, ботакларның очында урнашкан. Чәчәкләре вак, җил б-н серкәләнә, ата чәчәкләр — яшькелт, асылынып торучан озынча алкаларда, ана чәчәкләр — берле яки 2–3 ле, матур түгел, утырма яисә озынча чәчәк сабында. Җимеше тышына озынча буйлар төшкән коңгырт-көрән чикләвек, үз озынлыгының 1/3 е кадәр кәшәнкә б-н әйләндереп алынган. Яфрак яру б-н бер үк вакытта, апрель ахырыннан июнь башына кадәр чәчәк ата. Җимешләре сентябрьдә өлгерә. Төптән чыккан үсентедән һәм коелган орлыклардан үрчи, чәчү культурасында чикләвеген чәчеп үстерәләр. И. 400–500 ел, аерым агачлар 1000 елга кадәр яши. Чагыштырмача җылылык яратучы үсемлек. Тамыры имән гөмбәләре, ак гөмбә һ.б. б-н микориза хасил итә. И. ТРда киң яфраклы урманнар барлыкка китерүче төп токымнарның берсе. Имән утыртмаларының мәйданы 189,5 мең *га* (урман б-н капланган мәйданның 16,7% ы) тәшкил итә. Аеруча Кама аръягы һәм Идел алды р-ннарында таралган. Иделнең уңъяк ярында 1860 елларга кадәр корабль төзү урманнарының нигезен тәшкил иткән Казан таулы имәнлекләре калдыклары сакланган. И.нең үзагачы — нык, чыдам, озын гомерле.




**Сабакчалы имән**. 1. Гомуми күренеше; 2. Чәчәк атучы ботак; 3. Язгы үренте; 4. Чикләвекләре кәшәнкәсе белән; 5. Өлгергән чикләвек; 6. Көзге яфрак.

Төзелештә, суднолар төзүдә кулланыла. Кайрысында дуплау матдәләре бар. Төнәтмәсен эч киткәндә бөрештергеч һәм ялкынсынуга каршы чара буларак файдаланалар. И. яфраклары азык продуктларын саклау өчен әзерләгәндә кулланыла. Баллы. Чикләвеге урман хайваннары һәм кошлар өчен азык.

**ИМӘ́Н ГӨМБӘЛӘРЕ́**, болетчалар семьялыгы гөмбәләренең берничә төре. Күп өлеше Европада, ш.у. Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә зәйтүн-көрән И.г. яисә Имән гөмбәсе (Boletus luridus) һәм тимгелле И.г. (Boletus erytropus) очрый. Яфраклы урманнарда, имән астында үсәләр. Эшләпәсе зәйтүн-көрән төстә, диаметры 5–20 *см*, калын итле, эшләпәнең өсте шома, коры. Йомшагы лимондай сары, сынган урыны зәңгәрләнә, хуш исле һәм тәмле. Эшләпәсенең көпшәле катламы кызгылт-көрән. Споралы порошогы зәйтүн төсле. Сабы 7–12 *см* биеклектә, төбе бүлбесыман калынайган, көрән-алсу челтәр бизәкле. Тимгелле И.г. караңгырак эшләпәсе, кызгылт таплы һәм буй-буй аксыл-сары сабы б-н аерыла. Ике төре дә ашарга яраклы, яңа җыелган һәм тозланган килеш кулланыла.

**ИМӘ́Н ҮЛӘНЕ́** (Teucrium), иренчәчәклеләр семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләннәр, ярымкуаклар яки куаклар. 300 дән артык төре билгеле, бөтен җир шарында диярлек, башлыча, Урта диңгез буенда таралган. ТР терр-ясендә бер төре — имән сарымсагы (T. scordium) очрый. Нигездә, Кама аръягында үсә. Тозлы туфракта һәм су баса торган болыннарда очрый. 15–45 *см* биеклектәге күпьеллык үләнчел үсемлек, сарымсак исле, йөнтәс саплы, шуышма җир асты тамырчалы. Яфраклары озынча-бөтен, каурый сыман канатлы яисә каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре зәңгәр яки куе кызыл. Җимеше — чикләвекчек. Июль–августта чәчәк ата. Июль–сентябрьдә җимеш бирә. Орлыктан, вегетатив органнардан үрчи. Җир асты өлешендә углевод, эфир мае, алкалоид, флавоноидлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе аппетитны күтәрү өчен, сару кайнау вакытында файдаланыла. Мөгезле эре терлек өчен агулы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ИМӘНБОРЫ́Н** (Coccothraustes coccothraustes), тау чыпчыклары семьялыгыннан сайрар кош. Европа, Азия һәм Төньяк Американың яфраклы һәм катнаш урманнарында яши. ТР терр-ясендә оялаучы һәм даими кышламаучы төр. Оя кору чорында Кама аръягында — гадәти, Кама алдында сирәк кош. Күбесенчә яфраклы урманнарда, бакча һәм паркларда оялый. Гәүдәсенең озынлыгы 16–19 *см*, авырлыгы 50–70 *г*. Томшыгы юан, зур (исеме шуннан), каты җимеш орлыкларын һәм төшләрен җиңел ватып ашый. Койрыгы кыска. Ата кош алсу-җирән төстә, канатлары, койрыгы һәм томшык төбендәге табы кара төстә. Ана кош соры төстә. Оясын агачларда ясый. Кара тимгелле зәңгәрсу төстәге 4–6 йомырка сала. Агач, куак орлыклары һәм җимешләре, ш.у. бөҗәкләр, бигрәк тә коңгыз һәм аларның личинкалары б-н туклана. Чия бакчаларына зыян салырга мөмкин.

**ИМӘНКИСКӘ́** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2008 елда 655 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә мәчет, җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 8 юлаучылар йорты, 5 вак-төяклә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1159,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чирпы волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 398, 1897 дә — 759, 1908 дә — 925, 1920 дә — 943, 1926 да — 1019, 1938 дә — 1036, 1949 да — 844, 1958 дә — 702, 1970 тә — 761, 1979 да — 715, 1989 да — 644, 2002 дә — 680 кеше. И. янында *Имәнкискә комплексы* бар.

**ИМӘНКИСКӘ́ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Лаеш р-ны Имәнкискә авылы янында, Бырыс елгасының (Чулман елгасының уң кушылдыгы) түбән агымы буенда урнашкан. И.к.ның истәлекләре беренче тапкыр 1870 елларда Н.Ф.Толмачёв, А.Н.Стоянов, соңрак В.Ф.Смолин, Н.Ф.Калинин, П.Д.Степанов, В.Ф.Генинг, А.Х.Халиков, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә.



Имәнкискә шәһәрлеге күренеше.


И.к. Казан яны, Азелино, Ананьино, Имәнкискә, Болгар һ.б. археол. культураларга караган 7 торулыкны, 2 шәһәрлекне, 4 авыллыкны, 4 каберлекне үз эченә ала. Иң борынгылары — Чулман елгасының уң ярының болынлыклы террасасында сакланган, терр-яләрендә чакматаштан һәм балчыктан эшләнгән әйберләр табылган, алар Казан яны культурасы истәлекләренә карый. И.к. терр-ясендә күп күләмдә матди материал (эш һәм сугыш кораллары, балчык савыт-саба, бизәнү әйберләре калдыклары) җыеп алынган. И.к. истәлекләренең күпчелеге, ш.и. болгар авыллыклары, Имәнкискә II шәһәрлеге (Коллар каласы) Куйбышев сусаклагычыннан зыян күргән. Ш.у.к. *Имәнкискә культурасы.* *П.Н.Старостин.*

**ИМӘНКИСКӘ́ КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), тимер гасырда (якынча 5–7 йөзләрдә) Идел буенда, Чулман аръягында, Урал алдында яшәүчеләр тарафыннан калдырылган культура. Атамасы Лаеш р-ны Имәнкискә авылы янындагы шәһәрлектән алынган. Археол. культура сыйфатында 1956 елда В.Ф.*Генинг* тарафыннан бүлеп чыгарыла. *Имәнкискә комплексы* составына керә. И.к. истәлекләре 19 йөзнең 2 нче яртысыннан өйрәнелә (Н.Ф.Толмачёв, А.Н.Стоянов, В.Ф.Смолин, Н.Ф.Калинин, П.Д.Степанов, В.Ф.Генинг, А.Х.Халиков, П.Н.Старостин, Е.П.Казаков һ.б.). 21 йөз башына И.к.ның 500 истәлеге ачыкланган, шуларның 400 гә якыны Татарстан терр-ясендә; араларында иң танылганнары — Имәнкискә авылы һәм Спас р-ның Балымер авылы янындагы шәһәрлекләр. И.к. истәлекләре 2 шәр шәһәрлектән, 6–7 авыллыктан һәм каберләрдән гыйбарәт төркемнәрне тәшкил итә. Фаразлар буенча, И.к. балт кабиләләре тарафыннан калдырылган.

И.к. халкы, башлыча, игенчелек, терлекчелек, аучылык, ш.у. балыкчылык (кырпы, мәрсин һ.б. тоту) б-н шөгыльләнгән. Авыллыкларда җир сөрү коралларының тимер очлыклары, ураклар, чалгылар, кул тегермәне ташлары, бөртекле ашлык (арыш, бодай, тары, карабодай, борчак, ясмык һ.б. а.х. культуралары) калдыклары, ш.у. терлекләр (ат, сыер, сарык, дуңгызлар һ.б.) һәм кыргый хайваннар (поши, аю, кабаннар һ.б.) сөякләре табыла. Тимер (корыч) эшкәртү һәм инструментлар ясау (балта, өтерге, кыргыч, без, тишкеч, игәү, келәщәләр һ.б.) үсеш алган. Кайбер торулыкларда бакыр эретү эзләре (металл коелмалары, җитештерелгән әйберләр һ.б.) табыла. Имәнкискә кабиләләре сөяк эшкәрткәннәр, тукыма тукый белгәннәр, балчыктан (башлыча, эре бөртекле чуер кушып, кулдан әвәләп) яссы төпле бизәлмәгән чүлмәкләр ясаганнар (савыт-сабаны һөнәрче түгәрәгендә ясау эзләре ачыкланды). И.к. халкы зур авылларда, башлыча, ярымземлянкаларда яшәгән. Шәһәрләр, гадәттә, болыннар өстендә калкып торган биек урыннарда төзелгән, алар агач диварлар куелган балчык өемнәре һәм чокырлар б-н әйләндереп алынган. Археол. казу эшләре вакытында беркадәр җиргә казылып салынган квадрат тораклар, ш.у. хуҗалык һәм торак өлешләренә бүленгән озынча зур агач йортлар калдыклары ачыла. Торулыкларда хуҗалык чокырлары, металл эретү мичләре, бакыр кою остаханәләре калдыклары табыла. 500 дән артык кабер тикшерелгән. Мәетләр, кагыйдә буларак, киендерелгән килеш яндырылган, аларның калдыклары б-н бергә азык-төлек салынган савыт-саба кечерәк чокырларга күмелгән. Башлары б-н төньякка юнәлдерелгән, яндырылмаган мәетләр җирләнгән каберләр дә очрый. Аларда эш һәм сугыш кораллары, ат дирбияләре, балчык савыт-саба, кием-салым, бизәнү әйберләре, атларның баш сөякләре табыла. Бу каберләр Имәнкискә кабиләләренә *Турбаслы культурасының* йогынтысы булуын күрсәтә.

*Әд.:* Старостин П.Н. Памятники именьковской культуры // Свод археологических источников. 1967. Вып. 32; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; Казаков Е.П. К вопросу о турбаслинско-именьковских памятниках Закамья // Культуры евразийских степей второй половины I тысячелетия н. э. Самара, 1996.

*П.Н.Старостин.*



**Имәнкискә культурасы мәкаләсенә.** 1. Рождествено каберлеге: мәетләр яндырып күмелгән урыннар; 2. Маклашеев каберлегендәге күмү урыннары; 3. Түбән Кама янындагы Имәнкискә культурасына караган җирлектә табылган тимер әйберләр; 4. Тимердән эшләнгән кораллар һәм ат җигү кирәк-яраклары.

**ИМӘНЛЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зәй елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,8 *км*, бассейнының мәйданы 42,6 *км*². Зәй р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Имәнлебаш авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Кече Пәлчекәү авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге — 160 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 36%. И.нең 2,8 һәм 4,9 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 98 *мм*, ташу вакытында агым катламы 69 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,042 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Су ресурслары хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**ИМӘНЛЕ́ БОРТА́С** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 20 *км* көнчыгыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2008 елда 171 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.та 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 756 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульяновка, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 277, 1897 дә — 684, 1908 дә — 761, 1920 дә — 782, 1926 да — 717, 1938 дә — 747, 1949 да — 502, 1958 дә — 513, 1970 тә — 465, 1979 да — 349, 1989 да — 191, 2002 дә — 180 кеше.

**ИМӘНЛЕБА́Ш** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 15 *км* көнбатыштарак, Имәнле елгасы буенда. 2008 елда 318 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, балта осталары булып эшли. И. осталары ясаган чаналар бөтен тирә-якта танылa. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1134 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында (1929–30) И.та «Югары Чишмә» к-зы төзелә, соңрак ул «Кызыл Татарстан» (1954 тән), «Путь к коммунизму» (1958 дән), «Татарстан» (1992 дән) к-злары составында, 1997 дән «Имәнлебаш» а.х. товарлары җитештерү кооперативында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Токмак волостенда керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 356, 1870 тә — 457, 1897 дә — 758, 1920 дә — 1037, 1926 да — 611, 1938 дә — 636, 1949 да — 542, 1958 дә — 535, 1970 тә — 664, 1979 да — 510, 1989 да — 350, 2002 дә — 319 кеше. И.та язучы *Таҗетдин Ялчыгол* җирләнгән.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ИМӘНЛЕ́К**, Казанның Киров р-ны терр-ясендәге урман массивы (*«Аккош күлләре»* урман паркының бер өлеше); табигать истәлеге (1985). Мәйданы 25 *га*. Идел елгасының сулъяк яр буенда юкә, очлы яфраклы өрәңге һ.б. киң яфраклы агачлар б-н сакланган (элеккеге Игумный урманыннан калган) табигый имән урманнары фрагментларын, ш.у. 1767 елда Екатерина II нең Казанга килүе уңаенnan булдырылган аллеяны



Имәнлек урман массивы.

(Боевая урамында 32 имән сакланган) үз эченә ала. И.нең фәнни, тарихи һәм мәдәни-танып белү әһәмияте зур. 1905–07 елларда агачлыкта Елга арьягы эшчеләренең, Казан гарнизоны солдатларының массакүләм чыгышлары һәм маёвкалары үтә (бу вакыйгалар К.Нәҗминең «Язгы җилләр» романында чагылыш таба). 1948–76 да И. терр-ясендә б.э.к. 4–2 меңьеллыкларга караган археологик урыннар ачыкланды.

*Әд.:* Р о г о в а Т.В. Голубое и зелёное. К., 1984.

**ИМГЕ́Ч СУАЛЧАННА́Р**, к. *Трематодлар*.

**ИМЕЗҮЧЕЛӘ́Р** (Mammalia), умырткалы хайваннар классы. 4,5 меңгә якын төре билгеле. Җир шарының бөтен материкларында, океан һәм диңгезләрдә таралган. ТР терр-ясендә бөҗәкләр б-н тукланучылар (10 төр), кулканатлылар (12), кимерүчеләр (32), куянсыманнар (2), ерткычлар (17) һәм партояклылар (3) отрядларына керүче 76 төр бар. Аларның төп үзенчәлекләре: үзәк нерв системасының югары үсеше, сизү органнарының катлаулы төзелеше, йон капламы булу, төрле тире бизләре (май, тир һ.б.; аеруча балаларын имезү өчен сөт бизләре булу әһәмияткә ия — классның исеме дә шуннан), бүленгән теш системасы (кискечләр, казык, урт (азу) алды һәм урт (азу) тешләр, аларның һәрберсе үз функциясен үти), даими диярлек тән темп-расы (уртача 30 °С тирәсе), үпкә б-н сулау, дүрт камералы йөрәк. И.нең бер төрләре җир өстендә яшәү рәвешен үзләштергәннәр һәм тиз йөгерүгә җайлашканнар (тояклылар, бүре, куян) яисә сыену урынын җирдә тапкан (бурсык, сөркә, йомран); башкалары агачта яшәүгә күчкән (очкалак тиен, тиен, сусар); өченчеләре һавага күтәрелгән, һәм аларның алгы очлыклары канатка әверелгән (ярканат); дүртенчеләре җир астында яшәү рәвеше алып бара — аларның күрү сәләте шактый дәрәҗәдә редукцияләшкән һәм кайбер органнары туфракта йөрү юллары казуга җайлашкан (сукыр тычкан, кыр тычканчыгы); И. арасында сулы тирәлек б-н тыгыз бәйләнештә булган төрләр бар (җофар, кама, ондатра). Тиен, куян, төлке, сусар һ.б. кыйммәтле мехлы хайваннар промысел әһәмиятенә ия. Ярканатлар, җир тычканнары, ләтчә һ.б. зарарлы бөҗәкләрне һәм кимерүчеләрне юк итәләр. Кайбер төрләре (күп кенә кимерүчеләр һәм тояклылар) үсемлекчелеккә, урман хуҗалыгына һ.б. зыян китерергә мөмкин. Күп кенә И. (мәс., кимерүчеләр) куркыныч авыру (чума, туляремия) тудыручыларны таратучы һәм йоктыручылар. Татарстанда Америка чәшкесе, янутсыман эт, ондатра, гади сөркә климатка яраклашу узган. 34 төр ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* П о п о в В.А., Л у к и н А.В. Животный мир Татарии. К., 1988; А с ь к е е в И.В., А с ь к е е в О.В., Б е л я е в А.Н. Каталог млекопитающих Татарстана. К., 2000.

**ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ́**, иминият кертемнәре нигезендә формалаштырылган махсус акча (иминият) фондлары хисабына хәвефле очракларда (стихияле бәла-казаларда, аварияләрдә һ.б.) физик һәм юридик затларның сәламәтлеген, тормышын, милек мәнфәгатьләрен яклауны оештыру системасы. РФдә И. РФнең 1992 елның 27 ноябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә иминләштерү эшен оештыру турында»гы Законы буенча алып барыла. Дәүләтнең мөстәкыйль финанс системасы ин-ты буларак, И. иминләштерүчеләрнең ихтимал зыян кичерүләрен булдырмау өчен профилактик чаралар күрүгә бәйле кисәтү, иминләштерүченең чыгымнарын тулысынча яки өлешчә каплауны торгызу, И. вакытына бәйле рәвештә И. кертемнәрен азайтуга юнәлдерелгән туплау функцияләрен башкара. И. мөнәсәбәтләрендә өченче — иминләштерелгән һәм И. түләвен алу өчен билгеләнгән файда күрүче затлар да катнашырга мөмкин. И. 3 тармакка: милекне (объект сыйфатында төрле матди байлыклар күрсәтелә), шәхси (икътисади мөнәсәбәтләрнең нигезен физик затлар тормышындагы вакыйгалар тәшкил итә), җаваплылыкны И. (иминләштерүченең өченче затлар күргән зыянны каплау буенча йөкләмәләре предмет булып тора) тармакларына бүленә. Беренче тармак эчендә милекне И.нең 18 төре аерып карала.

Классификация нигезенә оештыру билгесе салынган очракта иминият базары барлыкка килгән шартларда И. эчке (чикләнгән), тышкы һәм катнаш төрләргә бүленә. Иминият мөнәсәбәтләре урнашу нигезе буенча И. мәҗбүри (закон тәртибендә) һәм ирекле (килешү буенча) төрләргә аерыла. Объектка бәйле рәвештә: милекне И. (матди байлыкларны И.), шәхси И. (тормышны, сәламәтлекне, хезмәткә сәләтлелекне И.; к. *Медицина иминләштерүе*), җаваплылыкны И. һәм эшмәкәрлек тәвәккәллеген И. төрләре була. Гамәлдә булуы буенча сроксыз яки гомерлек һәм вакытлы: кыска вакытлы (берничә айдан 1 елга кадәр), озак вакытлы (1 елдан 5 елга кадәр) һәм билгеле бер вакытка исәпләнгән И. төрләренә бүленә. ТРда И. хезмәте күрсәтү б-н 20 дән артык И. агентлыгы, компаниясе һәм җәмгыятьләре шөгыльләнә (2008). Алар арасында иң танылганнары — «Чулпан», «Росгосстрах — Татарстан» АҖ, «Мегарусс-Д», «Сәнәгый иминләштерү компаниясе», «Итил», «Аско — Татарстан». Татарстан халкына ш.у. «Ак-Барс Страхование» иминият компаниясе, «Альфа Страхование» ф-ллары, «Ак Барс-Мед» ҖЧҖ, «Талисман» иминләштерү җәмгыяте, «РОСНО» иминләштерү фирмасы һ.б. И. хезмәте күрсәтәләр. Аларның күбесе физик һәм юридик затларның барлык төр милекләрен хәвефле очраклардан И. б-н шөгыльләнә.

2008 дә ТР иминләштерү оешмаларының устав капиталы 3890,8 млн. сум, иминләштерү кертемнәре — 20461,9 млн. сум, түләүләр — 15394,8 млн. сум, табыш 238,3 млн. сум тәшкил итә.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ИММУНОФЕРМЕ́НТ АНА́ЛИЗ** (ИФА), авыруларны китереп чыгаручының тибын һәм кан сыгынтысындагы антитәнчекләр титрын төгәл һәм тиз арада ачыклау мөмкинлеге бирә торган ысул. ИФАның өстенлекләре — гади, реагентлар тотрыклы һәм җиңел табыла, тиз башкарыла, күпләп анализлар үткәрү өчен автоматлаштыру мөмкинлеге бирә, нәтиҗәдә ИФА ысулы үсемлек һәм хайван авыруларына диагноз куюда файдалану тәэмин ителә.

Биотехнология казанышлары нәтиҗәсендә ИФА ысулы көчле үсеш ала; геннар инженериясе ярдәмендә — югары дәрәҗәдә чистартылган төрдә кыен табыла торган антигеннар, фермент-маркерлар һәм аларның конъюгатлары, күзәнәк инженериясе ысуллары ярдәмендә моноклональ антитәнчекләрнең махсус һәм аффин төрләре алына.

Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) 1980 елдан терлекләрдәге йогышлы авыруларга диагноз кую өчен ИФА үткәрү буенча киң колачлы тикшеренүләр алып барыла. Россиядә беренче тапкыр дуңгызларда классик чумага (1983), Ауески авыруына (1983), котыру (1988), Ку бизгәге (1990, Р.Х.Йосыпов, Г.Х.Ильясова, Н.Ә.Хисмәтуллина, И.А.Корбанова, Г.Ф.Ильясова, Ш.А.Насыйров), бруцеллёз (1985), себер түләмәсенә (1966; К.М.Салмаков, А.К.Галиуллин, Н.С.Садыйков һ.б.) диагноз кую өчен иммуноферментлы җыелмалар эшләнә һәм чыгарыла. Институтта диагностик җыелмалар эшләү өчен анализларның үзенчәлекле күрсәткечләрен арттыра торган моноклональ антитәнчекләр кулланыла.

*Әд.:* Е г о р о в А.М., О с и п о в А.П., Д з а н т и е в Б.Б. Теория и практика иммуноферментного анализа. М., 1991.

*Р.Х.Йосыпов, Г.Р.Йосыпова.*

**ИМПЕРА́ТОР АЛЕКСА́НДР II ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. 1881 елның апрелендә Казан шәһәр думасы Александр IIгә һәйкәл төзү турында карар кабул итә. 1888 дә Казан губернасы буенча 6 мең сумлап акча җыела. Шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко җәмәгать оешмаларына һәм губернадагы барлык земстволарга Азатлык китерүче патшага һәйкәл кую турында мөрәҗәгать б-н чыга. Иганәгә җыелган акча 33 мең сумга җитә, дума шәһәр бюджетыннан ел саен меңәр сум акча күчерүне оештыра. 1889 да С.В.Дьяченко рәислегендә махсус ком-т оештырыла һәм һәйкәл проектын



Казанда император Александр II һәйкәле. 1895.

төзүгә конкурс игълан ителә. 1890 ның башында Россиянең төрле шәһәрләреннән 13 проект җибәрелә, шулар арасыннан иң яхшысы дип акад. В.О.Шервуд проекты таныла. 16 мартта дума утырышында һәйкәл өчен Иван (Иоанн) мәйданында (хәзер Беренче Май мәйданы) дума бинасы каршында урын билгеләнә. 1891 нең 28 ноябрендә монументны урнаштыруга рәсми рөхсәт алына. Бронза һәм гранит өлеше Мәскәүдә әзерләнә, кварц-комташлы постаменты Сембер губернасы Сөнгәләй өязенең таш чыгару урыныннан кайтарыла. Һәйкәл төзү эшләре акад. Шервудның шәхсән күзәтчелегендә башкарыла. 1895 нең 30 августында тантаналы төстә ачыла. Император яланбаш, иңбашыннан төшеп торган порфира кигән кыяфәттә, йөзе б-н Кремль ягына борылган рәвештә тасвирланган. Сул кулы хакимият символы булган скипетр һәм таҗ яткан колонна өстендә, уң кулы күкрәгенә куйган хәлдә сурәтләнгән. Һәйкәлнең пластик чишелеше Алек-

сандр IIнең Россия үсешендә прогрессив роль уйнаган реформаларының мөһимлеген ассызыклый.

Александр IIнең бронза сыны урнаштырылган постаментның өч ягына император уздырган реформалар саналып язылган, алгы ягында таҗның астыннан чыгып аска төшкән имән һәм лавр гирляндаларга «Александр IIгә. Азатлык китерүче патшага» дигән язу язылган. Постаментның аскы почмаклары 4 аждаһа — Казан гербындагы Елан сынnары б-н бизәлгән, алар Елан авызындагы лавр такыялар, гирляндалар б-н тоташтырылган. Һәйкәл Чабакса авылы осталары тарафыннан эшләнгән нәфис рәшәткәләр б-н әйләндереп алынган. 1918 дә монумент сүтелеп, 1920 нең 1 маенда аның постаментына металл коючы эшче сыны («Азат хезмәт», скульп. В.С.Богатырёв) урнаштырыла; һәйкәл 1930 елларга кадәр тора.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895. *А.В.Гарзавина.*

**ИМПЕРА́ТОР А́ННА ИОА́ННОВНА ФӘРМАНЫ́** (1740 ел, 11 сент. «Об отправлении архимандрита с некоторым числом священнослужителей в разные губернии для обучения новокрещённых христианскому закону и о преимуществах, новокрещённым дарованных»), яңа чукынганнарга христиан дине кануннарын өйрәтү һәм алар өчен каралган өстенлекләрне аңлату өчен төрле губерналарга берничә рухани б-н бергә архимандритны җибәрү турындагы фәрман. Шуның нигезендә Казан, Әстерхан, Түбән Новгород һәм Воронеж губерналарында мөселманнар б-н мәҗүсиләрне чукындыруны активлаштыру өчен *Яңа чукындырылганнар конторасы* оештырыла. Фәрман рус булмаган халыкларны христиан диненә күчерү чараларын, яңа чукындырылганнарга православие дине канун-тәртипләрен өйрәтүне, башка диндәгеләр б-н русларның никахын хуплауны күздә тота; православие динен кабул иткәннәргә өстенлекләр һәм бүләкләр бирү, «чукыну өчен килгән» кешеләрне акчалата, өс һәм аяк киемнәре б-н бүләкләүне арттыру чараларын билгели; фәрман яңа чукынган кешеләргә, аларны поташ з-дларындагы казна эшләреннән, рекрутлык йөкләмәсеннән, җан башына тигән салымнардан һәм земство җыемнарыннан азат итеп, 3 елга ташламалар бирү турындагы 1720–22 һәм 1731 еллар фәрманнарын раслый. Фәрман яңа чукынганнарга Саратов б-н Царицын шәһәрләре арасында чиркәүләр төзеп, анда руханилар һәм причтлар билгеләп, хөкемдар вазифалары булган старосталар сайлау, 1000 утарлык буш җирләр бирүне күздә тота. Фәрман нигезендә Казан, Алабуга, Царёвококшайск, Цивильск шәһәрләрендә руханилар әзерләү өчен әҗнәбиләр мәктәпләре оештырыла. Яңа чукындырылганнар конторaларын тоту өчен Икътисад коллегиясеннән елына 10 мең сум акча һәм икмәк жалованиесе бирелә. Фәрман 1740–50 елларда христианлаштыруның яңа кампаниясен башлап җибәрә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 1. № 8236.

*Е.Б.Долгов.*

**ИМПЕРА́ТОР ЕКАТЕРИ́НА II ФӘРМАНЫ́** (1784 ел, 22 февр. «О позволении князьям и мурзам татарским пользоваться всеми преимуществами Российского дворянства»), татар бәкләре һәм морзаларына Россия дворяннарының барлык өстенлекләреннән файдалану хокукы бирү турындагы фәрман. Ул мөселман бәкләре һәм морзаларының хокукларын, үз җирләренә хокук биргән грамоталарын һәм әлеге катлауга керүләре турындагы башка язма дәлилләрен саклаган хәлдә, Россия дворяннары хокуклары б-н тиңләштерә. Бер үк вакытта аларга христиан динендәге крепостной крәстияннәр тоту тыела. Әлеге йомышлы татарларның исемлеген генерал-губернаторлар һәм губернаторлар төзи, Сенат раслый.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 22. № 15936.

*Е.Б.Долгов.*

**ИМПЕРА́ТОР ЕКАТЕРИ́НА II ФӘРМАНЫ́** (1788 ел, 22 сент. «Об определении мулл и прочих духовных чинов магометанского закона и об учреждении в Уфе Духовного собрания для заведования всеми духовными чинами того закона, в России пребывающими»), Уфа шәһәрендә мөфти һәм Казан татарларыннан 2–3 утырышчы мулла составында Россия мөселманнары Диния нәзарәте (к. *Оренбург губернасы мөселманнары җәмгыяте*) оештыруны күздә тоткан фәрман. Яңа органга мөселман дин әһелләрен сайлап алу һәм урыннарга билгеләү, аларның ышанычлылыгын, әхлакый сыйфатларын тикшерү, эшкә сәләтле булуларын сынау бурычлары йөкләнә. Диния нәзарәте эшчәнлеге генерал-губернатор һәм губернаторлар күзәтчелегенә куела. Беренче мөфти итеп ахун М.*Хөсәенов* билгеләнә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 22. № 16710.

*Е.Б.Долгов.*

**ИМПРЕССИОНИ́ЗМ** (фр. impression — тәэсир), сәнгати агым. И. тарафдарлары чынбарлыкны үзгәрүчән мизгелләрендә табигый рәвештә гәүдәләндерергә, үзләренең тәэсирләрен чагылдырырга омтылалар. И.ның сәнгати концепциясе: дөнья матурлыгына сокланa белүче, нечкә зәвыклы, хисчән, тәэсирләнүчән шәхес булдыру. Яңа сәнгати агым беренче тапкыр үзен сынлы сәнгатьтә таныта. И.ның атамасы да Клод Моненың «Impression. Sunrise» («Тәэсирләнү. Кояш чыкканда») картинасы исеменнән килә. И. рухында О.Ренуар, Э.Дега, А.Сислей, Ван Гог, П.Гоген, А.Матисс, П.Сезанн, К.Писсарро һ.б. иҗат итә. Россиядә И. агымына К.А.Коровинны, И.Э.Грабарьны һ.б. кертәләр. И. сыннар ясау сәнгатендә дә (О.Роден, М.Россо, П.П.Трубецкой һ.б.), музыкада да (К.Дебюсси, М.Равель, А.Н.Скрябин һ.б.) чагылыш таба.

Француз шагыйре Ш.Бодлер, үзенчәлекле музыкаль аһәңлелек, хискә бай яңгыраш һәм тон биреп, И. принципларын үз лирикасына кертә. Француз шагыйрьләре П.Верлен һәм А.Рембо И.ның төп вәкилләреннән санала. Проза өлкәсендә И. беркадәр Ги де Мопассан, К.Гамсун, Б.Келлерман, Гуго фон Гофмансталь, О.Уайльд, А.Саймонс, И.Ф.Анненский, Б.К.Зайцев һ.б.ның иҗатларында чагыла.

20 йөз башы татар әдәбиятында И.ның аерым алымнары (пейзаж күренешләрен фотографиядәгечә тергезү, сурәт һәм халәт алмашынуын сүзләр агымына салу, музыкаль яңгыраш бирү) Дәрдемәнднең фәлсәфи ике-өч-дүртьюллык шигырьләрендә гәүдәләнеш таба. Ф.Әмирханның («Хәят», «Хәкарәт саналган мәхәббәт»), Ш.Камалның («Буранда», «Акчарлаклар», «Курай тавышы») проза әсәрләрендә И.ны романтизм һәм реализм б-н «синтезлаштыру» омтылышы күзәтелә.

1915 елдан соң татар әдәбиятында чын мәгънәсендә импрессионистик әсәрләр языла. Г.Исхакый «Бер манзара» исемле хикәясендә таң ату мизгелләренең алышынып торуын, беренче тапкыр эш урынына барган яшь мулланың нечкә күңел кичерешләрен, шул кичерешләргә тиң табигать аһәңен тасвирлый. Ф.Әмирхан «Яз исереклегендә» хикәясендә уянып килүче табигать күренешләреннән алынган тәэсирләрне күрсәтә, шул вакытта яшь күңелдәге тойгыларның «күңел лирикасы»на әверелүен чагылдыра. «Берен-







1. П.П. Б е н ь к о в. «Террасада». 20 йөз башы; 2. Б.И. У р м а н ч е. «Кечү урынында». 1929. Икесе дә — ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда; 3. Н.Д. К у з н е ц о в. «Татарстанның индустриаль пейзажы». 1966–69.

че ашкыну» хикәясендә гашыйк шәкертнең бер көне тасвирлана. Ф.Вәлиев «Көймәдә» исемле хикәясендә беренче саф мәхәббәтнең, гашыйкларның очрашу-күрешү мизгелләре гүзәллеген сурәтли. Хикәядә лирик сагыш, импрессионистик «үтәкүренмәлелек» б-н сугарылган табигать сурәтләре урын ала.

Импрессионистик әсәрләрдә тирә-юнь хисләр аша кабул ителә, кешенең күңеле, кәеф-халәте, көндәлек вакыйгалар ниндидер бер мистик яктылык каймасына урала, ләкин ачык, изге матурлык артында иртәгесе көннең фаҗигасе сиземләнә. Геройларның кичерешләре матур һәм фаҗигале. 20 йөз башы татар прозаикларының тормышка үзенчәлекле карашы һәм эстетик каршылыклары шуның б-н билгеләнә.




Г.Г.Р а х м а н к у л о в а. «Казан Кремленең Спас манарасы». Акварель. 1967.

Сынлы сәнгатьтә И.ның аерым билгеләре Н.И.Фешин, П.П.Беньков, П.А.Радимов картиналарында, В.С.Богатырёв сыннарында чагылыш таба. 20 йөз сәнгатендә табигатьне сурәтләү (пленэр), натурада ясалган этюд эстетикасы алымнары Б.Урманче, Г.Рахманкулова, Н.Д.Кузнецов, А.А.Аникеенко, Р.Нигъмәтуллина иҗатларына хас.

*Әд.:* З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003; Теория литературы. Т. 4. Литературный процесс. М., 2001; Ренессанс в татарской литературе нач. XX века и импрессионистические приёмы в творчестве Шарифа Камала // Г а н и е в а Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. К., 2002.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ИМШЕНЕ́ЦКИЙ** Василий Григорьевич (4.1.1832, Вятка губ., Сарапул өязе Ижевск корал заводы — 24.5.1892, Мәскәү), математик, Петербург ФА академигы (1881). 1853 елда Казан ун-тын тәмамлый, Түбән Новгород һәм Казандагы урта уку йортларында эшли, 1860–71 дә — Казан ун-тында, проф. (1868). 1872–82 дә Харьков ун-тында механика каф. мөдире. 1884 тән Петербургтагы Югары хатын-кызлар курсларында, 1891 дән Петербург технол. ин-тында. Харьков (1879) һәм Петербург (1890) матем. җәмгыятьләренә нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре механика һәм матем. физикада дифференциаль тигезләмәләрне интеграллау теориясенә карый. И. Монж-Ампер тибындагы тигезләмәләрнең аерым интегралы булганда сызыкча тәргә рәвешүзгәртүнең гомуми аналитик теориясен үстерә. Үзе керткән махсус интеграллау тапкырлаучысы ярдәмендә сызыкча дифференциаль тигезләмәләрнең рациональ чишелешен табу ысулын тәкъдим итә. Интегралларны якынча исәпләүдә кулланып, Бернуллиның теләсә нинди тәртиптәге функциясен кертә һәм өйрәнә.



В.Г.Имшенецкий.

Х е з м.: Исследование способов интегрирования уравнений с частными производными второго порядка функции двух независимых переменных // Уч. зап. Казан. ун-та. 1868. Т. 4, вып. 3/4; Общий способ нахождения рациональных дробных частных интегралов линейных уравнений с рациональными коэффициентами // Уч. зап. Петербург. АН. 1887. Т. 55; Дополнение теории и одно приложение общего способа нахождения рациональных дробных решений линейных дифференциальных уравнений с рациональными коэффициентами // Уч. зап. Петербург. АН. 1888. Т. 58.

*Әд.:* А н д р е е в К.А. Василий Григорьевич Имшенецкий. Хар., 1895; А н д р е е в К.А., Н е к р а с о в П.А., Ж у к о в с к и й Н.Е. Жизнь и научная деятельность Василия Григорьевича Имшенецкого. М., 1896.

**ИНА́Л** (инакъ), урта гасырларда феодаль дәрәҗә, титул. 6–8 йөзләрдә төрки каганлыкларда затлы нәсел вәкиленә бирелгән. 10–13 йөзләрдә кайбер төрки дәүләтләрдә (Уйгыр һәм Хәзәр каганлыкларында, сәлҗуклар һәм караханилар дәүләтләрендә) аксөякләрне атау өчен кулланылган. 10–14 йөзләрдә «И» термины кайчак катлаулы исемнәр составына исем-дәрәҗә сыйфатында кергән. Идел буе Болгарында И. сүзе, катлаулы исемнең бер өлеше буларак, 1320 елгы кабер ташында теркәлгән.

*Әд.:* М а л о в Е.С. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Древнетюркский словарь. Л., 1969; Х а к и м з я н о в Ф.С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978.

*И.Л.Измайлов.*

**ИНВЕ́РСИЯ** (лат. inversio — әйләндерү, урынын алыштыру) (лингв.), җөмләдә теге яки бу элементны аерып күрсәтү, яисә бөтен җөмләгә үзгә бер мәгънә бирү максатыннан сүз һәм сүзтезмәләрнең гадәти тәртибен (к. *Сүз тәртибе*) үзгәртү. Татар телендә И. хис-тойгылы сөйләмдә, аеруча шигъри сөйләмдә кулланыла, бу исә шигырьнең үлчәме, ритмикасы һәм рифмасы таләпләренә бәйле. Мәс.:

Ирек алып бирдең син илгә.
Бу ирлегең үлмәс гомергә (М.Җәлил).

Гадәти проза җөмләсендә бу сүзләр түбәндәге тәртиптә урнашкан булыр иде:

Син илгә ирек алып бирде́ң.
Бу (синең) ирлегең гомергә үлмә́с.

Еш кына И. җөмләдә әһәмиятле сүзне логик яктан аерып, аңа басым ясап күрсәтү өчен кулланыла, мәс.:

Алсу быел **күргәзмәгә** бара.
Алсу күргәзмәгә **быел** бара.
Күргәзмәгә быел **Алсу** бара.

**ИНВЕСТИ́ЦИЯЛӘР** (нем. Investition, лат. investio — киендерәм), ил эчендә яки чит илдәге төрле тармак пр-тиеләре икътисадына озак срокка капитал, кыйммәтле кәгазьләр, эшмәкәрлек проектлары, ягъни күпмедер вакыттан соң табыш китерүне тәэмин итә торган соц.-икътисади программалар, инновацион проектлар салу. И.нең: дәүләт бюджеты һ.б. дәүләт финанс чыганакларыннан; шәхси, корпоратив пр-тиеләр һәм оешмалар, гражданнардан; чит ил инвесторлары, дәүләтләр, чит ил банклары, компанияләре эшмәкәрләреннән кертелгән акчалардан барлыкка килә торган төрләре бар. Шәхси һәм дәүләт И.ен юнәлешләре, максатлары һәм финанслау чыганаклары буенча аерып йөртәләр. Җитештерү өлкәсендәге И. яңа төзелешләргә, гамәлдәге пр-тиеләрне реконструкцияләүгә, киңәйтүгә һәм аларны яңа җиһазлар б-н тәэмин итүгә, ә интеллектуаль И. белгечләр әзерләүгә, тәҗрибә үткәрүгә, фәнни эшләр алып баруга юнәлтелә. Шәхси И. халык хуҗалыгының күбрәк табыш бирә торган тармакларына, дәүләт И. исә капитал әйләнеше сүлпән барган, аз табышлы тармакларга, инфраструктурага җибәрелә.

Капиталның урнаштырылуына карап, И. реаль, интеллектуаль һәм финанс төрләренә бүленә. Реаль И. — яңа капиталь байлыклар, ягъни компаниянең нинди дә булса матди яктан сизелерлек реаль активын (җир, корылмалар һ.б.) яки шәхси мөлкәт (алтын әйберләр, антиквариат, сәнгать әсәрләре һ.б.) булдыру өчен капитал салудан гыйбарәт. Финанс И. — бу очракта капитал корпорацияләргә яки дәүләт тарафыннан чыгарылган акцияләргә, облигацияләргә һ.б. кыйммәтле кәгазьләргә салына.

Турыдан-туры һәм читләтелгән И.дә була. Турыдан-туры И. — инвесторга кыйммәтле кәгазьләрне яки мал-мөлкәтне турыдан-туры милек итеп алу хокукы бирә торган төре. Читләтелгән (портфельдәге) И. — эмитент-компания б-н идарә итү хокукы бирми, алар табыш алу өчен салынган кыйммәтле кәгазьләр яки мөлкәти кыйммәтләрдән гыйбарәт.

И. тәвәккәллек дәрәҗәсенә карап та бүленә. Тәвәккәллек дәрәҗәсе түбән булган И. алдан ук фаразланган табыш алуның хәвефсез чарасы булып санала. И.нең югары тәвәккәллелеге спекуляциягә нигезләнә: алар буенча югары табыш алырга да мөмкин.

Гамәлгә куелуына карап, И. кыска һәм озак вакытлыга бүленә. Кыска сроклы И. бер елга, озак сроклы И. бер елдан артык яки чикләнмәгән вакытка исәпләнә.

И. өчен шәхси, бурычка алынган, читтән җәлеп ителгән акчалар да тотылуы ихтимал. Дәүләт икътисадның мөһим юнәлешләренә И.не арттыру өчен өстенлекле шартлар тудыра. Андыйлар рәтенә ТРда пр-тиеләрнең төрле дәрәҗәдәге бюджетларга булган бурычларын реструктуризацияләү, дәүләт заказын бүлү, салым салуны оптимальләштерү, продукция җитештерүдә көндәшлеккә сәләтле яңа технологияләр сатып алуны стимуллаштыру, а.х.н дотацияләү һ.б., ш.у. респ-ка икътисады өчен аеруча әһәмиятле пр-тиеләргә

бюджеттан турыдан-туры акча бүлеп бирү дә керә. 2007 елда Татарстанда икътисадны үстерү һәм социаль сфераның төп капиталына 210,1 млрд. сумлык И. юнәлтелгән. 2007 дә эре һәм урта оешмаларның, пр-тиеләрнең төп капиталына кертелгән И.нең төп чыганагы — шәхси кертемнәр — алар барлык И.нең 49,9% ын тәшкил итә, ш.и. 24,4%ы табыштан, калганы амортизациягә чигерүләрдән кергән. Бюджеттан юнәлтелгән И.ләрнең өлеше — 13,4%, банклардан кредитка алынган ресурслар өлеше 19,1% тәшкил иткән.

*Әд.:* Портфель приватизации и инвестирования. М., 1992; Инвестиционно-финансовый портфель. М., 1993; Финансовый менеджмент. М., 1998; Шарп У.Ф., Александер Г.Д., Бэйли Д.В. Инвестиции. М., 1999; Инвестиционные возможности РТ // Рынок ценных бумаг. К., 2000.

*О.В.Андреева.*

**И́НГВАР** (Линсцер) Игорь Германович (18.4.1905, С.-Петербург — 8.2.1993, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1968). Г.Ф.*Линсцерның* улы. Казанда Югары совет-партия мәктәбенең клуб эше сыйныфын (1922), Шәрекъ пед. ин-тын (1928) тәмамлый. Бер үк вакытта *Хәзерге заман театрының конструктив-тәҗрибә остаханәсе* (*КЭМСТ*) студиясендә укый (1924–25), шул ук театрда эшли, Татпрофсоветның күчмә театрында актёр була. 1928–29, 1933–34 елларда Казан Зур драма театрында актёр. Шулай ук Петропавловск, Самара, Ульянов, Махачкала, Ярославль шәһәрләре театрларында эшли. 1935 тән режиссёрлык б-н дә шөгыльләнә башлый. Ульянов драма театрында А.В.Сухово-Кобылинның «Кречинскийның туе» («Свадьба Кречинского», 1935), Ярославль Яшь тамашачылар театрында А.Н.Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» («Бедность не порок», 1938), «Күктән төшкән бәхет» («Не было ни гроша, да вдруг алтын», 1938), В.З.Масс һәм Н.Г.Куличенконың «Бакчалар чәчәккә күмелә» («Сады цветут», 1939) әсәрләрен сәхнәгә куя. Актёр буларак, күбрәк характерлы рольләрдә уйный; төрле сурәтләү чараларыннан файдаланып, персонажның төгәл социаль-психол. портретын булдыра. КЭМСТ актёры буларак, эстрада спектакльләрендә биюче сыйфатында да чыгышлар ясый. Күренекле рольләре арасында Лаэрт («Гамлет», У.Шекспир), Труффальдино («Хан кызы Турандот», К.Гоцци), фон Кальб («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Курбский («Борис Годунов», А.С.Пушкин), Мигаев («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Алёшка («Тормыш төбендә», М.Горький) образлары бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. Демобилизацияләнгәннән соң, Ульянов өлкә драма театрында режиссёр булып эшли. Анда 1946 да А.Н.Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» («Бедность не порок»), «Соңгы корбан» («Последняя жертва») пьесаларын куя. 1946–49 да Чистай рус драма театрында баш режиссёр, анда К.М.Симоновның «Прагада каштан агачлары астында» («Под каштанами Праги»), «Рус мәсьәләсе» («Русский вопрос»), К.А.Тренёвның «Любовь Яровая», Л.Н.Рахмановның «Тынгысыз картлык» («Беспокойная старость»), Д.Гоу һәм А. д'Юссоның «Тирән тамырлар» («Глубокие корни») әсәрләрен сәхнәләштерә. 1952–68 дә Казан Зур драма театрында әдәби бүлектә, 1968 дән шул театрда музей мөдире булып эшли. Р.Ишморатның Казан Зур драма театрында куелган «Үлмәс җыр» («Бессмертная песнь»), «Давылга табан» («Буре навстречу») әсәрләрен русчага тәрҗемә итә. Казан Зур драма театрының музей фондына күп әйберләрнең (театр афишалары, программалар, фотографияләр һ.б.) коллекцияләрен туплый. Пропаганда һәм публицистик эш б-н шөгыльләнә. Бер үк вакытта Татар театр техникумында (1924–28), Казан театр һәм Казан сәнгать уч-щеләрендә (1950 дән), Казан Зур драма театры студиясендә укыта. Аның шәкертләре арасында — Г.*Булатова*, К.*Тумашева*, Х.*Сәлимҗанов*, Н.*Гәрәева*, В.*Гатаев*, В.*Кешнер*, Е.*Кузин* һ.б. бар.

Хезм.: Народные артисты. К., 1980 (автордаш); Казанская театральная лениниана. К., 1989; Русский театр в Казани. К., 1991 (автордаш).

*Ю.А.Благов.*

**ИНДУСТРИА́ЛЬНЫЙ** (Ямбай) посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Кармәт елгасы (Кече Сөлчәнең уң кушылдыгы) бассейнында. 2008 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда Яңа Кирәмәт авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта — Енбаевка, соңрак Индустрия исеме б-н билгеле. ТАССРның Чистай кантоны Аксубай волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 282, 1938 дә — 336, 1949 да — 329, 1958 дә — 279, 1970 тә — 268, 1979 да — 215, 1989 да — 69, 2002 дә — 64 кеше.

**ИНДУСТРИЯЛӘШТЕРҮ́**, халык хуҗалыгының барлык тармакларында эре машина җитештерүне оештыру һәм шуның нигезендә аграр җәмгыятьтән индустриаль җәмгыятькә күчү процессы. Ул җитештерүче көчләрнең билгеле бер дәрәҗәдә үсүе һәм хезмәтнең иҗтимагый бүленешенә бәйле. И.нең алшартлары сәнәгый җитештерүнең кул хезмәтенә нигезләнгән беренчел формалары (мануфактура, кустарь сәнәгать һәм һөнәрчелек җитештерүе) барлыкка килгәч, а.х. производствосы кысаларында туа. И. барышында вак товар җитештерү ф-ка һәм з-д җитештерүенең эре формалары б-н катлаулы үзара бәйләнешләрны дәвам иттерә.

И.нең 1 нче этабында (1830–80 еллар) — Россиядә сәнәгать борылышы чорында — кул хезмәтеннән машина хезмәтенә күчелә. Сәнәгать пр-тиеләре пар һәм нефтьтә эшләүче двигательләр, локомобильләр, махсус машиналар һ.б. б-н тәэмин ителә. 1880 еллар ахырына Казан губернасы сәнәгатендә машина б-н җитештерү өстенлек ала. Тармак структурасының төп элементлары барлыкка килә. Күн эшкәртү, сабын кайнату — шәм кою һәм тукыма җитештерү әйдәп баручы тармакларга әверелә, аларның тиз үсеше хезмәтнең иҗтимагый бүленеш процессының активлашуын күрсәтә, чөнки аларның товарларын авыл халкы күп куллана. Азык-төлек (ярма, он, кондитер әйберләр, шәраб-аракы, сыра, крахмал җитештерү), агач һәм металл эшкәртү сәнәгатьләренең әһәмияте арта, аларның үсеше күп яктан су транспорты үсеше һәм шактый дәрәҗәдә хөкүмәтнең бу транспортка хезмәт күрсәтүче производстволарга ярдәм чаралары б-н бәйле була (к. «*Кавказ һәм Меркурий*», «*Самолёт*»). 19 йөз уртасына су транспорты атлы транспортны кысрыклап чыгара бара һәм йөк әйләнешендә төп рольне уйный башлый (ташылган йөкләрнең 1/3 өлеше аңа туры килә); йөкләр арасында а.х. продукциясе өстенлек итә. Сәнәгатьнең һәм транспорт коммуникацияләренең үсеше кредит системасын яңа принципларда формалаштыру б-н бергә бара. 1880 еллар башында Казан губернасында Казан шәһәр җәмгать банкы, Сәүдәгәрләр банкы, Дәүләт, Азов-Дон, Идел-Чулман, Петербург халыкара, Рус-Азия акционерлык коммерция банкларының бүлекчәләре, Үзара кредитлау җәмгыяте һәм башка финанс-кредит структураларының капиталлары сәнәгатькә тирән үтеп керә башлый. Баштарак сәүдәне кредитлау б-н шөгыльләнүче Россия коммерция банкларының Казан ф-ллары төп урынны алып торса, 1870–80 елларда сәнәгать кредиты ин-тларының барлыкка килүе әлеге операцияләрнең алга таба үсеше өчен шартлар әзерли. Төбәк икътисады, нигездә, а.х. характерында булганлыктан, ф-ка-з-д машина индустриясе үсү б-н бергә кул хезмәтенә нигезләнгән вак сәнәгать һәм мануфактура да яши бирә һәм ишәя бара. 1858 дә Казан губернасында 2 меңләп һөнәрчелек оешмасы исәпләнә, аларда 7 мең чамасы кеше (тегүчеләр, балта осталары, итекчеләр, малярлар, тимерчеләр, тире эшкәртүчеләр һ.б.) эшли.

И.нең 2 нче этабы (1880–90 еллар) 1881–82 еллардагы кризис һәм 1882–87 дәге депрессия шартларында башлана. 1887–90 да сәнәгать үсешенең кыска гына вакытка җанлануын Идел буендагы коточкыч ачлык һәм дөньякүләм икътисади кризис б-н бергә туры килгән 1887–90 дагы яңа кризис алыштыра. 1893 тән җирле сәнәгать үсә башлый. Эре з-д һәм ф-каларның саны 75 тән (1879) 124 кә (1903), ә җитештерү суммасы 267% ка кадәр арта. Авыр индустриянең база тармаклары (химия, агач эшкәртү, төзелеш, машина төзелеше) оешкач, җирле сәнәгатьнең тармак структурасын (тире һәм азык-төлек җитештерү сәнәгатьнең иң эре тармаклары булып кала) формалаштыру тәмамлана. Сәнәгать җитештерүе арту б-н бергә, ул эре пр-тиеләрдә, бигрәк тә губернаны И.дә төп рольне уйнаган химия, туку, тегү, азык-төлек тармакларында туплана. Бер үк вакытта капитал туплау һәм аны үзәкләштерү процессы бара, бу исә сәнәгать пр-тиеләрен акционерлаштыруда чагыла. 1890–1900 еллар чигендә акц. җәмгыятьләре төп капиталның, ш.у. җирле з-д һәм ф-ка сәнәгате производство фондларының шактый зур өлешенә ия була. Энергетика сәнәгатен үстерү-

дә Бельгия капиталы мөһим роль уйный. Ф-ка һәм з-дларының терр. бүленешендә дә үзгәрешләр күзәтелә. Гадәттәге Казан икътисади р-ныннан тыш, Татарстан терр-ясендә яңа: Паратск (агач һәм тимер эшкәртү, суднолар ремонтлау сәнәгате), Бондюг-Кокшан (химия сәнәгате), Бөгелмә (металл эшкәртү) һ.б. сәнәгать р-ннары барлыкка килә. 1858–88 дә сәнәгать пр-тиеләренең саны Казанда 127 дән 79 га кадәр кими, ә өяз шәһәрләрендә 24 тән 65 кә кадәр арта. Әлеге р-ннарда а.х. теге яки бу дәрәҗәдә җирле сәнәгатькә һәм арта барган сәнәгать халкына хезмәт күрсәтүгә йөз тота башлый, бу исә бакчачылык, терлекчелек һәм сөтчелек хуҗалыгы үсешендә чагыла. Шуның б-н бергә Казан, Лаеш, Спас, Зөя өязләрендә, башлыча, а.х. продукциясен эшкәртүгә (крахмал-патока, ярма, он тарту, май чыгару һ.б. производстволар) көйләнгән р-ннар барлыкка килә. 1905 тә 339 эре з-д һәм ф-ка исәпләнә, аларның 25%ы — терлекчелек, 55% ы үсемлекчелек продукциясен эшкәртә. Шәһәрдәге һөнәрчелек эшчәнлегендә дә хәлләр үзгәрә: 1888 дә, 1858 б-н чагыштырганда, ашамлыклар җитештерү һәм азык-төлек әзерләү өлкәсендә эшләүче һөнәрчеләр саны — 4, кием-салым тегүчеләр 3 тапкырга арта. Мәскәү–Казан тимер юлын төзүгә бәйле рәвештә (1891–93) йөк ташу күләме шактый үсә. Россиянең Европа өлешендә сәнәгать алга киткән төбәкләр б-н икътисади элемтәләр көчәя. Су һәм тимер юл транспортының үсеше сәнәгатьтә һәм а.х.нда И. процессларын тизләтүгә ярдәм итә, төбәкнең халык хуҗалыгын бердәм системага әверелдерү өчен кирәкле шартлар тудыра, бу системаның нигезен аерым р-ннарның специальләшүе һәм алар арасындагы хезмәт бүленеше тәшкил итә. И.нең су һәм тимер юл транспортында ташылган йөкләрнең күпчелеге а.х. продукциясеннән, асылда, бөртекле ашлыктан гыйбарәт булган 1 нче этабыннан аермалы буларак, 1880–90 елларда сәнәгать йөкләренең өлеше арта. Күпләп сатуда төп урын ярминкәләрдән биржаларга күчә. 1900 еллар башында банклар саны үзгәрешсез диярлек кала, аларның эшчәнлегендә тиз арта барган товар әйләнешен кредитлау төп юнәлешкә әверелә. Вексельләрне исәпкә алу, ш.у. товарларга һәм вексельләргә карата кредитлар бирү шактый үсә. Россиянең дәүләт һәм коммерция банклары ф-ллары яңа акц. банклары оештыруда һәм инде гамәлдәге компанияләрнең өстәмә акцияләрен чыгаруда булышалар, шул рәвешле сәнәгатьне финанслау юлына басалар. Дәүләт банкы уставына (1894) «кыска вакытлы кредитлау юлы б-н ил сәүдәсенә, сәнәгатенә һәм авыл хуҗалыгына булышлык итү» турындагы яңа нигезләмә кертелгәч, әлеге банкның Казан ф-лы төбәк икътисадын актив финанслый башлый. 1913 елга сәнәгать пр-тиеләре саны 423 кә җитә, аларның 17% ы — терлекчелек, 63% ы үсемлекчелек продукциясен эшкәртә. Машина төзелеше һәм металл эшкәртү продукциясенең тулаем күләме 5% чамасы тәшкил итә. 20 йөз башында губернада эшләүче халыкның якынча 12% ы сәнәгатьтә, транспортта һәм төзелештә мәшгуль була һәм миллиуниң... ли керемнең 30% тан күбрәген китерә. Сәнәгатьнең үсеш темплары а.х. үсеше темпларыннан артып китә генә түгел, ә бәлки аның йогынтысы да көчәя бара.

И.нең 3 нче этабы (1900–21) җитештерүнең эре капиталистик формалары җирле сәнәгатьтә өстенлек иткән һәм алар банклар б-н берләшә башлаган, сәнәгатьнең тармак һәм төбәкара структуралары оешып җиткән, хезмәтнең терр. бүленеше ихтыяҗларын, аграр һәм индустриаль р-ннарның үзара хезмәттәшлек итүен, эчке һәм тышкы сәүдәне канәгатьләндерерлек коммуникацияләр системасы формалашкан шартларда бара. Элеккесе кебек үк, бу этап та кризис нәтиҗәсендә килеп туа. Төбәк икътисадының җанлануы 1906–07 дә башлана. Сугыш алды күтәрелешенең төп факторлары авылның активлаша барган үсешеннән, шәһәр халкы артуы, сәнәгатьнең җитештерү фондлары яңару, капитал тупланууыннан гыйбарәт була. Дәүләт банкының, Россия коммерция банклары ф-лларының губерна бүлекчәләренең, 1 нче һәм 2 нче Үзара кредитлашу җәмгыятьләренең һ.б.ның банк операцияләре шактый арта. Бу елларда сәнәгать җитештерүе дә сизелерлек үсә. *Беренче бөтендөнья сугышы* башланыр алдыннан, элеккечә үк, азык-төлек, күнчелек, туку, химия һәм төзелеш сәнәгате ныграк үскән тармаклар булып кала (продукциянең гомуми бәясенең 40% тан артыгragы). Җитештерү средстволары эшләп чыгару тармакларының өлеше кечкенә була. Губерна терр-ясендә беренче монополистик берләшмәләр һәм финанс төркемнәре барлыкка килә, алар сәнәгать продукциясен җитештерү һәм сатуны контрольгә алалар; И. шартларында аларның җитештерүгә йогынтысы көчәя бара. Вак товар җитештерү (һөнәрчелек артельләре, а.х. җәмәгатьләре һ.б.) һәм вак кредит (кредит ширкәтләре һ.б.) өлкәсендә кооперация үсә. 1914 елга җирле сәнәгать губернаның он-ярма продуктларына, күн, сабын-шәм әйберләрәнә, төзелеш материалларына һ.б.га ихтыяҗын канәгатьләндерә. Губернадан читкә сабын, шәмнәр, агач-такта материаллар, күн һәм тукыма әйберләр, он-ярма продуктлары һ.б. чыгарыла; сәнәгать машиналары (станоклар, двигательләр) һәм механизмнар, транспорт чаралары, а.х. машиналары һәм хезмәт кораллары, эл. техникасы, химия продуктлары һ.б. кертелә. 1913 елга Казан губернасы гомумроссия тулаем сәнәгать продукциясенең якынча 2% ын җитештерә, завод һәм фабрика товарлары җитештерү буенча 31 губерна арасында 13 нче урынны алып тора. *Столыпинның аграр реформасы* елларында а.х. производствосының тиз үсүе нәтиҗәсендә а.х.на машиналар һәм механизмнар күпләп кертелә башлый. А.х. производствосын структур үзгәртеп кору да дәвам итә. Моны, аерым алганда, техник культураларның роле арту да дәлилли. Казан губернасы а.х. продукциясен иң күп җитештерүче һәм бирүчеләрнең берсе булып кала. Халык хуҗалыгы өлкәсендә сәнәгать һәм а.х. күргәзмәләре мөһим роль уйный. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан махсус урта уку йортларының саны арта бара, аларның күпчелеге халык хуҗалыгы өчен белгечләр әзерли; коммерция нигезләрен укыту принципиаль яңа күренеш була. Сәнәгать корылмалары, эл. станцияләре, тимер юл вокзаллары, кредит учреждениеләре биналары, керем (доход) йортлары, эре универсаль кибетләр (пассажлар), шәһәр транспортының яңа төрләре (атлы трамвай, трамвай), эл. линияләре, телефон һәм телеграф, күпләгән рекламалар шәһәрләрнең, аеруча Казанның архит-ра йөзен шактый үзгәртәләр. Икътисадта барган процесслар җәмгыять тормышының күп якларына катлаулы һәм каршылыклы йогынты ясыйлар. И. тормыш шартларының һәм гражданнар аңының, халыкның төп катлавы көнкүрешенең һәм аның структурасының кискен үзгәрүе б-н бергә туры килә. Авылларда бер төркем халык җирсез кала һәм бер үк вакытта икенчеләрнең шәхси җирбиләүчелеге (*хуторлар, отрублар*) арта; шәһәргә китүче крәстияннәрнең саны күбәя: берәүләр — эшмәкәрлек б-н шөгыльләнү өчен; икенчеләре з-д һәм ф-каларда, читтә эшләү өчен китә (к. *Хуҗалыктан читкә китеп эшләү*).

Дворяннарның биләмәләре туктаусыз кими. Шул ук вакытта аларның шактый өлеше эшмәкәрлек б-н шөгыльләнә башлый. Буржуазиянең кискен артуы күзәтелә, аның составы губерна халкының барлык катлаулары вәкилләре б-н тулылана. Эшчеләр сыйныфы арасында да шундый ук процесслар бара. Тормыш темпларының, аның сыйфатының кискен үзгәрүе, җәмгыятьнең структур үзгәреп корылуы, мәнфәгатьләр бәрелеше социаль каршылыклар китереп чыгара, шәхесне яңа шартларда үз урынын эзләүгә (кайчак фаҗигале төстә) этәрә. Нәтиҗәдә төрле формадагы иҗтимагый инициативалар (иганәчелек, меценатлык) һәм иҗтимагый хәрәкәтләр (крәстиян кузгалышлары, эшчеләр стачкалары, шәхси террор) активлаша; сәяси партияләр, профсоюзлар, эшмәкәрлек җәмгыятьләре һ.б. барлыкка килә. Милли мәсьәлә кискенләшә. Көндәлек матбугат аеруча тиз үсә: төрле профсоюз басмалары чыга, газеталарның саны һәм аларның тиражы бик нык арта. Иҗтимагый фикер төрле юнәлештәге фәлсәфи тәгълиматлардан, иң радикаль юнәлештәге фикерләрдән алып уртача һәм консерватив характердагы карашларга кадәрге икътисади һәм социаль доктриналардан гыйбарәт була. Беренче бөтендөнья сугышы елларында тышкы икътисади факторлар йогынтысы астында И.нең асылы үзгәрә. Сугыш икътисади яңартып кору механизмының нормаль эшләвен боза, шәһәр б-н авыл, халык хуҗалыгының башка тармаклары һәм икътисади районнар арасында урнашкан элемтәләрне тарката. Дәүләт финанс учреждениеләренең эшчәнлеге, нигездә, хәрби чыгымнарны финанслауга юнәлдерелә. Икътисадны хәрби ихтыяҗларга көйләү корал, сугыш кирәк-яраклары һәм хәрби киемнәр җитештерүче пр-тиеләрнең бик нык артуына китерә. Дәүләт органнарының хәрби һәм гражданлык продукциясен җитештерү арасындагы тигезсезлекне чимал, ягулык, җиһазларны, транспорт чараларын, эшче көчләрне һәм азык-төлекне базардан тыш бүлү юлы б-н

бетерергә тырышуы (махсус киңәшмәләр һ.б. ярдәмендә) якынаеп килүче социаль-икътисади кризисны булдырмый кала алмый. Социаль киеренкелек сугыш чоры кыенлыклары б-н кискенләшә һәм 1917 елгы Февр. һәм Окт. рев-цияләре вакыйгаларында чагыла. Гражданнар сугышы башлангач, з-дларның һәм ф-каларның шактый өлеше эшләүдән туктый, күбесе талана, хуҗалары һәм директорлары производствоны идарә итүдән читләштерелә (к. *Национализацияләү*). Капиталистик базар үзәкләштерелгән бүлү б-н алыштырыла (к. «*Хәрби коммунизм*»). Тимер юллар җимерелә, тәртиптән чыгарыла. Сугыш чоры инфляциясеннән һәм банкларны национализацияләгәннән соң шәхси кредит системасы яшәүдән туктый. Татарстан икътисады И.нең башлангыч чорларына алып ташлана. 1921 ел башына респ-каның сәнәгать пр-тиеләре продукциянең сугышка кадәрге 30% ы чамасын гына җитештерә. 1914 б-н чагыштырганда, сабын эшләп чыгару — 20, аяк киемнәре — 5 тапкырга, күн әйберләр — 87% ка, җитен тукымалар җитештерү 71% ка кими.

И.нең 4 нче этабы (1921–41) сәнәгатьнең нык зәгыйфьләнгән үсеше һәм крәстиян хуҗалыкларын көчләп күмәкләштерү шартларында бара. Ул Татарстанда коточкыч ачлык чорында башлана (к. *Ачлык 1921–22*) һәм дөньякүләм икътисади кризиска туры килә. Респ-каның икътисады 1924–25 тә җанлана башлый, бу процесста *яңа икътисади сәясәтнең* (*нэп*) уңай нәтиҗәләре сизелә. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары елларында җимерелгән халык хуҗалыгын торгызуга базар мөнәсәбәтләре, сәнәгать пр-тиеләрен берләштерү, аларны хуҗалык исәбенә күчерү, эшче көчләр яллауга һәм җитештерү средстволарын арендалауга рөхсәт бирү, *продразвёрстканы* бетерү ярдәм итә.

1920 елларның 2 нче яртысыннан Татарстанда, бөтен СССРдагы кебек үк, яңа з-дларны һәм ф-каларны, бигрәк тә эре сәнәгать пр-тиеләрен тизләтелгән темпларда төзү сәясәте үткәрелә. И.нең бу этабында, эре дәүләт һәм кооператив пр-тиеләр респ-ка икътисадында өстенлек алгач, халык хуҗалыгы бердәм директив дәүләт планы нигезендә үсә башлый. И. барышында респ-када (1941 гә кадәр) шул вакыт өчен яңа техника һәм технология б-н коралланган 70 тән артык эре, 300 уртача зурлыктагы һәм вак пр-тие төзелә. Сәнәгатьнең яңа: самолётлар, приборлар төзү, синтетик каучук җитештерү, кино-фото тасма, фотожелатин, ясалма күн, кетгут, музыка инструментлары, консерва, фетр аяк киемнәре, галантерея һ.б. тармаклары барлыкка килә. Сәнәгатьнең мех, тире-аяк киеме, тегү, туку, азык-төлек, киез итек-киез һ.б. тармаклары техник-яктан үзгәртеп корыла. Электр энергетикасы бик тиз үсә (к. *ГОЭЛРО планы*). Татарстан Идел буенда машина төзелеше, металл эшкәртү, химия сәнәгатенең иң эре үзәкләренең берсенә әверелә. 1926–40 та респ-каның тулаем сәнәгать продукциясе 20,6 тапкырга (59,1 млн. сумнан 1219 млн. сумга кадәр), җитештерү фондлары 31,6 тапкырга (32,6 млн. сумнан 1032 млн. сумга кадәр) арта. Сәнәгать продукциясенең халык хуҗалыгындагы тулаем өлеше 86% (1941), эре сәнәгатьтә 77,6% тәшкил итә.

Респ-ка халык хуҗалыгының тиз индустриаль үсеше аны фәнни яктан тәэмин итү ихтыяҗын тудыра. Татарстанда фәнни-тикшеренү ин-тлары һ.б. фән учреждениеләре саны арта. Респ-ка галимнәре кызыксынган өлкәләр шактый киңәя, фәннең яңа юнәлешләре барлыкка килә. 1932 ел ахырында Бөтенсоюз уйлап табучылар ирекле җәмгыяте Татарстан бүлекчәсенең 10 з-д советы, 128 ячейкасы (барысы 3998 әгъза) эшли. 1930 елларда респ-ка сәнәгате кайбер тармаклар буенча (синтетик каучук, ясалма күн, фотожелатин җитештерү) серияләп җитештерүдә фән-техника яңалыкларын куллануда СССРда алдынгы урыннарга чыга (күбесенчә чит ил техникасын һәм технологиясен файдалану һәм яраклаштыру нигезендә үсә). Респ-каның икътисади тормышында сәнәгать һәм а.х. күргәзмәләре (к. *ТАССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе*) мөһим роль уйный. Бер үк вакытта *югары уку йортлары* саны арта, аларның күбесе халык хуҗалыгы өчен белгечләр әзерли: урта һөнәри-техник белем бирү (техникумнар, ф-ка һәм з-д уч-щеләре, массакүләм һөнәрләргә укыту мәктәпләре һ.б.) принципиаль яңа төс ала. Сәнәгать һәм торак объектлары, мәдәни-массакүләм ял итү биналары, шәһәр транспортының яңа төрләре (автобуслар, таксилар) Татарстан шәһәрләренең социаль-мәдәни һәм икътисади йөзен шактый үзгәртәләр. Респ-ка сәнәгате географиясендә сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Казанда гына түгел, Яшел Үзән, Чистай, Бөгелмә шәһәрләрендә дә сәнәгать үсә башлый. А.х. продукциясен җитештерүне техник яктан тәэмин итүдә күләм һәм сыйфат үзгәрешләре күзәтелә; тракторлар, тагылма комбайннар, ашлык суктыргычлар һ.б. механизмнар киң кулланыла башлый (к. *Машина-трактор станциясе*).

И. респ-ка халкының тормыш дәрәҗәсен шактый чикләү, халык энтузиазмын рәхимсез изү (соц. ярыш, стахановчылык хәрәкәте, удар бригадалар, күп станокларда эшләү, берничә һөнәр үзләштерү һ.б.) исәбенә тизләтелгән темпларда гамәлгә ашырыла, массакүләм *репрессияләр* б-н бергә бара. Тизләтелгән И. иҗтимагый тормышның барлык якларына кагыла; ул крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү б-н бергә туры килә, соңгысы исә авыл халкының социаль структурасын, крәстиян тормышының социаль-икътисади шартларын нык үзгәртә. Җирдән һәм төп җитештерү чараларыннан мәхрүм ителгән крәстияннәр, нигездә, *шәхси ярдәмче хуҗалык* хисабына яшәргә мәҗбүр булалар. З-дларда һәм ф-каларда эшләү өчен шәһәрләргә, зур төзелешләргә китүче крәстияннәр саны арта. Эшчеләр саны туктаусыз күбәя; шул ук вакытта эшсезләр шактый кими (к. *Эшсезлек*). Инженер-техник персоналның кискен артуы күзәтелә, аның составы респ-ка халкының барлык төп социаль катлаулары исәбенә тулылана. 1941 нең 1 гыйнварына сәнәгать һәм тимер юл транспорты пр-тиеләрендә 6 мең чамасы инженер-техник хезмәткәр эшли. Вакытлы матбугат аеруча зур үсеш ала: 155 газета һәм журнал чыга, аларның тиражы арта. Республикада 337 кино күрсәтү җайланмасы, 59,3 мең радионокта исәпләнә.

И.нең 5 нче этабы (1941–90 еллар) Бөек Ватан сугышы елларында башлана, бу вакытта И.гә респ-ка икътисадын хәрбиләштерү нык йогынты ясый. Сугыш икътисады яңадан җитештерү механизмының нормаль эшләвен, шәһәр б-н авыл, сәнәгать җитештерүенең төрле тармаклары, икътисади р-ннар арасында урнашкан багланышларны боза; корал, сугыш кирәк-яраклары, хәрби кием-салым җитештерүче хәрби-сәнәгать комплексы пр-тиеләренең артуына китерә. СССРның көнбатыш өлкәләреннән эвакуацияләнгән пр-тиеләр (ш.и. 70 эре з-д һәм ф-ка) базасында Татарстан яңа производстволар (авиация, медицина инструментлары, оптика-механика, моторлар төзү, сәгатьләр эшләп чыгару һ.б.) барлыкка килә. Сугыш вакытында гражданлык сәнәгатенең күп кенә тармаклары бөлгенлеккә төшә, аларның җиһазлары физик һәм мораль яктан туза, хәрби һәм гражданлык продукцияләрен җитештерү арасындагы аерма нык арта. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач һәм халык хуҗалыгын торгызу чоры башлангач (40 нчы елларның икенче яртысы), респ-када сәнәгать җитештерүе җайга салына. 1940 еллар ахыры — 1950 еллар башында Татарстанда эре нефть ятмалары ачылганнан соң, сәнәгатьнең яңа: нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе, нефть машиналары төзелеше һ.б. тармаклары барлыкка килә. 1950–70 елларда самолётлар, вертолётлар, кече корабльләр, приборлар һ.б. хәрби техника җитештерүгә специальләшкән оборона комплексы пр-тиеләре тиз үсә. Сәнәгать производствосы үсү б-н бергә, ул эре пр-тиеләрдә, аеруча респ-каны И.дә мөһим роль уйнаучы нефть чыгару, нефть химиясе, машина-самолёт һәм приборлар төзү, энергетика, металл эшкәртү тармакларында туплана бара. Агросәнәгать интеграциясе процесслары нәтиҗәсендә автомобиль, су һәм тимер юл транспортының тагын да үсүе халык хуҗалыгын И.не тизләтүгә булышлык итә. Традицион *Казан-Яшел Үзән сәнәгать төйнәлешеннән* тыш, Татарстан терр-ясендә яңа *Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше*, *Түбән Кама территориаль-җитештерү комплексы* сәнәгать р-ннары барлыкка килә. Бер үк вакытта сәнәгать һәм а.х. производстволары интеграциясе бара (к. *Агросәнәгать интеграциясе*): сәнәгать, башлыча, билгеле бер а.х. продукциясен (шикәр чөгендере, терлекчелек продукциясе, бөртекле һәм ярмалы культуралар һ.б.) эшкәртүгә яраклаша. А.х. производствосын механикалаштыру арта; аз куәтле тракторларга һәм тагылма комбайннарга алмашка яңа а.х. машиналары һәм механизмнары килә; авыр хезмәт сорый торган процессларның шактый өлеше механикалаштырыла. И. төзелеш тармагында бик тиз бара: яңа юллар инфраструктурасы (автомобиль, автобус, троллейбус, торбаүткәргеч һ.б.) барлыкка килә, эре сәнәгать пр-тиеләре (*Кама автомобиль заводы* һ.б.), эл. станцияләре (*Түбән Кама ГЭСы* һ.б.)

корыла, шәһәрләр (Чаллы, Түбән Кама һ.б.), зур торак микрорайоннар (Казанда Горки-1 һәм Горки-2 һ.б.) төзелә. Радио элемтә коммуникацияләренең техник нигезләре яңартыла, тапшыруның яңа формалары (телевидение һ.б.) булдырыла. Бу елларда Татарстанда 3 меңнән артык сәнәгать объекты сафка бастырыла. Респ-каның сәнәгать потенциалы тиз үсү нәтиҗәсендә тармак фәнни-тикшеренү ин-тлары саны арта, югары һәм урта махсус уку йортларының, ш.и. фәнни-техник бурычларны хәл итүгә йөз тотканнарының челтәре киңәя. Бер үк вакытта фәннең производство б-н берләшү процессы бара (к. *Житештерү берләшмәләре*, *Фәнни-җитештерү берләшмәләре*). Респ-ка сәнәгатен яңартып коруда *фән-техника революциясе* зур роль уйный.

1970 елларның 2 нче яртысыннан респ-каның индустриаль үсешендә торгынлык күренешләре чалымлана башлый. Файдалануга тапшырылмаган сәнәгать объектлары күбәя. 1980–90 еллар башында сәнәгать продукциясе җитештерү шактый кими. Авыр индустрия һәм хәрби-сәнәгать комплексы тармакларының өстенлекле үсүе халык киң куллана торган сәнәгать товарлары кытлыгына һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелеккә (эшчеләр стачкалары, ачлык игълан итүләр һ.б.) китерә. 1980–90 елларда респ-када арта барган товар кытлыгын машина төзелешен, җиңел сәнәгать тармакларын тизләтеп үстерү, дәүләт органнарының азык-төлекне һәм иң кирәкле товарларны карточка системасы буенча базардан тыш бүлү юллары б-н бетерергә тырышуы якынлашып килүче социаль-икътисади кризисны туктата алмый. Милли мәсьәлә кискенләшә. Социаль киеренкелекне үзгәртеп кору чоры кыенлыклары тирәнәйтә, бу 1991 дәге «август фетнәсе» вакытында күренә. Башланган икътисади реформалар дәвамында дәүләт сәнәгать пр-тиеләренең шактый өлеше милекнең башка формасына күчә, акц. компанияләре, агрофирмалар, катнаш һәм хосусый пр-тиеләр барлыкка килә. Җитештерүнең кимүе һәм икътисадтагы структур үзгәрешләр басымы астында эш б-н мәшгуль кешеләрне халык хуҗалыгы тармаклары арасында яңадан бүлү башлана. Җиңел сәнәгатьтә, авиация сәнәгатендә, машина төзелешендә эш урыннары сизелерлек кими. Эшләүче кешеләрнең тотрыклы рәвештә артуы хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә, аеруча базар инфраструктурасы (арадашчылык һәм финанс эшчәнлеге), ш.у. сәнәгатьнең нефть чыгару һәм нефть химиясе өлкәләрендә күзәтелә. 1990 еллар уртасыннан сәнәгать җитештерүе үсә башлый. 2004 нең башында сәнәгать продукциясе структурасында 92,5% — авыр сәнәгать, 7,5% җиңел һәм азык-төлек сәнәгате өлешенә туры килә. Авыр сәнәгать структурасында беренче урынны — ягулык сәнәгате (40,1%), икенчене — машина төзелеше (21,1%), өченче урынны химия һәм нефть химиясе (18,9%) били. Милли керемдә сәнәгать продукциясенең өлеше 40% тан күбрәк (2004) тәшкил итә.

Татарстанда И. тарихы, нигездә, эшчеләр сыйныфының һәм сәнәгатьнең аерым тармакларының үсешен яктырткан әдәбиятта чагылдырылган. И.нең гомуми закончалыклары, аның динамикасы, халык хуҗалыгының һәм социаль структураның эволюциясе җитәрлек өйрәнелмәгән. Тарихи-икътисади әдәбиятта И.нең формалары һәм ысуллары, эчке объектив ихтыяҗларның һәм тышкы йогынтыларның И.нең факторлары буларак нисбәте һ.б. турында төрле фикерләр әйтелә. Ш.у. к. *Авыл хуҗалыгы, Сәнәгать, Транспорт, Элемтә, Эшчеләр сыйныфы.*

Чыг.: Индустриализация Татарской АССР. 1926–1941. К., 1968; Промышленность и рабочий класс Татарии (1946–1980): Док. и материалы. К., 1986; Промышленность Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2001; Республика Татарстан 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Транспорт и связь Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2001; Республика Татарстан 2002: Стат. сб. К., 2003.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б. Руководство хозяйственным строительством в Татарии в годы Гражданской войны (1918–1920). К., 1963; ш у л у к. Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в национальных регионах Среднего Поволжья (1926–1944 гг.). К., 1978; Н а з и п о в а К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921 гг.). М., 1976; Рабочий класс Татарии (1861–1980 гг.). К., 1981; Рабочий класс Поволжья в годы Первой мировой войны и Февральской революции (1914–1917 гг.). К., 1989; Н и з а м о в И.А. Научно-технический прогресс и кадры. Елабуга, 1998.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ИНДЮХО́В** Николай Петрович (17.4.1932, Орёл өлкәсенең Моховая р-ны Ломовое а.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1965). Казандагы М.С.Урицкий исем. мәдәният йортында сынлы сәнгать студиясе оештыра һәм аның б-н җитәкчелек итә (1963–75). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1974). Иҗатының башлангыч чорында И.К.Зариповның нәкышь йогынтысына таянып эшли, үзенең иҗат юлын аның б-н хезмәттәшлектә башлый («Аэродром кырында», 1968). 1960–70 елларда күбесенчә тематик картиналар жанрында иҗат итә — «Татар авылында бәйрәм» (1969), «Уңыш» (1972), «Шефлар» (1973–74), «Нефтьчеләрнең тынгысыз хезмәте» (1973), «Солдат хезмәте» (1977), «КамАЗда өмә» (1975–77) һ.б. Әсәрләренең композицияләре төгәл ритмлы төзелешләре, динамикалы хәрәкәтләре б-н аерыла, төп игътибар картинаның рухын билгеләүче нәфис итеп эшләнгән табигать күренешенә юнәлтелә. Тон һәм төс тулылыгы ягыннан җылы, алтынсу төсмерле буяуларның мажорлы гаммасы өстенлек итә. Буяуны тукымага куе катлам б-н төшерү манерасы картинаның фактурасына сизелерлек үзгәлек өсти. 1980 елдан башлап И. күбрәк лирик пейзажлар һәм натюрмортлар иҗат итә. Аның пейзажлары табигатькә якын торуы, язу рәвешенең сәнгатьчә дәртле рухта, ә колоритының йомшак, тыенкы булуы, хисләр, тойгылар төрлелеге б-н аерылып тора. «Казансу» (1981), «Тынлык» (1981), «Апрель» (1984), «Соңгы кар» (1985) һ.б. шундыйлардан. Натюрмортларында да рәссам сәнгатьчә пластиканы ачык һәм якты төсләр аша бирә — «Лаләләр» (1980), «Шомыртлы натюрморт» (1982), «Сөлгеле натюрморт» (1983), «Кәрҗинле натюрморт» (1985), «Бакчам чәчәкләре» (1999) һ.б. И. иҗаты — рус реалистик сәнгате традицияләренең дәвамы. 1964 тән — респ-ка; 1974 тән — төбәк («Зур Идел», 1974, 1980, 1991, 1999); 1975 тән — бөтенроссия, 1968 дән — бөтенсоюз; чит илләрдә — Яңа Зеландиядә (1977), Вьетнам (1982), АКШ (1983), Англия (1986), Япония (1987), Франциядә (1987) узган күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1982, 1990, 1995, 2002 дә (Казан), 1987 дә (Мәскәү) уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Яңа Кырлайдагы Г.Тукай музей комплексында, ТР, РФ, чит илләрдәге шәхси тупланмаларында саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; В а л е е в а Д.К. Искусство Татарстана. 20 век. К., 1999.

*М.Е.Ильина.*

**ИНЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зәй елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 18 *км*, бассейнының мәйданы 84,9 *км*². Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Болгар авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Байгол авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9%. И.нең 1,6 дан 5,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 63 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. И. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,008 *м*³*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. И. бассейнында гомуми күләме 0,79 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИНЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Игәнә елгасының сул кушылдыгы (Минзәлә елгасы бассейны). Озынлыгы 17,8 *км*, бассейнының мәйданы 124,4 *км*². Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Мусабай Заводы авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Теләнче Тамак авылы кырыеннан (читтәннән) төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 179 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. И.нең 0,5 тән 7,3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. И. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының уртача күпьеллык чыгымы 0,09 *м*³*/с*. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик

каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. И. бассейнында гомуми күләме 0,65 млн. $м^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИНЕ́Ш** елгасы, Идел алдында, Гөбенә елгасының сул кушылдыгы (Зөя елгасы бассейны). Озынлыгы 13,9 *км*, бассейнының мәйданы 52,9 $км^2$. Елга башы Чуаш Респ-касы терр-ясендә; Кайбыч р-ны Хуҗахәсән авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан, тамагына кадәр Чуаш Респ-касы чиге буйлап ага. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 73 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 48%. И.нең 0,3 тән 4 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,5–1 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга үрге агымында кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 93 *мм*, ташу агымы катламы 83 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,055 $м^3/с$. Суы ел дәвамында уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**ИНЕ́Ш** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13 *км*, бассейнының мәйданы 31,2 $км^2$. Буа р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Каенлык авылыннан 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Килдураз авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 58%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый арта. Җир асты туендыру модуле 0,1 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. И. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 $м^3/с$. Су язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ИНЕ́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бөре елгасының уң кушылдыгы (Вятка елгасы бассейны). Озынлыгы 11,5 *км*, бассейнының мәйданы 63 $км^2$. Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Шәмәрдән авылыннан 1,5 *км* көньяктарак, тамагы Яңил авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. И.нең 0,5 тән 4,9 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,26–0,5 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 91 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. И. октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,055 $м^3/с$. Су язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. И. бассейнында суының гомуми күләме 0,9 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИНЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Урман Чишмәсенең уң кушылдыгы (Чишмә елгасы бассейны). Озынлыгы 8,5 *км*, бассейнының мәйданы 32 $км^2$. Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Тукмак авылыннан төньяктарак, тамагы Керкәле авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 218 *м*, тамагыныкы — 116 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 46%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә аз гына арта. Җир асты туендыру модуле 1,1–3 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 136 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. И. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 $м^3/с$. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ИНЕ́Ш** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 65 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда 238 кеше (татарлар) яши. 1997 нең 8 октябрендә яңа торак пункт буларак теркәлә. Халык саны: 2002 дә — 200 кеше.

**ИНЕ́Ш КЕРКӘСЕ́** (Salmo trutta), сөләйман балыклар семьялыгыннан. Евразия, Төньяк Америка, Африкада яши, Австралия һәм Яңа Зеландиядә климатка ярашкан. Татарстан терр-ясендә Идел, Кама бассейннарының чиста һәм салкын сулы инешләрендә һәм вак елгаларында (Зәй, Бөрсет, Кече Шомбыт һ.б.) тереклек итә. Гәүдәсенең озынлыгы 37 *см* га кадәр, ян-яктан кысылган. Авырлыгы 0,2–0,8 *кг*. Башы өске яктан яссыланган. Төсе кара, ян-яклары алтынсыман сары, корсак өлешендә күп санда төрле төстәге тимгелләр бар. Уылдыгын (200 дән 2 меңгә кадәр бөртек) көзен чуер ташлы сай сулы урыннарда чәчә. Умырткасызлар (зоопланктон, бөҗәкләр һ.б. умырткасызларның личинкалары) б-н туклана. И.к. буада үрчетү объекты булып тора. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ИНЖЕНЕРЛЫ́К ГЕОЛО́ГИЯСЕ**, корылмалар төзелергә тиешле грунтлар үзенчәлекләрен һәм аларда бара торган үзгәрешләрне өйрәнүче фән. Грунт белеме, инженерлык геодинамикасы, региональ һәм диңгез И.г.нә бүленә. Гамәли бүлекләре: шәһәр һәм шәһәр агломерацияләре И.г., файдалы казылма чыганаклары, мелиорация И.г. һ.б. Геология, физика, механика, география, башка фәннәрнең казанышларын һәм алымнарын куллана, гидрогеология һәм туңлык белеме б-н тыгыз бәйләнештә. Иң зур тикшеренүләр АКШ (К.Терцаги, Р.Пек һ.б.), Бөекбритания (А.Скематон), Франция (Ж.Талобр) һ.б. илләрдә үткәрелгән. Россиядә 19 йөз ахырында инженерлык-геол. эшләр башлангач (тимер юллар төзелеше б-н бәйле) барлыкка килә. Аларда геологлар А.П.Карпинский, В.А.Обручев һ.б. катнаша. Мөстәкыйль фән буларак 1920 елларда оеша. Ф.П.Саваренский, М.М.Филатов һ.б. галимнәр тарафыннан төп хезмәтләр языла. 1964 тә И.г.нең Халыкара ассоциациясе оеша. РФдә инженерлык-геол. эзләнүләрне РФАнең И.г. һәм гидрогеология буенча Фәнни советы координацияли.

Татарстанда И.г. үсешенә зур өлеш кертүчеләр: М.С.Кавиев, Б.М.Йосыпов, С.Г.Каштанов, Е.Ф.Станкевич, Е.И.Краев, Е.И.Синявский һ.б. Алар тарафыннан карст упкыннары барлыкка килүнең суффозиональ теориясе, инженерлык-геол. эзләнүләр методикасы эшләнә; экзогеодинамик процессларның гомуми үсеш закончалыклары, грунтларның физ.-механик үзенчәлекләре, корылмаларның торышына йогынты ясаучы мөһим факторлар (чыдамлык, тотрыклылык һ.б.) ачыклана. И.г. буенча эзләнүләр Казан ун-тында, Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, Казан төзүчелек эзләнүләре ин-тында, «Татсельхозстрой», «Казметрострой» трестларында һ.б. оешмаларда алып барыла. Инженерлык-геол. эзләнүләрнең (картага төшерүләрнең) нәтиҗәсе буенча конкрет терр-ядә төзү өчен инженерлык-геол. шартларны тасвирлаучы карталар төзелә һәм уңай (Көнбатыш Идел алды һәм Көнбатыш Кама алдының су б-н бүленгән өлешләре), шартлы-уңай (ТР терр-ясенең күпчелек өлеше), уңай булмаган (барлык елга үзәннәре) һәм бөтенләй уңай булмаган (Идел елгасының уңъяк яр буендагы төп текә битләр) р-нnарга бүленә. Экзоген-геол. процесслар мониторингын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагыч ярларының үзләштерелүен, шуышма һәм ерым эрозияләрен режимлы күзәтүне «Татарстангеология» пр-тиесе каршындагы махсус үзәк үткәрә.

*Е.И.Синявский.*

**ИНЖЕНЕРЛЫ́К САКЛАГЫЧЛАРЫ́**, торак пунктларны, сәнәгать һәм гражданлык биналарын һәм корылмаларын табигатьнең стихияле җимергеч көчләре тәэсиреннән һәм кеше эшчәнлеге нәтиҗәләреннән саклауга юнәлдерелгән комплекслы чаралар. Татарстанда торак пунктларны һәм а.х. җирләрен саклау өчен 1953–64 һәм 1978–81 елларда Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының суы күтәрелүгә бәйле рәвештә И.с. корыла. 1953–64 тә Казанда И.с. уздырган чаралар вакытында Казансуның юлы үзгәртелә һәм шәһәрне 57 *м* күрсәткеченә кадәр су басудан саклау өчен төрле биеклекле корылмалар комплексы төзелә. Шәһәрне саклауның

1 нче биеклеге — гомуми озынлыгы 25,2 *км* булган дамбалар (Идел, Көньяк, Югары һәм Түбән Елга аръягы, Порт, Федосеев дамбалары) һәм плотиналар (Югары һәм Түбән), ш.у. дулкын аергыч; 2 нче биеклек — ябык горизонталь су саркыткычлар (7,2 *км*); 3 нче биеклек — дамба алдындагы күпьяруслы ачык су саркыткычлар челтәре (30,9 *км*) б-н тәэмин ителә. Комплекска гомуми җитештерүчәнлеге 70 мең *м*³/*сәг*. булган 7 насос станциясе, яңгыр суын агызу челтәре, ачык һәм грунт суларының биеклек режимын күзәтү өчен төзелгән 70 скважина керә. 1955 тән комплекстан файдалануны оештыру б-н Казанның Инженерлык саклагычлары идарәсе шөгыльләнә. Чистай (1957), Яшел Үзән (1958) шәһәрләрендә, Яшел Үзән р-нындагы шәһәр тибындагы Васильево поселогында (1958), Актаныш (30 *км* лы дамба) һәм Минзәлә р-нnарында (1970 еллар) саклагыч корылмалар (дамбалар, плотиналар, насос станцияләре, дренаж канаулары) төзелә.

Шулардан файдалану һәм аларга күзәтчелек итү эшләрен «Татэнерго» АҖ, ТРның Экология һәм табигый ресурслар, Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыклары, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларыннан файдалану идарәләре гамәлгә ашыра.

*Әд.:* Корнеева Т. Укротители водной стихии // Казань. 2001. № 3.

**ИНҖИ́Л**, Иисус Христосның җир йөзендәге тормышын бәян иткән әүвәлге христиан язмалары (Евангелие); *Библиянең* бер өлеше. И.не канунлаштырылган (Марк, Матфей, Лука һәм Иоанн тарафыннан язылганнар; алар Яңа Гаһед составына кертелгән) һәм уйдырма (Библия канунына кертелмәгән) И.ләргә аералар. Христиан чиркәве И.нең авторлары — хәвариюннар (апостоллар) яки аларның шәкертләре дип исәпли. И. китаплары 1 йөз ахыры — 2 йөз башында язылган дип санала. Коръәндә И. яһүдиләрнең Бишкитабы б-н бергә илаһи язмалар буларак искә алына. Христианнардагы Гайсә — Исраил пәйгамбәрләренең соңгысы. Коръән буенча, аңа иңгән вәхи — ул Инҗилдә теркәлгән — Мөхәммәднең килүе якынлашуы, аның соңгы пәйгамбәр булуы турында куанычлы хәбәр сыйфатында әйтелә. Анда ш.у. канунлаштырылган һәм уйдырма И.ләрдә бәян ителгән дәлилләр, образларда бар (әйтик, Гайсәнең анисе *Мәрьямнең* һәм *Гайсәнең* тууы, ул кылган могҗизалар турында хикәяләр). Алар барысы да Гарәбстанда исламга кадәрге дәвердә күбесенчә телдән таралган христиан риваятьләрен кабатлыйлар. 8–9 йөзләрдә И.нең грек, сүрия, копт телләреннән гарәпчәгә тәрҗемәләре киң тарала башлый. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан И.нең татарчага тәрҗемәләре барлыкка килә.

*Әд.:* Богдашевский Д.И. О Евангелиях и евангельской истории. Против современного рационализма. Киев, 1902; Михаил (Лузгин). Толкование Евангелия: В 3 т. К., 1903–05; Феофан (Говоров). Евангельская история о Боге-Сыне, воплотившемся нашего ради спасения, в последовательном порядке изложения словами святых Евангелистов. М., 1918; Рановский А. Первоисточники по истории раннего христианства. М., 1933; Новый Завет Господа нашего Иисуса Христа. М., 1976; Свеницкая И.С. Апокрифические Евангелия. М., 1996; Мень А.В. Сын Человеческий. М., 1998; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ИНКРУСТА́ЦИЯ**, к. *Кырлау*.

**ИННОКЕ́НТИЙ** (Никифоров Иван Иванович) (27.3.1879, Казан губ., Мамадыш өязе Олы Мәшләк а. — 4.2.1937, Курск ш.), дин эшлеклесе, дин гыйлеме канд. (1918). Керәшен татарлардан. Уфа руханилар семинариясенең 4 сыйныфын (1899), Тобол руханилар семинариясен (1914), Казан руханилар академиясен (1918) тәмамлый. 1899 елдан Омск шәһәрендәге кафедраль собор дьяконы, 1903 тән Омск епархиясенең Фёдоровское, 1906 дан Лаптев Лог авылларында, 1912 дән Семипалатинск шәһәрендәге Казаклар чиркәвендә рухани. 1918 дән Омск приход храмының настоятеле. 1925 тән монахлыкта. 1925 тән Семипалатинск епископы, Омск епархиясе викарие, 1928 дән Семипалатинск һәм Усть-Каменогорск шәһәрләренең епархия епископы, 1936 дан Орёл епископы. 1937 дә кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә; үлгәннән соң аклана.

**ИНОГА́МОВ** Наил Алим улы (28.1.1951, Ташкент), физик, физ.-матем. фән. д-ры (1990). 1974 елда Мәскәү физика-техника ин-тын тәмамлый. 1977 дән Л.Д.Ландау исем. Теоретик физика ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре гидродинамикага, плазма физикасына, югары тизлекле бәрелүләр физикасына карый. Релей-Тейлор тотрыксызлыгы гидродинамикасы теориясен, электр кырындагы плазма динамикасын, автомодельле гидродинамик чишелешне тасвирлый. Югары тизлекле бәрелү теориясе «Вега — Галлей кометасы» программасы буенча космик тәҗрибә үткәрүдә әһәмиятле роль уйный (1986).

**ИНОЗЕ́МЦЕВ** Асаф Семёнович (1753 — 1808 елдан соң), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре, җәмәгать эшлеклесе. Таишев бакыр кою з-ды (Кукмара а.), Казанда 2 таш йорт һәм амбар хуҗасы. Россия һәм Германия товарлары б-н сату итә. 1776 елда А.А.Чекмарёв б-н бергәләп сәүдәгәр П.П.*Каменевның* яшь балалары (Гавриил, Пелагея һәм Анна) өстеннән караучы (опекун) итеп билгеләнә. 1777–80 дә Казан губернасы магистраты президенты, 1782–88 елларда Казан шәһәре магистраты утырышчысы.

*Л.М.Свердлова.*

**«ИНОРО́ДЧЕСКОЕ ОБОЗРЕ́НИЕ»** («Рус булмаган халыклар тормышына күзәтү»), журнал. Казан руханилар академиясенең миссионерлар бүлеге органы. «*Православный собеседник*» ж-лына кушымта итеп чыгарыла һәм 1912 елның декабреннән 1916 га кадәр елга 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә. 16 саны чыга. Башлап җибәрүчесе, мөхәррире, мәкаләләрне тәрҗемә итүче һәм авторы — Н.Ф.*Катанов*. Авторлар арасында, башлыча, академия укытучылары. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең гомуми җыелышларында ясалган аерым докладлар басыла. Күпчелек мәкаләләр Россиянең Европа һәм Азия өлешендә яшәүче төрле диндәгеләрнең (христианнар, мөселманнар, ламачылар, шаманчыларның) көнкүрешен, динен, гореф-гадәтләрен яктыртуга багышлана. Россия империясендә яшәүче әҗнәбиләрнең, ш.и. чуаш, мари, казакъ, хакас, бурят, ш.у. Көнбатыш Кытайдагы мөселманнарның тарихын, этнографиясен һәм мәдәниятен яктыртуга зур игътибар бирелә. Кайбер халыкларның исемнәре этимологиясенә багышланган, Идел-Кама төбәгендәге рус булмаган халыкларның, бигрәк тә татарларның дини-әхлакый, дини карашлары, канун һәм күрсәтмәләре мәсьәләләренә караган мәкаләләр зур урын ала. Этнограф галимнәр Н.В.Никольский, В.М.Васильев, В.И.Иванов мәкаләләре б-н беррәттән һәвәскәр (гади) хәбәрчеләрнең күпсанлы хәбәрләре дә басыла. Ш.Саттаровның татар бәйрәмнәренә багышланган мәкаләләр сериясе дөнья күрә. Г.Пчёлов һәм Г.Филиппов материалларында Мәлки керәшеннәре һәм мордва-каратайлар тасвирлана. Казан губернасы шәһәрләренең истәлекле урыннары турындагы материалларга зур урын бирелә. Рус телле укучыларга багышланган татар иҗтимагый фикере, милли хәрәкәте һәм мәдәнияте турындагы мәкаләләр мөһим урын алып тора. «Тәнкыйть һәм библиография» бүлегендә татар газета һәм журналларына, календарьларга, дини-әхлакый характердагы әсәрләргә, дәреслекләргә, муз. әсәрләргә, Казан уку-укыту округы идарәсе каршындагы тәрҗемәчелек комиссиясе басмаларына күзәтүләр басыла. «Вакыт», «Кояш», «Сибирия», «Тормыш», «Йолдыз» г-таларыннан, «Аң», «Шура» һ.б. ж-ллардан алынган тәрҗемә мәкаләләргә урын бирелә. Матур әдәбиятка күзәтүләр урнаштырыла, ш.и. Г.Тукай, Н.Думави, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Камал иҗатларына, кыргыз һәм казакъ әдәбияты әсәрләренә җентекле анализ ясала (авторы — Казан укытучылар семинариясе укытучысы А.И.Емельянов). 1915 елда яңа ысул б-н эшли торган мәктәп һәм мәдрәсәләрдә кулланылучы укыту ярдәмлекләренә күзәтүләр басыла (авторлары — Н.Ф.Катанов, Я.Д.Коблов, И.Я.Ашмарин, А.И.Емельянов). Журналда беренче мәртәбә Я.Д.Кобловның «Казан татарларының конфессиональ мәктәпләре» («Конфессиональные школы казанских татар», 1916) мәкаләсе басыла. Финанслау җитмәү сәбәпле, журнал чыгудан туктый.

*Әд.:* Gokgoz S.S. The Kazan-Tatar press from the pen of a missionary: Inorodcheskoe Obozrenie (1912–1915) // Eurasian studies. 2002. № 21.

*Г.Р.Заманова, Е.В.Липаков.*

**ИНСА́Р РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* көньягында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 968,7 *км*². Үзәге — Инсар шәһәре (Саранскидан 77 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 18,2 мең кеше, ш.и. 300 татар. Татарлар 17 йөз уртасында Темников йомышлы татарлары нигез салган Яндавишча (210 кеше), Жегалино (13) авылларында яшиләр.

**ИНТЕРМЕ́ДИЯ** (лат. intermedius — урталыкта торучы), драма спектакле яки опера актлары арасында башкарыла торган зур булмаган сәхнә күренеше (гадәттә, көлкеле). 15 йөздә мистерия составына кергән тормыш-көнкүрештән күренешләр яки музы-

каль номер формасында барлыкка килә. Татар драматургиясе әсәрләрендә И. агитация-сатира төсмерен дә ала. Г.Камалның агитпьесаларында И. персонажлары булып Аҗак б-н Кужак, Корфетдин б-н Торфетдин, Хатип б-н Латип тора. Ф.Бурнаш та үз пьесаларына («Таң атканда», «Әҗәл», «Колчак-Деникин зарлары»), Һ.Такташ та («Авыл кызлары», «Гармунчылар») И.не кертәләр. Хәзерге татар драматургиясендә И. кулланылмый диярлек.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**ИНТЕРНАЦИОНА́ЛЬ БАТАЛЬО́Н**, К.Маркс исемендә, 1918 елның февраль-мартында Казанда руслардан, татар, чуаш, мари, латыш, украиннардан, Германия һәм Австро-Венгрия армияләренең хәрби әсирләреннән оештырыла. Командиры — С.А.Бирюков. 1918 нең июнендә батальон Казанда сул эсерлар фетнәсен булдырмый калуда катнаша. Июльдә Казан совет дивизиясе составына керә. 1918 елның августында Казанны чех-словак һәм КОМУЧ Халык армиясе корпусларыннан саклауда катнаша. Шул елның көзендә таратыла.

*Әд.:* С у б а е в Н.А. Родники солидарности. К., 1971. *И.Г.Гыйззәтуллин.*

**ИНТЕРНАЦИОНА́ЛЬ СҮЗЛӘ́Р**, *алынмаларның* бер төре; төрле телләрдә кулланылышта йөреп, тышкы формалары, язылышлары б-н бер-берсенә якын торган һәм мәгънәләре дә тулысынча яисә өлешчә бердәй булган алынма сүзләр. И.с. фән, техника, иҗтимагый тормыш, мәдәният, сәнгать өлкәсенә караган халыкара төшенчәләрне белдерәләр һәм якын туганлыкта булмаган 3 яисә аннан да артыграк телдә яшиләр. Татар телендәге И.с. килеп чыгышлары ягыннан 5 төркемгә бүленә: 1) Европа алынмалары (грек-латин сүзләре): президиум, комедия, прогресс; 2) *гарәп алынмалары* һәм *фарсы алынмалары*: цифра, климат, әдәбият, сәнгать, китап; 3) *рус алынмалары*: совет, большевик, спутник; 4) кытай, япон алынмалары: дзюдо, тайфун, цунами, чәй, дөге; 5) һинд теленнән алынган сүзләр: әрдәнә, сыра, алма.

Татар телендә И.с.гә кайбер үзенчәлекләр хас: 1) исем И.с. рус телендәге кебек әйтеләләр (мәс., интервенция, компенсация); 2) сыйфатлар, күп очракта кыскартылып кулланылалар (экономик, социаль); 3) И.с.нең аерым грамматик категорияләре, агглютинатив тел буларак, татар теле чаралары б-н белдереләләр (стабиль-лә-ш-тер-ү).

*Әд.:* А к у л е н к о В.В. Интернациональные элементы в лексике и терминологии. Хар., 1980; Х а й р у л л и н М.Б. Некоторые вопросы единства интернационального и национального в разносистемных языках. К., 1991. *Л.К.Бәйрәмова.*

**ИНТЕРНЕ́Т** (лат. inter — ара һәм net [work] — челтәр), зур (глобаль), ш.у. кече (локаль) компьютер челтәрләреннән файдаланучыларны үзара бәйләнешкә кертә торган бөтендөнья компьютер челтәре. АКШ Оборона министрлыгының төрле радио һәм иярченнәр системаларын ARPAnet челтәре б-н берләштерергә омтылу нәтиҗәсендә 1970 еллар уртасында барлыкка килә. ARPAnetның төп принцибы челтәрдәге һәр компьютерның төйнәлеш сыйфатында теләсә кайсы компьютер б-н аралаша алуыннан гыйбарәт. Локаль хисаплау челтәрләрен актив эшләү яңа ихтыяҗ барлыкка килүгә — ARPAnetka зур бер компьютер урынына бердәм локаль челтәрләр тоташтырырга ярдәм итә. Формалаша башлаган яңа челтәрләрдән АКШ хөкүмәтенең Милли фәнни фонды тарафыннан оештырылганы аеруча мөһим була. 1980 еллар ахырында әлеге фонд әйдәп баручы Америка ун-тларында 5 суперкомпьютер үзәге оештыра һәм шул ресурсларны барлык акад. тикшеренүләр өчен файдаланырлык итә. ARPAnet челтәре технологиясе җирлегендә коммуникация проблемаларын чишү өчен Милли фонд хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән челтәр соңыннан И.ның үзәген хасил итә.

1990 елларда Россиядә, ш.и. Татарстанда да, коммуникацияле технологияләргә нигезләнгән нык үскән инфраструктура булдыру эшләре башлана. 1993–94 тә ТРда беренче коммерция челтәрләре («Комтат», «Трансинформ» АҖләре, «БанКорп» мәгълумати-финанс корпорациясе) барлыкка килә. Аларга кермәгәннәре берничә ведомство челтәрен, ш.у. ТРның Гражданнар челтәрен (ГЧ), Фәнни һәм укыту оешмаларының «SENet-Tatarstan» челтәрен тәшкил итә, коммерциянекеләрдән аермалы буларак, алар фән, мәгариф, дәүләт идарәсе, сәламәтлек саклау һәм мәдәният оешмаларына һәм учреждениеләренә хезмәт күрсәтә.

1994 елда Казан ун-ты җирлегендә РФА КГҮ һәм Казан югары уку йортлары б-н бергәләп ТР ГЧ — 130 дан артык оешманы берләштергән региональ масштабтагы телекоммуникацияле система оештырыла. Федераль ведомствоара телекоммуникацияләрнең программ проекты аның оештырылу һәм финанслау нигезе булып тора (РФ Фән министрлыгы, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды акчаларына һәм ТР Хөкүмәтенең финанс ярдәмендә гамәлгә ашырыла); оештыручы-башкаручысы — Казан ун-тының Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты. ГЧ, асылда, Казан, Чаллы шәһәрләрендәге югары уку йортлары, РФА КГҮ һәм ТР ФА ин-тлары, респ-ка хастаханәләре һәм клиникалары, дәүләти идарә учреждениеләре, мәдәният һ.б. коммерцияле булмаган оешмалар компьютер челтәрләренең гомумтехник базасы берләшмәсе булып тора. И.ның күрше үзәкләр б-н элемтә бәйләнышлары Мәскәү һәм Ульянов шәһәрләренең шәһәрара аерым телефон каналлары аша гамәлгә ашырыла. 1997 дә ТР ГЧ хезмәтеннән көн саен Татарстанда 5 меңнән артык кеше файдалана. 1998 елның ноябрендә «Ачык җәмгыять» ин-ты (Россиядәге Сорос фонды) һәм РФ хөкүмәте б-н берлектә төзелгән «Интернет» программасы кысаларында Казан ун-тында заманча компьютер һәм телекоммуникацияләр б-н җиһазланган И. үзәге ачыла, бу исә ТР ГЧ мөмкинлекләрен шактый киңәйтә (проект җитәкчесе А.М.Елизаров). 2000 дә оешкан респ-ка фәнни һәм укыту оешмаларының «SENet-Tatarstan» челтәре РФА КГҮ, ТР ФА ин-тларын, Казан югары уку йортларын берләштерә. 2001 дә SENetның коммуникацияле нигезен күп җепселле тоташтырмаларга күчерү проекты гамәлгә ашырыла. ТР ГЧ һәм SENet челтәрләренең эше бергә алып барыла башлый. 1994 тән ГЧнең үзәк серверындагы «Казан Интернет челтәре»ндә Web-сервер эшли, 1997 ел ахырында «Татарстан Интернет челтәрендә» (http: // www.kcn.ru) серверы оештырыла. Анда, аерым алганда, «Lobachevskii Journal of Mathematics» һәм «Magnetic Resonance in Solids» электрон ж-ллары, шәһәр вакытлы басмаларының электрон версияләре урын ала. Серверда фәнни һәм укыту-методик конференцияләр уздырылу хакында даими рәвештә игълан ителә, Казан ун-ты Фәнни китапханәсе мәгълүматларыннан файдалану мөмкинлеге бирелә, Казан югары уку йортлары галимнәре һәм акад. ин-тлар хезмәтләрендә үстерелгән мөһим юнәлешләр (респ-ка тарихы, икътисады, сәясәте, төзелеше, мәдәнияте) күрсәтелә, 2001 дә ТРның рәсми серверын (http: // www.tatar.ru) булдыру мәгълүмат ресурслары өлкәсендәге казанышларның берсенә әверелә. Андый материалларның тематикасы: сәясәт, икътисад, тарих, мәдәният, рәсми документлар һәм белешмә мәгълүматлар. Серверда ТР Президентына шәхси бит, рәсми серверлар һәм И.та Татарстан мәгълүмат чараларының тулы каталогы урнаштырылган. ТРның күп кенә фәнни һәм укыту оешмалары катнашында төзелгән массакүләм мәгълүмат чаралары проектлары, ш.и. РФА КГҮ һәм Казан ун-ты каршындагы Математика һәм механика ин-ты тарафыннан эшләнгән «Татарстан Республикасының электрон китапханәсе» проекты кертелгән.

*Әд.:* К р о л Э. Всё об Интернет. Киев, 1995; Электронная почта и доступ к Internet в Татарстане. К., 1996; Е р ш о в а Т.В., Х о х л о в Ю.Е. Межведомственная программа «Российские электронные библиотеки»: подходы и перспективы // Электронные библиотеки. 1999. Т. 2, вып. 2; Б и к т и м и р о в М.Р., Ш а б а ш в и л и Э.Е., Е л и з а р о в А.М. О концепции проекта «Электронная библиотека Республики Татарстан» // Вестн. Рос. фонда фундам. исслед. 2001. № 3. *А.М.Елизаров.*

**ИНТЕРФЕРЕ́НЦИЯ** (лат. inter — арасында һәм ferio — кагылам, сугам); тел белемендә — тел контактлары яисә чит телне үзләгеңнән өйрәнгән вакытта барлыкка килә торган икетеллелек шартларында тел системаларының үзара тәэсир итешүе. Туган телнең йогынтысы нәтиҗәсендә өйрәнелә торган телнең нормалары һәм системасыннан читкә китүләрдә чагыла; акцент буларак беленә. Телнең барлык өлешләренә хас, аеруча фонетикада күзәтелә. И.нең төп чыганагы — туган тел һәм өйрәнелә торган тел системаларындагы аермалар. Лингвистик табигате буенча И. телнең барлык өлешләрендә күзәтелә (фонетик, лексик-фразеологик, грамматик И.) һәм аның берничә төре бар: 1) аерып бетермәү (туган телдә булмау сәбәпле, өйрәнелә торган телдәге дифференциаль билгеләрне аерып бетермәү): «лекция», «в целом» һ.б. шундый сүзләрдә татарларның [тс] урынына [с] дип әйтүләре; русча «она ушёл» дип әйтү

татар телендә род булмау б-н аңлатыла; 2) артык аеру (туган телдә булган, ә өйрәнелә торган телдә булмаган дифференциаль билгеләрне шул телгә күчерү): сингармонизм законы тәэсирендә татарларның русча сөйләмендә акцент сизелергә мөмкин: бо[л]ной — больной, ходи[л́] — ходил; 3) реинтерпретация (өйрәнелә торган телдәге аера торган билгеләрне туган тел кагыйдәләре б-н аңлату). Реинтерпретацияләнгән хаталар (функциональ И.) — калькалаштыру, туган телдән сүзгә-сүз тәрҗемә итү нәтиҗәсе: «готов сквозь землю провалиться» урынына татарларның русча сөйләмендә — татарча «җир астына керерлек булу» фразеологизмындагы кебек — «готов под землю провалиться»; «чана шуу» урынына русларның татарча сөйләмендә — рус сүзтезмәсендәге «кататься на санях» кебек — «чаналарда шуу» дип әйтү.

*Әд.:* Ахунзянов Э.М. Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. К., 1978; Закирьянов К.З. Двуязычие и интерференция. Уфа, 1984; Байрамова Л.К. Что такое фразеологическая интерференция // Совет мәктәбе. 1985. № 7.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**ИНТЕРЬЕ́Р** (фр. interieur — эчке), йортның бүлгәли-чикли торган өлешләрдән, җиһазлардан, киң куллану әйберләреннән һәм ансамбль тудыручы башка йорт кирәк-яракларыннан торган уңай һәм матур итеп җыелган эчке өлеше. Традицион И.га этник үзенчәлекле һәм милли сәнгати-архитектур стильле авыл һәм шәһәр халык торакларының эчке күренеше керә.

Традицион татар И.ын тарихи чыганаклар 19 йөзнең 1 нче яртысыннан башлап күзалларга мөмкинлек бирә. Үзенең төп асылы б-н ул гасырлар буена формалашкан стационар торак төренә, утрак тормыш алып барган борынгы игенче татарлар культурасына карый. Анда борынгы төркиләрнең күчмә тораклары — йортлары өчен характерлы булган әүвәлге, күчмә культураларының аерым өлешләре сакланган. И.ның корылышы икмәк пешерү миченең кайда урнашуына бәйле була. Мич исә ишекнең уң яки сул ягында, дивардан беркадәр ара калдырып чыгарыла. Мич турысы буйлап түшәм б-н тоташмаган бүлмә тактасы яки *чаршау* корып куела. Бүлмә (чаршау) торак мәйданын 2 якка — ирләр яки кунак (түр) һәм хатын-кызлар яки



Авыл йорты интерьеры.
19 йөз ахыры — 20 йөз башы. Реконструкция.

почмак якларга аерып тора. Ирләр ягында өй түре диварына терәп — ишек каршында — күтәренке итеп такта түшәп ясалган мәйданчык яки *сәке* корып куела. Өй җиһазы буларак, аның роле күптөрле булган. Йокы, аш, эш урыннары булып саналган. Керәшен татарлар һәм мишәр-татарларда сәке урынына түр һәм ян диварлар буена озынча эскәмияләр куелган. Сәндерәләр — агач түшәмәләр, гадәттә, ишек янындагы диварның югары буена беркетелгән. Түшәм астына төрле көнкүреш кирәк-яраклары саклау өчен киштә-шүрлекләр ясап куела. Болардан кала И.ны социаль һәм яшь үзенчәлегенә карап бүлү дә яшәп килә. Кунаклар ягында, ишеккә карап торган җирдә, гаилә башлыгы һәм абруйлы кунаклар өчен махсус урын (түр) билгеләп куела. Балалар һәм яшьрәкләр өчен урын ишек төбендәрәк тәгаенләнә. Керәшен татарларда, урыс йортларындагы кебек, икона урнаштырылган кадерле, «кызыл» почмак та була. И.ны бизәү өчен *туку* һәм *чигү* техникасы б-н бизәлгән күптөсле тукымалар әһәмиятле роль уйный. И.дагы бизәкле тукымалар, борынгы төрки юрталарына хас булганча, өй почмакларын, диварларны каплап, ямьләп торган. Сәкегә тукылган паласлар һәм киезләр җәелгән; эскәтер (җәймә, япма), декоратив сөлгеләр һәм кашагалар тәрәзәләр арасындагы диварларга, бүлмә такталарына, агач шүрлекләргә, матчаларга эленгән. Чаршау И.ның төрле урыннарын (сәке, почмак як) бүлеп торган, чатыр формасындагы *чыбылдык* яшь парлар түшәген, бала бишеген катлап алган. Кашага-түрләмә исә түшәм астына, матча һәм кунаклар ягы диварлы буенча, чаршау өстенә эленгән. И.ны бизәгәндә диварга эленә торган *шәмаилләр, ләүхәләр* өй күрке булырлык иң хөрмәтле урынга — түр яккa яки бүлмә ишегe өстенә куелганнар. *Намазлыклар*, гадәттә, бүлмә такталарына һәм түр диварларга эленгән. Урын-җирнең күплеге И.ның характерлы үзенчәлеге булган: ястык һәм мендәрләр сәке-сандык өсләренә күпертеп өеп куелган. Идәнгә тукылган келәмнәр, бай гаиләләрдә йон келәмнәр яки киез җәелгән, сандыкларны сырган япма-көрпә б-н каплаганнар. И. бизәү туй йоласының бер өлеше булып саналган «өй киендерү», «өй бизәү» кебек ритуал кагыйдәләр б-н бәйле. Йола килен йортында үткәрелгән, ул кияүнең туганнарына һәм кунакларга киленнең кул эше белүен һәм уңганлыгын бәяләргә мөмкинлек биргән. И.ның иң мөһим элементы буларак, бизәкле тукыма аның ансамблен, ачык бизәкле образын формалаштыра. Төсләр гаммасы агач диварлардагы, җиһазлардагы, бакыр һәм җиз кирәк-яраклардагы җылы төсләр б-н гармонияләш куе кызыл, көрән, охра-сары, яшел, күк-зәңгәр, ак һ.б. төсләр б-н бергә туры килә. И.ның көнкүреш ансамблен тудыруда каты материалдан ясалган эшләнмәләргә (агачтан, сирәк кенә металлдан эшләнгән (сандык, төрле агач савыт-саба, самавыр, чәйнек, комган, ләгән һ.б.), ш.у. йорт эш коралларына — җеп эрләү машинасына, кырлы бәләккә, сирәк кенә, уеп ясалган бизәкле туку станогына беркадәр әһәмият бирелгән. 19 йөзнең 2 яртысыннан татар йортының И.ны бизәүче йорт җиһазларында Европа һәм рус шәһәр культурасы элементлары: җиһаз (урындыклар, өстәлләр, өс киеме һәм савыт-саба шкафлары), яктырту приборлары, башка көнкүреш әйберләре күренә башлый. Мул тормышлы шәһәр татарларның йорт И.лары Европа һәм рус архит-расында киң таралыш алган архит-ра-сәнгать стильләре б-н берлектә милли традицияләрнең үзенчәлекле бәйләнешен чагылдыра. 19 йөз — 20 йөз башында татар югары катлау кешеләрнең йортларында Европалашуга омтылыш чагылган ирләр (олы як) һәм традицион культура үзенчәлекләрен саклаган хатын-кызлар (ахирәт) ягына бүленүе б-н бәйләнешле катлауландырылган планлаштыру хөкем сөргән. Шәһәр И.н бизәү Европа таләпләренә җавап биргән. 20 йөзнең 1 яртысыннан алып, И.ны планлаштыру үзгәрә башлый (газ б-н ягып җылыта башлагач, мичләр юкка чыга), көнкүрешнең камилләшүе б-н бәйле үзгәрешләр барлыкка килә. Заманча авыл өе И.ы барлык традицион өлешләре б-н шәһәр тормышына якыная бара (сәкеләр, бүлмә такталары, сәндерәләр, эскәмияләр юкка чыга). Заводта житештерелгән функциональ типтагы (җыелма, корпуслы, йомшак һ.б.) йорт җиһазлары, заманча җиһазлар (кухня һәм торак) һәм көнкүреш кирәк-яраклары тарала башлый. Традицияләрнең дәвамлылыгы И.дагы декоратив бизәлешләрдә, аерым алганда, бүгенгә кадәр



Авыл йорты интерьеры. 19 йөз ахыры.
Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылындагы К.Насыйри музее. Реконструкция.



Татар йорты интерьеры.
Көнбатыш Кама аръягы. 1926.

сакланган бизәкле тукымаларда, шәмаилләрдә, комганнарда беркадәр сизелә. Заманча авыл йорты И.ы шәһәрнекенә якынлаша.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. М., 1956; Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Нугманова Г.Г. Татарская городская усадьба: Дис. ... М., 2000; Сулейманова Д.Н. Этническое своеобразие традиционного татарского интерьера // Традиционная культура: Науч. альманах. М., 2007, № 3.

*Д.Н.Сөләйманова.*

**«ИНТИ́М ТЕА́ТРЫ»**, Казанда миниатюралар театры. 1909 елның 19 ноябрендә Сәүдәгәрләр җыены бинасында ачыла (хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы). Антрепренёры — М.П.Ромаскевич-Марковская, реж. — Н.Б.Табенцкий, труппа составында П.Н.Андреев, О.Н.Вехтер, В.А.Марковский, Н.С.Тимирёв, А.М.Шумский була. Театрның репертуарында бер актлы комедияләр, пародияләр, оперетталар, тамашалар, концерт программалары, ш.и., «Казан шәһәрендә мәхәббәт һәм маҗаралар төне. Шәһәрнең 4 өлешендә акылга сыймаслык вакыйга» («Ночь любви и приключений в гор. Казани. Невероятный случай в 4-х частях города») программасы; «XX гасырдагы ир белән хатын» («Супруги XX века») опереттасы; Казан авторы Е.Ю.Геркенның «Алар сөя иде» («Они любили»), А.Смолдовскийның «Ярату көче» («Сила любви»), Н.Б.Табенцкийның «Үч алу төне» («Ночь расплаты»), Д.А.Мансфельдның «Нина», А.С.Пушкинның «Саран рыцарь» («Скупой рыцарь») пьесалары бар. Шулай ук А.П.Чеховның 50 еллык юбилее уңаеннан әзерләнгән бер актлы пьесалары һәм миниатюралары кичәсе; О.Уайлдның вафатына 10 ел тулуга багышланган кичә була. Артистлык зәвыгы, күпчелек постановкаларның эзләнүчән режиссёр күзлегеннән чыгып тиешле чишелеш алуы, пародияләнүче персонаж яки күренешләрнең актуальлеге һәм таныш булуы Казанда театрга уңыш китерә. Сезон тәмамлану б-н труппа таркала. Театр үзенең эшчәнлеген 1913–14 елларда В.В.Образцов антрепризында «Chat noir» («Кара мәче» — «Чёрный кот») исеме б-н яңадан башлап җибәрә. Бу юлы Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамында Соломин йортындагы миниатюралар театры бинасында урнаша. Шул сезон спектакльләре арасында «1913 елдагы Казанны күзәтү» («Обозрение г.Казани 1913-го года») дә бар.

**ИНТОНА́ЦИЯ** (лат. intono — кычкырып әйтәм), сөйләмдәге мелодика, озынлык, ритм, темп, ешлык, акцент төзелеше, тембр, пауза һ.б. кебек просодик элементлар җыелмасы. И. сөйләмне фонетик яктан оештыра, төрле синтаксик мәгънә һәм категорияләрне, экспрессив һәм эмоциональ бизәлешне белдерүче чара булып тора, матур әдәбиятта сурәтләү функциясен үти. Сөйләм агышында И. компонентлары үзара төрле мөнәсәбәтләргә керәләр, шул ук вакытта аларның һәрберсенең үз мәгънәсе бар, мәс., татар телендә сорау мелодика һәм озынлык б-н ясала, ә интенсивлык һәм тембр аның өчен иррелевант билге булып тора. Боеру һәм өндәү җөмләләр ясалганда интенсивлык һәм тембр релевант билгеләргә әвереләләр. Татар сөйләменең синтагмаларга бүленешендә мелодика, темп һәм пауза актив катнаша. Синтагма һәм фраза *басымы* сүз басымы компонентларыннан, ягъни озынлык, интенсивлык һәм төп тонның югарылыгыннан гыйбарәт. Эмфатик басым оешуда һәм төрле эмоциональ-экспрессив төсмерләр белдерүдә И.нең төрле мөнәсәбәтләргә кергән компонентлары катнашырга мөмкин. Телнең интонацион чаралары синтаксик төзелеш б-н бәйләнешкә керәләр һәм синтаксик конструкцияләрне сурәтләгәндә сизеләләр. И. шигърияттә аеруча әһәмиятле роль уйный, ул шигырьләрнең фонетик-мелодик һәм мәгънәви байлыгын ачарга ярдәм итә.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 1998. Т. 1; Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация. Яр Чаллы, 1999.

**ИНФЕ́КЦИЯ** (латин. infectio — йогышлану), кеше яисә хайван организмына авыру тудыручы микроорганизмнарның үтеп керүе һәм үрчүе, реактив процесслар комплексы б-н уза, йогышлы авыру барлыкка килү, бактерияләр йөртү яисә микробларның үлүе б-н тәмамлана. Йогышлы авыру үзенең чыгышы буенча бактериаль (бактериозлар), вируслы, риккетсиоз (риккетсиозлар), микоплазмалы (микоплазмозлар), хламидияле (хламидиозлар), спирохетозлы (спирохетозлар) булырга, аны гөмбәләр (микозлар), гади төзелешлеләр (протозоозлар) һәм паразит суалчаннар (гельминтозлар) да китереп чыгарырга мөмкин. Авыру тудыручыларның 3 төп яшәү урыны (резервуары) бар: кеше организмы (антропонозлар), хайван организмы (зоонозлар), абиотик терек булмаган мохит — туфрак, сулыклар, үсемлекләр (сапронозлар). Авыру китереп чыгаручыларның кайберләренең ике яшәү урыны була (Себер түләмәсе, лептоспирозлар, иерсиниоз, ялган туберкулёз, листериоз, зәңгәр-яшел үлек таякчыгы һ.б. китереп чыгаручылар). И. организмга тире (тимгелле тиф, йогышлы тире авыруы һ.б.), ашкайнату тракты (дизентерия, корсак тифы һ.б.), сулыш юлларының лайлалы тышчасы (грипп, кызамык һ.б.), җенес органнары (гонорея, сифилис һ.б.) аша үтеп керә. Кайбер микроорганизмнар кеше организмына төрле юллар б-н эләгә (чума бактериясе, гепатит вирусы һ.б.). И.ләр түбәндәге төрләргә бүленә: микроорганизмнарның бер төрен китереп чыгаручы моноинфекцияләр, берничә төр авыру китереп чыгаручы (мәс., икенчел, ягъни үрчеп баручы И.гә яңалары өстәлү) тудырган микстинфекцияләр; ассоциацияләшкән И.ләр (аерым форма) — организмга бер үк вакытта яисә эзлекле рәвештә патоген агентлар үтеп керү, еш кына эндоген төре — аутоинфекцияләр. Микроорганизм б-н макроорганизмның үзара бәйләнеше һәрвакытта да авыру барлыкка китерми. И. процессы кайчак савыгып килүчедә һәм «сәламәт» кешедә билгеләре күренмичә субклиник дәрәҗәдә узучы авыру чыганагын йөртүгә бәйле рәвештә бара. «Персистик» (озак яшәүче) И.ләр авыру китереп чыгару (генетик материалны) микроорганизм күзәнәгенең (ВИЧ-инфекция, гади герпес вирусы һ.б.) хромосом аппаратына кертү б-н бәйле. Клиник формада чагылучы манифестант формалар (кочле һәм хроник) иң күп өйрәнелгән. Типик формадагы И.нең узу үзенчәлекләре — процессның эзлекле рәвештә фазалар алмашынуы б-н цикллашуы (инкубация, сиздерә башлау чоры, көчәя баручы фазалы клиник чагылышлар, көчәйгән вакыт, төп билгеләр чагылышының кимүе, сәламәтләнү). И. б-н авырудан соң иммунитет барлыкка килү чоры башлана (киеренке, йомшак, көчсез, кыска вакытлы, аерым бер төрле). Авыру чорларын, дәвамлылыгын исәпкә алу диагноз куюда әһәмияткә ия. И.нең атипик формалары вакытында клиниканың диагностик симптокомплексы тулы булмый, диагностика өчен клиник мәгълүматлардан бигрәк эпидемиологик һәм лаб. мәгълүматлары әһәмиятлерәк.

Йогышлы авыру көчәюгә авыруны китереп чыгаручының үзлекләре (патогенлык, вирулентлык дәрәҗәсе, агулау сәләте, организмның аерым системаларын зарарлау, таркатучы ферментлар барлыкка китерү сәләте), зарарлану дәрәҗәсе (микроблар микъдары), кешенең халәте (үзенчәлекле, үзенчәлекле булмаган иммунитет булу), әйләнә-тирә мохитнең торышы (физик, химик, биологик факторлары) тәэсир итә. Клиника практикасында авыруны формасына, авырмы-җиңелме, ничек узуына карап бүләләр (җиңел, уртача авыр, үлем ихтималы булган авыр). Авыру дәрәҗәсе яшәү өчен мөһим әгъзалар һәм системаларның (үпкә, йөрәк-кан тамырлары, бүлеп чыгару системалары, бавыр һ.б.) җитәрлек эшләмәве б-н билгеләнә. Хроник форманың үз диагностик симптом комплекслары була; кабатланучан хроник форма И. үсешенең үзенчәлекле мөстәкыйль варианты булып тора. Тумыштан килгән формалар күбрәк яңа туган балаларда күзәтелә. Катлауланган вариантларда үзенчәлекле һәм үзенчәлекле булмаган И.не аерып карыйлар. Аерым төркемгә кинәт барлыкка килә, авыр уза һәм еш кына үлем б-н тәмамлана торганнары керә. Ш.у.к. *Йогышлы авырулар.*

*Әд.:* Шувалова Е.П. Инфекционные болезни. М., 1995. *В.Х.Фазылов.*

**ИНФОРМА́ТИКА ИНСТИТУТЫ́**, ТР ФАнең фәнни-тикшеренү институты, 1983 елда, СССР ФА Информатика проблемалары ин-тының Казан ф-лы буларак, персональ компьютерларны программалар б-н тәэмин итү максатында төзелә, 1998 дән ТР ФАнең Информатика проблемалары ин-ты, 2009 дан хәзерге исемдә. И.и. мәгълүматлаштыру өлкәсендә фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр алып бара, республика эшчәнлегенең төрле сфераларында яңа мәгълүмати технологияләрне гамәлгә кертә. Институт структурасында — 3 фәнни бүлек (фундаменталь һәм системалы тикшеренүләр; корпоратив мәгълүмати системалар; социаль мәгълүмати системалар), квантлы хисаплаулар фәнни-тикшеренү лаб-ясе, Регионара мәгълүмати-эзләнү үзәге, кече типография. Ин-тның төп фәнни проблематикасы — яңа мәгълүмати технологияләр, системалы анализ алымнары, катлаулы мәгълүмати-идарә системаларын, челтәрләр һәм мәгълүмат базаларын

проектлаштыруның теоретик нигезләрен һәм алымнарын тикшерү һәм эшләү. Социаль-икътисади табигатьле төрле процессляр һәм күренешләрне, ш.у. аларны тикшерү алымнарын анализлау максатында күпфакторлы модельләр төзү буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла. Ин-т хезмәткәрләре төбәкне мәгълүматлаштыру өчен норматив-хокукый база булдыруда, ш.и. «ТРның мәгълүмати ресурслары һәм мәгълүматлаштыру турында»гы законны гамәлгә ашыруда катнашалар. «Татарстан Республикасында фәннәрнең өстенлекле юнәлешләрен үстерү программасы» кысаларында корпоратив ANTAT.RU доменының бериш булмаган бүлекгән инфраструктурасын булдыру һәм үстерү буенча фәнни-гамәли нәтиҗәләр ясала (П.А.Зиновьев).

Фундаменталь тикшеренүләр өлкәсендә икътисади һәм социаль табигатьле процессларны планлаштыру, фаразлау һәм алар б-н идарә итү мәсьәләләрен хәл итү өчен матем. модельләр төзүнең теоретик нигезләре эшләнә (И.З.Батыршин, И.В.Коннов). Вариацияле тигезсезлекләр нигезендә катнашучыларның камил һәм камил булмаган көндәшлек шартларында икътисади тигезләнешнең гомуми модельләре булдырыла, вариацияле скаляр һәм векторлы тигезсезлекләр өчен чишелешләр барлыгы һәм аларның бердәнберлеге турында нәтиҗәләр ясала. Нәклассик логика алгебрасы теориясе базасында интеллектуаль мәгълүмат системасы төзүнең теоретик нигезләре эшләнә; нәтиҗәләре гамәли системаларда куллануга кертелә. Анык булмаган логиканың нәклассик операцияләре теориясенең фундаменталь мәсьәләләре хәл ителә һәм алар нигезендә экспертлау системаларында мәгълүмат җыю һәм аны эшкәртүнең яңа алымнары тәкъдим ителә; нәтиҗәләр химия технологиясе, нефть чыгару, экологиядәге экспертлау системаларын эшләүдә кулланыла, Компьютер лингвистикасы өлкәсендә нәтиҗәләргә киленә: гадәти телдәге сүзләрнең мәгънәсен (семантикасын) тасвирлау теле эшләнә, бер телдән икенчесенә семантик тәрҗемәнең уңайлы алгоритмнары булдырыла (В.Д.Соловьёв). Гамәли тикшеренүләр өлкәсендә корпоратив системалар төзүнең актуаль проблемалары эшләнә һәм алар элемтә пр-тиеләрендә мәгълүматлаштыру системасының нигезен тәшкил итә; нәтиҗәләр РФ һәм БДБ илләренең 150 дән артык шәһәрендә һәм өлкәсендә гамәлгә кертелә. «Татэнерго», «Казан аракы-ликёр заводы», «Таттелеком» пр-тиеләрендә производствоны автоматлаштыру буенча эшләр башкарыла; Интернет челтәрендә ТР ФАнең Интернет-порталы булдырыла. Ин-т — Татарстанда гына түгел, РФдә дә информатика, тарих, хәрби археология, архивлар эше, педагогика һәм социология фәннәре киселешендә Ватанны саклаучыларның истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендәге эшләрне үстерә барган бердәнбер фәнни учреждение. Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар турында мәгълүмат базасы булган (4 млн. шәхес) мәгълүмати-эзләнү системасы эшләнә, «Имена из солдатских медальонов» китабының 3 томы чыгарыла (2005–08). Ел саен (1999 дан) ин-т «Исследования по информатике» дигән фәнни хезмәтләр җыентыгын чыгара. Ин-т директорлары — И.З.Насыйров (1997–2008), Ф.М.Аблаев (2008 дән).

Әд.: Насыров И.З. Информационные технологии — основа инновационной деятельности в РТ // Науч. Татарстан. 2006. Спец. вып.

*И.З.Насыйров, А.Н.Гыйльманов, Р.Г.Усманов.*



Казанда ТР ФАнең Информатика институты бинасы.

**ИНФРАКЫЗЫ́Л ТЕ́ХНИКА**, табигый һәм ясалма объектларның үзнурланыш энергиясеннән файдаланып эшләүгә (пассив типтагы) һәм спектрның инфракызыл (ИК) өлкәсендә ясалма хасил ителгән нурланышны теркәүгә нигезләнгән (актив типтагы) оптик-электрон приборлар. ИК-нурланыш (лат. infra — түбән, аскы) спектрның 0,78–1000 *мкм* лык өлешен алып тора; инглиз галиме В.Гершель тарафыннан 1800 елда ачыла. Пассив типтагы приборның гадиләштерелгән гадәти варианты оптик системадан, ИК-нурланыш алгычыннан һәм эл. сигналларын эшкәртү җайланмасыннан гыйбарәт. Аның эшләү принцибы түбәндәгечә: ИК-нурланыш күзәтү объектыннан атм. катламы аша уза, аннары оптик система тарафыннан кабул ителә, алгычка юнәлтелә, ул ИК агымны приборның билгеләнешенә бәйле рәвештә төрле чаралар б-н эшкәртеп эл. сигналына әверелдерә. Актив типтагы И.т. бердәм конструкциягә берләштерелгән яки фәзада сибелгән нур таратучы һәм оптик-электрон кабул итүче блоклардан гыйбарәт. И.т.ның яңа элементлар базасын (модульләрен) — алгычлар, нурланыш чыганаклары, сканерлар, кечкенә күләмле суыткыч системалары һ.б. булдыру буенча 20 йөз ахырында алып барылган тикшеренүләр тормыш-көнкүреш һәм хәрби максатлар өчен билгеләнгән приборларны: контактсыз оптик шартлаткычлар, үзлегеннән төбәлә торган ракета очлары, җылылык пеленгаторлары, һава һәм космик разведка аппаратлары, термовизион приборлар, радиометрлар, спектрометрлар һ.б.ны эшләргә мөмкинлек бирә. ТРда И.т. приборлары ГИПОда һәм Казан оптика-механика з-дында (КОМЗ) эшләнә. ГИПО И.т.ның күп кенә юнәлешләре буенча баш пр-тие буларак эш итә һәм термовизион техника төзү өлкәсендә әйдәп баручы булып тора. 1ПН79 һәм 1ПН86 приборлары һәм аларның модификацияләре танкларга каршы ата торган комплексларда термовизион төбәгечләр буларак файдаланыла, алар РФдә һәм чит илләрдә яхшы мәгълүм. ГИПО ирешкән фәнни казанышлар КОМЗда күп кенә оптик-электрон приборлар эшләү өчен нигез булып тора. Оптик-электрон, ИК-приборлар төзү, спектроскопия белгечләре әзерләү Казан вузларында гамәлгә ашырыла.

*Әд.:* Смит Р., Джонс Ф., Чесмер Р. Обнаружение и измерение инфракрасного излучения. М., 1959; Ллойд Дж. Системы тепловидения. М., 1978; Мирошников М.М. Теоретические основы оптико-электронных приборов. Л. 1983; Авдеев С.П. Анализ и синтез оптико-электронных приборов. СПб., 2000.

*В.М.Иванов.*

**ИНФРАСТРУКТУ́РА** (лат. infra — түбән, аскы һәм structura — төзелеше, урнашуы), җитештерү һәм товар әйләнеше, ш.у. кешеләрнең тормыш эшчәнлеге өчен нормаль шартлар тудырырга тиешле тармаклар, пр-тиеләр, оешмалар, эшчәнлек төрләре җыелмасы. И. тармакларының сәнәгать темпларын үстерүгә тәэсир итә алу мөмкинлеген күздә тоткан, 10–25 елга исәпләнгән фаразлаулар 1950–60 елларда ГФРда һәм АКШта барлыкка килә. СССРда И. проблемаларын өйрәнү 1970 елларда башлана.

Социаль-икътисади әчтәлеге буенча И. социаль-икътисади эшчәнлекнең төрле юнәлешләренә, өлкәләренә һәм базарның төрле структураларына хезмәт күрсәтү И.ларына бүленә.

И. тудырган шартлар түбәндәгечә классификацияләнә: 1) җитештерүне турыдан-туры тәэмин итү процесслары (матди-техник тәэминат, продукцияне сату, мәгълүмат туплау һәм эшкәртү, бухгалтерлык хезмәте, технол. һәм идарә итү мәсьәләләре буенча консультацияләр); 2) эшче көчләр санын яңадан торгызу шартлары (эшче һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау; аларның белемнәрен һәм проф. әзерлекләрен күтәрүләренә ярдәм итү шартлары һ.б.); 3) микро һәм макропропорцияләрнең тигезлеген тәэмин итү шартлары.

Шушылар нигезендә, җитештерү һәм социаль И. аерылып йөртелә. Җитештерү И.сы — җитештерү процессларын турыдан-туры тышкы шартлар б-н тәэмин итә торган тармаклар комплексы булып тора. Моңа йөк транспорты, күпләп сәүдә итү, эл., газ һәм су б-н тәэмин итү, складлар хуҗалыгы, элемтә, мәгълүмат, консультация хезмәте күрсәтү, инжиниринг, эшче көчләргә булган ихтыяҗны вакытлыча тәэмин итү өлкәсе һ.б. керә. Социаль И. — эшче көчләрне яңадан әзерләү, ш.у. сәламәтлек саклау, мәгариф, ваклап сәүдә итү, пасс. транспорты, торак-коммуналь хуҗалыклары, җәмәгать туклануы өлкәләре һ.б. РФдә базар тибындагы икътисад булдыру «И.» төшенчәсен «базар И.сы» категориясенә үзгәртүне таләп итте. Мондый төшенчә базар икътисадының нормаль эшләвен гомуми шартлар б-н тәэмин итә торган формалар, ысуллар, процесслар җыел-

масын күздә тота. И.га күпләп сату пр-тиеләре, биржалар, брокерлык һәм дилерлык оешмалары, финанс ин-тлары, эре сәнәгать берләшмәләре, концерннар һ.б.ның шәхси коммерция структуралары керә. Җитештерү чаралары милкенә мөнәсәбәт И.ның милек объектлары формалары б-н тәңгәл килә. РФдә дәүләти, муниципаль, хосусый һәм коллектив (күмәк) пр-тиеләр, җәмәгать оешмалары пр-тиеләре, ш.у. чит ил капиталы пр-тиеләре гамәлдә.

Икътисад ихтыяҗлары б-н И. потенциалы арасында, ш.у. И.ның үз эчендә нисбәтлек (пропорция) сакланырга тиеш. И. икътисадның өзлексез һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итә торган хуҗалык механизмының төрле тармакара элементлары җыелмасы. Бу очракта И. элементларының балансл ы үсеше күздә тотыла. Халык хуҗалыгының теге яки бу секторларының беренче нәүбәттәге юнәлешләрен билгеләгәндә, бер тармакка (кайчагында терр-ягә) булышлык күрсәтүгә өстенлек бирелә һәм бу И. элементлары үсешендә диспропорциягә һәм тулаем алганда икътисадка зыян китерә.

ТРда җитештерү һәм социаль И. алга киткән. Икътисадның төрле тармак пр-тиеләре нефть, газ һәм аларны эшкәртү продуктлары ташу өчен 11 мең *км* дан артык торба үткәргечләрдән, 1800 *км* чамасы — тимер юлдан, 1000 *км* — эчке су юлыннан, 19 мең *км* автомобиль юлларыннан файдалана.

Транспорт чараларына 80 меңгә якын йөк автомобиле, 5 мең пасс. автобусы, 600 трамвай вагоны, 300 дән артык троллейбус керә. 22 млн *кВт*. сәг. эл. энергиясе җитештерелеп, респ-ка ихтыяҗлары тулысынча диярлек тәэмин ителә. 1,2 мең элемтә пр-тиесе, 1 меңгә якын телефон станциясе исәпләнә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтә торган күп тармаклы пр-тиеләр челтәре гамәлдә. Респ-каның торак фонды 70,4 *млн* $м^2$ тәшкил итә, бер кешегә 18,6 $м^2$ торак мәйданы туры килә. Торак фондының 78%ы — су үткәргечләр, 70,4%ы — файдаланылган суны агызу каналлары, 88% ы үзәктән җылыту б-н җиһазландырылган. Шәһәр һәм авылларга газ кертү программасы гамәлгә ашырыла (2003). 265 пр-тие торак һәм коммуналь хуҗалыкка хезмәт күрсәтә, аны үстерүгә 6,6 млрд. сумлык инвестиция юнәлтелгән. Татарстан халкына 5 меңнән артык ваклап сәүдә итү пр-тиесе һәм объекты, 900 гә якын җәмәгать туклануы пр-тиесе хезмәт күрсәтә. 2007–08 уку елында респ-када 2,3 меңнән артык гомуми белем бирү мәктәбе, 67 махсус урта уку йорты, 33 югары уку йорты, 97 проф. техник белем уч-щесе эшләде.

Базар шартларына күчү уңае б-н И.га гына хас инструментлар үсеш ала. «Казан фонд сәүдәсе советы» дигән фонд биржасы, ике баскычлы банк системасы — ТРның милли банкы б-н бергә 30 коммерция банкы һәм аларның 200 дән артык ф-лы эшли. Пр-тиеләр җитештерүгә контрольлек һәм идарә итүнең мөһим инструменты саналган һәм төрле фондлар инвесторлары өчен мәгълүмат чыганагы булган бизнес-планнар төзүгә күчәләр. Хезмәт базарын җайга салучы арадашчы органнар барлыкка килә. Базар хуҗалыгы субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала торган хокук нормалары (федераль һәм респ-ка законнары, РФ һәм ТР президентлары указлары, РФ һәм ТР хөкүмәте карарлары, идарә итү органнарының норматив актлары) булдырыла.

*Әд.:* Одесс В. Инфраструктура российского рынка // Риск. 1998. № 2–3; Шумов В. Инфраструктура // шунда ук. 2000. № 3–4; Современный экономический словарь. М., 1999; Республика Татарстан. Стат. сб. К., 2008.

*Р.А.Борһанова.*

**ИНФУЗО́РИЯЛӘР** (Ciliophora), бер күзәнәкле хайваннар тибы. 6 меңгә якын төре бар, Татарстан терр-ясендә 70 тән артык төре билгеле. Сулыкларда еш кына Tintinnidium, Halteria, Vorticella ыругларының вәкилләре очрый, биологик чистарту корылмаларының ләмендә Tetrachymena pyriformis һәм Paramecium, Colpidium, Vorticella, Aspidisca ыругларының вәкилләре яши. И. башка бер күзәнәкле хайваннардан органеллалары — хәрәкәт функциясен башкаручы керфекчәләр һәм икеләтелгән төше булу б-н аерылып тора. И.нең 2 астибын билгелиләр: иркен йөзүче керфеклеләр (Ciliata) һәм беркетелүче имүчеләр (Suctoria), аларның калынайган очында корбанын параличлый һәм үтерә торган матдәләр бүлеп чыгаручы ау кармавычлары бар. И.нең тәне тышкы яктан пелликула б-н капланган цитоплазмадан тора. Цитоплазмада су балансын, сулышны көйләүче һәм осмотик басымны көйләүче 1–3 кыскарту вакуольләре, һәм 2 тип төш бар: макронуклеуслар — тереклек процессларын көйләүче һәм микронуклеуслар — җенси процесста, ягъни нәсел информациясен тапшыруда катнашучылар. И. бактерияләр, иң түбән төзелешлеләр һ.б. микроорганизмнар б-н күзәнәкнең өске ягында урнашкан авыз куышлыгы (цитост) аша туклана. Ашкайнату процессы ашкайнату вакуольләрендә бара. Җенессез (күзәнәкнең икегә бүленүе) һәм җенси юл б-н үрчи. Хәрәкәтләнә торган (йөзәләр яки суда, туфракта, комда һ.б. дымлы биотопларда үрмәлиләр), ш.у. берегеп тереклек итүче (берәмләп яки колония булып ташларга, су үсемлекләренә һәм хайваннарга урнаша) формалары бар. Паразитик формалары да билгеле (умырткасыз организмнарда да, умырткалы хайваннарда да яши), мәс., ихтиофтирус һәм триходиннар — балык паразитлары. Кешенең юан эчәгесендә балантидия И. яши. Хайваннарның эчәк трактында тереклек итүче И. үсемлек азыгын эшкәртүдә катнаша.

И. әйләнә-тирәлек пычрануның органик индикаторы булып тора. Бактерияләр б-н тукланып (авыру тудыручыларны да кертеп) сулыкларны чистартуда һәм сәламәтләндерүдә, агым суларны биологик чистартуда мөһим роль уйныйлар.

*Әд.:* Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Кутикова Л.А. Фауна аэротенков: Атлас. Л., 1984.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**ИҢ ТҮБӘ́Н ТӨЗЕЛЕШЛЕЛӘ́Р**, к. *Протистлар*.

**ИОА́НН** Казанский (? — 24.1.1529, Казан), Рус Православие чиркәве изгеләренең берсе. Түбән Новгород шәһәрендә яши. Казанлыларның 1505 елгы һөҗүме вакытында әсирлеккә төшә, Казанда Мөхәммәдәмин ханның туганына коллыкка эләгә. Ислам динен кабул итүдән баш тартканы өчен үтерелә. 1592 дә изгеләштерелә, үлгән көнендә искә алына.

*Әд.:* Арсений (Брянцев). Жития святых и богоносных святителей и страстотерпцев земли Казанской. К., 1900; Два рукописных сказания о мученике Иоанне Казанском // Известия по Казанской епархии. К., 1910; Жития святых мучеников Казанских Иоанна, Стефана и Петра. К., 2001.

**ИОА́НН-ПРЕДТЕ́ЧА ИРЛӘ́Р МОНАСТЫРЕ́**, Казанда, архит-ра ядкәре. Казан Кремленең Спас манарасыннан көньяктарак, Беренче Май мәйданы урнашкан тугай өстендәге тау киртләченең текә битенә урнашкан. 1550 еллар азагында Зөядәге Успение-Богородица монастыреның Кунак йорты буларак нигезләнә, 1590 нан — мөстәкыйль монастырь. 17 йөзгә кадәр агачтан була, 1649 да чыккан янгын монастырьның барлык корылмаларын көлгә әйләндерә. 1649–52 дә монастырь сәүдәгәр Г.Фёдоров-Антипин акчасына өр-яңадан кирпечтән төзелә. Андагы салкын чикрәү Русьта сирәк очрый торган өч чатырлы гыйбадәтханәләргә карый. План буенча ул ярымтүгәрәк апсидалы, болдыры һәм галереясы булган турыпочмаклы корылма. Башта кыңгыраулы манара аерым торган һәм комплексның башка биналары б-н бәйләнеше булмаган. Во имя Введения в храм Пресвятой Богородицы исемендәге җылы чиркәү кушып салынган монастырь башлыгы хөҗрәләре булган өч ярусл ы корылманың өске өлешенә урнашкан. Ур-


1


2

Казанда Иоанн-Предтеча монастыре. 17–19 йөзләр. 1. Гомуми күренеш. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Изге Мәрьям Ана храмы Введение чиркәве. 17 йөз уртасы.

та яруста — монахлар хөҗрәләре, аста аш-су әзерләү һәм кирәк-яракларны саклау бүлмәләре урнашкан. Монастырь терр-ясе Гостиный двор ягыннан оброкка бирелүче таш сәүдә кибетләре б-н чикләнгән. Тузу сәбәпле өч чатырлы гыйбадәтханә 1886 да сүтелә, 1894 тә архитекторлар В.В.Суслов һәм Г.Б.Руш проекты буенча шул ук формада яңадан төзелә.

1918 дән И.-П.и.м. епархия идарәсе карамагында була. 1929 да ябыла. 1931 дә өч чатырлы чиркәү, түп капкалы дивар һәм капка өстендәге чиркәү юкка чыгарыла. Совет хакимияте елларында монастырь биналары учреждениеләр һәм торак урыннары булып хезмәт итә. Бары тик Введение чиркәве, өч яруслы манара һәм архимандрит корпусы гына сакланып кала (1896, арх. П.М.Тюфилин).

Баганасыз биш гөмбәзле җылы Введение чиркәве андагы монастырь башлыгының бүлмәләре б-н монастырь терр-ясен көньяктан чикли. Ул 3 ярымтүгәрәк апсидалы тоташ гөмбәз б-н ябылган зур булмаган ике рәтле тәрәзәдән торган бинадан гыйбарәт. Фасадларның архитектур композициясе һәм декоратив бизәкләре рус «кирпеч белән бизәкләү» һәм «Мәскәү бароккосы» стильләренә туры килә. Чиркәүгә төньяктан кушып салынган борадәрләр корпусы тоташып киткән. Манара бернинди үзгәрешсез сакланган. Сигез кырлы 3 ярус дүрт кырлы нигездә утыра. Биек барабанга тоташкан суганбашчасыман гөмбәз 3 рәтле кокошникларга таянып тора. Манара төзелешендә 17 йөз архит-расында сирәк очрый торган алым кулланылган: барабанга чорма тәрәзәсе ролен башкаручы 4 вертикаль ярык уелган. 1992 дән И.-П.и.м. яңадан эшли башлый, 1998 дә монастырьның коймасы кабат торгызыла.

*Әд.:* А з л е ц к и й П. Описание Иоанно-Предтеченского монастыря // Известия по Казанской епархии. К., 1898; Ф е х н е р М. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978; Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XIX веков). К., 1998.

*С.Г.Персова.*

**ИОА́НН-ПРЕДТЕ́ЧА ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р МОНАСТЫРЕ́**, Яшел Үзән р-ның Зөя авылында. 16 йөз ахырында нигез салына. 1795 елгы янгыннан соң, борынгы Троица һәм Сергий чиркәүләре комплексы архит-ра ядкәре 16 йөз уртасы — 20 йөз башының рус дини архит-ра нигезен тәшкил иткән Троица ирләр монастыре (1551 дә нигезләнә, 1764 тә бетерелә) урынына күчерелгән. 1796 да таштан хөҗрәләр корпусы һәм агачтан каралтылар төзелә. 1819–20 елларда хөҗрәләр яңадан үзгәртеп корыла, 1820 дә ике катлы монастырь башлыгы йорты төзелә. 1879 да, аннан көньяктарак, агачтан ике катлы хөҗрәләр корпусы салына. 1890 елларда Сергий чиркәвенең көньяк-көнчыгыш ягында кирпечтән аш өе корыла. Шул ук елларда агач биналар кирпеч б-н тышлана, юлчылар өчен флигельле йорт төзелә. 1897 дә монастырь зур булмаган манаралар һәм яңа кирпеч стена б-н әйләндереп алына. Гыйбадәт биналары һәм башка төр корылмалар хәзергәчә яхшы сакланган.

Борынгы Троица чиркәве 1551 дә төзелә. Ул ике яруслы, сигез почмаклы өске каты дүрт почмаклы аскы каттан күтәрелгән, сигез





Зөя авылында Иоанн-Предтеча монастыре. 1. Троица чиркәве. 16 йөз уртасы; 2. «Барлык хәсрәт чигүчеләр шатлыгы» Мәрьям Ана соборы. Архитекторы Ф.Н. Малиновский. 1906–13.

кыеклы түбә б-н ябылган; сигез кырлы барабанга беркетелгән гөмбәз б-н төгәлләнә. Алтарь өлешенең почмаклары кисеп эшләнгән. Аш өенә өсте ябулы чиркәү алды баскычы корып куелган. Чиркәүнең көньяк һәм төньяк ягында стеналарга терәп эшләнгән баскычлар бар. Алар 1819 да моңа кадәр чиркәүне өч яктан әйләндереп алган ябык галереялар урынына төзелә. Башта чиркәү такта б-н тышланмаган, агач түбәле һәм биек чатырлы була. Такта б-н 1821 дә тышлана, түбәләрне калай б-н 1836 да яба башлыйлар. 1833 тә чиркәү астына кирпечтән фундамент салына. Троица чиркәвенең интерьеры бик гади. Юан бүрәнәләр эчке яктан шомартылган. Баштарак алтарь идән тигезлегендә урнаштырыла, әмма 1742 дә алтарь һәм солея бер баскыч югары күтәртелә, әйләнәсе агач рәшәткә б-н корып алына. Иконостас дүрт ярuslы, барокко стилендә бизәлгән. 1959 да Троица чиркәве реставрацияләнә.

Сергий чиркәве 16 йөз ахыры — 17 йөз башында төзелә (1594 тә изгеләштерелә, диварда сакланып калган язулар шул хакта сөйли). Чиркәү ике катлы, манаралы. Диварлары ак таштан салынган. Бер баганалы аш бүлмәсе көнчыгыш ягыннан чиркәүнең һәм кушып салынган йортның апсидасыз өлеше б-н тоташкан. Сергий чиркәвенең эчке өлеше декоратив бизәкле кирпечләре һәм түгәрәк барабанда зур гөмбәзле булуы б-н аерылып тора. 1 нче



Зөя авылында Сергий чиркәве. 1604.

һәм 2 нче каттагы бүлмәләр гөмбәзләр б-н ябылган. Төньяк-көнбатыш ягыннан бер баганалы аш бүлмәсенә гөмбәз б-н төгәлләнгән манара тоташа. Диварның эчке ягындагы баскыч чаң кагу мәйданчыгына илтә. Тагын бер эчке баскыч храм б-н кушып салынган йорт арасында урнашкан. Фасадлар, нигездә, түп диварларның урнашуына карап яраклаштырылган яссы калаклар б-н бизәлгән; ике кат арасындагы сырт детальләрсез, көймәләп ясалган тәрәзә йөзлекләре гади. Бинаның тышкы һәм эчке ягына төрле рәсемнәр, бизәкләр төшерелгән. Порталының уң өлешендә, диварның тышкы ягында 17 йөз башында эшләнгән «Троица» фрескасы урнашкан.

Монастырьда һәм Зөя авылының бөтен көнчыгыш өлешендә «Барлык хәсрәт чигүчеләр шатлыгы» Мәрьям Ана соборы күтәрелә, ул — төзелү вакыты буенча соңгы һәм әһәмияте ягыннан иң өстен саналган храм (1906–13, арх. Ф.Н.Малиновский). Псевдовизантия стилендә төзелгән. Планда үзәкләшкән бина хачны хәтерләтә. Үзәктәге шарсыман гөмбәзне зур булмаган дүрт гөмбәз әйләндереп алган. Фасадларның купшы декоратив бизәкләре күпсанлы кәрнизләр, ярымбаганалар һәм декоратив ялгаулар б-н кызыл, фигуралы кирпечтән эшләнгән.

Монастырь 1929 да ябыла, бина торак һәм учреждение итеп файдаланыла, 2000 дә гыйбадәт кылу чиркәүләре һәм корпуслар Успение ирләр монастырена тапшырыла; Троица чиркәве Казан епархиясе һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музейларының уртак кайгыртуында тора.

*Әд.:* П о к р о в с к и й И.М. Свияжский второклассный Иоанно-Предтеченский монастырь и его святыни. К., 1905; О с т р о у м о в В.П., Ч у м а к о в В.В. Свияжск. К., 1971; Ф е х н е р М. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999; Православные храмы Татарстана: Альбом. К., 2000.

*С.Г.Персова.*

**ИОАСА́Ф** (Удалов Иван Иванович) (5.4.1886, Уфа ш. — 2.12.1937, Казан), дин эшлеклесе. Казан руханилар академиясен тәмамлый (1910), 1910 елдан монахлыкта. 1912–18 дә Казан Спас-Преображенье мо-

настыре игумены һәм Казан миссионерлык курсларын күзәтүче. 1918–20 дә Чистай епискобы *Анатолий* (Грисюк) б-н бергә Казан епархиясенә идарәчелек итә. 1920–21 дә Мамадыш епискобы. 1921–24 тә берүзе Казан епархиясен җитәкли, «яңартучыларга» каршы кискен каршы чыга. 1924 тә мәҗбүри рәвештә Мәскәүгә китерелә һәм кулга алына, 1926 да Красноярск краена сөрелә. 1929–31 дә Мари автономияле өлкәсенең Козьмодемьянск шәһәрендә сөргендә яши. 1931 дә кулга алына, 1932 дә Казандагы Хак православие чиркәве эше буенча 3 елга лагерьга хөкем ителә, 1934 тә лагерьда хөкүмәткә каршы агитация алып баруда гаепләнә, җәза үтәү вакыты 2 елга озайтыла. 1936 дан Казанда, Ярославль могҗиза тудыручылар чиркәвендә хезмәт итә. 1937 елның ноябрендә кулга алына, репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Журавский А.В. Епископ Чистопольский Иоасаф (Удалов) как последователь митрополита Казанского Кирилла // Ежегодная богословская конференция Православного Свято-Тихоновского института: Материалы 1992–1996 гг. М., 1996; шул ук. Жизнеописания новых мучеников Казанских: год 1918-й. К., 1996.

**ИОАСА́Ф** (Зеленкин Иван Петрович) (30.3.1838, Түбән Новгород губ., Түбән Новгород өязе Безводное а. — 27.3.1912, Саратов губ. Хвалынск ш.), дин эшлеклесе. Озак еллар дәвамында Ыргыз елгасы (Саратов губернасы) буендагы иске дин тарафдарлары скитларында яши. 1865 елдан Хвалынск шәһәрендәге Черемшан монастырендә. Казан иске дин тарафдарларының Белокриницк епархиясенең беренче епискобы *Пафнутий* (Шикин) заманында хезмәт итә. 1893 тән Казан епискобы. И. идарә иткән епархия Урта Идел һәм Вятка төбәкләрен били. 1905 нең 17 октябрь Манифесты чыкканнан соң, Иоасаф заманында Казан губернасы терр-ясендә 40 тан артык рәсми иске дин тарафдарлары приходы ачыла, күпсанлы гыйбадәтханәләр, ш.и. Казанда Покров кафедраль соборы төзелә. Иске дин тарафдарлары съездларында актив катнаша.

**ИО́В** (Кресович Владимир Александрович) (15.9.1898, Волынь губ. Мокрец а. — 4.12.1977, Львов ш., Украина ССР), дин эшлеклесе. Кременец руханилар семинариясен тәмамлый (1922). 1922–42 елларда Волынь епархиясе (1939 га кадәр Польша составына керә) гыйбадәтханәләрендә рухани. 1942 дән монахлыкта. 1942 дә Луцк, 1943 тән Кременец һәм Дубна (немецлар оккупациясе шартларында), 1950 дән Великие Луки һәм Торопец, 1951 дән Чабаксар һәм Чуашия епискобы. 1954 тән Чабаксар һәм Чуашия, 1955 тән Казан һәм Чистай, 1958 дән Казан һәм Мари архиепискобы. Н.С.Хрущёв чорында дингә һөҗүмнең көчәюе шартларында епархия б-н җитәкчелек итә, гыйбадәтханәләр ябылуга һәм приходлар бетерелүгә каршы чыга. 1960 ның мартында И., салымнар түләүдән баш тартуда һәм керемнәрне яшерүдә гаепләнеп, кулга алына, 3 елга ирегеннән мәхрүм ителә, әмма Рус Православие чиркәве җитәкчелеге аны гаепле дип санаудан баш тарта. И. эше дингә каршы пропаганда алып баруда киң файдаланыла. Иреккә чыккач, И. актив эшчәнлеген дәвам итә. 1967 дән — Уфа һәм Эстәрлетамак, 1973 елдан Иваново һәм Кинешма архиепискобы.

*Әд.:* Архиепископ Иов (Кресович): Некролог // Журн. Моск. патриархии. 1978. № 3.

**ИО́ВЛЕВ** Владимир Александрович (13.1.1920, Ташкент ш. — 18.10.1944, Венгрия, Дебрецен ш.дә җирләнә), Сов. Союзы Герое (28.4.1945, үлгәннән соң), гв. капитаны. 1940 елга кадәр «Урак һәм Чүкеч» (Казан) з-дында токарь булып эшли. Казан пехота уч-щесен тәмамлый (1941). 1940 тан Кызыл Армия сафларында. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танк ротасы командиры (6 нчы гв. кавалерия корпусының 13 нче Ровно гв. кавалерия дивизиясе). 1944 нең 18 октябрендә Дебрецен өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: танкистларны үз артыннан ияртеп, беренче булып шәһәргә бәреп керә һәм дошманның 4 авыр танкын, пехотасы б-н 2 бронетранспортёрын, 2 зенит тубын юк итә. Танкы сафтан чыгып, И. һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1982. Кн. 1; Татарстан в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИО́НА ҺӘМ НЕКТА́РИЙ**, Казан могҗизалар тудыручыларына тиңләштерелгән изгеләр, ата һәм угыл. Нектарийның атасы Иван Елизарович Застолбский чыгышы б-н Тверь төбәге Бежецк өязенең Застолбье авылыннан, боярлар катлавыннан була, Казан архиепискобы *Гурий* заманында Архиерей йортында дин хезмәтчесе; Ионаның улы Дмитрий (чукындырылганнан соң — Нестор, монахлыкта — Нектарий) Казан Спас-Преображенье монастыре монахы, тормышы тәкъвалык б-н үтә, якынча 1564 елда вафат була. Улы үлгәннән соң, И.Е.Застолбский шул ук монастырьда Иона исеме б-н монахлык кабул итә һәм тиздән вафат була. Аларның монастырь соборы алтаре янындагы каберләрен 1595 тә Гурий һәм православие миссионеры *Варсонофий* каберләре б-н бергә ачалар. Мәетләре таркалмау сәбәпле, И. һәм Н.ны җирле изгеләр сыйфатында рәсми булмаган рәвештә олылый башлыйлар. 1899 да Казан һәм Зөя архиепискобы *Арсений* (Брянцев) башлангычы б-н И. һәм Н.ны искә алу көне рәсмиләштерелә. Совет чорында Спас-Преображенье монастырен җимерү нәтиҗәсендә И. һәм Н. каберләре югала. 1995 нең 11 октябрендә җирләнгән дип фаразланган урында казу эшләре вакытында аларның сөякләре кабат табыла; хәзер алар Казанның Петропавел чиркәвендә саклана. Искә алу көне 4 (17) октябрьдән соң беренче шимбәдә үткәрелә.

*Әд.:* Воскресенский А. Пещерка Спасо-Преображенского монастыря. К., 1889; Лебедев Е.М. Спасский монастырь в Казани. К., 1895; Пещерка Казанского Спасо-Преображенского монастыря и исторические сведения о погребённых в ней. К., 1902; Житие и Акафист преподобным Ионе и Нектарию, Казанским чудотворцам. К., 2001.

**ИОНЕ́НКО** Иван Михайлович (10.6.1913, Смоленск губ., Краснинск өязе Зайцовка а. — 20.12.1989, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1966), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән



В.А.Иовлев.

эшлеклесе (1983). 1939 елда Ленинград пед. ин-тын тәмамлагач, фәнни һәм пед. эштә, 1945 тән Казан пед. ин-тында декан урынбасары, 1946 дан Казан югары партия мәктәбендә тарих каф. мөдире. 1960 тан Казан ун-тында, 1970–83 дә СССР тарихы каф. мөдире. Бөек Ватан сугышында катнаша. Идел буе һәм Урал алдында Окт. рев-циясе тарихы буенча хезмәтләр, Бөек Ватан сугышы турында мемуарлар авторы, 1 дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Крестьянство Среднего Поволжья накануне Великого Октября. К., 1957; Октябрь в Казани. К., 1967 (автордаш); Солдаты тыловых гарнизонов в борьбе за власть Советов. К., 1976; Солдатские массы в Октябрьской революции. К., 1982; Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1983; Нам жить и помнить. К., 1988.

*Әд.:* Фёдорова Н.А., Телишев В.Ф. Иван Михайлович Ионенко, 1913–1989. К., 2002.

*С.И.Ионенко.*

**ИО́НКИН** Алексей Сергеевич (31.7.1962, Пенза өлкәсе Кузнецк ш.), химик, химия фән. д-ры (1992). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында. 1992 дән Массачуссетс ин-тында (АКШ), 1994 тән Торонто ун-тында (Канада) эшли. 1996 дан Вильмингтон шәһәрендәге тикшеренү үзәгендә (АКШ). Хезмәтләре фосфор һәм мышьякорганик кушылмалар химиясенә карый. Фосфор һәм мышьякның яңа тип кушылмалары түбән координацияле атомнарының, фосфенитлар классы кушылмаларының төзелешен һәм реакциягә керү сәләтен өйрәнә, синтезлау ысулын эшли, силадиеннарны тотрыклыландыру алымнарын тәкъдим итә. 1996 елдан АКШта яши.

Хезм.: 1,2,4 Azadiphosphole // Heteroatom. Chem. 1991. 2 (5) (автордаш); Thermal Retro-Trimerization of Some 1,3,5,2,4,6-Trioxatriphosphorinanes to Phosphenites // J.Organ. Chem. 1995. 60 (16) (автордаш).

**ИО́НОВ** Эрнест Филиппович (21.12.1936, Яңа Чишмә р-ны Яңа Чишмә а.), галим-агроном, селекция белгече, биол. фән. канд. (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996), ТАССРның атказ. агрономы (1991). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1964). 1963 елда Алексеев контроль орлыкчылык лаб-ясе мөдире. 1963–65 тә «Столбище» тәҗрибә-житештерү хуҗалыгы бүлегендә агроном. 1968 дән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: бодай селекциясе лаб-ясе мөдире (1968–80), селекция бүлеге мөдире (1980–87), бодай селекциясе секторы мөдире (1988–91). 1991 дән Чистай р-нында селекция-орлыкчылык фермерлык

хуҗалыгы башлыгы. Хезмәтләре көзге бодай селекциясе мәсьәләләренә карый. Селекция практикасында Н.И.Вавилов һәм И.А.Раппопорт өйрәтмәләрен куллануны актив дәвам иттерүче. Генетик үзгәрүчәнлекне көчәйтү И. тарафыннан гибридлаштыру һәм аннан соң химик мутагенез алып бару юлы б-н башкарыла. Гибрид популяцияләрнең элгәреге буыннары көзге-кышкы вегетация чорында уңайсыз шартларда үстерелә. И. чыгарган һәм районлаштырылган сортлар: көзге бодай — «Мишә» (1987), «Казан 84» (1989), «Мишә 2» (1990), «Казан 285» (1997), «Казан 560» (2000); язгы бодай — «Керба» (1998), «Дебют» (2001), «Тимер» (2007). ТР Дәүләт бүләге көзге бодайның кышка һәм корылыкка чыдам «Казан 84» һәм «Мишә 2» сортларын чыгарганы һәм куллануга кертkәне өчен бирелә. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Создание сортов озимой пшеницы для северных районов Среднего Поволжья // Генетика, физиология и селекция зерновых культур. М., 1987; Экологическая пластичность сортов мягкой озимой пшеницы по морозо- и зимостойкости, выделение сортов классификаторов, источников и доноров морозостойкости. СПб., 1993; Генетико-физиологические системы адаптивности, аттракции и микрораспределений сортов озимой пшеницы в различных географических зонах бывшего СССР. СПб., 1995; Итоги и перспективы селекции озимой пшеницы в Республике Татарстан // Основные итоги научных исследований по сельскому хозяйству в Центральном регионе Нечернозёмной зоны России. М., 2001.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ИО́СИФ (Йосыф) КАГА́Н** (? — 965 тән соң), хәзәр *каганы*. И. заманында Хәзәр дәүләте сизелерлек тотрыклылыкка ирешә. 954–61 елларда Кордова (Испания) хәлифәсенең сарай тарихчысы Хисдай ибне Шәфруг б-н хат алыша (к. *Иосиф каган хаты*). Киев кенәзе Святослав б-н сугыш вакытында һәлак була.

*Әд.:* К о к о в ц е в П.К. Еврейско-хазарская переписка в X в. Л., 1932; А р т а м о н о в М.И. История хазар. Л., 1962.

*И.Л.Измайлов.*

**ИО́СИФ КАГА́Н ХАТЫ́**, борынгы яһүд телендә язылган 10 йөз эпистоляр ядкәре. Иосиф «патша» (каган яки шад-бәк) әмере б-н 954–61 елларда Кордова (Испания) хәлифәсе Габдрахман II чиновнигы һәм сарай тарихчысы Хисдай ибне Шәфруг хатына җавап итеп язылган. Чыгышы б-н яһүд Хисдай ибне Шәфруг Идел буенда яһүдиләр дәүләте булуы турындагы мәгълүматлар б-н кызыксына һәм аның идарәчесенә хат яза. Җавап хатында *Хәзәр каганлыгы* тарихы, аның терр-ясе, гореф-гадәтләре һәм *Болан* «патша»ның яһүдилекне ничек кабул итүе турында мәгълүматлар бирелә, шәһәрләр (*Бәрәнҗәр*, Сәмәндәр), каганга ясак түләүче кабиләләр һәм халыклар исемлеге китерелә, *болгарлар, бортаслар*, *суарлар*, чирмешләр һ.б. турында мәгълүматлар бирелә. Хат ике: кыска (1577 дә табыла һәм басыла) һәм киңәйтелгән (Россия шәркыятьче галиме А.Я.Гаркави тарафыннан 1877 дә табыла һәм басыла) редакциядә сакланган. Ике редакциядәге текстлар да Россия шәркыятьче галиме П.К.Коковцев тарафыннан өйрәнелә һәм нәшер ителә (1932). Кайбер тикшеренүчеләр (Й.Маркварт, И.Х.Крамерс) хатның төп нөсхә булуына шик белдерәләр, ләкин борынгы яһүд телендә язылган кайбер документлар (мәс., Кембридж документы) табылу нәтиҗәсендә, ш.у. И.Шехтер, Н.Голб, О.Прицак хезмәтләре нигезендә И.к.х.ның чынлыгы дәлилләнә.

*Әд.:* К о к о в ц е в П.К. Еврейско-хазарская переписка в X в. Л., 1932; Г о л б Н., П р и ц а к О. Хазарско-еврейские документы X в. М., 1997; M a r q u a r t J. Osteuropaische und ostasiatische. Streifzuge. Lpz., 1903; K r a m e r s J. Les Khazars // Analecta Orientalia. Leiden, 1954. V. 1.

*И.Л.Измайлов.*

**ИОФХ**, к. *Органик һәм физик химия институты*.

**ИПА́ТОВ РАЙОНЫ́**, *Ставрополь краеның* төньягында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 4033 *км²*. Үзәге — Ипатово шәһәре (Ставрополь шәһәреннән 120 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 71,1 мең кеше. Татарлар саны — 1334 кеше (1989). Алар күпләп Кече Барханчак, Югары Барханчак һәм Түбән Барханчак авылларында төрекмәннәр б-н бергә яшиләр. Кече Барханчак авылына 1788 дә Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор авылы (хәзер Балтач р-нында) һәм Казан губернасының Мамадыш өязе Кирмән (хәзер Мамадыш р-нында) авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1917 гә кадәр Кече Барханчакта 3 мәчет, мәдрәсә эшли.

**ИПОТЕ́КА** (грек. hypothēke — залог, заклад) ссуда алу өчен күчемсез мөлкәтне, башлыча, җир һәм корылмаларны залогка салу. И. беренче мәртәбә б.э.к. 6 йөздә Грециядә барлыкка килгән һәм бурычлы затның билгеле бер җир биләмәләре хисабына кредитор алдында җаваплылыгын тәэмин итү б-н бәйле булган. И. — залогка салынган мөлкәтнең бурычка алып торучы кулында кала торган төре. И. ссудасы (И. кредиты) — күчемсез милекне залогка салып, билгеле бер максат өчен финанс-кредит учреждениеләре тарафыннан бирелә торган акча суммасы. И. — бурычлы затның мөлкәтен залогка салуының бер төре, бурычка алучы төп йөкләмәләрен үтәмәгән очракта, залог тотучы кредитор үз дәгъвасын залогка салынган күчемсез мөлкәт исәбенә канәгатьләндерергә хокуклы. И. кредитына рәсми төс биргәндә, аны закладка салу кәгазьләре һ.б. кыйммәтле кәгазьләр базарында файдаланырга мөмкин. Күчемсез мөлкәтне закладка салу кәгазе кредиторга ссуда буенча үз мөлкәтен залогка салу хокукы бирә һәм аны И. кредиты б-н тәэмин итә торган документ булып тора. Кагыйдә буларак, бары тик күчемсез милек кенә И. кредиты була: җир кишәрлекләре (дәүләт һәм муниципаль милек карамагындагы җирләрдән тыш), эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган пр-тиеләр, биналар, корылмалар һәм бүтән күчемсез милек, ш.у. милек яки хуҗалык алып бару хокукына ия булган залог бирүче оешмалар яки физик затлар карамагындагы торак йортлар, фатирлар, аларның бер өлеше, дачалар, бакча йортлары, гаражлар, һава һәм диңгез суднолары, космик объектлар. Йөкләмәләрне үтәүнең барлык ысуллары арасында күчемсез милекне кредит б-н тәэмин итүдә торак бинасы И.сы (залог) киңрәк таралыш алган. И. — төзелешкә, а.х. производствосына һәм икътисадның башка тармакларына капитал кертүнең төп каналларыннан берсе. И. буенча кредит озак вакытлы (15–30 ел) һәм максатлы булуы б-н аерыла.

И. АКШ, Канада, Бөекбритания, Германия, Франция, Швециядә аеруча үсеш ала. «Залог турында» (29 май, 1992), «Ипотека (күчемсез милекне залогка салу) турында» (16 июль, 1998) РФ Законнары; «ТРда торак йортлар төзелешен үстерү чаралары турында» (30 март, 1995) ТР Президенты Указы; «ТРда торак йортларны кредит б-н тәэмин итү һәм торак ипотекасын үстерү чаралары турында» (23 дек., 2002, № 731) ТР МК карары һ.б. хокук актлары РФ һәм ТРда И. законнарының нигезе булып тора.

*Әд.:* Л и с о в А.М. Доверительная собственность (траст) и залоговое право // Деньги и кредит. 1995. № 1; Ч и н е н к о в А.В. Правовые основы ипотеки и ипотечного кредитования // Бухгалтерия и банки. 1996. № 3; С м о л я н и н и к о в А.Н. Ипотека: теория сквозь призму законодательства // Вопр. экономики. 1997. № 7; Развитие ипотечного кредитования в России // Рынок ценных бумаг. 1999. № 8; Х и с а м у т д и н о в Р.Г. Ипотечный кредит. Проблемы развития в РТ // Бизнес-панорама. 2002. № 2; Ипотечное кредитование в Татарстане: первые шаги // Науч. Татарстан. 2003. № 1; Жильё в кредит: быть или не быть? // Лидер Татарстан. 2003. № 6.

*И.Н.Мерзликина, К.Г.Харисов.*

**ИППОДРО́М**, К а з а н н ә с е л л е а т з а в о д ы к а р ш ы н д а, 1868 елда нигез салына. Инициаторы — Казан губернасының Атлар үрчетү баш идарәсе каршындагы Казан ат чабышын яратучылар җәмгыяте. Юрткакларны беренче тапкыр ярыштыру 1868 дә уздырыла (к. *Ат спорты*). 1920–46 елларда И. Игенчелек халык комис-ты карамагында, 1991 гә кадәр ТАССР А.х. министрлыгы,





1. Ипподромга керү аркасы; 2. Ипподромның ат спорты мәйданчыгы күренеше.

2001 гә кадәр ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгы, 2001 дән «Татспиртпром» җитештерү берләшмәсе карамагында була. 1969–2001 дә «Казан» ат з-ды составына керә. 1868–1920 дә — призлы чабышлар өчен грунтлы (1067 *м*) һәм комлы 2 чабыш юлын, ат абзарын; 1922 дә — яңартылганнан соң, 30 *га* терр-яне, грунтлы юлны (1067 *м*), 100 атка исәпләнгән 5 абзарны, ярдәмче биналарны; 1948 дә — 23 *га* терр-яне, чабыш юлын (1067 *м*), 400 урынлы трибунаны, 120 атка исәпләнгән 6 абзарны, производство бүлеген; 1991 дә 12 *га* терр-яне, чабыш (1067×12 *м*) һәм күнегүләр үткәрү (1000×6 *м*) юлларын, 1400 урынлы трибунаны, 8 ат абзарын (150 атка), остаханәне үз эченә ала. 2000 дә И. каршында Казан ипподромы һәм ат үрчетүчелек тарихы музее (директоры Ж.И.Хәбибуллин) һәм «Аргамак» балалар-яшүсмерләр ат спорты мәктәбе (директоры М.С.Чинаев, 2003 тән — Г.М.Галиева) ачыла.

**ИРГА́,** дүңкәл (Amelanchier), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрак коючан агач яки куаклар ыругы. 25 кә якын төре билгеле, башлыча, Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралган. ТРда 2 төре бар:



Озынча түгәрәк яфраклы ирга.

озынча түгәрәк яфраклы И. (A. ovalis) һәм Канада И. (A. canadensis) үсә. Нигездә, һәвәскәр бакчачылар үстерә. 150–250 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы җирнең өске катлавында, 30–40 *см* тирәнлектә ята. Яфраклары түгәрәкләнгән яки овал, өсте кара-яшел, асты аксыл-яшел, көзен саргылт-кызыл яки кара-кызыл. Чәчәкләре ак яки аксыл-сары, яшь ботак очында калкансыман чукка җыелган. Җимеше — җиләккә охшаш, түгәрәк, зәңгәрсу-кара яки кызгылт шәмәхә, татлы. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан, тамыр үсентесеннән, культурада үрентедән, чыбыкчадан үрчи. Үсү шартларына талымсыз, кышка чыдам культура. Җимешләрендә шикәр, органик кислоталар, А витамины, дуплау матдәләре бар; ашарга яраклы. Согы ашказаны-эчәк авырулары вакытында бөрештергеч чара буларак файдаланыла. Декоратив, баллы үсемлек. Үзагачы кызыл-көрән, бик каты, вак-төяк әйберләр ясау өчен яраклы.

**ИРЕ́К** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 70 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Майна елгасы башланган урында урнашкан. 2008 елда даими яшәүчеләр юк. Халкының төп шөгыле кырчылык булган. 1920 елларда Иске Бәрән (хәзерге Иске Рәҗәп) авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта Урта Бәрән дип атала. ТАССРның Спас кантоны Кузнечиха волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1926 да — 28, 1938 дә — 245, 1949 да — 234, 1958 дә — 191, 1970 тә — 180, 1979 да — 143, 1989 да — 58, 2002 дә — 33 кеше.

**«ИРЕ́К»**, газета. Әстерхан милли ком-ты органы. 1917 елдан Әстерханда татар телендә нәшер ителә. Нашире — Ф.Шаммасов, мөхәррире — Н.Мәүләмбердиев (Н.*Гасрый*).

*Әд.:* Нуруллина Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«ИРЕ́К»**, газета. Татар сул эсерларның Уфа губкомы органы. 1917 елның 30 мартыннан 11 сентябренә кадәр Уфада татар телендә нәшер ителә, барлыгы 35 саны чыга. Нашире — Ф.*Сәйфи-Казанлы*, мөхәррире — Г.*Ибраһимов*. М.Гафури, Ш.Бабич, С.Кудаш, С.Рәмиев һ.б.ның мәкаләләре басыла. 1917 нең сентябрендә «*Солдат теләге*» һәм «*Авыл халкы*» г-талары б-н кушыла. Ш.у.к. «*Безнең юл*».


**«ИРЕ́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Троицк өяз ком-ты һәм РКСМ ком-ты органы. 1920 елның 15 гыйнварыннан 12 июненә кадәр Троицк шәһәрендә (Оренбург губ.) татар телендә нәшер ителә, барлыгы 37 саны чыга.

*Әд.:* Нуруллина Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«ИРЕ́К»**, атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. РКП(б)ның Орск өяз ком-ты органы. 1923 елның 18 апреленнән 1924 нең 21 июленә кадәр Орск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 71 саны чыга. Г.Айсов, К.Әхмәр, М.Габдерәхимов, Г.Галиәкбәр, Х.Галиәкбәрова, М.Латыйпов, А.Мирзабәк, М.Хуҗиәхмәтов һ.б. мәкаләләре басыла. Редакция партия һәм совет хакимиятенең яңа директиваларын вакытында яктырту, халыкның сәяси үзаңын һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү максатын куя. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг астында чыга. Газетада икътисади бөлгенлекне бетерү юллары, сәнәгать һәм а.х. өлкәсендә кадрлар мәсьәләсе, чит илләр технологиясен кертү, РКСМ ячейкалары эшчәнлеге, эшче һәм крәстияннәрнең файдалы ялын оештыру, эчкечелеккә каршы көрәш, акча реформасы, Кырым, Себер, Мәскәүдә яшәүче татарларның хәле, хатын-кызларның ирләр б-н тигез хокуклылыгы һ.б. турында мәкаләләр басыла. Революцион лозунгларны пропагандалый, пролетариат хәрәкәтен яклый, динне алга таба үсешнең төп тоткарлыгы дип саный. Гомуми белем бирү мәктәпләре программаларыннан дини дисциплиналарны чыгаруны яклый. Мулла һәм имамнарны тәнкыйтьләүче сатирик мәкаләләр, революцион эчтәлекле шигырьләр, төрле хәлләр хроникасын, белдерүләр бастыра. Төпле белгечләр, басмаханә җиһазлары җитешмәве һәм бина булмау сәбәпле редакция халыкка һәм төрле оешмаларга матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. *А.Ә.Хәсәвнех.*

**ИРЕ́К МӘЙДАНЫ́**, Казанда, шәһәрнең үзәк мәйданы. 20 йөзнең 40–60 елларында элекке Театр мәйданы урынында оештырыла. И.м. периметры буенча, әүвәлге ансамбльдән *Дворяннар җыены*, Шахмат клубы (19 йөзнең 2 нче яртысы), Почта конторасы (1957 дә арх. Р.М.Мортазин проекты буенча Казан авиация ин-тының уку корпусы итеп реконструкцияләнә, хәзер Казан техник ун-ты бинасы), А.Н.Булыгин йорты (1850, арх. А.К.Ломан) биналары сакланган. 1870 елда Театр мәйданына *Державин Г.Р. һәйкәле* күчерелә. 1924 тән мәйдан хәзерге исемен йөртә. Элекке Театр мәйданына тоташкан Державин бакчасы урынында *Татар академия опера һәм балет театры* бинасы төзелә. 1954 тә И.м. үзәгенә кечкенә бакча утыртыла һәм *Ленин В.И. һәйкәле* куела (скульпторы П.П.Яцыно, арх. А.И.Гегелло). Мәйданның турыпочмаклык формасын театрга каршы яктан ТР Министрлар Кабинеты һәм Дәүләт Советы биналары төгәлли (1962, П.А.Саначин, Г.И.Солдатов һ.б., 2005 тә реконструкцияләнә, арх. Г.А.Бакулин һ.б.). Мәйданның тышкы күренешенә ТР Зур концерт залы һәм ТР Конституцион суды биналары (2003, арх. И.Д.Галанин һ.б.) өстәлә. Совет власте елларында И.м.нда 7 ноябрь, 1 һәм 9 май бәйрәмнәрендә халык демонстрацияләре үткәрелә. Хәзерге вакытта массакүләм дәүләт һәм иҗтимагый чаралар уздыру урыны булып хезмәт итә.

*Х.Г.Надыйрова.*



Казанның Ирек мәйданы. 2008.

**ИРЕ́К ТАҢЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 28 *км* коньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 87 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 183, 1949 да — 168, 1958 дә — 161, 1970 тә — 167, 1979 да — 133, 1989 да — 84, 2002 дә — 71 кеше.

**ИРЕКЛЕ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2008 елда 23 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1931 дә нигез салына. Оештырылган көннән Азнакай р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 183, 1949 да — 168, 1958 дә — 132, 1970 тә — 139, 1979 да — 114, 1989 да — 43, 2002 дә — 24 кеше.


**ИРЕКЛЕ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Чалпы елгасы буенда. 2008 елда 253 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Бөгелмә кантоны Тымытык волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 153, 1938 дә — 173, 1949 да — 201, 1958 дә — 205, 1970 тә — 303, 1979 да — 245, 1989 да — 180, 2002 дә — 211 кеше.

**ИРЕКЛЕ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 43 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Салкынсу елгасы буенда. 2008 елда 264 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау, умартачылык. 1926–27 елларда Дүсем авылыннан (хәзер Сарман р-нында) күчеп килүчеләр нигез сала. ТАССРның Минзәлә кантоны Карамалы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 28, 1938 дә — 348, 1949 да — 330, 1958 дә — 219, 1970 тә — 280, 1979 да — 241, 1989 да — 224, 2002 дә — 236 кеше.

**ИРЕКЛЕ́ КӨРӘ́Ш**, билгеле бер кагыйдәләргә нигезләнгән спорт төре. Татарстанда 1950 елларда үсеш ала, башлап җибәрүчеләре һәм иң яхшы көрәшчеләр — Р.А.Азизов, Л.С.*Сәлимуллин*, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*. 1955 тән — Казан, 1958 дән Татарстан беренчелегенә ярышлар уздырыла. Иң яхшы спортчы һәм тренерлар: Г.А.Аношин, Ж.Б.*Гафиатуллин*, Л.Ф.Исламова (халыкара класслы спорт остасы, 1994), В.Ф.*Маркелов*, А.А.*Романов*, С.Ф.*Тимофеев*, И.И.Шишкин («Динамо» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советы беренчелегендә 3 нче урынны алучы, 1969). И.к. Казан, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Тәтеш, Менделеев, Мамадыш, Зәй шәһәрләрендә киң җәелгән.

**ИРЕКЛЕ́ РАДИКАЛЛАРДА́ ЭПР**, радионурланыш энергиясенең үрнәк матдә тарафыннан сайланышлы йотылуы, ирекле радикаллар (молекуляр яки тышкы атомнар орбитасында парлашмаган электроны булган молекулалар яки молекула кисәкчекләре) концентрациясен билгеләү мөмкинлеге һәм аларның төзелеше, парлашмаган электроннарның таралып урнашу (урыннан күчү) механизмы химик бәйләнешләрнең табигате турында мәгълүмат бирә. И.р. ЭПР буенча тикшеренүләр 1947 елда СССР ФА Казан ф-лы Физика-техника ин-тында Б.М.Козырев һәм С.Г.Салихов тарафыннан органик кушылмаларда башлап җибәрелә һәм РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында А.В.Ильясов тарафыннан ирекле фосфорорганик радикалларда һәм ионрадикалларда дәвам иттерелә.

И.р. ЭПРның төп характеристикалары булып микродулкынлы энергиядәге резонанслы йотылу сызыгының көче һәм магнит кырындагы торышы, йотылу сызыгының киңлеге һәм ЭПР спектраль сызыгының үтә нәзек



Эремәдәге (T=293K) нитроксиль И.р. ЭПР спектрының үтә нәзек структурасы.

структурасы (ҮНС) тора. Йотылу сызыгы сигналының көче ирекле радикаллар концентрациясенә пропорциональ. Резонанслы йотылу тигезләмәсе ω'=gβH (биредә ω — резонанс ешлыгы, H — магнит кырының көчәнешлелеге, β — Бор магнетоны) нигезендә ЭПР сызыгының магнит кырына карата торышы g-факторның кыйммәте белән билгеләнә. Ирекле электрон өчен g-фактор — магнит моментының механик моментка чагыштырмасы ул ($g_{эл}$=2,0023). Ирекле органик радикалларның күпчелеге өчен g-фактор ирекле электрон (радикал) өчен $g_{эл}$ зурлыгына якын һәм молекуладагы парлашмаган электронның таралып урнашуын характерлый. Нәорганик ирекле радикаллар һәм локальләшкән парлашмаган электроны булган башка парамагнитлы молекулалар өчен g-фактор бу зурлыктан сизерлек аерылырга мөмкин. Матдәләрне И.р. ЭПР юлы б-н тикшерү эшләре ЭПР сызыклары спектрларының ҮНС ачыкланганнан соң киң җәелә: ул парлашмаган электрон б-н ирекле радикал молекуласы составына кергән төшләрнең магнит моментлары арасындагы үзара тәэсир итешүләрне характерлый (рәс). Спектрларның ҮНСн күзәтү эшләре ирекле радикал молекуласының химик төзелеше һәм структурасы турында, парлашмаган электроннарның молекуладагы төрле атомнар арасында бүленеше, парамагнитлы молекуланың тирәлек б-н үзара тәэсире турында күп кенә нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Мәс., бензолның анион радикалы ҮНСн экспериментал күзәтүләр нигезендә бензолның А.Кекуле фаразлаган (1865) 6 буынлы циклик төзелеше тәҗрибәдә исбатлана. Ирекле радикалларда парлашмаган электронның урыннан күчүе (таралып урнашуы) күп очракларда радикалларның химик бәйләнешләре характерын, төзелешен һәм мөмкин булган әверелешләрен билгели. Ирекле радикаллар радиация тәэсире астында, химик, термик, электрохимик, биохимик һ.б. реакцияләр процессында барлыкка килә. Ирекле радикалларның күпчелеге — тотрыксыз кушылмалар, һәм ЭПР юлы б-н тикшеренүләр өчен аларны генерацияләү алымнарын эшләү таләп ителә. Казанда уйлап табылган оригиналь алымнар ирекле фосфорорганик радикалларның зур классын тикшерергә мөмкинлек бирә. Тотрыклы ирекле радикаллар биологик объектларның, полимерлар һ.б. матдәләрнең төзелешен һәм молекуляр хәрәкәтчәнлеген билгеләү өчен спинлы тамгалар һәм зондлар сыйфатында кулланыла.

*Әд.:* Козырев Б.М., Салихов С.Г. Парамагнитная релаксация в пентафенилциклопентадиениле // Докл. АН СССР. 1947. Т. 58, № 6; Альтшулер С.А., Козырев Б.М., Салихов С.Г. Влияние ядерного спина на резонансное парамагнитное поглощение в растворах солей марганца и меди // шунда ук. 1950. Т. 71, № 5; Спектры ЭПР и стереохимия фосфорсодержащих свободных радикалов. М., 1985.

*А.В.Ильясов.*

**ИРЕКЛЕ́ ХЕЗМӘ́Т**, к. *Свободный Труд*.

**ИРЕКЛЕ́ ШИГЫ́РЬ** (франц. vers libre — верлибр), төп ритмик берәмлекне тәшкил итүче, төрле озынлыкта килүче юлларның чиратлашуына корылган шигырь яки үзенчәлекле ритмик система. Әлеге шигырьдә башка шигырь төзелешләрендә төп роль уйнаучы иҗекләрнең басымлы-басымсыз булып килүе дә, аларның саны да ритмик нигез итеп алынмый, ш.у. ирекле озынлыктагы юллар даими зурлыктагы строфаларга да берләшми, рифмаларның булуы да мәҗбүри түгел. Ритмны оештыручы һәм саклап баручы төп нигез — төрле ритмик-интонацион чаралар (янәшә торучы яки эчке рифмалар, композицион яки юлара ялгау, вакыт компенсациясе, тәңгәл турак-цезуралар һ.б.) ярдәмендә бер-беренә ялганып, тезелеп баручы шигырь юллары, ягъни ритмик-интонацион яктан үзгәреп торучы синтаксик берәмлекләр — синтагмалар, гыйбарәләр. Ирекле шигырьне беренчеләрдән булып Бельгиядә Э. Верхарн, Төркиядә Н.Хикмәт, Россиядә А.Блок, В.Брюсов, татар поэзиясендә С.Рәмиев куллана. Әлеге шигырь үрнәкләрен Һ.Такташ, Г.Кутуй, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Ш.Анак, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, М.Әгъләмов, Зөлфәт һ.б. иҗатында очратырга мөмкин. Мәс.:

Синең йөзне күрдем.
Идел көзгесендә
    син
    кайчандыр
    шушы биеклектән караган.
Көмеш әремнәрне ера-ера,
    нигезеңә барам,
    аякларга сугылып сыкрый ташлар,
    балакларга сырыла сырлан,
    ябыша тарих.
(Роберт Әхмәтҗанов)

*М.Х.Бакиров.*

**ИРЕНЛӘ́Ч УТ** (Epipogium), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразия, Африка һәм Австралиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — яфраксыз И.у. (E. aphyllum) Көнбатыш Кама аръягында очрый. Мүк катламы яхшы үскән һәм урман түшәлмәсе булган күләгәле, ылыслы, дымлы, сирәк кенә катнаш һәм яфраклы урманнарда үсә. 5–20 *см* биеклектәге хлорофиллсыз, сапрофит үсемлек. Тамырчасы күпсанлы тамырлар һәм столоннар — янүсентеләр б-н тармакланган. Сабагы кызыл буйлар төшкән ачык сары төстә, аскы өлешендә аз гына кабарынкы. Яфраклары элпәле саргылт кабыкка кадәр редукцияләшкән. Чәчәкләре җете кызыл таплар һәм буйлар төшкән ачык сары, бераз хуш исле, иелеп торучан, 2–5 әрләп көпшәк чукка җыелган. Җимеше — тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Күбесенчә озын һәм нәзек столоннар хисабына үрчи. Орлыктан авыр үрчи, гөмбәләрнең билгеле бер төрләре — симбионтлар туфракта булганда гына орлык шыта. Үсемлек чәчәк ату вакытында гына күренә. Чәчәк атып бетергәннән соң, берничә ел дәвамында җир астында гына тереклек итәргә мөмкин. Бик сирәк төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Яфраксыз иренләч ут.

**ИРЕНЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р**, баллутчалар (Lamiaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Үләннәр, ярымкуаклар, куаклар, лианалар. 200 гә якын ыруг, 3500 дән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буенча диярлек таралган, аеруча Урта диңгез буенда күп үсә. ТР терр-ясендә 24 ыругтан 47 төре, ш.и. *мәче бөтнеге, кузлут, нәдербаш, шалфей, баллут* һ.б. Сабагы дүрт кырлы. Яфраклары капа-каршы торышлы, сирәк кенә такыялы, төпчек яфраклары юк. Чәчәкләре ике җенесле, күп өлеше сабакта такыя, ягъни катлаулы чук яки себеркәчсыман чәчәк төркеме хасил итүче куентылы ярымчатырга җыелган. Ике иренчәле таҗ: өске иренчәсе шлемсыман яки яссы, ике таҗ яфракчыгыннан барлыкка килә, аскы иренчә горизонталь урнашкан, яки аска таба бөгелгән һәм өч таҗ яфракчыгыннан тора. Җимеше бер орлыклы чикләвексыман 4 өлешкә бүленә. Күп кенә төрләре эфир майларына бай (*киек мәтрүшкәсе, мәтрүшкә,* арыслан тырнагы, эльсгольция һ.б.), алар арасында әһәмиятле дару үсемлекләре (*бөтнек*, мәтрүшкә, *сукыр кычыткан*, шалфей һ.б.), баллы (*үрмәләк*, *будра*, шалфей) үсемлекләр бар, кайберләре, башлыча, тәмләткеч буларак азык-төлек әзерләүдә кулланыла (кыр бөтнеге, гади чабыр үләне, мәче бөтнеге, гади мәтрүшкә). Баллут, кузлут, берьеллык һәм саз нәдербашы — чүп үләннәр. 6 төре (шуышма яра үләне, дарулы арыслан койрыгы, украин мәче бөтнеге, иенке шалфей, имән сарымсагы, ябышкак шалфей) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**И́РИС**, к. *Сусыл.*

**ИРКЕ́Н** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй-Каратай елгасы буенда. 2008 елда 195 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1924 тә шәһәр тибындагы Карабаш посёлогыннан күчеп килүчеләр нигез сала. ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 12 октябреннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 416, 1938 дә — 477, 1949 да — 505, 1958 дә — 461, 1970 тә — 442, 1979 да — 328, 1989 да — 205, 2002 дә — 206 кеше.

**«ИРКЕННЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү, нефть чыгаруны гамәлгә ашыру, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлаштыру, төзү һәм файдалануга әзерләү буенча нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). «Лениногорскнефть» нефть промыселы идарәсенең 4 нче һәм 5 нче нефть промыселлары җирлегендә «И.» нефть промыселы идарәсе буларак 1964 елда оештырыла. 1970 тән НГДУ. «И.» составында 20 дән артык бүлекчә исәпләнә (2002). Үзәкләштерелгән сәнәгый база башта Лениногорск шәһәрендә урнашкан була. 1985 тә Бөгелмә р-нындагы Карабаш штп на күчерелә. *Ромашкино чыганагының* Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск р-ннарында урнашкан Габдрахман мәйданын эшкәртә. Эшкәртелә торган төп объектлар: девонның франк ярусының Д1 (Паша) катламы (9 файдалы катлаудан гыйбарәт, нефть күләменең 75% чамасы чыгарыла) һәм карбонның Бобриково катламының 9 нчы ятмасы (1980 нән эшкәртелә). Габдрахман мәйданы 1954 тә сәнәгый эшкәртүгә бирелә; ятмалар нефть бирүчәнлеге б-н үзенчәлекле. Скважиналарның челтәр тыгызлыгы 36 *га* булган бөҗра системасы эшләнә. Барлык катлауларда да бердәм фильтр файдаланыла. 1976 да нефтьне җыю һәм ташуның герметик системасына күчү төгәлләнә. Бер үк вакытта нефть чыгару, нефть әзерләү һәм катламнардагы басымны саклау цехлары комплексы механикалаштырыла, автоматлаштырыла һәм телемеханикалаштырыла. Ятмалар катламнарындагы басым су кудыру алымы б-н саклана. Су кудыру системасы контур эчендә, контур тирәли, катнаш рәвештә башкарыла; 31 тармак насослар станциясенә тоташтырылган 660 кудыргыч скважинаны үз эченә ала. Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру максатында 20 дән артык алдынгы алым (сейсмоакустик тәэсир итү, кушылган полимер системалар кулланып катламнарга полимер тәэсир итү технологиясе, гидродинамик, физик-химик алымнар, скважиналарны горизонталь бораулау ысулы һ.б.) кулланыла. Карабаш һәм Кама-Исмәгыйль җайланмаларында нефть әзерләү комплексы алып барыла. Карабаш җайланмасының 2 нче блогында дизель ягулыгы компонентлары җитештерелә. Нефть чыгаруда иң зур күрсәткечкә (12,2 млн. *т*) 1991 дә ирешелә. 1990 еллар ахырыннан нефть чыгаруның еллык күләме 1,2 млн. *т* чамасы тәшкил итә. 2000 еллар уртасында 2800 дән артык скважина бораулана, шуларның 1400 е нефть бирә. Чыгарылган продукциянең сулылыгы 94%. СССР Нефть сәнәгате министрлыгы карарларында идарәнең оештыру-техник автоматлаштырылган системасы җиһазларын һәм программ тәэмин ителешен сынау тәҗрибәсе эксперименталь база буларак билгеләп үтелә. «И.» эшчәнлеге зонасындагы әйләнә-тирә мохиткә техноген тәэсирне киметүгә, зыян килгән җирләрне табигый хәленә кайтаруга, эчәргә яраклы су чыганакларын төзекләндерүгә аеруча әһәмият бирелә. «И.» — шәһәр төзүче идарә; Карабаш посёлогында торак йортлар, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәният, спорт объектлары һ.б. учреждениеләр төзетә. НГДУның уку комб-ты, социаль объектлары, ял базасы, мәдәният йорты, ярдәмче хуҗалыгы бар. «И.» нең алдынгы хезмәткәрләре хөкүмәт бүләкләренә, ш.и. мактаулы исемнәргә лаек була: Соц. Хезмәт Герое — 1, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты — 3, РФ, ТРның атказанган нефтьчеләре, халык хуҗалыгының төрле тармакларының атказ. хезмәткәрләре — 29 кеше. Пр-тие җитәкчеләре: Е.И.Швецов (1964), В.М.Шестернин (1964–79), В.С.Дешура (1979–82), А.Ф.Харланов (1982–86, 1987–88), А.К.Максимов (1986–87), М.З.Таҗиев (1988–2001), Р.Х.Галимов (2001 дән).

2006 елда төп производствоны реконструкцияләү программасы буенча «И.» «Лениногорск» НГДУына кушыла.



«Иркеннефть» идарәсенең (НГДУ) хакимият бинасы.



Карабаш нефтьне комплекслы әзерләү җайланмасы.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов. М., 1993. Т. 2.

*И.Н.Фәйзуллин.*

**ИРКУ́ТСК МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**. 1905 елның 14 мартында оештырыла. Оештыручысы һәм идарә рәисе — Ш.Ш.Шәфигуллин. Төп максаты — мохтаҗларга һәм мөселман мәдәни-агарту оешмалары үсешенә матди ярдәм күрсәтү. 1917 дән соң таркала.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**ИРКУ́ТСК ӨЛКӘСЕ́**, РФдә урнашкан. Мәйданы — 767,9 мең *км*$^2$. Үзәге — Иркутск шәһәре. Халкы — 2824,9 мең кеше (2003), ш.и. 39,6 мең татар (1989). Татарлар Иркутск (6,7 мең кеше), Ангарск (3 мең), Братск (2,3 мең), Черемхово (2,1 мең), Усолье-Сибирское (1,8 мең), Тайшет (1 меңләп) шәһәрләрендә, Усть-Орда Бурят автономияле округында (4,4 мең), Залари, Нукут, Чунский, Оса р-ннарында яшиләр. 6 татар, 23 катнаш торак пункты бар. Татар халкы Себер татарларыннан һәм Идел-Урал регионыннан чыккан кешеләрдән тора. Иркутск өязенә күченгән татарларның беренче җәмгыяте 19 йөз уртасында оештырыла (Биликтуй һәм Новоямский а.). 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Иркутск, Нижнеудинск шәһәрләрендә, Усолье-Сибирское, Черемхово, Залари, Голуметь, Александровский, Слюдянка, Култук, Зима, Тайшет авылларында, яңа җирләргә күченгән Кулиш, Тарея, Долгановский, Черемшанский, Харагун, Шаховской һ.б. торак пунктларда татар җәмгыятьләре оештырыла. Татар халкы ташкүмер шахталарында, төзелештә эшли; игенчелек, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1898 елда Иркутскида җамигъ мәчет ачыла, аның каршында ир балалар өчен мәдрәсә һәм кызлар өчен мәктәп эшли. Татарлар урнашкан башка җирләрдә дә мөселманнарның гыйбадәт кылу урыннары, уку йортлары була. 1905–17 дә Иркутскида *Иркутск мөселманнары хәйрия җәмгыяте*, «Бертуган Шәфигуллиннар һәм Әхтәмовларның сәүдә йорты» эшли. 1920 елларда И.ө. терр-ясендә 40 лап татар мәктәбе, балалар йортлары (Иркутскида — 2, Нижнеудинск, Голуметь, Манзуркада — 1 әр), М.Вахитов исем. эшчеләр клубы һәм пионерлар коммунасы (Иркутск), китапханәләр, уку өйләре (Иркутск, Черемхово, Залари, Голуметь, Зима, Николаевский Завод) була. Хәзерге вакытта милли-мәдәни үзәкләр Иркутскида (1990 нан), Ангарскида (1993 тән), Черемховода (1991 дән), Усолье-Сибирскоеда (2001 дән), Тайшетта (1997 дән), шәһәр тибындагы Залари (1993 тән) һәм Чунский (1995 тән) посёлокларында; Халык авыз иҗаты йорты (Нукутский р-нының Закулей а.), татар китаплары китапханәсе (Чунский), төбәк тарихы музее (Залари), «Бүләк» халык фольклор коллективы (Иркутск) эшли. Иркутск өлкә мөселман җәмгыятенә теркәлгән 8 мөселман җәмгыяте керә (2004). 4 мәчет (Иркутск, Черемхово, Тайшет, Усолье-Сибирское) эшли. Оса, Залари, Чунский р-ннары мәктәпләрендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла. Иркутск, Ангарск, Черемховода якшәмбе татар сыйныфлары эшли. Генерал-лейтенант М.А.*Сулькевич*, мед. фән. д-ры Ә.Б.*Терегулов*, геогр. фән. д-ры Б.М.*Ишморатов,* мед. фән. д-ры Р.Г.*Сәйфетдинов*, техник фән. д-ры Г.П.*Хәмитовларның* тормыш һәм эшчәнлекләре Иркутск шәһәре б-н бәйле. Иркутск губернасыннан чыккан шәркыятьче галим Д.*Банзаров*, Казан ун-ты проф. А.П.*Щапов* Казанда укыйлар һәм эшлиләр.

*Г.И.Бобкова.*

**ИРМӘ́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2008 елда 117 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төрле кәсеп б-н шөгыльләнә; Әҗәкүл пристанендә йөк ташучы булып эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 555 дис. тәшкил итә. Күмәкләштерү елларында (1929–30) И.та «Үрләч» к-зы төзелә, 1950 елларда ул — «Урал», 1958 дә «Үзәк» к-злары составына керә (хәзер а.х. кооперативлары берләшмәсе). 1913 кә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1913 тән Такталачык волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 62, 1834 тә — 128, 1859 да — 176, 1870 тә — 192, 1897 дә — 177, 1908 дә — 187, 1920 дә — 233, 1926 да — 222, 1938 дә — 241, 1949 да — 206, 1958 дә — 233, 1970 тә — 236, 1979 да — 182, 1989 да — 126, 2002 дә — 113 кеше.

**ИРНӘ́** елгасы, к. *Урман Зәе.*

**ИРНӘ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2008 елда 3 кеше (татарлар) яши. 1926 да Ирнә посёлогы буларак нигез салына. Күмәкләштерү елларында (1929–30) И.дә «Алга» к-зы төзелә, 1958 дә Чапаев исем. к-з, 1963 тә «Правда» к-зы составына керә. 1979 дан И.нең элеккеге а.х. җирләрендә Зәй агротехника лицееның ярдәмче хуҗалыгы эшли. Халык саны: 1926 да — 37, 1938 дә — 221, 1949 да — 217, 1958 дә — 137, 1970 тә — 157, 1979 да — 43, 1989 да — 4, 2002 дә — 2 кеше.

**ИРО́НИЯ** (грек. Eironéia — ялган кыланыш, мыскыллау), шаян киная; ясалма рәвештә уңай бәя биреп, теге яки бу күренешкә, әйбергә тискәре, мәсхәрәле, кимсетүле мөнәсәбәт белдерү. Сүзнең яки сөйләмнең тискәре мыскыллы мәгънәсе теге яки бу хәлнең үзеннән, сөйләм контекстыннан яки интонациясеннән ачыклана. Әдәбиятта И. стилистик алым, троп булып килә. Аерым очракларда артык үтемле, көчле И. сарказмга әверелә һәм гротеск, пародия, парадокс чаралары б-н белдерелә. Татар әдәбиятында И.гә һәм сарказмга бай иҗат — Г.Тукай иҗаты. И.нең төрле формa һәм төсмерләре аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында, «Кечкенә музыкант», «Буран», «Егет илә кыз» шигырьләрендә очрый. Үзләренең юмористик шигырьләрендә И.дән М.Җәлил, С.Баттал, Ә.Ерикәй, Ш.Галиев һ.б. шагыйрьләр дә файдалана.

*В.Х.Ганиев.*

**ИРРИГА́ЦИЯ**, к. *Сугару.*

**ИРСА́ЕВА** Нурия Исхак кызы (13.10.1942, БАССРның Канбик а.), драма актрисасы, БАССР, РСФСР, ТРның халык артисты (1980, 1984, 1998). Уфада сәнгать уч-щесен (1965) һәм ин-тын (1987) тәмамлый. 1965 елдан Башкорт акад. драма театрында эшли. Матур җырлаучы артист буларак, татар муз. драмаларында баш рольләрне башкара: Галиябану (М.Фәйзинең шул исем. әсәре), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Сәрвәр («Башмагым», Х.Ибраһимов) һ.б. Матурлыкка, урманнарга һәм тауларга гашыйк табигать баласы Айгөл («Айгөл иле», М.Кәрим), саф күңелле, романтик Галия («Тапшырылмаган хатлар», Г.Кутуй), эчкерсез, беркатлы яшь кыз Динә һәм батыр йөрәкле, язмыш авырлыкларына бирешмәүчән Мәдинә («Үзебез сайлаган язмыш», «Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин) образларында И. башкаруында драматик тормыш каршылыклары нечкә лиризм һәм психол. тирәнлек б-н оста үрелеп бара. Актрисаның иҗат диапазоны искиткеч киң: шаян, тормыш сөючән үсмер егет Әсхәтне дә («Озын-озак балачак», М.Кәрим), иләмсез шыксыз Серафина («Нискавуори хатыннары», Х.Вуолийоки) һәм Һашия (Г.Шәфиковның шул исем. әсәре) рольләрен дә бертигез осталык б-н, ышандырырлык итеп башкара. Ф.Бүләковның «Сөясеңме-сөймисеңме?» әсәре буенча куелган спектакльдәге Фатыйма образында И. ак күлмәкле кечкенә генә карчыкның вак-төяк мәшәкатьләре, ыгы-зыгысы артында сабыр, карусыз, башкалар бәхете өчен барын да эшләргә әзер торучы хатынны гәүдәләндерә.

Башка зур рольләре арасында: Луиза («Солдат улы», Ә.Мирзаһитов), Рабига («Сандугач чакыруы», З.Ихсанов), Галия (Т.Таһировның шул исем. әсәре), Айсылу («Айсылуның айлы кичләре», И.Абдуллин), Мәдинә («Җәяүле Мәхмүт», М.Кәрим), Домна Пантелеевна («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», А.Н.Островский), Таня («Июньдә саубуллашу», А.В.Вампилов) һ.б. бар. БАССРның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1987).

*Әд.:* Тойганов Р. Нурия Ирсаева. Уфа, 1992.

*И.И.Илялова.*

**«ИРША́Д»**, Уфа губернасы Эстәрлетамак шәһәрендәге нәшрият. 1912 елда имам Мөбарәкшаһ әл-Хәнәфи тарафыннан татар китапларын һәм вакытлы басмаларын нәшер итү һәм сату максатында ачыла. 1913 тә Т.Мәүледов һәм Г.Миңнебаев (Гомәрский) милкенә күчә. Соңыннан Г.Миңнебаев «И.»ның бердәнбер хуҗасы, кайбер басмаларның тәрҗемәчесе һәм авторы була. «И.» 1918 елда ябыла.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**ИСА́ВНИН** Алексей Геннадьевич (5.9.1971, Оренбург өлкәсенең Бозаулык ш.), физик, физ.-матем. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1993), шунда ук эшли. 1998 елдан Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тының Чаллы ф-лында. 1999 дан Кама

инженерлык-икътисад академиясендә, проф. (2007 дән). Хезмәтләре исемдәш магнит кисәкчәләре системасында стохастик резонанска карый. Нанометрик диапазондагы магнит кластерлары системаларында даими һәм очраклы процессларның үзара максималь йогынтысы өлкәсендә тикшеренүләр алып бара.

Х е з м.: Стохастический резонанс в системе одноимённых магнитных частиц. Н.Челны, 2004; Влияние произвольно направленного постоянного магнитного поля на динамическую восприимчивость суперпарамагнитной частицы в условиях стохастического резонанса // Изв. вузов. Физика. 2006. Т. 49, № 3.

**ИСА́ЕВ** Алексей Петрович (1906, Казан губ., Зөя өязе Малый а. — 22.1.1945, Будапешт ш., Венгрия), Сов. Союзы Герое (28.4.1945, үлгәннән соң), сержант (1945). Колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 42 нче укчы полкның автоматчылар ротасында отделение командиры (46 нчы армиянең 180 нче укчы дивизиясе). Төньяк Кавказ, Көньяк-Көнбатыш фронтлар гаскәрләре составында Кавказ өчен барган сугышта (1943), Украина, Молдавия, Румыния, Болгария, Венгрияне азат итү сугышларында катнаша (1943–45). 1945 нең 22 гыйнварында Будапешт өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: дошман пулемётын гәүдәсе б-н каплап, үзенең подразделениесенә уңышлы һөҗүмне тәэмин итә. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә. Туган авылы һәм Казан шәһәренең бер урамына И. исеме бирелгән.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Считать живыми. Киш., 1978; Бессмертные подвиги. М., 1980; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИСА́ЕВ** Алексей Степанович (19.5.1924, Бөгелмә кантоны Иске Писмән а. — 6.6.1997, Бөгелмә ш.) экскаватор машинисты, Соц. Хезмәт Герое (1971), Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (1981). 1950–84 елларда «Строймеханизация» трестының 32 нче Бөгелмә төзелеш идарәсендә эшли. Герой исеме бишьеллык планны (1966–70) үтәүдә ирешкән казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләре өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1977–84 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Экипаж экскаватора на хозрасчёте // Слово Героям Социалистического Труда. М., 1972. Вып. 1; Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ИСА́ЕВ** Борис Михайлович (18.6.1935, Рязань өлкәсенең Михайловск ш. — 2.10.2004, Мәскәү), партия, хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1959 елда Рязань а.х. ин-тын тәмамлагач, Михайловск шәһәре пр-тиеләрендә партия һәм хуҗалык эшендә. 1962–63 тә Татарстан респ-ка «Сельхозтехника» берләшмәсенең (Казан) фермаларны механикалаштыру бүлегендә дәүләт техник күзәтчелеге буенча өлкән инженер, 1963–65 тә башлык. 1965–69 да КПСС-ның Татарстан өлкә ком-ты оештыру-партия эше бүлеге инструкторы. 1969–73 тә КПССның Аксубай райкомы 1 нче секретаре. 1973–84 тә ТАССР МС рәисе урынбасары, 1 нче урынбасары, бер үк вакытта 1983 тә Татарстан респ-ка агросәнәгать берләшмәсе рәисе. 1985–86 да РСФСР әзерләүләр министрының, 1986–88 дә РСФСР икмәк продуктлары министрының 1 нче урынбасары, 1991–93 тә РФ ЮС Аппаратының социаль-икътисади үсеш бүлеге мөдире. 1999 да Бөтенроссия «Депутатлар ассоциациясе» иҗтимагый оешмасы рәисе. 1996–99 да РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы рәисе киңәшчесе. 1971–85 тә ТАССР ЮС депутаты, 1990–93 елларда РФ халык депутаты.

*Әд.:* Современная политическая история России (1985–1998 годы). Лица России. М., 1999. Т. 2.



А.П. Исаев.



А.С. Исаев.



О.Н. Исаев.

**ИСА́ЕВ** (Гыйсаев) Габделбари (Бари) Низаметдин улы (1907, Уфа ш. — 1982, Ленинград), дин эшлеклесе. БАССРның Бөре кантоны Түләгән авылы мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (1926), шул ук кантонның Карьяуды авылында имам булып тора. 1929 елда кулга алына. 1930 дан, тоткынлыктан азат ителгәч, Кыргызстанда яши, мулла вазифаларын башкара. Бөек Ватан сугышында катнаша. Яраланганнан соң (1943), Уфага әйләнеп кайта, 1946–53 тә СССРның Европа һәм Себер өлеше мөселманнарының Диния нәзарәтендә эшли, 1953–56 да Уфадагы 2 нче мәхәллә мәчетендә имам-хатиб булып хезмәт итә. 1956 дан Ленинград җамигъ мәчете имам-хатибы. 1975–80 дә СССРның Европа һәм Себер өлеше мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти.

*А.Б.Юнысова.*

**ИСА́ЕВ** Николай Александрович (13.12.1945, Биектау р-ны Олы Дәрвиш а.), инженер-электромеханик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1970). 1972–94, 1999–2000 елларда «Казан оптика-механика заводы» АҖндә эшли: өлкән инженер, җыю цехы башлыгы урынбасары (1982 дән), баш технолог (1986 дан), производство җитәкчесе (1993–94), АҖнең ген. директоры (1999–2000). 1994–97 дә Казанда торак хуҗалыгы производство трестында баш инженер. 1997–99 да «КОМЗ-Байгыш» АҖндә ген. директор. 2000 елдан Яңа Савин базары баш инженеры. Дәүләт бүләге приборлар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ИСА́ЕВ** Олег Николаевич (14.1.1964, Балтач р-ны Иске Көшкәт а. — 5.4.1996, Воронеж ш.), РФ Герое (13.6.1996, үлгәннән соң), очучы, майор. Арча пед. уч-щесен (1983), очучыларның В.И.Чкалов исем. Борисоглебск Югары хәрби авиация уч-щесен (1988) тәмамлый. 1988–93 елларда Төньяк-Кавказ хәрби округында, ш.у. Әзәрбайҗан, Германия, Таҗикстанда, Ставрополь краенда хезмәт итә. 1993 тән Будённовск шәһәрендә (Ставрополь крае) хәрби частьтә. 1996 ның 4 гыйнварында, майор Матвиенконың самолёты бәреп төшерелгәч, аны коткару операциясен уңышлы үткәрүне тәэмин итә. 1996 ның 5 апрелендә Чечен Респ-касында гаскәр колоннасын саклау бурычын үтәгәндә батырлык күрсәтә: дошманның засадасын табып, сугышка керә һәм һәлак була. Медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИСА́ЕВА** Зоя Григорьевна (17.5.1921, Спас кантоны Бугровка а. — 10.5.1990, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1967). 1944 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1947–63 тә Казан ун-ты каршындагы Химия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1963–85 тә СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында табигый кушылмалар лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре скипидардан аерып алына торган терпеннар химиясенә, шуларның реакциягә керә алуына, әверелү механизмнарына, төркемләнүләренә, стереохимиягә карый.

Х е з м.: Об изомеризации бициклических терпеновых окисей в реакции с уксусным ангидридом // Журн. общей химии. 1954. Т. 24, вып. 7 (автордаш); О восстановлении окиси а (альфа) — пинена и дельта[3] — карена // Изв. АН СССР. Отд-ние хим. наук. 1959. № 6 (автордаш); Окисление 3-карена тетраацетатом свинца в уксусной кислоте // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1969. № 12 (автордаш).

**ИСА́ЕВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 12 кеше (руслар) яши. 1651 дән Малая исеме (бу исемне 1963 нең 13 июленә кадәр йөртә) б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да 2 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 841 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 357, 1897 дә — 467, 1908 дә — 532, 1920 да — 539, 1926 да — 555, 1938 дә — 500, 1949 да — 550, 1958 дә — 232, 1970 тә — 91, 1979 да — 40, 1989 да — 21, 2002 дә — 11 кеше.

**ИСА́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Зөя елгасы тамагы буенда. 2008 елда 29 кеше (руслар) яши. 1565–67 еллардан Зөя Успение монастыре карамагындагы кечкенә авыл буларак билгеле. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.та Богоявление чиркәве (беренче тапкыр 1567 дә телгә алына, хәзерге бинасы 1792–99 да төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 2 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1124 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1958 нең 12 июленнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 204 ир-ат; 1859 да — 945, 1897 дә — 578, 1908 дә — 848, 1920 дә — 864, 1926 да — 968, 1938 дә — 678, 1949 да — 631, 1958 дә — 487, 1970 тә — 222, 1979 да — 128, 1989 да — 56, 2002 дә — 33 кеше.

**ИСА́КОВА** Лариса Васильевна (28.9.1947, Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.), балет артисты, балетмейстер, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). 1964 елда Фрунзе хореография уч-щесен, 1973 тә Дәүләт театр сәнгате ин-тының (Мәскәү) режиссёр-балетмейстерлар бүлеген тәмамлый. 1964–68 дә Кыргыз опера һәм балет театры (Фрунзе) балет артисткасы. 1973 тән Татар опера һәм балет театры балетмейстеры, 1985–89 да баш балетмейстеры; 1989–90 да Башкорт опера һәм балет театры баш балетмейстеры, бер үк вакытта Уфа хореография уч-щесе сәнгать җитәкчесе. Казанда ул куйган әсәрләр: «Конёк-Горбунок» (Р.Щедрин, 1975), «Лауренсия» (А.Крейн, 1978), «Доктор Айболит» (И.Морозов, 1981), «Сестра Керри» (Р.Паульс, 1983), «Макбет» (К.Молчанов, 1984), «Фидаи» (Р.Яхин музыкасына, 1987) балетлары; «Риголетто» (Дж.Верди, 1973), «Фауст» (Ш.Гуно, 1974), «Борис Годунов» (М.Мусоргский, 1980) операларына биюләр һ.б. 1990 нан Мәскәүдә яши.

*Әд.:* Т а р а с о в а О. Встреча с героями Мольера // Советский балет. 1985. № 5; Ш е р е м е т ь е в с к а я Н. Судьба поэта // шунда ук. 1987. № 5.

*В.Н.Горшков.*

**ИСӘ́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы чигендә. 2008 елда 264 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1686 дан мәгълүм. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, терлек үрчетү, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.тә 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр һәм 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1316 дис. тәшкил итә. 1929 да И.тә «Быру» (1938 дән — «Революция») к-зы төзелә, 1964 тә «Чулпан» к-зына (1997 дән — «Таң» күмәк хуҗалыгы) кушыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Әлки волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 нең 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 159 ир-ат; 1859 да — 782, 1897 дә — 1025, 1908 дә — 1298, 1920 дә — 1498, 1926 да — 1004, 1938 дә — 1181, 1949 да — 829, 1958 дә — 661, 1970 тә — 674, 1979 да — 520, 1989 да — 397, 2002 дә — 329 кеше.

**ИСӘНБА́Й** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 86 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда. 2008 елда 989 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, участок хастаханәсе, китапханә. Волость идарәсе бинасы — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, колмак үстерү б-н шөгыльләнә. 1868 дә И.да рус-татар земство мәктәбе ачыла. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 3 мәчет, мәдрәсә, мәктәп, су тегермәне эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 810, 1890 да — 1650, 1920 дә — 2323, 1926 да — 2089, 1938 дә — 2046, 1949 да — 1565, 1958 дә — 1312, 1970 тә — 1593, 1989 да — 1117, 2002 дә — 1001 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**ИСӘНБӘ́Т** Йолдыз Нәкый кызы (30.5.1936, Казан), музыка белгече, педагог, сәнгать фән. канд. (1970), ТАССРның, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1987, 1997). Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң (1962), 1962–94 елларда шунда ук укыту эшендә: 1966–68 дә музыка теориясе каф. мөдире, 1989–94 тә татар музыкасы каф. мөдире. 1994–99 да ТР ФА нең Татар энциклопедиясе ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре, 1994–95 тә фәнни-методик эшләр һәм тикшерү бүлеге мөдире. 1999 дан ТР Мәдәният министрлыгының Татар халкы фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. ТРның Композиторлар берлеге әгъзасы (1983). Хезмәтләре татар музыкасы тарихына, татар композиторлары һәм язучылары иҗатына карый.

Х е з м.: Муса Джалиль и татарская музыка. К., 1977; Газиз Альмухаметов и Султан Габаши в Казани. Уфа, 1995; Рустем Яхин. К., 2002; Словарь музыкально-сценических произведений татарских композиторов. К., 2003.

*Әд.:* Л а т ы й п о в а Е. Танылган музыка белгече // Мирас. 1996. № 7–8; С а л и т о в а Ф.Ш. Новый взгляд на известные факты // Татарстан. 1996. № 6; ш у л у к. Волшебная сила музыки // Идель. 2001. № 3.

**ИСӘНБӘ́Т** Нәкый Сиразетдин улы (29.12.1899, Уфа губ., Златоуст өязе Малаяз а. — 15.9.1992, Казан), язучы, фольклорчы, тел белгече, педагог. ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1959), ТАССРның халык язучысы (1986). Мулла гаиләсендә туа. «Хәсәния» (1910–12, Уфа) һәм «Мөхәммәдия» (1912–16, Казан) мәдрәсәләрендә белем ала. Кыска вакытлы пед. курсларны тәмамлаганнан соң, 1917–20 елларда Башкортстан авылларында балалар укыта. 1919–22 елларда, укытучылык хезмәтеннән аерылмыйча, Уфа Халык мәгарифе ин-тында һәм Харьков ун-тында, Мәскәүдә Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик ун-тында укый. 1917–39 елларда мәктәпләрдә һәм техникумнарда татар, башкорт телләре һәм әдәбияты һ.б. фәннәрне укыта, методист, пед. курсларның лекторы булып эшли (1917–20, 1922–23 тә туган төбәге авылларында, 1923–30 да Уфада, 1930, 1932–37 дә Казанда, 1938–39 да Әтнә р-нында), 1920 еллар ахырында бер төркем татар-башкорт язучылары б-н бергә контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнә (к. «*Җидегәнчеләр*» эше), 1929–30 елларда аклана, ләкин үз хезмәтеннән читләштерелә, шул сәбәпле 1930–32 елларда Казанда «Спартак» ф-касында эшли. 1939 дан профессиональ язучы.

И.нең беренче әсәрләре 1910 еллар уртасында басыла, алар арасында халык, кеше язмышы, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны турында уйланулар б-н сугарылган «Сукбай», «Укытучы кыз» поэмалары, «Рияга каршы», «Күңел ярасы», «Кешелек дөньясы», «Сугыш», «Инкыйлаб» шигырьләре бар. «Коммуна тимерлегендә», «Пролетариат килә» исемле шигырьләрендә автор азатлык хакына актив көрәшкә чакыра. «Чаң» (1925) җыентыгына кергән шигырьләрендә ирекле күмәк хезмәткә, «Эшче Хафиз» (1920), «Днепрострой» (1932), «Нужа бабай» (1950) исемле поэмаларында һәм башка шигырьләрендә хезмәткә, яшьлеккә, мәхәббәткә, табигать гүзәллегенә дан җырлый. Шул ук елларда руханилар тормышын яктырткан беренче пьесалары — «Әмирхан хәзрәт» (1916), «Сират» (1919) языла. 1920 елларда ул берничә комедия яза, мәс., «Һиҗрәт» (1923) пьесасында рев-циядән Себергә качучыларның трагикомик хәлләргә тарулары тасвирлана, «Пикуләй Шәрәфи» (1929) пьесасында автор нэпманнардан, ярым-йорты белемле мәдәният хезмәткәрләреннән, сугышчан атеистлардан, төрле ялган исемнәр б-н йөрүчеләрдән, карак түрәләрдән көлә. Бу чорда И. театр тәнкыйтьчесе буларак та актив эшли. Үзенең мәкаләләрендә һәм рецензияләрендә милли театр сәнгатенең уңышларына һәм проблемаларына бәя бирә («Таһир-Зөһрә», 1923; «Отелло», 1923; «Гамлет», 1924; «Әлмансур», 1924 һ.б.). И. — 30 дан артык пьеса (драма, трагедия, комедияләр) авторы. Фольклор мотивларына нигезләнеп язылган «Хуҗа Насретдин» (1939, куела 1940), «Идегәй» (1941), «Түләк» (1942), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (1942, куела 1944), «Әбүгалисина» (1959, куела 1971), «Хәйләкәр Дәлилә» (1966), «Кырлай



Н. Исанбет.

егете» (1965, куела 1968) пьесалары киң танила һәм сәхнәдә зур уңыш б-н бара. И. — «Түләк белән Сусылу» операсының либретто авторы (музыкасын Н.Җиһанов яза, 1944). Халыкчан телле әлеге пьесаларга Шәрекъ колориты, гадәти булмаган (ешрак көлкеле) хәлләр, геройларына милләтпәрвәрлек, батырлык, фидакарьлек, югары әхлаклылык хас. Пьесаларның төп геройлары (Хуҗа Насретдин, Әбүгалисина, Дәлилә) тапкыр, оптимист, акыллы, гадел, ирек сөючән. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп язылган «Кырлай егете» фарс-комедиясендә шул чор тормышына сатирик мөнәсәбәт чагыла. Тарихи вакыйгаларга таянып иҗат ителгән трагедияләрендә халыкның социаль тигезлек һәм гаделлек турындагы хыяллары сәнгатьчә гәүдәләнеш таба. «Спартак» (1934) трагедиясендә борынгы Римдагы коллар күтәрелеше җитәкчесенең героик һәм трагик язмышы тасвирлана. «Идегәй» пьесасының вакыйгалары үзәгендә Алтын Урда чорының легендар гаскәр башлыгы һәм дәүләт эшлеклесе тора (к. «*Идегәй*»). Аерым пьесаларында И. шәхес ирекe һәм хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урыны мәсьәләләрен күтәреп чыга. «Миркәй белән Айсылу» (1935, куела 1936) пьесасында кадимчеләрнең җәдитчеләргә каршы көрәше халык фаҗигасе буларак күрсәтелә; укытучы Җаннур — заманының алдынгы фикер иясе. Геройлары театр сөюче 20 йөз башы яшьләре, алдынгы татар зыялылары булган «Гөлҗамал» (1944) тарихи драмасында да шундый ук каршылык чагылыш таба. Беренче татар проф. актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская образы — драматургның зур уңышы, аның Гөлҗамалы — югары идеаллар кешесе, чын милләтпәрвәр, фидакарь мәгърифәтче. И., халык, ил тарихы темасына тугры калып, «Болак арты республикасы» (1940), «Мулланур Вахитов» (1944), «Муса Җәлил» (1954) һ.б. әсәрләр иҗат итә. «Болак арты республикасы» — сәяси памфлет булса, калганнары — трагедия. Аларның геройлары югары идеаллар өчен һәлак булалар. Бөек Ватан сугышы елларында И. иҗатында патриотик тема зур урын ала. Пьесаларның героикасы тарихи шәхесләр һәм фольклор персонажлары хисабына тагын да көчәя («Идегәй», «Мәрьям», 1943; «Түләк белән Сусылу», «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Гөлҗамал», «Мулланур Вахитов»). Сугыш кайтавазы «Рәйхан» (1948) пьесасында да чагылыш таба. «Мәрди белән Нәфисә» (1974) драмасы — үткән сугыш еллары вакыйгаларына бәя бирә. «Зифа» (1954) комедиясендә гаилә тормышындагы, көнкүрештәге әхлакый кимчелекләр б-н бергәттән чиновникларның башбаштаклыгы да фаш ителә. 1950 елларда сугыш темасы интернациональ позициядән чыгып ачыла. «Муса Җәлил» пьесасы — легендар татар шагыйренең һәм аның иптәшләренең фашистлар зинданындагы тормышлары һәм үлемнәре турында бәян ителгән оптимистик трагедия. Пьеса татар әдәбиятында героик-патриотик пафосны көчәйтә. 1960 елларда И. кабат сатирага әйләнеп кайта һәм «Кырлай егете» фарс-комедиясен яза. Пьесада совет чынбарлыгына карата сатирик мөнәсәбәт чагылыш табу сәбәпле, спектакль Татар акад. театры сәхнәсеннән төшерелә.

И. — фольклорчы галим, татар фольклорын җыючы, фундаменталь фәнни хезмәтләр авторы. 28 күчермәгә (вариантка) таянып, «Идегәй» дастанының җыелма текстын эшли. Ул — «Татар халык мәкальләре» (т. 1–3, 1959–67), «Татар халык табышмаклары» (1970), «Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен» (1984) җыентыкларын; «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н (т. 1–2, 1989–90), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (т. 1–4, кульязма рәвешендә) төзүче. И. А.С.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан», 1937), «Таш кунак» («Каменный гость», 1937), «Полтава» (1937) әсәрләрен, А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласы» («Горе от ума», 1946) комедиясен, Ж.Б.Мольерның «Суган суфые» («Тартюф», 1937) пьесасын, У.Шекспирның «Король Лир» (1944), «Гамлет» (1950) трагедияләрен һ.б. татар теленә тәрҗемә итә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1968).

Ә с ә р.: Ни өчен ни булган, яки утыз ялган: Әкиятләр. К., 1956; Кырлай егете: Пьесалар. К., 1980; Әсәрләр: 4 томда. К., 1988–89.


*Әд.:* Ш а м у к о в Г. Нәкый Исәнбәт. К., 1959; Әдип һәм галим. К., 1969; Х а н з а ф а р о в Н. Нәкый Исәнбәт драматургиясе. К., 1982; Ә х м ә д у л л и н А.Г. Үзенчәлекле талант турында сүз // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993.

*А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Ә.Ганиев, Н.Г.Ханзафаров.*

**ИСӘНБӘ́Т** Празат Нәкый улы (9.10.1927, Уфа ш. — 15.12.2001, Казан), актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның халык артисты (1981), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Мәскәү Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) Татар студиясен (1949) һәм режиссёрлык ф-тын (1958) тәмамлый. 1949–50 елларда Казан Яшь тамашачылар театрында татар төркеме актёры, 1950 дән Татар акад. театры труппасында, бер үк вакытта 1958 дән шул театрның режиссёры да. И. шактый күренекле рольләрдә уйный, алар арасында Кодар («Козы Көрпеш һәм Баянсылу», Г.Мөсрәпов), Дерамо («Болан-Патша», К.Гоцци), Синцов («Дошманнар», М.Горький), Васильков («Котырган акчалар», А.Н.Островский) рольләре бар. Татар акад. театры сәхнәсендә 50 дән артык спектакль куя. Беренче әсәрләреннән үк («Муса Җәлил», Н.Исәнбәт, 1957; «Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов, 1960; «Янар чәчәк», И.Юзеев, 1961; «Җырланмаган җыр», М.Кәрим, 1962) үзен нечкә зәвыклы, авторның төп идеясенә сак караучы, пьесага һәм һәр рольгә төпле психол. анализ ясый белүче режиссёр итеп таныта. Н.Исәнбәтнең «Гөлҗамал» әсәре буенча И. тарафыннан куелган спектакль (1963) татар театр сәнгатенең зур казанышы буларак кабул ителә; хатын-кызлардан беренче татар актрисасының язмышы спектакльдә дәртле, романтик-күтәренке рухта күрсәтелә. Кешенең рухи ирекка омтылуы һәм кешелек кыйммәтләренең догматик кузаллаулар б-н бәрелеше темасы режиссёрның башка спектакльләрендә дә күтәрелә. Кайбер әсәрләрне ул сәхнәгә икешәр тапкыр куя. Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» пьесасы (1957, 1966), Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» (1960, 1978), Х.Вахитның «Туй алдыннан» (1960, 1978), Г.Камалның «Бәхетсез егет» (1984), Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» (1985), Р.Хәмиднең «Ике сәгать — бер гомер» (1985) әсәрләре б-н тамашачы игътибарын геройларының рухи тормышларындагы киеренкелеккә юнәлтә. Г.Фигейредуның «Эзоп» (1967), Г.Исхакыйның «Зөләйха» (1992) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә рухи азатлык өчен көрәш темасы фәлсәфи мәгънәгә ия була. И. күбрәк психол. драма жанрына тартыла, классик комедияләр аның иҗатында аерым урын алып тора. Ж.Б.Мольерның «Суган суфые» («Тартюф», 1978), Г.Камалның «Банкрот» (1979), Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» (1994) спектакльләрендә режиссёр образларны гротеск дәрәҗәсенә җиткерә; хәрә-



П.Н.Исәнбәт.





П.Н.Исәнбәт тарафыннан куелган спектакльләрдән күренешләр.
1. Г.Фигейреду. «Эзоп»;
2. Г.Ибраһимов. «Татар хатыны ниләр күрми».

кәтләрнең кызу ритмнары, күркәм муз. эшләнешләре б-н бу спектакльләр тамашачыда зур популярлык казана. М.Горькийның Казанда яшәгән чоры б-н бәйле әсәрләренә таянып, П.Исәнбәтнең үзе язган «Һаваларда йолдыз» пьесасы буенча куйган спектакле театр сәнгатендә зур казаныш буларак кабул ителә. И. куйган спектакльләргә сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан лирик күтәренкелек, бөтенлек, төгәллек хас. Аларны әзерләү вакытында режиссёр актёрлар б-н эшләүгә зур игътибар бирә; Казан театр уч-щесендә укыта.

Башка спектакльләре: «Һиҗрәт», «Әбүгалисина», «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт); «Карлыгач канат кага», «Илһамия», «Мәхәббәтең чын булса», «Давыл» (Х.Вахит), «Әңгер-меңгер» (А.Гыйләҗев), «Ике фикер» (Г.Коләхмәтов), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Җан Баевич» (Г.Исхакый), «Чамасына күрә чарасы» (У.Шекспир) һ.б.

*Әд.:* Иляловa И. Театр имени Камала. К., 1986; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство. 1957–1990. К., 2002; Празат Исанбет. Грани призвания. К., 2007.

*И.И.Илялова.*

**ИСӘНГО́Л** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1714 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә, тирә-юньдәге алпавыт утарларында ялланып эшли. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында авыл халкы Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 604 дис. тәшкил итә. 1931 дә И.да «Исәнгол» к-зы төзелә, 1950 дән — «Победа» к-зында (соңрак Мичурин исем. к-з). 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 188, 1870 тә — 198, 1908 дә — 363, 1913 тә — 409, 1920 дә — 422, 1926 да — 302, 1938 дә — 238, 1949 да — 166, 1958 дә — 114, 1970 тә — 165, 1979 да — 145, 1989 да — 114, 2002 дә — 108 кеше.

**ИСӘНГУ́ЛОВА** (ире фамилиясе буенча Яремчук) Гөлсем Сабир кызы (10.6.1938, БАССРның Мәләвез р-ны Карагай а.), драма актрисасы, ТАССРның, БРның халык артисты (1988, 1996). Мәскәүдә М.С.Щепкин исем. югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1961), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Зур драматик сәләткә ия, темпераментлы актриса буларак, И. шактый зур рольләр башкара: Корри («Фаҗигале юлда», А.Муис романы буенча), Маһисәрвәр, Зәмзәмбану («Чаткылар», «Ташкыннар», Т.Гыйзәт), Айсылу, Бибкәй («Миркәй белән Айсылу», «Әбүгалисина», Н.Исәнбәт), Шәфәкъ, Гера («Ай тотылган төндә», «Ташлама утны, Прометей!», М.Кәрим), Ханша («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш) һ.б. Аның героиняларында барыннан да бигрәк хатын-кыз горурлыгы, рухи азатлык, бәйсезлек кебек сыйфатлар чагыла, шуның б-н алар эпик масштаблылыкка ирешәләр.



Г.С. Исәнгулова.

Замандашлары рольләреннән Роза («Әңгер-меңгер», А.Гыйләҗев), Хәдичә («Китәм инде», Р.Хәмид), Гөлсем («Мирас», Г.Каюмов), Миңзифа («Кичер мине, әнкәй!», Р.Батулла), Саҗидә («Дуслар җыелган җирдә» һәм «Хушыгыз», Т.Миңнуллин), Щёголева («Чит кеше», И.М.Дворецкий) образларын башкарганда И. үз геройларын яклаучы түгел, бәлки аларны хөкем итүче дә; ул үзе, әзлекле рәвештә, образның асылына төшенә; ялкынланып үзенең гражданлык позициясен яклый, инанган фикереннән кире кайтмый.



Г.С.Исәнгулова Назлыгөл ролендә (М.Байҗиев. «Хуш, Назлыгөл», уңда И.Баһманов).

М.Байҗиев әсәре буенча куелган «Хуш, Назлыгөл» спектаклендәге Назлыгөл образы тирән драматизм б-н сугарылган; ул рухи, әхлакый дилемма алдында калган героиняның каршылыклы характерын гәүдәләндерә. Актрисага хас эмоциональлек, хисләр ачыклыгы ул башкарган Фатыйма («Бәхетлеме син?», М.Садыйкова), Айшә («Зифа», Н.Исәнбәт), Хәдичә («Алдым-бирдем», Г.Исхакый), Ана, Судья («Кияү белән Кәләш», М.Байҗиев), Лариса Даниловна («Бер төн», Б.Л.Горбатов), ш.у. «Инсаният» труппасында уйнаган Сәлимә («Әбиләргә ни җитми?», Ф.Бүләков), Наһар («Чакырылмаган кунак», Р.Җиһаншина) рольләрендә ачык чагыла. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Д.Э.Гыймранова.*

**ИСӘНСЕ́Ф** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәҗәнә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 226 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1693 тән Исенсубино авылы буларак билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында И.тә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең җире 1545,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 170, 1834 тә — 254 ир-ат; 1870 тә — 754, 1897 дә — 1068, 1920 дә — 1314, 1926 да — 765, 1938 дә — 797, 1949 да — 542, 1958 дә — 444, 1970 тә — 472, 1979 да — 400, 1989 да — 276, 2002 дә — 235 кеше.

**ИСӘНСЕ́Ф-ЧИШМӘ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы бассейнында. 2008 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. 20 йөз башында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Пучы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 201, 1989 да — 45, 2002 дә — 54 кеше.

**ИСЕ́М**, киң мәгънәсендә предметны белдерә торган сүзләрне үз эченә алучы сүз төркеме. Татар телендә И.нең берничә лексик-семантик төркеме бар. Конкрет мәгънәле исемнәргә реаль чынбарлыктагы затларны һәм предметларны, төрле күренешләр һәм вакыйгаларны, табигать күренешләрен белдергән исемнәр керә: кеше, китап, җил һ.б. Абстракт мәгънәле И.нәр төрле абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләрдән гыйбарәт: матурлык, фикер, үсеш һ.б. Матдәләрне белдергән И. аерым өлешләргә таркалмый торган тоташ әйбер атамаларын белдерәләр: он, көмеш, ярма һ.б. Җыйма И.нәрне предметлар (затлар) җыелмасын бербөтен буларак белдерүче сүзләр тәшкил итә: 1) кешеләр төркеме: халык, җәмгатьчелек; 2) үсемлекләр һәм тереклек ияләре күплеге: сарык көтүе, каенлык; 3) табигатьтәге җисемнәр: комлык, сазлык һ.б. Ялгызлык һәм уртаклык И.нәр бар. Ялгызлык И.нәр: кеше И.нәре — Алсу, Айрат; географик атамалар — Идел, Җидегән йолдыз; әдәби әсәрләр, сәнгать әсәрләре, газета, журнал исемнәре һ.б. — «Шүрәле», «Мәгариф», «Татарстан яшьләре» һ.б. Уртаклык И.нәргә бер төрдән булган затларның, тереклекләрнең, предметларның барысы өчен дә уртак булган И.нәр керә: кеше, бала, эт, елга һ.б. Җанлылык-җансызлык татар И.нәрендә күрсәтелми, чөнки мондый бүленеш грамматик әһәмияткә ия түгел. Морфологик яктан И.гә *килеш, тартым, сан* һәм хәбәрлек категорияләре хас. Татар телендә род категориясе юк. Синтаксик яктан И. теләсә кайсы җөмлә кисәге була ала, ешрак ия, тәмамлык, аергыч булып килә.

*Әд.:* Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.Ә. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1972; Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. К., 1978; Татар грамматикасы. К., 2002. Т. 2; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Современный татарский литературный язык. М., 1971.

**ИСЕМЛЕ́ ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ́ КЕРТЕМЕ́** (ИХК), номиналь бәясе күрсәтелгән дәүләт таныклыгы. Дәүләт һәм коммуналь мөлкәтне хосусыйлаштыру процессында, ТРның 1993 елның 1 август «Татарстан Республикасында исемле хосусыйлаштыру счётлары (кертемнәре) турында»гы Законына туры китереп, бүленә торган дәүләт һәм коммуналь милекләр өлешенә ия булу хокукын билгеләү максаты б-н кертелә. ИХКнең номиналь бәясе ТРның бер гражданина 30 мең сум күләмендә (1993 елның 1 гыйнвары бәяләрендә) билгеләнә. ТРның «Татарстан» саклык банкларында һәр гражданга исемле хосусыйлаштыру счёты ачыла. ИХКн аукционда сатарга, махсуслашкан инвестиция фондлары чеклары («Образование» — «Мәгариф», «Доверие» — «Ышаныч», «Золотой колос» — «Алтын башак», «Финансист», «Национальный инвестиционный фонд РТ» — «ТРның милли инвестиция фонды» һ.б.) аша хосусыйлаштырылган пр-тиеләрнең исемле акцияләренә алыштырырга рөхсәт ителә. Әмма инфляция (нигездә 1993 һәм 1998 елларда) шартларында күп тапкырлар кертемнәрнең бәяләре төшү һәм индексацияләнмәве сәбәпле, аларның гамәли әһәмияте юкка чыга.

Хезм.: Приватизация: Основные Законы и положения РТ. К., 1993. Вып. 4–5.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ИСЕМСЕ́З КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Элеккеге су юлында сакланып калган күл: Казансу елгасы тугаеның уңъяк ярында, Биектау р-ны Щербаково авылыннан 3 *км* төньяктарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,9 *га*. Озынлыгы 400 *м* га якын, киңлеге 60 *м*, уртача тирәнлеге 1 *м* га якын. Формасы дугасыман. Суы югары минеральләшкән (2 *г/л*), бик каты (22,7 *мг-экв/л*), сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта, составында органик һәм биоген матдәләр күп. Туенуы катнаш; Казансу елгасына көчсез генә агымы бар, үсемлекләр б-н каплана һәм сазлана бара. Су һәм сазлык үсемлекләреннән тар яфраклы җикәнбаш, гади курак (камыш), күрән, бака тәңкәсе үсә.

*Н.М.Миңнаҗева.*

**ИСЕМСЕ́З КҮЛ**, Көнбатыш Кама арьягында. Спас р-ны Өчкүл авылы янында. Су өслегенең мәйданы 10,4 *га*, күләме 135 мең *м³*.



Исемсез күл. Спас районы.

Озынлыгы 480 *м*. Иң зур киңлеге 410 *м*, уртача тирәнлеге 1,3 *м*, иң зур тирәнлеге 1,9 *м*. Күл казанлыгы ясалма. Формасы түгәрәк. Җир асты туенуы тотрыклы. Суы аз минеральләшкән (59,7 *мг/л*), бик йомшак (катылыгы 1,1 *мг-экв/л*), аз болганчыклы, сары төстә, иссез, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. ТРның табигать истәлеге (1978).

**ИСЕРГӘ́П** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Томбарлы елгасы буенда. 2008 елда 947 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, И.тә мәчет, мәктәп, 4 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3351 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 1090, 1889 да — 1638, 1897 дә — 1938, 1920 дә — 2366, 1926 да — 2107, 1938 дә — 2063, 1949 да — 1791, 1958 дә — 1407, 1970 тә — 1059, 1979 да — 1247, 1989 да — 1040, 2002 дә — 1038 кеше. И.тә язучы М.*Юныс* туган.

**ИСКӘНДӘ́Р**, урта гасырлар Шәрекъ фольклоры һәм әдәбияты персонажы; реаль тарихи шәхес — Александр Македонский буларак билгеле. И. образы 11–15 йөзләрдә яшәп иҗат иткән Шәрекъ әдәбияты классиклары Фирдәүси, Низами, Җами, Нәвоиның күп кенә әсәрләрендә урын ала. Төрки-татар фольклорына, болгар һәм татар әдәбиятына әлеге образ Шәрекъ әдәбиятыннан килеп керә. Төрки-татар фольклорында да, Шәрекъ традицияләреннән файдаланып, И.не геройлаштырып бирү дәвам итә. Бу образ б-н бәйле ике сюжет киң таралган: тере су эзләү (татар легендасы «Нократ», татар дастаны «Бүз егет») һәм геройның яшерен мөгезләре булу (казакъ әкияте «Муйизди хан», үзбәк әкияте — «Мугузли Искандар»). Кайвакыт татар фольклорында икенче бер персонаж — *Зөлкарнәйн* дә — Искәндәр исеме б-н бирелә торган була. И. Идел Буе Болгар дәүләтенең кайбер шәһәрләренә нигез салучы буларак та сурәтләнә (10 йөз легендалары); идеаллаштырылган хаким образын гәүдәләндерә. «Китабе Гөлестан бит-төрки» җыентыгында искә алынып китә. Татар әдәбиятында да И. образы идеаллаштырылып бирелә (Х.Кятибнең «Җөмҗөмә солтан», Сәйядинең «Дастаны Бабахан», Мөхәммәдъярның «Төхфә-и мәрдан», Утыз Имәнинең «Мөһиммәтез-заман»).

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы. К., 2000; Исламов Р.Ф. Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се. К., 2001; Бертельс Е.Э. Роман об Александре и его главные версии на Востоке. М.–Л., 1949; Казахская народная поэзия (из образцов, собранных и записанных Н.А.Диваевым). А.-А., 1964; Казахские народные сказки. А.-А., 1971. Т. 2; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. К., 1993.

*Ф.И.Урманчеев.*



М.Җ. Искәндәров.

**ИСКӘНДӘ́РОВ** Габдрахман Идрис улы (15.7.1898, Казан губ., Казан өязе Кече Рәс а. — 9.5.1938, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. 1914–17 елларда И.И.Алафузов ф-касында кисүче була. Гражданнар сугышында катнаша. 1920–23 тә ТАССР Эчке эшләр халык комис-тында бүлек башлыгы, Арча (1923–25) һәм Мамадыш (1926–28) кантоннары башкарма ком-тлары рәисе. 1929–37 дә ТАССР җир эшләре халык комиссары. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

**ИСКӘНДӘ́РОВ** Марс Җамал улы (27.10.1927, Казан — 1.10.2003, С.-Петербург), вице-адмирал (1982), хәрби фәннәр д-ры (1990). М.В.Фрунзе исем. Югары хәрби-диңгез уч-щесен (1949, Ленинград), Хәрби-диңгез академиясен (1965, Ленинград), СССР Кораллы Көчләре Генераль штабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (1971, Мәскәү) тәмамлый. 1949–83 тә — су асты көймәсе штурманы, командиры, су асты көймәләре берләшмәсе штабы башлыгы, командиры, оператив идарә башлыгы — Төньяк флот штабы башлыгы урынбасары. 1983–91 дә СССР Оборона министрлыгының Хәрби диңгез флоты буенча Үзәк фәнни-тикшеренү институты башлыгы. 1992 дән — Россия Дәүләт атом күзәтчелеге аппаратында. Хәрби диңгез флотын мәгълүматлаштыру, атом-төш һәм радиация куркынычсызлыгы мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ИСКӘНДӘ́РОВ** Хәлим Фәттах улы (1888, Уфа губ., Златоуст өязе Арыслан а. — 1958, Казан), журналист. «Рәсүлия» (Троицк ш.), «Галия» (Уфа ш., 1910) мәдрәсәләрен тәмамлый. 1912–14 елларда «Дар әл-мөгаллимин» («Укытучылар йорты», Уфа) мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1926 да Томск пед. техникумында, 1927 дә Мәскәүдә Асадуллаев мәктәбендә эшли, 1929–34 тә Мәскәү Шәрекъ халыклары коммунистик ун-тында татар теле һәм әдәбияты укыта. 1908 дән «Казан мөхбире», «әл-Ислах», «Тормыш», «Ил» г-таларында татар мәктәпләренең, укытучыларның авыр хәле турында, белем бирү системасын үзгәртергә кирәклеге хакында мәкаләләр, татар язучылары әсәрләренә,

«Сәйяр» труппасы тарафыннан куелган спектакльләргә рецензияләр бастыра. 1912 дә И. тарафыннан төзелгән «Белек йорты» хрестоматиясе дөнья күрә, анда татар шагыйрь һәм язучылары әсәрләреннән өзекләр, Идел буе халыклары фольклоры турында, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясыннан мәгълүматлар, астрономия буенча мәкаләләр туплана. Окт. рев-циясеннән соң Уфада «*Ил теле*» г-тасын чыгаруны оештыра, «Кызыл яу» г-тасында (Бөгелмә ш.), «Сәнәк» ж-лында (Уфа) хезмәттәшлек итә. Бөек Ватан сугышы елларында Арча пед. уч-щесендә уку-укыту бүлеге мөдире, рус теле укытучысы була. 1948 дә Совет хөкүмәтенә каршы эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына, 1956 да аклана. 1956–58 елларда Татар укытучылар белемен күтәрү ин-тында рус теле һәм әдәбияты кабинеты методисты.

*Әд.:* Мәһдиев М. Г.Ибраһимов әсәрләрендәге образларның прототиплары // Казан утлары. 1977. № 1; Ахунов А. Новые штрихи к биографии педагога Халима Искандерова // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ИСКӘ́Р**, к. *Кашлык.*

**ИСКЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Тетвел елгасының уң кушылдыгы (Кичү, Чишмә елгалары бассейны). Озынлыгы 10,8 *км*, бассейнының мәйданы 25,1 *км²*. Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Калиновка авылыннан (даими яшәүчеләр юк) 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Тетвел авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 205 *м*, тамагыныкы — 92 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туену модуле 3–5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 69 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. И. ноябрьнең беренче унконлегендә ката. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы чыгымы 0,076 *м³/с*. Суы язын каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ИСКЕ́ АБДУ́Л** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 612 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.да 2 мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2529,90 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 1146, 1897 дә — 1603, 1920 дә — 1934, 1926 да — 1366, 1938 дә — 1232, 1949 да — 769, 1958 дә — 641, 1970 тә — 780, 1979 да — 597, 1989 да — 447, 2002 дә — 494 кеше.

**ИСКЕ́ АВЫ́Л** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 18 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — ТАССРның Чистай кантоны Чулпан волостенда. 1930 ның 10 августыннан Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 126, 1938 дә — 137, 1949 да — 147, 1958 дә — 139, 1970 тә — 171, 1979 да — 120, 1989 да — 63, 2002 дә — 32 кеше.

**ИСКЕ́ АЙМА́Н** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 54 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 301 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аймаково исеме б-н дә билгеле. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.да 2 мәчет (беренчесе — 18 йөздән, икенчесе — 1860 тан), мәктәп, җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2720 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 225, 1834 тә — 592, 1859 да — 929, 1870 тә — 952, 1884 тә — 1322, 1897 дә — 983, 1906 да — 801, 1913 тә — 1056, 1920 дә — 1161, 1926 да — 870, 1938 дә — 823, 1949 да — 611, 1958 дә — 604, 1970 тә — 640, 1979 да — 536, 1989 да — 400, 2002 дә — 366 кеше.

**ИСКЕ́ АЛА́Н**, к. *Иске Ялан.*

**ИСКЕ́ АЛЕКСА́НДРОВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 86 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә И.А. урынында ясаклы татарлар яшәгән Калмыштамак авылы (1732 дән мәгълүм) була. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында авыл халкы Е.И.Пугачёв ягында көрәшә. 1770 елларда Калмыштамак авылы тирәсендәге җирләрне рус алпавытлары Можаровлар сатып ала башлыйлар, 19 йөз башында бу җирләр дүрт бертуган Аристовларның (Александр, Лев, Павел, Пётр) хосусый милкенә әверелә, алар 1820 елларда Казан губернасының Лаеш өязендәге Богородский (Уракчы) авылыннан крепостной крәстияннәрен шунда күчерәләр. 1940 елларга кадәр авыл Аристовларның берсе — Александр исемен йөртә, авылның икенче атамасы — Аристовка (1917 гә кадәр кулланыла) шундагы алпавытларның нәселдән килгән фамилияләреннән алына. Халкы игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, монда җил тегермәне, 20 йөз башында тимерчелек, ашлык саклау-сату кибете, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 721 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1834 тә — 269, 1858 дә — 250, 1870 тә — 334, 1884 тә — 437, 1897 дә — 424, 1906 да — 420, 1913 тә — 446, 1920 дә — 526, 1926 да — 516, 1938 дә — 501, 1949 да — 398, 1958 дә — 272, 1970 тә — 209, 1979 да — 168, 1989 да — 245, 2002 дә — 94 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ АЛПА́Р** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 19 *км* көнчыгыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 385 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1677 елга кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.да 3 мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2449 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 202 ир-ат; 1859 да — 1424, 1897 дә — 2334, 1908 дә — 2279, 1920 дә — 2672, 1926 да — 1927, 1938 дә — 1316, 1949 да — 1210, 1958 дә — 1151, 1970 тә — 1232, 1979 да — 1024, 1989 да — 619, 2002 дә — 440 кеше.

**ИСКЕ́ АРЫ́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 18 *км* төньяктарак, Пановка елгасы буенда. 2008 елда 366 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.та мәчет, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1764 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе,

1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 617, 1897 дә — 903, 1908 дә — 1056, 1920 дә — 1085, 1926 да — 758, 1949 да — 763, 1958 дә — 770, 1970 тә — 769, 1989 да — 444, 2002 дә — 396 кеше.

**ИСКЕ́ АШПАЛА́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 14 *км* көнбатыштарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 33 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1656 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт һәм алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, агач әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.да Покрау чиркәве (1903 тә ачыла), чиркәү-приход мәктәбе, мәчет һәм мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1085 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда. 1920 дән ТАССР-ның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1870 тә — 404, 1897 дә — 614, 1920 дә — 747, 1926 да — 661, 1938 дә — 593, 1949 да — 381, 1958 дә — 237, 1970 тә — 219, 1979 да — 162, 1989 да — 77, 2002 дә — 56 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ АШЫ́Т** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2008 елда 547 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1615–16 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Пустошь Шатуловка исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балта эше, он тарту, курыс һәм кайрыдан әйберләр ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.А.та 2 мәчет, мәктәп, 3 җил һәм су тегермәне, фельдшерлык пункты, йон-тукыма мануһәм бакыр-калайдан әйберләр ясау остаханәләре, 2 кибет була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1995,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 203 ир-ат; 1859 да — 1154, 1897 дә — 1484, 1908 дә — 1490, 1920 дә — 1342, 1926 да — 1258, 1938 дә — 1269, 1949 да — 723, 1958 дә — 734, 1970 тә — 746, 1979 да — 600, 1989 да — 512, 2002 дә — 550 кеше.

**ИСКЕ́ ӘГЪБӘ́З** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 40 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2008 елда 271 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1731 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә мәчет (1809 дан телгә алына), мәктәп (1862 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3368 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 107, 1834 тә — 171, 1859 да — 381, 1870 тә — 456, 1884 тә — 691, 1897 дә — 907, 1906 да — 969, 1913 тә — 1132, 1920 дә — 1034, 1926 да — 953, 1938 дә — 993, 1949 да — 754, 1958 дә — 556, 1970 тә — 627, 1979 да — 506, 1989 да — 349, 2002 дә — 280 кеше.

**ИСКЕ́ ӘЛЕ́М** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 12 *км* көньяктарак, Биҗәды елгасы буенда. 2008 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1738 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында И.Ә.дә 2 мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2243 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 88, 1870 тә — 399, 1884 тә — 479, 1897 дә — 516, 1906 да — 620, 1913 тә — 779, 1920 дә — 821, 1926 да — 616, 1938 дә — 626, 1949 да — 348, 1958 дә — 346, 1970 тә — 477, 1979 да — 377, 1989 да — 274, 2002 дә — 185 кеше.

**ИСКЕ́ ӘЛМӘЛЕ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 670 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер игү. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Чиркәү. 1730 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Калмыково, Старый Климовой Куст исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә Архистратиг Михаил чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), тегермән, вак-төякләр кибете эшли; чәршәмбе саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1687 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кутәмә волостенда. 1920 дән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 732, 1897 дә — 1039, 1908 дә — 1055, 1920 дә — 1256, 1926 да — 858, 1949 да — 814, 1958 дә — 790, 1970 тә — 886, 1979 да — 773, 1989 да — 603, 2002 дә — 597 кеше.

**ИСКЕ́ ӘЛМӘЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чынлы елгасы бассейнында. 2008 елда 439 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Старый Ильмовый Куст исеме б-н билгеле. 1720 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел идарәчелеге карамагында, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, 9 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 945 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1723 тә — 193 ир-ат; 1859 да — 470, 1897 дә — 642, 1913 тә — 942, 1920 дә — 967, 1926 да — 956, 1938 дә — 970, 1949 да — 789, 1958 дә — 1052, 1970 тә — 794, 1979 да — 734, 1989 да — 488, 2002 дә — 446 кеше.

**ИСКЕ́ ӘЛМӘ́Т** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 42 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2008 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ельметьево исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Ә.тә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 260,62 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 44, 1834 тә — 110 ир-ат; 1870 тә — 270, 1913 тә — 628, 1920 дә — 644, 1926 да — 396, 1938 дә — 554, 1949 да — 415, 1958 дә — 371, 1970 тә — 411, 1979 да — 315, 1989 да — 159, 2002 дә — 107 кеше.

**ИСКЕ́ ӘЛМӘ́Т** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 53 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы буенда. 2008 елда 298 кеше (2002 елгы халык саны исәбе буенча, татарлар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Мәдәният йорты, китапханә. 1561 дән йомышлы татар Сөндеков утары буларак билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.тә волость идарәсе урнаша, Александр Невский чиркәве (1897 дә төзелә), 2 мәчет (1815 һәм 1898), 2 мәктәп, земство мәктәбе (1883 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 4 тимерчелек, сыраханә, шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете

эшли; чәршәмбе саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2277 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 116 ир-ат; 1859 да — 1205, 1897 дә — 2101, 1908 дә — 2203, 1920 дә — 2248, 1926 да — 1236, 1938 дә — 589, 1949 да — 485, 1958 дә — 441, 1970 тә — 746, 1979 да — 477, 1989 да — 285, 2002 дә — 349 кеше.

**ИСКЕ́ ӘМЗӘ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 58 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гәрәй елгасы буенда. 2008 елда 208 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1687 елларга кадәр нигез салына. 1920 елгы рәсми чыганакларда Иске Әмзә һәм Иске Рус Әмзәсе авыллары бер авыл — Иске Әмзә авылы буларак теләгә алына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә чиркәү-приход мәктәбе (1900 дә ачыла), тимерчелек, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1655 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 1010, 1897 дә — 1658, 1908 дә — 2031, 1920 дә — 1832, 1926 да — 550, 1938 дә — 518, 1949 да — 395, 1958 дә — 424, 1970 тә — 444, 1979 да — 369, 1989 да — 248, 2002 дә — 247 кеше.

**ИСКЕ́ ӘНӘЛЕ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 2 *км* көньяктарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2008 елда 408 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә мәчет, мәдрәсә, 7 су тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, май язу йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1858 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинский-Шонгат волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 181 ир-ат; 1859 да — 1024, 1897 дә — 1550, 1908 дә — 1612, 1920 дә — 1465, 1926 да — 1017, 1938 дә — 789, 1949 да — 648, 1958 дә — 566, 1970 тә — 579, 1979 да — 530, 1989 да — 393, 2002 дә — 448 кеше.

**ИСКЕ́ ӘНҖЕРӘ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда 260 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1716–17 гә кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1688 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 100 ир-ат; 1859 да — 696, 1897 дә — 1202, 1908 дә — 1503, 1920 дә — 1476, 1926 да — 826, 1938 дә — 584, 1949 да — 492, 1958 дә — 559, 1970 тә — 717, 1979 да — 511, 1989 да — 281, 2002 дә — 284 кеше.

**ИСКЕ́ ӘРӘМӘЛЕ́** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2008 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Лисовка исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.дә тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 972,9 дис. тәшкил итә. 1921 дә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 336, 1887 дә — 426, 1905 тә — 423, 1920 дә — 409, 1926 да — 442, 1938 дә — 342, 1949 да — 245, 1958 дә — 177, 1970 тә — 170, 1979 да — 130, 1989 да — 313, 2002 дә — 35 кеше.

**ИСКЕ́ ӘХМӘ́Т** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 6 *км* төньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 4 кеше (татарлар) яши. 1643 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Әхмәт-Абыз исеме б-н дә билгеле. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ә.тә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2619,80 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт-Муллино волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 88, 1834 тә — 63 ир-ат; 1870 тә — 369, 1920 дә — 262, 1926 да — 252, 1938 дә — 271, 1949 да — 201, 1958 дә — 162, 1970 тә — 139, 1979 да — 65, 1989 да — 7, 2002 дә — 1 кеше.

**ИСКЕ́ БАГРА́Ж** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 55 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 931 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. Мәчет (1880 дә төзелә; архит-ра истәлеге). 17–18 йөзләр арасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Елховый Ключ, Елхово, Мәхмүт, Елхово Озеро, Баграж исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 1841 дә И.Б.да мәчет, тимерчелек, су тегермәне эшли. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша. 2 мәчет, 2 мәдрәсә, тимерчелек, 2 ашлык саклау-сату кибете, 6 мануфактура һәм 6 бакалея кибете була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2698,6 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волосте үзәге, 1918 дән Иске Баграж волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Чистай кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 340, 1795 тә — 400, 1841 дә — 646, 1870 тә — 1082, 1885 тә — 1091, 1897 дә — 1796, 1905 тә — 2131, 1912 дә — 2559, 1920 дә -2443, 1926 да — 1187, 1949 да — 1391, 1958 дә — 1579, 1970 тә — 1540, 1979 да — 1544, 1989 да — 826, 2002 дә — 990 кеше.

**ИСКЕ́ БАЙЛА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак, Тиргәвеш елгасы бассейнында. 2008 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек эше, аркан үрү, агач көрәк ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.да мәчет, мәктәп (1831 дә ачыла), 3 су тегермәне, ашлык кабул итү пункты, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2293 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 257, 1859 да — 763, 1870 тә — 717, 1884 тә — 951, 1897 дә — 547, 1906 да — 587, 1913 тә — 536, 1920 дә — 587, 1926 да — 398, 1938 дә — 425, 1949 да — 379, 1970 тә — 401, 1979 да — 310, 1989 да — 239, 2002 дә — 202 кеше.

**ИСКЕ́ БАЙСА́Р** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөн елгасы буенда. 2008 елда 676 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, он тарту, чабата һәм ит сату б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)*

чорында Е.И.Пугачёв ягында көрәшә. 20 йөз башында И.Б.да волость идарәсе урнаша; 4 мәчет, кыз балалар һәм ир балалар мәктәпләре, икмәк һәм печән кабул итү пунктлары, ашлык саклау-сату кибете була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3878 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 486, 1859 да — 1165, 1870 тә — 807, 1884 тә — 1712, 1897 дә — 1909, 1906 да — 2034, 1913 тә — 2038, 1920 дә — 2169, 1926 да — 1885, 1938 дә — 1198, 1949 да — 752, 1958 дә — 1073, 1970 тә — 1046, 1979 да — 947, 1989 да — 717, 2002 дә — 663 кеше.

**ИСКЕ́ БАЛЛЫКУ́Л** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2008 елда 46 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1710 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түгәрәк Күл, Круг-Озеро, Баллыкүл исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.дә мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1773 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 469, 1908 дә — 1018, 1920 дә — 1060, 1926 да — 536, 1938 дә — 537, 1949 да — 260, 1958 дә — 345, 1970 тә — 297, 1979 да — 224, 1989 да — 92, 2002 дә — 57 кеше.

**ИСКЕ́ БАЛТА́Ч** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 22 *км* көнбатыштарак, Шәбез инеше буенда, 2008 елда 130 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1738 дән мәгълүм. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында көрәшә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Б.та мәчет (1808 дән билгеле), мәктәп, җил һәм 3 су тегермәне эшли. 1913 тә авыл җәмәгатенең имана җире 2369 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип (Такталачык) волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 70, 1859 да — 263, 1870 тә — 471, 1884 тә — 321, 1897 дә — 371, 1906 да — 405, 1913 тә — 451, 1920 дә — 454, 1926 да — 493, 1938 дә — 473, 1949 да — 271, 1958 дә — 294, 1970 тә — 325, 1979 да — 248, 1989 да — 146, 2002 дә — 135 кеше.

**ИСКЕ́ БАРЫ́Ш** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогыннан 46 *км* төньяк-көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2008 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.та волость идарәсе урнаша; 2 мәчет (1882 һәм 1909 да төзелә), мәктәп, ссуда-саклау ширкәте, бөтнек мае һәм балавыз ясау з-длары, тимерчелек, күн эшкәртү остаханәсе, су тегермәне, ярма яргыч, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1363 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 698, 1884 тә — 968, 1897 дә — 1195, 1908 дә — 1395, 1920 дә — 1458, 1926 да — 1000, 1949 да — 641, 1958 дә — 441, 1970 тә — 396, 1979 да — 322, 1989 да — 227, 2002 дә — 231 кеше.

**ИСКЕ́ БИКЧӘНТӘ́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 31 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы бассейнында, 2008 елда 127 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1736 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Биксентеева исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында көрәшә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Б.дә мәчет (1802 дән), мәктәп (1837 дә ачыла), 2 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2196 (1913 тә — 1622) дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1816 да — 97 ир-ат; 1859 да — 596, 1870 тә — 705, 1884 тә — 799, 1897 дә — 631, 1906 да — 739, 1913 тә — 805, 1920 дә — 644, 1926 да — 526, 1938 дә — 492, 1949 да — 336, 1958 дә — 342, 1970 тә — 362, 1979 да — 261, 1989 да — 151, 2002 дә — 148 кеше.

**ИСКЕ́ БОГАДЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Биҗады елгасы буенда. 2008 елда 569 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар (1747 һәм 1762 елгы халык исәбе буенча, типтәрләр дә теркәлгән) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Авылның күп кенә җирләре, урманнар (18 йөз ахыры — 19 йөз башында — 10300 дис.), балык тоту биләмәләре башка авыл крәстияннәренә арендага бирелеп тора. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Б.да мәчет (1836 дан мәгълүм), мәктәп (1853 тә ачыла), су тегермәне эшли. 1911 дә 2 мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3972 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 67, 1834 тә — 200, 1859 да — 461, 1870 тә — 684, 1884 тә — 635, 1897 дә — 802, 1906 да — 957, 1913 тә — 1150, 1920 дә — 1147, 1926 да — 904, 1938 дә — 566, 1949 да — 490, 1958 дә — 438, 1970 тә — 552, 1979 да — 960, 1989 да — 698, 2002 дә — 660 кеше.

**ИСКЕ́ БОРЫНДЫ́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2008 елда 108 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 52%, руслар — 43%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май з-ды. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче чирегендә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835 тә Удел идарәчелегенә күчерелә һәм 1860 елларга кадәр аның карамагында була. Игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.та волость идарәсе урнаша. Никола чиркәве (1873–77 дә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 мәктәп (Халык мәгариф министрлыгы һәм чиркәү-приход мәктәпләре), тегермән, 17 сәүдә-сәнәгать оешмасы була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2577,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 744, 1859 да — 754, 1897 дә — 1897, 1913 тә — 1650, 1920 дә — 1643, 1926 да — 1509, 1938 дә — 1190, 1949 да — 908, 1958 дә — 684, 1970 тә — 656, 1979 да — 234, 1989 да — 134, 2002 дә — 127 кеше.

**ИСКЕ́ БУА́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасыннан 2 *км* ераклыкта. 2008 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Буинка, Иске Корбаш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Б.да вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгате-

нең имана җире 434,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1921–22 дә Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 116, 1897 дә — 121, 1908 дә — 345, 1920 дә — 329, 1926 да — 269, 1938 дә — 309, 1949 да — 219, 1958 дә — 226, 1970 тә — 102, 1979 да — 93, 1989 да — 56, 2002 дә — 29 кеше.

**ИСКЕ́ БҮСЕРӘ́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бүсерәк елгасы буенда. 2008 елда 85 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөз башында нигез салына. Беренче исеме — Түбән Бүсерәк. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, тәгәрмәч, мичәү ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 545 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә; 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 247, 1920 дә — 454, 1926 да — 507, 1938 дә — 543, 1949 да — 554, 1958 дә — 435, 1970 тә — 288, 1979 да — 192, 1989 да — 101, 2002 дә — 98 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ИСКЕ́ ВАРВА́РИНКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 75 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы Вятка суының югары агымы буенда. 2008 елда 1 кеше яши. 1830 да Пенза губернасының Арбищево авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1857 елгы мәгълүматларга караганда, И.В.да ат һәм аракы з-длары була. 20 йөз башында земство мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 695 дис. һәм аренда җире 1028 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варваринка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 27 октябреннән — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 244, 1883 тә — 357, 1889 да — 430, 1900 дә — 483, 1910 да — 571, 1920 дә — 689, 1926 да — 840, 1938 дә — 627, 1949 да — 412, 1958 дә — 413, 1970 тә — 237, 1979 да — 100, 1989 да — 18, 2002 дә — 3 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИСКЕ́ ВӘРӘ́Ш** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 6 *км* төньяктарак, Вәрәш елгасы буенда. 2008 елда 386 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Беренче исеме — Зур Бәрәш. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.В.тә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 738,85 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирек волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1834 тә — 50 ир-ат; 1870 тә — 230, 1920 дә — 505, 1926 да — 497, 1938 дә — 524, 1949 да — 561, 1958 дә — 493, 1970 тә — 540, 1979 да — 485, 1989 да -438, 2002 дә — 378 кеше.

**ИСКЕ́ ГӘРДӘЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 17 *км* көнчыгыштарак, Шилнә елгасы бассейнында. 2008 елда 176 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1713 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Г.дә мәчет, мәктәп эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 847,6 дис. була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарьев волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 423, 1897 дә — 725, 1920 дә — 1000, 1926 да — 592, 1938 дә — 567, 1949 да — 493, 1958 дә — 435, 1970 тә — 498, 1979 да — 332, 1989 да — 222, 2002 дә — 159 кеше.

**ИСКЕ́ ДИН ТАРАФДАРЛЫГЫ́**, Россиядәге Рус Православие чиркәвендә чиркәү йолалары реформалауга каршы протест буларак 17 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килгән дини-иҗтимагый хәрәкәт. Чиркәү идарәсен үзәкләштерү чиркәү йолаларындагы җирле аермалыкларны бетерү максатында һәм кайбер тышкы сәяси вазгыять шартларында патша Алексей Михайлович булышлыгы б-н патриарх Никон тарафыннан уздырыла. 1654 елдагы соборда гыйбадәт китапларын Константинополь православие чиркәве үрнәгендә бердәй нормага китерү, ш.у. күп кенә йолаларны, гыйбадәт кылу тәрләрен үзгәртү турында карар кабул ителә. Иске дин тарафдарлары хәрәкәте җитәкчеләре протопоплар Иоанн Неронов, Логгин, Даниил, Аввакум (1682 дә җәзалап үтерелләр) һәм епископ Павел Коломенский (1654 тә үлем җәзасына дучар ителә) өч бармак (ике бармак урынына) б-н чукынуны, Гайсә исемен Иисус (Исус урынына) дип атауны, чукынганда, никахлашканда, тәре күтәреп барганда кояш әйләнешенә каршы хәрәкәт итүне (кояш әйләнүе — сәгать йөреше уңаена хәрәкәт итү), Инану символының 8 нче пунктын формалаштырудагы үзгәрешләрне («Хак һәм яшәү көче бирүче Ходайның Изге Рухына», — дигән беренчел варианттан «хак» сүзе төшереп калдырыла); «аллилуя»ны өч (ике урынына) тапкыр әйтүне, биш просфора белән гыйбадәт кылуны (җиде урынына) һ.б. яңалыкларны кире кагалар. 1656, 1666 һәм 1667 дә булып узган соборларда барлык үзгәрешләр раслана, ә яңалыкларга каршы килүчеләр җәзага тартыла, дәүләт һәм чиркәү тарафыннан җәберләүләргә дучар ителә. Иске дин тарафдарлары дәүләтнең төньяк, көнчыгыш, көньяк чикләренә, чит илләргә качарга мәҗбүр булалар. Соңрак И.д.т. төп рухани үзәкләре оеша: Керженец (Түбән Новгород губ.), Стародубье (Чернигов губ.), Ветка (Польша), Ыргыз (Саратов губ.), Рогожское зираты (Мәскәү) һ.б. Казан губернасында иске дин тарафдарлары һәр җирдә очрыйлар, алар Казан, Зөя өязләрендә тупланып яшиләр. 18 йөздә И.д.т. ике төп агымга — Рус православие чиркәвеннән И.д.т.на күчкән, руханиларны үз агына авыштырган поплылар һәм руханилары булмаган попсызлар агымнарына бүленәләр. Поплылар 1846 да митрополит Амвросий җитәкчелегендәге Белокриница иерархиясен оештыралар (Белая Криница ш., Австрия-Венгрия империясе, хәзерге Украина терр-ясе). 1853 тә Мәскәү иске дин тарафдарлары архиепископлыгы төзелә. 1856 да Рус православие иске дин тарафдарларының *Казан-Вятка рус православиесенең иске дин тарафдарлары чиркәве епархиясе* оештырыла. Поплыларның иерархия кабул итмәгән бер өлеше Рус православие чиркәвеннән И.д.т.на күчкән руханиларны үз якларына тартуны дәвам итәләр. Алар качак поплылар дип атала башлыйлар, 1923 тә Рус борынгы православие чиркәвен оештыралар, аңа архиепископ Николай (Позднев) нигез сала. Соңгы руханилары үлеп беткәннән соң, попсызларның чукындыру һәм тәүбә йолаларын җәмәгатьчелек тарафыннан сайлап куелган остазлар (уставчылар һәм хәреф ятлаучылар) башкарырга керешә. И.д.т.ның бу юнәлешенә күп кенә дини агымнар охшаш, мәс., Федосеев, Данилов агымнары, кәшәнәлеләр һ.б. 1905 тә император Николай II нең «Диннәр тигезлеген тану башлангычларын ныгыту» турындагы Фәрманы басылганнан соң, И.д.т. җәмгыятьләре гражданлык һәм дини хокукларга ия булалар. 1988 дә Рус православие иске дин тарафдарлыгы чиркәве (поплылар) митрополит Алимпий (Гусев) җитәкчелегендәге метрополия итеп үзгәртелә. 2004 тә митрополит булып Казан-Вятка епархиясе епископы Андриан (Четвергов), 2005 тә Корнилий (Титов) сайлана. 1971 дә Рус православие чиркәвенең Поместный соборында И.д.т.н диннән сөрү бетерелә. 2008 дә ТРда 5 И.д.т. чиркәве эшли (3 се — поплылар һәм 2 се — попсызлар).

*Әд.:* Каптерев Н.Ф. Патриарх Никон и его противники в деле исправления церковных обрядов. М., 1913; Мельников Ф.Е. Краткая история древнеправославной (старообрядской) церкви. Барнаул, 1999; Верхний Услон: Край родной, навек любимый ... . К., 2001; Зеньковский С.А. Русское старообрядчество: В 2 т. М., 2006; Свобода совести в поликонфессиональном обществе. К., 2008.

**ИСКЕ́ ДӨРЕ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы — Сарман автомобиль юлы буенда. 2008 елда 336 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1721 елга кадәр нигез салына, Беренче исеме — Дөреш. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Д.тә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 785,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 625, 1926 да — 391, 1938 дә — 475, 1949 да — 400, 1958 — дә — 380, 1970 тә — 393, 1979 да — 338, 1989 да — 337, 2002 дә — 382 кеше.

**ИСКЕ́ ДУВА́Н** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2008 елда 250 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында йомышлы чуашлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Дрожжаной Куст исеме б-н дә билгеле. 1724 тә халкы — дәүләт, 1840 елларда удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Д.да Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, 8 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1074,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 274, 1897 дә — 342, 1913 тә — 575, 1920 дә — 517, 1926 да — 562, 1938 дә — 590, 1949 да — 563, 1958 дә — 437, 1970 тә — 431, 1979 да — 168, 1989 да — 298, 2002 дә — 265 кеше.

**ИСКЕ́ ҖИРЕКЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәләкәс елгасы буенда. 2008 елда 808 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1795 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Җирекле-Мәләкәс исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Җирекле-Мәләкәстә җил тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 751,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 391, 1913 тә — 473, 1920 дә — 452, 1926 да — 334, 1938 дә — 437, 1949 да — 334, 1958 дә — 351, 1970 тә — 321, 1979 да — 263, 1989 да — 135, 2002 дә — 370 кеше.

**ИСКЕ́ ҖИЯ́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 18 *км* көнбатыштарак, Шәбез инеше буенда. 2008 елда 184 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1738 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында халкы Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Җ.тә мәчет (1816 дан билгеле), мәктәп, 4 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1844 (1913 тә — 4377) дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип (Такталачык) волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 234, 1859 да — 548, 1870 тә — 585, 1884 тә — 652, 1897 дә — 697, 1906 да — 662, 1913 тә — 767, 1920 дә — 740, 1926 да — 662, 1938 дә — 560, 1949 да — 404, 1958 дә — 365, 1970 тә — 368, 1979 да — 340, 1989 да — 215, 2002 дә — 189 кеше.

**ИСКЕ́ ҖОГЫ́П** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 27 *км* төньяктарак, Шашы елгасы буенда. 2008 елда 155 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 16 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Җ.та мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 544 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) өязе Кышлау волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 260, 1897 дә — 523, 1908 дә — 553, 1920 дә — 514, 1926 да — 554, 1938 дә — 427, 1949 да — 185, 1958 дә — 274, 1970 тә — 218, 1979 да — 186, 1989 да — 169, 2002 дә — 143 кеше.

**ИСКЕ́ ҖӨЛБИ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 26 *км* көнбатыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2008 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Җ.дә мәчет, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 670,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир-ат; 1859 да — 400, 1897 дә — 435, 1908 дә — 490, 1920 дә — 416, 1926 да — 470, 1938 дә — 390, 1949 да — 243, 1958 дә — 173, 1970 тә — 125, 1979 да — 117, 1989 да — 72, 2002 дә — 89 кеше.

**ИСКЕ́ ҖӨРИ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 400 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, бүрек-кием тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Җ.дә мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1319 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән- Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 506, 1897 дә — 663, 1908 дә — 713, 1920 дә — 791, 1926 да — 710, 1938 дә — 845, 1949 да — 624, 1970 дә — 530, 1979 да — 443, 1989 да — 355, 2002 дә — 383 кеше.

**ИСКЕ́ ЗАВО́Д** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2008 елда 89 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле-кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 19 йөздә нигез салына. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.З.та мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 600 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостена керә. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1897 дә — 183, 1908 дә — 212, 1920 дә — 285, 1926 да — 301, 1938 дә — 351, 1949 да — 267, 1958 дә — 215, 1970 тә — 271, 1979 да — 212, 1989 да — 119, 2002 дә — 88 кеше.

**ИСКЕ́ ЗАДУ́Р** авылы, Чүпрәле районында, Иске Чүпрәле авылыннан 5 *км* көнчыгыштарак, Чынлы елгасы бассейнында. 2008 елда 83 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен башкара, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.З.да мәчет, мәдрәсә, 6 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1418,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930

ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1850 дә — 692, 1897 дә — 990, 1913 тә — 1399, 1920 дә — 1255, 1926 да — 971, 1938 дә — 1366, 1949 да — 912, 1958 дә — 496, 1970 тә — 470, 1979 да — 360, 1989 да — 155, 2002 дә — 116 кеше.

**ИСКЕ́ ИБРА́Й** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 2003 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.да 4 мәчет, 2 мәдрәсә, 2 су тегермәне, 3 ярма яргыч, тимерчелек, йон тетү йорты, 14 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4428 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 216 ир-ат; 1859 да — 3003, 1897 дә — 3342, 1908 дә — 3790, 1920 дә — 3860, 1926 да — 2833, 1938 дә — 2365, 1949 да — 2500, 1958 дә — 2618, 1970 тә — 2916, 1979 да — 2916, 1989 да — 2087, 2002 дә — 1198 кеше.

**ИСКЕ́ ИВАНА́ЕВО** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 17 *км* көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы буенда. 2008 елда 142 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 17–18 йөзләр арасында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.да волость идарәсе урнаша, этап йорты була; Вознесение чиркәве, земство мәктәбе (1875 тә ачыла), 7 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2710,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванаево волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 488, 1897 дә — 870, 1908 дә — 1320, 1920 дә — 1300, 1926 да — 1187, 1938 дә — 723, 1949 да — 475, 1958 дә — 374, 1970 тә — 283, 1979 да — 172, 1989 да — 129, 2002 дә — 140 кеше.

**ИСКЕ́ ИГЛА́Й** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 12 *км* көнчыгыштарак, Кондырча елгасы буенда. 2008 елда 125 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. 1920 гә кадәр — Самара губернасының Самара өязе Шонталы волостена, 1920 дән ТАССРның Чистай кантоны Иске Чаллы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 354, 1938 дә — 306, 1949 да — 267, 1958 дә — 248, 1970 тә — 311, 1979 да — 191, 1989 да — 109, 2002 дә — 120 кеше.

**ИСКЕ́ ИКШЕРМӘ́** (Югары Өчнарат) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 508 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Өчнарат, Көек исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.дә Никола чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1892 дә ачыла), су тегермәне, йон-тукыма ману остаханәсе, 2 сыраханә, казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли; чәршәмбе саен базар була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2421 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 814, 1897 дә — 1064, 1908 дә — 911, 1920 дә — 1041, 1926 да — 943, 1938 дә — 717, 1959 да — 505, 1970 тә — 736, 1979 да — 720, 1989 да — 577, 2002 дә — 537 кеше.

**ИСКЕ́ ИЛТЕРӘ́К** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 604 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17–18 йөзләр арасында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.тә укый-язарга өйрәтү мәктәбе, 3 су тегермәне, 2 тимерчелек, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3605 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 177 ир-ат; 1859 да — 1678, 1897 дә — 1596, 1908 дә — 1626, 1920 дә — 1645, 1926 да — 1449, 1938 дә — 1393, 1949 да — 929, 1958 дә — 978, 1970 тә — 1102, 1979 да — 945, 1989 да — 657, 2002 дә — 582 кеше.

**ИСКЕ́ ИМӘ́Н** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Саклаусу бассейнында урнашкан. 2008 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1735 кә кадәр нигез салына. Беренче исеме — Иманово. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кутузас исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3799,02 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 27 октябреннән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 437, 1870 тә — 968, 1920 дә — 1232, 1926 да -975, 1938 дә — 808, 1949 да — 425, 1958 дә — 419, 1970 тә — 464, 1979 да — 340, 1989 да — 244, 2002 дә — 272 кеше.

**ИСКЕ́ ИРКӘНӘ́Ш** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2008 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, таш чыгару һәм эшкәртү б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында И.И.тә мәчет (1820 дән мәгълүм), мәктәп, тимерчелек, су тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2126 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе — Пучы, 1918–19 да Әтрәкле волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 90, 1859 да — 346, 1870 тә — 434, 1884 тә — 360, 1897 дә — 703, 1906 да — 720, 1913 тә — 762, 1920 дә — 720, 1926 да — 696, 1938 дә — 531, 1949 да — 457, 1958 дә — 354, 1970 тә — 400, 1979 да — 436, 1989 да — 319, 2002 дә — 265 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ ИСА́КОВО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 423 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 55%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Лисьи Горы исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 230 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 176, 1889 да — 129, 1897 дә — 188, 1910 да — 280, 1920 дә — 187, 1926 да — 58, 1938 дә — 218, 1949 да — 195,

1958 дә — 124, 1970 тә — 166, 1979 да — 212, 1989 да — 425, 2002 дә — 424 кеше.

**ИСКЕ́ ИШЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасы (Суранын уң кушылдыгы) бассейнында. 2008 елда 312 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1665–67 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; лашманлыкта эшли. 20 йөз башында И.И.дә мәчет, мәдрәсә, 5 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1378,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мунча волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 627, 1897 дә — 817, 1913 тә — 1001, 1920 дә — 1050, 1926 да — 998, 1938 дә — 1331, 1949 да — 939, 1958 дә — 814, 1970 тә — 913, 1979 да — 598, 1989 да — 339, 2002 дә — 334 кеше.

**ИСКЕ́ ИШТИРӘ́К** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 37 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 519 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Көнчыгыш Кама арьягында хәрәкәт итүче баш күтәрүчеләр отрядлары б-н И.И.тә туып үскән А.*Уразмәтов* җитәкчелек итә. 20 йөз башында 3 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3038 дис. тәшкил итә. 1909 да И.И. тә җәдиди мәдрәсә, 1915 тә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 451, 1889 да — 1289, 1897 дә — 1369, 1910 да — 1638, 1920 дә — 1887, 1926 да — 1584, 1938 дә — 1053, 1949 да — 830, 1958 дә — 805, 1970 тә — 721, 1979 да — 781, 1989 да — 545, 2002 дә — 524 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИСКЕ́ ИЯБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2008 дә — 221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән Ияббаш авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Ияббаш, Яваш исемнәре б-н дә йөртелә. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез-баш киеме тегү, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.И.та мәчет, җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 626,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 июленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 300, 1897 дә — 487, 1908 дә — 488, 1920 дә — 467, 1926 да — 441, 1938 дә — 406, 1949 да — 348, 1958 дә — 289, 1970 тә — 312, 1979 да — 270, 1989 да — 223, 2002 дә — 232 кеше.

**ИСКЕ́ ЙОМРАЛЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасы бассейнында. 2008 елда 376 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 га кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Й.да мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1636,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 706, 1897 дә — 1376, 1908 дә — 1601, 1920 дә — 1554, 1926 да — 1110, 1938 дә — 1171, 1949 да — 852, 1958 дә — 740, 1970 тә — 752, 1979 да — 658, 1989 да — 479, 2002 дә — 417 кеше.

**ИСКЕ́ ЙОРТ** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Иске Йорт елгасы буенда. 2008 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1602–03 еллардан Епанчино исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Селищи авылы буларак билгеле. 1930 еллардан хәзерге исемен йөртә. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И. Й.та мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 948,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 330, 1897 дә — 494, 1908 дә — 518, 1920 дә — 473, 1926 да — 421, 1938 дә — 446, 1949 да — 310, 1958 дә — 253, 1970 тә — 169, 1979 да — 120, 1989 да — 105, 2002 дә — 123 кеше.

**ИСКЕ́ ЙОРТ** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2008 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Йолгыш исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман кисү, балта эше, йон тетү, бау ишү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И. Й.та мәчет, җил тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 717 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 309, 1897 дә — 484, 1908 дә — 599, 1920 дә — 632, 1926 да — 615, 1938 дә — 593, 1949 да — 411, 1958 дә — 403, 1970 тә — 358, 1979 да — 305, 1989 да — 201, 2002 дә — 182 кеше.

**ИСКЕ́ ЙОРТ** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2008 елда 120 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И. Й.та мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 935 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Селәнгеш волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 333, 1897 дә — 594, 1908 дә — 560, 1920 дә — 693, 1926 да — 700, 1949 да — 423, 1958 дә — 441, 1970 тә — 402, 1979 да — 360, 1989 да — 174, 2002 дә — 142 кеше.

**ИСКЕ́ ЙОРТ** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бирәзә елгасының уң кушылдыгы (Казансу елгасы бассейны). Озынлыгы 6,6 *км*, бассейнының мәйданы 26,3 *км*$^2$. Арча р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Иске Йорт авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Югары Бирәзә авылы янында. Елга башының абс. биеклеге — 163 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 134 *мм*, ташу вакытында агым катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. И. октябрь ахыры – ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,045 *м*$^3$*/с*. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм язын бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада гомуми күләме 1 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Суы сугару өчен файдаланыла.

**ИСКЕ́ КАДЕРМӘ́Т** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Терпеле елгасы буенда.

2008 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөз ахырында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә мәчет (1808 дән мәгълүм), мәктәп (1857 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1110 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1859 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 56, 1834 тә — 371, 1859 да — 461, 1870 тә — 546, 1884 тә — 659, 1897 дә — 743, 1906 да — 830, 1913 тә — 733, 1920 дә — 571, 1926 да — 497, 1938 дә — 582, 1949 да — 381, 1958 дә — 374, 1970 тә — 406, 1979 да — 346, 1989 да — 180, 2002 дә — 164 кеше.

**ИСКЕ́ КАДИ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы (Олы Сөлчәнең уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 602 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1701 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Утыз Имән исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да 3 мәчет, мәдрәсә, мануфактура һәм 5 вак-төякләр кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2854,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 1169, 1897 дә — 1980, 1908 дә — 2063, 1920 дә — 2278, 1926 да — 1540, 1949 да — 1106, 1958 дә — 1203, 1970 тә — 1416, 1979 да — 1232, 1989 да — 804, 2002 дә — 708 кеше.

**ИСКЕ́ КАЕНСА́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 16 *км* көньяктарак, Оча елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 118 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1719 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Каенсар-Оча исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 771,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны:







**Иске Казан тарих-мәдәнияткәм табигать музей-саклаулыгы мәкаләсенә.** 1. Керәч сәнгате. Бер тоткалы бизәкле савытлар. Идел буе Болгар дәүләте. 12–13 йөзләр; 2. Тимер эшләнмәләр: ыргак, кадак, борау, келә тимере; чүкеч. Идел буе Болгар дәүләте. 13–14 йөзләр; 3. Хуҗалык кирәк-яраклары. Агач. 18 йөз; 4. Чулпылар. Көмеш, асылташлар. 18–19 йөзләр; 5. Бакырдан ясалган көнкүреш кирәк-яраклары. 19 йөз.

1782 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 207, 1897 дә — 243, 1908 дә — 260, 1920 дә — 272, 1926 да — 256, 1949 да — 265, 1958 дә — 255, 1970 тә — 283, 1979 да — 197, 1989 да — 130, 2002 дә — 143 кеше.

**ИСКЕ́ КАЗА́Н**, 13–16 йөзләрдә Казансу елгасы буендагы болгар-татар шәһәре. 13–14 йөзләрдә Казан артының эре сәяси һәм икътисади үзәкләренең берсе. Рус гаскәрләренең 1376 һәм 1399 еллардагы яуларыннан соң элекке әһәмиятен югалта. Казан ханлыгы чорында (15–16 йөзләр) феодаль биләмә үзәге. Җангали хан 1535 тә сөрелгән урын. 1552 дә рус гаскәрләре тарафыннан җимерелә. 18 йөз татар язма әдәбиятында И.К.га бертуганнар *Алтынбәк* б-н *Галимбәк* нигез салган дигән риваятьләр китерелә. *Рус Урматы авыллыгы* һәм *Камай шәһәрлеге* И.К.ның археол. калдыклары дип уйланыла. Ш.у.к. *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы.*

*Әд.:* М а л о в П. Городище Старая Казань и город Арск // Зап. Археол. об-ва. 1853. Т. 5; Х о м я к о в М.М. Где была Старая Казань // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1911. Т. 27, вып. 6; К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ 1945–1952. К., 1954; Ю с у п о в Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**ИСКЕ́ КАЗА́Н ТАРИ́Х-МӘДӘНИЯ́Т ҺӘМ ТАБИГА́ТЬ МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫГЫ́**, ТР МКның 1992 елның 14 февралендә кабул ителгән «Татарстан Республикасының Биектау районында Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгын оештыру турында»гы карары б-н *Болгар тарих-архитектура саклаулыгы* нигезендә оештырыла. Мәйданы — 137,2 *га*. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверләренә караган археол. истәлекләрне, ш.и. *Камай шәһәрлеген, Рус Урматы авыллыгын*, Рус Урматы һәм Камай авыллары янындагы 13–16 йөзләргә нисбәтле кабер ташлары сакланган зиратларны, Камайдагы тарих-этнография музеен (1163 саклау берәмлеге); Казансу елгасының су басмый торган сөзәк яр буйларын, күлләре булган болыннарны, елга тамагын үз эченә алган таби-

гать ландшафтын; Гайшәбикә кабере, «Изге Муллахаҗи чишмәсе», «Хан чишмәсе» кизләүләреннән гыйбарәт изге урыннарны берләштерә. Музей-саклаулык ТР Мәдәният министрлыгы карамагында. Татарстанның татар халкы тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү, саклау һәм пропагандалау б-н шөгыльләнүче фәнни-тикшеренү һәм фәнни-агарту үзәкләренең берсе. Музей-саклаулык терр-ясендәге истәлекләр 18 йөздән башлап өйрәнелә.

*Әд.:* Изучение, охрана, реставрация и использование памятников истории и культуры в Республике Татарстан: Информ. сб. К., 2001. Вып. 2–3.

*И.М.Нестеренко.*

**ИСКЕ́ КАЗА́Н ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Камай шәһәрлеге*.

**ИСКЕ́ КАЗА́НКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зәй елгасы (Дала Зәенең уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 128 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 77%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 19 йөз ахырында нигез салына. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 2808 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1910 да — 583, 1920 дә — 595 (Яңа Казанка авылын да кертеп), 1926 да — 280, 1938 дә — 289, 1949 да — 313, 1958 дә — 121, 1970 тә — 157, 1979 да — 179, 1989 да — 161, 2002 дә — 155 кеше.

**ИСКЕ́ КАЗИЛЕ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 42 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кыярмәт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 184 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.дә 2 мәчет (1879 һәм 1900 дә төзелә), мәдрәсә, мәктәп, су тегермәне, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1106,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда. 1920 дән — ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 103 ир-ат; 1859 да — 511, 1884 тә — 806, 1897 дә — 1103, 1908 дә — 1294, 1920 дә — 1114, 1926 да — 755, 1938 дә — 634, 1949 да — 503, 1958 дә — 484, 1970 тә — 431, 1979 да — 322, 1989 да — 232, 2002 дә — 239 кеше.

**ИСКЕ́ КА́МА АРЪЯГЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасы буенда. 2008 елда 14 кеше (руслар, татарлар) яши. 1924 тә нигез салына; торак пункт буларак, 1959 да теркәлә. Оештырылган көннән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 301, 1979 да — 180, 1989 да — 84, 2002 дә — 27 кеше.

**ИСКЕ́ КАМКА́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 266 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1649 га кадәр нигез салына. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысына кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да 2 мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1556 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 988, 1897 дә — 1471, 1908 дә — 1579, 1920 дә — 1762, 1926 да — 1115, 1938 дә — 813, 1949 да — 576, 1958 дә — 390, 1970 тә — 593, 1979 да — 459, 1989 да — 380, 2002 дә — 301 кеше.

**ИСКЕ́ КАРАБАЯ́Н** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нырсы елгасыннан 1 *км* читтә. 2008 елда 96 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1680 нән Починок Коробян исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Колбагушево буларак та билгеле. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да земство мәктәбе (1867 дә ачыла), су һәм җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 556,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 266, 1897 дә — 403, 1908 дә — 601, 1920 дә — 658, 1926 да — 576, 1938 дә — 445, 1949 да — 347, 1970 тә — 398, 1979 да — 301, 1989 да — 175, 2002 дә — 101 кеше.

**ИСКЕ́ КАРАЗИРЕ́К** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бәйрәкә елгасы буенда. 2008 елда 497 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 18 йөз – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә 2 мәчет була; шимбә саен базар эшли, ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3844 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай (Баулы), 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1859 да — 559, 1889 да — 1664, 1897 дә — 1275, 1910 да — 1109, 1920 дә — 1369, 1926 да — 1096, 1938 дә — 1020, 1949 да — 797, 1958 дә — 610, 1970 тә — 749, 1979 да — 533, 1989 да — 413, 2002 дә — 509 кеше.

**ИСКЕ́ КАРАМАЛЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 25 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2008 елда 736 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек; «Промсервис» ҖЧҖ. Мәдәният йорты, китапханә. 1735 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Карамалы, Калмыя исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.К.да мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 316,79 дис. тәшкил итә. 1920 кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1795 тә — 51, 1816 да — 50 ир-ат; 1859 да — 243, 1870 тә — 351, 1913 тә — 847, 1920 дә — 891, 1926 да — 861, 1938 дә — 714, 1949 да — 672, 1958 дә — 705, 1970 тә — 852, 1979 да — 887, 1989 да — 821, 2002 дә — 747 кеше.

**ИСКЕ́ КАРАТА́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 13 *км* көньяктарак, Ата елгасы буенда. 2008 елда 247 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рус чыганакларында 1920 еллар уртасына кадәр — Хурада, рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Иштубай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да Козьмодемьянск чиркәве, земство мәктәбе, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2708 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 139 ир-ат; 1859 да — 665, 1897 дә — 1256, 1908 дә — 1493, 1920 дә — 1252, 1926 да — 942, 1938 дә — 595, 1949 да — 518, 1958 дә — 521, 1970 тә — 500, 1979 да — 399, 1989 да — 299, 2002 дә — 271 кеше.

**ИСКЕ́ КАРМӘ́Т** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан

8 *км* төньяктарак, Кармәт елгасы буенда. 2008 елда 463 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 55%, чуашлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә мәчет, мәдрәсә, 6 җил тегермәне, 4 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1529 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 978, 1897 дә — 1128, 1908 дә — 1340, 1920 дә — 1439, 1926 да — 1267, 1938 дә — 1598, 1949 да — 939, 1958 дә — 841, 1970 тә — 1231, 1979 да — 895, 1989 да — 456, 2002 дә — 495 кеше. И.К. — шагыйрь Х.*Туфанның* туган авылы (музее бар).

**ИСКЕ́ КӘКЕРЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 16 *км* төньяктарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2008 елда 1216 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Кирпеч з-ды, урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1665–67 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, лашманлыкта эшли. 20 йөз башында И.К.дә 4 мәчет, 3 мәдрәсә, 25 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2079,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Яңа Кәкерле волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1084, 1897 дә — 1552, 1913 һәм 1920 дә — 2204, 1926 да — 2551, 1938 дә — 2445, 1949 да — 1307, 1958 дә — 2402, 1970 тә — 2707, 1979 да — 2474, 1989 да — 1625, 2002 дә — 1240 кеше.

**ИСКЕ́ КӘШЕ́Р** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 12 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы Камышлы бассейнында урнашкан. 2008 елда 477 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты китапханә. 1680 нән Кәшер авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кәшер-Камышлы исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.дә волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, 3 кибет була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1437 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1859 да — 345, 1870 тә — 684, 1897 дә -1051, 1920 дә — 1372, 1926 да — 775, 1938 дә — 736, 1949 да — 467, 1958 дә — 574, 1970 тә — 642, 1979 да — 567, 1989 да — 485, 2002 дә — 457 кеше.

**ИСКЕ́ КЕНӘ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 14 *км* көньяктарак, Вятка бассейнындагы Кенә елгасы буенда. 2008 елда 218 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Кенә исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К. дә чиркәү-приход мәктәбе, тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 703 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 194, 1897 дә — 323, 1908 дә — 335, 1920 дә — 341, 1926 да — 352, 1938 дә — 332, 1949 да — 290, 1958 дә — 298, 1970 тә — 335, 1979 да — 340, 1989 да — 241, 2002 дә — 219 кеше.

**ИСКЕ́ КЕНӘ-ЮМЬЯ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 337 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1306 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда. 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир-ат; 1859 да — 297, 1897 дә — 480, 1908 дә — 535, 1920 дә — 518, 1926 да — 521, 1938 дә — 512, 1949 да — 510, 1958 дә — 452, 1970 тә — 530, 1979 да — 426, 1989 да — 392, 2002 дә — 355 кеше.

**ИСКЕ́ КЕНӘ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ашыт елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2008 елда 164 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1678 дән Кенәр авылы буларак билгеле. 1920 гә кадәрге рәсми рус чыганакларында Шинер-Кинер исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү, урман кисү, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.дә мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире (Мәмсә елгасы буендагы авылны да кертеп) 4122,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 190 ир-ат; 1859 да — 371, 1897 тә — 476, 1908 дә — 636, 192 дә — 472, 1926 да — 445, 1938 дә — 439, 1949 да — 294, 1958 дә — 261, 1970 тә — 300, 1979 да — 243, 1989 да — 163, 2002 дә — 171 кеше.

**ИСКЕ́ КИШЕ́Т** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симет елгасы буенда. 2008 елда 428 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорына кадәр үк нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, агач материаллары әзерләү, он тарту, вак-төякләр сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә 2 мәчет, мәктәп, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2004,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 172 ир-ат; 1859 да — 980, 1897 дә — 1196, 1908 дә — 1421, 1920 дә — 1215, 1926 да — 1075, 1938 дә — 707, 1949 да — 713, 1958 дә — 515, 1970 тә — 556, 1979 да — 469, 1989 да — 390, 2002 дә — 438 кеше. И.К. янында кабер ташлары язмалары — 14 йөз — 16 йөзнең 1 нче яртысына караган эпиграфик истәлекләр сакланган.

**ИСКЕ́ КОЛМӘ́Т** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тархан елгасы буенда. 2008 елда 15 кеше (руслар) яши. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Глинки исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә 4 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 168,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 114, 1897 дә — 185, 1913 тә — 272, 1920 дә — 243, 1926 да — 250, 1938 дә — 232, 1949 да — 162, 1958 дә — 158, 1970 тә — 75, 1979 да — 69, 1989 да — 30, 2002 дә — 17 кеше.

**ИСКЕ́ КОМАЗА́Н** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мамадыш — Кукмара автомобиль юлы буенда. 2008 елда 478 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр-

чылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да 2 мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1585,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында, 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 165 ир-ат; 1859 да — 965, 1897 дә — 1287, 1908 дә — 1579, 1920 дә — 1512, 1926 да — 1367, 1938 дә — 1211, 1949 да — 910, 1958 дә — 859, 1970 тә — 936, 1979 да — 804, 1989 да — 672, 2002 дә — 516 кеше.

**ИСКЕ́ КОРМА́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 25 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2008 елда 452 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, сарык тиресе иләү, калач пешерү б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында И.К.та мәчет (1813 тән мәгълүм), мәктәп (1859 да ачыла), печән кабул итү пункты, ашлык саклау амбары, 12 кибет була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2093 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1859 да — 662, 1870 тә — 741, 1897 дә — 973, 1920 дә — 1138, 1926 да — 1069, 1938 дә — 1012, 1949 да — 676, 1958 дә — 650, 1970 тә — 797, 1979 да — 688, 1989 да — 491, 2002 дә — 459 кеше.

**ИСКЕ́ КОТЫ́Ш** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 29 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 557 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, мордвалар — 58%, руслар — 41%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.та волость идарәсе урнаша; Рождественский чиркәве, земство мәктәбе (1872 дә ачыла), фельдшерлык пункты, волость банкы, су һәм җил тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, май язу йорты, 2 сыраханә, казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4374,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 278 ир-ат; 1859 да — 1283, 1897 дә — 2368, 1908 дә — 2498, 1920 дә — 2796, 1926 да — 2424, 1949 да — 1351, 1958 дә — 1361, 1970 тә — 1399, 1979 да — 1055, 1989 да — 695, 2002 дә — 651 кеше.

**ИСКЕ́ КОЩА́КОВО**, к. *Кощаково* (Питрәч р-ны).

**ИСКЕ́ КӨЛКӘ́Ш**, к. *Көлкәш* (Апас р-ны).

**ИСКЕ́ КӨШКӘ́Т** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач поселогыннан 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Көшкәт елгасы буенда. 2008 елда 187 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән Көшкәт елгасы буендагы Починок буларак билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басып сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.тә су тегермәне, Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1894 тә ачыла), бакалея һәм шәраб кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2379,60 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 154, 1763 тә — 81, 1811 дә — 184 ир-ат; 1859 да — 648, 1884 тә — 663, 1897 дә — 536, 1905 тә — 752, 1920 дә — 928, 1926 да — 829, 1938 дә — 1000, 1949 да — 654, 1958 дә — 464, 1970 тә — 458, 1979 да — 443, 1989 да — 208, 2002 дә — 214 кеше.

**ИСКЕ́ КУА́К** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 52 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 1022 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 еллар ахырында Польшаның вак дворяннар нәселеннән чыккан кешеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; тирә-як татар авыллары крәстияннәренә арендага җир биреп тора. 1900 елгы мәгълүматларга караганда, И.К.та полиция урәтнигe, урманчы һәм ветеринария белгече фатирлары урнаша; Покрау чиркәве, земство (1883 тә ачыла) һәм чиркәү-приход мәктәпләре, авырулар кабул итү пункты (табиб, фельдшер һәм акушер кабул итә), халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек оешмасы, май з-ды, чәйханә, 2 су тегермәне була; пәнҗешәмбе саен базар, ярминкә (1–4 окт.) эшли. 1910 елда Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, ссуда бирү-саклык кассасы ширкәте идарәсе, 2 хәрби хезмәткә алу участогы ачыла; 3 нче су тегермәне төзелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 8368 дис. тәшкил итә. 1910–15 елларда чиркәүнең яңа бинасы төзелә (хәзергә кадәр сакланган; архит-ра истәлеге). 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1762 дә — 1073, 1795 тә — 1410 (Яңа Куак авылын да кертеп), 1859 да — 994, 1889 да — 1541, 1897 дә — 1838, 1900 дә — 1849, 1910 да — 1886, 1920 дә — 2236, 1926 да — 1997, 1938 дә — 1687, 1949 да — 1168, 1958 дә — 1064, 1970 тә — 1092, 1979 да — 1137, 1989 да — 1014, 2002 дә — 1024 кеше. И.К.та Сов. Союзы Геройлары И.А.*Заварыкин* һәм В.И.*Яницкийлар* туган.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИСКЕ́ КУ́ЙБЫШЕВ КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Болгар шәһәре янында урнашкан. Комплекс терр-ясенең зур өлеше Куйбышев сусаклагычы астында кала. И.К.к. истәлекләре С.М.Шпилевский, В.Обрезков (19 йөзнең 2 нче яртысы), Н.Ф.Калинин (1940–50 еллар), А.Х.Халиков, Р.С.Габәшев, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин, М.М.Кавиев, И.Л.Измайлов һ.б. (20 йөзнең 2 нче яртысы — 21 йөз башы) тарафыннан тикшерелә. Таш һәм бронза гасырларга караган туктаулыклар һәм торулыклар калдыкларын, Имәнкискә, Болгар һ.б. археол. культураларга нисбәтле шәһәрлекләрне, авыллыкларны һәм каберлекләрне үз эченә ала. Болгар шәһәрлегендә агач диварлар һәм манаралар, торак корылмалары һәм һөнәрчелек остаханәләре калдыклары табыла. Идел буе Болгар дәүләте чорында аның тирәсендә Бизнәнең ике яры буйлап эре болгар авыллары туплана. Аларның терр-ясендә һөнәрчелек эшләнмәләре (V авыллыкта — бакыр казаннар, IV авыллыкта — ихтимал, сату өчен әзерләнгән әйберләр) калдыклары, читтән китерелгән әйберләр табыла. И.К.к. истәлекләре терр-ясендә чакматаштан эшләнгән әйберләр, балчык савыт-саба ватыклары, сөяк әйберләр, кием де-



Идел болгарларының бронза йозаклары. 11–12 йөзләр.

тальләре, төсле металлдан һәм пыяладан ясалган бизәмәләр табып алына.

*Әд.:* Обрезков А. Следы древнего поселения в окрестностях г.Спасска Казанской губернии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 2; Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР 1945–1952 гг. К., 1954; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986; Казаков Е.П. Булгарское село X–XIII веков низовий Камы. К., 1991.

*Е.П.Казаков.*

**ИСКЕ́ КУЛАТКЫ́ РАЙОНЫ́**, РФдә. *Ульянов өлкәсенең* көньягында урнашкан. 1943 елга кадәр — Урта Идел, 1943 нең 19 гыйнварыннан Ульянов өлкәсенә керә. Мәйданы — 1178 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Иске Кулаткы посёлогы (Ульянов шәһәреннән 230 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 17505 (2002), ш.и. татарлар — 16342 (1979 да — 20954, 1989 да — 18270) кеше. И.К.р. терр-ясендә татарлар 17 йөз ахыры — 18 йөз башында күренә башлый. Темников, Сембер, Казаннан күчеп килгән морзаларга һәм йомышлы татарларга монда Пётр I указы б-н җирләр бирелә. 1917 дә И.К.р. терр-ясендә 71 мәчет, 45 мәктәп һәм мәдрәсә (иң атаклысы Зимницы авылындагы Хансәяровлар мәдрәсәсе), 6 земство мәктәбе эшли. Хәзерге вакытта районның 18 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 5 татар үзешчән коллективы: халык драма театры, «Гөлшаян» төркеме, «Лира» вокаль төркеме, «Йолдызчык» балалар бию коллективы, Г.Н.Алтынбаева җитәкчелегендә бию коллективы эшли. Район китапханәләре татар телендә вакытлы матбугат («Мәгариф», «Сөембикә», «Ялкын», «Салават күпере» ж-лларын, «Өмет», «Юлдаш», «Гаилә учагы». «Күмәк көч» г-таларын) алдыра, аларда «Кулаткым минем, туган ягым, синдәй гүзәл бармы тагын?» дигән китап күргәзмәләре даими үткәрелә. 1996 дан «Яңа дулкын» җирле телеканалы эшли. Татар халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында 19 клуб учреждениесе, балалар сәнгать мәктәбе, Х.А.Әбләзев исем. тарих-туган якны өйрәнү музее эшли. Районда татар халкының тарихы һәм мәдәнияте б-н бәйле чаралар: «Сабантуй» һәм «Нәүрүз» бәйрәмнәре, «Туган ягым — мәхәббәтем минем» фестивале, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия фольклор коллективлары фестивале үткәрелә. 2005 тән «Хансәяров укулары» фәнни-практик конференциясе (суфи, шәех Х.Хансәяров истәлегенә) уздырыла. 25 мәчет, ш.и. 5 се — район үзәгендә. Сов. Союзы Геройлары: М.И.*Аипов*, Н.Н.*Нугаев*, В.С.*Хәбиев*, З.С.*Хөсәенов*, Соц. Хезмәт Герое Т.К.Рәшитова, дәүләт эшлеклесе Г.А.*Әбдерәззаков*, икътисадчы К.И.*Азизов*, техник фән. д-ры Э.А.Ганиев, җырчы Р.З.*Ильясов*, биол. фән. д-ры Р.Х.Насыйров, тарих фән. д-рлары Р.Г.*Әмирханов*, Ф.А.*Рәшитов*, М.З.*Тутаев*, икътисад фән. д-ры А.В.Улюкаев, социолог Н.С.*Фәтхуллин*, пед. фән. д-ры Я.И.*Ханбиков*, психол. фән. д-ры Р.М.Шамионовларның тормышы һәм эшчәнлекләре И.К.р. б-н бәйле.

*Әд.:* Сафин И. Меңнәрнең остазы — ишан Хәбибулла Хансәяров. Самара, 2005; Из этнической истории Ульяновской области: Сб. Ульяновск, 1993; Насыров Х.А. История Старокулаткинского района Ульяновской области, Ульяновск, 2002.

**ИСКЕ́ КҮКЛЕ́К** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнбатыштарак, Күклек елгасы буенда. 2008 елда 332 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, марилар — 61%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1719 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Күклек исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1074,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 229, 1887 дә — 308, 1905 тә — 373, 1920 дә — 420, 1926 да — 442, 1938 дә — 481, 1949 да — 370, 1958 дә — 364, 1970 тә — 388, 1979 да — 386, 1989 да — 484, 2002 дә — 412 кеше.

**ИСКЕ́ КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасы буенда. 2008 елда 35 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 16 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы игенчелек, терлекчелек, капчык-чыпта сугу, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да мәчет, мәктәп (1809 дан мәгълүм) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1172,6 дис. тәшкил итә. 1905 тә мәчет имамы булып шагыйрь Д.Г.*Гобәйди* эшли, ул мәчет каршында мәдрәсә ача, анда үзе укыта. Авыл 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1744 тә — 94 ир-ат; 1887 дә — 450, 1905 тә — 535, 1920 дә — 676, 1926 да — 382, 1938 дә — 346, 1958 дә — 151, 1970 тә — 120, 1989 да — 33, 2002 дә — 40 кеше.

**ИСКЕ́ КЫРЛА́Й** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 12 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2008 елда 330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз башына кадәр Хохлово авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да 2 мәчет, су тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1158,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 555, 1897 дә — 684, 1908 дә — 674, 1920 дә — 763, 1926 да — 669, 1938 дә — 574, 1949 да — 464, 1958 дә — 457, 1970 тә — 465, 1979 да — 384, 1989 да — 247, 2002 дә — 332 кеше.

**ИСКЕ́ КЫЯЗЛЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 1038 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (элек өченче җамигъ мәчет, 1907 дә төзелә; архит-ра истәлеге). 1697 ел тирәсендә нигез салына. Башта Ишмәт (Ишметьево) дип атала. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.К.да 3 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, тукымалар сату һәм 11 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3398 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 1430, 1897 дә — 2425, 1908 дә — 2518, 1922 дә — 2300, 1926 да — 1707, 1949 да — 928, 1958 дә — 1143, 1970 тә — 1516, 1979 да — 1300, 1989 да — 1055, 2002 дә — 1038 кеше.

**ИСКЕ́ ЛАШЧЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 21 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 1 *км* читтәрәк. 2008 елда 306 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Л.да мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 605,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черкен-Килдураз волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 349, 1897 дә — 614, 1908 дә — 759, 1920 дә — 658, 1926 да — 627, 1938 дә — 561, 1949 да — 378, 1958 дә — 367, 1970 тә — 398, 1979 да — 368, 1989 да — 300, 2002 дә — 325 кеше.

**ИСКЕ́ МА́ВРИНО** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 29 *км* көньяктарак, Чикмән елгасы буенда. 2008 елда 309 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 17 йөз ахыры — 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, аркан ишү, чабата үрү, арба, мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да земство мәктәбе (1911 дә ачы-

ла) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1670 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 июленнән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 417, 1897 дә — 833, 1913 тә — 959, 1920 дә — 945, 1926 да — 896, 1938 дә — 649, 1949 да — 514, 1958 дә — 484, 1970 тә — 436, 1979 да — 224, 1989 да — 272, 2002 дә — 300 кеше.

**ИСКЕ́ МАҖЫ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Мажын елгасы буенда. 2008 елда 380 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 84%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1703 тән Умъядка исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, агач материаллары әзерләү б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында эшли. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында И.М. Е.И.Пугачёв отрядларының туплану урыны була. 20 йөз башында Вознесение чиркәве (1906 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, балалар яслесе, тимерчелек, кабак, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3106 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 287, 1859 да — 773, 1870 тә — 875, 1884 тә — 1141, 1897 дә — 1444, 1906 да — 1468, 1913 тә — 1856, 1920 дә — 1753, 1926 да — 1567, 1938 дә — 842, 1949 да — 532, 1958 дә — 448, 1970 тә — 680, 1979 да — 514, 1989 да — 373, 2002 дә — 386 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ МАСРА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2008 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Масра исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, баш киеме һ.б. әйберләр тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да мәчет, су тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1447,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 135 ир-ат; 1859 да — 675, 1897 дә — 694, 1908 дә — 813, 1920 да — 989, 1926 да — 848, 1938 дә — 688, 1949 да — 495, 1958 дә — 459, 1970 тә — 335, 1979 да — 313, 1989 да — 208, 2002 дә — 191 кеше.

**ИСКЕ́ МАТА́К** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2008 елда 388 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1670 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский, Урта Матак исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.та Рождество-Христово чиркәве, земство мәктәбе, су һәм 8 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 3 тимерчелек, 2 йон тетү йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2432 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 733, 1908 дә — 1538, 1920 дә — 1573, 1926 да — 1248, 1938 дә — 929, 1949 да — 707, 1958 дә — 650, 1970 тә — 670, 1979 да — 586, 1989 да — 456, 2002 дә — 396 кеше.

**ИСКЕ́ МАТВЕ́ЕВКА** (Кәҗә) авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2008 елда 348 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 66%, руслар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә И.М. авылы урынында Кәҗә (Коза) исемле татар авылы (1735 тән мәгълүм) була. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында авыл халкы Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 1780 елларда рус алпавытлары Матвей һәм Никита Можаровлар Кәҗә авылы тирәсендәге җирләргә рус крәстияннәрен китереп утыртa. Матвеевка һәм Троицкий исемнәре б-н беррәттән, авылның элеккеге атамасы (ул тора-бара Козино дип үзгәртелә) рәсми чыганакларда 1917 гә кадәр кулланыла. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда су тегермәне, 2 кирпеч з-ды, 1885 тә 3 крахмал һәм 2 патока з-ды эшли. 20 йөз башында Матвеевкада волость идарәсе урнаша, Троица чиркәве (1804 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1885 елларда ачыла), земство мәктәбе (1912 дән), 2 су тегермәне, тимерчелек, 2 икмәк саклау-сату кибете, кабак, 6 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2443 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. 1944 нең 19 февраленнән Матвеевка р-ны үзәге, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 57, 1811 дә — 86, 1816 да — 242 ир-ат; 1858 дә — 586, 1870 тә — 995, 1897 дә — 1085, 1906 да — 1175, 1913 тә — 1290, 1920 дә — 1465, 1926 да — 1279, 1938 дә — 1311, 1949 да — 1249, 1959 да — 676, 1970 тә — 657, 1979 да — 498, 1989 да — 353, 2002 дә — 374 кеше. И.М.да Сов. Союзы Герое генерал-полковник В.Н.*Гордов* туган, монда язучы Р.*Солнцевның* балачак һәм үсмер еллары уза.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ МӘҢГӘ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак, Симет елгасы буенда. 2008 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.дә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, «китайка» тукымасы җитештерү ф-касы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1050,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 641, 1908 дә — 749, 1920 дә — 568, 1926 да — 649, 1938 дә — 645, 1949 да — 453, 1958 дә — 325, 1970 тә — 328, 1979 да — 290, 1989 да — 241, 2002 дә — 259 кеше. И.М. тирәсендә 16 йөзнең эпиграфик истәлекләре — кабер ташларындагы язмалар сакланган.

**ИСКЕ́ МӘРТЛӘ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 21 *км* көньяктарак урнашкан. 2008 елда 282 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1665–67 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чапы Горы исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче чирегендә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 1835 тә Удел идарәчелегенә күчерелә һәм аның карамагында 1860 елларга кадәр була. Игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.дә Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе, 6 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1046 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 254, 1897 дә — 501, 1913 тә — 724, 1920 дә — 752, 1926 да — 812, 1938 дә — 733, 1949 да — 698, 1958 дә — 637, 1970 тә — 665, 1979 да — 654, 1989 да — 373, 2002 дә — 315 кеше.

**ИСКЕ́ МИНЗӘЛӘБА́Ш** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 22 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 742 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыга-

накларда Бикбулатово исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.та 3 мәчет, 3 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2995,55 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1824 тә — 309 ир-ат; 1897 дә — 1766, 1920 дә — 2167, 1926 да — 1371, 1938 дә — 1522, 1949 да — 1136, 1958 дә — 1040, 1970 тә — 1212, 1979 да — 1041, 1989 да — 723, 2002 дә — 734 кеше.

**ИСКЕ́ МИХА́ЙЛОВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Салкынсу елгасы буенда. 2008 елда 263 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 65%, руслар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1794 ел тирәсендә майор И.К.Пасмуров нигез сала. Беренче булып монда Мәскәү губернасының Поварово авылыннан китерелгән крепостной крәстияннәр (51 кеше) килеп урнаша, 1800 дә аларга Кострома губернасының Половчиново авылыннан 116 кеше кушыла. Халык игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, мичкә ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да кәшәнә, земство мәктәбе (1876 да ачыла), су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 220 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт р-нында. Халык саны: 1800 дә — 54, 1816 да — 166, 1834 тә — 240, 1858 дә — 276, 1870 тә — 317, 1884 тә — 409, 1897 дә — 376, 1912 дә — 445, 1920 дә — 510, 1926 да — 540, 1938 дә — 321, 1949 да — 530, 1958 дә — 324, 1970 тә — 223, 1979 да — 155, 1989 да — 166, 2002 дә — 205 кеше.

**ИСКЕ́ МИЧӘ́Н** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2008 елда 255 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1613 елдан Мисен исеме б-н мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.дә мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 833,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 310, 1897 дә — 442, 1908 дә — 568, 1920 дә — 589, 1926 да — 526, 1938 дә — 472, 1949 да — 381, 1970 тә — 367, 1979 да — 287, 1989 да — 247, 2002 дә — 247 кеше.

**ИСКЕ́ МОЧА́ЛКИНО** (Мунчала Күле, Шәдче Башы) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 70 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мунчала Күле исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире (Яңа Мочалкино авылын да кертеп) 450,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 282 (Яңа Мочалкино авылын да кертеп), 1897 дә — 268, 1908 дә — 679 (Яңа Мочалкино авылы б-н бергә), 1920 дә — 309, 1949 да — 252, 1958 дә — 320, 1970 тә — 319, 1979 да — 245, 1989 да — 141, 2002 дә — 73 кеше.

**ИСКЕ́ МУЙ** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2008 елда 138 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1616 дан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 елларда Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 203, 1897 дә — 361, 1908 дә — 408, 1920 дән — 437, 1926 да — 381, 1970 тә — 205, 1979 да — 165, 1989 да — 141, 2002 дә — 126 кеше.

**ИСКЕ́ МУКШЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 21 *км* көньяктарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 480 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 68%, руслар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Агролицей, клуб, китапханә бар. 1697 дә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да Троица чиркәве, земство мәктәбе (1870 елларда ачыла), тегермән, казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2563 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 222 ир-ат; 1859 да — 883, 1897 дә — 1379, 1908 дә — 1591, 1920 дә — 1793, 1926 да — 1345, 1938 дә — 1112, 1949 да — 931, 1958 дә — 772, 1970 тә — 850, 1979 да — 755, 1989 да — 523, 2002 дә — 512 кеше.

**ИСКЕ́ МУ́ЛЛИНО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 62 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 122 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1691 гә кадәр нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.М.да чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 728 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда. 1920 дән ТАССРның — Спас, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 161 ир-ат (Татар Мулла Иле авылын да кертеп); 1859 да — 398, 1897 дә — 673, 1908 дә — 665, 1920 дә — 629, 1926 да — 515, 1938 дә — 562, 1949 да — 412, 1958 дә — 245, 1970 тә — 244, 1979 да — 330, 1989 да — 161, 2002 дә — 143 кеше.

**ИСКЕ́ МУНЧА́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2008 елда 29 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1739 елдан мәгълүм. Беренче исеме — Синтәк. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үреп сату, олаучылык б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында авыл халкы Е.И.Пугачёв ягында сугыша. И.М.да православие диненә күчкәннәрнең бер өлеше 19 йөз ахырында ислам диненә кире кайта. 1884 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне эшли; авыл җәмәгатенең имана җире 997 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Маҗын волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 91, 1859 да — 253, 1870 дә — 301, 1906 дә — 441, 1920 дә — 437, 1926 да — 423, 1938 дә — 292, 1949 да — 142, 1958 дә — 116, 1970 тә — 119, 1979 да — 102, 1989 да — 41, 2002 дә — 36 кеше.

**ИСКЕ́ МУРЗИ́ХА** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2008 елда 121 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле —

мөгезле эре терлек, сарык асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 291 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 131, 1887 дә — 279, 1905 тә — 478, 1920 дә — 447, 1926 да — 525, 1938 дә — 460, 1949 да — 249, 1958 дә — 191, 1970 тә — 113, 1979 да — 70, 1989 да — 36, 2002 дә — 115 кеше.

**ИСКЕ́ НИКО́ЛЬСКИЙ** посёлогы, Әгерже р-нында, Әгерже шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Бәрклә̆т елгасы бассейнында. 2008 елда 1 кеше (рус) яши. 1872 дә нигез салына. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Яңа Кочек волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерже, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерже, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1920 дә — 106, 1926 да — 121, 1938 дә — 150, 1958 дә — 72, 1970 тә — 39, 1989 да — 14, 2002 дә — 1 кеше.

**ИСКЕ́ НОХРА́Т** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 4 *км* көнбатыштарак, Нохрат елгасы буенда. 2008 елда 4 кеше (руслар) яши. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Н.та укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1890 да ачыла), 2 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1033 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 125 ир-ат; 1859 да — 437, 1908 дә — 651, 1920 дә — 571, 1926 да — 402, 1938 дә — 359, 1949 да — 364, 1958 дә — 176, 1970 тә — 91, 1979 да — 48, 1989 да — 20, 2002 дә — 12 кеше. И.Н. янында *Иске Нохрат комплексы* урнашкан.

**ИСКЕ́ НОХРА́Т КОМПЛЕКСЫ́** (археол.), Актай елгасы бассейнында Нохрат инеше буенда, Әлки р-нының Иске Нохрат авылы янында урнашкан. Беренче тапкыр И.Н.к. истәлекләрен 1877 елда С.М.Шпилевский, соңрак төбәкне өйрәнүчеләр В.Е.Бетьковский, В.В.Егерев (1910–11), археолог А.П.Смирнов тасвирлыйлар. И.Н.к.нда археол. тикшеренүләр 1946 да — Н.Ф.Калинин, 1975 тә — Р.Г.Фәхретдинов, 1990 да — Ф.Ш.Хуҗин, И.Л.Измайлов, 2005 тә А.Ә.Борһанов тарафыннан уздырыла. Болгар һәм Алтын Урда археол. культурасына нисбәтле ике шәһәрлекне һәм Болгар археол. культурасына караган (10–14 йөзләр) 3 авыллыкны үз эченә ала. Комплекс терр-ясендә һөнәрчелек эшчәнлеге һәм халыкара сәүдә эзләре, болгарлар дәверендә алтыннан һәм көмештән эшләнгән зәргәрчелек әйберләре хәзинәләре табыла. Археологлар фаразлавынча, Идел Болгары чорында шәһәрлек урынында эре шәһәр — аерым бер төбәкнең сәяси һәм хуҗалык үзәге урнашкан.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Б е т ь к о в с к и й В.Е. Село Матаки // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии. 1880. Т. 3; К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ КФАН СССР за 1945–1952 гг. К., 1954. Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Х у з и н Ф.Ш., И з м а й л о в И.Л. Археологические разведки в Западном Закамье // Археологические открытия Урала и Поволжья. Ижевск, 1991.

*И.Л.Измайлов.*

**ИСКЕ́ ОЧА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көньяктарак, Оча елгасы буенда. 2008 елда 243 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 18 йөздә И.О. тирәсендә бакыр руднигы эшли. 20 йөз башында авылда 11 тимерчелек, 2 су тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1107 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавловск волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 296, 1897 дә — 536, 1908 дә — 559, 1920 дә — 622, 1926 да — 631, 1949 да — 480, 1958 дә — 409, 1970 тә — 492, 1979 да — 414, 1989 да — 278, 2002 дә — 279 кеше.

**ИСКЕ́ ӨҖЕ́М** авылы, Этнә р-нында, Олы Этнә авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2008 елда 195 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ө.дә мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Яңа Өҗем авылын да кертеп) 1855 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) өязе Кышлау волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Этнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 1177, 1897 дә — 968, 1908 дә — 1541, 1920 дә — 913, 1926 да — 865, 1938 дә — 737, 1949 да — 455, 1958 дә — 364, 1970 тә — 328, 1979 да — 261, 1989 да — 204, 2002 дә — 201 кеше (1859 һәм 1908 елгы мәгълүматлар Яңа Өҗем авылын да кертеп бирелә). И.Ө. тирәсендә 16–17 йөзләр эпиграфик истәлекләре — кабер ташлары сакланган.

**ИСКЕ́ ПӘЛЧЕКӘ́Ү** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасы буенда. 2008 елда 54 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 17 йөз ахыры — 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Лебяжье, Николаевский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре һәм ирекле игенчеләргә бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мичкә ясау, тимерчелек һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында көрәшә. 20 йөз башында И.П.дә Никола чиркәве (1745 тә төзелә; башка чыганакларда — 1794 ел), земство мәктәбе (1875 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 657 дис. тәшкил итә. Гражданнар сугышы елларында җирле крәстияннәрнең бер өлеше *«Сәнәкчеләр» фетнәсендә* (1920) катнаша. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Токмак волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 261 ир-ат; 1897 дә — 603, 1913 тә — 804, 1920 дә — 901, 1926 да — 642, 1938 дә — 615, 1949 да — 462, 1958 дә — 346, 1970 тә — 218, 1979 да — 113, 1989 да — 60, 2002 дә — 60 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ИСКЕ́ ПИСМӘ́Н** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2008 елда 719 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 62%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авылга 1738 дә отставкадагы солдатлар нигез сала. 1820 елларда алар дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.П.дә чиркәү, земство (1842 дә ачыла) һәм чиркәү-приход мәктәпләре, 4 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5800 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1746 да — 711, 1859 да — 1677, 1889 да — 2365, 1897 дә — 2369, 1910 да — 1948, 1920 дә — 2641, 1926 да — 2051, 1938 дә — 1311, 1949 да — 950, 1958 дә — 768, 1970 тә — 791, 1979 да — 638, 1989 да — 622, 2002 дә — 674 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИСКЕ́ ПРИ́СТАНЬ** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 4 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы яры буенда. 2008 елда 1760 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 73%, татарлар — 24%) яши. Елга судноларына хезмәт күрсәтүче «Агрохимсервис» АҖ бар. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1930 елларда нигез салына. Авыл төзелгән көннән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 43, 1949 да — 184, 1970 тә — 747, 1979 да — 855, 1989 да — 1480, 2002 дә — 1761 кеше.

**ИСКЕ́ ПУКШИНЕ́Р** (Ушла) авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 38 *км* төньяктарак, Кубыр елгасы буенда. 2008 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ошлан исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1050,63 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 227, 1884 тә — 346, 1905 тә — 416, 1920 дә — 417, 1926 да — 416, 1938 дә — 255, 1949 да — 208, 1958 дә — 163, 1970 тә — 117, 1979 да — 83, 1989 да — 49, 2002 дә — 52 кеше.

**ИСКЕ́ РӘҖӘ́П** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 87 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе чигендә. 2008 елда 892 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1699 елдан мәгълүм. Беренче исеме — Бәрән, 1958 гә кадәр — Иске Бәрән. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү, тимерчелек, арба тәгәрмәчләре ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Р.тә 7 мәчет, 3 мәдрәсә, 12 тегермән, пар тегермәне, 8 ярма яргыч, 17 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5310,25 дис. тәшкил итә. 1914 тә рус-татар земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда. 1920 дән ТАССР Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 420 ир-ат; 1859 да — 2352, 1897 дә — 3754, 1908 дә — 4823, 1920 дә — 4634, 1926 да — 2789, 1938 дә — 2213, 1949 да — 1768, 1958 дә — 2093, 1970 тә — 2329, 1979 да — 1871, 1989 да — 1251, 2002 дә — 976 кеше.

**ИСКЕ́ РОМА́Н** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2008 елда 638 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1645 кә кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысына кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Р.да 3 мәчет, мәдрәсә, 9 бакалея һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3394 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 1330, 1897 дә — 2089, 1908 дә — 2356, 1920 дә — 2311, 1926 да — 1881, 1938 дә — 1803, 1949 да — 1044, 1958 дә — 842, 1970 тә — 801, 1979 да — 707, 1989 да — 636, 2002 дә — 645 кеше.

**ИСКЕ́ РУС МӘМӘТХУҖАСЫ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 173 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан татар авылы буларак билгеле, 17 йөзнең 2 нче яртысында рус крәстияннәре килеп урнаша. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Мәмәтхуҗа, Иске Мәмәтхуҗа исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт (алар арасында кенәз Баратаевлар да була) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Р.М.нда чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 886 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташкабак волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 222 ир-ат; 1859 да — 602, 1897 дә — 633, 1908 дә — 742, 1920 дә — 762, 1926 да — 827, 1938 дә — 618, 1949 да — 534, 1958 дә — 482, 1970 тә — 225, 1979 да — 250, 1989 да — 190, 2002 дә — 205 кеше.

**ИСКЕ́ САЛАВЫ́Ч** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 8 *км* көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2008 елда 986 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.та мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1226,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 17 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 527, 1884 тә — 554, 1905 тә — 672, 1920 дә — 698, 1926 да — 645, 1938 дә — 558, 1949 да — 506, 1958 дә — 429, 1970 тә — 1020, 1979 да — 997, 1989 да — 827, 2002 дә — 998 кеше.

**ИСКЕ́ САЛМА́Н** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 17 *км* көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2008 елда 509 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз уртасына кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон-тукыма ману һәм он тарту б-н шөгыльләнә. Реформадан соң И.С. авылы *Татар крәстияннәре кузгалышлары* (1878–1879) үзәге була. 20 йөз башында И.С.да 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 5 җил тегермәне, кирпеч з-ды, тимерчелек, 4 йон-тукыма ману остаханәсе, ярма яргыч, 2 тукымалар һәм 7 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2716 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир-ат; 1859 да — 988, 1908 дә — 1864, 1920 дә — 1825, 1926 да — 1032, 1938 дә — 1214, 1949 да — 999, 1958 дә — 993, 1970 тә — 1178, 1979 да — 901, 1989 да — 599, 2002 дә — 534 кеше.

**ИСКЕ́ САУРЫ́Ш** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Саурыш елгасы буенда. 2008 елда 474 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Саурыш елгасы буендагы Авыл буларак та билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.та чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), 5 тегермән, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1886 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 216, 1897 дә — 280, 1908 дә — 389, 1920 дә — 843, 1926 да — 653, 1938 дә — 751, 1949 да — 540, 1958 дә — 525, 1970 тә — 730, 1979 да — 709, 1989 да — 511, 2002 дә — 481 кеше.

**ИСКЕ́ СӘЕ́Т** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 38 *км* төньяк-көнчыгышта-

рак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 90 кеше яши. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сәет авылы дип телгә алына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.С.тә мәчет һәм мәктәп була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1202,18 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 128 ир-ат; 1834 тә — 316, 1859 да — 605, 1870 тә — 700, 1897 дә — 887, 1913 тә — 638, 1920 дә — 688, 1926 да — 358, 1938 дә — 466, 1949 да — 298, 1958 дә — 262, 1970 тә — 256, 1979 да — 228, 1989 да — 132, 2002 дә — 93 кеше.

**ИСКЕ́ СӘФӘ́Р** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Терпеле елгасы буенда. 2008 елда 927 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәчләр ясау, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.С.дә 2 мәчет, 4 мәктәп, 2 су һәм 4 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6166 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 499, 1834 тә — 544, 1859 да — 931, 1870 тә — 1083, 1884 тә — 1422, 1897 дә — 1772, 1906 да — 1852, 1913 тә — 1869, 1920 дә — 1911, 1926 да — 1558, 1938 дә — 1549, 1949 да — 1119, 1958 дә — 1059, 1970 тә — 1361, 1979 да — 1243, 1989 да — 904, 2002 дә — 877 кеше.

**ИСКЕ́ СЕРЁЖКИНО** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе чигендә. 2008 елда 109 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Киве-Шерушкеял исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.да чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Яңа Серёжкино авылын да кертеп) 2458 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Карамалысы волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1939 ның 22 июленнән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 210, 1889 да — 337, 1910 да — 369, 1920 дә — 369, 1926 да — 347, 1938 дә — 363, 1949 да — 369, 1958 дә — 345, 1970 тә — 414, 1979 да — 294, 1989 да — 161, 2002 дә — 121 кеше.

**ИСКЕ́ СМЫ́ЛОВКА** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Республикасы б-н чиктәш. 2008 елда 26 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1712–13 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Смысловка исеме б-н дә билгеле. 1860 ка кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, күн итек тегү, чабата үрү һәм чана ясау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 631,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 203, 1897 дә — 563, 1920 дә — 338, 1926 да — 280, 1938 дә — 277, 1949 да — 205, 1958 дә — 109, 1970 тә — 107, 1979 да — 67, 1989 да — 45, 2002 дә — 42 кеше.

**ИСКЕ́ СОЛТАНГӨ́Л** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Биҗады елгасы бассейнында. 2008 елда 141 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.да 2 мәчет, мәктәп (1865 тә ачыла), почта станциясе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1962 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 164, 1834 тә — 364, 1859 да — 550, 1870 тә — 588, 1884 тә — 741, 1897 дә — 751, 1906 да — 955, 1913 тә — 1060, 1920 дә — 939, 1926 да — 776, 1938 дә — 568, 1949 да — 398, 1958 дә — 336, 1970 тә — 392, 1979 да — 334, 1989 да — 201, 2002 дә — 163 кеше.

**ИСКЕ́ СУМАРО́КОВО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зәй елгасы (Дала Зәенең уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2008 елда 723 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Гулёнка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.да земство мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1345 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 609, 1889 да — 800, 1897 дә — 805, 1910 да — 805, 1920 дә — 821, 1926 да — 874, 1938 дә — 425, 1949 да — 379, 1958 дә — 297, 1970 тә — 206, 1979 да — 202, 1989 да — 399, 2002 дә — 677 кеше.

**ИСКЕ́ СУ́РКИНО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куак елгасы бассейнында. 2008 елда 840 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Суркино Батрак исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон тетү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.С.да волость идарәсе урнаша; кредитлау ширкәте, чиркәү-приход мәктәбе, 4 су тегермәне, 2 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2085 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Ивановкасы волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 79, 1834 тә — 382, 1859 да — 494, 1883 тә — 618, 1889 да — 780, 1897 дә — 949, 1910 да — 1058, 1916 да — 1039, 1920 дә — 918, 1926 да — 984, 1938 дә — 1012, 1949 да — 1005, 1958 дә — 1150, 1970 тә — 1135, 1979 да — 856, 1989 да — 617, 2002 дә — 799 кеше.

**ИСКЕ́ СУЫКСУ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2008 елда 1151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1672 елда Темников шәһәреннән күчеп килүчеләр нигез сала. 1720 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел идарәсенә буйсына, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә; балта остасы, лашманлыкта эшли. Донбасс һәм Уралдагы күмер шахталарына китеп эшли. 20 йөз башында И.С.да волость идарәсе урнаша; 4 мәчет, 4 мәктәп, 18 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3669,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 1002, 1859 да — 1385, 1897 дә — 2186, 1913 тә — 2910, 1920 дә — 2656, 1926 да — 2637, 1938 дә — 2465, 1949 да — 2332, 1958 дә — 2312, 1970 тә — 2324, 1979 да — 1775, 1989 да — 1455, 2002 дә — 1326 кеше.

**ИСКЕ́ СУЫКСУ́ ВЫ́СЕЛКАСЫ** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чилчә елгасы буенда. 2008 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; лашманлыкта эшли. 20 йөз башында И.С.В.нда мәчет, мәдрәсә, 12 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 755,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 266, 1897 дә — 465, 1913 тә — 700, 1920 дә — 621, 1926 да — 670, 1938 дә — 765, 1949 да — 525, 1958 дә — 453, 1970 тә — 559, 1979 да — 638, 1989 да — 217, 2002 дә — 203 кеше.

**ИСКЕ́ ТАКТАЛЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* көнбатыштарак, Тakталы елгасы буенда. 2008 елда 371 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1661 ел тирәсендә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.да Казан Богородица чиркәве, Изге Гурий бораҗдәрлеге мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 тегермән, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2122,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 119 ир-ат; 1859 да — 1032, 1897 дә — 1053, 1908 дә — 1182, 1920 дә — 1193, 1926 да — 802, 1938 дә — 540, 1949 да — 497, 1958 дә — 529, 1970 тә — 575, 1979 да — 448, 1989 да — 362, 2002 дә — 366 кеше.

**ИСКЕ́ ТАМБО́ВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Ык елгасының сул кушылдыгы буенда. 2001 елдан даими яшәүчеләр юк. 1815 тә Тамбов губернасыннан күчеп килүче руслар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, авылда су тегермәне эшли. 1913 тә авыл җәмгатенең имана җире 325 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 312, 1870 тә — 443, 1884 тә — 274, 1897 дә — 289, 1906 да — 272, 1913 тә — 337, 1920 дә — 345, 1926 да — 380, 1938 дә — 293, 1949 да — 258, 1958 дә — 130, 1970 тә — 112, 1979 да — 86, 1989 да — 14 кеше.

*Әд.:* Мензелинский край: история и современность. Мензелинск, 2006.

**ИСКЕ́ ТАТА́Р ӘДӘБИ́ ТЕЛЕ́**, кайбер этник кардәш халыкларның — татар, башкорт, өлешчә казакъ һәм кыргызларның гомуми язма әдәби теле. И.т.ә.т. Идел буе Урал төбәгендә һәм Казакъстанда кулланылган иске төрки әдәби телнең җирле варианты нигезендә 16 йөздә барлыкка килә. 14–15 йөзләрдәге иске төрки әдәби тел И.т.ә.т. формалашуның башлангыч чоры итеп карала. Анда болгар-кыпчак халык сөйләм теленә һәм угыз шивәләренә хас үзенчәлекләр чагылыш таба (бу иске төрки язма традицияләрнең дәвам итүе һәм әлеге регионнарда төрле этник кардәш халыкларның аралашуы һәм кушылып китүе б-н дә аңлатыла). Казан, Әстерхан, Касыйм ханлыкларында яшәүче татарлар, Себер татарлары һәм Ука буенда урнашкан кыпчак-мишәрләр һ.б. арасында да кулланылыш таба.

И.т.ә.т. атамасы Алтын Урдадагы төрки халыклар этнонимыннан барлыкка килә — «татар». И.т.ә.т.нең җирле лексик, грамматик, өлешчә фонетик һәм стилистик нормалары Алтын Урда чоры тел практикасында күзәтелә башлый. Алга таба Казан ханлыгы чорында үсеш ала. Алтын Урда, соңрак Казан ханлыгы халыклары мөселман мәдәниятен (ш.и. ислам) үзләштерүләре дәвамында И.т.ә.т.нең лексик төзелешендә гарәп һәм фарсы алынмалары зур урын ала башлый. Хәзерге тюркологлар И.т.ә.т. дә матур әдәбият, фәнни-популяр, канцеляр-эш һәм эпистоляр жанр-стиль төрләрен, ш.у. югары, урта, түбән 3 стильне аерып күрсәтәләр. Иске татар телендә төрки телле халыклар арасында киң таралган *Мөхәммәдьярның* «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») һәм «Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмалары (16 йөз), *Мәүла Колый* (17 йөз), Г.*Утыз Имәни* (18 йөз), Г.*Чокрый*, Һ.*Салихов* (19 йөз башы) һ.б.ның шигъри әсәрләре; *Кадыйргали бәкнең* «Җамигы әт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы») тарихи әсәре (17 йөз башы), авторы билгесез «*Дәфтәре Чыңгызнамә*» җыентыгы, *Шәрәфеддин бине Хисамеддин* әл-Мөслими әл-Болгариның «*Тәварихы Болгария*» («Болгар тарихы») тарихи язма истәлеге (18 йөз ахыры — 19 йөз башы), Таҗетдин *Ялчыголның* «Тәварихы Болгария»се (19 йөз башы), татар *шәҗәрәсе*, Исмәгыйль *Бикмөхәммәдовның* Һиндстанга сәяхәтен тасвирлау (18 йөзнең 2 нче яртысы) һ.б. әсәрләр язылa. Бу телдә шактый гына публицистик әдәбият һәм эшлекле язмалар сакланып калган. Болар арасында аеруча Пугачёв циклы документлары (*Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* башлыкларының өндәмәләре һәм хатлары) һәм 15–19 йөзләрдәге акт материаллары (Алтын Урда һәм татар ханлыклары чорларының рәсми документлары, рус патшаларының дипломатик язышулары) күбрәк өйрәнелгән: Россия империясендә И.т.ә.т. арадашчы тел сыйфатында Шәрекъ илләре б-н дипломатик мөнәсәбәтләрдә, ш.у. илнең үз эчендә нинди дә булса берәр эш башкарылганда кулланыла. 18 йөз ахырыннан башлап дәүләт түрәләре әзерләү максатыннан Россиянең кайбер уку йортларына (Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе, Оренбургта Неплюев кадет корпусы һ.б.) И.т.ә.т. укыту кертелә. И.т.ә.т., язып аралашуда күпфункциональ чара буларак, 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр татар халкының төрле иҗтимагый өлкәләрендә кулланыла һәм татар милли әдәби теле нормалары формалашуга шактый йогынты ясый. 19 йөз уртасыннан И.т.ә.т.дә халык сөйләм теле элементлары киң кулланылган әдәби әсәрләр барлыкка килә. Әлеге юнәлешне шагыйрь Г.*Кандалый* башлап җибәрә. И.т.ә.т. Л.Җ.Җәләй, М.З.Зәкиев, Э.Р.Тенишев, В.Х.Хаков, Ф.С.Фасиев, Ф.С.Хәкимҗанов, Ф.М.Хисамова, И.Б.Бәширова, Ф.Ш.Нуриева һ.б. галимнәр тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* Б а с к а к о в Н.А. О периодизации истории литературного языка тюрки // Лингвогеография, диалектология и история языка. Киш., 1973; З а к и е в М.З. О периодизации истории тюрских письменных литературных языков // Советская тюркология. 1975. № 5; Т е н и ш е в Э.Р. Языки древне- и среднетюркских письменных памятников в функциональном аспекте // Вопр. языкознания. 1979. № 2; Ф а с е е в Ф.С. Старотатарская деловая письменность XVIII в. К., 1981.

**ИСКЕ́ ТАТА́Р ӘДӘМСУЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәмсу елгасы буенда. 2008 елда 284 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Беренче җәмигъ мәчет бинасы (1906; архит-ра истәлеге) сакланган. 17 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.Ә.нда 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 тегермән, тимерчелек, тукыма һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2278 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 861, 1897 дә — 1539, 1908 дә — 1661, 1920 дә — 1706, 1926 да — 1431, 1938 дә — 1311, 1979 да — 617, 1989 да — 359, 2002 дә — 299 кеше.

**ИСКЕ́ ТАТА́Р БИСТӘСЕ́**, *Казанның яулап алынуыннан* соң (1552), рус хөкүмәтенә уңай мөнәсәбәттәге татарлар тарафыннан төзелә. 1565–68 еллардагы язу кенәгәсендә күрсәтелгәнчә, ул «Кабан күле янындагы төрмә һәм Болак артында» урнашкан; бистәдә 150 татар һәм чуаш йорт-җире исәпләнә; аларның күпчелеге җәй коннәрендә бушап кала; «... әлеге татар йорт-җирләренә татарлар һәм чуашлар кышын яшәргә яки хәвефле вакытларда кайталар» һәм ул чакта «... бер йортта

унар гаилә, ә кайберләрендә хәтта уннан да артык гаилә яши». Бистә татарлары эшен 4 «прикащик» йөртә, 16 йөзнең 2 нче яртысында Татар бистәсендә беренче мәчетләр төзелә. Чыганакларда «Казанны алганнан соң кырык ел буе Татар бистәсендә мәчетләр булмавы, ә хәзер посадка якынрак урыннарда мәчетләр сала башлаулары» турында хәбәр ителә. 1593 тә *Патша Федор Ивановичь фәрманы* нигезендә җирле хакимияткә аларны җимерергә кушыла. Бистәдә яшәүчеләрнең бер өлешен (1646 да — 39 йорт-җир) җир биләмәләре һәм хезмәт хакы алучы, хәрби, административ яки дипломатия хезмәтендәге *йомышлы татарлар* тәшкил итә. Казанның йомышлы татарлары «хезмәткә акчалата һәм ашлык б-н түләүгә» алмашка сәүдә кәсепчелеге б-н шөгыльләнү мөмкинлегенә ия булалар. Бистә татарларының өстенлекле хәлдә булуы Казан посадында яшәүчеләрнең ризасызлыгын тудыра. 1685 тә Казан йомышлы татарларының аерым статусы раслана, алар җиргә җан башыннан түләүдән һәм йөкләмәләрдән азат ителә. Воевода И.И.Голицынга «татарларны элеккечә үк якларга, Казанның посад кешеләренә татарларны җәберләргә һәм кыерсытырга ирек куймаска ...» кушыла (к. *Пётр* Алексеевич *һәм Иоанн Алексеевич патшаларның фәрманы*). 18 йөз башыннан бистә халкының хәле үзгәрә башлый. Анда яшәүчеләрнең, йомышлы татарларның мөстәкыйль хуҗалык итүе 1718 дә аларны корабльләр төзү өчен урман кисүгә, агач әзерләүгә һәм аны чыгаруга йөкләп язу нәтиҗәсендә чикләнә (к. *Лашманнар*). 18 йөзнең 1 нче яртысында *христианлаштыру сәясәтен* гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә хөкүмәтнең һәм православие чиркәвенең Татар бистәсе халкының рухи тормышына тыкшынуы көчәя. Исламга карата дошмани мөнәсәбәттәге *Лука* (Канашевич) Казан епискобы булган елларда әлеге сәясәт аеруча зур колач ала. 1740 еллар башында Казанда һәм Казан өязендә 536 мәчетнең 418 е юк ителә. 1749 елгы янгыннан Казанның шактый өлеше зыян күргәч һәм Татар бистәсе янгач, Лука хакимиятләргә татарларны Казаннан куарга киңәш итә. Ләкин Сенат аларга элеккеге урыннарында яшәргә рөхсәт бирә. Шуңа да карамастан, миссионерлар татарларга йортлар төзергә комачаулыйлар, бистәдә чиркәү салына. Тарихчы Н.Ф.Калинин сүзләренә караганда, «... дворяннар администрациясе һәм чиркәүнекеләр XVIII йөз уртасында Казан татарлары өчен түзә алмаслык шартлар тудырлар ...» Миссионерларның туктаусыз басымына түзә алмыйча, бистәнең төньягында яшәүчеләрнең бер өлеше (108 йорт) Поповка авылы җирләренә күченеп утыра һәм анда *Яңа Татар бистәсенә* нигез сала (1751). Бистәнең Пләтән авылына терәлеп торган өлешендә икенче чиркәү төзелә, ә көнбатыш өлешенә Поповка авылы крәстияннәре күчерелә. 1753 елга И.т.б. Кабан күле буйлап озынлыкка — 270 сажень, киңлеккә 145 сажень мәйдан били. 18 йөзнең 2 нче яртысында Казан татарлары тормышында уңай үзгәрешләр була. *Батырша хәрәкәте* миссионерлар басымын киметә, 1755 тә мөселманнарны әзәрлекләүче Лука башка епархиягә күчерелә. Бистә татарларына сәүдә итү ирегенгә биргән 1763 елгы фәрманнар икътисади тормышны үстерүгә ярдәм итәләр. 1767 дә Казанга килгәч, *Екатерина II*, И.т.б.ндә ике таш мәчет салырга рөхсәт бирә. *Яңа кануннар эшләү комиссиясен* чакырган вакытта (Казан татарларының мәнфәгатьләрен депутат С.Хәлфин яклый) И.т.б. кешеләре Яңа бистә халкы б-н берлектә хакимиятләрдән үз хәлләрен яхшыртуны: рекрутлыкка алудан, «җан башына» түләүдән, мунчага «ясак акчасы» түләүдән һ.б. азат итүне; аларга киләчәктә каршылыксыз, аеруча Казанда, сәүдә итәргә, ш.у. «... лавкаларда утырырга, ... тире эшкәртү йортлары һәм ашлык амбарлары тотарга, Идел буйлап аска һәм өскә суднолар җибәрергә ...» рөхсәт итүне; «... сәүдә итүдә өяз түрәләренең бернинди дә комачаулыгын булдырмауны»; татарларны көчләп чукындыруны туктатуны; аларның дини хисләрен законлы рәвештә яклауны тәэмин итүне; татар бистәләрендә патша әмереннән тыш чиркәүләр салдырмауны һ.б. сорыйлар. *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы* оештырылгач (1781), И.т.б. кешеләре үзидарә мөмкинлеге алалар. 1784 тә ратушага беренче сайлаулар була, аларда И.т.б.ннән 132 кеше катнаша. 1781 дә И.т.б.ндә 481 ир-ат яши. К.Ф.Фукс хәбәр иткәнчә (19 йөзнең 1 нче яртысы), тирә-як авыллардан килеп, сабын кайнату һәм тире з-дларында эшләүче татарлар да сезонлы эшләр вакытында татар бистәсе халкын ел саен 700 кешегә арттыра. И.т.б. халкы җәмгысе 5 меңнән артык ир-ат яшәгән *мәхәлләләргә* берләшә, алар бистәнең Юныс, Апанай, Борнай, Гали һ.б. мәчетләренә карый. 18 йөз ахырында шәһәр составына керә. Казанның тәртипкә китерелгән планы расланганга кадәр бистә стихияле рәвештә төзелә. И.т.б. корылмалары арасында мәчетләр, мәдрәсәләр, татар сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре йортлары аерылып тора. *Печән базары* һәм *Юнысовлар мәйданы* сәүдә, иҗтимагый һәм мәдәни тормыш үзәге була. 18 йөз ахырында И.т.б.ндә 7 пр-тие эшли. 19 йөз — 20 йөз башында Апанаевлар, Юнысовлар, Галиевләр, Үтәмишевләрнең сәүдә фирмалары, И.Арслановның сабын кайнату з-ды, Әҗимовларның туку ф-касы, В.Ибраһимовның кондитер ф-касы һ.б. эшли. Бистә татарларының милли мәдәниятен үстерү үзәгенә әверелә. Анда «Мәрҗания», «Касыймия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре һ.б. уку йортлары була, аларны тәмамлаучылар татар интеллигенциясенең төп өлешен тәшкил итә (К.Насыйри, Г.Баруди, Г.Исхакый, Г.Камал, М.Бигиев, З.Бигиев, С.Сәйдәшев, Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин, Ф.Бурнаш, М.Гафури, К.Тинчурин, Н.Исәнбәт һ.б.). Казан татарлары интеллигенциясенең мәдәни үзәге булган *Шәрекъ клубында* әдәби кичәләр үткәрелә, лекцияләр укыла, спектакльләр куела. *Кәримовлар басмаханәсендә* фәнни-популяр һәм матур әдәбият, дәреслекләр, дини-дидактик характердагы әсәрләр һ.б. нәшер ителә. Совет хакимияте елларында мәчетләр эшләүдән туктый (Мәрҗани мәчете генә ябылмый), мәхәлләләр бетерелә, И.т.б.нең архит-ра манзарасына нык зыян китерелә. 1992 дә тарих-архит-ра тыюлыгы, 1998 дә «*Иске Татар бистәсе тарих-архит-ра территориаль саклаулыгы*» булдырыла.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф. Казан времён пугачевских событий // Тр. Казан. филиала Академии наук СССР. 1959. Вып. 2; История Казани. К., 1988. Кн. 1; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Старо-Татарская слобода — От прошлого к будущему. К., 2001; Татарские слободы Казани: Очерки истории. К., 2002.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ИСКЕ́ ТАШ МӘЧЕ́Т**, Казанда, ш.у. Тугызынчы җамигъ мәчет буларак та мәгълүм. 1802 елда сәүдәгәр Г.А.Үтәмишев иганәсенә төзелә. 1830 еллар башында классицизм стилендә үзгәртеп корыла, архит. А.К.Шмидт проекты буенча дип фаразлана. Риваятьләргә караганда, мәчет мөселман яугирләре (1552 дә Иван IV гаскәрләреннән Казанны саклап шәһит киткән каһарманнар) җирләнгән туганнар каберлеге урынында төзелгән, мәчеткә нигез салганда бу урын зур иске таш б-н билгеләп куелган. Яңа Татар бистәсендәге әлеге бина манарасы түбәнең үзәгенә урнаштырылган ике катлы, ике заллы мәчетләр төренә карый. Гыйбадәт кылу залы икенче, келәтләре беренче катта планлаштырылган турыпочмаклы таш бина. Тышкы ишеге төньякка уелган. Вестибюльдә, ишекнең уң ягында, икенче катка алып менүче өч рәтле баскыч урнашкан. Өстә бер-бер артлы тезелеп киткән намаз уку залларын ике метр киңлектәге дивар аерып тора. Шул дивар әченнән манарага тар баскыч күтәрелгән. Заллар, ихтимал, А.К.Шмидт проекты буенча яссы түшәм белән корылган. Мәчетнең биек әвернә гөмбәзләр б-н ябылган беренче каты келәт сыйфатында файдаланылган. Гөмбәзләрнең үзәктәгесен зур квадрат багана терәтеп тора. Мондый төр түшәмнәр мәчетләрдә 19 йөз башыннан сакланып калган һәм алга таба үзгәреш кичермәгән. Мәчетнең фасадлары классицизм стилендә эшләнгән. Буй ягы үзәк ризолит б-н ныгытылган. Фасадларның катгый чишелеше заллар арасындагы ныклы аркылы диварга беркетелгән дүрт ярусллы манара б-н бәйле. Манара болгар архит-ра формаларында күтәрелгән. Күләмле рәвештә планлаштырылып, фасадлары һәм манаралары болгар дини архит-расыннан башланып киткән бизәү ысуллары б-н



Иске таш мәчетнең хәзерге күренеше.

аралаштырып төзелгән татар дини архит-ра истәлеге.

*Әд.:* Х а л и т о в Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ИСКЕ́ ТӘКМӘ́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 9 *км* төньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2008 елда 208 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган мәктәп, клуб, китапханә. 1677 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, сәүдә һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.тә волость идарәсе урнаша. Троица чиркәве (1856 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1871 дә ачыла) була; җомга саен базар, ярминкә (8–11 ноябрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3210 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 996, 1884 тә — 1682, 1897 дә — 864, 1913 тә — 1830, 1920 дә — 890, 1926 да -1186, 1938 дә — 978, 1949 да — 684, 1958 дә — 625, 1970 тә — 502, 1979 да — 372, 1989 да — 205, 2002 дә — 237 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ИСКЕ́ ТӘРБИ́Т** (Ырым Тәрбите) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ырым елгасы буенда. 2008 елда 535 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.тә Петропавел чиркәве, 2 укырга-язарга өйрәтү мәктәбе, 2 тегермән, 4 ярма яргыч, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1663,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивиль өязе Иске Тәрбит волостена керә. 1920 дән — Чуаш автономияле өлкәсе составында, 1921–22 дә Зөя кантонында. 1927 нең 14 февралендә — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1721 дә — 116, 1747 дә — 127, 1782 дә — 143 ир-ат; 1859 да — 693, 1897 дә — 1337, 1908 дә — 1573, 1920 дә — 1605, 1926 да — 1393, 1938 дә — 1379, 1949 да — 1229, 1958 дә — 1150, 1970 тә — 1035, 1979 да — 916, 1989 да — 700, 2002 дә — 620 кеше.

**«ИСКЕ́ ТЕГЕРМӘ́Н»**, табигать тыюлыгы. Мишә елгасы үзәненең уңъяк ярында, Питрәч р-нының Иске Йорт авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1991 елда оештырыла. Мәйданы 111,8 *га*. Төрле яшьтәге наратлыклардан, урман чикләвеге, гөлҗимеш, мурт, эт шомырты, кошкунмас агач куакларыннан торучы урман участогын, Елан тавын һәм елга үзәнендәге зур булмаган болынны били. ТРның Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре бар: биек аю табаны, сөңгесыман какалия, Урал төймәчәчәге. Сырлач сыртлы тритон, соры гөберле бака, бакыр кәлтә, кара елан яши; кошларның сирәк төрләре: үләт бөркете, зур каракош, сапсан, балобан, яр чыпчыгы, сары корташар, яшел тукран һ.б. очрый. Мишә елгасы буенда элекке бай табигате, су тегермәне калдыклары сакланган матур табигать почмагы.



«Иске тегермән» табигать тыюлыгы.

**ИСКЕ́ ТЕЛӘКӘ́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 15 *км* көнбатыштарак, Шәбез инеше буенда. 2008 елда 428 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1724 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Т.дә мәчет (1811 дән билгеле), мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1133 (1913 тә — 3150) дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип (Такталачык) волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 229, 1834 тә — 379, 1859 да — 324, 1870 тә — 373, 1884 тә — 400, 1897 дә — 505, 1906 да — 475, 1913 тә — 630, 1920 дә — 625, 1926 да — 649, 1938 дә — 1080, 1958 дә — 607, 1970 тә — 668, 1979 да — 599, 1989 да — 466, 2002 дә — 418 кеше.

**ИСКЕ́ ТЕЛӘНЧЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 39 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы — Сарман автомобиль юлы буенда. 2008 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1703 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Т.дә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 708,69 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 360, 1897 дә — 540, 1920 дә — 366, 1938 дә — 374, 1949 да — 377, 1958 дә — 216, 1970 тә — 212, 1979 да — 172, 1989 да — 691, 2002 дә — 86 кеше.

**ИСКЕ́ ТИМО́ШКИНО** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 918 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1700 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бирдебәк исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.да чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе, җил һәм 2 су тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете була; җомга саен базар, 14 сентябрьдә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2837,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 178 ир-ат; 1859 да — 966, 1897 дә — 1573, 1908 дә — 1629, 1920 дә — 1673, 1926 да — 1681, 1938 дә — 1450, 1949 да — 1023, 1958 дә — 1382, 1970 тә — 1486, 1979 да — 1215, 1989 да — 896, 2002 дә — 954 кеше.

**ИСКЕ́ ТИМО́ШКИНО (Зөябаш) ПОСТА́У МАНУФАКТУ́РАСЫ**. 1849 елда Себер губернасы Иске Тимошкино (Зөябаш) авылында 1 нче гильдия сәүдәгәре С.А.Акчурин тарафыннан нигезләнә. Яңа техника (куәтле пар казаннары һәм механик станоклар) б-н җиһазландырыла; ирекле яллы хезмәт файдаланыла. 1861 дә 327 станокта 1423 кеше эшли, елга 340 мең сумлык постау җитештерелә. Губернадагы постау мануфактуралары арасында беренче урынны били. 1892 дә 300 мең сумлык төп капиталы булган «Акчуриннарның Иске Тимошкино постау мануфактурасы ширкәте» оештырыла. Оештыручылары — Тимербулат Курамша улы һәм Якуп Сөләйман улы Акчуриннар. Ул патша хөкүмәтенең рәсми рөхсәте б-н татар эшмәкәрләре тарафыннан оештырылган беренче сәнәгый берләшмә була. 1913–14 тә ширкәт тарафыннан 948,5 мең сумлык постау җитештерелә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында, башлыча, казнага эшләгән ширкәт җитештерүне киң җәелдерә. 1918 елда национализацияләнә. Ш.у.к. *Акчуриннар*.

*А.Х.Мәхмүтова.*

**ИСКЕ́ ТИНЧӘЛЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чилчә елгасы буенда. 2008 елда 370 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1670

елларда нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, лашманлыкта эшли. 20 йөз башында И.Т.дә 4 мәчет, 3 мәдрәсә, 26 сәүдә-сәнәгать оешмасы була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3426,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 1424, 1897 дә — 2173, 1913 тә — 3021, 1920 дә — 2456, 1926 да — 2043, 1938 дә — 1990, 1949 да — 1395, 1958 дә — 983, 1970 тә — 980, 1979 да — 928, 1989 да — 515, 2002 дә — 469 кеше.

**ИСКЕ́ ТОРЖА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасыннан 1 *км* читтә. 2008 елда 164 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 948,95 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1763 тә — 92 ир-ат; 1795 тә — 171, 1811 дә — 227, 1850 дә — 231, 1859 да — 262, 1884 тә — 339, 1897 дә — 377, 1905 тә — 347, 1920 дә — 518, 1926 да — 490, 1938 дә — 516, 1949 да — 337, 1958 дә — 291, 1970 тә — 301, 1979 да — 263, 1989 да — 177, 2002 дә — 176 кеше.

**ИСКЕ́ ТӨРНӘЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2008 елда 182 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1617 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Төрнәле исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, туку станогы кылычы ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.дә мәчет, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 551,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 242, 1897 дә — 345, 1908 дә — 404, 1920 дә — 439, 1926 да — 442, 1938 дә — 434, 1958 дә — 316, 1970 тә — 223, 1979 да — 215, 1989 да — 185, 2002 дә — 196 кеше.

**ИСКЕ́ ТУМБА́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 50 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2008 елда 120 кеше (чуашлар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Тумбасы исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.да Михаил-Архангел чиркәве, земство мәктәбе, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 805 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1965 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 522, 1897 дә — 839, 1908 дә — 824, 1920 дә — 1064, 1926 да — 815, 1938 дә — 526, 1949 да — 527, 1958 дә — 554, 1970 тә — 443, 1979 да — 274, 1989 да — 137, 2002 дә — 132 кеше.

**ИСКЕ́ ТУРА́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 10 *км* төньяктарак, Сола елгасы (Казансуның уң кушылдыгы) бассейнында. 2008 елда 13 кеше (руслар) яши. 1565 елдан Тура авылы буларак билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тегү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Т.да земство мәктәбе (1901 дә ачыла), тимерчелек, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 907,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 36, 1782 дә — 240 ир-ат; 1859 да — 382, 1897 дә — 357, 1908 дә — 508, 1920 дә — 544, 1926 да — 646, 1938 дә — 505, 1949 да — 406, 1958 дә — 237, 1970 тә — 113, 1989 да — 35, 2002 дә — 9 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ИСКЕ́ УРЫССУ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 5 *км* көнбатыштарак, Әтәмби елгасы буенда. 2008 елда 824 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.У.да 2 мәчет, зур мәдрәсә (200 ләп укучы), 4 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2408 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1859 да — 807, 1889 да — 1443, 1897 дә — 1637, 1910 да — 2100, 1922 дә — 2247, 1970 тә — 913, 1979 да — 909, 1989 да — 809, 2002 дә — 835 кеше.

**ИСКЕ́ ҮБИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2008 елда 129 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 17 йөз уртасына кадәр йомышлы чуашлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Куликеева исеме б-н дә билгеле. 1720 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел идарәсенә буйсына, игенчелек, терлекчелек, агач эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ү.дә сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 283 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 128, 1897 дә — 222, 1913 тә — 275, 1920 дә — 276, 1926 да — 313, 1938 дә- 397, 1949 да — 376, 1958 дә — 342, 1970 тә — 332, 1979 да — 238, 1989 да — 127, 2002 дә — 117 кеше.

**ИСКЕ́ ҮЗИ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2008 елда 694 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1698 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ү.дә су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1433,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 150 ир-ат; 1859 да — 484, 1897 дә — 823, 1908 дә — 831, 1920 дә — 1062, 1926 да — 857, 1938 дә — 837, 1949 да — 789, 1958 дә — 822, 1970 тә — 1003, 1979 да — 916, 1989 да — 695, 2002 дә — 688 кеше.

**ИСКЕ́ ҮРГӘГА́Р** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Актай елгасы бассейнында. 2008 елда 141 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Китапханә. 1692 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Меметчелеева авылы буларак билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-

лекчелек б-н шөгыльләнә. 1861 елгы реформадан соң И.Ү. *Татар крәстияннәре кузгалышлары* (1878–79) үзәге була. 20 йөз башында мәчет (1905 тә төзелә; архит-ра истәлеге), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1367 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 172 ир-ат (Яңа Үргәгар авылын да кертеп); 1859 да — 857, 1897 дә — 1080, 1908 дә — 1018, 1920 дә — 1125, 1926 да — 585, 1938 дә — 497, 1949 да — 577, 1958 дә — 602, 1970 тә — 341, 1979 да — 267, 1989 да — 189, 2002 дә — 146 кеше.

**ИСКЕ́ ҮРЬЯДЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 32 *км* көнбатыштарак, Бәҗәнә бассейнында урнашкан. 2008 елда 123 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1706 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Үрьяды исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында И.Ү.да мәчет (1844 тән мәгълүм), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1962 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 212 кеше; 1816 да — 146, 1834 тә — 218 ир-ат; 1859 да — 499, 1884 тә — 530, 1897 дә — 709, 1906 да — 877, 1913 тә — 865, 1920 дә — 382, 1926 да — 308, 1938 дә — 668, 1949 да — 382, 1958 дә — 325, 1975 тә — 320, 1989 да — 134, 2002 дә — 115 кеше.

**ИСКЕ́ ҮТӘМЕ́Ш** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үтәмеш елгасы буенда. 2008 елда 440 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Халкы кырчылык, мөгезле эре терлек асрау б-н шөгыльләнә. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Беренче җамигъ мәчет (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге) бинасы сакланган. 1730–40 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ү.тә 2 мәчет (1876–77 һәм 1903 тә төзелә), 2 мәктәп, 2 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3743 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва-Кармалы волостенда. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 785, 1889 да — 1372, 1910 да — 1902, 1920 дә — 1860, 1926 да — 1181, 1949 да — 1196, 1958 дә — 995, 1970 тә — 1015, 1979 да — 716, 1989 да — 520, 2002 дә — 469 кеше.

**ИСКЕ́ ЧАКМА́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 11 *км* көньяктарак, Ык елгасы буенда. 2008 елда 120 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.та мәчет һәм мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 862,4 дис. тәшкил итә. 1916 да земство китапханәсе ачыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирек волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 89, 1834 тә — 83 ир-ат; 1859 да — 411 (Яңа Чакмак авылын да кертеп), 1870 тә — 828, 1897 дә — 1483 (Яңа Чакмакны да кертеп), 1920 дә — 517, 1926 да — 530, 1938 дә — 445, 1949 да — 352, 1958 дә — 297, 1970 тә — 282, 1979 да — 202, 1989 да — 166, 2002 дә — 132 кеше.

**ИСКЕ́ ЧАЛЛЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Актайның уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 266 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1685 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мерәс исеме б-н билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.да мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, йон тетү йорты, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1658 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда. 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 117 ир-ат; 1859 да — 784, 1897 дә — 1110, 1908 дә — 1187, 1920 дә — 1157, 1926 да — 803, 1938 дә — 826, 1949 да — 754, 1958 дә — 822, 1970 тә — 716, 1979 да — 567, 1989 да — 377, 2002 дә — 208 кеше.

**ИСКЕ́ ЧАЛЛЫ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2008 елда 936 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57%, чуашлар — 33%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1690 елларда нигез салына. Беренче исеме — Чаллы Пүчинкәсе. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.да волость идарәсе урнаша; чиркәү, земство мәктәбе (1871 дә ачыла), хастаханә, вак кредит учреждениесе, чәйханә, 2 сырахanә, шәраб һәм 7 вак-төякләр кибетләре була; чәршәмбе саен — базар, 20–23 сентябрьдә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2204 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 1325, 1897 дә — 1731, 1908 дә — 2220, 1920 дә — 2185, 1926 да — 1384, 1938 дә — 1041, 1949 да — 1095, 1970 тә — 1042, 1979 да — 934, 1989 да — 919, 2002 дә — 918 кеше.

**ИСКЕ́ ЧӘБИЯ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 51 *км* төньяк-көнбатыштарак, Баш-Арбаш елгасы буенда. 2008 елда 210 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау; умартачылык. Башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, клуб, китапханә. 1616 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Чәбия исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.дә мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 731,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадаш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 19 ир-ат; 1859 да — 246, 1897 дә — 583, 1908 дә — 610, 1920 дә — 638, 1926 да — 630, 1949 да — 479, 1958 дә — 446, 1970 тә — 432, 1979 да — 386, 1989 да — 300, 2002 дә — 289 кеше.

**ИСКЕ́ ЧӘКЕ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов өлкәсе чигендә. 2008 елда 257 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.дә чиркәү, мәчет, мәктәп, тегермән, 14 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1901,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 946, 1897 дә — 1416, 1913 тә — 1767, 1920 дә — 1805, 1926 да — 1180, 1938 дә — 1008, 1949 да — 710, 1958 дә — 829, 1970 тә — 840, 1979 да — 698, 1989 да — 327, 2002 дә — 291 кеше.

**ИСКЕ́ ЧӘЧКА́Б** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 5 *км* көнбатыштарак, Бәрле елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан.

2008 елда 458 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.та җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 831 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 411, 1897 дә — 900, 1908 дә — 1148, 1920 дә — 1009, 1920 дә — 838, 1938 дә — 784, 1949 да — 833, 1958 дә — 734, 1970 тә — 717, 1979 да — 688, 1989 да — 512, 2002 дә — 486 кеше.

**ИСКЕ́ ЧЕПЬЯ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Арбор елгасы буенда. 2008 елда 97 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 772,14 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда. 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 306, 1884 тә — 466, 1905 тә — 620, 1920 дә — 812, 1926 да — 701, 1938 дә — 596, 1949 да — 389, 1958 дә — 282, 1970 тә — 175, 1979 да — 138, 1989 да — 99, 2002 дә — 107 кеше.

**ИСКЕ́ ЧИРКӘ́С** (Мари Чиркәсе) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 26 *км* төньяктарак, Вятка елгасыннан 1,5 *км* читтә. 2008 елда 80 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чиркәс Пучинкәсе исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.тә тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Яңа Чиркәс авылын да кертеп) 386,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 5 ир-ат; 1859 да — 283 (Яңа Чиркәсне дә кертеп), 1897 дә — 124, 1908 дә — 542 (Яңа Чиркәс б-н бергә), 1920 дә — 137, 1926 да — 140, 1949 да — 93, 1958 дә — 93, 1970 тә — 103, 1979 да — 101, 1989 да — 76, 2002 дә — 85 кеше.

**ИСКЕ́ ЧИШМӘ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 59 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2008 елда 1326 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1645 тә Кама аръягы авылларын калмык һәм нугайлар һөҗүменнән саклау ныгытмасы буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Иске Чишмә Бистәсе исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек отставкадагы солдатлар) һәм алпавыт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.дә волость идарәсе урнаша; Богоявление чиркәве, земство мәктәбе (1875 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 2 тимерчелек, 3 су тегермәне, казна шәраб һәм 7 бакалея кибете була; сишәмбе саен базар, Казан ярминкәсе (8–12 июльдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5000 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 июленнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 3063, 1897 дә — 3623, 1908 дә — 3871, 1920 дә — 4162, 1926 да — 3294, 1949 да — 2151, 1958 дә — 1959, 1970 тә — 1687, 1979 да — 1407, 1989 да — 1463, 2002 дә — 1333 кеше.

**ИСКЕ́ ЧОКАЛЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 11 *км* көньяктарак, Олы Яклы елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 688 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1665–67 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.да 4 мәчет, 3 мәдрәсә, 24 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3162,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1694, 1897 дә — 2526 (Югары Татар Чокалысы авылын да кертеп), 1913 тә — 3420, 1920 дә — 3097, 1926 да — 3332, 1938 дә — 3096, 1949 да — 2388, 1958 дә — 1970, 1970 тә — 2028, 1979 да — 1678, 1989 да — 884, 2002 дә — 720 кеше.

**ИСКЕ́ ЧУА́Ш ӘДӘМСУЫ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әдәмсу елгасы буенда. 2008 елда 365 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1690 еллар тирәсендә нигез салына. Беренче исеме — Кече Чирмешән елгасы буендагы Әдәмсу Пүчинкәсе. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.Ә.нда земство мәктәбе, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 829 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 327 ир-ат; 1859 да — 305, 1897 дә — 503, 1908 дә — 583, 1920 дә — 643, 1926 да — 430, 1938 дә — 499, 1949 да — 451, 1958 дә — 387, 1970 тә — 611, 1979 да — 542, 1989 да — 402, 2002 дә — 396 кеше.

**ИСКЕ́ ЧҮПРӘЛЕ́** авылы, Чүпрәле р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнбатыш чигендә, Ульянов–Зөя тимер юлындагы Борындык станциясеннән 45 *км* көнбатыштарак, Кече Чынлы елгасы (Зөя бассейны) буенда. Казаннан 200 *км* ераклыкта урнашкан. 2008 елда 3416 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 79%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май-сыр, икмәк з-длары, а.х. техникасы, төзелеш пр-тиеләре, газ эшләре участогы. 2 урта мәктәп, һөнәри уч-ще, район мәдәният йорты, район хастаханәсе, балалар-яшүсмерләр спорт һәм музыка мәктәпләре, 2 китапханә эшли. Район



Иске Чүпрәле авылы. Гомуми күренеш.

тарихы музее бар. Мәчет. 1654 кә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Старый Дрожжаной Куст исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашманнар), игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, И.Ч.дә мәчет була. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 2 мәчет, 2 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1472,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волосте үзәге була. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чүпрәле р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Буа р-нында, 1966 ның 30 декабреннән яңадан район үзәге. Халык саны: 1859 да — 858, 1897 дә — 1248, 1913 тә — 1554, 1920 дә — 1389, 1926 да — 1175, 1938 дә — 1727, 1949 да — 1621, 1958 дә — 1614, 1970 тә — 2175, 1979 да — 2611, 1989 да — 2947, 2002 дә — 3332 кеше.

**ИСКЕ́ ЧҮПРӘЛЕ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Иске Чүпрәле авылында. 1970 елда җәмәгатьчелек тарафыннан оештырыла, 1990 да Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән ТРның Милли музее) ф-лы буларак ачыла, 2007 дән муниципаль музей. 20 йөзнең 1 нче яртысында төзелгән агач йортта урнашкан (элек район хәрби комис-ты). Экспозиция мәйданы — 105 *м*². Музей коллекциясендә 1500 саклау берәмлеге исәпләнә. Дүрт залны биләгән экспозиция



Иске Чүпрәле төбәк тарихы музее. Экспозиция күренеше.

төбәк тарихына, районда туган күренекле шәхесләргә багышлана. Палеонтология, археол. коллекцияләре, чуашлар һәм татарларның, көнкүреш әйберләре һәм өс киемнәре (19 йөздә тукылган сөлгеләр, 20 йөз башы туку станогы һәм җеп эрләү станогы) урын алган. «Районның хезмәт даны» бүлегендә Соц. Хезмәт Геройлары Ә.Ш.*Әбдриев*, У.Г.*Алиев*, П.В.*Дементьев*, Л.В.*Дергунов*, А.Ф.*Мокшин*, С.Е.*Немасев*, Р.М.*Низаметдинов*, А.С.*Сабирҗанов* фотосурәтләре һәм документлары бар. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә «Үлем үзәне»ннән (Новгород өлкәсендә 2 нче удар армия сугышкан урыннардан) табылган совет һәм немец кораллары үрнәкләре, солдат көнкүреше әйберләре, сугыш чорындагы телефон аппараты куелган. Сов. Союзы Геройлары З.З.*Алимов*, Н.Г.*Фазлаев*, И.К.*Хәкимов*, С.А.*Уганин*, П.С.*Юхвитов*, Дан орденының тулы кавалеры З.М.*Арсланов*, Россия Герое Г.Г.*Хәйруллин* документлары тупланган. Бүлекләрнең берсе Чүпрәле р-нында туган күренекле шәхесләр — шагыйрь-публицист Ш.*Мөдәррис*, шагыйрь З.*Нури*, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты Р.*Таҗетдинов*, ТАССРның халык артисты Һ.*Солтанов* һ.б.ның тормыш юллары һәм иҗади эшчәнлекләре б-н таныштыра. Аеруча мөһим экспонатлар арасында этнография, палеонтология коллекцияләре, З.Нуриның шәхси китапханәсеннән китаплар, орденнар һәм медальләр бар.

Ел саен Җиңү бәйрәме (9 май), Халыкара музейлар (18 май), Чүпрәле р-ны оешу (10 авг.), Татарстан Республикасы (30 авг.) көннәре уздырыла.

**ИСКЕ́ ЧҮРИЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Пермь автомобиль юлы буенда. 2008 елда 712 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 69%, руслар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзнең 1 нче яртысында халкының бер өлеше — алпавыт, икенчеләре дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон тетү, агач эше, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.дә Казан Богородица чиркәве (1830 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1870 тә ачыла), почта станциясе, 2 тимерчелек, 3 юлаучылар йорты, сыраханә, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3213,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 479 ир-ат; 1859 да — 920, 1897 дә — 1039, 1908 дә — 976, 1920 дә — 1000, 1926 да — 1172, 1938 дә — 1102, 1949 да — 897, 1958 дә — 789, 1970 тә — 499, 1979 да — 598, 1989 да — 599, 2002 дә — 677 кеше.

**ИСКЕ́ ЧҮТЕ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2008 елда 122 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 900 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1816 да — 26 ир-ат; 1834 тә — 52, 1859 да — 188, 1889 да — 279, 1897 дә — 376, 1910 да — 504, 1920 дә — 593, 1926 да — 430, 1938 дә — 385, 1949 да — 302, 1958 дә — 272, 1970 тә — 287, 1979 — 246, 1989 да — 115, 2002 дә — 126 кеше.

**ИСКЕ́ ЧЫКАЛДА́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 69 *км* көньяктарак, Чыкалда елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 338 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау, умартачылык. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1810 елларда Вятка губернасының Сарапул өязе Нарядово (Ожгихино дигән исеме дә бар) авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киез итек басу, тимерчелек, сумала кайнату, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ч.да чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе була; базар эшли. 1897 дә — умартачылар җәмгыяте, 1908 дә аграр тәҗрибә участогы оештырыла, 1908 дә — тимерчелек һәм күн эшкәртү остаханәләре, 1911 дә земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1035,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1887 дә — 812, 1905 тә — 800, 1920 дә — 952, 1926 да — 934, 1938 дә — 541, 1949 да — 713, 1958 дә — 620, 1970 тә — 651, 1989 да — 461, 2002 дә — 370 кеше.

**ИСКЕ́ ШӘЙМОРЗА́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2008 елда 1244 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. Мәчет. 1674 тән чуаш авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уразбаево исеме б-н дә билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел идарәчелеге карамагында, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, И.Ш.да 3 мәчет була. 20 йөз башында чиркәү, мәктәп, 5 мәчет, 5 мәктәп, 36 сәүдә-сәнәгать оешмасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5027,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Зур Чынлы волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы р-ннары үзәге, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 2021, 1897 дә — 2345, 1913 тә — 3557, 1920 дә — 2525, 1926 да — 3779, 1938 дә — 3806, 1949 да — 2617, 1958 дә — 2684, 1970 тә — 2818, 1979 да — 2067, 1989 да — 1439, 2002 дә — 1296 кеше.

**ИСКЕ́ ШИГАЛИ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сула елгасы (Мишәнең уң кушылды-

гы) буенда. 2008 елда 873 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 62%, татарлар — 36%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Питрәч юл эшләре участогы ф-лы, асфальт-бетон, сөяк оны з-длары. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1550 еллардан — рус авылы. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сарык тиресе эшкәртү, он тарту, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ш.да Екатерина чиркәве, 2 земство мәктәбе, кредит учреждениесе, су һәм җил тегермәне, йон тетү йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1276,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 183 ир-ат; 1859 да — 473, 1897 дә — 553, 1908 дә — 524, 1920 дә — 737, 1926 да — 858, 1949 да — 589, 1958 дә — 489, 1970 тә — 566, 1979 да — 832, 1989 да — 907, 2002 дә — 827 кеше.

**ИСКЕ́ ШИМБЕ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 18 *км* көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2008 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мирәтәк исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ш.дә су тегермәне, «китайка» тукымасы җитештерүче ф-ка, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 225,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) өязе Күлле Киме волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 115, 1897 дә — 368, 1908 дә — 348, 1920 дә — 339, 1926 да — 325, 1938 дә — 309, 1949 да — 222, 1958 дә — 177, 1970 тә — 193, 1979 да — 137, 1989 да — 89 кеше.

**ИСКЕ́ ШӨГЕ́Р** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 32 *км* көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2008 елда 913 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, И.Ш.дә 19 йорт һәм 1 мәчет була. 1870 елларда Америка сәнәгатьчесе Л.Шандор механика остаханәсе һәм 2 нефть чыгару скважинасы, 1881 дә гудрон (битум) з-ды төзи. Шуның нәтиҗәсендә авыл нык үсә. 1910 да И.Ш.дә 439 йорт исәпләнә, 3 мәчет, 3 мәктәп, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3883 дис. тәшкил итә. 1943 тә И.Ш. янындагы 1 нче скважинадан Татарстанда беренче булып сәнәгать нефте алына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1747 дә — 53 ир-ат; 1785 тә — 140, 1859 да — 134, 1889 да — 1660, 1897 дә — 1875, 1910 да — 2150, 1920 дә — 2548, 1926 да — 2080, 1938 дә — 2273, 1949 да — 1259, 1958 дә — 1315, 1970 тә — 1292, 1979 да — 1036, 1989 да — 841, 2002 дә — 913 кеше. И.Ш.дә Сов. Союзы Геройлары И.Х.*Мурзин*, С.С.*Садриев*, И.Р.*Халиков*, Соц. Хезмәт Геройлары З.Г.*Шәрифуллин*, Ф.М.*Шәрәфетдинов*, ТР ФА академигы И.Р.*Таһиров* туган.

Авылның истәлекле бинасы булып мәчет (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге) санала.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ИСКЕ́ ШЫРДА́Н** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәкел елгасы буенда. 2008 елда 10 кеше (руслар, татарлар) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 264 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Норлат, 1963 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1920 дә — 135, 1926 да — 335, 1938 дә — 182, 1949 да — 137, 1958 дә — 156, 1970 тә — 126, 1979 да — 79, 1989 да — 32, 2002 дә — 14 кеше.

**ИСКЕ́ ЭСЛӘ́К** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 80 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда. 2008 елда 385 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1681 елга кадәр нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында рус-татар мәктәбе була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6978,9 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 817, 1905 тә — 1567, 1920 дә — 1867, 1926 да — 1609, 1938 дә — 1469, 1949 да — 1292, 1958 дә — 1013, 1970 тә — 940, 1989 да — 487, 2002 дә — 474 кеше.

**ИСКЕ́ ЮМЬЯ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 23 *км* көнбатыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2008 елда 656 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ю.да волость идарәсе урнаша; земство мәктәбе (1885 тә ачыла), җил һәм су тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1650,6 дис тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1920 дән — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 168 ир-ат; 1859 да — 655, 1897 дә — 754, 1908 дә — 811, 1920 дә — 944, 1926 да — 882, 1938 дә — 581, 1949 да — 745, 1958 дә — 711, 1970 тә — 909, 1979 да — 767, 1989 да — 675, 2002 дә — 684 кеше.

**ИСКЕ́ ЮРА́Ш** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2008 елда 560 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1666 елдан Юбраш авылы буларак билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.Ю.та 2 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3124,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1021, 1887 дә — 1510, 1905 тә — 1886, 1920 дә — 2115, 1926 да — 1845, 1938 дә — 1372, 1949 да — 938, 1958 дә — 780, 1970 тә — 832, 1979 да — 712, 1989 да — 597, 2002 дә — 617 кеше.

**ИСКЕ́ ЯЛА́Н** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 31 *км* көньяктарак, Кичү елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 157 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Козьмодемьянск исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.Я.да Козьмодемьянск чиркәве (1736 да төзелә, архит-ра истәлеге), су тегермәне эшли, 1880 дә чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында авылның имана җире 1682,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән

Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Әлмәт, 1995 нең 12 июленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1870 тә — 529, 1897 дә — 929, 1920 дә — 1144, 1926 да — 896, 1938 дә — 613, 1949 да — 731, 1958 дә — 618, 1970 тә — 390, 1979 да — 246, 1989 да — 127, 2002 дә — 143 кеше.

**ИСКЕАВЫ́Л** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Наратлы елгасының сул кушылдыгы (Ык елгасы бассейны). Озынлыгы 9,8 *км*, бассейнының мәйданы 32,2 *км*². Азнакай р-ны Бүтерр-ясе буйлап ага. Елга башы Балан Бүләк авылыннан 3 *км*, тамагы Чалпы авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы чигендә. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 98 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,30 *км/км*². Җир асты туендыру модуле тотрыклы түгел. Елга җәйге айларда еш кына тамагына җитмичә кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Су язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм язын бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын — 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада гомуми күләме 0,45 млн. *м*³ булган буа бар. Суы сугару өчен файдаланыла.

**«ИСКО́Ж»**, к. *Казан ясалма күн заводы*.

**«И́СКРА»**, Әтнә р-нындагы колхоз. 1931 елда «Удар» исеме б-н оештырыла (1951–57 дә Маленков исем., 1957 дән «И»). 645 хуҗалыклы 7 авылны берләштерә; үзәк утары — Күңгәр авылы. А.х. җирләренең мәйданы 6848 *га*, ш.и. сөрүлек җирләре — 6134 *га* (1993). 1993 тә колхоз — терлекчелек продуктлары һәм а.х. культуралары уңышы күрсәткечләре югары булган икътисади яктан көчле, күп тармаклы хуҗалык санала, мөгезле эре терлек 3100 баш, ш.и. сыерлар 885 баш. 1986–93 тә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 24–37 *ц*, 1 *га* сөрү җиренә 248 *кг* туклыклы минераль ашламалар кертелә. Уртача еллык савым 1 сыердан 3900 *кг* тәшкил итә, 100 *га* а.х. җирләренә — 504 *ц* сөт, 73 *ц* ит җитештерелә (1993). Бөтенсоюз соц. ярышларындагы уңышлары өчен колхоз КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның (1975, 1978, 1979), РСФСР МС һәм ВЦСПСның (1982) күчмә Кызыл байраклары; РСФСР МС һәм ЮС Президиумының Мактау грамоталары (1972) б-н бүләкләнә. 1944–93 тә к-з б-н Ф.Ә.*Галиев* җитәкчелек итә. 1993 тә 3 а.х. җитештерү кооператив хуҗалыгына: «Күңгәр», «Күшәр» һәм «Ташчишмә»гә бүленә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ИСКУ́ЖИН** Зыя (Зәбих) Газим улы (1910, Уфа губ., Сабир волосте Мәксүт а. — 1936), шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе. Оренбург татар пед. техникумын, Казан пед. ин-тын тәмамлый. М.Гафури, Ш.Бабич, Һ.Такташ, М.Әмир һ.б. иҗатына багышланган мәкаләләр авторы.

**ИСЛА́ЕВ** Фәйзелхак Габделхак улы (2.1.1946, Пермь краеның Октябрь р-ны Уразмәт а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2005), проф. (2007). Пермь ун-тын тәмамлый (1970). 1963–66 елларда Уразмәт мәктәбендә лаборант, укытучы. 1966–72 дә «Спецстрой» трестының 6 нчы төзү-монтаж идарәсендә торбалар салучы, Киров исем. з-дта слесарь, смена башлыгы, 1972–73 тә һөнәри-техник уч-щедә укытучы, 1973–84 тә Киров исем. ФҖБнең сәяси мәгариф кабинеты мөдире. 1983–93 тә Пермь а.х. ин-тында укыта. 1990–92 дә гуманитар ф-т деканы. 1993 тән ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты, 1997 дән Тарих ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре. 1998 дән ТРның Мәгарифне үстерү ин-тында: 1998–2007 дә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәре каф. мөдире, 2007 дән шул ук каф. профессоры. Хезмәтләре Россия дәүләтенең дини сәясәтенә, 1755–56 еллардагы *Батырша хәрәкәтенә*, конфессияара мөнәсәбәтләрдә толерантлык формалаштыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Православные миссионеры в Поволжье. К., 1999; Восстание Батырши. Год 1755. К., 2004; Ислам и православие в России: от конфронтации к веротерпимости. Век XVIII. М., 2004.

*Әд.:* Ислаев Файзелхак Габдулхакович // Тюркологи современного Татарстана: Справ. М., 1997.

**ИСЛА́М** (гарәп. إسلام сүзгә-сүз — үзеңне Аллаһка тапшыру, буйсыну), дөньякүләм диннәрнең берсе. 7 йөздә Гарәбстанда формалаша. И.ның төп принциплары *Коръән* һәм *Сөннәдә* тасвирлана. Эчтәлеге дин тәгълиматының 5 баганасында ачыла; 1) әш-шәһадәт — Аллаһның берлеген (*тәүһид*) һәм *Мөхәммәднең* рәсүллеген тану; 2) ас-салат (*намаз* уку, гыйбадәт кылу); 3) ас-саум (*ураза*); 4) әз-зәкят, ярлылар хакына салым түләү (*зәкят*); 5) хаҗ кылу (*хаҗ*). Бу биш кагыйдәнең дүртесе әхлакый характерда, нигездә, алар игътибарны дини тормыштагы гадәтләрне һәм йолаларны үтәүгә юнәлдерәләр, бу исә алга таба хокукның догматикага караганда өстенлекле үсешен билгеләде. Төп юнәлешләре — *сөнниләр* һәм *шигыйлар*. Дөньяда мөселманнарның гомуми саны 1 млрд. 200 млн. кеше (90%ы — сөнниләр). Идел буенда И. тыныч юл б-н тарала. Төбәкнең исламлашу процессында 2 төп факторны аерып күрсәтергә мөмкин: 7–8 йөзләрдә оешып килүче ислам цивилизациясенең нигезен тәшкил иткән Иран, Кавказ һәм Урта Азия б-н күпьеллык сәүдә-икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр; мөселман вәгазьчеләренең эшчәнлеге (беренче фактор аеруча мөһим роль уйный). Диннең таралуы озак еллар дәвамында *Идел буе Болгар дәүләте* һәм мөселман илләре арасында урнашкан үзара мөнәсәбәтләрнең традицион формалары кысаларында бара. Болгарлар өчен исламга кадәрге чор утка, кояшка, суга, бабаларга һ.б. табынулар б-н характерлы. Аллаларның мәҗүси пантеонында (җыелмасында) иң бөеге — күк алласы *Тәңре* була, һәм бу исем алга таба татарларда Аллаһка мөрәҗәгать итүнең бер төрендә сакланып кала. И. таралу барышында исламга кадәрге җирле йолаларның байтагы И.ның төп принципларына каршы килмәүче *гореф-гадәтләргә* әверелә. Әлегәчә сакланып калган *изге урыннар* (әүлия кабере, әүлия ташы, изге таш, изге зират һ.б.) ш.у. мөселман гореф-гадәтләрендә читтән кергән элементларның да булуын раслый. И. Идел буена Урта Азия аша үтеп керә, әлеге төбәктәге дини мәктәпләрнең тәгълиматлары һәм традицияләре, ш.и. хәнәфиләр *мәзһәбе* (к. *Хәнәфиләр*) кабул ителү шуның б-н бәйле. 922 елда Ислам Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми дине булып әверелә (к. *Болгарга әл-Мокътәдир илчелеге. 921–23*). Башкача фикер йөртүчеләргә карата түземлерәк мөнәсәбәттә булган, исламга кадәрге җирле гореф-гадәтләрне киң файдаланган хәнәфиләр мәзһәбе нормаларын куллану көндәлек хокукый гамәл булудан бигрәк, мөселман цивилизациясенең бер өлеше булуны белдергән. *Алтын Урдада* дини-хокукый мохитнең сәясиләштерелүе һәм И.ның формаль-структур җәһәттә ахыргача төзелеп бетмәве беркадәр дәрәҗәдә болгар чорындагы вазгыятьне хәтерләткән. Әйдәп баручы дини-хокукый мәктәпләрнең (мәзһәбләрнең) төп кагыйдәләрен кануньлаштыру (бу процесс ислам дөньясында 11 йөздә үк тәмамлана) бу дәүләттә гамәлгә ашырылмый кала. Бары тик мәҗүси килеш тәхеткә утырган *Үзбәк хан* идарә иткән чорда гына (1312–42) Алтын Урда тулысынча исламлаштырыла, ләкин элеккеге ышанулар йогынтысы гади халык арасында гына түгел, хәтта аксөякләрнең югары катлау вәкилләре, ш.и. *Җучиләр* даирәсендә дә сакланып кала. И.ның һәм *мөселман руханиларының* позицияләре ныгуы *Казан, Әстерхан, Кырым* һ.б. татар *ханлыклары* оешкач тәмамлана. Урта Идел буенда Казан ханлыгы төзелгәч кенә, мәзһәбләрнең берсе булган хәнәфиләрнең хокукый өстенлекләре тулысынча таныла. Әлеге ханлыкта дәүләттә дәрәҗәле урын биләгән мөселман руханиларының катлаулы иерархиясе оеша. *Сәедләр* арасыннан гына сайланган руханилар башлыгы дәүләттә ханнан кала беренче кеше булып санала, тәхеттә ханнар алмашу аралыгында аңа ил б-н идарә итү хокукы бирелә. Казан ханлыгын яулау вакытында җирле халыкның аяусыз көрәшкә күтәрелүендә дини йогынты көчле чагыла. 1555 тә төбәктә яшәүчеләрне, иң беренче нәүбәттә татарларны христианлыкка аудару өчен архиепископ кафедрасы төзелә. Патша Фёдор Иоаннович (1584–98) тарафыннан «барлык мәчетләрне җимереп, аларның тәмам тамырын корыту» турындагы фәрман чыгарыла. Христиан Русенең хакимлек итүен һәм яңадан-яңа идарә ин-тлары кертелүне татар халкы үзенең традицион яшәү рәвешенә һәм милли мәдәниятkә турыдан-туры куркыныч янау буларак кабул итә. Әлеге чорда иҗтимагый-терр. берләшмәнең башка формасы — *җыенның* роле сизелерлек көчәя. 16–18 йөзләрдә Урта Идел буена И. б-н бер үк вакытта диярлек *Нәкышбәндийә* һәм *Ясәвийә* борадәрлекләре б-н бергә үтеп кергән *суфичылык* мистик-аскетизм агымы татарлар арасында үзенең позициясен ныгыта. Суфичылык тышкы куркыныч һәм эчке тотрыксызлык шартларында мөселман җәмгыятьләрен бергә туплау факторы ролен үти. Татар әдәбиятында дөньядагы явызлыкка шәхеснең эчке куәте, рухи байлыгы б-н каршы торырга чакырган Ә. *Ясәви* традицияләре яңа-

ра. Ихтимал, суфичылык ш.у. крәстиян кузгалышларының идеологик базасын хасил иткән, бу чыгышлар өчен шәкерт-мөриднең остаз-*ишанга* карусыз буйсынуына нигезләнгән катгый дисциплиналы махсус структура тудырган. Шулай итеп, суфичылык 16–18 йөзләрдә татар җәмгыятендә барлыкка килгән идеологик, социаль-сәяси бушлыкны өлешчә тутыра һәм татарларның рухи тормышына үзенең йогынтысын 20 йөз башына кадәр саклый. С.Т.Разин җитәкчелегендәге 1670–71 еллардагы, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге 1773–75 еллардагы татарлар актив катнашкан крәстиян сугышлары патша хөкүмәтен милли сәясәткә билгеле бер үзгәрешләр кертергә мәҗбүр итә. Екатерина II нең 1773 елгы Фәрманы «дәүләт төзелеше мәнфәгатьләре б-н килештерелгән тулы түземлелек принципы нигезендә», Россия империясендәге башка диннәргә, шул исәптән И.га карата түземлелек башлангычларын гамәлгә кертә. 1788 дә Екатерина II нең Фәрманы буенча Уфа дини Мөхәммәди канун Җыены (к. *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте*) оештырыла. Ул, патша хакимияте мәнфәгатьләрен күздә тотып, татар руханилары эшчәнлеген тикшереп торырга тиеш була. Ихтимал, традицион мөселман җәмгыяте шартларында дәүләтнең руханилык б-н әлеге берлеге киң массалар аңына йогынты ясауның нәтиҗәле формасы була алыр иде, әмма 18 йөздә татар иҗтимагый фикерендә дөньяга дини карашларның урта гасырларга хас бөтенлеге һәм йомыклыгының җимерелә башлавы, дөньяви элементларның көчәюе тенденцияләре тәгаенләнә. Мәчетләр төзергә рөхсәт алу күпләп мәчетләр төзелүгә, алар карамагындагы мәктәпләр һәм *мәдрәсәләр* ачылуга, 18 йөз ахыры — 19 йөз башында рәсми идеологиягә бәйле булмаган халык мәгарифе системасы формалашуга китерә. 1889 га Оренбург мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы 5 млн. кеше яшәгән терр-ядә 4222 мөселман мәхәлләсенә 7203 рухани зат (ш.и. 60 ахун, 2734 *имам-хатиб*, 2621 *мөдәррис* һ.б.), 7 меңнән артык мәчет исәпләнгән. Казан губернасында 1917 елга 1152 мәчет була, аларда 2648 *мулла* хезмәт итә; 1912 дә 83 мең шәкерт укыган 1088 мәктәп эшли. Алар арасында аеруча мәгълүм булганнары — «*Мөхәммәдия*», «*Касыймия*», «*Мәрҗания*», «Халидия», «*Госмания*», «Гаффария», авыл җирләрендә — «*Буби*», «*Кышкар мәдрәсәсе*», Курса, Ташкичү, Түнтәр, Сатыш һ.б. авылллардагы мәдрәсәләр. Казанда югары типтагы 12 мәдрәсә була, алар каршында 24 урта һәм 13 башлангыч мәктәп эшли. Вакытлар узу б-н әлеге система татарлар арасындагы милли азатлык хәрәкәтенең социаль нигезен яңарту һәм яңа идеяләр тарату өчен интеллектуаль база булып әверелә. 18 йөздә, милли мәгариф системасы оешу б-н бергә, татарларда китап басу эше дә барлыкка килә. 1917 гә кадәр 73,9 млн. данә тираж б-н 10,3 мең исемдә китап басыла. Шуларның 19%ын дини, 30%ын уку-укыту әдәбияты тәшкил итә. Татар телендә вакытлы матбугат 20 йөз башында гына барлыкка килә. Шуңа да карамастан, 1917 гә кадәр Россия терр-ясендә төрле вакытта татарча 100 гә якын исемдә газета-журнал дөнья күрә. Дини басмалар арасында аеруча әһәмиятлеләре — «*Дин вә мәгыйшәт*», «*әд-Дин вә әл-Әдәб*» ж-ллары, «*әл-Галәми әл-Ислами*» г-тасы һ.б. 20 йөз башына татар җәмгыятендә җәдитчелек формалашуга бәйле яңа тенденцияләр барлыкка килә. Җәдитчелек асылында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә демократик принципларны нигезләүче һәм гарантияләүче нормаларга һәм ин-тларга омтылу ята. Совет чорында мөселманнар гамәлдәге дини оешмалар һәм рәсми дини идеология б-н элемтәләрен югалта. 1988 гә ТАССРда теркәлгән 19 мөселман мәхәлләсе кала, алар дини йолаларны сакларга омтыла, әмма халыкны дини агарту мөмкинлекләре булмый. И. рәсми атеистик идеология тәэсиренә азрак дучар булган көнкүреш өлкәсендә саклана. И. мәгарифенең булмавы, мәчетләр санының кимүе дини наданлыкка китерә. 1990 елларда И. Татарстанда яңарыш чоры кичерә. 1992 дә *Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте* оештырыла. Бер үк вакытта мәчетләр каршындагы башлангыч курслар, урта һәм махсус мәктәп-мәдрәсәләрдән алып югары уку йортларына кадәрге (ш.и. 1998 дә *Россия ислам университеты* ачыла) мөселман уку йортлары барлыкка килә. Татарстанда 9 махсус мөселман уку йорты, 986 мөселман оешмасы бар, 1300 мәчет (2009) исәпләнә. Мөселман вакытлы матбугат басмаларыннан «Иман», «Дин вә мәгыйшәт», «Ислам инфо», «Ислам нуры» (Чаллы) г-талары, «Иман нуры» (Казан), «Кыйбла» (Казан) ж-ллары һ.б. дөнья күрә, ТРда «Иман» мөселман нәшрияты эшли.

*Әд.:* Фәхреддин Р. Ислам дине — нинди дин? К., 2009; Малов Е.А. О Татарских мечетях в России. К., 1868; Коблов Я.Д. Религиозные обряды и обычаи татар-мусульман. К., 1908; Валидов Д.Д. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.), М.–П., 1923; Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. К., 1941; Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: Духовная культура. К., 1990; Ислам в татарском мире: история и современность. К., 1997; Государственно-конфессиональные отношения в современном Татарстане. К., 2003; Мухаметшин Р.М. Татары и ислам в XX веке. К., 2003; Религии и религиозные объединения в Республике Татарстан. К., 2004; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Islam in Post-Soviet Russia. L.–N.Y., 2003.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**«ИСЛА́М»**, дини-әдәби җыентык. 1914 елда Истанбул шәһәрендә (Төркия) гомумтөрек телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире — Н.Сабит.

**«ИСЛА́М»**, җыентык, к. «*Ислам мәҗәлләсе*».

**«ИСЛА́М БАЛАСЫ́»**, айлык иҗтимагый-сәяси һәм дини-фәлсәфи кулъязма журнал; «Хакыйкать йолдызы» оешмасы органы. Казанда 1925 елның февраленнән 1928 нең маена кадәр татар телендә 37 саны чыга. Исеме берничә мәртәбә үзгәртелә: беренче санында — «Яшь динче»; 1927 нең гыйнварыннан маена кадәр — «Тукай». Оештыручысы һәм беренче мөхәррире — М.Вахитов исем. мәктәп укучысы И.К.Закиров. Материалларының кайберләре Совет хакимиятенең дингә каршы пропагандасын, татар алфавитын латинлаштыруны гаепли. ОГПУның Татарстан бүлекчәсе «И.б.»н чыгудан туктата. Җинаять эше кузгалтыла; 12 нче мәчет имамы Г.С.Якупов, мөәзин Ш.А.Ибраһимов, журнал мөхәррире З.И.Абдуллин хөкемгә тартылалар; балигъ булмаган авторлар мәктәптән куыла.

*Р.А.Кашапов.*


**ИСЛА́М БӘЙ** (? — 1552), Казан ханлыгының *карачы бәге*. 1552 елның мартында оештырылган, Чапкын бәк Отыч улы җитәкләгән хөкүмәт әгъзасы. Казанда Иван IV явына каршы актив көрәшүчеләрнең берсе (1552). *Казанның яулап алынуы* вакытында һәлак булган дип фаразлана.

**«ИСЛА́М ВӘ МӘГАРИ́Ф»**, 1916–18 елларда Петроградта мөселманнарның мәдәни-мәгърифәт һәм хәйрия җәмгыяте. Оештыручылары — Ф.А.Байрашев, Г.И.Мусин. Төп максаты — мәгърифәт тарату, мөселманнарның мәдәни-әхлакый һәм рухи-дини дәрәҗәсен үстерү. Җәмгыять мохтаҗларга матди ярдәм оештыра, ятимханәләр ача, татар мәдәнияте кичәләре үткәрә, дини китаплар тарата.

**ИСЛА́М ҖӘМГЫЯТЕ́**, Финляндиядә, 1925 елда Хельсинкида төзелгән җәмәгать оешмасы, максаты — Финляндиядә яшәүче татарларның рухи, дини һәм милли гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү. 1809 да Финляндия Россиягә кушылгач, анда Идел буеннан татар солдатлары килеп төпләнә башлыйлар. 19 йөз ахырында сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләр көчәеп китү сәбәпле, Бөек Финляндия кенәзлегендә 1 меңгә якын татар сәүдәгәре исәпләнә. 1925 тә Хельсинкида «Ислам» җәмгыяте оеша, 1945 тә шундый ук исемдәге җәмгыять Тампере шәһәрендә төзелә. Хәзер Финляндиядә якынча 950 татар исәпләнә, шуларның 500 е Хельсинкида яши, биредә аларның — мәчете, мәдәни, спорт һ.б. оешмалары эшли. Төрле төбәкләргә сибелеп гомер кичерүче татар диаспоралары арасында Финляндиядәге И.җ. иң актив милли мәдәният учакларыннан санала.

**ИСЛА́М КАБУ́Л ИТҮНЕ́Ң МЕҢ ЕЛЛЫГЫ́ ШӘРӘФЕНӘ́ САЛЫНГА́Н МӘЧЕ́Т**, к. *Кабан арты мәчете.*

**«ИСЛА́М МӘҖӘЛЛӘСЕ́»**, айлык дини-әхлакый һәм фәлсәфи җыентык. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте (ҮДН) органы. 1924–28 елларда Уфада татар телендә (1925–27 дә елга 6 сан) нәшер ителә. 1926 дан «Ислам» исемендә чыга. Нашире һәм мөхәррире Үзәк Диния нәзарәте рәисе урынбасары — К.*Тәрҗемани*. «Кешеләрнең иминлеге һәм бәхете — дини тормышта!» дигән лозунг астында чыга. Җыентыкның максаты: исламның фән һәм иҗтимагый тормыш б-н тыгыз элемтәдә булуын аңлату; үсеп килүче буынны ислам һәм аның төп принциплары рухында тәрбияләү. Җ.Абызгилдин, М.Буби, З.Камали, М.Магкули, Г.Сөләймани, К.Тәрҗемани, Р.Фәхрет-



М.Г. Исламгалиев.

дин һ.б.ның мәкаләләре басыла. Дини әсәрләр, Коръән сүрәләре, ҮДН пленумы һәм съездлары утырышлары турындагы язмаларга урын бирелә. Дини белем бирүгә, хатын-кыз мәсьәләләренә зур игътибар юнәлтелә. 1927 елгы саннарда Р.Фәхретдиновның Бөтендөнья мөселманнары конгрессына (Мәккә ш.) баруы турындагы хисабы, дөньядагы барлык мөселманнарга халыкара характердагы төрле мәсьәләләр буенча ҮДН өндәмәләре басыла. Урта Азия республикаларында һәм чит илләрдә таратыла. 1927 елгы барлык саннары да Дәүләт сәяси идарәсе тарафыннан тоткарлана. 1928 елда аерым саннары гына чыга, аннан соң җыентык чыгудан туктатыла.

*Әд.:* З ә й н у л л и н Җ.Г. XVIII йөз — XX йөз башында татар рухани әдәбияты. К., 1998; Ю н у с о в а А.Б. Ислам в Башкортостане. Уфа, 1999; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1.

**«ИСЛА́М МӘХӘЛЛӘСЕ́»**, җыентык, к. «*Финляндия ислам мәхәлләсе*».

**ИСЛА́М СӘНГАТЕ́**, к. *Мөселман сәнгате.*

**ИСЛАМГАЛИ́ЕВ** Мөдәррис Габдулла улы (25.10.1945, Саба р-ны Олыяз а.), токарь, Соц. Хезмәт Герое (1977). 1963–66 елларда Таҗикстан ССРның Куйбышев р-ны а.х. пр-тиеләрендә эшли. 1966 дан Усть-Магадан балык комб-тында балык эшкәртүче, 1967 дән Магадан механика з-дында токарь. 1968–70 тә Киров өлкәсенең урман сәнәгате пр-тиеләрендә эшли. 1970–72 дә Полтава р-ны «Сельхозтехника» берләшмәсендә (Украина ССР). 1972 дән КамАЗда: җиһазлар ремонтлау һәм инструментлар з-дында; 1987 дән Яңа эшләнмәләрне гамәлгә кертү һәм үстерү департаментының тәҗрибә-сәнәгать производствосы цехында токарь. КамАЗның 1 нче чираты төзелешендә катнаша. Герой исеме производство йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (1999).

*Әд.:* К ә л и м у л л и н Д. Чаткылар. К., 1979; Герои Социалистического труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Т а у р и н Франц. Передовик КамАЗа Исламгалеев М.А. — Герой 10-й пятилетки. М., 1978; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**ИСЛАМИЯ́Т** ( гарәп. إسلامية), *шәркыять гыйлеменең* исламның барлыкка килүен, таралуын, аның чыганакларын, догматикасының төп кагыйдәләрен, гыйбадәт-йола күрсәтмәләрен, юнәлешләрен, классик гарәп-мөселман текстларын, мөселман теология-фәлсәфә һәм хокук фикерләре эволюциясен, ислам традицияләренең хәзерге заманда җәмгыять үсеше процессларына ясаган йогынтысын өйрәнүче махсус тармагы. 1787 елда Россиядә беренче мәртәбә С.-Петербургта *Коръәннең* гарәп телендәге тулы тексты басыла (бер үк вакытта аның Европа телләреннән рус теленә тәрҗемәләре дөнья күрә), 1818 дә ислам тарихының кульязма мирасы, шәркыять гыйлеме китапларыннан торган китапханәсе булган Азия илләре музее оештырыла. Петербург һәм Казан ун-тларында гарәп, фарсы, төрек телләре укытыла, грамматикалар, сүзлекләр, хрестоматияләр, беренчел мөселман чыганаклары текстларының тәрҗемәләре басыла, Көнчыгыш телләрендәге кульязмалар туплана һәм каталогка салына, Шәрекъ-мөселман илләренә сәяхәтләр оештыру Россиядә И.не үстерүгә көчле этәргеч бирә. Университет курслары программаларына Коръән нигезләрен, мөселман хокук белеме тарихы һәм теориясен өйрәнү кертелә. Идел буенда, Дагстан, Кавказ аръягында һәм Кырымда табылган татар, гарәп, фарсы телләрендәге эпиграфик язмаларны туплау, аларны бастыру тикшеренүләрнең төп юнәлешенә әверелә. 1807 дә Казан ун-тында Шәрекъ телләрен өйрәнү өчен Шәрекъ бүлеге оештырыла. 1863 тә Петербург ун-тының Шәрекъ ф-тында Шәрекъ тарихы, Лазарев Шәрекъ телләре ин-тында мөселман Шәрегы тарихы кафедралары ачыла. В.Ф.Гиргас һәм В.Р.Розенның 1876 да нәшер ителгән «Гарәп хрестоматиясе» (СПб.) гарәп телен өйрәнүче студентларны грамматик, поэтик, тарихи материалларны, Коръәнне укырга әзерләү. 1860–80 дә Казанда И.Ф.Готвальдның («Гарәп-рус сүзлеге тәҗрибәсе» — «Опыт арабско-русского словаря», 1863) һәм В.Ф.Гиргасның («Коръән һәм гарәп хрестоматиясе өчен сүзлек» — «Словарь к арабской хрестоматии и Корану», 1881) Коръәнне уку өчен әзерләнгән махсус сүзлекләре басылып чыга. Ислам мәдәниятле халыкларның тарихын һәм мәдәниятен яктыртуда дини хезмәтләрне гарәп, фарсы, татар телләрендә Петербургта, Мәскәү, Казан, Сәмәрканд, Ташкент, Баку, Бакчасарай, Оренбург, Троицк, Уфа һ.б. шәһәрләрдә бастырган мөселман нәшриятлары мөһим роль уйный. 20 йөз башында М.*Бигиев*, З.*Камали* һәм К.*Мотыйгый*, татарча тәфсирләр (Коръәнгә шәрехләүләр) традицияләрен үстереп, Коръәнне татар теленә тәрҗемә итәргә омтылыш ясыйлар. 1912–13 тә Император шәркыять гыйлеме җәмгыяте С.-Петербургта И. буенча курслар оештыра һәм «*Мир ислама*» ж-лын (мөхәррирләре В.В.*Бартольд*, Д.М.Позднеев) чыгара. 19 йөзнең соңгы чиреге — 20 йөз башында *җәдитчелек* иҗтимагый-сәяси хәрәкәте барлыкка килә, аның вәкилләре игътибарны исламны (Г.*Баруди*, М.Бигиев, К.*Тәрҗемәни*, З.*Кадыйри*, Г.*Баязитов* һ.б.) һәм Россия мөселманнары арасында мәгърифәтчелекне реформалаштыру (И.*Гаспринский*, Р.*Фәхретдин*, Ф.*Кәрими*, З.Камали, Г.*Буби* һ.б.) зарурлыгына юнәлтәләр. Россиядә И.нең үсеше иң элек тикшеренүләрнең тарихи-филологик (тарихи-мәдәни) юнәлешле һәм комплекслы булуларына бәйле. 19 йөз — 20 йөз башында әлеге юнәлешнең иң зур вәкилләре булып исламны тарихи, географик, этнографик, мәдәни, икътисади, сәяси һәм көнкүреш аспектларда өйрәнгән Е.А.Беляев, А.О.Мухлинский, Д.А.Хвольсон, В.В.*Григорьев*, В.Ф.Гиргас, В.Р.Розен, А.Э.Шмидт, А.Е.*Крымский*, Н.А.Медников, И.Ю.*Крачковский*, В.В.Бартольд санала. Бу чорда Россиянең фәнни һәм мәдәни үзәкләрендә Коръәннең кульязма коллекцияләре, кучермәләре һәм өлешләре туплана. Бер үк вакытта 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе базасында исламны өйрәнүче 2 агым: академик университет (Г.К.*Казимбәк*, И.Н.*Березин*, А.П.*Смирнов*, И.Н.*Холмогоров*, В.В.*Вельяминов-Зернов* һ.б.) һәм миссионерлык (Г.С.*Саблуков*, Н.И.*Ильминский*, Е.А.*Малов*, М.А.*Машанов*, Н.П.*Остроумов*, һ.б.) агымнары формалаша. 1920 елларда ТАССРда И.ның үсеше Н.Ф.*Катанов*, Я.Д.*Коблов* һ.б. тикшеренүләре б-н бәйле. Ислам цивилизациясе халыклары классик рухи мирасының тарихи чыганакларын һәм ядкәрләрен өйрәнү, тәрҗемә итү һәм шәрехләү б-н Х.Д.*Френ*, П.А.Грязневич, Х.И.Кильберг, М.-Н.О.Османов, А.С.Тверитинова, А.И.Фалина, И.М.Фильштинский, Ә.Б.*Халидов*, Т.А.Шумовский һ.б. шөгыльләнә. О.Ф.Акимушкин, О.Г.Большаков, В.В.Наумкин, М.Б.Пиотровский, С.М.Прозоров, Е.А.Резванның И. өлкәсендәге филологик-тарихи тикшеренүләре яңа мөселман чыганакларының киң кулланылышы б-н аерылып торалар. Совет чорында татар галимнәре төп игътибарны исламны атеизм күзлегеннән чыгып тәнкыйтьләүгә юнәлтә (Р.Г.*Балтанов*, Р.Ә.*Нәбиев*, Г.М.*Гафуров-Чыгътай*, Г.Ш.*Гобәй*, Б.Ишемгулов, З.А.Ишмөхәмmәтов, Г.Касыймов, К.Ф.*Фасиев* һ.б.), тарих белеме өлкәсендә дә тикшеренүләр алып барыла (Н.А.Мәҗитова, Р.М.*Вәлиев* һ.б.). Илнең исламият галимнәре игътибары үзәгендә рәсми һәм халык исламын өйрәнү б-н бәйле төрле темалар була. 1980–90 да дөнья сәясәте һәм икътисадында «ислам факторы» көчәю нәтиҗәсендә, исламият проблемалары Россия шәркыять гыйлемендә актуаль юнәлешкә әверелә. Хәзерге исламият галимнәренең (А.А.Игнатенко, Г.М.Кәримов, Р.Г.Ланда, А.В.Малашенко, Р.М.*Мөхәммәтшин*, А.Б.Юнысова һ.б.) хезмәтләрендә атеистик һәм сәясиләштерелгән принциплардан чигенү күзәтелә. Россиядә, Мәскәү һәм С.-Петербургтан кала, Түбән Новгород, Казан, Уфа һ.б. шәһәрләрдәге академияләр һәм ун-тлар каршында исламият үзәкләре үсеш ала. 20–21 йөзләр чигендә исламият гыйлеме буенча язылган хезмәтләрдә тарихка, чыганакларны өйрәнүгә, тарих белеме үсешенә, социология һәм политологиягә караган проблемалар махсус аерып күрсәтелә.

*Әд.:* Ф ә х р е д д и н Р. Ислам дине — нинди дин? К., 2009; Ш м и д т А.Э. Очерки истории как религии. СПб., 1912; Б а р т о л ь д В.В. Сочинения. Т. 6. Работы по истории ислама и Арабского халифата. М., 1966; Б е л я е в Е.А. Арабы, ислам и

Арабский халифат в раннее средневековье. М., 1966; Мусульманское право (структура и основные институты). М., 1984; Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция. М., 1985; Грюнебаум фон Г.Э. Классический ислам. Очерк истории (632–1258). М., 1986; Сюкияйнен Л.Р. Мусульманское право. Вопросы теории и практики. М., 1986; Суфизм в контексте мусульманской культуры. М., 1989; Ислам: Историограф. очерки. М., 1991; Валеев Р.М. Из истории Казанского востоковедения середины — второй половины XIX в.: Гордий Семенович Саблуков — тюрколог и исламовед. К., 1993; Хрестоматия по исламу. М., 1994; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20-гг. XX в.). К., 1998; Средневековая арабская философия. Проблемы и решения. М., 1998; Мухаметшин Р.М. Татары и ислам в XX веке. К., 2003.

*Р.М.Вәлиев.*

**ИСЛА́МОВ** (Ислямов) Исхак Ибраһим улы (27.6.1865, Кронштадт ш. — 4.6.1929, Төркия), диңгезче, географ-гидролог, генерал-майор (1917). Диңгезчелек ведомствосының техник уч-щесен (1882), Николай диңгезчелек академиясен (С.-Петербург) тәмамлый. 1885–99 елларда 1 нче, 6 нчы, 8 нче, 9 нчы флот экипажлары составында; «Разбойник» клиперы, «Наварин» эскадра броненосецының кече, өлкән штурманы, Баш гидрография идарәсенең метеорология бүлеге мөдире ярдәмчесе, практик эшләр үткәрү комиссиясе әгъзасы; Җир шары тирәли сәяхәтләрдә, Кронштадт портын ныгыту буенча гидрография эшләрендә, Каспий диңгезенең Кара Бугаз-Гол бугазында үткәрелгән тикшеренүләрдә катнаша. 1900–04 тә «Амур» мина транспортында вахта башлыгы. 1904 тә Тын океан флотының «Севастополь» эскадра броненосецының өлкән, соңрак флагман штурманы. 1904–05 тә рус-япон сугышында катнаша. 1905 нең мае — 1906 ның апрелендә Төньяк диңгез юлы буйлап Гамбург шәһәреннән Енисей елгасы тамагына кадәр кораблар үткәрү экспедициясен җитәкли. 1907–08 дә Балтыйк флотында хезмәт итә: С.-Петербургта хәрби-диңгез мәхкәмәсе әгъзасы, «Кораблар төзү һәм тәэминат баш идарәсендә сугыш чоры хәлләре буенча килеп туган эшләрне хәл итү» комиссиясе әгъзасы, Диңгез корпусының өлкән офицеры, экипаж мәхкәмәсе рәисе. 1909–11 дә «Бакан» транспорты, «Вихрь» канонер көймәсе командиры, «Шквал» канонер көймәсендә 1 нче ранг капитан ярдәмчесе, Амур елга флотилиясе штабы башлыгы. 1912–14 тә яңадан Балтыйк флотында, 1914 тә төньякны тикшерүче Г.Я.Седовның югалган экспедициясен эзләү б-н җитәкчелек итә. 1915 тә Кара диңгезгә җибәрелә; Төркия яр буена десант төшерү пункты коменданты, база башлыгы. 1916 да Иоканг базасы башлыгы, армия, флот һәм эшчеләрнең Гельсингфорс мөселман башкарма ком-ты әгъзасы. 1917 дә отставкага чыга. Гражданнар сугышы вакытында ак армиянең Кара диңгез флотында хезмәт итә. Төркиягә китә, диңгез уч-щесендә (Истанбул) укыта. Рус флотына багышланган мәкаләләр сериясе, рус телендәге татар теле тамырлары сүзлеге авторы. 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ахметшин Ш., Гришин Я., Насеров Ш. Генерал-майор И.И.Ислямов // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 3/4; Султанбеков Б. Ислямовы: гордость российского флота и авиастроения США // Татарстан. 2004. № 1.

**ИСЛА́МОВ** Рәмил Фәнәви улы (14.9.1958, БАССРның Балтач р-ны Госман а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2002). Башкорт ун-тын тәмамлый (1987). 1990 елдан ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли (2002 дән әдәбият белеме бүлеге мөдире, 2007 дән фәнни эшләр буенча директор урынбасары, 2009 дан кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсен җитәкли). Хезмәтләре урта гасырлар төрки, төрки-татар әдәбиятына карый.

Хезм.: Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. К., 1998; Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се. К., 2001.

**ИСЛА́МОВ** Рөстәм Роберт улы (16.4.1965, Казан), гистолог, мед. фән. д-ры (2005). 1988 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук патологик анатомия кафедрасында, 1989 дан гистология кафедрасында эшли. Германиядә (1993–94), Көнчыгыш Каролина ун-тында (АКШ, 2001–03) фәнни эштә. Хезмәтләре мотонейроннарның җәрәхәтләрдән соңгы сыгылмалыгын, мотонейроннарны җәрәхәтләрдән соң регенерацияләүдә эстрогеннар ролен билгеләүгә карый.

Хезм.: Влияние янтарной кислоты на ишемические повреждения скелета и сердечной мышцы в эксперименте. Критическая ишемия // Сб. трудов III Междунар. конгр. Сев. стран и регионов. Петрозаводск, 1999 (автордаш).

**ИСЛА́МШИН** Рәшит Әхәт улы (27.10.1939, Апас р-ны Чүри-Бураш а.), педагог, пед. фән. д-ры (1996), проф. (1993), ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1970, 1989). 1962 елда Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Апас урта мәктәбендә укыта, 1965 тән ВЛКСМның Апас райкомы секретаре. 1967 дән Казанда: урта мәктәптә физика укытучысы; 1970 тән Татарстан укытучылар белемен күтәрү ин-тында (1993 тән ТР Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-ты): методист, физика кабинеты мөдире, директор (1984–93), ректор (1993–2004). 2005 тән ТР Мәгарифне үстерү ин-тының профессор-консультанты. Урта мәктәпләр өчен физика дәреслекләре һәм уку ярдәмлекләре, педагогларга өзлексез белем бирү мәсьәләләре турында фәнни-методик мәкаләләр авторы. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының К.Д.Ушинский медале б-н бүләкләнә (2004).

Хезм.: Связь преподавания физики с трудовым обучением. К., 1986; Моделирование личностно-ориентированного обучения учителей в системе повышения квалификации. К., 1997 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Рәшит Исламшин // Мирас. 1998. № 1; Мусин Ф. Галим һәм мәгърифәтче // Мирас. 1998. № 10.

**ИСЛА́МШИНА** Тәслимә Гайсә кызы (23.3.1939, Оренбург өлкәсенең Тоцк р-ны Әмирхан а.), социолог, социология фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). Урал пед. ин-тын тәмамлый (1961). 1961–62 елларда Казакъстан ССР Курдай р-нының Михайловка авылы мәктәбендә укытучы; 1962–64 тә ВЛКСМның Курдай райкомы секретаре. 1964–65 тә ТРның Биектау р-ны Константиновка авылында мәктәп укытучысы; 1965–73 тә ВЛКСМның Биектау райкомы секретаре. 1973 тән Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты). Хезмәтләре теоретик социология, этносоциология, социаль стратификация, демография мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Возвращение утраченного: Диалог о национальном. К., 1991; Этнические ценности полиэтнического общества: Социол. очерк. К., 1996; Молодёжные субкультуры. К., 1997 (автордаш); Дифференциация ценностных ориентаций студентов // Социол. исследования. 1999. № 8; Социология. К., 2004 (автордаш).

**«әл-ИСЛА́Х»**, шәкертләрнең яшерен сәяси оешмасы. 1904 ел ахырында Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә оеша, тиз арада шәкертләрнең киң хәрәкәтенә әверелә. Максатлары: бердәм программа нигезендә мәдрәсәдә укыту системасын үзгәртеп кору, укытыла торган дөньяви фәннәрне күбәйтү, яңа тикшеренүләр нигезендә илаһият фәнен укытуны яңарту, мәгариф системасын демократияләштерү. Эшен Россия с.-д. партиясе йогынтысында алып бара. Үзәге Казанда була. Җитәкчесе — Ф.*Әмирхан*. Әгъзалары — Р.Алуши (Ибраһимов), И.Әмирханов, Х.Әбелханов, В.Бәхтияров, Н.Мамин, Габдрахман һәм Гарифҗан Мостафиннар, М.Укмаси, К.Патый. Филиаллары Касыйм, Оренбург, Троицк, Уфа, Чистай һ.б. шәһәрләрдә барлыкка килә. Оешма әгъзалары 1905–07 еллардагы рев-циядә актив катнашалар: 1905 нең октябрендә Казанда полицияне коралсызландыралар, халык милициясе оештыралар. 1906 ның 27 февралендә Казанда шәкертләр забастовкасын оештыралар, анда 1,5 меңләп кеше катнаша. «әл-И.» башлангычында 2 яшерен Бөтенроссия татар шәкертләре съезды чакырыла (1906 ның 10–15 мае, 1907 нең 1–6 мае). 1907 нең 2 нче яртысында «әл-И.» оешмасы яшәүдән туктый, иң актив әгъзалары шул ук исемдәге газета тирәсендә тупланалар.

*Әд.:* Фахрутдинов Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX – начале XX века (очерки политической истории). К., 1998.

*Р.Г.Әмирханов.*

**«әл-ИСЛА́Х»** («الاصلاح» — «Реформа»), атналык газета. Шул исемдәге оешма органы. 1907 елның 3 октябреннән 1909 ның 22 июленә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барлыгы 68 саны чыга. Рәсми нашире һәм мөхәррире — Ә.*Бәхтияров*, гамәлдә — Ф.*Әмирхан*. Газетада Х.Абоздров, И.Акчура, Й.Акчура, С.Әмирхания, Ш.Әхмәров, К.Бәкер, А.Бикколов, Г.Галимов, Г.Гафуров-Чыгътай, Г.Ибраһимов, Г.Камал, С.Рәмиев, Г.Сәгыйдов, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Р.Фәхретдин һ.б.ның мәкаләләре һәм әсәрләре басыла. «Белем һәм мәгариф — барлык халык бәхетенең нигезе!» шигаре астында чыга. Мәгариф системасын үзгәртеп кору, яңа ысул б-н укытуны кертү, халыкта белем алуга омтылыш тәрбияләүне пропагандалый. «Уку йортлары эшчәнлеге турында» дигән рубрикада укучылар хатлары урын ала. Икътисад, дин һәм фәлсәфә, хатын-кызларның хокуклары


К.Х. Исмаев.


Г.Г. Исмәгыйлев.

мәсьәләләре, татар язуын латин әлифбасына күчерү проблемасы яктыртыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ИСЛА́Х»** («إصلاح» — «Реформа»), әдәби-фәнни һәм сәяси газета. 1907 елның 15 апреленнән 22 маена кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 3 саны чыга. Җаваплы мөхәррире — А.Дашкин, нашире — А.Хаҗиев. «И.» татарларның берләшүе, субэтносларга (Әстерхан, Себер, Казан һ.б. татарларга) бүленүенә юл куймау идеясен яклый. Дәүләт Думасын таратуга, патша хөкүмәтенең колониаль сәясәтенә, православие миссионерларының кысрыклавына каршы чыга. Дини фанатизмны тәнкыйтьли, татарлар җәмгыятендәге торгынлык күренешләренә каршы чыга, фән, мәгариф һәм мәдәниятне үстерү мәсьәләләрен күтәрә. Дәүләт Думасы эшчәнлеген, эчке һәм тышкы сәясәт яңалыкларын, дөньяви һәм дини белем бирү торышын һ.б. мәсьәләләрне яктырта. Шактый материаллар Әстерхандагы «Шураи ислам» җәмгыяте, «Борһане тәрәкъкый» г-тасы, «Дар әл-әдәб» мәктәбе эшләрен яктыртуга багышлана. «Укучылар хатлары» дигән даими рубрикасы була.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ИСЛӘ́ЕВ** Рифад Габбас улы (1.4.1953, Ленинград), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1995), проф. (1995). Ленинград пед. һәм финанс-икътисад ин-тларын (1980, 1986) тәмамлый. 1980–82 дә Ленинград пед. ин-тында фәнни хезмәткәр, 1982–92 дә Ленинград финанс-икътисад ин-тында укытучы. 1990–95 тә Региональ-сәяси тикшеренүләр үзәге ген. директоры. 1995 тән Инженерлык икътисады академиясенең (С.-Петербург) Региональ икътисад һәм идарә итү ин-ты директоры һәм муниципаль идарә итү каф. мөдире. Хезмәтләре региональ икътисад сәясәтенә, терр. табигый һәм социаль-икътисади системаларны тотрыклы үстерүгә карый. И. тарафыннан региональ үсешнең дәүләт стратегиясе һәм региональ икътисад сәясәте нигезләре эшләнә. РФнең тотрыклы үсеш моделенә күчерү концепциясе проекты өчен РФ Хөкүмәте бүләге һәм дипломы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные положения концепции перехода Российской Федерации на модель устойчивого развития. СПб., 1995; Региональная экологическая политика: принципы формирования и механизмы реализации. СПб., 1995.

**ИСЛӘ́Й** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Каргалы елгасы буенда. 2008 елда 241 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, мич чыгару, балта эше, киез — киез итек басу һәм йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә мәдрәсәләре булган 2 мәчет, су тегермәне, 6 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3200 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 865, 1897 дә — 1466, 1908 дә — 1440, 1920 дә — 1793, 1926 да — 1262, 1938 дә — 1116, 1949 да — 754, 1958 дә — 724, 1970 тә — 684, 1979 да — 467, 1989 да — 284, 2002 дә — 304 кеше.

**ИСЛӘЙТА́Р УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**. Биектау һәм Әтнә р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1935 елда оештырыла. Илләт елгасы үзәнендә урнашкан урман массивы 1918 гә кадәр элекке Казан губернасы Царёвококшай өязе казна урманчылыгы составына керә. Урман хуҗалыгы чикләре берничә тапкыр үзгәрә. 2007 ел башына И.у.х.ның гомуми мәйданы 17104 *га*, ш.и. урман мәйданы 16608 *га*. Урман хуҗалыгы дирекциясе — Биектау р-ны Наратлык авылында. Эшләүчеләр саны — 110 кеше.

1 нче төркем урманнар 13415 *га* мәйданны били, ш.и. эрозиягә каршы урманнар — 1021 *га*, су саклагыч урманнар — 7754 *га*, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен әһәмиятле урманнар — 4617 *га*, аеруча саклаулы табигать терр-яләре — 23 *га*. 2 нче төркем җирле әһәмияткә ия урманнар 3689 *га* мәйданны били, урман культуралары 4837 *га* мәйданны алып тора. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 37%, урта яшьтәгеләр — 33%, өлгереп килүчеләре — 18%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 12%. Кулдан утыртылган яшь урманнардан һәм утыртмалардан торучы ылыслы урманнар 6545 *га* мәйдан били, бонитет классы 1а-2; агач запасы 1224 мең $м^3$. Чыршы урманнарының мәйданы зур түгел (883 *га*). Юкә урманнары (1536 *га*) төп кулланылыштан төшереп калдыру нәтиҗәсендә сакланган һәм умартачылыкның даими базасы булып тора. Моннан тыш, юкә төп үсентеләре исәбенә яңара һәм барлык утыртмалар арасында диярлек үсеп чыга. Каенлыклар (2986 *га*, агач запасы 481 мең $м^3$) һәм юкәлекләр (1665 *га*, агач запасы 313 мең $м^3$) төп урманнар урынында икенчел бергәлекләр хасил итәләр. Үсентедән үсеп чыккан, тәбәнәк имәнлекләрнең аерым кишәрлекләре очрый. Аларның гомуми мәйданы 2258 *га*, агач запасы — 281 мең $м^3$.

Төп кулланылышка еллык урман кисү 10 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 539 *га* мәйданда кисү эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 6 мең $м^3$ тан күбрәк агач әзерләнә. 60 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, ерым-сыза утыртмалары — 89 *га* мәйданда. И.у.х. халык хуҗалыгы товарлары (пычкы материаллары, каплау һәм койма такталары, буралар) җитештерә. 2007 ел ахырында шул ук исемдәге урманчылык дип үзгәртелә.

**ИСЛЕ́ БАШАКЧЫ́К** (Anthoxanthum), кыяклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — гади И.б. (A. odoratum) очрый. Респ-каның барлык р-ннарында, сирәкләнгән урманнарда, су басмый торган болыннарда, көтүлекләрдә үсә. 20–30 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек, тамыр системасы кыска, чагыштырмача зур булмаган чирәмлекләр (кәс) хасил итә. Сабы куыш, шома. Яфраклары буйлы, элпәле, үткен телле. Чәчәге — башаксыман себеркәч. Җимеше — бөртекчә. Май–июньдә чәчәк ата, июль–августта җимеше өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив органнардан үрчи. Җир асты өлешендә печәнгә үзенчәлекле ис бирүче кумарин бар. Халык медицинасында үсемлек төнәтмәсе ютәл вакытында, йокысызлыктан файдаланыла. Үсемлек чәйләре составына керә. Сабаклары һәм яфраклары парфюмериядә кулланыла.

**ИСМА́ЕВ** Кәримулла Хөснулла улы (11.7.1898, Казан губ., Тәтеш өязе Иске Кармалы а. — 1978, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе. Казан политехник ин-тын тәмамлый (1920 еллар башы). 1918 елда Казан губернасы Тәтеш өязенең Богородск авылында халык судьясы, соңрак Тәтеш шәһәре коменданты. Гражданнар сугышында катнаша, адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы сугыша (1919). 1920 дә Буа кантоны башкарма ком-ты рәисе, ВКП(б)ның Тәтеш канткомы секретаре. 1921–22 дә Дәүләт банкының Казан конторасы управляющие иптәше (урынбасары). 1923–24 тә Бохара Центросоюзы идарәсе рәисе урынбасары, 1926–27 дә Татсоюз идарәсе рәисе. 1928–30 ТАССР ХКС рәисе. 1935 елдан хакимият-хуҗалык эшендә.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Гамир Әхмәтгариф улы (3.3.1939, БАССРның Күгәрчен р-ны Калдар а.), хирург, мед. фән. канд. (1971), ТР һәм РФнең атказ. табибе (1978, 1987). 1962 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук 1 нче хирургия кафедрасында эшли. 1964 тән Түбән Кама үзәк р-н хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире. 1984 тән «Түбән Кама күп профильле 3 нче шәһәр хастаханәсе» муниципаль унитар пр-тиесе баш табибе. 1972–73 елларда чит илдә (Нигерия Респ-касында) командировкада була. Хезмәтләре хирургиягә карый. И. тарафыннан эндоскопик диагнозлау проблемасы тикшерелә, ашказаны яман шеше вакытында лапароскопия алымын куллану гамәлгә кертелә (1971), йөрәгендә авыр формада ишемия булган авыруларны хирургик дәвалау алымнары (миокардны туннельләндерү операциясе) эшләнә (1996–2005). Дуслык, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданы (1987).

Х е з м.: Роль лапароскопии в диагностике рака желудка // Хирургия. 1971. № 5; Повторные операции после прямых методов реваскуляризации //

Бюл. НЦССХ им. А.Н.Бакулева; Хирургическое лечение аневризма восходящего отдела аорты с коронарным синдромом. Материалы международного конгр. хирургов. Петрозаводск, 2002 (автордаш).

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Гомәр Гыйммран улы (15.6.1907, Чиләбе ш. — 8.11.1983, Үзбәкстан ССР, Әндижан ш.), актёр, режиссёр. Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1967). Казан сәнгать-театр техникумын тәмамлый (1928), бер үк вакытта Мәскәүдә Үзәк театр сәнгате ин-тында актёрлык һәм режиссёрлык осталыгына өйрәнә (1935, И.Я.Судаков классы). 1926–31 елларда Татар акад. театрында сәхнә инспекторы, 1934–37 дә шул ук театрда режиссёр. Театрда куйган беренче спектакле — «Ил үскәндә» (Т.Гыйззәт, 1930). 1934 тә диплом алды практикасына кайткач, театр хезмәткәрләре өчен К.С. Станиславский системасын өйрәнү буенча семинар үткәрә; шул нигездә сәнгать хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү ин-ты оештырыла. Укыту эшенә Г.Ф.Линсцер, Ю.А.Муко, Г.В.Хавис һ.б. җәлеп итеlә. Ин-тта укучылар арасында З.Солтанов, Ш.Шамильский, К.Шамил, Х.Уразиков, Г.Ибраһимова, М.Шәриповалар була. Куйган спектакльләре — «Тормыш чакыра» («Жизнь зовёт» В.В.Билль-Белоцерковский, 1934), «Чаткылар», «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт, 1935, 1937), Ф.Вольфның «Профессор Мамлок» (1935), «Дошманнар» («Враги», М.Горький, 1936), «Яшь гомер» (Г.Коләхмәтов, 1936), «Галиябану» (М.Фәйзи, 1936), «Таш кунак» («Каменный гость», А.С.Пушкин, 1937). И. режиссурасына сәхнә хәрәкәтләрендә сәяси тенденциозлык, тирән социаль анализ һәм кискен публицистика б-н психол. дәлилләүне бергә бәйләп алып бару хас. Татар театры сәхнәсендә К.С.Станиславский системасын гамәлгә кертергә омтыла, спектакльне эшләгәндә, актёрларны сәнәгать пр-тиеләренә алып барып, эшчеләр б-н пьесалар уку һәм фикер алышулар оештыра. И. спектакльләре матбугатта үткен бәхәсләр тудыра. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Татар акад. театры актёрларының башкару осталыгы шактый үсә, театрның алга таба үсеш юнәлеше билгеләнә. 1937 дә илдә социаль-сәяси хәлләрнең кискенләшүе аркасында репрессияләр башлангач, Казаннан китәргә мәҗбүр була. 1938–43 елларда Симферополь татар драма театрында режиссёр, 1944–71 дә Әндижан үзбәк муз.-драма театрында режиссёр, 1957–60 та баш режиссёр. Анда ул У.Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» (1945), Уйгунның «Хөррият» («Хуррият», 1959), А.Н.Островскийның «Урман» («Лес», 1960) һ.б. әсәрләрне сәхнәләштерә. 1950 дә репрессияләнә; 1954 тә аклана.



Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» пьесасы буенча куелган спектакльдән күренеш. 1936. Режиссёры Г.Г. Исмәгыйлев.

*Әд.:* А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992.

*Ю.А.Благов.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Зинфир Ришат улы (15.10.1947, БАССРның Нуриман р-ны Байгилде а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1988), проф. (1991). 1969 елда Новосибирск ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА Себер бүлегенең Катализ ин-тында (Новосибирск ш.) эшли, лаб. мөдире (1980 нән). Хезмәтләре физ. химиягә, гетероген катализга, каталитик реакцияләр механизмына, йөрткечләр һәм катализаторлар синтезына карый. Водородның, спиртлар һәм азотлы органик кушылмаларның, ш.у. гетероген-гомоген каталитик оксидлашу реакцияләре механизмын ачыклый. Ягулыкларның экологик чиста каталитик януының фәнни нигезен төзи. Автотранспортта эшкәртелгән газларны нейтральләштерү катализаторын һәм системасын, җылылык электр станцияләрендәге газ төтенен чистарту катализаторын эшли. Күкертле водородны турыдан-туры күкерткә оксидлаштыруны гамәлгә ашыра, күкертле водородтан арындыру процессын эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 95 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Разработка, создание производства и перспективы использования блочных катализаторов для защиты окружающей среды в России // Хим. пром-сть. 1996. № 4; Catalysis in energy production in perspectives in catalisis // Chemistry for 21-st century monograph. Oxf., 1992 (автордаш); A.Role of Catalysis for the Destruction of Wastes from the Nuclear Industry // Catalysis Today. 2000. V. 55 (1).

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Ильяс Идрис улы (1.10.1954, Мари АССРның Мари-Төрек р-ны Хлебниково а.), хисаплау техникасы һәм мәгълүмат технологияләре гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998). 1978 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, ГИПОда эшли. 1982–98 дә Үзбәкстан ФА «Кибернетика» ФҖБнең «Алгоритм» фәнни-тикшеренү ин-тында. 1998 дән Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ин-тында информатика һәм югары матем. каф. мөдире. Хезмәтләре дискрет эверелдергечләр, сигналлар һәм сурәтләрне санлы эшкәртү теориясенә карый. Өлешчә полиномиаль функцияләрнең гомумиләштерелгән ортогональ базисларын, Радемахер һәм Уолшның авыш функцияләре дискрет системаларының теоретик нигезләрен, ш.у. дискрет эверелдергечләр нигезендә сигналларны һәм сурәтләрне санлы эшкәртү ысулларын, алгоритмнарын һәм хисаплау структураларын эшли. Уйлап табуга 10 лап авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Обобщённые дискретные базисы кусочно-полиномиальных функций // Докл. АН Респ. Узбекистан. 1994. № 8 (автордаш); Спектральные алгоритмы многомерной полиномиальной аппроксимации // Мат. моделирование. 1996. № 8 (автордаш); Наклонные функции Радемахера: свойства и применения в задачах цифровой обработки сигналов // Изв. вузов. Радиоэлектроника. 1996. № 12.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Мәгъсүм Фәсәх улы (30.11.1936, Пермь өлкәсенең Краснокамск ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1989), Мари Респ-касының, ТРның атказ. табибе (1994, 1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). 1963 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, ТР мед. учреждениеләрендә эшли. 1965 тән Казан мед. ун-тында (бүленеп, 1974–77 дә Гвинеядә Конакри политехник ин-тының мед. ф-тында нерв авырулары курсы мөдире), 1987 дән невропатология, нейрохирургия һәм мед. генетикасы каф. мөдире. Хезмәтләре вегетатив нерв системасы патологиясенә, церебраль инсультлар вакытында баш мие кәүсәсенең ретикуляр формациясе патоморфологиясенә, баш миендә кан тамырлары авырулары килеп чыгу шартларын өйрәнүгә карый. И. вегетатив эшчәнлек бозылу билгеләрен реабилитацияләү өчен *димефосфон* препаратын тәкъдим итә. Дәүләт бүләге «Димефосфон — нерв системасы эшчәнлеген җайга салучы үзенчәлекле дару препараты» дигән хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Неврология. К., 1975; Вазоактивное средство, нормализующее функции вегетативной нервной системы. К., 1985.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Муса Иса улы (15.9.1911, хәзерге Курган өлкәсенең Усть-Уйск р-ны Дубровная а. — 4.3.1993, Алма-Ата), зоолог, биол. фән. д-ры (1966), проф. (1976). Казакъстан ун-тын тәмамлаганнан соң (1941), «Барса-Килмәс» саклаулыгында (Кызыл Урда өлкәсе, Казакъстан ССР) эшли. 1946–70 елларда Казакъстан ССР ФАнең Зоология ин-тында, 1970–80 дә Казакъстан пед. ин-тының зоология каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләренең авырулары эпизоотологиясенә, патогенезына, патоморфологиясенә һәм диагностикасына карый. Гельминтозларны дәвалау һәм химик профилактика үткәрү алымнарын тәкъдим итә. Кимерүчеләрнең, акчарлакларның яшәеш циклын һәм таралу шартларын тикшерә. Казакъстанда саклау чараларына аеруча мохтаҗ ау хайваннары төрләренең запасын ачыклый.

Х е з м.: Экология ландшафтных грызунов Бетпак-Далы и Южного Прибалхашья. А.-А., 1961; Остров куланов. Заповедник «Барса-Кельмес». А.-А., 1973; Млекопитающие Казахстана: В 2 т. А.-А., 1967–77 (автордаш).


**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Нәҗип Фәйзрахман улы (псевд. — Нәҗип Нәкъкаш) (30.7.1948, Мамадыш р-ны Үсәли а.), әдәбият белгече, рәссам-хаттат, график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (2001). 1980 еллар ахырыннан татар хаттатчылыгы сәнгате яңарышына күп көч куя; график рәвештә һәм пыялада, кайвакыт көзгедә нәкышь б-н башкарылган шәмаилләр (к. *Шәмаил*), мәдәният, сәнгать, сәясәт эшлеклеләренә багышланган *тугралар* һәм *шәҗәрәләр* авторы; китап бизәүче. Хаттатчылык сәнгатенә Б.И.Урманчедан өйрәнә. Нигездә, *гарәп язуы үрнәкләре* б-н эш итә. И.нең шәмаилл-

рендә Коръәннән текстлар, Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләре, нәсыйхәт бирүче фәлсәфи әйтемнәр, әдәби әсәрләрдән өзекләр, шигъри юллар, мәкальләр һ.б. китерелә («Туган тел», 1988; «Нух пәйгамбәр көймәсе», 1991; «Галим бул», 1992; «Җәннәт аналарның аяк астында», 1993; «Фатыйха сүрәсе аятьләре», 2002; «Савыгу турында хәдис», 2003 һ.б.); аның гарәб графикасында, кайвакыт кириллицада татар телендә язылган шәмаилләре, нигездә, китап, журнал, календарьлар һәм башка вакытлы матбугат басмалары өчен әзерләнә. Күп кенә шәмаилләр татар халкының тарихына һәм аның истәлекле даталарына, әдәбиятның олы шәхесләренә (Кол Гали,



Н.Ф. И с м ә г ы й л е в. «Аятел-көрси» шәмаиле. Кәгазь, тушь, гуашь, акрил. 1991.

Мөхәммәдъяр, Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, М.Җәлил һ.б.) багышлана; алар төсләрнең чикләнгәнлеге һәм капма-каршылыгы, катгыйлыгы һәм композициянең симметриялелеге б-н аерылып тора, аерым бер әйбер сурәте (архит-ра корылмасы, сюжет күренеше), декоратив бизәкләр б-н баетыла. И. шәмаилләренең күпчелегендә образлы гармония мәһабәтлелеге һәм тантаналылыгы әчтәлекнең һәм теманың рухын ачып бирә («Сөембикә манарасына ай кую», 1990; «Әҗем мәчете сурәтләнгән шәмаил», 1991; «Болгарда ислам кабул итү», 1991; «1552 не хәтерләү көне», 1992; «Татарлар», 1996 һ.б.). И. пыялада майлы буяу, лак, алтын һәм көмеш фольга б-н традицион шәмаилләр башкару өлкәсендә дә



Н.Ф. И с м ә г ы й л е в. «Кодрәтле Аллаһы Тәгалә». Пыяла, майлы буяу, фольга, лак. 2002.

актив эшли: «Аллаһ — иң яхшы саклаучы» (1998–2004 вариантлары), «Аллаһ көрсие» (1994–2004 вариантлары) һ.б. 1983 тән 60 ка якын китапның бизәүчесе һәм рәссамы (башлыча, тышлыкларының). Алар арасында «Татар фольклоры поэтикасы» (1991), «Алтын Урда тарихыннан» (1993), «Татар календаре» (1994–96), «Татар мөселман календаре» (1996–2003), «Татар теле әлифбасы» (М., 1996) һ.б. бар. Урта гасырлар татар прозасын тикшерүче, текстолог; 1994 тә Казанда басылган «Фазаилеш-шәһүр» (Җ.Бикташи) һәм «Мәҗмугыл хикәят» кебек кулъязма әсәрләрнең төзүчесе һәм рәссам-бизәүчесе. Татар әдәбиятын һәм сынлы сәнгатен өйрәнүдәге актуаль проблемаларга багышланган мәкаләләр авторы. И. Казан гуманитар ин-ты (1992–96 да татар көллияте) һәм Россия ислам ун-ты (2000 нән башлап) студентларын хаттатлык осталыгына өйрәтә. Аның шәкертләре арасында — рәссамнар В.*Попов*, А.Хәлиуллина, Г.Вәлиева һ.б. бар. Халыкара «Изге Коръән» (Тәһран, 2001); төбәкара бөтентатар «Татарт» (С.-Петербург — Казан, 1991) күргәзмәләрендә; «Хаттатчылык сәнгате: үткәне һәм хәзергесе» күргәзмәсендә (Казан, 1996), халык сәнгати промыселлары һәм гамәли-бизәлеш сәнгате күргәзмә-конкурсларында (Казан, 2002, 2003, 2004; 2004 тә 3 нче дәрәҗә диплом б-н бүләкләнә) һ.б. катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1993, 1998, 1999, 2000, 2001 дә (Казан) һ.б. елларда уза. Әсәрләре Дәүләт Эрмитажында, Россия халыкларының этнография музеенда (С.-Петербург), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда, Әлмәт, Чаллы картиналар галереяларында, Г.Тукай музеенда (Казан), чит илләрдәге шәхси тупланмаларда (Голландия, АКШ, Австралия) саклана.

Х е з м.: Мәҗмугыл-хикәйәт (XVIII йөз) // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. К., 1981; Татар әдәбиятында Болан патша сюжеты // Язучы биографиясенә яңа чыганаклар. К., 1989; Борынгыдан килгән сәнгать // Идел. 1991. № 7; Хаттат кызлар // Сөембикә. 1999. № 7; Обновление традиций // Татарстан. 1995. № 11–12.

*Әд.:* В ә л и е в а Д. Гүзәллек вә нәфислек үрнәге // Мирас. 1993. № 12; М у л л а н у р о в а Р. Хикмәтле шәмаил остасы // Сөембикә. 1998. № 10; С а ф и н М. Неповторимый мир Наджипа Наккаша // Аргамак. 1998. № 4; С у л т а н о в а Р. Ностальгия по утраченному // Дизайн и новая архитектура. 2002. № 9; Хаттату машхур // Гулистан Коран. Тегеран. 2001. № 100.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Равил Барил улы (28.10.1940, Пермь ш.), монументаль-бизәлеш һәм гамәли сәнгать рәссамы, сынчы, нәкышьче, дизайнчы. Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укый (1960–62), В.И.Мухина исем. Ленинград югары сынлы сәнгать-сәнәгать уч-щесенең пыяла һәм керәч бүлеген тәмамлый (1972). 1972–73 елларда Сылва пыяла з-дында (Пермь) баш рәссам. 1973 тән Пермь сәнгать фондында эшли. 1993–98 дә Россия нәкышь, скульптура һәм архит-ра академиясенең Урал ф-лында гамәли-бизәлеш сәнгате каф. мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). Кама алды төбәгендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе, иҗаты б-н үзен



Р.Б. И с м ә г ы й л е в. «Автопортрет». Линогравюра. 1969.

сынлы сәнгатьтә һәм бизәлеш сәнгатенең нәфис пыяла, металл, керәч һәм витраж, станлы нәкышь, графика һәм скульптура жанрларында таныта. И. әсәрләре, нигездә, Пермьдәге эре җәмәгать корылмаларының интерьерларын бизи. Ул — зиннәтләү әйберләренең барлык өлешләрен: люстралар, фарфор сыннар, металл рельеф һәм җиһазлар, витраж һәм мозаикаларны үзе эшләп гармонияле ансамбльләр тудырган интерьерларның архит-ра-сәнгать бизәлеше проектлары авторы да («Кичке Гайва» рестораны интерьеры (В.Жехов б-н бергә, 1976), «Галактика» (В.Бережных б-н бергә, 1979) рестораннары интерьеры; М.Горький исем. мәдәният йорты, 1980; «Родина» кино-концерт залы, 1981;



Р.Б. И с м ә г ы й л е в. «Кичке Гайва» рестораны интерьеры. Пермь ш. 1979.

Кудымкар шәһәрендәге мәдәният йорты, 1992 һ.б.). 1989–93 тә И. үз эскизлары буенча Пермьдәге «Урал» кунакханәсе, «Самоцветы» кафесы һәм Җамигъ мәчет өчен монументаль-бизәлеш витражлары әзерли. Нәфис пыяла һәм керәч сәнгате остасы буларак, төрле күргәзмә әйберләр: савыт-саба, шәмдәл, ваза, рельефлар һ.б. ясый («Бүләк кубогы», бәллүр, гравирлау, 1972; «Экспромтлар», пыяла, 1973; «Идәнгә куела торган вазалар» һәм «Рәссам» дивар рельефы, техник фарфор, 1978, 1980 һ.б.). Станлы һәм монументаль-бизәлеш скульптура (түгәрәк һәм рельефлы пластика) юнәлешләрендә эшли, мәрмәрдән һәм нәфис металл кулланып ясалган оригиналь әсәрләр: Пермьдә 19 йөздә яшәгән атаклы кешеләр (В.Татищев, С.Дяги-

лев, бертуган Г. һәм Ф.Каменскийлар һ.б.) барельефлары, Сов. Союзы Герое З.Г.Исхаковка, язучылар В.П.Астафьев, А.П.Гайдарга һ.б. багышланган барельеф һәм мемориаль такталар авторы. 1986 дан И. станлы нәкышь өлкәсендә актив эшли (портрет, пейзаж, натюрморт, фигуратив һәм абстракт композицияләр). Аның әсәрләренә сәнгать тәненең ачыклыгы, төсләр һәм композицияләр шартлылыгы (локаль тон, күп планлы киңлек), образ төзелешенең камералылык һәм лирика югалмаган монументальлеге («Рәссам хатыны портреты», 1973; «Киносәяхәтче М.Заплатин», 1979; «Язучы М.Голубков портреты», 1988; «Шәһәр башы», 1998; «Язгы урман», 1999; «Клее истәлегенә», 2000 һ.б.). 2000 нән улы Р.Р.Исмәгыйлев б-н иҗат итә (металлдан эшләнгән «Траус», «Дракон», «Марс — сугыш алласы» инсталляцияләре, барысы да — 2003; Пермьдәге «Спортивная» кунакханәсе, хореография уч-щесе витражлары, 2001, 2003). СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган бөтенсоюз күргәзмәсендә (Мәскәү, 1972), «Социалистик Урал» (Пермь ш., 1964; Уфа ш., 1974; Төмән ш., 1979) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 2000 дә, 2004 тә (Пермь ш., Р.Р.Исмәгыйлев б-н бергә) уза. Әсәрләре Пермь сәнгать галереясында, Чусовой шәһәренең әдәбият музеенда, чит илләрдәге (Германия, Бельгия, АКШ, Италия һ.б.) шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* К а з а р и н о в а Н. Художники Прикамья. Пермь, 1984; Равиль Исмагилов: Каталог. Пермь, 2000; Художественный мир Исмагиловых: Буклет. Пермь, 2004.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Рафаэль Ришат улы (25.3.1951, БАССРның Нуриман р-ны Байгилде а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (1992), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998). БРның атказ. фән. эшлеклесе (2000). Башкортстан а.х. ин-тын тәмамлый (1973). 1973–75 елларда Нуриман үсемлекләрне саклау станциясе башлыгы (БАССРның Красная Горка а.). 1977–94 тә Башкортстан а.х. ин-тында, проф. (1992). 1994 тән Башкорт ун-тының үсемлекчелек каф. мөдире, бер үк вакытта Башкорт а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары (1998–99), 1999 дан БР ФА һәм Россия а.х. академиясенең Башкортстан гыйльми үзәге рәисе урынбасары. БР ФА гыйльми советы рәисе (2003). Хезмәтләре үсемлекчелек продукциясен җитештерү технологиясе мәсьәләләренә карый. СССР ВДНХсының 3 алтын, 2 көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Озимая пшеница. Уфа, 1980; Озимая рожь в Башкирии. Уфа, 1991 (автордаш); Качество и технология производства продовольственного зерна озимой ржи. М., 2001; Качество и технология хлебопекарного зерна пшеницы. Уфа, 2005.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Ренат Закуан улы (16.7.1955, Алма-Ата ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1996), Казакъстан Респ-касы ФА мөхбир әгъзасы (2000). 1978 елда Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлагач, Казакъстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгының А.Н.Сызганов исем. Хирургия фәнни үзәгендә эшли; 1996 дан әгъзаларны һәм тукымаларны күчереп утырту бүлеге мөдире, проф. (2002). Казакъстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгының әгъзаларны һәм тукымаларны гемодиализлау һәм күчереп утырту буенча баш белгече. Хезмәтләре күчереп утырту, гемодиализ, экстракорпораль детоксикациягә карый. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Справочник хирурга. Алматы, 1997.

*Әд.:* Кто есть кто в казахстанской науке. Алматы, 1999.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Ренат Хөснулла улы (17.9.1937, Төрекмәнстан ССР, Чарджоу өлкәсе, Кирсә р-ны Халач а. — 15.12.2004, Төрекмәнстан, Ашхабад ш.), драма актёры, режиссёр, 1969 елда ГИТИСның режиссёрлык ф-тын тәмамлый (Мәскәү). Төрекмәнстан ССРның атказ. артисты (1983). Сәхнә эшчәнлеген 1959 елда Ашхабад рус драма театрында башлый. 1972–89 елларда Ашхабад (1989 дан баш режиссёр), Чиләбе, Кишинёв, Днепропетровск рус драма театрларында режиссёр. Ул куйган спектакльләр: «Кечкенә трагедияләр» («Маленькие трагедии», А.С.Пушкин), «Мәхәббәт белән шаярмыйлар» («С любовью не шутят», П.Кальдерон), «Геростратны оныту» («Забыть Герострата», Г.И.Горин), «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), «Гамьсез Атабаев» (Б.Кербабаев). Төрекмәнстан ССРның Мәхтумкули исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1970).

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Фәнзат Җәүдәт улы (2.6.1955, Азнакай р-ны Мәлбагыш а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), ТРның атказ. нефтьчесе (2005), Казан химия-технол. ин-тын (1979), Уфа нефть техник ун-тын (2002) тәмамлый. 1979 елда С.М.Киров исем. ФҖБндә (Казан) эшли. 1983 тән «Татнефть» АҖндә: «Сөләйнефть» НГДУында мастер, әйдәп баручы инженер-технолог, цех башлыгы, технол. бүлек башлыгы урынбасары (1999 га кадәр), инженерлык үзәгендә скважиналарны капиталь һәм җир астында ремонтлау бүлеге башлыгы (2001 гә кадәр), скважиналарны ремонтлау һәм катламнарның нефть бирүчәнлеге идарәсе башлыгы (2001 дән). Дәүләт бүләге нефть чыгару скважиналарының нәтиҗәлелеген саклау, торгызу һәм арттыруны тәэмин итүче техник һәм технол. чишелешле хезмәтләре һәм аларны сәнәгатьтә гамәлгә кертүе өчен бирелә. Файдалы модельләр эшләүгә 16 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Флюр Ришат улы (10.10.1944, БАССРның Нуриман р-ны Нимисәр а.), электромеханика гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1998), проф. (1998), БРның атказ. уйлап табучысы (1997), РФнең мактаулы югары проф. белем бирү хезмәткәре (2002). 1973 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлый, Башкортстан ун-тында эшли. 1982 дән Уфа авиация ин-тында: каф. мөдире, җитештерүне автоматлаштыру ф-ты деканы. Хезмәтләре махсус билгеләнгән электромеханик энергия әверелдергечләре эшләүгә карый. И. — шартлауга бирешми торган двигательләрне сериялəп җитештерүне оештыра.

Х е з м.: Конструирование электрических машин. Уфа, 1995 (автордаш); Электромеханические элементы систем управления со сложной геометрией ротора. Уфа, 1997; Электромагнитные демпферы с продольными прорезями полого ротора // Электротехника. 2000. № 8; Неоднородный диэлектрик в электрическом поле // Проблемы энергетики. 2001. № 3–4 (автордаш).

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ** Фоат Ришат улы (25.1.1949, БАССРның Нуриман р-ны Байгилде а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1992), проф. (2000). 1971 елда Башкортстан ун-тын тәмамлаганнан соң, Нефть химиясе җитештерү фәнни-тикшеренү ин-тында (Уфа ш.) эшли. 1979 дан Идел-Урал газ эшкәртү фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тында (Оренбург ш.): сектор мөдире (1981 дән), газны плазма һәм мембрана ярдәмендә эшкәртү лаб-ясе мөдире (1986 дан). 1988 дән «Грознефтехим» ФҖБнең Башкортстан махсус конструкторлык-технол. бюросында: директор урынбасары, директор (1990 нан). 1993 тән Яңа Уфа нефть эшкәртү з-дында директор урынбасары. 1995 тән Уфа сервис-технол. ин-тында әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану каф. мөдире. Хезмәтләре нефть һәм газны химик эшкәртү технологиясенә, сәнәгый экологиягә карый. Алкилароматик углеводородларны парофазлы оксидлаштырып, пиромеллит кислотасының диангидридын — термик чыдамлы полимерларны синтезлау өчен мономер алу технологиясен эшли һәм җитештерүгә кертә (башкалар б-н бергәләп), тәҗрибә-сәнәгый масштабта нефть сульфоксидлары һәм сульфоннары алу технологиясен гамәлгә ашыра. Оренбург газ конденсаты чыганагындагы меркаптаннардан табигый газ одоранты алуның сәнәгый технологиясен, табигый газны сәнәгый чистарту һәм киптерү-йотылу һәм киптерү процессларын, күкертле газларны плазмохимик һәм мембраналы тәҗрибә-сәнәгый эшкәртү технологияләрен үзләштерүдә һәм камилләштерүдә катнаша.

Х е з м.: Медико-социальные последствия чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера. Уфа. 1997 (автордаш); Технико-экологические аспекты промышленной экологии. Уфа, 1999 (автордаш); Экология и новые методы очистки сероводородосодержащих газов. Уфа, 2000 (автордаш).

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВ-ШИРВА́НСКИЙ** Мостафа Лотфи (19 йөзнең 2 нче яртысы, Баку губ. Шемаха ш. — 20 йөзнең 1 нче яртысы), публицист, нашир. Төркиядә белем ала, аннан соң Әстерхан шәһәренә күчеп китә, анда актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара. 1906 елда Әстерханда «Шураи Ислам» (ярлы татарларга ярдәм җәмгыяте) оештыра һәм аның рәисе була. Бу җәмгыятькә 400 дән артык вак сәүдәгәр, мещан, укытучы керә. Җәмгыять әгъзаларыннан җыелган акчага ятим һәм фәкыйрь балалар өчен яңа ысуллы программа б-н укыта торган «Дар әл-әдәб» (1906–10) мәктәбе ача. Әстерханда беренче булып татар телендә әдәби кичәләр, спектакльләр оештыра. «*Мизан*» нәшриятын һәм басмаханәсен ача, анда «*Борһане тәрәкъкый*», «*Хәми-*

*ят*», «*Мизан*» г-талары басыла, 1906–11 елларда шул газеталарның нашире һәм мөхәррире була. 1911 дә «*Хак*» г-тасының нашире һәм мөхәррире. Әстерхандагы күренекле татар зыялыларыннан Н.Гасрый, З.Җаппаров, Г.Сәмәки-Әбүбәкеров, социал-демократ З.Садыйков, әзәрбайҗан мәгърифәтчесе һәм революционеры Н.Нариманов һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. «Борһане тәрәкъкый» г-тасында басылган «Победоносцев көйрыгы» (1907, 16 март) мәкаләсе өчен — суд хөкеменә, сөргендә яшәүче Н.Наримановка теләктәшлек күрсәткән «Доктор Нариман бәк» (1909, 22 дек.) мәкаләсе өчен штрафка тартыла. Соңгы еллардагы язмышы билгесез. 1909 елда Н.Ниязи «Шәһәремезнең мулла-мөгаллимнәре, мөхәррирләре мәҗлесе» дигән комедия куя, андагы бер персонажда Исмәгыйлев-Ширванский сыйфатлары (характеры) чагыла.

*Әд.:* Затымызга мөнасиб сыйфатларымыз // Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1989. Т. 3; Т у к а й Г. Әсәрләр. К., 1985. Т. 2; Т. 4. 197 б.

*Ф.Х.Җәүһәрова.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВА** Асия Фәхретдин кызы (3.6.1952, БАССРның Шаран р-ны Наратасты а.) вет. фармакологиясе галиме, биол. фән. д-ры (1997), проф. (1998). Башкорт а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Башкортстан мед. ин-тында эшли. 1980–88 елларда Оренбург а.х. ин-тында. 1988–97 дә РФА Уфа гыйльми үзәгенең Органик химия ин-тында. 1997 дән Башкортстан аграр ин-тының йогышлы булмаган эчке авырулар, клиник диагностика һәм фармакология каф. мөдире. Хезмәтләре пиримидинның һәм глицирризин кислотасының яңа синтезы чыгарылмалары һәм нефтьтән алына торган органик күкерт кушылмалары нигезендә дару чаралары булдыруга карый. Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм 8 патенты бар.

Х е з м.: Синтез, иммунотропная и противовоспалительная активность некоторых производных пиримидина на иммунитет // Химико-фармацевт. журн. 1997. № 9; Пиримидины и их применение в птицеводстве. Уфа, 1998 (автордаш); Влияние МАОП на организм цыплят // Ветеринария. 1999. № 8.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВА** Роза Нургали кызы (29.3.1928, Томск ш.), этнограф, тарих фән. д-ры (1971), проф. (1991), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Урта Азия ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1950). 1954–60 елларда СССР ФАнең Этнография ин-тында эшли. 1960 тан РФАнең Африка ин-тында, 1979 дан милли һәм мәдәни проблемалар секторы мөдире, 1998 дән Тарихи, милли һәм мәдәни тикшеренүләр үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, 2000 нән «Африка» энциклопедиясен әзерләү үзәге директоры. Хезмәтләре Африканың этник һәм этномәдәни проблемаларына, үзбилгеләнү мәсьәләләренә, БДБ илләре һәм РФнең традицион социаль структураларын һәм ин-тларын чагыштырып өйрәнүгә карый. Африка илләренә 20 дән артык экспедицияләрдә катнаша һәм аларны җитәкли, «Африка мәдәнияте» сериясендә чыккан басмаларның җаваплы мөхәррире һәм автордашы (т. 1–5, М., 1984–2000). РФА Гыйльми советының Африка проблемалары буенча (1966 дан), Халыкара социологик ассоциация бюросы (1985–2006, Мадрид), Этниклыкны һәм милләтчелекне өйрәнү буенча ассоциация (1998 дән, Лондон) әгъзасы. Африка мәдәнияте буенча комиссия рәисе (1995–2002). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Народы Кении в условиях колониального режима. М., 1956; Народы Нигерии. М., 1963; Этнические проблемы современной Тропической Африки. М., 1973; Традиционные культуры африканских народов: прошлое и настоящее. М., 2000 (автордаш); Ethnic Problems of Tropical Africa. Can They be Solved? М., 1978.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВА** Сания Гата кызы (20.7.1932, Бондюг, хәзерге Менделеев р-ны Турай а.), педагог, пед. фән. канд. (1969), проф. (1995), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1988), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1998). 1960 елда Алабуга пед. ин-тын тәмамлый. 1951–55 елларда Чуаш АССРның Шемурша р-ны Өчбалтай (Өч Балтай) җидееллык мәктәбендә укытучы, 1961 дән Әлмәт р-ының Иске Михайловка мәктәбендә, 1967 елдан Алабуга пед. ун-тының татар филологиясе кафедрасында. Хезмәтләре татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасына карый.

Х е з м.: Мәктәптә драма әсәрләрен өйрәнү. К., 1983; Лирик әсәрләрне өйрәнү. К., 1985; Рус мәктәпләрендә белем алучы татар балаларына ана телен һәм әдәбиятын укыту. К., 1993; Мәктәптә әдәби әсәргә анализ ясау алымнары. Алабуга, 1998; Мәктәптә Гаяз Исхакый драматургиясе. Алабуга. 2002.

*Әд.:* В ә л и у л л и н М. Кешеләргә шатлык өләшә // Мәгариф. 2002. № 7.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЕВА** Сания Нургали кызы (4.3.1931, Алексеев р-ны Коры Көрнәле а.), драма актрисасы, ТАССРның атказ. (1970) һәм халык (1979) артисты. Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң (1951), Республика татар күчмә (хәзерге Татар драма һәм комедия) театры труппасына кабул ителә һәм 1987 елга кадәр шунда эшли. И. тарафыннан башкарылган рольләрдән Сара («Сулган чәчәкләр», Д.Җаббарлы), Разия («Бистә кызы», Р.Ишморат), Елена («Йөрәк көчлерәк янсын», Л.И.Митрофанов), Анна «Зарыгып көткәнем» («Долгожданная», А.Д.Салынский) хисләренең сафлыгы, экчерсезлеге б-н аерылып тора. Сара ролендә җәберләнгән, кимсетелгән хатын-кыз күңелендә үз бәяңне белү, аңлау хисләре уяңуны тамашачыга ышандырырлык итеп җиткерә. Н.Исәнбәтнең «Рәйхан» әсәре буенча куелган спектакльдә Рәйхан, М.Гафуриның «Кара йөзләр»ендә Галимә, М.Кәримнең



С.Н.И с м ә г ы й л е в а Галимә ролендә (М. Гафури, «Кара йөзләр»).



С.Н.Исмәгыйлева.

«Айгөл иле»ндә Зөлхәбирә образларын тирән драматизм, психол. нечкәлек б-н уйный, героиняларның катлаулы кичерешләрен ачып бирә. И. башкарган образларга хатын-кыз мөлаемлыгы, ачык күңеллелек хас; аның хәтта эпизодик характердагы персонажлары да истә калырлык, чынбарлыктагыча дөрес чагылдырыла. Иң яхшы башкарылган рольләреннән Зиннәтбану («Хәзрәт үгетләргә килде», З.Шәһиморатов), Җәмилә («Әниемнең чал чәчләре», Ә.Мирзаһитов), Николь («Сәер кеше», Н.Хикмәт), Аманда («Терезаның туган көне», Г.Д.Мдивани), Женя («Бүген һәм һәр көнне», Г.М.Мазин), Татьяна («Мещаннар», М.Горький) образларын санарга мөмкин. И. башкарган үзенчәлекле рольләр арасында Камилә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Сәхилә («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Гөлниса («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Галимә («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Мәгыйшә («Хәзинә», Г.Ахунов), Зөлфия («Бөркетләр кыяга оялый», И.Юзеев), Суфия («Туган җирем», Т.Миңнуллин) һ.б. бар.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**ИСМӘГЫ́ЙЛЬ**, Коръән персонажы, *Ибраһим* улы; Библиядәге Измаил. Әтисенең динен Төньяк Гарәбстан кабиләләре арасында тарата һәм *Мөхәммәд* пәйгамбәр б-н бәйләнешле Хиҗаз гарәпләренең ыру, нәсел башлыгы була. *Коръәнне* аңлатучыларның күпчелеге фикеренчә, Ибраһим нәкъ менә И.не корбан итәргә тиеш була. Риваятьләрдә И. Ибраһимның кәнизәк Һаҗәрдән туган өлкән улы дип бәян ителә. Ибраһим, хатыны Сараның көнләшүе аркасында, Һаҗәр б-н И.не Гарәбстанга алып китәргә мәҗбүр була. Кызу чүлдә суга сусаган И.гә *Җәбраил* фәрештә ярдәмгә килә: аның теләге буенча, И. аягы б-н типкән урында чишмә бәреп чыга (хәзерге изге *Зәмзәм* чишмәсе). И. этисе б-н бергә изге *Кәгъбәне* төзи, риваятьләргә караганда, И. Кәгъбә б-н янәшә җирләнгән.

*Әд.:* П и о т р о в с к и й М.Б. Коранические сказания. М., 1991; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ИСМӘГЫ́ЙЛЬ БӘК** (? — 1563), Олы Нугай Урдасы идарәчесе (1555 тән). Тәхеткә абыйсы Йосыф бәкне бәреп төшерен утыра. 1555 елда үзара сугышта Йосыфның улларын җиңә, Хаҗитархан ханы Дәрвиш Галине куып җибәрә. Рус дәүләте б-н хезмәттәшлек итү тарафдары. 1557 дә Иван IV б-н дуслык килешүе төзи. 1558 елгы ачлыктан һәм үләт авыруы таралганнан соң, И.б.нең хакимияте йомшый, олысларның кайберләре Кырым ханлыгына буйсынуга күчә.

*И.Л.Измайлов.*

**«ИСМӘГЫ́ЙЛЬ БИКМӨХӘММӘ́ТОВНЫҢ ҺИНДСТАНГА́ СӘЯХӘТЕ́ ТУРЫНДА́ ҮЗ ХАТИРӘЛӘРЕ́»**, 18 йөз кульязма ядкәре, татар сәүдә капиталы үсешен һәм рус-һинд мөнәсәбәтләрен өйрәнү өчен

тарихи чыганак. Язылу вакыты ягыннан Афанасий Никитинның «Өч диңгез артына сәяхәт» («Хождение за три моря») дип аталган язмаларыннан кала Һиндстан турындагы икенче әсәр.

Төп нөсхәсе табылмаган. «Хатирәләр»нең берничә күчермәдә билгеле булуы аның татарлар арасында киң таралганлыгын күрсәтә. 2 күчермә буенча И.Н.Березинның («Төрек хрестоматиясе» — «Турецкая хрестоматия». Т. 2, 1862), Г.С.Саблуковның («Ике хаҗинең юлъязмалары» — «Путевые записки двух хаджиев», 1862), «Борынгы татар әдәбияты» хрестоматиясендә Р.Фәхретдиннең («Исмәгыйльнең сәяхәте», 1903) мәкаләләре бар. Соңрак вакытка караган 2 күчермә Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана. «Хатирәләр»не 1964 елда М.Г.*Госманов* өйрәнә. Галимнәр Г.Рәхим, Г.Г.Гобәйдуллин әлеге тарихи ядкәрнең зур әһәмияткә ия булуын билгеләп үтәләр. Проф. Г.Г.Сәгъди ачыклаганча, И.Бикмөхәммәтов үзенең Һиндстанга сәяхәтен 1751 дә, Һиндстан б-н сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырга омтылган Оренбург өлкәсе генерал-губернаторы И.И.Неплюев тарафыннан Бохарага җибәрелгән сәүдә кәрваны составында башлый. Кәрванда, И.Бикмөхәммәтовтан тыш, тагын 4 кеше (барысы да укымышлы): Надур (хезмәтчесе б-н), Якуб, Исмәгыйль, Габдрахман (дүртесе дә сәфәр вакытында һәлак була) катнаша. Алар Оренбург янындагы Сәет (Каргалы) бистәсеннән юлга чыгалар, Үргәнеч аркылы Бохарага килеп җитәләр дә, шунда кышлыйлар. Бохарада алар Оренбургтан Һиндстанга илче итеп җибәрелү турында күрсәтмә алалар. Шуннан соң Әфганстан (Анхай, Маручак, Һират, Кандагар) һәм Пакъстан (Калат, Белудж, Кеч) шәһәрләре аркылы барып, ихтимал, энҗе сатып алу өчен Гыйракның Басра шәһәренә килеп җитәләр. Фарсы култыгын кичеп, Һиндстанга киләләр. Берничә шәһәрдә (Мөршидабад, Бенарес, Патна) булалар, 1756–57 дә Дәһлидә яшиләр. Әфган кабиләләре арасында үзара сугыш хәрәкәтләре барганга Россиягә кире кайту юлы ябыла, шуңа күрә әйләнеч юл б-н кайтырга ниятлиләр. Сурат портыннан чыгып, Цейлон утравы аша Җиддә портына (Согуд Гарәбстаны) киләләр. Мөселманнар өчен изге саналган җирләрдә — Мәккә, Таиф һәм Мәдинә шәһәрләрендә булалар, шулай итеп, хаҗ кылалар. Күп хәвефләр, авырулар, юлдашларының үлемен кичереп, мал-мөлкәт югалтып, хаҗ кылырга килгән Кырым татарлары ярдәме б-н И.Бикмөхәммәтов Истанбулга килә. 25 ел гомерен шунда мохтаҗлыкта һәм фәкыйрьлектә уздыра. Үзенең күргәннәрен көндәлегенә язып бара. Юлына җитәрлек акча туплаганнан соң, 1784–85 елларда ватанына әйләнеп кайта. «Хатирәләр» 18 йөздәге сәүдә юлларын, төрле халыкларның икътисадын, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышын, аларның диннәрен, гореф-гадәтләрен өйрәнү өчен мәгълүматларга бай.

*Әд.:* Усманов М.А. Записки Исмаила Бекмухамедова о его путешествии в Индию // Ближний и Средний Восток. История. Экономика: Сб. статей. М., 1967. *И.А.Новицкая.*

**ИСМӘ́Т** тимер юл разъезды посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2008 елда 9 кеше (татарлар, башкортлар) яши. 1940 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1970 тә — 73, 1979 да — 52, 1989 да — 22, 2002 дә — 18 кеше.

**ИСПӘРӘ́К** (Delphinium), казаякчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Америкада һәм тропик Африка тауларында таралган. ТР терр-ясендә 3 төре үсә. Чәчүле И. (D. consolida) барлык р-ннарда очрый, чөйсыман яфраклы И. (D. cuneatum) — Кама аръягында, биек И. (D. elatum) — Кама алдында. Урманнарда, куаклар арасында, болыннарда үсә. 20–200 *см* биеклектәге, тамыр системасы кыска булган үсемлек. Сабагы ботаклы. Яфраклары икеләтә, өчләтә каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре эре, зәңгәр, күк, шәмәхә чуксыман яки себеркәчле чәчәк төркемендә. Җимеше — табакҗимеш. Июнь–августта чәчәк ата, җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Башлыча, орлыктан үрчи. Җир асты өлешләрендә алкалоид, флавоноид бар. Халык медицинасында чәчүле И. һәм биек И.нең үлән төнәтмәсе бәвел кудыру өчен файдаланыла. Бу төрләрнең орлыклары агулы, порошок хәлендә инсектицид чара буларак кулланырга мөмкин. Культуралы үсемлекләр. Биек И. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ИСРАФИ́Л** (إسرافيل) (Сарафил), Аллаһка иң якын торган 4 фәрештәнең берсе. Тәкъдир тактасыннан дөнья һәм кеше язмышлары турында Аллаһның хөкемен укый, хөкем үтәүне башка фәрештәләргә тапшыра. Аның төп атрибуты — сур мөгезе. Кыямәт көнендә И. Иерусалимдагы изге тау башыннан беренче тапкыр сурга өргәч, Җирдәге һәм Күктәге мәхлукларның барысы да һәлак булачак һәм, икенче тапкыр сурга өргәч, аларны Аллаһ кабат терелтәчәк. Риваятьләргә караганда, И. — *Мөхәммәд* пәйгамбәргә тәүге вәхиләрне тапшырган һәм аның үзен берничә ел саклап торган, аннары ул әлеге вазифаны *Җәбраил* фәрештәгә йөкләгән. И. гаять зур зат итеп тасвирлана: җирдә басып торганда аның башы Аллаһ тәхете биеклегенә җитә.

Көндез һәм төнлә өчәр тапкыр ул *җәһәннәм* ишегенә ачып карый һәм анда газап чигүчеләр өчен кайгырып, аларны кызганып, иңрәп елый. Ихтимал, И. фәрештәнең исеме Библиядәге Серафимга барып тоташса кирәк: аңа хас булган кайбер сыйфатларның тамырлары яһүди һәм христиан демонологиясендә дә чалымлана.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ИСРАФИ́ЛОВ** Ирек Хөснимәрдән улы (20.8.1950, Зәй р-ны Шикмамай а.), җылылык техникасы һәм геоэкология өлкәсе галиме, техн. фән. д-ры (2003), проф. (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), Казан авиация ин-тында эшли. 1981 елдан Кама политехник ин-тында (хәзер Кама инженерлык-икътисад академиясе, Чаллы ш.), 2001 дән югары энергетикалы инженерия һәм азык инженериясе каф. мөдире. Хезмәтләре плазма техникасы эшләнмәләрен булдыруга карый. Эрозияләгеч стеналы электр дугалы җылыткычның сыйфатламаларын, гидросфераны сорбцион чистартуның экологик-технол. аспектларын тикшерә. Дөгә һәм карабодай кабыгыннан сорбентлар алу һәм аларны табигатьне саклаучы ресурс саклаулы технологияләрдә куллану өчен түбән атмосфера басымының югары ешлыклы бушанулары характеристикаларын исәпли. Уйлап табуга патенты бар.

Хезм.: Единый эколого-технический комплекс модификации среды обитания человека с помощью сорбционной очистки гидросферы. К., 2002 (автордаш); Моделирование процесса обработки плазменным технологическим комплексом для достижения заданных показателей качества // Вестн. КГТУ им. А.Н.Туполева. 2007. № 2 (автордаш).

**ИСРАФИ́ЛОВ** Рифкат Вәкил улы (8.9.1941, БАССР, Мәчетле р-ны Яңа Мөслим а.), драма актёры, режиссёр, педагог, РСФСРның халык артисты (1989), БАССР, РСФСР, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977, 1987, 1994). Уфа сәнгать уч-щесен (1965), Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, Мәскәү, 1973) тәмамлый. 1965 елдан Башкорт акад. драма театрында актёр, 1973 тән режиссёр, 1981 дән баш режиссёр һәм сәнгать җитәкчесе. 1998 дән Оренбург рус драма театрында баш режиссёр. Ричард Галин («Айгөл иле», М.Кәрим), Һарун («Солдат улы», Ә.Мирзаһитов), Хаммат («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Труфальдино («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони) рольләрен яшьләргә хас ярсулы хис б-н яңача башкара. Режиссёр буларак, М.Фәйзинең «Галиябану», Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрләре буенча куйган спектакльләре башкорт театры тормышында зур вакыйга булып кабул ителә. Рухи күтәренкелек, тормыш чынбарлыгын фәлсәфи аңлатуның үткен форма б-н үрелеп баруы яшь режиссёрның иҗат үзенчәлеген билгели. Х.Вуолийокиның «Чит йолдыз» («Чужая звезда»), М.Кәримнең «Озын-озак балачак», И.П.Друценың «Изгеләрдән изге» («Святая святых») спектакльләре нечкә психологизм б-н, «Кыз урлау» (М.Кәрим), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектакльләре жанрның чын табигатен аңлап эшләнүләре б-н аерылып торалар. «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), «Бибинур, ах, Бибинур», «Сөясеңме-сөймисеңме?» (Ф.Бүләков), «Капитан кызы» («Капитанская дочка», А.С.Пушкинның шул исем. повесте буенча), «Хыянәтче хатынның киң күңелле ире» («Великодушный рогоносец», Ф.Кроммелинк) әсәрләрендә шәхеснең рухи яктан изелгәнлеге һәм аның ялган, буш хыяллар дөньясында җимерелүе темасы, шул заманның акылга сыймаслык мәгънәсезлеге масштаблы төстә, ышандырырлык итеп ачыла. Т.Миңнуллинның «Әлләдем, бәгърем, сине» пьесасы буенча куелган спектакль кешелеклелек хисләрен, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын яктыртуга багышлана. Театр теленең бөтен байлыгын үзләштергән режиссёр буларак, И. әсәрнең эмо-

циональ киеренкелеген, төп идеясен ачу өчен күп төрле чаралардан оста файдалана. Мәскәү Үзәк балалар, Татар опера һәм балет, Татар акад. театрларында спектакльләр куя. Уфа сәнгать ин-ты профессоры. БАССРның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1976). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сафуанов И. Люди и манекены // Театральная жизнь. 1984. № 4; Иляловa И. Межнациональные связи татарского театра. К., 1985; Ахунзянов Т. Жатва наших надежд // Театральная жизнь. 1987. № 11.

*И.И.Илялова.*

**ИСРАФИ́ЛОВ** Сәйдәш Мәгъсум улы (28.2.1947, Балтач р-ны Пүскән а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, инженер-механик, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1989). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1971). 1971 елдан Балтач р-нының Тимирязев исем. к-зында: баш инженер, колхоз рәисе (1975–99 елларда, бүленеп, 1984–86 да Мамадыш р-н башкарма ком-ты рәисе). 1999–2002 дә ТР а.х. һәм азык-төлек министры урынбасары. 2002 дән «Татарзернопродукт» АҖ ген. директоры (2005 тән «Рапс» ҖЧҖ). И. колхоз б-н җитәкчелек иткәндә бөртекле культураларның уңышы 1 гектардан 54 *ц* га кадәр арта, 100 *га* а.х. җирләренә 98 *ц* ит, 420 *ц* сөт җитештерелә (1997). Колхоз бернчә тапкыр Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия ярышларында җиңүче була һәм аңа КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байрагы, РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагы бирелә. Почёт ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ИССА́ РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* төньяк өлешендә урнашкан. 1967 елда оештырыла. Мәйданы — 926 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Исса посёлогы (Пензадан 98 *км* төньяктарак). Халкы — 14,9 мең кеше (1989), ш.и. татарлар — 778 кеше. Татарлар күпләп Югары Салмовка (304 кеше), Кильмаевка (124), Татар Плетнёвкасы (48) авылларында яши. 1930 еллар башына кадәр Югары Салмовка авылында 2 мәчет һәм мәктәп була. 1994 тән үзешчән сәнгать коллективы эшли, 1995 елда мәчет ачыла.

**ИСТӘМИ́ КАГА́Н** (? — 575), Төрки каганлык идарәчесе. 552 елда Төрки каганлыкта хакимиятне үз кулына ала. 558 дә Идел-Урал төбәгендәге далалы җирләрне яулый. 563 тә Иран шаһы Хөсрәү I б-н берлектә эфталитларны (ак һуннарны) җиңә һәм Урта Азияне басып ала. 571 дә Иранга каршы Византия б-н килешү төзи, Төньяк Кавказдагы болгар, алан һ.б. кабиләләрне үзенә буйсындыра.

*Әд.:* Гумилев Л.Н. Древние тюрки. М., 1993.

*И.Л.Измайлов.*

**ИСТПА́РТ** (Октябрь рев-циясе һәм РКП(б) тарихын барлаучы комиссия), фәнни һәм нәшер итү үзәге. И. бүлекчәсе ТАССРда 1920 елның октябреннән — Дәүләт нәшрияты, аннары Дәүләт архивы карамагында, 1921 дән РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында мөстәкыйль бүлек. Җитәкчеләре (төрле елларда): М.Корбут, Н.Знаменский, С.Гафуров, М.Айнетдинов. И.ның Окт. рев-циясе тарихы, РКП(б) тарихы, яшьләр хәрәкәте тарихы, профсоюз хәрәкәте тарихы, татарларның революцион хәрәкәте тарихы секцияләре була. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: документлар туплау, музейлар ачу, күргәзмәләр һәм революцион хәрәкәттә катнашучылар б-н искә алу кичәләре оештыру, нәшерлек итү («*Пути революции*» ж-лы, Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы турында истәлекләр җыентыгы). И.ның Татарстан бүлекчәсе б-н В.В.Адоратский, С.А.Пионтковский, А.Аросев, Г.Г.Ибраһимов, В.С.Шәфигуллин һ.б. хезмәттәшлек итә. 1940 елның 5 февралендә бетерелә.

*Әд.:* Литвин А.Л., Циунчук А.Г. Создание и деятельность Татарского Истпарта (1920–1939 гг.) // Историография федосеевских марксистских кружков в Поволжье. К., 1972.

*А.Л.Литвин.*

**ИСХА́К** (Исхаков) Әхмәт Габдулла улы (1.5.1905, Казан — 24.6.1991, шунда ук), шагыйрь, тәрҗемәче. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм Татар пед. техникумында укый. 1922 елда аны тәмамлагач, ВЛКСМның өлкә ком-ты каршындагы матбугат бүлеге экспедициясендә эшли. 1925–28 елларда «Эшче» (Мәскәү) г-тасы редакциясендә. 1928–39 да «Чаян» һәм «Кызыл Татарстан» ж-лларында, 1939–42 дә СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле. «Кызыл кошлар» исемле беренче шигыре «Кызыл Шәрекъ яшьләре» г-тасында 1923 елда басыла. «Таш урамнар җыры» (1929) дип аталган беренче җыентыгы Мәскәүдә дөнья күрә. «Бәхет турында җыр» (1939), «Курай» (1946), «Җырда очрашу» (1957), «Уйланулар, елмаюлар» (1983) һ.б. шигырь һәм поэмалар җыентыклары авторы. Стиле ягыннан И.ның шигырьләре кискен публицистик характерда. Аеруча мәсәл һәм сатирик поэмалары уңышлы иҗат ителгән. Әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Нәвои, Абай, Мәхтүм Колый, Низами, Нәсими, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә; Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (1983) поэмасын хәзерге татар әдәби теленә күчерүгә дә зур өлеш кертә. Әдәбият белгече буларак та билгеле: «Тукайның шигъри осталыгы» (1963), рус телендә нәшер ителгән «Поэт-герой Муса Җәлил» (1956) китаплары. Г.Бәшировның «Намус» романы буенча эшләнгән опера либреттосы (Н.Җиһанов музыкасы, 1951) авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1965; Илһамнар чишмәсе. К., 1985.

*Әд.:* Хәким С. Казан — шагыйрьләр шәһәре // Үз тавышың белән. К., 1969; Ахунов Г. Егетлек // Социалистик Татарстан. 1985. 24 май; Мәҗитов З. Җаваплылык // Шәһри Казан. 1995. 24 июнь.

*Р.Ә.Мостафин.*

**ИСХА́К бине ГАБДЕЛКӘРИ́М** (1730, Вятка губ., Малмыж өязе Адай а. — 1802, Оренбург губ. Каргалы бистәсе), ташка уеп язу остасы, хаттат. Каргалыдагы Сәгыйт бистәсе мәчетендә имам булып тора. Көмештән бизәнү әйберләре ясау б-н шөгыльләнә. Өлә Казаклар (хәзерге Биектау р-ны), Бәрәскә (хәзерге Әтнә р-ны) авыллары һәм Сәгыйт бистәсе зиратларында ул ясаган кабер ташлары сакланган. Алар ак таштан, турыпочмаклы итеп, 140×60×22 *см* зурлыкта, өске өлешләре ярымтүгәрәк рәвешендә ясалган, бизәк төшерелмәгән. Ташларның алгы ягындагы язулар гарәп графикасында сөлес имлясында башкарылган, яссы рельефлы рәвештә уелган,



Өлә Казаклар авылындагы кабер ташы (хәзерге Биектау районы). Известьташ. Уеп бизәкләү. 1765.

матур каллиграфиясе б-н аерылып тора; дини эчтәлекле язуларга останың үз шигырьләре өстәлгән.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Сәгыйт. К., 1897; Мәрҗани Ш. Мостафәдел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1900.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ИСХА́КОВ** Әнәс Гатуф улы (14.8.1945, Лениногорск р-ны Югары Чыршылы а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, шагыйрь, социол. фән. канд. (2000), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан ун-тын (1971), Саратов югары партия мәктәбен (1983) тәмамлый. 1965 елдан Азнакай р-нында: Актүбә урта мәктәбендә укытучы (1971 гә кадәр), 1971–72 дә ВЛКСМ райкомы инструкторы, 1972–73 тә секретаре, 1973–78 дә 1 нче секретаре, 1978–83 тә КПССның р-н ком-тында оештыру бүлеге мөдире, 1983–92 дә халык депутатларының р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1992–2005 тә Азнакай р-ны һәм шәһәре хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта, 1995 тән Азнакай р-ны халык депутатларының берләштерелгән Советы рәисе. 2005–07 дә ТР МКда бүлек җитәкчесе. 1990–95 тә ТССР ЮС депутаты, 1995–2004 елларда ТР халык депутаты. ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2000). Социологиягә нисбәтле мәкаләләр авторы. Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Бу дөнья нигә уйчан? К., 1999; Чишмәләр иле син, Туган як! К., 2001; И гомер агышлары... К., 2005; Критерий — отношение к труду. К., 2000.

*Әд.:* Әхмәдиев Н. Халыкның күцел сәфәрләре // Мәдәни җомга. 2000. 21 гыйнв.

**ИСХА́КОВ** Бөркет (4.11.1924, Казакъстан ССРның Караганда өлкәсе, Нурин р-ны Күкмүлдер а. — 1991, Алма-Ата), әдәбият галиме, шагыйрь, тәрҗемәче, филол. фән. канд. (1951). Казакъ ун-тын тәмамлый (1948). 1969–90 елларда Казакъстан ССР ФАнең М.Ауэзов исемендәге Тел һәм сәнгать ин-тында эшли. Хезмәтләре казакъ әдәбиятының

башка төрки әдәбиятлар б-н бәйләнешенә карый. «Сенің Отаның» («Синең Ватаның», А.-А., 1959), «Жеткіншек» («Яшүсмер», А.-А., 1985) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. Казакъ теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский, М.Җәлил һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә.

Х е з м.: Казак-татар әдәби бәйләнешләре. А.-А., 1976.

**ИСХА́КОВ** Госман Гомәр улы (25.5.1957, Казан), дин эшлеклесе. «Мир Араб» урта мөселман мәдрәсәсен тәмамлый (Бохара, 1982), Ислам ун-тында укый (Триполи ш., 1984–85). 1982–84 елларда СССРның Европа һәм Себер өлешендәге мөселманнарның Диния нәзарәте секретаре. 1986–94 тә БРның Октябрьск шәһәрендә үзәк мәчет имам-хатибы, 1991 дән үзе оештырган «Нурул-Ислам» мәдрәсәсе ректоры. 1994–98 дә мөфти урынбасары, 1998 дән *ТР мөселманнарының Диния нәзарәте* мөфтие, Казандагы Россия ислам ун-ты ректоры (1998–2006). Хезмәтләре мөселман догматикасы һәм ритуалы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Динсез яшәп булмый. К., 2000; Ислам әхлагы. К., 2002; Ислам за мир. К., 1999.

**ИСХА́КОВ** Дамир Мәүләви улы (3.1.1952, Саба р-ны Шәмәрдән штп), этнолог, тарих фән. д-ры (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1974–77 елларда Саба районының Икшермә урта мәктәбе укытучысы. 1977–80 дә СССР ФАнең Н.Н.Миклухо-Маклай исем. Этнография һәм антропология ин-ты каршындагы аспирантурада укый. 1981 дән Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1987–93 тә этнография бүлеге мөдире), 1997 дән ТР ФА Тарих ин-тында, 2004–09 да ин-тның Этнология мониторингы үзәге җитәкчесе. И. тарафыннан татарларның этник тарихын өйрәнүдә яңа фәнни юнәлеш булдырыла. Хезмәтләре татар халкы демографиясе, этнографиясе һәм тарихына, этносоциологиягә, исламият гыйлеменә карый, ш.у. урта гасырларда татар этносының барлыкка килүе, татар милләтенең формалашуы һәм үсеше проблемаларына багышлана. Татар милли хәрәкәте идеологларының берсе (*Бөтентатар иҗтимагый үзәге* сәяси советы әгъзасы, *Милли Мәҗлес* составына керә), Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты рәисе урынбасары (2002 дән). Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты каршындагы Этнология мониторингы үзәге җитәкчесе (2004). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003).

Х е з м.: Этнографические группы татар Волго-Уральского региона (принципы выделения, формирование, расселение и демография). К., 1993; Проблемы становления и трансформации татарской нации. К., 1997; Суверенный Татарстан. Документы. Материалы. Хроника: В 3 т. М., 1998; Татары: Краткая этническая история. К., 2002; Этнография татарского народа. К., 2004 (автордаш); Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. К., 2009.

*Әд.:* Исхаков Дамир Мавлявеевич // Кто есть кто в изучении народов и национальных проблем России. М., 1995; Исхаков Дамир Мавлявеевич: К 50-летию со дня рождения и 30-летию научной деятельности. К., 2001.

**ИСХА́КОВ** Зиннәтуллина Гыйниятулла улы (17.8.1908, Казан губ., Спас өязе Яңа Үргәгар а. — 5.7.1958, Пермь ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. полковнигы. Хәрби-сәяси уч-ще (1937), Югары Сәяси состав курсларын (1942), «Выстрел» курсларын (1943), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1950) тәмамлый. Әстерхан шәһәрендә райбашкарма ком-ты рәисе урынбасары булып эшли. 1935 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 13 нче гв. һава десанты полкы командиры (53 нче армиянең 1 нче гв. һава десанты дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, Дала һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Демян операциясендә (1943), Курск һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (1943), Кировоград, Умань-Ботошани (икесе дә — 1944), Будапешт (1944–45) һәм Прага (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең октябрь–ноябрь айларында Тиса елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: И. командалагындагы полк, дошманның плацдармын (Венгрия, Сольнюк шәһәреннән төньяктарак) яулап алып, 5 тәүлек дәвамында аның контрһөҗүмнәрен кире кага; 6 ноябрьдә полк, Шаруд, Поречно торак пунктлары янында елганы икенче тапкыр кичеп, 20 ноябрьдә Верпелет шәһәре тирәсенә килеп чыга. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам итә. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Суворов, Александр Невский, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Р а к и п о в Ш.З. По следам героев. К., 1975; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИСХА́КОВ** Камил Шамил улы (8.2.1949, Казан), дәүләт һәм хуҗалык эшлеклесе, РФ торак-коммуналь хуҗалыгының атказ. эшлеклесе (1998). Казан ун-тының физ. ф-тын тәмамлый (1973). 1965–69 елларда В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-дының телефон станциясендә элемтә электромонтёры. 1973–80 дә ВЛКСМның Казан шәһәре Совет районы ком-ты 1 нче секретаре. 1980–87 дә Казандагы «Алгоритм» ФҖБндә фәнни-укыту үзәгенең директор урынбасары, директоры. 1987–88 дә Казан исәпләү техникасы һәм информатика ФҖБ ген. директоры, бер үк вакытта Казан фәнни-укыту үзәге директоры. 1988–89 да КПССның Казан Совет районы ком-ты 1 нче секретаре. 1989–91 дә халык депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе, 1991 дән Казан шәһәре хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта, 1993 тән халык депутатларының Казан шәһәр советы, Казан берләштерелгән советы рәисе. Башкала икътисадын базар шартларына яраклаштырып үзгәртеп коруда, эшмәкәрлек үсешендә, эре эшмәкәрлекне реструктуризацияләүдә, шәһәрнең әйдәп баручы пр-тиеләренең (Казан вертолёт з-ды, Казан авиация җитештерү берләшмәсе, «Органик синтез» з-ды һ.б.) кадрлар потенциалын һәм җитештерү көчләрен саклауда, Казанның тарихи үзәген күләмле реконструкцияләүдә, җимерек йортларны бетерүдә һәм шәһәрдә торак төзелешен киңәйтүдә, метро һәм Казансу елгасы аша яңа күпер төзелешләрен оештыруда зур роль уйный. И. — Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча зур чараларны, Казан б-н Мәскәү, С.-Петербург, Екатеринбург һәм РФнең башка сәнәгать үзәкләре арасында хезмәттәшлекне оештыручыларның берсе. Россиянең тарихи шәһәрләре һәм төбәкләре палатасы рәисе (1999), Европа тарихи шәһәрләре һәм өлкәләре ассоциациясе (1999), «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимият» бөтендөнья оешмасы вице-президенты (2004), ЮНЕСКО программаларына булышлык итү үзәгенең региональ бүлеге президенты, «Рубин» футбол клубы президенты (2005 кә кадәр). 2005 тән РФ Президентының Ерак Көнчыгыш федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле. 2007–2008 дә РФнең региональ үсеш министры урынбасары. 2008 дән Ислам Конференциясе Оешмасында (Согуд Гарәбстаны, Җиддә ш.) РФнең даими вәкиле. 1971–75 тә ТАССР, 1991–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2004 елларда ТР халык депутаты. «Почёт билгесе», 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. СССР МС бүләге лауреаты (1986). «Россия мэры — 95» конкурсында җиңгәне өчен «Алтын Меркурий» бүләгенә лаек була.



Г.Г.Исхаков.



З.Г.Исхаков.

**ИСХА́КОВ** Корбангали (18 йөз уртасы — 19 йөз башы), С.-Петербургта *Азия басмаханәсендә* хәреф җыючы. 1785 елда, армия хезмәтендә вакытта, Шәрекъ телләре белгече буларак, басмаханәгә хәреф җыючы итеп билгеләнә. 1800 дә күрү сәләте начараю сәбәпле, үз теләге б-н эштән китә һәм туган ягы Вятка губернасына кайта. Үз урынына Адмиралтейство коллегиясеннән Сәйфулла Мәсгутовны тәкъдим итә.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992.

**ИСХА́КОВ** Фазыл Гариф улы (30.10.1901, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Троицк ш. — 17.5.1959, Мәскәү ш.), тел белгече, филол. фән. канд. (1959). Оренбург шәһәрендә Татар халык мәгарифе ин-тын (1922), Халык мәгарифе практик ин-тын (1926) тәмамлый. Троицкида татар мәктәбендә укытучы (1919–20), Үзәк татар китапханәсе мөдире (1920), Оренбургта Кыргыз край совет партия мәктәбендә (1921–22), Татар халык мәгарифе ин-тында китапханәче (1922–23), татар мәктәпләрендә мөдир һәм укытучы (1923–26) булып эшли. 1926 елдан Мәскәүдә: Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик ун-тында (1926–30,

1933–37) һәм Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (1936–38) татар теле укытучысы, СССР ФАнең Тел һәм язу ин-тында фәнни хезмәткәр (1939–40). 1943 елдан Абакан шәһәрендә: пед. ин-тында укытучы һәм хакас теле каф. мөдире (1943–46), Хакас тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-тында сектор мөдире (1944–46). 1946 да Мәскәүгә кайта. 1946–50 дә РСФСР Мәгариф министрлыгында инспектор-консультант, 1950–59 да СССР ФАнең Тел белеме ин-тында фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре төрки телләрнең фонетикасы, морфологиясе һәм лексикасын чагыштырма өйрәнүгә карый. Нугай, татар, хакас, тува телләре буенча дәреслекләр, татар һәм хакас мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Вопросы изучения хакасского языка и его диалектов. Абакан, 1954 (автордаш); Хакасский язык: Краткий очерк по фонетике. Абакан, 1956; Тувинский язык: Очерк по фонетике. М.–Л., 1957; Грамматика тувинского языка. Фонетика и морфология. М., 1961 (автордаш).

**ИСХА́КОВ** Харис Исхак улы (6.8.1939, Мәскәү), җылылык техникасы белгече, техник фән. д-ры (1991). 1967 елда Мәскәү автомеханика ин-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү химик саклану хәрби академиясендә, 1976 дан Югары инженерлык янгын техникасы мәктәбендә эшли. Хезмәтләре җылылык тотрыклылыгы һәм машиналарны яну-шартлаудан саклау теориясенә карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Охрана труда при организации перевозок и движения на автотранспортных средствах. М., 1985; Пожарная безопасность автомобиля. М., 1987; Техника безопасности на автомобилях и тракторах. М., 1987.

**ИСХА́КОВА** Резеда Риф кызы (1.11.1964, Казан), тарихчы, педагог, тарих фән. канд. (1990), пед. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1986). 1992 елдан Казан пед. ун-тында, 1998 дән РМАнең Урта һөнәри белем бирү ин-тында (Казан) һәм Казан социаль-юридик ин-тында, 2002 дән РФ Юстиция министрлыгы Владимир юридик ин-тының Казан ф-лында укыту һәм фәнни эшләр буенча җитәкче урынбасары. Хезмәтләре пед. белем бирү тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001; Казанская татарская учительская школа и её роль в формировании и становлении национального образования. К., 2002; Формирование российской правительственной политики в сфере педагогического образования (историко-образовательный подход). К., 2002.

**ИСХА́КОВА-ВА́МБА** Роза Әхмәт кызы (27.5.1927, Ульянов ш. — 12.2.2007, Казан), музыка белгече, педагог, сәнгать фән. канд. (1975), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). 1954 елда Гнесиннар исем. муз.-пед. ин-тын тәмамлый (Мәскәү). 1971–83 тә Казан пед. ин-тында укыта. 1991 дән ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Дәүләт фольклор үзәгендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Татар муз. фольклорын җыючы һәм өйрәнүче. Татар музыка тарихына һәм теориясенә караган хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Народные песни казанских татар крестьянской традиции. К., 1976; Ангемитоника как музыкальная система. М., 1990; Татарские народные песни. М., 1990; Салих Сайдашев. К., 1991; Татарское народное музыкальное творчество: традиционный фольклор. К., 1997; Тукай и татарская музыка. К., 1997; О семнадцатиступенной системе восточной музыки. К., 1998.

*Әд.:* Н и г м е д з я н о в М. Роза Исхакова-Вамба // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; У с е и н о в а Р. Пентатоника — её любовь // Идель. 1997. № 5; У р м а н ч е Ф. Ценное исследование о татарской народной песне // Науч. Татарстан. 1998. № 3.

**ИСХА́КОВЛАР**, бертуганнар, Кытай милли азатлык хәрәкәте эшлеклеләре. 1. **Әсгать Тимергали улы** (12.1.1921, Синьцзян провинциясе Дурөбуджин ш. — 1.7.1976, Синьцзян автономияле р-ны). Кытай КП Югары партия мәктәбен тәмамлый (Пекин, 1960 еллар). 1942–44 елларда Голҗа шәһәрендә татар мәктәбендә укыта. Гоминьдан армиясенә каршы сугышларда катнаша; 1944–49 да баш кутәрүчеләрнең баш штабы секретаре, Җәмәгать куркынычсызлыгы министрлыгында бүлек башлыгы, Шәркый Төркестан Халык Респ-касы Милли армиясенең оператив бүлеге башлыгы. 1949 да Яшьләр демократик берлеге секретаре, 1950 дән Синьцзян- Уйгыр автономияле р-ны хөкүмәте әгъзасы, КП ҮК секретаре. КХРда «культура революциясе» вакытында репрессияләнә; үлгәннән соң аклана. 1980 еллар башында Урымчы шәһәрендәге «Революция корбаннары» каберлегенә күчереп җирләнә. 2. **Мәргуб Тимергали улы** (13.3.1923, Голҗа ш. — 1993, Алма-Ата), генерал-майор (1955). Кытай Халык-азатлык армиясенең Югары хәрби академиясен тәмамлый (Пекин, 1960). 1941–44 тә Голҗада татар һәм уйгыр мәктәпләрендә укыта. Гоминьдан армиясенә каршы сугышларда катнаша; Шәркый Төркестан Халык Респ-касы Милли армиясен оештыручыларның берсе. 1945–55 тә Кытай халык армиясенең Синьцзян Коралллы көчләре штабы башлыгы урынбасары. 1960 елның декабрендә СССРга күчеп китә.

*М.Г.Госманов.*

**ИСХАКЫ́Й** (Исхаков) Гаяз (Мөхәммәтгаяз) Гыйлаҗетдин улы (мөһаҗирлектәге псевд. Иделле) (22.2.1878, Казан губ., Чистай өязе Яуширмә а. — 22.7.1954, Әнкара, Истанбулда җирләнә), язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе; 20 йөз башындагы татар яңарыш әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Гаяз, Гаяз Исхаков, Казанлы, Гаяз Исхакый, Иделбай, Бикбулат, Биктимер, Бичура углы, Котлы Мөхәммәт, Тимер, Ураллы, Хәбибрахман әл-Болгари, Кәндилле, Хәмит, Чыңгыз, Япанчы кебек исемнәр һәм псевдонимнар б-н яза һәм басыла.

Мулла улы. 12 яшенә кадәр туган авылында әтисендә укый, 1890–93 елларда Чистайда танылган дин эшлеклесе Закир Камал мәдрәсәсендә, 1893–97 дә Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә белем ала. 1898–1902 дә Казан татар укытучылар мәктәбендә укый, Көнбатыш Европа, рус иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик фикерләре б-н таныша, И.С.Тургенев, И.А.Гончаров, Ф.М.Достоевский, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький иҗаты б-н кызыксына; татар теленә А.С.Пушкинның «Капитан кызы» («Капитанская дочка», 1899), Н.В.Гогольнең «Борынгы алпавытлар» («Старосветские помещики», 1902) әсәрләрен тәрҗемә итә. 1901 елда аның тырышлыгы б-н «*Шәкертлек*» дигән яшерен түгәрәк оеша, гектографта «*Тәрәкъкый*» г-тасы басыла. 1902 нең көзеннән Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Ун-тка керү нияте б-н 1903 нең җәендә Казанга килә, ләкин ата-анасының ихтыяры б-н туган авылына кайтырга һәм мулла вазифаларын башкарырга мәҗбүр була. 1904 тән янә Казанга килә, шул чордан башлап үзен тулысынча иҗтимагый-сәяси һәм әдәби эшчәнлеккә багышлый. 1905–07 дә И. милли хәрәкәттә актив катнаша: шәкертләрнең «*Берек*» исемле яшерен оешмасын төзи, Казанда татар яшьләренең яшерен сәяси «Хөррият» җәмгыятен җитәкли, татар эсерларының «*Таңчылар*» төркеме лидеры була; Россия мөселманнарының «Иттифакъ әл-мөслимин» фиркасе съездларында радикал татар яшьләре вәкиле буларак та катнаша; гамәлдә «*Таң йолдызы*», «*Тавыш*», «*Таң мәҗмугасы*» г-таларында мөхәррир вазифасын башкара. Революцион эшчәнлеге, хакимияткә каршы ясаган чыгышлары өчен 18 тапкыр кулга алына; Чистай, Казан, Мәскәү, С.-Петербург төрмәләрендә утыра, Архангельск губернасына сөргенгә озатыла. 1909–11 дә сөргеннән качып, И. ике тапкыр Төркиягә барып чыга, анда әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә, «Сират әл-мөстәкыйм» («Туры юл»), «Төрк дәрнәге дәргиси» («Төрек җәмгыяте мәҗмугасы») исемле төрек басмаларында языша. Романовлар Йортының тәхеткә утыруына 300 ел тулу уңае б-н 1913 нең 3 апрелендә игълан ителгән амнистия карары нигезендә тоткынлыктан чыгарыла (Казанда яшәргә рөхсәт бирелми). Мәскәүдә, Петербургта яши, «*Ил*» г-тасын нәшер итә. 1917 елгы Февр. рев-циясен хуплап каршылый, Вакытлы хөкүмәтнең милли сәясәтен яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче съездында Идел буе һәм Урал төрки-татарлары өчен милли-мәдәни автономия — *Идел-Урал Штаты* төзү фикерен алга сөрә. Аның бу идеясе Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче съездында да (Казан, 1917), Милләт Мәҗлесендә дә (Уфа, 1917–18) хуплау таба. И. *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы* әгъзасы итеп сайлана. Совет хакимиятен кабул итми. Большевиклар эзәрлекләвеннән качып, Себер якларына (Петропавловск шәһәренә) китә, «*Маяк*» г-та-



Сулдан уңга: Г. Исхакый, С. Максуди, Ф. Туктаров. Париж. 1920.



Г. Исхакый.

сын чыгаруда катнаша (1918–19). 1919 да И., Версаль тынычлык конференциясендә катнашу өчен, Ерак Көнчыгыш аша Европага юнәлә. 1920 нең мартыннан 1922 нең җәенә кадәр Парижда, аннары Берлинда яши. 1925 тән — Төркиядә; Истанбулда «*Түрк юрду*» ж-лында, «*Җөмһүрият*» г-тасында актив хезмәттәшлек итә. Әмма мәкаләләрендә татарлар б-н башкортларның милли дәүләтен төзергә, төрки халыкларны берләшергә чакырганы өчен, совет дипломатиясенең Төркия хакимиятенә ясаган басымы нәтиҗәсендә, Төркиядән китәргә мәҗбүр була. Премьер-министр Ю.Пилсудский чакыруы буенча (алар Архангельск губернасында сөргендә танышалар) 1927 дә И. Польшага күчеп килә, анда «Идел-Урал комитеты»н оештыра, Варшава ун-тының Шәрекъ факультетында төрек теле укыта. 1931 нең декабреннән 1932 елның башына кадәр Иерусалимда үткән Бөтендөнья мөселманнар конгрессында катнаша, докладында Советлар Россиясендә ислам динен кысу, мәчетләрны ябу, дин әһелләрен эзәрлекләү турында сөйли. Бу мәсьәлә б-н ул Мисыр, Иран, Гыйрак, Әфганстан, Йәмән дәүләтләре башлыкларына, ш.у. Марокко солтанына һәм Рим папасына мөрәҗәгать итә. 1933–36 да И. Ерак Көнчыгыш илләре буйлап сәяхәт кыла, Кытай, Маньчжурия, Япония, Кореяда яшәгән төрки-татарларны берләштерү, *Мукден конгрессын* оештыру һәм үткәрү, «*Ерак Көнчыгыш төрки-татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе*»н төзү буенча зур эш алып бара. 1936 да И. Варшавага әйләнеп кайта, 1939 да Польшага фашистлар Германиясе басып кергәч, Төркиягә китә һәм соңгы көннәренә кадәр шунда яши. Мөһаҗирлек елларында И. «*Милли юл*» (1928 нең декабре — 1930), «*Яңа милли юл*» (Берлин, Варшава, 1930–39) ж-ллары, «*Милли байрак*» (Мукден, 1935–45) г-тасы нашире һәм мөхәррире була. Бу басмаларда ул татарларны югалган дәүләтчелекләрен кайтару, милли азатлыкка ирешү өчен берләшергә чакыра.

И. иҗат юлының башланып китүе 19 йөз ахыры — 20 йөз башына — татар әдәбияты үзенең Яңарыш чорына аяк баскан дәвергә туры килә (к. *Яңарыш*). Язучы иҗатын шартлы рәвештә 4 чорга бүлеп өйрәнергә мөмкин: 1) 1897–1904 елларны үз эченә алган мәгърифәтчелек дәвере; 2) «таңчылык» баскычы — инкыйлаби идеяләр б-н мавыккан 1905–10 еллар; 3) милли бердәмлек идеяләренә өстенлек биргән 1911–18 еллар; 4) мөһаҗирлек дәвере — татарларның милли дәүләтчелеген торгызу идеологиясен актив рәвештә алга сөргән 1918–54 еллар. И.ның беренче әдәби тәҗрибә үрнәкләре һәм төрек теленнән татар теленә тәрҗемәләре («Җәррах баба» хикәясе) сакланмаган. Иҗатының башлангыч чорында ук прозаик, драматург, публицист буларак таныла. Әсәрләренең төп мотивы — урта гасырлар мөселман әдәбиятларында ук киң таралган «гыйлем-наданлык» антиномиясе. Аның фикеренчә, җәмгыятьнең социаль-икътисади һәм рухи тәрәккыятен тәэмин итүдә һәм кешене тәрбияләүдә төп чара булып Акыл, Гыйлем һәм Сүз сәнгате тора. Беренче басылган әсәре — «Тәгалләмдә — сәгадәт» (1897) хикәясе. Анда автор җәдит мәдрәсәсендә (к. *Җәдитчелек*) укыган Хәлим шәкертнең милләт хадиме булып җитешүен һәм шәхси тормышында да бәхеткә ирешүен тасвирлый. Әлеге хикәядә күтәрелгән мәсьәләләр «Бай угылы» (1897, 1903 тә басыла) повестенда да чагылыш таба. Аның төп герое Кәрим, укымышсыз ата-ана киңәшен тотып, җәдит мәдрәсәсен ташлап китә; үзенә «тәрбияче» итеп куелган урам малае Фәхринең тискәре йогынтысына бирелеп, иркә, азгын яшүсмергә әверелә, җинаятьләр кыла һәм ызгыш-сугышларның берсендә үлә. И.ның мәгърифәтчелек прозасы һәм драматургиясендә күп төрле мотивлар ярдәмендә ачылган феминизм мәсьәләләре үзәк урынны алып тора. Авторга язучы буларак зур танылу алып килгән «Кәләпүшче кыз» (1900) повестеның героинясе Камәр дә акчага хирыс, уйнашлыкка этәрүче Зөһрә карчык һәм азгын приказчик Вафа корбаны буларак гәүдәләнә. «Өч хатын белән тормыш» (1900) пьесасында ул татарлар арасында киң таралган күп хатынга өйләнү гадәтен тәнкыйтьли, гаиләдә хатын-кызларның ирләр б-н тигез хокуклы булуларын яклап чыга. Француз һәм төрек драматургиясе йогынтысында язылган «Ике гашыйк» (1902) пьесасында да искергән феодаль-патриархаль гореф-гадәтләр, гаилә корудагы катлауларга бүленү күренешләре тәнкыйть ителә. Бу темага багышланган әсәрләр арасында «Очрашу, яки Гөлгыйзар» (1903) романтик повесте аерым бер урын алып тора. Әсәрдә Шәркый мөселман һәм Европа мәдәниятендә кабул ителгән мәхәббәт, өйләнү, гаилә кору турындагы карашлар чагыштырыла, бер-берсенә каршы килгән фикерләр әйтелә. Повесть геройлары Гөлгыйзар б-н Габдулла Көнбатыш материализмы, Шәрекъ идеализмы һәм рухияте, Коръәндәге язмыш һәм кеше ихтыяры төшенчәләре, Ч.Дарвинның табигый сайланыш теориясе, А.Бергсонның интуитивлык һәм тормыш фәлсәфәсе хакында фикер алышалар.

И. иҗатында гына түгел, бәлки 20 йөз башы татар иҗтимагый һәм әдәби тормышында зур вакыйга булып торган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) исемле мәгърифәтчелек антиутопиясендә бүгенге татарларның ерак бабалары — болгарларның 10–13 йөзләрдә югары цивилизациянең чәчәк ату чорын кичерүләре, ә инде 19–20 йөзләргә җиткәндә, икътисади һәм рухи төшенкелек кичереп, әхлакый бозыклыктан, йогышлы яман чирләрдән кырылып, 21 йөз ахырында милләт буларак тарих мәйданыннан юкка чыгулары турында сөйләнә. Әсәрдә болгарларның үлеп бетүләренең сәбәбе кадими «голәмалар сыйныфының» милли татар яшьләренең тәрәккыяткә, фәнгә, Европа һәм рус мәдәниятен үзләштерергә омтылуларына, рус уку йортларында белем алуларына каршы чыгулары аркасында туган иҗтимагый торгынлык нәтиҗәсе итеп аңлатыла (к. *Кадимчелек*). Әсәрнең сюжет җепләре, анда чагылыш тапкан иҗтимагый идеаллар, әдәби-эстетик фикерләр, образ-сурәтләр Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Г.Камал, Н.Думави, Ф.Туйкин һ.б. бик күп язучылар иҗатында үстерелә һәм сәнгатьчә эшкәртелә.

«Таңчылык» чорында иҗат ителгән, марксизм эстетикасының көчле тәэсирен кичергән әсәрләрнең әйдәп баручы мотивын «Тартышуда гына табарсың син үз бәхетеңне!» исемле шигарь тәшкил итә. Думага сайлаулар һәм революцион хәрәкәткә бәйле чын вакыйгалар Чистай төрмәсендәге хәлләрне сурәтләгән автобиографик һәм публицистик язмалар рәвешендә «Зиндан» (1907) повестенда чагылыш таба. Социалистик идеяләр б-н өртелгән феминистик карашлар йогынтысында искергән йолаларга, катлауларга бүленүгә каршы чыккан, бай ата-ана йортын ташлап, ярлырак гаиләдән булган сөйгәне Ибраһим янына качкан Галия образы «Алдым-бирдем» (1907) драмасының төп героинясы булып тора. Драма авторның үзе тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә һәм М.Горький тырышлыгы б-н «Заветы» ж-лында басылып чыга (1914, № 6). Рус язучысы б-н И. күп хатлар алыша. И.га язган хатларының берсендә М.Горький: «Кайчагында минем башыма шундый бер уй килә: әгәр дә берәр татар кешесе русларның татарлар б-н бергә күрше булып гомер кичерүе рус халкының яшәеше турындагы күзаллауларына нинди йогынты ясаганлыгын төшендерә алса, татарларга да, русларга да зур бушлык күрсәтер иде» — ди. Татар пролетар әдәбиятының үрнәге булган «Тартышу» (1908) драмасында социал-демократларның, «таңчы»-эсерларның, народник яшьләрнең самодержавиегә каршы чыгышлары сурәтләнә. Пьесада катнашучылар «татар революциясе», «рус революциясе» дигән төшенчәләрнең мәгънәсе, үзенчәлекләре турында әңгәмәләр алып баралар. Алар фикеренчә, «Татар революциясе» ул — мәгърифәтчеләрнең, җәдитчеләрнең 19 йөз ахыры — 20 йөз башы



Г. Исхакый кызы Сәгадәт белән. Берлин. 1931.



Г. Исхакый. Япония. 1934.

татар иҗтимагый һәм рухи тормышын европалаштыруга омтылулары; «рус революциясе» исә — 1905–07 елларда татарлар б-н русларның самодержавиегә һәм аның бюрократиясенә каршы бергәләп чыгыш ясаулары. Народниклык идеяләренең көчле тәэсире «Мөгаллим» (1908) һәм «Мөгаллимә» (1913) драмаларында аеруча ачык күзәтелә. Аларның төп геройлары Салих һәм Фатыйма, ир-егетләр б-н хатын-кызларның никахлары аларның милләт каршындагы иҗтимагый бурычларын үтәүгә аяк чала, дип, мәхәббәттән дә, гаилә корудан да баш тарталар, үзләренең эшчәнлекләрен милләт мәнфәгатьләре б-н бәйле бөек идеалларга хезмәт итүгә багышлыйлар: халыкның социаль-сәяси активлыгын, мәдәнилек дәрәҗәсен, милли аңын күтәрү өчен, шәхси бәхетләрен корбан итәләр. И. антиклерикаль темаларга язылган комедияләре б-н дә танылa. Ул иске карашлы муллаларның схоластик фикерләүләреннән, җаһиллекләреннән «Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләрендә ачы көлә.

20 йөз татар иҗтимагый һәм рухи тормыш манзарасы бөтен тулылыгында И.ның «Тормышмы бу?» (1911), «Мулла бабай» (1910, тәмамланмаган), «Теләнче кыз» (1–3 китап, 1906–14) романнарында гәүдәләнә. «Теләнче кыз» — татар әдәбияты тарихында тәнкыйди реализм кысаларында (Л.Н.Толстойның «Воскресение» — «Яңадан туу» романы йогынтысында) язылган һәм күпмедер дәрәҗәдә мәгърифәтчелек реализмы һәм пролетар әдәбият өчен хас алымнар б-н үрелгән беренче роман. Автор татар милләтенең яңарышында җәмгыятьтәге социаль каршылыкларны, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен уңай хәл итүне әһәмиятле бер шарт дип саный. Алданрак язылган әсәрләреннән аермалы буларак, бу романында автор Толстойның явызлыкка каршылык күрсәтмәү фәлсәфәсе б-н бәхәскә керә, хатын-кызларны язмышларын үз кулларына алырга өнди. Бу идеяне кабул иткән романның төп героинясы Сәгадәт күңелсез үткән яшьлеге б-н араны өзәргә, бай ире Габдулла йортын ташлап, Петербургка укырга китәргә көч таба, үзен халыкка хезмәт итүгә багышларга карар кыла. Габдулланың әхлакый яктан үзгәрүенә, Сәгадәтнең рухи яңаруына зур йогынты ясаган автобиографик Мансур образында халыкчылык идеяләре дә көчле чагылыш таба. М.Горький кебек тормыш-көнкүрешне натуралистик, фотографтай төгәл тасвирлап, бу әсәрендә И. «тормыш төбе»нә ташланган геройларның күмәк портретын иҗат итә. Аларның рухи дөньясы төшләр, символик сурәт, монолог, табигать күренешләре б-н чагыштырулар ярдәмендә дә ачыла. «Тормышмы бу?» психологик романы мәдрәсә шәкертенең көндәлеге формасында язылган. Анда И. татар җәмгыятенең хәләтен Шәркый мөселман традицияләреннән Көнбатыш мәдәниятенә таба күчеше рәвешендә гәүдәләндерә. Моны ул әсәрнең төп герое — башта ислам фәннәрен өйрәнгән, үзләштергән, аннары рус һәм Европа мәдәниятенә таба йөз тоткан, ислахчы булып халкына хезмәт итәргә хыялланган мәхдүмнең — мулла улының — рухи әзләнүләре рәвешендә чагылдыра. Әмма тормыш киртәләрен җиңә алмаган герой уртакул авыл мулласы булып кала. Автор яшәешнең мәгънәсен җуйган, үз-үзенә «Тормышмы бу?» дигән риторик сорау куйган геройның газаплы уй-кичерешләрен күрсәтә. Тәмамланмый калган «Мулла бабай» романында реалистик осталык, тирән психологизм, мул һәм ачык этнографик буяулар б-н бирелгән татар тормышы, кадими һәм җәдиди мәдрәсәләрдә укыту системасы, төрле тип руханилар һәм хәлфәләр образлары гәүдәләнә. Романның төп герое имам Хәлим халкыбызның акыл иясе һәм гомумкешелек кыйммәтләренә ия дин әһеле булып күз алдына килеп баса. 1910–11 дә язучы Фрейд тәгълиматы рухында психоанализга корылган, «Фамилия сәгадәте», «Татар гакълы», «Мәдрәсә җимеше», «Көтелгән бикәч», «Шәкерт абый» дигән хикәяләр бәйләмен яза. Бу циклда кеше психикасының аңсыз катламнарын, невроз хәләтләрен, эротик мәхәббәтне чагылдыруга шактый урын бирелә.

1910 елларда И.ның иҗтимагый-сәяси карашлары һәм сәнгатьчә фикерләве җитди үзгәрешләр кичерә. Ул, инкыйлаби-сыйнфый көрәш идеяләреннән баш тартып, гомуммилли мәнфәгатьләрне яклау юлына баса, бөтен көчен татар җәмгыятенең төрле катлауларын берләштерүгә һәм милли үзаңны үстерүгә юнәлтә. Моны язучы татар милләтенең бөтендөнья мәдәнияте казанышларын үзләштерүдә, тәрәккыяткә ирешүдә мөһим чара дип саный. Күпсанлы публицистик һәм әдәби әсәрләрдә милли бердәмлек темасына басым ясау И.ны татар милли азатлык хәрәкәтенең лидеры итеп таныта. Россия дәүләтенең сәяси тарихы кысаларында милли мәсьәләләрне яктырту, мәдәни, дини, гаилә мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерү аның бик күп әсәрләренең үзәген тәшкил итә. Милли кыйммәтләрне чагылдыру ягыннан «Сөннәтче бабай» (1911) повесте аерылып тора. Аның төп геройлары — Корбангали карт б-н аның карчыгы Гөлйөзем — татар халкының иң күркәм әхлакый сыйфатларын үзләренә туплаган образлар. Аларның озакка сузылган бәхетле гаилә тормышы бик күп буыннарның тарихи тәҗрибәсенә, гасырлардан килгән мөселман традицияләренә нигезләнә. Әсәрдә пейзаж, этнографик детальләр, татар халкының милли характер үзенчәлекләре (хезмәт сөючәнлек, кунакчыллык, чисталык) сәнгати яктан дөрес һәм үтемле итеп тасвирланган. Повестьның хикәяләү стиленә Н.В.Гогольнең «Борынгы алпавытлар»ындагы җиңелчә ирония һәм юмор б-н хикәяләү алымы зур йогынты ясаган. «Зөләйха» (1912, 1918 дә басыла) романтик трагедиясендә мөселман татарларны көчләп чукындыру һәм урыслаштыру сәясәте күрсәтелә. Аның геройлары — рухи яктан нык, илаһи гаделлек, азатлык, изгелек, кешелеклелек идеалларының тормышка ашачагына ышанган кешеләр. Зөләйха ахырга кадәр кешелек дәрәҗәсен, милли-дини хасиятләрне саклап калырга тырыша. «Остазбикә» (1915) повестенда мөселман мәдәниятенә хас кыйммәтләр — гаилә, балаларга карата мәхәббәт, ананы хөрмәтләү, милләткә тугрылык — алга чыгарыла. Язучының хатын-кызга карата тирән психологизм б-н сугарылган гуманистик карашлары остазбикә Сәгыйдә образында гәүдәләнеш таба. Аның акылы һәм югары әхлаклы гамәлләре алдында ире Вахит хәзрәт тә баш ия.



Г. Исхакый әсәре буенча куелган «Зөләйха» спектакленнән күренеш. Г. Камал исем. Татар академия театры. 1992.

«Ул әле икеләнә иде» (1914) һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) повестьларында И. милләтара никахлар мәсьәләсен күтәрә. Аның геройлары милли менталитет һәм дини традицияләр кысаларыннан чыгу талпынышы да ясап карыйлар. Әсәрләрдә мәхәббәт һәм гаилә турында төрле карашлар очрый. Автор аларны гомумкешелек позицияләреннән дә, христиан һәм ислам диннәре күзлегеннән дә чыгып аңлатырга тырыша. Рус хатын-кызлары образлары әсәрдә, гадәттә, романтик рухта идеаллаштырып бирелә; аларга рухи торгынлык кичергән мохиттә яшәргә мәҗбүр булган, шул сәбәпле интеллектуаль үсеш ягыннан да түбәнрәк торган татар хатын-кыз образлары капма-каршы куеп сурәтләнә.

Мөһаҗирлек дәверендә язылган публицистик һәм әдәби әсәрләренең төп темасын татар халкының колониаль бәйлелеккә эләгүе, сугышлар, инкыйлаби тетрәнүләр, көчләп урыслаштыру, совет хакимиятенең дошманы дип игълан ителгән милли зыялыларны һәм руханиларны юк итү нәтиҗәсендә туган зур тарихи фаҗига тәшкил итә («Дулкын эчендә» драмасы, 1920). Язучы патша Россиясенең рус булмаган халыкларны изү сәясәтен кискен тәнкыйтьли («Өйгә таба» повесте, 1922); төрки халыкларны берләшергә,

югалткан дәүләтчелекләрен торгызырга, милли азатлык өчен көрәшергә чакыра. «Локман Хәким» (1923) әкият-антиутопиясендә И. киләчәктә СССРда мәйданга чыгачак тоталитар хакимият турында алдан хәбәр бирә. Импрессионистик стильдә язылган «Көз» (1923) психологик повестенда И. руслаштыру сәясәте нәтиҗәсендә морзалар катлавының юкка чыгачагын искәртә. Сукырларча Көнбатышка иярүнең милли тамырларны югалтуга китерү мәсьәләсе «Жан Баевич» (1923) комедиясенең төп конфликты булып тора. Карикатура һәм фарс рәвешендә сурәтләнгән төп герой Мольер пьесаларындагы көлке геройларны хәтерләтә. 1930 елларда И. Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләренә сәяхәт кыла, милли азатлык өчен көрәш турында күпсанлы һәм күләмле мәкаләләр б-н чыгышлар ясый. «Ислам мәмләкәтләрендә» (1933) исемле мәкаләләр циклында мөселман илләрендә ислам диненең торышына анализ ясала, большевикларның Идел буе һәм Урал мөселманнарының дини хокукларын кысу сәясәте тәнкыйтьләнә. Ул исламның татар милләте тәрәккыятенә, аның бербөтен булып яшәвенә, халык буларак әхлакый куәтен, кодрәтен саклап калуына ярдәм итүче универсаль рухи көч булуын раслый. КПСС ҮКның татар халкына үз тарихын һәм әдәбиятын өйрәнүне рәсми рәвештә тыйган «Татар партия оешмасы эшенең торышы һәм массакүләм-сәяси, идеологик эшне яхшырту чаралары турында» дип аталган 1944 елгы 9 август карарына И. «Олуг Мөхәммәд» (1947) исемле тарихи драмасы б-н җавап бирә. Пьесада *Олуг Мөхәммәд хан* образы руслар б-н тату яшәргә омтылган хан буларак сурәтләнә; рус тарих фәнендә шактый киң таралган — Алтын Урда — золым символы, дигән карашлар кире кагыла.

И. — төрки халыкларның азатлык хәрәкәте тарихына багышланган күп кенә хезмәтләр авторы. Алар арасында татар халкының милли дәүләтчелеге мәсьәләсенә багышланган «Идел-Урал» (1927) хезмәте, аның татар, рус, француз (1933), япон (1934), инглиз һәм поляк (1938) телләренә тәрҗемәләре аеруча зур әһәмияткә ия. Анда Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы тарихына, аларның матди һәм рухи мәдәниятенә кыскача күзәтү ясала, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкының авыр колониаль изелүгә дучар ителүе, аның үз динен, телен, менталитетын саклап калу өчен алып барган авыр көрәше турында сөйләнә. Хезмәттә И. татарларның тарихи үсеш дәвамында югалган мөстәкыйльлекләрен яңадан торгызу һәм «Идел-Урал» дәүләте төзү мөмкинлеген дәлилли. Бу мәсьәлә И. тарафыннан 1917–18 дә үк көн тәртибенә куела, мөһаҗирлеккә киткәч язылган «Өйгә таба» повестенда һәм «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасында сәнгати чаралар б-н чагылдырыла. И. фикеренчә, Россия патша заманында да, большевиклар килгәч тә «халыклар төрмәсе» булып кала. Ул бөтен иҗтимагый-сәяси катаклизмнарның сәбәбен иң актуаль мәсьәләнең — милли мәсьәләнең — хәл ителмәвендә күрә: «Рәсәйдә революция әле тәмамланмаган. Большевиклар чоры бу революциядә бер күчеш этабы гына. Инкыйлабның төп асылы милли мәсьәләгә барып тоташа. Шуңа күрә ул милли мәсьәләне хәл иткәндә генә, бәйсезлек өчен көрәшне даими дәвам итүче халыклар тулаем азатлыкка ирешкәндә генә тәмамлана ала», — дип яза ул. И. — ш.у. журналистика («Гәзитчелек эшендә 25 ел», 1931), әдәбият тарихына һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган хезмәтләр авторы. «Шималь төрек әдәбиятына бер нәзар» исемле басылмый калган монографиясендә һәм мәкаләсендә татар әдәбияты үсешенә мәдәният-тарих мәктәбе һәм биографик метод принципларыннан чыгып бәя бирә. Мәкаләләренең байтагында К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, И.Гаспралы, Р.Фәхретдин кебек татар мәгърифәтчеләренең фидакарь эшчәнлекләре; Ф.Кәрими, С.Максуди, Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Камал, Г.Коләхмәтов һ.б.ның әсәрләре анализлана. Публицистик чыгышларында большевикларның әдәбият өлкәсендә алып барган сәясәтләре тәнкыйтьләнә. Аерым әсәрләре («Алдым-бирдем», «Шәкерт абый», «Сөннәтче бабай», «Калуш») 1913–16 да рус телендә дә дөнья күрә.

Совет хакимияте елларында эмигрант язучы һәм «халык дошманы» дип тамгаланган И.ның әсәрләре онытылуга дучар ителә. 1980 еллар ахырында гына аның мирасы халыкка кире кайтарыла. И. исемен аклау эшенә әдәбият галиме И.Нуруллин һәм язучы Ә.Еники зур өлеш кертәләр. Аның әдәби иҗаты, сәяси-тарихи карашлары Н.Дәүләт, С.Чыгъ-тай, М.Таһир, И.Нуруллин, Һ.Мәхмүтов, Л.Гайнанова, М.Хәсәнов, Ф.Мусин, М.Сәхапов, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Ф.Ибраһимова, Р.Ганиева, А.Шәмсутова, Р.Харрасова, Р.Яруллина, Б.Т.Гали һ.б. авторларның хезмәтләрендә яктыртыла.

1991 дә ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге булдырыла, соңрак Яуширмә авылында язучының музее ачыла.

Ә с ә р.: Мәҗмугаи асар: 8 томда. К.–М.–СПб., 1911–18; Әсәрләр. К., 1998–2005. Т. 1–4, 6, 8.

*Әд.:* М у с и н Ф. Гаяз Исхакый. К., 1998; Х а р р а с о в а Р. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. К., 2002; Ш ә м с у т о в а А. Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идеал-эстетик эволюциясе. К., 2003; М и ң н е г у л о в Х. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. К., 2004; Н у р у л л и н И. Два письма М.Горького // Вопр. литературы. 1988. № 4; Г а л и Б.Т. Щедрый талант. Общественно-политическая деятельность и исторические взгляды Г.Исхаки. К., 2002; С а х а п о в М. Исхаки и татарская литература XX века. К., 2003; Г а н и е в а Р. Гаяз Исхаки // Ислам на Европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004.

*Р.К.Ганиева.*

**ИСХАКЫ́Й ГАЯ́З ТАРИХИ́-МЕМОРИА́ЛЬ ҺӘМ ЭТНОГРА́ФИЯ КО́МПЛЕКСЫ**, Чистай р-ны Яуширмә авылында. ТР МК карары б-н 1997 елның 27 маенда оештырыла һәм 1999 ның 30 июнендә ачыла. 1999–2006 да ТР Дәүләт (2001 дән Милли) музее ф-лы. Яуширмә авылында туган Г.*Исхакыйга* багышлана. Язучының иҗаты турында сөйләүче беренче экспозиция 1993 нең 3 февралендә авыл мәдәният йорты каршында булдырыла. Соңыннан музейны сәүдәгәр Сәйфетдиннең (Г.Исхакыйның Фәризәбану



Г. Исхакый музее.

исемле бертуган сеңлесенең ире) элеккеге утарында оештыру турындагы программа эшләнә. Утардан 19–20 йөзләр чигендәге үзенчәлекле архит-ра истәлеге булган ике катлы кирпеч йорт сакланып калган; беренче каты кибет булган, икенче каты яшәү урыны булып файдаланылган. Утар ансамбленең архит-ра-планлаштыру эшләре Г.Исхакый бертуганының кызы С.Шәрипова тәкъдиме буенча башкарыла. Комплекс терр-ясенең мәйданы — 5200 *м*², ш.и. янәшәсендә парк зонасы — 0,16 *га*, экспозициянең гомуми мәйданы — 186 *м*². Коллекцияләргә 958 саклау берәмлеге керә. Экспозиция 2 төп бүлектән: сәүдәгәр кибете интерьерын чагылдыручы



Г.Исхакый музее. Экспозиция күренеше.

тарихи-этнографик һәм язучының иҗади эшчәнлегенә, тормышына багышланган биографик бүлекләрдән тора. Иң әһәмиятле экспонатлар арасында Г.Исхакый һәм аның гаиләсенең әйберләре: намазлык, сөлге, сандык һ.б. йорт кирәк-яраклары, ш.у. язучының фотосурәтләре, документлары, хатлары, исән чагында басылып чыккан китаплары. Музей комплексы галереясында рәссам Р.Галимуллинның Г.Исхакый иҗаты мотивлары буенча язылган әсәрләреннән даими эшләүче күргәзмә оештырылган. Музей ел саен язучының туган көне (22 февр.) һәм бүләкләр кабул итү көннәре уздыра. Музей директоры Н.В.Әгъзәмов.

**ИСХАКЫ́Й** (Исхаков) Хәбиб Шәрифулла улы (1.10.1883, Уфа губ., Бөгелмә өязе Бәркәтә а. — 20.1.1913, Казан), шагыйрь. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, соңыннан шунда ук укыта. «Яз» исемле беренче шигыре 1908 елда «Әхбар» г-тасында басыла. Алдагы елларда әсәрләре «Ялт-Йолт», «Шура», «Аң» ж-лларында чыга. Шигырьләрендә туган як табигате («Көз килде», 1910),

лирик геройның тойгы-хисләре («Искә төшә», 1912) тасвирлана, социаль гаделсезлек тәнкыйтьләнә («Ышанмыйм!», 1910). Аерым мәгълүматларга караганда, үз-үзенә кул сала.

Ә с ә р.: Х.Исхакый шигырьләре. К., 1910; Милләт бакчасы. К., 1911; Гөл бакчасы. К., 1912; Искә төшә: Шигырьләр // Мирас. 1998. № 8.

*Әд.:* Б ә ш и р и З.Ш. Замандашларым белән очрашулар. К., 1968.

*З.З.Рәмиев.*

**ИТ ЭШКӘРТӮ СӘНӘГАТЕ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгатенең иң эре тармакларының берсе; терлек, кош-корт, йорт куяннарын чалу һәм сугым продукциясен эшкәртү б-н шөгыльләнә; ит, казылык ризыклар, ит консервлары, ярымфабрикатлар, котлет, пилмән, кулинария ризыклары, ш.у. коры терлек азыклары (сөяк оны), кыйммәтле мед. препаратлары (инсулин, гепарин, липокаин һ.б.), җилем, желатин, тире, каурый-мамык әйберләр һ.б. җитештерә. ТРда төп туклану продуктларын (алкогольле һәм җиңелчә алкогольле эчемлекләрдән тыш) эшләп чыгаруда И.э.с.нең өлеше 30% чамасы тәшкил итә.

18 йөзгә кадәр Россиядә ит эшкәртү кәсебе йортта башкару-кустарчылык характерында була. 18 йөз башында С.-Петербургта терлек чалуга карата полиция күзәтчелеге кертелә, беренче гомуми терлек суючу урыны оештырыла, немец казылыкчыларының пр-тиеләре ачыла. 1902 елга илнең Европадагы өлешендә 1683 чалу урыны исәпләнә, шуларның 19%ы таш корылмаларда урнаша, 290 урында даими вет. күзәтчелеге алып барыла. 1908–13 тә ел саен терлекләрнең барлык төрләреннән 16,2–17 млн. баш хайван чалына. 1917 дә 2,5 меңләп казылык ф-калары һәм остаханәләре 50 мең *т* дан артык казылык, сосиска һәм ысланган ризыклар җитештерә.

Казан губернасында И.э.с. эре ит һәм терлек сәүдәсе үсеше б-н бер үк вакытта барлыкка килә. 1839 да Казанда 22, 1857 дә 25 ит кибете була, аларда еллык сәүдә әйләнеше көмеш акча б-н 70 мең сум тәшкил итә. 19 йөзнең икенче яртысында күмәртәләп сәүдә итүче эре фирмалар оеша. 20 йөз башында Казанга ел саен Самара һәм Вятка губерналарыннан (50%), Урал өлкәсеннән һәм Оренбург губернасыннан (20%), Казан губернасы өязләреннән (20%), Петропавловск һәм Чиләбе шәһәрләреннән (10%) якынча 800 мең пот терлек, яңа суелган түшкәләр һәм төрле дәрәҗәдә тозланган ит кителә. Казан, Чистай һәм Лаеш сәүдәгәрләре С.-Петербургка һәм Мәскәүгә 100 мең пот чамасы дуңгыз ите җибәрәләр. Шул ук шәһәрләргә һәм чит илләргә Казан фирмаларының Мәскәү–Казан тимер юлы станцияләре каршында оештырылган сатып алу-симертү-хәзерләү бүлекчәләре тарафыннан 50 мең пот тирәсе кош ите озатыла. Бу бүлекчәләрнең иң зурысы Урмар станциясендә урнашкан була, ул 2 суыткыч б-н җиһазландырыла. 1890 еллар башына Казанда 10 лап вак хосусый чалу урыны эшли. Эчке эшләр министрлыгының махсус боерыгы б-н шәһәрдән һәм эчәргә яраклы су чыганакларыннан читтә Казан шәһәр чалу урыны төзелгәннән соң, 1892 дә аларның барысы да ябыла. Бу чалу урынында елга 19,4 мең баш мөгезле эре терлек, 25,4 мең сарык һәм кәҗә, 956 ат һәм 66 дуңгыз чалына (1897). Аның каршында терлекләргә һәм иткә вет. тикшерүе уздыручы контора, эчәк-аксым (1896 дан) һәм утильләштерү (1912 дән) з-длары эшли. Итне саклау өчен шәһәрдә даими түбән дымлылыктагы һәм түбән температуралы, һава йөрү чикләнгән подваллар арендалана. Аны саклауда ш.у. түшкәләрне пешекләү, өтү, тозлау ысуллары кулланыла. 1913 тә губерна земствосы тарафыннан Казанда 800 *т* сыйдырышлы суыткыч төзү проекты эшләнә (гамәлгә ашырылмый). 20 йөз башында Казанда казылык фабрикасы һәм 2 оешма, 6 вак май эретү һәм сөяк кайнату пр-тиесе эшли.

1918–20 дә дәүләт милкенә күчерелгәннән соң И.э.с.нең кайбер пр-тиеләре Казан ит эшкәртү з-дының ит-май, казылык һ.б. цехлары итеп үзгәртелә. Эре индустриаль тармак буларак, Татарстанда И.э.с. беренче бишьеллыклар чорында (1929–41) оеша башлый. 1929 да 1600 *т* га исәпләнгән Казан суыткычы файдалануга тапшырыла. 1920 еллар ахырында республикада хәзерләүләр пунктлары челтәре оештырыла, суыклар башлангач аларда терлекләрне кулдан чалалар. 1930 елларда бу пунктлар нигезендә Казан, Бөгелмә, Чистай, Чаллы һ.б. ит комб-тлары барлыкка килә, аларда терлек чалуның һәм итне азык-төлек һәм техник продуктларга аерып эшкәртүнең бердәм технол. процессы гамәлгә кертелә. 1936 елга республикада ит продуктларын сәнәгый җитештерү 8 мең *т* га, 1940 та 10,2 мең *т* га җитә. Бөек Ватан сугышы чорында пр-тиеләрнең Ленинград өлкәсеннән һ.б. өлкәләрдән эвакуацияләнгән җиһазлары Зөя ит комб-тын һәм Алабуга консерв з-дын төзү өчен нигез була. 1950 елларда И.э.с. продукциясенең күләме үсә һәм төрләре шактый күбәя, кулланучылар тарафыннан аеруча теләп алына торган ризыкларның өлеше арта. Шул ук вакытта республиканың кайбер пр-тиеләрендә элеккечә үк искергән техника, камилләшмәгән технология кулланыла. Аеруча суыту хуҗалыгының, казылыклар һәм коры азыклар җитештерүнең техник яктан җиһазлануы заман таләпләреннән артта кала. Ит продуктларын, бигрәк тә казылыкларны һәм ысланган ризыкларны җан башына куллану РСФСР буенча уртача күрсәткечтән түбән була. Шул ук вакытта ел саен 6 мең *т* дан артык ит һәм аннан әзерләнгән ризыклар республикадан читкә чыгарыла. 1960 еллар башына Татарстанның И.э.с. 7 ит һәм 2 кошчылык комб-тларыннан, кулланучылар кооперациясенең терлекләрне төрле шәхси хуҗалыклардан кабул итүче 9 чалу пунктыннан гыйбарәт була. Чимал совхозлардан (ш.и. махсуслаштырылган «Скотооткорм» тресты хуҗалыкларыннан) кителә, колхозлардан һәм халыктан сатып алына. 1960 елларда яңадан җиһазландырылу, үзгәртеп кору, эшләүче пр-тиеләрне яңа сәнәгый мәйданчыкларга күчерү һәм яңа пр-тиеләрне файдалануга тапшыру нәтиҗәсендә Татарстан И.э.с.нең җитештерү фондлары 2 тапкырдан күбрәккә, ш.и. Казан ит комб-тында — 5, Зөя ит комб-тында — 4 тапкыр, Бөгелмә ит комб-тында 20% ка арта һ.б.; суыткычларның гомуми сыйдырышлылыгы 9,4 мең *т* га җитә. 1970 елларда йорт кошлары үстерүче һәм кошчылык продуктларын сәнәгый нигездә җитештерүче кошчылык ф-каларын төзү башлана. 1960–90 елларда итнең барлык төрләрен җитештерү 57,8 мең *т* дан 180 мең *т* га, казылык һәм ысланган ризыклар — 12,9 мең *т* дан 41 мең *т* га, төрле консервлар — 5,6 млн.нан 27,4 млн. шартлы банкага, коры азыклар эшләп чыгару 0,8 мең *т* дан 9,2 мең *т* га кадәр арта; суыткычларның сыйдырышлылыгы 12,7 мең *т* га җитә. 1990 еллардагы икътисади кризис, халыкның сатып алу мөмкинлеге кимү һәм чит илләрдән күпләп арзан ит продуктлары кертү Татарстан И.э.с. пр-тиеләрендә җитештерүнең икеләтәдән артык кыскаруына китерә. Тармакта мөһим структур үзгәрешләр була: ит комб-тлары һәм кошчылык ф-калары акционерлаша, яңа хосусый вак һәм уртача зурлыктагы пр-тиеләр барлыкка килә. Продукциянең төрләре арта: күп кенә пр-тиеләрдә итне һәм ит ризыкларын дини нормаларны үтәү нигезендә (хәләл ит), ш.у. традицион татар кухнясы ризыкларын (чи килеш ысланган ат казылыгы) җитештерү үзләштерелә. 1990 еллар ахырында И.э.с.ндә продукция эшләп чыгару күләмнәренең тотрыклы үсеш тенденциясе күзәтелә. 2006 да пр-тиеләрнең производство куәтләре ит җитештерүдә 36%, казылык эшләүдә 61,6% ка файдаланыла.

Республиканың И.э.с. 1920 елларда РСФСР Хәзерләүләр халык комис-ты вәкиле, 1930–39 да — Татарстан сөт-ит тресты (Татмолмясотрест), 1939–50 дә — ТАССР Ит-сөт сәнәгате халык комис-ты (министрлыгы), 1950–59 да — Татарстан ит-кошчылык тресты (Татмясоптицетрест), 1960–63 тә ТАССР Ит һәм сөт сәнәгате идарәсе, 1964–93 тә Татарстан республика ит сәнәгате ЖБ, 1993–2006 да «Татарстан ит җитештерү сәнәгате» (Татмясопром) холдинг компаниясе үзәкләштерелгән идарәсендә була. Хәзерге вакытта ТР И.э.с.нең нигезен 11 ит комб-ты (Казанда, Бөгелмә, Болгар, Алабуга, Чаллы, Нурлат, Тәтеш, Чистай шәһәрләрендә, Яшел Үзән р-ныңдагы Карамалы Тау, Саба р-ныңдагы Шәмәрдән шәһәр тибындагы посёлокларында, Югары Ослан р-ныңдагы Югары Ослан авылында) һәм 13 кошчылык ф-касы (аларның 3 се — Казандагы, Чаллыдагы һәм Питрәч р-ының Питрәч авылындагылары ит җитештерәләр) тәшкил итә. И.э.с. ш.у. кулланучылар кооперациясе, агрофирмалар һ.б. а.х. оешмалары пр-тиеләрен һәм цехларын, 2 сөяк оны з-дын үз эченә ала. И.э.с.нең чимал базасы башлыча җирле терлекчелектән гыйбарәт.

ТР И.э.с.нең әйдәп баручы пр-тиеләре конвейер линияләре, автоматлар, башка төрле югары җитештерүчәнлекле җиһазлар, ясалма суыту б-н тәэмин ителгән. Терлек итен эшкәртү технологиясенең үзенчәлекләре җитештерүне тулысынча автоматлаштыруга мөмкинлек бирми. Тармак буенча кул хезмәте 52% тәшкил итә. Пилмән, сосиска, сарделька, кайнатылган азык майлары, коры

терлек азыклары җитештерү технол. процесслары тулысынча, ит консервлары эшләп чыгару 70% ка автоматлаштырылган. 2006 да тармак пр-тиеләре тарафыннан җитештерелгән продукция (мең *т*): сыер, дуңгыз, сарык, ат ите (1 нче категория субпродуктларны кертеп) — 49,8, тавык, каз, үрдәк, күркә һ.б. ите — 50 дән артык, казылыклар һәм ысланган ризыклар — 20,1; төрле консервлар — 29,3 млн. шартлы банка. И.э.с.нең эре пр-тиеләрендә вет. хезмәтләре җитештерүнең барлык этапларында вет.-сан. контроле алып бара. И.э.с. өчен кадрлар Казан технол. («ит һәм ит продуктлары технологиясе» белгечлеге буенча) һәм Казан аграр («авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүне механикалаштыру») ун-тларында, Казан вет. медицинасы академиясендә («стандартлаштыру һәм сертификатлаштыру»), ш.у. урта техник һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләрендә хәзерләнә.

*Әд.:* Скоропортящиеся продукты казанского рынка. К вопросу об устройстве земских холодильников. К., 1913; Рентабельность производства на мясоперерабатывающих предприятиях Татарской и Башкирской АССР. К., 1968; Р о г а т к о С.А. История развития мясной промышленности России // Пищевая пром-сть. 1999. № 7.

*С.Г.Белов.*

**ИТИ́Л** (Әтил), урта гасырларда (8–10 йөзләр) хәзәрләр шәһәре. Идел тамагында, хәзерге Әстерхан шәһәреннән югарырак урнашкан, эре сәяси һәм икътисади үзәк. Хәзәр каганлыгының соңгы башкаласы. Иделнең ике ярын һәм утрауны (анда каган сарайлары булган) биләгән 3 өлештән торган. 965 елда Киев кенәзе Святослав I гаскәрләре тарафыннан җимертелә.

*Әд.:* Н о в о с е л ь ц е в А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; А р т а м о н о в М.И. История хазар. СПб., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**«ИТИ́ЛЬ»**, к. *«Ак барс»*.

**И́ТКИН** Моисей Эммануилович (25.2.1902, Витебск губ., Лиозно өязе Колышки бистәсе — 21.8.1978, Казан), машиналар төзү гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (1964), проф. (1964). 1926 елда Днепропетровск тау эшләре ин-тын тәмамлый. Паровозлар ремонтлау з-дында (Днепропетровск ш.) техника бүлеге мөдире, 1929 дан Харьков механика-машиналар төзү ин-тында укытучы, 1933 тән Орджоникидзеград машиналар төзү ин-тында металлар кистерү каф. мөдире (Орёл өлкәсе). 1941 дән Казан авиация ин-тында: металлар кистерү, станоклар һәм инструментлар каф. мөдире (1976 га кадәр), моторлар төзү ф-ты деканы (1945–46). Хезмәтләре металларны кистерү процессында барлыкка килә торган физ. күренешләрне өйрәнүгә карый. Металларны кистергәндә хасил булган көчне билгеләү, кистергән вакытта эшләнмәләр өслегендәге темп-раны билгеләүнең теоретик-эксперименталь ысулын эшли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Задачник по теории резания. К., 1941; Атлас кинематических схем металлорежущих станков и их настройка: в 2 ч. К., 1954–63 (автордаш); Выбор наивыгоднейших режимов резания. К., 1970 (автордаш).

**ИТКУ́Л РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1926 елның 4 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 2558,5 *км*². Үзәге — Иткүл авылы (Чиләбе шәһәреннән 45 *км* көньяктарак). Халкы — 30165 кеше (2002). Татарлар саны: 1970 тә — 768, 1979 да — 531, 1989 да — 805, 2000 дә — 924, 2002 дә — 766 кеше.

**«ИТТИФА́К»** (اتفاق — «Берлек»), газета. Бөтенроссия мөселман руханилары берлеге органы. 1918 елның 31 гыйнварыннан 7 июненә кадәр Казанда татар телендә атнага 1–2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 14 саны чыга. Нашире — мөселман руханилары берлегенең үзәк идарәсе. Газетада Г.Баруди, Г.Габделбәдигый, Г.Габдерәхимов, И.Габидов, В.Җәлал, С.Иманкулов, К.Салихов, К.Тәрҗеманов, А.Хәмзәви һ.б. языша. «Бөтендөнья мөселманнары, берләшегез!» дигән лозунг астында чыга. Мөселман руханилары



«Иттифак» газетасы.

һәм татар дин галимнәре ихтыяҗларын чагылдыра, совет хакимиятенең дин өлкәсендәге сәясәтенә каршы чыга. Ислам дөньясындагы хәлләрне, илнең милли һәм социаль-икътисади сәясәтен, Россия мөселманнарының 2 нче хәрби съезды эшен, мәктәптә белем бирүне реформалаштыруның барышын, эчке һәм тышкы сәясәтне һ.б. мәсьәләләрне яктырта. Газета большевикларның Төркестанда һәм Кырымда алып барган сәясәте турында хәбәр итә; хөкүмәтнең дин турындагы декретын — дин иреген һәм дини оешмаларның эшчәнлеген кысу сәясәтен, хакимиятнең Милли идарәне тарату турындагы карарын кискен гаепли; Милли Мәҗлеснең Идел-Урал штатын оештыру турындагы карарын хуплый. Татар халкының бәйсез дәүләтен булдыру өчен көрәштә газета милли армиягә зур өметләр баглый. 1918 елның 8 мартында газета редакциясе бинасы утка тотыла; 7 июньдә газетаны чыгару тыела.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ИТТИФА́К»**, к. *Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифакъ»*.

**«ИТТИФА́К әл-МӨСЛИМИ́Н»** («Мөселманнар берлеге»), Россия мөселманнарының либерал-демократик юнәлешле сәяси партиясе. Россия мөселманнарының үзенчәлекле яшәү рәвешен саклау өчен шартлар тудыруны максат иткән бердәм оешмасын оештыру идеясе 1905–07 еллардагы рев-ция чорында туа. Бердәм сәяси платформа эшләү өчен 1905 нең августында Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае җыела (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*), анда гомумроссия «И.ә.-м.» партиясен оештыру турында карар кабул ителә. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаенда (1906 ның гыйнвары) партиянең уставы, вакытлы программасы һәм «Русия мөселманнары иттифакы» дигән яңа исеме кабул ителә. Устав нигезендә Россиянең мөселманнар яшәгән терр-яләре 16 р-нга бүленә: Кавказ (үзәге — Баку ш.), Кырым (Симферополь ш.), Петербург (С.-Петербург), Литва (Минск), Түбән Идел (Әстерхан ш.), Югары Идел (Казан), Уфа (Уфа ш.), Оренбург (Оренбург ш.), Төркестан (Ташкент), Себер (Иркутск ш.), Дала (Уральск ш.), Омск (Омск ш.), Семипалатинск (Петропавел ш.), Каспий аръягы (Ашхабад), Семиреченский (Верный ш.). Барлык үзәкләрдә әлеге районнарның гомуми җыенында сайлана торган җирле мәҗлесләр оештырыла. Район мәҗлесләренә җирле мәсьәләләрнең һәркайсын хәл итү, ш.и. партиягә кабул итү хокукы бирелә. Иң югары орган — корылтай. Һәр корылтайда 16 мәҗлес вәкилләреннән торган баш мәҗлес билгеләнә. Ул чираттагы корылтайны әзерләргә һәм аның программасын эшләргә тиеш була. Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаенда (1906 ның августы) партия б-н җитәкчелек итү өчен даими эшләүче органнар — ҮК һәм Үзәк бюро (С.-Петербургта) оештырыла. Бюро составына Й.Акчура, С.Алкин, Г.Апанаев, Г.Баруди, М.Бигиев, Г.Буби, И.Гаспринский, М.Давидович, С.Җантурин, Р.Ибраһимов, Ш.Кощегулов, С. һәм Ә.Максудилар, Ш.Сыртланов, А.Топчибашев сайлана. ҮК үзенә баш мәҗлес вазифаларын ала (кирәк булган очракта корылтайны чакырмыйча да программаны үзгәртү хокукына ия була), Дәүләт Думасына сайлау кампаниясе һәм Дума фракциясе б-н җитәкчелек итә, партия кассасындагы акчаларны тикшереп тора; партиянең исеме «Бөтен Русия мөселманнары иттифакы» итеп үзгәртелә. Корылтай икенче корылтайда эшләнгән һәм хупланган программаны тикшереп тормыйча гына кабул итә. Программаның беренче пунктында, «партия үзалдына, әлеге программада билгеләнгәнчә, кайбер сәяси, икътисади, социаль, дини һәм тормыш тарафыннан куелуы һәм күрсәтелүе ихтимал булган башка реформаларны гамәлгә ашыру өчен, Русиянең сәяси карашлары буенча бер фикердәге барлык мөселман гражданнарын гомуми бер практик эшчәнлеккә берләштерү бурычын куя», диелә. Программаның төп нигезләмәләре: конституцион-парламент монархиясе, демократик хокуклар һәм ирекләр, хосусый милекне саклау, крәстияннәргә дәүләт фондыннан җир бүлеп бирү, акча түләү исәбенә алпавыт җирләренең бер өлешен ирексезләп алу, диннәрнең дәүләт алдындагы тигезлеге, мөселманнарга мәчет һәм мәдрәсәләр милкен кайтарып бирү. Бөтенроссия мөселманнарының икенче һәм өченче корылтайларыннан соң партия лидерлары тарафыннан аны рәсми рәвештә теркәтергә

тырышу уңышсыз тәмамлана, күпчелек районнарда ком-тлар эшләми. Түбәнге оешмалар ролен шәһәрләрдә түгел, авыл җирләрендә дә эшләүче иганәчелек һәм мәгърифәтчелек җәмгыятьләре үз өсләренә ала. Әгъзалар исәбе алып барылмый. Партия Россиянең мөселман халыклары арасында, бигрәк тә Казан губернасында, билгеле бер дәрәҗәдә абруй казана. Партия әгъзалары Дәүләт Думасы эшендә катнашалар, *мөселманнар фракциясен* оештыруда башлап йөриләр, мөселманнарның милли һәм мәдәни-дини мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән законнар кабул иттерергә тырышалар. 1907 дә оешма эшчәнлегендә таркаулык башлана (3 июньдә Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турындагы законны үзгәртүгә бәйле рәвештә), августта чираттагы корылтайны чакыру мөмкин булмый. Түбән Новгород шәһәренә җыелган партия әгъзалары (60 лап кеше), корылтай үткәрүгә рөхсәт ала алмыйча, берничә киңәшмә уздыралар (аларның эчтәлеге мәгълүм түгел). 1908 дә партия үз-үзен тарату турында белдерә; күзәтеп-тикшереп тору вазифасын мөселманнар фракциясе үз өстенә ала. Аның аерым оешмалары (бюролары), мәс., «И.ә.-м.»ның Казан бюросы, үз эшләрен дәвам иттерә. Оешманың кайбер әгъзалары аны яңадан торгызырга омтыла. 1914 тә Бөтенроссия мөселманнарының 4 нче корылтае үткәрелә, анда, партия әле эшли, дип белдерелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң «И.ә.-м.» программасында игълан ителгән кайбер идеяләр тормышка ашырыла: Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының мәдәни-милли автономияләре игълан ителә, Милләт Мәҗлесе чакырыла. Казандагы матбугат органнары — «*Казан мөхбире*», «*Әхбар*» г-талары.

*Әд.:* Ибрагимов Г. Татары в революции 1905 г. К., 1926; Давлетшин Т. Советский Татарстан. Лондон, 1974; Политическая жизнь русских мусульман до Февральской революции. Оксфорд, 1987; Исхаков С.М. Общероссийская партия мусульман // История национальных политических партий России (Материалы междунар. конф. Москва. 21–22 мая 1996 г.). М., 1997; Фахрутдинов Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX – начале XX века (очерки политической истории). К., 1998; Ямаева Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественно-политическое движение (по материалам Уфимской и Оренбургской губерний). Уфа, 2002.

*Л.М.Айнетдинова.*

**«ИТТИХА́Д»** («Бердәмлек»), 1901–1904 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе (Казан) шәкертләре оешмасы. Җитәкчеләре: Ф.*Әмирхан*, Р.Алуши (Ибраһимов), Г.Мөгыйнов, Х.Түләков, Б.Сәетгалиев һ.б. Төп максаты — мәдрәсәдә уку-укытуны реформалаштыру. Рәсмиләштерелмәгән кульязма «әл-Мәгариф» г-тасы чыгара, мөхәррире — Ф.Әмирхан, сәркәтибе — Р.Алуши. «И.» әгъзалары инициативасы б-н 1904 ел ахырында «*әл-Ислах*» оешмасы төзелә.

*Р.Г.Әмирханов.*

**ИУДАИ́ЗМ**, иң борынгы монотеистик дин. Б.э. к. 2 нче меңьеллыкта Урта диңгез буйларының көнчыгышында көн күргән терлекчеләр һәм игенчеләр кабиләләре арасында барлыкка килә. Тулысынча б.э.к. 1 нче меңьеллык башында Иудея сугышыннан соң, яһүдиләрне Палестинадан куып чыгаргач формалаша. И. (яһүди) динендәгеләр күзаллавынча, Яхве б-н антлы килешү төзегән беренче яһүдинең исеме Авраам булган. Бу килешү буенча, яһүдиләр Яхве тарафыннан җибәрелгән вәхине йөртүчеләр булып санала. Дини тәгълиматның чыганаклары — Тәүрат (Моисейның Бишкитабы), Танах (Иске Гаһеднең 30 китабы) һәм Талмуд (И.ның догматик, дини-әхлакый һәм хокукый кагыйдәләр җыентыгы). И. тотучы төп халык — һәрвакыт яһүдләр (аларның мәдәнияте формалашуда И. мөһим роль уйный), әмма әлеге дин тарафдарлары арасында башка халыклар вәкилләре дә бар. 8 йөздә яһүди диненә өндәүчеләр Хәзәр каганлыгында да пәйда була, тиздән бу илдә И. рәсми дин буларак игълан ителә (к. *Болан*, *Обадия*). Хәзерге төрки халыклардан караимнар шушы диндә. И. Россиядә 18 йөзнең 2 нче яртысында Украинаның уңъяк яр буе җирләре, Белоруссия, Литва һәм соңрак яһүдиләр күпләп яшәгән Польша җирләре Россия империясенә кушылгач тарала башлый. Россиядә И. динендәгеләрне дәүләт хезмәтенә кабул итү, җирләрне хосусый милеккә сатып алу тыела, «утраклык сызыгыннан», ягъни көнбатыш губерналар чикләреннән читтә яшәү хокукы чикләнә. 19 йөздә Россиянең барлык эре шәһәрләрендә яһүдиләр җәмгыятьләре барлыкка килә. Казанда беренче яһүдиләр (Казан гарнизоны батальоны һәм Адмиралтейство эшче экипажы солдатлары) 1830 елларда күренә башлый. 1847 елда хәрби кануннарга яраклаштырып яһүди солдатларның дини җәмгыяте төзелә; диндәшләре сайлавыннан соң гарнизон командиры әмере б-н солдат З.А.Симановский беренче раввин итеп билгеләнә (үз вазифаларын 1875 кә кадәр башкара). Хакимиятләр гыйбадәт кылу өчен махсус йорт билгелиләр. Яһүдиләр җәмгыятенең хәрби рәвеше 1889 га кадәр саклана. Дәүләт советының яһүдиләргә — махсус әзерлекле һөнәрчеләргә — утрак чикләрдән читтә яшәргә ризалык бирү турындагы фикере Галиҗәнаби расланганнан соң, 1867 дә отставкадагы яһүд солдатларына империянең теләсә кайсы шәһәренә урнашырга рөхсәт биргән закон кабул ителә, шуннан соң Казанда һәм губернада яһүди динендәгеләрнең саны бик тиз арта башлый. 1889 дан яһүдиләр җәмгыяте гражданлык төсе ала, губерна идарәсе күзәтүендә тора, аның раввиннары һәм башка хезмәткәрләре губернатор тарафыннан (якынча, нәкъ муллаларны билгеләгән кебек) раслана. Гыйбадәт кылу йортын җәмгыять үз хисабына тота. 1914–15 тә махсус бина төзелә; яһүдиләр үзләре аны синагога дип атыйлар, әмма Россия империясе кануннарына яраклаштырып, ул гыйбадәт кылу йорты дип исемләнә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында яһүди динен тотучыларның саны көнбатыш губерналардан качып килүчеләр исәбенә шактый күбәя һәм 1917 гә 3 меңнән артып китә. Совет чорында да аларның саны кимеми. 1929 да синагога бинасы тартып алына, ә 1930 ахырында исә яһүдиләр җәмгыяте яшәүдән туктый. 1990 да Казанда яһүдиләр җәмгыяте яңадан теркәлә, 1997 елда аңарга синагога бинасы кайтарып бирелә. Хәзерге вакытта җәмгыять эшчәнлеге яһүдиләрнең мәдәни һәм хәйрия оешмалары б-н тыгыз бәйләнгән.

*Е.В.Липаков.*

**«ИХЛА́С»** мәчете, Чаллыда 1996–2000 елларда арх. В.А.Манукян проекты буенча төзелә. Гөмбәзле, һәр катында гыйбадәт залы, ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым керү ишекләре булган, манарасы төньяк ягына кушып салынган ике катлы бина. Мәчетнең матур композициясе төрле биеклектәге күләмнең яссы тышлауларына, залның гөмбәзле күләменә, баскыч бүлмәсенә, югарыга таба конус сыман очлая барган манарасына ярашлы итеп төзелгән. Хатын-кызлар һәм ир-атлар заллары урнашкан 1 нче һәм 2 нче кат планда квадрат күләмле, яктылык бирүче сигезкырлы нигездәге ярым сфералы гөмбәз б-н төгәлләнә. Мәчет ишеге биек портал б-н аерып куелган. Мәчетнең архит. чишелешендә постмодерн үзенчәлекләре көнчыгыш-мөселман, болгарлар һәм татарларның традицион дини архит-ра үрнәкләре б-н кушылып бара.

*Әд.:* Мечети Татарстана. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ИХСА́НОВ** Рамазан Миңнехан улы (2.4.1930, БАССРның Кандыр р-ны Туктагол а. — 12.11.1983, Әлмәт ш.), драма актёры, ТАССРның атказ. (1969) һәм халык (1979) артисты. Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1950), БАССРның Аургазы колхоз-совхоз театры труппасына җибәрелә. 1952–60 елларда Салават шәһәрендә Башкорт драма театрында актёр. 1960 тан Әлмәт татар драма театрында, әйдәп баручы актёрларның берсе. Күп кенә үзенчәлекле рольләр башкара. Алар арасында Хәйретдин («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Һилал («Кандыр буе», К.Тинчурин), Рамай («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Хөлмәт («Бай һәм хезмәтче», Х.Хәмзә), Дивана («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Сәйфулла («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Тимурчал («Анам кыры», Ч.Айтматов), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский) бар. Образ өстендә эшләгәндә үз геройларының социаль табигатенең асылын, конкрет тормыш хәлләрен күрсәтергә, шәхеснең әхлагын ачарга омтыла. Ат карагы Миңгали («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), авыл бае, комсыз Касыймхан («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), мәкерле Җантык («Козы Көрпеш белән Баянсылу», Г.Мөсрәпов), буйдак Галим («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Хәзрәт («Хәзрәт үгетләргә килде», З.Шаһиморатов), бай малае Низами («Җизнәкәй», Х.Ибраһимов) кебек тискәре характердагы рольләрне уйнаганда, И. һәр персонажның асылына төшенеп, кискен сатирик буяуларда гәүдәләндерә. Студент Андрей («Гомер бер генә», А.Мовзон), хуҗалык эшләрен башкаручы Чуфаров («Барабанчы кыз», А.Д.Салынский), Сукбай («Таң әтәче кычкырганчы», И.Буковчан) рольләре тирән психологизм б-н сугарылган, алар аша актёр үз геройларының катлаулы эчке дөньяларын оста гәүдәләндерә. Шулай ук Әлмәт театры сәхнәсендә шактый спектакльләр куя: «Кеше



Р.М.Ихсанов.

бәхете» (Н.Әсәнбаев, 1966); «Җирән чәч» (М.Садыйкова, 1967), «Бай һәм хезмәтче» (Х.Хәмзә, 1968, Бөтенроссия театр смотры дипломы), «Сафура бураннары» һәм «Очрашырбыз, Гөлсылу!» (Ю.Әминев, 1975, 1977).

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*Д.Ә.Гыйммранова.*

**ИХСА́НОВА** Венера Фәез кызы (23.8.1933, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1974). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Совет Татарстаны» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1960–77 елларда «Яшь ленинчы» г-тасының, 1977–88 дә «Азат хатын» ж-лының баш мөхәррире. Производство алдынгылары, герой-аналар турындагы китапларның төзүчесе-авторы. Балалар өчен хикәяләр яза, башка телләрдән әсәрләр тәрҗемә итә. Очерклары, публицистик мәкаләләре балалар тәрбияләү, уку-укыту, гаилә мәсьәләләренә карый. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Учаклар. К., 1974; Тырыш хуҗалар илендә. К., 1976.

**ИХСА́НОВА** Ләбибә Фәез кызы (23.8.1923, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн а. – 27.7.2010, Казан), язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972, 1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1948), ТАССР МС каршындагы Радиолаштыру ком-тында балалар өчен тапшырулар мөхәррире булып эшли. 1955–60 та «Пионер» ж-лының баш мөхәррире, 1960–67 дә Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, 1967–78 дә «Казан утлары» ж-лында җаваплы сәркәтип. Беренче китабы — «Көмеш елга» повесте (1948; русчага тәрҗемәдә «Река Серебрянка», М.–Л., 1953). Үзенең әсәрләрендә И. аеруча балаларның, яшүсмерләрнең уй-хыялларын, романтик омтылышларын яратып сурәтли. Ул — маҗаралы сюжетка корылган «Җир астында җиде көн» (1949), «Саралан малайлары» (1966), «Тал бөгелә» (1974), «Космонавтлар урамы» исемле повесть һәм хикәя җыентыклары авторы. «Робинзоннар лагеренда» (1965; русчага тәрҗемәдә «В лагере Робинзонов», 1977) повесте белән И. аеруча таныла. Мәхәббәт, дуслык, тугрылык турында лирик хикәяләре тупланган «Тау чәчәге» (1967), «Гөлләр кояшка карый» (1972; рус теленә тәрҗемәсе «Цветы тянутся к солнцу», М., 1976), «Тузганак» (1993) җыентыклары игътибарга лаек. И.ның кайбер хикәяләре һәм повестьлары рус, башкорт, чуаш, украин, эстон телләренә тәрҗемә ителгән. Л.Кассильнең «Кече улның урамы» («Улица младшего сына», 1953), А.Талвирның «Буа юлында» («На Буинском тракте», 1958) әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Матбугатта очерклар, рецензияләр, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән еш чыгыш ясый. ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты (1996).

*Әд.:* Ш ә р ә ф и Г. Ихласлык // Казан утлары . 1983. № 8; Т и м б и к о в а К. Якты язмыш // Татарстан. 1998. № 8/9; Балалар әдәбиятын баласытмыйк // Мәдәни җомга. 2004. 13 февр.

**ИХСА́НОВА** (Миңнуллина) Нәҗибә Гыймаделислам кызы (25.1.1938, Тымытык, хәзерге Азнакай р-ны Яңа Ташлыяр а.), драма актрисасы, ТАССР һәм РФнең халык артисты (1982, 2000), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1998). М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1961), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Гандәлиф («Көзге ачы җилләрдә», А.Гыйләҗев), Маһисәрвәр («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Фатыйма («Тормыш җыры», М.Әмир) образларын башкарып, беренче рольләреннән үк сәхнәдә үзен иркен тотуы,



Н.Г.И х с а н о в а Маһисәрвәр ролендә (Т.Гыйззәт, «Чаткылар», сулда Н.Дунаев).

тормыш дөреслеген төгәл сиземләве б-н игътибарга лаек була. Мәйсәрә, Хәдичә, Нәгыймә («Американ», «Зәңгәр шәл», «Назлы кияү», К.Тинчурин), Гөлҗиһан («Банкрот», Г.Камал), Өммия, Әүдәки, Әсимә («Әлдермештән Әлмәндәр», «Гөргөри кияүләре», «Йөрәк маем», Т.Миңнуллин), Розина («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), Элеонора («Хатыннар гайбәте», К.Гольдони) образларын иҗат иткәндә И., җете, ачык төсләр кулланып, характерларны гротеск дәрәҗәсенә җиткерә. Актриса куллана торган төсләр гаять киң һәм күп төрле — купшы-кыланчыклыктан алып әкәмәт тамашага кадәр. И. образның асылын калку итеп күрсәтү өчен геройларына кызыклы детальләр, үз-үзләрен тоту гадәтләрен, аерым сөйләм рәвешләрен таба. Фемида («Ташлама утны, Прометей!», М.Кәрим), Таланова («Ябырылу», Л.М.Леонов), Гөлниса («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җәмилә («Бәхетсез егет», Г.Камал), Мәхбүзә («Зөләйха», Г.Исхакый), Гөлфинә («Әниләр һәм бәбиләр», Т.Миңнуллин) рольләрен актриса тирән драматизм б-н уйный һәм зур колачлы, тирән хисләрне ачып бирерлек сәләте барлыгын күрсәтә. Радиодан чыгышлар ясый, телефильмнарда төшә.



Н.Г.И х с а н о в а Әүдәки ролендә (Т.Миңнуллин, «Гөргөри кияүләре»).



Н.Г.Ихсанова.

Ул уйнаган башка рольләр: Гөлчирә («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Рокыя («Чикләвек төше», Г.Ахунов), Тәңкәбикә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Миләүшә («Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз!», Т.Миңнуллин), Зифа (Н.Исәнбәтнең шул исем. пьесасы), Гөлсем («Мирас», Г.Каюмов). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Уйнап узган гомер. К., 2008.

*Әд.:* И л я л о в а И.И. Г.Камал театры артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**«ИХТИЛЯ́Л БАЙРАГЫ́»** («اختلال بيرعى» — «Баш күтәрү байрагы»), иҗтимагый-сәяси газета. 1919 елда Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә (1 нче саны февральдә дөнья күрә). Мөхәррире — К.*Мотыйгый*. «Барлык илләр пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг астында чыга.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать. К., 1999.

**ИХТИМАЛЛЫЛЫКЛА́Р ТЕО́РИЯСЕ ҺӘМ МАТЕМА́ТИК СТАТИ́СТИКА**, аныксызлык шартларында очраклы күренешләрнең матем. модельләрен, аларның үзара бәйләнешләрен һәм чишелешләрен өйрәнә торган бер-берсенә бик якын ике фәнни дисциплина. Ихтималлылыклар теориясе 17 йөздә — 18 йөз башында (Б.Паскаль — Франция, И.Бернулли, А.Муавр — Англия) барлыкка килә. Соңрак П.Лаплас, К.Гаусс һәм «рус мәктәбе» галимнәре (П.Л.Чебышев, А.А.Марков, А.М.Ляпунов) хезмәтләрендә үсеш ала. Ихтималлылыклар теориясенең матем. фәне буларак тәмам формалашып җитүе А.Н.Колмогоровның «Ихтималлылыклар теориясе төшенчәләре нигезләре» («Основы понятий теории вероятностей», М.–Л., 1936) дигән китабының дөньяга чыгуы б-н бәйле. Матем. статистиканың барлыкка килүе 17–18 йөзләр чикләренә карый һәм иминиятләү хезмәтенең үсеше б-н бәйләнгән, формалаша башлавы — К.Пирсон, Дж.Нейман (20 йөз башы) хезмәтләренә, тәмам формалашуы А.Вальд хезмәтләренә нисбәтле. Россиядә И.т.һ.м.с. өлкәсендә А.Н.Колмогоров, А.Я.Хинчин, Н.В.Смирнов, С.Н.Бернштейн, Ю.В.Лин-

ник, Ю.В.Прохоров, Л.Н.Большев, И.Г.Ибраһимов һ.б. зур казанышларга ирешә. «Ихтималлылыклар теориясе һәм аны куллану» («Теория вероятностей и её применения», М., 1956) ж-лы нәшер ителә.

1960 елларда Казан ун-ты каршындагы Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында матем. статистика бүлеге оештырылу б-н И.т.һ.м.с. буенча фәнни юнәлеш барлыкка килә, бүлекнең беренче мөдире А.В.*Сульдин* була. Аның тарафыннан якынаюлар теориясендә ихтималлылык ысулларын куллану мәсьәләләре өйрәнелә, төрүче Гильберт фәзасының гомуми концепциясе эшләнә һәм якынаюлар теориясендә күп кенә мәсьәләләрне яңача кую һәм чишү мөмкинлеге бирә торган проекция турында теорема булдырыла. С.В.Григорьев тарафыннан квазирациональ спектраль тыгызлыклары булган стационар процесслар өчен анык фаразлау формуласы чыгарыла. В.И.Ладохин параболик дифференциаль тигезләмәләрдән табылган квази үлчәмнәрне тикшерә, кайбер очракларда андый үлчәмнәрдә санау аддитивлыгының булмавын да күрсәтә. А.Н.*Шерстнев* очраклы нормалаштырылган фәза төшенчәсен гамәлгә кертә һәм шул фәзаларның теориясен үстерә. Е.А.Беговатов, бәйсез үсемтәләр булган процесска караганда, очраклы процесслар классы өчен киңәйтелгән стохастик интегралларның гомумирәк булуын исбатлый. Аның Татарстан археологиясе һәм тарихын өйрәнгәндә матем. статистика ысулларын куллануга караган хезмәтләре киң таныла. Е.А.Новосёлов саннар теориясенең ихтималый мәсьәләләрен натураль саннар күплегенә яңа топология кертеп чишү алымын тәкъдим итә.

1970–90 елларда И.т.һ.м.с.га кагылышлы барлык бүлекләрне дә эченә алган тикшеренүләр тематикасы киңәя. Теоретик саннар бүленеше теориясенә һәм мультипликатив функцияләрнең суммасы теориясенә караган нәтиҗәләр алына. Д.А.Москвин, Ф.Г.Габбасов, В.Т.Дубровин, теоретик саннарны кулланып, ихтималлылык теориясендә чикле теоремаларны тикшерү б-н шөгыльләнәләр. Аз бәйләнгән очраклы зурлыкларны кушу теориясендә «якынаюлар эзлеклеге» ысулы эшләнә. Д.А.Москвин динамик системалар траекторияләренең үзлекләре турында нәтиҗәләр алуга ирешә. Л.Н.Пушкин классик Кантор күплегенең барлык саннарының да икегә нигезләнүен исбатлый. И.Н.*Володин* тикшеренүләр күләмен статик чыгаруның һәм оптималь планлаштыруның ышанычлылыгын тикшерә. Аның тарафыннан кирәкле күләмне сайлап алу өчен югары төгәллекле асимптотик таркатулар алына, уртача күләмне сайлау өчен аның бирелгән стат. стратегия чикләмәләренең ышанычлылыгын тәэмин итүче универсаль түбән чиге төзелә. И.Н.Володин (А.А.Новиков һәм С.В.Симушкин б-н берлектә) стат. чыгарылыш ышанычлылыгының *d*-апостерлиор теориясен төзи. Алар тарафыннан матем. статистиканы астрономиядә, метрологиядә, производство травмалары һәм сыйфат тикшерү проблемаларында куллануга караган хезмәтләр нәшер ителә. Д.Х.*Мөштәри* хезмәтләре Банаховча һәм сызыкча топологик фәзалардагы ихтималлылык үлчәмнәре теориясенә карый. Аның тарафыннан андый үлчәмнәрне өйрәнү өчен топологик ысул эшләнә, Бохнер һәм Леви теоремаларының чиксез үлчәмле аналоглары исбатлана. Д.Х.Мөштәри б-н С.Г.Хәлиуллин ихтималлылык үлчәмнәренең контигуаль эзлеклелеген өйрәнгәндә ультратапкырлаулар идеясен кулланып эш итәләр. А.И.Володин Банахов фәзаларындагы очраклы зурлыклар өчен зур саннар турындагы күп кенә гомуми теоремаларны исбатлый. А.Н.*Чупрунов* тарафыннан очраклы параметрларга бәйле ихтималый процесслар өчен чикле функциональ теоремаларның теориясе үстерелә. Е.И.Трофимов кайбер очраклы процесслар — семимартингалларның һәм очраклы кырларның төгәл функциональ йөрткечләрен билгели. М.Д.Миссаров б-н Э.Ю.Лернер тарафыннан *p*-адик аргументы б-н индексланган очраклы кырларга нигезләп өйрәнү алымы үстерелә. Хәзерге вакытта Казан ун-тының күп кенә кафедраларында һәм Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында И.т.һ.м.с. теориясенә кагылышлы тикшеренүләр алып барыла.

*Әд.:* Сульдин А.В. Мера Винера и её приложения к приближённым методам: В 2 ч. // Изв. вузов. Математика. 1959. № 6; 1962. № 5; Новосёлов Е.В. Новый метод в вероятностной теории чисел // Изв. АН СССР. Сер. матем. 1964. Т. 28, № 2; Муштари Д.Х. Некоторые общие вопросы теории вероятностных мер в линейных пространствах // Теория вероятностей и её применения. 1973. Т. 18, вып 1; Володин И.Н. Нижние границы для среднего объёма выборки и эффективность процедур статистического вывода // шунда ук. 1979. Т. 24, вып. 1; Москвин Д.А. К метрической теории эргодических эндоморфизмов двумерного тора // Изв. АН СССР. Сер. матем. 1981. Т. 45, № 1.

*И.Н.Володин, Д.Х.Мөштәри.*

**ИХТИМАЛЫ́Й АВТОМА́Т**, хәтерле мәгълүматны дискрет әверелдергеч, аның эшләү алгоритмнарында очраклы вакыйгалар конструктив күзаллана. Детерминирланган дискрет машиналарда очраклы вакыйгаларның тоткарланып яки өзелеп торуы — аларның ышанычлы эшләмәвенең төп факторы. И.а.та шул фактор төп элементка әверелә, шунлыктан төзелешенең катлаулылыгына бәйсез рәвештә ышанычлы эшләве аның мөһим үзенчәлеге булып тора. Шул үзенчәлек И.а.лар һәм аларның челтәрләрен кирәк кадәр катлауландырырга мөмкинлек бирә. Челтәрләр үтә тиз эшләүчән гибрид исәпләү системаларыннан гыйбарәт, алар ихтималый санлы һәм логик мәгълүмат йөрткеч була ала. Аеруча катлаулы мәсьәләләрне статистик модельләштерү һәм очраклы эзләү ысуллары б-н чишкәндә, ш.у. катлаулы системаларны модельләштергәндә һәм аларның үз-үзен тотышларын билгеләгәндә И.а.лар һәм аларның челтәрләреннән файдалануның гамәли әһәмияте гаять зур. Алдан бирелгән сыйфатлары булган И.а.ны анализлау һәм синтезлау теоремасы специальләштерелгән һәм универсаль *ихтималый процессорлар* төзегәндә кулланыла. И.а. төшенчәсен гамәлдә бер үк вакытта һәм бер-берсеннән бәйсез рәвештә диярлек 1963 елда — Дж.Карлайл, М.О.Рабин (АКШ) һәм П.Штарке (ГФР), СССРда — Р.Г.*Бохараев* (1964, Казан) фәнни әйләнешкә кертеп җибәрәләр, соңгысы җитәкчелегендә 1961 дән үк ихтималый машинаның теоретик моделе принципларын ачыклау эшләре алып барыла. Р.Г.Бохараев һәм аның шәкертләре (В.М.Захаров, Ф.М.Аблаев, Р.Ф.Латыйпов, В.Д.Крашенинников, Ф.И.Сәлимов һ.б.) уздырган тикшеренүләр б-н фундаменталь нәтиҗәләр алуга ирешелә. Чикле И.а.та күрсәтелә алмый торган телнең беренче үрнәге төзелә, чикле И.а.та төп матем. объектларның күрсәтелә алу (күп контактлы каналлар, сүзлек функцияләре, телләр һәм очраклы кодлар эзлеклелеге) теоремасы исбатлана, И.а.та гомоморфизм, эквивалентлык һәм минимальләштерү теорияләре төзелә. 1968–91 елларда Казан ун-тында И.а.лар һәм аларның комплексы «Кибернетика» проблемасы кысаларында кулланылышы буенча СССР ФА Президиумының кече комиссиясе (рәисе Р.Г.Бохараев) эшли, анда Казан, Мәскәү, Ленинград, Рига, Киев, Иркутск һ.б. шәһәрләрдә алып барылган фәнни тикшеренүләр координацияләнә.

*Әд.:* Бухараев Р.Г., Хасанов Ф.А. Моделирование вероятностных процессов на ЭВМ «Урал» // Итоговая конф. Казан. ун-та: Тезисы докл. К., 1961; Бухараев Р.Г. Вероятностные автоматы. К., 1969; шул ук. Основы теории вероятностных автоматов. М., 1985; Bukharaev R.G. Theorie stochastischen Automaten. B.G. Teubner. Stuttgart. 1995.

*Р.Г.Бохараев.*

**ИХТИМАЛЫ́Й ПРОЦЕ́ССОР**, ихтималый машина составындагы модельләштерелә һәм идарә итә торган дискрет исәпләү җайланмасы, ул динамик үзгәрүчән ихтималлылыклар торышын очраклы кодларга әверелдерә, аларны үзгәртү һәм эшкәртү алгоритмнары б-н идарә итә. И.п. идарә итүче командалар системасы б-н дә тәэмин ителергә мөмкин. Аеруча катлаулы мәсьәләләрне стат. модельләштерү һәм очраклы эзләү ысуллары б-н чишү, имитацион модельләштерү, массакүләм хезмәт күрсәтү һ.б. мәсьәләләрне чишү И.п. куллануның нәтиҗәле өлкәсе булып тора. И.п. идеясен очраклы кодларның идарә ителүле генераторы рәвешендә беренче мәртәбә Р.Г.*Бохараев* тәкъдим итә (1961). Соңрак (1962 — 90 елларда) Казан ун-тында аның тарафыннан И.п. төзү принциплары формалаштырыла, И.п.ның күп кенә специальләштерелгән проектлары һәм универсаль проекты (В.М.Захаров б-н берлектә, 1985) төзелә. Шул ук елларда әлеге идеяләр И.п. теоремасы б-н теоретик яктан дәлилләнә. Казан авиация ин-тында бердәм ЭВМ системасы (ЕС) өчен И.п.ның махсус проекты (Б.В.Кирьянов, В.А.Песошин, В.И.Глова) төзелә һәм гамәлгә кертелә. И.п. проблемасы буенча Ленинград тимер юл транспорты ин-тында (В.В.Яковлев, Р.Ф.Фёдоров), Иркутск политехник ин-тында (Г.П.Хәмитов), Мәскәү халык хуҗалыгы ин-тында (В.С.Гладкий), БССР ФАнең Минск радиотехника ин-тында (А.Е.Леусенко, Э.Л.Баканович) һ.б. үзәкләрдә интенсив һәм нәтиҗәле эш алып барыла.

*Әд.:* Бухараев Р.Г., Хасанов Ф.А. Моделирование вероятностных процессов на ЭВМ

«Урал» // Итоговая конф. Казан ун-та: Тезисы докл. К., 1961; Бухараев Р.Г., Захаров В.М. Управляемые генераторы случайных кодов. К., 1978; Бухараев Р.Г. Основы теории вероятностных автоматов. М., 1985.

*Р.Г.Бохараев.*

**ИХТИОЛО́ГИЯ** (грек. ichthys — балык һәм ... *логия*), балыкларны һәм божра авызлыларны өйрәнүче фән; умырткалылар зоологиясе бүлеге. Гамәли юнәлешләре — балык тоту һәм балык үрчетү. Балыклар турында системалы беренче мәгълүматлар Аристотель язмаларында (б.э.к. 4 йөз) очрый. И. үсешенә сизелерлек өлешне, асылда, балыклар классификациясен төзүче швед галиме П.Артеди кертә. Соңыннан бу мәгълүматларны табигать фәннәре буенча швед белгече К.Линней үзенең «Табигать системалары» («Системы природы», 1735) хезмәтендә куллана. Россиядә И. үсеше Петербург ФА оешу (1725) һәм кайбер экспедицияләр оештыру б-н бәйле. Балыкларның үзенчәлекле систематикасы авторы — табигать фәннәре буенча рус белгече П.С.Паллас. Россия И.сендә сизелерлек эзне «Арал-Каспий-Понт ихтиология өлкәсендәге сулыкларда яшәүче һәм очраучы балыклар» («Рыбы, водящиеся и встречающиеся в Арало-Каспийско-Понтийской ихтиологической области». СПб., 1877) хезмәтен язган рус зоологы К.Ф.Кесслер калдыра. И.не алга таба үстерүгә рус зоологы Н.М.Книповичның Баренц (1899), Каспий (1904, 1912–13, 1914–15), Азов һәм Кара (1922–27) диңгезләрдәге балыкларны һәм балык промыселын өйрәнү максатында оештырылган экспедицияләре һәм акад. Л.С.Бергның балыклар анатомиясенә, систематикасына, таралуына, палеонтологиясенә караган хезмәтләре булышлык итә.

Казан ун-тында беренче ихтиологик тикшеренүләр чөгә балыгын ясалма аталандыруны (1868) гамәлгә ашыручы А.О.Ковалевский тарафыннан үткәрелә. Аның эмбриологиясен 2 томлы «Чөгә балыгының үсеш тарихы» («История развития стерляди», 1878) авторы В.В.Заленский өйрәнә. Казан губернасы сулыкларындагы балыкларны беренче тапкыр тулы итеп Н.А.Варпаховский тасвирлый (1886). И.нең алга таба үсеше А.А.Остроумов эшчәнлеге б-н бәйле. Аның күпсанлы хезмәтләре арасыннан чөгә балыгының үсеш закончалыкларын беренче тапкыр эксперименталь рәвештә аквариум шартларында өйрәнүгә багышланган мәкаләләр циклы аерылып тора (1905–18). Җирле ихтиофаунаны балык хуҗалыгы максатында М.Е.Макушок башлаган өйрәнүне С.Д.Лавров, А.Я.Недошивин, А.В.Лукин дәвам иттерә. 1931 дә ун-тта И. каф. оештырыла, 1950 дә ул умырткалылар зоологиясе каф. итеп үзгәртелә, әмма И. төп фәнни юнәлешләрнең берсе буларак саклана (В.А.Кузнецов). И. белгечләре әзерләү буенча Казан ун-ты илнең фәнни үзәкләренең берсенә әверелә. Ун-т галимнәренең тырышлыгы нәтиҗәсендә 1931 дә Күл һәм елга балыгы хуҗалыгы ин-тында Татар бүлеге оештырыла, аның беренче директоры А.В.Лукин була. 1960 еллардан Татарстан сулыкларында, иң элек Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында балык запасларын, төбәктә балык үрчетүне бәяләү максатында тикшеренүләр үткәрелә башлый (Ю.М.Махотин, Р.А.Ризванов, Р.Г.Таиров). ТРда балык тотуны, саклауны һәм балык запасларын арттыруны тәртипкә салу өчен Республика балык инспекциясе булдырыла. Балык ресурсларының торышын күзәтүче ихтиология бүлеге дә аның составына керә. Ихтиологик тикшеренүләрне ш.у. Казан пед. ун-ты хезмәткәрләре дә үткәрә (А.А.Попов).

Казан ихтиологлары тарафыннан Урта Идел буе ихтиофауна составы ачыклана, аларның төп вәкилләренә биологик характеристика бирелә (балыкларның 9 сирәк төре ТР Кызыл китабына кертелә); Куйбышев сусаклагычы базасында балык запасларының торышын бәяләү һәм аларны нигезле файдалану буенча чаралар үткәрү мөмкинлеге бирүче комплекслы тикшеренүләр үткәрелә; яңартылып төзелгән сулык экосистемасын һәм аның ахыргы трофик буынын — балык бергәлеген формалаштыру концепциясе оештырыла. Татарстанда И.нең мөһим бурычы — Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларындагы балыклар популяциясенең санча динамикасы мәсьәләләрен хәл итү, даими алышынып торучы һава шартларына бәйле рәвештә аларның биологик үзенчәлекләрен ачыклау, балык запасларының күләмен һәм аларны нигезле куллану ысулларын билгеләү. Кече елга һәм күл балыклары җитәрлек өйрәнелмәгән. Тармак хуҗалыкларында балыклар үрчетү һәм аларны ясалма арттыруда И.нең гамәли әһәмияте зур.

*Әд.:* Варпаховский Н. Очерк ихтиологической фауны Казанской губернии. СПб., 1886; Рузский М.Д. Бассейн реки Свияги и его рыбы. К., 1887; Остроумов А.А. О некоторых результатах культуры стерляди в зоологическом кабинете Императорского Казанского университета. М., 1915; шул ук. К истории зоологического кабинета Казанского университета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1926. Т. 86, кн. 1; Лукин А.В. Основные черты экологии осетровых в Средней Волге // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1947. Т. 57, вып. 3–4; шул ук. Обзор ихтиологических исследований кафедры зоологии позвоночных Казанского университета // Материалы науч. конф. Казан. отд-ния Всесоюз. гидробиол. об-ва. К., 1971; Кузнецов В.А. Динамика численности и выживаемости молоди пресноводных рыб. К., 1975; шул ук. Особенности воспроизводства рыб в условиях зарегулированного стока реки. К., 1978; Лукин А.В., Кузнецов В.А., Смирнов Г.М. Рыбы Среднего Поволжья и методы их изучения. К., 1981.

*В.А.Кузнецов.*

**«ИХТЫЯҖИ́ БОРАДӘРЛЕ́К»**, к. *«Немецларның контрреволюцион-фашистик оешмасы»* эше.

**ИЧКИ́** (эчке), 15–16 йөзләрдә Казан ханлыгында ирекле хәрби хезмәткәрләр катлавы. Ханлыкның эчке гарнизоннарында, чик буенда яллы хәрби хезмәттә булганнар.

**ИША́Н** (фарсы ایشان), Урта Азия һәм Идел буе халыклары мөселманнарында суфилар борадәрлеге җитәкчеләре һәм алар нәселе вәкилләренең титулы. Урта Азиядәге мөселман дәүләтләрендә И.нарның күбесе ханәкәләрдә һәм тәккәләрдә яки берәр изгенең (әүлиянең) дөрбәсендә яшиләр. И. титулын йөртү хокукына ия булучылар: 1) барлык борадәрлекнең башлыгы, борадәрлеккә нигез салучының турыдан-туры дәвамчысы яки өлкән варисы; 2) борадәрлекнең теге яки бу төбәктәге төркемнәре башлыгы, борадәрлекләр башлыгы вәкиле, аның кече варисы; 3) аерым мәхәллә башлыгы, борадәрлек төркемнәре башлыгының вәкиле (хәлфә). Югары рухи камиллеккә ирешкән һәм үзенең остазыннан иярченнәре-мөридләре б-н мөстәкыйль җитәкчелек итү хокукы алган теләсә кайсы мөселман И. була алган. Әмма халык күзаллавынча, әүлиялекнең иң югары дәрәҗәсенә Мөхәммәд пәйгамбәр һәм тәкъва, хәлифәләр нәселе вәкилләре генә хокуклы санала. И.нарның күпчелек өлеше үз дәрәҗәләрен хезмәтләренә карап түгел, ә бәлки варислык буенча ала. 15–16 йөзләрдә И.нар Урта Азия дәүләтләренең сәясәтенә актив йогынты ясыйлар, нәтиҗәдә суфи остазлар һәм аларның мөридләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең ритуаль һәм социаль аспектлары алгы планга чыга, ә мистик фәлсәфә икенче планга күчә. И.ның эшчәнлеге әкренләп дәвалауга, им-томга, саклану бөтиләре әзерләүгә, коллектив гыйбадәт йолалары үткәрүне оештыруга кайтып кала. 19 йөздә суфилар борадәрлекләре арасында элемтәләр йомшый һәм абруйлы һәр И. мөстәкыйль мәхәлләгә нигез сала. Хөкүмәткә каршы фикердә торганга күрә, Россия хакимияте И.нарга карата тискәре мөнәсәбәттә була. Совет чорында И.нар мөселман руханиларының советларга каршы аеруча актив өлеше итеп карала, шунлыктан алар һәрвакыт эзәрлекләүләргә дучар ителәләр. Күп кенә татар И.нары *абызлар хәрәкәте*, аларның миссионерлык эшчәнлеге б-н тыгыз элемтәдә торганнар (мәс., Ибәтулла-ишан (Салихи)). Татар И.нары силсиләне (И.ның — рухани дәрәҗәле остазның үз шәкертенең — мөриденең казанышларын һәм остазлык эшчәнлегенә хокукын рәсми тануын раслаган документны), кагыйдә буларак, Төркестанга барып алганнар. Уфа дини Мөхәммәди канун Җыены оешканнан соң, И.нар рухани хакимият вәкилләре буларак эш йөртәләр (Хәбибулла бине Хөсәен әл-Уруви, Нигъмәтулла Эстәрлебаши (Тукаев) һ.б.). И.нарның йогынтысы 1865 елдан соң, мөфтиләрне дөньяви кешеләрдән билгели башлагач кочәя. Аларның бер өлеше мөфтинең сайланып куелуын яклап чыга (мәс., З.*Рәсүлев*, соңрак аның мөриде Г.Баруди). И.нарның икенче бер төркеме яңалыкка каршы көрәштә *кадимчелекнең* нигезен тәшкил итә (И.*Динмөхәммәтов*). Совет чорында да татарлар арасында И.нар була. Хәзер Идел буе төбәгендә иҗтимагый-дини күренеш буларак ишанлык сизелерлек роль уйнамый.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. 2 томда. К., 1984–86; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1; Ислам в Среднем Поволжье. История и современность: Очерки. К., 2001; Хабутдинов А.Ю. Формирование нации и основные направления развития татарского общества в конце VIII — начале XX веков. К., 2001.

**ИШӘККОЛА́К** (Symphytum) кыярчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразия

һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә 2 төре үсә. Дарулы И. (S. officinale) барлык р-ннарда, Дон И. (S. tanaicense) Кама аръягында очрый. Дымлы болыннарда, яр буйларында, уйсу сазлыкларда үсә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек, каты төкчәләре булганлыктан кытыршы. Тамырчасы юан, кыска. Сабагы туры, юан. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, озынча түгәрәк яки ланцетсыман озынча, тамыр янындагылары — сабаклы, өскеләре — утырма. Чәчәкләре кыңгыраусыман көпшәле, вак, җете кызыл-шәмәхә, бөтеркәле чәчәк төркемендә. Җимеше — чикләвекчек. Май ахырыннан августка кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив ысул б-н үрчи. Дым яратучан, суыкка чыдам үсемлек. Дарулы И.ның тамырчасы һәм тамырында алкалоидлар, гликозидлар, дуплау матдәләре, сумала, органик к-талар бар; халык медицинасында төнәтмәсе эч киткәндә файдаланыла, йомшарткыч чара, ш.у. сынган урыннарда сөякләрнең үсүен тизләтү өчен кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**ИШӘЛЕ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 40 *км* көньяктарак, Чистай — Нурлат автомобиль юлы буенда. 2008 елда 349 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә земство мәктәбе, 2 тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1473 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 393, 1897 дә — 806, 1908 дә — 1017, 1920 дә — 1060, 1926 да — 725, 1938 дә — 648, 1949 да — 569, 1958 дә — 431, 1970 тә — 583, 1979 да — 440, 1989 да — 323, 2002 дә — 356 кеше.

**ИШБӘЛӘ́ ЧӘЧӘ́К**, к. *Шеббуй.*

**ИШБУ́ЛДИНА** Хәлимә (29.10.1910, Казан губ., Бөгелмә өязе Тимәш а. — 7.10.2001, Шөгер штп), татар фольклоры әсәрләрен җыючы. Кайберләре «Татар халык иҗаты» җыентыгында басылган.

**ИШБУЛӘ́КОВ** Идеал Дәүләт улы (26.12.1926, Үзбәкстан Респ-касы Карши ш. — 15.2.1998, Казан), җырчы (драм. тенор), ТАССРның халык артисты (1968), РСФСРның атказ. артисты (1978). 1958 елда Казан консерваториясен (А.Шиканян классы) тәмамлый. 1946–50 дә Таҗикстан Хәрби округының чик сакчылары гаскәрләре җыр һәм бию ансамбле солисты, 1956–88 дә Татар опера һәм балет театры солисты. Җырчының иҗат биографиясендә аеруча югары күтәрелешкә ирешкән чор — 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Н.Җиһановның «Җәлил» операсында Җәлил партиясен башкаруы (беренче башкаручы) һәм шул ук партияне 1959 да Мәскәүнең Зур театр сәхнәсендә җырлавы. Табигать тарафыннан бирелгән көчле, яңгыравыклы тавышка, сәхнәдә темпераментлы үзенчәлекле башкару сәләтенә ия була. И.ка бигрәк тә героик пландагы көчле характерларны чагылдыручы, күтәренке рухлы образларны башкару уңыш китерә. Төп партияләре: Манрико, Радамес («Трубадур», «Аида», Дж. Верди), Хозе («Кармен», Ж.Бизе), Германн («Пики дамасы», П.Чайковский), Сергей («Катерина Измайлова», Д.Шостакович) һ.б. Концерт эшчәнлеге алып бара. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



И.Д. Ишбуләков.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*Р.И.Такташ.*

**ИШЕ́ЕВО** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2008 елда 2 кеше яши. 1646 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, тимерчелек, мичкә ясау, балта эше, өй җиһазлары ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да полиция үрәтниге фатиры була, Никола чиркәве (1795 тә төзелә), земство уч-щесе (1897 да ачыла), кредит ширкәте, 2 җил тегермәне, 2 тимерчелек, май язу йорты, ярма яргыч, казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете, пәнҗешәмбе саен базар эшли; 2 тапкыр ярминкә (10 июнь һәм 23–25 сентябрьдә) үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 971,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 250 ир-ат; 1859 да — 649, 1897 дә — 937, 1908 дә — 933, 1920 дә — 649, 1926 да — 608, 1938 дә — 503, 1949 да — 432, 1958 дә — 258, 1970 тә — 100, 1979 да — 54, 1989 да — 36, 2002 дә — 11 кеше.

**ИШЕ́М** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ишем елгасы буенда. 2008 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә Олы Кариле авылы пүчинкәсе буларак нигез салына. Беренче исеме — Яңа Кариле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, мич чыгару, урман кисү, балта эше, тегүчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә мәчет (1896 төзелә), су тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1664,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостенда. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 130 ир-ат; 1859 да — 679, 1897 дә — 1053, 1908 дә — 1225, 1920 дә — 1129, 1926 да — 795, 1938 дә —







И.Д. И ш б у л ә к о в: 1. Түләк (Н.Җиһанов, «Түләк һәм Сусылу» операсы, Аембикә ролендә Г.И. Сәйфуллина); 2. Германн (П.И. Чайковский, «Пики дамасы»); 3. Риббо (Дж. Верди, «Леньяно вакытында сугыш», Лида ролендә — З.Г. Хисмәтуллина) рольләрендә. М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры.

650, 1949 да — 474, 1958 дә — 304, 1970 тә — 220, 1979 да — 165, 1989 да — 100, 2002 дә — 82 кеше.

**ИШЕ́М** елгасы, Идел алдында, Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,9 *км*, бассейнының мәйданы 77,3 *км²*. Кама Тамагы р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Шершалан авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Кирельский авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. И.нең 0,6 дан 3,3 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км²*. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый арта. Җир асты туендыру модуле 0,1 *л/с·км²* га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 62 *мм*, ташу вакытында агым катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,026 *м³/с*. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**«ИШЕ́М ДАЛАСЫ́»**, газета. 1913 елда Петропавловск шәһәрендә татар һәм казакъ телләрендә нәшер ителә.

**ИШЕМБА́Й РАЙОНЫ́**, БРның үзәк өлешендә урнашкан. 1930 ның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 4006 *км²*. Үзәге — Ишембай шәһәре (Уфадан 160 *км* көньяктарак). Халкы — 97992 кеше (1999). Татарлар саны: 1970 тә — 10359, 1979 да — 9407, 1989 да — 12059 кеше. Районда — 84, ш.и. 1 татар (Яңа Йорт хуторы), 4 татар-башкорт торак пункты бар. Татарларның күпчелеге (10514 кеше) район үзәгендә яши (1999).

**ИШИ́МОВА** Ләлә Мөхәмматхан кызы (2.7.1922, Зөя кантоны Мамадыш-Әкил а.), патофизиолог, аллерголог, мед. фән. д-ры (1954), проф. (1958), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1975). А.Д.*Адо* шәкерте. 1946 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1953–57 елларда Куйбышев мед. ин-тында патологик физиология кафедрасында. 1958–88 дә Мәскәүнең 2 нче мед. ин-ты профессоры. Хезмәтләре аллергиянең күзәнәк һәм гумораль механизмнарын өйрәнүгә карый. И. аллергия авырулары этиологиясендә нерв системасының төп ролен исбатлый, тоташтыргыч тукыманың юан күзәнәкләре ярдәмендә аллергия авыруларына диагноз кую ысулын эшли һәм клиник куллануга кертә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патологическая физиология. М., 1966 (автордаш).

**ИШКӘГАЯКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р** (Copepoda), кысласыманнар классыннан умырткасызлар отряды. 1800 гә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә 60 чамасы. Буынлы, кабырчыксыз, башкүкрәк, баш һәм корсак өлешенә бүленгән гәүдәсе б-н аерылып торучы вак кыслалар. 2 пар озын мыекчасы һәм кысла хәрәкәтләнгәндә ишкәк сыман (исеме шуннан) йөреш ясаучы 5 пар күкрәк очлыгы бар. Гәүдәсе 0,5–3 *мм* озынлыкта, ана затлар аталарына караганда эрерәк. Ана И.к. аталанган йомыркаларын корсак астындагы махсус капчыкларда йөртә. Личинкалары метаморфоз юлы б-н үсә һәм науплиус, копеподит стадияләрен уза. Өч асотрядка бүленәләр: каланоидлар (Calanoida), циклопоидлар (Cyclopoida) һәм гарпактикоидлар (Harpacticoida). Туклану характеры буенча беренчеләре — фильтрлаучыларга, икенчеләре — фильтрлаучы һәм ерткычларга, өченчеләре җыючы-детритофагларга карый. И.к. акмый торган һәм агымлы сулыклар зоопланктонының мөһим компонентлары, су төбе катламнарында да, су үсемлекләре арасында да яшәргә мөмкиннәр, алар — планктон б-н тукланучы балыкларның яраткан азыгы. Циклопларның кайбер төрләре кеше паразитларының (мәс., лентец, ришта) арадаш хуҗалары булып тора. Ergasilus төренең циклоплары балыклар паразиты буларак билгеле һәм аларга зур зыян китерергә мөмкиннәр.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977.

*В.А.Яковлев, М.Г.Борисович.*

**ИШКӘ́ЕВ** Равил Кәлимулла улы (28.12.1941, Казакъстан ССРның Көньяк Казакъстан өлкәсе Шәвелдер а. — 12.12.2005, Азнакай ш.), нефть һәм газ чыганаклары технологиясе гыйлеме белгече, техник фән. д-ры (2000). ТССРның атказ. нефтьчесе (1991), РФ атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1998). 1969 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый. 1964 тән «Азнакайнефть» НГДУнда эшли (бүленеп, 1982–96 да «Актүбәнефть» НГДУ башлыгы), идарә башлыгы (1977–82), структур бүлек башлыгы (1996 дан). Хезмәтләре катламга суны аз җитештерүчән насослар б-н кудырганда нефть чыгаруның күләмен көйләүгә һәм нефть чыганакларын эшкәртүне камилләштерүгә карый. Скважиналар бораулый торган перфораторларның катламнарны икенчел (кабат) ачу конструкциясен һәм ысулын эшли. ТР ның Дәүләт бүләге лауреаты (2001). ТР ның халык депутаты (2000 нән). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые способы вторичного вскрытия пластов и конструкций забоев скважин. Тюмень. 1998; Технология закачивания нефтяных и газовых скважин. Уфа. 1998; Гидродинамические исследования скважин и методы обработки результатов измерений. М., 1999; Комплексные физико-химические технологии обработки призабойной зоны нефтяных пластов. К., 1999.

**ИШКӘ́Й** (Тәкмәле) авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда — 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 94, 1938 дә — 137, 1949 да — 150, 1958 дә — 117, 1970 тә — 94, 1979 да — 60, 1989 да — 41, 2002 дә — 51 кеше.

**ИШКӘКЛЕ́ КАНДАЛАЛА́Р** (Corixidae), су кандалалары семьялыгы. Фауна дөньясында 800 гә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә Sigara, Corixa һәм Microneota ыругыннан өч төре бар. Гәүдәсенең озынлыгы 1,5–16 (еш кына 5–7) *мм*. Сулыкларда яши. Яхшы йөзәләр һәм очалар, төнлә б-н еш кына утка очып килләр. Үсемлек һәм хайван азыгы б-н тукланалар, озынборын личинкаларын юк итәләр. Үсемлек б-н тукланучы төрләрнең кечкенә күрәк рәвешендәге алгы аяклары су асты суүсемнәрен кыру өчен җайлашкан.

*Әд.:* Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

**ИШКИ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 396 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан Акман Пүчинкәсе исеме б-н мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта һәм токарьлык эше, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.дә мәчет, 2 су тегермәне, йон-тукыма ману остаханәсе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1750,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык-Күпер волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 1054, 1897 дә — 1547, 1908 дә — 1563, 1920 дә — 1788, 1926 да — 1558, 1949 да — 892, 1958 дә — 1105, 1970 тә — 1145, 1979 да — 898, 1989 да — 641, 2002 дә — 479 кеше.

**ИШКО́ВА** Галина Семёновна (24.8.1927, Алтай крае, Шелабалихин р-ны Юдиха а. — 1.12.2008, Казан), драма актрисасы, РФнең атказ. (1963) һәм халык (1980), ТРның халык (2002) артисты. Алтай крае Кемерово өлкәсе Анжеро-Судженск шәһәр театры каршындагы студияне тәмамлый (1948), бер үк вакытта шул театрда актриса булып эшли (1945–51). 1951–53 елларда Ачинск драма театры актрисасы, 1953–65 тә — Кемерово, 1965–66 да Тамбов өлкә театрларында эшли, 1966 дан Казан Зур драма театры труппасында. Кемерово театрында Таня, Валя («Таня», «Иркутск вакыйгасы», А.Н.Арбузов), Аня («Океан», А.П.Штейн), Ксения («Разлом», Б.А.Лавренёв), Финея («Юләр кыз», Лопе де Вега) рольләрендә уйный. Казан театры сәхнәсендә уйнаган беренче рольләреннән үк — Поля («Мунча», В.В.Маяковский, 1967), Ольга Носова («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов, 1967), Тафаева («Гади вакыйга», И.А.Гончаров романы буенча, 1968) — актри-

саның өлгергән оста икәнлеге, образның жанрын һәм социаль табигатен төгәл сиземли белүе күренә. Төрле жанрлардагы Надя («Бервакыт Яңа ел төнендә», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов) һәм Рөкыя («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин — икесе дә 1969) кебек рольләрдә уйнаганда аның иҗат мөмкинлекләре киң ачыла. Сурәтләү чараларыннан аз файдаланып та, актриса лирик-драматик пландагы рольләрне дә, үткен характерлы һәм көлкеле рольләрне дә бертигез җиңеллек һәм табигыйлык б-н башкара. Образның тормышчан дөреслегенә И. тышкы сурәтләү чаралары, аерым детальләргә басым ясау ярдәмендә генә түгел, ә аеруча героиняның эчке халәтен төгәл тоемлавы аша ирешә. Шактый гына катлаулы язмышлы, хезмәтчән хатын-кызлар образларын тудыра: Мария Аркадьевна («Гадәттән тыш бүләк», Е.Габрилович, С.Розен, 1971), Әни («Кыерсытылган апостол», А.Е.Макаёнок, 1972), Анна Васильевна, Марина, Васюта («Узган җәйдә Чулымда», 1974, «Провинциаль анекдотлар», А.В.Вампилов, 1981, 1999), Хатын («Югалган көн», А.Гыйләҗев, 1977), Агафья («Имеш-мимешләр», А.Д.Салынский, 1981), Барабанова («Сагыш», А.М.Галин, 1981), Голда («Үлгәннәрне искә алу догасы», Г.И.Горин, 1992), Әби («Чит кеше белән төшкән гаилә портреты», С.Л.Лобозёров, 1994). Рус классик драматургиясе әсәрләре буенча башкарылган образлары: Притыкина («Варварлар», М.Горький, 1972), Домна Пантелеевна, Глумова, Фоминишна («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», 1974; «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», 1977; «Банкрот», 1996, А.Н.Островский), Арина Власьевна, Ислаева («Аталар һәм балалар», 1979; «Авылда бер ай», 1995, И.С.Тургенев), Анна Павловна («Тере мәет», Л.Н.Толстой, 1983), Анна Шойбес («Мадам Шойбес йорты», А.И.Купринның «Чокыр» повесте буенча, 1993) чынбарлык мәктәбенә тугрылыклары, драматургик материалның асылына тирән үтеп керүләре б-н әһәмиятле. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



Г.С.Ишкова.

*Әд.:* Суворова Э. Полюбившаяся людям // Театральная жизнь. 1964. № 1; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ИШМА́ЕВ** Фәрит Мансур улы (14.1.1911, Казан — 28.8.1990, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1936). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1932), Урал геол.-разведкалау идарәсенең Төмән геол.-разведкалау партиясе башлыгы булып эшли. 1938–81 елларда Казан ун-тында, геол. ф-ты деканы (1956–77). Хезмәтләре Татарстан петрографиясенә һәм югары палеозойның файдалы казылмаларын өйрәнүгә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Литология отложений Белебеевской свиты Среднего Поволжья // Уч. зап. Казан. ун-та. 1952. Т. 8, вып. 2.

**ИШМА́ЕВА** Элеонора Әхмәт кызы (18.4.1940, Уфа ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1982), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, элементорганик кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1988 дән). Хезмәтләре түбән координацияле фосфор кушылмаларының синтезына, төзелешенә һәм реакциягә керә алуына, элементорганик кушылмалардагы эчке молекуляр электроннарның тәэсирләшүләрен конформацион анализлауга һәм тикшерүгә карый. Күп кенә туендырылмаган фосфорорганик кушылмаларның конформацион үзенчәлекләрен һәм фәзаи төзелешен, бер һәм икеле координацияле фосфорның тотрыклы кушылмаларын өйрәнә. Кремнийфосфорорганик кушылмаларның һәм силатраннарның электрик һәм электроптик үзлекләрен анализлый, аларны конформацион анализлауны гамәлгә ашыра. Фосфор атомы катнашындагы күп кенә бәйләнешләрнең поляргылыгын билгели һәм аларны элементорганик кушылмаларның төрле класс конформацияләрен һәм үзара электрон тәэсирләшүләрен билгеләү өчен файдалана. Тикшеренү нәтиҗәләре монографияләргә һәм Керрның диполь моментлары һәм константаларына кагылышлы белешмәлеккә кертелгән.

Хезм.: Полярность и структура ненасыщенных производных четырёхкоординированного фосфора // Успехи химии. 1978. Т. 47, вып. 9; Конформации фосфорорганических соединений // Конформационный анализ элементоорганических соединений. М., 1983; Справочник по дипольным моментам фосфорорганических соединений. К., 1998 (автордаш).

**ИШМӘМӘ́ТОВ** Хафиз (1892, Пенза губ., Наровчат өязе Аллагөл а. — 1961), мишәр-татарлар җырларын һәм бәетләрен башкаручы. Аңардан язып алынган фольклор әсәрләре муз. һәм шигырь җыентыкларында басылган.

**ИШМИ́ ИША́Н**, к. *Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт.*

**ИШМОРА́Т** (Ишморатов) Риза Фәхретдин улы (1.11.1903, БРның хәзерге Яңавыл р-ны Бәдрәш а. — 29.10.1995, Казан), драматург, публицист, театр һәм җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1953, 1983). «Госмания» мәдрәсәсендә (1916–18) һәм Уфада пед. курсларда (1920) укый. Берникадәр вакыт эчке иминлек гаскәрләренең Уфа политбүлегендә хәрби хезмәткәр, аннары Минзәлә балалар шәһәрчегендә тәрбияче, Актаныш төбәгендә башлангыч мәктәп укытучысы булып эшли. Казан театр техникумын тәмамлагач (1926) Татар акад. театры режиссёры була. Ленинград сәнгать тарихы ин-ты каршындагы театр сәнгате югары курсларында белем ала (1930). 1931–40 елларда Татар акад. театрында режиссёрлар коллегиясе җитәкчесе, режиссёр-куючы һәм әдәби бүлек мөдире, ТАССР ХКС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсе башлыгы урынбасары вазифаларын башкара. 1926 да Татар акад. театры сәхнәсендә аның беренче пьесаларыннан «Йокы патшалыгында» һәм «Өтек философ» спектакльләре куела. И. драматургиясенең тематикасы һәм эчтәлеге совет чорының идеологик шартлары б-н бәйле. 1930 елларда И. драматургиясендә алгы планда авылда сыйнфый көрәш, колхоз төзелеше, эшчеләр, интеллигенция, студентлар тормышына бәйле рәвештә совет кешесенең мораль сыйфатларын чагылдырган «Пожар» (1929), «Данлы чор» (1930), «Мәдинә» (1930), «Гөлзада» (1940) пьесалары тора. Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең батырлыгы турында «Дошман лагеренда» (1941), «Ватан кызлары» (1941) пьесаларын яза; «Кайту» (1942) пьесасы күп кенә театрлар сәхнәләрендә уйналып, татар драматургиясенең алтын фондына керә. И.ның иҗатында яктыртылган төп темаларның тагын берсе — хезмәт кешесен олылау. «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1949), «Бистә кызы Гөлсинә» (1952) пьесаларында, «Шайтан таугы» (1954), «Серле моң» (1959), «Шаулыйлар дулкыннар» (1964) комедияләрендә яшь геройларның эчке дөньясы, тыныч тормыш романтикасы чагыла. Аның М.Җәлил турындагы «Үлмәс җыр» (1956)







Г.С.Ишкова: 1. Надя (Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов, «Бервакыт яңа ел төнендә»); 2. Рокыя (К.Тинчурин, «Җилкәнсезләр»); 3. Тафаева (И.А.Гончаров, «Гадәти вакыйга») рольләрендә.

героик драмасы Казан Зур драма, ТАССР күчмә, Чуаш, Казакъстан (Алма-Ата), Семипалатинск акад. театрларында зур уңыш б-н бара. Тын океан давылларын җиңеп узган Ә.Җиһаншин һәм аның иптәшләренең җанлы образлары сурәтләнгән «Алар дүртәү иде» (1961), В.И.Ульяновның Казан ун-тында укыган елларын чагылдырган «Давылга табан» (1963), Г.Тукай һәм аның замандашларына багышланган «И мөкатдәс моңлы сазым» (1982) драмалары да татар драматургиясе казанышлары булып тора. И. — татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Г.Камал, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, К.Тинчуриннар турында «Гомер сукмаклары» (1987) һәм «Дусларым, остазларым» дигән документаль повестьлар авторы. И.Я.Франконың «Урланган бәхет» («Украденное счастье», 1951) драмасын, Д.И.Фонвизинның «Җитлекмәгән егет» («Недоросль», 1953) комедиясен татар теленә тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1966–67; Гүзәл син, хәят: Пьесалар.К., 1973; Моңлы сазым: Пьесалар. К., 1983; Драмы. Комедия. К., 1962.

*Әд.:* Г ы й з з ә т Б. Риза Ишморат һәм аның геройлары // Совет әдәбияты. 1963. № 12; М ә х м ү т о в Һ. Бәрәкәтле гомер юлы // Социалистик Татарстан. 1983. 29 окт.; И г л а м о в Р. Риза Ишморат // Театральный календарь. Л., 1977.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ИШМОРА́ТОВ** Байрон Мостафа улы (15.9.1935, Ютазы р-ны Урал пос.), географ-икътисадчы, геогр. фән. д-ры (1980). 1958 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, ВЛКСМның Зеленодольск шәһәр ком-тында эшли. 1961–62 дә Зеленодольск халык мәгарифе системасында. 1965 тән СССР ФА (1991 дән — РФА) Себер бүлегенең Себер һәм Ерак Көнчыгыш географиясе ин-тында (Иркутск ш.). Хезмәтләре иҗтимагый һәм сәяси географиягә, табигатьтән файдалану мәсьәләләренә карый. Хәзерге географиянең фундаменталь нигезле юнәлеше буларак, табигатьтән файдалану, ш.у. җитештерүче көчләрнең региональ системаларын оештыру һәм аларның структур дәрәҗәләре концепциясен эшли. Икътисади географиядә чагыштырма-тарихи ысулның принципларын бәян итә, «МХР милли атлас»ын («Национальный атлас МНР», Новосибирск, 1989) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Региональные системы производительных сил: Методол. основы геогр. анализа. Новосиб., 1979; География Сибири. М., 1992 (автордаш).

**ИШМОРА́ТОВ** Габдрахман Әхмәт улы (1857–1922), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, җирбиләүче, шәһәрнең нәселдән күчмә мактаулы гражданы. Сәүдәгәрләр катлавыннан. Ат з-ды (Үрнәк авылында, атларына күп мәртәбә Россия һәм чит илләрнең дәрәҗәле бүләкләре бирелә), май з-ды, бәз ману ф-касы (Казан губ-насының Казан өязе Казанбаш а.), чәй үлчәү-бүлү бинасы («Ишморат чәе» бөтен Идел буенда танылган була), Казанда 3 таш йорт, Казан өязендә 664 дис. җир һ.б. хуҗасы. Казан шәһәр думасы гласные, Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе исәп-хисап-ссуда ком-ты әгъзасы (1893–1917), фатир салымнары буенча губерна идарәсе әгъзасы һ.б. Кадимчеләрне яклый, татар халкы тормышындагы җәдитчелеккә, мәдрәсәләрдә яңача укытуга каршы чыга. Җәдитчеләр б-н көрәшүгә акча бирә, И.*Динмөхәммәтов* б-н хезмәттәшлек итә. 10 мәчет төзүгә (ш.и. 1897 елда Зәңгәр мәчетне төзекләндерүгә), *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенә* һ.б.га иганәчелек кыла. Дүрт «Тырышлык өчен» алтын медале б-н бүләкләнә.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**ИШМОРА́ТОВ** Гомәр Йосып улы (28.9.1951, БАССРның Октябрьский ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1993), проф. (1997). 1974 елда Башкортстан ун-тын тәмамлый. 1975 тән РФА Уфа гыйльми үзәгенең Органик химия ин-тында эшли, бөҗәкләр биорегуляторлары лаб-ясе мөдире (1995 тән). Хезмәтләре биоорганик химиягә карый. Түбән молекуляр биорегуляторларны синтезлауның фәнни юнәлешен формалаштыра һәм үстерә, универсаль блок-синтоннар алу ысулын эшли һәм шулар нигезендә феромоннар (60 тан артык бөҗәк төре), ювеноидлар һәм хитин биосинтезы ингибиторлары синтезын гамәлгә ашыра. 1-алкилциклоалкеннарны кетоспиртларга әверелдерүнең бер стадияле югары селектив озонолитик ысулын эшли. Енин кушылмаларыннан, монотерпеноидлардан файдаланып, феромоннарны синтезлауны гамәлгә ашыра. Ацетогенин, изопреноид һәм макролид төзелешле бөҗәкләр феромоннарын (а.х. культуралары, урманнар һәм ашлык запаслары корткычлары), рацемик һәм оптик актив формалардагы гидропрен һәм метопрен ювеноидларны синтезлау схемасын тәкъдим итә. Мамык күбәләге («Армигаль»), тегермән һәм көньяк утчылы санын («Кюнемон»), бал кортларының тәртибен һәм тереклек эшчәнлеген («Апимил», «Апирой», «Уфамил», «Меллан», «Кандисил», «Аписил», «Биосил») көйли торган феромон препаратлары уйлап таба, шуларны җитештерүне оештыра. Уйлап табуга 44 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФАнең А.Н.Несмеянов исем. бүләге бирелә (1999). СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Озонолиз ненасыщенных соединений в синтезе феромонов насекомых и ювеноидов // Успехи химии. 1995. Т. 63, № 6; Монотерпеноиды в синтезе оптически активных феромонов насекомых. Уфа, 1999; Синтез 9-оксо- и 10-гидрокси-2е-деценовых кислот // Химия природных соединений. 2002. № 1.

**ИШМОРА́ТОВА** Рәйсә Гыйниятулла кызы (20.7.1917, Чистай ш. — 7.4.1997, Казан), язучы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Мәскәү азык-төлек ин-ты каршындагы курсларны тәмамлый (1937). 1942–49 елларда Эчке эшләр министрлыгы органнарында оператив эштә. Шул елларда гы күзәтүләре аның әдәби әсәрләрендә дә чагылыш таба. Яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган «Милиция лейтенанты» (1972; русчага тәрҗемәдә «Лейтенант милиции», 1982), «Язмышлар» (1978) исемле повестьлары — шундыйлардан. «Рәйханә» (1985), «Яшьлегем — гөлбакчам» (1987), «Тормыш дәвам итә» (1991) повестьлары — тугрылык, намуслылык, катлаулы тормыш каршылыкларын җиңүче ныклы кеше язмышлары хакында. Аның «Бай кияү» (1952), «Омтылыш» (1953), «Яшьлек канат җәйгәндә» (1969) һ.б. пьесалары буенча спектакльләр үзешчән һәм проф. театр сәхнәләрендә куела.



Риза Ишморат.



Т.К.Ишмөхәммәдов

*Әд.:* И х с а н о в а Л. Матур язмыш // Казан утлары. 1997. № 7; З у б а и р о в а Д. В творчестве — ее жизнь // Советская Татария. 1977. 19 июня.

**ИШМӨХӘММӘ́ДОВ** Тамерлан Кәрим улы (8.8.1919, хәзерге Төмән өлкәсенең Ялутор р-ны Осиново а. — 15.5.1995, Төмән ш.), Сов. Союзы Герое (15.5.1946), гв. өлкән лейтенанты. Свердловск пед. уч-щесен (1936), Оренбург хәрби авиация уч-щесен (1940), Офицерлар составын камилләштерү курсларын тәмамлый (1943). Туган авылының колхоз яшьләре мәктәбендә укытучы булып эшли. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 43 нче гв. штурм авиациясе полкының эскадрилья командиры урынбасары (4 нче һава армиясенең 230 нчы штурм авиациясе дивизиясе), Көньяк, Төньяк Кавказ, Кавказ аръягы һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Кавказ өчен барган сугышта (1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Сугыш ахырына кадәр 188 сугышчан очыш ясый, дошманның 60 тан артык орудиесен, 22 танкын, 49 автомашинасын, 9 бензин цистернасын, 14 вагонын, 5 дзотын, 6 катерын, һавада — 1, җирдә 14 самолётын, 7 кичүен юк итә. 1947 дән запаста. Төмән индустриаль ин-тында эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои боёв за Крым. Симферополь, 1972; Герои земли тюменской. Свердловск, 1975; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИШМӨХӘММӘ́ТОВ** Әхмәдулла Хаҗи улы (7.11.1919, хәзерге Пермь өлкәсенең Лысьва ш. — 16.4.1952, Свердловск ш.), Сов. Союзы Герое (23.9.1944), гв. майоры. Новосибирск хәрби пехота уч-щесен тәмамлый (1941). «Госконтроль» (Свердловск өлкәсе)



Ә.Х. Ишмөхәммәтов.

пр-тиесендә инспектор-ревизор булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 29 нчы гв. мотоукчылар бригадасының мотоукчылар батальоны командиры (4 нче танк армиясенең 10 нчы гв. танк корпусы). Сталинград, Дон, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Дон өчен барган оборона (1942), Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943) һәм Белоруссия (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 21–23 июлендә Львов шәһәрен азат иткәндә батырлык күрсәтә: И. җитәкчелегендәге батальон дошманның йөзләрчә солдатын, күпсанлы сугышчан техникасын юк итә; каты яралануына карамастан, И. сафта кала. 1945 тән запаста. Свердловск шәһәрендә эшли. Югары Пышма шәһәре (Свердловск өлкәсе) хәрби комис-тында хәрби комиссар урынбасары. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Туган шәһәрендәге бер урам аның исемен йөртә, анда Геройның бюсты урнаштырыла.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Отчизны верные сыны. Пермь, 1964; Звёзды доблести боевой. Львов, 1968; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1985. Кн. 3; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ИШМӨХӘММӘ́ТОВ** Гаяз Мәһди улы (1891, хәзерге Казакъстан Респ-касының Уральск ш. — 19.6.1971, Казан), педагог, лексикограф. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1932). Гражданнар сугышында катнаша. Уральскида мәдрәсә тәмамлаганнан соң (1910), Төркиядә, Ливанда (Бәйрут ш.) укуын дәвам итә. 1916–19 елларда Уральскида укытучы, 1919–21 дә Самара губернасының Пугачёв шәһәрендә өяз халык мәгарифе бүлегендә инспектор; 1922–28 дә балалар йорты мөдире, Уральск губерна халык мәгарифе бүлегендә инспектор. 1928–46 да ТАССРның Куйбышев шәһәрендә, аннан соң Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучысы. 1946–49 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында кече фәнни хезмәткәр. 1950–54 тә Казан ун-тында гарәп теле укытучысы. 1954–57 дә Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире. Сүзлекләр, уку ярдәмлекләре автор-төзүчесе. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестен гарәп теленә тәрҗемә итә (1968).

Х е з м.: Татарча-русча сүзлек. К., 1950 (автордаш); Гарәп теле. К., 1951; Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча сүзлекчә. К., 1954.

*В.Х.Хаков.*

**ИШМӨХӘММӘ́ТОВА** Диләрә Галим кызы (29.7.1941, Буа р-ны Кырык Садак а.), биохимик, биол. фән. д-ры (1996), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), СССР ФАнең Башкортстан ф-лында эшли. 1974 тән Казан ун-тында, биохимия каф. мөдире (2005–2007). Хезмәтләре организмның һәм шешнең үзара иммунологик тәэсирен тикшерүгә карый. И. тарафыннан шеш күзәнәкләре бүлеп чыгарган РНКның организмга системалы йогынты ясавы, аның иммун системасы регуляциясен җимерүе билгеләнә.

Х е з м.: Иммуномодулирующее действие низкомолекулярных РНК, выделяемых клетками асцитного рака Эрлиха // Эксперим. онкология. 1991. Т. 13. № 3 (автордаш); Аутоантитела к ДНК: половой диморфизм и возрастная динамика их содержания в сыворотке крови здоровых лиц // Иммунология. 2003. № 5 (автордаш); Аутоантитела к ДНК в сыворотке крови больных геморрагической лихорадкой с почечным синдромом // Медицинская иммунология. 2006. Т. 8. № 5–6 (автордаш).

**ИШНАРА́Т** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 40 *км* төньяктарак, Носы елгасы буенда. 2008 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1678 дән мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу, балта эше, чыпта сугу, агач материаллары әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.та мәчет, 1 ярма яргыч һәм 1 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 873,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 264, 1897 дә — 369, 1908 дә — 459, 1920 дә — 426, 1926 да — 294, 1938 дә — 298, 1949 да — 215, 1958 дә — 235, 1970 тә — 157, 1979 да — 143, 1989 да — 94, 2002 дә — 92 кеше.

**ИШНИЯ́З бине ШИРНИЯ́З** (?, Үргәнеч ш. — 1790, Оренбург губ. Каргалы бистәсе), дин эшлеклесе һәм галиме. Харәземдә белем ала. 1776 елдан Идел буенда яши. Казан өязендә, соңрак Оренбург янындагы Каргалы бистәсендә мәдрәсә б-н җитәкчелек итә. Хрестоматияләр, «Гакәиде Болгарийә» (1780) дип аталган дини философик кулъязма әсәр авторы.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2003.

**ИШТИРӘ́К** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Аулаш елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 509 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән Бачкеева Пустошь исеме б-н мәгълүм, рев-циягә кадәрге чыганакларда Алансу авылы буларак та билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, И.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1002,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән — Зәй, 1977 нең 26 декабреннән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 486, 1897 дә — 756, 1920 дә — 1073, 1926 да — 902, 1938 дә — 954, 1949 да — 718, 1958 дә — 410, 1970 тә — 508, 1979 да — 395, 1989 да — 448, 2002 елда — 540 кеше.

**ИШТИРӘ́К** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасыннан 2 *км* читтә. 2008 елда 11 кеше (татарлар) яши. 1924 тә Урта Кәшер авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Яңа Иштирәк. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Сарман волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1966 ның 3 гыйнварыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 90, 1938 дә — 159, 1949 да — 164, 1958 дә — 94, 1970 тә — 72, 1979 да — 54, 1989 да — 22, 2002 дә — 15 кеше.

**ИШТИРӘ́К БӘК** (? — 1619), Олы Нугай Урдасы идарәчесе (1600 дән). *Динәхмәд бәкнең* улы. Рус гаскәрләре ярдәмендә Ырыс морзаның фетнәчел улларын сугышта җиңеп, Олы Нугай Урдасының күпчелек өлешен берләштерә. 1604 елда Россиягә буйсына. 1613–14 тә казак атаманы И.М.Заруцкийга Әстерханны басып алырга булыша. 1916 да Әстерхан тирәсенә күчеп килә һәм рус патшасына ант бирә. И. үлгәннән соң, Олы Нугай Урдасы берничә олыска таркала.

*Әд.:* Н о в о с е л ь с к и й А.А. Борьба Московского государства с татарами в XVII веке. М.–Л., 1948.

*И.Л.Измайлов.*

**ИШТУГА́Н** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 25 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2008 елда 71 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иштуган Пүчинкәсе исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында И.да вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Иске Кенә-Юмья авылы җирләрен дә кертеп) 1306 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда; 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 116, 1897 дә — 169, 1908 дә — 208, 1920 дә — 230, 1926 да — 257, 1938 дә — 186, 1949 да — 164, 1958 дә — 139, 1970 тә — 155, 1979 да — 127, 1989 да — 100, 2002 дә — 94 кеше.

**ИШТУГА́Н** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы посёлогы, Саба р-нында, Байлар Сабасы авылыннан 18 *км* төньяктарак, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2008 елда 631 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 66%) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1950 елларда нигез салына. Оешты-

рылган көннән — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән Саба р-нында. Халык саны: 1979 да — 497, 1989 да — 571, 2002 дә — 641 кеше.

**ИЩЕРЕ́КОВ** Виктор Петрович (21.4.1872, Түбән Новгород губ. Сергач ш. — 23.9.1936, Казан), агрохимик, а.х. магистры (1911). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1902), шунда ук эшли: приват-доцент (1906–17), агрохимия каф. профессоры (1917–36). Бер үк вакытта ун-тның мед. ф-тында (1935 тән мед. ин-ты) аналитик химия кафедрасын җитәкли. Казан а.х. ин-тын оештыруда һәм аны ныгытуда актив катнаша, проректоры була (1925–27). Беренче фәнни-тикшеренүләре туфрак гумусын «хамелеон» б-н оксидлап билгеләү алымын эшләүгә багышлана. Бу алым кайбер үзгәртүләр б-н безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә киң тарала. Үсемлекләрнең туфрак хим. составына караганда аның физик режимына таләпчәнрәк булуын раслый. Чәчү әйләнешенең туфрак эремәсе составын көйләүче ышанычлы чара булуын исбатлый. Чәчү әйләнешенә клевер кертү һәм фосфорит, гипс, известь кулланунның көлсу туфраклар уңдырышлылыгын күтәрүгә ярдәм итүен күрсәтә.

Х е з м.: Определение гумуса в почве титрованием «хамелеоном» // Журн. опытной агрономии. 1904. Т. 5; Почвенные растворы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1910. Т. 77; О плодородии почвы. К., 1914; Удобрение подзолистых почв в связи с их кислотностью // Уч. зап. Казан. ун-та. 1928. Т. 88; Несколько наблюдений над изменением реакции почвы при внесении в неё углекислой извести. К., 1930; К вопросу о перспективах гипсования почв // Уч. зап. Казан. ун-та. 1931. Т. 91.

*Әд.:* К о л о с к о в а А.В. Виктор Петрович Ищереков // Почвоведение. 1989. № 2.

**ИЯ́ (ХУҖА)**, Казан һәм Себер татарлары, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Алтай һәм Саян төрки телле халыклар мифологиясендә өй, йорт хуҗасы, абзар, су, җил, урман, юл ияләре һ.б. Алтай һәм Саян халыкларында тау (таг-ээзи) һәм урман (тайга) ияләре шулай ук нәсел сакчылары санала. И.ләр үзләре яши торган урыннарны саклый. Нигездә, зыян китермиләр, әмма аларга карата тискәре эш-гамәлләр кылынса, үзләре дә шундый ук начар гамәлләр б-н җавап кайтаралар. И.ләрнең тышкы кыяфәтләре турында төгәл күзаллаулар юк диярлек. Еш кына аларны кечкенә кешеләр кыяфәтендә сурәтлиләр.

*Әд.:* Н а с ы р о в К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Зап. Имп. Рус. геогр. об-ва. СПб., 1890. Т. 6; А л е к с е е в Н.А. Традиционные религиозные верования тюркоязычных народов Сибири. Новосиб., 1992; Е г о р о в Н.И. Чувашская мифология // Культура Чувашского края. Чебоксары, 1995. Ч. 1; М е с с а р о ш Д. Сборник чувашского фольклора. Чебоксары, 2000. Т. 1.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ИЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,9 *км*, бассейнының мәйданы 117 *км*². Арча р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Яңа Кырлай авылы янында, тамагы Күпербаш авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 91 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 4%. И.нең 1,8 һәм 9,7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 1,1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 154 *мм*, ташу вакытында агым катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. И. октябрь ахыры – ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 *м³/с*. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм язын (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Бассейнында гомуми күләме 0,33 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ИЯ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Үшнә елгасының сул кушылдыгы (Норма, Мишә елгалары бассейны). Озынлыгы 18,3 *км*, бассейнының мәйданы 91 *км*². Елга башы Арча р-ны Иске Чүриле авылыннан 5 *км* көньяктарак, Биектау р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Питрәч р-ны Олы Бутырка авылыннан 0,5 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 19%. И. елгасының 0,3 *км* дан 3,3 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты туендыру модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 130 *мм*, ташу агымы катламы 125 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче көннәрендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,001 *м³/с*. Су язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. И. бассейнында күләме 1,78 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

# Й

**ЙАБГУ́** (җабгу), борынгы төрки идарәче титулы. Төрки каганлыкларда (6–8 йөзләрдә) дәрәҗә буенча иң югары идарәче — каганнан кала икенче зат. Каган тарафыннан билгеләнә. Кушма исем-титулларның өлеше буларак та кулланыла (мәс., Тун — Җабгу хан — Көнбатыш Төрки каганлык идарәчесе). Төрки каганлыклар таркалганнан соң 9–11 йөзләрдә угызлар дәүләтендә иң югары идарәче титулы.

*Әд.:* Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. М., 1993.

*И.Л.Измайлов.*

**ЙАРА́К**, сугышчы өс киеме, турыпочмаклы металл пластиналардан һәм боҗралардан эшләнә. Кырыйлары тишекле яисә үзәгендә заклёпкалар булган турыпочмаклы кабарынкы калай пластиналардан җыела. Й., детальләренең зурлыкларына карап, вак кисәкләрдән (ламелляр) һәм эре кисәкләрдән (ламинар) җыелган төрләргә бүленә; беркетелү ысулы буенча: пластиналы (үзара күн каешлар б-н беркетелгән), кабырчыклы (тукыма яки күн нигезгә заклёпкалар яисә каешлар б-н беркетелгән), куяк (бригандина) (зур пластиналардан аерым-аерым тире яки тукыма нигезгә җыелган) төрләргә бүленә. Й. билгә кадәр төшкән күкрәкчәдән һәм арка өлештән тора, ян-яктан һәм иңбашларда эләктерелә. 12–14 йөзләрдә иңсәләр һәм озын итәкләр (ботларны саклау өчен), ш.у. пластиналы саклагыч б-н (муен һәм бит өчен) тулыландырыла. Идел буенда пластиналы Й.лар б.э.к. 1 нче меңьеллыкта барлыкка килә. Идел Болгарында 10–11 йөзләрдә — вак, 12–13 йөзләрдә эре металл пластиналардан эшләнгән Й.лар кулланыла.

*Әд.:* Кирпичников А.Н. Военное дело на Руси XIII–XV вв. Л., 1976; Горелик М.В. Ранний монгольский доспех (IX — первая половина XIV вв.) // Археология, этнография и антропология Монголии. Новосиб., 1987; Измайлов И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII в. К.–Магадан, 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**ЙАРГУНАМӘ́**, Алтын Урдада һәм Һулагулар Иранында Яса нигезендә чыгарылган мәхкәмә карарын теркәүче мәхкәмә грамотасы төре.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950.

**ЙАРГУЧЫ́**, судья яки мәхкәмә әгъзасы (гражданнар эшләре буенча). Алтын Урдада мәхкәмә эшләре *Ясага* нигезләнеп башкарыла. Гадәттә, бу вазифаны югары катлау аксөякләр вәкиле башкара. 15 йөздән кулланылмый.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950.

**ЙӘЗДИ́** (یزدی) Шәрәфетдин Гали улы (?, Иран, Йәзд ш. — 1454, Тафт ш.), фарсы тарихчысы. Шаһрух сараенда хезмәт итә (1377–1447). «Зафәрнамә» («Җиңүләр китабы», 1969 елда Сәмәркандта басыла) дигән хезмәтендә Урта Азия хакиме *Аксак Тимернең* 14 йөз ахыры — 15 йөз башында Алтын Урда ханнары б-н үзара мөнәсәбәтләре тасвирлана.

**«ЙӘСИ́Н»** (гарәп. یس), Коръәндәге 36 нчы сүрәнең исеме. Сүрәнең башында торган «йа» һәм «син» гарәп хәрефләреннән ясалган. Кайбер очракларда әлеге хәрефләр «Йа, инсан!» («Йә, кеше!») тәгъбиренең кыскартылган үрнәге дип тә аңлатыла, ләкин әлеге исемнең төгәл мәгънәсе ачыкланып бетмәгән. Әлеге сүрә тән газапларын җиңеләйтә, дип исәпләнә, аны ураза тотканда, авыру яки үлем алдындагы кеше янында кычкырып укыйлар. «Й.» текстын, язып, бөти итеп тә тагып йөриләр. Риваятьләр буенча, Мөхәммәд пәйгамбәр әлеге сүрәне «Коръәннең йөрәге» дип санаган. Ул Мәккә чорына карый һәм Коръәни вәгазь-нәсыйхәтнең барлык төп нигезләрен үз эченә ала: дәһриләрне тәнкыйтьләү, Пәйгамбәрне башта ук яклап чыгучыларга күбрәк ышанырга чакыру. Аллаһның кодрәт иясе булуы хакында дәлилләр китерелә: аның дөньяны яраltуы, үлгәннәрне терелтү сәләте, Нух (Библиядәге Ной) көймәсендәге кешеләрне коткаруы; Мәхшәр көненең, *җәннәт* һәм *җәһәннәмнең* кыскача тәфсире, Аллаһның чиксез кодрәт иясе булуын раслап тәмамлануы.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**«ЙӘСТӘ́Й МӨҢКЕ́»**, Себер татарларының борынгы мифологик-героик дастаны. Баш герой исеме б-н аталып йөртелә. Әтисез-анисез үсә (геройның күптәннән килгән ялгызлыгын ассызыклаучы мифологик мотив). Егет ялгызлыктан кешеләр б-н түгел, ә кыргый хайван б-н аралашып котыла. Әлеге хайванның баласы Й.М. сыерының сөтен эчеп савыга һәм бик чибәр кызга әверелә. Й.М.гә кияүгә чыга (баһадирны кодалау мотивы). Борынгы әсәрләргә генә хас булганча, әлеге дастанда да хәлиткеч рольне геройның хатыны башкара: Й.М.гә лаек булырлык дошманнарның кайда яшәгәнлекләрен бары ул гына белә (сугыш — мифологик-эпик геройның язмышын билгеләүче күренеш). Беренче дошманы — Тимер Җилбегән — төрки-монгол эпосының борынгы персонажларыннан берсе. Батыр аны авырлыкларсыз җиңеп чыга. Икенчесе — Яр Кара, «җирнең читендә» яши. Ул Й.М. хатынының сеңлесен кызның ризалыгыннан башка хатынлыкка алырга тели. Баһадир б-н алып арасында мифологик-эпик традицияләргә хас зур сугыш була. Җирдә булып узган бәрелештән соң, аларның берсе карчыгага, икенчесе лачынга әверелеп, сугышны күк йөзендә дәвам итәләр (бүтән дөнья б-н кушылу кебек борынгы мотив). Авыр мизгелләрдә Й.М.гә ул кирәксез никахтан коткарган кыз ярдәмгә килә. Көрәш 7 көн, 7 төн дәвам итә һәм батырның җиңүе б-н тәмамлана. Әсәр әкиятләргә хас чишелеш ала: Й.М. кызны көтүче егеткә кияүгә бирә; көтүче — вәзиргә, ә герой үзе ханга әверелә. Й.М.дә поэтик һәм прозаик элементларның чиратлашып баруы дастанның килеп чыгышы ягыннан борынгы заманнарга каравын күрсәтә. Беренче тапкыр әсәр 1860 елларда бараба татарларыннан язып алына һәм В.В.Радлов тарафыннан нәшер ителә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЙИРТӨШЛЕ́К**, Себер татарларының героик-мифологик әкият-дастаны. Баш герой исеме б-н аталып йөртелә. В.В.*Радлов* дастанның этимологиясен геройның җир асты патшалыгына төшүе б-н бәйли. Хикәяләү ярәшү кебек гомумэпик мотивтан башланып китә. Ханның җиде улы җиде бертуган кызга өйләнергә тели. Хан, өлкән улларын иярътеп, кәләш эзләргә чыгып китә, ә иң кече улын өйдә калдыра. Тиздән җиде кызы булган хан табыла. Аталары кызларның һәрберсенә бирнә биреп, гөрләтеп туй уздыралар. Бары «кияүсез калган» кече җиденче кызлары гына язмышыннан канәгать түгел. Ул, бер сихерче карчыкка килеп, үзенең язмышыннан зарлана. Тегесе исә аңа сабыр булырга һәм батыр кияү өчен җир астыннан кабыргасы астында алмаз кылыч яткан тылсымлы Чалкөйрык атны табып бирергә киңәш итә. Бу очракта сүз борынгы мифологик мотивлар турында бара: батырның тылсымлы кылычын аның булачак хатыны табып бирергә тиеш. Монда матриархат заманнарының кайтавазы чагылыш тапкан булуы ихтимал. Хан алты улы һәм җиде килене б-н кайтыр юлга җыенганда, кызларның атасы аларга тыелган урында ял итәргә тукталмаска куша (тыелган урыннар, әйберләр, эш-гамәлләр һ.б. турында борынгы күзаллауларның чагылышы). Әмма юлчылар кисәтүне онытала һәм *аждаһа* кулына килеп эләгәләр. Котылу өчен хан үзенең барлык улларын, хәтта иң яраткан кече улын да корбан итәргә риза була. Аждаһага кече улы — Й. бирелә, һәм ул җир асты патшалыгына барып эләгә. Анда ул Ак елан кызына өйләнә, күп кенә батырлыклар эшләгәннән соң, икенче тапкыр өйләнеп, җир өстенә әйләнеп кайта. Монда ул яңадан-яңа батырлыклар күрсәтә, өченче тапкыр өйләнә. Туган иленә өч хатыны б-н әйләнеп кайта һәм этисенең тәхетенә утыра. Әсәрнең күп сандагы милли версияләре бар. Дастанның сюжетына якынча 6–8 йөзләрдә нигез салынган булырга тиеш.

Мөстәкыйль дастан буларак, ул 10–13 гасырларда тәмам формалашып бетә һәм күп кенә төрки халыклар арасында киң тарала. Академик В.М.Жирмунский фикеренчә, Й. образының барлыкка килүе 6–14 йөзләргә карый.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЙОГЫ́РТ** (Galium), мареначалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел, сирәк кенә ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 400 дән артык төре билгеле, бөтен җир шары буенча, башлыча, Төньяк ярымшарда таралган. Татарстан терр-ясендә 20 төре үсә. Төньяк Й. (G. boreale), саз Й. (G. palustre), инеш буе Й. (G. rivale), хуш исле Й. (G. odoratum) һ.б. барлык р-ннарда очрый; куе чәчәкле Й. (G. densiflorum), маренасыман Й. (G. rubioides), өч яфраклы Й. (G. trifidum) һ.б. — сирәк очраучы төрләр. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, су буйларында, юл кырыйларында, тау битләрендә үсә. Нигездә, 15–20 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабаклары дүрт кырлы. Яфраклары бөтен, 4–14 әр булып такыяда урнашкан. Чәчәкләре вак, ак яки сары, сабак очында себеркәчле чәчәк төркемендә, яки ярымчатырда, кайвакыт ялгыз урнашкан. Җимеше — коры, вакланучан, берәр орлыклы 2 өлешкә бүленә. Май ахыры — сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Хуш исле Й.ның җир өсте өлеше тәмле исле, составында кумарин бар, чәй, алкогольсез эчемлекләргә үзенчәлекле ис бирү өчен кулланыла, сәламәтләндерү чәйләренең составына керә. Халык медицинасында чын Й. үләненең төнәтмәсе тынычландыру, авыртуны басу, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Яңа җыелган үләннәрнең согы кан туктату үзлегенә ия. Төньяк Й., инеш буе Й., рус Й. (G. ruthenicum), чын Й. — баллы үсемлекләр. Вак Й. (сырлан) (G. aparine) — чүп үлән, чәчүлекләрдә үсә. Өч чәчәкле Й. (G. triflorum) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЙОГЫШЛЫ́ АВЫРУЛА́Р**, авыру тудыручы микроорганизмнар: бактерияләр (бактериозлар), риккетсия (риккетсиоз), вирус, микоплазма (микоплазмоз), хламидия (хламидиоз), спирохета (спирохетоз), гөмбә (микоз), гади төзелешлеләр (протозоозлар), шулай ук паразит суалчаннар (гельминтозлар) китереп чыгара торган авырулар. Авыру чыганагы — авыручы кешеләр генә түгел, сәламәтләнеп килүчеләр һәм бактерия йөртүчеләр дә. Й.а.га төрле дәрәҗәдә йогышландыру, микроорганизмның үзенчәлекле реакциясе, патологик процессның цикллы рәвештә — периодларның эзлекле алмашуы, йогышлы авырудан соң иммунитет барлыкка килү, кайбер йогышлы авыруларның пандемиягә (аеруча куркыныч, карантинлы йогышлы авырулар) кадәр массакүләм эпидемиологик таралуы хас. Зарарлану билгесе авыручыда яисә авыру чыганагын йөртүчедә чагыла. Тормыш өчен куркыныч булган күчле авырулар (шок, бавыр функциясе тукталу, бөерләрнең хәлсезлеге, үпкәләргә һәм баш миенә кан саву һ.б.) кичектергесез ярдәм таләп итәләр. Й.а.ны Л.В.Громашевский бүленеше (1941) буенча — эчәкләр (туры эчәктә йогышлы авырулар), сулыш юллары (аэроген ысул б-н тапшырыла), кан, яисә трансмиссив (буынтыгаяклылар аша йога), тире (контактлы юл б-н йога) авыруларына аералар.

Йогышлы авырулар турында мәгълүматлар борынгы язма истәлекләрдә (һинд Ведалары, Борынгы Кытай һәм Мисыр язмалары, Тәүрат, рус елъязмалары һ.б.) «кизү», «үләт» һ.б. исемнәр б-н бирелгән. Коточкыч эпидемия һәм пандемияләр һәр тарихи чорга хас. Урта гасырларда «кара үлем»нән — чумадан Европа халкының өчтән бер өлеше үлә, 17–18 йөзләрдә чәчәк авыруы һәр ел саен 10 млн. кешегә йога, тимгелле тиф барча сугышларга хас була. 1917–18 елларда грипп пандемиясе («испанка») 20 млн. кешенең гомерен өзә. 19 йөз башында Татарстан җирендә йогышлы эчәк (холера, корсак тифы, паратифлар, дизентерия һ.б.), кан (тимгелле һәм кайтма тиф, бизгәк), сулыш юллары (туберкулёз, кызамык, дифтерия) эпидемияләре еш килеп чыга; тире (корчаңгы, йогышлы гөмбәләр, стафило- һәм стрептодермия, тире ялкынсынуы) авырулары, чәчәк, Себер түләмәсе, трахома, венерик һәм башка авырулар таралган була. Озак вакытлар йогышлы авыруларның сәбәбен һавада агулы матдәләр парлары — миазмалар булу б-н бәйлиләр. 16 йөздә контагияләр турында тәгълимат барлыкка килә (Италия галиме Д.Фракасторо), 1784 тә рус микробиологиясенә нигез салучы Д.С.Самойлович хезмәтләрендә авыру китереп чыгаручыларның бик кечкенә тереклек ияләре икәнлеге күрсәтелә, ул чуманың контагиоз юл б-н таралуын исбатлый. «Й.а.» атамасы 1840 елдан кулланышка керә. Й.а. турында тәгълимат бактериология нык үскән һәм иммунология таныла башлаган чорда үсеш ала. Фәнни ачышлар француз галиме Л.Пастер, немец бактериологы Р.Кох, рус галимнәре И.И.Мечников, П.Эрлих, А.Ф.Гамалей, Г.Н.Минх, Г.Н.Габричевский, Д.И.Ивановский, И.Г.Савченко, Д.К.Заболотный, Л.А.Зильбер һ.б. исемнәр б-н бәйле; Й.а. клиникасы һәм патогенезы тәгълиматын рус галимнәре С.П.Боткин, Е.И.Марциновский, И.Я.Чистович һ.б. үстерә, Ленинград галимнәре — йогышлы авырулар белгечләре (С.С.Златогоров, Г.А.Ивашенцов, М.Д.Тушинский һ.б.) Й.а.ны булдырмау ысулларын эшли.

Россиядә Й.а. буенча беренче кафедралар Мед.-хирургия академиясендә (С.-Петербург, 1898), Мәскәү, Казан ун-тларының мед. ф-тларында, Казан клиника ин-тында (1920 еллар) ачыла. 1930 еллар башында балаларның күпләп авыруы сәбәпле, Россия югары мед. уку йортларында, ш.и. Казан мед. ин-тында (1933) педиатрия ф-тлары ачыла. Балалардагы йогышлы авырулар аерым фән буларак өйрәнелә һәм этиологик билгеләре (таралу характеры, клиник билгеләре, дәвалау һәм профилактика ысуллары) буенча берләштерелә; аларга стафилококк, стрептококк, менингококк йогышлы авырулары, эпидемик паротит, дифтерия, сальмонеллёзлар, эчәк, энтеровирус йогышлы авырулары, чәчәк, кызамык, цитомегаловируслы, герпетик йогышлы авырулары, полиомиелит керә. 1940 елда республика сәламәтлек саклау органнарының профилактик эшләре нәтиҗәсендә балалардагы йогышлы авырулар күләме кими (корсак тифы — 26, кызамык 30% ка, дизентерия — 5, дифтерия — 2,5% ка, скарлатина 3 тапкырга). 1950–60 елларда актив профилактика (иммунлаштыру) үткәрү, яңа дару препаратлары (антибиотиклар, сульфаниламидлар, вируска каршы чаралар һ.б.) куллану, дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге хезмәтен оештыру республика халкының Й.а. б-н авыруын киметә. Әмма 1970–80 елларда Татарстанда дифтерия, күчле респиратор, вируслы эчәк авырулары, төрле грипп, Лайм авыруы, герпетик, цитомегаловирус авырулары, туберкулёз, талпан энцефалиты, геморрагик бизгәк һ.б. Й.а. эпидемияләре нык таралуы теркәлә; диагноз кую кыен булган һәм эпидемиологик катлаулы зоонозлар (лептоспироз, ялган туберкулёз, эчәк иерсиниозы, бореллиоз) куркынычы туа. 20 йөз ахыры — 21 йөз башында ТРда спид (ВИЧ), вируслы парэнтераль гепатит проблемалары актуальләшә. 2008 елда ТРда ВИЧ б-н — 761 кеше, гепатит (А, В һәм С) б-н 15808 кеше исәптә тора, күчле йогышлы эчәк авырулары б-н — 10084 кеше, грипп б-н — 1663, башка күчле йогышлы вируслы авырулар б-н 23392 кеше авырый. 20 йөздә Татарстанда Й.а. б-н көрәшүгә эпидемиология галимнәре һәм йогышлы авырулар белгечләре Б.А.*Вольтер*, Д.М.Петров, Д.С.Черняков, Н.В.Васильева, В.Я.Царёва, А.Е.*Резник*, Н.П.*Кудрявцева*, В.И.*Качурец*, Д.Ш.*Бәширова*, Д.Ш.*Еналеева*, В.Я.Давыдов, А.А.Сорокин, С.Х.Насыйбуллина, А.Д.*Царегородцев*, В.Х.*Фазылов*, В.А.*Анохин*, И.Г.Закиров, Л.М.Малышева, М.С.Фәткулов, Г.В.Краева һ.б. зур өлеш кертәләр.

*Әд.:* Татарская АССР в годы Великой Отечественной войны. К., 1948; Шувалова Е.П. Инфекционные болезни. М., 1995; Инфекционная и паразитарная заболеваемость в Республике Татарстан (1920–1998). К., 1999.

*В.Х.Фазылов, А.А.Анохин.*

**ЙОД ҮЛӘНЕ́** (Epipactis), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 25 кә якын төре билгеле. Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә 3 төре үсә. Куе кызыл Й.ү. (E. atrorubens), киң яфраклы Й.ү. (E. helleborine) яфраклы һәм катнаш якты урманнарда, урман аланнарында, куаклар арасында, саз Й.ү. (E. palustris) сазлыклы болыннарда үсә. Җәенке сабаклы. 30–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы шуышма яки кыска. Яфраклары чиратлашкан, озынча яки йомыркасыман. Чәчәкләре җете кызыл яки яшькелт, шактый эре, иелеп торучан, бөтерелгән чәчәк сабында. Җимеше — тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Күбесенчә орлыктан үрчи. Декоратив үсемлек. Куе кызыл Й.ү. һәм саз Й.ү. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЙОКЛАЧЛА́Р** (Gliridae), кимерүчеләр отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 15 төре билгеле, Евразия һәм Африкада таралганнар.

Татарстан фаунасында 4 төре бар. Зур Й. (Glis glis), бакча Й. (Eliomys quercinus), урман Й. (Dryomys nitedula), чикләвек Й. (Muscardinus avellanarius) респ-када аз санда яши. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарның яхшы үскән куаклыкларында, бакчаларда һәм паркларда яшиләр. Иң зурысы — зур Й., гәүдәсе 13–15 *см*, койрыгы 11–12 *см* озынлыкта, 110–135 *г* авырлыкта; иң кечкенәсе — чикләвек Й., гәүдәсе 9 *см* озынлыктан артмый, койрыгы 7 *см*, авырлыгы 20 *г* га якын. Сырты көрән-кызгылт (бакча Й), көрән-соры (зур Й), охра-җирән (чикләвек Й), соргылт яисә саргылт-кызгылт (урман Й), асты — саргылт-аксыл. Бакча Й.ның борыныннан күзе һәм колагы аша кара тап сузылган. Колаклары кечкенә, ялангач. Аяклары кыска, тырнаклары үткен. Күбесенең койрыгы озын төкләр б-н капланган. Барлык Й. эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Агач куышлары алар өчен яшеренү урыны булып хезмәт итә. Кайвакыт агач ботакларында, куакларда оя ясый яки башка кошларның ояларыннан файдалана. Бакча Й. еш кына йорт корылмаларына оялый. Кышын 7–8 айга сузылган тирән йокыга тала (исеме шуннан), ул вакытны җир асты өннәрендә үткәрә, аларны үзләре казый яки кимерүчеләр һәм сукыр тычканнарның өннәреннән файдалана. Зур Й., берничәсе бергә җыелып, агач куышларында кышлый. Агач һәм куакларның җимеш һәм орлыклары б-н (ш.и. имән чикләвеге, чикләвек, җиләкләр) туклана. Берникадәр хайван азыгын (бөҗәкләр, вак имезүчеләр, кайвакыт кечкенә кошларның йомыркаларын һәм балаларын) ашый. Ана затлар ел саен һәрберсендә 2–8 бала булган 1–2 оя бала китерә. Й. 5 елга якын яши. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЙО́КОВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы (Зөянең уң кушылдыгы) буенда. 2008 елда 292 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 18 йөз — 19 йөзнең 1 яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, мичкә ясау, юкә кабыгыннан төрле әйберләр эшләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Й.да чиркәү-приход мәктәбе, 5 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1865,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Пролей-Каша волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 174 ир-ат; 1859 да — 529, 1897 дә — 874, 1908 дә — 1095, 1920 дә — 1339, 1926 да — 930, 1938 дә — 1052, 1949 да — 907, 1958 дә — 907, 1970 тә — 981, 1979 да — 715, 1989 да — 449, 2002 дә — 356 кеше.

**ЙОКЫ́ ҮЛӘНЕ́** (Pulsatilla), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 35 тән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның субтропик, уртача һәм салкын поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — ачык Й.ү. (P. patens) барлык р-ннарда да очрый. Нарат урманнарында, куаклар арасында, сөзәклекләр буенда үсә. 15–50 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы караңгы көрән төстә, вертикаль. Тамыр яны яфраклары сабаклы, бармаксыман теленмә, яфрак таралгысына җыелган, сабактагылары утырма. Чәчәкләре ялгыз, шәмәхә төстә, киң кыңгыраусыман, чәчәк үзгәгендә күпсанлы ачык сары серкәчләр һәм җимешлекләр урнашкан. Бөтен үсемлек куе кәмешсыман төкчәләр б-н капланган. Җимеше — күп чикләвекчек. Яфраклары күренә башлау б-н, апрель–май аенда чәчәк ата. Җимешләре июньдә өлгерә. Нигездә, орлыктан үрчи. Тире һәм лайлалы эчке тышчаларның ялкынсынуын китереп чыгаручы анемонин матдә булганлыктан, үсемлек агулы. Яфракларында сапонин, каротин, E витамины бар. Халык медицинасында ялкынсынуга каршы һәм кан туктату, тынычландыру чарасы буларак файдаланыла. Й.ү. яфрагыннан ясалган сыгынты бактерицид һәм фунгицид үзлекләргә ия. Декоратив үсемлек буларак үстерелә.

**ЙОЛА́ ҖЫРЛАРЫ́**, *халык җырлары* жанрының бер төре; төрле *татар халык йолаларын* озатып барган һәм уздырган вакытта башкарылалар. Алар борынгы заманнарга барып тоташалар. Календарь һәм гаилә-көнкүреш Й.ж.на бүленәләр. Календарь Й.ж. — кайчандыр аграр-гамәли ихтыяҗлар йогынтысында формалашкан йолалар, төп бәйрәмнәр уздыру б-н бәйле булган. Татар календарь Й.ж.ның текстлары чагыштырмача аз сакланган. Күбесе Нәүрүз һәм Нардуган бәйрәмнәре б-н бәйле. Аларда бәйрәмнең якынлашып килүе турында хәбәр ителә, матур, яхшы теләкләр әйтелә. Төркем-төркем балалар һәм яшүсмерләр, өйдән-өйгә йөреп, тәрәзә яннарында, ишек алларында, йорт эчендә яки өй алдында Й.ж. җырлаганнар һәм бүләккә прәннекләр, конфетлар, тиен акчалар һ.б. алганнар. Кайвакыт башкаручылар саранлык күрсәткән хуҗаларга, шаяртып, янау-ачулану сүзләрен дә җырлый торган булганнар. Календарь Й.ж.на салынган беренчел магик, сакраль мәгънә, вакытлар узу б-н, үз көчен югалта; алар инде архаик җырлардан санала башлый. Кайберләрен хәзерге балалар әдәбиятында да очратырга мөмкин (санамышлар, такмазалар). Гаилә-көнкүреш Й.ж. тормыштагы мөһим вакыйгалар б-н бәйле. Татарларда туу һәм үлүгә карата җыр репертуары булмаган. Халык авыз иҗатына караган башка жанрлар кулланылышта йөргән: санамышлар, такмазалар, такмаклар (бала туганда); такмаклап елаулар, мөнәҗәтләр, бәетләр (мәетне күмгәндә). Болар хәзер дини догалар һәм шәригать күренешләре тарафыннан тулысынча кысрыклап чыгарылган. Гаилә-көнкүреш Й.ж. арасында туй җырлары әһәмиятлеләрдән санала. Аларда кызның туган йортыннан, әти-әнисе янынннан елап китүе һәм аерылышканда елап җырлавы чагылыш таба; ике якта да туганнар арасында бер-беренә мактау сүзләре әйтү, яхшы теләкләр теләү, егет һәм кәләшкә киңәшләр, үгет-нәсыйхәт бирү һ.б. күзәтелә. Туй җырлары туй йоласының бөтен этапларында да — кыз сораудан башлап, кызны кияү йортына алып кергәнче — саклана (туй өстәле артында да, тәрәзә янында да, капка алдында да, бусагадан атлап чыкканда да җырлыйлар). Туй Й.ж.ның эчтәлеге яшьләрнең яңа тормышка аяк баскандагы хис-кичерешләрен генә чагылдырып калмый, ә иҗтимагый шартларны да, татар патриархаль гаилә тәртипләрен дә яктырта. Кайбер элементлар сакраль мәгънәгә дә ия булган: язмышны «юмалау», «кара» көчләрне алдалау яки куркыту һ.б. Й.ж. традицион татар поэтикасы юнәлешендә иҗат ителә. Аларның күпчелеге диалог, риторик сорау, мөрәҗәгать һәм импровизация формасында төзелә. Эчтәлегеннән чыгып, кызу яки озын көйләргә башкарылалар. Й.ж. татарларның барлык этнографик төркемнәренә дә хас. Беренче тапкыр «Татар халык җырлары. Лирик җырлар. Йола җырлары» («Татарские народные песни. Лирические песни. Обрядовые песни», 1965) җыентыгында басылып чыга. Татар Й.ж. 1980 еллар башыннан Ф.С.Баязитова, И.Н.Надиров тарафыннан эзлекле рәвештә өйрәнелеп килә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Урманчеев Ф. Йола фольклоры // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. К., 2005.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЙОЛДЫ́З** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ямаш елгасы (Дала Зәе бассейны) буенда. 2008 елда 46 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 59, 1989 да — 20, 2002 дә — 17 кеше.

**ЙОЛДЫ́З** посёлогы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 26 *км* көньяктарак, Шыя елгасы бассейнында. 2008 елда 56 кеше (руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1930–40 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1989 да — 133, 2002 дә — 74 кеше.

**ЙОЛДЫ́З** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 68 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2008 елда 140 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. 1920 елларда Чәчәкле (элеккеге Яңа Бәрән) авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1992 нең 5 июненнән Йолдыз исемен йөртә. Оештырылган көннән ТАССРның Спас кантоны Кузнечиха волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1926 да — 86, 1938 дә — 127, 1949 да — 143, 1958 дә — 134, 1970 тә — 267, 1979 да — 209, 1989 да — 135, 2002 дә — 141 кеше.

**ЙОЛДЫ́З** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 5 *км* көнчыгыштарак урнаш-

кан. 2008 елда 939 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 53%, руслар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1925 тә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Галактионов волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1989 да — 698, 2002 дә — 1046 кеше.

**ЙОЛДЫ́З** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 60 *км* көньяктарак, Мәми елгасы буенда. 2008 елда 11 кеше (татарлар) яши. 1925 тә Кырлыбаш һәм Казеево (Кази) авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостена керә. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 сентябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 266, 1989 да — 43, 2002 дә — 17 кеше.

**«ЙОЛДЫ́З»**, Чистай р-нындагы совхоз. 1976 елда «Стахановчы» (1941 дә оештырылган) с-зы җирлегендә оештырыла. Үзәк утары — «Йолдыз» с-зы посёлогы. Эшләүчеләр саны якынча 250 кеше (2000). Файдалану җирләренең мәйданы 5033 *га*. Төп тармак — мөгезле эре терлек симертү, ярдәмче тармаклар — сөт, бөртекле ашлык, терлек азыгы җитештерү. 100 *га* файдалану җирләренә 37,1 *ц* ит, 101,5 *ц* сөт җитештерелә; бөртекле ашлыкның уңышы 1 *га* дан 23,66 *ц* (1999) тәшкил итә, 1 савым сыердан елына уртача 3060 *кг* сөт алына. Хуҗалык җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Күчмә Кызыл Байраклары (1972, 1974, 1978, 1980, 1981) һәм ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның дипломнары (1972, 1979, 1984, 1987, 1988), СССР ВДНХсының Мактау дипломнары (1974, 1979) б-н бүләкләнә. 2000 дә хуҗалык шул ук исемдәге җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә. 2006 дан «Йолдыз» агрофирмасы» «Чиста кыр» агросәнәгать компаниясе ҖЧҖ составында. Җитәкчеләр арасында хуҗалык үсешенә иң зур өлеш кертүче — Н.А.*Савельев* (1971–2000).

**«ЙОЛДЫ́З»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, 1900 саны чыга. И.Н.Харитонов, бертуган Кәримовлар, «Өмид» басмаханәләрендә басыла. «Й.» башта атнага бер, аннары 2–3 мәртәбә, алга таба көн дә чыга башлый. Газетаның редакция тарафыннан билгеләнгән юнәлеше — «Нинди дә булса сәяси партия мәнфәгатьләреннән азат булу». Нашире һәм мөхәррире — Ә.*Максуди*, сәркәтибе — Г.*Камал*. Газетаның даими авторлары: С.Максуди, Җ.Вәлиди, Һ.Атласи, Г.Баттал, Г.Лотфи, Ш.Әхмәдиев һ.б. Анда Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов, К.Бәкри һ.б.ның әдәби әсәрләре һәм тәнкыйть мәкаләләре басыла. Газета һәрдаим эчке һәм тышкы сәясәт яңалыкларын, бигрәк тә мөселманнарга караганнарын яктырта, Россия һәм мөселман илләре тарихы турындагы фәнни-популяр эчтәлектәге мәкаләләр, китапларга күзәтү, театр репертуарларын бастыра. Россиянең төрле төбәкләрендә генә түгел, аннан читтә дә редакциянең үз хәбәрчеләре була. Балканда барган вакыйгалар вакытында Г.Камал Төркиягә җибәрелә, ул андагы хәлләр,



«Йолдыз» газетасы.

рух турында, ватандашлар хакында мәгълүматлар биреп бара. «Й.»ның Балкандагы сугышка карата фикере күп кенә татар басмаларыннан аерылып тора, шуңа да аны «Тәрҗеман», «Вакыт» г-талары тәнкыйтьләп чыга. Фактларны бозып күрсәтүдә гаепли. Редакция үз укучыларын Дәүләт Думасында карала торган законнарның төп проектлары б-н таныштыра, аларга үз аңлатмаларын бирә; мөселман кандидатларын сайлау кампанияләрен оештыруга һәм бу эшнең барышына аеруча игътибар итә. Утырыштан репортажларны, депутатлар чыгышы текстларын, 1907–12 еллардагы аналитик мәкаләләрне, кагыйдә буларак, С.Максуди әзерли. Аның мөселман фракцияләре, асылда, депутатлар эшчәнлеге турында 2 нче Дәүләт Думасы таратылганнан соң басылган «Хисапнамәләре» кызыклы. Газета битләрендә милләтләр арасындагы тигез хокуклылык, милли үзаңны үстерү мәсьәләләре яктыртыла. Мәкаләләрнең темасы иҗтимагый-сәяси тормыштагы үзгәрешләр б-н бәйле була. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, хәрби хәрәкәтләр, сугыш барышы, армияне тәэмин итүне оештыру һ.б. турында хәбәр итеп тора. Соңрак сугыш шартларында хуҗалык-икътисад мәсьәләләрен анализлауга күбрәк игътибар итә башлый. Мәгариф, укыту, тәрбия мәсьәләләре даими рәвештә яктыртыла, укыту программалары һәм дәреслекләргә анализ бирелә. Тел, орфография проблемаларын яктырту «Й.» ның абруен күтәрә. Аңарда яңа басмаларга һәм әдәби әсәрләргә даими күзәтү ясала. «Й.» башка татар, рус, чит ил газеталары материалларыннан да файдалана; «Речь», «Новое время», «Русское слово», «Земщина» һ.б. газеталар б-н сәяси бәхәскә керә. «Й.» революциягә кадәрге татар басмалары арасында иң абруйлы, тотрыклы газеталарның берсе санала, татарлар яшәгән күп кенә Россия төбәкләре һәм шәһәрләрендә тарала.

*Әд.:* Гаффарова Ф.Ю. Әхмәдһади Максуди. К., 2002.

**ЙОЛДЫЗА́К** (Stellaria), канәферчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 120 гә якын төре билгеле, бөтен җир шарында таралган. ТР терр-ясендә 9 төре очрый. Аеруча киң таралган кыяклы Й. (S. graminea), каты яфраклы Й. (S. holostea) — җирдән үрмәләп үсүчән күпьеллык үсемлекләр һәм юеш Й. (S. media) — берьеллык үсемлек. Респ-ка терр-ясеннән Бунге Й. (S. bungeana) ареалының көнбатыш чиге үтә.


Урманнарда, куаклар арасында, кырда, сазлыклы болыннарда, елга ярларында, инеш буйларында үсә. 5–45 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары овал яки ланцетсыман. Чәчәкләре вак, ак төстә, таҗ яфракчыклары икегә аерылган яки уемлы йомшак ярымчатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — тартмачык. Май–августта чәчәк ата, орлыктан һәм шушыма тамырчадан үрчи. Халык медицинасында баткаклык Й. (S. alsine) һәм юеш Й. үләннәре тонәтмәсе бавыр һәм үт куыгы авыруларын дәвалауда кулланыла. Юеш Й. — юк ителүе кыен чүп үлән, башлыча, сызма культуралар басуын чүпли. Бер үсемлек туфракта шыту сәләтен 10 елдан артык саклый торган 25 меңгә кадәр орлык бирә. Көрәш чаралары: иртә яздан туфрак өстен эшкәртү, тырмалау, тирән итеп сөрү, үләнле чәчү әйләнеше кертү. Үләне һәм орлыгы кошларга азык булып тора. Бунге Й., каты яфраклы Й. — баллы. Калын яфраклы Й. (S. crassifolia), каты яфраклы Й., имәнсәр Й. (S. nemorum), саз Й. (S. palustris) — агулы үсемлек. Баткаклык Й., йөнтәс кәсәле Й. (S. hebecalyx), Бунге Й., калын яфраклы Й. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Юеш йолдызак.

**ЙОЛДЫЗЛА́Р**, эчке өлешләрендә термотөш реакцияләре барганда хасил булган энергия хисабына яктыртучы кайнар газдан торган күк җисемнәре. Җиргә иң якын йолдыз — Кояш. Башка Й. Җирдән шактый ераклыкларда урнашкан, хәтта иң көчле телескоптан да алар төрле төстә яктыртучан нокталар булып кына күренә. Гади күз б-н күк йөзенең ярымсферасында — 3 меңгә якын, телескоп ярдәмендә, нигездә, безнең *Галактикада* урнашкан йөзләрчә мең йолдызны күрергә мөмкин. Аларның Галактикадагы гомуми саны 100 млрд. чамасы. Й.ның төп параметрлары: яктыртучанлылыгы (йолдыз өслегеннән нурланган тулы энергия), массасы, радиусы һәм химик составы. Й.ның массасы 0,08 дән 100 Кояш массасы чикләрендә исәпләнә, радиуслары Кояш радиусыннан берничә мәртәбә кечкенә һәм 1000 тапкыр зуррак та булырга мөмкин. Й. өслегендәге темп-ра, башлыча, 2–5 мең К арасында. Массалары зуррак Й.ның радиуслары да зуррак, өслектәге темп-расының да югарырак булуы исбатланган. Й. массасының өчтән ике өлешен — во-

дород, өчтән берен гелий тәшкил итә, авыр химик элементлар 1% тан артык түгел. Й.ның үзенчәлеге турындагы барлык мәгълүмат аларның нурланышларын күзәтү һәм анализлау нәтиҗәләреннән чыгып алына. Мәгълүм булганча, Й. водородка бай газ-тузан болытларының тартылу көче тәэсирендә кысылуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Конденсация үзәгендә югары тыгызлыкка һәм темп-рага (10–12 млн. градус чамасы) җиткәндә, водородны гелийга әверелдерүче термотөш реакцияләре башлана. Яңа йолдыз барлыкка килә, аның гомеренең 90%ы шул этапта уза. Й.ның яшәү вакыты аларның массасына бәйле. Иң зур массалы Й. (Кояш массасыннан 8 тапкырга артыграк) берничә млн. ел яши һәм эволюциясе ахырында һәлакәткә дучар була: я үтә яңа йолдыз булып күренеп




Орион йолдызлыгы тирәсе. Фоторәсем Казан ун-тының В.П.Энгельгард исемендәге астрономия обсерваториясендә төшерелгән. 1948.

шартлый һәм шуның нәтиҗәсендә андагы матдәләрнең күпчелеге галәм киңлегенә сибелә, ә калдыклары нейтрон йолдызга (үтә тыгыз матдәдән гыйбарәт булган 10–15 *км* радиуслы компактлы объект) әверелә, я йолдызның катастрофик кысылышы «кара тишек» (классик ысуллар ярдәмендә күзәтеп булмый торган нәгадәти гипотетик объект) хасил булуга китерә. Массалары өч Кояш массасыннан кимрәк Й.ның эволюциясе (безнең Кояш та шуларга керә) тыныч кына уза. Төштәге водород янып беткәннән соң, алар компактлы тыгыз объектларга — гелийлы ак кәрлә Й.га әвереләләр, суыну хисабына яктырталар, аларның үлчәмнәре Җир зурлыгы б-н чагыштырырлык дәрәҗәдә була. Кояш массасы зурлыгындагы Й. 10 млрд. ел чамасы яши. Шундый массалы Й.дагы водород һәм аннары төштәге гелий янып беткәннән соң, аларның өслегеннән матдәләр ыргылып төшәргә мөмкин. Шунда алар планетар томанлыклар — бер яки берничә киңәючән сүрү б-н әйләндереп алынган кайнар Й. буларак күзәтелә. Андый Й. углерод-кислородлы ак кәрлә Й. сыйфатында яшәүдән туктыйлар. Ялгыз Й.ның (тотрыклы Й.) водород яну стадиясендә физик сыйфатламалары үзгәрми диярлек. Алмаш һәм тотрыксыз Й. да бар, аларның яктыртучанлыгы периодик яки тәртипсез рәвештә бер тәүлектән алып уннарча һәм йөзләрчә ел саен үзгәреп тора. Яктыртучанлык үзгәрүнең сәбәбе — Й.ның ике төрлелеге яки физик үзгәрүчәнлеге, ялгыз Й.ның пульсацияләре һәм куш системаларда тәэсирлечә тәэсир итешүе б-н аңлатыла. Казан галимнәре Й.ны Казанда беренче шәһәр обсерваториясе төзелгәннән бирле күзәтәләр (1814). 19 йөздә галимнәрдән И.М.Симонов, М.В.Ляпунов, М.А.Ковальский, Д.И.Дубяго күк йөзендәге яктырткычларның координатларын билгеләү һәм фәзаи хәрәкәтләрен өйрәнү максаты б-н күзәтүләр уздыралар. 1920 еллардан Й.ның физик сыйфатламаларын өйрәнү Д.Я.Мартынов б-н А.Д.Дубягоның куш Й.ның яктыртучанлыгы үзгәрүен күзәтүләреннән башлана. В.А.Крат тарафыннан тыгыз куш системалардагы компонентларның фигураларын тикшерү эшләре башкарыла (1937). М.И.Лавров сайлап алынган куш Й.ның үлчәмнәрен һәм массаларын билгели (1976). Н.А.Сәхибуллин һәм аның шәкертләре тарафыннан Й.ның спектрын анализлау вакытында Й.ның өске катламнарындагы темп-ра, басым, тыгызлык һәм химик элементларның таралышы турында алынган мәгълүматлар (1991) Й. эволюциясе һәм Галактикадагы нуклеосинтез тарихы хакында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Релятивистик компонентлы куш системалардагы физик процесслар, Й. тирәли аккрецион дискларның структурасы һәм нурланышы өйрәнелә. РТТ-150 оптик телескобы ярдәмендә Казан галимнәре катнашында 1998 елдан якын Галәмдә актив үзәкле уннан артык яңа Галактика, компакт объектлар — ак кәрләләр һәм нейтрон йолдызлары булган берничә яңа тыгыз куш йолдызлар системасы, ш.у. безнең Галактикадагы аккрецияләнүче кара тишекле SS433 микроквазарының яңа оптик үзлекләре ачыла.

*Әд.:* Физика космоса: Маленькая энцикл. М., 1986. *Л.И.Машонкина.*

**ЙОМРАННА́Р** (Citellus), тиенсыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 38 төре билгеле, Төньяк ярымшарның ачык ландшафтында таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Тимгелле Й. (C. suslicus) Идел алдында, җирән яки зур Й. (C. major) Кама аръягында һәм Идел алдында очрый. Далаланган сөзәклекләрдә, көтүлек җирләрдә, болыннарда, юл кырыйларында яши. Гәүдәсе



Тимгелле йомран.

14–40 *см*, койрыгы — 4–20 *см* озынлыкта, 1 *кг* га кадәр авырлыкта. Арткы очлыклары алгыларына караганда берникадәр озынрак. Колаклары күренми диярлек. Койрыгы йонтәс. Тимгелле Й.ның сырты ачык таплар сибелгән соры-коңгырт яки көрән төстә. Җирән Й.ның сырты саргылт-соры, ян-яклары җирән, яңакларында җирән яки көрән таплар ачык күренә. Аларның йоны кышка йомшак һәм куе була. Колонияләргә тупланып, үзләре казыган өннәрдә яшиләр. Көндез активлар. Суыклар башлану б-н, кышкы йокыга талалар. Куркыныч килүне сизү б-н, өннәре янына «баганадай» басалар һәм хәвеф сигналы бирәләр (ачы итеп сызгыралар). Кышкы йокыдан уяну б-н, парлашу башлана, йөклелек чоры 25–30 көн дәвам итә. Бер оядa 7–9 бала була. Үсемлекләрнең җир өсте һәм җир асты өлешләре, кайвакыт бөҗәкләр б-н тукланалар. Бөртекле ашлыкка зыян китерәләр, күп кенә авыру тудыручыларның табигый күчерүчеләре. 3–4 ел яшиләр. Тимгелле Й. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЙОМРЫ́ СУАЛЧАННА́Р**, к. *Нематодлар.*

**ЙОМША́К ТӨКЛӘ́Ч** (Myosoton), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бердәнбер төре — су Й.т. (M. aquaticum) Евразиянең уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә ара-тирә барлык р-ннарда да очрый. Сулык ярлары буенда, яшелчә бакчаларында, чүплекләрдә, юл кырыйларында үсә. 30–70 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы үрмәле, озын. Үсемлекнең аскы өлеше шәрә, ялангач, өске өлеше төкле. Яфраклары йомшак, йөрәксыман яки озынча түгәрәк, очланган. Чәчәкләре ак, хуш исле, таҗ яфракчыгы икегә аерылган, җәенке ярымчатырда урнашалар. Җимеше — йомыркасыман тартмачык. Орлыклары кызгылт-көрән, түгәрәк бөресыман, яссы, вак чәнечкеле. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Терлек азыгы буларак кулланыла.



**ЙОМШАКТӘНЛЕЛӘ́Р**, к. *Моллюсклар.*

**ЙОМШАКТӘННӘ́Р** (Contharidae), төрле азык б-н туклануучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Гәүдә озынлыгы 15 *мм* га кадәр, яссыланган, төкчәләр б-н капланган. Гәүдәнең тышкы капламы йомшак (исеме шуннан). Төсе кара, кызгылт-көрән яки металлсыман яшел. Кайбер төрләрнең ана затларында өске канатлары юк. Мыеклары җепсыман яки пычкысыман. 3 меңнән артык төре билгеле, РФдә — 200 гә якын, Татарстан терр-ясендә — 100 ләп. Аеруча коңгырт Й. (Contharis fusca) еш очрый. Гәүдә озынлыгы 11–15 *мм*, кара төстә; башының алгы өлеше, мыек урыны һәм корсак өлеше сары-кызыл; гадәттә, аркасының ян кыры уртасында кара тап бар; аяклары тоташ кара. Коңгызлар җәй башында күренә башлый, чәчәкләрдә еш очрый; кортлары туфракта, сирәк кенә агач кайрысы астында яшиләр. Ерткычлар. Бөҗәкләр б-н тукланалар. Корбаннарын казналыклары б-н тотып алалар да тукымаларны эретә торган ферментлар кертәләр, аннары сыек азыкны суыралар. Элек бу семьялыкка *утлы коңгызлар* да кертелгән.

**ЙОМЫ́К КҮЛ**, к. *Кече Тирәнкүл.*

**ЙОМЫШЛЫ́ ТАТАРЛА́Р**, 15–18 йөзләрдә Россиядә дәүләт хезмәтен башкаручы рус милләтеннән булмаган кешеләр катлавы.

Й.т. катлавы Василий II (1425–62) һәм Иван III (1462–1505) идарә иткән чорда барлыкка килә. Татар ханлыкларының Мәскәү яклы аксөякләре бөек Мәскәү кенәзенә хезмәткә ялланалар, аларга утарлар бирелә. Й.т. еш кына, христиан динен кабул итеп, Россия дворяннары б-н кушылып йотылалар. 15 йөз уртасыннан Й.т. Касыйм ханлыгына күчеп утыра башлыйлар, аларны рус кенәзләре Казан ханлыгына каршы көрәштә файдалана. Ханлык яулап алынгач, *ясаклы кешеләрне* административ, хәрби яки дипломатия хезмәте башкару шарты б-н үз биләмәләрендә төпләндереп калдыру нәтиҗәсендә, Й.т. катлавын булдыру киң колач ала. Әлеге сәясәт рус хөкүмәте өчен җирле халык арасыннан социаль терәк әзерләүне күздә тота. Й.т. тәрҗемәчеләр, күчереп язучылар, илчеләр булып хезмәт итәләр, хәрби яуларда, дәүләт чикләрен саклауда катнашалар. Ливон сугышы вакытында (1558–83) Й.т. отрядлары Смоленск, Полоцк, Могилёв һ.б. шәһәрләр тирәсендә сугышалар. Поляк һәм швед гаскәрләренә каршы көрәштә катнашып, Й.т. Болгавыр заманда сизелерлек роль уйныйлар. Аларга хезмәтләре өчен җир, акча һәм ашлык бирелә. 16 йөзнең икенче яртысы — 17 йөздә Й.т.ның күпчелеге дәүләт хезмәтенә төрле катлау кешеләре арасыннан алынган йомышлылар булып саналалар. Шуннан соң йомышлылар өстен сыйныф составына керәләр һәм ясак түләүдән азат ителәләр. Әмма икътисади хәлләренә карап, йомышлылар шактый югары категориядәге йомышлы кешеләр («ватанга хезмәт итүче» йомышлылар, йомышлы морзалар) б-н ясаклы кешеләр арасында урталыкны билиләр. 18 йөз башында Й.т.ның хәле үзгәрә. Пётр I идарә иткән заманда — 1713 һәм 1715 елларда — Й.т.ның биләүчелек хокукларын чикләүче фәрманнар кабул ителә (к. *Патша Пётр I фәрманы* (1713 ел, 3 нояб.), *Патша Пётр I фәрманы* (1715 ел, 12 июнь)). Аларда чукынмаган татарлардан утарларны, биләмәләрне, крепостной крәстияннәрне тартып алу күздә тотыла. 1718 елда Й.т. кораблар төзү өчен агач кисү, эшкәртү һәм урманнан агач чыгару эшләренә яздырыла (к. *Лашманнар*). Соңрак Й.т. җан башыннан салым түләүчеләр хәленә төшерелә һәм *дәүләт крәстияннәре* төркемнәренең берсен тәшкил итәләр.

*Әд.:* Алишев С.Х.Социальная эволюция служилых татар во второй половине 16–18 вв. // Исследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода. К., 1984; Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002.

*И.Л.Измайлов, Д.Г.Мостафина.*

**ЙОН ТЕТҮ҆ ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ́**, йон эшкәртү (тетү) б-н бәйле һөнәрчелек. Йонны иләктә тимерчыбык һ.б. төрле кереш б-н тетәләр. Тимерчыбык йон өстендә тирбәлә, йонның тупас өлешләре читкә алып ташлана, тузан һәм чүп-чар иләктән төшә. Тәҗрибәле оста бер көнгә 1,5–2 пот йон тетә. 20 йөз башында йон тетү машиналары кулланыла башлый. Йон тетү сезоны көз көне, а.х. эшләре тәмамлангач башлана. Эш эзләп, йон тетүчеләр 2–3 кеше бергәләп тирә-як авылларга, күрше өяз һәм губерналарга баралар. Әдәбиятта йон тетүчеләрнең Казан өязеннән — Вятка губернасына, Чистай өязеннән — Самарага, Мамадыш өязеннән Вятка һәм Уфа губерналарына барулары турында искәртелә. 1880 еллар ахырында Й.т.һ. б-н шөгыльләнүчеләр Казан губернасында — 876, ш.и. Казан өязендә — 249, Мамадыш өязендә — 168, Спас өязендә — 158, Чистай өязендә — 133, Лаеш өязендә 101 кеше исәпләнә. Й.т.һ.нең төп продукциясе — киез итек, киез, эшләпә, тула җитештерү өчен әзерләнгән йон.

*Әд.:* Материалы для исследования промыслов населения Казанской губернии. К., 1887; Кустарные промыслы Казанской губернии. К., 1903. Вып. 7; Мелкая промышленность Казанской губернии. К., 1911.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЙОНКОЯ́Р**, сарык канәчкече (Melophagus ovinus), канәчкечләр семьялыгыннан канатсыз чебен. Көнбатыш Европадан Кытайга кадәр таралган, Америка һәм Австралиягә китерелгән. Россиянең Көньяк Европа өлешендә, Себердә (Ерак Көнчыгышка кадәр) күренә; Татарстан терр-ясендә сирәк очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 5–7 *мм*, яссы, тышкы билгесе буенча үрмәкүчне хәтерләтә, төкчәләр б-н капланган; борыны озын, нечкә, күзләре кечкенә; күкрәгенең арты шактый тар; бызылдавыклары юк; арткы очы батынкы, корсагы киңәйгән; төсе көрән, аскы ягы аксыл. Сарыкларда, сирәк кенә кәҗәләрдә паразитлык итә. Чебен салган личинка озынча, ак, озынлыгы 4 *мм* га якын; хайванның йонына беркетелә, шунда курчаклана. Елга 6–10 буын бирә. Сарыкларның канын суыра торган олы чебеннәре зыян китерә; сарыклар алар тешләп кычыттырган урыннарын еш кашыганлыктан, йоннары бозыла. Аеруча яшь бәрәннәр зыян күрә, үләргә дә мөмкиннәр. Й. кан паразитын (Tripanosoma melophagyum) күчерергә мөмкин.

**ЙОНЧА́** (Poa), кыяклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 300 дән артык төре билгеле, ике ярымшарның да салкын һәм уртача поясларында очрый. ТР терр-ясендә 9 төре: тар яфраклы Й. (P. angustifolia), урман Й.сы (P. nemoralis), саз Й.сы (P. palustris), болын Й.сы (P. pratensis) һ.б. үсә. Киң таралганнар. Болыннарда, куаклар арасында, сулык ярлары буенда, юл кырыйларында үсә. 5–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек, шуышма җир асты бәбәкләре яки алардан башка гына чирәмлек хасил итә. Яфраклары тар — кыяксыман. Чәчәк төркеме — җәенке себеркәчле, башакчыклары вак, йомыркасыман яки эллиптик, 2–5 чәчәкле. Җимеше — озынча бөртекчә. Май–августта чәчәк ата. Июнь–сентябрьдә җимешләре өлгерә. Орлыктан үрчи. Терлек үләне (1 *га* дан 25–28 *ц* печән алына). Болын Й.сы культуралы көтүлек һәм газон үләне буларак файдаланыла. Суыкка һәм корылыкка чыдам үсемлек. Суганчалы Й. (P. bulbosa), сирәк Й. (P. remota) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЙОНЧАЛЫЛА́Р**, к. *Кыяклылар*.

**ЙОРТ** (төрки.), төрки халыкларда биләмә, торак, яшәү урыны, ил, җир-су. 14 йөзнең 2 нче яртысына кадәр кабилә күченеп йөргән терр-я. 14 йөз ахыры — 15 йөз башында феодалның хан урдасындагы урыны, феодал яки хан станы урнашкан җир. Рус чыганакларында Монгол империясе һәм Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләрнең терр-яләре.

*Әд.:* Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

**ЙОРТ КАЗЛАРЫ́**, үрдәкләр семьялыгындагы кошлар. Башка төр а.х. кошлары б-н чагыштырганда соңрак (34–44 атна эчендә) җитлегәләр. Й.к. сатуга үстерелгән хуҗалыкларда 3–4 ел, нәсел үрчетү хуҗалыкларында 5 ел асрала. Көтүдәге җенси нисбәт: 1 ата казга — 3–4 ана каз. Бер ана каз 25–50 һәм артыграк йомырка сала, бу күрсәткеч 3 яшькә кадәр арта бара. Үсеп җиткән ата казның авырлыгы 5–8, ана казның 4–7 *кг* га җитә. Иткә үстерелгән яшь казларны 3,5–4,5 *кг* га кадәр үстереп, 9 атналык булгач суялар. ТРда венгр, горький, кытай, кубан, линда һәм җирле токымнар үрчетелә. Линда токымы иң уңышлылардан санала, тиз җитлегүе, күп йомырка салуы, тиз симерүе һәм җирле шартларга яраклаша алуы б-н үзенчәлекле. Питрәч р-ны «Карповка» хуҗалыгы, ш.у. Азнакай, Баулы, Балтач, Кукмара, Лаеш, Балык Бистәсе һ.б. р-ннардагы хуҗалыкларда Й.к. үрчетүгә күбрәк игътибар бирелә.

*Әд.:* Садеев П.Ф. Промышленное гусеводство. М., 1982; Боголюбский С.И. Селекция сельскохозяйственной птицы. М., 1981.

*Ә.Х.Фазылҗанов, М.Ш.Алиев, Ә.Р.Вәлиев.*

**ЙОРТ ТАВЫКЛАРЫ́**, тавыклар отрядындагы кошлар. Көньяк һәм Көнчыгыш Һиндстанда, Һинд-Кытайда, Малайя архипелагы утрауларында таралган банкив кыргый тавыкларыннан килеп чыкканнар. Продукция бирү юнәлеше буенча аларны йомырка һәм ит тавыкларына бүләләр. ТРда, башлыча, йомырка салу юнәлешендәге бөгелмә, хайсекс, ломанн, родонит һәм ит җитештерү юнәлешендәге гибро, хаббард, кобб токымнары (кросслары) үрчетелә. Респ-када йомырка җитештерү буенча иң эре пр-тиеләр — «Птицевод» дәүләт токымлы кошчылык з-ды, «Лаишевский» кошчылык комплексы, «Юбилейное» а.х. пр-тиесе» ААҖ, «Лениногорск кошчылык фабрикасы» ҖЧҖ, «Чистопольская» ААҖ. 2010 елның 1 гыйнварына аларда 3,7 млн. тавык исәпләнә, барлыгы 680 млн. данә йомырка әзерләнә, һәр тавыктан 282–328 данә йомырка җыеп алына. Ит җитештерүче иң эре пр-тиеләр: «Чаллы-Бройлер» ҖЧҖ, «Казанская» кошчылык ф-касы ААҖ, «Ак Барс-Питрәч» агрофирмасы, «Ак Барс» кошчылык комплексы (соңгы икесе бераздан берләшәләр). 2010 ның 1 гыйнварына аларда 6 млн.нан артык тавык исәпләнә, 102,6 мең *т* ит җитештерелә; бройлерларның уртача тәүлеклек артымы 51,2 *г* тәшкил итә. Шәхси хуҗалыкларда кошчылык үсешен тәэмин итү б-н 18 дән артык инкубатор-кошчылык станцияләре шөгыльләнә, ел саен 4 млн. лап чебеш сатыла. «Татптицепром» ААҖ пр-тиеләрендә 2010 ның 1 гыйнварына 9,8 млн. тавык исәпләнә, 712,7 млн. данә (һәр тавыктан 308 данә) йомырка җыеп алына, 108,1 мең *т* ит җитештерелә. 2009 да

респ-када, шәхси хуҗалыкларны да кертеп, 12,5 млн. тавык исәпләнә, 127 мең *т* ит, 1 млрд.данәдән артык йомырка җитештерелә.

*Ә.Х.Фазылҗанов, М.Ш.Алиев, Ә.Р.Вәлиев.*

**ЙОСЫ́ПОВ** Артур Маяк улы (13.2.1960, Мәскәү), спортчы, тренер (шахмат), халыкара гроссмейстер (1980), СССРның атказ. спорт остасы (1987), Халыкара шахмат федерациясенең атказ. тренеры (2005). Спорт б-н 1966 елда шөгыльләнә башлый, М.М.Ботвинник исем. шахмат мәктәбендә тәрбияләнә, тренерлары (төрле елларда): М.И.Дворецкий, М.М.Юдович. Дөнья чемпионатларында (1977, яшүсмерләр арасында; 1985), Европа (1980, 1983), дөнья яшьләр чемпионатларында (1980–81, 1983, СССР җыелма командасы составында), Бөтендөнья шахмат олимпиадаларында (1982, 1984, 1986, 1988, 1990, СССР җыелма командасы составында), дөньяның сайлап алынган шахматчылары командасы матчында (1984) җиңүче, СССР (1979), дөнья чемпионатларында (1978, яшүсмерләр арасында) көмеш медаль ала. 1989–92 елларда Йосыпов–Дворецкий шахмат мәктәбе эшли. Анда тәрбияләнүчеләр арасында халыкара гроссмейстерлар В.Звягинцев, С.Моисеев, П.Свидлер һ.б. бар. Медаль б-н бүләкләнә. 1992 дән Германиядә яши.

**ЙОСЫ́ПОВ** Билал Мөгтәсим улы (15.12.1904, Уфа губ., Бәләбәй өязе Иске Морас а. — 26.2.1999, Казан), геолог-нефтьче, геол.-минер. фән. д-ры (1959), проф. (1969), ТАССР, БАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1964, 1969, 1974). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1935), Татгеолтрестта эшли (1942 елдан управляющие). 1944 тән ТАССР ХКС каршындагы ягулык сәнәгате идарәсе башлыгы урынбасары, 1946 дан СССР ФАнең Казан ф-лы Геология ин-тының гыйльми секретаре (1947 дән нефть һәм газ чыганаклары геологиясе лаб-ясе мөдире), 1967 дән Һиндстанда БМОның нефть буенча эксперты, 1968 дән СССР ФА Башкорт ф-лының Геология ин-ты директоры (1974–92 дә консультанты). Хезмәтләре файдалы казылмалар чыганаклары геологиясенә, тектоникага, гидрогеологиягә, инженерлык геологиясенә, карст процессларына карый. Нефть турында татар телендә беренче популяр брошюралар авторы. Нефть барлыкка килү һәм аның чыганаклары хасил булуның яңа концепциясен эшләүдә катнаша, Җир кабыгында метаносфера дип аталучы өлешне аерып күрсәтә. Аның тикшеренүләре нефть (Шөгер, Ромашкино һ.б.), «Иж» минераль суы, ш.у. ТР һәм күрше респ-каларда руда булмаган файдалы казылмалар, җир асты төче суларының чыганакларын ачуда ярдәм итә. Удмуртиядә ташкүмер, Мари Респ-касында кәгазь сәнәгате һәм төзелеш өчен известь куллану, Казанда грунт сулары биеклеген киметү буенча һ.б. күрсәтмә-тәкъдимнәр эшли. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Тектоника // Труды КФАН СССР. Сер. геол. 1960. Вып. 5, т. 1; Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1970 (автордаш).

*Әд.:* Малов А.М. Б.М. Юсупов. К., 2006.

**ЙОСЫ́ПОВ** Габдулла Фәтхулла улы (1899, Оренбург губ., Верхнеуральск өязе Бурилe а. — 24.10.1969, Казан), режиссёр. Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң, Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Сталинград (хәзерге Волгоград) өлкәсе Камышин шәһәрләренең татар һәм рус театрларында эшли. 1946 елда *Республика күчмә театрына* баш режиссёр итеп билгеләнә. Тәҗрибәле, киң белемле кешенең билгеләнүе коллективның иҗади үсешенә уңай йогынты ясый. Театрда Й. М.Әмирнең «Тормыш җыры», Г.Насрыйның «Күңел дәфтәре», М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар», А.Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» («Бедность не порок»), А.Корнейчукның «Украина далаларында» («В степях Украины») һ.б. пьесаларын сәхнәләштерә.

1948 дән Й.ны Татар акад. театрына баш режиссёр итеп күчерәләр. Сәнгатьтә реалистик юнәлеш тарафдары буларак, Й. пьесаның, һәр образның төгәл логикасын аңлый, әсәрдәге хәрәкәтләрне үтәли күрә. Актёрлар б-н эшләгәндә Й. әсәрне сәхнәгә куючы гына түгел, алар өчен чын педагог та була. Й. эшләгән чорда театрга А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Ш.Хөсәенов, Ю.Әминев кебек яшь драматурглар җәлеп ителә. Ул үз чорының драма әсәрләренә дә, классик һәм тәрҗемә әсәрләргә дә бик еш мөрәҗәгать итә: «Чын мәхәббәт», «Бишбүләк» (Т.Гыйззәт), «Әбли авылы» (Ф.Хөсни), «Умырзаялар» (Ю.Әминев), «Көзге ачы җилләрдә» (А.Гыйләҗев), «Кыз урлау» (М.Кәрим), «Икенче фронт артында» («За вторым фронтом», В.Собко), «38 нче параллель» («38-я параллель», Тхай-Дэн-Чун), «Жорж Данден» (Мольер), «Ефәк сүзәнә» («Шелковое сюзане», А.Каххар), «Кара йөзләр» (М.Гафури), «Мартын Боруля» (И.Карпенко-Карый), «Ул килде» («Он пришёл», Дж.Пристли) һ.б. әсәрләрне сәхнәләштерә.

*И.И.Илялова.*

**ЙОСЫ́ПОВ** Гата (Гатаулла, чыганакларда Касыйм, Бакир исемнәре дә очрый) (? — ?), график. Казан сәнгать техникумының графика остаханәсен беренче булып тәмамлаучылардан (1929), Б.И.Урманче шәкерте. Й. 1920 еллар ахыры — 30 елларда Татарстанның рәсем сәнгатендә сизелерлек эз калдыра. Сатирик рәсем, плакат остасы һәм ксилография алымындагы станлы әсәрләр авторы. «Чаян» ж-лында карикатуралары басылуы, гарәп, латин, кириллица шрифтларында ике телдә әзерләгән «Татиздаттагы китаплар һәм журналлар» (1929) реклама плакаты барлыгы мәгълүм (П.М.Дульский китабында күчереп ясала). Ф.Кәримнең «Улак белән еракка» китабы тышлыгы (1930), «Б.Урманче китабыннан» экслибрисы (агачта гравюра) (1929), хатыны портреты (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана) авторы. Й. мирасы начар өйрәнелгән. 30 елларда армиягә алынуы, Самарадагы җирле газетада рәссам булып эшләве һәм анда «Сәнгать буенча ярдәмлек» китабын бизәве (1930 еллар) билгеле.

Казан сәнгать-театр техникумының графика бүлегендә уздырылган конкурс эшләре күргәзмәләрендә (1929, Казан), Париждагы «Китап сәнгате» халыкара күргәзмәсендә (1931) катнаша.

*Әд.:* Дульский П.М. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; Урманче Б.И. Казан Сәнгать мәктәбе һәм ул заман // Баки Урманче и татарская культура. К., 2005.

**ЙОСЫ́ПОВ** Заһид Гайфулла улы (псевд. Заһид Шәркый-Йосыпов) (1901, Оренбург — 1960, Уфа), журналист, публицист, филол. фән. канд. (1955). 1908–18 елларда «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәсендә, 1934–37 елларда Кызыл профессорлар ин-тында (Мәскәү) укый. 1914–18 елларда «Вакыт» басмаханәсендә (Оренбург) хәреф җыючы, фальцовкалаучы. Гражданнар сугышында катнаша. 1920 дә — Оренбургта чыга торган «Башкортстан хәбәрләре» (1920–23), «Юксыллар сүзе», «Юл», «Очкын» г-талары, 1929–30 елларда «Урта Идел» (Самара ш.) г-тасы мөхәррире. Марксизм-ленинизм курсларын тәмамлаганнан соң (1932), «Пролетар» (Донбасс) г-тасы мөхәррире. 1933–34 елларда татар телендә нәшер ителә торган «Коммунист» (Мәскәү) г-тасы мөхәррире урынбасары. «Литературная газета»да пропаганда бүлеге мөдире (Мәскәү, 1935–41) булып эшли. 1941–44 елларда ВКП(б)ның БАССР Кыйгы райкомының пропаганда бүлеге мөдире. 1944–56 елларда Башкортстан Тарих, тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында фәнни хезмәткәр (Уфа). Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормыш мәсьәләләрен яктырткан очерклар авторы. Тикшеренүләре 19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче яртысы татар һәм башкорт әдәбиятлары тарихы һәм әдәби тәнкыйтенә, Донбасста татар язучылары иҗатына, М.Җәлил иҗатын өйрәнүгә карый.

Хезм.: Башкорт әдәбияты тарихы. Уфа, 1955 (автордаш); История революционного движения в Оренбурге. Оренбург, 1927.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ЙОСЫ́ПОВ** Изил Галимҗан улы (25.10.1937, Әлмәт), нефтьче, техник фән д-ры (1984), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), проф. (1986), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989). СССР, ТР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1989, 1994). 1960 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлый. ТатНИПИнефтьтә эшли: директорның беренче урынбасары (1979–97, 2000–2004), директор (1997–2000), баш фәнни хезмәткәр (2004 тән). Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә, нефть скважиналары төзелешенә, энергия саклаулы технологияләргә һәм нефть чыгару системаларының экологик куркынычсызлыгына карый. Химия полимер казанышларын нефть чыгаруда киң куллануны башлап җибәрүчеләрдән берсе. Углеводород чыганакларын разведкалау һәм эшкәртү, торба үткәргечләрне коррозиядән саклау өчен полимер материаллар һәм пластмассалар куллану өлкәсендә яңа юнәлешләр булдыра. СССР Дәүләт бүләге «Нефть һәм газ чыганакларындагы

торба үткәргечләрнең эчке өслеген саклаучы каплам технологияләрен эшләү һәм сәнәгатькә кертү» һәм ТР Дәүләт бүләге «Авыр чыгарыла торган нефть запасларын эшкәртүнең югары нәтиҗәле комплекслы системасы» дигән хезмәтләре өчен бирелә. СССР ФАнең И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1982). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ограничение притока пластовых вод в нефтяные скважины. М., 1976; Геология, разработка и эксплуатация Ромашкинского нефтяного месторождения: В 2-х т. М., 1995. (автордаш); Получение ценных химических продуктов из пластовых вод РТ. К., 2005.

**ЙОСЫ́ПОВ** Илдар Мәсгут улы (19.6.1945, Казан), психолог, психол. фән. д-ры (1995), проф. (1997), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2003). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, 1969–71 елларда һәм 1974–78 дә шунда ук эшли, 1971–74 тә Ленинград ун-тының психология ф-тында аспирантурада укый. 1978 дән Казан пед. ун-тында, 2004 тән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тының үсеш психологиясе һәм психофизиология кафедрасында. Хезмәтләре белештермичә эшләү психологиясе, аралашу психологиясе, девиант халәт мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Психология взаимопонимания. К., 1991; Вчувствование, проникновение, понимание. К., 1993; Социопатические предпосылки криминальных деяний. К., 1996; Психологический дизонтогенез и психогенные растройства детского подросткового возраста. К., 2005.

**ЙОСЫ́ПОВ** Искәндәр Усман улы (15.3.1954, Казан), дипломат. Казан ун-тын (1976), Бөтенсоюз тышкы сәүдә академиясен (1987) тәмамлый. 1976–84 елларда СССР ФАнең Космик тикшеренүләр ин-тында. 1987–91 дә СССР Тышкы эшләр министрлыгында 2 нче, 1 нче секретарь, бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1991–94 тә ТРның Мәскәүдәге даими вәкиле, 1994–95 тә ТРның РФдәге вәкаләтле вәкиленең 1 нче урынбасары. 1995 елдан ТРның Франциядәге вәкаләтле вәкиле.

**ЙОСЫ́ПОВ** Ислам Йосыф улы (5.9.1925, БАССРның Илеш р-ны Буралы а. — 16.4.1991, Уфа ш.), автоматлаштырылган идарә итү системалары белгече, техник фән д-ры (1971), проф. (1978), БАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1985), подполковник. Харьков хәрби уч-щесен (1944), Рига югары авиация-инженерлар уч-щесен (1952), Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (1962) тәмамлый. 1972 елда Уфа авиация ин-тында җитештерү процессларын автоматлаштыру (1978 дән АСУ) кафедрасын оештыра һәм җитәкли. Хезмәтләре аеруча кискен шартларда (критик ситуацияләрдә) эшләүче югары дәрәҗәдә оештырылган системалар б-н идарә итү проблемаларына карый. Й. беренче тапкыр карарлар кабул итү автоматлаштырылган системаларының өч контурлы төзелешен тәкъдим итә һәм дәлилли, аларның методологик нигезләрен һәм төзелеш принципларын эшли. Хезмәтләре очкыч аппаратлар, сәнәгый җитештерү, махсус билгеләнешле системалар б-н идарә итү өлкәсендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Уфа авиация-техника ун-тында мемориаль такта куелган.

Х е з м.: Автоматизированные системы принятия решений. М., 1983; Автоматизированное управление ситуациями в агропромышленном комплексе. Уфа, 1988 (автордаш).

**ЙОСЫ́ПОВ** Касыйм Нәзиф улы (26.11.1935, БАССРның Чакмагыш р-ны Сыерышбаш а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1985), проф. (1991), РФАнең мөхбир әгъзасы (1996), БАССР, РФ, ТРның атказ. фән эшлеклесе (1985, 2006, 2007). 1959 елда Башкорт дәүләт ун-тын тәмамлый. 1959–61 дә Чакмагыш р-ны Митрәй-Әюп урта мәктәбендә эшли, 1961–65 тә ВЛКСМның Чакмагыш р-н ком-ты 1 нче секретаре, Башкортстан өлкә ком-тының мәдәният-масса эшләре секторы мөдире. СССР ФАнең Башкортстан ф-лы аспирантурасын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1965–1990): фәнни хезмәткәр, сектор мөдире, иҗтимагый җитештерү пропорцияләре лаб-ясе мөдире (1985 тән). 1990–95 тә Бөтенроссия финанс-икътисад читтән торып уку ин-тының Уфа ф-тында эшли, 1995 тән Башкорт ун-тының җитештерү б-н идарә итү һәм милли икътисад каф. мөдире. Хезмәтләре региональ икътисад проблемаларына карый. Төбәкләрне тармакара, төбәкара анализлау методологиясен, ш.у. милли һәм төбәк йогынтыларының оптималь нисбәте шартларында төбәкнең милли икътисадка керткән өлешен бәяләү методикасын эшли. Й. — Башкорт ун-тының шәрәфле профессоры, күптомлы «Башкортостан» энциклопедиясенең фәнни советы һәм редколлегиясе әгъзасы; икътисад фәннәре өлкәсендәге казанышлары өчен БР ФАнең М.И.Токымбәтов исем. бүләгенә лаек була. Публицист, татар телендә язылып, Уфа татарлары генеалогиясенә, тарихы һәм мәдәниятенә багышланган «Имәннәр», «Йосыф-Сыерышбаш», «Сыерышбаш хикмәтләре», «Тамырлар» дигән китаплар авторы. БР Язучылар берлегенең Г.Рамазанов исем. бүләге лауреаты (2006).

Х е з м.: Автономная республика в системе общественного воспроизводства. М., 1980; Региональная экономика. М., 2006; Национальная экономика. М., 2007.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**ЙОСЫ́ПОВ** Мансур (18 йөз), татар сәүдәгәре, *Ташкент кәрваны* җитәкчеләренең берсе. 1741–42 елларда татар сәүдәгәре Ш.*Арсланов* һәм Курск сәүдәгәре С.Дроздов б-н бергә сәүдә кәрванын Оренбург кальгасыннан Ташкентка илтә һәм аннан Оренбургка алып кайта.

**ЙОСЫ́ПОВ** Марат Габбас улы (29.3.1928, Спас кантоны Алпар а. — 15.3.1993, Чаллы ш.), инженер-гидротехник, хуҗалык җитәкчесе, ТАССРның атказ. энергетигы (1986), Түбән Кама ГЭСы директоры (1969–88). Ташкент а.х.н сугару һәм механикалаштыру инженерлары ин-тын тәмамлый (1957). 1942–48 елларда Үзбәкстан ССРның Исбаскент р-ны пр-тиеләрендә эшли. Чирәм җирләрне үзләштерүдә катнаша: 1958–65 тә участок башлыгы, төзелеш-монтаж идарәсе баш инженеры, «Чардарстрой» төзелеш идарәсе (Көньяк Казакъстан өлкәсе) баш инженеры урынбасары. 1965–69 да «Камгэсэнергострой»ның 2 нче төзелеш-монтаж идарәсе башлыгы. Аның җитәкчелегендә Түбән Кама ГЭСы төзелә. Й. — Әхсән Баянның «Ут һәм су» романы прототипларының берсе (1973). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, Казакъстан ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Аның исеме («Марат Юсупов») буксир теплоходына бирелә (1998). Й. яшәгән йортка мемориаль такта куела (1999).

*Әд.:* Р ә х и м о в Җ. Тынгысыз як // Казан утлары. 1976. № 8; А й с и н Р., Д е н ч и к Т., Л а п ш и н М. В золотых огнях гидростанции... Наб. Челны, 1999.

**ЙОСЫ́ПОВ** Марс Фәйзелхак улы (16.10.1939, Чаллы ш. — 25.1.2004, Казан), химик-технолог, техник фән. канд-ты (1974), Россия Ракета һәм артиллерия фәннәре академиясе мөхбир әгъзасы (1994), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1991). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Красноармейск механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе) эшли. 1965 елдан Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында: лаб. (1968 дән), бүлек башлыгы (1972 дән), директор (1994 тән), баш конструктор-бүлек башлыгы (1997–2003). Хезмәтләре көпшәле системалар өчен ату зарядларын проектлауга һәм төзүгә карый. Аткан вакытта оптималь эчке баллистика булдыру максаты б-н дары һәм зарядларның кабыну, яну процессларын тикшерә. Тулысынча бөртекле дарылардан торган зарядлар булдыру эшендә катнаша: киеренке баллистикалы мондый зарядларның тотрыклылыгын тәэмин итүче — үзләре янып бетеп күчәрдә ялкынландыра торган металл көпшәләр уйлап чыгара һәм эшли; алар озынча заряд камералы арт. системаларында да кулланыла. Югары тизлекле ату системалары, ш.у. аеруча төгәллек һәм нәтиҗәлелек таләп ителгән атулар өчен баллистика һәм куллану характеристикалары югары булган зарядлар эшли. СССР Дәүләт бүләге махсус машиналар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. 147 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 142 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лучшие люди России: Энцикл. М., 2004. Ч. 2.

**ЙОСЫ́ПОВ** Мидхәт Кәрим улы (10.8.1928, Ташкент ш. — 25.12.2007, шунда ук), химик-органик, химия фән. д-ры (1981), проф. (1991). 1951 елда Урта Азия ун-тын (Ташкент ш.) тәмамлаганнан соң, 1956 дан шунда ук эшли, 1951–56 да оборона пр-тиесендә): өлкән фәнни хезмәткәр (1980 нән), табигый кушылмалар химиясе кафедрасы профессоры (1991 дән). Хезмәтләре Colchicum (безвременник) ыругы алкалоидлары химиясенә карый. Бу үсемлекнең 8 төреннән Й. 100 яңа алкалоид аерып ала, аларның төзелешен, конфигурациясен билгели, физиологик процесслардагы ролен күрсәтә. Әлеге кушылмалар-


ның структурасы гомоизохиномен алкалоидларны тикшерү нигезендә, ш.у. трополон алкалоидларның төзелешен модификацияләү юлы б-н билгеләнә. Й. колхицин һәм колхамин амидларны, аларның N-ациллы һәм N-алкиллы кушылмаларын (чыгарылмаларын) синтезлый. Колхицин, колхамин табуның яңа ысулларын эшли (Батуми химфармзаводында производствога кертелә). Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Трополоновые алкалоиды // Химия природных соединений. 1978. № 1; Биогенез колхицина и изохинолиновых алкалоидов семейства лилейных // Структура и функции физиологически активных соединений. Ташк., 1990; Фотохимические изомеры трополоновых алкалоидов // Химия природных соединений. 1990. № 2.

**ЙОСЫ́ПОВ** Мират Зыятдин улы (1927, БАССРның Чакмагыш р-ны Сыерышбаш а.), геофизик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980), техник фән. канд. (1975), ТРның атказ. нефтьчесе (1977), РФнең атказ. геологы (1988). Уфа геол.-разведка техникумын (1948) һәм Мәскәү нефтехимия һәм газ сәнәгате ин-тын (1962) тәмамлый. 1948 дән СССР Нефть сәнәгате министрлыгы Геофизика трестының көнчыгыш бүлегенә кергән Татар промысел-геофизика экспедициясендә, 1950 дән «Башнефтегеофизика» трестында. 1953–90 да «Татнефтегеофизика» җитештерү берләшмәсендә (1958 дән Лениногорск промысел-геофизика конторасының баш геологы). ТРның битум, нефть (Ромашкино, Яңа Елховой) һ.б. чыганакларын эшкәртүнең геофизика өлешендә катнаша. Углеводород ятмаларын эзләү һәм разведкалау өчен иң кулай промысел-геофизика тикшеренүләре комплексын эшли. Медальләр, ТАССР ЮСның Мактау грамоталары, СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. премиясе б-н бүләкләнә.

**ЙОСЫ́ПОВ** Муса Рахман улы (1896, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Әбсәләм а. — 3.8.1937, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый (Оренбург ш.). 1915 елда Россия армиясенә алына, 1917 нең апреленә кадәр 103 нче пехота полкында хезмәт итә. Уфада Кызыл гвардия отрядларын оештыручыларның берсе. 1919–20 дә Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясендә сәяси эштә. 1920–22 дә РКП(б)ның Омск губкомы татар-кыргыз секциясе бюросы рәисе, РКП(б)ның Себер өлкә бюросы татар-кыргыз секциясенең җаваплы секретаре, Себер ревкомында бүлек мөдире, «Азат Себер» г-тасы мөхәррире. 1922–29 да «Башкортстан», «Яңа авыл» (Уфа ш.) г-талары мөхәррире, мәгариф хезмәткәрләре профсоюзы өлкә ком-ты рәисе, профсоюзларның Башкортстан респ-ка советы рәисе урынбасары. Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-тны тәмамлаганнан соң (1931), ВКП(б)ның Башкортстан, Татарстан өлкә ком-тларында матбугат секторы мөдире. 1933–35 тә — Татар пед. ин-ты, 1935–37 дә Татар акад. театры директоры. Репрессияләнә; вафатыннан соң аклана.

*И.Г.Газизуллин.*



Н.Х. Йосыпов.

**ЙОСЫ́ПОВ** Наил Хәбибулла улы (1.3.1930, Үзбәкстан ССРның Әндиҗан өлкәсе Җәлал-Кудук р-ны Ахунбай а. — 10.1.2010, Казан), сәнәгать җитештерүен оештыручы, ТР һәм РФнең атказ. химигы (1990, 1993). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын, 1962 дә КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый. 1953–58 елларда Тымытык МТСның баш инженеры. 1958–74 тә партия эшендә: КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, бүлек башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы (1969–74), Яр Чаллы (1962–65), Түбән Кама (1965–69) шәһәр ком-тларының 1 нче секретаре. 1974–86 да Казанда «Тасма» ҖБ директоры. Й. эшләгән вакытта пр-тиедә реконструкция үткәрелә, фототехник һәм рентген плёнкалары җитештерү куәтләре гамәлгә кертелә, яңа продукциянең 40 төре үзләштерелә, ш.и. тасмасыман коры фоторезисторларның, микрофильтрларның һ.б.ның ассортименты һәм күләме күпкә киңәйтелә. 1986–2003 тә «Казаноргсинтез» АҖ директоры, ген. директоры. Аның җитәкчелегендә гамәлдәге производстволарда яңартулар һәм үзгәртүләр үткәрелә; дөнья базарында көндәшлеккә сәләтле яңа төр продукцияләр эшләү үзләштерелә. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы, 40 тан артык патенты бар. 1970–75, 1985–90 да ТАССР ЮС, ТССР ЮС һәм 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 2002–03 тә «Россиянең иң профессиональ 1000 менеджеры» рейтингында Й. беренче йөзлеккә керә; «Россиянең иң яхшы менеджеры» дипломнарына (2000, 2002) ия; «Россия эшмәкәрлегенең алтын китабы» (2000) альманахына кертелә.

**ЙОСЫ́ПОВ** Нурулла Зәйнур улы (1902 — 1974), партия эшлеклесе. Баку шәһәрендә Югары партия мәктәбен тәмамлый (1922). Хезмәт юлын 1916 елда Баку нефть промыселларында эшче булып башлый. 1923 тән партия эшендә. 1926–29 да Әзәрбайҗан КП(б)ның Баку райкомы, 1929 да Карабах округ ком-ты секретаре. 1930 да ВКП(б)ның Кавказ арьягы крайкомының оештыру бүлеге мөдире урынбасары. 1925–32 дә Әзәрбайҗан КП(б) ҮК әгъзасы. 1933–34 тә Кугалы МТСының (Алма-Ата өлкәсе) сәяси бүлеге башлыгы, бер үк вакытта партия райкомы секретаре. 1934–35 тә ВКП(б)ның Казакъстан крайкомы бүлек мөдире урынбасары. 1935–38 дә ВКП(б)ның Алма-Ата шәһәр ком-ты, өлкә ком-ты секретаре. 1934–38 дә ВКП(б)ның Казакъстан крайкомы, Казакъстан КП(б) ҮК әгъзасы. 1956–69 елларда «Алма-Ата» мебель фирмасының ген. директоры. Ике Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А. 1988. Т. 2.

**ЙОСЫ́ПОВ** Рамазан Хәбибрахман улы (26.7.1949, Чиләбе ш.), энергетика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1993), проф. (1997). Чиләбе политехник ин-тын тәмамлый (1974). 1976–87 һәм 1994–2005 елларда Чиләбе агроинженерлар ун-тында, а.х. җитештерүен автоматлаштыру каф. мөдире (1994 тән); 1987–94 тә Красноярск аграр ун-тында, машина-трактор агрегатлары каф. мөдире (1993 тән). 2005–06 да Көньяк Урал ун-тының идарә итү системалары каф. җитәкчесе (Чиләбе ш.). 2006 дан Мәскәү агроинженерия ун-тының мәгълүмат-идарә системалары кафедрасында. Хезмәтләре мобиль а.х. машиналары энергетикасына һәм аларны автоматлаштыруга, җитештерү һәм мәгариф системаларында мәгълүмат технологияләренә карый. Машина-трактор агрегатларының энергетик күрсәткечләрен исәпләү һәм оптимальләштерүнең универсаль алымнарын эшли, азык продуктларын зарарсызландыруның комплекслы системасын тәкъдим итә. Й.ның хезмәтләре Чиләбе һәм Волгоград трактор з-дларында, агросәнәгать комплексы пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Взаимодействие элементов системы «двигатель-трансмиссия» трактора. Красноярск, 1991; Эксплуатация и наладка систем автоматики. Челябинск, 1999; Сырьё для хлебопекарного и кондитерского производства и методы его улучшения. Челябинск, 2004.

**ЙОСЫ́ПОВ** Расих Хәлиулла улы (10.9.1940, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кыр Бикшиге а.), вет. иммунологы, вирусолог, вет. фән. д-ры (1982), проф. (1988), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1996). 1964 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1964–65 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1965 тән Казан вет. ин-тында. 1965–74 тә тәҗрибә иммунология лаб-ясе хезмәткәре, 1974–84 тә лаб. мөдире, бер үк вакытта 1975–84 тә фәнни эшләр буенча проректор. 1984 тән Бөтенсоюз (1989 дан Бөтенроссия) вет. фәнни-тикшеренү ин-тында: директор урынбасары, бер үк вакытта иммунология лаб-ясе мөдире, 2004 тән директор урынбасары, бер үк вакытта Хайваннар токсикологиясе һәм радиацион иминлеге федераль үзәгендә аеруча куркыныч йогышлы авыруларга диагноз кую һәм аларны булдырмау бүлеге мөдире. Фәнни эшләре вет. иммунологиясенә, вирусология мәсьәләләренә, а.х. терлекләренең йогышлы авыруларына диагноз кую чараларын һәм ысулларын эшләүгә, терлекләрнең йогышлы авыруларга һәм тирәлек факторларына тотрыклылыгын арттыру максатында табигый ныклыкны иммунологик көйләүгә багышлана. Аеруча куркыныч вируслы авыруларга, дуңгызларда классик чума авыруы, котыру, Ку бизгәгенә диагноз куюның лаб. ысулларын эшли һәм гамәлгә кертә. 1984 елда а.х. терлекләренең аеруча куркыныч авыруларына диагноз куюның комплекслы чараларын һәм ысуллары эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен СССР МС бүләге бирелә, «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Лабораторная диагностика чумы свиней. К., 1973; Профилактика и ликвидация классической чумы свиней // Ветеринарный врач. 2001. № 3; Разработка экспресс-методов иммунологического мониторинга при бешенстве // Вопр. вирусологии. 2001. № 5 (автордаш); Инфекционные болезни свиней (этиология, эпизоотология, диагностика, профилактика). М., 2006 (автордаш); Эпизоотолого-эпидемиологический надзор за бешенством. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* История ветеринарии Татарстана. К., 2002; Казанская гос. академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006;

**ЙОСЫ́ПОВ** Рафаил Акмал улы (10.3.1948, Юдино р-ны Норлат а.), химик, химия фән. д-ры (2003), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук эшли. 1979 елдан Казан химия-технол. ин-тында (хәзерге Казан технол. ун-ты). Хезмәтләре каты матдәләрдә ионнар алмашу процессларының кинетикасына һәм механизмына карый. Эремәләрдән утырымга төшерү юлы б-н металл сульфидларының юка поликристаллик элпәләрен синтезлый. Юка поликристаллик элпәләрдә һәм халькогенидларның гельле матрицаларында металлар, ш.у. каты җисем-сыеклык фазалары контакты вакытында металл оксидлары ионнары диффузиясен, ионнар алмашу процессына лигандларның йогынтысын тикшерә. Төрле халәттәге (утырымнар, юка поликристаллик элпәләр, нанокристаллар) металл сульфидларында тирән изоморфик ионнар алмашуның күп стадияле процессларын санча сурәтли торган тигезләмәләр ала. Металл тозларының һәм тиоамидларның судагы эремәләреннән лигандлар катнашында металл сульфидлары һәм аларның элпәләре барлыкка килү кинетикасын, ш.у. аз эрүчән ионлы кушылма — металл комплексларның судагы эремәләре фазалары контакты вакытында ионнар алмашу кинетикасын санча сурәтләү өчен матем. модельләр эшли. Тикшерү нәтиҗәләре утырымнар, юка элпәләр, мембрана, нанокристаллар рәвешендә нәорганик кушылмалар синтезлауда һәм аларны легирлау процессларында кулланыла. Гамәли метрология, нефть продуктларын күкертле катнашмалардан чистарту буенча хезмәтләр авторы. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Расчёт параметров трёхстадийной диффузии ионов металлов в тонких поликристаллических плёнках // Журн. физ. химии. 1997. Т. 71, № 3 (автордаш); Глубокий ионный обмен в металлосульфидных имплантантах. К., 2004 (автордаш); Ионообменные процессы в тонкоплёночных биополимер-иммобилизованных металлосульфидах. М., 2007 (автордаш).

**ЙОСЫ́ПОВ** Рафаэль Мидхәт улы (17.7.1934, Казан), генерал-майор (1980), техник фән. д-ры (1968), проф. (1974), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1984). А.Ф.Можайский исем. Хәрби-һава инженерлары академиясен (1958), Ленинград ун-тын (1964) тәмамлый. 1958–85, 1986–89 елларда А.Ф.Можайский исем. Хәрби-һава инженерлары академиясендә: 1970–71 дә ракеталар һәм космик аппаратлар б-н идарә итү системалары каф. җитәкчесе урынбасары, 1971–76 да ракета-космик техниканың сугышчан нәтиҗәлелеге каф. җитәкчесе, 1976–85 тә мәгълүмат җыю һәм эшкәртү ф-ты җитәкчесе, оператив-тактик әзерлек каф. җитәкчесе. 1985–86 да СССР Хәрби көчләре Генераль штабы Оператив-стратегик тикшеренүләр үзәгенең стратегик операцияләрне модельләштерүгә юнәлеш бирү җитәкчесе. 1989 дан РФАнең Петербург информатика һәм автоматлаштыру ин-тында, 1989–91 дә директор урынбасары, 1991 дән — директор, фәнни-тикшеренүләрне автоматлаштыру каф. мөдире. Хезмәтләре ракета-космик техника өлкәсендәге катлаулы информацион-идарә системаларының сизгерлеге һәм нәтиҗәлелеге теориясенә һәм анализлауның гамәли методларын эшләүгә һәм үстерүгә карый. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. РФАнең Петербург фәнни үзәге Президиумы әгъзасы, үзәкнең Информатика, элемтә һәм идарә итү буенча берләштерелгән фәнни советы рәисе, РФ Куркынычсызлык Советы каршындагы Фәнни совет әгъзасы (1999 дан). СССРның мактаулы радисты (1976), А.Ф.Можайский исем. Хәрби инженер.-космик академиянең шәрәфле профессоры (1996). Кызыл Йолдыз, Почёт орденнары, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы получения информации об управляемом процессе в самонастраивающихся системах. М., 1966; Чувствительность систем управления. М., 1981; Введение в геофизическую кибернетику и экологический мониторинг. СПб., 1998; Социология конфликта: методы и модели. СПб., 1999 (автордаш); Наука и национальная безопасность. СПб., 2005; Sensitivity of Automatic Control Systems. CRS Press, Roca Raton, London, New York, Washington, 1999 (автордаш).

**ЙОСЫ́ПОВ** Ривкат Рәшит улы (9.4.1950, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1996), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (2000, 2006). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1976). 1980 елдан Башкорт ун-тында. 1984 тән Казан мәдәният ин-тында (2002 дән — Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты): КПСС тарихы һәм политэкономия кафедрасында, соңрак ватан һәм чит илләр тарихы кафедрасында укыта, 1989 дан проректор, 1996 дан ректор. Й. ректор булып эшләгән чорда Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында Милли сәнгать ин-ты, Театр, кино һәм телевидение ин-ты, Белемнәр трансферы ин-ты, Инновацион пед. технологияләр үзәге оештырыла, «Гамәли-бизәлеш сәнгате һәм халык сынлы сәнгать кәсепчелеге» белгечлеге, икътисад, менеджмент һәм туристлык факультетлары ачыла, вуз «Мәдәният һәм сәнгать уку йортларының университет мәгарифе округы» ассоциациясенең төп оешмасына әверелә, 2003 тән «Вестник КГУКИ» ж-лы чыга башлый. Хезмәтләре Польшаның өр-яңа тарихына карый, аларда поляк интеллигенциясенең 20 йөзнең икенче яртысындагы тарихи язмышы мәсьәләләре тикшерелә. «Урта Идел буе социомәдәни өлкәсе һәм сәнгате белгечләрен өзлексез профессиональ әзерләүнең төбәк системасын гамәлгә ашыру методологиясе һәм технологиясе» дигән хезмәтләре циклы өчен РФ хөкүмәте бүләгенә лаек була (2006); медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Власть и интеллигенция: Из истории Польши XX столетия. К., 1996; Польская интеллигенция в период народной демократии (1944–1980 гг.). К., 1998; Из истории Союза польских писателей (1945–1980 гг.). К., 2002.

*Әд.:* Казанский государственный институт культуры и искусства 1969–2004: Краткая история. К., 2004.

**ЙОСЫ́ПОВ** Рөстәм Гомәр улы (27.8.1935, Ташкент өлкәсе Яңа Базар пос.), геохимик, геол.-минерал фән. д-ры (1986), Нью-Йорк ФА академигы (1994). 1959 елда Ташкент ун-тын тәмамлаганнан соң, «Ташкентгеология» трестының геол.-картага төшерү-эзләнү экспедициясендә эшли. 1964 тән Үзбәкстан ССР Геология министрлыгының комплекслы экспедициясендә, 1986 дан Алжирда, 1989 дан Үзбәкстан Республикасы Геология дәүләт ком-тының Геол. музее директоры. Бер үк вакытта Ташкент милли ун-тында (1974 тән) укыта һәм Халык табибләренең халыкара ассоциациясендә эшли (2000 нән). Хезмәтләре геохимиягә, минералогиягә карый. Хамрабаевит минералын, алмазлар, кыйммәтле һәм сирәк металлар чагылмаларын һәм чыганакларын ачучыларның берсе. Калийлы ашламаларның яңа төрләрен, ташлар һәм минераллар ярдәмендә дәвалау ысулларын эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыклары һәм патентлары бар. Татар иҗтимагый үзәге рәисе (Ташкент, 1997, 2000), «Халык бирлиги» хәрәкәте әгъзасы (1998 дән). «Почёт билгесе» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геохимия пород интрузивного магматизма. Таш., 1983.

**ЙОСЫ́ПОВ** Рөстәм Изил улы (15.10.1968, Бөгелмә ш.), геофизик, техник фән канд. (2003), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Россия Нефть һәм газ ун-тын тәмамлый (Мәскәү, 1992). «Татнефтегеофизика» АҖдә эшли, геол. партия (1995 тән) һәм идарә (1998 дән) башлыгы, ген. директор урынбасары (2003 тән), «Татнефть» АҖнең Сүрия ф-лында ген. менеджер (2005 тән, Димәшкъ). Хезмәтләре нефть ятмаларын эшкәртүдә төш геофизикасы ысулларын куллану өлкәсенә карый. Катлам суының һәм скелетның (коллекторның) нейтрон үзенчәлекләре хакында җитәрлек мәгълүмат булмаганда, эшкә әзерләнә торган коллекторларның нефтькә туенуы дәрәҗәсе үзгәрү диапазонын санча бәяләргә мөмкинлек бирүче интерпретацияле модель тәкъдим итә; нейтрон генераторның чыгу юлында ташкынлы тотрыксызлыкны күрсәтүче яңа метрологик параметр һәм аны катламдагы водород күләмен сан ягыннан билгеләүдә куллану мөмкинлеген кертә. Дәүләт бүләге углеводород чыганакларында экологик халәтнең мониторингы өчен скважина термометриясенең геофизик комплексын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Новый аппаратно-программный комплекс импульсного каротажа АИНК-90НГ и возможности его применения в нефтяной геофизике // Геоинформатика. 1998. № 2 (автордаш); Геоинформационное обеспечение строительства и эксплуатации скважин сложной архитектуры // Тр. на-



Х.Г. Йосыпов.



Фәйзи С. Йосыпов.

уч. техн. конф., посвящённой 60-летию разработки Ромашкинского месторождения. К., 2008 (автордаш).

**ЙОСЫ́ПОВ** Сөләйман Даут улы (25.7.1925, Лаеш кантоны, хәзер Теләче р-ны Алан а. — 20.2.2003, Казан), җырчы (бас), ТАССРның атказ. артисты (1960). 1948–50 елларда Белоруссия хәрби округы җыр ансамбле артисты. 1950–64 тә ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле солисты, 1964–70 тә Татарстан филармониясендә солист-вокалист. 1990 га кадәр концертларда катнаша. Йомшак тембрлы бас тавышка ия. Татар композиторларының җырларын һәм халык көйләрен башкара. Татар муз. фольклор әсәрләрен җыя. ТАССР Дәүләт радио-телевидение фондында күпсанлы язмалары саклана. Аның башкаруында бигрәк тә халык көйләреннән «Умырзая», «Вәгъдә», «Сәҗидә», «Алма бакчасы», «Су буйлап», «Тәзкирә», «Җизнәкәй», «Кәвәл авылы көе», «Нурия» һ.б.; композиторлар әсәрләреннән Җ.Фәйзинең «Яшь наратлар», Р.Еникиевнең «Өф-өф итеп», И.Хисамовның «Бәрәңге», В.Хәбисламовның «Җиз кыңгырау моңнары», З.Хәбибуллинның «Казакъ дустыма», Ш.Мәҗитовның «Улым үземә охшаган» һ.б. җырлары популяр була.

*Әд.:* Арсланова Ф.Т. Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан. К., 2007.

**ЙОСЫ́ПОВ** Тәлгат Сөнгатулла улы (11.10.1935, Казан), файдалы казылмаларны баету өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), проф. (1996). Томск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), РФА Себер бүлегенең Геология һәм геофизика ин-тында (хәзер Геол. һәм минерал. ин-ты) эшли (Новосибирск ш.): 1972–2007 елларда минерал. технологиясе һәм минераллар бүленеше лаб. мөдире, 2007 дән Аналитик үзәкнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре минерал. технологиясенә, файдалы казылмаларны баетуга һәм минералларны аеруга карый. Ваклаганда минералларның структур һәм химик үзгәрешләрен тикшерә, минераль компонентларны аерып алуның яңа ысулларын эшли. Й. эшкәртмәләре руда чыгару һәм тау эшләре сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. Россия минерал. җәмгыяте әгъзасы (1987). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Физические и химические свойства тонкодиспергированных материалов. М., 1981 (автордаш); Механохимические взаимодействия природных цеолитов с фосфатами // Докл. РАН. 1999. Т. 364, № 4 (автордаш); Новые технологические аспекты обогащения кварцсодержащего сырья // Гравитационные методы обогащения. Новосиб., 2007.

**ЙОСЫ́ПОВ** Фәйзи Сәйяр улы (24.12.1910, Казан губ., Чистай өязе Яуширмә а. — 14.2.2001, Казан), эстрада артисты, нәфис сүз остасы, ТАССРның атказ. артисты (1957). Казан сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлагач (1930), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. 1932 елда Мәскәүдәге Кызыл Армия Үзәк йорты каршындагы драма студиясенә укырга керә. 1934–37 елларда Мосэстрада артисты. 1937–39 да һәм 1945 тән Татар филармониясе артисты һәм конферансье. 1939–45 тә — Кызыл Армиядә, совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Эстрада артистларының 1 нче Бөтенсоюз һәм нәфис сүз осталарының Бөтенроссия конкурслары лауреаты (1939, 1956). 1957 дә Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә Татарстан сәнгать осталары концертларында катнаша. Татар филармониясенең концерт бригадалары б-н СССРның күп шәһәрләрендә гастрольләрдә була. Репертуарын Г.Тукай, К.Насыйри, М.Җәлил, Х.Туфан һ.б. әсәрләре тәшкил итә. Сәхнәдә үзен иркен тотуы, материалның эчтәлеген төгәл чагылдыруы, юмор хисенә бай булуы аңа популярлык китерә. *Ю.А.Благов.*

**ЙОСЫ́ПОВ** Фәүзи Садри улы (16.10.1926, ТАССРның Зөя кантоны Тугай а. — 8.4.1982, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1967), ТАССРның атказ. табибе (1981). 1949 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казан травматология һәм ортопедия ин-тында, 1976 дан патентлар бирү һәм мәгълүмат бүлеге, 1979 дан өлкәннәр травматологиясе бүлеге җитәкчесе. Хезмәтләре сөяк сынуларын терәүле ятакта дәвалау ысулларына карый. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Компрессионный остеосинтез спицами с упорными площадками // Ортопедия, травматология, протезирование. 1970. № 2; О лечении переломов заднего края большеберцовой кости // Ортопедия, травматология, протезирование. 1977. № 5 (автордаш); Биомеханика компрессионного остеосинтеза косого диафизарного перелома двумя спицами с упорами // Труды Свердловского НИИ травматологии и ортопедии. 1978.

**ЙОСЫ́ПОВ** Феритс Йосыф улы (15.5.1939, Яшел Үзән р-ны Олы Карагуҗа а.), тел белгече, филол. фән. д-ры (1989), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1962 елдан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1972 дән Алабуга пед. ин-тында, 1984 тән РФ Мәгариф министрлыгының Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лы директоры, 1996 елдан Казан ун-тында. Хезмәтләре диалектология, морфология, ареаль лингвистика, татар телен укыту методикасына карый. Урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре авторы, балалар бакчалары өчен татар әдәбиятыннан хрестоматия, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту. К., 1977; Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре. К., 1979; Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре. К., 2003; Красноуфим татарлары: Тарих, тел, фольклор. К., 2004 (автордаш); Сафакул татарлары: Тарих, тел, халык иҗаты. К., 2006.

**ЙОСЫ́ПОВ** Хәмит Габбас улы (15.6.1917, хәзерге БРның Әлшәй р-ны Нигъмәтулла а. — 21.1.1993, Чаллы ш.), бульдозерчы, Соц. Хезмәт Герое (1958). Казан танк уч-щесен тәмамлый (1945). 1938–45 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә, Хәсән күле буендагы сугышларда һәм Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–72 төзелеш-монтаж оешмаларында эшли (БАССР, Ишимбай, Салават шәһәрләре.), 1972–77 дә «Камгэсэнергострой» АҖнең Төзелешне механикалаштыру идарәсендә (Чаллы ш.). Смена нормаларын 150% ка, бишьеллык йөкләмәләрен 3–3,5 ел эчендә үти. Тракторның капиталь ремонтсыз эшләү вакытын 1,8 тапкырга арттыра. Яшьләрнең остазы, унлап квалификацияле бульдозерчы әзерли. Герой исеме төзелештә һәм төзелеш материаллары сәнәгатендә ирешелгән зур уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, БАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: КамАЗ в моей судьбе // Подвиг на Каме. М., 1978.

*Әд.:* Канеев Б. Батыры Прикамья // Аргамак. 1996. № 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

**ЙОСЫ́ПОВ** Һарун Вәли улы (22.6.1914, Казан — 2.6.1968, шунда ук), тюрколог, этнограф, эпиграфия белгече, филол. фән. канд. (1952). Казан ун-тының геогр. ф-тын тәмамлый (1941). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–49 елларда Казан ун-тының этнография музее мөдире. 1952–58 дә СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында. 1958–68 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Экспедицияләр вакытында 14–17 йөзләргә нисбәтле (600 ләп кабер ташын барлап) зур күләмле эпиграфик материал туплый, беренчеләрдән булып Идел буе һәм Урал алды эпиграфия ядкәрләренең тулы җыелмасын төзи. Болгар һәм татар эпиграфия ядкәрләренә караган хезмәтләр авторы. Казан төбәгендә сакланган эпиграфия ядкәрләрендәге язмаларның тел һәм стилистик үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. «*Татарстан Республикасының археологик картасы*»н эшләүгә һәм төзүгә керткән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1994, вафатыннан соң).

Хезм.: Татарские эпиграфические памятники 15 в. (К вопросу о происхождении казанских татар) // Эпиграфика Востока. 1951. Т. 11; К вопросу об истории и классификации булгаро-татарской эпиграфики // шунда ук. 1956. Т. 5; Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар // Вопр. этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. К., 1971.

*Әд.:* Халиков А.Х. Юсупов Г.В. Некролог // Сов. археология. 1969. № 1; Национальный центр археологических исследований. К., 2007.

*С.Ю.Измайлова.*

**ЙОСЫ́ПОВА** Галия Расих кызы (30.9.1963, Мордва АССР, Зур Березники р-ны Зур Березники а.), микробиолог, вирусолог, вет. фән. канд. (1991), доцент (2003), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 1985 елда Казан вет. ин-тының вет. ф-тын тәмамлый. 1985–92 елларда Хайваннар токсикологиясе һәм радиацион иминлеге федераль үзәгендә (элек Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-ты) фәнни хезмәткәр, 2005–06 да кошлар авыруларын өйрәнү лаб-ясе мөдире. 2006 дан Казан вет. мед. академиясенең фәнни-тикшеренү секторы башлыгы. Хезмәтләре Себер түләмәсе, бруцеллёз, дуңгызларда классик чума вакытындагы аеруча куркыныч йогышлы авырулар чыганагын бетерү өчен югары нәтиҗәле, экологик чиста, зыянсыз дезинфекцияләүгә, технол. химик препаратларны эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Дезинфекцияләгеч, дәвалау-профилактик һәм технологик препаратлар эзләү, эшләп чыгару һәм куллануга кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Разработка экологически чистых средств для ветеринарии и медицины // Экологические проблемы ветеринарной санитарии: материалы науч.-техн. конф. М., 1993. Ч. 1 (автордаш); Ликвидация классической чумы свиней в моделированной энзоотии с помощью дезинфекции // Ветеринарный врач. 2005. № 3; Изыскание новых дезинфицирующих средств при классической чуме свиней // шунда ук. 2007. № 2.

**ЙОСЫ́ПОВА** Луиза Әфгат кызы (24.3.1973, Удмуртия АССРның Можга ш.), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (2006). 1996 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук дерматовенерология кафедрасында эшли. Хезмәтләре психик һәм үз-үзләрен тотышы үзгәргән авыруларда озакка сузылган дерматозларны тикшерүгә һәм дәвалауга карый.

Х е з м.: Лечение больных экземой // Рос. журн. кожных и венерологических болезней. 2005. № 6 (автордаш); Современные аспекты диагностики и фармакотерапии хронических дерматозов (псориаза, экземы, нейродермита), токсикодермии у больных с психическими и поведенческими расстройствами. К., 2005 (автордаш).

**ЙОСЫ́ПОВА** Луиза Мәгъданур кызы (13.9.1946, хәзерге Сарман р-ны Карашай Саклау а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (2003), проф. (2006). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзерге Казан технол. ун-ты) тәмамлый. 1967 дән шунда эшли (2002–2003 тә Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә укыта). Хезмәтләре махсус химиягә карый. Й. бензофуроксан рәте нитрокушылмалары химиясен тикшерә. Шартлаткыч матдәләр синтезы өчен ярымпродуктлар эшләүдә, ш.у. биологик актив кушылмалар табуда катнаша. Ветеринария өчен паразитларга каршы (антигильминт) тәэсир итүче дару препаратлары, җир асты катламнарын ачканнан соң сульфат торгызучы бактерияләр тәэсирен киметү өчен бактерицид чаралар уйлап таба. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Биологическая активность хлорпроизводных нитробензофуроксана // Вопр. мед., биол. и фарм. химии. 2005. № 4 (автордаш); Фунгицидные и токсикологические свойства функционально замещённых нитробензофуроксанов // Химико-фармацевт. журн. 2006. Т. 40, № 9 (автордаш); 4, 6-Динитробензофуроксаны, содержащие аминоацетальные фрагменты // Журн. общей химии. 2007. Т. 77, вып. 7 (автордаш).

**ЙОСЫ́Ф**, Коръән персонажы, *Ибраһим* нәселеннән булган Ягъкуб пәйгамбәрнең улы, тәкъва адәм һәм пәйгамбәр; Библиядәге Иосиф. Й.ның тормышы бәла-казалар б-н тулы була (абыйларының хыянәте, Мисырда коллыкта яшәү, падишаһ хатыны б-н көтелмәгән вакыйга һ.б.), шуңа да карамастан, дин-иман ярдәмендә ул җиңеп чыга. Й. турындагы риваятьләр Библиягә барып тоташа, ләкин аларда телдән-телгә күчү нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзенчәлекләр дә бар. Ихтимал, сюжетлардагы аермалар Коръәндәге Й.ны яһүди һәм христиан дине вариантларындагы Й.ка каршы куюны көчәйтү теләгенә бәйледер. Җирдәге мәхәббәт һәм Аллаһ б-н тыгыз бәйләнештә торган Й. образы суфилар әсәрләрендә еш очрый: Й.ның яшәү тарихы, яшерен асыл мәгънәгә төшенүнең бер ысулы буларак, төшләр турында фәлсәфә куерту өчен бер сәбәпкә әверелә. Коръәнгә багланышы булмаган риваятьтә Й.ка кагылышлы төп мотивларның берсе — аның хур егетләредәй чибәрлеге һәм шушы чибәрлеккә бәйле рәвештә туган падишаһ хатыны турындагы күп хикәятләргә, әдәби әсәрләргә нигез булган кыйсса. Й. турында хикәят татар фольклорында киң таралган, ул әдәби әсәрләрдә, ш.и. урта гасырлар әдәбиятында да кулланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ЙОСЫ́Ф БӘК** (?—1554) Нугай Урдасы *нурадыны* (1530–40 еллар), бәге (1549–54). *Идегәй* нәселеннән булган *Муса бәкнең* улы. Ул идарә иткән чорда Нугай Урдасы моңарчы күрелмәгән куәтенә ирешә. Урданың бәйсезлеген ныгыту, аның дәүләти төзелешен тәртипкә салу һәм актив тышкы сәясәт (Мәскәү, Кырым, Казан б-н мөнәсәбәтләрдә) алып бару тарафдары. Аның заманында нугайлар Казан ханлыгы сәясәтендә мөһим роль уйныйлар. Кама алды төбәгендә аларга биләмә (Нугай даругасы) бирелә, нугайлар шуннан махсус түләүләр — «мангыт керемнәре» алалар, Мусаның улы Җанмөхәммәд исә Казанда яши. Династия бәйләнешләрен ныгыту максатында Й.б. кызы *Сөембикәне* Казан ханлыгы идарәчесе *Җангали ханга* кияүгә бирә (1533). Ул хан тәхеттән бәреп төшерелгәннән соң, Сөембикә *Сафагәрәй ханның* хатыны була (1535). Й.б. Мәскәүнең бөек кенәзе һәм Казан ханы б-н сөйләшүләр алып бара, ләкин Мәскәүгә каршы сугышта катнашудан баш тарта. Сафагәрәйгә теләктәшлек күрсәтә; аксөякләр фетнә күтәреп, ул Казаннан куылса, аның б-н төзелгән шартнамә нигезендә Казанга яу оештырган очракта Й.б.кә Арча даругасы һәм Тау ягыннан салымнар җыю хокукы, ш.у. «мангыт керемнәре» вәгъдә ителә. 1546 елның июлендә Й.б.нең улы Юныс нугайлар отряды б-н Казанга килә һәм Сафагәрәйне тәхеткә утырта, ләкин хан Нугай Урдасы б-н төзелгән шартнамәне үтәүдән баш тарта. Моңа җавап йөзеннән Й.б. Казанга яулар оештыра (1549, 1551). Казан б-н ике арадагы мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнүе нәтиҗәсендә Й.б. *Казанның яулап алынуы* (1552) вакытында казанлыларга ачыктан-ачык ярдәм итми. Казан рус гаскәрләре тарафыннан алынгач, ул «мангыт керемнәре»нең бер өлешен кайтарып алуга омтылыш ясый, ләкин аның дәгъваларын рус хөкүмәте кире кага. Й.б. 1551 елда рус әсирлегенә алып кителгән кызы Сөембикәне өенә кайтару хакында рус хөкүмәте б-н актив рәвештә хат алыша, ләкин аның гозерләре һәрвакыт кире кагыла. Ул Рус дәүләтенә каршы сәясәт алып бара. 1554 тә *Мамышбирде* җитәкчелегендә баш күтәргән казанлыларга ярдәм итә, Ак-Балта б-н кечерәк отряд җибәрә. Й.б.нең сәясәте нугай ыруглары арасында ризасызлык тудыра. Үзара барган көрәштә ул Нугай Урдасы нурадыны *Исмәгыйль бәк* тарафыннан үтерелә (1554).

Чыг.: Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой: 1489–1549 гг. Махачкала, 1995; Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1551–1561 гг. К., 2006.

*Әд.:* П е р е т я т к о в и ч Г. Поволжье в XV и XVI веках. М., 1877; Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв., К., 1972; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; З а й ц е в И.В. Астраханское ханство. М., 2004; И с х а к о в Д.М., И з м а й л о в И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**«ЙОСЫ́Ф КИТАБЫ́»**, төрки-татар шагыйре Кол Галинең «Кысса-и Йосыф» поэмасының фольклор версиясе. Күп сандагы кульязма һәм китап вариантлары бар. Телдән-телгә күчеп, ш.у. күп тапкырлар күчереп яза торгач, төп нөсхә үзгәрешләр кичерә: күләме кыскара, сюжеты гадиләшә. Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтен, Йосыфның үтә диндарлыгын, аның чиксез сабыр булуын һәм Аллаһ алдында баш июен, әтисе Йагъкубның газиз улы б-н аерылу хәсрәтеннән туган рухи газапларын яктырткан эпизодлар күбрәк тарала. Поэманың аерым эпизодлары, кайбер аеруча мәгънәле, тәэсирле сюжет сызыклары мөстәкыйль әсәр сыйфатында яши. «Й.к.»ның 39 кульязма һәм сөйләм варианты теркәлгән: 29 — ТР р-ннарында; 4 — Омск өлкәсендә; 2 — Чиләбе, 1 әр данә — Горький, Төмән, Иркутск өлкәләрендә һәм Чуаш респ-касында. Алар барысы да «Татар халык иҗаты» җыентыгына кергән.

*Әд.:* Х и с а м о в Н. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше // Казан утлары. 1974. № 9; ш у л у к. «Кыйссаи Йосыф» поэмасында әдәбият-фольклор бәйләнешләрен өйрәнүгә карата // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 кит.; Кыйссаи Йосыф: Йосыф турында дастан. К., 1983.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЙОСЫ́Ф бине ИСМӘГЫ́ЙЛЬ әл-КАЗАНИ́** (?–1823), Казан сәүдәгәре, сабын заводлары һәм матбага хуҗасы. Казанда Коръән бастыруны оештыручыларның берсе.

**ЙОСЫ́Ф-АЛА́Н** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2008 елда 85 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 еллар башын-

да нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Мамадыш кантоны Саба волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Саба р-нында. Халык саны: 1926 да — 189, 1989 да — 104, 2002 дә — 98 кеше.

**«ЙОШКА́Р САЛТА́К»** («Кызыл солдат»), көндәлек газета. 1919 елның 29 апреленнән 1 июленә кадәр Казанда мари телендә нәшер ителә, барлыгы 24 саны чыга. Кызыл Армиянең Көнчыгыш фронты 2 нче армия сәяси бүлегенең милләтләр бүлекчәсе органы.

**ЙОШКА́Р-ОЛА́** шәһәре, РФдә, *Мари Республикасы* башкаласы. Мәскәүдән 862 *км* көнчыгыштарак, Иделнең сул кушылдыгы Кече Кокшага елгасы буенда. Халкы — 278,9 мең кеше (2007 ел), ш.и. татарлар — 23 мең кеше (2002). Утрак тормышлы татарлар Й.-О.да (элеккеге Царёвококшайск) 19 йөз башында күренә башлый. Аларның төп шөгыле сәүдә һәм күн эшкәртү була. Бөек Ватан сугышыннан соң сәнәгать пр-тиеләре (Мари машина төзү, ярымүткәргечле приборлар, витамин з-длары) үсү б-н татарлар шәһәрдә шактый күбәя. Хәзерге вакытта татар җәмгыяте күбесенчә ТРның Арча, Әтнә, Балтач районнарыннан һәм Түбән Новгород өлкәсеннән күчеп килүчеләрдән тора. Й.-О.да Республика татар мәдәни үзәге (1997 дән), Татар-башкорт керәш федерациясе (1998), Мөселманнарның региональ дини идарәсе (1998) эшли. Рәсем ясау студияләре һәм 5, ш.и. 1 балалар үзешчән сәнгать коллективы бар. Сов. Союзы Геройлары Т.К.*Кержнев* һәм Х.Х.*Хәсәновның* тормышы һәм эшчәнлеге Й.-О. б-н бәйле. Шәһәрнең бер урамы Х.Х.Хәсәнов исемен йөртә, тимер юл вокзалы бинасына (ул монда эшләгән) һәм Т.К.Кержнев яшәгән йортка мемориаль такталар куелган.

**ЙӨЗ КЫРЫ́К ҖИДЕНЧЕ́ УКЧЫ́ ДИВИ́ЗИЯ**, 1939 елда Кривой Рог шәһәрендә оештырыла. Бөек Ватан сугышы башында Славута шәһәре тирәсендә немец гаскәрләре б-н сугышка керә, Киевны саклауда катнаша, 1941 нең ноябрендә Борисполь шәһәре тирәсендә чолганышта кала. Дивизиянең бер өлеше, сугышып, чолганыштан чыга, декабрь башында Кукмара посёлогына җибәрелә, анда 426 нчы укчы дивизия оештырыла (дивизиянең бер өлеше ш.у. Чуаш АССРның Шумерле станциясе тирәсендә оеша; 1941 нең декабрь ахырында аны тулысынча Кукмарага җибәрәләр). 1942 нең гыйнварыннан 147 нче укчы дивизия дип атала башлый (командиры полковник И.В.Ковригин). Нигездә, респ-каның запас кадрлары һәм өлешчә Чуаш АССР кешеләре исәбенә тулыландырыла. 1942 нең апрелендә дивизияне Ковров шәһәренә җибәреп, шунда коралландыралар. 1942 нең маенда хәрәкәттәге армиягә озатыла һәм Көньяк-Көнбатыш фронтның 62 нче армиясе, аннары Сталинград фронты составына килеп кушыла. Дивизия командиры итеп генерал-майор А.А.Вольхин билгеләнә. 1942 нең июне ахырына кадәр Сталинградта була. 12 июльдә дивизия Дон елгасының көнбатыш ярында оборонага урнаша, өченче тәүлектә канкойгыч сугышларда катнаша. Чолганышка эләгә, Дон аша чыгу урынына үтәргә тырышып, 13 августка кадәр сугышлар алып бара. Чолганыштан дивизиянең бик аз өлеше генә чыга. Сталинградка бару юлында ныклы оборона тотып, дивизия сугышчылары немец командованиесенең шәһәрне бер һөҗүм б-н алу ниятен өзүгә үз өлешләрен кертәләр. Дивизиянең 4 мең сугышчысы батырлыклары өчен хөкүмәт бүләкләренә, ш.и. 27 кеше Сов. Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә.

*Әд.:* Д ю р я г и н Г.М. Боевой путь и подвиги воинов дивизий, сформированных в Татарии (1941–1945 гг.): Дисс. ... К., 1972.

*В.Ф.Телишев.*

**ЙӨЗБАШЫ́**, монголлар һәм төрки-татарлар гаскәрләрендә хәрби дәрәҗә; 100 кешелек гаскәри берәмлек башлыгы. Тыныч вакытта «Й.» термины феодаль биләмә (лен) хуҗасына карата кулланылган.

**ЙӨЗГӘЛӘКЛӘ́Р** (Dytiscidae), ерткычлар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Гәүдәләре яссы, овал. 2,5 меңгә якын төре билгеле, Россиядә 300 гә якын төре бар. Татарстан терр-ясендә яшәүче төрләрнең төгәл саны билгесез. Бу Й.нең аз өйрәнелүе һәм төрләрен ачыклау авыр булу б-н аңлатыла. Агымсыз, үләннәр б-н капланган сулыкларда яши. Аеруча зурлары (3–4 *см* га кадәр): каймалы Й. (Dytiscus marginalis) һәм киң Й. (D. latissimus), беренчеләренең аркасы коңгырт-кара, икенчеләренең — куе яшел төстә, күкрәк калканын һәм канат өслекләрен саргылт тар кайма уратып алган. Зур Й. арткы пар аяклары ярдәмендә йөзәләр, юкарган тәпиләрендә озын кыллар бар. Вак Й. су төбе һәм үсемлекләре буйлап үрмәлиләр. Атмосфера һавасын сулыйлар. Йомыркалардан үрчиләр, ана затлар аларны су үсемлекләренә яки сулык ярлары буена сала. Суда һәм коры җирдә кышлыйлар. Личинкалары тышкы тозелеше буенча төрле, яннарында һәм корсагында трахеялы саңаклары бар. Личинкаларның ураксыман казналыгы буенча сыек азыкны суыру өчен җайлашкан канал уза. Й. суда яшәүче организмнар, күбесенчә бөҗәкләр б-н, ш.у. моллюсклар, чукмарбаш һәм вак балыклар б-н туклана. Балык маймычларын ашап, Й. балык хуҗалыгына зыян китерәләр. Киң Й. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 3; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Р а й к о в Б.Е., Р и м - с к и й - К о р с а к о в М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**ЙӨЗЕ́К**, кашлы, боҗра формасындагы яки мөһер рәвешендәге зәркән бизәнү әйбере. Татарларга Й. кию гадәте борынгыдан, Идел буе Болгар дәүләте чорыннан ук килә. Й. формасы, материалы (алтын, көмеш, бакыр, бронза һ.б.), аны эшләү алымы (эретеп кою, өлге б-н эшләү, чүкеп ясау) һәм бизәкләү төрләре (җепкыр, уеплау, каралту һ.б.) буенча аерылалар. Төзелеше буенча Й.лар төп ике төркемгә: төрле өлешләрдән торган (каймадан һәм калканчыктан яки асылташлы кысадан) һәм тоташ коелмадан ясалган төркемнәргә бүленә. Төрле өлешләрдән торган Й.ларнең күпчелеге 18 йөз ахыры — 19 йөзнең 1 нче яртысына карый. Аларның каймалары коеп эшләнә, еш кына киңәйтелгән яки икегә аерылган була, уеп яки каралту ысулы, ш.у. җепкыр, бөртекләү б-н бизәлә. Й.нең кысалары түгәрәк яки квадрат рәвешендә: аларның нигезләре тирәли еш кына борчаксыман бөртекләр коеп ябыштырыла, кырыйларына (бигрәк тә ир-ат Й.ларендә) гади геометрик бизәкләр урнаштырыла. Кысаларга аерым асылташлар — сердолик, ахак, фирәзә, топаз, тау бәллүре һ.б. (к. *Кырлау*) яки алар чәчәксыман композициядә бергә куела. Калканчыклар каралтылган, уеп яки чүкеп ясалган үсемлек рәсемнәре б-н бизәлә, аларга ш.у. гарәп хәрефләре б-н яхшы теләкләр, Й. иясенең исеме языла. Зур коелма Й.лар ирләр өчен эшләнә.





1. Йөзек. Көмеш. Кою. Гравировка, каралту. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 2. Йөзек-мөһер. Бакыр, паста, көмеш. Кою. Идел буе Болгар дәүләте. 12–14 йөзләр. ТР Милли музее.

Аларның уртасына (кагыйдә буларак, 19 йөзнең 2 нче яртысында) дүртпочмак формасындагы кырлап шомартылган яссы асылташлар куела. Ир-атлар, гадәттә, зур, исемнәре яки тамгалары уелган мөһерле Й.лар кигән. Хатын-кыз Й.ләре үзләренең матурлыгы, купшылыгы б-н аерылып торган, борынгы ышанулар буенча, бөти сыйфатында да кулланылган, алар үз ияләрен явыз рухлардан сакларга тиеш булган. К.Фукс язуынча, татар хатын-кызлары һәр кулга көн саен 2–3 Й. кигән, кунакка барганда аларның барлык бармакларында диярлек, кайвакытта һәр бармакта берничә Й. булган. 19 йөз ахырында фабрикаларда ясалган Й.лар киң тарала. 20 йөзнең 2 нче яртысына кадәр Казан артындагы аерым авылларда халык осталары кою алымы б-н эшләнгән гади бизәкле Й.лар җитештерә. Й.ларнең уеп һәм каралтып бизәлгән кайбер традицион формалары ш.у. 20 йөзнең 2 нче яртысында да эшләнә (Х.Ганиев, Саба р-ны Тенәки авылы). Нечкә җепкыр, бөртекләр, кырланган асылташлар б-н бизәлгән татар Й.ләрен профессиональ Казан зәргәрчеләре (Ковалевскийлар гаиләсе, Ә.Шәмсетдинов, И.Фазылҗанов, Р.Мөхәммәтшин, И.Васильева, Т.Соловьева һ.б.) эшли. Татар Й.ләре үрнәкләре Дәүләт Эрмитажында, Дәүләт тарих музеенда (Мәскәү), Россия этнография музеенда (С.-Петербург), ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һ.б. саклана.

*Әд.:* Ф у к с К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; К а т а н о в Н.Ф. Несколько слов по поводу русских и татарских перстней, принадлежащих А.А.Сухареву и А.Т.Соловьёву // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1904. Т. 20, вып. 1; С у с л о в а С.В. Женские украшения казанских татар середины XIX — начала XX вв. М., 1980; В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЙӨЗЕ́М** (Vitis), йөземлеләр семьялыгыннан күпьеллык агачсыман лианалар ыругы. 60–70 төре билгеле. Культуралы Й. (V. vinifera) үстерелә. Озын (3–5 *м*), нәзек, берьеллык үрентеләре һәм көчле тамыр системасы б-н туфракка 7 *м* тирәнлеккә кадәр китүче лиана. Чәчәкләре ике җенесле яисә ана җенесле себеркәчле чәчәк оешмасына җыелган, читтән (бөҗәкләр яисә җил б-н) һәм үзеннән серкәләнә. Җимеше — төрле формада һәм төстә (гәрәбәдәй сарыдан яшел, алсу, куе шәмәхә һәм хәтта кара төскә кадәр). Җимешләре тәлгәш һәм чук булып җыелган. Составында 10 нан 30% ка кадәр шикәр булуы б-н кыйммәтле санала. Җылылык һәм яктылык яратучы үсемлек. ТРда җиңел уңдырышлы туфраклы, җылына торган тау битләрендә яхшы үсә. ТРда иртә өлгерә торган сортлары гына үстерелә. Үстерү өчен иртә өлгерешле Европа сортлары — «Жемчуг Сабо», «Мадлен Анжевин», «Изабелла» ш.у. Куйбышев бакчачылык — тәҗрибә станциясендә һәм Башкортстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында чыгарылган җирле сортлары — «Первенец Куйбышева», «Куйбышевский скороспелый», «Русич», «Корунд», «Пальмира» һ.б., алар өчен актив темп-ралар суммасы 2200°С һәм 125–130 кыраусыз көн булуы җитә. Сентябрьдә өлгерәләр. Яз көне туфрак +10°С кадәр җылынгач, рәтләрдә 1,5 *м* ара калдырып утырталар. Й. үстерүнең төп нигезе булып куакны формалаштыру тора. Татарстанда иң кулай формасы — ике җиңсәдән җилпәзә яисә авыш кордон формалары. Төп кисү — октябрьдә, кышка томалау алдыннан була, җәй көне артык үсентеләрне кисәләр. Җиңсә һәм үсентеләрен җәен 35–40 *см* ара калдырып горизонталь шпалерларга бәйлиләр. Кышка куакның калган өлеше б-н җиңсәне җиргә беркетеп куялар һәм плёнка б-н каплыйлар, өстенә туфрак яисә черемә салалар. Кар капламы өстәмә җылыткыч ролен үти. Үзтамырлы үсемлекләр — 60–70 елга, ялганганнары 30–40 елга кадәр җимеш бирә.

*Әд.:* А р у т ю н я н А.С. Удобрение виноградников. М., 1983; Виноградство. Энцикл.: В 3 т. Кишинёв, 1986.

*В.А.Наумов.*

**ЙӨЗҮ́ СПОРТЫ́**, 100 *м* дан 1500 *м* га кадәр дистанциядә кроль (ирекле стиль), брасс, баттерфляй (дельфин), чалкан йөзү, ш.у. гамәли йөзү, су астында йөзү, синхрон (сәнгатьчә) йөзү төрләрен берләштерә. Татарстанда Й.с. 1922 елдан үсеш ала, ярышлар 1928 дән уздырыла — Бөтентатар спорт бәйрәме финалы, Казан беренчелеге, Автономияле республика һәм өлкәләр спартакиадасы, 1934 тән даими рәвештә шәһәр һәм республика чемпионатлары уздырыла. ТРда Й.с.н башлап җибәрүчеләр (оештыручылары һәм тренерлары) — Д.А.*Ваши*, А.А.Лывин. 20 йөзнең беренче яртысында ТАССР җыелма командасы — Автономияле республика һәм өлкәләр спартакиадасында (1928), Идел буе (1934, бронза), 9 автономияле республика спартакиадаларында (1940, көмеш) җиңүче (приз алучы); иң көчле спортчылар — А.Г.*Әхмәтов*, И.Батурин, В.Дубицкий, С.Крестовский, Т.Н.*Полыгалова*, Ш.К.Салихов, В.Хованов.

20 йөзнең 2 яртысы — 21 йөзнең башында ТР җыелма командасы Идел буе спартакиадасында (1971, көмеш), Бөтенроссия яшьләр уеннарында (1981, көмеш), Идел буе терр-ясе чемпионатында (1991, көмеш), Россия беренчелеге һәм зона чемпионатларда 1999 (көмеш), 2000 (бронза), 2003 (кышкы, бронза), 2003 дә җиңүче була һәм бүләкләр ала. Казан пед. ин-тының йөзүчеләр җыелма командасы — Студентларның 6 нчы бөтенроссия уеннарында җиңүче була (1967) һәм 5 нчесендә көмеш медаль ала (1966). Й.с. бүлеге Казан, Әлмәт, Баулы, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Чаллы шәһәрләренең балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә (ш.и. олимпия резервының махсуслаштырылган мәктәпләрендә) эшли. 2007 дә ТРда 109 су-спорт комплексы һәм йөзү бассейны эшли; шуларның 5 се — 50 *м*; 73 е — 25 *м* йөзү юлы б-н; бассейннарның 89 ы ябык. Иң зурлары: «Органик синтез» (Казан), «Татнефть» (Әлмәт ш.), «Дуслык» «Түбәнкаманефтехим» (Түбән Кама ш.) АҖләренә карый; спорт-сәламәтләндерү комплекслары — «Нефтьче» (Баулы), «Яшьлек» (Бөгелмә), «Олимпия» (Чаллы), «Юбилейный» (Лениногорск). ТРның иң көчле йөзүчеләре — РСФСР, СССР, Россия, Европа, дөнья, Бөтендөнья тимерьюлчылар союзы чемпионатларында, Идел буе, РСФСР, СССР халыклары спартакиадаларында, Россия, ш.у. «Буревестник», «Спартак», «Труд», «Локомотив», ирекле спорт җәмгыятьләренең үзәк советлары беренчелекләрендә, Студентларның бөтенсоюз һәм бөтенроссия спорт уеннарында катнашучылар, җиңүчеләр һәм медаль алучылар: В.Анисимов, З.Б.Баженова, В.Буканов, Т.Булушева, В.Вавилов, Т.Волкова, А.Зацепин, Л.Зыятдинова, В.А.Ившин, А.А.Камешков, Я.Мартынова, И.Насыйров, И.А.*Нечаева*, Э.Николаева, М.А.Перевозчикова, С.Поляков, Р.Рәмиев, Р.Салихов, М.Селиванова, Е.Ушаков, О.А.Фёдорова, В.Французов, Х.Хисмәтуллин, И.Хөснуллина, Д.Чинаева, А.С.Шәмсетдинов, Ю.Шимин. 1992 дә ТРда йөзү спорты буенча «Идел» ветераннар клубы оештырыла (рәисе А.А.Камешков). ТРның иң көчле ветеран-йөзүчеләре — ТР, Европа, дөнья кубокларына һәм ачык чемпионатларда катнашучылар, җиңүче һәм медаль алучылар: В.Б.Абрамович, Ә.Г.Әхмәтов, З.П.Баженова, Е.В.Бахлин, Р.Бикбулатов, В.Вавилов, Ю.Городецкий, М.Дунаев, М.А.Ермакова, В.М.*Ермолаев*, К.Золотько, В.А.Ившин, И.Ионов, А.А.Камешков, М.Кондратьев, В.Лелюх, М.Логинов, Л.Мәһдиева, Л.Мельникова, В.Мумжиев, И.А.Нечаева, В.Николаев, О.Погодицкий, М.Саммитов, И.Сосновский, А.А.Сюткин, Е.Ушаков, Т.Фәизов, Х.Хисмәтуллин, А.С.Шәмсетдинов. Иң яхшы тренерлар: В.Б.Абрамович, Г.М.Әминова, В.И.Андрианов, Ә.Г.Әхмәтов, З.П.Боженова, И.А.Басин, Е.В.Бахмин, Э.В.Булгаков, А.Г.Ваккасова, Ф.А.Галиев, В.А.Грязнова, В.А.Ившин, И.С.Илалетдинов, А.А.Камешков, Е.А.Камешкова, Н.А.Коробков, Р.И.Лемешко, В.Е.Невзоров, Н.С.Пономаренко, Т.С.Пономаренко, А.А.Сюткин, В.Е.Феоктистов, Р.А.Шәйхәттәров, Р.Р.Шакиров, Х.Х.Шәфиков, В.И.Шпагин, Л.И.Якубчик, Э.П.Янклович.

*Әд.:* Ш ә м с е т д и н о в А.С., К а м е ш к о в А.А. Спортивное плавание Республики Татарстан: Справ. (1922–1999). К., 2000; ш у л а р у к. Клуб «Идел» в ветеранском плавании России. К., 2007.

**ЙӨЗЬЯШӘ́Р**, к. *Алоэ.*

**ЙУРА́** (Йугъра, Йогъра), Печора һәм Төньяк Урал елгалары арасында хант һәм манси кабиләләре яшәгән тарихи төбәк. Й. турындагы мәгълүматлар урта гасырлар Шәрекъ әдәбиятында (әл-Мәрвази, әл-Гарнати һ.б.), рус елъязмаларында китерелә. Болгар сәүдәгәрләре анда җирле кабиләләр б-н үзара алмашу сәүдәсе алып баралар. Алар Й.га кием-салым, тоз, «кылычлар» (диңгез балыкларын тоту өчен гарпуннар) һ.б. товарлар алып киләләр, «искиткеч кешләр»гә һ.б. мехларга алмашалар. 12 йөз ахырыннан Новгород феодаль республикасы йогынтысында була, Й. халкы аңа мехлар һәм морж сөяге б-н ясак түли. 15 йөзнең икенче яртысында Й. акрынлап Рус дәүләте составына кертелә. Й. этнонимы күп кенә географик атамаларда сакланган (Йугра Шары, Йугра бугазлары һ.б.).

Чыг.: Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). М., 1971.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

**ЙҮГНӘКИ́** Әхмәд (Әхмәд бине Мәхмүд Йүгнәки) (12 йөз ахыры — 13 йөз башы), төрки-татар шагыйре. «Һибә әл-хәкаикъ» («Хакыйкатьләр җыентыгы», Истанбул, 1915) исемле поэма авторы. Бу дидактик әсәрдә сүз кеше гомеренең тиз үтүчән, җирдәге һәр нәрсәнең үзгәрүчән икәнлеге турында бара; автор тәкәбберлекне, саранлык һәм наданлыкны кире кага; гыйлемле булуның файдасы турында яза, әдәбиятны һәм фәннәрне аеруча югары бәяли. Поэма *гаруз* б-н язылган, текст әйтемнәргә, мәкальләргә бай, үгет-нәсыйхәтләрнең күбесе хикмәт формасында бирелә.

*Әд.:* Краткая литературная энциклопедия. М., 1962. Т. 1.

# КУШЫМТА

**ДАН О́РДЕНЫНЫҢ ТУЛЫ́ КАВАЛЕРЛАРЫ́**, СССР Кораллы Көчләренең Совет илен яклаган сугышларда шанлы батырлыклар, кыюлык һәм куркусызлык күрсәткән өчен Дан орденының барлык өч дәрәҗәсе б-н бүләкләнгән рядовойлары һәм сержантлары (авиациядә - кече лейтенантлар), Сов. Союзы Героена тиңләштерелә. Орден 1943 елның 8 ноябрендә булдырыла.

Дан ордены статутына авыр яраланган, янган танкта калган хәлдә дә сугышчан бурычны үтәүне дәвам иткән; сугыш хәрәкәтләренә шәхси батырлык б-н уңышлы өлеш керткән; үзләренең часть байрагын дошман кулына төшүдән саклап калган; үзенең коралы б-н дошманның 10 нан алып 50 гә кадәр солдат һәм офицерын юк иткән; дошманның 2 дән дә ким булмаган танкын сафтан чыгарган; дошман офицерын әсирлеккә төшергән; дошманның каравыл постын басып алган; һава сугышында дошманның 2 дән алып 4 кә кадәр самолёт-истребителен яки 3 тән алып 6 га кадәр самолёт-бомбардировщигын юк иткән; һөҗүм вакытында дошманның 2 дән алып 5 кә кадәр танкын яки 3 тән алып 6 га кадәр паровозын юк иткән; тимер юл станциясендә яки хәрәкәт вакытында эшелонны шартлаткан; аэродромда дошманның 2 дән дә ким булмаган самолётын юк иткән солдатларның бүләкләнүе турында язылган.

1946 елга кадәр орденнның иң югары 1 нче дәрәҗәсе бер-бер артлы 3 нче һәм 2 нче дәрәҗә орденнар б-н бүләкләнгәннән соң гына бирелгән. Соңрак, элек 3 нче, 2 нче дәрәҗә өч орден б-н бүләкләнгән кайбер сугышчыларны (Х.Х.Габдрахманов, Я.Г.Бикчәнтәев, Р.Х.Гайнуллин, А.И.Едиханов, П.И.Захаров, Б.Н.Плотников, Р.Г.Тукаев, Р.К.Халитов, Ә.Г.Хөснетдинов, Х.И.Янаев), 1 нче дәрәҗә ордены б-н яңадан бүләклиләр, шуннан соң алар тулы кавалерлар булалар.

1 нче дәрәҗә орден алтыннан, 2 нче дәрәҗәдәгесе — көмештән (алгы ягындагы Мәскәү Кремле һәм Спас манарасы сурәте урнашкан түгәрәккә алтын йөгертелгән), 3 нче дәрәҗә орден тулысынча көмештән эшләнгән. Бүләкләнүче күкрәгенә орден урынына өч кара сызык сузылган кызгылт сары төстәге муар тасмалы планка тагып йөрергә хокуклы.

1943-91 елларда СССРда 2631 кеше Дан орденының тулы кавалеры була, алар арасында Татарстанда туган һәм анда яшәүче, ш.у. илнең башка өлкәләре, республикалары һәм крайларында яшәгән татарлар да бар — 87 кеше (к. Таблица).

*М.З.Хәбибуллин.*

*Таблица*

ДАН ОРДЕНЫНЫҢ ТУЛЫ КАВАЛЕРЛАРЫ

| | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Бүләкләнү еллары |
|---|---|---|
| 1. | АБДРАХМАНОВ Хәниф Хаҗигали улы | 1944, 1945, 1958 |
| 2. | АЙСИН Аләм (Галләм) Хәбибулла улы | 1944, 1945, 1945 |
| 3. | АЛАЕВ Михаил Константинович | 1944, 1945, 1946 |
| 4. | АРСЛАНОВ Зыятдин Миңлебай улы | 1944, 1945, 1945 |
| 5. | ӘБҮБӘКЕРОВ Мәннаф Әбүбәкер улы | 1944, 1945, 1946 |
| 6. | ӘҮХӘДИЕВ Минрәхмәт Сәхәбетдин улы | 1944, 1944, 1945 |
| 7. | БАЙМӨХӘММӘТОВ Гобәй Җандәүләт улы | 1944, 1945, 1946 |
| 8. | БАЛТАЕВ Газиз Минай улы | 1944, 1944, 1973 |
| 9. | БАСЫЙРОВ Георгий Васильевич | 1944, 1945, 1946 |
| 10. | БАШКИРОВ Алексей Иванович | 1943, 1945, 1946 |
| 11. | БИКЧӘНТӘЕВ Ярхәм Гәрәй улы | 1944, 1944, 1958 |
| 12. | БУЛАТОВ Даян Вагыйз улы | 1944, 1944, 1945 |
| 13. | ВАРФОЛОМЕЕВ Василий Михайлович | 1944, 1944, 1945 |
| 14. | ВАСИЛЬЕВ Алексей Афанасьевич | 1944, 1944, 1946 |
| 15. | ВИЛДАНОВ Абдулла | 1944, 1944, 1945 |
| 16. | ГАЗИЗОВ Мостафа Шакир улы | 1944, 1944, 1944 |
| 17. | ГАЙНУЛЛИН Рифгат Хәйрулла улы | 1944, 1944, 1970 |
| 18. | ГЕНЕРАЛОВ (Николаев) Яков Иванович | 1944, 1945, 1945 |
| 19. | ГОРЯЧЕВ Алексей Андреевич | 1944, 1945, 1945 |
| 20. | ГРИШИН Михаил Иванович | 1944, 1944, 1945 |
| 21. | ДАНИЛОВ Семён Степанович | 1944, 1944, 1945 |
| 22. | ДАУТОВ Әхәт Габделхәй улы | 1944, 1945, 1945 |
| 23. | ДЕГТЕВ Сергей Сергеевич | 1943, 1944, 1945 |
| 24. | ДИНЕЕВ Фатих Юныс улы | 1943, 1944, 1945 |
| 25. | ЕДИХАНОВ Андрей Иванович | 1944, 1945, 1991 |
| 26. | ҖАББАРОВ Каюм Закир улы | 1944, 1945, 1946 |
| 27. | ЗАЕВ Александр Алексеевич | 1944, 1944, 1945 |
| 28. | ЗАРИПОВ Зиннур Зариф улы | 1944, 1944, 1945 |
| 29. | ЗАРИПОВ Хөсәен Габдрахман улы | 1944, 1944, 1945 |
| 30. | ЗАХАРОВ Пётр Иванович | 1944, 1945, 1970 |
| 31. | ЗОТОВ Николай Иванович | 1944, 1944, 1945 |
| 32. | ИБРАҺИМОВ Гариф Ибраһим улы | 1944, 1944, 1945 |
| 33. | ИЗМАЙЛОВ Габбас Хәлиулла улы | 1944, 1944, 1945 |
| 34. | КАДЫЙРОВ Абдулла Насрулла улы | 1944, 1944, 1945 |
| 35. | КАРПОВ Павел Алексеевич | 1944, 1945, 1945 |
| 36. | КОСТИН Яков Дмитриевич | 1944, 1945, 1945 |
| 37. | КЫЯМОВ Дәүли Кыям улы | 1944, 1944, 1945 |
| 38. | ЛАПИН Трофим Якимович | 1944, 1945, 1946 |
| 39. | ЛАРЯГИН Николай Григорьевич | 1944, 1944, 1945 |
| 40. | МАЛКИН Пётр Иванович | 1944, 1944, 1946 |
| 41. | МАННАНОВ Шакир Фатих улы | 1943, 1944, 1945 |
| 42. | МӘСГУТОВ Миңнехан Мәсгут улы | 1944, 1945, 1946 |
| 43. | МЕЩЕРОВ Зариф Ибраһим улы | 1944, 1944, 1945 |
| 44. | МИҢНЕКӘЕВ Хаҗи Миңнекәй улы | 1944, 1945, 1945 |
| 45. | МИХЕЕВ Павел Егорович | 1944, 1945, 1946 |
| 46. | МОРТАЗИН Кәрим Абдулла улы | 1944, 1945, 1946 |
| 47. | МОТЫЙГУЛЛИН Габдулла Мотыйгулла улы | 1944, 1944, 1946 |
| 48. | МӨХӘММӘТҖАНОВ Миңкасыйм Низаметдин улы | 1944, 1945, 1946 |
| 49. | НАСЫЙБУЛЛИН Ислам Насыйбулла улы | 1943, 1944, 1945 |
| 50. | НАСЫЙБУЛЛИН Хәмидулла Нотфулла улы | 1944, 1944, 1946 |
| 51. | НАУМОВ Пётр Иванович | 1944, 1944, 1945 |
| 52. | НӘҖМЕТДИНОВ Тимур Гарәфетдин улы | 1944, 1945, 1945 |
| 53. | НИЗАЕВ Әбүзәр Гаяз улы | 1944, 1945, 1945 |
| 54. | ПЕСТОНОВ Николай Фёдорович | 1944, 1944, 1946 |
| 55. | ПЛАТОНОВ Василий Романович | 1944, 1944, 1945 |
| 56. | ПЛОТНИКОВ Борис Николаевич | 1944, 1945, 1968 |
| 57. | ПОРТНОВ Григорий Андреевич | 1944, 1944, 1945 |
| 58. | РӘФЫЙКОВ Шәмсетдин Хөснетдин улы | 1944, 1945, 1945 |
| 59. | САБИТОВ Салих Гыйззәт улы | 1944, 1945, 1945 |
| 60. | САДОВНИКОВ Григорий Данилович | 1944, 1944, 1945 |
| 61. | САДЫЙКОВ Хәким Садыйк улы | 1944, 1945, 1945 |
| 62. | САЛИХОВ Бәдигъ Мөхәммәт улы | 1944, 1944, 1945 |
| 63. | САФОНОВ Гавриил Васильевич | 1944, 1944, 1945 |
| 64. | СӘЛӘХЕТДИНОВ Гарәфетдин Сәләхетдин улы | 1944, 1945, 1945 |
| 65. | СЕМЁНОВ Григорий Трофимович | 1944, 1944, 1945 |
| 66. | СЕМЁНОВ Николай Иванович | 1944, 1945, 1945 |
| 67. | СКРЕМЕНТОВ Михаил Никифорович | 1944, 1945, 1946 |
| 68. | СОЛТАНОВ Хәтмулла Асылгәрәй улы | 1945, 1945, 1946 |
| 69. | СӨЛӘЙМАНОВ Әхмәт Нурмөхәммәт улы | 1944, 1944, 1945 |
| 70. | СУББОТИН Иван Павлович | 1944, 1944, 1945 |
| 71. | ТИМЕРГАЛИЕВ Корбан Тимергали улы | 1944, 1945, 1946 |
| 72. | ТӨХФӘТУЛЛОВ Бәдретдин Садретдин улы | 1944, 1944, 1945 |
| 73. | ТУКАЕВ Рифкат Галимҗан улы | 1944, 1944, 1958 |
| 74. | ТЯКИН Анатолий Владимирович | 1944, 1944, 1945 |
| 75. | УСМАНОВ Гайса Идрис улы | 1944, 1944, 1945 |
| 76. | УСМАНОВ Муллаян Әхмәтьян улы | 1944, 1944, 1945 |
| 77. | ФӘХРЕТДИНОВ Тимерҗан Җиһанша улы | 1944, 1945, 1946 |
| 78. | ФРОЛОВ Никита Васильевич | 1944, 1945, 1945 |
| 79. | ХАЛИТОВ Рөстәм Касыйм улы | 1944, 1945, 1956 |
| 80. | ХАРИТОНОВ Яков Моисеевич | 1944, 1944, 1945 |
| 81. | ХИТЕВ Михаил Дмитриевич | 1944, 1944, 1945 |
| 82. | ХӨСӘЕНОВ Хөрмәт Хәмзә улы | 1944, 1945, 1946 |
| 83. | ХӨСНЕТДИНОВ Әхнәф Галимҗан улы | 1944, 1945, 1959 |
| 84. | ШЛЯПНИКОВ Михаил Сергеевич | 1944, 1945, 1951 |
| 85. | ЯКИН Хәбибулла Хәйрулла улы | 1943, 1945, 1945 |
| 86. | ЯНАЕВ Хәмзә Исмәгыйль улы | 1944, 1945, 1962 |
| 87. | ЯРКӘЕВ (ЯРКАЛОВ) Хөснулла Нажар улы | 1944, 1944, 1945 |

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль, генерал
геогр. — география
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
имп. — император, императрица
ин-т — институт
ингл. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат(ы)
к-та — кислота (исем янында)
К° — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра/сы
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб., лаб-я — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
либр. — либретто
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос.- посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология
публ. — публикация
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
ст. — станция/се
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
төрки. — төркичә (төрки телләрдән)
ун-т — университет
ур. — урам/ы
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физ. — физика, физик
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр
эл. — электр; электро-...

## ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Дүш./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.—Л. — Мәскәү—Ленинград/Москва—Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — México
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

## БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр(е)
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал (лар)
зап. — записки
кис. — кисәк
кит. — китап
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
т. — том
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче(се)
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләре)
чыг. — чыганак
экз. — экземпляр
энцикл. — энциклопедия

## АББРЕВИАТУРАЛАР

АЖ — акционерлык җәмгыяте
ААЖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Берләшкән Дәүләтләр Берлеге
БР — Башкортстан Республикасы
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибләрнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ЖБ — җитештерү берләшмәсе
ЖЧЖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия Мәгариф академиясе
РМФА — Россия Медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — җылылык-электр энергиясе җитештерү үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных полезных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАЖ — ябык акционерлык җәмгыяте

## ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

*А* — ампер
*а.б.* — астрономик берәмлек
*а.к.* — ат көче
*В* — вольт
*Вб* — вебер
*В·А* — вольт-ампер
*Вт* — ватт
*Гн* — генри
*Гц* — герц
*Гпа* — гектопаскаль
*Гс* — гаусс
*г* — грамм
*га* — гектар
*град* — почмакча градус
*Дж* — джоуль
*дБ* — децибел
*дал* — декалитр
*дптр* — диоптрия
*К* — кельвин
*кВт·сәг.* — киловатт-сәгать
*кал* — калория
*кар* — карат
*кг* — килограмм
*Кл* — кулон
*км* — километр
*л* — литр
*лк* — люкс
*лм* — люмен
*м.а.б.* — массаның атом берәмлеге
*м* — метр
*мг* — миллиграмм
*мин.* — минут
*мкм* — микрометр
*мм* — миллиметр
*н* — ньютон
*окт* — октава
*Па* — паскаль
*рад* — радиан
*с* — секунд
*°С* — градус (Цельсий шкаласы буенча)
*сәг.* — сәгать
*см* — сантиметр
*т* — тонна
*Ф* — фарад
*Э* — эрстед
*эВ* — электронвольт
‰ — промилле

## КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Географик тематик карталар.
Татарстан Республикасының геологик картасы (104–105), «Дуслык» халыкара нефть үткәргече (296), Идел-Урал газ-нефть төбәге (513).

Тарихи карталар.
1918–19 елларда Татарстан территориясендә гражданнар сугышы (168), Казан төбәге даругалары (220), Зәй кантоны (459), Зәй өязе (460), Идел буе Болгар дәүләте (920–1236 еллар) (505), Идел-Урал штаты (515).

Районнарның административ карталары.
Зәй районы (426).

## КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н — район
с-з — совхоз
ш. — шәһәр
штп. — шәһәр тибындагы посёлок

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

**Торак пунктлар**

Татарстан Республикасы башкаласы - Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ӘГЕРҖЕ — Шәһәрләр
КАРАБАШ — Шәһәр тибындагы посёлоклар
*Чирмешән* — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гә кадәр
500 дән 1000 гә кадәр
500 дән кимрәк

**Чик билгеләре**

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
1Р 241 — Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
а б — Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар

Елгалар
Сусаклагычлар

### ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2008 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

### ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары
Өязләр

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

## Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

**Археология.** Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Борһанов, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.

**Архитектура.** С.С.Айдаров (рәис), Г.Н.Айдарова, Х.Г.Надыйрова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.

**Астрономия.** Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.

**Биология.** А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов, Р.Х.Фәйзрахманова.

**География.** Ю.П.Переведенцев (рәис), А.Х.Газизуллин, Ю.А.Горшков, Э.П.Наумов, В.А.Рубцов.

**Геология.** Д.К.Нургалиев (рәис), В.М.Винокуров, У.Г.Дистанов, Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Р.Р.Хәсәнов.

**Дәүләт һәм хокук.** В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.

**20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы.** М.Г.Госманов (рәис), И.К.Заһидуллин, И.Л.Измайлов, Ф.Г.Ислаев, Д.Г.Мостафина.

**20—21 йөзләр Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Р.Таһиров (рәис), Р.К.Вәлиев, И.А.Гыйләҗев, Р.Р.Салихов, О.В.Синицын.

**20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты.** Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.К.Ганиева, Р.Ф.Исламов, З.З.Рәмиев, Н.Ш.Хисамов.

**20—21 йөз татар әдәбияты.** Д.Ф.Заһидуллина (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, З.З.Рәмиев, Р.Ф.Рахмани, Р.Г.Фәйзуллин, Р.М.Харисов.

**Икътисад.** Ф.Г.Газизуллин (рәис), В.П.Захаров, В.А.Мальгин, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** В.З.Гарифуллин (рәис), Е.С.Дорощук, Р.М.Нуруллина, Р.А.Ратникова.

**Математика.** М.М.Арсланов, А.М.Елизаров, Д.Х.Мөштәри, Э.В.Скворцов.

**Медицина. Сәламәтлек саклау.** М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, В.Ф.Богоявленский, Я.Г.Павлухин, В.Х.Фазылов.

**Музейлар.** Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, Р.М.Нургалиева, Л.И.Саттарова.

**Музыка.** Р.К.Абдуллин (рәис), В.Н.Горшков, В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.

**Педагогика, халык мәгарифе.** Ә.Н.Хуҗиәхмәтов (рәис), М.М.Гыйбатдинов, Җ.Г.Нигъмәтов, Ф.Ә.Шәрифуллин, И.Э.Ярмәкиев.

**Рус әдәбияты.** А.М.Сәяпова (рәис), Л.С.Ачкасова, В.В.Корчагин, Р.Ә.Мостафин, В.И.Шишкин.

**Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә.** Ш.М.Вәлитов (рәис), И.Ш.Мостюков, Р.З.Рәхимов, И.Ш.Рахманкулов, К.Ф.Фәсхетдинов.

**Сынлы сәнгать.** Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), А.Ә.Абызгилдин, Е.П.Ключевская, З.Ф.Гыймаев, Х.Г.Якупов.

**Театр сәнгате.** А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, Ю.А.Благов, Д.Ә.Гыймранова, И.И.Илялова.

**Тел белеме.** М.З.Зәкиев (рәис), Л.К.Бәйрәмова, И.Б.Бәширова, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Ш.Нуриева, Д.Б.Рамазанова.

**Терлекчелек. Ветеринария.** Р.Г.Госманов (рәис), А.М.Алимов, А.В.Иванов, Н.Н.Мөхәммәтгалиев, К.Х.Папуниди, М.Ш.Шәкүров.

**Техника һәм технология.** Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, Г.Ю.Даутов, И.М.Закиров, С.О.Мирумянц.

**Торак пунктлар тарихы.** М.И.Әхмәтҗанов (рәис), Д.Г.Мостафина, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.

**Үсемлекчелек.** Г.Г.Җиһаншин (рәис), Е.И.Захарова, Ф.З.Кадыйрова, М.Л.Пономарёва, И.П.Таланов.

**Фәлсәфә һәм дин.** Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), В.П.Козлов, Н.М.Мөхәррәмов, Р.Ә.Нәбиев, Р.М.Нугаев, Ф.М.Солтанов.

**Физик культура һәм спорт.** Х.Х.Шәйхетдинов (рәис), Р.А.Абзалов, А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, И.Г.Илдарханов, З.Н.Пантелеева, А.М.Яруллина.

**Физика.** К.М.Салихов (рәис), В.А.Голенищев-Кутузов, А.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев.

**Фольклор.** Ф.И.Урманчеев (рәис), Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов, И.Н.Надыйров .

**Хәрби эшлеклеләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары.** А.А.Иванов (рәис), Н.Х.Булатов, И.И.Мостюков, В.Ф.Телишев, С.Н.Погодин, М.В.Черепанов.

**Химия һәм химия технологиясе.** В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин, Ф.П.Мадякин.

**Этнография.** Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, С.В.Суслова, Р.К.Уразманова, В.И.Яковлев.

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү буенча фәнни мөхәрририят.** М.З.Зәкиев (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Г.Гарипова, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, Р.Ә.Шакирҗанов.

# Татар энциклопедиясе институты

Директоры — филол. фән. д-ры, ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы М.Х.ХӘСӘНОВ
Директор вазифаларын башкаручы — тарих фән. д-ры Р.М.ВӘЛИЕВ
Фәнни эшләр буенча директор урынбасары — тарих фән. канд. Г.С.САБИРҖАНОВ
Гыйльми секретарь — тарих фән. канд. А.И.НОГМАНОВ

## Бүлекләр

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге.** Мөдире — филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: В.Г.Габдрахманова, Л.К.Галиева, Э.А.Гобәев, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, Г.И.Каюмова, И.Г.Нигъмәтҗанов, М.Х.Харисов, Р.И.Хәлиуллина; әдәби мөхәррирләр төркеме: житәкчесе — Ф.Ә.Шәрифуллин; мөхәррирләр: Р.С.Вафина, Г.Х.Нургалиева, И.Х.Хәлиуллин, С.С.Шәмси; корректор Ф.Г.Макарова.

**Биология, география һәм геология бүлеге.** Мөдире — а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән канд. В.Г.Бакирова, геол.-минерал. фән. канд. Э.Х.Рәхмәтуллин, О.В.Ерёгин, Л.Р.Камалиева, Р.Э.Рәхмәтуллин.

**Икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге**. Мөдире — Г.Я.Мәүлетова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: икътисад фән. д-ры Ф.С.Зыятдинов, а.х. фән. д-ры Ә.Х.Фазылҗанов, а.х. фән. канд. Р.Ә.Әсретдинова, икътисад фән. канд. М.Ж.Гаитов, И.Н.Афанасьев, С.Г.Белов.

**Иллюстрацияләр һәм картография бүлеге**. Мөдире — Ф.Ә.Ибраһимова, өлкән фәнни хезмәткәрләр: геогр. фән. канд. Г.Н.Булатова, Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Г.Нурмөхәммәтов; фәнни хезмәткәрләр: Л.Н.Донина, Р.А.Фәсахова; фотограф Р.Н.Шакиров.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәният учреждениеләре бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Р.А.Айнетдинов; өлкән фәнни хезмәткәр — филол. фән. канд. З.З.Гыйләҗев.

**Медицина, сәламәтлек саклау һәм спорт бүлеге**. Мөдире — биол. фән. канд. Р.Г.Исхакова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: пед. фән. канд. Н.Д.Бобырев, Л.Ф.Ильина; фәнни хезмәткәр Ф.Ф.Нуриева.

**Рус телендәге текстларны редакцияләү бүлеге**. Мөдире — пед. фән. канд. И.И.Барабанова; редакторлар: Р.Х.Нуриев, С.А.Ярмөхәммәтова; корректорлар: Ф.Ш.Әхмәтҗанова, В.П.Лащёнова, Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Табигать һәм техник фәннәр бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. Г.Г.Осокина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: физ.-матем. фән. д-ры Р.Г.Усманов, В.Г.Абзалова, Н.Ф.Мироновская, фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

**Тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге.** Мөдире — тарих фән. д-ры Р.В.Шәйдуллин; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. д-ры Е.П.Казаков, тарих фән. канд-тлары Л.М.Айнетдинова, Р.Х.Әхмәтҗанов, Р.Р.Батыршин, И.Р.Вәлиуллин, Е.Б.Долгов, Ф.Г.Кәлимуллина, М.З.Хәбибуллин; өлкән фәнни хезмәткәр А.В.Климин.

**Тел белеме һәм әдәбият бүлеге**. Мөдире — филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. д-рлары Ф.И.Урманчеев, В.Х.Хаков; филол. фән. канд. А.М.Ахунов, Л.Р.Әскәрова, Г.М.Габделхакова.

**Торак пунктлар тарихы бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. А.И.Ногманов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Р.Р.Ибраһимов, Х.Ә.Абдулкаюмов, С.А.Фәйзуллин; фәнни хезмәткәрләр: Э.В.Әбдрәхимова, Д.М.Васильев.

**Мәгариф һәм мәдәният бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Е.П.Липаков; өлкән фәнни хезмәткәрләр: сәнгать фән. д-рлары Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Ф.Ш.Салитова, архит. фән. канд. Х.Г.Надыйрова, Ф.Ә.Әхмәтшина, Ю.А.Благов.

**Фәнни мәгълүмат хезмәте һәм библиография бүлеге**. Мөдире — Р.Ф.Шәрәпова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Э.Г.Сәйфетдинова, Г.Р.Садриева, Э.Т.Сибагатуллина; архив хезмәткәре Л.М.Сәхапова; әйдәп баручы библиографлар: Р.М.Вовченко, Н.Ф.Мироновская.

**Фәнни методика һәм контроль бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. И.Г.Кадошникова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. д-ры Н.Н.Максютова, А.В.Гарзавина, Р.И.Гурьянова, Т.П.Жучкова.

**Фәнни нәшрият бүлеге.** Мөдире — техн. фән. канд. Р.Р.Сәләхиев; программист Г.Х.Галимуллина; компьютерда җыючылар: Л.С.Касимова, Г.Н.Харисова, Л.Р.Хисамиева.

* * *

**Бухгалтерия.** Баш бухгалтер Н.Г.Локманова, бухгалтер-икътисадчы А.Н.Вәлиева.

**Канцелярия мөдире** Г.Р.Вәлиуллина.

**Кадрлар буенча белгеч** Ә.Р.Мөхәммәтҗанова.

**Маркетинг һәм хуҗалык эшләре бүлеге**. Мөдире — Э.А.Гобәев, хуҗалык бүлеге башлыгы Е.Н.Алькова, склад мөдире З.Н.Таҗиева.

## ТЭ 2 нче томының авторлар исемлеге

В.Г.Абзалова, Ш.Ш.Абилов, Г.Д.Аверьянов, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, Л.А.Аксентьев, А.А.Аксянов, Е.П.Алексеева, М.Ш.Алиев, А.М.Алимов, Т.А.Алмазова, Н.С.Альтшулер, О.В.Андреева, М.Д.Анисимова, А.А.Анохин, В.И.Ануфриев, И.Н.Афанасьев, А.М.Ахунов, Ф.И.Әгъзамов, Р.И.Әдһәмов, Р.Г.Әмирханов, А.Г.Әхмәдуллин, М.И.Әхмәтҗанов, Ф.З.Әхмәтҗанов, Л.Р.Әхмәтҗанова, Н.Ш.Әхмәтҗанова, О.В.Бакин, М.Х.Бакиров, В.Г.Бакирова, Н.А.Баныкин, Б.И.Барабанщиков, Р.Р.Батыршин, А.И.Бахтин, М.Ш.Бәдретдинова, Л.К.Бәйрәмова, С.Г.Белов, В.И.Белявский, Е.Е.Беляева, Р.З.Бикбов, Ю.А.Благов, Г.И.Бобкова, В.Ф.Богоявленский, Н.Д.Бобырев, В.А.Бойко, М.Г.Борисович, В.П.Боронин, Ф.Г.Борһанов, Р.А.Борһанова, Р.Г.Бохараев, Б.В.Буров, Ә.Р.Вәлиев, Г.Б.Вәлиев, Р.В.Вәлиев, Р.К.Вәлиев, Р.М.Вәлиев, Ф.З.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева–Сөләйманова, И.Р.Вәлиуллин, О.Г.Вербина, М.А.Верещагин, В.М.Винокуров, П.В.Вишневский, И.Н.Володин, В.Г.Востриков, Р.С.Габәшев, Г.Г.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Г.М.Габделхакова, И.Р.Габдуллин, И.Г.Газизуллин, Р.Г.Газизуллина, И.Р.Газимҗанов, М.Җ.Гаитов, М.В.Гайнетдинов, М.З.Гайнетдинов, Б.М.Галиев, Н.С.Галимов, Г.Х.Галимуллина, Т.Н.Галиуллин, Д.М.Галиуллина, А.Б.Галләмов, Д.М.Гальперин, В.Х.Ганиев, Ф.Ә.Ганиев, Р.К.Ганиева, В.И.Гаранин, А.В.Гарзавина, З.Г.Гарипова, Ф.Г.Гарипова, Р.Г.Гафуров, Р.С.Гәрәев, М.С.Глухов, Г.Ф.Гобәйдуллина, Т.В.Голубцова, С.Г.Гордиенко, М.В.Гордова, О.Л.Горшевникова, В.Н.Горшков, Ю.А.Горшков, М.Г.Госманов, Д.М.Госманова, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, И.Г.Гыйззәтуллин, З.З.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗев, Т.Ш.Гыйләҗев, А.Н.Гыйльманов, О.М.Гыйльметдинова, Х.М.Гыйльфанов, Д.Ә.Гыймранова, Ф.Ф.Даутов, Г.М.Дәүләтшин, А.П.Дедков, Г.А.Денисенко, Е.Б.Долгов, Е.П.Дудырева, В.Р.Дулат-Алиев, Н.Б.Егорова, А.М.Елизаров, М.Г.Елисеева, К.Ф.Ераполов, О.В.Ерёгин, А.Х.Җаббаров, Л.Ш.Җамалетдинов, Ф.Х.Җәүһәрова, А.А.Җиһаншин, Н.Е.Завойская, Р.А.Закиров, Г.Р.Заманова, Д.И.Зарипов, С.А.Захарова, И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, Г.Г.Зәйнуллин, М.З.Зәкиев, Ф.С.Зыятдинов, Р.Р.Ибраһимов, Ф.И.Ибраһимов, М.Й.Ибраһимова, Ф.И.Ибраһимова, А.В.Иванов, А.С.Иванов, В.Б.Иванов, В.М.Иванов, М.И.Иванов, И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова, М.Е.Ильина, А.В.Ильясов, И.И.Илялова, С.И.Ионенко, Н.Ф.Исмәгыйлев, Д.М.Исхаков, С.М.Исхаков, Р.Р.Исхакова, С.М.Исхакова, Р.Х.Йосыпов, Ю.Ю.Йосыпов, Г.Р.Йосыпова, С.И.Кадошников, Е.И.Кадошникова, И.Г.Кадошникова, Е.П.Казаков, Л.Р.Камалиева, В.Д.Капитов, С.Г.Карпов, И.В.Карташова, Р.А.Кашапов, Ф.Г.Кәлимуллина, Х.З.Кәримов, Ә.Г.Кәримуллин, М.В.Киреева, В.Д.Киселёв, А.В.Климин, Е.П.Ключевская, Т.А.Кондратьева, Р.Җ.Корбанов, М.Е.Королёв, А.В.Костерин, А.В.Косточко, М.А.Кострюков, В.В.Костюшко, Б.И.Кочелаев, В.А.Кузнецов, В.Т.Куклин, К.И.Куликов, К.Н.Куранов, Х.Р.Курбатов, В.Н.Куршев, Е.В.Липаков, А.А.Литвин, Г.Л.Лобанов, Е.И.Ломако, А.В.Лукин, О.Д.Любарская, Е.Л.Любарский, Г.М.Макаров, А.Л.Маклыгин, З.Д.Маһиярова, Л.И.Машонкина, М.М.Мәүләтшин, Г.Я.Мәүлетова, М.И.Мәхмүтов, А.Х.Мәхмүтова, Г.З.Минсафин, Н.М.Минһаҗева, К.С.Миңлебаев, Х.Й.Миңнегулов, Җ.С.Миңнуллин, Ф.Ф.Мирзина, К.М.Мирзоев, С.О.Мирумянц, И.М.Мөлеков, Р.Х.Мөслимов, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Х.Мөштәри, В.И.Мозжерин, Ш.Х.Монасыйпов, Л.М.Мортазина, Р.Ә.Мостафин, Ш.С.Мостафин, Д.Г.Мостафина, Л.В.Мошкова, Р.Р.Мусабәкова, Ф.М.Мусин, Х.Г.Надыйрова, Т.М.Насыйров, В.А.Наумов, Э.П.Наумов, К.А.Нәҗипова, И.М.Нестеренко, Г.А.Николаев, И.А.Новицкая, А.И.Новицкий, А.И.Ногманов, Г.Г.Ногманова, Д.Р.Нуретдинова, Г.Г.Нуриев, С.М.Окулова, Г.Е.Осипов, Г.Г.Павлухин, К.Х.Папуниди, Т.В.Пашагина, А.Н.Пашкуров, С.Г.Персова, Н.Г.Петров, С.И.Поляков, Л.Д.Полякова, Д.Б.Рамазанова, А.Р.Рахмани, З.З.Рәмиев, Э.Х.Рәхмәтуллин, Н.Г.Ризванов, Г.С.Сабирҗанов, Р.М.Сабиров, А.Х.Садыйкова, Ф.Ш.Салитова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Салихов, В.В.Самарцев, Е.А.Сапаев, М.Ә.Сәгыйтов, А.М.Сәгыйтова, М.А.Сәйдәшева, Г.Р.Сәйфуллина, Л.М.Свердлова, Р.Х.Сверигин, Л.А.Севастьянова, Ю.В.Сементовский, М.М.Сидорова, И.И.Силкин, Е.И.Синявский, Р.Т.Сиражетдинов, Л.М.Ситдыйкова, А.Э.Скворцов, З.В.Скворцова, З.М.Слепак, О.В.Слепова, Д.Н.Сөләйманова, Р.Р.Солтанова, А.А.Сорокин, В.М.Спиридонова, П.Н.Старостин, Е.А.Стахов, Н.И.Таиров, Ә.С.Тайсин, Р.И.Такташ, И.Р.Таһиров, В.Ф.Телишев, Н.М.Ткачёв, Н.Н.Трофимов, А.А.Турцева, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усманов, Б.В.Успенский, Ә.Х.Фазылҗанов, В.Х.Фазылов, Г.Р.Фәйзрахманова, М.П.Фәйзулаева, И.Н.Фәйзуллин, С.А.Фәйзуллин, Н.Н.Фәрхетдинов, К.Ф.Фәсхетдинов, В.М.Федотов, Н.Л.Фомичёва, В.П.Фролов, С.А.Фролова, В.Х.Хаков, А.Б.Халидов, Н.Х.Халитов, Р.Ф.Халитов, Н.Г.Ханзафаров, К.Г.Харисов, Ф.И.Харисова, А.Ю.Хәбетдинов, Г.Х.Хәбибрахманов, М.З.Хәбибуллин, Ф.С.Хәбибуллина, И.М.Хаертынова, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Р.Хәйретдинов, Җ.Ф.Хәкимова, И.Х.Хәлиуллин, Л.Х.Хәмидуллин, Ф.Р.Хәмидуллин, А.Ә.Хәсәвнех, М.Х.Хәсәнов, Н.Ш.Хисамов, Ф.М.Хисамова, Р.А.Циунчук, Ю.А.Челышев, Т.С.Чудинова, И.З.Чупикова, В.А.Шагалов, Б.Н.Шапуков, Б.К.Шаһиева, Р.Г.Шаһиева, Р.В.Шәйдуллин, С.Шәмси, Р.И.Шәмсутов, Д.Р.Шәрәфетдинов, С.М.Шәфигуллина, В.А.Шевченко, О.Е.Шелковская, А.А.Шинкарёв, А.М.Шихалёв, Н.П.Шулаев, Е.С.Шуликов, А.Б.Юнысова, В.А.Яковлев, А.Г.Яруллина.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, Е.Г.Бычков, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакиров тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, А.Г.Гаянов, В.А.Голенищев-Кутузов, Ф.С.Гобәев, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, А.Л.Яскович, И.В.Яценко архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры музее (Р.И.Такташ), Г.Камал исем. Татар академия театры, В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры музейлары, Казан дәүләт университеты Геология музее, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе фотоархивы фондларыннан алынган фоторәсемнәр һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре А.И.Дубин, Г.В.Фролов коллекцияләреннән алынды.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәргә өчен ТР ФА Президиумына (Ә.М.Мазһаров), ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына (рәисе В.П.Кандилов), ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә (Д.И.Ибраһимов), ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (Н.А.Никифоров), Икътисад (М.Р.Сафиуллин), Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (М.Г.Әхмәтов), Мәгариф һәм фән (А.Х.Гыйльметдинов), Мәдәният (З.Р.Вәлиева), Сәламәтлек саклау (А.З.Фәррахов) министрлыкларына, Казан (Идел буе) федераль университеты (ректоры И.Р.Гафуров), Казан дәүләт консерваториясе (ректоры Р.К.Абдуллин), Казан дәүләт медицина академиясе (ректоры К.Ш.Зыятдинов), Казан дәүләт медицина университеты (ректоры А.С.Созинов), Казан дәүләт техник университеты (ректоры Ю.Ф.Гортышев), Казан дәүләт технология университеты (ректоры Г.С.Дьяконов), Казан дәүләт аграр университеты (ректоры Җ.И.Фәйзрахманов); ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (директоры К.М.Миңнуллин), Тарих институты (директоры Р.С.Хәкимов), Экология проблемалары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану институты (директоры И.А.Ларочкина), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (директоры Е.М.Аксёнов), Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (директоры М.Ш.Таһиров) галимнәренә һәм белгечләренә зур рәхмәтен белдерә.

Төрле вакытта Татар энциклопедиясенең 2 нче томын әзерләүдә: Ф.Т.Арсланова, Ф.З.Вәлиев, Ф.Г.Гарипова, Д.Ә.Гыймранова, В.К.Зыятдинов, А.Х.Мәхмүтова, Г.С.Нуретдинова, Р.Х.Фәйзрахманова, Р.Ф.Халитов, А.И.Хәбибуллина, Л.Х.Хәмидуллин, Ә.М.Хисамова, Р.Ә.Шакирҗанов катнашты.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

Томның материалларын туплауда ТР Милли архивы (директоры Л.В.Горохова), ТР Тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы (директоры В.Г.Хәмидуллина), ТР Аудио-визуаль документлар үзәк дәүләт архивы (директоры С.И.Горохов). Казан университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе (директоры Җ.С.Миңнуллин), ТР Милли китапханәсе (директоры Н.А.Камбеев), ТР Милли музее (директоры Г.Р.Нәҗипова), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее (директоры Р.М.Нургалиева) хезмәткәрләре катнашты.

**Татар энциклопедиясе:** 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Хәсәнов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. — Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2010. — **2 т.**: Г—Й. — 656 бит, илл., карталар.

ISBN 978-5-902375-06-7

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан беренче фәнни универсаль басма. Китапта 3320 мәкалә (1900 биографик), 955 иллюстрация (500 төсле) урын алды.

**Tatar ensiklopediəse:** 6 tomda / Baş məxərrir M.X.Xəsənov, cavaplı məxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: «TR FAneŋ Tatar ensiklopediəse institutı» dəülət uçrejdeniyese, 2010. — **2 т.**: Г—Й. — 656 b., ill., kartalar.

Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannıŋ borıngı zamannardan alıp bezneŋ kənnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal' basma. Tomda 3320 məqalə (1900 şəxeslərgə qarıy), 955 illustratsiə (500 təsle).

**Татар энциклопедиясе**

2 нче том

Китапны компьютерда җыю һәм макетка салу Татар энциклопедиясе институтының фәнни нәшрият бүлегендә башкарылды.

Басарга кул куелды 15.12.2010. Махсус кәгазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 68,9. Нәшер-хисап табагы 123,2.
Заказ Р-7.

«ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.